ТАТАР
ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

БАШ МӨХӘРРИР М.Х. ХӘСӘНОВ

1

А–В

КАЗАН
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ИНСТИТУТЫ
2008

УДК 94(470.41):031
ББК 63.3(2Рос=Тат)2-64 я2
Т 23

ЖАВАПЛЫ МӨХӘРРИР
Г.С.САБИРҖАНОВ

Баш гыйльми мөхәрририят

М.Х.Хәсәнов (рәис), Р.К.Абдуллин, С.С.Айдаров, А.Г.Әхмәдуллин, Б.В.Буров, Р.Г.Бохараев, Н.М.Вәлиев, З.Р.Вәлиева, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, В.З.Гарифуллин, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, А.П.Дедков, М.З.Зәкиев, Г.Г.Җиһаншин, А.А.Җәләлов, Д.М.Исхаков, Е.П.Казаков, В.П.Кандилов, А.Н.Латышев, Ә.М.Мазһаров, Х.Й.Миңнегулов, М.К.Михайлов, Г.С.Сабирҗанов (рәис урынбасары), К.М.Салихов, М.Х.Сәләхов, М.М.Сепперов, Н.А.Сәхибуллин, И.Р.Таһиров, Җ.И.Фәйзрахманов, Р.М.Харисов, Р.С.Хәкимов.

ISBN 978-5-902375-04-5

© «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2008.

«Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында»гы РФ Законы нигезендә саклана.
Китап материалларын Татар энциклопедиясе институтының язма рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

## КЕРЕШ СҮЗ

Күптомлы Татар энциклопедиясе Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевнең 1997 ел, 10 февраль Указы һәм республика хөкүмәте раслаган программа нигезендә ТР ФА-нең Татар энциклопедиясе институты тарафыннан әзерләнә һәм нәшер ителә.

Басма 6 томнан торачак һәм анда 20 меңләп мәкалә урын алачак. Шуларның 8 меңнән артыгы дәүләт, сәясәт, җәмәгать, дин, мәдәният, мәгариф һәм сәламәтлек саклау эшлеклеләренә, күренекле галимнәргә, сәнәгать, авыл хуҗалыгы, төзелеш, элемтә, транспорт, сәүдә, финанс, банк һ.б. хезмәтне оештыручы танылган шәхесләргә, хәрби җитәкчеләргә, атаклы спортчыларга багышлана.

Энциклопедиядә төп урын Татарстанның тарихын, дәүләти-сәяси төзелешен, географик-территориаль чикләрендәге җир-суын, үсемлек һәм хайваннар дөньясын, шәһәр һәм авыллары тарихын, республика халыкларының икътисади, фәнни-техник, мәгариф, сәнгать өлкәсендә ирешкән төп казанышларын яктыртуга бирелә.

Татар энциклопедиясе (ТЭ) – универсаль басма, әмма анда хәзерге заман белемнәренең барлык өлкәсен дә яктырту бурычы куелмый, энциклопедиягә фәкать татар халкы һәм күпмилләтле Татарстан тарихы белән турыдан-туры бәйләнеше булган вакыйгалар һәм фактлар гына сайлап алына.

Әлеге фундаменталь хезмәтне әзерләү барышында бүгенге татар телендәге фәнни төшенчәләр дә игътибар үзәгендә булды. Киң даирә тел белгечләре катнашында фәннең барлык тармаклары, аеруча табигыять, техник фәннәр, сәнәгать өлкәләренә караган терминнарны яңадан системалаштыруда нәтиҗәле эш башкарылды. Шулай ук Татарстан Республикасындагы күп кенә авыллар һәм башка торак пунктлар турында моңарчы матбугатта басылмаган мәгълүмат бирелә, аларның татарча исемнәре тикшерелеп языла, Татарстан Республикасының физик-географик, административ-территориаль бүленеш һәм район карталары беренче тапкыр татар телендә тәкъдим ителә.

Бу хезмәтнең мөһим үзенчәлеге – халкыбызның иң борынгы заманнардан алып бүгенге көнгә кадәрге озын, катлаулы тарихи юлының хәзерге фәнни күзлектән, милләтебезнең социаль тәҗрибәсеннән чыгып эшләнүендә һәм татар телендәге беренче энциклопедик региональ-универсаль басма булуында.

Татар энциклопедиясенең 1 нче томы, рус телендәге вариант нигезендә эшләнсә дә, эчтәлеге һәм күләме буенча аннан аерыла, бигрәк тә шәхесләргә, әдәбият, сәнгать, икътисад, сәнәгатькә, авыл хуҗалыгы, торак пунктларга, район, шәһәр муниципаль берәмлекләренә һ.б.га караган мәкаләләр яңа мәгълүмат б-н тулыландырылды, аңа 300 ләп яңа мәкалә өстәлде.

Әлеге басманы әзерләгәндә Институт коллективы бертомлы «Татар энциклопедиясе сүзлеге»н (Казан, 2002) эшләү тәҗрибәсенә, укучыларның аның эчтәлеген камилләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәренә һәм киңәшләренә таянды.

Бу томны әзерләүдә катнашкан авторлар исемлеге китапның ахырында урнаштырылды.

Мәдәниятебез тарихында мондый җитди хезмәт туган телебездә беренче тәҗрибә булганлыктан, анда җитешсезлекләр очравы да ихтимал. Шуңа күрә Татар энциклопедиясе институты коллективы һәр файдалы тәкъдимне рәхмәт белән кабул итәчәк.

Безнең адрес:
420015. Казан, Пушкин урамы, 56, а/я 190.
тел./факс (843)-238-25-58.
тел. (843)-236-25-61.
E-mail: info-ite@mail.ru

## ЭНЦИКЛОПЕДИЯДӘН НИЧЕК ФАЙДАЛАНЫРГА

Татар энциклопедиясендәге мәкаләләрнең атамалары («кара сүзләр») алфавит тәртибендә урнаштырыла һәм алар берлек санда бирелә, мәсәлән, «АБЫСТА́Й», «АЙ», «БАЛА́Н», «ВЕРТОЛЁТ» һ.б. Атама берлек санда булмаган очракта, әлеге сүзне (терминны) күплек санда эзләргә кирәк, мәсәлән: «АЛЛЕРГЕННА́Р», «АМИНОКИСЛОТАЛА́Р», «АМЁБАЛАР», «КУЗАКЛЫЛА́Р» һ.б. Бер иҗекле һәм «ё» хәрефе кергән сүзләрдән тыш, мәкалә исемендәге һәр сүздә басымлы иҗеккә басым билгесе куела.

Мәкалә исеме итеп аерымланып, кара (калын) шрифт белән басылган терминнарның синонимнары ачык шрифт белән, сирәкләндерелеп — АЮ́ ТАБАНЫ́, а ю к ө п ш ә с е, яисә җәяләр эчендә — АЛТЫ́Н ТӘХЕ́Т (Алтын таш) рәвешендә бирелә.

Мәкалә исемендә башка телләрдән кергән терминнар булган очракта, бу сүзләрнең килеп чыгышы (этимологиясе) буенча кыскача белешмә китерелә. Бер тамырдан булган мәкаләләр исемнәре янәшә килсә, этимологик белешмә бу мәкаләләрнең берсендә генә (кагыйдә буларак, беренчесендә) урнаштырыла.

Чит ил эшлеклеләренең фамилияләре, вакытлы матбугат басмалары, торак пунктлар, географик объектлар һ.б. атамалар җәя эчендә оригиналдагыча китерелә. Бу кагыйдә шулай ук гарәп, латин графикасындагы чит телләрдәге атамаларга да кагыла (борынгы грек атамалары латин алфавитында бирелә), мәсәлән: АЗА́Н (гарәп. أذان — хәбәр салу), АКВАРЕ́ЛЬ (фр. — aquarell), АВТОНО́МИЯ (грек. autonomia — үзидарә, бәйсезлек) һ.б.

1918 елның 1 (14) февраленә кадәрге тарихка кагылышлы вакыйгаларның даталары, кагыйдә буларак, иске (Юлиан) календарь стилендә, башкалары, шулай ук чит илләр тарихына нисбәтлеләре, яңа календарь буенча алына.

Шәхесләргә караган мәкаләләрдә шәхеснең фамилия, исем һәм атасы исеменнән соң җәя эчендә аның туу һәм үлү даталары (көн, ай, ел) һәм урыны күрсәтелә, мәсәлән: ӘМИРХА́Н Фатих (Мөхәммәтфатих) Зариф улы (1.1.1886, Казан — 9.3.1926, шунда ук).

Аерым сүзлекләрдә, ТРның административ-территориаль бүленеше турындагы белешмәлекләрдә торак пунктлар язылышында төрлелек еш очрый. ТРдан читтәге республикаларда һәм өлкәләрдә татарлар күпләп яшәгән торак пунктларның татарча дөрес язылышын билгеләү дә зур кыенлык тудыра. Авторлар коллективы ТРның район һәм шәһәр хакимиятләреннән алынган исемлекләргә, шулай ук район һәм авыл муниципаль берәмлегенең территорияләре чикләрен билгеләү турында Татарстан Дәүләт Советының 2005 елда кабул иткән законнарына һәм карарларына таянып эш итте. Торак пунктларның татарча исеме шул исемлектәгечә бирелде, кайбер очракта, җәяләр эчендә башкача билгеле исем вариантлары да күрсәтелде.

Иллюстрация һәм карталар, нигездә, аларга караган мәкалә эчендә бирелә. Техник сәбәпләр аркасында аерым урнаштырылсалар, аларның урыны күрсәтелә, мәсәлән: илл. (яисә картаны ) 11 биттән кара. Том ахырында карталарның гомуми исемлеге китерелә.

Кирәкле мәгълүматны эзләп табуны җиңеләйтү максатыннан чыгып, энциклопедиядә сылтама-искәрмәләр системасы кулланыла. Текст эчендә нинди дә булса атаманың *курсив* белән җыелуы әлеге сүзгә багышланган аерым мәкалә булуын аңлата. Мәсәлән, «Археология» дигән мәкаләдә *Археологик казу эшләре, Тимер гасыр*, *Татарстанны өйрәнү җәмгыяте* һ.б. сүзләр курсив б-н бирелгән.

Энциклопедиядә шартлы кыскартулар системасы кулланыла. Телебездә гомуми кабул ителгән кыскартулардан тыш (һ.б., ш.у.), әлеге басма өчен махсус кыскартулар да ясалды (том ахырыннан кара). Текстта мәкалә исеме кабатланса, ул «кара сүзнең» исемдәге беренче хәрефләре белән, мәсәлән, «*Алмагач*» — «А.» хәрефе, «*Вәисиләр хәрәкәте*» — «В.х.», «*Бөек Болгар дәүләте*» — «Б.Б.д.» хәрефләре белән белдерелә. Әдәби, музыкаль әсәрләр, фәнни хезмәтләр һ.б. исеменнән соң җәяләр эчендә китерелгән сан — аның иҗат ителү, беренче тапкыр башкарылу яисә басылу елын; бүләк, гыйльми дәрәҗә һ.б. соң җәяләр эчендә куелган сан аларның бирелү вакытын күрсәтә.

ТЭдә кулланылган үлчәү берәмлекләре атамалары һәм аларның билгеләмәләре 1963 елның 1 гыйнварында кабул ителгән Халыкара берәмлекләр системасына туры китереп эшләнде.

Күп кенә мәкаләләрдә һәм кайберләренең ахырында библиография китерелә. Библиографиядә урнаштырылган әсәрләр, кагыйдә буларак, мәкалә текстында кабатланмый.

# А

**АБАГА́ ГӨЛ** (Asplenium), абага гөлчәләр семьялыгыннан абагалар ыругы. 700 гә якын төре билгеле, һәркайда, бигрәк тә тропикларда киң таралган. ТРда сирәк очрый торган бер төре — үрмәле А.г. (A. ruta-muraria). Биектау һәм Лениногорск р-ннарының җилләнгән известьташлы урыннарында очрый. Кыска, шуышма тамырчалы, ике каурыйсыман (җәймәсенең нигезе янында өч каурыйсыман) яфраклы, 3–15 *см* озынлыктагы күпьеллык үләнчел үсемлек. Споралары май–сентябрь айларында өлгерә. Яфракларында вегетатив үрчү өчен яраклы җенессез үрчү бөресе бар. Декоратив максатларда кулланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**АБАГАСЫМАННА́Р**, а б а г а л а р (Polypodiophyta), югары төзелешле споралы үсемлекләр бүлеге. А.ның күпчелеге — күпьеллык үләнчел яисә агаччыл үсемлекләр. 300 ләп ыругы, 12 меңнән артык төре билгеле, бөтен Җир шары буйлап таралганнар. Иң күп төрләре дымлы тропикларда һәм субтропикларда. ТР терр-ясендә 9 семьялык төре очрый: күбаяклылар, тәңкәяфраклылар, елан абагасыманнары, оноклеячәләр һ.б. Урман кырыйларында, чокырларда, сазлы болыннарда, сулы яр буйларында үсәләр. Җир астындагы органнары — өстәмә тамырлар, тамырчалар. Яфраклары каурыйсыман телгәләнгән, үсә башлаганда әкәм-төкәмсыман спиральне хәтерләтә, үсә-үсә ачыла. Яфракларының аскы ягында үрчү органнары — соруслар дип аталучы күч-күч булып җыелган спорангияләр урнашкан, сорусларның формасы һәм урнашуы һәр төр өчен аерым. Яфракның аскы ягында яки кырыйларында урнашкан спорангияләр бер яки күп оялы була. А. вегетатив юл б-н (яфрактагы җенессез үрчү бөреләреннән) һәм тамырча өлешләреннән үрчи. Чәчәк атмыйлар. Куе куаклыклар хасил итәләр, ел саен 1 гектарга 2 *т* га кадәр коры матдә җитештерәләр. А.ның күбесе — декоратив. Кайберләре агулы. Ата абага — дару үләне. А.ның 11 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**АБАЙДУ́ЛЛОВ** Гали Мәгаз улы (15.2.1953, Ленинград), балет артисты, балетмейстер. Ленинград акад. хореография уч-щесен (1971), Мәскәүдәге Театр сәнгате ин-тын (ГИТИС) (1987) тәмамлый. 1971–77 елларда Ленинград консерваториясе каршындагы опера студиясендә балет артисты, Лукас, Коррехидор («Треуголка», М. де Фалья), Шамакай («Шамакайның иртәнге серенадасы», М.Равель) һ.б. партияләр башкара. 1977 дән С.-Петербургның М.П.Мусоргский исем. Опера һәм балет театрында балет солисты. Төп партияләре: Дроссельмеер («Щелкунчик», П.Чайковский), Мисаил («Борис патша», С.Прокофьев), Панталоне («Ике хуҗаның хезмәтчесе», М.Чулаки), Хуҗа («Доненбай кош турында легенда», Ю.Слонимский) һ.б. «Лентелефильм» студиясендә «Иске танго» (1979, Карак), «Анюта» (1982, Модест Алексеевич), «Әзәрбайҗанфильм» студиясендә «Җиде сылу» (1983, Вәзир) фильм-балетларында уйный. «Чаплиниана» фильм-балетында (1987) хореография авторы һәм төп рольләрне (Диктатор, Клоун) башкара. А. үзенчәлекле шаян характерлы рольләрне аеруча уңышлы башкара. РСФСРның бертуган Васильевлар исем. Дәүләт (1984), Халыкара «Бронза роза» (Монтрё ш., Швейцария, 1987) бүләкләре лауреаты.

*Әд.:* К у з о в л е в а Т. Прогулки по Петербургу // Балет. 1993. № 1–2; ш у л  у к. Спектакль и время: от гротеска к трагедии // Балет. 1997. № 2–3.

*Ф.Ш.Салитова.*

**АБАЛА́Ч** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 18 *км* көнбатыштарак, Юраш елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 340 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1781 елда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Убалач исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, Алабуга шәһәрендә сату өчен утын әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.та мәчет, тегермән була. 1920 гә кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Грахов волостена керә. 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсендә; 1921 дән — ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 484, 1887 дә — 992, 1920 дә — 1307, 1926 да — 1387, 1938 дә — 1017, 1949 да — 634, 1958 дә — 516, 1970 тә — 405, 1979 да — 380, 1989 да — 302 кеше.

**АБАЛО́НИН** Борис Ефимович (19.12.1941, Киев ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1990), проф. (1991). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1966). 1969 елдан Бөтенсоюз углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), 1972–2003 тә Казан пед. ун-тының химия кафедрасында, 2003–05 тә Казан энергетика ун-тында эшли. Өч валентлы мышьяк кислоталарының эфирлары рәтендә Арбузов реакциясенә охшаш әверелешләрне тормышка ашыру мөмкинлеген өйрәнә. Алкокси группалары кермәгән дүртенчел арсоний тозларының реакция продуктлары булуын раслый. Өченчел арсиннарның оксидлары, сульфидлары һәм селенидлары рәтендә ретроарбузов реакциясен үткәрә. Мышьяк атомы тирәлегенә, электрофиль реагентның табигатенә, мышьяк-гетероатом бәйләнешенең характерына, реагентларның үзара тәэсир итешү шартларына бәйле рәвештә бу әверелешләр һәм реакцияләрнең гомуми закончалыкларын һәм үзенчәлекләрен таба. Билгеле булган һәм яңа алынган нәтиҗәләрдән чыгып, өйрәнелгән әверелешләрнең гомуми схемаларын тәкъдим итә. 2006 елдан Германиядә яши.

Х е з м.: Продукты взаимодействия эфиров арсинистых кислот с галоидными алкилами // Журн. общей химии. 1970. Т. 40, № 8 (автордаш); Синтез и некоторые свойства арсинселенидов // Журн. общей химии. 1990. Т. 60, вып. 5 (автордаш); Исследования в области арбузовской и ретроарбузовской реакции в ряду органических соединений мышьяка // Успехи химии. 1991. Т. 60, вып. 12; Основы химических производств. М., 2000 (автордаш).

**АБА́Н РАЙОНЫ́**, Красноярск краеның төньяк-көнбатыш өлешендә. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 9,5 мең *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Абан посёлогы (Красноярскидан 309 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 25839 кеше (2002), ш.и. 506 татар (2002), шуларның 230 ы 1913 елда Эстәрлетамак шәһәре (хәзерге Башкортстан Респ-касы) тирәсеннән күчеп килүчеләр нигез салган Эстәрлетамак авылында яши. Авыл мәдәният йорты каршында фольклор ансамбле эшли.

**АБА́ШЕВ** Рәшит Җәләлетдин улы (27.3.1951, Киров өлкәсенең Слободской р-ны Карино а.), терапевт, ТРның һәм РФнең атказ. табибе (1996, 2006), мед. фән. канд. (1999). 1977 елда Казан. мед. ин-тын тәмамлый. 1979–86 да Лениногорск р-нындагы «Бәкер» курортында һәм 1986–94 тә Лениногорск шәһәренең үзәк хастаханәсендә баш табиб булып эшли, 1994 тән Республика мед. диагностика үзәге (2000 нән Республиканың 2 нче клиник хастаханәсе, Казан) баш табибе. Хезмәтләре вертеброневрологиягә: умырткa авыруларына диагноз кую һәм дәвалау, нейромиофиброз вакытында алгик тригер зоналар формалашу механизмнарындагы нейротрофик контрольнең бозылуы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Республиканский медицинский диагностический центр: Концептуальные перспективы развития // Казан. мед. журн. 1996, № 3; Периартикулярные проявления вертеброгенной гониалгии. К., 1999.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**АБА́ШЕВО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), бронза гасырда (б.э.к. 2 меңьеллыкның 2–3 чирекләре) урман-далалы Дон, Урта Идел һәм Көньяк Урал буйларында яшәүчеләргә нисбәтле археологик культура. Беренче тапкыр 1925 елда В.Ф.Смолин тарафыннан тасвирлана, атамасы Чуаш Респ-касы Абашево авылы янында табылган борынгы каберлеккә бәйле рәвештә бирелә. 1950–70 елларда А.к.

истәлекләре К.В.Сальников, Н.Я.Мерперт, А.Д.Пряхин, А.Х.Халиков һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Алар А.к.ның берничә җирле төрен — Баланбаш (Урал), Дон-Идел, Урта Идел һ.б. бүлеп чыгаралар. А.к. халкы Һинд-Европа (Һинд-Иран) тел берлеге кабиләләренә карый дип фараз ителә. Халкы нигездә терлек асрау, аучылык, балык тоту б-н шөгыльләнгән, игенчелек ярдәмче роль уйнаган. Алар бронза коя белгән (бронза балталар, сөңге очлыклары, хәнҗәр, пычак, урак, бизәнү әйберләре һ.б. табыла), арбалардан файдаланган. А.к.на балчыктан ясалган түгәрәк һәм яссы төпле, кыңгырау һәм банка рәвешендәге, тарак теше эзе сыман һәм сырлар төшерелгән бизәкле савыт-сабалар хас. А.к. кабиләләре бер рәт булып төзелгән киң һәм озын агач торакларда яшәгән. Мәетләр чокырларга күмелгән, каберләр өстенә курганнар өелгән. Башы б-н көнчыгышка каратып салынган



Абашево культурасы. Такталачык каберлегендә табылган керәч савытлар. ТР ФА Тарих ин-тының Милли археол. тикшеренүләр үзәге фонды.

мәетләрнең баш очына савытлар куелган. Татарстан терр-ясендә А.к. истәлекләре Яшел Үзән р-нының Бәчек, Карашәм, Югары Ослан р-нының Йолдыз, Актаныш р-нының Такталачык авыллары янында табыла.

*Әд.:* Халиков А.Х. Памятники абашевской культуры в Марийской АССР // Материалы и исследования по археологии СССР. 1961. № 97; Сальников К.В. Очерки древней истории Южного Урала. М., 1967; Пряхин А.Д. Абашевская культура в Подонье. Воронеж, 1971; Казаков Е.П. Памятники черкаскульской культуры в восточных районах Татарии // Советская археология. 1979. № 1.

*Е.П.Казаков.*

**АББА́СОВ** Азат Зиннәт улы (19.1.1925, Алабуга ш. — 11.10.2006, Казан), җырчы (лирик-драматик тенор), СССРның халык артисты (1977). Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен тәмамлый (1950). Беренче тапкыр Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә Трике («Евгений Онегин», П.Чайковский) партиясен башкара; 1950–90 елларда театрның әйдәп баручы солистларыннан берсе. Ул Көнбатыш Европа, рус классиклары һәм хәзерге заман композиторларының операларында, опереттaларында, муз. комедияләрендә үзен героик-эпик, фаҗигале рухтагы партияләрне башкарырга сәләтле җырчы итеп таныта. Йөздән артык опера партиясендә: Фауст («Фауст», Ш.Гуно), Ричард («Бал-маскарад», Дж.Верди), Рудольф, Каварадосси, Пинкертон («Богема», «Тоска», «Чио-Чио-Сан», Дж.Пуччини), Самозванец («Борис Годунов», М.Мусоргский), Синодал («Демон», А.Рубинштейн), Андрей



А.З. Аббасов.

(«Тарас гаиләсе», Д.Кабалевский), Алексей («Оптимистик трагедия», А.Холминов), Сергей («Катерина Измайлова», Д.Шостакович) һ.б. образлар тудыра. И.Штраусның «Яркaнат» һәм «Чегән бароны», Ф.Лоуның «Гүзәл ханым минем», К.Листовның «Севастополь вальсы», Р.Гаджиевның «Ромео — минем күршем» оперетта һәм мюзиклларында баш рольләрне башкара. Татар композиторларының «Алтынчәч», «Җәлил», «Түләк һәм Сусылу» (Н.Җиһанов), «Самат» (Х.Вәлиуллин), «Башмагым» (Җ.Фәйзи) әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә төп партияләрне башкарып, милли муз. сәхнә сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертә. 1955–62 дә А. Татар акад. театры сәхнәсендә К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (С.Сәйдәшев муз.) спектаклендә Булат ролен зур уңыш б-н башкара. Актив рәвештә концерт эшчәнлеге алып бара, татар композиторлары С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, А.Ключарёв һ.б.ларның вокаль әсәрләрен радио, телевидениедән башкара. А. — кабатланмас матур тембрлы тавышка ия җырчы; вокаль һәм актёрлык осталыкларын органик куша белүе б-н башкару культурасының югары баскычына күтәрелә. «Татарстан» ДТРК фондларында аның башкаруында йөздән артык язма саклана.

*Әд.:* Бикчурина Ф. Бәхет китерүче осталык: А.Аббасовка 60 яшь // Казан утлары. 1985. № 1; Народные артисты. К., 1980; Полежаева Е. Небо! Небо! // Театр. жизнь. 1964. № 16; Ванслов В. Пробиваясь сквозь тьму // Театр. жизнь. 1965. № 11; Аббасов Азад Зиннатович // Музыкальная энцикл. М., 1973. Т. 1.

**АББА́СОВ** (Габбасов) Габделәхәт Гомәр улы (30.9.1929, Түбән Новгород өлкәсенең Пилнә р-ны Яңа Мөчәләй а. — 11.8.1996, Мәскәү), контр-адмирал (1983), Сов. Союзы Герое (16.12.1981). Югары хәрби-диңгез уч-щесен (1954, Ленинград), Хәрби-диңгез академиясен (1968, Ленинград) тәмамлый. 1950 елдан СССР Хәрби диңгез флотында. 1962–83 тә Төньяк флотта: атом су асты көймәсе, 1980 нән хәрби часть командиры. 1983–88 дә СССР Хәрби диңгез флотының хәрби әзерлек үзәгендә бүлек җитәкчесе. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Г.Г. Аббасов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Герои Советского Союза: Краткий биографический словарь. М., 1987. Т. 1.

**АББРЕВИАТУ́РА** (итал. abbreviatura, лат. abbrevia — кыскартам, кисәм), катлаулы сүзнең яки сүзтезмәнең башлангыч хәрефләреннән яисә иҗекләреннән ясалган сүз; кайвакыт А.ның соңгы компоненты кыскартылмаска да мөмкин. Сүз ясау ысулы буларак кыска атамалар барлыкка китерү өчен кулланыла. Европа телләрендә А. бигрәк тә 20 йөздә, рус телендә — Октябрь рев-циясеннән соң киң таралыш ала. Татар телендә 1990 елларга кадәр, башлыча, рус А.сы гамәлдә була: ВДНХ, ТАСС, ВЛКСМ һ.б. Шул ук вакытта татар теленең үз А.лары да барлыкка килә: АКШ, БМО, КДУ, ГФР һ.б. 1990 елларда татар телендә А.лар ясалу тенденциясе көчәя: КДПУ (Казан дәүләт педагогика университеты), ЮХИДИ (Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе) һ.б.

А. ике төрле ысул б-н — инициаллардан һәм сүз элементларыннан ясала. Инициаллардан торган сүзләр өч төргә бүленә: 1) сүзнең баш хәрефләрен ялгау юлы б-н ясалган А. (ТИҮ — Татар иҗтимагый үзәге; 2) сүзнең башлангыч авазларыннан торган А. (АКШ — Америка Кушма Штатлары; 3) сүзнең баш хәрефләрен һәм авазларын ялгау юлы белән ясалган А. (ТРТ — ТэәРТэ — Татарстан Республикасы телевидениесе, РФ — Россия Федерациясе). Сүз элементларын кушып ясалган А. ике төргә аерыла: 1) сүзләрнең беренче иҗекләрен ялгау юлы б-н ясалган А. (райком — район комитеты; 2) беренче сүзнең беренче иҗеге һәм икенче сүз тулысы б-н

А.З. Аббасов: 1. Түләк («Түләк һәм Сусылу», Н.Җиһанов); 2. Кенәз Шуйский («Борис Годунов», М.Мусоргский); 3. Ричард («Бал-маскарад», Дж.Верди) рольләрендә.











алынган А. (драмтүгәрәк, ветврач, телестудия). Аларны ш.у. кыскартылган кушма сүзләр дип тә атыйлар.

*Әд.:* Татар грамматикасы: 3 томда. М.–К., 1998. Т. 1; Большой энциклопедический словарь: Языкознание. М., 1998.

**АБДАЛЛА́Һ** бине Тәкин, к. *Сәлки* (Шилки).

**АБДЕРӘШИ́ТОВ** Шамил Монасыйп улы (19.5.1921, Оренбург ш. — 4.5.1944, Кырым АССР, Херсонес ш.), Сов. Союзы Герое (2.8.1944, вафатыннан соң), лейтенант (1943). Оренбург хәрби авиация уч-щесен тәмамлый (1941). 1943 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 402 нче истребительләр авиация полкының эскадрилья командиры урынбасары (8 нче һава армиясенең 265 нче истребительләр авиация дивизиясе). 4 нче Украина фронты гаскәрләре составында Одесса, Севастополь, Новороссийскины һәм Кырым ярымутравын азат итү сугышларында катнаша. 160 тан артык сугышчан очыш ясый, 17 һава сугышында катнаша, дошманның 12 самолётын юк итә. Кырымны азат итү сугышында һәлак була. Ленин, Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Оренбуржцы в боях за родину. Челябинск, 1978; Герои твои, Херсонщина. Симферополь, 1980.

**АБДЕ́РШИН** Алимкәй Абдулла улы (25.5.1911, хәзерге Мордва Респ-касының Ковылкин р-ны Иске Аллагол а. — 26.5.1983, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), старшина (1944). 1933–35 елларда һәм 1941 нең июненнән Кызыл Армиядә. 1936 дан Мәскәү сәнәгать пр-тиеләрендә эшли. 1943 тән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 38 нче армиянең 180 нче укчы дивизиянең автоматчылар ротасы отделениесе командиры (86 нчы укчы полк). Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Украина, Венгрия, Румыния һәм Чехословакияне азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 30 сентябрендә Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә. Ленин, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Сугыштан соң Мәскәүдә яши.


*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои огненных лет. М., 1978. Кн. 3; Геройская быль. Саранск, 1985.

**АБДЕ́РШИН** Рамил Хәйрулла улы (1925, Оренбург өлкәсенең хәзерге Шарлык р-ны Яңа Муса а. — 8.11.1943), Сов. Союзы Герое (17.11.1943, вафатыннан соң), сержант (1943). Каттакурган шәһәрендә (Үзбәкстан ССРның Сәмәркand өлкәсе) мәктәптә укыта. 1943 елның февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче гв. танк армиясенең 69 нчы механикалаштырылган бригадасы мотоукчылар батальонында отделение командиры. 1943 тә Дала фронты составында Курск тирәсендәге сугышта катнаша. Черкасск өлкәсе Канев р-нының Зарубинцы авылы янында Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә (1943 нең 22 сент.). Сугышта һәлак була. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Салахутдинов Ф., Хасанов М., Косько М. Звёзды Самарканда. Таш., 1968; Таджибаев Х.Н. Мужество. М., 1977; Шёл парнишке в ту пору... Киев, 1985.



Ш.М. Абдерәшитов.



А.А. Абдершин.



Р.Х. Абдершин.



А.К. Абдрахманов.

**АБДРАХМА́НОВ** Альберт Габделхәй улы (20.7.1941, Казан), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1987). 1969 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1965–70 тә Идел буе гражданлык авиациясе идарәсенең Казан берләшкән авиаотрядында элемтә инженеры, смена башлыгы. 1970–75 тә ГНИПИ-ВТда фәнни-тикшеренү эшендә. 1975–94 тә КПО ВСта: махсус КБда бүлек башлыгы, баш инженер, 1987 дән заводның баш инженеры, 1989 дан ген. директор урынбасары. 1994–95 тә «Алга-Интер» консорциумы ген. директоры, 1995–97 дә Казан шәһәре «Олимп» үзәк сәүдә йорты директоры. 1997–98 дә ТР Дәүләт мөлкәте б-н идарә итү дәүләт ком-тының сәнәгать департаменты идарәсе башлыгы. 1998–2003 тә ТРның Икътисад һәм сәнәгать министрлыгында сәнәгатьне икътисади анализлау һәм мәгълүмат туплау бүлеге башлыгы. Электрон-хисаплау машиналарының Бердәм системасы базасындагы ЕС 1033, ЕС 1045, ЕС 1046, ЕС 1007 системаларын, мәгълүматларны телеэшкәртүче ЕС 8375 процессорын үзләштерүдә катнаша. Бу системалар сәнәгатьтә, фән, мәгариф һәм хәрби сәнәгать комплексында исәпләү техникасының нигезен тәшкил итә. СССР Дәүләт бүләге соц. илләрдәге электрон-хисаплау машиналарының Бердәм системасы өчен операцион системалар төзегән, үзләштергән һәм гамәлгә керткән өчен бирелә. СССР ВДНХсының алтын, көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Хезм.: Электронная вычислительная машина ЕС 1033. М., 1982 (автордаш).


**АБДРАХМА́НОВ** Асаф Котдус улы (20.12.1918, Вятка губ., Сарапул өязе Әгерҗе а.- 3.9.2000, Севастополь ш.), Сов. Союзы Герое (22.1.1944), 1 нче ранг капитан (1973). 1939 елдан Кызыл Армиядә. Севастополь югары хәрби диңгез уч-щесен тәмамлый (1942). 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, Кара диңгез флоты Азов хәрби флотилиясенең 1 нче гв. бронекатерлар дивизионы бронекатер командиры. Севастополь шәһәрен, Керчь ярымутравын, Югославия, Венгрия, Чехословакия, Австрияне азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең ноябрендә Керчь ярымутравы өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң СССР Хәрби диңгез флотында җитәкчелек вазифаларын башкара. 1973 тән отставкада. Ленин, ике Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои боёв за Крым. Симферополь, 1972; Герои Советского Союза Военно-Морского флота 1937–1945. М., 1977.

**АБДРАХМА́НОВ** Васил Рәүф улы (3.10.1939, Зәй р-ны Кәрәкәс а.), кардиолог, мед. фән. д-ры (1986), проф. (1992). 1963 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1965 тән Казандагы мед. оешмаларында табиб. 1970 тән СССР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Баш идарәнең Үзәк фәнни-тикшеренү лабораториясендә (Мәскәү); 1990 нан Мәскәү мед. стоматология ин-тының ашыгыч һәм кичектергесез ярдәм күрсәтү каф. профессоры. Хезмәтләре кичектергесез кардиологиягә, кичектергесез ярдәм вакытында тын алу функциясенә, ашыгыч ярдәм итүгә, табибләрне дипломнан соң әзерләүне оптимальләштерүгә карый. «Кичектергесез кардиологиядә тын алуның кыенлашуы» («Дыхательная недостаточность в неотложной кардиологии», М., 1979) монографиясе өчен СССР МФАнең Г.Ф.Ланге дипломы б-н бүләкләнә (1981).

**АБДРАХМА́НОВ** Габдерәшит Солтан улы (24.12.1936, Куйбышев өлкәсенең Мәләкәс ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (1990), проф. (1992), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Мәскәү нефтехимия һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1964). 1957 елдан ТатНИПИнефтьтә эшли: 1969 дан сектор, 1986 дан скважиналар бораулаудагы катлауланулар б-н көрәшү лаб.; 1991 дән скважиналарны локаль ныгыту, 1997 дән скважиналар төзү техникасы һәм технологиясе бүлекләре мөдире, 2004 тән «Татнефть-Регионнар» АҖ (Әлмәт) баш белгече. Халыкара күләмдә беренчеләрдән булып локаль ныгыту һәм катламны аеру ысулын куллана һәм гадиләштерелгән конструкцияле скважиналар төзү мөмкинлеген исбатлый. Аның эзләнүләре һәм тикшеренүләре нигезендә скважиналар төзү процессында энергия һәм материал сыйдырышлылыгын киметүнең конкрет мәсьәләләре хәл ителә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Хезм.: Бурение нефтяных и газовых скважин: Учеб. М., 1969 (автордаш); Isolation profile liner helps stabilize problem well bores // Oil & Gas Journal. Week of September 2. 1995.



Х.Х. Абдрахманов.

**АБДРАХМА́НОВ** Идрис Сабир улы (12.2.1943, Бөгелмә ш.), төзелеш инженеры, ТРның атказ. төзүчесе (1997). Хезмәт эшчәнлеген 1958 елда «Татнефтепроект» ин-тында башлый. Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), «Калининстрой» трестының 15 нче төзү-монтаж идарәсендә прораб, планлаштыру-производство бүлеге башлыгы булып эшли. 1973 тән Казанда: «Татремстрой» тресты төзү-монтаж идарәсендә баш инженер, «Казаньхимстрой» трестында техника бүлеген җитәкли. 1975–85 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты аппаратында. 1985–2001 дә ТР Министрлар Кабинетының «Татинвестгражданпроект» фирмасы президенты, 2001 дән фирма президентының фәнни эшләр буенча урынбасары. Ул елларда фирмада мәгълүмат-исәпләү һәм автоматлаштырылган планлаштыру системалары кертелә, Татарстанның Мәскәүдәге вәкиллеге бинасын (1996), *Казан тимер юл вокзалын* (1997), Спорт сараен (1998) үзгәртеп кору, *Колшәриф мәчетен* төзү (1998), Түбән Кама, Әлмәт, Алабуга, Яшел Үзән, Менделеев һ.б. шәһәрләрдә төрле корылмалар төзү проектлары эшләнә.

**АБДРАХМАНО́В** Кадыйр Габделхак улы (4.9.1896, Сембер ш. — 1990, Казан), сәясәт эшлеклесе. Сембер гимназиясен (1917), Тышкы сәүдә академиясен (1933, Мәскәү) тәмамлый. 1918 елдан РКП(б) әгъзасы, РКП(б)ның Сембер губкомында мөселманнар секциясен оештыруда катнаша. Губерна башкарма ком-тында милләтләр бүлеге секретаре һәм мөдир урынбасары. 1919 да Икенче аерым Идел буе татар укчылары бригадасында сәяси бүлек башлыгы, РКП(б)ның Казан губкомында мөселманнар секциясе бюросы секретаре, Сембер хәрби-революцион трибуналында рәис урынбасары. ТАССРны оештыру комиссиясе әгъзасы (1919, ноябрь). 1920–21 дә Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы секретаре, Лазарев исем. Көнчыгыш телләре ин-ты комиссары (Мәскәү). 1921–23 тә Төркиядә дипломатик эштә. 1923–31 дә Әзәрбайҗан, Казакъстан, Грузия респ-каларында партия эшендә. 1931 дән СССР МС каршындагы Главлит оешмасының Җиңел сәнәгать үзәк нәшриятындагы вәкиле, 1933 тән шул нәшриятның директор урынбасары. 1938 елдан СССР ФА нәшрияты мөхәррире, Тышкы сәүдә халык комис-тының Көнчыгыш идарәсе өлкән консультанты, «Международная книга» сәүдә конторасы (Мәскәү) директоры урынбасары. 1942–46 елларда Алма-Атада партия эшендә. 1946–48 дә Грузия ССРның Сәүдә министрлыгы эксперты.

*Әд.:* Сайдашева М. Абдрахманов К.А. // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

**АБДРАХМА́НОВ** Мансур Ибраһим улы (31.1.1912, Казан — 25.12.1972, шунда ук), философ, филос. фән. д-ры (1959), проф. (1959), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1968). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1940). Совет-фин (1939–40) һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1944 елдан Казан ун-тында марксизм-ленинизм каф. укытучысы, 1950–53 тә тарих-филология ф-ты деканы, 1956 дан диалектик һәм тарихи материализм каф. мөдире, бер үк вакытта, 1958–65 тә проректор. Хезмәтләре социаль фәлсәфә, КПССның Татарстан өлкә ком-ты тарихына карый. 1963–71 дә ТАССР ЮС депутаты, 1963–67 дә ТАССР ЮС рәисе.

Хезм.: Диалектик материализм. К., 1966; О роли социалистических производственных отношений в развитии производительных сил. К., 1957.

**АБДРАХМА́НОВ** Мәхмүд (18 йөз), педагог, ахун. 1739 елда Самара шәһәрендә ачылган *Татар-калмык мәктәбендә* татар, төрек, гарәп телләре укыта. П.И.Рычков инициативасы б-н эшләнә башлаган «Рус-татар-калмык сүзлеге»н (нәшер ителмәгән; кульязмасы РФА китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана) төзүдә катнаша.

*Әд.:* Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1974.

**АБДРАХМА́НОВ** Равил Салих улы (31.10.1939, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1994), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1962), СССР ФАнең Казан филиалы Физика-техника ин-тында эшли. 1988 елдан Казан энергетика ун-тында, 1989 дан электр станцияләре каф. профессоры, электроэнергетика ф-ты деканы (1995–2004). Хезмәтләре конденсацияләнгән мохит радиоспектроскопиясенә һәм гадәти булмаган энергетикага, пыяласыман матдәләрнең арадаш төркемнәргә кергән элементлар ионнарының структур үзенчәлекләрен ЭПР ысулы б-н гомуми тикшерүгә карый. Урта Идел буе климаты шартларында гадәти булмаган энергетиканың техник системалары бирә алган электр энергиясен бәяли (Ю.Г.Нәҗмиев б-н берлектә). РФнең мактаулы югары һөнәри мәктәп хезмәткәре (2006).

Хезм.: Об определении параметров тонкой структуры спектров ЭПР Сч$^{III}$ в стеклообразных средах // Физика и химия стекла. 1977. Т.3, вып. 6 (автордаш); Исследование ранней кристаллизации стёкол системы $K_2O$-MgO-$AL_2O_3$-$B_2O_3$-$SiO_2$-F методом ЭПР // Физика и химия стекла. 1985. Т. 2, вып. 2 (автордаш); Возобновляемые источники энергии. К., 1992 (автордаш); Использование энергии ветра для выработки электроэнергии в Татарстане // Изв. РАН. Энергетика. 1998. № 4 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**АБДРАХМА́НОВ** Рәсим Миңрахман улы (2.4.1958, Кукмара пос.), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (2002), 1981 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1982–97 елларда Чаллы шәһәренең тире-венерология авырулары диспансеры табибе, 1997 дән Казан мед. академиясендә. Хезмәтләре а.х. производствосында һөнәри тире авыруларын дәвалауга карый. А. тарафыннан шиннар җитештерү шартларында тире авырулары барлыкка килүе тикшерелә. Шиннар һәм а.х. продуктларын җитештерү шартларында тиредә үзгәрешләр башлану сәбәпләре ачыклана, тире авыруларын киметү буенча методик киңәшләр эшләнә һәм гамәлгә кертелә.

Хезм.: Профессиональные дерматозы в шинном производстве. К., 1996; Производственно-обусловленные дерматозы в сельском хозяйстве. К., 2000.

**АБДРАХМА́НОВ** Ринат Кадыйр улы (1.5.1951, Лаеш р-ны Атабай а.), а.х. механикалаштыру гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2002), проф. (2004), ТРның атказ. а.х. механизаторы (2001). А.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), «Кызыл Йолдыз» хуҗалыгында (Лаеш р-ны Пәрәү а.) баш инженер булып эшли. 1975–84 елларда — Казан а.х. ин-тында хезмәтне саклау һәм өйрәтү паркы (1975–78), 1985 тән — Автомобиль транспортының автоматик идарә системаларын фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тында сектор, 1988–90 да — «Орлыкчылык» фәнни-җитештерү берләшмәсендә механикалаштыру бүлегенең сектор мөдире. 1990 нан Казан а.х. академиясендә укыта, энергия ресурсларын саклау кафедрасын оештыручы һәм мөдире (2004). Хезмәтләре а.х. җитештерүен комплекслы механикалаштыруга карый. Төбәктә бәрәңге игү технологиясен, колорадо коңгызына каршы көрәшнең механик ысулын тәкъдим итә. Сызма культураларны эшкәртү өчен эшче механизмнары әйләнмәле чәчү машиналары төзи (ТР хуҗалыкларында гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Хезм.: Пропашной культиватор с комбинированными рабочими органами // Земледелие. 1982. № 10 (автордаш); Анализ состояния производства картофеля в РТ и пути повышения его эффективности. К., 1997; Актуальные вопросы механизации сельскохозяйственного производства // Машины и орудия для междурядной обработки почвы (конструкция, теория, расчёт, эксплуатация). К., 2001; Колебания ротационного рабочего органа при наличии люфта в узле крепления // Тракторы и сельскохозяйственные машины. 2004. № 8 (автордаш).

**АБДРАХМА́НОВ** Хәниф Хаҗигали улы (25.12.1925, Башкортстан Респ-касының Әлшәй р-ны Үрнәк а. — 23.4.1999, Уфа ш.), Дан орденының тулы кавалеры (28.6.1944, 12.4.1945, 27.2.1958), капитан. 1943 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең июненнән 50 нче армиянең 139 нчы укчы дивизия 609 нчы укчы полкның разведка бүлегендә орудие командиры. Үзәк һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Могилёв (1944), Минск (1944), Белосток (1944) операцияләрендә, Польшаны азат итүдә катнаша. 1944 нең 26 июнендә Горбовичи торак пункты (Могилёв өлкәсе), 1944 нең 17 июлендә Погараны авылы (Белосток өлкәсе) янында барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә: төгәл ут ачып, дошман орудиесен юк итә; 1945 нең февралендә Тухель торак пунктыннан көнчыгыштарак (хәзерге Тухоль, Польша) барган бәрелештә дошманның ут ноктасын юк итә һәм аның күзәтү пунктын кулга төшерә. Сугыштан соң Башкорт пед. ин-тын (1950) тә-

мамлый, Уфа шәһәрендә укыта. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ерошин А.Е. Солдатская слава. Уфа, 1967; шул ук. Не ради славы. М., 1969; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1985. Кн. 5; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**АБДРАХМА́НОВА** (Габдрахманова) Ләйлә Габдулла кызы (3.10.1949, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1997), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). РФнең мактаулы югары һөнәри мәктәп хезмәткәре (2001). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында. 1974 елдан Казан архитектура-төзелеш ун-тында, төзелеш материаллары һәм конструкцияләре технологиясе каф. профессоры (1997 дән). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә карый. Полимер өслекләрен диффузия ярдәмендә модификацияләү буенча фәнни юнәлеш уйлап таба. Олигомерлар нигезендә поливинилхлорид өчен тотрыклыландыру системалары, органоминераль тоташтыргычлар (бәйләгечләр) һәм үсемлек чималлары нигезендә җылылык үткәрми торган материаллар, ш. у. полимер композицияләр һәм полимер-олигомер материаллар тәкъдим итә. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Хезм.: Модификация свойств ПВХ новыми эпоксиуреновыми олигомерами // Изв. вузов СССР. Химия и хим. технология. 1977. Вып. 5 (автордаш); Каркасно-волокнистые композиции для теплоизоляции в строительстве // Изв. вузов. Строительство. 1999 Вып. 8 (автордаш); Диффузионная модификация наполненных эпоксидных полимеров // Изв. вузов. Строительство. 2001. Вып. 9 (автордаш).

**АБДРАХМА́НОВА** Рәйсә Шәрәфетдин кызы (22.5.1923, Чиләбе ш.), терапевт, мед. фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1980). 1949 елда РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгының Мәскәү мед. ин-тын тәмамлый. 1951 дән Казан мед. ун-тында, 1971–82 дә факультет терапиясе каф. мөдире, 1983 тән эчке авырулар каф. профессоры. Ә.Г.Терегулов шәкерте. Төп хезмәтләре функциональ пульмонология, ревматология, специфик булмаган хроник үпкә авырулары вакытында тышкы сулыш функцияләрен тикшерүгә карый. Казандагы «Медфизприбор» махсус конструкторлык-техник бюросы галимнәре б-н берлектә Мета 1–25Б, «Татарстан», ЩМ-1, ЩМ-2, АЗИВ-1, АКОР-1, диффузиометр һ.б. аппаратлар эшли һәм гамәлгә кертә. ТР Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында ревматология хезмәтенең фәнни-гамәли һәм оештыру аспектлары» («Научно-практические и организационные аспекты ревматологической службы в Республике Татарстан») дигән хезмәте өчен бирелә (2000).

Хезм.: Нервно-сосудистые реакции у больных с ревматизмом по данным плетизмографических исследований и гистаминовой пробы. К., 1956; Клинико-физиологическое обоснование комплексной терапии больных с хроническими неспецифическими заболеваниями лёгких. К., 1970.

*Әд.:* Профессор Раиса Шарафутдиновна Абдрахманова // Казан. мед. журн. 1983. № 5.

**АБДУ́** (Габдөһ) Мөхәммәд (1849 — 1905), Мисырның дин белгече, мөселман ислахчылыгы идеологы, җәмәгать эшлеклесе. Җамалетдин әл-Әфгани шәкерте һәм фикердәше. 1883 елда хөкүмәткә каршы күтәрелештә катнашкан өчен Мисырдан сөрелә. 1884 тә Парижда әл-Әфгани б-н «әл-Урва әл-вуска» («Якын бәйләнеш») дигән яшерен оешма төзиләр, шул ук исем б-н мөселман зыялыларына зур йогынты ясаган газета нәшер итәләр. 1899 дан Мисырның баш мөфтие. *әл-Әзһарда* белем бирү системасын үзгәртеп кора. Мөселман закон чыгару һәм мәхкәмә системасын үзгәртеп кору тәкъдиме б-н чыга; мөселманнарга банкларга кертемнәр ясарга һәм алардан процент алырга рөхсәт итүче *фәтвә* бирә. А. башында төрек солтаны торган ислам илләре конфедерациясе сыйфатындагы мөселман хәлифәлеген торгызырга чакыра. Соңгырак чордагы дини авторитетларга иярүне (*тәкълид*) кире кага, аларга *иҗтиһад*ны каршы куя. А. фикеренчә, һәр тарихи дәвердә Коръәнне шул заман таләпләренә җавап бирерлек итеп аңлату зарур. А. идеяләре һәм хезмәтләре татар фикер ияләре арасында да (М.Бигиев, З.Кадыйри, З.Камали һ.б.) тарафдарлар таба.

*Әд.:* Баттал Г. Ислам философлары Мөхәммәт Габдөһ вә Җамалетдин Әфгани. К., 1908; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**АБДУ́Л САЛМАНЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 17 *км* көнбатыштарак. Салман суының югары агымы буенда. 2002 елда 63 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — ит өчен терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.С.нда мәчет, мәктәп, 2 бакалея кибете эшли. 1920 гә кадәр А.С. Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 211, 1897 дә — 255, 1908 дә — 290, 1921 дә — 266, 1926 да — 182, 1938 дә — 236, 1949 да — 255, 1958 дә — 189, 1970 тә — 240, 1979 да — 216, 1989 да — 75 кеше.

**АБДУ́ЛИН РАЙОНЫ́,** *Оренбург өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә (1934 елның 7 ноябреннән). 1925 нең 14 маенда оештырыла. Мәйданы — 1738 *км²*. Үзәге — Абдулино шәһәре (Оренбургтан 280 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 34400 кеше (2006), ш.и. 6784 татар (2000). Районда 6 татар авылы: Яңа Якуп (1052 кеше), Абдрахман (385), Иске Шалты (697), Тирес-Усман (661), Чаганлы (606), Яңа Тирес (351); 2 катнаш авыл: Степановка № 2 (290), Артемьевка (341). Иң борынгылары — Иске Шалты (1743 тә нигез салына), Тирес-Усман (1748). Бу авылларга Казан төбәге хакимиятләре рөхсәте б-н Яңа Мәскәү юлыннан почта ташу өчен күчеп килгән татарлар нигез сала. 1930 елларга кадәр А.р. терр-ясендә 14 мәчет, 1 мәдрәсә, 6 мәктәп эшли. 2000/01 уку елыннан башлап районның 5 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. 2005 тә А.р.нда татар җирле милли-мәдәни автономиясе оештырыла. Җирле «Абдулино» телерадиокомпаниясе татарлар өчен махсус тапшырулар алып бара. Татар авыл үзешчән коллективлары фестивальләре үткәрелә. Абдрахман һәм Тирес-Усман авыллары мәктәпләрендә төбәкне өйрәнү музейлары эшли. Районда 6 мәчет бар. А.р. Сов. Союзы Герое М.Х.*Хәйретдинов*, Дан орденының тулы кавалеры Г.И.*Усманов*, икътисад фән. д-ры М.Т.*Шабаев*, шагыйрь С.Г.*Муллагалиев*, язучы М.М.*Хәбибуллин* кебек шәхесләрне биргән.

**АБДУЛЛА́ЕВ** Рөстәм Габдерәшит улы (7.8.1946, Әстерхан ш.), драма актёры, режиссёр, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984). 1965 елда Әстерхан мәдәни-агарту уч-щесен тәмамлый. 1966–68 дә Казан театр уч-щесендә, 1968–73 тә Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тында укый. Институтны тәмамлагач, *Әлмәт татар драма театрында*: актёр, 1976 дан режиссёр һәм 1983–88 елларда баш режиссёр. Беренче рольләреннән үк яшь актёр талантының үзенчәлекле яклары ачыла (Исмәгыйль — «Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин; Әлмәшев — «Үлмәс җыр», Р.Ишморат; Шакир — «Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал; Зариф — «Шәмсекамәр», М.Әблиев). 1976 дан Әлмәт театрында яшь татар драматургларыннан Ф.Садриев комедияләре буенча «Их сез, егетләр», «Ач тәрәзәң» (1976, 1978), Р.Хәмиднең «Иске өй хуҗалары», «Синең урыныңа кайттым» (1979, 1981), Р.Батулланың «Исәп-хисап» (1980) әсәрләрен сәхнәгә куя. Бу елларда ул А.Гыйләҗев, Р.Хәмид, Р.Мингалим, Н.Фәттах, Т.Миңнуллин, Ф.Садриев, Ю.Сафиуллин һ.б. пьесаларын сәхнәләштерә. А. тарафыннан К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр», А.Островскийның «Гел май да бал түгел» («Не всё коту масленица», 1984), Б.Васильевның «Ә таңнар гүзәл тынлыкта иде» («А зори здесь тихие», 1985), Н.Фәттахның «Сармат кызы Сәринә» (1986) әсәрләре буенча куелган спектакльләр театр тормышында аеруча әһәмиятле вакыйгага әверелә. 1989 да А. Оренбургка проф. татар театрын оештыру өчен чакырыла; 1990 нан М.Фәйзи исем. театр директоры һәм баш режиссёры. Оренбург сәнгать ин-тының драма сәнгате ф-тында укыта.

*Әд.:* Рәхимов Җ. Әлмәт татар дәүләт драма театры: 50 ел. Әлмәт, 1994.

*Р.Игъламов.*

**АБДУЛЛА́Һ ХАН** (1340 тирәсе — 1370 тирәсе, Кырым), Алтын Урда ханы (1361–70). *Үзбәк хан* улы (онытсы дигән мәгълүмат та бар). *Алтын Урдада тәхет чуалышлары* барган елларда идарә итә. Мамай бәк ярдәмендә 1361 елның язында Кырым ханы дип игълан ителә. 1362 нең җәендә Мамай б-н бергә Алтын Урда ханы Мөридкә каршы көрәшә, Сарай әл-Җәдид, Азак шәһәрләрен ала, үз исеменнән акча суктыра. Сарай аксөякләре арасында яклау тапмый. Шул ук елда Мөрид хан Күк Урда гаскәре ярдәмендә аны тәхеттән куа. 1363 тә А.х. кабат Сарай әл-Җәдидне яулап ала; соңрак Булат Хаҗи хан тарафын-

нан аннан куып җибәрелә. 1363–68 елларда Кырымда Мамай ставкасында. Анда баш идарәче Мамай үзе була, идарә итүче дип формаль рәвештә А.х. санала. 1368 нең ахыры — 1369 ның башында А.х. кабат Сарай әл-Җәдид тәхетенә утыра.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Куликовская битва. М., 1980.

**АБДУЛЛА́Һ бине́ МИКАЙ́Л** (940 еллар — 10 йөзнең 2 нче яртысы), болгар идарәчесе. *Алмыш* (*Алмас*) *илтәбәр* оныгы. Исеме Суар (948–49) һәм Болгарда (957–58) сугылган акчалардан мәгълүм. Фараз ителүенчә, А. бине М. идарә иткән елларда Болгар һәм Суар бәклекләре оешып беткән була.

**АБДУ́ЛЛИН** Айрат Лесталевич (10.1.1961, Казан), двигательләр төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2005), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2007). 1984 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, автомобильләр двигателе һәм сервис каф. мөдире (2004 тән), бер үк вакытта 2002 дән ТР транспорт проблемалары ин-ты директоры, 2007 дән ТР ФА вице-президенты. Хезмәтләре двигатель агрегатларында һәм энергия җайланмаларында эшче процессларны матем. модельләштерүгә карый. А. нәстационар реакторда идеаль катнашмага нигезләнгән югары темп-радагы агымның тәэсирләнүен тикшерүнең яңа ысулын тәкъдим итә. Хим. кинетика мәсьәләләрен чишү өчен сплайн-интеграллауның нәтиҗәле ысулын, югары басым вакытында ялкынның ламинар юнәлешен исәпләүнең физик системасын, матем. моделен, алгоритмнарын һәм программаларны эшли, газ турбинасы двигателенең яну камерасындагы эмиссион сыйфатланмасын һәм газ генераторындагы сыек газ агымы тәэсирләнү параметрларын фаразлауның, агулы матдәләр һәм корым хасил булуның схемасын төзи. Тикшеренү нәтиҗәләре авиация-ракета һәм автомобиль комплекслары төзү пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт эксперты (2005 тән).

Хезм.: Горение и течение в агрегатах энергоустановок: моделирование, энергетика, экология. М., 1997 (автордаш); Численное исследование процессов во фронте ламинарного пламени однородной смеси. К., 2003.

**АБДУ́ЛЛИН** Әзһәр Хәниф улы (20.10.1923, Минзәлә кантоны Тауасты Байлар а. — 30.8.1993, Казан), хор дирижёры, педагог, сәнгать фән. канд. (1971), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан консерваториясен (1952) һәм Мәскәү консерваториясе каршында аспирантура (1955) тәмамлаганнан соң, Казан консерваториясендә укыта. Бер үк вакытта Татар акад. театрының музыка җитәкчесе һәм дирижёры (1957–67), Татар опера һәм балет театрында дирижёр һәм хормейстер (1958–59), ТАССР Җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе (1967–68). Актив иҗат һәм концерт эшчәнлеге алып бара. 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында татар композиторлары әсәрләрен башкарган СССР Дәүләт симф. оркестрына дирижёрлык итә. А. СССР Дәүләт телерадио ком-ты, «Татарстан» ДТРК фондлары өчен 70 тән артык татар халык җыры эшкәртмәләрен яздыруда дирижёр һәм автор буларак катнаша. Бөтенсоюз «Мелодия» грамъязмалар фирмасы аның 6 пластинкасын чыгара. Хор өчен җыентыклар, татар халык җырларын һәм композиторлар әсәрләрен хор, инструменталь ансамбль һәм симф. оркестрлар өчен эшкәртмәләр, татар фольклорына караган фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр авторы. Шәкертләре арасында ТАССРның халык артисткасы В.*Гәрәева*, удмурт «Италмас» ансамбле җитәкчесе, РСФСРның халык артисты А.Мамонтов, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклеләре М.Кәшипов, В.Чепкасов һ.б. бар. 1958–75 тә ТАССР Хор җәмгыяте идарәсе рәисе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Татарское народное музыкальное творчество // Музыкальная культура Советской Татарии. М., 1959; Татарские народные песни. М., 1963; Тематика и жанры татарской дореволюционной песни // Вопр. татарской музыки. К., 1967; Тематика и жанры татарской народной песни в советский период // Уч. зап. Казан гос. консерватории. 1970. Вып. IV.

*Әд.:* Арсланова Ф. Сәнгатькә багышланган гомер // Казан утлары. 2002. № 12.

*Ф.Ш.Салитова.*

**АБДУ́ЛЛИН** Әнәс Габдерәүф улы (2.5.1941, Сарман р-ны Юлтимер а.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1976). Әлмәт нефть техникумын тәмамлый (1973). 1960–65 елларда «Туймазы нефть бораулау» трестының 2 нче бораулау конторасында бораулаучы ярдәмчесе булып эшли. 1965 тән «Татнефть» АҖнең скважиналарны капиталь ремонтлау һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру буенча Әлмәт идарәсендә бораулаучы, мастер, өлкән мастер. Гамәлгә кертелгән 14 рационализаторлык тәкъдиме авторы. Дәүләт бүләге алдынгы хезмәт казанышлары, җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттыруда резервлар куллану һәм эзләнүләрдә инициатива күрсәткәне өчен бирелә. Октябрь Революциясе ордены б-н бүләкләнә.

**АБДУ́ЛЛИН** Әнвәр Абдулла улы (5.6.1917, хәзерге Башкортстан Респ-касының Илеш р-ны Иске Дөм а. — 28.10.2002, Уфа), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), өлкән сержант (1944). Уфа шәһәре кооператив техникумында укый. Май з-дында эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 5 нче армиянең 277 нче укчы дивизия 846 нчы артиллерия полкы орудие командиры. Көньяк-көнбатыш, Көнбатыш, 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Киевне саклауда (1941), Мәскәү яны сугышында (1941–42), 1945 тә Белоруссияне, Балтыйк буен азат итү сугышларында, Көнчыгыш Пруссиягә һөҗүм итү операциясендә катнаша. 1944 нең 21 августында Каунас (Литва) шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый. Партия ком-ты секретаре, завод директоры урынбасары булып эшли (Уфа). Ленин, Октябрь



Ә.А. Абдуллин.

Революциясе, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1965. Кн. 1; Алёшкин А.М. Сердцем на амбразуру. Иркутск, 1976; Люди легенд. Уфа, 1980.

**АБДУ́ЛЛИН** Әсфәт Сөләйман улы (11.5.1933, Азнакай р-ны Урманай а. — 19.9.1989, Казан), онколог, киң профильле хирург, мед. фән. д-ры (1988), проф. (1989). 1959 елда Башкортстан мед. ин-тын тәмамлый, 1966 елдан Казан мед. ин-тында, 1974 тән профессор вазифасын башкара, онкологик авырулар хирургиясе курсы мөдире. Казан Сәламәтлек саклау идарәсенең штаттан тыш баш онкологы. Хезмәтләре төрле әгъзалардагы яман шешләр клиникасына, аларга диагноз кую һәм дәвалауга, ашказанында анатомик үзгәрүләрне тикшерү ысулларына карый.

Хезм.: Злокачественные меланомы кожи. К., 1974 (автордаш); Оперативное лечение рака желудка. К., 1976 (автордаш).

**АБДУ́ЛЛИН** Габденур Габделбәр улы (23.8.1954, Удмурт АССРның Можга ш.), генерал-майор (1993). Пермь югары хәрби команда-инженерлар уч-щесен (1976), Ф.Э.Дзержинский исем. Хәрби академияне (1983, Мәскәү), РФ Хәрби Көчләре Генштабының хәрби академиясен (1996, Мәскәү) тәмамлый. 1976 елдан ракета гаскәрләрендә. 1983–90 да полк штабы башлыгы, дивизия штабы башлыгы, 1992–95 тә дивизия командиры. 1995–98 дә стратегик ракета гаскәрләрендә армия командующиенең 1 нче урынбасары (Омск ш.). «Хәрби хезмәтләре өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**АБДУ́ЛЛИН** Зөфәр Нурмөхәммәт улы (27.2.1949, Кукмара р-ны Югары Өскебаш а.), урман белгече, ТРның атказ. урманчысы (1994). Лубян урман хуҗалыгы техникумын (1968), Мари политехника ин-тын (1984) тәмамлый. 1970–86 елларда Саба урман сәнәгате хуҗалыгында эшли, баш урманчы (1983 тән), баш инженер (1985 тән). 1986 дан Яшел Үзән урман хуҗалыгы директоры, 2004 тән РФ Табигать ресурслары министрлыгы урман хуҗалыгы федераль агентлыгының ТР буенча урман хуҗалыгы агентлыгы җитәкчесе, 2006 дан ТР урман хуҗалыгы министры. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә (1985).

**АБДУ́ЛЛИН** Ибраһим Әхмәт улы (20.9.1920, Башкортстан Респ-касының хәзерге Шаран р-ны Зирекле а. — 9.7.2005, Уфа ш.), драматург, прозаик, Башкортстан АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978). Башкорт телендә яза. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1957). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–52 елларда «Совет Башкортстаны» г-тасының үз хәбәрчесе. 1938 дә «Көй-

мәдә», «Вагонда» дигән беренче хикәяләре, «Ал яулык» исемле пьесасы басылып чыга. А. әдәбиятта тәүге адымнарыннан ук зур проблемалар күтәрергә омтыла. «Гөлмәрфуга» (1953), «Розалар» (1957), «Йөрәк менән шаярмайҙар» (1961) драмаларында катлаулы тормыш вакыйгалары чагылдырыла. «Бажалар» (1952), «Ялҡынһыз яна йөрәк» (1960), «Тиле йәшлек» (1970) комедияләрендә эшчеләр даирәсендә әхлак сафлыгы мәсьәләләре күтәрелә. А.ның «Йыр булып ҡайтырмын» (1970), «Карпатта таң ата» (1985) һ.б. драмалары реаль фактларга нигезләнә. А. пьесалары Татар акад. театрында да куела. А. — ш.у. совет һәм итальян партизаннарының фашизмга каршы көрәшен сурәтләгән «Хуш, Рим!» (1969), партизаннарның Киевтәге яшерен эшчәнлеге турындагы «Ҡош юлыннан барам» (1983) романнары, Бөек Ватан сугышы вакыйгалары тасвирланган «Чардаҡка ташланган хаттар» (1965), «Меңәр йыл йәшәй кедр» (1973) повестьлары авторы. Башкортстан Респ-касының Салават Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1996). 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә. Уфа шәһәрендә яшәде.

Ә с ә р.: Йолдызлар атыла: Повестьлар һәм хикәяләр. К., 1964; Әҫәрҙәр: 2 томда. Өфө, 1986; Әҫәрҙәр: 3 томда. Өфө, 1998–99.

*Әд.:* Р а м а з а н о в Ғ. Замандаш, ҡаләмдәш, яуҙаш // Агиҙел. 1971. № 12; Н у р ғ а л и н З. Теманы тормош бирә // Агиҙел. 1984. № 6.

*С.Г.Сафуанов.*

**АБДУ́ЛЛИН** Илгиз Гали улы (14.7.1940, Уфа ш.), материаллар гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1988), проф. (1990). РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998). 1962 елда Уфа авиация ин-тының авиация двигательләре ф-тын тәмамлый. 1969–94 елларда Уфа нефть ин-тында (хәзерге Уфа нефть техник ун-ты), материаллар гыйлеме һәм тутыгудан саклау каф. мөдире (1980 елдан). 1994 тән Уфа нефть техник ун-ты каршындагы Өстәмә проф. белем бирү ин-ты директоры. Хезмәтләре металл конструкцияләрнең коррозион-механик ныклыгы, озакка чыдамлыгы, җимерелүләрнең үзенчәлекле төрләре һәм ватылу-бозылуның сизгер параметрларын билгеләүгә карый. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Коррозионно-механическая стойкость нефтегазовых трубопроводных систем. Уфа, 1977; Прогнозирование коррозионно-механических разрушений магистральных трубопроводов. М., 1997.

*Әд.:* Уфимский нефтяной технический университет. Доктора наук, профессора: Науч.-библиогр. сб. М., 1997; Кто есть кто в газовой промышленности. СПб., 1996; Диагностика растрескивания трубопроводов. Уфа, 2003.

**АБДУ́ЛЛИН** Илдар Гариф улы (2.12.1966, Бөгелмә ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1992). 1992–98 дә һәм 2000 елдан «Серго исем. завод» җитештерү берләшмәсе» федераль унитар пр-тиесендә әйдәп баручы инженер-сынаучы. 1998–99 да «Яшел Үзән икмәк комбинаты» АҖдә эшли, 1999–2000 дә ТР Миграция хезмәте башлыгы урынбасары. Дәүләт бүләге донор канын һәм аның компонентларын югары сыйфатлы итеп саклау һәм куллануны тәэмин итүче яңа буын суыту техникасын эшләгәне һәм мед. практикасына керткәне өчен бирелә.

**АБДУ́ЛЛИН** Илдар Фәрт улы (1.3.1951, Балтач р-ны Сасна а. — 2.10.2002, Казан), химик, химия фән. д-ры (1995), проф. (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, 1975 елдан Казан ун-тының аналитик химия кафедрасында эшли. Хезмәтләре органик кушылмаларны электрохимик ысуллар б-н билгеләүгә карый. Металларны анодлы эретү, галогеннар һәм галогенидларны оксидлаштыру юлы б-н, үзгәрешле валентлы металл тозларыннан яңа кулонометрик титрантлар табу шартларын нигезли. Канда фенол, шикәр, сидек кислотасын, дару препаратларын (кислота гидразидлары, сульфаниламидлар һ.б.), азык продуктларында, яшелчә һәм җиләк-җимешләрдә биологик актив кушылмаларны һәм антиоксидантларны анализлауның яңа алымнарын тәкъдим итә. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар, шуларның кайберләре химик анализлау гамәлләнә кертелгән.

Х е з м.: Переносчики электронов в электрохимических методах анализа: Обзор // Журн. аналитической химии. 1989. Т. 44, вып. 10 (автордаш); Иод (1) — новый кулонометрический реагент в среде ледяной уксусной кислоты: Обзор // Журн. аналитической химии. 1995. Т. 50, вып. 7; Кулонометрический анализ органических соединений: Обзор // Заводская лаб. 1998. Т. 64, № 1 (автордаш).

**АБДУ́ЛЛИН** Илдар Шәүкәт улы (3.3.1954, Казан), физик-химик, техник фән. д-ры (1990), проф. (1992) ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), шунда ук эшли, 1981–1986 елларда лаб. мөдире. 1986 дан «Мединструмент» фәнни-җитештерү берләшмәсендә бүлек мөдире, 1990 нан ген. директорның фән буенча урынбасары. 1998 дән Казан технол. ун-тында күн һәм мех технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре түбән басым астында югары ешлыклы бушанулардагы физик процессларны, каты җисем өслеген һәм югары молекуляр кушылмаларны түбән темп-ралы тигезләшмәгән плазма ярдәмендә үзгәртүне өйрәнүгә карый. Ионнарның каты җисем өслегенә югары ешлыклы плазма б-н үзгәртү вакытындагы энергиясен исәпли. А.ның каты җисемнәрне плазма ярдәмендә ялтырату һәм ныгыту буенча эшкәртмәләре мед. инструментлары, газ турбиналы двигательләрнең калакларын эшләү технологиясенә кертелә; оптик системаларның сыйфатын яхшырту өчен файдаланыла. Түбән темп-ралы тигезләшмәгән плазма ярдәмендә натураль югары молекуляр кушылмаларның (тире, мех) функциональ һәм куллану сыйфатлары яхшыртыла. ТР Дәүләт бүләге (2003), РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2005).

Х е з м.: Расчёт характеристик индукционного диффузного разряда // Изв. Сибирского отд-ния АН СССР. Сер. техн. наук. 1981. № 13, вып. 3 (автордаш); Модификация поверхности диэлектрических и полупроводниковых материалов низкотемпературной плазмой // Плазмохимия-91. М., 1991 (автордаш); Электродуговые и высокочастотные плазмотроны в химико-металлургических процессах: Учеб. пособие. Киев, 1991.

**АБДУ́ЛЛИН** Илнур Габдулла улы (11.1.1954, Саба р-ны Сатыш а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2001), проф. (2002), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1977 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1991 дән укыту-производство башлыгы, 2006 дан проректор. Хезмәтләре гетероген системалар химиясе һәм технологиясенә карый. Югары нәтиҗәле энергиянең автоном локаль чыганагы булган пиротехник составлар һәм пиротехник корылмалар барлыкка китерүнең фәнни нигезләрен булдыра, куерган катнашмаларны бөртекләндерүнең сулы-эмульсион технологиясен уйлап таба. Төрле функциональ билгеләнештәге (эретеп ябыштырылган җөйләрдә көчәнешне юкка чыгару өчен термохимик тасмалар, җиргә тоташтыручы үткәргечләрне эретеп ябыштыру һ.б. өчен пиропатроннар) пиротехник җылыткычлар тәкъдим итә. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пиротехнические составы безгазовые и малогазовые // Энергетические конденсированные системы. М., 2000; Компьютерное моделирование процесса теплообмена продуктов сгорания пиротехнических составов при различных граничных условиях // Вестн. технол. ун-та. 2000. № 1; Исследование процессов тепломассопереноса при горении малогазовых составов // Материалы 4 Междунар. форума по тепло- и массообмену. Минск, 2000 (автордаш).

*Әд.:* Мамадыш — судьба моя: Историко-краеведческая летопись. Ижевск, 2005; Специалисты по взрывчатым материалам, пиротехнике и боеприпасам: Биогр. энцикл. М., 2006.

**АБДУ́ЛЛИН** Илфак Габделхак улы (20.5.1942, Балтач р-ны Комаров Заводы а.-28.9.2003, Казан), электрохимик, химия фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991). 1967 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый, 1970 тән аның Түбән Кама ф-лында эшли. 1974 тән Бөтенсоюз мед. инструментлары фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек мөдире. 1976 дан Казан мед. ун-тында, 1978–98 елларда нәорганик һәм аналитик химия, 1998 дән гомуми һәм органик химия каф. мөдире. Хезмәтләре стационар һәм стационар булмаган электролиз шартларында композицион электрохимик капламнарның составы, структурасы һәм морфологиясе формалашуының теоретик аспектларына карый. Саклагыч декоратив һәм композицион электрохимик капламнарны алдан билгеләнгән функциональ сыйфатлары (коррозиягә, тузуга каршы торучанлык, майлanучанлык һ.б.) буенча ясау технологиясен, аларны химик-термик үзгәртү алымнарын һәм гальваник капламнар ясау өчен алмаш ток чыганакларын эшли, аларны гамәлгә кертә («Органик синтез» АҖ, С.М.Киров исем. синтетик каучук з-ды, «Теплоконтроль» ҖБ, Түбән Кама механика з-ды һ.б.).

Х е з м.: Мёссбауэровские исследования покрытий Sn и Sn-ZrC, полученных при нестационарных режимах электролиза // Электрохимия. 1984. Т. 20, № 9 (автордаш); Опыт нанесения композиционных электрохимических покрытий в режимах перио-


М.Һ. Абдуллин.


Н.Т. Абдуллин.


Мөслим М. Абдуллин.


Р.М. Абдуллин.

дического тока // Вестн. машиностроения. 1989. № 7 (автордаш); Влияние природы электролита на структуру и свойства КЭП с матрицей из меди // Защита металлов. 1997. Т. 33, № 2 (автордаш).

*Әд.:* Л о з о в о й А.С. Мы — кировцы. К., 1969; Ильфак Абдуллин: Уроки жизни. К., 1997.

**АБДУ́ЛЛИН** Искәндәр Габдулла улы (22.10.1935, Яшел Үзән р-ны Олы Күлбаш а. — 23.10.1992, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1990). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1956). Чиләбе өлкәсендә укытучы булып эшли (1956–59). 1962 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Әрмән графикасындагы кыпчак язма истәлекләрен тикшерә, рев-циягә кадәрге татар публицистикасы телен өйрәнә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (1–3 т., 1977–81), бер томлы «Татарча-русча сүзлек»не (1988) төзүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Г.Камал драмаларының теле. К., 1968.

**АБДУ́ЛЛИН** Мансур Һидият улы (15.9.1919, Башкортстан АССРның хәзерге Эстәрлебаш р-ны Эстәрлебаш а. — 8.6.1996, Уфа), Сов. Союзы Герое (7.8.1942), лейтенант (1945). 1941 елның июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: 70 нче армиянең 1 нче гв. артиллерия дивизиясе 167 нче гв. артиллерия полкында туп командиры. Көнбатыш, Калинин, Үзәк һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Польшаны, Венгрия, Чехословакияне азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 10 июлендә Молотыги авылы (Курск өлкәсе Ратежск р-ны) янында барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң (1945) туган төбәгенә кайта, Уфа шәһәрендә яши. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1965. Кн. 1; А л е щ е н к о Н.М. Долг и подвиг. М., 1981.

**АБДУ́ЛЛИН** Мәүлетҗан Сәмигулла улы (19.10.1923, Бөгелмә кантоны, хәзерге Ютазы р-ны Бәйрәкә а. — 5.8.1998, шунда ук), агроном, ТАССРның атказ. агрономы (1977), РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1984). Бөек Ватан сугышында катнаша. Колхоз рәисләре әзерләү буенча Татарстан а.х. мәктәбен тәмамлый (1952, Казан). 1953–84 елларда Баулы р-нының «Коммунизмга» к-зы рәисе. А. җитәкчелек иткән елларда колхоз а.х. культураларыннан югары уңыш ала, терлекчелектә ирешкән уңышлары белән аерылып тора. 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

**АБДУЛЛИ́Н** Мидхәт Исмәгыйль улы (16.9.1930, Башкортстан АССРның Эстәрлетамак ш. — 15.1.1994, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1987). Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1955). 1955–56 елларда КПССның Подберёзино райкомында (ТАССР) пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире. 1956–62 дә Бөтенсоюз читтән торып уку политехника ин-тының Эстәрлетамак укыту-консультация пунктында эшли. 1962–65 тә Уфа нефть ин-тының Эстәрлетамак ф-лында КПСС тарихы каф. өлкән укытучысы, 1965–73 тә доцент. 1973–90 да Казан авиация ин-ты доценты. Хезмәтләре КПССның Башкортстан оешмасы тарихына, Көнбатыш Европа советологлары хезмәтләрендә СССРдагы милли мәсьәләнең яктыртылуын тәнкыйтьләүгә карый.

Х е з м.: Татарская АССР: реальность и буржуазные мифы. К., 1977 (автордаш); Борьба без компромиссов: критика буржуазных концепций разрешения национального вопроса в республиках Поволжья и Урала. К., 1982; Сражающаяся правда: критика буржуазных концепций развития советских наций Поволжья и Урала. К., 1985; Тонущий хватается за змею: критика буржуазных фальсификаций национальной политики КПСС. К., 1988.

**АБДУ́ЛЛИН** Мортаза Мостафа улы (1910, Казан — 1946, шунда ук), театр рәссамы, педагог. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тының театр бизәлеше остаханәсендә укый (1933 елга кадәр). 1933 тән Татар акад. театрында, 1939–46 да Татар опера һәм балет театрында рәссам, бер үк вакытта Казан сәнгать уч-щесенең татар бүлегендә укыта (1935–37). Татар һәм рус классик драматургиясе әсәрләре нигезендә куелган спектакльләр (Ш.Камалның «Томан артында», 1935; Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», 1937; Г.Коләхмәтовның «Яшь гомер», 1937; А.Пушкинның «Таш кунак», 1937; Н.Җиһановның «Качкын» операсы, 1940) бизәлеше авторы. Нечкә зәвыклы нәкышь культурасына ия булган рәссамның осталыгы театр сәхнәсендә Европа һәм татар йортларының интерьерларын гәүдәләндерүдә, күмәк күренешләрне бизәүдә аеруча ачык чагылыш таба. А. сугыш алды елларында татар сәхнәсен бизәү сәнгате үсешенә, милли нәкышьчеләр һәм сәхнә рәссамнары (Х.Г.Якупов, Л.Г.Фәттахов, Ә.И.Тумашев, М.Г.Сутюшев) әзерләүгә зур өлеш кертә. Бөек Ватан сугышы елларында плакатлар иҗат итә. Әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.


М.М. А б д у л л и н. А.С.Пушкинның «Таш кунак» әсәре буенча куелган спектакльгә декорация эскизы. 1937. А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музее. Мәскәү.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Татарии: Биогр. справ. К., 1975; Ф а й н б е р г А.Б. Художники Татарии. Л., 1983. *Р.Г.Шаһиева.*

**АБДУ́ЛЛИН** Мөслим Мокыйм улы (1.3.1916, хәзерге Казакъстан Респ-касының Усть-Каменогорск ш.), җырчы (лирик тенор), Казакъстан ССРның халык артисты (1947). Р.М.*Абдуллинның* игезәк туганы. 1932–35 елларда Алма-Ата музыка техникумында, 1935–38 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Казакъ опера студиясендә (проф. А.Вишневский классы) укый. 1938–70 тә Абай исем. Казакъ опера һәм балет театры солисты. Бу театр сәхнәсендә Түләгән, Болпан, Кайракпай («Кыз-Жибек», «Ер Таргын», «Жалбыр», С.Брусиловский), Азим («Абай», А.Жубанов һәм Л.Хәмиди) һ.б. партияләрне башкаручы буларак таныла. П.Чайковскийның «Евгений Онегин»ында Ленский, А.Рубинштейнның «Демон»ында Синодал һ.б. рус композиторлары операларындагы төп партияләрне башкара. Казакъстан сәхнәләрендә Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсындагы Җик партиясен җырлый. Игезәк туганы Р.М.Абдуллин б-н бергә Казакъ радиосы һәм телевидениесендә чыгышлар ясый, СССР шәһәрләрендә гастрольләрдә йөри, татар музыкасы концертларында катнаша.


М.М.А б д у л л и н Түләгән ролендә («Кыз-Жибек» операсы, Е.Брусиловский).

*Әд.:* Х а м и д и Л., Х а м и д и Р. Жизнь в искусстве. А.-А., 1975.

**АБДУ́ЛЛИН** Нигъмәтулла Төхфәтулла улы (23.5.1937, Чаллы р-ны Казаклар а.) металл

эшкәртү техник-технологы. Соц. Хезмәт Герое (1981). Воткинск машиналар төзү һәм Түбән Кама энергетика техникумнарын (1966, 1987) тәмамлый. 1970 елдан «Камгэсэнергострой» җитештерү берләшмәсенең «Металлургстрой» идарәсендә комплекслы бригада җитәкчесе, 1987 дән Алабуга р-ны «Котловский» с-зы прорабы, баш инженеры. 1992–98 елларда «Янус» сәнәгать-финанс компаниясендә директор урынбасары, баш инженер. Герой исеме КамАЗның икенче өлешен төзегәндә ирешкән казанышлары өчен бирелә. Ике Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ф а с х у т д и н о в К. Абдуллин Нигматулла Тухбатуллович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**АБДУ́ЛЛИН** Нурулла Гайнулла улы (6.12.1931, Балтач р-ны Хәсәншәех а.), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. канд. (1965), ТССРның атказ. геологы (1992). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), «Татнефтегазразведка» трестында эшли. 1957 елдан «ТатНИПИнефть»тә, 1970 тән геологик эзләнүләр бүлеге мөдире, 1993–2006 да әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Сабанчы нефть чыганагын ачучыларның берсе (1986). Татарстандагы Чияле Алан, Черёмушка, Урыстамак, Архангель, Яңа Чишмә, Берёзовка, Өнбия һ.б. нефть чыганакларын билгеләүдә катнаша. Идел-Урал төбәге палеозой утырмаларының нефтьлелеген фаразлауда, нефть һәм газ запаслары урнашуын чагылдырган геологик карталар төзүдә һәм Татарстандагы күпкатламлы чыганаклар эзләүдә нәтиҗәле ысуллар кертү һәм эшкәртүдә катнаша. СССР ФАнең И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1977).

Х е з м.: Закономерности размещения и условия формирования залежей нефти и газа Волго-Уральской области: Татарская АССР. М., 1979. Т. 3 (автордаш); Месторождения нефти и газа Волго-Уральской нефтегазоносной провинции: Татарская АССР // Нефтяные и газовые месторождения СССР. Справ.: В 2 т. М., 1987 (автордаш).

**АБДУ́ЛЛИН** Рәшит Фарук улы (20.8.1951, Казан — 19.2.2004, шунда ук), композитор, җырчы (бас). 1979 елда Казан консерваториясенең композиция бүлеген (Р.Билалов классы) тәмамлый. 1970–83 тә «Сәйяр» вокаль-инструменталь ансамбле һәм Татар филармониясенең эстрада бүлеге җитәкчесе. Популяр эстрада җырлары авторы. Рус (М.Глинка, П.Чайковский, С.Рахманинов) һәм Көнбатыш Европа композиторларының (Дж.Россини, Г.Доницетти, Дж.Верди операларыннан арияләр), вокаль соло программаларын башкара. «Татарстан» ДТРК фондына Ф.Шубертның «Тегермәнче гүзәлкәй» («Прекрасная мельничиха») вокаль циклын яздыра. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1980). Инструменталь-камера әсәрләре, спектакльләргә музыка, җырлар, татар халык көйләренә эстрада өчен эшкәртмәләр авторы. Төп әсәрләре: «Скрипка һәм оркестр өчен концерт» (1981), «Кыллы оркестр өчен музыка» (1983), балалар өчен «Мырау Батыр» мюзиклы (1990).

*Әд.:* У с е и н о в а Р. Рашид Абдуллин // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

*Р.Усеинова.*

**АБДУ́ЛЛИН** Ришат Мокыйм улы (1.3.1916, хәзерге Казакъстан Респ-касының Усть-Каменогорск ш. — 1988), җырчы (баритон), СССРның халык артисты (1967). М.М.*Абдуллинның* игезәк туганы. 1933–35 елларда Алма-Ата музыка техникумында, 1936–39 да Мәскәү консерваториясе каршындагы Казакъ опера студиясендә (проф. А.Вишневский классы) укый. Казакъстан опера сәхнәсенең беренче осталарыннан. 1939–85 тә Казакъ опера һәм балет театры солисты. Олжай («Бекет», А.Зильбер), Айдар, Артём («Алтын астык», «Дударай», Е.Брусиловский), Абай («Абай», А.Жубанов һәм Л.Хәмиди), Гөлмат («Назугум», К.Кужамьяров) партияләрен, казакъ композиторлары операларындагы башка төп партияләрне беренче булып башкара. А. классик опера репертуарында Онегин, Елецкий («Евгений Онегин», «Пики дамасы», П.Чайковский), Демон («Демон», А.Рубинштейн), Жермон («Травиата», Дж.Верди), Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Шарплес («Чио-Чио-сан», Дж.Пуччини) һ.б. партияләрне башкара. Казакъ театр сәхнәләрендә СССР композиторларының, ш.и. З.Палиашвили (Киязо, «Даиси»), Н.Җиһанов (Хан, «Алтынчәч») операларында җырлый. М.М.Абдуллин б-н бергә концертларда, радио һәм телевидениедә солист буларак казакъ халык җырларын, казакъ (Л.Хәмиди, А.Еспаев, С.Мөхәммәтҗанов һ.б.), рус (В.Соловьёв-Седой, С.Туликов, Е.Родыгын, Б.Мокроусов һ.б.) композиторлары әсәрләрен башкара. Үзенең концерт программаларына татар халык җырларын («Минзәлә», «Сарман», «Туган тел» һ.б.), С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, Р.Яхин һ.б. татар композиторларының әсәрләрен дә кертә. Ш.у. М.Глинка, П.Чайковский һ.б. романсларын җырлый. СССР шәһәрләрендә, Монголия, Кытай һ.б. чит илләрдә гастрольләрдә була. А.ның иҗатына образларны реалистик рухта ачып бирү хас; үтә көчле вокаль сәләткә ия җырчы. Казакъстан ССРның Дәүләт бүләге лауреаты (1978).



Р.К. Абдуллин.

*Әд.:* М е с с м а н В. Возрождение песни. А.-А., 1958; Х а м и д и Л., Х а м и д и Р. Жизнь в искусстве. А.-А., 1967; Е р з а к о в и ч Б. Абдуллин Ришат Мукимович // Музыкальная энцикл. М., 1973, Т. 1.

*Ф.Ш.Салитова.*





Р.М. А б д у л л и н: Абай («Абай», Ә.Жубанов, Л.Хәмиди), Евгений Онегин («Евгений Онегин», П.И.Чайковский) рольләрендә.

**АБДУ́ЛЛИН** Рубин Кәбир улы (19.8.1950, Йошкар-Ола ш.), пианист, органчы, педагог, ТРның халык артисты (1992), РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1997), РФнең халык артисты (2007). Казан консерваториясенең фортепиано бүлеген (Э.Монасзон классы, 1973), Ленинград консерваториясенең орган бүлеген (Н.Оксентян классы, 1974) тәмамлый, Мәскәү консерваториясе каршында ассистентура-стажировка (Л.Ройзман җитәкчелегендә, 1979) уза. 1973 елдан Казан консерваториясендә махсус фортепиано каф. укытучысы (1986 дан махсус фортепиано һәм орган), 1989 дан ректор, проф. (1992). Беренче татар органчысы. Актив концерт эшчәнлеге алып бара. 15 йөзләрдә иҗат иткән полифонистлардан алып 20 йөзгә кадәрге чорда яшәгән композиторларның орган өчен язылган әсәрләреннән концерт цикллары башкара: «Орган музыкасы тарихыннан», «Бах, аңа кадәрге шәхесләр һәм замандашлары», «Әгәр Бах көндәлек алып барган булса» һ.б. Ш.Шәрифуллинның «Борынгы татар халык көйләре темасына вариацияләр»ен, И.Якуповның «Прелюдия һәм фуго»сын, А.Миргородскийның «Полифоник дәфтәр»ен («Полифоническая тетрадь») һәм татар композиторларының орган өчен язылган әсәрләрен беренче булып башкаручы. М.Мусоргскийның «Күргәзмәдән сурәтләр» («Картинки с выставки») циклыннан пьесалар, Н.Җиһанның 5 нче симфониясеннән Largo, Ф.Әхмәтовның «Истәлек» әсәре һәм орган өчен эшләнгән башка оригинал эшкәртмәләр авторы. Ш.у. пианист буларак та чыгышлар ясый (солист һәм ансамблист). Таллин, Вильнюс, Рига, Пицунда шәһәрләрендә узган орган музыкасы фестивальләрендә катнаша, Германия, Италия, Англия, Швеция, Голландия һ.б. чит илләрдә гастрольләрдә була. Шәкертләре арасында Бөтенроссия, халыкара конкурслар лауреатлары һәм дипломантлары — Л.Камелина, Л.Лабзина, Д.Меерковa, Д.Зарецкий, Е.Базова. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. (1988), РФнең Дәүләт бүләкләре (2000) лауреаты.

*Әд.:* Г а л е е в Б. Замечательный цикл // Советская музыка. 1981. № 9; На новых рубежах. Фортепианный факультет // Казанская гос. консерватория. К., 1998.



Х.Х. Абдуллин.



Я.Г. Абдуллин.

**АБДУ́ЛЛИН** Сафиулла (25.12.1849, Сембер губ., Буа өязе Кече Чынлы а. — 1927, Казан), дин эшлеклесе. «Мәрҗани» мәдрәсәсендә белем ала. Ш.Мәрҗани шәкерте. 1880 елда туган авылында имам вазифасын башкарырга указ ала. 1889 да Оренбург мөселман Диния нәзарәте тарафыннан Казанга дини китаплар буенча корректор итеп җибәрелә. Бер үк вакытта «Мәрҗани» мәдрәсәсендә укыта. 1890 да мәхәллә халкы б-н низагка керә һәм Казаннан китә. Әчке Кыргыз Урдасының Нарын Пески авылы мәчетенә имам-хатиб итеп билгеләнә. 1899 да Казанга Мәрҗани мәчете имамы итеп чакырыла. Ул эшләгән вакытта «Мәрҗани» мәдрәсәсе яңадан җәдитчелек үзәгенә әверелә. Казанда «Бәянелхак» г-тасында хезмәттәшлек итә. Россия мөселманнарының иҗтимагый-сәяси тормышында катнаша.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р. Имамы Сафиулла Абдуллин и Габдулла Апанаев — ученики и последователи Ш.Марджани // Марджани: наследие и современность. К., 1998.

**АБДУ́ЛЛИН** Хәйрулла Хәмидулла улы (25.6.1908, Сембер губ. Буа өязе, хәзерге Буа р-ны Үгез Куагы а. — 12.11.1997, Казан), микробиолог, эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1959), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970, 1973). Казан вет. микробиология мәктәбенә нигез салучы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан вет. ин-тын тәмамлагач (1932), шунда ук эшли, 1945–69 елларда микробиология һәм вирусология кафедрасы, бер үк вакытта 1960–88 дә Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү вет. ин-тында бактериаль инфекцияләр лаб. мөдире. Эзләнүләре түләмә патогенезын өйрәнү, бруцеллёз, колибактериоз, листериозга диагноз кую һәм булдырмау ысулларын эшләүгә, дезинфекция үткәрү өчен нәтиҗәле чаралар булдыруга карый. 25 уйлап табу авторы. А. җитәкчелегендә листериозга (АУФ), бруцеллёзга (штамм 82), колибактериозга каршы вакциналар, дезинфектантлар (феносмолин һ.б.) эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сибирская язва. М., 1975.

*Әд.:* История Казанского государственного ветеринарного института им. Н.Э.Баумана: Очерки. К., 1973; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*А.А.Барсков.*

**АБДУ́ЛЛИН** Яхъя Габдулла улы (9.1.1920, Саба р-ны Зур Кибәчә а. — 4.1.2006, Казан) философ, филос. фән. д-ры (1979), проф. (1982), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1996), ТАССР, РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1980, 1985). Казан юридик ин-тын (1952) һәм КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1957) тәмамлый. 1936 елдан Теләче р-ны газетасы редакциясендә эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–59 да Казанда партия эшендә. 1959–71 дә Казан вет. ин-тында укыта. 1971 дән СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында: бүлек мөдире, директор урынбасары, директор (1982–86), 1986 дан баш фәнни хезмәткәр. 1997–2003 тә ТР ФАнең Тарих ин-тында баш фәнни хезмәткәр. Татар фәлсәфи һәм иҗтимагый фикере тарихына караган хезмәтләрендә татар мәгърифәтчелеге һәм җәдитчелек мәсьәләләре, күренекле татар мәдәнияте эшлеклеләренең дөньяга карашлары тикшерелә. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мәгърифәт нуры ачар... К., 1987; Татарская просветительская мысль. К., 1975; Общественная и философская мысль в Татарии начала XX в. М., 1990 (автордаш); Джадидизм среди татар: Возникновение, развитие и историческое место. К., 1998.

**АБДУ́ЛЛИНА** Равия Самат кызы (12.10.1949, Мамадыш р-ны Баскан а.), тел галиме, филол. фән. канд. (1988). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1976 елдан Алабуга пед. ин-тында укыта. 1990 нан Чаллы пед. ин-тының татар теле һәм әдәбияты кафедрасында, 1992–94 елларда филол. ф-ты деканы, 1999 дан профессор. Татар теленең стилистикасы, фигыль формалары лингвометодикасы һәм сөйләм культурасы өлкәләрендә тикшеренүләр алып бара. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр авторы.

Х е з м.: Стилистика һәм сөйләм культурасы. Чаллы, 1997; Риторика һәм интонация. Чаллы, 1999; Алфавитка бәйле орфоэпия һәм орфография мәсьәләләре. Яр Чаллы, 2006; Семантика и стилистика временных форм татарского глагола. Наб. Челны, 2002.

**АБДУ́ЛЛИНА** Саре Нури кызы (18.1.1929, Кырым АССРның Алупка ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1980), проф. (1981), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1986), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1999). 1952 елда Идел буе урман-техника ин-тын (Йошкар-Ола ш.) тәмамлый. 1963 тән Казан финанс-икътисад ин-тында, 1980–91 елларда икътисад һәм җитештерүне оештыру, 1991–98 дә җитештерү икътисады һәм маркетинг каф. мөдире, 1998 дән җитештерү икътисады каф. профессоры. Хезмәтләре сәнәгать һәм пр-тиеләрдәге автоматлаштырылган системалар б-н идарә итү, ш.у. кризисны булдырмау, стратегик планлаштыру мәсьәләләренә карый. Фәнни эшләрен гамәлгә кертү нәтиҗәләре СССР ВДНХсында күрсәтелә, ике мәртәбә көмеш медальгә лаек була.

Х е з м.: Экономика технического обслуживания и ремонта. Ижевск, 1966 (автордаш); АСУ ремонтной службы предприятия. М., 1975; Управление ремонтом оборудования непрерывных производств. М., 1982.

**АБДУ́ЛЛИННАР И.А. ҺӘМ А.И. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́** (литографиясе), Казандагы полиграфия предприятиесе. 1872 елда И.А.Абдуллин М.Яхиннан сатып ала, 1873 тә И.С.Перов ташбасмаханәсе б-н берләштерелә, 1883 тә улы А.И.Абдуллин кулына күчә. 1875 тә — беренче ике басмасы, 1883 ел башына 13 басмасы (догалыклар, календарьлар, шәмаилләр) чыга, аларның гомуми тиражы 136910 данәгә җитә. Ташбасмаханәдә 2 станок, ротация, литография машиналары, басма өчен ташлар һ.б. була. 2–4 кеше эшләгән. 1908 елның язында ябыла.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; ш у л у к. Татарская книга пореформенной России. К., 1983.

**АБДУ́ЛЛИННАР УТАРЫ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. 19 йөз уртасыннан сакланып калган бердәнбер татар сәүдә утары, элеккеге Печән базары янында урнашкан. Бертуган Г.А.һәм Х.А. Абдуллиннар милке була. Утар мәйданга каратып салынган һәм үзара капка б-н тоташкан ике йорттан, берәр катлы ике кибеттән тора. Почмактагы корпусның ике ягы мәйданга һәм Печән базары урамына чыга, ә икенчесе — урам буйлап сузылган. Ишегалды корылмалары таш келәтләрдән, агачтан салынган биналардан, ике торак флигельдән гыйбарәт. Утарның бер өлешен бакча били. Башта 1850 елда ике кыеклы түбәле ике катлы таш йорт (1848 елгы үрнәк проект буенча) һәм Печән базары урамындагы кибетләр (1849 елгы үрнәк проект буенча) төзелә. Йорт фасады ике кат арасында һәм диварның югары өлешендә кәрнизләр, турыпочмаклы сандриклар, тәрәзә асты филёнкалары, кат саен ян-як пилястралар б-н бизәлә. Кибетләрнең алгы ягында пилястралар б-н кысаланган зур ишекләр алдавыч тәрәзәләр б-н чиратлаша. 1858 дә аскы катында кибетләр урнашкан икенче йорт салына (1849 елгы үрнәк проект буенча), аның уң ягына почмактагы кибетләр корпусы килеп тоташа (1849 елгы үрнәк проект буенча). 1 нче кат фасадының бизәлеше кибетләрнең алгы ягында да кабатлана. Йортның өске катын турыпочмаклы сандриклы, пилястралар б-н кысаланган һәм астан филёнкаланган 5 тәрәзә бизәп тора. Әлеге торак кат аерым ишекләр б-н ирләр һәм хатын-кызлар ягына бүленгән була. Урам тарафына ка-



Абдуллиннар утары. Йорт фасады проекты. 19 йөз уртасы.

раган бүлмәләр, ш.и. ян-яклары почмаклап киселгән мичләре булган квадрат зал, бер-берсенә анфилада ысулы б-н бәйләнгән. 1859 дагы янгыннан зыян күргәннән соң, утар ике ел эчендә элеккеге хәленә кайтарыла. 19 йөз ахырында икенче йорт киңәйтелә, кибетләр биегәйтеп салына. Хәзерге вакытта йортларның эчке бүленеше үзгәртелгән, фасадындагы бизәкләр өлешчә югалган, почмактагы кибетләр урынында дүрт катлы торак йорт салынган. А.у.ның архит-расы классицизм юнәлешендәге әүвәлге эклектика стиленә карый.

*Әд.:* Н у г м а н о в а Г.Г. Образцовые проекты середины 19 в. в жилой застройке Казани // Памятники культуры. Новые открытия. М., 2000.

*Г.Г.Ногманова.*

**АБДУ́ЛЛОВ** Бакый (18 йөз), 1773–75 еллардагы крәстияннәр кузгалышында катнашучы. Е.И.Пугачёв җитәкчелегендә баш күтәргән гаскәр полковнигы. 1773 ел ахырында Пугачёв әмере б-н аның отряды Уса-Ижевск төбәгенә җибәрелә. Шул елның декабрендә ул Рождественск, Камбарка, Шермяит, Аннинск, Баржы-Алексеев з-дларын яулап ала. 1774 нең гыйнвар башында отрядның Ижевск з-ды тирәсендә булганлыгы мәгълүм. А.ның шуннан соңгы язмышы ачыкланмаган.

**АБДУ́ЛЛОВ** Усман Нәҗметдин улы (17.9.1922, Казан), кино һәм телевидение рәссамы, нәкышьче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972), Татарстанның халык рәссамы (2004), Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1941). 1954–59 елларда Татар опера һәм балет театрында сәхнә рәссамы, 1959–83 тә Казан телестудиясендә баш рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980). Н.Җиһановның «Качкын» операсы (1957), Ж.Фәйзинең «Башмагым» муз. комедиясе (1964), Ч.Айтматовның «Анам кыры» повесте (1966), А.Евгеньевның «Раифадагы обелиск» («Обелиск в Раифе», 1970) пьесасы нигезендә төшерелгән телеспектакльләр, Н.Җиһановның «Җәлил» операсы (1985) нигезендә эшләнгән муз. фильмның декорация эскизлары авторы. «Кырлай» (Тбилисидә узган VI Бөтенсоюз телефильмнар фестивале лауреаты, 1975), «Сабантуй» (1977), «Н.Җиһанов музыкасы» (1972 һәм 1977) һ.б. телевизион фильмнарның һәм тапшыруларның рәссамы, еш кына аларда үзе үк сценарийлар авторы һәм режиссёр да була. Кино һәм телевидение өлкәсендә милли декорация сәнгатенә нигез салучы рәссамнарның берсе. Аның эшләре декорация төзелешенең үзенчәлеге, образларның тәэсир итү көче, җете төсләр һәм яктылык эффектлары, үзенчәлекле ракурслары б-н аерылып тора. Сәхнә образлары тудырганда А. телевидениенең визуаль мөмкинлекләренә, нәкышь, дизайн, фотомонтаж алымнарына мөрәҗәгать итә, телеспектакльнең эчтәлеген ачу өчен драматургия, музыка һәм бизәлеш сәнгате ысулларын берләштерә.

Станлы нәкышь өлкәсендә А. күбесенчә пейзаж һәм натюрморт жанрында эшли («Зур Идел икмәге», 1979; «Көзге Казан», 1982; «Жигули таулары», 1982; «Казансу иртәсе», 1990 һ.б.). 1990 елларның 2 нче яртысында А. милли тарихка караган жанрлы әсәрләр («Печән базары», 1997; «Тукай Петербургта», 1998; «Б.Урманче мәчет янында», 1999; Казанның



У.Н. А б д у л л о в. «Печән базары мәчете», 1990. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Иске татар бистәсе күренешләрен чагылдырган пейзажлар сериясе: «Печән базары мәчете», 1990; «Иске ишегалды», 1997; «Иске Казан почмаклары», 1998) иҗат итә. Бөтенсоюз («Театр һәм кино рәссамнары әсәрләре», Мәскәү, 1978, 1979), Бөтенроссия («Телевидение студияләре рәссамнары эшләре», Мәскәү, 1966), зона («Зур Идел», 1980 елдан) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1972–73, 2002), Әлмәттә (1983) күрсәтелә. Әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АБҖАБА́Р** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 8 *км* көнбатыштарак, Аты суы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр юк. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 16 йөз уртасында ташландык хәлгә килгәннән соң, 16 йөз ахыры — 17 йөз башында рус авылы буларак яңадан торгызыла. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына, Чулпан авылы мәхәлләсенә керә; игенчелек, терлек үрчетү, йон тетү, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да земство мәктәбе, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 437,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Казан өязе Арча волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 61 ир заты; 1859 да — 146, 1897 дә — 148, 1908 дә — 164, 1920 дә — 173, 1924 тә — 173, 1926 да — 187, 1938 дә — 165, 1949 да — 107, 1958 дә — 121, 1970 тә — 38, 1979 да — 8, 1989 да — 1 кеше.

*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда с кратким их описанием. К., 1885.



Рем А. Абзалов.

**АБЗА́ЛОВ** Рем Абзал улы (28.6.1914, хәзерге Апас р-ны Урта Балтай а. — 7.2.1983, Ташкент), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), майор (1950). Казан ун-тында рабфакта укый. Казан авиация з-дында профком рәисе булып эшли. 1939–40 елларда совет-фин сугышында катнаша. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 4 нче гв. армиянең 40 нчы гв. укчы дивизиясендә рота, батальон командиры. 3 нче Украина фронты гаскәрләре составында Украина, Молдавия, Венгрия, Румыния, Югославияне азат итү сугышларында катнаша. 1944 нең 1 декабрендә Дунапатай авылы тирәсендә (Венгрия) Дунайны кичкәндә батырлык күрсәтә. «Выстрел» Югары командирлар курсын тәмамлый (1946), Ташкент шәһәре хәрби комис-тында эшли. Ленин, ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Б е р е з н я к Н.Г. Герои Советского Союза — узбекистанцы. Таш., 1984.

**АБЗА́ЛОВ** Ринат Абзал улы (22.11.1935, Чуаш АССРның Чкалов р-ны Кызыл Чишмә а.), физиолог, биол. фән. д-ры (1987), проф. (1988), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1976), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1988), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2004). 1964 елда Казан пед. ин-тының (2005 тән Татар гуманитар-педагогика ун-ты) физик тәрбия ф-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли: 1975 тән физик культура ф-ты деканы, бер үк вакытта 1988 дән физик культура теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре мускулларга көч килгәндә йөрәк эшчәнлеген көйләү механизмнарын өйрәнүгә карый. Мускуллар

У.Н. А б д у л л о в. 1. «Кечкенә Тукай Печән базарында», 1997; 2. «Иске Казан почмаклары» сериясеннән. 1998.



эшчәнлеге вакытында йөрәк кыскаруы ешлыгының нәселдәнлек факторларына бәйле булуын өйрәнә. Үсү һәм организмның җитлегү процессында мускулларга физик йөкләнеш шартларында йөрәкнең насос функциясенә нерв көйләнеше тәэсиренең кимүен ачыклый (1978). Культурологиянең бер өлеше буларак, физик культура мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. А. тарафыннан мәктәпләр өчен физик культурадан яңа программа төзелә һәм ТРда уку процессына кертелә. «Мәктәптә физик культура» («Физическая культура в школе», 2005) уку ярдәмлеге авторы. РФ Дәүләт Думасының физкультура һәм спорт буенча эксперты (2004 тән). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Движение и развивающееся сердце. М., 1985; Развивающееся сердце и двигательный режим. К., 1998 (автордаш); Теория физической культуры. К., 2002; Насосная функция сердца развивающегося организма и двигательный режим. К., 2005.

*Әд.:* Ш ә р и ф у л л и н Ф.Ә. Физиолог, педагог Ринат Абзалов // Мәгариф. 2005. № 11; А х м е т ш и н а И. Человек, влюблённый в жизнь // Спортивный еженедельник Татарстана. «Ак Барс». 2005. № 52.

**АБЗА́ЛОВА** Венера Галихан кызы (1.2.1940, Башкортстан АССРның Яңавыл р-ны Ямады а.), химик, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2005). 1959 елда Казан җиңел сәнәгать техникумын тәмамлаганнан соң, Чита шәһәрендә тире-мех ф-касында эшли, 1962–64 тә Байкал аръягы фәнни-тикшеренү ин-тында. 1970 тә Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшкә калдырыла. 1973–91 дә «Волга» фәнни-җитештерү берләшмәсендә өлкән инженер, 1991 дән ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. Дәүләт бүләге «Татарский энциклопедический словарь» (1999) һәм «Татар энциклопедиясе сүзлеге»н (2002) төзүгә керткән хезмәтләре өчен бирелә.

**АБЗА́НОВ** Гаделша, татар морзалары нәселе башында торучы. Типтәрләр катлавына кергән Абзановлар 18–19 йөзләрдә Уфа өязе Байгилде авылында яшәгән. А. 1812 елгы Ватан сугышында катнаша, тырышлыгы, үрнәк хезмәте өчен 1813 елда прапорщик дәрәҗәсенә ирешә. 1817 дә подпоручик чинында отставкага чыга. 1824 тән регуляр казак гаскәрләренең 1 нче типтәр полкы сотнигы. 1825 тә А. һәм уллары Александр, Мөхәммәдвәли, Габделвәли Абзановлар Оренбург губернасы дворяннары катлавына теркәлгәннәр.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории уфимского дворянства. Уфа, 1879; А с ф а н д и я р о в А.З. История сёл и деревень Башкортостана. Уфа, 1997, Кн. 7.

*И.Р.Габдуллин.*

**АБЗА́Р ИЯСЕ́**, төрки-татар мифологиясе персонажы, ихатада, сарайда яки ат абзарында яшәүче рух; ияләрнең берсе. А.и.нә ышанулар Казан татарлары, башкортлар һәм мишәрләр арасында таралган. Себер татарлары мифологиясендә Мал иясе, Зәнги (Сәнги) баба һәм Пәшә ана, чуашларда — Карта пусе, якутларда — Исәгәй айысытка туры килә. Ихатада асрала торган барлык мал-туарның яклаучысы дип санала. А.и. бигрәк тә атларга ияләшә. Үз иткән терлекне А.и. чистарта, ашата; атларның ялларын тарый һәм үрә. Үзе яратмаган терлекне әзәрлекли: ач тота, төнлә йоклатмый, хәтта үтерә дә ала. Кайвакыт, төнлә, кеше яки хайван сурәтендә кешеләргә дә күренә. Иртәнге сыер савудан йоклап калган хуҗабикәне тәрәзә шакып уята; төнлә күршесе яки туганы тавышы б-н хуҗаларга аларның сыеры бозаулавы турында әйтә һ.б. Ачуы кабарган А.и. хуҗалар каршына коточкыч кыяфәттә килергә һәм барлык терлекне үтерергә мөмкин; мондый хәл булмасын өчен абзарны чиста тотарга кирәк; А.и. үргән ат ялларын сүтәргә яки кисәргә ярамый; А.и.н юмалау өчен махсус ботка пешерәләр.

Татар фольклорында А.и.нә бәйле сюжетның ике версиясе яшәп килә. Беренчесе буенча, А.и. аерым бер төстәге, гадәттә, кара төстәге терлекләрне яратмый. Икенче версия хуҗаның бер атын яраткан А.и.нең әле генә сатып алынган икенче атны әзәрләкләвен күрсәтә: абзарга килеп кергәч, хуҗа ямьсез кешене күрә. Ул аның икенче атын, аякларын өскә әйләндереп, тагаракка салып куйган. Бу сюжетның дәвамы юк; хуҗаның бәлага тарган атны сатып җибәрүдән башка чарасы калмый.

*Әд.:* Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Татар мифлары. К., 1996; Н а с ы р о в К. Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Зап. Имп. Русского географического об-ва по отделению этнографии. СПб., 1880. Т. 6; К о б л о в Я.Д. Мифология казанских татар. К., 1910.

*Ф.И.Урманчеев.*

**АБИ́ЛОВ** Шакир Шиһап улы (15.7.1915, хәзерге Чиләбе өлкәсенең Коншак р-ны Яңавыл а. — 26.12.2004, Казан), әдәбият белгече, филол. фән. канд. (1961), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1964). Оренбург пед. ин-тын тәмамлый (1938). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1958–86 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. Мөхәммәдъярның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнә, аның «Төхфә-и мәрдан» («Егетләр бүләге») һәм «Нур-ы содур» («Күңелләр нуры») поэмаларын бүгенге әдәби телгә күчерә, басмага әзерли: кереш сүз, искәрмәләр, комментарийлар яза һәм сүзлек төзи. Баласагуни, Кол Гали, Харәзми, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб, Мәүла Колый иҗатларына караган хезмәтләр авторы. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Борынгы татар әдәбияты. К., 1963 (автордаш); Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. Т. 1 (автордаш).

**АБКАЛА́Р КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама аръягында, Идел елгасының биек террасасында, Спас р-ны Ямбакты авылының көнчыгыш кырыенда урнашкан. Су өслеге мәйданы 3,2 *га*. Су күләме 50 мең $м^3$ чамасы. Озынлыгы 350 *м*, иң зур киңлеге 110 *м*. Уртача тирәнлеге 1,6 *м*, иң зур тирәнлеге 3,2 *м*. Күл казанлыгы карст-суффозия процесслары тәэсирендә барлыкка килгән. Суы аз минеральләшкән, бик йомшак, гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**АБЛА́ЕВ** Мансур Мөхәммәт улы (25.12.1917, Казан — 16.6.1980, шунда ук), «Спартак» аяк киеме җитештерү сәүдә-сәнәгать берләшмәсенең ген. директоры (1959–80). Казан күн-аяк киеме техникумын тәмамлый (1936). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1936–37 елларда Саратов күн з-дында. 1937 дән «Спартак» аяк киеме җитештерү сәүдә-сәнәгать берләшмәсендә: смена, тәэминат бүлеге башлыгы, директор урынбасары, ген. директор. Аның җитәкчелегендә предприятиедә технологик реконструкция уздырыла, Чистай, Мамадыш, Йошкар-Ола шәһәрләрендә филиаллары һәм Казанда балалар аяк киеме ф-касы ачыла. Аяк киемен еллык җитештерү күләме 2,5 млн. нан (1950) 11,5 млн. парга (1970) җитә. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АБЛА́ЕВ** Фәрит Мансур улы (10.4.1953, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1995), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2004). 1975 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1978 дән шунда ук эшли. 1998 дән теоретик кибернетика кафедрасы, бер үк вакытта 1995 тән Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тының информатика бүлеге мөдире, проф. (1996). 2006 дан Казан ун-ты һәм ТР ФА каршындагы «Квант информатикасы» тикшеренү үзәге директоры. Хезмәтләре хисаплау һәм алгоритмнарның катлаулылык теориясенә карый. Ихтималый сәбәпләре тәгаен билгеле булмаган яки билгеле булган хисаплау модельләренең чагыштырмача катлаулылыгын тикшерә. Бинар программаларның ихтималый модельләрен кертеп җибәрә һәм катлаулылыкны күпкә кимету мөмкинлеген исбатлый. Очраклылыкның әһәмиятен һәм аның хисаплау катлаулылыгын гадиләштерүдәге ролен ачыклый. А. җитәкчелегендә исәпләүләрдә классик һәм квантлы модельләрнең чагыштырмача мөмкинлекләре өлкәсендә тикшеренүләр үткәрелә, квантлы бинар программа төшенчәсе кертелә, классик детерминияләнгән, ихтималый һәм квантлы тармакланган программа һәм автоматларның чагыштырма катлаулылыгы турында нәтиҗәләр алына.

Х е з м.: Влияние степени изолированности точки сечения на число состояний вероятностного автомата // Математические заметки. 1988. Т.44, вып. 3; Lower bounds for one-way probabilistic communication complexity and their application to space complexity // Theoretical Computer Science. 1996. V. 157; О сложности классических и квантовых моделей вычислений // Математические вопросы кибернетики. 2004. Вып.3.

**АБЛЯ́СКИНО** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 16 *км* төньяктарак, Олы Чирмешән елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2002 елда 224 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 18 йөз ахырында Абляскино Пүчинкәсе авылы буларак нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да ярма ярдыру тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. 1908 дә земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Чистай өязе Егор-

кино волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 1247, 1897 дә — 2021 (мәгълүмат Чияле Алан авылын да кертеп бирелә), 1908 дә — 392, 1920 дә — 452, 1926 да — 425, 1938 дә — 394, 1958 дә — 329, 1970 тә — 383, 1979 да — 290, 1989 да — 192 кеше.

**АБО́ЛИН** Лев Михайлович (9.2.1940, Мәскәү), педагог, психолог, психол. фән. д-ры (1990), проф. (1991), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1999). Ставрополь пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Ставрополь урта мәктәпләрендә эшли, 1969–70 елларда Ставрополь пед. ин-тында укыта. 1973 тән Бөтенсоюз физик культура фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (Мәскәү). 1978 дән Казанда: Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лында психол., 1987 дән Татарстан укытучылар белемен күтәрү (хәзер Мәгарифне үстерү) ин-тында пед. психол. каф. мөдире. 2000 нән Казан социаль-юридик ин-тының психол. һәм пед. ф-ты деканы, бер үк вакытта 2001 елдан Казан ун-ты профессоры.

Х е з м.: Психологические механизмы эмоциональной устойчивости человека. К., 1989; Психологическое развитие ребёнка дошкольного возраста. К., 1991; Духовно-нравственное развитие личности в событийной деятельности. К., 2002.

**АБРА́ЗИЯ** (лат. abrasio — кырылу, ашалу), диңгез, күл һәм сусаклагыч ярларының дулкыннар тәэсирендә җимерелү процессы. А. нәтиҗәсендә текә кыядан һәм мәйданчыктан торган абразияле ярлар барлыкка килә. Татарстан терр-ясендә А. Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында уңъяк ярларның күпчелек өлешенә хас. Казан ярусы известьташлары һәм доломитларыннан торган урыннарда абразияле ишелмә һәм абразияле таралучан ярлар, татар ярусы, юра һәм плиоценның балчык-мергельле утырмаларында күбрәк абразияле шуышма ярлар формалаша. Төп токымнардан төзелгән ярларда А.ле җимерелү киңлеге күп очракта 100 *м* дан артмый. Бу сусаклагычларның сулъяк ярларында А. барышына елганың тугай һәм түбән террасаларын каплап алган сай сулыклар комачаулый; биредә А. дүртенчел чорның көпшәк утырмаларыннан төзелгән текә ярлы урыннарда күзәтелә. Лаеш р-ны Татар Сараланы авылы тирәсендә, ш.у. Спас р-ының Актай һәм Үрдәк елгалары тамагыннан өстәрәк А. нәтиҗәсендә Куйбышев сусаклагычы ярлары 100–200 *м* га чигенгән. Ярлар А.се сусаклагычлар төзелүнең беренче елларында аеруча көчле була (елына 10 *м* га кадәр). Соңрак, дулкыннар энергиясен киметүче абразион мәйданчыкның киңәя баруы нәтиҗәсендә, бу процессның интенсивлыгы кими. Аерым елларда, сусаклагычларда су биеклеге күтәрелгәндә (1979, 1990), А. яңадан көчәеп китә. ТР терр-ясендә А. нәтиҗәсендә сусаклагычларга ел саен 4 млн. $м^3$ чамасы грунт керә.

*Әд.:* Берега Куйбышевского водохранилища. М.–Л., 1962.

*А.П.Дедков.*



Куйбышев сусаклагычы ярлары абразиясе.

**АБРА́МОВ** Василий Семёнович (6.4.1904, Сембер губ., Алатыр өязе Мишуков а. — 3.8.1968, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1961), проф. (1965). А.Е.*Арбузов* һәм Б.А.*Арбузов* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), Казан хим.-технол. ин-тының синтетик каучук химиясе һәм технологиясе кафедрасында, 1937 елдан Казан ун-тының органик химия кафедрасында, 1943–1948 елларда СССР ФАнең Органик химия ин-тында югары молекуляр кушылмалар лаб. дә (Мәскәү, Бөек Ватан сугышы елларында Казанда) эшли. 1948–1960 та Казан хим.-технол. ин-тының синтетик каучук технологиясе каф., 1961 дән Казан хим. фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире, бер үк вакытта Казан вет. ин-тында укыта. Беренче хезмәтләре терпеннар химиясе б-н бәйле. Аннан соңгы тикшеренүләре циклоннарга (циклоннарны углеводородлар б-н кайтару; циклоннарның винил радикаллы һәм галоидлы кушылмалар б-н реакциясе; циклоннар б-н диен синтезы h.б.), галоидалмашкан органик кушылмаларның диалкилфосфит кислоталары тозларына тәэсире б-н бәйле. Бөек Ватан сугышы елларында каучукның махсус билгеләнешле кайбер төрләрен синтезлау б-н шөгыльләнә. Диалкилфосфит кислоталарның карбониль кушылмалар б-н α-гидроксиалкилфосфонат кислоталары эфирлары хасил булу реакциясен ача (к. *Абрамов реакциясе*). 100 дән артык төрдәге эфирны синтезлый, аларның үзлекләрен һәм барлыкка килү механизмын өйрәнә. Тиоколларны тикшерү, аларга пластиклык, өзелмәүчәнлек сыйфатлары бирә торган яңа структуралаштыручы өстәлмәләр табу һәм синтезлау, ш.у. элементорорганик кушылмалар нигезендә гетероатомлы тиоколлар синтезлау эшләренә җитәкчелек итә.



К.А. Абрамов.

Х е з м.: Изучение состава живицы из Pinus insignis // Журн. общей химии. 1932. Т. 2, вып. 4–5 (автордаш); Об алкоксизамещённых эфирах фосфористой кислоты и действии на них галоидзамещённых эфиров // Журн. общей химии. 1949. Т. 19, вып. 5 (автордаш); О взаимодействии диалкилфосфористых кислот с альдегидами и кетонами. Новый метод получения эфиров альфа-оксиалкилфосфиновых кислот // Журн. общей химии. 1952. Т. 22, вып. 4 (автордаш).

*Әд.:* А в е р к о - А н т о н о в и ч И.А. Химия в Казанском университете. К., 1968; Абрамов В.С.: Биобиблиография. К., 1988; Казанский химико-технологический институт вчера, сегодня, завтра. К., 1990. Ч. 2.

*В.Г.Абзалова.*

**АБРА́МОВ** (Хәсәнов) Кыям Алимбәк улы (7.6.1897, Сембер губ., Буа өязе Иске Тинчәле а. — 9.5.1938, Казан), дәүләт эшлеклесе. Иске Тинчәле мәдрәсәсен (1911), Сембер рус-татар мәктәбен һәм укытучылар әзерләү курсын (1917), Татар коммунистик ун-тын (1925) тәмамлый. 1911–16 елларда Екатеринослав шәһәре янәшәсендә ташкүмер чыгару ширкәтендә күмер чабучы булып эшли. 1917–20 дә Буа өязендә укытучы. 1920–21 дә Буа өязе азык-төлек ком-ты инспекторы. 1927–28 дә Казанда ВКП(б)ның Түбән шәһәр райкомы 1 нче секретаре. 1930 елда ВКП(б)-ның Татарстан өлкә ком-тында оештыру бүлеге мөдире. 1930–37 дә ТАССР ХКС рәисе; СССР ҮБК Президиумы әгъзасы. ТАССР икътисадына һәм мәдәниятенә караган хезмәтләр авторы. Ленин ордены б-н бүләкләнә. 1937 нең 31 июлендә кулга алына, репрессияләр чоры корбаны (к. «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы*» *эше*).

Х е з м.: Татарстан в завершающем году пятилетки. К., 1932; Татарстан на рубеже двух пятилеток. К., 1933.

*Әд.:* Б е л я л о в У. Абрамов К.А. // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2; Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2000. Т. 1.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*


**АБРА́МОВ** Николай Александрович (1897, Лаеш өязе, хәзерге Питрәч р-ны Казиле а. — 1973, Яшел Үзән ш.), терапевт, сәламәтлек саклау эшлеклесе. 1933 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казиле авылы хастаханәсенең баш табибе. 1941 дән ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары урынбасары, 1946–50 елларда респ-каның 2 нче клиник хастаханәсе баш табибе (Казан), 1950–52 дә ТАССР сәламәтлек саклау министры.


**АБРА́МОВ** Павел Васильевич (23.2.1914, хәзерге Балык Бистәсе р-ны Шомырбаш а. — 22.9.1992, Казан), географ-икътисадчы, геогр. фән. канд. (1953), проф. (1968), ТАССР-ның атказ. фән эшлеклесе (1969). Керәшен татар. Казан ун-тын тәмамлый (1937). 1937–39

елларда Татарстан китап нәшриятында редактор-картограф. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–56 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы республика партия мәктәбендә укыта, 1957–88 дә Казан финанс-икътисад ин-тында, 1962 гә кадәр ректор, 1962 дән икътисади география һәм планлаштыру каф. мөдире. Хезмәтләре Татарстанны өйрәнү, халык хуҗалыгын үстерү һәм урнаштыру мәсьәләләренә карый. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, шул исәптән П.П.Семёнов исем. алтын медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татарская АССР: Экономико-географическая характеристика. К., 1960; Российская Федерация: Европейский Юго-Восток: Поволжье, Северный Кавказ. М., 1968; Наш край Татарстан. К., 1970 (автордаш).

**АБРА́МОВ РЕА́КЦИЯСЕ**, селтеле металлар алкоголятлары катнашында диалкилфосфитларның карбониль кушылмалар белән гидроксиалкилфосфонатлар хасил итүе:



Реакциягә , группалы гидрофосфориль кушылмалар һәм алифатик, алициклик, ароматик карбониль кушылмалар керә; аларда электронакцептор группалар булу реакция барышына ярдәм итә. Шул рәвешле $(C_2H_5)_3N$ катнашында шикәрләр фосфорильләшә. 1950 елда В.С.Абрамов тарафыннан ачыла. Орган. синтезда, ш.и. хлорофос инсектициды табуда кулланыла.

*Әд.:* В а ц у р о К.В. Именные реакции в органической химии: Справ. М., 1976.

**АБРА́МОВА** Зинаида Ивановна (21.2.1952, Кырым өлкәсенең Бакчасарай ш.), биохимик, биол. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда эшли, 1997 елдан нуклеин кислоталары биохимиясе лаб. дә әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, лаб. мөдире (2006 дан), бер үк вакытта Казан ун-ты биохимия кафедрасы профессоры (2006 дан). Хезмәтләре төш аксымнары биохимиясенә — нуклеин алмашы ферментлары активлыгы көйләнешенең молекуляр механизмнарын өйрәнүгә карый. А. тарафыннан беренче тапкыр бавыр хроматины нейтраль ДНКазасының тыныч күзәнәк төшләрендә ДНКның репликатив синтезын башлап җибәрергә сәләтле булуы тасвирлана; күзәнәкнең үсү, җитлегү һәм картаю процессларында төш ДНКазаларының активлык регуляторлары ачыклана.

Х е з м.: Влияние Ca, Mg — зависимой ДНКазы на синтез ДНК в ядрах эмбрионов морского ежа Strongylocentrotus intermedius // Биохимия. 1987. Т. 52, № 12 (автордаш); Очистка и иммунохимическая характеристика нейтральной ДНКазы // Биохимия. 1993. Т. 58, № 9 (автордаш).

**А́БРУКОВ** Сергей Андреевич (13.9.1921, хәзерге Аксубай р-ны Кече Сүнчәләй а. — 1.5.2006, Чабаксар), физик, Чуаш Респ-касы Фән һәм сәнгать милли академиясе академигы (1994), Чуаш АССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970, 1976). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1948 елда Казан ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1955 тән молекуляр физика каф. мөдире; проф. (1966). 1967 дән Чуаш ун-тында, 1967–96 елларда җылылык физикасы каф. мөдире, бер үк вакытта 1983 кә кадәр директор. 1979 дан тотрыксыз яну физикасы буенча проблемалы фәнни-тикшеренү лаб. җитәкчесе, 1996 дан баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре яну физикасына, яну, газ динамикасы һәм җылы алмашу процессларын оптик ысуллар б-н тикшерүгә карый. Яну процессларын яңача тикшерүнең күләгәле, интерференция һәм голография ысулларын эшли; янганда гистерезис күренешенең механизмын, ялкын вибрацияле таралуның төп закончалыгын ачыклый; электр кырының һәм бушануының янугa һәм яну режимы б-н идарә итүгә тәэсирен ачыклау буенча яңа мәгълүматлар ала. 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теневые и интерференционные методы исследования оптических неоднородностей. К., 1962; Вибрационное распространение пламени. Чебоксары, 1975 (автордаш); Периодические явления при горении. Чебоксары. 1987.

*Әд.:* Академия наук Чувашской Республики. Чебоксары, 1994.

**АБРЫ́СКИНО** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнбатыштарак. 2002 елда 281 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Салдакай авылы пүчинкәсе буларак 1782 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, тимерче алачыгы, вак-төякләр кибете эшли. 1913 тә земство мәктәбе ачыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1276 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркин волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1792 дә — 66, 1859 да — 307, 1897 дә — 531, 1908 дә — 614, 1920 дә — 829, 1926 да — 712, 1938 дә — 652, 1949 да — 540, 1958 дә — 458, 1970 тә — 586, 1979 да — 507, 1989 да — 290 кеше.

**АБСАТТА́РОВ** Әсхәт Әхмәт улы (9.4.1932, Ленинград), хәрби радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1985). 1957 елда А.С.Попов исем. Югары элемтә хәрби-диңгез уч-щесен (Петродворец ш.) тәмамлый. СССР Хәрби-Диңгез флотында хезмәт итә: корабльдә радиотехника хезмәте башлыгы, су асты атом көймәләре өчен йөзмә базаның радиотехника хезмәте башлыгы (1957–59), су асты атом көймәләре берләшмәсенең флагман элемтәчесе ярдәмчесе (1959 дан). 1961 дән Яшел Үзән проект-конструкторлык бюросында: төркем башлыгы (1962–65), радиоэлемтә һәм навигация бүлеге башлыгы урынбасары (1965–70), сектор башлыгы (1970–75), корабльләрнең электр техникасы җиһазлары бүлеге башлыгы (1975–79), әйдәп баручы инженер (1979 дан). Махсус билгеләнештәге корабльләр проектын төзүдә һәм сынауда катнаша. Дәүләт бүләге яңа техниканы үзләштерүдә катнашкан өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**АБУЛА́ДЗЕ** Сергей Владимирович (4.10.1949, Кыргызстан ССРның Фрунзе ш. — 9.11.1995, Казан), хирург, ТРның атказ. табибе (1993). 1972 елда Саратов мед. ин-тын тәмамлый, 1973 тә Казан мед. ин-ты каршында интернатурада укый. 1972 дән Республика клиник хастаханәсендә, 1986–95 тә хастаханәнең баш табибе. 1990–95 елларда ТР ЮС депутаты.

**АБУТАЛИ́ПОВА** Людмила Николаевна (13.11.1948, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1998), проф. (1995). ТРның атказ. җиңел сәнәгать хезмәткәре (1998). РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2004). 1971 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (хәзер Казан технол. ун-ты) һәм шунда ук эшли, җиңел сәнәгать технологиясе ф-ты деканы (1987–2000), 1993 тән конструкциялəү һәм тегү технологиясе каф. мөдире, 2000 нән Җиңел сәнәгать ин-ты директоры. Хезмәтләре ультратавыш тибрәнүләренең органик кушылмалардагы электрохимик реакциягә тәэсирен, тигезләшмәгән түбән темп-ралы плазма агышының тукыма җепләргә, тукымаларга, натураль күнгә, синт. плёнка материалларына тәэсирен өйрәнүгә карый. А. җепьясагыч полимерның химик табигате б-н аны плазмалы эшкәртү сыйфаты арасындагы бәйләнешне ачыклый; җиңел сәнәгать материаллары һәм эшләнмәләренең куллану характеристикаларын яхшыртырга мөмкинлек бирүче ысуллар — үсемлек полимерларын ныгыту алымнарын, тукымаларны утка чыдамлы итеп эшкәртү, күнне плазмалы активлаштыру ысулларын эшли һ.б. фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре гамәлгә кертелә («Спартак», «Сафьян», «Адонис», «Казан җитен комбинаты» АҖләре).ТР Дәүләт бүләге (2003), РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2005).

Х е з м.: Полимеры как новый объект модификации с помощью низкотемпературной плазмы: Текст лекций. К., 1997; Физические основы взаимодействия неравновесной низкотемпературной плазмы с капиллярно-пористыми полимерными материалами лёгкой промышленности. К., 1997.

**АБУТИЛО́Н**, б ү л м ә  ө р ә ң г е с е (Abutilon), тырнакгөлчәләр семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Үләннәр (күбесе күпьеллыклар), куаклар, ярымкуаклар, сирәк кенә кечкенә агачлар. 400 гә якын төре билгеле. Төп үскән җире — Җирнең тропик һәм субтропик пояслары. ТРда 10 га якын төре бар. Аеруча Томпсон өрәңгеләре төрдәше булган кызыл чәчәкле А.ны (A. hibridum maximum) декоратив бүлмә гөле буларак үстерәләр. Озын сабакларындагы кышын коелмый торган яфраклары йомшак мамык б-н капланган, кайбер төрләренеке өрәңге яфракларын хәтерләтә. Чәчәкләре кыңгыраусыман, ак, кызыл яки алтынсу кызгылт-сары төстә, иелгән, озын сабаклы. Яздан алып көзгә кадәр чәчәк ата. Җимеше бүлгәләнгән. Орлыклардан һәм чы-

бычка ялгау юлы б-н үрчетелә. Яктылык һәм дым яратучан үсемлек (аеруча чәчәк аткан-да һәм орлыкланган чорда).

**АБУША́ЕВ** Хөсәен Йосыф улы (псевд. — Абушаев-Атлаши) (19.1.1892, хәзерге Ульянов өлкәсенең, Иске Кулаткы р-ны Иске Атлаш а. — 1961 елдан соң, Казакъстан ССР), шагыйрь. «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. 1916 елдан башлап соңгы көннәренә кадәр Казакъстанда укытучы булып эшли. Шигырьләре 1909–15 елларда «Идел», «Вакыт» г-таларында, «Шура», «Чүкеч» ж-лларында басыла. Аерым шигырьләре «Яңа әдәбият» хрестоматиясенә (1914, төзүчеләре Г.Ибраһимов, Г.Баттал) кертелә. «Алтыннарым» (1915) җыентыгына 22 шигыре керә. Шигырьләрендә тормыштан зарлану мотивлары, халыкны агартуның зарурлыгы темасы чагылыш таба, Тукайга багышланган шигырьләре бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Р ә м и З. XX гасыр башы татар шигърияте // Мирас. 1998.№ 3.

*З.З.Рәмиев.*


**АБЧУ́К** (Scleranthus), канәферчәләр семьялыгыннан берьеллык, сирәк кенә күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 лап төре билгеле, Европа, Азия, Африка һәм Австралиядә киң таралган. ТРда бер төре — берьеллык А. (S. annuus) респ-каның барлык р-ннарында очрый. Басуларда, коры болыннарда, ачык сөзәклекләрдә үсә. 5–20 *см* озынлыктагы яшькелт яки күксел төстәге берьеллык үсемлек. Сабагы көчле тармакланган. Яфраклары кыяклы, капма-каршы чиратлаша. Чәчәкләре куе ярымчатырда. Җимеше — бер орлыклы тартмачык. Май-август айларында чәчәк ата. Терлек азыгы.

**АБЫ́З** авылы, Кама Тамагы р-нында, Карамалы елгасы бассейнында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 20 *км* көнбатыштарак. 2002 елда даими яшәүчеләр юк. Рев-цийгә кадәрге чыганакларда Кече Салтык исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А. да мәчет, 3 җил тегермәне, 2 ярмаяргыч, йон тетү бинасы, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 555,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир заты; 1859 да — 248, 1897 дә — 350, 1908 дә — 398, 1920 дә — 383, 1926 да — 239, 1958 дә — 85, 1970 тә — 48, 1979 да — 33, 1989 да — 10 кеше.

**АБЫЗГИ́ЛДИН** Абрек Әмир улы (1.3.1937, Башкортстан АССРның Баймак ш.) нәкышьче, монументаль сәнгать рәссамы, ТРның халык рәссамы (1995), РФнең атказ. рәссамы (2002), ТАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1986, 2002), РФСАнең мөхбир әгъзасы (2007). Казан сәнгать уч-щесен (1965), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын, К.П.Тутеволь җитәкчелегендәге монументаль нәкышь сәнгате остаханәсен (1970) тәмамлый. 1970 еллар ахырыннан Казанда. 1993–2007 дә ТР Рәссамнар берлеге рәисе. Киңкырлы иҗат диапазонына ия рәссам, станлы һәм монументаль нәкышь өлкәсендә әйдәп баручы осталарның берсе, керәч һәм смальтәлы мозаика техникасын кулланып иҗат итә. Республика шәһәрләренең җәмәгать биналары диварларындагы монументаль бизәлеш композицияләре авторы. Мозаикалары: Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты интерьерындагы «Китап — белем чишмәсе» (1971), Бөгелмә шәһәре Техника йорты фасадларындагы «Фән һәм хезмәт», «Сәнгать һәм спорт» (1972, В.И.Охотин б-н берлектә); фрескалары: Казанда «Акчарлак» ресторанЫ интерьерындагы «Яшьлек» (1973) һәм Яшьләр үзәге бинасы вестибюлендәге «Комсомол тарихы» (1976) һ.б. А.ның станлы нәкышь әсәрләрендә тирән фәлсәфә композициянең оригинальлеге һәм төсләр берелешенең күптөрлелеге б-н үрелеп бара: «Сабан туе» (1973), «Тукай төше» (1975, 1979), «Г.Тукай һәм Шүрәле» (1980) картиналары, «Б.Урманче» (1989), «Сәнгать белгече М.Алпатов» (1990), «Дәрдемәнд» (1997), «София Гобәйдуллина» (1998), «С.Сәйдәшев» (2000) портретлары, антик чор мифлары темасына багышланган рәсемнәр циклы (1974–95). Гамәли бизәлеш сәнгате өлкәсендә керәч юнәлешендә дә эшли. А. тарафыннан ялтыравык йөгертеп шамот балчыктан эшләнгән декоратив тәлинкәләр Казандагы студентлар ашханәсе (1979), Чаллыда бала тудыру йорты (1981) интерьерларын бизи. Халыкара (Германия, 1992; Голландия, 1995, 1997), бөтенроссия (Автономияле респ-калар рәссамнары иҗаты күргәзмәсе, Мәскәү, 1971; «Совет Россиясе», Мәскәү, 1980 һәм «Россия-9», Мәскәү, 1991), зона («Зур Идел») күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Татарстанда (1994, 1995, 1997, 2000, 2007) һәм Башкортстан Респ-касында (2000) оештырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт Сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда һәм «Казан» милли мәдәни үзәгенең Милли мәдәният музеенда, М.В.Нестеров исем. Сәнгать музеенда (Уфа ш.), Каракалпакстан Сынлы сәнгать музеенда (Нукус ш.), шәхси коллекцияләрдә (Германия, Голландия) саклана. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1997). 2003 елда Россия Сәнгать академиясенең көмеш медаленә, 2005 тә Татарстан Рәссамнар берлегенең Б.Урманче исем. бүләгенә лаек була.

*Әд.:* М ә һ д и е в Р. Урал-тауның бер кыйтгасы // Казан утлары. 2007. № 3; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; ш у л у к. Художники Советской Татарии. К., 1984; С а т т а р о в а Л.И. Другое искусство Абрека Абзгильдина // Казань. 1997. № 5/6.

*М.Е.Ильина.*



А.Ә. Абызгилдин.

А.Ә. А б ы з г и л д и н. 1. «Сабан туе». Декоратив тәлинкә (керәч). 1978. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Тукай төше». 1979. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. «Сабан туе». 2001.



1



2



3


**АБЫЗГИ́ЛДИН** Җиһангир Талха улы (1873 — 1938, Уфа ш.), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала, «Чикерткә» һәм «Яз», соңрак «Шура» ж-лларында хезмәттәшлек итә. 1907 елдан «Госмания» мәдрәсәсе мөдире һәм мөдәррисе, 1912 дән Уфа шәһәре ахуны. 4 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда (15–25 июнь, 1914, С.-Петербург) катнаша. 1917 дә мөселманнар Диния нәзарәте казые урынбасары һәм Уфа губернасыннан Учредительләр җыенына делегатлыкка кандидат итеп сайлана. 1920 дән мөселманнар Диния нәзарәтендә: Голәмәләр Шурасы сәркәтибе; имамнар һәм мөәзиннәр әзерләү программасын төзи; дини әдәбият нәшер итү б-н шөгыльләнә, «Ислам мәҗәлләсе» ж-лында хезмәттәшлек итә. Мәдрәсәләр өчен фәлсәфә, астрономия, гигиена буенча дәреслекләр авторы. Репрессияләр чоры корбаны.

Х е з м.: Рух хакында фәлсәфәи җәдидә вә Исламиятка бер назар. Уфа, 1909.

*А.Ю.Хәбетдинов.*

**АБЫЗЛА́Р (АБЫЗАГАЙЛА́Р) ХӘРӘКӘТЕ́,** иҗтимагый-дини хәрәкәт. 16 — 18 йөзләрдә Идел буе һәм Урал алды төбәгендә яшәгән татар халкы арасында киң тарала. А.х. вәкилләре ислам гореф-гадәтләрен һәм мөселман мәгарифен авылларда аерымланып яшәгән


Г.А. Абызов.


Р.Ю. Абязов.

мөселман җәмәгатьләре шартларында сакларга омтылалар. А.х. үзәкләштерелгән бердәм көч тәшкил итми, рәсми хакимияттән читләшүгә йөз тоткан дин әһелләре йогынтысында була. Хәрәкәтнең нигезендә мөселман җәмәгатенең автономияле рәвештә сайланган башлыгы — имам турындагы карашлар ята. А.х. татар җәмгыятенең дини һәм интеллектуаль катлауларының нигезен тәшкил иткән. Рәсми мөселман руханиларыннан аермалы буларак, А.х. мөселманнарның үз хокукларын яклап чыгуын алга сөрә. *Оренбург Мөселман Диния нәзарәте* төзелгәннән соң, абызлар рәсми руханилар карашын кабул итмиләр. 19 йөздә А.х. акрынлап татарлар тупланып яшәгән башка төбәкләргә дә җәелә. А.х. вәкилләре «Болгар кала»ны — Идел-Урал төбәгендә идеаль мөселман дәүләте буларак торгызу идеясен яклыйлар. Бу идея ш.у. Батырша күтәрелешендә катнашучылар, Морад мулла һәм шагыйрь Г.Чокрый тарафыннан яклау таба. 18 йөз ахырында Рус дәүләтенең дини сәясәте үзгәрү, татарларда милли мәгариф системасы барлыкка килү һ.б. факторлар А.х.нең 19 йөзнең 1 нче яртысында акрынлап юкка чыгуына китерә.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Асар. К., 1900. 1 җөзья; Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере. К., 1925; Гайнетдинов М. XVII йөздә татар яңарыш хәрәкәте // Казан утлары. 1976. № 7–8; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Хабутдинов А. Миллет Оренбургского Духовного собрания в конце XVIII — в начале XIX вв. К., 2000.

*А.Ю.Хәбетдинов.*

**АБЫ́ЗОВ** Вадим Гадел улы (17.12.1955, Киев), архитектор, архитектура д-ры (2001), Украина архитектура академиясенең мөхбир әгъзасы (2001). Киев милли архит-ра һәм төзелеш ун-тын (1979), Роттердам торак һәм шәһәр төзелешен үстерү ин-тын (Нидерландия, 1998) тәмамлый. 1979 елдан Киев экспериментал проектлау зональ фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1988 дән Архитектура һәм шәһәр төзү теориясе һәм тарихы фәнни-тикшеренү ин-тында: сектор, бүлек мөдире (1991 дән), баш архитектор (2001 дән), директор (2002 дән), бер үк вакытта Киев милли архитектура һәм төзелеш ун-ты проф. (2002 дән). Хезмәтләре гражданлык биналары һәм шәһәр төзү типологиясенә, архитектура-төзелеш системаларына, Украинаның торак һәм шәһәрләр төзү сәясәтенә, шәһәр төзү менеджментына, тарихи мохитне комплекслы торгызуга, архитектура истәлекләрен һәм мәдәни мирасны саклау һәм алардан файдалануга карый. 40 тан артык торак һәм гражданлык бинасы проектын эшли. Украинаның шәһәр төзү һәм архитектура өлкәсендә законнар чыгара торган һәм норматив-методик документлар авторы. Истәлекләр һәм атаклы торулыклар мәсьәләләре буенча халыкара советның Украина комитеты президенты.

Хезм.: Проектирование торговых предприятий. Киев, 1986 (автордаш); Архитектура общественных зданий с гибкой планировкой. Киев, 1990 (автордаш); Дом, который построил я. Киев, 1996 (автордаш).

*Әд.:* Киевская летопись XXI столетия. Выдающиеся имена и предприятия Украины. Киев, 2002; Киевляне: Библиогр. словарь. Киев, 2004; Ведущие предприятия и организации Украины. Киев, 2005.

**АБЫ́ЗОВ** Григорий Александрович (14.1.1919, Казан губ., Чистай өязе Елантау а.), Сов. Союзы Герое (1.11.1943), полковник (1964). 1940 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 51 нче армиянең 91 нче укчы дивизиясе 321 нче арт. полкы туп командиры. Көньяк һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында, Кырым һәм Украинаны азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 12–23 октябрендә Мелитополь шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. Тбилиси хәрби арт. уч-щесен тәмамлаганнан соң (1949), Совет Армиясендә җитәкче вазифалар башкара. 1979 дан отставкада. Ленин, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Севастополь шәһәрендә яши.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн.1.

**АБЫ́ЗОВ** Рөстәм Гадел улы (29.2.1944, Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск ш.), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1990), проф. (1994). Киев мед. ин-тын тәмамлый (1967) һәм шунда ук оториноларингология кафедрасында эшли. 1972 елдан Киев ГИДУВында, 1973 тән оториноларингология каф. профессоры вазифасын башкара. Төп тикшеренүләре: тавыш аппараты, хроник тонзиллит авырулары патогенезы һәм аларга диагноз кую, дәвалау.

Хезм.: Хронический тонзиллит: Диагностика и консервативное лечение. Киев, 1971; Применение жидких холестерических кристаллов в медицине. Киев. 1977.

**АБЫСТА́Й** (иске татар. абыз — мәгърифәтле), мөселман рухание хатыны; Коръән укучы һәм дини йолалар үтәүне оештыручы. Татарларда А.лар, гадәттә, үз йортларында кыз балалар укыткан. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында А.ларның башлап йөрүе һәм турыдан-туры катнашуы нәтиҗәсендә мәчетләр һәм мәдрәсәләр каршында хатын-кызлар өчен мәктәпләр ачыла (*Мәһруй Барудия мәктәбе, Аитова Фатиха гимназиясе, Ләбибә Хәсәения мәктәбе,* Уфада Гайшә Абызгилдина мәктәбе, Оренбургта Бәһбостан Мөэминова һәм Фатыйма Әдһәмова мәктәпләре, «Иж Буби» мәдрәсәсендә, Рязань губернасының Касыйм өязе Яубалы авылында хатын-кыз сыйныфлары һ.б.). 20 йөз башында А.лар татар җәмгыятенең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында, хатын-кызлар өчен вакытлы басмалар («Сөембикә» ж. һ.б.) нәшер итүдә, матбугатта үзләренең әдәби һәм публицистик әсәрләре б-н катнашалар.

**АБЯ́ЗОВ** Рөстәм Юныс улы (29.3.1959, Казан), скрипкачы, дирижёр, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык артисты (1998). 1982 елда Мәскәү (И.Бочкованың скрипка классы) һәм 1990 да Казан (Ш.Шәрифуллинның композиция классы) консерваторияләрен тәмамлый. 1983–86 да Татар филармониясендә солист, бер үк вакытта Казан музыка уч-щесендә укыта. 1986–96 да Казан консерваториясе каршындагы Махсус музыка урта мәктәбе директоры. 1989 дан «La Primavera» Казан дәүләт камера оркестрын оештыра, аның сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёры. Скрипкачы һәм дирижёр буларак Россия шәһәрләрендә, Украина, Молдавия, Венгрия, Германия, Испания, Франция һ.б. илләрдә гастрольләрдә була, «Европа-Азия» (Казан, 1993, 1996, 1998), «Ак төннәр йолдызлары» («Звёзды белых ночей», С.-Петербург, 1996), «Мәскәү көзе», (Мәскәү, 1998), «Юнселе-99» (Швеция) фестивальләрендә, Волос (Греция, 2001) шәһәрендә үткән 1 нче халыкара фестивальдә катнаша. Инструменталь һәм вокаль әсәрләр авторы. Алар арасында: «Җырга әверелгән» вокаль циклы (1985, Р.Харис шигырьләре), скрипка һәм симф. оркестр өчен «Тукай моңнары» (1986) сюитасы, Скрипка һәм фортепиано өчен соната (1988), кыллы квартет, скрипка һәм саксофон б-н соло башкаруында симф. оркестр өчен концерт-рапсодия (1990), эстрада җырлары һ.б. бар. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2003).

*Т.А.Алмазова.*

**«АВА́З»**, иҗтимагый-сәяси газета. Татар приказчиклары җәмгыяте тарафыннан 1917 елның 8 апреленнән 24 декабренә кадәр Казанда «Өмет» басмаханәсендә атнага 3 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 37 саны чыга. Мөхәррире Ш.Әхмәдиев. «А.» г-тасында илдәге һәм чит илләрдәге сәяси хәлләр яктыртыла, шәһәр һәм волость земствосы органнарына, сайлауларга һәм җир мәсьәләләренә кагылышлы мәкаләләр басыла. Газета эшчеләрне сайлауларда актив катнашырга һәм социалистларны яклап тавыш бирергә чакыра. Аның битләрендә бөтендөнья күләмендә социализм урнаштыру идеяләрен пропагандалауга зур урын бирелә. Рубрикалары: «Дөнья яңалыклары», «Илдәге яңалыклар», «Казанда» һ.б.

**АВА́З ИЯРТЕМНӘРЕ́**, кеше һәм башка җан ияләре чыгарган авазларга, ш.у. төрле әйберләр һәм табигать күренешләренең тавышларына охшатып ясалган сүзләр. Яктылык һәм хәрәкәт күренешләре дә А.и. б-н тасвирланырга мөмкин. Семантик яктан А.и. ике зур төркемгә бүленә: 1) тавыш ияртемнәре; 2) образ ияртемнәре. Тавыш ияртемнәре үзләре биш төркемгә аерыла: 1) кеше сөйләменә, көлүенә, елавына, йөткерүенә охшатып ясалган А.и.: ха-ха-ха, хи-хи-хи; 2) кеше хәрәкәтеннән барлыкка килгән тавышка охшатып ясалган А.и.: шап-шоп (авыр гәүдәле кешенең аяк тавышы), тук-тук (шаку), тыпыр-тыпыр (биючеләрнең аяк тавышы); 3) хайван, кош-корт һәм төрле бөҗәкләр чыгарган тавышка охша-

тып ясалган А.и.: чут-чут (сандугач сайравы), карр-карр (карга кычкыруы); 4) машиналар, механизмнар, эш, сугыш һәм музыка уен кораллары тавышларына охшатып ясалган А.и.: тыр-тыр (трактор тавышы), чатыр-чотыр (янган утын тавышы); 5) табигать тавышларын чагылдыра торган А.и.: чылтыр-чылтыр (чишмә тавышы), у-у-у (җил сызгыруы).

Образ ияртемнәре өч семантик төркемгә бүленә: 1) яктылык күренешләрен чагылдыра торган А. и.: ялт-йолт, ялтыр-йолтыр (ялтырау), җем-җем (җемелдәү); 2) эчке сиземләүләрне һәм соматик реакцияләрне чагылдыра торган А.и.: челт-челт (күзне ачып йому), дер-дер (тәннең калтыравы); 3) кыяфәт һәм характерны чагылдыра торган А.и.: тырт, тырт-мырт (үзсүзле, тиз үпкәли торган кеше турында).

Морфологик яктан А.и. 4 типка бүленә: 1) ялгызак А.и.: лап, шап, выж, чалт; 2) бердәй ике компонентлы А.и.: кых-кых, мыгыр-мыгыр, тук-тук; 3) парлы А.и. ык-мык, шатыр-шотыр, чаш-чож; 4) катлаулы А.и.: хи-ха-ха-ха, бака-ка-ка, фу-у-у-у.

А.и. исем һәм фигыльләр ясау өчен нигез булып хезмәт итәләр. Исемнәр А.и.нә -а/-ә, -га/-гә, -ылте/-елте, -ым кушымчалары ялганып ясалалар: бак-а, кар-га, гөр-елте, йолдыр-ым һ.б.

Аерым очракларда төрле тавышларның тасвирлары метафорик нигездә тавыш ияләренең үзләренә — җанлы һәм җансыз предметларга — күчерелеп, аларның исемнәренә әвереләләр: ләкләк, чыпчык, кәккүк һ.б. Фигыльләр А.и.нә -а/-ә, -ла/-лә, -да/-дә, -на/-нә, -ылда/-елдә кушымчалары ялганып ясалалар; ялтыр-а-у, гү-лә-ү, мыгыр-да-у. Татар телендә А.и. кил- һәм ит- ярдәмче фигыльләре тагылып тезмә фигыльләр ясау да киң таралган: гөлт итү, кых-кых итү, чыр-чыр килү һ.б. А.и. җөмләдә, күбесенчә, рәвеш хәле, сирәгрәк — аергыч һәм хәбәр булып киләләр.

*Әд.:* Татар грамматикасы: 3 томда. М.-К., 1998. Т.2.

**АВАЗБАКИ́ЕВА** Мәһинур Фәтхулла кызы (7.3.1907, Семипалатинск ш. — 8.2.1987, Алма-Ата ш.), физиолог, биол. фән. д-ры (1955), проф. (1958), Казакъстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1979). Казакъ пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1934), Кытайда (Голҗа ш.) СССР консуллыгы каршындагы урта мәктәптә биол. фәнен укыта. 1938–43 елларда Казакъ ун-тында; 1943–86 да Казакъ пед. ин-тында, 1947 дән кеше һәм хайваннар физиологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре кеше һәм хайваннар физиологиясен өйрәнүгә карый. Гомуми матдәләр алмашын, биек тау, чүл шартларында йөрәк-кан тамырлары системасындагы функциональ үзгәрешләрне, гемодинамиканы, кан составын һәм оешучанлыгын тикшерә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние климата Казахстана и Киргизии на организм человека. А.-А., 1958; Об адаптивных реакциях в организме человека в горах // Вестн. АН Казах. ССР. 1979. № 6.

**«АВАНГА́РД»**, арыш сорты. 1927 елда Казан а.х. тәҗрибә станциясендә Е.Н.Борисова тарафыннан кабат серкәләндерелгән Альп арышыннан кат-кат индивидуаль сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Сынау елларында 1 *га* дан 24 *ц* уңыш бирә (җирле стандарт сортка караганда 5,1 *ц* га артык). 1 мең бөртегенең авырлыгы 27,4 *г*. Салкынга, корылыкка чыдам, тутык авыруы б-н сирәк зарарлана. Он ясау — ипи пешерү өчен уртача сыйфатлы. 1929 елда районлаштырыла. 1930 елларда СССРда зур мәйданнар алып тора. 25 елдан артык игелә.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**«АВАНГАРД»**, Азнакай р-нындагы а.х. предприятиесе. 1929 елда «Тымытык» к-зы буларак оештырыла, 1940 та «Авангард» итеп үзгәртелә. «Кызыл байрак» (1950), «Чишмә» (1958),«Коминтерн» (1960) к-злары б-н берләштерелә. 1990 да аның составыннан «Яланкул» к-зы аерылып чыга. 1992 дә колхоз ябык типтагы АҖ итеп үзгәртелә, 1998 дән а.х. җитештерү кооперативы. Тымытык һәм Әгер авылларын үз эченә ала, 556 хуҗалыкта 1628 кеше яши. Үзәк утары — Тымытык авылы. А.х. җирләренең мәйданы 5635 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 4890 *га*, печәнлек һәм көтүлекләр — 736 *га*. Хуҗалыкта



«Авангард» авыл хуҗалыгы кооперативы. Уҗым арышы кыры.

178 кеше эшли (1998). Төп җитештерү тармаклары: игенчелек, чөгендер үстерү һәм терлекчелек. Сөрүлек җирләренең 50% ында бөртекле культуралар үстерелә. Зур мәйданнарда карабодай игелә. Хуҗалык югары җитештерү культурасына ирешкән, игенчелекнең туфрак саклау системасын үзләштергән. 2005 елда «А.» пр-тиесендә а.х. җирләренең 100 гектарына 37 *ц* ит, 261 *ц* сөт җитештерелгән. Бер савым сыердан 3722 *кг* сөт алынган. Хуҗалыкның төп тармакларында продукция җитештерү рентабельле. Хуҗалыкта игенчелек һәм терлекчелекнең алдынгы технологияләре, җитештерүне оештыру һәм идарә итүнең яңа формалары кертелә. «А.» пр-тиесе җирлегендә а.х. культураларын игүдәге алдынгы технологияләр, хезмәтне оештыру һәм түләү мәсьәләләре, колхозларны үзгәртеп кору тәҗрибәсе һ.б. буенча бөтенроссия һәм республика семинарлары уздырыла. Икътисади үсештәге уңышлары өчен СССР ВДНХсының Бөтенсоюз Мактау тактасына кертелә (1980, 1987), 15 эшчегә РФ һәм ТРның мактаулы исемнәре бирелә.

*Г.Х.Хәбибрахманов.*

**АВДЕ́ЕВ** Анатолий Петрович (23.3.1921, Казан — 20.5.1985, шунда ук), журналист, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1971, 1980). Казан ун-тын тәмамлый (1951). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–47 елларда Вена (Австрия) Хәрби комендатура идарәсе секретариаты башлыгы. 1941 һәм 1949–61 елларда «Комсомолец Татарии» г-тасында. 1961 дән «Советская Татария» г-тасының җаваплы сәркәтибе урынбасары, 1972–81 дә әдәбият, сәнгать һәм мәдәни-агарту эшләре бүлеге мөдире. А. эшләгән елларда газетада атналык «Әдәбият һәм сәнгать» сәхифәсе бирелә башлый. Анда татар шагыйрьләре һәм язучыларының әсәрләре, әсәрләрдән өзекләр рус теленә тәрҗемә итеп бастырыла, яңа китапларга күзәтүләр, Татар опера һәм балет театрында, Г.Камал исем. Татар акад. театры һәм Казан Зур драма театрында куелган спектакльләргә рецензияләр бирелә. А.ның юмористик хикәяләре «Чаян» (Казан) һәм «Крокодил» (Мәскәү) ж-лларында басыла. Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Жилина Е. К., 1957; Как я стал боксёром // Первая встреча. М., 1963; С улыбкой в сердце. К., 1965; Бумеранг // Рассказы. К., 1968.

**АВЕ́РКО-АНТОНО́ВИЧ** Ирина Юрьевна (19.4.1960, Казан — 24.1.2006, шунда ук) химик-технолог, химия фән. д-ры (1997), проф. (1999), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1982 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1985 тән Эластомерлар эшкәртү үзәгендә эмульсион полимерлаштыру лаб. мөдире. Хезмәтләре полимерлар синтезына карый. Латекслардан каучук аерып алганда, А.-А. эмульсион һәм суспензион полимерлаштыру процессында электрохимик активлаштыру куллана. Полимер эмульсияләрне тотрыклыландыручы һәм үзгәртүче сыйфатында актив өслекле матдәләр куллануның теоретик һәм практик аспектларын эшли. А.-А.ның фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре «Түбәнкаманефтехим» АҖдә, С.М.Киров исем. синтетик каучук з-дында, Эстәрлетамак синтетик каучук з-дында һ.б. гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Использование поверхностно-активных веществ различных типов в процессах эмульсионной полимеризации // Обзорная информ. / ЦНИИТЭнефтехим. Сер. Пром-сть синтет. каучука., 1989. Вып. 6 (автордаш); Повышение эффективности процессов эмульсионной полимеризации физическим воздействием на водные среды // Обзорная информ. / ЦНИИТЭнефтехим. Сер. Пром-сть синтет. каучука. М., 1991. Вып. 2 (автордаш); Методы исследования структуры и свойств полимеров. К., 2002 (автордаш).

**АВЕ́РКО-АНТОНО́ВИЧ** Людмила Александровна (17.12.1936, Донецк өлкәсенең Луганск ш.) химик-технолог, техник фән. д-ры (1978), проф. (1980), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987). 1959 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук 1993 кә кадәр эшли. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар физикасына һәм химиясенә карый. Тикшеренүләре полисульфид олигомерлар (сыек тиоколлар) б-н бәйле. Сополимер тиоколларның яңа типларын синтезлый һәм тәкъдим итә, шуларның берсе җитештерүгә кертелә һәм махсус техниканың җитди проблемаларын хәл итә. А.-А. җитәкчелегендә төзелеш герметиклары эшләнә,

алар беренче тапкыр эре панельле йортлар һәм Казан циркы төзелешендә файдаланыла; түбән темп-рада төрле химик табигатьле олигомерларны катализатор ярдәмендә бергә катырып, яңа төр материаллар алына, алардан тиоуретанлы һәм тиоэфирлылары сәнәгатькә кертелә. Гомуми кулланышлы каучукны вулканлаштыру вакытында, күкерткә донор буларак, күкертнең олефиннар, диеннар б-н булган сополимерларын кулланырга тәкъдим итә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Полисульфидные олигомеры и герметики на их основе. Л., 1983 (автордаш); Химия и технология синтетического каучука: Учеб. Л., 1987 (автордаш); Модификация герметиков на основе полисульфидных олигомеров: Обзор // Высокомолекулярные соединения. 1989. Т. 31А, № 2 (автордаш).

*Әд.:* Казанский химико-технологический институт вчера, сегодня, завтра. К., 1990. Ч. 2.

**АВЕ́РКО-АНТОНО́ВИЧ** Юрий Олегович (13.12.1937, Казакъстан ССРның Усть-Каменогорск ш.), химик-технолог, химия фән. канд. (1968), проф. (1990), 1959 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. Хезмәтләре полимерлар химиясенә карый. А.-А. каталаулы олигоэфирларны синтезлый һәм алар нигезендә туендырылмаган әвәләнүчән уретан каучуклар алуга ирешә; резиналарның физ.-хим. һәм техник үзлекләрен, эшкәртү үзенчәлекләрен, куллану характеристикаларын өйрәнә; бу полимерларның төзелеше һәм үзлекләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклый. Югары уку йортлары өчен төзелгән дәреслек һәм уку ярдәмлекләренең авторы һәм автордашы.

Х е з м.: Структура и свойства ненасыщенных уретановых каучуков на основе сложных полиэфиров // Синтез и физико-химия полимеров. 1973. Вып. 12; Химия и технология синтетического каучука: Учеб. Л., 1987 (автордаш); Технология резиновых изделий: Учеб. пособие. Л., 1991 (автордаш).

*Әд.:* Казанский химико-технологический институт вчера, сегодня, завтра. К., 1990. Ч. 2.

**«А́ВЕРС»**, медицина коммерция банкы ҖЧҖ. 1990 елда Казанда оештырыла. Оештыручылары: ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы, ТР Финанс министрлыгы, «Ильдан» фирмасы, «Татарстанфармация» җитештерү берләшмәсе. «А.» сәламәтлек саклау оешмаларын финанслау һәм льготалы кредитлауны, үз карамагындагы торак йортлар программасын инвестицияләүне, чит ил валюталары, кыйммәтле кәгазьләр б-н эш итүне, эшсезлек буенча компенсация һәм пособиеләр түләүне гамәлгә ашыра. Республика инвалид балаларны реабилитацияләү үзәгенә финанс ярдәме күрсәтә. 2000 елдан «А.» эшчәнлек юнәлешен үзгәртә: икътисадның реаль секторын кредитлауны гамәлгә ашыра, кыйммәтле кәгазьләр б-н эш итә, пластик карталар чыгара, физик һәм юридик затларга банк хезмәте күрсәтә. Филиалы Чаллы шәһәрендә. Устав капиталы 600 млн. сум. Банк эшендә ТАИФ компанияләре төркеме катнаша. РФ һәм ТРның 21 банкы б-н хезмәттәшлек итә (2007).

**АВЕРЬЯ́НОВ** Василий Игнатьевич (8.1.1936, Апас р-ны Янгелде а.), механизатор, Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры (1983). 1958–96 елларда Апас р-ны Г.Тукай исем. к-з тракторчысы. Колхозда беренчеләрдән булып коллектив подряд нигезендә эшләүче механикалаштырылган звеноны җитәкли. 1982 дә звено бөртеклеләрдән 35,8 *ц/га*, районның уртача күрсәткеченнән бер ярым тапкыр күбрәк уңыш ала. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.


Василий И.Аверьянов.

*Әд.:* Г о н ч а р о в В. Честь по труду // Сельская жизнь. 1983. 12 янв.; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**АВЕРЬЯ́НОВ** Виталий Иванович (11.1.1931, Казакъстан ССРның Кустанай өлкәсе Югары Кут пос. — 20.10.1984, Казан), геолог-палеонтолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1973), проф. (1974). Казан ун-тын тәмамлый (1953). 1962–74 елларда ВНИИгеолнерудта, 1974–75 тә Ивано-Франковск нефть һәм газ ин-тында (Украина ССР), 1975–83 тә Казан төзүче-инженерлар ин-тында эшли. Рус платформасының көнчыгышындагы югары девон утырмаларында остракодлар һ.б. казылма байлыкларның характерлы комплексларын ачыклый. Татарстан һәм аның б-н чиктәш регионнардагы девон утырмаларында нефть табу һәм биостратиграфия, палеогеография мәсьәләләрен тикшерә һәм шуның нәтиҗәсендә Тимань төбәгендә, Көнбатыш Уралда, Рус платформасының көнчыгышында девон чорындагы палеогеографик торыш ачыклана.

Х е з м.: О взаимосвязи зоогеографических провинций центральной и восточной частей Русской платформы в эйфельское время // Докл. АН СССР. 1960. Т. 132, № 4; О дробном расчленении средней и нижней части верхнего девона на востоке Русской платформы // Тр. Казан. геол. ин-та. 1970. Вып. 26.

**АВЕРЬЯ́НОВ** Григорий Дмитриевич (28.12.1936, Биектау р-ны Зур Дербышки а. — 31.5.2007, Казан), агроном, ТАССРның атказ. агрономы (1980). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, Югары Ослан р-ның «Заветы Ильича» к-зында агроном. 1965 елдан Казан а.х. ин-тының гомуми җир эшләре каф. укытучысы, 1969 дан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында бөртекле-кузаклы культуралар лаб. мөдире, директор урынбасары, 1988 дән Бөтенроссия а.х. фәнни-тикшеренү һәм проект-технология ин-тының Идел-Вятка ф-лында а.х. культураларын үстерүнең интенсив технологияләр лаб. мөдире. 1995–2004 тә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында, 1998 дән гыйльми секретарь. Хезмәтләре шикәр чөгендере һәм яшел борчак агротехникасына, туфракны эшкәртү системасын камилләштерү мәсьәләләренә карый. Татар энциклопедиясендә шул ук тематика буенча күп кенә мәкаләләр авторы. Татарстанда игенчелек системасын эшләүгә зур өлеш кертә.

Х е з м.: Пласты плодородия. К. 1983; Безотвальная система обработки почвы в Татарской АССР // Кукуруза и сорго. 1988. № 5 (автордаш); Системы земледелия Татарской АССР. К. 1988 (автордаш).

**АВЕРЬЯ́НОВА** Лидия Арсентьевна (4.3.1960, Биектау р-ны Киндерле а.), спортчы (академик ишү), СССРның атказ. спорт остасы (1984). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1983). Спорт б-н 1974 елда Казанда «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тренер С.М.Ульянова шөгыльләнә башлый. СССР чемпионы (1983–89), дөнья чемпионы (1983, 1985–86), «Дуслык-84», «Игелекле уеннар» (1986) халыкара ярышларында җиңүче; дөнья беренчелегендә бронза медаль ала (1987), Сеул шәһәрендә үткән Олимпия уеннарында катнаша (1988). 1978–94 елларда ТРның Физик культура, спорт һәм туристлык дәүләт ком-тында инструктор. 1995 елдан Мәскәүдә яши.

**АВЕРЬЯ́НОВКА** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 12 *км* көнчыгыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2002 елда авыллар исемлегеннән сызыла. 19 йөз башында нигез салына. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1885 тә А.да чиркәү-приход мәктәбе ачыла. 20 йөз башында вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 349 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 218, 1897 дә — 319, 1908 дә — 404, 1920 дә — 454, 1926 да — 473, 1938 дә — 339, 1949 да — 242, 1958 дә — 196, 1970 тә — 118, 1979 да — 64, 1989 да — 23 кеше.

**АВЗАЛО́ВА** Әлфия Авзал кызы (15.1.1933, Башкортстан АССРның Калтасы р-ны Кабан а.), җырчы, ТАССРның халык (1970), РСФСРның атказ. артисткасы (1983). Профессиональ сәхнәгә үзешчән сәнгатьтән килә. А.ның иҗади үсешенә А.Ключарёв, З.Әхмәтова, Р.Тимерханова йогынты ясый. 1957 елдан Татар филармониясе артисткасы. ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле солисты буларак, Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында ясаган чыгышлары җырчыга беренче уңышлар алып килә (1957). Халык вокаль традицияләренең хәзерге эстрадага хас үзенчәлекләр б-н бергә кушылуы, милли аһәңнәрнең байлыгы, эмоциональлек һәм ихласлык, тавышының матурлыгы һәм яңгырашы А. стиленең нигезен тәшкил итә. Татар халык җырларын иң яхшы башкаручыларның берсе. «Шахта», «Гөлҗамал», «Өй артында шомыртым», «Сарман», «Минзәлә», «Казан сөлгесе», «Зөләйха», «Шәл бәйләдем», «Актаныш басмалары» кебек татар халык җырларын; татар композиторлары Ф.Латыйпов, С.Садыйкова, А.Монасыйпов, үзешчән автор-

лар Ф.Әхмәдиев, Л.Айтуганов, В.Әхмәтшин, З.Гыйбадуллин, М.Имашев һ.б.ның әсәрләрен башкара. Аның репертуарында башкорт, казакъ, үзбәк, әзәрбайҗан һ.б. халыклар җырлары да бар. Репертуарын дөнья халыклары (һинд, гарәп, фарсы һ.б.) җырлары б-н баета. Радио, телевидениедән чыгышлар ясый. Мәскәү, Уфа, Ташкент, Себер шәһәрләрендә, Ерак Көнчыгышта гастрольләрдә була. Эстрада артистларының бөтенроссия конкурсы лауреаты (Мәскәү, 1961). ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1992). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары б-н бүләкләнә.


Ә.А. Авзалова.

Ә с ә р.: Үзем турында: Җыр, сәхнә — минем тормышым, язмышым. К., 1995.

*Әд.*: З ә й н а ш е в а  Г. Кәккүк // Казан утлары. 1970. № 3; Ю с у п о в а  Р. Күктә йолдызлар атыла // Азат хатын. 1988. № 5; С е м ё н о в  Г. Татарский соловей // Театр. жизнь. 1964. № 62; Народные артисты. К., 1980.

**АВИА́ЦИЯ** (франц. *aviation*, лат. *avis* — кош), атмосферада һавадан авыррак аппаратларда очу теориясе һәм практикасы. А. төшенчәсе берничә фән тармагын, аэродинамика, аэронавигация, төзелеш механикасын, ш.у. авиация сәнәгатен (самолётлар, вертолётлар, двигательләр төзү), һава транспортын, аэроклубларны һ.б. үз эченә ала. ТРда өч эре авиация з-ды: *Казан авиация җитештерү берләшмәсе* (КАПО), *Казан вертолёт заводы* (КВЗ), *Казан моторлар төзү берләшмәсе* (КМПО) һәм очкыч аппаратлар өчен радиоэлектрон һ.б. җиһазлар эшләп чыгара торган берничә пр-тие урнашкан. ТР гражданнар һава флотында 150 ләп самолёт һәм вертолёт, 9 авиакомпания исәпләнә (2000). Авиация белгечләре әзерләүне Казан техника ун-ты (1992 елга кадәр Казан авиация ин-ты — КАИ), Казан авиация техникумы һәм ТР Аэроклубы гамәлгә ашыра.


КАИ-1 пассажир самолёты.


КАИ-1 пассажир гидросамолёты.

Казанда авиациянең башланып китүе хәзерге заман аэродинамикасына нигез салган Н.Е.Жуковскийның эшен дәвам иттерүче, 1910 да Казан ун-тында һавада очу түгәрәге оештырган һәм 1911 дә «Һавада очу» курсын укыта башлаган проф. Д.Н.*Зейлигер* исеме б-н бәйле.

1919 да Казанда политехника ин-ты ачыла (директоры — Д.Н.Зейлигер), ин-тның механика ф-тында аэродинамика лабораториясе оештырыла.

СССР Хөкүмәте 1931 дә Казанда самолётлар, авиация моторлары җитештерү буенча эре авиация комплексы төзү һәм шәһәрдә авиация техникасы белгечләре әзерләү өчен институт һәм техникум ачу турында карар кабул итә. Д.Н.Зейлигерның шәкерте проф. Н.Г.*Четаев* Казан ун-ты каршында аэродинамика бүлеге (1931) һәм аэродинамика белгечләре әзерләү лабораториясе (беренче чыгарылыш 1934 елда) оештыра, 1932 елда лаборатория җирлегендә Казан авиация ин-ты ачуга ирешә.

Татарстан башкаласы Казанда 1924 тә Арча кырында беренче аэропорт төзелә. 1932 дә 124 нче авиация з-ды (хәзер КАПО) корыла башлый һәм планёрда очучылар мәктәбе ачыла. Шул ук елда очкыч аппаратларны сынау өчен аэродинамик торба төзелә. 1933 елда Казан аэропортында өч У-2 самолёты даими рәвештә урнаша. Салына башлаган 124 нче з-дның, 1933 тә КАИ каршында оешкан Казан аэроклубы һәм авиаотрядының үз У-2 самолётлары була. Транспорт өчен детальләр җитештерүче 169 нчы з-д (соңрак 387 нче, хәзер КВЗ) 1935 тән самолёт чаңгылары эшләп чыгара. Казан авиация ин-тының тәҗрибә КБсы (ОКБ), 124 нче з-д б-н берлектә, 1934 тә КАИ-1 тибындагы ике моторлы беренче аэроплан төзи. Шул ук елда КАИ-1 планёры һавага күтәрелә. КБ эшләү чорында (1940 ка кадәр) дүрт КАИ-1 самолёты, КАИ-1, КАИ-2 һәм КАИ-3 тәҗрибә планёрлары, ДКЛ һәм УК-1 самолётлары күккә күтәрелә. 1939 да 124 нче з-д (1941 дән 22 нче з-д) еракка оча торган биш ДБ-А, ике Пе-8 һәм АНТ-20 («Максим Горький») бомбардировщиклары эшләп чыгара. Соңга таба завод яңадан Пе-8 самолётлары чыгара, Ли-2 транспорт машиналары һәм 1941 дән Пе-2 бомбардировщигы җитештерүне үзләштерә.

1941–45 тә Татарстан авиация з-длары Мәскәү, Ленинград һәм Воронеждан эвакуацияләнеп килгән пр-тиеләр б-н берлектә фронт өчен барлыгы 20,5 мең хәрби самолёт (Пе-2, Пе-8 һәм По-2) һәм 20 меңләп ВК-105 мотор эшли. Авиация ин-тында аэродинамика, самолётлар ныклыгын һәм ВК-105 двигательләрен камилләштерү буенча тикшеренүләр алып барыла. 16 нчы з-дта (хәзер КМПО) беренче РД-20, РД-500 һәм РД-45 совет реактив двигательләре җитештерелә. 1950 еллардан 22 нче з-д (хәзер КАПО) Ту-16 һәм Ту-104 авыр реактив самолётлар эшләп чыгаруны уңышлы үзләштерә. 16 нчы з-д шул машиналар өчен двигательләр җитештерә. Ми-4 вертолётларын җитештерү (елына 330 данәгә кадәр) 387 нче з-дта гамәлгә ашырыла. КАИның аерым студентлар


По-2 самолёты.


Пе-2 самолёты.

КБсында илебездә беренче буларак планёрларның берничә тибы эшләнә (1959), шуларның икесе серияләп җитештерүгә кабул ителә.

1960–90 елларда 22 нче з-д тавыштан тизрәк оча торган Ту-22 самолётларын, Ил-62 аэрофлот флагманнарын, стратегик ракета йөртүче Ту-22 М һәм Ту-160 хәрби самолётларын эшләп чыгара. 16 нчы з-дта Ил-62 һәм Ту-154 самолётлары өчен НК-8 двигательләре, аннары Ил-86 аэробуслары өчен НК-86 двигательләре җитештерелә. КВЗда 1966 дан Ми-8 вертолётлары һәм

Пе-8 самолётлары.




**Авиация** һәм **Авиация сәнәгате** мәкаләләренә. Самолётлар. 1. Ту-4; 2. Ту-16; 3. Ту-22У; 4. Ту-22М3; 5. Ту-160; 6. Ил-62; 7. Ту-214.

аларның модификацияләре эшләп чыгарыла. Авиация ин-тында очкыч аппаратларның 20 дән артык тибы (дельтапланнардан алып самолётларга кадәр) конструкцияләнә һәм төзелә.

1990 елларда Казанда авиация техникасы проблемаларына караган тикшеренү эшләре тагын да үсеш ала. Казан техника ун-тының фәнни-тикшеренү бүлегенә 2 инженерлык үзәге, 60 тан артык проблемалы, тармак һәм фәнни-тикшеренү лабораторияләре һәм студентларның 10 КБсы керә.

2000 елдан КАПО Ту-214 самолёты эшләп чыгара. Ту-324 самолёты эшләп чыгаруга әзер. Вертолёт з-ды Ми-8, Ми-17 тибындагы вертолётлар җитештерә, җиңел вертолётлар «Ансат» һәм «Актай», урта класслы Ми-38 вертолётларын серияләп җитештерүгә әзерли. КМПО, авиация двигательләре җитештерү б-н беррәттән, газ кудыру агрегатлары эшләп чыгару б-н шөгыльләнә, пр-тиедә НК-93, АИ-22 һәм PW-207К тибындагы авиация двигательләре җитештерүгә әзерлек эшләре алып барыла.

Казан авиация ин-тында 1958 дә «Известия высших учебных заведений» сериясенә керnum «Авиационная техника» ж-лы нәшер ителә башлый. Ул инглиз теленә тәрҗемә ителә һәм дөньяның 30 лап иленә тарала. 1998 дә Казан техника ун-ты һәм Казан вертолёт з-ды мәгълүмати-техник «Вертолёт» ж-лы оештыралар.

*Әд.:* Ибрагимов Р.А. Крылья Татарстана. К., 1984; Казанский авиационный институт. М., 1992; Вениаминов Р. Запас прочности // Казань. 1999. № 3/4; Иванов А.А. Авиаторы Татарстана в годы Великой Отечественной войны (1941–1945 гг.). К., 2000.

*Р.Г.Вениаминов.*

**АВИÁЦИЯ СӘНӘГАТÉ**, машиналар төзү тармагы. Гражданлык һәм хәрби өлкәләрдә кулланыла торган очкыч аппаратлар, агрегатлар, алар өчен узеллар һәм детальләр җитештерә. Җитештерү югары дәрәҗәдә кооперацияләшкән һәм концентрацияләнгән, техник яктан иң югары үсешкә ирешкән тармакларның берсе. ТРның машиналар төзү өлкәсендә әһәмиятле урын алып тора. Продукция җитештерү күләме, төп сәнәгать җитештерү фондларының бәясе һәм эшләүчеләр саны буенча А.с. респ-ка машиналар төзелеше сәнәгатенең 22, 12 һәм 15% ын, ә тулаем сәнәгатьтә — җитештерү күләме һәм төп фондларның бәясе буенча 2,9% ын (1998) (к. табл.) алып тора. ТРда куәтле фәнни-техник һәм җитештерү көченә ия булган авиация комплексы эшли: аңа *Казан авиация җитештерү берләшмәсе* (КАПО), «*Казан моторлар төзү берләшмәсе*» *АҖ* (КМПО), «*Казан вертолёт заводы*» *АҖ* (КВЗ) һәм аларның ф-ллары, «*Электроприбор*» АҖ, «*Радиоприбор*» АҖ, *самолёт*лар *төзү*, *вертолёт*лар *төзү*, *двигательләр төзү*, электр-радиоприборлары эшләү, спорт авиациясе буенча тәҗрибә-конструкторлык оешмалары; авиацион технологияләр һәм җитештерүне оештыру (Госимпром-КНИАТ), двигательләр төзү (НИИД), радиоэлектроника («Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү үзәге), авиация сәнәгате пр-тиеләрен проектлау (Гипроавиапром) буенча фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру институтлары керә. А.с. мәсьәләләрен хәл итүдә Казан техника ун-тының тармак һәм проблемалы лабораторияләре катнаша. А.с. үсеше процессында бу тармаклар өчен респ-када югары квалификацияле белгечләр әзерләү системасы булдырыла — Казан авиация ин-ты, Казан авиация техникумы, ш.у. Казан белгечләрнең квалификациясен күтәрү ин-ты.

А.с. респ-када 1932 елдан Казанда авиакомбинат — самолётлар, двигательләр, винтлар, арматуралар, беркетү детальләре җитештерү з-длары комплексын корудан башланып китә. Бер үк вакытта ярдәмче производстволар да үсеш ала (ТЭЦ, су җыю җайланмасы, тимер юл һәм трамвай парклары,



Вертолётлар. 1. Ми-1; 2. Ми-4; 3. Ми-8; 4. Ми-14; 5. Ми-8МТВ; 6. Ми-17; 7. Ми-172; 8. «Ансат»; 9. «Актай».

силикат кирпеч з-ды, икмәк з-ды). 1937 дә аларга ТБ-1, ТБ-3 тоташ металл бомбардировщиклар ремонтлаучы һәм ДБ-А, ТБ-7, МТ, ДС-3 машиналарын аз серияләрдә эшләүче 124 нче самолётлар төзү з-ды сафка баса. Бөек Ватан сугышы алдыннан пике ясарга сәләтле Пе-2 бомбардировщигын җитештерү үзләштерелә. 1940 та двигательләр з-ды төзелеп бетә. Арба-чана детальләре з-дында авиачаңгылар җитештерү башлана. 1940 ел ахырына авиатөзелеш респ-када машина төзелешенең төп тармагына әверелә: респ-каның төп сәнәгать җитештерү фондлары бәясенең 80% ы, барлык эшләүчеләрнең 70% тан артыгы, җитештерү күләменең 60% тан артыгы бу тармакка туры килә.

Бөек Ватан сугышы елларында Казанга фронтны хәрби самолётлар һәм двигательләр б-н тәэмин итә торган С.П.Горбунов исем. 22 нче Мәскәү авиация з-ды, 16 нчы Воронеж моторлар з-ды, 387 нче Ленинград авиация з-ды эвакуацияләнә. Сугыш елларында якынча 10 мең Пе-2, 11 меңнән артык По-2 (У-2ВС) бомбардировщигы һәм 20 мең чамасы ВК-105 двигательләре төзелә; продукция эшләп чыгаруның күләме 7,5 тапкыр, сәнәгать җитештерү фондлары бәясе 2,1 тапкыр, эшчеләр саны 2 тапкыр арта. Эвакуацияләнгән заводлар сугыштан соң Татарстанда кала. Республиканың А.с. илнең гражданлык һава флотын һәм хәрби һава көчләрен техник яктан яңадан коралландыруда әһәмиятле роль уйный, аларны А.Н.Туполев конструкциясендәге югары класслы Ту-4, Ту-16, Ту-22 самолётлары, С.В.Ильюшин конструкциясендәге Ил-62 б-н тәэмин итә. 1996 дан С.П.Горбунов исем. Казан авиация з-дында Ту-214 самолётын җитештерү үзләштерелә; Ту-330 транспорт-йөк һәм Ту-324 пассажир самолётларын җитештерүгә әзерлек бара.


Казан моторлар төзү берләшмәсендә Ту-104 самолётлары өчен газ турбиналы РД-3М500 двигательләре һәм Ил-62 самолётлары өчен турбореактив НК 8–4 двигательләре җитештерелә. Ту-154 самолётлары өчен НК-8–2У, Ил-86 самолётлары өчен НК-86 турбореактив двигательләр әзерләнә. Газ суырту станцияләре өчен НК-16СТ, НК-18СТ газ турбиналы двигательләр эшләп чыгарыла.

Вертолётлар төзү зур үсеш ала. «Казан вертолётлар төзү заводы» АҖ исемлегендә М.Л.Миль конструкциясендәге Ми-4, Ми-8, Ми-14, Ми-17 вертолётлары, ш.у. хәрби һава

1940–98 елларда республиканың сәнәгать һәм машина төзелешендә төп техник-икътисад күрсәткечләре буенча А.с.нең тоткан урыны

| | 1940 | 1945 | 1957 | 1961 | 1965 | 1980 | 1998 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| А.с.нең республика сәнәгатендәге өлеше (%): | | | | | | | |
| продукция җитештерү күләме буенча | 12,7 | 44,3 | 18,1 | 16,6 | 12,3 | 11,9 | 2,9 |
| төп сәнәгать-җитештерү фондларының бәясе буенча | 38,4 | 35,4 | 31,2 | 14,6 | ... | ... | 2,9 |
| А.с.нең республика машина төзелешендәге өлеше (%): | | | | | | | |
| продукция җитештерү күләме буенча | 60,6 | 67,8 | 63,1 | 57,0 | 46,3 | 38,2 | 22,2 |
| төп сәнәгать-җитештерү фондларының бәясе буенча | 80,0 | 70,1 | 60,3 | 54,8 | ... | ... | 12,4 |

* Югарыда бирелгән күрсәткечләр 1998 елдан соңгы статистик белешмәлекләрдә китерелми.




Авиация двигательләре. 1. ВК-105ПФ; 2. РД-3М-500; 3. НК-8-4; 4. НК-8-2У; 5. НК-86; 6. НК-16-18СТ.

көчләре һәм гражданлык авиациясе өчен Ми-38 яңа буын машиналары бар. 2004 тә заводта «Ансат» маркалы җиңел вертолётны серияләп җыю башлана. 1990 нан Казан вертолётлар төзү з-дының 70% продукциясе чит илләргә чыгарыла.

Респ-каның А.с. пр-тиеләре югары җитештерүчәнлеккә ия булган җайланмалар б-н җиһазландырылган. Барлык төп җитештерү процесслары механикалаштырылган һәм автоматлаштырылган, заманча очкыч аппаратлар төзергә мөмкинлек бирә торган югары технологияләр эшләнә һәм үзләштерелә. Титанны вакуумда 160 *мм* тирәнлектә эретеп-ябыштыра торган җайланма эшләнә. Җөйләрне тоташ автоматлаштырылган тикшерү гамәлгә ашырыла. Озынлыгы 30 *м* га җиткән катлаулы профильле панельләрне эшкәртә торган автомат линия эшли. Очкыч аппаратлар җитештерүдә эшне җиңеләйтә һәм сыйфатны яхшырта торган программалар һәм техник чаралар файдаланыла. Самолётлар төзүдә титанлы, алюминий-литийлы яңа эретмәләр кулланыла. Вертолётлар төзелешендә күтәрүче винтның югары ресурслы канатларын полимер-композицион материаллардан җитештерү өйрәнелә, очкыч аппаратларны клёпкалау һәм буяу, үткәргеч торбалар җыю процессларының автоматлаштырылган яңа технологияләре кертелә. Двигательләр төзелешендә җитештерүне әзерләүнең технологик процесслары б-н идарә итү автоматлаштырыла. Конструкторлар тарафыннан космос, ракета һәм авиация техникасы өчен күпсанлы уникаль приборлар һәм системалар эшләнә. 1990 еллардан базар мөнәсәбәтләренә күчүгә бәйле рәвештә, респ-каның А.с.ндә нык үзгәрешләр бара. ТРның А.с. продукциясе дөнья базарында конкуренциягә сәләтле.

*Әд.:* Татарская АССР за 40 лет: Стат. сб. К., 1960; Греньков А.И. Отраслевой район авиастроения и проблемы планового управления его экономикой. Казанский филиал НИАТ. К., 1962; Гильманов З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне (1941–45 гг.) К., 1977; Сабиров Г.Т., Хафизов А. Расчёт на лизинг. Первые шаги «КАПО-Туполев» // Казань. 1999. 3/4.

*А.И.Сурская, Г.Я.Мәүлетова.*


**АВИ́ЛОВ** Вадим Александрович (30.9.1907, Могилёв ш. — 19.12.1967, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1965), проф. (1967). 1928 елда Мәскәү икътисад-статистика ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан хезмәтне фәнни оештыру ин-тында, 1934–37 елларда бүлек җитәкчесе. 1937 дән Казан хим.-технол. ин-тында укыта, 1942 дән икътисад һәм җитештерүне оештыру каф. мөдире. Хезмәтләре техник-икътисади тикшеренүләрдә матем. статистика ысулларын куллану, технол. процессларның төгәллеген билгеләү мәсьәләләренә карый. Сәнәгатьтә җитештерү резервларын тикшеренүнең фәнни юнәлешен булдыра.

Хезм.: Научная организация труда в промышленности. К., 1966; Математико-статистические методы технико-экономического анализа производства. М., 1967.

**АВИ́ЛОВА** Вилора Вадимовна (29.1.1955, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1997), проф. (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан технол. ун-тында (1978–81 дә һәм 1993–96 да бүленеп) эшли, 1996–2002 елларда декан, 1997 дән икътисад каф. мөдире. ТРның Сәүдә-җитештерү палатасы рәисе урынбасары (2000), ТР икътисады буенча фәнни-методик берләшмә җитәкчесе (2006 дан). Хезмәтләре җитештерүне специальләштерүгә һәм хуҗалык итүнең яңа төрләрен өйрәнүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә, РФнең мактаулы югары проф. белем мәктәбе хезмәткәре (2001).

Хезм.: Основы функционирования предприятий в рыночных условиях. СПб., 1995.

**АВЛАКОГЕ́Н** (грек. áulax — буразна һәм génos — туу), Җир кабыгының борынгы платформасы *кристаллик нигезендә* яткан озын чокырга охшаш эре бөгелеш. Атама СССР ФА академигы Н.С.Шатский тарафыннан кертелә (1960). А.ның озынлыгы — берничә йөз, киңлеге — дистәләрчә *км* га кадәр. Утырма, сирәгрәк вулканик тау токымнары б-н тула һәм аларның гомуми калынлыгы берничә *км* га җитә. А.нар барлыкка килү тирән тектоник җимерелүләр б-н бәйле. Татарстан терр-ясендә соңгы протерозой яшендәге өч А. билгеле: респ-каның көнбатышында Казан–Киров (к. *Казан–Киров бөгелеше*), төньяк-көнчыгышында — Кама–Агыйдел (Кокарск–Бородулино) А.нары; икесе дә төньяк-көньяк юнәлештә (к. *Югары Кама*




Авлокогенның схематик киселеше (Көнчыгыш Европа платформасы). AR – архей; PR₁ – түбәнге протерозой; PR₂ – югары протерозой (R – рифей, V – венд); PZ – палеозой; MZ-KZ – мезозой-кайнозой.

*иңкүлеге*); көньягында — көнбатыш-көнчыгыш юнәлештәге Серноводск–Абдулино (Радаевск–Абдулино) А.ы. Рус һәм Себер платформаларының рифей А. нефть ятмалары һәм алмаз чыганаклары ачуда перспективалы санала.

*Әд.:* Валеев Р.Н. Авлакогены Восточно-Европейской платформы. М., 1976; Перспективы нефтегазоносности кристаллического фундамента на территории Татарстана и Волго-Камского края: Тр. науч.-практ. конф. к 50-летию Ромашкинского месторождения. К., 1998; Геология Татарстана. Стратиграфия и тектоника. М. 2003.

**АВРА́МЕНКО** Александр Никифорович (1.10.1951, Баулы р-ны Баулы эшчеләр посёлогы), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), ТРның атказ. нефтьчесе (2001). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате

ин-тын тәмамлый (1978). Хезмәт эшчәнлеген 1968 елда «Татнефть» берләшмәсенең «Баулынефть» нефть сәнәгате идарәсендә скважиналарны җир астында һәм капиталь ремонтлау цехында слесарь-ремонтлаучы булып башлый. 1978–98 дә «Әлмәтнефть» НГДУында: мастер, технолог, нефть һәм газ чыгару цехы башлыгы урынбасары, цех башлыгы, үзәк инженерлык-технология хезмәте башлыгы. 1998 дән «Татнефть» АҖ аппаратында: башкарма аппаратның нефть һәм газ чыгару буенча җитештерү бүлеге башлыгы, матди-техник тәэминат идарәсе башлыгы (2002 дән). Уйлап табуга 11 патенты бар. Дәүләт бүләге «Тираннан суыручы штангалы насос җайланмаларының ышанычлылыгын күтәрү буенча техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшкәртү һәм сәнәгатькә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**АВРА́НЕК** Ульрих Иосифович (26.1.1853, Чехия, Клученице ш. — 12.8.1937, Мәскәү), хормейстер, дирижёр, РСФСРның халык артисты (1932), Хезмәт Герое (1934). Прага консерваториясенең виолончель һәм муз. теориясе классын тәмамлый (1870). Немец операсы оркестрында (Прага ш.) уйный. 1874 елда танылган опера иганәчесе П.М.Медведев чакыруы б-н Россиягә күчеп килә. 1882 гә кадәр, аның антрепризасында виолончелист һәм дирижёр булып Казанда (1877–80), Түбән Новгород, Самара, Саратов, Харьков һ.б. шәһәрләрдә эшли. А.җитәкчелегендә Казан опера театрында Д.Мейерберның «Гугенотлар» («Гугеноты»), «Пәйгамбәр» («Пророк»), «Роберт Иблис» («Роберт Дьявол»), Ш.Гунoның «Фауст», Дж.Вердиның «Трубадур», «Травиата», «Риголетта», «Аида», «Эрнани», М.Глинканың «Патша өчен үлемгә әзер» («Жизнь за царя»), «Руслан һәм Людмила», А.Даргомыжскийның «Су кызы» («Русалка»), П.Чайковскийның «Опричник» һ.б.ның опералары куела. А. эшчәнлеге хор һәм оркестрның башкару осталыгын камилләштерү, репертуарын баету, Казан тамашачылары арасында опера жанрының популярлыгын үстерүгә этәргеч бирә. 1882 дән Мәскәүдәге Зур театр дирижёры һәм баш хормейстеры, бер үк вакытта 1928–33 тә К.С.Станиславский исем. опера театрының баш хормейстеры. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Р е м е з о в И. У.И.Авранек // Советская музыка. 1937. № 12; Л о к ш и н Д. Замечательные русские хоры и их дирижёры. М., 1963; К а н т о р Г. Репертуар Казанского оперного театра дореволюционного периода // Вопр. истории, теории музыки и музыкального воспитания. К., 1972; П т и ц а К. Авранек Ульрих Иосифович // Музыкальная энцикл. М., 1973. Т. 1.

**АВРО́В** Дмитрий Николаевич (25.1.1890, Сембер губ. Липовка а. — 5.8.1922, Мәскәү), хәрби эшлекле. Петербург психоневрология ин-тын (1914), прапорщиклар мәктәбен (1915) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1918 елдан Кызыл Армиядә; Казанны Чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык Армиясе кулыннан азат итү өчен барган сугыш бәрелешләрендә катнаша (1918, сентябрь); 1 нче Казан совет укчы дивизия башлыгы, 1918 нең ноябреннән Казан губернасы хәрби комиссары. 1919 да Казан һ.б. ныгытылган хәрби районнар комендантлары һәм Казан хәрби гарнизоны башлыгы. Шул елның августыннан Петроград сагында — ныгытылган хәрби район коменданты, шәһәрнең эчке сагы башлыгы, аерым гаскәри бригада командиры. 1920–21 дә 55 нче укчы дивизия башлыгы, Петроград хәрби округы командующие, 7 нче армия командующие һәм армиянең РВС әгъзасы.

*Әд.:* А в р о в Н.Н. Солдат революции. Чебоксары, 1968; ш у л у к. Авров Д.Н. // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**АВТАНДИ́ЛОВ** Арсен Маркович (16.11.1910, Баку — 26.9.1986, Казан), генерал-майор (1954). М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне тәмамлый (1940). Бөек Ватан сугышында кавалерия дивизиясе командиры була. 1954–64 елларда Идел буе хәрби округының мотоукчылар дивизиясе командиры. 1955–63 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Кутузов, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**АВТО**... (грек. autos — үзем).

**АВТОБИОГРА́ФИЯ** (*авто... био...* һәм *графия*), авторның үз тормышын, тәрҗемәи хәлен бәян итүе, мемуарга якын булган әдәби жанр. А. алымнары Мәхмүд Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис» («Оҗмахларның ачык юлы», 1358), Мөхәммәдъярның «Төхфә-и мәрдан» («Егетләр бүләге», 1539–40) әсәрләрендә үк очрый. Лирик чигенешләрдә авторлар үзләре һәм иҗатлары турында хәбәрләр бирәләр. Аерым очракларда китапны күчерүче хаттат яңа мәгълүматлар, мәс., авторның үлгән елын өстәп куя. Татар әдәбиятында беренче автобиографик әсәрләр буларак, авторның тормышы, аның хаҗ кылуы тасвирланган «Мөхәммәдәмин сәяхәте»н (1783) һәм «Рихләт әл-Мәрҗани»не («Мәрҗани юлына басу», 1879) атарга мөмкин. Соңрак А. жанрына Г.Тукай («Исемдә калганнар», 1909), М.Гафури («Шагыйрьнең алтын приискасында», 1931) мөрәҗәгать итә. Бу жанрда ш.у. Х.Туфан («Бәлки, шагыйрь булмас та идем», 1970), С.Хәким («Үзем турында», 1971) һ.б. да язалар.

*Ш.Ш.Абилов.*

**АВТОКРА́ТОВ** Дмитрий Михайлович (3.2.1868, Пенза губ., Мокшанск өязе Морат а. — 10.5.1953, Мәскәү), вет. анатом, вет. фән. д-ры (1935), проф. (1916), РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1940). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1895), шунда ук эшли. 1908–15 елларда Варшава, 1918–35 тә Новочеркасск вет. ин-тларында йорт хайваннары анатомиясе каф. мөдире. 1935 тән Мәскәүдә: 1937 гә кадәр Кошчылык ин-тында, 1937–41 дә Хәрби вет. академиясендә, 1941–43 тә Зоовет. ин-тында, 1943 тән Ит сәнәгате химия-технол. ин-тында. Хезмәтләре йорт хайваннарының анатомиясенә, гистологиясе, фармакологиясе һәм офтальмологиясенә карый. Артериаль системаның вариабельлеген өйрәнә, йорт хайваннары һәм кошларның вегетатив нерв системасы морфологиясен тикшерә. Россиядә беренче булып а.х. хайваннары һәм кошлар анатомиясе буенча дәреслек һәм кулланмалар яза. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анатомия сельскохозяйственных животных. М.–Л., 1930; Анатомия домашних животных для заочного обучения. М., 1940; Анатомия домашних животных для зоотехнических вузов. М., 1949.

*Әд.:* К а л у г и н В.И. Д.М.Автократов // Ветеринария. 1968. № 7; М и х а й л о в Н.В. Жизненный путь и творческая деятельность заслуженного деятеля науки РСФСР, профессора Автократова // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1968. Т. 103; ш у л у к. Школа ветеринарных морфологов // Ветеринария. 1973. № 5; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006; Ветеринарная энциклопедия. М., 1968. Т. 1.

**АВТОМОБИ́ЛЬ ҖИТЕШТЕРУ́ СӘНӘГАТЕ́**, машиналар төзү сәнәгате тармагы. Җиңел һәм йөк автомобильләре (ш.и. махсус эшләнгән), автобуслар, тагылма җайланмалар, ш.у. алар өчен детальләр, узеллар, агрегатлар җитештерелә. ТРда А.җ.с. зур үсеш алган. Тармак пр-тиеләре Чаллы, Алабуга, Зәй шәһәрләрендә, Кама Аланында тупланган. ТРда А.җ.с. үсеше 1969 елда илдә зур йөк автомобильләре җитештерү буенча иң эре з-д — *КамАЗ* төзелешеннән башлана. 1976 ның 16 февралендә з-дның төп конвейерыннан беренче «КАМАЗ» автомобиле төшә. Авыр йөк ташучы транспорт автомобильләре, үзбушаткычлар, ш.у. махсус автомобильләр җитештерә. 1989 дан башлап КамАЗ кечкенә класслы «Ока» җиңел автомобильләре эшләп чыгара башлый. Әһәмияте ягыннан ТРда икенче урында *Алабуга автомобильләр заводы* тора (АлАЗ) (1984 елда Кама трактор з-ды буларак төзелә башлый). Якынча 200 төр продукция, ш.и. Россия автомобиль з-длары заказы буенча детальләр һәм узеллар чыгара. 1996–2001 елларда «Корпорация «ЕлАЗ-Дженерал Моторс»ның җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять з-дларыннан килгән машина комплектларыннан «Шевроле-Блейзер» һәм «Опель-Вектра» автомобильләре җыела. 2002 дән «Беларусь-1221» һәм МТЗ-82 (Минск трактор з-ды лицензиясе б-н) универсаль тәгәрмәчле сөрү тракторлары җыела.

Бу тармак пр-тиеләре җитештергән продукциянең чагыштырмача күләме ТР сәнәгатендә җитештерелгән тулаем продукция күләменең 10% ын, ә эшчеләр саны респ-ка сәнәгатендә эшләүчеләрнең 15% ын тәшкил итә (2005). 1999 да КАМАЗда файдалану характеристикалары яхшыртылган яңа модельдәге автомобильләр һәм двигательләрнең — Евро-1, 2002 дә Евро-2 рәтен җитештерүгә

1991–2006 елларда автомобильләр эшләп чыгару (данә)

| | 1991 | 1992 | 1993 | 1994 | 1995 | 1996 | 1997 | 1998 | 1999 | 2000 | 2006 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Йөк автомоб. | 66952 | 53646 | 56831 | 25536 | 20732 | 20737 | 12742 | 3296 | 14387 | 22192 | 43825 |
| Җиңел автомоб. | 3150 | 4509 | 5275 | 6117 | 8639 | 8935 | 17935 | 19102 | 28004 | 33796 | 9653 |
| Барлыгы: | 70102 | 58155 | 62106 | 31653 | 29371 | 29672 | 30677 | 22398 | 42391 | 55988 | 53478 |









Йөк автомобильләре. 1. «КАМАЗ-43101»; 2. «КАМАЗ-5511»; 3. «КАМАЗ-5320»; 4. «КАМАЗ-54115».



1



2

Җиңел автомобильләр. 1. ВАЗ-11113; 2. «Шевроле-Блейзер».

күчү була. 2001 дә КАМАЗ автомобильләренең иске типтагы модель һәм модификацияләрен серияләп җитештерү туктатыла. 2005 тә төрле газ двигательләрен серияләп җитештерүгә кертү эше төгәлләнә. 2006 ел башыннан двигательләре «Евро-2» стандарты таләпләренә туры килә торган автомобиль техникасын чыгаруга тулысынча күчелә һәм 2007 дә двигательләре «Евро-3» стандартына туры килерлек йөк автомобильләрен тәҗрибә-сәнәгый эшләп чыгару башлана. Автомобильләрнең дизайнын яңарту, серияле двигательләрне һәм көч агрегатларын а.х. техникасына — трактор, комбайннарга җайлаштыру буенча эш алып барыла. Автобуслар төзү мөстәкыйль юнәлеш ала. Павлово автобуслар з-ды (Түбән Новгород өлкәсе) б-н берлектә КАМАЗ җитештергән үзйөрешле шасси нигезендә ПАЗ-5272 маркалы шәһәр автобуслары эшләнә. Бүләндек пр-тиедә (Нефтекамск ш., Башк. Респ.) «КАМАЗ» шассие нигезендә автоүзбушаткычлар, вахта автобуслары, шәһәр эчендә йөрүче автобуслар чыгарыла. ТР А.җ.с. продукциясен төп кулланучылар: автотранспорт пр-тиеләре, нефть-газ чыгару тармаклары, а. х., коммуналь пр-тиеләр, төзелеш һәм урман сәнәгате комплекслары, РФнең Оборона һәм Эчке эшләр министрлыклары.

Йөк автомобильләре һәм алар өчен запас детальләр БДБ илләренә, Үзәк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия, Якын Көнчыгыш, Төньяк Африка илләренә чыгарыла. А.җ.с.нә белгечләр әзерләү Кама политехника ин-ты, Алдынгы технологияләр һәм бизнес региональ ин-ты, Кама автомеханика техникумы, Кама машиналар төзү техникумы һәм 7 башлангыч һөнәри белем бирү учреждениесе (Чаллы) тарафыннан тормышка ашырыла.

*Әд.:* Республика Татарстан за 1999: Стат. сб. К., 2000; Годовой отчёт ОАО «КамАЗ» за 1999 год. К., 2000. *Б.Л.Кузнецов, А.С.Тайбинский.*

**АВТОМОБИ́ЛЬ ТРА́НСПОРТЫ**, рельссыз юлларда йөк һәм пассажирлар ташучы транспорт төре. ТРда А.т.на гомуми кулланыштагы, ведомствога караган, акционерлык җәмгыятьләрендә, коммерция структураларында һәм ш.у. гражданнарның шәхси милке булган транспорт керә. Аңа гомуми йөк әйләнешенең һәм пассажирлар ташуның төп өлеше туры килә. Казан урамнарында беренче автомобильләр 1903 елда чыга. 1909 да шәһәр үзәге б-н бистәләр арасында йөк һәм пассажирлар ташучы «Аутотранспорт» ширкәтенә нигез салына. 1917 дә Казан губернасында автомобильләр губерна һәм шәһәр хакимияте карамагында исәпләнә, Казан дары з-дында берничә машина була. 1918 дә Казанда Автосекция оештырыла, ул автомобиль җиһазларын бүлеп бирү, автомобильләр ремонтлауны оештыру, азык-төлек һәм йөк ташу б-н шөгыльләнә; Казанда чит илдә җитештерелгән 150 гә якын җиңел һәм йөк машинасы була, аларның бер өлеше Көнчыгыш фронтка хезмәт күрсәтә. Автосекция карамагына национальләштерелгән Остерман механика з-ды һәм ремонт мастерскойлары тапшырыла. 1921 дә Җирле транспортның татар үзәк идарәсе оештырыла, ә кантоннарда транспорт агентлыклары барлыкка килә. Беренче автобус маршруты Казанда 1925 нең апрелендә ачыла; аңа өч автобус хезмәт күрсәтә. 1930 да шәһәрара автобуслар Казаннан Лаеш авылына, Алабуга һәм Йошкар-Ола шәһәрләренә йөри башлый. 1940 та Татарстанда якынча 300 автомобиль була, шуларның 80 е — автобус. Бөек Ватан сугышы елларында А.т. нигездә фронт өчен эшли. Автомобиль паркының тизләтелгән үсеше 1950 еллардан башлана. Пассажирлар һәм йөк ташу транспортының махсуслаштырылган эре пр-тиеләре, берләшмәләр барлыкка килә, алар автомобиль транспортыннан файдаланунын нәтиҗәлелеген күтәрергә мөмкинлек бирә. 1990 ел-

Кулланышына карап хәрәкәттәге автомобиль транспорты берәмлеге (ел ахырына)

| | 1960 | 1980 | 1990 | 1995 | 1996 | 1997 | 1998 | 1999 | 2000 | 2006 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Йөк автомобильләре | 24667 | 52405 | 64176 | 77235 | 76074 | 77352 | 79140 | 80113 | 77782 | 72408 |
| Автобуслар | 1077 | 10392 | 13910 | 15491 | 15510 | 15615 | 14718 | ... | 15682 | 9243 |
| Җиңел автомобильләр | 4825 | 79426 | 167047 | 285432 | 325825 | 384360 | ... | 425806 | 424951 | 583781 |
| Махсус автомобильләр | 3906 | 22594 | 27964 | 28810 | 26424 | 24921 | 23628 | 22295 | 23082 | 14939 |

ТРда автомобиль транспорты белән йөк һәм пассажирлар ташу

| | 1960 | 1980 | 1990 | 1995 | 1996 | 1997 | 1998 | 1999 | 2000 | 2006 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Икътисад тармагында автотранспорт белән йөк ташу (млн. *т*) | 61,8 | 290,9 | 281,5 | 201,3 | 134,6 | 119,4 | 92,5 | 139,6 | 111,2 | 132,0 |
| Гомуми файдаланудагы автотранспорт пассажирлар ташу (млн. кеше) | 111,4 | 589,6 | 806,0 | 723,2 | 722,9 | 706,2 | 661,7 | 679,3 | 707,5 | 257,8 |

лар ахырына ТР гомуми кулланыштагы автобуслар һәм шәхси транспорт б-н тәэмин ителеше буенча Россиядә алдынгы урыннарның берсенә чыга. 2005 тә 43 адм. авыл районына һәм 90 маршрут буенча респ-кадан читкә, 20 шәһәр һәм шәһәр тибындагы посёлокларда (шәһәр эчендә һәм шәһәр тирәсендә) пассажирлар ташучы даими маршрутлар оештырыла. 18 автовокзал, 13 автостанция һәм стационар кассалар эшли. 2000 нән республика шәһәрләрендә һәм шәһәрара юлларда маршрут таксилар киң үсеш ала. 2006 да шәһәр яны һәм шәһәрара юлларда пассажирлар ташу б-н хосусый милекчелекнең төрле формаларына караган 59 маршрут такси шөгыльләнә («Татавтотранс», «Казан ПАТП-1» АҖләре, «Автовокзал» (Алабуга ш.). 2005 тә гомуми кулланыштагы автомобиль транспорты б-н 6,9 млн. *т* йөк ташылган, 283,0 млн. пассажирга хезмәт күрсәтелгән. ТРда 2 авторемонт з-ды (Казан, Чистай ш.) хезмәт күрсәтә. Шәһәрара автобус маршрутларының озынлыгы якынча 23000 *км*, ә респ-калар арасында 16000 *км* артык тәшкил итә. А.т. тармагында 25 меңнән артык кеше эшли. Ш.у. к. *Автомобиль җитештерү сәнәгате*, *Шәһәр транспорты*, *«Татавтотранс»* (к. Таблица).

*Әд.:* Новинка для Казани // Казанский телеграф. 1903. 15 апр.; Назипова К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976; Синицына К.Р., Тутаев М.З., Ахметов А.Н. Автомобильный транспорт Татарии. К., 1987; Анализ и основные направления развития и размещения производительных сил Республики Татарстан. К., 1996.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**АВТОМОБИ́ЛЬ ЮЛЫ́**, к. *Юл-транспорт төзелеше*.

**АВТОНО́МИЯ** (грек. autonómia — үзидарә, бәйсезлек), милли яисә социаль төркемнең хокукый хәле. Үзидарәнең суверен булмаган шартларында мәгълүм төркем мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру чарасы булып тора. Җәмәгать А.се территориаль һәм экстерриториаль (мәдәни) була ала. Территориаль А. адм.-терр. (региональ), милли-терр. һәм милли дәүләтлегә бүленә. 20 йөз башында татар милли-демократик хәрәкәтендә унитаристлар һәм федералистлар агымнары була. Беренчеләре (С. һәм Һ. Максудилар, Г.Терегулов һ.б.) Россиянең унитар төзелешен, Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтариятын яклыйлар; икенчеләре (М.Бигиев, Р.Ибраһимов, Г.Ибраһимов, И.Алкин, Ш.Әхмәдиев, Ф.Кәрими һ.б.) илнең федератив төзелешен һәм татарлар б-н башкортлар өчен терр-ясе билгеләнгән А. (мохтарият) булдыруны яклыйлар. А. мәсьәләләре *Бөтенроссия мөселманнары корылтайларында* (1917) көн тәртибе үзәгендә була һәм бәхәсләр чыгара (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда Эчке Россия һәм Себер төрки-татар халыкларының милли-мәдәни мохтарияты турында декларация игълан ителә һәм Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының *милли-мәдәни мохтарият нигезләрен эшләү комиссиясе* оештырыла. Эчке Россия һәм Себер төрки-татар мөселманнарының *Милләт Мәҗлесендә* мохтарият элементларын саклап, *Идел-Урал Штатын* оештыру мәсьәләсен караганда терр. А. тарафдарлары *(туфракчылар)* фикере өстенлек ала. Алар Идел-Урал Штаты, Татар-Башкорт Респ-касы, Татар Респ-касы проектлары эшләнгән вакытта хәлиткеч роль уйныйлар. Ике агым да сәяси аренадан 1918–20 елларда төшеп кала.

Окт. рев-циясеннән соң Россиядә А. милли мәсьәләләрне чишүдә төп дәүләти формаларның берсе була. 1920 нең 27 маенда РСФСРның БҮБК һәм ХКС Декреты нигезендә *Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы* (ТАССР) оештырыла. Респ-каның үз Конституциясе, закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары, Югары хөкем (Югары мәхкәмә) һәм закон чыгару хокукы, гражданлыгы, терр-ясенең кагылгысызлыгы, символлары (герб, флаг, башкала) һ.б. дәүләти билгеләре була. ТАССРның югары дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт идарәсе карамагында Конституция кабул итү, аңа үзгәрешләр, өстәмәләр кертү һәм үтәлешен күзәтеп тору; районнарга бүленешне раслау; дәүләттә тәртип, гражданнарның хокукларын һәм ирекен саклау; респ-каның халык хуҗалыгы планын һәм бюджетын раслау, аның үтәлеше хакында хөкүмәтнең хисап тотуы; дәүләт салымнарын һәм җирле салымнарны, акча җыюларны һәм салымсыз керемнәрне кертү; районнар, шәһәрләр һәм авыл советлары, иминият һәм саклык кассалары эше б-н җитәкчелек итү, респ-ка карамагындагы сәнәгать, а.х. һәм сәүдә пр-тиеләре, оешмалары б-н идарә итү; СССР һәм РСФСР органнарына буйсынган пр-тиеләрнең торышына, идарәсенә контрольлек һәм күзәтчелек итү; җир һәм җир асты байлыкларыннан, урманнар һәм сулардан файдалану тәртибен контрольдә тоту; халык мәгарифенә, мәдәният һәм фән учреждениеләренә, сәламәтлек саклау, физик тәрбия һәм спорт, социаль тәэминат, тарих һәм мәдәният истәлекләрен саклау б-н җитәкчелек итү була. СССР һәм РСФСР законнары нигезендә ТАССР законнар чыгаруны татар, рус телләрендә башкара. Респ-ка СССР һәм РСФСРның югары дәүләт хакимияте органнарында үзенең вәкилләрен булдыра. СССР шартларында А. рус булмаган халыкларга милли дәүләт төзүгә хокукларын белдерү һәм милли суверенитетны тормышка ашыру өчен мөмкинлек бирми.

1980 еллар ахырына А. милли дәүләтчелек формасы буларак үзенең мөмкинлекләрен файдаланып бетерде, ә социаль-икътисади мәсьәләләрнең кискенләшүе, халыкның милли-мәдәни ихтыяҗлары тиешенчә канәгатьләндерелмәү милли үзенчәлекләрне яклаучы иҗтимагый хәрәкәт активлашуга һәм СССРның союздаш респ-калары халыклары б-н бертигез хокукта булуны таләп итүгә китерде. 1990 ның 30 августында ТАССР ЮС респ-каның сәяси һәм икътисади статусын күтәрүне игълан итте һәм аны Татарстан ССР дип үзгәртте (к. *Татарстан АССРның дәүләт суверенитеты турында декларация*). СССР таркалу нәтиҗәсендә (1991) Татарстанны союздаш респ-кага әйләндерү ахырынача җиткерелмәде. 1992 нең 7 февралендә ТССР ЮС «ТССР атамасын үзгәртү турында» Закон кабул итте һәм шуның нигезендә респ-ка Татарстан Республикасы (ТР) дип аталды. 1992 нең 21 мартында ТРның дәүләт статусы турында *референдум* үткәрелде, аның нәтиҗәләре ТРның суверен демократик дәүләт булуын раслады, 1992 нең 6 ноябрендә ТР ЮС сессиясендә Татарстан Респ-касы Конституциясе кабул ителде.

1994 нең 15 февралендә РФ исеменнән Б.Н.Ельцин, В.С.Черномырдин, Татарстан Респ-касы исеменнән М.Ш.Шәймиев, М.Г.Сабиров «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында*»гы шартнамәгә кул куйдылар.

Шартнамә яңа дәвердә РФ һәм ТР арасындагы дәүләти мөнәсәбәтләрнең нигезен билгеләде. 1996 ның 5 июнендә «Милли-мәдәни мохтарият турында» РФ Законы кабул ителде, аның нигезендә Россиядә татарлар күпләп яшәгән урыннарда *Татарларның милли-мәдәни мохтариятлары* оештырыла башлады.

РФнең 1999 ның 6 октябре һәм 2000 нең 29 июлендә шуңа үзгәртүләр һәм өстәмәләр кертелгән «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте субъектларының закон чыгару һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында»гы Законы нигезендә Татарстанда респ-ка законнарын федераль законнар б-н тәңгәлләштерү эше үткәрелде. ТРның конституцион төзелеше мәсьәләләрен федераль мөнәсәбәтләр үсеше яктылыгында карап чыгу өчен ТР Дәүләт Советының 2001 нең 20 сентябрь карары б-н ТР Президенты М.Ш.Шәймиев рәислегендә ТР Конституцион комиссиясе оештырылды. Комиссия тарафыннан ТР Конституциясенә кертелгән төзәтүләрне ТР Дәүләт Советы кабул итте һәм «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәртүләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы ТР Законы нигезендә 2002 нең 19 апрелендә расланды.

ТР Конституциясенең 1 маддәсе буенча ТР демократик, хокукый дәүләт, РФ һәм ТР Конституцияләре, РФ б-н ТР арасындагы «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары б-н Татарстан Респ-касы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында»гы шартнамә нигезендә РФ б-н берләштерелгән дәүләт һәм аның субъекты булып тора.

Чыг.: Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1978; Конституция Республики Татарстан. К., 2002; Образование Татарской АССР: Сб. док. и материалов / Под ред. И.М.Климова, М.К.Мухарямова. К., 1963.

*Әд.:* Таһиров И.Р. Бәйсезлек баскычлары: суверенлык турында уйланулар. К., 1994; Хафизов Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; Тагиров И.Р. В борьбе за власть Советов: Октябрь и национально-освободительное движение в Поволжье и на Урале, июль 1917 — март 1918 гг. К., 1977;

шул ук. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; Ягудин Ш.Ш. Политико-правовой статус автономной республики в советской федерации // Советское государство и право. 1990. № 3; Хаким Р.С. Сумерки империи: к вопросу о нации и государстве. К., 1993.

*Е.Б.Долгов, Г.С.Сабирҗанов.*

**АВТОСПО́РТ**, спорт төре. Татарстанда 20 йөз башларыннан үсә башлый. Беренче ярышларны Казан елга «Яхт-клуб»ы оештыра (1913). 1937 елда, А.ны пропагандалау һәм үстерү, проф. һәм һәвәскәр автомобиль йөртүчеләр әзерләү максаты б-н, ТАССР ХКС каршындагы Физик культура һәм спорт эшләре ком-тының респ-ка автомотоклубы оештырыла. Аның тарафыннан Казанда (1937) һәм Чистайда (1939) автомотомәктәпләр ачыла. 1939–40 та клубның автопаркында 11 автомобиль була: 7 — ГАЗ-АА, 2 — ГАЗ-А, 1 — ЗИС-5, 1 — ГАЗ-42. 1940–50 дә клуб агитация максатыннан респ-ка шәһәр һәм районнарында автомотоузышлар, шәһәр шартларында иң яхшы автомобиль йөртүчеләр ярышлары уздыра. 1940–60 та А. «Искра», «Локомотив», «Труд», «Крылья Советов», «Урожай», «Динамо», «Красное знамя», «Наука», «Буревестник» спорт җәмгыятьләрендә, ДОСААФта, «Икар» спорт-техника клубында (Казан авиац. ин-ты) үсеш ала. Автомотоспорт федерациясе тарафыннан уздырылган ТАССР чемпионатларында (1960 еллар), РСФСР һәм СССР чемпионатларында (1973) автомобильдә күп төрле ярышларда, ике төр буенча ярышларда, кросста, ипподромда узышуда Р.Вафин, Н.Матков, Г.Белоголовский, И.Мәҗитов, М.Сәгъдиев, А.Тарасов, Г.Пулинец, Н.Галиуллин, Г.Шакиров танылалар. «Икар» клубы командасы шоссе-бożрада узышу буенча (иң яхшы спортчылар — В.Кузьмичёв, А.Баталов) РСФСР чемпионатларында (1971–85) катнаша. Тректа беренче кышкы автоузышлар 1978 дә уздырыла. Аларда «Икар» спорт клубы, Казан ДОСААФ автомәктәбе, КамАЗ ДОСААФ клубы, «Автоваз» респ-ка үзәге, «Түбәнкамашин» сәнәгать берләшмәсе спортчылары катнаша (Тольятти, Ижевск һ.б. ш.).

1984–85 елларда Татарстан җыелма командасы (Ю.Чугунов, Г.Стинский, В.Милованов, Н.Ефстафьев, Ф.Төхфәтуллин, Г.Вәлиуллин) автомобильдә күп төр буенча оештырылган ярышларда катнаша һәм РСФСР чемпионы исемен яулый. 1985 тә автомобильчеләрнең күп төр буенча ярышларында Ю.Чугунов, С.Стинский СССР чемпионнары була; С.Петрухин 1984 тә бożрада узышуда РСФСР чемпионатында бронза, 1987 дә тректа үткәрелгән кышкы СССР чемпионатында көмеш медальләр ала. 1992 нең 11 декабрендә Россия автомобиль федерациясе (РАФ) Халыкара автомобиль федерациясенә кабул ителә. 1996 да ТР Автомотоспорт федерациясе оештырыла (президенты В.А.Швецов). 1996 да җәйге автокросслар өчен «Биектау» автоспорт комплексы, 1998 нең февралендә тректа кышкы узышлар үткәрү өчен «Усад» автомотоспорт комплексы (Биектау р-ның Усад а., Казаннан 30 *км*) файдалануга тапшырыла. 1990 еллар ахырыннан А. зур үсеш алган спорт-техника һәм СКлары: Казанда — «Дорожник РТ», «Таиф», «Чыңгызхан», «Сувар», «Намус», «Совет районы»; Чаллыда — «Девон», «ФРАС-КамАЗ»; Түбән Камада — «Автокросс», «ЗАО-ТрансТЭК»; Биектау р-ның Усад авылында — «Тимерхан». РФ, ТР, Европа чемпионатларында, Россия кубогы этапларында (1980–90 еллар), «ТР Президенты кубогы» автоузышларында (1996–2005) җиңүчеләр



«Биектау» автоспорт комплексы трассасында.

һәм алгы урыннарны алучылар — Ф.*Бәдретдинов*, Г.Вәлиуллин, Н.Жаворонков, Н.Иванов, И.Миңнәхмәтов, Р.Миңнеханов, И.Мостафин, В.Николаев, С.Петрухин, И.Рәхмәтуллин, Р.Фәттахов, А.Шәймиев, Р.Рамазанов, Е.Ручкан, Н.Сәләхетдинов, А.Сахаров, С.Скобельцин, А.Ураскин, Р.Шәймиев. ТРның «КамАЗ-Мастер» (Чаллы ш.) командасы спортчылары Ф.*Кәбиров*, С.*Савостин*, С.*Якубов*, А.*Беляев*, В.*Чагин*, Н.*Һаһаветдинов*, В.*Московских*, А.Кузьмин, Ф.Бәдретдинов — 1989 «Обжектив Сюд» (Европа-Көнбатыш Африка), 1991, 1999, 2001, 2002, 2004,



«КАМАЗ» автомобиле ралли-марафон трассасында.

2005 (Париж–Дакар), 1992 (Париж–Мәскәү–Пекин, Париж–Кейптаун, Париж–Пекин), 1996, 1999 (Париж–Гранада–Дакар), 1999, 2002 («Чүлне буйсындыру», Берләшкән Гарәп Әмирлекләре), 2000 (Париж–Дакар–Каһирә, «Итальянская Бажа»), 1996 (Париж–Мәскәү–Улан-Батыр), 1997 (Париж–Сәмәрканд–Мәскәү), 2000 (Париж–Истанбул) елларда уздырылган халыкара ралли-марафоннарда җиңүчеләр һәм бүләкләр алучылар; «Чүлне буйсындыру»-2000 (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре), «Телефоника-Дакар»-2004, «Лиссабон–Дакар»-2006 ралли-марафонында Дөнья кубогын А.Беляев, В.Бигашев, В.Голуб, Ф.Кәбиров, И.Мәрдиев, Р.Миңнеханов, В.Чагин, С.Якубовлар ала.

*Әд.:* Покорение «Высокой Горы». К., 1999.

**«АВЫ́Л»**, атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Самара Башкарма ком-ты каршындагы ачларга ярдәм күрсәтү бүлеге һәм РКП(б)ның Самара губерна ком-ты каршындагы Татар-башкорт бюросы, соңрак губерна халык мәгарифе бүлеге каршындагы Татар-башкорт бюросы һәм татар-башкорт секциясе органы. 1922 елның 4 мартыннан 1924 кә кадәр Самара шәһәрендә атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Газета битләрендә хөкүмәт декретлары һәм карарлары басыла; крәстиян хуҗалыкларының алдынгы тәҗрибәсе яктыртыла, авыл халкының тормыш һәм хезмәт шартларын яхшырту проблемалары күтәрелә, яшь татар язучыларының әсәрләреннән өзекләр урын ала. Төп рубрикалары: «Губерна хәбәрләре», «Чит ил яңалыклары», «Вакытлы матбугат битләреннән», «Партия тарихыннан», «Яшьләр тормышыннан», «Балалар почмагы», «Әдәбият».

**«АВЫ́Л ГАЗЕ́ТАСЫ»**, иҗтимагый-сәяси газета. Уфа губернасы халык мәгарифе һәм сәяси аң-белем тарату бүлеге органы. 1921 елда Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. «А.г.» илдәге сәяси һәм икътисади хәлләрне, а.х. өчен проф. кадрлар әзерләү проблемаларын яктырта. Авылда наданлыкны бетерү эшенә аеруча зур игътибар бирә. Рубрикалары: «Яңалыклар», «Уфада» һ.б.

*Әд.:* Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000.

**АВЫ́Л ҖӘМГАТЕ́**, кешеләрнең борынгы җәмгыять вакытында барлыкка килгән берләшү-оешу формасы. Баштарак кан кардәшлек элементларына нигезләнеп, әкренләп күрше-территориаль җәмәгатькә әверелгән. Аның карамагында сөрүлек җирләре, болынлык, урманнар, балык тоту, аучылык биләмәләре, көтүлекләр һ.б. булган.

Казан төбәгендә А.җ. Идел буе Болгары чорында округларга берләшкән җыеннар формасында оешкан дип исәпләнә. Сөрүлек, печән чабу җирләрен, болынлык, көтүлек һәм башка биләмәләрне уртак файдалануга нигезләнгән җыен институты дөньяви хуҗалык эшләренә уртак җитәкчелек итүне, традицион дини һәм халык бәйрәмнәрен үткәрүне гамәлгә ашырган. Казан ханлыгын Рус дәүләте яулаганнан соң (1552) һәм аны руслар колонияләштерә, төп халыкны көчләп *христианлаштыра* башлагач, А.җ. әкренләп үзенең традицион-оештыру вазифаларын югалта һәм 20 йөз башына кадәр үзгәрешсез сакланган А.җ. булып кала һәм таркала. Бары тик төбәктәге мариларда һәм чуашларда гына әлеге институтның кайбер элементлары катлаулы А.җ. формасында сакланган. Мәс., Шумшеваш чуаш А.җ. — 33, Шуматныкы (Ядрин өязе) — 41, «Зур бау» («Большая верёвка»; Козьмодемьян өязе) 42 торак пунктны берләштергән. Казан губернасындагы барлык катлаулы А.җ.нең 85%ы чамасы Козьмодемьян, Царёвококшай, Цивиль, Чабаксар, Ядрин өязләренә туры килгән.

А.җ. нең башкаручы органы — авыл җыены. Анда староста, ясак җыючы, писарь, каравылчы, көтүчеләр һ.б. сайлана. А.җ. зур бер авылдан, кайчакта берничә вак торак

пункттан (катлаулы А.җ.) тора. Ул төрле хуҗалык, социаль һәм шымчылык-полиция вазифаларын башкара (1861 елгы крәстиян реформасыннан соң җир хуҗасы). Уртак җаваплылык принцибында А.җ. алпавыт һәм дәүләт файдасына натуралата һәм акчалата салымнарның төгәл үтәлүе өчен җавап бирә, рекрутлар билгеләгәндә аңа чиратны саклау бурычы йөкләнә. А.җ. крәстиян йортындагы гаилә мөнәсәбәтләренә катнаша (мирас калдыру, тәрбиягә алу, гаилә милкен бүлү, крәстиян йортыннан авыл җыенында вәкил булучыны, җәзаларны үтәү өчен җаваплы гаилә башлыгын билгеләү). Мондый хәл крәстиян хуҗалыгының түләү сәләтен тәэмин итү турында кайгырту белән аңлатыла. Шуның белән бергә, А.җ. үз өстенә «социаль тәэминат» — кече яшьтәге ятим крәстиян балалары турында кайгырту, ялгыз гаиләләрне һәм өлкән яшьтәгеләрне карау вазифаларын да ала. Крәстияннәргә өй салганда, ашлык суктырганда яки башка кичектергесез а.х. эшләрен башкарганда, шулай ук табигый бәла-казалардан зыян күрүчеләргә булышу (к. *Өмә*) кебек традицион ярдәм итүләр дә киң кулланыла.

1893 елда Казан губернасында 3003, 20 йөз башында 2992 А.җ. (ш.и. 46% — рус, 25,4% — татар, 15,1% — чуаш, 4,5% — мари) була. А.җ.н үзгәртеп кору *Столыпинның аграр реформасы*ннан соң башлана, реформа барышында уртак җаваплылык бетерелә, крәстияннәргә А.җ.ннән чыгарга рөхсәт ителә, җәмәгать әгъзасына яңа — хуҗа-милекче статусы билгеләнә һ.б. Әмма җир турында (1917) һәм җирне социалистик милек итү турында (1918) декретлар чыккач, А.җ.нең позицияләре шактый ныгый. А.җ.н Совет властеның беренче елларында социаль яклау институты буларак саклауга түбәндәге факторлар сәбәп була: авылның социаль-икътисади үсешенең чагыштырмача түбән булуы, Казан төбәгенең географик һәм табигый шартларының үзенчәлекләре, авыл җирләрендә халыкның күп урнашуы һәм кешеләрнең халык хуҗалыгының җир белән бәйле булмаган тармакларына аз күчеп китүе һ.б. Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү барышында 1920 еллар ахыры — 30 еллар башында А.җ. тәмам юкка чыгарыла.

Чыг.: Общий свод данных хозяйственно-статистического исследования Казанской губернии: Часть экономическая. К., 1898; Свод узаконений и распоряжений правительства об устройстве сельского состояния. СПб., 1903. Т. 1–2.

*Әд.:* Александров В.А. Сельская община в России (XVII–XIX вв.). М., 1978; Смыков Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма (социально-экономическое исследование). М., 1984.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**АВЫ́Л КӨЙЛӘРЕ́**, Идел-Кама буе татар авылларында лирик җыр жанры буларак яши. А.к. симметрик, тигез өлешле озынлыкта булуы, метрик үлчәменең җөпләлеге, дүрт өлешле ангемитон һәм пентатон лад формалары, көйнең соңгы авазы өч мәртәбә кабатланган каданс әйләнеше б-н аерылып тора. А.к. татарларның башка лирик җыр жанрларыннан аермалы буларак, күмәк рәвештә дә башкарыла, ә 19 йөз ахырларында гармунга кушылып җырлана башлый. Текстларның үзгәреп торуы сәбәпле, А.к.нең аерым исемнәре дә юк диярлек. Ә «Арча», «Күн авылы», «Минзәлә» кебек көйләрнең исемнәрендә алар барлыкка килгән төбәк исеме чагыла. А.к.нә җырлана торган дүртьюллыклар фольклористикада аерым жанр буларак йөри һәм *кыска җырлар* дип атала.

*Әд.:* Надиров И. «Кыска җыр» — короткая песня в устном народном творчестве // Вопр. татарского языка и литературы. К., 1969. Кн. 4; Нигмедзянов М. Народные песни волжских татар. М., 1982.

*З.Сәйдәшева.*

**«АВЫ́Л КӨНКҮРЕШЕ́»**, айлык а.х. журналы. ВКП(б)ның Минзәлә канткомы органы. 1925–26 елларда Минзәлә шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Журнал битләрендә авыл хуҗалыгын квалификацияле кадрлар б-н тәэмин итү мәсьәләләре күтәрелә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, яшелчәчелек тармаклары буенча киңәшләр басыла. Рубрикалары: «Терлекчегә киңәшләр», «Умартачыга киңәшләр», «Файдалы киңәшләр» һ.б.

**АВЫ́Л КҮЛЕ́**, Көнчыгыш Кама аръягында. Элеккеге су юлында сакланып калган күл: Ык елгасының сулъяк тугаенда, Азнакай р-нындагы Сөендек авылының көньяк читендә. Су өслегенең мәйданы 1,08 *га*. Озынлыгы 300 *м*, иң зур киңлеге 50 *м*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**«АВЫ́Л ТОРМЫШЫ́»**, айлык а.х. журналы. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан Советы җир бүлеге органы. 1919 елда Казанда татар телендә нәшер ителә. Журнал битләрендә хөкүмәтнең декретлары, карарлары басыла, РСФСРда коммуна һәм артельләрнең социаль-икътисади үсеше мәсьәләләре яктыртыла. Ш.у. урманнарны, елга-күлләрне саклау, иген кырларының торышын яхшырту юлларын күрсәткән мәкаләләр урын ала. «А.т.» ж-лы яшь үсентеләр үстерү, а.х. культураларын кышка әзерләү турында киңәшләр бирә. Төп рубрикалары: «Терлекчелек», «Игенчелек», «Авыл тормышы яңалыклары», «Әртилләр һәм коммуналар».

**«АВЫ́Л ХАЛКЫ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. Крәстиян депутатларының Уфа губерна Советы органы. 1917 елның июненнән сентябренә кадәр Уфада «Шәрекъ» басмаханәсендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 16 саны чыга. Газетада Г.Баембәтов, С.Сүнчәләй, Ш.Сүнчәләй, М.Йосыпов һ.б. актив языша. «А.х.» «Җир һәм ирек!» шигаре астында чыга. Илдәге сәяси һәм икътисади вакыйгаларны, 1 нче Бөтендөнья сугышы фронтларындагы хәрби хәрәкәтләрнең барышын яктырта, җир турындагы мәсьәләләрне крәстияннәр файдасына хәл итүне яклый, авылда наданлыкны бетерү эшенә зур игътибар юнәлтә. Рубрикалары: «Яңалыклар», «Россиядә», «Уфада», «Сугыш турында» һ.б. Ш.у.к. «*Безнең юл*».

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты: (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000.

**АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́**, матди җитештерүнең иң төп тармакларыннан берсе; *үсемлекчелек* һәм *терлек асраучылык* продукциясе алу өчен а.х. культуралары үстерү һәм а.х.терлекләре үрчетүне эченә ала. Төп тармаклары — үсемлекчелек (*бөртекле ашлык хуҗалыгы, бәрәңге үстерүчелек, чөгендер үстерүчелек, терлек азыгы җитештерү, яшелчәчелек, бакчачылык, балыкчылык* һ.б.) һәм терлекчелек (*мөгезле эре терлекчелек, дуңгыз асраучылык, сарык асраучылык, кошчылык, ат асраучылык, җәнлекчелек, умартачылык* һ.б.). А.х.на шулай ук үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен беренчел эшкәртүнең төрле төрләре керә.

Татарстанда а.х. җирләренең мәйданы (*Авыл хуҗалыгы җирләре*) 4491,1 мең *га* (җир фондының 65,5% ы), ш.и. сөрүле җирләр — 3457, табигый терлек азыгы җирләре (печәнлек һәм көтүлек) — 995,3 мең *га*. 2007 елның 1 гыйнварына мөгезле эре терлек 1122,7 мең баш, ш.и. сыерлар — 437,1, дуңгыз — 748,9, сарык һәм кәҗә — 374,9, кошлар — 9451,9 мең баш. 2006 елда бөртекле ашлык — 4522,7 мең *т*, шикәр чөгендере — 2124,3, бәрәңге — 1745,3, яшелчә — 325,7, ит — 207,3, сөт — 1617,7, йон — 956 *т*, йомырка — 1071,5 млн. данә җитештерелә. ТРда А.х. өлешенә тулай продукциянең 7,7% туры килә. Татарстанның а.х.да 2006 ел ахырына 954,3 мең кеше эшләгән (республикадагы халыкның 25,5%ы). Казан төбәгендә игенчелекнең иң борынгы чыганаклары б.э.к. 1 меңьеллыкка карый. Идел буе Болгар дәүләте чорында сөрүле *игенчелек* (урман һәм далалы яткын җирләр) һәм терлекчелек (ярым утрак һәм ябып асрау формасында), ат, сарык асраучылык, умартачылык авыл халкы хуҗалыгы эшчәнлегенең нигезен тәшкил итә. Соңга табарак ике басулы игенчелеккә алмашка өч басулы чәчү әйләнешле пар системасы килә (көзге чәчү, язгы чәчү, пар басуы), бу система 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башына кадәр гамәлдә була. Идел-Кама халкы а.х. продукциясенә үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндереп калмый, бөртекле ашлык, бал, балавыз, кыйммәтле җәнлек мехы, тире һәм күнне читкә дә чыгара. Игенчелек һәм терлекчелекнең үсеше, хезмәт бүленеше, җитештерүчәнлекнең артуы б-н А.х. халык хуҗалыгының төп тармагына әверелә, арта барган шәһәр халкы өчен — азык-төлек, сәнәгатьнең күп кенә тармаклары өчен чимал чыганагына әйләнә.

Казан губернасы дәверендә (1708–1920), далалы җирләрнең өстенлек итүе, табигать шартларының уңайлылыгы аркасында игенчелек үсеш ала. Фабрика-завод сәнәгате һәм һөнәрчелек җитештерүе 20 йөзнең 1 нче чиреге ахырына кадәр, башлыча, а.х. чималы эшкәртүгә нигезләнә. А.х. җитештерүе Казан губернасында, һәм гомумән Россия буенча, крепостной хокук вакытында да, ул бетерелеп, җәмәгать җиренә күчү чорында да түбән продукцияле була. Бөтен а.х. эшләре кул һәм ат көче ярдәмендә башкарыла, җирнең 75% ы — сукалар, 8% ы — кыек сука, 17% ы сабаннар б-н эшкәртелә. А.х. җитештерүе культурасын һәм товарлыклылыгын үстерүгә күпмедер дәрәҗәдә *Столыпинның аграр рефор-*

*масы* (1906–14) булышлык итә, аның барышында Казан губернасында авыл җәмгатьләреннән 33 мең крәстиян хуҗалыгы аерылып чыга (гомуми санның 8,8%ы). Күбрәк уҗым арышы, карабодай, солы, түбәнрәк дәрәҗәдә бодай, арпа, борай, тары, борчак, җитен, киндер, колмак, бәрәңге игелә. 1870–90 елларда бөртекле культураларның тулай җыемында уҗым арышы — 45–58%; төп фураж культурасы буларак солы — 28–34; сабан бодае — 2–3,5; арпа — 3,5–4,5; карабодай 5,5–12% алып тора.

1913 елда бөртекле культуралар чәчүлек мәйданының 96,5% ын, техник культуралар — 1,6, бәрәңге — 1,5, яшелчә — 0,04, терлек азыгы культуралары 0,3% ын тәшкил итә.

Беренче бөтендөнья һәм гражданнар сугышлары нәтиҗәсендә чәчүлек мәйданнары — 375,5 мең, бөртекле культуралар 392,4 мең *га* га кими, бәрәңге чәчүлеге мәйданы 53,3 мең *га* га арта. Терлек азыгы культуралары бары тик 12,2 мең *га* да гына үстерелә.

Культураларның уңдырышлылыгы түбән була, 1880–1911 елларда уңыш җыюның чәчкән орлыкка карата чагыштырмасы уҗым арышы буенча 1,2–5,6; сабан бөртекләре — 2,5–3,25; бәрәңге буенча 3–3,8 тәшкил итә. Казан губернасында терлекчелек крәстиян хуҗалыкларында тупланган була. 1856 да бер крәстиян хуҗалыгына 11 баш терлек туры килгән: атлар — 2,3, мөгезле эре терлек — 1,8; сарык — 5,6; дуңгыз — 1; кәҗә — 0,3. 1883 тә авылда яшәүче һәр 1000 кешегә 218,7 баш ат, 187,7 баш мөгезле эре терлек, 613,4 баш мөгезле вак терлек туры килгән. Эшче атлар саны 289,6 мең баш тәшкил иткән; 1 эшче атка а.х. җирләренең якынча 20 дис. туры килгән. 1911 дә 1856 га караганда бөтен төр терлекләрнең баш саны 45,8% ка, ш.и. атлар саны 26,9% ка, мөгезле эре терлек 27,0% ка арта. Халыкның төп шөгыле булып игенчелек кала.

Столыпинның җир реформасын уздыру нәтиҗәсендә Казан губернасында аграр кризис кискенләшә һәм авылда сыйнфый катлауларга аерымлану көчәя. 1912 дә Казан губернасында 117815 атсыз хуҗалыкка күп атлы (7–30 баш) 382 хуҗалык туры килә. А.х. Беренче бөтендөнья сугышы чорында тагын да түбәнрәк дәрәҗәгә төшә. Җирнең 40% ы алпавытлар кулында була, 11% крәстиян хуҗалыгы җирсез, 13% крәстияннәр, үз җирләрен кулакларга арендага биреп, үзләре батраклыкка яллананалар яки читкә китеп эшлиләр. Җирнең 17% ы гына сабаннар б-н эшкәртелә; эшләүче халыкның саны 22% ка, чәчүлек җирләре 36,3% ка кими. 1920 гә кадәр А.х. элеккечә түбән продуктлы, җитештерү эшләре артта калган була. Җир, кагыйдә буларак, примитив эш кораллары (сука, агач тырма, атлы сабаннар) б-н эшкәртелә, ашлык урак һәм чалгылар б-н урыла, чабагач б-н сугыла. 1920 еллардан А.х. Татарстанда һәм, гомумән, бөтен илдә катлаулы тарихи һәм икътисади шартларда үсә. *Национализацияләү* һәм «җирне социализацияләү» барышында җирсез һәм аз җирле крәстияннәргә алпавыт, хөкүмәт һәм удел җирләре алып бирелә, ләкин ул гына А.х.ндагы түбән җитештерүчәнлек сәбәпләрен бетерә алмый. 1920 елларда *яңа икътисади сәясәткә* (НЭП ка) көчүү нәтиҗәсендә А.х. үсешендә сизелерлек җанлану күзәтелә. 1928 дә а.х. культураларының чәчүлек мәйданнары 2718,4 мең *га* га, бөртеклеләрнең мәйданы 2516 мең *га* га кадәр арта, бу 1920 ел б-н чагыштырганда 28,7% һәм 25% ка күбрәк була. Бөртеклеләрнең тулай җыемы — 2,7, бәрәңгенеке 6 тапкырга үсеп, 1710 мең *т* һәм 1057,8 мең *т* тәшкил итә. Әмма төп тарту көче булып һаман да атлар кала, 1929 га аларның баш саны 1900 ел б-н чагыштырганда 23,5% ка арта һәм 544 мең башка җитә (ш.и. эш атлары — 359,5 мең). Мөгезле эре терлекнең баш саны 1916 ел б-н чагыштырганда 45,1% ка (ш.и. сыерлар — 21,4% ка), дуңгызлар — 48,9% ка, сарык һәм кәҗәләр 70,4% ка арта. Ләкин *Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү* чорында бу күрсәткечләр кискен түбәнәя: 1934 тә атларның баш саны 340,3 мең баш тәшкил итә (275,9 мең эш аты) һәм 1941 гә кадәр артмый. 1933 тә 1929 ел б-н чагыштырганда мөгезле эре терлек 207,3 мең башка (23,5%) (ш.и. сыерлар — 137,9 меңгә, ягъни, 29,6% ка), дуңгызлар — 186,9 (56,1% ка), сарыклар һәм кәҗәләр — 2001,3 мең башка (3 тапкыр) кими. Мөгезле эре терлекнең баш саны буенча 1929 ел дәрәҗәсенә 1960 та гына (ш.и. сыерлар — 1963 тә), дуңгызлар буенча 1952 дә генә ирешелә. Сарык һәм кәҗәләрнең баш саны бу дәрәҗәгә бервакытта да ирешә алмый, 2005 нең 1 гыйнварына республикада аларның баш саны 1929 дагының 13,3% ын гына тәшкил итә.

1940 ка республикада 3893 колхоз оештырыла, 103 *машина-трактор станциясе* төзелә, аларда 6,8 мең трактор, 3,3 мең иген җыю комбайны, 2,9 мең автомобиль, 7,2 мең трактор сабаны, 4,1 мең чәчкеч, 3,5 мең культиватор кулланышта була. 53 совхоз эшли. Игенчелек тармаклары экстенсив алып барыла, а.х. культураларының уңдырышлылыгы 1928 ел дәрәҗәсендә кала. Бөртеклеләрнең тулай җыемы 8% ка гына арта (1710 мең *т* дан 1849,3 мең *т* га кадәр). Бөек Ватан сугышы республиканың А.х.на гаять зур зыян китерә. Атларның күпчелеге фронтка җибәрелә, колхоз һәм совхозларда, — тарту көче буларак, — үгезләр, ә шәхси хуҗалыкларда хәтта сыерлар файдаланыла.

1945 тә 1941 гә караганда колхозларда бөртекле культураларның мәйданы 39,9% ка, техник культураларның 35,2% ка (ш.и. җитен һәм киндер 64,5 ка), бәрәңге 8,1% ка кимрәк була, атлар саны 20,3% ка, дуңгызлар 44,1% ка, сарык һәм кәҗәләр 34,5% ка кими. Мөгезле эре терлек саны 4,7% ка арта.

1940 еллар ахыры — 50 еллар башында колхоз һәм совхозларны эреләндерү уздырыла. А.х.н үстерү, аның матди-техник базасын ныгыту, иҗтимагый җитештерүдә колхоз һәм колхозчыларны матди яктан кызыксындыру һ.б. чаралар КПСС ҮКнең сентябрь пленумында (1953) кабул ителә. 1958 дә КПСС ҮКнең февраль пленумыннан соң МТСлар ремонт-техника станцияләре (РТС) итеп үзгәртелә, тракторлар, комбайннар һ.б. катлаулы а.х. машиналары колхозларга сатыла. Сентябрь (1953) һәм февраль (1958) пленумнары карары нигезендә колхозчыларның шәхси ярдәмче хуҗалыкларыннан натуралата түләү бетерелә. Ремонт-техника станцияләрендә (РТС) башкарылган эшләр өчен колхозлар акчалата түли башлый. 1958 дән колхозларны һәм совхозларны эреләндерү икенче тапкыр уздырыла, шуның нәтиҗәсендә перспективасыз дип исәпләнгән күп авыллар бөлгенлеккә төшә һәм юкка чыгарыла, авыл тормышын демократияләштерү дәрәҗәсе тагын да түбәнәя, колхоз крәстияннәренең, совхоз эшчеләренең җитештерү б-н идарә итүдә, колхоз һәм совхоз җитәкчеләре эшен күзәтүдә катнашуы кискен кими. 1960 елга респ-када 795 колхоз һәм совхоз исәпләнә, аларның матди-техник базасын ныгыту башлана, тракторлар, комбайннар һ.б. а.х. машиналарының саны шактый арта, бу исә үсемлекчелектә механикалаштыру дәрәҗәсен күпкә күтәрә.

А.х. культураларының чәчүлек мәйданы 1960 та 1940 ел б-н чагыштырганда 10,8% ка (384,1 мең *га*), бәрәңге — 13% ка (44,7 мең *га*), терлек азыгы культуралары 3,3 тапкыр (661,8 мең *га*) арта; бөртеклеләрнең тулай җыемы — 25,3% ка, бәрәңге — 2,2 тапкыр, яшелчә 6% ка арта. 1944 тән Татарстанда а.х. җитештерүендә яңа тармак — чөгендер игү барлыкка килә, шикәр чөгендере игелә башлый, 1960 та аның тулай җыемы 301,5 мең *т* була. Бөртеклеләрнең уңышы 10 *ц/га*, шикәр чөгендеренең — 101, бәрәңгенең — 79, яшелчәнең — 88 *ц/га* тәшкил итә. Мөгезле эре терлекнең баш саны 78,7% ка, ш.и. сыерлар 32,9% ка арта.

А.х. үсешендә яңа этап КПСС ҮКнең март (1965) пленумыннан соң башлана, ул а.х. эшләрен механикалаштыру, җирләрне химияләштерү һәм мелиорацияләү, хуҗалык исәп-хисабы һәм кредит мөнәсәбәтләре системасын камилләштерү юлы белән хуҗалыкларны ныгыту (к. *Хуҗалык исәп-хисабы*), а.х. хезмәткәрләрен матди яктан кызыксындыру, а.х. җитештерүенең матди-техник базасын ныгыту, а.х. хезмәтенең характерын үзгәртү, а.х. производствосына фән һәм техника казанышларын кертүдә фәнни учреждениеләрнең, галим һәм белгечләрнең ролен күтәрүгә юнәлтелгән һ.б. чаралар ярдәмендә ил буенча а.х. производствосын интенсивлаштыруга юл ала.

1960 елларның 2 нче яртысы — 1990 еллар башында А.х. үстерүгә зур күләмдә акча бирелә. А.х. на капитал салулар күләме республика халык хуҗалыгында кулланылган гомуми капиталның 1965 тә — 5,4% ын, 1970 тә — 7,2%, 1980 дә — 9,0, 1985 тә — 10,1, 1990 да — 18,2% ын тәшкил итә. 283,1 мең *га* да сугару, 23,9 *га* да киптерү системалары төзелә, эре яшелчәчелек хуҗалыклары булдырыла: *ачык грунтлы* — «Нармонка», «*Ворошилов*», «Овощевод» һ.б. совхозлар, *ябык грунтлы* — «*Майский*», «*Весенний*» һ.б. совхозлар. Мөгезле эре терлек, дуңгызлар, сарыклар өчен яңа ферма биналары, кошчылык фабрикалары (йомырка алу юнәлешендә — 2,5 млн. тавыкка, кош ите җитештерү юнәлешендә — елына 17,4 млн. баш кошка исәпләнгән) төзелә, яңартып корыла; колхозларда хуҗалыкара оешмалар тарафыннан, ш.у. колхозчылар һәм авыл интеллигенциясе үз хисабына һәм дәүләт кредиты ярдәмендә 5,6 млн. $м^2$ дан артык мәйданда торак йорт, 34,8 мең урынлы балалар бакчалары, 2053 урынлы хастаханә-

ләр, 149,6 мең урынлы 759 гомуми белем бирү мәктәбе, 190,9 мең урынлы клуб һәм мәдәният йортлары төзелә. Бу чаралар җитештерү күләменең сизелерлек үсешенә китерә.

1990 да бөртекле культураларның уңышы 20,4 *ц/га*, шикәр чөгендереннеке — 190, бәрәңгенеке — 105, яшелчәнеке — 145 *ц/га* була, 1960 та шулар ук 10, 101, 79 һәм 88 *ц/га* тәшкил итә; елына 1 савым сыердан 3300 *кг* сөт, 1 сарыктан 3,1 *кг* йон, 1 тавыктан 244 данә йомырка алына.

1960 ел б-н чагыштырганда мөгезле эре терлек саны 82,3% ка, (ш.и. сыерлар — 39%), дуңгызлар — 53,8% ка арта.

Гомумән республика буенча 1990 да тулай продукциянең бәясе 1960 дәрәҗәсе б-н чагыштырганда 81% ка, ш.и. үсемлекчелектә — 68% ка, терлекчелектә 88% ка үсә.

Төп фондлар структурасында җитештерүдәге актив средстволарның — авыр эш машиналары, җайланмалар, механикалаштырылган транспорт чаралары һ.б. ның тоткан урыны күтәрелә. А.х. пр-тиеләренең машина-трактор паркларының саны арта һәм сыйфат ягыннан яхшыра. А.х.да төп кыр эшләре тулысынча механикалаштырыла; сыер саву һәм терлекчелектәге башка авыр хезмәтне механикалаштыру дәрәҗәсе яңа югарылыкка күтәрелә.

А.х. механикалаштыру б-н беррәттән җирләрне мелиорацияләү, корткычлардан, авырулардан һәм чүп үләннәрдән *үсемлекләрне саклау*, туфракның уңдырышлылыгын күтәрү (к. *Ашламалар, Авыл хуҗалыгын химияләштерү, Туфракны комплекслы агрохимик культуралаштыру, Туфракны известьләү, Эрозияләнгән җирләрне саклау, Мелиорация*) кебек чаралар гамәлгә ашырыла.

1990 елларда базар мөнәсәбәтләренә күчү а.х. производствосын оештыруда зур үзгәрешләргә китерә. Колхоз һәм совхозларның төп өлеше яңа а.х. берләшмәләре итеп үзгәртелә: АҖ, а.х. җитештерү кооперативлары, предприятие, ассоциация, крәстиян хуҗалыклары (фермер хуҗалыклары), җаваплылыгы чикләнгән ширкәт һәм җәмгыятьләр, ышанычлы ширкәт, тулы ширкәтләр, күмәк предприятиеләр, кооперативлар берләшмәсе, *агрофирма*лар һ.б. 2006 елга А.х. пр-тиеләренең гомуми саны 735 булган, шулардан — яңа хокукый формадагылары — 727, колхозлар — 7, совхозлар — 1. Алардан тыш, 2006 да 2461 крәстиян (фермер) хуҗалыгы, 110,2 мең *га* мәйданда шәхси ярдәмче хуҗалыклары булган 425,4 мең гаилә, 28 мең *га* мәйданда коллектив һәм шәхси бакчалары булган 370,7 мең гаилә, 0,7 мең *га* мәйданда коллектив һәм шәхси яшелчә бакчалары булган 4,8 мең гаилә теркәлә. А.х. пр-тиеләре а.х. җирләренең 49,3% ын, крәстиян (фермер) хуҗалыклары — 7,1% ын, гражданнар — 43,6%, шулардан шәхси ярдәмче хуҗалыклар һәм коллектив һәм шәхси бакчалар 2,8% ын алып тора. 2006 да а.х. оешмаларында, крәстиян һәм халык хуҗалыкларында җитештерелгән төп а.х. продукциясе төрләренең а.х. җитештерүенең гомуми күләмендә тоткан урыны (% ларда): бөртекләләр 86,2; 13,8; һәм 0, бәрәңге — 10,4; 87; һәм 2,3, җиләк-җимеш — 0,1; 0; һәм 99,9, яшелчә — 25,7; 1,1; һәм 73,7, терлек һәм кош ите — 54; 2,8; һәм 43,2, сөт — 51,6; 5,7 һәм 36,8, йомырка — 67,9; 4; һәм 28,1, йон — 4,1; 2,2; һәм 93,7, бал — 18,6; 4,4; һәм 77.

Энергиягә һәм а.х. техникасына бәяләр күтәрелү, салымнар арту хуҗалыкларда акча җитмәүгә, минераль ашламалар, пестицидлар, а.х. машиналары, җиһазлар һ.б. сатып алу күләмнәренең кыскаруына китерә.

А.х. пр-тиеләрендә техник чараларның саны кими: тракторлар — 2,1% ка; ашлык җыю комбайннары — 3,6 тапкыр, чөгендер җыю комбайннары — 4, силос җыю комбайннары — 2,5, бәрәңге җыю комбайннары — 7 тапкыр, сабаннар — 2,8% ка, чәчкечләр — 2,5, культиваторлар — 2,9, тезмә ургычлар — 4 тапкыр. А.х. пр-тиеләренең энергетика куәте 46,2% ка, энергия б-н тәэмин ителеше 61,5% ка кими. 2006 да 1995 б-н чагыштырганда органик ашламалар куллану 3,5 тапкыр, минераль ашламалар — 28,8% ка, ачы туфракны известьләү 35% ка түбәнәя.

Нәтиҗәдә 2006 да (1990 б-н чагыштырганда) чәчүлек мәйданнар 13,6% ка, ш.и. бөртекле культуралар — 20,8% ка, яшелчә — 10,3% ка, терлек азыгы культуралары — 12,7% ка, бәрәңге 22% ка кими. Мөгезле эре терлекнең баш саны — 491 меңгә (30,4% ка), ш.и. сыерлар — 127,1 меңгә (22,5%); дуңгызлар — 355,8 меңгә (32,9%); сарык һәм кәҗәләр 1137,9 меңгә (4 тапкыр) кими. Элек нәтиҗәле эшләп килгән күп кенә терлекчелек комплекслары эшләүдән туктый. Ит җитештерү 75,1 мең *т* га (26,6%), сөт — 42,4 мең *т* (2,5%), йон — 3,2 мең *т* га (4 тапкыр), йомырка — 186,9 млн. данәгә (14,9%) кими.

А.х.ның төп капиталына инвестицияләр республика буенча гомуми күрсәткечнең 1990 да — 18,2% ын, 2000 дә — 4,1%, 2006 да 6,2% ын тәшкил итә. 2006 да 30,9%, ягъни 227 а.х. пр-тиесе зыянга эшли. Бу чорда республика хөкүмәте тарафыннан минераль ашламалар һәм үсемлекләрне саклау чаралары һ.б. сатып алуда а.х. продукциясе җитештерүчеләрне яклау буенча күп кенә чаралар үткәрелә. Нәтиҗәдә бөртекле культуралар уңышы күтәрелә, бөртеклеләрнең тулай җыемы арта, тулай җыем 2000 дә — 5294,2 мең *т*, 2006 да — 4522,7 (1990 да — 3986,5) тәшкил итә; 2000 дә — 1355,7 мең *т*, 2006 да 1731,3 мең *т* ашлык сатыла.

2006 да а.х. продукциясенең күләме 77,2 млрд. сум, ш.и. а.х. оешмаларында — 37,6, крәстиян-фермер хуҗалыкларында — 3,7, шәхси хуҗалыкларда — 35,9 млрд. сум тәшкил итә. Үсемлекчелектә продукция 11,2% ка, терлекчелектә 13,4% ка арта. Җан башына 55,1 *кг* ит, 431 *кг* сөт, 285 данә йомырка җитештерелә.

А.х. җитештерүендә 2004 тә яңа кредитларның күләме 5,8 млрд. сум тәшкил итә, бу 2003 елдагы күрсәткечләрдән ике тапкыр артып китә. А.х. ын техник яктан үзгәртеп коралландыру өчен 532 млн. сум, ш.и. ТР бюджетыннан 445,6 млн. сум бүлеп бирелә һәм үзләштерелә. 280 МТЗ-1221 тракторы, 180 «Нива» комбайны, 30 «Нью-Холланд» комбайны, 11 бәрәңге игү һәм җыю машиналары комплекты сатып алына. ТР МКның 27.04.2006 елгы карары б-н республикада гомуми смета бәясе якынча 37 *млрд.* сум булган агросәнәгать комплексы үсешендә өстенлекле милли проектлар гамәлгә ашырыла. Идел буе федераль округының 12,3% чәчүлек мәйданы туры килгән Татарстанда 2006 да бөртекле ашлыкның 19,9% ы, шикәр чөгендеренең — 32,3, бәрәңгенең — 17,7, терлек һәм кош итенең (тере үлчәмдә) — 14,8, сөтнең — 15,8, йонның 15,4% ы җитештерелә; а.х. оешмалары тарафыннан бөртекле ашлыкның 21,2% ы, бәрәңгенең — 19,2, яшелчәнең — 19,4, терлек итенең (тере үлчәмдә) — 18,5, сөтнең 21% ы сатыла. Бөртекле культураларның уртача уңышы округның уртача күрсәткеченнән 10,6 *ц/га* га, шикәр чөгендере — 28, бәрәңге — 40, яшелчә 21 *ц/га* га югарырак була, һәм ТР округта бөртек культуралар уңышы, бөртекле ашлык, шикәр чөгендере һәм бәрәңге җитештерү, а.х. оешмаларының бөртекле ашлык, яшелчә, сөт, терлек һәм кош ите сату күләме буенча беренче урынга чыга. Икътисадның А.х. секторы б-н 43 бүлекчәдән һәм 43 район а.х. идарәсеннән торган *Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы* җитәкчелек итә. Бу ведомстводагы 75 ачык һәм ябык АҖ, дәүләт унитар пр-тиеләре, холдинг һәм лизинг компанияләре, концерннар, үзәкләр, ассоциацияләр, федераль дәүләт идарәләре бүлекчәләре, инспекцияләр һ.б. оешмалар. А.х. тармакларының фәнни тәэмин ителеше *Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты*, Россия а.х. академиясенең Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-ты тарафыннан гамәлгә ашырыла. А.х. җитештерүе өчен кадрларны әзерләүчеләр: Казан аграр ун-ты (*Казан авыл хуҗалыгы академиясе* (2006 га кадәр), *Казан ветеринария медицинасы академиясе*, Татарстан кадрларны яңадан әзерләү һәм агробизнес ин-ты, 9 а.х. техникумы. 1990–2006 елларда югары белемле 16549, махсус урта белемле 37827 а.х. белгече әзерләнә. Ш.у.к. *Агрономия, Агротехника, Агрохимия, Ветеринария, Зоотехния, Крәстияннәр, Үсемлекчелекне механикалаштыру, Игенчелек системасы.*

Чыг.: Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001; Республика Татарстан. 2001: Стат. сб. К., 2003; Сельское хозяйство Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2007.

*Әд.:* Х а л и к о в Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала. К., 1995; Проблемы — будни фермеров и крестьянских подворий Республики Татарстан (в очерках). К., 2000; Ш а й д у л л и н Р.В. Крестьянские хозяйства Татарстана: проблемы и пути их развития в 1920–1928 гг. К., 2000; З и я т д и н о в Ф.С. Ресурсный потенциал агропромышленного комплекса: анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001; М а л и к о в М.М. Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002; Слагаемые эффективного агробизнеса: обобщение опыта и рекомендаций. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005; Итоги социально-экономического развития Республики Татарстан в 2004 и задачи на 2005. К., 2005.

*И.Н.Афанасьев.*

**АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ҖИРЛӘРЕ́**, табигый үзлекләре б-н аерыла һәм аерым җитештерү максатларында хуҗалыкта системалы файдаланыла торган а.х. җир мәйданнары. Төп а.х.җ. — сөрү җирләре, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчалары, болын һәм көтүлекләр. Аларга ш.у. төзелешләр, урман полосала-

ры, юллар, су чыганаклары булган җирләр дә керә. Тулырак файдалану максатында А.х.җ. бер төрдән икенче төргә күчерелә (к. табл.).

ТРда 1965–2006 еллар эчендә А.х.җ. мәйданы динамикасы (мең *га*):

| Еллар | Барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Сөрү җирләре | Табигый терлек азыгы җирләре |
| 1965 | 4747,0 | 3920,5 | 899,0 |
| 1990 | 4573,8 | 3758,3 | 804,0 |
| 1995 | 4562,1 | 3715,1 | 807,9 |
| 2000 | 4514,3 | 3478,8 | 996,6 |
| 2006 | 4491,1 | 3457,0 | 995,3 |

1965–90 елларда А.х.җ. составындагы үзгәрешләр җирләрнең, башлыча, Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт һ.б. шәһәрләрдәге сәнәгать төзелешләренә бирелүе нәтиҗәсендә; 1990–2006 да — нигездә эрозияләнгән сөрүлек җирләрне терлек азыгы җирләренә күчерүгә бәйле рәвештә була. 2006 елга А.х.җ.нән файдаланучылар: а.х. пр-тиеләре — 49,3%, крәстиян (фермер) хуҗалыклары — 7,1%, гражданнар — 43,6%, ш.и. шәхси ярдәмче хуҗалыклары булганнар (йорт яны җирләреннән файдалану) — 2,2%, коллектив һәм шәхси бакчалар — 0,6%.

Ш.у.к *Туфрак белеме, Туфрак, Болын, Көтүлекләр*.

Чыг.: Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001; Сельское хозяйство Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2007.

*Әд.:* Б а к и р о в Н.Б. Земельный кадастр Татарстана: прошлое, настоящее, будущее. К., 2002.

*И.Н.Афанасьев.*

**АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ КОММУ́НАСЫ**, ТАССРда 1918–32 елларда авыл хуҗалыгы тармагында эш барышын оештыруның бер төре: кооперация буларак берләшкән беренчә хуҗалык уртактан җир эшкәртә һәм җитештерелгән продукцияне җан башы санынннан чыгып бүлә. Татарстанда шундый беренче коммуналар Гражданнар сугышы чорында ук барлыкка килә; мәс. «Карл Маркс» (Каймар а.), «Надежда» (Колсәет а.), «Красный луч» (Киндерле а.) һ.б. Алар, башлыча, батраклар, ярлылар һәм авылга кайткан эшчеләр тарафыннан элекке алпавытлар җирләрендә оештырыла. ТАССРда 1920 елның 1 октябренә шундый 20 коммуна, 1928 нең 1 октябренә 9 коммуна теркәлә. Коммуналар а.х. тармагы җитештерүчәнлегендә зур роль уйнамыйлар, чөнки җир эшкәртүдә рентабельсез ысуллар һәм иске технологияләр кулланыла. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында — крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү барышында А.х.к. колхозларга әверелдерелә.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**«АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ СӘХИФӘСЕ́»**, к. «*Татарстан авыл хуҗалыгы*».

**АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ТЕРЛЕКЛӘРЕ́Н ТУКЛАНДЫРУ́**, зоотехниянең мөһим бүлеге, терлекләрнең нормаль үсешен һәм генетик яктан тиешле продукция сыйфатын булдыру, азыклардан отышлы файдаланып, сәламәт һәм югары үрчемле итү өчен, рациональ тукландыруның теоретик нигезләрен, ысулларын һәм технол. алымнарын эшли. Тукландыруның төп бурычлары: терлекләрнең туклану матдәләренә ихтыяҗын һәм азыкның сеңдерелү-эшкәртелүен өйрәнү, азыкны ашату эзлеклелеген билгеләү, тукландыру рационы нормасын, тәртибен эшләү, тукландыруны дөрес оештыру һәм техникасын булдыру. А.х.т.т. агрохимия , агрономия, биология, физиология, химия, микробиология һәм биохимия казанышлары нигезендә үсә, аларның ысуллары һәм казанышларыннан файдаланыла.

Терлекләрне тукландыру тулы сыйфатлы булырга һәм рациондагы азыктан организмга җитәрлек дәрәҗәдә минераль һәм биологик актив матдәләр керергә тиеш. Начар тукландыру продуктлылык кимүгә, үрчем түбәнәюгә, авырулар артуга, үрчемнең яшәүгә яраклаша алмавына китерә. Терлекләрне тулы сыйфатлы тукландыру, азык һәм өстәмәләрдән рациональ файдалану, рационнар төзү мәсьәләләре Татарстан а.х. фәнни тикшеренү ин-ты, Казан дәүләт вет. медицинасы академиясе галимнәре тарафыннан эшләнә, 1943–2000 елларда А.х.т.т. теориясе һәм гамәли үсешенә А.М.Барсков, Л.П.Зарипова, В.Т.Коршун, Ә.Х.Фазылҗанов, Ш.К.Шакиров, А.В.Якимов зур өлеш кертәләр.

А.х.т.т. дисциплина буларак Казан вет. медицинасы академиясендә, Буа, Минзәлә, Тукай а.х. техникумнарында укытыла.

*Әд.:* П о п о в И.С. Кормление сельскохозяйственных животных. М., 1957; Т о м м э М.Ф. Нормы и рацион кормления сельскохозяйственных животных. М.: 1969; К а л а ш н и к о в А.П., К л е й м е н о в Н.М. Нормы и рационы кормления сельскохозяйственных животных. М., 1986.

*Н.Н.Мөхәммәтгалиев, Ә.Х.Фазылҗанов.*

**АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ҮСЕМЛЕКЛӘРЕ́ АВЫРУЛАРЫ́**, авыру тудыручы организмнар һәм мохитнең уңайсыз шартлары тәэсирендә үсемлекләрдә барлыкка килгән патологик процесслар. Яшәү өчен әһәмиятле функцияләр бозылуда күренә башлый, үсемлекләрне яисә аларның аерым өлешләрен зарарлый, уңышның кимүенә һәм сыйфаты начарлануга китерә. 30 меңнән артык төрдәге а.х. авырулары билгеле. Аларны йогышлы һәм йогышсыз авыруларга бүлеп йөртәләр. Йогышсыз авыруларны минераль туклану режимы бозылу, югары һәм түбән темп-ралар, аларның кискен үзгәреше, һава һәм туфрактагы зарарлы матдәләр, яктылык һәм су режимының, ионлаштыручы нурларның начар тәэсире кебек тирәлек факторлары китереп чыгара. Йогышлы авыруларга *үсемлекләрдә вируслы авырулар*, *үсемлекләрдә бактериаль авырулар*, *үсемлекләрдә гөмбә авырулары* керә. Йогышлы авырулар патогенезында йоктыру алды фазасы, йоктыру, инкубация һәм инкубациядән соңгы чорлар, саклану реакцияләре аерып күрсәтелә. ТРда бөртекле ашлык культуралары авыруларыннан иң куркынычлылары: бодай, арпа, солы, тарыда — тузанлы кисәү гөмбәсе; бодай, арпа, солыда — каты кисәү гөмбәсе; арышта — сабак кисәү гөмбәсе. Кыяклы үсемлекләрдәге ончыл чык һәм тутык авырулары: бодай һәм арышта сабак тутыгы һәм көрән яфрак тутыгы, арпада — кәрлә тутык, солыда таҗлы тутык уңышның шактый өлешен юкка чыгара. Тарыда бактериаль һәм гөмбә авырулары комплексы китереп чыгарган некротик меланоз авыруы тары ярмасының сыйфатын начарайта. Уҗым арышы һәм бодае аерым елларда — арыш анасы б-н, кыш карлы, җылы булганда — склеротиния, кар күгәреге; кузаклылар дымлы елларда аскохитоз һәм тутык авырулары б-н зарарлана. Бәрәңгедә вируслы авырулар, бактериаль авырулардан — юеш черек, гөмбә авыруларыннан — гади кутыр, коры черек, фитофтороз, макроспориоз, фузариоз, фомоз таралган. Җимеш культураларыннан алма һәм грушага — кутыр, чиягә — коккомикоз, сливага клястериоспороз авырулары зур зыян китерә. Көрәш чаралары: үсемлекләрнең ТР шартларына яраклаштырылган бердәм саклау системасын булдыру, чыдамлы сортлар игү, рациональ орлыкчылык, а.х. үсемлекләренең үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру, орлыкларны, үрентеләрне, утырту материалларын эшкәртү, вегетатив юл б-н үрчи торган утырту материалларын меристема алымы б-н сәламәтләндерү, а.х. үсемлекләрен пестицидлар һәм биопрепаратлар б-н эшкәртү, карантин чаралары уздыру. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында бөртекле, бөртекле-кузаклы һәм җиләк-җимеш культураларының тышкы тирәлекнең уңайсыз шартларына җайлашкан һәм авыруларга чыдам сортлары чыгарыла.

*Әд.:* Инфекционные болезни растений. М., 1935; Болезни растений. М., 1956; Р о д и г и н М.Н. Общая фитопатология. М., 1978; Химическая защита растений. М., 1987; Фитосанитарный прогноз основных вредителей и болезней сельскохозяйственных культур на 2007 год и система мероприятий по борьбе с ними в Республике Татарстан. К., 2007.

*Ф.Ф.Җамалиева, Н.П.Капитонова.*

**АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ҮСЕМЛЕКЛӘРЕ́ КОРТКЫЧЛАРЫ́**, культуралы үсемлекләрне зарарлый яки аларны һәлак итә торган корткычлар. А.х. культураларына бөҗәкләр иң зур зыян китерә, бу аларның биологик үзенчәлекләре, төрләренең күплеге, тиз үрчүе, күп ашавы, күп төр личинкаларның тәүлеккә үз авырлыкларыннан да күбрәк үсемлек ашарга сәләтле булуы б-н аңлатыла. Бөҗәкләрдән төп корткычларга турыканатлы, тигезканатлы, ярымкатыканатлы, чуклы канатлы, катыканатлы, тәңкәканатлы, элпәканатлы һәм икеканатлылар отрядлары керә. Үсемлек ашаучы бөҗәкләр һәм талпаннар полифагларга, яисә төрле үсемлекләр б-н тукланучыларга; олигофагларга — бер семьялыктагы үсемлекләр б-н тукланучыларга (мәс., әвернә чәчәклеләр б-н) бүленә. Типик олигофагка колорадо коңгызы мисал булып тора. А.х. культураларына полифаглардан иң зур зыян китерүчеләр: саранчалылар, аю чикерткә, шыртлавыклар, ужым ябалакчыгы һәм аларга якын төрләр, бигрәк тә ябалакчык гамма, сабак һәм болын күбәләкләре. Татарстанда игелә торган бөртекле ашлык культураларына олигофаглардан швед чебене, яшел күз, гессен чебене, икмәк коңгызы иң зур зыян китерә. Кузаклы үсемлекләрне — бүлбе озынборыны, борчак җимеш корткычы, борчак гөбләсе; кәбестәне — кәбестә күбәләге, кәбестә көясе, әвернә чәчәклеләр борчалары күб-




**Авыл хуҗалыгы үсемлекләре корткычлары.** 1. Кәбестә күбәләге: а – күбәләк; б – корт; в – курчак; г – яфракка салынган күкәйләр; 2. Әвернә чәчәклеләрнең кара борчасы һәм аның личинкасы; 3. Җир һәм кура җиләкләре коңгызы: а – коңгыз; б – личинка; в – чәчәк бөресендәге личинка; г – зарарлану; 4. Крыжовник утчыл күбәләге: а – күбәләк; б – корт; в – кортлар зарарлаган җиләкләр; 5. Кура җиләге коңгызы: а – коңгыз; б – личинка; в – зарарланган кура җиләге; 6. Парсыз ефәк күбәләге: а – ана күбәләк; б – ата күбәләк; в – корт; 7. Лайлалы кисмән: а – җитлеккән бөҗәк; б – курчак; в – кузы; г – ялган корт; 8. Алмагач көясе: а – күбәләк; б – корт; 9. Алмагач җимешашары: а – күбәләк; б – корт; в – зарарланган җимеш; 10. Колорадо коңгызы: а – коңгыз; б – личинка; в – күкәйләр; г – зарарланган бәрәңге төбе.

рәк зарарлый. Күп төрле корткычлардан бигрәк тә җимеш һәм җиләк үсемлекләре нык зыян күрә. Болар — җимеш йомшагын ашап керә торган алма, груша, слива җимеш кортлары, чия чебене, лайлалы һәм чия кисмәннәре, алмагачның чәчәк бөреләрен зарарлаучы алмагач чәчәкашары һәм чия озынборыны. Вегетатив бөре һәм яфракларны зарарлаучы корткычлар — алмагач, чия, слива яфрагы, крыжовник бәбәге гөбләләре, дүрт аяклы гөбләләр һәм күп сандагы яфрак кимерүче корткычлар — букарка, дуләнә күбәләге, боҗралы парсыз ефәк күбәләкләре, алмагач көясе, кышкы карышлавык, чия көясе. Алардан иң куркынычлысы — агачның бөтен яфрагын юк итүче алмагач көясе. Җиләк культуралары өчен куркыныч корткычлар — карлыган пыялач күбәләге, карлыган кисмәне, карлыганның яфрак һәм сабак оры чебеннәре, карлыган бөреләре талпаны, пәрәвез талпаны, крыжовник утчыл күбәләге, крыжовник карышлавыгы, кура һәм җир җиләге озынборыны, яфракашар, җир җиләге талпаны, кура җиләк коңгызы, кура җиләк бөресе көясе, кура җиләк сабагы чебене, кура җиләк оры чебеннәре һ.б.

Басу, яшелчә һәм бакча культураларының бөҗәк корткычларына каршы хим. (пестицидлар), биол. һәм механик (участокларны чүп үләннәрдән арындыру, туфракны үз вакытында эшкәртеп тору) көрәш чаралары кулланыла. Имезүче хайваннардан бакча үсемлекләренә иң зур зыян китерүчеләр — кимерүчеләр: тычканнар, кыр тычканнары һәм куяннар, алар бер сезон эчендә бакчачыларның күпьеллык хезмәтен юкка чыгарырга сәләтле. Тычкан һәм кыр тычканнарына каршы хим. көрәш чаралары (агуланган алдавыч), биопрепаратлар (бактериаль) кулланыла. Агач кәүсәләрен һәм ботакларын куяннардан саклау өчен аларны төрле материаллар б-н урап бәйлиләр яисә куркыткыч матдәләр сылыйлар.

*Әд.:* Вредители и болезни полевых культур. М., 1970; Мамаев К.А., Ленский Г.К., Соболева В.П. Борьба с вредителями и болезнями плодовых, ягодных и овощных культур. М., 1970; Павлов И.Ф. Защита полевых культур от вредителей. М., 1987; Фитосанитарный прогноз основных вредителей и болезней сельскохозяйственных культур на 2007 год и система мероприятий по борьбе с ними в Республике Татарстан. К., 2007.

*В.А.Наумов.*

**«АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ЭШЧЕСЕ»**, газета. Игенчелек совхозлары эшчеләре берлеге, терлекчелек совхозлары эшчеләре берлеге, МТС хезмәткәрләре берлегенең Татарстан ком-ты органы. 1927 елның 1 ноябреннән 1932 нең 18 октябренә кадәр Казанда атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Исеме үзгәрә: 1930 ның апреленә кадәр «Ялчы», 1931 нең гыйнварына кадәр «Авыл-урман хуҗалыгы эшчесе», 1931 нең 15 гыйнварыннан «Авыл хуҗалыгы эшчесе». 1932 дә «*Колхоз газеты*» б-н берләштерелә. Төрле елларда мөхәррирләре: М.Мөхәммәтҗанов, И.Сәйфуллин, И.Хәлимов. Аеруча актив язышучылар: Г.Зарипов, В.Камалов, Х.Мөдәррисов, Х.Тугаев, Х.Хәйруллин. «А.х.э.» г-тасы битләрендә илдәге сәяси хәлләр яктыртыла, РСФСР ХКС декретлары һәм карарлары басыла, хуҗалыкларны күмәкләштерүнең барышы, алдынгы колхоз-совхозларның тәҗрибәләре турында мәкаләләр дөнья күрә, авыл халкы арасында наданлыкны бетерү эшенә зур игътибар бирелә. Төп рубрикалары: «Безнең алдынгылар», «Наданлык белән көрәш», «Советлар Союзында», «Чит ил яңалыклары», «ВКП(б) тарихыннан».

**«АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ – УРМАНЧЫЛЫ́К»**, журнал. ТАССР Җир эшләре халык комис-ты органы. 1928–31 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә.

**АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́Н ХИМИЯЛӘШТЕРҮ́**, а.х. практикасында химик чаралар куллану; туфракның уңдырышлылыгын, а.х. культураларының уңышын, терлекләрнең продуктлылыгын күтәрү, үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясенең сыйфатын яхшырту, үсемлекләр һәм терлекләрне корткычлардан, авырулардан, чәчүлекләрне чүп үләннәрдән саклау максатында фән-техника прогрессы һәм тармакны интенсивлаштыру юнәлешләренең берсе. А.х.х. *ашламалар* куллануны, *туфракны известьләү*, *туфракны комплекслы агрохимик культуралаштыруны* үз эченә ала. Органик һәм минераль ашламалар кертү а.х. культураларының туклану процесслары б-н идарә итәргә, үсемлекләрнең үсешен көчәйтергә, аларның химик составын үзгәртергә, тышкы уңайсыз шартларга чыдамлылыкларын арттырырга мөмкинлек бирә һәм уңышның шактый үсешенә китерә. Бер үк вакытта ашламалар туфракның сыйфатын яхшырта (сеңдерү сәләте, туфракның реакциясе, физ. үзенчәлекләре һ.б.). А.х. культураларын үстерүдә интенсив технологияләр, уңышны программалаштыру б-н бәйле рәвештә ашламаларның роле кискен үсә. А.х.х.нең әһәмиятле ягы булып химик чараларны зарарлы бөҗәкләргә каршы (инсектицидлар), культурадагы үсемлекләр һәм терлекләрдә гөмбә авыруларын тудыручыларга һәм бактериаль авыруларга каршы (фунгицидлар, бактерицидлар, антибиотиклар һ.б.), чүп үләннәрне бетерүдә (гербицидлар) куллану тора (к. *Үсемлекләрне саклау*, *Үсемлекләрдә вируслы авырулар*).

А.х. җитештерүендә агач культуралары үсентеләренең һәм күчереп утыртыла торган зур агачларның тамырлануын көчәйтүче, өлгереп җитмәгән җимешләрнең коелуын киметүче синтетик матдәләр һәм орлыкчылык чәчүлекләрендә бәрәңгенең сабак, яфракларын корытучы десикантлар кулланыла.

Терлекчелектә химик өстәмәләр — терлек азыгы фосфатлары, карбамид премикс, витамин, дарулар киң файдаланыла. Терлек азыгы өстәмәләре тулы рационлы катнаш азыклар җитештерүдә файдаланыла.

Яшелчәчелек хуҗалыкларында, җылытылган грунт корылмаларында һәм буа, сусаклагыч төпләрендә гидроизоляция сыйфатында полимер материаллар киң кулланыла. Полиэтилен каплавычлар б-н силос, сенаж һәм аларның корылмаларын каплыйлар.

1964 елда «Татсельхозтехника» системасында А.х.х. проблемаларын хәл итү өчен ашламалар, химик мелиорантлар кертү, торф һәм известьле материаллар чыгару, торфлы компост әзерләү һ. б. төр агрохимик эшләр башкару буенча механикалаштырылган отрядлар; Казан а.х. тәҗрибә станциясе җирлегендә ике агрохимия лабораториясе (Казан һәм Әлмәттә) оештырыла. 1979 да а.х.на агрохимия хезмәте күрсәтү буенча «Татсельхозхимия» бердәм җитештерү берләшмәсе төзелә. Аның составына «Сельхозхимия»нең район бүлекләре, Респ-ка а.х. химияләштерүнең проект-тикшерү станциясе һәм аның Әлмәттәге ф-лы, Респ-ка үсемлекләрне саклау станциясе, 2 известь карьеры керә. 1995 тә бу берләшмә «Трастовая К°» «Татагрохим» АҖ итеп үзгәртелә, аңа «Агрохимсервис»ның 46 район оешмасы, 2 карьер, «Татсельхозхимпроект» проектлау конторасы, «Татсельхозхимкомплект» районара специальләшкән пр-тиесе керә. Үсемлекләрне химик саклау чараларын куллануның фәнни яктан тәэмин ителешен түбәндәге Федераль дәүләт учреждениеләре гамәлгә ашыра: «Татарский» Үзәк агрохимия хезмәте, «Әлмәт» агрохимия хез-

1965 – 2005 елларда ТРдагы сөрү җирләренең туфрак уңдырышлылыгы күрсәткечләре динамикасы

| Күрсәткечләр | Еллар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1965–70 | 1971–79 | 1980–85 | 1986–90 | 1991–95 | 1996–2000 | 2001–2005 |
| Тикшерелгән мәйдан | 3725,1 | 3749,9 | 3734,4 | 3714,2 | 3639,2 | 3611,0 | 3364,0 |
| | Ачылык дәрәҗәсе | | | | | | |
| Югары | 13,9 | 19,3 | 20,4 | 24,4 | 40,2 | 36,5 | 26,6 |
| Уртача | 252,6 | 266,9 | 269,4 | 316,8 | 363,0 | 309,6 | 228,1 |
| Түбән | 1306,3 | 1356,0 | 1397,7 | 1352,2 | 1303,1 | 1141,4 | 1124,8 |
| Барлык ачы туфраклар | 1572,8 | 1642,2 | 1687,5 | 1693,4 | 1706,3 | 1487,5 | 1379,5 |
| Нейтраль туфракка якын | 1083,8 | 1087,7 | 1054,9 | 1073,1 | 993,1 | 1106,5 | 1069,9 |
| Нейтраль | 1068,5 | 1020,0 | 992,0 | 947,7 | 939,8 | 1017,0 | 914,6 |
| | Күчмә фосфор микъдары | | | | | | |
| Түбән | 1017,4 | 905,5 | 469,0 | 247,4 | 120,6 | 89,7 | 124,5 |
| Уртача | 1731,1 | 1699,3 | 1541,7 | 1383,8 | 1066,7 | 2090,6 | 2113,3 |
| Югары | 976,6 | 1045,1 | 1723,7 | 2083,0 | 2451,8 | 1430,7 | 1126,2 |
| Уртача, *мг/кг* | 87,0 | 97,0 | 107,9 | 121,6 | 136,1 | 141,7 | 132,6 |
| | Алмаш калий микъдары | | | | | | |
| Түбән | 421,9 | 343,4 | 223,9 | 218,1 | 113,7 | 101,3 | 137,0 |
| Уртача | 842,3 | 990,9 | 809,6 | 763,3 | 657,8 | 1945,1 | 1887,4 |
| Югары | 2460,9 | 2415,6 | 2700,9 | 2732,8 | 2867,7 | 1564,6 | 1339,6 |
| Уртача, *мг/кг* | 125,0 | 133,5 | 130,5 | 132,0 | 137,8 | 138,7 | 133,2 |

мәте станциясе, аларның фәнни-методик җитәкчелегендә эшләүче 36 район агрохимия лабораториясе, *Татарстан Республикасы үсемлекләрне саклау станциясе*, Россия а.х. академиясенең Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-ты, Татарстан а.х. ин-ты, Казан аграр ун-ты, Казан ветеринария медицинасы академиясе, ТР Баш ветеринария идарәсе, ТР а.х. һәм азык-төлек министрлыгының Терлек азыгы өстәмәләре фәнни-тикшеренү ин-ты, «Биоветфарм» дәүләт унитар пр-тиесе.

Туфракны агрохимик тикшерүнең респ-ка буенча 5 нче, 30 районда 6 нчы, 8 районда 7 нче циклы тәмамлана. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, А.х.х. ачы туфраклы җирләрнең артуын туктата. 2001–2005 тә алар 1991–1995 еллардагыдан 326,8 мең *га* кимегән, 1379,5 мең *га* тәшкил итә, әмма туфракның фосфат һәм калий режимы начарлана (к. Таблица). Ш.у.к. *Ашламалар системасы*.

*Әд.:* Тезисы докладов 3-й научной конференции по вопросам химизации сельского хозяйства Татарской АССР. К., 1971; Айметдинов А.М. Химизация как важная часть интенсификации сельскохозяйственного производства // Влияние удобрений на урожай сельскохозяйственных культур в условиях Волго-Вятского района. К., 1974; Мещанов В.И. Известкование кислых почв. М., 1982; Шакиров Р.С. Земное плодородие. К., 1989; Зиганшин А.А. Современные технологии и программирование урожайности. К., 2001; Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002; Агрохимической службе Республики Татарстан 38 лет. К., 2002; Основные подходы к разработке программы «Плодородие». К., 2002.

*И.Н.Афанасьев.*

**«АВЫ́Л ЯШЬЛӘРЕ́»**, журнал, к. «*Колхоз яшьләре*».

**«АВЫ́Л-УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́ ЭШЧЕСЕ́»**, газета, к. «*Авыл хуҗалыгы эшчесе*».

**АВЫЛЛА́Р**. Идел-Урал буе татарлары элек-электән А.да тормыш алып барган, һәм биредә алар тораклар, йортлар төзегәннәр. Урта гасырларда татар җирләре А.ы (авыл, ил) б-н генә түгел, күпсанлы шәһәрләре б-н дә дан тоткан. 16 йөздә Казан ханлыгы яулангannan соң, шәһәрләрдән көчләп куылган татарларның күпчелеге авылда яшәүче этнос булып әверелә. Татар авыллары һәм салалары зурлыклары — берничә дистәдән меңгә кадәр һәм аннан да артыграк йортлары булуы; төрләре — су б-н бүленгән урында, елга, күл, юл буенда урнашулары; планлаштырылулары — урамлы, әйләнәле, кварталлы һ.б. булулары б-н аерылып торганнар. Борынгы авыллар, аеруча Кама алды төбәгендәгеләре, кардәш гаиләләр утарларының бергә тупланып, оя-оя булып яшәүләре б-н үзенчәлекле. Урамнар тыкрыклар б-н кисешкән. Гадәттә, таза хәлле крәстияннәр, руханилар, сәүдәгәрләр утарлары, мәчет (керәшен А.ында — чиркәү), кибетләр, җәмәгать амбарлары, кайчакта мәктәпләр, янгын сүндерү сарайлары үзәктә урнашкан. Авыл читенә тегермән салынган. Аның тирә-юне көтүлекләр өчен файдаланылган, басу капкасы, киртә б-н әйләндереп алынган. Авылдан беркадәр ераклыкта зират була. Урта Идел буендагы татар А.ы яшеллеккә күмелеп утырган, җирле рус А.ыннан алар шул сыйфат б-н аерылганнар. Утарлар 2 өлешкә — ишегалды (мишәрләрдә — йорт, азбар) һәм ындыр якка бүленеп, ишегалдында — йорт, келәт, амбар, терлек өчен каралты-кура, еш кына җәйге аш алачыгы; ындыр ягында бәрәңге бакчасы, мунча, ындыр табагы, кибәнлек, әвен урнашкан. Ука елгасы бассейнындагы мишәр А.ына хуҗалык корылмаларын (амбар, келәт) утарның тышына, урам ягына урнаштыру гадәте хас. Утар җирләре җитмәгәндә, бәрәңге бакчасы һәм ындыр еш кына авыл читендә урнашкан: гаилә үскән һәм утар җирендә, башка чыгару гадәте буенча, өйләнгән угылларга йортлар салынган. 3 өлештән торган зур утарлы (2 катлы йорт, күпсанлы терлек һәм хуҗалык каралтылары, бакча ягы) таза хәлле гаиләләрдә — бигрәк тә Касыйм, Оренбург татарлары арасында — аз булмаган. Һәр төбәктә дә ишегаллары ачык һавалы урында корылган. Төньяк өчен гадәти булган торакны һәм хуҗалык корылмаларын уртак түбә б-н тоташтыру алымы Чыпца һәм Пермь татарларында таралган. Урман һәм урман-дала төбәкләрендә, гадәттә, бөтен утар буеннан-буена корып алынган: урам якка татар яки рус үрнәгендәге капка (к. *Капка*) урнаштырылган, тоташ бүрәнәләрдән, тактадан, кайчакта таштан салынган биек койма б-н әйләндерелгән. Капкага һәм коймаларга бизәкләр төшерелә, алар төрле төсләргә буяла. Казан артында, ш.у. Касыйм, Сергач татарларында йорт ишегалды түренә салына. Аның каршындагы тоташ койманың бер өлешен беркадәр тәбәнәгәйтеп, аңа челтәрле рәшәткә өстәлә. Өй түренә шомырт, миләш агачлары, чәчәкләр утыртып бакча ясала. Татар А. еш кына ике исем б-н аталалар: берсе — хәзерге административ, икенчесе — аларның халык телендә йөргәне — оно-, этно-, социо-, топо-, гидроним мәгънәсенә ия гадәти атама. Бер үк исемдәге А.ның оешу вакытларын «иске», «яңа» искәрмәләре ачыклый. Кайбер татар А.ында, аеруча Урта Идел буенда, төбәкне Рус дәүләтенә кушу вакытында татар халкы авылларына руслар килеп урнаша, әмма нигез салучыларның эзләре авылның исемнәрендә сакланып кала (мәс., Аракчино, Атлашкино, Камай, Киндерле, Ометьево һ.б.). Этник яктан катнаш халыклы (татар-рус, чуваш, мари, удмурт) шәһәрләрдә һәм А.да дустанә мөнәсәбәтләр хөкем сөргәндә дә, дин, тел, мәдәният-көнкүреш аермалыклары булу сәбәпле, милли бүлгәләнү гадәткә керә, яшәү даирәсе аерымлана, шул рәвешле, вакытлар узу б-н, милли бистәләр, урамнар, яклар барлыкка килә (мәс., татар бистәсе, урамы, ягы). Ш.у.к. *Торак*.

*Әд.:* Воробьев Н.И. Казанские татары. К., 1953; Халиков Н.А. Поселения жилища // Татары. М., 2001.

*Н.А.Халиков, Ф.Ф.Гулова.*

**АВЫЛЛЫ́К** (археол.), билгеле бер территориясе һәм культура катламы булган борынгы авыл калдыклары. Гадәттә, А. дип элгәреге тимер гасыр (якынча б.э.к. 8 йөздән) һәм урта гасырлар истәлекләрен атыйлар. Таш һәм бронза дәверләре авылларына карата «торулык» төшенчәсе кулланыла. А. ларның күпчелеге кешеләр хуҗалык итүнең җитештерү — терлекчелек һәм игенчелек б-н шөгыльләнә башлагач барлыкка килә. Кагыйдә буларак, озак вакыт бер урында яшәгән утрак халыктан бай культура катламы, ә ярымутрак (күчмә) халыктан кайбер очракларда җир өстендә балчык савыт-саба кисәкләре, мал-туар сөякләре генә кала. Татарстан терр-ясендә 2 меңнән артык А. бар, шуның 1 меңнән артыгы болгарлар дәверенә карый.

А.лар турында беренче мәгълүматлар 19 йөздә туплана. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан А.лар актив рәвештә Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков, Р.Г.Фәхретдинов, Е.П.Казаков, К.А.Руденко, М.М.Кавиев, А.Ә.Борһанов, С.И.Вәлиуллина һ.б. тарафыннан өйрәнелә. А.ларда уздырылган археол. казулар вакытында торак, хуҗалык һәм һөнәрчелек-җитештерү корылмалары калдыклары, төрле эш һәм сугыш кораллары, кием-салым һәм ат дирбиясе әйберләре, *зәргәрчелек* эшләнмәләре, тәңкәләр, кечкенә герләр, үлчәүләр, Шәрекъ илләреннән, Русьтан һ.б. тарафлардан китерелгән әйберләр табыла. Бу табылдыклар авылларда яшәгән халыкның игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек һәм сәүдә б-н шөгыльләнүе хакында сөйли. Халкы даими һөнәрчелек һәм сәүдә б-н көн күргән А.лар Иделнең һәм Чулманның сулъяк ярында алып барылган тикшеренүләр барышында өйрәнелде (Алексеев IV, Кожаевка VI, Семенов I, Иске Куйбышев V А.лары һ.б.). *Әҗмәр авыллыгы* Идел һәм Чулман елгалары аша Евразиянең күп кенә төбәкләре б-н зур күләмдә товар алмашкан иң эре сәүдә һәм һөнәрчелек үзәге булган. Сәүдә һәм һөнәрчелек б-н шөгыльләнгән зур авыллар ш. у. Биләр төбәгендә дә урнашкан (к. *Биләр III авыллыгы*).

*Әд.:* Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ КФАН СССР за 1945–1952 гг. К., 1954; Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. К., 1975; Казаков Е.П. Булгарское село X–XIII вв. низовий Камы. К., 1991; Руденко К.А. Материальная культура булгарских селищ низовий Камы XI–XIV вв. К., 2001.

*Е.П.Казаков.*

**АВЫ́Р АТЛЕ́ТИКА**, авырлык (штанга) күтәрү буенча ярыш төре. 1934 елга кадәр биш төр ярыш (ике кул б-н салмак күтәрү, бер яисә ике кул б-н ыргымлы һәм салмак этеп күтәрү), 1934–72 дә ирләр арасында классик өч төр ярыш (ике кул б-н салмак күтәрү, кинәт тартып һәм салмак этеп күтәрү), 1972 дән — ике төр ярыш (төрле үлчәү категорияләрендә ике кул б-н ыргымлы һәм салмак этеп күтәрү), 1991 дән бу ике төр ярыш хатын-кызлар арасында да үткәрелә. Авырлык күтәреп күнегүләр ясау спортның күп төрендә спортчыларны көч ягыннан әзерләү чарасы булып тора. А.а. 1910 еллардан Казан шәһәренең «Бөркет», «Көч һәм сәламәтлек» спорт җәмгыятьләрендә; 1920 елларның 2 нче яртысыннан Казан, Бөгелмә, Алабуга, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләренең «Спартак», «Труд», «Зенит», «Урожай», «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятьләрендә, Урицкий исем., Воровский исем. спорт клубларында, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә, Профсоюзларның физкультура-спорт җәмгыятендә үсеш алган. Казан шәһәренең беренче чемпионаты 1912 елда уздырыла, җиңүче-

ләр (программаның төрле төрләрендә): В.Магницкий, Н.Руфимский, П.Петухов. 1926 дан Татарстанның даими чемпионатлары уздырыла. 1930–80 елларда ТАССР, РСФСР ирекле спорт җәмгыятьләренең үзәк советлары, РСФСР халыклары спартакиадасы, СССР, Европа, дөнья беренчелегендә приз алучылар — К.Я.Варварин, Р.Ш.Гыймадетдинов, А.П.Горшенин, Н.Г.*Жеребцов*, Н.А.*Колесников*, А.П.*Курынов*, Х.Г.Кучушев, Ф.Мөхәмәтдинов, В.Николаев, А.О.Прохоров, М.С.Сәхәбетдинов, А.Г.Солдатов, О.Н.Соловьёв, Г.Н.Умылин, Б.Фәрхетдинов, П.Г.Шмаков. Татарстанның иң көчле спортчылары (халыкара класслы спорт осталары) — В.К.Алиев (2003), А.Ю.Деманов (2005), И.Ш.Ибнеәминов (1980), С.Г.Минин (1979), А.Ю.Мохина (2004), С.В.Шимкова (2003). А.а. ш.у. Казан («Батыр», «Мотор»), Бөгелмә, Алабуга, Болгар шәһәрләре, Аксубай посёлогы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә үсештә (2007). Ел саен Казанда А.П.Курынов исем. призга (1978 дән) Бөтенроссия ярышлары, Бөгелмәдә Е.Ә.*Тимержанов* исем. призга (2001 дән) яшүсмерләр арасында республика ярышлары уздырыла. Иң яхшы тренерлар — Н.В.Капитонов, Н.А.Колесников, В.А.*Павлов*, Е.Ә.Тимержанов. Халыкара категорияле судьялар — Н.А.Колесников, Р.Ә.Хәйруллин.

**АГÁ БАЗÁР**, 10–15 йөзләрдә Болгар шәһәренең зур сәүдә һәм һөнәрчелек бистәсе. Шәһәрдән 6 чакрым төньяк-көнбатыштарак, Иделнең сул яры б-н Мәләнә елгачыгы арасында урнашкан була. Идел буе Болгар дәүләтенең эре сәүдә, һөнәрчелек һәм мәдәният үзәге. 1431 елда кенәз Фёдор Пёстрый җитәкчелегендә Болгарга яу б-н килгән рус гаскәре талап һәм җимереп киткәннән соң, ташландык хәлгә килә. Хәрабәләре Иделнең сул ярында, хәзерге Болгар шәһәре янәшәсендә. Археол. казулар барышында аерым йортлар, хуҗалык корылмалары, һөнәрчелек остаханәләре (мөгез-сөяк эшкәртү, металл кою, чүлмәк ясау һ.б.) калдыклары, төрле хуҗалык әйберләре, ш.у. акчалар, чит илләрдән китерелгән эшләнмәләр табыла. А.б. хәрабәләрен 1852 дә И.Н.Березин, 1877 дә А.А.Спицын, 1893 тә П.А.Пономарёв, 1952–54 тә Б.Б.Жиромский б-н К.А.Смирнов тикшерәләр. 1955–57 елларда А.Б. Куйбышев сусаклагычы астында кала.

*Әд.:* Ж и р о м с к и й Б.Б. Ага-Базар // Материалы и исслед. по археологии. 1954. № 42; Город Болгар: Очерки истории и культуры. М., 1987.

*И.Л.Измайлов.*

**АГАБÁБОВ** Александр Григорьевич (12.2.1863, Әстерхан ш. — 11.6.1922, Казан), офтальмолог, медицина д-ры (1893), проф. (1905). 1888 елда Казан ун-тын тәмамлый. Е.В.Адамюк шәкерте. 1888 дән Казан ун-тының күз авырулары клиникасында, бер үк вакытта 1902 дән офтальмология каф. мөдире. Шәкертләре арасында: К.Х.Орлов, В.В.Чирковский, В.Е.Адамюк. Төп хезмәтләре цилиар тәнчек иннервациясенә, глаукома, трахома авыруларын дәвалауга карый.

Х е з м.: Обзор случаев глаукомы в глазной клинике Казанского университета с 1884–1894 // Вестн. офтальмологии. Киев, 1896. Т. 13.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Н и к и т и н С.К. Профессор Александр Григорьевич Агабабов // Казан. мед. журн. 1965. № 1; Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989.

**АГÁВА** (Agave), агавачалар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Күпьеллык яфраклы суккулентлар. Мексикада һәм Үзәк Американың башка районнарында 300 ләп төре һәм бакча формалары үсә. Күпчелек А.ның яфраклары тамыр тирәли тупланган, тыгыз, итләч һәм чәнечкеле. Үсү дәверенең 6–15 елында күп чәчәкле сабак хасил итеп чәчәк ата. Монокарпик (бер мәртәбә чәчәк атучы) төрләре бар. Тамырча үрентеләреннән үрчетелә. Яктылык яратучан үсемлек. Туган җирендә А.ның кайбер төрләрен туку һәм азык-төлек сәнәгатендә чимал буларак файдаланалар. Чәчәкләреннән һәм чәчәк сабакларыннан исерткеч эчемлек (пульке) ясыйлар. Татарстанда акрын үсүче кайбер төрләре декоратив бүлмә гөле буларак үрчетелә. А.ның еш очрый торган төрләре: Мексика А.сы (A. mexicana), Америка А.сы (A. americana), җепсыман А. (A. filifera). Аеруча матур, әмма сирәк очрый торган А.лар — королева Виктория (A. Victoriae — reginae Moore) һәм король Фердинанд А. (A. ferdinandi regis Bgr.).

**АГАДИ́** Әхмәд Илтифад углы (30.3.1965, Казакъстан ССР, Чимкент өлкәсе Чимкент р-ны 25 нче партсъезд исем. совхоз), җырчы (лирик тенор), РФнең атказ. (2001) һәм ТРның халык артисты (2006). 1993 елда Мәскәү консерваториясен (Е.Кибкало классы буенча) тәмамлаганнан соң, К.Станиславский һәм В.Немирович-Данченко исем. Мәскәү Муз. театры, 2005 тән Мария исем. (С.-Петербург) театр солисты, бер үк вакытта дөньяның күпләгән опера сәхнәләрендә (Зур театрда, Амстердам, Дания Корольлеге театрлары, Будапешт, Страсбург театрларында, Альберт-холлда, Лондон, Бөекбритания, «Колон» театрында (Буэнос-Айрес, Аргентина) чыгышлар ясый. Түбән Новгород, Кишинёв, Саратов һ.б. опера фестивальләрендә катнаша. Төп опера партияләре: Граф Альмавива («Севилья чәчтарашы», Дж. Россини), Альфред, Герцог Мантуанский, Радамес, Дон Карлос («Травиата», «Риголетто», «Аида», «Дон Карлос», Дж. Верди), Фауст (шул исемдәге опера, Ш.Гуно), Рудольф, Каварадосси («Богема», «Тоска», Дж.Пуччини), Хозе («Кармен», Ж.Бизе), Баян («Руслан һәм Людмила», М.Глинка), Ленский («Евгений Онегин», П.Чайковский), Яшь чегән («Алеко», С.Рахманинов) һ.б. Берничә тапкыр Казанда Ф.И.Шаляпин исем. Халыкара опера фестивалендә катнаша (1998 дә бу фестивальдә иң яхшы тавышлы җырчы дип танылa). 2006 елда М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театрында Р.Ахиярованың беренче куелыштагы «Шагыйрь мәхәббәте» операсында Тукай партиясен башкара. Җырчы репертуарында ш.у. вокаль-симфоник әсәрләрнең соло партияләре («Реквием», Дж. Верди; Сигезенче симфония һәм «Җир турында җыр», Г.Малер; «Кыңгыраулар», С.Рахманинов; «Тантаналы месса», Л.Бетховен) бар. Россия һәм чит илләрдә (Австрия, Аргентина, Бельгия, Бөекбритания, Германия, Голландия, Дания, АКШ, Төркия, Көньяк Корея һ.б.) актив концерт эшчәнлеге алып бара. М.Глинка исем. Бөтенроссия вокалистлары конкурсы дипломанты (1993), РФнең «Алтын битлек» театраль премиясе, ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2008) лауреаты.

*Ф.Ш.Салитова.*

**АГÁНИН** Александр Алексеевич (13.8.1954, Мари АССРның Звенигово р-ны Красногорск пос.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1976–80 дә системаларны программалаштыру КБсында (БССР, Гомель ш.), 1980 нән Казан пед. ин-тында. 1988–91 дә РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында. Хезмәтләре газларның чикләре хәрәкәтчел өлкәләрдә нәсызыкча тирбәнешләрен санча модельләштерүгә карый. Ябык торбада гага баганасының нәсызыкча тирбәнеше үсешен тикшерә, сыеклык күләмендәге шарсыман газ күбекләре динамикасы моделен эшли. Урта агымнарны һәм дулкыннарны, газ пульсациясен беренче мәртәбә санча модельләштерә.

Х е з м.: Экспериментальное и численное исследование акустических течений около объёмных резонаторов // Прикладная математика и техн. физика. 1997. Т. 38, № 6; Нелинейные колебания газа в закрытой трубе при непериодическом движении поршня // Изв. РАН. Механика жидкости и газа. 1998. № 2; Динамика пузырька газа в центре сферического объёма жидкости // Докл. РАН. 1999. № 2.

**АГÁНИН** Фәрит Габдулла улы (23.7.1926, Мордва АССРның Тарбеев р-ны Сыркыды а.), дипломат. Мәскәү шәркыятьчелек ин-тын тәмамлый (1949). 1949–87 елларда СССРның Тышкы эшләр министрлыгында илчелек хезмәтендә: СССРның Кытай Халык Респ-касындагы консуллык оешмаларында эшли (1949–59), 1963 тән Багдадтагы (Гыйрак), Каһирәдәге (Мисыр) консуллыкларның мөдире; 1967–87 дә СССР Тышкы эшләр министрлыгында СССРның Азия һәм Африка илләре б-н консуллык мөнәсәбәтләре үсеше мәсьәләләре бүлеге мөдире. Хезмәтләре Кытай, Якын Көнчыгыш илләре б-н үзара мөнәсәбәтләргә, Азия, Африка илләре б-н консуллык мөнәсәбәтләрен үстерүгә карый.

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы: Справ. изд. М., 2001.

**АГÁНОВ** Альберт Вартанович (21.4.1941, Монголия Халык Респ-касының Ундурхан ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1987), проф. (1988). ТРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996, 2003). 1963 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1985 тән гомуми физика каф. мөдире, бер үк вакытта 1991 дән физика ф-ты деканы, органик кушылмалар төзелешен өйрәнү фәнни-тикшеренү лабораториясенең ТМР спектроскопия төркеме җитәкчесе. Төп хезмәтләре молекуляр спектроскопиягә һәм молекуляр динамикага карый. Башка галимнәр б-н берлектә органик кушылмалардагы химик алмашу процессларының гомуми принципларын ТМР кысаларында тасвирлауны үстерә, элек тасвирланмаган яки молекулалар берләшүенең төгәл ачыкланмаган кайбер механизмнарын тәкъдим итә, гетероцикллар-

ның стереодинамик закончалыкларын ачыклый, целлюлоза төрләренең структурасын билгеләү буенча фундаменталь тикшеренүләр уздыра. БДБ илләренең ТМР спектроскопистлары ассоциациясе вице-президенты, «Новости ЯМР в письмах» бюллетене баш мөхәррире. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Новые аспекты применения ЯМР в исследовании процессов химического обмена // Успехи химии. 1985. Т.54. № 10 (автордаш); Физика вокруг нас. М., 1998 (автордаш). DMR spectroscopy of middle size heterocycles // The latest MR research in organic and polymer chemistry in Russia. N.-Y., 1996 (автордаш). Conformational Analysis of MNCB (MBNC) Esters and Amides: Promising Chiral Reagents for Stereoselective Applications // Tetrahedron. 55. 1999.

*Р.Г.Усманов.*

**АГА́ПОВ РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* көньягында. Мәйданы — 2610 *км*². Үзәге — Агаповка авылы (Чиләбедән 436 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 37816 кеше, ш.и. 2192 татар (2002). А.р. терр-ясендә татарлар, Оренбург казак гаскәренә керүче авыллар һәм посёлоклар халкының бер өлеше буларак, элек-электән яшиләр. Хәрби хезмәттән тыш алар крәстиян хуҗалыгы алып бара, каеш-сбруй әйберләре ясау, күн эшкәртү, сәүдә, олаучылык һ.б. кәсепләр б-н шөгыльләнәләр. 19 йөз ахырында Әбләз посёлогы (хәзерге Оренбург өлкәсенең Саракташ р-ны Әбләз а.) татарлары Яңа Әбләз (хәзер Әбләз а.) посёлогына нигез салалар. 20 йөз башында татарлар Агаповка авылына килеп урнашалар. 1929 елга кадәр монда мәчетләр эшли. 1920–30 елларда Агаповка авылы янында көчләп күчерелгән Казан татарларыннан торган Известковый (хәзер район үзәгенә керә) посёлогы барлыкка килә. Хәзерге вакытта Агаповка һәм Әбләз авылларында мәчет эшли.

**АГА́РКОВ** Алексей Григорьевич (17.7.1939, Башкортстан АССРның Эстәрлетамак р-ны Яңа Васильевка а. — 13.6.2002, Баулы ш.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1987). Пермь нефть техникумын тәмамлый (1970). 1960–68 һәм 1970–2002 елларда «Татнефть» АҖнең «Баулынефть» НГДУында бораулаучы ярдәмчесе, нефть һәм газ скважиналарын бораулаучы, скважиналарны җир астында һәм кап. ремонтлау буенча мастер, скважиналарны җир астында кап. ремонтлауга әзерләү операторы. 1968–70 тә «Пермьнефть» җитештерү берләшмәсенең «Осинскнефть» НГДУында мастер. Дәүләт бүләге хезмәттәге зур казанышлары, нефть һәм газ чыгаруны арттыруга зур өлеш керткәне өчен бирелә. М.Җәлил исем. респ-ка бүләге лауреаты (1978). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**АГАФО́НОВ** Алексей Андреевич (30.5.1926, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1973), проф. (1975). ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). 1949 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1951 дән Салехард, Казан мед. оешмаларында эшли. 1966 дан Казан мед. ун-тында, 1974–91 елларда топографик анатомия һәм ашыгыч хирургия каф. мөдире. Хезмәтләре ашкайнату юлларының микроциркуляр юлларын тикшерүгә, хирургик патологияләр вакытында йөрәк-кан тамырлары һәм лимфа системаларын өйрәнүгә карый. СССРда беренче булып лапароскопия ысулын эшли (1964). Беренчеләрдән булып А. интубация наркозын куллана. А. һәм аның шәкертләре тарафыннан хирургик патологияләр вакытында макро- һәм микро дәрәҗәдә йөрәк-кан тамырлары, лимфа системалары турында яңа мәгълүматлар, хирургик патологияләр (холемия һәм ахолия, эчәк үткәрмәүчәнлеге, панкреонекроз, кан югалту, корсак куышлыгы асты гематомасы) күрсәткечләре, ш.у. дигестив тракт тышчалары регенерациясенә караган мәгълүматлар алына, үңәчне, ашказанын, эчәклек әгъзаларын саклап калу буенча оригиналь операцияләр эшләнә.

Х е з м.: Лечение спаечной болезни живота // Казан. мед. журн. 1964. № 2; Лапароскопия в диагностике спаечной болезни живота // Казан. мед. журн. 1964. № 4; Обоснование выбора метода дренирования жёлчных путей при механической желтухе // Хирургия. 1979. № 5; Резекция подслизистой основы и слизистой оболочки желудка с сохранением серозномышечных оболочек и пилорического жома // Казан. мед. журн. 1993. № 3.

**АГАФО́НОВ** Андрей Фёдорович (25.11.1884, Самара ш. — 30.7.1946, Казан), педиатр, йогышлы авырулар белгече, сәламәтлек саклау эшен оештыручы, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1935), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Казан йогышлы авырулар белгечләре фәнни мәктәбен оештыручы. 1910 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли. Казан шәһәре 1 нче номерлы йогышлы авырулар клиник хастаханәсе (хәзер А. исем.) А. тырышлыгы б-н оештырыла, 1918 дән баш табиб. 1924 тән Казан ГИДУВында, бер үк вакытта 1930 дан Казан мед. ин-тында йогышлы авырулар каф. мөдире. 1938–39 да ТАССР Сәламәтлек саклау халык комиссары урынбасары, 1943–44 тә РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгының Үзәк педиатрия ин-ты директоры. 1930 да А. В.М.Аристовский һәм И.П.Савченко җитәкчелегендә тикшеренүләр үткәрә, аларның нәтиҗәләре «Дәвалау анафилаксиясе мәсьәләсенә карата» («К вопросу о местной анафилаксии») исем. монография нигезен тәшкил итә. А.ның тикшеренүләре балалардагы йогышлы авыруларның иммун-аллергик аспектларын өйрәнүгә; кызамыкны булдырмауның махсус ысулына, дизентериягә сульфаниламид, скарлатина, дизентерия һәм корсак тифы авыруларын кан алмаштыру юлы б-н дәвалауга; тимгелле тифка диагноз куюга һәм дәвалауга карый. А. хезмәтләре клиника эшчәнлегенең фәнни юнәлешен билгеләүгә, йогышлы авыруларның иммун-аллергологик аспектларын экспериментал ь өйрәнүгә багышлана. 1938–46 да РСФСР ЮС депутаты. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу об этиологии скарлатины. К., 1925; О кожной чувствительности скарлатинозных больных к стрептококковой вакцине. К., 1925; О сывороточном лечении скарлатины. К., 1939.


*Әд.:* М и х а й л о в М.К., Б а ш и р о в а Д.К. Профессор Андрей Фёдорович Агафонов // Казан. мед. журн. 1984. № 6.

**АГАФО́НОВ** Виктор Павлович (16.8.1939, ТАССР, Куйбышев р-ны Молоствовка а. — 17.12.1999, С-Петербург ш.), вице-адмирал (1990). Ленин комсомолы исем. Югары су асты хәрби диңгез уч-щесен (1961, Ленинград), Н.Г.Кузнецов исем. Хәрби диңгез академиясен (1974, Ленинград), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. академиясен (1983, Мәскәү) тәмамлый. 1961–72 елларда Балтыйк флотында: дизельле су асты көймәсендә штурман, корабль командиры. 1974–92 дә Төньяк флотта: атом су асты көймәсе командиры, дивизия командиры, штаб башлыгы, 1988 дән 11 нче атом су асты флотилиясе командующие. 1992–95 тә Хәрби диңгез флотының Югары офицерлар курсы җитәкчесе урынбасары. Октябрь революциясе, 1 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АГАФО́НОВ** Михаил Викторович (16.11.1901, Казан губ., Лаеш өязе Корноухово а. — ?), хокук белгече. Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1949). 1920–24 елларда Кызыл Армия сафларында. 1924–52 дә (бүленеп, 1926–30 да Казанда, Буа кантонында халык судьясы, 1934–37 дә ТАССР Баш мәхкәмәсе әгъзасы, инструктор) ТАССР Юстиция халык комис-тында (министрлыгында): 1937 дән халык судьялары бүлеге, адвокатура секторы башлыгы, 1941 дән халык комиссары урынбасары. 1952–53 тә Казан өлкә мәхкәмәсе рәисе. 1953–65 тә ТАССР Адвокатлар коллегиясе президиумы рәисе.

*Е.Б.Долгов.*

**АГАФО́НОВ** Николай Яковлевич (25.11.1842, Казан — 7.7.1908, шунда ук), тарихчы, төбәк белгече, нашир, библиограф, җәмәгать эшлеклесе, надворный советник (1890). 1866–67 елларда иректе тыңлаучы булып Казан ун-тына лекцияләргә йөри (укуын тәмамламый). 1870–75 тә Казанда аерым гаиләләрдә балаларга тарих, география укыта. 1875 тән Дәүләт банкының Казан бүлегендә кассир, 1876–81 елларда сәркәтип. 1881 дән Казан уку округы идарәсендә бухгалтер. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятен оештыруда катнаша (1878), җәмгыятьнең шәрәфле әгъзасы була (1905). 1866 да П.П.Васильев б-н бергә «Казанда китапчылык эше» («Казанское книжное дело») җыентыгын нәшер итә. 1868 нең декабреннән «Казанский биржевой листок»ның сәркәтибе, 1870 нең май-июненнән мөхәррире. 1872–74 тә «Камско-Волжская газета»ның нашире-мөхәррире. 1870 елларда Казанда иҗтимагый-әдәби түгәрәк оештыра һәм аның җитәкчесе була, эмиграциядә яшәүче оппозиция һәм революцион хәрәкәт вәкилләре, ш.и. I Интернационалның рус секциясе б-н элемтәдә тора. Җирле матбугатта Н.Н.Булич, Д.В.Григорович, Н.И.Костомаров, М.Е.Салтыков-Щедрин, А.П.Щапов кебек шәхесләргә багышланган мәкаләләр бастыра. Н.Г.Чернышевский б-н 1861 дән таныш була, соңрак аның хезмәтләре исемлеген төзи (1868–71, басылмаган). «И.С.Тургенев әсәрләренең тулы тупламасы өчен материаллар» («Материалы для полного собрания сочинений И.С.Тургенева») библиографик


Н.Я. Агафонов.

белешмәсен бастырып чыгара (1883). Ул төзеп нәшер иткән «Казан тарихыннан» («Из Казанской истории», 1906), «Казан һәм казанлылар» («Казань и казанцы», 1–2 басма, 1906–1907) җыентыкларында дворян һәм сәүдәгәрләрнең шәҗәрәләренә нисбәтле материаллар, шәһәр башлыклары һ.б. турында мәкаләләр, 1794–1894 еллар Казан зираты турында мәгълүматлар тупланган. Көнкүреш вакыйгаларына багышланган хикәяләр, хатлар рәвешендә язылган, Нерон яшәгән чорны тасвирлаган «Христианнар» повесте («Христиане», 1887) һәм «Башка тормыш: Иске, ләкин мәңге яшь секта» («Иная жизнь: Старая, но вечно юная секта», 1906) романы авторы. Идел буе, Урал һәм Себер төбәге язучылары, журналистларының биобиблиографик сүзлеге, Казан энциклопедиясе өчен әзерләнгән язмалары тәмамланмыйча кала. Ул туплаган сирәк очрый торган китаплар вафатыннан соң Казан ун-ты китапханәсенә тапшырыла.

Х е з м.: Обозрение корреспонденции из Казани в русских газетах и журналах за 1866 год. К., 1867; Краткие сведения о жизни Г.И.Солнцева. К., 1867; Воспоминания об И.А.Шидловском. К., 1884; Заволжская вивлиофика. К., 1887. Вып. 1; Историческая объяснительная записка наименований улиц. К., 1899; К столетию учреждения учебных округов: Краткий исторический очерк Казанского учебного округа. К., 1903.

*Әд.:* Н.Я.Агафонов (1842–1908): Некролог. К., 1908; Каталог книг библиотеки покойного Николая Яковлевича Агафонова в Казани. К., 1911; Русские писатели 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1989. Т. 1.

*Е.Б.Долгов, В.А.Шагалов.*

**АГАФО́НОВ Н.Я. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**. Китапханәне Н.Я.Агафоновның этисе — Я.А.Агафонов нигезли. Ул чыгышы б-н крәстиян гаиләсеннән була, төбәк тарихчысы, борынгы китаплар белгече, К.Ф.*Фукс* китаплары тәэсирендә яшьтән үк иске китаплар җыярга керешә, соңыннан китапханәсе улына күчә. 20 йөз башында Казандагы иң эре һәм бай шәхси китапханәләрнең берсе. Анда 2703 саклау берәмлеге исәпләнә, шуларның 37 се чит телләрдә. 18 йөзгә нисбәтле басмалар арасында: тарихи, фәнни хезмәтләр, тәрҗемәдә Ф.Вольтер әсәрләре. Дворяннарның һәм сәүдәгәрләрнең биографияләре һәм шәҗәрәләре турында материаллар, сүзлекләр; мемуар һәм дини әдәбият, дин тарафдарлары тарихына караган хезмәтләр, библиографияләр, журналистика тарихы буенча китаплар, әдәби альманахлар була. Китапханәдә Казан басмалары зур урын ала. Коллекциядә П.М.Медведевның «Мокей Михеич һәм аның кыз туганы» («Мокей Михеич и его сестрица», 1883) кебек бары бер нөсхәдә басылган китаплар да очрый. Китапханәдән Казан ун-ты профессорлары, ун-т каршындагы Археология, тарих, этнография җәмгыяте әгъзалары еш файдаланган. Н.Я.Агафоновның вафатыннан соң китапханә сатыла, фондының бер өлеше Казан ун-тының фәнни китапханәсенә алына.

*Әд.:* Каталог книг библиотеки покойного Николая Яковлевича Агафонова в Казани. К., 1911; Л и х а ч ё в Н.П. Генеологическая история одной помещичьей библиотеки. СПб., 1913; К о р н и л о в П. Книжные знаки библиотеки Н.Я.Агафонова. К., 1929.

*И.А.Новицкая.*

**АГАФО́НОВ** Рафаэль Габделхәй улы (10.7.1934, Владимир ш.), сынчы. ТРда станлы һәм монументаль скульптура өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Казан сәнгать уч-щесенең театр декорациясе бүлеген тәмамлаганнан соң (1963), Әлмәттә яши. Драма театрында — рәссам, 1 нче шәһәр сәнгать мәктәбендә — укытучы, Татарстан сәнгать фондының Бөгелмә ф-лында — сынчы (1976–86), «Әлмәтнефть» НГДУында эстетик иҗат төркеме җитәкчесе (1986–96) булып эшли. Иҗат эшчәнлеген Казанда үзешчән рәссам буларак башлый. Казанда уздырылган үзешчән рәссамнарның респ-ка күргәзмәсендә (1957) «Соңгы җыр» («Муса Җәлил үлем җәзасы алдыннан») сыны өчен аңа 1 нче урын бирелә. Бетон, җиз һәм алюминий, төс йөгертелгән гипстан һ.б.дан гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы чорлары (Сов. Союзы Герое М.Сыртланова һәйкәле, 1985; әлмәтле М.Вәлиуллин бюсты, 1980; Бөгелмә мәдәният паркындагы геройлар бюстлары, 1975; Әлмәт р-ны Кәләй авылында Сов. Союзы Герое М.Әхмәдуллин бюсты, 1975 һ.б.), туган як һәм Ватан тарихы («Бөек Болгар», 1970; Лениногорск ш. хакимияте бинасы янындагы «Татарстан», Әлмәт шәһәр яны чишмәсендәге «Зөһрә» сыннары, 1970–80 һ.б.) темаларына әсәрләр иҗат итә, нефтьчеләр, галимнәр, мәдәният эшлеклеләренең (Бөгелмәдәге Г.Тукай һәйкәле горельефы, 1976; Россия ФАнең мөхбир әгъзасы П.И.*Рычковның* туган җирендә — Бөгелмә р-нының Спас авылындагы бюсты, 1984; Лениногорск техник уч-щесе бинасы янындагы акад. А.Губкин бюсты, 1980 һ.б.) портретларын ясый. А.ның милли-романтик юнәлешләре б-н аерылып торган әсәрләрендә болгар сугышчысы һәм татар батыры, нәсел саклаучы ана, матурлык һәм сафлыкны гәүдәләндерүче яшь кыз рәвешендә халык каһарманының гомумиләштерелгән символик-аллегорик образы чагылдырыла. А.ның стиленә һәм сәнгать алымына форманы чынбарлыкка охшатып иҗат итү, детальләр аша характерны ачу, ясалачак үрнәкнең җисми үзенчәлекләрен әвәләмәгә күчәрлек итеп эшкәртү, гипс композицияләренә бронза төсе йөгертү хас.


Р.Г.А г а ф о н о в. «Батыр». Төс йөгертелгән гипс. 1990. Әлмәт картиналар галереясы.

Төп әсәрләре: монументаль скульптура — «Мәңгелек ут» (Бөгелмә, 1995), «Девон хәзинәсе» («Әлмәтнефть» идарәсе вестибюле, 1996), «Шартлау» (гипстан эскиз, 1990), «Татарстан» (Әлмәт ял зонасы, 1995), «Феникс» (Әлмәт, 1990), гипстан ВЛКСМның 50 еллыгына монумент эскизы (1964); жанрлы скульптура — «Татарстан» (1977), «Мәхәббәт турында» (1966), «Әлмәтнефть» спорт комплексы өчен «Батыр», «Гимнаст кыз», «Җиңүче», «Факел йөртүче» (барысы да 1970) сыннары; сынлы портрет — «Урсалы комячейкасының беренче рәисе И.Швыдкин» (1968), 12 плакаттан торган серия: «Мәүлә Колый», «Якуб ибне Ногман» (1997) һ.б.

Драма спектакльләре декорацияләре, костюм эскизлары, театр афишалары авторы. Төбәк, республика һәм район күргәзмәләрендә катнаша (1957 дән). Әсәрләре Әлмәт картиналар галереясында, шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* В а с ю х и н а К. Скульптор Агафонов // Знамя труда. 1994, 9 июля.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АГАФУРОВЛА́Р**, Екатеринбург шәһәре сәүдәгәрләре. Династия башында Хисаметдин А. тора (19 йөз). 4 улы: **Камалетдин** (? — ?), 2 нче гильдия сәүдәгәр; **Зәйнетдин** (? — ?), 2 нче гильдия сәүдәгәр; **Кашафетдин** (? — ?); **Җәләлетдин** (? — ?). 1884 елда Камалетдин б-н Зәйнетдин галантерея товарлары б-н сәүдә итүче «Бертуган Агафуровлар сәүдә ширкәте»н ачалар (1890 еллар башында сәүдә капиталы 10 мең сум була). Эрбеттә, Мәкәрҗә ярминкәсендә, Чиләбе шәһәрендә кибетләр тоталар, Эрбет ярминкәсендә һәм Төмән, Пермь, Мәскәү, Варшава шәһәрләрендә күпләп сату бүлекләре була. Хәйрия оешмаларына ярдәм итеп торалар, Екатеринбургта мәчет б-н мәктәп, Түбән Новгородта имам йорты тотуга, С.-Петербургта Җамигъ мәчет төзелешенә иганә кылалар. А. Екатеринбург мөселманнары хәйрия җәмгыяте эшендә актив катнашалар, Зәйнетдин А. җәмгыятьнең рәисе итеп сайлана.

*Әд.:* К о р е п а н о в а С. Агафуровы // Татарстан. 2002. № 5; Т а и р о в Н. Купцы Агафуровы: торговля и меценатство // Идель. 2003. № 3.

**АГА́Ч ӘЗЕРЛӘ́Ү**, урманнан файдалануның бер төре; урман кисү, аны чыгару, ботакларын чабу, диләнкеләрне чистарту, чималны беренчел эшкәртү кебек төп һәм ярдәмче эшләрне үз эченә ала. 18 йөзнең 1 нче чирегендә корабльләр төзү эше үсеш алганнан соң, Идел буе имәнлекләре тыюлыкка әвереләдерелә, алар Балтыйк һәм Кара диңгез флотлары өчен имән агачы әзерләүнең төп чыганагы була. Корабль төзүгә яраклы агач б-н С.-Петербург верфе, ш.у. Әстерхан һәм Архангельск портлары тәэмин ителә. Казан адмиралтействосы мәгълүматларына караганда,

1803–10 елларда гына да губернада 295 мең $м^3$ кыйммәтле имән агачы әзерләнеп озатылган. 19 йөзнең 2 нче яртысында урманны тәртипсез рәвештә күпләп кисү башлана. Гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы елларында урман хәрби сәнәгать һәм ягулык кризисыннан котылу максатында киселә. Тимер юл буйларындагы әзерләү һәм чыгару өчен уңайлы урыннардагы урман күпләп юк ителә.

ТРда һәр елны 1,9 млн. $м^3$ тирәсе агач әзерләнә, ш.и. 700 мең $м^3$ чамасы агач карап-тәрбияләп үстерү максатыннан киселә.

Республика урман хуҗалыгында эш 2 юнәлештә алып барыла: урман хуҗалыгын үстерү һәм ярдәмче-сәнәгый җитештерү. Хуҗалыклар компенсацияне өлешчә ярдәмче-сәнәгый җитештерүдән килгән акчадан алалар. 2002–2006 еллар эчендә эшкәртү һәм читкә озату өчен агач әзерләү һәм чыгару елга 400 мең $м^3$ тәшкил итә. Агач эшкәртү нәтиҗәсендә төзү эшенә яраклы агач, баганалар, бүрәнәләр, такта, рәшәткә материаллары, утын һ.б. алына. Бура, ишек-тәрәзә блоклары, әрҗә-тартма комплектлары, киселгән әзерләнмәләр, фанер, сувенирлар һ.б. төрле җитештерү-техник эшләнмәләр һәм көнкүреш кирәк-яраклары җитештерелә. Эшләп чыгарыла торган товарның ассортиментын яңарту буенча да шактый эш башкарыла: вак һәм тирәнтен эшкәртү таләп итә торган әйберләр — умарта, умарта рамнары, мунча кирәк-яраклары, сыр өчен аскуймалар, өстәл-урындыклар, хоккей калканнары, салат өчен савытлар җыелмасы, филёнкадан ишекләр, үргән әйберләрнең яңа төрләре, беседкалар һ.б. эшләнә. Урман кисү калдыкларыннан һәм вак-төяк агачлардан хуҗалык һәм торак төзелешләре өчен арболит блоклар ясыйлар. Яшел Үзән фанера җитештерү з-ды, ш.у. бераз күләмдә Уфа фанера-мебель комб-ты, Киров өлкәсендәге з-длар чимал б-н тәэмин ителә.

*И.Н.Зарипов.*

**АГА́Ч БАЛ КОРТЫ́** (Xylocopa valga), умарта кортлары семьялыгыннан булган бөҗәк. Зур умарта кортларын, төклетураны хәтерләтә. Гаилә булып яшәмиләр; оя ясау өчен корыган агачка бүлемнәр һәм кереп йөрү юллары тишеп, төрле токымдагы агачларның кипкән үзагачларында, телеграф баганаларында һәм иске корылмаларда, утын һәм агач материалларында оялыйлар. Далалы участокларда ояларын кайвакыт чокыр һәм текә яр битләрендә туфракта ук ясыйлар. Гәүдәсе һәм канатлары куе шәмәхә төстә. Озынлыгы 20–23 *мм*. Төньяктан тыш, Россиянең барлык Европа өлешендә таралган. Татарстанда һәр җирдә диярлек очрый. Мамадыш р-нын исәпләмәгәндә, һәркайда аз санлы төр. Карт урман читләрендә һәм урман аланнарында, чокыр һәм сызаларның урманлы сөзәклекләрендә, зур торак пунктлардагы агач өемнәрендә, ташландык авылларда тереклек итә. Татарстан терр-ясендә җитлеккән затлар июньнән оча башлый. Ана кортлар 60 төргә якын чәчәкле үсемлекләргә, шәһәрдә күбрәк сәрви агачына куна. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Е.А.Сапаев.*

**АГА́Ч ГӨМБӘЛӘРЕ́**, к у г ө м б ә л ә р е, базидиомицетлар классының афиллофор гөмбәләр тәртибендәге базидиаль гөмбәләр төркеме. 10 семьялыкны, 600 гә якын төрне үз эченә ала, барлык континентларда да таралганнар. ТР терр-ясендә имән А.г. (Inohotus dryophilus), усак А.г. (Phellinus tremulae), чын А.г. (Fomes fomentarius), каймалы А.г. (Fomitorsis pinicola), каен болыты (Piptoporus betulinus), имән болыты (Daedalea quercina) һ.б. очрый. А.г.нең вегетатив өлеше (мицелий) тере яки корыган агачлар үзагачында үсә, аларны черетә. Үрчүнең төп формасы — базидиоспоралы базидияләр, алар зурлыгы, формасы (тояксыман, төерсыман, мендәрсыман, җәелгән яки җәелеп кайтарылган, утырып торган ярым эшләпәле, түгәрәк эшләпәле һ.б.), өслек рәвеше (шома яки ярыкланган, шәрә, төкле, кыллы, бәрхетсыман һ.б.ш.) буенча төрле булган һәм берьеллык яки күпьеллык үрчү өлешләрендә барлыкка килә. Кайбер А.г. үрчү өлешләре өслекләренең төсе ачык (сары, кызгылт сары, кызыл), эчке тукымасы еш кына башка төстә була.

А.г.нең туенуы һәм матдәләр алмашы үзагач торышына һәм агачның физиологик халәтенә бәйле. Гөмбәләргә туену өчен кирәк булган матдәләрнең күп өлеше эреми торган хәлдә була. Гөмбә үзагачка бүлеп чыгара торган ферментлар ярдәмендә субстрат кушылмалар эреми торган халәттән эри торганга әверелә. Агачны бозучы барлык гөмбәләр дә целлюлозаны тарката торган целлюлаза ферментын бүлеп чыгара. Кайбер А.г. ш.у. лигниннарны таркатучы оксидаза ферментларын чыгаралар. Үзагачның таркалуы агач череп бетүгә кадәр бик күпкә элегрәк башлана. Урманнарда А.г. китереп чыгарган черек авыруларыннан килгән зыян шактый зур һәм ул үсеп утырган агачларны зәгыйфьләү һәм юкка чыгаруга китерүче биологик зыяннан гыйбарәт. *Кара каен гөмбәсе* антибиотик һ.б. кыйммәтле үзлекләргә ия, дарулар һәм биопрепаратлар алу өчен файдаланыла. Каты төкле А.г. (Inonotus hispidus) матур бизәкле була һәм шкатулкалар, сувенирлар ясауда кулланыла. Җәймәле ку гөмбәсе (Polyporus agariceus), лаклы ку гөмбәсе (Ganoderma lucidum), пычрак-сары ку гөмбәсе (Dichomitis squalens) һ.б. ТРның Кызыл китабына кертелгәннәр.

*Әд.:* Жизнь растений. Грибы. М., 1976. Т. 2.

**АГА́Ч КОРТЛАРЫ́** (Cossidae), төнге күбәләкләр семьялыгы. 800 ләп төре билгеле, Татарстанда 2 төре очрый: исле агачтишәр (Cossus cossus) һәм батынкы агач күбәләге (Zeuzera pyrina). Исле агачтишәр — зур гәүдәле күбәләк. Канат җәеме 8 *см* га кадәр, көрән төстә, ак һәм кара сызыклары бар. Личинкаларының озынлыгы 12 *см* га кадәр, өсте куе кызыл, асты сары төстә, зәһәр исле. Гадәттә 3 ел үсә, кәүсәнең аскы өлешен киң һәм тирән юллар ясап кимерәләр. Дала зонасында утыртылган агачларда очрыйлар, тал, корычагач, алмагач һ.б. агачларга урнашалар. Батынкы агач күбәләге — уртача зурлыктагы күбәләк (4 *см* га кадәр). Канатлары ак төстә, кара тимгелләре бар, корсагы кара төстә, буй-буй ак сызыклы. Личинкасы (корты) ак төстә, кара таплары бар, яфраклы агачлар үзагачында үсә. Ике төр күбәләк тә май аеннан август аена кадәр оча, җимеш агачларына зыян китерергә мөмкин. Исле агачтишәр ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1984. Т. 3; Г о р д и е н к о С.Г. Бабочки Татарии. К., 1990.

*Н.В.Шулаев, Н.Г.Петров.*

**АГА́Ч ЭШЛӘНМӘЛӘ́Р СӘНӘГАТЕ́**, Казан губернасында 19 йөздән башлап берничә эре фабрика эшли. Ш.и. Казанда: «Е.М.Цыганов варисларының паркет җитештерү фабрикасы» (1845 елда нигезләнә), Л.С.Розенбергның столяр-паркет эшләнмәләр ф-касы (1876 елдан), Г.Ф.Локкенең чан-кисмәк һәм паркет җитештерү ф-касы (1878 дән); Казан өязе Питрәч авылында Я.М.Смолевның паркет җитештерү ф-касы (1893 тән). Бу фабрикаларда җитештерелгән әйберләр: чан-кисмәкләр, паркет, өй җиһазлары (шкаф, өстәл һ.б.), ишекләр, тәрәзә рамнары, кибет җиһазлары. 1913 тә аларда 48 дән алып 133 кә кадәр кеше эшли. 1918–19 да фабрикалар Совет хакимияте тарафыннан үзләштерелә.

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. П., 1914.


**АГГЛЮТИНАТИ́В ТЕЛЛӘ́Р**, сүзләрнең ясалышы һәм үзгәреше *агглютинация* юлы б-н башкарылган телләр; алар ш.у. сүзләрнең мәгънәсен үзгәртмичә бертөрле төрләндерү, бердәй грамматик кушымчалар ялгау б-н характерлана. А.т. гә төрки һәм фин-угор телләре керә. Монгол, тунгус-маньчжур, япон, корея һәм кайбер африка телләре дә аларга якын тора. Агглютинатив төзелешле төрки телләрдә (ш.и. татар телендә дә) морфемалар арасында чикләр ачык саклана, сүзнең нигезе һәм парадигмалар үзгәрми.

*Әд.:* А л п а р о в Г. Шәкли нигездә татар грамматикасы. К., 1926; Б а с к а к о в Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1962; Общее языкознание. Внутренняя структура языка. М., 1972; Г а н и е в Ф.А. К вопросу о морфологическом типе тюркских языков // Типология как раздел языкознания. М., 1976.

**АГГЛЮТИНА́ЦИЯ** (лингв.) (лат. agglutinatio — ябыштыру), сүзнең тамырына яки нигезенә стандарт аффикслар ялгау юлы б-н яңа грамматик формалар һәм сүзләр ясау ысулы. А. төрки телләргә һәм фин-угор телләренә хас. Татар телендә аффикслар эзлекле рәвештә берсе артыннан берсе килә. Мәс., исемгә башта күплек кушымчасы ялгана, аннан соң — тартым һәм килеш кушымчалары: ат + лар + ы + быз + ның, бакча + лар + ы + быз + да. Сүз төзелешендә морфемаларның чикләре ачык күренә, морфема чикләрендә, кагыйдә буларак, аваз үзгәрешләре күзәтелми. Кушымчалар ялгану сингармоник рәткә һәм сүз тамыры яки нигезенең нинди тартыкка тәмамлануына бәйле: өстәл + ләр, нарат + лар, урман + нар; башкорт телендә: ат + тар (атлар), венгр телендә: fal — on (стенада), kep — en (картинада). А.гә нигезләнеп *агглютинатив телләрне* аералар.

*Әд.:* Г а н и е в Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле. Сүзьясалышы. К., 2006; Татар грамматикасы. 3 томда. М.–К., 1998. Т. 1; Б а с к а к о в Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1962.

*Ф.Ә.Ганиев.*



Ф.Н.Агиев.

**АГЕ́ЕВА** Любовь Владимировна (7.11.1946, Оренбург өлкәсе Түбән Челяево а.), журналист, ТАССР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1989, 2002). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1965 елдан Казанда, 1968–77 дә «На стройке», «Бауманец», «Приборостроитель» күптиражлы г-таларында эшли. 1979 дан «Вечерняя Казань» г-тасында хәбәрче, бүлек мөдире. 1991–95 тә «Казанские ведомости» г-тасының беренче баш мөхәррире. 1995–2003 тә ТР Дәүләт Советының матбугат үзәге җитәкчесе. 2003 тән «Казанские истории» г-тасы баш мөхәррире. Фән, уку йортлары, мәдәният, мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләренә караган мәкаләләр, кулъязмалар авторы.

Ә с ә р.: Казанский феномен: миф и реальность. К., 1991; Республика Татарстан: новейшая история. К., 2000 (автордаш).

**АГИ́ЕВ** Фәхрелислам Нигъмәтулла улы (12.3.1887, Тамбов губ., Темников өязе Тенеш а. — 1938), журналист, педагог, язучы. 1908 елда Казанда үзлегеннән әзерләнеп Татар укытучылар мәктәбе курсын тәмамлый. 1908–15 елларда Рус-татар уч-щесендә (Казан) укытучы булып эшли. 1907 дән башлап «Аң», «Мәктәп» ж-лларында, «Әлислах», «Кояш», «Йолдыз», «Бәянелхак», «Ил» г-таларында мәкаләләрен һәм хикәяләрен бастыра. 1913–16 да балалар өчен «Ак юл» ж-лын чыгара. А. — «Хикәяләр җыентыгы» (1926), «Кыйраәте ибтидаия» («Башлангыч сыйныфларда уку китабы») хрестоматиясе (1908), «Кызыл йолдыз» әлифбасы» (1924, Г.Тимербулатов б-н берлектә) авторы. 1917 дә 1 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда катнаша. 1924 тән СССР халыклары Үзәк нәшриятында (Мәскәү) эшли. Репрессияләр чоры корбаны (1938).

Ә с ә р.: Мәрхәмәт. К., 1990.

*Әд.:* И б р а һ и м о в а Ф. Тынгысыз шәхес // Шәһри Казан. 1997. 27 июнь; Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Литературная энциклопедия. М., 1929. Т. 1.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**АГИ́ЕВ** Шамил Рәхим улы (8.1.1949, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (1998). Казан авиация ин-тын (1972), РФ МК каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен тәмамлый (1992). 1972–73 елларда ВЛКСМның Казан шәһәр ком-ты секретаре, 1973–75 тә 1 нче секретаре, 1975–77 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1977–82 дә 1 нче секретаре, 1978–88 дә ВЛКСМ ҮК әгъзасы. 1982–84 тә КамАЗда ремонт-инструменталь з-д директоры урынбасары (Чаллы ш.). 1984–93 тә «Электроприбор» з-дының (Казан) ген. директоры урынбасары. 1993 тән ТР Сәүдә-сәнәгать палатасы ген. директоры һәм идарә рәисе. 1980–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәтләре эшмәкәрлек, җитештерү һәм ресурс мөмкинлекләре, кризис вакытында пр-тиеләр б-н идарә итүгә карый.

Х е з м.: Развитие производительных сил и предпринимательства региона в условиях формирования рыночных отношений: Социально-экономический анализ на примере Республики Татарстан. М., 1996; Страхование как фактор стабильности развития малого предпринимательства: Очерки на экономические темы. М., 1997.

**«АГИТА́ТОР БЛОКНОТЫ́»**, журнал, к. «*Офык*».

**«АГИТА́ТОР СҮЗЕ́»**, журнал, к. «*Офык*».

**АГИ́Ш** (Агишев) Сәгыйт Ишмөхәммәт улы (25.12.1904, Оренбург губ., Оренбург өязе Исәнгилде а. — 21.5.1973, Уфа ш.), язучы. «Хөсәения» мәдрәсәсендә (1917–19), Башкортстан пед. ин-тында (1932–34) укый. Башкортстан АССРның пед. уч-щеләрендә һәм мәктәпләрендә укыта (1924–39; 1941–43). БАССР МС каршындагы Сәнгать эшләре идарәсендә инспектор (1943–49), «Әҙәби Башҡортостан» ж-лында җаваплы сәркәтип (1949–51) булып эшли. Әсәрләре 1925 елдан басыла башлый. «Беҙҙең көләү» дип аталган беренче шигырьләр җыентыгы 1927 елда дөнья күрә. «Ҡуш төймә» (1928), «Шартына килһен» (1933) хикәяләрендә, «Мәхмүтов» (1940), «Мәзин йортонда» (1939) повестьларында А. иҗтимагый-сәяси стройның кискен алмашыну шартларына яраклашу кыенлыкларын сатирик күренешләрдә тасвирлый. Бөек Ватан сугышы елларында А.ның совет кешеләренең тылдагы һәм фронттагы батырлыклары турында «Атлы Илмырҙа» (1942), «Фронтка» (1943), «Әхмәҙулла» (1944) дип исемләнгән хикәяләре һәм очерклары басыла. «Егеттәр» (1939) повесте һәм «Нигеҙ» (1951) романы 1920–30 елларда башкорт халкы тормышындагы зур үзгәрешләргә һәм милли интеллигенциянең формалашуына багышлана. «Тәүге дәрестәр» (1961), «Якташтар» (1962) повестьларында М.Җәлилнең балачак еллары, татар һәм башкорт мәдәниятләренең күренекле вәкилләре М.Гафури, С.Рәмиев, Дәрдемәнд, А.Таһиров, Ш.Ходайбирдин, А.Карнай һ.б. турында бәян ителә. Башкортстан АССРның Салават Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1975). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Һайланма әҫәрҙәр: 4 томда. Өфө, 1979–80.

*Әд.:* Ә б с ә л ә м о в а Г. Сәгит Агиш ижады. Өфө, 1964; Башҡорт әҙәбияте тарихы. Өфө, 1993. 4 т.

*Р.К.Әмиров.*

**АГИ́ШЕВ** Гаделша Әгъзам улы (10.8.1939, Ташкент), кинодраматург, сценарийлар язучы, Үзбәкстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1975). 1962 елда Мәскәүдә Бөтенсоюз кинематография ин-тын (ВГИК) тәмамлый. 1973–84 тә Ташкентта «Үзбәкфильм» киностудиясенең сценарийлар остаханәсе, 1985 тән Мәскәүдә Бөтенсоюз кинематография ин-тының сценарийлар остаханәсе җитәкчесе. 1986–90 елларда СССР Кинематографистлар берлеге сәркәтибе. «Ап-ак ләкләкләр» («Белые, белые аисты», 1965), «Наз» («Нежность», 1966), «Гадәттән тыш комиссар» («Чрезвычайный комиссар», 1971), «Мәхәббәт һәм ярсу» («Любовь и ярость», 1978), «Нинди безнең еллар!» («Какие наши годы!», 1980), «Даһиның яшьлеге» («Юность гения», 1983), «Газаплы мәхәббәт» («С любовью и болью», 1990), «Тугыз пәйгамбәр васыяте» («Завет девяти пророков», 1992) фильмнарына сценарийлар яза, алар «Үзбәкфильм», «Таҗикфильм», М.Горький исем. (Мәскәү) киностудияләрдә куела. Кинорежиссёрлар А.И.Хамраев, Р.И.*Батыров*, Э.М.Ишмөхәммәдов, Ж.Ристич (Югославия) б-н эшли. Иҗатының төп темасы — яшь кешене рухи яктан тәрбияләү. А. иҗатына лирик интонацияләр, әйләнә-тирә мохитне үз герое күзе аша күрә белү хас. Үзбәкстан ССРның Х.Н.Хәмзә исем. (1971), СССР Дәүләт (1984) бүләкләре лауреаты.

Ә с ә р.: Нежность. Влюблённые: Киносценарии. М., 1973; Последняя встреча: Киносценарий. М., 1975.

*Әд.:* П а в л о в а И. Далёкое и близкое // Искусство кино. 1983. № 11; Кино: Энцикл. словарь. М., 1986; Г о л у б и н а Л. Пять вариантов. М., 1988.

**АГИ́ШЕВ** Мөнир Хәсән улы (14.4.1932, Пенза өлкәсе Бичи а. — 3.3.1994, Казан), архитектор. Әзәрбайҗан политехника ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Горький өлкәсенең Дзержинск шәһәрендә эшли. 1958–60 елларда Горький тимер юлының Казан бүлекчәсендәге «Дорпроект» проектлау конторасында архитектор, 1960–62 дә ТАССР Коммуналь хуҗалык министрлыгы архитекторы, 1962–71 дә «Татгражданпроект» ин-тында проектларның баш архитекторы. 1962–67 дә СССР Архитекторлар берлегенең Татарстан

М.Х.А г и ш е в. 1. Шәһәр яны тимер юл вокзалы бинасы (Г.П.Горлышков, Н.В.Точилин б-н берлектә). Казан. 1967; 2. Г.Камал исем. Татар академия театры. 1986.







М.Х.А г и ш е в. Югары Ослан р-нының Кызыл Байрак авылындагы мәчет (Т.М.Агишев б-н берлектә). 1994.

оешмасы рәисе. Бер үк вакытта 1969 елдан Казан төзелеш инженерлары ин-тында архитектур проектлау фәнен укыта. 1971–90 да Казан шәһәренең баш архитекторы. 1990 нан мөстәкыйль иҗат остаханәсе җитәкчесе. 1980 елларда аның җитәкчелегендә Казанның үзәк өлешен, шәһәрнең «Төньяк Елга аръягы» төбәген, архит-ра истәлекләрен саклау зоналарының детальләп планлаштыру проектлары, шәһәрнең тарихи кварталларын үзгәртеп кору проектлары эшләнә һәм Казанның функциональ-тирәлек моделе барлыкка китерелә. А. проектлары б-н Казанда шәһәр яңы вокзалы (1967), *«Татарстан» кунакханәсе* (1970), *Татар академия театры* (1986, автордаш), Югары Ослан р-нының Кызыл Байрак авылында мәчет (1994, арх. Т.М.Агишев б-н берлектә) һ.б. корылмалар төзелә. А. — М.Вахитов һәйкәленең архитектур чишелеше авторы (1985, арх. В.А.Петербуржцев һәм А.В.Степанов б-н берлектә).

**АГИ́ШЕВ** Равил Рөстәм улы (14.7.1954, Казан), мәгълүмат эшкәртү һәм идарә системалары гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1995), проф. (1997). 1977 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. Хезмәтләре ерактан торып экологик мониторинг үткәрүнең оптик-электрон системаларына, лазер б-н ерактан зондлау системасының комачаулау тотрыклылыгы теориясен үстерүгә һәм методологиясен эшләүгә карый. Зондлау системаларының фәзада тотрыклылыгын сайлап алуын яхшыртуга һәм фонга тотрыклылыгын күтәрүгә нигезләнгән комачаулыклардан саклауның нәтиҗәле ысулларын эшли. Бадминтон буенча Бөтенсоюз турнирларында призлар ала, 10 мәртәбә Татарстан чемпионы (1973–83). СССР ВДНХсының ике көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Защита от фоновой помехи в оптико-электронных системах контроля состояния атмосферы. М., 1994; Системы оптической локации и дистанционного зондирования: особенности защиты от внешних помех. К., 1996.

**АГИ́ШЕВ** Якуб Хәлил улы (28.7.1899, хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнецк р-ны Пәлдәңге а. — 20.6.1972, Казан), әдәбият галиме, текстолог, филол. фән. канд-ты (1946). Архангельск реаль уч-щесен (1918), Казан пед. ин-тын (1934) тәмамлый. 1934–39 елларда Казан пед. техникумында һәм сәнгать техникумында укыта. 1939 дан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли, 1946–51 дә Казан пед. ин-ты укытучысы һәм татар әдәбияты каф. мөдире. 1951–60 та Казан ун-тында укыта. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихын дәверләргә бүлеп өйрәнүгә, Г.Тукай иҗатына карый. Урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Халык шагыйре Габдулла Тукай. К., 1956; Творчество Габдуллы Тукая. К., 1948.

*Әд.:* Г и н и я т у л л и н а А.К. Писатели Советского Татарстана: Библиогр. справ. К., 1970.

**АГРАМА́К** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 45 *км* көнчыгыштарак, Наясолка елгасы башланган җирдә урнашкан. 2002 елда 410 кеше (руслар — 61%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1920 елларда «Коминтерн» а.х. коммунасы буларак нигез салына. ТАССРның Спас кантонына керә. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935–91 елларда — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 286, 1958 дә — 620, 1970 тә — 750, 1979 да — 519, 1989 да — 430 кеше.

**АГРО**... (грек. agrós — кыр, басу).

**АГРОКЛИМА́ТИК ЗО́НАЛАР**, температура (җылылык б-н тәэмин итетү) һәм явым-төшемнәрнең күпьеллык күрсәткечләре буенча аерымланган төбәкләр. Җылылык б-н тәэмин итетү күрсәткече итеп а.х. культураларының актив вегетация чорындагы (10°С тан югары темп-ра булганда) уртача тәүлеклек һава темп-ралары суммасы санала. Бу күрсәткечтән чыгып, ТР терр-ясе салкынча, уртача салкын, уртача җылы, җылы А.з.га бүленә. Салкынча зона Кама алдын алып тора. Актив темп-ралар (10°С тан югары) суммасы 2070–2130°. Вегетация чоры 130–135 көн. Явым-төшемнәр майдан сентябрьгә кадәр 250 *мм* дан артык. Кыраусыз көннәрнең дәвамлылыгы 120–130 көн. Язгы кыраулар майның 2 нче декадасында, түбән урыннарда майның 3 нче декадасында туктый. Беренче көзге кыраулар, гадәттә, сентябрьнең 3 нче декадасында төшә, 1 нче декадасында да төшәргә мөмкин. Тотрыклы кар катламы ноябрьнең 2 нче яртысында ята. Соңгы елларда аның калынлыгы 41–42 *см*, кар яту вакытының дәвамлылыгы 143–148 көн. Уҗымнарның кышлавы өчен шартлар чагыштырмача уңайлы.

Уртача салкын зона Кама аръягының көнчыгыш күтәренке өлешен алып тора. Уртача



тәүлеклек актив темп-ра суммасы терр-янең күп өлешендә 2150–2200°, биегрәк көньяк-көнчыгыш өлешендә 2150° тан кимрәк. Үсемлекләрнең актив вегетация чоры 130–135 көн. Явым-төшемнәр суммасы (май-сент. айларында) 240–250 *мм*, көнбатыш сөзәклекләрдә күрсәткечләр югарырак. Кыраусыз көннәрнең дәвамлылыгы 124–130 көн. Соңгы язгы кыраулар калкулыкларда май уртасында, уйсу җирләрдә май ахырында бетә. Беренче көзге кыраулар сентябрьнең 2 нче яртысында, аерым елларда сентябрь башында күзәтелә. Тотрыклы кар катламы ноябрьнең 2 нче яртысында ята, калынлыгы уртача 38–41 *см*, яту дәвамлылыгы 140–147 көн. Уҗымнар һәм җимеш культураларының кышлавы өчен шартлар уңайсыз.

Уртача җылы зона респ-каның Идел алды өлешен алып тора. Актив темп-ралар суммасы 2200–2250°, актив вегетация чоры 133–137 көн. Үсемлекләрнең вегетация чорындагы явым-төшем суммасы 230–250 *мм* га кадәр. Кыраусыз вакыт уртача 135 көн, Идел яры буе тирәләрендә 140 көн. Язгы кыраулар, башлыча, майның 2 нче декадасында, аерым елларда июньнең 1 нче декадасында бетә. Көзге кыраулар гадәттә сентябрьнең 3 нче декадасында башлана. Тотрыклы кар катламы ноябрьнең 2 нче декадасында ята, дәвамлылыгы 138–145 көн. Кар катламының калынлыгы 32–40 *см*, һава темп-расының абс. минимумы уртача — 34–35°. Уҗым һәм җимеш культураларының кышлавы өчен шартлар күпчелек очракта яхшы.

Җылы зона Көнбатыш Кама аръягын алып тора. Актив тәүлеклек темп-ралар суммасы 2250° тан артыграк. Явым-төшемнәрнең (май-сент. айларында) күләме 220–230 *мм*, кыраусыз вакытның дәвамлылыгы 125–136 көн. Язгы кыраулар уртача майның 2 нче декадасында, аерым елларда июньнең 1 нче декадасында бетә. Тотрыклы кар катламы ноябрьнең 2 нче яртысында ята; кар яту дәвамлылыгы 137–144 көн; һава темп-расының абс. минимумы уртача 34–36°. Уҗымнарның һәм җимеш культураларының кышлавы өчен шартлар канәгатьләнерлек.

*Әд.:* Система ведения сельского хозяйства в Татарской АССР. К. 1974; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**АГРОКУЛЬТУ́РА** посёлогы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 9 *км* көньяк-көнбатыштарак. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чистай кантоны Галактионов волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Чистай р-нында. Халык саны: 1926 да — 58, 1938 дә — 142, 1949 да — 114, 1958 дә — 69, 1970 тә — 50, 1979 да — 30 кеше.

**АГРОНО́МИК РУДАЛА́Р**, табигый һәм техноген юл б-н барлыкка килгән минераль токымнар; алар туфракның уңдырышлылыгын күтәрү максатында аңа турыдан-туры кертелә һәм минераль ашламалар эшләп чыгару өчен чимал булып тора. «А.р.» атамасын 1921 елда геолог Я.В.Самойлов тәкъдим итә. А.р.ның төп компонентлары үсемлекләрнең тереклек эшчәнлеге өчен әһәмиятле макро- һәм микроэлементлардан (азот, фосфор, калий, күкерт, бор, бакыр һ.б.) гыйбарәт. Фосфор апатитлар, *фосфоритлар* һәм фосфатлы кварц комнары составына керә; калий — калий тозларында, *глауконит*ларда, сынныритларда; азот — калий һәм натрий (чили) селитрасында; күкерт — *гипста, ангидритта*, күкерт рудаларында була. Карбонатлы токымнар — *акбур, известьташ, доломит, мергель, известьлы туф*, күл известе *туфракны известьләүдә* кулланыла. А.р.га ш.у. *цеолитлар, бентонитлар, сапропельләр, торф* һ.б.да керә. Бакыр (к. *Бакыр рудалары*), бор, молибден, цинк, кобальт, марганец рудалары һәм техноген калдыклар микроашламалар эшләп чыгаруда кулланыла. ТРда фосфоритларның 20 дән артык очраклы күренеше һәм 5 чыганагы (*Сөендек фосфоритлар чыганагы*, Башчы чыганагы һ.б.) билгеле; известьташның 80 ләп чыганагы бар, аларның җидесе (Бимә, Иске Комазан һ.б.) известь оны әзерләүдә файдаланыла; күл сапропеленең 50 ләп чыганагы һәм ятмасы бар. Бентонитларның — 50 дән артык, гипсның — 7 һәм цеолитлы токымнарның 1 чыганагы ачылган.

*Әд.:* Проблемы геологии твёрдых полезных ископаемых Поволжского региона. К., 1997.

**АГРОНО́МИЯ** (*агро...* һәм *...номия*), а.х. үсемлекләрен игү, аларның уңышын һәм җитештерелгән продукциянең сыйфатын, туфракның уңдырышлылыгын һәм а.х. җирләренең продуктлылыгын күтәрү алымнары турындагы фәннәр комплексы. Үсемлекчелек, игенчелек, агрохимия, селекция, орлыкчылык, а.х. фитопатологиясе, энтомологиясе, мелиорация, метеорология һ.б. фәннәрне үз эченә ала. Ботаника, үсемлекләр физиологиясе, генетика, биохимия, микробиология, туфрак белеме һ.б. биология фәннәренә нигезләнә. Фән буларак, А. Татарстанда 20 йөз башыннан үсеш ала. Казан губернасы земствосының а.х. фермасы (Ерак Кабан күле яры буенда) беренче тәҗрибә учреждениесе була, анда 1909 елдан тугыз басулы чәчү әйләнеше кертелә башлый. 1911–12 дә чәчү әйләнеше буенча (тирес б-н ашлап һәм тирессез, ун басулы чәчү әйләнеше кертеп), минераль ашламалар (фосфоритлар, суперфосфатлар, томас-шлак, калий тозлары, мич көле) куллану буенча кыр тәҗрибәләренә нигез салына. 17 төрле кыяклы һәм кузаклы терлек азыгы үләннәренә сынаулар үткәрелә. 1912–15 тә Лаеш, Спас, Бөгелмә тәҗрибә кырлары оештырыла. Шактый тәҗрибә туплана. Лаеш тәҗрибә кырында агроном И.В.Благовещенский 1913 тән үләннәр, органик һәм минераль ашламалар, пар (пар күтәрү сроклары, сөрүнең тирәнлеге), бәрәңге, чөгендер һәм турнепс (орлык күмдерү ысуллары, үсемлекләрне урнаштыру куелыгы, утырту һәм чәчү вакыты, карау-тәрбияләү, сортлары); язгы кыяклы үсемлекләр (туфрак эшкәртү, чәчү вакыты, орлыкны күмдерү ысулы, чәчү ысулы һәм куелыгы, тирес һәм минераль ашламаларның тәэсире), ш.у. борчак, ясмык, җитен б-н тәҗрибәләр уздыра. Казан губернасында 1910 да губерна һәм өяз земствосы идарәләре каршында агрономия хезмәте оештырыла. Губерна земство идарәсе составында а.х. бүлеге эшли, аның штатында губерна агрономы һәм инструкторлары була. Өяз земство идарәсе штатында өяз агрономы булдырыла, ә өязләр 3–4 участокка бүленә, аларның һәркайсында участок агрономнары эшли. Губерна земство идарәсе ел саен аграр киңәшмәләр уздыра, Казан җир эшләре уч-щесендә һәм а.х. фермасында кырчылык, бакчачылык һ.б. а.х. тармаклары буенча 6 айлык курслар оештырыла. Курслар б-н а.х. фермасы управляющие һәм Казан җир эшләре уч-щесе директоры В.В.Танеев җитәкчелек итә. Теоретик һәм гамәли дәресләрне Казан ун-ты профессоры А.Н.Остряков, губерна агрономы И.И.Штуцер, хөкүмәт агрономы Н.В.Васильев, уч-ще укытучылары алып бара. Өяз земстволарында ике атналык курслар уздырыла. Курсларда тыңлаучыларның төп өлеше крәстияннәр була. Урыннарда крәстияннәр б-н земство агрономнары инструкцияләр үткәрә. А.х. белемнәрен пропагандалау максаты б-н земстволар тарафыннан «Вестник сельского хозяйства», «Хуторянин», «Самарский земледелец», «Сельский вестник», «Крестьянское земледелие» ж-ллары таратыла. Ләкин, агрономия хезмәте һәм земстволарның тырышлык күрсәтүенә карамастан, бу чараларның файдасы зур булмый. Крәстияннәрнең игенчелек хуҗалыгы традиция буенча өч басулы чәчү әйләнешенә (пар — уҗым — сабан) нигезләнә, сөрү җирләренең 33% ы парга калдырыла, 32,9% ында арыш, 15,2% — солы, 4,4% — карабодай, 2,2% — сабан бодае, 2,4% — борай, 0,7% — борчак, 2,2% — бәрәңге, 1% — җитен, 3,7% ында калган культуралар игелә. Бөртеклеләрнең уңышы һәр гектардан 3–7 *ц* дәрәҗәсендә була. Крәстиян хуҗалыкларындагы җирнең аерым кишәрлекләргә бүлгәләнүе, заманча машина һәм эш коралларының булмавы һәм крәстияннәрнең гомуми культура дәрәҗәсе түбән булуы А. казанышларыннан файдалануда тоткарлык ясый. Алпавыт утарларында а.х. алып бару дәрәҗәсе югарырак була: управляющий итеп агрономиядән белеме булган белгечләр торган саен күбрәк тартыла, а.х. техникасы сатып алына.

1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң а.х. производствосын эреләндерүгә юнәлеш тотылу сәбәпле, аграр тикшеренүләрне үстерүгә һәм А. казанышларын гамәлгә кертүгә зур игътибар бирелә. 1919 да Казан политехника ин-ты каршында а.х. ф-ты, 1922 дә Казан а.х. һәм урманчылык ин-ты ачыла, тәҗрибә кырларының саны арта. Агротехника алымнарын системалы тикшерүләр һәм селекция эшләре уздырыла башлый. Казан политехника ин-тында А.Я.Гордягин, Б.И.Горизонтов, Н.А.Ливанов, Д.И.Морохин, А.М.Алексеев кебек профессорлар һәм укытучылар эшли. 1919 дан А. казанышларын һәм алдынгы тәҗрибәне пропагандалау максатында «Казанский земледелец» («Казан игенчесе») ж-лы нәшер ителә башлый. Татарстанда А.нең фән буларак үсеше В.П.Мосолов, И.В.Благовещенский, П.И.Трухин, С.С.Ильин, В.Т.Макаров, Б.И.Горизонтов, А.В.Ватагин, А.К.Вершинин, Р.Р.Хөсәенов, Г.Г.Җиһаншин, Л.Р.Шәрифуллин, Х.Х.Хәбибрахманов, Г.Д.Аверьянов, И.А.Гайсин, Р.Г.Гәрәев, Г.С.Шакиров, Т.З.Дәүләтшин, Р.А.Юнысов һ.б. агрономия галимнәренең, Е.Н.Борисова, Г.И.Попов, З.Х.Шәрәф,

М.Н.Шумкова, Х.Х.Байчурова, В.З.Шәкүров, Ш.В.Вәлиев, Н.Н.Петелина, Э.Ф.Ионов, Ф.З.Кадыйрова, М.Л.Пономорёва, Ф.М. һәм Л.А.Киселёвлар, Г.И.Розанова, Л.А.Севастьянова кебек селекция белгечләренең, М.А.Винокуров, А.В.Колоскова, Р.К.Даутов, И.В.Үтәй кебек туфрак белгечләренең һәм А.М.Алексеев, Н.А.Гусев, И.А.Тарчевский, Ф.Д.Самуилов һ.б. үсемлек физиологиясе белгечләренең исемнәре б-н бәйле. 1930 еллар башында пар мәйданнары кимрәк һәм өлешчә биләүле пар җирләре булган; язгы бодай һәм борчак чәчүлекләре киңәйтелгән (пар — уҗым арышы — язгы бодай — сызма культуралар б-н кузаклылар — солы) чәчү әйләнешләре кертелә. Соңрак чәчү әйләнешләрен специальләштерә башлыйлар (кыр культуралары, терлек азыгы һәм техник культуралар). Алар — күпьеллык үлән чәчүлекләре кергән яисә үләннәрсез күп басулы чәчү әйләнешләре булган. Язгы сөрү тулысынча көзге туңга сөрү б-н алыштырыла: камыл алдан лущильник б-н йомшартылып, 20 *см* дан ким булмаган тирәнлектә алтөрәнле сабаннар б-н сөрелә. В.П.Мосолов тарафыннан калын сөрү катламы булдыру һәм кәсле-көлсу һ.б. туфракларны яруслап (катламлап) сөрү алымнары тәкъдим ителә. С.С.Ильин җирле һәм минераль ашламаларның а.х. культураларына тәэсирен ачыклау максатында киң күләмле тәҗрибәләр уздыруны оештыра. 1956 да Казан селекция станциясенең Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясе итеп үзгәртелүе һәм шул җирлектә 1969 да Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты төзелү б-н киң күләмдә селекция эшләре җайга салына. 1927 дә Е.Н.Борисова тарафыннан арышның «Авангард» сорты чыгарыла, 1950 елларга ул тагын да мулрак уңыш бирә торган «Казан» сорты б-н алыштырыла. Борчакның «Казан 38» сорты, арпа, тары, карабодай, люцерна, клевер сортлары чыгарыла. А.х. культураларын чәчү нормалары, ысуллары, вакытлары тикшерелә, чәчүлекләрне карауның механикалаштырылган алымнары, иң уңай сроклары, болыннарны сугару нормасы һәм ысуллары өйрәнелә. Аграр казанышларны кертү нәтиҗәсендә 1980 еллар ахырына Татарстанда бөртеклеләрнең гектарыннан алынган уңыш 20 *ц* дан узып китә. Уңышны программалаштыру алымы (И.С.Шатилов һ.б.) барлыкка килү б-н, Татарстанда А. сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрелә. 1970 еллар башында бу юнәлеш б-н Г.Г.Җиһаншин җитәкчелек итә. Ул, Л.Р.Шәрифуллин һ.б. б-н берлектә, а.х. культураларын чәчү әйләнешендә урнаштыру (арыш, язгы бодай, арпа, солы, тары, борчак, вика, карабодай, бәрәңге, люцерна), туфракны эшкәртү, ашламалар куллану, сугару, сортлар сайлау, чәчү уздыру, чәчүлекләрне карау кебек мәсьәләләрне һәм игеннәрне урып-җыю үзенчәлекләрен өйрәнә. ТРда чәчүлек модельләре үсемлекләрнең үсеш фазалары буенча аныкланган һәм югары уңыш алу өчен кирәк булган яшәү факторларының параметрларын исәпкә алып эшләнә. Адаптив *агроландшафтлы игенчелек* буенча үткәрелгән фәнни-җитештерү тәҗрибәләре агрономия тикшеренүләренең әһәмиятле өлеше булып тора.

*Әд.:* Казанская губерния в сельскохозяйственном отношении. К., 1889; Благовещенский И.В. Опыты с травами. К., 1913; В борьбе за культурное крестьянское хозяйство. К., 1928; Ильин С.С. Удобрение полевых культур. К., 1940; Зиганшин А.А. Интенсивные технологии и программирование урожайности. К., 1987; Жученко А.А. Стратегия адаптивной интенсификации сельского хозяйства. Пущино, 1994; Основные подходы к разработке программ «Плодородие». К., 2002; Слагаемые эффективного агробизнеса: обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*Г.Г.Җиһаншин, В.А.Наумов.*

**АГРОСӘНӘГА́ТЬ ИНТЕГРА́ЦИЯСЕ**, авыл хуҗалыгы производствосы, анда җитештерелгән продукцияне эшкәртү сәнәгате һәм авыл хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче предприятиеләр арасында бәйләнешләр урнаштыру, аларны бердәм хуҗалык итү организмына берләштерү процессы. Агросәнәгать пр-тиеләре а.х. һәм сәнәгать пр-тиеләрен бергә кушу, а.х. секторында продукция эшкәртү пр-тиеләре төзү яки гамәлдәге сәнәгать пр-тиеләре каршында а.х.ның чимал базасын булдыру юлы б-н оеша. Агросәнәгать берләшмәләре тармак яки терр. тармак принципларына нигезләнеп оештырыла. Берләшмәләргә керүчеләрнең хуҗалык итү мөстәкыйльлеге һәм юридик зат булу хокукы саклана. Икътисади мөнәсәбәтләр бердәм план һәм хуҗалык килешүе нигезендә гамәлгә ашырыла. А.и.ндә а.х. продукциясе җитештерүнең, аны сәнәгый эшкәртү, яңадан эшкәртү, кайчак саклауны да кертеп, оештыруның технологик һәм икътисади бердәмлеге тәэмин ителә. Кулланучыга әзер эшләнмә яки продукт эшләп чыгаруда барлык процессларны продукция-чимал б-н тәэмин итүче буларак, а.х. төп интегратор ролен үти. Тиешле шартларның өлгерүе нәтиҗәсендә аграр һәм сәнәгать тармакларының бергә кушыла баруы а.х. һәм сәнәгать производстволары арасындагы тарихи өзеклекне җиңәргә мөмкинлек бирә. А.и. матди-техник һәм хезмәт ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрә. А.х. производствосын сәнәгать б-н кооперацияләү нигезендә төзелгән беренче хуҗалыклар Окт. рев-циясеннән соң дәүләт милке итеп үзгәртелгән азык сәнәгате пр-тиеләре һәм элеккеге алпавыт имениеләре җирлегендә барлыкка килә. Алар составына он тарту, шикәр җитештерү, аракы, май з-длары һ.б. кергән. 1930 елга 300 гә якын аграр-индустриаль комб-т оештырыла, әмма 1932 дә эшкәртү сәнәгате пр-тиеләре алар составыннан аерылып чыга һәм трестларга берләшә. 1960 еллар ахырыннан, а.х. пр-тиеләрендә җитештерүнең специальләшүе һәм үзәкләргә тупланышы үсү б-н, агросәнәгать кооперациясе тарихында яңа этап башлана. А.и. Татарстанда 1970 елларда сизелерлек үсеш ала. Җиләк-җимеш эшкәртү буенча специальләшкән заводы булган «Масловка» җиләк-җимеш с-зы, яшелчә һәм яшел борчак консервлары җитештерә торган куәтле цехлары булган «Ворошилов», «Нармонка» яшелчәчелек с-злары оештырыла. 1990 еллар башында яңа төр агросәнәгать пр-тиеләре — «Салмачы», «Нокса», «Идел», «Бөреле» агрофирмалары, «Татрапс» фәнни-җитештерү берләшмәсе, ш.у. составында җиләк-җимеш, яшелчә үстерү с-злары, җиләк-җимеш питомниклары, агрофирмалар, эшкәртү пр-тиеләре, саклау базалары һәм сәүдә итү челтәре булган «Татплодоовощпром» концерны оештырыла. Аннан соңгы елларда яңа агросәнәгать берләшмәләре барлыкка килә: «Биосельхоз» фәнни-сәнәгать предприятиесе ААҖ, «Буа шикәр заводы» АҖ, «Зәй шикәре» АҖ, «Татарстан сөте» АҖнең ашлык кабул итү предприятиеләре» идарәсе, «Кызыл Шәрекъ—Агро» АҖ, «КамАЗ-зернопродукт» ААҖ, «Чаллы-икмәк» АҖ, «Чистое поле» агросәнәгать компаниясе, «Агрофирма Кулон» ААҖ һ.б.

*Әд.:* Опыт и проблемы аграрно-промышленного кооперирования. М., 1975; Перестройка аграрного сектора экономики. М., 1990; Республика Татарстан в цифрах: Стат. сб. К., 2006.

**АГРОСӘНӘГА́ТЬ КО́МПЛЕКСЫ**, а.х. продукциясе җитештерү, эшкәртү, сату-урнаштыру буенча специальләшкән, а.х.на матди-техник хезмәт күрсәтүче тармаклары булган һәм бу тармаклар өчен җитештерү чаралары булдырган халык хуҗалыгы, оешмалар һәм пр-тиеләр җыелмасы. А.к.ның төп звеносы — а.х. А.к. звенолары өч сферага: игенчелек һәм терлекчелек продукциясе җитештерү, А.к. өчен җитештерү чараларын булдыру һәм а.х. чималын сәнәгый эшкәртү тармакларына бүленә. А.к.ның барлык звенолары үзара бәйләнгән. А.х. продукциясе җитештерү күләменең үсүе А.к.ның барлык тармакларының да пропорциональ үсешен таләп итә. Илне индустрияләштерү чорында тракторлар һәм а.х. машиналары төзелеше, минераль ашламалар җитештерү, җиңел һәм азык-төлек сәнәгате пр-тиеләре булдырыла. Сугыштан соңгы чорда А.к. формалаштыру тизләшә. 1960 елларда үсеш стимуляторлары, аксымлы өстәмәләр һ.б. җитештерү өчен микробиология сәнәгате барлыкка килә. А.х.н. мелиорацияләү һәм химияләштерү үсеш ала. А.х. һәм эшкәртү пр-тиеләре арасында вертикаль һәм горизонталь интеграция бәйләнешлары көчәя. 1998 елда Татарстан А.к. төрле милек формасындагы 1130 а.х. пр-тиесен берләштерә, шуның 156 сы — дәүләт, 949 ы — хосусый, 16 сы катнаш милекле пр-тиеләр. Моннан тыш, 1330 крәстиян (фермер) хуҗалыгы һ.б. барлыкка килә. 2005 тә 821 эре һәм уртача а.х. оешмасы була, ш.и. 9 колхоз, 4 совхоз, 9 дәүләт хуҗалыгы, 29 АҖ, 9 ышанычлылыкка нигезләнгән ширкәт, 298 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, 357 а.х. кооперативы, 11 крәстиян (фермер) хуҗалыклары ассоциациясе. Шуларның 35 е — дәүләт, 825 е — хосусый, 19 ы катнаш милекле предприятиеләр. Вак крәстиян (фермер) хуҗалыкларының саны 2378 гә җитә. 1998 дә 126, 2005 тә 1193 азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгате пр-тиеләре эшли. Шулар арасында иң эреләре: «Буа шикәр заводы» АҖ, «Зәй шикәре» АҖ, «Нурлат шикәр заводы», спирт һәм шәраб-аракы сәнәгате пр-тиеләре (к. *Спирт һәм шәраб-аракы җитештерү сәнәгате*), сөт һәм ит эшкәртү з-длары һәм комб-тлары, ш.и. Актаныш һәм Яңа Чишмә коры сөт з-длары, федераль дәрәҗәдәге Алексеев сөт консервлау комб-ты (к. *Сөт һәм сыр-май җитештерү сәнәгате*). Казан, Әлмәт, Зәй һәм Җәлил-

дә кондитер пр-тиеләре урнашкан. «Татшерсть» җитештерү берләшмәсе, «Кукмара киез итек-киез комб-ты», «Татваленок» ААҖ, Казандагы «Сафьян» күн җитештерү берләшмәсе, «Мелита» җитештерү берләшмәсе а.х. продукциясен сәнәгать максатлары өчен эшкәртә. Яшелчә консервлары «Татплодоовощпром» концерны хуҗалыкларында эшләнә. «КамАЗ» җитештерү берләшмәсе а.х. өчен зур йөк машиналары җитештерә.

А.х. машиналары һәм җайланмалары җитештерүче предприятиеләр: Буа машиналар төзү з-ды «КМПО» — ККН тибындагы культиваторларның модельле рәте, ККШ-11.3, КПИР-3.6, КПУ-3.6, КПИР-6.8 культиваторлары; «Казан сельхозтехникасы» АҖ — төгәл чәчү чәчкечләре (чөгендер һәм кукуруз өчен) «Мультикорн», БДП (дискатор) тырмалары, ЗККШ-6 катоклары, ПЛН-4–35, ПЛН-5–35 сукалары, ЗМ-3 бөртек сиптергечләре, КИР-1,5, КДН-210 чапкычлары, КБМ-7,2 культиваторы, КСТ-1,4 бәрәңге казыгычлары, ОП-2000М «Руслан», «Агро», ОП-2500М, «Болгар», «Шүрәле» су сиптерү җайланмалары; «Татэлектромаш» АҖ (Казан) — авыр тырмалар, «Кузбасс» тибындагы чәчү комплексы үзбушаткычына прицеплар; «КАМАЗ» АҖ — ДОН-1500, «Полесье», КСК-100 комбайннары, Т-150, Т-4, ХТЗ тракторлары өчен «КАМАЗ» көч җайланмалары; «Роста» ААҖ (Казан) — «Умач ПВЗ-14» орлык изгечләре; «Кулонэнергомаш» АҖ (Казан) — ПЗ-700 орлык изгечләре, ДА-1 орлык ваклагычы, МКА-1 катнаш мал азыгы ваклагычы, КОС-3 культиваторы, ИСК-3 тибындагы мал азыгы ваклагычлар, ПК «Кулон» чәчү комплекслары; «Вакууммаш» АҖ — ВВН вакуум насослары; Чистай «Автоспецоборудование» з-ды АҖ — КБМ-2,1–15 культиваторларының модельле рәте, чәчкечләр, БДМ дискаторлары; «ЕлАЗ» җитештерү берләшмәсе ДУП — МТЗ-80, 82, МТЗ-1221 тракторлары; «Союз» махсус конструкторлык (Казан) — СТВС-12 тибындагы төгәл чөгендер чәчкечләре; «Интеспроц» ААҖ (Бөгелмә) — Л-6 тибындагы чөгендер төягеч; «Агроидея» ААҖ («Лемкен» фирмасы б-н берлектә) (Лениногорск) — «Лемкен» дисклы культиваторларының модельле рәте; «Татагрохимсервис» АҖ — КСН-3, КСН-4 культиваторлары («Квернелад» комплектлаштыру детальләре б-н), ОМПШ-2000Р, 2500 сиптергечләре (РАУ фирмасы җайланмалары комплекты б-н), ПС-10АМ орлык агулау агрегатлары; «Вамин-Чистай» ААҖ (Чистай) — чүмәләләр ташу җайланмасы; «Балтач сельхозтехникасы» АҖ — ДКУ-2,0 орлык ваклагычлары, ТСН-35, ТСН-160 тирес транспортёрлары, КРН-2,1 чапкычлары, ГВК-6,0 тырмалары, ККН-2,8, ЗКК-6 катоклары, аркалы ангарлар, дуңгыз фермалары, БДТ-7 дисклы тырмалары; «Маратон» ремонт-механика з-ды ААҖ (Яр Чаллы) — ПЗУ-20 орлык төягечләре; «Хуҗәмәт РМЗ» АҖ — ПСМ-2,5; 5; 10; 25 пневматик сортларга аергыч; «Арскдизель» ААҖ — ЗГМ-20 «Арчанка» гравитацион ашлык чистарткыч машиналар; «Бөгелмә РМЗ» АҖ — СКУ-10 карусельле ашлык киптергечләр; «Татарстанның элиталы орлыклары» ассоциациясе (Чистай) — СМВО-10П; СМВО-10С орлык чистарту машиналары; «Алабуга композит эшләнмәләр з-ды» ААҖ — терлек азыгын төрү өчен агро-стреч плёнкалар. «Татагрохим» АҖ бүлекләре, ТРның Үсемлекләрне саклау федераль территориаль станциясе һ.б. җитештерү һәм төзелеш оешмалары а.х.на даими хезмәт күрсәтәләр. «Татарстан сөте» АҖнең ашлык кабул итү предприятиеләре» идарәсе, «Алтын башак» идарә компаниясе һ.б. оешмаларның пр-тиеләре бөртекле ашлык әзерләү һәм эшкәртүне гамәлгә ашыра. Россия авыл хуҗалыгы академиясенең Татарстан а.х. фәнни-җитештерү ин-ты, Казан аграр ун-ты, Казан вет. медицинасы академиясе, Бөтенроссия фәнни-тикшеренү вет. ин-ты, Казан ун-тының биология-туфрак ф-ты, Россия а.х. академиясенең Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-ты Респ-ка агросәнәгате комплексының фәнни яктан тәэмин ителеше б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* Карлюк И.Я. Аграрно-промышленный комплекс. М., 1981; Сдобнов С.И. Агропромышленный комплекс РСФСР: Сущность, цели, задачи. М., 1986; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992; Сельское хозяйство Республики Татарстан. Стат. сб. К., 2006.

*Г.Х.Хәбибрахманов.*

**АГРОТЕ́ХНИКА** (*агро*... һәм грек. tehnike — осталык), игенчелек технологиясе, а.х. культураларын үстерү алымнары системасы. А. ның бурычы — җитештерелгән продукциянең һәр берәмлегенә хезмәт һәм матди чыгымнарны кимрәк тотып, а.х. культураларыннан югары уңыш алу. А. җитештерү процессларын комплекслы механикалаштыруны, ашлама һәм туфрак эшкәртү системаларын куллануны, иң яхшы сортлы орлыклар чәчүне, чәчү әйләнешендә үсемлекләрнең урнашуын, чәчүне (утыртуны), үсемлекләрне карау-тәрбияләүне, чүп үләннәр, а.х. үсемлекләре авырулары һәм корткычлары б-н көрәшүне, туфрак өслеген тигезләүне, кар тотуны, сугаруны һ.б. үз эченә ала. А. явым-төшем суларының агып китүен туктату, туфрак юылуын (эрозия) һәм дымның парга әйләнүен киметү, туфракны органик һәм минераль ашламалар б-н балансլап баету кирәклеген исәпкә алып, һәр зонаның туфрак-климат үзенчәлекләренә бәйле рәвештә дифференцияләп үткәрелә. Татарстанда, тулаем бөтен илдәге кебек, А. 1930 елларга кадәр түбән дәрәҗәдә була. Сөрү җиренең 1/3 өлешен соңгы яшел пар биләгән өч басулы чәчү әйләнеше, сабан һәм сука б-н язын сай итеп сөрү, агуланмаган сортсыз орлыкларны тубалдан кул б-н чәчү, чүп үләннәрне кул б-н утау, игеннәрне урак һәм чалгылар ярдәмендә җыю, чабагач б-н сугу кулланылган. Нәтиҗәсе түбән, бер дисәтинә җирдән 5–6 *ц* бөртекле ашлык уңышы алына. Төп үзгәрешләр 1930 еллар башында — а.х.ын коллективлаштыру барышында, колхоз һәм совхозлар оештырылганнан соң башлана, а.х. машиналары, тракторлар файдаланыла, ашламалар, сортлы орлыклар һәм а.х. фәне казанышлары кулланыла башлый. 1950 елларда А. үсешенең яңа этабы башлана. ТРда 1990–2000 елларда зур уңышларга ирешелә: корылыклы елларда да игеннәрнең уңышы гектардан уртача 12–17 *ц* дан кимеми, уңай килгән елларда (1997, 2001) гектардан 37,8–39,8 *ц* уңыш алына. ТРда бөртекле һәм терлек азыгы культураларын үстерү технологияләре Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында һәм Казан аграр ун-тында эшләнә. А.да игенчелекнең барлык культураларын үстерүгә йогынты ясый торган гомуми алымнары (чәчү әйләнеше, туфрак эшкәртү системасы, ашламалар куллану, сугару, орлыкчылык, үсемлек авырулары, корткычлар, чүп үләннәр б-н көрәшү, урман полосаларыннан файдалану) һәм һәрбер культураны үстерү, җыю, саклау, эшкәртү кебек махсус шәхси алымнар аерып карала. А.да кырларның уңдырышлылыгын киметә торган үсемлекләрне (язгы һәм көзге кыяклы культуралар), кырларның уңдырышлылыгын арттыра торган үсемлекләр б-н (ашлама кертеп күпьеллык үләннәр, берьеллык кузаклылар, сызма культуралар чәчү) чиратлаштыра торган алмаш чәчү әйләнеше кертү зур әһәмияткә ия. Игелә торган культуралар җыелмасын исәпкә алып, кыр, ферма яны, болынлы-көтүлекле, чөгендерле, яшелчәле һ.б. чәчү әйләнешләре кертелә. Юыла торган кырлар, кагыйдә буларак, күпьеллык үләннәр катнашмасы чәчү өчен билгеләнә, 3–5 градустан текәрәк сөзәклекләр печән-көтүлекләр өчен күпьеллык үсемлекләр чәчү максатында файдаланыла. Туфрак юылуның туктавына һәм аның уңдырышлылыгы яхшыруга карап, болынга әверелгән басуларны полосалы (горизонталь полосалар) игенчелеккә күчерәләр һәм анда, чиратлаштырып, күпьеллык үләннәрне берьеллык үләннәр б-н аралаштырып чәчәләр.

Үсемлекчелек продуктлары җитештерүне киметмәү өчен, сөрү җирләрендә бөртеклеләрнең уңышын 40–60 *ц/га* һәм аннан да күбрәк итеп программалаштырып, адаптив технологияләр үзләштерелә. Туңга сөрү зона һәм туфрак үзенчәлекләренә, кырларның чүпләнүенә бәйле рәвештә үткәрелә: алдан камыл лущильник б-н йомшартыла, аннан калаклы яисә калаксыз сабаннар һәм яссы кискеч — тирән йомшарткыч б-н 20–30 *см* тирәнлектә сөрелә.

Чиста пар калаклы лущильник яисә культиватор б-н катламлап эшкәртелә. Чәчү алдыннан сабан һәм уҗым культуралары өчен туфрак эшкәртү, ш.у. тырмалау, рәт араларын эшкәртү, үсемлекләрнең төбенә өю, һәрбер үсемлекнең үзенчәлекләрен исәпкә алып, кабул ителгән система буенча башкарыла. Ашламалар системасы пар басуындагы пар биләүче культуралар, сызма культуралар астына тирес, черемә, сидератлар кертү, известьләү, органик һ.б. ашламаларның тәэсир итү көчен исәпләп, аерым культуралардан планлаштырылган уңыш алу өчен кирәкле ашламаларның күләмен билгеләүдән һәм кертүдән гыйбарәт. Чәчү өчен үсеше көчле (80% тан да ким булмаган) һәм тишелеше югары булган эре орлыкларны сайлап алалар. Бөртекле культураларны тоташ чәчкәндә, вегетация чорында чәчүлекләрне химикатлар б-н эшкәртү һәм минераль ашламалар кертү максатында, кулланылырга тиешле машиналар-

ның киңлеген исәпкә алып, даими технол. колеяләр (чәчелмәгән эзләр) калдырыла.

*Әд.:* З и г а н ш и н А.А. Агротехника полевых культур в Татарской АССР. К., 1952; ш у л у к. Современные технологии и программирование урожайности. К. 2001; М о с о л о в В.П. Полевые культуры Татарии и техника их возделывания // Собр. соч. М., 1955. Т. 5; Ш а т и л о в И.С. Экологические, биологические и агротехнические условия получения запрограммированных урожаев // Изв. ТСХА. 1970. Вып. 1; Слагаемые эффективного агробизнеса: обобщение опытов и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*Г.Г.Җиһаншин.*

**АГРОУРМА́Н МЕЛИОРА́ЦИЯСЕ**, һава һәм туфракның корылыгы, коры җилләр, туфрак эрозиясе һәм тышкы тирәлекнең башка уңайсыз факторлары б-н көрәшүгә юнәлтелгән саклагыч утыртма урманнар һәм агротехник чаралар системасы. А.м.нең нигезләре В.В.Докучаев тарафыннан салынган. Агрономия, туфрак белеме, агрометеорология, урманчылык һ.б. фәннәрнең казанышларына нигезләнә. Субүләр калкулыкларда, елга, сулык һәм чокыр буйларында, торак пунктлар янында урман полосалары һәм массивлары, сөзәк тау битләрендә һәм кырара тигезлекләрдә кыр саклау урман полосалары кебек утыртма урманнар файдаланыла. Алар микроклиматны яхшырта, җил тизлеген киметүгә, кар тотуга ярдәм итә; җир өстендә су агымнарын киметә, туфракның дымлылыгын арттыра. Урман полосаларының аграр нәтиҗәлелеген агач һәм куаклыкларның составы һәм урнашуы билгели. ТРда, ш.у. бөтен ил буенча кыр ышыклау урман полосаларын күпләп утырту 1950 елларда башлана; барлыгы 100 мең *га* тирәсе урман утыртыла. Татарстанда бу максатта каен, тирәк, имән, өрәңге һәм куаклыклар утырту өчен төрле куак үсемлекләре кулланыла. Кыр ышыклау урман полосалары *агротехник*, гидротехник һ.б. чаралар б-н бергә туры килгәндә нәтиҗәле була. Югары Ослан, Кама Тамагы, Биектау, Арча, Әгерҗе, Түбән Кама, Лениногорск р-ннарының телгәләнгән рельефлы кырларында, саклагыч утыртма урманнар б-н беррәттән, туфрак саклау системасы чаралары (сөзәклеккә аркылы сөрү, тирәнәйтелгән оячыклар, ярыклар ясау, буразналау, үлән чәчү), ә кирәк булганда — гидротехник корылмалар системасы да кулланыла. Саклагыч урманнар утырту хуҗалыктагы җир төзү эшләре б-н бер үк вакытта планлаштырыла.

**АГРОФИ́РМА** (*агро*... һәм итал. firma), предприятие, а.х. продукциясе җитештерү, аны саклау, эшкәртү, сату-урнаштыру һ.б. төр эшчәнлек б-н шөгыльләнә; а.х. пр-тиеләрен эшкәртү һәм сәүдә итү пр-тиеләре б-н интеграцияләүнең бер формасы. А.х. пр-тиеләрен эшкәртү һәм сәүдә пр-тиеләре б-н берләштерү яки, юридик зат хокукыннан мәхрүм итеп, берсен икенчесенә кушу юлы б-н оештырыла. А.лар катнашучыларның составы, эшчәнлеге, милек формалары буенча төрлечә булырга мөмкин. А. җитештерүне специальләштерү һәм кооперацияләүне гамәлгә ашыру, хезмәт, технология, финанс ресурслары б-н идарә итүнең оперативлыгын, алардан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен шартлар тудыра. А. финанс ресурсларын туплау, җитештерүнең аеруча перспективалы юнәлешләрен инвестицияләү, нәтиҗәле технологияләрне гамәлгә ашыру, бердәм маркетинг хезмәте оештыру, базар коньюктурасын өйрәнү һәм табыштан отышлы файдалану мөмкинлеге бирә. ТРда 2000 елга 6 агрофирма теркәлгән: «Бөреле», «Идел», «Нокса» (Биектау р-ны), «Салмачи» (Питрәч р-ны), «Фролово» (Буа р-ны) һәм «Рассвет» (Лаеш р-ны). Ш.у. к. *Агросәнәгать интеграциясе*.

*Әд.:* Б а к л а ш е н к о Г. Концепция хозяйственного управления АПК // АПК: экономика, управление. 1998, № 6.

*М.Х.Ибраһимов.*

**АГРОХИ́МИЯ**, агрономик химия, үсемлекләрне минераль тукландыру турындагы фән. Үсемлекчелектән экологик чиста продукция алу өчен ашламалар куллануның иң нигезле алымнарын эшләү максаты б-н туфрак, үсемлек һәм ашламаларның бер-берсенә тәэсир итү процессларын өйрәнә; а.х. химияләштерүнең фәнни нигезе булып тора. Туфрак белеме, үсемлекчелек, үсемлекләр физиологиясе һәм биохимиясе, экология һ.б. б-н тыгыз бәйләнгән. А. 19 йөзнең 1 нче яртысында барлыкка килә. 19 йөзнең 30 елларында француз биологы Ж.Буссенго игенчелектә матдәләрнең өзлексез әйләнешен тикшерә, немец химигы Ю.Либих үсемлекләрне минераль тукландыру теориясен формалаштыра, Ротстед тәҗрибә станциясенә (Бөекбритания) нигез салучы Дж.Лос дөньяда беренче суперфосфат з-дын төзи. Ул вакыттагы рус агрохимиясе вәкилләре И.М.Комов һәм А.Т.Болотов туфракның уңдырышлылыгын яхшырту өчен органик ашламалар куллануга зур игътибар бирәләр. 19 йөзнең 60 елларында А.Н.Энгельгардт агрохимия буенча тикшеренүләрен башлый: көлсу туфракта фосфорит онының югары нәтиҗәлелеген исбатлый. А. үсеше өчен К.А.Тимирязевның үсемлекләр фотосинтезы һәм минераль тукланууына багышланган классик тикшеренүләре, Д.И.Менделеевның минераль ашламалар б-н тәҗрибәләре, П.С.Коссович, К.К.Гедройц, Д.А.Сабинин һ.б. галимнәрнең хезмәтләре зур әһәмияткә ия. Россия агрохимия фәненә нигез салучы булып Д.Н.Прянишников санала. Аның үсемлекләрне азот б-н тукландыру һәм азотлы ашламалар куллану буенча классик тикшеренүләре бөтен дөньяга танылa. Д.Н.Прянишников билгеләмәсе буенча, химик элементларның балансы һәм өзлексез әйләнеше б-н идарә итү А.нең төп бурычы булып тора. Илебезнең А. фәне үсешенә Татарстан галимнәре дә зур өлеш кертә. Б.Н.Горизонтов Казан агрохимиклар мәктәбенә нигез сала. Аның җитәкчелегендә 1920 елда Казан политехника ин-ты каршында респ-када беренче А. кафедрасы оештырыла. Б.И.Горизонтовның фәнни тикшеренүләре, башлыча, игенчелектә фосфор куллану мәсьәләсенә карый. Казан ун-ты, Казан а.х. академиясе һ.б. уку йортлары галимнәренең А. өлкәсендәге тикшеренүләре зур казанышларга китерә. Микроашламалар составының хелат формаларын (Урыссу тәҗрибә-хим. з-ды) һәм аммиак селитрасын (*Яңа Менделеев химия заводы*) эшләп чыгару җайга салына. Респ-када Дәүләт агрохимия хезмәте күрсәтү оештырыла (1964). А.х. химияләштерүдә фәнни нигезләнгән чаралар куллану сәясәтен *«Татарский» агрохимия хезмәте күрсәтү проект-эзләнү үзәге* гамәлгә ашыра. 1980 елларда респ-када а.х. проблемаларын чишүдә А.нең роле үсә. А.х. культураларын үстерүнең *интенсив технологияләре*, башлыча, ашламалар һ.б. химик чараларны рациональ куллануга нигезләнә. Бу исә үсемлекләрне оптималь тукландыру режимнарын, ашламаларның яңа формаларын һәм аларны куллануның яңа алымнарын тудыра.

*И.А.Гайсин.*

**АГУЛЫ́ БИЛЧӘ́Н**, с ө т л е с а б а к (Lactuca), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер, ике һәм күпьеллык үләннәр, сирәгрәк ярымкуаклар ыругы. 100 дән артык төре билгеле, Евразиядә һәм Көньяк Африкада, беркадәр Төньяк Америкада таралганнар. ТРда 4 төре үсә. Кыргый А.б. (компас үлән) (L. serriola) һәм татар А.б. (L. tatarica) респ-каның барлык терр-ясендә, тозлак А.б. (L. saligna) һәм себер А.б. (L. sibirica) — Кама һәм Идел алды төбәкләрендә очрыйлар. Ташландык, чүпле урыннарда, су буйларында, басу, юл тирәләрендә үсәләр. 30–120 *см* озынлыктагы үләнчел үсемлекләр. Сабаклары туры, төкчәле. Яфраклары чиратлашкан, бөтен яки уемтыклы каурыйсыман — бүленмә, артка бөгелгән өлешле һәм сабакны уратып алган уксыман нигезле. Чәчәкләре тоныкс сары төстә, сирәк себеркәчтә урнашкан вак кәрзиннәргә җыелган. Җимеше — йөнтәс орлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре июль–октябрьдә өлгерә. Вегетатив юл б-н һәм орлыктан үрчиләр. Агулылар, үсемлекнең бөтен җирендә дә ак сөтчел сыекча бар. Халык медицинасында кыргый А.б. төнәтмәсе тынычландыру, эч йомшарту, бәвел кудыру чарасы буларак файдаланыла. Чүп үлән, терлек азыгы. Себер А.б. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**АГЫЙДЕ́Л** елгасы, Каманың сул кушылдыгы. Елга бассейнының төп өлеше Башкортстан Респ-касы терр-ясендә, тамагы Татарстан терр-ясендә. Озынлыгы 1420 *км* (ТРда 76 *км*), бассейнының мәйданы 142 мең *км*$^2$ (ТРда 2 мең *км*$^2$). Көньяк Уралдагы Ирәмәл тавыннан көнчыгыштарак агып чыга. Түбән Кама сусаклагычы төзелгәнче, А. Актаныш р-нының Дәрбиш посёлогы тирәсендә Камага койган. Өске агымында (Нөгеш елгасы тамагына кадәр) су агышы көчле һәм тиз, сай сулы урыннар күп. Татарстан чикләренә А. тигезлек җирләр өчен хас булган тын агымлы елга булып килеп керә. Иң зур кушылдыклары: уң яктан — Нөгеш, Сим, Уфа (Караидел), Бөре, Тере Танып; сул яктан — Ашказар, Өршәк, Дим, Кармасан, Чирмәсән, Базы, *Сөн*. Татарстан терр-ясендә, Түбән Кама сусаклагычы төзелгәнче, А. нең шактый киң тугае һәм аның күп санлы күлләре, 400–500 *м* киңлектәге бормаланып аккан су юлы булган. Хәзерге вакытта елганың түбән агымы су астында. ТРга якын гидрологик постлар: Андреевка авылы (Сөн елгасы тамагы тирәсендә, күзәтүләр 1881 елдан алып барыла, 1917–32 елларда күзәтелми) һәм Бөре шәһәре (1881 елдан). Камага койган урынында уртача ел-



Е.В.Адамюк.

лык су чыгымы 950 $м^3/с$. Су агымының еллык бүленеше түбәндәгечә (уртача еллык зурлыктан %):

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| гыйнв. | февр. | март | апр. | май | июнь |
| 3,0 | 2,4 | 2,4 | 17,6 | 35,3 | 10,1 |
| июль | авг. | сент. | окт. | нояб. | дек. |
| 6,5 | 4,9 | 4,6 | 5,4 | 4,4 | 3,4 |

Бик озакка сузылган язгы ташулар вакытында (уртача 75 көн, кайвакыт 100–110 көн) еллык агымның 60% ы (аерым елларда 75–77%) агып үтә. Ташу башлануның уртача вакыты 10 апрельдә, тәмамлануы 23 июньдә. Бу вакытта иң зур тәүлеклек су чыгымы 10–15 мең $м^3/с$ (максимум 19 мең $м^3/с$). Су биеклегенең уртача еллык тирбәнүләр амплитудасы 7,5–8,0 *м* (максимумы 9 *м* дан артык). Кышкы һәм җәйге челләдә су түбән, су чыгымы 250–500 $м^3/с$. Җәйге һәм көзге яңгыр ташулары язгы ташулар биеклегеннән кимрәк, бу фазада су чыгымы, гадәттә, 1000 $м^3/с$ тан артмый. Су өстенең боз б-н каплануы ноябрь уртасында башлана һәм апрель уртасына кадәр (уртача 170–175 көн) дәвам итә. Бозның иң зур калынлыгы (75–100 *см*) март азагында. Суның иң җылы вакыты (21–23 °С кадәр) июль аенда, шуннан соң темп-ра әкренләп түбәнәя һәм ноябрь башында 0 °С ка кадәр төшә.

Ел саен А. тамагына 3,5 млн. *т* йөзмә утырма агып килә. Ташу вакытында суның болганчыклыгы 900 *мг/л* га кадәр җитә, 8–9 ай дәвамында бу күрсәткеч 50 *мг/л* дан артмый. 1950 еллар уртасына кадәр эремә матдәләрнең уртача еллык күләме 7,5 млн. *т*, суның минеральләшүе 250 *мг/л* булса, 1990 елларда — 12 млн. *т* дан ким түгел һәм 400 *мг/л*. Эремә матдәләрнең күбесе — гидрокарбонат һәм сульфат ионнары. Суда сульфатларның югары концентрациясе А. бассейнының тигезлекле өлешендә киң урын алган нефть чыгару һәм сәнәгать пр-тиеләре пычратуы б-н бәйле.

А. елгасы тамагыннан Уфа шәһәренә кадәр (язын югарырак) суднолар йөри, ул Татарстан б-н Башкортстан арасындагы елга транспортында мөһим урын алып тора. Татарстан терр-ясендәге А. буйларында ком-гравий чыганаклары эшкәртелә.

*Әд.:* Ресурсы поверхностных вод СССР. Бассейн р. Камы. Л., 1971. Т. 2; Доманицкий А.П., Дубровина Р.С., Исаева А.И. Реки и озёра Советского Союза. Л., 1971; Малые реки волжского бассейна. М., 1998.

*В.И.Мозжерин.*

**АДА́В-ТОЛЫМБА́Й** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Карлы елгасы буенда. 2002 елда 892 кеше (татарлар — 82%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1655 тә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сиушево исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.-Т.да мәчет (1884 тән аның каршында мәктәп эшли) була. 20 йөз башында монда 2 мәчет, чиркәү эшли. 1920 гә кадәр авыл Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 276, 1859 да — 402, 1897 дә — 1022, 1913 тә — 1417, 1920 дә — 1456, 1926 да — 1235, 1938 дә — 1523, 1949 да — 1523, 1958 дә — 1517, 1970 тә — 1373, 1979 да — 1525, 1989 да — 931 кеше.

*Әд.:* Буа ягым — Тау ягым = Буинские просторы. К., 2000.

**АДА́Й** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 35 *км* көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычы астында калган зона чигендә. 2002 елда 307 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1747 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, мүк әзерләү һәм аны сату б-н шөгыльләнә. Мәчет А.да 18 йөз ахырларында барлыкка килә. 20 йөз башында ир һәм кыз балалар өчен 4 сыйныфлы 2 земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 918 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1747 дә — 35, 1795 тә — 106, 1859 да — 341, 1870 тә — 365, 1884 тә — 548, 1897 дә — 751, 1906 да — 910, 1913 тә — 931, 1920 дә — 985, 1926 да — 715, 1938 дә — 756, 1949 да — 629, 1958 дә — 607, 1970 тә — 693, 1979 да — 577, 1989 да — 380 кеше.

**АДА́Й** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2002 елда 497 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да мәчет, тегермән эшли. 1920 гә кадәр авыл Вятка губернасының Малмыж өязе Күкшел волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан яңадан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 914, 1884 тә — 1117, 1921 дә — 1528, 1924 тә — 1460, 1926 да — 1336, 1938 дә — 1011, 1949 да — 671, 1958 дә — 514, 1970 тә — 599, 1979 да — 540, 1989 да — 446 кеше.

**АДА́МОВ** Иосиф Романович (10.1.1826, Терек өлкәсе Кизләр ш. — ?), тел галиме, педагог. Казан ун-тын тәмамлый (1851). 1852–62 елларда Ставрополь губернасы гимназиясендә төрек теле укыта. Кумык һәм нугай телләре материалы нигезендә язылган «Төрки телнең кавказ диалекты этимологик очерклы» («Этимологический очерк кавказского диалекта тюркского языка», 1851; кулъязмасы Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсендә саклана) дигән хезмәтендә кумык һәм нугай җыр текстлары да китерелгән. «Төрек һәм татар телләре хрестоматиясе» («Хрестоматия турецкого и татарского языков», 1858), «Төрек теленең кавказ сөйләшләре грамматикасы» («Грамматика кавказских наречий турецкого языка», 1862) авторы.

*Әд.:* Радзиевская С.Б. Описание рукописей научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского: Лингвистика. К., 1958. Вып. 2.

**АДАМЮ́К** Валентий Емилианович (13.2.1877, Казан — 16.6.1950, шунда ук), офтальмолог, медицина д-ры (1907), проф. (1918), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). Е.В.Адамюкның улы һәм шәкерте. 1902 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1903 тән Казан мед. ин-тында, бер үк вакытта Казан ГИДУВында офтальмология каф. мөдире (1929–32). Хезмәтләре күзнең патологик анатомиясенә, мөгез тышчаны күчереп утыртуга, трахоманы дәвалауга багышланган.

Х е з м.: Местный амилоид соединительной оболочки глаза. Клиническое и экспериментальное исследование. К., 1907; Опыт применения в офтальмологии Атуберкулёзного артивируса синих палочек доктора медицины Б.Л.Мазура. [Б. м.], [Б. г.].

*Әд.:* Казанский ГИДУВ 1920–1990. К., 1990.

**АДАМЮ́К** Емилиан Валентиевич (11.6.1839, Гродно губ. Бельск ш. — 5.9.1906, Казан), офтальмолог, медицина д-ры (1867). Россия офтальмологиясен оештыручыларның берсе, Казан офтальмологлар фәнни мәктәбенә нигез салучы. 1863 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли. Мед. ф-тының күз клиникасын оештыручы һәм 1870–1902 дә күз авырулары каф. мөдире, проф. (1871). Аның шәкертләре: А.Т.Агабабов, В.В.Чирковский, К.Х.Орлов, В.Н.Иванов, И.И.Чистяков. Хезмәтләре күзнең эчке кан әйләнешенә һәм басымына, глаукома, трахомага карый; беренче булып күз пәрдәсенең тамырлы тышчасында кан йөреше бозылудан трахома барлыкка килүен дәлилли.

Х е з м.: Практическое руководство к изучению болезней глаза. К., 1881; Болезни светоощущающего аппарата глаза. К., 1897.

*Әд.:* Памяти Емилиана Валентиевича Адамюка, профессора офтальмологии в Казанском университете. К., 1906; Некролог // Вест. офтальмологии. 1906. Т. 23, № 5; Адамюк и его заслуги перед отечественной офтальмологией // Советская медицина. 1957. № 5; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**АДАПТА́ЦИЯ** (соңгы лат. adaptatio — җайлашу), организмның эволюция процессы ба-

рышында тупланган һәм әйләнә-тирә мохитнең конкрет шартларында яшәү мөмкинлеге бирә торган морфофизиологик, гадәти һ.б. үзенчәлекләр җыелмасы. Ш.у. организмнарның яшәү шартларына һәм аларның үзгәрүләренә карата индивидуаль җайлашу процессы да А. дип атала. Органик эволюциянең төп өч факторы — нәселдәнлек, үзгәрүчәнлек һәм табигый яисә ясалма сайланыш тәэсире нәтиҗәсе буларак, организм, популяция, төр һ.б. дәрәҗәләрдә гамәлгә ашырыла. А.нең нигезе булып күп санлы генетик үзгәрүләр — нәселдән нәселгә килгән, буыннарда ныгып барган мутацияләр тора. А. нииндидер төр организмнарның барлык яшәү циклы стадияләрендә дә чагыла, организмның сакланып калуын тәэмин итә, үрчем коэф. күтәрә, үлем коэф. түбәнәйтә. А. гомуми (зур тирәлек зоналарында яшәү шартларына җайлашу) һәм аерым очраклы А.гә (билгеле бер яшәү тәртибенә махсуслашу) бүленә. Татарстан терр-ясендә хайваннарның аерым очраклы А.сенә мисал итеп кыя кошларының (кәрләчләр, күк күгәрченнәр, чәүкәләр) һәм имезүчеләрнең (ярканатлар), кыр үрдәгенең, яшел гөберле баканың зур шәһәрләрдә, күл бакасының — эре сулыкларда һәм сусаклагычларда, кыр үрдәкләре, кашкалаклар, су тавыклары, чүрәкәй үрдәкләр, ондатра, ас, төлке, куяннарның Казан тирәсендәге сулы-сазлыклы урыннарда («Иске үзән», Камышлы утрау, Утраучыклар) яшәргә җайлашуын алырга була. Респ-када урманнар кимү сәбәпле, дала хайваннары төрләре яңа шартларда яшәргә җайлаша; ш.и. аксыл көзәннең, тычкансыманнар б-н тыклануы сәбәпле, теш төзелеше үзгәрә. А.не селекция нәтиҗәләрен фаразлау, үсемлекләрне һәм хайваннарны *акклиматизацияләү*, ш.и. үсемлек сортларын һәм терлек токымнарын районлаштыру, авыл һәм урман хуҗалыкларында үсемлекләрне биологик саклау чаралары куллану максатларыннан чыгып өйрәнәләр.

Физиологиядә һәм медицинада «А.» атамасы — нәрсәгәдер күнегү процессын (темп-ра, яктылык, психик, биеклек А.ләре), социологиядә шәхеснең яисә иҗтимагый төркемнең җәмгыяви тирәлек б-н үзара мөнәсәбәтен аңлата.

*Әд.:* Слоним А.Д. О физиологических механизмах природных адаптаций животных и человека. М.–Л., 1964; Шмальгаузен И.И. Проблемы дарвинизма. Л., 1969; Жученко А.А. Адаптивный потенциал культурных растений. Кишинёв, 1988; Зелёная книга Республики Татарстан. К., 1993. *С.И.Кадошников.*

**АДАПТИ́В АГРОЛАНДШАФТЛЫ́ ИГЕНЧЕЛЕ́К СИСТЕ́МАСЫ**, туфракны һ.б. табигать ресурсларын саклау һәм яхшырту, а.х. культураларының уңышын күтәрү максатында туфрак-климат шартларын һәм җирлекнең рельефын максималь исәпкә алып гамәлгә ашырыла торган агротехник, гидротехник, агроурман мелиорациясе һәм оештыру-хуҗалык эшләре системасы. Игенчелекнең мондый системасын проектлаштырганда аерымланган агроландшафтлар-субүләрләр арасындагы терр-яләр барлык елга һәм ярлар челтәрен, су җыелу мәйданнарын кертеп исәпкә алына.

А.а.и.с. туфракның юылуын һәм җил туздыруын, су агымын һәм явым-төшемнең файдасыз парга әйләнүен туктатуны, а.х. культураларының уңышын һәм туфракның уңдырышлылыгын күтәрүне тәэмин итәргә тиеш. Ә моңа исә шушы агроландшафтта сөрүлек җирләр, болын һәм урманнар арасында иң яхшы нисбәт урнаштыру юлы б-н ирешелә. Барлык начарланган (деградацияләнгән) җирләр тоташ яисә полосалап күпьеллык үләннәр чәчү өчен калдырыла. Туфрак эшкәртү, чәчү һ.б. эшләр рельефның яссылыгы (горизонтальләр) буйлап яисә сөзәклеккә аркылы үткәрелә. Көчле юылган сөзәклекләрдә вал, канау, траншея кебек гидротехник корылмалар кулланыла. Ерымнар тирәли составында куаклар булган урман полосалары утыртыла, полосалардан алда һәм алардан түбәнрәк, сөзәклекләр буйлап, суны тоткарлаучы траншеялар ясала; күпьеллык үләннәр чәчеп ныгытыла, су агызу юллары корыла, ерым төпләренә агачлар утыртыла. Су агышын, туфрак юылуны һәм дымның парга әйләнүен туктату өчен, кыр ышыклау яисә су әйләнешен көйләү полосалары утыртыла. Текә сөзәклекләргә һәм а.х. өчен яраксыз җирләргә тулысынча урман утыртыла. Туфракның уңдырышлылыгын һәм а.х. культураларының уңышын күтәрү алмаш һәм үлән чәчүле чәчү әйләнешләрен кертү, туфракны рациональ эшкәртү, минераль, органик, сидераль һәм бактериаль ашламалар куллану, ш.у. шушы төбәк өчен чыдам һәм югары уңыш сортларын сайлап алып игү хисабына гамәлгә ашырыла.

ТРда А.а.и.с. моделе Татарстан а.х. фәнни-җитештерү ин-тында «Земля» республика кадастр үзәге катнашында эшләнә һәм Биектау р-нының «Чулпан» коллектив пр-тиесендә, ш.у. Буа, Мөслим, Яңа Чишмә һәм Арча р-ннарының алты хуҗалыгында гамәлгә кертелә. А.х. җирләре югары дәрәҗәдә эрозиягә дучар ителгән (82%), ерымнар челтәре б-н капланган (бүлгәләнү коэф. 2,4) «Чулпан» хуҗалыгында 6 мең *га* мәйданда потенциаль продуктлылыгы югары булган, эрозиягә чыдам игенчелек системасы булдырыла. 1999 елда ТР МК карары б-н «Чулпан» коллектив пр-тиесенә Дәүләт туфрак тыюлыгы статусы бирелә. Ерымнар челтәре киң таралган һәм дулкынсыман рельефлы а.х. җирләре күп булган (35–40% терр-я) ТР халык хуҗалыгы өчен А.а.и.с.ның әһәмияте зур.

*Әд.:* Зиганшин А.А., Аглуллин Р.А. Севообороты Татарии. К., 1973; Шакиров Ф.Х. Восстановление уравновешенности ландшафтных процессов агролесомелиоративными средствами // Тр. 10 междунар. конгресса почвоведов. М., 1974. Т. 2; Пухачёв А.П., Бухараева Л.Г. Почвам — надёжную защиту. К., 1984; Жученко А.А. Стратегия адаптивной интенсификации сельского хозяйства. Пущино, 1994.

*А.А.Җиһаншин, А.П.Пухачёв.*


Биектау р-ны «Чулпан» күмәк пр-тиесе. Агроландшафтлы игенчелек элементлары.

**АДА́ШЕВ** Алексей Фёдорович (? – 1561, Ливония, Юрьев ш.), дәүләт эшлеклесе, хәрби җитәкче, окольничий (1550). Кострома дворяннары нәселеннән. 1540 еллар ахырыннан Рус дәүләтенең Көнчыгыш сәясәтен билгеләүче, 1550 еллар уртасыннан дипломатик эшләргә җитәкчелек итә. Илчелек приказы башлыгы. 1540–50 елларда дәүләттә реформа үткәрүчеләрнең берсе. Иван IV кә йогынтысы зур була; соңрак «Избранная Рада» дип аталачак хөкүмәтнең фактик җитәкчесе. Рус дәүләтенең көнчыгыш тарафка «киңәю» сәясәтен яклаучылардан. 1545–52 елларда Казан ханлыгына оештырылган яуларны дипломатик һәм сәяси яктан әзерләүгә җитәкчелек итә. Шаһгали хан һәм чуаш, мари аксөякләре б-н сөйләшүләр алып бара. 1552 дә Казанга яу б-н баруда катнаша, шәһәр диварын шартлату эшләренә җитәкчелек итә, соңгы һөҗүмне оештыручылар сафында була. Казан ханлыгы яулангганнан соң, җирле идарә структурасын билгеләүдә, *Казан сарай идарәханәсен* оештыруда зур роль уйный. Патшалыкның «Вазифалар китабы» («Разрядная книга»), «Патша шәҗәрәсе» («Государев родословец») һәм рәсми «Патшалык башы елъязмасы» («Летописец начала царства») төзүгә һәм редакцияләүгә җитәкчелек итә. 1558–83 еллардагы Ливон сугышына дипломатик әзерлек эшләрен дьяк И.М.Висковатый б-н бергә башкара. Польша б-н Швеция дә сугышка катнашкач, яуны туктату тәкъдимен кертә, шул сәбәпле Иван IV б-н үзара мөнәсәбәтләре бозыла: 1560 та җаваплы эшләрдән читләштерелә, Зур полкның воеводасы итеп билгеләнә (сөргенгә җибәрелә), соңрак кулга алына; озакламый вафат була.

*Әд.:* Зимин А.А. Реформы Ивана IV. М., 1964; Шмидт С.О. Правительственная деятельность А.Ф.Адашева // Уч. зап. Моск. ун-та. 1994. Вып. 167.

*Е.В.Липаков.*

**АДӘ́М** (борынгы яһүд. — кеше), күп кенә халыкларның изге китапларында һәм мифологиясендә — беренче кеше, кешелекнең нәсел атасы. Коръәндә бәян ителгәнчә, Аллаһ А.не туфрактан һәм «җан өрелгән» балчыктан үзенең Җирдәге «урынбасары» (хәлифәсе) сыйфатында, барлык фәрештәләрдән өстен итеп яралта һәм аларга А.гә буйсынырга боера. Фәрештәләрнең берсе *Иблис* А.гә буйсынудан баш тарта һәм күктән җиргә төшерелә. Аллаһка үч итеп, Иблис Адәм б-н беренче хатын-кыз заты *Хәваны* җәннәттәге тыел-

ган җимеш б-н сыйлап, гөнаһ кылдырта. А. б-н Хәва, бу эшләре өчен җәннәттән сөреләп, бер-берсеннән аерым рәвештә җиргә төшереләләр. Риваятьләрдә бәян ителгәнчә, алар Мәккә янындагы Гарәфә тавында табышалар, Аллаһ ихтыяры б-н шунда А. *Кәгъбә* төзи. Аллаһның ярлыкавына ирешә һәм беренче пәйгамбәр була. Мөселман дини әдәбиятында А. — кешенең илаһи асылы гәүдәләнеше.

**АДВЕНТИ́ЗМ** (лат. adventus — килү, пәйда булу), протестантизмга караган конфессия. Аңа 1840 елларда АКШта рухани У.Миллер тарафыннан нигез салына. А. 1863 елда дини тәгълиматны системага салган, аны рәсми рәвештә гамәлгә керткән Элен Уайт җитәкчелегендә оешып җитә. Әлеге конфессия тарафдарлары җанның үлемсезлеген, Тәмуг һәм Җәннәт идеясен инкарь итәләр, христиан дине могҗизаларыннан чукындыруны һәм евхаристияне, ягъни гыйбадәт кылучыларга тәкъдим ителгән икмәк б-н шәрабта Гайсә пәйгамбәр «тәне һәм каны» гәүдәләнүен генә таныйлар. Протестантлыкның башка төрләреннән А. Гайсәнең икенче тапкыр кайтуы даими көтелә дигән караш б-н аерыла.

Үз доктринасында А. дөньякүләм дини тәгълимат булуы б-н берләттән, бер үзәк тирәсенә тупланган дөньякүләм чиркәү буларак карала, һәр община шушы үзәк чиркәүгә буйсынырга тиеш дип санала. Бу бердәм структурага кергән А. вәкилләре «җиденче көн адвентистлары» (ҖКА) дип атала. ҖКА тәгълиматының мөһим үзенчәлеге — шимбә көнен хөрмәт итү. Яһүдиләр кебек үк, А. тарафдарларына шимбә көннәрендә эшләү, ризык әзерләү гөнаһ санала. ҖКА тәгълиматында Э.Уайт тарафыннан игълан ителгән «Санитария реформасы» — режим б-н яшәү һәм туклануны, физик күнегүләр б-н шөгыльләнүне таләп иткән, алкоголь, наркотиклар, кәеф күтәргеч эчемлекләр һәм препаратлар куллануны, тәмәке тартуны тыйган нормалар мөһим урын алып тора. ҖКАдан тыш, төп оешмадан төрле вакытта аерылып чыккан аз санлы адвентист-реформаторлар оешмалары бар. Россиядә алар киң таралмаган.

Россиягә А. 1880 елларда үтеп керә. Бу тәгълиматны беренчеләрдән булып немецлар, ш.и. Идел буе немецлары кабул итә. Россиядә беренче адвентистлар җәмгыяте 1890 да Ставрополь (1964 тән Тольятти ш.) шәһәрендә (Самара губернасы) барлыкка килә. 1905 кә кадәр, башка көнбатыш дини агымнары кебек үк, А. да тыелган була.

1905 тән соң Казан губернасында адвентистлар Казан халкы һәм Мамадыш, Тәтеш өязләре крәстияннәре арасында күренә башлый, әмма җәмгыятьләре 1920 елларда гына оеша (Казан). Татарстандагы җәмгыятьләре Көнбатыш Россия А. чиркәве советына (үзәге Тула өлкәсе Заокский посёлогында) һәм Бөтендөнья советына (АКШ, Вашингтон) буйсына. Армия хезмәтеннән баш тарткан, ш.у. шимбә көннәрендә эшкә чыкмаган һәм дәресләргә йөрмәгән өчен А. тарафдарлары СССРда башка конфессия вәкилләренә караганда ныграк эзәрлекләнә. 1930–70 елларда СССРдагы, ш.и. Татарстандагы адвентистларның барлык оешмалары яшерен рәвештә эшли. 1945 тә төзелгән ҖКА советы 1960 елда тыела. А. җәмгыятьләре фәкать 1975 тә СССР дәүләте Хельсинки киңәшмәсенең Йомгаклау актына кул куйганнан соң гына теркәлә башлый. А. хәрәкәте яңадан 1978 дә Казанда, 1981 дә Бөгелмәдә теркәлә.


**АДВОКАТУ́РА**, адвокатлар оешмасы. Россиядә 1864 елгы Мәхкәмә реформасы үткәрү нәтиҗәсендә оеша. Казан мәхкәмә палатасы һәм Казан округы мәхкәмәсе каршында антлы дәгъва вәкилләре (дәүләт хезмәтендәге адвокатлар) ин-ты 1870 елда гамәлгә кертелә. Бер үк вакытта 1874 тә хосусый дәгъва вәкилләре ин-ты булдырыла (Округ мәхкәмәсе һәм Мировой съезд каршында). Һәр адвокат мөрәҗәгать итүчене аерым кабул иткән һәм үзара килешеп алып барылган эш өчен гонорар күләмен билгеләгән. 1915 тә Казан губернасында 52 антлы дәгъва вәкиле, 55 антлы дәгъва вәкиле ярдәмчесе, 13 хосусый антлы дәгъвачы була. ХКСның 1917 ел 22 ноябрендәге «Мәхкәмә турында»гы декреты б-н рев-циягә кадәрге барлык мәхкәмә органнары, ш.и. А. да таркатыла. Җинаять һәм гражданнар эшләре каралганда яклау һәм ышаныч белдерү хокукы барлык гражданнарга бирелә. 1918 дән Казан губернасында губерна һәм өяз эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлар советларының башкарма ком-тлары, революцион трибуналлар каршында адвокатлар — хокук яклаучылар коллегиясе оештырыла. РСФСРның 1920 ел 21 октябрендәге Халык мәхкәмәсе турындагы положениесе нигезендә мәхкәмәдә яклаучы булу хокукы гражданнарның, үти алган очракта, җәмгатьчелек бурычы итеп карала. Татарстанда А. БҮБКның 1922 ел 26 май декреты нигезендә оештырыла һәм 1922 нең 9 августыннан Татарстан халык судьялары советы, 1923 тән ТАССРның Баш мәхкәмәсе, 1937 дән ТАССРның Югары мәхкәмәсе каршындагы яклаучылар коллегиясе буларак эшли. 1922–30 да А.ның төп эшләү формасы — индивидуаль практика, 1930 дан яклаучылар коллективында эш алып бару була. СССР ХКСның 1939 ел 16 август карары б-н ТАССР Адвокатлар коллегиясе оештырыла, ул ТАССР Юстиция халык комис-тына буйсына, 1946–74 тә (бүленеп) ТАССР Юстиция министрлыгы (1963–71 дә ТАССР МСның Юридик комиссиясе) карамагында, 1974 тән ТАССР адвокатлар коллегиясе (1992 дән ТР) бәйсез, үзидарәле оешма. А.ның төп функциясе халыкка, пр-тие, оешма һәм учреждениеләргә телдән һәм язма рәвештә барлык хокук мәсьәләләре буенча хокукый киңәшләр б-н ярдәм итү; хокукый документлар төзү, гражданлык эшләре һәм хакимият органнарында хокук бозу эшләре буенча мәхкәмәдә, арбитраж мәхкәмәсендә һ.б. дәүләт органнарында вәкаләтлек итү; җинаять эшләре буенча яклаучы буларак, беренчел тикшерү эшендә һәм мәхкәмәдә катнашу. Республика адвокатлар коллегиясенең югары органы булып әгъзаларның гомуми җыелышы (конференциясе), башкарма органы — президиум, контроль-ревизия органы — ревизия комиссиясе санала. Коллегия районнарда, шәһәрләрдә, эшчеләр посёлокларында, шәһәрләрнең аерым микрорайоннарында хокукый киңәш бирү (консультация) пунктлары (барлыгы 75, ш.и. Казанда — 26, Чаллыда — 4, Түбән Камада — 2) һәм адвокат бюролары (барлыгы 18, ш.и. Казанда — 12, Чаллыда — 4, Әлмәттә — 2) оештыра, анда 640 тан артык (2000) адвокат эшли.

ТАССР, ТР яклаучылар коллегиясе һәм адвокатлар коллегиясе президиумы рәисләре: М.И.Бабаджан (1922–23), Н.Н.Андреев (1927–30), Н.М.Рахманкулов (1930–31), С.Т.Тәхәветдинов (1931–33), М.В.Чернышёв (1933–34), Н.П.Газизов (1934–35), Г.Х.Әхмәдуллин (1935–37), С.И.Гыйльметдинов (1937–39), Д.С.Овчинин (1939–40), А.М.Шмаков (1940–41), К.Ф.Цивильский (1941–51), Р.С.Кәбирова (1951–53), М.В.Агафонов (1953–67), Г.А.Әһлиуллин (1967–84), Л.М.Дмитриевская (1984 тән). 1923–27 дә сайланылмый.

*Әд.:* Долгов Е.Б. У истоков татарстанской адвокатуры: Страницы истории // Правосудие в Татарстане. 2000. № 4.

**А́ДЛЕР** Бруно (Бруно Вильгельм Карл Адольф) Фридрихович (26.10.1874, Воронеж ш. — 1942, Омск ш.), этнограф, географ, археолог, музей белгече, фәлсәфә д-ры (1900), география магистры (1911). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1899). Россия геогр. мәктәбен оештыручы акад. Д.Н.Анучин укучысы. 1900–02 елларда Лейпциг ун-тында антропогеография фәненә нигез салучы Ф.Ратцель җитәкчелегендә стажировка үтә һәм Гросның этнография музеенда ассистент булып эшли. 1902 дән С.-Петербургта: антропология һәм этнография музеенда Кытай һәм Япония бүлеге мөдире, 1910 нан Рус музееның этнография бүлегендә җаваплы хезмәткәр. 1911 дән Казан ун-ты профессоры, 1923 кә кадәр география, этнография һәм антропология каф. мөдире. А. тәкъдиме б-н Казан ун-тында Археология һәм этнография музее оештырыла (1914), А. аның беренче директоры була. 1918 дән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте рәисе. Казанда Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография ин-тын ачуда катнаша (1917), этнография ф-тында декан (1917–20). Танылган укучылары — А.А.Половинкин, С.Н.Лаптев, И.А.Лопатин, С.А.Теплоухов, Н.И.Воробьёв. А. музей эшен оештыруга зур өлеш кертә. 1919 дан Казан губернасы музее директоры. РСФСР Мәгариф халык комис-тының музей эшләре, сәнгать һәм борынгы ядкәрләрне саклау буенча Казан губернасы бүлеге рәисе. А. җитәкчелегендә Казан губернасы музее фәнни яктан үзгәртелә, фондлары күпкә баетыла. 1920 дә Шәрекъ халыклары музее ачыла һәм илдә музейларга багышланган 1 нче журнал «*Казанский музейный вестник*» чыга башлый. РСФСР Мәгариф халык комис-тының музей эшләре буенча Бөтенроссия коллегиясе советы әгъзасы, Мәскәүдә Бөтенроссия этнография музеен оештыру комиссиясе рәисе. 1920 еллар уртасыннан Мәскәүдә яши: Мәскәү ун-ты, ун-т каршындагы Антропология ин-ты профессоры. Урал, Себер һәм Ерак Көнчыгышны өйрәнү җәмгыятенең этнография бү-

леге җитәкчесе, «Северная Азия» ж-лы редколлегиясе әгъзасы. 1922 дә музейлар эшчәнлеген өйрәнү өчен Германиядә командировкада була. Хезмәтләре география, этнография, музейны өйрәнүгә багышлана. Беренче Бөтенроссия музей хезмәткәрләре съездында (1930) Германиядә совет этнографиясенә багышлап басылган мәкаләләре кискен тәнкыйтьләнә. 1933 тә кулга алына, 1934 тә төньякка сөргенгә озатыла. 1936 да яңадан хөкем ителә. 1942 дә атып үтерелә. Үзгәртеп кору чорында аклана (1990).



Б.Ф. Адлер.

Х е з м.: Происхождение и переселение народов с географической точки зрения // Русский антропологический журн. 1901. Кн. 5; География в Казанском университете. К., 1914; Областные и местные музеи // Казан. музейный вестн. 1920. № 1/2; Коллекция Сиклера // Казанский музейный вестн. 1922. № 2; От наготы до обильных одежд. Берлин, 1923; Этнографический музей в столице Советского Союза. Берлин, 1925.

*Әд.:* К р о т о в П.И. Б.Ф.Адлер и его учёные труды по географии и этнографии.К., 1911; З о р и н Н.В. Забытое имя // Татарстан. 1993. № 4; ш у л у к. Профессор Бруно Фридрихович Адлер как музеевед // История вузовских музеев страны. Музей и личность. Сыктывкар, 1994; Р е ш е т о в А.М. Репрессированная этнография // Кунсткамера: Этнографические тетради. СПб., 1994. Вып. 4; Б у с ы г и н Е.П., З о р и н Н.В. Этнография в Казанском университете. К., 2002; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 1.

*Н.В.Зорин.*

**АДМИНИСТРАТИ́В-ТЕРРИТОРИА́ЛЬ БҮЛЕНЕ́Ш**, дәүләтнең территориаль оешу системасы; шуның нигезендә дәүләт хакимияте органнары оештырыла һәм эшли. Дәүләт терр-ясе өлкә, провинция, губерна, округ, штат, департаментларга һ.б. бүленә. Идел буе Болгар дәүләтендә 10–13 йөзләрдә А.-т.б.нең төп берәмлеге буларак феодаль биләмә — билек, бәклек, Алтын Урдада (13–15 йөзләр) — *олыс*, Казан ханлыгында (15–16 йөз уртасы) *даруга* тора. Казан ханлыгы Рус дәүләтенә буйсындырылгач, аның терр-ясе Казан, Арча, Тау һәм Болын якларына бүленә. 16 йөзнең 60–70 нче елларында *өязләр* булдырыла, ш.у. даругалар сакланып кала. 1708 елда Казан губернасы барлыкка килгәч, даругалар бетерелә һәм терр-я воеводстволарга, *провинцияләргә* (1719 дан), өязләргә (1775 тән) бүленә. 1920 дә ТАССР оештырылгач, аның терр-ясе 10 кантонга һәм алар карамагындагы 125 өязгә бүленә. СССРда адм.-терр. реформа барышында (1923–29) ТАССРда кантоннар һәм өязләр бетерелә һәм *районнар* оештырыла. 1930 да 45 район һәм алар карамагында 2133 авыл советы исәпләнә. Аларның саны үзгәреп тора: 1934 тә — 43 район һәм 2074 авыл советы, 1935 тә — 60 һәм 1695, 1938 дә — 63 һәм 1663, 1944 тә — 70 һәм 1681. 1952 нең маенда ТАССР Казан һәм Чистай өлкәләренә, 1953 нең февралендә ш.у. Бөгелмә өлкәсенә (Чистай өлкәсеннән аерылып чыга) бүленә, ә 1953 нең апрелендә өлкәләр бетерелә. Район һәм авыл советларының иң аз вакыты 1963 елга туры килә: 17 һәм 766. Соңрак аларның саны арта бара. 2007 ел башына ТРда 57 адм.-терр. берәмлек, ш.и. 43 район һәм республика карамагындагы 14 шәһәр, районнар карамагындагы 7 шәһәр, шәһәр тибындагы 19 посёлок, 916 авыл җирлеге исәпләнә. Ш.у. к. *Муниципаль берәмлекләр.*

*М.Р.Мостафин.*

**АДМИРА́Л** (Vanessa atalanta L.), нимфалидлар семьялыгыннан көндезге күбәләк. Алгы канатларының өске ягындагы, арткы канатларының тышкы каймасындагы аркылы кызыл сызымы б-н аерыла; канат җәеме 6 *см* га кадәр. Татарстанның барлык терр-ясендә очрый. Һәрвакыт күчеп йөри. Язын Урта диңгез буеннан очып кайта, җәй дәвамында көз көне көньякка очып китүче бер буын үстерә. Кайвакыт кышлый. Якты урыннарда: урман аланнарында, болыннарда, басуларда, еш кына шәһәр зонасында чәчәк клумбаларында һәм паркларда очрый. Күбәләк корты кычытканда һәм шайтан таягында үсә. А. саны шактый күп, ләкин гел күчеп йөрүе сәбәпле аны очратуы кыен. ТРның Кызыл китабына кертелгән. К. илл. һәм библ. *Күбәләкләр.*

**АДМИРАЛТЕ́ЙСТВО**, к. *Казан адмиралтействосы.*

**АДМИРАЛТЕ́ЙСТВО БИСТӘСЕ́**, к. *Бишбалта бистәсе.*

**АДМИРАЛТЕ́ЙСТВО КОНТО́РАСЫ КО́МПЛЕКСЫ**, Казанда архит-ра истәлеге, соңгы барокко стилендә, 18 йөзнең 2 нче яртысыннан бик аз сакланып калган гражданлык архит-расы үрнәкләренең берсе. 1774 елда арх. В.И.Кафтырев проекты б-н төзелә. Башта ул беренче катында гөмбәз түшәмле бүлмәләр урнашкан зур булмаган ике катлы кирпеч корылма итеп салына. Төп фасадында дүрт пилястралы ионик портигы һәм барокко стилендәге фронтоны булган ризалит чыгып тора. Адмиралтейство идарәсе Әстерхан шәһәренә күчерелгәннән соң (1826), биредә хастаханә урнаштырыла. 1830 еллар ахыры — 40 еллар башында бина ике яклап киңәйтелә (арх. билгесез) һәм төп фасад б-н бер үк стильдә бизәлә. Буйга сузылган ике катлы бинаның бүлмәләре озын коридорның як-ягына яисә бер генә ягына урнашкан. Төп фасадның композициясе тигез дивар һәм ризалитларның үзара чиратлашуы ритмына нигезләнгән. Дүрт пилястралы, ионик портиклы, барокко стилендәге фронтонлы ризалит урнашкан үзәк өлешкә таба якынайган саен, бизәкләр зурая һәм тыгызлана бара. Үзәк ризалитның 1 нче каттагы тәрәзәләре барокко стилендәге купшы йөзлекләр б-н кысаланган, ә икенче каттагы тәрәзәләр классицизм архит-расына хас җәясыман сандриклар һәм архивольтлар б-н бизәлгән. 1 нче кат бүлмәләренең бер өлеше гөмбәз түшәмле. Үзәк баскычның чуеннан коелган култыксалары башларын түбән игән еланнар рәвешендә эшләнгән.

*Әд.:* О с т р о у м о в В.П. Казань. К., 1978; Ф е х н е р М. Великие Булгары. Казань. Свияжск., М., 1978; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Т.Пашагина.*

**АДНА́Ш** Хафиз бине Мөхәммәдхафиз (16 йөз уртасы), Казан ханлыгының дәүләт эшлеклесе, Казан яуланыр алдыннан Мәскәү дәүләте вәкилләре б-н дипломатик сөйләшүләрдә катнаша. Казан өчен сугышлар барган вакытта илчелек тоткын ителә, А. шул тоткынлыкта чагында (1553) гарәп теленнән төрки телгә күчерелгән кыйссаларны үз эченә алган «Сираҗ әл-колүб» («Күңелләр нуры») исемле җыентык төзи. Сорау һәм җавап рәвешендә төзелеп, дөньяның яратылышы, ахыры, җәннәт, тәмуг, пәйгамбәрләр һәм күренекле тарихи шәхесләр, мөселман изгеләре турында язылган бу җыентыкның 16 йөзгә караган бер кулъязма нөсхәсе Лондонның Британия музеенда саклана. Җыентыкның кулъязма нөсхәләре Казан, С.-Петербург, Мәскәү фәнни китапханәләре фондларында да бар. Беренче тапкыр 1863 елда Казанда нәшер ителә. Дини эчтәлектәге «Шәраигъ әл-әхкям» («Шәригать хөкемнәре») җыентыгының да төзүчесе А. дип уйланыла. А.ның Мәскәү тоткынлыгындагы соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Н а д ж и п Э.Н. Историко-сравнительный словарь тюркских языков на материале «Хосров и Ширин» Кутба. XIV в., М., 1979. Кн. 1; Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). К., 1999.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**АДО́** Андрей Дмитриевич (12.1.1909, Казан — 29.10.1997, Мәскәү), аллерголог, патофизиолог, мед. фән. д-ры (1938), СССР МФА академигы (1965), ТАССР һәм РСФСРның





Адмиралтейство конторасы. 1. 1890 елгы фото; 2. Төп фасадның ионик портигы. Хәзерге күренеш.



А.Д. Адо.



В.В. Адоратский.

атказ. фән эшлеклесе (1945, 1964). Н.Н.Сиротинин шәкерте. Россия аллергологлар фәнни мәктәбенә нигез салучы. Биол. укытучысы Д.И.Адоның улы, Н.И.Миславский оныгы. 1931 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, проф. (1939), 1931 дән патофизиология каф. мөдире, 1941–42 дә педиатрия ф-ты деканы, 1952–86 да Н.И.Пирогов исем. 2 нче Мәскәү мед. ин-тының шул ук исем. каф. мөдире. СССРда беренче булып СССР МФАнең Аллергология фәнни-тикшеренү лабораториясен (НИАЛ) оештыручы һәм җитәкчесе. Тикшеренүләренең төп юнәлешләре: йогышлы авырулар патогенезы, ялкынсыну, аллергия, аллергик авыруларга диагноз кую һәм дәвалау. Казан чоры хезмәтләре эритроцитларның аллергик альтерациясе үрнәгендә күзәнәк мембраналары функциясен, аллергия механизмнарын (ацетилхолинэстераз системасын) өйрәнүгә карый. Казанда А. тарафыннан аутоаллергия өлкәсендә беренче нәтиҗәләр алына һәм иммунитет проблемаларына кагылышлы тикшеренүләр башлап җибәрелә. Шәкертләре арасында: М.А.Ерзин, А.И.Малкин, Л.М.Ишимова, И.М.Рәхмәтуллин, Д.М.Зөбәеров. А. һәм СССР МФА НИАЛ хезмәткәрләре тырышлыгы б-н аллергеннарның күп кенә мөһим төркемнәренең (тузанлы, серкәле, ашамлык төрләренә бәйле, бактериаль һ.б.) нормативлары эшләнә һәм илебездәге специальләшкән аллергология хезмәтендә аллергик авыруларга диагноз кую һәм дәвалау өчен гамәлгә кертелә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Казан мед. ун-ты бинасы (Толстой ур., 6/30) диварына мемориаль такта куела (1999).

Х е з м.: К механизму аллергических реакций каротоидного синуса собаки // Материалы к патологической физиологии аллергических реакций: Сб. работ кафедры патологич. физиологии КГМИ. К., 1947 (автордаш); Антигены как чрезвычайные раздражители нервной системы. К., 1952; Общая аллергология. М., 1977; Частная аллергология. М., 1978.

*Әд.:* Казанский медицинский институт, 1814–1989. К., 1989; Деканы Казанского медицинского университета. К., 1997; Академик АМН СССР А.Д.Адо // Казан. мед. журн. 1999. № 1.

**АДО́** Игорь Дмитриевич (17.1.1910, Казан — 30.6.1983, шунда ук), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1935), проф. (1939), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1956). Н.Г.Чеботарёв шәкерте. 1931 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм 1941 гә кадәр шунда ук эшли. Бер үк вакытта 1935 тән Казан хим.-технол. ин-тында, 1958–70 тә матем. каф. мөдире. 1935 тә кандидатлык диссертациясен яклауга тәкъдим итә, анда ул сыйфат саны нуль булган һәрбер чикле үлчәмле Ли алгебрасының сызыкча рәвешкә чикле үлчәмдә төгәл китерелүен исбатлый. Адо теоремасы буларак мәгълүм булган бу нәтиҗә өзлексез төркемнәр теориясе һәм аның кушымталары өчен фундаменталь әһәмияткә ия һәм төрүче универсаль алгебралар теориясенең башлангычы булып тора. Әлеге хезмәт өчен А.га физ.-матем. фән. д-ры дигән гыйльми дәрәҗә бирелә. Хезмәтләре абстракт төркемнәргә һәм аларның кушымталарына да багышланган. Аның тарафыннан минимальлек шарты үтәлгән нормаль астөркемнәрдәге җирле-чикле р-төркемнәрнең санаулы булуы исбатлана, чикле төркемнәрнең сыйфат теориясе төзелә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О структуре конечных непрерывных групп // Изв. Казан. физ.-мат. об-ва. 1934. Т. 1; К теории характеров конечных групп // Докл. АН СССР. 1945. Т. 50; Представление алгебр Ли матрицами. // Успехи мат. наук. 1947. Т. 2, вып. 1 (17)-6(22).

**АДО́НИС** (Adonis), казаякчалар семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 дән артык төре билгеле. Евразиянең урта поясында һәм Төньяк Африкада үсә. ТРда күбрәк көньяк-көнчыгыш, ара-тирә төньяк р-ннарда язгы А. яки язгы утчәчәк (A. vernalis) очрый. Күбесенчә көньякка караган дала тау битләрендә, башлыча, Кама аръягы төбәкләрендә (к. *Адонис урманы*, *Владимировка сөзәклеге*, *Казанка ботаника тыюлыгы*, *Үргәнеч ботаника тыюлыгы*), сирәгрәк Кама алды төбәкләрендә (*Яңасала сөзәклеге*) үсә. Кара туфракта һәм карасу-соры урман туфрагында яхшырак үрчи. 15–60 *см* озынлыктагы күпьеллык үсемлек. Тамырчасы вертикаль, кыска. Җиргә якын аскы ботакларыннан берничә туры сабак чыгара. Яфраклары утырма, бармаксыман, вак өлешләргә бүленгән. Чәчәкләре алтынсу-сары, эре, ялгыз. Җимеше — күпчикләвек. Яфрак чыгару б-н бер үк вакытта апрель-май айларында чәчәк ата. Җимеше июнь-июль айларында өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юсыл б-н үрчи. Декоратив, агулы, баллы; кыйммәтле дару үләне. Җир өстендәге өлешләрендә гликозидлар, сапониннар, дуплау матдәләре, эфир мае бар. Үлән һәм чәчәкләренең төнәтмәсе медицинада йөрәк-кан тамырлары авыруларын дәвалау өчен кулланыла.



Язгы адонис.

**АДО́НИС УРМАНЫ́**, ботаника тыюлыгы. Бөгелмә р-нының Яңа Александровка авылыннан төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 1991 елда язгы адонисның зур популяцияләрен саклау максатында оештырыла. Мәйданы 61 *га*. Сирәкләнгән нарат урманында югары төзелешле үсемлекләрнең 50 ләп төре, ш.и. сирәк һәм бетеп баручы төрләре — Трансильвания ярмабашы, туры чалгычут, чөйсымын испәрәк очрый. Язгы адонисның куелыгы 1 $м^2$ га 5 үсемлеккә кадәр.

**АДОРА́ТСКИЙ** Владимир Викторович (7.8.1878, Казан — 5.6.1945, Мәскәү), тарихчы, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1932). Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1903). 1890 елларда Казандагы революцион түгәрәкләрдә эшчәнлек алып бара. 1904 елдан РСДРП әгъзасы һәм Казан ком-ты секретаре, Казанда 1905–07 еллардагы рев-ция вакыйгаларында катнаша. 1905 нең декабрендә кулга алына, Әстерхан губернасында сөргендә була, Швейцариягә китәргә рөхсәт ала. 1908–10 да Казанда, 1911–18 дә эмиграциядә яши. 1 нче Бөтендөнья сугышы вакытында Германиядә гражданлык тоткынлыгында була. 1918 нең августында Россиягә кайта, РСФСР Мәгариф халык комис-тында эшли. БҮБКның Социалистик (соңрак Коммунистик) академиясен оештыручыларның берсе. 1919 да Казан ун-тында укыта, рев-ция хәрәкәте һәм гражданнар сугышы турында мәгълүматлар җыя. 1920 дән Мәскәүдә: Октябрь рев-циясе һәм РКП(б) тарихы комиссиясе — *Истпарт* җитәкчеләреннән берсе, РСФСР дәүләт архивы мөдире, Үзәк архив идарәсе мөдире урынбасары. 1920 елларда Я.М.Свердлов исем. Коммунистик ун-тта, Кызыл профессура ин-тында укыта. 1928 дән В.И.Ленин исем. ин-т дирекциясе әгъзасы, 1931–39 да Маркс-Энгельс-Ленин һәм СССР ФАнең философия ин-тлары директоры. 1938–45 тә К.Маркс, Ф.Энгельс һәм В.И.Ленин хезмәтләрен бастыруда катнаша. Хезмәтләре марксизм-ленинизм мәсьәләләренә, Октябрь рев-циясе тарихына карый.

Х е з м.: О государстве // К вопросу о методе исследования. М., 1923; К вопросу о научной биографии В.И.Ленина. М., 1933; К.Маркс — основоположник научного коммунизма. М., 1933; Избранные произведения. М., 1961.

*Әд.:* К о н ю ш а я Р.П. В.В.Адоратский. Биогр. очерк // Адоратский В.В. Избранные произведения. М., 1961; Л и т в и н А., М у л л и н а Л. Адоратский В.В. // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**А́ДРЕС-КАЛЕНДА́РЬ**, рәсми белешмәлек басмасы. Губерна, андагы оешмалар, халыкның шөгыле, билгеле бер елга аларның адреслары, ш.у. транспорт хәрәкәте расписаниесе, тарихи һ.б. мәгълүматлар белешмәлеге. Моңа охшаш беренче басма «Сарай календаре» («Придворный календарь», 1733–1917, 1800 елдан тыш) чыга, анда сарай әһелләре штаты һәм сарайда үтә торган тантаналар тәртибе турында мәгълүматлар бирелә. 1840–41 еллар өчен чыгарылган «Казан шәһәре күрсәткече яки Казан губернасында яшәүчеләр өчен хәтер кенәгәсе» («Указатель города Казани или Памятная книжка для жителей Казанской губернии») Казанда басылган беренче А.-к. Ул биналар биләү һәм эшче көчләр б-н килешү төзү эшләрен башкаручы «Белешмәлекләр урыны...» («Справочное место...») дигән оешма төзегән стат. мәгълүматлар нигезендә И.С.Чернов тарафыннан нәшер ителә. Ул оешманы И.С.Чернов үзенең туганы б-н берлектә ача, ләкин 1842 елгы янгыннан соң

«Күрсәткеч» башка басылмый. 1855 тән губерна стат. ком-тлары башта Воронежда, аннан соң башка шәһәрләрдә хәтер кенәгәләре нәшер итә башлыйлар; 1865 тән бу хокук аерым шәхесләргә дә бирелә. 1861 дән алар Казанда адрес-календарь, адрес-календарь һәм хәтер кенәгәсе, адрес-календарь һәм белешмәләр кенәгәсе, адреслар кенәгәсе, календарь, хәтер китабы, хәтер кенәгәсе, белешмәләр кенәгәсе исемендә нәшер ителә; кайвакытта аларның исеме «Казан...» сүзеннән яисә наширнең фамилиясеннән башлана. 19 йөзнең соңгы чирегеннән «Мәскәү» («Вся Москва», 1875–1917), «Петербург» («Весь Петербург», 1894–1914), «Казан. Адреслар һәм белешмәләр китабы» («Вся Казань. Адресная и справочная книга», 1899) дигән белешмәлекләр нәшер ителә. 1917 дән соң андый басмалар чыгудан туктый (Әстерхан шәһәреннән кала). 1920 елларда гына аларны яңадан чыгаруга омтылышлар була: «1920 елга Казан шәһәре һәм Казан губернасы белешмәлеге» дөнья күрә («Справочник по гор. Казани и Казанской губернии на 1920 год») (у. һәм е.к.).

Гомуми белешмәлекләрдән башка, төрле ведомстволарның махсус белешмәлекләре чыгарыла (епархияләр, уку-укыту округлары, табибләр һ.б.), алар арасында Казан басмалары, мәс.: «Казан шәһәрендә ирекле эшләүче табиб-белгечләрнең адреслар күрсәткече» («Адрес-указатель вольнопрактикующих врачей-специалистов г.Казани», 1910), «Табибләр күрсәткече...» («Врачебный указатель ...», 1927), «Казандагы фәнни хезмәткәрләр. Белешмәлек» («Научные работники Казани. Справочник», 1927); Казан руханилар академиясенең 1895/96 — 1915/16 акад. елларга хәтер кенәгәләре, Казан уку-укыту округы түрәләре һәм укытучылары исемлекләре (1846 дан 1914 кә кадәр, өзеклек б-н), Казан ун-ты студентлары исемлеге (1834 тән 1918 гә кадәр, өзеклек б-н); Әмиров К.Ф. «Казан: кайда ул урам, кайда ул йорт?: Казан шәһәре урамнары белешмәлеге» («Казань: где эта улица, где этот дом?: Справочник улиц города Казани», 1995).

Адреслар китабының тагын бер төре — телефоннар белешмәлеге: 1895–1903 еллар өчен «Абонентларга Казан шәһәрендәге телефоннар турында хәбәрләр» («Абонентам на телефонное сообщение в г. Казани»), «1915 елга Казан хөкүмәт телефон челтәре абонентлары исемлеге». («Список абонентов Казанской правительственной телефонной сети на 1915 год»), «Казан юл бүлеге телефоннар белешмәлеге» («Телефонный справочник Казанского отделения дороги», 1971), «Шәһәр телефон челтәренең белешмә-мәгълүматлар хезмәте белешмә бирә» («Справочно-информационная служба городской телефонной сети даёт справку», 1987), «Эшлекле Казан 1999: Телефоннар һәм адреслар белешмәлеге» («Деловая Казань 1999: Телефонно-адресный справочник», 1999) һ.б. китаплар басыла.

*Әд.:* Павлов А. Казанские календари: 1840–1891; Историко-библиографическая заметка // Казанские вести. 1892. № 365 (10 янв.) — № 366 (12 янв.); Справочники по истории дореволюционной России: Библиогр. указ. М., 1978; Балацкая Н.М., Раздорский А.И. Памятные книжки губерний и областей Российской империи: 1863–1917. Предварительный список. СПб., 1994; Недорезова И. «... Дело полезное и похвальное» // Татарстан. 1997. № 10; Книга: Энцикл. М., 1999. *И.А.Новицкая.*

**АДРИ́АН** (дөньялыкта Андрей) (1637, Мәскәү — 16.10.1700, шунда ук), дин эшлеклесе. Мәскәү Кремлендәге Чудов монастыре архимандриты (1676–86), 1686 елдан Казан һәм Зөя митрополиты, 1690 нан Мәскәү һәм Бөтен Русия патриархы, синод дәверенә кадәрге соңгы патриарх. А. Казанда вакытта Введенский монастырен төзү артыннан йөри (к. *Кизик ирләр монастыре*); Благовещение кафедраль соборы биш гөмбәзле итеп яңартып корыла, яңадан бизәлә, чиркәү кирәк-ярагы алына. А., патриарх буларак, Пётр I нең күп кенә үзгәртеп коруларына каршы чыга. Гомеренең соңгы елларын үз теләге б-н Никола Перервинский монастырендә (Мәскәү) ялгызлыкта үткәрә.

*Әд.:* Скворцов Г.А. Патриарх Адриан, его жизнь и деятельность. К., 1913.

**АДЫГЕ́Я РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, РФ дә. Кавказның төньяк-көнбатыш өлешендә, Кубань һәм Лаба елгаларының сулъяк ярында урнашкан. Краснодар краена керә. Мәйданы — 7800 *км²*. Башкаласы — Майкоп шәһәре. Халкы 450 меңләп кеше (2002), ш.и. 3000 гә якын татар. Алар, башлыча, Майкоп шәһәрендә, Кошехабель р-нының Политотдел һәм Отрадный хуторларында, Шовгенов р-нының Киров хуторында һәм Пшизов авылында яшиләр. 1991 елдан «Дуслык» мәдәни-агарту җәмгыяте, аның каршында татар якшәмбе мәктәбе (1996 дан), «Дуслык» фольклор ансамбле, татар мәдәнияте музее (2004 тән) эшли. 2005 тән татар телендә «Дуслык» г-тасы нәшер ителә. 2001 дән Сабан туе бәйрәме үткәрелә. ТР б-н А.Р. арасында нык мәдәни элемтәләр урнашкан: ТР Мәгарифне үстерү ин-тында татар теле укытучылары үзләренең белемнәрен күтәрәләр, Майкоп шәһәрендәге татар мәктәбе 2001 дә Казанда үткәрелгән төбәкара олимпиадада катнаша.

**АЕ́ПА**, к. *Әййүб хан.*

**АЕРУ́ЧА САКЛАУЛЫ́ ТАБИГА́ТЬ ТЕРРИТО́РИЯЛӘРЕ ҺӘМ АКВАТО́РИЯЛӘРЕ**, хуҗалык эшләрендә тулысынча яки өлешчә файдаланылмый торган һәм махсус саклау режимы билгеләнгән, табигатьне саклау, фәнни, мәдәни, эстетик, рекреацион һәм сәламәтләндерү җәһәтеннән әһәмиятле табигать комплекслары һәм объектлары урнашкан җир һәм су өслеге мәйданнары. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре, саклау режимы һәм аларда урнашкан табигатьне саклау учреждениеләренең статусына карап, түбәндәгечә бүленәләр: дәүләт табигать саклаулыклары, ш.и. биосфера саклаулыклары; милли парклар; дәүләт табигать тыюлыклары; табигать истәлекләре; дендрология парклары һәм ботаника бакчалары; дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлары. Алар федераль, региональ яки җирле әһәмияткә ия булырга мөмкин. Табигать саклаулыклары түбәндәге бурычларны хәл итә: биологик күптөрлелекне дәвамлы итү максатында табигать терр-яләрен саклау, фәнни тикшеренүләрне оештыру һәм үткәрү, ш.и. *табигать елъязмасын* алып бару; экологик мониторингны тормышка ашыру; экологик агарту һ.б. Милли паркларда ландшафтларны торгызу, сирәк очрый торган һәм югалып баручы үсемлек һәм хайван төрләрен саклау буенча эшләр үткәрелә. Кагыйдә буларак, алар зур мәйданны билиләр һәм табигате матур җирләрдә урнашалар; саклаулыклардан аермалы буларак, милли паркларда йөрү тыелмый. Табигать тыюлыклары табигать комплексларын яки аларның компонентларын саклау, торгызу һәм экологик балансны саклау өчен булдырыла. Тыюлыклар төрле файдаланучылар җирләрендә күбесенчә 10 елга оештырыла. Алардан аермалы буларак, табигать истәлекләре озаграк вакытка билгеләнә.

Татарстанда 1960 елда Иделнең сулъяк ярындагы уникаль табигать экосистемасын саклау максатында Көнбатыш Кама алды чикләрендә *Идел-Кама саклаулыгы* оештырыла. 1991 дә Татарстанда беренче булып *Түбән Кама милли паркына* нигез салына. Аңа зур урман массивлары, су баса торган болыннар, республиканың төньяк-көнчыгышында урнашкан Каманың сул һәм уң ярларындагы табигать комплекслары керә. Республикада табигать тыюлыкларын билгеләү 1980 еллар башында күзәтелә. 2006 ел башында ТРда 25 тыюлык исәпләнә: комплекслы яки ландшафтлы (мәс., *Кичке Таң, Ашыт, Чатыр Тау*), ботаника (*Адонис урманы, Яңа Александровка сөзәклеге, Наратасты урманы* һ.б.), гидрологик (*Зәңгәр Күлләр*), геологик (*Лобач тавы*) һ.б. тыюлыклар. Беренче 14 табигать истәлеге 1972 дә билгеләнә, алар арасында *Зур Наратлык, Кызыл Тау, Игим наратлыгы, Казансу башы* урман массивлары һ.б. ТРда барлыгы 122 табигать истәлеге, ш.и. су өслегенең гомуми мәйданы 446 *га* га тигез булган 33 күл, гомуми озынлыгы 3 мең *км* дан артыграк булган 30 кече елга бар. «Татарстан Республикасының аеруча саклаулы табигать территорияләрен саклау дәүләт реестры»на (К., 1998) 167 табигать объекты, ш.и., тыюлыклар һәм милли парктан тыш, 16 табигать тыюлыгы һәм 131 табигать истәлеге керә. 2006 ел башында ТРда 150 аеруча саклаулы табигать терр-ясе исәпләнә, аларның гомуми мәйданы 151,2 мең *га* (респ-каның гомуми мәйданының 2,2%). Монда гамәли эшләр «Аеруча саклаулы табигать территорияләре» турындагы РФ Законы (1995) нигезендә алып барыла.

*Әд.:* Памятники природы Татарии. К., 1977; Особо охраняемые природные территории Республики Татарстан. К., 1995.

*Ф.Г.Борһанов.*

**АЕРЫЛЫШУ́**, өйләнешеп яшәүче гаиләләрнең никахны гамәлдән чыгару нәтиҗәсендә таркалу процессы. 1 елда 1000 кешегә яки өйләнешеп торучы 1000 парга туры килә торган аерылулар саны (А. коэф.) б-н исәпләнә.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда, шул чорның демографик үзенчәлекләрен исәпкә алып, А. процессын суд тәртибендә хәл итү законы кертелә һәм бу чорда Россиядә А. күрсәткече иң түбән була. 1965 елдан, никахны гамәлдән чыгару процедурасы гадиләштерелгәннән соң, А.лар саны даими арта

бара. 1950 елда Татарстанда А. коэф. (1000 кешегә) — 0,4, 1970 тә — 1,9, 1980 дә — 3,3. 1990 еллар уртасына кадәр А. коэф. туктаусыз үсә, унъеллык ахырына исә кимү процессы күзәтелә (1994 тә 4,0 дән 1998 дә 2,9 га кадәр). Ләкин шуннан соңгы елларда А.лар нык арта һәм 2002 дә иң зур күрсәткечкә җитә, барысы 21020 аерылышу теркәлә (5,6). 2006 да ТРда 15245 А. теркәлгән.

А.лар саны ир б-н хатынның яшенә бәйле һәм иң күбесе 20–30 яшьтәгеләргә туры килә. Кагыйдә буларак, хатын-кызлар арасында А.лар — яшьрәк вакытта, ә ирләр арасында олыгая төшкәч ешрак очрый. 2006 елда аерылышучы ирләрнең 5,8% ы һәм хатын-кызларның 12,5% ы 18–24 яшьтә, тиңдәшле рәвештә, 49,4% һәм 50,2% — 25–39 яшьтә, 22,3% һәм 20,2% — 40–49 яшьтә, 9,5% һәм 8,3% ы — 50–59 яшьтә булган. Шәһәр халкы, бигрәк тә зуррак шәһәрдәгеләр, авыл халкына караганда ешрак аерылыша. А.ның күпчелеге никахның беренче 5–10 елына туры килә. Баласыз гаиләләр балалыларга караганда чагыштырмача ешрак таркала. Шулай ук бер балалы гаиләләр арасында А. коэф. ике яки өч балалы гаиләләргә караганда югарырак.

**АЕ́Ш** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 11 *км* көньяктарак, Башкортстан Респ-касы чигендә. 2002 елда 476 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1745 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. А.та мәчет беренче тапкыр 1831 дә телгә алына, 1882 дә аның яңа бинасы ачыла. Мәчет каршында ир балалар өчен мәктәп эшли. 19 йөзнең 2 нче яртысында авылда дәүләт ихтыяҗы өчен печән кабул итү пункты була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 4477 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында А.та — Ленин исем. к-з, 1991 дән «Аеш» к-зы оештырыла. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Актаныш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 216, 1884 тә — 1006, 1897 дә — 1029, 1906 да — 1084, 1913 тә — 1450, 1921 дә — 1644, 1926 да — 1265, 1938 дә — 1268, 1949 да — 830, 1958 дә — 728, 1970 тә — 844, 1979 да — 723, 1989 да — 524 кеше.

**АЖДАҺА́** (борынгы фарсы мифологиясендә Ажи Даһака, Фирдәүсинең «Шаһнамә»сендә — Заһхак), борынгы фарсы мифологиясе персонажы, явыз зат. А. образы борынгы төркиләр мифологиясендә зороастризм дәверендә (б.э.к. XV–VI йөзләрдә) барлыкка килә. Урта Идел, Урал буе, Кече һәм Урта Азия, Казакъстан, Көнбатыш Себер һәм Төньяк Кавказ төрки һәм иран халыклары мифологиясендә бер үк исемнең төрле вариантларында йөри: Казан татарларында, әзәрбайҗаннарда, башкортларда, казакъларда (соңгыларында ш.у. — айдагар) — аждаһа, мишәрләрдә — аздяка, үзбәкләрдә — аждархо һ.б. Зороастризмның изге китаплар җыентыгы «Авеста» буенча, «алтын гасыр» дип аталган чорда, җирдә авырулар, картлык, үлем, әхлакый кимчелекләр булмаган дәвердә А. — Ажи Даһака — хак диндәге Йима патшаны үтергән, мең елга сузылган явызлык патшалыгы урнаштырган, ә Йиманың апалары Сакнавак һәм Арнавакны үзенең кәнизәкләре иткән. Бу сюжет казан татарлары, мишәрләр, башкортлар, казакълар һәм кайбер башка халыклар мифологияләрендә саклана. Сасанидлар хакимияте чорында (224–651) Заһхак булып әверелгән Ажи Даһака иранлыларның дошманнарын — тураннарны (төрки кабиләләр) гәүдәләндерә. Борынгыдан су стихиясе б-н бәйле; татар тылсымлы әкиятләрендә, гадәттә, елга, күл һәм диңгез буйларында яши. Мифологиядә А. зур елан кыяфәтендә сурәтләнә. Татарларның ышануларында йөз яшькә җиткән елан А.га, меңгә җиткәне *юхага* әверелә, диелә.

Төрки-татар язма әдәбиятында А. беренче тапкыр Сәйф Сараи иҗатында (1321–96) «Аждарһа» рәвешендә искә алына, әмма ешрак тылсымлы әкиятләрдә очрый. А.ның шәһәрләргә һәм патшалыкларга даими һөҗүм итүен тасвирлаган сюжет аеруча киң таралган. Түләп котылу өчен халык А.га гөнаһсыз кызларны корбан иткән. А.га иң ахыр чиктә бирелгән патша кызын көтмәгәндә килеп чыккан каһарман коткара, ул А.ны үтерә, патша кызына өйләнә һәм бүләк сыйфатында ярты патшалыкны ала. Икенче бер сюжет А.ның *Сәмругъ кош* балаларын ашарга җыенуы турында сөйли. Егет аларны коткара, шуның өчен Сәмругъ кош аны җир асты патшалыгыннан чыгара. «Кырык уллы кеше» әкиятендә каһарман юлчыларны тирән йокыга (аналогия: йокы — үлем) талдыручы А. яшәгән елга яныннан үтеп китәргә тиеш. А.ның татар фольклоры әсәрләрендәге тагын бер сыйфаты — А. үлгәч тә, аның гәүдәсенең кайбер өлешләре яшәвен һәм хәрәкәтләнүен дәвам итә. «Аучы» әкиятендә үтерелгән А.ның ике тешенә йоклап яткан батыр колакларына килеп керә һәм аны үтерә. Мишәрләр мифологиясендә А. — утлы елан, тол хатынның үлгән ире кыяфәтенә кереп, аның б-н яши. Нәтиҗәдә хатын авырый башлый һәм үлә. «Ике туган» әкиятендә А. оча торган канатлы елан кыяфәтендә сурәтләнә; шул рәвешчә ул патша кызын урлап китә.

*Әд.:* Татар халык әкиятләре. Тылсымлы әкиятләр. К., 1994; Авеста в русских переводах (1861–1996). СПб., 1997; Р а к И.В. Мифы древнего и раннесредневекового Ирана. СПб., 1998.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«АҖАГА́Н»**, әдәби-нәфис яшьләр журналы. Оештыручылары: «Раифа» с-зы, редакциянең хезмәт коллективы. 1991–98 елларда Яшел Үзән шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 9 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире А.Ф.*Вергазов*. Журналда язучыларның проза һәм шигъри әсәрләре, ш.у. татар халкы тарихы, гореф-гадәтләре һәм милли бәйрәмнәренә багышланган язмалар басыла. Яшь авторлар әсәрләренә шактый урын бирелә.

**АҖИ́ЕВ** Әнвәр Әбделхәмид улы (10.3.1914, хәзерге Дагстан Респ-касының Хәсәүйорт р-ны Костек а. — 1991), Дагстан АССРның халык шагыйре (1969). Кумык телендә язган. Тау халыкларының яңа тормышка аяк басулары бәян ителгән «Яңару» (1934) җыентыгында, Дагстан халыкларының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары тасвирланган «Чапкын» (1942), «Кылычлар» (1943) җыентыкларында, ш.у. «Йөрәк януы» (1972), «Тәрәзәләрдәге ут» (1980), «Ташчы һәм шагыйрь» (1983) җыентыкларында тупланган шигырьләрендә лирик геройның рухи дөньясына тирән үтеп керү, чынбарлыкны фәлсәфи яктан күрсәтү омтылышы күзәтелә. А. иҗатына Тукай шигърияте зур йогынты ясый. Ул Тукай шигырьләренә нәзыйрәләр яза, аларны кумык теленә тәрҗемә итә («Туган тел», «Казан», «Государственная дума», «Бер татар шагыйренең сүзләре» һ.б.).

Ә с ә р.: Сайламлы йырлар. Магъачкъала, 1954.

**АЗ ТӨКЛЕ́ СУАЛЧАННА́Р** (Oligochaeta), умырткасызлыр классы. 3 меңләп төре билгеле, күбесенчә туфракта тереклек итә, 500 дән артыграк төре төче суларда яши. Россия терр-ясендә 500 ләп төре билгеле, әмма күбрәк булырга да мөмкин. Татарстан терр-ясендә олигохетлар аз өйрәнелгән, 100 дән артыграк төре теркәлгән. Туфракта яшәүчеләр: вак аксыл, саргылт һәм алсу суалчаннар — энхитреидлар (Enchytraeidae), 30 *см* га кадәр озынлыктагы гадәти зур яңгыр суалчаны (Lumbriculus terrestris), халыкта аны «зур кызыл суалчан» дип йөртәләр. Ул җир өслегеннән 2 *м* га һәм аннан тирәнрәккә киткән юллар казый. Яңгырдан соң суалчан өскә чыга һәм, коелган яфракларны яки кипкән үләннәрне авызы б-н эләктереп, балчык б-н бергә ашый. Кече кызыл суалчан (Lumbricus rubellus) туфракның өске катламында һәм урман түшәмәсендә яши, ә соры аллолобофора (Allolobophora caliginosa) сөрелгән җирләрдә, бакчаларда һәм басуларда иң гадәти төр санала. Начар исле һәм ачык кызыл төстәге тирес суалчаны (Eisenia foetida) тирестә, черегән саламда яки парникларда яши. Ул ярсынган вакытында көчле исле сары сыеклык бүлеп чыгара. Сулыклар төбендә яшәүче олигохетларның төп вәкилләре — боҗралылар, аларның иң гадиләре Tubifex tubifex, Limnodrilus hoffmeisteri, Nais communis, Lumbriculus variegatus һ.б. Су олигохетларының, бигрәк тә боҗралыларның канына гемоглобин булу сәбәпле, гәүдәләре кызыл төстә. Бу аларга бөтенләй диярлек кислород булмаган ләмле сулыклар төбендә урнашырга мөмкинлек бирә. Татарстан терр-ясендә туфрак олигохеты 5 тән 20–25 *см* га кадәр, ә сунакылар *мм* өлешләреннән башлап 10 *см* га кадәр озынлыкта. Олигохетлар органнарының гәүдә үзәге буйлап дөрес кабатлануы б-н характерланалар (метамерия). Суалчансыман гәүдә боҗраларга яки сегментларга бүленә, аларның саны төрлечә, 5 тән 600 гә кадәр. Гәүдәнең алгы очында баш калагы, авыз сегменты урнашкан. Калган барлык сегментларда 4 бәйләмгә кадәр төкләр

була, аларның саны күп төкле суалчаннар б-н чагыштырганда азрак — 3 тән алып 150 гә кадәр (исеме шуннан). Гәүдәнең эчке куышлыгы сыеклык б-н тулган һәм тышкы сегментациягә тәңгәл рәвештә аерым буынтыкларга бүленгән. Буынтыкларда эчке органнар урнашкан. А.т.с. гермафродитлар. Олигохетларның күп төрләре партеногенетик, җенессез, вегетатив юл б-н үрчергә мөмкин. Туфрак олигохетлары туфрак йотып тукланалар. Исәпләүләр күрсәтүенчә, олигохетлар тәүлек саен уртача һәр гектарда 250 *кг* чамасы җир эшкәртәләр (2–3 *т* га кадәр), шуның б-н олигохетлар туфракны минераль матдәләр б-н баеталар, шулай ук аралаштыралар һәм күпертәләр, ягъни туфракның уңдырышлылыгын арттыралар. Ләмле грунтларда яшәүче су олигохетлары, грунтның органик матдәләрен файдаланып, сулыкларның үзлегеннән чистаруында катнашалар, балыклар өчен азык булып торалар, күп кенә төрләре — сулыкларның пычрану индикаторлары. Ак энхитрей (Enchytraeus albidus) олигохет — аквариум балыклары өчен уңайлы азык.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968; Т. 1. Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977.

*В.Я.Яковлев.*

**АЗА́К**, шәһәр, Дон елгасының Азак (Азов) диңгезенә койган тамагында. Элек ул җирдә греклар колониясе, византиялеләр һәм кыпчаклар торак пунктлары урнашкан була. 13 йөздән Алтын Урданың эре сәүдә һәм һөнәрчелек үзәге буларак мәгълүм; акча сугу урыны. А. аша Кытай б-н Европа илләрен тоташтырган Ефәк юлы узган. 1330 елларда Үзбәк хан б-н килешү нигезендә А.та Генуя һәм Венеция сәүдәгәрләре колонияләре барлыкка килә. Шул чорда Европа илләре язма чыганакларында шәһәр Тана исеме б-н теркәлә. 15 йөздә италиялеләр колонияләре тирәли ныгытмалар төзелә. А. аша сатуга коллар, кыйммәтле җәнлек тиреләре, мал-туар һәм бодай чыгарылган. 1395 елда А.ны Аксак Тимер гаскәрләре талый, җимерә. 15 йөз башында генуялылар (җәнүизләр) колониясе кабат торгызыла. 15 йөз уртасыннан А. Кырым ханлыгына, 1471–1696 һәм 1711–74 елларда Госманлы империясенә керә. 1696–1711 дә һәм 1775 тән Россиягә буйсына. Хәзер А. — Ростов өлкәсенә кергән Азов шәһәре.

*Әд.:* Ковалевский М.М. К ранней истории Азова // Тр. 12-го Археол. съезда. М., 1905. Т. 2.; Барбаро и Контарини о России. Л., 1971; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985.

*И.Л.Измайлов.*

**АЗАЛА́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 10 *км* төньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2002 елда 496 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 17 йөз ахырында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр, башкорт-вотчинниклар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балта эшләре б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, А.та мәчет, мәктәп, су тегермәне була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1721,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 192 ир заты; 1859 да — 799, 1897 дә — 1124, 1926 да — 915, 1938 дә — 848, 1949 да — 591, 1958 дә — 606, 1970 тә — 700, 1979 да — 577, 1989 да — 457 кеше.

**АЗАМА́ТОВ** Венер Һидиятулла улы (29.12.1934, Казан), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1975), проф. (1983). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), Татарстан нефть фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (инженер, нефть һәм газ запасларын исәпләү лаб. мөдире). 1970–88 елларда Пермь нефть сәнәгате фәнни-тикшеренү ин-тында промысел геологиясе лаб. мөдире. 1967–70 тә һәм 1976–78 дә Алжирда Хасси-Мессауд, Зарзайтин нефть чыганакларын эшкәртүне проектлаштыру һәм анализлау буенча тикшеренүләрне җитәкли (контрактның баш инженеры). 1988 дән Мәскәүдә: 1994 кә кадәр Янучан файдалы казылмалар геологиясе һәм разведкасы ин-тында лаб. мөдире, 1994–2001 дә «ЛУКОЙЛ» нефть компаниясе» фәнни-инженерия үзәгендә геология һәм геофизика бүлеге башлыгы. Татарстандагы Ромашкино, Яңа Елховой һ.б. нефть чыганакларындагы, ш.у. Пермь өлкәсендәге чыганаклардагы нефть ятмалары запасларын исәпләүне җитәкли. Нефть промыселы геологиясендә яңа юнәлешкә, ягъни рациональ эш итүне оештыру өчен нефть запасларын төрләргә бүлеп өйрәнү юнәлешенә нигез сала. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Методы изучения коллекторов в связи с оценкой запасов нефти и газа. М., 1975 (автордаш); Дифференциация запасов нефти в неоднородных коллекторах. М., 1982 (автордаш).

**АЗА́Н** (гарәп. أذان — хәбәр салу, игълан итү), мөселманнарны намазга өндәү. Риваятьләрдә бәян ителгәнчә, 622–23 елларда Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан гамәлгә кертелә. Сөнниләрдә А. кабатланып баручы җиде өлештән тора. Намаз вакыты җиткәч, мөәзин тарафыннан — мәчет манарасыннан, кечкенә мәчетләрдә имам тарафыннан манарадан яисә мәчеттән әйтелә. А.чы йөзе б-н Мәккәгә (*кыйблага*) карарга, баш һәм имән бармаклары б-н колак йомшагын тотарга тиеш. А.нан соң ук намаз алдыннан әйтелә торган икенче чакыру (икамә) да шул ук өлешләрдән гыйбарәт. А. яңа туган баланың уң колагына пышылдап әйтелә, ш.у. явыз рухлар борчыган кешене өшкерү өчен дә файдаланыла.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1961.

**«АЗА́Т»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1906 елның 1 февраленнән 30 маена кадәр Казанда атнага 3 тапкыр нәшер ителә. Барлыгы 56 саны чыга. Рәсми нашире һәм мөхәррире Г.Апанаев, гамәлдә мөхәррирлек хезмәтен Г.Камал үти. «А.» г-тасында язучылар М.Гафури, Н.Думави, Г.Коләхмәтов, М.Укмаси һ.б.лар язышa. Аның битләрендә 1 нче Дәүләт думасы эшчәнлеге киң яктыртыла, милли мәсьәләләр күтәрелә, татар халкын яңарышка, тәрәккыят итүгә чакырган мәкаләләр урын ала. Эшчеләр һәм крәстияннәр мәнфәгатен яклаган, с.-д. юнәлештәге материаллар («Россия социал-демократларының максатлары», «Катлау, сыйныф, фирка», «Ике Европа» һ.б.) басыла. Радикаль караштагы, хакимияткә тәнкыйтьләгән мәкаләләр бастырган өчен мөхәррир берничә мәртәбә штрафка тартыла. Мөхәррир б-н радикаль карашлы хезмәткәрләр арасында еш кына сәяси бәхәсләр чыга. Нәтиҗәдә Г.Апанаев газетага матди ярдәм күрсәтүдән баш тарта һәм ул ябыла. 1906 елның 4 июненнән Г.Камал «*Азат халык*» г-тасын чыгара башлый.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты: (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001; Нафигов Р.И. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. К., 1964; Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«АЗА́Т ВАТА́Н»**, иҗтимагый-сәяси, әдәбинәфис журнал. 1952–53 елларда Мюнхен шәһәрендә (Германия) татар һәм рус телләрендә нәшер ителә. Мөхәррирләре: А.Фәйзуллин, М.Кәрими. Г.Исхакый, Ш.Нигъмәти һ.б.ның әсәрләре басыла. Журнал Советларга каршы фикердә тора. Аның битләрендә халыкара вакыйгалар турында материаллар басыла, СССРда милли мәсьәләнең торышы, татар халкы тарихы, күренекле мәдәният эшлеклеләренең (Г.Тукай, Р.Фәхретдин, Й.Акчура, Г.Камал, К.Насыйри, Г.Баруди һ.б.) иҗаты яктыртыла.

*Әд.:* Гилязов И. Неоконченный урок // Казань. 1994. № 5/6; Миннегулов Х. «Азат Ватан»: Скорбь и надежда: (Татарский журнал в Германии) // Татарстан. 2003. № 2.

**«АЗА́Т СЕБЕ́Р»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. ВКП(б)ның Көнбатыш Себер край ком-ты һәм революцион ком-ты органы. 1919–21 елларда Омск, 1921 нең сентябреннән 1936 га кадәр Новониколаевск (хәзерге Новосибирск) шәһәрләрендә атнага 3 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре: Ф.Әхмәтов, С.Фәхриев, М.Йосыпов, И.Вәлиев, Х.Курмаев. Даими язышучылары: Х.Бәдәни, Б.Ибраһимов, Г.Камаев, Ш.Мәхмүт, Г.Нигъмәти, Г.Сәйфи. 1921–23 тә кушымта булып «Яшьләр сәхифәсе» ж-лы, 1933–34 тә «Яңалифче» ж-лы һәм «Яңалиф походы» г-тасы чыга. «А.С.» РСФСР ХКСның декретларын һәм карарларын бастыра, илдәге һәм чит илләрдәге икътисади хәлләрне яктырта, икътисад яңалыклары б-н таныштыра, халыкның наданлыгын бетерү мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Рубрикалары: «Мәгариф», «Тормышыбыз яңалыклары», «Чит ил яңалыклары» һ.б.

*Г.Г.Хәсәнова.*

**«АЗА́Т ХАЛЫ́К»**, атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. «*Азат*» г-тасының дәвамчысы. 1906 елның 4 июненнән 12 сентябренә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә. Барлыгы 15 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире Г.Камал. Газетада З.Бәшири, Н.Думави, М.Укмаси һ.б.ның мәкаләләре дөнья күрә. Материалларның күпчелеге имзасыз басыла. Аерым бер партиягә дә карамый, ләкин, Россия с.-д. йогынтысында булганлык-

тан, сул радикаллыкка тартылган мәкаләләргә күп урын бирә («Конституция нигезләре», «Халыкның үзидарәсе», «Социал-демократлар нәрсәгә өйрәтә?», «Нәрсә ул Россия мөселманнары берлеге?» һ.б.). Хакимият тарафыннан ябыла. Мөхәррире хөкемгә тартыла, ләкин аклана.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001; Нафигов Р.И. Формирование и развитие передовой татарской общественной мысли. К., 1964; Гайнуллин М. Татарская литература начала XX века. К., 1983.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«АЗА́Т ХАЛЫ́К»**, иҗтимагый-сәяси атналык газета. Әстерхан милли шурасы нәшер итә. Нашире Әстерхан мөселманнарының Үзәк бюросы. Мөхәррире Х.Гомәрзадә. 1917 елның апрелендә Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Чыгудан тукталу вакыты төгәл билгеле түгел. «Яшәсен халык республикасы! Яшәсен интернациональ туганлык!» шигаре астында чыга. Илдәге сәяси хәлләрне яктырта, мөселманнарның берләшүе, сәяси көрәштә бердәм хәрәкәт итү зарурлыгы идеясен яклый.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**«АЗА́Т ХАНЫ́М»**, әдәби-иҗтимагый, фәнни-педагогик хатын-кызлар журналы. 1917 елның 15 октябреннән 1918 нең 1 маена кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Барлыгы 3 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире Г.Мөслимов. Журналда Г.Байчурин, М.Крымская, Г.Терешкавия һ.б. авторларның мәкаләләре басыла. «Яшәсен хөр Русия мөслимәләре! Русия мөслимәләренең бөтен хокуклары ирләр белән бертигез булуы вәҗүдкә чыгарылсын!» шигаре астында чыга. Хатын-кызларга белем бирү, аларны иҗтимагый-сәяси тормышка актив катнаштыру, аларның һәртөрле, ш.и. дин өлкәсендә дә хокукларын яклау мәсьәләләрен күтәрә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«АЗА́Т ХАТЫ́Н»**, журнал, к. «Сөембикә».

**«АЗА́Т ХАТЫ́Н»**, иҗтимагый-сәяси хатын-кызлар газетасы. РКП(б)ның Башкортстан губкомы хатын-кызлар бүлеге чыгара. 1921 елда Эстәрлетамак шәһәрендә «*Башкортстан хәбәрләре*» г-тасының кушымтасы буларак татар телендә нәшер ителә. Чыгудан тукталу вакыты төгәл билгеле түгел. Мөхәррире Р.Рәхмәтуллина. «А.х.» хатын-кызларга ирләр б-н бертигез хокук бирү мәсьәләсен күтәрә, аларны мәгърифәт эшендә актив катнашырга чакыра.

*Әд.:* Башкортостандың милли матбугат альбомы // Ватандаш. 2000. № 3.

**«АЗА́Т ШӘРЕ́КЪ»**, татар мөһаҗирләре журналы. 1923 елда Берлинда татар телендә нәшер ителә. Журналда Г.Исхакый, Ф.Туктаров һ.б. мәкаләләре басыла. «А.ш.» битләрендә дөньядагы һәм СССРдагы сәяси хәлләргә анализ бирелә. Журналның наширләре татар халкын милли яңарышка, большевиклар диктатурасына каршы көрәшкә чакыралар, «кызыл террор»ны гаепләп чыгалар.

*Әд.:* Ибраһимов Г. Әсәрләр. К., 1986. 6 т.

**АЗА́Т** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 126 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чистай кантоны Аксубай волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан яңадан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 54, 1938 дә — 190, 1949 да — 183, 1958 дә — 122, 1970 һәм 1979 да — 185, 1989 да — 122 кеше.

**«АЗАТЛЫ́К»** радиосы, «Ирекле Европа» — «Азатлык» радиокорпорациясенең татар, башкорт телләрендәге тапшырулар редакциясе. АКШ конгрессы тарафыннан финанслана. Татар-башкорт редакциясе 1953 елда татар мөһаҗирләре катнашында оештырыла. Директорлары: Шиһап Нигъмәти, Гариф Солтан, Фәрит Иделле, 2006 елдан Рим Гыйльфанов. Башта Мюнхен, 1995 елдан Прага шәһәрләрендә урнаша. Тапшырулар кыска дулкыннарда көненә 4 сәгать алып барыла, озын һәм FM дулкыннарында трансляцияләнә, эчтәлеге Интернетта да бирелә. Тапшырулар Европа, Азия илләрендә һәм Австралиядә кабул ителә. 1996 дан «А.»ның Казан вәкиллеге эшли (2000 елдан директоры — Р.С.*Вәлиев*). Россиядә Екатеринбург, Ижевск, Комсомольск-на Амуре, Мәскәү, Омск, Оренбург, С.-Петербург, Самара, Төмән, Ульянов, Уфа һ.б. шәһәрләрдә хәбәрчеләр үзәкләре оештырылган; дөнья хәбәрләре, татар, башкорт, Кырым татарлары һ.б. төрки халыклар тормышындагы иҗтимагый-сәяси вакыйгалар һәм мәдәният яңалыклары яктыртыла.

**«АЗАТЛЫ́К» ТАТА́Р ЯШЬЛӘРЕ́ БЕРЛЕГЕ́**, иҗтимагый-сәяси оешма. 1990 елның октябрендә Татар иҗтимагый үзәге тәкъдиме б-н татар яшьләренең Казанда үткәрелгән 1 нче корылтаенда төзелә. Оешманың Казан бүлекчәсе 1992 нең 7 апрелендә рәсми теркәлә. Филиаллары Әлмәт, Түбән Кама, Азнакай шәһәрләрендә, Башкортстан Респ-касында һ.б. урыннарда. Югары башкарма органы — съезд (корылтай). Идарә органы — Үзәк совет (Шура). Әйдәп баручы әгъзалары — Т.Әхмәдишин, И.Гарипов, Р.Гыйльфанов, М.Сәгыйдуллина, Р.Юлдашев һ.б. Оештыру корылтаенда «А».т.я.б.нең уставы һәм программа-максатлары турындагы декларация кабул ителә. Программа 1993 нең апрелендә Чаллы шәһәрендә үткәрелгән Татар яшьләре оешмалары форумында раслана. Устав нигезендә «А.»т.я.б. — ирекле, бәйсез, экстерриториаль оешма. Программа-максатлары — татар халкының милли бәйсезлегенә ирешү, бәйсез татар дәүләте төзү, Россия Федерациясенең регионнарында яшәүче бөтен татар халкына терәк булу, татар халкының берлеген нигыту өчен барган омтылышта исламны төп фактор итеп алу, татар яшьләренең белемен һәм мәдәни дәрәҗәсен күтәрү, милләтнең хокукларын һәм ихтыяҗларын саклау, кайгырту, гадел демократик җәмгыять төзү. «А.»т.я.б. программасына *Татар милли бәйсезлек партиясе «Иттифак»*ның идея принциплары салынган. Оешма 1991 нең октябрендә Татарстанның бәйсезлеге турында акт кабул итүне яклап чыга; 1991–92 елларда республика яшьләрен Россия хәрби көчләренә хезмәткә бармаска чакыра, ш.у. 1994–95 тә Чечня Респ-касындагы сугышка каршы һ.б. демонстрация һәм митинглар үткәрә. «А.»т.я.б. тәкъдиме б-н «Хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәткә чакырылучылар эшләре буенча комитет» (1992 нең февр.), Югары уку йортлары студентларының координацион советы (1992), Төрки яшьләр ассоциациясе (1992) төзелә; Бөтендөнья татар яшьләре көннәре, татар укучылары һәм студентлары форумнары, татар студентларының «Ягымлы яз» фестивале үткәрелә. 1990 елларның 2 нче яртысыннан «А.»т.я.б., нигездә, мәдәни-агарту юнәлешендәге эшчәнлек алып бара. Матбугат органы — «Азатлык нуры», 1996 елдан Уфада чыга.

*Әд.:* Исхаков Д. Союз татарской молодёжи «Азатлык». Современные национальные процессы в Республике Татарстан. К., 1992; Программа Союза татарской молодёжи «Азатлык» // Алтын Урда. 1993. № 2; Юлдашев Р.З. «Азатлык» — это свобода. Общественно-политическая характеристика и история деятельности Союза татарской молодёжи «Азатлык» в 1989 — 1998 гг. К., 1998; Терентьева И.В., Беляков Р.Ю., Сафаров М.Ф. Политические партии и движения Республики Татарстан. К., 1999.

*Л.М.Айнетдинова.*

**АЗБАБА́**, к. *Акхуҗа.*

**АЗЕ́ЛИНО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), тимер гасырда (якынча 3–7 йөзләр) Идел-Нократ елгалары арасында яшәүчеләргә нисбәтле археологик культура. Беренче тапкыр 1956 елда В.Ф.Генинг тасвирлый, атамасы Киров өлкәсендәге Азелино авылы янында табылган каберлеккә бәйле рәвештә бирелә. А.к. турындагы беренче мәгълүматлар 19 йөзгә карый. А.к. истәлекләре А.А.Спицын, П.А.Пономарёв, М.Г.Худяков, А.П.Смирнов, В.Ф.Генинг, А.Х.Халиков, П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Кайбер тикшеренүчеләр фаразынча, А.к. *Пьянобор культурасы* нигезендә үсеп чыга һәм Идел аръягында яшәгән ахыргы чор Городец культурасы кабиләләре, ш.и. фин-угыр кабиләләре катнашында барлыкка килгән дип санала. А.к. халкы игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, аучылык б-н көн күргән, сөяк эшкәртү, тимер эретү-коюю һөнәрен белгән (эш, сугыш кораллары, бизәнү әйберләре һ.б. җитештергән). А.к.на балчыктан ясалган яссы һәм түгәрәк төпле савыт-сабалар хас. Торулыклары уртача 1,5 мең $м^2$ мәйданны алып торган. Биектау р-нындагы Соловцово шәһәрлеге якынча 6 мең $м^2$ мәйданны биләгән. Агач тораклары җир өстенә төзелгән. Мәетләрне кабер казып җирләгәннәр, мәет б-н бергә ат дирбияләре күмү гадәте дә булган. Каберләргә кылыч, сөңге, тимер башлык, ук очлыклары, тимерчелек кирәк-ярагы, уклы садак салып калдыру гадәте дә очрый. Татарстанда А.к. истәлекләре Яшел Үзән р-ның Әйшә, Кама Тамагы р-ның Сөйке, Лаеш р-ның Нармонка, Рождествено авыллары, Тәтеш шәһәре янында, Казанның элекке елга порты һ.б.

урыннарда (барлыгы 48 истәлек, ш.и. 13 шәһәрлек, 3 авыллык, 11 каберлек) табыла.

*Әд.:* Генинг В.Ф. Азелинская культура III–V вв. Очерки истории Вятского края в эпоху Великого переселения народов // Вопр. археологии Урала. Свердловск–Ижевск. 1963, Вып. 5.

*П.Н.Старостин.*

**«АЗИА́ТСКИЙ МУЗЫКА́ЛЬНЫЙ ЖУРНА́Л»** («Азия музыка журналы»), Россиядә музыкага багышланган һәм ноталы беренче периодик литографик басма. 1816–18 елларда скрипач, дирижёр, педагог, фольклорчы һәм муз. аң-белем таратучы И.В.Добровольский тарафыннан Әстерхан шәһәрендә рус телендә 8 саны чыгарыла. Россия халыклары муз. фольклоры үрнәкләрен язып алу, гармонизацияләү алымнарын гамәлгә кертүнең беренче тәҗрибәсе булып тора. «А.м.ж.»нда 32 көй, ш.и. Әстерхан һәм Казан татарларының 2 көе чыга. Җырларны һәм бию көйләрен тавыш һәм фортепиано өчен эшкәрткәндә, биюләрне фортепианода башкаруда И.В.Добровольский татар көйләре үзенчәлекләрен гомумевропа классик музыка системасы законнчалыкларына яраклаштырырга омтыла. «Казанские известия» г-тасының 1816 ел 26 июль санында басылган «А.м.ж.» проспектында татар җырлары һәм биюләре исемлеге басыла.

*Әд.:* Луганский Н. Неутомимый просветитель // Советская музыка. 1966. № 12; Ямпольский И. Азиатский музыкальный журнал // Музыкальная энцикл. М., 1973. Т. 1; шул ук. Добровольский Иван Викентьевич // Музыкальная энцикл. М., 1974. Т. 2.

**АЗИ́ЕВ** Камил Гали улы (16.7.1930, Башкортстан АССРның Благовар р-ны Каргалы Тамак а. — 9.1.1999, Омск ш.), галим агроном, Россия АХФАнең мөхбир әгъзасы (1990). Башкортстан а.х. ин-тын тәмамлый (1952). 1956–73 елларда Себер а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында (Омск ш.), 1965 тән орлыкчылык бүлеге мөдире. 1973 тән Көнбатыш Себер селекция үзәге җитәкчесе, бередә Урал, Себер һәм Төньяк Казакъстан өлкәләрендә сортлар чыгару һәм гамәлгә кертү буенча өр-яңа программалар эшләнә һәм үзләштерелә, бөртекле, бөртекле-кузаклы культураларның, бәрәңге һәм үләннәрнең 60 лап яңа сорты һәм гибриды чыгарыла; бу сортлар 7 млн. *га* дан артык мәйданда 37 өлкә, край, республикада районлаштырыла; 8 сортның автордашы. Хезмәтләре а.х. җитештерүчәнлеген интенсивлаштыруга, орлыкчылык агроэкологиясенә һәм оештыру-икътисад нигезләренә, Көнбатыш Себердә югары сыйфатлы орлык җитештерү технологиясен эшләүгә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Семеноводство в Омской области. Новосиб., 1981; Яровая пшеница в Западной Сибири. М., 1981.

**АЗИ́З ШӘЁХ**, к. *Газиз Шәех.*

**АЗИ́ЗОВ** Борис (Барис) Миргарифҗан улы (25.12.1937, Казан), химик технол. процесслары һәм аппаратлары гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2004). 1960 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук химик җитештерү машиналары һәм аппаратлары кафедрасында эшли, 1992–96 да сәнәгать иминлеге каф. мөдире. Хезмәтләре гетероген катнашмаларны эшкәрткәндә актив гидродинамик режимнарда масса алмашуга, хәвефле җитештерү объектларының сәнәгый иминлегенә карый; гетероген системаларда җылылык-масса алмашу процессларын оештыруның ике фазалы капма-каршы ташкыннар ысулын эшли. Шул ысул нигезендә югары җитештерүчән, нәтиҗәле һәм киң диапазонда тотрыклы эшли торган яңа төр масса алмашу аппаратлары төзелә. Медаль б-н бүләкләнә. РФнең 58 авторлык таныклыгына һәм патентына ия.

Хезм.: Очистка дымовых газов бариевого производства от сернистого ангидрида // Изв. вузов. Химия и химическая технология. 1991. Вып. 5; Новая технология обезжиривания кости // Fourth International Symposium «Ecology-95». Bourgas, Bulgaria, 1995. V. IV.

**АЗИ́ЗОВ** Камил Исхак улы (15.3.1930, Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Иске Мостяк а.), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1959), проф. (1989), РСФСРның атказ. икътисадчысы (1982), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). 1953 елда Идел буе урман-техника ин-тын (Йошкар-Ола ш.) тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Коми филиалында эшли. 1962–67 елларда СССР ФАнең Казан филиалы Геология ин-тында икътисади тикшеренүләр секторы мөдире. 1968 дән Казан финанс-икътисад ин-тында, 1980 нән хезмәт һәм хезмәткәрләр б-н идарә итү каф. мөдире. Хезмәтләре икътисад, хезмәтне оештыру һәм сәнәгый җитештерүнең нәтиҗәлелегенә мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Эффективность использования материальных и трудовых ресурсов в промышленности Татарии. К., 1977; Эффективность производства: сущность, факторы, показатели. К., 1981; Выбор пути: точка зрения на некоторые системообразующие основы рынка труда. К., 1995.

**АЗИ́ЗОВ** Миргарифҗан Җамалый улы (27.4.1907, Сембер губ., Сембер өязе Иске Шәйморза а. — 1969, Казан), дәүләт эшлеклесе. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1937). 1925–28 елларда Украина ССРның Макеевка шәһәрендә 28 нче номерлы шахта эшчесе. 1930–31 дә ТАССРның Буа р-ны хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма ком-ты финанс бүлеге инспекторы. 1937–38 дә Госстрах идарәсе башлыгы, 1938–40 та ТАССР Финанс халык комис-тында өлкән контролёр-ревизор. 1940–42 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында кадрлар бүлегенең сектор мөдире, 1942–43 тә оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире урынбасары. 1943–50 дә ТАССР финанс министры, 1950–57 дә ТАССР МС рәисе. 1957–60 елларда ТАССР «Промбанк», «Стройбанк» контралары башлыгы. ТАССР (1947–59), РСФСР (1951–55) һәм СССР (1954–58) ЮСлары депутаты. Ленин, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**АЗИ́ЗОВ** Рәшит Абдрахман улы (20.2.1925, Горький өлкәсе Сергач р-ны — 29.10.1989, Казан), спортчы, тренер, судья (ирекле көрәш), СССРның спорт остасы (1956), Бөтенсоюз категорияле судья (1963), ТАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1984). 1964–85 елларда «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте тренеры (Казан). ТАССРда ирекле көрәшне башлап җибәрүчеләрнең берсе. Татарча көрәш кагыйдәләрен төзүче һәм беренче ярышлар оештыручы. Шәкертләре арасында В.Ф.Маркелов, ирекле көрәш буенча бөтенсоюз ярышларында алгы урыннарны алган И.Шишкин, В.Клименко, М.Токранов, А.Груздев, Ф.Мөслимов, Н.Нигъмәтуллин һ.б.



В.М. Азин.

*Әд.:* Илдарханов И.Г. Без көрәшле халык. Чабаксар, 2003.

**А́ЗИН** Вольдемар Мартинович (Владимир Михайлович) (26.9.1895, Витебск губ., Полоцк өязе Марьяново а. — 18.2.1920, Кубань өлкәсенең Тихорецкая станицасы), Кызыл Армия командиры, Гражданнар сугышы каһарманы. Полоцк шәһәр уч-щесен тәмамлый (1910). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1918 елның февраленнән Көнчыгыш фронтта — Латыш коммунистик отряды, июльдән Вятка батальоны командиры. Шул елның сентябрь башыннан Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясендә — Казанны азат итү сугышында Арча ягыннан һөҗүм итүче гаскәри берәмлек командиры буларак танылa. Баш күтәргән чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык Армиясе көчләреннән шәһәрне азат иткәч, сентябрь урталарыннан 2 нче берләштерелгән дивизия командиры, Сарапул, Ижевск, Воткинск шәһәрләрен азат итү шул дивизиягә йөкләнә. 1918 нең декабреннән 28 нче укчылар дивизиясе башлыгы, адмирал А.В.Колчак гаскәренә һәм соңрак, 1919 ның сентябреннән, генерал А.И.Деникин көчләренә каршы сугыша. 1920 нең 17 февралендә Төньяк Кавказдагы Целина станциясе янындагы сугыш барышында әсир ителә, җәзалап үтерелә. Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Макаров Ф.П. К боевой биографии Азина В.М. Ижевск, 1935; Владимир Азин. Ижевск, 1958; Захаров С.А. Владимир Азин. Свердловск, 1960; Ладухин В.Н. Азин. М., 1967; Кондратьев Н.Д. Начдив Владимир Азин. М., 1968.

**А́ЗИЯ БАСМАХАНӘСЕ́**, Петербургта. 1785 елда Петербург ФАнең Азия ф-лы басмаханәсен һәм И.К.Шнор басмаханәсен бергә кушу юлы б-н барлыкка килә, аның арендаторы итеп И.К.Шнор билгеләнә. 1781–85 тә үк И.К.Шнор Шәрекъ телләрендә китаплар бастыра. Россия мөселманнары өчен Коръәннең 3 басмасын чыгара. Басмаханә ул вакытта Россиядә иң яхшылардан санала. Хәреф

җыючылары Хәмзә Мәмәшев, Гали Рәхмәтуллин, Корбангали Исхаков бу вакытта Петербургта хәрби хезмәттә булалар, аларны басмаханәгә эшкә җибәрү шул хәрби хезмәтне үтәү булып исәпләнә; Сенат күрсәтмәсе буенча корректор да татар кешесеннән билгеләнә. А.б. ачылган 1785 тә татар һәм Кырым татарлары телләрендә гарәп шрифтында «Русия империясендә вилайәтләрнең низам вә тәртибе ...» дигән законнар җыентыгы 4 мең данәдә басылып чыга; 1786 да татар телендә тагын 500 данә өстәп басыла. Шул ук телләрдә «Тәртип саклау һәм Полиция уставы» («Устав Благочиния и Полицейский», 1786) басыла. Бу басмаларны Исхак *Хәлфин* тәрҗемә итә һәм шул эшләре өчен патшабикә Екатерина II указы б-н губерна секретаре дәрәҗәсенә күтәрелә, 1000 сум акча б-н бүләкләнә.

А.б. басмаларының үзенчәлеге — басылу мәгълүматларының булмавында. Патшабикә Екатерина II нең соңгы указларының берсе нигезендә 1796 ның 16 сентябреннән шәхси басмаханәләр ябыла, А.б. турыдан-туры Сенат карамагына тапшырыла.

*Әд.:* Сборник постановлений и распоряжений по цензуре с 1720 по 1862 год. СПб., 1862; Б у л г а к о в Ф.И. Иллюстрированная история книгопечатания и типографского искусства. СПб., [1889]. Т. 1; К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги. К., 1971.

*И.А.Новицкая.*

**А́ЗИЯ БАСМАХАНӘСЕ́** (Гимназия басмаханәсе). Казандагы беренче басмаханә. Казан, Оренбург губерналары татарлары һәм Оренбург Диния нәзарәтенең үтенечләрен күздә тотып, император Павел I нең 1800 ел 9 май һәм Сенатның шул елның 18 сентябрь указлары нигезендә «Кирәк кадәр санда Коръән, догалыклар һ.б. шундый китаплар нәшер итү өчен» ачыла. Цензура вәкаләте шул ук А.б.нә тапшырыла. Басмаханәнең беренче китаплары: «Һәфтияк», «Өстуани китабы» (Дәмәшкъ галиме Мөхәммәд әл-Өстуани китабы), Аллаһияр Суфиның «Сөбат әл-гаҗизин»е («Гаҗизләргә терәк»), «Кыйсса-и Сәйфелмөлек» һ.б. 1806 елда басмахана Беренче ир балалар гимназиясеннән Казан ун-тының төп бинасы каршында махсус төзелгән йортка күчерелә. Бөтен эшләрне оештыручы-хуҗа — отставкадагы прапорщик Габделгази Бурашев; корректор — Хәмзә Мәмәшев, хәреф җыючы — Гали Рәхмәтуллин, вакытлыча цензор — Ибраһим *Хәлфин*. Цензорны Диния нәзарәте мөфтие билгеләгән, басыласы китапларга да рөхсәтне ул биргән. Дини-дидактик «Фәүзән-нәҗат» («Котылу шатлыгы») кульязмасыннан мөфти алып ташлаган өч бит текстны басма китапка керткәне өчен 1802 елның ноябрендә Г.Бурашев һәм цензор булып эшләгән Казан имамы Мөхәммәд Әбдерәзаков хөкемгә тартылалар. 1803 ел азакларында Г.Бурашев нәшрият эшеннән читләштерелә, басмаханә 1804 нең 31 мартыннан сатуга куела. 1806–14 тә А.б. Казан сәүдәгәре Йосыф Апанаев карамагында, аннары эшмәкәр һәм сәүдәгәр Гобәйдулла Юнысов җитәкчелегендә эшли. 1829 да ун-т басмаханәсе б-н бергә кушыла. Барлыгы 90 га якын исемдә китап бастыра, аларның гомуми тиражы









Азнакай шәһәре. 1. Нефтьчеләр урамы; 2. Мәчет; 3. Балалар иҗаты үзәге; 4. «Азнакайнефть» НГДУының 45 еллыгы уңаеннан нефтьчеләргә һәйкәл.

280 меңнән артып китә. Басмаларның төп өлешен дини әдәбият, дәреслекләр, Шәрекъ белгечләре әсәрләре, медицинага караган хезмәтләр тәшкил итә.

*Әд.:* В л а д и м и р о в В. Историческая записка о 1-й Казанской гимназии 18 столетия. К., 1867; А р и с т о в В.В. Материалы цензурного комитета при Казанском университете: 1812–1827 // Описание рукописей Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского. К., 1961. Вып. 7; К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги. К., 1971.

**АЗНАКА́ЕВ** Әмир Гани улы (5.4.1951, Киев), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1997). 1973 елда Киев ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1997 дән Украина ФАнең Гидромеханика ин-тында, бер үк вакытта Халыкара гражданнар авиациясе ун-тында (Киев). Хезмәтләре молекуляр, статистик һәм биологик физикага карый. Тыгыз газда, сыеклыкларда һәм аларның катнашмаларында, бер кисәкчәле һәм күп кисәкчәле хәрәкәтне дә исәпкә алып, кисәкчекләр күчеше процесслары теориясен, ш.у. турбулент хәрәкәт теориясен төзи, аерым чыгарылмалы интегродифференциаль тигезләмәләрне аналитик чишү ысулларын эшли.

Х е з м.: Электричество: Учеб. для студентов вузов. Киев, 1991; Магнетизм: Учеб. для студентов вузов. Киев, 1992.

**АЗНАКА́Й**, республика карамагындагы шәһәр, Азнакай р-ны үзәге. Татарстанның көнчыгыш төбәгендә, Казаннан 376 *км* ераклыкта, Эстәрле елгасы буенда, Ульянов–Уфа тимер юлындагы Ютазы станциясеннән 34 *км* төньяк-көнбатыштарак. Мәйданы — 15,3 *км*². 2006 елда 34,8 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 89,1%) яши. Республиканың көньяк-көнчыгышындагы сәнәгать үзәкләреннән берсе. «Азнакайнефть» НГДУы, «Нефтемаш», «Перекрыватель», УАЗ автомобильләрен ремонтлау, май з-длары, икмәк комб-ты, типография; энергетика, а.х. техникасы, тегү сәнәгате һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү пр-тиеләре. 9 урта, 1 музыка мәктәбе, һөнәри лицей бар. Төбәк тарихын өйрәнү музее, район мәдәният йорты, 6 китапханә (ш.и. 2 се балалар өчен), үзәк район һәм балалар хастаханәләре эшли. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинник катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эшләре б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да 1 мәчет, 1889 да 2 мәчет була. 20 йөз башында волость идарәсе, земство станы урнаша. 4 су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр А. Самара губернасы Бөгелмә өязенең Азнакай волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 ның 10 августыннан Тымытык р-нында. 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай р-ны үзәге, 1956 ның 14 июненнән — шәһәр тибындагы посёлок, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-ны составында, 1963 нең 27 августыннан — яңа оешкан Азнакай сәнәгать р-ны үзәге, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан район үзәге, 1987 нең 12 мартыннан — республика карамагындагы шәһәр. Халык саны: 1859 да — 1103, 1889 да — 1610, 1908 дә — 1932, 1926 да — 1326, 1938 дә — 2105, 1949 да — 1958, 1958 дә — 9731 кеше, 1989 да — 32,2 мең кеше.

*Әд.:* Азнакай: Кыскача мәгълүмат. К., 1996.

**АЗНАКА́Й АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, Азнакай р-нының үзәк өлешендә урнашкан.

Мәйданы 30 мең *га*, ш.и. урманнар — 8,9 мең *га*. Мәллә, Кәкре Елга, Сукаеш, Вәрҗәде, Мәнәвез елгалары ага. 1978 елда ТРда сирәк очрый торган сөркә-байбак төрен саклауны көчәйтү максаты б-н оештырыла. 1000 нән артыграк сөркә исәпләнә. Тыюлыкта ш.у. поши, кабан дуңгызы, кәҗәболан, суер, соры көртлек саклана. 1999 елда А.а.т. составыннан «*Чатыр Тау*» комплекслы табигать тыюлыгы бүленеп чыгарыла.

**АЗНАКА́Й РАЙОНЫ́**, ТРның көнчыгышында урнашкан, Башкортстан Респ-касы б-н чиктәш. Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы икътисади р-нына керә. Мәйданы — 2141 *км*². 26 авыл, 1 шәһәр җирлеген (штп Актүбә), 77 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Азнакай шәһәре. Халкы — 2006 елда 30,6 мең кеше (район үзәгендәге халык санын кертмичә), 2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 80,8%, руслар — 14,9%. Шәһәр халкы — 9,6, авылларда 21 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 15 кеше. Район 1931 нең 30 октябрендә оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Самара губернасының Бөгелмә өязенә, 1920–30 елларда — Бөгелмә кантонына, 1930–31 дә Тымытык р-нына керә. 1931 нең октябрендә Тымытык р-ны үзәге Азнакай авылына күчә һәм район Азнакай р-ны дип үзгәртелә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1016 *км*², халкы — 24,8 мең кеше, 18 авыл советы, 37 торак пункт була. 1958 дә А.р.на 1935 тә яңадан торгызылган һәм соңрак таркатылган *Тымытык районының* бер өлеше керә. 1960 та район 1631,1 *км*² җир били, составында 2 посёлок советы (шәһәр тибындагы Азнакай һәм Актүбә посёлоклары), 15 авыл советы, 77 торак пункт исәпләнә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә А.р. таркатыла, биләмәсе Әлмәт р-нына бирелә. 1963 нең 27 августында Азнакай, Актүбә, Ак Түбә торак пунктларыннан махсус Азнакай сәнәгать р-ны оештырыла. Азнакай сәнәгать р-ны, Әлмәт һәм Бөгелмә р-ны терр-яләренең бер өлешен кертеп, 1965 нең 12 гыйнварында А.р. яңадан торгызыла. 1966 да мәйданы — 2183 *км*², халкы — 56,7 мең кеше, 2 посёлок советы, 19 авыл советы, 101 торак пункт исәпләнә. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль р-н дип үзгәртелә. А.р. рельефы — калкулыклы тигезлек (биеклеге 76 — 334,5 *м*), киң тирән елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән. Нефть һәм газ ятмалары бар. Район җиреннән Ык, аның кушылдыклары Эстәрле, Мәллә һ.б. елгалар ага. Җирләре күбесенчә типик, селтесезләнгән, карбонатлы кара туфраклы. Терр-ясенең 16,8% урманнар б-н капланган. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Ык һәм Эстәрле елгалары, *Чатыр Тау* табигать саклаулыгы, *Владимировка сөзәклеге* табигать тыюлыгы, *Азнакай аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә нигездә бронза дәверенә караган 40 тан артык археологик истәлек табыла. А.р. — нефть сәнәгате нык үскән регион. Сәнәгать пр-тиеләре, нигездә, район үзәгендә һәм шәһәр тибындагы Актүбә посёлогында урнашкан. Тымытык авылында агач эшкәртү комб-ты бар. *Азнакай урман хуҗалыгы* эшли. Терлекчелек, умартачылык тармаклары алга киткән. 2006 да а.х. җирләре 131 мең *га* били, ш.и. 111,9 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, арыш, арпа, борчак, карабодай игелә; шикәр чөгендере үстерелә. 2006 да районда 36 а.х. пр-тиесе исәпләнә, ш.и. 13 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, 21 а.х. товарлары җитештерү кооперативы, 1 крәстиян-фермерлык хуҗалыгы, 1 ышанычтагы ширкәт. А.р.н Әлмәт, Бөгелмә, Баулы һ.б. шәһәрләр б-н автомобиль юллары тоташтыра. Районда (район үзәге б-н бергә) 57 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 9090 укучы укый), ш.и. 14 башлангыч, 42 урта мәктәп, 2 коррекция мәктәбе; 1 балалар сәнгать һәм 3 музыка мәктәбе, 56 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 48 клуб, 37 китапханә, 610 урынлы 6 хастаханә эшли. Азнакайда төбәк тарихын өйрәнү музее бар. Татар һәм рус телләрендә «Маяк» г-тасы нәшер ителә.




**АЗНАКА́Й ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Азнакай муниципаль музее. 1992 елның 14 июлендә оеша, 1999 ның 18 маенда ачыла. Биш катлы бинаның бер катлы янкормасында урнашкан. Экспозициянең мәйданы 191 *м*², төп фондта 4687 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция өч залны били, төбәкнең иң борынгы дәверләрдән алып бүгенге көннәргәчә тарихын чагылдыра. Беренче залда археологик коллекцияләр, көнкүреш, һөнәрчелек, җирле кәсепчелек әйберләре, татарларның 19–20 йөзләрдәге декоратив-гамәли сәнгате эшләнмәләре урнаштырылган. «Азнакай районы — нефть һәм газ төбәге» залында палеонтологик коллекцияләр һәм минераллар, бораулау вышкасы, нефть чыгару җайланмалары макетлары һәм танылган нефтьчеләрнең — Социалистик Хезмәт Геройларының фотографияләре куелган. «Азнакай, синең кешеләрең» экспозициясендә күренекле кешеләр: шагыйрьләр М.Б.*Галиев*, Ә.К.*Кари*, И.С.*Гыйләҗев*, Ф.С.*Гыйззәтуллина*; язучылар Н.Г.*Әхмәдиев*, Г.З.*Галиева*, РФнең халык артисткасы Н.Г.*Ихсанова*, РСФСРның халык артисты Ә.Ш.*Шакиров*, генераллар Ф.Г.*Булатов*, Т.Э.*Сәйфетдинов* һ.б.ның мемориаль әйберләре, районның танылган шәхесләренең документлары урын алган.



Азнакай төбәк тарихы музее. Экспозиция фрагменты.

Музейда ел саен Халыкара музейлар көне (18 май), Татарстан Республикасы көне (30 авг.) уздырыла.

**АЗНАКА́Й УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Азнакай, Сарман һәм Мөслим р-ннары терр-ясендә урманчылык эшләрен алып бара. 1931 елда 29846 *га* мәйданда Тымытык урман хуҗалыгы буларак оештырыла. 1939 да аңа җирле әһәмияте булган урманнар кушыла. 1994 тә Азнакай урманчылыгыннан Чатыр Тау урманчылыгы аерылып чыга. 1995 тә Сарман урманчылыгы булдырыла. 2006 ның 1 гыйнварына А.у.х.ның гомуми мәйданы 44401 *га*, ш.и. урман мәйданы 40942 *га*. Түбәндәге урманчылыкларны үз эченә ала: Азнакай — 8132 *га*, Җәлил — 11845 *га*, Мәлбагыш — 10523 *га*, Чатыр Тау — 9680 *га*, Сарман — 4221 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Азнакай шәһәрендә. Эшләүчеләр саны 181 кеше. 1 нче төркем урманнар 16160 *га* мәйданны били, алар эчендә: табигать истәлекләре — 439 *га*, яшел зона урманнары — 4724 *га*, туфрак саклый торган урманнар — 10997 *га*. Җирле әһәмияткә ия булган 2 нче төркем урманнар 28241 *га* мәйданны били. Ылыслы агачлар — 27,6%, каты яфраклылар — 13,1%, йомшак яфраклылар 59,3% урман мәйданын алып тора. Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 35,2%, урта яшьтәгеләр — 21,4%, өлгереп килүчеләре — 14,1%, өлгергәннәре һәм картайганнары — 29,3%. Нарат урманнары 10874 *га* мәйданны биләп тора, яшь һәм урта яшьтәге кулдан утыртылган агачлардан гыйбарәт. Агач запасы 1588,7 мең *м*³. Бонитет классы 1а, 1 һәм 2. Типлары буенча куаклы һәм өрәңгеле нарат урманнары аеруча киң таралган. Кулдан утыртылган чыршы урманнары 771 *га* мәйданны били. Агач запасы 82,5 мең *м*³. Бонитет классы 1. Каенлык һәм усаклыклар чиста массив булып утыралар, ара-тирә имән б-н катнаш. Каенлыклар мәйданы — 12813 *га*, усаклыклар — 6514 *га*. Агач запасы 2291,4 мең *м*³ һәм 1038,2 мең *м*³. Бонитет классы 1 һәм 2. Типлары буенча күрәнле,

сырмавыклы һәм тубылгылы каенлыклар; күрәнле, сырмавыклы һәм өрәңгеле усаклыклар киң таралган. Каен һәм усакның яше 65 кә кадәр, кәүсә биеклеге 24 *м* га кадәр җитә. Имәнлекләрнең мәйданы — 6603 *га*, нигездә, үсентеләрдән барлыкка килгәннәр, тәбәнәкләр, өлешчә каен б-н катнаш. Агач запасы 778,9 мең $м^3$. Юкә урманы күбесенчә Чатыр Тау урманчылыгының төньяк өлешендә тупланган. Гомуми мәйданы 1168 *га*. Урман үстерү үрнәге булган югары җитештерүчәнлекле нарат урманнары, ш.у. эстетик һәм рекреацион әһәмияткә ия булган кыйммәтле урман массивлары аеруча саклана торган табигать терр-яләре буларак билгеләнә: «*Бохарай наратлыгы*» (1989), «*Сөлек урманы*» (1994) һәм «*Чатыр Тау*» (1999). Төп кулланылышта еллык урман кисү 25 мең $м^3$ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан 596 *га* мәйданда чистарту эшләре башкарыла, шуның б-н бергә 7 мең $м^3$ күләмдә агач әзерләнә. 2005 елга кадәр урман фондындагы 80–100 *га* мәйданда урманнарны торгызу эшләре үткәрелгән. А.х. җирләренең 60–100 *га* мәйданында саклагыч агачлыклар булдырылган. Урман хуҗалыгы питомнигында 16 төрле агач-куак токымнарыннан 2 млн. үсенте һәм чәчкен үстерелә. А.у.х.нда 15 тән артык төрдәге халык хуҗалыгы товарлары (пиломатериаллар, такталар, штакетниклар, буралар, әзер коймалар һ.б.) җитештерелә. Урман хуҗалыгы үсешенә һәм аның эшчәнлеген камилләштерүгә зур өлеш кертүчеләр — ТРның атказ. урманчылары С.Г.Гурьянов, С.Г.Кашапова, А.Г.Галимов.

*И.Н.Зарипов, Л.В.Веткасова.*

**«АЗНАКАЙНЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть һәм газ чыгару идарәсе (НГДУ). Нефть чыганакларын эшкәртү, нефть чыгару һәм сату, нефть һәм газ сәнәгате объектларын проектлау, төзү һәм файдалану б-н шөгыльләнә. 3091 кеше эшли (2005). 1956 елда «А.» нефть промыселы идарәсе буларак оештырыла, 1970 тән НГДУ. 1965 елда аның җирлегендә 2 мөстәкыйль идарә оештырыла: «А.», «Актүбәнефть», 1996 елда алар яңадан «А.» НГДУ булып берләшә. Үзәкләштерелгән сәнәгать базалары Азнакай шәһәрендә һәм шәһәр тибындагы Актүбә посёлогында урнашкан. «А» составында: 7 нефть чыгару цехы, нефть катламнарында басымны нормада тотучы 2 цех, нефтьне суыртып агызу һәм комплекслы әзерләү цехы, сәнәгать базаларына хезмәт күрсәтүче 9 цех, 2 технология-транспорт идарәсе эшли (2006). Эшне Ромашкино нефть чыганагының 6 биләмәсендә — Павлово, Зеленогорск, Көнчыгыш Лениногорск, Холмово, Азнакай, Карамалы мәйданнарында алып бара. Эшкәртүнең соңгы стадиясендә торган югары девонның паший горизонты терриген утырмалары төп эксплуатация объекты булып тора. Ш.у. түбән карбонның терриген (№№ 2, 3, 33, 190) һәм карбонат (№№ 281, 292), югары девонның Данков-Лебедянь горизонты утырмаларының вак ятмалары эшкәртелә.

Ятмаларның зур өлеше катламнарның басымын су тутыру юлы б-н көйләп эшкәртелә. «А.»нең нефтьле мәйданнарында нефть чыганакларын эшкәртү процессларын көйләү һәм тикшерү буенча яңа технологияләр, приборлар һәм алымнар сынала. «А.» тарафыннан гамәлгә кертелгән эре масштаблы проектлар арасында — скважиналар челтәре тыгызлыгының нефть чыгаруга йогынтысы, аз үткәрүчән коллекторларны эшләү технологиясе, урынын сайлап суландыру, нефть катламнарына циклы тәэсир итү, нефть чыгаруны арттыруның гидродинамик һәм физ.-хим. алымнары бар.

Азнакай нефть мәйданының тәҗрибә участогында мицелляр-полимер суландыру алы-



Нефть суырту җайланмасы.

мы б-н катламның нефть бирүчәнлеген күтәрү буенча тармакkүләм әһәмияткә ия сәнәгый тәҗрибәләр уздырыла. Катламнарга прогрессив алымнар б-н тәэсир итү исәбенә табылган нефть ел буе чыгарылган нефтьнең 42% ын тәшкил итә. Еллык нефть чыгаруның максималь күләме — 17,1 млн. *т* (1972); барлыгы 450 млн. *т* нефть чыгарылган, ш.и. 2005 елда — 3,4 млн. *т*. Чыгарылган продукциянең сулылыгы 88%. 2005 елга 6130 скважина бораулланган, шуларның 2919 файдаланыла (нигездә, насос алымы б-н). Нефть җыю системасы герметик хәлдә. «А.»тә нефть чыгару һәм әзерләүнең алдынгы технологияләре кулланыла. Нефть промыселларын комплекслы автоматлаштыру һәм телемеханикалаштыру гамәлгә ашырыла. Республикада беренчеләрдән булып, җиңел фракцияләрне тотып калу юлы б-н нефтьне комплекслы әзерләү алып барыла. Девон нефте Азнакайның нефтьне комплекслы әзерләү җайланмасында әзерләнә, югары горизонтлардагы нефть «Татнефть» АҖнең «Җәлилнефть», «Иркеннефть» НГДУларына җибәрелә. «А.» үзе эшчәнлек алып барган зонадагы зарарланган җирләрне яңадан торгызуга, әчәргә яраклы су чыганакларын карап тотуга, әйләнә-тирәгә техноген йогынтыны киметүгә аерым игътибар итә. Укыту-курслар комб-ты, социаль объектлар, ял йорты, 2 санаторий-профилакторий, Актүбәдә мәдәният йорты бар.

«А.» Азнакай шәһәрендә һәм Актүбә посёлогында торак йортлар, халык мәгарифе һәм сәламәтлек саклау, социаль-мәдәният, мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, спорт объектлары һ.б. төзү эшләрен дә башкара. «А.» НГДУ эшчеләренең шактыена югары дәүләт бүләкләре бирелә, ш.и. Соц. Хезмәт Герое исеме — 1 кешегә, Ленин ордены — 9, Октябрь Революциясе — 12, Хезмәт Кызыл Байрагы — 70, Халыклар Дуслыгы ордены 7 кешегә бирелгән. «А.» НГДУ җитәкчеләре: Н.А.Мальцев (1956–60), В.А.Тимонин (1960–63), А.С.Халаберда (1964–70), В.А.Сорокин (1970–74); Е.И.Старов (1974–85), А.А.Фәсхетдинов (1985–96), Р.К.Ишкәев (1996–2005), Р.Х.Галимов (2005 тән). «Актүбәнефть» НГДУында: Р.М.Шаһалиев (1965–69), А.С.Яруллин (1969–82), Р.К.Ишкәев (1982–96).

*Әд.:* Х а с а н о в М.М. Азнакаевские фонтаны: Очерк. К., 1967; 40 лет НГДУ «Азнакаевскнефть» (1956–96). Азнакаево, 1996.

*В.И.Морозов, Р.И.Фәйзуллин, В.М.Хөсәенов, Н.Г.Әхмәтов.*

**АЗО́В-ДОН АКЦИОНЕРЛЫ́К-КОММЕ́РЦИЯ БА́НКЫ**, 1871 елда Таганрог шәһәрендә оештырыла, 1903 тән идарәсе С.-Петербургта. Максаты: финанс ресурсларын туплау, дәүләт, сәнәгать, сәүдә оешмаларына һәм аерым кешеләргә бурычка (кредитка) акча биреп тору, кыйммәтле кәгазьләр б-н эшләү. А.-Д. а.-к.б. Франция банклары, Англия финансистлары б-н эш йөртә (Парижда бүлендек банкы эшли). Төп капиталы 50 млн. сум (1913). Россиядә 70 бүлекчәсе эшли. Казан бүлеге 1871 елның 2 июлендә ачыла, 1915 тә аның активында 3,6 млн. сумнан артыграк акча була. 1917 нең декабрендә милке дәүләт тарафыннан үзләштерелә. Ш.у.к. *Татарстан Республикасының милли банкы.*

**АЗО́ТЛЫ АШЛАМАЛА́Р**, составында азот булган һәм үсемлекләрне азот б-н тукландыру чыганагы буларак кулланыла торган минераль матдәләр. Азот, аксымнар синтезында катнашып, чәчүлекләрдә үсемлекләрнең үсешен көчәйтә, а.х. продукциясенең, бигрәк тә кыяклы бөртеклеләрнең һәм күпчелек терлек азыгы культураларының сыйфатын яхшырта. Сәнәгать эшләп чыгарган минераль ашламалар б-н беррәттән, составында үсемлекләр туклануы өчен азоттан башка элементлары да булган органик ашламалар (торф, тирес, компост), ш.у. яшел ашламалар (люпин, донник, сераделла һ.б.) азотлылар сыйфатында күптәннән кулланылып килә.

Минераль А.а. 4 төркемгә берләшә: амидлы, аммиаклы, аммиаклы-нитратлы, нитратлы. Амидлы ашламаларга мочевина (карбамид) һәм кальций цианамиды керә. Мочевина аеруча кыйммәткә ия (составында 46% азот бар), туфракта ул аммоний карбонатына әверелә. Күшәүче хайваннарны өстәмә тукландыруда аксым буларак файдаланыла. Кальций цианамиды (составында 20–22% азот бар) — селтеле ашлама, туфракның ачылыгын киметә. Көпшәк, нейтраль туфракларда нәтиҗәле, ләкин рәтләргә һәм оялап кертү өчен яраксыз. Аммиаклы һәм аммонийлы ашламалар — аммоний сульфаты, хлорлы аммоний, аммоний бикарбонаты һәм сыек А.а. Аммоний сульфаты (20,5% азот һәм 24% күкерт) б-н хлорлы аммоний шушы ук ашламаларның әчетү тәэсирен нейтральләштерүче нигезләр б-н туенган туфраклар (кара туфрак, соры туфрак, аксыл-коңгырт туфрак) өчен файдалы. Хлорлы аммонийда хлорның кирәгеннән артык булуы күп кенә а.х. культуралары (бәрәңге, майлы үсемлекләр һ.б.) уңышының күләменә һәм сыйфатына

начар йогынты ясый. Аммоний бикарбонаты (составында 17% азот бар) селтеле реакциягә ия, ләкин туфракта нитрификацияләнә. Аммиак формалы А.а.дан сусыз сыек аммиак һәм сулы аммиак кебек сыек ашламалар яхшы нәтиҗә бирә. Аммиаклы (аммонийлы)-нитратлы ашламаларга аммиак селитрасы (к. *Яңа Менделеев химия заводы*), аммоний сульфанитраты (аммоний нитросульфаты) керә. ТР шартларында А.а.дан аммиак селитрасы (34% азот) киң кулланыла, ул туфракны аз ачыландыра. Аммоний сульфанитратының ачыландыру сәләте чагыштырмача югары. Нитратлы ашламаларга натрий һәм кальций селитралары керә. Натрий селитрасы (натрий нитраты, чили селитрасы) — физиологик селтеле ашлама, күбесенчә ачы туфракларда кулланыла (шикәр чөгендере һәм бодай иккәндә). Кальций селитрасы туфракны селтеләндерә. Үсемлек калдыклары черемәсе, тирес һ.б. төрдәге А.а. борынгы заманнардан бирле кулланылган. 20 йөз башында сәнәгать натрий селитрасын, аммоний сульфатын, кальций селитрасын эшләп чыгара башлый. 1914–18 елларда аммиакны һавадагы азоттан һәм водородтан синтезлау сәнәгать масштабында үзләштерелгәннән соң, А.а. җитештерү кискен үсеш ала.

А.а., төп ашлама буларак, өстәмә тукландыру өчен һәм чәчү вакытында кертелә (рәтләп ашлау). А.х. җирләренең яртысы диярлек кәсле-көлсу һәм соры урман туфраклы булган ТРда А.а. куллануга зур игътибар бирелә, аммиаклы су һәм сыек аммиак (82,2% азот) куллану буенча да бай тәҗрибә тупланган. Сыек А.а., төп ашлама буларак, барлык а.х. культуралары басуына кертелә. ТРда а.х.ның А.а. б-н тәэмин ителеше (азотка күчереп исәпләгәндә, мең *т*): 1975 елда — 59,2, 1981 дә — 110,8, 1985 тә — 137,4, 1990 да — 177,5, 2000 дә — 146,1 һәм 2006 да — 105. Органик ашламаларда азот концентрациясе якынча 0,3–3,5%, минераль ашламаларда — 13–82,3%. ТРда А.а. кертүнең якынча нормасы (азотка күчереп исәпләгәндә, 1 гектарга *кг* нарда): уҗым һәм сабан ашлыкларына 40–60; силос өчен кукурузга — 60–120; шикәр чөгендеренә кара туфраклы җирләрдә — 45–60, кара туфраклы булмаган зонада — 80–120; бәрәңгегә — 45–90. Табигый азотка баерак туфракларга ашламалар нормадан кимрәк кертелә.

*Әд.:* Прянишников Д.Н. Избр. соч. М., 1963. Т. 1; Справочник по удобрениям. М., 1964; Системы земледелия Татарской АССР. К., 1983; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992.

*И.А.Гайсин, Ф.С.Зыятдинов.*

**АЗОТОБА́КТЕР** (Azotobakter), һава азотын үзенә җыеп, шуннан үз күзәнәкләренең аксымын синтезлаучы мөстәкыйль аэроб бактерияләр ыругы. Табигатьтә азот әйләнешендә әһәмияте зур, таркалганда үсемлекләрне азотның җиңел үзләштерелә торган формалары һәм минераль матдәләр б-н тәэмин итә. ТРда туфракта уңайлы шартлар (pH 5,5–7,8, иң уңайлы дымлылык һ.б.) булганда А. 1 *га* да 20 *кг* га кадәр азот туплый. Республикада А.ның бактериаль ашлама — азотобактерин әзерләү өчен кулланыла торган хрококкум төре киң таралган.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**АЗУРИ́Т** (фр. lazur — зәңгәр, лазурь), бакыр зәңгәре, карбонатлар классына керүче минерал, $2CuCO_3 \cdot Cu(OH)_2$ малахит төркемендә. Бакыр микъдары 55,3% ка кадәр. Куе зәңгәр, җирсыман массаларда — сыек зәңгәр төстә, пыяласыман ялтырый. Катылыгы 3,5–4, уалучан. Тыгызлыгы 3,7–3,9 *г/см*³. А. кислоталарда эри ($CO_2$ бүленеп чыга). Вак кристаллардан торган друзалар, тоташ бөртекле массалар рәвешендә була. ТРда Кама елгасының



Бакырлы комлыктагы азурит б-н малахит. ТРның югары Пермь ятмалары.

уңъяк ярындагы югары Пермь утырмаларының *бакыр рудаларында* юка кристалл хәлендә очрый. Зәңгәр буяу эшләү өчен чимал булып тора.

**АЗЫ́К-ТӨЛЕ́К ҖИТЕШТЕРУ́ СӘНӘГАТЕ́**, сәнәгатьнең азык-төлек продуктлары — ит, сөт, сыр-май, икмәк пешерү, макарон, шикәр, кондитер әйберләре, спирт һәм аракы-ликёр, сыра кайнату, алкогольсез эчемлекләр, җиләк-җимеш, яшелчә, крахмал-патока, балык һәм парфюмерия-косметика әйберләре, тәмәке җитештерү тармакларын берләштерә.

ТРда милекнең төрле формаларына караган (күбесенчә хосусый) 1193 пр-тие (ш.и. 182 кече пр-тие) санала. 2005 елга сәнәгать продукциясендәге өлеше 6,3% (31,7 млрд. сум) тәшкил итә, эшләүчеләр саны 8,9% (34,2 мең кеше). Бигрәк тә икмәк пешерү, сөт һәм сыр-май, ит, шикәр, сыра, спирт, аракы-ликёр эшләп чыгару тармаклары алга киткән. Республикада аларны эшләү өчен куәтле чимал базасы булдырылган. Казан губернасында А-т.җ.с. 18 йөз урталарында формалаша. Казан, Чистай, Мамадыш һ.б. шәһәрләрдә икмәк пешерү, аракы, спирт з-длары, 19 йөзнең 2 нче яртысында кондитер ф-калары эшли башлый. 19 йөздә азык-төлек җитештерү пр-тиеләренең саны арта, пар машиналары һ.б. техник җайланмалар кулланыла. 19 йөз уртасында а.х. продукциясен эшкәртүче сәнәгать пр-тиеләренең өлеше 80% тан артып китә. 1870 елларда азык-төлек сәнәгатендә эшләүчеләр сан һәм эшләп чыгаруның чагыштырма күләме ягыннан сәнәгатьтә 1 нче урында тора, бу тармак пр-тиеләрендә яллаunion эшләүчеләрнең саны 45,7% тәшкил итә. Пр-тиеләрнең яртысы диярлек терлекчелек чималын эшкәртә, өчтән бере — үсемлекчелек чималы куллана. Азык-төлек сәнәгате пр-тиеләре, башлыча, шәһәрләрдә урнаша. 19 йөз ахырында терлекчелек продукциясе эшкәртү пр-тиеләренең саны кими, үсемлекчелек продукциясен эшкәртү арта. 1888 дә үсемлекчелек продукциясен эшкәртүче пр-тиеләр төбәктәге тулай сәнәгать продукциясенең 24,5% ын тәшкил итә (1858 дә 17% тан артмый). 1858–88 дә азык продуктларын җитештерүдә һәм азык әзерләүдә эшләүчеләрнең саны 4 тапкырга арта.

1905 тә Казан губернасында үсемлекчелек продукциясе — 186, терлекчелек продукциясе 81 эре пр-тиедә эшкәртелә, күбесенчә кул хезмәте кулланыла. 1913 елга сәнәгать пр-тиеләре санына карата (423) беренчеләренең өлеше 63% ка кадәр арта, икенчеләренеке 17% ка кадәр кими. А.х. продукциясен эшкәртү сәнәгатенең гомуми күләме 68% тәшкил итә. Эре пр-тиеләр күбрәк спирт, аракы-шәраб, сыра һәм бөртекле ашлыкны эшкәртү, икмәк пешерү тармакларына карый. Алар арасында И.Г.Стахеев (хәзерге Сарман р-ны Петровка а.), Н.Щербаков (Мамадыш ш.), И.В.Александров (Казан) спирт з-длары; О.Э.Петцольд һәм И.В.Александровның сыра кайнату з-длары (Казан). Е.С.Смоленцевның крахмал-патока з-ды (Столбище, Дәүләки а.); бертуган Афанасьевлар һәм И.С.Один-

ТР азык-төлек җитештерү сәнәгатенең төп күрсәткечләре

| Еллар | 1990 | 2000 | 2006 |
|---|---|---|---|
| Гамәлдәге пр-тиеләр саны | 123 | 328 | 1172 |
| Продукциянең күләме, млн. сум | 1423 | 13349 | 37592 |
| Җитештерү сәнәгате индексы, алдагы елга карата % ларда | 103,9 | 108,6 | 107,2 |
| Продукциянең табышлылыгы, % ларда | ... | 9,8 | 4,8 |
| Җитештерү сәнәгатендә эшләүчеләр саны, мең кеше | 31 | 38 | 34 |
| Ит, 1-категорияле субпродуктларны да кертеп (сәнәгый эшләп чыгарылган), мең *т* | 206 | 41,3 | 49,8 |
| Балык продукциясе, мең *т* | 7,4 | 2,3 | 2,4 |
| Аертылмаган сөт продуктлары сөт исәбеннән, мең *т* | 479,4 | 160,6 | 221,8 |
| Майлы сыр, мең *т* | 10,3 | 12,1 | 39,5 |
| Атланмай, мең *т* | 30,8 | 17,5 | 22,0 |
| Икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре, мең *т* | 482 | 263 | 213,4 |
| Шикәр комы, мең *т* | 61,6 | 153,6 | 166,7 |
| Кондитер әйберләре, мең *т* | 66,6 | 33,6 | 34,9 |
| Аракы һәм шәраб-аракы әйберләре, мең *дал* | 3244 | 8734 | 4771 |
| Сыра, мең *дал* | 9356 | 26134 | 18463 |

цов, В.Ибраһимов, Н.П.Пирогов, И.Д.Смирновларның кондитер ф-калары; сәүдәгәр Е.С.Смоленцевның икмәк пешерү фирмасы (3 пекарня һәм 3 сәүдә ноктасы) һ.б.

Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышы елларында А.-т.җ.с. пр-тиеләренең шактые ябыла. 1922 дә дәүләтләштерелгән пр-тиеләр базасында ТАССР азык-төлек сәнәгате пр-тиеләренең берләштерелгән завод һәм фабрикалар идарәсе «Тат. азык-төлек тресты» оештырыла (1931 гә кадәр яши). 1920 еллар ахырында азык-төлек сәнәгатенең эре дәүләт пр-тиеләре төзелә. 1924 тә Казанда «Светоч» кондитер ф-касы, 1929 да 1 нче номерлы икмәк з-ды, «Казан суыткычы» файдалануга тапшырыла. Сөт һәм сыр-май з-дларының саны 160 ка җитә (1930).

А-т.җ.с. 1930 елларда интенсив үсеш ала. 1933–37 дә төп җитештерү фондлары ике мәртәбә арта. Ит һәм сыр-май җитештерү тармаклары тиз алга китә, алар республика А.-т.җ.с. продукциясенең 20% ын тәшкил итәләр. *Казан ит комбинаты, Бөгелмә ит комбинаты, Чистай ит комбинаты*, Бөгелмәдә ярма яру з-ды, азык-төлек җитештерү комб-ты, суыткыч җайланмалар төзелә; Казанда 2 икмәк пешерү з-ды (№ 2 һәм № 4), макарон ф-касы (к. *Казан макарон фабрикасы*), он тарту комб-ты; Азнакай, Буа р-ннарында май з-длары, Алексеев авылында коры сөт з-ды (к. *Алексеев сөт-консерв комбинаты*), Мамадыш һәм Алабуга шәһәрләрендә спирт-аракы з-длары, күп кенә район үзәкләрендә икмәк з-длары төзелә.

Бөек Ватан сугышы елларында тармак пр-тиеләре фронт ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен эшли. 1946–50 дә продукция җитештерү 41% ка арта, 1940 ел б-н чагыштырганда 95% ка җитә, 1950 дә азык-төлек продукциясе республика сәнәгать продукциясе күләменең 5% ын тәшкил итә. 1951–70 тә продукция җитештерү 5 тапкыр үсә. Казан, Алабуга (к. *Алабуга ит-консерв комбинаты*), Чаллы, Чистай, Норлат (хәзерге Нурлат) шәһәрләрендә, Шәмәрдән посёлогында ит комб-тлары төзелә; 30 сөт һәм сыр-май, 25 икмәк пешерү, 5 консервлау з-ды, кондитер әйберләр җитештерү пр-тиеләре төзелә (Чистай, Әлмәт ш. һ.б.).

1950–60 та Татарстанда *шикәр җитештерү сәнәгате* барлыкка килә: *Норлат шикәр заводы* (1958), *Буа шикәр заводы* (1960), *Зәй шикәр заводы* (1967). 1950 елларда Казанда һәм Буада тәмәке ф-калары сафка баса. 1968 дә А-т.җ.с. продукциясе республика сәнәгать продукциясе күләменең 15,9% ын алып тора. 1971–85 тә азык-төлек продукциясенең күләме 57% ка, 1986–90 да 28% ка арта. Үсемлек мае, майонез, маргарин җитештерү (Казан май комб-ты, 1996), кондитер әйберләр (ЖЧ «Джойта» ширкәте, «Чаллы-икмәк» АҖ — икесе дә Чаллы шәһәрендә, 1994), өсте алынмаган сөт продуктлары, ак май җитештерүче «Эдельвейс-М» ЖЧҖ (1995) пр-тиеләре сафка баса.

1990 елларның 2 нче яртысында А-т.җ.с.нең продукция җитештерү күләме 30% ка кими, 2000 нән үсеш башлана, 1990 га карата җитештерү күләме индексы: 70% (1997), 84% (2000), 93% (2003). 2000–2004 тә эшләп килүче пр-тиеләрне реконструкцияләү һәм яңарту, яңаларын төзү эшләре башлана. Тармакның төп капитал фондына инвестицияләр салу 10,8 млрд. сум тәшкил итә. Төп фондларны яңарту коэффициенты 18,8% тан (2000) 27,6% ка (2003) күтәрелә, аларның тузу дәрәҗәсе 34–37% тан (1990 еллар) 26–30% ка (2000–2004) кими.

1930–90 да А-т.җ.с. структурасында район азык-төлек комб-тлары һәм кулланучылар кооперациясе пр-тиеләре мөһим урын алып тора, икмәк-күмәч, макарон, ит-сөт һ.б. продукциянең шактый өлешен алар чыгара.

*Ит эшкәртү сәнәгатенә* 9 ит эшкәртү комб-ты, 13 кошчылык ф-касы керә. Казан, Чистай, Шәмәрдән ит комб-тлары, Чаллы, Казан, Питрәч, Лаеш («Юбилейная» АҖ) кошчылык фабрикалары бу тармакта иң эреләрдән санала. Җитештерелгән продукциянең бер өлеше РФ төбәкләренә җибәрелә. Ит сәнәгате пр-тиеләрендәге җитештерү куәтенең ит җитештерүдә — 41,8%, колбаса җитештерүдә 65,7% файдаланыла (2004).

*Сөт һәм сыр-май җитештерү сәнәгатендә* милекнең төрле формаларына караган якынча 50 ләп эре һәм уртача зурлыктагы пр-тие исәпләнә, аларның гомуми эшкәртү куәте елга 2 млн. *т* сөт эшкәртергә мөмкинлек бирә. Алар арасында «*Вамин-Татарстан*, «Чистай сөт комбинаты», Яшел Үзән сөт комб-ты АҖләре, «Эдельвейс-М» (Казан), «Химкамагро» (Түбән Кама) ЖЧҖләре иң эреләреннән санала. 1990 еллар уртасыннан тармак пр-тиеләрен үзгәртеп кору һәм яңарту башлана. Сөт продуктларының 160 тан артык төре чыгарыла, аларның 80 төре 1998–2004 елларда үзләштерелә. *Икмәк пешерү һәм макарон җитештерү сәнәгате* 300 ләп пр-тиене эченә ала. Икмәк-күмәч әйберләре җитештерүче төп пр-тиеләр: «Татархлеб» (продукциянең 22,5%), «Берләштерелгән икмәк компаниясе» (29,2%), «Чаллы-икмәк» (14,4%) АҖләре, «*Татреспотребсоюз*» икмәк комб-тлары һәм пекарняләре (14,8%). Кайбер сәнәгать һәм а.х. пр-тиеләре, фермер һәм шәхси эшмәкәрләрнең кече пекарняләре бар (19,5%). Икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре җитештерү елына 251–223 мең *т* тәшкил итә (2001–04). Пр-тиеләрнең төп җитештерү фондлары яңартыла, яңа технологик җиһазлар куела. Пр-тиеләр 80 нән артык төр икмәк, 125 төр кондитер һәм 20 төр макарон әйберләре чыгара. Макарон әйберләре Казан (1931–2005), Әлмәт, Бөгелмә, Чистай макарон ф-каларында, «Берләштерелгән икмәк компаниясе» АҖ дә, 8 кече пр-тиедә җитештерелә. 2005 тә 3,7 мең *т* тирәсе продукция чыгарыла (гомуми ихтыяҗның 15–25%). Продукция эшләп чыгаруда җитештерү куәте 11% ка файдаланыла (2005).

Шикәр җитештерү сәнәгатенә 3 пр-тие: «Буа шикәр заводы», «Зәй шикәре», «Нурлат шикәре» АҖләре керә. 2000–05 елларда бер елга уртача 186,3 мең *т* шикәр комы җитештерелә. Шикәр, башлыча, җирле чимал — шикәр чөгендереннән һәм өлешчә чит илдән кайтарылган чималдан алына. Буа һәм Зәй шикәр з-дларын реконструкцияләү нәтиҗәсендә аларның эшкәртү куәте 2 тапкыр арта.

*Кондитер әйберләр җитештерү сәнәгате* махсуслашкан 8 ф-ка, 20 икмәк пешерү з-дын һәм 10 нан артык кече пр-тиене эченә ала. *Казан «Заря» кондитер фабрикасы*», Казан күмәч-кондитер комб-ты, «Чаллы-икмәк» АҖләре, «Бәхетле» сәүдә компаниясе» ЖЧҖ, Чаллы, Чистай, Зәй һ.б. кондитер ф-калары эре җитештерүчеләрдән санала. Алар барысы бергә елга 29 мең *т* тирәсе кондитер ризыклары эшләп чыгара (2005). Чимал итеп, башлыча — җирле, өлешчә — РФнең коньяк төбәкләреннән һәм БДБ илләреннән алынган продукция кулланыла.

*Спирт һәм шәраб-аракы җитештерү сәнәгатенә* 7 пр-тие, ш.и. «*Татспиртпром*» АҖ керә, аның карамагында филиал хокукында спирт (6) һәм спиртлы эчемлекләр (2), алкогольле продукция (7) чыгара торган 15 пр-тие бар. 2003 тә елына 6 мең *дал* спирт чыгарырга сәләтле Буа ашлык эшкәртү комплексының 1 нче чираты сафка баса; ул нефть химиясе сәнәгатенә кирәкле чимал — техник спирт җитештерә. ТРда җитештерелә торган спиртның 50%ы РФ төбәкләренә һәм БДБ илләренә җибәрелә. 1996–2000 дә производствоны яңартып коруга 756 млн. сум инвестиция кертелә.

*Сыра һәм алкогольсез эчемлекләр җитештерү сәнәгате* «Кызыл Шәрекъ» сыра кайнату берләшмәсе» АҖ, «Солодовпиво» (Казан), «Болгарпиво» (Чаллы), «Агропак-Татарстан» ЖЧҖ (Лениногорск ш.), «Шифалы су» минераль сулар з-дын (Менделеев р-ны Ижевка пос.) (к. *Иж минераль сулары*) һ.б. шәраб з-дларын һәм азык комб-тларын берләштерә. РФдә эшләнә торган сыраның 3,0%ы ТРда җитештерелә (2005). 1996–2001 елларда Казанда елына 106 млн. *дал* сыра эшләү куәтенә ия булган зур завод төзелә.

*Җиләк-җимеш, яшелчә эшкәртү сәнәгатенә* «Татреспотребсоюз»ның Азнакай, Аксубай, Кукмара р-н кулланучылар җәмгыятьләренең консерв цехлары, Лаеш р-нының «Нармонка» АҖ, Яшел Үзән р-нының «Майский» агрокомбинаты, Арча р-нының Яңа Кенәр яшелчә киптерү з-ды керә, алар 12 млн. шартлы банка продукция җитештерә. 2006 да җиләк-җимеш, яшелчә консервлары җитештерү 5 млн. нан артык шартлы банка тәшкил итә, 285 *т* киптерелгән бәрәңге җитештерелә.

*Крахмал-патока җитештерү сәнәгатенә* «Таткрахмалпатока» АҖ керә, анда елына 2,3 мең *т* мальтоз патокасы, 4,7 мең *т* куас сосласы, 52 *т* саго җитештерелә (2006).

Балык үрчетү һәм эшкәртү сәнәгате балык тоту, эшкәртү һәм сату б-н шөгыльләнүче 5 заводны берләштерә. Тагын 50 ләп балык тотучы вак оешма эшли. 2006 елда балык тотуның күләме 1647 *т*, буаларда үстереп сатылганы 577 *т* тәшкил итә. 14 кечкенә пр-тие һәм цехлар диңгез һәм елга балыгын эшкәртү-тозлау, ыслау һәм балык продуктлары әзерләү б-н шөгыльләнә.

Парфюмерия һәм косметика әйберләре җитештерү буенча Идел буенда бердәнбер булган Казан «*Аромат*» АҖ (1942 дә нигез салына) эшләп килә. Илдәге табигый чимал-

дан 60 тан артык исемдә продукция эшләп чыгара.

Тәмәке җитештерү б-н 1942 елдан Казан тәмәке фабрикасы (1996 дан АҖ) шөгыльләнә. 1970–80 елларда елына 4–4,5 млрд данә төрле маркалы сигарет эшләп чыгара, 2005 тә ябыла. Буа тәмәке фабрикасы 1948--74 елларда елына 100 *т* га кадәр тәмәке (махорка) җитештерә, 1974 тән Буа сигарет тасмалары фабрикасы (Россиядә бердәнбер), 2002 дән АҖ, 2005 тә ябыла.

ТРда Һиндстаннан китерелгән чәйне үлчәп төрү б-н шөгыльләнүче берничә оешма бар: «Интат» ҖЧҖ, «Виктория» агрофирмасы» АҖ, «ТС Компани ЛТД». Алар елына 2,5 мең *т* чәй үлчәп төрәләр (кулланылган продукциянең 33–35% ын тәшкил итә).

Татарстанның А-т.ж.с. продукциясе сыйфат ягыннан чит илләрдән китерелгәннән калышмый, күп очракта аннан өстенрәк тә санала. Башлыча эчке базар ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Кайбер тармаклар һәм пр-тиеләр Россия һәм БДБ илләре базарларына да чыгалар (сөт продуктлары, спирт һ.б. алкогольле эчемлекләр, сыра, тәмәке). А-т.ж.с.нең специфик үзенчәлеге — җирле базарда эре пр-тиеләр монополиясе һәм аларның өстенлек итүе. Гомумән алганда, ТРның А-т.ж.с. икмәк-күмәч пешерү, сөт продуктлары, май, ит, казылык, йомырка, шикәр һ.б. азык продуктлары җитештерү ягыннан халык ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Республиканың азык-төлек базарында җирле товарлар 80–90% тәшкил итә, ш.и. сөт продуктлары — 90%, май — 85%, кош ите — 49%, казылык — 75%, шикәр — 75%, ярмалар — 63%, он — 70%, алкогольле эчемлекләр — 64% алып тора. Куллану товарлары күләменең 48,8% ын азык продуктлары тәшкил итә (2005). 1990 еллар башыннан шәригать кануннарына туры китереп, махсус стандарт нигезендә «хәләл» азык-төлек (ит, сөт продуктлары, кондитер эшләнмәләре һ.б.) җитештерелә. Андый ашамлыклар РФнең башка төбәкләренә дә чыгарыла.

Тармак пр-тиеләре өчен инженер-техник белгечләрне Казан технол. ун-ты һәм Казан механика-технол. техникумы, эшчеләрне 5 башлангыч һөнәри уку йорты әзерли.

*Әд.:* Абрамов П., Кладков Н., Шагимухаметов Ф. Наш край Татарстан. К., 1970; Белялов У.Б. Руководство Коммунистической партии социалистической индустриализацией в республиках Среднего Поволжья. К., 1978; Рабочий класс Татарии. К., 1981; История Казани: В 2 кн. К., 1988–91; Зарипов И.М. Пищевая промышленность Республики Татарстан // Пищевая промышленность. 1996. № 10; От прошлого в будущее / ОАО «Казанский молочный комбинат». 1932–2002. К., 2002.

*К.Ф.Фәсхетдинов, М.Җ.Гаитов.*

**АЙПОВ** Мәхмүт Ильяс улы (12.7.1920, хәзерге Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Кирюшкино а. — 22.4.1945, Каульсдорф, Германия), Сов. Союзы Герое (31.5.1945, вафатыннан соң), рядовой. 1942 елның маеннан Кызыл Армиядә. 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 5 нче удар армиянең 230 нчы укчылар дивизиясе 990 нчы укчылар полкы укчысы. Сталинград, Көньяк-Көнбатыш, Көньяк, 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Украинаны, Молдавияне, Польшаны азат итү сугышларында, Берлин операциясендә катнаша. Берлин, Каульсдорф өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



М.И. Аипов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Подвиг во имя Родины. Куйбышев, 1965. Кн. 1.

**АЙПОВ** Умар (Гомәр) Хәсән улы (март, 1905, Тамбов губ., Елатьма өязе Толстиково а. — ?), партия һәм профсоюз эшлеклесе. Ленинградта икътисадчылар курсларын тәмамлый (1931). 1931–37 елларда «Спартак» аяк киемнәре җитештерү ф-касында икътисадчы, тегү цехы парторгы, профсоюз ком-ты рәисе, кадрлар буенча директор урынбасары. 1937–38 дә ВКП(б)ның Казан шәһәре Молотов райкомында инструктор, секретарь; 1939–41 дә Татарстан өлкә ком-тында инструктор, оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире урынбасары, 1941–42 дә җиңел һәм җирле сәнәгать бүлеге мөдире. 1942–43 тә ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-тында сәнәгать тармаклары секретаре, 1943–46 да кадрлар буенча секретарь. 1946–53 тә ТАССРның җиңел сәнәгать министры, 1953–57 дә Профсоюзларның Татарстан төбәк советы рәисе. ТАССР ЮС депутаты (1947–51, 1955–59). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АЙТОВ** Аитзәк (1908, хәзерге Саратов өлкәсенең Дергач р-ны Алтата а. — 28.10.1941), шагыйрь. 1928 елдан комсомол эшендә. 1930 елларда А.ның күмәкләштерү чоры, комсомоллар тормышы турындагы патриотизм б-н сугарылган шигырьләре вакытлы матбугатта басыла. Күбесе 1961 дә чыккан «Алар сафта» исемле күмәк җыентыкка да кертелә. Смоленск өлкәсе Демидов шәһәре өчен барган сугышта һәлак була.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**АЙТОВ** Габдерәшит (18 йөз), 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында катнашучы, Е.И.Пугачёв гаскәре полковнигы. Пугачёвчылар кузгалышына 1773 елның декабрендә килеп кушыла. Баштарак И.Черняев һәм Ә.Уразмәтев отрядларында була. 1774 нең гыйнварында Е.И.Пугачёв штабы урнашкан Бәрде бистәсенә килә (19 йөздән бистә Оренбург ш. биләмәсенә керә), анда полк командиры итеп билгеләнә. Шул елның февралендә Бозаулык һәм Сорочинск кальгалары төбәгендә, март аенда Татищев кальгасы өчен барган сугышларда катнаша. Баш күтәрүчеләр отряды җиңелгәч, Бәрде бистәсенә чигенә. 1774 нең апрель башында Каргалы бистәсе һәм Сакмар шәһәрчеге тирәләрендә хөкүмәт гаскәрләре һөҗүменә каршы торучылар сафында була; әсир ителә, Оренбург шәһәре төрмәсенә ябыла. Шуннан соңгы язмышы ачыкланмаган.

*Әд.:* Под знаменем Пугачёва. Челябинск, 1973.

**АЙТОВ** Давид Александрович (Даут Мөхәммәтшәриф улы) (1852, Оренбург ш. — 1914 тән соң), народник. Морзалар нәселеннән. Оренбургта хәрби уку йортын тәмамлый (1871), С.-Петербургта Михайлов исем. артиллерия уч-щесендә укый (1871–73). Шунда народниклар түгәрәген оештыра (1872). I Интернационалның рус секциясе әгъзасы. 1874 елда народникларның «халык арасына чыгу»ында («хождение в народ») катнаша. Шул елның маенда кулга алына, Петропавел кальгасы төрмәсендә тотыла (С.-Петербург). 1878 дә «193 ләр эше» буенча хөкем ителә, полиция күзәтүендә яшәү шарты б-н Оренбургка озатыла. 1879 елдан эмиграциядә, 1881 дән Парижда яши; картография ин-ты Erhard Freres хезмәткәре. Бертуган Гранатлар заказын үтәп, энциклопедия сүзлеге өчен карталар сыза. Сәяси тоткыннар һәм сөргендә яшәүчеләргә ярдәм итү өчен В.Фигнер тарафыннан оештырылган ком-тның Париж бүлеге казначее була. В.Фигнер һәм Г.Лопатин б-н бергә «Рус халкы дусларына» («Друзьям русского народа») революцион мөрәҗәгать авторы (1910). Мөрәҗәгатьтә барлык дәүләтләрдә дә тән җәзасы бирүне тыю һәм сәяси тоткыннарны башка төр җинаять кылган тоткыннардан аерым тоту һ.б. таләпләр куела. 1912 дән Париж геогр. җәмгыяте әгъзасы.

*Әд.:* Процесс 193-х. М., 1906; Нафигов Р.И. Тайны революционного подполья. К., 1981.

*Р.И.Нәфигов.*

**АЙТОВ** Исмәгыйль Мөхәммәтшәриф улы (1856 — ?), скрипкачы, педагог. Морзалар нәселеннән. Мәскәү консерваториясендә югары муз. белем ала дип фаразлана. Татарлардан беренче проф. музыкантларның берсе. Россия буйлап һәм чит илләрдә (Берлин, Париж, Лондон һ.б.) гастрольләрдә була. 1884–1908 елларда Казанда яши, опера театры оркестрының концертмейстеры, Рус император музыка җәмгыятенең Казан бүлеге каршындагы «*Казан музыка сөючеләр түгәрәге*»ндә кыллы һәм тынлы уен кораллары дәресләре бирә (1884–91). Концертларда катнаша, эшчәнлеге Казан һәм С.-Петербург тәнкыйтьчеләре, ш.и. С.-Петербургның «Музыкальное обозрение» г-тасы тарафыннан югары бәяләнә. 1907–08 дә «Шәрекъ клубы» эшчәнлегендә актив катнаша: гомуммилли мәгариф системасына музыка дәресләрен кертүне яклап чыга.

*Әд.:* Монасыпов Ш. Развитие татарского профессионального скрипичного искусства устной традиции на рубеже XIX–XX веков // Страницы истории татарской музыкальной культуры. К., 1991.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**АЙТОВ** Локман Мөхәммәтхан улы (7.4.1891, Пермь ш. — 22.12.1971, Казан), драма актёры, театр эшлеклесе. Сәхнә эшчәнлеген 1913 елда «*Нур*» труппасында башлый. Карун («Карун», Мольер), Хәйрүш («Казанга сәяхәт», И.Багданов) кебек рольләр башкара. 1919–21 дә В.М.Азин командалыгындагы 28 нче дивизия каршында эшләгән фронт театр труппасын җитәкли. 1921 дән Татар акад.



Ф.Г. Аитова.

театры труппасында, анда Камали («Банкрот», Г.Камал), Ахун («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), гофмаршал Фон Кальб («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Озрик («Гамлет», У.Шекспир), Апанас («Изге әманәт», Т.Гыйззәт), Йосыф («Яшь гомер», Г.Коләхмәтов) рольләрен башкара. Соңрак Татар акад. театрында, Татар филармониясендә администратор булып эшли. Мемуарлар, пьесалар авторы.

*Әд.:* Артистның тормыш юлы // Казан утлары. 1966. № 6–8.

**АЙТОВ** Мөхәммәтҗан Сөләйман улы (5.10.1823, Казан — 1890, шунда ук), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, төбәк тарихын өйрәнүче, борынгы акча үрнәкләрен туплаучы. *Йомышлы татарлар* нәселеннән. Сәүдә эшчәнлегеннән тыш, үзлегеннән Казан ханлыгы сәяси тарихын өйрәнә; татарлардан беренче буларак, Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крәстияннәр кузгалышына бәйле вакыйгаларны тасвирлап калдыра. Аның Лука Конашевич, Е.И.Пугачёв, Ишбулат мулла һәм Касыйм шәехкә багышланган язмалары К.Насыйри тарафыннан басмага әзерләнгән. Алар «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре» җыентыгына кергән (1926).

*Әд.:* Алишев С.Х. По следам минувшего. К. 1986.

**АЙТОВ** Нариман Габдрахман улы (29.12.1926, Казан — 17.8.1999, Алма-Ата), социолог, филос. фән. д-ры (1967), проф. (1970), БАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1975, 1988). Казан ун-тының тарих-филология ф-тын тәмамлый (1956). 1964–88 елларда Уфа авиация ин-тында фәнни коммунизм каф. мөдире, 1964 тә социология лабораториясен оештыра. 1988 дән Казакъстан ун-тында филос. каф. мөдире. Хезмәтләре социаль һәм региональ планлаштыру теориясе, социаль проектлаштыру өлкәсенә карый. Социалистик җәмгыять шартларында социаль структураларның һәм социаль күченүләрнең үзенчәлекләрен, аларны көйләү юлларын тикшерә.

Хезм.: НТР и социальное планирование. М., 1978; Социальные проблемы ускорения НТП. М., 1987.

**АЙТОВА** Фатиха Габделвәли кызы (1866, Оренбург губ. Троицк ш. — 1944(42), Казан), җәмәгать эшлеклесе. Сәүдәгәр Г.Яушев кызы (к. *Яушевлар*). Троицк кыз балалар гимназиясен тәмамлый. 1887 елда атаклы Казан сәүдәгәре М.Аитов улы Сөләйман Аитовка (к. *Аитовлар*) кияүгә чыга. 1897 елда А. Казанның Суконный бистәсендә фәкыйрь татар кызларын укырга-язарга һәм тегәргә өйрәтүне оештыра. Бу класслар өч ел дәвамында эшли. 1909 елның 27 августында Ф.Аитова рәсми рәвештә үз хисабына башлангыч җәдид кыз балалар мәктәбе ача (к. *Аитова Фатиха гимназиясе*). 1913 елдан Ф.Аитова үзенең елдан-ел камилләшә барган мәктәбен рус кызлар гимназияләре үрнәгендә сигезьеллык итеп үзгәртергә керешә. А.ның беренче милли кызлар гимназиясе 1916 елның 29 октябрендә ачыла.

Егерменче еллар урталарында А. татар хатын-кызларын кисү-тегү эшенә өйрәтү өчен махсус курслар ача. Йөзгә якын хатын-кыз аннан кисү-тегү эшләре остасы таныклыгы алып чыга. 1926 елдан соң курслар ябыла.

*А.Х.Мәхмутова.*

**АЙТОВА ФАТИХА́ ГИМНА́ЗИЯСЕ** («Аит мәктәбе»), Казанда кызлар өчен беренче шәхси татар гимназиясе. 1909 елның 27 августында Казан губернасы халык мәктәпләре директоры М.Н.Пинегин рөхсәте белән Ф.Аитова тарафыннан башлангыч җәдид кызлар мәктәбе буларак ачыла. Ф.Аитованың мирас акчасына мәктәп өчен барлык таләпләргә дә туры китерелеп җиһазланган махсус ике катлы таш бина салына. Мәктәпкә үрнәк итеп Буби һәм Ләбибә Хөсәения кызлар мәктәпләре алына, аларның тәҗрибәсе киң кулланыла (к. *«Буби» мәдрәсәсе*, *Ләбибә Хөсәения мәктәбе*). Укытучылыкка да аларда белем алган кызлар чакырыла. Мәктәп укучылары да, укытучылар да дәресләргә махсус киемнәрдә йөрергә тиеш була. Укучыларның көндәлек киеме — ак якалы коңгырт кызыл төстәге .күлмәк, кара алъяпкыч, алсу каймалы ак яулык; бәйрәмнәрдә — ак алъяпкыч, ә өлкән кызларга нәфис калфак кию тәкъдим ителә. Укытучылар Европа модасы белән тегелгән ак челтәр якалы куе зәңгәр төстәге күлмәк һәм энҗеле калфактан йөргәннәр. Беренче уку елында мәктәптә 85 Казан кызы укыган. Соңрак аларның саны арта, читтән килеп укучылар да була. Алар өчен мәктәп ишегалдында махсус йорт — тулай торак төзелә. 1911 елда мәктәптә 120-дән артык кыз сабак алса, 1913–14 уку елында мәктәпнең биш сыйныфында 230 кыз белем ала. Аларны 9 мөгаллимә укыта — җидесе җиде сыйныфка беркетелгән була, икесе (рус милләтеннән) — рус теле укытучысы В.Ивлиева һәм кул эшләре мөгаллимәсе В.С.Моисеева. Бу гадәти булмаган хәлне Казан вице-губернаторы 1913 елның 26 ноябрендә эчке эшләр министрына җибәргән юлламасында аеруча басым ясап күрсәтә: «Бу мәктәп үзендә мөслимә мөгаллимәләр белән бергә рус укытучылары да эшләве ягыннан татарларда бердәнбер мәктәп булып тора; аның укыту программасы да чуарлыгы белән башкалардан аерыла». Бу дәвердә мәктәп программасына инде татар теле һәм әдәбияты, арифметика, география, тарих, табигать белеме, дин сабаклары, рус теле, рәсем, матур язу һәм кул эшләре дәресләре кертелә, ягъни Аит мәктәбе гадәти башлангыч мәктәп кысаларына сыеймый башлый.

1916 елның 29 октябрендә беренче милли кызлар гимназиясе ачыла. С.Аитов акчасына махсус төзелгән бинада урнаша (хәзерге 12 нче татар гимназиясе. Архит-ра истәлеге). Гимназиянең укыту программалары дәүләт кызлар гимназиясе күләмендә төзелә. Монда татар, гарәп һәм рус телләре, гомуми һәм Ватан тарихы, гомуми һәм Русия географиясе, математика (арифметика, алгебра һәм геометрия), физика, табигать белеме, кеше анатомиясе һәм физиологиясе, гигиена, педагогика, ислам дине нигезләре, татарча (гарәпчә) һәм русча матур язу, рәсем һәм кул эшләре дәресләре була. Рус теле һәм әдәбияты, Русия тарихы һәм географиясе дәресләре рус телендә, калганнары татар телендә укытыла. 1916–17 уку елында мәктәптә 22 мөгаллимә һәм мөгаллим эшли. Алар арасында Казан югары хатын-кызлар курсларын тәмамлаган М.Ш.Әкимбәтова һәм М.С.Гобәйдуллина, Ләбибә Хөсәения мәктәбен тәмамлаган Н.Ш.Гайнуллина, Шумкова гимназиясенең 8 классын тәмамлаган М.М.Мөштәриева һәм М.Г.Сәгыйтова, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган Мөхетдин Корбангалиев, гимназия тәмамлаган В.С.Моисеева һ.б. була. Бу вакытта мәктәп өч бинага урнашып, анда 450-гә кадәр кыз белем ала. Аитова гимназиясе 1918 елда икенче баскыч татар мәктәбе итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Биктимерова Т. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. К., 2002; Девятых Л. Из истории казанского купечества. К., 2002; Махмутова А.Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). К., 2006.

*А.Х.Мәхмутова.*

**АЙТОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре, эшмәкәрләре һәм җәмәгать эшлеклеләре: 1) **Заманов Аит Бики улы** (1731–97) (к. *Замановлар*), морза, сәүдәгәр, А. династиясен нигезләүче; 2) **Яхья Аит улы** (? — 1796 тирәсендә), 2 күн эшкәртү з-ды хуҗасы; 3) **Бәшир Аит улы** (? — 1835), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, күн эшкәртү з-ды һәм 2 торак йорт хуҗасы (йортларның берсе 7 мең сумга бәяләнгән). Казанда ваба б-н авыручылар өчен салынган хастаханә төзелешенә акчалата ярдәм итә (1830), Казан Иганә җәмгыятенә ел саен 50 сум биреп тора; 4) **Муса Аит улы** (? – ?), 3 нче гильдия сәүдәгәр, киҗе-мамык җепләр һәм тукымалар б-н сәүдә итә. Сәүдәгәрләр исемлегендә варислары теркәлмәгән; 5) **Салихйосыф Аит улы** (? – ?), тире-күн з-ды хуҗасы (елына 9 мең тире эшкәртелгән); 6) **Якуп Аит улы** (? – ?), тире-күн эшкәртү з-ды хуҗасы (елына 18 мең тире эшкәртелгән); 7) **Сөләйман Аит улы** (1764–1844), балалары: Измаил, Әхмәт, Мостафа, Мөхәммәтҗан (к. М.С.*Аитов*); 8) **Сөләйман Мөхәммәтҗан улы** (1.2.1862–1922), Исхак Арсланов вафатыннан соң сәүдәгәр Х.В.Гыйззәтуллин б-н бергә 1901 елда «Арслановның сабын һәм гөлсирин җитештерү заводы ширкәте»нә (Казан) хуҗа булып кала. Завод 1917 елга кадәр уңышлы эшли. 1897 елдан Казан шәһәр думасы гласные. Бер үк вакытта Казан сәүдәгәрләр банкы һәм Казан губ-насы ятим балалар йортлары иганәчеләре идарәләре әгъзасы. 1898 дән *Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыяте*нең шәрәфле әгъзасы, 1896 дан Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы. 20 йөз башында татарларның милли хәрәкәтендә актив

катнаша, «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенең Казан бюросы эшчәнлеген финанслый. А. Бишбалта бистәсе мәчете төзелешенә (1898) һәм Казанда Беренче татар кыз балалар гимназиясен ачу һәм тотуга (к. *Аитова Фатиха гимназиясе*), Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятенә акчалата ярдәм итә.

*Әд.:* А л и ш е в С.Х. По следам минувшего. К., 1986; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**АЙ́ТОВЛАР**, татар дворяннары нәселе. Нигездә, Оренбург губернасы авыл һәм шәһәрләрендә яшиләр (мәс., хәзерге Оренбург өлкәсе Татар Каргалысы, ТРның Баулы р-ны авылларында һ.б.). 18 йөз ахырында А. Россия дворяннары исемлегендә теркәләләр. 1) **Абдулсәлам** (Габделсәлам) (? – ?), А. нәселен нигезләүче. 1783 елда, Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крәстияннәр кузгалышын бастыру вакытындагы хезмәтен искә алып, «аеруча тырышлыгы өчен» аңа подпоручик, ә улы Рәхмәтуллага 1785 тә прапорщик дәрәҗәсе бирелә; 2) **Мөхәммәтшәриф Рәхмәтулла улы** (? – ?), майор, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М.И. Татар шәҗәрәләре. К., 1995; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**АЙ**, Җирнең табигый иярчене, безгә иң якын күк җисеме. Айның массасы — Җир массасыннан 81,3, авырлык көче тизләнеше Җирнекеннән 6 тапкыр кимрәк, шуңа Айда атмосфера юк. Ай — Кояш нурлары б-н яктыртыла торган шарсыман караңгы җисем (радиусы 1737 *км*). Ай өслеге темп-расы экваторда көн уртасында 390 К, төнлә 100–120К чамасы. Җир тирәсендә түгәрәк орбита буенча диярлек хәрәкәт итә, әйләнү периоды йолдызларга карата 27,3217 тәүлек. Ай үз күчәре тирәсендә дә шундый ук период б-н әйләнә, шуңа күрә ул Җирдән һәрвакыт бер ягы б-н генә күренә.

Җир тирәсендә хәрәкәт иткәндә Кояшка карата төрле торышта булганга, Ай дискының яктыртылган мәйданы да даими үзгәреп тора. Аның иң зур яктыртылган өлеше киңлегенең Ай диаметрына чагыштырмасы фаза дип атала. Ай фазаларын төп дүрт төргә бүләләр: яңа Ай, беренче чирек, тулы Ай һәм соңгы чирек. Ай фазаларының кабатлану периоды — 29,5356 тәүлек. Ай өслеге күпсанлы кратерлар — кәсасыман тирән чокырлар б-н капланган, аларның күбесе боҗрасыман калкулыклар б-н уралган. Айда зур таулыклар, «диңгез» дип аталган тигез төпле киң чокырлар бар.

Айга ясалма иярченнәр, соңрак аңа төшеп утыра торган космик кораблар (КК) җибәрелү б-н космик эра башлана. Айның Җирдән күренми торган ягының беренче сурәтен 1959 да планетаара «Луна-3» совет станциясе төшереп ала. Айга беренче булып Америка астронавты Нил Армстронг аяк баса (1969, 20 авг.). Якын киләчәктә Айда фәнни лабораторияләр төзү планлаштырыла, аларны ерак космик очышлар өчен станцияләр итеп файдалану мөмкинлеге карала.

Айга ясалма иярченнар җибәрү өчен Айның әйләнү хәрәкәтен һәм андагы урыннарның координатларын төгәл белү әһәмиятле. Ай, үз күчәре тирәсендә аз гына тирбәнешләр ясап, тигез диярлек әйләнә. Андый тирбәнешләр Айның физик либрациясе (АФЛ) дип атала. Казан астрономнары Т.А.Банахевич (1910–15), А.А.Яковкин (1916–31), И.В.Белькович (1931–48), А.А.Нефедьев (1938–55), Ш.Т.Хәбибуллин (1949–52) — АФЛны дөньяда иң озак күзәтүче галимнәр. Ш.Т.Хәбибуллин (1966) һәм Н.К.Петрова (1993–95) АФЛның заманча теориясен Көнбатыш галимнәре б-н бер үк вакытта төзиләр. Н.Г.Ризванов Ай өслегенә космик корабларны уңышлы төшереп утырту өчен кирәкле төп нокталарның бәйсез фундаменталь челтәрен билгели (1985).

*Әд.:* К о н о н о в и ч Э.В., М о р о з В.И. Общий курс астрономии. М., 2001.

*Ш.Т.Хәбибуллин, Л.И.Машонкина.*

**АЙ** (фольк.), күп кенә халыклар, ш.и. татарларның борынгы бабалары арасында табыну объекты; яңадан туу, яңару, байлык символы. А. культы *Кояшка* табыну б-н тыгыз бәйләнештә торган, әмма алай киң таралмаган. Борынгы Шәрекъ мифологиясендә А. һәм *Кояш* һәрвакыт пар булып йөриләр (бертуган апа һәм абый, кайчак игезәкләр, егет б-н кыз, ир һәм хатын, ата б-н ана). Төрки-татар фольклорында бу күзаллауларның кайтавазлары гына сакланган. А., Кояш һәм йолдызлар турында күпсанлы табышмаклар, әйтемнәр, мәкальләр, такмазалар яшәп килә, мәс., «Көндез кыз, төнлә егет», «Бер атасы, бер анасы, нича йөз мең баласы», «Ай симерсә, йолдызлар арык». А.ны Кояшның икегә ярылган бер яртысы дигән борынгы күзаллаулар Урал тауларының барлыкка килүе турындагы башкорт риваятендә чагыла. Соңгырак чорларда А. татар халык шигъри иҗатында аерылышу, кайгы, ялгызлык символы буларак очрый. Шул ук вакытта ул чын гүзәллек образы итеп тә кабул ителә. А.га охшату күп кенә татар *кеше исемнәрендә* чагыла, мәс., Айгөл, Айсылу, Айнур һ.б.


*Әд.:* Борынгы татар әдәбияты. К., 1963; И с ә н б ә т Н. Татар халык табышмаклары. К., 1970; У р м а н ч е е в Ф. Дастаннарга лаек замана. К., 1990; И в а н о в В.В. Лунарные мифы // Мифы народов мира. М., 1988. Т. 2.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«АЙ, БЫЛБЫЛЫ́М»** («Сандугачым, былбылым»), татар халык җыры. Анда яшь егетнең саф мәхәббәте турында сөйләнә. Гомумән алганда, көе татар фольклоры өчен хас түгел. Көйдә Көнчыгыш халыклары музыкасының ритмик-интонацион үзенчәлекләре шактый сизелә. Җырның татарлар яши торган төрле районнарда язылган берничә варианты билгеле. Кайберләренең ноталары һәм текстлары «Мандолина» (М., 1913) һәм М.Мозаффаров, Ю.Виноградов, З.Хәйруллинаның «Татар халык җырлары» (1954) җыентыкларында, ш.у. күптомлы «Татар халык иҗаты» басмасында («Тарихи һәм лирик җырлар», 1988) урнаштырылган.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988.

**АЙ КАЛЕНДАРЕ́**, ел көннәрен исәпләү ысулы, Кояшның күренмә хәрәкәтенең һәм Ай фазаларының периодиклыгына нигезләнә. А.к.нда ай башы яңа Ай туган көннән исәпләнә. А.к. Борынгы Вавилонда барлыкка килгән дип санала, анда берничә мең ел дәвамында иң борынгы вакыт исәпләү системасы төзелгән. Айның Кояшка карата даими рәвештә бер үк торышка кайту периоды бу системада вакыт үлчәме булып хезмәт иткән. Соңрак бу период синодча ай дип атала башлаган. Синодча айның озынлыгы 29,531 тәүлек, аның Җирдән бик яхшы күренә торган фазалары — яңа Ай, беренче чирек, тулы Ай һәм соңгы чирек. Әмма Ай фазасының башлану мизгелен төгәл итеп күзәтеп билгеләү гаять кыен. Шуңа күрә ай көннәрен исәпләү башы итеп яңа туган Айның бик тар урагы күренү мизгеле (неомения) алына. А.к.нда ел 12 айга бүленә, алар, чиратлашып, 30 яки 29 тәүлектән тора. Ай елында барлыгы (һиҗри ел) 354 тәүлек. Һәр елда, беренче ай яңа Айга туры килсен өчен (А.к.на куела торган төп таләпләрнең берсе), билгеле бер елларда соңгы айга бер тәүлек өстәлә; 355 тәүлекле ел кәбисә ел булып санала. Кояш елыннан якынча 11 тәүлеккә кыскарак булганга, Ай елы ел саен алгарак күчеп башлана һәм Кояш елының теләсә кайсы аена туры килергә мөмкин. Мәс., 1973 елда Ай елы башы — 4 февральгә, 1974 тә — 25 гыйнварга, 1975 тә 14 гыйнварга туры килә. Җиде көнлек атна көннәре Кояш календарендагы кебек. А.к., Һиҗри ел исәбе буларак, мөселман халыкларында киң таралган. А.к.ларының кәбисә еллар күрсәтелгән төрек, гарәп цикллары гамәлдә йөри. Гарәп циклы төрек циклына кабатлы булмаганлыктан, бу системаларда кәбисә еллар һәрчак туры килеп бетми. Шуңа







Айның фоторәсемнәре.
1. Җирдән күренгән өлеше;
2. Җирдән күренми торган өлеше
(Американың «Клементина» космик аппаратыннан алынган).

күрә, теге яки бу А.к.ннан файдаланып, А.к. даталарын хәзерге заман календарена күчергәндә ялгыш җибәрмәс өчен, кайсы кәбисә ел системасы кулланылуын истә тоту зарур. А.к. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күчеп китү (һиҗрәт кылу) көненнән, б.э.ның 622 ел 16 июленнән башлап исәпләнә.

Идел буе Болгарында, Алтын Урдада һәм Казан ханлыгында (б.э.ның 922 ел язында Идел буе Болгарында ислам дәүләт дине дип игълан ителгәннән соң) А.к. рәсми календарь буларак кулланыла башлый. Мөселман А.к.нда айларның гарәпчә исемнәре: 1. Мөхәррәм. 2. Сәфәр. 3. Рабиг әл-әүвәл. 4. Рабиг әс-сани. 5. Җөмади әл-әүвәл. 6. Җөмади әл-ахир. 7. Рәҗәб. 8. Шәгъбан. 9. Рамазан. 10. Шәүвәл. 11. Зөлкагъдә. 12. Зөлхиҗҗә. Ай елы, гадәти яисә кәбисә ел булуга карап, Кояш елыннан 10, 11 яки 12 тәүлеккә кыскарак булганга, Һиҗри ел һәр 33 ел саен 1 елга алга китә, ягъни 33 Ай елы 32 Кояш елына тигез була. Мөселманнар дини йолаларын һәм дини бәйрәмнәрен А.к. на карап үтиләр.

А.к. Кояш календарена күчерү өчен хәзерге вакытта төрле компьютер программалары бар, Кояш чыгу һәм бату, Ай калку һәм бату мизгелләрен исәпләү программалары, ш.у. Айның төрле фазаларын күзәтү мөмкинлеген бәяләү, неомениясен күзәтү программалары эшләнгән. Астрономик А.к. Ай фазаларының таблицалары яңа Ай тууының төгәл исәпләнгән мизгелләренә нигезләнеп төзелгән: мәс., яңа Айның б.э.к. 3000 елы һәм б.э.ның 3000 нче елы арасындагы дәверне эченә алган яңа Ай таблицалары төзелгән. Мөселман хәдисләре һәм сөннәләре таләпләренә туры килә торган А.к. һәм таблицалар яңа Ай неоменияләренә нигезләнеп төзелгән. Андый А.к. барлык ислам дәүләтләрендә нәшер ителә. ТРда ике А.к. — «Мөселман календаре», «Татар мөселман календаре» басыла. Бу көндәлек календарьларда Ай һәм Григориан еллары исәбенең мөһим даталары, кайбер шәһәрләрдә Кояш чыгу һәм бату, Ай калку һәм бату, биш вакыт намаз уку, ураза башлану вакытлары, мөселман бәйрәмнәре h.б. турында мәгълүмат бирелә.

Мөселман календареның төгәл эшләнүен әйтергә кирәк: аның төгәлсезлеге 2500 ел дәвамында нибары 1 тәүлек тәшкил итә. Ш.у.к. *Календарь*, *Кояш календаре*.

*Әд.:* И д е л ь с о н Н.И. Этюды по истории небесной механики. М., 1975; С е л е ш н и к о в С.И. История календаря и хронологии. М., 1977; Ц ы б у л ь с к и й В.В. Календари и хронология стран мира. М., 1982; Мусульманский календарь и астрономия. К., 1999.

*М.А.Вайсов, Р.Г.Усманов.*

**АЙӘ́Т** (гарәп, آية — ачыш, билге, могҗиза). Коръән текстыннан мөстәкыйль мәгънәгә ия булган өзек, гыйбарә. «А.» төшенчәсенең Коръәндәге башлангыч мәгънәсе — «могҗиза», «ачыш». Соңрак шушы сүз б-н Коръәнгә таянып дәлилләнгән фикерләрне дә атый башлыйлар. А. Европа телләрендә һәм хәзерге мөселман дөньясы басмаларында кабул ителгән (1936 дан) яңа Мисыр тәртибендә билгеләнә. А.ләрдән өзекләр мәчет, мәдрәсә h.б. биналар бизәлешендә кулланыла, кабер ташларына языла. Мөселманнар карашынча, кайбер А.ләр тылсым көченә ия.


**АЙБАЛТА́**, сугыш коралы; озынча түтәле, тар йөзле, агач саплы җиңел балта. Идел-Чулман буйларында 7 йөздә эшләнгән А.лар табыла. 8–11 йөзләрдә болгарлар шундый турыпочмаклы А. кулланалар. 11–13 йөзләргә нисбәтле болгар А.лары яңа калыккан Ай сыман озынча тар йөзле булган, кайберләренә бизәк-орнамент төшерелгән. 13–14 йөзләрдә аксөякләр өчен йөзенә үсемлек бизәге төшерелгән махсус затлы балталар да эшләнә. Алар, башлыча, дәрәҗәлелек билгесе саналган. 16 йөздән башлап А. сугыш коралы булудан бигрәк аксөяклек билгесе буларак сакланган.

*И.Л.Измайлов.*



Айбалталар. 1, 3 — чүкелгән балталар, 10–11 йөзләр; 2, 4–7 — сугышчы балталары, 10–13 йөзләр; 8 — бизәкле балта, 15–16 йөзләр; 9 — айбалта, 16 йөз.

**АЙБА́Ш** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 41 *км* төньяк-көнбатыштарак, Питиал елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 347 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 20 йөз башы архит-ра истәлеге — мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Олы Айбаш атамасы б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балта эшләре, мич чыгару, итек тегү б-н шөгыльләнә. Мәчет беренче мәртәбә 1858 дә искә алына. 1878 дә мәдрәсә, җил тегермәне; 20 йөз башында 4 вак-тәякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1927,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Суыксу волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 175 ир-ат; 1859 да — 655, 1878 дә — 891, 1897 дә — 994, 1908 дә — 1086, 1920 дә — 986, 1926 да — 1080, 1938 дә — 937, 1949 да — 763, 1958 дә — 666, 1970 тә — 592, 1989 да — 344 кеше.



Айбаш авылы мәчете.

*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.


**АЙБӘ́К** хан, к. *Каганбәк хан.*

**АЙБӘ́ТОВ** Хәйрулла (19 йөз), педагог. 1852–67 елларда Казан руханилар семинариясендә татар һәм гарәп телләре укытучысы. А.ның тормышы һәм иҗаты өйрәнелмәгән.

*Әд.:* Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1974.

**АЙВА́Н** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 552 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты. Китапханә. 1602–03 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Хайван исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да җамигъ мәчет була, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 815 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында, 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир заты; 1859 да — 316, 1897 дә — 470, 1908 дә — 597, 1920 дә — 653, 1926 да — 648, 1989 да — 522 кеше.

**АЙДА́** Гадилә (Адилә) (1912, С.-Петербург — 1992, Әнкара), Төркия дипломаты, тарихчы. Садри *Максуди* кызы. Истанбулда «Нотр дам де Сион» француз мәктәбен, Әнкара ун-тының хокук ф-тын һәм тарих-филология ф-ты аспирантурасын тәмамлый. 1932 елдан бернкадәр вакыт дипломатия эшендә. Аннары Истанбул ун-тында: әдәбият ф-тында француз әдәбияты һәм мәдәнияте тарихын укыта (1957 гә кадәр), бер үк вакытта «Cumhuriyet» («Республика») г-тасында мәкаләләр бастыра. 1958 дә дипломатия эшенә кайта: 1958 нең көзеннән БМОда (Нью-Йорк) Төркия вәкиллегендә, 1959 да Гаагада Төркия илчелегендә, 1960 та Белградта Төркия илчесе киңәшчесе, 1967–71 елларда Римда Төркия илчелеге ышанычлысы. 1963–67 дә тышкы эшләр министрының мәдәният мәсьәләләре буенча киңәшчесе. 1976–78 елларда Төркиянең Бөек Милли Мәҗлесе сенаторы. Төркия хатын-кызлары берлегенең президент-оештыручысы, Бөтендөнья хатын-кызлары конгрессы әгъзасы. Хезмәтләре борынгы төрки халыклар тарихына, француз символист шагыйре Стефан Малларме иҗатына карый. Әтисенә багышланган документаль-биографик китап авторы.





Айдагы кратерлар. 1. Клавиус кратерлары сериясе; 2. Коперник кратеры.

Х е з м.: Садри Максуди Арсал. М., 1996; Etruskler (Tursakalar) Turk idiler. Ankara, 1992.

**АЙДАГЫ́ КРА́ТЕРЛАР**, Ай рельефының аеруча үзенчәлекле урыннары. А.к. боҗрасыман валлардан гыйбарәт, андый валның төбе тигез, ә үзәгендә таучык урнаша, аның биеклеге күпчелек очракларда валныкыннан тәбәнәгрәк. Күп кенә кратерлар метеорит төшү, кайберләре вулкан атылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип фаразлана. Иң зур кратерларның диаметры 100 *км* чамасы. Кратерларга охшаган, әмма үзәгендә таучык булмаган урыннар цирклар дип атала. Кайбер кратерлар тирәсендә радиаль нурлар булып таралган аксыл матдә күзәтелә. Айдагы зур кратерларга һәм циркларга галим-голәмә, ш.и. эшчәнлекләре Казан һәм Татарстан б-н бәйле галимнәрнең исемнәре бирелгән: Т.А.Банахевич, И.В.Белькович, М.А.Грачёв, Д.И.Дубяго, Г.С.Жирицкий, М.А.Ковальский, А.В.Краснов, И.А.Литтров, Н.И.Лобачевский, Д.Д.Максутов, В.П.Энгельгардт, А.А.Яковкин.

*Л.И.Машонкина.*

**АЙДА́Р** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Нырсы елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 352 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматлар буенча, А.да мәчет, 1908 дә вак-төякләр кибете була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 602,5 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 29 ир заты; 1859 да — 367, 1897 дә — 625, 1908 дә — 759, 1926 да — 715, 1938 дә — 597, 1949 да — 524, 1958 дә — 463, 1970 тә — 512, 1979 да — 419, 1989 да — 346 кеше.

**АЙДА́Р** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2002 елда 261 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 20 йөз башы архит-ра истәлеге — мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. А.да беренче мәчет 1878 дә төзелә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 4 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1020,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивиль өязе Яңа Кавал волостена керә. 1920 дән Чуаш Автономияле өлкәсендә, 1921 нең 22 сентябреннән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 127 ир заты; 1859 да — 601, 1897 дә — 936, 1926 да — 763, 1938 дә — 772, 1949 да — 575, 1958 дә — 502, 1970 тә — 466, 1979 да — 384, 1989 да — 298 кеше.

**АЙДА́Р** (Айдаров) Әсгать Харис улы (6.6.1906, Самара губ., Бозаулык өязе Иске Сорочино а.- 24.1.1959), язучы. Атасы Бозаулык өязендә ахун булган. Әсәрләре 1928 елдан басыла башлый. «Әсгать Айдар шигырьләре» (1928), «Барабызлар турында» (1929) шигъри җыентыклары, балалар өчен «Ташбай» (1932) повесте (күп тапкырлар басыла), армия хезмәте турындагы «Соңгы сулышта» (1935) хикәясе, «Солдат хикәясе» (1946), геологлар тормышына багышланган «Таулар легендасы» (1960; рус теленә тәрҗемә, 1964) повесте авторы. 1935–38 елларда нигезсез репрессияләнә. Шул сәбәпле 1940 та Казаннан китәргә мәҗбүр була. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң 1948 елга кадәр Казанда «Кызыл Татарстан» г-тасында эшли. Гомеренең соңгы елларында Үзбәкстанда яши. Сугышчан орден, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

*Н.Г.Гыйззәтуллин.*

**АЙДА́Р ХАН**, риваятьләргә кергән болгар идарәчесе. 17–18 йөзләргә караган тарихи әдәбиятта Тукый хан улы, болгарлар идарәчесе буларак телгә алына. Мөхәммәд пәйгамбәрнең өч сәхабәсе йогынтысында ислам динен кабул иткән, шуларның берсенә үз кызын биргән, дип фараз кылына. Әлеге сәхабә Болгар илендә ислам динен тараткан, диелә.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**АЙДА́РОВ** Җәүдәт Кәраматулла улы (31.12.1918, Пермь ш. — 18.11.2000, Казан, Балтач р-ның Түнтәр авылында җирләнә), хор дирижёры, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1985). Ленинград консерваториясен тәмамлый (1951). 1937–40 елларда Ленинград опера һәм балет акад. театры оркестры, 1940–43 тә — Ленинград хәрби комендатурасы үрнәк оркестры, 1943–46 да Ленинград радиокомитеты зур симф. оркестры артисты (бәрмә уен коралларында уйнаучы). Ленинград камалышы вакытында Д.Шостаковичның 7 нче симфониясен беренче башкаруда катнаша. 1951 елдан Чита радиокомитетының халык уен кораллары оркестры дирижёры. 1953 тән Ижор з-дының (Ленинград) хор капелласы сәнгать җитәкчесе. 1958 дән Карелия «Кантеле» ансамбле хормейстеры. 1959–65 тә ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле сәнгать җитәкчесе, 1963–75 тә Казан консерваториясенең халык уен кораллары каф. укытучысы, бер үк вакытта 1969–73 тә Казан консерваториясе каршындагы махсус музыка мәктәбе директоры, 1975–96 да Казан музыка уч-щесенең халык уен кораллары бүлеге укытучысы. 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.


**АЙДА́РОВ** Сәйяр Ситдыйк улы (25.6.1928, Казан), архитектор, архит-ра д-ры (1990), проф. (1992), Россия архит-ра һәм төзелеш фәннәре академиясенең мөхбир әгъзасы (1993), РСФСРның атказ. архитекторы (1980), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). С.Х.*Айдаров* һәм Г.М.*Кайбицкаяның* улы. Мәскәү архит-ра ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Казан фәнни-реставрация эшләрен башкару остаханәсенең фәнни бүлеге җитәкчесе булып эшли. Татарстанда архит-ра истәлекләрен фәнни нигездә реставрацияләүне җайга салган белгечләрнең берсе. 1961 елдан Казан төзүче-инженерлар ин-тында, 1970–83, 1985–88 дә архит-ра теориясе һәм тарихы каф., 1990 нан архит-рада милли проблемалар, 1999 дан архит-ра теориясе, тарихы һәм архит-радагы милли проблемалар кафедралары мөдире. 2001 дән Казан архит-ра-төзелеш академиясенең (хәзер — Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) архит-ра һәм дизайн ин-тының фәнни эшләр буенча директор урынбасары. Борынгы Болгар һәм Казан ханлыгы архит-расын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр, Биләр, Болгар шәһәр-



С.С. А й д а р о в. «Рамазан» мәчете. 1994.



С.С. Айдаров.



С.Х. Айдаров.

ләре, Казан Кремле, Зөя шәһәре архит-ра истәлекләрен торгызу һәм реставрацияләү, *«Рамазан»* мәчете һ.б. проектлар авторы. А.ның Татарстан архит-расы тарихы һәм теориясенә караган хезмәтләрендә беренче тапкыр төбәк архит-расындагы милли үзенчәлекләр тикшерелә. 1962 дән — ТАССР Архитекторлар берлеге әгъзасы, 1970–89 да аның идарә рәисе.

Х е з м.: Архитектурное наследие Казани. К., 1978; Великие Булгары. К., 1983 (автордаш); Теория и практика становления национально-региональной школы в архитектуре Татарстана // Вестн. Волжского регион. отд-ния Рос. академии архитектуры и строит. наук. Н.Новгород, 1998. Вып. 2; Поиск утраченного лица // Национально-регион. своеобразие в архитектуре Татарстана. К., 1999.

*Әд.:* Нашёл себя // Казань. 1993. № 9; С о к о л о в С. Академик архитектуры // Республика Татарстан. 1998. 25 июня.

**АЙДА́РОВ** (Рәхмәтуллин) Ситдыйк Хәнәфи улы (25.12.1895, Казан — 13.9.1938, шунда ук), драма һәм опера актёры. Вак сәүдәгәр-һөнәрче гаиләсендә туа, «Мәрҗания» мәдрәсәсендә һәм рус-татар мәктәбендә укый, танылган Казан җырчысы Ф.А.Ошустовичтан җыр дәресләре ала. 1910–12 елларда *«Шәрекъ»* клубында татар кыллы оркестрында уйный. 1912 дә *«Сәйяр»* труппасына керә. Гражданнар сугышы елларында татар фронт театр труппалары актёры һәм режиссёры, концерт эшчәнлеге б-н шөгыльләнә; 1921 дә Мәскәүдә узган Коммунистик Интернационалның III конгрессында катнашучыларга этнографик концертлар оештырганы өчен рәхмәткә лаек була. 1923 тә Петроградта Азчылык милләтләрнең татар бүлеге каршында оештырылган Беренче агитацион татар труппасын җитәкли. 1924–33 тә Татар акад. театрында. Матур тембрлы җырчы тавышына ия А. муз.-драматик спектакльләрдә баш рольләрдә уйный: Булат, Исмәгыйль, Ильяс («Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе», К.Тинчурин), Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи), Батырҗан («Наёмщик», Т.Гыйззәт). Ш.у. Фердинанд («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Хлестаков («Ревизор», Н.В.Гоголь), Миловзоров («Гаепсездән гаепleләр», А.Н.Островский), Мәхмүт («Козгыннар оясында», Ш.Камал) рольләрен дә башкара. 1934–38 дә Мәскәүдә Татар опера студиясендә укый.


С.Х. А й д а р о в Булат («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин) (сулда), Батырҗан («Наёмщик», Т.Гыйззәт) рольләрендә.





**АЙДА́РОВА** Галина Николаевна (19.7.1947, Алексеев р-ны Биләр а.) архитектор, архит-ра д-ры (1997), проф. (1999). Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), «Татаргражданпроект» ин-тында архитектор булып эшли. 1977 елдан Казан төзүче-инженерлар ин-тында (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты): 1987 дән архитектур проектлаштыру кафедрасында, 1991 дән шәһәр төзелеше каф. доценты, 2000 нән архит-ра ф-ты деканы, 2004 тән архит-ра теориясе һәм тарихы каф. мөдире. А. проектлары б-н Ленино-Кокушкино авылында мәктәп (1976), Татарстан Эчке эшләр министрлыгының укыту үзәге биналары комплексы (1983) һ.б. төзелә. Хезмәтләре Татарстан һәм Урта Идел буе шәһәрләре төзелеше һәм архит-расы тарихына карый. Татарстан Архитекторлар берлеге әгъзасы (1983).

Х е з м.: Архитектурная культура Среднего Поволжья 16–19 веков: модель развития, структура типов, влияния. К., 1997; Татарские слободы Казани: архитектурно-градостроительное развитие и методологические аспекты реконструкции. К., 1999.



С.С. А й д а р о в. Архитектура истәлекләренең график реконструкцияләре. 1. Биләр җамигъ мәчете. 10 йөзнең 2 нче яртысы: а) иң беренче агач мәчет; б) агач һәм таш заллы, манаралы мәчет; 2. Төньяк һәм Көнчыгыш төрбәле Болгар җамигъ мәчете комплексы (14 йөз башы): а) комплексның гомуми күренеше; б) комплекс планы; в) Көнчыгыш төрбә; 3. Болгар шәһәрендәге Кара пулат (14 йөз урт.): а) пулат киселеше һәм интерьер бизәге өлешләре; б) гомуми күренеш; 4. Казан Кремленең хан ныгытмасындагы мәчетләр. 16 йөзнең 1 нче яртысы: а) Нургали, Хан мәчетләре, хан төрбәләре биналары булган сарай комплексы; б) сарай комплексы планы; в) төрбәләр; г) Колшәриф мәчетенең өстән күренеше; д) Колшәриф мәчетенең гомуми күренеше.

**АЙДА́РСКИЙ** (Вәлитов) Газиз Исхак улы (1899, Казан губ., Цивиль өязе Айдар а. — 30.10.1933, Мәскәү), драма актёры, режиссёр. 1917–18 елларда Әстерхан крае Мөселман эшләре комис-ты составында татар яшьләре арасында мәдәни-агарту эшләре б-н шөгыльләнә. 1918–20 дә ТАССР Мәгариф халык комис-тында эшчеләр ком-ты секретаре, 1920–22 дә сәнгать бүлеге мөдире. Беренче татар үрнәк театрында Таһир («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Незнамов («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Хлестаков («Ревизор», Н.В.Гоголь), Кассио, Лаэрт («Отелло», «Гамлет», У.Шекспир) рольләрен башкара. 1922 елда Дәүләт театр сәнгате ин-тына (ГИТИС) укырга керә, бер үк вакытта Мәскәүдә татар «Эшче театры»н оештыра (к. «*Мәскәү үзәк татар эшче театры*»). Аның сәхнәсендә берничә муз.-драма спектаклен («Галиябану», М.Фәйзи; «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», К.Тинчурин; «Наёмщик», Т.Гыйззәт; «Аршин мал алан», У.Гаджибәков) куя. А. тарафыннан С.Баттал пьесасы буенча куелган «Оештыручы» спектакле аеруча киң яңгыраш таба. 1925 елда Казанда беренче татар операсын («*Сания*») куючы режиссёр.

Ә с ә р.: Театр сәнгате. К., 1931.

*Әд.:* С т р е л ь н и к о в а О. Звезда и смерть Газиза Айдарского // Республика Татарстан. 1999. 11 нояб.; А й д а р с к а я А.Г. Память сердца. К., 2002.

**АЙЗАТУ́ЛЛОВ** Таһир Измаил улы (10.1.1922, Бурят АССРның Улан-Удэ ш. — 22.8.2000, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. төзүчесе (1984). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1944). 1945–54, 1959–60 елларда Казан автогараж җиһазлары з-дында, 1950 дән баш инженер. 1954 тән Сарман р-нында: Карамалы МТСы, Сарман ремонт-техника станциясе директоры. Аның катнашында ТАССРда беренче тапкыр механикалаштырылган борчак чабу җайланмасы булдырыла (уйлап табу 1956 да теркәлә). 1960–62 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире урынбасары, 1962–67 дә ТАССРның а.х. министры урынбасары. 1967–86 да «Татколхозстрой» берләшмәсе советы рәисе, 1986–91 дә «Татагропромстрой» берләшмәсе советы секретаре. Колхозларда төзелеш эшләрен хуҗалык ысулыннан подряд алымы б-н эшләүгә күчүне оештыра. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Система ведения сельского хозяйства в Татарской АССР. К., 1974 (автордаш); Строительство в колхозах Татарии // Сельское стр-во. 1982. № 12.

**АЙЗӘ́ТОВ** Фәрит Әхмәт улы (25.7.1948, Мордва АССРның Ләмберә р-ны Инәт а.), философ, филос. фән. д-ры (1999). Мордва ун-тының физика ф-тын тәмамлый (1971). 1971 елдан Мордва АССР Ромодан р-ның Аккүл урта мәктәбендә физика укыта. 1974–79 елларда Мордва ун-тында өлкән инженер. 1979 дан Мордва пед. ин-тында: 1986 дан филос. каф. доценты, 1993–96 да югары уку йортына әзерләү ф-ты деканы. Хезмәтләре тотрыклы үсеш һәм детерминизм методологиясе мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Устойчивое развитие: состояние, модель, стратегия (методологический и социально-экологический анализ). Саранск, 1998.

**АЙМА́НОВ** Якуб (1891, хәзерге Казакъстан Респ-касы Талды-Курган ш. — 2.11.1937, шунда ук, Павлодар ш.), шагыйрь. «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1920–30 елларда Павлодарда урта мәктәп директоры. Шигырьләре «Кояш» г-тасында һәм «Шура» ж-лында басыла. «Табигать» (1913) исемле шигырьләр җыентыгында Казакъстан һәм Алтай табигатенә мәдхия җырлый, «Саман» поэмасы (1914) төркиләрнең борынгы тарихына багышлана. А.ның романтик характердагы шигъриятендә Тукай иҗатының йогынтысы сизелә. Репрессияләр чоры корбаны.

Ә с ә р.: Табигать. Уфа, 1913; Хөрмәтле шагыйремез Тукаевка // Кояш. 1913. 9 апр.; Саман. Семипулат, 1914; Шигырьләр // Мирас. 1998. № 3.

*Әд.:* М у с и н Г. Яңа юлда // Йолдыз. 1915. 23, 29 окт.

*З.З.Рәмиев.*

**АЙНА́ЛОВ** Дмитрий Власьевич (8.2.1862, Мариуполь ш. — 12.12.1939, Ленинград), сәнгать тарихы белгече, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1914). Новороссийск ун-тында белем ала (Одесса ш.), Н.П.Кондаков шәкерте. 1890 елдан Казан ун-тының сәнгать белеме һәм тарих кафедрасында приват-доцент. Бер үк вакытта 1897 дән ун-тның борынгы әйберләр һәм сәнгать музее мөдире. Россия сәнгать белеме тарихында беренче булып Греция (Афон, Сиракуз), Италия (Равенна, Рим, Солерно, Амальфи, Чефалу, Помпей), Мисырдагы (Каһирә, Александрия) борынгы христиан һәм Византия сәнгате истәлекләрен, Берлин һәм Вена музейлары коллекцияләрендәге әсәрләрне тасвирлый һәм системалаштыра. «Икона язу һәм борынгы христиан сәнгате стиле өлкәсендә тикшеренүләр» («Исследования в области иконографии и стиля древнехристианского искусства», 1865), «Византия сәнгатенең эллинистик нигезләре» («Эллинистические основы византийского искусства», 1900) дигән хезмәтләрендә икона язу сәнгатенә караган күләмле материалларны гомумиләштерә, византистика һәм Византия сәнгате өлкәсендәге күп кенә мөһим мәсьәләләрне тәгаенли, ачып бирә. А. хезмәтләре Европа илләрендә дә таныла. Казан губернасы терр-ясендәге урта гасырларда рус сәнгате истәлекләрен өйрәнүгә зур өлеш кертә. 1899 да Мәскәү археол. җәмгыяте аңа Зөя шәһәрендәге Успение соборында 16 йөз фрескаларын реставрацияләүгә күзәтчелек итүне йөкли. А. әлеге уникаль фреска ансамбленең беренче фәнни тасвирламасын бастырып чыгара. Рус археол. җәмгыяте (1890), Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы (1891). Казанда сәнгать сөючеләр җәмгыятен (1895) оештыручыларның берсе, Одесса тарих җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1896), 1899 да Казан ун-ты каршында яңадан оешкан Пушкин исем. Әдәбият һәм сәнгать җәмгыяте советы сәркәтибе. 1903 тә Петербург ун-тына күчерелә. И.В.Цветаев тарафыннан Александр III исем. Нәфис сәнгать музееен оештыруга җәлеп ителә. Мәскәүдәге Публичный һәм Румянцев музейларының шәрәфле мөхбире, Киев археол. ин-тының шәрәфле әгъзасы, София соборында (Киев) фәнни-тикшеренү һәм реставрация-ремонт эшләре барышын тикшерү ком-ты әгъзасы, 1931 дән Украина ФАнең София соборы комиссиясе эшендә катнаша. Галимнең бай мирасында Византия, Италия, рус сәнгатенең истәлекле әсәрләрен өйрәнү төп урынны алып тора.

Х е з м.: Фресковая роспись храма Успения Богородицы в Свияжском мужском Богородицком монастыре // Древности: Тр. Московского археол. об-ва. 1906. Т. XXI, вып. 1; Древние памятники искусства Киева. Харьков. 1899 (автордаш); Этюды о Леонардо да Винчи. Л.-М., 1939.

*Әд.:* Б р у н о в Н. Памяти Д.В.Айналова // Архитектура СССР. 1940. № 3; М а с л е н и ц ы н С.Д. В.Айналов // Искусство. 1987. № 7; К л ю ч е в с к а я Е.П. Казанский период жизни и деятельности Д.В.Айналова и кафедра теории и истории искусств Казанского университета на рубеже XIX–XX веков // Сб. Калужского худож. музея. Калуга, 1993. Вып. 1.

*Е.П.Ключевская.*

**АЙНЕТДИ́НОВ** Альберт Кәрим улы (1.4.1937, Чүпрәле р-ны Иске Чокалы а. — 25.10.1998, Казан), журналистика өлкәсендәге галим, тарих фән. канд. (1972). Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1963). 1964–68 елларда Казан шәһәре Ленин р-ны прокуратурасында эшли. 1971–77 дә — Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында марксизм-ленинизм каф., 1978 дән Казан ун-тының журналистика каф. доценты. Хезмәтләре татар вакытлы матбугаты, Бөек Ватан сугышы тарихына карый. «Советлар Союзы Геройлары — безнең якташларыбыз» («Герои Советского Союза — наши земляки», 1–3 кит., 1982–85); «Правда» һәм Татарстан» («Правда» и Татария», 1982) һ.б. китапларны төзүче.

Ә с ә р.: Летопись подвига: (Ист. очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984; Центральная пресса: Жизнь автономных республик. К., 1985.

**АЙРАВЫ́К** (Dactylis), бөртеклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. А.ның 5 төре билгеле. ТРда бер төре — башаклы А. (D. glomerata) киң таралган. Сабаклары биек (150 *см* га кадәр), күп яфраклы, тамыр яны яфраклары озын һәм бик күп. Чәчәк оешмасы — өчкырлы үзәге һәм ботаклары ике яклап аерылган, киң ябалдашлы себеркәч. Башаклары ян-яктан кысылган, тыгыз учмага җыелган 3–5 чәчәкле, ә ботаклары очында себеркәчләр урнаша. Корылыкка чыдам, озакка сузылган дымлылыкны яратмый. Табигый шартларда ТРда барлык җирдә очрый. Кыйммәтле терлек азыгы. Яз көне әчелеге аз реакцияле һәм дымлылыгы җитәрлек булган уңдырышлы туфракка печәнлек һәм көтүлекләр өчен чәчелә, ш.у. басу чәчү әйләнешендә (люцерна б-н) һәм орлык өчен чиста чәчүлекләрдә дә игелә. А. яз көне уҗым арышы б-н бергә үсә. Яшел массаның уңышы май ахырына 1 гектардан 70–80 *ц* га җитә. Башка күпьеллык кузаклы үләннәр б-н чагыштарганда А.ның яшел массасында ике тапкыр күбрәк коры матдә һәм 25–30% ка күбрәк эшкәртелә торган протеин була. Ике тапкыр чабып алуга 1 гектар-




дан 100 *ц* печән алына. Өч елда үсеп җитә һәм үлән булып 6 ел һәм аннан да күбрәк тора. Татарстан шартларында үстерү өчен «Свердловская 79» (1982) сорты районлаштырылган. Төрле сәбәпләр аркасында Татарстан кырларында А. чәчү киң таралыш алмый: кайбер елларда аны язның соңгы кыраулары зарарлый, ә аз карлы салкын кышларда тармаклану төене җир өстенә якын урнашу сәбәпле өши; вакыт үтү б-н тармаклану төене җир өстенә чыгып өем барлыкка китерә һәм азык массасын механикалаштырып җыеп алуда кыенлык тудыра.

*Әд.:* Кормовые растения сенокосов и пастбищ. М., 1950. Т. 1; Минина И.П. Луговые травосмеси. М., 1972; Шумакова Г.А., Георгиади Н.И. Продуктивность ежи сборной // Химия в сел. хоз-ве. 1986. № 2; Шайтанов О.Л., Сафиуллин Ф.Н. Больше кормов высокого качества // Кормопроизводство. 1987. № 4; Рогов М.С. Многолетние злаковые травы. М., 1989.

*О.Л.Шайтанов.*

**АЙРШИ́Р ТОКЫМЛЫ́ МӨГЕЗЛЕ́ ЭРЕ́ ТЕРЛЕ́К**, мул сөтле сыер токымы. 18 йөздә Шотландиянең Айр графлыгында җирле терлекне тисватер, голланд, фламанд һәм олдернен токымнарын кушу юлы б-н яхшыртып чыгарыла. Нәсел эшләре аерып алу һәм сайлау юлы б-н экстерьерны, сөт бирүне һәм сөт майлылыгын яхшырту буенча үткәрелә. А.т.м.э.т. матур экстерьер, имчәкләренең формасы машина б-н саву өчен җайлы, авырлыгы зур түгел, сөтне күп бирә, сөтенең майлылыгы югары. Бу токым сыерлар башка сөт токымнарына караганда бер продукция берәмлегенә азрак азык берәмлеге сарыф итәләр (4% лы 1 *кг* сөткә — 0,7–1,0 азык берәмлеге, 1 *кг* сөт маена 17–23 азык берәмлеге). Россиядә 1950 елдан үрчетелә. Мәскәү, Ленинград, Вологда өлкәләре, Карелия Респ-касында күпләп асрала һәм нәселле хуҗалыкларда уртача 4,12–4,27% майлылыктагы 3905–5208 *кг* сөт бирә. ТРга беренче тапкыр 1974 елда Финляндиядән кайтарыла. 2000 дә бу токым 6,9 мең баш (хуҗалыклардагы мөгезле эре терлекнең гомуми санының 2,1% ын тәшкил итә) исәпләнә һәм уртача 3,9% майлылыклы 3213 *кг* сөт бирә. Бу токымның иң яхшылары Бөгелмә р-ынының «Восточный» (уртача савым 6088 *кг*), «Пугачёвский» (6090), «Семеновод» (5085), Әлмәт р-ынының Токарликов исем. (5130) хуҗалыкларында үрчетелә. 2007 ел башына А. токымлы 266 баш терлек исәпләнә.





Айршир токымлы мөгезле эре терлек.

*Әд.:* Болгов А.Е., Карманова Е.П. Использование айрширского скота для улучшения молочных пород. М., 1989.

*Р.А.Хәйретдинов.*

**А́ЙСИН** Аләм (Галләм) Хәбибулла улы (17.2.1924, Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Ключищи а. — 11.3.1989, Мәскәү). Дан орденының тулы кавалеры (22.1.1944, 29.3.1945, 26.6.1945), старшина. «Кызыл пролетарий» (Мәскәү) станоклар төзү з-дында токарь булып эшли. 1943 елның августыннан Бөек Ватан сугышында гв. кече сержанты, 121 нче гв. махсус сапёрлар батальонының сапёрлар отделениесе командиры (3 нче гв. танк армиясе). 1 нче Украина фронты гаскәрләре б-н Украина һәм Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1943 нең 30 декабрендә Скоморохи авылы (Житомир өлкәсе) янында; 1945 нең 25 гыйнварында Глейвиц шәһәре (Германия, хәзерге Гливице, Польша), 1945 нең 21 апрелендә Клаусдорф торак пункты (Германия) өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Мәскәүнең 73 нче мәктәбендә хуҗалык мөдире булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Солдатская слава. М., 1963; Кавалеры ордена Славы — горьковчане. Г., 1970; Остроухов П.Г., Романьков А.И., Рощин И.И. Богатыри земли Московской. М., 1977; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**АЙ-СИ-ЭЛ-КПО ВС** (ICL-КПО ВС), радиоэлектроника сәнәгате пр-тиесе; РФдә компьютер технологияләре өлкәсендә әйдәп баручы пр-тиеләрнең берсе. Фуджитсу (Fujitsu) компанияләре төркеменә керә, Казанда урнашкан. 600 дән артык кеше эшли (2006). 1991 елда *Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе* (КПО ВС) һәм Британиянең International Computers Lemited (ICL) компаниясе катнашы б-н оештырыла. 1994 тән АҖ. Пр-тие составында 6 фәнни-техник үзәк, җитештерү һәм сервис бүлекләре эшли. Әстерхан, Волжск (Мари Респ-касы), Мәскәү, Чаллы, Сургут (Төмән өлкәсе), Тамбов шәһәрләрендә вәкилләкләре эшли. Заманча җитештерү куәте һәм фәнни базасы бар. Пр-тиенең төп эшчәнлеге һәм продукциясе: системалы интеграция (төрле максатларда кулланыла торган автоматлаштырылган системаларны проектлаштыру), урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү, программалар б-н тәэмин итү һәм алар нигезендә компьютерлар һәм системалар, мәгълүмат саклау, укыту-өйрәтү, MRP II, ERP халыкара стандартларына таянып, пр-тиеләр б-н идарә итү системаларын гамәлгә ашыру. АЙ-СИ-ЭЛ-КПО ВСның продукциясе халык хуҗалыгында, дәүләт идарәсендә, сәламәтлек саклау, сәүдә, кораллы көчләр, хокук саклау органнарында һ.б. өлкәләрдә файдаланыла. 1998 дән ген. директоры В.В.Дьячков.

*А.В.Артамонов.*

**«АЙСЫЛУ́»**, люцерна сорты. 1986 елда Татарстан а.х. фәнни тикшеренү ин-тында Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тының 42 төрле люцерна сортыннан торган коллекциясе һәм җирле селекция сортларыннан поликросс ысулы б-н (җиңел ачылучан чәчкәле һәм үзеннән үрчи торган үсемлекләр нигезендә) М.Ш.Лапина, В.М.Комарова, Л.А.Киселёва һәм Х.З.Кәримов тарафыннан чыгарыла. Кышкы суыкларга чыдам, авыруларга бирешмәүчәнлеге уртача, мул уңыш бирә (конкурс сынавы вакытында печәннең уртача уңышы 70 *ц*, орлыкныкы — 2 *ц*). Елына 2–3 тапкыр чабып алына. Вегетация чоры беренче чабылуга кадәр — 45–50 көн, орлыклары өлгергәнгә кадәр — 110–120 көн. Куе булып үскәндә яхшы тармаклана. Сөрлегүгә чыдам, чәчәк ата башлаганда уртача биеклеге 60 *см*, кузаклары өлгергәндә — 80 *см*. Сабакларының катылыгы уртача, түгәрәк формада, кузаклары 2–3 катлы, тыгыз, карасу-көрән төстә, 1 мең орлыкның авырлыгы — 2 *г*. Урта-Идел регионы буенча Селекция казанышлары дәүләт реестрына кертелгән (1990) һәм ТРда районлаштырылган.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**АЙТАЛА́Н** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 34 *км* көнбатыштарак, Нократ (Вятка) елгасыннан 4 *км* читтә. 2002 елда 14 кеше (татарлар) яши. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык б-н шөгыльләнә, күрше авылларда көнлекче булып эшли. 1920 гә кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Черкасов волостена керә. 1921 дән — ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 100, 1887 дә — 310, 1920 дә — 331, 1926 да — 354, 1938 дә — 321, 1949 да — 261, 1958 дә — 142, 1970 тә — 120, 1979 да — 69, 1989 да — 18 кеше.

**АЙТКУ́ЛОВ** Сәлим Нигъмәт улы (10.1.1913, Казакъстан Респ-касы Урал өлкәсенең хәзерге Җангали р-ны Мухор пос. — 24.4.1975, Уральск ш.), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), кече лейтенант (1945). 1930 елдан Уральскида заводта эшли. 1941 нең июленнән Кызыл Армиядә, сентябрьдән Бөек Ватан сугышы фронтларында. 60 нчы армиянең 75 нче гв. укчылар дивизиясендә 231 нче гв. укчылар полкы автоматчысы. Воронеж, Үзәк, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары

гаскәрләре составында Харьков оборонасы операциясендә (1942), Курск сугышында (1943), Украина, Польша, Чехословакияне азат итү сугышларында катнаша. Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Уральск өлкәсе кулланучылар берлегенең оештыру бүлеге җитәкчесе. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга героев. К., 2000; Герои Приуралья. Уральск, 1965; Герои Советского Союза — казахстанцы.А.-А., 1968. Кн. 1; Ракипов Ш.З. Хранить вечно. К., 1980.

**АЙТМА́ТОВ** Чыңгыз Түрәкол улы (12.12.1928, Кыргызстан Респ-касының хәзерге Киров р-ны Шекер кышлагы), язучы, Кыргызстан ССРның халык язучысы (1968), Кыргызстан ССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1974). Кыргыз һәм рус телләрендә яза. Авыл хуҗалыгы ин-тын (1953), М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны (Мәскәү) тәмамлый. 1988–90 елларда «Иностранная литература» ж-лының баш мөхәррире, 1990–94 тә СССР һәм РФнең Люксембургтагы илчесе, 1994 елдан башлап Франция һәм Бенилюкс илләрендә (Бельгия, Нидерланд, Люксембург) Кыргызстан Респ-касы илчесе. Әсәрләре 1952 дән басыла. «Җәмилә» (1958), «Бәхил бул, Гөлсары!» (1966), «Ак пароход» (1970) повестьлары, «Гасырдан да озын көн» (1980), «Ахырзаман» (1987), «Кассандра тамгасы» (1994), «Таулар ишелгәндә (Мәңгелек кәләш»)» (2007) романнары авторы. Психологик портрет остасы. А. иҗатында күтәрелгән төп проблема — кеше һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтләре. А. әсәрләренең геройлары — автор яшәгән чорның актив, көчле рухлы замандашлары. «Кызыл яулыклы гүзәлкәем», «Беренче укытучы», «Анам кыры» повестьлары, «Гасырдан да озын көн» романы һ.б. татар теленә тәрҗемә ителә. «Кызыл яулыклы гүзәлкәем» («Гүзәлем Әсәл», 1966), «Ахырзаман» (1987) әсәрләренә нигезләнеп эшләнгән спектакльләр — Татар акад. театры сәхнәсендә, «Анам кыры» (1971) Әлмәт татар драма театрында зур уңыш казана. 1966–89 елларда СССР ЮС депутаты, 1989–92 дә СССР халык депутаты. Ленин бүләге (1963), СССР Дәүләт бүләкләре (1968, 1977, 1983) лауреаты.

Әсәр.: Собр. соч.: В 3 т. М., 1982–84; Плаха. Буранный полустанок: Романы. Днепропетровск. 1989.

*Әд.:* Гачев Г.Д. Чингиз Айтматов: (В свете мировой культуры). Фр., 1989; Акматалиев А.Л. Чингиз Айтматов и взаимосвязи литератур. Бишкек, 1991.

**АЙТУГА́НОВ** Ләбиб Кәрам улы (21.10.1935, Әгерҗе р-ны Нарат а. — 24.3.1964, Казан), шагыйрь, композитор, журналист. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1957 елдан ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында муз. тапшырулар редакторы булып эшли. Әсәрләре 1950 елларда «Яшь сталинчы» г-тасында басыла башлый. «Төнбоек» (И.Юзеев шигыре), «Юллар» (Ә.Ерикәй шигыре), «Безнең күңелләр» (Р.Гарипов шигыре) кебек популяр җырларга көйләр, «Ышанам» (Р.Еникеев һәм Р.Яхин көе), «Сандугач җыр суза» (А.Монасыйпов көе) җырларының текстлары авторы. Бу шигырьләр «Һәрвакыт истә» (1972), «Ышанам» (1995) җыентыкларында басылып чыкты.

**АЙТУГА́НОВ** Мәннаф Ногман улы (10.4.1912, Казан губ., Тәтеш өязе Олы Карамалы а. — 30.3.1979, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. 1932 елда Казан а.х. техникумын тәмамлый, Казан а.х. ин-тында укый. 1932–35 тә Актаныш һәм Олы Кариле (Кама Тамагы р-ны) МТСларында агроном, 1935–38 дә Кызыл Йолдыз р-ны җир эшләре бүлегендә баш агроном, 1938–42 дә орлык тикшерү лабораториясе директоры, 1942–43 тә ТАССР Җир эшләре халык комис-тының сортлар буенча идарә башлыгы, 1943–44 тә Ютазы МТСында директор, 1944–51 дә ТАССР А.х. министрлыгының МТСлар буенча Төньяк-Көнчыгыш идарәсе башлыгы, 1951–55 тә ТАССР а.х. министры урынбасары, 1955–58 дә Ямаш һәм Тәкәнеш р-ннары башкарма ком-тлары рәисе. 1958–68 елларда ТАССР ВДНХсының беренче директоры. Республиканың а.х.на машина-трактор хезмәте күрсәтүне оештыруга, күксагыз җитештерүне (чын каучук алу өчен) оештыруга өлеш кертә. ТАССР ЮСның беренче дүрт чакырылышы депутаты (1938–59), 1951–59 елларда ТАССР ЮСның а.х. буенча даими комиссиясе рәисе. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**АЙТУГА́НОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм җәмәгать эшлеклеләре: 1) **Идрис** (1818, хәзерге Теләче р-ны Олы Мәтәскә а. — 29.11.1880, Казан), сәүдәгәр А. нәселен нигезләүче, 1869 елдан 1 нче гильдия сәүдәгәр. Тукымалар б-н сәүдә иткән, Гостиный дворда 2 кибет тоткан; 2) **Исхак Идрис улы** (1843–90), 2 нче гильдия сәүдәгәр, тукымалар б-н сәүдә иткән. Казан шәһәр думасы гласные (1883–87), 1885 елдан Казан шәһәре җәмәгать банкының исәп-хисап тоту ком-ты әгъзасы; 3) **Исмәгыйль Исхак улы** (1873–1917 дән соң), 2 нче гильдия сәүдәгәр, *Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятен* оештыручыларның берсе һәм аның идарә рәисе (1899–1902). «Халидия» мәдрәсәсен тотучы иганәчеләрдән һәм аның тышкы идарәчеләреннән берсе.

*Әд.:* Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX веков). К., 1995.

**АК АМУ́Р** (Ctenopharyngodon idella), карплар семьялыгыннан төче су балыгы. Озынлыгы 120 *см* га, авырлыгы 32 *кг* га кадәр җитә. Гәүдәсе озынча, тәңкәләре эре, көмешсыман сары төстә; йоткылык тешләре ике рәтле. Көнчыгыш Азиянең тигезлек елгаларында, Россиядә Амур елгасының урта һәм түбән агымында яши. Җенси җитлегү чоры — 6–8 ел. Яшь балыклар — зоопланктон, зурлары үсемлекләр б-н туена. Үсү темпы югары. Балык тоту һәм үрчетү объекты булып тора. Сулыкларны үсемлекләрдән чистарту өчен файдаланыла. Татарстанда көньяктан кайтарылган ак һәм чуар ташмаңгай б-н бергә А.а. личинкалары, 1967 елдан башлап, берничә тапкыр — Зәй ГРЭСы су суыткычына,



А.Х. Айсин.




С.Н. Айткулов.

1971 дән Куйбышев сусаклагычына җибәрелә. Ләкин, җирле шартларның (су агымы тизлеге, темп-ра үзгәреше һ.б.) биол. үрчү үзенчәлекләренә туры килмәве сәбәпле, табигый шартларда уылдык чәчми.

**«АК БАРС»**, акционерлык коммерция банкы. 1993 елда Казанда оештырыла. РФнең Үзәк банкында теркәлә. Акционерлары — ТРның эре сәнәгать пр-тиеләре һәм дәүләт идарәсе структуралары: «Татнефть» АҖ, «Промтрактор» АҖ, «Икс-Луч» ҖЧҖ (икесе дә Мәскәү), «Чабаксар агрегатлар заводы» АҖ, «Селена Нефтехим» ҖЧҖ, «Инвестнефтехим» ҖЧҖ, «Ак Барс» холдинг компаниясе» АҖ һ.б. 2007 елның 1 гыйнварына «А.Б.»ның ТР терр-ясендә 84 өстәмә офисы һәм 118 операцияләр кассасы эшли. Банкның Россиядә гамәлдә йөрүче барлык лицензияләре дә бар һәм ул корпоратив яки шәхси клиентларга 100 дән артык төрдә хезмәт күрсәтә. 1 млн. 489 меңнән артык шәхси затка һәм 29 меңнән артык корпоратив клиентка хезмәт күрсәтә. Алар арасында ТРның иң эре экспортёрлары, нефть-газ һәм нефть-химия комплексы, машина төзелеше, телекоммуникация, төзелеш, химия, автотранспорт, сәүдә һәм агросәнәгать пр-тиеләре бар. Респ-каның икътисади һәм социаль үсеш программаларын гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтә; Россиянең эре банклары рейтингында әйдәп баручылар рәтендә. «А.Б.» АКШ, Германия, Франция, Швейцария, Швеция, Финляндия банклары б-н хезмәттәшлек итә. Бөтендөнья «СВИФТ» («SWIFT») банклар телекоммуникациясе берләшмәсе әгъзасы, «Рейтерс Дилинг» («Reuters Dialing») мәгълүмат дилинг системасы абоненты, Мәскәү банкара валюта биржасы, Фондлар базарында катнашучыларның милли ассоциациясе Вексель базарында катнашучылар ассоциациясе (АУВер), Россия сәүдә системасы һәм Россия банклар ассоциациясе әгъзасы. 2007 ел башына устав капиталы — 19,2 млрд., үз капиталы 27,2 млрд. сум тәшкил итә.

*Р.Х.Хәмидуллин, Ф.С.Зыятдинов.*

**«АК БАРС»**, 1990 еллардан Россиядә әйдәп баручы хоккей командаларының берсе. 1955 елда 16 нчы з-д (хәзер Казан моторлар төзү берләшмәсе) каршында «Машстрой» исеме б-н оештырыла, 1958 дән — «Урицкий исем. СК», 1991 дән — «Итиль», 1995 тән — хәзерге исемендә. 1958–62 елларда СССР, Россия чемпионатларының «Б» классында, 1962–92 дә «А» классындагы өченче дивизионда (ш.и. 1989–92 дә югары лигада),



«Ак Барс» хоккей командасы — Европа чемпионнары кубогы иясе (2007).

1992 дән милләтара, 1996 дан Россия хоккей лигасында, 1998–99 елларда Европа хоккей лигасында, 1999–2000 дә континенталь кубок турнирында катнашучы. «А.Б.» хоккей СКның президентлары Ф.Х.Мөхәммәтшин (1997–2004), Ш.Ф.Тәхәветдинов (2004 тән). Иң югары казанышлары: РСФСР чемпионы (1962, 1976); РФ чемпионы (1998, 2006), РФ чемпионатының көмеш медале иясе (2000, 2002), 1999/2000 елда Россия кубогы финалисты, Европа чемпионнары кубогы (2007), Континенталь кубок (2008) иясе. Команданың спорт казанышларына зур өлеш керткән тренерлар: А.В.Муравьёв (1956–65, 1966–68); В.Я.Андреев (1975–78); В.Ф.Васильев (1978–82); Г.Ф.Цыгуров (1984–87); В.А.Елфимов (1988–91, 1994–95); Ю.И.Моисеев (1995–99 һәм 2001 дән); В.В.Крикунов (1999–2000); З.Х.Билалетдинов (2004 тән). Иң яхшы уенчылар: капкачылар — Я.Клопоух, С.Абрамов, Д.Ячанов, һөҗүмчеләр — А.В.Ерёменко, Г.Маслов, С.Столбун, В.Шалахин, С.Котов, И.Рәхмәтуллин, С.Золотов, М.Сарматин, Д.Зарипов, А.Морозов, С.Зиновьев, Э.Кадермәтов, сакчылар — А.В.Терещенко, А.В.Бадюков, Э.Г.Лисин, Д.А.Обухов, В.Андреев, И.Хөснуллин, Р.Хафизов, Р.Шәвәлиев, С.Закамский, Р.Якубов, Д.Балмин, И.В.Щадилов, И.В.Никулин, А.С.Первышин.

Клуб өчен яшь хоккейчылар Урицкий исем. СК (1955–72), «Зенит» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан өлкә советы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе (1972–85), Урицкий исем. СКның балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе (1985–90), «Итиль» СКның балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (1990–94), 1994 тән ТР Физкультура, спорт һәм туризм дәүләт ком-ты каршындагы олимпия әзерлеге мәктәбендә тәрбияләнә. Шәкертләре арасында — яшьләрдән дөнья беренчелегенә ярышларда җиңүчеләр (СССР, Россия яшьләр җыелма командалары б-н): В.Михайлов (1980), И.Рәхмәтуллин (1980), Д.Архипов (1989); көмеш медаль алучылар — А.Анисимов (1995), Д.Архипов (1999), Р.Зәйнуллин (2000). Яшүсмерләрнең Европа беренчелегендә көмеш медаль алучылар (СССР, Россия җыелма командаларында) — тренер Г.Цыгуров (1988); А.Анисимов (1994); бронза медаль алучы — Е.Константинов (1998). «А.Б.» үзендәге календарь уеннарын 2005 тән «Татнефтьарена» боз спорт сараенда үткәрә.

**АК БҮРЕ́**, төрки-татар һәм төрки-монгол мифологиясе персонажы; төркиләрнең тотемик нәсел башы. А.б. образы төрки-монгол халыклары өчен уртак булган Бүз бүре (Борте Чино) образыннан килә. Борынгы кытай чыганакларында кайбер борынгы төрки генеалогик риваятьләр сакланган. Шуларның берсе буенча, Туг-юлар кайчандыр хунну кабиләсеннән төньякта яшәгән со кабиләсеннән барлыкка килә. Туг-ю токымының 70 бертуганы арасыннан иң олысы — Нишиду — бүредән туа. Башка риваятьтә хуннарның бабалары бүре б-н шаньюйның (ул дәверләрдәге төркиләр ханының яки каганның) сылу кызыннан тууы турында әйтелә. «Китабы дәдә Коркут» («Коркут бабам китабы», 15 йөз) дип аталган угыз героик эпосында нурлар чәчеп торуы б-н илаһилыгы күренгән Бүз бүре катнаша. Ул, Угыз-каганга һәм аның гаскәренә юл күрсәтеп, җиңүне тәэмин итә. Монголларның «Яшерен риваять» (13 йөз) җыентыгында Чынгыз ханның бабасы Борте Чинонын Бөек Күк ихтыяры б-н тууы, борынгы әбисенең Гоа-Марал («Нурлы Болан») булуы турында сөйләнә. Алтай дастаны «Ак Тойчы»да бүре мифологик геройның тәрбиячесе һәм яклаучысы буларак сурәтләнә. А.б.нең болгар кабиләләренең тотемик нәсел башы булуы да ихтимал; ак (бүз) төс аның илаһилыгы турында сөйли. Табигате б-н күп төрле: чибәр егет, әкияти кош һәм баһадир ат кыяфәтенә керергә мөмкин. Татар һәм башкорт риваятьләрендә А.б.нең мессиячел роле дә ассызыклана: ул куе урманнарда яки тауларда югалган кабиләне коткара. Татар әкияте «Ак бүре»дә ул яшәү һәм үлемнән өстен, кара урманның кырыс һәм кодрәтле хуҗасы буларак сурәтләнә. А.б. образы Н.Фәттахның Идел буе болгар дәүләтендә булган 10 йөз вакыйгаларын сурәтләгән «Итил суы ака торур» (1972) тарихи романында чагылыш таба.

*Әд.:* Татар халык иҗаты. Әкиятләр. К., 1977. 1 кит; Урманчеев Ф.И. По следам Белого волка: Ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племён. К., 1994.

*Ф.И.Урманчеев.*

**АК ГӨМБӘ́** (Boletus edulis), агариклар рәтендәге болетчалар семьялыгыннан көпшәле гөмбә. Табигатьтә, күбрәк Төньяк ярымшарда киң таралган. Яшь гөмбәнең эшләпәсе

ярымшар рәвешендә, үсә төшкәч, кабарынкы җәенке формага керә, 4–20 *см* диаметрлы, өске ягы — аксылдан караңгы-коңгырт төскә кадәр, аскы ягы — яшь гөмбәнеке ак, өлгергәненеке — яшькелт-соргылт төстә. Буе 4–15 *см* биеклектә, түбәнге өлешендә киңәйгән яисә кечкенә мичкәсыман рәвештә. Төсе аксылдан көрәнгә кадәр үзгәрә, өске өлеше ак яисә ачык көрән челтәрсыман сурәтле. А.г. кайбер агач токымнары б-н микориза булдыру сәләтенә ия. ТР терр-ясендә чыршылыкта А.г. еш очрый. Эшләпәсе ачык-көрәннән куе көрән төскә кадәр. Чыршы һәм чыршы катнаш урманнарда үсә. Каенлыкта үсә торган А.г. ачык-көрәнсу яисә тонык ак эшләпәле була. Башка гөмбәләрдән аермалы буларак, үлән арасында очрый. Имәнлектә А.г. зур төркемнәр ясап үсә. А.г. башка гөмбәләрдән ак төсе (атамасы шуннан), сындырганнан, киптергәннән һәм пешергәннән соң төсе үзгәрмәве б-н аерыла. Ашарга яраклы, тәмле. Аксым һәм витаминнарга бай. Пешерергә, кыздырырга, маринадларга һәм киптерергә яраклы. Халык медицинасында киптерелгән А.г. тәнәтмәсе өшегән урынны дәвалау өчен кулланыла. Рәсемен *Гөмбәләр* мәкаләсендә кара.

*Әд.:* Книга о грибах. Смоленск, 1996.

**АК ЕЛА́Н**, төрки-татар фольклоры һәм мифологиясе персонажы; халыкның тотемик нәсел башы; бүләк бирүче, геройның ярдәмчесе; еланнар патшасы. А.е. образы барлык мифологияләрдә дә диярлек чагылыш тапкан елан образыннан килә. Борынгы мифологияләрдә елан роле еш кына ике төрле була: ул бер үк вакытта яхшы да, куркыныч та; зур көчкә ия буларак, ул эпик геройдан карусыз буйсынуны таләп итә. Каюм Насыйри татар фольклорында барлык еланнарның кара төс б-н сурәтләнүен, шул ук вакытта еланнар патшасына ак төс хас булуын билгеләп үтә. Кешенең дошманы саналган кара еланнардан аермалы буларак, А.е. кешене ярата һәм яклый, хәвеф турында кисәтә һәм булыша. Татар әкияте «Ак елан»да, мәс., геройга падишаһның төшен ничек юрарга кирәген әйтә һәм берничә тапкыр аны үлемнән коткарып кала. Татар әкияте «Елан патшасы Шаһмара»да, кайбер галимнәр фикеренчә, фарсы эпик традициясе күзәтелә. А.е. монда да геройга ярдәм итә: ханны Ак елан ите б-н дәвалап, каты авырудан савыктыра. Шул ук әкияттә еланның гайре табигый көче — алдан күрүчәнлек сәләте ачыла, шуңа күрә герой, елан итеннән шулпа ашагач, кошлар һәм җәнлекләр телен аңлый башлый. «Урал батыр» исемле башкорт кобайырында еланнар патшасы Каһкаһа — батырның куркыныч дошманы; монда А.е. тауларны да эретерлек көчкә ия булган аждаһа кыяфәтендә сурәтләнә. Борынгы заманнардан ук ак төскә хөрмәт хисе А.е. образының уңай якларын тудырган. Ш.у. казакълар, Көньяк Себер һәм Урта Азия халыклары мифологиясендә ак һәм кара еланнар көрәше турындагы сюжет киң таралган. Бу көрәшнең шаһиты булган төп герой Ак еланга ярдәм итә. Урта Азиядә таралган ышану буенча, йортта яшәгән Ак еланга кагылырга ярамый. Күп кенә халыклар мифологиясендә А.е.га карата табу яши. А.е.ны күргән кеше аның баш өстенә он сибәргә яки сөт б-н сыйларга тиеш. Ш.у. А.е. образында төрки легенда һәм риваятьләрендә популяр булган Хызыр пәйгамбәр гәүдәләнгән дип фаразлана.

*Әд.:* Урманчеев Ф.И. Ак елан һәм еланнар // Мәдәни җомга. 2001. № 6, 7, 11, 12; Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр. К., 1994; Казахский фольклор в собрании Г.Н.Потанина. А.-А., 1972; Урманчеев Ф.И. По следам Белого волка. Ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племён. К., 1994.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«АК ИДЕ́Л»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1919 елда Уфа шәһәрендә атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Наширләре Н.Үтәлиев, Л.Газизов. Мөхәррире М.Нәүрузов. Уфаны адмирал А.В.Колчак армиясе яулап алганнан соң чыга башлый. Колчакның приказлары, боерыклары басыла, большевиклар диктатурасына каршы чыга, татарча милли вакытлы матбугат басмаларын ачарга өнди, большевиклар яклы вакытлы матбугатны фактларны бозып күрсәтүдә гаепли. Рубрикалары: «Дөньяда», «Уфада», «Белдерүләр» һ.б.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000. .

**АК КАЕ́Н**, татар мифологиясендә һәм фольклорында — изге агач. Яктылык, чисталык һәм гүзәллек символы буларак, каен күп кенә Көнчыгыш һәм Көнбатыш мифология системаларында киң таралган. Каенны олылау агач культына — күп кенә халыкларда ыруглык чорында киң таралган табигатькә табынуның бер төренә кайтып кала. Мәс., бурят ыругларында кайбер йолалар изге каенлыкларда гына үткәрелгән; Урта һәм Төньяк Азиядәге кайбер халыкларның шаманнары, йолалар үткәргәнче, җиргә каен ботагы кадап куйганнар. Кемне дә булса шаман дип игълан итәр алдыннан, урманнан казып алынган каенны махсус урынга күчереп утыртканнар. Шаманның шөлдерле барабанының тоткасын да шул каеннан ясаганнар.

Каенга табыну йоласы калдыклары татарларда да күзәтелә: кырда ялгыз үсеп утырган каен төбендә куркыныч вакыйгалар һәм күренешләр була: каен янына явыз рухлар килсә, яшен сугу ихтималы бар, дигән ышану яши. А.к.ны татарлар зират агачы буларак хөрмәт итәләр (хәзерге вакытка кадәр «каен зиратлы» дигән гыйбарә сакланган); бу карашлар үлгәннәрнең җаннары зиратта үскән каеннарга яки аларның яфраклары арасында сайраган кошларга күчә дигән ышанудан килә. Кәләшне усал рухлар сихерләвеннән саклау өчен аны, гадәттә, туй алдыннан мунчада каен себеркесе б-н чабындырганнар. Идел буе Болгары дәверенә караган «Айдар хан һәм Мөхәммәд илчеләре» хикәясендә Пәйгамбәр илчеләренең болгар патшасы Айдар ханның кызын каен чыбыкчалары б-н дәвалавы турында сүз бара. Каенга табыну күпсанлы әйтемнәрдә, мәкальләрдә, ш.у. халык җырларында чагылыш тапкан.

*Әд.:* Урманчеев Ф. Ак каеннар моңы // Хәсән Туфан. Шагыйрьнең иҗат юлы турында. К., 1976; шул ук. Ак каен нигә тирбәлә // Дастаннарга лаек замана. К., 1990; Манжигеев И.А. Бурятские шаманистические и дошаманистические термины. М., 1978.

*Ф.И.Урманчеев.*

**АК КИРМӘ́Н** (Аккирмән), Днестр тамагында урнашкан шәһәр, борынгы грекларның Тира исемле торак пункты урынында барлыкка килгән. А.К.нең археол. калдыклары хәзерге Одесса өлкәсе (Украина) Белгород-Днестровск шәһәре биләмәсенә керә. 545 елда А.К.нең — антларга, 9–11 йөзләрдә тивер һәм улич кабиләләренә караганлыгы мәгълүм. 13 йөзнең 1 нче яртысында аны монголлар яулап ала, исеме Ак Либо дип үзгәртелә. Алтын Урда дәүләтенең Кырымдагы Генуя (җәнүизләр) колонияләре һ.б. б-н сәүдә итүче эре диңгез порты була. Аның аша чит илләргә сатуга, нигездә, бодай чыгарыла. Шәһәр ш.у. эре һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак билгеле. Анда ак таштан 1438–54 тә төзелгән кирмән корылмасы сакланган. Археол. тикшеренүләрне А.К.дә төрле елларда Э.Р.Штерн, Л.Д.Дмитров, М.Г.Рабинович, А.А.Кравченко, Г.Братиану, Н.Константинеску һ.б. башкара. Казулар вакытында балчыктан ясалган савытларны яндырып чыныктыру өчен кулланылган бик үзенчәлекле мичләргә юлыгалар: аларда һава йөрү юлы катлауландырылган була. А.К.дә яшәүчеләргә хас кайбер башка үзенчәлекләр дә ачыклана: торак йортның суфа-сәкесе аерым учак-тандыр б-н җылытылган, идәндә юыну-тәһарәт алу чокыр-савыты — ташнау табыла. Бу үзенчәлекләр Алтын Урданың үзәк өлешендә урнашкан торак пунктларга да хас күренеш. А.К. хәрабәләреннән ш.у. Алтын Урда дәверенә хас ялтыравык өслекле, төрле рәвешле итеп сырланган чүлмәк кисәкләре (гәнеч), Кытай фарфоры (селадон) үрнәкләре дә табыла. Археол. казу-тикшерүләрдән соң шундый нәтиҗәгә киленә: бу шәһәрдә тормыш-көнкүреш кинәттән өзелмичә, әкренләп сүнә барган. Бу исә Л.Л.Полевой фикерләрен дәлилли, аның күзаллавынча, Прут-Днестр аралыгыннан төньяктарак яңа Молдова кенәзлеге оеша, аның даими басымы нәтиҗәсендә бу төбәктә тормыш сүнә бара. Иң соңгылары булып биредән А.К. халкы китә. 1484 тә шәһәрне төрекләр биләп ала һәм аңа А.К. исеме бирелә. 1812 дән ул Россиягә керә (1944 тән Белгород-Днестровск ш.).

*Әд.:* Кравченко А.А. Жилые комплексы золотоордынского Белгорода // Материалы по археологии Северного Причерноморья. Киев, 1976. Вып. 8; шул ук. Производственные комплексы Белгорода XIII–XIV вв. // Античная Тира и средневековый Белгород. Киев, 1979; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985; Федоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994.

*А.Ә.Борһанов.*

**АК КҮБӘЛӘКЛӘ́Р** (Pieridae), көндезге күбәләкләр семьялыгы. Дөнья фаунасында 500 ләп, Татарстанда 15 төре исәпләнә. Канат җәеме 8 *см* га кадәр. Арткы канатларында эчке уемты булмавы һәм аларда ике аналь сеңерчә булуы А.к.нең үзенчәлекле билгесе бу-

лып тора. Алгы аяклары яхшы үскән. Түсләре күбесендә ак, сары һәм кызгылт сары. Күбәләк кортлары яшел яки чуар, кыска төкләр б-н капланган. Курчаклары башларын өскә каратып урнаша, ефәк җебеннән биле б-н субстратка беркетелә. А.к. һәр җирдә очрый, кайбер төрләре күп санлы. А.к.нең аерым ыругларының үсеше, кагыйдә буларак, үсемлекләрнең билгеле семьялыклары б-н бәйләнгән: ак күбәләк (Pieris) әвернә чәчәклеләрдә, сары күбәләк (Colias) — кузаклыларда, кайберләре кошкунмасчаларда, розачаларда һ.б. яшиләр. ТРда кәбестә күбәләге киң таралган. Алгы канатларының очы кара төстәге эре ак күбәләк, ана күбәләкнең 2 шәр түгәрәк кара табы бар. Еш кына лимон күбәләге дә очрый. Канатлары очлы. Аталары — сары, аналары яшькелт ак төстә. Киң таралган төрләре: сары кыр күбәләге, дүләнә күбәләге, борчак күбәләге, шалкан күбәләге һәм гәрәнкә күбәләге. Аерым төрләре туклану чылбырында мөһим роль уйный. Гәрәнкә күбәләге, шалкан күбәләге, кәбестә күбәләге — әвернә чәчәклеләр; сары күбәләк — кузаклылар, дүләнә күбәләге — төшле һәм орлыклы җимеш культураларының корткычлары. А.к. б-н көрәшү өчен механик, химик һәм биологик ысуллар кулланыла. Таң күбәләге (Зегрис күбәләге) ТРның Кызыл китабына кертелгән. К. *Күбәләкләр*.

*Н.В.Шулаев, Н.Г.Петров.*

**АК КҮБЕ́К (АККҮБӘ́К) ХАН** (? – 1550 тирәсе), Әстерхан ханы (1532–33, 1545–50). Себер ханы *Мортаза* улы, Әстерхан ханы *Касыймның* туганнан туганы. Нугай Урдасының көчсезләнүеннән файдаланып, чиркәс көчләре ярдәмендә Касыйм ханны тәхеттән куа һәм үзе утыра (1532). Үз ханлыгын ныгыту, аның Нугай Урдасы б-н Кырым ханлыгыннан бәйсезлеге сәясәтен алып бара. 1533 елда, *Габделрахман хан* аның тәхетен яулап алгач, Төньяк Кавказ төбәгенә качарга мәҗбүр була. 1545 елда Әстерхан тәхетен кайтарып ала, әмма 1546 да Ямгырчы хан аны чиркәсләр ярдәмендә бәреп төшерә. Кырым ханы Сәхибгәрәй Хаҗитарханны алганнан соң (1547), А.К.х.ны кабат тәхеткә утырта. Соңрак Ямгырчы хан рус гаскәре ярдәмендә аның урынын биләүгә ирешә.

*Әд.:* Кушева Е.Н. Народы Северного Кавказа и их связи с Россией. М., 1963; Османская империя и страны Центральной, Восточной и Юго-Восточной Европы в XV–XVI вв. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**АК КҮЛ**, Яшел Үзән р-ның Бело-Безводный авылыннан көньяктарак, Сумка елгасы үзәненең киңәйгән урынында. Идел-Кама саклаулыгы зонасына керә. Су өслегенең мәйданы 5,3 *га*. Су күләме 89 мең $м^3$. Озынлыгы 540 *м*, уртача киңлеге 98 *м*, иң зур киңлеге 140 *м*, уртача тирәнлеге 1,7 *м*, иң зур тирәнлеге 4 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Күл аша Сумка елгасы ага. Суы үтә күренмәле, чиста, уртача минеральләшкән (234–268 *мг/л*), гидрокарбонат-сульфат-магнийлы, чагыштырмача каты (4,1–4,9 *мг-экв/л*). Күлнең төньяк-көнчыгыш өлеше сазланган, көнчыгыш өлешендә — комлы кечкенә пляж, төньяк өлешендә — 15–20 *м* киңлектә су үсемлекләренең (сары төнбоек һәм ак төнбоек) популяцияләре. Су һәм су яны флорасы өчен үзенчәлекле үсемлекләр: Канада элодеясы, вак бака тәңкәсе, соры зирек, кара тирәк. Фаунасы өчен — Америка чәшкесе, ондатра, гади яр чыпчыгы, күл акчарлагы, елга акчарлагы, күл бакасы һәм очлы башлы бака, алтын табан балык үзенчәлекле. Сумка елгасының комлы-балчыклы кителремәләре аркасында күлнең күләме кечерәя. ТРның табигать истәлеге (1978).

**АК МӘЧЕ́Т**, урта гасырларда Алтын Урда шәһәре, Көньяк Буг елгасының уң ярында урнашкан була. Археол. калдыклары Украинаның хәзерге Николаев өлкәсе Ак Мәчет авылы янәшәсендә. Риччо Занони төзегән картада (1772) ул урында мәчет сурәте урнаштырылган. Шәһәр биналары калдыклары булуы 19 йөздә теркәлгән. Археол. тикшеренүләр үткәрелмәгән.

*Әд.:* Эварницкий Д.И. Вольности запорожских казаков. СПб., 1898, Карта 1; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985; Петрунь Ф.О. Степове Побужжя в господарскім та віськовім укладі українского пограниччя // Журн. науково-дослідчіх катедр м. Одеси. 1925. Т. 2, № 2.

**АК ПУЛА́Т**, Болгар шәһәренең Алтын Урда дәверенә караган болгар архит-расы истәлеге, Шәрекъ илләренә хас җәмәгать мунчасы. Идел буе Болгар дәүләте башкаласында (хәзер Болгар тарих-архит-ра саклаулыгы) 14 йөз урталарында төзелә. Атамасы ак известьташтан салынган эчке диварларының төсенә карап бирелгән. Эчке ягы һәм үзәк залының гөмбәзе архивольтлар, кессоннар б-н бизәлгән була. 32х16 *м* мәйданны биләгән бина башта гөмбәзләр һәм күп кыеклы агач түбә б-н капланган берничә өлештән торган. Әрка рәвешендәге төп керү юлы көнчыгыш ягында урнашкан, аның аша диварлары буйлап таш сәкеләр тезелгән чишенү бүлмәсенә үткәннәр. Тар мунча алды аша юыну бүлмәләре урнашкан үзәк өлешкә кергәннәр. Уртадагы хачсыман нигезгә корылган зал ярымшар рәвешендәге гөмбәз б-н капланган һәм почмакларындагы гөмбәзле бүлмәләр б-н тоташкан. Таштан ясалган су савытлары тезелгән юыну залының көньягында ике түгәрәк мич һәм су чаннары булган озынча бүлмә урнашкан. Мичләрдән башланып киткән җылы кудыру юллары юыну бүлмәләренең идәне астыннан узган, дивар эченнән күтәрелгән торбалар җылы һаваны өскә суырган. Чүлмәк сусүткәргеч һәм юынтык суларны агызу юллары диварлар эченнән үткәрелгән. А.п.ның корылышында урта гасырлардагы Урта Азия, Кырым, Кавказ арты архит-расы һәм җирле мигъмарият мотивлары берләшкән. 1860 елларга кадәр корылма ярым җимерек хәлдә тора. Аның ул чордагы сурәте П.С.Паллас, Н.Г.Дюранд, бертуган Чернецовлар, И.И.Шишкин, А.К.Шмидт рәсемнәрендә саклана. 1834 тә А.К.Шмидт А.п. үлчәмнәренең альбомын бастырып чыгара. 19 йөз ахырында В.А.Казаринов хәрабәләрнең сызымнарын эшли. 1981–83 тә археологлар Т.А.Хлебникова, Р.Шәрифуллин һәм реставрацияләүче арх. Р.В.Билалов тарафыннан А.п. хәрабәләрендә археол. һәм архитектур тикшеренүләр үткәрелә. Консервацияләү эшләре башкарыла.

*Әд.:* Башкиров А.С. Памятники Булгаро-татарской культуры на Волге. К., 1928; Айдаров С.С., Аксёнова Н.Д. Великие Булгары. К., 1975; Казаринов В.А. Развалины древних зданий при с. Болгар // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии. 1888. Т. 6, вып. 2.

*С.С.Айдаров.*

**«АК РОМА́ШКА»**, («Ак чәчәк көне»), һәр ел саен туберкулёз б-н чирләгән кешеләргә ярдәм йөзеннән үткәрелә торган хәйрия акциясе. «Ак чәчәк көне»н үткәрү фикере Скандинавиядә барлыкка килә, беренче тапкыр бу көн 1908 елның 1 маенда — Швециядә, соңрак Норвегия, Дания, Германия һ.б. Европа илләрендә үткәрелә. Бөтенроссия туберкулёзга каршы көрәш лигасы 1910 да оештырыла. 1913 тә ул 190 чамасы мөстәкыйль җәмгыятьне берләштерә һәм анда 30 меңгә якын кеше исәпләнә. Медицина әдәбиятында, махсус брошюраларда зур шәһәрләрдә туберкулёздан үлүчеләр һәм авыручылар турында статистик мәгълүмат басыла. Бөтенроссия туберкулёзга каршы көрәш лигасының Казан бүлеге 1911 дә оеша (рәисе — проф. А.Н.Казимбәк). 1911 нең 1(14) маенда үткәрелгән гуманитар акциядә Казан халкы һәм ун-т студентлары актив катнаша. Бу көндә урамнардан ак чәчәкләр б-н бизәлгән атлы арбалар үтә, мәйданнарда туберкулёз турында әңгәмә һәм лекцияләр оештырыла. Казанда беренче «Ак чәчәк көне»нә багышланган витрина бизәлә. Җыелган акча ютәлгә каршы көрәш өчен тотыла (бушлай дәвалау, рус, татар, чуваш һәм мари телләрендә брошюралар һәм рәсемле плакатлар нәшер итү). 1912–15 тә җәмгыять 65 мең сум акча туплый. А.Н.Казимбәк инициативасы б-н шушы акчага һәм аның фондка керткән шәхси иганәсенә балалар санаторие төзелә (1920).

1998 дә «Каменка» хастаханәсенең баш табибе Р.Ә.*Җәләлиев* тырышлыгы б-н «Ак ромашка» гуманитар акциясе яңадан торгызыла, туберкулёзга каршы көрәш буенча хәйрия фонды булдырыла (президенты Р.Ә.Җәләлиев). 1998 нең октябрендә телемарафон уздырыла. Беренче иганәчеләр — Усад спирт з-ды (директоры И.М.Егоров) һәм Биектау р-ны хакимияте җитәкчелеге. Җыелган акчага «Каменка» хастаханәсенә кап. ремонт ясала, фонд тарафыннан проф. А.Н.Казимбәк исем. еллык бүләк раслана (елның иң яхшы фтизиатрына бирелә), мед. ун-тын тәмамлаганнан соң фтизиатр булып эшләргә ниятләгән студент-отличникларга стипендия билгеләнә. Ел саен 24 мартта ТРда Халыкара туберкулёзга каршы көрәш көне — «Ак ромашка» хәйрия акциясе үткәрелә.

*Әд.:* Залялиев А. Река времени. К., 2001.

*Р.Г.Исхакова.*

**АК САРА́Й**, урта гасырларда Алтын Урда шәһәре, Идел кушылдыгы Ахтүбә елгасының сул ярында урнашкан. Археол. калдыклары хәзерге Әстерхан өлкәсенең Хәрабәле р-ны Лапас авылы янында. Эре һөнәрчелек үзәге була. В.Л.Егоров фикеренчә, А.С.да, нигездә, һәйкәл-төрбәләр, төрбә-мавзолейлар төзүчеләр яшәгән. Элекке шәһәр урынында кирпеч, ялтыравык өслекле гәнеч (ма-

йолика), архит-ра бизәлеше әйберләре җитештерү эзләре сакланган. 1495 елда Аксак Тимер явы вакытында А.С. җимерелгән, таланган дип фаразлана. 1580 елларда А.С. корылмалары кирпечен рус осталары Әстерхан Кремлен төзегәндә кулланган. Аерым төрбә диварлары калдыкларын әле 1930 еллар башында да күрергә мөмкин булган. Соңрак аларны Хошеут авылы кешеләре язгы судан саклану корылмалары төзегәндә сүтеп бетергән. Шәһәрдән көнчыгышта 4 мөселман төрбәсе хәрабәләре сакланган, алар яндырылган кызыл кирпечтән, кирпеч өслекләре кафель б-н бизәлгән. Бу мавзолейлар Ахтүбә елгасыннан читтәрәк, калку урыннарда төзелгән. Нигезләре тигез квадрат шәкелендә, ян-яклары берничә йөз метрга сузылган. Мөгаен, бу биналар бик зур, мәһабәт корылмалар булгандыр. Хәзер инде алар тулаем җимерелеп беткән. Шәһәр үзе бу корылмалардан 2 *км* чамасы ераклыкта. Монда күп санда яндырылган кирпеч калдыклары, балчыктан эшләнгән савытлар, гәнеч яндыру мичләре табыла. Бу шәһәр һәм мавзолей хәрабәләрен 20 йөздә беренчеләрдән булып Әстерханның төбәк музее директоры В.А.Филипченко тикшерә, хәрабәләр урнашкан мәйданның планын төзи, иң зур төрбәнең җирле халыкта Дәүләт хан исемен йөртүен яза. 1990 елларда РФАнең Археология ин-ты каршындагы Идел буе археол. экспедициясе (В.В.Дворниченко һ.б.) төрбәләр урнашкан урыннарның топографик картасын төзи. Экспедиция, әлеге 4 зур төрбәдән тыш, тагын берничә кечерәк төрбә урыннарын да билгели. 2000 дә Д.В.Васильев җитәкчелегендәге археол. отряды андагы газүткәргеч янәшәсендә 2 урында казу эшләренә керешә. Тиздән алар яндырылган кирпечтән квадрат рәвешендә салынган йорт нигезенә юлыга. Диварлары көн тарафларына төгәл каратып салынган бинаның эчке ягы акшарланган. Төньяк-көнбатыш дивар буен биләгән суфа-сәкенең 2 башында учак-тандыр табыла. Учак авызлары ишегалдына чыгарып эшләнгән. Бер учакның ике төпсез чүлмәктән ясалган морҗасы да сакланган. Казу вакытында Алтын Урда чорына караган балчык савыт, гәнеч калдыклары, Үзбәк хан (1312–42) дәверенә нисбәтле 85 данә тәңкә һ.б. әйберләр табыла. Бертуган Пицигано (1364) һәм Фра-Мауро (1459) төзегән карталарда А.С. урынында ханнар (императорлар) каберлеге булуы күрсәтелгән. Плано Карпини фикеренчә, Алтын Урдада «императорлар, бәкләр һ.б. күренекле шәхесләр, кайда гына вафат булсалар да, кайтарып җирләнә торган билгеле бер урын билгеләнә». Бу урынга теләсә кем кертелмәгән, аның саклаучылары булган. В.Л.Егоров фикеренчә, А.С. мавзолей-төрбәләре Җүчиләрнең ислам динен кабул иткән вәкилләрен (Бәркә, Үзбәк, Җанибәк, Бирдебәк һ.б.) җирләү урыны саналган. Ул ш.у. монда Бату ханның һ.б. мәҗүси Җүчиләрнең җирләнү ихтималын да кире какмый. Монголларда идарәчеләр нәселе вәкилләрен аерым бер тыюлы биләмәдә («курук») күмү йоласы яшәгән. Кайбер этнографик экспедицияләр (Э.Ш.Идрисов, А.В.Сызранов һ.б.) Лапас авылы кешеләреннән А.С.тарихына караган кызыклы җыр-бәетләр дә язып алган. Шуларның берсендә «Дәүләт хан шәһәре»н Ахтүбә елгасы б-н тоташтырган җир асты юлы булуы, икенчесендә — Җиһангир ханга бәйле бер риваять тасвир ителә. Бер яу вакытында Җиһангир хан, имеш, сылу кызы һәм зур байлык-хәзинәләре б-н шундый җир асты юлына төшеп яшеренгән.

*Әд.:* Бартольд В.В. К вопросу о погребальных обрядах турков и монголов. Соч. М., 1966. Т. 5; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985; Путешествие в восточные страны Плано Карпини и Гильома де Рубрука. Алматы, 1993; Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994; Рудаков В.Г. Вопрос о существовании двух Сараев и проблема локализации Гюлистана // Уч. зап. Татар. гос. гуманитарного ин-та. 1999. Вып. 7; Васильев Д.В. Городище Ак-Сарай // Археология Нижнего Поволжья на рубеже тысячелетий. Астрахань, 2001.

*А.Ә.Борһанов.*

**АК ТӨЛКЕ́**, бүреләр семьялыгыннан ерткыч җәнлек. Кыйммәтле мех алу өчен читлектә үрчетелә. Җәнлекнең мехы куе һәм озын. Төсе аксыл көрәннән куе көрәнгәчә, аксыл сорыдан карага кадәр. Җенси җитлегү чоры 9–10 айдан соң башлана. Аталану вакыты февральнең 2 нче ункөнлегеннән апрельгә кадәр дәвам итә. Йөклелек вакыты 51–52 көн. Бер А.т. 24 кә кадәр бала тудыра ала, уртача 8–10 бала китерә. Яңа туган җәнлекнең авырлыгы 60–90 *г*. 1 айлык яшь төлкенең авырлыгы 580–690 *г* (ана), 630–750 *г* (ата), 2 айда 1,6–1,7 *кг* га (ана) һәм 1,7–2 *кг* га (ата) җитә. Октябрьнең соңгы ункөнлегендә җәнлекләрне суя башлыйлар. Татарстанга А.т. 1941 елда китерелә. А.т. Мамадыш р-ны «Бөрсет», Питрәч р-ны «Кощаково», Лаеш р-ны «Матюшино», Биектау р-ны «Бөреле» фермаларында үрчетелә. 2007 ел башына ана А.т.ләр саны 880 исәпләнә. 2006 да бер ана төлкедән 8,71 бала алынган. Төп токымнар — көмешсыман һәм вуаль төстәгеләр (к. «*Бөреле*» агрофирмасы мәкаләсенә илл.).

*Әд.:* Лебедько В.П. Охотоведение и звероводство. Брянск-Трубчевск. 2003.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**АК УРДА́**, 13–15 йөзләрдә Алтын Урда дәүләтенең уң канаты атамасы. Башында Бату хан һәм аның варислары, 1380 елдан соң Җүчиләр дәүләтенең сул канаты (Күк Урда) вәкилләре варислары (Урда Эҗен, Тука Тимер, Шәйбан) торган. 13 йөз урталарыннан А.У. Җүчиләре Алтын Урдада Күк Урда вәкилләре б-н чагыштырганда өстен — идарәче нәсел саналган. А.У., үз чиратында, ш.у. 2 өлешкә бүленә. Нугай, аннары Хурумша кул астындагы көнбатыш өлешкә Кырым, Кара диңгезнең төньягындагы җирләр, Дон елгасы төбәкләре керә; Бату, аннары Бәркә һ.б. Идел буена, Төньяк Кавказ җирләренә — көнчыгыш өлешкә баш булалар. 1260 еллардан А.У. ханнарына рус кенәзләре, болгар әмирләре һәм Кырым шәһәрләре дә буйсынган. Кайбер тарихчылар (А.Ю.Якубовский, К.А.Пищулина), соңрак иҗат ителгән чыганакларга таянып, А.У. биләмәсен Алтын Урданың көнчыгыш өлешенә нисбәтлиләр. Мондый карашны М.Г.Сәфәргалиев, Г.А.Фёдоров-Давыдов, Ә.Г.Мөхәммәдиев, В.Л.Егоров һ.б. кире кага. Алар А.У. биләмәләрен Көнчыгыш Европада урнашкан дип билгелиләр.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Фёдоров-Давыдов Г.А. Кочевники Восточной Европы под властью золотоордынских ханов. М., 1966; шул ук. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система 12–15 вв. М., 1983; Исхаков Д.М, Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар в VI — первой четверти XV вв. К., 2000.

*И.Л.Измайлов.*

**АК ЧӘЧӘ́К**, болын ромашкасы (Leucanthemum), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 ләп төре билгеле, Евразиянең уртача поясында таралган. ТРда бер төре билгеле — гади А.ч. (L. vulgare) — барлык р-ннарда да очрый. Коры үзәнле болыннарда, урман аланнарында, елга тугайларында үсә. Сабагы туры, күбрәк ялгыз, ботаксыз, 15–60 *см* озынлыкта. Яфраклары чиратлашкан, тамыр янындагылары — озын саплы һәм каяулы, сабактагылары — утырма, озынча. Сабак очында ялгыз зур кәрзине бар. Кырыйдагы телсыман чәчәкләре ак, уртадагы көпшәсыман чәчәкләре сары төстә, серкәчләре һәм җимшәне бар. Җимеше — сырлы орлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрь айларында өлгерә. Орлыклардан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Яфракларында аскорбин к-тасы, каротин, орлыкларында май бар. Үсемлек бәвел кудыру, авыртуны басу, ялкынсынуга каршы, җәрәхәтне төзәтү үзлекләренә ия. Баллы үсемлек. Бакчадагы катмарлы төрләрен декоратив үсемлек буларак үстерәләр.

**АК ЧЫРШЫ́**, пихта (Abies), наратчалар семьялыгыннан мәңге яшел ылыслы агачлар ыругы. 40 лап төре билгеле. Тауларда, сирәгрәк Төньяк ярымшар тигезлекләрендә үсә. ТР терр-ясендә бер төре — Себер А.ч.сы (A. sibirica) Кама алдында, Көнчыгыш Кама аръягында — *Кызыл Тау* ландшафтлы табигать истәлегендә очрый. Биеклеге 30 *м* га, диаметры 0,8 *м* га кадәр җитә. Конуссыман куе ябалдашлы. Кайрысы шома, куе соры төстә, хуш исле сумала б-н тулган күпсанлы төерләре бар. Ылысы йомшак, яссы, өстән куе яшел, астан ике буй-буй аксыл сызыгы бар. Ана «күркәләре» яшел яки кызгылт-шәмәхә төстә, ябалдашның өске өлешендә үткән елгы ботаклар очында берәмләп вертикаль урнашалар. Ата башакчыкларында саргылт яки кызгылт серкәлек бар, ябалдашның урта һәм түбән өлешләрендә ике яшьлек ботакларның өске ягында ылыс куентыгында берәмләп урнашалар. Чыршы күркәләреннән аермалы буларак, алар һәрвакыт өскә караган һәм сумала б-н ябышкан. Һәр орлык кабыгы астында икешәр канатлы орлык үсә. Күп кенә ылыслыларныкы кебек, орлыклары сибелгәч, күркәләр агач төбенә өзелеп төшми, сентябрь-октябрь айларында алар агачта коелалар, шуңа күрә А.ч. агачлары төбендә бөтен күркәләр булмый. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (аскы ботаклар тамырлану) үрчи. А.ч. акрын үсә. Һаваның төтен һәм газ б-н пычрануын авыр кичерә. Үзагачы төзе-

лештә, әрҗәләр һәм музыка кораллары ясауда кулланыла. А.ч.да йөрәк эшчәнлеген көчәйтә торган камфараның төп чыганагы — эфир мае бар. Ылысында ш.у. флавоноидлар, марганец, бакыр, цинк, С витамины бар, аны зәңгелә авыруына каршы файдаланалар. А.ч. 150–400 ел яши. Ш.у.к. *Бөрсет акчыршылыклары, Порфирьев акчыршылыгы.*

**АК ШИГЫ́РЬ**, силлабик һәм силлабо-тоник шигырь төзелешендә рифмалашмаган шигырь. Татар поэзиясендә А.ш.нең бай традицияләре бар. Аңа Г.Тукай («Мужик йокысы», 1905), Дәрдемәнд («Түгел лаек», «Ил») мөрәҗәгать итә. Барлык традицияләрне инкяр итү хөкем сөргән 1920 елларда А.ш.дә мелодик ритмика кулланудан беркадәр читләшү күзәтелә (К.Нәҗми, Г.Кутуй, Сирин). Ләкин татар әдәбиятында бу күренеш киң таралыш алмый. Х.Туфан, М.Җәлил, Н.Исәнбәт, Ә.Фәйзи, Ф.Кәрим үз иҗатларында А.ш.не актив кулланалар һәм аны яңа формалар б-н баеталар. Рифмалашкан һәм рифмалашмаган шигырьләрне аралаштырып язуның беренче үрнәкләре Х.Туфан («Бөдрә көннәр», 1926), М.Җәлил («Алтынчәч», 1941), Н.Исәнбәт («Түләк», 1944), И.Юзеев («Тынлык белән сөйләшү», 1966), Ә.Баян («Каракош», 1992) әсәрләрендә очрый. А.ш. б-н язылган әсәрләр ш.у. Ә.Давыдов, Ш.Анак, З.Мансуров, Р.Фәйзуллин, Р.Зәйдулла, Г.Морат, Р.Сүлти иҗатларында урын алган.

*Әд.:* Юзиев Н. Ак шигырь // Шигырь гармониясе. К., 1972.

*Т.Н.Галиуллин.*

**«АК ЮЛ»**, рәсемле балалар журналы. 1913 елның 15 апреленнән 1916 ның 22 гыйнварына кадәр Казанда айга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 74 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире Ф.Агиев. Даими язышучылары: Ш.Алкин, Ш.Әхмәдиев, Г.Баттал, И.Бикколов, С.Җәлал, Н.Исәнбәт, Х.Кәрим, Г.Рәфикый, Ф.Сәйфи-Казанлы, С.Сүнчәләй, Г.Шәрәф, З.Ярмәки һ.б. Журнал милләтнең терәге булырдай укымышлы, югары әхлак сыйфатларына ия булган буын тәрбияләүне максат итеп куя, балаларны милләткә хезмәт итәрлек итеп үз-үзләрен камилләштерергә чакыра. Гаиләдә һәм мәктәптә балалар тәрбияләү проблемаларын күтәрә, балалар өчен язылган шигырь һәм проза әсәрләрен, рус һәм чит ил классик язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итеп бастыра. Акча җитмәү сәбәпле чыгудан туктый.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«АК ЮЛ»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби рәсемле журнал. 1964–74 елларда Оулу, 1974–77 тә Хельсинки (Финляндия) шәһәрләрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 64 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире С.Хәмит. Журнал аң-белем тарату максатында чыгарыла. Татар халкы тарихына, әдәбияты, сәнгатенә кагылышлы мәкаләләр бастыра, фин татарлары тормышын яктырта. Берничә саны балаларга атап чыгарыла. Финляндиядә яшәүче татарлар арасында таратыла.

*Әд.:* Таһир Г., Надиров И. Бәрәкәтле хәрәкәт // Казан утлары. 1986. № 4; Кәримуллин Ә. Суоми иленең татар китаплары // Казан утлары. 1990. № 9; Надиров И. Татары в Финляндии // Материалы по истории татарского народа. К., 1995.

*И.Н.Надиров.*

**АКАДЕ́МИК ИШҮ́**, су спорты төре, ишкәкле һәм күчмә утыргычлы көймәләрдә ишүдән гыйбарәт. Академик көймәләр ике төрлегә аерыла — ике калаклы ишкәкле (ишкәкче бер ишкәк б-н ишә) А-2РсР, А-2РбР, А-4РсР, А-4РбР, А-8РсР класслы һәм парлы (ишкәкче ике ишкәк б-н ишә) А-1П, А-2П, А-4ПсР, А-4РбР класслы. Узышу дистанцияләре туры, ирләр — 2000, хатын-кызлар — 1000, яшүсмерләр — 1500, кызлар — 800 *м* да ярыша. Татарстанда А.и. *байдаркада һәм каноэда ишү* б-н бергә 1950 еллардан үсеш ала. ТР ның иң яхшы ишкәкчеләре — Олимпия уеннары, дөнья, Европа чемпионатларында, СССР кубогына, СССР, РСФСР халыклары Спартакиадаларында катнашучылар, приз алучылар, чемпионнар: Л.А.*Аверьянова*, В.Н.*Валюкевич*, В.А.*Гоголин*, С.М.*Закирова*, А.А.Зарубин, И.В.Ковальков, В.М.Колесов, О.В.Лигачёв, Г.Т.*Московский*, А.В.*Плюшкин*, В.Ф.*Потапов*, А.В.Устинов, И.Ю.Шамрай, С.Г.Янковский. Иң яхшы тренерлар — В.Т.*Глухих*, А.А.Гоголин, В.М.Колесов, С.М.*Ульянов*. 2001 елда Казанда 100 спорт көймәсе (60 — академик, 40 — байдарка һәм каноэ) өчен эллинг файдалануга тапшырыла.

**АКАДЕ́МИЯ БИСТӘСЕ́**, 19 йөзнең 2 нче яртысында Казанның көньяк-көнчыгыш читендә барлыкка килә. Исеме Казан руханилар академиясенә нисбәтле рәвештә бирелә. А.б.нда төзелеш 1842 елгы янгыннан соң башлана. Казанның иң эре бистәләреннән була. Биредә, руханилар академиясеннән тыш, вет. ин-ты, Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе урнаша. А.б.нең көнчыгышы һәм көньягы шәһәрнең чите булса, төньяктан һәм көнбатыштан аны *Кирпеч сугучылар бистәсе* һәм Госпиталь бистәсе, *Рус Швейцариясе*, Куртина (хәзерге Арча кыры) зираты чикләгән. Бистә, нигездә, бер һәм ике катлы агач йортлардан торган. Төп урамы 1 нче Академия (хәзер Вишневский) исемендә була. Шәһәр планында А.б. чикләренә: Арча кыры — Себер тракты — Ветеринария — 1 нче Солдат — Мурашов — Госпиталь урамнары керә (хәзерге Ершов, Әбҗәлилов, Шмидт, Товарищеская, Чехов урамнары). 20 йөз башыннан шәһәр эчендә кала.

*Әд.:* Бикбулатов Р. Академическая слобода // Татарстан. 1993. № 8.

*Р.Х.Бикбулатов.*

**АКАДЕ́МИЯ ЭКСПЕДИ́ЦИЯЛӘРЕ**, фәнни экспедицияләр; 18 йөз башында Петербург ФА тарафыннан Россия империясенең аерым төбәкләрен, табигать байлыкларын, халкын, тарихи истәлекләрне һ.б. өйрәнү өчен оештырыла. 1760 еллардан А.э. даими рәвештә Урал, Урал арьягы, Алтай, Урта һәм Түбәнге Идел буйларын, яңа яуланган яки үзләштерелә башланган көньяк һәм көньяк-көнбатыш төбәкләрне өйрәнә. 1768 елда гомуми программа буенча эшләүче шундый 5 экспедиция оештырыла (рәсми телдә алар «физика экспедицияләре» дип атала). 1768–74 тәге А.э. Россия төбәкләре табигатен һәм халкын һәрьяклап исәпкә ала, аларның икътисади торышына бәя бирә, а.х., урманчылык, балык тоту һәм һөнәр-кәсепчелек тармаклары үсешенең мөмкинлекләрен билгели. Халыкның тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, мәгарифе һәм сәламәтлек саклауның торышы буенча мәгълүмат туплый. Төп юнәлешле 3 экспедиция Оренбург исеме (җитәкчеләре П.С.Паллас, И.И.Лепёхин, И.П.Фальк), 2 се Әстерхан исеме (җитәкчеләре С.Г.Гмелин, И.А.Гильденштедт) б-н аталган. Гадәттә, ФАнең танылган галиме җитәкләгән экспедициягә 3–4 ярдәмче галим, рәсем остасы, кош-хайваннар сынын (чучело) ясаучы, ау остасы (егерь) һ.б. кергән. Экспедицияләр вакытында П.С.Паллас б-н Н.П.Рычков Бөгелмә-Бәләбәй һәм Югары Кама калкулыкларын аерым билгели һәм өйрәнә. П.С.Паллас Урта һәм Көньяк Урал төбәкләрен җентекләп тикшерә, Н.П.Соколов һәм И.П.Фальк б-н бергәләп Каспий алды (Төньяк Каспий) түбәнлеген тикшерә. И.И.Лепёхин, Урал-тау төбәгендәге фәнни тикшеренүләрдән тыш, Н.Я.Озерецков б-н бергә Ак диңгез буйларын, Кола ярымутравын өйрәнә. А.э.ндә катнашучылар Идел, Дон, Җаек (Урал), Терек елгаларын фәнни яктан тикшерә, төгәл мәгълүмат туплыйлар; Көнчыгыш Европа тигезлегенең күпчелек өлешен һәм Европа б-н Азия кушылган чик буйларын беренчеләрдән булып тасвирлыйлар. 1768–74 тәге А.э. төрле минераллар, тау токымнары коллекцияләрен җыя, элек билгеле булмаган үсемлек һәм җәнлек төрләрен ачыклый, күп кенә халыкларның мәдәни традицияләрен барлый. Тарих, археол. һәм этногр. материаллары соңыннан П.С.Паллас, И.И.Лепёхин, С.Г.Гмелин һ.б. хезмәтләрендә системага китерелә һәм дөньяга чыга. Казан төбәгенә караган кыйммәтле мәгълүматлар П.С.Паллас б-н И.И.Лепёхин хезмәтләрендә тупланган. Аларда төбәктәге торак пунктлар тасвирламасы, җирле халыклардан татар, мордва, чуаш, башкортларның гореф-гадәтләренә караган язмалар урын алган. Шушы А.э. эшчәнлегенә таянып, 1760–80 елларда гомумиләштерелгән картографик материаллар төзелә. 19 йөз башларында оештырылган махсус А.э. Россиядә шәркыятьчелек гыйлеме үсешенә (Г.Ю.Клапрот, Х.Д.Френ хезмәтләре), С.-Петербургта Азия музее ачылуга (1818) этәргеч була. 1845 тә оештырылган Рус география җәмгыяте экспедицион тикшеренүләргә җитәкчелек итүне үз кулына ала. Совет хакимияте дәверендә СССР ФАнең эшчәнлеге, нигездә, халык хуҗалыгы проблемаларын хәл итүгә һәм мәдәният мәсьәләләренә юнәлдерелә. СССР ФАнең Шәрекъ дөньясын өйрәнү ин-ты 1934 тә Татарстан халыклары тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү максатында фәнни экспедиция оештыра. Бу А.э. барышында Урта Идел буе халыклары тарихына, мәдәниятенә, ш.и. Казан татарларының этнографик үзенчәлегенә караган байтак кына язма һ.б. төр материаллар туплана. Аларны туплауда танылган археограф С.Вахидов җитәкчелегендә ТАССР Дәүләт музее хезмәткәрләре дә катнаша. Соңрак регионнарның аерым үзенчәлекләрен тикшерү һәм өйрәнү вази-

фасы СССР ФАнең урыннардагы ф-лларына, фәнни-тикшеренү ин-тларына йөкләтелә.

*Әд.:* Л е п ё х и н И.И. Дневные записки путешествия... по разным провинциям Российского государства. СПб., 1771. Ч. 1; П а л л а с П.С. Путешествие по разным провинциям Российской империи. СПб., 1773. Ч. 1; Г н у ч е в а В.Ф. Материалы для истории экспедиций Академии наук в 18 и 19 вв. М.–Л., 1940; Б е р г Л.С. Очерки по истории русских географических открытий. М.–Л., 1946; Л е б е д е в Д.М., Е с а к о в В.А. Русские географические открытия и исследования. М., 1971.

**АКАДЕМҮЗӘ́К**, к. *Гыйльми Үзәк.*

**АКАЕ́ВСКИЙ** Анатолий Иванович (29.6.1893, Тамбов губ., Лебедянск өязе Гудово а. — 1983, Воронеж ш.), вет. анатомы, вет. фән. д-ры (1940); чыгышы б-н татар. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1918). Проф. Л.А.Третьяков шәкерте. Омск вет. ин-тын оештыруда катнаша, 1919–45 елларда анатомия каф. мөдире, проф. (1924), бер үк вакытта 1925 тән ин-т директоры урынбасары була; анатомия музееn оештыра. 1945–47 дә Мәскәү хәрби вет. академиясендә эшли. 1947–50 дә Белоцерковь а.х. ин-ты директоры урынбасары. 1950 дән Мәскәү ит һәм сөт сәнәгате технол. ин-тында анатомия каф. мөдире. Төп хезмәтләре кан һәм лимфа әйләнеше системасы, хайваннарның сизү органнары, нерв системасы, төньяк боланы анатомиясенә карый. Хайваннар анатомиясе дәреслекләре авторы. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952). Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анатомия северного оленя. Л., 1939; Анатомия домашних животных. М., 1955 (автордаш); Анатомия домашних животных. М., 1962; Анатомия и физиология сельскохозяйственных животных. М., 1965 (автордаш).

*Әд.:* Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана. К., 1993.

**АКАЛА́ЕВ** Али-әскәр (Әскәр) Хөснетдин улы (8.7.1908, Әүлия-Ата, хәзерге Казакъстан Респ-касы Җамбул ш. — 27.5.2000, Зеленоград ш.), Казан мед. инструментлары з-ды директоры (1945–63). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1939). 1939–45 елларда Казан оборона заводларында. А. җитәкчелегендә пульмонология операцияләре өчен беренче тегү аппаратлары һәм бөер авырулары вакытында кан чистарту өчен «Ясалма бөер» аппараты җитештерү үзләштерелә. 1963–78 дә «Элион» з-дында цех башлыгы (Мәскәү өлкәсе Зеленоград ш.).

**АКАЛА́ЕВ** Рөстәм Нурмөхәммәт улы (21.1.1950, Үзбәкстан ССР, Ташкент), терапевт, мед. фән. д-ры (1996). 1974 елда Ташкент мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1983 елдан бөернең хроник зәгыйфьлеге лаб. мөдире. 1985 тән Ташкент респ-ка гемодиализ үзәге мөдире, «Dr. Акалаев» мед. үзәген оештыручы (1999) һәм җитәкчесе. РМФА академигы В.И.Шумаков, Үзбәкстан Респ-касы ФА академиклары У.Л.Арипов һәм Б.А.Ташмөхәммәтовлар шәкерте. Тикшеренүләре бөернең хроник зәгыйфьлеге патогенезы, клиникасы һәм дәвалау проблемаларына багышлана. Беренче тапкыр нерв-мускуллар синапсы очындагы пластинканың миниатюр потенциаллары ешлыгын һәм липид мембраналар (биофиз. ысул) үткәрүчәнлеген үлчәү ысуллары б-н уремик интоксикация үсешенең этиопатогенетик механизмнары ачыклана. Сидектән кан б-н чыгарылган «уртача молекулалар»ның мембранотроп һәм каналоформер эффектлы нейротоксикологиясе ачыклана.

Х е з м.: Одномоментные операции на почках и мочевых путях при поздней стадии обструктивной ХПН // Клиническая хирургия. 1987 № 12 (автордаш); Тактика лечения острого гломерулонефрита, осложнённого острой почечной недостаточностью // Мед. журн. Узбекистана. 1988. № 11.

**АКАЛА́ЕВ** Хәйдәр Хөснетдин улы (21.12.1921, Әүлия-Ата, хәзерге Казакъстан Респ-касы Җамбул ш. — 16.4.1997, Казан), Казан трамвай-троллейбус идарәсе башлыгы (1962–95), РСФСРның атказ. торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре (1985), ТРның атказ. транспорт хезмәткәре (1995). Казан авиация техникумын (1942), Ленинград артиллерия техник уч-щесен (1943) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947–52 елларда Казанда 387 нче номерлы з-дта, 1955–59 да 634 нче номерлы з-д җитәкчесе урынбасары, цех башлыгы булып эшли. 1959–62 дә КПССның Казан шәһәре Киров райкомы секретаре, 2 нче секретаре. 1995 тән Казан коммуналь пр-тиесенең «Горэлектротранспорт» җитештерү берләшмәсендә башлык урынбасары. А. җитәкчелегендә 3 трамвай, 2 троллейбус депосы төзелә; 17 трамвай, 14 троллейбус маршрутлары хәрәкәтен оештыруга мөмкинлек биргән трамвай юлларының һәм троллейбус линияләренең озынлыгы 2 тапкыр арта. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз һ.б. орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* 100 лет трамваю. К., 1999.

*Э.И.Әхмәтҗанова.*

**АКА́ЦИЯ**, к. *Сәрви.*

**АКБА́Ш** елгасы, Димнең (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 17,4 *км*, бассейнының мәйданы 56,5 *км²*. Ютазы р-ны терр-ясе буйлап ага. Елга башы Енәй авылыннан 1 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Акбаш авылыннан 0,6 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагыныкы — 145 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 8%. А.ның 0,6 дан алып 4 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 75 *мм*, ташу вакытындагы су катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр.

**АКБА́Ш** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнбатыштарак, Акбаш елгасы буенда. 2002 елда 539 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек һәм сарык асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 20 йөз башы архит-ра истәлеге — мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ташкичү исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, таш вату һәм алебастр чыгару б-н шөгыльләнә. 1808 дә А.та беренче мәчет, 1867 дә — икенче, 1915 тә өченче мәчет төзелә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, земство почта станциясе, су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр авыл Самара губернасының Бөгелмә өязе Александров волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1795 тә — 206 ир заты; 1859 да — 1015, 1886 да — 1431, 1897 дә — 1682, 1926 да — 1506, 1938 дә — 1379, 1949 да — 1056, 1958 дә — 752, 1970 тә — 850, 1979 да — 669, 1989 да — 462 кеше.

**АКБА́Ш** т и м е р ю л с т а н ц и я с е посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2002 елда 615 кеше (руслар — 49%, татарлар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1930 елларда нигез салына һәм шуннан бирле Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 41, 1949 да — 47, 1970 тә — 230, 1979 да — 342, 1989 да — 593 кеше.

**АКБА́ШЕВ** Риф Хәбибназар улы (20.1.1934, Башкортстанның Авыргазы р-ны Батыр а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1999), проф. (1988), ТРның атказ. икътисадчысы (1995). 1962 елда Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый. 1962–68 дә КПССның Совет р-н ком-тында (Казан) партия эшендә. 1971–76 да Казан хим.-технол. ин-тында. 1976–84 тә Казан мәдәният ин-ты доценты, проректоры. 1984–2005 тә Казан коммерция ин-ты ректоры һәм гомуми икътисад теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре фәнни-техник прогресс шартларында эшче кадрларның квалификациясен, җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүдәге роленә; аренда мөнәсәбәтләренә күчү, сәүдә һәм хезмәт күрсәтү сферасын реформалаштыру мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Рыночные отношения и торговля. К., 1991 (автордаш); Внешний рынок: договорные аспекты. К., 1995.

**АКБЕ́РДИНА** Динама Лотфи кызы (8.9.1926, Казан — 15.7.2004, шунда ук) травматолог, мед. фән. д-ры (1972), ТАССРның атказ. табибәсе (1974). 1949 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1949 елдан Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1969–88 елларда өлкәннәр ортопедиясе бүлеге мөдире. Тикшеренүләре экспериментта һәм клиникада сөяк тукымасы регенерациясе проблемаларына, сөяк пластикасына, дөрес тоташмаган буыннарны дәвалау-

га, эре буыннарның дегенерация-дистрофия авыруларына багышланган. А. ортопедик-травматологик авыруларны дәвалауның яңа хирургик ысулларын эшләү, травматологик ярдәм күрсәтүдә гамәлгә кертелгән уйлап табулар авторы.

Х е з м.: Характеристики клинико-рентгенологических и морфологических особенностей и состояния нервных элементов при ложных суставах трубчатых костей. К., 1971.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**АКБИ́ЕВ** Солтанморад Хаҗак улы (18.7.1938, Дагстан АССРның Хәсәүйорт р-ны Боташйорт а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1989), проф. (1990), Дагстан Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1994). Дагстан пед. ин-тын тәмамлый (1967). 1982 елдан Дагстан пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре кумыкларның гарәп хәрефле язма әдәбияты тарихына, Россия халыкларының әдәби бәйләнешләренә карый. Кол Гали, К.Насыйри, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил иҗатына багышланган мәкаләләр авторы.

Х е з м.: Дагестанско-татарские литературные связи XIX — начала XX веков: Дис.: А.-А., 1989.

*Әд.:* И с л а м о в Ф. Әдәбиятлар дуслыгын яктыртучы хезмәт // Казан утлары. 1988. № 5.

**АКБУЛА́Т** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 29 *км* көньяктарак, Баганалы елгасы буенда. 2002 елда 256 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1724 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.та мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 тегермән, ярма ярдыру тегермәне, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 975 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 95 ир заты; 1859 да — 525, 1897 дә — 918, 1908 дә — 990, 1926 да — 809, 1938 дә — 835, 1949 да — 556, 1958 дә — 463, 1970 тә — 562, 1979 да — 442, 1989 да — 286 кеше.

**АКБУ́Р**, 1) җиңелчә цементланган утырма, тау токымы, вак кальцит бөртекләреннән, карбонат суүсемнәре — кокколитофоридлар һәм фораминифералар тышчасыннан, сирәк кенә кремний, пирит һәм фосфорит конкрецияләреннән гыйбарәт. Төсе ак яки саргылт. Катылыгы 1 дән кимрәк. Тыгызлыгы 2690–2720 *кг/м*³, күзәнәклелеге 44–50%. Характерлы билгеләре — йомшаклыгы, сынган урынның кытыршы, балчыксыл булуы. А. җылы диңгезләрнең 30 дан алып 500 *м* га кадәр тирәнлектә утырма тәшкил иткән ярымкаты ләмнәре рәвешендә була. Саф төре А. системасының югары катламнарында ешрак очрый. А. утырмаларының иң зур полосасы Европада таралган, иң калын урыны Харьков шәһәре р-нында 600 *м* тәшкил итә.

Татарстан терр-ясенең Чүпрәле р-нында акбур системасы катламнарының югары өлешендә 30 *м* га кадәр калынлыктагы язу акбуры ятмалары табыла. Сәнәгый әһәмияте юк, җирле халык тарафыннан бина һәм йортларны агарту, әче туфракны известьләү өчен кулланыла.

А.ны буяулар, цемент, шикәр әзерләүдә, кәгазь, резина, пластмасса, клеёнка ясауда, электродларны каплауда, химия сәнәгатендә, төзелештә һ.б. файдаланырга мөмкин.

2) *Акбур системасы (чоры)ның* кыскача исеме.

**АКБУ́Р СИСТЕ́МАСЫ (ЧОРЫ́)**, а к б у р, *мезозой эратемасының* югары системасы, мезозой эрасының соңгы геологик чоры. Башлануы 145, тәмамлануы 65,5 млн. еллар элек булган. А.с. түбән һәм югары бүлекләргә бүленә, аларның һәркайсы 6 ярустан тора; башлангыч чордагы акбурның дәвамлылыгы 45 млн. нан артык, соңгысыныкы — 34 млн. ел чамасы.

Акбур чорында микроорганизмнар, күп төр умырткасызлар һәм сөйрәлүчеләр киң үсеш ала, ә чор ахырында аларның күпләп үлүе бара; зур тешле кошлар, беренче соңгылыклы имезүчеләр, кылчыклы балыклар, зур рептилияләр — ихтиозаврлар, плезиозаврлар һ.б. диңгез кәлтәләре тарала. Үсемлекләренә абагалар һәм ачык орлыклылар, Акбур чоры уртасында — ябык орлыклылар, ахырында чәчәклеләр хас. Соңгы акбурда флора һәм фаунаның бик югары үсеше Җир шары тарихындагы иң җылы һәм дымлы климат б-н бәйле була.

А.с. утырмалары Татарстан терр-ясенең көньяк-көнбатыш читендә генә (Чүпрәле р-нында, Буа һәм Тәтеш р-ннарының бер өлешендә) таралган. Алар составында гипс, пирит һәм сидерит б-н баетылган күксел соры һәм кара балчыклы токымнар күпчелекне тәшкил итә, сирәк кенә глауконитлы комнар һәм алевролитлар, кремнезёмлы һәм акбурга охшаш мергельләр, цеолитлы һәм комташлы токымнар очрый. Түбән ярус утырмаларында глауконитлы комнар, комташлар һәм алевролит горизонтларында ятучы фосфоритлы конгломератлар (10–12 *см* га кадәр төерләре булган) очрый. Комлы-балчыклы катламнарда диңгез фаунасы: аммонитлар, белемнитлар («шайтан бармагы»), моллюсклар һ.б. бар. Югары акбур ташлы-карбонатлы һәм карбонатлы-ташлы токымнардан гыйбарәт.

А.с. юшкыннары сай сулы диңгез бассейнында утырган. Акбурның башлангыч чорында диңгез Поляр океанны Кырым-Кавказ өлкәсен каплаган бассейн б-н тоташтыручы бугаз формасын саклый. Акбур чоры ахырында диңгез сулыгы юкка чыга һәм 40–50 млн. елга континенталь режим урнаша.

Татарстан терр-ясендәге акбур катламнарында файдалы казылмалар: фосфоритлар, глауконитлы комнар, цеолитлы һәм карбонатлы токымнар, керамзитлы балчыклар ачыкланган. Аерым алганда, Чүпрәле р-нында югары акбур утырмаларында Татар Бизнәсе известьташлар чыганагы һәм Татар Шатыршаны цеолитлар чыганагы ачыклана.

*Әд.:* Геология Татарстана. М., 2003.

*С.О.Зорина, Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**АКБУЗА́Т**, төрки-татар фольклоры һәм мифологиясе персонажы; халыкның тотемик нәсел башы, гаять зур сынлы игелекле ат. Бу образның килеп чыгышы, бер яктан, төрки кабиләләр арасында тотемистик карашларның киң таралуы, ш.у. борынгы төрки халыкларның тормышында зур роль уйнаган атка табыну йоласы б-н; икенчедән, төркиләрдә, ш.у. күп кенә башка халыкларда да, ак төснең сау-сәламәт тууны, бәхетле тормышны, тыныч үлемне һәм лаеклы җирләүне символлаштыруы б-н бәйле. А. — геройның үткәнен, хәзергесен һәм киләчәген белеп торучы даими юлдаш һәм ярдәмче. Татар мифологиясендә күктә яшәүче ике баһадир ат — А. һәм Күкбүзат турындагы сюжет бар. Җиргә төшеп, атлар миф, әкият яки дастан героеның гамәлләрендә катнашалар һәм яңадан күккә ашалар. Күктә, тимер казыкка (Тимер Казык — Котып йолдызы) аркаланган килеш, аның тирәсендә утлап йөриләр. Җиде карак (Зур Җидегән йолдызлыгы) бу атларны урларга ниятли һәм А. б-н Күкбүзатны өзлексез эзәрлекли, ләкин тота алмый. Татарларда хәзер дә «Акбүзат йолдыз, Күкбүзат йолдыз, Тимер Казык бер ялгыз» дигән мәкаль һәм «Казыкка бәйләнгән ике атым дулый, дуласа да, бер тирәдән китә алмый» дигән табышмак яши.


*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; У р м а н ч е е в Ф.И. По следам Белого волка. Ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племён. К., 1994.

*Ф.И.Урманчеев.*


**АКБҮРЕ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 20 *км* көньяктарак. 2002 елда 620 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөздә нигез салына, 1994 кә кадәр Татар Булчие дип атала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, авылда мәчет, 1908 дән мәктәп була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 640 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1940 ның 7 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 201, 1897 дә — 587, 1908 дә — 783, 1926 да — 639, 1949 да — 774, 1958 дә — 862, 1970 тә — 1236, 1979 да — 1028, 1989 да — 691 кеше.

**АКВАРЕ́ЛЬ** (фр. aquarelle, итал. acquerello, лат. aqua — су), йомшак пигментны үсемлек җилемендә изеп ясалган, суда эретелә һәм аның б-н юыла торган буяу, ш.у. шушы төр буяу б-н төшерелгән рәсем. А.дә графика һәм рәсем сәнгатенә хас сыйфатлар бергә кушыла. Ул күптөсле һәм бертөсле төрләргә бүленә. Борынгы Мисыр, Греция, Рим, ш.у. урта гасырларда Европа һәм Азия дәүләтләре сәнгатендә А. мәгълүм урын алып тора. 17 йөзгә кадәр ул кулъязмаларны иллюстрацияләү, гравюралар, архит-ра сызымнарын бизәү кебек гамәли максатларда кулланыла, мондый кулланыш хәзер дә өлешчә дәвам итә. 18 йөздә бик күп илләрдә, шул җөмләдән










**Акварель.** 1. Е.М. Корнеев. «Казанның көнбатыштан күренеше». 1803. Дәүләт тарих музее. Мәскәү; 2. А.Н. Ракович. «Казан Кремленең Подлужная урамы ягыннан күренеше». 1840–60 еллар; 3. П.М. Дульский. «Казан. Пятницкий чиркәве». 1921; 4. И.Н. Плещинский. «Паркта». 1924; 5. А.Н. Кашаев. «Кызыл Армия». Плакат эскизы. 1923; 6. Җ.Г. Булат. «1905 ел баррикадаларында». 1925; 7. Р.Ә. Госманов. «КамАЗ туганда». 1973; 8. Г.Г. Рахманкулова. «Татар өе». 1970 еллар; 9. В.В. Карамышев. «Г.Тукайның «Су анасы» поэмасы мотивлары буенча». 1969; 10. Б.И. Урманче. «Шүрәле» темасына вариация». 1980. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. А.И. Чебинев. «Болакта кыш. Казан». 2002.



А.Х. Акҗегетов.

Россиядә дә, проф. акварельче рәссамнар үсеп чыга. 18 йөзнең икенче яртысы — 19 йөздә Казанның байтак уку йортларында — Беренче ирләр гимназиясендә, ун-т, реаль уч-ще, сәнгать мәктәбендә А. сәнгате класслары була. Җирле рәссамнәр иҗатында А. пейзаж һәм портретларда, гаилә альбомнары графикасында, ш.у. татар кулъязма китапларын бизәүдә киң кулланыла. Пейзажчы А.Н.Ракович провинциаль романтизм алымнары кергән академик пейзаж традицияләрендә иҗат итә. Л.Д.Крюков, Р.А.Ступинның портрет А.ләре форманы бертөсле фонда вак штрихлар һәм нокталар ярдәмендә виртуозларча модельләштерүләре б-н үзенчәлекле.

20 йөздә А.гә жанрлар (архит-ра проектлары эскизлары, сәхнә бизәлеше, китап иллюстрацияләү, журнал һәм сәнгать графикасы, гамәли графика) һәм техник ысуллар (гуашь, темпера, пастель, күмер, бронза буяу, карандаш) төрлелеге хас. 20 йөз башында станлы А.гә импрессионизм һәм символизмнан алып супрематизм һәм конструктивизмга кадәр булган күптөрле стиль юнәлешләрен берләштерә. Бу Казан сәнгать мәктәбендә укыган А.М.Родченко, И.А.Никитин, А.Г.Платунова, М.В.Барашов, В.Э.Вильковиская һ.б. иҗатларында аеруча ачык чагыла. П.М.Дульский, А.И.Фомин, И.А.Денисов, Н.Н.Ливанова, И.Н.Плещинский, Д.П.Мощевитиннарның лирик пейзажлары ирекле композицияләре б-н аерылып тора. Д.Г.Булатның «Төркестан сериясе», В.А.Шолпоның «Фарсы циклы» Шәрекъ миниатюрасы традицияләрендә иҗат ителгән. 1940 еллардан алып Б.М.Әлминов, Х.Г.Якупов, Л.Г.Фәттахов, М.Г.Усманов, З.Н.Хөсәенов, Р.А.Сабитова, И.С.Хантимеров, М.Л. Язынин һ.б. татар халкының авыз иҗаты әсәрләрен һәм классик әдәбиятын иллюстрацияләүче ирекле композицияләр иҗат итәләр. 1970–80 елларда Б.И.Урманче пейзажлар, натюрмортлар, татар милли киемнәре эскизлары, татар бизәкләре серияләре эшли. Аның «Шүрәле» темасына багышланган график эшләрендә (Кытай туше катнаштырып) рәссамның үзенә генә хас иҗат ысуллары аеруча ачык чагыла. 1960–80 елларда И.К.Әхмәдиев, И.Е.Бобровицкий, Э.Б.Гельмс, В.П.Игнатьев, Р.Ф.Имашев, И.К.Колмогорцева китап һәм журнал графикасында А.гә еш мөрәҗәгать итәләр. 1960 еллардан башлап монументаль А.дә (лирик жанрдагы камера формаларыннан тыш) тематик цикллар һәм серияләргә берләштерелгән күләмле әсәрләр өстенлек ала.

Г.Г.Рахманкулова иҗатында А.нең традицион жанрлары белән бергә (пейзаж, натюрморт) портрет һәм татар интерьеры төрләре, шулай ук тарихи тема үсеш ала. В.А.Попов, Р.Ә.Госманов А.серияләрендә зур, монументаль әсәрләр иҗат итәләр. Алар буяу төрләрендәге яктылык муллыгы, төсләр байлыгы һәм аһәңлеге, сурәтләү үзенчәлеге б-н аерылып тора. В.В.Карамышев, Э.Б.Бусова пейзажлары, жанр композицияләре һәм натюрмортлары серияләре натурага якынлыгы б-н аерылып тора. Э.Б.Гельмс, А.А.Спориус, Н.У.Әлмиевнең юл жанрындагы А. графикасына югары культура хас. Татар халык сәнгатенә хас бизәкләү һәм декоративлык акварельле вариацияләр ярдәмендә В.П.Аршиновның әдәби драматик опера темаларында үзенчәлекле чагыла. 1980–90 елларда республика рәссамнарының А. б-н кызыксынуы көчәя, Б.Мәрдәнов (Бөгелмә), Л.Г.Зиннәтуллин (Лениногорск), Е.М.Бирючевский, Е.Н.Миронов, Ю.Е.Ершов (Яшел Үзән) һ.б. шул алым б-н иҗат итә.

*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978; шул ук. Искусство Татарии. История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987; Файнберг А.Б. Художники Татарии. Л., 1983.

*Е.П.Ключевская.*

**АКҖЕГЕ́ТОВ** (Акъегетов) Азиз (Газиз) Харьяс улы (ноябрь, 1917, хәзерге Пенза өлкәсенең Каменск р-ны Мөчәләй а. — 3.1.1944), Сов. Союзы Герое (29.10.1943), өлкән сержант (1943). 1938 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 38 нче армиянең 180 нче укчылар дивизиясе 21 нче укчылар полкының пулемёт отделениесе командиры. Көньяк-Көнбатыш, Сталинград, Брянск, Воронеж фронтлары гаскәрләре составында Киев оборонасы операциясендә (1941), Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең октябрендә беренчеләрдән булып Киев өлкәсе, Вышгород р-ны Лютеж тирәсендә Днепрны кичә. Киев янындагы сугышта үлем җәрәхәте ала. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои и подвиги. Саратов, 1978. Кн. 4; Днепр — река героев. Киев, 1983.

**АКҖЕГЕ́ТОВ** Гаяс Насыйбулла улы (4.1.1929, Волгоград өлкәсенең Камышлы ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1973). 1955 елда Волгоград мед. ин-тын тәмамлый. 1957 дән Камышлы шәһәренең Үзәк хастаханәсендә бүлек мөдире. 1959 дан Мәскәүдәге 1 нче мед. ин-тында. 1973 тән Волгоград мед. ин-тының балалар хирургиясе каф. мөдире, өлкәара балалар хирургиясе үзәге җитәкчесе һәм өлкә сәламәтлек саклау бүлегенең балалар баш хирургы. А. Волгоград шәһәрендә балаларга хирургик ярдәм күрсәтүне яхшыртуда зур эшләр башкара. А. тырышлыгы б-н махсуслаштырылган бүлекләр ачыла (торакаль, травматология, реанимация). Аның җитәкчелегендә өлкәара балалар хирургиясе үзәгендә балалар авырулары арасында иң катлаулылардан берсе — көчле деструктив үлекле пневмонияне дәвалауда шактый уңышларга ирешелә (балалар үлеме 20% тан 1,5–2% ка кадәр кими). Тикшеренүләре онкология, ортопедия, пульмонология, гастроэнтерология, фармакотерапиягә һәм сәламәтлек саклау оешмалары эшләрен оештыруга карый.

Хезм.: Острый панкреатит. М., 1976; Острые хирургические заболевания органов брюшной полости. М., 1977; Организация и работа хирургического стационара. М., 1979; Остеомиелит. М., 1986.

**АКҖЕГЕ́ТОВА** Надежда (Надира) Ибраһим кызы (8.12.1928, Пенза өлкәсенең Белинский р-ны Кутеевка а.), геоботаник, биол. фән. д-ры (1983), проф. (1995). Урта Азия ун-тын тәмамлый (1953, Ташкент). 1957 елдан Үзбәкстан ССР ФАнең Ботаника ин-тында, 1985–87 дә директор урынбасары, 1987–94 тә геоботаника лаб. мөдире, 1994 тән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре үсемлек бергәлекләренең формалашу һәм таралуын, аларның туфрак-грунт шартлары б-н үзара бәйләнешен өйрәнүгә, чүл үсемлекләренең индикация һәм толерантлылык үзенчәлекләре, аларның экология классификациясе мәсьәләләренә карый. Үзбәкстандагы чүл, тау итәге, тау һәм биек тау зоналарында геоботаник тикшеренүләр үткәрә.

Хезм.: Галофильная растительность Средней Азии. Таш., 1982; Растительный покров Узбекистана и пути его рационального использования: В 4 т. Таш., 1971–84 (автордаш).

*Әд.:* Новикова Н.М. О творческом пути Н.И.Акжигитовой // Аридные экосистемы. 1998. Т. 4, № 8.

**АКИ́МОВ** Владимир Яковлевич (27.11.1950, Куйбышев өлкәсенең Сергеев р-ны Ендурайкино а.), нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994), Татарстанның халык рәссамы (2006). Чабаксар сәнгать уч-щесен (1971), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (1980) тәмамлый. 1980–83 тә Казанда Х.Г.Якупов җитәкчелегендә СССР Сәнгать академиясенең нәкышь иҗат остаханәсендә укый. 1983 тән Чаллы шәһәрендә яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1983). Тематик картина («Ваня дәдәйнең тормышы» циклы, 1987–92; «Марина әби такмаклары», 1992), пейзаж («Ендурайкино авылы» сериясе, 1985–93; «Алабуга мотивлары», 1991; «Көз», 1995), портрет («Атам портреты», 1987; «Кузьмич», 1987; «Яшка-Кино», 1988; «Ваня дәдәй», 1989) һәм натюрморт («Шешә белән тавык», 1994) остасы. А. иҗатына төрле стиль алымнарының бергә кушылуы хас. Беренче әсәрләре 1970 еллар совет сәнгатенең реалистик стиле тәэсирендә иҗат ителә («Зәңгәр иртә» һәм «Озату», 1986; «Сугыш елы», 1989), соңрак Көнбатыш Европа нәкыше («Ваня дәдәй төше», 1989; «Очыш ихтималы», «Ваня дәдәйне җирләү», 1990; «Очучы сыерга һәйкәл салу», 1996) һәм сюрреализм («Кентавр мәхәббәте», 1990; «Пандора исәнлеге өчен», 1993) йогынтысы өстенлек ала. Күп кенә монументаль әсәрләр иҗат итә: Казанның Киров р-нындагы бензин салу станциясендә мозаикалы рельеф (1981), Лениногорск шәһәрендә «Хезмәт һәм сәнгать берлеге» мозаикасы (1983), Татар ашлары йорты бизәлеше (1989), Чаллы шәһәрендә Козьма һәм Дамиан чиркәве интерьеры бизәлеше





В.Я.Акимов. 1. «Зәңгәр иртә». 1986; 2. «Очыш ихтималы». 1990. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

(1991–92, В.Анютин, Ю.Свинин б-н автордашлыкта). «Зур Идел» төбәкара күргәзмәләрендә катнаша (1985, 1998). Шәхси күргәзмәләре Мәскәү (1993), Казан (1994, 1996, 1998, 2000), ш.у. Чаллы (1990), Чабаксар (1995), Әлмәт (1990), Алабуга (1996) һәм ш.у. Вена (2000), Берлин (1998–2001), Ролли (АКШ, 2005), Нью-Йорк (2007) шәһәрләрендә күрсәтелә. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Чаллы картиналар галереясында, Чуаш Респ-касы Дәүләт сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Каталог выставки в Москве. М., 1993; Цой В. Житие художника Акимова // Татарстан. 1995. № 1–2; Пашкова Л. Мастерская Акимова // Аргамак. 1998. № 12.

*Р.Р.Солтанова.*

**АКИ́МОВ** Юрий Петрович (1.2.1932, Баку), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. ТРның атказ. торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре (1993). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1955). 1955–56 елларда «Әлмәт нефть төзелеше» тресты мастеры, 1956–57 дә прорабы, 1957–60 та сәнәгать пр-тиеләре конторасының җитештерү-техник бүлеге башлыгы. 1960–61 дә Казанның 4 нче тимер-бетон әйберләр з-ды баш инженеры. 1961–64 тә КПССның Казан шәһәр ком-тында төзелеш һәм шәһәр хуҗалыгы бүлеге мөдире урынбасары, 1965–72 дә мөдире. 1972–80 дә «Главтатстрой» идарәсе башлыгы урынбасары. 1980–90 да ТАССР торак-коммуналь хуҗалыгы министры. 1990–93 тә «Татжилкомхоз» җитештерү берләшмәсе директорының 1 нче урынбасары, 1994 тән ТРның Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының торак-коммуналь эшчәнлеккә лицензияләр бирү үзәге директоры (1998 гә кадәр — «Татжилкомхоз» каршында). 1980–90 да ТАССР ЮС депутаты.

**А́КИШЕВ** Ирек Малик улы (20.3.1931, Казан — 29.9.1999, шунда ук), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. канд. (1961), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1976). Казан ун-тын тәмамлый (1954). 1957–86 елларда ТатНИПИнефтьтә, 1964 тән геол. бүлеге мөдире. 1987–94 елларда Бөтенсоюз нефть-газ фәнни-тикшеренү ин-тының Бөгелмә комплексы бүлегендә табигый битум запаслары һәм геол. лаб. мөдире. Татарстандагы төп нефть чыганакларын (Яңа Елховой, Бондюг, Ромашкино һ.б.) эшкәртүне проектлаштыра. Татарстан терр-ясендәге битум һәм нефть ятмаларының бүленеп урнашу һәм төзелеш үзенчәлекләренең кайбер закончалыкларын ачыклый, ул ресурсларның күләмен исәпли.

Хезм.: История формирования нефтяных месторождений ТАССР. М., 1975 (автордаш); Закономерности распределения природных битумов ТАССР. М., 1984 (автордаш).

**АККАНА́Т** (Calla), ароидчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Бер төре — саз А. (C. palustris) билгеле. Евразиядә һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә барлык р-ннарда очрый. Сазлыкларда, елга, инеш, күл, буа һәм сусаклагычларның баткак ярларында үсә. Тамырчасы — яшел, юан, куыш, төенләнгән урыннарында бәйләмле чуктамыр. Сабагы юан, 15–30 *см* озынлыкта. Яфраклары озын сабаклы, йөрәксыман, очлы, ялтыравыклы. Чәчәкләре вак, тирәлексез, ак япма б-н әйләндереп алынган чәкәндә. Җимеше — күп орлыклы ачык-кызыл итләч җиләк. Май-июнь айларында чәчәк ата. Күбрәк вегетатив ысул б-н үрчи. Халык медицинасында тамырча һәм үләннәренең төнәтмәсе бәвел кудыру, авыртуны басу һәм эч йомшарту өчен кулланыла. Агулы үсемлек. Терлекләрне язын көтүгә иртә чыгарганда зур куркыныч тудыра.

**АККИРӘ́Й** (Әккәрәй) авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 29 *км* төньяктарак, Олы Кәминкә елгасының сул кушылдыгы Сөлчә суы буенда. 2002 елда 671 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.дә чиркәү-приход мәктәбе, 3 вак-төяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2327 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кутәмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 163 ир заты; 1859 да — 982, 1897 дә — 1507, 1908 дә — 1689, 1920 дә — 1644, 1926 да — 875, 1949 да — 794, 1958 дә — 1009, 1970 тә — 1201, 1979 да — 1021, 1989 да — 739 кеше.

**АККЛИМАТИЗА́ЦИЯ** (лат. ad — өчен, караган (кушымча) һәм грек. klíma — климат), организмнарның яңа яисә үзгәргән яшәү шартларына җайлашуы, бу шартларда барлык үсеш стадияләрен тулысынча үтеп, яшәргә сәләтле яңа буын бирә алуы. А. эзлекле өч этаптан тора: *интродукция*, *адаптация* һәм натурализация (яңа экологик урын алу). Кайбер очракларда А. процессы организмнарның төрле сәбәпләр аркасында элек үзләре яшәгән урыннардан юкка чыгып, яңадан шунда күчеп кайтулары (реакклиматизация) нәтиҗәсендә бара. Интродукция очрагында (ясалма А.) хайваннарның һәм үсемлекләрнең культуралы төрләре, ш.у. организмнарның кешеләр, хайваннар, җил һ.б. тарафыннан икенче районнарга очраклы күчерелгән кыргый төрләре табигый шартларда (табигый А.) яңа урында яшәү өчен җайлашырга мөмкин. Үсемлекләр А.сендә төп урынны туфрак һәм климат шартлары алып тора; хайваннар А.сендә — көндәшләр, ерткычлар, авыру тудыручыларның булу-булмавы мөһим шарт. Яңа шартларда популяция сан ягыннан сакланып калу һәм депрессия чорларында кире үз хәленә кайту сәләтенә ирешсә, А.не төгәлләнгән дип санарга була. ТР терр-ясендә күп кенә культуралы үсемлек төрләре һәм сортлары (бодай, бәрәңге, томат, кыяр, җимеш һәм декоратив агачлар һәм куаклар), йорт хайваннарының төрле токымнары (*айршир токымлы* һәм *кара-чуар токымлы мөгезле эре терлек*, *эре ак токымлы* һәм *эре кара токымлы дуңгызлар*, *прекос токымлы сарыклар* һ.б.), промысел җәнлекләре (*ондатра*, Америка чәшкесе, *янутсыман эт*), кысласыманнар (мизидалар, креветкалар) һ.б. ясалма акклиматизацияләнде. Табигый А. нәтиҗәсе буларак, Татарстанда балыкларның яңа төрләре (тюлька, йомры ташбаш, йолдызсыман пуголовка, диңгез инәсе, ротан), моноданка атамалы моллюск, птерокума атамалы вак кысласыманнар, хипания атамалы күп төкле суалчан, бөҗәкләрдән — очраклы рәвештә кертелгән колорадо коңгызы һ.б. үрчи башлады. Идел-Кама саклаулыгы терр-ясендә кондызны, ТРның көньяк-көнчыгышында — Европа сөркәсен яшәү шартларына яңадан җайлаштыру эшләре алып барыла. Үсемлекләр һәм хайваннарның яшәү шартларына җайлашу сәләтеннән авыл һәм урман хуҗалыгы, җиләк-җимеш үстерү, җәнлек һәм балык үрчетү, торак пунктларын яшелләндерү һәм төзекләндерү проблемаларын хәл итүдә файдаланалар.

*Әд.:* Егерева И.В. Краткие итоги работ по акклиматизации кормовых беспозвоночных // Закономерности формирования кормовой базы и ихтиофауны Куйбышевского водохранилища: Тр. Татар. отд-ния Гос НИОХР. К., 1970; Павлов П.М. Состояние и перспективы акклиматизации охотничьих животных в СССР // Акклиматизация охотничьих животных в СССР. Минск, 1978; Некрасов В.И. Актуальные вопросы акклиматизации растений. М., 1980; Калайда М.Л. К вопросу об акклиматизации полихет в Куйбышевском водохранилище // VII съезд Гидробиол. об-ва РАН: Материалы съезда. К., 1996. Т. 3.

*С.И.Кадошников.*

**АККО́Ш**, төрки-татар мифологиясе персонажы; халыкның тотемистик нәсел башы. Аерылу, сагыш һәм бер үк вакытта якты өмет символы буларак, А. күп кенә мифологик системаларда билгеле. А. төрки-монгол кабиләләрендә, мәс., Алтай халыкларында һәм кыпчакларда (команнарда — аларның үзатамалары куу (аккош) һәм -ман аффиксыннан барлыкка килгән) тотем булып санала. Алтай кабиләләре — командиннәр һәм лебединнәрнең ыруг-кабилә атамасы, ш.у. борынгы Лебедия-Леведия иленең исеме дә әлеге кошка бәйле. Бурят фольклорында кыз кыяфәтендәге А.ның 11 хорин ыруының борынгы нәсел башы булуы турындагы сюжет киң таралган. Ихтимал, мондый риваятьләр Алтай командиннәренә һәм кыпчакларга (команнарга), димәк, төрле татар кабиләләренең борынгы бабаларына да билгеле булгандыр. Әлеге фольклор әсәрләренең сюжет юнәлеше борынгы төркиләрнең ыругларга нигез салган ата-бүре һәм ана-бүре турындагы риваятьләренә якын. Саф мәхәббәт һәм өмет символы буларак, А. образы татар халык җырларында, бәетләрендә, ш.у. хәзерге әдәбиятта, аеруча поэзиядә очрый.

*Әд.:* Урманчеев Ф.И. Дастаннарга лаек замана. К., 1990; Баранникова Е.В. Бурятские волшебно-фантастические сказки. Новосиб., 1978; Менгес К.Г. Восточные элементы в «Слове о полку Игореве». М., 1985.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«АККО́Ш КҮЛЕ́»**, шәһәр урман паркы, Казан шәһәре эчендәге урман массивы. Мәйданы 3684 *га*. 3212 *га* мәйдан урман б-н капланган, аларның 46% өлгергән һәм картайган агачлар.

Урман паркы көнбатыштан көнчыгышка таба 13 *км* га, төньяктан көньякка таба 2–5 *км* га сузыла. Урман массивы аша асфальт җәелгән юллар, шәһәр яны челтәренә кергән тимер юл участогы уза. Транспорт юллары яхшы булу сәбәпле шәһәрдә яшәүче халык елның һәр фасылында урманга күпләп килә. Урман күлләре урнашкан район ял урыны буларак аеруча җәлеп итә.

Берничә участокны үз эченә ала: нарат һәм катнаш урманнарның зур «А.к.» массивы; Нагорный һәм Карьер посёлоклары әйләнә-тирәсендә (120 һәм 121 кварталлар) (элекке заманда — крәстиян урманнары), Дальний посёлогы һәм 2 нче Горки микрорайоннары арасындагы (127–131 кварталлар) яфраклы урман участоклары, Мирный посёлогының көнбатыш читендәге катнаш урман (125 кварталлар) участоклары; *Имәнлек* табигать истәлеге (123–124 кварталлар).



«Аккош күле» урман паркы.
Өстән күренеше.

«А.к.»нең төп урман массивы шәһәрнең төньяк-көнбатыш читендә (Киров, өлешчә Мәскәү р-ннары) урнашкан, элек-электән шәһәр халкы, Ягодный һәм Пороховой бистәләре эшчеләре өчен ял итү, җиләк һәм гөмбә җыю урыны булган. Урман аша Казанны губернаның ерак өязе һәм Царёвококшайск б-н тоташтыручы юл үткән; хәзер трактның урман аллары яхшы формалашкан бу участогы урман паркы буйлап ял итеп кайту маршруты ролен үти. Монда беренче урман торгызу эшләре 1897–98 елларда 3512 дис. мәйданда (якынча 3837 *га*) үткәрелә. 1929 елда нарат һәм яфраклы агачлар буенча 2 хуҗалык оештырыла; кисү әйләнеше нарат өчен наратлыкларда 80–100 ел, имән һәм юкә өчен — 80 ел, каен һәм усак өчен — 60 ел итеп билгеләнә. 1934 тә урман массивы шәһәр өчен урман-парк буларак әһәмиятле дип танылa һәм аның базасында Казан урман паркы хуҗалыгы оештырыла. 1996 да ТР МК карары нигезендә «А.к.» урман паркы «шәһәр урманнары» категориясенә кертелеп, җирле әһәмияткә ия булган аеруча нык саклаулы территория дип игълан ителә. 2002–2003 тәге соңгы урман бүленеше нигезендә «А.к.» терр-ясе: урман-парк зонасы (3043 *га*), килүчеләр саны тәртипкә салынган (массивның үзәк өлешендә 578 *га*), килүчеләргә хезмәт күрсәтү (48 кварталда 37 *га*) һәм аеруча нык саклау режимлы (26 *га*, «Имәнлекләр» массивы) зоналарга бүленә. Төп бурычлары: булган ландшафтларны яхшырту һәм реконструкцияләү, таза, тотрыклы һәм фитонцид агачлар булдыру, терр-яне төзекләндерү.


«А.к.» массивы Идел елгасының югары террасасында урнашкан. Терр-янең көньяк өлеше рельефы — ком утырмалары дюналары ачык чагыла торган наратлыклы сөзәк-калкулыклардан тора; төньяк һәм төньяк-көнчыгыш өлешләрдә — тирән сызалар һәм үзәннәр б-н уелган яссы таулык. Төпләре тигезләнгән тирән булмаган казанлыкларны *Аккош күлләре* (Кече, Зур һәм Коры) алып тора, алар үзара ермаклар б-н кушылалар, язын ташыйлар, коры вакытта аз сулы булалар.

Алардан төньяк-көнчыгыштарак текә биек ярлы, карст нәтиҗәсендә хасил булган *Тирән күл* (иң зур тирәнлеге 18,2 *м*) һәм *Кече Тирән күл* урнашкан. Левченко посёлогыннан 1 *км* көнбатыштарак матур ярлы Дряничный күле бар. Юдино посёлогы янындагы ком карьеры урынында шактый зур *Юдино күле* хасил булган. Туфраклары көньяк өлешендә, күбесенчә, комлы кәсле-көлсу һәм комсу, төньяк өлешендә — ачык соры төстәге комсу балчыклы урман туфрагы. Урман барлыкка китерүче төп токым — гади нарат, урман б-н капланган мәйданның 40% били. Нарат урманнарының иң киң таралган тибы — комлы туфракта үсә торган мүк баскан нарат урманы: югары яруста — каен катыш югары бонитетлы һәм бик юан нарат агачлары, куаклыкта — талтирәк, миләш һәм артыш, туфракның өске капламында — абага-бөркет канаты, нарат җиләге һәм яшел мүкләр. Нарат урманнарының башка типларыннан түбәндәгеләр очрый: урман паркының көньяк өлешендә коры наратлыктан яңасына күчә баручы лишайниклы-мүкле наратлыклар; каен, юкә, сирәгрәк усак катыш нарат агачлары, куаклык өлешендә — кабар агачы, миләш, зелпе һәм куак рәвешендәге юкә, үлән капламында — нарат җиләге, ландыш, сәрдә, күрән үскән куаклыклы наратлыклар. Яфраклы токымнардан каен күбрәк очрый (урман б-н капланган мәйданның 39%), ул катнаш урманнарда да,чиста каенлыкларда да күп үсә. Үлән баскан (күрәнле) каенлыклар урманның төп тибы булып тора, алар субор һәм өлешчә куаклы наратлыклар урынында барлыкка килгән; югары яруста — нарат, каен һәм юкә, куаклыкта — миләш, зелпе, кабар агачы, үлән капламында күрән, сәрдә, йолдызак үсә. Урман паркының төньяк өлешендә чыршы, имән һәм юкә катыш кара-кучкыл ылыслы-киң яфраклы урманнарның кайбер өлешләре сакланган, сирәк очрый торган үсемлек төрләреннән сарана лаләсе, эре чәчәкле сыңар чәчәк, киң яфраклы йод үләне, чын оялаш уты күренә. Урман культуралары 522 *га* мәйданны били. «А.к.» массивының көнбатыш өлешендә урыны б-н 1899 елда утыртылган каен һәм чыршы катыш карт нарат агачлары сакланган. Ел саен 15 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла, ш.и. 10 *га* мәйданда тоташ культуралар булдырыла.

*Әд.:* Роготова Т.В. Голубое и зелёное. К., 1984.

*Ф.Г.Борһанов, А.Р.Каюмов.*

«Аккош күле» урман паркы.
Нарат урманы өлеше.



**«АККОШ КҮЛЕ»**, Татарстан язучыларының иҗат йорты. Казаннан 17 *км* ераклыкта, шул исем. урман массивында, Кече Тирәнкүл буенда урнашкан. ТАССР язучыларының Әдәби фонды тарафыннан 1955 елда төзелә. Беренче коменданты Н.Дәүли була. Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, Ә.Фәйзи, Х.Туфан, С.Хәким, И.Гази, Г.Әпсәләмов, С.Баттал, Ш.Мөдәррис, Л.Ихсанова, З.Нури, Ф.Хөсни, Р.Ишморат, Н.Юзиев, Г.Латыйп, А.Әхмәт, М.Елизарова, А.Талвир, Х.Хәйри, Г.Зәйнашева, М.Мәһдиев, Ш.Галиев, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Р.Кутуй, Р.Миңнуллин, Р.Мостафин, М.Әгъләмов, Р.Гатауллин һ.б. язучылар анда яшәп иҗат итә. «А.к.»ндә төрле елларда тугандаш әдәбият язучыларыннан М.Кәрим, К.Мәргән, С.Кудаш, Ш.Анак, Г.Голәм, К.Кулиев, Р.Гамзатов, Д.Кугультинов, Ж.Молдагалиев, С.Муканов, М.Львов, С.Куняев, В.Шамшурин, Р.Моран, С.Трахимёнок, П.Хузангай, Я.Ухсай, П.Афанасьев, Ю.Семендер, В.Тургай һ.б.лар була.

*Әд.:* Аккош күле — илһам аланы: истәлек хатирәләр. К., 2007.

**АККО́Ш КҮЛЛӘРЕ́**, Казанның Киров р-нында, «Аккош күле» урман паркы терр-ясендәге күлләр системасы: *Кече Аккош күле, Олы Аккош күле* һәм *Коры Аккош күле*. Су тирәнлеге һәм яр сызыклары сезонга карап үзгәрә. Озын, ташу вакытында, күлләр ташый, җәй ахыры — көз башында саегалар һәм кечерәяләр. А.к. су өслегенең гомуми мәйданы ташу вакытында 73 *га*, суының иң аз вакытында — 34,4 *га*. Гомуми күләме ташу вакытында 190 мең *м*³, суының иң аз вакытында — 21,3 мең *м*³. Гомуми озынлыгы 2600 *м*. Күл казанлыгы дюналар арасындагы иңкүлекләрдә карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә катлауланып ясалган. Күлләрнең төньягындагы ярлар аз сөзәкле һәм биек түгел, урыны-урыны б-н сазланган; көньяк өлеше — текәрәк һәм калкурак, нарат урманнары б-н капланган.

Күлләр күбесенчә язгы кар сулары исәбенә туена. Суы бик йомшак, төссез, җәй ахырында һәм көзен саргылт. Күлләр системасының бөтен сулыкларында да җир-су хайваннарының берничә төре һәм балыкларның өч төре — табан балык, сазан, ләрге балыгы бар. Камыш һәм күрән үскән сай сулы җирләрдә үрдәкләр оялый. А.к. — ел дәвамында ял итү урыны.

**АККОШЛА́Р** (Cygnus), үрдәк кошлар семьялыгыннан кошлар ыругы. 6 төре билгеле: 4 се Төньяк ярымшарда, 1 төре — Көньяк Америкада, 1 төре Австралия һәм Тасманиядә. ТРда 2 төре бар. Ысылдавык аккош (C. olor) — оя ясаучы аз санлы күчмә төр, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының су яны һәм су асты үләннәре күпләп үскән култыкларда һәм плёсларда, Сукыр Кадыш һәм Кайбыч балык үрчетү хуҗалыгы буаларында апрельдән октябрьгә кадәр яши. Сары борынлы аккош (C.cygnus) язын һәм көзен миграция вакытында очрый. Зур кошлар, гәүдәләре 150 *см* га кадәр озынлыкта, авырлыгы 12 *кг* га кадәр. Гәүдәсе сузынкы, муены озын. Каурыйлары ак төстә. Башы уртача зурлыкта. Аяклары кыска, бармак арасындагы йөзү ярылары зур. Яшь кошларның томшыклары алсу төстә, очы кара. Ысылдавык аккошның гәүдәсе, муены озын, кызгылт сары томшык төбендә калынайган кара урыны бар. Сары борынлы аккош беркадәр тәбәнәк формасы һәм кыска муены б-н аерылып тора, томшык төбе сары. А. бер сезонда соргылт-зәңгәр төстәге 5–9 зур йомырка сала. Су үсемлекләре, ш.у. бөҗәкләр һәм аларның личинкалары, суалчаннар, кабырчыклар, балыклар б-н тукланалар. 2 төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Ысылдавык аккош.

**АККУЧА́Т БИНЕ́ КИЛМӨХӘММӘ́Д** (17 йөз ахыры — 18 йөз башы), хаттат, ташка уеп язу остасы. Мәгълүм эпитафияләр авторы *Килмөхәммәт бине Ишманның* улы дип фаразлана. Аккучат эшләгән кабер ташы Минзәлә р-нындагы Бикбау авылыннан 3–4 *км* ераклыкта урнашкан, хәзер инде юкка чыккан Килморза авылының иске зиратында сакланган. Зурлыгы һәм бизәү стиле, язу рәвеше буенча әлеге эпитафия Килмөхәммәт бине Ишман бизәгән ташларга охшаш. Остазыннан аермалы буларак, Аккучат имзасын һәйкәлнең сулъяк кырына уйган һәм үзен ташка уеп язу остасының улы дип атаган. Бу мәгълүмат аны күренекле останың улы дип фаразлауга нигез була. Кабер ташының ал ягындагы өске өлеше үсемлек рәсемнәре б-н бизәлгән, текст гарәп графикасының сөлес имлясында язылган. Әлеге эпитафия беренче тапкыр 18 йөз ахырында Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» китабында искә алына. Һәйкәл беренче булып 1992 елда М.Әхмәтҗанов тарафыннан тикшерелә.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Тарихи чыганаклар // Идел. 1994. № 3.

**АККҮ́З** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 27 *км* көньяктарак, Сөн елгасы буенда. 2002 елда 291 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1745 елдан мәгълүм. Авыл башта Югары Ахун дип атала. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, чыпта сугу б-н шөгыльләнә. А.дәге мәчет турында беренче тапкыр 1821 дә искә алына, 1854 тә аның каршында ир балалар өчен мәктәп ачыла. 20 йөз башында авылда су тегермәне, 2 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3269 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында А.дә «Гранит» к-зы оештырыла, хәзерге вакытта монда «Ахун» кооперативлар берләшмәсенең үзәк утары урнашкан. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 55, 1959 да — 522, 1870 тә — 592, 1884 тә — 733, 1897 дә — 906, 1906 да — 918, 1913 тә — 939, 1922 дә — 890, 1926 да — 792, 1938 дә — 695, 1949 да — 511, 1958 дә — 487, 1970 тә — 596, 1979 да — 493, 1989 да — 354 кеше.

**АККҮ́Л** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 9 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасыннан 1 *км* читтә. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. 1920 елларда Түбән Наратбаш авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. ТАССРның Буа кантонына керә, 1930 ның 10 августыннан — Буа р-нында. Халык саны: 1938 дә — 127, 1949 да — 128, 1958 дә — 116, 1970 тә — 110, 1979 да — 60, 1989 да — 17 кеше.

**АККҮ́Л** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 8 *км* көньяктарак, Бор елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 171 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1910 да нигез салына. 1930 дан А. — «Очкын» к-зы (соңрак «Комбайн» дип үзгәртелә), 1957 дән — «Лениногорский», соңрак «Октябрьский» с-злары составында. 1920 гә кадәр авыл Самара губернасының Бөгелмә өязе Михайлов волостена, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонына керә. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 230, 1938 дә — 198, 1949 да — 220, 1958 һәм 1970 тә — 177, 1979 да — 158, 1989 да — 139 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**«АККҮ́Л»**, минераль ашлама сапропель чыганагы. ТРда иң эреләрдән. Тукай р-ны терр-ясендә, Чаллыдан 22 *км* төньяк-көнчыгышта, Илбухтино авылыннан 5 *км* төньяк-көнчыгышта урнашкан. Кама һәм Ык елгаларының сул як тугаендагы шул исемдәге күл янында. 1969 елда ачылган. 1978 дән Түбән Кама сусаклагычы астында кала. 1989 дан бирле эшкәртелә. Сапропельнең калынлыгы 0,4–5 *м* (уртача — 3 *м*). Су капламы 0,4–4 *м*. Дүртенчел система комнары б-н түшәлгән. 2007 елның 1 гыйнварына сапропельнең $C^2$ категориясе запасы (дымлылык 60% булганда) 219 мең *т* тәшкил итә. Сапропель органикалы-известьле һәм известьле типта, көллелеге 53,6–62%, дымлылыгы — 77–82%, реакциясе нейтраль — җиңелчә селтеле (pH 6,7–7,1). Составында $CaCO_3$ — 24,7; $Fe_2O_3$ — 2,4; N — 1,86; $P_2O_5$ — 0,7; $K_2O$ — 0,6; S — 1,25%. Сапропельнең иң күп алынуы (200 мең *т*) 1994 елга туры килә. Чыганак комплекслы, көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләрендә сапропель өстендә 0,9–4,2 *м* калынлыгында уйсулык тибындагы (урман, камыш) торф капламы ята. Торфның уртача таркалу дәрәҗәсе 50%, көллелеге — 33%, табигый дымлылыгы — 79,1%, реакциясе җиңелчә әчелектә (pH

5,1–6,3). 2007 елга торф запаслары (дымлылыгы 40% булганда) 2664 мең *т*. Ятманың кырый чикләренә кадәрге мәйданы — 983 *га*, сәнәгатькә яраклы тирәнлектәге (0,6 *м*) урыннарының мәйданы — 797 *га*. Чыганак районара әһәмияткә ия, эшкәртү әйләнә-тирә мохиткә начар йогынты ясамый. Сапропель минераль ашлама, известьлы мелиорант һәм терлек азыгына кушу өчен витаминлы минераль чимал буларак кулланыла; торф органик ашлама итеп файдаланыла.

**АККҮ́Л БИГӘНӘ́Й** (Ак Бигәнәй) авылы, Саба р-нында, Байлар Сабасы авылыннан 13 *км* көньяктарак, Казкаш елгасы буенда. 2002 елда 204 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты. 16 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.Б.дә мәчет була. 20 йөз башында су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 850,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир заты; 1859 да — 314, 1897 дә — 480, 1908 дә — 515, 1926 да — 415, 1938 дә — 460, 1949 да — 370, 1970 тә — 238, 1979 да — 248, 1989 да — 198 кеше.

**АКМА́ЕВА** Алия Әдһәм кызы (2.6.1951, Казан), инженер-конструктор, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1973). 1973 елдан Казан компрессорлар төзү КБсында, 1979 дан «ТатНИИнефтемаш» АҖдә инженер-конструктор, әйдәп баручы конструктор, бүлек мөдире. Татарстан җирлегендәге нефтьне чыгаруга бәйле үзенчәлекле җайланмалар эшләүдә катнаша. Бер җайланма өчен РФнең уйлап табучылык таныклыгын ала (2000). «Татнефть» АҖдә автомобиль шиннарын пиролизлау цехын эшләүче конструкторлар төркеме мөдире. СССР Химия машиналары төзелеше министрлыгының Мактау грамотасына (1988), ТРның Мактау грамотасына (2002) һәм РФнең Мактаулы нефтьчесе исеменә (2003) лаек була. Дәүләт бүләге «Экологик чиста технологияләр эшләү һәм файдалануга кертү, вакланмаган тузган шиннарны утильләштерү өчен сәнәгатьтә модульле җайланмалар комплексын җитештерүне оештыру» дигән хезмәте өчен бирелә.

*Л.Х.Хәмидуллин.*

**АКМА́ЛОВ** Нияз Рәшит улы (14.2.1954, Сарман р-ны Катыш Каран а. — 11.8.2007, Казан, туган авылында җирләнә), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1976). «Яшь ленинчы» г-тасы (1979–87), «Казан утлары» ж-лы (1987–91), «Татарстан хәбәрләре» (1991–95), «Мәдәни җомга» (1995 тән) г-талары редакцияләрендә эшли. Язмалары 1970 еллардан бирле басылып килә. А. шигырьләренә нечкә лиризм, фикер тирәнлеге хас. Аның туган җиргә мәхәббәт хисләре, гражданлык рухы б-н сугарылган шигырьләре, балладалары, поэмалары «Учак» (1986), «Килер бер көн» (1988) «Күзләремнең төсе үзгәрмәде» (2004) исемле китапларында тупланган. А. хәзерге заман кешеләренең катлаулы язмышларын бәян иткән, кискен сюжетка корылган детектив характердагы «Үз урамым» (1991), «Күгәрчен сөте» (1993), «Бохара мачысы» (1999) кебек хикәя һәм повесть җыентыклары авторы. Публицистика өлкәсендә дә уңышлы иҗат итә. Көндәлек матбугатта аның памфлетлары һәм фельетоннары, татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре турындагы очерклары еш басыла.

*Әд.:* Г ы й л ь м а н Г. Заман сүз сорый // Осталык. К., 1991.

*Г.М.Габделхакова.*

**АКМА́Н** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Комазан елгасы буенда. 2002 елда 267 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп. Китапханә. 18–19 йөз урталарыннан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да мәчет була. 20 йөз башында монда мәктәп, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 396,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 52 ир заты; 1859 да — 221, 1897 дә — 372, 1908 дә — 446, 1920 дә — 402, 1926 да — 391, 1938 дә — 455, 1949 да — 346, 1958 дә — 338, 1970 тә — 402, 1979 да — 356, 1989 да — 319 кеше.

**АКМУЛЛА́** (псевд.; чын исеме Мифтахетдин Камалетдин угылы) (27.12.1831, Оренбург губ., Бәләбәй өязе Туксанбай а., хәзер Башкортстан Респ-касының Миякә р-ны — 8.10.1895, Миасс ш.), татар мәгърифәтче шагыйре, чичән. Иҗат мирасы башкорт һәм казакъ әдәбиятларының да уртак хәзинәсе булып санала. А. авыл имамы гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне Ябалактамак авылында ала, аннан Мәләүзтамак, Әсән, Эстәрлебаш авыллары, Троицк мәдрәсәләрендә укый. Шагыйрь һәм дин галиме Шәмсетдин Зәкинең шәкерте. Троицкида дин гыйлемен Зәйнулла ишан Рәсүлидән өйрәнә. Мәдрәсә елларында җәйләрен казакъ далаларында мөгаллимлек итә. Соңга таба Көнбатыш Себер, Казакъстанның төньяк-көнбатыш төбәкләрендә балалар укыта, халык арасында татар мәгърифәтчеләренең фикер-карашларын тарата. Сүздә тугрылыгы һәм гаделлеге өчен Акмулла кушаматы алып, үз заманы өчен кыю фикерләре б-н таныла. Гаскәри хезмәттән качып йөри дигән әләк б-н кулга алынып, 1867–71 елларда төрмәдә утыра (сәбәбе — Зәйнулла ишан б-н элемтәдә булганы өчен дигән фаразлар да бар). Төрмәдә чагында атаклы «Төрмә шигырьләре»н иҗат итә. 1871 дә А. ярлыкау сорап гариза яза һәм залог кертү шарты б-н ирекkә чыгарыла. Әммә шагыйрь, үзен бөтенләй аклауларын теләп, соңгы казакъ ханнары нәселеннән булган ген.-полковник Гобәйдулла Букиевка мөрәҗәгать итә, аңа мәдхия багышлап, бу эштә ярдәм итүен сорый. Генерал, шагыйрьнең гозерен тыңлап, патша тәхете тирәсендәге элемтәләре аша эш йөртә һәм А.ны ярлыкау турында патша Александр II нең фәрман чыгаруына ирешә. Бер елдан А. Петропавел (Кызылъяр) шәһәрендәге Рәхмәтулла имам мәдрәсәсенә мөгаллим булып урнаша, аннары Күкчәтау шәһәре тирәсендәге авылларда мөгалимлек эшчәнлеген дәвам иттерә. 1894 тә А. Уфа шәһәрендә Риза Фәхретдин б-н очраша. Мәгърифәтче галим аңа шигырьләрен чыгарышуда ярдәм кулы сузарга вәгъдә итә, әмма шагыйрьнең фаҗигале үлеме бу эшне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми. А. 19 йөз татар поэзиясендә Шәрекъ һәм Көнбатышның фәлсәфи фикер казанышларын бергә кушу, синтезлау җирлегендә шигырьдәге традицион жанрларны халык авыз иҗаты, хикмәтле сүз хасиятләре б-н баетуның гармоник үрнәкләрен биргән шагыйрьләрнең берсе булды. Аның шигъри иҗаты фикер тирәнлеге, эчтәлегенең заманча булуы, тел-сурәтләү чараларының образлы, афористик, үткен, эмоциональ лирик бизәкләргә бай булуы, фәлсәфи фикернең, публицистик һәм лирик башлангычларның, сатираның шигырь тукымасында гаҗәеп табигый яңгыраштa гәүдәләнүе б-н үзенчәлекле. Катлаулы фикерләрне дә А. укучыга тел-стиль чаралары б-н җиңел аңлаешлы итеп җиткерә белә. Иҗатында ул гади кешеләрнең теләк-омтылышларын чагылдыра, аларны белемгә, мәгърифәткә өнди, шәхеснең рухы хөр булырга тиеш дигән идеяне алга сөрә. Мәгърифәт, гаделлек өчен көрәшүче шагыйрь образы аның төрмә шигырьләрендә аеруча ачык сизелә: ул тормыштагы золымны, мәрхәмәтсезлек күренешләрен ачы тәнкыйтьли, бер үк вакытта кеше акылының, гаделлекнең җиңеп чыгачагына тирән ышанычын белдерә. А. фикер ияләреннән бигрәк тә Ш.Мәрҗанине үзенә остаз итеп саный, аңа багышлап үзенең мәгълүм мәрсия-мәдхиясен яза, анда Казанны татар мәдәниятенең үзәгенә тиңләп, үзен шул мәдәниятнең бер вәкиле итеп күрә. Әлеге мәрсия — А.ның үзе исән чакта басмада дөнья күргән бердәнбер әсәре. Иҗатында иске карашлы дин әһелләрен кискен тәнкыйтьләп, А. аларга каршы ислам дөньясының үткәндәге бөек галимнәрен, Мөхәммәд пәйгамбәрне һәм үз замандашларыннан Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин образларын үрнәк итеп куя. Әсәрләре өчен тема һәм сюжетларны А. реаль тормыштан — 19 йөзнең 2 нче яртысындагы чынбарлыктан алган; алар 20 йөз башында да бик актуаль яңгырап, укучыларда зур кызыксыну уяткан. Вафатыннан соң, 1904, 1907 елларда, шагыйрьнең ике җыентыгы дөнья күрә. А.ның күпчелек әсәрләре төрки халыклардагы чичәннәр, акыннар иҗаты традициясе калыбында язылган, ятлау өчен алар бик җиңел. Теле — катнаш казакъ-татар теле, арада баш-



Акмулла.

корт сөйләше элементлары да очрый. Әсәрләренең кайберләре исә саф иске татар әдәби теле традициясендә язылган һәм хәзерге әдәби тел кагыйдәләренә яраштырмыйча да укучыга җиңел аңлашыла.

Ә с ә р.: Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе. К., 1892; Акмелла әфәнденең иншад итдеки мәнзумати илә башка бер кач моншәдатене үз кәндесенең тәрҗемәи хәлене моштәмил мәҗмугадыр. К., 1904; Акменланың Шиһабетдин әл-Мәрҗани мәрсиясе вә башка шигырьләре. К., 1907; Өлеңдер җыйнагы. Алматы, 1935; Шигырьләр. К., 1981; Шиғырҙар. Өфө, 1981; Күңдер мен түндер. Өлеңдер, толгаулар, термелер, айтыс. Алматы, 1986; Стихи. Уфа, 1986.

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Мифтахетдин Акмулланың иҗаты һәм мирасы // Акмулла. Шигырьләр. К., 1981; Мәгърифәтче шагыйрь Акмулла. Тууына 150 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. К., 1983; Ә х м ә т о в Р. Мифтахетдин Акмулла // Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Г а й н у л л и н М.Х. Татар әдәбияты. XIX йөз. К., 1986; М и ң н е г у л о в Х. «Милләт өчен зарлы» Акмулла // Дөньяда сүземез бар... К., 1999; Х а р и с о в Ә.И. Башҡорт халкының әҙәби мираҫы. Өфө, 1965; В и л ь д а н о в Ә.Х. Акмулла — яктылык йырсыһы. Өфө, 1981; К а л и ж а н о в У. Агартушы — демократ акың // Акмолла. Күңдер мен түңдер. Алматы, 1986; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975.

*Р.Ә.Әхмәтов.*

**«АКМУЛЛА́»**, сатирик-юмористик, рәсемле журнал. 1911 елның 15 июленнән 1916 нең 29 гыйнварына кадәр Троицк шәһәрендә (Оренбург губ.) айга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 51 саны чыга. Х.Сосновскийның «Энергия» басмаханәсендә басыла. Нашире Х.Ганиев. Төрле еллардагы мөхәррирләре: Х.Ганиев, К.Габетдинов, Ә.Галимов, С.Галимов, Х.Искәндәров, К.Карипов, В.Хәкими, Ж.Юмаев. «А.»да басылган әсәрләр шигырь, фельетон, карикатура жанрларына карый. Журнал татарларның иҗтимагый тормышындагы җитешсезлекләрне, иске карашлы дин әһелләрен, ялкау, гамьсез, надан шәкертләрне көлке утына ала. Сәяси вакыйгаларга карата урталык позициясендә тора. Радикаль карашлы авторларның моннан канәгать булмаган өлеше журнал б-н язышудан читләшә, нәтиҗәдә аның абруе төшә һәм чыгудан туктый.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

*Р.Г.Әмирханов.*

**АКСА́Й** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 12 *км* төньяктарак, Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы Зәй суы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 1920 еллар башында нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 нең 10 августыннан — Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 85, 1938 дә — 72, 1958 дә — 21, 1970 тә — 25, 1979 да — 16, 1989 да — 9 кеше.

**АКСА́К ТИМЕ́Р** (Әмир Тимер, Тимер бәк, Тамерлан, Тимерләнг) (9.4.1336, Шәһрисәбез янындагы Хуҗа Илгар а. — 18.2.1405, Утрар шәһәре; Сәмәркандта җирләнә), җиһангир, Урта Азия дәүләте әмире. Барлас ыругы бәге Тарагай улы. 1362 елда могол ханы Туглак Тимер аны Кеш (Шәһрисәбез) өлкәсе идарәчесе итеп билгели. А.Т. 1363 тә Туглак Тимер улы Ильяс Хуҗа б-н үз өлкәсенең мөстәкыйльлеге өчен көрәшә башлый, Бәлх һәм Сәмәрканд шәһәрләре идарәчесе Хөсәен б-н бердәмлек килешүе төзи. 1365 тә моголлар гаскәре аларның берләштерелгән көчләрен җиңә, Сәмәрканд каласын яулап ала. 1366 да Сәмәрканд халкы баш күтәрә, шәһәр идарәчелегенә Хөсәен б-н А.Т. кире кайтарыла. 1370 тә А.Т. союздашы Хөсәен көчләрен үзара көрәштә җиңә. Аксөякләр корылтайда аны Сәмәрканд вилаяте әмире дип игълан итә. Шул ук елда ул чыңгызыйлар нәселеннән булган Казан ханы кызына өйләнә. Мавәраәннәһер өлкәсенең фактик идарәчесенә әверелә. Үз биләмәләрен киңәйтү максатыннан чыгып, күрше ил-өлкәләрне басып ала башлый. 1381–84 тә Иран өлкәләрен буйсындыра. 1387 дә Алтын Урда биләмәсенә яу б-н килә, 1388 дә Харәземне яулап ала. Идел буендагы 2 зур сугышта Туктамыш хан гаскәрен тар-мар итә, байтак шәһәрләрне талап, җимереп китә (к. *Кондырча елгасы буендагы сугыш*, *Терек елгасы буендагы сугыш*). 1398 дә Һиндстанга басып керә, Дәһли шәһәрен яулап ала, Төньяк Кавказ өлкәләрен тәмам буйсындыра. 1402 дә көньяктагы көчле күршесе, төрек солтаны Баязид гаскәрен Әнкара шәһәре янында җиңүгә ирешә. Кытайга каршы яу оештырып йөргәндә Утрар шәһәрендә кинәт авырып вафат була. Ул идарә иткән дәвердә Урта Азия дәүләте байтак өлкәләрне үзенә буйсындыра (Иран, Харәзем, Хорасан, Пәнҗаб, Кавказ аръягы ханлыклары) һәм иң югары икътисади, мәдәни үсешенә ирешә. Варислары тарафыннан Сәмәркандта төзелгән Гүр Әмир мавзолей-төрбәсе дөнья күләмендә танылган сәнгать үрнәге булып тора. 1990 елларда Үзбәкстан Респ-касында Әмир Тимер исемендәге орден булдырыла, берничә шәһәрдә аңа һәйкәлләр куела.

*Әд.:* Автобиография Тимура. М., 1937; Я к у б о в с к и й А.Ю. Тимур // Вопросы истории. 1946. № 8/9; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; М у м и н о в И. Роль и место Амира Тимура в истории Средней Азии // Вопросы истории. 1973. № 2.

*И.Л.Измайлов.*

**АКСА́КОВ** Сергей Тимофеевич (1.10.1791, Уфа ш. — 12.5.1859, Мәскәү), язучы. 1801–05 елларда Казанның Беренче ирләр гимназиясендә, 1805–07 дә Казан ун-тында укый. А.ның дөньяга карашлары педагоглар Г.И.Карташевский һәм Н.М.*Ибраһимов* йогынтысында формалаша. Язучының әдәби, театраль, фәнни карашлары студентлык елларында ук тәгаенләнә. 1807 дән ул Рус әдәбиятын сөючеләр җәмгыяте әгъзасы. А.И.Панаев (шагыйрь И.И.Панаевның бертуганы) б-н кулъязма журналлар (ш.и. «Журнал наших занятий» 1806–07) чыгара, анда үзенең беренче шигырьләрен урнаштыра. К.Ф.*Фукс* йогынтысында күбәләкләр җыю, табигатьне өйрәнү б-н мавыга. Болар барысы да А.ның язучы-реалист булып формалашуына тәэсир итә. Ун-т каршындагы студентлар театрын җитәкли, спектакльләрдә үзе дә катнаша. 1807 дә, укуын тәмамламыйча, Петербургка күчә. 1801–15 еллар вакыйгаларын яктырткан «Истәлекләр» («Воспоминания», 1856) һәм «Күбәләк җыйганда» («Собирание бабочек», 1859) хикәясендә А. гимназия һәм



С.Т.Аксаков.

ун-т тормышын киң яктырта, укытучыларга бай характеристикалар бирә. А.ның әсәрләре Казан ун-ты тарихын, Казанның 19 йөз башындагы мәдәни тормышын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булып тора. А. үзенең шәхес буларак формалашуын Казан гимназиясендә һәм ун-тында укуы б-н бәйләп: «Күңелемдә сакланып калган яхшы сыйфатларым өчен мин гимназиягә, университетта укуыма, анда хөкем сөргән якты бер җанлылыкка бурычлымын», — дип яза.

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 4 т. М., 1955–56.

*Әд.:* А р х а н г е л ь с к и й А.С. С.Т.Аксаков: Детство и студенчество: 1791–1807 // Русское обозрение. 1895. № 7–9; М а ш и н с к и й И.С. С.Т.Аксаков. Жизнь и творчество. М., 1973; А р и с т о в В.В. Первое литературное общество Поволжья. К., 1992.

*Л.Е.Бушканец.*

**АКСАКУ́Л** посёлогы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 6 *км* төньяктарак. 2002 елда 12 кеше (руслар) яши. 1920 еллар башында нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантонына керә. 1930 нең 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 августыннан — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 84, 1938 дә — 100, 1949 да — 130, 1958 дә — 39, 1970 тә — 19, 1979 да — 13, 1989 да — 6 кеше.

**АКСА́Р** елгасы, Шепкә елгасының (Зәй елгасы бассейны) уң кушылдыгы, Көнчыгыш Кама аръягында. Озынлыгы 10,4 *км*, бассейнының мәйданы 32,9 $км^2$. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Шепкә авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы Аксар авылыннан 1 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 58%. А.ның 1 һәм 1,8 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 $м^3/с$. Ел дәвамында суы бик каты (20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр.

**АКСÁР** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Аксар елгасы буенда. 2002 елда 746 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1650 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Шепкә, Яңа Аксар, Әсәй исемнәре б-н дә билгеле. Беренче күчеп килүчеләр марилар була. 18 йөзнең 1 нче чирегендә татарлар урнаша башлый. 1773–75 еллардагы крәстияннәр кузгалышында шушы авыл старшинасы Аренкул Алиев баш күтәрүчеләрнең Зәй округындагы 600 ләп кешесе булган иң зур отрядын җитәкли. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 1763 елгы 3 нче ревизия документларында 25 ир заты керәшен татар булып язылган; 1884 тә 96 крәстиян хуҗалыгыннан 90 ы — ислам, 6 сы православие динен тота. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, А.да мәчет, 2 мәдрәсә, 2 су тегермәне була. Крәстияннәр, игенчелек, терлек үрчетү һәм умартачылык б-н бергә, олаучылык, арба көпчәкләре, чана ясау, киндер сугу, чаршау тегү б-н шөгыльләнәләр. 1463 дис. җире булган икмәк б-н сәүдә итүче А.И.Стахеевның «Аксар дачасы» утарында ялланып эшлиләр. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 948 дис. тәшкил итә. 1929–30 елларда А.да «Кызыл Октябрь» к-зы оештырыла, 1959 да ул XXI партсъезд исем. к-зга керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1724 тә — 65, 1795 тә — 68 ир заты; 1859 да — 429, 1913 тә — 1075, 1926 да — 893, 1938 дә — 839, 1949 да — 792, 1958 дә — 806, 1970 тә — 908, 1979 да — 815, 1989 да — 719 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**АКСÉНТЬЕВ** Леонид Александрович (1.3.1932, Баку), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1972), проф. (1974), ТССР һәм РФнең атказ.фән эшлеклесе (1991, 2004). Казан ун-тының атказ. проф. (2007). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук матем. анализ кафедрасында эшли. Хезмәтләре кайтма кырый мәсьәләләргә һәм комплексы үзгәрешле функцияләрнең геом. теориясенә карый. Аналитик функцияләр теориясенең кырый мәсьәләләре бер яклы өслектә чишелә алуы турындагы проблема буенча төп нәтиҗәләр ала, функцияләрнең геом. теориясендә бер яклы өслек булу билгеләрен нигезли. Кайтма кырый мәсьәләләрне Риман өслекләрендә чишү схемасын һәм конформ радиуслы өслекләрне тикшергән тышкы кайтма кырый мәсьәләләрнең чишелеш рәвешләрен бирә. Россия югары мәктәбенең мактаулы хезмәткәре (1998). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основные результаты в достаточных условиях однолистности аналитических функций // Успехи мат. наук. 1975. Т. 30, вып. 4 (автордаш); Достаточные условия конечнолистности аналитических функций и их приложения / ВИНИТИ // Итоги науки и техники. Мат. анализ. 1987. Т. 25 (автордаш); Многолистные функции из расширенных классов Беккера и Нехари и их гидромеханическое истолкование // Изв. вузов. Математика. 1999. № 6.

*Әд.:* И л ь и н с к и й Н.Б., С а л и м о в Р.Б., Ш е р с т н ё в А.Н. Леонид Александрович Аксентьев // Изв. вузов. Математика. 1982. № 4.

**АКСЁНОВ** Василий Павлович (20.8.1932, Казан), язучы. Казан ун-тының шәрәфле д-ры (2007). П.В.*Аксёнов* һәм Е.С.*Гинзбургның* улы. Ата-анасы кулга алынганнан соң (1937), туганнарында яши. 1950 елда Казан мед. ин-тына укырга керә, 1954 тә Ленинград мед. ин-тына күчә. Аны тәмамлаганнан соң, табиб булып эшли. 1960 тан Мәскәүдә яши. 1960 елларда яшьләр прозасында билгеле бер урын алган «Хезмәттәшләр» («Коллеги», 1960), «Йолдызлы билет» («Звёздный билет», 1961), «Марокко әфлисуннары» («Апельсины из Марокко», 1963), «Вакыт җитте, дустым» («Пора, мой друг, пора», 1965), «Тулган мичкә» («Затоваренная бочкотара», 1968) повестьлары авторы. «Безнең алтын тимеребез» («Золотая наша железка», 1975), «Пешкән җәрәхәт» («Ожог», 1976), «Кырым утравы» («Остров Крым», 1977), «Жанрны эзләү» («Поиски жанра», 1978) повестьларында һәм романнарында 60 нчы еллар зыялыларының эзләнүләре тасвирлана. «Һәрвакыт сатуда» («Всегда в продаже», 1969), «Дүрт темперамент» («Четыре темперамента», 1978), «Челән» («Цапля», 1980) пьесалары авторы. А. иҗатының башлангыч чорындагы Көнбатыш әдәбиятына йөз тоткан беренче повестьларында модернизм элементлары күренә башлый. Аны рус модернизмы традицияләрен дәвам иттерүче дип санарга мөмкин. 1980 нән А.Джордж Мейсон ун-ты (Вашингтон) профессоры. Чит илдә дә, нигездә, рус темасын яктыртып, «Кәгазьле пейзаж» («Бумажный пейзаж», 1982), «Йөзем дип әйт» («Скажи: изюм», 1985), «Мәскәү кыйссасы» («Московская сага», 1991), «Вольтерчылар» («Вольтерьянцы и вольтерянки», 2004; Букер бүләге), «Москва Ква-Ква» (2006) романнарын яза. Тормышының Казан дәвере истәлекләре үзенең биографиясенә һәм Казандагы туганнары, дуслары тормышына таянып язылган «43 нче елның иртәнге ашлары» («Завтраки 43-го года», 1962), «Мәйданда һәм елга аръягында» («На площади и за рекой», 1967), «Ишегалдыбыз Җирәне» («Рыжий с нашего двора», 1967), ш.у. АКШта басылган «Зөя» («Свияжск», 1981), «Моңсу баланы эзләгәндә» («В поисках грустного бэби», 1985), «Йомырка сарысы» («Желток яйца», 1989), «Яңа татлы стиль» («Новый сладостный стиль», 1996) әсәрләрендә чагылыш таба. 2002 елдан Франциядә (Биарриц ш.) яши.

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 5 т. М., 1995.

*Әд.:* Г л э д Джон. Беседы в изгнании: Русское литературное зарубежье. М., 1991.

*Е.С.Тимофеева.*




**АКСЁНОВ** Евгений Михайлович (7.8.1937, Казан), геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1998), ТРның атказ. геологы (1997), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), Себер геология, геофизика һәм минераль чимал фәнни-тикшеренү ин-тында (Новосибирск ш.). 1962 елдан ЦНИИгеолнерудта, 1980 нән сәнәгать минераллары геологиясе бүлеге мөдире, 1995 тән директор урынбасары, 2002 дән директоры. Көнчыгыш Европа платформасындагы венд һәм рифей утырмаларының стратиграфик схемаларын, терр-ялләрдә металл булмаган файдалы казылмаларның күләмен исәпләү һәм фаразлау — минераген анализлау методикасын һәм принципларын гамәлгә кертә һәм камилләштерә. СССР терр-ясе докембриенең гомуми шкаласын эшләүдә, «Континентлар докембриенең тектоника карталары»н («Карты тектоники докембрия континентов», 1972) төзүдә катнаша. Металл булмаган файдалы казылма чыганакларның урнашу һәм формалашу закончалыклары, борынгы платформалар үсеше тарихына караган хезмәтләр авторы һәм карталар редакторы: «СССРдагы металл булмаган файдалы казылмалар картасы» («Карта неметаллических полезных ископаемых СССР», 1991)). Аның җитәкчелегендә РФ һәм СССРның минераль чимал потенциалына бәя бирелә, БДБның аерым районнарында сәнәгать минераллары турындагы фаразлар раслана.

Х е з м.: О формационных рядах протерозоя Восточно-Европейской платформы // Изв. АН СССР. Сер. Геология. 1979. № 8; Новая стратиграфическая шкала докембрия СССР // Изв. АН СССР. Сер. Геология. 1991. № 4; Геология Татарстана. Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**АКСЁНОВ** Павел Васильевич (28.1.1899, Рязань губ., Ряжск өязе Покровский а. — 1991, Казан), партия һәм профсоюз эшлеклесе. Мәскәүдә Үзәк совет-партия мәктәбен тәмамлый (1919). 1914–16 елларда Рязань тимер юлында һәм Мәскәү оешмаларында эшли. 1916–18 дә Покровский волостенда писарь ярдәмчесе, җир ком-ты әгъзасы, 1918–19 да Покровский авылында РКП(б) ячейкасы секретаре. 1919 ның көзеннән Көньяк-көнбатыш фронтның Ряжск станциясе сәяси идарәсе агитаторы, 15 нче Инза (Сиваш) дивизиясе сәяси идарәсе инструкторы; Каховка өчен барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1921–22 елларда РКП(б)ның Донецк губернасы Гришинск өязе ком-тында бүлек мөдире, секретарь. 1922–28 дә ВКП(б)ның Рыбинск, Орёл (1923), Түбән Тагил (1925–28) ком-тларында агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире, 1928–30 да Казанда Киров райкомы секретаре. 1930–35 тә Профсоюзларның Татарстан өлкә советы рәисе. 1935–37 дә Казан шәһәре хезмәт ияләре депутатлары советы рәисе. 1937 нең 17 июлендә кулга алына, ВКП(б) сафларыннан чыгарыла, репрессияләнә: 15 елга иреგеннән мәхрүм ителә. 1956 да аклана, КПСС сафларында торгызыла. 1956 дан пенсионер. 1931–37 дә ТАССР, СССР ҮБКлары һәм РСФСР БҮБК әгъзасы. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С а р к и н В. Аксёнов П.В. // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3; Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2000. Т. 1.

**АКСЍРИС** (Axyris), алабутачалар семьялыгыннан берьеллык үләннәр ыругы. Европа һәм Азиядә 7 төре үсә. ТРда бер төре — таҗ-


Аксубай посёлогы.
1. Банк бинасы. 1913; 2. Мәчет; 3. Изге Феодосий Тотемский чиркәве; 4. Техник һөнәр училищесе бинасы. 1910.

гөлчә А. (A. amaranthoides). Юл буенда, ачык сөзәклекләрдә очрый. 10–60 *см* озынлыкта, туры сабаклы. Яфраклары тар ланцетсыманнан алып йомыркасыман-ланцет формасында, чиратлашып урнашкан. Чәчәкләре вак, ямьсез. Июль-август айларында чәчәк ата. Җимеше 3–4,5 *мм* диаметрлы, шома элпә б-н капланган орлыкча. Орлыклардан үрчи. Бер үсемлек 3,5 мең орлык бирә. Чүп үлән.

**АКСУ́** (Кишер Аксуы) авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы чигендә. 2002 елда 708 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Ак Воложка, Камышлы исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, 8 җил тегермәне, тимерче алачыгы, мануфактура һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1157 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Әлки волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 175 ир заты; 1859 да — 876, 1897 дә — 1596, 1920 дә — 2073, 1926 да — 1790, 1938 дә — 1688, 1949 да — 1344, 1958 дә — 1140, 1970 тә — 1540, 1979 да — 1505, 1989 да — 900 кеше. Күренекле җәмәгать эшлеклеләре агалы-энеле Борһан, Галимҗан, Гыйльметдин һәм Шәһәретдин Шәрәфләр туып-үскән авыл.

*Әд.:* Буа ягым — Тау ягым — Буинские просторы. К., 2000.

**АКСУБА́Й**, шәһәр тибындагы посёлок, Аксубай р-ны үзәге. Татарстанның көньяк төбәгендә (Казаннан 210 *км*), Ульянов–Уфа тимер юлындагы Нурлат станциясеннән 58 *км* төньяктарак, Кече Сөлчә елгасы буенда урнашкан. 2006 елда 9,7 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 32,8%, чуашлар — 36,4%, татарлар — 29,4%) яши. Бау ишү, май з-длары; агач эшкәртү комб-ты; а.х. техникасы, төзү, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү пр-тиеләре; типография. 2 урта мәктәп, гимназия, балалар музыка мәктәбе, һөнәри уч-ще. Төбәк тарихын өйрәнү музее, кинотеатр, мәдәният йорты, 2 китапханә, район үзәк хастаханәсе. Мәчет, чиркәү. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий びуларак та билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау, бияләйләр тегү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да чиркәү, 1882 дә земство мәктәбе, 1910 да техник-һөнәри уч-ще була. 20 йөз башында А.да волость идарәсе урнаша. Банк, фельдшерлык пункты, ярма ярдыру тегермәне, 3 тимерче алачыгы, 7 вак-төякләр, 1 шәраб һәм 3 сыра кибете була; һәр елның июнендә — ярминкә, җомга саен базар эшли. 1920 гә кадәр А. — Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Октябрь р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан район үзәге, 1973 тән — шәһәр тибындагы посёлок. Халык саны: 1782 дә — 173 ир заты; 1859 да — 1016, 1897 дә — 1675, 1908 дә — 2015, 1920 дә — 2244, 1926 да — 2385, 1938 дә — 3401, 1949 да — 2850, 1958 дә — 2911, 1970 тә — 4751 кеше, 1989 да — 7,6 мең кеше.

**АКСУБА́Й АГА́Ч ЭШКӘРТҮ́ ЗАВОДЫ́** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 8 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Канау елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 31 кеше (чуашлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Аксубай р-нында, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан яңадан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 219, 1949 да — 102, 1970 тә — 50, 1989 да — 25 кеше.

**АКСУБА́Й РАЙОНЫ́**, ТРның көньягында урнашкан. Көнбатыш Кама аръягы икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1439,2 мең *км*². 20 авыл һәм шәһәр җирлеген, 78 торак пунктны берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Аксубай посёлогы. Халкы — 2006 елда 32,7 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 44,3%, татарлар — 38,5%, руслар — 16,6%). Район үзәгендә — 9,7 мең, авылларда 23 мең кеше яши. Халкының уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 23 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Чистай өязенә, 1920–30 елларда ТАССРның Чистай кантонына керә. Оешкан вакытында А. р.на 38 авыл советы, 42786 кеше (руслар — 15215, татарлар — 6664, башка халыклар — 20907) яшәгән 81 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 966 *км*², халкы — 38,6 мең кеше, 26 авыл советы, 72 торак пункт була. 1958 дә А.р.на таркатылган *Тельман районы* терр-ясенең бер өлеше керә. 1960 та район 1232,4 *км*² җир били, составында 17 авыл советы, 96 торак пункт исәпләнә. ТАССР да адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, А.р. 1963 нең 1 февралендә таркатыла, биләмәсе Октябрь р-нына бирелә. 1965 нең 12 гыйнварында район яңадан торгызыла, мәйданы — 1229 *км*², халкы — 46,2 мең кеше, 17 авыл советын, 87 торак пунктны берләштерә. 2005 нең 26 гыйнварында муниципаль район дип үзгәртелә. А.р. рельефы — биек булмаган тигезлек (биеклеге 125–150 *м*). Торф, мергель, комташ, балчык ятмалары бар. Олы Сөлчә елгасы һәм аның кушылдыгы Кече Сөлчә елгасы ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, көлсуланган кара, карасу соры һәм соры урман туфраклы. Терр-ясенең 20,3% урман б-н капланган. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Олы Сөлчә, Кече Сөлчә, Кече Чирмешән елгалары, *Биләр аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә



бронза дәверенә һәм *Имәнкискә культурасына* караган 60 тан артык археол. истәлек табыла. А.р. — нигездә, а.х. районы, терлекчелек тармагы үскән. 2006 да а.х. җирләре 100,9 мең *га* били, ш.и. 83,1 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, арыш, арпа, борчак, көзге бодай, солы игелә; шикәр чөгендере, бәрәңге үстерелә. 2006 да районда 19 а.х. пр-тиесе һәм 2 агрофирма: «Вамин-Аксу», җаваплылыгы чикләнгән «Продкорпорация» җәмгыяте исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә урнашкан. *Аксубай урман хуҗалыгы* эшли. А.р. терр-ясеннән Чистай–Нурлат автомобиль юлы уза. Районда 35 гомуми белем бирү мәктәбе (2006/07 уку елында 4925 укучы укый), ш.и. 4 башлангыч, 4 тулы булмаган урта мәктәп, 27 урта, музыка мәктәбе, һөнәр уч-щесе, 36 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 58 клуб, 39 китапханә, 169 урынлы 2 хастаханә эшли. Шәһәр тибындагы Аксубай посёлогында төбәк тарихын өйрәнү музее, Иске Кармәт авылында — Хәсән Туфан, Яңа Үзи авылында Газиз Кашапов музейлары бар. Татарча «Авыл таңнары», русча «Сельская новь», чуашча «Ял пурнасе» г-талары нәшер ителә.

*Әд.:* Волков В.И. Край родимый Аксубай. К., 1993.

**АКСУБА́Й ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, 2007 елга кадәр ТРның Милли музее филиалы, 2007 дән муниципаль район карамагында. 1987 нең 17 апрелендә ачыла. Алпавыт В.В.Марковников йортында (1904) урнашкан. Экспозиция мәйданы — 106 $м^2$, музей коллекцияләре 2 мең саклау берәмлеген тәшкил итә. Ул төбәкнең 16 йөз уртасыннан 20 йөз ахырына кадәрге тарихы б-н таныштыра. Палеонтология һәм геология коллекцияләре (соңгысы Аксубай битум чыганаклары урыннарын үзләштерү тарихына нисбәтле) бар. Этнография бүлеге шул төбәктә яшәүче татар, чуаш, русларның көнкүрешенә багышлана (хезмәт кораллары, йорт кирәк-яраклары, костюмнар, халыкның декоратив-гамәли сәнгать әйберләре). Рус нумизматикасының 1800–1909 га караган кечерәк коллекциясе урын алган. Музейның бер бүлеге Аксубай р-нында туып үскән язучыларга, галимнәргә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һ.б.ларга багышланган. Чуаш педагогы һәм язучысы Е.В.Елиевның торак бүлмәсе, мемориаль җиһазлары яңадан торгызылган. Ел саен Халыкара музейлар (18 май), Белем (1 сент.), посёлок (30 авг.), Өлкәннәр (1 окт.) көннәре, Батырлык дәресләре (4–7 май) уздырыла.





1. Аксубай төбәк тарихы музее;
2. Экспозициядән бер күренеш.

**АКСУБА́Й УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Аксубай, Чистай һәм Яңа Чишмә р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда оештырыла. 1969–92 дә Аксубай урман комб-ты. 2006 ның 1 гыйнварына урман фондының гомуми мәйданы 29359 *га*, ш.и. урман б-н капланган мәйдан — 27200 *га*. 3 урманчылыкны үз эченә ала: Аксубай — 8831 *га*, Ибрай — 8569 *га*, Чабаксар — 11959 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Аксубай посёлогында. Эшләүчеләр саны — 237 кеше. 1 нче төркем урманнар, нигездә, саклаучы урманнар 2701 *га* мәйданны били. 2 нче төркем — файдаланыла торганнары — 26658 *га*. Урман культуралары 3525 *га* мәйданны алып тора. Токым составы ягыннан йомшак яфраклы урманнар күпчелекне тәшкил итә (урман б-н капланган мәйданның 81%): усак (мәйданы 15477 *га*, уртача 19 яшь, агач запасы 1814,9 мең $м^3$), каен (2291 *га*, 29 яшь, 238,6 мең $м^3$), юкә (3839 *га*, 48 яшь, 389,5 мең $м^3$). Каты яфраклы токымнарны (урман мәйданының 10%) 2262 *га* мәйдандагы биек һәм тәбәнәк кәүсәле имәннәр һәм 405 *га* мәйдандагы өрәңге тәшкил итә. Ылыслы агачлар, нигездә, кулдан утыртылган, урман мәйданының 9% били; алардан: нарат — 2057 *га*, уртача яше — 25, агач запасы 260,1 мең $м^3$; чыршы — 475 *га*, карагай — 7 *га*. Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 50,6%, урта яшьтәгеләре — 28,8%, өлгереп килүчеләре — 16,6%, өлгергәннәре һәм картайганнары — 4%. Күпчелекне тәшкил итүче урман типлары: өрәңге-юкәле имәнлекләр (87,1%), чикләвек куаклы наратлыклар (4,7%) һәм катнаш урманнар (3,2%). Уртача агач запасы 107 $м^3/га$, бер елга уртача гомуми артым 119,2 мең $м^3$. Урман кисүнең исәпләнгән күләме 48,5 мең $м^3$. Урманны карау максатыннан чистарту эшләре 922 *га* мәйданда башкарыла, шуның б-н бергә 8,6 мең $м^3$ агач әзерләнә. Ел саен 115 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла. 65 *га* мәйданда урман утыртыла. 25 *га* мәйданда — а.х. җирләренең ерым-сызалы урыннарында агачлар утыртыла. А.у.х.нда сәнәгать өчен кирәкле продукция һәм халык хуҗалыгы товарлары (такта, бүрәнә кебек агач материаллары, арболит блоклары) җитештерелә. Югары казанышлары өчен А.у.х. хезмәткәрләре В.В.Мастриков һәм П.С.Баталинга РФнең атказ. урманчысы, И.Ф.Крайновка ТРның атказ. урманчысы, Е.Ф.Емельяновага ТРның атказ. икътисадчысы дигән мактаулы исемнәр бирелә.

*В.В.Мастриков, Т.В.Мартынова.*

**АКСУМЛА́** елгасы, Көнбатыш Кама арьягында, Олы Чирмешәннең сул кушылдыгы. Озынлыгы 22,4 *км*, бассейнының мәйданы 103,8 $км^2$. Нурлат р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Биккол авылыннан 1,5 *км* төньяктарак, тамагы Якушкино авылыннан 5 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 130 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. А.ның су җыелу терр-ясе урмансыз диярлек. А. елгасының 0,2 дән алып 3,3 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Җәен, вак күлләр системасына әверелеп, үрге агымында һәм Якушкино авылыннан түбәндәрәк елга кибә. Ел дәвамында суы бик каты (9–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада күләме 400 мең $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**АКСУМЛА́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 13 *км* көнбатыштарак, Аксумла елгасы буенда. 2002 елда 542 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1782 дән мәгълүм. Башта — Кече Аксумла, соңрак Олы Аксумла дип атала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 4 тимерчелек алачыгы, 2 җил, 3 ярма ярдыру тегермәне, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2014 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркин волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 824, 1897 дә — 838, 1920 дә — 979, 1926 да — 681, 1938 дә — 701, 1949 да — 664, 1958 дә — 619, 1970 тә — 673, 1979 да — 539, 1989 да — 519 кеше.

**АКСЫРГА́К** (Veratrum), лаләчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 45 ләп төре билгеле, Евразиянең һәм Төньяк Американың уртача һәм субтропик поясларында таралганнар. ТРда бер төре Лобель А. (V.lobelianum) күбесенчә көньяк р-ннарда очрый. Тугай болыннарында, дымлы урман аланнарында, урман буйларында үсә. Тамырчасы күпсанлы шнурсыман тамырлар б-н калынайган, юантык, кыска. Сабагы туры, юан, 100–150 *см* озынлыкта. Яфраклары чиратлашкан, эре, киң эллипс формасында, озынча җыерчыклы. Чәчәкләре күзгә чалынмый, саргылт яшел төстә, сабак очындагы озын себеркәчкә җыелган. Җимеше — өч аерылы коры тартмачык. Орлыклары җил б-н оча. Июнь-июльдә чәчәк ата. Җимешләре август аенда өлгерә. Тамырчасында алкалоидлар, гликозид, сумала, дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында спиртлы төнәтмәсе һәм сулы төнәтмәсе ялкынсыну авыруларында авыртуны басу өчен кулланыла. А. — агулы үсемлек, печәнлек һәм көтүлекләрдәге иң агулы

үсемлекләрдән санала, аның б-н йорт хайваннары агулана.

**АКСЯ́НЦЕВ** Моисей Израилевич (1897, Могилев губ., Сеннинск өязе Черея а. — 10.1.1965, Казан), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1937), проф. (1935). 1918 елда Воронеж ун-тының мед. ф-тына укырга керә. Тиздән армиягә чакырыла һәм Казанга Респ-каның Запас Армиясенә җибәрелә. 1921 дә хәрби хезмәтне тәмамлый, Казан ун-тының мед. ф-тына кабул ителә. 1923 тә проф. М.Н.Чебоксаров җитәкчелегендәге ординатурада укый башлый. 1926 да Германиягә командировкага җибәрелә. 1929–30 да Казан мед. ин-тында. Бер үк вакытта 1928–29 да Казан туберкулёз ин-тын оештыручы һәм аның директоры. 1930 дан Казан ГИДУВында, 1933–37 дә аның ректоры, бер үк вакытта 1935–37 дә ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары урынбасары. Репрессияләнә (к. «*Троцкийчыларның Контрреволюцион-террористик оешмасы» эше*). 1946–47 дә Хабаровск крае хастаханәсендә дәвалау бүлеге мөдире. 1947 дән Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында физиол. лаб. (Казан) мөдире. Озакламый яңадан Красноярск краена сөргенгә озатыла: 1949–54 тә Төньяк Енисей р-ны хастаханәсенең терапия бүлеге мөдире. 1954 тә аклана; Казан ГИДУВының экспериментал хирургия бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Тикшеренүләре нурланыш авыруы алган организмда лимфа системасы функциясен өйрәнүгә, туберкулёз иммунологиясе һәм патохимиясенә, травматологиягә һәм савыктыру хирургиясенә карый.

Х е з м.: Гематоэнцефалический барьер и его роль в антидифтерийном иммунитете. К., 1936.

*Әд.:* Казанская медицинская академия: 75 лет (1920–1995). К., 1997.

**АКТАЖИ́К** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Бужай елгасы буенда. 2002 елда 159 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 18 йөздә А. тирәсендә бакыр руднигы була. 1920 елга кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Кураков волостена керә. 1921 дән ТАССРның Алабуга, 1928 дән — Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р- нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир заты; 1859 да — 245, 1887 дә — 372, 1911 дә — 455, 1920 дә — 385, 1926 да — 381, 1938 дә — 363, 1949 да — 279, 1958 дә — 301, 1970 тә — 360, 1979 да — 265, 1989 да — 171 кеше.

**АКТА́Й** (Ахтай) елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Иделнең сул кушылдыгы. Озынлыгы 75,3 *км*, бассейнының мәйданы 1016 *км*². Әлки, Алексеев һәм Спас р-ннары терр-ясеннән ага. Елга башы Әлки р-ның Югары



Актай елгасының урта агымы.

Матак авылы, тамагы Спас р-нының Вожи посёлогы янында. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Елганың су җыелу урыны төньяк-көнбатышка авышкан һәм җиңелчә бүлгәләнгән тигезлектән гыйбарәт. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 9 %, сөрү җирләре 65 %. Елга үзәне асимметрияле, киңлеге үрге агымында 60 *м* дан тамак өлешендә 2 *км* га кадәр. Елга ярлары текә (20–60°), кайвакыт 8 *м* биеклеккә җитеп, терраса киртләчләре хасил итә. Сул кушылдыкларының үрге агымында карст процесслары күзәтелә. А. елгасының 1 дән алып 25 *км* га кадәр озынлыктагы 13 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Чаллы (12 *км*), Ромодан (15 *км*) — уң кушылдыклары, Салман (25,3 *км*), Сушка (17,7 *км*) — сул кушылдыклары. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,46 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Елга режимын күзәтү Караваево авылы янындагы гидрологик постта үткәрелә (1935 тән). Караваево авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәнешләре 4 *м* чамасы (макс. — 6 *м*). Язгы ташу март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана, бу вакытта еллык су агымының 80–90%ы үтә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Караваево авылы янында уртача күпьеллык су чыгымы 2,1 *м*³*/с* тәшкил итә. Макс. су чыгымы 480 *м*³*/с*. Су агымының торышы тотрыклы түгел, түбән. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,442 *м*³*/с*. Җәйге саегу кайвакыт яңгыр ташкыннары б-н үзгәрә, әмма күп кенә урыннарда елга кибә, моның сәбәбе җир асты суларының җитәрлек булмавына бәйле. Кышкы саегу боз күренә башлау вакытында, гадәттә, ноябрьнең беренче яртысында башлана. Кыш азагына бозның калынлыгы 90 *см* га җитә, макс. калынлыгы 155 *см* (1969). Суы бик болганчык (1200 *г/м*³ ка кадәр). Елга утырмаларының уртача еллык күләме 82 мең *т*. Утырмаларның уртача еллык модуле 120 *т/км*² (Караваево посты). Суы гидрокарбонат-кальцийлы, язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. А. елгасы бассейнында гомуми күләме 6,9 млн. *м*³ булган 8 буа бар. Суы сугару һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**АКТАНЫ́Ш** авылы, Актаныш р-ны үзәге. Башкортстан Респ-касы чигендә, Агыйдел елгасының түбән агымы буенда, Казан–Екатеринбург тимер юлындагы Камбарка станциясеннән 66 *км* көньяктарак, Казаннан 381 *км* ераклыкта. 2002 елда 8148 кеше (татарлар) яши. Майсызландырылган коры сөт җитештерү з-ды, а. х. техникасы, төзү пр-тиеләре; типография, 2 урта мәктәп, балалар музыка мәктәбе, сәнгать мәктәбе, һөнәри уч-ще. Төбәк тарихын өйрәнү музее, 2 мәдәният йорты, 4 китапханә, район үзәк хастаханәсе. Мәчет. 1715 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинник катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә, юлаучылар йортлары тота, пристаньнарда эшли. 20 йөз башында А.та земство почта станциясе урнаша, 1846 елдан мәчет мәгълүм, кыз һәм ир балалар өчен мәктәпләр эшли. Һәр ел сентябрьнең соңгы атнасында ярминкәләр уздырыла, атнага бер тапкыр базар эшли. 1917 гә кадәр авыл җәмәгатенең имана җире 1943 дис. тәшкил итә (моннан тыш, аның Уфа губернасының Бөре өязе Кыргыз волостенда 1320 дис. җире була). 1920 гә кадәр — Уфа губернасының Минзәлә өязе Актаныш волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан район үзәге. 1988

Актаныш авылы. 1. Җиңү паркы; 2. Район хакимияте бинасы; 3. Автовокзал күренеше.









Актаныш авылының иске өлеше күренеше.

нең 29 июленнән 1991 нең 21 гыйнварына кадәр шәһәр тибындагы посёлок статусында була. Халык саны: 1816 да — 378 ир заты; 1884 тә — 906, 1897 дә — 1243, 1906 да — 1292, 1913 тә — 1417, 1920 дә — 1739, 1926 да — 1274, 1938 дә — 1874, 1949 да — 1699, 1958 дә — 2168, 1965 тә — 2242, 1970 тә — 2842, 1979 да — 4446, 1989 да — 6814 кеше.

**АКТАНЫ́Ш НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, ТР-ның төньяк-көнчыгыш өлешендә, Актаныш р-ны терр-ясендә. 1960 елда ачылган, 1995 тән бирле эшкәртелә. Тектоник яктан Татар гөмбәзенең көньяк өлешендә, төньяк-көнчыгышка караган битләүгә туры килә. Чыганак составында түбән карбонның 2 файдалы горизонты (Тула һәм төп катлам булган Бобрики) билгеле; аларның һәркайсында гөмбәз тибындагы катламлы икешәр нефть ятмасы бар. Пласт-коллекторлар калынлыгы 1 *м* дан 16,4 *м* га кадәр булган комташ һәм алевролитлардан тора. Нефть җыела торган урыннарның биеклеге 7–15 *м*, аларда нефть ятмаларының калынлыгы 1–13 *м*. Нефтьле катламның калынлыгы Тула горизонтында 1,5 *м*, Бобрики горизонтында — 4,9 *м*. Катламнар уртача 1356 *м* тирәнлектә ята. Нефть күкертле (4%), парафинлы (3,4%), үзлелеге югары (92,8 *МПа·С*). Газ факторы 9,3 $м^3/т$, пласт басымы 11 *МПа*, нефть дебеты тәүлеккә 10,6 *т*. Нефть чыгару тыгыз суэтем режимында алып барыла. Чыганак башлангыч үзләштерү хәлендә, нефть чыгару елдан-ел арта бара. Еллык макс. чыгарылышы 160 мең *т* тирәсе (1999). Нефть чыгару эшләрен «Азнакайнефть» нефть-газ чыгару идарәсе алып бара.

*Г.С.Габделмәҗитова.*

**АКТАНЫ́Ш РАЙОНЫ́**, ТРның көнчыгышында урнашкан, Башкортстан Респ-касы б-н чиктәш. Төньяк-көнчыгыш Кама буе икътисади р-нына керә. Мәйданы — 2037,7 $км^2$. 28 авыл җирлеген, 87 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Актаныш авылы. Халкы — 2006 елда 31,7 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 96,6%). Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 $км^2$ га 16 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Уфа губернасының Минзәлә өязенә, 1920–30 елларда ТАССРның Минзәлә кантонына керә. Оешкан вакытында А.р.на 53 авыл советы, 54813 кеше (шулардан татарлар — 52474, руслар — 1494, башка халыклар — 845) яшәгән 98 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1298 $км^2$, халкы — 41,9 мең кеше, 27 авыл советы һәм 77 торак пункт була. 1959 да А.р. составына таркатылган *Калинин районының* бер өлеше керә. 1960 та районның 2044,5 $км^2$ биләмәсе була, составында 25 авыл советы, 129 торак пункт исәпләнә. ТАССР да адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә А.р. таркатыла, терр-ясе Минзәлә р-нына бирелә. 1965 нең 12 гыйнварында район яңадан торгызыла, мәйданы — 2019 $км^2$, халкы — 52,6 мең кеше, 25 авыл советын, 112 торак пунктны берләштерә. 1940–98 дә А.р.нда Дәрбиш посёлок советы була. 2005нең 26 гыйнварында А.р. муниципаль район дип үзгәртелә. Районның рельефы — калкулыклы тигезлек. Биеклек кискен үзгәрә: Кама һәм Агыйдел үзәннәрендә — 60 *м* чамасы, көньякта — 160–235 *м*. Кама елгасы (Түбән Кама сусаклагычы), Агыйдел һәм аның кушылдыгы Сөн елгалары ага. Район күлләргә бай. Төньяк-көнбатышта *Көләгеш сазлыгы* бар. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, көлсуланган һәм кара туфраклы; районның үзәк өлешендә соры урман туфраклы. Терр-ясенең 4,9%ы урман б-н капланган. Нефть, торф, балчык, ком, комлы чуерташ ятмалары бар. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Ык һәм Сөн елгалары, *Казылма күл*, *Кама-Ык аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә таш һәм бронза дәверләренә караган 100 дән артык археол. истәлек табыла. А.р. — нигездә, а.х. р-ны. Кырчылык, үсемлекчелек, терлекчелек тармаклары нык үскән. Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак игелә; бәрәңге үстерелә. 2006 да а.х. җирләре 110,5 мең *га* били, ш.и. 90,8 мең *га* сөрүлек җир. 2006 да районда 28 а.х. пр-тиесе, ш.и. 1 колхоз, 12 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, 15 а.х. товарлары җитештерү кооперативы исәпләнә. Район үзәгендә сәнәгать пр-тиеләре эшли. А.р.ның көньягыннан Казан–Уфа автомобиль юлы уза. Агыйдел буенда Әҗәкүл пристане урнашкан. Районда 68 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 4341 укучы) бар, ш.и. 36 башлангыч, 18 тулы булмаган урта, 14 урта мәктәп; 1 музыка мәктәбе һәм 9 филиалы, 40 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 68 клуб, 38 китапханә, 5 хастаханә эшли. Татарча «Актаныш таңнары» район г-тасы нәшер ителә.




**АКТАНЫ́Ш ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, Актаныш авылында, 1977 елда җәмәгатьчелек тәртибендә ачыла. Музейны оештыруда М.Г.Атнагулов, Г.М.Сәетгалиева, Д.М.Ханнанова, М.Г.Газетдинова, И.Г.Гарипов башлап йөриләр. Баштарак «Актаныш авылы мәдәнияте комплексы»нда 60 $м^2$ лы бүлмәдә урнаша. 1987 дә музей ябыла. 1993 тән ТРның Милли музее ф-лы буларак яңадан эшли башлый. 2005 тән элек районның кулланучылар җәмгыятенә караган 522,1 $м^2$ мәйданлы бинаны били (1 нче катның бер өлеше, 2 нче һәм 3 нче катлар). Коллекция 8000 саклау берәмлегеннән тора. Экспозиция 10 залда урнаштырыла, ике бүлектән тора: «Актаныш җире табигате» һәм «Төбәкнең борынгыдан бүгенге көнгәчә тарихы». Табигатькә караган бүлек җирле флора һәм фауна үрнәкләре б-н таныштыра. Экспозициянең Актаныш р-нында туган күренекле шәхесләргә багышланган бүлегендә ТР Президенты М.Ш.*Шәймиев* (аерым залда), шагыйрьләр Г.Г.*Афзал*, Н.Г.*Баян*, Соц. Хезмәт Геройлары Г.Х.*Латыйпова*, С.Г.*Гыйльманова*, җырчы — Ә.А.*Авзалова*, актёр М.И.*Мутин* һ.б.ларның шәхси әйберләре, документлары һәм фотосурәтләре күргәзмәгә куелган. Ш.у. төбәкнең сәнгать эшлекләләре — рәссам А.А.Хәбибуллин һәм скульп. З.Р.*Басыйров*ның эшләре урын алган.

Музей ел саен Халыкара музейлар (18 май), Ватанны саклаучылар (23 февр.) Халыкара хатын-кызлар көннәрен (8 март) билгеләп уза.

**АКТАНЫШБА́Ш** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 3 *км* көнбатыштарак. 2002 елда 298 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек.



Актаныш төбәк тарихы музее. 1. Татар өе күренеше (19 йөз ахыры – 20 йөз башы); 2. Экспозициянең Ә.А.Авзаловага багышланган фрагменты; 3. Президент М.Ш.Шәймиевнең тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган зал.

Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1744 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә А. халкы башкорт-вотчинниклар катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, урман хәзерләү кәсепчелеге б-н шөгыльләнә. Мәчет турында беренче тапкыр 1847 дә телгә алына. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1570 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү чорында авылда «Актанышбаш» к-зы оештырыла. 1950 дән А. — «Урал», 1958 дән «Үзәк» к-зында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Такталачык волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 140, 1859 да — 469, 1870 тә — 466, 1884 тә — 585, 1897 дә — 632, 1906 да — 648, 1913 тә — 305, 1921 дә — 373, 1926 да — 330, 1938 дә — 320, 1949 да — 315, 1958 дә — 350, 1970 тә — 341, 1979 да — 319, 1989 да — 224 кеше.

**АКТА́У** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы буенда. 2002 елда 204 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Покровский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1735 тә православие приходы барлыкка килә, 1834 тә таштан Покрау чиркәве (архит-ра истәлеге) салына. 19 йөздә керәшен татарлар б-н бергә руслар да яши. 20 йөз башында земство мәктәбе, Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 3 җил, 2 су тегермәне, ярмаяргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2813 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр А. Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванай волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 169 ир ат; 1859 да — 689, 1897 дә — 1095, 1908 дә — 1285, 1920 дә — 1319, 1926 да — 1064, 1938 дә — 841, 1949 да — 491, 1958 дә — 434, 1970 тә — 350, 1979 да — 246, 1989 да — 202 кеше.

**АКТА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Дала Зәенең сул кушылдыгы. Озынлыгы 10,2 *км*, бассейнының мәйданы 32,1 *км*$^2$. Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Дербеден авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Рус Акташы посёлогы янында. Елга башының абс. биеклеге 250 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 31%. А. ның 1 дән алып 3 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*$^2$. Туклануы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,3–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 125 *мм*, ташу агымы катламы 65 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана, ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,072 *м*$^3$/*с*. Ел дәвамында суы бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Су ресурслары хуҗалык максатларында кулланыла.

**АКТА́Ш РАЙОНЫ́**, ТАССР да. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — шәһәр тибындагы Рус Акташы посёлогы. 1920 гә кадәр район терр-ясе — Уфа губернасының Минзәлә өязенә, 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонына керә. Оешкан вакытында А.р.на 47 авыл советы, 52025 кеше (руслар — 39389, татарлар — 7071, башка халыклар — 5565) яшәгән 124 торак пункт керә. 1935 нең 10 февралендә ТАССР да адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, А.р.ның бер өлеше Зәй һәм Шөгер р-ннарына бирелә. 1940 та мәйданы — 1462 *км*$^2$, халкы — 36,9 мең кеше, составында 30 авыл советы, 82 торак пункт була. 1944 нең 19 ноябрендә А.р.ның бер өлеше яңа оештырылган *Ямаш районына* бирелә. 1956 да район 942 *км*$^2$ җир били, аңа 16 авыл советы, 56 торак пункт керә. 1959 ның 26 мартында А.р. таркатыла, биләмәсе Әлмәт, Зәй, Сарман һәм Беренче Май р-ннарына бүлеп бирелә.

**АКТА́Ш УПКЫНЫ́**, Көнчыгыш Кама аръягындагы карст упкыны, Дала Зәе елгасы үзәнлегенең сулъяк сөзәклегендә, Әлмәт р-нының Кәләй тимер юл станциясе посёлогының көнчыгыш читендә, 148 *м* абс. биеклектә, Дала Зәе елгасы биеклегеннән 70 *м* югарырак. 1939 елның 7 августында убылып, тракторчысы б-н тракторны үзенә суырып хасил була. Аның барлыкка килүе түбән Пермь известьташлары, доломитлары һәм гипсларының җир асты сулары б-н юылуы һәм югарыда яткан токымнарның куышлык барлыкка китерүе, шуннан соң җимерелеп төшүе б-н бәйле. А.у. ның баштагы тирәнлеге 52 *м*, диаметры 4–5 *м*. 1960 еллар ахырына тирәнлеге 35 *м* га кадәр кими, диаметры 25 *м* га кадәр киңәя. Цилиндр формасында, текә читле. Чокыр төбендә җир асты сулары б-н туенучы 15 *м* тирәнлектәге күл хасил була. Суы үтә күренмәле, нык минеральләшкән (630 *мг/л*),



Акташ упкыны.

каты (7 *мг-экв/л*). А.у. карст процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән упкынның бердәнбер үрнәге буларак фәнни яктан әһәмиятле. ТРның табигать истәлеге (1978).

*Әд.:* Ступишин А.В. Равнинный карст и закономерности его развития на примере Среднего Поволжья. К., 1967.

*А.П.Дедков.*

**АКТЁРЛА́Р ЙОРТЫ́**, театр хезмәткәрләренең проф.-иҗади берләшмәсенә хезмәт күрсәтү өчен Театр эшлеклеләре берлеге каршында Казанда төзелгән оешма. А.й. 1941 елның февралендә ачыла, башта Яшь тамашачылар театры бинасында, аннан соң 1942 нең көзеннән элеккеге «Гранд-отель» кунакханәсе (хәзер торак йорт) бинасында урнаша. 1968 дә Бөтенсоюз театр җәмгыяте президиумы карары нигезендә Щапов урамында үзенә аерым бина салына (арх. А.А.Спориус, В.А.Петров, М.Г.Хәйруллин). Актёрлар, режиссёрлар, театр рәссамнарының проф. укуларын, иҗади конференцияләр, семинарлар, спектакльләр турында фикер алышулар оештыра, театр фестивальләре уздыруда катнаша. Театр эшлеклеләренең тамашачылар б-н иҗади очрашуларын, төрле мәдәни чаралар үткәрү хезмәтен үти. Мәдәни-агарту эшчәнлеге алып бара. 2003 тә Казан А.й.на М.Х.Сәлимҗанов исеме бирелә. Казанда А.й. каршында даими эшләүче секцияләр, сәхнә ветеранна-

ры, иҗат итүче яшьләр, театр тәнкыйтьчеләре, яшь драматурглар берләшмәләре, А.й. советы эшләп килә. Ш.у. китапханә һәм архив бар, анда ТРның Театр эшлеклеләре берлеге тарихына караган документлар саклана. Казан А.й.нда үткәрелгән чараларда Ю.А.Завадский, Н.П.Акимов, В.А.Плучек, С.В.Образцов, В.С.Лановой, С.А.Кочарян кебек күренекле театр эшлеклеләре, Б.Ш.Окуджава, Р.И.Рождественский, Д.С.Самойлов кебек шагыйрьләр, композитор Д.Ф.Тухманов һ.б.лар катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында Кызыл Армия офицерлары, партизаннар, антифашист язучылар В.Бредель, Э.Вайнер, Ж.Р.Блок б-н очрашулар үткәрелә.

*Әд.:* Традиции театрального братства // Казань. 2002. № 3–4.

**АКТЁРЛЫ́К СӘНГАТЕ́**, иҗат төре, актёрның сәхнә образы тудырып, аны драма, опера, балет спектакльләрендә гәүдәләндерүе. А.с.нең үзенчәлеге шунда: актёр образны тавышы, мимикасы, хәрәкәтләре б-н тудыра, сәхнә образы иҗат процессында гына яши, спектакль тәмамлангач юкка чыга. А.с.нең идеологик һәм мәгънәви нигезе булып драма тора (муз. спектакльдә либретто һәм муз. партитура), әмма үзенең башлангыч чорында А.с. импровизация формасында яшәгән, актёрлар сценарий нигезендә барлыкка килгән текстны сөйләгәннәр. Татар халык иҗатында *шамакайлар* сәнгате, һәвәскәр спектакльләрдә уйнаучы *шәкертләр* сәнгате, рус халык иҗатында көлдерүчеләр (скоморохлар, мәзәкчеләр) сәнгате шундыйлардан. А.с. уен-көлкеле йолалардан килеп чыга, һәм аларда катнашучылар барысы да актёрлар (фр..acteur, лат. actor — хәрәкәт итүче, эшлекле) дип атала. Һөнәргә өйрәнү аерым бер-берсеннән тәҗрибә алу юлы б-н бара, ә 16 йөздә А.с.нә монастырьда, аннан соң дөньяви театр мәктәпләрендә өйрәтә башлыйлар. Пётр I боерыгы б-н 1721 елда басылып чыккан «Рухани коллегия регламенты» нигезендә Казан руханилар семинариясендә эшләгән педагог һәм драматург В.Я.Свентицкий 1723–28 дә семинария укучыларын халыкка «комедия акцияләре» күрсәтергә өйрәтә. Ләкин 19 йөз дәвамында Казан шәһәр театрында уйнаучы актёрларның күпчелеген махсус белеме булмаган һәвәскәрләр тәшкил итә. 19 йөз ахырында гына театрга Петербург һәм Мәскәү театр мәктәпләрендә укыган актёрлар килә башлый. Казанда да А.с.нә проф. нигездә өйрәтүче театр мәктәпләре, драма курслары, студияләр ачыла. Җәмгыять тормышын чагылдыруны бурыч итеп куйган А.с. җәмгыятьнең идеологик һәм эстетик ихтыяҗына һәм зәвыгына бәйле рәвештә өстенлек иткән эстетик юнәлешләрнең таләпләренә буйсынып үзгәрә. Классицизм, сентиментализм, романтизм чорлары А.с. шул чорларга хас үзенчәлекләре б-н аерылып тора. Әмма 1830 еллар ахырыннан А.с.нә тормышны дөрес чагылдыру таләпләре куела. А.с. тормышчанлык принцибына йөз тотып корыла башлый. А.с.ндә бу принципны катгый һәм эзлекле үткәрүче М.С.Щепкин була, 1830 еллар ахыры — 1840 еллар башында аның Казанда ясаган чыгышлары сәхнәдә реализм принцибын ныгытуда мөһим роль уйный. Казан театрларында төрле елларда уйнаган Н.К.Милославский, П.М.Медведев, П.А.Стрепетова, М.И.Писарев, Е.Б.Пиунова-Шмидгоф, В.И.Качалов, А.И.Каширин, Н.И.Собольщиков-Самарин, соңрак Ф.В.Григорьев, Г.П.Ардаров, Е.Е.Жилина, Н.И.Якушенко, Е.В.Лисецкая, С.Айдаров, Х.Әбҗәлилов, Ф.Ильская, З.Солтан, В.А.Чернецкий, М.П.Неменко-Бабковская, В.И.Улик, Ю.С.Федотов, Ш.Әсфәндиярова, Е.А.Кузин, Г.Ибраһимова, Ф.Халитов, Г.Шамуков һ.б. артистлар иҗатында реализм принцибы үсеш ала. Актёрның осталыгын күзаллау аның рольне башкарганда иҗтимагый фикерне, алдынгы идеяләрне җиткерүенә, сәхнәдә характерның аерым бер тибын гына түгел, бәлки реалистик гәүдәләндерү чарасы аша аның артында торган социаль күренешне чагылдыра алу сәләте б-н дә бәйләп карала башлый. А.с.нең иҗтимагый әһәмияте аны бәяләү критериенә әверелә; актёр — үз чорының, үз буынының алдынгы гуманистик идеяләрен чагылдыручы. А.с. тормышка макс. якынлаша, актёрдан сәхнәдәге драматик вакыйгага карата булган эмоциональ кичерешләрнең чынлык иллюзиясен тудыру сорала. Шул ук вакытта А.с.нең үсешен билгеләүче реалистик принциплар аерым характерларны яки тормыштагы вакыйгаларны сурәтләгәндә күпмедер дәрәҗәдә романтик күтәренкелеккә дә урын калдыра. Бу, мәс., Н.К.Милославский яки Г.П.Ардаров кебек кайбер актёрларның иҗатына аерым, үзенә бер төрле сәнгатьлелек өсти. Татар театрында А.с. башта халык *чичәннәре* һәм шамакайлар иҗатында, шәкертләр театрында үсеш ала. 19 йөз азагы — 20 йөз башында татар интеллигенциясе арасында өй театрлары барлыкка килә. Аларда артистлар сыйфатында студентлар, гимназия укучылары, мәдрәсә шәкертләре, сәүдәгәрләр катлавыннан чыккан алдынгы карашлы яшьләр, ш.и. кызлар да чыгыш ясый. Киң катлау халыкка күрсәтелгән шундый спектакльләрнең берсе — шамакайлар һәм шәкертләрнең импровизациягә корылган сәнгатеннән аермалы буларак, Европа, аерым алганда рус театры үрнәгендә формалашканы — татар проф. театрының (к. *Театр*) башлангычы булып исәпләнә. Татар А.с.нең формалашуы, рус театрындагы кебек үк, тормышны реалистик чагылдыру, гәүдәләндерелгән персонажның эчке дөньясына үтеп керү юлыннан бара. Г.Кариев, З.Солтанов, Г.Болгарский, Б.Тарханов кебек актёрлар, зур социаль көчкә ия булган һәм ышандырырлык образлар тудырып, яңача гәүдәләндерүгә һәм чын тормыш чынбарлыгына омтылып, үз иҗатларында төп игътибарны дөреслеккә охшатып иҗат итүгә биргәннәр. С.Гыйззәтуллина-Волжская, М.Мутин, Ф.Ильская, киресенчә, театрдан эмоциональ тәэсирлелек, хисләр күтәренкелеге таләп итеп, төп игътибарны геройларның эчке дөньясын ачуга юнәлтәләр. Татар театрында алар иҗаты тәэсирендә А.с.нең героик-романтик мәктәбе формалаша. Соңрак, мәс., Х.Әбҗәлилов кебек кайбер актёрларның иҗатында бу ике юнәлеш бергә кушыла. Татар актёрлары үз сәнгатьләре б-н алдынгы идеяләр алып киләләр, шул рәвешле татар милләтенең үзаңы үсү, үз-үзен раслау, җәмгыятьне төрле юк-барга ышанулардан арындыру, башка халыкларның, барыннан да элек Европа халыкларының мәдәниятләрен якынайту процессында зур роль уйныйлар. Татар актёрлары, рус сәнгате казанышларын, ш.и. К.С.Станиславский тәгълиматын иҗади үзләштереп, сәнгатьлелекнең традицион чараларын кулланып, үзенчәлекле, якты һәм тирән, заманча сәнгать формалаштырып, А.с.нә милли үзенчәлек бирәләр. К.Тинчурин, Ш.Шамилский, Х.Уразиков, К.Шамил, Камал III, Г.Булатова, Г.Шамуков, Ф.Халитов, Ш.Биктимеров, Р.Җиһаншина, Ш.Әсфәндиярова, В.Минкина, Р.Таҗетдинов, Р.Шәрәфиев, Ә.Шакиров, Н.Дунаев, Н.Ихсанова, А.Гайнуллина, И.Хәйруллин кебек актёрларның иҗаты татар милли театрының үзенчәлекле һәм кабатланмас культурасын формалаштыра һәм дөнья театр сәнгатен баета.

*Әд.:* Татар Совет театры; К., 1975; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958; Илялова И. Театр имени Камала. К., 1986; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991; Театральная энциклопедия. М., 1963. Т. 2.

*Ю.А.Благов, И.И.Илялова.*

**АКТИ́В ӨСЛЕКЛЕ́ МАТДӘЛӘ́Р**, фәзаара бүленү өслегендә җыелып (адсорбланып), өслек тартылышын киметергә сәләтле матдәләр. Фәнгә термин П.А.*Ребиндер* тарафыннан кертелә (1925). Үзлекләре буенча капма-каршы ике өлештән торган: поляр (суга карата гидрофиль) һәм поляр булмаган (гидрофоб) молекулалы кушылмалар типик А.ө.м. булып тора. Аларның һәркайсы үзара бәйләнештәге фәзаларның берсендә яхшы эри, ә икенчесендә эреми. Гидрофиль төркем (гидроксиль, карбоксиль, амино- һ.б.), актив өслекле матдә молекуласын поляр мохиттә тотып калып, аны суда эретә, гидрофоб төркем (гадәттә, углеводород чылбырлары) поляр булмаган фәзада эретә, ягъни молекулаларның поляр (су) мохитеннән поляр булмаган мохиткә күчү тенденциясен билгели. А.ө.м., чикнең фәзаара өслекләрендә адсорбланып, ориентлашкан молекулаларның мономолекуляр катламын барлыкка китерәләр һәм җисем өслекләренең молекуляр табигатен, аларның башка җисемнәр б-н үзара тәэсир итешү шартларын үзгәртәләр. Химик табигате буенча А.ө.м.нең гидрофиль төркемнәрен анион, катион, амфолит һәм ион булмаган төрләргә бүләләр. А.ө.м.не сәнәгый җитештерүнең гомуми күләмендә әйдәп баручы урынны анион матдәләр — карбонат к-тасы тозлары (сабыннар), алкилсульфатлар, алкилсульфонатлар, фторуглеродлы сульфонатлар һ.б. тәшкил итә. Ион булмаган А.ө.м. — алифатик спирт һәм кислоталар, алкилфенолларның полиоксиэтилен эфирлары киң кулланыла. Азрак күләмдә катион (алкиламин, алкилпиридин чыгарылмалары, дүртенчел аммоний кушылмалары һ.б.), амфолит (алкиламинокарбон к-талары, алкилбетаиннар, алкилимидазолин чыгарылмалары һ.б.) А.ө.м. файдаланыла, әмма аларны куллану өлкәсе киңәя бара. Югары молекуляр (аксымнар, целлюлоза чыгарылмалары, лигносульфон к-талары һәм аларның тозлары, синт. полиэлектролитлар һ.б.), кремнеорганик, перф-

торланган, суда һәм майда эрүчән А.ө.м.не аерып өйрәнәләр. А.ө.м. эрегәндә хасил булган системалар тибына карап, эрүчән һәм коллоидларга бүленәләр. Коллоид А.ө.м. эремәләрдә тупланыш көчәйгәндә (мицелла хасил булуның критик тупланышыннан югарырак) агрегатлар — А.ө.м.нең озын чылбырлы молекулалар яки ионнары мицеллаларын барлыкка китерәләр. Мицелляр системаларның мөһим үзенчәлеге шул: алар суда эреми торган яки начар эрүчән органик кушылмаларны «эретергә» сәләтле. А.ө.м.нең күбрәк куерган эремәләрендә сыек кристалларга эзлекле күчүчән югары дәрәҗәдәге агрегация (везикулалар, ламеллалар) структуралары формалаша. А.ө.м.не эмульгаторлар, диспергатор, стабилизатор, күбек һәм структура барлыкка китерүчеләр, пластификатор, флотореагентлар, бизәнү әйберләре сыйфатында; юа һәм чистарта торган әйберләр, тукыма, сүс, тире, бизәнү һәм гигиена әйберләре, фармпрепаратлар, янгын сүндерү әйберләре, лак, буяу, латекслар, төзү материаллары итеп, кәгазь сәнәгатендә; нефть, газ, күмер табу, ташу, эшкәртүдә; техник чаралар, үсемлекләрне саклау чаралары җитештерүдә кулланалар. А.ө.м.не куллануның перспективалы өлкәләре: биотехнология, микроэлектроника, магнитлы тасмалар һәм үтә сизгер материаллар, ашламаларның яңа формаларын җитештерү. А.ө.м. биол. системаларда мөһим роль уйный.

А.ө.м. тәгълиматына нигез салучы — Америка галиме И.Ленгмюр (1917). Мицелла хасил булуның классик тикшеренүләре инглиз галиме Г.Хартли тарафыннан башкарыла (1936). А.ө.м. тәгълиматы үсешенә безнең ил галимнәре шактый зур өлеш кертә. Адсорблану көчләренең табигате турында фараз әйтелә, нефть эшкәртү процессларында А.ө.м.нең әһәмияте (Л.Г.Гурвич), фәзалар бүленү чигендә өске катлау үзенчәлекләре (А.Н.Фрумкин) өйрәнелә, А.ө.м. өстәмәләре тәэсиренең механизмы һәм физ.-хим. закончалыклары (П.А.Ребиндер), адсорбция һәм мицелла барлыкка килүнең термодинамикасы һәм кинетикасы (А.И.Русанов) фәнни тикшерелә. Татарстанда А.ө.м.өлкәсендәге тикшеренүләр 19 йөз ахыры — 20 йөз башында башлана һәм сабын кайнату — шәм җитештерү формалашу һәм технол. камилләштерү б-н бәйле (М.Я.*Киттары*, А.М.*Зайцев*, М.М.*Зайцев*, С.А.*Фокин*, А.Е.*Арбузов*, В.В.*Евлампиев*). 1930 елларда металл коллоидларын аксымнар б-н стабильләштерү буенча эшләр комплексы тормышка ашырыла (А.Ф.*Герасимов*). 1950–70 елларда органик кушылмаларның электродларда бергәләшеп һәм аерым адсорбцияләнүенең теоретик нигезләре үстерелә, мономолекуляр адсорбцияләнгән катлам структураларын модельләштерүнең молекуляр нигезләре эшләнә (Г.А.*Добреньков*). 1960 еллар урталарына кадәр А.ө.м. терлек яки үсемлекнең органик чималын үзләштерү юлы б-н алынган. 1970 елларда нефть чималы һәм эре тоннажлы хим. сәнәгате калдыкларыннан яңа А.ө.м. синтезлау буенча эшләрнең интенсив үсеше яңа төр А.ө.м. синтезлау һәм сәнәгый үзләштерү буенча фәнни юнәлешләр формалашуга, химиядә, нефть химиясендә, нефть табуда һәм эшкәртүдә А.ө.м. кулланып, фәнни нигезле югары нәтиҗәле технологияләр булдыруга ярдәм итә. Ион булмаган яңа А.ө.м. — гликольләр, күп атомлы спиртлар, аминнар һәм диаминнар, этилен окисьләре нигезендә оксиэтилен һәм пропилен блоксополимерлары; төрле дәрәҗәдә оксиэтиллашкан югарымолекуляр азотлы ион булмаган А.ө.м.; молекулаларына фосфор, азот, күкерт һәм карбоксиллы функциональ төркемнәрне кертү юлы б-н модификацияләнгән ион булмаган А.ө.м.; фосфор к-тасының оксиэтиллашкан эфирлары нигезендә амфолит А.ө.м.; катион А.ө.м. (Л.М.Козлов, К.И.Кузьмин, И.Н.Дияров, Н.А.Лебедев, А.А.Гречухина, С.А.Варнавская) эшкәртелә һәм синтезлана. Катион А.ө.м.не алу ысуллары — функциональ алыштырылган аммоний кушылмалар — полимер капламнар гидрофилизаторлары, комплексы тәэсир ясаучы югары нәтиҗәле реагентлар (Г.В.Романов, П.С.Фәхретдинов) ТРның Дәүләт бүләге б-н билгеләнә (1997). А.ө.м. кушылмалары нигезендә нефть үзлелеген киметү, нефть чыгаручы скважиналарга су керүне чикләү, су-нефть эмульсияләрен таркату, коррозиядән, парафин һәм тоз утырмаларыннан саклау өчен нәтиҗәле реагентлар булдырыла; бактерицидлар, су-битум эмульсияләре өчен эмульгаторлар, битум өчен адгезивлар һ.б. алына. Нефть бирүчәнлекне арттыру, катламның забой янындагы зонасын эшкәртү, нефтьне әзерләү өчен технологияләр эшләнә (И.Н.Дияров, В.Г.Козин, Н.А.Лебедев, Г.В.Романов). Нефть эмульсияләрен таркатуда А.ө.м.нең чылату-юу тәэсиренең (И.Н.Дияров, Р.Ф.Хәмидуллин), пласт сулары шартларында полимер электролитларның адсорбциясе һәм структура барлыкка китерүенең (С.В.Крупин) физ.-хим. нигезләре үстерелә. Эластомерларны синтезлау, модификацияләү һәм эшкәртү процесслары өчен А.ө.м. һәм алар нигезендә композицияләр тәкъдим ителә (И.Ю.Аверко-Антонович). Сирәк җир элементлы ионнар кергән магнитлы сыек кристаллар (смектиклар һәм нематиклар) алу буенча хезмәтләр (Ю.Г.Галләметдинов, И.В.Овчинников, И.Г.Бикчәнтәев, Г.И.Иванова) ТРның Дәүләт бүләгенә лаек була (2001). Активлыгы көйләнә торган югары нәтиҗәле биомиметик каталитик системалар булдыруга (А.И.Коновалов, Л.А.Кудрявцева, Р.Ф.Бакыева) һәм биохим. реакцияләр модельләштерүгә (В.Д.Федотов, Ю.Ф.Зуев, Е.А.Ступишина, Н.Н.Вылегжанина), полимер электролитларның А.ө.м. б-н ассоциацияләнүенең физ.-хим. нигезләрен эшләүгә (В.П.Барабанов, А.Я.Третьякова), мицелляр системаларда комплекс хасил булу реакцияләренең термодинамик аспектларын төзүгә (А.А.Әмиров, А.Р.Мостафина, З.А.Сапрыкова) юнәлдерелгән А.ө.м. нең мицелляр эремәләрендә катализ һәм үзеннән-үзе оешу процесслары буенча фундаменталь тикшеренүләр үткәрелә. А.ө.м. синтезы һәм кулланылышы буенча тикшеренүләр Казан технол. ун-тында, РФА КФҮ инт-ларында — Органик һәм физик химия ин-тында, Биохимия һәм биофизика ин-тында, «НИИ нефтепромхим» АҖдә һ.б. тармак институтларында, «Түбән Кама нефтехим», «Оргсинтез» һ.б. АҖ лабораторияләрендә алып барыла. Фәнни тикшеренүләр эре һәм аз тоннажлы химия пр-тиеләренә кертелгән, ТР, Башкортстан Респ-касы, Россия һәм БДБның башка төбәкләрендәге нефть промыселларында файдаланыла.

*Әд.:* Мицеллообразование, солюбилизация и микроэмульсии. М., 1980; А б р а м з о н А.А. Поверхностно-активные вещества. Свойства и применение. Л., 1981; Р у с а н о в А.И. Мицеллообразование в растворах поверхностно-активных веществ. СПб., 1992; Химическая энциклопедия. М., 1992. Т. 3. *А.Я.Третьякова.*

**АКТИНИ́ДИЯ** (Actinidia lindl), диллениййылар семьялыгыннан агачсыман лиана. Яфраклары тулы, чиратлашып үскән. Чәчәкләре ак төстә, берәм-берәм яисә бер бәйләмгә җыелган. Җимешләре — күп орлыклы яшел җиләкләр. Тамыры яхшы үскән, чуклы, тирәнгә китми. А.нең 27 төре билгеле, культурада, ш.и. ТР терр-ясендә А. коломикта (A. kolomicta) төре киң таралган. Лианаларның кайрысы коңгырт төстә, кубалаклана торган. Яфраклары ике яклап теш сыман киртләчләнгән, җәй көне чуарлана. Май азагында чәчәк ата. Ике өйле үсемлек. Кышкы суыкларга бик чыдам. Җимешләре озынча түгәрәк, яшькелт-сары төстә, 3–4 *г* авырлыкта; сусыл, хуш исле, С витаминына бай (500–800 *мг%*). Составында 5–10% шикәр, 0,8–2,5% органик кислоталар, 0,7–0,8% пектин бар. Җимешләре яңа өлгергән килеш тә, эшкәртелеп тә (кайнатма, сок, компот) файдаланыла. Бер лианадан 2–3 *кг*, ә бер куактан 10–15 *кг* уңыш алына. А. туфрак һәм һава дымлы булганда яхшы үсә, ләкин акмый торган тымызык суларны яратмый. А. өчен көпшәк, уңдырышлы, черемәгә бай туфрак кирәк, орлык һәм чыбыкчалардан үрчетәләр. Куакларны бина-корылмаларның көньягына утырту әйбәт. Икееллык үсенте яисә чәчкеннәрне яз көне, бөреләре ачылганчы күчереп утырталар, 8–10 ике җенесле үсемлеккә бер ата чәчәкле үсемлек, бер-берсеннән 1,5–2 *м* ара калдырып утыртыла.

А. 3–4 елдан соң, ә орлык өчен 5–6 елдан соң җимеш бирә башлый. 1993 елдан А.нең коломикта төре «Түбән Кама» с-зының җиләк-җимеш питомнигында үстерелә.

*В.А.Наумов.*

**АКТЛА́Р**, тарихи төрки-татар язмалары, икътисади, сәяси һәм милеккә кагылышлы эшчәнлек нәтиҗәләрен теркәү документлары. А. атамасы борынгы Рим дәүләтендә берәр төрле рәсми эш нәтиҗәсен теркәү ахырындагы латинча actum es («эшләнгән») сүтезмәсен кыскарту нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Урта гасырлар чорында үзара килешү актларына, килешү-канунлаштыру һәм килешү-бүлешү актларына бүленәләр. Тикшерүчеләр кайвакытта аларны ике якның үзара мөнәсәбәтен хокукый теркәү документы буларак кына кабул итә. Шул ук вакытта бу төшенчәгә кануни, регистрацион (теркәү), тәртипкә салу, хәтта эпистоляр һ.б. төр документларны да кертү очраклары күзәтелә. Безнең чорга килеп җиткән иң борынгы төрки (борынгы төрки яки уйгыр язуында) хокукый документ үрнәкләре булган А. 7–12 йөзләр-



М.С. Актуганов.

гә карый. Рәсми хокукый А.үрнәге итеп Алтын Урда идарәчеләре, Әстерхан, Казан һәм Кырым ханлыклары ханнары ярлыклары, аерым шәхесләргә бирелгән тарханлык яки сөйургаллык грамоталары карала (к. *Сәхибгәрәй хан ярлыгы*, *Мәхмүд хан хаты*). Татар ханлыкларын Россиягә кушканнан соң (16–18 йөзләр), төрки-татар телендәге рәсми А. төзү тәртибе юкка чыга (Россия патшаларының Шәрекъ дәүләтләре б-н төзелгән, рус һәм татар телләрендә язылган кайбер документларын исәпкә алмаганда). 17 йөз — 20 йөзнең 1 нче чирегендә, башлыча, шәригать нормаларына нигезләнеп төзелгән аерым шәхси А. гына сакланган. Татарларга кагылышлы шундый күп кенә мәгълүм А. милек бүлешү, сату-алу, милекне закладка бирү, бүләк итү, өйләнешү яки аерылышу нәтиҗәләрен теркәүгә һ.б. карый. Ш.у.к. *Сөйургал*, *Тархан*, *Ярлык*.

*Әд.:* К а ш т а н о в С.М. Очерки русской дипломатии. М., 1970; У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*М.Г.Госманов.*

**АКТОЯ́К** (Petasites), оешма чәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Төньяк ярымшарның урта поясында 18 төре таралган. ТРда бер төре — ялган А. (P. spurius) очрый. Елга, күл, буа ярлары буенда куе булып үсә. Тамырчасы юан, юанайган буынтыкларыннан нечкә тамырлар китә. Чәчәк сабаклары 15–30 *см* озынлыкта, тәңкәсыман яфраклар һәм күпсанлы сары яисә тонык ак чәчәк кәрзиннәре б-н капланган. Яфраклары җәенке өчпочмак сыман. Чәчәкләре вак, саргылт яисә тонык куе кызыл, исле; иртә язда яфраклары күренгәнче үк ачылалар. Җимеше — бөрекчәле орлыкча. Дару үләне. Яфракларында һәм тамырларында эфир мае, гликозидлар, сумала, органик кислоталар бар. Яфраклары төнәтмәсе тамак йомшарту өчен һәм ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла. Яфракларын ш.у. җәрәхәтләрне дәвалау һәм дезинфекцияләү өчен файдаланырга мөмкин.

**АКТУГА́НОВ** Мәхмүт Сафа улы (25.12.1924, Башкортстан АССРның Мишкә р-ны Яңа Сәфәр а. — 25.1.1971, Ленинград ш.), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), майор (1969). 1942 елның августыннан Кызыл Армиядә; сентябрьдән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 61 нче армиянең 77 нче укчылар дивизиясе 221 нче укчылар полкында танкка каршы атучы мылтыкны төзәүче. Үзәк, Көнбатыш, 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украина, Белоруссия, Польшаны азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 28 сентябрендә Гомель өлкәсенең Комарин р-ны Брагинск посёлогы өчен барган сугышта һәм Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә. Хәрби уч-ще тәмамлый (1956). Сугыштан соң Совет Армиясендә җитәкче вазифалар башкара. 1969 дан отставкада. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Геройлар китабы — Книга героев. К., 2000; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1985. Кн. 3.

**АКТҮБӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ямаш елгасының (Бөгелмә Зәе елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 4 *км*, бассейнының мәйданы 12,6 *км*². Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы шәһәр тибындагы Актүбә посёлогының көнбатыш читендә, тамагы әлеге посёлоктан 3 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 120 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 55 *мм*, ташу агымы катламы 40 *мм*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,014 *м*³/*с*.

**АКТҮБӘ́**, шәһәр тибындагы посёлок, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 21 *км* көнбатыштарак, Лениногорск–Азнакай автомобиль юлы буенда. 2006 елда 9,6 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 62,6%, руслар — 31,9%) яши. Газ-нефть чыгару сәнәгате («Актүбәнефть» НГДУы), икмәк з-ды. Халкының төп шөгыле — кырчылык, кошчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. 2 урта мәктәп, татар гимназиясе, балалар музыка һәм сәнгать мәктәпләре, мәдәният йорты, клуб, 4 китапханә (ш.и. 2 се — балалар өчен), район хастаханәсе. Мәчет. 1920 елда Мәлбагыш авылы халкы нигез салган Ак Түбә авылы тирәсендә 1953 тә төзелә башлый. 1956 ның 5 июлендә Бөгелмә р-нындагы торак пункт буларак теркәлә, 1956 ның 27 августыннан — шәһәр тибындагы посёлок. 1959 ның 29 июненнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1963 нең 27 августыннан — Азнакай сәнәгать р-нына, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нына керә.

**АКТҮБӘ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 43 кеше (татарлар) яши. 1678 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, арба ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне була. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афанасов волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 541, 1897 дә — 607, 1920 дә — 778, 1926 да — 647, 1938 дә — 668, 1949 да — 585, 1958 дә — 437, 1970 тә — 397, 1979 да — 373, 1989 да — 92 кеше.

**АКТҮБӘ́ РАЙОНЫ́**, Әстерхан өлкәсенең төньяк-көнчыгыш өлешендә. Мәйданы — 7,8 мең *км*². 1927 елда (1975 нең февраленә кадәр — Владимир р-ны) оештырыла. Үзәге — Актүбә шәһәре. Халкы — 36 мең кеше (район үзәгендәге халык санын кертмичә), ш.и. 1,1 мең татар (1997). А.р. терр-ясендә татарлар 18 йөз ахырында — 19 йөз башында яши башлыйлар. Алар, нигездә, 1782–91 елларда Казан губернасы Тәтеш өязеннән һәм Сембер губернасы Буа өязеннән чыккан кешеләр нигез салган Ташлы Яр (хәзерге Черноярск р-нының Ташлыяр а.) авылыннан күчеп утыручылар була. Татарлар күбесенчә Казачий, Сотенный, Средний торак пунктларында (элеккеге казакъ хуторларында) яшиләр. Баскунчак күле буенда 1790 елларда патша армиясеннән казакъ далаларына качып киткән Казан татарларыннан булган хәрбиләр гаиләләре яши. Татарлар туган телләрен һәм фольклорны саклап калганнар. 1992 дән А.р.нда татар өлкә милли-мәдәни җәмгыятенең «Дуслык» ф-лы эшли.

**АКТҮБӘ́ УРМА́Н МАССИВЫ́**, к. *Владимировка сөзәклеге*.

**АКУ́ЛОВ** Тимур Юрьевич (25.4.1953, Үзбәкстан ССРның Яңа Юл ш.), тарихчы-шәркыятьче галим, дипломатик хезмәткәр. Ленинград ун-тын тәмамлый (1979). 1970–71 елларда Ташкент өлкәсе Яңа Юл р-нының Калинин исем. к-зында эшли. 1971–73 тә Совет Армиясендә хезмәттә. 1973–74 тә Орджоникидзе исем. Балтыйк з-дында (Ленинград) суднолар төзү слесарь-монтажчысы. 1979–82 дә Йәмән Халык Демократик Респ-касында хәрби тәрҗемәче (инглиз, гарәп телләре). 1983–88 дә Казан ун-тының фәнни коммунизм каф. ассистенты. 1988–91 дә Йәмән Респ-касының (Аден ш.) Иҗтимагый фәннәр ин-тында укытучы. 1991–95 тә ТР Президентының халыкара мәсьәләләр буенча киңәшчесе. 1995 тән ТР Президентының Тышкы багланышлар департаменты директоры — ТР Президентының халыкара мәсьәләләр буенча дәүләт



Актүбә посёлогындагы урам.

киңәшчесе. РФнең Тышкы эшләр министрлыгы каршындагы халыкара һәм тышкы икътисади багланышлар буенча Федерация субъектларының консультатив Советы әгъзасы (1995 тән), чит илләрдә ватандашлар эшләре буенча РФнең хөкүмәт комиссиясе әгъзасы (2004 тән), Европа регионнары Ассамблеясы бюросы әгъзасы (2006 дан). Кандагарда (Әфганстан) талиблар тарафыннан кулга алынган Россия очучыларын азат итү буенча сөйләшүләрдә катнашуы өчен 1996 ның августында Почёт ордены б-н бүләкләнә.


*Г.С.Сабирҗанов.*

**АКУПУНКТУ́РА** (лат. acus — энә, puncktura — кадау), күп төрле нерв, аллергия һ.б. авыруларны рефлектор ысул б-н дәвалау. А. тән өслегенең билгеле бер зоналарына махсус энәләр кадап һәм төрле вакыт дәвамында, төрле дәрәҗәдә ярсытып, организм функцияләрен көчәйтүгә нигезләнә. Көнчыгыш традицион медицинасының бер өлкәсе, 5 мең ел чамасы гамәлдә, Кытай халык медицинасына барып тоташа. А.ның төп төшенчәләре: меридиан, акупунктур нокта, «Чи» энергиясе. Акупунктур нокталар төп нерв баганалары тупланган урыннар б-н туры килә. Меридиан — энә кадау координатларын табу системасы. «Чи» — шул ноктаның биол. энергиясе. Акупунктур нокта б-н гадәти тире өстендәге урынның электр каршылыгы төрле зурлыкта була. Баш тиресендәге нокталарны сайлап А. ясау — скальпотерапия, колак тирәсендәге нокталар А.сы — аурикулотерапия, кул чугындагы нокталарны файдаланып дәвалау ысулы — су-джок терапияне барлыкка китерә һ.б. Радиоэлектроника, физика һәм химия казанышлары: пьезо- һәм тензография пульсы, акупунктур нокталарда тиренең электр каршылыгын үлчәү, кеше тәне өлешләренең термографиясе, электростатик кырларны теркәү һ.б. ЭВМ програмларының нәтиҗәлелегенә бәйле. Бу казанышлар диагноз куюһәм дәвалау методикаларына нигез була. А. гомеостаз бозылуны төзәтүнең әһәмиятле ысулы булып санала. А. безнең илдә рефлексотерапия төре буларак формалаша. Күп кенә авыруларны А. ысулы б-н дәвалауның теоретик һәм гамәли тәкъдимнәре эшләнә. Бу эшкә Казан мед. академиясе галимнәре И.И.*Русецкий*, Д.М.*Табеева*, Г.А.*Иваничев* һ.б. мөһим өлеш кертә. Рефлексотерапия ысулы нигезенә салынган төп фәлсәфи концепцияләр анализлана, гамәли неврология һәм психологиядә рефлексотерапияне куллануның методологик принциплары тәгъбирләнә. И.И.Русецкий «Кытайча энә кадап дәвалауның кыскача кулланмасы»н («Краткое руководство по китайскому иглоукалыванию», 1962) яза. Д.М.Табееваның илебездә беренче булып «Колакка энә кадап дәвалау» («Ухоиглотерапия», 1976) монографиясе, ш.у. «Энә кадап дәвалау буенча атлас» («Атлас по иглорефлексотерапии», 1979), «Энә кадап дәвалау буенча кулланма» («Руководство по иглорефлексотерапии», 1988), «Гамәли акупунктура»(«Практическая акупунктура», Смоленск, 1977) исемле китаплары нәшер ителә, (к. *Рефлексотерапия*).


*Әд.:* Иваничев Г.А. Акупунктура // Научный Татарстан. 1997. № 4.

*Р.Г.Исхакова.*

**АКУ́СТИК ПАРАМАГНЕ́ТИК РЕЗОНА́НС** (АПР), даими магнит кырына урнаштырылган каты җисемнең билгеле бер ешлыктагы акустик тирбәнеш энергиясен сайлап йоту күренеше. Парамагнетик ионнар яки төшләрнең магнит кимәлләре арасындагы квант күчешләренә бәйле күренеш. Энергиянең акустик дулкыннан электрон яки төш спиннарына тапшырылуы кристаллик атомнары арасы периодик үзгәрү һәм кристалл эчендәге кырның (спин-фонон тәэсирләшүенең) модуляциясе аша бара. С.А.*Альтшулер* тарафыннан 1952 елда фаразлана. АПР




Акустик парамагнетик спектрометрның блок-схемасы.
1. Югары ешлыклы генератор; 2. Радиоалгыч; 3. Теркәү (регистрация) системасы; 4. Килештерү трансформаторы; 5. Кварц; 6. Тавыш туендыру генераторы; 7. Үрнәк; 8. Магнит полюсы; 9. Тавыш егәрлеге үлчәве.



Акустик магнетик спектрометр.

матдәнең микроскопик үзлекләре турында мөһим мәгълүмат алырга мөмкинлек бирә. АПР ярдәмендә ионнар һәм төшләрнең энергетик спектрларын, спин системаларының динамикасын, кристаллик структураның микроскопик кимчелекләрен тикшерергә мөмкин. АПРны бер-берсенең спектроскопик мөмкинлекләрен тулыландыра һәм киңәйтә торган күренешләрнең — *электрон парамагнетик резонанс* һәм *төшнең магнит резонансының* акустик аналогы дип тә карарга мөмкин. Акустик дулкынның озынлыгы (1000–10 *МГц* ешлык диапазонында 1–100 *мкм*) үрнәк үлчәменнән шактый кечерәк булганга, көчле спин-фонон тәэсирләшкән кристалларда үзлегеннән кысылу һәм сүнмәүче акустик импульслар барлыкка китерә алу (үзиндукцияле үтә күренүчәнлек), нәсызыкча эффектлары булу мәгълүматны акустик хәлендә җәйланмаларда эшкәртергә мөмкинлек бирә. АПР һәм динамик акустик спин эффектлары теориясе Казан ун-ты һәм РФА КГҮнең Физ.-техника ин-ты галимнәренең бергә эшләве нәтиҗәсендә камилләштерелә (С.А.Альтшулер, А.Р.Кессель, У.Х.Копвиллем, Б.И.Кочелаев, В.А.Самарцев). 1961 елда У.Х.Копвиллем җитәкчелегендә СССР ФАнең Казан ф-лы Физ.-техника ин-тында системалы рәвештә АПРны тикшерү тәҗрибәләре башлана. Фонон ташкыннары (С.А.Альтшулер, Б.И.Кочелаев, А.Х.Хәсәнов), акустик дулкын кырында спиннарның квантлануы (А.Р.Кессель, М.М.Шакирҗанов, В.А.Голенищев-Кутузов, В.Ф.Тарасов), акустик спин кайтавазы һәм үзиндукцияле үтә күренүчәнлек (А.Р.Кессель, Х.Г.Богданова, Б.П.Смоляков, В.Ф.Тарасов) күренешләре теоретик яктан фаразлана һәм тәҗрибәдә исбатлана. Икеләтә магнито-акустик электрон-төш резонансы табыла һәм тикшерелә (В.А.Голенищев-Кутузов, Н.А.Шамуков), төрле класс кристаллардагы (диэлектрикларда, ярымүткәргечләрдә, магнетикларда) спин-фонон тәэсирләшүе тензорлары билгеләнә. АПРны файдалану нигезендә лазер техникасында кулланыла торган кристалларның сыйфатын тикшерүнең яңа ысулы эшләнә һәм гамәлгә кертелә (В.А.Голенищев-Кутузов, С.А.Мигачёв).

*Әд.:* Кессель А.Р. Ядерный акустический резонанс. М., 1969; Альтшулер С.А., Козырев Б.М. Электронный парамагнитный резонанс соединений элементов промежуточных групп. М., 1972; Ремптон В., Такер Дж. Гиперзвук в физике твёрдого тела / Пер. с англ. М., 1975; Магнитная квантовая акустика. М., 1977; Голенищев-Кутузов В.М., Самарцев В.В., Хабибуллин Б.М. Импульсная оптическая и акустическая когерентная спектроскопия. М., 1988.

*В.А.Голенищев-Кутузов.*

**АКУШЕРЛЫ́К ҺӘМ ГИНЕКОЛО́ГИЯ**, клиник медицина өлкәсе, бердәм фәнни дисциплина. Акушерлык йөклелек, хатын-кыз һәм яралган бала организмындагы процессларны, патологияләрне өйрәнә, бала тудыру һәм аннан соңгы вакытка бәйле дәвалау-профилактика чараларын эшли. Гинекология хатын-кыз организмының анатомик-физиологик үзенчәлекләрен, җенес әгъзалары авыруларын, җенес органнары авыруларына диагноз куюны, дәвалау һәм шул авыруларны булдырмауны өйрәнә. Гинекология мөстәкыйль фән буларак 19 йөз урталарында формалаша һәм аның үсеше хирургия, эндокринология, физиология һ.б. өлкәләрдәге уңышларга бәйле. Эндокринология, рентгенология, электрофизиология, патогистология, неонатология, эмбрионология, иммунология, генетика, лаборатория эшләре һ.б. ярдәмче фәннәр булып санала. А.һ.г. медицина һәм табиблек сәнгатенең борынгы өлкәләреннән берсе. Һиндларның изге китапларының берсе «Аюрведа»да (б.э.к. 8 йөз) хатын-кызларга бала тудырганда ярдәм итү ысуллары

китерелә. Талмудта баланы карыннан ярып алу операциясе бәян ителә. Гиппократ аналыктагы бала дөрес урнашмаган очракта анын башын уңай якка борырга өйрәтә, шул вакытта балага зыян килү очракларын сурәтли. Фәнни акушерлык анатомия, эмбриология, физиология һәм клиник медицина уңышлары б-н бәйле рәвештә үсә. 17 йөздә беренче акушерлык клиникасы (Париж) төзелә, акушерлык буенча беренче китап (Ф.Морисо) языла. Россиядә акушерлык ярдәме күрсәтү 13 йөздә башлана. 1754 елда С.-Петербургта кендек әбиләрен акушерлык осталыгына өйрәтү уку йорты эшли, рус телендә беренче дәреслек нәшер ителә (1762), бала тудыру госпитальләре (Мәскәү, 1764; С.-Петербург, 1771) ачыла. 19 йөздә гамәли акушерлыкта авыртуны басу чарасы буларак эфир һәм хлороформ куллану бу өлкәдә алга китеш була. Тармакның үсешенә рус акушерлык мәктәбе вәкилләреннән И.П.Лазаревич, А.Я.Красовский, В.М.Флоринский, А.И.Макеев, Н.Н.Феноменов, В.В.Строганов, Н.И.Побединский, В.С.*Груздев*, Д.О.Отто һ.б. мөһим өлеш кертә. Йөклелек физиологиясе, бала тудыру алды токсикозы (эклампсия), бала тудыру процессы, бала тудырганнан соңгы өзлегү кебек мөһим теоретик проблемаларны фәнни хәл итү һәрьяклап үсеш ала. Казанда А.һ.г. үсеше 19 йөзгә карый. 1812 дә Казан ун-тында хирургия һәм акушерлык осталыгы кафедрасына нигез салына. Акушерлык буенча Ф.Г.Мартинсның «Таблицада күрсәтелгәнчә бала тудыруда гамәли ярдәм итү осталыгына күзәтү» («Обозрение практического родовспомогательного искусства, начертанное в таблице», 1813) исемле беренче дәреслеген немец теленнән кафедраның беренче профессоры А.М.Аргнгольд тәрҗемә итә.

Акушерлык осталыгы курсларын танылган галимнәр А.М.Аргнгольд (1812–15), Э.О.Вердерамо (1815–20), А.П.Владимировский (1821–23), А.Е.Лентовский (1823–53) һ.б. укый. 1833 тә Казан ун-ты каршында *Акушерлык-гинекология клиникасы* ачыла, 1844 елда клиникада А.А.Китер б-н Ф.О.Елачич Россиядә беренче булып яман шеш б-н зарарланган аналыкны җиңсә аркылы алу операциясен башкаралар. Казан ун-тында А.һ.г. кафедрасының беренче профессоры А.И.Козлов була (1856–76), ул бала тудырганнан соңгы сепсиска каршы көрәшүнең нигезен сала. Корсак куышлыгын ачып гинекол. операцияләрен ясауны К.Ф.Славянский гамәлгә кертә. 1885 тә Н.Н.Феноменов тарафыннан иң яхшы кулланмаларның берсе — «Оператив акушерлык» («Оперативное акушерство») нәшер ителә һәм ул акушерлыкта асептика, антисептика принципларын гамәлгә кертә. 1900–30 елларда Казан мед. ун-ты галимнәре (1 нче А.һ.г. кафедрасы 1900 дән, 2 нче А.һ.г. кафедрасы 1930 дан) һәм Казан ГИДУВы галимнәре (1 нче А.һ.г. кафедрасы 1920, 2 нче А.һ.г. кафедрасы 1956) катнашында Казан акушер-гинекологлар фәнни мәктәбе барлыкка килә (нигез салучысы — В.С.Груздев). В.С.Груздев шәкертләре морфол.-физиол. юнәлештәге тикшеренүләрне дәвам итәләр. А.И.Тимофеев (1913) шешләр һәм яман шешләрне өйрәнә, дөньяда беренче булып кеше күкәйлегендәге сары бизнең эпителиаль килеп чыгышын исбатлый. 1940–70 елларда П.В.Маненков, Н.Е.Сидоров, М.В.Монасыйпов, М.И.Слепов, Л.Д.Пароник, М.Р.Сафин һ.б.ның фәнни эзләнүләре онколо-гинекологик патология проблемаларына юнәлтелә. И.Ф.Козлов тарафыннан акушерлык-гинекол. операцияләрендә җирле анестезия ысуллары эшләнә (1948), Р.Г.Бакиева (1960 еллар) йөклелекнең соңгы токсикозы вакытында тамырлар системасының функциональ торышын өйрәнә. Мондый тикшеренүләрне Г.М.Шәрәфетдинов дәвам итә, ул урта мед. персоналы өчен татар телендә акушерлык буенча дәреслек яза. 1960 та З.Н.Якупова аналык эчендә кулланыла торган чараларның (ВМС) безнең илдә эшләнгәннәрен өйрәнү һәм куллану үзгәен оештыра. Бу эшне Р.Х.Әмиров, Р.С.Барышкина, Б.М.Кошкин дәвам итә. 1964 тән гинекологик эндокринология (М.Х.Мещеров), акушерлыкта кан китү профилактикасы, акушерлык патологиясе өйрәнелә, гинекол. эндокринология казанышлары гамәлгә кертелә (И.В.Данилов, З.Ш.Гыйләҗетдинова). И.В.Данилов башлаган тикшеренүләр: хатын-кыз организмындагы төрле яңа шешләр, гормональ тайпылышлар, дистрофик процесслар вакытындагы нейрогумораль үзгәрешләр — З.Ш.Гыйләҗетдинова, Л.М.Тәхфәтуллина, Н.Л.Капелюшник тарафыннан дәвам иттерелә. Ясалма аналык җиңсәсенең аллопластикасы эшләнә (Н.Л.Капелюшник, 1974). 1977 дә йөклелекнең соңгы чорында токсикоз вакытында дәвалау системасы тәкъдим ителә, бу исә бала тудырганнан соң була торган эклампсияне бетерә, гипертонияне һәм протеинурияне киметә (К.В.Воронин, Л.А.Козлов, Ф.Я.Банщик). Иммуноконфликтлы йөклелек һәм нейросенсибилизация проблемалары Б.Г.Садыйков, Д.П.Игнатьева һ.б. тарафыннан өйрәнелә (1970–80 еллар). Алар яңа туган балалардагы гемолитик авыруны классификацияләүнең зарурлыгын раслыйлар, гипосенсибилитик дәвалау ысулларын эшлиләр, яңа туган балаларда гемолитик авыруларны дәвалау тәкъдимнәрен кертәләр. Балага узмауны дәвалау (З.Н.Якупова, А.И.Хәйруллина һ.б., 1960–80 еллар), хатын-кызларның операциядән соң хезмәткә сәләтен кайтару буенча (Ф.А.Мифтахова, 1960–90 еллар) тикшеренүләр үткәрелә. Груздев мәктәбендә әзерлек үткән Казан галимнәренең күпчелек хезмәтләре җенес органнарының ялкынсынуына (К.Н.Сызганова, А.З.Уразаева һ.б.), аналык көпшәләре моторикасын савыктыруга (Р.А.Осипов), ультратавыш б-н дәвалауга (Ф.А.Мифтахова), оператив дәвалау вакытында ангиотензиометрия һәм трансиллюминацияне куллануга карый; микрохирургия техникасы һәм операция микроскобыннан файдаланып, аналык көпшәләренә реконструктив-савыктыру операцияләре ясала (Р.Н.Володин, 1980–90 еллар). Эндометриоз, балага узмау, поликистоз, аналыкта миома һ.б. аналык эче патологияләрен дәвалаганда гинекологик стационарларда югары нәтиҗәле лазерлар куллану гамәлгә керә. Баланы карыннан ярып алганда һ.б. гинекологик операцияләрдә киселгән урын лазер ярдәмендә ялгана. Бу ысул операциядән соңгы өзлегүләрне булдырмауга ярдәм итә (И.Ф.Фәткуллин, 1997). Шулай итеп, А.һ.г.нең фәнни проблемаларны хәл итүдә В.С.Груздев башлаган морфол.-физиол. юнәлешне Казан акушер-гинекологлары фәнни мәктәбе галимнәре дәвам иттерә.

*Әд.:* Маненков П.В., Бакиева Р.Г., Садыков Б.Г. Роль казанских учёных в решении вопросов акушерско-гинекологической науки и практики // Материалы юбилейной науч. конф. КГМИ. К., 1973; Итоги и перспективы развития помощи при иммуноконфликтной беременности в ТАССР: Сб. науч. трудов. К., 1978; Козлов Л.А., Садыков Б.Г. Итоги научной работы кафедр акушерства и гинекологии № 1 и № 2 с 1963 по 1988 // Казанский медицинский институт, 1814–1989. К., 1989; Красильников Д.М., Фаткуллин И.Ф., Карпухин О.Ю. Новые лазерные технологии в хирургии, акушерстве, гинекологии // Казан. мед. журн., 1999. № 2.

*Л.А.Козлов, Б.Г.Садыйков.*

**АКУШЕРЛЫ́К-ГИНЕКОЛО́ГИЯ КЛИ́НИКАСЫ** В.С.Груздев исемендә, 1833 елда Казан ун-ты каршында ачыла. Клиниканың акушерлык бүлеген А.Е.Лентовский (1833–63), гамәли гинекологияне А.А.Китер җитәкли (1833–36). 1900 елларда клиника өчен 4 бина төзелә, шуларның берсендә А.-г.к.ның бала тудыру йорты (мөдире И.М.Львов) һәм Казан ун-тының акушерлык һәм гинекол. кафедрасы (каф. мөдире В.С.Груздев) урнаша (к. *Университетның яңа клиникалары*).



В.С.Груздев исем. акушерлык-гинекология клиникасы.

А.-г.к.ның матди-техник базасын үстерү, фәнни һәм дәвалау эшләрен оештыруга 1900–31 дә клиника б-н җитәкчелек иткән һәм Казан акушер-гинекологлар мәктәбенә нигез салган В.С.Груздев зур өлеш кертә. Клиникада яшь белгечләргә фәнни эшләр һәм уку өчен шартлар тудырыла, патологоанатомик тикшеренүләр, клиник һәм бактериологик лаборатория өчен биналар җиһаз-



Клиникада В.С.Груздев мемориаль кабинеты.

ландырыла, хайваннарда тикшеренүләр үткәрү өчен махсус бүлмәләр бирелә, физиотерапия, рентген һәм радиология кабинетларындагы эшләр киң колач ала. Хатын-кызларның җенес органнарындагы рак авыруын, ш.и. рентген һәм радий нурлары б-н дәвалауга зур әһәмият бирелә. Соңрак клиникада В.С.Груздев шәкертләре П.В.Маненков (хатын-кыз җенес органнары онкологиясе, оператив онкология, 1960 еллар), З.Н.Якупова (акушерлыкта кан китүләр, балага узуны булдырмый калу, 1960–80 еллар), Л.А.Козлов (эклампсия, баланы карыннан ярып алу проблемалары, 1970–90 еллар), Р.Г.Бакиева (йөклелекнең соңгы чоры һәм бала тудыру вакытында токсикоз, 1970–80 еллар), Б.Г.Садыйков (ТРда резусны ачыклау хезмәте, 1970–90 еллар) һ.б. эшли.

Фәнни эшчәнлекнең төп юнәлешләре: резус һәм кан группалары тәңгәлсезлеге вакытында нейроиммуноконфликтлы йөклелек, йөклелекнең соңгы чорында токсикоз, онкология, хатын-кызларның җенси органнары ялкынсыну, бала төшү һ.б. (к. *Акушерлык һәм гинекология*).

2006 елда клиникадагы бүлекләр: гинекология, бала тудыру, йөклелек патологиясе, яңа туган балалар (140 урын); УЗИ кабинеты, заманча җиһазландырылган лабораторияләр. Клиника ТРда акушерлык һәм гинекология буенча методик үзәк булып тора.

1936 да клиникага В.С.Груздев исеме бирелә, галимнең биредә сакланган мемориаль кабинетында хезмәтләре һәм шәхси әйберләре, замандашлары һәм хезмәттәшләренең портретлары һәм фотоальбомнары, дөнья, Россия һәм ТРның танылган акушер-гинеколог галимнәренең портретлар галереясы тупланган. Үзенең васыяте буенча кабинетында В.С.Груздевның йөрәге һәм баш мие саклана. Клиникада укытучылар, хезмәткәрләр һәм студентлар — фәнни түгәрәк әгъзалары тарафыннан эшләнгән муляжлар, микропрепаратлар куелган укыту музее эшли.

*Әд.:* Улескина Т. Мозг и сердце Груздева // Трудовая слава. 1990. № 31.

*Л.А.Козлов.*

**АКХУҖА́** (Азбаба) авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 35 *км* төньяктарак, Зөя елгасыннан 3 *км* читтә. 2002 елда 306 кеше (татарлар — 63%, чуашлар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Клуб. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында авылЕче Аткозино исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 2 җил тегермәне, ярма ярдыру тегермәне, бакалея кибете була; 1914 тән мәчет һәм мәктәп эшли. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Зөя өязе Иваново волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 39 ир заты; 1859 да — 299, 1897 дә — 601, 1908 дә — 751, 1926 да — 717, 1938 дә — 801, 1949 да — 645, 1958 дә — 478, 1970 тә — 493, 1979 да — 439, 1989 да — 308 кеше.

**АКЦИ́З** (франц. *accise* — кисеп алу, алып калу), башлыча, киң куллану товарлары бәясенә кертелгән турыдан-туры булмаган салым төре. Акцизлы товар җитештерә һәм хезмәт күрсәтә торган пр-тиеләр А. җыючылар булса, товар яки хезмәт күрсәткән өчен исәп-хисап ясаучылар — кулланучылар — аны түләүчеләр. А. төбәк һәм җирле бюджетларның керемнәрен кейләү чыганагы булып тора, ләкин ул сатып алучыларның реаль керемнәренең кимүенә китерә. 2000 елда А. өлеше федераль бюджет керемнәрендә — 15%, салым түләвендә — 17,8% иде; ТРда тиңдәшле рәвештә 13,7% һәм 28,8% тәшкил итә. Рев-циягә кадәрге Россиядә А.лар дәүләтнең төп керем чыганагы була. Мәс., 1901 дә А.лар дәүләт керемемең 60,8% ын тәэмин иткән. А. салымы иң кирәкле әйберләргә (тоз, шикәр, шырпы, чәй һ.б.ш.), ш.у. киң куллану товарларына (аракы, тәмәке, сыра салаты һ.б.) салына. Акцизлы товарлар саны туктаусыз артып, салым күләме даими күтәрелеп тора. Окт. рев-циясеннән соң дәүләт керемендә А.лар өлеше бик нык кими. 1930 дагы салым реформасы нәтиҗәсендә А.лар тулысынча бетерелә. РФнең салым реформасы нәтиҗәсендә 1992 нең 1 гыйнварыннан А.лар яңадан кертелә. Акцизлы товарлар җитештерә һәм аларны сату-урнаштыруны гамәлгә ашыра торган оешмалар, 1997 дән эшмәкәрлек б-н шөгыльләнүче юридик зат булмаган һәм РФ таможня чигеннән чыгарылучы товар өчен салым түләргә тиешле гражданнар да бюджетка А. түләүчеләр булып торалар. РФдә этил спиртына, спиртлы эчемлекләргә, башка спиртлы продукциягә, сыра, тәмәке продукциясенә, автомобиль бензины, дизель ягулыгы, җиңел автомобиль һәм мотоциклларга, дизельле һәм карбюраторлы двигательләр өчен мотор маена, турыдан-туры куылган бензинга А. салымы салына. А. алына торган товарлар исемлеге һәм аларның күләме дәүләт тарафыннан билгеләнә һәм РФнең барлык терр-ясендә бердәм булып санала. ТР ЮС карары нигезендә 1993 тән өстәмә рәвештә респ-када җитештерелә торган полиэтилен, йөк автомобильләре, автомобиль двигательләре, ш.у. автомобильләр җыю з-дларына җибәрелә торган шиннарга А. салына. Моннан башка, халыкны адреслы социаль яклауга юнәлтелгән бюджеттан тыш фондка күчерелә торган А. салымы «Кварт» АҖнең резин-техник эшләнмәләренә, «Руда булмаган материаллар» җитештерү берләшмәсе чыгара торган ком, гравий, вакланган ташка, «Восток» з-ды сәгатьләренә, гипс ташына, югары басымлы полиэтиленга салына. Алар РФ субъектлары һәм федераль закон актларын тәңгәлләштерү тәмамланганчы гамәлдә була. А. салымы нормаларын үлчәү берәмлеге буларак процентлар яки сумнар алына.

Чыг.: Закон РФ «Об акцизах» от 6 декабря 1991 г. № 1993–1 // Ведомости съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР. 1991. № 52. Ст. 1872; Налоговый кодекс РФ. М., 2006. Ч. 2.

*Әд.:* Черник Д.Г., Починок А.П., Морозов В.П. Основы налоговой системы. М., 1998; Финансово-кредитный словарь. М., 1984. Т. 1; Экономика, право, финансы. Термины и определения: Словарь-справ. для сотрудников госналогслужбы и налоговой полиции. М., 1995; Панеков В.Г. Налоги и налогообложение в Российской Федерации. М., 2004.

*Н.З.Капкаева.*

**АКЦИ́З ИДАРӘЛӘРЕ́**, губерна һәм округлардагы дәүләт оешмалары, *акциз* салымнарын җыю б-н шөгыльләнгәннәр. 1860 елның 26 октябрь һәм 1861 нең 4 июль кануннары нигезендә Казан губернасында да оештырыла. Спиртлы эчемлекләр, тәмәке, шикәр, шырпы, керосин һәм нефтьтән майлар җитештерүчеләр акциз салымы түләгән. А.и. ш.у. тәмәке сатуга рөхсәт лицензияләре биргән, дәүләт аракы-спирт з-дларында сыйфат тикшерүгә булдырган, эчүчелеккә каршы көрәшү максатына тоту өчен акчалата өлеш чыгарган. Казан губернасы А.и. 4 округка бүленә (1 нчесенә — Казан, Лаеш, Мамадыш өязләре, 2 нчесенә — Чистай, Спас, Тәтеш, 3 нчесенә — Зөя, Цивиль, Ядрин, 4 нчесенә — Козьмодемьян, Чабаксар, Царёвококшай өязләре керә). А.и. штатында идарә башлыгы, ревизорлар, техниклар, мәхкәмә чиновниклары, бухгалтер һ.б. хезмәткәрләр; округ идарәләрендә надзиратель, аның ярдәмчеләре булган (1912 дә Казан идарәсендә барлыгы 77 хезмәткәр теркәлгән). Заводларда даими күзәтчелек һәм тикшерү эшен башкаручылар да шул исәпкә керә. 1898 дә казна тарафыннан аракы-спирт сату операцияләрендә киңәшче-ярдәмче орган сыйфатында губерна А.и. каршында хуҗалык ком-ты оештырыла. Губерна А.и. Россия Финанс министрлыгының өстәмә салым җыю Баш идарәсенә буйсына. А.и. РСФСР ХКС декреты б-н 1918 елның 1 ноябрендә бетерелә.

*С.А.Фролов.*

**АКЦИОНЕРЛЫ́К ҖӘМГЫЯТЕ́** (АҖ), физик һәм юридик затларның акцияләр чыгару һәм сату ярдәмендә үз капиталын формалаштыру юлы б-н хуҗалык эшчәнлеген бергәләп алып бару өчен оешкан берләшмәсе; капиталны үзәкләштерү һәм пр-тиеләрнең җитештерү эшчәнлеген оештыру формасы. Россиядәге беренче АҖ «Россиянең Константинопольдәге сәүдә итү компаниясе» 1757 елда барлыкка килә. 1861 дә 120 АҖ эшли. Алар, нигездә, чит ил капиталын җәлеп итү өчен һәм аның шактый катнашуында оеша. АҖ иң элек тимер юл транспорты һәм кредит өлкәсе пр-тиеләрендә, соңрак, а.х.ннан тыш, һәр тармакта эре пр-тиедә өстенлекле форма булып әверелә. 1925 ел башына Россиядә 161 АҖ исәпләнә, шуларның 61е — дәүләтнеке, 64е — катнаш, 34е — хосусый, 2се — кооператив. Ул чорда Казанда һәм губернада эре пр-тиеләр акционерлашу принциплары нигезендә ширкәтләр тибында оештырыла (бертуган Крестовниковларның «Шәм-стеарин, сабын кайнату, гөлсирин җитештерү химия заводы» ширкәте, бертуган И.Д. һәм Н.Д. Родыгиннарның киез итек җитештерү ширкәте һ.б.). 1917 дән соң аларның барысы да мәҗбүри рәвештә тартып алына. 1930 елларда күпчелек АҖләр трестлар, торглар һ.б. төр дәүләт милке итеп үзгәртелә. 1990 елларда,

милекне дәүләт карамагыннан чыгару барышында, АҖләр яңадан оештырыла башлый. Устав АҖне оештыру документы булып санала. Анда җәмгыятьнең максаты, капитал күләме, идарә итү тәртибе, җитәкче органнар структурасы билгеләнә. АҖнең устав капиталы акционерлар тарафыннан сатып алынган җәмгыять акцияләренең номиналь бәясеннән чыгып туплана. АҖнең иң югары идарә итү органы — акционерларның гомуми җыелышы, ул, кагыйдә буларак, елга бер мәртәбә чакырыла. АҖ ачык яки ябык була. Ачык АҖ (ААҖ) акционерлары үз карамакларындагы акцияләрне җәмгыятьнең бүтән акционерлары ризалыгыннан башка да читкә сатарга мөмкин. Андый җәмгыять үзе чыгара торган акцияләрен сатарга һәм аларга ачык подписка уздырырга хокуклы. ААҖ еллык исәп-хисапны, бухгалтерия балансын һәр ел саен игълан итәргә тиеш. Акцияләре алдан мәгълүм затлар — оештыручылар арасында гына тарала торган җәмгыять ябык АҖ (ЯАҖ) дип атала. Татарстанда икътисади реформа елларында АҖләр төрле җитештерү берләшмәләре, завод, фабрика, колхоз, совхозлар җирлегендә оеша. Шулардан иң эре җитештерү берләшмәләре: «Татнефть», «КамАЗ», «Түбәнкаманефтьхим», «Түбәнкамашин», «Оргсинтез», Казан авиация моторлары төзү з-ды. «Ак барс», «Аверс», «Заречье», «Экобанк», «Энергобанк» һ.б. акционерлык коммерция банклары оештырыла. 1999 га колхоз, совхозлар җирлегендә төрле типтагы 16 АҖ оеша. 2005 тә а.х.нда 29 АҖ һәм 357 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять (ҖЧҖ) эшли. Хосусыйлаштыру барышында эре пр-тие һәм берләшмәләр акцияләренең контроль пакеты (51%) ТРда дәүләт милке итеп беркетелә. Хакимиятнең башкарма идарәләре андый акцияләрнең бер өлешен пр-тиенең ышанычлы идарә җитәкчелегенә яки башка органнарга, инвестиция компанияләренә һ.б. тапшырырга мөмкин.

*Р.А.Борһанова.*

**А́КЦИЯ** (лат. actio — боерык-күрсәтмә, рөхсәт бирү, дәгъва итү), кыйммәтле кәгазь, аны тотучыга АҖ табышының бер өлешен дивиденд (керем) рәвешендә алырга, АҖ б-н идарә итүдә катнашырга хокук бирә. Ул А. хуҗасының АҖнең капиталына үз өлешен кертүен раслый. А. куллану тәртибе беренче мәртәбә Англия, Голландия һәм Франциядә 17 йөз башларында тәүге АҖ төзелә, Россиядә 19 йөз урталарында барлыкка килә. Бездә базар структуралары Европа илләреннән соңрак формалаша. 1930 елларда җитештерү чараларының җәмәгать милке булып әверелүе б-н А. СССРда үз әһәмиятен югалта һәм гамәлдән чыгарыла. Россиядә, ш.и. Татарстанда да, милекнең дәүләт карамагыннан чыгарылуы һәм дәүләт пр-тиеләренең күпләп АҖ итеп үзгәртелүенә бәйле рәвештә, 1990 еллар башында АҖләре яңадан барлыкка килә. А.нең төрле төрләре бар, гади һәм өстенлекле А.ләр аеруча киң таралган. Гади А. хуҗасы акционерлар җыелышында бер тавышка ия һәм ул аңа устав капиталындагы А.се күләменә тәңгәл рәвештә табыш алу хокукы бирә. А.гә хуҗа булу АҖ идарәсе карарларын кабул иткәндә йогынты ясау мөмкинлеге ача. Өстенлекле А. тавыш хокукы бирми, әмма, АҖ эшчәнлегендә финанс нәтиҗәләренең нинди булуына карамастан, дивиденд алу хокукын гарантияли. Бу керемнең күләме А.нең эмиссиясе вакытында билгеләнә һәм артырга да мөмкин, чөнки өстенлекле А. буенча дивиденд гади А.некеннән ким булмаска тиеш. Татарстандагы хосусыйлаштырылган пр-тиеләрнең өстенлекле А.ләре, Россиядәге кебек үк, аларның классик вариантыннан аерыла. Хосусыйлаштыру барышында өстенлекле А.нең ике тибы эмиссияләнә: «А тибы» хезмәт коллективлары әгъзалары арасында таратыла (аның буенча алдан билгеләнгән дивиденд түләнә, әмма гади А.некеннән ким түгел); «Б тибы»ның күләме «А тибы» А.сенә караганда билгеләнгән дивидендтан 2 мәртәбә кимрәк, әмма гади А.некеннән ким түгел. «Б тибы» А.сенә бары тик Дәүләт милке фонды гына ия була ала. Саткан вакытта алар гади А.ләргә конверсияләнә. А.нең үзгәртелгән һәм үзенә генә хас вариантлары булуы мөмкин. Хосусыйлаштыру вакытында аеруча әһәмиятле дәүләт пр-тиеләре «алтын» А.ләр б-н эмиссияләнә. Алар пр-тиедә берәр данә генә чыгарыла, дәүләт милке булып кала һәм акционерлар җыелышында аеруча мөһим карарлар кабул ителгәндә «вето» хокукы бирә. А.ләр номиналь, эмиссион һәм базар яисә курс бәясе б-н билгеләнә. ТРда сатып алу һәм сату, базар бәясе курсын формалаштыру А.ләре эре акционерлык пр-тиеләренең «Казан фонд сәүдәсе советы» фонд биржасында гамәлгә ашырыла. Тотрыклы производстволары булган һәм конкуренциягә сәләтле продукция эшләп чыгара торган «Татнефть», «Түбәнкамашин», «Түбәнкаманефтьхим», «Органик синтез» һ.б. АҖ пр-тиеләренең А.ләренә ихтыяҗ аеруча зур. «Түбәнкамашин» АҖ А.ләре Россия сәүдә системасына (РТС-2), «Татнефть» А.ләре Лондон һәм Нью-Йорк фонд биржасының сәүдә системасына кертелгән.

*Әд.:* Политическая экономия. М., 1972; Большой экономический словарь. М., 1997.

*Р.А.Борһанова.*

**«АКЧА́»**, Уфа шәһәрендәге нәшрият. 1905–07 еллар рев-циясе чорында эшли, татар телендә фольклор җыентыклары, әдәби һәм тарихи истәлек китаплары чыгара. Үзенең басмаханәсе булмый, заказларын шәһәрдәге шәхси һәм губерна идарәсе матбагаларында бастыра. Китаплар сату б-н дә шөгыльләнә.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; ш у л у к. Становление и развитие татарской советской книги (1917–1987). К., 1989.

**АКЧА́ РЕФО́РМАСЫ**, акча әйләнешен тәртипкә салу һәм ныгыту максаты б-н илдә акча системасын тулысынча яки өлешчә үзгәртеп кору. А.р. уздыру, барыннан да элек, инфляциянең социаль-икътисади нәтиҗәләренә бәйле.

Илнең икътисади һәм халыкара хәленә, акча бәясенең төшү дәрәҗәсенә һәм дәүләтнең эчке сәясәтенә карап, А.р. төрле ысуллар б-н гамәлгә ашырыла һәм төрле максатларны күздә тота: аның төре үзгәртелү б-н яңа акча системасына, мәс., көмеш монометаллизмыннан алтын монометаллизмына, алтынга ваклана торган акчалардан ваклanмаучы кредит акчаларына күчүгә; акча системасын өлешчә үзгәртүгә, мәс., акча берәмлеге һәм хасиятенең төрен, исемен, акча әйләнешен гамәлгә ашыручы органнарны һ.б. үзгәртүгә юнәлтелгән булуы да мөмкин. А.р.ның төп ысулы — нуллификация (гамәлдән чыгару) — дәүләтнең кыйммәте төшкән кәгазь акчалары гамәлдән алына һәм ваклана торган тотрыклы алтын тәңкәләр чыгару турында игълан ителә (алтын стандарт вакытында).

Акча әйләнешенең тотрыклылыгын тәэмин итү максатларында А.р.ның мөстәкыйль рәвештә яисә акча деноминациясе б-н бер үк вакытта уздырылуы да ихтимал — акча знагына куелган бәянең билгеле бер нисбәттә яңага үзгәртелеп алмаштырылуы, бер үк вакытта һәм шул ук нисбәттә бәяләрнең, тарифларның, хезмәт хакларының яңадан хисапланылуы һ.б.

Озакка сузылган инфляция шартларында акча әйләнеше тәэмин ителә алмаганда, А.р. урынына, гадәттә, акча ихтыяҗын акча-кредит һәм салым механизмнары аша бәяләрне, хезмәт хакын һ.б. чараларны эченә алган инфляциягә каршы комплекслы дәүләт программасы гамәлгә кертелә.

Россия акча әйләнеше тарихында төрле А.р. уздырыла: 1704 елда Пётр I тарафыннан унарлыклы кәгазь акча системасы кертелә. Императрица Екатерина II вакытында, хәрби чыгымнарны каплау һәм күп санлы авыр бакыр акчалар таләп ителә торган исәпләүләрне җиңеләйтү өчен 1769 елда ассигнацияләр (кәгазь акча) чыгаруның Россия акча системасы өчен әһәмияте зур була. 100, 75 һәм 25 сумлык кәгазь акчалар хөкүмәт тарафыннан С.-Петербургта һәм Мәскәүдә оештырылган махсус банкларга салынган бакыр тәңкәләр б-н тәэмин ителә.

1839–43 тә Россиядә көмеш монометаллизмын законлаштыручы А.р. уздырыла. Ул ассигнацияләнгән сумны девальвацияләү б-н гамәлгә ашырыла һәм көмеш бер тәңкәнең кыйммәте 3 сум 50 тиенлек акча бәясе б-н билгеләнә. 1841 дә 50 сумлык кредит билетлары чыгарыла, алар көмеш һәм вак акчалар б-н беррәттән әйләнештә йөри.

Көмеш монометаллизмы артта калган икътисад һәм түләү балансы дефициты шартларында сумның тотрыклылыгын тәэмин итә алмаган. Шуңа күрә 1895–97 дә Россиядә алтын монометаллизмын урнаштыру буенча А.р. уздырыла (ул вакытта алтын стандарты күп кенә алдынгы илләрдә киң таралган). 0,774234 *г* саф алтыннан ясалган алтын тәңкә Россиядә төп акча системасын тәшкил итә, кредит билетларын (банкнотлар) 1,5:1 нисбәтендә алтынга иркенлә алмаштыру кертелә. Кредит билетларын алмаштыруны уздыру максатларында аларның алтын б-н тәэмин ителеше Россия Дәүләт банкы уставы б-н рәсмиләштерелә. 5 һәм 10 сумлык алтын тәңкәләр сугыла. Яңа банк билетлары чыгару хөкүмәттәге алтын запасы б-н чикләнә. Алтын акчалар стандарты Россиядә акча системасының чагыштырмача тотрыклы булуына һәм милли валютаның абруе ныгуына яр-

дәм итә. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, алтын акчалар әйләнештә йөрүдән туктатыла, кәгазь акчаларны алтынга алмаштыру да бетерелә, кулланылышта кәгазь акчалар гына кала.

Окт. рев-циясеннән һәм Гражданнар сугышыннан соң сумның кыйммәте төшә, шул хәл акчасыз товар алмашуның үсүенә китерә. Яңа икътисади сәясәткә (НЭП) күчү б-н, акча әйләнешен тотрыклыландыру өчен 1922–24 тә А.р. уздырыла. Шул чакта кабул ителгән акча системасы Сов. Союзы таркалганга кадәр гамәлдә була. Ул деноминациядән, акча берәмлеген эреләндерүдән һәм акча знакларында күрсәтелгән номиналь бәяне киметүдән башлана. 1922 дәге деноминация яңа үрнәктәге 1 сумлыкны — элеккеге 10000 сумлыкка, 1922 дәге 100 сумлыкны 1923 тә 1 сумлыкка тигезли.

Дәүләт банкы тарафыннан 1922 дә 25%ы — затлы металлар һәм тотрыклы чит ил валюталары, 75%ы җиңел реализацияләнә торган товарлар һәм вексельләр б-н тәэмин ителгән ун сумлык кәгазь акча әйләнешкә кертелә. Бер үк вакытта бюджет дефицитын каплау өчен совет акча берәмлекләре (знаклары) чыгарыла. Рев-циягә кадәрге ун сумлыкны эмиссияләү б-н 1 сумлык бәясендәге алтын авырлыгының чагылышын торгызу А.р.ның беренче этабында иң мөһим элементларның берсе була. 1923 тә кәгазь акчалар чыгару б-н бер үк вакытта 10 сумлык алтын тәңкәләр дә сугыла. 1924 тә илдә 10 сумлык алтын тәңкәләрнең 90% чамасы әйләнештә йөри. 1924 нең февралендә казначылык билетлары чыгарыла башлый. Ул акчалар алтын б-н тәэмин ителмәгән, шуңа күрә алар өчен эмиссия чикләмәсе билгеләнгән. Әйләнештә көмеш илле тиенлекләр барлыкка килә (1927 гә кадәр сугыла), бер тәңкәлек (1924 кә кадәр генә сугыла), ш.у. 20; 15 һәм 10 тиенлек көмеш (1931 гә кадәр сугыла) һәм 5; 3; 2; 1 тиенлек бакыр акчалар сугыла. 1925–28 дә ярты тиенлекләр сугыла.

Совет акчалары сатып алу юлы б-н әйләнештән алына: 1923 тә чыгарылган 50 мең сумлык акча знаклары 1 сумга алмаштырыла. 1924 нең 10 апреленнән совет знакларының әйләнештә йөртелүе туктатыла. 1922–24 елларда А.р. уздыру этабы тәгәлләнгән дип санала.

«Акча реформасы уздыру һәм азык-төлек, сәнәгать товарларына карточкаларны бетерү турында»гы 1947 ел 14 декабрь карары б-н иске акча знаклары яңа чыгарылган акчаларга алмаштырыла һәм тупланган акчалар яңача бәяләнә: иске 10 сумны яңа 1 сум нисбәтендә алмаштыру бер атна эчендә уздырыла. Саклык кассаларындагы 3 мең сумга кадәр булган кертемнәр яңача бәяләнми. 3 меңнән 10 меңгә кадәрге кертемнәр — 3:2, ә 10 меңнән артканда — 2:1 нисбәтендә бәяләнә. Дәүләт заём облигацияләре 3:1 нисбәтендә бәяләнә. Дәүләт оешмалары һәм пр-тиеләрнең акча средстволары яңача бәяләнми, ә кооператив пр-тиеләрнең һәм оешмаларның, ш.у. колхозларның акча средстволары иске 5 сум яңа 4 сум исәбеннән бәяләнә. 1947 елгы реформа акча системасының элекке структурасын тулысынча саклый. Аерма шунда гына, СССР Дәүләт банкы билетлары алтын ун тәңкәләр урынына кәгазь ун сумлыклар буларак чыгарыла башлый.

СССР Югары Советының 1961 нең 1 гыйнварындагы карары б-н илдә А.р. уздырыла: моңарчы әйләнештә йөргән ун сумлык акчалар яңасы б-н 1 сумлык нисбәтендә алмаштырыла. Шул ук вакытта товарларга, хезмәт күрсәтүләргә, керемнәрнең барлык төрләренә, түләү йөкләмәләренә һ.б. бәяләр 10 мәртәбә төшерелә. Чит ил валюталарына тәңкәнең кыйммәте күтәрелә.

1992 дә СССР таркалганнан соң, беренче Россия банкнотлары Сов. Союзы банкнотлары б-н беррәттән әйләнештә йөри. «Россия Федерациясенең акча системасы турында»гы 1992 нең 25 сентябрендәге Федераль законы буенча акчалар әйләнеше камилләштерелә. Әлеге законда Россия акчаларының элеккеге СССР илләрендә дә, РФ б-н төзелгән шартнамә нигезендә файдаланылуы әйтелә. РФ Үзәк банкы 1993 нең 26 июлендә СССР Дәүләт банкы һәм РФ Банкы тарафыннан 1961–92 дә чыгарылган акчаларны куллланудан алу һәм аларны РФ Үзәк банкының 1993 елгы акчаларына алмаштыру турында карар кабул итә. Илдә акча берәмлеге 1000:1 нисбәтендә деноминацияләнгәннән соң, 1998 нең 1 гыйнварыннан РФ банкының 1997 елдагы акчалары әйләнештә йөри. Россиядә акча системасы «РФ Үзәк банкы (Россия банкы) турында» 1995 нең 12 апрелендәге Федераль законда билгеләнгән хокукый нигезләргә таянып эш итә.

*Әд.:* Юхт А.И. Русские деньги от Петра I до Александра I. М., 1994; Белоусов В.Д. Денежные реформы России. Самара, 1995; Нечаев Г.М. Деньги России. Омск, 1996; Юровский Л.Н. Денежная политика Советской власти. М., 1996; Финансы, денежное обращение и кредит. М., 2000.

*Н.Г.Харисов.*

**АКЧАРЛА́К КОШЛА́Р** (Laridae), шөлдисыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 88 төре билгеле. ТРда 17 төре: күл акчарлагы (Larus ridibundus), көмеш акчарлак (Larus fuscus), кара крачка (Chidonias niger), кече крачка (Sterna albifrons) һ.б. Сулыкларда (сусаклагыч, елга, күл, буаларда) яшиләр. 9 төре күченү вакытында гына күренә, 8 төре оя кора. Тыгыз тәнле, йомыркасыман, озынлыгы 17 дән алып 55 *см* га, авырлыгы 55 *г* нан 800 *г* га кадәр. Зур кошлар арасында ак, соры, кара төстәгеләре күпчелекне тәшкил итә. Томшыгы туры, яннан нык кысылган һәм очы ыргактай кәкре. Озаклап очу өчен җайлашкан озын канатлы. Койрыгы киң, кыска. Яхшы йөзә. Каурыйлары тыгыз, суга чыланмый. Утрауларда оя коралар (к. *Күл акчарлаклары колониясе*). Ояларын кипкән куралар арасында яки түмгәкләрдә ясыйлар. Ояда 2–3 саргылт-яшел яки кызгылт-көрән йомырка була. Ата һәм ана А.к. алар өстендә утырып бәбкә чыгара. Күбесенчә балык, ш.у. бөҗәк, бака, моллюсклар б-н тукланалар. 5 төре: карабашлы шаркылдавык акчарлак (Larus ichthyetus), кечкенә акчарлак (Larus minutus), шаркылдык акчарлак (Larus cachinnans), ак яңаклы крачка (Chlidonias hybrida), кече крачка ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**АКЧИШМӘ́** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 27 *км* төньяктарак, Хәтнә елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 252 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. 17 йөздә нигез салына. 1939 ның 16 июненә кадәр Татар Буклаучы дип йөртелә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Пөшәңгәр-Баклауш авылы буларак та билгеле. 18 — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.дә мәчет, 1908 дә вак-төякләр кибете була. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 387,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 33 ир заты; 1859 да — 166, 1878 дә — 225, 1885 тә — 264, 1897 дә — 312, 1908 дә — 271, 1920 дә — 336, 1926 да — 386, 1949 да — 332, 1958 дә — 312, 1970 тә — 370, 1979 да — 274, 1989 да — 237 кеше.

**АКЧИШМӘ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 91 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп. 1907–09 да нигез салына. 1917 гә кадәр А. авылында мәчет була. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 146, 1938 дә — 268, 1949 да — 264, 1958 дә — 270, 1970 тә — 159, 1979 да — 130, 1989 да — 68 кеше.

**АКЧИШМӘ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 31 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бөгелмә Зәе елгасының уң кушылдыгы Ямаш суының югары агымы буенда. 2002 елда 13 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда Бишмунча авылыннан чыккан кешеләр нигез сала. ТАССРның Бөгелмә кантонына керә. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1938 дә — 181, 1949 да — 185, 1958 дә — 150, 1970 тә — 139, 1979 да — 101, 1989 да — 26 кеше.

**АКЧИШМӘ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнбатыштарак. Ушма елгасы буенда. 2002 елда 56 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.дә мәчет һәм селте-поташ з-ды була. 20 йөз башында 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 400 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Ма-

мадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 167, 1897 дә — 210, 1908 дә — 240, 1920 дә — 281, 1926 да — 305, 1938 дә — 299, 1949 да — 246, 1958 дә — 151, 1970 тә — 166, 1979 да — 121, 1989 да — 67 кеше.

**АКЧИШМӘ́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ютазы елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 46 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 еллар башында нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән — Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 228, 1938 дә — 205, 1949 да — 204, 1958 дә — 192, 1970 тә — 184, 1979 да — 108, 1989 да — 65 кеше.

**АКЧУРА́** (Акчурин) Йосыф Хәсән улы (29.11.1876, Сембер ш. — 11.3.1935, Истанбул ш.), сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, журналист. Сембер губернасы сәүдәгәрләре *Акчуриннар* нәселеннән. Әтисе вафатыннан соң (1878), әнисе Бибикамәрбану б-н (Казан фабриканты А.Юнысов кызы) берникадәр вакыт Кырымда әтисенең якын туганы Зөһрә Акчурина-Гаспринская гаиләсендә яши. 1883 елда А. Истанбулга китә, анда махсус мәктәптә һәм югары хәрби уку йортында (1888–96) белем ала. Шул елларда берничә мәртәбә Россиядә һәм туган төбәгендә була. 1896 да өлкән лейтенант дәрәҗәсендә штаб офицерлары курсына укырга керә. 1897 дә Каһирәдә төрек телендә нәшер ителгән «Мосаувәр мәгълүмат» г-тасында «Шиһабетдин Мәрҗани» исемле беренче мәкаләсен бастыра. «Хәрбия»дә уку елларында ук солтан Габделхәмид II идарәсеннән, аның халыкны җәберләвеннән канәгать булмаган ирек сөюче бер төркем югары катлау яшьләре хәрәкәтенә тартыла. «Яшь төрекләр» хәрәкәте әгъзалары кулга алынгач, солтан әмере б-н А. 1897 дә Триполи (төрекчә Траблис) шәһәренә гомерлек сөргенгә озатыла. 1899 да сөргеннән кача, Парижга килеп урнаша. 1899–1903 тә анда Ирекле сәясәт гыйлеме мәктәбендә укый, Сорбонна ун-тының Гамәли фәннәр югары мәктәбе лекцияләренә йөри. Анда сәясәт, фәлсәфә, социология, тарих һ.б. фәннәрне өйрәнә. Шул елларда Парижда нәшер ителгән «Мөшәвәрәт» («Киңәшү») һәм Каһирәдә чыгучы «Шура-и өммә» («Җәмәгать киңәше») г-таларында мәкаләләрен бастыра. 1903 тә «Тәрҗеман» г-тасы чыга башлавына 20 ел тулу уңаеннан С.Максуди б-н бергә шул юбилейга багышлап Женевада 100 данә махсус брошюра бастыра һәм аны Төркия, Россия зыялылары арасында тарата. 1904 тә А. Россиягә — Акчуриннарның төп нигезе булган Зөябаш авылына кайта (рәсми теркәлеше: Сембер губ., Сөнгәләй өязе Иске Тимошкино а.). Акчуриннарның сәүдә-сәнәгать ширкәте аңа мирас өлеше бүлеп бирә. Шул ук елда Каһирәдә төрекчә нәшер ителгән «Түрк» г-тасында беренче сәяси-теоретик хезмәте «Өч тарыз вә сәясәт» («Сәясәттә өч юл») берничә санда басыла. Автор, Госманлы империясенең (Төркиянең) киләчәге «гражданлык» б-н «ислам» нигезләренә түгел, ә миллилеккә корылган булырга тиеш, дигән фикерне алга сөрә. 1904 нең көзендә А. Казанга килә. «*Мөхәммәдия*» мәдрәсәсе мөдәррисе Г.Баруди аны тарих һәм геогр. фәннәрен укытырга билгели. 1905 тә С.Алкин «*Казан мөхбире*» г-тасын чыгаруга рөхсәт ала, җаваплы сәркәтип вазифасына (мөхәррирлеккә) А.ны чакыра. А. бер үк вакытта «Әлислах», «Вакыт» г-таларында да язышa. 1906 да аның «Голүм вә тарих» исемендә лекцияләр җыентыгы басыла. А. анда тарихның чын фән буларак башка фәннәргә тиң булуын исбатларга тырыша.



Йосыф Акчура.

А. — җәдитчелекнең либераль канаты тарафдары. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче, 2 нче, 3 нче корылтайларын оештырып, әйдәп йөрүчеләрнең берсе. 3 нче корылтайда кабул ителгән рәсми кәгазьләрне әзерләүче сәркәтип буларак сайлана. Корылтай карары нигезендә «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясе оештырыла, А. аның ҮК на сайлана, устав һәм программаларын эшләүчеләрнең берсе була. Бер үк вакытта Россия кадетлар партиясенең Казан ком-ты әгъзасы була, шул партиянең 2 нче корылтаенда катнаша, аның да ҮК әгъзасы итеп сайлана (1906 ел, гыйнв.). Дәүләт Думасында кадетлар б-н «Иттифакъ әл-мөслимин» вәкилләренең үзара мөнәсәбәттәшлек итү тарафдары. Казанда А. полиция күзәтүе астында яши. 2 нче Дәүләт Думасына сайлаулар алдыннан берничә айга төрмәгә ябыла. 1908 дә Россиядән кабат Төркиягә китә. Анда аны зур үзгәрешләр көтә: солтан тәхеттән куылган, хакимияткә конституциягә нигезләнгән идарә тарафдарлары килгән. Истанбулда А. «Төрек учаклары» хәрәкәтен һәм «Төрек йорты» ж-лын (1911) оештыруда катнаша, журналның әйдәп баручы мөхәррирләреннән була. Бер үк вакытта Истанбул ун-тында һәм хәрби уку йортларында сәясәт тарихы һәм яңа чор тарихы фәннәреннән дәрес бирә. Төркия мөстәкыйльлеге өчен көрәш барган елларда Мостафа Кәмал Ататөрек тарафдары була, Төрек Җөмһүрияте (Респ-касын) төзүдә катнаша. 1923 тән — Олуг Милли Мәҗлес депутаты, президент К.Ататөрекнең мәдәният һәм сәясәт мәсьәләләре буенча киңәшчесе. Истанбул һәм Әнкара ун-тлары профессоры. Төркиядә Тарих җәмгыятен оештыручы һәм аның беренче рәисе (1931 елдан). 1932 дә Төркия тарихчыларының 1 нче конгрессы ачыла, К.Ататөрек тәкъдиме б-н А. анда рәислек итә.

Х е з м.: Дамелла Галимҗан әл-Баруди, тәрҗемәи хәле. К., 1904; Өч тарыз вә сәясәт. Каһирә, 1904; Голүм вә тарих. К., 1906; Дин моназаралараында иркенчелек хакында. К., 1906; Мәүкуфият хатирәләре. Оренбург, 1907; Өченче июнь вакыйгаи мөәссәфәсе. Оренбург, 1907; Тюркизм. Истанбул, 1928; Ug tarzi siyaset. Ankara, 1976; Turkguluk ve dis Turkle. Istanbul, 1990.

*Әд.:* Т и м е р Ә. Бөек шәхесләребезнең берсе // Казан утлары. 1992. № 12; Н и г ъ м ә т у л л и н Э. Тоткынлыкта // Казан утлары. 1998. № 7; М у х а м е т д и н о в Р.Ф. Зарождение и эволюция тюркизма. К., 1996; Татарские интеллектуалы: исторические портреты. К., 2005; F r a n c o i s G e o r g e o n. Aux origines du nationalisme turc. Yusuf Akcura. P., 1980; S a d r i M a k s u d i Arsal. Dostum Yusuf Akcura // Turk kulturi. Ankara, 1997; T i m e r Ә. Yusuf Akcura. Ankara, 1987.

*Л.М.Айнетдинова.*

**АКЧУ́РИН** Алимҗан (Галимҗан) Кәлимулла улы (1895, Пенза губ. Югары Рахман а. — 1933, Мәскәү), партия эшлеклесе, шагыйрь. Казан өязендәге Кышкар мәдрәсәсен тәмамлый (1907), 1910–12 елларда Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә укый, шәкертләр хәрәкәтендә катнаша. 1914–15 тә Төркестанда мамык чистарту з-дында эшли. 1915 тә патша армиясенә алына; 1917–20 дә Кызыл Армиядә хезмәт итә. 1917–18 дә Чарҗауда эшләгән Бохара революцион трибуналы әгъзасы, 1918–19 да Төркестан ҮБК һәм Төркестан АССР Тышкы эшләр комис-тының баш коллегиясе әгъзасы. 1920–26 да Харәзем, Бохара ССР Коммунистлар партияләре ҮКләрының 1 нче секретаре. 1926–28 дә ТАССР финанс халык комиссары урынбасары. 1930 дан Ташкент ВКП(б) тарихы фәнни-тикшеренү ин-тында гыйльми хезмәткәр. Казанда яшәгән вакытта иҗат итә башлый, 1913–16 елларда лирик шигырьләре «Сөембикә», «Шура» ж-лларында, «Йолдыз» г-тасында басыла. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов әсәрләрен тәрҗемә итә. Ике Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Воспоминания о двадцатом годе в Хиве и Бухаре. Таш., 1930; Ш а р а ф у т д и н о в Д. Акчурин А.К. // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

**АКЧУ́РИН** Әнвәр Гафур улы (28.4.1944, Казакъстан ССРның Урал өлкәсе Чапаев р-ны Битек а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1979), проф. (1982). СССРның атказ. уйлап табучысы (1983). 1965 елда Саратов а.х. механикалаштыру ин-тын тәмамлый. 1967 дән РСФСРның Көньяк-Көнчыгыш а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында (Саратов ш.). 1970–79 да Казакъстан ССРның А.х.н механикалаштыру һәм электрлаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында, 1979–83 тә Казакъстан ССР «Госкомсельхозтехника»сының Хезмәтне фәнни оештыру һәм җитештерү б-н идарә итү үзәге директоры. 1983–2000 дә Усть-Каменогорск юл төзү ин-тының Алма-Атадагы гомумтехника ф-тында каф. мөдире. 2000 нән Казакъстан Президенты каршындагы Дәүләт идарәсе академиясендә эшли. Хезмәтләре мәгълүмат һәм хисаплау техникасына, машиналарның техник төзеклеген сүтмичә тикшерүгә, җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлаштыруга карый. уйлап табуга 10 нан артык авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Механизация процессов управления в сельском хозяйстве. А.-А., 1975; Опыт диспетчерского управления в хозяйстве. М., 1981; Техническая диагностика сельскохозяйственных машин. А.-А., 1981.

**АКЧУ́РИН** Рәсим Сөләйман улы (3.1.1932, Үзбәкстан ССР, Ташкент өлкәсе Яңа Юл р-ны Зәңки Ата а.), ген.-полковник (1990). Сов. Союзы Маршалы Г.К.Жуков исем. Һава һөҗүменнән саклану хәрби командирлар академиясен (1970, Калинин ш.) тәмамлый. 1954–65 елларда Төркестан Һава һөҗүменнән саклану гаскәрләрендә, 1970–73 тә Мәскәү хәрби округында, 1973 тә Һава һөҗүменнән саклану көчләре корпусы зенитлы ракета гаскәрләре башлыгы (Горький ш.). 1974–82 дә Һава һөҗүменнән саклану корпусы командиры урынбасары, корпус командиры (Ярославль ш.), бер үк вакытта Ярославль гарнизоны башлыгы. 1983 тән Мәскәү хәрби округында һәм 1985–92 дә СССРның Һава һөҗүменнән саклану көчләре карамагындагы зенит-ракета гаскәрләре командующие. Кызыл Байрак, 1 нче, 2 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АКЧУ́РИН** Ренат Сөләйман улы (2.4.1946, Үзбәкстан ССР, Әндиҗан ш.), хирург, РМФА академигы (1997), Башкортстан Респ-касы ФА академигы (1997), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1999). 1971 елда Мәскәүдәге 1 нче мед. ин-тын тәмамлый. 1973 елдан СССР МФА нең Хирургия фәнни үзәгендә, 1984 тән РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм мед. сәнәгатенең Россия кардиология фәнни-җитештерү комплексында йөрәк-кан тамырлары хирургиясе бүлеге җитәкчесе, 1991 дән — проф. Хезмәтләре реконструктив һәм пластик микрохирургиягә — очлыклар, коронар артерияләр хирургиясенә, йөрәкнең ишемия авыруларын һәм ритмы бозылуын хирургик дәвалауга, миокардны саклауга, лазерлы ангиопластикага, аорта һәм аның тармакларын, мультифокаль атеросклероз авыруларын хирургик дәвалауга; онкологик авырулар хирургиясендә заманча технологияләр куллануга карый. А. тарафыннан ампутацияләнгән аяк-кулларны савыктыру технологиясе эшләнә һәм БДБ илләренең дәвалау учреждениеләрендә гамәлгә кертелә. Эндартерэктомия кулланып реконструкцияләнгән артериаль сегментларда тамыр протезлары үткәрүчәнлеген, ш.у. дислипопротеидемик ярсынулар дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, коронар шунтларны, микрохирургия техникасын файдаланып, катлаулы коронар аутоартериаль шунтлар куюның яңа ысулларына бәйле тикшерүләр үткәрә. Үзе уйлап тапкан микроинструментлардан файдаланып (Казанда җитештерелә), коронар артерияләрдә йогышлы авырулар китереп чыгармыйча гына оператив дәвалау тактикасын һәм техникасын, ш.у. коронар артерияләрдә реконструктив операцияләр ясау ысулларын гамәлгә кертә. СССРда беренче булып «йөрәк-үпкә» комплексын йөрәк-үпкә зәгыйфьлеге кичерүче авыруга күчереп утырта; ирекле мускул трансплантантын кулланып, кардиомиопластика операциясен башкара, миокардны кисәтүдә коронар синустан файдалана, бөер артерияләрендә һәм аяклар кан тамырларында микротамырларга операцияләр, ш.у. РФ президенты Б.Н.Ельцин йөрәгенә операция ясый. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. А. Кардиологлар фәнни җәмгыятендә ангиологлар секциясе рәисе, М.Дебейка исем. хирурглар башкарма ком-ты әгъзасы, Россия йөрәк-кан тамырлары хирурглары фәнни җәмгыятенең идарә президиумы әгъзасы. СССР һәм РФ Дәүләт бүләкләре лауреаты (1982, 2004). «Почёт билгесе» (2002) ордены б-н бүләкләнә.



Рәсим С. Акчурин.



Ренат С. Акчурин.

Х е з м.: Реконструктивная микрохирургия беспалой кисти. М., 1984; Болезни сердца и сосудов: Руководство для врачей. М., 1992. Т. 2 (автордаш).

**АКЧУ́РИН** Фәрит Измаил улы (10.7.1944, Казакъстан ССР, Гурьев ш.) авиация ген.-лейтенанты (2001), СССРның атказ. очучысы (1986). Качинск югары хәрби авиация уч-щесен (1966), Хәрби Һава көчләренең Ю.А.Гагарин исем. академиясен (1975, Мәскәү өлкәсе, Монино штп), Мәскәү авиация ин-тын (1980) тәмамлый. 1966–72 елларда очучы-инструктор, Качинск югары хәрби авиация уч-щесендә эскадрилья командиры урынбасары, 1975 елдан шунда ук эскадрилья командиры. 1976 дан авиация полкы (Волгоград өлкәсе) командиры урынбасары, 1978 дән Краснодар Югары хәрби авиация уч-щесендә полк командиры, 1984 тән Вяземск авиация үзәге башлыгы. 1987 дән СССР ДОСААФ очучылар әзерләү авиация уч-щесе (1988 дә Запорожье шәһәренә күчерелә, соңрак — очышка әзерләү үзәге, 2002 дә Бөтенукраина очышка әзерләү үзәге итеп үзгәртелә) башлыгы. 18 төрле очкыч һәм вертолётны сыный, барлыгы 6000 сәгатьтән артык очыш ясый. Реактив очкычларда югары пилотажлык буенча спорт мастеры.

**АКЧУ́РИН МОРЗАЛА́Р**, 15 йөздән мәгълүм татар бәк-морзалар нәселе. 15 йөзнең 2 нче яртысы — 16 йөз уртасында династия башында Адаш Акчура тора, 1509 елда ул бөек Мәскәү кенәзе кул астына хезмәткә күчә. Иван IV заманында аңа биләмәгә мордва җирләре бүлеп бирелә. 17–18 йөзләрдә А.м. нәселе вәкилләренең күпчелеге Пенза һәм Саратов төбәкләрендә яши. 18 йөз ахырында хәзерге Башкортстан җирләренә күчеп утыра башлый. 1779 да Оренбург губернасының Габдуллин а. (хәзерге Татарстан Респ-касы, Азнакай р-ны Илбәк а.) йомышлы татарлары, алар арасында морзалар Надырша, Үмрәк һәм Кадрәк Урмаевлар (Урамәтовләр) һәм А.м.ның балалары Уфа губ., Нугай даругасы, Юрмат волосте башкортларыннан җирләр сатып алалар, соңрак аларның нәселләре Батыр һәм Балыклы авылларында (хәзерге Башкортстан Респ-касының Фёдоровка р-ны) яши. Сенатның 1796 ел, 1 декабрь Указы б-н әлеге авылларда яшәүчеләр дворяннар нәселе кенәгәсенә кертелә. Кайберләренә морза дәрәҗәсе бирелә. 18 йөз ахырында Түбән Новгород губернасыннан морза А.Әхмәт гаиләсе яшәргә Бәләбәй өязенең Бүздәк авылына (хәзерге Башкортстан Респ-касының Бүздәк р-ны) күчә. 1795 елда Краснослободск өязенең Адай авылыннан Бәләбәй өязенең Яңа Калмаш авылына (хәзерге Башкортстан Респ-касы Чакмагыш р-ны) А.ның улы Хансуар Рәҗәп; 1814 тә А.ның улы Мухай Рәҗәп Иске Калмаштан күчеп килә. А.м.лар 19 йөз — 20 йөз башында ш.у. Краснослободск өязе Нөркәй, Яңа Аллагол, Рахмантамак (хәзерге Мордва Респ-касы), Саратов губернасы Кузнецк өязе Яковлевка, Пәндәлкә, Чертанлы, Дёмино авылларында (хәзерге Пенза өлкәсе) яшәгәннәр. Аларның барысы да дәүләт крәстияннәре сословиесендә калганнар. Танылган хәрбиләр, дипломатлар һәм дәүләт эшлеклеләре В.Г.Акчурин (1689–1760), С.В.Акчурин (1722–1790), ген.-полковник Р.С.*Акчурин*, хирург Р.С.*Акчурин* А.м. нәселенә карый. Сембер төбәге сәүдәгәр-фабрикантлары *Акчуриннар* да А.м. нәселеннән дип уйланыла.

*Әд.*: Бархатная книга. СПб., 1778. Ч. 1; Русский биографический словарь. СПб., 1886; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**АКЧУ́РИНА** Зөһрә Әсфәндияр кызы (1862, Сембер губ., Сөнгәләй өязе Зөябаш а. — 13.4.1903, Бакчасарай ш., Кырым), беренче татар хатын-кыз журналисты. Сембер төбәге сәүдәгәрләре Акчуриннар нәселеннән, И.Гаспринскийның хатыны. Татар хатын-кызлары арасында сирәк күренеш булган дөньяви (дини булмаган) белем ала. 1880 елда Кырымга баргач, И.Гаспринский б-н таныша. Аның б-н бергә Бакчасарай шәһәрендә «Тәрҗеман» г-тасын чыгаруда катнаша. А. газетаның беренче хезмәткәре була, үз акчасының шактый өлешен газетаны бастыруга тота. А. мәкаләләр яза, губерналар б-н элемтәгә керә, алардан килгән материалларны тәрҗемә итә, эш кәгазьләрен рәсмиләштерә, абунәчелек эшләрен оештыра. И.Гаспринский югында газетаны редакцияли. Туган авылындагы мәчеткә һәм мәдрәсәгә еш кына иганәлек кыла. Р.Фәхретдиннең «Мәшһүр хатыннар» дигән китабындагы бер бүлек А.га багышланган.

*Әд.:* И с х а к ы й Г. Исмәгыйль бәк, Зөһрә ханым // Ил. 1914. № 41–47; Х ә м и д у л л и н Л. Зөһрә йолдыз — Таң йолдызы // Сөембикә. 1996. № 3; Ю с у п о в А.И. Господа Акчурины. К., 1974.


*Л.Х.Хәмидуллин.*

**АКЧУ́РИНА** Мәхбүбҗамал (март, 1869, Саратов губ., Кузнецк өязе Димау а. — 1948, Баку ш.), язучы. Сембер төбәге сәүдәгәрләре Акчуриннар нәселеннән. 1908 елдан әсәрләре «Шура» һәм «Сөембикә» ж-лларында басыла башлый. Язмалары татар җәмгыятенең 20 йөз башындагы иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләренә — балалар тәрбияләүгә, татар хатын-кызының җәмгыятьтә тоткан урынына һ.б. багышлана. «Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә» (1914), «Шәфкатьсез ата яки мишәрләр тормышы» (1914) исемле хикәяләре тормыштан алынган реаль фактларга нигез-

ләнеп язылa. «Сәйфелмөлек», «Таһир белән Зөһрә» дастаннарын өйрәнеп, татар халык иҗаты әсәрләренең балаларны әхлакый һәм эстетик яктан тәрбияләүдәге әһәмиятен күрсәтә. 1929 да Бакуга күчеп китә, әдәби эшчәнлектән читләшә.

*Әд.:* Гайнуллин М. Татар әдипләре. К., 1978; Өмет йолдызлары. К., 1988; Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек. К., 2001.

**АКЧУ́РИНА** Хәдичә (19 йөз ахыры — 20 йөзнең 1 нче чиреге), татар хатын-кызларыннан беренче нәкышьче-рәссам, график. Строганов уч-щесендә (Мәскәү) белем ала. 1910 елларда Казанда чыккан «Ак юл» балалар ж-лы б-н хезмәттәшлек итә, рәсемнәрен «Х.А.» монограммасы б-н имзалаган дип санала. Авыл юлында, кулын маңгаена куеп, күтәрелеп килгән кояшка карап торучы малай рәсеме — «Ак юл» (№3) ж-лының эмблемасы А. тарафыннан ясалган дип фаразлана. Бу рәсем башка басмаларда да кабатлап басыла. Станлы нәкышь композицияләре, татар мәчетләре силуэтлары төшерелгән пейзаж, этюд, график рәсемнәр (мәс., «Көзге алдындагы татар кызы»), архит-ра һәм бизәк



Х.Акчурина. «Ак юл» балалар ж-лының тышлык рәсеме. 1913. №3.




Х.Акчурина. «Көзге алдындагы татар кызы». Рәсем. 1910-15.

мотивлары чагылыш тапкан виньеткалар авторы. 1915 тә «Аң» ж-лында А.га багышланган махсус мәкаләдә билгесез автор «аңа татар милләте зур өметләр баглый» дип яза. А.ның шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Санаигы нәфисә юлында милли адым (Хәдичә туташ Акчурина рәсемләре мөнәсәбәте белән // Аң. 1915. № 5; Урманче Б.И. Татарстанның сынлы сәнгате // Совет әдәбияты. 1960. № 10; Червонная С.М. Искусство Татарии. К., 1987.

**АКЧУ́РИННАР**, Сембер губернасы сәүдәгәр-эшмәкәрләре, Сембер губернасында постау җитештерүне оештыручылар, җәмәгать эшлеклеләре: 1) **Сафа Акчурин** (18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башы), сәүдәгәр А. династиясен нигезләүче, дәүләт крәстияннәреннән. Сату, сарык йоны җыю һәм аны постау мануфактуралары хуҗаларына сату белән шөгыльләнә; 2) **Габдулла Сафа улы** (? — 1848 тирәсе), әтисе эшен дәвам иттерүче; йонны ерак ярминкәләрдән кайтартып сатуны җайга сала; 3) бертуганнар: **Сөләйман Габдулла улы** (1802 — 30.11.1864), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан. А.дан беренче булып туган авылы Зөябашта (рәсми теркәлеше Сембер губ., Сөнгәләй өязе Иске Тимошкино а.) махсус җиһазлы постау ф-касы төзи (1849). 1860 еллар башында фабрикада 1420 ләп кеше эшли, елына 340 мең сумлык постау җитештерелә. Аның варислары 1864 елның ахырында «Акчурин хатыны һәм уллары сәүдә йорты»н оештыра; **Курамша Габдулла улы** (1796 — 17.7.1868), 1 гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан, Сембер губернасы Гурьевка авылында (хәзер Самара өлкәсе Барыш ш.) постау ф-касы хуҗасы. Башта йон б-н сәүдә итә. Гурьевкадагы постау мануфактурасын сатып ала, пар машиналары б-н җиһазлап, эре фабрикага әверелдерә. 1853 тә Сембер шәһәрендә мөселманнар өчен намаз уку йортын салдыра; 4) **Ильяс Габдулла улы** (? — ?), Зөябаш авылында 2 нче постау ф-касын төзүче; 5) **Хәсән Сөләйман улы** (? — 1878), атасы фабрикасының дәвамчы хуҗасы, Сембер губернасы фабрикант-сәүдәгәрләре җәмгыяте әгъзасы. Йосыф *Акчураның* атасы; 6) бертуганнар: **Тимербулат Курамша улы** (1826 — 19.9.1906), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан, Гурьевка (1908 дә 1715 кеше эшли) б-н Самайкино (1908 дә 804 кеше эшли) авылларындагы постау ф-калары хуҗасы. А.ның уртак пайлы ике зур ширкәтен оештыруда башлап йөрүче («Акчуриннарның Иске Тимошкино постау мануфактуралары ширкәте», 1892; «Тимербулат Акчуринның сәүдә-сәнәгать ширкәте», 1894). «Тырышлык өчен» алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә. 1865 тә Сембердәге намаз уку йортын чын мәчет рәвешенә китереп төзекләндерә; **Ибраһим Курамша улы** (1859 — 1933 (?), Уфа), фабрикант, Зөябаштагы 2 нче постау ф-касы хуҗасы, 1892 елда оешкан «Акчуриннарның Иске Тимошкино постау мануфактуралары ширкәтен» нигезләүчеләрдән. Сембер постау фабрикантлары җәмгыяте рәисе (1907), Сембер шәһәр думасы гласные һәм шәһәр управасы әгъзасы. Татарларның милли хәрәкәтендә, Бөтенроссия мөселманнары корылтайларының күпчелегендә, «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен оештыруда катнаша, Сембер мөселманнары җәмгыятен нигезли. Сембердә татар кызлары өчен дөньяви мәктәп ача. Совет хакимияте дәверендә эзәрлекләнә; 7) **Хәсән Тимербулат улы** (1866–1916), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан, 19 йөз ахырында А. оештырган ике сәүдә-сәнәгать ширкәтенең пайчысы. Мохтаҗ мөселманнарга һәм мәктәп-мәдрәсәләргә ярдәм итүче хәйрия оешмалары әгъзасы. Татар-болгарлар тарихына, тормыш-көнкүрешенә багышланган бай коллекция (борынгы әйберләр, кулъязмалар, китаплар, тарихи акчалар) туплый. Башлыча, Сембердә яши. 1914 тә бертуганнары Якуб һәм Абдулла б-н бергә Гурьевка авылында җәмәгать китапханәсе ачалар. А. иганәсенә Сембер һәм Самара губерналары авылларында мәчетләр салына, мәктәпләр ачыла. Ш.у.к. Й.*Акчура*, З.*Акчурина*, Х.*Акчурина*.



И.К. Акчурин.



Т.К. Акчурин.



Х.Т. Акчурин.

*Әд.:* Хәмидуллин Л. Акчуриннар // Шәһри Казан. 1997, март; Юсупов А.И. Далёкое и близкое. Ульяновск, 1969; шул ук. Господа Акчурины. К., 1974; Таиров Н. Ибрагим Акчурин: штрихи к портрету // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1996, № 1–2; шул ук. Духовное завещание Сулеймана Акчурина // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 3/4; шул ук. Духовное завещание Курамши Акчурина // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 3/4; шул ук. Акчурины. К., 2002.

*Н.И.Таиров.*

**АКЧУ́РИННАРНЫҢ КИТАПХАНӘ́-КЫЙРАӘТХАНӘСЕ́**, Сембер губернасының Карсун өязе Гурьевка бистәсендә (хәзер Барыш ш.) 1913 елда Хәсән, Якуб һәм Абдулла Акчуриннар тарафыннан урындагы туку ф-касы эшчеләре һәм җирле зыялылар өчен ачылган гавами китапханә, уку залы. Һәр кеше өчен бушлай булып, бөтен чыгымны Акчуриннар үз өсләренә алган. Китапларны өйгә алырга да рөхсәт ителгән. Фабрика контрасында эшләгән Булатов фамилияле хезмәткәрнең истәлекләренә караганда, китапханәнең китап фондын татар һәм рус телендәге әдәби әсәрләр, татар телендә чыккан барлык газета-журналлар («Шура», «Вакыт», «Казан мөхбире», «Тәрҗеман», «Ак юл» һ.б.), ш.у. русча «Нива», «Современник» ж-ллары, «Симбирские губернские ведомости» кебек көндәлек матбугат басмалары тәшкил иткән. Хуҗалар тарафыннан билгеләп куела торган мөдирне һәм аның ике ярдәмчесен Сембер губернаторы раслаган. Беренче мөдир — Габделхәй Кадыйрмәтов. 1917 дән эшен фабрика китапханәсе буларак дәвам

итә (мөдире — М.Алимбәкова, 1920 елларда — «Пролетарский путь» г-тасының эшче хәбәрчесе З.Шәмсетдинов).

*Әд.:* Таиров Н. Бесплатная библиотека-читальня Акчуриных // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1997. № 1/2.

*Н.И.Таиров.*

**АКЧУ́РИННАРНЫҢ ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘЛӘРЕ́**, Сембер губернасы сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре Акчуриннар нәселе вәкилләренең 1880 еллардан 20 йөзнең беренче унъеллыкларына кадәр тупланган хосусый китапханәләре.

**Ибраһим Курамша улы Акчурин (1859–1933) китапханәсе**, Сембер шәһәрендә беркатлы зур иркен йортның яртысын алып торган. Тупланмасы татар, рус, гарәп, француз, немец, төрек, фарсы, уйгыр һ.б. телләрдә басылган берничә мең китап, газета-журнал һәм кулъязма ядкәрләрне эченә алган. Матур әдәбияттан: И.С.Тургенев, М.Ю.Лермонтов, Г.И.Успенский, француз телендә А.Франс, Ги де Мопассан әсәрләре басмалары һәм күп кенә татар язучыларының китаплары; Н.Г.Чернышевскийның тыелган «Нәрсә эшләргә?» «(Что делать?») романы; әдәбият белеменә, медицина, иҗтимагый-сәяси, тарихи әдәбиятка нисбәтле басмалар, Ф.А.Брокгаузның немец телендә 16 томлык «Энциклопедик сүзлеге» (Берлин–Вена, 1892–95), Н.И.Ильминскийның «Хатлар»ы (1898), Д.И.Языковның «Вафат рус язучыларының тормыш һәм хезмәтләренә күзәтү» («Обзор жизни и трудов покойных русских писателей», вып. 1–6, СПб., 1881–86) сериясендә чыккан китаплары, Б.Аубахның рус телендә басылган «Рейндагы дача»сы («Дача на Рейне», М., 1907) һ.б.; Шәркыяткә нисбәтле кулъязма китаплар, 14–15 йөз төрки шагыйре Мирхәйдәрнең «Тимер белән кырмыска» («Аксак Тимер белән кырмыска») шигъри хикәяте, 11 йөз төрки шагыйре Йосыф Баласагуниның В.В.Радлов тәрҗемәсендә «Игелекле белем» («Котадгу белег») поэмасы басмасы һ.б. Китапханәдән Ибраһим Акчуринның туганнары (Хәсән Акчурин, Йосыф Акчура), дуслары (мәс., Зәки Вәлиди) һ.б. еш файдаланган.

1918 елда хосусый китапханәләр конфискацияләнгәч, китапларның бер өлеше башта Сембер губернасы китап саклагычына, аннары Ульянов өлкәсе фәнни китапханәсенә тапшырыла (50 гә якын исемдәге китап һәм вакытлы матбугат басмалары, альманахлар. Барысына да китапханә иясенең мөһере сугылган). Тупланманың зур өлешенең язмышы билгесез.

**Хәсән Акчурин китапханәсе**, Сембер губернасының Карсун өязе Гурьевка бистәсендәге (хәзер — Ульянов өлкәсенең Барыш ш.) өендә фабрикант Хәсән Тимербулат улы Акчурин (1866 — 1916) җыйган китап, кулъязма һәм акчалар коллекциясе. Берничә мең китап исәпләнгән. 1914 елда китапханә б-н танышкан Риза Фәхретдин болай яза: «Хәсән Акчуринда китап байлыгы, хосусән Европада басылган мөселман әсәрләре б-н язма китаплар әйтеп бетергесез. Аның борынгы акчалар коллекциясе шулкадәр байдыр ки, өстән генә карап бетерү өчен дә көннәр кирәк. Петербургтагы «Эрмитаж» коллекциясе Акчуриндагы акчаларның бик күбесенә ия түгелдер. Аның коллекциясендә гарәп, төрек, Мисыр хакимнәре, татар ханнары акчалары һәрберсе диярлек бардыр». Китапханәне үз вакытында Ф.Әмирхан, Г.Баруди, М.Бигиев, Г.Тукай, Й.Акчуралар да күреп белгән. 1916 да Х.Акчурин вафат булгач, китапханә варислары кулында кала. Революция башында (1917) китапханә һәм нумизмат коллекциясе җирле оешмалар тарафыннан кулга алына. Шуннан соңгы язмышы билгесез. Х.Акчуринның шәхси мөһере сугылган бердәнбер китап — Каюм Насыйриның «Гакаид рисаләсе» («Уку китабы») дигән уку әсбабы соңыннан Ульянов өлкәсе Иске Тимошкино (Зөябаш) авылы мәчетенең подвалында табыла.

**Маһруй Тимербулат кызы Акчурина китапханәсе**, Сембер губернасының Карсун өязе Гурьевка авылында. М.Акчурина Акчуриннар тарафыннан Гурьевкада һәм Зөябашта ачылган мәктәпләргә җитәкчелек итә, мәктәпләр өчен дәреслекләр бастыруга акчалата ярдәм күрсәтә. Китапханәсендә нинди китаплар һәм күпме санда булуы билгесез. Хуҗасының мөһере басылган бердәнбер китап — Г.Барудиның 1910 елда Казанда нәшер ителгән «Күркәм гыйбадәт» («Хөсн әл-гыйбадәт») дәреслеге табылган.


**Ирле-хатынлы Якуб һәм Мәргубә Акчуриннар китапханәсе**, Сембер губернасының Сөнгәләй өязе Зөябаш (Иске Тимошкино) авылында. Татар, гарәп, рус һ.б. телләрдә басылган китаплар тупланмасы. Китапханәдә булган китаплардан табылганнары: Н.Думавиның Оренбургта басылган «Безнең мәктәп» дәреслеге; Г.Мостафинның 1911 елда Казанда нәшер ителгән «Саулыкны саклау» дигән хезмәте; А.П.Барсуковның «Шереметевлар нәселе» («Род Шереметевых») дигән, 1895 елда Сембер гыйльми архив комиссиясенә бүләк итеп бирелгән китабы. Ш.у.к. *Акчуриннарның китапханә-кыйраәтханәсе.*

*Әд.:* Таиров Н., Таиров И. Акчуриннарның китапханәләре // Идел. 2001. № 4; Таиров Н., Таирова Г. В поиске книги // Татарстан. 1993. № 2; Таиров Н.И. Акчурины. К., 2002.

*Н.И.Таиров.*

**АКЧЫ́Л**, андромеда (Andromeda), арчанчалар семьялыгыннан агаччыл үсемлекләр ыругы. Бер төре — күп яфраклы А. (A. polifolia) Төньяк ярымшарның уртача зонасында киң таралган. ТР терр-ясендә Кама алдында очрый. Торфлы, мүкле сазлыкларда үсә. 15–30 *см* озынлыктагы, аз гына күтәренке сабаклы мәңге яшел куакчык. Яфраклары тар кыяклы, түбәнгә таба бөгелгән, куе яшел төстә өстән ялтырый, астан балавызсыман аксыл куник б-н капланган (исеме шуннан). Чәчәкләре алсу төстә, шарсыман, чатырчәчәк төркемендә. Җимеше — шарсыман тартмачык. Майда — июнь башында чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (күбесенчә тамырчадан) үрчи. Яфракларында гликозид һәм микроэлементлар бар. Халык медицинасында ревматизм, үпкә туберкулёзы авыруларын дәвалаганда файдаланыла. Яңа гына өзелгән яфракларын ярага куялар. Кәҗә һәм сарыклар өчен агулы. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**АКШУА́Т** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 24 *км* көнчыгыштарак, Кырым-Сарай елгасы буенда. 2002 елда 44 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык үрчетү. 18 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 елларда күн з-ды була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1185 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумороково волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 442, 1897 дә — 657, 1920 дә — 806, 1926 да — 529, 1938 дә — 340, 1949 да — 314, 1970 тә — 224, 1979 да — 151, 1989 да — 65 кеше. А. тирәсендә чишмәләр күп, кайбер урыннарда шарлавыклар бар.




Акшуат авылы янындагы чишмә.

**АКЪЕГЕ́Т** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 48 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы чигендә. 2002 елда 387 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Сәүдәгәр З.Ш.Шәфигуллин йорты — 19 йөз ахыры архит-ра истәлеге (мәчет буларак файдаланыла). 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманнар хезмәтендә була, игенчелек һәм терлек үрчетү б-н берәттән зәркән әйберләре эшләү, балта эше, итек тегү, кирпеч җитештерү, 1840 еллардан киез итек басу б-н шөгыльләнә. 1830 елгы мәгълүматларга караганда, А.тә мәчет була. 1872 дән аның каршында мәдрәсә эшли. 1890 да сәүдәгәр З.Ш.Шәфигуллин акчасына икенче мәчет һәм мәдрәсә, 1899–1900 дә — өченче мәчет, 1898 дә Казан губернасының Цивиль өязендә ир балалар өчен яңа ысул б-н укыта торган бердәнбер мәктәп, 1906 да кыз балалар өчен мәдрәсә төзелә, соңрак рус-татар мәктәбе итеп үзгәртелә. 1910 елларда бу уку йортларында укучыларның саны 442 кешегә җитә. 20 йөз башында А.тә 3 җил, 3 су, 1 пар тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1990,6 дис. тәшкил итә. 1896 га кадәр — Акъегет волостенең үзәге, 1896 дан Цивиль өязенең Яңа Кавал волос-



М. Акъегетзадә.



А. Акыш.

тена керә. 1920–21 дә Чуаш автономияле өлкәсендә, 1921 нең 22 сентябреннән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 223 ир заты; 1834 тә — 693, 1850 дә — 1044, 1859 да — 1163, 1897 дә — 2312, 1908 дә — 3101, 1926 да — 1300, 1938 дә — 1439, 1949 да — 815, 1958 дә — 725, 1970 тә — 796, 1979 да — 595, 1989 да — 432 кеше.

*Әд.:* Т и м е р ш и н И.Г. Акъегет авылы тарихы сәхифәләре. К., 2001.

**АКЪЕГЕТЗАДӘ́** (Акъегет, Акҗегетов) Муса Мөхәммәдҗан угылы (3.12.1864, Пенза губ., Чембар ш. — 24.9.1923, Истанбул), язучы, журналист, икътисадчы галим. Бабасы Алтынбай Акъегетов 1812 елгы Ватан сугышында күрсәткән батырлыгы өчен дворянлык дәрәҗәсе ала. Муса әүвәл этисенең туган авылы Өчәләйдә (Чембар өязе) татарча укый, аннары Чембарда (хәзерге Белинский ш.) рус мәктәбендә, соңыннан Пенза шәһәре гимназиясендә белем ала. 1884 елда гимназияне тәмамлагач, туган ягында мөгаллимлек итә. 1886 да Кырымга күчеп, «Тәрҗеман» г-тасына эшкә урнаша. 1888 дән А. Төркиядә. 1888–91 дә дәүләт оешмалары өчен югары белемле хезмәткәрләр әзерли торган «Мөлкия» мәктәбендә укый. Мәктәпне тәмамлагач, Истанбулдагы Югары хәрби мәктәптә һәм Хәрби академиядә рус теле һәм икътисад фәнен укыта, «Мәтен» («Асыл нөсхә»), «Өч кардәш» исемле г-талар нәшер итә, Измир һәм Сивас шәһәрләрендә җирле идарә оешмаларында эшли. 1914 тә Истанбулга кире кайтып, гомеренең ахырынача Казаннан сатып алынган Н.Ф.Катанов китапханәсендәге кулъязма һәм китапларны барлау, тәртипкә салу, каталогларын төзү эше б-н шөгыльләнә. А. татар әдәбияты тарихында беренче роман — мәгърифәтчелек реализмы юнәлешендә язылган «Хисаметдин менла» (1886) китабы авторы буларак билгеле. Язучы анда үз заманының татар тормышына кагылышлы күп мәсьәләләрне күтәрә, яңалыкка, белемгә омтылучы яшь геройлар аша милләтнең киләчәк язмышы турында кайгырта. Роман укучылар арасында зур уңыш казана, төрек теленә дә тәрҗемә ителә. Г.Ибраһимов А.не «татар реализмы әдәбиятының атасы» дип бәяли. А. нигез салган реалистик роман традицияләре соңга таба З.Бигиев, Ф.Кәрими, Р.Фәхретдин, Г.Исхакый һ.б.лар тарафыннан дәвам иттерелә. Фәнни-публицистик хезмәтләрендә А. Шәрекъ мәдәниятенең дөнья цивилизациясенә керткән өлеше турында кат-кат искәртә. Аның «Аурупа мәдәниятенең әсасына бер нәзар» («Европа мәдәниятенең нигезенә бер караш») исемле хезмәте Төркиядә аерым китап булып чыга, өзекләре *«Әлгасрелҗәдид»* ж-лында басыла (1906). Икътисад фәнен, аның классик вәкилләре Адам Смит, Давид Рикардо һ.б. галимнәрнең хезмәтләрен тирәнтен өйрәнү нәтиҗәсендә «Икътисад, яхуд Гыйльме сәрвәт» («Икътисад, яки баю гыйлеме», 1918) исемле монографиясендә кайбер икътисади тәгълиматларга фәнни-тәнкыйди анализ ясарга омтыла.

Ә с ә р.: Хисаметдин менла. К., 1886.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; М и ң н е г у л о в Х. Татар реализм әдәбиятының атасы // Татарстан. 1996. № 5; Ә й д и Т. Муса Акъегет Төркиядә // Казан утлары. 1996. № 4; Ө л к ә н Х.З. Муса Акъегет // шунда ук. 172–178 б.; Г а й н у л л и н М.Х. Татар әдипләре. К., 1978; Г а з и з у л л и н Ф.Г. Социально-экономическая мысль татарского народа как феномен его духовной культуры. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**АКЪЮ́Л** (Иштирәк) авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 14 *км* көнбатыштарак. 2002 елда 30 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1927 дә — 140, 1938 дә — 115, 1949 да — 124, 1958 дә — 88, 1970 тә — 80, 1979 да — 52, 1989 да — 40 кеше.

**АКЪЯ́Р** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2002 елда 427 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Ак Тау исеме б-н дә билгеле. 18 — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 да А.дә мәчет була. 20 йөз башында монда 2 мәчет, 2 мәктәп, су тегермәне, тимерче алачыгы, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4192 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Каргалы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 183 ир заты; 1859 да — 1113, 1897 дә — 1682, 1908 дә — 1926, 1920 дә — 2150, 1926 да — 1165, 1938 дә — 962, 1949 да — 675, 1958 дә — 528, 1970 тә — 589, 1979 да — 461, 1989 да — 406 кеше.

**АКЫ́Ш** (Akiş) Али (Агишев Алиулла) Хисаметдин улы (1.1.1918, Хайлар ш., Кытай), җәмәгать эшлеклесе, журналист, публицист. Хайлар шәһәрендә башлангыч мөселман төрки-татар мәктәбен (1929) һәм рус гимназиясен (1936) тәмамлый. 1930 еллар башында Хайларда «Төрки-татар җәмгыяте» эшендә катнаша. 1934 тән Европа илләре вәкилләренең «Идел-Урал» бәйсезлек комитеты»нда эшли. 1936 да Каһирәдәге Әл-Әзһәр ун-тына укырга керә, 1938 дә Варшавага китә һәм большевикларга каршы сәясәт алып баручы «Прометей» лигасында Г.Исхакыйның техник ярдәмчесе була. «Милли байрак» г-тасына мәкаләләр яза. 1940 тан Төркиядә: 1941–44 тә «Төрек мәдәнияте берлеге» конфедератив оешмасының «Идел-Урал» бүлеге әгъзасы; 1945–47 дә төрек армиясе офицеры, 1954–56, 1958–66 елларда НАТОның Әнкарадагы хәрби вәкиллеге бюросында тәрҗемәче. 1966 дан Мюнхенда, 2001 дән Әнкарада яши. 1966–83 тә «Азатлык» радиостанциясенең татар-башкорт редакциясендә (Мюнхен ш., Германия); Дөнья җәмәгатьчелегенең игътибарын СССРда яшәүче төрки халыкларның, бигрәк тә татарларның бәйсезлеге мәсьәләләренә юнәлтергә омтыла. Мәкаләләрен эмиграциядәге мөселманнарның «Türkiye» («Төркия») г-тасында, «Kırım («Кырым»), «Türk Yurdu» («Төрек йорты») ж-лларында бастыра, аларда СССР җитәкчеләренең милли сәясәтен тәнкыйтьли.

Ә с ә р.: Гаяз Исхакый: Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы // Казан утлары. 1994. № 2; Исемдә калганнар // Идел. 2000. № 1–2; İdil-Ural Davasi ve Sovyet Emperyalizmi. Ankara, 1963; İdil-Uralda Hürriyet Mücadelesi. Ist., 1985; Aklımda kalanlar: Hatıralar-Konuşmalar. Ankara, 2002.

*Әд.:* Б а р ы й Т. Гаяз Исхакый варисы // Мәдәни җомга. 1998. 30 янв.; Х ә й р и Ә. Гали батыр // Идел. 1999. № 12.

*Г.Р.Заманова.*

**«АК КҮБЕ́К»**, Алтай төркиләре һәм нугайларда таралган шул исемдәге дастанның Себер татарларындагы версиясе. Монгол яуларына кадәр яки Алтын Урда чорында барлыкка килгән, дип фаразлана. Бу хакта 14 йөз гарәп тарихчылары ән-Нүвәйри һәм Ибне Халдун хезмәтләренә кергән дастан сюжетының кыскартылган вариантлары сөйли. Беренче мәртәбә «А.к.» 19 йөзнең 60 елларында акад. В.В.Радлов тарафыннан язып алына һәм аның «Көньяк Себер һәм Җунгар даласында яшәүче төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи», 1866–99) исемле ун томлык хезмәтенә кертелә. Дастанның татар версиясен фәнни яктан тикшерү 1970 еллар ахырында башлана, шул вакытта аның беренче басмалары дөнья күрә. Дастан татар фольклорының күптомлы «Татар халык иҗаты» басмасына (т. 1–13, 1976–93) кергән.

«А.к.» эпик батыр Аккүбекнең Кидән (Кодән) хан һәм аның улы Маңгыш б-н көрәше турында сөйли. Маңгыш образының чыгышы төрки-монгол мифологиясенә бәйле. Ул анда төрле исемнәр б-н йөри (Мангас, Мангус, Мангыс), еш кына уңай геройның төп дошманы була һәм, гадәттә, җиңелә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Р а д л о в В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи, собранные В.В.Радловым.

СПб., 1872. Ч. 4; Урманчеев Ф. Героическое сказание «Ак Кубек» // Советская тюркология. 1977. № 3. *Ф.И.Урманчеев.*

**АЛ ГӨМБӘ́** (Russula), базидиаль гөмбәләр классындагы җәймәле гөмбәләр ыругы. 200 ләп төре билгеле, Евразиядә, Америкада, Австралиядә үсәләр. ТРда 12 төре очрый: ашый торган А.г. (R. vesca), зәңгәр-сары эшләпәле А.г. (R. cyanoxantha), соргылт эшләпәле А.г. (R. decolorans), саз А.г. (R. paludosa), сары эшләпәле А.г. (R. claroflava), зәңгәр эшләпәле А.г. (R. azurea) һ.б. Ылыслы һәм катнаш урманнарда июльдән сентябрьгә кадәр төркемләп үсәләр. Микориза ясаучылар. Эшләпәсе башта кабарынкы-яссы яки батынкы-җәелгән, соңрак, үсүенә карап — җәелгән, түгәрәк, яссы яки бүрәнкәсыман, уртада батынкы; диаметры 10 *см* га кадәр җитә. Соры-яшел, яшел, алсу-кызыл, куе кызыл төстә. Эшләпәсе йомшагыннан җиңел аерыла торган яры б-н капланган. Йомшагы уалучан, баллы яки ачы, сөтчел сыекчасы юк. Пластинкалары ачык, сабагы ак яки алсу төстә. Споралы порошогы ак яки аксыл-сары. Зәһәр А.г.дән (R. emetica) кала барлык төрләре дә ашарга яраклы.

**АЛ МӘЧЕ́Т** (10 нчы Җамигъ мәчет, Яшел мәчет), Казанда татар дини архитектурасы истәлеге. 1906 елда Яңа Татар бистәсе зираты янында милли романтика юнәлешенең эклектика стилендә төзелә. Архитекторы билгесез.

Бер заллы гыйбадәтханәнең җиргә утыртылган манарасы төньягында урнашкан. Турыпочмаклы кирпеч бина дүрт кыеклы түбә б-н ябылган. Гөмбәз түшәмле зал аслы-өсле ике рәт урнашкан а́ркалы тәрәзәләр аша яктыртыла. Залның өч як диварында (көньяктагысыннан кала) антресольләр урнашкан.



Ал мәчет.

Ишеге мәчетнең төньягында. Манараның аскы катында — вестибюль. Аңа көнбатыштан һәм төньяктан китек почмаклы ике янкорма тоташа. Ишектән керүгә, уң якта — антресольгә күтәрелү баскычы, ул манара эчендәге бормалы баскычка килеп ялгана, сул якта эш бүлмәләре урнашкан. Янкормалар аерым түбәләр б-н ябылган. Көньяк фасадтагы биш кырлы михраб чыгынтысы гыйбадәт кылу залы б-н а́ркасыман уем аша тоташа. Фасадлар Шәрекъ мотивлары өстенлек иткән эклектика стилендә бизәлгән. Тышкы почмакларында һәм тәрәзә араларында фасонлы кирпеч б-н башкарылган үзенчәлекле капительләре булган киң пилястралар урнашкан. Манараның шакмак рәвешендәге аскы өлеше өскә таба кисек пирамида формасын ала, аннан сигез кырлы ярус күтәрелә, аның өстенә куелган цилиндр рәвешендәге тагын да таррак ярус тирәли култыксалары чүкеп бизәкләнгән түгәрәк балкон урнаша. Иң югарыдагы ярус зиннәтле сталактит кәрниз б-н бизәлгән һәм алты кырлы сөзәк нигезгә утыртылган биек чатыр б-н төгәлләнә.

1931 дә А.м. ябыла. 1930 елларда манарасының чатыры сүтелә, 20 йөз ахырына балконга кадәрге өлеше генә сакланып кала. Совет дәверендә залы ике катлы итеп корыла, а́рка рәвешендәге тәрәзәләре зурайтыла һәм турыпочмаклы итеп үзгәртелә. Күп еллар дәвамында әлеге бинада «Точмаш» з-ды профилактория эшли. 20 йөз ахырында манарасы элеккеге хәленә кайтарыла.

*Әд.:* Халитов Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; Мечети Татарстана / Сост.: Х.Г.Надырова, Р.Р.Хайрутдинов, Р.Р.Салихов. К., 2000. *Х.Г.Надыйрова.*

**АЛА́ КЫЯ́К** (Molinia), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 3–5 төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Американың уртача һәм салкын пояслараында таралганнар. ТРда бер төре — зәңгәр А.к. (M.coerulea) Кама алдында һәм Көнчыгыш Кама аръягында очрый. Нарат урманнарында, киселгән урман аланнарында, торфлы җирләрдә үсә. 30–120 *см* озынлыктагы үсемлек. Кыска тамырчалы. Сабагы буынсыз, туры, шома. Яфраклары каты, тар, ак б-н әйләндереп алынган соргылт-яшел төстә. Яфрак кыякчыгы төбеннән үк диярлек төкләр рәтенә күчә. Себеркәчләре кысынкы, башакчыклары карасу-миләүшә төсендә. Шактый көпшәк кәс хасил итәләр. Июль–сентябрьдә чәчәк ата. Декоратив; терлек азыгы.

**АЛАБАКУ́Л** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Дим елгасы буенда. 2002 елда 391 кеше (татарлар — 62%, руслар — 31%) яши. Кирпеч сугу цехы. Урта мәктәп. Клуб. 1837 дә нигез салына. 19 йөздә А.дә руслар һәм мордвалар яши. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 елларга кадәр авыл җәмәгатенең имана җире 180 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1859 да — 221, 1886 да — 322, 1897 дә — 365, 1926 да — 461, 1938 дә — 377, 1949 да — 429, 1958 дә — 457, 1970 тә — 510, 1979 да — 258, 1989 да — 389 кеше.


**АЛА́БИН** Пётр Владимирович (29.8.1824, Мәскәү губ. Подольск ш. — 10.5.1896, Самара ш.), җәмәгать эшлеклесе, төбәкне өйрәнүче. Петербургта коммерция уч-щесен тәмамлаганнан соң, Россия армиясендә офицер булып хезмәт итә, рус гаскәрләренең Венгрия явында (1849), Дунай кампаниясендә һәм Севастополь шәһәрен саклауда (1855–56) катнаша. 1857 дән Вятка шәһәрендә гражданлык хезмәтендә. Бер үк вакытта Вятка төбәген өйрәнү б-н шөгыльләнә. 1858 дә И.В.Шишкин б-н бергә *Ананьино каберлегендә* беренче археологик казу эшләре үткәрә. 1866 дан — Самара губерна палатасында дәүләт милке башлыгы. 1877–78 еллардагы рус-төрек сугышы вакытында София шәһәренең беренче граждан губернаторы. 1885–91 дә — Самара шәһәре башлыгы, 1891 дән — Самара губернасы земство идарәсе рәисе, 1892 дән — Самара шәһәре думасы гласные. А. Самара шәһәренең мәдәни тормышын үстерүгә сизелерлек өлеш кертә, халык музеен оештыруга ярдәм итә (Болгариядән алып кайткан шәхси төрек сугыш кораллары коллекциясен аның фондына тапшыра). Хезмәтләре Вятка һәм Самара губерналары тарихына, мәдәниятенә карый.

Хезм.: Ананьинский могильник // Вестн. Географического об-ва. М., 1860. № 6; Заметка относительно некоторых древностей Вятского края. Вятка, 1865; Трёхвековая годовщина г.Самары. Самара, 1887.

*Әд.:* Кабытов П.С. Легендарный самарец — П.В.Алабин. Куйбышев, 1990; Алабин Пётр Владимирович // Историко-культурная энциклопедия: Персоналии. Самара, 1993.

**АЛАБИРДЕ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2002 елда 526 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кодыбирде исеме б-н дә мәгълүм. 18 — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.дә мәчет була, 1870 тә су, җил, ярма ярдыру тегермәне; 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 2 җил һәм су тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана жире 1282,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмәк волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән — Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 172 ир заты; 1859 да — 650, 1897 дә — 1214, 1908 дә — 1284, 1926 да — 923, 1938 дә — 906, 1949 да — 702, 1958 дә — 691, 1970 тә — 867, 1979 да — 736, 1989 да — 549 кеше.

**АЛАБУГА́** (Perca fluviatilis) балыгы, алабугасыманнар семьялыгыннан. Евразия сулыкларында киң таралган. ТР терр-ясендә сусаклагыч, күлләр һәм елгаларда очрый. Озынлыгы 15–30 *см*, авырлыгы, гадәттә, 150–400 *г*.



Алабуга балыгы.

Сусаклагычларда 50 *см* га кадәр озынлыктагы, 1 *кг* га кадәр авырлыктагы төрләре очрый. Гәүдәсе ян-яктан кысынкы. Анда җирән-сары яки яшькелтрәк төстәге 5–9 аркылы сызык аерылып тора. Саңак каплавычлары нык чәнечкеле. Пар йөзгечләре һәм күзе кызыл төстә. Ата балыкның җенси җитлегү чоры — 2, сиргәрәк — 3, ә ана балыкларныкы 3–6 яшьтә була. Уылдыгын язын берьюлы, куаклар тирәсенә чәчә, уылдык бөртекләре, ябышып, челтәр рәвешен ала. Үрчемлелеге — 10–200 мең уылдык бөртеге. Яшь А.лар — планктон, зурлары вак балык (чабак, җилем балык, өсләч) б-н туклана.



Алабуга шәһәренең иске өлеше күренеше.

**АЛАБУГА́** шәһәре, республика карамагындагы шәһәр, *Алабуга районы* үзәге. ТРда иң борынгы шәһәрләрнең берсе. ТРның төньяк-көнчыгышында, Казаннан 215 *км* ераклыкта, Әгерҗе–Акбаш тимер юлындагы Тихоново станциясеннән 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Туймa елгасының Камага кушылган урынында урнашкан. Автомобиль юллары Казан, Чаллы, Менделеев шәһәрләре б-н тоташтыра. Мәйданы — 41,1 *км*². 2006 елда 69,7 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 51,9%, татарлар — 41,8%). Нефть чыгару сәнәгате («Прикамнефть» нефть-газ чыгару идарәсе), җиңел автомобильләр, металл арматура, тимер-бетон конструкцияләр җитештерү, 2 асфальт-бетон, кирпеч з-длары, мәктәп җиһазлары җитештерү ф-касы бар. Җиңел сәнәгать (киҗе-мамык туку берләшмәсе) һәм азык-төлек җитештерү пр-тиеләре («Махеев» сәүдә маркалы майонез, кетчуп, соуслар һ.б.ны эшләп чыгаручы «Эссен Продакшн АГ» ябык АҖ, сыра з-ды, ит консервлары, сөт, азык комб-тлары) эшли. Пед. ун-ты, Казан техника ун-ты филиалы, мед. һәм мәдәният уч-щеләре, махсус милиция урта мәктәбе, 17 гомуми белем бирү мәктәбе, 2 һөнәри уч-ще, 2 музыка, 2 сәнгать, 1 спорт мәктәбе, 25 мәктәпкәчә тәрбия һәм сәламәтлек саклау учреждениесе, 4 клуб, 5 хастаханә, 10 китапханә, *Казан-Богородица хатын-кызлар монастыре*, 2 православие храмы, 2 мәчет. *Алабуга тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы* бар.

11 йөз башында А.ның хәзерге тарихи өлешендә шул ук исемдәге болгар авылы булуы мәгълүм. 16 йөзнең 2 нче яртысында аның урынында рус авылы Трёхсвятский (тарихи чыганакларда Алабуга дип тә атала) барлыкка килә. 17 йөз башында монда 200 дән артык хуҗалык исәпләнә. Халыкның төп шөгыле — балыкчылык һәм патша сараен балык б-н тәэмин итү. 17 йөз уртасында Трёхсвятскийда чокыр-канау һәм җир өемнәре б-н әйләндереп алынган 6 манаралы төрмә төзелә; 1707 дә авыл агач саклану дивары б-н әйләндереп алына. Авылны 1739 да А.Күчүмов җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләр (к. *Башкорт-татар баш күтәрүләре*), 1774 тә Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крәстиян отрядлары камап ала. 1780 дә авыл Нократ наместниклыгының (1796 дан — губернасының) өяз шәһәре статусын ала һәм хәзергечә атала башлый. Бу чорда 3 чиркәү (таш һәм 2 агач), 430 йорт була, 1200 ләп кеше (аларның 1056 сы — сарай крәстияннәре) яши. 1784 һәм 1796 да шәһәрнең беренче төгәл төп планы эшләнә. 19 йөз башында беренче таш йортлар калкып чыга, *Спас соборы* (1808–16), Покрау (1808–1815), Никола (1813–16), Троица (1829–32) чиркәүләре таштан салына. 1827 дә шәһәр хастаханәсе ачыла, 1833 тә беренче сууткәргеч корыла. 1850 елгы янгыннан соң (500 дән артык йорт яна), А.да барлык корылмалар таштан салына башлый, өяз шәһәренең хәзергә кадәр сакланган уникаль архит-ра ансамбле формалаша. 1850–60 елларда сәүдә рәтләре, Казан-Богородица хатын-кызлар монастыре, Спас соборының 5 ярусны чиркәү манарасы, шәһәр хастаханәсе комплексы, төрмә шәһәрчеге, Сәүдәгәрләр җыены бинасы, Александра исем. ятим балалар йорты комплексы, мәчет һ.б. зур җәмәгать корылмалары төзелә. 1866–68 дә чуен рәшәткәле яр буе урамы, Александров бакчасы барлыкка килә, 1874 тән шәһәрнең үзәк урамнарында таштан һәм агачтан тротуарлар (җәяүлеләр юллары) салына. Географик торышы уңайлы булу сәбәпле, А. тиздән сәүдә үзәге булып китә. 1890 да Кама буйлап 714 мең пот товар (ш.и. 320 мең пот икмәк) озатыла һәм 203 мең пот кертелә. А.дан Казан, Пермь шәһәрләренә пароходлар йөри. 19 йөз ахырында балавыз-шәм ясау, туңмай эретү, терлек маеннан шәм ясау, сыра-бал кайнату, прәннек пешерү, чуен кою, чаң ясау з-длары, пар б-н эшли торган он тарту тегермәне эшли. Казан Богородица хатын-кызлар монастыре, 9 чиркәү, мәктәбе булган мәчет, земство хастаханәсе (1870 елларда ачыла), шәһәр китапханәсе (1896 да ачыла), 19 уку йорты, ш.и. реаль уч-ще (1878 дә ачыла), кыз балалар гимназиясе, кыз балалар епархиаль уч-щесе (1898 дә ачыла), дини уч-ще (1848 дә ачыла), һөнәр уч-щесе (1880 дә оештырыла, рәсми рәвештә 1888 дә ачыла; 1899 да аның җирлегендә Алабуга һөнәр мәктәбе оештырыла), 3 сыйныфлы шәһәр уч-щесе һ.б. була. 20 йөз башында шәһәр банкы, Рус сәүдә-сәнәгать банкы бүлеге эшли. 1901 дә яңа сууткәргеч сузыла, 1902 дә шәһәр электрлаштырыла. 1905 тә А.да 421 сәүдә бинасы исәпләнә. Рев-циягә кадәрге А. ярлыларга матди ярдәм күрсәтүе б-н аерылып тора (1870 еллардан 1917 гә кадәр «И.И. һәм Д.И.Стахеевларның хәйрия комитеты» зур эш башкара — 1904 тә 2 млн.нан артык акчасы була). Җәмәгать биналары, чиркәүләр төзүдә, ярлыларга матди ярдәм күрсәтүдә сәүдәгәрләр династияләре — Гирбасов, Чернов, Ушковлар зур өлеш кертә. ТР терр-ясендә А. Совет власте урнашкан (16.11.1917) беренче өяз шәһәре була. 1919 ның 27 мартында А. өязе Казан губернасына керә. 1920 нең 18 июнендә Вятка губернасына кире кайтарыла. 1921 нең 5 гыйнварында ТАССР составына күчерелә. 1921–28 дә — А. кантоны үзәге, 1928 дән — Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — А. р-ны үзәге. Бөек Ватан сугышы елларында А. Мәскәүдән эвакуацияләнгән фән

1. Алабуга шәһәренең яңа кварталлары панорамасы; 2. М.И.Цветаева мемориаль комплексы.





(акад. В.А.Амбарцумян, А.В.Венедиктов, В.И.Смирнов, В.А.Фок һ.б.) һәм иҗат интеллигенциясе вәкилләрен үзенә кабул итә. Шәһәр һәм тирә-як төбәкнең икътисади үсешендә «Прикамнефть» нефть-газ чыгару идарәсе (1958 дә оештырыла) зур роль уйный. 1984 тә А. тирәсендә Кама трактор з-ды (к. *Алабуга автомобильләр заводы*) төзелә башлый һәм бу шәһәр инфраструктурасын яхшыртуга, сәнәгать һәм торак төзелешен үстерүгә китерә. 1995 тә А. «Россиянең кече һәм уртача шәһәрләрен торгызу, төзү, реконструкцияләү, реставрацияләү» Федераль программасына кертелә. Бу программага нигезләнеп, шәһәрнең 1000 еллык юбилеена әзерлек барышында аеруча әһәмиятле тарихи-төзелеш үзеге дип саналган шәһәр кварталларын реконструкцияләү һәм реставрацияләү буенча зур эш башкарыла. А.ның 1000 еллыгы 2007 нең 24–26 августында бәйрәм ителә һәм зур иҗтимагый-мәдәни яңгыраш таба. Бәйрәмгә шәһәрдә яңа стадион, боз сарае, ябык җиңел атлетика залы һ.б. социаль, спорт һәм мәдәният объектлары төзелә, А.га нигез салучы легендар болгар әмире Ибраһимга һәйкәл-ансамбль, «Трактир» музей-театры һәм интерактив остаханәләре булган төбәк тарихын өйрәнү комплексы ачыла,



Алабуга шәһәре. Шишкин буалары.

*«Алабуга»* аерым икътисади зонасын тәкъдим итү уздырыла, аның эшчәнлеге А.га Татарстанның иң эре сәнәгать үзәкләреннән берсенә әверелергә ярдәм итәчәк. А.да рәссам И.И.*Шишкин*, язучы Д.И.*Стахеев*, археограф һәм археолог К.И.Невоструевлар туып үскән; реаль уч-щедә Сов. Союзы Маршалы Л.А.*Говоров* укыган. Шәһәр зиратында 1812 елгы Ватан сугышы герое Н.А.*Дурова*, шагыйрә М.И.*Цветаева* каберләре бар. А. янында, Каманың уң ярындагы биек урында, Алабуга шәһәрлеге урнашкан. Анда б.э.ның 6–9 нчы йөзләрендә яшәгән кабилә истәлекләре табыла; шәһәрнең көнчыгыш өлешендә Идел буе болгарларының таш корылма калдыклары (к. «*Шайтан каласы*») сакланган. Халык саны: 1859 да — 5563, 1889 да — 11209, 1897 дә — 9776 кеше, 1917 дә — 13,9, 1923 дә — 10,2, 1926 да — 11,2, 1939 да — 15, 1959 да — 22, 1970 тә — 31,7, 1979 да — 35,6, 1989 да — 53,5 мең кеше.

*Әд.:* Шишкин Н.И. История города Елабуги с древнейших времён. Елабуга, 1901; Здравствуй, Елабуга! К., 1980; Древняя Елабуга. Елабуга, 2000; Валеева Н.Г. Елабужское земство и Россия: Гуманно-просветительская деятельность Елабужского земства (1867–1917). М., 2002.

**«АЛАБУГА́»**, Алабуга р-нында сәнәгый-җитештерү тибындагы аерым икътисади зона. РФ Хөкүмәтенең 2005 ел, 12 декабрь карары нигезендә ТР һәм РФ икътисадларын үстерүгә булышлык итү, сәнәгый-җитештерү өлкәсендә Россия һәм халыкара компанияләрнең инвестицион проектларын гамәлгә ашыру өчен аеруча уңайлы шартлар тудыру максаты б-н 2007 елның 25 августында ачыла, 1998 дән эшли башлый. «А.» ирекле икътисади зонасы (2003 тән — «А.» сәнәгый мәйданы терр-ясендәге «Инвестицион программалар дирекциясе») «Шевроле-Блейзер» һәм «Опель-Астра» җиңел автомобильләре, пасс. автобуслары, автомобиль компонентлары, велосипедлар, металл конструкцияләр, ягулык газ тутыру һәм җылыту җиһазлары, мебель, ит продуктлары һ.б. җитештерү пр-тиеләрен үз эченә ала. «А.» инж. һәм трансп. коммуникацияләре, күп кенә производство корылмалары булган 20 *км*$^2$ мәйданны били. Торак йортлар салу өчен якыннан гына 10 мең кешегә исәпләнгән мәйдан бүлеп бирелә. «А.»да теркәлгән оешмалар трансп. салымыннан тулысынча, җир һәм мөлкәт салымнары түләүдән 10 елга азат ителә, табыштан алынган салымны түбән ставкадан чыгып түли. «А.»да урнаштыру өчен чит илдән кертелә һәм чит илгә чыгарыла торган җиһазлардан таможня салымы түләтелми. «А.»да 10 нан артык пр-тие теркәлгән (2007). «АлАЗ» җитештерү берләшмәсе Минск трактор з-ды лицензиясе буенча көпчәкле «Беларусь» тракторлары һәм махсус техника җыюны, төрле билгеләнештәге махсус автомобильләр җитештерүне; «Северсталь-авто», «Великая стена» («Бөек дивар») (Кытай), «Хёндай» (Корея) һәм «Нильссон» (Швеция) компанияләре автомобильләр җыю производстволарын, «Татнефтехиминвест-холдинг» һәм «Алабуга полистирол заводы» АҖләре махсус полимер эшләнмәләр җитештерүне оештыра; Россия, Корея, Германия, Австрия, АКШ, Төркия, Италия, Люксембург, Словения, Босния һәм Герцеговина пр-тиеләре автомобиль компонентлары, хим. продуктлары һәм көнкүреш техникасы җитештерүне җайга салырга әзер. «А.» эшчәнлегенә җитәкчелек һәм контрольлек итүне Аерым икътисади зоналар б-н идарә итү буенча Федераль агентлыкның терр. органы, Күзәтү советы һәм идарә итүче компания гамәлгә ашыра.

**АЛАБУГА́ АВТОМОБИЛЬЛӘ́Р ЗАВОДЫ́** (АлАЗ), автомобильләр җитештерү сәнәгате берләшмәсе. Алабуга шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 4 мең чамасы кеше эшли (2006). 1984 елда төзелә башлаган Кама җир сөрү тракторлары з-ды җирлегендә аз литражлы автомобильләр җитештерү өчен 1988 дә оештырыла. 1999 дан «АлАЗ» җитештерү берләшмәсе» дәүләт унитар пр-тиесе, 2005 тән «АлАЗ» җитештерү берләшмәсе» АҖ. 1990 еллар уртасында башка автомобиль пр-тиеләре кооперациясе б-н берлектә, күптөрле автомобильләр эшләп чыгаруга көйләнә. Инженерлык һәм транспорт коммуникацияләре челтәре б-н тулысынча җиһазланган гамәлдәге көчләрне, ш.у. сәнәгать җитештерүен киңәйтү өчен кирәкле корылмаларны эченә ала. Пр-тие составына станок инстр-тлары з-ды (баш пр-тие; 1992 дән файдаланыла), җитештерү һәм энергетика объектларына хезмәт күрсәтү үзәге, «АлАЗстрой» төзелеш фирмасы, транспорт пр-тиесе, мәгълүмат һәм элемтә департаменты керә. Санлы программалар ярдәмендә идарә ителә торган станоклар б-н җиһазланган һәм автоматик проектлаштыру системалы станок инстр-тлары з-ды 200 төргә якын продукция, ш.и. Россия автомобиль з-длары заказы буенча детальләр һәм узеллар; «КАМАЗ», «Урал» автомобиль шассилары нигезендә нефть скважиналарын цементлау һәм ремонтлау өчен агрегатлар эшләп чыгара; «ЗИЛ» һәм «ГАЗ» автомобильләре нигезендә вет. хезмәте өчен күчмә дезинфекция җайланмалары; Россия нефть компанияләре өчен нефть-газ чыгару җиһазлары, төзелеш материаллары һәм конструкцияләр, җилемләнгән борыслар, агач эшләнмәләре, халык ихтыяҗлары өчен товарлар җитештерә. 1996–2001 елларда «Дженерал моторс» (АКШ) автомобиль компаниясе б-н берлектә «АлАЗ-ДМ» корпорациясе» уртак пр-тиесе эшли, анда 3,5 мең тиз йөрешле «Шевроле-Блейзер» һәм 300 аз литражлы «Опель-Вектра» автомобильләре җыела. 2002 нең октябреннән Минск трактор з-ды лицензиясе б-н «Беларусь-1221» һәм «МТЗ-82» тәгәрмәчле универсаль җир сөрү тракторлары җыела, алар махсус тагылма җиһазлар ярдәмендә шәһәр коммуналь хуҗалыгында, юл транспорты төзелешендә дә кулланыла. Заводта 2001 дә халыкара ИСО-9000 стандарты буенча сертификацияләнгән сыйфат б-н идарә итү систе-

Алабуга җиңел автомобильләр заводы. 1. Станок һәм инструментлар заводы. Гомуми күренеше; 2. Санлы программалар белән идарә ителә торган станокларның бер өлеше.





масы гамәлгә кертелә. «АлАЗ»ның бүтән бүлекчәләре сәнәгать һәм көнкүреш объектлары төзелешен гамәлгә ашыра, транспорт хезмәте күрсәтә, телефон (ш.и. спутниклы) һәм электрон элемтәсен тәэмин итә. 1998 дә пр-тие терр-ясендә ТРда беренче «Алабуга» ирекле икътисад зонасы оештырыла. (2003 тән — «Алабуга» сәнәгать мәйданы терр-ясендәге Инвестиция программалары дирекциясе» дәүләт учреждениесе). Шул зона кысаларында пассажир автобуслары, кабызу системалары, автомобильләр өчен коррозиягә каршы мастикалар җитештерү буенча «АлАЗ» һәм Германия, Италия, Кипр, Чехия фирмалары катнашында берничә уртак пр-тие оеша. Завод җитәкчеләре: Н.И.Бех (1984–87), А.И.Шуваев (1987–89), Р.А.Карачурин (1989–91), Н.Т.Сорокин (1991–92), Р.Х.*Зарипов* (1992 дән).

**АЛАБУГА́ АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, Алабуга районының көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы 56,2 *га*, ш.и. 7,1 мең *га* — урман. 1984 елда җәнлекләрнең ау төрләрен саклау, елга кондызларына һәм су кошларына сезонлы миграция чорында Вятка һәм Кама елгалары тугайларында тыныч шартлар булдыру максатыннан оештырыла. Поши, кәҗәболан, кабан дуңгызы, соры көртлек саклана.

**АЛАБУГА́ ИТ-КОНСЕ́РВ КОМБИНАТЫ́**, азык-төлек сәнәгате пр-тиесе. Алабуга шәһәрендә урнашкан. 2 сәнәгать мәйданының берсендә ит консервлары эшләп чыгару цехы, икенчесендә терлек суюу, терлек һәм кош итләре эшкәртү цехлары урын алган. Якынча 100 кеше эшли (2006). Алабуга ит комб-ты (Казан ит комб-тының терлек чалу пункты буларак 1942 елда нигез салына) һәм Алабуга консерв з-ды (аның тарихы, Алабуга крахмал киптерү з-ды терр-ясенә Ленинград җимеш-яшелчә консервлау цехы эвакуацияләнеп килгәннән соң, 1943 елдан башлана) җирлегендә 1964 тә оештырыла. 1947 дә Алабуга консерв һәм крахмал киптерү з-длары җирлегендә Алабуга өлкә азык-төлек комб-ты оеша. 1953 тә ул Алабуга р-н азык-төлек комб-тына һәм Алабуга консерв з-дына бүленә. 1956 да пр-тиегә реконструкция үткәрелү б-н, Алабуга консерв з-ды итеп берләштерелә (крахмал эшләп чыгару туктатыла, крахмал цехы консерв цехы итеп җиһазлана, яшелчә эшкәртү цехы, суыткычлар төзелә). 1963–64 тә Казан «Пламя» җитештерү берләшмәсенә керә. 1993 тән АҖ. Реконструкция үткәрелә, заманча җиһазлар урнаштырыла, продукциянең ассортименты киңәйтелә (20 төрдән артык консерв, 80 нән артык исемдә казылык эшләп чыгарыла). Алабуга, Мамадыш, Менделеев, Тукай, Кукмара р-ннарының а.х. пр-тиеләре терлек б-н тәэмин итәләр. 2007 нең 1 гыйнварына 570,7 *т* ит һәм субпродукт, 1291,2 *т* казылык әйберләре, 718 мең шартлы банка консерв җитештерелә. 1996–2006 да уздырылган Бөтенроссия конкурсларында һәм күргәзмәләрендә «Томалап пешерелгән ат ите» консервысы 1 нче, 2 нче дәрәҗә дипломнар һәм алтын медаль, «Сыер ите б-н арпа ярмасыннан пешерелгән ботка» — көмеш медаль, «Бавыр паштеты» 1 нче дәрәҗә диплом б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре — Гатауллин (1940–45), Я.Ф.Жубрицкий (1972–87), Г.Т.Мелкумянц (1987–92), В.Н.Овечкин (1992–2002), Р.Г.Фазлыәхмәтов (2003 тән). Ш.у.к. *Ит эшкәртү сәнәгате.*

*В.Н.Овечкин, Г.Я.Мәүлетова.*




**АЛАБУГА́ КАНТОНЫ́**, 1921–28 елларда ТАССРда адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Респ-каның төньяк-көнчыгышында урнашкан. Үзәге — Алабуга шәһәре. Мәйданы 4156 *км*². Халкы 159758 кеше, ш.и. руслар 48,5%, татарлар 46,5%, марилар 3,2% (1926). 24471 кеше шәһәрдә, 135287 кеше авылда яши. Халыкның уртача тыгызлыгы 1 *км*² га 38,4 кеше, авыл җирендә — 32,6 кеше. Кантон 353 авылны берләштерә, авыллар 7 волостька бүленә: Алабуга, Исәнбай, Камай, Костенеево, Цига, Салагыш, Чиркәс (1924). Металл эшкәртү, азык-төлек җитештерү һәм химия сәнәгате пр-тиеләре эшли. Һөнәрчелек б-н шөгыльләнүчеләр саны 1926 елда 2,5 мең кеше чамасы була. 1925 тә а.х. кооперативлары саны — 90, 1928 дә хосусый крәстиян хуҗалыклары саны — 25236. 1928 дә сөрү җирләре мәйданы 180 мең *га* чамасы; ш.и. арыш — 58580, солы — 31531, карабодай — 7736, бодай — 1797, тары — 1727, борай — 1611, бәрәңге — 1560 һәм техник культуралар 3180 *га* биләгән. 185426 баш мал асралган, ш.и. 34349 баш мөгезле эре терлек, 22533 ат, 122377 баш сарык булган. 1927 дә А.к.нда 137 мәктәп эшли. 1928 елда А.к. *Чаллы кантонына* кушыла.

Чыг.: Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928. Т. 3; 1929. Т. 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике. К., 1928; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**АЛАБУГА́ МАХСУ́С МИЛИ́ЦИЯ УРТА́ МӘКТӘБЕ́**, РФ Эчке эшләр министрлыгы уку йорты. 1953 елның августында СССР Эчке эшләр министрлыгының Казан хәрби-сәяси уч-щесе җирлегендә СССР Эчке эшләр министрлыгының Алабуга милиция мәктәбе буларак оештырыла, 1955 тән хәзерге исемдә. Эчке эшләр органнары өчен түбәндәге белгечлекләр буенча урта һөнәри белемле белгечләр әзерли: хокук саклау, адм.-хокук эшчәнлеге, хокук белеме. Мәктәпне тәмамлаучыларга «милиция лейтенанты» дәрәҗәсе һәм хокук белгечлеге бирелә. 2005 тә 1350 кеше тәмамлый (көндезге бүлектә — 580, читтән торып уку бүлегендә — 670 һәм түләүле бүлектә — 100); укытучылар коллективы 75 кешедән тора. 30 меңләп белгеч әзерләнгән. Мәктәпне тәмамлаучылар арасында: РСФСР (1990–91) һәм СССР (1991) эчке эшләр министры, РФ куркынычсызлык министры (1992–93) В.П.Баранников, РФ эчке эшләр министры (1992–95), РФ Герое В.Ф.Ерин, ТР эчке эшләр министры урынбасары (1993) Р.Г.Ногманов. Биналары комплексы Алабуга тарих-архит-ра һәм сәнгать музей саклаулыгының бер өлеше булган уку корпусын (элекке Реаль уч-ще (1878–82) бинасы) һәм 19 йөз уртасы — 20 йөз башында төзелгән элеккеге 25 торак йортны били. Аларда мәктәпнең тулай тораклары, китапханә, мәдәни-тәрбия эшләре үзәге урнашкан.

**АЛАБУГА́ МӘДӘНИЯ́Т УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Мәдәният министрлыгының махсус урта белем бирү уку йорты. 1935 елда Алабуга пед. уч-щесенең китапханә бүлеге җирлегендә ачылган китапханә техникумы б-н 1949 да оештырылган мәдәни-агарту мәктәбен берләштерү нәтиҗәсендә 1960 елда барлыкка килә. 1960 тан Татарстан респ-ка мәдәни-агарту уч-щесе, 1990 нан — Татарстан респ-ка мәдәният уч-щесе, 1993 тән — хәзерге исемдә.

Мәдәният учреждениеләре, гомуми белем мәктәпләре һәм сәнгать мәктәпләре өчен махсус урта белемле хезмәткәрләр әзерләнә: китапханә эше, социаль-мәдәни эшчәнлек һәм халык иҗаты (белгечлекләр: хореография иҗаты, театр иҗаты, халык хоры иҗаты, халык уен кораллары иҗаты, декоратив-гамәли иҗат, театральләштерелгән тамашалар куелышы).

2005 тә көндезге бүлектә — 335, читтән торып уку бүлегендә — 250, түләүле бүлекләрдә 40 студент укый; укытучылар коллективы 108 кешедән тора. Эшләү елларында якынча 12 мең белгеч әзерләнгән. Уч-щене тәмамлаучыларның иң күренеклеләре — ТР ФАнең беренче президенты М.Х.*Хәсәнов*, ТАССР мәгариф министры Р.А.*Низамов*, ТАССРның халык артисты В.М.*Гыйззәтуллина*, композитор Ә.З.Шәрәфиев, проф., сәнгать белгече Н.Ф.Максютин. Уч-щенең Яр буе һәм Спас урамнарындагы ике бинасы да 19 йөз уртасы архит-ра истәлеге, Алабуга тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгының бер өлеше.

*Е.В.Липаков.*


**АЛАБУГА́ МЕДИЦИ́НА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының һөнәри урта белем бирү уку йорты. Шәфкать туташлары курсларыннан башлангыч ала (1934–35). 1936 елда курслар җирлегендә икееллык шәфкать туташлары мәктәбе оештырыла, 1939 дан — шәфкать туташлары һәм акушерлар мәктәбе, 1940 тан — фельдшер-акушерлык мәктәбе; 1955 тән — хәзерге исемдә. Урта һөнәри белем б-н шәфкать туташы һәм дәвалау эше белгечлекләре буенча мед. хезмәткәрләре әзерли; ш.у. массаж курслары, урта мед. хезмәткәрләренең белемен күтәрү бүлеге эшли. 2005 елда 450 студент, ш.и. түләүле бүлектә 135 студент укый; укытучылар коллективы 50 кешедән тора.

Эшләү елларында якынча 20 мең белгеч әзерләнгән.

*Әд.:* Елабужское медицинское училище — первое знакомство. Елабуга, 2003.

*Е.В.Липаков.*

**АЛАБУГА́ ӨЯЗЕ́**, 1797–1920 елларда Вятка губернасының адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Үзәге — Алабуга шәһәре. Башта, 1708 дә Россия дәүләт терр-яләрен губерналарга бүлгәндә, Алабуга Азов губернасы составына, аннан соң үз терр-ясе б-н Пенза шәһәренә теркәлә һәм Казан губернасына кертелә. 1719 да Себер губернасының Вятка провинциясенә кушыла, 1727 дә Казан губернасы составына керә. 1780 дә А.ө. Вятка наместниклыгына күчерелә. 1797 дә Вятка губернасында, аның көньяк-көнчыгыш өлешен били. Төньяктан һәм төньяк-көнбагыштан — Малмыж, төньяк һәм төньяк-көнчыгыштан — Сарапул, көньяк һәм көньяк-көнчыгыштан — Минзәлә, көньяк-көнбатыштан Мамадыш өязләре б-н чикләнә. Өяз терр-ясеннән Чулман, Нократ елгалары һәм аларның кушылдыклары Туйма, Танай, Әнҗәрә, Үмәк һ.б. ага. Мәйданы 7,4 мең *км*². 1905 кә кадәр А.ө. — 3, 1906 дан 4 станга бүленә. 1897 гә кадәр өязгә — 20, аннары 19 волость керә. 1890 еллар башыннан Макан-Пельга волосте — Васильевка, Әсән волосте Алнаш волосте итеп үзгәртелә. 1895–97 дә Бимә һәм Тирсә волостьлары бетерелә, Баржы-Ятчә волосте оештырыла. 1910 да — Новогор, Биләр, Поршур, 1913–14 тә Сарсак-Умга волостьлары барлыкка килә. 1916 да өяз 23 волостьтан тора. Беренче станга (үзәге — Алабуга) — Трёхсвятский, Качык, Лекарево, Козыльск, Чиркәс, Иске Ятчә волостьлары; икенче станга (үзәге — Можга а.) — Новогор, Грахово, Бемышево, Васильевка, Можга, Поршур, Биләр; өченче станга (үзәге — Сарсак Умга а.) — Александровка, Мөшек, Алнаш, Ильинский, Сарсак-Умга, Олы Кибьян; дүртенче станга (үзәге — Пьяный Бор а.) Баржы-Ятчә, Күрәк, Пьяный Бор, Салагыш волостьлары керә. Халкы 241 мең кеше, ш.и. руслар — 53,3%, удмуртлар — 22,2%, татарлар — 16,2% (1897). Башлыча иген иккәннәр (арыш, солы, арпа, борай, бодай, тары), ш.у. терлекчелек (аеруча ат асрау), балык үрчетү, бакчачылык һәм төрле һөнәрчелек (мөгездән әйберләр, мичкә, арба ясау, тимерчелек, киез итек басу, буяу, сумала кайнату һ.б.) б-н шөгыльләнгәннәр. Халыкның бер өлеше завод һәм фабрикаларда эшләгән. А.ө.ндә пыяла, шәраб-тәмәке, балавыз, шырпы җитештерү, сабын, сыра-бал кайнату, чаң, чуен коюз-длары һ.б. (ш.и. Кокшан, Бондюг химия, Бемыш бакыр эретү-кою з-длары) була. 19 йөздә Алабуга ашлык сәүдәсе үзәкләренең берсенә әверелә. 19 йөз ахырында А.ө.ндә земство карамагындагы — 46 (аларның 3 се Алабугада), министрлык карамагындагы 5 мәктәп, 14 чиркәү-приход уч-ще-се, укырга-язарга өйрәтүче — 10, рус булмаганнар өчен 11 миссионерлык мәктәбе һәм раскольникларга каршы юнәлештәге 11 мәктәп эшли (татар авылларында мәктәп-мәдрәсәләр рәсми рәвештә теркәлмәгән). 1920 елда А.ө. волостьларының бер өлеше — Вотяк автономияле өлкәсенә, икенче өлеше ТАССР составына керә.




*Әд.:* Столетие Вятского наместничества. Вятка, 1880; Кустарная промышленность Вятской губернии: Стат. очерк. Вятка, 1882; Р о м а н о в Н.Н. Краткий очерк уездов Вятской губернии. Вятка, 1889; Материалы по статистике Вятской губернии. Елабужский уезд. Вятка, 1890. Т. 6; Календарь и памятная книжка Вятской губернии на 1894 год. Вятка, 1893; Здравствуй, Елабуга! К., 1980.

*Д.Г.Мостафина.*

**АЛАБУГА́ ПЕДАГО́ГИЯ УНИВЕРСИТЕТЫ́**. 1939 елда Укытучылар ин-ты буларак ачыла. Бөек Ватан сугышы елларында аның составында Воронеж һәм Ленинградтан эвакуацияләнгән ун-тларның ф-ллары да эшли. РСФСР МСның 1952 ел 19 авг. карары б-н 1953 тән пед. ин-ты итеп үзгәртелә, 2003 нең февралендә РФ Мәгариф министрлыгы коллегиясе карары б-н пед. ун-тына үзгәртелә. Укытучылар һәм пед. ин-тында матем. һәм филол. ф-тлары эшли, 1962 дә — педагогика һәм башлангыч мәктәп укытучылары әзерләү ф-тлары, 1965 тә — чит телләр, 1975 тә — гомуми техника, 1983 тә — биол., 1985 тә — тарих ф-тлары оештырыла. 1979 да Чаллы шәһәрендә ф-лы ачыла (1990 да мөстәкыйль пед. ин-ты итеп үзгәртелә).



Алабуга педагогия университеты. Төп бина.

Ун-т составына 8 ф-т: тарих, физ.-матем., чит телләр, филол., технол.-икътисад, биология, психол.-пед., физика һәм яңа мәгълүмати технологияләр; 23 кафедра (ш.и. татар теле, татар филологиясе), квалификация күтәрү курслары, 29 проблемалы-фәнни лаб., Лениногорскидагы (1990 нан) ф-лы керә. 10 белгечлек буенча укыту алып барыла; 7 белгечлек буенча аспирантурасы бар. 2005 тә 300 укытучы эшли (ш.и. 11 фән докторы, 90 фән канд-ты), көндезге бүлектә — 3340, читтән торып уку бүлегендә — 1550 студент, 70 аспирант укый. 4 уку корпусы, агро-биол. станциясе, редакция-нәшрият комплексы, спорт-сәламәтләндерү лагере бар. Төп корпусы — Алабуга епархия уч-щесе бинасы (1899–1903 елларда махсус аның өчен неоклассицизм стилендә төзелә, арх. И.А.Чарушин; архит-ра истәлеге).

Эшләү елларында Кама буе һәм Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы төбәкләренең пед. хезмәткәрләре нигезен тәшкил итүче 40 меңнән артык белгеч әзерләнә. Ун-тны тәмамлаучы профессорлар: Л.Ш.Арсланов, Н.М.Вәлиев, С.Г.Исмәгыйлева, Т.В.Капустина, Н.Х.Ләисов, А.В.Леонтьев, Ә.Т.Сибгатуллина. Ун-тта татар теле һәм әдәбияты, төбәкне өйрәнү тарихы һәм әдәбияты, төрле тирәлектәге электромагнитлы дулкыннарның сызыкча булмаган үзара тәэсире, табигый тирәлек торышының икътисади мониторингы һ.б. проблемалар буенча фәнни тикшеренүләр алып барыла. Ун-т ректорлары — Т.Н.Галиуллин (1971–86), Ж.Г.Нигъмәтов (1986–89), Н.Х.Ләисов (1989–2000); Н.М.Вәлиев (2000–2007).


*Әд.:* Елабужский педагогический: история и современность. Елабуга, 1998; Учёные Елабужского государственного педагогического университета: Биобиблиогр. словарь-справ. Елабуга, 2003.

*Е.В.Липаков.*

**АЛАБУГА́ ПЕДАГО́ГИЯ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1918 елның 23 ноябрендә Стахеев епархия уч-щесе җирлегендә Татар укытучылар семинариясе буларак ачыла, 1923 тән — Татар пед. техникумы, 1930 дан — Рус-татар пед. техникумы, 1936 дан пед. уч-ще. Эшчәнлегенең төп юнәлеше — башлангыч мәктәпләр өчен укытучылар әзерләү. 1945 елга 6 мең белгеч әзерләнә. 1952 дә Алабуга укытучылар ин-тын пед. ин-ты итеп үзгәртү һәм укыту мәйданнары җитмәү сәбәпле, абитуриентлар кабул итү туктатыла, ә 1953 тә укытучыларның һәм укучыларның бер өлеше Минзәлә пед. уч-щесенә күчерелә.

*Е.В.Липаков.*


**АЛАБУГА́ РАЙОНЫ́**, ТРның төньяк-көнчыгышында, Удмурт Респ-касы б-н чиктәш. Төньяк-көнчыгыш Кама буе икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1360,3 *км*². 15 җирле үзидарә советын (ком-тын), 48 авыл торак пунктын берләштерә. Үзәге — Алабуга шәһәре. Халкы — 2006 елда 10,5 мең кеше (район үзәген кертмичә), (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 50,7%, татарлар — 42,5%). Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га




8 кеше. 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязенә, 1920–21 дә ТАССР составына керә, 1921–28 дә ТАССРның — Алабуга, 1928–30 да Чаллы кантоннарында. Оешкан вакытында А.р.на 1 шәһәр, 1 посёлок, 67 авыл советы, 148 торак пункт керә, аларда 101149 кеше (руслар — 62627, татарлар — 35405) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 тә А.р.ннан 1931 дә аңа килеп кушылган *Бондюг районы* бүленеп чыга. 1940 та районның мәйданы — 1402 *км*$^2$, халкы — 55,8 мең кеше, 32 авыл советы, 93 торак пункт исәпләнә. 1944 нең 19 февралендә А.р.ның бер өлеше яңа оештырылган Костенеев (1944 нең 8 июненнән — Морт) р-нына бирелә (1954 нең 19 ноябрендә кире кайтарыла). 1960 та 1407,3 *км*$^2$ җир били, составында шәһәр советы, 13 авыл советы, 82 торак пункт була. ТАССР да адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә А.р.на Әгерҗе һәм Бондюг р-ннары кушыла. Мәйданы — 3944 *км*$^2$, халкы — 71,9 мең, 54 авыл советы, 232 торак пункт исәпләнә. Әгерҗе (1964 нең 4 марты) һәм Менделеев р-ннары (1985 нең 15 авг.) А.р. составыннан чыккач, терр-ясе 1270 *км*$^2$ га кадәр кими, халкы — 9,5 мең кеше, 13 авыл советы, 51 торак пункт кала. 2005 нең 26 гыйнварында А.р. муниципаль район дип үзгәртелә. Районның хәзерге чикләре Менделеев р-ны Бехтерев авыл советын (1988 нең 11 февралендә күчә) кертеп исәпләнә. Рельефы — елга үзәннәре, чокырлар б-н бүлгәләнгән киртләчле тигезлек (биеклеге 53–240 *м*). Кама һәм аның кушылдыклары Вятка, Туйма, Танай елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл-соры һәм соры урман, кәсле көлсу, көрәнсу соры туфраклы. Терр-ясенең 12% урманнар б-н капланган. Доломит, нефть, мергель ятмалары. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Туйма елгасы, *Түбән Кама милли паркы*, *Алабуга аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә таш гасырдан алып Идел буе Болгары чорына караган 80 гә якын археол. истәлек (ш.и. 7 шәһәрлек, 40 авыллык, 12 җир асты һәм 2 җир өсте каберлекләре) табыла. А.р. — нефть сәнәгате нык үскән төбәк. Сәнәгать пр-тиеләре, башлыча, район үзәгендә урнашкан. 1998 дән «АлАЗ» җитештерү берләшмәсенең (Алабугадан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак) җитештерү терр-ясендә «Алабуга» ирекле икътисади зонасы (2007 дән — «Алабуга» аерым икътисади зонасы) эшли. Монда «Барс» туризм автобуслары, тәгәрмәчле тракторлар, автомобиль һәм нефть сәнәгате өчен җиһазлар җитештерү пр-тиеләре бар, пластмасса әйберләр, трубалар, газ баллоннары, киң куллану товарлары эшләп чыгарыла. 2005 тә а.х. җирләре — 100,3 мең *га* , ш.и. 66,1 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак игелә. Мөгезле эре терлек, җәнлек, умарта үрчетелә. 2005 тә 14 а.х. пр-тиесе: 17 а.х. товарлары җитештерү кооперативы, 5 җаваплылыгы чикләнгән оешма, 2 ябык АҖ, 6 ярдәмче хуҗалык. А.р. җиреннән Акбаш–Әгерҗе тимер юлы, Казан–Уфа, Алабуга–Можга автомобиль юллары уза. 22 гомуми белем бирү мәктәбе (2004/05 уку елында — 1451 укучы), ш.и. 8 башлангыч, 3 тулы булмаган урта, 11 урта, 19 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 28 клуб, 22 китапханә, 40 урынлы 2 хастаханә (Морт һәм Костенеево а.) эшли (2002). Татарча «Алабуга нуры», русча «Новая Кама» район г-талары нәшер ителә. Бехтерев авылында (1929 га кадәр Саралы дип атала) невропатолог, психиатр В.М.*Бехтерев* туган.

**АЛАБУГА́ ТАРИ́Х-АРХИТЕКТУ́РА ҺӘМ СӘНГА́ТЬ МУЗЕ́Й-САКЛАУЛЫГЫ́**, РСФСР МСның 1989 ел 30 август карары нигезендә 1990 елда Алабуга шәһәрендә оеша. Саклау зонасының мәйданы — 491,5 *га*, терр-ясе — 131 *га*; 196 архит-ра истәлеген берләштерә; төп фонды 16868 саклау берәмлеген тәшкил итә. 1995 тән музей-саклаулык федераль әһәмияткә ия тарихи һәм мәдәни мирас объектлар исемлегендә. Музей-саклаулыкка 18 йөз ахыры — 20 йөз башына караган корылмалар ансамбле, *Шишкин И.И. музей-йорты*, *Дурова Н.А. музей-утары*, Марина Цветаева мемориаль комплексы, В.М.Бехтерев исем. *өяз медицинасы музее*, төбәк тарихы комплексы, *Алабуга шәһәрлеге* («Шайтан каласы»), *Ананьино каберлеге* керә. Алабуга шәһәренең архит-ра ансамбле — сәүдәгәрләр яшәгән өяз шәһәренең урамнарыннан һәм елга ярларыннан күзгә ташланган Туйма һәм Кама елгалары буйларындагы болыннарның гүзәл күренешләре, табигый урынының хозурлыгы б-н архит-ра үзенчәлекләренең бердәм киңлеген хасил иткән уникаль төзелеш үрнәге. Шәһәрнең иске (үзәк) өлеше терр-ясендә торак, гражданлык, дини, җәмәгать, мәдәният һәм сәүдә-сәнәгать архит-расы истәлекләре тупланган. Ансамбльнең композицион үзәге — Спас соборы (1808–16), эклектика элементлары б-н рус классицизмы стилендә төзелгән архит-ра истәлеге. Россиядә сынлы сәнгатьнең реалистик пейзаж мәктәбенә нигез салган И.И.Шишкинның мемориаль музей-йорты Шишкиннар гаиләсе яшәгән йортта урнашкан. Биредә рәссамның балачагы һәм яшьлеге узган, соңыннан ул монда кайтып йөргән. Фельдмаршал М.И.Кутузовның ординарецы, 1812 елгы Ватан сугышында катнашкан атаклы Н.А.Дурованың музей-утары ул 1841–66 елларда яшәгән йортта ачыла. Марина Цветаеваның мемориаль комплексына М.И.Цветаева һәйкәле (2002, скульпторлар А.В.Головачёв, В.А.Демченко) куелган мемориаль мәйдан, шагыйрәнең әдәби музее, 1941 елда эвакуациядә чакта ул яшәгән йорт, аның җәсәде җирләнгән Петропавел зираты һ.б. керә. Төбәк тарихы комплексында Алабуга тарихы музее, интерактив остаханәләр, «Трактир» музей-театры һәм Күргәзмә залы бар. Алабуга тарихы музее элеккеге сәүдәгәр А.Ф.Николаев йортында урнашкан (19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге), анда б.э.к. 9–4 йөзләрдәге Ананьино культурасына караган табылдыклар, 12–14 йөзләрдәге болгар керәч әйберләре фрагментлары, 1773–75 еллардагы Крәстияннәр сугышы чоры кораллары, татар, рус, удмурт, мари этнографик коллекцияләре саклана; шәһәр тарихына багышланган экспозиция эшли. Музей-саклаулык составына ш.у. Алабуга янындагы Алабуга шәһәрлеге — Ананьино, Пьяный Бор, Имәнкискә һәм Болгар культуралары калдыклары сакланган археол. истәлек, б.э.к. 4–3 йөзләргә караган Ананьино каберлеге керә. Каберлек коллекцияләре (1500 дән артык әйбер) Татарстанның һәм Россиянең, ш.у. чит илләрнең күп кенә музейларында саклана. Алабуга тирәсендә Шишкин иҗатында тасвирлау объекты булып хезмәт иткән уникаль табигать мохите — нарат урманы, күлләр, болыннардан гыйбарәт үзенчәлекле ландшафт ансамбле яшәп килә. Музей-саклаулык фәнни-тикшеренү, фәнни-мәгърифәтчелек һәм фәнни-методик эшчәнлек алып бара, матди һәм рухи мәдәният истәлекләрен саклау эшләрен башкара. Саклаулыкның директорлары: Д.Г.Галләмова (1990–92, 1997–2002), А.А.Елфимов (1992–97), Г.Р.Руденко (2002 дән).

1991 дә музей-саклаулык Ә.Г.Сабировның «Алабуга аларның исемнәрен хәтерли» («Их имена помнит Елабуга») дигән китабын нәшер итә.







Алабуга тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы.
1. Сәнгать галереясы; 2. Шәһәр тарихы музее.

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999. Древняя Алабуга. Елабуга, 2000.
*И.М.Нестеренко, О.Е.Шелковская.*

**АЛАБУГÁ УРМÁН ХУҖАЛЫГЫ́**, Алабуга, Менделеев һәм Тукай р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда оештырыла, Алабуга, Морт һәм Бондюг (соңрак Менделеев) урманчылыкларын берләштерә. 1991 елда Алабуга һәм Чаллы (элек Кызыл Тау, аннан соң Белоусов урманчылыгы, 1980–86 да — Чаллы урман-парк тибындагы урман хуҗалыгы) урманчылыклары «Түбән Кама» милли паркы составына керә. 2006 ел башына урман хуҗалыгының гомуми мәйданы 29041 *га*, ш.и. Морт — 9882 *га*, Менделеев — 6726 *га*, Татарстан (элекке Мәләкәс) урманчылыклары 12433 *га* мәйданда.

1 нче төркем урманнар 16732 *га* мәйдан били, алар эчендә: Алабуга һәм Чаллы шәһәрләренең яшел зона урманнары — 1643 *га*, сусаклагыч урманнар — 4496 *га*, эрозиягә каршы утыртылган урманнар — 9837 *га*, автомобиль юллары буйлап саклагыч полосалар — 756 *га*. 2 нче төркем, ягъни файдаланыла торган урманнар 12309 *га* мәйдан алып тора. Урман культуралары мәйданы — 5770 *га*. Ылыслы агачлар — 33%, каты яфраклылар — 25%, йомшак яфраклылар 42% мәйдан били. Урманнарның 80% чамасы яшь һәм урта яшьтәге агачлардан гыйбарәт. Нарат урманнары нигездә кулдан утыртылган, 5613 *га* мәйдан били; бонитет классы 1а һәм 1. Агач запасы 824 мең $м^3$. Типлары буенча катлаулы, мүкле һәм чикләвек куаклы нарат урманнары урын алган. Чыршы урманнары 2493 *га* мәйдан били. Чыршы күп очракта себер ак чыршысы б-н бергә үсә һәм караңгы ылыслы чыршы — ак чыршы ценозлары хасил итә. Гомуми агач запасы — 300 мең $м^3$. Имән урманнарының мәйданы — 6072 *га*, ш.и. биек кәүсәлеләр 4355 *га* мәйдан били. Өрәңге-юкәле имәнлекләр киң таралган, гомуми агач запасы 538 мең $м^3$. Каен (1012 *га*, 124 мең $м^3$) һәм усак (5190 *га*, 692 мең $м^3$) урманнары нигездә икенчел, элеккеге урманнар урынында барлыкка килгәннәр. Юкә урманнарының (4026 *га*, 558 мең $м^3$) күп өлеше имәнлекләрне, аеруча 1978–79 еллардагы салкыннардан зарарланганнан соң, алыштырган.

Төп кулланыш һәм урман торгызу эшләрен башкаргандагы еллык урман кисү күләме — 3,1 мең $м^3$. Урманны карау максатыннан 790 *га* мәйданда чистарту эшләре башкарыла, шул вакытта 8 мең $м^3$ дан күбрәк агач әзерләнә. Урманны торгызу эшләре 80 *га* мәйданда үткәрелә. Ел саен а.х. җирләренең 40 *га* мәйданында агач утыртыла. Урман хуҗалыгының төп питомнигында 12 исемдәге агач-куак токымнарының 3,2 млн. үсентесе һәм чәчкене үстерелә.

**АЛАБУГÁ ШӘҺӘРЛЕГÉ** («Шайтан каласы»), археология истәлеге; 10–16 йөзләргә караган болгар шәһәре (кальгасы) калдыклары. Алабуга шәһәренең көньяк-көнбатыш читендә Тойма елгасы (Каманың уң кушылдыгы) ярында урнашкан. Беренче тапкыр 1767 елда Троица монастыре монахлары, 1769 да Н.П.*Рычков* тарафыннан тасвирлана. Археологик тикшеренүләр 19 йөздән алып барыла (Ф.И.Эрдман, Н.Н.Кафтанников, К.И.Невоструев, В.Ф.Генинг, Т.А.Хлебникова, С.В.Кузьминых һ.б.). 1888 дә А.А.Спицын, 1981 дә М.М.Кавиев, 1991–92 дә К.И.Корепанов, 1993 тә А.Х.Халиков һ.б. казу эшләре алып бара. Шәһәрлек мәйданы 30 мең $м^2$ тирәсе, елга тигезлегеннән 52–60 *м* га күтәрелгән биек борында урнашкан. Кыр ягыннан 3 рәт булып сузылган таш-туфрак өемнәре һәм тирән канаулар б-н ныгытылган. А.ш. мәйданының көнбатыш ягында болгарлар заманыннан калган таш манара урнашкан (к. *«Шайтан каласы» манарасы*). Казу эшләре барышында биредә *Ананьино, Пьянобор, Азелино, Имәнкискә, Болгар* һ.б. археологик культуралар катламнары табыла. Табылдыкларның төп өлеше болгарлар яшәгән дәвергә карый. Археологлар тарафыннан почмаклары түгәрәк, диварлары ярым түгәрәк маналар (диаметрлары 5 *м*) б-н ныгытылган квадрат формасындагы (21×21 *м*), ак таштан төзелгән бина калдыклары тикшерелә. Казу эшләре барышында Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы һәм



Алабуга шәһәрлеге. «Шайтан каласы» манарасы һәм борынгы корылмалар хәрабәләре.

соңгырак дәверләргә нисбәтле көнкүреш һәм сәүдә кирәк-яраклары, кораллар, хатын-кызларның бизәнү әйберләре, Җучи акчалары һ.б. табыла. А.ш.нең төньяк-көнбатыш читендә һөнәрчелек бистәсе урнашкан була. Шәһәрлек б-н бистә, Кама буйлап узган сәүдә юлында төзелеп, Көнчыгыш Кама алдының сәүдә һәм хәрби-административ үзәге булган, аның аша болгар әмиренең хакимлеге күршедәге фин-угыр кабиләләре даирәсенә таралган дип фаразлана.

*Әд.:* Ш и ш к и н И.В. История города Елабуги. М., 1871; Древняя Алабуга. Елабуга, 2000.
*А.З.Нигамаев, Ф.Ш.Хуҗин.*

**АЛАБУТÁ** (Atriplex), алабутачалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләннәр, ярымкуак һәм куаклыклар ыругы. 200 дән артык төре билгеле; уртача җылы климатлы р-ннарда таралган. Татарстанда 10 төре үсә: Оше А.сы (A. aucheri), бакча А.сы (A. hortensis), киң яфраклы А. (A. latifolia), яр буе А.сы (A. littoralis), озынча яфраклы А. (A. oblongifolia), әрсез А. (A. patens), җәенке (йомшак) А. (A. patula), алсу А. (A. rosea), уксыман яфраклы А. (A. sagittata), татар А.сы (A. tatarica). 15–150 *см* биеклектәге берьеллык үләннәр, теофитлар. Торак йортлар арасында, юл буйларында, елга ярларында, тау битләрендә, чүплекләр тирәсендә, катыр туфраклы болыннарда үсәләр. Терлек азыгы һәм дару үләне буларак әһәмияткә ия, баллы үлән. Бакча А.сы — декоратив үсемлек. Йомшак А., татар А.сы — чүп үләннәр: басу һәм бакчаларны каплап үсәргә мөмкин. Орлыктан үрчиләр. Йомшак А.ның бер үсемлеге 600 гә кадәр орлык бирә, бу орлыклар туфракта 3–4 ел буе шыту сәләтен югалтмый.

*Әд.:* Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.
*И.Н.Афанасьев.*

**АЛАБУТАЧАЛÁР** (Chenopodiaceae), канәферчәләр рәтендәге ике орлык өлешле үсемлекләр семьялыгы. Күбесенчә күпьеллык үләннәр, ярым куакчыклар һәм куаклар. 100 дән артык ыругы һәм 1,5 меңләп төре билгеле, бөтен җир шары буйлап, күбрәк уртача һәм субтропик поясларның тозланган урыннарында таралганнар. ТРда 11 ыругтан 40 төре бар. Тамыры, нигездә, үзәк, киң тармаклы. Кайбер ыругларның тамыры үсеп җәелүгә, юанаюга сәләтле, мәс., чөгендер. Орчыксыман һәм бүлбесыман тамырлар бассиядә, алабутада очрый. Сабаклары күбесенчә туры. Яфраклары чиратлашкан, гади, төпчек яфраклары юк, формасы буенча бик күп төрле — безсыман һәм кыяклы каты яфраклардан алып киң, оваль, итләч, тешле читлеләргә кадәр. Чәчәкләре бер яки ике җенесле, вак, ямьсез, яшел яки сары төстә, ялгыз, башаксыман, чуксыман яки себеркәчсыман чәчәк төркеменә җыелган аз чәчәкле йомгакларда. Чәчәк тирәлеген 1–5 яшькелт яки аксыл-элпәсыман яфракчыклар тәшкил итә. Җимеше — чикләвекчек, кайбер төрләренең (чөгендер, шпинат) җимешләре тәлгәштә кушылып үсә. А. хуҗалыкта зур әһәмияткә ия. Иң әһәмиятле төре булып чөгендер санала, техник (шикәр алу өчен төп чыганак), яшелчә һәм терлек азыгы буларак файдаланыла. А. арасында котүлек (тозлак, дөя үләне), дару (алабута), декоратив (чыбык үлән) үсемлекләр бар. Алабута һәм онлычаларның кайбер төрләре — басу һәм бакчалардагы чүп үләннәр. Яткын чыбык үләне, гади терескен ТРның Кызыл китабына кертелгән.



М.К.Алаев.

**АЛÁЕВ** Михаил Константинович (21.11.1925, Бөгелмә кантоны Васильевка а. — 16.9.1946, Германия, Исна ш.), Дан орденының тулы кавалеры (27.8.1944, 25.2.1945, 15.5.1946), старшина. Туган авылында колхозда эшли. 1943 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең апреленнән Бөек Ватан сугышында; гв. сержанты, автоматчы, 8 нче гв. армиянең 79 нчы гв. укчы дивизиясе 216 нчы укчы полкта отделение командиры. 1 нче Бело-

руссия фронты гаскәрләре б-н Рогачёв-Жлобин (1944), Белоруссия (1944), Минск (1944), Люблин-Брест (1944) операцияләрендә, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1944 нең 19 июлендә Любомль шәһәре (Волынь өлкәсе), 1945 нең 14 гыйнварында Радом шәһәре (Польша) өчен барган сугышта, 1945 нең 19 апреленнән 2 маена кадәр Берлин янында барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**АЛА́ЕВ** Юрий Прокопьевич (1.8.1949, Бөгелмә ш.), журналист, ТАССРның һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1977, 2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), «Советская Татария» г-тасында хәбәрче, җаваплы сәркәтип урынбасары булып эшли. 1980–85 елларда «Вечерняя Казань» г-тасының җаваплы сәркәтибе, 1985–91 дә яңадан «Советская Татария» г-тасында (бүлек мөдире, мөхәррир урынбасары). 1991–96 да «Известия Татарстана», 1996 дан «Время и деньги» г-таларының баш мөхәррире. Ш.у. мәкаләләрен «Правда», «Известия» (Мәскәү) г-таларында бастыра. Мәкалә һәм очеркларында ТРның икътисади һәм социаль сәясәте проблемаларын яктырта. 1972 дән ТР телевидениесендә мәгълүмати һәм аналитик программаларның авторы һәм алып баручысы. 1990–95 елларда ТР ЮС депутаты.

**АЛА́Н** елгасы, Кушай елгасының (Зәй елгасы бассейны) уң кушылдыгы, Көнчыгыш Кама алдында. Озынлыгы 10,4 *км*, бассейнының мәйданы 65,6 *км*². Түбән Кама р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Алан авылыннан 1,8 *км* көнчыгыштарак, тамагы Сарсаз-Бли авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 162 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 34%. А.ның 0,6 дан алып 5,1 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,48 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 89 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,066 *м*³*/с*. Ел дәвамында суы бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**АЛА́Н** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 14 *км* көнчыгыштарак. 2002 елда 140 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына, Арча р-нына керә; 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан яңадан Арча р-нында. Халык саны: 1938 дә — 160, 1949 да — 210, 1958 дә — 156, 1970 тә — 171, 1979 да — 122, 1989 да — 72 кеше.

**АЛА́Н** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 17 *км* көнчыгыштарак, Бөре елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 574 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек үрчетү, умартачылык. Урта мәктәп. Клуб. Китапханә. Мәчет. 1788 елда Яңгул авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Башта Сәрдегәрбаш дип атала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чыпта сугу, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 382 дис. тәшкил итә. 1930 да «Берек» к-зы төзелә, 30 нчы еллар уртасында ул респ-када иң яхшы күмәк хуҗалыкларның берсе була. 1950 дә ул, Яңгул авылындагы колхоз б-н берләшеп, «Яңа тормыш» дип атала башлый. 1979 да А.да «Алан» умартачылык с-зы оештырыла. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Яңгул волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1939 ның 22 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1788 дә — 32 ир заты; 1834 тә — 100, 1884 тә — 201, 1926 да — 445, 1949 да — 504, 1958 дә — 396, 1970 тә — 553, 1979 да — 562, 1989 да — 448 кеше.

**АЛА́Н** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 18 *км* көнбатыштарак, Омар елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. 1930 елларда нигез салына. Барлыкка килгәннән бирле Мамадыш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 122, 1949 да — 140, 1958 дә — 173, 1970 тә — 119, 1979 да — 72, 1989 да — 25 кеше.

**АЛА́Н** (Пробуждение) авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зәй–Сарман автомобиль юлы буенда. 2002 елда 148 кеше (татарлар — 66 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, җәнлек үрчетү. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган вакытыннан ТАССРның Чаллы кантоны Нөркәй волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1926 да — 182, 1989 да — 34 кеше.

**АЛА́Н** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тәмте елгасы буенда. 2002 елда 532 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Агролицей. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1654 елдан рус чыганакларында Аланка авылы буларак билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да мәчет була. 20 йөз башында монда 2 мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, ярма ярдыру тегермәне, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1284,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән кабат Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир заты; 1859 да — 641, 1897 дә — 991, 1908 дә — 1330, 1920 дә — 1388, 1924 тә — 1259, 1926 да — 1238, 1938 дә — 1061, 1949 да — 944, 1958 дә — 805, 1970 тә — 818, 1979 да — 772, 1989 да — 585 кеше.

**АЛА́Н** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 4 *км* көньяктарак, Алан елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 27 кеше (руслар) яши. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, А.да су тегермәне була. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 850,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афонасово волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 231, 1870 тә — 269, 1920 дә — 622, 1926 да — 657, 1938 дә — 591, 1949 да — 345, 1958 дә — 184, 1970 тә — 205, 1979 да — 312, 1989 да — 15 кеше.

**АЛА́Н**, к. *Полянка*.

**АЛА́Н БӘКСӘ́Р** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 34 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2002 елда 353 кеше (татарлар — 63%, руслар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, умартачылык. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавында була, Алат авылы православие приходына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1888 дә А.Б.дә земство мәктәбе ачыла. 20 йөз башында монда 1778 елда төзелгән кәшәнә, тимерче алачыгы, 2 ярма ярдыру һәм 1 җил тегермәне, сарык тиресе эшкәртү, йон-тукымаману остаханәләре, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1191,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1763 тә — 63 ир заты; 1859 да — 455, 1897 дә — 831, 1908 дә — 1024, 1920 дә — 869, 1926 да — 895, 1938 дә — 1014, 1949 да — 834, 1958 дә — 510, 1970 тә — 316, 1989 да — 303 кеше.

*Әд.:* Известия по Казанской епархии. К., 1880; Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда с кратким их описанием. К., 1885; Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанского уезда. К., 1916; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**АЛА́Н ҖӨРИ́** (Казаклар) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 8 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2002 елдан даими яшәүчеләр юк. 16 йөз ахыры — 17 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Морза авылы, Казаклар, Кече Алан исемнәре б-н дә мәгълүм. 18 — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 144,2 дис. тәшкил итә.

1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 9 ир заты; 1859 да — 30, 1897 дә — 56, 1908 дә — 75, 1926 да — 72, 1938 дә — 168, 1949 да — 148, 1970 тә — 104, 1979 да — 69, 1989 да — 27 кеше.

**АЛА́Н-ЕЛГА́** авылы, Саба р-нында, Байлар Сабасы авылыннан 12 *км* төньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2002 елда 342 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз үрчетү. Урта мәктәп. 18 йөздә Олы Шекше авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Яңа Шекше, Өтернәс исемнәре б-н дә мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, кием-салым, бүрек тегү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.-Е.да мәчет, поташ з-ды, 1908 дә 2 вак-төякләр кибете була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1039,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 50 ир заты; 1859 да — 292, 1897 дә — 583, 1908 дә — 785, 1920 дә — 843, 1926 да — 743, 1938 дә — 648, 1949 да — 528, 1970 тә — 431, 1979 да — 409, 1989 да — 329 кеше.

**АЛА́Н-ПОЛЯ́Н** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе авылыннан 48 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2002 елда 274 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек үрчетү. Урта мәктәп. Клуб. Китапханә. 17 йөз ахырында Үри Чаллысы авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. Православие динендә. Шомырбаш авылы приходына карыйлар. Игенчелек, терлек үрчетү, җиңел арба ясау, тегүчелек, күмер сату б-н шөгыльләнәләр. 1873 тә А.-П.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе ачыла, 1893 тә ул чиркәү-приход мәктәбе итеп үзгәртелә. 20 йөз башында монда 2 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 674,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостена керә. 1920дән — ТАССРның Лаеш кантонында; 1927 нең 14 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 412, 1897 дә — 744, 1908 дә — 895, 1920 дә — 876, 1924 тә — 800, 1926 да — 727, 1938 дә — 705, 1949 да — 613, 1958 дә — 469, 1970 тә — 392, 1989 да 234 кеше.

**АЛА́Р РАЙОНЫ́**, Усть-Урда Бурят автономияле округының төньяк-көнбатышында 1923 елда оештырыла. Мәйданы — 2,4 мең *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Кутулик посёлогы. Халкы — 28803 кеше (2000), ш.и. 834 татар. Татарлар, нигездә, район үзәгендә (382 кеше) һәм Шахов (225), Александров (59), Егоров (33) авылларында яши. Татарлар А.р.на 20 йөз башында килеп урнаша. 1902–03 елларда Казан губернасының Мамадыш өязе авылларыннан күчеп килгән кешеләр Шахов авылына нигез сала. 1917 гә кадәр агач мәчет (1910 да төзелә), мәдрәсә, 1920–30 елларда берничә татар мәктәбе була. 1997 дән шәһәр тибындагы Кутулик посёлогында татар мәдәни үзәге эшли, Шахов авылы мәктәбендә татар теле укытыла.

**АЛА́Т ДАРУГАСЫ́**, Казан ханлыгында, соңрак Россиянең Урта Идел буенда адм.-терр. бүленеш төбәге (18 йөз башына кадәр). Казаннан төньяк һәм төньяк-көнбатыштарак урнашкан. А.д. Казансуның уң ягыннан (Болак ермагы турысында) койган бер инеш (17 йөздә Комаровский дип атала) тамагыннан башланган була. А.д. чикләре 17 йөзгәчә төгәл билгеләнмәгән. «*Писцовый кенәгәләр*»дә кайбер торак пунтларны күрше Галич даругасы биләмәсенә теркәү очраклары да очрый. А.д.на Казансу (Нокса, Коры елга, Сула, Савинка, Шуман, Верезинка һ.б. кушылдыклары б-н), Ашыт (Үртәм, Бәрәскә, Шашы, Алат, Оры, Симет, Күшәр, Мәңгәр һ.б. кушылдыклары б-н), Нократ (Шушма һ.б. кушылдыклары), Мишә (һәм аның кушылдыклары) елгалары буендагы җирләр кергән. Үзәге — Алат авылы. Төньяк-көнбатыш б-н көньяк-көнчыгышны — Вятка һәм Пермь б-н Казанны тоташтыручы сәүдә-транспорт магистрале буенда урнашкан торак пункт. А.д. волость һәм сотня (йөзлек) берәмлекләренә бүленә, аңа Чыпчык, Борисоглебский, Ишлык, Ильино, Дәүләзәр, Чураз, Олы Саирә (Матвеевка), Кырлай (Кирилловка), Өнсә, Өнбе, Мишәүкә, Өбрә, Әблә, Сая, Әлдермеш, Чуаш Иле, Кошелево, Өҗем, Әйше, Битаман, Тура, Кадыш, Караваево, Күшәр, Олы Әтнә, Күәм, Бимәр (Товалево), Кушлавыч, Савиново, Көнбүлмәс, Каймар, Олы һәм Кече Сая, Дөбъяз, Чыршы, Югары һәм Түбән Ташлык, Шәпше, Түбән һәм Югары Сылабаш, Кукарск, Ларинск, Гремяцк, Занемдежск (Давыдово) һ.б. торак пунктлар кергән. Аларда татар, мари, бисермән, чуашлар һәм 16 йөздән башлап руслар да яшәгән (башлыча, ясаклылар). 16 йөзнең 2 нче яртысыннан анда йомышлылар катлавы ишәя — рус алпавытлары, морзалар, йомышлы татарлар һәм яңа чукындырылганнар; 17 йөздән монастырь җир биләмәләре үстәлә. А.д. халкы, башлыча, игенчелек, мал асрау, балык тоту б-н шөгыльләнә. Йөк ташучылар, тире-күн эшкәртүчеләр, буяу ясаучылар, кирпеч сугучылар, агач әзерләүче һәм агач әйберләр, балчык савыт-саба ясаучылар, аракы-спирт куучылар, сәүдә б-н көн күрүчеләр дә булган. А.д. бүленеше 1708 елда бетерелә, аның биләмәсе башта Казан губернасының шул исемдәге өязенә, 1719 дан губернаның Казан провинциясенә керә; 1782 елда Казан б-н Нократ наместниклыклары карамагындагы Казан, Царёвококшай, Царёвосанчур, Уржум һәм Яран өязләренә карый.

*Д.Г.Мостафина.*

**АЛА́Т СПИРТ ЗАВОДЫ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2002 елда 119 кеше (татарлар — 62%, руслар — 35%) яши. 1898–1900 дә сәнәгатьче Булыгин нигез сала. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 594, 1949 да — 816, 1958 дә — 837, 1970 тә — 465, 1989 да — 168 кеше.

**АЛА́ТЫРЕВ** Валерий Иванович (27.1.1940, Мари АССРның Куженер а. — 29.4.1996, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1990), проф. (1991). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Йошкар-Ола шәһәрендә табиб. 1965 елдан Казан ун-тында, кеше һәм хайваннар физиол. каф. мөдире (1991 дән). Хезмәтләре нейрофизиологиягә, хәрәкәт аппараты физиологиясенә, хәрәкәт б-н идарә итү, авырту мәсьәләләренә карый. Эчке органнар авырулары вакытында корсак тышчасы мускулларының саклагыч киеренкелеген экспериментал һәм клиник рәвештә тикшерә. Саклану рефлексларының оригиналь классификациясен төзи, корсак куышлыгы авыруларын диагнозлауның объектив электромиографик ысулын эшли; эчке әгъзалар тәэсиренә җавап буларак, арка мускулларының саклаучы реакцияләре үсешендә арка мие эшчәнлегенең төп механизмнарын билгели. А. тарафыннан эшләнгән мускуллар эшчәнлеге координациясенең функциональ диагностика ысулы клиникаларга һәм спорт медицинасына кертелә.

Х е з м.: Защитное напряжение мышц брюшной стенки. К., 1971 (автордаш); Электромиография брюшной стенки в диагностике острых заболеваний органов живота. К., 1978; Постишемические изменения функций спинного мозга. К., 1982 (автордаш).

*Н.В.Звёздочкина.*

**АЛА́ТЫРЦЕВА** Ирина Евгеньевна (20.2.1914, Пенза ш. — 26.10.1988, Казан), эпидемиолог, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1976), ТАССРның атказ. табибәсе (1964). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1935). 1936 елдан Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-тында: 1938 дән анаэроб бүлеге мөдире, 1942 дән җитештерү бүлеге мөдире, директоры (1961–70). 14 рационализаторлык тәкъдиме авторы. А. җитәкчелегендә гаммаглобулин җитештерү оештырыла. Хезмәтләре бактерияле аллергеннарны уйлап табу һәм җитештерүгә, эпидемиология һәм иммунологиянең теоретик мәсьәләләренә, специфик балалар авыруларын булдырмау мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О комплексной иммунизации в свете современных данных физиологии возбуждения // Материалы науч. сессии ин-тов эпидемиологии и микробиологии РСФСР, посвящённой 50-летию КНИИЭМ. К., 1953; Экспериментальные обоснования и иммунологические наблюдения по изучению облегчённых методов ревакцинации против дифтерии, коклюша и столбняка. К., 1969.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**АЛАФУ́ЗОВ** Иван Иванович (1839, Ставрополь ш. — 26.8.1891, С.-Петербург губ. Ораниенбаум ш.; Казанда җирләнгән), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре (1863), фабрикант, мануфактур-киңәшче (1874), нәселдән күчмә шәрәфле граждан, җәмәгать эшлеклесе. 1856 елдан Казан һәм Вятка губерналарында сәүдә-сәнәгать эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. 1858 дә С.Е.Александров һ.б. б-н бергә уртак пайлы «Казан күн эшкәртү заводы ширкәте»н оештыра. 1865 тә Казан җитен эрләү-туку ф-касын нигезли, фабрика Идел-Урал һәм Себер төбәгендә туку сәнәгатенең үзәге буларак таныла. 1870 еллардан А. Россиянең иң эре сәнәгатьчеләре исәбендә йөри. 1870–80 елларда Пермь губернасы Камышлы шәһәрендә күн эшләү з-дын, Уфа губернасының Бәләбәй өязе Түбән Троицк бистәсендә постау туку ф-касын ача. Казан һәм Петербург биржалары аша Европа илләренә һәм Америкага иген, җитен тукымалар чыгара, Петербург хәрби округын һәм Каспий буендагы шәһәрләрдәге хәрби гарнизоннарны азык-төлек һәм фураж б-н тәэмин итеп тора. Аның завод-фабрикалары җитештергән 27 төр әйбер Халыкара һәм Россия күргәзмәләрендә медальләр ала (1867–90). Казанда эре иганәче буларак мәгълүм: Мария исем. хатын-кызлар һөнәрчелек мәктәбе (1862), Бишбалта бистәсендәге хастаханә (1876) биналарын төзүгә акча бирә, 1883 елда Казанда оешырылган хезмәткә яраксыз эшчеләр йортын тотуга ярдәм итеп тора. Ш.у.к. *Алафузов театры*, *Алафузовлар завод-фабрикаларының сәүдә-сәнәгать ширкәте*.



И.И. Алафузов.

*Әд.:* И.И.Алафузов: Некролог. К., 1891; А н и с и м о в Н.Г. Казанский льнокомбинат. 100 лет. К., 1960.

**«АЛАФУ́ЗОВ ТЕАТРЫ́»**, Казанда 19 йөз ахыры тарих һәм архит-ра истәлеге. 1898–1900 елларда И.И.Алафузов акчасына арх. Л.К.Хрщонович проекты б-н «җәмәгать йорты» һәм эшчеләр өчен уч-ще буларак төзелә. Классицизм юнәлешенең эклектик формаларында симметрик композиция б-н төзелгән, эргә каты тәрәзәле, Т хәрефе рәвешендәге клуб-театр бинасы. Дәрес һәм клуб бүлмәләре бинаның ике катын били. Алар урамга чыккан баскычлары булган коридорлар б-н тоташа. Урам буйлап сузылган өлешенең уртасында, Казансу елгасының иске яры ягыннан ике катлы янкорма тоташкан. Анда үзәк ишекләр булган вестибюль, тамаша залы һәм сәхнә урнашкан. Тамашачылар өчен урыннар партерга һәм ике яруслы балконнарга куелган. Бинаның алгы почмакларына шпиль б-н очланучы, дүрт кырлы гөмбәзле тәбәнәк манаралар утыртылган. Төп фасад катлаулы аттиклы ризалит б-н бизәлгән. Бинаның аркылы торган өлеше гөмбәзле дүрт кыеклы түбә б-н ябылган була, соңрак бу гөмбәз юкка чыга. Икенче каттагы биек аркалы тәрәзәләр бинага купшылык өсти. Фасад тирән рустовка (1 нче катта), сыңарлы ордер — дорик, парлылары — катлаулы ордерга караган пилястралар (2 нче кат), ш.у. чуарланган кәрниз, аттиклар, күпертмә фигуралар



«Алафузов театры». Арх. Л.К.Хрщонович. 1900. 20 йөз башы фотосы.

б-н бизәлгән. 1996 да бинаны үзгәртеп кору һәм яңарту башлана. «А.т.»да хәйрия чаралары үткәрелә, һәвәскәр труппаларның спектакльләре күрсәтелә. Соңрак проф. труппаларга арендага бирелә башлый. Биредә Н.Д.Дымов җитәкчелегендәге «Бөтенроссия драма артистлары союзы», Дж.Мори һәм дирижёр Ю.Ф.Закржевский җитәкчелегендәге «Яшь опера артистлары ширкәте» спектакльләре уйнала. 1918–21 дә «А.т.» Елга аръягы эшчеләр театры дип йөртелә, Казанның «үрнәк» театрлары рәтендә шәһәр казнасыннан финанслана. Монда В.Б.Набатов, Н.М.Григорьев-Пороховский, актёр А.И.Каширин җитәкчелегендәге труппалар эшли. Театрның танылган актёрлары арасында С.Б.Писарева, В.И.Окунева була. 1924 тән «А.т.» Эшчеләр сарае, соңрак Җитен комб-ты клубы сыйфатында һөнәри берлекләр карамагына тапшырыла. 1998 дән биредә *Казан Татар яшь тамашачылар театры* урнаша.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Х.Г.Надыйрова, Ю.А.Благов.*

**АЛАФУ́ЗОВЛАР ЗАВО́Д-ФА́БРИКАЛАРЫНЫҢ СӘҮДӘ́-СӘНӘГА́ТЬ ШИРКӘТЕ́**, акционерлык җәмгыяте. Император Александр III фәрманына нигезләнеп, 1894 елда оештырыла. Хуҗалары — Л.А., Н.И., Н.Н.Алафузовлар. Ширкәткә Казанда җитен эрләү-туку ф-касы, 2 йомшак күн һәм олтанлык күн эшләү з-ды, җилем кайнату һәм газ з-длары, аяк киемнәре тегү, ат дирбияләре эшләү остаханәләре, икмәк пешерү йорты һәм тимерчелек; Пермь губернасының Пермь һәм Камышлы шәһәрләрендәге күн эшләү з-длары, Уфа губернасы Түбән Троицк бистәсендәге постау туку ф-касы; С.-Петербург, Мәскәү, Түбән Новгород, Саратов, Ростов-Дон һ.б. шәһәрләрдә күпләп сату складлары һәм ваклап сату кибетләре керә. Ширкәттә күн, бау һәм җепләр, җитен, постау тукымалар, брезент, аяк киемнәре, ат дирбиясе, гаскәриләр кием-салымы һәм кирәк-ярагы, палаткалар, капчык-торыпшалар җитештерелә. Төп капиталы 4 млн. сум, сәүдә әйләнешендә һәм маяда 1,23 млн. сум була. 1913 тә 6500 кеше эшли, 8,5 млн. сумлык әйбер җитештерелә. РСФСР БҮБК һәм ХКСның 1918 елгы 28 июнь декреты нигезендә шул елның 19 октябрендә ширкәт милке дәүләт тарафыннан үзләштерелә. Соңрак ширкәтнең Казан пр-тиеләре җирлегендә *Казан җитен комбинаты* оештырыла.


*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. П., 1914; А н и с и м о в Н.Г. Казанский льнокомбинат. 100 лет. К., 1960; Н а з и п о в а К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976.

*Е.Б.Долгов.*

**АЛБАБА́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2002 елда 16 кеше (руслар) яши. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Ильинский, Элбаба атамалары б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 399 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында; 1927 нең 14 феврален-

1. Алафузовлар завод-фабрикаларының сәүдә-сәнәгать ширкәте идарәсе бинасы. Казан. 1890 еллар фотосы;
2. Алафузовларның җитен эрләү һәм туку фабрикалары. Гомуми күренеш. Казан. 1890 ел фотосы.





нән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 49 ир заты; 1859 да — 236, 1897 дә — 341, 1908 дә — 406, 1920 дә — 467, 1926 да — 379, 1938 дә — 494, 1949 да — 412, 1958 дә — 218, 1970 тә — 63, 1979 да — 65, 1989 да — 28 кеше.

**АЛБАБА́** тимер юл станциясе посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2002 елда 96 кеше (татарлар) яши. Ремонт-техника пр-тиесе, сөт һәм асфальт-бетон з-длары. Һөнәр уч-щесе. А.га 1940 елларда нигез салына. Норлат р-нына керә; 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1958 дә һәм 1970 тә — 101, 1979 да — 149, 1989 да — 129 кеше.

**АЛБА́Й**, күл. Зөя елгасының сулъяк тугаенда, Буа р-ны Чабры авылының көнчыгыш читендә. Су өслегенең мәйданы 0,68 *га*. Озынлыгы 490 *м*, иң зур киңлеге 30 *м*.

**АЛБА́Й** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 57 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2002 елда 278 кеше (татарлар — 74 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Урта Әрнәш исеме б-н мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең беренче яртысында халкы — дәүләт крәстияннәре, Әбде авылы приходына карый, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 19 йөздә А.га руслар килеп урнаша башлый. Күчеп утыручылар арасында төрле җирләрдән килүчеләр, ш.и. Теләче авылы кешеләре дә була. 1873 тә авылда чиркәү төзелә, 1875 тә ир балалар өчен Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе ачыла. 20 йөз башында монда Иоанн-Предтеча чиркәве, 2 су тегермәне, май язу йорты, шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 983,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир заты; 1859 да — 473, 1897 дә — 867, 1920 дә — 1103, 1926 да — 964, 1938 дә — 730, 1958 дә — 510, 1970 тә — 537, 1979 да — 469, 1989 да — 329 кеше.

*Әд.:* Приволжские города и селения в Казанской губернии. К., 1892.

**АЛБАСТЫ́** (төрки телдәге *әл* (кул) яки *ал* (алгы як) һәм *басмак* — бастыру, кысу сүзеннән ясалган), төрки-татар мифологиясе персонажы; су стихиясенә бәйле явыз рух. Төрки халыклар мифологиясендә А. исеме төрле вариантларда йөри: Казан, Кырым, Көнбатыш Себер татарларында (соңгыларында ш.у. — сары чәч) — А., кыргызларда — албарсты, каракалпакларда, нугайларда — албаслы һ.б. Еш кына шыксыз-ямьсез, тузган озын чәчле, җилкә аша салырлык гаять зур имчәкле карчык кыяфәтендә күзаллана. Кайбер күзаллаулар буенча, аның эчке әгъзалары күренеп тора, аркасында тиресе юк. Агач, күчеп йөрүче печән чүмәләсе һ.б. сурәтенә керә ала; эт өргән яки әтәч кычкырган тавыш ишеткәч, юкка чыга. Ташландык өйләрдә, пычрак сулыкларда, күбесенчә күлләрдә яши. Казан татарларында, А. кеше янына төнлә йоклаганда килеп чыга, дигән ышану яшәп килә. Йоклаган кеше өстенә утырырга, аны буарга һәм аның канын эчәргә мөмкин. Кеше уянгач, юкка чыга. А. образы явыз рухлар *Убыр, Убырлы карчык, Шүрәле* турындагы күзаллауларга якын.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«АЛГА́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РСДРП(б)ның Уфа ком-ты органы. 1917 елның 4 августыннан 17 декабрьгә кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 7 саны чыга. Мөхәррире Ә.Хәбиби, гамәлдә җитәкчесе Б.Нариманов. «Бөтен дөнья пролетарийлары, берләшегез!» шигаре астында чыга. Әзлекле, төгәл аныкланган сәяси юлы булмый. «А.»ның мәсләгендә төрле юнәлештәге социаль һәм радикаль идеяләр урын ала. Шул ук вакытта «милли социализм» идеяләре дә чагыла.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«АЛГА́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Оренбург губкомы тарафыннан 1919 елда Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

**«АЛГА́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Эчке Россия мөселманнары эшләре комис-тының Сарапул бүлеге тарафыннан 1919–20 елларда Сарапул шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

**«АЛГА́»**, журнал, к. *«Алмашка»*.

**АЛГА́** авылы, Аксубай р-нында, Аксубай посёлогыннан 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Карасу елгасы буенда. 2002 елда 96 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 еллар башында нигез салына, 1940 ка кадәр Садыйк дип атала. ТАССРның Чистай кантоны Иске Әлмәт волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 94, 1938 дә — 158, 1949 да — 142, 1958 дә — 153, 1970 тә — 221, 1979 да — 174, 1989 да — 112 кеше.

**АЛГА́** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 76 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1925 тә нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 88, 1938 дә — 197, 1949 да — 200, 1958 дә — 146, 1970 тә — 153, 1979 да — 111, 1989 да 91 кеше.

**АЛГА́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Саклаусу елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 84 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек үрчетү. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. 1929–30 елларда нигез салына. Сарман р-нына керә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1938 дә — 292, 1949 да — 192, 1958 дә — 195, 1970 тә — 196, 1979 да — 129, 1989 да — 77 кеше.

**АЛГА́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 11 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 62 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек үрчетү. Башлангыч мәктәп. 1930 елда нигез салына. Башта Саба р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1938 дә — 254, 1949 да — 258, 1958 дә — 344, 1970 тә — 213, 1979 да — 155, 1989 да — 72 кеше.

**«АЛГА́»**, Тәтеш р-нындагы авыл хуҗалыгы җитештерү (1995 тән) кооперативы. 1930 елда «Марс» к-зы буларак оеша; 1951 дә «Ленин Суляпя» («Путь Ленина») к-зы б-н берләштерелә һәм «А.» к-зы итеп үзгәртелә. Соңрак «Победа» (1960) һәм «Эшчән» (1964) к-злары б-н берләштерелә. 1969 да «А.»дан «Татарстан», 1990 да «Свияга» к-злары аерылып чыга. 1994 тән хәзерге исемдә. «А.» га Бакырчы (үзәк утары), Чуаш Чыкылдымы, Татар Чыкылдымы, Чуаш Чурапаны, Үтәмеш авыллары керә. 346 йортта 924 кеше яши (1997). А.х. җирләренең мәйданы 4640 *га*, ш.и. сөрү җирләре 4292 *га*, 336 *га* печәнлек һәм көтүлекләр. Төп җитештерү тармаклары: игенчелек, терлекчелек һәм чөгендер үстерү. 2000 һәм 2005 елларда а.х. культураларыннан алынган уңыш (*ц/га*): бөртекле ашлык 30,5 һәм 26,5; шикәр чөгендере 193 һәм 174; 2000 елда 1 сыердан 2490 *кг*, 2005 тә — 3876 *кг* сөт алына. 1971 елдан «Югары культуралы игенчелек хуҗалыгы» исемен йөртә. А.х. культураларыннан югары уңыш алганы өчен ТАССР һәм СССР ВДНХлары дипломнары бирелә.

*Әд.:* Зыятдинов Ф.С. Кырлар батыры. К., 1975.

**АЛГА́** (псевд., чын фамилиясе Бачков) Александр Егорович (14.11.1913, Сембер губ., Буа өязе Кошки-Яңа Тимбай а. — 15.6.1977, Чабаксар ш.), шагыйрь, тәрҗемәче, әдәби тәнкыйтьче, Чуаш АССРның халык шагыйре (1970). Башлангыч белемне туган авылында, чуаш мәгърифәтчесе И.Я.Яковлев мәктәбендә ала. Яшьли ятим кала, 1922 елдан Казанда ятимнәр йортында тәрбияләнә, 1938 дә Казанда Чуаш пед. техникумын тәмамлый, укытучы булып эшли. Соңрак Чабаксар шәһәрендә Чуаш пед. ин-тын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–50 елларда «Ялав» («Байрак») әдәби ж-лының баш мөхәррире булып эшли, 1960–67 дә Чуаш АССРның Язучылар берлеге рәисе. 40 тан артык шигырь, поэма һәм повесть җыентыклары авторы. Беренче шигырьләре «Утăм» («Адым», 1931) альманахында басыла. «Шывармань» («Су тегермәне», 1935) легендасы беренче чуаш операсына нигез итеп алына. А. Татарстанга һәм Чуашиягә багышланган аерым әсәрләр һәм шигырьләр, поэма цикллары иҗат итә («Идел белән Зөя арасында»,

«Ватанда», «Идел дулкыннары», «Сөйгән җирем», «Минем якташларым»). Чуаш теленә Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан шигырьләрен тәрҗемә итә. Кызыл Байрак, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары б-н бүләкләнә. 1950–67 дә Чуаш АССР ЮС депутаты.

Ә с ә р.: Мои земляки. Чебоксары, 1959; На новой Волге. М., 1962; Солнечное утро. Чебоксары, 1973; Хамаръялсем (Земляки). Шупашкар, 1983.

*Әд.:* Краткая литературная энциклопедия. М., 1962. Т. 1; Чувашские писатели: Биобиблиогр. справ. Чебоксары, 1964; БСЭ. 3 изд. М., 1970. Т. 1.

*В.П.Станьял.*

**«АЛГА́, ДОШМА́Н ӨСТЕНӘ»**, фронт газетасы. 1942 елның ноябреннән 1943 нең 20 октябренә кадәр татар телендә Калинин фронты сәяси идарәсе органы буларак чыга; фронт таратылганнан соң, редакция яңа оештырылган Балтыйк буе фронты сәяси идарәсе карамагына күчерелә. Газета 1945 елның 5 июненә кадәр нәшер ителә, барлыгы 308 саны чыга. Мөхәррире М.Гыймадиев. Редакция хезмәткәрләре һәм хәрби хәбәрчеләре А.Әхмәт, Ш.Маннур, А.Шамов; рәссам Б.Әлминов рәсемнәре бирелә, солдат һәм офицерлардан Х.Атнагулов, Ф.Басыйров, Г.Вәлиев, М.Гаязов, И.Закиров, С.Мәгъсүмов, З.Хәсәнов һ.б.ларның мәкаләләре басыла.

*Әд.:* А й н у т д и н о в А.К. Летопись подвига: Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет. К., 1984.

**«АЛГА́ ТАБА́»**, газета. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Алабуга советы каршындагы керәшеннәр бүлекчәсе тарафыннан 1919 елның гыйнварыннан апреленә кадәр Алабуга шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — М.И.Зубков.

**АЛГА́-КӨЕ́К** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 14 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 150 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 16 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кырлай, Кара Көек исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, йөк ташу һәм Казан халкына су китерү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.-К.тә мәчет, 1908 дә вак-төякләр кибете була. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 633,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 41 ир заты; 1859 да — 364, 1897 дә — 285, 1908 дә — 325, 1920 дә — 359, 1926 да — 320, 1938 дә — 434, 1949 да — 305, 1958 дә — 245, 1970 тә — 181, 1979 да — 215, 1989 да — 141 кеше.

**АЛГА́Й** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 42 *км* төньяк-көнбатыштарак, Өске елгасы буенда. 2002 елда 299 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Урта Өске исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да мәчет була. 20 йөз башында 2 ярма ярдыру, 1 он тарту тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 872,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәвеш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 ның 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 29 ир заты; 1859 да — 352, 1897 дә — 657, 1920 дә — 746, 1926 да — 774, 1949 да — 564, 1958 дә — 426, 1970 тә — 467, 1979 да — 409, 1989 да — 336 кеше.

**АЛГАМА́**, *Карамалы* елгасының үрге агымындагы исеме.

**А́ЛГЕБРА** (гарәп. علم الجبر), математика фәненең бер бүлеге, санлы системаларның гомуми үзлекләрен, хәреф тамгалары кулланып төзелгән тигезләмәләр ярдәмендә мәсьәләләр чишүнең гомуми ысулларын өйрәнә. Баштарак хәрефле аңлатмалар, хәрефләрдән торган формулаларны үзгәртү гыйлеме буларак үскән. 17 йөз ахыры — 19 йөз башларында А., беренче чиратта, тигезләмәләр турындагы фән булып формалаша. Хәзерге заман А.сы үзлекләре рациональ саннарны кушу һәм тапкырлау гамәлләренә азмы-күпме дәрәҗәдә охшаган төрле табигатьле объектлар җыелмаларын өйрәнә. Андый гамәлләр — алгебраик гамәлләр дип, алар буйсына торган законнар аксиомалар дип атала. Кагыйдә буларак, аксиомалар геометрия, матем. анализ, физика, А.ның үз мәсьәләләрен чишкәндә барлыкка килә. Ул алгебраик гамәлләре билгеләнгән җыелмаларны үзлекләренә карап классификацияли һәм шул җыелмада табигый рәвештә барлыкка килгән төрле мәсьәләләрне өйрәнә. Татарстанда А. буенча беренче мөһим тикшеренүләр Казан ун-тында Н.И.Лобачевский тарафыннан башкарыла, ул, аерым алганда, алгебраик тигезләмәләрнең тамырларын якынча исәпләүнең киң таралган бер ысулын эшли. Бу ысул аның «Алгебра» (1834) дигән китабында бәян ителә.

Казанда алгебраик тикшеренүләрнең иң югары үсеше 1930 елларга туры килә, ул вакытта күренекле алгебра галиме Н.Г.Чеботарёв тырышлыгы б-н Казан ун-тында А. каф. ачыла, Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-ты оештырыла. Шул елларда Чеботарёв һәм аның шәкертләре В.В.Морозов, И.Д.Адо, Н.Н.Мейман һ.б. тарафыннан Галуа теориясенә, алгебраик саннар теориясенә, Ли төркемнәренә, дәвам итеп лүче полиномнарга һәм резольвент проблемасына караган тикшеренүләр уздырыла. 1932 елда ул Цюрихта математикларның халыкара съездында Галуа теориясенә кагылышлы доклад ясый. Казан ун-тында эшләү елларында А.ның күп кенә өлкәләрендә — алгебраик саннар һәм функцияләр кырлары теориясендә, резольвент проблемасында мөһим нәтиҗәләр алына. Гиппократның циркуль һәм линейка ярдәмендә түгәрәк «айчыклар»ның мәйданнарын табу турындагы классик проблемасын хәл итү ысулы эшләнә, һәм ул 1947 дә Чеботарёвның шәкерте А.В.Дороднов тарафыннан чишелә. И.Д.Адо сыйфат саны нуль булган чикле үлчәмле Ли алгебраларын чикле үлчәмле итеп төгәл билгеләү проблемасын чишә. В.В.Морозов ярым гади Ли төркемнәренең барлык ярым гади булмаган иң зур астөркемнәрен тулысынча төркемли. 1951 дә Мәскәү математигы Е.Б.Дынкин ярым гади Ли алгебраларының ярым гади булган иң зур астөркемнәрен төркемли. Шулай итеп, 19 йөздә Норвегия математигы Софус тарафыннан Ли алгебрасының комплекслы примитив күптөрлелеген төркемләү турында куелган проблема В.В.Морозов б-н Е.Б.Дынкин тарафыннан тулысынча чишелә. 1960 еллардан башлап Казан ун-тының алгебра кафедрасында, Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-ты каршында бәйләнешле җирле бөҗралар теориясе, модульләр һәм категорияләр, Линың модуляр алгебралары һәм аларны бирү буенча тикшеренүләр алып барыла (И.И.Сахаев, С.Н.Тронин, Ю.Б.Ермолаев, А.Х.Долотказин, Н.А.Корешков, С.М.Скрябин һ.б.). А.ның А. һәм матем. логика чигендә үсә торган чагыштырмача яңа бүлекләрендә дә тикшеренү эшләре алып барыла. Алгоритмик танып булмаган объектларны өйрәнү һәм төркемләү вакытында барлыкка килә торган алгоритмик табигатьле структуралар өйрәнелә (М.М.Арсланов), сызыкча А.дагы чикле рациональ процедуралар тикшерелә (Ю.А.Альпин, С.Н.Ильин). Бу хезмәтләр А.ның актуаль проблемаларын, аның башка өлкәләрдә кулланылышын өйрәнүгә юнәлтелгәннәр һәм Россиянең әйдәп баручы үзәкләре (Мәскәү, Новосибирск, Түбән Новгород), АКШ, Англия, Германия, Италия һ.б. илләр б-н тыгыз бәйләнештә уздырылалар.

*Әд.:* Ч е б о т а р ё в Н.Г. Собр. соч.: В 3 т. М.–Л., 1949–50; М а л ь ц е в А.И. Алгебраические системы. М., 1970; К о с т р и к и н А.И. Введение в алгебру. М., 1977.

*М.М.Арсланов.*

**«АЛГОРИ́ТМ»**, к. *Казан хисаплау техникасы һәм информатика фәнни-җитештерү берләшмәсе.*

**АЛДА́Н ОЛЫСЫ́**, Якутия Респ-касының көньяк өлешендә; 1930 елда Алдан р-ны (1993 тән хәзерге исемдә) буларак оештырыла. Мәйданы — 156,8 мең *км*². Үзәге — Алдан шәһәре (Якутскидан 520 *км* көньяктарак). Халкы — 55 мең кеше (2000). Татарлар А.о. терр-ясенә 1920 елларда, биредә алтын чыгарыла башлагач килеп урнашалар. 1930–40 елларда татарлар саны урман әзерләү һәм шахталарда эшләү өчен илнең үзәк төбәкләреннән көчләп күчерелгән халык исәбенә арта. 1979 да татарлар — 668, 1989 да 1114 кеше исәпләнә. Башлыча, Алдан шәһәрендә яшиләр.

**АЛДА́Р** (Алдар таз, Алдар күсә), татар фольклоры персонажы. Хәйләкәр кеше турындагы борынгы заманда ук туган көнкүреш әкиятләрендә очрый. Төрле хәйләләр б-н А. башка әкияти персонажларны алдый. Ш.у.к. *Таз, Шомбай.*

**АЛДО́ШИН** Леонид Тихонович (5.8.1936, Брянск өлкәсе Почеп ш. — 23.12.1985, Мәскәү), спортчы, тренер (авиамодель спорты),

СССРның халыкара класслы спорт остасы (1976). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1963). Радио б-н идарә ителә торган планёр һәм самолёт модельләре очырту буенча СССР һәм дөнья чемпионы, рекордчысы (1969, 1971, 1974, 1975). 1963–78 елларда Казан авиация ин-тының авиамодельләр лаб. җитәкчесе, 1978–82 дә радио аркылы идарә ителә торган модельләр б-н эшләү тренеры (Мәскәү).

**АЛЕВРОЛИ́Т** (грек. áleuron — он һәм líthos — таш), үлчәмнәре 0,01 *мм* дан алып 0,1 *мм* га кадәр булган вак кисәкчекләрдән торган утырма тау токымы. Эре (0,1–0,05 *мм*), уртача (0,05–0,025 *мм*) һәм вак (0,025– 0,01 *мм*) бөртекле була. А. лар составында җилләнү процессына бирешмәүчән минераллар (кварц, микроклин) күпчелек урын алып



Алевролит.
Татар ярусы утырмаларыннан
(Тәтеш р-ны).

тора; карбонатлар, сульфатлар, цементланган оксидлар җыелмасы була. ТР терр-ясендә А.лар барлык геол. дәверләрнең утырма токымнарында киң таралган. Алар, гадәттә, ком һәм комташларга тиңдәш. Еш кына нефть, газ һәм су резервуарларын формалаштыручы токым ролен үтиләр. Өске катламга якын утырмалардагы һәм грунттагы специфик төрчәләре комсыл балчык (балчыклы кисәкчекләр микъдары 10–30%), балчыклы ком (3–10%) һәм лёсслардан (3% тан кимрәк) гыйбарәт. Цемент, керамзит һәм төзелеш керамикасы эшләп чыгаруда балчыклар б-н бергә чимал итеп кулланыла.

**АЛЕ́ЙНИКОВА** Мария Марковна (6.5.1906, Сембер ш. — 31.3.1988, Казан), энтомолог, туфрак зоологиясе белгече, биол. фән. канд. (1949). Казан ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый (1929). 1929–45 елларда ТАССР Җир эшләре халык комис-тының а.х. культуралары корткычларына каршы көрәш отрядын җитәкли. 1946 дан СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында, СССРда беренчеләрдән булып Туфрак зоологиясе лабораториясен оештыра һәм җитәкли (1962–76). Бөтенсоюз энтомология җәмгыятенең Казан бүлеген оештыручыларның берсе (1972). Беренче мәртәбә аның җитәкчелегендә Татарстан, күрше өлкәләр һәм респ-калар терр-ясендә туфрак фаунасы тирәнтен тикшерелә. А.х. үсемлекләренә аеруча зур зыян китерүче корткычлар таралышы буенча карта төзелә һәм аларга каршы көрәш чаралары билгеләнә.

Х е з м.: Почвенная фауна Среднего Поволжья. М., 1964; Животное население почв агроценозов и его изменения под влиянием сельскохозяйственного производства. К., 1969; Парцеллярная структура елово-широколиственных лесов востока европейской части СССР. М., 1979.

**АЛЕ́КИНА ПОЛЯ́НА** (Алекин Аланы) авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Үләмә елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 214 кеше (руслар — 73%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек үрчетү. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына; соңрак таралып, ташландык хәлгә килгәннән соң, 17 йөзнең 2 нче яртысында яңадан торгызыла. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Алексин Аланы (Алексина Поляна) исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1892 елда чиркәү-приход мәктәбе ачыла, 2 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 998 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волостена керә. 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 339, 1897 дә — 485, 1908 дә — 514, 1920 дә — 610, 1926 да — 471, 1938 дә — 341, 1949 да — 280, 1958 дә — 230, 1970 тә — 186, 1979 да — 205, 1989 да — 263 кеше.

**АЛЕКСА́НДР I** (12.12.1777, С.-Петербург — 19.11.1825, Таганрог ш.), Россия императоры (1801 елдан). Императорлыкка варис вакытында атасы император Павел I б-н бергә Казанга килә, Арча кырында гарнизон гаскәриләре осталыгын тикшерүне үткәрә, Богородица монастыре соборына нигез салуда катнаша, шәһәрне төзекләндерүгә иганәлек итә, шәһәр халкы б-н очраша, патша килү уңаеннан оештырылган мәҗлесләрдә була. Тәхеткә утырганнан соң либераль реформалар үткәрә, 1804 елның 5 ноябрендә Казан ун-тын оештыру фәрманына кул куя, ун-тының еллык чыгымын 130 мең сум чамасында билгели.

*Әд.:* П и н е г и н М.Н. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895.

**АЛЕКСА́НДР II** (17.4.1818, Мәскәү — 1.3.1881, С.-Петербург), Россия императоры (1855 елдан). Императорлыкка варис булган дәвердә, 1837 елда ил буйлап сәяхәте вакытында Казанга килә, шәһәрнең истәлекле урыннары б-н таныша: Кремльдә, Богородица монастырендә, университетта була, шәһәрне төзекләндерүгә иганәлек итә. Аның килүе хөрмәтенә Казан сәүдәгәрләре Арча кырында халык өчен бәйрәм, ә губернатор С.С.Стрекалов зыялылар өчен күңел ачу мәҗлесе (бал) һәм спектакль оештыралар. Тәхеткә утырганнан соң, А. II Казанда 1871 елда кабат була: гарнизон гаскәриләре осталыгын тикшерүне үткәрә, делегацияләр кабул итә, Мария исем. кызлар гимназиясенә бина сатып алуга, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тын һәм Үзәк керәшен-татар мәктәбен тотуга акчалата иганәлек кыла.

*Әд.:* П и н е г и н М.Н. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; К а з а н с к и й М.В. Путеводитель по Казани. К., 1899.

**АЛЕКСА́НДР III** (26.2.1845, С.-Петербург — 20.10.1894, Ливадия, Кырым), Россия императоры (1881 елдан). Императорлыкка варис вакытында — 1866 елның августында, 1869 ның июлендә һәм 1871 нең августында Казанга килә. Арча кырында Казан гарнизоны гаскәриләренең хәрби уеннарын үткәрә, шәһәр халкы бәйрәмендә, Кремльдә, соборда, монастырьларда, университетта һ.б. истәлекле урыннарда була. Шәһәрнең ярлы-ятимнәре йортларына акчалата ярдәм итә, Үзәк керәшен татар мәктәбендә укучы 20 баланы укыту-тәрбияләүне үз өстенә ала.

*Әд.:* П и н е г и н М.Н. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895.

**АЛЕКСА́НДР III ФӘРМАНЫ́**, 1888 елның 16 июлендә эчке эшләр министры Д.А.Толстой тәкъдиме б-н кабул ителә, Оренбург Диния нәзарәтенә (мөфтиятенә) караган мөселман руханиларының белем дәрәҗәсен билгеләү таләбен чагылдыра («О введении образовательного ценза для духовных лиц магометанского исповедания по округу Оренбургского духовного собрания»). Фәрманда, Оренбург Диния нәзарәтендә (мөфтияттә) эшләргә билгеләнә торган дин әһеленең белем дәрәҗәсе рус гимназиясенең башлангыч 4 нче сыйныфы яки өяз һәм шәһәр уч-щеләре яисә татарлар өчен ачылган Укытучылар мәктәбе күләмендә булырга, аерым очракта 2 сыйныфлы башлангыч халык уч-щеләрен тәмамлаучылар белеменнән дә түбән булмаска тиеш, дигән таләп куела. Шәһәр мәхәлләләре имамнары — бер сыйныфлы башлангыч халык уч-щеләре күләмендә, авыл муллалары — русча сөйләшерлек һәм укырлык дәрәҗәдәге белемгә ия булырга тиеш, диелә. Авыл муллаларының белем дәрәҗәсен билгеләүче таныклык өяз уч-щеләре советы тарафыннан бирелергә тиеш була. Фәрман 1891 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә; бу фәрман алда аталган вазифаларны моңарчы үтәп килгән дин әһелләренә кагылмый.

**АЛЕКСА́НДР БИСТӘСЕ́** (Гүәрдин) авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 16 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасы буенда. 2002 елда 525 кеше (руслар — 70%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек үрчетү. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1650 елларда нигез салына. 1736 дан отставкага чыгучы унтер-офицерлар һәм лейб-гвардиячеләрнең яшәү урыны буларак билгеле. 1767 дә монда, гади крәстияннәрдән тыш, шундый 61 «җирләшкән солдат» хуҗалыгы теркәлгән (гаилә әгъзалары б-н 214 җан иясе). Соңрак авыл халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, итек тегү һәм чүлмәк ясау б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы крәстияннәр кузгалышында А.Б. баш күтәрүчеләрнең җыелу урыны була. 1814 тә архит-ра истәлеге — Христово-Рождество чиркәве төзелә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, авылда тегермән,

земство уч-щесе эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 3513 дис. тәшкил итә. 1920 елгы «*Сәнәкчеләр» фетнәсе* вакытында авыл халкының бер өлеше һәлак була. 1919 да А.Б.ндә беренче совет, 1930 да «Яңа тормыш» һәм «Пролетарий» к-злары төзелә. 1950 дән авыл «Кызыл партизан» к-зына, 1970 тән — шул исемдәге совхозга, 1998 дән «Александровский» а.х. товарлары җитештерү кооперативына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостена карый. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 906, 1897 дә — 1628, 1913 тә — 1889, 1926 да — 1004, 1938 дә — 589, 1949 да — 454, 1958 дә — 455, 1970 тә — 368, 1979 да — 344, 1989 да — 426, 2002 дә — 525 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**АЛЕКСА́НДРА ИСЕМЕНДӘГЕ́ КЫЗ БАЛАЛА́Р ЯТИМХАНӘСЕ́**, сәүдәгәр К.Л.Крупеников тырышлыгы б-н Казанда 1845 елның февралендә нигез салына. Патшабикә Александра Фёдоровна хөрмәтенә аның исеме бирелә. К.Л.Крупеников, О.С.Александрова-Гейнс һ.б. байларның иганәсе исәбенә тотыла. Ятимханә бинасын О.С.Александрова-Гейнс төзетә. Ятимханәдә 4 ир-ат, 2 хатын-кыз укытучы һәм бер хезмәткәр эшли. Балалар тулаем ятимханә исәбенә тәрбияләнә; аларга башлангыч белем бирелә, кул эшләре һ.б. һөнәрләр өйрәтелә. 1904 елда һәр баланы асрау 66 сум 27 тиенгә төшкән (башка ятимханәләр б-н чагыштырганда иң аз чыгым). 19 йөз ахырында 100 ләп кыз бала тәрбияләнүе мәгълүм. 1917 дә ябыла.

*Әд.:* Благотворительные учреждения Казани. К., [Е.к.]; Отчёт Казанского губернского попечительства детских приютов за 1889 г. К., 1890; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**АЛЕКСА́НДРОВ** Александр Иванович (монахлыкта Анастасий) (16.4.1861, Казан губ., Лаеш өязе Байтирәк а. — 3.5.1918, Петроград), филолог, чагыштырма тел белеме д-ры (1888), Казан ун-тының атказ. ординар проф. (1911–13). Казан ун-тын тәмамлый (1883). И.А.*Бодуэн де Куртенэ* һәм Н.В.*Крушевский* шәкерте. 1884 елда Дерпт ун-тына белемен камилләштерү өчен җибәрелә. 1884–88 елларда Дерпт, Харьков ун-тларында укыта. 1889–1913 тә Казан ун-тында эшли: чагыштырма тел белеме һәм санскрит теле каф. (1889), славян филол. каф. (1889–96) профессоры, тарих-филол. ф-ты деканы (1905–11), ректор вазифаларын башкаручы (1908). 1881–1911 дә Казан ун-ты кушуы буенча көньяк славяннарның тарихын, мәдәниятен һәм рухи традицияләрен өйрәнү максатында Далматия, Черногория һ.б. илләрдә була. 1896 да Казанда ир балалар өчен якшәмбе мәктәбе ача һәм анда укыта. 1911 дән монах, Казан руханилар академиясендә епископ (1912) була. 1911 дән Казан руханилар академиясе профессоры, 1912 дән ректоры. 1913 тән Петербург руханилар академиясе ректоры. Хезмәтләре славян тел белеменә, чагыштырма тел белеменә, рус диалектологиясенә, Казан губернасы сөйләшләрен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Некоторые особенности падежных окончаний имён существительных говора деревни Сорочьи Горы Лаишевского уезда Казанской губернии // Русский филол. вестн. 1883. Т. 9, № 1–2; Языковедение и славяноведение. К., 1889; Политическая и церковная жизнь славянства в XIX в. // Православный собеседник. 1911. Ч. 1.

*Әд.:* К у р г а н о в Ф.А., Ц а р е в с к и й А.А., П о к р о в с к и й И.М. Отзыв ... о сочинениях А.И.Александрова // Православный собеседник. 1912. Сент.; Б у л а х о в М.Г. Восточнославянские языковеды: Биобиблиогр. словарь. Минск, 1976. Т. 1; Казанский университет. 1804–1979: Очерки истории. К., 1979; Славяноведение в дореволюционной России: Биобиблиогр. словарь. М., 1979.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**АЛЕКСА́НДРОВ** Альберт Васильевич (7.3.1938, Чуаш АССРның Кызыл Армия р-ны Янгазы а.- 20.1.2004, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1984), проф. (1986), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). 1960 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан. технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли: 1984–2000 елларда каты химик матдәләр технологиясе каф. мөдире, 1985–90 да инж.-хим.-технол. ф-ты деканы. Хезмәтләре каты җисемнәр һәм органик кристалларның пластиклык һәм ныклык физикасына, органик матдәләр һәм алар нигезендәге композицияләрнең структура үзенчәлекләрен исәпкә алып, каты җисемнең дислокацион физикасын үстерүгә карый. Композицион һәм конструкторлык функциональ материалларның яңа буынын, аларны эшләп чыгару технологияләрен (ш.и. импульслы эшкәртүнең прогрессив алымнарын кулланып) эшли. 200 дән артык мәкалә, 2 монография авторы, 60 уйлап табу таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**АЛЕКСА́НДРОВ** Иван Васильевич (?, Вятка губ. Слободской ш. — 1893, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, сәнәгатьче, нәселдән күчмә шәрәфле граждан. Минераль һәм җиләк-җимеш сулары, квас ясау (1884 елда нигезләнә, 50 кеше эшли), спирт куу, сыра һәм татлы сосла ясау (1892 елда нигезләнә, 310 кеше эшли, елына 800 мең чиләк сыра җитештерелә — хәзер «Кызыл Шәрекъ» АҖга керә) з-длары хуҗасы. Вафатыннан соң варислары А. исем. сәүдә йорты оештыралар («Наследники коммерции советника И.В.Александрова в Казани»). 1898 елда Мәкәрҗә ярминкәсендә А. заводлары җитештергән спиртның сыйфаты өчен алтын медаль бирелә.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казанский летописец. К., [Е.к.]; Вся Россия. Русская адресная и справочная книга фабрик, заводов и торгово-промышленности на 1912 год. М., 1912.

*Л.М.Свердлова.*

**АЛЕКСА́НДРОВ И.В. ВАРИСЛАРЫНЫ́Ң СЫРА́ ҺӘМ СОСЛА́ КАЙНАТУ́ ЗАВОДЫ́ КО́МПЛЕКСЫ**, Казанда 19 йөз ахыры — 20 йөз башы сәнәгать архит-расы истәлеге. Түбән Кабан күле ярына урнашкан. Екатерининская урамындагы (хәзерге Тукай ур.) бер кварталның зур өлешен биләп торган. «Казанда коммерция советнигы И.В.Александров варислары» сәүдә йортының милке булган. Тарихы 19 йөз ахырында берничә җитештерү корпусы, таш подвал, хезмәткәрләр өчен 2 торак йорт төзүдән башлана.



И.В.Александров варисларының сыра һәм сосла кайнату з-ды.
Казан. Арх. Ф.В.Усвечев. 1907-08.

1907–08 дә Ф.В.Усвечев проекты б-н яңа корпуслар салына, элеккеләре киңәйтелә. Комплексның урнашу композициясе сыра һәм сосла кайнату эше таләп иткән шартларга яраштырыла. Төрле биеклектәге биналар йөзе б-н күл ягына юнәлгән каре хасил итә. Җитештерү корпусларының бер өлеше урам буйлап, калганнары аңа перпендикуляр рәвештә урнаша. Кварталның түрен Г хәрефе рәвешендәге 4 катлы салат киптерү һәм 2 катлы салат ясау корпуслары биләгән. Аларның бизәлеше бер үк төрле: җәя сыман формадагы уемнар, сырлы консолькалы кәрнизләр, сухариклар. Өч катлы сосла җитештерү корпусы түрдә, урамга перпендикуляр рәвештә урнашкан. Аның буй як фасадының аскы ярусын турыпочмаклы уемнар, ә югары өлешен — ярымбаганалар, ук сыман тар тәрәзәләр һәм алар өстендә ромб сыман рамкалар бизи. Әлеге корпусның бер башына терәп сосла суыту бинасы салына. Ул биек фронтон һәм зур ярымтүгәрәк уемнар б-н аерылып тора. Әчетү бүлеге бинасының икенче каты бизәлешендә модерн элементлары файдаланыла. Комплекс өстендә беренче булып 2 төтен торбасы күзгә ташлана, аларның очларына 1907 ел — төзелү датасы төшерелгән флюгерлар беркетелә. Җитештерү биналарында металл конструкция элементлары — чуен колонналар, ике таврлы балкалар (салат ясау һәм әчетү бүлекләре), буынтыклы фермалар (сосла суыту корпусы) файдаланылган. Биналар комплексы архит-расында эклектиканың модерн элементлары кушылган рациональ юнәлеше сакланган, ул бүген дә әлелә ни үзгәреш кичермәгән. 1930 еллардан биредә «Кызыл Шәрекъ» сыра з-ды урнаша. Соңгы елларда берничә корпусы «*Эдельвейс*» сәүдә-сәнәгать төркеме карамагында, калганнары файдаланылмый.

*Г.Г.Ногманова.*

**АЛЕКСА́НДРОВ РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 3 мең *км*² га якын. Үзәге — Александровка авылы (Оренбургтан 158 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы —

19900 кеше (2002), ш.и. 3266 татар. Алар, башлыча, 1820–40 елларда нигезләнгән Тукай (735 кеше), Сөлтәкәй (528), Яфаров (624) авылларында яши. 1860 елларда Тукай һәм Сөлтәкәй авылларында мәчетләр (1932–35 тә юкка чыгарыла) төзелә, алар каршында мәдрәсә һәм мәктәпләр эшли. 1920–30 елларда А.р.ның 3 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла. 1993 тән Сөлтәкәй авылы мәдәният йорты каршында — «Дуслык» халык театры, Яфаров авылында Ләйсән татар халык вокаль ансамбле эшли. А.р.ның 1 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 3 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла.

**АЛЕКСА́НДРОВА-ГЕЙНС** Ольга Сергеевна (1850–1927), җәмәгать эшлеклесе, иганәче, Казан шәһәренең шәрәфле гражданы. Сәүдәгәр Александровлар нәселеннән, губернатор А.К.*Гейнс* хатыны. Бертуганы А.С.Александров вафатыннан соң (1883) байтак мирас-байлыкка берүзе ия булып кала. Иганәлек кылуны изге бурычы санап, шуның б-н дан казана: 1881 елдан Ксения исем. кызлар гимназиясе попечителе, 1889 да гимназиягә бина сатып алуга 50 мең сум, попечительләр советы кирәгенә 10 мең сум акча бирә. Шул ук елда Казанда хастаханә ачу өчен 85 мең сум, аның балалар бүлеген тотуга 15 мең сум акча бүләк итә. Хастаханәнең хатын-кызлар бүлегендә 5 ятак урын тотуны да үз өстенә ала. Александра исем. кыз балалар ятимханәсенең яңа бинасы төзелешенә акчалата ярдәм итә (А.-Г. 30 ел дәвамында гимназиянең иганәче-идарәчеләре исемлегендә тора). 1890 да шәһәр музее һәм аның кибете өчен бина алырга 500 мең сум көмеш акча бирергә җыенган була. Шәһәр җитәкчелеге үтенечен истә тотып, акча урынына Казанга *Александровлар пассажын* бүләк итә (ул бинаны төзүгә 800 мең сум һәм җиһазландыруга 100 мең сумнан артыграк акча тотылган). Шундый изге эшләре өчен А.-Г. Казан шәһәренең шәрәфле гражданы дигән мактаулы исемгә лаек була. Ул ш.у. *Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятен*енең шәрәфле әгъзасы (1898). 1917 елгы инкыйлабтан соң байлыгын югалта, мохтаҗлыкта яши. Казанда Елантау монастырендагы Александровлар төрбәсендә җирләнә.

*Әд.:* Приволжские города и селения Казанской губернии. К., 1892; Учебные заведения ведомства учреждений императрицы Марии: Краткий очерк. СПб., 1906; Благотворительные учреждения России. [У. һәм е.к.]; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*



О.С. Александрова-Гейнс. Рәссам И.Е.Репин. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

**АЛЕКСАНДРО́ВИЧ** Исмәгыйль Мостафа улы (18.7.1929, Белоруссия ССРның Минск өлкәсе Клецк ш.), дин эшлеклесе. Польша-Литва татары. Дин белемен әтисе — Клецк шәһәре мәчете имамы (1939–53) Мостафа Йосыф улыннан ала. Белоруссия политехника ин-тының төзелеш ф-тын тәмамлый (1953). 1953–89 елларда Минск шәһәре төзелеш оешмаларында эшли. 1990 нан татар мөселман «әл-Китап» берлеге б-н актив хезмәттәшлек итә. 1994 тә Беларусь Респ-касының Мөселман дини берләшмәләре идарәсе рәисе-мөфтие итеп сайлана.

**АЛЕКСАНДРО́ВИЧ** Мостафа (? — 1945 тән соң), тарихчы, дипломат. Польша-Литва татары. Львов һәм Каһирә ун-тларын тәмамлый (1933, 1937). 1937 елда Речь Посполитаның (Польшаның) Иерусалимдагы баш консуллыгы хезмәткәре. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Франциядә Каршылык хәрәкәтендә катнаша, соңрак Швейцариядә Польша эмигрантлары оештырган университетта укыта. Хезмәтләре «*Жиче Татарске*» ж-лы һәм «*Рочник Татарски*» бюллетенендә (ж-лында) басыла.

Хезм.: Очерки исламской религии. Вильно, 1937.

**АЛЕКСАНДРО́ВИЧ** Хәсән Мостафа улы (20.4.1924, Белоруссия ССРның Минск өлкәсе Клецк ш.), химик, химия фән. д-ры (1970), проф. (1972). Польша-Литва татары. Бөек Ватан сугышында катнаша. Белоруссия ун-тын тәмамлый (1953, Минск ш.). 1956 елдан БССР ФАнең Гомуми һәм нәорганик химия ин-тында, 1966 дан лаб. мөдире һәм директор урынбасары (1980 гә кадәр), 1990 нан — баш, соңрак әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре коллоидлар химиясе, нәорганик матдәләр һәм минераль ашламалар технологиясенә карый. Актив өслекле матдәләр тәэсиренең физ.-хим. һәм коллоид-хим. нигезләрен һәм кулланылышын тикшерә. Файдалы казылмаларны баету, калийлы ашламалар алуның яңа нәтиҗәле реагентларын һәм технологиясен эшли һәм аларны җитештерүгә кертә («Белорускалий» ЖБ). 150 авторлык таныклыгына ия, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Технология калийных удобрений. Минск, 1968 (автордаш); Калийные соли Белоруссии, их переработка и использование. Минск, 1973 (автордаш); Основы применения реагентов при флотации калийных руд. Минск, 1973; Физикохимия селективной флотации калийных солей. Минск, 1983.

**АЛЕКСАНДРО́ВИЧ** Якуб Мостафа улы (15.1.1934, Белоруссия ССРның Минск өлкәсе Клецк ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1990), проф. (1991). Польша-Литва татары. 1957 елда Халык хуҗалыгы ин-тын (Минск ш.) тәмамлый. 1961–67 елларда БССР ФАнең Икътисад ин-тында эшли. 1968 дән Белоруссия ССР План дәүләт ком-ты каршындагы Икътисад һәм планлаштыруның икътисади-матем. ысуллары фәнни-тикшеренү ин-тында сектор, бүлек мөдире. Хезмәтләре Белоруссиянең җитештерү көчләрен урнаштыруга һәм социаль-икътисади үсешен фаразлауга карый.

Хезм.: Региональное планирование: вопросы развития и размещения производительных сил БССР. Минск, 1982.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 35 *км* көнбатыштарак, Ямаш елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 21 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек үрчетү. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. 1980 елларның 2 нче яртысында авыллар исемлегеннән сызыла. 1998 нең 18 февралендә яңа торак пункт буларак рәсми теркәлә. Халык саны: 1859 да — 193, 1889 да — 62, 1920 дә — 53, 1926 да — 92, 1938 дә — 91, 1948 дә — 112, 1958 дә — 60, 1970 тә — 29, 1979 да — 20 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 38 *км* көньяктарак, Баранка елгасы буенда. 2002 елда 146 кеше (руслар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек үрчетү. Башлангыч мәктәп. Клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Алан исеме б-н дә мәгълүм. 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да 1883 елда ачылган башлангыч белем бирү мәктәбе, 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 95 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 172, 1897 дә — 263, 1908 дә — 285, 1920 дә — 342, 1926 да — 317, 1938 дә — 302, 1949 да — 106, 1958 дә — 206, 1970 тә — 250, 1979 да — 203, 1989 да — 205 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 12 *км* төньяктарак, Самара — Чиләбе автомобиль магистрале буенда. 2002 елда 1133 кеше яши (руслар — 53%, татарлар — 37%). Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, дуңгыз үрчетү. «Александровский» спирт з-ды. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөз ахырында алпавыт Александр Кротов тарафыннан нигез салына, шуңа күрә авылның Кротовка дигән икенче исеме дә бар. 1861 елгы ре-

формага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе була. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1795 тә — 87 ир заты; 1859 да — 455, 1897 дә — 730, 1926 да — 750, 1938 дә — 1084, 1949 да — 821, 1958 дә — 955, 1970 тә — 1099, 1979 да — 1110, 1989 да — 1087 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** посёлогы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2002 елда 17 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — умартачылык. 19 йөз урталарыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Икенче Александровка исеме б-н дә билгеле. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивиль өязе Иске Тәрбит волостена керә. 1920 дән Чуаш автономияле өлкәсенә карый, 1921 дән ТАССРның Зөя кантонында; 1927 елның 14 февраленнән — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 елның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 296, 1897 дә — 126, 1908 дә — 153, 1920 дә — 90, 1926 да — 72, 1938 дә — 99, 1958 дә — 55, 1970 тә — 44, 1979 да — 33, 1989 да — 27 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** посёлогы, Лаеш р-нында, шәһәр тибындагы Лаеш посёлогыннан 8 *км* төньяктарак, Казан–Лаеш автомобиль юлы буенда. 2002 елда 290 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек үрчетү. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 1910 елларда нигез салына. ТАССРның Лаеш кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1922 дә — 233, 1926 да — 292, 1938 дә — 330, 1949 да — 190, 1958 дә — 265, 1970 тә — 339, 1979 да — 257, 1989 да — 264 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 4 *км* төньяктарак, Мәчкәрә елгасы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 1910 елларда Горкино авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Писмән волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. 1930 да А.да «Ирек» к-зы оештырыла, 1957 дән — «Лениногорск» с-зы составындагы посёлок. Халык саны: 1926 да — 214, 1949 да — 95, 1958 дә — 157, 1970 тә — 130, 1979 да — 36, 1989 да — 19 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт Каменевскийларның крепостной крәстияннәре булган, шул сәбәпле авыл рев-циягә кадәрге чыганакларда Каменевка исеме б-н дә билгеле. Игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнәләр. 1884 елгы мәгълүматлар буенча, А.да аракы з-ды, 1908 дә 2 тимерче алачыгы була. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 367 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр А. Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 115, 1897 дә — 157, 1908 дә — 153, 1920 дә — 220, 1926 да — 169, 1949 да — 144, 1958 дә — 104, 1970 тә — 58, 1979 да — 29, 1989 да — 9 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Карамалы елгасы буенда. 2002 елда 604 кеше (татарлар — 73%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1805 елда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Рус Карамалысы исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, А.да уч-ще, тегермән була. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, Александр чиркәве, земство мәктәбе эшли. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Карамалы волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман р-нында. Халык саны: 1859 да — 246 ир заты; 1870 тә — 539, 1920 дә — 1211, 1926 да — 1060, 1938 дә — 994, 1949 да — 785, 1958 дә — 778, 1970 тә — 667, 1979 да — 592, 1989 да — 605 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 11 *км* көнчыгыштарак, Кама елгасының сул кушылдыгы Грязнуха суы буенда. 2002 елда 733 кеше (руслар — 80%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1930 елларда алпавыт утары урынында авылга нигез салына. 2001 нең 27 июненә кадәр Галактионов исем. совхоз посёлогы дип атала. Халык саны: 1938 дә — 578, 1949 да — 607, 1958 дә — 702, 1970 тә — 954, 1979 да — 926, 1989 да — 843 кеше.

**АЛЕКСА́НДРОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм кәсәбәчеләре, җәмәгать эшлеклеләре: 1) **Евсей Васильевич** (? — 1818), сәүдәгәр, А. династиясенә нигез салучы; 2) **Сергей Евсеевич** (1792 — 4.12.1870), 1 нче гильдия сәүдәгәр, коммерция советнигы, нәселдән күчмә шәрәфле граждан, Казан күн з-ды ширкәте («Товарищество Казанского кожевенного завода на паях») хуҗаларының берсе. 1840 еллар башыннан Россиядә чәй сәүдәсе тотучыларның иң билгелесе. Кияве И.И.Алафузов б-н берлектә Казанда зур сәүдә-сәнәгать ширкәтен нигезли («С.Е.Александров и И.И.Алафузов в Казани»). Аңа җитен эрләү (1870 елда 650 кеше эшли, 345600 сумлык әйбер җитештерелә) һәм туку (350 кеше эшли, 300 мең сумлык тукыма җитештерелә) ф-калары керә. Ш.у. алар күн з-дының уртак хуҗалары булалар (соңрак С.Е. Александров үз өлешен И.И.Алафузовка бирә). 1842–44, 1851–54 тә Казан шәһәр думасы башлыгы, бер үк вакытта Казан шәһәре җәмәгать банкы директоры. *Сәүдәгәрләр биржасын* (1866) оештыручыларның берсе. *Казан икътисадчылар җәмгыяте* әгъзасы, җәмгыятьнең 4 нче бүлеге җитәкчесе. Рус сәнәгатенә һәм сәүдәсенә булышлык итү җәмгыяте рәисе; 3) **Александр Сергеевич** (1844, Казан — 1883), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан, *Сәүдәгәрләр банкын* (1873) оештыручылардан, аның беренче рәисе. *Александровлар пассажына* нигез салучы. Атасы вафатыннан соң, 1871 дән А. сәүдә йортын җитәкли. Александра һәм Николай исем. балалар ятимханәләренә, Александровларның шәһәр хастаханәсенә һ.б. ярдәм иткән өчен алтын медаль б-н бүләкләнә. Ш.у.к. О.С. *Александрова-Гейнс*.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казанский летописец. К. [Е.к.]; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**АЛЕКСА́НДРОВЛАР ПАССАЖЫ́**, Казанда архит-ра истәлеге. Металл конструкцияләр б-н ныгытылган пыяла түбәле, эчке ишегалды, сәүдә һәм тамаша бүлмәләре булган табыш йорты. 1883–86 елларда сәүдәгәр А.С.Александров акчасына арх. В.В.Суслов һәм Н.И.Поздеевларның конкурста җиңеп чыккан проектлары нигезендә романтизм юнәлешенең эклектик формаларында Г.Б.*Руш* тарафыннан төзелә. 1890 да пассажның хуҗабикәсе О.С.Александрова-Гейнс аны музей оештыру өчен шәһәргә бүләк итә. Ләкин, мондый типтагы биналарга музей урнаштыру





1. Александровлар пассажы. Казан. Арх. В.В.Суслов, Н.И.Поздеев. 1883-86;
2. Эчке ишегалды. Ф.Бибин фотосы. 1890

кыен булганлыктан, ул элекке максатларда файдаланыла. А.п. шәһәрнең өске өлешендә, Кремль калкулыгы итәгендә (хәзерге Кремль һәм М.Җәлил урамнары чатында) урнашкан тар һәм сузынкы мәйданны били. Рельефның Черек күлгә (Дзержинский ур.) таба кисәк түбәнәюе нәтиҗәсендә бинаның төрле ягында катлар саны төрлечә: Кремль урамында 3, ә Дзержинский урамы ягында 5 катлы. Ике почмагы түгәрәкләнгән һәм эчке ишегалды булган турыпочмаклы бина. Аскы катларында кибетләр, беренче катта пыяла түбәле ишегалдыннан керешле кибетләр, өске катларында торак бүлмәләр һәм төрле оешмалар урнашкан булган. Төп керү юлында (Кремль ур.) агачтан эшләнгән тамбур корыла. Ишегалдының төп мәйданын вестибюльдән колонналар аерып тора. 1 нче катта, ишегалдының як-ягында, фасадлары а́рка хасил итүче кибетләр рәте тезелгән. Ишегалды өлешенең идәне пыяладан эшләнгән, ул эргә каттагы йөрү юлына яктылык биреп тора. Ишегалдының түрендә Черек күл ягына төшүче баскыч. Аның өстеннән бизәкле чуен күпер үткән, күпер аша көзгеләр һәм бизәкләр б-н зиннәтләнгән ресторан бүлмәләренә узганнар. А.п.ның Черек күлгә караган ягында, башка тарафларыннан аермалы буларак, коесыман ишегалды бар, ул йөк ташу өчен файдаланыла. Хәзерге М.Җәлил урамы ягыннан ул ишегалдына киң а́рка аша керелгән. Аның ян диварыннан эргә каттагы кибет конторларына һәм келәтләргә илтүче юл башланып китә. Товар ташу өчен файдаланылган киң пандуслы бу юл үзәк ишегалдының астыннан үтә. Келәтләр һәм конторлар ике яруска бүленеп урнашкан. Бинаның алгы ягы бизәлешендә ренессанс стиле, кабартып ясалган үсемлек сурәтләренә бай барокко һәм классицизм архит-расы элементлары кулланыла. Ярымколонналар, кариатида, хатын-кыз башы сыннары һ.б. ак таштан ясала. Күпсанлы бәйләгечләр, филенкалар һәм рустовка фигуралы кирпеч өслегендә штукатур измәсе б-н башкарыла. Бинаның манараны хәтерләтүче түгәрәкләнгән почмаклары шпильле гөмбәз б-н очлана. Гөмбәзнең Кремль урамына караган тәрәзәсенә пассажда сәгать кибете тоткан Климов акчасына куга торган сәгать урнаштырыла. Үзәк ишегалды диварының бизәлеше күп ягы б-н фасад бизәлешен кабатлый һәм бирерә уйма сыннар, ябыштырылган бизәк, көзгеләр һ.б. кулланыла. А́ркалар рәтендәге уемнарга агачтан ясалган зиннәтле зур ишекләр беркетелгән. Алар арасындагы диварга филенка б-н уратылган көзгеләр элене. Вестибюльдәге аралыкларда су кызларының алтынланган сыннары үзенчәлекле терәк булып хезмәт итә. Вестибюль колонналары арасында көбә киемле рыцарь сыны тора. Ишегалдының пыяла гөмбәз астына туры килгән үзәк урынында кулына бала күтәргән бронза ана сыны рәвешендәге яктырткыч куела. Ишегалдының үзәген урап алган уемнарда елның 4 фасылын чагылдыручы 4 аллегорик уйма сын урнаштырыла. 1930–70 елларда бирерә «Пионер» кинотеатры эшли. 1977 дә бинаның төньяк почмагы җимерелә. Сакланып калган өлеше үзгәртеп корылганнан соң (1980), анда хакимият һәм сәүдә оешмалары урнаштырыла. 2002 елдан яңадан торгызу эшләре алып барыла, нигезләре ныгытыла, стеналар, түбәләр яңартыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *С.Г.Персова.*

**АЛЕКСАНДРО́ВСКИЙ** Александр Александрович (2.4.1929, Ставрополь крае Пятигорск ш. — 5.2.1992, Казан), химия машиналары төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1977), проф. (1980), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1989). 1952 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый һәм шунда ук 1980 нән машиналар төзү технологиясе һәм машина детальләре каф. мөдире. Хезмәтләре үзәктән куучы кыр тәэсирендә тирәлекләрне эшкәртүне көчәйтүче югары нәтиҗәле хим. һәм массаалмашу технол. аппаратларын эшләүгә; дисперс системаларны ректификацияләү, экстракцияләү, катнаштыру, күчерү һәм ваклауга карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование процесса смещения и разработка композиций, содержащих твёрдую фазу: Автореф. дис.... К., 1977; О моделировании процесса массообмена с учётом флуктуации физико-химических параметров // Инженерно-физ. журн. 1982. Т. 43, № 2.

**АЛЕКСЕ́ЕВ** Алексей Михайлович (23.5.1893, Казан — 2.5.1971, шунда ук), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1938), проф. (1933), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1944, 1965). Казан үсемлекләр физиологиясе мәктәбен оештыручы. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1917), шунда эшли, үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (1932 дән). Бер үк вакытта Казан а.х. ин-тында үсемлекләр физиологиясе һәм микробиология каф. мөдире, Казан пед. ин-тында ботаника каф. мөдире. 1946–54 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында ботаника секторы җитәкчесе, 1954–60 та ин-т директоры һәм үсемлекләр физиологиясе лаб. мөдире. Хезмәтләре үсемлекләрнең су режимын өйрәнүгә карый. Корылык тәэсиренең физиологик закончалыкларын ачыклый, тигезләнешле системалар термодинамикасы нигезендә үсемлекләрнең су алмашу процессын анализлый, беренчеләрдән булып үсемлекләр физиологиясенә күзәнәк суының термодинамик халәте күрсәткечләрен кертә (парциаль химик потенциал һәм активлык). Үсемлекләрнең су режимын физик-химик яктан өйрәнеп, үсемлек күзәнәкләре цитоплазмасы структураларында һәм матдәләр алмашында мөһим ингредиент буларак суның әһәмияте турында яңа күзаллауларны тәкъдим итә һәм нигезли. Ш.у. фитопатология һәм микология мәсьәләләре б-н дә шөгыльләнә, беренче мәртәбә Татарстанның фитопатоген гөмбәләр флорасын билгели һәм тасвирлый. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физиологические основы влияния засухи на растения. К., 1937; Водный режим растения и влияние на него засухи. К., 1948; Влияние минерального питания на водный режим растения. М., 1957 (автордаш); Водный режим клеток растения в связи с обменом веществ и структурированностью цитоплазмы. М., 1969.

*Әд.:* Л и п ш и ц С.Ю. Русские ботаники. М., 1947. Т. 1; Х о х л о в а Л.П. Жизненный и творческий путь профессора А.М.Алексеева: становление и развитие казанской школы физиологов растений — исследователей водного обмена. К., 1998. *Л.П.Хохлова.*



А.М. Алексеев.

**АЛЕКСЕ́ЕВ** Аркадий Владимирович (17.10.1946, Казан), физик, физ.-мат фән. д-ры (1988), РФАнең мөхбир әгъзасы (1997). Казан ун-тын тәмамлагач (1969), СССР ФАнең Казан ф-лы Физ.-техника ин-тында, 1973 елдан Калининград ун-тында эшли. 1974 тән РФАнең Ерак Көнчыгыш бүлегенең Тын океанны өйрәнү ин-тында, 1980 нән диңгез радиоспектроскопия бүлеге мөдире, директор урынбасары (1984 тән), океан һәм атмосфера физикасы бүлеге мөдире (1995 тән). Бер үк вакытта 1995 тән РФАнең Ерак Көнчыгыш бүлеге (Владивосток ш.) рәисе урынбасары. 2002 дән РФАнең Милек белән идарә итү агентлыгы (Мәскәү) директоры урынбасары. Хезмәтләре океанология характеристикаларын спектроскопия ысуллары б-н өйрәнүгә карый. Океанның өске һәм атмосфераның түбәнге катламнары параметрларын, ш.и. океан һәм атмосфераның үзара тәэсире модельләрен төзү өчен яңа мәгълүмат бирүче параметрларны анализлау өчен лазер техникасын, когерент һәм полихроматик спектроскопия куллану методикасын эшли. Табигый тирәлекләр радиоспектроскопиясе нигезендә океанда авыр металлар таралу кырлары мониторингы принципларын үстерә. Беренчеләрдән булып Кызыл диңгездә тоз эремәләрен анализлау һәм төбендә утырмалар формалашуны сыйфатлау өчен ЭПР алымын куллана, океанда планктон бергәлекләре таралышын һәм аның пычрануын бәяли. Алынган нәтиҗәләре реаль вакыт режимында әйләнә-тирә мохитнең бик зур акваторияләренә лазерлы мониторинг үткәрү һәм диңгез суының химик составын ерактан торып тикшерү өчен океанологик тикшеренүләрдә гамәли кулланылыш таба. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Акустическое возбуждение сверхизлучательного электромагнитного состояния вещества // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1968. Т. 55, вып. 11 (автордаш); Метод электронного парамагнитного резонанса в биогеохимических исследованиях океана // Океанология. 1987. Т. 27, вып. 1 (автордаш); Аномальное поведение европия в донных осадках береговой зоны юго-западной части Калифорнийского залива // Докл. РАН. 1998. Т. 361, № 5 (автордаш); Полихроматическая спектроскопия. Владивосток, 1999 (автордаш); Использование лазерной искровой спектроскопии с многоимпульсным возбуждением плазмы для мониторинга качества морской воды и состояния фитопланктона // Оптика атмосферы и океана. 2003. Т. 16, № 1 (автордаш). *Р.Г.Усманов.*



Алексеев посёлогының гомуми күренеше.

**АЛЕКСЕ́ЕВ**, шәһәр тибындагы посёлок, Алексеев р-ны үзәге. Казан тимер юл станциясеннән 108 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кама елгасының сулъяк ярында, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2006 елда 10,1 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 69,2%, татарлар — 24%) яши. Кирпеч з-ды, бизәкле нәфис тукыма туку ф-касы, икмәк һәм азык-төлек җитештерү, сөт-консерв комб-тлары, типография, а.х. техникасы, көнкүреш хезмәте күрсәтү пр-тиеләре. 3 урта һәм 1 башлангыч мәктәп, музыка мәктәбе, һөнәри уч-ще, төбәк тарихын өйрәнү музее, 2 мәдәният йорты, 3 китапханә.




Алексеев посёлогы. Универмаг.

1710–12 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Воскресенский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек алар кенәз А.А.Визапурский һәм ротмистр А.И.Сахаровның крепостной крәстияннәре булалар) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, күн аяк киеме тегү, җеп эрләү, штукатурлау һәм мич чыгару эшләре б-н шөгыльләнә. 1840 та А.та Вознесение чиркәве төзелә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, армия өчен тукыма җитештерү ф-касы, почта станциясе була. 20 йөз башында авылда волость идарәсе урнаша; земство хастаханәсе, Алексеев шәһәр уч-щесе, земство һәм чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), чиркәү, шәхси даруханә, телефон, телеграф, ашлык пристане була. 10 тимерче алачыгы, су, пар һәм 16 җил тегермәне, 5 ашлык киптергеч, 4 чәйханә, 5 кунып чыгу йорты, 5 кибет; 45 вак-төякләр, 2 сыра, 1 шәраб кибете була; җомга саен базар эшли. 1920 гә кадәр А. — Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волосте үзәге. 1920 дән — ТАССРның Лаеш, 1922 дән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Чистай р-нында, 1964 нең 4 мартыннан — яңадан районы үзәге. 1965 нең 17 июненнән — шәһәр тибындагы посёлок. Халык саны: 1859 да — 3570, 1897 дә — 3173, 1908 дә — 3551, 1920 дә — 3848, 1926 да — 3974, 1938 дә — 4823, 1949 да — 3778, 1958 дә — 4989, 1970 тә — 6368, 1979 да — 6332 кеше, 1989 да — 8,1 мең, 2002 дә — 9,7 мең кеше. А. янында Кама елгасы аша күпер бар.

**АЛЕКСЕ́ЕВ БИЗӘКЛӘ́П ТУКУ́ ФА́БРИКАСЫ**, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогында урнашкан халык сәнәгате һөнәрчелеге предприятиесе. Биредәге промкомбинатның 1920 еллар ахырында Лаеш туку остаханәсеннән күчерелгән җиһазлар б-н эшләп килгән туку цехы нигезендә 1969 да ачыла. Алексеев авылында әүвәлдән килгән йон, җеп эшкәртү һөнәрчелеге һәм элеккеге Лаеш өязенә кергән авылларда 19 йөз ахыры — 20 йөз башында киң таралган тукучылык традицияләренә нигезләнеп эшли. 1970 еллар уртасына кадәр ф-када җирле рус халкының кулдан (көрәләп) туку тәҗрибәсе үрнәгендә, бигрәк тә аның күп җепселләр кулланыла торган ысулы б-н киже-мамык һәм җитен әйберләр тукыла һәм челтәр катнаштырылган чүпләмле сөлгеләр, ашъяулыклар, урын-җир япмалары җитештерелә. 1970 елларның 2 нче яртысыннан татар халкының чүпләмләп туку традициясендә милли төсләр һәм бизәкләр б-н баетылган сөлгеләр, ашъяулыклар, тәрәзә пәрдәләре һ.б. әйберләр эшләп чыгарыла. 1970–80 елларда серияле эшләнмәләрнең үрнәкләре Мәскәү нәфис сәнәгать фәнни-тикшеренү ин-ты рәссамнары тарафыннан эшләнә (Н.Назаренко һ.б.). Төп продукцияләре: ашъяулык, тастымал, сувенир сөлгеләр җыелмалары. 1970–80 елларда әйдәп баручы осталар — В.Фомичёва, Т.Русакова.



Туку җиһазлары һәм кайбер эшләнмәләрнең үрнәкләре.

*Әд.:* Художественные промыслы РСФСР: Справ. М., 1973; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АЛЕКСЕ́ЕВ** Валерий Павлович (22.8.1929, Мәскәү — 1991, шунда ук), антрополог, тарихчы, этнограф, археолог, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1987; 1986 елдан мөхбир әгъза). Мәскәүдә Көнчыгышны өйрәнү ин-тының Ерак Көнчыгыш ф-тын тәмамлый (1952). 1952–87 елларда СССР ФАнең Этнография ин-тында, 1988–91 дә СССР ФАнең Археология ин-ты директоры, бер үк вакытта СССР ФАнең Тарих бүлеге академик-секретаре урынбасары. Антропологик материаллар нигезендә Көнчыгыш Европа халыклары, ш.и. Урта Идел буе татарларының килеп чыгышын тикшерүчеләрнең берсе. Хезмәтләре расалар тарихы, антропологиясе һәм географиясенә карый.

Х е з м.: Происхождение народов Восточной Европы. М., 1969; Происхождение народов Кавказа. М., 1974; Палеоантропология земного шара и формирование человеческих рас. Палеолит. М., 1978; Историческая антропология. М., 1979.

*Әд.:* А м и р х а н о в Х.А. Памяти В.П.Алексеева // Советская археология. 1992. № 2.

*П.Н.Старостин.*

**АЛЕКСЕ́ЕВ** Геннадий Александрович (18.3.1940, Чуаш АССРның Красноармейск р-ны Синьял-Чурино а.), вет. табибе, фармаколог һәм токсиколог, вет. фән. д-ры (1987), проф. (1992). Свердловск а.х. ин-тын тәмамлагач (1965), Удмуртия АССРның «Понинский» с-зы баш вет. табибе. 1967–93 елларда Казанда Бөтенроссия фәнни-тикшеренү вет. ин-тында эшли, 1985 тән вет. токсикология лаб. мөдире. 1994 тән Чуаш а.х. академиясендә фармакология һәм терапия каф. мөдире. Хезмәтләре әйләнә-тирә табигый объектларны авыр металлардан зарарсызландыру, Чуаш Респ-касы Алатырь чыганагында табылган табигый цеолитларны санитария-токсикологик яктан бәяләү һәм аларны терлекчелектә, кошчылыкта, ветеринариядә куллануны нигезләүгә карый. 4 авторлык таныклыгы, 11 рационализаторлык тәкъдиме бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**АЛЕКСЕ́ЕВ** Игорь Николаевич (23.9.1936, Казан), мәдәният эшлеклесе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). 1959 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. Лениногорск р-ны Шөгер посёлогы урта мәктәбендә укыта. 1962–68 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, ТАССР МС каршындагы Радио һәм телевидение дәүләт ком-ты хәбәрчесе, 1968–74 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1971–97 дә Казан кинохроника студиясе директоры. Бер үк вакытта 1981–86 да ТАССР Кинематографистлар берлеге секретаре. Халыклар Дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Рубежи кинодокументалистов Татарии. К., 1974.

**АЛЕКСЕ́ЕВ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Алексеев р-ны үзәге тирәсендәге археологик

җыелма, калкулыкларда һәм Кама елгасының сул кушылдыгы үзәне өстендәге сөзәклекләрдә урнашкан. 1960, 1966 елларда Т.А.Хлебникова тарафыннан тикшерелә. Таш (неолит) һәм бронза гасырларга караган торулыклар, Ананьино, Имәнкискә, ш.у. Болгар археологик культураларына нисбәтле шәһәрлекләр, авыллыклар, каберлекләр керә. Болгар дәвере истәлекләре күбрәк өйрәнелгән, арада 6 йөзнең Алексеев сәүдә-һөнәрчелек үзәге, 10–13 йөзләрдәге тораклар сакланган Алексеев шәһәрлеге, 14 йөз каберлеге бар.

*Әд.:* Х л е б н и к о в а Т.А. Алексеевское городище (К вопросу о своеобразии раннеболгарской культуры) // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. К., 1971; Археологические памятники Центрального Закамья. К., 1988. № 237–273; Р у д е н к о К.А. Алексеевское селище и могильник («У дамбы») в Татарии // Проблемы средневековой археологии волжских финнов. Йошкар-Ола, 1994.

**АЛЕКСЕ́ЕВ РАЙОНЫ́**, ТРның үзәк өлешендә, Кама елгасының сулъяк ярында урнашкан. Көнбатыш Кама аръягы икътисади р-нына керә. Мәйданы — 2080,1 *км*². 19 авыл һәм 1 шәһәр җирлеген, 59 торак пунктны берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Алексеев посёлогы. Халкы — 2006 елда 25,9 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 57,5%, татарлар — 30,9%, чуашлар — 6,5%) яши. Шәһәр халкы — 10,1, авылларда 15,8 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 13 кеше. Район 1930 нең 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Лаеш, Спас һәм Чистай өязләрендә, 1920–30 да Лаеш, Спас һәм Чистай кантоннарында, 1922–30 да ТАССРның Чистай һәм Спас кантоннарында. Оешкан вакытында А.р.на 27 авыл советы, 34422 кеше (руслар — 29189, татарлар — 3627, башка халыклар — 1606 кеше) яшәгән 60 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1224 *км*², халкы — 32,4 мең кеше, 27 авыл советы, 50 торак пункт була. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февраленнән А.р. бетерелә, биләмәсе Чистай р-нына бирелә. 1964 тә Чистай һәм Куйбышев р-ннарының бер өлеше А.р.на кертелә, район яңадан торгызыла. 1966 елгы мәгълүматларга караганда, мәйданы — 2326 *км*², халкы — 45,2 мең кеше, 1 посёлок советы, 19 авыл советы, 89 торак пункт исәпләнә. 1977 нең 29 августыннан А.р.ның бер өлеше Аксубай р-нына бирелә. 2005 елның 26 гыйнварында А.р. муниципаль р-н дип үзгәртелә. Рельефы — калкулыклы тигезлек (уртача биеклеге — 100–150 *м*). Кама елгасы (Түбән Кама сусаклагычы) һәм аның кушылдыклары Актай, Шонталы, Кече Чирмешән елгалары ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, көлсуланган, типик кара, карасу-соры урман туфраклы. Терр-ясенең 10,7% ы урманнар б-н капланган. Балчык, ком, торф ятмалары бар. Саклаулы табигать һәм мәдәният объектлары: Кече Чирмешән елгасы, *Упкын күле* — табигать истәлеге, *Ивановский наратлыгы* табигать тыюлыгы, *Биләр тарих, археология һәм табигать музей-саклаулыгы*. Район терр-ясе таш дәвереннән алып урта гасырлар ахырына кадәрге вакыт аралыгына караган археологик истәлекләргә бай (*Балынгуз шәһәрлеге*, *Биләр шәһәр*леге, *Зур Тигәнәле каберлеге* һ.б.) А.р. — нигездә, а.х. р-ны. Кырчылык, терлекчелек тармаклары үскән. 2006 елда а.х. җирләре 132,8 мең *га* били, ш.и. 110 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак, тары игелә. 2006 да районда 10 а.х. пр-тиесе, ш.и. 3 колхоз, 2 а.х. товарлары җитештерү кооперативы, 1 крәстиян хуҗалыклары һәм кооперативлар ассоциациясе, «Ясная Поляна» ЖЧҖ (9 колхоз һәм совхоз керә), «Красный Восток-Алексеев» агросәнәгать комплексы (6 совхоз керә) һәм 5 башка төр хуҗалык исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә урнашкан. Балчык, комлы чуерташ чыгарыла. Биләр урман хуҗалыгы эшли. А.р. җиреннән Казан–Оренбург, Алексеев–Югары Колок автомобиль юллары уза. Районда 43 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 3431 укучы укый), ш.и. 14 башлангыч, 5 тулы булмаган урта, 24 — урта; 1 сәнгать мәктәбе, һөнәр лицее (401 укучы укый), 32 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 51 клуб, 33 китапханә, 131 урынлы 1 хастаханә, дәвалау амбулаториясе (Биләр а.), 45 фельдшер-акушерлык пунктлары эшли. Шәһәр тибындагы Алексеев посёлогында төбәк тарихы музее бар. Татарча «Таң», русча «Заря» г-талары нәшер ителә.




**АЛЕКСЕ́ЕВ СӨТ-КОНСЕ́РВ КОМБИНАТЫ́**, азык сәнәгатенең унитар пр-тиесе. Алексеев посёлогында урнашкан. 330 кеше эшли (2005). Коры сөт консервлары, атланмай, коры сыворотка, аертылган коры сөт, соялы коры оеткылар һәм башка төр ризыклар чыгару буенча специальләшә. 1933 елда Алексеев коры сөт җитештерү з-ды буларак нигез салына. Проект куәте — елына 4500 *т* чимал эшкәртү. 1936 да беренче продукция — 80 *т* коры сөт консервлары чыгара. 1941 елда Алексеев сөт-консерв комб-ты итеп үзгәртелә. 2002 дән «А.с.-к.к.» ЖЧҖ, 2006 дан «Вамин» АҖ филиалы. 1980–2000 елларда җитештерү мәйданнары киңәйтелә, коры сөтне алыштыручы продукция җитештерә һәм соя эшкәртә торган цехлар файдалануга тапшырыла, технология җиһазлары яңартыла, җитештерү процесслары камилләштерелә. Нәтиҗәдә җитештерү куәте елына якынча 40 мең *т* сөт, 30 мең *т* сыр сывороткасы, 400 мең *т* соя эшкәртү мөмкинлеге туа. 2005 тә 4481 *т* коры сөт, 371 *т* соялы коры сөт, 1578 *т* сыворотка, 190 *т* май җитештерелә. Чимал Алексеев р-ны а.х. пр-тиеләреннән алына. Комбинат составында казылык цехы һәм 1300 баш дуңгыз асрау өчен ярдәмче хуҗалык бар. Җитәкчеләре: П.С.Королёв (1946–53), Н.Г.Ковалёв (1953–68), В.П.Смирнов (1968–81), Г.С.Боровиков (1983–98), Н.Л.Банницин (1998–2000), Е.С.Макарихина (2002 дән).

Алексеев коры сөт җитештерү җайланмасы.



*Г.Я.Мәүлетова.*

**АЛЕКСЕ́ЕВ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогында, 1987 елның 1 мартында оештырыла, 1987 нең 6 ноябрендә ачыла. Үзәк китапханә бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы 83 *м*². 8000 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция төбәкнең борынгы чорлардан башланган тарихын чагылдыра. Төп бүлекләре: табигый-фәнни, төбәк тарихы, сәнгать. Неолит чорыннан сакланган әйберләрдән: ташбалталар, очлыклар, өтергеләр һәм борынгы кешеләрнең башка төрле эш кораллары күргәзмәдә урын алган. Бай нумизматик коллекциягә Болгар (10 йөз), Алтын Урда (14 йөз), Россия (18–19 йөзләр) тәңкәләре, ш.у. Гражданнар сугышы чоры акча билгеләре: «керенкалар», Колчак акчалары һ.б. керә. 18 йөзгә караган сугыш кораллары үрнәкләре: Демидовлар з-дларында коелган туп ядрәсе, кистәннәр һ.б. бар. Крәстияннәрнең 19–20 йөз башы көнкүреше һәм христиан диненә кагылышлы әйберләрнең коллекциясе күп төрле. Традицион вак һөнәрчелек сәнәгате нигезендә 1927 дә торгызылган кәсеп, ш.и. җирле сәнгати тукучылык әйберләре киң күрсәтелә (к. *Алексеев бизәклән туку фабрикасы*). Төбәктә туган П.С.Тихоновның Австро-Венгрия тоткынлыгыннан язылган хатлары (1916–18) Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларын чагылдыра; шул вакыттагы корал үрнәкләре һәм хәрби кирәк-яраклар (1917 елгы хәнҗәр, 1914 тә Будапештта эшләнгән фляга һ.б.) бар.



Алексеев төбәк тарихы музее.
Бөек Ватан сугышына багышланган зал.

Бөек Ватан сугышына багышланган бүлектә төбәктә туган ике Дан ордены кавалеры К.И.Митягин, Сов. Союзы Геройлары И.Е.*Кочнев*, М.А.*Федин*, Х.Н.*Хәйруллин*, В.Д.*Халев* һәм солдатларның документлары, фотографияләре, фронттан язган хатлары һәм шәхси әйберләре куелган. Соңгы вакыттагы экспонатлардан сәнгати тукучылык, керамика һәм «урман» скульптурасы коллекцияләре кызыксыну уята. Авылда туган ТРның халык артисты М.П.*Пантюшин*га багышланган даими «Бөтен тормышы — театр» фотокүргәзмәсе эшли.

Аеруча мөһим экспонатлар арасында нумизматика (1200 дән артык саклау берәмлеге), палеонтология (60 тан артык саклау берәмлеге) коллекцияләре, тукучылык әйберләре (100 гә якын саклау берәмлеге), Бөек Ватан сугышында катнашучыларның документлары һәм шәхси әйберләре (1000 гә якын саклау берәмлеге), «урман» скульптурасы әсәрләре (30 саклау берәмлеге) игътибарга лаек.



Алексеев төбәк тарихы музее. Кайбер көнкүреш әйберләре (19 йөз ахыры – 20 йөз башы).

Музей ел саен музей ачылу (6 ноябрь), Ватанны саклаучылар (23 февр.), Җиңү (9 май), Халыкара музейлар (18 май), Белем (1 сент.), Өлкәннәр (1 окт.) көннәрен билгеләп уза.

**АЛЕКСЕ́ЕВ** Сергей Михайлович (6.7.1886, Түбән Новгород губ. Княгинино ш. — 24.8.1960, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1926), проф. (1934), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1940). А.В.*Вишневский* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1913). 1914–34 елларда Казан ун-тының госпиталь хирургиясе клиникасында (бүленеп, 1918–20 дә Кызыл Армия табибе) эшли. 1934 тән Казан мед. ин-тының факультет хирургиясе каф. мөдире. Хезмәтләре урология һәм аппендектомия өлкәләренә карый. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Об одномоментной операции нефропексии и аппендектомии // Казан. мед. журн. 1922. № 5; К вопросу о происхождении аномалий формы и положения почек // Вестн. хирургии. 1926. № 1; Правая смещённая почка и хронический аппендицит. К., 1926; Камень дивертикула интрамуральной части мочеточника // Урология. 1929. № 6.

**АЛЕКСЕ́ЕВКА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 175 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 1920 еллар башында нигез салына. ТАССРның Чистай кантоны Көтеш волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 160, 1938 дә — 240, 1949 да — 240, 1958 дә — 279, 1970 тә — 304, 1979 да — 228, 1989 да — 161 кеше.

**АЛЕКСЕ́ЕВКА** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 30 *км* көньяктарак, Кандыз елгасының сул кушылдыгы Сула суы буенда. 2002 елда 573 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Узла исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да чиркәү, мәктәп, 2 су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2137,8 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Иваново волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1829 да — 304, 1859 да — 563, 1897 дә — 933, 1926 да — 1113, 1938 дә — 841, 1949 да — 738, 1958 дә — 777, 1970 тә — 793, 1979 да — 688, 1989 да — 646 кеше.

**АЛЕКСЕ́ЕВКА** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 32 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасының уң кушылдыгы Ямаш елгасы бассейнында. 2002 елда 129 кеше (татарлар — 74%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 19 йөз уртасында Тетвель (хәзерге Түбән Кама р-ны) авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Авыл башта Яңа Тетвель дип атала. 1917 гә кадәр җирле халыкның төп шөгыле игенчелек, терлекчелек һәм умартачылык була. Крәстияннәрнең бер өлеше вак һөнәрчелек б-н көн күрә: дуга, тәгәрмәч тугымы бөгү, киез итек басу, чыпта, киндер, тупас постау тукыма сугу б-н шөгыльләнә. 1871 дә А.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе ачыла. 1929–30 елларда Энгельс исем. к-з оештырыла. 1959 да эреләндерелгән «Рассвет» к-зы составына керә. 1990 нан А.да Зәй автоагрегат з-дының ярдәмче хуҗалыгы урнаша. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1920 дә — 489, 1926 да — 375, 1938 дә — 461, 1949 да — 408, 1958 дә — 344, 1970 тә — 280, 1979 да — 174, 1989 да — 112 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**АЛЕКСЕ́ЕВСКИЙ** посёлогы, Лаеш р-нында, шәһәр тибындагы Лаеш посёлогыннан 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* читтәрәк. 2002 елда 10 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Башта ТАССР ның Лаеш кантонына керә. 1927 елның 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1926 да — 46, 1938 дә — 71, 1949 да — 58, 1958 дә — 32, 1970 тә — 36, 1979 да — 20, 1989 да — 12 кеше.

**АЛЕ́КСИЙ** (Баженов Дмитрий) (21.5.1872, Кырым — 1938 тирәсе), дин эшлеклесе. Таврия руханилар семинариясен (1894) һәм Петербург руханилар академиясен (1902) тәмамлый. 1913 елдан Николаев шәһәре епископы. Совет чорында православиедәге яңарыш хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе. 1923–33 тә Казан яңарышчылар епархиясен җитәкли, 1924 тән митрополит. 1933 тән Кырым митрополиты. Репрессияләр чоры корбаны дип фаразлана.

**АЛЕМА́СОВ** Александр Михайлович (1902, хәзерге Чиләбе өлкәсе Златоуст ш. — декабрь 1972, Воронеж ш.), сәясәт эшлеклесе. Златоустта чиркәү мәктәбен (1914), Кызыл профессура ин-тын (Ростов ш., 1931), Кызыл профессура тарих-партия ин-тын (1933) тәмамлый. 1914–19 елларда Златоуст оешмаларында эшли. 1920 дән Кызыл Армия сафында — Польша фронтындагы 4 нче укчылар дивизиясенең 28 нче полкында пулемётчы, разведчиклар командасында политрук. 1922–25 елларда Хәрби диңгез флотында — «Парижская коммуна» линкорында һәм «Ленин» канонер көймәсендә өлкән электрик. 1927 дән партия эшендә: ВКП(б)ның Прохладный райкомында, аннары Кисловодск шәһәр ком-тында агитация-пропаганда бүлеге мөдире (1927–29), җаваплы секретарь (1929–30). 1930 да А. Минеральные Воды тимер юл станциясенә, соңрак Ростовтагы паровозлар ремонтлау з-дына (1931–32) партком секретаре итеп билгеләнә. 1933–35 тә Воронеж паровозлар ремонтлау з-дында парторг; 1935–36 да ВКП(б)ның Воронеж шәһәр ком-тында 2 нче секретарь. 1937 елның июль–сентябрь айларында ТАССР эчке эшләр халык комиссары. 1937–42 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. Татарстанда массакүләм сәяси репрессияләрне

оештыручыларның берсе. 1942 дән ВКП(б)ның Ленинск-Кузнецк, Томск, Кременчуг шәһәр ком-тларында секретарь. СССР (1937–46), ТАССР (1938–42) ЮСлары депутаты. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Султанбеков Б. Кровавый след операции «Новаторы» // Страницы секретных архивов. К., 1994; Петров Н.В., Скоркин К.В. Кто руководил НКВД. 1934–1941. М., 1999.

**АЛЕМА́СОВ** Вячеслав Евгеньевич (11.7.1923, Казан — 15.6.2006, шунда ук), җылылык энергетикасы һәм двигательләр төзү гыйлеме белгече, РФА академигы (1992; 1984 елдан СССР ФАнең мөхбир әгъзасы), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1992), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1970, 1974). 1947 дә Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый, 1948 дән шунда ук эшли, махсус двигательләр каф. мөдире (1965–89), проф. (1966), термодинамик һәм җылылык физикасы тикшеренүләре буенча тармак лаб. җитәкчесе (1963–89). 1987–91 дә СССР ФАнең Казан ф-лы президиумы рәисе, 1991–2003 тә РФА КГҮнең Энергетика бүлеге директоры, 2003 тән баш гыйльми хезмәткәр. Хезмәтләре ракета ягулыкларында һәм энергия җайланмаларында бара торган процессларның аэротермохимиясенә; реактив двигательләрдә югары темп-ралы реакциягә керә торган тирәлекләр һәм процессларның составын һәм үзенчәлекләрен исәпләүгә һәм өйрәнүгә карый. Илнең ракета двигательләре төзелешендә җылылыкны хисаплауга караган яңа фәнни юнәлешне тәкъбирли. Нефть-битум катламнарына термофизик тәэсир итүнең фәнни нигезләрен һәм техник чараларын эшләү б-н җитәкчелек итә. Югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы. Уйлап табуга 40 лап авторлык таныклыгы һәм патенты бар. 1987–89 елларда ТАССР ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1984, 1991). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Теория ракетных двигателей. М., 1962; Термодинамические и теплофизические свойства продуктов сгорания. Справ.: В 10 т. М., 1971 (автордаш); Турбулентные струйные течения в каналах. К., 1988; Математическое моделирование высокотемпературных процессов в энергосиловых установках. М., 1989.

*Әд.:* Татарстан Фәннәр академиясе. К., 1994; Академия наук Татарстана. К., 1992.

**АЛЕ́ШКОВ** Николай Петрович (26.6.1945, хәзер Чаллы шәһәренә кергән Орловка а.), шагыйрь. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1982). «Знамя коммунизма» (Чаллы ш.), «Гвардеец труда» (Оренбург өлкәсе Новотроицк ш.), «На боевом посту» (Мәскәү) г-таларында эшли. 1972 елдан КамАЗ төзелешендә: матбугат үзәге җитәкчесе, «Казэнергострой» йортлар төзү комб-тында инженер-диспетчер. 1976–86 елларда Кама төбәге яшь язучыларының «Орфей» әдәби оешмасын җитәкли. 1989 дан янә журналист хезмәтендә, «Время», «Бизнес-класс» г-таларында эшли. Беренче шигырьләре матбугатта 1970 еллар уртасында күренә башлый. «Мине бәхетле итеп хәтереңдә калдыр» («Запомни меня счастливым», 1983) җыентыгына сугыштан соңгы балачагы, Кама төбәгенең гүзәл табигате, «Орёл бożрасы» («Орловское кольцо», 1988) җыентыгына Чаллы шәһәренең төзелүе, сугыштан соңгы буынның язмышы, экология проблемалары турындагы шигырьләре кергән; «Лимит» (1993) җыентыгында публицистик шигырьләре тупланган. «Ерак болыннар» («Дальние луга», 1995), «Пётр һәм Мария улы» («Сын Петра и Марии», 2005) җыентыклары — шагыйрьнең күп елларга сузылган әдәби эзләнүләре, классик рус поэзиясе традицияләренә мөрәҗәгать итүе нәтиҗәсе. Рус теленә Г.Тукай, Разил Вәлиев шигырьләрен тәрҗемә итә.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Сафин М. Дней горизонт становится светлее // Аргамак. 1997. № 12.

*Б.А.Канеев.*


**АЛЁШКИН-САПЛЫ́К** авылы, Чүпрәле р-нында Иске Чүпрәле авылыннан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 539 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Катнаш терлек азыгы әзерләү з-ды. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә; читкә китеп, балта остасы, такта яручы, Буа һәм күрше өяз авылларында кара эшче булып эшли. 20 йөз башында А.-С.та 8 сәүдә-сәнәгать оешмасы була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 915,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Уби волостена керә. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 319, 1911 дә — 711, 1920 дә — 766, 1926 да — 700, 1938 дә — 862, 1949 да — 878, 1958 дә — 830, 1970 тә — 1031, 1979 да — 878, 1989 да — 597 кеше.

*Әд.:* Субаев Р.С. Чүпрәле: узган еллар, үткән юллар: Район тарихыннан очерклар. Чүпрәле, 2000.

**АЛЁШКИНО** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кислинка елгасы буенда. 2002 елда 71 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1785 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Югары Лещи исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1890 елгы мәгълүматларга караганда, А.да чиркәү була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1786 дис. тәшкил итә. 1930 дан А. «Трактор» к-зында, 1960 тан — «Путь к коммунизму», 1967 дән «Яңа Чыршылы» с-зында. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Каратай волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 313, 1885 тә — 504, 1920 дә — 775, 1926 да — 763, 1938 дә — 442, 1949 да — 400, 1958 дә — 342, 1970 тә — 329, 1979 да — 181, 1989 да — 87 кеше.



В.Е. Алемасов.



Г.Г. Алиев.

**АЛИ́**, к. *Гарәбшаһ хан.*

**АЛИЕ́В** Габдулла, к. *Батырша.*

**АЛИ́ЕВ** Госман Гатаулла улы (18.8.1924, Чүпрәле р-ны Олы Чынлы а. — 25.1.1986, шунда ук), тракторчы-машинист, Соц. Хезмәт Герое (1974). Бөек Ватан сугышында катнаша. Чүпрәле р-ны «Ирек» к-зында комбайнчы (1959–63), тракторчылар бригадасы җитәкчесе (1963–84) булып эшли. Герой исеменә югары җитештерү күрсәткечләре өчен лаек була. 1973 елда А.кә беркетелгән участокларда бөртеклеләрдән югары уңыш (29 *ц/га*) алына. Ике Ленин ордены, медальләр, ш.и. ВДНХның алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә. 1978 дә Олы Чынлы авылы мәктәбе музеенда аның бюсты куела.

*Әд.:* Камал Б., Хәйретдинов С. Кырга тартыла күңел. К., 1975; Матвеева Е. Алиев Усман Гатауллович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**АЛИ́ЕВ** Илтазар Нури улы (29.12.1926, Буа ш.), мәдәният эшлеклесе, Каракалпакстан АССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1952). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952–54 елларда Петропавловск пед. ин-тының марксизм-ленинизм каф., 1956–58 дә филос. каф. укытучысы, 1954–55 тә директор урынбасары, 1955–56 да Казакъстан КП Петропавловск шәһәр ком-тының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире. 1960–69, 1985–92 дә Казан ун-тының филос. каф. укытучысы, 1969–76 да партком секретаре. 1976–85 тә ТАССР мәдәният министры. Хезмәтләре эстетик тәрбия мәсьәләләренә карый. 1980–85 тә ТАССР ЮС депутаты.

**АЛИ́ЕВ** Марс Шәриф улы (18.7.1947, Буа р-ны Иске Тинчәле а.), галим-зоотехник, а.х. фән. д-ры (2004), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1997). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Биектау р-нының «Биектау» терлек симертү с-зында директор урынбасары булып эшли. 1983 елдан шул ук районның «Урак һәм чүкеч» к-зы рәисе. 1995 тән ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары, 1998 дән «Татптицепром» АҖ директоры. Хезмәтләре төрле шартларда асрала торган дуңгызларда матдә-

ләр алмашын тикшерүгә, йомырка сала торган тавыкларны үрчетү шартларын камилләштерүгә карый. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Халыклар дуслыгы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Создание кросса материнской родительской формы с использованием генов — маркеров скорости оперения // Птицеводство. 2003. № 2; Влияние отдельных технологических факторов на продуктивность яичных кур // Нива Татарстана. 2003. № 1.

**АЛИ́ЕВ** Михрали Мирзали улы (7.11.1951, Әзәрбайҗан ССР, Геокчай ш.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2002). 1973 елда Әзәрбайҗан политехника ин-тын (Баку) тәмамлый, 48 нче күпер салучылар отрядында (Псков ш.) эшли. 1976 елдан Төзелеш конструкцияләре үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). 1980–94 тә Бакуда, Төзелеш конструкцияләренең үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында, 1963 тән Әзәрбайҗан төзүче-инженерлар ин-тында. 1994 тән Әлмәт нефть ин-тында, гамәли механика каф. мөдире (1995 тән), бер үк вакытта инженерлык механикасы ф-ты деканы (2000 нән). Хезмәтләре рәвеше үзгәрүчән каты җисем механикасына, төзелеш механикасына һәм тау токымнары механикасына карый. Төрлечә каршылык б-н сузылган һәм кысылган бериш булмаган анизотроп мохит өчен ныклык критериен (чик тигезләнеш шартын) эшли.

Х е з м.: Предельное равновесие анизотропного несимметричного сыпучего клина, нагруженного двухсторонним давлением // Строит. механика и расчёт сооружений. 1984. № 4; Расчёт несущей способности анизотропных оснований сооружений // Изв. вузов. Строительство. 2001. № 6 (автордаш); Предельное напряжённое состояние анизотропной сыпучей среды, угол внутреннего трения которой является функцией координат // Изв. вузов. Строительство. 2001. № 7 (автордаш).

**АЛИ́ЕВ** Мохтар Али улы (1933), хирург, Казакъстан ССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1983). 1970 елдан Алма-Ата табибләр белемен күтәрү ин-тының хирургия, 1976 дан Алма-Ата мед. ин-тының ф-т хирургиясе каф. мөдире. 1978 дән Казакъстан ССР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш хирургы. 1980 нән Казакъстан клиник һәм эксперименталь хирургия фәнни-тикшеренү ин-ты директоры (бүленеп, 1983–87 елларда Казакъстан ССР сәламәтлек саклау министры).

Хезмәтләре ашыгыч хирургиягә, кан тамырлары пластикасына, корсак куышлыгы әгъзалары, ашказаны асты, калкансыман, күкрәк бизләре авыруларына диагноз кую һәм аларны хирургик дәвалауга карый.

**АЛИ́ЕВ** (Улеев) Муса (18 йөз), 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында катнашучы, Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләр армиясе полковнигы. Каргалы бистәсе старшинасы. 1773 октябрь башында патша хакимияте тәртипләре б-н килешмәүчеләрдән 500 кешелек полк оештыра. 1773–74 елларда Оренбург тирәсендәге сугышларда катнаша. 1774 елда старшина А.Абдуллин җитәкчелегендәге хакимиятләргә турылыклы Каргалы авылы кешеләре тарафыннан кулга алына. Соңыннан азат ителә. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* А л и ш е в С.Х. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973; Муса Улеев // Оренбургская Пушкинская энциклопедия. Оренбург, 1997.

**АЛИ́ЕВ** Нури Лотфулла улы (15.3.1898, Сембер губ., Буа өязе Шатыршан а. — 19.8.1961, Караганда ш.), партия, хакимият-хуҗалык эшлеклесе. 1915–18 елларда Буа өязендә укыта. 1919–20 дә Гражданнар сугышында: укчы ротада сәяси агартучы, укчы дивизиянең сәяси бүлегендә агитатор-оештыручы. 1920–27 дә Акмола өлкәсенең Акмола өязендә (Казакъстан) һәм ТАССРның Буа кантонында партия һәм хакимият-хуҗалык эшендә. 1927–32 дә халык мәгарифе оешмаларында эшли: Ульянов өлкәсе халык мәгарифе бүлегендә инспектор, Самара шәһәрендә татар мәктәбе мөдире, Урта Идел буе крае халык мәгарифе бүлегендә бүлек мөдире урынбасары (Самара ш.). 1933 тән Казакъстан ССРда партия эшендә (бүленеп, 1938–41 дә Төньяк Казакъстан өлкәсе планлаштыру ком-ты рәисе). ВКП(б)ның Төньяк Казакъстан өлкәсе Степняк райкомы 1 нче секретаре (1937), Төньяк Казакъстан өлкә ком-ты секретаре (1941). Бөек Ватан сугышында катнаша: укчылар бригадасы комиссары, укчы полк командиры урынбасары була. 1945–52 дә Казакъстан ССР халык мәгарифе комиссары урынбасары, Казакъстан ССР ХКСнда Мәдәният-агарту оешмалары ком-ты рәисе. Күкчәтау хезмәт ияләре депутатлары советы рәисе урынбасары, рәисе. 1952–58 елларда Казакъстан ССРның Караганда шәһәрендә: өлкә советында мәдәният-агарту оешмалары бүлеге мөдире, «Белем» җәмгыятенең өлкә бүлекчәсе җаваплы секретаре. Татар телендә чыккан «Урта Идел краеның географиясе» (Самара, 1933) дәреслеге авторларының берсе. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**АЛИ́ЕВ** Шамил Ариф улы (5.9.1946, Буа р-ны Яңа Тинчәле а.), агрохимик, а.х. фән. д-ры (2001), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1996). Казан а.х.ин-тын тәмамлый (1970), «Татарский» агрохимия хезмәте күрсәтү үзәгендә химияләштерү чараларын куллану бүлеге башлыгы (1990 нан), директор (1993 тән). Бер үк вакытта Казан а.х. академиясендә агрохимия һәм туфрак белеме каф. профессоры (2002–05). Хезмәтләре Татарстан Респ-касы игенчелегендә җирле агрорудаларны ашлама һәм мелиорантлар сыйфатында куллануга карый. Сөендек чыганакларындагы фосфорит онының агроикътисади нәтиҗәлелеген нигезли, цеолитлы токымлы, бентонитлы балчык һәм глауконитлы комны авыр металлар б-н пычранган туфракны чистарту өчен куллану мөмкинлеген нигезли.

Х е з м.: Агрохимия фосфора и нетрадиционного минерального сырья. М., 2001 (автордаш); Агрохимия высококонцентрированных минеральных удобрений и их применение. М.-К., 2001 (автордаш); Использование местных фосфоритов и природных сорбентов для повышения продуктивности земледелия. М., 2004 (автордаш).

**АЛИ́ЕВА** Әнисә Хәниф кызы (29.9.1952, Чүпрәле р-ны Кече Чынлы а.), текстология белгече, филол. фән канд. (1990), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1977 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1997 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) эшли. Хезмәтләре текстологиягә, әдәби ядкәр чыганакларын тикшерүгә һәм татар классик әдәби мирасын, сәяхәтнамә жанрын өйрәнүгә карый. Язучы-мәгърифәтче Ф.Х.Халиди әсәрләрен гарәп графикасыннан кириллицага күчерә, хәзерге татар әдәби теленә «Мең дә бер кичә»не тәрҗемә итә (2001, 2002).

Х е з м.: Путешествие Исмагил ага в Индию: Исследование языка татарских путевых записок XVIII в. «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе». К., 1993; Татарско-русский словарь для начальных школ. М., 1997; Русско-татарский словарь для начального обучения. К., 2003.

*Н.Ш.Хисамов.*

**АЛИМӘ́ТОВ** Халид Аразхан улы (21.8.1947, Дагстан АССРның Сөләйман — Стальский р-ны Ашагастал а.), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1996). 1971 елда Дагстан мед. ин-тын тәмамлый. 1974 тән Казан мед. ун-тында; 1992 дән оториноларингология каф. мөдире. Бер үк вакытта 1976 дан Казан шәһәр онкология диспансерының баш һәм муен шешләре бүлеге мөдире. 1978 дән ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсендә оториноларинголог. Хезмәтләре йоткылыктагы яман шеш авыруларының башлангыч чорында диагноз кую һәм дәвалауга, йоткылыкның лимфа аденоид бөҗрасында яман шешләрне дәвалауның нәтиҗәлелеген билгеләү ысулларына, тавыш ясалу бозылышына диагноз кую, ракны хирургик дәвалауга һәм тавыш ярыклары тонусын көйләүгә карый.

Х е з м.: Пластика голосовой складки при раковом её поражении // Актуальные проблемы фониатрии и клинической сурдологии. М., 1988; Категоризационная рентгеноконтрастная серийная полисунография // Новые методы диагностики и лечения. К., 1996. Ч. 1; Состояние задней перстнечерпаловидной мышцы гортани в норме // Актуальные проблемы в клинической сурдологии. М., 1998 (автордаш).

**АЛИМБӘ́КОВ** Әхмәт Вәлиулла улы (1896, Сембер губ., Карсун өязе Дракино а. — 1957, Ташкент), хәрби эшлекле, сәяси икътисад фән. канд. (1942). Ә.В.*Алимбәкованың* бертуганы. Казан ун-тының совет төзелеше һәм хокук ф-тын тәмамлый (1931). 1914 елдан Россия армиясендә: баштарак 140 нчы запас укчы полкта, Казанда прапорщиклар мәктәбен тәмамлаганнан соң (1916), 158 нче запас укчы полкта. Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының 1 нче Бөтенроссия съездында катнаша. *Беренче аерым Идел буе татар укчылары бригадасын* оештыручыларның берсе, 1919 да әлеге бригаданың 3 нче, 2 нче укчы полклары командиры. 1920–22 дә *Икенче аерым Идел буе татар укчылары бригадасы* командиры, Төркестан фронтының Ташкент мөселман укчылар курслары башлыгы урынбасары, Бохара халык совет җөмһүриятенең хәрби нәзарәт комендатны, хәрби назыйры (халык комиссары), Төркестан АССР милициясе башлыгы ярдәмчесе. 1930 дан Ташкентта фәнни һәм пед. эштә. Сәяси икътисадка караган хезмәтләр авторы.

*Әд.:* Б е л я л о в У.Б., Т а и р о в Н.И. Алимбековы. К., 1986.

*Н.И.Таиров.*

**АЛИМБӘ́КОВА** Әминә Вәлиулла кызы (1892, Сембер губ., Карсун өязе Дракино а. — 15.9.1938, Кырым АССР, Евпатория ш.), сәясәт эшлеклесе, табибә. Ә.В.*Алимбәковның* бертуганы. Сембердә кызлар гимназиясен тәмамлаганнан соң, губернаның Буа һәм Карсун өязләрендә балалар укыта. 1918 елның җәендә баш күтәргән Чех-словак корпусына һәм КОМУЧның Халык армиясенә каршы Сембер шәһәре өчен барган бәрелешләрдә катнаша. 1919 да Сембер губернасының халык мәгарифе бүлеге инструкторы һәм РКП(б)ның Сембер шәһәр ком-тында татар секциясе секретаре. 1919 ның октябреннән Казанда укыта, бер үк вакытта РКП(б) губерна ком-тында мөселман коммунистлар бюросы әгъзасы. 1919–27 дә (бүленеп) Казан ун-тының мед. ф-тында укый. Күпмедер вакыт Е.Дебс исем. ятим татар балалары йорты мөдире була. 1921 дән Урта Азиягә партия эшенә җибәрелә, Ташкентта хатын-кызлар арасында эшли. Табиблек дипломы алганнан соң, 1932–35 тә В.С.Груздев җитәкчелегендә Казан мед. ин-тының акушерлык-гинекология клиникасында. 1935–37 елларда А. Согуд Гарәбстанында табибә булып эшли.

*Әд.:* Б е л я л о в У.Б., Т а и р о в Н.И. Алимбековы. К., 1986; Т а и р о в Н. Алимбекова А.В. // Борцы за счастье народное. К., 1983, Кн. 2.

*Н.И.Таиров.*

**АЛИ́МОВ** Азат Миргасыйм улы (10.8.1946, Чүпрәле р-ны Кече Чынлы а.), микробиолог, эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1993), проф. (1998), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1998). Казан вет. ин-тын тәмамлагач (1970), шунда ук эшли. 1984 елдан Бөтенроссия фәнни-тикшеренү вет. ин-тында биохимия лаб. мөдире. Хезмәтләре терлекләрдәге листериоз авыруына каршы АУФ штаммыннан вакцина, түләмәгә диагноз кую өчен аллерген, йогышлы авыруларга диагноз кую өчен радиоиммун анализ һәм молекуляр гибридлаштыру ысулларын куллануга карый. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм 2 патенты бар. Медальләр, ш.и. ВДНХның көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Аминокислотный обмен и иммунохимия листерий различной вирулентности. К., 1974.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**АЛИ́МОВ** Зариф Закир улы (1921, хәзерге Чүпрәле р-ны Яңа Кәкерле а. — 31.1.1945, Венгрия), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, вафатыннан соң), лейтенант (1942). 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, автоматчылар взводы командиры (23 нче танк корпусының 56 нчы мотоукчылар бригадасы). 2 нче һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Украина, Румыния, Венгрияне азат итү сугышларында катнаша. 1944 нең 2–3 сентябрендә Венгриянең Онешти шәһәре тирәсендә барган сугышта батырлык күрсәтә. Балатон күле янындагы сугышта һәлак була. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Т. 1.

**АЛИ́МОВ** Зәки Җиһанша улы (14.8.1927, Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Грибаново а.) хирург, мед. фән. д-ры (1976). И.И.Русецкий шәкерте. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1953 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли (бүленеп, 1957–64 тә Республика клиник хастаханәсендә). Хезмәтләре йөрәк ишемиясе патогенезы һәм аңа диагноз кую, ревмокардит авыруына, аяк-кул артериитына (облитерацияле эндартериит һәм атеросклероз) һ.б. карый. Нормаль һәм авыруның үсеше вакытындагы симпатик нерв системасының төрле зоналарындагы симпатотамырлар реакцияләрен өйрәнүнең ысулларын һәм алымнарын эшли. Үзе өйрәнгән авыруларны булдырмау принципларын бәян итә.

Х е з м.: Значение гиперреактивных зон симпатической иннервации в патогенезе и диагностике аппендицита и холецистита. М., 1989 (автордаш); Значение гиперреактивных зон симпатической иннервации в патогенезе и диагностике облитерирующего эндартериита нижних конечностей, ишемической болезни сердца и ревмокардита. М., 1999.


**АЛИМО́В** Нурмөхәммәт Нәүмән улы (1892, Тверь ш. — 1964, Мәскәү), профсоюз эшлеклесе, бокс буенча Россия чемпионы (1915) (рингта Кара Малай исемен йөртә). 1930 елда Бөтенсоюз сәүдә академиясен тәмамлый. 1915–17 дә Россия армиясендә — Саратов губернасы Петровск шәһәрендәге 145 нче запас полкта. 1917 дә Көнбатыш фронтның 10 нчы армиясе солдатлар ком-ты әгъзасы, Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 2 нче корылтае делегаты. 1918 елда, 1 нче мөселман социалистлар полкы командиры буларак, Казан өчен барган бәрелешләрдә катнаша. 1919–24 тә профсоюз һәм хуҗалык эшләрендә; 1920–22 дә Бакуда нефть идарәсе директоры, 1922–24 тә Кырымда шәраб җитештерү з-длары идарәсе башлыгы. 1924 тән ТАССРда Алабуга кантоны башкарма ком-ты рәисе, 1925–28 дә Сәүдә эшләре халык комис-ты коллегиясе әгъзасы, ТАССРның Мәскәүдәге сәүдә эшләре буенча вәкиле. 1930 дан Ташкент, Ленинград һәм Мәскәүдә профсоюз һәм хуҗалык эшләрендә.

*Әд.:* И л я л о в Р.И. Батыр уходит в легенду. К., 1984; Е л и з а р о в а С. Алимов Н.Н. // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

**АЛИ́МОВ** Пётр Иванович (30.9.1907, Пенза ш. — 16.9.1974, Казан), химик, хим. фән. д-ры (1974), А.Е.Арбузов шәкерте. Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1938). 1946 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физ.-хим. ин-тында эшли. Хезмәтләре пирофосфат, пирофосфит , субфосфат кислоталары эфирларын синтезлауга һәм аларның химик үзлекләренә карый. Бу кушылмаларның минераль һәм карбонат кислоталары, альдегидлар б-н үзара тәэсир итешүен өйрәнә. Өч һәм биш валентлы фосфор кислоталары амидлары химиясе өлкәсендә эшли. Октаметил инсектицидын һәм пирофос дару препаратын ясауда һәм аларны гамәлгә кертүдә катнаша.



З.З. Алимов.



Н.Н. Алимов.

Х е з м.: Производные пирофосфорной кислоты как инсектициды // Изв. КФАН СССР. Сер. хим. наук. 1955. Вып. 2 (автордаш); Алкиламиды органических производных кислот фосфора // Изв. АН СССР. Отд-ние хим. наук. 1956. № 8 (автордаш); Синтезы тетраэтилмонотиопирофосфата // Тр. КФАН СССР. Сер. Химия. 1956. Вып. 2 (автордаш); О получении системного инсектицида октаметилтетраамида пирофосфорной кислоты // шунда ук. С. 27–36 (автордаш).

**АЛИ́МОВ** Рәшит Җиһанша улы (25.5.1921, Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Гребаново а.), җылылык энергетикасы галиме белгече, техник фән. д-ры (1971), проф. (1973). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1950), 1953–91 елларда шунда ук эшли, 1971–83 тә гамәли физика каф. мөдире. Хезмәтләре гадәти һәм бөтерелгән бер яки ике фазалы газ-сыеклык агымындагы җылылык-масса алмашының закончалыкларын тикшерүгә карый; ламинар агымның турбулент агымга күчү механизмын нигезли. Кызыл Йолдыз, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Теплоотдача при поперечном омывании двухфазным потоком нагретой цилиндрической трубы // Журн. техн. физики. 1956. Т. 26, № 6; Об одной устойчивой форме свободной поверхности тонкого слоя нагреваемой жидкости // Докл. АН СССР. 1956. Т. 109, № 3; Интенсификация конвективного тепло- и массообмена в трубах с помощью завихрённого двухфазного потока // Изв. АН СССР. Энергетика и автоматика. 1962. № 1.

**АЛИ́МОВ** Сабир Алим улы (24.11.1873, Мордва Респ-касының хәзерге Ләмберә р-ны Татар Таулысы а. — 15.11.1939, Әстерхан ш.), журналист, археограф. Бохарадагы «Мир-и Гарәб» мәдрәсәсендә (1896) һәм Каһирәдәге әл-Әзһар ун-тында (1904) белем ала. 1896–1921 елларда Ташкент, Оренбург, Әстерхан уку йортларында укыта, бер үк вакытта 1900–10 елларда Каһирәдә чыга торган «әл-Лива» г-тасының штаттан тыш хәбәрчесе. 1935–39 да СССР ФАнең Ленинградтагы Көнчыгыш телләр ин-ты хезмәткәре. Гарәп, фарсы, иске татар, төрек, үзбәк, казакъ, нугай һ.б. телләрдә 500 ләп кульъязма китап һәм йөзләрчә документ җыя. Алар арасыннан 13 йөзгә караган «Китаб әл-Коният әл-Мония» китабы зур әһәмияткә ия. Китап ахырында борынгы харәзем теле сүзлеге бирелә.

*Әд.:* М и ң н у л л и н Ж. Рухи мирасны барлаганда // Казан утлары. 1984. № 12; Ф ә т х и е в А.С. Татар әдипләре һәм галимнәренең кульъязмалары. К., 1986; Б е л я е в В.И. Арабские рукописи в собрании Института востоковедения Академии наук СССР // Уч. зап. Ин-та востоковедения АН СССР. М.–Л., 1953. Т. 4.



И.К. Алимова.



Абдулла Алиш.

**АЛИ́МОВА** Ирина (Бибииран) Кәрим кызы (16.6.1918, Төркестан АССРның Мары ш.), кино артисты, разведчик, подполковник (2000). 1930 еллар башында Ашхабад а.х. ин-ты рабфагында укый. 2 нче курсны тәмамлагач, «Төрекмәнфильм» студиясенә эшкә чакырыла, 1936 елда чыккан «Умбар» исемле кинофильмда катнаша. Ленинград театр уч-щесен тәмамлый. 1939 дан «Үзбәкфильм» киностудиясендә. Бөек Ватан сугышы елларында СССР НКВД гаскәрләрендә тәрҗемәче. 1947 дән Дәүләт иминлеге ком-тында (КГБ) хезмәт итә: 1950–53 тә Көнбатыш Европа илләрендә яшерен бурыч үти; 1953 нең сентябреннән Көньяк-Көнчыгыш Азия илләренең берсенә күчерелә. Шунда булачак ире, разведчик Ш.Г.*Хәмзин* б-н очраша; 1954 нең язында алар Гонконг шәһәренә, соңрак Японияга күчеп, эшләрен дәвам итәләр, «Мохит белән Садыйк сәүдә ширкәте»н ачалар. А. Корея ярымутравында тупланган Америка гаскәрләре, Сеулда оештырылачак Азия-Тын океан илләре берлеге (АзПАК) эшчәнлекләре турында мәгълүмат җыюда катнаша. 1967 дән Мәскәүдә яши. 1 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Бөек Җиңү», Ю.В.Андропов орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ихсанова В. Сират күперендә // Шәһри Казан. 1996. 26 июнь — 10 июль; Дроздов Ю.И. Нужная работа. М., 1994; Морозов И. Оперативный брак // Совершенно секретно. 1994. № 5.

*Г.Н.Булатова.*

**АЛИ́МОВА** Ләйлә (1924, Түбән Новгород өлкәсенең Пилнә р-ны Питрәксә а.), педагог, әкиятче. 1941–80 елларда Питрәксә авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Татар фольклорының күптомлы «Татар халык иҗаты» басмасына («Кыска җырлар», 1976; «Дастаннар», 1984) А.дан язып алынган «Кыйсса-и Йосыф», «Сәйфелмөлек» дастаннары һәм лирик, мәхәббәт турындагы 700 кыска җыр кергән.

**АЛИ́МОВА** Фәридә Кәшиф кызы (20.5.1953, Казан), микробиолог, биол. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1975). Шунда ук эшли, биохимия каф. мөдире (2007 дән). Хезмәтләре Trichoderma ыругы төрләренең биологик яктан күп төрле булуы һәм аларның микробиоталар яшәешендә һәм агроценозларда үсемлекләрне саклаудагы ролен өйрәнүгә карый. А.ның фәнни эшләре а.х.нда гамәлгә кертелгән («Казанский тепличный» биоз-ды, «Майский» с-зының биолабораториясе, ТР үсемлекләрне саклау станциясе). Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Фитосанитарное состояние семенного фонда и посевов белокочанной капусты Республики Татарстан // Вест. Рос. акад. с.-х. наук. 2002. № 1 (автордаш); Влияние осадков сточных вод, содержащих металлы, на микробные сообщества серой лесной почвы // Почвоведение. 2005. № 5 (автордаш); Промышленное применение грибов рода Trichoderma. К., 2006; Trichoderma / Hypocerea (Fundi, Ascomycetes, Hypocreales): Таксономия и распространение. К., 2006.

**АЛИХА́Н**, к. *Илһам хан.*

**АЛИ́Ш** Абдулла (Алишев Габдуллаҗан Габделбари улы) (15.9.1908, Казан губ., Спас өязе Көек а. — 25.8.1944, Германия), язучы. Казан җир төзелеше техникумын тәмамлаганнан соң (1930), ТАССРның Минзәлә кантонында, КазГРЭС (ТЭЦ № 1) төзелешендә эшли. Беренче әсәрләре 1929 елда «Яшь ленинчы» г-тасы битләрендә басыла. 1934 тә «Техника» ж-лының җаваплы сәркәтибе итеп билгеләнә. 1937–41 дә «Пионер каләме» ж-лы редакциясендә, ТАССР радиокомитетында эшли, Казан пед. ин-тының кичке бүлегендә укый. Башлыча балалар өчен яза. «Отряд флагы» дигән беренче җыентыгы 1931 дә басылып чыга. «Якты күл буе» (1933) повесте, «Дулкыннар» (1934) исемле хикәяләр җыентыгы , «Илгиз белән икебез» (1940), «Минем абый» (1940) исемле шигырь җыентыклары А.ны балалар язучысы итеп таныта. А.Әхмәт б-н берлектә «Күршеләр» (1934), «Йолдыз» (1935) пьесаларын яза. А.ның «Капкорсак патша» (1934), «Чуар тавык» (1936), «Нечкәбил» (1937), «Сертотмас үрдәк» (1937), «Койрыклар» (1937) исемле әкиятләре зур популярлык казана. «Әкиятләр» (1937), «Ана әкиятләре» (1941) җыентыкларына кергән әкиятләре образлы тел б-н, татар фольклоры традицияләренә нигезләнеп язылган. Әкиятләр күп мәртәбә татар һәм рус телләрендә басыла. 1941 нең июленнән А. фронтта. 12 октябрьдә Брянск шәһәре янында чолганышта калып, әсирлеккә эләгә. «Идел-Урал» (к. *Җәлилчеләр*) легионында антифашистик оешманың актив әгъзасы була: листовкалар яза һәм аларны әсирләр арасында тарата; легионерларның тоткынлыктан качуын, аларның кораллы чыгышларын оештыруда катнаша. 1943 тә яшерен оешманың эше ачыла. А. башка җәлилчеләр б-н бергә 1944 нең 25 августында гильотинада җәзалап үтерелә. А.ның әсирлектә язган шигырьләр блокноты, күп куллар аша үтеп, ш.у. әсирлектә булган Н.Терегуловка килеп эләгә. Ул шагыйрьнең 15 шигырен күчереп ала. Алар, рус теленә тәрҗемә ителеп, «Три поэта-воина» (1979) җыентыгына кертеләләр. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнә. 1996 да ТР Язучылар берлеге тарафыннан балалар әдәбияты өлкәсендәге казанышлар өчен Алиш исемендәге бүләк булдырыла; 2001 дә туган авылында шагыйрьнең бюсты куела.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1969; Әкиятләр. Хикәяләр. К., 1978; Болтливая утка. Сказки и рассказы. К., 1970.

*Әд.:* Шакир С. Абдулла Алиш: Тормышы һәм иҗат юлы турында очерк. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Язучы да Алиш, батыр да. К., 2001; Краткая литературная энциклопедия. М., 1962. Т. 2.

*Р.Ә.Мостафин.*

**АЛИ́ШЕВ** Сәлам Хатыйп улы (20.3.1929, ТАССРның Чистай кантоны Шәрбән а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1990), ТРның ат-каз. фән эшлеклесе (1996). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1951). 1951–60 елларда Лаеш р-ны Татар Сараланы авылы мәктәбендә укытучы, укыту бүлеге мөдире, директор була. 1960–62 дә Югары Ослан р-нында мәгариф бүлеге мөдире. 1966 елдан, аспирантура тәмамлаганнан соң, СССР ФА КГҮнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1990–96 да ин-тның тарих бүлеге мөдире. 1997 ел башыннан ТР ФАнең Тарих ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре татар халкы, Урта Идел буе, Казан ханлыгы һәм аның Рус дәүләте б-н үзара мөнәсәбәтләре тарихына һәм тарихи чыганакларына, Урта Идел буе халыкларының Россиягә кушылганнан соң барлыкка килгән социаль-икътисади халәтенә, татар халкының милли-сәяси изүгә каршы көрәшен өйрәнүгә карый.

Хезм.: Каһарман бабайлар. К., 1976; Татар тарихчылары. К., 2006; Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973; Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. XVI – нач. XIX вв. М., 1990; Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV – XVI вв. К., 1995; Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. 2-я половина XVI – XIX вв.). К., 1999; Историки. Татарский народ. К., 2000; Древний тюркский мир. К., 2000; Источники и историография города Казани. К., 2001; Казанское ханство. К., 2002; Все об истории Казани. К., 2005.

*Әд.:* Салям Хатыпович Алишев. К., 1999.

**АЛИ́ШИНА** Хәнисә Чавдат кызы (29.5.1953, Төмән ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2000). Төмән ун-тының тарих (1982) һәм филол. (1988) ф-тларын тәмамлый. 1993 елдан шунда ук эшли, 2000 нән гомуми тел белеме каф. профессоры. Хезмәтләре төрки диалектлар, Себер татарлары ономастикасы, төрле системаларга керүче телләрдәге семантика, сүз ясалышы, онимнар грамматикасы проблемаларына, урта гасыр татар язуы истәлекләрен анализлауга, татар ойконимнарын реконструкцияләүгә карый.

Хезм.: Боль моя и радость — язык сибирских татар. Тюмень, 1994; Тоболо-иртышский диалект языка сибирских татар. К., 1994; Ономастикон сибирских татар: В 2 ч. Тюмень, 1999; Этнический состав татар по данным топонимии // Сибирские татары. К., 2002.

**АЛКА́**, татар хатын-кызларының колакка тагыла торган бизәнү әйбере. Гадәттә, А.ны, колак йомшагын тишеп, беренче мәртәбә 3–4 яшьтә тактырганнар. А.ның төрледән-төрлесен (җирле зәркәнчеләр җитештергән һәм читтән китерелгән эшләнмәләрне, яңа мода буенча ясалган һәм буыннан буынга мирас ителгән бизәмәләрне) картлык көннәренәчә тагып йөргәннәр. Шуңа күрә аларның кулланылган вакытын һәм урынын шартлы рәвештә генә билгеләргә мөмкин. Болгар заманнарыннан алып 19 йөз ахыры — 20 йөз башларына кадәр «сорау билгесе» рәвешендәге көмеш, алтын йөгертелгән А.лар популярлык казана. Әлеге алкалар муенса яисә металл

сырлар төшерелгән асылмалы бизәкләр б-н тәмамланган, йомык булмаган боҗра композициясеннән гыйбарәт. 19 йөз уртасында «тәңкәле сырга»лар — төрле акчалардан һәм акчага охшаш әйберләрдән эшләнгән А.лар киң тарала. Еш кына алар мәрҗән асылмалар, тәңкәләр б-н бизәлә. Эшләү технологияләре катлаулы булмаганлыктан, аларны гади тимерчеләр дә ясаган. Алтынчылар, һөнәри зәркәнчеләр исә яссы һәм күпертмә җепкыр ысулы б-н ике (кечкенә һәм зур) аелдан торган үзенчәлекле татар А.лары эшләгәннәр. Тәңкәләрдән һәм кысага утыртылган асылташлардан (фирүзә, аметист, сердолик, тау бәллүре) торган асылмалар б-н бизәлгән аелның формасына карап, әлеге А.лар махсус әдәбиятта бадәм чикләвеге яки груша рәвешендәге А.лар дип аталалар. Этник яктан




Алка. 1. Алтын йөгертелгән көмеш, фирүзә. Җепкыр. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Алтын йөгертелгән көмеш, фирүзә. Җепкыр, кырлау. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

катнаш халык яшәгән төбәкләрдә аларны «татар сыргасы» дип йөртәләр. Аеруча грушасыман эре А.ларны (озынлыклары — 10–13 *см* га кадәр) еш кына чигә-муен бизәмәләре итеп тә кулланганнар — аларны колакка такмаганнар, баш киеменә беркеткәннәр, ияк астыннан тасма яки асылмалы чылбыр б-н бәйләгәннәр. Халык киемнәренең борынгы монументаль стиленә туры килгән мондый зур, бизәкле А.лар 19–20 йөзләр чикләрендә керәшеннәрдә генә сакланып калган. 19 йөз ахырыннан башлап татар киемнәренең европалаша баруы һәм гомумшәһәр нормаларына якынаюы борынгы «ай» формасындагы зур булмаган боҗра А.ның элекке популярлыгын арттыра. Җәенке, чәчәк-үсемлек бизәкләре төшерелгән «айлы» А.лар эшләү б-н нигездә татар зәркәнчеләре шөгыльләнә. Ә менә шома, бизәксез, кабартылган, ягъни эче куыш «айлы» А.ларны 19 йөз ахырыннан Казан губернасы Лаеш өязенең Балык Бистәсе авылында яшәүче рус осталары да ясый башлый. Татар хатын-кызлары рус үрнәгендәге А.ларны да элек-электән тагып йөргәннәр: 16–17 йөзләрдә «берлек», «икелек», «өчлек» А.лары, 18–19 йөзләрдә сәйлән, энҗе б-н бизәлгән кәрзин, имән чикләвеге, бант рәвешендәге А.лар таралган. Урта Азия, Кавказ якларыннан китерелгән А.ларны да бик теләп алганнар. 20 йөзнең 1 нче яртысы дәвамында татар зәркән сәнгатенең эре үзәкләре генә түгел (Казан, хәзерге Саба, Арча, Мамадыш р-ннарындагы авыллар), үзәктән читтәге милли бизәмәләр ясау учаклары да юкка чыга. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан фабрикаларда күпләп җитештерелгән бизәмәләр кулланыла башлый. А.лар беркайчан да модадан чыкмый, хәзер дә иң популяр бизәнү әйбере булып калалар. Аларны сайлау мөмкинлеге гаять зур — арзанлы бижутериядән алып (пыяладан, керамикадан, пластмассадан һ.б.дан ясалган А.лар һәм клипслар) кыйммәтле металлардан һәм ташлардан эшләнгән тиңдәшсез нәфис әйберләргә кадәр. Республикадагы нәфис һөнәрләр яңара барган саен, проф. рәссам-зәркәнчеләр һәм осталар җитештергән әйберләрне — милли үзенчәлекле А.ларны да базар тәкъдим итә башлады.

*Әд.:* С у с л о в а С.В. Женские украшения казанских татар середины 19 – начала 20 вв. М., 1980; В а л е е в Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф., Ш а г е е в а Р.Г. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990; ш у л у к. Ювелирное дело // Татары. М., 2001; Р а м а з а н о в а Д.Б. Названия одежды и украшений в татарском языке. К., 2002.

*Ф.Ф.Гулова.*

**АЛКА́ЕВ-ЧҮПРӘЛЕ́** Вәлиулла (19 йөзнең 2 нче яртысы), дин эшлеклесе, шагыйрь. Тумышы б-н Сембер губ. Буа өязе Яңа Чүпрәле авылыннан дип уйланыла. Туган авылы мәдрәсәсендә һәм Казанда Зәңгәр мәчет каршындагы мәдрәсәдә белем ала. Аннан соң туган авылында имам булып тора, балалар укыта, әдәби иҗат б-н шөгыльләнә. Сатирик шигырьләр һәм мәдхияләр яза. Гали Рәхимдә сакланган зур кульязма архивы 30 нчы елларда юкка чыга. Иҗаты һәм тәрҗемәи хәле аз өйрәнелгән. Гали Чокрыйның «Мәдх-е Казан» (1889) исемле китабына кушымта итеп басылган 4 шигыре билгеле.

*Әд.:* Г а з и з Г., Р ә х и м Г. Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере. К., 1925; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2.

*М.В.Гайнетдинов.*

**АЛКА́ЕВА-ЧҮПРӘЛЕ́** Мәхбүбә (19 йөзнең 2 нче яртысы), шагыйрә. Тумышы б-н Сембер губ. Буа өязенең Яңа Чүпрәле авылыннан дип уйланыла. Вәлиулла Алкаев-Чүпрәленең бертуган сеңлесе. Шигырьләре халык арасында кульязма нөсхәләрдә таралган, күбесе югалган. Үз заманында экспромт шигырьләр остасы булып танылган. Иҗаты да, тәрҗемәи хәле дә аз өйрәнелгән. Бер шигыренең өзеге 1925 елда Г.Рәхим һәм Г.Гобәйдуллин тарафыннан матбугатта игълан ителә.

*Әд.:* Г а з и з Г., Р ә х и м Г. Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере. К., 1925.

**АЛКАЛЫ́ ХОККЕ́Й**, к. *Хоккей*.

**АЛКЕ́ЕВ** Пётр (18 йөз), укытучы. 1770 елларда Мәскәү ун-ты каршындагы гимназиядә татар теле укыта.

*Әд.:* Объявление о учениях и упражнениях в обеих гимназиях Императорского Московского университета. М., 1774.

**А́ЛКИН** Габделлатыйф (1817 тирәсе — 1867 дән соң), 1865–66 елларда Казан губернасында чукынган татарларны мөселманлыкка кайтару хәрәкәтен җитәкләүчеләрнең берсе. Зөя өязе Чәчкаб авылы мөэзине була, керәшеннәрне элекке диннәренә кире кайтырга үгетләгәне өчен 1856 да эшеннән азат ителә. Зөя, Тәтеш, Цивиль өязе керәшеннәре арасында абруе зур була.Ул аларны рус патшасының чукынган татарларга мөселман булып калырга рөхсәт биргән фәрман чыгарачагына ышандырырга тырыша. 1867 елда кулга алына һәм ерак Себергә (Туруханөлкәсенә) сөргенгә озатыла. Шуннан соңгы язмышы ачыкланмаган.

*Әд.:* З а г и д у л л и н И.К. К вопросу об отпадении крещёных татар Казанской губернии в мусульманство 1866 года // Национальный вопрос в Татарии доактябрьского периода. К., 1990.


*И.К.Зәһидуллин.*

**А́ЛКИН** Җиһангир Сәетгәрәй улы (13.10.1897, Казан — 1919), милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе. С.Ш.*Алкинның* улы. Казанда реаль уч-ще тәмамлый (1915). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, прапорщик. 1915–16 елларда абыйсы И.С.Алкин б-н бергә Петроградта «*Татар учагы*» түгәрәге эшен оештыруда катнаша. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң татар милли азатлык хәрәкәтендә катнашашучыларның берсе була. Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 1 нче һәм 2 нче корылтайлары делегаты (1917–18), *Хәрби Шураны* оештыручыларның һәм җитәкләүчеләрнең берсе. «*Безнең тавыш*» г-тасын нәшер итүдә башлап йөри. 1917 нең көзендә мөселманнар социаль исемлеге буенча Учредительләр җыенына сайлана. «Болак арты республикасы» вакыйгалары барышында Совет хакимияте вәкилләре тарафыннан кулга алына, соңрак азат ителә. Шуннан соңгы язмышы ачыкланмаган.

*Әд.:* Д а в л е т ш и н Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; С у л т а н - Г а л и е в М. Избранные труды. К., 1998.

*Д.М.Усманова.*

**А́ЛКИН** Илиас (Ильяс) Сәетгәрәй улы (28.11.1895, Казан — 27.10.1937, Мәскәү), хәрби-сәяси эшлекле, географ, подпоручик (1917). С.Ш.Алкинның улы. Казанда 1 нче реаль уч-щене (1914), Мәскәү халык хуҗалыгы ин-тының икътисад ф-тын тәмамлый (1925). 1914 елдан Петроградта Политехника ин-тында укый; шәһәрдә «*Татар учагы*» түгәрәген оештыручы һәм җитәкчеләренең берсе. Сәяси карашлары буенча баштарак меньшевикларга, соңрак эсерларга якын тора. 1915 тән Россия армиясендә. 1916 ның язында Петроградтагы Константин артиллерия уч-щесенә укырга керә. 1917 нең гыйнварыннан Казанда, 2 нче запас артиллерия бригадасының 2 нче батареясында прапорщик. Февр. рев-циясеннән соң милли-сәяси хәрәкәттә әйдәп баручылардан була. 1917 нең мартында Казан милициясе башлыгы урынбасары, 16 мартта Казан мөселманнары хәрби ком-ты рәисе итеп сайлана. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче корылтае эшендә катнаша, Милли Шура президиумы әгъзасы була. Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 1 нче корылтаенда *Хәрби Шура* рәисе итеп сайлана. Петроградка баргач, Вакытлы хөкүмәтнең Хәрби Шураның мөселманнар мәсьәләләре буенча эш итү хокукын тануына ирешә. Чыгышларында мөселманнардан аерым хәрби берәмлекләр оештырырга кирәклеген таләп итә. 1917 нең августында генерал Корнилов җитәкчелегендәге фетнәне бастыруда катнаша. Окт. рев-циясе көннәрендә



И.С. Алкин.



С.Ш. Алкин.

Хәрби Шура исеменнән Совет хакимиятен яклавын белдерә. Соңыннан ул фикереннән кире кайта, большевиклар сәясәте илдә татулык, тынычлык урнаштыруга ярдәм итми, дигән нәтиҗәгә килә. Татар милләтен саклап калу чараларын күрергә чакыра. Учредительләр җыенына Казаннан делегат булып сайлана. Эшчәнлеге шул ук көннәргә туры килгән *Милләт Мәҗлесенең* дә депутаты була. Анда А.ны рәис урынбасары итеп сайлыйлар; ул зур бәхәсләрдән соң җиңүгә ирешкән *туфракчылар* фракциясен оештыручылардан санала. Аңа *Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү һәйәте* рәисе вазифасы йөкләнә. Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 2 нче корылтаен чакыру һәм аны үткәрүне оештыруда башлап йөри. Идел-Урал Штатын төзегәндә халыкны сыйныфларга бүлгәләмичә, төбәктә яшәүче һәркемнең, һәр милләт кешесенең ихтыяҗын канәгатьләндерүне яклап чыга. Идел-Урал Штатын Федератив Россиянең бер өлеше буларак күзаллый. Большевиклар уздырган сәяси чараларны тәнкыйтьләп, «социализм илдә штык һәм нагайка ярдәмендә урнаштырыла» дип белдерә. Аның уй-фикерләре б-н килешмәгән большевик делегатлар мөселман гаскәриләренең 2 нче корылтаен ташлап чыгалар. Корылтайда Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү утырышлары алдыннан А. һәм аның тарафдарлары кулга алына. Большевиклар аларны Казанда түнтәреш әзерләүдә гаепли. Күпмедер вакыттан соң А. һ.б. азат ителә. Март ахырында Хәрби Шура һәм кайбер башка милли оешмалар эшчәнлеге тыела. 1918 нең апрелендә А. КОМУЧ тарафдарларына кушыла: куып таратылган Учредительләр җыены әгъзалары бюросына кабул ителә, 1918 нең сентябрендә Уфада һәм Екатеринбургта уздырылган съездларда рәис урынбасары була. 1918 нең ноябрендә Екатеринбургта башка КОМУЧ әгъзалары б-н бергә колчакчылар тарафыннан кулга алына. Аннан качып китә, Әхмәтзәки *Вәлиди* оештырган Башкорт мохтарияты хөкүмәтенә кабул ителә: милли башкорт гаскәрләре штабы башлыгы һәм гаскәр командующиеның урынбасары, Башревком әгъзасы, хезмәт комиссары, Башкорт Респ-касының хәрби комиссары вазифаларын үти. 1919 ның башында Башкорт мохтарияты җитәкчеләре большевикларга кушылу чаралары күрә башлый. Ә.Вәлиди б-н бергә А. да хакимият вәкилләре б-н уртак сөйләшүләрдә катнаша. 1919 ның февраль ахырларында аларны хөкүмәт башлыклары В.И.Ленин б-н И.В.Сталин кабул итә. Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Респ-касын төзү турында декрет кабул ителгәч, А. большевиклар ягына чыга, РКП(б) сафларына алына. 1920 нең июнендә, БАССР хөкүмәте фетнәсеннән соң, Ә.Вәлидинең көрәштәше буларак, А. кулга алына, Мәскәүнең Бутырка төрмәсенә ябыла. Шул елның декабрендә ҮБК секретаре А.Енукидзе ярдәмендә төрмәдән чыгарыла. А.ны И.В.Сталин кабул итә. Шәрекъ хезмәт ияләре коммунистик ун-тына (Мәскәү) эшкә билгеләнә: Көнчыгыш (Шәрекъ) илләре икътисады һәм географиясе кабинеты мөдире, лектор, ассистент булып эшли. Урта Азия икътисади географиясенә багышланган монографиясе басылып чыккач («Средняя Азия. Экономико-географический очерк». М., 1931), җитди тәнкыйтьләнә, буржуаз милләтчелектә гаепләнә, М.Солтангалиев тарафдары дип атала. Әмма 1937 елга кадәр гыйльми эшчәнлеген дәвам иттерә, Бөтендөнья зур атласын нәшер итүгә әзерлек барышында Урта Азия бүлеге җитәкчесе була. Бер үк вакытта Мәскәү ун-тында укыта, аңа профессор дәрәҗәсе бирелә. 1937 нең 22 сентябрендә кулга алына, бер айдан соң, 27 октябрьдә, контрреволюцион эшчәнлектә һәм шпион-террорчылыкта гаепләнеп, атып үтерелә. 1955 тә аклана. Икътисади географиягә караган хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Основы нашего производства: Экономико-географический очерк. М.–Л., 1924.

*Әд.:* Политические деятели России 1917: Биогр. словарь. М., 1993; У с м а н о в а Д. Из рода Алкиных // Татарстан. 1993. № 12; С у л т а н б е к о в Б. Ильяс Алкин: жизнь и судьба // Татарстан. 1994. № 9–10; Илиас Алкин — общественный деятель, военачальник, учёный: Док. и материалы. К., 2002. *Д.М.Усманова.*

**А́ЛКИН** Нил Хәлил улы (13.4.1928, Бөгелмә ш. — 8.7.1995, Казан), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). Казан пед. ин-тын (1951) һәм Ленинград Югары партия мәктәбен (1968) тәмамлый. 1951–63 елларда Чуаш АССР, Краснодар крае, ТАССРның Куйбышев р-ны, Ярославль өлкәсе мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1963–66, 1972–74 тә «Советская Татария» г-тасында, 1968–72 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында эшли. 1974–75 тә «Труд» (Мәскәү) г-тасының ТАССР буенча үз хәбәрчесе. 1979 дан «Вечерняя Казань» г-тасында (бүлек мөдире, 1989–94 тә мөхәррир урынбасары). Язмалары күбесенчә очерк, репортаж жанрына карый. Г.Тукай, С.Хәким, М.Әмир әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә. Татарстан Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. республика бүләге лауреаты (1986).

**А́ЛКИН** Сәетгәрәй Шаһиәхмәт улы (13.7.1867, Казан губ., Мамадыш өязе Алкино а. — 1919, Казан), хокук белгече, җәмәгать эшлеклесе, *«Иттифакъ әл-мөслимин»* партиясен оештыручы һәм җитәкчеләренең берсе. Морзалар нәселеннән, дворян, Алкин авылында җир биләмәләре хуҗасы. Ш.М.Алкинның улы. Казанда Беренче ир балалар гимназиясен (1883) һәм Казан ун-тының юридик ф-тын (1893) тәмамлый. 1894–1917 елларда Казан хөкем палатасында адвокат. 1905–08 дә *«Казан мөхбире»* г-тасының нашире һәм рәсми мөхәррире, бер үк вакытта (1907–08) *«Әхбар»* г-тасын да нәшер итә. Казан губернасыннан 1 нче Дәүләт думасына депутат булып сайлана (1906), анда кадетлар фракциясе әгъзасы һәм мөселманнар фракциясен оештыручыларның берсе була. Дума таратылгач, *Выборг өндәмәсенә* кул куйган өчен 3 айга төрмәгә ябыла (1908 елда чыга). 1905 тән Казан губернасы Кадетлар партиясе ком-ты әгъзасы, Россия күләмендә танылган мөселман либераллар лидеры. Бөтенроссия мөселманнарының «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен оештыруга юнәлтелгән 1 нче, 2 нче, 3 нче корылтайларда катнаша, соңгы оештыру съездында партия ҮКна сайлана. 1903–08, 1917 дә Казан шәһәр думасы әгъзасы; титулярный советник. 1914 нең июнендә Бөтенроссия мөселманнарының 4 нче съездында делегат була, шул ук елның декабрендә Бөтенроссия мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре корылтае эшендә катнаша. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Казанда *Мөселман качакларга ярдәм итү комитетын* җитәкли. 1917 дә *Мөселманнар комитетын* оештыруда катнаша, *«Корылтай»* г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. 1917 нең мартында Петроградта оешкан Россия мөселманнарының вакытлы үзәк бюросына керә. 1917 нең маенда Мәскәүдә узган Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче корылтае делегаты була, «Милли вә дини мохтарият нигезләре» дигән нотыгын сөйли. 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң Казанда совет халык мәхкәмә оешмаларын оештыруда катнаша.

*Әд.:* Т у к т а р о в Ф. (Усал). Беренче, Икенче, Өченче Думада мөселман депутатлар вә аларның кылган эшләре. К., 1909; У с м а н о в а Д.М. Из рода Алкиных // Татарстан. 1993. № 12; Мусульманские депутаты Государственной Думы России (1906–1917): Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

**А́ЛКИН** Шәйхулла Сибгатулла улы (15.8.1893, Казан губ., Зөя өязе Иске Чәчкаб а. — 1918 дән соң), сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы. Крәстиян катлавыннан. Казанда җәдиди мәдрәсә (1905) һәм коммерция уч-щесен (1913) тәмамлый. 1913–18 елларда (бүленеп) Мәскәү коммерция ин-тында укый. *«Ил»* г-тасы, *«Ак юл»* ж-лы б-н хезмәттәшлек итә. Балаларга багышланган тәүге хикәяләре, русчадан тәрҗемәләре 1913–14 тә матбугатта басыла. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары эшендә катнаша, көндәлек матбугатта аларның барышы турында хәбәрләр урнаштыра. Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче корылтаенда (Казан) *Милли Шурага* сайлана. Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтарият нигезләрен эшләү комиссиясе эшендә катнаша. *Милләт Мәҗлесе* депутаты (1917–18), анда финанс эшләре комиссиясе җитәкчесе була, *Малия* (финанс) *нәзарәте* рәисе итеп сайлана. Булачак Идел-Урал Штаты биләмәсенә Әстерхан һәм Самара губерналарын да кертү кирәклеген дәлилләп чыга. Төп карашы буенча милли-мәдәни мохтарият (автономия) тарафдары. Окт. рев-циясен кабул итми. Большевиклар Уралга якынлашкан көннәрдә, 1918 нең көз башында, бер төркем Милли Идарә әгъзалары б-н бергә, Уфаны калдырып, Себер тарафына күчеп китә.

А.ның Уфадан киткәннән соңгы тормышы ачыкланмаган. 1922 нең 7 февралендә Г.Ибраһимов «Татарстан хәбәрләре» г-тасында Ш.Алкинның Оренбург шәһәрендә үз-үзен үтерүе турында хәбәр урнаштыра.

*Ә с ә р.:* Балалар күңеле. К., 1921.

*Әд.:* Д а в л е т ш и н Т. Советский Татарстан... Лондон, 1974; У с м а н о в а Д. Шайхулла Алкин // Татарстан. 1995. № 9–10; С у л т а н - Г а л и е в М. Избранные труды. К., 1998.

*Д.М.Усманова.*

**А́ЛКИННАР**, татар дворяннары нәселе. Чыгышлары Сембер губернасының Буа өязеннән. Казан губернасы дворяннары исемлегендә теркәлгәннәр. 1) **Йосыф Әбдери** улы А. (? — ?) (хатыны Суфия Тәфкилева), җирбилүче, титулярный советник. Уфа өязендә җир биләмәләре алып, Казан губернасы Тәтеш төбәгендәге крәстияннәрдән 45 кешене шунда күчерүе, анда Узы Тамак авылын нигезләве документларда теркәлгән. 1839 елда Узы Тамакта А. крәстияннәреннән 21 гаиләдә 124 кеше булуы мәгълүм; 2) **Мөхәммәд Йосыф** улы (? — ?), җирбилүче, поручик. Җир биләмәләре Казан губернасы Зөя өязендә була; 3) **Шаһиәхмәт Мөхәммәд** улы (1812 — 78 яки 1879), җирбилүче, титуляр советник (1841), коллегия советнигы. Казан полициясе приставы, 1846 дан Казан полицмейстеры ярдәмчесе. 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены б-н бүләкләнә. Ш.у.к. С.Ш.*Алкин*, Җ.С.*Алкин*, И.С.*Алкин*.

*Әд.:* Алфавитный список родам потомственных дворян, внесённых в дворянскую родословную книгу Казанской губернии с обозначением имени и отчества тех из них, кои впервые вписали свои роды в сию книгу и с обозначением времени их записи с 1787 по 1895 гг. К., 1898; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

**А́ЛКИНО** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Карабаш сусаклагычыннан 4 *км* көньяктарак. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан — Лениногорск, 1959 ның 26 мартыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1920 дә — 116, 1926 да — 114, 1938 дә — 140, 1949 да — 240, 1958 дә — 75, 1970 тә — 60, 1979 да — 21, 1989 да — 13 кеше.

**А́ЛКИНО** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 45 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Ирнә елгасы буенда. 2002 елда 106 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык асрау. 18 йөз башында Сембер губернасыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау, тимерчелек б-н шөгыльләнә, алпавыт Мельгуновлар утарында ялланып эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 995 дис. тәшкил итә. 1929–30 да А.да «Красный боец» к-зы оештырыла. 1958 дә ул Калинин исем. (1963 тән Куйбышев исем.) к-з составына керә, 1998 дән — «Бохарай» а.х. товарлары җитештерү кооперативы. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Сарман, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 306, 1913 тә — 580, 1920 дә — 612, 1926 да — 639, 1938 дә — 529, 1949 да — 420, 1958 дә — 434, 1970 тә — 317, 1979 да — 170, 1989 да — 116 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**А́ЛКИНО** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ушма елгасы буенда. 2002 елда 48 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1822 дә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ак Чишмә исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да поташ з-ды була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 84 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кече Кирмән волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 61, 1897 дә — 141, 1908 дә — 170, 1920 дә — 258, 1926 да — 285, 1938 дә — 234, 1949 да — 253, 1958 дә — 184, 1970 тә — 208, 1979 да — 184, 1989 да — 75 кеше.

**АЛКЫШЛА́Р ҺӘМ КАРГЫШЛА́Р**, татар халык авыз иҗатының афористик жанры. Борынгы заманнан билгеле. Татарларның барлык этник төркемнәрендә дә киң таралган. Татар фольклорының үзенчәлекле жанры буларак, беренче тапкыр күптомлы «Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр» (1987) басмасында кереш мәкаләдә тасвирлана. А.һ.к. сүзнең могҗизалы көченә ышануга нигезләнә һәм сихерләү буларак кулланыла: «Алкыш алган — аман, каргыш алган — тәмам»; «Бер кулың майда, бер кулың балда булсын»; «Тыныч йокы, татлы төш»; «Кулың корысын». «Алкыш» һәм «каргыш» терминнары 11 йөз язма ядкәрләрендә теркәлгән. Йосыф Баласагунының «Котадгу белег» (1069–70) поэмасында түбәндәге юллар бар: «Киши едгү атын көр алкыш булур, // Атыкмыш есиз өлсә каргыш булур» («Яхшы исемле кешене шатлыклы алкышлар белән каршылыйлар, // Начар исемле кешене кабергә дә каргышлар белән озаталар»). А.һ.к. башка борынгы төрки язма чыганакларда да сакланган: «Агылыңта йылкың болсун» («Абзарыңда атлар булсын»), «Тәңри каргышы аның үзә» («Тәңре каргышы аңа төшсен») һ.б.

*Әд.:* Древнетюркский словарь. Л., 1969; М а х м у т о в Х.Ш. Афористические жанры татарского фольклора. К., 1995.

*Х.Ш.Мәхмутов.*

**АЛЛА́Һ** (гарәп. أﷲ — илаһи зат), ислам динендә иң югары илаһи Зат, аның 99 исеменнән иң әүвәлгесе. Исламда А. — бер һәм бердәнбер илаһи көч, дөньяны яралтучы. Кыямәт көнендә хөкемдар, кешеләр арасына *Мөхәммәд* пәйгамбәрне үзеннән илче итеп җибәрүче. Исламда иман кәлимәсе: «Лә иләһә илл-ә-Аллаһ Мөхәммәдүн габдүһу вә рәсүлүһ», ягъни «Алладан башка берниндиде илаһи көч юк һәм Мөхәммәд аның илчесе», дигән сүзләрдән тора. Дөньяда бар нәрсә А.ка буйсына һәм баш ия, аның ихтыярыннан һәм боерыуннан узып берни дә башкарылмый. Ул бар нәрсәгә хаким һәм үзе яралткан һәр әйберне күреп, белеп тора. Бәндәләргә карата шәфкатьле, мәрхәмәтле һәм ярлыкаучан. Кешеләр А.ның кодрәтен һәм бөеклеген аңлап, тулысынча Аңа буйсынырга, А. кушканнан тайпылудан куркырга, иманлы булырга, һәрчак А.га ышанырга, А.ның ихтыярына һәм шәфкатенә өмет итәргә тиеш. А. үзенең барлыгын гамәлләре б-н күрсәтә һәм белдереп тора. Дөньядагы һәр нәрсә — А. могҗизасы. Коръән — ш.у. кешеләргә бүләк ителгән могҗиза. Хәдисләрдә, тәфсирләрдә, дини хезмәтләрдә А.ның асылы төрле яклап аңлатыла. 18 йөз — 20 йөз башы татар дини әдәбиятында (А.Курсави, Ш.Мәрҗани, З.Камали, М.Бигиев һ.б.) А.ның асылына, гамәлләренә, исемнәренә һәм билгеләренә кагылышлы мәсьәләләр еш тикшерелә.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**АЛЛАҺИАРИЛА́Р** (Алдагаровлар), бертуганнар: Закирҗан Сабирҗан улы (1874, Җаркәнд ш., хәзерге Казакъстан Респ-касы, Талды Курган ш. — 1937, Кытай Төркестаны, Өремче ш.) һәм Фатих Сабирҗан улы (15.8.1885, Җаркәнд ш. — 28.11.1966, Кытай Төркестаны, Голҗа ш.), Кытай Төркестанындагы татар сәүдәгәрләре һәм кәсәбәчеләре, җәмәгать эшлеклеләре. 1910–20 елларда Голҗа шәһәре татар җәмәгатьчелеге кирәгенә дип тупланган вакыфның (фондның) актив оештыручылары һәм идарәчеләре. Голҗада беренче җәдиди (яңача укытуга нигезләнгән) мәктәп бинасын төзүгә өлеш кертәләр (1913). Бертуган А.лар — 1930 еллар башында Урта Азия респ-калары б-н сәүдә итүче «Алтай ширкәте» сәүдә фирмасын оештыручылардан, Голҗа шәһәре читендә татар бистәсен төзүдә башлап йөрүчеләрдән. Шәһәрнең төп халкы булган уйгырлар соңрак аны «Нугай гурт», ягъни, «Татар шәһәре» дип атыйлар. Бу төзелешнең Кытай Төркестаны шәһәр төзелеше культурасына һәм архит-расы үсешенә йогынтысы зур була. А.лар — Голҗа төбәге татар яшьләренең чит илләргә (нигездә, Төркия, Германиягә) китеп югары белем алуына рухи һәм матди ярдәм итүче байлар. Закирҗан 1937 дә Гоминдан хөкүмәте тарафыннан кулга алына һәм төрмәдә вафат була. Фатих А. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында Якын Көнчыгыш һәм Европа илләрендә, ш.и. СССРда була. 1930–50 елларда ул Голҗа татарлары мәгарифен һәм мәдәниятен үстерүгә байтак ярдәм итә, 1939 да татар мәктәбе бинасын төзүгә зур өлеш кертә. Хатыны Хәдичә дә (1895–1956) иганәче буларак танылa. Кытайда коммунистлар хакимияте урнашканнан соң, Фатих А. берничә мәртәбә кулга алына. Аның улы Мәсгуд А. (1913–92) 1980 еллар башында Австралиягә күчеп китә.

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Ябылмаган китап. К., 1994.

*М.Г.Госманов.*

**АЛЛАҺИЯ́Р СУФИ́** (1616, кайбер чыганакларда 1630 еллар тирәсе, Үзбәкстанның хәзерге Кәттәкурган шәһәре янындагы Минкаль төбәге — 1713, кайбер чыганакларда 1723, Искәндәрия ш., Мисыр), суфи шагыйрь. Төрки һәм фарсы телләрендә язган. Таҗетдин Ялчыголның «Рисалә-и Газизә» (1795) китабында һәм К.Насыйриның шуңа таянып язган «Мәҗмуг әл-әхбар» («Хәбәрләр җыелмасы», 1859) әсәрендә бәян ителгән риваяти мәгълүматларга караганда, А.С. Бохара шәһәрендә иҗат иткән. Ата-бабаларының төп чыгышы Идел буеннан дип уйланыла. Олыгайган яшьтә А.С. хаҗ сәфәренә чыга, барышлый Идел буенда, Казан, Болгарда була, кардәш-туганнары б-н күрешә. Әмма ул Мәккәгә барып җитә алмый, Искәндәрия шәһәрендә вафат була. Төп әсәрләре: «Сөбат әл-гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк», 1802), «Морад әл-гарифин» («Укымышлыларның максаты», М., 1858), «Мәсләк әл-мөттәкыйн» («Тәкъвалар юлы», К., 1899), «Мәхзән әл-мотыйгыйн» («Күндәмнәрнең хәзинәсе»). Нигездә суфичылык рухында, Алла гыйшкына мәдхияләр җырлау максаты б-н язылган бу әсәрләрдә социаль мотивлар, шәхес иреге, рухи азатлык идеяләре дә яңгыраш таба. «Сөбат әл-гаҗизин» поэмасы исә шигъри бизәкләре, эмоциональ тәэсирлелеге б-н 19 йөз татар поэзиясенә үрнәк булып хезмәт итә. 40 тан артык басмасы дөнья күрә. А.С.әсәрләре күп кенә татар язучыларының иҗатына сизелерлек йогынты ясый. Мәс., татар галиме һәм язучысы Таҗетдин Ялчыгол «Сөбат әл-гаҗизин» әсәренә шәрехләр язып, «Рисалә-и Газизә» китабын иҗат итә. Шул исемдә ул мөстәкыйль әсәр буларак халык арасында киң таралыш таба. 19–20 йөзләр аралыгында әсәрләрнең һәр икесе татар мәктәп һәм мәдрәсәләрендә төрки телдән ярдәмлек сыйфатында файдаланылган.

Ә с ә р.: Суфи Аллаһияр. Сөбат әл-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк). К., 2000.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. Т. 1.; Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). К., 1999. *М.В.Гайнетдинов.*

**АЛЛЕРГЕННА́Р**, антиген яисә гаптен табигатьле матдә, организмга тәэсир итеп, җавап реакциясе — аллергия китереп чыгара. Экзоаллергеннар (читтән кергән А.) классификациясе А.Д.*Адо* тарафыннан тәкъдим ителә (1963). Шул классификациягә биологик матдәләр (чагучы бөҗәкләр агуы), көнкүреш матдәләре (эпидермис һәм хайваннар селәгәе, балыклар өчен коры азык, өй тузаны, көнкүреш химиясе препаратлары), үсемлек серкәсе (күгәрек гөмбәләр споралы һ.б.), сәнәгать әйберләре (хим. реагентлар, буяу, лак, сумала, Ni, Cr, Br, I һ.б.) һәм азык-төлек (җиләк-җимеш, ит, балык, балык консервлары, сөт, күкәй һ.б.), дезинфекция эремәләре, дару препаратлары, кайбер микроблар керә. Эндоаллергеннар организмның үз тукымаларыннан барлыкка килә һәм аутоиммун чирләрнең үсүенә китерә. Аллергик авыруларга диагноз кую һәм дәвалау өчен *Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү институтында* илебездә беренче бактериаль А. (ш.и. гемолитик стрептококклар, алтынсыман стафилококк, эчәк таякчыклары), гөмбә А. препаратлары булдырыла; 30 дан артык А. җитештерелә. Ш.у.к. *Аллергология.*

*Әд.:* Ф а с с а х о в Р.С. Механизмы аллергии // Научный Татарстан. 1995. № 4.

**АЛЛЕРГИ́Я**, (грек. állos — бүтән, érgon — тәэсир итү), аллергик авырулар, организмның сизүчәнлеге үзгәрүе һәм *аллергеннарның* иммунологик механизмнарына кабат тәэсир итүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән авырулар. ТРда бронхиаль астма (30–50%), ринит, коньюктивит, атопик һәм аллергик дерматит, кычыткан бизгәге, тимрәү аеруча киң таралган, ашыгыч ярдәм таләп ителә торган анафилактик шок сирәк була. Экзоаллергеннар организмга читтән керә, еш кына сулыш юлларының лайлалы тышчасы, ашкайнату әгъзалары, тире аша эләгә. Организмга аллерген үтеп кергәннән соң аллергик реакция башлана (үзенчәлекле һәм үзенчәлексез). Үзенчәлекле реакцияләр өч стадиягә бүлеп карала. Беренчесендә — организмга беренче тапкыр эләккән аллергенга карата югары дәрәҗәдә сизүчәнлек күзәтелә (яңа аллергенга җавап рәвешендә антитәнчекләр яисә аның б-н тәэсир итешә алучан лимфоцитлар барлыкка килә). Икенче стадиядә — аллерген кабат организмга үтеп кергәч, антитәнчекләр яисә лимфоцитлар б-н кушыла (медиаторлар барлыкка килү стадиясе), гистамин, серотонин һ.б. биол. актив матдәләр бүленеп чыга торган биохимик процесслар башлана. Алар әгъзаларның күзәнәкләрен һәм тукымаларын зарарлый. Өченче (патофизиологик) стадиядә зарарлануның клиник билгеләре беленә. Андый очракта организмның югары сизүчәнлеге үзенчәлекле, ул элегрәк сенсибилизация халәтен китереп чыгарган аллергенга бәйле рәвештә барлыкка килә. Аллергик реакцияләр үсеше механизмы 4 типка бүленә. 1 нче тип А. — анафилаксия, серкә (печән) бизгәге, кычыткан бизгәгенең кайбер төрләре, Квинке шешенүе һ.б. 2 нче тип (цитотоксик) реакцияләр — кан бозылу (аллергик анемия, агронулоцитоз). 3 нче тип реакцияләр — тукымаларның иммункомплекслар б-н зарарлануы, сүл авыруы, тышкы аллергик үпкә альвеолалары ялкынсынуы һ.б. аутоаллергик чирләрне арттыра (системалы кызыл төче авыруы, ревматоид артрит һ.б.). 4 нче тип реакцияләр — контактлы дерматитлар, күчереп утырткан әгъзаны организмның кабул итмәве. 1,2,3 нче типлардагы А. патогенезында антитәнчекләр, 4 нче типта лимфоцитлар мөһим урын тота. А.гә бирешүчәнлек факторлары: әйләнә-тирә мохитнең пычрануы, түбән сыйфатлы туклану, ашамлыкларда консервантлар булу, дару препаратларын тикшермичә куллану. Татарстанда 1969 елга кадәр авырулар дәвалану курсларын стационарларда үтә. 1969 дан дәвалау-профилактика оешмаларында аллергия кабинетлары челтәре үсеш ала. Т.Б.Толпегина тырышлыгы б-н 1976 да Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-ты каршында йогышлы аллергик авырулар өчен СССРда беренче консультация-диагностика клиникасы ачыла (к. *Аллергология*). Дәвалауның төп ысуллары: аллерген б-н контакт булдырмау, ашамлыклардан аллергия булганда катгый диета саклау, аллергия китереп чыгара торган дарулардан тыелу; үзенчәлекле иммунотерапия (гипосенсибилизация) — А.М.Безредка алымын кулланып, аллерген микъдарын акрынлап арттыра барып, организмга аны күп тапкыр кертү. Бу организмга «киртә» тудырырлык антитәнчекләр эшләргә мөмкинлек бирә һәм аллергенга карата сизүчәнлекне бетерүгә китерә. Симптоматик дәвалауда глюкокортикоид, бронхолитик, олы күзәнәкләрнең мембраналарын стабильләштерә торган матдәләр кулланыла. 1960–90 елларда Казан аллергологлары тарафыннан эшләнгән аллергик авыруларны булдырмау методикасы: сенсибилизациягә сизгер матдәләрдән саклану чараларын үтәү, үз вакытында профилактик дарулар куллану, сәнәгать пр-тиеләрендә аллерген б-н контакт булдырмый торган технологияләрне гамәлгә кертү, организмда сенсибилизация чыганагы булган һәртөрле инфекцияләрне бетерү (бигрәк тә ашказаны-эчәк әгъзалары функциясен нормальләштерү) һ.б.дан гыйбарәт. ТРда аллергик авырулар б-н ел саен халыкның 4–10% интегә.

*Әд.:* Ф а с с а х о в Р.С. Механизмы аллергии // Научный Татарстан. 1995. № 4.

*Р.С.Фәссахов, Р.Г.Исхакова.*

**АЛЛЕРГОЛО́ГИЯ** (*аллергия* һәм ... *логия*), фән, аллергик авыруларның этиологиясен һәм үсеш механизмын өйрәнә. Клиник мед. бүлеге — клиник аллергология аллергик авыруларга диагноз кую, аларны дәвалау һәм булдырмау ысулларын эшли. 1902 елда француз иммунологлары Р.Портье һәм С.Рише анафилаксия күренешен ачалар, 1906 да Австрия педиатры фон Клемент Пирке «аллергия» терминын кулланышка кертә, 1910 да инглиз патологы Дейл аллергик реакцияләрдә гистаминның әһәмиятен күрсәтә, 1937 дә француз фармакологлары Д.Бове һәм М.Штауб беренче антигистамин препаратын уйлап табалар. 1966 да иммунологлар К. һәм Т.Ишизака, швед галимнәре С.Йохансcон һәм Р.Бенних Е (lgE) иммуноглобулинын ачалар. А.нең Россиядә (1960 тан) үсеше Казан мед. ин-ты б-н тыгыз бәйләнгән. Казан галиме А.Д.*Адо* — илебез А.сенә нигез салучы. Шул елларда чәчәк серкәсе аллергиясен — полинозны (авыруны 500 мең төрле үсемлек китереп чыгарырга мөмкин) өйрәнү буенча тирәнтен тикшеренүләр үткәрелә. 1969 да беренче аллергология кабинеты ачыла, Казан ГИДУВында илдә беренче клиник аллергология кафедрасына нигез салына (1970; каф. мөдире Т.Б.Толпегина), клиника ил өчен аллергологлар әзерләүнең төп базасы була. Бронхиаль астма, дерматитның этиологиясе, патогенезы өйрәнелә (Р.Х.Бурнашева һ.б.). Аллергик авыруларга каршы препаратлар эшләнә һәм гамәлгә кертелә: кеше иммуноглобулины (1982), гистосероглобулин (1990), комплекслы дәвалау ысуллары, беренче тапкыр аэрозоль терапиясе кулланыла. 1976 дан ТРда специальләштерелгән аллергологик консультация-диагностика поликлиникасы эшли. 1986 да балалар аллергологиясе курсы (Казан ГИДУВында), аннан соң Казандагы 7 нче балалар хастаханәсе базасында балалар аллергологиясе кафедрасы (СССРда беренче, 1989, каф. мөдире А.М.Потёмкина) оештыры-

ла, анда илнең балалар аллергологлары белемнәрен арттыра. Балаларда аллергик авыруларның формалашуы — табиб-аллергологлар коллективы эшләгән фәнни юнәлешләрнең берсе (туганнан соң беренче айларда авырган балаларның 90% ында ашамлыкка аллергия күзәтелә). Яшь балаларда авыру куркынычы ихтималын ачыклау программасы (ул авыруны дәвалау һәм булдырмый калу мөмкинлеге бирә) эшләнә. Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-тында диагноз кую һәм дәвалау *аллергеннары* эшләнә, бу — Россиядә бердәнбер бактерия һәм гөмбә аллергеннары производствосы, аларны эшләү технологиясе 1960–80 елларда Татарстанда башлана. Шул елларда Казан аллергологлары һәм иммунологлары (Н.Н.Сиротинин, А.Д.Адо, Т.Б.Толпегина, А.М.Потёмкина, Р.Х.Бурнашева, И.М.Рәхмәтуллин, Р.С.Фәссахов) фәнни мәктәбе оеша.

А. фәненең башка тармаклары: ботаника, молекуляр биология (аллергеннарның төзелеше һәм үзенчәлеге), биотехнология (рекомбинант дәвалау аллергеннары булдыру), генетика өлкәләре (аллергиягә бирешүчәнлек маркерларын һәм механизмнарын өйрәнү) б-н үзара бәйләнгән. 2006 елда ТРда 5 стационар, 15 тән артык аллергология кабинеты өлкәннәргә һәм балаларга ярдәм күрсәтә.

*Әд.:* П о т ё м к и н а А.М. Диагностика и лечение аллергических заболеваний у детей. К., 1994; Г у щ и н И.С. Механизмы аллергических реакций. М., 1998; П ы ц к и й В.И. Аллергические болезни. М., 1998.

*Р.С.Фәссахов, Р.Г.Исхакова.*

**АЛЛИТЕРА́ЦИЯ** (урта гасырлар лат. alliteratio, лат. ad — янына, янында, каршында, littera — хәреф), чәчмә әсәрләрдә һәм шигырьләрдә эмоциональ-экспрессив максатларда бер үк төрле яки охшаш яңгырашлы тартык авазларның кабатланып килүе. Татар шигъриятендә А. шигырьне оештыру ысулы буларак кулланыла.

Җиктере**п** **п**ар ат, Казанга
Ту**п**-туры киттем кара**п**.
Ча**п**тыра атларны кучер
Суккала**п** та, тарткала**п**.
(Г.Тукай)

А. нең юл башы саен тезелеп килүе (анафора рәвешен алуы) үзенә бер төрле рифма хасил итә. Борынгы төрки халыкларның авыз иҗаты әсәрләрендә юл башы рифмасы еш кулланыла. Хәзерге вакытта юл башы А. (яки рифмасы) үзе генә түгел, бәлки юл азагы рифмасы б-н берлектә дә (еш кына горизонталь А.) очрый.

**С**андугачка җим **с**алмыйсың,
**С**айрый бирсен ди**с**еңме?
**С**агынганда юк **с**әламең,
**С**аргаеп үлсен ди**с**еңме?
(Халык җырларыннан)

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Литературный энциклопедический словарь. М., 1987.

*Х.Р.Курбатов.*

**АЛЛЮВИА́ЛЬ КӘСЛЕ́ ТУФРАКЛА́Р**, елга тугайларының аллювиаль утырмаларында ташу сулары б-н вакытлыча дымлану шартларында формалашкан туфраклар төркеме. Елгаларда су кимеп (челләдә), туфрак-грунт сулары тирән яткан очракларда атмосфера сулары исәбенә туеналар. Катнаш үләнле, сарутлы һәм чәчбайлы болыннарда, сирәк үләнле, таллы-топольле, карама, юкә һәм имән урманнарында таралганнар. Елга юлыннан еракылыгына, дуен катламының составы һәм күләменә карап, А.к.т.ның ачы, туенган һәм карбонатлы типлары оеша. Туфрак профиленең морфологик төзелеше: Ag- җирсыман, азрак тыгызланган сай катламлы кәс; А — 30–40 *см* га кадәр булган гумуслы катлам, соры һәм карасу-соры төстә, валчыклы һәм бөртекле структуралы; В — күчмә горизонт, катлам-катлам, псевдомицелий рәвешендәге карбонатлар җыелмасы (карбонатлы туфракларда); CD — төрле механик составтагы аллювий, күксел һәм күгәрек төсендәге таплар (конкрецияләр) рәвешендә җиңелчә глейләнү билгеләре. Татарстанда А.к.т. ның мәйданы 271,6 мең *га* (ТР терр-ясенең 4%), күбесенчә Мамадыш, Алабуга, Түбән Кама, Апас, Буа, Яшел Үзән һәм Биектау р-ннарында, Вятка, Зөя, Зәй, Дала Зәе, Чишмә, Ык, Казансу елгалары тугайларында урын алган. Идел һәм Кама елгалары тугайларының А.к.т., Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары булдырылганнан соң, су астында кала. Бу туфракларның туенган (ш.и. катламлы, гадәти, далаланып баручы төрләре) һәм карбонатлы типлары күбрәк таралган. Гумус микъдары 1–3 тән 6–8% ка кадәр; механик составы нигездә авыр комсыл балчык. Урман җирләре, болыннар һәм көтүлекләр буларак файдаланыла; сөрүле җирләрдә яшелчә культуралары игелә.

*Әд.:* Ф а т к у л л и н А.Ш. Почвы пойм малых рек Татарии. К., 1968.


*Ф.Г.Борһанов.*

**АЛМА́ ҮЛӘНЕ́**, к и р к а з о н (Aristolochia), кирказончалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 350 ләп төре билгеле, җир шарының тропик, сирәгрәк уртача поясларында (Австралиядән башка) таралган. ТРда бер төре — гади А.ү. (A. clematitis) барлык р-ннарда да очрый. Тугай урманнарында, елга үзәне сөзәклекләрендә үсә. Кыска шуышма тамырчалы һәм туры яки беркадәр бормалы гади сабаклы, озынлыгы 30–60 *см*. Яфраклары чиратлашкан, озын саплы, түбән өлеше кабарынкы, өске өлешендә телсыман, бәйләм-бәйләм җыелган, өске яклары яшел, аскы ягы күгелҗем төстә. Чәчәкләре яшькелт-сары, көпшәсыман, нигез өлеше кабарынкы, өстә бәйләмнәргә җыйналган кечкенә телләр рәвешендә. Җимеше — өчпочмак формасындагы орлыклар б-н тулган грушасыман эре тартмачык. Майның икенче яртысы – июньдә чәчәк ата. Орлыклары сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Үсемлекнең орлыклары һәм яшел өлешләрендә агулы алкалоид — аристолохин, дуплау матдәләре, яфракларында сапониннар, органик кислоталар, эфир мае, орлыкларында май бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе авыртуны басу, җәрәхәтләрне йогышсызландыру, тынычландыру, иммунитетны күтәрү өчен кулланыла. Йорт хайваннары өчен агулы. Декоратив үсемлек.

**АЛМА́-АТА́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Уруссу посёлогыннан 24 *км* көнбатыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2002 елда 92 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1923–25 тә нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантонына керә. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 229, 1938 дә — 262, 1949 да — 211, 1958 дә — 155, 1970 тә — 201, 1979 да — 111, 1989 да — 76 кеше.

**АЛМА́-АТАДА́ ТАТА́Р БИСТӘСЕ́**, 1860 елларда Верный (хәзер Алма-Ата ш.) ныгытмасыннан көнчыгышта урнашкан татар авылы. Татар бистәсенә Казан, Вятка, Тубыл губерналарыннан, Семипалатинск өлкәсеннән, Түмән шәһәреннән һәм Төркестаннан сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, кәсәбәчеләр килеп утырган. 1879 елда анда 600 ләп кеше яшәгән. 20 йөз башында күн (йомшак күн), сарык тиресе эшкәртү, шәм кою, йон юу, сабын кайнату һ.б. пр-тиеләр булган. Мәчет. Башлангыч мәктәп. 1950 еллардан Алма-Ата чикләрендә, хәзерге Әстерхан, Казан, Кырым, Оренбург, Уфа, Татар урамнары районында урнашкан.

**АЛМАГА́Ч** (Malus), роза чәчәклеләр семьялыгыннан яфрак коя торган агачлар һәм куаклыклар ыругы; җимеш культурасы. Татарстанда культуралы сортларның күбесе керә торган йорт А., урман А. һәм слива яфраклы яисә кытай А. төрләре киң таралган. Алмагачларның биеклеге бакчаларда 3,5–5 *м*, кыргый хәлдә 7–10 *м* га җитә. А.ның тамырлары яхшы үсә, 3 *м* га кадәр тирәнгә китә. Утыртканнан соң 4–7 елдан алма бирә башлый. 12–18 елдан соң тулысынча уңыш бирә. Чәчәк бөреләре көздән нигезләнә, майның 3 нче декадасында чәчәк ата. Чәчәкләре эре, ике җенесле, ак яки алсу төстә, чатырсыман чәчәк төркеменә 5–12 данә булып җыела. Җимешләре зурлыгы, формасы, төсе (бертөсле, төрле төсле, кызылның төрле төсмерләре) б-н аерылалар. Җәйге сортлары — августның 2 нче яртысында, көзгеләре — сентябрьнең 1 нче яртысында, иртә өлгерә торган кышкылары — сентябрьнең 2 нче яртысында, кышкылары октябрьдә өлгерә. Җәйге сортлар 2 атна, көзгеләре 1–1,5 ай, иртә өлгерә торган кышкылары 2–3 ай, кышкылары март–апрель ахырына кадәр саклана. Татарстан шартларында А. кышка чыдамлыгы һәм озак яшәве б-н (30–35 ел) аерылып тора; Татарстанның барлык җимеш мәйданының 85% ын били. Алмада 15–16% коры матдәләр (10–12% шикәр, 0,2–1,6% органик кислоталар, 10–30 мг% C витамины, пектин, дуплау матдәләре һ.б.) бар. Алмалары яңа өлгергән килеш һәм эшкәртелеп (киптереп, җебетеп, кайнатма, джем, повидло, сок, шәраб һ.б.) кулланыла. А.ның туфрак уңдырышлылыгына таләпчәнлеге уртача. Уртача һәм авыр — балчыксыл селтесезләнгән кара туфраклы, соры һәм кызгылт-соры урман, кәсле-көлсу, ачылыгы аз булган яисә нейтраль (pH 6–7) туфрак А. өчен иң яраклы дип санала. А. үстерү өчен иң уңайлы район — Идел алды тө-



Алмалар. 1. «Буй-буй әнис»; 2. «Солнцедар»; 3. «Боровинка»; 4. «Мәскәү грушовкасы»; 5. «Июльское Черненко»; 6. «Осеннее полосатое»; 7. «Башкорт чибәре».

бәге (Югары Ослан, Кама Тамагы һәм Тәтеш). А.ны ялгап үрчетәләр. Ялганма сыйфатында «Мәскәү грушовкасы», әнисләр һәм эре алмалы кытай алмагачларының чәчкеннәре алына. А., башлыча, умарта сортлары ярдәмендә серкәләнә. А. уртача дымлылыкны ярата, фәкать коры җәйләрдә генә сугаруга мохтаҗ. Дым саклау өчен көзге сугаруны ел саен уздырырга кирәк. Туфракта артык дымлылык хлорозга китерә, яфраклар вакытыннан алда коела, актив тамырлар чери. ТРда җәйге сортлардан — «Мәскәү грушовкасы», «Июльское Черненко», «Солнцедар»; иртә өлгерешле — «Буй-буй әнис»; көзге — «Боровинка», «Алсу әнис», «Волжская красавица», «Осеннее полосатое»; соң өлгерешле — «Жигулёвское»; иртә өлгерә торган кышкы — «Гади Антоновка»; кышкы — «Башкорт чибәре», «Татар ренеты» сортлары үстерелә. 3,5–4 *м* дан артык үсмәслек итеп һәм яктылык тигез төшсен өчен ботакларын пространствода тигез калдырып, системалы рәвештә А. ябалдашын формалаштырып кисеп тору кирәк. Мондый ябалдаш югары уңыш алырга һәм кышка чыдамлылыкны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Бакчада А. ны 6×6 *м* ара калдырып утырту отышлы. Төп корткычлар — алмагач чәчәкашары һәм алмагач җимешашары. Аерым елларда А. яфракларын алмагач көясе һәм парсыз ефәк күбәләге зарарлый. Авырулардан иң зыянлысы — кутыр авыруы, бигрәк тә җәй дымлы килгән елларда киң тарала.

*В.А.Наумов.*

**«АЛМАГАЧЛАРЫ́»**, татар халкының иң танылган лирик, мәхәббәт җырларыннан берсе. Җырның исеме, гомуми интонациясе татар халкының алмагач һәм алма — мәхәббәт, тынычлык, дуслык символы дигән борынгы карашларына нигезләнгән. «А.»нда бер-беренә булган мәхәббәт хисе турында җырлана. Ул Казан арты бистәләрендә киң таралган, татарлар тупланып яшәгән башка төбәкләрдә дә мәгълүм. «А.»ның көе дәртле, оптимистик рухта, күңелле яңгырый. Аны проф. скрипкачылар һәм гармунчылар да үз репертуарларына кертәләр. Җыр күп тапкырлар муз. һәм шигъри җыентыкларда басыла.

**АЛМА́ЕВ** Мәхмүт Садретдин улы (24.8.1874, Сембер губ., Сызрань өязе Сайман а. — 27.8.1907, Оренбург ш.), шагыйрь, журналист, китап басу эше белгече. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый, Истанбул ун-тында укый, Германиядә китап басу эшенә өйрәнеп кайта. Ана теленнән тыш, гарәп, төрек, рус, француз, немец телләрен яхшы белә. Казанда бертуган Кәримовлар, 1905 елдан Оренбургта «Кәримов, Хөсәенов һәм К°» ширкәте типографияләрендә эшли. 1906–07 дә Оренбургта сатирик «*Чукеч*» ж-лы мөхәррире. «Урал» г-тасын чыгаруда Х.Ямашевка булышлык итә. Мәхмүтфуад һ.б. псевдонимнар б-н чорның юмористик журналларында, «Вакыт» г-тасында язышa. Татар шигъриятендә революцион поэзия юнәлешен башлап җибәрүчеләрнең берсе. «Төрмәдән» (1907), «Агъладым», «Тиҗарга» («Сәүдәгәргә»), «Аһларым», «Дума һәм хөкүмәт» һ.б. шигырьләре мәгърифәтчелек, азатлык, гыйсъянчылык рухы б-н сугарылган. Публицистик мәкаләләрендә дөньяви фәннәр укытыла торган татар мәктәпләрен ачу мәсьәләләрен күтәрә. «Сиксән сигез фикъръ» («Сиксән сигез хикәячек», 1902), «Талчукчылар китабы» (1908) исемле җыентыклар авторы. А. турындагы язма һәм басма материаллар ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты архивында саклана.

*Әд.:* Гыймадиев Ү. Сатира коралы белән. К., 1977; Рәмиев З. Мәхмүт Алмаев // Мирас. 1998. № 4.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**АЛМА́З** (төрки — алмас, грек. adámas — җиңелмәс), иң каты минерал, табигый углеродның кристаллик төзелешле төрләренең берсе. Гадәттә, А. кристаллары төссез, сирәк очракларда — сары, коңгырт, яшел, кара һ.б. төсләрдә була. Катылыгы 10, тыгызлыгы 3,5 *г/см*³, уалучан. Кислоталарга бирешми. Табигый А.ларның үлчәме микроскопик бөртекләрдән массалары йөзәр һәм меңәр каратка җиткән (1 карат = 0,2 *г*) чагыштырмача эре кристалларга кадәр була; 100 караттан эрерәк А. кристаллары сирәк очрый. Табигый А.лар ювелир (Җир шарында чыгарылганнарының 25% ы) һәм техник төрләргә бүленә. Сәнәгатьтә синтезланган техник А.лар күләме табигый табылганнан күпкә артык. Төрле приборлар, кораллар, абразив порошок һәм пасталар, бриллиант һ.б. эшләп чыгаруда кулланыла. Татарстан терр-ясе алмаз табу перспективасы булган Идел-Вятка минераген өлкәсенә керә. Респ-каның көнчыгыш р-ннарында А. күренешләре дүртенчел системаның аллювиаль утырмаларында һәм аның иярченнәре — югары Пермь яшендәге токымнарда очрый. Көнбатышта Токмово гөмбәзе нигезендә А. эзләүдә перспектив, торбасыман типтагы («шартлау трубкалары») өч аэромагнит аномалиясе билгеле,

ә дүртенчел утырмаларда аның иярченнәре — пироп, хромшпинелид һәм пикроильменит очрый. Татарстанда билгеле А.ларның үлчәмнәре 0,3 *мм* га җиткән үтә күренмәле ак һәм саргылт төстәге кристаллардан (идеаль октаэдрлар) һәм кристалл үсентеләреннән гыйбарәт. ТРда Якутия алмазларын эшкәртүче 2 зәркәнчелек з-ды эшли.

*Әд.:* Перспективы алмазоносности юго-восточной части Волго-Уральской антеклизы // Разведка и охрана недр. 1999. № 2.

*Р.А.Хәйдәров.*

**АЛМА́ЗОВ** Җәвад Диндар улы (1916, Чистай өязе Чиртуш а. — 23.3.1979, Ташкент ш.), тел галиме, текстолог, археограф. Смоленск пед. ин-тын тәмамлый (1939). 1934–42 елларда Ташкентта Халык мәгарифе белгечләренең квалификациясен күтәрү ин-тында рус теле укыта. Бер үк вакытта Ташкенттагы Шәрекъ кульъязмаларын өйрәнү ин-тында белем ала. 1943 тә Үзбәкстан ССРның Халык мәгариф комис-ты каршындагы методик бюро директоры, 1944–46 да Ташкент финанс-икътисад техникумы директоры. Экстерн тәртибендә Ташкент юридик мәктәбен тәмамлый. 1947 дән Сәмәркәнд пед. ин-тында, 1948–53 тә Үзбәк ун-тында, 1953–55 тә Харәзем пед. ин-тында, 1958–61 дә Казан ун-тында укыта. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» поэмасын өйрәнә (поэманың 17 вариантын чагыштырып, аның критик текстын төзи һәм рус теленә тәрҗемә итә). 1960 та Мәскәүдә 25 нче Халыкара шәркыятьче галимнәр конгрессында «Кыйсса-и Йосыф — болгар-татар ядкәре» дигән доклад б-н чыгыш ясый. Бүгенге укучыга 20 йөз башында иҗат иткән татар шагыйрәсе Г.Сәмитова иҗатын ача, аның шигъри җыентыгын басмага әзерли (1965). 1961 дә Ташкентка күчеп китә. ТР Милли музее архивына соңгы елларда язган хезмәтләренең кульъязмалары кайтарылды.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Галим һәм шагыйрь Җәвад Алмаз // Мирас. 1996. № 12.

**АЛМАЛЫ́** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 25 *км* төньяктарак, Пошалым елгасының югары агымы буенда. 1930 елларда нигез салына. Кызыл Юл (1956 ның 18 июленнән — Тукай), 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1938 дә — 124, 1949 да — 152, 1958 дә — 98, 1970 тә — 56, 1979 да — 40, 1989 да — 14 кеше. 1999 ның 20 маенда авыллар исемлегеннән сызыла.

**АЛМАЛЫ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Борды елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 13 кеше (татарлар) яши. 1920 елларның 2 нче яртысында Бура-Киртә авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1929–30 елларда авылда «Алмалы» к-зы оештырыла. 1958 гә кадәр башлангыч мәктәп эшли. 1950 дән А. — «Кызыл Шәрекъ», 1958 дән — «Якты Йолдыз» к-зларында, 1991 дән — «Таң» а.х. артеле составында. 1930 га кадәр авыл ТАССРның Чаллы кантоны Әлмәт волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1938 дә — 114, 1949 да — 94, 1952 дә — 119, 1958 дә — 103, 1970 тә — 113, 1979 да — 72, 1989 да — 23 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**АЛМАТАВИ́** Лотфулла, к. *Өммәти-Алматави.*

**«АЛМАШКА́»**, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журнал. РКП(б) ҮКнең Себер бюросы органы. 1922 елда Новониколаевск (хәзерге Новосибирск) шәһәрендә 2 айга 1 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Г.Даутов, А.Курмаш, Ф.Таипов, М.Уразмөхәммәтов һ.б. авторларның язмалары басыла. Илдәге һәм чит илләрдәге сәяси хәлләрне яктырта, игътибарын аеруча профсоюз һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегенә юнәлтә, аң-белем тарату проблемаларын күтәрә. Ш.у. журналда яшь татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре дә басыла.

**«АЛМАШКА́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВЛКСМ ҮКнең Свердловск өлкәсе буенча оештыру бюросы органы. 1932 елның 22 ноябреннән 1935 кә кадәр Свердловск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. 1934–35 тә «Алга» исемендә чыга.

**АЛМАШЛЫ́К**, объектив чынбарлык күренешләрен атамыйча, бары тик аларга ишарәли торган сүз төркеме. А.ларның конкрет лексик эчтәлекләре юк. Аларның нинди реаль чынбарлык күренешләренә ишарә итүләре сөйләм барышында, контекстта гына ачыклана. А.ларны куллану кирәкмәгән кабатлаулардан коткара, сөйләмне кыска, ачык, аңлаешлы итә. Кайсы сүз төркеме б-н мөнәсәбәттәш булуларыннан чыгып, А.лар исем А.ларына (мин, әллә нәрсә), сыйфат А.ларына (шушы, әллә нинди), сан А.ларына (ничаклы, берничә), рәвеш А.ларына (ничек, кайчан), фигыль А.ларына (итү, нитү, нишләү, нихәл итү), теркәгеч А.ларына (кемнең, шуның), кисәкчә А.ларына (әнә, менә, бары) бүленәләр.

Татар телендә А.лар мәгънәләре буенча зат (мин, сез), күрсәтү (бу, андый), сорау (кем, кайсы), билгесезлек (кемдер, каядыр), юклык (беркем, беркайда), билгеләү (барлык, һәрбер) А.ларына бүленәләр.

*Әд.:* Татар грамматикасы. М.–К., 2002. Т. 2.

**АЛМЫ́Ш** (Алмас, ислам динен кабул иткәннән соң — Җәгъфәр бине Абдаллаһ) (9 йөз ахыры — 10 йөз уртасы), Идел буе Болгар иле илтәбәре (идарәчесе). Сәлки (Абдаллаһ) улы. 10 йөз башында Урта Идел буенда Хәзәр каганлыгына буйсынган өлкә идарәчесе. 913/14 елда Гарәп хәлифәлегенә караган Хәзәр (Каспий) диңгезе буе җирләренә һөҗүм иткән русларны җиңә. Таркау яшәгән төрки кабиләләрне болгарлар тирәсенә туплап, мөстәкыйль дәүләт булдырырга нияте барлыгы ачыклангач, Хәзәр каганлыгы идарәчеләрендә канәгатьсезлек туа. Каган кичекмәстән А.ның улын үз сараена тотык итеп, кызын хатынлыкка ала. А. Болгар дәүләтенең мөстәкыйльлеген ныгыту чараларын күрә, Урта Азия илләре, угыз кабиләләре берлеге б-н илчелек-арадашлык элемтәләре урнаштыра. Угызлар берләшмәсендә йогынтысы зур булган бер кабилә башлыгы Әтрәккә кызын (башка мәгълүматлар буенча сеңлесен) кияүгә бирә. 921 дә хәлифәлек башкаласы Багдадка хәлифәнең ислам дине белгечләрен җибәрүен һәм кальга төзергә ярдәм итүен үтенеп илчеләрен җибәрә (к. *Бохарага* һәм *Багдадка Алмыш илтәбәр илчелеге*). Аңа җавап итеп, 922 дә Идел буе Болгарына хәлифәлек илчеләре килә (к. *Болгарга әл-Моктадир илчелеге*). Бу вакыйганы А. үз хакимиятен ныгыту һәм ислам дине йогынтысын Урта Идел төбәгендә киң җәелдерү максатында файдалана. 930 елларда А.ның улы да илчелек б-н Багдадта булып кайта. Кайбер Шәрекъ авторлары язганча (мәс., әл-Мәсгуди), А. илтәбәр 944 елга кадәр идарә иткән.

*Әд.:* К о в а л е в с к и й А.П. Книга Ахмеда ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков, 1956; С м и р н о в а О.И. К имени Алмыша, сына Шилки, царя Булгар // Тюркологический сборник. 1977. М., 1981; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**АЛНА́Ш РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көньяк өлешендә. 1929 елда оештырыла. Мәйданы — 896 *км*². Үзәге — Алнаш авылы (Ижевскидан 128 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 22258 кеше (2002), ш.и. татарлар — 688 кеше. Район үзәгендә, ш.у. Татар Тоймабашы, Игенче, Татар Көҗәге, Бакыр-Завод авылларында яшиләр. Әсән посёлогында агротехника техникумы бар. Элек Татар Тоймабашы һәм Татар Көҗәге авылларында татар мәктәпләре эшләгән. Хәзерге вакытта Татар Тоймабашы авылында 1865 тә төзелгән мәчет яңадан торгызыла. 1993 тән татар милли-мәдәни оешмасы, Бакыр-Завод авылында «Умырзая» ансамбле эшли.

**АЛОКА́ЗИЯ**, а р у м (Alocasia), ароидчалар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Күпьеллык үлән. 70 ләп төре билгеле. Туган җире — Азия һәм Американың тропик киңлекләре. Яфраклары ачык яшел төстә, эре, калкансыман; озын сабаклы. Чәчәкләре вак, чәкәндә тупланган; согы агулы. ТРда А. декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә: Сандера А.се (A. san deri hort), Амазонка А.се (A. amazonica hort) һәм җирән-кызыл А. (A. cuprea C. Koch). Соңгысының яфраклары түгәрәк, җирән төстә, ялтыравыклы, аскы яктан — карасу кызыл төстә. Тамыр бүлбесеннән, үрентедән, тамырчаны бүлеп һәм орлыклардан үрчетелә. Яктылык яратучан, әмма кояш кызуыннан шиңүчән, культурада таләпчән түгел. Туган җирендә кайбер төрләренең бүлбеләрен, мәс., тамырчалы А.нең (A. mak rorrhiza), бәрәңге шикелле, пешереп яки кыздырып аш-суда кулланалар. Киптерелгән бүлбеләреннән он ясыйлар. Халык медицинасында какырык чыгару, бәвел кудыру, аппетитны ачу, ашказаны-эчәк системасы эшчәнлеген яхшырту өчен файдаланыла.

**АЛО́Э**, й ө з ь я ш ә р (Aloe), лаләчәләр семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Күпьеллык үләннәр яки агачсыман суккулентлар. Берничә йөз төре билгеле. Туган җире — тропик Африка һәм Көньяк Американың коры өлкәләре. Яфраклары итләч, күп төрләренеке балавыз куныклы, кырыйларында тешчекләре яки энәләре бар. Чәчәкләре көпшәсыман яки

тар кыңгыраусыман, кызыл, кызгылт сары яки сары төстә, нектарга бай себеркәчле яки башаксыман чәчәк төркемендә тупланган. Бүлмә шартларында бик сирәк чәчәк ата. ТРда агачсыман А. (A. arborescens), чәнечкеле А. (A. aristataaa), чуар А. (A. variegata), сабын А. (A. saponaria) төрләре декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Орлыклардан һәм сабаклы үрентедән үрчетелә. Яктылык яратучан, әмма туры кояш нурларыннан шәлперәючән. Яфракларында биоген матдә — алоин бар. Халык медицинасында файдаланыла: яфракларының согы яки сыек измәсе яралар, пешкән урыннар, чуаннарны тиз төзәтергә, күгәргән урыннарда канны таратырга, тиредәге бетчәләрне бетерергә ярдәм итә, томауны дәваларга мөмкин. А. согы (сабур) эч йомшарту сыйфатына ия. А. агулы газлар тәэсирен нейтральләштерә.

**АЛПАВЫ́Т** (алпагыт, алпаут, олбуд), төрки хәрби-социаль атама. А. «алып» (батыр, пәһлеван кеше) тамырына кушымча өстәлеп ясалган. 6–13 йөзләрдәге төрки дәүләтләрдә йомышлы хәрби катлау атамасы. 13–16 йөзләрдә атаманың мәгънәсе берникадәр үзгәрә: Казан ханлыгында ул «хан киңәшчесе»н, Касыйм ханлыгында «югары хәрби дәрәҗә»не, «яугир» төшенчәләрен белдерә. «Батыр» мәгънәсендәге әйтелеше рус елъязмаларында теркәлгән. 16–17 йөзләрдә, татар ханлыкларын Рус дәүләте яулаганнан соң, ул татар эре җирбиләүчеләре атамасына, русның «помещик» (к. *Алпавытлар*) сүзе синонимына әверелә. Шул мәгънәдә А. Идел һәм Урал буенда яшәүче күпчелек башка халыклар теленә дә кергән.

*Әд.:* С е в о р т я н Э.В. Этимологический словарь тюркских языков. М., 1974; А х м е т ь я н о в Р.Г. Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1989.

*И.Л.Измайлов.*

**АЛПАВЫ́Т КРӘСТИЯННӘРЕ́**, Россиядә 1861 елгы Крәстиян реформасына кадәр феодалларга беркетелгән крепостной крәстияннәр катлавы. Казан төбәгендә 16 йөзнең 2 нче яртысында алпавытлар катлавы б-н бергә барлыкка килә. Баштарак А.к. бу төбәктә бик аз санда була, йомышлы татарлар күпчелек очракта андый хокукка ия булмыйлар (к. *Крепостной хокук*). Алпавытларның күпчелеге үз крепостной крәстияннәрен Россиянең үзәк өлкәләреннән монда күчереп утырта. Качкын крәстияннәрне үз җир биләмәләренә кабул итү очраклары да еш була. 1646 га караган *писцовый кенәгәләрдән* күренгәнчә, Зөя өязендә 498 татар алпавытыннан 378 енең, Казан өязендә 619 дан 449 ының крепостной крәстияннәре булмаган, калган алпавытлар барысы бергә 1672 А.к.нә ия булган. 17–18 йөзләрдә Казан төбәгендә алпавыт җир биләмәләре арта бара. 1760 елларда Казан губернасында 45,8 мең крепостной крәстиян теркәлгән (губерна крәстияннәренең гомуми санының 17,4%). 1724 тә крепостной крәстияннең җан башыннан түләү салымы 74 тиен була. 18 йөзнең 2 нче яртысында алпавытка эшләү көннәре (барщина) атнага 4–5 көн тәшкил итә. Казан губернасы алпавытлары арасында А.к.н кыйнау-җәберләү, аларны талау б-н дан тотучылар да очрый. Мәс., алпавыт Нармоцкий, барщинада бушлай эшләтүдән тыш, һәр крәстияннән 30 сум акча алган; Тәтеш алпавыты Страхов 1831 дә 4 кешене җәзалап үтергән. Алабуга алпавыты Салыков та ярымач хәлдә яшәткән крәстияннәрен камчылап җәзалаган. Крәстияннәрнең үз җирләре Казан төбәгендә ир заты башына 1,5 дис. дән 3 дис. гә кадәр була. 1835 тә Казан губернасында 96219 һәм 1858 дә 103088 А.к. теркәлгән. Губернаның эре җир биләүчеләре (500 һәм аннан артыграк А.к. тотучылар) 19 йөздә 3,5% чамасы була. А.к.нең 86% барщина тәртибен үти. 19 йөзнең 50 елларында һәр ир затыннан җыеп алына торган оброк күләме 6 сумнан 15 сумга күтәрелә. А.к. Казан, Лаеш, Зөя, Спас, Чистай, Тәтеш өязләрендә күбрәк теркәлгән. 1861 елгы реформа нәтиҗәсендә крепостной крәстияннәр үз иркенә чыгарыла (к. *Крәстиян реформасы*).

*Әд.:* К а б у з а н В.М. Крепостное крестьянство России в XVIII – 50 гг. XIX в. Численность, состав и размещение // История СССР. 1982. № 3.

**АЛПАВЫТЛА́Р**, Россиядә 15 йөз ахыры — 20 йөз башында эре җирбиләүче феодаллар. Русча атамасы (помещик) дәүләт мәнфәгатенә үтәлгән хезмәт өчен җир биләмәләре (поместье) бүлеп бирүдән килеп чыккан. 15 йөз ахыры — 20 йөз башында А. дип, нигездә, *дворяннар* аталган. Патшаның 1714 елда чыгарылган «Бер варислылык турындагы указ»ыннан соң («Указ о единонаследии») дворяннарның нәселдән килгән җир биләмәсе (вотчина) б-н хезмәте өчен бирелгән җир биләмәсе берләштерелә, утар (имение) дип атала. Шунлыктан 18–19 йөзләрдә «поместье» атамасы кайбер очракларда утар мәгънәсендәге синоним буларак та кулланыла. Поместьега хуҗа булу өчен дәүләт хезмәтен башкару таләп ителгән. 18 йөз башларына чаклы утарларда даими яшәүче А. булмаган. Дворяннар иреклеге турында манифест игълан ителгәч кенә (1762), А., үз җир биләмәләренә тулы хуҗа хокукы алып, даими рәвештә анда яшәү һәм үз хуҗалыгында а.х. эшләре б-н шөгыльләнү мөмкинлеге алган. А.ның бер өлеше кәсәбәчелек б-н шөгыльләнә, үз мануфактураларын булдыра. 1766 елдан башланган җир биләмәләрен рәсмиләштерү тәртибе («генеральное межевание») А.ның җиргә хуҗа булу хокукын ныгыта (ул тәртип үзгәрешсез диярлек 1917 елга чаклы саклана). А.ның милек-биләмәләре бер-берсеннән нык аерыла. 19 йөзнең урталарына кадәр утарларның кыйммәте андагы эшкә яраклы кешеләр исәбе б-н бәйле. 10 нчы ревизия (1859–60) күрсәткечләре буенча Россиядә А.лар саны 103,2 мең, аларга беркетелгән «холоп»лар 10,7 млн. кеше булган. 100 дән ким крәстияне булган А. гомуми санның 41,6% тәшкил иткән, алар өлешенә барлык крепостнойларның 3,2% туры килгән. 1000 нән артык крәстияне булган А. гомуми санның 3,8%ын тәшкил иткән, алар карамагында җәмгысе 43,7% крепостной исәпләнгән. Крепостнойлар тоту тәртибе бетерелгәннән соң, А.ның төп байлыгы җир биләмәсе булып кала һәм ул әкренләп кимүгә таба бара. 20 йөз башы әдәбиятында Россиядә эре җирбиләүче А.га шундый ук җир биләмәләренә ия булган сәүдәгәр һәм кулаклар да кертелә. Урта Идел буен Рус дәүләте яулап алганнан соң, татар феодаллары эре җир биләү, крәстиян тоту хокукыннан мәхрүм ителә. Алар үз өлешләренә туры килгән «бер йорт», «бер гаилә» җирен үзләре яки кеше яллап эшкәртергә тиеш булалар. Фәкать Рус дәүләтендә хезмәттә булган *йомышлы татарлар* б-н чик буе сагында казак офицеры хезмәтен үтәгән мишәрләр генә А. катлавына керү һәм җир биләмәсе алу хокукына ия булганнар. 1861 елгы *Крәстиян реформасына* кадәр Урта Идел буенда барлыгы 3018 А. биләмәсе теркәлгән (ш.и. Казан губ. 853, Сембер губ. 1363, Самара губ. 802). Һәр алпавыт гаиләсенә Казан губернасында — уртача 643,4 дис., Сембер губернасында — 1311,7, Самара губернасында 2214,9 дис. җир туры килгән. 1858 дә Казан губернасында А. крәстияннәре катлавына керүче 212209 кеше теркәлгән, шуларның күпчелеге рус кешеләре. А. җир биләмәләрендә «барщина» системасы өстенлек итә. 1861 елгы реформадан соң, Урта Идел буенда А. элек крепостной крәстияннәр эшкәрткән һәм файдаланган җирләрнең 583,6 мең дис. үз карамакларында калдыралар. 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң дворяннар биләгән җирләр дәүләт милкенә күчерелә, А. катлавы бетерелә.

*Әд.:* Крестьянское землевладение Казанской губернии. К., 1909; С м ы к о в Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма (социально-экономическое исследование). М., 1984; З а г и д у л л и н И.К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. К., 2000; Казанское дворянство 1785–1917 гг.: Генеалогический словарь. К., 2001.

**АЛПА́К**, сугышчы баш киеме. Металлдан яки калын күннән эшләнгән. Күпчелек очракта очлыгы тоташ металлдан булып, түбә тирәсе аерым металл кисәкчәләреннән ясалган, аңа муен тирәсен каплап торган вак боҗралардан торган көбә эленә. А. астыннан йомшак тула яки сырма башлык киелә. Идел-Чулман буйларында б.э.к. 1 нче меңьеллыктан башлап күннән эшләнгән А. кигәннәр. 1 нче меңьеллык урталарында металл А.лар кулланыла башлый. 8–13 йөзләрдә Идел буе Болгар дәүләтендә түбә очы шар рәвешле А. гамәлдә була, аларның очлык башына әләм сабы сыярлык тишек ясала. 13 йөздә борын өстен каплаучы яки тулаем йөзне каплаучы А.лар да эшләнә. 13–15 йөзләрдә мисырлылар үрнәгендә эшләнгән — баш түбәсе күпкатлы булган, корыч очлык б-н тәмамланган, кечкенә козырёклы, бит, колакны тар корыч пластинкалар б-н каплый торган А. кулланылган. Аңа корыч боҗралы көбә киелгән (мондый А.лар рус елъязмаларында «мисюрка» («Мисыр» сүзеннән ясалган) дип аталган). 16 йөздә тоташ корычтан коелган биек А.лар (русларда «ерихонка» дип атала) яки калын сырма, күн бүрек өстенә тар калай пластинкалар беркетеп эшләнгәннәре дә гамәлдә була. А. сугышчы өчен корал б-н бердәй кирәкле әйбер саналган.

*И.Л.Измайлов.*

**«АЛПАМША́»**, гомумтөрки дастанның татар әкияте рәвешендәге варианты. Урта гасыр-

лар башыннан мәгълүм. Дастанның борынгы грек эпосы «Одиссея» сюжетына якын булган кунграт версиясе иң борынгы дип санала. «А.» сюжетының килеп чыгышы (ирнең озакка сузылган сәяхәттән соң өенә әйләнеп кайтуы) Көньяк Себер һәм Алтай б-н бәйле дип фаразлана. Дастанны Урал һәм Идел буйларына күченгән дәвердә кыпчак кабиләләре алып килгән дип уйланыла (бу хакта дастанның татар һәм башкорт версияләре сөйли). Сюжеты һәм төп геройлары бер-берсенә охшаш «А.» турындагы эпик хикәятләр урта гасырларның беренче яртысыннан бүгенге көннәргә кадәр төрки халыкларда таралган: үзбәкләрдә «Алпамыш», казакъларда «Алпамыс», алтайлыларда «Алып-Манаш» һ.б. Әкияткә якын вариант Идел буе татарларында, төрки эпоска якынрак вариант Себер татарларында тулырак сакланган. «А.»га архаик сюжет, шигырь б-н прозаның аралашып килүе хас. Дастанның төп темасы — татулык, гаделлек һәм туган ил-җирнең азатлыгы өчен көрәш. Гомуми эчтәлеге буенча «А.» Идел буе болгарлары, Идел һәм Урал буе татарларының алыплар турындагы легендаларына якын. Гасырлар дәвамында яшәп килгән бу дастан, эпик үзенчәлекләрен югалта барып, халык әкиятләренә якынлашкан. Дастан героеның образы әдәби әсәрләрдә, аеруча поэзиядә чагылыш таба.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Жирмунский В.М. Сказание об Алпамыше и богатырская сказка. М., 1960; Урманчеев Ф. Легенда о булгарских богатырях и сказание об Алпамыше // Советская тюркология. 1980. № 2.

*Ф.И.Урманчеев.*

**АЛПА́РОВ** Гыйбад (Гыйбадулла) Хәбибулла улы (14.11.1888, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Корманай а. — 31.7.1936, Казан), тел галиме, проф. (1932). «Галия», «Госмания» мәдрәсәләрен, Казан татар укытучылар мәктәбен, Көнчыгышны өйрәнү ин-тын (1932, Ленинград) тәмамлый. 1914–18 елларда Карамалы авылында китапханә мөдире, 1919–21 дә Уфа шәһәрендә укытучы; язмалары татар газеталарында басыла. 1921–24 тә Ташкентта: «Чулпан» ж-лы сәркәтибе, «Ак юл» г-тасы хезмәткәре. 1926–27 дә ТАССР Мәгариф халык комис-ты каршындагы Академүзәк сәркәтибе, 1932 дә Казан пед. ин-тының татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире. Татар теле грамматикасы өлкәсендә «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) дигән беренче фундаменталь фәнни хезмәт авторы. Бу хезмәттә А. сүз төркемнәренең үз классификациясен бирә, килеш категориясенә, суффикс, иярчен җөмләгә карата яңача караш белдерә. А. тел белеме мәсьәләләрендә Н.Я.Маррга ияреп, татар тел белгечләреннән беренче булып тел белеме б-н фәлсәфәнең үзара бәйләнешен таный. «Яңалиф»не камилләштерү юнәлешендә эшли. Урта мәктәпләр өчен татар теле дәреслекләре авторы.

Хезм.: Хәреф вә имламыз. Әлифба тарихы. Иске язулар. К., 1912; Инструкцияләр җыентыгы. К., 1926 (гарәп графикасында); Татар теленең имла сүзлеге. К., 1927 (гарәп графикасында); 10 ел эчендә татар теле // Мәгариф. 1927. № 10–12; Сайланма хезмәтләр (татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре). К., 1945.

*Әд.:* Хаков В.Х. Күренекле тел галиме: (Г.Алпаровның тууына 110 ел тулу уңаеннан) // Мәдәни җомга. 1998. 25 дек.; Ганиев Ф.А. Г.Алпаров (100 лет со дня рождения) // Советская тюркология. 1989. № 4.

*Ф.Ә.Ганиев.*

**АЛПА́РОВ** Үзбәк Гыйбад (Гыйбадулла) улы (11.9.1914, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Корманай а. — 13.8.2003, Казан), төзүче-инженер, ТАССР һәм РСФСР ның атказ. төзүчесе (1968, 1975). Г.Х.Алпаров улы. Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1936), Казан шәһәренең проектлау оешмаларында эшли. Бөек Ватан сугышы елларында аэродромнар һәм юллар төзелешен проектлаштыруда катнаша. 1945–51 елларда Хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советының архитектура-планлаштыру остаханәсендә төзүче-инженер. 1951–64 тә




Ү.Г.Алпаров. КПССның Татарстан өлкә комитеты бинасы (төньяк блок). Казан. 1979–81 (Г.М.Пичуев б-н берлектә). Хәзер ТР Дәүләт Советы бинасы.

«Татпроект» конторасы җитәкчесе, 1964–85 тә «Татаргражданпроект» ин-ты директоры, 1985–92 дә «Казгражданпроект» ин-тында юллар һәм корылмалар секторы җитәкчесе. А. проектлары б-н 1950 еллар ахыры — 1960 еллар башында Болак ярлары, Казан Кремле төзекләндерелә, Актаныш, Яңа Чишмә р-нныры үзәкләрендә, Чаллының көньяк-көнбатыш өлешендә корылмалар төзелә. А. җитәкчелегендә Казанда *Үзәк стадион*, Үзәк универмаг, Цирк, Яшьләр үзәге (1978), КПССның Татарстан өлкә ком-ты бинасының төньяк блогы (1979–81, Г.М.Пичуев б-н берлектә), Казанның торак кварталлары һ.б. төзелеш проектлары эшләнә. СССР Архитекторлар берлеге әгъзасы (1940). СССР МС бүләге лауреаты (1976). Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе», Халыклар Дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Г.Х. Алпаров.



Ү.Г. Алпаров.

**«АЛСУ́»**, к. *«Алсу» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы.*

**«АЛСУ́» ӘЛМӘ́Т ОЕ́К-ОЕКБА́Ш ФА́БРИКАСЫ**. Оек-оекбаш, трикотаж әйберләр һәм эш киемнәре җитештерүче предприятие. Әлмәт шәһәрендә урнашкан. 633 кеше эшли (2006). Оек-оекбаш ф-касы 1979 елда төзелә башлый, 1985 тә беренче продукциясен чыгара. 1989 дан Татарстан сәүдә-сәнәгать трикотаж берләшмәсе, 1991 дән «Алсу» аренда фирмасы, 1994 тән АҖ һәм хәзерге исемдә. Пр-тие составында төп җитештерү цехлары (бәйләү, тегү, эшләп чыгару) һәм ярдәмче цехлар (ремонт-механика, ремонт-төзелеш, энергетика, электр, автотранспорт һәм җылыту) эшли. Рәсем-бизәкләрне эшләү, әйберләрне модельләштерү һәм конструкцияләү б-н пр-тиенең үз бизәү сәнгате лабораториясе шөгыльләнә. Ел саен 110 га кадәр яңа модель үзләштерелә. Әйберләр «Носкофф» сәүдә маркасы б-н чыгарыла. 1990 да җитештерүнең күләме 25,8 млн. пар, 2005 тә 10,3 млн. пар оек-оекбаш тәшкил итә. Чимал б-н тәэмин итүче берләшмәләр: «Чабаксар киҗе-мамык комбинаты» АҖ, «Химволокно» (Курск ш.), «Кузбасслегпром», «Ротанг» (Латвия), «Илеритекстиль» (Төркия) ҖЧҖ. Продукциясе РФ һәм якын чит илләрдә сатыла. «Алсу» — «Бирмингем факелы» (АКШ, 1995), «Алтын пальма» (Франция, 1997), «Алтын Бөркет» (АКШ, 1997), «Сәнәгать лидеры-98» (Австралия) халыкара призларына лаек була, «Татарстан республикасының иң яхшы товарлары», «Россиянең иң яхшы 100 товары» (2004, 2005) конкурслары лауреаты. Пр-тие җитәкчеләре: А.В.Яфаркин



«Алсу». Тегү цехы.

(1978–88), Ф.И.Ургачев (1988–89), Р.А.Гарипов (1989–2001), Ш.Ф.Нәфыйков (2001–2002), Р.М.Шәвәлиев (2002–2005), А.З.Габдрахманов (2005 тән).

*Г.Я.Мәүлетова.*

**«АЛТА́ЙН САЙ́Н СҮМӘ́»**, Себер татарларының борынгы героик эпосының бер үрнәге. Дастанның килеп чыгышы һәм формалашуы Алтай героик эпосы б-н бәйле дип фаразлана. Конкрет урынның атамасы — Алтаин һәм төрки-монгол мифологиясендә, героик-эпик традицияләрендә киң таралган «намуслы», «хакимияткә ия», «илаһи» мәгънәсендәге саин сүзләреннән ясалган батыр исеме шуны күрсәтә. Төрки эпос традицияләре өчен ят булган күренешләр «А.С.С.»дә юк диярлек. Аның сюжетында борынгы героик-мифологик мотивлар, ш.у. баласызлык мотивы (герой корбан китергәннән һәм картаеп килгән ата-ана догаларыннан соң гына туа) саклана. Дастанда хәзерге караш өчен бик үк аңлаешлы булмаган мотив бар —

ата-ана үзенең озак еллар көтеп алган баласын үтерергә омтыла. Егетне аның ышанычлы батыр аты гына коткарып кала, һәм ул өеннән китәргә карар кыла, ләкин әлегә исеме юклыгы тоткарлый. Шуннан соң атасы аңа Алтаин Саин Сүмә исеме куша. Егет кызын кияүгә бирергә әзерләнгән хан янына килеп чыга. Ярышларда башка көндәшләреннән көчлерәк булып, Алтаин Саин Сүмә хан кызына лаек була. Соңрак «А.С.С.» герое хәшәрәт җан — җиде йөз *Җилбегәннәр* анасы б-н көрәштә ярдәм иткән һәм кыяфәте б-н үзенә охшаган Эне Солым б-н очраша. Рәхимсез сугышларда бик күп җәрәхәтләр алып, алар һәлак булалар. Әмма үз атлары аларны терелтә. Дастан геройларның туйлары б-н тәмамлана.


*Әд.:* Р а д л о в В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. СПб., 1872. Ч. 4; У р м а н ч е е в Ф. Героико-архаическое сказание «Алтаин Саин Суме» // Советская тюркология. 1984. № 2. *Ф.И.Урманчеев.*

**«АЛТА́Й»**, иҗтимагый-сәяси газета, «*Корылтай*» г-тасының дәвамчысы. Казандагы *Мөселманнар комитеты* органы. 1918 елның 8 апреленнән 23 маена кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барлыгы 13 саны чыга. Мөхәррирләре Г.-Г.Баттал, Н.Мохтаров. Г.Баттал, Г.Гобәйдуллин һ.б. авторларның язмалары басыла. Газета федераль-демократик республика төзү һәм милли-мәдәни автономия идеяләрен яклый. «А.» Русиядә милли сәясәт мәсьәләләрен, мөселман хәрби частьләрен оештыру проблемаларын, Беренче бөтендөнья сугышы фронтларындагы хәлләрне яктырта. Рубрикалары: «Сәяси яңалыклар», «Сугыш хәрәкәтләре», «Безнең тормышыбыздан».

**АЛТА́Й ТЕЛЛӘРЕ́**, Алтай телләре гаиләсенә кергән, сүзлек составлары һәм грамматик төзелешләре охшаш үзенчәлекләргә ия булган төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләренең гомуми атамасы. А.т. нең килеп чыгышы һәм тугандашлыгы турында төрле фаразлар яши. Ләкин баба теленең анык системасы ачыкланмау сәбәпле, А.т. арасындагы генетик кардәшлек әлегә дәлилләнеп җитмәгән. Кайбер галимнәр А.т. нә япон һәм корея телләрен дә кертә. А.т.нә кагылышлы фаразлар Г.И.Рамстедт, Н.Н.Поппе, Е.Д.Поливанов, В.Л.Котвич, М.Рясянен, Җ.Г.Киекбаев һ.б.ның хезмәтләрендә урын алган. А.т. лексикасында, сүзнең фонетик төзелешендә (фонетик тәңгәллек, сингармонизм) һәм күп кенә грамматик категорияләрнең (агглютинация, тартым, җөмлә төзелеше) уртаклыгында типологик охшаш билгеләр күзәтелә. А.т.ндә сүзнең тамыры тотрыклы аваз составы һәм мөстәкыйльлеге б-н аерылып тора. Сүз ясалышы һәм үзгәреше тамырга бердәй кушымчалар ялгау юлы б-н (*агглютинация*) башкарыла. А.т. өчен алкушымчалар характерлы түгел. Барлык А.т.нә дә диярлек сингармонизм хас. А.т.ндә род категориясе юк, аларның күпчелегендә тартым категориясе бар. Затланышсыз фигыль формалары (сыйфат фигыль, хәл фигыль һ.б.) еш кулланыла. А.т.ндә ия — җөмлә башында, хәбәр җөмлә ахырында килә. Җөмләдә сүз тәртибе гомуми кагыйдәләргә нигезләнә: ияреп килүче сүз алдагы сүзгә бәйле. Шуңа күрә А.т.ндә предлоглар түгел, ә бәйлекләр файдаланыла. Алтай халыкларының телен, тарихын, этнографиясен һәм фольклорын өйрәнә торган фән тармагы алтаистика дип атала. (Ш.у.к. *Төрки телләрнең генеалогик классификациясе*).

*Әд.:* Р а м с т е д т Г.И. Введение в алтайское языкознание. Морфология. М., 1957; К о т в и ч В.Л. Исследование по алтайским языкам. М., 1962; Киекбаев Дж. Г. Введение в урало-алтайское языкознание. Уфа, 1972; Б а с к а к о в Н.А. Алтайская семья языков и её изучение. М., 1981. *В.Х.Хаков.*

**АЛТА́Й ТОКЫМЛЫ́ САРЫКЛА́Р** (беренче атамасы — себер рамбульесы), йон һәм ит бирүче нечкә йонлы токым. 1930–48 елларда катлаулы, күп тапкыр кушулар юлы б-н чыгарылган. Эре, нык бәдәнле, күп йон бирүче сарыклар. Тәкәләрнең терелтә авырлыгы — 90–140 *кг*, сарыкларның — 60–70 *кг*.



Алтай токымлы тәкә.

Тәкәләрдән 17–18 *кг* (юганнан соң 6,8–7,2 *кг*), сарыклардан 7,8 *кг* (юганнан соң 2,6–3,1 *кг*) йон алына. Йон бөртегенең озынлыгы 9,5–10 *см* (тәкә) һәм 8–9 *см* (сарык). Үрчем 130–170%. Бәрәннәре — яшәүгә тиз җайлашуы, сарыклар күп сөтлелеге б-н аерыла. ТРда а.х. пр-тиеләрендә үрчетелә торган А.т.с. 14% тәшкил итә. 2004 елның 1 гыйнварына ТРда 3700 баш А.т.с. исәпләнә. Әгерҗе, Актаныш, Зәй, Минзәлә, Мөслим р-ннарында үрчетелә. 2007 ел башына А.т.с. 1133 баш исәпләнә.

*Әд.:* Ф а з у л ь з я н о в А.Х. Овцеводство в условиях интенсивного земледелия. К., 1974; Овцеводство. М., 1983; Ф а з у л ь з я н о в А.Х., М и н к и н А.Ф. Интенсификация овцеводства Татарии. М., 1991. *Ә.Х.Фазылҗанов.*

**АЛТА́Й** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 65 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасының уң кушылдыгы Вятка елгасы бассейнында. 2002 елда 15 кеше (татарлар) яши. 1924–25 тә Кирлегәч авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала, ТАССРның Бөгелмә кантоны Чыршылы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 210, 1938 дә — 207, 1948 дә — 241, 1958 дә — 181, 1970 тә — 138, 1979 да — 75, 1989 да — 22 кеше.

**АЛТЕ́Й**, к. *Песи борчагы.*

**«АЛТЫ́ БАРМА́К КИТАБЫ́»**, төрек галиме Мөхәммәд ибне Мөхәммәд Чыкрыкчызадәнең (вафаты 1623) дини-дидактик әсәре. Китапның исеме авторның кушаматы Алты Бармак б-н бәйле. Шул исем б-н әсәр киң таралыш алган, автор биргән исем («Дәлаил-нөбүвәт Мөхәммәди вә шәмаилел-фөтүвәт Әхмәди» — «Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә вә Әхмәднең затлы сыйфатларына дәлилләр») әкренләп онытылган. Китап фарсы галиме Мөхәммәд әл-Фәрәхинең (Муин-Мискиннең) «Мөгариҗ ән-нөбуа» («Пәйгамбәрлек баскычлары») исемле трактаты нигезендә язылган. Әсәр кереш өлештән, дүрт бабтан һәм хатимәдән (йомгаклау бүлеге) тора. Кереш өлештә Аллаһка, Мөхәммәд пәйгамбәргә традицион мактау сүзләре әйтелә, Коръәннән айәтләр, хәдисләрдән өзекләр кителә. Төп текстта пәйгамбәрләр тормышыннан вакыйгалар сөйләнә, сәхабәләрнең һәм авторга замандаш галимнәрнең Мөхәммәд пәйгамбәр турында, аның кылган гамәлләре хакында бәяләмәләре, уй-фикерләре санап кителә. Китап ш.у. тарихтан, педагогика һ.б. фән тармакларыннан да күп кенә мәгълүматларны үз эченә ала. 18–19 йөзләрдә «А.б.к.»ның кульязма нөсхәләре Идел буе, Урал төбәкләрендә киң таралган була. Беренче типографик басмасы Казанда 1861 елда дөнья күрә, аннан соң да күп мәртәбәләр басыла.

*Әд.:* Г а з и з Г., Р ә х и м Г. Татар әдәбияты тарихы. К., 1922; Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 т.; Г ә р ә е в Ф.М. «Алты бармак» китабы // Гуманитарные науки: проблемы и аспекты изучения. К., 1997; К а т а н о в Н.Ф. Алты бармак китабы (книга Шестипалого) // Деятель. 1899. № 10. *Ф.М.Гәрәев.*

**АЛТЫ́Н** (лат. Aurum), 1) хим. элемент (Au); 2) алтын һәм кушылмалардан — көмеш, бакыр һ.б. торган минерал. 40 лап минерал билгеле. А. ачык сары, тонык сары, кызгылт-сары, яшькелт төстә. Бөртекләр, тәңкә, тоташ массалар һ.б. хасил итә. Катылыгы 2–3, тыгызлыгы 15,6–18,3 *г/см*³. Азот һәм тоз кислотасы катнашмасында, ш.у. цианид кислотасында эри. Тузансыман (5–50 *мкм*), вак (0,05–2 *мм*) һәм эре (2 *мм* дан артыграк, ш.и. самородок) төрләре бар. Төп чыганакларда (кварцлы, полиметаллы, комплекслы һ.б.) һәм чәчелмәләрдә очрый. Төп рудаларда А.ның күләме 1–50 *г/т* һәм артыграк, чәчелмәләрдә 0,05–2 *г/м*³ һәм артыграк. 2006 елда дөнья күләмендәге запасы 87,1 мең *т* чамасы, табыш (*т/ел*) — 2500, ш.и. ЮАРда — 279, АКШта — 257, БДБда — 250 (РФдә — 173).

ТРда чәчелмә А. (вак, 0,25 *мм* га кадәр) 1993–94 елларда Тәтеш, Актаныш, Мөслим һ.б. р-ннарда дүртенчел системаның комлы-вак ташлы аллювиаль утырмаларында табыла (алтынның күләме 0,03 *г/м*³); полиметаллы А. төньяк-көнчыгыш р-ннарда Пермь системасының бакыр утырмаларында (4 *г/т* га кадәр), түбән акбур системасы карбонат утырмаларындагы Fe һәм Cu сульфидларында (0,25 *г/т* дан артык), Уфа ярусының битумлы утырмаларында (0,2 *г/т* дан артык), кристаллик фундамент токымнарында (14 *г/т* га кадәр), бакыр рудалары өемнәрендә (4 *г/т* га кадәр) табыла. ТР терр-ясендә А.ның (полиметаллы) фаразланган ресурслары — 60 *т* дан артык.

*Әд.:* Первичное золотообразование в породах фундамента и осадочного чехла территории РТ // Проблемы геологии полезных ископаемых Приволжского региона. К., 1997; Минеральное сырьё. Золото. М., 1998; Металлические полезные ископаемые // Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*Р.А.Хәйдәров.*

**АЛТЫ́Н** (төркичә алты сүзеннән), 1) урта гасырларда төрки-татарларның акча-үлчәү һәм акча-хисап берәмлеге. Беренче мәртәбә Төрки каганлык чорына караган мәгълүматта А. акча-үлчәү берәмлеге һәм кыйммәтлек дәрәҗәсе буларак искә алына. А.ның алыш-биреште акча берәмлеге буларак әйләнештә йөрүе соңрак бу атаманың алтын акча дип үзгәрүенә китерә. А. атамасы акчага карата караханилар, сәлҗуклар дәүләтләрендә, Харәземдә һәм Чыңгызыйлар чорында кулланыла, динарга алмаш була. Башлыча, А. алты көмеш дирһәмгә тиң саналган; 2) урта гасырларда русларда акча һәм акча-хисап берәмлеге. Төркиләрнең «алты» саны атамасына нисбәтле. Русларда 16 йөз ахырыннан билгеле, 6 «даник»ка («деньга»га) тиң булган. Русларның 10 һәм татарларның 12 берәмлекле акча системасының арадашчысы буларак кулланылган (мәс., 100 А. 3 сумга тиң саналган). 1534 елдан А. 3 тиенгә тәңгәл була. 1651 дән бакырдан, 1704–26 да көмештән сугыла. Шуннан соң акча әйләнешеннән алына. 1840 елларда 3 тиенгә тиң А. акча кулланылышта йөри.

*Әд.:* Спасский И.Г. Алтын и его место в русских денежных системах 14–15 вв. // Краткие сообщения Института истории материальной культуры. М., 1956. № 66; шул ук. Русская монетная система. Л., 1962; Янин В.Л. Денежно-весовые системы русского средневековья. М., 1956; Давидович Е.А. Золото в денежном хозяйстве Средней Азии 9–18 вв. // Ближний и Средний Восток. Товарно-денежные отношения при феодализме. М., 1980; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система 12–15 вв. М., 1983; шул ук. Древние монеты Поволжья. К., 1990; Фёдоров-Давыдов Г.А. Монеты — свидетели прошлого. М., 1985.

*Рафаэль М. Вәлиев, И.Л.Измайлов.*

**АЛТЫ́Н КАМЧЫ́** (Solidago), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләннәр, сирәгрәк ярымкуаклар ыругы. 100 ләп төрне үз эченә ала, башлыча, Төньяк Америкада, кайбер төрләре Европада, Азиядә киң таралган. ТРда 2 төре бар. Гади А.к. (S. virgaurea) республиканың барлык төбәкләрендә дә очрый. Якты урманнарда, куак араларында, болыннарда, сөзәклекләрдә һәм елга буйларында үсә. Канада А.к.сы (S. canadensis) декоратив максатларда үстерелә. 30–250 *см* озынлыктагы күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Тамырчасы шуышма. Сабагы туры, җиңелчә ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, кыяк-ланцетсыман, өстәгеләре — утырма, астагылары — сапларда. Чәчәкләре вак, алтынсу сары төстә, күпсаплы кәрзиннәргә җыелган, алар сабак очында озынча себеркәч хасил итәләр. Җимеше — бүрекчәле орлыкча. Июль — сентябрь айларында чәчәк аталар. Орлыклардан һәм тамырчадан үрчиләр. Корылыкка һәм күләгәгә чыдам үсемлекләр. Барлык өлешләрендә дә флавоноидлар, сапониннар, органик кислоталар бар. Үлән төнәтмәсе халык медицинасында үттән таш һәм бәвел кудыру, яра төзәтү чарасы буларак файдаланыла. Баллы үсемлекләр.

**АЛТЫ́Н КОҢГЫЗЛА́Р**, ялтырлар (Buprestidae), коңгызлар семьялыгы. Барлыгы 12 меңләп төре билгеле, тропик поястагы фауна аеруча бай. Россиядә 200 дән артык төре бар (аларның 100 ләп төре — агаччыл һәм куакчыл үсемлекләрне зарарлаучылар), Татарстан терр-ясендә 30 га якын төре бар. Гәүдәсенең озынлыгы 2–32 *мм*, яссы, озынча, очы тарайган. Төсе ачык: яшел, зәңгәр, җирән-кызыл, алтын төсендә (исеме шуннан алынган). Коңгызлар җәй башында күренәләр һәм кызу көннәрдә актив очалар. Барлык агачларның һәм куакларның кәүсәләрендә һәм ботакларында, кайберләре чәчәкләрдә очрый. Ана коңгыз ярылган урынга, ярыкка, кайры астына яки аның шома өслегенә берәрләп яки бик күп итеп йомырка сала. Личинкаларының озынлыгы 4–70 *мм*, аяксыз, саргылт-ак төстә, ялпак гәүдәле. Комга охшаш соры он б-н тыгызлап томаланган, такыр, борылмалы, озын юллар салып, агач кайрысы астында, агач төбендә, коры-сарыда, корыган агачларда, бүрәнәдә, агач каралтыларда ел дәвамында (кайвакыт 2–3 ел) үсә. Кереп-чыгып йөрү юлының азагында личинкаларның курчакка әйләнү урыны бар. Курчактан барлыкка килгән яшь коңгызлар кимереп эллипс формасында тишек ясыйлар һәм очып чыгалар. Чәчәк серкәсе, яфрак тукымалары б-н туеналар. Зәгыйфьләнгән, кипкән яки яңа гына кискән яфраклы һәм ылыслы агачларда урнашалар. Гадәтиләре: зур нарат алтын коңгызы (Buprestis mariana), зәңгәр нарат алтын коңгызы (Phaenops cyanea), дүрт төрткеле алтын коңгыз (Anthxia quadripunctata), бәләкәй алтын коңгыз (Trachis minima).

*А.К.Жеребцов.*

**«АЛТЫ́Н МӨНБӘ́Р»**, к. *Халыкара «Алтын мөнбәр» мөселман киносы фестивале.*

**АЛТЫ́Н ТАШ** (Алтын Сарай мәгънәсендә), к. *Алтын тәхет.*

**АЛТЫ́Н ТӘХЕ́Т** (Алтын Таш), Алтын Урда ханнарының тәхете урнашкан урын; Алтын Урда ханнары башкаласы һәм хан сараеның, урдасының шагыйранә рәвештә аталуы. Атама 13–16 йөзләргә караган Шәрекъ авторлары язмаларыннан, татар, рус язма чыганакларыннан мәгълүм. А.т. — урта гасырларда ш.у. ханнарның зур дәрәҗәгә һәм байлыкка ия булуын күрсәткән атама. 16–17 йөзләр татар фольклорында һәм тарихи язмаларында А.т. сүзтезмәсе Алтын Урда дәүләте мәгънәсен дә аңлаткан.

*Әд.:* Богатова Г.А. Золотая Орда // Русская речь. М., 1970. № 1; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в 13–14 вв. М., 1985.

**АЛТЫ́Н ТУЙ ЧӘЧӘГЕ́**, туйчәчәк (Trollius), казаякчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 лап төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралган. ТРда бер төре — Европа туй чәчәге (T. europaeus) аратирә барлык р-ннарда да очрый. Куак араларында, уйсулыклы болыннарда, кече елгалар үзәнендә үсә. 30–60 *см* озынлыктагы үсемлек, кыска тамырчалы һәм баусыман тамырлы. Сабагы туры, гади. Яфраклары чиратлашкан, бармаксыман телмә яки аерчалы, тамыр янындагылары озын саплы, сабактагылары вак. Чәчәкләре лимон кебек сары төстә, эре, ялгыз, шарсыман, чәчәк сабы озын. Җимеше — кара ялтыравык орлыклы шарсыман күптабак. Май ахыры – июньдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–июльдә өлгерә. Орлыклардан үрчи. Җир өстендәге өлешләрендә алкалоидлар, сапониннар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе ашказаны авыруларын дәвалауда кулланыла. Яшь үләннән ясалган мазь чуан чыкканда файдаланыла. Катмарлы чәчәкле бакча формалары декоратив үсемлек буларак үстерелә. Баллы, агулы (аеруча тамырлары) үсемлек.



Европа туй чәчәге.

**АЛТЫ́Н УРДА́**, Европаның төньяк-көнчыгыш һәм Азиянең төньяк-көнбатышында урнашкан дәүләт (1269–1502). Татарча язма чыганакларда ул Олуг Олыс яки *Җүчи Олысы* дип атала. Гарәп телендәге тарихи-географик хезмәтләрдә «төньяк татарлар дәүләте *Дәште кыпчак*», рус елъязмаларында «Татарлар патшалыгы» яки «Золотая Орда», Көнбатыш илләрдәге латинча чыганакларда «Тартария» буларак теркәлгән. Русча тарихи әдәбиятта бу дәүләтне «золотая» сүзен өстәп атау тәртибе 16 йөз ахыры — 17 йөз башында кулланылышка керә һәм «Золотая Орда» рәвешле термин буларак 19 йөздә генә ныгый. Бу атаманың килеп чыгышы дәүләт башкаласының җирле халык сөйләмендә *Алтын тәхет* дип йөртелүеннән килә. А.У. дәүләтенең булачак нигезе 1207–08 елларда *Чыңгыз ханның* улы Җүчигә аерым *олыс* бүлеп бирүеннән соң барлыкка килә. Баштарак ул олыска Алтай б-н Иртеш елгасы буйлары керә; Урта Азия яулап алынгач, Харәзем дәүләте җире б-н Көнчыгыш Арал тирәләре дә аңа кушыла. Җүчинең вафатыннан соң, 1229, 1235 тәге бөтенмонгол *корылтаенда* олыс идарәчесе итеп аның улы *Бату хан* билгеләнә. Шул ук корылтайларда аңа көнбатыш тарафка яуларны дәвам иттерү бурычы йөкләнә һәм биләмәсенең «монгол атлары барып җитә алган җирләргәчә» арттырылачагы белдерелә. Монголларның кыпчак, болгар, алан, славян җирләрен яулап алу сугышлары барышында (1229–42) Бату хан олысына Көньяк Урал, Идел буеның түбәнге өлеше, Төньяк Кавказ, *Идел буе Болгар дәүләте* һәм рус кенәзлекләре, Кырым буйсындырыла. Польша, Чехия, Венгрия һ.б. ил-дәүләтләр җирләре Әдрән диңгезгә кадәр яулана һәм талана (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*). 1243 кә Җүчи Олысы биләмәләре көнчыгышта Иртеш буйларыннан көнбатышта Днестр елгасы буйларына кадәр барып җитә һәм Арал күле буйларын, Көнбатыш Себер, Югары Урал буйларын,

Төньяк Кавказ б-н Кырым җирләрен, Дәште Кыпчак, Дәште Хәзәр, Идел буе Болгар биләмәләрен, Киев, Чернигов, Новгород, Владимир-Суздаль, Галиция-Волынь һ.б. кенәзлекләрен үз эченә ала. 13 йөз уртасында Венгрия, Болгария һәм Сербия дә А.У.га вассаллык рәвешендә буйсыналар.

1243 тә Бату хан, Көнбатыш илләрен яулау сугышын калдырып, Идел буена әйләнеп кайта һәм Олыста ныклы тәртип урнаштыруга керешә. Төрки һәм монгол дәүләтләрендә яшәп килгән традиция буенча, үз кул астындагы Олыс биләмәсен *Сул* һәм *Уң канатларга* (Ак Урда һәм Күк Урда) бүлә. Алар, үз чиратында, кечерәк олысларга, төмән, меңлек, йөзлекләргә бүленә. Ак Урда идарәчелеге башында үзе кала, Күк Урда идарәчесе итеп агасы Урда Эҗен билгеләнә. Кечерәк олыс, *төмән* һ.б. берәмлекләр башына бертуганнары һәм уллары (*Бәркә, Нугай*, Тука (Тукай) — Тимер, Шибан һ.б.), нойоннар, бәкләр куела. Кечерәк биләмә идарәчеләре *сөйүргал* алу хокукына ия була. Олыс идарәчеләре әмир яки *олыс бәге*, кечерәк берәмлекләр башлыклары *төмәнбашы, меңбашы, йөзбашы, унбашы* дәрәҗәсендә була. Алар үз биләмәләрендә мәхкәмәче, салым җыючы, гаскәр туплаучы һәм ул гаскәри берәмлекнең башлыгы вазифаларын үтиләр. А.У. биләмәсендә бердәм транспорт системасы — ям тоту, ям йөрү тәртибе кертелә, һәр юнәлештә ямчылар авыл-станцияләре барлыкка китерелә.

Вассаллык хәлендә булган кайбер биләмәләр (Идел буе Болгары, рус кенәзлекләре һ.б.), А.У. ханнары тарафыннан идарә ителсәләр дә, турыдан-туры *Монгол империясе* бөек каганына (ханына) буйсынган булып саналган. Бу төбәкләрдә (Идел буе Болгары, рус кенәзлекләре һ.б. яңа яуланган илләр) 1257–59 да хан идарәсен ныгыту, салым-ясак җыю һ.б. вазифаларны үтәү (ям тоту, хәрби бурыч үтәү һ.б.) тәртибен булдыру ниятеннән чыгып, вассаллык буйсынуындагы өлкәләрдә халык санын исәпкә алу үткәрелә, баскаклык тәртибе урнаштырыла (к. *Баскак*). Шушы гамәлләр А.У.га 1250 еллар ахырыннан бөек каганнан беркадәр бәйсез булу мөмкинлеген тудыра, Бәркә хан чорында сугылган акчаларда Җүчи нәселе *тамгасы* кулланыла башлый. *Мәнгу Тимер хан* идарә иткән елларда А.У.дәүләте бөек каганга буйсынудан туктый, хан исеме язылган үз акчасын сугуга керешә. 1269 да Җүчи, Чагатай һәм Үгәдәй олысы ханнары корылтае була, анда бу олыс биләмәләре тәмам тәгаенләнә, шул рәвешле Монгол империясенең таркалуы канунлаштырыла.

13 йөз ахырында Ак Урдада 2 сәяси үзәк барлыкка килә: Кара диңгез төбәгенең төньяк өлешендә *бәкләр бәге* Нугай бәк идарәсе өстенлек итсә, Идел буе өлкәләре *Тукта ханга* буйсына. Капма-каршы торыш 13–14 йөзләр чигендә Тукта ханның җиңүе б-н тәмамлана. 1310–11 дә Тукта хан А.У.да олыслар б-н идарә итү, ш.и. акча берәмлекләрен тиңләштерү (унификацияләү) реформалары үткәрә.

А.У.да югары хакимият *Җүчиләр* кулында кала. 1360 ка кадәр тәхет биләүчеләр Бату хан нәселеннән, шуннан соң Тука Тимер хан нәселеннән (өзеклекләр б-н 1502 гә кадәр) була. Шибан нәселе варислары Күк Урдада һәм Урта Азия өлкәләрендә тәхет билиләр. 1313 тән башлап А.У. тәхетенә фәкать Җүчи токымыннан чыккан, мөселман динендәге кеше генә утыра алган. А.У. ханнары формаль рәвештә ил-дәүләт б-н ялгызы хакимлек итүче (монарх) дәрәҗәсендә булган, әмер, фәрманнар хан мөһере куелгач игълан ителгән, җомга һәм бәйрәм намазлары вәгазьләрендә (*хөтбә*ләрдә) хан исеме беренче булып телгә алынган. Хан карамагында идарә эшләрен башкару дүрт идарәче ыруг вәкилләреннән торган диванга йөкләнгән. А.У.да төп идарәче ыруглар: *Ширин* (Шырын)*, Барын, Аргын, Кыпчак* була. Башка монгол һәм төрки ыруглары аларга буйсына. Диван башлыгы булган вәзир, бәкләр бәге җитәкчелегендә дәүләт б-н идарә итү эшләре башкарылган. Олуг *карачы бәк* вазифасына тышкы һәм эчке сәясәт, мәхкәмә эшләре кергән, ул ш.у. гаскәр башлыгы саналган. Җитди мәсьәләләр хәл ителгәндә (тәхет варисын билгеләү, тәхеттән төшерү, сугыш игълан итү, хан нәселе вәкилләренең гаилә кору мәсьәләсен карау һ.б.), башка төрки һәм монгол дәүләтләрендәге кебек үк, югары дәрәҗәле аксөякләр корылтае җыелган. Корылтайларда гадәттә 70 ләп кеше — олыс әмирләре, ыруг башлыклары һ.б. катнашкан. А.У. тарихының төрле дәверләрендә дәүләт-хакимият эшләре барышына корылтайлар йогынтысы төрлечә булган.

Аксөякләрнең дәрәҗәсе, социаль хәле җир биләмәсенә хуҗа булу хокукына яисә күпме салым җыюына карап билгеләнгән (сөйүргаллык яки *тарханлык* хокукы). А.У. дәүләтендә иң югары дәрәҗәле аксөякләр катлавына карачы бәк һәм олыс бәкләре, хан варислары (*углан, солтан*), *әмирләр*, бәкләр һәм дан казанган хәрбиләр — баһадирлар (*батыр*) һ.б. кергән. Җирле адм.-хакимият вазифаларын даруга бәкләре (к. *Даруга*) башкарган. Дәүләткә һәм җирле феодалга салым түләүчеләр *кара халык* булган. Салымның төп төре — *ясак*; җир биләмәсе күләменнән, җан башыннан чыгып түләнә торган төрләре (*хәрәҗ*, тамга-тырнак һ.б.), төрле йөкләмәләр үтәү, гаскәр тоту һ.б. салымнар, ям тоту салымы (илче-кунак) да булган. Дин тотуга бәйле салым төрләре А.У.да мөселманнарга карата *гошер, зәкят* дип, башка диндәгеләр һәм яңа яуланган илдәге төп халык өчен җизйә дип аталган. Барлык салым төрләренең һәм үтәләсе йөкләмәләрнең саны 16 га җиткән чаклар да булган. Аларны җыю яисә үтәлешен күзәтү өчен унга якын төрле дәрәҗәдәге эш башкаручы билгеләнгән. Буйсындырылган өлкәләр халкы ясак-салымнарны хан файдасына (мәс., рус кенәзлекләрендә «*урда салымы*») һәм үз феодалларына түләргә, гаскәр тоту, ям йөртү йөкләмәләрен үтәргә тиеш булганнар.

А.У. дәүләте гаскәре турыдан-туры ханга буйсынган, ул югары дәрәҗәле аксөякләрнең гаскәри берәмлекләреннән, олыс һәм шәһәр бәкләре алай-дружиналарыннан һәм союздаш ил-дәүләт гаскәреннән тупланган (чама б-н аның саны сугыш очрагында 250 мең кешегә кадәр җиткән). Армиянең төп көчләре аксөякләрдән тупланган хәрби җитәкчеләр, даими рәвештә хезмәт итүче гаскәриләрдән (нигездә авыр дирбия-кораллы атлылар) торган (аларның саны 50 мең чамасы була). Җәяүле сугышчылар башлыча ярдәмчел бурыч үтәүчеләр саналган. Сугыш-яу барышында авыр кораллы атлы гаскәр башлап һөҗүм итүче көч була. Җиңел коралланган атлы гаскәр, уклардан атып, аңа ярдәм итә, дошман сафларын ерактан торып юк итүдә катнаша. Кальга-ныгытмаларны саклаганда утлы корал кулланылган. Дошманга һөҗүм итү вакытында төрле стратегик манёврлар, ялган чигенү һәм дошман гаскәрен кинәт урап, камап алу ысуллары гамәлдә булган. А.У. гаскәре сугышчылары бик чыдам, көнкүрештә талымсыз булалар, үз кирәк-яракларын үзләре табалар. Ерак араларга йөргәндә һәр җайдакның өстәмә аты булу юл йөрүне тизләтә, гаскәрнең манёврлар ясау мөмкинлеге арта. А.У. гаскәренең иң уңышлы зур сугыш-бәрелешләре түбәндәгеләр: әмир Нәвруй җитәкчелегендә Владимир кенәзе Андрей Ярославовичның көчләрен Переяславль шәһәре янында җиңү (1252), *Борындай* баһадир гаскәренең Сандомир шәһәрен яулап алуы (1259), Бәркә хан җитәкчелегендә Терек елгасы буенда Һулагу илһан (Иран) көчләрен тар-мар итү (1263), Тукта ханның Кунаклык янында Нугай бәк көчләрен җиңүе (1300), *Җанибәк хан* җитәкчелегендә Иранның өлкә үзәге булган Тәбриз шәһәрен яулап алу (1358), *Мамай* мирза б-н Мәскәү кенәзе *Дмитрий Донскойның* берләштерелгән көчләренең Болгар шәһәрен яулап алуы (к. *Болгарга 1376 елгы яу*), *Куликово кыры сугышы*, *Туктамыш* ханның (1382) һәм Идегәй мирзаның (1408) Мәскәү шәһәрен яулап алулары, Туктамыш хан б-н Аксак Тимер әмир гаскәрләре арасындагы 2 зур сугыш (к. *Кондырча буендагы сугыш*, 1391; *Терек елгасы буендагы сугыш*, 1395), Идегәй бәк җитәкчелегендәге гаскәрнең Литвага барып сыенган Туктамыш хан б-н Литва бөек кенәзе Витовтның берләштерелгән көчләрен Бурсыклы елгасы буенда җиңүе (к. *Бурсыклы (Ворскла) елгасы буендагы сугыш*, 1399), *Олуг Мөхәммәд* ханның Биләү шәһәре янында бөек кенәз *Василий II* нең гаскәрен тар-мар итүе (к. *Биләү (Белёв) янындагы сугыш*).

А.У. дәүләтендә 30 дан артык эре шәһәр булуы мәгълүм: Днестр буенда — *Ак Кирмән*, Иске Шәһәр; Кырымда — Кырык Ир, Кырым (Иске Кырым); Урта Идел буенда — *Болгар, Җукәтау, Иске Казан, Казан, Кашан, Мухша*; Иделнең түбән ягында — *Укәк, Сарай әл-Җәдид, Сарай әл-Мәхрусә, Бәлҗәмин, Хаҗитархан*; Дон елгасы буенда — *Азак*; Төньяк Кавказда — *Маҗар*, Дәрбәнт; төньяк-көнчыгыш Каспий буенда — *Сарайчык*; Харәземдә — Үргәнеч (Күнә Үргәнеч); Арал буенда — Җәнд, Сыгнак, Утрар, Сүрән һ.б. Болардан кала 150 ләп кече кала-шәһәр төрле олыс, әмирлек, феодаль берәмлекләрнең адм. хакимият үзәкләре була, аларда дини оешмалар, һөнәрчелек остаханәләре, сәүдә итү урыннары эшли. Ул шәһәрләр б-н әмирләр һәм *хакимнәр* идарә итә. Шәһәрләр тирәсендә иген игеп, җир эшкәртеп көн күрүче утрак тормышлы халык яши. А.У. шәһәрләрендә, бигрәк тә эреләрендә, күн әйберләр җитеште-




рү, агач эшкәртү һ.б. төр һөнәрчелек тармакларыннан тыш, тимер коюэшкәртү, корал җитештерү б-н дә шөгыльләнгәннәр; балчыктан, пыяладан кирәк-ярак ясау, зәркәнчелек һөнәрләре дә алга киткән була. Йорт диварларын бизәү-матурлау, металл әйбергә басма бизәкләр төшерү, затлы ташларны уеп-чокып һәм шомартып эшкәртү сәнгате киң таралыш ала; сәнгать өлкәсендә Урта Азия, Идел буе һәм Якын Көнчыгыш халыклары традицияләре бер-берсе б-н бәйләнештә үсә. Хуҗалык тармагында сәүдә күренекле роль уйный. А.У. Европа, Якын Көнчыгыш һәм Көнчыгыш илләре б-н сәүдә элемтәләре тота. Ш.у. Кытай һәм Һиндстан б-н Көнбатыш Европа илләре арасындагы әһәмиятле транзит сәүдә юллары да А.У. биләмәсе аша уза (ефәк тукымасы, җиләк-җимеш, тәмләткечләр һ.б.). А.У.дан чит мәмләкәтләргә ашлык, затлы җәнлек тиреләре, төрле көн эшләнмәләре, коллар һәм терлек сатуга озатыла. А.У. товарлары Көнбатыш Европа, ш.и. Урта диңгез буе сәүдәсен үз кулында тоткан Италия базарларына, Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия, Көнчыгышның мөселман илләренә (аеруча токымлы юртак атлар) чыгарыла. А.У.га затлы бизәлеш, көнкүреш әйберләре, кыйммәтле кораллар, затлы тукымалар, тәм-том һәм тәмләткеч әйберләр кайтарыла. Сәүдә үзәкләре булган күпчелек шәһәрләрдә төрле илләрдән килгән сәүдәгәр һәм һөнәр ияләренең үз җәмгыятьләре, яһүдиләр, әрмәннәр, греклар, итальяннар бистәләре була (мәс., Шәһри Болгарда *Әрмән колониясе*). Грек-итальян колонияләре һәм аерым шәһәр-республикаларның сәүдә җәмгыятьләре А.У.ның Кара диңгез буенда урнашкан була (мәс., Кафа, Судак шәһәрләрендә җәнүизләр (Генуя сәүдәгәрләре), Азак шәһәрендә венецианнар колонияләре һ.б.). Бу утрак сәүдә колонияләре эшчәнлеге А.У. дәүләте б-н килешенеп башкарыла.

14 йөзнең 1 нче чирегенә кадәр А.У. дәүләтенең башкаласы Иделнең түбәнге агымында Бату хан тарафыннан төзелгән Сарай әл-Мәхрусә шәһәре була, ул эре икътисади, дини-рухани, сәяси һәм сәүдә үзәге санала. Баштарак шәһәр фәкать адм. үзәк вазифасын үти. Аннары анда яшәүче халык ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен башкалага төрле тарафлардан тәҗрибәле һөнәрчеләр килеп төпләнә. Халык саны арту һәм сәүдәнең җанлануы шәһәрнең үсүенә китерә, 14 йөзгә кергәндә ул эре башкалага әверелә (бистәләре б-н бергә гомуми мәйданы 36 $км^2$ га җитә). Чыганакларда күрсәтелгәнчә, анда 75 мең чамасы кеше яшәгән. Шәһәрдә бер-беренә сыенып, тыгыз утырган йортлар, аксөякләрнең кала читендәге бай утар-сарайлары һәм иркен җимеш, яшелчә бакчалары булган. Аның күренеше һәркемне сокландырган. Шәһәр урам-йортларының төзеклеге, уңайлы б-н дә аерылып торган: йортларга сууткәргечләр, канализация торбалары үткәрелгән. Сарай-өйләрнең күпчелеге яндырылмаган кирпеч кулланып эшләнгән. А.У. шәһәрләре харабәләрен тикшерүче археологлар һөнәрче остаханәләренә еш юлыгалар. Ул шәһәрләрдә, гадәттә, аерым һөнәр ияләре тупланып, үз һөнәрдәшләре б-н бер мәхәллә хасил итеп урнашканнар. 14 йөзнең 1 нче чирегендә А.У.ның башкаласы Үзбәк хан төзеткән Сарай әл-Җәдидкә күчерелә. Хан сарае тулаем Үзбәк хан улы Җанибәк хан заманында сафка баса. Шәһәр бик тиз үсеп китә. Анда затлы өйләр, гыйбадәт йортлары төзек урам рәвешендә урнашкан була. Аксөякләрнең сарай-утарлары бер тирәдәрәк — каланың көньяк-көнчыгыш өлешендә төзелә; һөнәрче бистә-мәхәлләләре калкып чыга. 1360 елларга кадәр А.У. шәһәрләре кальга-кирмәннәр б-н уратып алынмый. А.У. дәүләте халкының төп шөгыле: игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, балык тоту һәм чолыкчылык. Тары, арыш, бодай, арпа, карабодай, борай игелә, төрле-төрле яшелчә, бакча җимешләре үстерелә. Үз кирәкләреннән тыш, ашлык чит илләргә сатуга да чыгарыла. А.У. биләмәсенең зур өлеше далалы җирләргә туры килгәнлектән, анда яшәүчеләрнең күпчелеге күчмә терлекчелек б-н шөгыльләнә. Терлекчелектә ат һәм сарык үрчетүгә өстенлек бирелә. Мал көтүләре б-н күченүләр язын көньяктан төньяк тарафка, көзен-кышын төньяктан көньякка таба оештырыла торган була.

Җүчи Олысының әкренләп Көнбатыш Себер, Арал диңгезе буйларыннан Көнчыгыш Европага таба киңәя баруы нәтиҗәсендә элек ул җирләрдә яшәгән кимәк-кыпчак кабиләлә-

ре берләшмәләре таркала, халкы яулап алына. Шул рәвешле А.У. халкының этник-социаль халәте һәм дини-рухи мәсләге шактый үзгәрә, төрләләнә. Яуланган кабиләләр аксөякләренең бер өлеше юк ителә, икенче бер өлеше яулаучыларга кушылып китә. А.У.ның төп халкы көнчыгыштан килгән монгол, төркиләр булып, алар яуланган төрки кыпчак, кимәк һәм фин-угырларның күпчелеген ассимиляцияли. Шул дәвердән башлап Евразия халыклары арасында әйдәп баручы халык булып татарлар (төрки-монголлар) танылa. Монголлар явына чаклы булган төрки сөйләм теле зур үзгәрешләр кичерми. А.У. дәүләтенең рәсми һәм көндәлек сөйләм теле — төрки тел. Соңрак шул җирлектә әдәби тел — *Идел буе төрки теле* барлыкка килә. Шул иске әдәби төрки телдә Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Мәхмүд әс-Сараи әл-Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис», Сәйф Сараинең «Китаб-е Гөлстан би-т төрки» кебек әсәрләре иҗат ителә. Идел буе төрки әдәби теле Көнчыгыш Европада 19 йөз урталарына кадәр гамәлдә була. А.У. дәүләтендә баштарак монгол теле, рәсми дәүләт теле буларак, эш кәгазьләрендә һәм илчелек ихтыяҗларында кулланыла. 14 йөзнең 2 нче яртысыннан ул төрки телгә алыштырыла. Ш.у. дини, фәлсәфи һәм кануни өлкәләрдә — гарәп, шигърият дөньясында фарсы телләре дә кулланылышта була.

1313 тән ислам дине рәсми дәүләт дине дип игълан ителә, А.У. халкының этник-мәдәни яктан якынаюында бу үзгәреш зур роль уйный. Шушы тарихи-мәдәни һәм этник процесслар нәтиҗәсендә үзләрен аерым этнослар мәдәниятеннән өстен куйган хәрбиләр һәм югары дәрәҗәле хезмәткәрләр даирәсе оеша. Чыңгызыйлар гореф-гадәтләрен һәм ислам дине йола-традицияләрен берләштергән аксөякләрнең этник-мәдәни үзаңы формалаша. Шул рәвешле яңа этник-сәяси татар исеме б-н танылган җәмгыять барлыкка килә. Алар нигездә мөселманлашкан төркиләр һәм монголлардан булып, Җүчиләргә карата вассаллык бәйләнешендә калалар. *Татар* этнонимын йөрткән бу катлауга яу б-н килгән төрки-монголлардан тыш, яңа яуланган җирләрдә элек-электән утрак тормышта яшәгән Болгар бәклеге, Харәзем ханлыгы халкы һәм өлешчә рус кенәзлекләре аксөякләре, күчмә кимәк-кыпчаклар һ.б. кергән. Идел буенда һәм Кара диңгезнең төньяк яры буенда утрак тормышта яшәүчеләр үзләрен тоткан диннәренә бәйле рәвештә «мөселман» дип тә йөрткәннәр. А.У. дәүләте таркалган чорда (15 йөзнең 1 нче яртысы) яңа этник-сәяси җәмгыятьләр оеша. Яңа җирле үзатамалар барлыкка килә, әмма төрки-мөселман аксөякләрнең төп политонимы рәвешендә «татар» атамасы кала. 15–16 йөзләрдә оешкан татар дәүләтләрендә (Әстерхан, Казан, Касыйм, Себер ханлыклары, Олы Урда һәм Нугай Урдасы) бу атама киң таралыш ала.

А.У. дәүләтенең беренче ханнары *Тәңрегә* табыналар, нәсари (христиан) диненә күчүчеләре дә була. Бәркә ханнан башлап алар нигездә ислам динен тоталар. Аксөякләр арасында мөселманнар һәм Будда динен тотучылар күпчелекне тәшкил итә. Яңа яуланган болгар бәклекләре, Харәзем ханлыгы халкы нигездә мөселман була. 14 йөзнең ахырларына ислам дине дәүләтнең барлык халкы арасында киң тарала.

А.У.да ислам дине башында *Сәедләр* нәселе вәкиле торган. Руханилар катлавы түбәндәге тәртиптә төзелгән: аерым өлкә-төбәк *мөфтиләре, мөхтәсибләр, казый, шәех, мулла, имам, хафиз* һ.б. Алар халыкка дин кагыйдәләрен өйрәткән, вәгазьләр сөйләгән, дини йолалар башкару тәртибен билгеләгән һәм мөселманнарның гореф-гадәтләр үтәүгә, мал бүлешүгә кагылышлы мәхкәмә эшләрен хәл иткән. Мәктәп-мәдрәсәләр тоту, укыту эшләренә дә алар җитәкчелек иткән. А.У. биләмәсенә кергән җирләрдә 10 меңнән артыграк мәчет биналары хәрабәләре табыла. Мәс., мәчет калдыклары яки борынгы мәчетләр Болгар, Алабуга, Сарай әл-Мәхрусә (хәзерге Селитренный авылы), Солхат (Иске Кырым), Үргәнеч шәһәрләре, Водянск, Югары Җулат (Татарупск), Кучугур, Иске Орхей шәһәрчекләрендә һ.б. урыннарда бар. Мәчетләр янәшәсендә мәктәп-мәдрәсә, хастаханә, кунакханә (ханәкә) биналары калдыклары да урнашканы мәгълүм. Идел буе өлкәләрендә ислам динен халыкка иңдерүдә суфиларның мәгълүм тарикатъ-җәмгыятьләре (мәс., Кубравийа, Ясәвия) әһәмиятле эш башкарган. Кайбер урыннарда аларның үз мәчетләре һәм ханәкәләре өстенлек иткән. А.У. дәүләтендә дин тоту ирекле булган. Мөселманнар б-н янәшә мәҗүсиләр һәм христиан диненә табынучылар яшәгән һәм аларның дини йола үтәү урыннары дәүләт тарафыннан сакланган. А.У. ханнарының, мәс., христиан дине руханиларына, чиркәү һәм монастырьларга карата чыгарылган махсус карар-фәрманнары мәгълүм. Алар салым һ.б. төр бурыч үтәүдән азат ителгәннәр. Шундый ук хокукка әрмән динен тотучы монофизитлар, католиклар һәм яһүд динен тотучылар да ия була. Барлык дин оешмаларының үз җир биләмәләре, милекләре һәм *вакыфлары* булган. А.У. дәүләте алдынгы мәдәният һәм сәнгатькә ия (к. *Алтын Урда культурасы, Алтын Урда сәнгате*). Күпсанлы мәктәп-мәдрәсәләрдә дин нигезләре укытылы, гомуми белем бирелә. Мәдрәсәләрдә китаплар туплана, китап күчереп язу, хаттатлык эшчәнлеге киң таралыш ала. А.У. халкының гыйлемлелеген йорт-җир кирәк-ярагында еш очраган язмалар һәм *эпитафияләр* дә исбатлый. Рәсми тарих фәненең үсеш алуы сакланып калган тарихи хезмәтләрдә («Чыңгызнамә», Рәшидеддиннең «Җамигъ әт-тәварих»ы), кайбер идарәчеләргә караган шәҗәрә язмаларында һәм риваятьләрдә чагыла. Төзелеш һәм архит-ра тармагында да зур казанышларга ирешелә. Төзелештә табигый ташлар, кирпеч кулланыла, таш-кирпечкә чокып бизәк төшерү (к. *Эпиграфика* ядкәрләре) ысулы еш файдаланыла. Декоратив-гамәли сәнгать, халык иҗаты алга киткән була.

Тышкы сәясәттә А.У. дәүләте 13 йөз урталарына кадәр Көнбатыш илләренең җирләрен яулауга, Кече Азия б-н Кавказ аръягыннан узган сәүдә-кәрван юлларын үзенә буйсындыруга зур әһәмият бирә. Үзәк һәм Көньяк-Көнчыгыш Европа ил-мәмләкәтләре дә А.У. ханнарының хәрби һәм дипломатик басымын даими тоеп яшиләр. 1243 елда А.У. гаскәре Галиция-Волын кенәзлегенә яу б-н бара, яу кенәз Даниил Романовичның Бату ханга вассаллык буйсынуын тануы б-н тәмамлана. Ләкин әле ул тулы буйсыну булмый. 1250 елларда *Хурумша* б-н *Борындай* баһадир җитәкчелегендә А.У. гаскәре Галиция-Волын кенәзлегенә, Польша б-н Литва илләренә һөҗүм итә. Аеруча Борындай баһадир җитәкчелегендәге 1254 елгы яу Польша дәүләте б-н Көньяк-Көнбатыш рус кенәзлекләре өчен аяусыз була, байтак торак пунктлар талана, каршылык күрсәткән Сандомир шәһәре яндырыла. Шушы яулардан соң А.У. дәүләтенең көнбатыш чикләре Прут елгасы һәм Карпат таулары б-н билгеләнә. Нугай бәк җитәкчелегендә башкарылган яулар (1275, 1277, 1280, 1286, 1287) Балкан төбәге илләре б-н Польшаның вассаллык буйсынуын ныгыту һәм хәрби йолым, ясак түләүләр б-н тәмамлана.

13 йөз ахырында Кавказ аръягы ил-өлкәләрен үз йогынтыларына алу өчен А.У. б-н Һулагу Олысы (Иран) арасында көрәш башлана. Кара диңгез аша Көнбатыш илләренә корабларда турыдан-туры сәүдә юлы һәм, димәк, дипломатия юлы үтә. Шуңа хуҗа булу өчен монголларның ике олысы арасында барган бу көрәшкә Византия дәүләте дә һулагулар ягыннан торып катнаша. Кавказ алды һәм Кавказ аръягында ике якның сугышлары 1262 дә башлана һәм 1390 елларга кадәр дәвам итә. 1269 да Нугай бәк һулагулар союздашы булган Византия җиренә бәреп керә, башкаласы Константинопольне камап тора, Болгарияне вассаллык тәртибендә А.У. га буйсындыра. Кавказ аръягындагы Нахичевань, Марага, Тәбриз шәһәрләре Бөек Ефәк юлының зур сәүдә үзәкләре һәм Якын Көнчыгыш илләрен яулау өчен плацдарм булып хезмәт итә. Шунлыктан монда зур яу-сугышлар кабатланып тора. 1263, 1265 тә Бәркә хан б-н Нугай бәкнең берләштерелгән гаскәре Һулагу көчләрен җиңә, ә 1267 дә Нугай гаскәре Шәмаха шәһәре янәшәсендә җиңелә. 1269 да Фәләстиннең Айн Җәлүт шәһәре янында Һулагу гаскәрен Мисыр идарәчесе мәмлүк Бәйбарс җиңә. Сугыш бер якка да хәлиткеч өстенлек китерми. Һулагу һәм аның варислары (Иран илһаннары), аларга союздаш булган Византия һәм Фәләстиндагы нәсари (христиан) корольлекләре б-н көрәш барышында А.У. дәүләте мәмлүкләрнең Мисыр дәүләте һәм төрек-сәлҗүкләр берләшмәсе б-н үзара арадашлык-булышлык мөнәсәбәтләренә керә, халыкара сәясәттә мөһим адым ясала. А.У.ның Византия б-н үзара илчелек мөнәсәбәтләре исә ара-тирә яу-сугышларга китерә. 1290 да Мәңгу Тимер ханның, 1318–19, 1325, 1335 тә Үзбәк ханның Византия җирләренә һөҗүм итүләре мәгълүм.

А.У.ның иң куәтле, барлык өлкәдә уңышка ирешкән чоры Үзбәк һәм Җанибәк ханнар идарә иткән елларга туры килә. Бу елларда илдә икътисади тотрыклылык, үсеш күзәтелә, ханлык б-н идарә итү ысуллары камилләштерелә, үзәк хакимият ныгый, чик буйларында тынычлык урнаша, гаскәр көчле була. Армия башлыча аерым җир биләмәләренә ия булган олыс, өлкә аксөякләренең гаскәри бирәмлекләреннән туплана. Бу елларда А.У.

Көнчыгыш Европада һәм Әзәрбайҗанда хәрби җиңүләргә ирешә. Үзбәк хан оныгы Бирдебәк ханның кыска вакытлы идарәсеннән соң башланган һәм 20 елга сузылган тәхет чуалышлары (к. *Алтын Урдада тәхет чуалышлары*), табигатьтәге тискәре үзгәрешләр (берничә елга сузылган корылык, чума авыруы таралуы, Каспий суларының Түбәнге Идел буе өлкәләрен басуы) 14 йөзнең 2 нче яртысында А.У.ның озак вакытка көчсезләнүенә китерә. Нәтиҗәдә аерым төбәкләрнең мөстәкыйльлеккә омтылу күренеше көчәя. Ак Урдада Мамай бәк хакимиятне үз кулына ала, тәхет чуалышлары вакытында башкалада үзе теләгән кайбер ханнарның җиңеп чыгуына ирешә; Харәземдә Суфилар династиясе идарә итә башлый, Болгар бәкләре *Булат Тимер* б-н *Хәсән* 1378–80 елларда мөстәкыйль рәвештә Мәскәү бөек кенәзе Дмитрий Донской б-н Мамайның берләштерелгән көчләренә каршы сугыша. 1380 дә Күк Урда ханы Туктамыш үз ханлыгы көчләре һәм башкала аксөякләре ярдәмендә Сарай әл-Җәдид тәхетенә утыра, Мамай бәк гаскәрен тар-мар итә, Мәскәүне сугышып алып (1382), рус кенәзлегенең А.У.га элеккечә салым түләп торуына ирешә. Туктамыш хан идарәчелегендә А.У.ның аерым төбәкләре кабат берләштерелә. Үзәк хакимиятне ныгытуга юнәлдерелгән чаралар үткәрелә башлый. Ләкин ул реформаларны кайбер аксөякләр кабул итәргә теләми.

Туктамыш хан заманында А.У. гаскәренең Аксак Тимер яулары вакытында җиңелүе (1388–89, 1391, 1395) Күк Урда, Идел буе, Төньяк Кавказ һәм Кырымның бөлгенлеккә төшүенә китерә. 15 йөз башында Идегәй тарафыннан уздырылган яңа реформалар (акча реформасы һәм дәүләтне ныгытуга юнәлдерелгән башка чаралар) нәтиҗәсендә илдәге эчке киеренкелек вакытлыча гына бетерелә. Ул ханнар исеменнән идарә иткән чорда тышкы сәяси уңышларга ирешелә (1399 да Бурсыклы елгасы буенда бөек Литва кенәзе Витовт һәм Туктамыш ханның берләштерелгән гаскәрләрен тар-мар итү, 1405 тә Мавәраәннәһергә яу белән бару, 1408 дә Мәскәүне камалышта тоту). Туктамыш хан уллары б-н сугыш вакытында Идегәй бәк һәлак булгач (1419), А.У.да кабат таркалу башлана; нәтиҗәдә берничә мөстәкыйль татар дәүләте барлыкка килә: *Себер ханлыгы* (1420), *Кырым ханлыгы* (1428), *Казан ханлыгы* (1438). А.У. ның Түбән Идел буенда соңгы кыйпылчыгы — *Олы Урда* саклана. 1502 дә Кырым ханы *Миңлегәрәй* гаскәрләренең Әхмәд хан варислары гаскәрләрен тар-мар итүе нәтиҗәсендә Олы Урда таркала (ш.у. к. *Нугай Урдасы*).

Татар милләтенең этник-мәдәни үсеше һәм формалашуында А.У.ның йогынтысы зур була. Ш.у. башкорт, казакъ, нугай, үзбәк (Мавәраәннәһер төркиләре) һ.б. төрки халыкларның тарихы һәм алга китешендә бу дәүләт мөһим роль уйный. Мәскәү дәүләтенең аякка басып, тернәкләнеп китүендә дә А.У. дәүләтенең йогынтысы сизелерлек була. Дәүләт-хакимият төзелеше, армия, идарә-элемтә эшен җайга салу үрнәге шуннан алына.

Җүчи Олысы һәм А.У. дәүләте ханнарының идарә итү еллары: Җүчи (1208–27), Бату (1227–56), Сартак (1256), Улакчы (1256), Бәркә (1256–66), Мәнгу Тимер (1266–82), Туда Мәнгу (1282–87), Тула Буга (1287–91), Тукта (1291–1313), Үзбәк (1313–42), Тәнибәк (1342), Җанибәк (1342–57), Бирдебәк (1357–59).

А.У.да тәхет чуалышы дәверендә идарә иткән ханнар: Күлнә (Күлпә) (1359–60), Нәүруз (1360), Хызыр (1360–61), Тимер Хуҗа (1361), Урда Малик (1361), Абдуллаһ (1361–70, өзеклекләр б-н), Килдебәк (1361–62), Мөрид (1361–64), Мирбулат (1364–65), Газиз Шәех (1365–67), Толынбәк (1370), Мөхәммәд Бүләк (1370–80, өзеклекләр б-н), Ырыс (1374–75), Чиркәсбәк (1374–75), Каганбәк (1375–77), Туктакыя (1376–77), Гарәбшаһ (1377–79).

Чуалышлар узганнан соңгы ханнар: Туктамыш (1380–97, өзеклекләр б-н: 1394–95 тә — Таштимер, 1396–97 дә — Коерчак), Тимер Котлыгъ (1397–99), Шадибәк (1399–1407), Булат Солтан (1407–10), Тимер (1411), Җәләлетдин (1411–12), Кәримбирде (1413), Кибәк (1413–14), Чокрый (1413–16), Җаббарбирде (1416), Дәрвиш (1416–19), Кадыйрбирде (1419), Олуг Мөхәммәд (1420–37, өзеклекләр б-н: 1420–38 дә — Гыясетдин, 1420–24 тә — Ходайдат, 1422–27 дә — Баракъ, 1433–35 тә — Хаҗигәрәй).

А.У. дәүләте таркалган дәвердә идарә иткән ханнар: Сәед Әхмәд (1433–55), Кече Мөхәммәд (1433–59), Әхмәд (1459–81), Мортаза (1481–94), Сәед Әхмәд II (1485–1502), Сәед Мөхәммәд (1485–1502), Шәех Әхмәд (1491–1502).

Чыг.: Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды: В 2 т. М.–Л., 1941; Путешествия в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957; Рашид ад-Дин. Сборник летописей: В 3 т. М.–Л., 1960; Полное собрание русских летописей. М., 1965. Т. 1–5, 15, 18; Барбаро и Контарини о России. Л., 1971; П о л о М. Книга Марко Поло. А.-А., 1990; Утемиш-хаджи. Чингиз-наме. А.-А., 1992; Г р и г о р ь е в А.П., Г р и г о р ь е в В.П. Коллекция золотоордынских документов XIV века из Венеции. СПб., 2002.

*Әд.:* С а б л у к о в Г.С. Очерк внутреннего состояния Кыпчакского царства. К., 1895; Н а с о н о в А.Н. Монголы и Русь (История татарской политики на Руси). М.–Л., 1940; Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; З а к и р о в С. Дипломатические отношения Золотой Орды с Египтом (XIII–XIV вв.). М., 1966; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Кочевники Восточной Европы под властью золотоордынских ханов. М., 1966; ш у л у к. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; ш у л у к. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994; Г р е к о в И.Б. Восточная Европа и упадок Золотой Орды (на рубеже XIV–XV вв.). М., 1975; У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979; Г р и г о р ь е в А.П. Золотоордынские ханы 60–70-х годов XIV в.: хронология правлений // Историография и источниковедение истории стран Азии и Африки. Л., 1983. Т. 7; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Е г о р о в В.Л. Историческая география Золотой Орды в 13–14 вв. М., 1985; Из истории Золотой Орды. К., 1993; Т р е п а в л о в В.В. Государственный строй Монгольской империи XIII в. Проблема исторической преемственности. М., 1993; Г а з и з Г. (Губайдуллин Г.С.). История татар. М., 1994; Х а л и к о в А.Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. К., 1994; Ф а х р е т д и н Р. Ханы Золотой Орды. К., 1996; К у л ь п и н Э.С. Золотая Орда. Проблемы генезиса Российского государства. М., 1998; М а л о в Н.М., М а л ы ш е в А.Б., Р а к у ш и н А.И. Религии в Золотой Орде. Саратов, 1998; К л я ш т о р н ы й С.Г., С у л т а н о в Т.М. Государства и народы Евразийских степей. Древность и средневековье. СПб., 2000; И з м а й л о в И.Л. Ислам в Золотой Орде // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье. История и современность. К., 2001; К р а м а р о в с к и й М.Г. Золото Чингисидов: культурное наследие Золотой Орды. СПб., 2001; S p u l e r B. Die Goldene Horde. Die Mongolen in Russland. Lpz., 1943; S c h a m i l o g l u U. The Qaraci byes of the later Golden Horde: Notes on the Organization of the Mongol World Empire // Archivum Eurasiae medii aevi. 1984. Vol.4; H a l p e r i n Ch. J. Russia and the Golden Horde. The Mongol Impact on Medieval Russian History. Bloomington, 1985.

*И.Л.Измайлов.*

**«АЛТЫ́Н УРДА́»**, иҗтимагый-сәяси газета. *Татар милли бәйсезлек партиясе «Иттифакъ»* органы. 1993 елның июненнән 1998 нең апреленә кадәр Чаллы шәһәрендә татар һәм рус телләрендә нәшер ителә. Мөхәррире — Р.Б.Хәплехәмитов. Газета Алтын Урда дәүләте оешуның 750 еллыгы уңаеннан чыга башлый. Редакция «Иттифакъ» партиясенең РФ б-н Татарстан хакимиятләре арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә, милли-мәдәни сәясәткә һ.б. мәсьәләләргә карашын чагылдыра. 1998 елның апрелендә ТРның мәхкәмә органнары карары б-н ябыла.

**АЛТЫ́Н УРДА́ КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), Евразиянең дала һәм урман-дала районнарына, Җүчи Олысы терр-ясенә нисбәтле 13–16 йөзләрдәге культура. 13 йөзнең 2 нче яртысында җирле Европа (болгар-мөселман һәм кыпчак) һәм Үзәк Азия (кидань-чжурчен һәм татар-уйгыр) традицияләренең үзара кушылуыннан барлыкка килә. А.У.к. берничә җирле-локаль (Болгар, Харәзем, Кырым) һәм социаль субкультураларга (шәһәр, аристократлар) бүленә. А.У.к. истәлекләрен тикшерү 18 йөзнең 2 нче яртысыннан алып бара. Беренче тапкыр ул мөстәкыйль археол. культура буларак А.В.Терещенко (1850 еллар) һәм Ф.В.Баллод (1920 еллар) хезмәтләрендә тикшерелә. А.У.к. истәлекләре 1920–50 елларда А.Ю.Якубовский, М.Г.Сәфәргалиев, 1960–90 елларда А.П.Смирнов, Г.А.Фёдоров-Давыдов, Ә.Г.Мөхәммәдиев, В.Л.Егоров, И.С.Вайнер, А.Е.Алихова, М.Д.Полубояринова, В.В.Дворниченко, Н.М.Булатов, Т.В.Гусев, Р.Г.Фәхретдинов, А.Ә.Борһанов, В.А.Иванов һ.б. тарафыннан тикшерелә.

А.У.к. утрак тормыш б-н яшәү зоналарында (Идел буе, Кырым, Арал буе, Днестр һәм Днепр буйлары, Төньяк Кавказ тау итәге) урнашкан төрле археологик истәлекләрдән тора. Аларда шәһәрлек, авыллык урыннары, каберлекләр, аерым каберләр һәм алар өстенә төзелгән төрбәләр, төрле әйберләр һәм акча хәзинәләре табыла. Билгеле булган 100 дән артык шәһәрчек арасында Европаның урта гасырлар шәһәрләреннән иң зурлары *Сарай*



**Алтын Урда культурасы.** 1. Алтын Урда гаскәрие. М.В.Горелик реконструкциясе; 2. Ияр түшәлмәсе. Алтын йөгертелгән көмеш. Чүкеп бизәкләү, гравирлау. 13 йөзнең 1 нче яртысы. Дәүләт Эрмитажы; 3. Бил каешы бизәкләрендә алтын очлыклар. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 4. Пайцза. Көмеш, кою, гравирлау. 1361. Дәүләт Тарих музее. Мәскәү; 5. Дару савыты. Яндырылган балчык. Гравирлау, дивар бизәге. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 6. Кубок. Көмеш. Гравирлау, чүкеп бизәкләү, кою, басма бизәк. Төньяк Кавказ. 13-14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 7. Камчы сабы. Сөяк. Кисеп бизәкләү. 13–14 йөз. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы; 8. Беләзек. Алтын.Чүкеп бизәкләү, кою, гравирлау, каралтылган көмеш. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 9. Беләзек. Алтын. Гравирлау. Болгар шәһәре. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 10. Касә. Көмеш. кою, гравирлау, чүкеп бизәкләү. Воронеж өлкәсенең Олен-Колодезь авылы янындагы курган. Дәүләт Эрмитажы; 11. Су кувшины. Яндырылган балчык, калыплау, кисеп бизәкләү. 13–14 йөз. Әстерхан дәүләт берләштерелгән тарих-архитектура музей-саклаулыгы; 12. Чүмеч. Алтын, гравирлау, чүкеп бизәкләү. Себер. 13 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 13. Касә. Ялтыравык йөгертелгән бизәк. Сарай әл-Җәдид шәһәре. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы.

*әл-Җәдид* (Царевский), *Сарай әл-Мәхрусә* (Селитренный), *Бәлҗәмин* (Водянский), *Үкәк, Болгар, Ак кирмән*, Мажар (Прикумский), Сарайчык була. Алтын Урда җирләрендә яшәүчеләр күчмә терлекчелек, игенчелек, балыкчылык, аучылык, һөнәрчелекнең күп төрләре б-н шөгыльләнәләр. Шәһәрләр квартал-утар тибында планлаштырып төзелгән, аларның югары үсеш алган гидротехник корылмалары булган (ясалма сулыклар, дамба, арыклар, керамик торбалардан корылган су үткәрү һәм канализация системалары). Авыллар исә шәһәрләр тирәсенә урнашкан. Авыллар урынында тирмә, землянка, агачтан салынган бер бүлмәле өй, ш.у. күп бүлмәле кирпеч йорт урыннары табыла. Шәһәрләрдә һәм шәһәр тирәләрендә зур-зур утарлар төзелгән (мәйданнары кайвакыт 5 мең $м^2$га кадәр җиткән), алар диварлар б-н әйләндереп алынган, дивар эчендә күп бүлмәле йорт, аерым торак һәм хуҗалык корылмалары, сулыклар (кайчак фонтаннар белән) булган. Күп бүлмәле йортларның штукатурланган стеналары матурлап бизәлгән, алар еш кына сурәт төшкән плитәләр б-н капланган, идәннәргә таш плитә яки кирпеч түшәлгән. Йортлар эчтән махсус мичләр (кан) белән җылытылган, горизонталь төтен үткәрү торбалары өстенә суфа дип аталган җылы ятаклар ясалган. Шәһәрләрдә, торак йортлар һәм хуҗалык корылмаларыннан тыш, ак таштан төзелгән җәмәгать биналары да табыла (мәчет, мунча, кәрвансарай һ.б.). Мәчетләр, гадәттә, туры почмак рәвешендә төзелеп, эчендә колонналар да булган. Кайвакыт алар тирәсендә мәдрәсәләр, суфилар һәм хаҗга баручылар өчен ханәкәләр дә төзелгән (Кырым, Идел буе). Мунчалар шактый катлаулы архитектур формаларда корылган, идән астыннан җылыткыч торбалар узган, су ясалма сулыклардан китерелгән (к. *Ак Пулат*).

Мәҗүсилек йолалары сизелеп торган курганлы каберләр б-н беррәттән (13 йөзнең 2 чиреге — 14 йөз уртасы) яртылаш җиргә һәм өскә урнаштырылган мавзолей-кәшнәле мөселман каберләре дә очрый. Идел-Кама төбәгендә торак һәм гарәп телләрендә гарәп графикасында язылган кабер ташлары да табыла (к. *Эпиграфика ядкәрләре*). Табылдыклар: кызыл балчыктан ясалган, үсемлек, геометрик һәм зооморфик бизәкләр, арабескалар төшерелгән түгәрәк савыт-сабалар (кувшин, касә, тирән тәлинкә, шешә һ.б.); хатын-кыз киемен бизәүче металл эшләнмәләр (к. *Җүкәтау хәзинәсе, Карашәм хәзинәсе*); тормыш-көнкүреш әйберләре (көзге, йозак һ.б.); хәрбиләр өчен бил каешы тагылмалары, корал кынылары, ат дирбиясе элементлары һ.б.; бизәкләр төшерелгән бронза савыт-саба, ш.у. Алтын Урда акчалары (к. *Җучи тәңкәләре*).

А.У.к. 15 йөздән тоташ бер күренеш буларак инкыйраз кичерә. Алтын Урда таралганнан соң барлыкка килгән төрки-татар ханлыкларында (Әстерхан ханлыгы, Олы Урда, Казан ханлыгы, Себер ханлыгы) бу сәнгатьнең җирле вариантлары формалаша башлый.

*Әд.:* Баллод Ф.В. Старый и Новый Сарай — столицы Золотой Орды. К., 1923; Егоров В.Л. Жилища Нового Сарая (по материалам исследований 1959–1965 гг.) // Поволжье в средние века. М., 1970; шул ук. Мавзолеи Водянского городища // Советская археология. 1980. № 1; Булатов М.Н. Классификация красноглиняной поливной керамики золотоордынских городов // Средневековые памятники Поволжья. М., 1976; Носков Л.М. Мозаика и майолики из средневековых городов Поволжья. М., 1976; Мухаммадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Кравченко А.А. Средневековый Белград на Днестре (конец XIII – XIV вв.). Киев, 1986; Мухаметшин Д.Г., Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники города Булгара. К., 1987; Полубояринова М.Д. Украшения из цветных камней Болгара и Золотой Орды. М., 1991; Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994; Недашковский Л.Ф. Золотоордынский город Укек и его округа. М., 2000; Город Болгар. Монументальное строительство, архитектура, благоустройство. М., 2001; Крамаровский М.Г. Золото Чингисидов: культурное наследие Золотой Орды. СПб., 2001.

*И.Л.Измайлов.*

**АЛТЫ́Н УРДА́ СӘНГАТЕ́**, *Алтын Урда* дәүләтенең сәнгате катлаулы этник, мәдәни, социаль мохитта формалаша. Ислам дәүләттә рәсми дин булып игълан ителгәннән соң, гомуммөселман цивилизациясенең мәдәни кысаларында үсеш ала. Күчмә дала һәм утрак шәһәр мәдәниятләренең үрелеп үсүе А.У.с. стиленең синкретик йөзен тәшкил итә: империя сәнгате б-н беррәттән Идел буе, Кырым, Төньяк Кавказ, Урта Азия кыпчаклары, Алтай һәм Себер төрки халыклары традицияләренә хас сәнгать үсеш ала. Шул нигездә А.У.с.нең төбәкләрдәге үзенә генә хас вариантлары барлыкка килә (к. *Болгар сәнгате*). А.У.с. билгеле бер дәрәҗәдә калыплашкан югары зәвыклы үрнәкләр йогынтысында иҗат ителә. Зәркән эшләнмәләр, кием бизәмәләре, торевтика (савытлар, тәлинкәләр, кубоклар), балчыктан ясалган һәм ялтыравык йөгерткән керәч (дивар бизәкләре, савыт-саба), сөяктән уеп эшләнгән көнкүреш әйберләре, бизәлгән сугыш кораллары үзләренең зиннәтлелеге, формаларының нәфислеге, бизәкләрнең байлыгы б-н аерылып тора. Ияр, камыт, ыңгырчак, ат дирбиясе әйберләре бизәлешенә зур игътибар бирелә (көмештән һәм бронзадан эшләнгән каеш тегелмәләре, эленмә, бөҗра, овал, йолдыз рәвешендәге аеллар). Ир-ат һәм хатын-кыз киемнәре бизәмәләре арасында бизәкләп эшләнгән металл аеллар, фигуралы тегелмә тәңкәләр киң кулланыла. Сакланып калган эшләнмәләрнең күпчелек өлеше кыйммәтле ташлар һәм асылташлар кулланып, алтыннан һәм көмештән ясала (күчмә кабиләләр каберлекләрендә, Урта һәм Түбән Идел буе, Кырым, Кавказда, Алтын Урдага кергән башка җирләрдә казу эшләре вакытында табыла). А.У.с. үсешенең башлангыч дәвере (13 йөзнең 2 нче яртысы) аның стиленә Ерак Көнчыгыш һәм Үзәк Азия традицияләре үтеп керүе б-н үзенчәлекле. 13 йөз ахыры – 14 йөз башында А.У.с. үсеше империянең эре калаларында чәчәк аткан *мөселман сәнгате* йогынтысында бара.

Шәһәрләрдә таш һәм кирпеч биналар төзелеше, архит-ра үсеше А.У.с.нең мозаикалы, майоликалы һәм терракоталы дивар тышламалары, орнаментлы гипс (алебастр) һәм *ташны уеп эшләү*, гипс кою, дивар нәкыше кебек ысулларның киң таралуына җирлек бирә (к. *Монументаль бизәлеш сәнгате*). Ислам дәүләтләре — сәлҗүкләр Кече Азиясе, мәмлүкләр Мисыры, һулагыйлар Ираны б-н алып барылган мәдәни һ.б. төр бәйләнешләрнең йогынтысы Болгар, Сөлхат, Кырык Ир (Чуфут Кала), Иске Йорт (Бакчасарай), Үргәнеч һ.б. шәһәрләрдә безнең көннәргә кадәр сакланган архит-ра истәлекләрендә чагылыш таба. Геометрик, эпиграфик һәм үсемлек сурәте төшкән бизәкләр, ачык төсләрнең мул кулланылуы, конструктив-бизәлеш детальләре («мәмлүкләр» кисеме, тромплар, сталактитлар, пәнҗәрәләр һ.б) Алтын Урда шәһәрләрендәге биналарга Якын Көнчыгыш һәм Кече Азия ислам архит-расы рухын бирә. А.У.с.ндә торак һәм җәмәгать биналары диварларын, мичләрне, кабер ташларын бизәкле, ялтыравык йөгертелгән керәч плитә — майолика б-н тышлау аеруча киң тарала. Төрле төстәге орнаментлар б-н бизәлүе, алтын йөгертеп эшләнүе б-н үзенчәлекле. Климат шартлары майоликаны биналарның тышкы ягында кулланырга мөмкинлек бирмәгән урыннарда ул интерьерларны бизәү өчен кулланыла (Болгар шәһәрендәге корылмалар). Алтын Урда шәһәрләрендә төзелеш өчен керәч эшләнмәләр җитештерү җайга салына (Харәзем, Иске һәм Яңа Сарай, Болгар). Керәч остаханәләре хәрабәләре, җитештерү технологиясе, бизәлеш һәм төсләр куллану үзенчәлекләре шул хакта сөйли. Кавказда, Кырымда, Кавказ аръягында, Харәземдә, Түбән һәм Урта Идел буйларында (болгар-татарларда) ялтыравыклы керәч савыт-саба җитештерү үзәкләре үсеш ала. Көнкүрештә кулланылган керәч савыт-саба һулагыйлар Ираны, Әзәрбайҗан, Урта Азия үрнәкләренә охшаш булса, гади керәч эшләнмәләрдә монголларга кадәрге традицияләр дәвам итә. А.У.с.нең төбәктәге үзенчәлеге ташка уеп бизәү сәнгатендә (архит-ра истәлекләре, кабер ташлары) аеруча ачык чагылыш таба. Харәзем һәм Кырым үрнәкләреннән аермалы буларак, болгар-татарларда таш кисү, фон яссылыгына кыйгачлап, яссы рельефлы ую техникасында башкарыла һәм бизәкләүнең үз системасы барлыкка килә. А.У.с.нә Якын Көнчыгыштагыча бизәк төшергәндә канунннарга катгый буйсыну хас түгел, аңа мотивларның иркелле үсеше, кәкре сызыклы формаларның өстенлек итүе, яссы рельефка салмак күчүче вак һәм эре бизәкләрнең контрастлылыгы характерлы. Орнаментта абстракт геометрик бизәкләр юк диярлек, ләкин үсемлек һәм чәчәкләрнең табигый формаларына охшаш лотос, пальма яфрагы, өчьяфрак, «бәхет төене», лалә, чәчәк таҗы, тау миләүшәсе, үрмәгөл, йөзем тәлгәше, бормалы бизәк мотивлары еш очрый; үсемлек сурәте рәвешендәге бизәк б-н үрелеп баручы гарәп язуы актив кулланыла. А.У.с. стиле сурәтләү нормаларын хаттатчылык һәм бизәк төшерү кануннары б-н тәңгәлләштергән мөселман хәлифәлеге сәнгате таләпләре кысаларында формалаша. Сурәтләү чараларында шартлы декоративлык принцибы өстенлек итә. Дала күчмәләрендә, бигрәк тә аларның көнкүреш сәнгате үрнәкләрендә образларны исламга ка-































**Алтын Урда сәнгате.** 1. Кара пулат. Болгар ш. 14 йөз; 2. Туктамыш хан кызы төрбәсе. 14–15 йөзләр. Кырык Ир шәһәре. (Кырым); 3. Кече манарадагы бизәкләнгән уем фрагменты. Болгар шәһәре. Ташны кисеп бизәкләү. 14 йөзнең 2 нче яртысы; 4. Фарсы язулы архитектур чынаяк кирпеч. Майолика. 15 йөзнең 1 нче яртысы. Дәүләт Эрмитажы; 5. Каен тузына уйгыр язуы б-н ике телдә (монгол һәм төрки) язылган хат фрагменты. 14 йөз башы. Саратов өлкәсенең Терновка авылы янында табылган. Дәүләт Эрмитажы; 6. Кара савыты. Кашин, ялтыравык йөгертелгән бизәк. Сарай әл-Җәдид шәһәре. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 7. Майоликалы тышлык фрагменты. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы; 8. Йозаклар. Бронза. Кою, гравирлау. Сарай әл-Җәдид шәһәре. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 9. Коръән тартмасы. Алтын йөгертелгән көмеш. Чүкеп бизәкләү, каралтылган көмеш. 14 йөзнең 2 нче яртысы. Дәүләт Эрмитажы; 10. Комган һәм кувшин. Бакыр. Гравирлау, кою. 14 йөз ахыры – 15 йөз башы. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы; 11. Көзге. Арткы як. Бронза. Кою, гравирлау. 13 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 12. «Өчаяклы» тамга сугылган Җучи акчасы. Көмеш. 13 йөз. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы; 13. Болгар акчасы. Көмеш. 13 йөз. Болгар тарих-архитектура музей- саклаулыгы; 14. Вак сыннар үрнәге. Яндырылган балчык, төсле ялтыравык. Сарай әл-Җәдид шәһәре. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы.

дәрге чор традицияләрендә чагылдыру дәвам итсә дә, 14–15 йөзләрдә металл, *керәч сәнгатендә*, сөяктән ясалган эшләнмәләрдә җәнлек мотивлары тулысынча диярлек юкка чыга, аларны чәчәк-үсемлек рәвешендәге, геометрик (ш.и. гарәпчә бизәү) һәм эпиграфик орнамент алыштыра (кабер ташлары, бронза йозаклар һәм көзгеләр, архит-ра майоликасы, көнкүрештә кулланылган керәч әйберләр, кечкенә *Коръән тартмачыклары*, *йөзекләр*, ш.и. аларның асылташларны уеп ясалганнары, беләзекләр һ.б.).

Урта гасырларда А.У.с.нең югары зәвыклы үрнәкләре тирә-күрше дәүләтләрдәге осталар иҗатына сизелерлек йогынты ясый. Бу бигрәк тә *металлны нәфис эшкәртү* сәнгате һәм зәркәнчелеккә (к. *Зәркән сәнгате*) карый. Аерым алганда, Алтын Урдада башкарылган *җепкыр* технологиясе һәм бизәкләре, эшләнмәләрнең асылташлар б-н бизәлешендәге полихром стиль рус һәм Көнбатыш Европа хакимнәренең сарайлары каршындагы остаханәләрдә ясалган әйберләрдә чагылыш таба. Татар осталарының эшләнмәләре еш кына рус патшалары сарайларында очрый (к. «*Мономах бүреге*»). А.У.с.нең стиль үзенчәлекләре, аның традицияләре Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыклары сәнгатендә эзлекле рәвештә дәвам итә.

А.У.с. әсәрләре күренекле музейларда — Эрмитаж (С.-Петербург), Дәүләт тарих музеенда һәм Корал палатасында (Мәскәү), Казан һәм РФнең кайбер шәһәрләрендә, ш.у. БДБ һ.б. илләрдәге (Украина, Үзбәкстан, Казакъстан, Венгрия һ.б.) музейларда саклана.

*Әд.:* А м и н   а л ь - Х о л и. Связи между Нилом и Волгой в XIII–XIV вв. М., 1962; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Кочевники Восточной Европы под властью золотоордынских ханов. М., 1966; ш у л   у к. Искусство кочевников и Золотой Орды. М., 1976; В а л е е в Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Р е м п е л ь Л.И. Изобразительный канон и стилистика формы на Среднем Востоке // Искусство Среднего Востока. М., 1978; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Национальная традиция в декоративном искусстве // Татары. М., 2001; G o r e l i k V. Mikhail and Mark G. Kramarovskii. The Mongol-Tatar states of the Thirteenth and Fourteenth Centuries // Nomads of Eurasia. Los.Ang., 1989.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АЛТЫ́Н УРДАДА́ ТӘХЕ́Т ЧУАЛЫШЛАРЫ́** (рус елъязмалары кулланышында «Великая замятня» — «Олуг болганыш»), 1360–80 елларда Алтын Урдада тәхет варисларының тәхет өчен үзара көрәшүе. Яңадан-яңа җирләр яулау, яуланган илләрдән салым җыю, эчке һәм тышкы сәүдәнең нигуы, тарханлык хокукыннан файдалану җирле феодалларның икътисади һәм сәяси яктан ныгуына китерә. Урындагы феодаллар көчәйгәч һәм үзара берләшә башлагач, үзәк хакимиятнең аларга йогынтысы йомшара. Үзәк хакимияттән бәйсез, мөстәкыйль булырга омтылган аерым шәһәрләр, өлкәләр барлыкка килә. Алар үз олысларының бай кереме исәбенә (аның күләме елына 600 меңнән алып 1200 мең дирһәмгә кадәр җиткән) зур алай-гаскәр тота алганнар (5 мең кешелек гаскәр тотучылар була). Бирдебәк хан идарә иткәндә (1357–59) тышкы сәясәт бәйләнешләре йомшый, урыннарда мөстәкыйльлеккә омтылыш, үзәк хакимияттән ераклашырга тырышу көчәя. Бер үк вакытта төрле феодаль төркемнәр арасында икътисади һәм сәяси өстенлеккә ирешү, җәен-кышын көтү йөртергә уңайлы булган җир-биләмәләргә ия булу өчен үзара көрәш-бәрелешләр ешая. Күтәрелеш елларында халык саны арту нәтиҗәсендә көтүлекләр җитми башлый. Бирдебәк ханның тәхеткә утырырдай якыннарының үтерелеп бетерелүе сәбәпле, аңардан соң Бату ханнан килгән идарәчеләр нәселе өзелә. Алтын Урда тәхете Җучинең икенче улы Урда Эҗен варислары кулына күчә. Элек-электән хан сараена якын торган кайбер аксөякләр арасында бу хәл ризасызлык тудыра. Шул рәвешле бер-берсе б-н көрәшүче ике төркем барлыкка килә. Сарай әл-Җәдидтә яңарак тәхет биләүче Урда Эҗен варислары даирәсенә Иделдән сул тарафта җир тотучы аксөякләр керә. Иделдән уң тарафтагы биләмәләрдә — Азак (Азов) диңгезе буе, Кырым төбәкләрендә Мамай әмир төркеме өстенлек итә. Мамай әмир чыңгызыйлар нәселеннән булмаса да, А.У.т.ч. вакыйгаларында актив катнаша — үз йогынтысындагы чыңгызыйларга тәхет яулаша. Ике төркемнең тарткалашуы нәтиҗәсендә илдә тотрыклылык бетә, Алтын Урда тәхетендә 20 ләп хан алмашына. Бер үк вакытта идарәче ыруглар (Аргын, Барын, Кыпчак, Ширин һ.б.) арасында да өстенлек өчен көрәш бара; аерым өлкәләр мөстәкыйль олыс дәрәҗәсен дәгъвалый. 1360 елларда Алтын Урдадан Харәзем (идарәче Суфилар династиясе), *Мухша Олысы* (Тагайлар), Хаҗитархан (Хаҗичиркәсләр), Сарайчык (идарәчеләре Илбан, Алып Хуҗа), *Болгар бәклеге* (идарәчесе Булат Тимер) һ.б. биләмәләр аерылалар. 1360 еллар ахыры – 1370 еллар башында Мамай әмир дә берничә олыс-өлкә тәхетенә үз кешеләрен утырта. Ләкин аның хакимияте тотрыклы булмый. Тотрыклылыкка ирешү өчен Мамай әмир 1380 дә Алтын Урда буйсынуында булган рус кенәзлекләренә яу б-н бара. Ләкин ул *Куликово кыры сугышыннан* соң Алтын Урданың көнбатыш олыс-өлкәләре өстеннән булган хакимлеген дә югалта. Элек аңа йөз тоткан Ак Урда хан-әмирләре *Туктамыш ханга* буйсыналар. Туктамыш Аксак Тимер б-н Идегәй ярдәмендә башта Күк Урда тәхетен, аннары, Ак Урданы да кертеп, Алтын Урда тәхетен яулап алуга ирешә. Шул рәвешле Туктамыш хан Алтын Урданың ике канатын кабат берләштерә, А.У.т.ч.на чик куя. Әмма дәүләт күләмендә барган көрәш, сугыш-бәрелешләр илнең көч-куәтен нык киметә, икътисади бөлгенлеккә төшерә. Сәүдә элемтәләре өзелә. Алтын Урданы читләтеп узган яңа сәүдә юллары, сәүдә үзәкләре барлыкка килә. Егерме ел дәвамында барган тәхет чуалышлары тәхеткә Туктамыш хан утыргач бастырыла, ләкин ул Алтын Урданың таркала башлавына китерә.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*Ә.Г.Мөхәммәдиев.*

**«АЛТЫ́Н УТРА́У»**, кварцлы ком чыганагы. Идел үзәненең уңъяк яр буендагы өлешендә, Яшел Үзән шәһәреннән 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 1991–92 елларда билгеләнә. Өске өлеше — хәзерге заман аллювиаль елга юлы-терраса утырмалары, түбәнге өлеше неоген комнары б-н түшәлгән. Су астында 1,5 тән алып 8 *м* га кадәр тирәнлектә урнашкан. Чыганакның өске өлеше формалар ясау чималы сыйфатында файдалану өчен яраклы вак һәм уртача бөртекле кварцлы комнардан гыйбарәт (катлам калынлыгы 12–15 *м*). Бу комнар балчык һәм комсыл балчык линзалары булган, вак таш-чуерташлы катлам б-н түшәлгән (калынлыгы 0,3–2 *м*). Чыганакның аскы өлешен пыяла сәнәгатендә куллана торган кварцлы комнар хасил итә (калынлыгы 9 *м* дан артык). Чыганакның көньяк өлешендә силикат әйберләр җитештерү өчен яраклы балчыклы кварцлы комнар табылган (калынлыгы 1,5–8 *м*). Комнар табигый халәтендә яшел шешә һәм тәрәзә пыяласы, изоляторлар, торбалар, баетылганнан соң — зур кисәкле силикатлар, электрон сәнәгате өчен пыяла җепселләр ясау өчен файдаланыла. $C_1$ категориясе буенча кварцлы ком запаслары 5,69 млн. *т* тәшкил итә (2006). 2006 елның 1 гыйнварына 600 мең *т* чамасы табыла. Комнар «КАМАЗ» АҖдә формалар ясау өчен һәм кирпеч сәнәгатендә чимал буларак кулланыла.

**АЛТЫ́Н ХАНЫ́М**, татар ханлыклары идарәчеләренең хатыннарын олылау гыйбарәсе; ханның баш хатынының шәрәфле титулы. 17–18 йөзләр татар тарихи язмаларында еш кулланылган төшенчә (мәс., Кадыйргалибәк хезмәтләрендә).

**АЛТЫ́Н ЧӘЧӘ́К**, х р и з а н т е м а (Chrysanthemum), оешма чәчәклеләр семьялыгындагы берьеллык, күпьеллык үләнчел яисә ярымкуакчыл үсемлек. 150 төрне үз эченә алган үсемлек ыругы; башлыча, Европа, Азия, Африкада; БДБ илләрендә 70–80 төре үсә. А.ч.нең яфраклары тоташ яисә кискәләнгән читле, куе яшел төстә. Чәчәкләре гади һәм чуклы, төрле формалары (эре чәчәкле, вак чәчәкле) һәм төсләре (ак, алсу, сары, алтынсу-кызгылт, кызыл һ.б.) б-н аерылалар. Җимеше — орлык. Эре чәчәкле сортлары бер ботаклы, сирәгрәк 3–4 сабаклы куак төрендә, вак чәчәклеләре куак формасында була. Асылмалы, энәле, батынкы, көпшәсыман сортлары бик киң таралган. Ш.у. чәчәкләре түбәнгә таба каскадсыман урнашкан А.ч. үстерелә. ТРда берьеллык А.ч.нең кылсыман, таҗлы, чәчеп үстерелә торган төрләре билгеле. Ачык грунтта үрчетелә, орлыклары көздән, яз көне яисә үренте түтәленә чәчелә. Чәчәк түтәлләренә, клумба һәм чүлмәкләргә күчереп утыртыла һәм киселгән килеш чәчәк бәйләмнәре ясау өчен файдаланыла. Грунтта үсә торган күпьеллык А.ч.нең эре, ачык кызыл, кискәләнгән читле яфраклы төрләре киң таралган, аларны куакларны аеру һәм чыбыкчалар ярдәмендә үрчетәләр (орлыктан үрчетү ысулы селекция максатларында кулланыла). 10 меңләгән сорты чыгарылган. Августтан декабрьгә кадәр чәчәк ата, чәчәк ату вакыты

буенча иртә (авг. — окт. уртасы), уртача (окт. ахыры — нояб.), соңгы (дек.) чәчәкләргә аерыла. ТРда А.ч. теплица хуҗалыкларында («Майский», «Весенний», «Декоратив культуралар») һәм бакчаларда декоратив үсемлек буларак үстерелә.

*Әд.:* К и с е л ё в Г.Е. Цветоводство. М., 1964; Энциклопедия цветовода. СПб., 2000.

**АЛТЫНБА́ЕВ** Равил Ибраһим улы (31.8.1925, Рязань өлкәсенең Касыйм р-ны), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1967), проф. (1989). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952 елда Мәскәү совет сәүдәсе ин-тын тәмамлый. 1958–63 тә Сәмәрканд өлкәсе кулланучылар берлеге рәисенең 1 нче урынбасары. 1963 тән Сәмәрканд кооперация ин-тында укыта, 1972–82 дә сәүдә икътисады каф. мөдире. Бер үк вакытта 1987–98 дә фәнни-тикшеренү лаб. мөдире, 1998 дән шул ук ин-тның инновация үзәге профессоры. Хезмәтләре кулланучылар кооперациясе системасында әзерләү һәм сәүдә итү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләренә карый. 1 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АЛТЫНБА́ЕВ** Рәфгат Зәки улы (21.9.1948, Лениногорск р-ны Сарабиккол а.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре, социол. фән. д-ры (1998), РФ Федераль Җыены Федерация Советының төбәк сәясәте ком-ты рәисе (2006 дан), бер үк вакытта «Гадел Россия» сәяси партиясенең политбюро әгъзасы (2006 дан). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1971). 1971 елдан Чаллы шәһәрендә: 1974 кә кадәр «Камгэсэнергострой» җитештерү берләшмәсендә инженер, 1974–75 тә төзелеш идарәсенең ВЛКСМ ком-ты секретаре, 1975–76 да КПССның шәһәр ком-ты инструкторы, 1976–83 тә КПССның Автозавод район ком-тында оештыру бүлеге мөдире, 1983–85 тә секретаре, 1985–87 дә Халык депутатларының Автозавод р-н советы башкарма ком-ты рәисе, 1987–90 да КПССның шәһәр ком-ты секретаре, 1990–91 дә Халык депутатларының шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе, 1991–99 да шәһәр администрациясе башлыгы, бер үк вакытта Халык депутатларының шәһәр советы рәисе. 1999 дан Мәскәүдә яши. 1999–2001 дә РФ авыл-хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, 2001–03 тә РФ Федераль Җыенының Федерация Советында ТР, 2005–2006 да Рязань өлкәсе вәкиле. 2003–05 тә РФ Федераль Җыенының Федерация Советы рәисе киңәшчесе, бер үк вакытта 2002–06 да «Россия Тормыш партиясе» рәисе урынбасары. 1995–99 да ТР халык депутаты. Хезмәтләре Чаллы шәһәре социаль инфраструктурасына багышлана.

Х е з м.: Основные факторы развития социального потенциала молодого города в условиях становления рыночных отношений. СПб.–Наб. Челны, 1997; Социально-экономические условия развития социального потенциала молодого города в условиях перехода к рынку. Наб. Челны, 1996; Местное самоуправление и развитие социального потенциала молодого города. Наб. Челны, 1996.

**АЛТЫНБӘ́К**, риваятьләрдә телгә алынган болгар бәге. 17–18 йөзләргә караган татар тарихи әдәбиятында Болгар шәһәре идарәчесе Габдулланың балигъ булмаган улы рәвешендә сурәтләнә. Аксак Тимер гаскәре шәһәрне яулап алгач, имеш, яу барышында һәлак булган Габдулланың А. б-н *Галимбәк* исемле улларын әмир ирекқә җибәрә. А., үсә төшкәч, Казансу тамагында бер шәһәр салдыра. Бу риваятьтә һәм Аксак Тимернең Болгар, Биләр, Балымер шәһәрләрен яулап йөрүе хикәятендә дөреслектә бер-берсеннән ерак торган ике тарихи вакыйга: Алтын Урданың Аксак Тимер тарафыннан 1395 елда яулап алынуы, Казан шәһәре б-н Казан ханлыгының нигезләнү вакыйгалары чагыла.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972. *И.Л.Измайлов.*

**АЛТЫНКҮЗЛӘ́Р** (Chrysopidae), челтәрканатлылар отрядыннан бер семьялык. 25–35 *мм* озынлыктагы, нәфис гәүдәле, чагыштырмача кечкенә бөҗәкләр, бик күп буй һәм аркылы җепселләре булган 2 пар үтә күренмәле канатлары бар. Мыеклары озын, күп буынтыклы, авыз әгъзалары кимерә торган типта. Зурлары еш кына яшькелт төстә, күзләре чыгынкы, ялтыравыклы, алтынсыман (исеме шуннан алынган). Хәрәкәтсез вакытта канатлары түбә рәвешен ала. Акрын очалар. Ана бөҗәк йомыркаларын яфракка ябышкан озын кылсыман сабакка сала. Личинкаларының гәүдәсе йомшак, төерләр һәм озын төк б-н капланган. Авызы корбаннары тәненнән сок суыру өчен үзгәрә. Актив ерткычлар, үсемлекләр буенча иркен үрмәлиләр, үлән бетләре, бәбәк төргечләр, яфрак төргечләр, бөҗәкләрнең яшь кортлары һәм йомыркалары б-н туеналар. Кайбер төрләре үзләренең үсеш дәверендә 300–400 үлән бетен юк итәргә мөмкин. Үсешне төгәлләп, личинка яфрак астында озынча, төк б-н капланган кузы үрә һәм курчакка әверелә. 800 дән артык төре билгеле. Татарстан терр-ясендә, үлән бетләре санын табигый җайга салучы буларак, зур әһәмияткә ия булган гади алтынкүз төре (Chrysopa carnea) очрый. Бу төр башка энтомофаглар б-н берәттән Республика үсемлекләрне саклау станциясе биофабрикасында үрчетелә һәм басуларга чыгарыла. Табигатьне файдалы бөҗәкләр б-н баетуның мондый ысулы үсемлекләрне корткычлардан саклауның биологик ысулы булып тора. Матур алтынкүз (C. perla) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1966; Р о с с Г., Р о с с Ч., Р о с с Д. Энтомология. М., 1985. *С.М.Шәфигуллина.*

**АЛТЫ́НОВ** Николай Николаевич (10.2.1924, Арча кантоны Осок-Ковали а. — 1997, Казан), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), старшина (1944). 1942 елның августыннан Кызыл Армиядә, 1943 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, танк йөртүче (2 нче гв. танк армиясенең 1 нче механикалаштырылган корпусы 219 нчы танк бригадасы). Үзәк, 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Белоруссияне, Польшаны азат итү сугышларында, Берлин операциясендә катнаша. 1945 нең 21 гыйнварында Кройц (хәзерге Кшиз, Польша) шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. 1947 дән запаста. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Н.Н.Алтынов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963.

**АЛТЫНЧӘ́Ч**, татар мифологиясендә тау кушында яшәүче рух; башка дөнья вәкиле; яшерелгән байлыкларны саклаучы. А. образы матриархат чорында ук туган дип фаразлана. Урта гасырлар (болгар) чоры риваятьләрендә, ихтимал, тарихи вакыйгалар йогынтысында (болгар халкының дәүләт бәйсезлеген һәм бөтенлеген саклау көрәше барышында) А. образы сугышчы хатын-кыз рәвешенә кергән. Халык әкиятләрендә алтын чәчле (кайвакыт А. исемен йөрткән) кыз гаҗәеп белемнәргә һәм сәләтләргә ия зат итеп сурәтләнә; гомумиләштерелгән игелекле кыз образы. А. персонажы Идел-Урал төбәгендә аеруча киң таралган.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1978. 2 кит.; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987. *Л.Ш.Җамалетдинов.*

**«АЛТЫНЧӘ́Ч»**, Н.Җиһановның героик-эпик операсы, М.Җәлил либреттосы. Татар музыкаль театр сәнгатен яңа тарихи баскычка күтәргән әсәрләрнең берсе. Опера 4 пәрдәдән һәм кереш бүлеге б-н бергә 6 күренештән тора. Премьера 1941 елның 12 июлендә Татар опера һәм балет театрында уза (дирижёры — Җ.Садриҗиһанов, режиссёры — Л.Баратов, баш рольләрдә: Алтынчәч — Г.Кайбицкая, Җик — Ф.Насретдинов, Тугзак — М.Рахманкулова). Аннан соңгы куелышлары шул ук театр сәхнәсендә: 1944, 1956 да (1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында күрсәтелә); 1979, 1993 тә (1994 тә Ф.Мансуровның сәхнә өчен эшләнгән концерт варианты). СССРның күп театрларында күр-



«Алтынчәч» операсының беренче куелышы (1941). Алтынчәч — Г.Кайбицкая, Җик — Н.Даутов.

сәтелә. «А.» сюжеты «*Жик Мәргән*» героик-эпик мотивларына корылган, М.Җәлил «Алтынчәч», «Алтын каурый» әкиятләрен, легендаларны, татар халкының риваятьләрен ирекле рәвештә кулланган. Анда борынгы бабаларыбызның коллыкка төшүе, башка халыклар б-н көрәше сурәтләнә. «А.»нең героик-эпик рухы кабилә башлыгы Тугзак образында аеруча көчле чагыла. Гүзәл Алтынчәч һәм батыр Жик Мәргән романтик образлары халыкның батырлык идеалын, көчлелеген һәм матурлыгын чагылдыралар. «А.»тә авторларның сәнгати-идея омтылышлары сәхнә формаларының матурлыгы б-н кушылып бара. Опера муз. яктан



«Алтынчәч» операсыннан күренеш: Алтынчәч — ТР һәм РФнең халык артисткасы В.Ганиева, Тугзак — ТРның халык артисткасы Г.Ластовка, Жик — ТРның атказ. артисты Р.Дәминов (1990 еллар).

милли колоритның ачыклыгы һәм оркестрлаштыруның бай аһәңе б-н аерылып тора. Истә кала торган арияләр, табигать күренешләре, балет номерлары һәм программалы инструменталь эпизодлар операның партитурасында ачык чагылыш таба. Н.Җиһанов «А.» операсы өчен 1948 дә СССР Дәүләт бүләгенә лаек була.

*Әд.:* Җ ә л и л М. «Алтынчәч» һәм «Илдар» опералары. Иҗат дуслыгы. Әсәрләр: 4 томда. К., 1976; Г и р ш м а н Я. Назиб Жиганов. М., 1975; С а л и т о в а Ф. Начало пути (1939–1950) // Татарский академический театр оперы и балета им. М.Джалиля. К., 1994; М и н у л л и н а Л. Литературное творчество Назиба Жиганова. М., 1996.

**АЛУ́Ф** Исаак Самуилович (30.11.1883, Витебск губ. Полоцк ш. — 20.7.1935, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (1928), проф. (1930). 1904 елда Казан ун-тына укырга керә. Студент елларында «Волжский листок» г-тасы редакциясе б-н хезмәттәшлек итә, революцион көрәш үзәгендә була. 1905 тә кулга алына, 1906 да ун-ттан чыгарыла һәм, 6 айлык тоткынлыктан соң, Архангельск губернасына сөргенгә хөкем ителә, аннары Россиядән куыла. 2 ел РСДРПның чит илдәге Үзәк бюросы әгъзасы. 1913 тә Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. 1914 тә хәрби хезмәткә чакырыла. 1917 гә кадәр полк табибе һәм Кызыл Хач Екатерина җәмгыятенең 2 нче лазаретында (Петроград ш.) нерв. авырулары бүлеге мөдире. Фронттан Казанга 93 нче госпиталь ординаторы итеп күчерелә, бер үк вакытта Казан ун-тының мед. ф-тында нерв авырулары клиникасы экстерны (1919). 1919–30 да Казан ун-тында, 1927 дән нерв авырулары каф. мөдире. 1931 дән Казан мед. ин-ты ректоры һәм Татарстан экспериментальь мед. ин-тын оештыручыларның берсе. 1926 да А. Германиягә командировкага җибәрелә, 2 елга якын Берлин ун-тының неврология ин-тында һәм Берлин баш мие ин-тында эшли. Хезмәтләре неврозлар, баш мие кәүсәсе кан тамырлары авыруларына, афазия, рефлексологиягә карый. Нерв авыруларын дәвалауның физиологик ысулларын эшли. Аның бензин б-н агуланган очракта үзәк нерв системасы үзгәрешен экспериментальь тикшерүләре хәзер дә гамәли һәм теоретик әһәмияткә ия. А. баш мие кабыгын гистогенетик классификацияләү һәм гистогенез мәсьәләсен өйрәнүгә зур өлеш кертә.

Х е з м.: Сравнительная архитектоника головного мозга млекопитающих. К., 1926.

*Әд.:* К у х н и н а Т.М. Профессор И.С.Алуф // Казан. мед. журн. 1984. № 4.

**АЛУШИ́** Ризван (Ибраһимов Ризван) (1883, Саратов губ. Биги а. — 1938, Уфа ш.), журналист, педагог. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала (1896–1902). Казан губернасы Ташбияче авылында, Ачинск (1905–07), Чита (1907–12), Хабаровск (1912–14), Чиләбе (1915–17) шәһәрләрендәге мәдрәсәләрдә укыта. Укытуда яңа ысуллардан файдалана: Ачинск мәдрәсәсендә кызлар б-н малайларны бергә укыта башлый. 1906 елдан «Фикер», «Казан мөхбире», «Сибирия», «Вакыт» г-таларында, «Шура» ж-лында Себер татарлары, мөселман уку йортларының торышы, укытучыларның тормыш шартлары турында мәкаләләре басыла. «Әлислах» г-тасының үз хәбәрчесе була. 1920 дә Эстәрлетамак шәһәрендә «*Мәгариф эшләре*» ж-лын чыгаруны оештыра. 1922–24 тә «*Башкортстан кооператоры*» ж-лы мөхәррире. 1920 елларда «Яңа авыл» г-тасында, «Белем» ж-лында эшчеләр мәктәпләре, укытуның төрле ысуллары турында мәкаләләрен бастыра. 1932–34 тә Свердловск пед. техникумы каршындагы рабфакта эшли. Гомеренең соңгы елларында Уфа театр техникумында татар теле укыта.

*Әд.:* Б и к к у л о в И. Кечкенә генә юбилей // Сибирия. 1913. 10 март; К у д а ш А. Фатих Әмирхан хатлары турында бер-ике сүз // Казан утлары. 1960. № 3; Б а й ч у р а Ш. Татар яшьләре хәрәкәте һәм Фатих Әмирхан (Истәлекләр буенча) // Казан утлары. 1961. № 1.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**АЛФАВИ́Т** (грек. alpha̋bētos, грек А.ының беренче — альфа һәм бета хәрефләреннән), язу системасында хәрефләрнең, иҗек билгеләренең һ.б. графемаларның билгеле бер эзлеклелектә урнашкан җыелмасы. А.ка тезү тәртибе көнбатыш семит халыкларында (Төньяк Сүрия) б.э.к. 3 меңьеллык урталарында барлыкка килә. Борынгы китап күчерүчеләр А.ны шумер телендә язу өчен кулланылган чөй язуыннан алынган иҗек билгеләрен классификацияләү нигезендә төзегәннәр. Чөй һәм мисыр язуы куллану тәҗрибәсе сузыклар б-н чиратлашкан тартыкларны белдерүче билгеләре (хәрефләр) булган беренче төр консонант-иҗек язуы барлыкка килүгә этәргеч бирә. Хәзерге хәрефле яисә иҗекле А.ларның күпчелеге, арамей (яһүд, гарәп), грек

Кириллица нигезендә татар алфавиты *Табл. 1.*

| Хәрефнең язылышы | Хәрефнең әйтелеше | Хәрефнең язылышы | Хәрефнең әйтелеше |
|---|---|---|---|
| А а | а | С с | эс |
| Ә ә | ә | Т т | тэ |
| Б б | бэ | У у | у |
| В в | вэ | Ү ү | ү |
| Г г | гэ | Ф ф | эф |
| Д д | дэ | Х х | ха |
| Е е, Ё ё | е, йо | Һ һ | һе |
| Ж ж | жэ | Ц ц | цэ |
| Җ җ | җэ | Ч ч | чэ |
| З з | зэ | Ш ш | ша |
| И и | и | Щ щ | ща |
| Й й | йкыска | Ъ ъ | катылык һәм аеру билгесе |
| К к | ка | | |
| Л л | эль | | |
| М м | эм | Ы ы | ы |
| Н н | эн | Ь ь | нечкәлек һәм аеру билгесе |
| Ң ң | эң | | |
| О о | о | | |
| Ө ө | ө | Э э | э |
| П п | пэ | Ю ю | ю |
| Р р | эр | Я я | я |

(латин, әрмән, славян-кириллица) А.лары аркылы Финикия А.нан барлыкка килгән. Хәзерге татарларның борынгы бабалары гарәп А.ын кабул иткәнче рун язуыннан файдаланганнар (к. *Борынгы төрки рун язуы*). Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгәч (10 йөз башы), гарәп А. гамәлгә керә (к. *Гарәп язуы*). Алтын Урданың рәсми документларында *уйгыр язуы* үрнәкләре сакланып калган, ләкин ул татарлар арасында артык киң таралмый. Язу культурасы гарәп А. нигезендә үсеш ала. ТАССР ХКС карары б-н 1927 елның 3 июлендә гарәп графикасыннан латин язуына күчү тормышка ашырыла (к. *Яңалиф*). 1939 да латин язуы кириллица б-н алыштырыла, татар теленең үзенчәлекле авазларын белдерү өчен өстәмә ә, ө, ү, җ, ң, һ хәрефләре кертелә, алар А.ның ахырында урнаштырыла. 1997 елның 20 гыйнварында ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты тәкъдиме б-н ТР Дәүләт Советы «Татар алфавитын тәртипкә китерү турында» Закон кабул итә, аның нигезендә А. тагы хәрефләрнең урнашуына үзгәреш кертелә (табл. 1). 1999 ның 15 сентябрендә ТР Дәүләт Советы тарафыннан «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Закон кабул ителә (табл. 2). Ләкин 2002 дә РФнең «Телләр турындагы Закон»ына РФ халыклары өчен кириллицага гына нигезләнгән алфавит куллануны расласган өстәмә кертелә.

*Әд.:* К у р б а т о в Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Графика һәм орфография // Татар грамматикасы. К., 1998. Т. 1; С т р у в е В. Происхождение алфавита. П., 1923; И с т р и н В.А. Возникновение и развитие

*Табл. 2.* Латин графикасы нигезендә татар алфавиты

| Хәрефләрнең язылышы | | Хәрефнең аталышы | | Мисаллар |
|---|---|---|---|---|
| | | латинча | кириллица белән | |
| A a | *A a* | a | ә | alma |
| Ə ə | *Ə ə* | ə | ә | ənkəy |
| B b | *B b* | be | бэ | belem |
| C c | *C c* | ce | җэ | cilək |
| Ç ç | *Ç ç* | çe | чэ | çəçək |
| D d | *D d* | de | дэ | dulqın |
| E e | *E e* | e | е | eşçe |
| F f | *F f* | ef | эф | fiker |
| G g | *G g* | ge | гэ | gəmbə |
| Ğ ğ | *Ğ ğ* | ği | гь | ğailə |
| H h | *H h* | he | һэ | həykəl |
| I ı | *I ı* | ı | ы | ılıs |
| İ i | *İ i* | i | и | imən |
| J j | *J j* | je | жэ | jurnal |
| K k | *K k* | ke | ка | kəlam |
| Q q | *Q q* | qı | къ | qabaq |
| L l | *L l* | el | эл | laçın |
| M m | *M m* | em | эм | manara |
| N n | *N n* | en | эн | narat |
| Ñ ñ | *Ñ ñ* | eñ | эң | ciñü |
| O o | *O o* | o | о | oçqın |
| Ɵ ɵ | *Ɵ ɵ* | ɵ | ө | ɵlkə |
| P p | *P p* | pe | пэ | peşerü |
| R r | *R r* | er | эр | rəxmət |
| S s | *S s* | es | эс | suğan |
| Ş ş | *Ş ş* | şa | ша | şalqan |
| T t | *T t* | te | тэ | tawış |
| U u | *U u* | u | у | uquçı |
| Ü ü | *Ü ü* | ü | ү | üzək |
| V v | *V v* | ve | вэ | vokzal |
| W w | *W w* | we | в(у) | watan |
| X x | *X x* | xa | ха | xoquq |
| Y y | *Y y* | y | й | yeget |
| Z z | *Z z* | ze | зэ | zəñgər |

письма. М., 1965; Г а м к р е л и д з е Т.В. Происхождение и типология алфавитной системы письма // Вопросы языкознания. 1988. № 5–6.

*В.Х.Хаков.*

**АЛФЁРОВ** Николай Фёдорович (1780–1840 еллар тирәсендә), архитектор, рәсем ясаучы, гравёр. С.-Петербургтагы Казан соборы төзелешендә арх. А.Н.Воронихинның ярдәмчесе. 1805–10 елларда Төркия, Греция, Италия буйлап сәяхәт итә, борынгы архит-ра истәлекләренең рәсемнәрен һәм сызымнарын ясый. 1813 тә имп. Александр I боерыгы б-н Казанны алганда һәлак булган рус гаскәриләренә һәйкәл-төрбә проектын эшли. 1838 дән Сынлы сәнгать академиясенең шәрәфле ирекле әгъзасы.

Х е з м.: Способ гравирования крепкой водкой с прибавлением способа гравировать карандашом. СПб., 1805; Письма русского путешественника // Вестн. Европы. 1808. Ч. 38, 39; 1810. Ч. 50; Письма русского путешественника // Русский вестн. 1808. Ч. 2, № 4; Ч. 4. № 10.

*Әд.:* Художники народов СССР. Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1.

**АЛФЁРОВКА** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Лениногорск–Азнакай автомобиль юлы буенда. 2002 елда 72 кеше (руслар, татарлар) яши. 19 йөзнең 1 нче чирегендә коллегия асессоры Андрей Алфёров тарафыннан нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Андреевка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиеннәре катлавына керә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, А.да су тегермәне була. Авыл җәмәгатенең имана җире 48 дис. тәшкил итә. 1931 дә авылда «Октябрьнең 14 еллыгы» (1950 дән Сталин исем.) к-зы оештырыла. 1957 дә ул «Сокольский», 1964 тән Актүбә, 1974 тән «Никитинский» (1997 дән «Азнакайнефть» НГДУының ярдәмче хуҗалыгы) с-злары составында. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1856 да — 111, 1889 да — 114, 1920 дә — 335, 1926 да — 254, 1938 дә — 315, 1949 да — 244, 1958 дә — 228, 1979 да — 65, 1989 да — 19 кеше.

**АЛШИ́Х** (Әлших, Әлшәех) авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 9 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2002 елда 738 кеше яши (чуашлар — 77%). Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1672 дә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиеннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.та мәчет, мәктәп, он һәм ярма ярдыру тегермәне эшли. 1920 елга кадәр авыл Сембер губернасының Буа өязе Рунга волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 303, 1859 да — 521, 1897 дә — 1182, 1913 тә — 1082, 1926 да — 1309, 1938 дә — 1270, 1949 да — 1121, 1958 дә — 1059, 1970 тә — 1375, 1979 да — 1257, 1989 да — 798 кеше.

**АЛЫНМАЛА́Р** (лингв.), халыкларның аралашуы нәтиҗәсендә бер телдән икенчесенә күчкән башка тел элементлары (сүз, морфема, синтаксик конструкция һ.б.), ш.и. бер тел элементларының икенчесенә күчү процессы. Гадәттә, сүзләр, сирәгрәк очракта синтаксик конструкцияләр, фразеологик гыйбарәләр күчә. А. күчә торган тел системасына шулкадәр җайлашалар, аларның алынма сүз икәнен күп очракта бары этимологик анализ ярдәмендә генә билгеләргә мөмкин (к. *Этимология*). Татар теле лексикасында төрле теллардән алынган сүзләр бар. Аларның күпчелеге *гарәп, фарсы* һәм *рус алынмалары* тәшкил итә. Татар телендә кытай (бакыр, энҗе), монгол (карагай, есаул), фин-угыр (бүкән) һ.б. алынмалар очрый. Хәзерге вакытта татар теленә, башлыча, рус теле аша инглиз һәм көнбатыш Европа телләреннән шактый А. керә (спикер, менеджер, ноу-хау, аншлаг, дуэт, мэр, штраф, мафия). А. искерергә (райком, ударник) яки яңадан кайтырга мөмкин (мәдрәсә, икътисад, сәясәт), шуның нәтиҗәсендә татар телендә синонимик А. еш кулланыла (имтихан — экзамен, җөмһүрият — республика, семья — гаилә).

*Әд.:* А х у н з я н о в Э.М. Русские заимствования в татарском языке. К., 1968; Х а й р у л л и н М.Б. Проблемы развития лексической системы татарского литературного языка. К., 2000.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**АЛЫ́П** (алп) (төрки). Беренче тапкыр 7–11 йөзләрдә Орхон-Енисей язмаларында телгә алына. «Пәһлеван», «баһадир» мәгънәсендә «А.» сүзе Мәхмүт Кашгариның (11 йөз) «Төрки телләр сүзлегендә» («Диван-е лөгать әт-төрк») һәм Кол Галинең (13 йөз) «Кыйсса-и Йосыф»ында теркәлгән. Башта баһадирны, төз атучы мәргәнне, каһарманны аңлаткан, соңрак Төрки, Хәзәр каганлыкларында һәм башка төрки дәүләтләрдә хәрби хезмәттәге аксөяк катлау титулына әверелгән. Казан һәм Касыйм ханлыкларында «алпут» формасында очрый (к. *Алпавыт*).

Төркиләр мифологиясендә «А.» термины «пәһлеван», «баһадир», «батыр» мәгънәсендә төркиләрнең борынгы нәсел башы буларак теркәлгән. 922 елда Идел буе Болгарына Багдад хәлифәсе әл-Мөктадир илчелегенең сәркәтибе буларак килгән Ибне Фазлан үзенең язмаларында болгарлар идарәчесе Алмышның кыяфәте б-н тирә-юньдәгеләрне куркуга төшерә торган пәһлеван булуын теркә ала. 1135–36 да һәм 1150 дә Болгарда булып киткән гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнати үзенең язмаларында А. турындагы болгар риваятьләрен китерә: ул бик көчле кеше булган, аның буе 7 терсәккә (3 *м* чамасы) җиткән; исламны кабул итмәгән өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан юк ителгән Гад, Гъәд-адитлар кабиләсеннән чыккан дип санала. Татар риваятьләренә караганда, А. чабата каккан урында үр-таулар калкып чыга («Алып таулары»). А. термины күп кенә тарихи һәм эпик персонажларның исемнәре составына керә (Алып-илтәбәр, Алпамша һ.б.), ш.у. төрки-татар топонимнарында да очрый.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Г ы й л ә җ е т д и н о в С. Борынгы риваятьләребезгә бер караш // Казан утлары. 1999. № 5; Ж и р м у н с к и й В.М. Тюркский героический эпос. Л., 1974; А х м е т ь я н о в Р.Г. Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1989; У р м а н ч е е в Ф. По следам Белого волка. Ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племён. К., 1994.

*Ф.И.Урманчеев, И.Л.Измайлов.*

**АЛЫ́П ИЛТӘБӘ́Р** (7 йөзнең 2 нче яртысы), Каспий буе савир кабиләләре (һуннар) идарәчесенең исеме, дәрәҗәсе. Дәрбәнт шәһәреннән төньяк тарафтагы Хәзәр каганлыгына буйсынган төбәк-өлкәнең баш хөкемдары атамасы. Өлкәнең үзәге Варачан шәһәрендә була. Албаннар кенәзе Җуаншер б-н бердәмлек килешүе төзи, үз кызын аңа кияүгә бирә. Җуаншер вафатыннан соң (669), мәмләкәтендәге чуалышлардан файдаланып, Албания өлкәләрен басып ала. Төньяк Кавказның бер өлеше һәм Дәрбәнт аңа буйсына.

670 елларда Кавказ аръягы өлкәләренә берничә мәртәбә һөҗүм итә. 682 елда албан епискобы Исраил йогынтысында, христианнарга таянып, Хәзәр каганлыгына буйсынудан котылырга һәм үз хакимиятен тагын да ныгыта төшәргә ниятли. Моңа каршы хәзәрләр каганы А.И. биләмәләренә һөҗүм оештыра, «һуннар иле»н яулый (684) һәм А.И.нең кызын хатынлыкка ала. А.И.нең шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Артамонов М.И. История хазар. Л., 1962; Гадло А.В. Этническая история Северного Кавказа. Л., 1979; Гмыря Л.Б. Страна гуннов у Каспийских ворот: Прикаспийский Дагестан в эпоху Великого переселения народов. Махачкала, 1995; Golden P. Khazar Studies.Bdpst., 1980. V. 1–2.

*И.Л.Измайлов.*

**АЛЬБЕ́ТКОВ** Вениамин (Ибнәмин) Вәли улы (1.5.1917, Үзбәкстанның Әндиҗан ш. — 17.4.1984, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), полковник (1959). 1939 елдан Кызыл Армиядә. Ярославль хәрби пехота уч-щесен (1941), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1948, Мәскәү) тәмамлый. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, батальон командиры (121 нче укчы дивизиянең 383 нче укчы полкы). Үзәк, Воронеж, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Харьковка һөҗүм операциясендә (1942), Курск сугышында (1943), Украина, Польша, Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1943 нең 26 сентябрендә батальоны б-н Днепрны кичүне оештыра, плацдармны саклау һәм киңәйтү сугышына уңышлы җитәкчелек итә. Сугыштан соң Совет Армиясендә җитәкче вазифалар башкара. 1959 дан запаста, Мәскәүдә эшли. Ленин, Кызыл Байрак, Александр Невский, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

**АЛЬБИ́ЦКИЙ** Алексей Андреевич (13.5.1860, Кострома губ., Кинешма ш. — 1.10.1920, Харьков ш.), химик-органик, химия д-ры (1902), А.М.Бутлеров һәм А.М.Зайцев шәкерте. Петербург ун-тын тәмамлый (1882). Казан (1884–1903), Харьков (1903–1920) ун-тларында укыта, проф. (1902 дән). Харьковта Югары хатын-кызлар курсларын оештыручыларның берсе. Хезмәтләре органик химиягә карый. А. олефин рәте углеводородларын һәм аларның чыгарылмаларын тикшерә. Майлы диоксикислоталарның туендырылмаган кислоталарга күчешен һәм диоксикислоталарның төрле стереоизомерларга әверелү мөмкинлеген исбатлый. Югары майлы кислоталар ангидридларын табуның уңайлы алымын эшли.

Хезм.: О некоторых превращениях олеиновой и других близких к ней кислот. К., 1898; К вопросу о стереоизомерии в ряду непредельных одноосновных кислот. К., 1902.

*Әд.:* Аверко-Антонович И.Н. Химия в Казанском университете. К., 1968.

**АЛЬБИ́ЦКИЙ** Валерий Юрьевич (14.4.1941, Казан) көнкүреш гигиенасы һәм мед. тарихы белгече, мед. фән. д-ры (1987), проф. (1989). 1964 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Алексеев р-н Үзәк хастаханәсенең балалар табибе, аннары ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы инспекторы. 1966–76 да һәм 1993 тән Казан мед. ун-тында, 1976–93 тә Чита һәм Горький мед. ин-тларында каф., Горький педиатрия фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек мөдире. 1995 тә Казан мед. ун-тында илебездә беренче биомедицина этикасы (1995) һәм мед. хокукы (1998) кафедралары оештыра. 2003 тән РМФА Балалар сәламәтлеге фәнни үзәгенең мәгълүмат-аналитика бүлегендә эшли.

Хезмәтләре Казан мед. мәктәпләре үсеше тарихына һәм күренекле Казан галимнәре Н.А.Виноградов, Ф.Г.Мөхәммәдъяров, А.В.Вишневский эшчәнлегенә, балалар авырулары һәм үлеме, медицинаның социаль проблемаларына багышлана. «Казан профессорлары — гигиенистлар» («Казанские профессора — гигиенисты», 1995), «Казан медицина университеты деканнары» («Деканы Казанского медицинского университета», 1997) дигән биографик сүзлекләр төзүче һәм аларның мөхәррире.

Хезм.: Очерки по истории казанской медицинской школы. К., 1991; Младенческая смертность в Республике Татарстан. К., 1997; Казанский государственный медицинский университет: Справ. материалы. К., 1999.

**АЛЬМАНА́Х** (гарәп. ألمناح — календарь), 1) нинди дә булса принцип (тематика, жанр үзенчәлеге, идея-сәнгатьлелек, региональ һ.б.) буенча төрле авторларның әсәрләрен бергә туплаган, периодик рәвештә яки ара-тирә генә чыга торган җыентык; 2) иҗтимагый эшчәнлеккә караган, кызыклы яки белешмәлек характерындагы мәгълүматлар тупланган периодик булмаган җыентык. Урта гасырларда Европада гарәпләрдән кергән календарь-таблицалар, астрономик мәгълүматлар һәм астрологик искәрмәләр тупланган белешмәләр А. дип аталган. Алар баштарак кульъязма рәвешендә йөргән. А.-календарьлар беренче басма әсәрләр булып тора (мәс., «1448 ел өчен астрономик календарь» — «Астрономический календарь на 1448», И.Гутенберг). 16–17 йөзләрдә А.-календарьлар А.ка һәм *календарьларга* аерылалар. А.лар, башлыча, әдәби-нәфис әсәрләр җыентыгы булып, вакытлы матбугат яки аерым басма рәвешендә чыгарылган. Беренче әдәби А.лар Франциядә барлыкка килә («Альманах муз», Париж, 1764–1833); Россиядә чыккан беренче А.лар булып Н.М.Карамзинның «Аглая» (1794–95) һәм «Аониды» (1799) басмалары санала.

Татар матбугатында 20 йөз башына кадәр А.лар *мәҗмуга* рәвешендә чыга («*Мәҗмугыль-хикайәт*», «*Мәҗмуга-Дастан*»). 20 йөз башында татар телендә басылган беренче А.ларның берсе — «*Мирьат*». Казанда рус телендә беренче А.лар



В.В. Альбетков.

19 йөз ахыры — 20 йөз башында чыга, бу яңа әдәби әсәрләрне бастыруның бер формасы булып тора. Бу елларда А.ларның ешрак басылуы цензураның аларга вакытлы матбугат басмаларына караганда кимрәк игътибар итүе б-н аңлатыла. Шул ук чорда Казанда рус телендә чыккан А.лар: «Беренче адым. Провинциаль әдәби җыентык» («Первый шаг. Провинциальный литературный сборник», 1876), «Казан әдәби җыентыгы» («Казанский литературный сборник», 1876), «Идел хәбәрчесе»нең әдәби җыентыгы« (»Литературный сборник «Волжского вестника», 1884, 1885, 1898, 1900), «Зиндан» («Застенок», 1906), «Казан кәмите» («*Казанский раёшник*», 1908), «Акчарлак» («Чайка», 1908), «Тайпылыш» («Уклон», 1909), «Нео-футуризм» (1913), «Көз флейталары» («Флейты осени», 1914). Казанда чыккан кайбер А.ларда танылган авторларның да әсәрләре басыла. Мәс., «Таң атканда» («На рассвете», 1910, нашире *А.Ф.Мантель*) А.ында шагыйрьләр А.Блок, М.Волошин, С.Городецкий, М.Кузьмин; рәссамнар А.Бенуа, И.Билибин, М.Врубель, С.Сомов әсәрләре дөнья күрә. 1905–07 елларда ш.у. рәсми теркәлмәгән, гектографта басылган А.лар һәм җыентыклар да чыгарыла.

1920–30 елларда А.лар күбрәк нәшер ителә. «Провинциаль муза» («Провинциальная муза», 1918), «Белемгә таба» («К знанию», 1921), «Сүз белән таранлау» («Тараном слов»,




1921), «Таңнар кануны» («Заповедь зорь», 1922), «Октябрь — балаларга» («Октябрь — детям», 1927), «Башлану» («Начало», 1936) һ.б. А.ларда әдәбияттагы агымнар төрлелеге, ш.у. иҗади эзләнүләр чагылыш таба. Казан график-рәссамнары берләшмәсе тарафыннан чыгарылган «Җайдак» («*Всадник*», № 1–4, 1920–23) ул еллардагы А.ларның яңа формасы булып тора. 1920 елларда татар телендә А.лар «җыентык» буларак нәшер ителәләр: «Инкыйлаб чаткылары» (1920), «Безнең яшьлек» (1927), «Көрәш еллары» (1927) һ.б. 1930 елларда татар телендә басмалар А. исеме б-н чыгарыла башлый, аларда, башлыча, яшь язучыларның әсәрләре урын ала. Күпчелеге Казанда басыла: «Төзү көннәрендә» (1929), «Төзү баррикадаларында» (1931), «Удар забой» (1931), «Штурм» (1931), «Манёвр» (1932), «Безнең яз» (1933), «Чәчәкләр» (1937), «Әдәби альманах» (1938), «Туган ил» (1938) һ.б. А.лар Татарстаннан читтә дә нәшер ителә: «Үсү адымнары» (М., 1930), «13 рапорт» (Свердловск, 1931), «Атака» (Башкортстанның Дүртөйле а., 1934), «Яңа Урал» (Свердловск, 1934), «Үсү җыры» (Курган өлкәсенең Сафакүл а., 1934), «Үсәбез» (Оренбург, 1938) һ.б. 1930 еллар ахырыннан А.ларның әдәби процесстагы роле кими, алар сирәк чыгарыла. Сугыштан соңгы елларда ТАССР Язучылар берлеге «*Үсү юлы*», «*Идел*», «Әдәби Татарстан» («*Литературный Татарстан*»), «Әдәби Казан» («*Литературная Казань*») А.ларын чыгара. ТАССР Язучылар берлегенең чуаш секциясе 1930 елларда чуаш телендә «Адым» («Утам»), 1960 елларда «Казан» («Хусан») А.ларын нәшер итә.

*Әд.:* Әдәбият баскычлары: Татар совет әдәбияты елъязмасы (1917–1973). К., 1976; Литературно-художественные альманахи и сборники: Библиогр. указ.: В 4 т. М., 1957–60; Смирнов-Сокольский Н.П. Русские литературные альманахи и сборники 18–19 вв.: Библиогр. указ. М., 1965; Аристов В.В.,Ермолаева Н.В. Казанские сатириконы // Всё началось с путеводителя...: Поиски литературные и исторические. К., 1975; Богомолов Н.К. Материалы к библиографии русских литературно-художественных альманахов и сборников. 1900–1937. М., 1994. Т. 1.

*Р.А.Айнетдинов.*

**АЛЬТШУ́ЛЕР** Семён Александрович (24.9.1911, Витебск ш., Белоруссия — 24.1.1983, Казан), физик, Казан магнит радиоспектроскопиясе фәнни мәктәбенә нигез салучыларның берсе, физ.-матем. фән. д-ры (1955), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1976), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970). 1932 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм аспирантурада калдырыла. 1933 ел башында Мәскәү физика фәнни-тикшеренү ун-тына командировкага җибәрелә, анда И.Е.Тамм җитәкчелегендә фәнни эшчәнлеген башлап җибәрә. 1934 елдан Казан ун-тында эшли, 1954 тән теоретик һәм эксперименталь физика, 1961 дән теоретик физика, 1973 тән квант электроникасы һәм радиоспектроскопия кафедралары мөдире, проф. (1956), бер үк вакытта 1957 дән проблемалы магнит радиоспектроскопиясе лаб. фәнни җитәкчесе. 1974 тән СССР ФАнең «Конденцияләнгән мохит радиоспектроскопиясе» проблемасы буенча Гыйльми совет рәисе урынбасары,



С.А. Альтшулер.

1981 дән рәисе. Төп хезмәтләре магнит радиоспектроскопиясенә карый. *Нейтронның магнит моменты* булуын фаразлый, бу моментның зурлыгын һәм тамгасын билгеләли (И.Е.Тамм б-н берлектә, 1934). Төш спинының ЭПР спектрларына тәэсир итүен ача (Б.М.Козырев һәм С.Г.Салихов б-н берлектә, 1948). *Акустик парамагнетик резонанс* күренешен фаразлый һәм теориясен төзи (1952), физикада яңа юнәлешне — квант акустикасын башлап җибәрә. Сферик булмаган органик сыеклык молекулаларында борылма Броун хәрәкәте һәм бу хәрәкәтнең сыеклыкларның йоту спектрына тәэсир итү мәсьәләләрен чишә (Альтшулер-Вәлиев механизмы). Ван Флек парамагнетикларының төш спиннарын адиабатик магнитсызландыруын нигезләгән үтә түбән темп-ра (0,0001 К кадәр) алу ысулын тәкъдим итә. Парамагнитик кристалларда тар фонон «тамагын» һәм фонон «бугазын» Мандельштам-Бриллюэновның яктылык таралу эффекты ярдәмендә тикшерә. «Парамагнитный резонанс» җыентыгын бастырып чыгару инициаторы һәм мөхәррире. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, ике мәртәбә 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе», Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Ун-тның А. лабораториясе урнашкан бинасына аның истәлегенә мемориаль такта куелган. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006, вафатыннан соң).

Х е з м.: Магнитный момент нейтрона // Докл. АН СССР. 1934. Т. 1, № 8 (автордаш); Резонансное поглощение звука в парамагнетиках // Докл. АН СССР. 1952. Т. 85, № 6; Электронный парамагнитный резонанс. М., 1961 (автордаш).

*Әд.:* Семён Александрович Альтшулер. М., 1991.

*Р.Г.Усманов.*

**АЛЬФО́НСОВ** Владимир Алексеевич (3.2.1949, Симферополь ш.), химик, химия фән. д-ры (1991), проф. (1998). А.Н.Пудовик шәкерте. Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1973 тән РФА КГҮнең Органик һәм физ. химия ин-тында, 1993 елдан гамәли тикшеренүләр бүлеге мөдире, 1996 дан фосфорорганик кушылмалар стереохимиясе лаб. мөдире. Хезмәтләре фосфор, күкерт, кремнийорганик кушылмаларның синтезына, структурасына, реакциягә керә алуына карый. Өч валентлы фосфор кушылмаларының ике юнәлештә реакциягә керә алу сәләтен ачыклый, өч валентлы фосфор кислоталары тиочыгарылмалары химиясендә кушылу реакцияләренең яңа юнәлешен үстерә. Фосфор сульфидларының реакциягә керүчәнлеге турында яңа мәгълүмат ала. Хезмәтләре молекулалар эчендә күкерт, фосфор һ.б. элемент атомнары катнашында валентсыз һәм күп валентлы үзара тәэсирләшүләрен өйрәнүгә, ш.у. региональ экологик проблемаларны хәл итүгә, табигый кушылмалар химиясе өлкәләренә карый.

Х е з м.: Получение и свойства органических соединений серы. М., 1998 (автордаш); Проблемы экологической химии Республики Татарстан. К., 1998 (автордаш); On Rupture of P-E Bond of the Trivalent Phosphorus Derivatives // Chemistry of Organophosphorus Compounds. Moskow, 1989 (автордаш).

**АЛЯ́ЕВ** Валерий Алексеевич (26.3.1959, Куйбышев ш., хәзер Болгар ш.), җылылык физикасы һәм теоретик җылылык техникасы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2004). 1982 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, механика ф-ты деканы (1996–2000), проректор (2000 нән), бер үк вакытта 2002 дән Химия һәм нефть машиналары төзү ин-ты директоры. Хезмәтләре җылылык алмашу өлкәсенә карый. А. югары темп-ралы органик сыеклыклардагы җылылыкның радиацион-кондуктив күчешен тикшерә. Аның катнашында үтә критик экстракциядәге күзәнәкле материалларны эшкәртү ысуллары эшләнә һәм чистарту өчен эксперим. җайланма булдырыла.

Х е з м.: Экология авиационных горюче-смазочных материалов. К., 2004 (автордаш); Система непрерывного высшего профессионального образования в области физики вакуума, вакуумной техники и технологии // Вакуумная техника и технология. 2004. Т. 14, № 4 (автордаш).

**АМАЗО́НКА ЛИЛИЯСЕ́**, к. *Эухарис.*

**АМА́Н ОШТЫРМА́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оштырма елгасының уңъяк кушылдыгы буенда. 2002 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — крычылык. Башлангыч мәктәп. Клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, такта яру, агач көрәкләр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.О.да мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, 2 вак-тәүәкләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1034,1 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Юмья волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 87 ир заты; 1859 да — 461, 1897 дә — 670, 1908 дә — 903, 1926 да — 627, 1938 дә — 445, 1949 да — 353, 1958 дә — 375, 1970 тә — 271, 1979 да — 191, 1989 да — 113 кеше.

**АМАНУЛЛА́**, к. *Камалиев Әмир Аман улы.*

**АМАРА́НТ** (Amaranthus), амарантчалар семьялыгыннан, башлыча, берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Северкәчле А. (A. paniculatus), койрыклы А. (A. caudatus) үстерелә. Килеп чыгышы Мексикадан, анда борынгы заманнардан бирле туклану һәм терлек азыгы буларак игелгән. Аксымга бай һәм мул уңыш бирә торган азык культурасы. ТРда 1990 елдан игелә; чәчү өчен «Стрех» сорты рөхсәт ителгән (1992). Яшел массасында аксым күп, шикәр аз һәм, гадәттә, кукуруз б-н бергә генә силослана. Мөгезле эре терлек һәм дуңгызлар өчен яхшы азык санала. Майның 2 нче яртысында, туфрак 10–12°С ка кадәр җылынгач, СО-4,2 яшелчә чәчкече ярдәмендә киң рәтле ысул б-н чәчелә. Чәчү нормасы —

0,8–1 *кг/га*, орлыкны туфракка күмдерү тирәнлеге 1,5–2 *см*. Практикада А.ны кукуруз б-н буй-буй аралаштырып чәчү кулланыла. Яшел массаның уңышы гектарыннан 500 *ц* га җитәргә мөмкин.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**АМАРИ́ЛЛИС**, к. *Гиппеаструм*.

**АМБА́Р КӨЯСЕ́**, бөртекле ашлык көясе (Nemapogon gronellus), күбәләк, чын көяләр семьялыгыннан. Канат җәеме 9–14 *мм*. Алгы канатлары кара таплы, көмешсу-соры төстә, арткы канатлары соры яки коңгырт. Кортлары 10 *мм* озынлыкта, саргылт-ак. ТРда киң таралган, ашлык амбарларында, өйләрдә күп очрый. Кортлары ашлыкка, ашлык продуктларына, сохарига һәм кабак орлыгына зыян китерә. Кузыга әверелеп кышлый. Күбәләкләрнең беренче буыны язын барлыкка килә һәм 100 ләп күкәй сала. 1 елда бер-ике буын үсеп җитә. А.к. б-н көрәш чаралары турында к. *Амбар утчыллары*.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**АМБА́Р ТАЛПАННАРЫ́** (Tyroglyphoidea), акариформалылар отрядының талпаннар семьялыгыннан, амбар корткычларының гаять киң комплексы, 200 гә якын төре бар. Иң зарарлы корткычлар: он талпаны, озынча талпан, Радионов талпаны, кара аяклы, төкле, гади талпаннар. Озынлыгы 0,2–0,6 *мм*, баш-күкрәк һәм корсак өлешләренә бүленә. Җитлеккән талпан — 4, кортлары — 3 пар аяклы. Авыз аппаратлары кимерә торган. Туфракта, җәнлек өннәре һәм ояларында, үсемлек тамырлары арасында һәм яшел сабак-яфракларында яшиләр. Амбарларга кырдан яңа уңышка ияреп кайталар. Ашлык, он һ.б. азык-төлеке зарарлыйлар (бигрәк тә ашлыкның дымлылыгы 14% тан артканда). ТРда он талпаны киң таралган. Үсеш циклы: күкәй, корт, нимфа 1, нимфа 2, җитлеккән талпан. Ашлык дымлылыгы 13%, онның дымлылыгы 12% тан кимрәк булган шартлар талпаннар өчен уңайсыз санала. 50 °С темп-рада талпаннар үлә. Ашлыкка кечкенә ярыклар аша үтеп керәләр. Талпаннар зарарлаган он һәм ашлыктан күгәрек исе килә. Көрәш чаралары: профилактика, физик-механик һәм химик ысуллар б-н юк итү. Фураж ашлыгы — хлорпикрин һәм бромлы метил, чәчүлек орлык дихлорэтан һәм металлилхрод б-н төтенләп эшкәртелә.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**АМБА́Р УТЧЫЛЛАРЫ́**, күбәләкләр, утчыллар семьялыгыннан. Нигездә азык-төлек складлары, ашлык амбарлары, элеваторлар, тегермәннәрдә тереклек итә. Татарстан терр-ясендә тегермән, он һәм бөртекле ашлык утчыллары киң таралган. Тегермән утчыллары (Ephestia kuehniella) респ-каның барлык р-ннарында очрый. Канат җәеме 20–25 *мм*, алгы канатлары — соры төстә, китекле ике ак сызыгы һәм кара төстәге буй-буй аркылы сызыклары һәм нокталары бар. Кортының озынлыгы 20 *мм* га җитә, ачык-сары, алсу, кайвакыт яшькелт төстә була. Башлыча он, ярма, сохари һ.б. ашамлыкларны зарарлый. Он утчылы (Pyralis farinalis) бөтен җирдә таралган, канат җәеме 30 *мм* га җитә, алгы канатлары — канат төбендә һәм очында шәмәхә-көрән, уртада көлсу-соры сызык үтә, арткы канатлары караңгы соры төстә, борылма сызыклы. Ел буена утчылларның 5 буыны үсеп өлгерә. Кортының озынлыгы 20 *мм* га җитә, саргылт-ак төстә, сирәк кенә кыска сызыклар б-н капланган; ашлык, он, ярма, печән, көрпә һәм кондитер азыкларын зарарлый. Ашлык утчылы (Ephestia elutella) ТРның кайбер р-ннарында гына очрый. Канат җәеме 17 *мм* га җитә, алгы канатлары җирәнсу-соры, арткы канатлары — тонык-соры. Кортының озынлыгы 17 *мм* га җитә, кызгылт-алсу яисә сарырак төстә, ашлык продуктларын зарарлый. Көрәш чаралары амбарларны, ашлык эшкәртү пр-тиеләрендәге биналарны, машина һәм инвентарьларны әзерләү, чистарту һәм утчылларның таралуын кисәтүдән гыйбарәт. Физ.-механик ысул: ашлык һәм ярмаларны чистарту, онны иләү, тузан суырткыч б-н стена, идән, машиналарны чистарту, ашлыкны ион нурлар б-н дезинсекцияләү; хим. ысул: аэрозоль һәм газ б-н дезинсекцияләү (хлорофос, тиофос, хлорпикрин) һ.б.

*Ф.С.Зыятдинов.*




Амбар утчыллары: 1 — бөртекле ашлык утчылы; 2 — тегермән утчылы; 3 — он утчылы.

**АМВРО́СИЙ** (Подобедов Андрей Иванович) (1742, Пермь губ., Көнгер өязе Молебский завод а. — 21.5.1818, Новгород ш.), дин эшлеклесе. Троица-Сергий лаврасы руханилар семинариясен тәмамлаганнан соң (1767), монахлык кабул итә. 1771 елдан Мәскәү руханилар академиясендә укытучы, 1774 тән ректор, 1778 дән — Севск, 1781 дән Крутицк епископы. 1785–99 да Казан һәм Сембер, 1799 дан Петербург архиепископы, 1801 дән Новгород митрополиты. А. вакытында Казан руханилар семинариясе Руханилар академиясе итеп үзгәртелә (1798), яңа чукындырылганнар мәктәбе эшчәнлеге активлаштырыла.

Х е з м.: Руководство к чтению Священного Писания Ветхого и Нового завета. СПб., 1779.

*Әд.:* Х а р л а м п о в и ч К.В. Материалы для истории Казанской духовной семинарии в XVIII в. К., 1903.


**АМВРО́СИЙ** (Протасов Алексей Иванович) (1762, Мәскәү губ. Боровск ш. — 1.7.1831, Тверь ш.), дин эшлеклесе. Мәскәү руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1790), шунда ук укыта. 1794 елдан монахлыкта. 1799 дан Петербург руханилар академиясендә укытучы. 1804 тән Тула епископы, 1816 дан Казан һәм Сембер, 1826 дан Тверь архиепископы. А. вакытында Казанда 1815 елгы янгыннан зыян күргән гыйбадәтханәләр һәм монастырьларның күпчелеге торгызыла. А.ның хакимиятнең комсызлыгын һәм алпавытларның явызлыгын фаш иткән, крепостнойлык хокукына каршы чыккан вәгазьләре риторика һәм гомилетика хрестоматияләренә кертелгән. Латин грамматикасы дәреслеге (1799) авторы.

Х е з м.: Слова и речи Амвросия, бывшего епископа Тульского и Белевского и архиепископа Казанского и Симбирского, Тверского и Кашинского. СПб., 1856.

**АМГА́МКА**, *Карамалы* елгасының үрге агымындагы исеме.

**АМЕ́РИКА ХӘЙРИЯ́-ЯРДӘ́М МӨДИРИЯТЫ́**, к. «*АРА*».

**АМЁБАЛАР** (Amoebina), саркодлылар классыннан иң түбән төзелешлеләр отряды. Ялган аяклар (псевдоподийлар) — цитоплазма бүлтәймәләре ярдәмендә хәрәкәтләнеп азык эләктерүче, тән формасы тотрыклы булмаган бер күзәнәкле организмнарны берләштерә. Псевдоподийларның формасы, зурлыгы, үрчү ысулы А.ның мөһим билгесе булып тора. Гәүдә зурлыгы 15 тән 700 *мкм* га кадәр. Бактерияләр, вак суүсемнәр, иң гади организмнар б-н тукланалар. Нигездә җенессез юл, ягъни 2 өлешкә бүленеп үрчи. Тискәре шартларда тышкы мохиттә яшәргә сәләтле стадияләр — цисталар барлыкка китерәләр. Тамырааклар асклассының кайбер ирекле тереклек итүче төрләре (кабырчыклы А.) каты кабырчыклар бүлеп чыгаралар яки, ком бөртекләрен беркетеп, үзләренең шәрә цитоплазмалары тирәли саклагыч катлам хасил итәләр.




1. Амёба протей; 2. Дифлюгия; 3. Арцелла.

ТРда төрләренең саны төгәл билгеләнмәгән, суда яшәүче формаларының 10 лап төре ачыкланган. Һәр җирдә киң таралган: сулыкларда (А. протей), яр буендагы комда (кабырчыклы А. — арцеллалар һәм дифлюгияләр). Ш.у. паразит А.лар да очрый. Кеше һәм хайван организмындагы паразит А.лар җитди авырулар (амёба дизентериясе һәм амёба менингоэнцефалиты) китереп чыгарырга мөмкин.

*В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.*

**АМИДИ́** (Гамиди) Шәриф (чын исеме Хәсән ибне Хөсәен ибне Мөхәммәд әл-Хөсәени әл-Хәнифи, ш.у. «Татар Али әфәнде» исеме б-н дә билгеле) (? — 1523 б-н 1544 еллар арасы, Амид ш., хәзерге Диярбәкер ш., Төркия), төрки телле шагыйрь һәм тәрҗемәче, мәмлүкләр Мисырында дәүләт эшлеклесе. Солтан Кансух әл-Гаури вакытында (1501–17) диван сәркәтибе булып хезмәт итә. Солтан тәкъдиме б-н 1501–10 елларда Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмасын фарсычадан төрки телгә тәрҗемә итә («Төрки Шаһнамә»). Тәрҗемәгә пролог һәм эпилог рәвешендә өстәп язган текстында 15–16 йөзләрдәге мәмлүкләр Мисырының идарәчеләре, илнең мәдәнияте, Каһирә шәһәренең топографиясе

турында мәгълүматлар бирә. «Төрки Шаһнамә»нең кулъязма нөсхәләре С.-Петербург, Дүшәмбе, Каһирә, Лондон, Вена шәһәрләре китапханәләрендә саклана. А. үгет-нәсыйхәт рухындагы тарихи язмаларны үз эченә алган «Нәфаис әл-мәҗалис әс-солтанийә» («Солтан киңәшләре энҗеләре») җыентыгы, газәл, мәдхия жанрларындагы аерым шигырьләр авторы буларак та билгеле. А. иҗаты төрки телле халыклар поэзиясенә, ш.и. татар поэзиясенә мәгълүм дәрәҗәдә йогынты ясаган.


*Әд.:* Исламов Р. Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: Язма мирас, мәдәни багланышлар. К., 1989; Zajączkowski A. Turecka wersja Šāh-nāme z Egiptu Mameluckiego // Prace Orientalistyczne. Warsz., 1965. T. 15; Bursali Mehmed Tahir bey. Osmanli Muellifleri. Ist., 1972. 2 cilt; Ozkirimli A. Türk edebiyati Ansiklopedisi. Ist., 1998. 4 cilt.

*Р.Ф.Исламов.*

**АМИНОКИСЛОТАЛА́Р**, составында карбоксиль һәм аминотөркемнәре булган кислота һәм селте үзлекләренә ия органик кушылмалар классы. А. аксымның структур бирәмлеген тәшкил итәләр. Алар гормоннар, витамин, медиатор, пигментлар биосинтезында иң төп кушылмалар рәвешендә организмдагы матдәләр алмашында катнашалар. Табигатьтә 150 дән артык А. бар. Терлек организмы төзелешенә кергән аксым составында 20 гә якын А. табылган. Шуларның 8 е алыштырыла, ягъни организмда бүтән А.дан яисә органик кушылмалардан кирәк кадәр синтезлана ала. Аларга аланин, аспарагин, глутамин, глицин, пролин, серин һәм глутамин кислоталары керә. 8 А. — алыштыргысыз, алар организмда синтезланмый, ләкин организм өчен кирәк. А. җитешмәгәндә организм авырлыгын югалта һәм һәлак була. Аларга валин, лицин, изолейцин, метионин, треонин, лизин, триптофан, фенилаланин керә. Мондый А. организмга читтән кертелергә тиеш. Өлешчә алыштырыла ала торган 4 А.: аргинин, гистидин, цестеин, тирозин. Күпчелек микроорганизмнар һәм үсемлекләр кирәкле А.ны аммоний тозлары һәм нитратларыннан, ә хайваннар гади, азотсыз туклану продуктларыннан һәм аммоний азотыннан синтезлыйлар. Терлекләрдән алынган азыкта А.ның тулы җыелмасы бар. ТРда терлек азыгы үсемлекләрендә кайбер А. җитми. Күшәмәүче хайваннар А. җитмәүгә аеруча сизгер, ә күшәүче хайваннарда А.га ихтыяҗ шактый аз. Бу — күшәүче хайваннарның карыккартасындагы бактериаль флораның алыштырыла алмый торган аерым А.ны гына, ә алыштырыла торган А.ны җитәрлек күләмдә синтезлавы б-н аңлатыла. Республикада, терлек азыгы рационын һәм катнаш азыкны баету өчен, сәнәгать юлы б-н җитештерелгән А. (лизин, треонин, метионин) кулланыла.

*З.Г.Закиров.*

**АМЛО́НГ** Фёдор Романович (Фердинанд-Юлиус Адольф Фридрихович) (17.9.1871, Мәскәү ш. — ?), архитектор. 1900 елда Россия гражданлыгын кабул иткән алманлы гаиләсендә туа. 1893–1900 дә Петербург Сынлы сәнгать академиясендә укый һәм аны рәссам-архитектор дәрәҗәсе б-н тәмамлый. 1900–1903 тә Казан сынлы сәнгать мәктәбендә укыта, бер үк вакытта 1902–03 тә Казан земство идарәсе архитекторы. 1904 тән Казан шәһәр архитекторы. 1915 тән «Современное зодчество» төзелеш-техник конторасы һәм Казан өязендә кирпеч-известь з-ды хуҗасы. А. — романтик модерн стиле тарафдары. А. проекты б-н *Шамил йорты*, *Подуруева йорты*, *Казан хәрби округы командующие йорты* (фараз итәлә), П.И.Климов йорты



Ф.Р. Амлонг. Подуруева йорты. Казан. 1906.

(1909) төзелә. Хатыны Германия файдасына шымчылык итүдә гаепләнә, һәм 1915 тә А. гаиләсе б-н Иркутск губернасына сөрелә. 1920 елларда Казанда яши һәм Татпрофсоветта эшли.

*Л.М.Мортазина.*

**АММИА́К СЕЛИ́ТРАСЫ**, к. *Азотлы ашламалар.*


**АММО́НИЙ СУЛЬФАТЫ́**, к. *Азотлы ашламалар.*


**АММОФО́С** — моноаммонийфосфат, $NH_4H_2PO_4$, концентрацияләнгән комплекслы фосфорлы-азотлы ашлама. А.ның нигезен моноаммонийфосфат һәм өлешчә диаммонийфосфат — $NH_4H_2PO_4$ тәшкил итә. А.та 11% азот, якынча 50% фосфор (43% тан ким түгел) бар. Ашлама дымны аз тарта, суда яхшы эри. Ортофосфор кислотасын аммиак б-н нейтральләштереп, А. алалар. Гранулалар яисә порошок хәлендә эшләп чыгарыла. ТРда А. бөтен тип туфракларда кулланыла, бигрәк тә кара һәм соры урман туфракларында бөртекле культураларга төп ашлама буларак, сызма, техник, яшелчә культураларына чәчү вакытында һәм өстәмә туклandыру максатында рәтләр арасына кертелә. 100% лы туклыклы матдәгә күчереп исәпләгәндә, фосфорлы ашламалар 1998 елда барлыгы 428,5 мең *ц* һәм 2000 дә 33,5, 2005 тә 41,8 мең *ц* кертелгән, шуларның дүрттән бер өлешен аммофос тәшкил итә.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**АМОРТИЗА́ЦИЯ** (лат. amortisatio — бурычны каплау), төп җитештерү чараларының кулланылу, производствода файдалану процессында акчага күчереп исәпләнгән тузуы; тузган хезмәт чараларының бәясен шул чаралар ярдәмендә үк җитештерелгән продукт бәясенә күчерү процессы, ысулы. А. бухгалтерия, финанс, салым һәм икътисад позицияләреннән чыгып тикшерелергә мөмкин. Бухгалтерия күзлегеннән караганда, А. — төп средстволар бәясенең хезмәт күрсәтү срогы барышында җитештерелгән продукция бәясенә күчергәндә пропорциональ рәвештә бүленеше. Финанс ягыннан караганда, А. — керемнең «тулай үз-үзен финанслау»ны гамәлгә ашыру өчен пр-тиедә кала торган өлеше, ягъни А. — капитал салуны финанслау чыганакларыннан берсе. Салым күзлегеннән караганда, А. чигерүләр зурлыгы — пр-тие керемннән салымнар түләгәнгә кадәр чигерелә торган өлеше. А.нең кирәклеге төп фондларның җитештерү процессында катнашу үзенчәлегеннән килеп чыга. Алар җитештерүнең күп кенә циклларында натураль формаларын саклаган хәлдә катнашалар. Яңа продуктның һәр берәмлегендә хезмәт средстволары бәясенең тузу дәрәҗәсенә туры килгән өлеше чагылыш таба. А.чигерүләреннән туплана торган акча пр-тие тарафыннан хезмәт итү срогы чыккан төп җитештерү фондларын натураль формада яңарту өчен яки капиталь ремонт ясау өчен файдаланыла. Барлык төр милек формасындагы пр-тиеләр һәм оешмалар өчен, төп фондларның бәясеннән һәм аларның хезмәт итү срогыннан чыгып, закон тәртибендә бердәм А. нормасы урнаштырыла. Россиядә А. чигерүләренә кагылышлы сәясәт берничә этапны үтә. 1923 елда расланган норма буенча А. чигерүләре табыштан реновация өчен генә алынган һәм продукциянең үзкыйммәтенә кертелмәгән. 1938 елда уртача-тармак нормалары гамәлгә кергәч, А. чигерүләре реновацияне дә, капиталь ремонтны да үз эченә ала. Тулаем халык хуҗалыгы өчен бердәм, төп фондларның төркемнәре, төрләре һәм объектлары буенча дифференцияләнгән яңа А. нормалары 1963 елда кертелә. Төп фондларның хезмәт итү срогы кыскарганлыктан, А. нормасы да

Ф.Р. Амлонг (Г.Б.Руш б-н берлектә). 1. Шамил йорты. 1903; 2. Зиннәтле баскыч.





шактый күтәрелә. 1975 елда бу нормаларга төгәллек кертелә. 1990 елларда дәүләти булмаган секторда А. фондларын формалаштыру һәм файдалану б-н пр-тиеләр үзләре шөгыльләнә.

*Әд.:* Райзберг А.Б., Лозовский А.Ш., Стародубцев Е.Б. Современный экономический словарь. М., 1997.

*Р.А.Борһанова.*

**А́МПИР** (фр. empire — империя), 19 йөз башында Европа архитектурасы һәм сәнгатендәге стиль. 18–19 йөзләр чигендә Франциядә барлыкка килә, классицизм стиле үсешен төгәлли. А. Борынгы Рим сәнгатен идеал итеп ала, ш.у. анда борынгы Мисыр сәнгате мотивлары да чагылыш таба. А.ның композициясе монументаль классик ордер формаларының тигез дивар өслеге б-н контрастлашуына, шушы стильгә хас формаларның һәр өлешен конструктив яктан аерымлап күрсәтүче тар бизәк пояслары кулланылуга корылган. А.га архит-ра ансамбльләре корылышында,



Ампир. Казанны алганда һәлак булган рус сугышчыларына һәйкәл. Арх. Н.Ф.Алфёров. Казан. 1823.

урам-мәйдан композицияләрен төзегәндә киң колачлылык һәм тәвәккәллек хас. Корылмаларның монументальлеге, формаларның зурлыгы, үзәк күчәргә нигезләнгән композициянең тотрыклылыгы, бизәкләрнең купшылыгы (ликтор бәйләгечләре, таҗлар, балталар, уклар, бөркет-кошлар һ.б.), ачык-җете төсләр (кызыл, зәңгәр, алтын төсле, ак) — А.ны характерлаучы сыйфатлар. Россиядә А. башкала һәм провинция юнәлешендә үсеш ала. Ул Казанда һәм Казан губернасында 1820–40 елларда тарала. Казанда *Рус гаскәриләре һәйкәл-төрбәсе*, «*Казанское подворье*», *Дротоевский йорты*, *Университет шәһәрчеге* корылмалары һ.б. шушы стильдә төзелгән. А.ның кайбер элементлары татар бистәләрендә һәм авылларында торак йортлар, мәчетләр төзелешендә кулланыла: «ампир тәрәзә» — аскы ягыннан култыксалар б-н бизәлгән өч бүлемле тәрәзәле фронтон уемнары; ачык ампир төсләр татарларга хас төс культурасына да туры килә (зәңгәр, яшел, сары), шунлыктан халык архит-расында киң кулланыла. Казан архитекторлары М.П.*Коринфский*, П.Г.*Пятницкий*, Ф.И.*Петонди* А. стилендә эшләгән.

*Әд.:* Некрасов А.И. Русский ампир. М., 1935.

Ампир. 1. Дротоевский йорты. Казан. Арх. Ф.И.Петонди. 1837; 2. Фасад бизәлеше.





**АМПЛУА́** (фр. emploi — эш, шөгыль, хезмәт урыны, вазифа), театрда сәхнә персонажының типик кыяфәте б-н актёрның сәләте һәм тышкы мөмкинлекләренең туры килүе. «А.» төшенчәсе драма әдәбияты тәэсирендә формалаша. Теге яки бу сәхнә әсәренең төгәл жанр аныклыгы үзенә туры килгән характерларны таләп итә, әйтик, беркатлы, мәзәк карт трагедиядә катнашучы була алмый, ш.у. трагик герой комедиядә урынсыз булыр иде һ.б. Шушы принциплар буенча теге яки бу рольне башкаручы актёр да әлеге рольгә тәңгәл килгән сәхнә мөмкинлекләренә — хис, тавыш, тышкы кыяфәткә һ.б.га ия булырга тиеш. Драма сәнгате тарихында А. төшенчәсе үзгәрә, Италиядә һәм Франциядә үз сәхнә типлары булдырыла. Россиядә театрда рольләрне А. принцибы буенча бүлү Екатерина II раслаган 1766 елгы указ нигезендә кертелә һәм ул 20 йөз башына кадәр саклана. А. принцибы буенча труппаны формалаштыру театр бинасын арендалаганда антрепренёр кул куйган килешү текстына мәҗбүри шарт буларак кертелә. Аерым алганда, Казан шәһәр думасы кулланган үрнәк килешүдә драма труппасында «хатын-кыз персоналы: 1) драматик актриса; 2) драматик ingenue; 3) комик ingenue; 4) grand dame; 5) драматик карчык; 6) комик карчык; 7) водевиль актрисасы...; ир-ат персоналы: 1) драматик актёр (резонёр); 2) комик (резонёр); 3) драматик сөяркә; 4) водевиль сөяркәсе; 5) комик (буфф); 6) простак — беркатлы кеше» булырга тиеш дип билгеләнә. К.С.Станиславский А. билгеләре буенча рольләргә бүлүгә принципиаль рәвештә каршы чыга, ул һәр актёр үзенчәлекле актёр булырга һәм теләсә нинди рольне уйный алырга тиеш дип саный. Казанда аптрепренёр *Н.И.Собольщиков-Самарин* А. принципларын үтәүне таләп иткән шәһәр думасы б-н озак бәхәс алып бара, ул яңа драматургиянең традицион А. кысаларына сыймый торган характерлар тәкъдим итүен исбатлый.

А. принцибы татар театрында аның беренче елларында кулланыла. Башлыча, көнкүреш, әхлакый-социаль проблемаларга корылган драматургия нигезендә бер типтагы битлек-рольләр турында күзаллаулар (тип) барлыкка килә: дуамал сәүдәгәр, «алдынгы» сәүдәгәр, тиран ата, тиргәшүчән хатын, такылдык күрше, астыртын, әрсез хезмәтче, газап чигүче герой яки героиня, мәзәк карчык һ.б. Башта барлык хатын-кыз рольләрен ир-атлар башкара. Әмма проф. театр барлыкка килү б-н татар труппаларында хатын-кыз актрисалар күренә башлый, шулай да күп рольләр, аеруча «такылдык күрше», «мәзәк карчык» кебек рольләр озак еллар дәвамында ир-ат актёрларга бирелеп килә. 1930 елларда, Станиславский идеяләренең киң таралуына бәйле рәвештә, театрда яңа сәнгать өчен җәелдерелгән көрәш А. принцибын тәмам кире кагуга китерә. Әмма әле бүген дә, аеруча классик пьесаларны сәхнәгә куйганда, актёрның сәхнә мөмкинлекләре ул башкара торган персонажның типик сыйфатларына туры килү принцибы исәпкә алына. Театр һәм кино хезмәткәрләре арасында шактый киң таралган «типаж» төшенчәсе нигездә амплуа принципларыннан килеп чыга.

*Әд.:* Театральная энциклопедия. М., 1961. Т. 1.

*Ю.А.Благов.*

**«АМУ́Р» НО́МЕРЛАРЫ**, Казанда 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы татар архит-расы истәлеге. Элеккеге Печән базары комплексында кунакханә тибындагы бина. 1864 елда сәүдәгәр Юнысов Гобәйдулланың уллары Ибраһим һәм Исхак акчасына арх. П.Е.Аникин проекты б-н табыш йорты буларак төзелә. Башта ул бер-берсенә почмакланып тоташкан, берсе — ал ягы б-н Печән базарына, икенчесе ишегалдына караган ике



«Амур» номерлары. Казан. 1864. Яңартып төзелгән. 1912.

корпустан тора. Урам яктагы галерея тибындагы бинаның 1 нче катында кибетләр, икенчесендә ике, өч бүлмәле номерлар була. Эклектика стилендәге төп фасад өч бүлемле, ян-яктан ризалитлы композициядә эшләнгән. Уң ризалиттагы а́рка ишегалдына керү капкасы булып хезмәт иткән. Ишегалдындагы бинаның 1 нче катында келәтләр, 2 нче катында номерлар урнашкан. 1886 да йорт, мирас буларак, Габделкәрим Исхак улы Юнысов милкенә күчә. 1912 дә бина кунакханә итеп үзгәртеп корыла һәм «Амур» номерлары сыйфатында эшкуар М.З.Рамазановка арендага бирелә. Элеккеге биналарга 3 нче кат өстәп салына, җир мәйданының буш торган читләрендә 3 катлы яңа биналар

төзелә, шул рәвешчә, «кое сыман» ишегалды хасил була. Мәйданга караган бина киңәйтелә, аның эчке бүленеше үзгәртелә. Уңъяк ризалиттагы а́рка-капка урынына баскыч мәйданчыгы урнаша, ә капка бинаның үзәгенә күчерелә. Төп фасад модерн стилендә бизәлә. Үзгәртеп корылганнан соң, «А.» н. кварталның түренә таба сузыла, ишегалдының як-ягында беренче катларда — келәтләр, өстәге катларда коридорлар б-н тоташкан номерлар урнаша. 1912–13 тә «А.»н.да Г.Тукай, Ф.Әмирхан, «*Сәйяр*» труппасы актёрлары Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская һ.б. күренекле шәхесләр яши, 1912–18 елларда бирედә «Кояш» г-тасы идарәсе эшли. 21 йөз башында бинаның ишегалды өлеше яңартыла. Хәзерге вакытта анда кибетләр һәм оешмалар урнашкан.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Нугманова Г.Г. Сенная площадь в Казани: Очерк истории архитектуры // Казань. 1998. № 3. *Г.Г.Ногманова.*

**АМФИ́БИЯЛӘР**, к. *Җир-су хайваннары.*

**АМФИБОЛИ́Т**, массив яисә полосасыман метаморфик тау токымы, башлыча, амфибол (ялган мөгезташ) һәм плагиоклаз минераллары кушылмасы. Беренчел утырма һәм магматик токымнарның үзара кушылуы, үзгәрүе нәтиҗәсендә хасил була. Төсе сыек сарыдан алып карага кадәр. Тыгызлыгы 2,9–3,1 *г/см*³. Гадәттә, А. эре чыганаклар хасил итми, гнейслар, гранитлар б-н бергә табыла. ТРда кристаллик нигез токымнары арасында киң таралган. Төзелештә (вакланган таш әзерләү), вак-төяк әйберләр ясауда һәм стеналарны бизәүдә кулланыла.

**АМФИТЕА́ТРОВ** Фёдор Захарович (1.3.1897, Орёл губ., Дмитриевск өязе Гнани а. — 5.7.1970, Казан), вирусолог, вет. фән. д-ры (1945), проф. (1947). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1924). 1924–28 елларда хәрби вет. табибе. 1928–59 да Казанда Фәнни-тикшеренү вет. ин-тында, 1959–70 тә Казан вет. ин-тында вирусология лаб. мөдире. Хезмәтләре йогышлы энцефаломиелит мәсьәләләренә һәм бу авыруга каршы дәвалау чаралары комплексын эшләүгә карый. Бозауларның ашказаны-эчәк авыруларын булдырмау ысулларын һәм ацидофилин б-н дәвалауны гамәлгә кертә. Беренче буларак ящур (тилчә) авыруы таралу үзенчәлеген тасвирлый.

Х е з м.: Энцефаломиелит (менингит) лошадей и борьба с ним. К., 1946; Ликвидация ящура в первичном очаге. М., 1956; Сохранение поросят. К., 1956; Искоренение ящура. К., 1964; Истребление мышевидных грызунов на животноводческих фермах. К., 1964.

*Әд.:* Шубладзе А.К., Гайзамович С.Я. Краткий курс практической вирусологии. М., 1954; Комаров Н.М. Итоги развития зоогигиены за 40 лет // Тр. Всесоюз. ин-та эксперим. ветеринарии. М., 1959. Т. 12; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**АМФИТЕА́ТРОВА** Надежда Фёдоровна (24.8.1932, Казан — 6.8.1992, шунда ук), микробиолог, мед. фән. д-ры (1974), проф. (1976). 1956 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1956–74 елларда Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-тында, 1972 дән эпидемиология бүлеген җитәкли, 1974 тән Казан мед. ин-тының микробиология каф. мөдире. Хезмәтләре сулыш юлларындагы бактериаль йогышлы авыруларның микробиологиясе һәм иммунологиясенә, организмның бума ютәлгә бирешмәүчәнлеге формалашу процессында иммунологик һәм аллергик тәэсирләнүенә багышлана. Бума ютәл һәм дифтериягә каршы борын аша вакцинацияләү ысулын эшли һәм гамәлгә кертә, бу авыруларга диагноз куюның яңа ысулларын — турыдан-туры булмаган иммунофлуоресцент ысулын һәм латекс-микроагглютинация һәм агглютинация ысулын тәкъдим итә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Серологические показатели у детей, подлежащих возрастной ревакцинации против коклюша, дифтерии и столбняка // Казан. мед. журн. 1973. № 3; Вопросы эпидемиологии и прикладной иммунологии. К., 1975; Динамика противококлюшных антител в слюне и сыворотке крови вакцинированных доноров // Казан. мед. журн. 1987. № 4.

*Әд.:* Казанский научно-исследовательский институт эпидемиологии и микробиологии (1900–1975). К., 1974; Профессор Надежда Фёдоровна Амфитеатрова // Казан. мед. журн. 1992. Т. 73, № 6.

**«АНА́»** («Басу»), авыл хуҗалыгы журналы. РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты каршындагы Чуаш бүлеге органы. 1918 елның августыннан 1920 нең июленә кадәр Казанда чуаш телендә нәшер ителә, барлыгы 13 саны чыга. Төрле елларда мөхәррирләре: П.Х.Христофоров, К.Н.Роднов, А.Т.Быков. Иң актив язышучылары: Тәтеш укытучылар семинариясе укытучысы О.Андреев, агрономнар А.Троцкий, Н.Ткаченко һ.б. Журналның Казанны Чехословакия корпусы частьләре һәм КОМУЧ Халык армиясе тарафыннан яулап алынуы алдыннан басылып чыккан беренче саны укучыларга барып ирешми. 1919 ның мартыннан даими рәвештә чыга башлый. Соңгы санында Чуаш автономияле өлкәсен оештыру турында БҮБК декреты һәм РСФСР ХКС карары басыла һәм журнал редакциясенең Чабаксар шәһәренә күчерелүе хәбәр ителә. 1922 нең мартыннан «Ана-Çаран» («Басу-болыннар») исемендә журналның 2 саны басыла. Игенчеләргә багышланган «А.» «Һәр бөртектән мең бөртек» шигаре б-н чыга. Рәсми бүлектә РСФСР ХКС һәм Милләтләр эшләре халык комис-тының җир төзелеше мәсьәләләре буенча карар һәм боерыклары урнаштырыла. Журнал укучыларны игенчелекне үстерү һәм крәстиян хуҗалыклары оештыруның алдынгы ысуллары, а.х. культураларының яңа сортлары б-н таныштыра, чуаш һәм татар авыллары тормышы турында мәкаләләр бастыра, крәстиян көнкүрешенең төрле проблемаларына кагылышлы эшлекле киңәшләр бирә.

*Әд.:* Чăваш календарĕ. Шупашкар, 1958; Сидорова А. Чăвашсен пирвайхи журналĕсем // Ялав. 1998. № 4. *А.Е.Никифоров.*

**«АНА́ БЕЛӘ́Н УГЫ́Л ДАСТАНЫ́»**, татар әдәбияты ядкәре. Берничә кульязма нөсхәсе буенча билгеле. Бер нөсхәсен 1920 елларда З.Ә.Максудова таба; соңрак М.Х.Бакиров тарафыннан өйрәнелә. Аның фикеренчә, дастан Болгар дәүләте дәверенә карый. Дастанның тагын кульязма өч нөсхәсен 1980 елларда М.И.Әхмәтҗанов Әлмәт һәм Лениногорск р-ннарыннан табып ала. Шулар нигезендә галим дастанның тәнкыйди җыелма текстын булдыра. М.И.Әхмәтҗанов ядкәрне 17–18 йөзләргә нисбәтли һәм барлыкка килү урыны итеп Касыйм ханлыгын саный. Эчтәлеге б-н дастан ислам мифологиясенә нигезләнгән һәм үгет-нәсыйхәт характерында иҗат ителгән. Әсәрдә тәгълим-тәрбиягә һәм әхлакка кагылышлы төрле мәсьәләләргә җавап бирелә. Тел-стиль ягыннан дастан 17 йөзнең әдәби ядкәре «Дәфтәр-е Чыңгызнамә»не хәтерләтә. Дастанның кульязма өч нөсхәсе ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының текстология һәм кульязмалар бүлегендә, берсе ТРның Милли музеенда саклана.

*Әд.:* Яхин А.Г.,Бакиров М.Х. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе (Мәзәкләр, бәетләр). К., 1979; Әхмәтҗанов М.И. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. К., 1999. *М.И.Әхмәтҗанов.*

**«АНА́ ДАНЫ́» ОРДЕНЫ**. СССР ЮС Президиумының 1944 ел 18 август Указы б-н раслана. Орден СССР ЮС Президиумы исеменнән союздаш һәм автономияле республикалар ЮС Президиумы указлары нигезендә тапшырыла. Орденның 3 дәрәҗәсе билгеләнгән: 3 нче дәрәҗә «Ана даны» ордены б-н — 7 бала; 2 нче дәрәҗә орден б-н — 8 бала; 1 нче дәрәҗә орден б-н 9 бала тудырып, тәрбияләп үстергән аналар бүләкләнә. Орден күкрәкнең сул ягына тагып йөртелә. Бүләкләнүченең башка орден һәм медальләре булган очракта, орден алардан өстәрәк урнаштырыла. 2007 елның 1 гыйнварына ТРда 641 кеше бүләкләнгән. *М.З.Хәбибуллин.*

**«АНА ДАНЫ — МАТЕРИНСКАЯ СЛАВА» МЕДАЛЕ**, ТРның дәүләт бүләге, ТР Президентының 2000 елның 2 ноябрь № УП-828 указы нигезендә гамәлгә кертелә. ТР гражданы булган, 5 һәм аннан артык бала тудырып яисә балалыкка алып тәрбияләп үстергән аналар бүләкләнә. Бүләкләгәндә, мәгариф, эчке эшләр оешмалары һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия нәтиҗәләренә нигезләнеп, ананың бала тәрбияләүгә намуслы мөнәсәбәте исәпкә алына. Медаль б-н бүләкләнүгә ана кече баласына 1 яшь тулганнан соң, башка балалары исән булган очракта тәкъдим ителә.

«Ана даны — Материнская слава» медале б-н бүләкләнүгә күрсәтелгәндә ананың закон нигезендә балалыкка алынган; Ватанны саклаганда яки башка хәрби бурычларны үтәгәндә, кеше гомерен коткарганда, законлылык һәм хокук тәртибен саклаганда һәлак булган яки хәбәрсез югалган, алда күрсәтелгән шартларда яралану, контузия алу, имгәнү, авыру яки хезмәт урынында имгәнү яисә һөнәри авыру, бәхетсез очрак, һәлакәт, табигать бәла-казалары нәтиҗәсендә үлгән балалары да исәпкә алына. Медаль күкрәкнең сул ягына тагылып йөртелә; бүләкләнүченең башка ор-

ден һәм медальләре булган очракта медаль алар янына яисә алардан астарак урнаштырыла. 2007 елның 1 гыйнварына ТРда «А.д. — М.с.» медале б-н 641 кеше бүләкләнгән.

Чыг.: Положение о порядке рассмотрения и представления документов к награждению медалью Республики Татарстан «Ана даны — Материнская слава» // Республика Татарстан. 2000. 6 нояб.

**АНА́ ТОКЫ́М**, туфрак ясаучы токым, тау токымының биологик һәм биохимик процесслар, ш.у. кеше эшчәнлеге йогынтысында *туфрак* хасил итүче өске катламы; туфрак ясалу факторларының берсе. А.т. килеп чыгышы (мәс., аллювиаль утырмалар, лёсслар һәм лёссыман комсыл балчыклар), химик составы (карбонатлы, хлорид-сульфатлы һ.б.), гранулометрик составы (комлы, комсыл балчыклы, балчыклы) буенча бүленә. Минераль составы һәм җилләнү дәрәҗәсенә карап, туфрак ясаучы токымнарны төркемнәргә бүләләр: беренчел минералларга бай массив кристаллик токымнар һәм аларның элювие; утырма вакланма токымнар; хәзерге континенталь элювиаль-делювиаль һәм аллювиаль китерелмәләр, бозлык, су-бозлык һәм эол утырмалары. А.т.ның үзенчәлекләре төрле интенсивлыкта һәм формаларда була, бу бигрәк тә туфрак төрләре һәм төркемнәре бүленешендә һәм классификациясендә чагыла.

ТРда А.т. буларак төп токымнар (известьташлар, доломитлар, мергельләр, балчыклар һәм комташлар), төп токымнарның җилләнгән элювиаль, делювиаль һәм эол продуктлары, елга үзәннәрендә аллювиаль утырмалар урын алган. Пермь системасының югары бүлек утырмалары аеруча күп очрый. Көнбатыш Кама алды һәм Идел алдында (аның үзәк һәм төньяк өлешләрендә) татар ярусының комсыл-балчыклы кызыл төстәге һәм карбонатлы-балчыклы чуар төстәге утырмалары киңрәк таралган. Көнчыгыш Кама аръягы һәм Көнчыгыш Кама алды терр-яләренең күп өлеше Казан ярусының известьташ катлаулары б-н аралашкан комсыл-балчыклы утырмалары б-н түшәлгән. Респ-каның көньяк-көнбатышында туфрак ясалу процессында юра һәм акбур системасы утырмалары — мергель һәм комташ катламнары б-н аралаш җилләнгән соры һәм коңгырт соры балчык продуктлары катнаша. Идел, Кама, Ык һ.б. елгаларның борынгы үзәннәрендә неоген системасының яшьрәк — күл-диңгез һәм континенталь утырмалары А.т. булып тора. Елгаларның хәзерге үзәннәре дүртенчел система балчык һәм комсыл балчыклары б-н түшәлгән. Ш.у. лёссыман комсыл балчыклар да дүртенчел чор яшендә, аларда аеруча уңдырышлы кара туфраклар хасил булган. Идел, Кама, Казансу, Илләтнең биек террасалары урыны-урыны эол комнары китерелмәләр б-н капланган, алардан яралган көлсу туфракларда нарат урманнары үсә. А.т. алмашуы рельефка һәм урынның абс. биеклегенә бәйле. Субүләрләрдә А.т. — аз үзгәргән төп токымнар һәм аларның элювие, ә субүләр сөзәклекләрендә — төп токымнарның су агымы б-н күчерелгән җилләнгән продуктлары (делювий).

А.т. туфракның гранулометрик, химик һәм минераль составына, аның физик һәм физик-механик үзлекләренә, бигрәк тә туфрак ясалуның башлангыч стадияләрендә су-һава, җылылык һәм туклану режимына йогынты ясый. А.т. составы һәм үзлекләре туфрак ясалу процессы тизлегенә һәм аның юнәлешенә тәэсир итә. Мәс., ТР терр-ясендә озак вакыт дәвамында тыгыз известьташлар һәм доломитлар элювийларында кәсле-карбонатлы сай туфраклар формалаша, аларның калынлыгы 20–30 *см* дан артмый. Шул ук вакытта комсыл балчык һәм балчыксыл утырмалар б-н түшәлгән сусүләр тигезлекләрендә һәм сөзәклекләрендә соры урман туфраклары һәм тирән профильле (1–1,5 *м* һәм артыграк) кара туфраклар киң таралган. Кальций һәм магний карбонаты булган токымнарда нейтраль яки аз ачылыклы реакцияле, мул гумуслы һәм суга чыдам структуралы туфраклар формалаша.

*А.П.Дедков, Ф.Г.Борһанов.*

**АНА́К** (Мәхмүтов Шамил Гомәр улы) (25.11.1928, Башкортстан Респ-касы, Әлшәй р-ны Габдерәшит а. — 21.10.2005, Башкортстан Респ-касы, Әлшәй р-ны Раевка пос.), шагыйрь, Башкортстан АССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1950). Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-тында (1957–59), Прага ун-тында (1959–60) укыта. Әсәрләре 1952 елдан басыла. А. тәрҗемәсендә төрек язучылары Решат Нури Гюнтекин, Омер Сәйфетдин, Орхан Кемал, Фаик Байсал әсәрләре, ш.у. Назыйм Хикмәтнең «Сайланма әсәрләр»е (1955) басылып чыга. А. татар, башкорт, рус телләрендә иҗат итә. Ул «Юл өстендә кояш» (1966; рус теленә тәрҗемәсе «Солнце на дороге», М., 1962), «Көтелмәгән очрашулар» (1971), «Тыйнак табын» (1982), «Европа уртаһынан репортаж» (1963), «Таш тамгалар» (1978), «Зәңгәр Өстүбә иле» (1984; рус теленә тәрҗемәсе «Три синих холма», М., 1971), «Һөйөү тамгалары» (1988) һ.б. шигъри җыентыклар авторы. А. әсәрләренең лирик героена рухи дөнья бөтенлеге, әхлакый максимализм хас. А. хәзерге татар шигыре төзелешенә, аның жанрлары үсешенә сизелерлек йогынты ясый, татар һәм башкорт поэзиясенә верлибр (ирекле шигырь) формасын кертә, беренчеләрдән булып татар поэзиясендә сонетлар бәйләмә булдыра, итальян терцинасын куллана, ода, касыйдә жанрларын яңарта, япон поэзиясендәге хайку һәм танка жанрларына назирәләр иҗат итә. Аның шигырьләре фәлсәфи уйлануларга бай, афоризм кебек яңгырый. Иҗатында еш кына новелла һәм шигъри проза формасына да мөрәҗәгать итә. А.ның шигырьләре немец, чех, словак, болгар һ.б. телләргә тәрҗемә ителә, аларның кайберләренә көйләр язылә. Г.Тукай шигырьләрен русчага тәрҗемә итә. Башкортстан Респ-касында яшәде.

*Әд.:* Харисов Р. Юл өстендә кояш // Казан утлары. 1967. № 12; Галиуллин Т.Н. Тыйнак табынга кил, укучы! // Казан утлары. 1983. № 11; Мустафин Р. Ищите крупицы добра // Образ времени. К., 1981.

**АНА́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 13 *км* көньяктарак, Сарман–Әлмәт автомобиль юлы буенда. 2002 елда 27 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.та мәчет була. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында; 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1811 дә — 52, 1816 да — 46 ир заты; 1870 тә — 185, 1920 дә — 280, 1926 да — 276, 1938 дә — 278, 1949 да — 191, 1958 дә — 129, 1970 тә — 110, 1979 да — 68, 1989 да — 43 кеше.

**АНАЛИ́ТИК ХИ́МИЯ**, матдәләрнең составы, табигате турында мәгълүмат алу ысулларын, чараларын һәм гомуми методологиясен өйрәнүче фән (фәза һәм вакыт эчендә). Дисциплинаара фәннәргә карый. Аның максаты — матдәләр составын микъдар һәм сыйфат ягыннан билгеләү, анализның төгәллеген, югары сизүчәнлеген, экспресслыгын һәм селективлыгын тәэмин итү. Анализның химик, физик, хим.-физ., биол. ысуллары бар. Микъдар һәм сыйфат билгеләү ысулларына нигезләнгән техник анализ аерым урын алып тора. Аңа чималны, җитештерү процессларын, әзер продукция, су, һава һ.б.ның аналитик контрольдә тоту керә. Анализ төрләрен классификацияләү табыла яки билгеләнә торган кисәкчекләрнең табигатенә нигезләнә. Шуңа бәйле рәвештә анализ изотоплы, элементлы (атом-ион), структуралы-төркемле (функциональ), молекуляр, матди һәм фәзалы төрләргә бүленә. 20 йөз урталарына кадәр органик матдәләр анализы органик химиягә карый. Органик матдәләр анализы — тикшеренүнең яңа, башлыча, физик ысуллары барлыкка килү һәм нәорганик анализда органик реактивларны киң куллану сәбәпле, аналитик химиянең бер өлешенә әверелә.

Борынгы чорларда ук тикшеренү эшләрендә химик анализ ысулы кулланылган, химиянең фән буларак үсеше, нигездә, А.х.дән башлана. Беренче аналитик прибор сыйфатында электән үк гади үлчәү кулланылган. Архимед (б.э.к. якынча 240 ел), көмеш катнашмасы барлыгын билгеләү өчен, үлчәү ярдәмендә «алтын» таҗның тыгызлыгын исәпләп чыгара. Матдәләрне танырга мөмкинлек биргән күп кенә ысуллар химия үсешенең алхимия чорында (11–14 йөзләр) эшләнә. «Химик анализ» терминын беренче мәртәбә инглиз галиме Р.Бойль (17 йөз) куллана. А.х. ысуллары химиянең төп законнары барлыкка килүдә әһәмиятле урын тота. Россиядә беренче хим. лаб. С.-Петербургта М.В.Ломоносов тарафыннан төзелә (1748). Анда тозлар, рудалар һәм минералларга анализ үткәрелә. Идел буенда А.х. үсеше Казан ун-тында 1844 елда рутений хим. элементын ачкан К.Клаус тикшеренүләреннән башлана. 20 йөз башында ун-тта металл тозларын каты халәттә төсле реакцияләр ярдәмендә билгеләү ысуллары эшләнә, алар — хәзерге тест-ысулларның башлангычы (Ф.М.Флавицкий). 1918 елда Казан ун-тында А.М.Васильев тарафыннан А.х. ка-

федрасы оештырыла, ул Татарстанда гына түгел, аннан читтә дә бу фәнне үстерүдә әйдәп баручы фәнни үзәк булып әверелә. 1920 елларда бик аз микъдардагы матдәләрне куерту ысулларының берсе буларак, матдәләрне утырымга төшерү күренеше өйрәнелә (А.М.Васильев). 1930 еллар ахырыннан эремәләрдә металл ионнарының комплексы кушылмаларын тикшерү үсеш ала (А.М.Васильев, В.Ф.Торопова һ.б.). Комплекслар хасил булу реакцияләренең закончалыкларын өйрәнү нигезендә, элементларның концентрациясен билгеләүнең полярографик, амперометрик һәм кулонометрик ысуллары эшләнә (В.Ф.Торопова, А.А.Попель, В.И.Гороховская, А.И.Костромин). 1960 еллардан бу ысуллар органик кушылмаларның электродтагы реакцияләрен өйрәнгәндә кулланыла башлый (Ю.П.Китаев, Ю.М.Каргин). *Электроаналитик химия* өлкәсендә тикшеренүләр Казан ун-тында, Казан технол. ун-тында, Казан техника ун-тында, РФА КГҮнең Органик һәм физ. химия ин-тында, Казан фотоматериаллар ин-тында алып барыла. Органик реагентлар, экстракцияләп куерту (В.Ф.Торопова, Г.К.Будников); полярография һәм аның төрле модификацияләре, хим. сенсорлар, ш.и. биосенсорлар (Г.К.Будников); сусыз электрохимия (Ю.М.Каргин); кулонометрия (И.Ф.Абдуллин); газ (С.М.Вигдергауз, В.Ф.Новиков) һәм сыеклык (М.И.Евгеньев) үзгәртүче органик реагентлар хроматографиясе б-н; редокс-анализда металларның боргидратларын куллану (К.Н.Мочалов); ш.у. берничә физ. ысул, ш.и. төш-магнит релаксациясе (А.А.Попель) һәм атом-эмиссия спектроскопиясе (И.С.Фишман) буенча тикшеренүләр алып барыла. Саналган ысулларның барысы да диярлек аз микъдардагы матдәләрне билгеләүдә файдаланыла. ТР югары уку йортларында һәм фәнни-тикшеренү ин-тларында аналитик приборлар эшләнә, заманча вольтамперографлар (Р.Ш.Нигъмәтуллин, М.Р.Вяселев) һәм югары мөмкинлекле спектраль приборлар (Р.Д.Мөхәммәдъяров) ясала. Фәнни эшкәртмәләр органик синтез, нефтехимия комплексы пр-тиеләренең аналитик лаб. практикасында, ш.у. әйләнә-тирәне саклау б-н бәйле ведомстволарда — «Түбәнкаманефтехим» АҖ, «Органик синтез» АҖ, Аналитик контрольнең специальләшкән үзәк инспекциясе, Руда булмаган материаллар геологиясе фәнни-тикшеренү ин-ты, Химия продуктлары фәнни-тишеренү ин-тында гамәлгә кертелә. Заманча җиһазлар, ш.и. компьютерлар ярдәмендә идарә итү, матдәләрнең хим. составы турындагы мәгълүматларны реаль вакыт масштабында алырга, экологик-аналитик мониторингның иң әһәмиятле проблемаларын чишәргә мөмкинлек бирә.

*Әд.:* З о л о т о в Ю.А. Аналитическая химия: проблемы и достижения. М., 1992; Основы аналитической химии. М., 1999. Кн. 1.


*Г.К.Будников.*

**АНА́НИКОВ** Сергей Ваганович (27.9.1938, Казан), хим. технология процессларын матем. модельләштерү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1998), проф. (1999). 1961 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, 1969 дан шунда ук эшли (бүленеп, 1974–75 тә ТатНИПИнефть ин-тының Казан филиалында сектор мөдире, 1975–78 дә Ижевск а.х. ин-тында, 1978–79 да ВНИПИнефтепромхимда химик продуктлар җитештерү технологиясе бүлегенең сектор мөдире), химия кибернетикасы каф. профессоры (1999 дан). Хезмәтләре йөзмә хәлдә киптерүгә һәм капма-каршы агымлы массаалмашу аппаратлары гидродинамикасына карый. Газда йөзү шартларында киптерү һәм дымсызландыру процессларының математик модельләрен эшли. А. химик реакторлардагы темп-ра кырын һәм чагыштырма җылылык агымнарын билгеләүнең теоретик чишелешен тәкъдим итә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Испарение капли топлива в ламинарном потоке газа // Физика горения и взрыва. 1973. № 6; О движении капли в потоке с изменяющейся скоростью // Инж.-физ. журн. 1977. Т. 32, № 1; Температурное поле в греющем элементе цилиндрического аппарата // Гидромеханика отопительно-вентиляционных и газоочистительных устройств: Межвузовский сб. науч. трудов. К., 1999.


**АНА́НЬИНО КАБЕРЛЕГЕ́**, *Ананьино культурасы* истәлеге. Табылган материаллар аның б.э.к. 8–5 йөзләрдә барлыкка килүен күрсәтә. Беренче тапкыр 1858 елда И.В.Шишкин, соңрак П.В.Алабин, П.А.Пономарёв, П.П.Ефименко, А.В.Збруева һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Чокыр итеп казылган каберләрдә түгәрәк төпле чүлмәк савытлар, бронза пычаклар, хәнҗәрләр, ук һәм сөңге очлыклары, бизәнү әйберләре табыла; күмү йоласында ут


1


2


3


4


5


6

**Ананьино культурасы.** 1. Кабер ташы. Б.э.к. 8–7 йөзләр. II Мурзиха каберлеге; 2. Ир-ат һәм хатын-кыз киемнәре; 3. Җиз авызлык һәм псалийлар. Б.э.к. 8 йөз уртасы — б.э.к. 7 нче йөзнең 1 нче яртысы. Мурзиха каберлеге (Алексеев р-ны); 4. Тимер балта, җиз сөңгеләр һәм аркылы балталар, тимер очлык; 5. VII Әҗмәр каберлегендә табылган сөяктән, җиз һәм көмештән эшләнгән әйберләр; 6. Б.э.к. 8–7 йөзләрдә эшләнгән әйберләр: сөңге очлыклары, псалий (сөяк), ат йөгәне бизәге, чакматаш, тимер пычак, псалий фрагментлары.

культы күзәтелә. Кабер өстенә утыртылган яссы ташларга чокып мәрхүмнең сурәте, кораллар төшерелгән.

*Әд.:* П о н о м а р ё в П.А. Ананьинский могильник // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии. 1882. Т. 10, вып. 4; З б р у е в а А.В. Ананьинский могильник // Советская археология. 1937. № 2; А л а б и н П.В. Ананьинский могильник // Вестн. Рос. геогр. об-ва. 1960. № 6.

**АНА́НЬИНО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.) тимер гасырда (якынча б.э.к. 8–3 йөзләр) Чулман, өлешчә Идел, Нократ һәм Агыйдел елгалары бассейннарында яшәүчеләргә нисбәтле археологик культура. Атамасы Алабуга шәһәре янындагы *Ананьино каберлеге* тикшерелгәч бирелә(1858). Фин-угыр кабиләләренә карый дип фараз ителә. А.к. халкы ышна ачып иген иккән, терлекчелек, балыкчылык, аучылык б-н көн күргән; бакыр, бронза һәм тимер эреткән (бронза һәм тимердән ук, сөңге очлыклары, хәнҗәр, пычак, бронза балталар); сөяктән эш кораллары, йоннан һәм үсемлек сүсләреннән тукымалар тукыган. А.к.на уемлы һәм үрелмә бизәк төшерелгән түгәрәк төпле балчык савыт-сабалар хас. А.к. халкы Кавказ, Себер кабиләләре, скифлар, сарматлар һ.б. халыклар б-н сәүдә итешә. Торулыклары элегрәк елга тамакларында, соңрак елга борылышларындагы биек яр өсләрендә, борыннарда урнашкан, җир-балчык өемнәре, тирән чокырлар, коймалар б-н уратып алынган. Кайбер торулыкларда торак һәм хуҗалык корылмалары калдыклары табыла. Тораклар нигездә җир өстенә, сирәк кенә яртылаш җиргә индерелеп төзелгән, квадрат яки турыпочмак рәвешендәге өйнең уртасында зур ташлар б-н әйләндереп алынган учак янган. Ш.у.к. *Әҗмәр комплексы*, *Мурзиха каберлеге*.

*Әд.:* З б р у е в а А.В. История населения Нижнего Прикамья в ананьинскую эпоху // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1952. № 30; Х а л и к о в А.Х. Волго-Камье в начале эпохи раннего железа (VIII–VI вв. до н. э.). М., 1977; К у з ь м и н ы х С.В. Металлургия Волго-Камья в раннем железном веке. М., 1983; М а р к о в В.Н. Ананьинская проблема: Памятники древней истории Волго-Камья // Вопр. археологии Татарстана. К., 1994. Вып. 1. *В.Н.Марков.*

**АНАРХИ́ЗМ** (грек. anarchía — идарә булмау, башбаштаклык), иҗтимагый-сәяси хәрәкәт; дәүләт хакимиятенә буйсыну тәртибен бетереп, гражданнарның ирекле, үзләре теләгәнчә берләшеп яшәвен яклый, шуны максат итеп куя. 1840–60 елларда барлыкка килә. А. карашларының нигезен индивидуальлек һәм субъективлык тәшкил итә. А. киләчәктә дәүләтсез яшәүгә күчү турындагы хыялый фикерне алга сөрә. А. термины беренче булып 1840 елларда француз философы П.Ж.Прудон хезмәтләрендә тасвирлана. А. тәгълиматы тарафдарлары Россиядә 1860 елларда, нигездә, народниклар арасында күренә башлый. 1870 елларда аларның күпчелеге, М.А.Бакунинның анархистик идеяләрен кабул итеп, хөкүмәткә каршы һәм парламент идеяләре өчен сәяси көрәш алып баруны инкарь итә. Россиядә крәстиян катлавының инстинктында ук җәмгыявилеккә тартылу ятканлыгын истә тотып, алар Россия крәстияннәренең берләшеп баш күтәрәчәгенә, якын киләчәктә социаль революция ясаячагына ышаналар. Бу елларда анархистларның төп тактикасы халыкта, бигрәк тә крәстияннәр арасында революцион фикер уяту, баш күтәрүләргә өндәүдән гыйбарәт була (к. *Народниклык*). Россиядә анархистлар хәрәкәтенең киң таралышы 1905 елның урталарына туры килә. Шул ук елларда бу хәрәкәт берничә тармакка аерыла. Террорчылык көрәшнең төп исулына әверелә. 1903–10 да Россиядә А. идеясенә табынучылар саны 7 мең чамасы кешегә җитә, 58 губернада һәм өлкәдә, ш.и. Казан губернасында да анархистлар эшчәнлеге җанлана. 1904 нең апрелендә Казан жандармериясенә бер төркем анархист-террорчының вет. ин-ты директорын үтерергә җыенуы мәгълүм була. 1908 дә Казанда анархист-террорчылар берничә мәртәбә кара эшләрен гамәлгә ашыруга да ирешәләр. 1914 тә Петроградта анархистларның Төньяк берлеге оештырыла. 1917 елгы Фев. рев-циясеннән соң А. хәрәкәте яңа көч-куәт ала. Бу вакытта А.ның ике төп юнәлеше: анархо-коммунизм һәм анархо-синдикализм барлыкка килә. 1917 нең июлендә анархистларның вак төркемнәрен берләштерү омтылышы була. Анархистларның бер өлеше Вакытлы хөкүмәтне бәреп төшерүдә һәм Совет хакимиятен ныгытуда катнаша. Күпчелек анархист төркемнәре Совет хакимияте урнашуга каршы була: алар регуляр армия төзүгә, эш урыннарында тәртип урнаштыруга һәм җирле советлар эшчәнлегенә каршы чыгалар, авылларда урта хәлле крәстияннәр мәнфәгатен яклыйлар. 1918 нең башында Россиядә 130 урында анархистлар төркеме актив хәрәкәт итә. А. хәрәкәтенә катнашучы аерым төркемнәрдән анархист-ялгызаклар, христиан-анархистлар, махаевчылар, анархо-универсалистлар һ.б. билгеле. 1920 нең ахырында оешкан анархо-универсалистлар секциясе анархо-коммунистлар б-н анархо-синдикалистлар төркемнәрен бердәм А. нигезендә берләштерергә тырыша. Анархистларның бер төркеме 1921 дә Казан янәшәсендәге Красная Горка (хәзер Юдино) авылында да оеша. Җитәкчеләре С.П.Жеребцов була, төркемгә 10 лап кеше, башлыча, Мәскәү–Казан тимер юлында эшләүчеләр керә. Бу секциянең төп максаты ирекле профсоюз оешмасы төзү, җитештерү-сәнәгать оешмаларын дәүләт катнашмаган эшче һәм крәстиян берлекләренә (ассоциацияләренә) бирү була. 1918 дә Мәскәүдә анархо-коммунистларның Бөтенроссия федерациясе, 1919 да яшь анархистларның Бөтенроссия федерациясе һәм «Почин» төркеме оеша. Бу оешмалар Совет хакимиятенә уңай караштa торалар. 1923–26 да шундый ук бер оешма («Живучие» дип атала) Казан ун-ты рабфагы каршында да эшли. Башлап йөрүчесе Г.Г.Парфёнов була, соңрак 15 ләп кешелек бу яшерен төркемгә А.Л.Эюпов җитәкчелек итә. Төркем әгъзалары завод-фабрикаларда эшләүчеләр арасында әңгәмәләр уздыралар (нигездә, эш хакын тигезләүне булдыру турында), анархистларның «Почин» г-тасын, «Вольная жизнь» ж-лын тараталар. Ил үзәгендәге шундый ук төркемнәр б-н ныклы элемтә урнаштыралар. Казан халкы арасында һәм респ-ка күләмендә йогынтылары булмый.



Анастасий.

1980 еллар ахырларыннан А. идеяләре б-н кызыксыну Россия студентлары арасында кабат күзәтелә башлый. 1989 да Мәскәүдә Анархист-синдикалистлар конфедерациясенең (берлегенең) 1 нче съезды уздырыла. Аңа җыелучыларның төп максаты коммунистлар чорында хөкем сөргән карашның үзгәрешен ачыкларга тырышу була. Казанда да анархист-синдикалистларның аерым таркау төркемнәре барлыкка килә.

*Әд.:* Я р о с л а в с к и й Е. Анархизм в России. М., 1939; Неформальная Россия: о неформальных политических движениях и группах в РСФСР. М., 1990; Анархия и власть. М., 1992; К р и в е н ь к и й В.В. Анархисты и анархизм. М., 1998; Анархисты. Документы и материалы. 1883–1935: В 2 т. М., 1998. *Л.М.Айнетдинова.*

**АНАСТА́СИЕВ** Андрей Иванович (30.11.1852, Сембер ш. — 1919, Казан), педагог. Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1878), Порецк укытучылар семинариясендә (Сембер губ., Алатырь өязе), Казан укытучылар ин-тында (1880 нән) рус теле укыта. 1895 елдан Сембер губернасының Николаев һәм Сембер өязләрендәге халык уч-щеләре инспекторы, 1896–1902 дә Казан укытучылар ин-ты директоры. 1894–1900 дә «*Городской и сельский учитель*» ж-лын нәшер итә, 1901–11 дә «*Начальное обучение*» ж-лы мөхәррире. Хезмәтләре дидактикага, рус телен укыту (ш.и. әҗнәби мәктәпләрдә) методикасына карый. Халык мәктәбендә православие кануннары буенча тәрбияләү тарафдары була, гомуми башлангыч белем бирүне, алдынгы укыту алымнарын кертүне яклый.

Х е з м.: Народная школа. Симбирск, 1890; Очерки по истории педагогики. К., 1900; Г р а ф Л.Н. Толстой как педагог. Вятка, 1901; Дидактический катехизис. К., 1902; Основы успешного обучения: Очерки дидактики. К., 1902; Внимание и интерес при обучении. СПб., 1903.

*Әд.:* Х а н б и к о в Я.И. Русские педагоги в Татарии. К., 1968; И с х а к о в а Р.Р. Педагогическое образование в Казанской губернии во 2-й пол. 19 – начале 20 вв. К., 2001. *Р.Р.Исхакова.*

**АНАСТА́СИЙ** (Меткин Александр Иванович), (27.8.1944, Тверь өлкәсе, Кимры р-ның Столбово а.), дин эшлеклесе. Мәскәү руханилар семинариясен (1975), Мәскәү руханилар академиясен (1983) тәмамлый. Төзелеш уч-щесен тәмамлаганнан соң (1963), Кимры шәһәрендә машиналар төзү з-дында эшли. 1967 елда Казан һәм Мари епархиясенең төрле храмнарында псалма укучы, 1968 дән дьякон, 1972 дән поп. 1976 дан монахлыкта, шул ук елда Казан Никольский кафедраль соборында (к. *Никола Нисский чиркәве*) игумен, чиркәү җитәкчесе, бер үк

вакытта Казан епархиаль идарәсе секретаре. 1986 да архимандрит чины ала. 1988 дән Казан һәм Мари, 1993 тән Казан һәм Татарстан епископы, 1996 дан архиепископы. 1997 дән Казан руханилар семинариясе ректоры. 3 нче дәрәҗә Изге апостолга тиң кенәз Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Сергий Радонежский, 2 нче дәрәҗә Изге Серафим Саровский, 2 нче дәрәҗә Изге кенәз Даниил, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АНАТО́ЛИЙ** (Грисюк Андрей Григорьевич) (20.8.1880, Волынь өлкәсе Ковель ш., Украина — 23.1.1938, Коми АССР, Кылтово а.), дин эшлеклесе. Киев руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1904), монахлык кабул итә. 1912 елда Киев руханилар академиясе профессоры, Мәскәү руханилар академиясе инспекторы. 1913 тән Казан руханилар академиясе ректоры, Чистай епископы. 1918 нең сентябреннән, митрополит Иаков (Пятницкий) чит илгә киткәч, академиядә ректорлык вазифаларын да башкара, 2 елдан артык Казан епархиясе б-н җитәкчелек итә. Авыр шартларда Казан руханилар академиясен саклап кала. 1921 дә кулга алына, 2 елга төрмәгә ябыла. 1922 дән Самара епископы, 1923 тән архиепископы. 1928 дән Одесса архиепископы, 1932 дән — митрополит. 1936 да кулга алына. Төрмә хастаханәсендә вафат була. Украина православие чиркәве Синоды тарафыннан изгеләштерелә. 10 (23) гыйнварда искә алына.

Х е з м.: Исторический очерк Сирийского монашества до середины VI века. Дис. ... Киев, 1911.

*Әд.:* Ж у р а в с к и й А.В. Казанская церковь в эпоху гонений. Страницы истории. К., 1994.

**АНАТО́МИЯ** (грек. anatomḗ — аеру, яру), организмның функциясе һәм үсешенә бәйләп, аның рәвешен, эчке һәм тышкы төзелешләрен өйрәнүче фән. Кеше, хайваннар, үсемлекләр А.се аерым-аерым өйрәнелә. А. — морфологик фәннәрнең бер өлеше. «А». терминын В.Гёте кулланылышка кертә. Өйрәнүнең төп ысуллары: яру, морфометрия, рентгенография, гистологик һәм биохимик анализлар.

**Кеше анатомиясе** (К.а.). Үсеш барышында берничә морфологик фәнгә бүленә. Системалы анатомия: остеология — сөякләр, синдесмология — скелет өлешләре арасындагы бәйләнеш төрләре, миология — мускуллар, спланхнология — ашкайнату, сулыш, сидек-җенес системаларындагы эчке органнар, ангиология — кан йөреше һәм лимфа системалары, неврология — үзәк һәм периферик нерв системасы, эстезиология — сизү органнары турындагы фәннәрдән гыйбарәт. К.а. фәненең тиз үсеп киткән бүлеге — эндокрин системаның төзелеше. Функциональ К.а. — әгъзалар һәм системаларның төзелеш үзенчәлекләре б-н функцияләре характеры арасындагы үзара бәйләнешне ачыклый. Яшь үзенчәлекләренә бәйле К.а. — организмның индивидуаль үсеше барышында тән төзелешенең һәм әгъзаларның үзенчәлекләрен өйрәнә. Әгъзаларның рәвешен, аларның урнашуларын һәм кан тамырлары, нервлар б-н үзара бәйләнешен *топографик анатомия* бәян итә. *Патологик анатомия* кеше организмындагы әгъзаларның һәм тукымаларның структур үзгәрешләрен, пластик А. кеше тәненең тышкы төзелеше үзенчәлекләрен өйрәнә, аның пропорцияләрен билгели. Россиядә беренче анатомик тикшеренүләр турындагы мәгълүматлар, К.а.нә нигез салучы А.Везалийның «Кеше тәне төзелеше турында»гы («О строении человеческого тела», 1543) хезмәте, Е.Славинецкий тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгәннән соң, 17 йөздә дөнья күрә. Россиядә мәетләрне яру тәҗрибәсе 18 йөздә Мәскәү госпиталендә башлана. 1750 елларда беренче рус анатомнары А.П.Протасов, М.И.Шеин тарафыннан русча анатомия терминнары төзелә. К.а. буенча зур тикшеренүләр И.В.Буяльский (1844), П.Ф.Лесгафт (1869) һ.б. тарафыннан үткәрелә. В.П.Воробьёв нервларны өйрәнүнең яңа ысулын тәкъдим итә, К.а.нең 5 томлы атласын төзи (1838–42). Россиядә лимфологиягә Г.М.Иосифов нигез сала, организмның үзгәрүчәнлеге турындагы тәгълиматны В.Н.Шевкуненко төзи. П.И.Карузин «Анатомия терминнары сүзлеге» («Словарь анатомических терминов») һәм «Пластик анатомия буенча кулланма» («Руководство по пластической анатомии») басмаларын нәшер итә. Функциональ К.а. М.Г.Привес (1940 еллар), Д.А.Жданов (1950 еллар), В.В.Куприянов (1940–60 еллар) хезмәтләрендә үсеш ала.

Казан ун-тында анатомия, физиология һәм мәхкәмә табиблеге фәннәре кафедрасы 1805 елда оештырыла. Кафедраның беренче профессоры И.П.Каменский (1806) була. 1836 да Казан ун-тында кешенең нормаль анатомиясе кафедрасы өчен махсус бина төзелә (к. *Анатомия театры*) һәм анатомия музеен оештыруга зур өлеш керткән Е.Ф.Аристов каф. мөдире итеп билгеләнә. В.Н.Тоновның кеше тамырлары системасын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә функциональ анатомия өлкәсендә яңа фәнни юнәлешкә нигез салына. В.Н.Терновский Казан анатомнарының фәнни мәктәбен нигезли (1924). Вегетатив нерв системасына караган тикшеренүләр зур әһәмияткә ия (В.Н.Терновский, В.Н.Мурат, А.М.Мещеряков, М.М.Халкузяев, У.Н.Камалетдинов, Э.Р.Люцкендорф, Х.Н.Әмиров, А.Г.Коротков, 1950–70 еллар). Нерв рецепторлары аппаратының морфофункциональ һәм гистохимик үзенчәлекләре ачыклана (Х.Г.Вәлиева, Н.М.Иванов һ.б., 1960–80 еллар). Эмбриогенез һәм филогенез процессында микроциркуляр кан йөреше юллары төзелешен өйрәнүгә, төрле эксперименталь тәэсирләр һәм патология вакытында нормадагы кан агышын көйләү һәм үзгәртү механизмнарын ачыклауга Э.Г.Вәлишин һ.б. хезмәтләре багышлана (1980 еллар). К.а. үсешенә ангиология, вегетатив нерв системасының периферик бүлекләрендә васкуляризация буенча тикшеренүләр сериясе (И.Ф.Харитонов, Г.Н.Богданова, М.Т.Ракеева, А.Е.Тихонова, 1970–80 еллар) зур өлеш кертә. М.Т.Ракеева хезмәтләрендә арка миенең кан б-н тәэмин ителеше үзенчәлекләре җентекләп аңлатыла. ТРда Казан мед. ун-ты, Казан мед. академиясе анатомик тикшеренүләр үзәге булып санала.

*Әд.:* В а л и ш и н Э.С. Достижения казанской научной анатомической школы // Казанский медицинский институт. 1814–1989. К., 1989. Ч. 2.

*Э.С.Вәлишин.*

**Хайваннар анатомиясе** (Х.а.). Системалы, топографик, чагыштырма, токым, яшь ягыннан, зоотехния һ.б. бүленә. К.Буржеланың чагыштырма Х.а.нә багышланган беренче тирән эчтәлекле китабы 1766–69 елларда Франциядә нәшер ителә. 19 йөздә В.Элленберг б-н Г.Баумның Х.а.нә караган немец телендәге кулланмасы аеруча тулы һәм әһәмиятле хезмәт булып санала. Россиядә вет. Х.а. фәненең үсеше 19 йөздә ун-тлар һәм югары мед. мәктәпләре ачылу вакытына туры килә. 1846–47 дә Петербург мед.-хирургия академиясенең вет. бүлеге профессоры В.Н.Всеволодов имезүче йорт хайваннары анатомиясе курсын нәшер итә. 19 йөз башында Мәскәү, Харьков һәм Казан ун-тларында беренче терлекләр табиблеге кафедралары оештырыла һәм аларда а.х. терлекләре анатомиясен өйрәнү б-н шөгыльләнәләр.

Россиядә беренче Х.а. кафедрасы Казан вет. ин-тында 1873 елда оеша. Совет вет. анатомнары мәктәбенә нигез салучылар — Казан вет. ин-тыннан чыккан галимнәр — Д.М.Автократов, А.Ф.Климов, А.И.Акаевский. Алар тарафыннан йорт хайваннары организмы системаларын өйрәнүнең яңа ысуллары эшләнә һәм яңа фәнни юнәлешләре барлыкка килә, дәреслекләр языла. 1950 еллардан Х.а. өлкәсендә топографиягә, хайван төрләрендә нервларның бүленеш зоналары һәм үзара бәйләнешенә (Н.А.Васнецов), йорт хайваннары һәм кошларда күкрәк читлеге биомеханикасы һәм нервларның макро- һәм микроморфологиясенә (Ю.Х.Миндубаев, Н.В.Михайлов), йорт хайваннарында вегетатив нерв системасының ультраструктур төзелеше (Р.Х.Шакиров) проблемаларына караган тикшеренүләр алып барыла.

*Әд.:* Очерки по истории анатомии домашних животных в России // Сб. науч. тр. Ленингр. ин-та усовершенствования ветеринарных врачей. 1951. Вып.7. Библиогр. ш. у. к. Д.М.*Автократов*, А.И.*Акаевский*, А.Ф.*Климов* мәкаләләрендә.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**Үсемлекләр анатомиясе** (Ү.а.), *ботаника* фәненең бер бүлеге, үсемлекләрнең эчке төзелешен өйрәнә. Ү.а.нең барлыкка килүе микроскоп уйлап табылу һәм үсемлек объектларын беренче тапкыр тулысынча микроскопик өйрәнгән итальян биологы М.Мальпиги һәм инглиз ботанигы Н.Грю хезмәтләре б-н бәйле (17 йөз ахыры). 19 йөздә үсемлек күзәнәкләрен тикшерү нәтиҗәсен немец биологы Т.Шванн күзәнәк теориясен төзегәндә файдалана (1839). 20 йөз уртасыннан башлап, Ү.а. өйрәнү ысулларыннан — электрон микроскопиягә, эволюцион һәм экологик юнәлешкә әһәмият бирелә. Аерым алганда, Казан ун-тының ботаника каф. вегетатив хәрәкәтчән үсемлекләрдәге вегетатив үрчү әгъзаларының анатомик төзелеше һәм аларга яшәү шартларының тәэсире тикшерелә (Е.Л.Любарский). Анатомик тикшеренү ысуллары культуралы үсемлекләрнең килеп чыгышын һәм а.х. үсемлекләре сортларына тышкы мохит шартларының тәэсирен ачыклауга бәйле мәсьәләләрне хәл иткәндә, ш.у. азык-төлек, фармацевтика, целлюлоза-кәгазь һ.б. шуның кебек сәнәгать тармакларында киң файдаланыла.

*Әд.:* Александров В.Г. Анатомия растений. М., 1966; Любарский Е.Л. Экология вегетативного размножения высших растений. К., 1967.

*Е.Л.Любарский.*




1. Казан мед. ун-тының Анатомия театры-музее; 2. Лекцияләр залы.

**АНАТО́МИЯ ТЕА́ТРЫ**, Казан мед. ун-тының укыту-фәнни эшләр бинасы. 1834–36 елларда арх. М.П.Коринфский проекты б-н һәм аның җитәкчелегендә Казан ун-ты ансамблендә төзелә. Архит-ра истәлеге. А.т.ның төньягы ярымтүгәрәк ясап чыгып торган өч катлы турыпочмаклы корпус. Әүвәл ярымтүгәрәк колоннада б-н китапханәгә һәм химия корпусына тоташкан була (соңрак сүтелә). Ярым сферик гөмбәзнең уртасына сигез кырлы фонарь куела һәм гөмбәзле ярымтүгәрәк чыгынтылы бина фасадын әйләндереп алган ионик ордерлы 8 колонна — бинаның композиция үзәген тәшкил итә. Амфитеатр б-н аудитория һәм тамашачылар өчен өске галереяга 2 нче каттан керү ишеге ротондада урнашкан. 1 һәм 2 каттагы уку бүлмәләре а́ркаларда ак таштан ясалган парадный баскыч б-н тоташкан. А.т.ның эчке өлешенең бизәлеше 1837 дә төгәлләнә. Бинада ун-тның мед. ф-тының, 1920 дән мед. ин-тының кешенең нормаль анатомиясе кафедрасы урнаша. 1841 дә бинаның 2 нче каты анатомия препаратларын саклау өчен зал итеп үзгәртелә. Залның эчке бизәлеше һәм җиһазлары М.П.Коринфский сызымнары буенча эшләнә. 2 нче катта урнашкан аудиториянең эчке ярымтүгәрәгендәге балкон металлдан коелган мед. эмблемалары б-н бизәлгән колонналар тезмәсе һәм рәшәткәләр б-н әйләндереп алынган. 1887 дә бинаның көньяктагы фасадына часовня (кечкенә чиркәү) кушып салына (арх. М.Д.Михайлов). 1950 елларда нигез каты (цоколь) уку-секция залы итеп җиһазландырыла. 1970 тә бинаның өске ягындагы ярымтүгәрәктә латинча «Hic locus est ubi mors gaudet succurrere vitae» («Биредә үлем яшәүгә ярдәм итә торган урын») дигән язма чокылган. 1980 елларда уку аудиторияләре тәрәзәләренә төсле пыялалар куела. 1988 дә бина реконструкцияләнә, гөмбәзе һәм диварлары ныгытыла (арх. М.В.Сафронов һәм О.И.Григорьев җитәкчелегендә). А.т.да баш сөякләре һәм скелетлар коллекциясе, 1806 да бетерелгән Мәскәү мед. хирургия академиясенең «гарипләр препаратлары» коллекциясе, мәетләрне консервацияләү ысулларын эшләгән голландияле Ф.Рюиш һәм француз анатомы Трамонд препаратлары, Россиягә Петр I алып кайткан 4 препарат урнаштырылган. Музей эшләре осталары В.Н.Тонков (остеология һәм синдесмология), В.И.Бик һәм А.В.Вишневский тарафыннан әзерләнгән препаратлар зур урын алып тора. 1998 дә Н.Н.Шишкова тарафыннан Россиядә кешенең табигый зурлыктагы бердәнбер артерия һәм веналар моделе эшләнә. Шунда ук мед. ин-ты хезмәткәрләренең А.т.на васыять иткән скелетлары саклана. Фәнни китапханәдә анатомия һәм катнаш фәннәр буенча илебездә һәм чит илләрдә нәшер ителгән 3000 нән артык басма тупланган. Фонд ел саен монографияләр, фәнни җыентыклар, вакытлы матбугат басмалары б-н тулыландырыла. А.т. нда кафедра хезмәткәрләре, анатомия препаратлары күрсәтеп, студентлар өчен лекцияләр укыйлар.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. История Императорского Казанского университета за первые сто лет его существования (1804–1904): В 4 т. К., 1902–06; Е в с и н а Н.А. Здания Казанского университета // Памятники культуры. Исследования и реставрация: Сб. статей. М., 1963. Вып. 4; Ф е х н е р М. Великие Булгары. Казань. Свияжск. М., 1978.

*Э.С.Вәлишин*, С.Г.*Персова*.

**АНАТЫ́Ш** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе авылыннан 2 *км* төньяктарак, Бәтке елгасы буенда. 2002 елда 654 кеше (руслар — 75%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Богоявленский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сәүдә, сарык тиресе эшкәртү, тимерчелек, түбә ябу, мич чыгару, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 16 йөз ахырыннан А.та православие приходы була. 1718 дә авылда агачтан Богоявление чиркәве (таш бинасы 1889–1903 тә корыла) төзелә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; 1868 дә ачылган земство уч-щесе, чиркәү-приход мәктәбе, волость уку биналары, аеклык җәмгыяте, су тегермәне, 4 вак-төякләр һәм шәраб кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3609,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Анатыш волостеның үзәге була. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 399 ир заты; 1859 да — 1697, 1897 дә — 1917, 1908 дә — 1788, 1920 дә — 1960, 1924 тә — 1753, 1926 да — 1659, 1949 да — 870, 1958 дә — 724, 1970 тә — 711, 1979 да — 724, 1989 да — 696 кеше.

**АНАЭРО́Б ОРГАНИ́ЗМНАР**, а н а э р о б л а р (грек. an — тискәре һәм *аэроблар*), атмосфера кислородыннан башка яшәүгә һәм үрчүгә сәләтле организмнар. Тулысынча кислород булмаганда яхшы үрчүгә сәләтле һәм аның б-н кушылганда үлә торган (бактерияләр) облигат һәм кислородлы мохиттә үсүгә сәләтле (бактерияләр, кайбер гөмбәләр, гади кортлар һ.б.) факультатив А.о. га аерылалар. «Анаэроб» терминын 1861 елда майлы әчетү бактерияләрен ачкан Л.Пастер гамәлгә кертә. А.о. кузаклы үсемлекләрнең тамыр бүлбеләрендә яисә туфракта азот туплый һәм күшәүче хайваннар әчәклегендә клетчатканы тарката. Алар үсемлек калдыкларын өлешчә генә таркатып, торф барлыкка китерәләр. А.о. тереклек эшчәнлеге өчен энергияне, кислоталар (уксус, пропион, сөт кислоталары), спиртлар (этил, бутил), ацетон, метан һ.б. барлыкка китереп, шикәр, целлюза һ.б. туклыклы матдәләрне оксидлаштыручы фермент системалары ярдәмендә ала. Бу кушылмаларның үзләрендә шактый энергия запасы бар, аларның моннан соңгы оксидлашуы атмосфера кислороды б-н факультатив А.о. яисә *аэроб организмнар* катнашында бара. А.о. техн. микробиологиядә спирт, органик кислоталар һ.б. продуктлар җитештерүдә, сыр ясау, терлек азыгы силослау, агынтык суларны чистартуда кулланыла. Кайбер А.о. кешеләр һәм хайваннарда йогышлы авырулар (ботулизм, столбняк, газлы гангрена) китереп чыгаралар.

**АНГА́РСК**, *Иркутск өлкәсендәге* шәһәр (1951 дән), Иркутскидан 46 *км* төньяк-көнбатыштарак. 1948 елда нигез салына. Халкы — 267,7 мең кеше (1996), ш.и. татарлар — 3127 кеше (1989). Иркутск-Черемховский сәнәгать р-нының иң зур үзәкләреннән берсе. «Ангарск нефтехимия компаниясе» АҖгә 10 нан артык з-д керә (нефть Татарстан һәм Башкортстаннан үткәргеч торбалар буйлап килә). 1994 тән татар-башкорт мәдәни үзәге эшли.

**АНГЕМИТО́НИКА** (грек. an — тискәре кисәкчә һәм hemi — ярым, tónos — тон), секунд, терция, кварта, квинта арасындагы ярымтоннарсыз лад төзелешен белдергән музыка термины. Төрле халыкларның музыка культурасында очрый. Татар халык музыкасында



Ангемитон тавыш рәтләре.

А. бигрәк тә борынгы көйләрдә күзәтелә, ул секундтан зуррак кварталы дихордлар, терцияле, кварталы трихордлар рәвешендә була. Татар музыка фольклорында квинталы ангемитон тетрахордлар, кече терциядә тәрлечә урнашуларына карап, өстә, уртада, аста кулланыла. Бу лад модельләренең һәркайсы үзенең аерым интонацион үсеш закончалыклары системасы б-н тар күләмле көй өзекләре, төп тоннар, каданслар һ.б.лар бәйләнешеннән тора. Киң үсеш алган ангемитон лад булып бишбаскычлы ярым тонсыз лад санала (к. *Пентатоника*).

*Әд.:* Гиршман Я. Пентатоника и её развитие в татарской музыке. М., 1960; Нигмедзянов М. О пентатонике в татарской музыке // Советская музыка. 1961. № 2; шул ук. Олиготонные лады в татарской музыке // Советская музыка. 1974. № 1; Квитка К. Избранные труды. М., 1971. Т. 1; Исхакова-Вамба Р. Ангемитоника как музыкальная система. М., 1990; Сайдашева З. Ладо-интонационные особенности ранних форм музыкального фольклора татар-мусульман // Пентатоника в контексте мировой культуры. К., 1995. *З.Н.Сәйдәшева.*

**АНГИДРИ́Т** (грек. an — тискәре кисәкчә, hу́dor — су), синвулькинит, Жигули, Бергамо мәрмәре. 1) Сульфатлар классындагы минерал, $Ca[SO_4]$. Составында CaO (41,2%), Ba, Mg, Sr кушылмалары бар. Ромбсыман сингонияле кристаллар; калын шакмак һәм призма формасында, гадәттә тоташ бөртекле масса яисә җепселле агрегатлар хасил итә. Төссез, зәңгәрсу-соры яки алсу төстә. Пыяласыман ялтырый. Катылыгы 3,5–3,8. Тыгызлыгы 2,9–3 *г/см*³. Су б-н кушылып, нормаль атмосфера басымында *гипска* әверелә һәм күләме арта (30% тан артык). Порошок хәлендә



Ангидрит. Казан ярусы утырмаларыннан (Кама Тамагы р-ны).

$H_2SO_4$ тә эри, ләкин, кальцит һәм доломиттан аермалы буларак, $CO_2$ бүлеп чыгармый. ТРда утырма токымнарда очрый. 2) Вак бөртекле тыгыз утырма тау токымы. Башлыча, А. минералларыннан тора һәм йомык бассейннарда $CaSO_4$ нең химик утырма продуктыннан гыйбарәт. Респ-каның күп урыннарында Пермь системасының Көнгер һәм Сакмар ярусларында шактый зур тупланышлары һәм ятмалары бар. А. рудалардан флотация ысулы б-н аерылып алына. Ашлама итеп файдаланыла, цемент, сульфат кислотасы эшләп чыгаруда чимал булып тора һәм декоратив-гамәли сәнгатьтә кулланыла.

**АНГИ́НА** (лат. angina – буылу), тонзиллит, каты яки дәвамлы йогышлы авыру, йоткылыктагы лимфатик бизләр бөҗрасының, аңкау миндальләренең ялкынсынуы. Аны бактерияләр (В-гемолитик стрептококклар, стафилококклар һәм аларның төрле кушылмалары), вируслар, кандида төрендәге гөмбәләрнең кокклар б-н берләшүе, кайчагында башка микроорганизмнар китереп чыгара. А. билгеләре Гиппократ (б.э.к. 5–4 йөзләр), Цельс (1 йөз), Әбүгалисина (11 йөз) хезмәтләрендә үк тасвирланган. Медицинада бактериологик тикшеренү ысулларын гамәлгә кертү А.ны, микробларга һәм авыруның барлыкка килү урынына карап, түбәндәге формаларга бүленү мөмкинлеге бирә: катараль, лакунар, фолликуляр, фибриноз, некротик, флегмоноз, септик һ.б. А. киң таралган авырулар төренә керә. А. б-н балалар һәм 30–40 яшьтәге кешеләр еш авырый. ТРда авыручыларның гомуми санының 15 – 17%ы А.га туры килә. Авыру чыганагы булып сәламәт, ләкин А. бактерияләре йөртүчеләр һәм аның көчәеп киткән вакытындагы авырулар санала. Авыру китереп чыгаручы микроблар һава-тамчылар юлы б-н тарала. Йогышлы авыруның барышы организмга читтән кергән микроблар санына һәм организмның саклану механизмының активлыгына бәйле. Авыруга каршы иммунитет юк. Микроблар бүлеп чыгарган күпсанлы токсиннар йөрәкне, бөерләрне, үзәк нерв системасын, ишетү органнарын һ.б. зарарлый. Дәвалау: антибиотиклар, фаготерапия, гамма-глобулинотерапия, фитотерапия. Махсус профилактика — стафилококклы анатоксин, стафилококклы фага (авыз һәм борын куышлыгын савыктыру) ысулы б-н В.Е.Григорьев һәм Р.Г.Исхакова тәкъдим иткән схема буенча алып барыла (Казан мед. академиясе, 1989). Профилактикасы үзенчәлекле — авыручыларны үз вакытында аерып дәвалау, бактерия йөртүчеләрне ачыклау һәм лайлалы тышчаларны савыктыру: борын эчен прополис кушып ясалган вазелин, авыз куышлыгын В.Е.Григорьев, Р.Г.Исхакова методикасы (1989) буенча прополисның спирттагы эремәсе б-н эшкәртү. Аларның методикасы РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы приказына кертелә һәм гамәли медицинада кулланыла, бу исә авырулар саны кимүгә китерә; бу ысул б-н дәвалау-савыктыру 3–5 елга гарантия бирә.

*Әд.:* Турьянов М.Х., Цaрегородцев А.Д. Инфекционные болезни. М., 1998; Справочник-путеводитель практикующего врача: 2000 болезней от А до Я. М., 1999. *Д.Р.Нуретдинова.*

**АНДРАМО́НОВА** Наталия Алексеевна (12.8.1930, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1981), проф. (1982), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан ун-тын тәмамлый (1953), шунда ук эшли, 1978–93 елларда рус теле каф. мөдире. Хезмәтләре системалы һәм функциональ аспектта кушма җөмләләр синтаксисын өйрәнүгә, текст синтаксисына һәм семантикасына, рус булмаган аудитория өчен рус телен өйрәтү лингвометодикасына, әдәби текст телен өйрәнүгә карый. Татар мәктәпләре өчен рус теле дәреслекләре һәм укытучылар өчен методик ярдәмлекләр авторы.

Хезм.: Сложные предложения с относительными придаточными. К., 1959; Синтаксис произведений Л.Н.Толстого. К., 1965; Сложные предложения, выражающие обстоятельственные отношения в современном русском языке. К., 1977; Синтаксис сложного предложения. К., 1985; Русский язык для 11 класса. К., 2002 (автордаш).

**АНДРЕ́ЕВ** Валентин Иванович (25.3.1940, Лаеш р-ны Зур Кабан а.), педагог, пед. фән. д-ры (1984), проф. (1985), РМАнең мөхбир әгъзасы (1992), 2007 дән академигы. РФнең атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан пед. ин-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң (1961), Лаеш р-нының Столбище урта мәктәбендә, 1968 елдан Казанның 131 нче урта мәктәбендә, 1971 дән Казан пед. ин-тының пед. кафедрасында, 1985 тән Казан ун-тының пед. каф. мөдире. Хезмәтләре югары мәктәп педагогикасы проблемаларына, пед. диагностикага, иҗади сәләтне үстерү һәм шәхеснең үзлегеннән үсеше мәсьәләләренә карый.

*Әд.:* Педагогика творческого развития. К., 1996–98. Ч. 1–2; Педагогическая этика: Инновационный курс для нравственного саморазвития. К., 2003; Педагогика высшей школы: Инновационно-прогностический курс. К., 2005.

**АНДРЕ́ЕВ** Вячеслав Максимович (10.8.1931, Мари АССРның Сотаурск р-ны Тошнер а. — 27.12.2002, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1981), проф. (1983). 1956 елда Ижевск мед. ин-тын тәмамлый, Мари АССРның мед. оешмаларында эшли. 1964 тән Казан ГИДУВында, хәзерге Казан мед. академиясендә. 1982 дән функциональ диагностика каф. мөдире. Тикшеренүләре йөрәк-кан тамырлары һәм бронх-үпкә системасы авырган кешеләрдә сулыш алуның клиник физиологиясе, йөрәк һәм үпкәләр авырганда сулыш зәгыйфьлеге патогенезына карый. Казандагы «Медфизприбор» махсус конструкторлык техник бюросында эшләнгән приборларга (спирограф, азотограф, капнограф, диффузиометр һ.б.) сынау үткәрә һәм клиникада гамәлгә кертә.

Хезм.: О равномерности альвеолярной вентиляции у больных клапанными пороками сердца // Кардиология. 1968. № 3; Современные методы исследования внешнего дыхания. Л., 1978; Лёгочный газообмен у больных ревматическими пороками сердца. К., 1986; Лёгочный газообмен при хронических заболеваниях лёгких. К., 1988; Диагностика и лечение больных с хроническим лёгочным сердцем // Казан. мед. журн. 1995. № 5.

*Әд.:* Профессор Вячеслав Максимович Андреев // Казан. мед. журн. 1992. № 5.

**АНДРЕ́ЕВ** Илья Николаевич (6.1.1938, Яшел Үзән ш.), электрохимик, химия фән. д-ры (1998), проф. (2000). 1961 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. 1998 дән электрохим. җитештерүләр каф. профессоры. Г.С.Воздвиженский җитәкчелегендә никельләү электролитларында катод яны тирәлеген автоматик тикшерү системасының электрохимик нигезләрен һәм конструктив формалаштыруны эшли. Газ турбиналы двигательләрне электрохимик эшкәртү технологиясен камилләштерүдә катнаша. «АвтоВАЗ» АҖ һәм «Ижмаш» ҖБләрендә автомобиль җитештерүдә кулланылган күпкатлы гальваник капламнарда коррозия барлыкка килү процессын тикшерә, барабанлы ванна-

ларда гальваник капламнар формалашу процессларының фәнни нигезләрен эшли. СССР Машина төзү министрлыгының комплексны программасы кысаларында эксперименталь тикшеренүләр һәм шушы өлкә пр-тиеләрендә тормышка ашырылган гальваник җитештерү технологик процесслары б-н идарә итүне автоматлаштыру системалары өчен математик модельләр төзү эшләрен җитәкли.

Х е з м.: Влияние технологических факторов на характеристики защитных гальванических покрытий / ВИНИТИ // Итоги науки и техники. Сер. Коррозия и защита от коррозии. М., 1985. Т. 11; Технологическая оснастка гальванических автоматических линий. Гальванические покрытия в машиностроении: Справ. М., 1985. Т. 2; О новом показателе рассеивающей способности электролитов // Журн. прикладной химии. 1988. № 9 (автордаш); Mathematical Evaluation of the Influence of Major Process Parameters of the Current Distribution in Barrel Plating // International Technical Conference AESF. SUR/FI № 97. Detroit. USA. 1997. June 23–26 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**АНДРЕ́ЕВ** Михаил Петрович (11.1.1896, Казан — 1.12.1980, шунда ук), психиатр, мед. фән. д-ры (1940), проф. (1949). ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). 1919 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1930–67 дә Казан мед. ин-тында, 1932 дән психиатрия каф. мөдире, 1967 дән проф.-консультант. А. В.М.Бехтеревның фәнни традицияләрен үстерә: югары нерв системасы эшчәнлеген тикшерүнең объектив ысулларын эшләү, соматик психозлар этиопатогенезын, чик патологиясе, акылы зәгыйфьләнгән авыруларны соматометрик ысул б-н өйрәнү, йогышлы агулану факторлары китереп чыгарган психик авыру формаларын, психик халәт һәм тән төзелешенең үзара бәйләнешен өйрәнү б-н шөгыльләнә, авыруның сөйләмен тикшерү методикасын төзи. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проблемы и методы соматометрического изучения душевнобольных // Современная психология. К., 1925. № 2; Структура пресенильных психозов // Работы Казанской психиатрической клиники. 1928. Вып. 2; Учение И.П.Павлова об условных рефлексах и психопатология // Казан. мед. журн. 1935. № 3–4.

*Әд.:* А н д р е е в В.П. О научной, педагогической, врачебной и общественной деятельности М.П.Андреева // Вопр. клинической психиатрии. К., 1966; А н д р е е в В.П., М е н д е л е в и ч Д.М. Профессор Михаил Петрович Андреев // Казан. мед. журн. 1966. № 1.

**АНДРЕ́ЕВ** Николай Кузьмич (20.7.1946, Подберезье, хәзерге Кайбыч р-ны Иске Тәберде а.), физик, техн. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1968), РФА Казан фәнни үзәгенең Физика-техника ин-тында эшли. 1995 тән Казан энергетика ун-тында, сәнәгый җайланмалар һәм технол. комплексларның электр күчергечләре һәм автоматлаштыру каф. мөдире. Хезмәтләре ТМР томографиясенә, электр күчергечен автоматлаштыру мәсьәләләренә карый. Төш-магнит релаксациясе процессларында беренчел адсорбция үзәкләренең ролен билгели. Магнит резонансы спектрометрларын һәм ТМР-интроскопларның магнит системаларын исәпләү, проектлаштыру һәм контрольдә тотуның автоматлаштырылган алымнарын эшли. Скважина сыекчасының составын анализлау һәм ТМР — үлчәү приборлары, электр күчергечен динамик контрольдә тоту приборларын һәм алымнарын эшли (автордаш) һәм гамәлгә кертә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияния окружения на неэкспоненциальность ЯМР-релаксации трёхспиновых групп // Физика твёрдого тела. 1976. Т. 18, вып. 3 (автордаш); Методы и приборы низкочастотной релаксационной ЯМР-интроскопии. К., 2003; ЯМР-расходометрия и анализ в современных технологиях. К., 2004. *Р.Г.Усманов.*

**АНДРЕ́ЕВ** Станислав Иванович (28.5.1939, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1984), проф. (1986). 1960 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1962–69 елларда Казан мед. ин-тында, 1969 дан Казан финанс-икътисад ин-тында укыта, 1984–89 да һәм 1995 тән икътисад теориясе каф. мөдире, шул ук елдан макроикътисад каф. мөдире. Хезмәтләре иҗтимагый җитештерүнең социаль-икътисади нәтиҗәлелегенә карый.

Х е з м.: Социальная эффективность и потребительная стоимость основных фондов. К., 1980; Эффективность функционирования основных фондов. М., 1980.

**АНДРЕ́ЕВ-БУРЛА́К** (Андреев) Василий Николаевич (1.1.1843, Сембер ш. — 10.5.1888, Казан), драма актёры, антрепренёр, язучы. 1862 елдан Казан ун-ты тарих-филология ф-тының ирекле тыңлаучысы, ләкин курсны тәмамламый. «Бурлак» пароходында капитан ярдәмчесе, соңыннан капитаны (шуннан псевд.-кушаматы). 1868 дә Ростов-Дон шәһәрендә проф. сәхнәдә актёр буларак чыгыш ясый, провинциаль театр труппаларында эшли. 1880 дә актёр М.И.Писарев б-н берлектә Мәскәүдә Пушкин исем. театрны оештыра (А.А.Бренко дирекциясе), 1882 дә Ф.А.Корш театрында хезмәт итә, 1883 тән «Рус актёрлары ширкәте» составында, актёр һәм антрепренёр буларак, Идел буе шәһәрләрендә һәм Россиянең көньягында гастрольләрдә йөри. Берничә тапкыр (1883, 1884, 1887, 1888) Казанда чыгыш ясый. Ул уйнаган Фамусов, Репетилов («Акыллылык бәласы», А.С.Грибоедов), Расплюев («Кречинскийның туе», А.В.Сухово-Кобылин), Городничий («Ревизор», Н.В.Гоголь), Юсов, Аркашка («Төшемле урын», «Урман», А.Н.Островский), Мармеладов («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский), Поприщин («Юләр кеше язмалары», Н.В.Гоголь) рольләрен замандашлары театр сәнгатенең күренекле вакыйгасы дип саныйлар. Талантлы сүз остасы һәм импровизатор буларак, А.-Б. еш кына концертларда үз әсәрләрен дә укый.

Ә с ә р.: На Волге: Повести и рассказы. СПб., 1881; Сцена и жизнь: Публичные лекции. Одесса, 1886.

*Әд.:* М о р о з о в М.М. Василий Николаевич Андреев-Бурлак. М.–Л., 1948; К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958.

**АНДРЕ́ЕВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасы



В.Н. Андреев-Бурлак.

буенда. 2002 елдан даими яшәүчеләр юк. 17 йөз уртасында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 657,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Алан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 49 ир заты; 1859 да — 281, 1897 дә — 462, 1908 дә — 562, 1920 дә — 777, 1924 тә — 581, 1926 да — 336, 1938 дә — 262, 1949 да — 168, 1958 дә — 164, 1970 тә — 139, 1979 да — 41, 1989 да — 17 кеше.

**АНДРЕ́ЕВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оренбург өлкәсе чигендә. 2002 елда 243 кеше (руслар — 68%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. 18 йөз уртасында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 2448,6 дис. тәшкил итә. 1896–1902 елларда А.да архит-ра истәлеге — Михаил-Архангел чиркәве төзелә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 465, 1897 дә — 941, 1920 дә — 1391, 1926 да — 982, 1938 дә — 912, 1949 да — 636, 1958 дә — 532, 1970 тә — 360, 1979 да — 261, 1989 да — 137 кеше.

**АНДРЕ́ЕВКА** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Киекле елгасы буенда. 2002 елда 718 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1710 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Андреевка Пүчинкәсе, Киеклебаш исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1864 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чаллы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан

Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 825, 1897 дә — 1245, 1908 дә — 1480, 1926 да — 1459, 1938 дә — 1127, 1949 да — 889, 1958 дә — 932, 1970 тә — 1047, 1979 да — 952, 1989 да — 709 кеше.

**АНДРЕ́ЕВКА** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 21 *км* көнчыгыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2002 елда 125 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Башлангыч мәктәп. Китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Глазово, Кирлегәч исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек князь Оболенскийларның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире 85 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Карамалысы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 445, 1897 дә — 332, 1920 дә — 459, 1926 да — 414, 1949 да — 334, 1958 дә — 206, 1970 тә — 159, 1979 да — 111, 1989 да — 137 кеше.

**АНДРЕ́ЕВКА** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 14 *км* көнчыгыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2002 елда 164 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 106 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 135, 1897 дә — 167, 1908 дә — 197, 1920 дә — 200, 1924 тә — 209, 1926 да — 264, 1938 дә — 303, 1949 да — 248, 1958 дә — 234, 1970 тә — 179, 1979 да — 112, 1989 да — 36 кеше.

**АНДРЕ́ЕВСКИЙ** Николай Ефимович (8.11.1822, С.-Петербург — 5.2.1889, Казан), дәүләт эшлеклесе, яшерен советник (1876). Александр исем. лицейны тәмамлый (1844, С.-Петербург). 1844–68 елларда Хәрби министрлыкта хезмәт итә, 1864 тән хуҗалык ком-ты рәисе. Россиядә 1860 елларда уздырылган хәрби реформаларны әзерләүдә катнаша. 1868 дән Эчке эшләр министрлыгы карамагында: Харьков губернасы губернаторы урынбасары (1869–70), Пермь (1870–78), Кострома (1878–84), Казан (1884 тән) губерналары губернаторы. 1884–85 еллардагы ачлык вакытында Казан губернасы халкын азык-төлек б-н тәэмин итүне оештыруда катнаша. Аның ярдәме б-н төбәктә хәйрия җәмгыятьләре һәм яңа уку йортлары ачыла. А. идарә иткәндә, Казанда чиркәү әһелләренең фәкыйрьлектә калган хатыннары һәм балалары өчен ятимханә (1885), сәүдәгәр И.Н.Журавлёвның мохтаҗлар өчен төн куну йорты (1886), А.А.Орлов-Соколовскийның музыка мәктәбе (1886), земство фельдшерлар мәктәбе (1887) һ.б. ачыла, хәрби санитарлар (1886), фармацевтлар (1888) җәмгыятьләре, Казан почта-телеграф округы (1885), Крәстиян җир банкы бүлеге (1886) эшли башлый. 1886 да А. инициативасы б-н Казанда һөнәрчелек тармагында һәм а.х.да җитештерелгән әйберләрнең 1 нче күргәзмәсе оештырыла. Ш.у. аның ярдәмендә Казанда шахмат клубы (1885), сукырлар өчен уч-ще (1887) ачыла, «Казанские новости» г-тасы (1885–86) нәшер ителә башлый. Тарихи һәйкәлләрне саклауга әһәмият бирә. Хокук җәмгыяте каршында 1886 да «Идел-Кама төбәгендә яшәүче русларның, башка җирле халыкларның хокукка кагылышлы гореф-гадәтләрен җыю һәм өйрәнү өчен даими комиссия» оештыра.



Н.Е. Андреевский.

*Әд.:* Долгов Е.Б. По Высочайшему повелению назначен Казанским губернатором: Н.Е.Андреевский // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 3/4. *Е.Б.Долгов.*

**АНДРЕЙ** (кенәз Ухтомский Александр Андреевич) (26.12.1872, Ярославль губ., Рыбинск өязе Вослома а. — 4.9.1937, Ярославль ш., башка мәгълүматларда — 1944, Архангельск өлкәсе), дин эшлеклесе, миссионер. Мәскәү руханилар академиясен тәмамлый (1895). 1895 елдан Казан руханилар уч-щесе укытучысы, 1897 дән Александров руханилар семинариясе (Владикавказ) инспекторы, 1889 дан Казан миссионерлар курсы күзәтүчесе. 1907 дән Мамадыш епископы. Казан епархиясенең миссионерлык эше һәм рус булмаган халыклар приходлары эше буенча викар епископ. 1911 дән — Сухуми, 1913 тән Уфа һәм Минзәлә епископы. Идел-Урал төбәгендә миссионерлык эшчәнлеген көчәйтә, Н.И.Ильминский системасы тарафдары. Ислам диненә кайтучыларга карата репрессия чаралары куллануга каршы чыга, гыйбадәт кылуны Идел буе халыклары телләрендә алып баруны һәм дини әдәбиятны шул телләрдә күпләп нәшер итүне яклый. А. тырышлыгы б-н *Керәшен татарларның Өч изге ирләр монастыре* (1911) һәм Покров хатын-кызлар җәмгыяте (Мамадыш өязе) ачыла, «Сотрудник Братства святителя Гурия» ж-лы, Уфада Ильминский алфавиты б-н керәшен татарлар өчен «*Дус*» исемле беренче г-та нәшер ителә башлый. 1917 дә чиркәү иҗтимагый хәрәкәтендә актив катнаша, чиркәү реформасын яклап чыга. 1922 дән сөргеннәргә сөрелә, әмма епархия б-н җитәкчелек итүен туктатмый, яңарышчыларга каршы көрәштә патриарх Тихонга теләктәш була. Аның вафатыннан соң митрополит Сергийны чиркәүнең законлы башлыгы дип танымый. 1927–28 дә сөргендә, 1928–31 дә төрмәдә була. 1932 дә Белокриница иерархиясенең иске дин тарафдарлары ягына күчә. Кайбер мәгълүматларда, Ярославь шәһәрендә атыла, башка хәбәрләрдә Архангельск өлкәсендә сөргендә үлә, дип күрсәтелә.

*Әд.:* Зеленогорский М.Л. Жизнь и деятельность архиепископа Андрея (князя Ухтомского). М., 1996.

**АНДРЕ́НА**, җир умарта корты (Andrena F.), умарта кортлары семьялыгыннан бөҗәкләр ыругы. Төрле зурлыктагы (5 тән алып 17 *мм* га кадәр) умарта кортлары. Гаиләләр төземиләр, ләкин кайбер төрләре колонияләр тәшкил итә. Ояларын җирдә һәм өннәрдә ясыйлар. Курчакка әверелү алдында торганнары кышлый. Иртә яз А.сы (язын очып чыгучы иң беренче бөҗәкләрнең берсе) һәм җәйге А. төрләренә аерылар. Барлыгы 200 ләп төре билгеле; Татарстан терр-ясендә 60 тан артык төре ачыкланган. Кайбер төрләре елга 2 буын бирә (A. dorsata Kirby, A. thoracica Kirby, A. labialis Kirby). Язын чәчәк атучы тал һәм үги ана яфракларында очрый торган соры А. (A. cineraria L.) һәм кларка (A. clarcella Kirby) төрләре киң таралган. А. үзәнлек һәм су баса торган болыннарда, чокыр, сыза, урман һәм урман полосалары буйларында, басу кырыйларында яши. Күп кенә төрләре кыргый һәм культуралы үсемлекләрне яхшы серкәләндерә. Сары аяклы А. (A. flavipes Panzer) һәм кайгылы А. (A. atrata Friese) ТРның Кызыл китабына кертелгән. Илл. к. *Элпәканатлылар* мәкаләсендә.

**АНДРИА́НОВА** Юлия Евгеньевна (25.11.1946, Казан), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1998), проф. (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында. 1972–2006 да — РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1998 дән), бер үк вакытта (2000 нән) Казан ун-тында. Хезмәтләре фотосинтетик пигментларның үсемлекләрнең потенциаль продуктивлыгын бәяләү параметры буларак өйрәнүгә карый. Чәчүле а.х. культураларында хлорофилл булуын спектраль яктылык коэффициенты буенча ерактан торып билгеләү ысулын эшли (И.А.Тарчевский б-н берлектә). Селекция үзәкләрендә югары продуктлы сортлар китереп чыгаруда киң кулланыла башлаган алым — үсемлекләрдә хлорофилл концентрациясен төсле шкала буенча билгеләү алымын тәкъдим итә.

Хезм.: Пигментная система и фотосинтетическая продуктивность растений // Фотосинтез и продукционный процесс. М., 1988; Хлорофилл и продуктивность растений. М., 2000.

**АНДРОМЕ́ДА**, к. *Акчыл.*

**АНДРО́НОВО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), Казакъстан, Көнбатыш Себер, Көньяк Урал терр-яләрендәге бронза гасыр ахырына нисбәтле мәдәни-тарихи бергәлек (б.э.к. 2 меңьеллык уртасы — 1 меңьеллык башы). Атамасы 1920 елларда Красноярск краеның Ачинск шәһәре тирәсендәге Андроново авылы янында табылган истәлекләргә бәйле рәвештә бирелә. 1970 елларда А.к. үсеше 3 этапка: Фёдорово, Алакул, Замарево дәверләренә бүлеп карала, кайбер тикшеренүчеләр аларны але-

ге бергәлекнең мөстәкыйль культуралары дип исәпли. А.к. халкы терлекчелек, аучылык, примитив игенчелек б-н көн күргән, таш һәм сөяк эшкәрткән; бронза эретү-коюю б-н шөгыльләнгән (эш һәм сугыш кораллары, бизәнү әйберләре һ.б. табыла), арбалардан файдаланган. Балчыктан яссы төпле, геометрик бизәкләр төшкән чүлмәкләр, банка сыман һәм кырлы савытлар җитештергән. Тораклар җир өстенә һәм яртылаш җиргә батырып төзелгән. Чокырлы каберләр өстенә тәбәнәк курганнар өелгән яисә алар ташлар б-н әйләндереп алынган. Мәетләр кабергә башларын төньяк-көнчыгышка таба юнәлтеп, бөгәрләнгән килеш, яны б-н салынган, сирәк кенә мәет яндыру йоласы үткәрелгән. Каберләрдә чакматаштан ясалган ук очлыклары, бронзадан эш, сугыш кораллары, җиз муенса, алтын һәм җиз алкалар, арба калдыклары табыла. Татарстанда А.к. элементлары Актаныш р-ның Такталачык, Спас р-ның элекке Соколовка авыллары тирәсендәге археологик истәлекләрдә очрый.

*Әд.:* Киселёв С.В. Древняя история Южной Сибири. М.–Л., 1949; Черников С.С. Восточный Казахстан в эпоху бронзы. М.–Л., 1960; Сальников К.В. Очерки древней истории Южного Урала. М., 1967.

*Е.П.Казаков.*

**АНДРУШКО́** Илсөя Әхмәт кызы (12.7.1937, Казан), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1990). ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1960 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1962 дән Казан мед. ун-тының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Тикшеренүләре кеше һәм хайваннар организмындагы кан оешу бозылулары механизмын өйрәнүгә багышлана. 1968 дә А. антикоагулянт тәэсирле дарулар куллануның кан оешуга гына түгел, тамырлар стенасының коагулятив үзлелеге җитди трансформацияләнүгә китерүен ачыклый. А. эшләгән тромбопластинемияне бәяләү һәм үзбәяләү ысулы гиперкоагулемия үсешендә инициаль стимулның билгеләрен ачыкларга һәм үз вакытында тиешле дәвалау үткәрергә мөмкинлек бирә. Тромборезистентлыгына карап аллопластик материалларның яраклы булуын билгеләү ысулын эшли, миелобластик лейкемия вакытында тукыма гены экспрессиясен гемостазиологик ысул б-н ачыклау буенча тикшеренүләр алып бара.

Хезм.: Тромбопластинемия — инициатор непрерывной гемокоагуляции в организме и синдрома диссеминированного внутрисосудистого свёртывания крови. К., 1999.

**АНДЫ́З** (Inula), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләннәр яки куаклар ыругы. 150 ләп төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Африкада киң таралган. ТР да 4 төре бар. Британия андызы (I. britannica), кытыршы А. (I. hirta), тал яфрагы сыман А. (I. salicina) респ-каның барлык р-ннарында очрый, озын А. (I. helenium) — сирәгәеп бара торган төр. Киңъяфраклы урман буйларында, болыннарда, елга тугайларында үсә. 20–150 *см* озынлыктагы каты, калын тамырчалы күпьеллык үсемлекләр. Яфраклары бөтен, чиратлашкан, читләре тешле. Чәчәкләре сары төстә, кубесенчә ялгыз яки күпсанлы кәрзиндә, калкансыман яки себеркесыман чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше озынча, 4 кырлы, коңгырт бүрекчәле орлыкча. Июль-август аенда чәчәк ата. Җимешләре август-сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл белән үрчи. Тамыры һәм тамырчасында сапониннар, аз микъдарда алкалоид матдәләре, инулин, эфир мае бар. Озын А. халык медицинасында ашказаны җәрәхәте, гастрит, үпкә туберкулёзы вакытында кулланыла. Декоратив; баллы үсемлек.

**АНЕМО́НА**, к. *Җилдәк.*

**АНЕСТЕЗИОЛО́ГИЯ** (грек. anaisthesía — тоймау һәм ... *логия*) клиник медицина өлкәсе, хирургик операцияләр үткәргәндә организмның авырту тоюын басу һәм аның яшәү өчен мөһим булган функцияләре б-н идарә итүне өйрәнә. А., мөстәкыйль клиника фәне буларак, 20 йөзнең 1 нче яртысында барлыкка килә. Гомуми А. авырта торган урында һәм гомуми авыртуны басу теориясе, анестезия ысуллары, клиник наркоз, яшәү өчен мөһим булган функцияләрнең патологик физиологиясен, авыруны операциягә әзерләүдәге, аның наркоздан һәм операциядән соңгы халәтен өйрәнү мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Ш.у. анестезия өчен кулланыла торган дару препаратларының: наркотик матдәләр, миорелаксантлар, анестетиклар, анальгетикларның һ.б. авыртуны баса торган матдәләрнең — сизү нервлары очларының ялкынсынуын киметә һәм нерв тукымалары буйлап импульслар үтүне туктату матдәләренең клиник фармакологиясен өйрәнә. Махсус А., конкрет авыруның халәтенә һәм булачак операциянең үзенчәлегенә бәйле рәвештә, авырту тоюны басу ысулларын билгели. А. төрле мед. фәннәре (нормаль һәм патологик физиология, биохимия, фармакология, хирургия, терапия), ш.у. реаниматология бүлеге б-н тыгыз бәйләнгән. Хирургик операцияләр үткәргәндә авырту тоюны басу ысуллары турындагы беренче мәгълүматлар б.э.к. 15 йөзгә карый: Борынгы Мисырда мандрагор, беладонна һәм әфьюннан файдаланганнар. Шуңа охшаганрак препаратларны Борынгы Греция, Һиндстан, Кытай табибләре дә кулланган. «Анестезия» терминын 17 йөз башында Бабий гамәлгә керткән. Немец табибе һәм табигать белгече Парацельс эфирның авыртуны басу үзенчәлеген исбатлаган (1731). Наркоз һәм авырткан урында анестезия куллану 19 йөздә ачыла. Наркоз өчен Р.Лонг — эфир (1842), Шотландия табибе Симпсон һәм рус химигы Н.И.Пирогов бер үк вакытта — хлороформ (1842), хирург С.П.Фёдоров гедонал куллана (1909). 1928 елда Казан хирургы А.В.Вишневский аерым урында анестезия ысулын гамәлгә кертүне тәкъдим итә; бу ысул 1929 елда Россиядә эксперименталь рәвештә раслана һәм АКШта күрсәтелә. Мускулларны йомшартып, авырту тоюны басу препаратларын гамәлгә кертү эндотрахеаль наркоз, йөрәк, үпкә һәм үңәч, кан тамырлары хирургиясе үсешенә этәргеч бирә. 1950 елларда бала тапканда авырту тоюны басуда, соңрак башка операцияләр вакытында газ наркозы («көлдергеч газ» — азот закисе), ш.у. 1958 дән фторотан (флюотанга охшаган), 1965 тән пентран (метоксифлюран) куллану СССРда А.не үстерүгә ярдәм итә.

1940–50 елларда Казанда А.В.Вишневский хирург-анестезиологларның фәнни мәктәбен оештыра. Ул башлап җибәргән юнәлешне шәкертләре С.М.Алексеев, И.В.Домрачев, Н.В.Соколов, А.А.Вишневский, Т.М.Новиков, В.И.Пшеничников, Н.П.Маслов, И.Ф.Харитонов, Р.А.Вяселев, М.К.Садыйкова һ.б. дәвам итә. Казан галимнәренең төп игътибары: веналар аша наркоз бирү (Б.Г.Герцберг, 1940 еллар); йөрәккә операция вакытында гипотермия (Н.П.Медведев, В.Н.Медведев, 1969–99); балалар үпкәсенә операция ясаганда авыртуны басуга (В.Ф.Жаворонков, 1976 ел), перидураль (А.Г.Нәҗипов, 1980 еллар) ысулларны фәнни эшләүгә юнәлтелә. А. өлкәсендәге казанышлар ТРда бит пластикасы хирургиясе (Е.А.Домрачева, Л.А.Кольцова, 1960–70 еллар), ортопедия һәм онкостоматология (Е.В.Крешетов, 1980 еллар) үсешенә юл ача. А. нең хәзерге заман казанышлары, ясалма кан әйләнеше булдырып, теләсә нинди, ш.и. йөрәккә һәм тамырларга озакка сузылган операцияләрнең дә уңышлы төгәлләнүен тәэмин итә. 20 йөзнең 2 нче яртысында Казан мед. ун-тында һәм Казан мед. академиясендә 500 гә якын табиб-анестезиолог әзерләнгән.

*Әд.:* Кафедра анестезиологии и реаниматологии // Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989. Ч. 1.

*В.Н.Войцехович.*

**АНЕСТЕЗИ́Я** Вишневский ысулынча, дәвалау урынында авырту тоюны басу — тәннең чикләнгән бер өлешендә авырту сизүне анестезия матдәсе белән тәэсир итеп яки өшетеп, вакытлыча туктатып тору. Авыртуны операция ясала торган урында гына басу идеясен 1880 елда рус токсикологы В.К.Анреп тәкъдим итә. Анестезия матдәсе кертелү урынына бәйле рәвештә, терминаль нерв кәүсәсе (регионар) һәм дәвалау урынын инфильтрацияләү А.се аерып карала. А.В.*Вишневский* (Казан, 1929) «таралучы тыгыз инфильтрат» ысулы дип үзе атаган зарарсыз, гади, куллану өчен уңай һәм югары нәтиҗәле инфильтрация анестезиясе вариантын тәкъдим итә. Фасциаль урынга күп итеп 0,25% лы новокаин эремәсен кертүкәч, эремә шул урынга тарала, операция ясаласы урындагы нерв очларына тәэсир итә, тукымаларга да сеңеп, авыртуны тулысынча бастыра. А.нең тискәре тәэсирен күрсәтә торган билгеләр: новокаинга чыдый алмау (яшь балаларның), тукымалар инфильтрациясе б-н барган зур үлекләү-ялкынсыну процессының новокаин эремәсе таралуны тоткарлавы.

Авыртуның нык көчәеп китү очраклары: тамырга энә кадаганда, анестетикның кан тамыры юлларына эләгүе, кайчагында симпатик нерв баганалары камалу нәтиҗәсендә кан басымы төшүе мөмкин. А. ысулының тасвирламасы «Үрмәле инфильтрат ысулы белән дәвалау урынындагы авыртуны басу» («Местное обезболивание способом ползучего инфильтрата») исемле монографиядә бәян ителә һәм Бөек Ватан сугышы елларында хирурглар тарафыннан кулланыла. А.В. һәм А.А.Вишневскийлар сугыш шартлары хи-

ругиясе өчен махсус ысуллар: сугыш яраларының авыртуын басу; шок б-н көрәшү чаралары системасын, җәрәхәтләрне кабат эшкәртү һәм ярадагы эренне агызу методикасын, күкрәк читлегендәге пуля һәм снаряд кыйпылчыклары яраларының катлауланууын дәвалау ысулларын эшлиләр. Бу ысуллар СССР МФАнең Хирургия ин-тында теоретик яктан нигезләнә, ашыгыч һәм хәрби-кыр хирургиясендә кулланыла. А.В.Вишневскийга дәвалау урыны анестезиясе ысулларын эшләгән өчен Халыкара Рене Лериш премиясе бирелә.

*Әд.:* З а х а р ь я н С.Т. А.В.Вишневский. М., 1967; Краткая медицинская энциклопедия. М., 1972. Т. 1. *В.Н.Войщехович.*

**АНЖЕ́РО-СУДЖЕ́НСК**, *Кемерово өлкәсе*ндәге шәһәр (1931 елдан), Кемеродан 115 *км* төньяктарак. 1897 елда, Анжерск һәм Судженск шахталарында күмер чыгарыла башлауга бәйле рәвештә тимер юл магистраленә нигез салына, торак пунктлар берләшә. Халкы — 100,7 мең кеше (2000). Татарлар саны: 1979 да — 5570, 1989 да — 5452 кеше. Татарлар А.-С. шәһәре нигезләнгән вакыттан бирле яшиләр. 1920–27 дә ВКП(б) райкомы каршында мөселман секциясе, 1920–30 да 2 татар башлангыч мәктәбе, татар балалар бакчалары һәм балалар йорты эшли. 1931 гә кадәр мәчет булган. 1930–40 та җирле күмер шахталарында Идел һәм Урал буйларыннан мәҗбүри күчерелгән татарларның хезмәте киң файдаланыла. Хәзерге вакытта А.-С. та татар клубы бар, аның каршында 1990–2000 дә «Рәхим итегез, дуслар» үзешчән коллективы эшләгән. 1993 тә Мөселман Диния нәзарәтенең БДБның Европа өлешендәге һәм Себердәге мөхтәсибәтенең шәһәр мөселман дини берләшмәсе оеша, ул 1999 дан «Әлиман» г-тасын нәшер итә. Мәчет эшли.

**АНИЗА́НТА** (Anisanta), кыяклылар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. ТРда бер төре — каплавыч А. (A. tektorum), иисә каплавыч кандырак (Bromus tektorum) үсә. Яткын җирләрдә, юл буйларында җиңел механик составлы туфракларда, юл буйларында очрый. 10–40 *см* озынлыктагы берьеллык үсемлек. Яфраклары кыяклы. Чәчәк төркеме — берьяклы куе себеркәч. Җимеше — озынча бөртекчә. Май-июнь айларында чәчәк ата. Күбрәк орлыктан үрчи. Иртә язгы көтүлек үсемлеге.


**АНИКИ́ЕВ** Афанасий Борисович (1722, Казан — 1787 дән соң, шунда ук), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. Иген-икмәк сәүдәсе б-н дан казана. Торак йортлар һәм кибетләр тота. 1740 елда Мәкәрҗә ярминкәсендә таможня хезмәтенә, аракы-шәраб сатучы оешмалар һәм канцелярия җыемнарына, 1742 дә таможня хезмәте б-н канцелярия җыемнарына күзәтчелек итүчеләр башлыгы — бурмистр итеп билгеләнә. 1745 елда Казанда аракы-шәраб сатучы оешмалар җыемына күзәтчелек итүчеләр башлыгы була. 1753–65 тә Казан губернасы магистраты президенты. 1776–81 дә Казан шәһәре башлыгы. 1782–85 тә — Казан губернасы магистратының Вөҗдан мәхкәмәсе, 1785 елдан Җәмәгать тәрбиясе приказы утырышчысы.


*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Вып. 1. *Л.М.Свердлова.*

**АНИ́КИН** Павел Евграфович (1.12.1827, Казан губ., Цивиль өязе Аникино а. — 26.12.1891, Казан ш.), архитектор, җәмәгать эшлеклесе. Дворян нәселеннән. 1854 елда Юллар һәм җәмәгать биналары баш идарәсенең Петербург төзелеш уч-щесен тәмамлый һәм Саратов төзелеш һәм юл комиссиясенә инженер итеп җибәрелә. 1863 тән Казан төзелеш һәм юл комиссиясендә шәһәр архитекторы, 1864 тән шәһәрнең өлкән архитекторы, в 1870–71 дә Казан губерна идарәсендә штаттан тыш техник, 1871–75 тә Казан шәһәр идарәсе архитекторы. 1875 тән отставкага чыгып, шәхси практика б-н шөгыльләнә. Казандагы классик стильнең эклектика юнәлешендәге күп кенә торак, җәмәгать биналары проектлары авторы. А. проектлары б-н И.М.Щербаков (1866), Д.Г.Лисичкин (1865), И.Н.Соболев (1869), Д.С.Волгин (1863) йортлары, И.Н.Соболевның гомуми һәм номерлы мунчалары, М.П.Платонов кибетләре, Юнысовның сәүдә келәтләре һ.б. төзелә.

Борынгы рус мотивларын кулланып, милли-романтик эклектика юнәлешендә башкарылган гыйбадәт кылу корылмалары проектлары 1870 елларның икенче яртысыннан А.ның иҗат эшчәнлегендә төп урынны алып тора: Биләр авылында (хәзерге Алексеев р-ны) Михаил-Архангел чиркәве (1877), Осиново авылында (хәзерге Яшел Үзән р-ны) Грузия-Богородица чиркәве (1884–89), Казан янындагы Вознесенский авылында Тихвин-Богородица чиркәве (1885, реконструкция), Борисоглебский авылында (хәзерге Биектау р-ны) Борисоглебский чиркәве (1889) һ.б. 1871–91 дә шәһәр думасы гласные. 1886 дан Казандагы 8 нче уч-щедә попечительләр советы рәисе. *Л.М.Мортазина.*







П.Е. А н и к и н. 1. Грузия Богородица чиркәве. Яшел Үзән р-ны Осиново авылы. 1884-89; 2. И.М.Щербаков йорты. Казан. 1886; 3. Юнысовларның сәүдә йорты. Казан. 1871.

**АНИЛИ́Н** (гарәп. أنلين — ән-нил — индиго), аминобензол, фениламин, $C_6H_5NH_2$, ароматик амин; аз гына исле төссез сыеклык, кайнау темп-расы 184,4°С, 20°С та тыгызлыгы 1027 *кг/м*[3]. Суда эрүчән, спирт, бензол, эфир б-н барлык чагыштырмаларда катнаша. Беренче мәртәбә Саксония (Германия) химигы Унфердорбен тарафыннан индигоны корылай куганда табыла. Рус академигы Ю.Ф.Фрицше 1840 елда А.ны индигога зәһәр калий б-н тәэсир иткәндә аерып ала. Синтетик юл б-н А.ны беренче мәртәбә 1842 елда Казанда Н.Н.*Зинин* таба (к.*Зинин реакциясе*), дөньякүләм анилин буяулар җитештерүгә нигез сала һәм органик синтез үсешенә хәлиткеч йогынты ясый. А. күп кенә органик матдәләр һәм, беренче чиратта, синтетик буягычлар табу өчен башлангыч продукт булып хезмәт итә. А.ның минер. кислоталы тозы ситсыга бизәк төшерүдә кулланыла; *п*-нитроанилин ясау өчен сәнәгать масштабында җитештерелә торган серкә кислотасы анилиды (ацетанилид), дифениламин, А.ны метиллаштырып табылган моно- һәм диметиланилиннар буягычлар җитештерүдә иң әһәмиятле ярымпродуктлар. А.ны диазотлаштырып сәнәгатьтә фенилдиазоний — азобуягычлар җитештерүдәге төп ярымпродуктны таба. А. окисьләшкәндә анилинлы кара буягыч хасил була. А. фотография өчен ачыклагычлар җитештерүдә, каучукны вулканлаштыру тизләткечләре, шартлаткычлар, дарулар, пестицидлар һ.б. матдәләр җитештерүдә кулланыла. Сәнәгатьтә А.ны аз микъдардагы хлорид кислотасы кушылган хәлдә нитробензолны чуен йомычкасы б-н җылытып алалар. Агулы, үзәк нерв системасына тәэсир итә, канда кислород җитешмәү китереп чыгара торган метгемоглобин барлыкка китерә.

*Әд.:* Вредные вещества в промышленности: Справ. М.–Л., 1965. Ч. 1; Ю к е л ь с о н И.И. Технология основного органического синтеза. М., 1968.

**А́НИН САЛМАНЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Салман елгасы буенда. 2002 елда 86 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 17 йөз урталарында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Аннино исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.С.нда җил тегермәне, 2 бакалея кибете була. Бу чорда авыл җәмә-

гатенең имана җире 648 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 10 февраленнән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 385, 1897 дә — 460, 1908 дә — 540, 1920 дә — 472, 1926 да — 320, 1938 дә — 197, 1949 да — 149, 1958 дә — 135, 1970 тә — 112, 1979 да — 79, 1989 да — 76 кеше.

**АНИ́СИМОВ** Александр Васильевич (22.8.1946, Казан), биофизик, физ.-матем. фән. д-ры (1988), проф. (1998). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында эшли, 1992 дән баш фәнни хезмәткәр, 1998 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 2002 дән транспорт процесслары биофизикасы лаб. мөдире. Хезмәтләре матдәләрнең күзәнәкара күчү биофизикасына карый. А. тарафыннан үсемлекләрдә сулы эремәләрнең симпласт аша радиаль-аксиаль күчерелүе моделе эшләнә; ТМР ысулы б-н симпластта суның күзәнәкләр буенча күпләп агуы билгеләнә; күзәнәкара контактларда структура һәм функция бәйләнеше — плазмодесм — осмос басымы б-н судагы эремәләрне хәрәкәтләндерү элементы булуы тасвирлана. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Траспорт воды в растениях. Исследование импульсным методом ЯМР. М., 1992 (автордаш); Плазмодесмы как модулятор осмотических потоков воды // Физиология растений. 2002. Т. 49, № 5 (автордаш); The symplast radial-axial water transport in plant: a MRa approach // Water transport in Plant under Climatic Stress. Cambridge University Press, 1993; The Influence of laser Radiation on the Velocity of Rotational Motion of Protoplasm in Elodea Cells // Laser Physics. 1997. V. 7, № 4 (автордаш); Water Diffusion in Biological Porous Systems: a MP Approach // Magnetic Resonance Imaging. 1998. V.16, № 5–6 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**АНИ́СИМОВ** Андрей Юрьевич (23.8.1961, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1996), проф. (2000), 1984 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1985–92 елларда Казан мед. оешмаларында эшли. 1995 тән Казан мед. академиясендә, 1998 дән ашыгыч һәм кичектергесез ярдәм күрсәтү курслары мөдире. Тикшеренүләре гадәттән тыш хәлләр хирургиясенә багышланган. Россиядә беренче булып клиник медицинаның мөстәкыйль бүлеге — катастрофалар хирургиясен бүлеп чыгаруның зарурлыгын исбатлый һәм аның концепциясен эшли. «Хирургия: Табибләр һәм студентлар өчен кулланма» («Хирургия: Руководство для врачей и студентов». М., 1997) китабын инглиз теленнән тәрҗемә итүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Перитонеостомия в лечении разлитого гнойного перитонита. К., 1991; Лапаростомия в комплексном лечении тяжёлых форм перитонита при травме живота // Сочетанные и множественные травмы. К., 1998 (автордаш).

**АНИ́СИМОВ** Валентин Ефимович (15.4.1925, Казан — 20.8.1987, Мәскәү), терапевт, мед. фән. д-ры (1964), проф. (1965). З.И.*Малкин* шәкерте. 1948 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1969 дан факультет терапиясе каф. мөдире, бер үк вакытта проректор. 1971 дән СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының 4 нче идарәсендә (Мәскәү), 1975–86 да Мәскәүдәге 2 нче мед. ин-тында, 1980 гә кадәр югары мед. белеме лаб. мөдире. Хезмәтләре кардиология, гепатология, клиник витаминологиягә карый. Казанда медицина үсеше тарихына багышланган китаплары авторы.

Х е з м.: Биохимические изменения при коронарном атеросклерозе и их клиническое значение. К., 1964; Витамин $B_{15}$ (пангамовая кислота) и его клиническое применение. К., 1965.

*Әд.:* Казанский медицинский институт. 1814–1989. К., 1989. Ч. 1.

**АНИ́СИМОВА** Меланья Дмитриевна (13.1.1937, Краснодар краеның Выселки р-ны Березанская станицасы), провизор. 1959 елда Пятигорск фарм. ин-тын тәмамлый. 1959 дан Казандагы 16 нчы даруханәдә, 1962 дән даруханәләр челтәре бүлеге мөдире, 1965 тән ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика даруханәләр идарәсе башлыгы урынбасары, 1968 дән ТАССР МСның Даруханәләр идарәсе башлыгы урынбасары, 1979 дан Даруханәләр идарәсе башлыгы. 1988 дән ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының «Фармация» җитештерү берләшмәсе ген. директоры, бер үк вакытта министр урынбасары. 1992–93 тә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстанфармация» пр-тиесе ген. директоры. Татарстанда фармация тарихына багышланган басмалары дөнья күрә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вехи истории фармации Татарстана (взгляд специалиста). К., 2001; Страницы летописи фармации. К., 2004.

**А́ННЕНКОВ** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2002 елда 29 кеше (руслар, татарлар) яши. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бәйрәш, Барышевка исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 365 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 316, 1897 дә — 246, 1920 дә — 312, 1938 дә — 245, 1949 да — 164, 1958 дә — 84, 1970 тә — 93, 1979 да — 80, 1989 да — 34 кеше.


**АНОНИ́М ӘДӘБИ́ ӘСӘ́Р**, авторның исеме яки псевдонимы куелмаган әсәр. Татар әдәбиятында А.ә.ә. сыйфатында «Кисекбаш китабы»н (14 йөз), «Кыйсса-и Сәкам»не (15 йөз), «Нәсыйхәт әс-салихин»не (16–17 йөзләр), «Комедия Чистайда»ны (19 йөз) һ.б. күрсәтергә мөмкин.

**«АНОНИ́М БАСМАХАНӘ́»**, кириллица шрифтлы басмаханәнең 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөз башындагы шартлы исеме. Эшчәнлеге турында Сольвычегодск Благовещение соборы исемлегендә (1601 елдан да соң түгел) һәм Мәскәүдәге Печатный дворның 1620 елгы Чыгымнар китабында телгә алына. 1570 еллар урталарында яки 2 нче яртысында басылган «Казан Мәрьям Ана иконасына гыйбадәт кылу» («Служба Казанской иконе Божией Матери») догалыгы — Казанда нәшер ителгән беренче китап. 1590–95 еллар тирәсендә догалыкның икенче басмасы да чыга. Икесе дә төрле төстәге Триоди шрифтында басылган, китапның чыгу мәгълүматлары юк, шуның өчен «А.б.»нең Мәскәүдә һәм Казанда кайсы елларда эшләгәнлеген төгәл ачыклау кыен. Россия матбагачылыгында бу турыда берничә гипотеза бар: Е.Л.Немировский фикеренчә, «А.б.» 1553–65 елларда Мәскәүдә эшләгән, В.И.Позднеева б-н А.А.Турилов «А.Б.»нең җиһазлары 1560 елларның икенче яртысында Мәскәүдән Казанга күчерелә, «А.б.» үз эшен яңа урында 1570–80 еллар чигендә генә башлап җибәрә, дип саныйлар; Е.И.Григорьев, «А.б.» Казанга 1750–60 елларда архиепископ Гурий тарафыннан чиркәү (Евангелие, Триоди, Псалтырь, Апостол) басмаларын һәм чиркәүләрдә гыйбадәт кылу һәм православие мәктәпләрендә укыту өчен кирәкле уку китапларын (Азбука, Часослов) бастыру максатында күчерелә, дип исәпли.

*Әд.:* Н е м и р о в с к и й Е.Л. Иван Фёдоров: около 1510–1583. М., 1985; Т у р и л о в А.А. Первенец казанского книгопечатания // Книжное обозрение. 1984. № 44; Б у д а р а г и н В.П. Фрагмент утраченного безвыходного издания Триоди цветной в рукописи XVI в. // Тр. Отд-ния древнерусской литературы. СПб., 1993. Т. 18; П о з д е е в а И.В.,Т у р и л о в А.А. Святые врата, раскрытые на Восток (загадка раннего казанского книгопечатания) // Науч.- богословские тр. по проблемам православной миссии. Белгород, 1999; ш у л а р у к. Казань — один из центров раннего книгопечатания // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 3/4; Г р и г о р ь е в Е.И. Книгопечатание в России: спор о первых экземплярах // Вестн. РАН. 2000. Т. 70. № 8.

*Е.И.Григорьев.*

**АНО́СОВ ЙОРТЫ́** (Енишевский йорты), Казанда архит-ра истәлеге. 20 йөз башында арх. П.П.Голышев проекты б-н псевдоампир стилендә Аносов өчен төзелгән шәһәр йорты. Биек эргә каты да булган бер катлы бина һәм бер катлы кибет бербөтен комплекс хасил итә. Эргә катында — кухня, хуҗалык бүлмәләре, хезмәтчеләрнең яшәү урыны, төп катта — биек а́ркалы тәрәзәләре булган тантаналар залы, торак бүлмәләр урнашкан. Үзәк бинаның төп фасадында ионик ордердагы



Аносов йорты. Казан. Арх. П.П.Голышев. 20 йөз башы.

ике ярымколоннадан торган портиклы ризалит һәм биек фризны күтәреп торучы, үсемлек сурәтләре б-н бизәлгән ярымбагана чыгынтыланып тора. Портикның өсте күпертелгән геральдик калканнар б-н бизәлгән. 1920 елларда биредә ТАССР Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлар советының ҮБК урнаша. Хәзерге вакытта балалар бакчасы итеп файдаланыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

**АНО́ХИН** Владимир Алексеевич (29.5.1956, Казан), балалар табибе, йогышлы авырулар белгече, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1995). 1979 елда Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. 1987 дән балалардагы йогышлы авырулар каф. мөдире. 1995 тән проректор, бер үк вакытта 1988 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының балалардагы йогышлы авырулар баш белгече. Хезмәтләре балаларда авыр формадагы вируслы һәм бактериаль йогышлы авырулар патогенезы һәм аны дәвалауга, иммунитет күрсәткечләренең специфик булмаган факторлары ролен ачыклауга, киногенез тайпылышларына һәм аларны сулыш юлларындагы вируслы йогышлы авырулар вакытында көйләүгә карый. А. илебездә яңа ФОС төркеменнән булган препарат — димефосфонны авыруларның авыр һәм катлаулы вариантларын дәвалаганда антицидотик чара сыйфатында гамәлгә кертүдә катнаша. «Балаларда көчле сулыш юллары авырулары вакытында бронхлар синдромын дәвалау ысулы»н («Способ лечения бронхообструктивного синдрома при острых респираторных заболеваниях у детей», 1990) уйлап тапкан авторларның берсе.

Х е з м.: Изменение функциональной активности нейрофиллов в динамике острых респираторных вирусных и вирусно-бактериальных инфекций у детей. ВИЧ-инфекция у ребёнка // Казан. мед. журн. 1997. № 3; Современные принципы клинической диагностики и классификации детских инфекционных заболеваний // Казан. мед. журн. 1998. № 3.

**АНО́ШИН** Геннадий Александрович (15.6.1954, Казан), спортчы, тренер (ирекле көрәш), СССРның спорт остасы (1974), Россиянең атказ. тренеры (1992). Волгоград физик культура ин-тын тәмамлый (1992). Спорт б-н «Ракета» спорт клубында тренер Ж.Б.Гафиатуллинда шөгыльләнә башлый (Казан). 1977–78 елларда шунда ук ирекле көрәш буенча тренер. 1978 дән Профсоюзлар ирекле спорт җәмгыятенең Тукай р-н советында ирекле көрәш буенча тренер (1982 гә кадәр), 1982 дән Чаллы шәһәренең балалар иҗаты үзәгендә. 1989 дан СССР, Россия җыелма командаларында тренер-массажчы.

**АНТ**, татар халык авыз иҗатының афористик характердагы бер төре. Борынгыдан мәгълүм, татарларның барлык этник төркемнәре арасында киң таралган. Урта гасырлар язма чыганакларында бәян ителгәнчә (7–14 йөзләр), А. борынгы төркиләр җәмгыятендә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләүдә мөһим роль уйнаган. «Кут колып ант антыкмышы талуй өгүздә териңрәк ол» («Шәфкатьлелек сораганда елгадан, диңгездән дә тирәнрәк булган антлар бирергә») дигән әйтем теркәлеп калган. Мәхмүд Кашгариның «Төрки телләр сүзлеге» («Диване лөгать әт-төрк», 11 йөз) хезмәтендә А. бирүнең кызыклы тәртибе китерелгән: кайбер төрки кабиләләрдә А. бирүче алдына кылыч куелган һәм «Бу көк кирсүн, кызыл чыксун» («Бу күк (ягъни, кылыч) керсен, кызыл (ягъни, кан) чыксын») дигән сүзләр әйтелгән. А. бер зат тарафыннан үзенең дөреслегенә, гаепсезлегенә, нәрсәгә дә булса катнашы булмаганлыгына, ш.у. А.ның какшамаслыгына ышандыру өчен бирелә. А. иткән кеше сүзендә тормаган очракта җәза кичерергә әзер булуын белдерә: «Кояш йөзе күрмим», «Иманымнан җөда булыйм», «Ике күзем чәчрәп чыксын», «Җир мине упсын». Баштарак А. иткәндә сихер хәрәкәтләре ясалган, бу А.ның «айак үрүп сүзи» («сүзләрен савытка өреп») әйтелүендә дә күренә.


*Әд.:* Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. К., 1987; Древнетюркский словарь. Л., 1969; М а х м у т о в Х.Ш. Афористические жанры татарского фольклора. К., 1995.


*Х.Ш.Мәхмүтов.*

**АНТЕ́ННА** (лат. antenna — мачта, кораб мачтасындагы рея), радио дулкыннарын тоту яки (һәм) тарату өчен хезмәт итә торган җайланма. Элемтә, радиолокация, радионавигация, радиоидарә, радиотелеметрия һ.б.ш. радиотехник системаларның бер компоненты. Тапшыру А.сы югары ешлыктагы ток энергиясен ирекле таралган радиодулкыннар энергиясенә әверелдерә. Мондый күренеш инглиз физигы Дж. Максвеллның теоретик хезмәтләренә нигезләнә һәм немец физигы Г.Герц тарафыннан 1880 елларда беренче мәртәбә тәҗрибәдә исбат ителә. Кабул итү А.сы кире функцияне башкара — ирекле таралган радиодулкыннарны алмаш ток энергиясенә әверелдерә. Беренче А. рус радио уйлап табучы А.С.Попов тарафыннан эшләнә (1895). СССРда А. өлкәсендә фәнни тикшеренүләр мәктәбе күренекле галимнәр акад. М.В.Шулейкин, мөхбир әгъзалар А.А.Пистолькорс, Л.Д.Бахрах һ.б. тарафыннан оештырыла. Татарстанда А. теориясе һәм техникасы үсә башлау Казан авиация ин-тында радиотехника ф-ты (1952) һәм 294 нче аерым КБ (1957, хәзер Казан радиоэлектроника ин-ты) оешуга бәйле. ТР галимнәренең тикшеренүләре хәзерге заман А. синтезы теориясенә зур өлеш кертә. А. теориясен үстерүдә Казан авиация ин-ты коллективы (җитәкчесе — проф.



Көзгеле антенна.





Антенна системалары: 1) рупорлы һәм ярыклы 2 рәшәткәле; 2) киң полосалы 2 вибраторлы.

В.И.Поповкин) зур уңышка ирешә. А. синтезы теориясе өлкәсендәге хезмәтләр циклы (билгеле юнәлеш диаграммасы буенча А. төзү теориясенең бер юнәлеше) өчен аңа СССР Дәүләт бүләге бирелә (1976). Очкыч аппаратлардан чыгып тормаган А. проектлаштыру ысуллары Ю.Ю.Радциг (1980), беришле булмаган фазадагы А. теориясе О.Ш.Даутов (1992) һ.б. галимнәр хезмәтләрендә үстерелә.



Сантиметрлы диапазондагы дулкыннарның бер көзгеле антеннасы.

ТР галимнәре тарафыннан төрле максатлардагы радиотехник чаралар өчен махсус А.лар эшләнә.

Республикада самолёт радиосистемалары өчен яңа типтагы А. лар (Казан, Әлмәт), актив фазаларга бүленгән челтәр элементлары (Чистай ш.) эшләнә һәм җитештерелә. Казан техника ун-тының радиотехника ф-ты А. белгечләре әзерләүдә РФдә әйдәп баручы үзәкләрнең берсе булып санала. А.лар системасын синтезлау, фазаларга бүленгән һәм актив А. челтәрләрен һәм сигналларны эшкәртә торган А. лар теориясе — перспективалы тикшеренү юнәлешләренең берсе.

*Әд.:* П и с т о л ь к о р с А.А. Антенны. М., 1947; П о п о в к и н В.И., Щ е р б а к о в Г.И., Е л у м е е в В.И. Оптимальные решения задач теории синтеза антенн // Радиотехника и электроника. 1969. Т. 14, № 7; А й з е н б е р г Г.З., Я м п о л ь с к и й В.Г., Т е р ё ш и н О.Н. Антенные УКВ:

В 2 ч. М., 1977; Сазонов Д.М. Антенны и устройства СВЧ. М., 1988; Бахрах Л.Д., Воскресенский Д.И. Проблемы антенной техники. М., 1989; Даутов О.Ш. Проектирование антенн в неоднородном пространстве // Фазированные антенные решётки и их элементы: Всесоюз. науч. конф., 11–15 июня 1990 г. К., 1990.

*Г.И.Щербаков, Е.А.Стахов.*

**АНТЕ́ННАЛАР СИ́НТЕЗЛАУ**, к. *Антенна.*

**А́НТИК ДӨНЬЯНЫ́ ӨЙРӘНҮ́ ГЫЙЛЕМЕ́** (антиковедение), Борынгы Греция һәм Рим дәүләтләренең (б.э.к. 3 нче меңьеллык — б.э.ның 1 нче меңьеллыгы урталары) тарихын, икътисадын, телен, әдәбиятын, сәнгатен, дини карашларын өйрәнә торган фәннәрнең гомумиләштерелгән җыелма атамасы. Борынгы заманны өйрәнүче аерым белем тармагы буларак Көнбатыш Европада урта гасырларда барлыкка килә, Яңарыш һәм Мәгърифәтчелек чорында кабат үсеш ала. Мәгърифәтчеләр Греция б-н Рим дәүләтләре яшәгән антик чорны бөтендөнья тарихының алга китешенә үрнәк дәвер, ул дәвердә демократия һәм греклар мәдәнияте чәчәк аткан, дип санаганнар. 19–20 йөзләрдә А.д.ө.г.ндә беренчел чыганакларны тәнкыйди күзлектән карап тикшерү ысулы һәм махсус фән тармаклары туа: антик археология, антик нумизматика, антик эпиграфика һ.б. А.Бек, И.Г.Дройзен, Т.Моммзен, К.Ю.Белох, Э.Мейер, А.Валлон, М.Финли, В.Тарн һ.б. антик дәвернең икътисады, сәяси тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләрен өйрәнү-тикшерүгә караган хезмәтләр язалар. Аларның кайберләре антик чорны капитализмның үзенчәлекле бер варианты дип тә бәяләмәкче була. Россиядә А.д.ө.г. фән буларак 18–19 йөзләрдә үсә башлый. Аңа 18 йөзнең 1 нче яртысында М.В.Ломоносов нигез сала. 19 йөз — 20 йөз башында антик дәвер тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән хезмәт авторлары түбәндәгеләр: М.С.Куторга (Афина тарихына багышланган хезмәтләре), В.Г.Васильевский (эллинизм чорының социаль-икътисади тарихы), Ф.Ф.Соколов (эпиграфикага нигезләнеп эллинизм тарихын тикшерү), М.И.Ростовцев (Греция һәм Рим дәүләтләре икътисады тарихы), М.П.Драгоманов (Рим империясе тарихы), В.П.Бузескул (антик чорга караган тарихи чыганаклар) һ.б. Совет хакимияте елларында антик дәвердәге сыйнфый көрәш мәсьәләләрен өйрәнүгә өстенлек бирелә (С.А.Жебелев, А.В.Мишулин). Борынгы коллар, илотия, колонат мәсьәләләре (Е.М.Штаерман, В.И.Кузищин), антик полис һәм империя тарихы (Н.А.Машкин, С.Л.Утченко, Ю.В.Андреев, Э.Д.Фролов, Л.П.Маринович, И.Л.Маяк), эллиннар җәмгыяте һәм мәдәнияте (А.Б.Ранович, К.К.Зельин, Н.Н.Пикус, Е.С.Голубцова, И.С.Свенцицкая, Г.А.Кошеленко, А.И.Павловская), антик дөньяда дәүләтара мөнәсәбәтләр (А.Г.Бокщанин) тикшерелә. Бүгенге Россиядә А.д.ө.г. илдә туган элекке традицияләрне дәвам итә.

19 йөзнең 2 нче яртысыннан борынгы Греция б-н Рим дәүләтләренең гомумиләштерелгән тарихын өйрәнү үзәкләренә Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе дә керә. Казан галимнәре тикшеренүләреннән Гомер яшәгән чор тарихына (*С.П.Шестаков*), Рим респ-касына (*В.И.Модестов*), христиан диненең башлангыч чорына (Я.И.Алфионов, Д.В.Гусев, Н.Ф.Красносельцев) караган хезмәтләрне атарга мөмкин. Казан галимнәре беренчеләрдән булып өйрәнгән мәсьәләләр дә бар: Ф.Г.*Мищенконың* антик дәвер федерализмына, М.М.*Хвостовның* Мисырда эллиннар дәвере социаль-икътисади тарихына караган хезмәтләре шундыйлардан. Казан галимнәренең казанышлары гомумроссия күләмендә генә танылмыйча, бөтен дөньяга билгеле була. Совет хакимияте чорында, 1940 еллар башында Казан ун-тында тарих-филология ф-ты кабат торгызылгач, А.д.ө.г.нә җитди әһәмият бирелә. Эллиннар җәмгыяте һәм мәдәнияте тарихына караган яңа хезмәтләр туа (М.П.Шкляев, Л.И.Савельева). 1940 еллар ахырыннан ун-тның гомуми тарих кафедрасы мөдире булган А.С.*Шофманның* бу өлкәдәге эзләнүләре рев-циягә кадәр үк башланган фәнни традицияләрне дәвам иттерә. Россиядәге А.д.ө.г.ндә ул беренчеләрдән булып антик Македония һәм эллинизмның тәүге чоры тарихын тикшерә. Аның тарафыннан антик дәверләр тарихын өйрәнүнең катлаулы мәсьәләләрен барлау һәм чишү ысуллары тәкъдим ителә. 1966 елда Казан ун-тында А.С.Шофман җитәкләгән «Антик дүшәмбе» («Античный понедельник») фәнни түгәрәге эшли башлый. А.С.Шофман һәм аның шәкертләре Россия һәм чит ил галимнәренең А.д.ө.г. өлкәсендәге эшчәнлеген барлауга (историографиягә) зур өлеш кертә. 1990 еллар башында Казан ун-тында гомуми тарих каф. җирлегендә борынгы дөнья һәм урта гасырлар тарихы белгечләге каф. булдырыла. Аның эшчәнлеге Борынгы Греция һәм Рим тарихы, антик чорга караган историография мәсьәләләрен өйрәнүгә юнәлдерелә (В.Д.*Жигунин*, Е.А.Чиглинцев, Ф.Н.Әхмәдиев, О.Л.Габелко һ.б.). А.д.ө.г.нә караган эзләнүләр Казан. пед. ун-тында (А.М.Ременников), Казан техника ун-тында (А.А.Розовский, Э.В.Рунг һ.б.), Казан энергетика ун-тында да (Н.А.Сергеев) алып барыла. Бәйсез Дәүләтләр Берлегенә кергән байтак фәнни үзәкләрдә Казанда югары белем алган, А.д.ө.г. үзләштергән белгечләр эшли (проф. В.И.Кащеев, проф. Н.С.Талашова, Г.В.Атласов, Ю.В.Лукиянов, А.А.Елагина, Э.Б.Петрова һ.б.).

*Әд.:* Шофман А.С. Изучение античной истории в Казанском университете. К., 1956; Константинова А.Д., Жигунин В.Д. Развитие антиковедения на кафедре всеобщей истории Казанского государственного университета в послевоенный период // Критика буржуазных концепций всеобщей истории. К., 1974. Вып. 3; Историография античной истории. М., 1980; Жигунин В.Д. Антиковедение в Казани: специфика и основные тенденции развития // Историческая наука в Татарстане: исследовательские и педагогические традиции. К., 1996; Жить историей: 60 лет историческому факультету Казанского университета. К., 1999.

*В.Д.Жигунин*, Г.П.Мягков.

**АНТИКОВЕ́ДЕНИЕ**, к. *Антик дөньяны өйрәнү гыйлеме.*

**АНТИ́ПИН** Игорь Сергеевич (7.4.1954, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1995), РФАнең мөхбир әгъзасы (2003), проф. (1998), РФ һәм ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004, 2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук эшли. 1999 елдан органик химия каф. мөдире. Циклик кушылу реакцияләрендә молекулаара тәэсир итешү термодинамикасын һәм тирәлекнең тәэсирен тикшерә. Эреткечләрдә куышлык барлыкка килү энтальпиясен һәм дисперсион үзара тәэсир итешүнең энергиясен бәяләүдә оригиналь ысуллар эшли. Органик кушылмаларның кислота-селте үзлекләренә тирәлекнең тәэсир итүен өйрәнә. Макроциклик комплекслы кушылмалар — литийорганик кушылмаларның криптатларын — куллану нигезендә органик кушылмаларның универсаль кислоталылык шкаласын (криптатлар шкаласы) төзи. Бу исә тирәлекнең CH-, NH-, OH кислоталылыкка тәэсирен корректлы тикшерергә мөмкинлек бирә. Криптатларны протон күчерү реакцияләрендә куллану макроциклик кушылмалар химиясен өйрәнү буенча тикшеренүләргә, өч үлчәмле рецепторлы молекулалар һәм аларның биологик әһәмиятле кушылмалар б-н комплексларын (гидрокси-, аминокислоталар, пептидлар б-н һ.б.) синтезлауга зур этәргеч ясый һәм аларны киләчәктә хим. объектларны молекуляр тануда кулланырга мөмкинлек бирә.

Хезм.: Фосфорорганические каликсарены // Успехи химии. 1998. Т. 68 (автордаш); Синтетические рецепторы на основе порфиринов и их коньюгатов с каликс[4] аренами. М., 2006 (автордаш); Cryptate acidity scales. Solvent polarity effect on ion-pair and free ion acidity of organic compounds // Phys. Org. Chem. 1994. V. 7 (автордаш).

**АНТИ́ПОВ** Николай Кириллович (15.12.1894, Новгород губ., Старо-Русский өязе — 24.8.1941), партия, дәүләт эшлеклесе. Адмиралтейство суднолар төзү з-дының техник мәктәбен тәмамлый (С.-Петербург, 1910). 1912–14 елларда Мәскәүнең төрле пр-тиеләрендә эшли. 1912 дән РСДРП(б) әгъзасы, яшерен түгәрәкләр эшчәнлегендә актив катнаша. 1914 нең ноябрендә кулга алына, 1915 нең августында ирекә чыга. 1915–16 да Мәскәүдә «Динамо» з-дында эшли, революцион эшчәнлеге өчен берничә тапкыр кулга алына. 1916 да Петроградта яшерен типографияләр җитәкчесе. 1916 ның ахырыннан 1917 нең февраленә кадәр төрмәдә утыра. РСДРП(б)ның Петроград ком-ты һәм Гельсингфорск оешмасы әгъзасы. 1917 елгы Апрель конференциясендә катнаша. 1917–18 дә Югары ХХС президиумы әгъзасы, Петроградта ЧК рәисе. 1919–20 дә РКП(б)ның Казан губерна ком-ты 1 нче секретаре, губернаның ЧК һәм Башкарма ком-ты рәисе, Республика запас армиясенең Революцион хәрби советы (РВС) әгъзасы. 1921–24 тә ВЦСПС президиумы әгъзасы. 1925–27 елларда ВКП(б)ның Урал һәм Ленинград өлкә ком-тлары секретаре. 1928–31 дә СССРның почта һәм телеграф халык комиссары, 1931–35 тә Эшче-крәстиян инспекциясе халык комиссары урынбасары, 1935–37 дә СССР ХКС рәисе урынбасары. РСФСР БҮБК, СССР ҮБК әгъзасы (1921–37). Репрессияләр чоры корбаны.

*Әд.:* Андрианов Н. Антипов Н.К. // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**АНТИТЕ́ЗА** (грек. antíthesis — капма-каршылык), матур әдәбиятта тәэсирлелекне көчәй-

тү өчен капма-каршы төшенчәләрне, образларны, күренешләрне һәм аларның үзенчәлекләрен чагыштыруга корылган әдәби-стилистик алым. А. принцибына бөтен әсәр яисә аның бер өлеше генә дә корыла ала. А. татар әдәбиятында киң кулланыла.

Бу дөньяда, табигыйдыр, кеше
буш булмый **дошманнан**!
Шулай ансы; вәләкин,
И ходаем, сакла **дустлардан**!
(Г.Тукай)

Күктә бер кош оча,
**Югары**, **югары**!
Мин ауныйм **идәндә** —
Кулларым богаулы.
(М.Җәлил)

Нинди **коточкыч** авыр көн!
Нинди **искиткеч** матур көн!
(Р.Харис)

Суык **колактан** алыр,
Сылу **йөрәктән** алыр.
(Мәкаль)

Әдәби әсәр, газета яки журнал мәкаләсе, фильм исеме дә А. шәкелендә булырга мөмкин, мәс. «**Чын вә ялган**» (Г.Тукай)

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; А х м а н о в а С.О. Словарь лингвистических терминов. М., 1969.

*Х.Р.Курбатов.*

**АНТИЦИКЛО́Н** (грек. anti — каршы һәм *циклон*), атмосфера басымы чагыштырмача югары булган һава массасы. Һава торышын билгеләүче (синоптик) карталарда йомык изобарлар (бертигез басым сызыклары) б-н күрсәтелә һәм иң югары басымлы үзәгендә «В» хәрефе б-н билгеләнә. А. — зур масштаблы циркуляция ясаучы барик өермә; үлчәмнәре горизонталь буенча 1000 *км* дан 6000 *км* га, вертикаль буенча 2 *км* дан 12 *км* га кадәр; төньяк ярымшарда һава хәрәкәте сәгать теле йөреше уңаена, көньяк ярымшарда — киресенчә. Төньяк ярымшарда А.ның көнчыгыш өлешендә һава массаларының күчеше күп очракта төньяктан, көнбатыш өлешендә көньяктан була. А. үзәгендә өстән аска таба төшүче һава агымнары өстенлек итә, шуңа күрә гадәттә биредә тыныч, аяз һәм аз болытлы, явымсыз, сирәк кенә томанлы һава торышы күзәтелә. Атмосферада, циклоннар б-н беррәттән, А.нар көн саен барлыкка килә, үзгәрә һәм хәрәкәт итә. Хәрәкәтчән А.ның уртача тизлеге 30 *км/сәг* тирәсе. Тотрыклы аз хәрәкәтчән А.да җәен һава шактый җылына (Татарстан терр-ясендә 30°С ка кадәр һәм югарырак), кышын — суына (–35°С ка кадәр һәм түбәнрәк). А. үзәгендә диңгез тигезлегенә китерелгән атмосфера басымы җәен 1030 *гПа*, кышын 1065 *гПа* гә җитәргә һәм югарырак күтәрелергә мөмкин (1000 *гПа* = 750 *мм* терекөмеш баганасы биеклеге). Антициклон тибындагы һава торышы Татарстанда елына уртача 192 көн, апрельдә ешрак (17 көн) һәм июльдә сирәгрәк (14 көн) күзәтелә. Кышын — көнчыгыш А., җәен көнбатыш А. өстенлек итә, язын һәм көзен аларның кабатланышы чагыштырмача бертигез. Көнчыгыш А. кышын, гадәттә, Себердән коры салкын һава, җәен Урта Азиядән җылы һава агымы алып килә; көнбатыш А. кышын һәм җәен Атлантик океаннан дымлырак һава массалары китерә. Шактый кискен һәм көчле суытулар Арктика һавасын күчерүче төньяк һәм төньяк-көнчыгыш А.га бәйле, көньяк һәм көньяк-көнбатыштан җылы тропик һава массалары керә.

*Әд.:* В о р о б ь ё в В.И. Синоптическая метеорология. Л., 1991; Климат и загрязнение в Татарстане. К., 1995.

*Э.П.Наумов.*

**АНТОЛО́ГИЯ** (грек. anthología, туры мәгънәсе — чәчәкләр бәйләме), берничә язучының иҗатын яки аерым бер дәвердәге әдәбиятны, әдәби агымны, халык мәдәниятен чагылдырган шигырьләр, гыйбарәләр, әсәрләрдән китерелгән өзекләр тупланган җыентык. Урта гасырлар Шәрекъ һәм төрки халыклар, ш.и. татар әдәбиятында А.нең беренче үрнәкләре — *тәзкирә*, *мәҗмуга*, җыентык. Мәс., Фәридеддин Гаттарның «Тәзкирәт әл-әүлия» («Изгеләр тормышын тасвирлау», 12 йөз ахыры -13 йөз башы), Дәүләтшаһ Сәмәркандинең «Тәзкирәт әш-шугара» («Шагыйрьләр тормышын тасвирлау», 1487), Галишер Нәвоиның «Мәҗәлис ән-нәфаис» («Нәзакәтлеләр җыены», 1490–98), Шәрекъ шагыйрьләренең татар теленә тәрҗемә ителгән сайланма шигырьләреннән торган «Шәрекъ гөлләре» (1919) җыентыклары. Татар әдәбиятында А. төзү 20 нче йөзнең 2 нче яртысында үсеш ала: «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Антология татарской поэзии» (1957), «Көнчыгыш шагыйрьләре» (1959), «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980), «Татар поэзиясе антологиясе» (т. 1–2, 1992), «XX гасыр башы татар шигърияте» (1998–99) һ.б. дөнья күрә.

*Ш.Ш.Абилов.*

**АНТО́НИЙ** (Храповицкий Алексей Павлович) (17.3.1863, Новгород ш. — 23.7.1936, Белград ш., Сербия), дин эшлеклесе һәм белгече, дин гыйлеме магистры (1887). 1877–78 елгы Рус-төрек сугышы герое генерал П.А.Храповицкийның улы. Петербург руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1885), монахлык кабул итә. 1885–90 да — Петербург, 1890 нан Мәскәү руханилар академияләрендә эшли, 1895–1900 дә Казан руханилар академиясе ректоры. 1897 дән Чабаксар епископы. А. вакытында Казан руханилар академиясендә студентлар саны арта, фәнни эшчәнлек активлаша. А. 1900 дән Уфа епископы, 1902 дән Волынь һәм Житомир епископы, 1906 дан — архиепископы, 1914 тән Харьков архиепископы булып тора. 1906 дан — Дәүләт Советы, 1917 дән Изге Синод әгъзасы. Патриарх тәхетенә дәгъва кылучыларның берсе. 1918 дән Киев һәм Галич митрополиты. 1920 дән Россиядән китә, чит илдәге Рус православие чиркәвенең баш иерархы буларак, митрополит Сергийга дошманлык позициясенә баса. А. рухани язучы буларак та таныла. Аның публицистик хезмәтләрендә һәм вәгазьләрендә иҗтимагый тормыш мәсьәләләре күтәрелә. Катгый уң монархист буларак, башка төрле диннәр тоту ирегенә һәм дәүләтне конституция нигезендә үзгәртеп коруга каршы чыга.

Х е з м.: Сочинения: В 3 т. К., 1900; Догмат Искупления. СПб., 1917; Опыт христианского православного катихизиса. Белград, 1924.

*Әд.:* Ф л о р о в с к и й Г.А. Пути русского богословия. М., 1996.

**АНТО́НИЙ** (Амфитеатров Яков Гаврилович) (15.10.1815, Оренбург губ., Миасс ш. — 8.11.1879, Казан), дин белгече, дин гыйлеме д-ры (1851). Киев руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1840), монахлык кабул итә. Киев руханилар семинариясе укытучысы, ректоры, 1858 елдан Смоленск епископы. 1866 дан Казан һәм Зөя епископы, 1868 дән архиепископы. Төбәктә дин һәм чиркәү мәгарифе системасын үстерүдә зур роль уйный. Миссионерлык эшчәнлеге алып бара, Н.И.Ильминскийны һәм аның системасын яклый. Беренче тапкыр Идел буе халыклары, ш.и. татарлар арасыннан христиан дине әһелләрен әзерләүне гамәлгә ашыра. «*Изге Гурий борадәрлеге*»н оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе була. Казан епархиясендә яңа монастырьлар ачуга һәм аларның эшчәнлеген активлаштыруга булыша. «Догматик дин тәгълимате» («Догматическое богословие», 1851) исемле төп хезмәте күп еллар дәвамында Россия һәм Греция дини уку йортларында дәреслек булып кулланыла.

*Әд.:* Антоний — архиепископ Казанский и Свияжский // Православный собеседник. 1879. Ч. 3.

**АНТО́НИЙ** (Вадковский Александр Васильевич) (1846, Тамбов губ., Спас өязе Ширингуши а. — 2.11.1912, С.-Петербург), дин белгече, чиркәү тарихы д-ры (1895). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1870). 1874 елдан «*Православный собеседник*» ж-лы мөхәррире. 1883 тән монахлыкта. Казан руханилар академиясе инспекторы. 1885 тән Петербург руханилар академиясе инспекторы. 1887 дән Ямбург епископы һәм шул ук академиянең ректоры. 1892 дән Финляндия архиепископы, 1898–1912 дә Петербург һәм Ладога митрополиты. 1900 елдан Синод әгъзасы. Рус православие чиркәвен үзгәртеп коруны, 1905 ел 17 октябрь Манифестын яклый. Хезмәтләре гомилетикага, Россиядә һәм көньяк славян илләрендә дәгъвәт тарихына карый.

Х е з м.: Речи, слова и поучения. СПб., 1903.

*Әд.:* Б о г о р о д с к и й Я.А. Митрополит Антоний (Вадковский) в казанский период его деятельности. К., 1913; Высокопреосвященнейший Антоний, митрополит Санкт-Петербургский и Ладожский. СПб., 1915.

**АНТО́НИМНАР** (грек. anti — каршы, ónyma — исем), капма-каршы күренешләрне аңлату өчен кулланыла торган капма-каршы мәгънәле сүзләр. А. мәгънәләре ягыннан берничә төркемчәгә бүленә: 1) күренешләрнең, предметларның, кешеләрнең сыйфатын (яхшы-начар, бай-ярлы); 2) озынлыгын, күләмен (озын-кыска, зур-кечкенә); 3) яшен (яшь-карт); 4) төсен (ак-кара) тасвирлыйлар; 5) төрле тоемлауларны (җылы-салкын, коры-юеш) белдерәләр; 6) процессларны капма-каршы куялар (бару-кайту, туу-үлү). А.ны тел (даими) һәм сөйләм (контекстуаль) төрләренә бүлеп йөртәләр. Тел А.ы контексттан тыш та аңлашыла, аларның капма-каршы мәгънәле сүзләр икәнлеге җиңел тоемлана (олы-кече, дус-дошман). Контекстуаль А. билгеле ситуациядә, контекстта гына А. булып киләләр, аерым кулланганда антонимик мөнәсәбәтләре юкка чыга.

**Көчлелегең** белән горурланма,
**Кешелегең** белән горурлан!
(М.Җәлил)

Төзелешләре ягыннан А. бер тамырлы (тозлы-тозсыз, ал-алма), төрле тамырлы (тиз-акрын, аз-күп) булалар. Сәнгатьле сурәтләүне көчәйтү өчен А. шигъри яки ораторлык сөйләмендә *антитеза* алымы буларак кулланыла.

Без **сугышта** юлбарыстан көчлебез,
Без **тынычта** аттан артык эшлибез.
(Г.Тукай)

Бер төшенчә булып берләштерелгән А., бер-берсенә логик яктан капма-каршы булсалар да, бер сүзтезмә булып йөри башлыйлар. Мондый сүзтезмә оксюморон дип атала (бай хәерче, тере мәет).

*Әд.:* Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999; Большой энциклопедический словарь: Языкознание. М., 1998.

*Г.Ф.Саттаров.*

**АНТО́НОВ Л.П. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́** (типолитография), Казанда. Титуляр киңәшче, «Казань» г-тасының беренче редакторы һәм нашире Л.П.Антонов тарафыннан 1894 елның декабрендә «Печёнкин һәм К°» ширкәте басмаханәсе җирлегендә ачыла. 19 эшчесе була, 1900 дә еллык товар әйләнеше 8000 сум тәшкил итә. Халыкта «скоропечатный» дип атап йөртелә. Ташбасма ысулы б-н татар китаплары чыгара. 1911 дә Л.П.Антонов В.Е.Казаковтан басмаханә җиһазлары һәм материаллар, татар шрифтлары сатып ала. Шул вакыттан басмаханәдә даими рәвештә татар китаплары нәшер ителә башлый. 1911–13 тә «Мәгариф» нәшрияты б-н актив хезмәттәшлек итә һәм башлыча аның заказларын үти. 1912 елда «Казань» г-тасы да шунда чыга. 295 мең данә гомуми тираж б-н 76 исемдә татар китабы бастыра: Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Н.Думави һ.б.ның әсәрләре, мәдрәсәләр өчен дәреслекләр, календарьлар, фәнни-популяр әдәбият. 1912 дә ш.у. 33 исемдә рус телендә дә китаплар бастыра (В.М.Залесскийның «Ярлыларны кайгырту системасы» — «Система призрения бедных», А.М.Мироновның «Италия сәнгатендә Яңарыш эпохасы» — «Эпоха Возрождения в итальянском искусстве» һ.б.).

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века, К., 1974; шул ук. Татарская книга пореформенной России. К., 1983.

**АНТО́НОВ** Олег Михайлович (27.3.1936, Ростов өлкәсе Цимлянск ш.), хокук белгече, РСФСРның атказ. хокук белгече (1986). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1965–72 елларда ТАССРның Югары мәхкәмәсе әгъзасы. 1972–76 да Чаллы шәһәр халык мәхкәмәсе рәисе, 1976–85 тә шәһәр прокуроры. 1985–92 дә — ТАССР, 1992–97 дә Белгород өлкәсе прокуроры, 1997 дән РФ Генераль Прокуратурасының төбәк укыту үзәге (Белгород ш.) башлыгы.

**АНТО́НОВКА** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2002 елда 89 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 17 йөз уртасында Зөя дворяны Антон Савельев тарафыннан нигез салына. 1695 елдан башлап, 20 йөрттән торган авыл Казан архиерей йорты милке булып исәпләнә. 1763 тә крәстияннәр — икътисади, 1841 дә дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. Игенчелек, терлек үрчетү, бакчачылык, суган үстереп сату, алма тутыру өчен әрҗәләр ясау б-н шөгыльләнәләр; Казан дары з-дында яллануп эшлиләр. Кәсепчелекнең иң әһәмиятле тармагы булып таш чыгару һәм алебастр җитештерү тора. 20 йөз башында А.да Богоявление чиркәве (1842 елда төзелә), земство уч-щесе (1884 тә ачыла), кредит ширкәте, 2 ярма ярдыру һәм 9 җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, йон тетү йорты, пароход пристане, шәраб, 2 сыра, 7 сәүдә кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2886,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостена керә. 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында; 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1709 да — 373, 1763 тә — 238 ир заты; 1834 тә — 1141, 1859 да — 1378, 1897 дә — 2043, 1909 да — 2152, 1926 да — 1655, 1938 дә — 1360, 1949 да — 1073, 1958 дә — 549, 1970 тә — 294, 1979 да — 188, 1989 да 119 кеше.

*Әд.:* Приволжские города и селения Казанской губернии. К., 1892.

**АНТО́НОВКА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 37 *км* көнчыгыштарак, Бизнә елгасы буенда. 2002 елда 672 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Алпавыт Мусин-Пушкиннар утары — 19 йөзнең 1 нче яртысы архит-ра истәлеге. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Рождественский, Рус Бизнәсе исемнәре б-н дә билгеле. 1925 елдан авыл крәстияннәре чуалышын җитәкләүче Антон Петров исемен йөртә (к. А.П.*Сидоров*). 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1861 дә А.да *Бизнә крәстияннәре кузгалышы* була. 20 йөз башында монда архит-ра истәлеге — Богородица чиркәве (1779 да төзелә), уч-ще, 1 су, 5 ярма ярдыру, 8 җил тегермәне, 3 тимерче алачыгы, 3 йон тетү йорты, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2420,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Гусиха волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935–91 елларда — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 329 ир заты; 1859 да — 1691, 1897 дә — 2447, 1908 дә — 2635, 1926 да — 1768, 1938 дә — 2125, 1949 да — 1591, 1958 дә — 2223, 1970 тә — 1225, 1979 да — 1057, 1989 да — 784 кеше.

**АНТО́НОВКА ЧОКЫРЛАРЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге. Кама Тамагы р-нының Антоновка авылы янында. 1997 елда игътибарга алына. Мәйданы 243 *га*. Идел елгасы үзәненең текә уңъяк ярында урнашкан. Рельефы нык челтәрләнгән, чокыр һәм сызалар б-н телгәләнгән. Өске капламы Пермь системасының татар ярусы, известьташ һәм комташ катламнары б-н аралашып, чуар төстәге балчык һәм мергельләрдән түшәлгән; су өстенә якын кыяларда Казан ярусының известьташ һәм доломит катламнары ачыла. Тәтеш урман хуҗалыгы тарафыннан 1960 та һәм шуннан соңгы елларда утыртылган нарат, имән, каен урманнарыннан гыйбарәт. Өрәңге, юкә, имән катнаш урманнар сакланып калган. Үләнчел үсемлекләрдән төп урманнарга хас гади сәрдә, төкле күрән һ.б. төрләр өстенлек итә. Ачык урыннарда дала үсемлекләре — каурый кылган, нут борчагы һ.б. очрый. Ял итү урыны.

**АНТРЕПРЕНЁР** (фр. entrepreneur — эшмәкәр), шәхси театр предприятиесе (*антреприза*) хуҗасы. Труппаны, спектакльләрдә хезмәт күрсәтү өчен техник хезмәткәрләрне (рәссам-декораторлар, яктыртучылар, сәхнә эшчеләре һ.б.) туплый, репетицияләр үткәрү һәм театр тамашалары өчен бина арендалый, реклама һәм билетлар сатуны оештыра, *репертуар* төзи. Еш кына А. бер үк вакытта актёр да, режиссёр да була. Шул ук вакытта, пр-тиенең барлык финанс эшчәнлеге б-н идарә итүче буларак, аның сәнгати ягына да йогынты ясый. Рус театр сәнгатенең үсүе, аның сәнгати-эстетик һәм әхлакый-этик принципларының формалашуы күбесенчә А.лар эшчәнлеге б-н билгеләнә. Казан театр тарихы Н.К.*Милославский*, П.М.*Медведев*, М.М.*Бородай*, Н.И.*Собольщиков-Самарин* кебек А.лар эшчәнлеге б-н бәйле. Алар — шәһәр һәм төбәк театр мәдәниятенә нигез салучылар, провинциаль театр сәхнәсендә сәнгатьнең үз иҗтимагый юнәлеше буенча реалистик һәм демократик принципларның ныгуына ярдәм итүчеләр. Алар үз антрепризаларында катнашу өчен башкала һәм провинция артистларын җәлеп итәләр һәм шул ук вакытта актёрларның яңа буынын тәрбиялиләр. Нәкъ менә Казандагы Медведев һәм Бородай труппаларында М.Г.Савина, П.А.Стрепетова, Е.Б.Пиунова-Шмидгоф, В.Н.Давыдов, К.А.Варламов, А.П.Ленский, В.А.Макшеев, М.А.Решимов, М.И.Писарев, В.И.Качалов, А.И.Каширин һ.б. киң танылa. 1908 елдан «*Сәйяр*» труппасын җитәкләгән Г.*Кариев*, И.*Кудашев-Ашказарский*, В.*Мортазин-Иманский* татар театрында шундый ук рольне уйныйлар. Ш.у. В.Б.Серебряков, Н.Д.Кручинин, В.В.Образцов, З.А.Малиновская һ.б.да Казанда антреприза тота.

*Әд.:* Мортазин М., Ченәкәй Т. Татар театры тарихыннан. М., 1926; Русский провинциальный театр. Л.-М., 1937; Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958.

*Ю.А.Благов.*

**АНТРЕПРИ́ЗА** (фр. entreprise — предприятие), хосусый театраль предприятие. Россиядә 1919 елга кадәр эшли. Антрепренёрның аерым идарә итүе яки берничә кешенең өлешчә катнашы нигезендә оештырыла. Берничә кеше катнашканда, алар арасыннан эшне оештыру һәм пр-тиедән килгән табышны бүлү өчен аерым кеше сайлана. А.га актёрлар, режиссёр һәм аның ярдәмчесе, суфлёр, рәссам, сәхнәне эшләүче техник хезмәткәрләр төркеме керә. Кагыйдә буларак, А.ның үз театр би-

насы булмый һәм шуңа күрә ул билгеле вакытка — гастрольләргә барган чорга, теге яки бу шәһәр б-н бер яки берничә сезонга бинаны арендалауга килешү төзегән очракта гына оештырыла. Килешү шартлары иҗат составының санын, репертуарның формалашу принципларын, тамашаларны оештыру, бинаны карап тотуны үз эченә ала. Махсус театр бинасы булган һәр шәһәрнең, гадәттә, декорация һәм костюмнар җыелмасы була, бу әйберләр арендаторга вакытлыча файдалану өчен бирелә. А. бары тик үз эшчәнлегеннән килгән табышка гына яши, аерым очракларда шәһәрдән бер тапкыр бирелә торган финанс субсидиясе дә ала. Казан театры 1802–1919 елларда А. сыйфатында яши (1852, 1872–74 тә башында шәһәр думасына буйсынган дирекция торган муниципаль театр); 1919 да, театрларны национальләштерү турында декрет кабул ителгәннән соң, аны тотуга дәүләт бюджетыннан акча бүленә башлый — ул дәүләт театры булып китә. Ләкин труппаларны А. ысулы б-н сезонлап формалаштыру аерым биналар бирү процессы башланганчы — 1930 елларга кадәр дәвам итә.

Татар театр труппалары да А. принципларында оештырыла, алар арасында ширкәтләр формасы аеруча киң тарала. П.М.Медведевтан башлап, кагыйдә буларак, Казан антрепренёрлары ике труппа — драма һәм опера труппалары формалаштыра. Алар, алмашлап, ике шәһәрдә эшли (Казан-Әстерхан, Казан-Саратов, Казан-Самара). 1914 тән опера һәм драма театры А.сы мөстәкыйль яши башлый, алар спектакльләрне бер үк вакытта куя: берсе — шәһәр театрында, икенчесе — Яңа клубта (к. *Театр биналары*). Шәһәр думасы б-н килешүгә кул куйган төп труппалардан тыш, шәһәрдә иҗтимагый клубларның, җәйге театрлар һ.б.ның хуҗалары б-н килешүләр төзегән аптрепренёрларга да эшләү мөмкинлеге була. Кайвакыт Казанда бер үк вакытта 6–8 театр труппасы эшли (1913–15).

*Әд.:* К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; Театральная энциклопедия. М., 1961. Т. 1.

*Ю.А.Благов.*

**АНТРОПОГЕ́Н СИСТЕ́МАСЫ (ЧОРЫ́)**, а н т р о п о г е н, к в а р т е р, *дүртенчел система* (*чор*) б-н бер үк.

**АНТРОПОГЕ́Н ТӘЭСИ́Р**, кеше эшчәнлегенең әйләнә-тирә мохиткә һәм экосистемалар эшчәнлегенә йогынтысы. Ул планлы яки очраклы, хәзерге яки үткәндәге, уңай яки тискәре булырга мөмкин. А.т. Җир өсте төзелеше, биосфера составы, табигатьтә матдәләр әйләнеше һәм балансы, энергия һәм җылылык балансы, кайбер үсемлек һәм хайван ареаллары үзгәрүдә чагыла. А.т. тере организмнарга карата турыдан-туры яки читтән булырга мөмкин. Турыдан-туры тәэсир кешенең ризык һәм кием-салымга булган ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен үсемлек яисә хайваннардан файдалануыннан гыйбарәт: мәс., сунарчылык, балык тоту, чикләвек, җиләк, гөмбә, дару үләннәре җыю, терр-яне сәнәгать, а.х., төзелеш яки ял итү өчен үзләштерү һ.б. Читтән тәэсир итү — сулыкларны, һаваны, туфракны пычрату, сәнәгать һәм а.х., транспорт эшчәнлеге, файдалы казылмалар чыгару (к. *Әйләнә-тирә мохитнең пычрануы*) нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохит параметрларының үзгәрүендә күренә. Татарстанда А.т. нефть чыгару, нефть эшкәртү, химия, машиналар төзү, ягулык һәм энергетика, транспорт пр-тиеләре урнашкан төбәкләрдә бик нык сизелә. Ш.у. респ-ка терр-ясенең күпчелек өлешен (65,5%) алып торучы а.х. сәнәгате комплексы пр-тиеләре дә тискәре А.т. ясый. Аларның озак еллар буена барган эшчәнлеге нәтиҗәсендә кайбер төбәкләрдә табигый ландшафтлар нык бозылган, ә агроландшафтлар камил түгел һәм тотрыксыз, туфрак деградациясе көчәя бара. Соңгы 40 ел эчендә сөрү җирләренең су эрозиясенә дучар ителгән мәйданы ике тапкыр артты. Элек массакүләм рәвештә урманнарны бетерү (урманнар 19 гасыр урталарында ТР терр-ясенең 40% ын, 20 гасыр азагында — 16,9% ын тәшкил иткән) һәм җирләрне сөрү (а.х. җирләренең 80% тан артыгы сөрелгән) кече елгалар озынлыгының кыскаруына, чишмә, күл һәм сазлыкларның өлешчә юкка чыгуына, зур терр-яләрдә су режимының бозылуына китерде. Чәчүлек мәйданнарын киңәйтеп, табигый үсемлек капламын культуралы үсемлекләр б-н алыштыру фитоценозларның һәм энтомофаунаның биологик күптөрлелеген киметә, кайбер төр үсемлек ареалларын кыскарта, чирәм һәм яткын җирләрдә яшәүче хайваннар (сөркә, йомран, дала тычканчыгы, дала чуары һ.б.) санын азайта. Су энергетикасы пр-тиеләре дә шактый зур А.т. ясый. Куйбышев (1955) һәм Түбән Кама (1978) сусаклагычлары төзелү нәтиҗәсендә югары продуктив тугай болыннары су астында кала (500 мең *га*). Идел, Кама һ.б. елгаларның гидрология режимы алышына, ярлары башкача формалаша; туфрак, үсемлек һәм хайваннар дөньясы үзгәрә. Су агышын көйләү су алмашу тизлеген акрынайта, елгаларның үзлегеннән чистару сәләтен түбәнәйтә һәм суның сыйфатын начарайта. А.т. кеше һәм кайбер төр хайваннар өчен уңай тәэсир ясарга да мөмкин. Бу экотоннар барлыкка килүдә, *җирләрне рекультивацияләүдә*, урманнарны торгызуда, яңа үсемлек төрләрен һәм хайван токымнарын *интродукцияләүдә* һәм *акклиматизацияләүдә* күренә. А.т. — Җир биосферасында кешелек дөньясының алмаштыргысыз яшәү шарты. В.И.Вернадский әйтүенчә (1944), ул «ноосфера» формалашуга, ягъни җәмгыять б-н табигать арасында акыллы үзара бәйлелек урнашуга китерәчәк. 1990 елларда Татарстанда А.т.не киметү максатында байтак кына законнар чыга («Җир турында», «Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау турында», «Калдыклар турында», «Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында», «Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы турында», «Татарстанның Кызыл китабын гамәлгә кертү турында»); ш.у. табигатьтән рациональ файдалануга һәм регионда экологик хәлне оптимальләштерүгә юнәлтелгән программалар тормышка ашырыла.

*Әд.:* В е р н а д с к и й В.И. Несколько слов о ноосфере // Успехи современной биологии. М., 1964. Т. 18, № 2; Влияние человека на ландшафт. М., 1977; Зелёная книга Республики Татарстан. К., 1993; Г а з е е в Н.Х., С и л к и н Е.А. Природопользование в Республике Татарстан: эколого-экономические аспекты. К., 1996.

*С.И.Кадошников.*

**АНТРОПОЛО́ГИЯ** (грек. ánthrōpos — кеше һәм ... *логия*), кешенең килеп чыгышын, өзлексез үсешен — эволюциясен һәм кеше расаларын өйрәнә торган фән. Фәннең төп бүлек-тармаклары: морфология, антропогенез, расаларны өйрәнү, палеоантропология.

А.дә кулланыла торган ысуллар: антропоскопия (язып тасвирлау) һәм антропометрия (үлчәм б-н тасвирлау). Соңгы ысул, тикшерү объектына карап, соматометриягә (тере кешене үлчәп тикшерү), краниометрия (кешенең баш сөяген үлчәү) һәм остеометриягә (кешенең гәүдә сөякләрен-скелетын үлчәү) бүленә. А.да өйрәнелә торган фәннәр: краниология, остеология (сөякләр), одонтология (тешләр), дерматоглифика (тән тиресе), серология (кеше каны) һәм антропологик төзелеш (баш сөягенә карап кеше йөзен билгеләү).


Фән буларак А. Россиядә 18 йөз башында барлыкка килә. 18 йөзнең 2 нче яртысында оештырылган академик экспедицияләр барышында Россиядә яшәүче халыклар, ш.и. татарлар турында кыйммәтле мәгълүмат туплана. Идел-Урал төбәгендә яшәүчеләрнең тән




Т.С.Б а л у е в а. Казан Кремле мавзолеендагы баш сөяге буенча битнең пластик реконструкциясе.

төзелешен (анатомиясен) җентекләп өйрәнү максатында 1836 елда Казанда *Анатомия театры* ачыла. Татарларны антропология ысуллары кулланып тикшерү эше 1870 еллардан башлана. Казан ун-ты каршындагы Табигать күренешләрен өйрәнү җәмгыятендә 1870 тә П.Ф.Лесгафт инициативасы б-н А. бүлеге оештырыла (җитәкчесе Н.Н.Фирсов). П.Ф.Лесгафт тырышлыгы б-н ун-т карамагында антропологик коллекция туплана. Проф. Н.М.Малиев ул коллекцияне татар, чуаш, мариларның баш сөякләре төзелеше (краниологии) материаллары б-н баета. Казанда А. фәненең 2 агымы үсеш ала: Казан губернасы халыклары А.се (П.Ф.Лесгафт) һәм краниология (Н.М.Малиев, С.М.Чугунов). Башкортларның баш сөяге төзелешен өйрәнгән Н.М.Малиев мондый нәтиҗәгә килә: далада яшәүче башкортлар татарларга тартым, ә урманлы җирдә яшәүчеләрнең баш сөяге Азия халыклары б-н катнашканлыкны күрсәтә. Мәскәү ун-ты профессоры А.П.Богданов беренчеләрдән булып Идел һәм Кама елгалары буенда яшәүче кабиләләрнең бер-берсенә тиңдәш түгеллеген әйтә, аларны бер антропологик типка берләштерү мөмкин түгел, ди. 19 йөз ахырларында Идел буе татарларының

төрле төркемен антропологик тикшерү нәтиҗәләре басыла (В.Н.Бензенгер, И.Благовидов, А.А.Сухарев, М.Н.Никольский һ.б.). А.А.Сухарев һәм М.Н.Никольский фикеренчә, Казан татарларының кыяфәте Урта диңгез буе (понтий) расасы б-н монгол расасы А. типлары кушылуы нәтиҗәсе. 1930–40 елларда Т.А.*Трофимова* б-н Г.Ф.Дебец Идел буен, Төмән, Тубыл, Бараба һәм Касыйм татарларын төрле яклап өйрәнәләр. Шуның нигезендә хәзерге заман татарларының антропологик типларын бер тәртипкә китереп (классификацияләп) бүлү мөмкинлеге туа. Тикшеренүләрдән соң галимнәр шундый нәтиҗәгә килә: татарларның төрле этно-терр. һәм субэтник төркемнәре антропологик яктан бер-берсенә якын, аларның уртак билгеләр җыелмасы бар. Тупланган антропологик мәгълүматлар татарларның килеп чыгышын ачыклауда беренче зур адым була. Татарлар этногенезында расалар кушылуы сизелерлек дәрәҗәдә чагыла, анда борынгы европалыларга хас чалымнар да, монгол расасы чалымнары да бар. Әмма европалыларга хас чалымнар өстенлек итә. Аерым төркемнәрдә бу чалымнар чагылышы төрлечә: Казан татарлары, мишәр һәм керәшеннәр арасында европеоид кыяфәтлеләрнең проценты зур, алар антропологик билгеләр буенча Идел-Урал төбәгендә яшәүче башка халыкларга якын. Себер һәм Әстерхан татарлары арасында исә монголоид кыяфәтлеләр өстенлек итә. Татарлар нигездә түбәндәге антропологик типларга бүленә: 1) понтий (Урта диңгезнең көнчыгышында яшәүчеләр) тибындагылар — озынча башлы (брахикранный), кара яисә аксыл-сары чәчле, күз ярысы төсе ачык, борын сырты калын, бөкре, борын очы аска таба төшкән, куе сакал-мыеклы. Чистай төбәге керәшеннәре арасында андыйлар 28%, Чистай р-ны һәм Пенза өлкәсенең Наручат төбәге мишәрләре арасында — 61%; 2) аксыл-сары европеоид тибындагылар — озынча түгәрәк башлы, аксылрак чәчле, күз ярысы төсе ачык, борын сырты туры, калку, сакал-мыегы уртача куелыкта, уртача буйлы. Барлык татарларның 17,5% шундый кыяфәтле, Алабуга һәм Чистай татарлары арасында андыйлар 16–17%, Алабуга р-ны керәшеннәрендә — 52%; 3) сублапоноид (Урал, Идел-Кама төбәге) тибындагылар — озынча түгәрәк башлы, чәче һәм күз ярысы төсләре төрлечә, киң борын төбе батынкырак, сирәгрәк сакал-мыек, уртача җәенке бит — монголларга хас чалымнар сизелерлек. Татар халкының 24,5% шушы типтагылар тәшкил итә; 4) монголоид (монголга тартым) типтагылар — кара чәчле, күз ярысы да карасу төстә, җәенке, тыгыз мускуллы бит, борын төбе батынкы; уртача буйлы. Татарлар арасында саф монголоид тибындагылар очрамый.



1



2




3



4

Т.А.Трофимова буенча татарларның антропологик типлары: 1. Понтий тибы (Чистай р-ны); 2. Европеоид аксыл тип (Чистай р-ны); 3. Европеоид аксыл тип (Алабуга р-ны); 4. Урал яки Идел-Кама ягына тартым сублапоноид тип (Арча р-ны); 5. Монголоид (көньяк Себер) тибы (Арча р-ны).



5

Татарларга мөнәсәбәтле антропологик тикшеренүләр 20 йөзнең 2 нче яртысында М.С.Акимова, М.М.*Герасимов*, В.П.Алексеев, Т.И.Алексеева, Н.М.Рудь (Постникова), С.Г.Ефимова һ.б. хезмәтләрендә дәвам иттерелә. Өйрәнү-тикшерү җирлегенең киңәюе Урта Идел буе халыкларының борынгы һәм урта йөзләрдәге тарихи антропологиясенең (палеоантропологиянең) байтак мәсьәләләрен чишү мөмкинлеге тудыра. Палеоантропология материаллары археологик казылмалар чыганакларына нигезләнеп эшләнә. Галимнәр шундый нәтиҗәгә киләләр: мезолит дәвереннән бирле Идел-Урал төбәгендәге кабиләләрнең төрле антропологик төркемнәре үзара катнашып яшәгән һәм субурал (Урал-лапоноид) расасы барлыкка килгән. Ул европеоид (европалы) расадан монголоид расасына күчеш дәверендәге раса, расалар барлыкка килүнең дүртенчел Урал алды үзәге (учагы). Мондый нәтиҗәне *Мәлләтамак комплексы* каберлекләрендәге палеоантропологик материаллар дәлилли.

Бронза чорында Идел-Урал төбәгендә антропологик төрләрнең күчеше дәвам итә. Мәс., *Абашево культурасына* караган Пепкинск курганы һәм *Баланово культурасына* караган Баланово каберлекләрендә Урта диңгезнең көнчыгыш төбәге европеоид тибы расасы билгеләре күпчелек мәетләргә хас. Ә *Чиркәскул культурасына* караган *Такталачык комплексы* каберлекләрендә субурал (Урал-лапоноид) тибындагы баш сөякләре б-н Көньяк Себер расасына хас булганнары да очрый. Тимер гасырының әүвәлге чорына караган *Ананьино культурасы* каберлекләрендә монголоид расага хас баш сөякләре табыла. Идел-Урал төбәгендә төрле расага караган кабиләләрнең актив аралашу-кушылуы аеруча урта гасырларның элгәререк чорына туры килә. Күпчелек тикшеренүчеләр урта гасырларда һәм борынгырак дәверләрдә яшәгән төрки-угыр кабиләләре кыяфәтендә субурал расасы тибындагы йөз төзелеше билгеләрен теркәгәннәр. Шундый ук палеоантропологик (тарихи антропологик) йөз төзелеше Идел буе Болгар дәүләтендә яшәүчеләргә дә хас. Бер үк вакытта монгол расасы билгеләрен хәтерләткән төркемнәр дә очрый. Биләр шәһәрлеге каберлегендә шушы төркемгә нисбәтле табылдык болгар аксөякләренеке булып, аларның Көньяк Себер расасы йөз төзелешенә якын торуын искә төшерә. Алтын Урда чорында Идел-Урал төбәгендә субурал һәм Көньяк Себер расасы тибындагыларның күпләп күчеп килүе сәбәпле кабилә-токымнар кушылуы (метизация) көчәя. Кайбер очракларда төрле раса вәкилләренең төрле социаль катламга нисбәтле булуын абайларга мөмкин: күчмәләрдән торган татар аксөякләренең йөз төзелеше монголоид (Көньяк Себер) раса чалымнарын саклый. Казан Кремле каберлекләрендәге аксөякләр (Казан ханнары дип уйланыла) шундыйлардан. Татар ханлыклары халкының йөз төзелеше дә, башлыча, субурал раса тибы билгеләрен саклый. Абашево, Ананьино археологик культуралары, Болгар шәһәрлеге, Казан кремле каберлекләрендә табылган баш сөякләре М.М.Герасимов, Т.С.Балуева һ.б. галимнәр тарафыннан антропологик яктан тикшерелә һәм борынгы кешеләрнең йөз-кыяфәтләре реконструкцияләнә. Антропологлар фикеренчә, Урта Идел буенда яшәүче татарлар һ.б. халыклар төрле раса төркемнәре кушылудан барлыкка килгәннәр (метислар). Күпчелек билге-күрсәткечләр буенча алар саф европеоид б-н саф монголоид расалары төркемнәре арасында урын ала. Идел-Урал төбәгендә яшәүчеләргә, ш.и. татарларга хас булган раса төркем-типлары түбәндәгеләр: Көньяк Себер, субурал, европеоид, понтий типлары һәм аларның төрле дәрәҗәдәге кат-

нашмалары. Антропологик типларның шушылай катнашып-буталып бетүе бу төбәктә барган катлаулы тарихи вакыйгаларның (расогенез) чагылышы булып тора.

*Әд.:* М а л и е в Н.М. К учению о строении черепа и к сравнительной анатомии рас: Материалы для антропологии восточного края России. К., 1874; Н и к о л ь с к и й М.Н. Цвет волос и глаз у татар Лаишевского уезда Казанской губернии по таблицам Fischera и Martina. К., [Б.е.]; Х о м я к о в М.М. Антропология в Казани за 43 года. К., 1914; ш у л у к. К вопросу об антропологическом типе казанских татар. К., 1914; Д е б е ц Г.Ф. Палеоантропология СССР // Тр. Ин-та этнографии АН СССР. Новая сер. М., 1948. Т. 4; Т р о ф и м о в а Т.А. Этногенез татар Поволжья в свете данных антропологии // Тр. Ин-та этнографии АН СССР. Новая сер. М.–Л., 1949. Т. 12; ш у л у к. Антропологический состав населения г.Болгара в IX–XV вв. // Тр. Ин-та этнографии АН СССР. Новая сер. М.–Л., 1949. Т. 7; С ы с а к Н.С. Материалы к краниологии населения Поволжья, Прикамья и Советской Азии. К., 1950; А л е к с е е в В.П. Очерк происхождения тюркских народов Восточной Европы в свете данных краниологии // Вопр. этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. К., 1971; ш у л у к. Историческая антропология. М., 1979; А к и м о в а М.С. Антропология древнего населения Приуралья. М., 1968; ш у л у к. Антропологические материалы из Танкеевского могильника // Вопр. антропологии. 1973. Вып. 45; Постникова (Рудь) Н.М. К антропологии сельского населения Волжской Булгарии // Вопр. антропологии. 1978. Вып. 58; Ф а т т а х о в Р.М. Антропологическая характеристика материалов из IV Билярского могильника // Новое в археологии Поволжья. К., 1979; ш у л у к. Краниологическая характеристика материалов из могильника Старый Чекмак // Об исторических памятниках по долинам Камы и Белой. К., 1981; Г е р а с и м о в М.М., Р у д ь Н.М., Я б л о н с к и й Л.Т. Антропология античного и средневекового населения Восточной Европы. М., 1987; Е ф и м о в а С.Г. Палеоантропология Поволжья и Приуралья. М., 1991; Мавзолеи Казанского Кремля. К., 1997.

*И.Л.Измайлов, Л.М.Айнетдинова.*

**АНТРОПОНИ́МИКА** (грек. ánthrōpos — кеше, ónyma — исем), *ономастика* фәненең антропонимнарны (*кеше исемнәре*, *атасы иseме*, *фамилия*, кушамат, *псевдоним*), аларның килеп чыгышын, төзелеш-ясалышын, үсеш-үзгәрешен, куллану закончалыкларын һәм географик таралышын өйрәнә торган тармагы. Теоретик А.да ономастиканың башка тармакларында да тасвирлау, тарихи, чагыштырма, стилистик, статистик һ.б. ысуллар кулланыла; гамәли А. тел нормалары (антропонимнарның орфографиясе һәм орфоэпиясе), исемнәрнең тәрҗемәсе һәм транслитерациясе мәсьәләләре, антропонимик сүзлекләр һәм белешмәләр төзү б-н шөгыльләнә. А. мәсьәләләре М.Я.Морошкин, Н.М.Тупиков, С.Б.Веселовский, А.М.Селищев, В.К.Чичагов, В.А.Никонов, Н.А.Баскаков һ.б. хезмәтләрендә чагылыш таба. Татар теле белеме өлкәсендә кеше исемнәрен фәнни яктан өйрәнү 19 йөзнең 2 нче яртысында башлана. Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Әхмәров, В.В.Радлов, Һ.В.Йосыпов һ.б.ның А. проблемаларына кагылышлы хезмәтләре мәгълүм. Татар А., мөстәкыйль фәнни тармак буларак, 1960–70 елларда Г.Ф.Саттаров хезмәтләре б-н аерылып чыкты.

Антропонимның үз формуласы бар. Татарларда борынгы антропонимик өлге кешенең шәхси атамасыннан ясалган: Күкбүре, Көнтуган. Соңрак ул кардәшлекне, титулны, социаль һәм дини терминнарны (ата, углан, баласы, бик, би, тархан, тылмач, солтан, шәех, (да)мелла, мулла һ.б.) белдерүче сүзләр б-н алышына: Чура (әсир кол), Айкилде морза. Гарәп-фарсы алынмалары телгә күпләп үтеп керү нәтиҗәсендә (10 йөз), төрле титуллы гарәп исемнәре формулалары да кулланыла башлый (әбү, бине, бинт; нәселе, туган һәм яшәгән җире, кушаматы, титулы һ.б. атамаларга бәйле рәвештә): Мәхмүт бине Гали бине Шәех бине Гомәр әл-Болгари әс-Сараи. Татар исемнәренең хәзерге рәвеше 19 йөз ахыры — 20 йөз башында формалаша, ул исемнән, атасы исеменнән, фамилиядән тора. Шуның б-н бергә татар телендә борынгыдан килгән ихтирам-хөрмәт б-н эндәшү формасы да яшәп килә: Габдулла улы (малае, баласы) Сабир; Хәбиб Мораты; Шакир абый (ага, бабай, әфәнде); Банат ханым (апа, туташ).

Функцияләре һәм кулланылышлары ягыннан А.ның номинатив категорияләре ике төркемгә бүленә: 1) төп төркем (кешенең үз исеме); 2) өстәмә төркем (атасы исеме, фамилия, кушамат).

А. мәдәният, дин, тарих, этнография, география, генеалогия б-н тыгыз бәйләнгән.

*Әд.:* С а т т а р о в Г.Ф. Татар исемнәре. К., 1981; ш у л у к. Исемең матур, кемнәр куйган? К., 1989; ш у л у к. Татар антропонимикасы. К., 1990; ш у л у к. Татар исемнәре ни сөйли? К., 1998; Ю с у п о в Г.В. Антропонимика в булгаро-татарской эпиграфике // Личные имена в прошлом, настоящем и будущем. М., 1970; С у б а е в а Р.Х. Мотивы выбора интернациональных имён у татар // Ономастика Поволжья. Г., 1971; Г а л и у л л и н а Г.Р. Личные имена татар в XX в. К., 2000.

*Г.Ф.Саттаров.*

**А́НУШКИН** Александр Иванович (3.9.1903, Петербург губ., Новая Ладога өязе Черенцово а. — 20.9.1978, Кырым өлкәсенең Ялта ш.), журналист, библиограф. Мәскәү журналистика ин-тын тәмамлый (1930). 1921 елдан «Ленинградская правда» г-тасында мәкаләләре басыла. Волхов ГЭСын төзүдә катнаша. 1925–27 дә Ленинград өлкәсендә комсомол эшендә. 1930 дан Казакъстанда: «Колхозный труд» (Күкчәтау р-ны) г-тасы мөхәррире, ВКП(б) крайкомында инструктор, «Большевистская печать» (Алма-Ата) ж-лы мөхәррире, «Казахстанская правда» г-тасында бүлек мөдире. 1934 тә Казанда чыга торган «Красная Татария» г-тасына эшкә җибәрелә (җаваплы сәркәтип, баш мөхәррир урынбасары, 1939–45 тә җаваплы мөхәррир). 1945 тән «Советская Литва» (Вильнюс ш.) г-тасының баш мөхәррире, 1954 елдан Ялта шәһәрендәге «Курортная газета»ның баш мөхәррир урынбасары. Уникаль китапханәсен, ш.и. борынгы басмалар тупланмасын Ялта шәһәренә бүләк итә. Хезмәтләре СССРда китап белеме үсешенә карый. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Во славном месте Виленском: Очерки из истории книгопечатания. М., 1962; На заре книгопечатания в Литве. Вильнюс, 1970; Тайны старопечатной книги. Поиски, находки, загадки. Симферополь, 1972; Рассказы о старых книгах. М., 1979.

*К.Н.Куранов.*

**АНФИНОГЕ́НТОВ** Владимир Иванович(24.6.1951, Казан), гамәли математика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2007). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан техника ун-тында эшли, махсус математика каф. проф. (2007 дән). Хезмәтләре физик кырларны һәм дулкынлы процессларны тикшергәндә хисаплау техникасы куллануга һәм матем. модельләштерүгә карый. А. виброакустик кырларның күп нокталы актив компенсацияле (сүндерү) системалары, алгоритмнар б-н идарә итү һәм синтезлауның стат. ысулын, төрле физик табигатьле кырларны торгызу һәм контрольлек итү системаларын, ачык һәм ябык типтагы камераларда электромагнит кырының төрле ысулларда тәэсирләшүенең, диэлектрик материалларны үтә югары ешлыкта (СВЧ) җылытуның матем. моделен һәм җайланмасын эшли. Аның эшләнмәләре суднолар төзү пр-тиеләрендә һәм нефть-газ чыгару сәнәгатендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Об оптимальном распределении потенциалов возбуждения излучателей при синтезе систем компенсации виброакустических полей // Акустический журнал. 1983. Т. 29, № 6 (автордаш); Статистический подход в задачах синтеза многоточечных систем измерения полей // Кибернетика и вычислительная техника. 1988. Вып. 79 (автордаш); Имитация и компенсация эксплуатационной вибрации. М., 1995 (автордаш); Математическое моделирование СВЧ нагрева диэлектриков. К., 2006; Математические модели СВЧ нагрева диэлектриков конечной толщины // Физика волновых процессов и радиотехнические системы. 2006. Т. 9, № 1.

**АНХУ́ЗА** (Anchusa), кыярчалар (сакалбайчалар) семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төре билгеле, күбесенчә Урта диңгез буенда таралган. ТРда бер төре — дару А.сы (A.officinalis) очрый. Кырларда, юл буйларында үсә. 30–90 *см* озынлыктагы күпьеллык үсемлек. Сабагы гади туры яисә тармаклы. Үзәк тамырлы. Яфраклары эре, кырыйлары дулкынлы, ланцетсыман, очлы, сабагы кебек үк каты төкләр б-н капланган. Чәчәкләре зәңгәрсу-кызыл, куе бөтеркәле. Июнь-август айларында чәчәк ата. Җимеше өч кырлы чикләвектән тора. Бер үсемлек 10 меңгә якын җимешчек бирә. А.х. үсемлекләрен чүпләндерә. Сабакларында һәм яфракларында алкалоидлар, фенол кислоталары, буяу матдәләре бар. Декоратив, баллы, агулы үсемлек. Халык медицинасында ялкынсынуга каршы, какырык куптару һәм үт кудыру чарасы буларак кулланыла.

**А́НЧИКОВА** Лидия Ивановна (20.8.1936, Чистай р-ны Изгар а.), эндокринолог, мед. фән. д-ры (1988), проф. (1991). ТРның атказ. табибәсе (1994). 1961 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1978 дән Казан мед. академиясендә, 1989 дан эндокринология курслары, 1996 дан эндокринология каф. мөдире. Кеше һәм хайван күзәнәкләре биоэнергетикасы (Казан мед. ин-ты 1976), гормоннар һәм радиоиммунология (Республика клиник хастаханәсе, 1981; Казан ГИДУВы, 1986) буенча фәнни лабораторияләр, ш.у., Республика клиник һәм Казан тимер юл хастаханәләрендә эндокринология

бүлекләрен ачуда турыдан-туры катнаша. Тикшеренүләре калкансыман бизнең патогенезы һәм этиологиясенә, аны булдырмау һәм дәвалауга карый. Эндокринологиядә яңа юнәлеш — гормональ булмаган, аз дәрәҗәдә токсик фосфорорганик препарат — димефосфон б-н гипофиз-тиреоидит һәм бөер өсте бизләре системасының активлыгын көчәйтү юнәлешен эшли; димефосфон б-н аутоиммун тиреодитны дәвалауның яңа ысулын гамәлгә кертә, калкансыман бизне гидрокортизон май һәм ультратавыш, диметилсульфоксид һәм гидрокортизон б-н бергә тәэсирләндереп, тиреодит авыруын дәвалау ысулларын эшли. 1991–95 елларда ТР ЮС депутаты.

Х е з м.: Экспериментальное обоснование для клинического применения димефосфона как тиреодиноактивирующего средства. К., 1988. Влияние дисбиоценоза кишечника на степень йодной недостаточности у детей с эндемическим зобом // Проблемы эндокринологии. 2001. № 1 (автордаш). Современное состояние медицинской помощи больным сахарным диабетом, находящимся в кетоацидотической коме // Практическая помощь. 2005, № 3 (12).

*Әд.:* М о р о з о в а Т. Личность крупным планом // Татарстан. 1996. № 9; П а в л у х и н Я.Г. История Татарстана в лицах. К., 1997.

**«АҢ»**, Казандагы басмаханә. 1917 елның октябрендә «*Гасыр*» нәшрияты тарафыннан «Аң» ж-лын чыгару өчен сатып алына. Г.Х.Рәхмәтуллин булышлыгы б-н ачыла. Басмаханәнең башлап оештыручылары һәм хуҗалары Ә.Хәсәни, З.Хәсәния, Г.Кәрамнар. Бер тиз басу машинасы, 2 «бостонка» һ.б. җиһазлары була. А.Тәхфәтуллин җитәкчелегендә 8 кеше эшли. 1917–18 дә басмаханә Казан хәрби коменданты, Идел буе Хәрби округы штабы ихтыяҗларын үти, ш.у. Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе штабы, өяз азык-төлек комитеты заказларын бастыра. 1918 нең ноябреннән 1919 ның февраленә кадәр совет хакимияте органнары басмаханәне арендада тота һәм РСДРП(б)ның Казан губернасы ком-ты һәм Казан губернасы ХХС заказларын башкара. Аренда срогы чыккач, хуҗалар басмаханәне хөкүмәткә тапшыралар. 1919 ның июнендә дәүләт милкенә күчә һәм 2 нче дәүләт басмаханәсе б-н кушыла.

*Әд.:* Г а ф у р о в В.З., М и ф т а х о в а З.З. Развитие полиграфии и печати в Татарии. К., 1977; К а р и м у л л и н А.Г. Книги и люди. К., 1985; ш у л  у к. Становление и развитие татарской советской книги (1917–32). К., 1989.

**«АҢ»**, әдәби-фәнни, иҗтимагый-сәяси рәсемле журнал. 1912 елның 15 декабреннән 1918 нең мартына кадәр Казанда айга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 123 саны чыга. «*Гасыр*» матбагасы органы. Төрле елларда мөхәррирләре: Ә.Хәсәни, Г.Ибраһимов. Актив язышучылар: Ф.Агиев, Һ.Атласи, Ф.Әмирхан, Ш.Әхмәдиев, Җ.Вәлиди, М.Гафури, Г.Гафуров-Чыгътай, Г.Гобәйдуллин, Н.Думави, Ш.Камал, З.Нуркин, С.Рахманколый, Г.Рәфикый, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Сөнгати, С.Сүнчәләй, К.Тинчурин, Г.Тукай, Н.Хәлфин һ.б. Либераль-демократик юнәлештәге журнал. Татар халкының социаль, рухи һәм мәдәни проблемаларын яктырткан абруйлы һәм популяр басмаларның берсе. Журнал битләрендә сәнгать мәсьәләләренә кагылышлы бәхәсләр алып барыла, Шәрекъ, рус һәм дөнья классикасы әсәрләре басыла. «А.» полиграфия эшләнеше һәм нәфис зәвыгы б-н аерылып тора. Татар басмалары арасында беренчеләрдән булып Леонардо да Винчи, Рафаэль, Рембрандт, В.В.Верещагин, И.К.Айвазовский, И.Е.Репин һ.б. рәссамнар әсәрләренең репродукцияләрен бастыра башлый. 1915 елда редакция әбүнәчеләргә «Альбом (Сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)» (Г.Ибраһимов әзерләгән) бастырып тарата.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Р ә м и И.Г., Д а у т о в Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001; Г а й н у л л и н М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983.

*Р.У.Әмирханов.*

**«АҢ»**, татар театр труппасы. 1918 елда Казанда актёрлар Ф.Ковалинский, Г.Сабитов, С.Габитов инициативасы б-н оеша. Баштагы чорда труппа составына яшь һәвәскәр актёрлар керә. Репертуарда Г.Камал, Ш.Камал, М.Фәйзи, Ф.Әмирхан пьесалары була. Ф.Шиллерның «Мәкер вә мәхәббәт», М.Фәйзинең «Галиябану» (Галиябану — М.Вәлишина, Хәлил — Ф.Ковалинский) пьесалары буенча куелган спектакльләр хуплап каршы алына. 1920 дә «А.» составына элекке «Сәйяр» труппасы актёрлары Г.Айдарский, С.Байкина, Х.Колмәмәт, Гата Уральский, Камал II керә. Труппаның сәнгать җитәкчесе итеп К.Шамил чакырыла. Коллектив Мамадыш кантонында уңышлы гастрольләр уздыра. Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә» әсәре буенча куелган спектакль яңа состав уйнавында зур уңыш б-н бара. 1921 елда труппа актёрлары Казанда Беренче татар үрнәк драма театры составына кертелә.

**АҢЛАТМАЛЫ́ СҮЗЛЕКЛӘ́Р**, тегe яки бу телдәге сүзләрнең мәгънәләре турында мәгълүмат бирә торган белешмәлек китаплар. Бу төп сүзлекләрдә сүзләрнең сөйләмдә кулланылышы аңлатыла, аларның грамматик һәм стилистик үзенчәлекләре ачыклана. Татар телендәге беренче аңлатмалы сүзлек 10467 сүздән торган «Ләһҗәи татари» (1–2 т., 1895–96) К.Насыйри тарафыннан төзелә. Әлеге сүзлек төрки телләр тарихында да беренче аңлатмалы сүзлек була. Җ.Вәлиди тарафыннан төзелгән «Татар теленең тулы сүзлеге» (1927–29, тәмамланмаган) ул вакыттагы татар алфавитының беренче 15 хәрефен колачлый, 11719 сүз тупланган. 1950 елларда СССР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты тарафыннан (1996 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) 3 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» төзелә (1977–81). Бу эш Л.Т.*Мәхмутова*, М.Г.*Мөхәммәдиев*, К.С.Сабиров, Ш.С.*Ханбикова* (редколлегия), И.Г.*Абдуллин*, Р.Г.*Әхмәтьянов*, Г.Х.*Ахунҗанов*, С.Б.Вахитова, Ф.М.Газизова, Л.Р.Гайнанова, Ф.Ә.*Ганиев*, Р.К.Рәхимова һ.б. галимнәрдән торган фәнни коллектив тарафыннан башкарыла. Сүзлек хәзерге татар теленең 19 йөз ахырыннан 20 йөзнең 70 елларына кадәрге чорда фольклор, матур, фәнни, фәнни-популяр, публицистик әдәбиятта, дәреслекләрдә, матбугатта кулланылган лексик һәм фразеологик байлыгын (фондын) туплый. Бу зур хезмәттә 32880 сүзгә һәм 14010 фразеологик берәмлеккә аңлатма бирелә.

*Әд.:* С а ф и у л л и н а Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999.

*Д.Б.Рамазанова.*

**АПА́ ТАРХА́Н**, 6 — 8 йөзләрдә төрки каганлыкларда хәрби хезмәттәге аксөякләр дәрәҗәсе (титулы). А.т. мәгънәсе «өлкән тархан» дигәнне аңлата дип уйланыла. Сугышчан (хәрби) уңышлары өчен каган тарафыннан тапшырыла. Мәс., Котлыг каганның киңәшчесе һәм гаскәр башлыгы Төньюкукка шундый дәрәҗә бирелә.

*Әд.:* Г у м и л ё в Л.Н. Древние тюрки. М., 1967; Древнетюркский словарь. Л., 1969.

**АПА́З** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 38 *км* төньяктарак, Шушма елгасы буенда. 2002 елда 583 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Рождественский исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, тимерчелек, он тарту, буяу, балта һәм агач эшләре б-н шөгыльләнә. 1720 дә авылда Рождество чиркәве төзелә. 1867 дә Халык мәгарифе министрлыгының 2 сыйныфлы уч-щесе һәм Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 1889 да кыз балалар өчен башлангыч белем бирү мәктәбе ачыла. 20 йөз башында монда су тегермәне, тимерчелек, буяу йорты, 4 ашханә, шәраб, сыра һәм 9 вак-төякләр кибете эшли; шимбә саен базар җыела. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1892 дис. тәшкил итә. 19 йөз ахырыннан көчләп чукындырылган А. халкы православиедән исламга кире кайта башлый. Озаклламый, 1917 дән соң, монда архит-ра истәлеге — мәчет төзелә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 190 ир заты; 1859 да — 831, 1897 дә — 1125, 1908 дә — 1363, 1920 дә — 1220, 1926 да — 1152, 1938 дә — 898, 1949 да — 757, 1958 дә — 803, 1970 тә — 871, 1979 да — 711, 1989 да — 647 кеше.

*Әд.:* Известия по Казанской епархии. К., 1880; И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**АПА́ЙКИНА ГАРЬ** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. 2002 елда 129 кеше (руслар — 50%, татарлар — 43%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 1819 да Чыпчык (авылның башка — Яңа Чыпчык исеме шуның б-н бәйле) авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, баз казу б-н шөгыльлә-



Габделшәкүр Апаков.

нә. 20 йөз башында А.Г.дә Изге Николай чиркәве (1900 дә төзелә), земство мәктәбе була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 410,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 232, 1885 тә — 279, 1897 дә — 289, 1908 дә — 323, 1920 дә — 296, 1926 да — 321, 1938 дә — 279, 1949 да — 213, 1958 дә — 204, 1970 тә — 113, 1979 да — 80, 1989 да — 72 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1916.

**АПА́К** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 46 *км* көньяктарак, Ульянов өлкәсе чигендә. 2002 елда 375 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1710 нан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.та Покрау чиркәве (1899 да төзелә), мәчет, чиркәү-приход мәктәбе (1892 дә ачыла), мәктәп, 7 җил тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1865 дис. тәшкил итә. 1930 елларда авыл икегә — Татар Апагы һәм Рус Апагына бүленә. 1965 нең 16 апрелендә авыллар яңадан берләштерелә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында; 1930 ның 10 августыннан Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 12 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 184 ир заты; 1859 да — 1190, 1897 дә — 1831, 1908 дә — 2180, 1920 дә — 2391, 1926 да — 1310, 1949 да — 917, 1958 дә — 742, 1970 тә — 848, 1979 да — 528, 1989 да — 452 кеше.

**АПАКА́Й** (Апакай-Диюш) Шәмсия Хәсән кызы (30.1.1914, Петропавловск-Камчатский ш. – 30.9.2007, Сан-Франциско ш., АКШ), чит илдә яшәүче татарларны берләштерү тарафдары, татар фольклорын популярлаштыручы. 1924 елдан Харбин шәһәрендә (Кытай), 1950 дән Япониядә, Төркиядә, 1961 дән АКШта яши. Япония, Төркия, Финляндия, Австралия, гарәп илләрендә һәм Татарстанда яшәүче татарлар арасында үз башкаруында татар халык җырларын популярлаштыра. Әлеге илләрдә аның тарафыннан язып алынган җыр текстлары күптомлы «Татар халык иҗаты» фольклор басмасына кергән. А. Сан-Франциско шәһәрендә татар балаларына ислам нигезләре, татар теле, әдәбияты һәм фольклоры дәресләре укыта.

*Әд.:* Әхмәтова Ф. Асыл затларыбыз // Татарстан. 1996. № 4.

**АПА́КОВ** Рәшид Усман улы (9.8.1946, Казан), инженер-конструктор-технолог, Казандагы «Радиоприбор» АҖ ген. директоры (1994 елдан). ТРның атказ. машина төзүчесе (1996), СССР һәм РФнең мактаулы радисты (1983, 1996), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1974). 1968–80 елларда һәм 1994 тән «Радиоприбор» з-дында: өлкән техник, инженер, махсус конструкторлык технол. бюросы башлыгы. 1980–94 тә «Волна» җитештерү берләшмәсендә (Беларусь Респ-касы, Гродно ш.) баш инженер (1987 дән), ген. директор (1992 дән). Аның җитәкчелегендә продукциянең яңа төрләре үзләштерелә. 2004 тән ТР ЮС депутаты. «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**АПА́КОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре: 1) **Муса Апаков** (? — 1824 тән соң), сәүдәгәр А. династиясен нигезләүче. Мануфактура б-н сәүдә итә, *Гостиный двор*ның сәүдә рәтләрендә кибет тота (1818 дә 1500 сумга бәяләнгән). Вафатыннан соң сәүдәсен хатыны Мәргүбә Рәфыйк кызы, уллары Исхак, Насыйр, Мостафа, Хөсәен һәм Хәсән дәвам иттерәләр. 1825–27 дә Мәргүбә Апакова 3 нче гильдия сәүдәгәр буларак теркәлгән; күн б-н сәүдә иткән, Печән базарында Кунак өе (кунакханә) тоткан; 2) **Исхак Муса** улы (? – 1854 тирәсендә), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле гражданин. Әтисеннән мираска кибет кала, 1830 еллар башында киҗе-мамык туку ф-касын ача. Казнага таләп ителгәннән 200 мең аршин тукыма артык сатканы өчен 2 алтын медаль б-н бүләкләнә. Үз заманында Казанның иң бай сәүдәгәрләреннән саналган — 500 мең сум тирәсе капиталы булган. Казан шәһәр думасы һәм Татар бистәләре ратушасы гласные. Вафатыннан соң эшен уллары Габдерәшит, Мостафа, Ибраһим һәм Исмәгыйль дәвам иттерәләр; 3) бертуганнар: **Габдерәшит Исхак улы** (? – ?), 3 нче гильдия сәүдәгәр. Уллары: Исмәгыйль, Якуп (2 нче гильдия сәүдәгәр), Ибраһим, Мортаза, Йосыф һәм оныклары Габдерахман Мортаза улы, **Габделшәкүр Мортаза улы** (1860–1923), Әхмәтҗан Ибраһим улы, Мортаза Ибраһим улы — барысы да сәүдәгәрләр гильдиясенә кергәннәр, башлыча, мануфактура б-н сәүдә иткәннәр. **Мостафа Исхак улы** (? – ?), 3 нче гильдия сәүдәгәр, **Ибраһим Исхак улы** (1821–85), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле гражданин. Табыш йортлары (өйләр, кунакханәләр) хуҗасы. Кызы Бибимәрьямбану (1866 – ?) Кавказ халыклары милли азатлыгы өчен көрәшкән шәех Шамилнең улы генерал Ш.Шамилгә кияүгә чыга; **Исмәгыйль Исхак улы** (1823 – 1884 тән соң), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле гражданин. Тукымалар һәм ашлык б-н сәүдә иткән, табыш йортлары төзеткән. Мөселман балалар ятимханәсенең алмашсыз эшләүче шәрәфле старшинасы.

*Әд.:* Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**АПАНА́ЕВ** Вәли Закир улы (Мөхәммәтвәли Мөхәммәтзакир) (30.8.1889, Казан — 1922, Казан), скрипкачы, драматург, җәмәгать эшлеклесе. Сәүдәгәр *Апанаевлар* нәселеннән. Казан музыка уч-щесендә (И.И.Руссо классы) белем ала. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый һәм Казан ун-тында ике курс укый, студентлар хәрәкәтендә катнашканы өчен аннан куыла. Демократик карашлы татар зыялылары вәкиле. Беренче татар концертларында катнаша. Аның репертуарында скрипка өчен дөнья халыклары һәм татар халык көйләре була. Солист буларак та чыгышлар ясый, инструменталь ансамбльләрдә скрипка, мандолина, гармуннарда уйный. 1907 елда *Шәрекъ клубында* инструменталь ансамбль оештыра. А. шушы клубта һәм өй шартларында уйнау өчен пьесалар яза, шулар арасыннан иң әһәмиятлесе — Казан ханлыгы чорына караган «Сөембикә» пьесасы; әдәби тәрҗемә б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* Монасыпов Ш. Развитие татарского профессионального скрипичного искусства устной традиции на рубеже XIX–XX веков // Страницы истории татарской музыкальной культуры. К., 1991.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**АПАНА́ЕВ** Габдулла Габделкәрим улы (15.3.1862, Вятка губ., Малмыж өязе Наратлы а. — 25.6.1919, Казан), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, нашир. Сәүдәгәр *Апанаевлар* нәселеннән. «Мәрҗания» мәдрәсәсен тәмамлый (1880). 1880–90 елларда Төркия һәм Мисырда яши. 1890 елдан Казанда Печән базары мәчете имам-хатибы, 1892 дә мәчет каршында җәдиди мәдрәсә ача. Бер үк вакытта, 1902–07 елларда *Казан шәһәр мөселманнары хәйрия җәмгыяте* идарәсе рәисе; 1904 тә 80 балага исәпләнгән ятимханә ачуга булышлык итә. Татар милли азатлык хәрәкәтендә әйдәп йөрүчеләрдән. «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясен оештыруда башлап йөри, аның программасын төзүдә катнаша; партиянең ҮК һәм Казан бюросы әгъзасы. «*Азат*» г-тасының нашире һәм мөхәррире (1906). 1908 дә дини һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен кулга алына һәм Вологда өлкәсенә сөргенгә җибәрелә. 1910 елдан Казан шәһәре думасы гласные. Большевикларның Учредительләр җыенын куып таратуын, татар милли хәрәкәте җитәкчеләрен кулга алуын һәм «*Болак арты республикасы*» вакыйгалары барышындагы эш-гамәлләрен тәнкыйтьли. Өендә яңа хакимият б-н килешмәүчеләрнең җыелышларын җыя. Казанда Татар запас батальоны Советларга каршы баш күтәргән көннәрдә кулга алына, атып үтерелә.

*Әд.:* Салихов Р.Р. Имамы Сафиулла Абдуллин и Габдулла Апанаев — ученики Ш.Марджани // Ш.Марджани: наследие и современность: Материалы междунар. науч. конф. К., 1998.

**АПАНА́ЕВ ЙОРТЫ́** (Юнысов йорты), Казанда, архит-ра истәлеге, бай татар сәүдәгәре йорты. Иске татар бистәсендәге Юнысов мәйданының көнчыгыш тарафында урнашкан. 19 йөз башында классицизм стилендә Г хәрефе рәвешендәге бер катлы кирпеч йорт М.И.Юнысов өчен төзелә. 1861 дә аның оныгы И.Г.Юнысов арх. П.И.Романов проекты б-н 2 нче катын өстәп салдыра. Йортны 1880 еллар ахырында сәүдәгәр М.Г.Апанаев сатып ала. 1906–14 тә модерн стилендә үзгәртеп корыла (архитекторы билгесез). Төрле озынлыктагы ян канатлары булган ике катлы почмак бина. Үзәк ишеге сул канаттагы яссы эркерда, башка ишекләре ишегалдына карый. Аскы катында кухня, хуҗалык бүлмәләре,



Апанаев (Юнысов) йорты. Казан.
Хәзерге күренеше.

өске катында тантана заллары, торак бүлмәләр була. Бинаның почмагында фасадларына карата 45 градуска борылган, өстенә биек чатыр куелган зур эркер чыгып тора. Ян-яклардагы ризалитлар авыш линияле аттиклар б-н тәгәлләнә. Бина фасадлары агачтан уеп ясалган ишекләр һәм чүкеп эшләнгән металл челтәр б-н бизәлгән. 1960 еллардан биредә мед. учреждениесе эшли. 1990 еллар ахырыннан файдаланылмый.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995.

**АПАНА́ЕВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, эре җирбиләүчеләр, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре. 18 йөздә сәүдәгәрләр катламында теркәлгәннәр. **Апанай Хафиз** (17 йөз), сәүдәгәр А. династиясен нигезләүче санала. Тумышы б-н Казан губернасы, Лаеш өязе Ямбулат авылыннан. Вак-төяк б-н сәүдә иткән. **Исмәгыйль Даут улы** (1715 – 1794), табышлы торак йорт-җир хуҗасы, тире эшкәртү кәсебе б-н шөгыльләнә. 3 улыннан 2 се татар дөньясында танылган династиянең 2 тармагы башында торучылар:

1) **Муса Исмәгыйль улы** (1766 – 1827), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан. Күн з-ды (1818 елда 5 мең сумга бәяләнгән), 2 табышлы торак йорт һәм кибет хуҗасы. Кытай сәүдәгәрләре б-н эш йөртә. Күренекле иганәче һәм җәмәгать эшлеклесе, берничә мәртәбә Вөҗдан мәхкәмәсе судьясы һәм Җинаять палатасы утырышчысы, Казан шәһәре магистраты әгъзасы булып сайлана. Аның эшен уллары дәвам иттерә: **Мортаза Муса улы** (? – ?), күн з-ды һәм Спас өязендә Епанчино авылы (җирләренең барлык мәйданы 2148 дис.) хуҗасы була; **Хәсән Муса улы** (1801 – 1863), 1 нче гильдия сәүдәгәр. Иганәчелек эшчәнлеге өчен 2 мәртәбә алтын медаль б-н бүләкләнә (ваба б-н авыручылар өчен Казанда ачылган хастаханә төзелешенә зур суммада акча бирә); **Мөхәммәт Муса улы** (1804 – 1877), 2 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан. Кече ир туганнары б-н уртак күн з-ды хуҗасы. 1839–41 елларда шәһәрнең Татар бистәләре ратушасы башлыгы. Аның улы **Мөхәммәтйосыф Мөхәммәт улы** (1833 – 1903), 1 нче гильдия сәүдәгәр, Казанның татарлар яшәгән өлешендә иң зурлардан саналган «Апанай йорты» кунакханәсе хуҗасы. Йон һәм күн б-н сәүдә итә. Казан шәһәр думасына сайлана, 2 нче Җамигъ мәчетнең җәмәгать идарәчесе була. Аның улы **Габдулла Мөхәммәтйосыф улы** (1873 – 28.9.1937), 1 нче гильдия сәүдәгәр, ат з-ды, 3 табышлы торак йорт, 300 дис. җир һәм утар хуҗасы. Апанаев б-н Казаковларның уртак сәүдә-сәнәгать ширкәтен оештыручылардан («Торгово-промышленное товарищество Апанаевых и Казаковых»). Иганәчелек эшчәнлеге өчен Казан губернасы балалар ятимханәләре җәмәгать идарәчеләренең шәрәфле әгъзасы итеп сайлана. 1937 елда кулга алына, атарга хөкем ителә; **Габделкәрим Муса улы** (1813–1874), 2 нче гильдия сәүдәгәр, бертуганнары б-н уртак күн з-ды хуҗасы. Казан өязе Курса авылында таш мәчет төзетүгә өлеш кертә. Уллары: Мөхәммәтвәли (1835–85), Мөхәммәтзакир (1846–1912), Габдерахман (1852–1910) — өчесе дә 2 нче гильдия сәүдәгәрләр. Ташкент, Бохара, Хива шәһәрләрендә сату-алу б-н шөгыльләнәләр. Мөхәммәтзакир улы Мөхәммәтвәли скрипкачы була (к. В.З.*Апанаев*); **Гобәйдулла Муса улы** (? – 1870), 2 нче гильдия сәүдәгәр. Бертуганнары б-н уртак күн з-ды хуҗасы. Казан өязе Курса авылында таш мәчет төзетүгә өлеш кертә.

2) **Йосыф Исмәгыйль улы** (1770 – 1825 тән соң), 2 нче гильдия сәүдәгәр, Казанда сабын һәм 3 күн з-ды хуҗасы була. Сабын з-ды 1818 елда 3 мең пот сабын җитештерә. 1806–09 елларда басмаханә тота. 1794–1800 дә Казан шәһәр думасы гласные, гражданлык һәм җинаять эшләре мәхкәмәләре утырышчысы. 3 улыннан — Хөсәен, Салих (1806 – 1887) һәм Исхактан (1815 – 1908) иң кечесе мәгълүм зат. **Исхак Йосыф улы** 1 нче гильдия сәүдәгәр, Казанда сабын з-ды тота. Аның улы **Габделкәрим Исхак улы** (5.4.1840 – 1893), 2 нче гильдия сәүдәгәр. Йон, күн, сабын һәм киҗе-мамык тукыма б-н сәүдә итә. Казанның Болак арты өлешендә берничә табыш йорты тота. Уллары Габдулла (к. Г.Г.*Апанаев*) һәм **Мөхәммәтбәдретдин Габделкәрим улы** (3.10.1867 – 1937 дән соң), 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән күчмә шәрәфле граждан. Сабын з-ды, Казанда 1 нче разрядлы кибет, Мәскәүдә комиссиягә тапшырылган товарлар сату конторасы хуҗасы



Мөхәммәтбәдретдин
Апанаев.

була. 1898–1917 елларда Казан шәһәр думасы гласные, Казан шәһәр мөселманнары хәйрия җәмгыяте рәисе (1910–17), Александр исем. һөнәр һәм Казан коммерция уч-щеләре җәмәгать идарәчеләре әгъзасы. Татар милли азатлык хәрәкәтендә катнаша, «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясенә финанс ярдәме күрсәтә. Татарлар өчен югары белем бирүче уку йорты ачу кирәклеген яклый. 1905 елның октябрендә полицияне коралсызландыруда катнаша. Казанның Иске һәм Яңа Татар бистәләре приставы вазифасын үтәргә халык тарафыннан сайлана. Совет хакимияте урнаштырылу б-н килешми, 1923 елда Төркиягә китә. **Әхмәт Мөхәммәтбәдретдин улы** (1892 – 1942), Окт. рев-циясенә кадәр әтисе белән бергә, Совет хакимияте урнашкач, Казанда ипи кибетендә эшли. 1930 еллар ахырында ун елга ирегеннән мәхрүм ителә, Печора елгасы тамагындагы «Устьпечлаг» лагеренда гомере өзелә.

*Әд.:* Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**АПАНА́ЕВЛАР ЙОРТЫ́**, Казанда, сәүдәгәрләр йорты, архит-ра истәлеге. Иске Татар бистәсендә Түбән Кабан күле буенда урнашкан. Казандагы атаклы сәүдәгәр Апанаевлар милке. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында «үрнәк» проект б-н әүвәлге классицизм стилендә, барокко элементлары кертелеп, сәүдәгәр М.И.Апанаев өчен төзелә. 1872 дә аның улы Г.М.Апанаев бинаны В.П.Александров проекты б-н үзгәртеп кора. Дүрт кыеклы биек түбәле ике катлы кирпеч йортның 1 нче катында хуҗалык максатында һәм кибет итеп фай-



Апанаевлар йорты. Казан.
18 йөз ахыры – 19 йөз башы.
Арх. В.П.Александров реконструкциясе. 1872.

даланылган кечкенә тәбәнәк бүлмәләр, ә 2 нче катта торак бүлмәләре урнашкан. Төп фасадны өчпочмаклы фронтон б-н тәмамланучы үзәк ризалит бизәгән. Аның үзәгендә чүкеп ясалган рәшәткәле балкон чыгып торган. Тәрәзәләр арасындагы аралыклар ике катлы пилястралар б-н бүленгән. 1960–70 еллардагы үзгәртеп кору вакытында бинага өченче кат өстәлә, фронтон, бизәкләнгән карниз, балкон юкка чыгарыла, 2 нче катның а́ркалы тәрәзәләре турыпочмаклы рәвешкә керә. Торак йорт итеп файдаланыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Х а л и т о в Н.Х. Памятники архитектуры Казани 18 – начала 19 вв. М., 1989; С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX веков). К., 1995.

*Н.Х.Халитов.*



Апас посёлогы. Гомуми күренеш.

**АПАНА́Й МӘЧЕТЕ́**, Казанда татар дини архит-ра истәлеге. Иске Татар бистәсендә Түбән Кабан күле буенда урнашкан. 1768–71 елларда сәүдәгәр Я.Солтангалиев иганәсенә төзелә. Архитекторы билгесез. А.м. мәхәлләсендә яшәүче сәүдәгәр Апанаевлар аңа матди



Апанай мәчете. Казан. 1768-71.
Литография. Э.Турнерелли. 1839.

булышлык күрсәтеп торалар, соңрак мәчет алар исеме б-н атала. Түбәсенә манара утыртылган ике катлы, ике заллы мәчетләр төренә керә. Башта ул бер заллы, зал б-н вестибюль арасындагы аркылы диварга таянучы сигез кырлы манаралы була. Фасадлары сыңар һәм парлы пилястралар, сталактит рәвешле карнизләр, тәрәзә башлары ярымтүгәрәк рәвешле сандриклар б-н бизәлгән. 1872 дә җәмәгать акчасына П.И.Романов проекты б-н бинаның төньягына янкорма салына. Зал, вестибюль һәм баскыч урнашкан 2 катлы янкорма төп бина б-н бер үк стильдә төзелә. Мәчетнең бизәлешендә «Мәскәү бароккосы» формаларының татар бизәлеш сәнгате элементлары б-н кушылуы күзәтелә. А.м. 1930 еллар башында ябыла. Аны балалар бакчасы итеп үзгәртеп корганда манарасы һәм залларының түшәме җимерелә, бинаның эче өч катка бүленә, икенче кат тәрәзәләре урынына яңа тәрәзә рәтләре уела. Бизәлешенең күп өлеше юкка чыга. 1995 тә бина «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе карамагына тапшырыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Х а л и т о в Н. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX веков). К., 1995; Ш у л у к. Исторические мечети Казани. К., 2005.

*Н.Х.Халитов.*

**АПА́С**, шәһәр тибындагы посёлок (2004 елга кадәр авыл), Апас р-ны үзәге. Татарстанның көнбатыш төбәгендә (Казаннан 109 *км*), Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда, Ульянов–Зөя тимер юлындагы Каратун станциясеннән 11 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2006 елда 4,9 мең кеше (татарлар) яши. Икмәк, сөт комб-тлары, кирпеч з-ды, а.х. техникасы пр-тиесе, типография. Урта мәктәп, һөнәри уч-ще, балалар музыка мәктәбе, төбәк тарихын өйрәнү музее, мәдәният йорты, 2 китапханә. Мәчет. 1647 елдан Еналеево исемендә мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.та мәчет була. 20 йөз башында монда 2 мәчет, 2 ярма ярдыру, су һәм 3 җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, май язу йорты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3422,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинский-Шоңгаты волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Апас р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Тәтеш р-нында, 1964 нең 4 мартыннан — яңадан район үзәге. Халык саны: 1782 дә — 177 ир заты; 1859 да — 958, 1897 дә — 1812, 1908 дә — 2085, 1920 дә — 2316, 1926 да — 1916, 1938 дә — 1902, 1949 да — 1685, 1958 дә — 1759, 1970 тә — 2345, 1979 да — 3261, 1989 да — 3814 кеше.

**АПА́С РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк-көнбатышында урнашкан, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш. Идел алды икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1047,5 $км^2$. 22 авыл, 1 шәһәр җирлеген, 73 торак пунктны берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Апас посёлогы. Халкы 2006 елда 22,5 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 90,7%, руслар — 4,8%, чуашлар — 3,9%). Шәһәр халкы — 4,9, авылларда 17,6 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 $км^2$ га 22 кеше. Район 1930










Апас посёлогы. 1. Район хакимияте бинасы; 2. Үзәк җамигъ мәчет; 3. Сугышчы-апаслылар истәлегенә мемориаль комплекс; 4. Крәстиян К.Латыйпов йорты. 20 йөз башы.




ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Тәтеш өязе, 1920–27 дә — ТАССРның Тәтеш, 1927–30 да Буа кантонына керә. Оешкан вакытында А.р.на 50 авыл советы, 49414 кеше (татарлар — 39641, руслар — 8664, башка халыклар — 1109) яшәгән 70 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 946 *км*², халкы — 41,8 мең кеше, 36 авыл советы, 67 торак пункт була. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә А.р. таркатыла, биләмәсе Буа һәм Тәтеш р-ннарына бирелә. 1964 нең 4 мартында Буа, Яшел Үзән, Тәтеш р-ннарының бер өлеше А.р.на кертелә һәм район яңадан торгызыла. 1966 елгы мәгълүматлар буенча, мәйданы — 2036 *км*², халкы — 62,3 мең кеше, 30 авыл советы, 141 торак пункт исәпләнә. 1991 нең 19 апрелендә А.р.ннан Кайбыч р-ны бүленеп чыга. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль р-н дип үзгәртелә. Районның рельефы — калкулыклы тигезлек (биеклеге 140–220 *м*), елга үзәннәре б-н бүгәләнгән. Зөя елгасы һәм кушылдыклары Бола, Үләмә, Коры Үләмә елгалары ага. Җирләре көлсуланган, селтесезләнгән кара, карасу соры һәм соры урман туфраклы. Терр-ясенең 8% урман б-н капланган. Известьташ, доломит, балчык, балчыксыл туфраклар, ком, торф ятмалары бар. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Зөя һәм Үләмә елгалары, *Гран-тау* ландшафтлы табигать истәлеге. Терр-ясендә 120 дән артык археологик истәлек табыла (таш дәвереннән алып болгар һәм Алтын Урда чорына кадәр). А.р. — нигездә, а.х. р-ны. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык асрау, кошчылык тармаклары нык үскән. 2005 елда а.х. җирләре 88 мең *га* били, ш.и. 72,5 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак, карабодай игелә; шикәр чөгендере үстерелә. Районда 4 фермер хуҗалыгы, 6 а.х. пр-тиесе, 2 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, 1 крәстиян хуҗалыклары ассоциациясе исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре Апаста урнашкан. Районда урман хуҗалыгы, Зөя елгасында балык питомнигы эшли. А.р. җиреннән Ульянов–Зөя тимер юлы, Казан–Ульянов автомобиль юлы уза. Районда 53 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 2911 укучы укый), ш.и. 30 башлангыч, 3 тулы булмаган урта, 20 урта; һөнәр лицее, сәнгать, балалар-үсмерләр спорт мәктәпләре, 41 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе һәм 61 клуб, 31 китапханә, 3 хастаханә, шифаханә, бала тудыру йорты, 57 фельдшер-акушерлык пункты, төбәк тарихын өйрәнү музее (Апас штп), композитор Сара Садыйкова (Тутай а.), җырчы Фәхри Насретдинов (Шәмбалыкчы а.) музейлары эшли. Татарча «Йолдыз», русча «Звезда» г-талары нәшер ителә.

**АПА́С ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ**, Апас посёлогында. 1991 елның 14 октябрендә ачыла, 1996 дан ТР Дәүләт музее ф-лы (2001 дән ТР Милли музее), 2007 дән — муниципаль музей. Бер катлы бинаны били. Экспозиция мәйданы — 120 *м*², төп фондта 902 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция өч бүлектән тора. Этнография бүлеге көнкүреш кирәк-яраклары, Казан татарларының тормыш рәвеше һәм кәсепчелеге б-н таныштыра. Музейда чигүле һәм тукылган сөлгеләр, алмагачыннан эшләнгән карават (20 йөз башы), удмурт челтәрләре (20 йөз башы) һәм башкорт сөлгесе (18 йөз ахыры) коллекцияләре урын алган. Җ.Вәлидинең шәхси буфеты күргәзмәгә куелган. Төбәктә булган гражданнар сугышына багышланган бүлектә сугыш кораллары фрагментлары, документлар һәм гражданнар сугышында катнашучыларның фотографияләре, чех-словак корпусы частьләре б-н бәрелешләр, алпавыт утарларының тар-мар ителүе турында материаллар бар. Экспозициянең Бөек Ватан сугышы турындагы бүлеге Апас р-нында туган Сов. Союзы Геройлары Д.И.*Горбунов*, С.Х.*Кәримов*, Р.А.*Абзалов*, Дан орденының тулы кавалеры — И.Н.*Насыйбуллин*, Нюрнберг процессында катнашкан контр-адмирал И.М.Золин б-н таныштыра. 1942 дә оборона корылмаларын кабул итү-тапшыру акты аерым игътибарга лаек (к. *Казан каймасы*).

Археологиягә, районның хәзерге тарихына, ш.у. танылган шәхесләр биографиясенә багышланган бүлекләр каралган, концепциясе эшләнгән яңа экспозиция төзелеше бара. Соц. Хезмәт Геройлары — М.С.*Калимуллина*, Ә.М.*Маликова* (Шәфигуллина), С.С.*Гобәйдуллин*, Г.С.*Галиев*, В.Г.*Садовниковлар* турында материаллар тупланган. Аеруча мөһим коллекцияләргә Казан татарларының 19 йөз ахыры — 20 йөз башында чигелгән һәм тукылган әйберләре (100 дән артык саклау берәмлеге), 1958 елда Турай авылында табылган хәзинәдән алынган савыт-саба (фарфор, пыяла, бакыр савытлар, 10 саклау берәмлеге), төрле илләрнең яңгынга каршы хезмәтенә нисбәтле, 1920–2000 елларда чыгарылган значоклар (429 саклау берәмлеге) керә. Музей ел саен мөселманча Яңа ел — Нәүрүз (21 март), «Каз өмәсе» (10 дек.), музей ачылган көнен (14 окт.) үткәрә.







1. Апас төбәк тарихы музее; 2–3. Экспозиция фрагментлары: чигүле һәм тукылган бизәкле сөлгеләр; Бөек Ватан сугышы турындагы бүлек — көнкүреш әйберләре һәм эш кораллары.

**АПА́Ч** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шәбез елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 203 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 1731 дә Кара бәк нәселеннән чыккан мулла Апас Түтиев тарафыннан нигез салына, шунлыктан авыл Апас дигән исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә. 1760 елгы мәгълүматларга караганда, халкының бер өлешен марилар тәшкил итә. Игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнәләр. Мәчет беренче тапкыр 1808 дә искә алына, 1837 дән аның каршында ир балалар өчен мәктәп эшли. 1892 дә җирле халык авылда яңа мәчет төзүгә рөхсәт ала. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, А.та 3 су тегермәне, 1906 да икмәк саклау келәте һәм бакалея кибете була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1151 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 88, 1816 да — 107, 1859 да — 337, 1870 тә — 319, 1884 тә — 481, 1896 да — 462, 1906 да — 525, 1913 тә — 579, 1926 да — 403, 1938 дә — 375, 1949 да — 164, 1958 дә — 291, 1970 тә — 362, 1979 да — 324, 1989 да — 242 кеше.

**АПА́Ч** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 34 *км* көньяк-көнчыгыштарак Кече Ирнә елгасы буенда. 2002 елда 76 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Сармаш, Анасеево исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, мичкә, тәгәрмәчләр ясау, чабата үрү б-н шөгыльләнә; тирә-як алпавыт утарларында көнлекче булып эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 434,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостена керә. 1920 дән ТАССР ның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 107, 1870 тә — 144, 1912 дә — 383, 1926 да — 374.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**АПЛЕЧЕ́ЕВ** Александр Андреевич (1768 — 10.8.1802, Казан), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1801). Дворяннар нәселеннән. 1787 елдан С.-Петербургта хәрби оешмаларда эшли. 1800–01 елларда С.-Петербургның өлкән (обер) полицмейстеры. 1801 елдан Казанда губернатор. А. губерна күләмендә ялган акча ясаучылар һ.б. җинаятьчеләр б-н актив көрәшә, С.-Петербургны азык-төлек б-н тәэмин итү эшен башкара. Аның заманында Казандагы 1 нче гимназия карамагындагы Азия басмаханәсендә татар китапларын басу җайга салына; Спас һәм Тәтеш өязләре кабат мөстәкыйль адм.-терр. берәмлеккә әвереләләр.

*Әд.:* П е т р о в П.Н. История родов русского дворянства. М., 1991. Т. 2.

**АПОЛЛО́Н** (Parnassius apollo L.), күбәләк, җилкәнканатлылар семьялыгыннан. К.Линней тарафыннан Аполлон алла исеме б-н аталган. Канат җәеме 70–90 *мм*, ак төстә, алгыларында зур кара таплар, арткы канатларында кара каймалы эре кызыл таплар бар. Европада, Кавказ, Урал, Көнбатыш Себердә киң таралган. ТРда Яшел Үзән, Спас, Лаеш р-ннарында очрый. Коры наратлыкларда, урман буйларында, ташлы сөзәклекләрдә яши. Июнь–августта оча. А. утрак яшәү рәвеше алып бара. Күбәләк кортлары кара төстә, зәңгәрсу чыгынтылы һәм ян-ягыннан кызгылт сары таплы, озынлыгы 50 *мм* га кадәр җитә. Кәрләч һәм яшь яфраклар б-н туклананалар, көндез кояш яктысында аеруча активлар. Формалашып җиткән күбәләк кортлары күкәй кабыгында кышлый. Курчаклары зәңгәрсу төстә туфракта кузыда үсеш ала. Июнь башында курчактан җитлеккән бөҗәк чыга. Елга бер буын үсә. Август аенда күбәләк үзенең яшәү циклын төгәлли. А.лар саны өзлексез кими бара. ТРның Кызыл китабына кертелгән. Библ. һәм илл. — к. *Күбәләкләр* мәкаләсендә.

**АПОЛЛО́НОВ** Борис Алексеевич (12.10.1924, Лаеш кантоны Надеждино а. — 24.6.1981, Краснодар крае Лоу пос.), җырчы (баритон), ТАССР һәм РСФСРның атказ. артисты (1956, 1957). Казан авиация ин-тын (1950), Казан консерваториясен (1952) тәмамлый. 1950–76 елларда Татар опера һәм балет театры солисты. Беренче тапкыр Онегин партиясе б-н чыгыш ясый («Евгений Онегин», П.Чайковский). Чит ил, рус, татар композиторлары операларында төрле пландагы партияләр башкара: Фигаро («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Валентин («Фауст», Ш.Гуно), Граф ди Луна, Амонасро, Риголетто («Трубадур», «Аида», «Риголетто», Дж.Верди), Марсель («Богема», Дж.Пуччини), Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Елецкий, Мазепа, Роберт («Пики дамасы», «Мазепа», «Иоланта», П.Чайковский), Грязной («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Демон (шул исем. опера, А.Рубинштейн), Хан, Андре («Алтынчәч», «Җәлил», Н.Җиһанов). А.ның тавышы яңгыравыклы, бай, киң диапазонлы, башкару манерасына тәэсирле, күтәренке эмоциональ рух хас.

**АПОЛЛО́НОВ** Леонид Алексеевич (24.1.1922, Лаеш кантоны Надеждино а. — 5.7.1997, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1979), проф. (1980), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1986). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан юридик ин-тын тәмамлый (1946). 1946–47 елларда Казанның Бауман р-ны халык судьясы. 1947–49 да ТАССР Югары мәхкәмә әгъзасы, 1949–50 дә рәис урынбасары. 1950–52 дә Казан юридик ин-тында, 1953–60 та Казан авиация ин-тында укыта. 1960 елдан Казан фининс-икътисад ин-тында: марксизм-ленинизм, 1977 дән КПСС тарихы, 1990 нан сәяси тарих каф. мөдире. Хезмәтләре КПССның Татарстан өлкә ком-ты тарихына багышлана. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: У истоков ленинского коллективного руководства. К., 1969; В.И.Ленин о съезде как верховном органе партии: По материалам нелегальных съездов РСДРП. К., 1974; Верховный орган ленинской партии: Очерки истории партийного строительства. К., 1981.

**«АПОЛО́ГИЯ ТАТА́Р»** («Apologia Tatarów»), 1630 елда Литва-Польша татары Азулевич тарафыннан Речь Посполита илендә бастырып чыгарылган җыентык. Литва-Польша мөселманнары хокукларын католик чиркәү әһелләре эзәрлекләвеннән (мәчетләр төзүне, үз диннәренә өндәүне тыю, сихерчелектә гаепләү һ.б.) яклап языла. Анда мөселман татарларның Речь Посполита дәүләтенә тугрылыклы хезмәт итүләре бәян ителә. Хезмәт өлешчә генә мәгълүм, тулаем сакланмаган.

*Әд.:* D z i a d u l e w i c z S. Herbarz rodzin Tatarskich w Polsce. Wilno, 1929.

*Р.А.Кашапов.*

**АППА́К** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 30 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2002 елда 384 кеше (руслар — 76%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1704 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Апак Бистәсе, Опачка исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сәүдә итү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1840 елларда халыкның бер өлеше Оренбург хәрби чик буе сызыгына күчеп утыра һәм анда казакларга килеп кушыла. 20 йөз башында А.та су тегермәне, бакалея кибете эшли; 1912 елда земство уч-щесе ачыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1106 дис. тәшкил итә. 1918 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Варварино, 1918 дән Кичү волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә, 1924 тән Чаллы кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1834 тә — 381, 1859 да — 278, 1885 тә — 523, 1897 дә — 667, 1910 да — 729, 1926 һәм 1938 дә — 803, 1949 да — 742, 1958 дә — 504, 1970 тә — 421, 1979 да — 381, 1989 да — 360 кеше.


**АППА́КОВА** Дәрҗия Сәйфулла кызы (2.3.1898, Уфа губ., Минзәлә өязе Байгол а. — 28.5.1948, Казан), язучы. Казандагы керәшен укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң (1917), Казанда һәм туган авылында балалар укыта, бер үк вакытта 1918 елдан «Кызыл әләм» г-тасының авыл хәбәрчесе була. 1922–23 елларда сов.-партия мәктәбендә һәм Казан Зур драма театры каршындагы театр студиясендә укый, Республика запас Армиясе Казан политбүлеге каршындагы театр труппасы б-н чыгышлар ясый. 1925–28 дә комсомолның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, РКП(б)ның Бөгелмә кантоны ком-тында оештыручы-хезмәткәр. 1928–43 тә Ташкентта укытучы булып эшли. 1938 дә «Кечкенә Бануның тарихы» (1938) повестен яза, әсәр аңа танылу китерә һәм рус, үзбәк, инглиз телләренә тәрҗемә ителә. Ташкентта яшәгән чорда «Сәнәкчеләр» (1932), «Мәмәт һәм Аман карт» (1934), «Лули» повестьларын, «Михнәт» (1934–35) романын иҗат итә. 1943 елда Казанга кайта; бирредә А. «Шүрәле» (1944), «Тапкыр егет» (1945, Татар акад. театрында куела), «Бишек җыры» (1946), «Илдус» (1947) пьесаларын, «Иске чиләк», «Гөлчәчәк белән Сандугач», «Сараның башыннан үткәннәре» әкиятләрен яза.

Ә с ә р.: Хикәяләр һәм пьесалар. К., 1953; Избранное. К., 1957.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Г и н и я т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана. К., 1970.


*Ф.И.Ибраһимова.*

**АППЛИКА́ЦИЯ СӘНГАТЕ́**, чәмчә, төрле төстәге тукыма, күн, киез һ.б. материал кисәкләрен шул ук яки башка материалга тегеп, ябыштырып рәсем хасил итү ысулы; шул юл б-н төшерелгән рәсем, бизәк. Татар халык



1

2



1. Калфак. «Тырнак алмалау» ысулы. Бәрхет, ефәк, энҗе, җемелдәвек тәңкә. 19 йөзнең 2 нче яртысы; 2. Фрагмент. ТР Милли музее.



Н.Сәйхетдинова. Келәм. Постау, тукыма б-н аппликацияләү. 1980.

сәнгатенең борынгы һәм үзенчәлекле бер төре — чәмчәнең тарихи тамырлары борынгы төркиләр мәдәниятенә барып тоташа. Сакланып калган үрнәкләре 19 йөз уртасына карый. А.с.нең тукымадан киселгән төрле төсләрдәге бизәкне тукымага, ә кайчак күнне күн нигезгә тегү (ияр, аяк киеме һ.б.) төрләре бар. Ефәк һәм атлас тасмаларны бант, зигзаг, ромб, чәчәк һ.б. бизәкләр б-н чәмчәләү киң таралган. А.с.нең «тырнак алмалау» төре башка халыклар иҗатында очрамый. Мондый аппликациянең барлык бизәкләре аерым таҗ яфраклары рәвешендә «колакландырып» бөтерелгән тасма кисәкләреннән ясала, алар



Р.Фәйзрахманова. Чаршау фрагменты. Тукымалар б-н аппликацияләү, чигү. 1983. ТР Милли музее.

төсле сәйлән, мәрҗән, ялтыравыклы металл кисәкләре б-н берлектә дәлия, кашкарый, лалә чәчәкләре, ачылып җитмәгән гонҗә, үлән сабагының кабарынкы сурәтләрен хасил итәләр. А.с. көнкүреш тукыма әйберләрен (җәймә асты), традицион өс киемен (алъяпкыч, *камзул*, *калфак*) бизәүдә кулланыла; хатын-кызлар *күкрәкчәсен* чәчәк бәйләме яисә «тормыш агачы» мотивлары б-н бизәкләү 20 йөз уртасына кадәр саклана. Бер төсле (ак, соры) киез паласларга киездән яисә тукымадан бизәкләр тегү ысулы 20 йөз башына кадәр кулланыла. Хатын-кыз һәм ир-ат киемнәрендә күн яисә тукыма өстендә мех, велюр, замша б-н чигеш кушу рәссам-модельерлар тарафыннан 1970 еллардан башлап кулланыла. Һәвәскәрләр һәм халык осталары тукыма әйберләрен (пәрдә, *намазлык* һ.б.), киез паласларны бизәгәндә А.с. ысулыннан файдаланалар. 1980 еллардан бирле А.с. Казан рәссамнәре иҗатында дивар панноларын, диван мендәрләрен бизәүдә кулланыла. Оста һөнәрчеләрдән: М.Бикбулатова, С.Кузьминых, Н.Кузьминых, И.Макарова, С.Гарбузова (Казан), З.Бикташева, Р.Круглякова (Чаллы) һ.б.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АПРА́КСИН** Пётр Матвеевич (24.6.1659 — 29.5.1728, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе, бояр (1709), граф (1710), сенатор (1715). 1698–99 елларда Новгородта воевода. Төньяк сугышында (1700–21) катнаша. 1705 елдан Әстерхан губернаторы. Әстерханда стрелецлар, солдатлар һәм бистә кешеләре баш күтәргәндә (1705–06), Б.П.Шереметев җитәкчелегендәге хөкүмәт гаскәрләренең тылын саклау отряды башлыгы буларак, А. 1706 да Казанда тора. 1708 дә калмык ханы Айука б-н калмыкларның Россиягә буйсынуы турында килешү төзи. 1708–13 елларда Казанда беренче губернатор. Аның дәверендә Казан губерна канцеляриясе, җир бүленеше мәсьәләләренә караган мәхкәмә эшли башлый, шәһәрләрдә хәрби гарнизоннар урнаштырыла, комендантлар билгеләнә. Кораблар төзү өчен кирәк булган агачларны кистереп С.-Петербургка озатуны һәм Россия флоты өчен корабларны урында төзүне оештыра. Армия ихтыяҗлары өчен үзәккә елына 20 меңләп ат җибәреп тора. 1711–13 елларда Каманың сулъяк ярындагы шәхси җир биләмәләрендә дистәләгән яңа авыл, ш.и. Алексеев авылын нигезли. Губерна халкыннан җыела торган салымны үз белдеге б-н 400 мең сумга арттыра. Моңа ирешү өчен ул салым түләүчеләргә карата төрле рәхимсез чаралар куллана. Нәтиҗәдә 33 меңләп гаилә башка губерналарга качып китәргә мәҗбүр була. 1711 елда Кубань Урдасына каршы җибәрелгән гаскәр башлыгы. 1712 дән Харьковта, Россиянең көньяк чикләрен саклауны оештыруда катнаша. 1715 тән «Коммерция турында коллегиум», 1717–18 дә Коммерция коллегиясе, 1722–25 елларда Юстиция коллегиясе президенты. 1725 елдан хакыйкый тайный советник.

*Әд.:* Бороздин К.М. Опыт исторического родословия дворян и графов Апраксиных. СПб., 1841; Долгоруков П.В. Российская родословная книга. СПб., 1855, Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**АПРЕ́СОВ** Владимир Григорьевич (16.1.1915, Баку — 20.6.1982, Казан), пианист, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1972). Мәскәү консерваториясен (М.Юдина классы, 1940) тәмамлый. 1945–66, 1980–82 елларда Казан консерваториясендә укыта, 1947–64 тә проректор. 1966–74 тә Ерак Көнчыгыш сәнгать ин-тында ректор. 1974–80 дә Ростов музыка-пед. ин-тында махсус фортепиано каф. мөдире, 1980 нән профессоры. Шәкертләре арасында А.*Луппов*, В.*Спиридонова*, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклеләре А.Миркина, Н.Сабитовская, К.Шашкина, Т.*Әхмәтов* бар. Симф. оркестр һәм соло концертлары б-н (ш.и. К.Зандерлинг, И.Шерман җитәкчелегендә) чыгышлар ясый. Репертуарында Л.Бетховен, Ф.Шопен, Ф.Лист, П.Чайковский, Д.Шостакович һ.б.ның әсәрләре бар. Пианистларның Бөтенсоюз конкурсы дипломанты (1938).

Хезм.: О программности Сонаты № 31 Бетховена // Из педагогического опыта Казанской консерватории. К., 1996.

*В.М.Спиридонова.*

**АПСАБА́Ш** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 48 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мари Респ-касы чигендә. 2002 елда 56 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлек асрау. 16 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Иске Апса исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.та мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 413,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир заты; 1859 да — 229, 1897 дә — 319, 1908 дә — 375, 1920 дә — 435, 1926 да — 368, 1938 дә — 349, 1949 да — 302, 1958 дә — 210, 1970 тә — 191, 1989 да — 78 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**АР ЯГЫ́ БӘКЛӘРЕ́** (рус елъязмаларында «Арские князья»), 14–17 йөзләрдә *Вятка* (Нократ) *җирендәге* Хлынов өязенең Карин һәм Югары Чыпца волостьларында яшәгән аксөякләр катлавы. Кыпчак ыругыннан чыкканнар (*Бачман хан* варислары дип тә фаразлана). Зур социаль статуска ия булганнар, Казан ханнарына турыдан-туры буйсынмаганнар. Рус язма чыганакларында А.я.б. Вятка кенәзләре, каринлылар яки Карин кенәзләре буларак та теркәлгәннәр (Чыпца елгасы буендагы Карин бәклеге 1361 елда оеша). 15 йөздә А.я.б. Мәскәү кенәзлеге б-н Казан ханлыгы арасында Нократ җире өчен барган сугышта катнашалар. Төбәкне Мәскәү яулап алганнан соң (1489), А.я.б.нең күбесенә Чыпца, Иж, Нократ елгалары буйларында җир биләмәләре бүлеп бирелә, аларның старшиналары җирле халыктан салым җыю, зур җинаятьләргә кагылмаган мәхкәмә эшләрен башкару хокукына ия булалар. А.я.б. зур дәрәҗәгә ия булмаган Казан феодаллары, мари, удмурт кабиләләре башлыклары исәбенә тулыландырылган. Алар Казан ханлыгының Тау ягы җирләрендә яшәүчеләрне Рус дәүләтенә ирекле кушылырга, аерым татар, удмурт һәм бисермән гаиләләрен Нократ җирләренә күчеп китәргә өндиләр. Рус дәүләтенең көнчыгыш чикләрен саклауда һәм яңа җирләр яулау сугышларында, ш.и. 16 йөз урталарында Казан ханлыгын яулау һәм халык кузгалышларын бастыруда катнашалар. Казан ханлыгы яулангannan соң, А.я.б.нең кайберләренә 16–17 йөзләрдә Казан төбәгендә биләмә җирләре бирелә, кайберләре крәстияннәр тоту хокукыннан мәхрүм ителә

яки дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. А.я.б.нең бер өлеше соңрак христиан диненә күчә һәм Россия феодалларына кушылып китә. А.я.б.ннән иң мәгълүм нәселләр: Арслановлар, Деветьяровлар, Дюняшевлар, Долгоаршинныйлар, Касимовлар, Яушевлар.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; Исхаков Д.М. Татаро-бесермянские этнические связи как модель взаимодействия булгарского и золотоордынско-тюркского этносов // Изучение преемственности этнокультурных явлений. М., 1980; шул ук. О происхождении «арских князей» и их месте в этнополитической структуре Казанского ханства // Проблемы истории и культуры Заказанья. К., 1995.

*Д.Г.Мостафина.*

**«АР ЯГЫ́ КЕШЕЛӘРЕ́»**, этник катлам төшенчәсе, русча язмаларда «Арские люди» дип теркәлгән. Тарихи хезмәтләрдә *Арча даругасы* биләмәсендә яшәүче төрле милләт вәкилләренең элекке җыелма атамасы; 16 йөз ахырларында халыкның салым түләүче өлешен ш.у. арлар (аряне), ар ягы кара халкы, ар ягы чуашлары дип тә атаганнар, *ар ягы бәкләре* дә булган. Рус чыганакларында әйтелгәнчә, Иван IV элекке Казан ханлыгы олыслары халкына рус гаскәрләренә каршы сугышкан өчен аларны «гафу итүен» һәм «әзәрлекләмәячәген» белдерүенә җавап итеп, 1552 елның 10 октябрендә «А.я.к.» Иван IV кә тугрылык анты бирәләр һәм Мәскәүгә ясак түләп торырга әзер булуын җиткерәләр. «А.я.к.» янында бояр улы Н.Казаринов б-н морза Камай (Смиленев) җитәкчелегендәге патша илчеләре булганнан соң, аларның күпчелеге 1552 нең 10 октябрендә Иван IV кә тугрылыклы булуларын белдерә. Шул ук елның декабрендә «А.я.к.»нең бер өлеше Болын ягы кешеләренең мәскәүлеләргә каршы күтәрелешенә кушыла. 1553 нең мартында Болын ягы һәм Яр буе кешеләре татар бәкләре Сәет Үсәен, Туакмыш Шаһзадә, Сары Батыр һ.б. җитәкчелегендә Мәскәү баскыннарына каршы баш күтәргәч, «А.я.к.» дә алар арасында көрәшә (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары*). 1554 нең февраль-март айларында баш күтәрүчеләргә кушылган «А.я.к.»нең бер өлеше ул хәрәкәттән читләшә, кабат патша җәнапларына буйсынганлыкларын белдереп ант итә. Буйсынмаучылардан Кибәнәк б-н Кормангали бәкләр, Колай, Чабак морзалар һ.б. тиздән җәзага тартылалар. 1554 елның октябрендә «А.я.к.»нең бер өлеше патша воеводасы М.В.Глинский һ.б. җитәкчелегендә баш күтәрүчеләрне бастыру һәм җәзалауда катнаша. Мамышбирде сотник җитәкчелегендә 1556 ның февралендә Болын ягы халкы баш күтәргәч, аларга «А.я.к.» дә кабат кушыла. Шул ук елның май-июль айларында бу кузгалыш та П.В.Морозов, Ф.И.Бутурлин, Ф.И.Салтыков, П.И.Шуйский җитәкчелегендәге әзәрлекләү отрядлары тарафыннан бастырыла. 1557 елның апрель-май айларында Әхмәт Батырның Болын ягы кешеләрен каршылык күрсәтергә чакыруы уңышсыз тәмамлана. 16–17 йөздә «А.я.к.» төшенчәсе кулланыштан чыга.

*Әд.:* Курбский А.М. История о великом князе Московском // Русская историческая библиотека. СПб., 1914. Т. 31; Алишев С.Х. Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. XVI — начало XIX вв. М., 1990; шул ук. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV — XVI вв. К., 1995.

*Д.Г.Мостафина.*

**«А́РА»** (инглиз. «ARA», «American Relief Administration» — «Америка хәйрия-ярдәм мөдирияты»), иҗтимагый хәйрия оешмасы. Беренче бөтендөнья сугышында каза күргән Европа илләре халкына азык-төлек, кием-салым һ.б. б-н ярдәм итүне оештыру максатында төзелә, 1919–23 елларда эшчәнлек алып бара. АКШ сәүдә министры Г.Гувер җитәкчелек итә. Идел буенда 1921–23 еллардагы ачлык чорында Совет хакимияте дә аның ярдәмен кабул итә (АКШ хөкүмәте 20 млн. доллар бүлеп бирә). «А.» РСФСРга 28 млн. пот азык-төлек кертә, ш.и. ТАССРга 886 мең пот бирелә. Азык-төлек, медикаментлар, хастаханә кирәк-яракларыннан торган 1 нче йөкләр респ-кага 1921 елның сентябреннән килә башлый. 1922 нең маена Идел буена 5 млн. пот сыешлы 5213 вагон Америка азык-төлеге килә, шуның 854 вагоны ТАССР, Чуаш һәм Мари автономияле өлкәләре өчен дип Казан базасына тапшырыла. ТАССРга 886154 пот он, ярма, май, сөт һ.б. йөкләр бүлеп бирелә. 1922 дә «А.» ТАССРда 2529 ашханә ача, аларда 1 млн.нан артык кеше туклана. Ш.у. мед. ярдәме күрсәтү пунктлары, халыкка азык-төлек, киемнәр һәм беренчел кирәк-ярак әйберләр тарату пунктлары эшли. «А.»ның Казан бүлеге җитәкчесе Америка язучысы Д.Р.Гайльдс була. «А.» ярдәмендә дистәләрчә мең кешенең тормышы коткарып калына. 1923 елдан Россиядә бу оешманың эшчәнлеге тыела.

*Әд.:* Гайльдс Д.Р. Очерки страшной действительности. К., 1922; Поляков Ю.А. 1921-й: победа над голодом. М., 1975; Белокопытов В.И. Лихолетье. К., 1976; «Голод особенно свирепствовал в деревнях...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1997. № 3/4.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**АРАНО́ВСКИЙ** Соломон Моисеевич (18.11.1885, Полтава губ. Кременчуг ш. — 1956), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1939), проф. (1940). 1920 елдан ВЦСПСның Днепропетровск һәм Харьков хезмәтне саклау ин-тларында фәнни-тикшеренү эшендә. 1939–52 елларда Казан мед. ин-тының хезмәт гигиенасы каф. мөдире, сан.-гигиена ф-ты деканы. 1952 дә Пермь шәһәренә күчеп китә. Хезмәтләре металлургия һәм тегү-туку сәнәгатендә, тимер юл транспортында гигиена һәм хезмәтне саклау мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Профилактика отёчной эритемы голеностопной области // Тр. Казан. мед. ин-та. 1944. Вып. 2; Ф.Ф.Эрисман и его роль в развитии гигиены труда как самостоятельной науки в России // Тр. Казан. мед. ин-та. 1951. Т. 1.

*Әд.:* Казанские профессора — гигиенисты: Биогр. словарь. К., 1995.

**АРА́ПОВА** Нәфыйга Мөхәммәтгалим кызы (30.4.1900, Казан — 13.4.1943, шунда ук), драма актрисасы, ТАССРның атказ. артисткасы (1939). Сәхнә эшчәнлеген 1916 елда *«Сәйяр»* труппасында башлый. Гражданнар сугышы елларында фронт театрларында, соңрак Уфа, Әстерхан шәһәрләре театрларында эшли. 1920 ел ахырыннан Татар акад. театрында. Комедияләрдә уйнау талантына ия буларак, колоритлы, чын халыкчан образлар тудыра. Яшүсмерләр һәм төрле яшьтәге кешеләрнең характерлы рольләрен башкара. Төп рольләре: Нәгыймә, Мәгъри («Банкрот», «Бәхетсез егет», Г.Камал), Рокыя, Хәдичә, Малай («Җилкәнсезләр», «Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Айтуган, Зөләйха («Наёмщик», «Бишбүләк», Т.Гыйззәт), Бәдыйга («Галиябану», М.Фәйзи), Кукушкина, Анфуса Тихоновна («Төшемле урын», «Бүреләр һәм сарыклар», А.Н.Островский), Караулова («Чит кеше баласы», В.Шкваркин), Квашня («Тормыш төбендә», М.Горький).



Н.М. Арапова.



Р.Р. Арат.

**АРАСЛА́НОВ** Әнвәр Мидхәт улы (27.1.1941, Казан), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1991), проф. (1993), РФнең атказ. югары мәктәп укытучысы (2002). 1964 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1994 елдан конструкцияләү нигезләре каф. мөдире, бер үк вакытта вузга әзерлек ф-ты деканы (2001 дән). Хезмәтләре очкыч аппаратлар элементларының оптималь конструкцияләрен проектлаштырганда ихтималлылыкны исәпкә алуга карый. Машина һәм корылмаларның төрле элементлары конструкциясен проектлаштыруның яңа концепциясен тәкъдим итә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Расчёт элементов конструкций. М., 1987; Вероятностные подходы к силовому проектированию элементов конструкций. К., 1992.

**АРА́Т** (Arat) Рәшит Рәхмәти (Рәхмәтуллин Габдерәшит) Исмәт улы (15.5.1900, хәзерге Әтнә р-ны Иске Өҗем а. — 29.11. 1964, Истанбул), тюрколог, филол. д-ры (1928). 1920–22 елларда Харбин шәһәрендә (Кытай) яши, «Ерак Шәрекъ» г-тасы редакциясендә эшли. 1922 дән Берлинда, Берлин ун-тын тәмамлый (1927). Шул ук ун-тта төрки телләр укыта һәм Берлин Фәннәр академиясе б-н хезмәттәшлек итә. 1933 тән Истанбул ун-тының төрки телләр һәм әдәбият каф. профессоры; 1949–51 дә Лондон ун-тында лекцияләр укый. 1951 дән Истанбул ун-ты каршындагы Тюркология ин-ты директоры. Хезмәтләре төрки халыкларның тарихы, телләре һәм әдәбиятларына карый. Й.Баласагуниның «Котадгу белег» («Игелекле белем», 11 йөз) исемле әсәренә — борынгы төрки әдәби ядкәргә багышланган өч томлы хезмәт авторы. «Islam Ansiklopedisi» («Ислам энциклопедиясе»)нә нигез салучыларның берсе һәм мөхәррире (Истанбул, 1930 еллар).

*Əд.:* Х ә к и м җ а н Ф. Казанлы Рәшит Рәхмәти // Идел. 1996. № 10; З ә к и е в М.З. Төркия аша төркологиягә (Р.Аратның 100 еллыгы уңаеннан) // Идел. 2000. № 5; ХХ гасырның күренекле төркологы Рәшит Рәхмәти Арат. К. 2001; Rəşit Rəxməti Arat (Галимнең 100 еллыгына багышланган халыкара конф. материаллары). К., 2001.

**АРБАЛЕ́Т**, сугыш коралы, эре корылмаларга ату җайланмасы. Арбага яки махсус җайланмага агачтан (11–13 йөзләр) яки корычтан (14–15 йөзләр) ясалган зур җәя беркетелә, җәя бавы чыгыр ярдәмендә тарттырыла. Тимер очлык яки болт куелган кыска авыр ук җәянең махсус «аткычы»на басу б-н атылып китә торган була. Зур станоклы А.лар кальга-ныгытмаларны саклаганда, арбага урнаштырылганнары — кальгаларга һөҗүм иткәндә кулланылган. Барлык Азия һәм Европа илләрендә, ш.и. Идел буе Болгары б-н Алтын Урдада киң таралган хәрби корал. Идел буенда 16 йөзгә кадәр кулланыла.

*И.Л.Измайлов.*

**АРБА́Ш** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 9 *км* көнбатыштарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. 2002 елда 405 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Китапханә. Хәзерге А.ка 16 йөз ахырында — 17 йөз башында нигез салынган һәм 1930 елларда кушылган Пашир Арбашы һәм Шира Арбашы авылларын берләштерә. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында ике авыл халкы да дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тире иләү б-н шөгыльләнә; бакалея һәм мануфактура б-н сәүдә итә. Шира Арбашында Арча сәүдәгәре Фәйзулла Монасыйповның күн з-ды була һәм анда җитештерелгән товар Казанда, Мәкәрҗә ярминкәсендә, Оренбургта сатыла. 20 йөз башында ике авылда 3 мәчет, мәдрәсә, мәктәп, вак-төякләр кибете була. Ике авыл җәмәгатенең берләштерелгән имана җире 2243,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр ике авыл да Казан губернасының Казан өязе Балтач волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1795 тә — 346, 1859 да — 592, 1897 дә — 849, 1908 дә — 985, 1920 дә — 1172, 1926 да — 832, 1938 дә — 750, 1949 да — 527, 1958 дә — 388, 1970 тә — 357, 1979 да — 358, 1989 да — 343 кеше.

*Əд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**АРБИТРА́Ж** (фр. arbitrage — арадашчы суд — ике якның бәхәсле эшен бәйсез рәвештә тикшерә һәм хәл итә торган өченче як катнашындагы мәхкәмә), 1) бәхәсле эшләрне якларның мәхкәмә органнарына түгел, бәлки аерым затларга — арбитрларга яки арадашчы судьяларга мөрәҗәгать итеп хәл итү ысулы. Арбитрлар яклар тарафыннан сайлана, шулай ук аларның үзара килешү шартында яки законда каралган тәртиптә билгеләнеп куела. А., башлыча, сәүдә, йөк ташу, товар китерү-җибәрү операцияләрен башкару вакытында килеп туган, мөлкәткә кагылышлы бәхәсләрне хәл итү өчен файдаланыла; 2) мөлкәткә кагылышлы һәм шуның б-н бәйле мөлкәткә карамаган бәхәсләрне хәл итә торган махсус орган. Очраклы А. һәм даими эшли торган А. гамәлдә. Очраклы А. бары тик нинди дә булса конкрет бер эшне хәл итү өчен оештырыла. Бу — А.ның башлангыч формасы. 19–20 йөзләрдә даими эшли торган А. өстенлек ала, ул яклар арасында килеп туган һәм шулар тарафыннан тикшерүгә куелган бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү б-н шөгыльләнә. 1918–22 елларда Россиядә А. мәхкәмәсе эшләүдән туктый. 1922 елда, пр-тиеләр хуҗалык исәбенә күчерелгәч, дәүләт (1931 елда бетерелә) һәм ведомство (1929 елда бетерелә) арбитраж комиссияләре, ә 1931 елда Дәүләт арбитражы төзелә. Бер үк ведомствога (министрлыкка) караган пр-тиеләр һәм оешмалар арасында килеп туган бәхәсләрне хәл итү өчен министрлыклар каршында ведомство арбитражлары оештырыла. РФдә гражданнар, хакимиятләр арасындагы хокукый мөнәсәбәтләргә кагылышлы бәхәсләрне хәл итү б-н югары орган — РФ Югары арбитраж мәхкәмәсе шөгыльләнә, аның рәисе, урынбасарлары һ.б. судьялары РФ Президенты тәкъдиме б-н РФ Федераль Җыелышының Федераль Советы тарафыннан билгеләп куела. Татарстанда ТРның Югары арбитраж мәхкәмәсе гамәлдә. Аның әгъзалары рәис тәкъдиме б-н ТР Дәүләт Советы тарафыннан сайлана. ТРның Югары арбитраж мәхкәмәсен оештыру, аның эшчәнлеге һәм компетенциясе ТР законы һәм РФнең арбитраж процессуаль законнары нигезендә билгеләнә. А. төрләренең берсе — халыкара А., анда яклар мәнфәгатьләрен үтәүдә, кагыйдә буларак, төрле дәүләтләрнең юридик һәм физик затлары, кайчакта үз органнары аша турыдан-туры дәүләт үзе катнаша.

Чыг.: Закон Республики Татарстан «О Высшем арбитражном суде Республики Татарстан» // Ведомости Верховного Совета Татарстана. 1992. № 11–12; Закон РФ «Об арбитражных судах в Российской Федерации». Арбитражный процессуальный кодекс Российской Федерации. Н.Новгород, 1995; Конституция Республики Татарстан. К., 1997; Конституция Российской Федерации. М., 1998.

*Н.Р.Болгар.*

**АРБОЛИ́Т**, төзү материалы, бетонның җиңел төре. Органик тутырмалар катнашмасыннан (агач эшкәртү һәм а.х.ындагы вакланган калдыклар һ.б.) һәм минераль тоташтыргычтан (портланд-цемент яисә аның төрләре) әзерләнә. Бетон катнашмасына минеральләштерү һәм агач калдыкларының сулы зарарлы тәэсиреннән саклау, цементның катуын тизләтү өчен кальций хлориды яисә сыек натрий пыяласы өстәлә. А.ның күләмчә авырлыгы 400 дән 800 *кг/м*³ кадәр. А.тан аз катлы торак йортлар, җәмәгать һәм сәнәгать биналары өчен дивар блоклары һәм панельләр, аралыкларны тоташтыру һәм каплау плитәләре һ.б. әзерләнә. ТРда А. җитештерү 1957 елда башлана. А. Казанда, Арча, Аксубай, Васильево ш.т.п.ларында, Азнакай р-ны Тымытык авылында җитештерелә. 1960 елда 21, 1970 тә — 38, 1980 дә — 46, 1990 да — 59, 1999 да 41 мең *м*³ күләмдә җитештерелгән.

*Əд.:* И в а н о в А.С. Изготовление арболита в Татарии. К., 1976; Г о р ч а к о в И.Г., Б а ж е н о в Ю.М. Строительные материалы: Учеб. пособие. М., 1986.

*Р.З.Рәхимов.*

**АРБО́Р** елгасы, Көнбатыш Кама алды төбәгендә. Шушма елгасының сул кушылдыгы (Вятка елгасы бассейны). Озынлыгы 31,3 *км*, ТР чикләрендә — 22 *км* чамасы. Бассейнының мәйданы 189,9 *км*². Елга башы Мари Респ-касында. Арбор авылыннан түбәндәрәк елга ТР терр-ясеннән ага. Тамагы Балтач р-нының Шеңшеңәр авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 66 *м*. Елганың су җыелу мәйданы эрозияләнеп нык бүлгәләнгән яссы калкулыктан гыйбарәт. А.ның 0,8 дән алып 3,3 *км* га кадәр озынлыктагы 23 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 140 *мм*, ташу агымы катламы 110 *мм*. Язгы ташу, кагыйдә буларак, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,18 *м*³*/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада гомуми күләме 250 мең *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**АРБО́Р** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 28 *км* төньяктарак, Арбор елгасы буенда. 2002 елда 642 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Мәчет. 1768 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында авыл Арбор-Себе Усад исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 3048 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында А.да волость идарәсе урнаша; почта станциясе, мәчет һәм мәктәп була. 1920 гә кадәр авыл — Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волосте үзәге, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1834 тә — 655, 1884 тә — 1198, 1920 дә — 1730, 1926 да — 1613, 1938 дә — 1210, 1949 да — 835, 1958 дә — 754, 1970 тә — 737, 1979 да — 648, 1989 да — 592 кеше.

**АРБУ́ЗОВ** Александр Ерминингельдович (30.8.1877, Казан губ., Спас өязе Арбузов-Баран а. — 21.1.1968, Казан), химик-органик, химик-фосфорорганиклар фәнни мәктәбенә нигез салучы, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1942, 1932 дән мөхбир әгъза), РСФСР һәм ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1935, 1940), Соц. Хезмәт Герое (1957). А.М.*Зайцев* шәкерте. 1900 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Ново-Александрия авыл хуҗалыгы һәм урманчылык ин-тында эшли, проф. (1906). 1911 елдан Казан ун-тында, органик химия каф. мөдире,

1922–1926 да физ.-мат. ф-ты деканы, 1930–63 елларда Казан хим.-технол. ин-тында органик хим. каф. мөдире. Бер үк вакытта 1929–1960 елларда Казан ун-ты каршындагы Фәнни-тикшеренү химия ин-ты директоры; 1945–1963 тә СССР ФАнең Казан филиалы президиумы рәисе һәм 1945–1965 елларда СССР ФА Казан филиалы Хим. ин-ты директоры. 1965 тән Органик һәм физик химия ин-тында элементорганик кушылмалар бүлеге мөдире. А. фосфорорганик кушылмаларны өйрәнгәндә, А.М.Бутлеровның химик төзелеш теориясен үстереп, Казан хим. мәктәбе традицияләрен дәвам итә. «Фосфорит кислотасы һәм аның чыгарылмаларының төзелеше» («О строении фосфористой кислоты и её производных») дигән магистрлык диссертациясендә (1905) бу кислотаның төзелешен ачыклап бирә һәм аның чиста эфирларын таба, фосфорит кислотасы урта эфирларының каталитик изомерлашуын ача (к. *Арбузов реакциясе*). Бу фосфорлы кушылмаларны синтезлауның универсаль ысулы булып тора. Шушы хезмәт фосфорорганик кушылмаларның кайбер бүлекләрен системалы өйрәнүгә нигез сала (Н.Н.Зинин һәм А.А.Воскресенский исем. Рус. физ.-хим. җәмгыяте бүләге, 1906). «Фосфорның кайбер кушылмалары әверелешләре өлкәсендә катализ күренеше» («О явлениях катализа в области превращений некоторых соединений фосфора») дигән докторлык диссертациясендә (1915) А. үзенең реакциясен фенилфосфинит һ.б. кислота эфирларына карата куллана һәм ш.у. изомерлашу каталитик процессын тизләтүче көчләр б-н гадәти хим. реакцияләр тизлегенә тәэсир итүче көчләрнең бердәмлеген күрсәтә. А. фаразлары гомоген катализның хәзерге заман теориясе тарафыннан дәлилләнә. Кулланылыш чикләрен киңәйтеп һәм реакция механизмын өйрәнеп, А. фосфорорганик кушылмаларның яңа классларын — фосфонкарбонат кислоталарын һәм аларның эфирларын ача һәм тикшерә, шуның б-н үзе ачкан реакциянең универсальлеген һәм кулланылыш мөмкинлекләрен күрсәтә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында А. Россия хәрби сәнәгать ком-тының химия секциясе кушуы буенча Казанда бертуган Крестовниковлар з-дында салицил препаратларын (салицил кислотасы, натр салицилаты, аспирин һ.б.) чыгаруны оештыра. А. эшләренең бер төркеме фосфит кислотасы диалкил эфирларының таутомериясенә һәм аларның металлы ясалмалары реакцияләренә багышлана. Бу кушылмаларны тикшереп (Б.А.Арбузов б-н берлектә), триарилбромметаннан триарилметил рәте ирекле радикаллары барлыкка килү реакциясен ача (1929). Эталон радикалга әйләнгән дивинилпикрилгидразилны таба һәм тикшерә, соңыннан А. тарафыннан ирекле радикаллар химиясе буенча хезмәтләр ЭПР ысулын кулланып үткәрелә. Ылыслы агачлардан сумала бүленеп чыгуны өйрәнеп, А. бу үсемлекләрнең сумала юлларында көчле басым (2–3 атм.) күренешен таба. Сагыз бүленеп чыгуның кайбер закончалыкларын билгеләп (Б.А.Арбузов б-н берлектә), сагызны очучан компонентларын югалтмыйча җыю ысулын эшли. Субфосфат, пирофосфат, пирофосфит һәм фосфит кислоталарының ясалмаларын ача һәм тикшерә. Үзе ачкан күп кенә кушылмаларның физиологик активлыгын ачыклый. Глаукомага каршы (А.И.Разумов б-н берлектә) мед. практикасына кертелгән нәтиҗәле чаралар, үсемлекләрне саклау


А.Е. Арбузов.

өчен инсектицид препаратлар уйлап таба. Бөек Ватан сугышы елларында А. эшчәнлеге илне саклауга юнәлтелә. Эвакуацияләнгән СССР ФА ин-тларын Казанга урнаштырганда аның оештыру таланты аеруча ачыла. Сугыштан соңгы елларда химия тарихы буенча хезмәтләрен бастыра башлый; аның бу өлкәдә төп хезмәте — «Россиядә органик химия үсешеннән кыскача очерклар» («Краткий очерк развития органической химии в России» (1948) монографиясе. Аның тарафыннан Россия химия фәне һәм Казан химия мәктәбе тарихы буенча 70 ләп хезмәт язылган. Сугыштан соңгы елларда Э.Фишерның аномаль реакциясе барышын фенилгидразоннар һәм аларга якын кушылмалар катнашында өйрәнә (Ю.П.Китаев б-н берлектә). Б.А.Арбузов, Г.Х.Камай, А.Н.Пудовик, А.И.Разумов, В.В.Евлампиев, В.С.Абрамов, П.И.Алимов кебек галимнәрнең яңа буынын тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Казан ун-ты каршында А.М.Бутлеров исем. Химия фәнни-тикшеренү ин-тын оештыра (1929). Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыятенең Татарстан респ-ка бүлекчәсен оештыручыларның берсе һәм рәисе (1934–1954), СССР ФАнең Казан ф-лын оештыру комитеты рәисе (1945). Күпкырлы талант иясе А. виртуозларча скрипкада уйный, соклангыч пейзажлар яза, пыяладан лаб. приборлары эшли. Казан урамнарының берсе, РФА КГҮнең Органик һәм физ.химия ин-ты аның исемен йөртә; 1977 елда ин-т фасады каршына галимнең бюсты куела. 1971 дә Казанда А. музей-йорты ачыла. 1997 дә *Халыкара Арбузов бүләге* булдырыла. 1946–1966 елларда СССР ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләге (1943, 1947) лауреаты. 2 нче, 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, алты Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Избранные труды. М., 1952; Казанская школа химиков. К., 1971; Избранные работы по истории химии. М., 1975; Избранные труды по химии фосфорорганических соединений. М., 1976.

*Әд.:* К а м а й Г.Х. Академик А.Е.Арбузов. К., 1952; Академик А.Е.Арбузов — каким он был: Сб. воспоминаний. К., 1975; Г р е ч к и н Н.П., К у з н е ц о в В.И. Александр Ерминингельдович Арбузов. М., 1977; Александр Ерминингельдович Арбузов: Очерки. Воспоминания. Материалы. М., 1989.

*В.Г.Абзалова.*

**АРБУ́ЗОВ А.Е. БЮСТЫ́**, Казанда. *Арбузов* А.Е. исем. Органик һәм физ.-химия ин-ты бинасы каршына урнаштырылган. 1977 елда атаклы химик-органикның тууына 100 ел тулуны бәйрәм иткән көннәрдә ачыла. Авторлары — скульпт. А.Н.Костромитин, арх. Н.В.Костромитина.

Бюстта Арбузовның образы бөтен тулылыгы б-н чагыла. Галимнең эчке дөньясының байлыгы, интеллектуаль куәте, кызыксынучан, йомшак холкы, кешелеклелек җылысы сиземләнә. Сәнгати-пластик тасвирлау нәтиҗәсендә күз алдына талпнанлеге, аз сүзлелеге, мәсьәләне җентекләп өйрәнүе б-н аерылып торган кеше килеп баса. Кара лабрадориттан эшләнгән турыпочмаклы постамент скульптураның рәвешенә туры килә.

*А.И.Новицкий.*

**АРБУ́ЗОВ** Антон Петрович (1797 яки 98 — гыйн. 1843, Енисей губ., Ачинск округы Назарьевск а.), декабрист. Дворян Арбузовлар нәселеннән (аларның җир биләмәләре Казан губ. Казан һәм Спас өязләрендә булган). 1810–19 елларда С.-Петербургта Диңгез кадет корпусы мәктәбендә укый, аны тәмамлагач, Гвардия экипажында хезмәт итә башлый. 1824 елдан декабристларның яшерен оешмасы әгъзасы. 1825 тә Н.А.Бестужев тәкъдиме б-н хәрәкәтнең Төньяк җәмгыятенә кабул ителә. 1825 елның 14 декабрендә А. Сенат мәйданында «мылтыкларны корырга дип әмер бирүчеләрдән» була. Декабристлар җәмгыятенең «дәүләтне һәм император гаиләсен юк итәргә ниятләүче» актив эшлеклесе булараk, 15 декабрь төнендә кулга алына, гомерлек каторгага озатыла (соңрак хөкем карары «20 елга» дип үзгәртелә). Сөргендә вакытта Себердә вафат була.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906, Вып. 1; Восстание декабристов. Материалы. М.–Л., 1926. Т. 2; М., 1986. Т. 16; Декабристы: Биогр. справ. М., 1988; Г а р з а в и н а А.В. «... Отчизне посвятим души прекрасные порывы!» К., 1990.

*А.В.Гарзавина.*

**АРБУ́ЗОВ** Борис Александрович (22.10.1903, Люблин губ. Ново-Александрия ш., хәзерге Польшаның Пулавы ш. — 6.11.1991, Казан), химик-органик, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1953; 1943 тән мөхбир әгъза), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы. Соц. Хезм. Герое (1969), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1945, 1961). А.Е.*Арбузовның* улы һәм шәкерте. 1926 елда Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык ин-тын тәмамлый. 1929–1935 елларда Казан вет. ин-тында эшли һәм бер үк вакытта 1931–1938 дә Казан хим.-технол. ин-тының синтетик каучук һәм авыр органик синтез каф. мөдире, проф. (1935), хим.-технол. ф-ты деканы (1936–1938). 1938 дән Казан ун-тында, органик химия каф. мөдире (1967 гә кадәр), химия ф-ты деканы (1940–1950); сектор мөдире (1944 тән), 1960–1989 да Казан ун-ты каршындагы Химия фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, органик кушылмалар төзелешен өйрәнү проблемалары лаб. җитәкчесе (1957–1988). Бер үк вакытта 1941–1947 дә Казанга эвакуацияләнгән СССР ФАнең Органик химия ин-тында югары молекуляр кушылмалар лаб. мөдире; СССР ФАнең Казан филиалы Органик һәм физик химия ин-тын (1965 кә кадәр СССР ФАнең Органик хим. ин-ты) оештыручы һәм беренче директоры (1958–1971), органик кушылмалар структу-

расы һәм реакцион мөмкинлекләре лаб. мөдире (1971–1989).



Б.А. Арбузов.


1960–1980 елларда *Казан химия фәнни мәктәбенең* танылган җитәкчесе. Органик (элементорганик химия, табигый кушылмалар химиясе, стереохимия) химия һәм физик химия өлкәсендәге тикшеренүләрнең берничә юнәлеше б-н җитәкчелек итә. Фәнни эшчәнлегенең башында (А.Е.Арбузов җитәкчелегендә) ылыслы агачлардан сумала агызу ысулын, сагыз составын һәм аны эшкәртеп табылган продуктлар — скипидар һәм канифольне өйрәнә. Бу хезмәтнең гамәли әһәмияте бик зур була, ул сумаладан алына торган скипидарны техникада яңача кулланырга мөмкинлек бирә (А.М.Бутлеров исем. Рус физ.-химия җәмгыяте премиясе, 1928).

1929 елда (А.Е.Арбузов б-н берлектә) триарилметил рәте ирекле радикаллары хасил булу реакциясен ача, фосфор пирокислоталары кушылмалары рәтендә үткәргән тикшеренүләре нәтиҗәсендә дару препараты пирофос һәм пестицид октаметил алына. 1930 елдан терпеннарның химик әверелешләрен тикшерә, тулыланмаган терпеннарның оксидлашу реакцияләренең юнәлешен, аларның оксидларының әверелеш механизмын ача. Бициклик терпеннарның алифатик булып башкача төркемләнүен (башлыча, α-пиненның аллооцименга) ача, $\Delta^3$-карен химиясе буенча тирән эзләнүләр алып бара. Диен синтезы реакциясен кулланып, левопимар кислотасының төзелешен билгели (1940). Бөек Ватан сугышы елларында А. синтетик каучукның салкынга каршы торучанлыгын арттыру, поликонденсацияле мономерларның һәм тиоколларның яңа төрләрен табу ысуллары өстендә эшли. 1945 елдан диен синтезы өлкәсендә эшен дәвам итә. Фосфор тригалогенидларының диеннарга циклләп кушылу реакциясен ача (А.О.Визель б-н берлектә). Нәантихолинэстераз фосфорорганик дару чараларын системалы өйрәнү нәтиҗәсендә мед. практикасына кертелгән *димефосфон* препараты ясала. Берничә гетероатомлы яңа тип гетероциклларны синтезлау ысулларын таба, аларның структурасын һәм үзлекләрен тикшерә (О.А.Ерастов б-н берлектә). Органик һәм элементорганик кушылмаларның төрле классларының төзелеше теориясенә фундаменталь өлеш кертә. А.ның гетероциклы молекулаларның электрон һәм пространстводагы структурасын билгеләү буенча хезмәтләре СССР ФАнең Д.И.Менделеев исем. бүләге б-н бүләкләнә (1949). ТАССР ЮС депутаты, рәис урынбасары (1955–66 еллар), СССР ЮС депутаты (1966–89). СССР Дәүләт бүләге (1951), Ленин бүләге (1978) лауреаты. Биш Ленин ордены, Октябрь Революциясе ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Халыклар Дуслыгы ордены, медальләр, ш.и. фосфор элементы ачылуга 300 ел тулу уңаеннан Париж шәһәренең Мактаулы зур көмеш медале б-н бүләкләнә. Франциянең химия җәмгыяте әгъзасы (1957), Мартин Лютер исем. ун-тның (1972, Галле ш., Германия) шәрәфле докторы, Гданьск ун-ты шәрәфле докторы, Лодзь шәһәренең (1977, Польша Респ-касы) шәрәфле гражданины. 1971 елда Казанда А.Е.Арбузов музей-йорты ачыла (1993 тән *Арбузовлар А.Е. һәм Б.А. музей-йорты*).

Х е з м.: Исследования в области изомерных превращений бициклических терпеновых углеводородов и их окисей. К., 1936; О строении хлорангидрида Бойда // Арбузов А.Е. Избранные труды. М., 1952; О новом методе получения свободных радикалов триарилметильного ряда // шунда ук. С.361–367; Об эфирах пирофосфористой, субфосфорной и пирофосфорной кислот: 1. Этиловые эфиры, получение и свойства // шунда ук. С.377–396; Спектры ядерного магнитного резонанса протонов и строение азинов и фенилгидразонов // Изв. АН СССР. Сер. Химия. 1966. № 1 (автордаш).

*Әд.:* А б р а м о в В.С., А к с ё н о в Н.Н. Борис Александрович Арбузов. К., 1946; П у д о в и к А.Н. Борис Александрович Арбузов // Рассказы о казанских учёных. К., 1983; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

**АРБУ́ЗОВ РЕА́КЦИЯСЕ**, триалкилфосфитларның алкилгалогенидлар б-н реакциягә керүе нәтиҗәсендә фосфонатларга әверелеп төркемләнүе (классик вариант):




Реакциягә алкилгалогенидлар, дүрт хлорлы углерод, α-галоген алмашкан гади һәм катлаулы эфирлар, галогенангидридлар керә. 1905 елда А.Е.*Арбузов* тарафыннан ачыла. Реакция «Арбузовның яңадан төркемләү ысулы» дип тә атала, гомуми характерлы һәм электрофил реагентлар тәэсирендә, өч валентлы фосфор кислоталары тулы эфирларының яңа фосфор-элемент Р-Э (Э=С, N,O,S) бәйләнешен хасил итеп, биш валентлы фосфор кушылмаларына әверелүе буларак билгеләнә ала. Фосфорорганик кушылмалар синтезлауның классик ысулы булып тора. Инсектицидлар табуда, дару һ.б. физиологик актив матдәләр ясауда кулланыла.

*Әд.:* В а ц у р о К.В., М и щ е н к о Г.Л. Именные реакции в органической химии: Справ. М., 1976; М о с к в а В.В. Реакция Арбузова // Александр Ерминингельдович Арбузов: Очерки. Воспоминания. Материалы. М., 1989.

**АРБУ́ЗОВ-БАРА́Н** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 40 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бәрән елгасы буенда. 2002 елда 216 кеше (руслар — 68%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 17 йөз урталарында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Троицкий исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 1779 да А.-Б.да Троица чиркәве төзелә. 20 йөз башында земство уч-щесе, 2 ярма ярдыру, 1 су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 506,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Алан волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә, 1924 тән Чистай кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 297, 1897 дә — 430, 1908 дә — 495, 1926 да — 543, 1938 дә — 354, 1949 да — 168, 1958 дә — 160, 1970 тә — 122, 1979 да — 290, 1989 да — 161 кеше. А.-Б. — атаклы химик А.Е.*Арбузовның* туган авылы.


**АРБУ́ЗОВЛАР**, химик-органиклар. **Александр Ерминингельдович**, А. нәселен нигезләүче (к. *А.Е.Арбузов*). Аның балалары Борис Александрович (к. *Б.А.Арбузов*); **Ирина Александровна** (19.10.1905, Казан – гыйнвар 1989, Мәскәү), химия фән. д-ры (1965). 1929 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1930 дан Ленинградта, Пластмассалар фәнни-тикшеренү ин-тында. 1942 дә Казанга эвакуацияләнә һәм СССР ФАнең Органик химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1944 тән Ленинградта, СССР ФА Органик химия ин-тының синтетик сумалалар лабораториясендә. 1948 дән оештыруда үзе актив катнашкан Югары молекуляр кушылмалар ин-тында, 1958–69 елларда күп функцияле кушылмаларны синтезлау группасы мөдире, 1969–79 елларда оптик үтә күренмәле термочыдам полимерлар лаб. мөдире. Фәнни эшчәнлеген фосфорорганик кушылмаларны өйрәнүдән башлый («О фосфиновых кислотах, содержащих асимметричный фосфор». Журн. Рос. физ.-хим. об-ва, 1929. № 61). Аннан соңгы тикшеренүләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә багышлана. И.А.Арбузова глицидилметакрилат, дивинилацетальләр, күп функцияле кушылмалар полимерлашуы, тулыланмаган кислота эфирларының циклләп полимерлашуы, метилолметакриламидның катлаулы эфирлары сополимерлашуы; реакциягә сәләтле полимерларны синтезлау, полимерларда эпоксид боҗрасының карбоксил группаларга кушылуы реакциясе буенча хезмәтләр башкара. Ереванда җитештерүгә кертелгән винилацетат синтезының гетероген-контакт-



Арбузовлар (сулдан уңга): Ирина Александровна, Юрий Александрович, Борис Александрович һәм Александр Ерминингельдович.

лы ысулын эшли. Гидрофиль полимерлар табу һәм клиник куллану буенча Архангельск мед. ин-тының күз авырулары каф. мөдире С.Н.Фёдоров б-н бергәләп эшләү нәтиҗәсендә 1978 елда күз күрүен төзәтү өчен комбинацияләнгән контактлы линза ясала, ул 1986 елдан Дзержинск шәһәрендә җитештерелә. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХның алтын медале б-н бүләкләнә; **Юрий Александрович** (10.7.1907, Люблин губ. Ново-Александрия ш. — 1.6.1971, Мәскәү), химия фән. д-ры (1953), Казан ун-тын тәмамлый (1930). 1932 елдан Мәскәү ун-тында. Хезмәтләре чиксез углеводородлар катнашындагы катлаулы органик синтезга карый. Олефин углеводородларының термик таркалуын, тулы булмаган циклик кушылмаларның контактлы изомерлашуын өйрәнә. Диен углеводородларының нитрозокушылмалар б-н реакцияләрен; глиоксилат кислотасы эфирлары, карбониль кушылмалар, молекуляр кислород, гетероатомлы диенофиллар б-н диен синтезы; тетрациклин синтезын реакцияләрен тикшерә; ен һәм моноен синтезын (карбониль кушылмалар б-н) өйрәнә. Аневринның хим. табигате, майлар рәтендәге диазокушылмалар катнашында яңа синтезлар, антирахит витаминнары химиясе, Е витаминының химик табигате турындагы мәкаләләре «Успехи химии» ж-лының 1937 (т.6, чыг. 10); 1938 (т.7, чыг. 4, 8); 1939 (т.8, чыг.1) еллардагы басмаларында урын ала. А. Казанның Арча кыры зиратында күмелгәннәр.

**АРБУ́ЗОВЛАР А.Е. ҺӘМ Б.А. МУЗЕЙ-ЙОРТЫ**, Казанда СССР ФА президиумы карары (1968) нигезендә 1916–68 елларда Арбузовлар гаиләсе яшәгән бинада оештырыла. 1971 дә А.Е.*Арбузов* музей-йорты буларак ачыла. 1993 елда Б.А.*Арбузовка* 90 яшь тулу уңаеннан (бу йортта ул 1955 елга кадәр яши) хәзерге исем б-н атала. Музей 19 йөз ахырында төзелгән бер катлы аерым йортны били. Мемориаль зонага ш.у. А.Е.Арбузов утырткан бакча керә. Гомуми мәйданы — 530 *м*², ш.и. 264 *м*² — йорт мәйданы. Музей коллекциясендә 20 меңгә якын экспонат, ш.и. 15 мең төп нөсхә (оригинал) әйбер исәпләнә. Алар *Арбузовларның*, ш.у. К.Л.*Мюфке*, Н.П.*Гречкин* шәхси фондларына бүленә. Музей даими эшләүче өч экспозицияне — шул замандагыча җиһазландырылган торак бүлмәләрне (кунак бүлмәсе, ашханә, йокы бүлмәсе, аш-су әзерләү урыны, Б.А.Арбузовның эш кабинеты), А.Е. һәм Б.А.Арбузовларның фәнни, иҗтимагый, педагогик һәм дәүләт эшчәнлеген чагылдырган тарихи-документаль экспозицияләрне эченә ала. Аның тупланмасында А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар фәнни хезмәтләренең кульязмалары, истәлекләре, илебез һәм чит ил галимнәре — И.П.Бардин, С.И.Вавилов, П.Л.Капица, А.Н.Несмеянов, О.М.Нефёдов, Б.Е.Патон, А.Тодд (Англия), Я.Михальский (Польша) һ.б. б-н язышкан хатлары; автографлар язылган китаплар; А.Е.Арбузов, Н.Е.Арбузова-Мюфке, К.Л.Мюфкеларның сынлы сәнгать әсәрләре; шәхси әйберләрдән А.Е.Арбузовның скрипкасы, Парижда бирелгән Мактаулы зур көмеш



А.Е. һәм Б.А.Арбузовларның Казандагы музей-йорты. 1. Кунак бүлмәсе; 2. Кабинет.

медаль (1969), Казанның шәрәфле гражданы медале һәм таныклыгы, Б.А.Арбузовка Гданьск ун-тының шәрәфле докторы булып сайлангач бирелгән мантия һәм баш киеме һ.б. саклана. Ел саен музей тарафыннан Арбузовларны искә алу көннәре уздырыла. Төрле елларда музей б-н Ф.Г.Вәлитова, В.М.Зороастрова, Н.П.Гречкин, Н.А.Чадаева (җәмәгать эше тәртибендә) җитәкчелек итә. 1986 елдан музей мөдире — Н.М.Гайдукова.

*Әд.:* Академик А.Е.Арбузов в Казани: Буклет. К., 1977; Материалы свода памятников истории и культуры РСФСР. Татарская АССР. М., 1984. Ч. 1; John H. Wottz. Chemistry museums of Europe // Chemtech. 1982. April.

*Н.М.Гайдукова.*

**«АРГАМА́К»**, айлык иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис журнал. Оештыручылары: Чаллы шәһәр хакимияте, журнал редакциясе хезмәткәрләре. 1991 елның октябреннән 2000




нең ноябренә кадәр татар һәм рус телләрендә нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре: А.Хәлим, М.Г.Мортазин, Р.Р.Сабиров, Г.Т.Вәлиев. Журналда, нигездә, җирле авторларның әсәрләре басыла. «А.» редакциясе «Аргамак» журналы китапханәсе» сериясеннән китаплар һәм балалар китаплары бастырып чыгара. Журналның эчтәлеген публицистика, проза, поэзия, Татарстан һәм татар халкы мәдәнияте һәм тарихы буенча мәкаләләр тәшкил итә.

**АРГАМАКЛЫ́ САРА́Й**, урта гасырлардагы (14–15 йөзләр) Алтын Урда шәһәре. Ингул елгасы кушылдыгы Громклейның уң ярында урнашкан була. Археологик калдыклары Украина Респ-касының Николаев өлкәсендә: таш торак йортлар һәм мәчет нигезләре очрый. Риччо Занониның 1772 елда төзелгән картасында А.С. урынында «татар мәчете» дип язылган. Археологик казу-тикшеренү эшләре үткәрелмәгән.

*Әд.:* Эварницкий Д.И. Вольности запорожских казаков. СПб., 1898. Карта 1; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985; Петрунь Ф.О. Нове про татарську Бозько-Дністряньского стену // Східні-світ. 1928. № 6.

**АРГАЯ́Ш РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 2791,3 *км*². Үзәге — Аргаяш авылы (Чиләбедән 56 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 42,6 мең кеше, ш.и. ике меңләп татар. Районда 2 татар авылы бар: Кызыл Бүләк һәм Яңа Юл. 1957 дә «Маяк» җитештерү берләшмәсендә радиоактив матдәләрнең табигый зонага күпләп чыгарылуы сәбәпле, бу ике авыл да радиация нурланышына дучар ителә.

**АРГИЛЛИ́Т** (грек. árgillos — балчык һәм líthos — таш), тыгызлану, сусызлану һәм цементлану нәтиҗәсендә балчыктан хасил булган утырма тау токымы. Кварц, кыр шпаты һәм карбонатлар катнашындагы балчыксыл минераллардан гыйбарәт, 40–60% өлеше 0,01 *мм* дан кимрәк үлчәмле кисәкчекләрдән тора. Балчыклардан аеруча катылыгы һәм суда җебемәүчәнлеге б-н аерыла. ТРда палеозой катламнарында таралган, су үткәрмәүчән катлам нефть һәм газ ятмаларына капкач ролен үти. Цемент, керамзит һәм сирәк очракларда төзелеш керамикасы әзерләү өчен чимал. Гиббсит катнаш каолин А.ларын утка чыдам материал (флинтклей) итеп файдаланырга мөмкин.



Аргиллит. Татар ярусы утырмаларыннан (Тәтеш р-ны).

**АРГУ́НОВКА** т и м е р ю л р а з ъ е з д ы п о с ё л о г ы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 1940 елларда нигез салына. Халык саны: 1958 дә — 68, 1970 тә — 53, 1979 да — 23, 1989 да — 6 кеше.

**АРГУТИ́НСКИЙ-ДОЛГОРУ́КОВ** Пётр Михайлович (26.4.1850, Тифлис — хәзерге Тбилиси — 4.9.1911, Австрия, Рива ш.), балалар табибе, медицина д-ры (1888), проф. (1893). 1879 елда Дерпт ун-тын тәмамлый. 1879–84 елларда хәрби-медицина хезмәтендә, 1885 тән Хәрби-мед. академиясендә. 1888 дән Хатын-кызларның югары мед. курсларында укыта (С.-Петербург). 1893 тән Казан ун-тында профессор, балалар авырулары каф. мөдире. Мед. ф-тында балалар клиникасын (соңрак В.К.Меньшиков исем.) оештыручыларның берсе. Хезмәтләре балаларда калкансыман биз авыруларын ачыклауга һәм билгеләүгә карый. А.-Д. плазмодийлар морфологиясен өйрәнә, Россиянең Европа өлешендә малярия таралу картасын төзи. Клиника лабораториясендәге бактериологик һәм гистологик материаллардан, макро һәм микропрепаратлардан файдаланып, мед. ф-тында пед. процессны оештыруны камилләштерә. Шәкертләре арасында: В.К.Меньшиков, Е.М.Лепский, А.Ф.Агафонов.

Х е з м.: О способе определения азота в органических соединениях. К., 1888.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989. Ч. 1.

**АРГЫ́** посёлогы (Төрнәс совхозының беренче бригадасы посёлогы), Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 31 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 36 кеше (чуашлар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — ТАССР ның Чистай кантоны Егоркино волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1989 да — 88 кеше.

**АРГЫ́ ИВА́НОВКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 58 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасыннан 1 *км* читтәрәк. 2002 елда 317 кеше (руслар — 75%) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә эшли. 1830–40 елларда Баграж-Никольский авылы хуҗасы гв. поручигы И.Г.Рюмин нигез сала. Башта Ивановка дип атала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство уч-щесе, 2 бакалея, 1 икмәк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 732,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостена керә. 1920 дән — ТАССР ның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1859 да — 299, 1897 дә — 669, 1920 дә — 823, 1926 да — 717, 1938 дә — 442, 1949 да — 397, 1958 дә — 372, 1970 тә — 457, 1979 да — 336, 1989 да 320 кеше.

**АРГЫ́ КАБА́Н** (У р т а К а б а н) күле, Казан шәһәре эчендә урнашкан, *Кабан күлләре* системасындагы иң зур күл. Су өслегенең мәйданы 112 *га*. Су күләме 7280 мең *м*³. Озынлыгы 3150 *м*, киңлеге 170 тән 580 *м* га кадәр. Уртача тирәнлеге 6,5 *м*, иң тирән урыны 12,5 *м* (1902 елда — 31 *м*, 1940 та — 23 *м*). Күлнең төньяк өлеше сай — су тирәнлеге 2–5 *м* дан артмый. Килеп чыгышы буенча күл казаны Кабан күлләре системасындагы башка күлләрнеке кебек, Идел елгасының элеккеге юлында карст эшчәнлеге нәтиҗәсендә тирәнәеп барлыкка килгән. Күлнең карст эшчәнлеге нәтиҗәсендә хасил булуын күл төбенең



Аргы Кабан күле.

тигезсезлеге, яр буйлап күзәтелә торган шактый зур тирәнлекләр һәм упкыннар раслый (20 йөз башында сулыкның көньяк-көнбатыш өлешендәге «Шайтан почмагы» култыгы ярында урнашкан «Аркадия» бакчасы корылмалары ишелеп төшә). Күлнең формасы катлаулы, яр сызыгы борылмалы, көнбатыш өлешендә ике тирән култык бар. Төньяк-көнчыгыш яры түбән һәм тигез, монда сай сулы һәм сазланган җирләр күп. Күлнең көньяк-көнчыгыш яры Идел елгасы биек террасасының текә киртләчәнә терәлеп үк диярлек тоташа. А.К. күле Бирге Кабан күле б-н Ботаника ермагы (аның көнчыгыш ярында Зоботаника бакчасы урнашкан; ермакның исеме шуннан) аша кушыла. Күлнең көньяк чиге ннән Иделнең Подувалье култыгы ягына 2 *км* дан артыграк озынлыкта, 8–10 *м* киңлектә, 1–1,5 *м* тирәнлектәге ермак аерыла, аның суы сусаклагыч төзер алдыннан салынган шәһәр инженерлык саклау дамбасы аша Куйбышев сусаклагычына суыртып агызыла (А.К. күленә караганда анда суның исәпләнгән тигезлеге 1,5–2 *м* га биегрәк).

Күлнең суы каты, югары минеральләшкән, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, биоген, органик һәм пычратучы матдәләрнең күп булуы күзәтелә. Күлнең экологик халәте гомумән начар. Аңа автомобиль юлларыннан яңгыр һәм кар сулары, авария очрагында кайбер пр-тиеләрдән сәнәгать һәм хуҗалык сулары агып төшә. 1990 нчы елларда пычратучы агымнар кимeтелә, балчык суыргыч ярдәмендә өлешчә күл төбен ләмнән тазарту эше үткәрелә.

А.К. ТЭЦ-1 дән агып чыккан суларны суыту урыны булып тора; күлгә ике ясалма канал буйлап кайнар су ага, шуның нигезендә бик көчле салкыннарда да акваториянең бу өлешләре боз б-н капланмый. Монда су кошлары (кыр үрдәге һ.б.) кышлый. Күлдә кызылканат, чабак, сазан, җилем балык, алабуга балыклары бар. Су үсемлекләреннән гади курак, киң яфраклы һәм тар яфраклы җикәнбаш күпчелекне тәшкил итә. Күлдә ишү спорты буенча ярышлар уздырыла.

*Әд.:* М о с т а ф и н Р. Кабан күле серләре. К., 1990; Очерки по географии Татарии. К., 1957; М и н г а з о в а Н.М., К о т о в Ю.С. Казанские озёра. К., 1989.

*Н.М.Минһаҗева.*

**АРГЫ́ ЯМА́Ш** (Ямаш) авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 65 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2002 елда 866 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Сөт комб-ты. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1716 дан мәгълүм. 19 йөзнең 1 нче яртысында А.Я. — математик Н.И.Лобачевскийның утары. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, балта эше, түбә ябу б-н шөгыльләнә, сату итә. 20 йөз башында Христово-Рождество чиркәве (1879–1887 дә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе, 2 сыраханә, шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете эшли; базар, һәр елның февраль аенда ярминкә була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4686 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән Ямаш р-ны үзәге, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 280 ир заты; 1859 да — 1244, 1897 дә — 2044, 1908 дә — 2346, 1920 дә — 2457, 1926 да — 2111, 1989 да — 705 кеше.

**АРГЫ́Н**, 15–18 йөзләрдә Казан, Касыйм һәм Кырым ханлыкларында идарәче ыругларның берсе. Ыруг вәкилләре ханнар диванына (идарәсенә) кергән ыруглар арасында дәрәҗәләре һәм йогынтылары буенча *Ширин-нәрдән* генә калышканнар. Татар ханлыклары Россия тарафыннан яулангannан соң (16–18 йөзләр), А.нар сәясәт мәйданыннан төшеп кала.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследования о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; И с х а к о в Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени. К., 1998.

**АРДА́РОВ** (Богданович) Григорий Павлович (28.3.1888, Одесса ш. — 17.2.1956, Казан), драма актёры, режиссёр, ТАССР һәм РСФСРның халык артисты (1939, 1954). 1908 елда Одесса театр мәктәбен тәмамлагач, Ростов-Дон шәһәрендәге Н.И.Собольщиков-Самарин антрепризасына керә. Харьков, Баку, Тифлис, Ярославль, Әстерхан те-

атрларында эшли, 1916–23 тә Одессада, бер үк вакытта режиссёрлык б-н шөгыльләнә башлый. 1936 елда Казанга күчеп килә. Рус театры романтик мәктәбенең иң югары казанышлары үрнәгендә тәрбияләнгән оста; башкалардан аерылып торган кыяфәткә, интонацияләргә бай тавышка ия була. Казан труппасы актёрлары арасында әйдәп баручы урын ала. Казан Зур драма театры сәхнәсендә уйнаган беренче рольләре үк — Командир («Оптимистик трагедия», В.В.Вишневский, 1936), Вурм («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер, 1937), Пушкин («Пушкин», А.П.Глоба, 1937), Отелло («Отелло», У.Шекспир, 1938), Уриэль Акоста («Уриэль Акоста», К.Гуцков, 1939) аның күпкырлы талантка ия булуын, форма б-н эчтәлекне үзара оста бәйләвен, образны ачканда аның характерына тирән үтеп керә белүен, героеның кыланышларын психологик яктан нигезләвен, тышкы хәрәкәтләрне тәэсирле итеп чагылдыруын күрсәтә. А.ның Арбенин образын тудыруы («Маскарад», М.Ю.Лермонтов, 1940, 1943) театр сәнгатендә зур вакыйга буларак кабул ителә. Башкалардан аерылып торган шәхеснең әхлаксыз, принципсыз өске катлау вәкилләре б-н бәрелешүе драмасы А. башкаруында художник б-н гавам арасындагы трагик мөнәсәбәтләрне мәңгелек проблема дәрәҗәсенә күтәрә. А.ның Борис Годунов ролен («Патша Фёдор Иоаннович», А.К.Толстой, 1940) башкаруы үзенең оригинальлеге б-н аерылып тора, актёр дәүләт кешесенең эшчәнлеге барыннан да элек ил мәнфәгатьләреннән чыгып башкарылырга тиешлеген күрсәтергә омтыла. Иван Грозный образын тудырганда да («Бөркет һәм ана бөркет», А.Н.Толстой, 1945) нигезгә шуңа охшаш идея салына. А. башкаруында патша образы мәһабәт, трагик ялгыз фигура буларак күз алдына килеп баса. Бу елларда совет тарихчыларының Иван Грозный шәхесен идеологик принциптан чыгып бәяләүләренә ияреп, актёр да конфликтның авырлыгын, патшаның шәхси сыйфатларыннан бигрәк сәяси каршылыклар өлкәсенә күчереп күрсәтергә, пьесаның авторы кебек үк, аның залимлыгын әйләнә-тирә даирәнең рухи торгынлыгы һәм консерватизмы б-н акларга омтыла. Бу елларда актёр режиссёрлык эше б-н актив шөгыльләнә, 1940–41 елларда ул Казан Зур драма театрының баш режиссёры һәм сәнгать җитәкчесе. А.ның Л.Н.Рахмановның «Профессор Полежаев», О.Бальзакның «Үги ана» («Мачеха», 1938), Н.В.Гогольнең «Ревизор» (1939), А.К.Толстойның «Фёдор патша» («Царь Фёдор Иоаннович», 1940), И.С.Тургеневның «Дворяннар оясы» («Дворянское гнездо», 1941), К.М.Симоновның «Рус кешеләре» («Русские люди», 1942) әсәрләре буенча куелган спектакльләре идеянең төгәллеге, форманың ачыклыгы һәм авторның әсәргә салынган фикерен максималь рәвештә ачарга омтылуы, зур актёрлык казанышлары, гадәттән тыш педагогик сәләте б-н аерылып тора.


Г.П. Ардаров.

1940 елларда А.ның осталыгы, хисләрнең романтик күтәренкелеген саклаган хәлдә, зур психологик тирәнлек һәм масштаблылыкка ирешә. Аның уйнавында Каренин («Анна Каренина», Л.Н.Толстой, 1948) каршылыклы трагик фигура булып күренә; үзендә горур, көчле стихияне һәм бер үк вакытта бөтенләй максатсыз, файдасыз бунтны гәүдәләндергән Сатин («Тормыш төбендә», М.Горький, 1949); сурәтләү чараларын оста куллану нәтиҗәсендә гротесклы фигура булып килеп баскан, мәгънәсез мал туплау, акча, хәтта чүп-чар җыюга кадәр барып җиткән Плюшкин («Үле җаннар», Н.В.Гоголь, 1952) шундый образлардан. Актёр хәзерге заман драматургиясендә эчке кичерешләргә бай, ышандырырлык образлар тудыра. Генерал Горлов («Фронт», А.Е.Корнейчук, 1942), Таланов («Ябырылу», Л.М.Леонов, 1943), проф. Добротворский («Намус законы», А.П.Штейн, 1948), Казан шәһәр оборонасы штабы башлыгы Орлов («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт, 1950), Георгий Димитров («Лейпциг, 1933», Л.В.Компанеец, Л.И.Кронфельд, 1951) рольләрен башкарганда А. эчке темпераментының тышкы гәүдәләнеше беркадәр идеаллашса да, асылда уңай, гуманистик идеяләрне чагылдыручы замандаш образын гәүдәләндерүгә ирешә. А.ның Казан театры сәхнәсендә тудырган соңгы роле Король Филипп («Дон Карлос», Ф.Шиллер, 1955) образы үзенең трагик көче б-н гаҗәпләндерә. А. рус реалистик театр сәнгатендә героик-романтик традицияләрнең күренекле вәкилләреннән берсе. Хәтта көнкүрешне сурәтләүче, характерлы рольләрдә уйнаганда да, үз геройларын көндәлек гадәти тормыштан өстен итеп күрсәтеп, игътибарны әхлакый, рухи проблемаларга юнәлтә, үз сәнгате б-н заманының рухи һәм эстетик идеалларын тудыра белә, шул рәвешле театр сәнгатендә тирән эз калдыра.

Г.П. Ардаров: 1. Каренин («Анна Каренина», Л.Н.Толстой), 2. Вершинин («Өч кыз туган», А.П.Чехов), 3. Сатин («Тормыш төбендә», М.Горький) рольләрендә.







Башка рольләре: Войницкий («Ваня абзый», А.П.Чехов), Багратион («Фельдмаршал Кутузов», В.А.Соловьёв), Кречинский («Кречинскийның туе», А.В.Сухово-Кобылин), Репетилов («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Великатов («Талантлар һәм аларга баш иючеләр», А.Н.Островский), Вершинин («Өч кыз туган», А.П.Чехов), Захар Бардин («Дошманнар», М.Горький), Матвеев («Үз балаларының әнисе», А.Н.Афиногенов). А. куйган спектакльләр: «Куркыныч суд» («Страшный суд», В.В.Шкваркин, 1940), «Көт мине» («Жди меня», К.М.Симонов, 1943), «Караңгыда очрашу» («Встреча в темноте», Ф.Ф.Кнорре, 1944), «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр» («На всякого мудреца довольно простоты», А.Н.Островский, 1946). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**АРДАШИ́Р** бине Ишгали Чалкавый-Болгари (19 йөз), шагыйрь. «Кыяфәтнамә. Рисаләт фи бәйан кыяфәте җенсел-инсан» («Кешенең тышкы кыяфәте турында рисалә», К., 1858) исемле әсәр авторы. Фарсы телендәге оригиналына таянып язылган. Тезмә өлеше кешенең тышкы кыяфәтендәге физиологик сыйфатларны тасвирлауга багышланган, чәчмә өлешендә һиҗри ел айларының әһәмияте һәм аларга туры килә торган мөселман бәйрәмнәре, атнаның кайсы көннәрендә нинди эшне эшләргә рөхсәт ителә, нинди эшне эшләүнең тыелуы турында мәгълүматлар бирелә. А.ның иҗаты һәм тәрҗемәи хәле аз өйрәнелгән.

*М.В.Гайнетдинов.*

**АРДАШИ́РОВА Өммегөлсем** Тәлгать кызы (7.4.1951, Уфа ш.), педагог, пед. фән. д-ры (1994), проф. (1995). 1973 елда Башкорт ун-тын тәмамлаганнан соң, Уфа шәһәре мәктәпләрендә укыта, 1978–2005 тә Башкорт пед. ун-тының эстетик белем бирү кафедрасында, 1999–2002 дә каф. мөдире. 2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-тының сынлы сәнгать һәм дизайн ф-ты деканы, бер үк вакытта сәнгать теориясе һәм сәнгать белеме каф. мөдире. Хезмәтләре укучыларның эстетик һәм рухи культурасын формалаштыру мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Эстетическая категория «катарсис» в педагогике. М., 1994; Основы культуры и этики учителя. М., 1997; Интеграция музыкального искусства с естественно-математическими и гуманитарными науками в педвузе: Краткий историко-теоретический очерк: классика и современность. М., 2001.

**АРДУА́НОВ** Мирсәет (1888, Уфа губ., Минзәлә өязе Иске Кормаш а. — 1959), Березники химия комб-ты төзелешендә җир казучы-бетончылар удар бригадасы бригадиры (Пермь өлкәсе). 1910–12 елларда Минзәлә шәһәрендә — кирпеч з-дында, 1912–14 тә Идел, Кама пристаньнарында эшли. 1918–21 дә Кызыл Армиядә, Гражданнар сугышында катнаша. 1927 дән Березники хим. комб-ты төзелешендә (1928–35 тә бригадир, 1935–41 дә бетон эшләре остасы). 7 нче (1935), 8 нче (1936) Бөтенсоюз Советлар съездына делегат итеп сайлана. 1934–36 да СССР ҮБК әгъзасы. 1934 тә Уралның удар бригадалары, стахановчы-химиклар киңәшмәләрендә катнаша. Березники шәһәрендә беренче каһарман төзүчегә бюст куела (1968). 1973 тә Пермь өлкәсендә төзүчеләр арасында соц. ярышларда җиңүчеләр өчен М.Ардуанов исем. бүләк булдырыла. Березники шәһәрендәге урамга А. исеме бирелә. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Наш труд не пропал даром // Говорят строители социализма. М., 1959.

*Әд.:* А х у н о в Г. Ардуан батыр. К., 1974; Уральская советская энциклопедия. М.-Свердловск, 1933. Т. 1; П а у с т о в с к и й К. Соль земли // Люди страны чудес. Пермь, 1965; История индустриализации Урала (1926–1932 гг.): Док. и материалы. Свердловск, 1967; Памятники истории и культуры Пермской области. Пермь, 1976; А х у н о в Г. Сочинения. К., 1982. Т. 2.

**АРЕА́Л** (лат. area — мәйдан, киңлек) (биол.), нинди дә булса үсемлек яисә хайваннарның төре, ыругы, семьялыгы таралган һәм тулы яшәү циклы үтә торган терр-я яисә акватория. А. мәйданы — бөтен Җир өслегеннән алып аның зур булмаган өлешләренә кадәр нык үзгәрергә мөмкин. Зур А.лар биләүче организмнар — космополитлар, аерым өлешләрдә яшәүчеләр — эндемиклар дип атала. А. чикләрен табигый объектлар (таулар, елгалар), ш.у. климат, туфрак, организмнар өчен азык булу һ.б. факторлар билгели. Табигый, ягъни табигый юл б-н формалашкан һәм ясалма (культиген), ягъни кешенең хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән А.лар була. Хайван һәм үсемлек А.лары *акклиматизация* һәм *антропоген тәэсир* нәтиҗәсендә нык үзгәрергә мөмкин. Үсемлек һәм хайваннарның күп төрләре үзләренең беренчел А.лары чикләреннән тыш та киң таралган. Мәс., элек фәкать Ерак Көнчыгышта гына очраган янутсыман эт, ш.у. Америкадан кертелгән ондатра һәм чәшке яңа яшәү урыннарына җайлаша һәм Россиянең күп районнарына тарала. Татарстанда ш.у. дала көзәне, сөркә һәм элек бөтенләй бетү чигенә җиткән кабан дуңгызының А.лары киңәя бара. Шул ук вакытта, антропоген тәэсир нәтиҗәсендә яшәү шартлары үзгәрү сәбәпле, хайваннар (җофар, кара ләкләк, рус осётры, хариус, подуст, кайбер күбәләк төрләре һ.б.) һәм үсемлекләр (эре чәчәкле тәңкәяфрак, бүлбеле кырлы борчак, сары җитен, урман җилдәге һ.б.) дөньясының кайбер вәкилләренең А.лары даими рәвештә тарая бара. Сирәк очрый һәм юкка чыгып бара торган үсемлек һәм хайван төрләренең А.ларын саклап калу өчен махсус статуска ия булган, аеруча саклаулы табигать терр-яләре игълан ителә (к. *Хайваннар дөньясы, Үсемлекләр дөньясы*).

*Әд.:* Т о л м а ч ё в А.И. Основы учения об ареалах. Л., 1962; Ареалы растений флоры СССР: В 3 вып. Л., 1965–76; Ареалы деревьев и кустарников СССР: В 3 т. Л., 1977–86.

*С.И.Кадошников.*

**АРЕА́ЛЬ ЛИНГВИ́СТИКА** (лат. area — мәйдан, киңлек, lingva — тел), тел белеме тармагы; телләр һәм тел күренешләренең таралу өлкәсен, ш.у. ареалдаш телләрнең үзара йогынты ясау закончалыкларын өйрәнә. А.л. диалектологик тикшеренүләргә турыдан-туры бәйләнгән тармак булып тора. «Ареаль лингвистика» төшенчәсен фәнгә беренче булып итальян тел белгечләре Дж. Бартоли һәм Дж. Видосси кертә (1943). Хәзерге А.л. мәсьәләләре төрле телләр — һинд-европа (Э.А.Макаев), славян (П.А.Бузук), герман (В.М.Жирмунский), фин-угыр (Б.А.Серебренников), төрки (Н.З.Гаджиева), балкан телләре (А.В.Десницкая) материалында тикшерелә. Татар теле белгечләреннән А.л. б-н Л.Т.Мәхмүтова, Д.Г.Тумашева, Р.Г.Әхмәтьянов, Ф.Й.Йосыпов, Д.Б.Рамазанова һ.б. шөгыльләнә. Идел буе, Урта Азия, Кавказ, Себер төрки телләрнең таралу ареаллары булып тора. Алар бер-берсе б-н тыгыз бәйләнештә. Мәс., Идел буе һәм Урал алды төбәге төрки телләре (татар, чуаш, башкорт) Кавказ (әзәрбайҗан, кумык, нугай, балкар һ.б.), Урта Азия һәм Казакъстан (үзбәк, төрекмән, казакъ, кыргыз, каракалпак, уйгыр), Себер (якут, алтай, хакас, тува, шор һ.б) телләре б-н үзара бәйләнгән. Татар теле мари, удмурт, чуаш, мордва һәм рус телләре б-н тарихи бәйләнештә тора. Географик яктан якын ареалларда үзара аралашу нигезендә телләрдә яңа, икенчел үзенчәлекләр барлыкка килә. А.л. *лингвистик география* б-н да тыгыз бәйләнгән.


*Әд.:* М а к а е в Э.А. Проблемы индоевропейской ареальной лингвистики. М.–Л., 1964; С е р е б р е н н и к о в Б.А. О некоторых отличительных признаках Волгокамского языкового союза // Языковые контакты в Башкирии. Уфа, 1972; Г а д ж и е в а Н.З. Проблемы тюркской ареальной лингвистики. М., 1975; А х м е т ь я н о в Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981.

*В.Х.Хаков.*

**АРЕ́НДА** (поляк. arenda, лат. arendare — хак алып, вакытлыча файдалануга биреп тору), мөлкәт, җир, табигать ресурсларына һәм пр-тиеләргә билгеле бер түләү хакына вакытлыча ия булу һәм алардан файдалану. Озак вакыт файдаланыла торган мөлкәти әйберләр генә А.га бирелергә мөмкин. А. хосусый милекчелек килеп чыккач кына гамәлгә керә. 1917 елдан Җир турындагы декрет буенча җирне А.га бирү туктатыла. СССРда аренда мөнәсәбәтләре, аерым алганда, дәүләт пр-тиеләрен, җитештерү чараларын һәм җирне А.лау яңа икътисади сәясәт елларында кабат торгызыла. Авыл хуҗалыгы өчен билгеләнгән җирләрне А.лау 1937 елда тулысынча бетерелә. СССРда дәүләт пр-тиеләре (оешмалары) арасында А. шартнамәсе төзелеп корылмалары һәм кеше яшәми торган биналар өчен — 5, җиһазлар һ.б. төр мөлкәт өчен бер елдан да артык булмаган вакытка төзелә. 1965 елдан җирле советлар карамагындагы биналарны һәм корылмаларны А.га бирү рөхсәт ителә. 1990 елларда радикаль икътисади реформалар башлану б-н сәнәгать һәм а.х.да, пр-тиеләр һәм аларның структур бүлекләрендә, хезмәтне оештыру һәм аңа түләү формасы буларак, хуҗалык эчендә аренда подряды барлыкка килә. 1992 елда ТР Дәүләт мөлкәтен идарә итү дәүләт комитетының «Дәүләт һәм коммуналь мөлкәтне арендалау турындагы нигезләмә»се кабул ителгәч, ТРда халык хуҗалыгының барлык тармакларында А. рөхсәт ителә. Пр-тиеләр, бина, җиһаз, транспорт чаралары, инвентарь һ.б. матди байлыклар А.га бирелергә мөмкин. ТР Җир кодексында әйтелгәнчә, җир кишәрлекләре, ш.и. а.х. җирләре, файдалану максатын үзгәртмичә, А.га бирелә. Дәүләт һәм коммуналь милек б-н эш итә торган вәкаләтле органнар — арендага бирүчеләр, пр-тиенең хезмәт коллективы, башка гражданнар, юридик затлар, ш.и. чит илнекеләр, арендага алучылар була. А. хакы мөлкәт өчен аны файдаланудан алынган табышның бер өлешен һәм амортизация чыгымнарын, ә җир өчен — җир салымын һәм җирдән файдаланудан алынган керемнең бер өлешен үз эченә ала. Арендаланган милектән файдалану нәтиҗәсендә алынган продукция һәм керем арендаторның хосусый милке булып санала. Гражданнарның хосусый милкендәге мөлкәтне А.га бирү РФ Гражданнар кодексы б-н көйләнә. Ш.у.к. *Лизинг*.

*Әд.:* Б у з д а л о в И. Арендные отношения в сельском хозяйстве // АПК: экономика, управление. 1998. № 5.

*Г.Х.Хәбибрахманов.*



А.В. Арестов.

**А́РЕСТОВ** Анатолий Васильевич (17.1.1922, Башкортстан АССРның Дуан р-ны Сальевка а.), нефтьче-инженер, Соц. Хезмәт Герое (1971). Мәскәү нефть һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1968). 1954–80 елларда «Татнефть» җитештерү берләшмәсендә нефть һәм газ чыгару операторы, нефть промыселы инженеры, скважиналарны җир астында ремонтлау мастеры, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча өлкән инженер. Соц. Хезмәт Герое исеменә нефть табу буенча 8 нче бишьеллык (1966–70) планы йөкләмәләрен үтәүдә зур хезмәтләре һәм югары икътисади-техник күрсәткечләре өчен лаек була. Бөек Ватан сугышында катнаша. 383 сугышчан очыш ясый. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан һ.б. орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М и р о л ю б о в а И. Арестов Анатолий Васильевич // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг): Док. очерки К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой славы — наши земляки. К., 2003.

**АРЖА́НОВ** Николай Николаевич (10.3.1913, хәзерге Кострома өлкәсенең Кологривск р-ны Вокшево а. — 7.2.1976, Казан), Сов. Союзы Герое (1.5.1957), очу-



Н.Н. Аржанов.



Ф.С. Аристов.

чы-сынаучы. ВЛКСМның Кологрив райкомында, аннан соң Казан авиация з-дында эшли. 1937 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казанның 124 нче авиация з-дында очыш-сынау станциясенең әйдәп баручы инженеры, башлыгы булып эшли. 1941 дән Казанның 22 нче авиация з-дында: очыш-сынау станциясе башлыгы, очучы-сынаучы (1944 тән), инженер (1964 тән). Беренче серияле Ту-4, Ту-16, Ту-22, Пе-2 бомбардировщикларын очышта сыный. Герой исеме яңа авиация техникасын сынаганда күрсәткән батырлыгы өчен бирелә. СССРның атказ. очучы-сынаучысы (1961). Ленин, ике Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

**А́РИСТОВ** Вячеслав Васильевич (16.6.1937, Спас, хәзерге Болгар ш. — 12.6.1992, Казан), библиограф, төбәк тарихын өйрәнүче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1960). 1960 елдан Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсендә фәнни хезмәткәр, 1965 тән кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире. Хезмәтләре 19 йөз — 20 йөзнең 1 нче чирегендә Казанның мәдәни, әдәби тормышына, Казан ун-ты һәм аның Фәнни китапханәсе тарихына карый. «Лобачевский Н.И. Фәнни-педагогик мирасы. Казан университеты белән җитәкчелек итүе. Фрагментлар. Хатлар» («Лобачевский Н.И. Научно-педагогическое наследие. Руководство Казанским университетом. Фрагменты. Письма», М., 1976) җыентыгын төзүдә катнаша. «Антарктида тирәли 2 тапкыр йөзү» («Два плавания вокруг Антарктиды», 1990) җыентыгында беренче тапкыр И.М.Симоновның 1819–21 елларда Җир тирәли ясалган сәяхәтен тасвирлаган «Көнчыгыш» («Восток») һәм «Тынычлык» («Мирный») язмаларын бастыра.

Х е з м.: Подарок декабриста. К., 1970; Всё началось с путеводителя: Поиски литературные и исторические. К., 1975 (автордаш); История Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского (1804–1850). К., 1985 (автордаш); Казанские находки. К., 1985.

*Әд.:* Ш и ш к и н В.И. Краевед, книговед, библиофил // Библ. вестн. 1997. № 2.

*В.И.Шишкин.*

**А́РИСТОВ** Евмений Филиппович (1806 — 26.10.1875, Казан), анатом, медицина д-ры (1834), проф. (1835). 1830 елда Мед.-хирургия академиясенең Мәскәү бүлеген тәмамлый. 1833 тән Казан ун-тында инспектор ярдәмчесе, анатомия прозекторы. 1835 тән адъюнкт-профессор, 1837–66 да экстраординар профессор һәм анатомия каф. мөдире. Казан ун-тының *Анатомия театрын* оештыручыларның берсе. Хезмәтләре кеше анатомиясенә, баш сөяге һәм нерв системасы төзелешенә, канның физиологик үзенчәлекләренә багышлана.

1867 елда А. ун-тның шәрәфле әгъзасы итеп сайлана, аның исемендәге стипендия билгеләнә, А. портреты бүгенгәчә Анатомия театрында саклана.

Х е з м.: О значении внешности человека: Актовая речь. К., 1846; О способе происхождения красного слоя крови на печёнке. К., 1856.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**А́РИСТОВ** Кирилл Владимирович (31.1.1939, Казан — 15.12.1992, шунда ук), кинооператор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). 1975 елда Казан ун-тының журналистика ф-тын тәмамлый. Куйбышев кинохроника студиясенең Казандагы корреспондент пунктында оператор ярдәмчесе булып эшли. 1960 тан Казан телевидение студиясендә оператор ассистенты, оператор, 1990 нан ТР Кинематографистлар берлегенең Таткиновидеоүзәге операторы. Хроникаль-документаль телевизион фильмнар төшерә, эчке кадрлар монтажы сәнгатен үзләштерә, кадрларның күп планлы корылышы аның фильмнарына үзенчәлекле бөтенлек, эчке бердәмлек һәм тирәнлек бирә. Ул төшергән «КамАЗ башлана» («КамАЗ начинается», 1971), «КамАЗ бригадирлары» («Бригадиры КамАЗа», 1972), «КамАЗ. Буыннар тууы» («КамАЗ. Рождение династии», 1977), «Николай Лемаевның эше һәм мәшәкатьләре» («Дела и заботы Николая Лемаева», 1980), «Кама трактор заводы. Биографиянең башлануы» («Камский тракторный. Начало биографии», 1986) фильмнары ТР кинодокументалистикасының тарихи фондын тәшкил итә.

**А́РИСТОВ** Николай Яковлевич (1.12.1832, Тамбов губ., Липецк өязе Стеньшино а. — 26.8.1882, Чернигов губ. Нежин ш.), тарихчы, публицист, рус тарихы д-ры (1871), хакыйкый статский советник (1882). Тамбов руханилар семинариясен (1854) һәм Казан руханилар академиясен (1858) тәмамлый. 1858–61 елларда Сембер руханилар семинариясендә укыта. 1861 дә руханилыктан китә. С.-Петербургка күчеп килә, аерым кешеләргә дәрес бирү б-н шөгыльләнә. Археология комиссиясе һәм Рус геогр. җәмгыяте эшләрендә катнаша, «Отечественные записки», «Древняя и новая Россия», «Исторический вестник» һ.б. ж-лларга публицистик мәкаләләр яза. Казан ун-тында 1866 да — магистрлык, 1871 дә докторлык диссертацияләре яклый. 1867–69 елларда Казан ун-ты доценты, 1869–73 тә Варшава ун-тында экстраординар (1869–71) һәм ординар профессор, 1873–75 тә Харьков ун-тында, 1875 тән Нежин тарих-филол. ин-тында ординар профессор. А.П.Щаповның народниклар хәрәкәтенә һәм мәгърифәткә караган карашларын яклый, аңа багышлап хезмәт яза. Славянофиллар идеясенә якын җирлелек традицияләрен хуплый. Рус фольклорын, Россия халкы тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен һәм халык кузгалышлары тарихын өйрәнә.

Х е з м.: Взгляд русских летописцев на события мира. К., 1859; Хрестоматия по русской истории для изучения древнерусской жизни, письменности и литературы от начала письменности до 16 в. Варшава, 1870; Состояние образования России в царствование Александра I. Киев, 1879; А.П.Щапов: Жизнь и сочинения. СПб., 1883; Первые времена христианства в России по церковно-историческому содержанию русских летописей. СПб., 1888.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Русские писатели 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1989. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**АРИ́СТОВ** Фёдор Сергеевич (8.10.1912, Рига ш. — 27.1.2005, Казан), Казан вертолётлар төзү з-ды директоры (1961–75), Соц. Хезмәт Герое (1971). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1954). 1931–34 елларда Воронеж авиация з-дында техник, цех башлыгы урынбасары булып эшли. 1934–61 дә Казан авиация з-дында: цех башлыгы, производство башлыгы урынбасары. 1961–93 тә Казан вертолётлар җитештерү берләшмәсендә: 1975 тән өлкән инженер, бүлек башлыгы урынбасары. А. җитәкчелегендә завод пешкәкле двигательле вертолётлар җитештерүдән турбовинтлы машиналар җитештерүгә күчә, завод яңадан җиһазландырыла, Ми-8, Ми-14 вертолётларын эшләп чыгаруда яңа технологияләр кертү гамәлгә ашырыла. Ике Ленин ордены, өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М о р о ш е к Е.М. На вертикальном взлёте. К., 1990; Ф а х р у т д и н о в Д. Директор // Советская Татария. 1992. 3 сент.; ш у л у к. Из твёрдого сплава // Республика Татарстан. 1997. 23 окт.; Казанские вертолёты: полёт продолжается. К., 2000.

**АРИСТО́ВСКИЙ** Вячеслав Михайлович (5.12.1882, Чистай ш. — 4.5.1950, Мәскәү), микробиолог, иммунолог, медицина д-ры (1912), СССР МФА академигы (1945), мед. хезмәте генерал-майоры, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1945). 1908 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. 1909 дан Казан ун-ты каршындагы Бактериология ин-тында, 1916 дан Эпидемиология һәм микробиология ин-тында (Петроград), 1918–32 елларда Казан ун-тында, 1920 дән профессор һәм микробиология каф. мөдире. Бер үк вакытта ГИДУВның шул исемдәге каф. мөдире. 1925–30 да ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты каршында аның тырышлыгы б-н ачылган Төбәк микробиология ин-ты директоры. 1932 дән Хәрби-мед. академиясенең (Ленинград) микробиология каф. башлыгы. А. фәнни эшчәнлеген 1909 елда И.Г.Савченко җитәкчелегендә Бактериология ин-тында башлый. 1916 да Кронштадттагы «Александр I» фортында чумага каршы препарат эшләү лабораториясенә командировкага җибәрелә, анда проф. Е.С.Лондон җитәкчелегендә столбняк (йогышлы тартышу) авыруына каршы антитоксин сыркындысы әзерләнә, столбняк токсинының актив фракциясен бүлеп чыгару ысулы эшләнә. Тикшеренүләре йогышлы авырулар микробиологиясе, иммунологиясе, патогенезы:

кайтма һәм тимгелле тиф, дифтерия, скарлатина, туберкулёз, сифилис авыруларын өйрәнүгә карый. Боррели культурасын саклау һәм үстерү өчен А.ның кайтма тиф б-н авыручы кеше каныннан алынган спирохетлар (махсус мохит булдыру) үрчетүне җәелдерү эшләре, кайтма тиф патогенезын һәм иммунитетын өйрәнүе б-н аеруча уңыш казана. Иммунитетның кайтма тиф вакытында үзенчәлеге трипонемаларда антиген төзелешенең гадәттән тыш төрле һәм үзгәреп торучанлыгы б-н бәйле икәнен исбатлый. А.ның дифтерия, скарлатина һәм туберкулёзны өйрәнүгә караган хезмәтләре дә иммунологиягә бәйләнгән. Ярадагы, бигрәк тә анаэроб йогышлы авыруларның микробиологиясен һәм иммунологиясен, санитар бактериологияне өйрәнүгә зур өлеш кертә. Аның тарафыннан анаэробиозның теоретик мәсьәләләре, патоген клостридийларын үстерү техникасы һәм анаэроб йогышлы авыруларга бактериологик анализ үткәрү этаплары, столбняк һәм куыклы йогышлы шешләр патогенезы һәм иммунитеты, бу авыруларны булдырмауның махсус ысуллары һәм дәвалау юллары эшләнә. Анаэробларны аз кислородлы мохитта үстерү приборы (Аристовский анаэростаты) кафедрада эшләнә һәм 1937 елдан дөньядагы барлык бактериологик лабораторияләрдә кулланыла. А. йогышлы авыруларга бактериологик диагноз кую буенча фронт лабораторияләре өчен гамәли кулланма төзи. Хәрби-мед. академиясе һәм Ленинград фронтының эвакогоспитальләре өчен бактериологик тикшеренүләр үткәрә. А. Ленинград хәрби округы мед. хезмәтендәге һәм Баш хәрби-мед. идарәсендәге гаскәрләрдә йогышлы авырулар булдырмау мәсьәләләре буенча даими консультант була.



В.М. Аристовский.

Х е з м.: Новая питательная среда для культивирования спирохет Obermeiera // Казан. мед. журн. 1925. Т. 21, № 7–8; О некоторых основных законах возникновения, развития и угасания эпидемий // Казан. мед. журн. 1929. Т. 25, № 2; Медицинская микробиология. Л., 1945.

*Әд.:* К о р о л ю к А.М. К 100-летию со дня рождения Вячеслава Михайловича Аристовского // Журн. микробиологии, эпидемиологии, иммунологии. 1983. № 3.

**«АРКА́ДИЯ» БАКЧАСЫ́**, 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казан халкының җәй айларында ял итә торган урыны. Аргы Кабан күленең көньяк-көнбатыш яры буенда урнашкан була. Казан губернаторы Н.Е.Андреевскийның элекке дача биләмәсендә 1895 елда утыртылган бакчада җәйге театр, башка төр күңел ачу урыннары була, спорт ярышлары уздырыла, оркестр уйный, фейерверклар оештырыла. 1920 еллар ахырына кадәр эшли.



«Аркадия» бакчасы. 20 йөз башы фотосы.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895.

**АРКАТА́У** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 20 *км* төньяктарак, Ия елгасы буенда. 2002 елда 23 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Беренче алпавытлар арасында дворяннар Пётр һәм Иван Аркатовлар (авылның исеме шуның б-н бәйле) була. 1746 да А.да архит-ра истәлеге — Смоленск Богородица чиркәве (хәзерге көндә дә эшли) төзелә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, монда арыш салаты оны җитештерү, май з-длары, 1 ярма ярдыру һәм 3 җил тегермәне була. 20 йөз башында А.да земство мәктәбе, 2 җил тегермәне, 2 икмәк, шәраб, 2 сыра һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 296 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 186 ир заты; 1859 да — 272, 1897 дә — 389, 1908 дә — 382, 1920 дә — 371, 1926 да — 435, 1949 да — 239, 1958 дә — 182, 1970 тә — 149, 1979 да — 70, 1989 да — 34 кеше.



Аркатау авылы.
Смоленск Богородица чиркәве. 1746.

**АРЛА́Р**, Нократ, Чыпца елгалары тирәлегендә урта гасырларда яшәгән фин-угыр кабиләләренең җыелма атамасы. Төрки халыклар әйтелешендәге «ар» — «ир»гә (кеше) нисбәтле атама дип фаразлана. Идел буе Болгар дәүләте чорыннан мәгълүм. А. 12 йөздә Казансуның югары агымы буйларында да яшәгән, Идел буе Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында төрки мөселманнар йогынтысында этник үзгәреш кичергәннәр. Бу төбәк соңрак «Арская земля» дип тә йөртелгән. А.ның бер өлеше руслар тарафыннан яуланган *Нократ җиренә* кергән. А.ның этник нигезен фин-пермь һәм угыр телләрендә сөйләшүче ыруг-кабиләләр тәшкил иткән, дип уйланыла. Кайбер удмурт галимнәре карашынча (В.Е.Владыкин, М.Г.Иванова һ.б.), А. хәзерге көньяк удмуртларның бабалары булырга тиеш; элекке Арча даругасында яшәүче А.ны да (рус язмаларындагы «аряне», «арские люди», «арские князья») өлешчә борынгы удмуртлар дип исәпләргә кирәк. Элегрәк татарлар Арча ягы кешеләрен, ш.и. удмуртларны да А. дип атаганнар.

Чыг.: Путешествие Абу Хамида аль-Гарнати в Восточную и Центральную Европу. М., 1971.

*Әд.:* Г е н и н г В.Ф. Археологические памятники Удмуртии. Ижевск, 1958; В л а д ы к и н В.Е., Х р и с т о л ю б о в а Л.С. Этнография удмуртов. Ижевск, 1991; И в а н о в а М.Г. Истоки удмуртского народа. Ижевск, 1994; ш у л у к. Удмурты // Финно-угры Поволжья и Приуралья в средние века. Ижевск, 1999.

**АРЛЕ́ЕВСКИЙ** Игорь Перецевич (13.10.1931, Белоруссия ССР, Витебск өлкәсе Городок ш. — 25.6.2007, Казан), кардиолог, мед. фән. д-ры (1985), проф. (1986). Казан мед. ин-тын тәмамлагач, 1954 елдан Лениногорск шәһәрендәге мед. оешмаларында, 1962 дән Казан мед. ин-тында (1995 тән мед. ун-ты) эшли, 1987–99 да 1 нче терапия каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлеше — кардиология. Л.М.Рахлин, Л.А.Щербатенко шәкерте. А. Казанда беренче булып (1966) терапия бүлекләрендә электроимпульс ысулы б-н дәвалауны көндәлек гамәлгә кертә. Атеросклероз һәм йөрәк ритмы бозылган вакытта кандагы биоэлементларны өйрәнә, шул нәтиҗәләргә таянып (В.К.Безуглов б-н берлектә), электроимпульс терапиясе ярдәмендә йөрәк ритмын нормаль эшләтү механизмнарының берсе — миокардның поляршлашуы турындагы концепцияне беренче мәртәбә дәлилләп күрсәтә. Бер гаиләдә һәм тумыштан килгән йөрәк ритмы бозылуын өйрәнә; дөнья әдәбиятында беренче булып Фредерикның гаилә синдромын тасвирлый (1988).

Х е з м.: Электроимпульсная терапия нарушений сердечного ритма. К., 1985; Новые взгляды на механизм действия высоковольтного разряда конденсатора, используемого в терапии нарушений сердечного ритма // Тез. докл. 12 междунар. конгресса по электрокардиологии. Минск, 1985.

*Әд.:* Профессор Игорь Перецевич Арлеевский // Казан. мед. журн. 1991. № 5.

**АРМИ́Н** (Arminum), антихолинэстераз тәэсирле дару ($C_{10}H_{14}NO_5P$). Сары төстәге сыеклык, суда аз эрүчән, органик эреткечләрдә яхшы эри. Беренче тапкыр Казан хим.-технол. ин-тында А.И.*Разумов*, Е.А.Маркович һәм О.А.Мухачева тарафыннан органик химия кафедрасында синтезлана (1953). А.ның фармакотерапевтик үзенчәлеген М.А.Алуф (1955) Казан мед. ин-тының фармакология кафедрасында исбатлый. Гельмгольц исем. Үзәк офтальмология ин-тында (Мәскәү), Гиршман исем. Украина күз авырулары фәнни-тикшеренү ин-тында, Филатов исем. Одесса табибләр белемен күтәрү ин-тының күз авырулары клиникасында үткәрелгән клиник сынаулар препаратның югары терапевтик активлыгын раслый. А. глаукоманы дәвалау өчен тәкъдим ителә. Фармакология комитеты А.ны куллану һәм җитештерүгә

рөхсәт бирә. А.ның дару формаларын күпләп җитештерү Казан фармацевтика з-дында (күз тамчылары, арминнның судагы 0,005% лы эремәсе) оештырыла. А. күп еллар буена чит илләргә җибәрелә, антихолинэстераз фосфорорганик кушылмалар төркеменнән глаукомотозга каршы төп препарат булып санала. А.ның холинэстеразны тоткарлавының югары нәтиҗәлелеге, аның клиник кулланылышын киңәйтү өчен тирәнтен өйрәнүгә нигез була. Бала табуны тизләтү үзенчәлеге, фибромиома китереп чыгарган кан китүне туктатуда уңышлы чара булуы, үлекле эндометрит вакытында аналыкның кыскаруы ачыклана. А.ның үзәк һәм периферик паралич, парез б-н авыручыларның нерв-мускул аппаратын нормальләштерүгә тәэсир итүе исбатлана; андый очракларда А. прозерин һәм дибазолга караганда көчлерәк һәм озаграк тәэсир итүчән. Казан мед. ин-тының психиатрия каф. галимнәре тарафыннан А.ның шизофренияенең кайбер формалары б-н авыручыларның хәлен яхшыртуы ачыклана: зиһенне яхшырта, кәефне күтәрә, ашау, эшләү теләге туа.

*Әд.:* А л у ф М.А. К фармакологии армина // Фармакология и токсикология. 1955. Т. 18, № 2; М а ш к о в с к и й М.Д. Лекарственные средства: В 2 т. М., 1986; Регистр лекарственных средств: Энцикл. лекарств. М., 1999. Т. 1.

*И.А.Студенцова, Е.А.Баранова.*

**А́РМИЯ ГАЗЕ́ТАЛАРЫ**, Гражданнар сугышы чорында чыккан газеталар. Хәрби частьләргә, фронт тирәсендә яшәүче халыкка хәбәрләр җиткереп тору максатында чыгарыла. Кызыл Армиядән тыш, акгвардиячеләр дә А.г. чыгаралар, кайчакта аларда бер үк вакыйга капма-каршы караштан торып яктыртыла. Еш кына А.г. фронт янындагы районнарда яшәүчеләр өчен бердәнбер мәгълүмат чарасы булып тора. Татарстан терр-ясендә «*Гражданская война*» («Гражданнар сугышы»), «Красный набат» («Кызыллар чаңы»), «Известия второй армии» («Икенче армия хәбәрләре»), «Набат революции» («Революция чаңы») аеруча зур г-талар булалар. Бу басмаларда Кызыл Армиянең төзелеше мәсьәләләренә, РКП(б)ның хәрби һәм азык-төлек сәясәтен аңлатуга, ак террорны фаш итүгә һ.б. зур игътибар бирелә. 1918 ел ахыры — 1919 ел башларында Көнчыгыш фронтның барлык армияләрендә дә татар телендә матбугат басмалары оештырыла. Шундыйларның беренчесе һәм иң күләмлесе — «*Кызыл Армия*» г-тасы; 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче армияләрнең сәяси бүлекләре органнары — «Кызыл йолдыз», «Кызыл көрәшче», «Коммунист», «*Ышаныч*», «Кызыл яу» г-талары. Көнчыгыш фронтның сәяси бүлекләре ш.у. чуаш телендә «Чухӑнсен сасси» («Пролетариат тавышы»), «Херлӗ салтак» («Кызыл солдат»), мари телендә «Йошкар салтак» («Кызыл сугышчы»), удмурт телендә «*Гудыри*» («Күк күкрәү») г-таларын чыгаралар. Эчтәлекләре һәм сәяси мәсләкләре ягыннан алар шундый ук характердагы рус басмаларыннан аерылмыйлар. Акгвардиячеләр газеталарында большевиклар хуҗалыкларның бөлгенлеккә төшүендә, анархиядә, гражданнар сугышын башлауда, террорчылыкта, ил б-н идарә итә белмәүдә, Россия мәнфәгатьләренә хыянәт итүдә һ.б. гаепләнә. Акгвардиячеләрнең иң зур газетасы — «Народная Армия» («Халык Армиясе»), татар телендә иң танылганы — «*Ватан*» г-тасы.

*Әд.:* Л и т в и н А.Л. Из истории борьбы местной печати за победу на Восточном фронте в 1918–1919 гг. // Из истории местной периодической печати. К., 1960; Н а с ы р о в Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; К а т к о в Н.Ф. Агитационно-пропагандистская работа большевиков в войсках и тылу белогвардейцев в период 1918–1920 гг. Л., 1977; Г и з з а т у л л и н И.Г. Защищая завоевания Октября: Центральная мусульманская военная коллегия. 1918–1920. М., 1979.

*Н.Р.Мөхәммәтҗанова.*

**АРМРЕ́СТЛИНГ** (инглиз. arm — кул, wrestling — көрәш), к. *Армспорт.*

**АРМСПО́РТ** (1996 елга кадәр — армрестлинг), спортның бергә-бер көрәш төре. Ярыш бу төр спорт өчен махсус ясалган өстәл янында үтә. Старт торышында спортчы бер кулы б-н көндәшенең кулын тота, икенчесе б-н таяну ноктасын ныгыту өчен өстәлгә беркетелгән тоткага ябыша. Судьяның әмере булуга, һәр як көндәшенең кулын (терсәк өстәлдән аерылырга тиеш түгел) өстәлгә бөгә. Җиңү көндәшенең кулын бөгеп, өстәлгә тидергән якка бирелә. А. буенча ирләр арасында беренче дөнья чемпионаты 1962 елда, хатын-кызлар арасында 1964 елда уздырыла. Россиядә спортның бу төре 1989 дан, Казанда 1991 дән үсеш ала. А.ны башлап җибәрүчеләр: А.В.Свиридов (спорт остасы, классик көрәш), В.Е.Трофимов, Н.Б.Маннанов (армрестлинг буенча спорт осталары). А. буенча бәйгеләр Казанда 1992 дән, ТРда 1994 тән уздырыла. 1992 елда ТРның җыелма командасы беренче тапкыр Мәскәүнең 3 нче ачык чемпионатында (В.Трофимов — көмеш медаль ала) һәм армрестлинг буенча Россия ассоциациясенең 1 нче ачык чемпионатында катнаша (М.Гурьева — бронза, В.Панин — бронза, В.Трофимов — көмеш медаль ала). 1998 дән ТРның А. федерациясе оештырыла (рәисе П.Н.Никулин, 2004 тән Ф.Ю.Әхмәтҗанов). А. буенча ТР җыелма командасы Россия чемпионатларында бронза медальләр ала (1992, 1994, 1995, 1996, 1999); 2000 елда ул РФ чемпионы исемен яулый. 1991 дән Россия, Европа һәм дөнья чемпионнары исемен һәм медальләр алучылар (төрле үлчәү авырлыкларында): В.Габагкова, Л.Ганиева, Ә.Зыятдинова, Д.Иванов, В.Новиков, Г.Нуретдинова, М.Павлова (кыз фамилиясе Гурьева), П.Рева, Ю.Сорокин, А.Урезов, Л.Хәмидуллина, Э.Хәмидуллина, Э.Храмцов. Иң яхшы тренерлар: Ф.Ю.Әхмәтҗанов, А.В.Свиридов, В.И.Маслов, П.Н.Никулин (Казан), О.Б.Саламахин, М.Хәмидуллин, С.Попов (Чаллы), С.М.Галиуллин (Әгерҗе), Р.Х.Борһанов (Балтач).

**АРНГО́ЛЬД** Адам Иванович (1785 — ?), хирург. 1807 елдан Диңгезчеләр госпиталендә хезмәт итә (С.-Петербург), 1810 нан Казан адмиралтейоствосы табибе. 1812 дән Казан ун-тының хирургия һәм акушерлык осталыгы кафедрасының беренче профессоры. 1817–19 елларда хирургия клиникасы мөдире. 1814–16 да Тобол губернасындагы мед. уч-щеләре директоры. Ф.Г.Мартинсның «Бала табуда таблицада күрсәтелгәнчә гамәли ярдәм итү осталыгын өйрәнү» («Обозрение практического родовспомогательного искусства, начертанное в таблице», 1813) исемле китабын немец теленнән тәрҗемә итә, китап акушерлык дәреслеге булып хезмәт итә.

Х е з м.: О влиянии воздуха и воды на здоровье // Заволжский муравей. 1832. № 2.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский медицинский институт. 1814–1989. К., 1989. Ч. 1.

**АРНШТЕ́ЙН** Карл Августович (17.3.1840, Мәскәү — 10.6.1919, Казан), гистолог, медицина д-ры (1867). Мәскәү ун-тында укый, 1864 елда Дерпт ун-тын тәмамлый. 1869 дан Казан ун-тында, 1871 дән профессор һәм гистология каф. мөдире. Казан нейрогистологлары фәнни мәктәбенә һәм илебездә гистологиягә нигез салучыларның берсе. 1873–76, 1890–92 елларда мед. ф-ты деканы, 1903 тән гистология лабораториясе җитәкчесе. Тере организмның нерв элементларын зәңгәр метилен ярдәмендә буяу ысулын гамәлгә кертә һәм камилләштерә. Хезмәтләре нерв системасы гистологиясенә карый.

Х е з м.: Концевые аппараты вкусового нерва // Неврологический вестн. 1893. Т. 1, вып. 1; Учение о нейронах перед судом новейших исследований // Неврологический вестн. 1900. Т. 8, вып. 2.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**«АРОМА́Т»**, Казандагы парфюмерия-косметика ф-касы. 150 кеше эшли (2005). 1942 елда Ленинградтан эвакуацияләнгән «Северное сияние» ф-касы җирлегендә оештырыла. Казан «Аромат» парфюмерия-косметика ф-касы» исемен ала. Одеколон, хушбуй һәм теш порошоклары чыгара. 1960 еллар ахырында фабрика яңартып төзелә һәм анда өз-






«Аромат» фабрикасы продукциясе.

лексез эшләүче механикалаштырылган линия куела. 1994 тән АҖ булып оеша. 50 дән артык исемдә косметика әйберләре җитештерелә. Төп продукциясе: одеколон, ислемай, парфюмерия-косметика җыелмалары, лосьоннар, теш эликсирлары, шампуньнар. Һәр көнне якынча 50 меңгә якын берәмлек продукция чыгарыла (2005). Фабриканың продукциясе РФдә, БДБ илләрендә сатыла. Парфюмерия җитештерү өчен композицияләр, башлыча, Франция, Швейцария, Польшадан кайтарыла. Фабрика җитәкчеләре арасында: Д.М.Коламазов (1942–45), Н.Е.Гончарова (1945–71), М.Н.Велижева (1971–95), Р.Н.Мусин (1995–2002), Е.В.Михайлова (2006 дан).

**АРОМА́ШЕВ РАЙОНЫ́**, *Түмән өлкәсендә.* Үзәге — Аромашев авылы (Түмәннән 235 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 14175 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 2000, 1989 да — 1700, 2002 дә 1385 мең кеше. Күбрәк 4 торак пунктта: Новоаптула (Көсәйкүл) (420 кеше), Яңа Юрты (198), Новоуфимск (Чумык) (162), Үткәрмә (113) авылларында яшиләр.

**АРПА́** (Hordeum), кыяклылар семьялыгыннан бер һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; бөртекле ашлык культурасы, якынча 10 төрне берләштерә. Иртә өлгерүчән сабан һәм уҗым үсемлеге. ТРда нигездә сабан А.сы үстерелә. Культурада Гордеум сативум (Hordeum sativum) төре генә киң таралган, ә калган төрләре — кыргый үсә торганнар. А.ның тамыр системасы чуклы, төп массасы сукаланган катламда тарала, аерым тамырлары 1 *м* тирәнлеккә кадәр китә. Сабагы — кыш эчле салам, биеклеге 30–35 *см* дан 130–135 *см* га кадәр. Яфрагы бүтән кыяклыларга караганда киңрәк. Чәчәк оешмасы — башак. Җимеше — бөртек, кабыклы яисә ялангач, сары, коңгырт яки көрән төстә. А. — дым яратучан берьеллык үсемлек, уңдырышлы балчыксыл, нейтраль реакцияле һәм туклыклы матдәләре җитәрлек булган туфракта яхшы үсә. А. күп рәтле, ике рәтле һәм арадаш рәтле өч төргә бүленә.

Аларның һәркайсы, үз чиратында, башакның тыгызлыгы (кабыклы һәм ялангач бөртекле), башак төсе һ.б. билгеләре буенча җыелма төркемнәргә бүленә. А. әһәмиятле терлек азыгы, ашамлык һәм техник культура. А. югары азык сыйфатларына ия һәм концентрацияләнгән азык буларак киң кулланыла. Энергетик туклыклылыгы буенча А. солыны уза. А. оны икмәк пешерү сәнәгатендә бодай һәм арыш онына өстәмә буларак кулланыла. А. бөртеге ярма ярдыруда киң кулланыла. Сыра кайнату сәнәгате өчен төп чимал чыганагы булып санала. Сыра кайнату өчен үстерелгән А.ның сыйфаты үстерү, җыйганнан соңгы эшкәртү һәм аннан соңгы саклау шартларына бәйле. Бөртекнең составы туфрак-климат һәм агротехник шартларга туры китереп үстерелгән аерым сортлардан алынырга һәм аерылып торырга тиеш. ТРда А. төп ашлык-фураж культурасы буларак үстерелә, чәчүлек мәйданы 381,4 мең *га* тәшкил итә, гектарыннан 34,3 *ц* уңыш алына (2005). ТРда чәчәргә рөхсәт ителгән сортлар: «Московский 2» (1984), «Нутанс 778» (1988), «Эльф» (1997), «Рәхәт» (1998), «Раушан» (1988), «Нур» (2002). Корткычлары — швед һәм гессен чебеннәре, яшелкүз, чыбык личинка, кандала-ташбакалар; авырулары — тузанлы һәм каты кисәү гөмбәләре, сабак һәм арпа күгәреге, ончыл чык һ.б.

*Әд.:* Бахтеев Ф.Х. Ячмень. М., 1955; Трофимовская А.Я. Ячмень. Л., 1972; Неттевич Э.Д., Сергеев А.В., Лызлов Е.В. Зерновые фуражные культуры. М., 1980; Технология возделывания ярового ячменя. К., 2001; Руководство по апробации сортовых посевов. К., 2002.

*Л.Н.Вальникова.*

**АРПАЯ́З** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Оштырма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 186 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да мәчет, мәктәп, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1186,9 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 ның 10 августыннан Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 42 ир заты; 1859 да — 440, 1897 дә — 736, 1908 дә — 742, 1926 да — 737, 1938 дә — 611, 1949 да — 426, 1958 дә — 383, 1970 тә — 314, 1979 да — 257, 1989 да — 159 кеше.

**АРСАЕВЛА́Р** (Әхмәровлар), Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре: 1) династияне нигезләүчеләр бертуган **Әхмәр** (? — 1807) һәм **Рахманкол** (? — 1796 дан соң) А. 1790 елларда сәүдәгәрләр буларак теркәлгәннәр; 2) бертуганнар: **Корбангали Әхмәр улы** (? — 1885 тән соң) һәм **Йосыф Әхмәр улы** (1773–1835), 1 нче гильдия сәүдәгәрләр, нәселдән күчмә шәрәфле гражданнар. Эшкәртелмәгән күн б-н сәүдә иткәннәр. 1820 еллар уртасында 3 сабын з-ды ачканнар. Проф. К.Ф.Фукс аларны Казанның иң зур сәүдәгәрләре рәтенә кертә. Казанда ваба б-н авыручылар өчен ачылган хастаханә (1830) һәм 4 нче җамигъ мәчет каршындагы мәдрәсә (1825) биналары төзелешенә байтак акча бирәләр. Мәчет озак еллар алар иганәсенә яши, шуңа күрә кайвакыт аны «Арсаев мәчете» дип тә йөртәләр; 3) **Гобәйдулла Йосыф улы** (? – 1871). **Әхмәтҗан** б-н **Мөхәммәд Корбангали уллары**, **Хәйрулла Йосыф улы**, **Хөсәен Гобәйдулла улы** ата-бабалары башлаган сәүдә эшен дәвам иттергәннәр.

*Әд.:* Хасанов Х.Х. Формирование татарской буржуазной нации. К., 1977; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**АРСЕ́НИЙ** (Брянцев Александр Дмитриевич) (1839 — 28.4.1914, Харьков ш.), дин эшлеклесе. Киев руханилар академиясен тәмамлый (1867). Киев губернасының дөньяви уку йортларында православие дине нигезләрен укыта. 1873 тән Таврия руханилар семинариясендә эшли (Симферополь ш.). 1875 тән монахлыкта. 1882 дән Ладога епископы һәм Петербург руханилар академиясе ректоры, 1887 дән Рига епискобы, 1897 дән Казан һәм Зөя архиепискобы, 1903 тән Харьков һәм Ахтыр архиепискобы. Оста вәгазьче буларак таныла, Казанда һәм епархиягә караган чиркәүләрдә күп мәртәбәләр чыгышлар ясый. «Изге Гурий борадәрлеге» җәмгыятенә, «Известия по Казанской епархии» һәм «Православный собеседник» ж-лларына миссионерлык эшчәнлеген алып баруда булышлык итә.

Хезм.: Патриарх Кирилл Лукарис и его заслуги для православной церкви. СПб., 1882; Собрание слов и речей Высокопреосвященного Арсения (Брянцева), архиепископа Харьковского и Ахтырского. Хар., 1908. Т. 1, 2, 4.

*Әд.:* Багрецов Л. Очерк архипастырской деятельности Высокопреосвященного Арсения, архиепископа Харьковского и Ахтырского, во время его пятилетнего управления Казанской епархией. Хар., 1905.

**АРСЕ́НТЬЕВА** Елена Фридриховна (2.6.1956, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1994), проф. (1996), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2007). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли. 1987–97 елларда Казан вет. медицинасы академиясендә (1995 тән чит телләр каф. мөдире). 1997 дән Казан ун-тының роман-герман филол. каф. мөдире. Хезмәтләре герман, славян һәм төрки телләрнең чагыштырма фразеологиясенә карый. Русча-инглизчә фразеологик сүзлек авторы (1999).

Хезм.: Сопоставительный анализ фразеологических единиц (на материале фразеологичских единиц, семантически ориентированных на человека, в английском и русском языках). К., 1989; Типы соответствий фразеологических единиц английского, русского и татарского языков // Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность: Тр. междунар. конф. 9–13 июня, 1992 г. К., 1992. Т. 1; Фразеология и фразеография в сопоставительном аспекте. К., 2006.

**АРСЛА́Н ХАН** (Гали Арслан) (? — 1627, Касыйм ш.), Касыйм ханы (1614 елдан). Гали хан улы, Күчүм хан оныгы; Касыйм ханлыгының соңгы идарәчесе Фатыйма Солтанның ире. Баштарак атасы б-н бергә Рус дәүләтендә хезмәттә була; патшалар династиясе алмашкан «*Болгавыр заман*»да төрле эчке чуалышларда катнаша, 1613 елда Михаил Романовны тәхеткә тәгаенләүне яклый. Шуның өчен тиздән Касыйм ханы итеп билгеләнә. Ул чорда хан хакимияте чикләнгән була, А.х. фәкать ханлыкта яшәүче мөселманнарга һәм шәһәрнең татар бистәсендә генә хаким булган, төп идарәче һәм хан өстеннән күзәтүчелек вазифасын рус воеводасы башкарган, дип фаразлана.

*Әд.:* Фәхретдинов Р.Г. Касыйм шәһәренең иске вә яңа вакытлары: Касыйм мөселманнары. Касыйм ханнары вә солтаннары // Татарстан. 1994. № 9/10, 11/12; Вельяминов-Зернов В.В. Исследования о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2.

**АРСЛА́НОВ** Айрат Гәрәй улы (10.4.1928, Башкортстан Респ-касының Бүздәк р-ны Ахун а.), драма актёры, артист, эстрада режиссёры, нәфис сүз остасы, ТАССР һәм РСФСРның халык артисты (1979, 1987). Татар театр техникумын (1949) һәм Дәүләт те-



А.Г. Арсланов.



Г.Ш. Арсланов.

атр сәнгате ин-тын (ГИТИС, 1967) тәмамлый. 1948 елдан Татар радиосында диктор булып эшли. 1956–61 елларда Татар акад. театрында тамашачының күңелен яулаган рольләр иҗат итә: Булат («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин, 1956), Мирвәли («Ташкыннар», Т.Гыйззәт, 1956), Алиш («Муса Җәлил», Н.Исәнбәт, 1957), Мөхәммәтша («Кыз урлау», М.Кәрим, 1958), Басыйр («Тормыш җыры», М.Әмир, 1958), Доминик («Рабурден токымы», Э.Золя, 1959), Таһир («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш, 1959). 1961–65 елларда Казан телевидение студиясендә актёр һәм диктор, 1965 тән Татарстан филармониясе эстрада артисты һәм 1985 елдан режиссёры. Күп еллар дәвамында Мәскәү, Ленинград һ.б. шәһәрләрнең концерт мәйданнарында татар әдәбияты әсәрләрен пропагандалый, чит илләрдә гастрольләрдә була (Польша, Венгрия, Чехословакия, Германия, Финляндия). Татар язучыларының А. тарафыннан башкарылган әсәрләре Бөтенсоюз «Мелодия» грамзапись фирмасында граммофон тасмасына язылган. А.ның «Шагыйрьнең тормышы» (Г.Тукай турында), «Россиядә яшәүчеләр» (Х.Туфан әсәрләре буенча), «Герой-шагыйрь» (М.Җәлил әсәрләре буенча), «Бөек Җиңүгә 50 ел», «Татарстан — туган җирем», «Милли кайгы» (Г.Исхакый һәм Г.Тукай әсәрләре буенча) исемле программалары, С.Хәким, Х.Туфан, хәзерге заман татар язучылары әсәрләре буенча эшләнгән әдәби композицияләре милли сәнгатьтә зур вакыйга булып кабул ителә. Ш.у. рус классик һ.б. милләт шагыйрьләре әсәрләрен татар һәм рус телләрендә укый. Артистның башкару стиле интонациянең күптөрлелеге, мелодик тәэсирлелек, гражданлык пафосы, ихлас лиризм һәм нечкә юмор б-н аерылып тора. Бөтенроссия нәфис сүз осталары (1970), А.С.Пушкинның 175 еллыгына багышланган сүз осталары (1974) конкурслары, ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1969) лауреаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Сүз тәме. К., 1998; Народные артисты. К., 1980. *И.И.Илялова.*

**АРСЛА́НОВ** Әмир Солтан улы (25.9.1926, Башкортстан Респ-касының Туймазы р-ны Кәлшәле а. — 23.2.1987, Уфа ш.), нәкышьче, Башкортстан АССРның атказ. рәссамы (1986). Бөек Ватан сугышында катнаша. Уфа сәнгать уч-щесенең сынлы сәнгать бүлеген тәмамлаганнан соң (1955), Октябрьск шәһәрендә яши, 1960 елдан РСФСР Сәнгать фондының Башкортстан иҗади-җитештерү комб-тында эшли. 1975 тә Уфага күчеп килә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1963). Пейзаж, тарих һәм көнкүреш жанрларындагы картиналар остасы, портретлар һәм натюрмортлар авторы. Эзлекле рәвештә реалистик нәкышь сәнгате традицияләрен үстерә һәм бу иҗат юнәлеше Уралның эпик пейзажларын эшләгәндә («Кызыл йорт», 1966; «Фермада яз», 1972; «Нарыш тау иртәсе», 1973; пейзажлар циклы — «Туган як күзе», 1985–86; «Кышкы пейзаж. Уфа», 1982), халык герое образын сурәтләгәндә («Салават Юлаев», 1959; «Тыл солдаты», 1974; «Игенче», 1973; «Акмулла», 1984; «Ш.Төхфәтуллин портреты», 1975 һ.б.); документаль һәм биографик яктан төгәллек саклаган тарихи вакыйгаларны һәм персонажларны романтик-мәһабәт пейзажлар фонында тасвирлаганда («Л.Н.Толстой Башкортстан далаларында», 1978; «В.И.Ленинның Яхъя Тукаев хуторында бертуган Носковлар белән очрашуы», 1985; «Г.Тукайның Уфада М.Гафури белән очрашуы», 1986;



Ә.С. А р с л а н о в. «Фермада яз». 1972.

«А.С.Пушкин Белогорск крепосте янында», 1986) ачык чагыла. Нәкышь үзенчәлеге якты яңгырашлы төсләр байлыгыннан, кояш һәм күләгә колоритының контрастлыгыннан, декоратив образлылыктан гыйбарәт.

«РСФСР автономияле республикалары рәссамнарының әсәрләре күргәзмәсе»ндә (Мәскәү, 1971), «Социалистик Урал» (Төмән, 1980), «Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 50 ел» (Мәскәү, 1995) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Октябрьский шәһәрендә (1976), Уфада (1971 һәм 1996) күрсәтелә.

Әсәрләре М.В.Нестеров исем. сәнгать музеенда (Уфа ш.), Миасс шәһәренең төбәкне өйрәнү музеенда, Башкортстанның Кыргыз-Миякә посёлогындагы Акмулла музей-йортында, Казандагы Г.Тукай музеенда,



Ә.С. А р с л а н о в. «Бөек Ватан сугышында катнашкан Ш.Төхфәтуллин портреты». 1975.



Ә.С. А р с л а н о в. «Г.Тукайның Уфада М.Гафури белән очрашуы». 1986. М.В.Нестеров исем. сәнгать музее. Уфа ш.

Техника йорты музеенда һәм Башкортстан берләштерелгән музееның Октябрьск шәһәрендәге ф-лында, шәхси коллекцияләрдә саклана. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а ф и з о в а Д. Кыюларның берсе // Башкортостан кызы. 1995. № 5; С а ф у а н о в С. Туган җирнең якты буяулары // Тулпар. 1996. № 5; Ф ә т к у л л и н Ф. Шигъри җанлы рәссам // Баш очымда кош сайрады. Уфа, 1999; Художники Советской Башкирии: Справ. Уфа, 1979; Амир Арсланов. Живопись: Каталог выставки. Уфа, 1988–89. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АРСЛА́НОВ** Әсхәт Зәки улы (11.8.1935, Чирмешән р-ны Яңа Кади а.), «Татар төзелеш материаллары» унитар пр-тиесе ген. директоры (1987–2000), ТАССРның атказ. төзүчесе (1989). Казан энергетика техникумын тәмамлый (1962). 1958–81 елларда Главтатстройның 2 нче төзү-монтаж трестында электрик, тимер-бетон әйберләр з-дында, төзелеш идарәсендә баш механик, участок башлыгы. 1981–87 дә «Татарстан төзелеш материаллары» берләшмәсенең Казан төзелеш материаллары комб-ты директоры. Аның җитәкчелегендә берләшмәнең Казандагы стена материаллары силикат з-ды һәм төзелеш материаллары комб-ты; Әгерҗе шәһәрендә һәм Кукмара посёлогында төзелеш материаллары з-длары, Чистай шәһәрендәге кирпеч з-ды реконструкцияләнә һәм техник яктан яңартып корыла. Елына 125 млн. данә шартлы кирпеч җитештерү куәте булган Алабуга керамик кирпеч з-ды, Казанда керамик стена материаллары з-ды төзелә. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**АРСЛА́НОВ** (Арасланов) Гафиятулла Шаһимәрдән улы (20.9.1915, хәзерге Башкортстан Респ-касының Күмертау р-ны Икенче Кинҗәбозау а. — 5.1.1945), Сов. Союзы Герое (7.4.1940), майор (1945). 1937 елдан Совет Армиясендә. Совет-фин сугышында (1939–40) катнаша, 13 нче армиянең 97 нче укчы дивизиясе 136 нчы укчы полкында танк укчы-радисты була. Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре составында 1940 ел башында һөҗүм операциясендә катнаша, Маннергейм линиясен өзгәндә батырлык күрсәтә. Ульянов танк уч-щесен тәмамлый (1941). 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, танк батальоны командиры, танк полкы командиры урынбасары. Курск сугышында (1943), Украинаны, Венгрияне, Румынияне азат итү сугышларында катнаша. Ленин, ике

1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966; Побратимы Матросова. Минск, 1984.

**АРСЛА́НОВ** (Арасланов) Госман Вәли улы (1897 — 1941, Казан), график, театр рәссамы. Пермь сәнгать остаханәсен тәмамлый (1922). 1920–22 елларда Пермь драма театрында бизәлеш рәссамы ярдәмчесе була. 1922 дән Казанда яши. 1923 тә татар театры өчен К.Гоццинының «Принцесса Турандот» әсәре буенча куелган спектакльгә декорация эскизлары ясый. А. «Чаян» ж-лы чыга башлаганнан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр әлеге басмада әйдәп баручы рәссамнарның берсе була. А.ның ике-өч төс б-н башкарылган гротесклы рәсемнәре «Чаян» ж-лы тышлыкларында басыла һәм сәяси мәкаләләрне бизи: «Беренче кар» (1929), «Исламның яшел байрагы астында» (1930) исемле



Г.В. Арсланов. «Драматург Г.Камал». Шарж. Кәгазь, тушь. 1920 еллар ахыры. ТР Милли музее.

тышлыклар, К.Нәҗминең «Туран парламенты» мәкаләсенә рәсем (1930) һ.б. 1920–30 да «Азат хатын», «Октябрь яшьләре», «Кызыл Татарстан» басмалары б-н хезмәттәшлек итә, китаплар бизи. 1923–25 тә актуаль көнкүреш һәм сәясәт темаларына 100 гә якын плакат иҗат итә. Беренчеләрдән булып Г.Тукай әсәрләре җыентыгына рәсемнәр ясый (1926). А. тарафыннан сурәтләнгән иске Казан күренешләрендә, 20 йөз башы мөселманнары портретларында узган чорларның тарихи-этник йөзе чагылыш таба, бу әсәрләр татар профессиональ китап графикасы өлкәсендә беренче хезмәтләр булып тора. «Безнең басма» җыентыгының тышлыгы Париждагы Халыкара бизәлеш сәнгате күргәзмәсенә (1925), сатирик рәсемнәре 1930 еллардагы респ-ка күргәзмәләренә куела. А.ның әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм ТР Милли музеенда саклана.

*Әд.:* Дульский П.М. Оформление татарской книги за революционный период. К., 1930; шул ук. Актуальная графика. К., 1935.

*Р.Г.Шаһиева.*

**АРСЛА́НОВ** Зыятдин Миңлебай улы (15.1.1923, Буа кантоны Кече Чынлы а. — 10.3.1999, Буа ш.), Дан орденының тулы кавалеры (6.7.1944, 27.2.1945, 29.6.1945), старшина. Свердлов өлкәсенең Карпинск шәһәре паровоз депосында слесарь булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең апреленнән Бөек Ватан сугышында катнаша, ефрейтор, 21 нче армиянең 46 нчы укчы дивизиясе 314 нче укчы полкында автоматчы. Ленинград һәм 2 нче Белоруссия фронты гаскәрләре б-н Ленинград блокадасын өзүдә, Белоруссия, Польшаны азат итүдә катнаша. 1944 нең 28 июнендә Таммисуо (Финляндия, хәзерге Ленинград өлкәсе) торак пункты янында сугыш кырыннан яралы штаб башлыгын алып чыга, 1945 нең 15 гыйнварында Пультуск торак пункты (Польша) янындагы бәрелештә дошман траншеясына беренче булып бәреп керә; 1945 нең 2 апрелендә Данциг шәһәреннән (Германия, хәзерге Гданьск ш., Польша) көньяк-көнчыгыштагы Нойендорф торак пункты янында разведчиклар төркеме б-н дошман тылына үтеп керә, 32 дошман солдатын әсирлеккә төшерүдә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Буа шикәр з-дында газ б-н эретеп ябыштыручы булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Лобода В.Р. Солдатская слава. М., 1967. Кн. 2; Вагапов И.М. Солдатская доблесть. Челябинск, 1968; Дубров Б.И. Солдатская слава. Киев, 1987.

**АРСЛА́НОВ** Леонид Францевич (20.8.1935, Якутск ш.), тренер, судья (баскетбол), РСФСРның атказ. тренеры (1973), бөтенсоюз категорияле судья (1966), халыкара категорияле судья (1977). Казан пед. ин-тының физик тәрбия һәм спорт ф-тын тәмамлый (1961). СССР чемпионатларында (1965–85), Бөтендөнья Универсиадасында (1973), Олимпия уеннарында (1980) судьялык итүдә катнаша. 1961–68 елларда Ленин р-нының балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә өлкән тренер; 1968–70 тә Волгоград шәһәренең «Динамо» командасы тренеры (1969 да СССР чемпионатының 1 нче төркемендәге командалар арасында көмеш медаль ала), 1970–78 дә Казанның «Университет» ирләр командасында өлкән тренер (1972 дә РСФСР кубогына ярышларда көмеш медаль ала). 1964–80 елларда ТАССР (1964–65 тә СССР беренчелегендә җиңүче һәм алгы урын алучылар), РСФСР (1965, 1967, 1972, 1976, 1978 елларда мәктәп укучыларының Бөтенсоюз Спартакиадасында җиңүче һәм алгы урын алучылар) яшүсмерләр җыелма командалары б-н эшләргә чакырыла. 1978–90 елларда Казан ун-тында укыта. 1990–93 тә «Уникс» командасының өлкән тренеры. 1993 тән ТР Физик культура, спорт һәм туристлык дәүләт ком-тының үзәк СКда (ЦСК) төп белгеч.

**АРСЛА́НОВ** Леонид Шәйхелсолтан улы (11.12.1932, Актаныш р-ны Мари Ямалы а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1983), проф. (1985), ТССРның атказ. фән. эшлеклесе (1991). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1960). 1964 елдан Алабуга пед. ин-тында, 1983–91 дә татар филологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре Әстерхан, Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае һәм Калмык Респ-касында таралган төрки этник группаларның сөйләшләрен һәм диалектларын өйрәнүгә, төрки телләрнең һәм диалектлары б-н үзара бәйләнешен, төрки һәм фин-угыр телләре топонимикасын өйрәнүгә карый.



З.М. Арсланов.



М.Н. Арсланов.

Хезм.: Формирование островных говоров татарского языка. К., 1983; Язык алабугатских татар Каспийского региона Калмыцкой АССР. К., 1988; Язык карагашей-ногайцев Астраханской области. Наб. Челны, 1992; Исследования по финно-угристике. Елабуга, 2001.

*Әд.:* Левитская Л.С. Новое в татарской диалектологии // Советская тюркология. 1979. № 2; Каранаев Ю. Во благо науки // Половецкая луна. 1993. № 1–2.

**АРСЛА́НОВ** Марат Мирза улы (7.2.1944, Лаеш р-ны Имәнкискә а.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1988), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). 1966 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1969 дан шунда ук эшли, 1989 дан алгебра каф. мөдире, 1993 тән Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында алгебра һәм математик логика бүлеге мөдире, проф. (1990). Хезмәтләре исәпләнә алучанлык теориясенә, алгебрага һәм математик логикага карый. Алгоритмнар теориясендә киң кулланышка кергән арифметик күплекләрнең тулы критерийларын эшли (1978). Махсус төрдәге алгоритмик табигатьле алгебраик структураларның элементар теорияләре аерылып торуын исбатлый (1988). Халыкара «Mathematical Logic Quarterly» ж-лы мөхәррире.

Хезм.: Рекурсивно перечислимые множества и степени неразрешимости. К., 1986; Relative enumerability in the difference hierarchy // J. of Sumb. Logic. 1998. V. 63; There is no low maximal d-c.e. degree, Curregendum // Math. Logic Quarterly. 2005. V. 50 (автордаш); The minimal e-degree problem in fragments of Peano arithmetic // Annals of Pure and Applied Math. 2005. V. 131 (автордаш).

**АРСЛА́НОВ** Мөхәммәт Нуриәхмәт улы (2.2.1910, Уфа губ. Мәмәк а. — 20.10.2001, Уфа ш.), театр рәссамы, нәкышьче, Башкортстан АССР һәм РСФСРның халык рәссамы (1968, 1980), Башкортстан АССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1943, 1964). Уфа сәнгать техникумын (хәзер Уфа сәнгать уч-щесе), Пролетар сынлы сәнгать ин-тын (1935, Ленинград) тәмамлый. Р.Р.Френц, М.П.Бобышев һәм Д.Н.Кардовский шәкерте. Башкорт драма акад. театры (1936–38) һәм Башкорт опера һәм балет театры баш рәссамы (1938–73). Уфа сәнгать уч-щесендә һәм Уфа сәнгать ин-тында укыта (1973–75; 1986–87). А. шәкертләре арасында Г.Имашева, И.Саяпов, М.Копьев бар. Башкортстан АССРның Рәссамнар берлеге әгъзасы (1941 дән) һәм рәисе (1955–60). Башкортстанда театр декорациясе сәнгатенең беренче рәссамнарыннан. 200 дән артык спек-

такль, ш.и. опера һәм балет спектакльләре (Н.Җиһановның «Качкын», 1943; «Алтынчәч», 1946; А.П.Бородинның «Князь Игорь», 1953; З.Г.Исмәгыйлевнең «Салават Юлаев», 1955, 1977; А.Чугаев һәм Х.Заимовның «Кара йөзләр», 1965; Дж.Вердиның «Аида», 1953, 1967; Ф.Яруллинның «Шүрәле», 1969; М.Мусоргскийның «Борис Годунов», 1971 һ.б.), драма спектакльләренең (М.Фәйзинең «Галиябану», 1936; Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», 1943 һ.б.) сәхнәләрен бизи. А. декорацияләренә сәхнәнең бизәлгән арткы өлеше яки пәрдәсе фонында ясалган күләмле композицияләр, монументаль образлылык, җете төсләр хас.

Башкортстанда беренче монументаль сәнгать рәссамнарыннан, Башкорт опера һәм балет театры фойесындагы нәкышьле панно



М.Н.А р с л а н о в. З.Исмәгыйлевнең «Салават Юлаев» операсына декорация эскизы. Картон, гуашь. 1955. М.В.Нестеров исем. сәнгать музее. Уфа ш.

авторы (1940 нчы еллар). 1949 дан халыкара театрлар күргәзмәсендә (Вена, 1955), Беренче бөтенроссия театр һәм кино рәссамнары күргәзмәсендә (Мәскәү, 1956,) «1917–1958 елларда Совет театры» (Мәскәү, 1958), «Театр һәм кино рәссамнары» (Ленинград, 1974) күргәзмәләрендә катнаша. 1979 да Мәскәүдә шәхси күргәзмәсе күрсәтелә. Әсәрләре Третьяков галереясе, А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музее (Мәскәү), М.И.Глинка исем. музеей (Мәскәү), М.В.Нестеров исем. Сынлы сәнгать музеенда (Уфа ш.) саклана. Башкортстан АССРның Салават Юлаев исем. Респ-ка бүләге лауреаты (1973). Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.



М.Н. А р с л а н о в. М.Мусоргскийның «Борис Годунов» операсына декорация эскизы. Картон, гуашь, темпера. 1971. М.В.Нестеров исем. сәнгать музее. Уфа ш.


*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; М.Арсланов: Каталог выставки. Уфа, 1971; П и к у н о в а Г.Р. Мухамед Арсланов. Л., 1978; Мухамед Нуриахметович Арсланов. Театрально-декорационное искусство: Каталог выставки. М., 1979; Художники Советской Башкирии: Справ., Уфа, 1979; Всеобщий словарь всех времён и народов. Лейпциг, 1983; О с ь к и н а И.Н. Арсланов Мухамед Нуриахметович // Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996; Т ю т ю г и н а Н. Мухамед Нуриахметович Арсланов. Сценография (персоналия). Уфа, 1998.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АРСЛА́НОВ** Мөхәммәтгали Гыйльмегали улы (6.10.1947, Актаныш р-ны Түмерҗә а.), театр белгече, сәнгать фән. д-ры (1993), проф. (1999), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2007), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). 1974 елда Казан мәдәният ин-тын тәмамлый. 1965–66 да Әлмәт татар драма театры актёры, 1974–75 тә Актаныш халык театры режиссёры. 1979 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, 1994 тән сәнгать белеме бүлеге җитәкчесе. Татар театры режиссурасы тарихына караган хезмәтләрендә Г.Кариев, В.Мортазин-Иманский, М.Мутин, К.Тинчурин, Г.Исмәгыйлев, Г.Девишев, Ш.Сарымсаков, Р.Тумашев, П.Исәнбәт, М.Сәлимҗанов кебек режиссёрларның иҗатына анализлар ясый.

Ә с ә р.: Хусаин Уразиков. К., 1986; Татарское режиссёрское искусство. 1906–1941. К., 1992; Татарское режиссёрское искусство. 1941–1956. К., 1997; Татарское режиссёрское искусство. 1957–1990. К., 2002; Режиссёр Ширъяздан Сарымсаков. К., 2004.

**АРСЛА́НОВ** Нури Газиз улы (19.9.1912, Петропавловск (Кызылъяр) ш. — 12.4.1991, Казан), шагыйрь, тәрҗемәче. 1931 елда Казан сәнгать техникумын тәмамлый. 1931–34 тә Урта Азия һәм Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә татар әдәбияты һәм рәсем сәнгате укытучысы, бизәүче рәссам булып эшли. 1936 елдан «Пионер каләме» ж-лы һәм «Яшь ленинчы» г-тасы редакцияләрендә хезмәттәшлек итә. Совет-фин (1939–40) һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Сугыштан соң А. Татарстан китап нәшриятында, «Социалистик Татарстан» г-тасында рәссам вазифаларын башкара. 1964–72 дә «Казан утлары» ж-лының поэзия бүлеге мөдире. 1942 дә замандашының тормышны сөюенә, рухи көченә дан җырлаган беренче «Мәхәббәт» поэмасын, 1943 тә Зоя Космодемьянская турындагы «Рус кызы» поэмасын бастыра. Шагыйрь поэзиясенең тематикасы күпкырлы, әмма сугыш һәм туган ил азатлыгы темасы аның иҗатында үзәк урынны били. Шигырьләрендә һәм поэмаларында А. әкиятләр һәм халык мифологиясе сюжетларына, мотивларына еш мөрәҗәгать итә («Ай Хан белән Ли» (1951), «Корея гөле» (1951), «Давыл кызы» (1954), «Көзге» (1955) һ.б.). А. «Девон фонтаннары» (1953) шигырьләр циклы б-н татар шагыйрьләре арасында беренчеләрдән булып респ-кабыз нефтьчеләре хезмәте темасын



Нури Арсланов.

күтәреп чыга. 1960 еллар башыннан А. иҗатында классик шәрекъ шигърияте-нең (ш.и. татар поэзиясенең дә) традицион формалары б-н баетылган фәлсәфи лирика өстенлек ала. Шагыйрь еш кына Шәрекъ поэзиясенә хас булган касыйдә, мәснәви, газәл жанрларына мөрәҗәгать итә. Төрле елларда А.ның «Ак таңнар» (1967; рус теленә тәрҗемәсе «Белые зори», 1982), «Моңсар» (1971), «Талпыну» (1974), «Иделем-илем» (1982; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1985), «Сөмбелләрем» (1987) исемле шигырьләр җыентыклары дөнья күрә. А. поэзиясенә хас сыйфатлар — тирән әхлакый мәгънәлелек, сүзнең тасвирлау байлыгы, формаларның кыскалыгы, җыйнаклыгы. Ул ш.у. җырлар һәм балладалар авторы; А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Гомәр Хәйям, Абай һ.б.ларның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Үз әсәрләре дә рус, казакъ, каракалпак, украин, үзбәк телләрендә нәшер ителә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1992.

*Әд.:* М ө х ә м м ә д и е в Р. Якутлар табыладыр вакыт белән // Әгәр без янмасак... К., 1980; Г а л и у л л и н Т. Нури Арсланов // Здравствуй, поэзия! М., 1987.

**АРСЛА́НОВ** Рифхәт Мөхәммәт улы (8.8.1946, Уфа ш.), театр рәссамы, нәкышьче, БАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1989, 1999), Уфа сәнгать академиясе проф. (2003). М.Н.*Арслановның* улы. Уфа сәнгать уч-щесен (1966), Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын (1978) тәмамлый; М.М.Курилко-Рюмин, М.Н.Пожарская шәкерте. 1966 елдан Уфа театрларында сәхнә рәссамы. 1978 дән Башкорт опера һәм балет театрында эшли, бер үк вакытта театр декорациясе остаханәсе б-н җитәкчелек итә, Уфа сәнгать ин-тының нәкышь ф-тында укыта. 1980–82 дә СССРның Зур акад. дәүләт театрында рәссам-стажёр. Уфа рус драма театрының (1983–87), Башкорт опера һәм балет театрының (1987–90 һәм 1995 тән), Уфа яшь тамашачылар театрының (1990–93) баш рәссамы булып эшли. Рәссамнар берлеге (1977), Театр эшлеклеләре берлеге (1980), Театр рәссамнары, архитекторлары һәм техникларының халыкара оешмасы (АКШ, 1983 тән) әгъзасы. 100 дән артык спектакльне бизи; алар арасында Башкорт опера һәм балет театрында куелган әсәрләрдән Оберның «Фра-Дьяволо» (1966), Ш.Гуноның «Фауст» (1978), П.И.Чайковскийның «Евгений Онегин» (1981) һәм «Пики дамасы» (1996), Р.Мортазинның «Давыл» (1979), З.Исмәгыйлевнең «Салават Юлаев» (1987), «Карын Түрә» (2005), Х.Әхмәтовның «Нәркәс» (1994) опералары; Ф.Әмировның «1001 кичә», Р.Хәсәновның «Курай турында риваять», Р.Паулсның «Керри туташ», 1980 еллар) балетла-

ры; башка театр сәхнәләрендә куелган әсәрләрдән: М.Н.Ермолова исем. Мәскәү драма театрында Л.Петрушевскаяның «Баскыч мәйданчыгы» («Лестничная клетка», 1982), Уфа «Нур» татар акад. театрында К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» (1994), Башкорт акад. театрында М.Фәйзинең «Асылъяр» (1999), Әлмәт татар драма театрында М.Кәримнең «Җырланмаган җыр» (2000) драмалары бар. Тематик жанрдагы рәсемнәр, пейзажлар һәм портретлар авторы («Метаморфозалар», «Мутацияләр», «Чүлмәк сатучы», «Коры-сары җыючылар» (1990 еллар), «Минем шәһәрем» серияләре (1994–2000), театр декорацияләре эскизлары).

«Прага квадрасы — 1975», Россия театр рәссамнарының Югославиядә үткән күргәзмәләрендә (Новый Сад, 1979; Белград, 1987),



Р.М. Арсланов. У.Шекспирның «Макбет» пьесасы буенча куелган спектакльгә декорация эскизы. 1975. М.В.Нестеров исем. сәнгать музее. Уфа ш.

кино рәссамнары күргәзмәләрендә (Варшава һәм Хельсинки, 1984), Испаниядә (Барселона, 1994) һәм АКШта (Сиэтл, 1994) уздырылган төркем күргәзмәләрендә, бөтенсоюз һәм бөтенроссия театр һәм кино сәнгате күргәзмәләрендә (1972 дән), «Социалистик Урал» (1974 тән), С.-Петербургтагы ТАТАРТ (1991) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1986, 1994–96, 1999, 2002, 2003 елларда Уфа шәһәрендә күрсәтелә. Әсәрләре Мәскәүдә А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда һәм М.И.Глинка исем. музейдә, М.В.Нестеров исем. Сәнгать музеенда (Уфа ш.), чит илләрдәге шәхси җыелмаларда (Испания, АКШ) саклана.

*Әд.:* Айзенштат О. Художники театра к 60-летию образования СССР // Советские художники театра и кино. М., 1983; Хасанова Э. Рифкат Мухамедович Арсланов. Сценография. Живопись: Персоналия. Уфа, 1998; Арсланов Рифкат Мухамедович // Выставка произведений художников-сценографов Республики Башкортостан: Каталог. Уфа, 2000; Художники Советской Башкирии: Справ. Уфа, 1979.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АРСЛА́НОВ** Хикмәтулла Һади улы (25.7.1932, Удмурт авт. өлкәсенең, Балезин р-ны Кестым а.), геохимик, геол.-минералогия фән. д-ры (1989), проф. (1999), РФнең атказ. геологы (1999). Ленинград ун-тын тәмамлый (1956). 1960–64 елларда СССР ФАнең Радий ин-тында, 1964–67 дә Бөтенсоюз геология фәнни-тикшеренү ин-тында (Ленинград) эшли. 1967 елдан Петербург ун-тының геогр. фәнни-тикшеренү ин-тында: палеогеография, табигый мохит эволюциясен өйрәнү (1993 тән) лаб. мөдире. 1997–2001 елларда Нагоя ун-тында (Япония) эшли. Радиоизотоп (радиоуглерод, уранион һәм ион) ысуллар б-н борынгы кешеләр яшәгән урыннарның, диңгез катламнарының һәм дүртенчел система ятмаларының яшен билгеләү методикасын камилләштерә. Балтыйк буе, Белоруссия, Россиянең Европа өлешендәге соңгы плейстоценның геохронологик схемаларын һәм Россиянең төньяк-көнбатыш голоценындагы ландшафтлы-климатик үзгәрешләр схемасын төзи.

Х е з м.: Радиоуглерод: геохимия и геохронология. Л., 1987; Radiocarbon dating evidence for mammoths Wrangel Island, Arctic Ocean, until 2000 BC // Radiocarbon. 1995. V.37, № 1.

**АРСЛА́НОВ** Шубай (18 йөз), татар сәүдәгәре, *Ташкент кәрваны* башлыкларының берсе. 1741–42 елларда сәүдәгәр М.*Йосыпов* һәм С.Дроздов (Курск ш.) б-н бергә Оренбург кальгасыннан (хәзерге Орск ш.) Ташкентка сәүдә кәрванын алып бара һәм алып кайта. Шуннан кайткач, Оренбург губернасын оештыру экспедициясе җитәкчесе И.И.Неплюев б-н очраша. И.И.Неплюев аңардан язып алынган мәгълүматны С.-Петербургка Сенатка җибәрә.

**АРСЛА́НОВА** Мәрьям Ислам кызы (8.4.1926, Кемерово өлкәсе, Юрга р-ны Сарсаз а.), радио дикторы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977). Татар театр техникумын (1949) һәм Казан пед. ин-тын (1963) тәмамлый. 1949–51 елларда Татар акад. театрында актриса. Төп рольләре: Айсылу («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Маша («Яшьлек белән очрашу», А.Н.Арбузов). 1951–63 тә Казан шәһәре мәктәпләрендә рус теле укыта. 1963–82 дә ТАССР МС каршындагы Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында диктор; тыңлаучыларда зур кызыксыну уята торган фәнни һәм иҗтимагый-сәяси темаларга багышланган, ш.и. музыкаль һәм балалар өчен тапшырулар алып бара. 1982–96 елларда Татарстан Мәгариф хезмәткәрләре йортында сәнгать җитәкчесе. 1975–2004 тә Татарстан радиосында ш.у. тыңлаучыларда зур популярлык казанган, татар теленең матурлыгын, байлыгын күрсәтүче, күренекле татар галимнәре әзерләгән «Тел күрке — сүз» тапшыруын алып бара.

Х е з м.: Илаһи көч // Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань!. К., 1998.

*Әд.:* Галимуллин Ф. Озын, матур булсын бу гомер // Сөембикә. 1996. № 5.

**АРСЛА́НОВА** Филүсә Тимергали кызы (20.2.1947, БАССРның Яңавыл р-ны Асауда а.), педагог, музыка белгече, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). Казан мәдәният ин-тын (1975), Казан консерваториясенең хор дирижёрлыгы бүлеген (1980) тәмамлый. 1968–70 елларда Дүртөйле р-ны (БАССР) мәдәният бүлегендә методист-инспектор, 1970–71 дә ТАССР Җыр һәм бию ансамбле солисты, 1978 дән Казан мәдәният ин-тында укыта. 1994 тән хор дирижёрлыгы кафедрасында әйдәп баручы укытучы. А. татар телендә хор белеме буенча программалар төзи һәм хор музыкасын эшкәртә. Музыка дәреслекләрен рус теленнән татар теленә тәрҗемә итә. Татар хоры һәм вокаль музыкасы үсеше мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр һәм китаплар авторы. ДТРК фонында аның җырчы буларак 50 ләп язмасы саклана. А. Россия һәм Татарстанның күп шәһәрләрендә гастрольләрдә була.

Х е з м.: Татар музыка фольклоры. К., 1998; Хор өчен халык җырлары, композиторлар әсәрләре. К., 2002; Былбыл тавышлары тынмасын. К., 2003; Хор белеме нигезләре. К., 2004; Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле — Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан. К., 2007.

**АРСЛА́НОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре: 1) **Гобәйдулла** (? — 1820 еллардан соң), сәүдәгәрләр династиясен нигезләүче; аның җәмәгать эшчәнлегенә кагылышлы беренче мәгълүмат 1795 елга карый. 1808 елдан 3 нче гильдия сәүдәгәр. Казанда 2 кибет тоткан, 1826 елда сабын з-дын нигезләгән; 2) **Габделмәҗит Гобәйдулла улы** (1795 — 1870 тән дә соң түгел), 2 нче гильдия сәүдәгәр. Сабын, шәм җитештерү б-н шөгыльләнгән, ашлык б-н сәүдә иткән. 1840–60 елларда аның заводында иң яхшы шәмнәр коелган һәм яхшы сабын җитештерелгән. Еллык капитал әйләнеше 3500 сум тәшкил иткән. Мәкәрҗә ярминкәсендә һәм Идел буеның башка шәһәрләрендә дә сәүдә иткән; 3) бертуганнар: **Исхак Габделмәҗит улы** (1852 – 1901), 1 нче гильдия сәүдәгәр, Казанда сәүдә ширкәте хуҗасы («Товарищество Исхака Арсланова в Казани», 1900 елдан «Товарищество мыловаренного и глицеринового завода Исхака Арсланова»). Завод 1910 елда җитештерү күләме буенча, бертуган Крестовниковлар заводыннан гына калышып, бу тармакта 2 нче урында торган (анда 120 кеше эшләгән, елына 900 мең сумлык әйбер җитештерелгән); **Ибраһим Габделмәҗит улы** (14.7.1841 – 5.7.1908), икмәк һәм бакалея товарлары б-н сату иткән. 1909 да аның варислары Бәдретдин Хисаметдинов б-н бергә сәүдә ширкәте оештыралар («Торговый дом. Наследники Ибрагима Арсланова и Бадретдин Хисамутдинов», мая капиталы 15 мең сум). Бу ширкәтне оештыручыларның берсе **Әхмәтҗан Ибраһим улы** (1871 – ?) була. Аның иганәсенә Зөя һәм Тәтеш өязләре авылларында берничә мәчет төзелә.

*Әд.:* Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**АРТАМО́НОВ** Дмитрий Панфилович (13.11.1897, Казан губ., Колай волосте Колай а. — 5.10.1957, Казан), нәкышьче, график. Казан архитектура-сәнгать остаханәсен тәмамлый (1926). П.П.Беньков һәм В.К.Тимофеев шәкерте. Казан урта мәктәпләрендә рәсем дәресләре алып бара. 1933 елдан «Татхудожник» берләшмәсендә эшли, бер үк вакытта Казан сәнгать уч-щесендә укыта (1937–39). ТатАХРР әгъзасы (1925–28), 1936 дан Рәссамнар берлеге әгъзасы. «Печән чабучылар», (1924), «Печән өсте» (1925),

«Силос салу» (1931) кебек тематик картиналары 1930–40 елларда Татарстанда рәсем сәнгате үсешен чагылдыра. А. рәсем сәнгате һәм график портрет жанрын үстерүгә өлеш кертә. А.ның иң яхшы эшләре образның психол. яктан тирәннән тасвирлануы б-н аерылып тора («Атказанган артист Туишев», 1934; «Хатыным портреты», 1936; «Автопортрет», 1942; «Сынчы С.С.Ахун портреты», 1945; «Композитор Н.Җиһанов портреты», 1950). 1925–55 елларда Казанда респ-ка күргәзмәләрендә, төбәкара күргәзмәләрдә, 1957 дә Мәскәүдә үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында оештырылган күргәзмәдә катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм ТР Милли музеенда, Түбән Новгород шәһәренең туган якны өйрәнү музеенда саклана.


*Әд.:* Художники народов СССР: Библиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.


*Е.П.Ключевская.*


**АРТАМО́НОВ** Михаил Илларионович (23.11.1898, Тверь губ., Весьегонск өязе Выголево а. — 31.7.1972), тарихчы, археолог, тарих фән. д-ры (1941), Польша ФАнең хакыйкый әгъзасы (1960). Шотландиянең антикварлар җәмгыяте шәрәфле әгъзасы (1942). 1935 елдан Ленинград ун-ты профессоры, 1949 дан археология каф. мөдире, 1948–51 дә ун-тның проректоры. Бер үк вакытта СССР ФАнең Матди мәдәният тарихы ин-ты (1938–43) һәм Дәүләт Эрмитажы (1951–69) директоры. Бөек Ватан сугышы елларында Алабуга шәһәрендә эвакуациядә яши. «СССР археологиясе буенча материаллар һәм тикшеренүләр» («Материалы и исследования по археологии СССР») һәм «Матди мәдәният тарихы институты докладлары һәм кыр тикшеренүләре турында кыска хәбәрләр» («Краткие сообщения о докладах и полевых исследованиях Института истории материальной культуры») исемле даими чыга торган фәнни басмаларга нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре скифлар, славяннар, Хәзәр каганлыгы һәм Киев Русе тарихларына, археологиясенә һәм мәдәниятенә карый. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Средневековые поселения на Нижнем Дону. Л., 1935; Очерки древнейшей истории хазар. Л., 1936; История хазар. Л., 1962; Сокровища скифских курганов в собрании Государственного Эрмитажа. Прага, 1966; Киммерийцы и скифы (от появления на исторической арене и до конца IV в. до н. э.). Л., 1974.

**АРТАМО́НОВ** Николай Степанович (26.12.1930, Новосибирск ш.), проектлаучы рәссам, нәкышьче, график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980). Казан сәнгать уч-щесен педагоглар В.С.Подгурский, С.А.Ротницкий, В.К.Тимофеев классында укып тәмамлый (1958). 1972–76 елларда Е.А.Розенблюм, М.А.Коник җитәкчелегендә СССР Рәссамнар берлегенең ел саен үткәрелә торган эксперименталь укыту студиясе («Сенеж») семинарларында катнаша. Татарстан Сәнгать фонды оешмасының баш рәссамы (1969–73). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). 1976–84 тә Казан сәнгать уч-щесендә укыта. Сәнгатьле бизәү һәм дизайн өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе, җәмәгать биналары — «Ёлочка» кафесы (1966), «Яхонт» зәркән әйберләр кибете (1967), «Идел» халыкара яшьләр лагере (А.А.Спориус б-н берлектә, 1967), Химиклар мәдәният сарае (1968), Татар ашлары йорты (1969–70, автордашлар В.И.Охотин һәм А.А.Спориус), ТАССР Дәүләт сынлы сәнгать музее фасадлары, интерьерлары һәм парклары бизәлеше, музей экспозицияләре (1963) авторы. «Зур Идел» күргәзмәсе (1980) һәм Лейпциг шәһәрендә узган халыкара күргәзмә-ярминкәнең ТАССР бүлеге (Е.Г.Голубцов, В.А.Нестеренко, А.П.Леухин б-н берлектә, 1980) экспозицияләрен эшли. 1960 елларда графика жанрында (линогравюра), 1990 еллардан пейзажчы-нәкышьче буларак танылa. Халыкара (Италия, 1976; Германия, 1980; Голландия, 1998) һәм бөтенсоюз күргәзмәләрендә (1976, 1981, 1982, 1983, 1987, 1989) катнаша. Шәхси күргәзмәсе 1990 да Казанда (улы И.Н.Артамонов б-н берлектә) оештырыла.







Н.С. А р т а м о н о в, И.Н. А р т а м о н о в. 1. «Санта» (Матюшино) санаторий-профилакторий бассейны витражы. 1990; 2. «Васильево» санаториеның фитобар витражы. 1992; 3. «Васильево» санаториеның мәдәният үзәге вестибюле интерьеры. 2000.

*Әд.:* Ф а й н б е р г А.Б. Художники Татарии. Л., 1973; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; ш у л у к. Художники Советской Татарии. К., 1984; А р т а м о н о в ы Н. и И. Живопись, декоративное искусство, графика, дизайн. К., 1991.

*К.П.Тулузакова.*

**АРТА́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Омар елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 177 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Мәчет. 1710 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чана табаны, тәгәрмәч тугымы ясау, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.та мәчет, мәктәп, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 812 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кече Кирмән волостена керә. 1920 дән ТАССР-ның Мамадыш кантонында; 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 217, 1897 дә — 645, 1908 дә — 786, 1920 дә — 796, 1926 да — 836, 1938 дә — 803, 1949 да — 466, 1958 дә — 447, 1970 тә — 450, 1979 да — 309, 1989 да — 200 кеше.

**АРТЕ́МЬЕВ** Александр Иванович (24.10.1820, Саратов губ. Хвалынск ш. — 29.9.1874, С.-Петербург), журналист, статист, географ, рус тарихы магистры. Казан ун-ты Көнчыгыш телләр бүлегенең кытай теле һәм әдәбияты каф. (1841) тәмамлагач, шунда ук китапханәче ярдәмчесе булып эшли. 1844 елда «Прибавление к «Казанским губернским ведомостям» г-тасына мөхәррир итеп билгеләнә. Газета битләрендә аның Идел буе Болгары дәүләте, Идел буе халыкларының тормышы, гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәренә һ.б. багышланган хезмәтләре еш урын ала. Дәвамлы бирелеп бара торган «Казан буйлап сәяхәт» («Прогулки по Казани») (1849–52) дигән рубрикада төбәк тарихына караган һәм шәһәрнең истәлекле урыннары турында мәкаләләр һәм язмалар бастыра. «Москвитянин» (Мәскәү) ж-лында 1848–52 елларда «Казаннан хатлар һәм хәбәрләр» дигән баш астында мәкаләләр циклы чыгара. 1852 елдан С.-Петербургта, Эчке эшләр министрлыгында статистика хезмәтендә; «Россия империясендә халык яши торган урыннар исемлеге»н («Списки населённых мест Российской империи ...» (1–65 чыг., СПб., 1861–85) чыгаруда катнаша; 9 губернаның (ш.и. Казан губ.ның) тарихи-географик, этнографик, статистик мәгълүматларына күзәтү төзи. 1 нче (1869, Мәскәү) һәм 2 нче (1871, С.-Петербург) археологлар съездында катнаша. Рус археологлары һәм Рус географлары җәмгыятьләренең хакыйкый әгъзасы (1850 елдан). «Казан университеты китапханәсендә саклангaн кулъязмалар тасвирламасы» («Описание рукописей, хранящихся в библиотеке Казанского университета») исемле хезмәте вафатыннан соң проф. Е.Е.Замысловский тарафыннан бастырыла (СПб., 1882).

Ә с ә р.: Древний болгарский город Жукотин. СПб., 1851; Исторические рукописи библиотеки Казанского университета: В 30 т. СПб., 1852–56; Обозрение трудов Имп. Русского географического общества по исторической географии. СПб., 1873; Казанские гимназии в XVIII столетии. СПб., 1874.

*К.Н.Куранов.*

**АРТЕ́МЬЕВ** Пётр Алексеевич (30.12.1908, Казан — 9.1.1976, шунда ук), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тының Казан филиалын тәмамлый (1954). 1931–33 елларда Чаллы р-ны «Татарстан» с-зында ремонтлау остаханәсе мөдире, 1934–35 тә Питрәч р-ны Пановка

авылында Татарстан Куллanучылар берлегенең кооператив хуҗалыгы мөдире. 1936–37 дә Казанда ВЛКСМның Молотов район ком-тының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире. 1937–39 да Казан коммуналь хуҗалык инженерлары ин-ты директоры урынбасары. 1941–42 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1942–43 тә Столбище МТСның сәяси бүлеге башлыгы. 1943–48 дә ВКП(б)ның Чаллы р-н ком-ты 1 нче секретаре. 1948–55 тә СССР Хәзерләүләр министрлыгының ТАССР буенча вәкиле. 1955–57 дә ТАССР МС рәисе урынбасары. 1957–70 тә Татарстан Кулланучылар берлеге идарәсе рәисе. 1955–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**АРТИКУЛЯ́ЦИЯ** (лат. articulo — аерам, бүләм, аерып әйтәм), сөйләм әгъзаларының авазлар әйткәндәге эшчәнлеге. Теге яки бу авазны әйтү өчен бу әгъзаларның нинди торышта булуы әлеге авазның А.сен тәшкил итә. Татар телендә сузык авазлар рәт, күтәрелеш, иренләшү-иренләшмәүгә карап бүленә. Мәс., «а» — арткы рәт (аваз ясалганда тел артка китә), түбән күтәрелешле (тел иң түбән торышта), иренләшкән һәм иренләшмәгән вариантларда да була. «Ө» — алгы рәт (авазны әйткәндә тел алга килә), урта күтәрелешле (тел уртача күтәрелештә), иренләшкән (иреннәр алга җыела). Тартык авазларны бер-берсеннән ясалу урынына һәм ысулына, тавыш ярыларына (резонаторга) нинди мөнәсәбәттә булуына карап аералар. Мәс., татар телендә ирен-ирен «W» авазы ясалганда аскы ирен өске иренгә таба тартыла. «Җ» авазын әйткәндә, тел очы өске тешләргә һәм каты аңкауга тия. «А.» термины шулай ук ачык әйтелеш дәрәҗәсен дә аңлата.

*Әд.:* Татар грамматикасы. 3 томда. М.–К., 1998. Т. 1; Большой энциклопедический словарь: Языкознание. М., 1998. *М.Ә.Сәгыйтов.*

**АРТТАГЫ́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама аръягында, Идел елгасының биек террасасында, Спас р-нының Ямбакты авылы янында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 3,08 *га*. Су күләме 35 мең $м^3$ чамасы. Озынлыгы 330 *м*, иң зур киңлеге 120 *м*. Уртача тирәнлеге 1,2 *м*, иң зур тирәнлеге 1,7 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Суы җиңелчә минеральләшкән, бик йомшак, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы. Хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**АРТЪЕЛГА́**, С о с н о в к а, Көнбатыш Кама аръягында. Каргалы елгасының (Чишмә елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 19,9 *км*, бассейнының мәйданы 90,5 $км^2$. Чистай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Татар Сарсазы авылыннан 2 *км* көнбатыштарак, тамагы Исләй авылыннан төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагынык — 66 *м*. Су җыелу терр-ясендә асылда урманнар очрамый диярлек. А.ның 2,3 тән алып 6,7 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 $км/км^2$. Туклануы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1–0,2 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 109 *мм*, ташу агымы катламы 106 *мм*. Язгы ташу, кагыйдә буларак, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга, гадәттә, ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,009 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л* (тамагында 300–400 *мг/л* га кадәр), кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада гомуми күләме 102 мең $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**АРТЫ́Ш** (Juniperus), кипарисчалар семьялыгыннан мәңге яшел ылыслы агачлар һәм куаклар ыругы. 60 лап төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТРда бер төре — гади А. (J. communis), Кама һәм Идел алдында очрый. Нарат урманнарында үсә. Куак, биеклеге 5 *м* га кадәр. Сабагы туры. Кабыгы соры-коңгырт төстә, нәзек, телмә яки куба торган. Яшь бәбәкләре 3 кырлы, саргылт-соры төстә. Ылысы очлы, энәсыман, сеңерчә буйлап киң ак сызыгы бар, өчәрләп бөҗрәга урнашканнар. Ике өйле үсемлек: ата күркә — кыска ян бәбәкләр очында, ана күркәләр — җиләксыман (күркә-җиләк), эчендә өч орлыгы бар. Өлгергән күркә-җиләк зәңгәрсу-кара төстә, балавыз куныгы бар. Май-июньдә серкәләнә, күркә-җиләкләр акрын үсәләр, 2 нче елга тәмам өлгереп җитәләр. Орлыклардан һәм вегетатив юл б-н, культурада чыбыкчадан, үрентедән үрчиләр. Суыкка, корылыкка чыдам булуы б-н аерылып тора, туфракка талымчан түгел. 500 елга кадәр яши. Бәбәкләрендә, ылысларында, күркә-җиләкләрендә эфир мае, гликозидлар, органик к-талар, сумалалар бар. Күркә-җиләкләре фәнни һәм халык медицинасында какырык куптару, бәвел, үт кудыру чарасы буларак кулланыла. А.ның антисептик тәэсире бар, һаваны чистарта. Сусыл җиләксыман күркәләре кошларны, бигрәк тә миләш чыпчыкларын үзләренә җәлеп итә. Декоратив үсемлек.



**АРТЮ́ХИН** Юрий Павлович (10.4.1937, Казан), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1981), проф. (1984). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тының атказ. проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (бүлеге, 1980–88 елларда Чаллы ш. Кама политехника ин-тында материаллар каршылыгы каф. мөдире). 1988 дән теоретик механика каф. профессоры, 2006 дан баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре деформацияләнүчән каты җисем механикасына карый. Пластиналар һәм сүрүләр теориясендәге чикле элементлар ысулын үстерә; күп катламлы ортотроп кабырчыклар теориясенең комплекслы гомуми тигезләмәләрен чыгара; пластиналар һәм кабырчыкларның каты җисемнәр б-н орынып тәэсирләшүен тирәнтен тикшерә; катлаулы термосыгылмалы сөзәк кабырчыкларны хисаплый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчёт ортотропных оболочек вращения на локальные нагрузки // Тр. 6 конф. по теории оболочек. М., 1966; Развитие метода граничных элементов в линейных и нелинейных задачах теории пластин и оболочек // Тр. 18 междунар. конф. по теории оболочек. Саратов, 1977. Т. 3 (автордаш); Теория оболочек с учётом поперечного сдвига. К., 1977 (автордаш); Контактные задачи для упругих элементов конструкций. К., 1988.

**А́РУМ**, к. *Алоказия.*

**АРУТЮНЯ́Н** Александр Ерёмович (24.7.1925, Ереван — 10.2.1981, Ленинград), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1980). 1954 елда Ленинград артиллерия инженерлары академиясен тәмамлый. 1942–69 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә, 1954 тән СССР Оборона министрлыгының Фәнни-тикшеренү ин-тында, 1958 дән Киев югары артиллерия инженерлары уч-щесендә реактив двигательләр каф. доценты. 1969 дан Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында лаб., бүлек башлыгы. Хезмәтләре күпшәле системаларның тышкы һәм эчке баллистикасына карый. Махсус машиналар төзелеше өлкәсендә технологик эшкәртмәләре өчен СССР Дәүләт бүләге бирелә (1980). Медальләр б-н бүләкләнә.

**АРХАИ́ЗМНАР** (грек. archáios — борынгы), телдә актив кулланылыштан төшеп калган сүзләр, гыйбарәләр һәм грамматик формалар. А. лексик һәм семантик төрләргә бүленә. Лексик А. түбәндәгеләрне үз эченә ала: а) тулысынча искергән сүзләр. Татар телендә аларга кайбер борынгы төрки һәм гарәп-фарсы телләреннән алынган сүзләр керә, мәс.: будун (халык), йазы (дала), мәлик (идарәче), нифак (кылану), үкүш (күп). Ш.у. пассив кулланыштагы, сөйләшүчеләргә аңлаешлы булган искергән сүзләр дә бар, мәс.: туар (йорт хайваннары) — хәзерге татар телендә парлы сүз формасында саклана: мал-туар, терлек-туар. Кайбер А. тотрыклы гыйбарәләрдә, мәкаль һәм әйтемнәрдә очрый, мәс.: «Дөягә ут кирәк булса, муенын озайтыр» әйтемендә «ут» («үлән») — А.булып тора; б) лексик-сүз ясагыч А. — искергән кушымчалы сүзләр, мәс.: кил-дәче (киләсе кеше), утырмак (утыру); в) лексик-фонетик А. — әйтелеше искергән сүзләр, мәс.: уйгат — уят, килтер — китер. Семантик А. — элекке (баштагы) мәгънәсен югалткан, хәзер башка төшенчәне белдергән сүзләр, мәс.: «йорт» сүзе элекке «ил», «дәүләт» мәгънәсендә кулланылыштан төшкән; аның хәзер «торак» мәгънәсе генә сакланган; «үгез» элек «елга» төшенчәсен белдергән. А., стилистик чараларның берсе буларак, тасвирлы сөйләмнең тәэсирен көчәйтү, аңа тарихи төсмер бирү өчен кулланыла.

*Әд.:* Хәзерге татар әдәби теле. К., 1965; С а ф и у л л и н а Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999.

*В.Х.Хаков.*

**АРХА́НГЕЛ БИСТӘСЕ́**, 16 йөзнең 2 нче яртысында Казанның көньяк-көнчыгыш читендә, Кабан күленең сул яры буенда (хәзерге Һ.Такташ урамы, Зооботаника бакчасы ти-

рәләре) барлыкка килә. Казан ханлыгы чорында анда Колмәмәт исемле татар авылы була. Казан ханлыгы яулангач (1552), баштарак Казан воеводасы Ф.Булгаковка, аннары 1567 дә Иван IV грамотасы нигезендә архиепископ Германга бирелә. Атамасы шунда төзелгән Михаил Архангел чиркәвенә бәйле. 17 йөз ахырында Архангельский авылы



Архангел бистәсе. 20 йөз башы фотосы.

йорт бистәсенә әверелә. Халкының төп өлешен Үзәк Россиядән күчерелгән җирсез крәстияннәр тәшкил итә. 1774 елгы исәпкә алу (ревизия) вакытында А.б.ндә — 106, 1744 тә 229 ир заты, нигездә, һөнәрчеләр (ташчылар, кирпеч сугучылар, сыра кайнатучылар, квас кайнатучылар, балта осталары һ.б.) теркәлә. 18 йөз урталарыннан шәһәр чикләренә керә. 1783 елдан башлап А.б. арх. В.И.Кафтырев планы буенча төзелә башлый.

*Әд.:* С у л т а н о в Р.И. Историческая география Казани (город и его предместье в XVI–XVII веках). К., 2004.

**АРХА́НГЕЛ БИСТӘСЕ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 11 *км* төньяктарак, Шушма елгасы буенда. 2002 елда 585 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1730 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шушма исеме б-н дә билгеле. Беренче булып соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелгән отставкадагы солдатлар килеп урнаша. Игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында А.Б.ндә Вознесение чиркәве (1876 да төзелә, архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1878 дә ачыла), фельдшерлык пункты, су тегермәне, 2 сыраханә, шәраб һәм 9 вак-төякләр кибете була; пәнҗешәмбе саен базар, Троица көнендә ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 645 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 1413, 1897 дә — 2857, 1908 дә — 2750, 1920 дә — 3034, 1926 да — 2668, 1938 дә — 1922, 1949 да — 1198, 1958 дә — 1028, 1970 тә — 960, 1979 да — 602, 1989 да — 483 кеше.

**АРХА́НГЕЛ РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* үзәк өлешендә. 1930 елда оештырыла. Мәйданы — 2422 *км²*. Үзәге — Архангел авылы (Уфадан 88 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 20165 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 2791, 1979 да — 2529, 1989 да — 2238, 2000 дә — 2310, 2002 дә 1860 кеше. Районда 76 торак пункт, ш.и. 9 татар, 5 татар-башкорт, 2 татар-рус авылы бар. Иң зур татар авыллары (2000): Шәрәй (269 кеше), Чишмә (190), Шакир (124). Элегрәк (1902–19) барлыкка килгәннәре — Зәет, Сәгыйт, Шакир авыллары. 2004/2005 уку елында А.р.ның 3 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла.

**АРХА́НГЕЛЬСК**, РФнең Европа өлешенең төньягындагы шәһәр, Архангельск өлкәсенең үзәге. Халкы — 372,1 мең кеше (1996), ш.и. 1819 татар (1989). Даими яшәүче татарлар 19 йөз ахырларында күчеп киләләр. Алар күбесенчә читтән китертелгән азык-төлек һәм мануфактура б-н сәүдә итәләр, агач әзерләүдә эшлиләр. 20 йөз башында татар җәмгате иганәсенә мәчет (1905), татар мәктәбе (1908) ачыла, хәйрия һәм мәгърифәт җәмгыятьләре эшли. 1920 елларда шәһәрдә Архангельск мөселман дини оешмасы, «Мөселманнар клубы» була. 1999 дан шәһәрдә һәм өлкәдә татарларның төбәк милли-мәдәни автономиясе эшли, «Татар газетасы» һәм «Мөселман газетасы» нәшер ителә.

**АРХА́НГЕЛЬСКИЙ** Александр Семёнович (12.7.1854, Пенза ш. — 24.4.1926, Мәскәү), әдәбият галиме, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1904), Казан ун-тының атказ. проф. (1907). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1876). 1878 елга кадәр Сембер гимназиясендә, 1882–1908 елларда Казан ун-тында укыта (1884 тән проф.). 1917 дән соң Сембер ун-тын оештыручыларның берсе. «Борынгы рус әдәбиятын өйрәнүгә карата... Борынгы рус язма әдәбиятында чиркәү әһелләренең иҗаты» («К изучению древнерусской литературы... Творения отцов церкви в древнерусской письменности», 1888) исемле фундаменталь хезмәте А.га мәшһүрлек китерә. Көнбатыш Европада әдәбият укыту тәҗрибәсен өйрәнеп, укыту практикасына фәнни-методик семинар алымын кертә. Россиядә беренчеләрдән булып рус әдәбияты тарихының системалы курсын (борынгы чорлардан 18 йөз уртасына кадәр) эшли һәм аны уку-укыту процессында гамәлгә куя. В.А.Жуковский, Е.А.Боратынский, С.Т.Аксаков, В.Г.Белинский, Н.В.Гоголь, Д.В.Григорович иҗатларын өйрәнә. 1902 дә А. редакциясендә В.А.Жуковский әсәрләренең тулы җыелмасы басылып чыга. Хезмәтләрендә аеруча типология, библиография, палеография, историография мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Рус әдәбиятының көньяк славян һәм Көнбатыш әдәбиятлары б-н бәйләнешләрен өйрәнә. А.ның тырышлыгы б-н Рус әдәбиятын сөючеләр җәмгыяте тарафыннан Казан һәм Урта Идел буеның әдәби, иҗтимагый һәм мәдәни тормышын өйрәнү активлашып китә. 1900–04 тә *Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте рәисе*. «Казанский телеграф» г-тасында, «Православный собеседник» ж-лында хезмәттәшлек итә. 1908 елдан соң С.-Петербургта яши.

Х е з м.: Пушкин в его произведениях и письмах. К., 1887; Образование и литература в Московском государстве конца XV–XVI вв.: В 4 вып. К., 1898–1913; Введение в историю русской литературы. История литературы как наука. СПб., 1916. Т. 1.

*Әд.:* Русские писатели. 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1989. Т. 1; В о р о н о в а Л.Я. А.С.Пушкин в оценке А.С.Архангельского // Уч. зап. Казан. ун-та. 1998. Т. 136.

*Л.Я.Воронова.*

**АРХА́НГЕЛЬСКИЙ** Константин Фёдорович (20.5.1870, Владимир губ. — 30.9.1906, Казан), терапевт, медицина д-ры (1899). Томск ун-тын тәмамлаганнан соң (1895), шунда ук эшли. 1903 елдан Казан ун-тында проф. һәм фармакология каф. мөдире. Хезмәтләре йөрәк эшчәнлегенә төрле дарулар тәэсирен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Материалы к фармакологии бромистого ареколина. Томск, 1989.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**АРХА́НГЕЛЬСКИЙ** Пётр Григорьевич (23.6.1884, Саратов губ. Сердобск ш. — 6.1.1921, Казан), тарихчы. Казан ун-тын тәмамлый (1912). Н.Н.Фирсов һәм Д.А.Корсаковның шәкерте. 1905–07 еллардагы рев-циядә актив катнашкан өчен Саратов шәһәрендә хөкем ителә һәм Саратов губернасыннан куыла. 1908–12 елларда «Камско-Волжская речь» г-тасында икътисад бүлеген җитәкли, 1912 дән Казан ун-ты укытучысы, проф. (1917). Бер үк вакытта Хатын-кызлар югары курсларында укыта. 1917 дән Казан ун-ты рабфагында; өяз шәһәрләрендә лекцияләр укый. Хезмәтләре Россиянең аграр тарихына һәм тарихи чыганакларга карый. Аларда А. рус авыл җәмгатенең үсеш юлларын М.Ф.Владимирский-Буданов, Н.П.Павлов-Сильванский һ.б. тикшеренүчеләр хезмәтләре б-н бәйләп тикшерә. 1767 елгы салым җыю күрсәтмәләрен земство үзидарәләренең узган чорлар актлары б-н чагыштырып тикшерә. Хезмәтләренең бер өлеше басылмыйча кала. Тиф авыруыннан вафат була.

Х е з м.: К вопросу о происхождении русской общины. К., 1913; Выборы в Екатерининскую Комиссию от крестьян Двинского Севера. П., 1915; Погостные наказы 1767 года как исторический источник. К., 1916; Очерки по истории земельного строя России. К., 1920.

*Әд.:* Б у р г с д о р ф - О в ч и н н и к о в а В. Памяти П.Г.Архангельского // Казанский библиофил. 1921. № 1.

*А.Н.Бикташева.*

**АРХАРОВКА**, к. *Көрнәле*.

**АРХЕ́Й** (грек. archáios — борынгы), кембрийга кадәр булган дәвердәге иң эре ике стратиграфик бүлекнең түбәнгесе. «А.» атамасы (элеккеге «архей төркеме») Америка геологы Дж. Дана тарафыннан кертелә (1872). 1,5 млрд. ел чамасы дәвам итеп, моннан 2,6 млрд. еллар элек тәмамлана. Кайчан башланганы төгәл билгеле түгел. А. токымнары борынгы платформалар (ш.и. Рус платформасының да) нигезен хасил итә; платформа күтәрелгән урыннарда (Балтыйк, Канада щитлары), ш.у. геосинклиналь поясларда җыерчык төзелешле урыннарның үзәгендә җир өстенә чыгалар. А. токымнарына түбәндәге петрографик состав хас: биотит-амфиболлы һәм биотитлы плагиогнейслар, амфибол-би-

отит һәм биотит-амфиболлы кристаллик сланецлар, гиперстенлы плагиогнейслар. А.ның гнейс комплексы эче (гнейс-гранитлар) һәм нигез (норит һәм габброноритлар, габбродиабазлар) токымнар кереп кискәләнгән. Хромит, бакыр-никель, тимер рудалары, алтын һ.б. чыганаклары А. токымнарына бәйле. 3 млрд. елдан да элекке иң борынгы токымнарда бер күзәнәкле примитив микроскопик суүсемнәрнең органик калдыклары табыла. Татарстан терр-ясендә А.токымнарының яше 2699+12 дән алып 3109+97 млн. елга кадәр дип исәпләнә. А. утырмалары 1,8 *км* дан артык тирәнлектә ята. Үтә тирән скважиналар ярдәмендә ачылган катлам калынлыгы 4 *км* дан артык. Татарстан терр-ясендә А.га бәйле файдалы казылма чыганаклары табылмаган. Сибелмә минераллашу магнетит, ильменит, пирротин, пирит, гематит, графит һ.б. минераллардан гыйбарәт. 1850–5800 *м* тирәнлектә үтә тирән скважиналар бораулау нәтиҗәсендә А. токымнарында яргаланган һәм вакланган зоналардан торучы берничә дистә метрлар калынлыгындагы потенциаль коллектор участоклары табыла. Коллекторларда углеводородлар (нефть, битум, газлар) һәм бальнеологик үзлекле нык минераллашкан сулар бар.

*Әд.:* Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996; Перспективы нефтегазоносности кристаллического фундамента на территории Татарстана и Волго-Камского края. К., 1998; Геология Татарстана. Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**АРХЕ́О**... (грек. archáios — борынгы)

**АРХЕОГРА́ФИК ЭКСПЕДИ́ЦИЯЛӘР**, язма тарихи чыганакларны барлау һәм җыеп алу өчен оештырылган фәнни экспедицияләр. Археографик чыганакларны барлау эшенә башлап дин әһелләре, язучылар, төбәк тарихы б-н кызыксынучылар керешә (мәс., Сәйф Сараи, Кол Шәриф, Кадыйргали бәк, Т.Ялчыгол һ.б.). Алтын Урда һәм татар ханлыклары яшәгән дәвердә гарәп, фарсы, төрки-татар телләрендә язылган байтак кульъязма туплана. Аларны туплауда мәчет, мәдрәсәләр әһәмиятле эш башкара. Мәс., Казанның Кол Шәриф җамигъ мәчете карамагындагы китапханәнең бик бай кульъязма мирасы булганлыгы мәгълүм. Башка мәчет-мәдрәсәләр дә аңардан калышмаган. 1552 елда Казан ханлыгы яуланганда бу мирасның зур өлеше юкка чыгарыла. 18–19 йөзләрдә сакланып калган төрки-татар кульъязма мирасын җыеп туплау эшенә Г.Утыз Имәни, Г.Чокрый һ.б. керешә. 19 йөз башында Казан ун-ты ачылгач, язма мирасны барлау һәм өйрәнү эшчәнлеге эзлекле күренеш ала башлый. Ун-т галимнәре (Х.Френ, К.Фукс, Ф.Эрдман, И.С.Хәлфин, Г.К.Казимбәк, И.Н.Березин, О.М.Ковалевский, В.П.Васильев һ.б.) тарафыннан Россия империясе һәм Шәрекъ илләре биләмәләрендә археографик тикшеренүләр алып барыла. 19 йөз урталарына гарәп, фарсы, кытай, маньчжур, монгол, тибет, татар, төрек һ.б. Көнчыгыш һәм Шәрекъ телләрендәге бай коллекция туплана. *Шәрекъ бүлеген* Казан ун-тыннан Петербург ун-тына күчергәннән соң (1854), җирле галим һәм дин әһелләреннән И.Ф.Готвальд, Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, К.Насыйри, Н.Ф.Катанов, Р.Ф.Фәхретдин, Г.Н.Әхмәров, Г.М.Баруди, С.Г.Вахиди һ.б. монда бу эшне дәвам иттерәләр. Тупланган коллекцияләрнең бер өлеше соңрак Казан, Уфа, С.-Петербург фәнни китапханәләренә эләгә һәм сакланып кала. Бу өлкәдә аеруча зур эшчәнлеге б-н танылган С.Г.Вахиди 1910–30 еллар арасында 3 мең чамасы язма чыганак туплый (ш.и. *Сәхибгәрәй хан ярлыгын* таба). Ул кульъязмаларның аңлатма каталогын төзи һәм бернинди түләүсез аларны СССР ФАнең Шәркыятьчелек ин-ты, Казан ун-ты китапханәләренә, ТАССРның Дәүләт музеена һ.б. оешмаларга тапшыра.

1963 елда Казан ун-тының СССР тарихы кафедрасы каршында (1989 елдан татар халкы тарихы кафедрасы каршында) даими эшләүче А.э. төркеме оештырыла, алдан билгеләнгән тәртиптә аерым төбәкләрдә Шәрекъ телләрендәге, ш.и. төрки телләрдәге язма чыганакларны җыю башлана. А.э. төркеме 1964 елдан алып РФнең 1000 гә якын торак пунктында (башлыча, авылларда) була; беренче фәнни җитәкчесе М.Г.Госманов, 1990 дан Җ.С.Миңнуллин. Экспедиция Касыймнан Иркутскига, Пермьнән Әстерханга һәм Оренбургка кадәр аралыкта урнашкан татар авылларыннан 10 меңнән артыграк санда кульъязма табып кайта. Ул кульъязмалар ислам диненә һәм мөселманча мәхкәмә-хокук тәртипләренә, фәлсәфә, мантыйк, Шәрекъ филологиясе, гомуми һәм төбәк тарихы мәсьәләләренә, әдәбият, фольклор, медицина, математика, астрономия һ.б. өлкәләргә карый. Ш.у. А.э. 2 меңгә якын гарәп хәрефле (борынгы) басма китап һәм газета-журналлар туплый. Казан ун-ты А.э. эшендә И.А.Гыйләҗев, Р.Ф.Мәрданов, Ш.Ф.Мөхәммәдъяров, А.С.Фәтхиев, Р.Ә.Шәйхиев, Ф.Н.Шәкүров һ.б. белгечләр актив катнаша. Археографик табышларны өйрәнеп, тасвирлап бастыру эше җайга салына. Төрле архивларда һәм гыйльми китапханәләрдә сакланган язма чыганакларны (рәсми һәм шәхси документлар, ш.и. ханнар ярлыклары) элекке СССР күләмендә (Ш.Ф.Мөхәммәдъяров, М.Г.Госманов һ.б.) һәм 1980–90 елларда чит илләрдән Иран, Мисыр, Төркиядә (И.З.Нуруллин, М.Г.Госманов, А.Б.Халидов, С.Т.Рәхимов һ.б.) эзләп табу һәм кайберләрен тасвирлап бастыру эше башкарыла. Идел төбәгендә 13–16 йөзләрдә яшәүчеләрдән калган, гарәп телендә язылган чыганаклар да очрый. Мәс., Таҗетдин әл-Болгариның фармакологиягә багышланган «әт-*Тирьякъ әл-Кәбир*» хезмәте шундыйлардан. 1960 еллар ахырыннан ТРда һ.б. төбәкләрдә сакланган язма мирасны барлау эшенә СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты (1996 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) галимнәреннән Ш.Ш.Абилов, М.И.Әхмәтҗанов, М.В.Гайнетдинов, Ф.С.Фасиев, Г.В.Йосыпов һ.б. керешә. Бу өлкәдә аеруча М.И.Әхмәтҗанов эшчәнлеге зур әһәмияткә ия: ул меңнән артык кульъязма, документаль чыганак һәм гарәп язуында басылган китаплар таба, аларның кайберләрен тасвирлап хезмәтләр бастыра. Ин-тның «Мирасханә»сендә хәзер 6 меңнән артык кульъязма чыганак һәм 2 мең чамасы документ саклана. Шәрекъ телләрендәге кульъязмаларны һәм сирәк китапларны туплау б-н ТРның Милли китапханәсе, Милли музее һәм «Казан» милли-мәдәни үзәге дә шөгыльләнә.

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Каурый каләм эзеннән. К., 1994; К р а ч к о в с к и й И.Ю. Собрание арабских рукописей в Казани. Избр. соч. М.–Л., 1960. Т.6; У с м а н о в М.А. Сколько потерь в каждой находке! // Памятники Отечества: Альманах Всерос. об-ва охраны памятников истории и культуры. 1989. № 1; ш у л у к. Zur Geschichte der tatarischen Handschriften // Muslim Culture in Russia and Central Asia from the 18 th to Early 20 th Centuries. Islamkundliche untersuchungen. Bdpst., 200, Klaus Schwars Verlag. B., 1996.

*М.Г.Госманов.*

**АРХЕОГРА́ФИЯ** (*архео* ... һәм ... *графия*), тарих фәненең махсус тармагы; элеккеге чорлардагы кульъязма истәлекләр һәм басма хезмәтләрне, төрле төрдәге документларны җыю, өйрәнү һәм тасвирлап нәшер итү б-н шөгыльләнә. Россиядә А. фәне язма чыганакларны барлау, документаль истәлекләрне өйрәнү (дипломатика, актология), палеография, филология, архив эшен алып бару (архивоведение) б-н бергә үрелеп үсә. 18 йөз — 20 йөз башында А.нең төп юнәлешләре билгеләнә: 1) элекке чорларга караган кульъязма истәлекләрне һәм басма хезмәтләрне урыннарга барып табу, җыю һәм аларның кулланыш даирәсен ачыклау (к. *Археографик экспедицияләр*); 2) табылган археографик материалны фәнни дөрес аңлату-өйрәнү, таралу колачын чамалау, белешмәсен төзү, тасвирламасын басмага әзерләү һ.б. А.нең ике юнәлеше дә бер төрле методик караштан чыгып башкарыла: табылдыкның саклану сыйфатын ачыклау, әчтәлегенең башка шундый язма мираска тәңгәллеген-охшашлыгын билгеләү, кулланыш-таралыш даирәсен, авторын, язылу вакытын тулырак белергә тырышу һ.б. Төрки-татарларда археографик тәҗрибә кульъязма китаплар язу дәвереннән туплана килгән (дини китапларны күчереп язуда төгәллек таләпләрен үтәү; Алтын Урда һәм татар ханлыклары чорында булдырылган матур язу — хаттатлар мәктәпләре тәҗрибәләре). Казанда Кол Шәриф мәчетендә күп санда кульъязма китаплар тупланган булуы, 1552 елгы яудан соң аларның Иван IV әмере б-н Мәскәүгә күчерелүе турында хәбәрләр бар. Заманча фәнни А.гә Казан төбәгендә 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Х.Френ, К.Фукс, Ф.Эрдман, И.Н.Березин, И.С.Хәлфин, Г.К.Казимбәк, О.М.Ковалевский, В.П.Васильев, Г.Чокрый, Г.Утыз Имәни, Г.С.Саблуков, И.Ф.Готвальд, Н.Ф.Катанов һ.б. Шәрекъ телләрендәге, ш.и. татар телендәге кульъязмаларны А. фәне таләбенчә җыю һәм тикшерү эшен башкара. Табылган кульъязмаларның байтагы нәшер ителә («Кыйсса-и Йосыф» әсәре, Ибне Фазлан, И.Бикмөхәммәдевнең юлъязмалары һ.б.). Төбәктә А. фәне үсешендә Казан ун-тында ачылган *Шәрекъ бүлегенең* әһәмияте зур була.

19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башындагы чорда төрле төр А. язма табылдыкларны бастырып чыгару эше тәртипкә салына. Бу дәвердә социаль-икътисади һәм мәдәни мохитны чагылдырган, татар халкы тарихына һәм әдәбиятына, иҗтимагый фикер үсеше-

нә караган язма чыганак һәм истәлекләрне барлауга ихтыяҗ арта бара. Мондый эчтәлекле язма мирасны бастырып чыгаруда уңышлы эшләүчеләрдән И.Ф.Готвальд, Ш.Мәрҗани, С.Б.Күкләшев һәм Х.Фәезханов, Р.Әмирханов, В.В.Вельяминов-Зернов, Н.И.Ильминский, К.Насыйри, Р.Ф.Фәхретдинов, Г.Н.Әхмәров, Г.М.Баруди, В.В.Бартольд, Һ.М.Атласи, С.Г.Вахидов һ.б. исемнәрен атарга кирәк («Кыйссас әл-әнбия», «Бабурнамә», «Тутыйнамә», «Диван-е хикайә әт-татар», «Асәр» һ.б.). 1916 елда Казан губернасында Гыйльми архив комиссиясе оештырыла, нәтиҗәдә А.эшен төрле яклап гамәлгә ашыру мөмкинлеге туа. Комиссия тырышлыгы б-н 1917 дә Казанда *Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институты* ачыла, ул оешма бик кирәкле язма истәлекләр һәм документларны саклап калу чарасын күрә. 1921 елда *Гыйльми Үзәк* оештырылгач, А.гә караган мирасны җыю-туплау, тасвирлау һәм нәшер итү эше аның җитәкчелегендә башкарыла башлый.

С.Г.Вахидов, Г.М.Рәхим, Г.С.Гобәйдуллин, Г.Г.Ибраһимов, Җ.Җ.Вәлиди, Г.Ә.Нигъмәти, Ф.Ә.Туйкин һ.б. бик күп язма ядкәрләрне туплый, өйрәнә һәм тасвирлап фән дөньясына кертеп җибәрәләр, шул рәвешле тарих, әдәбият, фәлсәфә һәм иҗтимагый фәннәр үсешенә булышлык итәләр, мондый эшләрне башкару кагыйдәләрен әзерлиләр. 1939 елда ачылган Тел, әдәбият һәм тарих фәнни ин-ты А.өлкәсендә байтак эшләр башкара, яңа мөмкинлекләр тудырыла. Ин-т галимнәре Ш.Ш.Абилов, М.И.Әхмәтҗанов, Р.Р.Гайнанов, М.В.Гайнетдинов, М.Х.Гайнуллин, Г.В.Йосыпов, Ф.С.Фасиев, Г.М.Халит, Х.Х.Хисмәтуллин, Н.Г.Юзиев һ.б. тарафыннан Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Г.Утыз Имәни, Акмулла, Г.Кандалый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан һ.б.ның әдәби иҗат мирасы өйрәнелә һәм дөнья күрә. Ин-т галимнәренең байтак эшләре үрнәк археографик югарылыкта башкарыла. Хәзерге дәвер А. фәне үсешенә Казан ун-ты галимнәре, ун-тның 1963 елда оештырылган *Археографик экспедицияләре* зур өлеш кертә. ТРның Милли китапханәсе, Милли архивы, ТР ФАнең Тарих ин-ты, ТРның Милли музее, «Гасырлар авазы — Эхо веков» ж-лы хезмәткәрләре һәм галимнәре дә республикада А.фәнен үстерүдә сизелерлек роль уйныйлар.

*Әд.:* Госманов М.Г. Язма мирасыбызның күтәреләсе катламнары // Казан утлары. 1984. № 5; Брегель Ю.Э. Восточные рукописи в Казани // Письменные памятники Востока: Ист.-филологические исследования: Ежегодник. К., 1969; Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979; шул ук. Итоги и перспективы археографических работ в Казанском университете // Материалы итоговой науч. конф. Казан. гос. ун-та за 1988 год. К., 1990; Ахметзянов М.И. Новые археографические материалы и их значение в исследованиях по истории татарской литературы. К., 1998.

*М.Г.Госманов.*

**АРХЕОЛО́ГИК ИСТӘЛЕКЛӘ́Р**, кеше эшчәнлегенең археология тарафыннан өйрәнелә торган матди калдыклары (к. *Археология*, *Археологик казу эшләре*). А.и. — кешелек дөньясының үткәнен өйрәнүдә файдаланыла торган матди тарихи чыганакларны тәшкил итә. Аларга торулыклар, авыллыклар, шәһәрлекләр, каберлекләр, хәзинәләр, йола үткәрү урыннары һ.б. керә. Андый урыннарда табылган эш кораллары, тормыш-көнкүреш, сәүдә, бизәнү әйберләре, кораллар һ.б. шушы А.и. не калдырган кешеләрнең нинди культурага каравын һәм яшәү вакытын билгеләргә ярдәм итә. Ш.у. күмү йолалары, каберлекләрдә табылган әйберләр, төрле язулар аларның нинди рухи культурага каравын күрсәтә. ТР терр-ясендә 2000 ел башына 5,5 мең А.и. табыла, шуларның 4,3 меңе тасвирлана. (к. «*Татарстан Республикасының археологик картасы*»). Иң билгеле А.и.: *Ананьино каберлеге*, *Биләр шәһәрлеге*, *Болгар шәһәрлеге*, *Олы Тархан каберлеге*, *Зур Тигәнәле каберлеге*, *Әҗмәр авыллыгы*, *Суар шәһәрлеге*, *Танкеевка каберлеге*.

*Әд.:* Авдусин Д.А. Полевая археология СССР. М., 1972; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

**АРХЕОЛО́ГИК КАЗУ́ ЭШЛӘРЕ́**, археологик истәлекләрне кыр шартларында фәнни өйрәнү, ТР ФА Тарих ин-тының Археологик тикшеренүләр милли үзәге каршындагы кыр тикшеренүләре бүлегенең махсус рөхсәте («ачык сәхифә») б-н истәлекләр, торулыклар, авыллыклар, шәһәрлекләр, каберлекләрнең культура катламын тулысынча тикшерүне тәэмин иткән методика нигезендә башкарыла. А.к.э. вакытында башта казу





Казан Кремлендә археологик казу эшләре.

урыны тикшерелә, планы сызыла, казу мәйданы билгеләнә, казыганда һәр табылдыкның урынын күрсәтү яисә фотога төшерү кебек ысуллар кулланыла, ш.и. казу мәйданының стратиграфиясе (катламнарның урнашуы) ачыклана. А.к.э. кешелек дөньясының борынгы тарихына караган материаллар тупларга ярдәм итүче төп фәнни эшчәнлек санала. Татарстанда А.к.э. 19 йөзнең 2 нче яртысында башлана. Бу эшне оештыруда Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте зур роль уйный. 1870–90 елларда А.Ф.Лихачёв, Н.Ф.Высоцкий, А.А.Штукенберг, П.А.Пономарёв, Ф.Д.Нефёдов һ.б. тарафыннан неолит, бронза, әүвәлге таш гасыр дәверләрен, болгар калаларын (Болгар, Биләр, Кашан һ.б.) археологик тикшерү буенча күп эшләр башкарыла. 1930 еллар уртасыннан А.П.Смирнов җитәкчелегендә Болгар, Суар шәһәрлекләрен һ.б. истәлекләрне планлы рәвештә тикшерү башланып китә. 1940 елларның 2 нче яртысыннан бу эшләр аеруча киң колач ала. Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков һ.б. галимнәр зур мәйданнарда Болгар, Биләр, Җукәтау, Иске Казан, Казан, Камай шәһәрлеге, Әҗмәр авыллыгы һ.б.ш. археологик истәлекләрне тикшерү чаралары үткәрә. 1990 еллар уртасыннан Ә.Г.Мөхәммәдиев, Ф.Ш.Хуҗин, А.Г.Ситдыйков һ.б. җитәкчелегендә Казан Кремлендә зур казу эшләре алып барыла. А.к.э.нең барышын ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Тарих, мәдәният ядкәрләрен саклау һәм файдалану буенча дәүләт контроле баш идарәсе һәм ТР ФА Тарих ин-тының Археологик тикшеренүләр милли үзәге тикшереп тора.

*Әд.:* Авдусин Д.А. Полевая археология СССР. М., 1972; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье. К., 1986.

*Е.П.Казаков.*

**АРХЕОЛО́ГИК КО́МПЛЕКС**, билгеле бер мәйданда тупланган, төрле типка (торулык, авыллык, шәһәрлек, каберлек һ.б.) һәм дәвергә караган археология истәлекләре җыелмасы. Гадәттә, истәлекләр төрле халыктан (кабиләләрдән) калган була (мәс., Балымер авылы янындагы елга буенда тар мәйданда урнашкан комплекста 20 дән артык истәлек керә, ш.и. бронза гасыр торулыклары, ике Имәнкискә һәм Болгар шәһәрлекләре, Имәнкискә һәм Болгар авыллыклары, 10 һәм 14 йөзгә караган курганлы каберлекләр, мөселман каберлекләре һ.б.). Истәлекләрнең кайберсе күп катламлы, мәйданнары тулысынча яки өлешчә туры килә. Татарстанда урнашкан А.к.лар түбәндәгеләр: Алексеев, Әҗмәр, Әтрәч, Әшнәк, Балым, Балымер, Дәвек, Җукәтау, Займище, Имәнкискә, Иске Куйбышев, Иске Нохрат, Иске Сөйке, Кабык Күпер, Кожаевка, Коминтерн, Котловка, Кумыс, Лаеш, Луговской, Маклашеевка, Мәлләтамак, Меңнәр, Никольский Баран, Олы Тархан, Рождествено, Свиногорье, Семёново, Такталачык, Танкеевка, Татар Ямалы, Ташкирмән, Троицк Урай, Шонгат һ.б.

*Әд.:* Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

**АРХЕОЛО́ГИК КУЛЬТУ́РА**, археология фәнендәге төп төшенчәләрнең берсе, уртак сыйфатларга ия булган һәм билгеле бер вакыт аралыгында киң мәйданда таралган археологик материаллар җыелмасын билгели. Гадәттә, этник берлек культурасын чагылдыра. Һәр А.к. икенчесеннән үзенчәлекле материаллары б-н аерылып тора. Татарстанда 30 га якын археол. культура истәлекләре бар: Абашево, Азелино, Алтын Урда, Ананьино,

Андроново, Баланово, Балахна, Болгар, Буралы Курган, Волосово, Гарино-Бор, Городец, Идел-Чулман буе, Имәнкискә, Казан яны, Чулман Тамагы, Кушнаренко, Ломоватово, Мазунино, Постпетрогром, Казан яны, Пьянобор, Салтау-Маяк, Чиркәскүл, Чиялек һ.б. Ш.у.к. *Археология*.

*Әд.:* Арциховский А.В. Основы археологии. М., 1954; Генинг В.Ф. Проблема построения фундаментальной археологической теории // Рос. археология. 1992. № 1; Гуляев В.И., Беляев Л.А. О современном состоянии археологии в России (полемические заметки) // Рос. археология. 1995. № 3.

*Е.П.Казаков.*

**АРХЕОЛО́ГИЯ** (*архео...* һәм *...логия*), сакланып калган матди чыганаклар нигезендә кешелек дөньясы тарихын өйрәнүче фән. Матди чыганаклар — артефактлар (лат. artefaktum — ясалган) — җитештерү кораллары һәм алар ярдәмендә барлыкка китерелгән матди байлыклар: корылмалар, кораллар, бизәнү әйберләре, савыт-саба, сәнгать әсәрләре һ.б., кыскасы, кешеләр тарафыннан җитештерелгән барлык әйберләр. Язма чыганаклардан аермалы буларак, артефактлар тарихи вакыйгалар хакында турыдан-туры сөйләми, шул сәбәпле алар нигезендә тупланган тарихи мәгълүматлар фәнни реконструкция нәтиҗәсе булып тора. А.нең үзенә хас тикшерү ысуллары бар. Стратиграфия ысулы арада иң мөһиме санала — ул бер урында озак яшәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән культура катламнарының урнашу тәртибен билгеләү һәм аларның хронологик бәйләнешен ачыклаудан гыйбарәт. *Археологик казу эшләре* барышында табылган әйберләр түбәндәге билгеләр буенча классификацияләнә: әйбернең кулланылу максаты, эшләнү вакыты һәм эшләнгән урыны. Коралның нинди максатта файдаланылуын һәм функциясен билгеләү өчен эш процессында барлыкка килгән эзләрне тикшерү ысулы кулланыла, эшләнгән вакытын билгеләү типологик ысул ярдәмендә башкарыла. А.нең үз ысулларыннан тыш башка фәннәрдә кулланылганнарын да эшкә җигәләр: әйбер калдыкларындагы радиоактив углерод микъдары буенча даталарны билгеләү, археол. истәлекләрдә табылган агачларның еллык боҗралары буенча чагыштырма һәм абс. даталарны ачыклау, яндырылган балчыктан ясалган әйберләрдәге магнитлылыкны үлчәп, аларның абс. яшен билгеләү, вакытны ачыклауның геол. ысуллары (мәс., тасма рәвешендә яткан балчык катламнарын тикшерү һ.б.). Борынгы әйберләрне өйрәнү һәм аларны җитештерү ысулларын ачыклау өчен спектраль анализ, металлография, техник петрография һ.б. кулланыла.

«А» термины беренче тапкыр б.э.к. 4 йөздә Платон тарафыннан борынгы дәверләргә нисбәтле фәннәрне күздә тотып кулланыла. Фән буларак, А. Россиядә 18 йөз башында барлыкка килә. Пётр I нигез салган Кунсткамерада борынгы әйберләр һәм археол. истәлекләр туплана. Археол. истәлекләр турында мәгълүматлар туплау дәүләт эшенә әверелә. Археол. истәлекләрне тикшерү, А. тарих фәненең бер өлеше буларак танылгач, 18 йөздә генә гамәлгә керә. Пётр I тарафыннан Себерне өйрәнү өчен җибәрелгән Д.Г.Мессершмидт анда беренче фәнни археол. казу эшләре үткәрә (1722). С.-Петербургта Фәннәр академиясенә (1724) нигез салынгач, *Академик экспедицияләр* оештырыла һәм кыйммәтле археол. материаллар туплана. Казан губернасында Болгар һ.б. археол. истәлекләр тикшерелә (П.С.Паллас, И.И.Лепёхин һ.б.). Бу төбәктә А. фәненә 1722 елда Пётр I Болгар хәрабәләрендә булып киткәч нигез салына, шуннан соң болгарлар чоры истәлекләре өйрәнелә башлый. Пётр I әмере б-н Идел буе Болгары чоры истәлекләрен саклау буенча чаралар күрелә. Й.*Ижбулатов* б-н К.*Сүнчәләев* болгар кабер ташларындагы текстларны күчереп язалар, русчага тәрҗемә итеп, С.-Петербургка җибәрәләр. Казан төбәгендә киң планлы археол. тикшеренүләр үткәрү 19 йөзнең 2 нче яртысыннан башлана, моңа 1858 дә П.В.Алабин инициативасы б-н *Ананьино — каберлегеи* тикшерүне оештыру сәбәп була. 1870–90 елларда А.Ф.Лихачёв, Н.П.Лихачёв, А.А.Штукенберг, Н.Ф.Высоцкий, Ф.Д.Нефёдов, П.А.Пономарёв һ.б. Казан артында һәм Чулман аръягында бронза һәм әүвәлге тимер гасырлар истәлекләрен казу эшләре үткәрәләр. А.Ф.*Лихачёв* Казан губернасы археол. истәлекләргә гаять бай дигән фикердә тора. С.М.*Шпилевский* Казан губернасындагы борынгы истәлекләр турында гомумиләштерелгән хезмәт яза, ул анда болгарлар чоры истәлекләренә беренче тапкыр фәнни характеристика бирә. Татарстан терр-ясендә *таш*, *бронза* һәм *тимер гасырлар* истәлекләре табыла. 1877 дә Казанда *Дүртенче археология съезды* үткәрелә. Зур әһәмияткә ия булган археол. истәлекләрне тәртипкә китерү һәм саклауга Казан ун-ты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* мөһим өлеш кертә. 1916 да Казан губернаторы каршында Гыйльми архив комиссиясе оештырыла, археол. истәлекләрне комплекслы тикшерүгә нигез салына. Комиссия алып барган эшчәнлек нәтиҗәсендә Казанда *Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институты* барлыкка килә, ул Казан губернасындагы археол. истәлекләрне саклау буенча практик чаралар күрә. ТАССР төзелгәннән соң, аның тарихына караган тикшеренүләрне координацияләү өчен *Академүзәк* оештырыла, аның кысаларында татар халкын һәм төбәкне өйрәнү оешмалары эш алып бара, ш.у. *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте*, *Татарстанны өйрәнү җәмгыяте*, *Татар мәдәнияте йорты* һ.б. барлыкка килә; татар халкы тарихына һәм Казан төбәге А.сенә кагылышлы күзәтү характерында язылган хезмәтләр дөнья күрә (М.Г.Худяков, П.А.Пономарёв, В.С.Смолин, А.В.Збруева, А.П.Смирнов, Г.Гобәйдуллин, Н.Н.Фирсов һ.б.). Куйбышев сусаклагычы зонасына кергән археол. истәлекләрне өйрәнү буенча әле 40 нчы елларда ук башланган эш 1950 дә яңадан торгызыла. Татарстанда археол. казу эшләрен Куйбышев экспедициясенең 3 отряды, СССР ФАнең А.П.Смирнов җитәкчелегендәге (ул бер үк вакытта Болгар шәһәрлеген казуны да алып бара) Матди культура ин-ты һәм Н.Ф.Калинин б-н А.Х.Халиков җитәкләгән Казан отряды эшли (соңгысы Чулман тамагыннан алып Яшел Үзән шәһәренә кадәр арада Идел ярларын тикшереп чыга). 1950 елларның 2 нче яртысында археол. казу эшләре инде Татарстанның күп р-ннарында алып барыла. 1950 еллардан СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты зур А. үзәкләренең берсенә әверелә (Н.И.Воробьёв, В.Ф.Генинг, Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков, Һ.В.Йосыпов, Т.А.Хлебникова, Р.Г.Фәхретдинов, П.Н.Старостин, Е.П.Казаков, Ф.Ш.Хуҗин һ.б.). Шушы ин-тның А. бүлеге бу фәнне республика күләмендә үстерүдә зур роль уйный, 1995 тә ТР МК карары нигезендә бүлек Археол. тикшеренүләр милли үзәге итеп үзгәртелә, ә 1996 дан ул ТР ФАнең Тарих ин-ты составына керә. Әлеге үзәк каршында Татарстанда алып барылган археол. казу эшләрен контрольдә тоту өчен Кыр тикшеренүләре бүлеге оештырыла. Археол. казу эшләре ш.у. Казан ун-тының тарих ф-тындагы археология һәм этнология кафедрасы (Ә.Г.Мөхәммәдиев һ.б.), Казан пед. ун-ты галимнәре тарафыннан да алып барыла. А.П.Смирнов, В.Ф.Генинг, Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков һ.б. галимнәр тарафыннан түбәндәге археол. культуралар истәлекләре өйрәнелә: Абашево, Азелино, Ананьино, Алтын Урда, Баланово, Балахна, Болгар, Буралы Курган, Волосово, Кушнаренко, Казан яны, Кама Тамагы, Идел-Чулман, Имәнкискә, Пьянобор, Салтау-Маяк, Чулман буе һ.б. *Олы Тархан*, *Танкеевка* һәм *Зур Тигәнәле каберлекләрен* һ.б. археол. истәлекләрне тикшерү нәтиҗәсендә Болгар, Салтау-Маяк культуралары кабиләләре һәм Урал төбәге угырларының Урта Идел буена килү вакыты ачыклана (8–9 йөзләр). А.П.Смирнов, Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков, Г.А.Фёдоров-Давыдов, В.А.Егоров, Р.Г.Фәхретдинов, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Ф.Ш.Хуҗин һ.б. галимнәр тарафыннан Идел буе Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы истәлекләре тикшерелә, алар 1950–90 елларда Болгарда, Биләр, Сарай әл-Җәдид, Сарай әл-Мәхрусә, Иске Казан, Казанда күләмле казу эшләре алып бара. Галимнәрнең казу эшләре алып бару методикасы борынгы калаларның элекке хәлен һәм чикләрен ачыкларга, күп гасырларга сузылган тарихын һәм мәдәниятен күзалларга ярдәм итә. 1960–70 тә Татарстанның көнчыгыш р-ннарында Түбән Кама экспедициясе (П.Н.Старостин, Е.П.Казаков, Р.С.Габәшев һ.б.) эшли. 1980–90 да бу эшләрне Урта Идел, Әүвәлге Болгар һ.б. экспедицияләр дәвам иттерә. Нәтиҗәдә *мезолит* һәм *неолит* торулыклары тикшерелә, *Постпетрогром* һәм *Чиялек культуралары* ачыла. 1990 еллар башында «*Татарстан Республикасының Археологик картасы*»н төзү эше тәгәлләнә, анда 4 меңнән артык археол. истәлек тасвирлана. 1990–2000 елларда Ф.Ш.Хуҗин, Ә.Г.Мөхәммәдиев, А.Г.Ситдыйков Казанның борынгы дәвергә һәм урта гасырларга караган культура катламнарын киң күләмдә тикшерәләр, нәтиҗәдә башкаланың монголлар чорына кадәр үк барлыкка килүе ачыклана. Археология белгечлеге буенча кадрларны Казан ун-ты, Татар гуманитар пед. ун-ты һ.б. гуманитар юнәлештәге югары уку йортлары әзерли, бу белгечлекне ш.у. ТР ФАнең Тарих ин-ты аспирантурасында укып та

үзләштерергә мөмкин. «Татарская археология» исемле ж-л чыгарыла.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ КФАН СССР за 1945–1952 гг. К., 1954; Археологические памятники у с. Рождествено. К., 1962; Генинг В.Ф., Халиков А.Х. Ранние болгары на Волге. М., 1964; Халиков А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; шул ук. Волго-Камье в начале эпохи раннего железа. М., 1977; Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975; Казаков Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978; шул ук. Культура ранней Волжской Болгарии. М., 1992; Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье. К., 1985; Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье. К., 1986; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987; Археологические памятники центрального Закамья. К., 1990; Ситдиков А.Г. Казанский Кремль: историко-археологическое исследование. К., 2006.

*Е.П.Казаков.*

**АРХЕОЛО́ГИЯ, ТАРИ́Х ҺӘМ ЭТНОГРА́ФИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́ (АТЭҖ)**, Казан ун-ты каршында (1878–1931), фәнни җәмгыять. Аны оештыру турындагы карар *Дүртенче археология съездында* (Казан, 1877 елның июле-августы) кабул ителә, оештыручылар даирәсе (арада И.А.*Бодуэн де Куртенэ*, Н.Я.*Агафонов*, Н.П.*Загоскин*, В.В.*Радлов*) һәм Устав әзерләү комиссиясе тәгаенләнә. Нигезләү вакыты булып халык мәгарифе министры раслаган 1878 нең 18 марты исәпләнә. Җәмгыятьнең максаты — «элеккеге Болгар-Хәзәр һәм Казан-Әстерхан патшалыклары җирлегендәге рус һәм башка халыкларның үткәнен һәм бүгенгесен өйрәнү». 1897 һәм 1917 дә Уставка өйрәнү өлкәсен киңәйтүне күздә тоткан төзәтмәләр кертелә: Себер һәм Урта Азия терр-яләрен өйрәнү, гомуми тарих мәсьәләләре өстәлә. Шул ук вакытта АТЭҖнең төп максаты булып Казан төбәген һәм Көнчыгыш Россияне өйрәнү мәсьәләләре кала. Җәмгыятьнең эшләре б-н Совет (ике елга сайлана) идарә итә, аның составына рәис, аның иптәше (урынбасары), 5 әгъза, сәркәтип һәм казначы керә. АТЭҖ рәисләре: Казан уку округы попечителе П.Д.*Шестаков* (1878–83, 1886), ун-т профессорлары С.М.*Шпилевский* (1884–85), Н.Н.*Булич* (1887), Н.А.*Фирсов* (1888–96), Ф.Г.*Мищенко* (1896–98), Н.Ф.*Катанов* (1898–1914), М.М.*Хвостов* (1914–18), Б.Ф.Адлер (1918–22), К.В.*Харлампович* (1922–24) һәм Н.Н.*Фирсов* (1924–30). АТЭҖнең беренче әгъзалары булып аның 40 оештыручысы сайлана. Совет җәмгыятьнең утырышларын уздыра (елга 4 мәртәбә чамасы). Җәмгыять эшчәнлеге дәверендә 600 дән артык кеше аның әгъзасы булып тора, ягъни елга 100 дән 200 гә кадәр кеше сайлана. Әгъзалык берничә категорияне колачлый. Хакыйкый әгъзалар, җәмгыять эшчәнлегендә катнашу дәрәҗәсе һәм хезмәтләре исәпкә алынып, ике әгъзаның тәкъдиме буенча гомуми җыелышта сайлана. Алар әгъзалык взнослары (елга 10 сум, соңрак 5 сум) түләргә тиеш булалар. Җәмгыять өчен файдалы мәгълүматлар тапшырырга әзер һәркем әгъза-хезмәткәр буларак кабул ителә. Шәрәфле әгъзалар булып сайланган атаклы Россия һәм чит илләр галимнәре: Г.Алквист, И.П.Аспелин, О.Доннер, Д.Н.Анучин (Финляндия), Ф.И.Буслаев, А.Ф.Бычков, Ф.А.Бюлер, В.П.Васильев, Р.Вирхов, И.И.Срезневский, А.И.Соболевский, В.Г.Тизенгаузен, А.С.Уваров, П.С.Уварова, Л.Х.Штида (Германия), В.В.Латышев, Л.Н.Майков, Леон де Рони (Франция) һ.б. Җәмгыятьнең әлеге дәрәҗәгә лаек булган, фән үсешенә өлеш керткән әгъзалары: Н.Я.Агафонов, А.И.*Александров*, Н.Ф.*Высоцкий*, Н.П.Загоскин, И.А.*Износков*, Н.Ф.Катанов, Д.А.*Корсаков*, П.И.*Кротов*, Н.П.*Лихачев*, А.Н.Островский, П.А.*Пономарёв*, Г.Н.Потанин, И.Н.*Смирнов*, А.А.*Спицын*, Н.Н.Фирсов, П.Д.Шестаков, С.М.Шпилевский, А.А.*Штукенберг*. Зур күләмдә акча яки фәнни коллекцияләр иганә кылган затларга, мәс., А.С.Аитовка, А.А.Кекинага, С.И.Порфирьевка, Е.А.Толмачёвага, В.А.Унженинга, М.В.Шимановскийга ярышчы әгъза исеме бирелә. Җәмгыять составына күп кенә күренекле галимнәр керә, алар арасында Петербург ФАнең (киләчәктә СССР ФА) 43 әгъзасы, Казан ун-тының 70 тән артык профессоры, Казан руханилар семинариясенең 9 профессоры, югары уку йортларының дистәләрчә укытучысы, профессор стипендиатлары була. АТЭҖ эшчәнлегендә гуманитар (филология, тарих, хокук, фәлсәфә), табигый һәм төгәл (геология, география, медицина, математика һ.б.) фәннәр вәкилләре катнаша. Проф. фәнни хезмәткәрләрдән тыш аның эшендә урта уку йортлары укытучылары (П.А.Пономарёв, Н.К.Горталов, М.Е.Евсевьев, А.И.Емельянов, С.И.Порфирьев һ.б.), Халык мәгариф министрлыгы карамагындагы инспекторлар һәм башка хезмәткәрләр (А.Е.Алекторов, Н.А.*Бобровников*, В.Л.Борисов, И.А.*Износков*, В.А.Казаринов, В.К.Магницкий һ.б.), халык уч-щеләре укытучылары (Г.*Әхмәров*, Н.Е.Ефимов, К.С.Рябинский, И.В.Яковлев һ.б.) мәшгуль булалар. Укытучылар арасында чуаш һәм мари интеллигенциясе вәкилләре шактый була. Җәмгыять б-н татар мәгърифәтчеләре дә (Ш.Мәрҗани, К.Насыйри һ.б.) актив хезмәттәшлек итә. Җәмгыять әгъзаларының 60%ы чамасы халык мәгарифе өлкәсендә һәм фәнни учреждениеләрдә эшли, арада мәхкәмә, хакимият, финанс, медицина органнары хезмәткәрләре, чиркәү вәкилләре, хәрбиләр, җирбиләүчеләр, сәүдәгәрләр һ.б. да була. АТЭҖкә 20 дән артык хатын-кыз (В.Д.Корсакова, Р.А.Нелидова, Н.В.Троицкая, П.С.Уварова, М.С.Гобәйдуллина, Л.И.Вараксина һ.б.) керә. Сов. чорында җәмгыятьнең составы бертөрлерәк сыйфат ала — ул башлыча фәнни учреждениеләр һәм югары уку йортлары хезмәткәрләреннән тора. АТЭҖ әгъзаларының яшәү географиясе өйрәнелүче терр-ягә туры килә, ләкин аның б-н генә чикләнми, Россиянең башка төбәкләрен һәм чит илләрне дә (Финляндия, Франция, Бельгия, Германия, Швеция, Англия, АКШ) колачлый. Җәмгыятьнең эшчәнлеге җирле һәм башкала архивларында, китапханәләрендә, музейларында һәм шәхси җыелмаларда сакланган археол., тарихи һәм этнографик материалларны эзләп табу һәм фәнни әйләнешкә кертүгә юнәлдерелә. Бу исә библиографик чыганакларны өйрәнү, историографик характердагы эшләрне күздә тота. Җәмгыятькә киң җәмәгатьчелек теләктәшлек һәм ярдәм күрсәтә: аңа түләүсез нигездә этнографик һәм археол. предметлар, кульязмалар һәм басмалар, төрле табылдыклар, шәһәрлекләр, курганнар һәм башка төрле тарихи истәлекләр турында мәгълүматлар тапшырыла. Еш кына җәмгыятькә һәвәскәр тарихчылар да материаллар җибәрәләр. Гомуми җыелышларда, әгъза булу-булмауга карамастан, һәркемнең дә катнашу хокукы була.

Төрле чорларда археол. истәлекләрне ачыклау һәм өйрәнү б-н Н.Ф.Высоцкий, И.А.Износков, В.А.Казаринов, П.И.Кротов, А.Ф.Лихачёв, Н.П.Лихачёв, П.А.Пономарёв, В.Ф.Смолин, А.А.Спицын, М.М.Хомяков, М.Г.Худяков, С.М.Шпилевский, А.А.Штукенберг һ.б. шөгыльләнә. 1907 дә Казан губернасының археол. картасын төзү бурычы көн тәртибенә чыгарылганнан соң бу эш максатчыл төс ала; картаны төзү буенча П.Н.Кротов рәислегендә махсус комиссия оештырыла. АТЭҖнең төп максатларының берсе *Болгар шәһәрлеген* саклап калу була; император Александр II нең 1880 нең 9 июнендә чыккан указы нигезендә аның бер өлеше (852 кв. сажин) шундагы истәлекләр б-н бергә җәмгыять карамагына тапшырыла. 40 ел дәвамында җәмгыять *Кара пулат*, *Кече манара* һ.б. объектларның сакланышын күзәтчелектә тота, даими рәвештә аларны ремонтлый, археол. табылдыкларны җыя, очраклы рәвештә табылган әйберләрне җирле крәстияннәрдән сатып ала. Фән өчен халык тормышының үзенчәлекле сыйфатларын һәм күп гасырлык традицияләрне теркәп калу омтылышы Идел буе, Урал алды, Оренбург крае, Себер, Төркестан халыкларының этнографиясенә нисбәтле күпсанлы хезмәтләрне нәшер итүдә чагыла (Г.Н.Әхмәров, Н.И.Воробьёв, Н.Ф.Катанов, Я.Д.Коблов, Г.И.Комиссаров, Д.К.Зеленин, С.М.Матвеев, В.К.Магницкий, Н.В.Никольский, И.Н.*Смирнов* һ.б.). Аларның иң мөһимнәрендә, аерым алганда, И.Н.Смирновның «Чирмешләр», «Вотяклар», «Пермяклар», «Мордва» («Черемисы», «Вотяки», «Пермяки», «Мордва») дип аталган хезмәтләрендә халыкның тарихи тамырлары, аның үткән чорларда һәм хәзерге вакытта таралып урнашуы, күрше халыклар б-н бәйләнешләре, дәүләт хакимиятенең халык язмышына йогынтысы мәсьәләләре яктыртыла. Н.Ф.Высоцкий, М.М.Хомяков антропология мәгълүматлары ярдәмендә Идел буе халыкларының килеп чыгышы мәсьәләләрен хәл итәргә омтылалар. АТЭҖнең аеруча мөһим бурычы халык авыз иҗаты үрнәкләрен — җырларны, әкиятләрне, табышмакларны һәм риваятьләрне барлаудан гыйбарәт була. Текстлар тикшерелә һәм үзара чагыштырып өйрәнелә, алар берничә вариантта: оригинал телендә, академик фәндә кабул ителгән махсус билгеләр б-н фонетик рәвештә, рус теленә тәрҗемәдә нәшер ителә. Төрле халыкларның авыз иҗаты әсәрләре чагыштырыла. Бу юнәлештә Н.И.Ашмарин, А.А.Диваев, М.Е.Евсевьев, М.И.Извощиков, Н.Ф.Катанов, К.Насыйри, П.А.Поляков, К.С.Рябин-

ский, Н.Я.Саркина һ.б. эшлиләр. Гомумроссия характерындагы аерым темалар тикшерелә. Гомуми тарихка нисбәтле хезмәтләр азчылыкны тәшкил итә (Н.А.Васильев, Н.П.Грацианский һ.б.). Казан төбәген өйрәнгәндә төп игътибар документларны һәм чыганакларны ачыклауга һәм нәшер итүгә бирелә. Хезмәтләрдә край б-н идарә итү, җир-милек мөнәсәбәтләре, социаль-икътисади һәм мәдәни тормыш, христианлык тарихы мәсьәләләре күтәрелә, халык хәрәкәтләре өйрәнелә. Бу мәсьәләләр буенча В.Л.Борисов, Н.К.Горталов, Д.А.Корсаков, Н.Ф.Катанов, Е.А.Малов, Н.М.Петровский, И.М.Покровский, П.А.Пономарёв, А.И.Соколов, С.И.Порфирьев, К.В.Харлампович һ.б.ның хезмәтләре дөнья күрә. АТЭҖ әгъзалары ш.у. сынлы сәнгать, декоратив-гамәли сәнгать һәм архитектура, халык музыка мәдәнияте истәлекләрен дә өйрәнәләр. Җәмгыять басмалары арасында тел тарихы, диалектология, палеография, текстологиягә нисбәтле хезмәтләр бар. АТЭҖ каршында кулъязмалар һәм актлар бүлеге булган гаять бай китапханә, археология, нумизматика һәм этнография коллекцияләрен үз эченә алган музей оештырыла. Соңрак бу җыелмалар Казан ун-тының Фәнни китапханәсе һәм ТРның музейлары составына керәләр. Россиянең һәм чит илләрнең күп кенә җәмгыятьләре, учреждениеләре, ин-тлары, журнал редакцияләре (160 лап берәмлек) б-н җәмгыять басмалар алмашына. АТЭҖ Россиянең иң танылган һәм абруйлы фәнни җәмгыятьләренең берсе була. Аның әгъзаларының хезмәтләре «*Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете*» («Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре») һ.б. журналларда нәшер ителә. Әгъзалык взносларыннан, җәмгыять басмаларын сатудан һәм лекцияләр, күргәзмәләр уздырудан кергән акча гына җитеп бетми, шуңа күрә җәмгыять эшчәнлеген финанслауда дәүләт ярдәменең әһәмияте зур була. Казан ун-ты китапханә, музей һәм АТЭҖ җыелмалары өчен бүлмәләр биреп тора, ел саен 13,5 табак (1892 дән — 20 табак) күләмендә бушлай «Хәбәрләр» бастыру мөмкинлеге тудыра. Казнадан «Борынгы Болгар шәһәре калдыкларын саклау» (1882–1917 дә ел саен 300 сум), нәширлек эшчәнлеге өчен (1898–1912 дә ел саен 600 сум), ш.у. 1914 нең 21 июнендә кабул ителгән закон нигезендә университет типографиясе бурычын каплау өчен бер мәртәбә 4000 сум, 1915–17 дә ел саен 1000 сум күләмендә пособие, 1912 дән 4 елга каралган фәнни тикшеренүләр максатында ел саен 500 сум пособие (нәтиҗәдә 1913–16 да Болгар һәм Биләр шәһәрлекләрендә археологик казу эшләре башкарыла) түләнә. Сов. чорында фәнни-тикшеренү эшләре өчен акча бүлеп бирү туктала, секретарь, редакция хезмәтенә түләү, музейны һәм китапханәне тәртиптә тоту өчен генә бераз акча бирелә. 1919 ның көзеннән Болгар шәһәрлеген кайгыртуны дәүләт органы — Музей эшләре һәм истәлекләрне саклау буенча Казан бүлеге үз өстенә ала. «Хәбәрләр»не нәшер итү хәзер тулысынча партия-дәүләт органнарына бәйле була. Алар теләгән очракта басылган тиражны тоткарлый, журналны нәшер итүне туктата алалар. Җәмгыятьнең бәйсез, оппозицион караштa торган җитәкчелеге хакимиятне канәгатьләндерми, 1924 нең сентябрендә ОГПУның Татарстан бүлеге аңа каршы эш ача, тикшерүләр вакытында җәмгыять рәисе К.В.Харлампович кулга алына һәм Көнчыгыш Казакъстанга сөрелә, Совет әгъзаларын тентүләр, сорау алулар була. АТЭҖ җитәкчелегенең яңа составы (профессорлар Н.Н.Фирсов, Г.С.Гобәйдуллин, М.К.Корбут һ.б.) җәмгыять эшчәнлеген сов. чынбарлыгына яраклаштырырга омтыла, бу исә докладларның һәм басмаларның тематикасында чагылыш таба (рев-ция, В.И.Ленинның тормышы һәм эшчәнлеге, эшчеләр һәм крәстияннәр хәрәкәте, декабристлар, тарихчы-демократ А.П.Щапов карашлары б-н бәйле мәсьәләләр һ.б.). Җәмгыятьнең 50 еллыгын бәйрәм итү (1927–28) б-н бәйле рәвештә аның әгъзаларының саны шактый арта. 1920–1930 еллар чигендә сәяси басым һәм репрессияләр кискен катгыйланган шартларда АТЭҖнең җитәкчеләре һәм актив әгъзалары марксизмга каршы булган, буржуаз, милләтчелек карашлар алып баруда гаепләнәләр, кайбер әгъзалар кулга алына. 1930 да җәмгыятьнең эшчәнлеге чынлыкта туктала, 1931 нең февралендә ул ябыла.

«Хрущев җепшеклеге» елларында АТЭҖне яңадан торгызу омтылышы ясала. РСФСР югары һәм махсус урта белем бирү министрының 1960 ның 12 апрелендә чыгарылган фәрманы нигезендә Оештыру комитеты төзелә, аның составына М.И.Абдрахманов, Н.И.Воробьёв, Г.Н.Вульфсон, С.И.Даишев, И.М.Ионенко, И.М.Климов, Ш.Ф.Мөхәммәдьяров, Р.И.Нәфыйгов, Е.И.Устюжанин, А.С.Шофман, И.Н.Юдин, Н.М.Силаева керә. Комитет «Тарих-археология җәмгыяте уставының проекты»н әзерли һәм бастырып чыгара (1961). 1962 нең апрелендә оештыру съезды була, анда ун-т каршында АТЭҖн торгызу турында карар кабул ителә. 160 кеше оештыручы-әгъза (Казанда, Мәскәүдә, Ленинградта, ш.у. Идел-Урал төбәгендә эшләп килгән югары уку йортлары укытучылары, фәнни-тикшеренү ин-тлары, архивлар, музейлар һ.б. учреждениеләр хезмәткәрләре) булып теркәлә. Җәмгыятьнең максаты дип Идел буе һәм Урал алды халыкларының тарихын, археологиясен, этнографиясен өйрәнү, фән казанышларын пропагандалау игълан ителә. Җәмгыятьнең эшчәнлеге б-н Н.И.Воробьёв рәислегендәге совет һәм И.М.Ионенко рәислегендәге редколлегия җитәкчелек итә. 1963 тә «Тарих, археология һәм этнография җәмгыяте хезмәтләре»нең беренче томы чыга, тиздән аның барлык тиражы аңлатусыз-нигезсез китапханәләрдән һәм шәхси затлардан җыеп алына һәм юк ителә. Җәмгыятьнең эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* Краткий очерк 8-летней деятельности Казанского общества археологии, истории и этнографии и его задачи. К., 1886; Ильинский Л.К. Общество археологии, истории и этнографии при Казанском университете // Краеведение. 1929. № 9; Пионтковский С. К 50-летию Казанского общества археологии, истории и этнографии // Историк-марксист. 1929. Т. 11; Зайцев А.В. Исторические учреждения Республики Татарстан в 20–30-е годы XX века. К., 1998; Сидорова И.Б. Поступают «сведения о группировке черносотенного элемента в Обществе археологии, истории и этнографии при Казанском университете» (ОАИЭ в первые годы Советской власти. 1917–1924 гг.) // Гасырлар авазы — Эхо веков, 2003. № 3–4; её же. Общество археологии, истории и этнографии при Казанском университете: Основные этапы истории // Краеведческие среды. Материалы заседаний, прошедших в Национальном музее Республики Татарстан в 2003 г. К., 2004; 125 лет Обществу археологии, истории и этнографии при Казанском университете. Проблемы историко-культурного развития Волго-Уральского региона: В 3 ч. К., 2004; История и историки в Казанском университете: К 125-летию Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете: Сб. науч. статей и сообщений. К., 2005.

*И.Б.Сидорова.*

**АРХИ́В** (лат. archivum, грек. archéion — җыелу урыны), 1) дәүләт учреждениеләре, предприятиеләре, фән һәм җәмәгать оешмалары, сәяси партияләр һәм аерым кешеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар җыелмасы; 2) документлар саклауны оештыручы учреждение яки аның бер өлеше. Татар халкы тарихына һәм яшәешенә караган тәүге язма ядкәр-истәлекләр Төрки һәм Хәзәр каганлыклары, Идел буе Болгар дәүләте идарәханәләрендә, Алтын Урда һәм татар ханлыклары сарайларында, мәчет һәм мәдрәсәләрдә туплана башлаган. Сакланып калган тарихи чыганаклар шул хакта сөйли (дипломатик вәкилләрне кабул итү турындагы мәгълүматлар, *Йосыф каган хаты, Мәхмүд хан хаты,* ханнар *ярлыклары*, *битикләр*, борынгы *шартнамәләр*, илчелек хатлары, башка төр документлар). Алтын Урда таркалгач һәм татар ханлыклары Рус дәүләте тарафыннан яулап алынгач, төбәк тарихына караган А. *Казан Сарай идарәханәсе*ндә туплана. Аның нигезен наместниклык идарәсе һәм 17 йөздән Казан төбәге (Казан, Зөя һ.б. Идел-Урал буе шәһәрләре) воевода идарәләре документлары, җирле идарә эшләре, тарханлык грамоталары, үзәктән җибәрелгән боерык-әмер кәгазьләре, милеккә, сату-алуга караган килешүләр һ.б. тәшкил итә. Мәчет һәм монастырьларның да зур А.лары оештырыла.

Пётр I чорында башланган реформалар һәм үзгәрешләрдән соң Казан губернасының җирле оешмалары составында төрле дәүләт А. бүлекчәләре: губерна идарәсе, жандарм һәм полиция идарәләре, мәхкәмә, казна һәм тикшерү палаталары, хәрби кабул итү урыннары, шәһәр идарәләре, округ мәхкәмәләре, өяз мировой судьялары, Ятимнәр һәм Гәпләшү мәхкәмәләре, нотариус, губерна һәм өяз земство идарәләре, ф-ка инспекторлары, акциз идарәсе, җир төзү эшләре комиссияләре, почта-телеграф һәм уку-укыту округ идарәләре, почта конторалары, дини советлар, җамигъ һәм приход чиркәүләре, дворяннарның губерна һәм өяз башлыклары, уку йортлары, волость идарәләре, монастырь һәм мәчетләр (туу-үлү дәфтәрләре һ.б.), Татар ратушасы һ.б. ведомстволар А.лары барлыкка килә. Губернада 1000 нән артык дәүләт һәм җәмәгатьчелек А.лары туплана (пр-тиеләр һәм аерым затлар А.ларын исәпләмичә), һәр ве-

домство үз А. б-н үзе теләгәнчә эш итә. Архив эшләре б-н үзәкләштерелгән идарә булмау акча җитмәү, А.ның дәүләт күләмендә мөһимлеген, аларның мәдәни һәм фәнни кыйммәтен төшенеп җиткермәү б-н аңлатыла. Кыйммәтле саналган язма ядкәрләрне бергә туплау эшенә төбәктә Казан ун-ты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* зур өлеш кертә. Документларны шәхси коллекцияләргә җыю киң колач ала. 19 йөзнең соңгы чиреге — 20 йөз башында А.Ф.Лихачёв, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Әхмәров, С.Вахиди һ.б.ның зур коллекцияләргә ия булуы мәгълүм.

Ведомство А.ларының тиз туплануы, алардагы тәртипсезлек, аерым биналар һәм бердәм җитәкчелек булмау аркасында байтак мөһим документлар бозыла, юкка чыга. Шуны истә тотып, 1916 елда С.П.*Покровский* Казан губернаторы карамагында губернаның гыйльми архив комиссиясен оештыра. Бу комиссия төбәктә А.лар эшен төрле яклап өйрәнүгә керешә. Комиссия эшчәнлеге нәтиҗәсендә Казанда *Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография институты* ачыла (1917). Ин-т хезмәткәрләре Казан губ. оешмаларында саклanучы әһәмиятле А. материалларын җыю һәм тәртипкә китерүдә практик чаралар күрә. Казан губернасы комиссарының 1917 елның 23 декабре әмере б-н ябылган, эшчәнлекләре туктатылган барлык оешмаларның А.ларын саклау хокукы шушы ин-тка тапшырыла. 1918 нең 1 июнендә «РСФСРда архив эшен үзгәртеп кору һәм үзәкләштерү турында»гы декрет чыга, ул Совет дәүләтендәге барлык документларны бердәм дәүләт архив фондына туплауда хокукый нигез була. РСФСР Мәгариф халык комис-ты карамагында Баш архив идарәсе (БАИ) барлыкка килә (1921 ел ахырында БҮБКка буйсындырыла), Казанда аңа буйсынган губерна архив бюросы оештырыла. 1917 дә оешкан Археология һәм этнография ин-ты советы да А.лар мәсьәләләрен хәл итү өчен рәсми комиссия төзи. 1918 нең октябрь-ноябрь айларында Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан губерна советы президиумы әлеге ин-тның патша чоры оешмаларының барлык А.ларын туплау һәм саклау хокукын раслый. БАИдә аны губернадагы үзенең бердәнбер оешмасы буларак таный. 1919 ның февралендә ун-т профессоры И.А.*Стратонов* БАИнең Казан губернасындагы вәкиле итеп билгеләнә. Губерна күләмендә таратылган А.лар материалларын исәпкә алу һәм Казан губернасы А.ын булдыру турында карар кабул ителә. Казан губернасындагы А.ларны саклау комиссиясе оештырыла (к. *Баш архив идарәсе*). Казан губернасы җирлегендә ТАССР барлыкка килгәч, әлеге комиссия 1921 нең гыйнварында Татарстан Үзәк архивы дип үзгәртелә (оешканда ТАССР Мәгариф халык комис-тына, 1922 дән ТАССР ҮБКсына буйсына). 1925 нең февралендә бу Үзәк А. икегә: Тарихи А. һәм Окт. рев-циясе А.ы бүлекләренә бүленә. 1924 тә Үзәк А.ның Алабуга, Арча, Бөгелмә, Буа, Зөя, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Тәтеш, Чаллы, Чистай кантоннарында 12 бүлекчәсе булдырыла. 1929 да, мөстәкыйль булек буларак, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты А.ы оештырыла (к. *Татарстан Республикасының тарихи-сәяси документларны саклау үзәк дәүләт архивы*). 1929–30 да ТАССРда 46 район А.ы ачыла. 1938 дә Татарстан Үзәк А. ТАССР Үзәк дәүләт А.ы дип үзгәртелә (к. *Татарстан Республикасының милли архивы*) һәм, бүлек буларак, ТАССР Эчке эшләр халык комис-тына (1946 дан министрлык) буйсындырыла; 1962 дән — ТАССР МС карамагында. 1994 тә ТРның тарихи-сәяси документларны саклау Үзәк дәүләт архивыннан *Татарстан Республикасының аерым шәхесләргә бәйле документлар саклау үзәге* аерылып чыга. 1996 ның мартында ТР Милли архивының Әлмәт ф-лы *Татарстан Республикасының нефть һәм газ сәнәгате тарихына караган документлар саклау үзәге* дип үзгәртелә. ТР А.лары ТР МК карамагындагы *Баш архив идарәсенә* буйсыналар, алар фондында 5 млн. чамасы саклау берәмлеге исәпләнә (2000), ш.и. 11–18 йөзләргә караган кулъязмалар коллекциясе, 7,6 меңнән артык үзәк һәм җирле газеталар комплекты, 25 мең данәдән артык журнал һәм китап, Н.И.Ильминский, Г.К.Казимбәк, А.С.Ключарёв, К.Насыйри, С.Җ.Сәйдәшев кебек шәхесләрнең шәхси язма мирасы һ.б. саклана. А.лар тарафыннан 30 дан артык документлар җыентыгы басылып чыга. Хәзерге вакытта ТР Баш архив идарәсе 20 гә якын һәм ерак чит ил милли А.лары б-н хезмәттәшлек итә.

*Әд.:* Национальный архив Республики Татарстан: Путеводитель. К., 1999; Центральный Государственный архив историко-политической документации Республики Татарстан: Путеводитель. К., 1999.

*А.Х.Төхфәтуллин, Р.Г.Шәмсетдинова.*

**АРХИ́В БЕЛЕМЕ́**, *архив*лар эшен, аның теориясен, тарихын, оештыру ысулларын һәм практикасын өйрәнә торган фән тармагы. Архив эшенең башлангыч үсеше тарихи язма чыганакларны саклау һәм җыйнауга нисбәтле практик эшләр б-н тыгыз бәйләнгән. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында канцелярия эшләре актларын (к. *Актлар*) саклау, исәпкә алу һәм системага салу б-н фонд оештыручы оешмалар (*диван* һ.б.) шөгыльләнгән һәм алар кабул ителгән документлар арасында өзлексез бәйләнеш булуны тәэмин иткән. Архив эшләрен *бакши* һәм *хафизлар* алып барган. Татар ханлыклары Россия тарафыннан яулап алынганнан соң, архивлар оештыруның бу тәртибе кайбер үзгәрешләр б-н Казан Сарае идарәханәсенең писарь һәм дьякларына һ.б. җирле оешмаларга беркетелә. Аларда бу эш структур бүлекчәләргә яки вазифаи затка беркетү принцибы б-н алып барыла. 18 йөздә архивлар эшен камилләштерүдә махсус законнар һәм норматив документлар кабул ителә (Ген. регламент 1720 елда, соңрак — инструкция, регламент, указлар). Аларда архив эшенең практик һәм методик якларына: документларны бигрәк тә практик максатлардан чыгып классификацияләүгә, язып алу һәм куллануга зур игътибар бирелә.

19 йөз ахырында А.б. турында архив хезмәтен рациональләштерү, архив документларын саклауны оештыру, классификацияләү, язып алу, бастырып чыгару өчен кирәкле мәгълүматлар бирү б-н шөгыльләнә торган аерым фән тармагы дигән караш формалаша. А.б. ш.у. архивлар тарихын, архивлар турындагы законнарны һәм эш башкару актларын, документлары сакланып калган оешмалар тарихын өйрәнә. А.б. үсешендә Казан ун-ты галимнәре, Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзалары һ.б. фәнни оешмалар мөһим роль уйный. 1916 да Казан губернасы гыйльми архив комиссиясе оешкач, төбәктә А.б.нә комплекслы якын килү башлана. Комиссия эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1917 дә Казанда *Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография институтына* нигез салына, анда А.б. өлкәсендә белгечләр әзерләү, архивларны саклау һәм коткару буенча практик чаралар күрүгә, шуның б-н бергә архив эшенең үзенчәлекләренә, татар халкы һәм төбәк тарихына караган чыганакларга игътибар юнәлтелә. Соңыннан бу эш *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте* һәм *Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте* тарафыннан дәвам иттерелә, алар, теоретик проблемаларны өйрәнү б-н беррәттән, татар халкы тарихы буенча документлар җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару б-н дә шөгыльләнәләр. 1920–30 елларда А.б. үсешендә «*Записки Центрального архива Татарской Социалистической Советской Республики*» — «*Татарстан Социалистик Совет Республикасы Үзәк архивы язмалары*» ж-лы (1925 елда нигез салына) күренекле роль уйный, анда архив эшенең теоретик, методик, техник һ.б. мәсьәләләренә караган мәкаләләр басыла. Бу вакытта Татарстанда архивлар б-н идарә итүнең дәүләт системасы барлыкка килә. 1930 еллардан архивларның үзәкләштерелүе һәм аларның НКВД карамагына тапшырылуы сәбәпле, архивлар б-н идарә итү системасында бюрократлык көчәя, фәнни-тикшеренү эшчәнлеге сүлпәнәя, А.б.нең теоретик-методологик һәм методик эшләнмәләренең кысрыклап чыгарылуы, аның югала баруы кебек тискәре тенденцияләр туа. Архив эшендә оештыру-идарәчелек һәм идеологик функцияләрнең өстенлек итүе А.б.нә фәкать гамәли даирәне генә калдыра.

1950 еллар урталарыннан А.б.ндә яңа этап башлана. Татарстан тарихчылары һәм архивчылары архив документларын теркәү һәм системага салуда, аларны фәнни һәм практик куллануга кертүдә зур эш башкаралар. 1960 еллар башында Казан ун-тының тарих ф-ты уку программасына А.б. курслары кертелә. 1960–80 дә А.б. тарихына һәм архив документлары комплексларының специфик үзенчәлекләренә багышланган фәнни язмалар һәм Татарстан архив фондларының беренче юл күрсәткечләре барлыкка килә. Татарстанда А.б. өйрәнү, укыту, аны үстерү мәсьәләләре б-н ТР МК каршындагы Баш архив идарәсе, ТРның Милли архивы, Казан ун-тының тарих ф-ты, «Гасырлар авазы — Эхо веков» ж-лы шөгыльләнә. 1999 дан Казан ун-тының тарих ф-ты тарих белеме үсешен һәм тарихи чыганакларны өйрәнү кафедрасы каршында А.б. буенча белгечләр әзерләү эшен алып бара.

*Әд.:* Национальный архив Республики Татарстан: Путеводитель. К., 1999; Центральный Госу-

дарственный архив историко-политической документации Республики Татарстан: Путеводитель К., 1999. *А.А.Сальникова.*

**АРХИЕПИ́СКОП** (*архи*... һәм грек. epískopos — күзәтчелек итүче), баш епископ; казанышлары яисә аеруча җаваплы вазифалар башкарганы өчен бирелә торган дәрәҗә (к. *Епископ*). А.лар, кагыйдә буларак, эре епархияләр, мохтариятлы (Финляндия, Кипр), хәтта бәйсез (Польша, Албания) православие чиркәүләре б-н җитәкчелек итә. А. Казан епархиясе б-н 1555–89, 1725–27, 1735–38, 1762–75, 1782–1917 елларда идарә итә. Казан яулап алынганнан соң, төбәктә беренче А. *Гурий* була. 1996 дан бу титул кабат торгызыла.

**АРХИЕРЕ́Й** (*архи*... һәм грек. hieréus — дин әһеле), Рус православие чиркәвендә хәвариюн (апостол) өстенлекләренә ия булган өченче һәм югары дәрәҗәдәге баш руханиларның гомуми атамасы (к. *Епископ*). А. төшенчәсе, башлыча, күплек санда кулланыла: «Рус православие чиркәве архиерейлары». Аерым А. турында сүз барганда аның дәрәҗәсе күрсәтелә: *епископ*, *архиепископ*, *митрополит*. 19 йөз урталарына кадәр Казанда епархия А.лары гына була. 1854 елдан викар епископлар — епархия А.ларының ярдәмчеләре билгеләнә башлый.

**АРХИЕ́РЕЙ ДАЧАСЫ́**, Казанда рус архитектурасы истәлеге, Казан архиепископлары һәм митрополитларының җәйге резиденциясе. 1781 елда Екатерина II фәрманы б-н митрополит Вениаминга бүләк рәвешендә шәһәр янындагы *Воскресение монастырендa*, В.И.*Кафтырев* тарафыннан, фаразлаганча, В.В.Растрелли сызымнары һәм рәсемнәренә нигезләнеп төзелә. 1789 дан — Казан митрополитларының даими яшәү урыны, 1830 дан — аларның дачасы. Сарайлар тибындагы ике катлы бинаның төп фасады паркка карый. Сузынкы фасадлы симметрик йорт Воскресенский соборы б-н янкорма аша тоташкан. Казан митрополитларының 1698 гә кадәр шушы урында торган гөмбәз түшәмле йортының 1 нче каттагы хөҗрәләр һәм келәтләр урнашкан өлеше А.д. составында сакланып калган. Өч борылышлы баскыч 2 нче каттагы тантаналар залына, торак бүлмәләргә һәм Вознесение Христова өй эче чиркәвенә алып менә. Бина үзәгендәге бөтен биеклегенә чыгып торган ризалитның түгәрәкләндерелгән почмаклары төп фасадның як-якта чатыр б-н тәмамланган тәбәнәгрәк ике канатына шома гына тоташып китә. Фасадларның декоратив бизәлеше «Петербург барроккосы» стилендә башкарылган. Аслы-өсле тәрәзәле үзәк залларның һәм алар янәшәсендәге бүлмәләрнең түшәм бизәкләре, диварларның һәм ишекләрнең бизәлеш фрагментлары, үзәк баскыч култыксасындагы үзенчәлекле нәфис баганачыклар сакланып калган. 1990 нан А.д.да «Татарстан кыры» Фәнни-җитештерү берләшмәсе урнаша.

*Әд.:* Покровский И.М. Казанский архиерейский дом. К., 1906; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*С.Г.Персова.*

**АРХИЕРЕ́Й ЙОРТЫ́**, Казанда епархия башлыгының биләмәләре б-н идарә итү оешмасы. Архиепископ *Гурий* заманында барлыкка килә. 1555–56 елларда аңа элеккеге Казан ханнары биләмәләренең бер өлеше бүләк итеп бирелә, соңга таба шул җирләрдә Болак аръягы Архиерей бистәсе оеша. 18 йөз уртасында А.й. 23 зур авыл, 28 авыл һәм башка торак урыннарына хуҗа була. Аның вазифаларына чиркәү җирләрендәге халыктан салым җыю һәм хөкем итү, башкарылырга тиешле йөкләмәләрнең күләмен билгеләү керә. А.й.ның хакимияте боярлардан, дьяклар, бояр балалары, приказ кешеләре һ.б.дан тора. А.й. карамагында икона язу остаханәсе,



Архиерейның шәһәр янындагы йорты. Казан. Арх. В.И. Кафтырев. 1781.

чиркәү җырчылары була. 1723 тә А.й. акчасына төбәктә беренче христиан дини белем бирү йорты — Славян-латин мәктәбе ачыла, 1773 тә ул тулы программа б-н укыта башлый һәм семинария статусы ала. Пётр I заманында А.й. элеккеге ролен югалта башлый, штатта торган архиерейларның резиденциясе генә булып кала. 19 йөз ахырына А.й. идарә итү ин-ты буларак яшәүдән туктый, аның зур биләмәләреннән (1764 елга кадәр 11830 дис. сөрүлек җире, 3005 дис. болыны, якынча 150000 дис. урманы була) нибары архиерейның Кремльдәге йорты, Воскресение монастырендагы җәйге йорты гына кала.

*Әд.:* Горчаков М.И. Монастырский Приказ. СПб., 1868; Покровский И.М.. Казанский архиерейский дом, его средства и штаты, преимущество до 1764 года. К., 1906.

*А.В.Гарзавина.*

**АРХИЕРЕ́Й КҮЛЕ́**, Тарлаш күле, Көнбатыш Кама төбәгендә. Лаеш р-нының Тарлаш авылы янында. Су өслегенең мәйданы 60 *га*. Су күләме 4495 мең $м^3$. Озынлыгы 2140 *м*, иң киң урыны 480 *м*. Уртача тирәнлеге 6,5 *м*, иң зур тирәнлеге 22 *м*. Күл карст-суффозия процесслары тәэсирендә барлыкка килгән. Идел елгасының биек террасасы буйлап сузылган. Җир асты сулары исәбенә туена. Суы болганчыграк, иссез, җиңелчә минеральләшкән (68,2 *мг/л*), гидрокарбонат-сульфат-хлорид-кальцийлы, йомшак (гомуми катылыгы 2,5 *мг-экв/л*). Күл ләмләнә бара. А.к. фәнни танып белү әһәмиятенә ия; ял итү урыны. ТРның табигать истәлеге (1978).



Архиерей күле.

**АРХИМАНДРИ́Т** (*архи*... һәм грек. mandrítes — монастырь), монахлык итүче руханиларга чиркәү хакимияте тарафыннан бирелә торган шәрәфле дәрәҗә. 5 йөздән Грециядә, 1174 елдан Русиядә А.лар иң эре монастырьлар б-н җитәкчелек итәләр. 18 йөздән бу дәрәҗә рухани уку йортларының (семинарияләр, академияләр) ректорларына һәм профессорларына да бирелә. Казан епархиясендә Казандагы Спас-Преображение һәм Зөядәге Успение монастырьлары б-н А.лар җитәкчелек итә. Казан епархиясендә беренче А.лар — *Варсонофий* һәм *Герман*. Кагыйдә буларак, А.лар *епископ* дәрәҗәсе алу өчен беренче кандидат булып торалар.

**АРХИМИЦЕТЛА́Р**, к. *Хитридиомицетлар*.

**АРХИ́ПОВ А.Л. БАСМАХАНӘСЕ́,** Чистай шәһәрендә 1888 елның октябрендә мещан А.Л.Архипов тарафыннан ачыла. 7 кеше эшли, еллык товар әйләнеше 3500 сум (1902). Казан губернасы һәм Чистай өязе земстволары заказларын үти. Башлыча, бланклар, хисап кәгазьләре, афиша, белдерүләр, ш.у. брошюралар, ш.и. К.Шишкинның «Сүз ясауның төп законнары» («Основные законы словописи», 1912), «Чистайдагы ир балалар гимназиясе укучыларына ярдәм итү җәмгыяте эшчәнлеге турында отчёт» («Отчёт о деятельности общества вспомоществования ученикам Чистопольской мужской гимназии», 1912), «Чистай биржасы каршындагы арбитраж комиссиясе өчен инструкция» («Инструкция для арбитражной комиссии при Чистопольской бирже», 1912) һ.б.ны нәшер итә.

*Әд.:* Белялов У.Б. Руководство хозяйственным строительством в Татарии в годы гражданской войны (1918–1920). К., 1963; Гафуров В.З., Мифтахов З.З. Развитие полиграфии и печати в Татарии. К., 1977.

**АРХИ́ПОВ** Дмитрий Панфилович (13.11.1897, Казан губ., Колай волосте Колай а. — 5.10.1957, Казан), рәссам, график. Казан архит-ра-сәнгать остаханәсен тәмамлый (1926). П.П.Беньков, В.К.Тимофеев шәкерте. Шәһәрнең урта мәктәпләрендә рәсем дәресләре бирә. 1933 елдан «Татхудожник»та эшли, бер үк вакытта Казан сәнгать уч-щесендә укыта (1937–39). ТатАХРР (1925–28), 1936 дан Рәссамнар берлеге әгъзасы. А. иҗаты 1930–40 елларда Татарстанда сынлы сәнгатьнең формалашуын, шул чорның әйдәүче жанры булган тематик картиналарның үсешен чагылдыра («Чалгычылар», 1924; «Печән өсте», 1925; «Силос салу», 1931). А. рәсем һәм график портрет жанрын үстерүгә өлеш кертә. А. ның иң яхшы әсәрләре нечкә психологик төсмерләр ярдәмендә ачылган образлары б-н аерылып тора («Атказанган артист Туишев», 1934; «Хатын портреты», 1936; «Автопортрет», 1942; «Сынчы С.С.Ахун портреты»; 1945; «Композитор Н.Җиһанов портреты», 1950). 1925–55 тә Казанда үткәрелгән республика, өлкәара күргәзмәләрендә, 1957 дә

Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы күргәзмәсендә катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать һәм ТР Милли музейларында, Түбән Новгород өлкәсенең туган якны өйрәнү музеенда саклана.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Е.П.Ключевская.*

**АРХИПОВКА**, к. *Көрнәле.*

**АРХИРЕ́ЕВ** Вячеслав Петрович (29.1.1937, Казан), хим.-технолог, техн. фән. д-ры (1985), проф. (1987), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1999). 1961 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук пластмасса технологияләре каф. мөдире булып эшли (1987 дән). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясе һәм физ. химиясенә карый. Изоцианатларның гомополимерлашуын, макромолекуляр реакцияләрне, полимерларның барлыкка килү һәм эшкәртү стадияләрендәге үзлекләре комплексын һәм структураларын үзгәртүләрнең хим. һәм физ.-хим. мөмкинлекләрен өйрәнә. Полимерларның, ш.и. биообъектларның үзлекләрен стабильләштерү һәм яхшырту принциплары турында «Органик изоцианатлар һәм аларның ясалмалары рәтендәге полимер кушылмаларның үзлекләре комплексын һәм структурасын үзгәртү» дип аталган докторлык диссертациясендә языла. Кан һәм сөяк җелеге күзәнәкләрен саклау өчен криоконсервант (дару формасы — гекмолит) ясау; тиешле функцияле полимер материаллар (антистатик һәм парланмаучы капламнар, электр үткәрүчән һәм ябыштыру материаллары һ.б.); «Оргсинтез» АҖ ацетон-фенол җитештерүнең күп тонналы калдыкларын утильләштерү алымнарын; буягычларда полимер лазер тирәлекләрен һ.б. өйрәнү эшләре б-н җитәкчелек итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Химическая технология безуглеродных (неорганических) полимеров и материалов на их основе. К., 1994 (автордаш); Новые пути химической модификации структуры и свойств полимеров // Вестн. Казан. технол. ун-та. К., 1997. № 1; Влияние наполнителя на взаимную растворимость компонентов в смесях полимеров // Высокомолекулярные соединения. Сер. А. 1998. Т. 40, № 4 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**АРХИТЕКТУ́РА БЕЛЕМЕ́**, архитекторлар һәм техник-архитекторлар әзерләү системасы. 18 йөзгә кадәр төзү сәнгатенә өйрәтү төзелеш артельләрендә осталар җитәкчелегендә алып барыла. Гадәттә бер үк кеше төзүче дә, архитектор да була. 18 йөз башында Россиядә гомуми белем бирү учреждениеләре (цифир һәм навигация мәктәпләре) оештырылу нәтиҗәсендә А.б. дә үсеш ала. «Архитектор» төшенчәсе шул чорда кулланылышка керә. 1724 елда эйдәп баручы архитекторлар каршында «архитектор командалары» оештыру турында указ чыга. С.-Петербургта — И.К.Коробов, М.Г.Земцов, С.И.Чевакинский, Мәскәүдә — И.А.Мордвинов, А.П.Евлашев, И.Ф.Мичурин, Д.В.Ухтомский «командалары» туплана. Шулай беренче рус архит-расы мәктәпләре барлыкка килә. «Команда»да укучы оста җитәкчелегендә проект сызарга өйрәнә, проектланган биналарны төзүдә катнаша. Укытуда Европа архит-расы мәдәниятен һәм рус халык архит-расы традицияләрен үзләштерүгә аерым игътибар бирелә; архитектур сызым киң кулланыла, Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә урта гасырларга караган биналарның үлчәмнәре алына, рәсемнәре ясала.

Россиядә махсус архитектура-сәнгать уку йортлары челтәре үсеше 1757 дә Сәнгать академиясе ачылудан башланып китә. Архитекторларны ш.у. Мәскәү сарай архит-ра уч-щесе дә әзерли. Россия классицизмына нигез салучылар А.В.Квасов, В.И.Баженов һ.б. беренче «команда»ларда белем алалар, нәтиҗәдә 18 йөз уртасы архитекторлары традицияләренең дәвамлылыгы тәэмин ителә. Казан архитекторы В.И.Кафтыревның да үз «команда»сы була, ул анда Ф.Е.Емельянов, Ф.М.Росляков, П.Дёминга гражданлык һәм хәрби архит-ра белеме укыта. 18 йөз ахырына Россиядә архит-ра белеме системасы оешып җитә, укыту барышында композиция нигезләре, рәсем, сызым, сынлы сәнгать, тушь б-н буяу дәресләре бирелә, ордерларның төзелеше, архит-ра һәм гармония кагыйдәләре өйрәтелә. Җәйге практика вакытында укучылар С.-Петербургтагы төзелешләрдә эшлиләр. Укулар тәмамлангач, архитектор дәрәҗәсе алу өчен проект төзү таләп ителә. Мөстәкыйль рәвештә уңышлы проект төзүгә ирешүчеләргә академик дәрәҗәсе бирелә. Архитектура гражданлык, тау, кораб төзелеше һәм гидравлика тармакларына бүлеп өйрәнелә. 18 йөз ахырында төзелеш инженерлары әзерләүче уку йортлары ачыла, бу белгечләр, үз чиратында, проектлау өлкәсендә гражданлык архит-расы конструкцияләре исәпләмәләрен куллана башлыйлар. 1832 дә С.-Петербургта төзелеш уч-щесе ачыла, 1882 дә ул Гражданлык төзелеше инженерлары ин-ты итеп үзгәртелә. Тимер юл, тау, технология, җир төзелеше инженерлары ин-тларында, Александров лицеенда ш.у. архитектура өйрәнелә. Казанда төзелеш һәм архит-ра белеме нигезләре 18 йөздә Гарнизон мәктәбендә һәм Беренче ир балалар гимназиясендә барлыкка килә. 19 йөз башында Казан ун-тының физ.-матем. бүлегендәге технологияләр һәм фәннәр кафедрасында гражданлык архит-расы һәм хәрби архит-ра курслары укытыла (ун-тның 1804 елгы уставы нигезендә; 1813 елдан С.Петровский укыта). Әлеге кафедрада арх. П.Г.Пятницкий (1820–25), Е.И.Линденау (1827–32), М.П.Коринфский (1837–51), Г.П.Гесс (1852–63) укыта. Уку программасына архит-ра тарихының кыскача курсы, гражданлык архит-расы теориясе, сызым, рәсем, смета төзү дәресләре керә. Дәреслекләр сыйфатында архит-ра теориясе классиклары Витрувий, Виньола, Менцель, Рудольфский, И.И.Свиязев һ.б.ның хезмәтләре файдаланыла.

Казан ун-ты ректоры, ике дистә ел дәвамында төзелеш ком-ты җитәкчесе Н.И.Лобачевский бу эшнең чын пәрвәре була. М.П.Коринфский уку әсбаплары һәм сәнгать коллекцияләре кабинеты оештыра, үзәктән читтә А.б. кертүдә башлап йөри. П.Г.Пятницкий шәһәр архитекторларына ярдәмгә урта техник персонал әзерләү идеясен тормышка ашыра. Университетка яңа устав кертелгәч (1863), кафедра ябыла.

19–20 йөзләр чигендә, җәмгыятьтә техник һәм сәнгати әзерлекле төзелеш белгечләренә ихтыяҗ үсү сәбәпле, А.б. төрле тармакларга бүленә. Төбәкләрдә махсус урта белемле архит-ра-төзелеш кадрлары әзерләүдә Сәнгать академиясенә буйсынучы сәнгать мәктәпләренең архит-ра бүлекләре, ш.и. 1897 дә ачылган *Казан сәнгать мәктәбенең* архит-ра бүлеге мөһим урын тота. Анда архитекторлар К.Л.Мюфке (1897–1912), Ф.Р.Амлонг (1900–03), А.И.Горохов (1905–08), П.И.Абрамычев (1903–18), М.С.Григорьев (1912–15) укыта. Уку курсы 6 елга сузыла. Укыту программасына түбәндәге махсус предметлар кертелә: проекцияле сызым, ордер системалары теориясе, сызма геометрия, күләгәләр теориясе, натурада планнар төшерү, нивелирлау, төзелеш эшләре һәм материаллары, смета төзү. Махсус сәнгать дәресләрендә Көнбатыш Европа архит-расы өйрәнелә, андагы биналарның сызымнары һәм рәсемнәре ясала. Ш.у. архитектур караламалар, архит-ра истәлекләренең үлчәмнәрен алу, бирелгән темага проект төзү һ.б. башкарыла. Укытуда архит-раның классик формаларын өйрәнүгә, проектлар тематикасында — утилитар максаттагы корылмаларга өстенлек бирелә. Укучылар белем алу б-н беррәттән Казан шәһәр идарәсенең җир төзелеше эшләре комиссиясендә шәһәр биналарын төзекләндерү буенча техник бүлектә дә эшлиләр. В.А.Дубровин, Н.А.Спасский, И.М.Коробейников, П.Р.Поляев һ.б. архитекторлар М.С.Григорьев, Ф.Р.Амлонг, В.А.Трифонов, К.С.Олешкевич, П.И.Абрамычев һ.б.да практикант, десятник, техниклар булып торалар. Казан сәнгать мәктәбенең архит-ра бүлеген барлыгы (ирекле тыңлаучылардан тыш) 136 кеше тәмамлый, алар арасында П.Т.Сперанский, Ф.П.Гаврилов, М.С.Григорьев, Д.М.Фёдоров, А.М.Рухлядев, С.О.Овсянников, Э.Я.Штальберг һ.б. була. Бүлекне тәмамлап чыгучылар архитектор ярдәмчесе дәрәҗәсе һәм урта белем бирү йортында укыту хокукы ала.

1927 гә кадәр Казанда архитекторлар ике югары уку йортында — Техник сәнгать (архитектор-рәссам дәрәҗәсе бирелә) һәм Политехника ин-тларында (инженер-архитектор дәрәҗәсе бирелә) әзерләнә. 1918 дә Казан сәнгать мәктәбе Ирекле дәүләт сәнгать остаханәләре итеп үзгәртелә, биредә архит-ра бүлеге саклана. Архитекторлар әзерләүгә аерым игътибар бирелүе уку йортларының исемнәрендә үк күренә: Казан архитектура-техника ин-ты (1922–25), Казан архитектура-сәнгать остаханәләре (1925–26). Махсус предметлар архитекторлар А.М.Рухлядев (1919–20), В.В.Егерев (1921–26), Ф.П.Гаврилов (1918–26), теория дәресләре — В.И.Нечкин (1920–23), В.К.Важинский (1919–26), П.М.Дульский (1919–26) тарафыннан укытыла. Укытуда архит-раның социаль бурычлары һәм халык архит-расы формаларын үзләштерү мәсьәләләре өстенлек ала. Яңа төр конструкцияләр һәм материалларның форма хасил итү үзлегеннән чыгып, архит-раны тамырдан үзгәртү мәсьәләсе өйрәнелә; сәнгатьчә образ тудыру проблемасы, пропорция, ритм, төзелеш материалы фак-

турасының асылын күрсәтү аша, архит-раның функциональ һәм техник элементлары арасында гармоник бердәмлек тудыру буларак бәяләнә. Студентлар һәм укытучылар тарафыннан яңа типтагы җәмәгать, хакимият (Татарстан Халык комиссарлары советы, Тат.ҮБК, Өлкә башкарма ком-ты һ.б.) биналарының проектлары эшләнә. Социаль яктан яңа типтагы иҗтимагый-коммуналь кулланылыштагы корылмалар б-н бер комплекс тәшкил итүче торак йортларга аерым игътибар бирелә. Шәһәр төзелеше проектларында бинаның композицион корылышы мөстәкыйль организм буларак та, табигать һәм шәһәр мохитенең аерылгысыз өлеше итеп тә карала башлый. Ул елларда укытуга кертелгән яңалык — студентларга рәссамнар һәм сынчылар б-н берлектә күмәк проектлар эшләтү. 1926 да Казан архитектура-сәнгать остаханәләре Казан сәнгать пед. техникумы итеп үзгәртелгәч, архит-ра бүлеге бетерелә.

Башлангыч һәм махсус урта белемле төзелеш инженерлары 1890 да ачылган Казан сәнәгать уч-щесенә кергән Башлангыч төзелеш уч-щесендә әзерләнә. Анда К.Л.Мюфке (1898–1912), К.С.Олешкевич (1899–1917). И.И.Брюно (1900–15), В.И.Сонин (1901–05), Ф.Н.Малиновский (1902–17), С.В.Бечко-Друзин (1914–18) укыта. 1917 дә сәнәгать уч-щесе Казан политехника уч-щесе итеп үзгәртелә, аның төзелеш бүлегендә булачак инженерлар укытыла. 1919 да училище политехник ин-т дәрәҗәсе ала, аның төзелеш-архит-ра һәм инженерлык ф-тлары 1922 дә төзелеш инженерлары ф-ты итеп берләштерелә, 1929 да бу ф-тта коммуналь төзелеш һәм гидротехника бүлекләре барлыкка килә. 1930 да әлеге ф-т базасында Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-ты оештырыла, анда гражданлык төзелеше, юллар һәм сууткәргечләр ф-тлары оештырыла. 1932 дә архитектура-планлаштыру бүлеге, 1933 тә архитектур проектлау кафедрасы ачыла, анда Ленинград һәм Казан архитекторлары (П.Г.Сперанский, В.П.Попов, А.А.Власов һ.б.) эшкә чакырыла. 1933 тә архитектура-планлаштыру бүлеге ябылгач, аның барлык студентлары төзелеш инженерлары бүлегенә күчерелә. Архитектура курсын укыту методикасы һәм архитектур проектлау дәресләре саклана, «Сәнәгать һәм гражданлык төзелеше» белгечлеге буенча укытыла. Киң профильле белгечләр әзерләнә. Архитектура, графика, рәсем һәм сызым кафедрасында В.В.Егерев, П.М.Дульский, П.Т.Сперанский, А.М.Густов, М.С.Григорьев, И.Г.Гайнетдинов, Н.А.Баталов, А.А.Трофимов, М.К.Игъламов, Р.М.Мортазин, Ә.Г.Бикчәнтәев эшли. Уку программасына рәсем, архит-ра графикасы һ.б. дәресләр керә. Студентларның диплом проектларына архит-ра белгечлеге дә кертелә, бу исә төзелеш инженеры дәрәҗәсе алып чыгучыларга архитектор булып эшләү мөмкинлеген дә бирә. Бөек Ватан сугышы башлангач (1941), институт ябыла. 1946 да ул Казан гражданлык төзелеше инженерлары ин-ты буларак ачыла, анда архит-ра һәм сызма геометрия кафедралары эшли. 1957 дән Казан төзелеш инженерлары ин-ты дип атала. 1966 дан архитекторлар әзерләү яңартыла, 1968 дә архитектур проектлау кафедрасы ачыла (каф. мөдире Ә.Г.Бикчәнтәев). 1969 да архитектура-төзелеш ф-ты оештырыла, 1977 дә ул архит-ра ф-ты итеп үзгәртелә.

И.Г.Гайнетдинов, С.С.Айдаров, Х.Х.Икъсанов, Т.Т.Зиннуров, Б.С.Калыгин, З.С.Батраев, И.В.Рәфыйков, Л.Я.Елькович — ф-тның беренче укытучыларыннан, аның беренче деканы В.П.Остроумов була. 1975 тә факультетта С.С.Айдаров җитәкчелегендә архит-ра теориясе һәм тарихы кафедрасы ачыла. 1989–90 да шәһәр һәм авыл торак пунктлары төзелешен планлаштыру, архит-раның милли мәсьәләләре, архитектура мохите дизайны, автоматлаштырылган проектлау системалары кафедралары эшли башлый. 1994 тә «Архитектур мохит дизайны» дигән яңа белгечлек ачыла. 1995 тә институт *Казан архитектура-төзелеш академиясе* итеп үзгәртелә. 1998 дә анда сынлы сәнгать кафедрасы оештырыла. 1999 дан инженер-архитекторлар әзерләү башлана. Хәзерге вакытта фак-тта 3 архит-ра д-ры, 24 архит-ра кандидаты, 8 проф. эшли. Архитектур проектлау, бөтендөнья архит-расы, ш.и. милли архит-ра тарихы, архит-ра графикасы һәм композициясе, рәсем, сынлы сәнгать, скульптура, техник фәннәр дәресләре керә. 1999 да ф-тта шәһәр төзелешенә караган архитекторлык һәм дизайнерлык диплом эшләренең Халыкара конкурсы була, анда Россия, БДБ илләре, Япония, Кытай һ.б. илләрдән архит-ра юнәлешендәге югары уку йортлары катнаша. 2000 дә факультет Казан архит-ра-төзелеш академиясе составындагы Архитектура һәм дизайн ин-ты итеп үзгәртелә, анда гомуми архит-ра-сәнгать әзерлеге, архит-ра һәм дизайнерлык ф-тлары эшли. 2004 тә архит-ра композициясе, архит-ра теориясе һәм интерьер сәнгате кафедралары ачыла. 2005 тә академия Казан архитектура-төзелеш ун-ты итеп үзгәртелә. 2006 да Архитектура һәм дизайн ин-тында Архитекторлык һәм дизайнерлык диплом эшләренең халыкара конкурсы уздырыла.

*Әд.:* История русской архитектуры. СПб., 1994; Казанской архитектурной школе 30 лет: Каталог. К., 1999; Каталог-справочник Казанской государственной архитектурно-строительной академии. К., 2000.

*Е.П.Ключевская, Х.Г.Надыйрова.*

**АРХИТЕКТУ́РА БИЗӘГЕ́** (декоры), биналарның тышкы һәм эчке бизәкләре җыелмасы, аерым корылмаларны бербөтен ансамбльгә берләштерү чараларының берсе. Ул эре һәм вак пластика (барельеф һәм горельеф), уеп язу, уеп бизәү, сграффито, майолика, кафель, төсле буяу, кабарынкы архит-ра детальләреннән һ.б. гыйбарәт. А.б. корылманың төзелү дәвере һәм урнашкан урыны, шул чор архит-расындагы стиль юнәлеше йогынтысында формалаша. Урта гасырларда Болгар, Казан шәһәрләренең монументаль биналары бизәлешендә майолика, терракота, кирпечне бизәкләп салу, штукатурага бизәкле язу төшерү, үсемлек сурәтендәге һәм геометрик фигуралы ганч һ.б. кулланылган. 16 йөз уртасында Казан һәм төбәк монументаль төзелешендә рус архит-ра мәктәбенең бизәү ысуллары, мәс., Владимир-Суздаль архит-расыннан а́ркалы-колонналы фриз, Псков һәм Мәскәү биналарына хас турыпочмаклы уемнардан хасил булган бизәк, поребрик, «йөгерүче» һ.б. (Казанда *Благовещение кафедраль соборы*, Зөядә *Успение ирләр монастыре* һ.б.) күренә башлый.

17 йөз башында «кирпечтән бизәк салу» («Кирпичное узорочье») дигән шартлы исем б-н мәгълүм булган гомум рус стиле юнәлеше үсеш ала. 17 йөз ахырыннан ордер структуралары һәм детальләре кулланыла башлый, бизәлештә симметриялелек принцибы өстенлек ала. Кирпеч диварга ак таштан бизәк ясау һәм ордер формаларының бергә кушылуы һәр төбәктә үз үзенчәлеге булган стиль юнәлеше — рус бароккосын китереп чыгара. Казандагы һәм төбәктәге барокко стилендәге бизәлеш С.-Петербург һәм Мәскәүдәгеләре б-н чагыштырганда тыйнаграк була. 18 йөз дәвамында биналар бизәлешендә төрле элементлар — ак ташны уеп ясалган фигуралы кирпечтән ясалган баскычсыман кәрнизләр, чынаяк кирпеч түшәлмә, майолик тышланма, фигуралы яисә «бүленгән» фронтоннар һ.б. бер-берсенә яраклаштырып кулланыла (*Адмиралтейство конторы комплексы, Покров чиркәве* манарасы, *Гостиный двор* чиркәве, *Апанай мәчете, Мәрҗани мәчете* һ.б.). *Петропавел соборы* купшы барокко бизәлеше б-н аерылып тора. 18 йөзнең соңгы чирегендә һәм 19 йөз башында *классицизм* стилендәге бизәлеш киң тарала. Аның нигезен тигез яисә рустланган дивардан чыгып торучы ордер элементлары — колонналы һәм пилястралы портиклар, кәрнизләр, фронтоннар, аттиклар, балюстрадалар һ.б. тәшкил итә. Классицизм стилендә фасадларның һәм интерьерларның төсләр кулланып бизәлеше пастель төсләрендәге (сары, соры, алсу) диварларның ак төстәге ордер пластикасы б-н чиратлашуына корылган. 19 йөз башындагы ампир стиле борынгы Рим хәрби дирбиясе элементларыннан — бөркет рәсеме төшерелгән легионер тамгасыннан, калкан, ук савыты, сөңгеләр бәйләме, ликтор балталарыннан гыйбарәт. *Казан университетының төп бинасы, Анатомия театры, Рус гаскәриләре һәйкәл-төрбәсе, Дротоевский йорты* һ.б. классицизм һәм *ампир* стильләрендә бизәлгән. 19 йөз уртасы — 20 йөз башы архит-ра бизәгенә төрле стильләрнең үзара кушылуы хас. 1830–90 еллардагы корылмаларның эклектик А.б. төрле дәвер һәм төбәкләр архит-расы мотивларын иҗади сайлап алуга һәм бер-берсенә яраклаштыруга нигезләнә. Ул бигрәк тә *Александровлар пассажы, Смоленцев сәүдә йорты, Әҗем мәчете* һ.б.ның бизәлешендә ачык чагылыш тапкан. 19 йөз ахыры — 20 йөз башындагы *модерн* стиленең һәр юнәлешендә үзенә хас бизәлеш мотивлары бар. Башлангыч модернга — озынча түгәрәк, эллипс, трапеция формаларындагы уемнар, манаралар, җәелеп ята торган бизәкләр, авыш линияле тәрәкләр, рәшәткәләр хас. Алар *Мюфке йорты, Олешкевич йорты, Шамил йорты* һ.б. бизәлешендә кулланылган. Романтик модерн бизәлеше бик күп халыклар һәм дәверләрнең архит-ра истәлекләре элементларын үзенә туплаган. *Казан сәнгать мәктәбе* бинасы бизәлешендә борынгы рус архит-расы мо-




**Архитектура бизәге.** 1. Кече манара. Болгар ш. 14 йөзнең 2 нче яртысы. Бизәкләнгән уем. Ташны кисеп бизәкләү; 2. Алтын Урда чорындагы Идел буе Болгары архит-ра һәйкәлләрендәге майолик йөзлек фрагменты; 3. Петропавел соборы. Казан. 1723-26. Фигуралы тәрәзә йөзлеге, ябыштырма бизәк, полихромия, икона язуы; 4. Әҗем мәчете. Казан, 1887-90. Манараның ак таштан уелган кәрнизе; 5. Әҗем мәчете. Казан. 1887-90. Гыйбәдәт залы интерьерындагы тәрәзә витражы һәм ябыштырма бизәк детальләре; 6. Александровлар пассажы. Казан. Ордер формалары, скульптура. Арх. В.В.Суслов, Н.И.Поздеев. 1883-86; 7. Михляев йорты. Казан. 17 йөз ахыры. «Кирпеч бизәк»ле фасад фрагменты; 8. Мәрҗани мәчете. Казан. 1766-70. Зал гөмбәзендәге күпертеп ясалган үсемлек бизәкләре; 9. «Шакир солдат» йорты. Казан. 1895. Төп фасад фрагменты. Фигуралы кирпеч дивар, ордер формалары, урам як фасадның фактуралы бизәлеше; 10. Халык төзелеш сәнгате. Тәрәзә һәм кәрнизләрдәге агачтан кисеп бизәкләнгән йөзлекләр. 19 йөз ахыры; 11. Татар опера һәм балет театры. Казан. Арх. И.Г.Гайнетдинов. 1948. Фойедагы колонналарның өске өлеше.

тивлары файдаланылган. *Казан хәрби округы командующие йортында* исә 17–18 йөзләрдәге француз сарае мотивлары һәм детальләре, образы һәм композициясе чагылыш тапкан. Сов. архит-расында А.б. 1930 еллар ахырында — 1950 елларда үсеш ала. «Сталин ампиры» стилендәге биналарда классицизм мотивлары татар бизәлеш сәнгате һәм совет символлары б-н бергә кушылган: *Татар опера һәм балет театры*, «Победа» к/т һ.б. Индустрияләштерү һәм төзелешне типиклаштыру елларында А.б. үзенең тоткан урынын югалта. 1980 еллар ахырыннан төрле максатларда төзелгән биналарда неоэклектика элементлары күбәя бара: *Татарстан Республикасы Зур концерт залы*, мәчетләр, чиркәүләр, коттеджлар һ.б.

*Х.Т.Надыйрова.*

**АРХИТЕКТУ́РА ГРА́ФИКАСЫ**, архитектура объектларын график яктан сурәтләү чаралары җыелмасы. А.г. — архитекторларга корылма, комплекс, шәһәр төзелеше турында мәгълүмат бирү өчен хезмәт итүче үзенчәлекле профессиональ телне тәшкил итә. Ул архитектур рәсем, сызымнар, архитектура-сәнгать басмалары һ.б. чаралардан файдалана. А.г. — архитектур проектлау иҗатының бер өлеше, ул проектлауның барлык стадияләрендә (эскиздан башлап төзелеш өчен кирәкле гамәли сызымнарга кадәр) объектны график яктан гәүдәләндереп бара. Пространствода күләм биләп торган предметларның яссылыкта урнашуын һәм зурлыгын чагылдыру өчен сызма геометриягә таяна. Сызма геометриянең нинди алымнарын куллануга карап, объектларны график яктан сурәтләү өч төргә аерыла: ортогональ проекциядә (план, киселеш, фасад, генераль план), перс-



Г.К.Л у к о м с к и й. «Зөядәге Благовещение чиркәвенең бер ягы». Рәсем. 20 йөз башы.



Г.К.Л у к о м с к и й. «Кизик монастырендагы Введение чиркәве». Рәсем. 20 йөз башы.



С.С.А й д а р о в. Рамазан мәчете проекты. Компьютер графикасы. 1980 еллар ахыры – 90 еллар башы.



А.А.С п о р и у с. Колшәриф мәчете күренеше. Акварель. 1996.

пективада һәм аксонометриядә чагылдыру. А.г. ш.у. графика сәнгате мөмкинлекләреннән файдалана: объектларның сурәте сызмалар яисә төрле ачыклыктагы төсләр б-н башкарылырга мөмкин. Соңгысы монохром һәм полихром төрләргә бүленә. Архитектура объектын сызымда чагылдыру архитекторга үз максатын гамәлгә төгәл ашыру мөмкинлеген бирә. Объектның сызма сурәте, исәпләүләр һәм аңлатмалар — барысы бергә проект дип атала. Проектлау процессы түбәндәге стадияләргә бүленә: эскиз проекты, проект, эш проекты, эш документациясе. Архитектур проектлау өлкәсенә компьютер техникасының үтеп керүе нәтиҗәсендә, архит-ра объектларын сурәтләүдә зур мөмкинлекләр бирүче автоматлаштырылган А.г. киң кулланылыш таба. А.г. архит-ра тарихы б-н тыгыз бәйләнештә, һәм һәр дәвер аңа үз эзен сала. Борынгы Болгар истәлекләре 18–20 йөзләрдә иҗат иткән рәссам һәм архитекторларның А.г. әсәрләрендә (Г.Г. һәм Н.Г.Чернецовлар, А.К.Шмидт, Н.Н.Кафтанников, В.И.Корсунцев, С.С.Айдаров һ.б.) чагылыш таба, алар географик, тарихи, этнографик хезмәтләргә иллюстрация сыйфатында кертелә. Казандагы бик күп тарихи биналарның А.К.Шмидт тарафыннан 1815–18 елларда ясалган сызымнары архит-ра тарихын өйрәнүдә мөһим роль уйный, реконструкцияләү һәм реставрацияләү проектларын төзүдә файдаланыла. М.П.Коринфский проектлары, классицизмның соңгы чоры А.г.ның характерлы үрнәге буларак, архитекторларның иҗади табышларын тулырак чагылдыра, әмма биналар күп вакыт гадиләштерелгән проект б-н төзелгән. А.г. әсәрләре, төп вазифаларыннан тыш, еш кына мөстәкыйль сыйфатта кулланыла — альбомнар, автор папкалары рәвешендә басылып чыга, олы юбилейлар уңаеннан император гаиләсенә бүләк итү өчен заказ б-н әзерләнә, фән-сәнәгать күргәзмәләренә куела (В.С.Турин, Э.П.Турнерелли альбомнары, П.В.Тихомировның А.г. сериясе, Д.М.Михайлов, П.М.Тюфилин проектлары һ.б.). Казан сынлы сәнгать мәктәбе архит-ра бүлеге укучыларының проектларында модерн стилендәге А.г. өстенлек итә (Г.К.Лукомский, А.И.Трапицын һ.б.). Ф.П.Гаврилов проектлары конструктивизм стилендәге А.г. үрнәге булып исәпләнә. 1930–50 елларда И.Г.Гайнетдинов, П.Т.Сперанский, П.Л.Саначин, Г.И.Солдатов һ.б. эшләп калдырган проектлардагы А.г.да Татарстан архит-расына милли үзенчәлек бирү омтылышы чагылыш таба. А.А.Спориусның 1970–80 еллардагы А.г. үзенең иҗади индивидуальлеге б-н аерылып тора. Төзелешне индустрияләштерү елларында А.г. шактый дәрәҗәдә стандартлаша. 20 йөзнең соңгы унъеллыгыннан А.г. нигездә компьютерда башкарыла.

*Әд.:* Т у р и н В. Перспективные виды губернского города Казани, рисованы с натуры и линогравированы. М., 1834; Т у р н е р е л л и Э.П. Собрание видов города Казани, рисованных с натуры. СПб., 1839; Олеарий Адам. Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно. СПб., 1906; Д у л ь с к и й П.М. Казань в графике Г.К.Лукомского. К., 1920; Ш м и д т А. Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. М., 1932; З а й ц е в К.Г. Архитектурная графика. М., 1983.

*Н.А.Мамакова, Е.П.Ключевская.*

**АРХИТЕКТУ́РА ГЫЙЛЕМЕ́**, архитектураны өйрәнүче иҗтимагый, техник һәм махсус фәннәр комплексы. Төп тармаклары: архит-ра, шәһәр төзелеше теориясе һәм тарихы, архит-ра истәлекләрен реставрацияләү һәм реконструкцияләү, ландшафтлар архит-расы, архит-ра иҗаты методологиясе, архит-ра тәнкыйте. А.г.нең фән буларак барлыкка килүен галимнәр Борынгы Рим архитекторы һәм инженеры Витрувийның «Архитектура турында ун китап» дигән трактаты (б.э.к. 1 йөз) б-н бәйлиләр, анда шәһәр төзелеше, инженер-техник һәм бизәлеш мәсьәләләре бәян ителә. А.г. үсешендә Л.Альбертиның «Биналар төзү турында» (1485), А.Палладионың «Архитектура турында дүрт китап» (1570), Д.Виньоланың «Архитектурада биш ордер кагыйдәсе» (1562) дигән трактатлары мөһим роль уйный. 18–19 йөзләрдә архит-ра фәне үсеше нигездә архит-ра (ордер) формалары теориясен эшләү, дөнья архит-расы истәлекләрен ачу һәм өйрәнү юнәлешендә бара. Моңа күренекле француз һәм немец галимнәренең (И.Винкельман, Г.Шлиман, Ф.Майер, К.Шинкель, Виолле ле Дюк, О.Шуази һ.б.) археология һәм реставрация өлкәсендәге эшчәнлекләре сәбәп була. Нәтиҗәдә дөнья халыкларына Троя, Микен, Помпеи, Петра, Персепольдәге мәдәни истәлекләр б-н танышу мөмкинлеге ачыла. Бу истәлекләрнең тарихын һәм архит-расын тирәнтен өйрәнүгә, төрле төбәкләр һәм дәверләрнең архит-расы арасындагы үзара йогынтыларны һәм бәйләнешларны тикшерүгә этәргеч бирә. Бөтендөнья архит-расы тарихын өйрәнүгә нигез салына. 20 йөздә тикшеренүләрне Л.Беневоло, З.Гидион, Г.Зитте, М.Майер, Н.Певзнер, М.Рагон һ.б. дәвам иттерә. Тикшеренүчеләр, архит-ра һәм шәһәр төзелеше композицияләре мәсьәләләреннән тыш, ландшафтка бәйле, техноген, экологик һ.б. аспектларның теоретик проблемаларына да игътибар итәләр.

Россиядә халык архит-расы истәлекләре б-н кызыксыну һәм алар турындагы беренче басмалар 18 йөз башында барлыкка килә. Архитектура истәлекләренең үлчәмен алу, алар-

ны системалы өйрәнү башлана. Петербург ФА Россия империясенең төрле тарафларына академик экспедицияләр оештыра. Бу экспедицияләрнең хисапнамәләре, танылган тикшеренүчеләр А.Глаголев, А.А.Мартынов, И.М.Снегирёв хезмәтләре басылып чыга. Борынгы рус архит-расының типлары билгеләнә. 19 йөз уртасында рус архит-расы тарихын язу ихтыяҗы туа, 1870–90 елларда ул Россия фәненең мөстәкыйль тармагына әверелә. Архитекторлар Л.В.Даль, А.М.Павлинов, В.В.Суслов, Н.В.Солтанов архит-ра истәлекләрен өйрәнгәндә архитектур форманы бинаның кулланылышы, материаллары һәм конструкциясе, фәзадагы күләме, композицион төзелеше б-н бәйләп тикшерүче яңа алымнар куллана башлыйлар. Архит-ра истәлекләрен график яктан үзгәртеп кору беренче тапкыр фәнни әйләнешкә керә, бу исә биналарны әүвәлге хәленә кайтару мөмкинлеген ача. 1894 елда А.М.Павлиновның «Рус архитектурасы тарихы» китабы дөнья күрә. 20 йөз башында А.г. үсешенә М.В.Красовский, А.Н.Бенуа, И.Э.Грабарь, Г.К.Лукомский, Н.П.Кондаков, А.И.Успенский һ.б. зур өлеш кертә. 20 йөз башында И.Э.Грабарь мөхәррирлегендә (Г.Г.Павлуцкий, А.В.Щусев, В.А.Покровский катнашындагы авторлар төркеме) «Рус сәнгате тарихы» басылып чыга, анда 10–19 йөзләрдәге рус архит-расы беренче мәртәбә рус сәнгатенең аерылгысыз өлеше буларак карала.

Окт. инкыйлабыннан соң А.г., нигездә, төбәкне өйрәнү фәне кысалары б-н чикләнә. 1930 еллар башыннан, сов. архит-расындагы яңа күтәрелеш нәтиҗәсендә, дөнья һәм Россия архит-расы тәҗрибәсен өйрәнү башлана. 1950 елларда күпьеллык тикшеренүләр «Рус сәнгате тарихы», «Рус архитектурасы тарихы» дигән фундаменталь хезмәтләрдә гомумиләштерелә, аларны эшләүдә А.И.Некрасов, Н.И.Брунов, А.В.Бунин, В.И.Пилявский һ.б. катнаша. Шул ук елларда рус шәһәр төзелеше тарихы формалаша башлый. 1980 еллар алдыннан А.г.нең яңа юнәлеше — «шәһәр төзелеше археологиясе» барлыкка килә: археологик тикшеренүләргә нигезләнеп, борынгы шәһәрләрнең планы, корылмалары, гомуми күренеше торгызыла (П.А.Раппопорт). Рус архит-расы тәгълиматын өйрәнү башлангыч ала (Е.И.Кириченко, Н.А.Евсина, А.Л.Пунин һ.б.), сәнәгать архит-расы, архитектура-төзелеш, техник һәм технологик системалар тарихы өйрәнелә (А.Л.Пунин, М.С.Штиглиц һ.б.). 12 томлы «Архитектураның гомуми тарихы»нда (1970–80 еллар) Россия архит-расы беренче тапкыр дөнья архит-расы контекстында карала. 20 йөз ахырында архит-ра үсешенең гомуми закончалыклары Россия халыкларының милли һәм тарихи үзенчәлекләренә нигезләнеп тикшерелә. Архит-ра методологиясенең нигезе формалаша, матди һәм рухи дөньяның бербөтенлегенә таянган караш барлыкка килә, архитектур тикшеренүләрдә культурология мәсьәләләре өстенлек ала.

Урта Идел буендагы Биләр һәм Болгар корылмаларын беренче тапкыр искә алу, күзәтүләр һәм тасвирлаулар гарәп сәяхәтчеләре Ибне Фазлан, Ибне Рустә, әл Гарнати язмаларында очрый. Камалыштагы Казанның Иван Грозный гаскәре тарафыннан алыну вакыйгасын патша яраннарының берсе кенәз А.Курбский тасвирлый. 1560 елларда инглиз Дженкинсон Казанда була һәм татарларның тормышы, көнкүреше хакында мәгълүматлар туплый. Европа сәяхәтчеләре А.Олеарий һәм Н.Витзен 17 йөздәге Казан рәсемнәрен ясыйлар, тасвирламалар төзиләр. Урта Идел халыклары, ш.и. татарларның архит-расы турында чагыштырмача төгәл мәгълүматлар И.И.Лепёхин, И.И.Георги, П.С.Паллас һ.б. язмаларында урын ала. 1827 дә арх. А.К.Шмидт Борынгы Болгар истәлекләренең үлчәмнәрен ала, рәсемнәрен ясый, тасвирламаларын яза. 1834 тә В.С.Турин Казанның перспектив күренешләрен бастырып чыгара. 1839 да Э.П.Турнерелли Казан күренешләренең график рәсемнәрен ясый. 19 йөзнең икенче яртысында Казан губернасында яшәүче халыкларның мәдәниятен өйрәнүгә фәнни оешмалар алына, аларның берсе — Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте. Төбәк архит-расы турындагы мәгълүматлар, аерым истәлекләр, шәһәрләр, торак пунктларның тасвирламалары В.М.Черемшанский, А.Ф.Риттих, В.А.Сбоев, В.А.Шпилевский, Е.А.Малов, Н.П.Загоскин һ.б. хезмәтләрендә урын ала. П.М.Дульский аерым ансамбльләр б-н бергә, шәһәр үсешенең гомуми тарихын тикшереп, Казан архит-расын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Ул Казан архит-расындагы классицизм стилен беренче булып тасвирлый. Аның Казан татарлары сәнгатенә кагылышлы хезмәтләре дә әһәмиятен югалтмый. 1930 елларда В.В.*Егеревның* классицизмның күренекле архитекторлары П.Г.Пятницкий һәм М.П.Коринфский иҗатларын өйрәнүгә һәм бәяләүгә багышланган хезмәтләре дөнья күрә. Республикада А.г. үсешендә тарихчы Н.Ф.Калинин, этнограф Н.И.Воробьев хезмәтләренең әһәмияте зур. 1930–50 елларда Казан Кремлендә, Биләр, Болгар шәһәрлекләрендә киң колачлы археологик тикшеренүләр үткәрелә, бу А.г.дә шәһәр төзелеше археологиясе һәм архит-расы фәне үсешенә этәргеч бирә. Әлеге эшнең башында А.П.Смирнов, Ф.Х.Вәлиев, А.Х.Халиков, С.С.Айдаров һ.б. тора. С.С.Айдаров, Ф.Х.Вәлиев, Н.Х.Халитовларның Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы архит-расына караган фундаменталь тикшеренүләре архит-ра истәлекләрен фәнни-график яктан реконструкцияләү, аларны күзаллау мөмкинлеге тудыра.

1970 еллар ахырыннан Татарстандагы тарихи-архитектур тикшеренүләрдә системалы график-аналитик алым, чагыштырма анализ кебек заманча фәнни алымнар кулланыла башлый. 1980–90 елларда 18 йөз ахыры — 20 йөз башы Казан архит-расында татар милли традицияләре, Идел-Чулман буенда ислам мәдәнияте, Казан ханлыгы архит-расы (Н.Х.*Халитов*), классицизм дәверендә Казанда шәһәр төзелеше (С.В.Кузнецов), 18 йөз — 20 йөз башында татар торак пунктларының урнашуы һәм төзелеше, ТРда сакланган архит-ра истәлекләренең стиле, архитектура-урнашу үзенчәлекләре, 18 — 20 йөз башы шәһәрләренең архит-ра-тирәлек төзелеше, Татарстанда бүгенге дини архит-ра традицияләре (Х.Г.Надыйрова), хәзерге вакытта Казанда планлаштыру һәм төзелеш (Т.Р.Закирова), Татарстан авыллары архит-расында халык традицияләрен куллану мәсьәләләре (Р.Р.Аитов, М.Ш.Фазлыев) өйрәнелә. Тикшеренүләрнең бер өлеше Татарстан архит-расы үсешенең теоретик һәм методологик мәсьәләләренә карый. Культурологик яктан тикшерү нәтиҗәсендә Урта Идел буе архит-расы — шәһәр төзелеше мәдәниятендә типик архит-ра комплексы булуы ачыклана (Г.Н.Айдарова). Бу — Татарстанда тарихи-архитектур тикшеренүләрнең яңа юнәлешен тәшкил итә. Казан архитектура-төзелеш академиясе респ-када А.г. үзәге булып тора.

*Әд.:* А й д а р о в С.С. Архитектурное наследие Казани. К., 1978; О с т р о у м о в В.П. Казань. К., 1978; Х а л и т о в Н.Х. Мечети Казани. К., 1986; А й д а р о в а - В о л к о в а Г.Н. Архитектурная культура Среднего Поволжья. К., 1997.

*Г.Н.Айдарова.*

**АРЦЫБА́ШЕВ** (Арцыбышев) Николай Сергеевич (1.12.1773, Казан губ., Цивиль өязе Мамино а. — 27.8.1841, шунда ук, Рындино а.), тарихчы, язучы. 1793 елда С.-Петербургта немец пансионын тәмамлый, Семёнов лейб-гвардия полкына хезмәткә керә. Якынча 1797 дә Казан гарнизонына прапорщик итеп күчерелә. 1806–07 дә Казан ополчениесендә (земство милициясе) хезмәт итә. 1812–23 тә Ядринск һәм Чабаксар уч-щеләренең шәрәфле иганәчесе була. 1802 дән рус тарихын өйрәнү б-н мавыга башлый. «Вестник Европы», «Русский зритель» ж-лларында тарихка караган мәкаләләр бастыра. Н.М.Карамзин хезмәтенә карата язылган «Россия дәүләте тарихы»на искәрмәләр» («Замечания на «Историю государства Российского») мәкаләсендә («Казанский вестник» ж-лында басыла, 1822–23) авторны төгәлсезлектә, тарихи вакыйгаларны беллитристик рәвештә тасвирлауда гаепли һәм шуның б-н рус тарихчылары, публицистлары арасында зур бәхәс уята. А.ның иң зур хезмәте — «Россия турында кыйсса» («Повествование о России», М., 1838–43). Аны язганда ул 500 дән артык чыганактан файдалана. 1811 дән Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте әгъзасы. «Күңелсезләнү» («Скука», 1800), «Очраклы вакыйга» («Слепой случай», 1841) одалары, «Рогнеда, яки Полоцкны җимерү» («Рогнеда, или Разорение Полоцка», СПб., 1818) исемле тарихи повестьлар авторы.

*Әд.:* А р и с т о в В.В. Казанские находки. К., 1985; Русские писатели. 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1989. Т. 1; Г у с а р о в Ю.В. Цивильский затворник. Чебоксары. 2000.

**АРЦЫБА́ШЕВ Н.С. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**, тарихчы һәм язучы Арцыбашевның шәхси китапханәсе. Рус елъязмалары күчермәләренең бай җыелмасы: Лаврентьев, Кёнигсберг (Радзивилов) елъязмалары; «Вятка иле елъязмачысы» («Летописец о стране Вяцкой») һ.б.; 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысы китаплары: мемуарлар (А.Мейерберг, С.Г.Гмелин, Плано Карпини язмалары), тәрҗемәи хәлләр (Павел I, Б.К.Миних, патриарх Никон); Ф.Вольтер, Ш.Монтескьё, М.В.Ломоносов, В.Н.Татищев, Н.М.Карамзин хезмәтләре;

сүзлекләр, карталар; Россия тарихы һәм борынгы истәлекләр җәмгыяте (Н.С.Арцыбашев — шул җәмгыятьнең әгъзасы) басмалары, ш.у. фәлсәфә, хокук фәннәре, авыл хуҗалыгы өлкәләренә караган әсәрләр. Бик сирәк очрый торган (раритет) басмалардан Ф.Гвичардининың Венециядә басылган «Италия тарихлары» (1599), Пётр I заманы китаплары, «Санкт-Петербургские ведомости» (1728) г-тасы, «Игорь полкы турында җыр» («Слово о полку Игореве», М., 1800) китабының беренче басмасы, 18 йөздә басылган «Казан тарихы»ның («Казанская история») 2 күчермәсе һ.б. Н.С.Арцыбашевның «Россиянең башлангычы турында» («О начале России») дигән үз әсәре, үзе тәрҗемә иткән «Европа Сарматиясе турында» («О Сарматии Европейской») исемле Целларий әсәренең тулы аңлатмалар бирелгән корректурасы сакланган. 1857 елда Н.С.Арцыбашевның улы китапханәдә сакланган документларның күп өлешен — 173 исемдә 357 томлык китап һәм кульъязмаларны Казан ун-тының Фәнни китапханәсенә тапшыра.

*Әд.:* А р и с т о в В.В. Казанские находки. К., 1985; Г у с а р о в Ю.В. К вопросу о частных книжных собраниях в Чувашском крае 1-й пол. 19 в.: Библиотека Н.С.Арцыбашева // Из истории дореволюционной Чувашии. Чебоксары, 1992.

*И.А.Новицкая.*

**АРЧА́**, урта гасырлар (13–16 йөзләр) болгар-татар шәһәре; Казансуның уң ярындагы калкулыкта урнашкан. 12–13 йөзләр арасында, чик буе кальгасы буларак болгарлар тарафыннан нигезләнгән дип фаразлана. Алтын Урда чорында Казан артындагы хәрби ныгытмаларның алгы сафтагыларыннан саналган. 15–16 йөзләрдә Казан ханлыгының *Арча даругасы* үзәге. А.төбәге бәкләре Казан ханлыгы тормышында мөһим роль уйнаган. 14–15 йөзләрдә А. Нократ җирләрендә (к. *Нократ җирләре*) Казан ханлыгы б-н Мәскәү кенәзлеге арасындагы үз өстенлекләрен урнаштыру өчен барган көрәш үзәкләренең берсенә әверелә. 1497 елда А.га Казан ханы Мамык та һөҗүм итә. 1552 дә рус гаскәрләре Казанны камаган вакытта А. төбәге камалыштагыларга ярдәм итеп торучы *Япанча*ның атлы гаскәре туплану урынына әверелә. А. 1552 нең сентябрендә А.Б.Горбатый-Шуйский һәм А.М.Курбский гаскәрләре тарафыннан яндырыла. Археологик калдыклары хәзерге шәһәр тибындагы А. посёлогы биләмәсендә сакланган (3 *га* чамасы). А. кальгасы калдыклары 1772 елда П.И.Рычков, 1852 дә Е.А.Малов, 1900 дә В.Л.Борисов, 1945 тә Н.Ф.Калинин, 1969 да Р.Г.Фәхретдинов, 1996 да А.Ә.Борһанов тарафыннан тикшерелә; А.ның җир өеме һәм тирән чокыр рәвешендәге элекке ныгытмасы билгеләнә, шәһәрчек урынында Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверләренә караган балчык савыт кыйпылчыклары, пыяла һәм тимердән коелган әйберләр (тимер урак, ук очлары һ.б.), чуен койганда барлыкка килгән шлак кисәкләре, 2 көмеш акча (Олуг Мөхәммәд исеменнән сугылган) һ.б. әйберләр табыла; 1552 елгы янгын эзләре билгеләнә. Казан төбәген колонияләштерү чорында, 1555 тә, руслар тарафыннан А. урынында яңа ныгытма төзелә.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и булгаро-татарские памятники Казанской губернии. К., 1877; Б о р и с о в В.Л. Древняя башня в г.Арске Казанской губернии // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1900. Т. 16, вып. 3; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. К., 1975; Б у р х а н о в А.А. Средневековое городище Арск-Арча (некоторые итоги историко-археологического изучения) // Интеграция археологического и этнографического исследований. Нальчик-Омск, 2001.

*А.Ә.Борһанов.*


**АРЧА́**, шәһәр тибындагы посёлок, Арча р-ны үзәге. Татарстанның төньяк-көнбатыш төбәгендә, Казаннан 65 *км* ераклыкта, Казансу елгасы буенда. Казан–Екатеринбург тимер



юл станциясе. 2006 елда 17,4 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 88,2%) яши. Җиңел сәнәгать (милли аяк киеме җитештерү берләшмәсе, «Мехчы» мех эшкәртү һәм тегү комб-ты, «Амфир» мех чималы эшкәртү ф-касы, тегү комб-ты), азык-төлек сәнәгате (Арча р-н кулланучылар берләшмәсенең азык комб-ты, крахмал з-ды, икмәк, сөт комб-тлары) пр-тиеләре, ремонт-механика з-ды, агач эшкәртү, төзү материаллары комб-тлары, элеватор, район типографиясе. Пед. көллияте, 5 урта һәм 1 башлангыч мәктәп, һөнәри уч-ще, балалар сәнгать мәктәбе, якташ язучылар музее, 3 китапханә, 2 мәдәният йорты, 2 мәчет. 13 йөздә нигез салына. Казан ханлыгы чорында А. *Арча даругасы*ның үзәге була. 1552 дә А.Курбский (к. *Арча*) гаскәрләре тарафыннан яндырыла. 1555 тә монда рус крепосте төзелә. 1781–96 елларда А. — Казан наместниклыгында өяз шәһәре, 1796 елдан — өяз үзәге булмаган шәһәр. 18 йөз — 19 йөз башларында бирегә игенче солдатлар күчереп утыртыла. Халкы игенчелек, терлек үрчетү, он тарту, кирпеч сугу, йон тетү, тимерчелек, балта һәм тегү эшләре б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да волость идарәсе урнаша, ар-



хит-ра истәлеге — Богоявление һәм Покрау чиркәүләре, почта-телеграф бүлеге, телефон станциясе, земство хастаханәсе (1872 дә Чыпчык авылыннан күчерелә), кыз балалар өчен земство уч-щесе, ир балалар өчен Халык мәгариф министрлыгы уч-щесе. 6 салат оны җитештерү, 2 күн, аракы з-длары, тегермән, 3 тимерче алачыгы, шәраб һәм 10 вак-төякләр кибете, 2 сыраханә, 2 трактир, 10 ашханә, 3 юлаучылар йорты эшли; һәр дүшәмбедә базар җыела. 1920 елга кадәр А. Казан губернасының Казан өязе Арча волосте үзәге булып тора. 1920–30 елларда —



ТАССРның Арча кантоны үзәге. 1926 да шәһәрләр исемлегеннән сызыла. 1930 ның 10 августыннан — район үзәге, 1938 дән — шәһәр тибындагы посёлок. Халык саны: 1782 дә — 290 ир заты; 1859 да — 1338, 1897 дә — 1228, 1908 дә — 1162, 1917 дә — 1415, 1920 дә — 1420, 1926 да — 2250, 1940 та — 5220 кеше, 1979 да — 11,5 мең, 1989 да — 13,9 мең кеше.


*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

Арча посёлогы. 1. Район хакимияте бинасы; 2. Тимер юл вокзалы; 3. Мәчет; 4. Покрау чиркәве. 1865–82; 5. «Алсу» кибете.





**АРЧА́ ӘДӘБИЯ́Т һӘМ СӘНГА́ТЬ МУЗЕ́Е**, Арча районының Арча эшчеләр посёлогында. 1993 елның 1 августында төзелә, 1995 нең 26 апрелендә ачыла. Экспозиция мәйданы 144 *м*². Коллекциядә 2000 гә якын саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозициянең төп бүлекләре: «Мәгърифәтчеләр Г.Курсави, Ш.Мәрҗани һәм Ш.Күлтәси», «Татарстан



Арча әдәбият һәм сәнгать музее.

Республикасының халык язучылары», «Якташларыбыз — халык артистлары Ш.Әхмәтҗанов, А.Фәйзрахманов, Г.Сафиуллина һәм башкалар», «Фёдор Шаляпин Арчада», «Арча шәһәрлеге тарихы», «Арча төбәге тарихы». Экспозиция авторлары — Л.Д.Хәйруллина, Г.Х.Еникиева (ТРның Дәүләт музее, хәзер ТРның Милли музее фәнни хезмәткәре), рәссам С.Н.Матвеев.

Музей экспозициясе язмышлары төбәк б-н бәйле булган 40 язучының, 20 ләп сәнгать һәм фән эшлеклесенең тормышы һәм иҗаты турындагы материалларны колачлый. 18–19 йөзләргә караган экспонатлар арасында мәгърифәтчеләр Ш.Күлтәси, Ш.Мәрҗани, Г.Курсави, драматург Г.Камал һәм шагыйрь Г.Тукайга нисбәтле документлар һәм әйберләр (Күлтәсинең таягы, Ш.Мәрҗанинең Коръән китабы һәм язу әсбаплары һ.б.), 20 йөз язучылары Г.Бәширов, Ә.Галиев, Г.Бакиров, М.Галәү һ.б.ның тормышы һәм иҗаты турындагы материаллар урын алган. Декоратив-гамәли һәм сынлы сәнгать әйберләре, Ш.Әхмәтҗанов, А.Фәйзрахманов, Г.Сафиуллина һ.б.ның сурәтләре, шәхси әйберләре, өс киемнәре куелган.

15 йөздән башлап, Арча төбәге тарихы археологик, тарихи-этнографик әйберләр һәм фотодокументаль материаллар аша чагылдырыла. Музейның иң мөһим коллекцияләре — якташ язучыларның шәхси әйберләре, кульязмалары, фотографияләре (1200 берәмлек), этнографик әйберләр коллекциясе (100 берәмлек), районның танылган кешеләренең сурәтләре (100 берәмлек) санала. Музей ел саен музей оешу һәм ачылу, Туган тел (26 апр.), Халыкара музейлар (18 май), Татарстан Республикасы (30 авг.) көннәрен билгеләп үтә.

Музей басмалары: Арский музей литературы и искусства: Буклет. К., 2000.

**АРЧА́ ДАРУГАСЫ́**, Казан ханлыгында һәм 16 йөз уртасыннан 18 йөз башына кадәр Рус дәүләтендә административ-территориаль бүленеш төбәге (податный округ). Казаннан төньяк һәм төньяк-көнчыгыш тарафта урнашкан була. Чикләре төгәл билгеләнмәгән: «*писцовый кенәгәләр*»гә теркәү вакытында үзгәртүләр күзәтелә. А.д.на Нокса, Казансу, Киндерле, Дүртьюл, Борнаш, Ташлы, Келәтле, Янчур, Таузар, Шәпше, Шәләнгеш, Ащерма, Кырлай, Ямаширмә, Үрсу, Буҗа, Чүриле, Урмат, Әҗмән, Бирәзә, Кесмәс, Налга, Нечка, Кече Гольян, Чулман, Сарапул, Беляевка, Малаховка, Шевыряловка, Имәнле, Петровка, Өянкеле, Шушма, Нократ, Сәрдә, Сәвәл һ.б. елга һәм елгачык буйлары кергән. Үзәге — Арча: Уржум шәһәренә илтүче Себер юлы буендагы торак пункт. Рус дәүләтенә буйсындырылганнан соң, волость һәм *сотня* берәмлекләренә бүленә. А.д.на Сарапул өязенең Архангельск (Кыныбай), Никольск (Каенлы), Покровский (Вятский), Ушаково, Дулесово, Пещеры (Красная), Нечкино, Карпов, Гольян, Иске Докши, Олы Докши, Сива, Костоватая, Галево, Дубровка, Шевырялово, Поспелово, Сагаево, Козлово, Чуваш Иле, Заелмичная, Тарасово, Ершовка, Патраково, Чоткарин һ.б., марилар (чирмешләр) волосте Малмыжга караган Бүртәк, Несла, Кучук, Гоньба, Сәвәл, Карадуган, Азан, Каратай, Красный, Мошлы, Кече Сәрдә торак пунктлары керә. А.д.на ш.у. Царицино, Подсеки, Рождественный, Чүриле, Вознесенский, Ястачы, Тауиле (Пермяк), Кече Борнаш, Кече Колсәет, Келәтле, Бөреле, Кече Кибәк Шәпшесе, Олы Яңа Шәпше, Урта Шәпше, Ащерма (Сидорово), Коркачык, Иске (Әчке) Казан, Мамадыш, Үрсәк, Хозяшево, Кишмәт, Божа, Кузнецы, Әки, Чабакса, Константиновка, Киндерле, Ямаширмә, Кече Түбән Мәтәскә (Айван), Әзәк, Кече Күртәнәс (Бируй), Казанбаш, Чокырча, Курса, Кече Муя, Төбәк Хуҗа һ.б. авыллар кергән. Татар, мари, удмуртлар һәм 16 йөздән башлап руслар яшәгән. А.д.на *Ар ягы бәкләре* биләмәләре дә кергән. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан рус алпавытлары, йомышлы морзалар, керәшеннәр һәм монастырьлар (Архиерей йорты, Казан Спас-Преображение, Хлынов, Вятка, Успение монастырьлары) җир биләмәләре кергән. Халкы игенчелек, терлекчелек, балык тоту, он тарту, салат оны әзерләү, йон тетү, умартачылык, агач әйберләр җитештерү, кием тегү б-н шөгыльләнгән. 1708 елда А.д. бетерелә, җир-су биләмәләре Казан губернасының Казан өязенә беркетелә.

*Әд.:* Городские поселения в Российской империи. СПб., 1861. Т. 1–2.

*Д.Г.Мостафина.*

**АРЧА́ КАНТОНЫ́**, 1920–30 елларда ТАССРда административ-территориаль бүленеш берәмлеге. Республиканың төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1920 елда Казан өязенә кергән 20 волость җирлегендә Казан кантоны буларак оештырыла. Соңрак аңа Кызыл Кокшай (элеккеге Царёвококшайск) өязенең 2, Малмыж өязенең 7 волосте кушыла. 1920 ел ахырыннан А.к. дип үзгәртелә. 1927 елда Воскресенск, Ильин, Столбище волостьлары һәм Калинин, Мәмдәл волостьларының кайбер торак пунктлары нигезендә Казан (Воскресенск) р-ны оештырыла. 1926 да А.к. мәйданы — 8007 *км*², 1928 дә — 7516 *км*². Халкы 374725 кеше, ш.и. татарлар — 59,2%, руслар — 37,5%, удмуртлар — 2,7% (1926). Шәһәрдә яшәүчеләр — 5655, авылларда яшәүчеләр 369070 кеше (1926). Бер *км*²га уртача — 69,2, авыл җирендә 46,1 кеше туры килә. Үзәге — Арча авылы. А.к.нда 815 торак пункт (1926) була, алар 15 волостька (Арбор, Арча, Әтнә, Балтач, Дөбъяз, Калинин, Кишет, Күлле Киме, Мәмсә, Мәмдәл, Пановка, Питрәч, Теләче, Тукай, Чүриле) керә (1929). А.к.да тире иләү, күн эшкәртү, агачтан һәм металлдан әйберләр җитештерү, азык-төлек пр-тиеләре эшли. Иң эре хуҗалыклар: Паратскида елга корабларын төзекләндерү з-ды, «Фанера» агач ярдыру з-ды, Лопатино торак пунктында (хәзер Яшел Үзән тимер юл станциясе җире) «Заря» агач материаллары эшкәртү з-ды, Васильево авылында пыяла з-ды. 1926 да һөнәри кәсепчелек өлкәсендә эшләүчеләр саны 12200 кешедән арткан. Күпчелек халкының төп шөгыле игенчелек. Бу тармакка караучы 73933 крәстиян хуҗалыгы (1928) һәм 62 а.х. кооперативы (1925) теркәлгән. 1928 дә сөрү җирләре мәйданы 500 мең *га* чамасы була, ш.и. арыш 164351 *га*, солы 96332 *га*, карабодай 19260 *га*, бодай 14939 *га*, бәрәңге 10026 *га*, техник куль-

Арча әдәбият һәм сәнгать музее. Экспозициядән фрагментлар: 1. Г. Тукайга багышланган почмак; 2–3. Г.Ахунов һәм М.Мәһдиевнең шәхси әйберләре.










туралар 4128 *га* һ.б. 516308 баш терлек, ш.и. 351669 сарык, 87689 мөгезле эре терлек, 57670 ат, 12104 дуңгыз, 7176 кәҗә була. А.к.нда барлыгы 404 мәктәп эшли, шуларның 393 башлангыч (1 нче баскыч) мәктәп (1927). 1930 да ТАССРны районлаштыру барышында А.к. биләмәсе Арча, Дөбъяз, Питрәч, Тукай һәм Түнтәр р-ннарына бүленә.

*Әд.:* Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике. К., 1928–29; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928–29. Т. 3, 9; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.

**АРЧА́ КЫРЫ́**, Казан шәһәренең элекке төньяк-көнчыгыш чигендә урнашкан, тирән чокыр-ярлар б-н кискәләнгән һәм сирәк урман үскән җир (хәзерге Ирек мәйданыннан алып Кызыл Позиция урамына кадәр мәйданны биләгән). Атамасы *Арча даругасы* юнәлешенә нисбәтле. 15 йөз ахырыннан анда Колмәмәт һәм Әмәт авыллары булуы мәгълүм. Казан ханлыгы дәверендә үк А.к. халыкның ял-бәйрәм итү урыны саналган. Анда ш.у. җәйге халыкара ярминкәләр оештырылган. Берничә мәртәбә А.к. Казан ханлыгына һөҗүм итүче Мәскәү көчләре б-н зур сугыш мәйданына әверелә. Соңрак А.к. аша почта юлы уза. 17 йөздән А.к.нда дворяннарның утар-дачалары төзелә башлый. 18–19 йөзләрдә А.к. Казан гарнизоны гаскәриләренең әзерлеген тикшерү һәм шәһәр халкының бәйрәм итү урынына әверелә. Е.Пугачёв гаскәре дә Казанга А.к.ннан һөҗүм итә. 19 йөз башыннан шәһәр чикләренә керә. А.к.ында Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты, хәрби госпиталь, руханилар академиясе һ.б. биналар төзелә. Ш.у.к.«*Немец Швейцариясе*», «*Рус Швейцариясе*».

*Әд.:* Р ы б у ш к и н М. Краткая история города Казани: В 2 ч. К., 1848; З а р и н с к и й П. Очерки древней Казани. К., 1877; П и н е г и н М.Н. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; П о к р о в с к и й И.М. Окраины города Казани в XVI–XVIII веках. К., 1905.

*И.Л.Измайлов, Г.А.Милашевский.*

**АРЧА́ МИЛЛИ́ АЯ́К КИЕМЕ́ ҖИТЕШТЕРҮ́ БЕРЛӘШМӘСЕ́**, к. «*Милли аяк киеме*».

**АРЧА́ ӨЯЗЕ**, 1781–96 елларда Казан наместниклыгында административ-территориаль бүленеш берәмлеге. Биләмәсенә Казансу (кушылдыклары Аты, Бирәзә, Кырлай, Каракөек, Кесмәс, Красна, Сола һ.б.), Ашыт (кушылдыклары Симет, Өшкәтә, Бирәзә һ.б.), Мишә (кушылдыклары Кече Мишә һ.б.), Нократ (кушылдыклары Бүрәй, Шушма, Бирәзә) елгалары кергән. Көнбатышта Цивиль, көньякта Казан, көнчыгышта Мамадыш өязләре, төньякта Вятка губернасының Уржум өязе җирләре б-н чикләнә. Үзәге — Арча каласы. Оешканда аңа Казан өязеннән 181, Царёвосанчурскидан 16, Малмыж өязеннән 31 — барлыгы 232 торак пункт беркетелә. Арча, Кармыш, Мәмсә, Чыпчык һ.б. волостьларга бүленә. Халкы, башлыча, татарлардан торган, ш.у. мари, удмурт, руслар (16 йөздән соң) да яшәгән. Алар, нигездә, дәүләт (ясаклы), казна, патша сарае һәм алпавыт крәстияннәре катлауларына кергәннәр. Халкы игенчелек, терлекчелек һәм төрле кәсепчелек б-н көн күргән. А.ө. гражданнар эшләре буенча Мамадыш округына, дини эшләр буенча руханиларның Чистай идарәсенә караган. 1796 елда бетерелә, биләмәсе Казан губернасы Казан өязенә беркетелә.

*Әд.:* Городские поселения в Российской империи. СПб., 1861. Т. 1–2; Опись городских поселений Казанской губернии. К., 1885; Очерки по родиноведению. Казанская губерния. К., 1912.

*Д.Г.Мостафина.*

**АРЧА́ ПЕДАГО́ГИЯ КӨЛЛИЯТЕ́**, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының махсус урта уку йорты. 1926 елда Арча 9 еллык мәктәбе җирлегендә оештырыла, шунда башлап пед. сыйныфлар ачыла. 1930 да мәктәп Арча агропедтехникумы итеп үзгәртелә. Шул ук елда техникумга ТАССРның 10 еллыгы исеме бирелә. 1937 дә башлангыч сыйныф укытучылары әзерләүче пед. уч-щесе итеп үзгәртелә. 1983 елдан Арча пед. уч-щесе, 1992 дән хәзерге исемдә. 2000 елга көллияттә 10 меңнән артык белгеч әзерләнә, алар арасында Г.А.Ахунов, М.С.Мәһдиев, С.Ф.Шакир, Ф.М.Миңнуллин, И.К.Хәйруллин һ.б. бар. Монда күп еллар татар теленең танылган әлифбалары һәм методик кулланмалар авторлары Р.Г.Вәлитова, С.Г.Вагыйзов укыта. 2005 тә А.п.к.ндә 139 укытучы эшли. Белгечлекләр: башлангыч сыйныфлар укытучысы һәм урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә балаларның ялын оештыручы; татар теле һәм әдәбияты укытучысы һәм төп гомуми белем бирү (тулы булмаган урта) мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы; милли төп гомуми (тулы булмаган урта) мәктәптә җыр һәм музыка укытучысы. Көллиятне тәмамлаучыларга өстәмә белгечлек бирелә: балалар коллективында оештыру эшләре җитәкчесе; төп гомуми (тулы булмаган урта) мәктәптә татар теле һәм әдәбияты, чит телләр (немец һәм инглиз) укытучысы; хезмәт күрсәтү дәресләре укытучысы һ.б. 1480 нән артык студент укый (2005).



Арча педагогия көллияте.

**АРЧА́ РАЙОНЫ́**, ТРның төньягында урнашкан, Мари Респ-касы б-н чиктәш. Казан икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1843,7 *км*². 1 шәһәр һәм 29 авыл җирлеген, 126 торак пунктны берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Арча посёлогы. Халкы — 2006 елда 50,9 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 92,2%, руслар — 6,6%). Шәһәр халкы — 17,4, авылларда 33,5 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 28 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Казан өязендә, 1920–30 елларда ТАССРның Арча кантонында. Оешкан вакытында А.р.на 63 авыл советы, 64136 кеше (татарлар — 48799, руслар — 15312, башка халыклар — 25) яшәгән 113 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1087 *км*², халкы — 54,3 мең кеше, 34 авыл советы, 112 торак пункт була. 1944 нең 19 февралендә А.р.ның бер өлеше яңа оештырылган *Чүриле районына* бирелә (1956 ның 14 маенда кире кайтарыла). 1960 та район 1095,5 *км*² җир били, составында посёлок советы, 16 авыл советы, 111 торак пункт исәпләнә. ТАССР да адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә А.р.на




Балтач, Тукай р-ннары һәм Биектау р-ның бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 3681 *км*², халкы — 120,2 мең кеше, 54 авыл советы, 296 торак пункт була. ТАССР да адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, 1965 нең 12 гыйнварыннан район терр-ясе 2527 *км*² га кадәр кими, халкы — 87,2 мең кеше, 38 авыл советы, 208 торак пункт кала. 1990 ның 25 октябреннән А.р.ннан Әтнә р-ны аерылып чыга. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль р-н дип үзгәртелә. Районның рельефы — калкулыклы тигезлек (биеклеге 170–266 *м*), елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән. Казансу елгасы (кушылдыклары Аты, Бирәзә, Ия, Кесмәс), Ашыт, Шушма елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл соры урман, кәсле көлсу һәм көрәнсу соры туфраклы. Терр-ясенең 11,7% урманнар б-н капланган. Балчык, бут ташы, бурташ, ком, торф ятмалары бар. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Казансу һәм Шушма елгалары башлангычы, «*Утыртылма урман*», *Курса соры челән колониясе*, *Яңасала сәзәклеге*, *Сорнар аучылык тыюлыгы* табигать истәлекләре. Район терр-ясендә Алтын Урда чорына караган 50 дән артык археологик истәлекләр табыла. А.р. — нигездә, а.х. р-ны. Мөгезле эре терлек, сарык үрчетү нык үскән. 2005 тә а.х. җирләре 147,9 мең *га* били, ш.и. 127 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак игелә, бәрәңге үстерелә. 2006 да А.р.нда 23 а.х. пр-тиесе, балык үрчетү хуҗалыгы исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре — район үзәгендә һәм Яңа Кенәр авылында (агач эшкәртү һәм яшелчә киптерү з-длары) урнашкан. Урман хуҗалыгы эшли. А.р. җиреннән Казан–Екатеринбург тимер юлы, Казан–Пермь, Олы Әтнә–Арча, Арча–Яңа Кенәр автомобиль юллары уза. Районда 106 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 7700 укучы укый), ш.и. 64 башлангыч, 11 тулы булмаган урта, 31 урта мәктәп; педагогия, социаль-хокук көллиятләре, һөнәр лицее, һөнәр уч-щесе, балалар сәнгать мәктәбе, 58 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 89 клуб, 59 китапханә, 287 урынлы 3 хастаханә, участок хастаханәсе (Яңа Кенәр а.), дәвалау амбулаториясе (Шушмабаш а.), 58 фельдшер-акушерлык пункты эшли. *Габдулла Тукай музей комплексы* (Яңа Кырлай а.), *Тукаевлар музей-йорты* (Кушлавыч а.), *Арча әдәбият һәм сәнгать музее* (Арча штп), «*Әлифба*» (Арча штп), татар мәгърифәтчесе Шәмсетдин *Күлтәси* (Күлтәс а.), ТРның халык язучысы Мөхәммәт *Мәһдиев* (Гөберчәк а.) музейлары бар. Татарча «Арча хәбәрләре», русча «Арский вестник» г-талары нәшер ителә.

*Әд.:* Ахунов Г.А. Без бит Арча яклары: Хикәяләр, очерклар, мәкаләләр. К., 1979; Арча төбәге тарихы — История Арского края. К., 1996.

**АРЧА́ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Арча, Әтнә һәм Балтач р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда 25500 *га* мәйданда оештырыла; түбәндәге урманчылыкларны үз эченә ала: Арча (1993 тән Тукай), Сорнар һәм Ленин урманчылыгы (1940 та Шәһәр яны урман хуҗалыгына тапшырыла). 1940 та А.у.х. составына керүче Балтач урманчылыгы оештырыла. 2006 елның башына А.у.х.ның гомуми мәйданы 30802 *га*, ш.и. урман мәйданы 28581 *га*. Тукай урманчылыгының гомуми мәйданы — 7838 *га*, Сорнар урманчылыгыныкы — 6895 *га*, Балтач урманчылыгыныкы — 6374 *га*, Кили урманчылыгыныкы — 4131 *га*, Кенәр урманчылыгыныкы — 5564 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Арча р-нының Үрнәк посёлогында. Эшләүчеләр саны 268 кеше.

1 нче төркем урманнар 10195 *га* мәйданны били, ш.и. табигать истәлекләре — 1291 *га*, сусаклагыч урманнар — 1579 *га*, эрозиягә каршы — 1496 *га*, саклаучы урманнар — 5644 *га*, юл буйларында саклаучы полосалар — 185 *га*. 2 нче төркем, ягъни файдаланыла торган урманнар 20607 *га* мәйданны алып тора. Урман культуралары мәйданы 17740 *га*. Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 35,4%, урта яшьтәгеләре — 36,2%, өлгереп килүчеләре — 14,5%, өлгергәннәре һәм картайганнары 13,9% тәшкил итә. Нарат урманнары 9432 *га* мәйданны биләп тора, аны яшь һәм урта яшьтәге, күбесенчә кулдан утыртылган агачлар тәшкил итә. Агач запасы 2213,0 мең *м*³. Алар барлык рельеф элементларында һәм төрле яшәү шартларында (дымлы борлардан башлап коры һәм дымлы суборларга кадәр) үсә. Бонитет классы 1 һәм 1а. Катнаш һәм мүкле наратлыклар аеруча киң таралган. Чыршы урманнары уйсулык һәм субүләрләрнең түбәнге өлешләрендә, нигездә Сорнар урманчылыгында таралган. Чыршы урманнарының гомуми мәйданы 6646 *га*. Агач запасы 871,3 мең *м*³. Чыршы күп очракта себер ак чыршысы б-н бергә үсә, каен катнаш караңгы ылыслы ак чыршы — чыршы ценозлары хасил итә. 1 нче ярустагы агачларның яше 80–90 ел. Бонитет классы 1. Туфрак өстендә чыршы иярченнәре — кымызлык, талакдар, ике яфраклы май чәчәге, төкле ялтыракбаш һ.б. күпчелекне алып тора. Мүк катламы тоташ, яшел мүк б-н капланган. Аерым кварталларда төрле яшьтәге утыртылган чыршы очрый, алар урыны б-н тоташ урман хасил итәләр. А.у.х. юкәлекләренә яхшы дренажлы субүләрләрдә һәм аларның сөзәклекләрендә үсүче юкә һәм караңгы ылыслы утыртмалар хас. Мәйданы 3832 *га*. Агач запасы 846,7 мең *м*³. Күп таралган типлары: каен, усак, ак чыршы катнаш үләнле юкәлек һәм башлыча төптән таралган чыршы — ак чыршылы юкәлек. 1 нче ярус агачларының биеклеге 26 *м* га кадәр җитә, яше — 80–90 ел. Бонитет классы 2. Каенлыклар һәм усаклыклар төп урманнар урынында барлыкка киләләр, алар



Арча урман хуҗалыгы.
Сорнар урманчылыгының базис-питомнигы.

чагыштырмача чиста утыртмалар буларак һәм караңгы ылыслы токымнар б-н бергә үсәләр. Каенлыкларның мәйданы 3704 *га*, усаклыклар — 2282 *га*. Агач запасы — тәңгәл рәвештә — 514,5 мең *м*³ һәм 325,1 мең *м*³. Бонитет классы 1 һәм 2. Күрәнчәле, тубылгылы каенлыклар, күрәнчәле һәм сырмавыклы усаклыклар киң таралган. Каен һәм усакның яше 65 кә, кәүсә биеклеге 24 *м* га кадәр җитә. Имәнлекләр аз таралган, Тукай урманчылыгы терр-ясенең аерым өлешләрендә генә очрыйлар, нигездә тәбәнәкләр, яшь үсентеләр. Гомуми мәйданы 1159 *га*. Запасы 154,7 мең *м*³. А.у.х.ның юкә, имән һәм катнаш урманнары умартачылык зоналарына керә. Урман культураларын җитештерү үрнәге булган, генетик-селекция сыйфаты ягыннан югары җитештерүчәнлеккә ия чыршы һәм нарат урманнары, ш.у. чыршы — ак чыршы урманнарының кыйммәтле урман массивлары, аеруча саклана торган табигать терр-яләре буларак билгеләнә: «*Казансу башы*» (1972) һәм «*Утыртылма урман*» (1987).

Төп кулланыш өчен еллык урман кисү күләме 23,7 мең *м*³ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан 1800 *га* мәйданда чистарту эшләре башкарыла, шуның б-н бергә 35 мең *м*³ дан күбрәк агач әзерләнә. Һәр ел саен 300–350 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла. Ел саен а.х. җирләренең 200–250 *га* мәйданында эрозиягә каршы агачлар утыртыла. А.у.х.да террасалау методы б-н текә тау битләрендә урман утырту технологиясе киң кулланыла. Мондый утыртмалар барлыгы 720 *га* тәшкил итә, ш.и. Балтач урманчылыгында 500 *га*. Урман хуҗалыгының даими эшләүче питомникларында ел саен 15 төрле агач-куак токымнарының 4,5 млн. үсентесе һәм чәчкене үстерелә. Сорнар һәм Тукай урманчылыгының базис-питомнигы «Югары культуралы урман питомнигы» исемен йөртә. А.у.х.нда 25 төрдәге халык хуҗалыгы товарлары (агач-такта материаллары,

паркет, койма такталары, буралар, тәрәзә һәм ишек блоклары, йорт кирәк-яраклары һ.б.) җитештерә. Урман хуҗалыгы үсешенә һәм урман хуҗалыгын алып баруны камилләштерүгә зур өлеш кертүчеләр: РФнең атказ. урманчылары Г.Ж.Җамалиев, А.Ә.Нәзиров һәм ТРның атказ. урманчылары Б.М.Абрамов, Ш.М.Хәйруллин. Урманчы И.Г.Яруллин Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

*В.И.Гуськов.*

**АРЧА́ ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, к. *Арча*.

**АРЧА́ ЯГЫ́**, Казан ханлыгы биләмәсендәге дүрт өлкәнең берсе (15 йөз — 16 йөз урталары). Казаннан төньяк һәм төньяк-көнчыгыш тарафта, Казансу б-н Нократ елгалары аралыгында урнашкан була. Арча шәһәрчегенә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән терр.-географик төшенчә.

«А.я.» төшенчәсен рус елъязмачылары һәм администрациясе Казан ханлыгы җирләрен өязләргә бүлгән вакытка кадәр кулланалар. Соңрак А.я., өлешчә Алат һәм Галич (Гәреч) даругалары б-н бергә Казан өязенә керә. Төп халкы: татарлар, удмуртлар, марилар һәм 16 йөз уртасыннан соң руслар. Халкы игенчелек, терлекчелек һәм төрле һөнәрчелек (тире иләү, күннән, алтын-көмештән, агачтан әйберләр ясау, чуен кою, тимердән һ.б. металлдан сугыш һәм хезмәт кораллары ясау) б-н шөгыльләнгән. Казан ханлыгы дәверендә А.я.нда ханнар һәм бәк-морзаларның җир биләмәләре була. Ханлык Рус дәүләте тарафыннан яулангач, 16 йөз уртасыннан алар дәүләт һәм патша сарае җирләренә әверелә, йомышлы кешеләргә һәм монастырьларга бүленеп бирелә. 16 йөзнең 2 нче яртысында А.я. халкы рус колонизациясенә һәм чукындыру сәясәтенә каршы көрәш үзәкләренең берсенә әверелә. (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары*).

Чыг.: Полное собрание русских летописей. СПб., 1903. Т. 19; СПб., 1914. Т. 20, ч. 2; М.–Л., 1959. Т. 26; М., 1965. Т. 13; История Татарии в документах и материалах. М., 1937; Щ е р б а т о в М.М. История Российская от древнейших времён. СПб., 1976. Кн. 5, ч. 1; Е р м о л а е в И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. Управление Казанским краем. К., 1982.

**АРЧА́ ЯГЫ́ КРӘСТИЯННӘРӘ́ КУЗГАЛЫШЫ́**, Совет хакимиятенең *продразвёрстка* тәртибен кертү сәясәтенә каршы 1918 елның 25 октябрендә Казан губернасы Казан, Лаеш, Мамадыш өязләре крәстияннәренең баш күтәрүе. Крәстияннәр, бөтенләй икмәксез һәм мал-туарсыз калабыз, дип шикләнәләр. 25–26 октябрьдә Казан өязе Олы Мәңгәр волосте крәстияннәре халыктан азык-төлек җыеп йөрүче отрядны коралсызландыралар, азык-төлек туплау пунктларын талыйлар. 10 ноябрьдә аларга Арча төбәгендәге 20 волость крәстияннәре кушыла, алар Арчаны үз кулларына алалар. 12 ноябрьдә Коркачык авылы крәстияннәре дә баш күтәрә. Аларны ЧК гаскәрләре куып тарата, 1 кеше үтерелә. Балтач волосте крәстияннәре волость комиссарын һәм аның гаиләэ әгъзаларын үтерәләр. Бер туп һәм 300 гаскәридән торган отряд 14 ноябрьдә Балтачны камап ала. Бу бәрелеш вакытында баш күтәрүчеләрдән 31 кеше үтерелә, 11 кеше яралана; волость комиссарын юк итүдә гаепләнүче берничә кеше кулга алына һәм атып үтерелә. Балтачның хәлле кешеләренә 100 мең сум акчалата, 2000 пот солы һәм 2500 пот арыш исәбеннән җәза салымы (контрибуция) түләтү карары чыгарыла. Балтач волостена билгеләнгән җәза салымы акчалата 300 мең сум, 10000 пот солы һәм 15000 пот арыш күләмендә була. Кузгалыш 1918 елның 15 ноябрендә тәмам бастырыла.

*Әд.:* Казанская губернская Чрезвычайная Комиссия (1917–1922): Сб. док. и материалов. К., 1989.

*А.Л.Литвин.*


**АРЧАНЧАЛА́Р** (Ericaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Мәңге яшел биек булмаган куаклар, куакчыклар, лианалар, сирәк кенә кечерәк агачлар. 80 нән артык ыругы һәм 2000 төре Җир шарының субтропик, уртача һәм салкын өлкәләрендә таралган. ТР терр-ясендә 6 ыругы һәм 8 төре очрый. Яфраклары чиратлашкан, кара-каршы яисә боҗрасыман урнашкан, төпчек яфраклары юк. Кечкенә куаклар. Чәчәкләре чатырсыман яисә себеркәч чәчәк төркемендә, икешәр чәчәк тирәлекле. Касәсе 4–5 аерым яисә кушылып үскән касә яфраклы. Җимеше күп орлыклы тартмачык, каты төшле җимеш яисә җиләк. Орлыклары вак. Күбрәк тамырчадан, кайвакыт орлыктан үрчи. Начар шартларда, ачы туфракларда үсә ала. А. тамырларында еш кына микоризалар була. Аю җиләге, саз сазанагы, мүк җиләге һ.б. — дару үләннәре; гади арчан, саз сазанагы, нарат җиләге — баллы үсемлекләр. Аю җиләге, күк җиләк, кара җиләкнең җимешләре урмандагы кыргый җәнлекләр өчен азык. Күпьяфраклы акчыл, саз сазанагы, гади арчан — декоратив үсемлекләр. Мүк җиләге, күк җиләк, нарат җиләге һ.б. азык-төлек сәнәгатендә кулланыла. 5 төре (күпьяфраклы акчыл, күк җиләк, гади аю җиләге һ.б.) ТРның Кызыл китабына кертелгән.


*Ә.Ф.Йосыпова.*

**АРШ** Михаил Маркович (22.10.1909, Воронеж өлкәсенең Борисоглебск ш. — 1.5.1996, Казан), химик-технолог, техн. фән. д-ры (1969), проф. (1966), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1969). 1939 елда Ф.Э.Дзержинский исем. Артиллерия академиясен тәмамлый (Мәскәү). 1931–1959 да Сов. Армиясендә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1939 дан Ф.Э.Дзержинский исем. Артиллерия академиясендә (бүлек башлыгы, укытучы, каф. башлыгы урынбасары). 1949 дан Казан хим.-технол. ин-тында, гетероген системалар химиясе һәм технологиясе каф. мөдире (1959 дан), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1985–91). Хезмәтләре дары, каты ягулык, пиротехник составларга; конденсатланган энергетик системаларның ялкынлануы һәм януына карый. Реактив һава двигательләре өчен пиротехник каты ягулык эшләү һәм аны җитештерүне җайга салуга, боз явуга каршы ракеталар өчен, ш.у. боз ясаучы каты ягулыклар һәм ясалма җылылык цельләре өчен җылылык нурланышлы пиротехник составлар эшләүгә зур өлеш кертә. 4 монография авторы. Техн. химия өлкәсендә 130 авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989). Кызыл Байрак ордены, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АРШИ́НОВ** Виктор Петрович (22.10.1945, Баку), график, нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Мәскәү өлкә сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1970), Казанда эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980). А.ның иҗат эшчәнлеге китап һәм журнал графикасы, станлы графика, плакат, рәсем сәнгате, скульптура, театр декорациясе һәм монументаль бизәлеш сәнгате өлкәләрен колачлый. Төсле һәм график портретларда, М.Җәлил («Моабит дәфтәрләре»ннән сериясе, 1973–76), Данте («Яңа тормыш»ка илл., 1970–71), П.Элюар («Элиот мотивлары», 1996–98) һ.б. әсәрләренә ясалган иллюстрацияләрдә һәм композицияләрдә иҗат теленең катлаулылыгы, символик-аллегорик образларга мөрәҗәгать итүе күзәтелә. А. графикасында Г.Тукай шигърияте темалары аерым урын алып тора. («Су анасы», 1975; «Шүрәле», 1975; «Тукай шигырьләре мотивлары» сериясе, 1976). А.ның нәкышь әсәрләренә шартлы бизәклелек, төсләр бирелешенең байлыгы һәм силуэтның рәсем үзенчәлеге хас («Реквием, 1924», 1973; «Нина Локтионова», 1979; «Зур натюрморт», 1979; «Югославия буйлап» сериясе, 1981). Бөтенсоюз («Ки-

В.П. А р ш и н о в. 1. «Моабит дәфтәрләреннән». Кәгазь, катнаш ысул. 1972-76;
2. «Алтынчәч». Кәгазь, гуашь. 1978; 3. «Үткәннәр хатирәсе». Триптих.
Уңъяк өлеш. Картон, тушь, гуашь. 1985. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.







но һәм театр рәссамнәре», Мәскәү, 1978–79), бөтенроссия («Совет Россиясе», Мәскәү, 1975; 1980) күргәзмәләрендә, төбәкара («Зур Идел», 1974 тән) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда һәм Татарстанның башка шәһәрләрендә (1977, 1978, 1979, 1981, 1985, 1996, 2000), Мәскәүдә (1980) һәм Йошкар-Олада (1982) күрсәтелә. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Удмурт һәм Каракалпак респ-калары музейларында, ТР Милли музеенда, Кораллы көчләр музеенда (Мәскәү), Баку, Әстерхан һ.б. шәһәрләрнең картиналар галереяларында саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; шул ук. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**АРШИ́НОВА** Рауза Петровна (14.1.1945, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1967), шунда ук Фәнни-тикшеренү химия ин-тында эшли, 1988–94 елларда элементорганик кушылмалар стереохимиясе һәм структурасы бүлеге мөдире. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясе, конформацион анализ, фәзаи һәм электрон структура, фосфорорганик кушылмаларның стереодинамик үзлекләрен өйрәнү өчен физ. методлар куллануга карый. 4–8 буынлы гетероциклик системалар синтезы һәм фәзаи төзелеше, аларның ТМР һәм инфракызыл спектраль характеристикалары, стереоэлектрон факторлар (бу системаларның конформацион эшчәнлеген билгеләүче), цикллар конформациясен микъдари тасвирлау һәм аларның энергетикасын билгеләү буенча эшләр башкара. Уртача гетероциклларның стереодинамикасын, аларның металлы комплексларының флуктуация үзлекләрен тикшерә, конформацион хәрәкәтчән системаларны төзү юлларын таба. 1994 тән АКШта яши.

Хезм.: Современные представления о конформациях восьмичленных циклических систем с планарными фрагментами // Успехи химии. 1988. Т. 57; Структурные проявления гиперконъюгационных взаимодействий в соединениях элементов третьего периода // Металлоорганическая химия. 1990. Т. 3; Phosphorus compounds with eight-membered heterocyclic system: synthesis and three-dimensional structure // Phosphorus, Sulfur and Silicon. 1992. V.68, № 12.

**АРЫ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Иләт елгасыннан 4 *км* читтәрәк. 2002 елда 333 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1710 нан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тимерчелек, җил тегермәне, мануфактура һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1583 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — ир заты; 1859 да — 683, 1897 дә — 1115, 1908 дә — 1233, 1920 дә — 1226, 1926 да — 1220, 1938 дә — 1344, 1949 да — 975, 1958 дә — 760, 1970 тә — 655, 1979 да — 527, 1989 да — 361 кеше.


**АРЫ́К БУГА́** (? — 1265/66), Монгол империясе каганы (1259–60). Мөнке каганның бертуганы. Болгар шәһәрендә А.Б. исеменнән көмеш акчалар сугылуы мәгълүм.

*Әд.:* Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система 12–15 вв. М., 1983; Түркістан, энциклопедия. Алматы, 2000.

**АРЫ́ КАЗЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Кады елгасының (Иж елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,2 *км*, ТР чикләрендә — 6,8 *км*. Бассейнының мәйданы 25 *км*$^2$ (ТР чикләрендә — 9 *км*$^2$). Сарапул калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әгерже р-ның Гали авылыннан 1,6 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 100 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 52%. А.-К.ның 6 *км* чамасы озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,64 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*$^2$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, җәен 400–500 *мг/л*.

**АРЫСЛА́Н** (Кумыл) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 11 *км* төньяктарак. 2002 елда 214 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Мамадыш-Арыслан исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да архит-ра истәлеге — Никольский чиркәве (1901 дә төзелә), чиркәү — приход мәктәбе (1885 тә ачыла), иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, май язу йорты, 3 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2053 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасы Зөя өязенең Әҗил волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 219 ир заты; 1859 да — 865, 1897 дә — 1303, 1908 дә — 1656, 1920 дә — 1553, 1926 да — 1456, 1938 дә — 1170, 1949 да — 562, 1958 дә — 394, 1970 тә — 366, 1979 да — 305, 1989 да — 191 кеше.

**АРЫСЛА́Н БӨҖӘКЛӘ́Р** (Myrmeleontidae), челтәрканатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Зур гәүдәлеләр, тышкы яктан энә каракларын хәтерләтәләр. 2 меңгә якын төре билгеле, Россиядә — 10. Татарстанда арыслан бөҗәк (Myermeleon formicarius) гадәти төр санала. Гәүдә озынлыгы 18–30 *мм*, мыеклары чукмарсыман, башыннан һәм күкрәгеннән кыскарак; куе соры төстә; корсагы озын, нәзек; канатлары сузынкы, төбенә таба тарайган, куе җепселле, җәелгәндә 56–70 *мм*, алдагы канатлары коңгырт, башы һәм күкрәкләре саргылт тимгелле; аяклары саргылт-көрән төстә. Җәенке, кыска личинкаларының авыз өлеше озын, алга чыгып тора; җир өстендә яки комда корбаннарын аулау өчен конуссыман чокыр казыйлар. Җир өстендәге төрле бөҗәкләр (аерым алганда, кырмыскалар) бүрәнкә сөзәклегенә эләгеп, ком бөртеге ташкыны б-н бергә аска тәгәри һәм аларның җиңел табышына әверелә. Арыслан



Арыслан бөҗәк.

бөҗәк ачык, яхшы җылына торган урыннарда, нарат урманы буйларында, урман юллары, елга ярлары буенда ком ишелмәләрендә яши. Кич һәм төнлә оча. Республикада һәркайда очрый, хәзер сирәгәя, саны кими бара. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**АРЫСЛА́Н ТЫРНАГЫ́** (Lycopus), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 нан артык төре билгеле, Төньяк ярымшарда киң таралган. ТРда 2 төре — биек А.т. (L. exaltatus) һәм Европа А.т. (L. europaeus) барлык р-ннарда да очрый. Сулык ярларында, сазлыкларда үсә. Озынлыгы 30–120 *см* га җитә. Сабаклары дүрт кырлы, ботаклы. Яфраклары каршыдаш, озынча ланцетсыман, вак кырлы, өстәгеләре — утырма, түбәндәгеләре — саплы. Чәчәкләре ак, яфрак куентыгында тирән урнашканнар. Июнь — сентябрь айларында чәчәк ата. Җимеше — күп чикләвек. Җир өстендәге өлешләрендә алкалоидлар, сапониннар, эфир мае, дуплау матдәләре, органик к-талар бар. Төнәтмәсе халык медицинасында кан туктату һәм тынычландыру өчен файдалыныла. Баллы үсемлек. Европа А.т. — сарыклар һәм кәҗәләр өчен азык.

**АРЫСЛАНЧА́ ЧЕБЕННӘ́Р** (Stratiomyidae), чебеннәр семьялыгы. 1,5 меңләп төре билгеле, аларның күбесе тропикларда, Россиядә 200 ләп төре яши. Гәүдәсенең озынлыгы 5–15 *мм*, канатлары ачылмаганда корсак турысында берсе икенчесе өстенә куела. Төсе ачык, еш кына чага торган умарта кортлары һәм шөпшәләр төсен хәтерләтә (саклагыч төс — мимикрия). Чебеннәр чәчәкләрдә, су янындагы үсемлекләр арасында, сирәгрәк агач кәүсәләрендә һәм ботакларында тереклек итә. Личинкалары пычрак сулыкларда, туфракта, тирестә, кайры асларында, корыган агачта, кырмыска ояларында үсә; сапрофитлар (органик калдыклар б-н туеналар) яки ерткычлар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: гади А.ч. (Stratiomyia chamaeleon Dg.) — гәүдәсенең озынлыгы 13–15 *мм*, кара, корсак асты сары төстә, бөҗра читләреннән кара бәйләвечле, һәм бакыр А.ч. (Geosargus cuprarius L.) — гәүдәсенең озынлыгы 10–12 *мм*, түше яшел, металлсыман ялтырый, корсагы бронза, зәңгәр яки шәмәхә төстә.

**АРЫ́Ш** (Secale), кыяклылар семьялыгыннан бер һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; бөртекле культура. Язгы һәм көзге арышка бүленә. Тамыр системасы чуклы, 25 *см* тирәнлектә үсеш ала, аерым тамырлары 1–1,5 *м* тирәнлеккә кадәр җитә. Сабагы куыш (салам), 3–6 төенле. Яфрагы — озын, тар яфраксыман пластина. Чәчкәсе — катлаулы башак. Читтән серкәләнә. Җимеше — шома, тар, тирән буразналы бөртек. А. кышка чыдам үсемлек. Көздән тамыр системасын яхшы үстереп, туфрактан дым һәм минераль матдәләр ала; шуңа күрә корылыкны җиңел кичерә. А. башка культуралар өчен яхшы элгәр булып исәпләнә, басуларны чүп үләннәреннән чистартуга булыша, туфракны органик матдәләр б-н шактый баета. ТРда ашлык җитештерүне тотрыклыландыручы запас культура булып санала. А. — кыйммәтле ашамлык һәм терлек азыгы культурасы. Ул безнең илдә 1000 елдан артык үстерелә һәм бодайдан кала икенче урында тора. Ипи пешерү өчен бөртекләрне он итеп тарталар. Арыш ипие балалар рационы һәм диетик туклану өчен әһәмиятле компонент булып тора. Бөртектән салат алына, ш.у. катнаш азык җитештерүдә бөртек чималы компоненты буларак кулланыла. 1 *кг* бөртектә 1,18 азык берәмлеге бар. А.ның яшел массасы терлек һәм кошларны өстәмә тукландыру, сенаж һәм иртә салына торган силос, туклыклылыгы югары булган үлән оны һәм гранулалар әзерләүдә файдаланыла. А. крахмал-патока сәнәгатендә, спирт җитештерүдә кулланыла. Бөртекләрдән чиста аксым һәм крахмал, глюкоза-галактозалы сироп алалар. А. культурасының чәчүлекләре тигез урнашмаган, бу ТР а.х. зоналарының туфрак һәм климат шартлары бертөрле булмавыннан килеп чыга. Көзге арыш игү буенча төп зона булып Кама алды зонасы санала, ТР чәчүлекләренең якынча 40% шунда урнашкан һәм анда арышның яртысы диярлек җитештерелә. Кама арты һәм Идел буе зоналарында А. азрак игелә, бу туфракның югары уңдырышлылыгы һәм бодай чәчүлекләренең яхшы урнашуы б-н бәйле. Соңгы 5 елда (2001–2005) чәчүлекләрнең мәйданы уртача 360 мең *га* тәшкил итә. А. уңышы 2001–2005 еллар эчендә гектарыннан 24,8 *ц* дан (2004) 42,0 *ц* га кадәр (2001) үзгәреп тора, гектарыннан уртача 35,2 *ц* тәшкил итә. ТРда кабул ителгән сортлар: «Безенчукская-87» (1993), «Татарская-1» (1994), «Саратовская-6» (1994), «Эстафета Татарстана» (1998), «Радень» (2001), «Антарес» (2002). Селекция белгечләре Х.Х.Байчурова б-н Е.Н.Борисова тарафыннан көзге арышның «Казанская» (1937) сорты чыгарыла. Бу сорт 1975 кә кадәр СССРның 8 өлкәсендә һәм республикасында районлаштырыла. Корткычлары — көзге чебен, швед һәм гессен чебеннәре, зыянлы ташбака; авырулары — арыш анасы, кисәү гөмбәсе, кар күгәреге, склеротиниоз, тамыр череге.



*Әд.:* Культурная флора СССР. // Л., 1989. Т. 2, ч. 1; Пономарева М.Л., Пономарёв С.Н., Салихов А.С., Шакиров Р.С. Озимая рожь в Республике Татарстан. К., 2001; Сельское хозяйство Республики Татарстан: Сб. статей. К., 2004.

*М.Л.Пономарёва, С.Н.Пономарёв.*


**АРЫ́Ш АНАСЫ́**, спорынья (Claviceps), арыш анасысыманнар семьялыгыннан сумкалы паразит гөмбәләр ыругы. ТР да бер төре — куе кызыл А.а. (C. purpurea) очрый. Кыяклы үсемлекләрдә, бигрәк тә арыш, тимофеевка, кындыр уты, бодай, арпада һ.б. да паразитлык итә. Зарарланган үсемлекләрнең чәчәк төркемнәрендә төрле формадагы һәм үлчәмдәге мөгезсыман куе шәмәхә төстәге склероцияләр (гөмбәлек) яхшы беленә. Туфракта яки ашлыкта кыш чыгып, язын үрә, аскоспоралары кыяклы үсемлекләрне чәчәк аткан вакытта зарарлый. Кыяклы культураларда үсеп, аларның уңышын киметә. Игенчелек алымнарын яхшырту (орлыкларны җентекләп чистарту, туфракны вакытында һәм югары сыйфатлы итеп эшкәртү) нәтиҗәсендә бу гөмбәнең чәчүлекләргә зыяны шактый кимеде. Хәзерге вакытта арыш өчен куркыныч түгел. А.а.нан күбрәк кыяклы азык культуралары (тимофеевка, кындыр уты) зыян күрә. Орлыкны склероцийлардан чистарту бик авыр, чөнки аларның үлчәмнәре нык үзгәрә. А.а. бөртекләрендә агулы алкалоидлар, ш.у. органик кислоталар, май, пигментлар һ.б. бар. Медицинада кан туктатучы препаратлар ясау өчен файдаланыла.

**АРЫШБА́Ш** (Agropyron), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 ләп төре билгеле, Европада, Азиядә, Төньяк Африкада, ш.у. Австралиядә һәм Яңа Зеландиядә киң таралганнар. ТРда өч төре — кикрикле А. (A. cristatum) һәм кикриксыман А. (A.pectinatum) үстерелә, чүл арышбашы (A. desertorum) көньяк-көнчыгыш р-ннарда очрый, ташлы-далалы сөзәклекләрдә үсә. 20–70 *см* озынлыктагы куакланган кыяклылар. Тамыр системасы калын, чук. Сабагы туры, җиңелчә кытыршы. Яфраклары тыгыз, озынча түгәрәк формада. Чәчәк төркемнәре — кыяк яки йомыркасыман катлаулы башаклар. Башаклары күп чәчәкле, ике рәтле. Җимеше — бөртекчә. Орлыктан үрчиләр. Суыкка, корылыкка чыдам, туфракка талымчан түгел. Көтү йөрүдән зур зыян күрми. Кыйммәтле терлек азыгы. Комлыкларны ныгыта, туфрак структурасын яхшырта. Декоратив максатларда үстерелә.

**АРЫШҺАЗДА́** (Арышкин) авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2002 елда 143 кеше (руслар — 66%, татарлар — 29%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт (А.Н.Толстая, Ю.И.Мейснер, П.П.Толстой, генерал-майор А.Л.Корсаков, Д.А.Корсаков һ.б.) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тәгәрмәчләр ясау, умартачылык һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да земство мәктәбе, 3 тимерчелек, икмәк кибете, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 726,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 81 ир заты; 1859 да — 435, 1897 дә — 632, 1920 дә — 835, 1926 да — 966, 1949 да — 669, 1958 дә — 625, 1970 тә — 335, 1979 да — 202, 1989 да — 174 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**АС** (Mustela erminea), ерткычлар отряды сусарлар семьялыгыннан имезүче хайван. Европада, Азиядә һәм Төньяк Америкада киң таралган. ТРда Казансу, Зөя, Вятка, Ык елгалары үзәнлегендә очрый. Гәүдәсе сузынкы, сыгылучан, озынлыгы 17–32 *см*, койрыгының озынлыгы 6–12 *см*, авырлыгы 200 *г*. Җәен мехы көрән-саргылт төстә, кышын — ак, койрык очы кара яки коңгырт-кара. Агачларга яхшы менә һәм яхшы йөзә. Ояларын өннәрдә, куышларда, агач тамырлары астында ясый. Төнлә актив яшәү рәвеше алып бара. Төп азыгы — тычкансыман кимерүчеләр, кошлар, кәлтәләр. А.лар — моногамнар, елга бер тапкыр үрчиләр. Кушылу вакыты яз яки җәй башында. Балалары (уртача 7–9 бала) киләсе елның язында туа. Кыйммәтле мех бирә торган җәнлек. 1920–30 елларда Татарстанда күп була, ел саен 14 мең данәгә кадәр А. аулана. 1960 елларда табыш 100 дән артмый. Хәзерге вакытта, аз санлы булу сәбәпле, промысел фаунасыннан төшеп кала. ТРның Кызыл китабына кертелгән.




Ас. 1. Җәйге чорда; 2. Кышкы чорда.

**АСАБА́ БАШКОРТЛА́Р**, 16 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз арасында Көньяк Уралның төньяк-көнбатышында яшәгән, җир биләүдә борынгы ыруглык тәртипләре хокукын саклаган халыкка карата Рус дәүләте оешмаларында кулланылган атама. А.б.га керүчеләр, этник яктан караганда, күп компонентлы булган. Рус дәүләтенә буйсынып алдыннан Урал төбәгендә яшәгән иштәк, нугай, татар һәм өлешчә фин-угыр этник төркемнәре дә А.б.га кергәннәр. Рус дәүләтендә башкорт атамасы алганнарга социаль һәм хокукый өстенлекләр бирелгәнлектән, Казан ханлыгы яулаганнан соң, Урал якларында сыену тапкан кешеләр дә (мәс., типтәрләр) А.б. булып язылырга тырышкан. Шул сәбәпле 17–18 йөзләрдә А.б. саны бик нык арта. Ни-

гездә, ул Урта Идел буеннан күчеп килгән ясаклы татарлар һәм аерым очракларда мордва, чуаш, марилар исәбенә арткан. Көньяк Уралның төньяк-көнбатышында А.б. этник төшенчәсе әкренләп өстенлекләргә ия булган аерым катлау атамасына әверелә. 1855 елдан типтәрләрне дә *башкорт-мишәр гаскәренә* ала башлагач һәм ул гаскәриләрне «яңа башкортлар» дип атауга күчкәч, «башкорт» дигән этник кавем төшенчәсе төбәктә тәмам юкка чыга дияргә була. Бу күренеш бигрәк тә хәзерге Татарстан Респ-касының көнчыгыш р-ннарына кергән төбәккә кагыла (элек ул төбәк халкы Вятка губернасының Сарапул һәм Алабуга, Уфа губернасының Минзәлә, Самара губернасының Бөгелмә өязләренә караган). Әлек монда яшәүчеләрнең күпчелеге документларда «башкорт» дип теркәлгән булса да, аларны, 19 йөз — 20 йөз башларыннан гына түгел, элекке чорлардан ук, һичшиксез, татар этносының бер өлеше дип санарга мөмкин.

*Әд.:* Исхаков Д.М. Из этнической истории татар восточных районов Татарской АССР до начала 20 в. // К вопросу этнической истории татарского народа. К., 1985; шул ук. Историческая демография татарского народа (18 – нач. 20 вв.) К., 1993; шул ук. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.). К., 1998; Рахматуллин У.Х. Население Башкирии в XVII–XIX вв. М., 1988;.

*Д.М.Исхаков.*

**әл-АСАДИ́ ТАКИАДДИ́Н ӘБҮБӘКЕ́Р ӘХМӘ́Д ибне ШОҺБА́** (أبو بكر احمد إبن شهبة الأسدي تقي الدين) (1377 — 1446 яки 1448), гарәп тарихчысы. Шөһба шәһәре казые улы. Дәмәшкътә баш казый вазифасын үтәгән. «Ислам тарихыннан белешмәләр» («Сведения из истории ислама») исемле мәшһүр хезмәте — әл-Җәһәбинең мәгълүм тарихи китабының дәвамы булып тора. Хезмәттә 1340–1403 еллар арасындагы вакыйгалар тасвирлана. Анда ш.у. Алтын Урда ханнары Тукта, Үзбәк, Туктамышка караган мәгълүматлар бар.

*Әд.:* Из летописи ибн Шохбы аль-Асади // Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов по истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1.

**АСАНБА́ЕВ** Нәҗип (Николай Васильевич) (7.11.1921, Уфа губ., Бәләбәй өязе Ахман а.), язучы, Башкортстан АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). Татар һәм башкорт телләрендә яза. Уфа финанс-икътисад техникумын (1939) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый (1963, Мәскәү). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1949–59 елларда «Кызыл таң» г-тасында әдәби хезмәткәр, соңрак бүлек мөдире һәм махсус хәбәрче булып эшли. 1959–61 дә Салават шәһәре драма театры, 1963–65 тә Башкорт акад. драма театры директоры. Әсәрләре 1939 елдан басыла. Балалар өчен «Кәрим» (1947), «Вәлимә» (1953) исемле хикәяләр, Башкортстан нефтьчеләренә багышланган «Минем геройым» (1953) дигән очерклар җыентыклары авторы. Драматург буларак киң таныла. 1955 елда «Безгә егеттәр килде» комедиясен яза. Соңрак нефтьчеләр тормышы тасвирланган «Рәйсә» (1958), «Ҡыйыу кешеләр» (1959), «Фәйзи» (1960) драмаларын, ш.у. «Зәйтүнгөл» (1975), «Аҡ сирендәр» (1976) пьесаларын иҗат итә. «Ҡанат йәйгәндә» (1969) драмасында М.Җәлил тормышының башлангыч чоры сурәтләнә. А.ның кискен конфликтка корылган «Кәләш әйттергәндә» (1964), «Күктән төшкән бәхет» (1969), «Һыу юлы» (1972) комедияләре бүген дә актуальлекләрен югалтмый. Революционер, дипломат Кәрим Хәкимов образы сурәтләнгән «Кызыл паша» (1982) драмасы өчен А. 1983 тә Башкортстанның Салават Юлаев исем. Дәүләт бүләгенә лаек була. А.ның пьесалары Казан, Уфа, Сибай, Салават, Әлмәт, Оренбург, Минзәлә театрларында куела. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике тапкыр Кызыл Йолдыз, Халыклар Дуслыгы, Салават Юлаев орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Уфа шәһәрендә яши.

Әсәр.: Красный паша: Пьесы. Уфа, 1987; Һайланма әҫәрҙәр. Өфө, 1991; Сәхнә әҫәрҙәре. Өфө, 1997.

*Әд.:* Абсалямова Г. Решать мирным путём // Театральная жизнь. 1983. № 12; Нурғалин З. Теманы тормош бирә // Ағиҙел. 1984. № 6.

*С.Г.Сафуанов.*

**АСА́НОВА** Нилуфәр Абдулла кызы (27.11.1935, Кырым АССРның Ялта ш. — 16.5.2000, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1981), проф. (1983). Үзбәкстан ун-тын тәмамлый (Ташкент, 1956). 1961 елдан Казан ун-тында, 1987–89, 1993–94 елларда Пекин ун-тында укыта. Жанна д'Арк исем. халыкара үзәк (Франция, Орлеан ш.) эшендә даими катнашып килә. Хезмәтләре хәзерге француз әдәбиятында роман жанры үсеше проблемаларына, романтизм теориясенә һәм әдәбиятның, сәнгатьнең бүтән төрләре б-н бәйләнешенә карый.

Хезм.: «Жан Кристоф» Р.Роллана и проблема взаимодействия в искусстве. К., 1978; Проблема взаимодействия литературы и музыки. К., 1978; Философский роман Мишеля Турнье. К., 1997.

**«АСА́Р»** («Асәр») (гарәп. آثار — билге, эз), Риза Фәхретдин төзегән 4 томлык биобиблиогр. белешмәлек. Идел буе Болгар дәүләте чорыннан алып 20 йөз башына кадәр Идел-Урал төбәгендә яшәгән төрки халыклар вәкилләреннән 1200 кешенең биографиясен эченә ала. Төп чыганак буларак урта гасырлар авторлары хезмәтләре (Ибне Фазлан, Ибне Рустә, әл-Мәсгуди, әл-Гарнати һ.б.), ш.у. татар галимнәренең тарихи язмалары (Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов һ.б.) һәм документлар файдаланылган. Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урда, Казан ханлыгында яшәгән җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре, галимнәр, язучылар, ш.у. 17 йөз — 20 йөз башының күренекле шәхесләре теркәлгән. А.ның 15 өлештән торган 2 томы 1900–1908 елларда нәшер ителә, 3 нче, 4 нче томнары кульязма хәлендә РФАнең Уфа фәнни үзәге Тарих, тел һәм әдәбият ин-ты мирасханәсендә саклана. А. кульязмаларының күләмле бер өлеше РФА Шәрекъ белеме ин-тының Петербург ф-лы Шәрекъ архивы фондында да бар.

Чыг.: Асар. К., 1900. Т. 1, 1 кис.; Оренбург, 1901, 2 кис.; Оренбург, 1903, 3–4 кис.; Оренбург, 1904. 5–8 кис.; Оренбург, 1905. Т. 2. 9–11 кис.; Оренбург, 1907. 12–13 кис.; Оренбург, 1908. 14–15 кис.

*Әд.:* Госманов М. Үткәннән — киләчәккә. К., 1990; Мөхәммәтҗанов А.А. Ш.Мәрҗаниның «Вафийәтел-әслаф...»ы һәм Р.Фәхретдиновның «Асар»ы // Ш.Мәрҗани: тарих һәм хәзерге заман. Халыкара фәнни конференция материаллары. К., 1998; Ризаэтдин Фәхретдин. К., 1999; Творчество Р.Фахретдинова: Сб. статей. Уфа, 1988.

**АСЕЕ́В** Аренкул (18 йөз), 1773–75 еллардагы крәстияннәр кузгалышында катнашучы. Минзәлә өязе (хәзерге Зәй р-ны) Аксар авылы старшинасы. 1773 ел ахырында баш күтәрүчеләр отрядын төзи, *Әсәнев* Нагайбәк б-н бергә Зәй кальгасын камауда катнаша. 1774 нең 15 гыйнварында аларның берләшкән көчләре кальганы каршылыксыз алуга ирешә. 16 гыйнварда А.ның отрядын (600 кеше, 3 туп) Аксар авылы янындагы бәрелештә Ю.Бибиков җитәкчелегендәге эзәрлекләү полкы тар-мар итә. А.ның шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в Пугачёвском восстании. К., 1973; Заинская энциклопедия. К., 1994.

**«А́СИЯ»** («Азия»), газета. 1908 елда Ташкентта татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире *Ә.Биктимеров*.

**АСКАРИ́ДАЛАР** (Ascaridae), нематодалар классыннан суалчаннар семьялыгы. Җенси яктан өлгергән халәттә кеше һәм умырткалы хайваннар эчәклегендә паразит булып яшиләр. Киң таралганнар. Ascaris типик ыругы 18 төрне берләштерә. А. гәүдәсе орчыксыман, койрыгы тарайган формада. Ата аскаридә ана аскаридадан кечкенәрәк, койрык очлары корсак ягына бөгелгән. Гадәтиләре: кеше аскаридасы (A. lumbricoides), дуңгыз аскаридасы (A. suum), ат аскаридасы (Parascaris equorum). Ана аскариданың озынлыгы — 25–40, атасыныкы — 12–25 *см*. Тәүлек дәвамында ана аскарида 200 дән алып 245 меңгә кадәр күкәй сала. Личинкалар үсеше тышкы мохиттә бара. Табигатьтә күкәйләр 7 ел дәвамында сакланырга мөмкин. Күкәйләр азык яки су б-н эчәкләргә эләгә һәм анда аларның үсеше башлана. Күкәйдән чыккан личинкалар кан юлына, катлаулы юллар аша үпкәгә үтеп керәләр. Аннары личинкалар йөткылыкка һәм тагын эчәклеккә эләгәләр, анда җенси яктан өлгерәләр. 2–2,5 айдан соң ана аскаридалар күкәй сала башлыйлар. Кеше организмында А.ның гомере 11–13 айдан артмый. А. каты авырулар — аскридозалар китереп чыгаралар.

*Әд.:* Павловский Е.Н. Руководство по паразитологии человека. М.–Л., 1946. Т. 1.

*О.Д.Любарская.*

**А́СКИН** Гайфетдин Гафиятулла улы (10.10.1924, хәзерге Башкортстан Респ-касының Нуриман р-ны Чураш а.), Сов. Союзы Герое (27.6.1945), гв. сержанты (1945). 1941 нең гыйнварыннан 1942 нең июленә кадәр Уфа нефть эшкәртү з-дында оператор ярдәмчесе булып эшли. 1942 елның августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 43 нче гв. артиллерия полкында тупчылар командиры (5 нче гв. армиясенең 15 нче гв. укчы дивизиясе). Воронеж, Дала, 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украинаны, Белоруссия, Польша, Чехословакияне азат итү сугышла-

рында, Берлинга һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. Висла елгасы буенда Поценув авылы тирәсендә урнашкан Сандомир плацдармындагы дошман оборонасын өзгәндә батырлык күрсәтә: 1945 нең 12 гыйнварында һөҗүм сугышында расчёт б-н бергә 3 станоклы пулеметны һәм 40 ка якын солдатны юк итә, Одер елгасын беренчеләрдән булып кичә һәм дошманның контрһөҗүмен кире кайтаруда катнаша. 1946 дан запаста. Сугыштан соң Нуриман р-ны Укарлы авылы, Нуриман районы советлары рәисе, 1954–57 дә КПССның Нуриман райкомы секретаре. Чураш авылында яши. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Г.Г.Аскин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1965. Кн. 1; Высоты мужества. Уфа, 1982.

**АСКОМИЦЕТЛА́Р**, сумкалы гөмбәләр (Askomycetes), югары төзелешле гөмбәләр классы. 30 мең төрне үз эченә алган 2 меңгә якын ыругы билгеле. А.ның төп билгесе — җенси процесс нәтиҗәсендә асклар яисә сумкалар барлыкка килә. Сумкалар үрчү өлешләренең өстендә яисә эчендә үсә. Сумкалы споралар йөртү күренешеннән тыш, күп кенә А.да җенессез үрчү киң таралган. Конидиаль спора йөртүчеләр порошоксыман кунык (күгәрекләр), ак ончыл порошок (*ончыл чык гөмбәләре*), таплар һ.б. хәлендә булалар. Күпчелек А. сапрофитлар буларак туфракта, үсемлек калдыкларында, төрле азык-төлектә (күгәрек), әчи торган сыеклыкларда (*чүпрә*) яшиләр. Кайбер А. культуралы үсемлекләр авыруларын: ончыл чык, үсемлекләр рагы авыруын, кутыр, черү һ.б., пеницилл, *аспергилл* ыругындагы гөмбәләр — азык-төлек продуктларының, җиләк-җимешләрнең, терлек азыкларының һ.б. бозылуын китереп чыгаралар. Микробиология сәнәгатендә ферментларның, антибиотикларның һ.б.ның продуцентлары буларак һәм ш.у. сыр ясауда, ипи пешерүдә кулланылалар. А.га ашарга яраклы (*җыерчалы гөмбәләр*, *җөйле гөмбәләр*, *томалан*нар), һәм ш.у. *лишайниклар* составына караган барлык гөмбәләр керә.

*Әд.:* Жизнь растений. Грибы. М., 1976. Т. 2.

**АСКЫ́Н РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасы*ның төньяк өлешендә. 1930 елда оештырыла. Мәйданы — 2542 *км*$^2$. Үзәге — Аскын авылы (Уфадан 213 *км* төньяктарак). Халкы — 23928 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 6705, 1979 да — 6027, 1989 да — 5610, 2002 дә — 4212 кеше. Районга 72 торак пункты, ш.и. 6 татар, 14 татар-башкорт, 2 рус — татар-башкорт авылы керә. Иң зур татар авыллары (1999): Көнгәк (766 кеше), Чишмә-Уракай (411 кеше). Иң борынгылары: Арбаш (1702 дән мәгълүм), Кучән (1718), Чишмә-Уракай (1723). 2004/2005 уку елында А.р.ның 12 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла. Татарча «Ышаныч» г-тасы нәшер ителә.

**АСПАРУ́Х** (Есперих, Исперих) (644 тирәсе — 701 тирәсе), болгарлар ханы, *Беренче Болгар патшалыгын* нигезләүче. *Кубрат хан* улы. 670 елларда, Кубрат хан вафатыннан соң, Бөек Болгар дәүләтенең таркалуы чорында үзенә буйсынган кабиләләр б-н көнбатыш тарафка күченә, Дунай буйларына барып җитә. Паннониядә төпләнгән Авар каганлыгы һәм Византия б-н көрәштә Дунай тамагындагы җирле кабиләләрне үзенә буйсындыра. 680 елда Византия императоры Константин IV нең болгарларны куарга җибәрелгән гаскәрен тар-мар итә. А. җитәкчелегендә болгарлар Дунайның уң ярына чыгалар (хәзерге Добруджа тирәләре), «Семь родов» берлегенә кергән славян кабиләләрен буйсындыралар. Монда А. Плиска шәһәрен нигезли, Болгар дәүләте оештырылуын игълан итә (681) һәм аның халыкара танылуына ирешә. 680 елларда үз биләмәләрен киңәйтү максатында Авар каганлыгы һәм Византия б-н сугышлар алып бара. А. идарә иткән елларда Болгар дәүләтенең хакимият оешмалары барлыкка килә, дәүләт идеологиясе булдырыла. Алар «*Болгар ханнары исемлеге*» («Именник болгарских ханов») чыганагында чагылыш тапкан.

*Әд.:* Чичуров И.С. Византийские исторические сочинения. М., 1980; Раннефеодальные государства на Балканах VI–XII вв. М., 1985; Петров П. Образуване на Българската държава. София, 1981; Именик на болгарските ханове. Критично издание с коментар и обяснителнии бележки от Ив.Богданов. София, 1981; Pritsak O. Die bulqarische Furstenliste und die spache der Protobulgaren. Wiesbaden, 1955.

**АСПЕРГИ́ЛЛ** (Aspergillus), сумкалы гөмбәләр классыннан бер ыруг. А.ның вегетатив тәне — субстратка үтеп керүчән күп күзәнәкле тармаклы мицелий. 160 ка якын төре билгеле. Үрчү, башлыча, җенессез юл б-н — башсыман кабарып торган конидияләр йөртүчеләрдә күпсанлы тезмәләр ясап үсә торган споралар (конидияләр) аша башкарыла. А.ның кайберләренә җенси үрчү дә хас. ТРда туфракның өске катламнарында киң таралган, аларны шулай ук төрле үсемлек продуктларында табалар, анда А. колонияләре төрле төстәге күгәргән куныклар хасил итәләр, ш.у. югары дымлылык шартларында сакланган азык-төлекләрдә үрчиләр. Күп төрләре сапрофитлар, A. fumigatus, A. bronchialis һ.б. — кеше һәм хайваннар паразиты. A. niger һәм бу төркемнең башка төр штаммнары лимон, кузгалак, глюкон кислоталары булдыруда киң кулланыла. Кайбер төрләре патоген бактерияләргә тәэсир итәргә сәләтле антибиотиклар бүлеп чыгара.

**АСПИДИ́СТРА** (Aspidistra), лаләчәләр семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Күпьеллык сабаксыз үләннәр. 8 төре бар. Туган җире — Япония, Көньяк Кытай. Мәңге яшел декоратив үсемлек, яфраклары озынча эллиптик, тыгыз кабыклы, куе яшел төстә. Чәчәкләре ялгыз, вак, коңгырт-сары төстә, тамырчаның җир өсте өлешендә — яфрак куентыгында үрчиләр. ТРда бер төре — биек А. (A. elatior Bl.) бүлмәләрне, вестибюльләрне яшелләндерү өчен кулланыла («дустанә гаилә» исеме б-н мәгълүм). Тамырчадан 4–5 яфракны бүлеп алып үрчетелә. Талымчан үсемлек түгел: күләгәне, дым җитмәүне, тузан б-н каплануны, һаваның газлар б-н пычрануын, температураның кискен үзгәреп торуын яхшы кичерә, ләкин су җыелуга чыдамый.

**АССИМИЛЯ́ЦИЯ** (лингв.), телдә авазларның үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә охшаш булмаган ике аваздан бертөрле яки якын артикуляцияле охшаш авазлар хасил булу күренеше. Татар телендә А. төрле аспектларда өйрәнелә: а) авазларның үзара охшашлануы нинди булуга карап — сузык авазлар А.се һәм тартык авазлар А.се күзәтелә; б) тәэсир итүе буенча алдагы аваз үзеннән соң килгән авазны охшашландырса — прогрессив А. була: урманлар > урманнар, ахырда торган аваз алдагы авазга тәэсир итсә — регрессив А. дип атала: әнкәй-[ә**ңк**әй]; алдынгы — [алды**ңг**ы]; в) охшашландыру нәтиҗәсе буенча А. тулы һәм өлешчә төрләргә аерыла. Тулы А. очрагы булганда, бер аваз икенче авазны үзенә тулысынча охшашландыра, ике төрле аваздан бер төрле озын аваз хасил була: күзсез — [кү**сс**ез], яки ассимиляциягә бирелгән аваз икенчесенә бөтен билгеләре б-н охшашлана: колы — [к**о**л**о**]. Бер аваз икенчесен нindидер бер билгесе буенча гына охшашландырса — А. өлешчә була, мәс.: авазның кайда ясалу урыны буенча: унбер — [у**мб**ер].

Акустик А. — тартыкларның саңгыраулыкта-яңгыраулыкта охшашлануы, алар ике төрле ясала; а) саңгырау тартыклар тәэсире б-н кайбер яңгырау авазлар саңгыраулаша: таҗсыз — [та**чс**ыз]; б) яңгырау тартыклар тәэсирендә кайбер саңгырау авазлар яңгыраулаша. Әдәби телдә мондый күренеш сирәк очрый: ак-рак > а**гр**ак, күп-рәк > кү**бр**әк. Диахроник һәм синхроник А. аерып карала. Диахроник А. — тарихи процесс нәтиҗәсендә авазларның яңача чиратлашуы барлыкка килүне һәм яңа кушымчалар ясалуны тәшкил итә: баш-да > ба**шт**а. Синхроник А. — авазларның сөйләм процессында охшашлануын күрсәтә: бөтен — [б**ө**т**ө**н]; болыт — [б**о**л**о**т]; тозсыз — [т**оссо**з].

*Әд.:* Татар грамматикасы. М.–К., 1998. Т. 1.

*Х.Х.Сәлимов.*


**АССИМИЛЯ́ЦИЯ** (этногр.), этник берләшү процессының бер төре, этносның яисә аның билгеле бер өлешенең чит этнос йогынтысына бирелеп, икенче мәдәниятkә тартылуы һәм милли үзаңын югалтуы, башка этнос б-н кушылуы. Этник А.гә кадәр халык тел, мәдәният өлкәсендәге А., яки аккультурация кичерә. Гадәттә, мәдәният өлкәсендә А. телдәге А.гә караганда алданрак башлана, ләкин озаккарак сузыла. А.гә этносның сан ягыннан азрак булуы яисә башка этнос б-н социаль-мәдәни яктан хокук тигезсезлеге сәбәпче. А. процесслары аеруча мөһаҗирләр өчен хас. А. табигый рәвештә, ягъни илдә яшәүче этник төркемнәр арасындагы бәйләнешләр, катнаш никахлар һ.б. нәтиҗәсендә барлыкка килергә яисә дәүләт сәясәте нәтиҗәсендә көч б-н алып барылырга мөмкин.

Татар халкының катлаулы этногенезы, аның зур бер этнос булып оешуы — объектив тарихи процессның, табигый А.нең ачык мисалы һәм нәтиҗәсе. Россиядә күп гасырлар дәвамында рус булмаган халыкларны көчләп А.ләү сәясәте алып барылуга карамастан (к. *Руслаштыру сәясәте*), татар халкы милли үзаңын югалтмый, күпчелек өлеше туган телен, мәдәни традицияләрен саклап килә. Татарстаннан читтәге төбәкләрдә тупланып яшәүче татарлар (к. *Диаспора*) милли үзаңның тотрыклылыгы б-н аерылып тора; татар мөһаҗирләренең чит ил шартларына җайлашуы, кагыйдә буларак, икетеллелек һәм беркадәр дәрәҗәдә аккультурация б-н чикләнә. Бертөрлелек, шәһәрләшкән мәдәният басымын җиңү өчен милли яңарыш хәрәкәтенең көчәюе һәм Россиядә дәүләтнең яңа милли сәясәте кабул ителү шарт булып тора.

*Әд.:* Народы России. М., 1994.

**АССОЦИА́ЦИЯ** (икътисад), оешмаларның үз эшчәнлекләрен координацияләү, ш.у. милеккә кагылышлы гомуми мәнфәгатьләрдән чыгып эш итү һәм яклау максатында төзелгән берләшмәсе. А. әгъзаларының мөстәкыйльлеге һәм юридик зат булу хокукы саклана. А. үз әгъзаларының йөкләмәләре өчен җавап бирми, аларга карата югары орган булып саналмый. Шулай да А. үз составына кергән субъектлар эшчәнлегенә, бирелгән хокукларына нигезләнеп идарә итүгә йогынты ясый. А. оештыручылар шартнамә һәм устав нигезендә эш итә. ТРда А. 1990 еллар ахырында агросәнәгать комплексларында аеруча киң таралыш ала: 1998 елга 17 А. оеша һәм эшли, шуларның 10 сы — сөт җитештерү һәм эшкәртү, 4 се — ит җитештерү һәм эшкәртү, 3 се — шикәр җитештерү б-н шөгыльләнә. А. ләр базар конъюктурасын исәпкә алырга, аларда катнашучылар арасында продукция сатудан алынган табышны гадел итеп бүләргә, барлык комплекста җитештерү һәм хезмәтне оештыру эшен камилләштерергә, һәр технол. буында җитештерүгә тотылган чыгымнарны киметергә мөмкинлек бирә.

**АСТА́НГОВ** (Ружников) Михаил Фёдорович (21.10.1900, Варшава — 20.4.1965, Мәскәү), драма актёры, СССРның халык артисты (1955). Мәскәү ун-тының юридик ф-тында укый. Сәхнә эшчәнлеген 1920 елда Мәскәүдә Ф.Шаляпин исем. студиядә башлый. 1925–27 елларда Мәскәү революция театрында, 1927–28 дә — Одесса драма театрында. 1928–29 да Казан Зур драма театрында. Монда ул шактый зур рольләр башкара, алар арасында: Незеласов («14–69 бронепоезды», В.В.Иванов), Геннадий («Утлы күпер», Б.С.Ромашов), Пешекче («Мәгърифәт җимешләре», Л.Н.Толстой), Квазимодо («Париж Изге Ана соборы», В.Гюго), Кюре («Кюре һөнәрен алыштыра», К.Вотейль), Бетховен («Бетховен», М.Жижмор). А.ның Казан сәхнәсендәге иҗаты театр тормышында сизелерлек вакыйга буларак танылa, аның һәрбер роле вакытлы матбугатның игътибар үзәгендә була. Тәэсирле бизәкләр куллануы, һәр хәрәкәтен җентекләп сайлап алуы, бай интонациясе, костюм детальләренең сәнгатьчә эшләнеше, тирән психологик халәт б-н бергә кушылып, актёрга спектакльнең идея-фикер бердәмлеген ачарлык образлар тудырырга ярдәм итә. Актёр Бетховенның иҗади кичерешләрен зур җанлылык һәм көчле темперамент б-н бирә, Незеласов һәм Геннадий Дубровин образлары аша «ак хәрәкәтнең» идея буларак җимерелүен ачып сала, көч җитмәслек авыр физик хезмәттән интеккән Пешекче тарафыннан әйтелгән сүзләр аристократиянең паразитларча яшәвенә каршы ачулы протест булып яңгырый. А. 1930 да яңадан Мәскәү революция театрында, 1943–45 тә Моссовет исем. театрда һәм 1945 елдан Вахтангов исем. театр труппасында. Ш.у. «Тоткыннар», «Хыял», «Рус мәсьәләсе», «Аларның туган илләре бар» һ.б. кинофильмнарда уйный. СССР Дәүләт бүләкләре (1948, 1950, 1951) лауреаты.



М.Ф. Астангов.



М.Ф.А с т а н г о в Бетховен ролендә («Бетховен», М.Жижмор).

*Әд.:* Ю з о в с к и й И. Образ и эпоха... М., 1947; Театральная энциклопедия. М., 1961. Т. 1; Астангов Михаил. Статьи и воспоминания. М., 1971.

**АСТА́ХОВ** Николай Прокофьевич (24.12.1920, Тула губ., Одоевский өязе Николо-Жупань а.), хокук белгече, хокук фән. д-ры (1984), проф. (1985), ТССРның атказ. хокук белгече (1991). Казан юридик ин-тын тәмамлый (1948). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–47 елларда Казан исәп-хисап кредит техникумы укытучысы. 1958 елдан Казан финанс-икътисад ин-тында, 1985 тән икътисад, статистика һәм хокук каф. проф. (1989 кадәр каф. мөдире), 1992 дән хокук, 1996 дан тарих, сәясәт белеме һәм хокук кафедралары профессоры.

Хезмәтләре гражданлык, хуҗалык хокукына карый. Югары уку йортлары өчен «Совет хокукы» («Советское право», 1969) дәреслеге авторы.

Х е з м.: Правовое регулирование хозрасчёта предприятий. К., 1976.

**АСТЕРО́ИДЛАР**, к. *Кече планеталар.*

**АСТРАХА́НКА** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 36 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 62 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Беренче тапкыр 1567 дә рус авылы буларак телгә алына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, агач, балта эше, тимерчелек, буяу-бизәк төшерү, мич чыгару, арба һәм тәгәрмәчләр ясау б-н шөгыльләнә. 1760 та А.да таштан архит-ра истәлеге — Казан-Богородица чиркәве төзелә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1871 дә ачыла), Халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче изба-читальня, 2 җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 6 вак-төякләр кибете була; җомга саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1217 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Астраханка волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 211 ир заты; 1859 да — 666, 1884 тә — 974, 1897 дә — 1001, 1908 дә — 974, 1926 да — 934, 1938 дә — 593, 1949 да — 377, 1970 тә — 131, 1979 да — 72, 1989 да — 49 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**А́СТРО**... (грек. ástron — йолдыз), баштарак кушма сүзләрдә «йолдызларга мөнәсәбәтле», «йолдызлык» дигән мәгънәләрне белдергән. Соңрак, гомумән, күк җисемнәренә, галәм киңлекләренә караган мәгънәдә кулланыла.

**АСТРОМЕ́ТРИЯ** (*астро*... һәм ...*метрия*), астрономия фәненең бер бүлеге, күк йөзендәге җисемнәрнең координатларын һәм торышын төгәл билгеләү б-н шөгыльләнә. Астрометрик тикшеренүләр ориентлашу, вакыт исәбен белү, ш.у. күк гөмбәзенең тәүлек эчендә әйләнүен, күктәге төрле җисемнәрнең хәрәкәтен өйрәнү өчен кирәк.

Беренче астрометрик күзәтүләр (күктәге яктырткычларның үзара торышын һәм координатларын билгеләү максаты б-н ясалган почмак үлчәгеч җайланмалар куллану) б.э.к. берничә мең еллар элек үк (Вавилон, Мисыр, Кытай, Англия) алып барылган. 800 гә якын йолдызның торышын күрсәткән беренче мәгълүм йолдызлар каталогы б.э.к. 4 йөздә Кытайда төзелә.


Җир турындагы фәнни күзаллаулар Борынгы Грециядә барлыкка килә, анда астрометрик күзәтүләр ярдәмендә Җирнең зурлыгын билгеләргә омтылалар. Борынгы Греция астрономнары б.э.к. 3–2 йөзләрдә йолдызларның торышын шул чор өчен гаять төгәл итеп (Ай һәм Кояш радиусларының күренмә почмагына туры килә торган почмакча 15 минутка кадәр төгәллек б-н) билгелиләр, каталоглар төзиләр һәм шул нигездә фундаменталь астрометрик күренеш — көн-төн тигезлеге ноктасының күчеше (прецессиясе) ачыла; йолдызлар каталогларын төзегәндә аны төгәл исәпкә алу зур әһәмияткә ия. Борынгы астрономнар файдаланган почмак үлчәгеч җайланмалар, инструментлар бик тә примитив була, күзәтү торбалары һәм телескоплар бары тик 17 йөз башында гына

барлыкка килә, аларны беренче мәртәбә Галилео Галилей куллана.

17 йөзнең 60 нчы елларында Париж обсерваториясе астрономы Жан Пикар почмакларны үлчәү өчен астрономик торбадан файдалана.

Россиядә беренче астрометрик күзәтүләр Пётр I заманында уздырыла. 1717 елда ул шәһәр һәм авылларның географик координатларын билгеләү өчен экспедицияләр оештыра. Россиядә беренче астрономия обсерваториясе Пётр I нең фикердәше Я.В.Брюсов тарафыннан Мәскәүдә төзелә, ул күк йөзендәге төрле күренешләрне күзәтү өчен шул чордагы камил телескоплар һәм почмак үлчәгеч инструментлар б-н җиһазландырыла.

Казандагы беренче астрономия обсерваториясе шәһәрнең Беренче ирләр гимназиясе терр-ясендә урнаша (1767–74); аның өчен кирәкле инструментлар Мәскәү ун-тыннан кайтартыла. 1769 ның 24 маенда гимназия



Меридиан әйләнәсе (В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе).

укытучысы Григорий Комов Казанда беренче астрономик күзәтүләр уздыра. Аның күзәтүләре Венера планетасының Кояш дискы аша узуын һәм шуның нигезендә Казанның географик киңлеген һәм озынлыгын теркәүдән гыйбарәт. Күзәтү нәтиҗәләре «Московские ведомости» г-тасының 1769 ел 18 август кушымтасында басылып чыга. 1774 нең 12 июлендә, Е.И.Пугачёв гаскәрләре Казанны алганда обсерватория янып көлгә әверелә. А.нең үсеше 1804 тә Казан ун-ты ачылу б-н бәйле, аның уставында астрономия обсерваториясен төзү дә карала. Казан ун-ты обсерваториясе өчен 1820–40 елларда сатып алынган җиһазлар системалы рәвештә астрометрик күзәтүләр уздырырга һәм *Казан астрономия мәктәбенә* нигез салырга мөмкинлек бирә. Йолдызлар, ш.у. Кояш системасындагы җисемнәр — Ай, Кояш, планеталар, кометалар, аеруча зур астероидлар күзәтелә. Мәс., 1835 тә И.М.Симонов Галлей кометасын рәттән 440 мәртәбә күзәтә. Казан галимнәренең җирле вакыт мизгелләрен һәм Кояш системасындагы җисемнәрнең координаталарын төгәл итеп билгеләүләре дә күк механикасына караган теоретик исәпләү ысулларын алга таба үстерүдә нигез булып торалар. 19 йөздә үк Казан астрометристлары йолдызлар каталогын төзегәндә Германия, Франция, Англия һ.б. илләр галимнәре б-н хезмәттәшлек итәләр. Казанда А.нең үсеше М.В.Ляпунов, М.А.Ковальский, М.А.Грачёв, Д.И.Дубяго исемнәре б-н бәйле. М.В.Ляпунов, С.-Петербург тирәсендәге Пулково обсерваториясе галимнәре б-н берлектә беренче булып күзәтү программаларын (1840–54) үтәүгә керешә. Бу күзәтүләр Европаның көнчыгышындагы Казан обсерваториясен бөтен дөньяга таныта. М.В.Ляпуновтан соң обсерваторияне җитәкләгән М.А.Ковальский, халыкара программаларны үтәү буенча күзәтүләр алып бару б-н бергә (+75 тән +80 кадәр авышлыктагы зонада 4200 дән артык йолдызның торышын күрсәткән каталог төзүдә катнаша), теоретик тикшеренүләрендә аларның күзәтү нәтиҗәләреннән киң файдалана. М.А.Ковальский безнең Галактиканың әйләнү идеясен беренче мәртәбә әйтә һәм классик булып әверелгән, соңыннан йолдызлар астрономиясе дәреслекләренә кертелгән ысулны — йолдызара киңлектә Кояш хәрәкәтен билгеләү ысулын эшли. Д.И.Дубяго тәкъдиме б-н Казан астрометристлары киңлек үзгәрү күренешен тикшерүдә катнашалар. М.А.Грачёв 1892–1901 дә 8 меңгә якын киңлекне гаять төгәл — бер төндә 0,05 почмакча секундка кадәр, ә күзәтү чорында 0,2 почмакча секунд төгәллек б-н билгеләүгә ирешә. Болар Җир полюсларының периодик хәрәкәтен өйрәнә башларга, ш.у. фундаменталь астрономик зурлыкларның берсен — даими аберрациясе — аның уртача күрсәткече (20",525±0"002) Җир шарындагы башка обсерваторияләрнең үлчәү нәтиҗәләре б-н тәңгәл килә — тикшерүне башлап җибәрергә этәргеч бирә.

*В.П.Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе*нә нигез салыну 20 йөздә Казанда А.нең алга таба үсешен билгели. Обсерватория иң яхшы астрометрик инструментлар б-н җиһазлана. Бу исә И.В.Белькович, А.А.Нефедьев, А.И.Нефедьева, И.А.Урасина, В.В.Лапаева һ.б. совет һәм чит ил галимнәре б-н берлектә озак вакытка исәпләнгән астрометрик күзәтүләрне зур төгәллек б-н үтәргә ярдәм итә. Обсерватория хезмәткәрләре геодезиянең гамәли максатлары һәм Халыкара вакыт хезмәте өчен географик киңлекләрне билгеләүдә катнашалар.

Айның рәвешен һәм әйләнү үзенчәлекләрен тикшерүгә (А.В.Краснов б-н А.А.Яковкин катнашында 19–20 йөзләр арасында Казанда барлыкка килгән астрономик юнәлеш) Ш.Т.Хәбибуллин зур өлеш кертә, ул, дөньяда беренче буларак, 1949–53 тә Айның физик либрациясен өйрәнү өчен фотографик күзәтүләрне уңышлы куллана, 1966 да Айның нәсызыкча либрация теориясен төзи. Космик эра башлану аңа Ай өчен координат системаларын билгеләүдә, Айның геометрик рәвешен һәм аның гравитацион кырын өйрәнү эшләрен тизләтүдә ярдәм итә. Ш.Т.Хәбибуллин тырышлыгы б-н Казан ун-тының *Төньяк Кавказ астрономия станциясе* төзелә, 1975 тә анда немец фирмасының 40 *см* лы киң почмаклы «Цейс» астрографы урнаштырыла. Ул, А.А.Нефедьев б-н берлектә, 1977 дә Ленинград оптика-механика берләшмәсенә Казан ун-ты өчен төп көзгесе 1,5 *м* лы телескоп әзерләргә заказ бирә, 1998 дә бу телескоп Төркиянең Коньягында урнаштырыла (к. *Оптик телескоп*). 40 *см* лы астрограф ярдәмендә Н.Г.Ризванов, И.А.Даутов һ.б. тарафыннан 1975–95 тә киң кырлы фотографик астрометрик программалар гамәлгә ашырыла, шулар арасында иң әһәмиятлеләре — «Венера-Галлей» совет космик программасында катнашып, Галлей кометасы Кояшка якынайганда (1986) аның төгәл координатларын билгеләү һәм –20 дән +90° ка кадәр авышлыкта күк йөзен фотографик күзәткәндә киң колачлы «ФОН» һәм «ФОКАТ» программаларын үтәү.

Җир өсте А.дәге җитди комачаулыкларның берсе — Җир атмосферасында яктылык рефракциясе (сынуы). Ул күк йөзендәге яктырткычларның координаталарын оптик А.нең классик ысуллары б-н 0,01 дән дә югары почмакча секунд төгәллек б-н күзәтү



Галлей кометасы.
Астроном И.Е.Целищев 1986 елда Казан университетының Төньяк Кавказ астрономия станциясендә төшергән рәсем.

мөмкинлеге бирми. В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә рефракцияне тикшерү һәм исәпләү буенча А.И.Нефедьева уздырган фундаменталь тикшеренүләр А. дә бу юнәлештәге үсешне билгелиләр. Гадәти ысуллар б-н генә күзәтүләр уздырганда рефракция координаталарын төгәл билгеләү чикләнгәнлектән, А.гә яңа юллар эзләү таләп ителә, шуңа күрә 1960–70 елларда яңа ысуллар уйлап табыла: радио һәм оптик интерферометрлар кулланыла, астрометрик телескоплар космик аппаратлар бортына урнаштырыла. Үтә озын базалы радиоинтерферометрлар (дөньядагы төрле илләрнең Җир шары буйлап таралган телескоплар челтәре) радиойолдызлар һәм галактикаларның координаталарын беренче мәртәбә 0,0001 почмакча секундка кадәр төгәллек б-н билгеләргә мөмкинлек бирә, бу инде Җир өстендәге берничә мең *км* озынлыктагы дугаларны 3 *мм* га кадәр төгәллек б-н исәпләү дигән сүз. Интерферометрик ысуллар б-н тагын да төгәлрәк күзәтүләр алып баруның чикләнгәнлеге, Җир җисеме үзегендәге сыек төшкә Айның гравитацион тәэсир итүе нәтиҗәсендә, Җирнең үз күчәре тирәли әйләнү нутациясе теориясендәге константаларның аныксызлыгы б-н аңлатыла. 1957 дән бирле В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе

сендә алып барылган тикшеренү нәтиҗәләре 1990 елларда Казанда В.В.Лапаева тарафыннан кабат эшкәртелгәч, нутация теориясенә анык константалар алына. Җир өстендә интерферометрик күзәтү ысулларын кулланганда шуларны исәпкә алу төгәл күзәтүләрнең чикләнгәнлеген бетерергә мөмкинлек бирә. Европа астрометристлары тарафыннан беренче мәртәбә борынгы атаклы грек астрономы Гиппарх хөрмәтенә «HIPPARCOS» исеме бирелгән космик астрометрик проект 1989–93 тә «HIPPARCOS» каталогында (1997) координатлар, йолдызларның ераклыгы һәм моңарчы тиңе булмаган күпсанлы 120 мең йолдызның хәрәкәтен 0,001 почмакча секундка кадәр төгәллек б-н билгеләгән мәгълүматлар тупланган. Андый астрометрик мәгълүматлар астрономия өчен генә түгел, геофизика, геология, геодезия өчен дә гаять әһәмиятле.

*Әд.:* Дубяго А.Д. Определение орбит. М.–Л., 1949; Корытников С.Н. Начало астрономии в Казани // Ист.-астрон. исслед. М., 1955. Вып. 1; Дубяго А.Д. О первой Симоновской обсерватории Казанского университета // Уч. зап. Казан. ун-та. 1957. Т. 117, кн. 9; Хабибуллин Ш.Т., Чиканов Ю.А. Лунный эллипсоид по измерениям абсолютных высот // Казан. гор. астрон. обсерватория. 1970. № 37; Хабибуллин Ш.Т., Санович А.Н. К вопросу об астрометрических наблюдениях с поверхности Луны методом равных высот // Астрон. журн. 1971. Т. 48, вып. 4; Казанский университет. 1804–1979: Очерки истории. К., 1979; Подобед В.В., Нестеров В.В. Общая астрометрия. М., 1982; Положенцев Д.Д. Радио- и космическая астрометрия: Учеб. пособие. Л., 1982; Урасина И.А. Наблюдения за изменяемостью широты и приливными колебаниями отвеса в Казани // Ист.-астрон. исслед. М., 1983. Вып. 16; Колчинский И.Г., Корсунь А.А., Родригес М.Г. Астрономы: Биогр. справ. Киев, 1986; Нефедьева А.И., Подобед В.В. Фундаментальная астрометрия. К., 1989; Ризванов Н.Г. Фотографическая астрометрия. К., 1991.

*И.Ф.Бикмаев.*

**АСТРОНО́МИЯ** (*астро*... һәм грек. ...*номия*), фән, күк җисемнәренең төзелешен һәм хәрәкәтен, алар хасил иткән системаларны һәм тулаем Галәмне өйрәнә. Кояш системасындагы җисемнәрне, йолдызларны, йолдызара матдәне, безнең Галактиканы, башка галактикаларны, аларның фәзадагы таралышын, физик табигатен, үзара тәэсир итешүен, килеп чыгышын һәм үсешен фәнни тикшерә. Тикшеренү темасына һәм ысулларына карап, бернибә фәнгә бүленә. *Астрометрия* астрономик үлчәүләр өчен төп инерциаль координатлар системасын төзү, күк җисемнәренең торышын һәм хәрәкәтен билгеләү, Җирнең әйләнү закончалыкларын һәм вакытны исәпләү б-н шөгыльләнә. Күк механикасы күк йөзендәге, ш.и. ясалма җисемнәрнең хәрәкәтен һәм күк җисемнәренең тигезләнеш халәтен өйрәнә. Йолдызлар А.се безнең Галактиканы тәшкил иткән йолдызлар системасын, Галактикадан тыш, А. — башка галактикаларны һәм галактика системаларын күзәтә. *Астрофизика* күк йөзендә булган җисемнәрдәге физик күренешләрне, ш.у. аларда бара торган химик процессларны тикшерә. Радиоастрономия космостагы радиодулкын чыганакларының үзлекләрен һәм киңлектә таралуын өйрәнә. Космогония аерым күк җисемнәре системасының, аерым алганда, Кояш системасының килеп чыгышы мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Космология Галәмнең килеп чыгышын һәм үсешен өйрәнә. А. борынгы заманнарда ук кешеләрнең әйләнә-тирә мохитне күзәтү һәм вакытны үлчәү ихтыяҗыннан барлыкка килгән. 5 мең еллар чамасы элек үк Борынгы Мисырда кешеләр, Кояш һәм йолдызларның күк йөзендәге хәрәкәтен күзәтеп, дөнья якларын төгәл табарга өйрәнгәннәр; елның дәвамлыгын билгеләгәннәр һәм вакытны исәпләү өчен календарь системасы кертkәннәр. Б.э.к. 4 йөздә Кытай астрономнары 800 дән артык йолдызны эченә алган беренче каталогны төзиләр. Күренә торган планеталарның һәм Кояшның хәрәкәтен анализлау поляк астрономы Н.Коперникка дөньяның гелиоцентрик системасын төзергә мөмкинлек бирә (1543). Бу ачыш А.гә генә түгел, бәлки



Казан шәһәр астрономия обсерваториясе бинасы.

барлык табигать фәннәре өчен дә зур әһәмияткә ия. Астрономик күзәтүләр өчен телескоплар куллану А.не үстерүдә икенче мөһим этап булып тора; Италия астрономы Г.Галилей 1609 да беренче мәртәбә телескоптан файдалана, соңрак Кояшта таплар һәм Юпитерның иярченнәре булуын ача. Шуннан соң Уран (1781), Нептун (1846), Плутон (1930) планеталары ачыла, Кояш системасының төзелеше, безнең Галактиканың структурасы өйрәнелә, башка күп кенә галактикалар барлыгы һәм Галәмнең аерым структурасы булуы ачыклана. 19 йөздә астрономик күзәтүләр өчен спектраль анализ ысулы кертелү йолдызларның табигатен аңларга ярдәм итә. Планеталар, йолдызлар һ.б. күк җисемнәренең физик сыйфатламалары өйрәнелә. 1924 тә совет астрофизигы А.А.Фридман Галәм эволюциясенең беренче моделен төзи, ул 1929 да, Америка галиме Э.П.Хаббл, галактикаларның нурланыш тизлекләрен үлчәп, «кызыл күчеш»не — галактикалар «таралышы» эффектын ачканнан соң раслана.

Россиядә А. фән буларак 18 йөз башыннан үсеш ала. 1701 дә С.-Петербург Навигация мәктәбе ачыла, аның каршында Россиядә беренче астрономия обсерваториясе эшли. Ул, нигездә, уку-укыту б-н шөгыльләнә. 1725 тә Петербург ФА каршында обсерваториягә нигез салына. Россиядә беренче астрономик ачыш М.В.Ломоносов тарафыннан ясала: 1761 дә ул Венераның атмосферасы барлыгын ача. Безнең төбәктә беренче мәртәбә Идел буе Болгарында, Шәрекъ илләре галимнәре ирешкән казанышларга һәм үзләренең күк җисемнәрен күзәтүләренә нигезләнеп, А.гә караган белемнәрне системага салу омтылышы була. Анда гномон (Кояш сәгатенең бер төре) һәм астролябия (почмак үлчәү приборы) кулланылуы, җирле календарьлар төзелүе мәгълүм. А. фәненең үсеше 1804 тә Казан ун-ты ачылу һәм 1810 да Россиядә беренчеләрдән булган А. кафедрасы оештырылу б-н бәйле.

1811 дә «Казанские ведомости» г-тасында студентлар И.М.Симонов б-н Н.И.Лобачевскийның кометаларны күзәтүләре хәбәр ителә. Ул Казанда астрономик күзәтү нәтиҗәләре турындагы беренче язмалардан була. 1814 тә И.А.Литтров Казан ун-ты каршында Россиядә беренче ун-т обсерваториясен — *Казан шәһәр астрономия обсерваториясен* җиһазлый. 1833–37 дә И.М.Симонов һәм Н.И.Лобачевский тырышлыгы б-н шәһәр обсерваториясенең яңа бинасы (арх. М.П.Коринфский) төзелә. Обсерваториядә йолдыз, планета һәм кометаларның торышын үлчәү эшләре уздырыла. 1869–82 дә халыкара проект кысаларында Бонн күзәтмәләре өчен йолдызларның координаталарын билгеләү эшләре башкарыла. Географик киңлекнең үзгәрүчәнлеген күзәтүне Россиядә беренче мәртәбә 1892 тә А.М.Ковальский башлап җибәрә. М.А.Грачёв бу күзәтүләрне дәвам итә һәм беренче мәртәбә Җир инерциясе күчәренең фәзадагы торышы үзгәрүен тикшерә. Айның әйләнүен күзәтү гелиометр ярдәмендә 1894 елда башлана һәм ул инде 100 елдан артык дәвам итә. Дөньяда Айны гелиометрик күзәтүләрнең иң күбесе — 1723 күзәтүнең 1176 сы Казанда уздырыла. М.А.Ковальскийның теоретик хезмәтләре дөньякүләм танылә: 1859 да ул Кояш системасының хәрәкәтен билгеләү ысулын эшли; күзәтелгән йолдызларның бердәм система хасил итүен исбатлый һәм аның әйләнүен фаразлый, йолдызларның күренмә хәрәкәтен анализлап, бу әйләнү үзәген табу мәсьәләсен чишә. Казан галименең йолдызлар системасын тәшкил итүче Галактиканың әйләнүе турындагы фаразы 1926 елгы күзәтү нәтиҗәләре б-н раслана.

Д.И.Дубяго безнең төбәктә генә түгел, Россиянең бүтән төбәкләрендә дә А. үсешенә өлеш керткән танылган астрономнар плеядасын тәрбияләве б-н мәгълүм: А.В.Краснов — Варшава ун-ты обсерваториясенә нигез салучы; А.А.Михайловский — Белоруссия ун-ты, А.Н.Нефедьев — Пермь, А.А.Яковкин — Урал ун-тлары профессорлары. 1901 дә Казан төбәгендә астрономия обсерваториясе ачыла (к. *Казан университетының астрономия обсерваториясе*, В.П.Энгельгардт исемендә). Анда урнаштырылган җиһазлар (меридиан түгәрәге, рефрактор, гелиометр) тикшеренүләрнең сыйфатын билгели. Күп еллар күзәтүләр алып барган А.А.Яковкин 1934 тә Айның күренмә түгәрәге асимметриясен ача (Яковкин эффекты). 19 йөз ахырыннан Казанда астрофизика юнәлеше үсә башлый. Алмаш йолдызларны беренче күзәтүләр 1893 тә П.Богоявленский тарафыннан башкарыла, системалы күзәтүләр 1920 елларда башлана. 1937 дә Д.Я.Мартынов өч җисемнең чикләнгән мәсьәләсен чишүне куш системаларга карата куллану мөмкинлеген беренче мәртәбә



Казан ун-тының Төркиядәге астрономия обсерваториясе (Бакырлы Тепе тавы).

күрсәтә. Тыгыз урнашкан куш системаларда компонентлар тигезләнеше сурәтләрен В.А.Крат тикшерә (1937). Совет заманында *Казан астрономия фәнни мәктәбенең* эшчәнлек юнәлешләре: периодик кометалар хәрәкәтен теоретик тикшерү һәм аларны күзәтү (А.Д.Дубяго, Ю.В.Евдокимов); Урал, Урта Идел һ.б. төбәкләрне гравиметрик тикшерү (В.А.Баранов, И.А.Дюков); Айны өйрәнү (И.В.Белькович, Ш.Т.Хәбибуллин, А.А.Нефедьев, Н.Г.Ризванов); Галактиканың структурасын өйрәнү (Ш.Т.Хәбибуллин); астрономик рефракцияне өйрәнү (А.И.Нефедьева). А.Д.Дубяго ике кометаны ача (1921, 1923), соңрак аларга аның исеме бирелә, аның тарафыннан нәгравитацион көчләрнең тәэсир итүен билгели торган яңа ысул тәкъдим ителә. Ш.Т.Хәбибуллин Айны күзәтү өчен 8 *м* лы горизонталь телескопны файдалануга кертә (1954), Айның физик либрациясе параметрын билгеләү ысулын эшли (1957). К.В.Костылев тәкъдиме б-н метеорларны өйрәнүнең яңа юнәлеше — радиолокация барлыкка килә.

1957 дә СССРда Җирнең беренче ясалма иярчене җибәрелгәннән соң, Кояш системасындагы җисемнәр космик аппаратлар ярдәмендә өйрәнелә башлый. Иярченнәрдә телескоплар урнаштыру астрономик күзәтүләрдә җир атмосферасының тәэсирен бетерергә һәм барлык дулкыннарда да тикшеренүләр алып барырга мөмкинлек бирә. Күк җисемнәренең нурланышы озын дулкынның киң диапазонында — радиодиапазоннан алып рентген һәм гамма-диапазонга кадәр — теркәп барыла. 1970 еллар башыннан йолдызларның физик параметрларын өйрәнү аларның спектрларын санча модельләштерү юлы б-н башкарыла. Н.А.Сәхибуллин 1972 дә СССРда беренче мәртәбә җирле термодинамик тигезләнеш гипотезасын кулланмый гына йолдызлар спектрын анализлауның яңа алымын гамәлгә кертә. Казан ун-ты астрономия кафедрасы шул проблемаларны өйрәнүнең Бөтенсоюз үзәгенә әверелә. Йолдызлар атмосферасы физикасын фәнни өйрәнүнең Н.А.Сәхибуллин җитәкләгән юнәлеше Россиядә һәм чит илләрдә танылган. 1975 тән астрономик күзәтүләр *Төньяк Кавказ астрономия станциясендә* уздырыла. 1998 дә Төркиядә Казан ун-тының 1,5 *м* лы яңа телескобы Бакырлы Тепе тавында төзелеп бетә (к. *Оптик телескоп*). Телескоптан күзәтүләр РФАнең Космик тикшеренүләр ин-ты (Мәскәү) һәм Төркиянең милли обсерваториясе галимнәре б-н берлектә алып барылачак.

Казан астрономнары TD-1A, BUSS иярченнәрендә, Ла-Пальма (Канар утраулары) обсерваториясенең 2,5 *м* лы телескобында халыкара проектлар буенча күзәтү эшләрендә катнашалар. Фәнни тикшеренүләр РФАнең Махсус астрофизик обсерваториясе (Түбән Архаз пос., Карачай-Чиркәс Респ-касы), РФАнең Астрономия ин-ты (Мәскәү), Кырым астрофизика обсерваториясе (Научный пос., Кырым өлкәсе), Мюнхен ун-тының (ГФР) Астрономия һәм астрофизика ин-ты, Макс Планк астрофизика ин-ты (Гархинг ш., ГФР) һ.б. астрономнар б-н берлектә уздырыла.

1930 елларда *Казан астрономия-геодезия җәмгыяте* оеша. 1893–1996 да *«Труды Казанской городской астрономической обсерватории»* («Казан шәһәренең астрономик обсерваториясе хезмәтләре»), 1910–96 да — *«Известия Астрономической обсерватории Энгельгардта»* («Энгельгардт астрономия обсерваториясе хәбәрләре»), 1934–65 тә — *«Бюллетень Астрономической обсерватории им. В.П.Энгельгардта»* («В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясе бюллетене»), 1943–54 тә «Астрономик циркуляр» («Астрономический циркуляр») исемендә Бөтенсоюз ж-лы (Казан) нәшер ителә. 4 кече планетага һәм 9 ай кратерына Казан астрономнарының исеме бирелә.

*Әд.:* Баранов В.А. Энгельгардтовская обсерватория, её возникновение и развитие (1901–1935 гг.) // Изв. Астрон. Энгельгардтовской обсерватории Казан. ун-та. 1937. Т. 1, вып. 1; Воронцов-Вельяминов Б.А. Очерки истории астрономии в России. М., 1956; Колчинский И.Г., Корсунь А.А., Родригес М.Г. Астрономы: Биогр. справ. Киев, 1986.

*Л.И.Машонкина.*

**АСТРОНО́МИЯ ОБСЕРВАТО́РИЯСЕ**, Казан ун-тының Астрономия обсерваториясе, В.П.Энгельгардт исемендә. Казаннан 20 *км* көнбатыштарак, Горький тимер юлы «Обсерватория» станциясеннән 1,5 *км* төньяктарак урнашкан. Обсерватория 1899–1901 дә Д.И.Дубяго җитәкчелегендә төзелә. Анда В.П.Энгельгардтның Дрездендагы шәхси обсерваториясенең Казан ун-тына 1897 дә бүләк итеп бирелгән җиһазлары куела. 1901 нең 21 сентябрендә ачыла. Баштарак Энгельгардт обсерваториясе дип атала (1931 елдан хәзерге исемдә). Җиһазланышы ягыннан Россиядәге иң яхшы Мәскәү ун-ты обсерваториясеннән калышмый. Эшли башлавының беренче елларында 12 дюймлы Энгельгардт рефракторы, Репсольдның меридиан әйләнәсе, ике пассаж инструменты, Тиде һәм Кноблих сәгатьләре була. 1908 дә Казан шәһәр обсерваториясеннән аңа Репсольд гелиометры күчерелә, 1914 тә 120 *мм* камералы Петцвальд астрографы сатып алына. 1930 еллардан соң обсерватория башка заманча инструментлар б-н җиһазлана, шулар арасында аеруча әһәмиятлеләре: Шмидт системасындагы 15 дюймлы телескоп (СССРда беренче), ЗТЛ-180 зенит телескобы, АЗТ-14 рефлекторы куелган йолдызлар электрофотометры, менисклы телескоп, Айны өйрәнү өчен горизонталь фотографик телескоп. 1951 дә А.о.нең сейсмик подвалында Җирнең эчке төзелеше һәм аның сыгылмалылык үзенчәлеге мәсьәләсен хәл итүдә гамәли әһәмияте булган асма сызыкларның тирбәнүен күзәтү эшләре башлап җибәрелә. Башта А.о. астрометрик бүлектән генә тора. 1932 дә астрофизика бүлеге, 1957 дә метеорлар бүлеге, 1971 дә Ай бүлеге оештырыла, 1989 да ул фотографик астрометрия бүлеге дип үзгәртелә. А.о.нең фәнни эшчәнлегендә аның китапханәсе мөһим урын тота. Яңа аппаратура әзерләү һәм инструментлар ремонтлау өчен 1935 тә механика остаханәсе, 1970 тә конструкторлык төркеме оештырыла. Казан тирәсендә астроклиматик шартлар кыенлашкач, 1975 тә Казан ун-тының *Төньяк Кавказ астрономия станциясе* оештырыла, аңа А.о.нең Шмидт системасындагы телескобы һәм «Цейсс» немец фирмасының киң почмаклы астрографы тапшырыла. Күзәтүләр өлешчә шушы станциядә уздырыла. А.о.нең беренче этап эшчәнлегендә йолдызлар, планеталар, ш.и. Ай әйләнүен, Айның рәвеше үзгәрүен, ш.у. кометалар хәрәкәте теориясе буенча астрометрик күзәтүләр алып барыла. А.о. хезмәткәрләре, башка обсерваторияләр хезмәткәрләре б-н берлектә, СССРда кабул ителгән (1932) фәнни программаларны: «Геодезик йолдызлар каталогы» һәм «Тонык йолдызлар каталогы» төзүдә катнашалар. Ш.у. елда Бөтенсоюз астрофизика конференциясе А.о.нә башка астрономик учреждениеләрдә тотыла-үзгәрә торган йолдызларны тикшерүне оештыру, планлаштыру эшен йөкли. 1931 дә Кояшны күзәтү эшләре башлана. 1932 дән обсерваториядә катлаулы геофизик күренеш — географик киңлекнең үзгәрүчәнлеге системалы күзәтелә. 1988 гә кадәр андый тикшеренүләр Полюс хәрәкәтен Халыкара күзәтү хезмәте (Мисузава ш., Япония) һәм Халыкара вакыт хезмәте (Париж) кысаларында уздырыла. 1984 тә Җирнең әйләнү параметрларын билгеләүнең Дәүләт хезмәте (Дәүләт стандарты, Мәскәү) оештырыла, А.о.дә шул челтәргә керә. 1960 тан Галактиканың

структурасын аныклау максаты б-н йолдызларны астрономик тикшерүләр активлаша. Шмидт системасындагы телескоп, күзәтү материаллары алу өчен 1964 тә А.о.нән Алма-Атаның биек тавындагы П.К.Штернберг исем. Дәүләт астрономия ин-тына күчерелә. Йолдызларны фотометрик һәм спектраль күзәтүләр А.о.ндә менисклы телескоп ярдәмендә уздырыла, 1955 тә метеорлар радиолокация ысулы б-н өйрәнелә башлый. Күк йөзендә метеорлар ташкыны таралу тыгызлыгын өйрәнү максатында метеорлар радиокайтавазын автоматик теркәүче махсус аппаратура булдырыла. Алга таба бу тематика Кояш системасындагы кече җисемнәрнең динамикасы һәм физикасы проблемаларын өйрәнүгә кадәр киңәйтелә һәм тирәнәйтелә. Казан астрономия фәнни мәктәбе Айның рәвеше һәм әйләнүе үзгәрүен, тотыла-үзгәрә торган йолдызларны тикшерү, планетаара киңлектәге метеор матдәләрне, яктылык нурларының җир атмосферасында сынуын астрометрик өйрәнүләре б-н бөтен дөньяга таныла. А.о.дә хәл ителә торган төп фәнни мәсьәләләр Айның селенодезиясе һәм динамикасы, фундаменталь һәм фотографик астрометрия проблемалары б-н дә бәйле. Җирнең ясалма иярченнәре җибәрелгәннән соң, А.о.ндә аларны визиуаль һәм фотографик күзәтүләр өчен станция оештырыла (1957–67). Айны өйрәнү проблемасына аеруча әһәмият бирелә. Казан шәһәр обсерваториясе һәм А.о. 80 ел буена диярлек өзлексез алып барган гелиометрик күзәтүләр дәвамлыгы һәм беришлеге буенча дөньяда бердәнбер булып тора. Ракета-космик ысуллар б-н өйрәнүгә кадәр үк алар Айның рәвеше һәм әйләнүе турында кызыклы мәгълүматлар алырга мөмкинлек бирә. Бу мәгълүматлар космик аппаратлар һәм корабларның Айга очышын планлаштырганда файдаланыла. 1949–52 дә А.о.дә фотографик ысулдан файдаланып, горизонталь телескоп аша Ай сурәтләре алына һәм аларны Айның физик либрациясен өйрәнү өчен кулланып булуы исбатлана. А.о.нең 1970–75 тә СССР ФАнең Космик тикшеренүләр ин-ты б-н берлектә Нахичевань тавына оештырылган экспедициясендә астрономиядәге күп кенә селенодезик мәсьәләләр принципиаль яңа ысуллар б-н хәл ителә һәм Айның йолдызлар фонындагы уникаль сурәтләре төшерелә. Айның өслеген Җирдән, ш.у. космостан торып картага төшерүгә зур әһәмият бирелә. Йолдызларның Ай түгәрәге б-н каплануын системалы рәвештә фотоэлектрик ысул б-н күзәтә торган А.о. кебек обсерваторияләр күп түгел. Шундый күзәтүләр нигезендә күп кенә координата-вакыт мәсьәләләре хәл ителә һәм 12 йолдызның диаметры билгеләнә, моның хәзерге заман астрономиясе өчен әһәмияте гаять зур. Астрометрия өлкәсендә йолдызлар торышының фундаменталь мәсьәләсен хәл итү һәм иң яхшы авышу системасын эзләү юлларын аерып күрсәтергә кирәк. А.о. дөньякүләм әһәмияткә ия булган төрле программалар буенча йолдызлар торышын күрсәткән күп кенә каталоглар төзи. Әлеге тематика б-н астрономик рефракция проблемасы тыгыз бәйләнгән. 1960–75 тә яктылык нурының Җир атмосферасы аша үтүе теориясе буенча фундаменталь тикшеренүләр уздырыла. Рефракциянең яңа теориясе Җир атмосферасының төзелеше турындагы соңгы мәгълүматларга нигезләнеп төзелә. Географик киңлекнең үзгәрүчәнлеген системалы күзәтү бу катлаулы геофизик проблеманы хәл итүгә билгеле бер өлеш кертә. ЗТЛ-180 телескобында үткәрелгән күпьеллык үлчәүләр нигезендә Халыкара астрономия берлегенең фундаменталь системасына 1976 да кабул ителгән даими нутациянең теоретик әһәмияте раслана, ул мөһим фәнни һәм гамәли әһәмияткә ия. А.о.ндә Кояш системасындагы күп кенә җисемнәр: зур планеталар һәм аларның иярченнәре, астероидлар һәм кометалар торышы күзәтелә һәм фотога төшерелә. Галлей кометасының соңгы мәртәбә күренүен А.о.ндә һәм Зеленчук станциясендә фотографик күзәтү бик күп күзәтүләр арасында иң төгәле һәм күләмлесе дип табыла. А.о.ндә планетара киңлектәге метеор матдәсен өйрәнүгә, метеорлар астрономиясенең статик мәсьәләләренә, Кояш системасындагы кече җисемнәрнең үзара бәйләнешенә: метеор җисемнәргә, астероид һәм кометаларга, метеор җисемнәр физикасына аеруча зур әһәмият бирелә. А.о. хезмәткәрләре Төньяк Казакъстанда (1936), Алма-Ата тирәсендә (1941), Ярославль шәһәрендә (1945), Тихорецк (1954), Джанкой (1961) шәһәрләре һәм Байкал күле (1981) тирәләрендә Кояшның тулысынча тотылуын күзәтүдә катнашалар. 1936, 1945 тә, болытлар калын булганлыктан, күзәтүләр уздырылмый. Кояшның хромосферасы һәм таҗы физикасы өлкәсендә өстәмә нәтиҗәләр алына. А.о.ндә илебездәге, ш.и. Казандагы астрономик тикшеренүләр тарихы буенча эшләр башкарыла. Фәнни эшчәнлек б-н бергә , А.о.ндә гамәли мәсьәләләр дә хәл ителә. 1930 елларда халык хуҗалыгын үстерү өчен астрогеодезик һәм гравиметрик эшләр башкару мөһим була. А.о. галимнәре тарафыннан ТАССР һәм Казакъстандагы күп кенә нокталарның төгәл географик координатлары билгеләнә, Татарстаннан алып Кузнецк бассейнына кадәр йөзләрчә гравиметрик нокталарда авырлык көче үлчәнә. А.о. галимнәре катнашында төзелгән йолдызларның геодезик каталогы СССР терр-ясен геодезик сурәтләү өчен файдаланыла. Географик киңлекләрне күзәтү буенча 1984 тән соң алынган мәгълүматлар Россиядә төгәл вакыт проблемасын хәл итү өчен кулланыла, ә Халыкара вакыт хезмәте аны 1988 гә кадәр төгәл вакыт шкаласын урнаштыру өчен дә файдалана. А.о.нең планетаара киңлекләрдәге метеор матдәләрне тикшерү мәгълүматлары буенча А.о.ндә космик киңлекләрдә метеор кисәкчекләр атылганда техник җайланмаларның ышанычлы эшләвен хисаплау һәм кешенең иминлеген саклау өчен файдаланыла торган стандарт булдырыла. Астрономияне үстерүгә зур өлеш керткән һәм төрле елларда А.о.ндә эшләгән галимнәр: Т.А.Банахевич, В.А.Баранов, И.В.Белькович, О.И.Белькович, С.Г.Вәлиев, М.А.Грачёв, К.К.Дубровский, А.Д.Дубяго, Д.И.Дубяго, И.А.Дюков, В.А.Крат, Д.Я.Мартынов, А.А.Нефедьев, А.И.Нефедьева, Н.Г.Ризванов, Ш.Т.Хәбибуллин, А.А.Яковкин. А.о. хезмәткәрләренең күбесе соңрак башка оешмаларда җитәкче урыннарны били. Д.Я.Мартынов — озак еллар ДАИШ директоры, В.А.Крат — СССР ФАнең Баш обсерваториясе (С.-Петербург ш. тирәсендә) баш астрономы, А.А.Яковкин — Украина ССР ФА об-



В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясенең төп бинасы һәм меридиан әйләнәсе павильоны. 1910 елгы фото.



В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясенең администрация корпусы.



В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясенең гелиометр урнаштырылган бинасы.

серваториясенең (Киев ш.) баш астрономы, Т.А.Банахевич Ягеллон ун-ты астрономия обсерваториясе (Краков ш.) директоры була. Проф. К.К.Дубровский Горький киңлек станциясенә нигез сала. А.о.ндә 15 физ.-матем. фән. д-ры, 28 фән. канд-ты әзерләнә. 6 хезмәткәр — *Халыкара астрономия берлеге,* 3 кеше Европа һәм Россия астрономия җәмгыятьләре әгъзасы. А.о. «*Известия Астрономической обсерватории Энгельгардта*», («*Энгельгардт Астрономия обсерваториясе хәбәрләре*», 1908–94) ж-лын һәм «*Бюллетень Астрономической обсерватории им. В.П.Энгельгардта*» («В.П.Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе бюллетене»н, 1934–65) нәшер итә.

*Әд.:* Баранов В.А. Энгельгардтовская обсерватория, её возникновение и развитие (1901–1935 гг.) // Изв. Астр. Энгельгардтовской обсерватории Казан. ун-та. 1937. Т. 1, вып. 1; Мартынов Д.Я. Астрономическая обсерватория им. В.П.Энгельгардта (1901–1951) // Изв. Астрон. обсерватории им. В.П.Энгельгардта. 1951. № 27; Астрономия в СССР за сорок лет. М., 1960; Нефедьев А.А. 75 лет Астрономической обсерватории им. В.П.Энгельгардта // Изв. Астрон. Энгельгардтовской обсерватории. 1978. № 44; Селенодезические исследования в СССР: Библиогр. указ. 1928–1975 гг. Киев, 1978; Cometary Astrometry. IHW-Proceedings ofa workshop held june 18–19, 1984, at the European Southern Observatory Headquarters in Garching, Federal Republic of Germany. November 15, 1984 / Editor D.K.Yeomans. JPL, California Institute of Technology with NASA; Archive of Observations of Periodic Comet Crommelin Made During its 1983–1984 Apparation / Editor Z.Sekanina. NASA, JPL. 1985.

*Н.Г.Ризванов.*

**АСТРОФИ́ЗИКА**, астрономия фәненең бер бүлеге, күк җисемнәрендәге һәм космик киңлектәге физик күренешләрне һәм химик процессларны өйрәнә. А. галәмдәге физик процесслар турында мәгълүмат алу ысулларын эшләү, астрономик күзәтүләр ярдәмендә шул мәгълүматны фәнни эшкәртү һәм теоретик гомумиләштерү б-н шөгыльләнә. Күзәтү А.сы ысулларын берләштереп, гамәли А. дип атыйлар. Күзәтелгән объектлары буенча Кояш физикасы, планеталар физикасы, йолдызлар физикасы һ.б. аерып карала. Теоретик А. физика законнары һәм ысуллары нигезендә фактик мәгълүматларны аңлату һәм гомумиләштерү б-н шөгыльләнә.

Борынгы Греция астрономы Гиппарх (б.э.к. 180–125 еллар тирәсе) хезмәтләрен беренче астрофизик тикшеренү дип санарга мөмкин. Ул, ялтырап күренүләренә карап, йолдызларны 6 класска бүлгән. Әмма А. тууын 17 йөз башларында телескоптан астрономик күзәтүләр алып бару б-н бәйләргә кирәк. Италия астрономы Г.Галилей Ай һәм Кояш өслекләрен өйрәнә, Венераның фәзалары күренешен, ә 18 йөздә М.В.Ломоносов Венерада атмосфера булуын ача. Хәзерге заман А.сының барлыкка килүе Кояш һәм йолдызларның спектрларын алу өчен спектрга таркату приборларын куллану б-н бәйле. Инглиз галиме У.Х.Волластон тарафыннан Кояш спектрындагы кара сызыклар (таплар) ачылу (1802) һәм немец физигы Г.Р.Кирхгоф б-н химик Р.В.Бунзен тарафыннан спектраль анализ законнары ачылу (1859–62) йолдызларның табигатен аңларга ярдәм итә. 19 йөзнең 90 нчы еллары башыннан йолдызларның спектрын өйрәнү өчен телескопларны спектрографлар б-н тәэмин итәргә керешәләр. Рус астрономы А.А.Белопольскийны хәзерге заман А.сына нигез салучыларның берсе дип санайлар. 20 йөзнең 1 нче яртысында квант механикасы һәм йолдызлар атмосферасындагы ионлашу теориясенең барлыкка килүе һәм йолдызлар спектрларын интерпретацияләү йолдызлар физикасын һәм йолдызлар атмосферасы теорияләрен үстерергә мөмкинлек бирә. Күктәге объектларның нурланышын спектраль анализлау аларның тыгызлыгын, темп-расын, химик составын, эчке хәрәкәт тизлеген, магнит кырлары булуын билгеләргә ярдәм итә. А. үсешенең икенче этабы күзәтүләрне киңрәк спектраль диапазонда үткәрүгә бәйле. 20 йөз урталарында радиоастрономия барлыкка килә, 1970 еллар башыннан иярченнәрдән күзәтүләр ярдәмендә ультрамиләүшә, рентген һәм гамма диапазоннарда нурланыш спектрлары алына. Квазарлар, галактикалар төше, пульсарлар һ.б. объектлар



Менисклы телескоп (В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе).

ачыла, аларның табигате йолдыз һәм планеталардан, йолдызара матдәдән үзгәрәк. Яңа А. барлыкка килә, ул, гравитация көчләре һәм тигезләнешле нурланыш процессларыннан тыш, электромагнитик, төштәге һәм җиңелчә тәэсирләшүләрнең мөһим ролен исәпкә ала, электромагнитик дулкыннар һәм элементар кисәкчекләр нурланышының барлык мәгълүм механизмнарын, релятивистик динамиканы һәм релятивистик тартылу теориясен куллана. Шулай итеп, ул барлык физик белемнәрне, экстремаль торыштагы матдәнең үзлекләре теориясен дә кертеп, исәпкә алып эш итә. Хәзерге заман А.сына: югары энергияләр, төш һәм нейтрино, релятивизм һәм квантлы релятивизм бүлекләре керә.

Казан ун-тында астрофизик тикшеренүләр 19 йөз ахырларыннан алып барыла. Астроном П.Богоявленский 1893 елда алмаш йолдызларны беренче булып күзәтә, системалы күзәтүләр 1920 елларда башлана (А.Д.Дубяго, Д.Я.Мартынов, В.А.Крат). 1930–40 елларда Казан тыгыз куш системаларны өйрәнүдә СССРда әйдәп баручы үзәк булып китә һәм бу юнәлеш *Казан астрономия фәнни мәктәбе* өчен традициягә әверелә. М.И.Лавров куш системалардагы йолдызларның массасын һәм зурлыгын билгеләү ысулын эшли (1976). Бу системаларны спектраль күзәтү башлана, алар РФАнең Махсус астрономия обсерваториясендәге 6 *м* лы телескоп ярдәмендә башкарыла. 1940 еллар ахырында Ш.Т.Хәбибуллин йолдызлар астрономиясе юнәлешендә тикшеренүләр башлап җибәрә. Ул караңгы томанлыкларны өйрәнү һәм йолдызларның икеләтә нурланышын санау анализы ысулларын тәкъдим итә (1949), Галактикада йолдызларның таралу тыгызлыгын тикшерә.

1970 еллар башында яңа астрофизик юнәлеш — йолдызларның физик параметрларын аларның спектрларын санча модельләштерү юлы б-н өйрәнү формалаша. 1972 дә Н.А.Сәхибуллин СССРда беренчеләрдән булып локаль термодинамик тигезләнеш гипотезасын кулланмый гына йолдызлар спектрын яңача анализлауны гамәлгә ашыра. Йолдызлар атмосферасы физикасы буенча ул җитәкләгән фәнни өйрәнү юнәлеше Россиядә һәм чит илләрдә танылa. Казан ун-тында локаль термодинамик тигезләнештән баш тарту нәтиҗәсендә кайбер ионнарның (CIII, CIV, NIV, SrII, EuII h.б.) спектраль сызыкларын анализлау эшләре башкарыла. Галактиканың химик эволюциясен һәм йолдызлар эволюциясен өйрәнү өчен әһәмиятле булган тикшеренүләр үткәрелә — химик элементларның составы тикшерелә. Нурланышны күчерүне санча модельләштерү юлы б-н аккрецион дисклы системалардагы физик процесслар өйрәнелә. Спектраль күзәтүләр өчен 1998 дә Казан ун-тының югары мөмкинлеккә ия 1,5 *м* лы яңа телескобын төзү эшләре төгәлләнә (Төркиядә урнаштырыла).

*Әд.:* Мартынов Д.Я. Курс общей астрофизики. М., 1988; Сахибуллин Н.А. Методы моделирования в астрофизике. Ч. 1. Звёздные атмосферы. К., 1997; Колчинский И.Г., Корсунь А.А., Родригес М.Г. Астрономы: Биогр. справ. Киев, 1986; Физика космоса: Маленькая энцикл. М., 1986.

*Л.И.Машонкина.*

**АСФАЛЬТИ́Т ЧЫГЫШЫ́**, геологик табигать истәлеге (1981). Чирмешән р-ның Түбән Карамалы авылыннан 3 *км* көньяктарак, Чишмә елгасының сул кушылдыгы — Урта инеш ярында урнашкан. Мәйданы 4 *га*. А.ч. үз эченә тирән битум ятмасын алган нык яргаланган борынгы Пермь токымнары б-н бәйле. Казан ярусының төп токымнарын каплаган дүртенчел система комсыл һәм балчыклы утырмалары оксидлашкан куе нефть-асфальтит б-н туенган. Борынгы рельеф иңкүлекләрендә асфальтит туплану дүртенчел чорның соңгырак дәверендә битум күле барлыкка килүгә һәм бу күлдә күпсанлы органик калдыкларның сакланып калуына китерә, шулар арасында моллюскларның 8, амфибияләрнең 1, кошларның 37, бөҗәкләрнең 30, имезүчеләрнең 18, үсемлекләрнең 8 төре билгеләнгән. Түбән Карамалы сакланышының казылма флора һәм фаунасын җыю В.А.Чердынцев (1941, 1944), фәнни өйрәнү

эшләре Н.К.Верещагин (1953) тарафыннан үткәрелә. Комплекслылыгы буенча бу сакланыш уникаль һәм шул типтагы мәгълүм булган Старунь (Галиция, хәзер Көнбатыш Украина терр-ясе), Бинагадах (Әзәрбайҗан), Ранчо ля Бреа (АКШ, Калифорния штаты) сакланышлары б-н бер рәттә тора.

*Әд.:* В е р е щ а г и н Н.К. Захоронение остатков верхнеплейстоценовых животных и растений у селения Нижние Кармалки на юге ТАССР // Зоолог. журн. 1953. Т. 32, вып. 5; Волжская фауна млекопитающих в Геолого-минералогическом музее Казанского университета. К., 1992.

*Н.Л.Фомичёва.*

**АСФАЛЬТИТЛА́Р**, каты табигый *битум*нар төркеменең берсе. Нефтьнең гиперген (тышкы) шартларда оксидлашу процессляры, ш.и. җир асты сулары йогынтысында Җир өстендәге яисә Җир астындагы биологик деградация һәм физик җиллэнү нәтиҗәсендә үзгәрүеннән хасил була. Улаксыман һәм яссы катлам рәвешендә очрый. Бензол, хлороформ,



Асфальтит. Шөгер битум чыганагы.

күкертле углеродта эри. Элементлар составы (%): C — 76–86, $H_2$ — 8–12, S — 0,25–9, N — 0,3–1,8, $O_2$ — 2–9. Төп составы асфальтеннардан (70% ка кадәр) һәм майлардан (30% ка кадәр) гыйбарәт. А.ның катламлы чыганаклары Татарстан чигенә якын гына, Башкортстанның көнбатышында (структур бораулауның Калтасы мәйданы) һәм Оренбург өлкәсенең төньягында (Садки чыганагы) табылган. А. аз күләмдә Сок-Чишмә валы (ТРның көньягы) табигый битум чыганакларында очрый. Лак, махсус замазка, җилем, изоляция материаллары һ.б. эшләп чыгаруда кулланыла (к. *Асфальтит чыгышы*).

**АТ АСРАУЧЫЛЫ́К**, терлекчелек тармагы. Борынгы дәвердә барлыкка килә (Европа һәм Азиядә б.э.к. 4 нче меңьеллыктан мәгълүм). Ат, кулга һәм йортка ияләштерүдән соң, хәрби эштә, кешеләрнең хуҗалык һәм рухи тормышында әһәмиятле роль уйный. Күп кенә борынгы халыкларда (ш.и. скифлар, һуннар, төркиләр, Урта Идел һәм Урал алды халыклары) А.а. хуҗалыктагы төп шөгыльләрнең берсе булып санала. 16 гасыр урталарында Казан ханлыгына атлар Ногай Урдасыннан китерелә.

Крәстиян хуҗалыкларында атларны башлыча йөк ташу өчен кулланалар. Казан губернасында нәселле чабыш һәм йөк ташу (җигеп йөрү) атлары алпавытларның ат з-дларында үрчетелә (Лаеш өязендә А.Горский, А.Толстой, Зөя өязендә Д.Нарышкин). Иң эре ат асрау заводлары тотучылар — җирбиләүче Молоствовлар нәселе була (Спас өязенең Өчкүл, Никольский, Куралово а.). Губернадагы атларның яртысыннан артыгы — гаскәр-





1. Рус юртагы; 2. Токымы яхшыртылган эш аты.

ләрдә атланып йөрү, унынчы өлеше артиллериядә йөк тартуда файдалану өчен яраклы була. Армиягә атларны куелган тәртип б-н түләп алалар.

1985 елда Казан һәм Лаеш өязләрендә 5 ат асрау заводы (хуҗалары — 1 гильдия сәүдәгәр Макашин, дворяннар С.Толстой һәм П.Останков), Мамадыш өязендә бер завод (статский советник Лебедев) һәм Чистай өязендә бер завод (А.Стрекалов) исәпләнә.

20 нче йөз башында Казан губернасында иң эре һәм мәгълүм ат заводлары Спас, Лаеш, Казан һәм Зөя өязләрендә (тиңдәшле рәвештә 11, 10, 8, 3 завод) була. Кармыш волосте Казанбаш авылында (Казан сәүдәгәре Г.Ишморатов), Казанда (Я.Максимов, Д.Ситников) ат асрау заводлары төзелә. Атларны сату-алу базарлары да эшли. Базарларның күбесе Спас өязендә (Матвеевка, Базарлы Матак, Пичкас, Кузнечиха а.) тупланган була. 1902 елда Казанда сәүдәгәр Л.Кекин иганәчелегендә 1 нче атлар күргәзмәсе («Эрмитаж»да, шәхси бакчасында) оештырыла. Күргәзмәдә 64 эш һәм чабыш аты күрсәтелә. Атларның баш саны турындагы беренче статистик мәгълүматлар Казан губернасында 19 йөзнең 2 нче яртысында күренә башлый: 1856 да — 359,6 мең, 1864 тә — 467,1 мең, 1883 тә — 300 мең тирәсе, 1886 да 445,6 мең баш. Крәстиян хуҗалыкларының атлар б-н тәэмин ителеше бик түбән була. 1900 елда хуҗалыкларның 24,9% ы атсыз, бер атлылар — 44,3%, ике атлылар — 20,6%, 3 әр атлы хуҗалыклар 10,2% тәшкил итә (атларның гомуми саны 440,6 мең баш).

1917 дә губернада 571,5 мең ат исәпләнә; хуҗалыкларның яртысы атсыз була. 1920 нче елларда республика хөкүмәте атлар үрчетү буенча карарлар кабул итә, чит өлкәләрдән атлар сатып алуга озак вакытлы кредитлар бирелә.

Молоствовларның ат з-длары нигезендә М.Вахитов исем. Дәүләт ат з-ды (Спас ш.) төзелә. Заводның төп бурычы итеп чиста токымлы Орлов атларын, ш.у. Орлов һәм Америка токымнарыннан яңа — метис токым үрчетү бүлеген оештыру һәм ТАССРның Җир эшләре халык комиссариатының Казандагы Үзәк ат конюшнясын тулыландыру куела; ш.у. Бөгелмә, Минзәлә, Спас, Тәтеш, Чистай кантоннарында да конюшняның бүлекчәләре эшли. Авыр йөк ташу атлары үрчетү өчен Мамадыш кантонында Нырты нәселле ат үрчетү бүлеге оештырыла. Әмма а.х.нда көчләп күмәкләштерү нәтиҗәсендә республикада атларның баш саны кимү дәвам итә.

1934 тә Татарстанда — 340,3 мең, 1940 та 333 мең ат исәпләнә. Бөек Ватан сугышы елларында А.а.ка зур зыян килә; 1952 дә республикада барлыгы 131,2 мең ат исәпләнә. Авыл хуҗалыгын механикалаштыруга бәйле рәвештә, сугыштан соңгы елларда йөк ташу көче буларак, атларның әһәмияте югала башлый.

2000 дә ТРда бар төр хуҗалыкларда ат саны — 64 мең баш, 2004 тә — 56,4 мең, 2007 дә 27,1 мең баш (шәхси хуҗалыклардан тыш) тәшкил итә. Хәзерге вакытта 4 төрле нәселле ат үрчетелә: рус юртагы (барлык баш саныннан 61%), Орлов юртагы (15,7%), Владимир авыр йөк аты (7,8%), рус авыр йөк аты (5,5%).

Нәселле атлар үрчетү б-н «Татарский» (Спас р-ны), «Нурлат» (Нурлат р-ны), «Казан» (Питрәч р-ны) ат з-длары шөгыльләнә. Республикада 3 дәүләт ат конюшнясы (Буа, Минзәлә, Чистай), 7 нәселле ат фермасы, ш.и.



Көтүлектә.

«Уңыш» (Мөслим), «Архангел» (Яңа Чишмә), «Актай» (Аксубай), «Өмет» (Биектау) эшләп килә.

А.а. ашамлыклар җитештерү, ш.у. медицинада һәм ветеринариядә куллану өчен төнәтмә һәм препаратлар (буаз бияләр сывороткасы, грippка, дифтериягә, ботулизмга каршы сывороткалар, ашказаны согы) алу өчен әһәмиятен югалтмаган. 1940–60 елларда Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни тикшеренү ин-тында дифтериягә каршы төнәтмә эшләнелә. Бия сөтеннән кымыз — дәвалау әчемлеге әзерләнә. «Тарловский» санаториендә (Чаллы ш.) кымыз б-н дәвалау алып барыла. 1990 елларның 2 нче яртысыннан республикада *ат спорты* үсешенә зур игътибар бирелә.

*Әд.:* П о п о в И.П. О движении крестьянского скотоводства Казанской губернии. К., 1858; ш у л у к. Породы домашних животных и птиц. СПб.,

1909; К а л и н и н В.И., Я к о в л е в А.А. Коневодство. М., 1966; БЭС. Т. 13. М., 1973.

*Ә.Х.Фазылҗанов, Х.А.Абдулкаюмов, Т.П.Жучкова.*

**АТ СПОРТЫ́**, атка атланып йөрү һәм алар б-н идарә итү төрләре, спорт максатларында ярышлар уздырыла.

А.с.ның заманча төрләре: җигүле ат, конкур (каршылыкларны сикереп чыгу), ике төр ярыш (манежда йөрү, конкур), өч төр ярыш (манежда йөрү, кыр сынаулары, конкур), ат чабышы, юырту, стипл-чейз, кросс, атлы аучылык, драйвинг, атлы-чаңгы ярышлары, ат ярышлары, атта күнегүләр ясау (вольтижировка), джигитовка (атта оста йөрү), тройка һәм тачанкалар ярышлары, пушбол уеннары, атка атланып туп уйнау. Казан һәвәскәр ат ярышлары җәмгыяте 1867 елда оештырыла (оештыручылар — ат з-ды тотучылар Н.Н.Кудрявцев, В.П.Молоствов, Г.Ә.Ишморатов, рәисе — И.Полторацкий), беренче юртаклар сынавы 1868 елның кышында Кабан күлендә уздырыла. Казан губернасының иң яхшы юртаклары: Аккредитив — Россия Дерби ярышы җиңүчесе (1907), Смельчак — Император призына уеннарда 2 нче урын (1907), Набат, Успех, Игла, Ловкий — төрле дистанцияләрдә Казан ипподромының җитезлек буенча рекордчылары.

1920–40 елларда Казан ипподромында даими рәвештә республиканың колхоз, совхоз, ат з-длары һәм дәүләт конюшняларының юртаклары сынала. Бу вакыттагы иң яхшы җайдаклар — М.Курицин, И.А.Матяев, Ф.Ф.Кашафетдинов, С.Макеев, П.Поляков, М.Угольков, М.Арсланов, П.Егоров-Дунай, Кар-Дидя, Миф, Драгист һ.б. рекордчы юртакларда чыгыш ясый. Казан ипподромының иң яхшы җайдаклары, 1950–70 елларда призлы чабышлар осталары: Х.Б.Гайнуллин, Җ.И.Хәбибуллин, С.Н.Староверов, А.М.Кузнецов, И.Ганчурин, Н.Н.Гришин, А.И.Булыгин. Алар тарафыннан җитез юртаклар, СССР, ТАССР, Идел буе рекордчылары — Док, Пихта, Ваза, Боярыня, Доспех, Кудесник, Рига, Талисман, Эфир, Орион һ.б. әзерләнә. Татарстан атчыларының җыелма командасы — Идел буе кубокларын ала (1955–58, 1960, 1962–65, 1968, 1976, 1986, 2001), Бөтенроссия ат ярышларында җиңә (1998) һәм призлар ала (бронза, 2003; көмеш, 2004). 1990 елларда ТРның иң яхшы спортчылары, ТР, РФ чемпионатлары һәм кубоклары җиңүчеләре һәм призёрлары, Зур Дерби призы, Элита призы, Дөнья призы һ.б. призлар ияләре — С.Н.Бакурин, Г.Г.Большаков, А.И.Булыгин, Е.В.Гришаева, К.Закирова (конкур), С.Н.Невкипилый, С.Прохоров (конкур), Ф.Халиков һ.б. ТР ат спортының классик төрләре буенча иң яхшы тренерлары — М.Р.Закиров, М.Н.Злобина, А.М.Щербаков, И.Н.Щербакова, Г.М.Галиева. ТРның иң яхшы юртаклары, СССР (РФ) рекордчылары — Рангоут, Ландр, Фараон, Аргон, Ледок, Панасоник, Заварзай, Массив, И я Кстати, Кокетливый, Абордаж, Позитрон, Ламборн.

ТР да «Аргамак» (Казан), «Тулпар» (Чаллы), «Кентавр» (Алабуга), «Буцефал» (Азнакай р-нының Актүбә пос.), «Мустанг» (Лениногорск), «Ягуар» СК (Нурлат), «Елховнефть» НГДУында, балалар-яшүсмерләр ат спорты мәктәпләре, ш.у. Зәй, Әлмәт, Буа, Тәтеш шәһәрләрендә клублар эшли. *Сабан туе* бәйрәмендә уздырыла торган ат ярышларының традициягә кергән төрләре: ат чабышлары, юртаклар узышы, ияр астында юртаклау, джигитовка (атта оста йөрү), «Пар ат» (парлап җигелгән атта ярыш), рус тройкасы (рус өчлеге), «Кыз куу», «Сөрән сугу» милли уеннары һ.б.

2005 елда Казанда Халыкара ат спорты комплексы ачыла, анда ТР һәм РФ президентлары, РФ А.х. министрлыгы, Татарстанның Алтын дагасы (2001 дән уйнатыла, 2005 тән халыкара статус), Казан Кремле,



Юртаклар ярышта.

ТРның ат үрчетү һәм ат спорты федерациясе, Бөтенроссия дербистлары (РФ рекордчысы, Элита призының 4 тапкыр җиңүчесе — Ронгаут), Критериум, Казанның 1000 еллыгы призлары уйнатыла.

2004 тән ТРның ат үрчетү һәм ат спорты федерациясе «Аргамак» ж-лын чыгара (баш мөхәррире — М.А.Поливанов).

*Әд.:* Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. Сабантуй (научно-популярный очерк). К., 1977.

**АТ СПОРТЫ́ КО́МПЛЕКСЫ**, Казанда. Европада иң эре халыкара спорт комплексларының берсе, 2005 елның 27 августында Казанның 1000 еллыгына ачыла. Гомуми мәйданы 92 *га*, аңа — керү зонасы (кассалар, автомобильләр өчен 2000 урын); спорт уеннары — демонстрацияләр зонасы (чабыш юлы — 1800×28 *м*, юырту юлы — 1600×28 *м*, 2000 урынлы ачык трибуна, 4000 урынлы ябык трибуна, конкур кыры); хуҗалык зонасы (һәрберсендә 40 ат өчен урын булган 12 конюшня, вет. клиникасы, атларны коендыру өчен бассейн, гаражлар, печән, ашлык һ.б. саклау урыннары, столярлык, тимерчелек, каеш сбруй остаханәләре); атка атланып йөрү паркы (атлар һәм пониларда йөрү өчен); өйрәнү-күнегүләр урыны (1400×14 *м* юл), ш.у. рестораннар, кафе, барлар, атчылык музее, тотализатор керә. А.с.к. терр-ясендә «Аргамак» балалар-яшүсмерләр ат спорты мәктәбе эшли. Комплексның заманча җиһазландырылу олимпия спорт төрләре, ат спорты уеннары буенча ярышлар, халыкара дәрәҗәдә күргәзмә һәм аукционнар уздырырга мөмкинлек бирә (к. *Ат спорты*).

**АТА́** елгасы, Кече Чирмешәннең уң кушылдыгы, Көнбатыш Кама аръягында. Югары агымында Инча исемендә йөри. Озынлыгы 23,3 *км*, бассейнының мәйданы 264,6 *км*². Әлки р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Колчура авылыннан 1,2 *км* көнбатыштарак, тамагы Түбән Әлки авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 137 *м*, тамагыныкы — 81 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 18%. А.ның 4 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Борнай (15,4 *км*) — уң, Шәпкә (11,5 *км*) — сул кушылдыгы. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,25 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,01 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 60 *мм*, ташу агымы катламы 40 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,022 *м*³*/с*. Түбән агымында елга кибә. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, җәен 500–700 *мг/л*. Елга бассейнында гомуми күләме 686 мең *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**АТАБА́Й** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2002 елда 72 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да мәчет, мәктәп, су, җил һәм ярма ярдыру тегермәннәре, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1010 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы Тәтеш өязенең Келәр волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 59 ир заты; 1859 да — 386, 1884 тә — 533, 1897 дә — 576, 1908 дә — 650, 1920 дә — 693, 1926 да — 467, 1938 дә — 437, 1949 да — 293, 1958 дә — 184, 1970 тә — 160, 1979 да — 115, 1989 да — 62 кеше.

**АТАБА́Й** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 56 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы буендагы пристань. 2002 елда 581 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кошчылык. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да мәчет була. 20 йөз башында монда 2 мәчет, мәктәп, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 557,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы Лаеш өязенең Саралан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир заты; 1859 да — 586,

1897 дә — 794, 1908 дә — 904, 1920 дә — 1032, 1926 да — 1183, 1938 дә — 1186, 1949 да — 911, 1970 тә — 902, 1979 да — 768, 1989 да — 694 кеше. Авыл янында *Атабай торулыгы* урыны саклана.

**АТАБА́Й ТОРУЛЫГЫ́**, Лаеш р-ны Атабай авылы янындагы бронза гасыр археология истәлеге (якынча б.э.к. 2 меңьеллык ахыры — 1 меңьеллык башы). Идел б-н Чулман тугайлары кушылган җирдәге борында урнашкан. Беренче тапкыр 1879–82 елларда А.А.Штукенберг һәм Н.В.Высоцкий, 1940 та Н.А.Прокошев һәм А.В.Збруева, 1951 дә — Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков һ.б. тарафыннан тикшерелә. А.т. халкы терлекчелек, балыкчылык, аучылык, бәлки примитив игенчелек б-н дә, көн күргән, һөнәрчелек төрләрен белгән (18 меңләп чүлмәк ватыклары, чакма таштан ясалган эшләнмәләр табыла). Торак-лар нигездә яртылаш җиргә иңдерелеп корылган. Беркадәр җиргә иңдереп корылган 2 бүлемле, комлы балчыктан катырылган идәнле, дүртпочмаклы землянка рәвешендәге торак калдыклары казылып тикшерелә, һәр бүлемдә 2 учак урыны табыла. Мәетләр чокырга һәм курган асты каберләренә күмелгән. А.Х.Халиков фаразынча, А.т. Казан яны культурасының соңгы дәверенә карый.

*Әд.:* Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. К., 1954; Халиков А.Х. Приказанская культура // Свод археол. источников. М., 1980. Вып. 1–24.

*Е.П.Казаков.*

**АТАБА́Й-ӘНКӘБӘ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы чигендә. 2002 елда 107 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.-Ә.дә мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, су һәм җил тегермәне, мануфактура һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 475 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы Тәтеш өязенең Әлки волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир заты; 1859 да — 386, 1897 дә — 612, 1908 дә — 687, 1920 дә — 744, 1926 да — 571, 1938 дә — 584, 1949 да — 437, 1958 дә — 320, 1970 тә — 317, 1979 да — 221, 1989 да — 145 кеше.

**АТАВИ́ЗМ** (лат. atavus — ерак баба), яшь буында көтелмәгән һәм ата-анасында булмаган, әмма ерак бабаларына хас булган билгеләр барлыкка килү. А. физиологик һәм филогенетик була. Физиологик А. — яшь буында тарихи билгеле ата-бабаларга кире кайту. Филогенетик А. — яшь буында ерак бабаларның аерым сыйфатлары чагылу. Мәс., сарык һәм мөгезле эре терлекнең чиста канлы мөгезсез токымы мөгезле яшь буын тудыра, ә атларның тояк янына ике яктан өстәмә кече тояклары үсә. Кешедәге А. койрыксыман үсенте, муенда балык һәм амфибиягә хас тишек булу; полимастия күренеше — күкрәктә сөт бизләре арту, кул чугы бармаклары саны арту (6–7) — полидактилия б-н характерлы. Кешедә психологик А. да (холыкта нормадан читкә китү) була. Нечкә йонлы сарыкларда Татарстанда 100 ел элек үрчетелгән роман токымы сарыкларына хас билгеләр — калын йон, кыска койрык, соры җепселләр, югары үрчем сыйфатлары күренә (физиологик А.).


**«АТА́КА»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис журнал. *Татар пролетар язучылары ассоциациясе* (*ТАПП*) органы. 1930–32 елларда Казанда татар телендә айга 2 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 20 саны чыга. М.Әмир, С.Әюп, Г.Кутуй, Ш.Камал, Ф.Кәрим, Х.Туфан, Һ.Такташ, Ф.Хөсни һ.б.ларның әсәрләре басыла. Укучыларны илдәге сәяси һәм икътисади хәлләр б-н таныштыра, сәясәт һәм дәүләт эшлеклеләре, галимнәрнең чыгышларына урын бирә. Журнал битләрендә татар язучыларының иң яхшы әсәрләре, әдәби тәнкыйть, әдәбият һәм сәнгать тарихына караган мәкаләләр басыла. Төп жанрлары: мәкалә, повесть, хикәя, шигырь, очерк, әдәбият-сәнгать хроникасы. 1931 дә журнал *«Пролетар әдәбияты»* кушымтасын чыгара.

*Әд.:* Мәрдиева М. Рухи тормыш көзгесе // Тонус. 1996. № 1.

**АТАЛЫ́К**, Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында хан балаларын тәрбияләүче. Баланы А.ка карамага бирү тәртибе борынгы кабиләчелек дәвереннән килә. Ханның ир баласын кече яшьтән үк яклаучы һәм тәрбияләүче, аның беренче киңәшчесе А. булган, ил һәм гаскәр б-н идарә итү тәртипләренә өйрәткән. Кайвакыт А. дәүләттә олуг карачы бәк (бәкләр бәге) вазифасын да үтәгән. Чорына карап, А.ның дәрәҗәсе күтәрелгән яки бала тәрбияләү б-н генә чикләнгән. Русча документларда А. төшенчәсе еш кына «дядька» язылышында бирелә.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследования о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1.; 1864. Ч. 2.; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973.

**АТАМА́Н КҮЛЕ́**, Атман күле, Көнбатыш Кама аръягында. Спас р-нының Өчкүл авылы янында. Су өслегенең мәйданы 14 *га*. Су күләме 113 мең $м^3$. Озынлыгы 500 *м*, иң зур киңлеге 380 *м*. Уртача тирәнлеге 0,8 *м*, иң зур тирәнлеге 1,8 *м*. Җир асты сулары б-н туена. Суы сары төстә, иссез, бик болганчык, аз минеральләшкән, йомшак (1,9 *мг-экв/л*). ТРның табигать истәлеге (1978).



Атаман күле.

**АТАМЫ́Ш** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 22 *км* көнбатыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында монда земство уч-щесе, җил тегермәне, тимерче алачыгы, казна шәраб кибете, 2 мануфактура һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1074 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы Краснококшайск (1919 га кадәр — Царёвококшайск) өязенең Күлле Киме волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 111 ир заты; 1859 да — 703, 1897 дә — 706, 1908 дә — 786, 1920 дә — 647, 1926 да — 625, 1938 дә — 570, 1949 да — 378, 1958 дә — 261, 1970 тә — 67, 1979 да — 28, 1989 да — 4 кеше. А. — генерал-полковник *В.А.Ачаловның* туган авылы.

**АТАСЫ ИСЕМЕ́**, антропонимик категория, кешене атасының исеменә бәйләп атау. Иң борынгы төрки А.и. Орхон-Енисей язмаларында (7–8 йөзләр) күзәтелә, мәс., Байна Саңгун оглы Кулуг Чур. Татар телендә А.и.нең ике төре бар. 1) Атасының исеме янына -ы, -е, -сы, -се тартым кушымчалы туганлык термины (улы, углы, малае) һәм шәхеснең үз исемен өстәп атау төре: Закир улы (углы, малае, баласы) Гайни, Закир кызы (баласы) Сания. 2) Атасының исеме янына шәхеснең 3 нче зат тартым кушымчалы (-ы, -е, -сы, -се) үз исемен өстәп атау: Закир Гайние, Закир Саниясе. А.и.нең бу төре атаны гына түгел, ана, баба, бабаның бабасын, нәсел кушаматын да атарга мөмкинлек бирә: Габдулхак Сафые Закиры Гайние, Габдулла Сафые Фатыймасы Саниясе, Карга Закиры Гайние. Идел буе Болгарында ислам дине кабул ителгәч (922), А.и. янында гарәп алынмалары, ш.и. туганлык терминнары күпләп кулланыла башлый: ибне, бине, бинте. 19 йөзнең ахырыннан рус *антропонимикасы* йогынтысында А.и. -ович/-евич, -овна/-евна кушымчалары б-н белдерелә башлый, мәс., Гайни Закирович, Закир Сафиевич, Сания Закировна, Фатыйма Сафиевна. Кешенең үз исеме янына атасының исемен өстәп атау (Гайни Закир улы, Сания Закир кызы) ш.у. рус антропонимикасы тәэсирендә кулланылышка керә. Татар тел белемендә А.и. Г.Ф.Саттаров өйрәнә. Ш.у.к. *Кеше исемнәре*, *Фамилия*.

*Әд.:* Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. К., 1990; шул ук. Татар исемнәре ни сөйли? К., 1998.

*А.М.Сәгыйтова.*

**АТАУ**, к. *Сосновый Юраш*.

**АТИ́Л**, к. *Итил*.

**АТИЯ́З** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 43 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үмәк елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 13 кеше (татарлар) яши. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына ке-

рә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә, тирә-як авылларда көнлекче булып эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.да тегермән була. 1920 гә кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостена керә. 1920 дән — Вятка автономияле өлкәсе, 1921 дән — ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 254, 1887 дә — 443, 1920 дә — 674, 1926 да — 725, 1938 дә — 556, 1949 да — 397, 1958 дә — 291, 1970 тә — 205, 1979 да — 92, 1989 да 12 кеше.

**АТЛАМА́ КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама аръягында. Элеккеге елга юлында сакланып калган күл. Кече Чирмешән елгасының уңъяк тугаенда, Әлки р-нының Түбән Әлморза авылыннан 2,2 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,88 *га*. Озынлыгы 430 *м*, иң зур киңлеге 45 *м*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**АТЛА́С** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 23 *км* көнбатыштарак, Мәллә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 49 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1920 еллар башында нигез салына. ТАССРның Минзәлә кантоны Кармалы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 161, 1938 дә — 196, 1949 да — 159, 1958 дә — 168, 1970 тә — 192, 1979 да — 112, 1989 да — 34 кеше.

**АТЛА́СОВ** Һади (Әхмәтһади) Мифтахетдин улы (Һади Атласи) (15.8.1876, Сембер губ., Буа өязе Түбән Чәке а. — 15.2.1938, Казан), тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Мулла гаиләсендә дөньяга килә. 1894 елда Буадагы «Нургали» мәдрәсәсен, 1898 дә Оренбург төбәгендәге Каргалы бистәсендә мөгаллимнәр белемен күтәрү курсын тәмамлый. 1898–1903 елларда Буа мәдрәсәләренең берсендә балалар укыта. 1903 нең маеннан Самара губернасы Бөгелмә өязе Әлмәт авылы имам-хатибы, мәдрәсә мөдәррисе; мәдрәсә каршында кызлар мәктәбен ача. Икенче Дәүләт Думасында Бөгелмә өязе крәстияннәреннән сайланган депутат (1907), анда *Мөселман хезмәт таифәсе* әгъзасы. «*Дума*» г-тасын чыгаручыларның берсе. Бөтенроссия мөселманнарының 3 нче корылтае депутаты. Патша хөкүмәтенең милли белем бирүдәге сәясәтен тәнкыйтьләп, 1906 да «Яңа низам вә голәмаларымыз» исемле публицистик хезмәтен бастыра, шуның өчен 1909 да өч айга төрмәгә утыртыла. Ирекккә чыккач, имам һәм мөдәррис вазифаларыннан баш тартырга мәҗбүр була. Полиция күзәтүе астында яши. Фән һәм әдәбият өлкәләрендә эшчәнлек алып бара. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1913). Бер үк вакытта «Йолдыз», «Вакыт», «Шура», «Мәктәп», «Аң» һ.б. вакытлы басмалар б-н хезмәттәшлек итә. Февр. рев-циясеннән соң милли демократик хәрәкәтнең актив әйдәүчесенә әверелә. Россиядә яшәүче төрки халыкларның милли-мәдәни мохтариятларын оештыруны яклап чыга. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче һәм 2 нче корылтайларында катнаша, 2 нче корылтайда Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни автономиясен


Һади Атласи.

төзү нигезләрен әзерләүче комиссиягә әгъза итеп сайлана. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18), *төркичеләр* фракциясе әгъзасы. КОМУЧ хакимлеге вакытында Бөгелмә шәһәренең җирле үзидарәсендә актив эшчәнлек алып бара (1918). Бөгелмәне Кызыл Армия алгач, Әзәрбайҗан Демократик Респ-касының башкаласы Гәнҗә шәһәренә күчеп китә (Респ-каның башлыклары М.Э.Рәсүл-Задә һәм Ф.И.Хан-Хойский б-н 1907 елдан бирле таныш һәм фикердәш була). 1920 нең сентябрендә Совет хөкүмәте тарафыннан кулга алына һәм Баку шәһәрендәге Баилов төрмәсенә ябыла. ТАССР җитәкчелеге таләбе б-н туган җиренә кайтарыла. Чистай шәһәрендә аклар контрразведкасына ярдәм итүдә гаепләп уздырылган мәхкәмә утырышында аклана һәм 1921 нең апрелендә ирекккә чыгарыла. 1920 елларда Бөгелмә кантонының Шөгер, Зәй, Каратай авыллары һәм Бөгелмә шәһәре мәктәпләрендә укыта. Татар язуын гарәп графикасыннан латинчага күчерүгә каршы чыга. 1929 да кабат кулга алына, 10 елга сөргенгә җибәрүгә хөкем ителә һәм Соловки лагерена озатыла. 1933 тә сәламәтлеге начараю сәбәпле лагерьдан азат ителә һәм янә мәктәпләрдә укыта. Репрессияләнә (1936) (к. «*Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел, яшерен мәгълүмат туплау оешмасы» эше*).

Х е з м.: Тарих табигый. К., 1902; Яңа низам вә голәмаларымыз. Оренбург, 1906; Себер тарихы. К., 1911; Сөен-Бикә. К., 1914; Казан ханлыгы. К., 1920; Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы. К., 1993; История Сибири. К., 2005.

*Әд.:* А б д у л л и н Я., Г о с м а н о в М., Т а һ и р о в И. Һади Атласи турында // Казан утлары. 1986. № 11; Татар тарихы: онытылмас сәхифәләр. К., 1994; Хаҗиев Вәли. Һади Атласи мәктәбе // Мирас. 1995. № 7–8; С у л т а н б е к о в Б. Из тайников истории. К., 1995; Мусульманские депутаты Государственной думы России (1906–1917): Сб. док. и материалов. Уфа. 1998; Татарские интеллектуалы: исторические портреты. К., 2005.

*М.Г.Госманов.*

**«АТЛА́СОВ ЭШЕ́»**, к. «*Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел, яшерен мәгълүмат туплау оешмасы» эше.*

**АТМА́С** елгасы, Бәтке елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы, Көнбатыш Кама алдында. Озынлыгы 19,5 *км*, бассейнының мәйданы 118,9 *км*$^2$. Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Түбән Солтан авылыннан 3 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Кече Укмас авылыннан 2,2 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Елга башыннан Шумково авылына кадәр елга Екатериновка исемендә йөри. А.ның 2 дән алып 4 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,47 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1,1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык сагаю б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 172 *мм*, ташу агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Су агымының торышы тотрыклы. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,17 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12 *мг-экв/л* га кадәр). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада күләме 380 мең *м*$^3$ суы булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**АТМОСФЕ́РА** (грек. atmós — пар һәм spháira — шар), Җир шарын чолгап алган газсыман тышча, сүрү. Җир өстендә тереклек итү мөмкинлеге бирә. Җир А.сы икенчел, ягъни планета формалашканнан соң, аның каты тышчасыннан (литосферадан) аерылып чыккан газлардан хасил булган дип фаразлана. А.ның үсеше геологик һәм геохимик процесслар, ш.у. тере организмнар эшчәнлеге б-н бәйле. А. газлары литосфераның үзгәреп торуына бик нык тәэсир итә. А. дагы кислород һәм А.дан килә торган су — тау токымнарына тәэсир итүчән мөһим факторларның берсе. А. Җир өстен аңа төшә торган метеоритларның җимергеч көченнән саклый, чөнки аларның күбесе А.ның тыгыз катлавына үтеп кергәндә янып бетә. А.ның үсешенә зур тәэсир итүче тере организмнар эшчәнлеге үзе А.дагы шартларга бәйле. А. организмга тәэсир итә һәм Кояштан килә торган ультрамиләүшә нурларның күбесен тотып кала. А.дагы кислород хайван һәм үсемлекләрнең сулыш алу процессында, углекислота исә үсемлекләрнең туклану процессында файдаланыла. А. катламнардан тора, бу исә, барыннан да элек, темп-раның вертикаль буенча бүленүе б-н бәйле. А.ның иң түбән өлеше — тропосфера (биеклеге 10 *км* га кадәр, анда барлык А.ның 80% ка якын массасы тупланган). Аннан өстәрәк стратосфера, мезосфера һәм термосфера (ионосфера) урнашкан.

Җир А.сы, башлыча, азот (78%) һәм кислородтан (20,93%), ш.у. аргон, углекислый газ, неон һ.б. даими һәм алмаш компонентлардан гыйбарәт. А.ның аеруча мөһим алмашынучан өлеше — су пары, аның төп массасы тропосферада тупланган. Биеклек арту б-н аның туплану концентрациясе тиз кими. Су парлары куеру нәтиҗәсендә болытлар, *атмосфера явым-төшемнәре* хасил була. Озон А. процессларына, бигрәк тә, Кояшның ультрамиләүшә радиациясен йотып, стратосферадагы җылылык режимына йогынты ясый. А.ның мөһим алмашынучан компоненты — углекислый газ, аның күләме үсемлекләр эшчәнлегенә, сәнәгый пычрануга, океаннар б-н

А. арасында газ алмашынуына бәйле. Соңгы дистә елларда А.да углекислый газ арта бара. Ул сәнәгать пр-тиеләренең әйләнә-тирә мохитне пычратуына бәйле. Углекислый газ хасил иткән «парник эффекты» Җирдәге климатка тискәре йогынты ясый. А. кыска дулкынлы Кояш радиациясен аз йота, Җир өслегенең озын дулкынлы җылылык нурланышын тотып кала. Нәтиҗәдә галәмгә җылылык таралу кими һәм темп-ра күтәрелә. *Кояш радиациясе* — А.да бара торган процесслар өчен бердәнбер диярлек энергия чыганагы. Кояш радиациясе, Җир төзелешенең катлаулылыгына, аның океаннарга, континентларга һәм зур тау системаларына бүленүенә карап, Җир өстенең төрле киңлекләренә төрлечә төшә һәм климатны төрлечә билгели. Һаваның зур тизлек б-н хәрәкәтләнүе нәтиҗәсендә А.ның барлык биеклекләрендә дә җилләр исә. Һава хәрәкәте күп кенә факторларга бәйле, шулардан иң мөһиме — Җир шарының төрле урыннарында А.ның тигез җылынмавы. Континентлар һәм океаннарның урнашу тәртибе Җир өстендәге темп-раның төрлечә бүленүенә тәэсир итә. Океан суларының җылылык кабул итүе һәм җылылык үткәрүе зур булганлыктан, алар Кояш радиациясенең ел дәвамындагы үзгәреп торуы нәтиҗәсендә туган темп-ра тирбәнүләрен шактый киметәләр. Шуңа күрә уртача һәм югары киңлекләрдә һава темп-расы җәен океаннарда, континентларга караганда, сизелерлек түбән, кышын югарырак була. А.ның тигез җылынмавы андагы җылылыкны горизонталь күчерүче зур күләмле һава агымы системасын тудыра. Нәтиҗәдә аерым урыннардагы темп-ра аермасы сизелерлек кими. Шуның б-н бергә, А. да дым әйләнеше бара, А. һавасы да, дымлылык та үзгәрә, океаннардан күтәрелгән пар коры җирләргә таба күчерелә һәм континентларны дымландыра. Һаваның өзлексез хәрәкәтләнүе, атмосфера басымының үзгәреп торуы Җирнең әйләнүе б-н дә тыгыз бәйләнгән. Тропик киңлекләргә кермәгән материкларда басым кышын, гадәттә, югарырак, җәен түбәнрәк була.

Һава агымнарының катлаулы системасы планетада басым таралышы б-н бәйле, кайберләре (пассатлар, муссоннар) чагыштырмача тотрыклы, кайберләре, киңлеккә һәм вакытка карап, даими рәвештә үзгәреп тора. Уртача киңлекләрдә көнбатышка юнәлгән һава агымнары өстенлек итә. Алар, гадәттә, йөзләрчә һәм меңнәрчә *км* га җәелеп, түгәрәк өермәләр — *циклон*нар һәм *антициклон*нар хасил итәләр. Барлык һава агымнарында, кагыйдә буларак, җил исүе — уртача һәм аз күләмле һава өермәләре хәрәкәте күзәтелә. Алар атмосферадагы процессларга җитди тәэсир итә торган А. турбулентлыгына бәйле. А.да электромагнитик нурланыш таралу яктылык йотылу һәм таралуга, рефракциягә бәйле төрле күренешләр китереп чыгара. Мәс., салават күпере Кояш нурларында су тамчыларының чагылуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Күк гөмбәзенең яссыланып күренүе һәм күк йөзенең зәңгәрлеге дә шул күренешкә бәйле. Болытлар һәм яшен электры хасил булу күренеше Җирнең тискәре корылуының Җир А.сындагы электр кырына тәэсир итү нәтиҗәсе булып тора. Җир А.сын күзәтү өчен метеорологик станцияләр һәм постлар корыла. Энергетика һәм сәнәгать үсеше, шәһәрләшү киңәя бару А.га ташландык, агулы матдәләр чыгуның артуына, һаваның бик зур күләмдә ягулык калдыклары б-н пычрануына китерә. Нәтиҗәдә А.ның составы үзгәрә, кайбер агулы матдәләр еш кына кешеләр, хайваннар, үсемлекләр тормышына куркыныч янау дәрәҗәсендә туплана, металлар бик тиз тутыга.

1990–2000 елларда ТР шәһәрләре А.сы һавасында агулы матдәләрнең рөхсәт ителгән чиктән артып китүе күзәтелә. Бу чиктән тузан — 23%, формальдегид — 16%, аммиак — 11%, азот оксиды 8% ка артып китә. Һава атмосферасын пычранудан саклау — бүгенге көндә гаять җитди экологик проблемаларның берсе.

*Әд.:* Сигал И.Я. Защита воздушного бассейна при сжигании топлива. Л., 1988; Гимадеев М.М. Современные проблемы охраны атмосферного воздуха. К., 1997; О санитарно-эпидемиологической обстановке в Республике Татарстан в 1999 году: Национальный доклад. К., 2000.

*Р.Г.Усманов.*

**АТМОСФЕ́РА БАСЫМЫ́**, атмосфера тарафыннан аның эчендәге барлык җисемнәргә һәм җир өстенә ясалган гидростатик басым. А.б. өске катламнар һавасы авырлыгыннан гыйбарәт, шуңа күрә югарырак күтәрелгән саен аның зурлыгы кими. Барометр ярдәмендә билгеләнә һәм терекөмеш баганасы биеклеге (*мм*) яки гектопаскальләр (*гПа*) б-н үлчәнә. Диңгез өсте тигезлегендә уртача А.б. 760 *мм* терекөмеш баганасы биеклегенә яки 1013,25 *гПа* гә тигез була, аны «гадәти» А.б. дип атыйлар. Синоптик карталарда диңгез тигезлегенә китерелгән А.б. күрсәтелә. А.б. ның кискен үзгәрүе *циклон*нар һәм *антициклон*нар хәрәкәтенә бәйле. Татарстан терр-ясендә иң зур уртача айлык А.б. кышкы айларда күзәтелә һәм ул көньяк-көнчыгышка таба арта бара; иң түбән басым — җәйге айларда һәм көнчыгышка таба кими. Елына уртача 190 көн югары һәм 170 көн түбән А.б. күзәтелә. Кайбер елларда, бигрәк тә кышкы айларда, басым зурлыгы күпьеллык күрсәткечләрдән шактый аерыла. А.б. ның гадәттән тыш зурлыклары кышкы антициклоннарда 1055–1057 *гПа* һәм циклоннарда 951–955 *гПа*; җәен аерма азрак — 1020–1025 тән 965–970 *гПа* гә кадәр. А.б. ның тәүлеклек үзгәреше гадәттә зур түгел (берничә *гПа*), ләкин елның салкын яртысында һава массалары кискен алмашынганда аерма 20–25 *гПа* гә җитәргә мөмкин һәм бу хәл йөрәк-кан тамырлары системасы авырулары б-н интегүчеләр сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый.

*Әд.:* Матвеев Л.Т. Курс общей метеорологии. Л., 1984; Климат Казани. Л., 1990.

*Э.П.Наумов.*

**АТМОСФЕ́РА КҮРЕНЕШЛӘРЕ́**, атмосферадагы күзгә күренеп кискен үзгәрә торган физик процесслар. А.к.нә *томан*, *яшенле яңгыр*, бозлавык, тузан (ком) бураны, кискен җил (шквал), *буран*, сыкы, чык, бәс, болытлар, поляр балкышлар, *атмосфера явым-төшемнәре*, салават күпере, коры (тузанлы) томан, *кар капламы* һ.б. керә. Физик табигате буенча А.к. оптик (мираж, салават күпере, шәфәкъ һ.б.), электр (яшен, поляр балкыш һ.б.), акустик (күк күкрәү) һ.б. төрләргә бүленә. ТР терр-ясендә кышын — кар, буран; җәен — чык, яшенле яңгыр, ел сезонына бәйсез рәвештә — болытлар, томан, коры томан, сирәк очракта — поляр балкыш, җәүһәрсыман һәм көмешсыман болытлар һ.б. А.к. күзәтелә. А.к. һава торышын һәм климатны өйрәнүдә мәгълүмат чыганагы булып тора.

*М.А.Верещагин.*

**АТМОСФЕ́РА ЦИРКУЛЯ́ЦИЯСЕ**, җир өстенә якын, шулай ук атмосфераның биегрәк катламнарында күзәтелә торган зур күләмле һава агымнары системасы. Тропосферадагы гомуми А.ц.нең төп һава агымнарына пассатлар, муссоннар, *циклон*нар һәм *антициклон*нар б-н бәйле һава агымнары керә, стратосферада һәм мезосферада һаваның зональ (көнбатыш һәм көнчыгыш) хәрәкәтләре өстенлек итә. А.ц. барлыкка килүнең сәбәбе — җылылык балансы аермалыкларына бәйле рәвештә атмосфера басымының Җир шары буенча төрлечә булуы. Горизонталь һәм вертикаль юнәлешләрдә бик зур һава массаларының даими күчеше Җир шарының төрле районнары арасында җылылык һәм дым күчешенең көчле механизмын тәшкил итә.

Шуңа бәйле рәвештә А.ц. атмосферадагы җылы һәм дым әйләнешенә йогынты ясый һәм климат барлыкка китерүче мөһим фактор булып тора.

Җирле физик-географик шартлар тәэсирендә җир өстенең чагыштырмача зур булмаган мәйданында барлыкка килгән А.ц. җирле циркуляция исемен йөртә.

ТР климатына уртача киңлекләрдән атлантик *һава массаларын* күчерә торган тропосфера көнбатыш ташкыннары күбрәк йогынты ясый, алар аны йомшарта һәм дымландыра. Моннан тыш, арктик һәм тропик киңлек р-ннарында формалашкан һава массалары да килә. Аларның күчеше циклоннарда һәм антициклоннарда барлыкка килгән һава агымнары йогынтысында үтә. Октябрьдән алып мартка кадәрге чорда циркуляция процесслары, уртача алганда, һава темп-расы күтәрелүгә, апрельдән сентябрьгә кадәр аның төшүенә сәбәп була. Бу процесслар атмосфера явым-төшемнәре режимына да хәлиткеч йогынты ясыйлар. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш һава агымнары өстенлек итү сәбәпле, ТР терр-ясендә, көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыштарак территорияләр б-н чагыштырганда, климатның континентальлеге кимрәк.

*Әд.:* Погосян Х.П. Общая циркуляция атмосферы. Л., 1972; Климат и загрязнение атмосферы в Татарстане. К., 1995.

*Э.П.Наумов, Ю.П.Переведенцев.*

**АТМОСФЕ́РА ЯВЫ́М-ТӨШЕМНӘРЕ́**, болытлардан яуган (яңгыр, кар, ярма кар, боз һ.б.) яки һавадан җир өстенә һәм андагы җисемнәргә утырган (чык, бәс, сыкы, бозлавык) сыек һәм каты хәлдәге су. Явым-төшемнең күләме билгеле бер вакыт (сәгать, тәүлек, ай, ел) эчендә агып китү, җиргә сеңү, парлану, җилгә очуны булдырмыйча җыеп алынган суның калынлыгын күрсәтүче *мм* ларда үлчәнә. Татарстанда А.я.-т.нең терр-я буенча үзгәрешенә рельефның йо-

гынтысы шактый зур. Еллык явым-төшемнәрнең уртача күләме Көнбатыш Кама аръягының түбән тигезлекләрендә 460 *мм*, Идел буе һәм Бөгелмә-Бәләбәй калкулыкларында 540 *мм* кадәр. Аерым пунктларда үзгәрешләр зуррак: мәс., Казанда 1920 елда 279 *мм*, 1978 дә 870 *мм*; Алабугада 1926 да 744 *мм*, 1982 дә 316 *мм*. Елның салкын вакытында (ноябрь-март) явым-төшемнәр уртача 130–180 *мм*, җылы вакытында (апрель–октябрь) 320–370 *мм*. Кагыйдә буларак, иң күп явым-төшемнәр июльдә (50–65 *мм*), иң азы февральдә (20–25 *мм*), шул ук вакытта алар кышын ешрак, җәен сирәгрәк ява. А.я.-т.нең айлык һәм тәүлеклек күләме бик нык үзгәрүчән. Кайбер айларда явым-төшемнең «нормадан» 2–3 тапкыр артып китүе һәм, киресенчә, аның 5–10% ына тигез яки кимрәк тә булуы мөмкин. Теркәлгән тәүлеклек максимумнар: Казанда — 121 *мм* (29.7.1899), Минзәләдә 90 *мм* (26.6.1904). Еллык А.я.-т. күләменең 64% ы сыек, 24% ы каты һәм 12% ы катнаш хәлдә булуы күзәтелә. Явым-төшемнәр елына уртача 1050–1360 сәгать дәвам итә.

*Әд.:* Климат Татарской АССР. К., 1983; Климат и загрязнение атмосферы в Татарстане. К., 1995.


**АТНАБА́ЕВ** Әнгам Касыйм улы (23.2.1928, Башкортстан Респ-касының Тәтешле р-ны Иске Күрдем а. — 13.10.1999, Уфа ш.), шагыйрь, драматург, Башкортстан АССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977; 1988), Башкортстан Респ-касының халык шагыйре (1997). Татар һәм башкорт телләрендә иҗат итә. 1943–51 елларда Иске Күрдем урта мәктәбендә укыта, 1951–68 дә Уфада чыга торган «Кызыл таң» г-тасында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, 1977–89 да «Һәнәк» ж-лында баш мөхәррир урынбасары булып эшли. 1946 елдан әсәрләре матбугатта басыла. 1958 дә яшьлекләре авыр сугыш елларына туры килгән буын вәкилләренең кичерешләре турындагы «Йөрәк менән һөйләшеү» исемле беренче шигырь һәм поэмалар җыентыгы дөнья күрә. А. поэзиясенең төп темасы — үз замандашларының тормышы («Йәшлек менән осрашыу» (1961), «Йылдарҙан йырҙар ҡала» (1975), «Мөхәббәт юлы» (1982), «Шигырьләр һәм поэмалар» (1993), «Җиз кыңгырау моңнары» (1998) исемле шигырь җыентыклары). Аның поэзиясенә тапкырлык, эчкерсезлек, нечкә лирика, ягымлы юмор хас. «Ул ҡайтты» (1960) пьесасында А., беренчеләрдән булып, тоткынлык газапларын кичереп ватанына тугры калган совет солдаты образын чагылдыра. «Шоңҡар» (1968) пьесасында шагыйрь Ш.Бабич образын сәхнә каһарманы биеклегенә күтәрә. «Әсә хөкөмө» (1963), «Законлы никах менән!» (1965), «Мөхәббәт турында йыр» (1968), «Балаҡайҙарым» (1970), «Ут» (1975) пьесалары бүгенге һәм тарихи вакыйгаларга багышлана. А.ның күп кенә әсәрләре Башкортстан һәм Татарстан театрлары сәхнәләрендә куела. Иҗатында җитди проблемалар күтәрелә, әсәрләренә төгәл уйланылган сюжет-композиция нигезе, киеренке драматизмның ягымлы юмор б-н үрелеп баруы хас. Г.Сәләм исем. респ. бүләге лауреаты (1971). 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Әҫәрҙәр: 2 томда. Өфө, 1988; Атнабай — халык шагыйре. К., 2000.

*Әд.:* В а с ф и Г. Поэмала заман геройы // Агыйдел.1962. № 4; К а р и м о в М. Шагыйр илендә // Агыйдел. 1978. № 2; А м и р о в Р. Годы оставляют песни // Чтобы шагнуть в завтра. Уфа, 1982.

*Р.К.Әмиров.*

**АТНАГУ́ЛОВ** Сәлах (Сәлахетдин) Садри улы (1893, Уфа губ., Бәләбәй өязе Суыккүл а. — 16.8.1937), сәяси эшлекле, публицист, язучы. «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый



(1916). 1917 елга кадәр Тамбов губернасының Әҗи авылы мәдрәсәсендә укыта. Февр. рев-циясеннән соң сәяси эшчәнлек алып бара, татар сул эсерлары платформасын яклап чыга һәм Вакытлы хөкүмәткә каршы була. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18). Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү коллегиясенең әгъзасы һәм баш секретаре вазифасын башкара. 1918–19 да Татар-башкорт комис-тының хәрби коллегиясе әгъзасы, «Кызыл Яу» г-тасы мөхәррире (Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе нәшер итә), РКП(б) ҮКнең Көнчыгыш халыклары үзәк бюросының хәрби инструкторы, «Кызыл Армия» г-тасы мөхәррире. 1920 дән ТАССР Мәгариф халык комис-тында эшли (бүленеп: 1921–22 дә Мәскәүдә «*Эшче*» г-тасы мөхәррире), бер үк вакытта 1925–27 дә «*Кызыл Татарстан*» г-тасы мөхәррире. 1927–29 да *Гыйльми Үзәк* рәисе. Татар алфавитын гарәп графикасыннан латинчага күчерүне яклап чыга. 1930 еллар башыннан 1936 га кадәр фәнни һәм пед. эшчәнлек алып бара. 1936 да кулга алына. Гыйльми хезмәтләре Башкортстан тарихына карый; татар теле дәреслекләре, хикәяләр авторы. Репрессияләр чоры корбаны. 1936 ның 2 сентябрендә кулга алына, гаепсезгә репрессияләнә, үлем җәзасына хөкем ителә (к. «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы» эше*, «*Уң троцкийчы милләтчеләрнең Совет хакимиятенә каршы оешмасы» эше*). Вафатыннан соң аклана.

Хезм.: Шәрекъ хатын-кызлары һәм иҗтимагый революция. К., 1921; Кечкенә шахтёр. К., 1925; Гарантияле мәхәббәт. К., 1927; Татар хатыны элек һәм хәзер. К., 1927; Каф тавы артында. К., 1928; Татар әдәби теленең орфографиясе. Шушы елның 19 маенда булачак конференциягә каратыла. К., 1929; Әлифбадан соң уку китабы. К., 1935. 1 нче кис. (автордаш); Татар теле дәреслеге. К., 1935. 2 нче кис. (автордаш).

*Әд.:* Глухов М. Атнагулов С.С. // Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1990; Султанбеков Б. Кровавый след операции «Новаторы» // Страницы секретных архивов. К., 1994; Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2000. Т. 1; Башкирия. М.–Л., 1925.

**АТНОМЕ́ТОВ (ӘТНӘМӘ́ТОВ)** Ниятбакый (1768, хәзерге Төмән өлкәсенең Тобол р-ны Саускан а. — ?), педагог. Тобол әсасый халык уч-щесендә татар теле укыта. «Татар вә гарәп әлифбасы» (СПб., 1802) исемле китап авторы.

*Әд.:* Зияев Х. Этому букварю 160 лет. Ташкент, 1961; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1974.

**АТРИБУ́ЦИЯ** (лат. attributio — ачыклау, аныклау), аноним яки псевдоним б-н билгеләнгән әсәрләрнең авторларын, язылу урынын һәм вакытын ачыклау. А. — текстологиянең мөһим бер өлеше. Сәнгатьтә, әдәбият белемендә, тарихи чыганакларны өйрәнү эшендә А.нең әһәмияте зур. Урта гасырлар татар әдәбияты ядкәрләрендә, кагыйдә буларак, әсәрнең соңгы дүртьюллыгында автор үзенең псевдонимын куя торган булган:

«Аты — Гали моны төзгән зәгыйфь колның,
Изге рәҗәп аеның нәкъ утызында,
һәм тарихның нәкъ алты йөз утызында,
Бу зәгыйфь кол бу китапны төзде инде».

Гарәб графикасында язылган текстларны транскрипцияләгәндә еш кына бер үк исемнең төрле укылышлары барлыкка килә, мәс., Мәүла Колый яки Меллагол. А. чыганакларны, аларның эчтәлеген анализлауга, автор теленең һәм стиленең индивидуаль үзенчәлекләрен ачыклауга нигезләнә. Ф.Сәйфи-Казанлы, Х.Хисмәтуллин, И.Нуруллин, Р.Гайнанов, И.Абдуллин, Р.Нәфыйгов, М.Госманов, Ш.Садретдинов, З.Рәмиев, Г.Гыйльманов һ.б. тарафыннан Тукайның (70 ләп псевдонимы билгеле), Ф.Әмирханның (20 гә якын псевдонимы бар), С.Рәмиев, М.Гафури, Г.Камал, Ш.Бабич, М.Гали, Г.Коләхмәтов, Г.Кандалыйның псевдоним астында яки аноним язылган күп кенә әсәрләре ачыкланды.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*З.З.Рәмиев.*

**АТТИ́ЛА** (Attila; Атилла) (? — 453), җиһангир, борынгы Европа һуннары (ак һуннар) берләшмәсе башлыгы. Һуннарның аннан элегрәк идарәчесе Ругиланың (Руа, Руга) бертуганы Мундцукның улы. Ругила вафат булгач (434), бертуганы Бледа (Билада) б-н бергә идарә итә. 445 елда Бледа үтерелгәч, тәхеттә берүзе кала. А. һуннарны куәтле империягә туплаучы буларак танылa. А. идарә иткәндә, һун кабиләләре югары иҗтимагый үсеш дәрәҗәсенә ирешәләр. А.ның дәүләтенә Иделнең түбәнге өлешеннән алып Рейн елгасына, Көньяк Германиядән Альп тауларына һәм Дунай буйларынача булган җирләрдә яшәүче кабиләләр кергән. Дәүләтнең үзәк каласы Дунайның уң тарафындагы Паннониядә (хәзерге Венгрия б-н Сербия җирләре) урнаша. 447 елда А. Көнчыгыш Рим империясенә һөҗүм оештыра, Вид елгасы буенда римлыларның армиясен тар-мар итә. Фракия, Иллирия өлкәләрендә 70 ләп шәһәр һәм кальганы яулап ала, Константинопольне камый. Солых килешүе буенча һуннар Дакия (хәзерге Румыния) җирләрен басып алалар һәм даими рәвештә ясак түләтәләр, 451 елда А. Көнбатыш Рим империясендә барган сугышта катнаша, гаскәре б-н Галлия һәм Бургундиягә бәреп керә. Ләкин Көнбатыш Рим империясе б-н аның союздашларының Аэций җитәкчелегендәге берләштерелгән армиясе тарафыннан җиңелә һәм чигенергә мәҗбүр ителә. Тарихта «халыклар сугышы» исемен алган бу орыш хәзерге Труа шәһәре янындагы Каталаун кырында 451 елның 15 июнендә була. Бу зур сугышта җиңелсә дә, А. төп көчләрен саклап кала, 452 дә Төньяк Италиягә һөҗүм итә, Аквилья, Верона, Милан, Падуя һ.б. шәһәрләрне яулап ала, Римнан контрибуция түләтә. Шул җиңүләрдән соң Паннониядәге төп шәһәренә әйләнеп кайта һәм тиздән вафат була. А.ның вафатыннан соң һуннар империясе берничә өлешкә таркала. Европа халыклары риваятьләрендә һәм дастаннарында ул көчле, дәһшәтле һәм бик бай җиһангир буларак тасвирлана. Герман телле язмаларда аның исеме «Атли», «Etzel», датларча Артила, испанча Аттила һ.б. теркәлгән. А. *халыкларның олуг күченеше* чорында тиңдәшсез хәрби җитәкче һәм сәясәтче санала. Хәрби көч, янаулар һәм сатып алулар ярдәмендә күп халыкларны куәтле хәрби-сәяси берләшмәгә туплый ала. Ш.у.к. *Һуннар.*

*Әд.:* Бернштам А.Н. Очерк истории гуннов. Л., 1951; Movavesi R.G. Attilas Tod in Geschichte und Sage. Bdpst., 1926; Jhompson E.A. A history of Attila. Oxf., 1948; Altheim F. Attila und die Hunnen. Baden-Baden, 1951; Maenchen-Helfen O. The World of the Huns. Berk.-Los Ang.-L., 1973.

*И.Л.Измайлов.*

**АТУ́ СПОРТЫ́**, сырлы һәм шома көпшәле (стендта ату), утлы һәм пневматик коралдан, ш.у. җәядән ату спорты.

Татарстанда беренче ату түгәрәкләре һәм секцияләре 1921 елда Идел буе хәрби фәнни җәмгыятенең Казан бүлегендә оештырыла. Спорт төре буларак ядрә б-н ату «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә, Совет Армиясе офицерлары йортында, ТРның РОСТО (1927 дән ОСОАВИАХИМ һәм 1951–91 дә ДОСААФ) оешмаларында үсеш ала. ТАССР җыелма командасы РСФСР халыклары спартакиадасында (1975, 1979), РСФСР укучылар спартакиадасында (1974) җиңүче була, РСФСР чемпионатында (1984), Бөтенроссия яшьләр уеннарында (1977) көмеш, РСФСР чемпионатында (1973) бронза медальләр ала. «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан советының җыелма командасы «Динамо» Физкультура-спорт җәмгыяте үзәк советының шәхси-команда ярышларында җиңүче (1988), көмеш (1986) һәм бронза (1989) медальләр иясе. ТРның иң көчле спортчылары — В.П.Абреимов, И.П.Алемаев, Л.Ю.Ананьев, К.Г.Андреев, К.В.Бутинов, Л.С.Васильева, А.Г.Вострокнутов, Н.А.Газеева, С.В.Дарвин, К.Т.Евстафьев, И.Н.Куртуков, В.В.Лукашов, Л.Б.Молодцова, О.К.Мөхәмәтгалиев, Р.Д.Нигъмәтуллина, С.Э.Парфимович, О.И.Подольская, С.М.Рязанов. Иң яхшы тренерлар — В.А.Алексеев, М.Ш.Галиев, Г.А.Ессин, Ю.В.Макаров, Б.У.Тагиев.

Стендка ату спорт төре буларак, 1960 еллар башыннан Татарстан респ-касының «Урожай», «Спартак», «Локомотив», «Зенит» ирекле спорт җәмгыятьләрендә, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә, Татарстан аучылык җәмгыятендә үсеш ала. 1961 дә стендка ату буенча Республика олимпия резервы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе оештырыла (директорлары 1961–86 да — С.С.Яруллин, 1986 дан — С.Ю.Протасов). ТАССР җыелма командасы — «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең үзәк советы беренчелекләрендә җиңүче һәм призёр (1963–87). ТРның иң яхшы спортчылары — ТР, РСФСР, ВЦСПС, СССР (ш.и. авыл ирекле спорт җәмгыятьләре), РФ, «Урожай» ирекле спорт җәмгыяте үзәк советы, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте чемпионатларында һәм беренчелекләрендә катнашкан иң яхшы спортчылар: А.И.Айтуганов, В.Д.Барышников, А.Г.Бычков, Т.И.Бычкова, А.Н.Вавилов, В.М.Василевский, Л.Г.Володина, И.В.Гладких, Р.В.Демидов, С.А.Дёмина, Д.П.Карташов, В.А.Мосин, Е.М.Панкратов, М.К.Попов, С.Ю.Протасов, А.В.Радионов, Л.С.Семёнов, Ю.А.Столыпин, Н.С.Спиридонов, Н.М.Тенилин, Е.Г.Фомин, В.М.Шевяков, Ю.В.Шегуров, Т.И.Шлячкова. Иң яхшы тре-

нерлар — А.А.Бәдретдинов, С.К.Дёмин, М.Т.Кузьмин, С.Ю.Протасов, В.И.Филиппов, Ю.А.Юдин, С.С.Яруллин. ТРда спортның ату төрләре өчен 354 корылма, ш.и. 11 ату стенды (2006) эшли.

*Әд.:* Марихин Б.Ф. Тетюшские стрелки. К., 1985. *Н.Д.Бобырев.*

**АТЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама төбәгендә; Казансуның уң кушылдыгы. Озынлыгы 20,1 *км*, бассейнының мәйданы 116 *км*². Арча р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Субаш Аты авылыннан 1 *км* төньяктарак, кәсләнгән сызада, тамагы Кишмәт авылыннан 1 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу терр-ясендә, асылда, урманнар юк диярлек. А.ның 4 тән алып 11 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*². Түбән агымында елга үзәне киң һәм асимметрияле (сул сөзәклекләре текәрәк), урыны б-н чокырлар ергалаган. Тугае яхшы күренә, тигез, кәсләнгән, югары агымдагы киңлеге 60 *м* га кадәр, түбәндә 300 *м* чамасы, елганың түбәнге өлеше сазланган. Елга юлы бормалы. Күп урыннарга текә ярлар хас. Елга төбе ташлы һәм комлы, түбән агымында ләмле. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 160 *мм*, ташу агымы катламы 140 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Су ресурслары сугару һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**АТЮ́РЬЕВ РАЙОНЫ́**, *Мордва Республикасының* көнбатыш өлешендә. 1937 елның 10 маенда оештырыла. Мәйданы — 825,5 *км*². 13 авыл советын, 55 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Атюрьево авылы (Саранск шәһәреннән 143 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 12,151 кеше (2002). Татарлар (658 кеше) 8 торак пунктта: Усть-Рахмановка (247 кеше), Олы Шуструй (187), Түбән Пешлә (82), Татар Велязьмасы (280), Татар Тенише (74), Югары Пешлә (73), Кече Шуструй (12), Түбән Богдановка (11) авылларында яшиләр. А.р.нда татар авыллары 16 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Алар, нигездә, Темников чик буе киртәсен саклаучы йомышлы крәстияннәрдән тора. 1917 гә кадәр Түбән Пешлә һәм Усть-Рахмановка авылларында 2 шәр мәчет, Татар Велязьмасы, Югары Пешлә, Татар Тенише, Олы Шуструй авылларында да мәчетләр эшләгән. Түбән Пешлә авылы мәдрәсәсендә шагыйрь Һади *Такташ* укыган. Хәзерге вакытта Усть-Рахмановка авылында яңа мәчет төзелде, Олы Шуструй һәм Түбән Пешлә авылларында мәчетләр яңадан торгызыла. Бу авыллардагы мәктәпләрдә татар теле фән буларак өйрәнелә. Усть-Рахмановка авылы мәдәният йорты һәм Олы Шуструй авылы клубы каршында татар үзешчән коллективлары эшли. А.р.нда ТАССРның беренче юстиция наркомнарының берсе Х.Р.*Палютин* (Югары Пешлә а.) һәм техник фән. д-ры З.И.*Сунәев* (Татар Велязьмасы а.) туган.

**АУ́ КОШЛАРЫ́ АСРАУЧЫЛА́Р**, патша сарае егермейстеры карамагындагы удел крәстияннәре категориясе. Ау кошлары (каргалар, шоңкарлар, лачыннар) тоту һәм аларны патша сараена җибәрү б-н шөгыльләнгәннәр. 1731 елга Указ буенча алар ел саен Мәскәүгә 20 шоңкар һәм 30 лачын җибәрергә тиеш булганнар. Хезмәт хакы һәм чыгымнар өчен акча таможня һәм исерткеч эчемлекләрдән кергән керемнәрдән түләнгән. Лачын аулаучылар Переяславль-Залесский, Ростов шәһәрләрендә, Суздаль, Белозёрск һәм Вологда өязләрендә; шоңкар аулаучылар Казан һәм Перьм губерналарында, Себердә яшәгәннәр. 1746 елгы халык саны алу буенча А.к.а. 868 кеше булган. Казан губернасында алар Казан, Козьмодемьян, Зөя һәм Чабаксар өязләрендә яшәгәннәр. 1800 дә Россиядә бу категория (Казан губернасындагы 102 ир затыннан гайре) дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. 1827 нең августында хөкүмәт аларның барысын да җан башыннан салым түләүче катлаулар — шәһәр кешеләре (сәүдәгәрләр, мещаннар) һәм дәүләт крәстияннәре составына күчерү турында карар кабул итә.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Р. Управление государственной деревней в Казанской губернии в конце XVIII – первой трети XIX вв. К., 2002; Брокгауз Ф.А., Ефрон И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1898. Т. 48. *Р.Р.Хәйретдинов.*

**АУДИ́ТОРЛЫК ХЕЗМӘТЕ́**, хуҗалык оешмаларының финанс-хуҗалык операцияләрен, бухгалтерлык исәп-хисапларын, отчётларын тикшерү һәм ревизия уздыру юлы б-н, урнаштырылган тәртипнең үтәлешенә түләүле бәйсез контроль ясый торган оешма. А.х. консультация бирү, бизнесны үстерүнең перспектив һәм агымдагы планнарын төзү хезмәте дә күрсәтә. РФдә А.х. 1991 елда оештырыла. 1992 дә «Татарстан Республикасында аудиторлык эшчәнлеге турында»гы положение раслана. А.х. икътисади субъектларның яңа оештыру-хокукый формалары (АҖләре, уртак пр-тиеләр, төрле җәмгыятьләр һәм компанияләр) оештырылу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Аудиторлык эшчәнлеген базар икътисады тудыра, һәм ул базар механизмының бер өлеше булып тора. Аудитның тышкы һәм эчке, мәҗбүри һәм инициатив (ирекле) төрләре була. Тышкы аудит аудитор фирмасы (аудитор) тарафыннан икътисади субъект б-н (пр-тие, оешма) төзелгән шартнамә нигезендә аның бухгалтерлык исәп-хисабының дөреслегенә объектив бәя бирү, ш.у. пр-тиенең финанс хәлен яхшырту, аның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, тәкъдимнәр әзерләү, җитештерүнең файдаланылмаган резервларын эзләү максатыннан чыгып уздырыла. Эчке аудит хуҗалык субъекты җитәкчелегенә турыдан-туры буйсынган оешманың махсус хезмәте яисә аның хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Аның төп бурычы — пр-тиенең чыгымнарын даими тикшереп тору һәм аларны киметү чараларын эшләү. Идарә итүнең икътисади ысуллары механизмын һәм эшмәкәрлек б-н шөгыльләнүче субъектларның дәүләт б-н икътисади мөнәсәбәтләрен көйли торган закон актларының катлаулануы сәбәпле, бигрәк тә эре һәм уртача оешмаларда эчке аудитка ихтыяҗ туа. Инициатив аудит икътисади субъектның үз карары буенча уздырыла, мәҗбүри аудит закон актларында каралганча үткәрелә.

ТРда дистәдән артык аудиторлык оешмасы эшли. Аудиторлык эшчәнлеге б-н шөгыльләнү хокукына физик затлар — аудиторлар һәм юридик затлар — аудиторлык фирмалары ия. Шулар арасында: «Аудит-консалтинг», «Аудэкс», «Аудит-эксперт», «Совет», «Һөнәри аудиторлар берлеге» («Союз профессиональных аудиторов»), «Бәйсез консалтинг фирмасы» («Независимая консалтинговая фирма»). Алар б-н идарә итү өчен республикада Аудиторлык палатасы оештырыла (1993). Предприятие-клиент аудиторлык фирмасын яки аерым аудиторны сайлап алу хокукына ия.

*Әд.:* Лоббен Дж.К., Аренс Э.А. Аудит. М., 1995; Суйц В.П., Смирнов Н.Б. Основы российского аудита. М., 1997; Глушков И.Е. Аудит на современном предприятии. М.-Новосиб., 1997. *Р.А.Абдрахманов.*

**АУЕ́СКИ АВЫРУЫ́** (Morbus Aujeszkyi), ялган котыру, йогышлы бульбар параличы, кычытулы чума, котырган корчаңгы, герпес—дуңгызлардагы вирус, барлык а.х. терлекләрендә, мехлы җәнлекләр һәм кимерүчеләрдә була торган каты авыру. Баш һәм арка мие зарарлану б-н үзенчәлекле. Россиядә (ш.и. ТРда), барлык Европа илләрендә, Көньяк һәм Төньяк Америка, Африка, Азия һәм Австралиядә очрый. Энзоотияләр рәвешендә бара һәм зур икътисади зыян китерә. Дуңгызлардан тыш, мөгезле эре терлек, атлар, сарык һәм кәҗәләрдә, ерткыч хайваннарда үзенчәлекле көчле кычыту күзәтелә. Имүче һәм имезүдән яңа аерылган дуңгыз балалары аеруча нык авырыйлар. Карында яисә туганнан соң беренче 10 көндә зарарланган дуңгыз балаларында авыру септик характерда була, һәм алар яшәүгә яраклаша алмый. 10 көнлектән 3 айгача яшьтәге дуңгызларда авыруның беренче билгеләре булып бизгәк тоту (тән темп-расы 41–42 °С җитә), сүлпәнлек, борыннан лайла агу күзәтелә. Аннары үзәк нерв системасы зарарлану билгеләре, муен һәм күшәү мускуллары, умырткалык мускулатурасы (арка сыгылып төшү) тартышуы күренә. Еш кына тартышу өянәге була. Алга таба йөткылык, бугаз, очлыклар параличы башлана. Афония: авыздан күбекле селәгәй агу, үпкә шешенүдән сулыш кысылу күзәтелә. Авыру берничә сәгатьтән алып 3 тәүлеккә кадәр дәвам итә. Авыруларның 70 тән 100% ка кадәре үлә. РФдә А.а.ның профилактика чарасы буларак 1976 елда Казандагы Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-тында БУК-628 штаммыннан алынган

(Г.Х.Камалов, А.В.Селиванов) инактивлаштырылган һәм тере вакциналар кулланыла.

*Р.Х.Йосыпов.*

**АУЕ́СКИ АВЫРУЫНА́ КАРШЫ́ ВИ́РУС-ВАКЦИ́НА**, БУК-628 штаммыннан алынган махсус эшләнгән коры препарат. Казан бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-тында 1976 елда Г.Х.*Камалов* һәм А.В.*Селиванов* тарафыннан уйлап табыла. Тере вакцина үсеп килүче тавык эмбрионнары тукымасыннан әзерләнгән күзәнәк культурасында көчсезләндерелгән вирус (БУК-628 штаммы) үстереп алына. Вакцина дуңгызларда Ауески авыруын булдырмау һәм фермаларны латентлы йогышлы авырулардан саклауның профилактик чарасы буларак һәр җирдә кулланыла. Хайваннарда иммунитет бер ел буе саклана.

*Р.Х.Йосыпов.*

**АУКЦИО́Н** (лат. auctio — халык алдында сату), халык алдында сатулашу нигезендә товарны иң югары бәя тәкъдим итүчегә сату ысулы. А.ның төп төрләре — товар, валюта сату һ.б. А.да бәяләрнең күтәрелүе дә, киметелүе дә мөмкин. Татарстанда сәүдә итүнең А. формасы 1920–30 елларда киң тарала, 1950 елларда нигездә нәселле терлекләр А.ы уздырыла. ТРда 1993 тән пр-тиеләр, аларның цехлары, участоклары, мөлкәте, ш.у. кыйммәтле кәгазьләр, җир кишәрлекләре А.га куеп сатыла. А. сатучы (мөлкәт хуҗасы яки тиешле вәкаләте булган зат) һәм потенциаль сатып алучылар катнашында уздырыла. Устав капиталында дәүләт өлеше 25% тан ким булган хосусыйлаштырылган объектлар А.ында пр-тиеләрнең хезмәт коллективлары әгъзалары, гражданнар, юридик затлар, ш.и. чит ил кешеләре дә катнаша ала. А. комиссиясе адресына А.да катнашу өчен заявка бирелә, ә ябык А. уздырылганда, мөһерләнгән аерым конвертка объектның бәясе күрсәтелгән тәкъдимнәре, ш.у. сатучының исәп-хисап счетына залог кертүен раслаган документ тапшырыла. Сатып алучы А.да катнашу өчен билет алган вакыттан анда катнашучы хокукына ия була. Ачык А. товарга кыскача характеристика бирүдән, аның башлангыч бәясен белдерүдән, ш.у. товарның бәясе арту адымын билгеләүдән башлана. Адым сатуга тәкъдим ителгән мөлкәтнең башлангыч бәясенең 5–15%ы күләмендә була. Ә башлангыч бәясе мөлкәтне бәяләү хакыннан кимендә 5% тан югары булырга тиеш. Һәр объект А. комиссиясе тарафыннан аерым билгеләнә. Чираттагы белдерелгән бәяне өч мәртәбә кабатлаганнан соң, сатып алучыларның берсе дә билетын күтәрмәсә, сатулашу тәмамланган булып санала. Билет номеры иң соңыннан аталган сатып алучы А.да җиңүче була. Ябык А. вакытында катнашучыларның бәяләр турындагы тәкъдимнәре салынган конвертларны ачу һәм А. га йомгак ясау заявкалар кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә башкарыла. А. да иң югары бәя тәкъдим иткән сатып алучы җиңүче була. Әгәр А.да ике яки аннан да артыграк катнашучының тәкъдимендә иң югары бәя күрсәтелсә, заявканы элегрәк биргәне җиңүче дип табыла. Конкрет объект буенча сатулашуда катнашучылардан өчтән ким заявка керсә һәм А.да башлангыч бәягә сатып алучылардан беркем дә өстәмә кертмәсә, сатып алучы А. нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә кул куйганнан соң хосусыйлаштырылган объектның бәясен 30 көн эчендә түләмәсә, А. уздырылмаган дип белдерелә. Сатулашу ярышын ТР Дәүләт мөлкәте б-н идарә итү дәүләт комитеты кушуы буенча биржалар яки инвестиция фондлары алып бара. Терлекләр А.ы нәселле терлекләрне күргәзмәгә куеп сату формасында уздырыла. Терлекләр б-н таныштыру өчен алдан каталог төзелә. А. вакытында сатыласы терлек мәйданга чыгарыла. 1996–99 елларда Казанда күбесенчә җир кишәрлекләре сату А.ы уздырыла. 2001–05 елларда бурычларын түли алмаучыларның, банкротларның мөлкәтләрен мәҗбүри сату да А. аша гамәлгә ашырыла. ТР пр-тиеләре (җәнлек с-злары) С.-Петербург, Мәскәү, Монреаль, Амстердамда уздырылган мәгълүм халыкара А.да (җәнлек тиреләре сату) катнаша.

*Әд.:* Положение о разгосударствлении и приватизации государственной и коммунальной собственности в Республике Татарстан на аукционе // Основные законы и положения по приватизации в Республике Татарстан. К., 1992. Вып. 2.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**АУЛА́К ӨЙ**, кызлар утырмасы, татар яшьләре ялын оештыруның борынгыдан килгән төре. А.ө., гадәттә, көз һәм кыш айларында үткәрелгән, өлкәннәр өйдә юк чакта кызларга үзара аралашырга, күңел ачарга мөмкин булган. А.ө.гә бизәнеп-ясанып, кул эшләрен алып, караңгы төшкәнче үк җыелалар. Ләкин бәйләү, чигү кызлар өчен сылтау гына була, А.ө.дә авыл яңалыклары турында сөйләшү, уртак чәй табыны — аулак аш оештыру, күңел ачу — җыр, бию, төрле уеннар чиратлашып бара. Утырма төн уртасына кадәр дәвам итә. Якын-тирәдә яшәүче кызлар өйләренә кайтып китә, кайберләре исә куныл та кала. А.ө.гә егетләрне кертмәгәннәр. Традицион вариантта А.ө. 1950 елларга кадәр яшәп килә. Татар халкында әле дә яшьләрнең эти-әниләре өйдә юк чакта кечкенә төркем булып кич утыруларын (хәзер инде егетләр катнашында) «А.ө.» дип атыйлар.

*Әд.:* Б а я з и т о в а Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; У р а з м а н о в а Р.К. Современные обряды татарского народа. К., 1984.

**АУЛА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында Зыча елгасының уң кушылдыгы (Зәй бассейнында). Озынлыгы 23 *км*, бассейнының мәйданы 192,4 *км*$^2$. Елга башы Тукай р-нының Бакчасарай авылы, тамагы Зәй р-нының Карман авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 71 *м*. А. сызалар һәм елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән калкулыклы тигезлек аша ага. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 32%. Урта агымында елга үзәне асимметрияле, сулъяк сөзәклекләре беркадәр текәрәк. А.ның 2 дән 9 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 75 *мм*, ташу вакытындагы су катламы 52 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,08 *м*$^3$*/с*. Суы бик каты (9–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Елганың гомуми күләме 1,8 млн. *м*$^3$ дан гыйбарәт 3 буасы бар. Суы сугару өчен файдаланыла.

**АУЛА́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Аулаш елгасы буенда. 2002 елда 98 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 18 йөздә Югары Аулаш буларак нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, А.та су тегермәне була. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән — Зәй, 1977 нең 26 декабреннән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 51 ир заты; 1870 тә — 220, 1913 тә — 498, 1920 дә — 522, 1926 да — 517, 1938 дә — 448, 1949 да — 333, 1958 дә — 239, 1970 тә — 260, 1979 да — 177, 1989 да — 131 кеше.

**АУРГАЗЫ́ РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасында* 1930 елның 30 августында оештырыла. Мәйданы — 2014 *км*$^2$. Үзәге — Талбазы авылы (Уфадан 80 *км* көньяктарак). Халкы — 38996 кеше (2002). Татарлар саны: 1939 да — 21866, 1970 тә — 25643, 1979 да — 21979, 1989 да — 18773, 1999 да — 20132, 2002 дә 16886 кеше. Районда 143 торак пункт, ш.и. 52 татар, 2 татар-башкорт, 1 татар-чуаш авылы бар. Иң зур татар авыллары (1999): Талбазы (11864 кеше), Ишле (1076), Исмәгыйль (839), Солтанморат (774), Семёнкин (720). Иң борынгылары: Зәет (1634 тән мәгълүм), Усман (1705), Иске Күзәк (1710), Кәбәч (1714). А.р.ның 17 мәктәбендә 2004/2005 уку елында укыту татар телендә алып барыла, 26 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Бу районда язучы Г.Г.*Ибраһимов* (Солтанморат а.), тел белгече Г.Х.*Алпаров* (Корманай а.), филол. фән. д-ры Ү.И.*Гыймадиев* (Яңа Карамалы а.), Башкортстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы Ә.В.*Бакыев* (Собханкол а.), генерал-лейтенант Я.Җ.*Чанышев* (Тукай а.), баянчы Б.М.*Гайсин* (Кешәнле а.) һ.б. атаклы шәхесләр туган.

**АУЭ́ЗОВ** Мохтар Омархан улы (16.9.1897, Семипалат губ., Чыңгыз волосте Чыңгызтау җәйләве — 27.6.1961, Мәскәү), казакъ язучысы, әдәбият галиме, җәмәгать эшлеклесе, Казакъстан ССР ФАнең хакыйкый әгъзасы. «Караш-Караш үткелендә булган хәл» (1927), «Текәлек» (1935) повестьлары, тәмамланмаган «Яшьләр токымы» (1962) романы, «Енлик-Кебек» (1917), «Ак каен» (1938, Ә.Таҗибаев б-н берлектә), «Абай» (1940, Л.С.Соболев б-н берлектә), «Кобланды» (1945) пье-

салары һ.б. әсәрләр авторы. А. татар әдәбиятын үз иҗатына йогынты ясаучы мөһим чыганак дип саный. Мәс., Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы А.ны «Абай юлы» роман-эпопеясын язуга этәрә (1 нче китап «Абай», 1–2 т., 1942–47, СССР Дәүләт бүләге, 1949; 2 нче китап «Абай юлы», 1–2 т., 1952–56, Ленин бүләге, 1959). 1957 елда роман С.Әдһәмова тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә. 1950 елларда герой-шагыйрь М.Җәлил исемен җәмәгатьчелек алдында аклауда, аның иҗатын татар халкына кайтаруда А. зур роль уйный.

Ә с ә р.: Таңдамалы шыгармалар: 6 томдык. А.-А., 1955–57; Сочинения: В 5 т. М., 1973–75.

*Әд.:* Х ә м и д у л л и н Л. Чыңгыз тауларының бөркете // Казан утлары. 1980. № 11; К а р а т а е в М. М.Ауэзов. А.-А., 1967.

*Р.К.Ганиева.*

**АФАНА́СИЙ** (Малинин Александр Антонович) (6.3.1884 — 27.4.1939), дин эшлеклесе, дин гыйлеме магистры (1909). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1908) һәм 1909 елдан шунда укыта. 1910 нан пасторлык каф. профессоры. 1908 дән монахлыкта. 1916 дан архимандрит, 1920 дән Чабаксар епископы, 1930 дан архиепископы. 1930 еллар башында репрессияләнгән митрополит Кирилл (Смирнов) урынында Казан епархиясен җитәкли. 1933 тән Ташкент архиепископы. 1935 тән ялга чыга.

**АФАНА́СИЙ** (Соколов Андрей Григорьевич) (27.6.1801, Кострома губ. Буй ш. — 9.11.1868, Казан), дин эшлеклесе, дин гыйлеме магистры (1826). Петербург руханилар академиясен тәмамлый (1825). 1825–41 елларда Псков, Харьков, Чернигов, Тверь, Петербург руханилар семинарияләрендә ректор. 1841–53 тә Томск, Енисей епископы, 1853–56 да Иркутск һәм Нерчинск, 1856 дан Казан һәм Зөя архиепископы. А. вакытында Казан епархиясендә керәшен татарларның православиедән күпләп ваз кичүләре башлана, әмма ул исламга кайтучыларга карата кискен адм. чаралар күрүне якламый. Г.К.Казимбәк, Г.С.Саблуков, Н.И.Ильминский тәрҗемәләрендәге дини китапларны бастыруны тизләтүгә ярдәм итә. Казан руханилар академиясендә миссионерлык бүлеге ачылуына һәм анда Н.И.Ильминскийның эшчәнлегенә каршы чыга, бу соңгысының аннан китүенә сәбәп була. Табигать фәннәренең ролен югары бәяли, аларны Казан руханилар академиясе һәм семинариясендә укытуны камилләштерүгә ирешә. Соңрак Казан керәшен татарлар үзәк мәктәбен оештыруда ярдәм итә. А. булышлыгы б-н Чистай Успение хатын-кызлар һәм Пернягаш Михаил-Архангел чирмеш ирләр монастырьлары ачыла.

*Әд.:* Высокопреосвященный Афанасий, архиепископ Казанский и Свияжский. К., 1868; З н а м е н с к и й П.В. История Казанской духовной академии за первый (дореформенный) период (1842–1870). К., 1892.

**АФАНА́СЬЕВ** Агафангел Александрович (5.12.1901, Самара өлкәсенең хәзерге Яңа Узден р-ны Куриловка а. — 12.6.1985, Казан), икътисадчы, проф. (1935), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1940, 1962). 1923 елда Г.В.Плеханов исем. халык хуҗалыгы ин-тын (Мәскәү) тәмамлый. 1925–32 елларда Казан хезмәтне фәнни оештыру ин-тында эшли. 1930–51 дә — Казан финанс-икътисад ин-тының бухгалтерлык исәбе, 1951–76 да Казан авиация ин-тының сәнәгать һәм җитештерүне оештыру кафедралары мөдире. Хезмәтләре пр-тиедә капитал әйләнешенә һәм хуҗалык эшчәнлеген анализлауга карый. Югары уку йортлары өчен «Сәнәгать предприятиесе отчётларын анализлау» («Анализ отчёта промышленного предприятия», Л., 1938) дәреслеге авторы, «Бухгалтерия балансын төзү нигезләре» («Основы построения бухгалтерского баланса», М., 1948) монографиясе Чехословакия, Польша, Венгрия, ГДР һәм Монголиядә кабат бастырыла. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кругооборот капитала на предприятии. Л., 1929; Анализ хозяйственной деятельности. К., 1935.

**АФАНА́СЬЕВ** Александр Иванович (8.2.1931, Әлмәт р-ны Кит Елга а. — 16.6.2005, Казан), журналист, тарих фән. канд. (1968), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2001). Казан ун-тын (1955) һәм КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1968) тәмамлый. 1955–58 елларда Лениногорск шәһәрендә өлкән тикшерүче. 1961–90 да «Коммунист Татарии» ж-лында: 1968–72 дә бүлек мөдире, баш мөхәррир урынбасары, 1987–90 да баш мөхәррир. 1972–87, 1990–91 дә КПССның Татарстан өлкә комитетында (1990 нан матбугат үзәге җитәкчесе). Бер үк вакытта 1975–86 да КПССның Татарстан өлкә комитеты каршында чыга торган «Агитатор блокноты» — «Блокнот агитатора» ж-ллары мөхәррире. 1992–2002 дә «Фән» нәшриятында баш мөхәррир, бер үк вакытта 1995–2001 дә «Научный Татарстан» — «Фәнни Татарстан» ж-лында баш мөхәррир урынбасары. Мәкаләләре тарих һәм иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә карый. «Совет Татарстаны ленинианасы» («Лениниана Советской Татарии», т. 1–10, 1980–87) сериясенең җәмәгать башлангычындагы редколлегия рәисе. ТАССР ЮС депутаты (1985–90). «Почёт билгесе» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Ленинская тактика классовой борьбы. К., 1974; В часы досуга // Перестройка: проблемы, поиски, находки. М., 1987; Академия наук Татарстана. К., 1994 (автордаш).

**АФАНА́СЬЕВ** Александр Петрович (25.7.1920, хәзерге Югары Ослан р-ны Түбән Ослан а. — 25.7.1944, Польша), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, вафатыннан соң), өлкән лейтенант (1944). 1938 елдан Кызыл Армиядә. Ленинград танк уч-щесен тәмамлый (1940). 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, танк ротасы командиры (2 нче танк армиясенең 3 нче танк корпусы 51 нче танк бригадасы). 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Украина, Белоруссия, Польшаны азат итү сугышларында катнаша. Пухачув шәһәре (Польша) өчен барган сугышта үзенең танкы б-н дошманның штурмлау тубын таптата һәм һәлак бу-



А.П. Афанасьев.

ла. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

**АФАНА́СЬЕВ** Анатолий Юрьевич (1.3.1940, Казан), электромеханика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1998), проф. (1999). 1963 елда Казан авиация ин-тының (хәзер Казан техника ун-ты) приборлар төзү ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1993 тән электр җиһазлары кафедрасында. Хезмәтләре электромеханика системаларын оптималь проектлаштыруга һәм алар б-н идарә итүгә карый. Магнит системасы куелган һәм магнит реакциясе хасил итә торган электр двигательләренең конструктив схемаларын, оптималь моментлы двигательләрнең охшашлык теориясен төзи. Уйлап табуга 62 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Моментные двигатели постоянного тока. М., 1989 (автордаш); Моментный электропривод. К., 1997; Моделирование электроприводов на ПЭВМ в системе Turbo-Pascal 5.5. К., 1999.

**АФАНА́СЬЕВ** Андрей Александрович (22.9.1950, Казан), тренер, судья (су тубы), халыкара категорияле судья (1982). Дәүләт үзәк физик культура ин-тын тәмамлый (1977, Мәскәү). 1971 елдан тренерлык эшендә, Казандагы 1 нче йөзү бассейнында инструктор (1971–77), 8 нче балалар-яшүсмерләр олимпия әзерлеге спорт мәктәбендә тренер-укытучы (1974–77), Волгоград физик культура ин-тының Казан филиалында йөзү каф. укытучысы (1977–82). 1982 дән 8 нче балалар-яшүсмерләр олимпия әзерлеге спорт мәктәбендә (Казан) тренер. СССР чемпионатларында (1981–91), СССР халыклары спартакиадасында (1983), Европа (1988–89, 1991–92, 1995, 1999), дөнья чемпионатларында (1985, 1991, 1995, 1999), «Игелекле уеннарда» (1986), Олимпия уеннарында (1996) судьялык итүдә катнаша.

**АФАНА́СЬЕВ** Вадим Алексеевич (8.9.1932, Чиләбе ш.), скрипкачы, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978). Мәскәү консерваториясенең скрипка классын тәмамлый (Ю.Янкелевич шәкерте). 1958 елдан Казан консерваториясендә эшли (1990–93 тә камера ансамбле һәм концертмейстерлык, 1993 тән — скрипка каф. мөдире, проф.). Бер үк вакытта 1964–69 да Казан консерваториясе каршындагы Махсус музыка урта мәктәбе директоры. Шәкертләре арасында Бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреатлары, дипломантлары Ф.Закирҗанова, Ю.Ви-


К.К. Афанасьев.


К.П. Афендулов.


ват, Л.Әхмәтова, Р.Баруковалар бар. 1979 дан Казан консерваториясенең камера оркестрын оештыра һәм җитәкли. Оркестр б-н актив концерт эшчәнлеге алып бара. Оркестр репертуарында Г.Гендель, И.Бах, А.Вивальди, В.Моцарт, П.Чайковский, Н.Җиһанов һ.б.ның әсәрләре бар. А. үзе дә концертларда актив катнаша. Камера ансамбле, скрипка өчен классик һәм хәзерге заман әсәрләрен башкара. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**АФАНА́СЬЕВ** Василий Григорьевич (3.2.1936, Куйбышев өлкәсенең Кинель-Черкасск р-ны Семёновка а. — 1.3.1982, Яшел Үзән ш.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983, вафатыннан соң). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1966). 1952 елдан «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсендә, 1970 тән цех башлыгы. Дәүләт бүләге махсус билгеләнештәге эшләнмәләрне камилләштергәне һәм аларны әзерләүдә алдынгы технологияләр булдырганы өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**АФАНА́СЬЕВ** Георгий Захарович (14.4.1906, хәзерге Мордва Респ-касының Ичалковск р-ны Баево а. — 24.9.1965), химик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). Казан ун-тын тәмамлый (1936). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1929–31 елларда сарык тиресе-мех з-дында (Горький өлкәсенең Б.Мурашкино авылында) смена мастеры, цех башлыгы. 1931–60 та (бүленеп) Казан мех комб-тының 1 нче, 2 нче мех ф-каларында: чимал-буяу производствосы мөдире, баш инженер, 1946–60 та директор, 1944–46 да шунда ук заказ бирүчеләрнең хәрби вәкиле. 1960–61 дә Казан мех техникумы директоры. Дәүләт бүләге иләнгән сарык тиресенең йон катламын затлы итеп эшкәртүнең яңа ысулын эшләгәне һәм сәнәгый кулланылышка керткәне өчен бирелә.

**АФАНА́СЬЕВ** Кузьма Кириллович (1917, хәзерге Әлки р-ны Иске Тумба а. — 20.12.1966, шунда ук), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), сержант (1944). 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 795 нче укчылар полкының пулемёт отделениесе командиры (53 нче армиянең 228 нче укчылар дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш, Резерв, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украина, Молдавия, Румыния, Венгрия, Чехословакияне азат итү сугышларында катнаша. 1944 нең октябрендә Сольнок шәһәреннән (Венгрия) төньяктарак Тиса елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң запаста. Әлки р-ны урман хуҗалыгында эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.


Гамил Афзал.

**АФАНА́СЬЕВ** Порфирий Васильевич (20.2.1942, Чирмешән р-ны Яңа Элмәле а.), шагыйрь, Чуаш Респ-касының халык шагыйре (1998), атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1964). 1965 елдан журналистлык эшендә, 1977–85 елларда «Хатĕр пул» («Әзер бул», Чабаксар) балалар ж-лында баш мөхәррир. 1986–90 да Чуаш АССРның Язучылар берлеге рәисе. 1998–2002 дә Чуаш Респ-касының Матбугат һәм мәгълүмат эшләре дәүләт комитеты рәисе урынбасары. А.ның «Ҫакăр» («Икмәк», 1974), «Сан ятупа» («Синең исемең белән», 1983), «Хĕвел хапки» («Кояш капкалары», 1988), «Юрату ҫĕршывĕ» («Мәхәббәт җире», 2002), шигырьләрендә һәм поэмаларында, «Урхамахпа трубач» («Ат һәм быргычы», 1969) балладасында, «Вучах» («Учак», 1978) повестенда заман һәм кеше турында уйланулары урын алган. А.ның күп кенә әсәрләрендә — «Ҫарăмсан кĕввисем» («Чирмешән көйләре», 1975) китабында, «Тав» («Бәхилләү» 1999) исемле шигырь һәм поэмалар җыентыгында Татарстан темасы чагылыш таба. «Ҫан ятупа» драматик поэмасының сюжеты Чирмешән буйларында барган Гражданнар сугышы чоры вакыйгаларына бәйле. «Элмәле чишмәләре» («Роднички под Ильмами», М., 1984) китабы туган авылына багышлана. Г.Тукай, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, К.Латыйп һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрен чуаш теленә тәрҗемә итә. Чуаш Респ-касы дәүләт бүләге лауреаты (2001).

Ә с ә р.: Чирмешәннең йотым суы. К., 1990; Солнечные врата. Чебоксары, 1992; Писатели Чувашии: Биобиблиогр. справ. Чебоксары, 2006; Чуваши Татарстана. Чебоксары, 2006 (автордаш).

*Әд.:* С т а в с к и й М. Эстетика тата чăваш илемлĕ литературы. Шупашкар, 1993.

*В.П.Станьял.*

**АФЕНДУ́ЛОВ** Константин Пантелеевич (18.2.1921, Украина ССР, Донецк өлкәсенең Тельман р-ны Иске Лаепа а. — 28.3.1984, Украина ССР, Чернигов ш.), галим-агроном, ВАСХНИЛның мөхбир әгъзасы (1973). Татар милләтеннән. Бөек Ватан сугышында катнаша. Воронеж а.х. ин-тын тәмамлый (1951). 1957 елдан — Донецк, 1960 тан — Чернигов өлкә а.х. тәҗрибә станцияләре, 1972 дән ВАСХНИЛның Себер бүлеге Себер терлек азыгы фәнни-тикшеренү ин-ты (Новосибирск өлкәсе) директоры, 1977 дән Украина Терлек азыгы фәнни-тикшеренү ин-тында терлек азыгы үстерү технологиясе бүлеге мөдире (Винница ш.). Хезмәтләре үсемлекләрне минераль тукландыру теориясе үсешенә, чәчү әйләнешендә а.х. культураларыннан планлаштырылган уңыш алу өчен ашламаларны рациональ куллануга, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Себер туфрагының потенциаль уңдырышлылыгын һәм реаль мөмкинлекләрен билгеләүгә карый. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Минеральное питание и удобрение кукурузы. Киев, 1966; Основы системы удобрений сельскохозяйственных культур в севообороте. Киев, 1971; Удобрение под планируемый урожай. М., 1973; Теория и практика программирования урожаев. М., 1983.

**АФЗА́Л** (Афзалов) Гамил Гыймазетдин улы (23.5.1921, Минзәлә кантонының Актаныш волосте Такталачык а. — 20.8.2003, Әлмәт ш.), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985), ТССРның халык шагыйре (1991). Әдәби иҗат б-н 1936 елда шөгыльләнә башлый. Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә татар пед. техникумында укый (1936–37). 1939–49 да Магнитогорск металлургия комб-тында эшли. Сәламәтлеге начараю сәбәпле эштән китәргә мәҗбүр була һәм 1953 тә Башкортстан АССРның Кушнаренко р-ны Шәрип авылына кайтып урнаша. 1965 тән Әлмәт шәһәрендә яши. 1955 тә «Совет әдәбияты» ж-лында басылган шигырьләре әдәбият тәнкыйтьчеләре һәм шигырь сөючеләр игътибарын җәлеп итә. А. — балаларга атап чыгарылган «Кар сулары» (1957), «Вөҗдан сүзе» (1958), «Кояшлы яз» (1961) һ.б. җыентыклар авторы. «Ышаныгыз» (1971), «Кышкы озын кичләрдә» (1975), «Айлы кичләр» (1977; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1977), «Шундый-шундый эшләр» (1988), «Август йолдызлары» (1994) җыентыкларына кергән шигырьләр афоризмнарга, көчле сатирик образларга бай, аларда лирика һәм юмор бергә үрелеп бара. Лирикасында тере табигатьнең бай палитрасы чагылыш таба. А.ның күп кенә шигырьләрендә фәлсәфи тирәнлек өстенлек итә. 1990 елларда А. иҗатында татар халкы тарихына игътибар көчәя. Әсәрләрендә ул борынгы бабаларыбызның бөек үткәненә дан җырлый, мөстәкыйльлек, милли үзаңны уяту омтылышы арта. Шигырьләре рус һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителеп басыла, аларның кайберләре көйгә салына. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1991; Гомер кичүләре. К., 2000; Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 2004; Бессонной ночью. М., 1966.

*Әд.:* Ю з и е в Н. Ул матурлык эзли дөньядан // Шигърият дөньясы. К., 1981; Ф ә й з у л л и н Р. Халыкчан шагыйрь // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т. 4; Г а л и у л л и н Т. Тынгысыз каләмнең үлемсез шигърияте // Татарстан. 2001. № 5.

*Т.Н.Галиуллин.*

**АФЗАЛЕТДИ́НОВ** Нәфис Әбелгата улы (5.1.1940, Әлмәт р-ны Кичүчат а.), нефтьче. Хезмәт даны орденының тулы кавалеры (1978, 1986, 1991), РСФСРның атказ. нефтьчесе (1983). 1963–70 елларда «Елховнефть» НГДУында бораулау мастеры, 1970–2000 дә — нефть һәм газ чыгару операторы. Нефть һәм газ чыгару өлкәсендәге уңышлары өчен орденнар б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры Ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**АФИ́ША** (фр. afficher — күрсәтүгә чыгару), спектакль, концерт, һ.б. тамаша чаралары турында хәбәр итүче белдерү. Бик борынгыдан ук (Мисыр, Греция, Рим) мәгълүм. Элек тамашалар турындагы белдерүләр йорт диварларына, кайвакыт махсус такталарга, папирусларга язылган. Европада китап басу эше үсеш алганнан соң, кәгазьдә басылган А. кулланышка керә. Кытайда, Япониядә А. озак вакытлар дәвамында рәссам-каллиграфлар тарафыннан ефәккә кулдан язылган. 19 йөз ахырыннан рәсемле афиша-плакатлар киң тарала, аларны эшләүгә танылган рәссам-графиклар тартыла; алар театр һәм рәсем сәнгате тарихында аерым урын алып тора. Казанда кулдан язылган беренче театр А.сы турында С.Т.Аксаков үзенең «Хатирәләр» («Воспоминания», 1804–07) дигән әсәрендә хәбәр итә. 1830 елларда типографиядә басылган А.лар барлыкка килә. Театр биналары, кибет витриналары янына эленә, заказчылар теләге буенча А. таратучылар тарафыннан өйләргә китерелә. 19 йөз ахырында шәһәрдә А. баганалары (тумбалар) барлыкка килә. А.да, кагыйдә буларак, күп актлы пьеса, бер актлы комедия-водевиль һәм кечкенә концерт программасы — дивертисмент кергән тамаша составы, пьеса авторлары, катнашучылар һәм башкаручылар исемлеге, тамашаның куелу вакыты, көне, билет бәяләре, шулай ук куярга әзерләнә торган пьеса исеме хәбәр ителә. 1920 елларда Казанда «Сул фронт»ның («Левый фронт») оешуы б-н конструктивистик А.лар киң тарала, ул элекке А. дан мәгълүмат бирү алымы, шрифтларны куллану үзенчәлеге, күләме, зурлыгы б-н бик нык аерыла. Басма А. б-н бергә рәссамнар ясаган А. да кулланыла. КЭМСТ театрының рәссамнар М.В.Барашов б-н К.К.Чеботарёв ясаган А.лары аеруча үзенчәлекле. Еш кына Казан урамнарында «тере афиша»ны күрергә мөмкин була. Махсус костюмнар яки як-якларына, кырларына хәрефләр ясалган картон кублар кигән кешеләр урамнарда йөри һәм гражданнарны тамаша карарга чакыралар. Шул елларда А.да еш кына актёрларның фотографияләре дә урнаштырыла. 1940 еллар ахырыннан А.да актёрларның портретлары, спектакльләрдән аерым күренешләр бирелә. 1950 еллар ахырында рәссамнар тарафыннан ясалган афиша-плакатлар кабат күренә башлый. Театр рәссамнары Э.Б.Гельмс, П.Т.Сперанский, Л.Х.Насыйров, Д.Е.Куликов һ.б. спектакльгә декорация эскизлары ясау б-н бергә әсәрнең төп фикерен сәнгать чаралары ярдәмендә ачкан плакатлар эшлиләр. Нәтиҗәдә А.дагы мәгълүматны акыл б-н генә түгел, хисләр аша кабул итү мөмкинлеге туа. 1960–70 елларда сәнгать күргәзмәләрендә костюм һәм эскиз декорацияләре б-н бергә театр А.лары да күрсәтелә. 1980–90 да рәсемле А.-плакатларны рәссамнар А.Е.Простов-Покровский, Р.Г.Сафиуллин, С.Г.Скоморохов, А.М.Патраков һ.б. ясый. Спектакльләргә багышланган А. аерым спектакль б-н таныштырса, репертуарга багышланганнары аерым театрның бер атна, 10 көн, бер ай буена куелачак спектакльләр исемлеген тәкъдим итә; җыелма А.да шәһәрнең барлык театрларының билгеле бер вакыт эчендә куела торган спектакльләре; бенефис А.сында берәр актёрның яки режиссёрның иҗат кичәсе турында хәбәр ителә.

*Әд.:* Театральная энциклопедия. М., 1961. Т. 1.

*Ю.А.Благов.*

Спектакль афишалары. 1-2. И.Кудашев-Ашказарскийның татар труппасы. 1907; 3. Казан шәһәр театры. 1867; 4. М.Булгаков. «Качу». Рәссам Л.Насыйров. 1967. Казан Зур драма театры; 5. Н.Исәнбәт. «Хуҗа Насретдин». Г.Камал исем. Татар академия театры. 1989; 6. Ж.Б.Мольер, «Скапен хәйләсе». Рәссам А.Патраков. 1994. Казан Зур драма театры.



1




2



3


4


5



6

**АФО́НСКИЙ** Сергей Иванович (25.6.1896, Мәскәү губ., Клин өязе Георгиевск а. — 1968, Мәскәү), вет. табибе, биохимик, биол. фән. д-ры (1936), проф. (1929), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). Казан вет. ин-тын тәмамлагач (1920), шунда ук эшли, 1924–48 елларда биологик химия каф. мөдире, бер үк вакытта 1941 елдан проректор. 1948 дән Мәскәү вет. академиясендә: органик һәм биологик химия каф. мөдире, бер үк вакытта 1949–61 дә проректор, 1961 дән — ректор. Биологик мембраналар, койкаларның физик-химик үтеп керүчәнлеген тикшерә һәм бу процессса водород ионнары, липоидлар һ.б. матдәләрнең концентрациясе тәэсирен ачыклый. 1948 дә хайваннар организмында биохимик комплекслар таралуның яңа теориясен тәкъдим итә һәм әлеге кушылмаларның классификациясен төзи. Аның теориясе проф. Х.Ш.Казаков һәм Р.Х.Кармалиев хезмәтләрендә үсеш ала. Мәскәү вет. академиясендә аның тырышлыгы б-н ветеринария профиле буенча биохимиклар һәм биофизиклар әзерләү өчен вет.-биол. ф-ты оештырыла. «Хайваннар биохимиясе» («Биохимия животных») дәреслеге (1960; 3 нче басма, 1970) авторы. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Краткое пособие к практическим занятиям по биологической химии. К., 1928; Физическая и коллоидная химия. М., 1954.

*Әд.:* Ш и ш к о в В.П., М а л а х о в А.Г. Памяти Сергея Ивановича Афонского // Ветеринария. 1971. № 12; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1893–2006 гг.). К., 2006.

*Н.Ж.Хажипов.*

**АФОРИ́ЗМ** (грек. aphorismós — ачыклау, кыска гыйбарә), төп контексттан тәэсир көче б-н аерылып торган кыска, гомумиләштерелгән фикер, гыйбарә. Ш.у. әдәбият һәм фольклорда мөстәкыйль жанр буларак та яшәп килә. Әйтемнәр һәм мәкальләр дә А.га карый. Алар борынгы чорлардан ук билгеле. А. кыскарак булган саен тәэсирлерәк һәм мәгънәлерәк: мәс., «Ут — мут», «Күл — күз» мәкальләре ике сүздән генә, А.ның күпчелеге 3–5 сүздән тора, мәс., С.Сараида — «Йимеше күп агачка таш атарлар», Г.Тукайда — «Эш беткәч уйнарга ярый», «Иң мөкатдәс нәрсә — эш». Халык А.нарына мисаллар: «Усал булсаң — асарлар, юаш булсаң — басарлар», «Безнең урамда да бәйрәм булыр әле»,

«Кеше урыны белән күркәм түгел, ә урын кеше белән күрекле». А. әдәби, фәнни һәм сәяси-публицистик әсәрләрдә тирән мәгънә белдерү һәм үткен сүз әйтү өчен еш файдаланыла. Мәкальләрдән аермалы буларак, А.нар итеп танылган авторларның сүзләре кулланыла. Дөнья әдәбиятында А. осталары — Ф.де Ларошфуко, И.В.Гёте, А.С.Пушкин, И.А.Крылов. Татар әдәбиятында Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» поэмасында, Мөхәммәдъяр әсәрләрендә дә очрый. Соңрак Г.Кандалый, Акмулла, Г.Тукай, Дәрдемәнд, М.Җәлил А.ның күренекле осталары булып танылды.

*Әд.:* Мәхмүтов Х. Афористик иҗат төрләре // Жанры татарского фольклора. К., 1978; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Литературный энциклопедический словарь. М., 1987.

*З.М.Мәҗитов.*

**АФТАНДИ́ЛОВ** Арсен Маркович (16.11.1910, Баку ш. — 26.9.1986, Казан), генерал-майор (1954). М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне тәмамлый (1940). Бөек Ватан сугышында кавалерия дивизиясе командиры. 1954–64 елларда Идел буе хәрби округының мотоукчылар дивизиясе командиры. 1955–63 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Кутузов, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**А́ФФИКС** (лат. affixus — ялганган, ныгытылган, ябыштырылган), сүзнең тамырына ялганып, аңа өстәмә грамматик, лексик, стилистик мәгънә бирү өчен кулланыла торган морфема. Сүзнең кайсы урынында килүенә карап, А. берничә төргә бүленә: алкушымча (яки префикс) — сүзнең тамыры алдыннан килә (нем. телендәге über+lesen һәм рус телендәге про+читать); кушымча — тамырдан соң килә (эш+че, очу+чы); инфикс — тамыр уртасында килә (инглизчә stand — басып торырга сүзе stold — басып торган, торды сүзеннән); интерфикс — рус телендә ике тамырны кушу (лес+о+степь) яки татар телендә сузык авазлар б-н чиктәш ике янәшә морфеманы ялгау өчен (алты+ш+ар) кулланыла; трансфикс — гарәп телендәге кебек (кәтәбә — укырга, к+и+таб — китап, кат+и+б — сәркәтип), сүзнең тамырын ике өлешкә бүлә; конфикс — сүзнең тамырына яки нигезенә бер үк вакытта ике яктан ялгана торган ике морфема (с+делать+ся, под+стакан+ник); флексия яки сүзне үзгәрткәндә грамматик мәгънә белдерә торган кушымча (өстәл, өстәл+гә, өстәл+не; ала+м, ал+а, ала+лар). Функциональ яктан А. сүз ясагыч, грамматик (форма ясагыч), стилистик төрләргә аерыла. Сүз ясагыч А., тамыр яки нигезгә ялганып, яңа мәгънәле лексик берәмлек барлыкка китерә (мәс., ур+ак, эш+ләү, иген+че, утыр+гыч). Грамматик характердагы А. нинди дә булса грамматик категория б-н бәйле мәгънәне белдерә яки сүзнең грамматик формасын ясый. Грамматик А.ның ике төре билгеле: синтаксик (сүзләрне бәйләүче) һәм форма ясаучы А.лар. Мәс., татар телендә грамматик А.ның күпчелеге җөмләдәге сүзләрне бер-берсенә бәйләү өчен кулланыла (синтаксик яки сүзләрне бәйли торган А.). Хәзерге татар телендә грамматик А.ка килеш, тартым, зат-сан кушымчалары керә. Грамматик А.ның икенче бер төренә сүзнең формасын үзгәртүче (форма ясагыч А.), мәс., сыйфат фигыль, сыйфат дәрәҗәләрен ясаучы кушымчалар керә. Кайбер А. сүз ясагыч та, форма ясагыч та була ала. Мәс., юнәлеш А. (тукта+л, ки+ен), барлык-юклык А. (сыер+лы булдык) һәм -сыз/-сез (ат+сыз калдык). Әгәр А. сүзнең стилистик төсмерен генә үзгәртсә, стилистик А. дип атала (күгәрчен+кәй, кыз+чык).

*Әд.:* Хангилдин В.Н. Татар телендә сүз ясалышы // Татар телен укыту мәсьәләләре буенча фәнни-практик конференция материаллары. К., 1953; Общее языкознание. Внутренняя структура языка. М., 1972; Ганиев Ф.А. Татар грамматикасы. М.–К., 1998. Т. 1.

*Ф.Ә.Ганиев.*


**АХИРӘ́Т** (гарәп. آخرة — ахыр, соң), теге дөнья, үлемнән соңгы тормыш, исламда ул мәңгелек дип санала. Исламият белемендә А. концепциясе ике юнәлештә: А.не фани дөньяга каршы куеп чагыштыру планында һәм, А.не тасвирлап, *җәннәт* һәм *җәһәннәм*, мәетләрнең кабат терелеп кайтуын һ.б. күренешләрне җентекләп тикшерүдән гыйбарәт. Татар дини әдәбиятында һәм фольклорында А. *бакый дөнья*, (мәңгелек дөнья), җирдәге тормыш исә *фани дөнья* дип атала. А. «якын дус» («ахирәт дус») мәгънәсендә дә кулланыла.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**АХИЯ́РОВА** Мәрьям Җәләл кызы (9.9.1930, Балык Бистәсе р-ны Балыклы Чүкәй а.), педагог-методист, пед. фән. канд. (1972), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1987). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1955). 1955–60 елларда БАССРның Илеш р-ны Югары Яркәй урта мәктәбендә укыта. 1960 тан Казанда: 97 нче урта мәктәптә уку-укыту бүлеге мөдире; 1961 дән РСФСР ПФА Милли мәгариф проблемалары фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лында фәнни хезмәткәр. 1989–94 тә «Татарстан хәбәрләре» г-тасында хәбәрче; 1994–95 тә Татарстан интеллектуаль милек агентлыгында (ТАИС) методист. РФдәге төрки халыклар мәктәпләренең 1–4 сыйныфлары өчен күп тапкырлар нәшер ителгән әлифбалар һәм укыту-методика кулланмалары авторы.

Хезм.: Межпредметные связи в развитии речи учащихся начальных классов. К., 1983; Обучение русскому языку в начальных классах тюркоязычных школ. Л., 1984; Русский язык: Учеб. для 2 класса школ народов тюркской группы: В 2 ч. СПб., 2000.

**АХИЯ́РОВА** Резеда Зәки кызы (1.6.1956, Башкортстан АССРның Илеш р-ны Югары Яркәй а.), композитор, ТРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1993, 2003), ТРның халык артисты (2006). Казан консерваториясендә Р.Билаловның композиция классын тәмамлый (1980). Төрле жанрлардагы симфоник, вокаль-симфоник, театр спектакльләре өчен, камера-инструменталь һәм вокаль музыка әсәрләре авторы. Аның әсәрләренә ышандыру көче, эмоциональлек, лирика, романтика, гуманлылык, табигыйлек хас. «Кол Гали» симфониясе һәм «Моңлы сазым» симф. поэмасы бөек шагыйрьләр Кол Гали һәм Г.Тукайга багышлана. А.ның лирик муз. сәләте Х.Туфан, И.Юзеев, Р.Харис, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, Ә.Атнабаев шигырьләренә язган җырларында ачык чагыла. А. әсәрләре халыкара музыка фестивальләрендә (Америка һәм СССР композиторлары фестивале, 1989; Япон һәм татар музыкасы фестивале, 1992; «Европа-Азия» фестивальләре, 1993, 1996, 1998) башкарыла; «Туй күлмәге» (1991),



Р.З. Ахиярова.

«Р.Ахиярова: җырлар» (1993) грампластинкалары, «Татар композиторлары җырлары һәм романслары» (1999) һ.б. компакт-дисклары чыгарыла. Төп әсәрләре: симфоник һәм вокаль-симфоник әсәрләр — симф. оркестр һәм баритон өчен «Ил таңы» (1983); солистлар, хор һәм симф. оркестр өчен «Дуслык юлы» (1985); тенор, нәфис сүз һәм симф. оркестр өчен «Ватаныма» кантатасы (1989); сопрано, тенор, хор һәм симф. оркестр өчен «Тарих битләре» триптихы (Р.Вәлиев һәм Р.Шаһиева шигырьләре, 1998); камера-инструменталь әсәрләр — Скрипка, виолончель һәм фортепиано өчен трио (1979), Скрипка һәм фортепиано өчен соната (1980), Виолончель өчен соната-монолог (1984), Кыллы квартет (1996), Скрипка өчен соната (1998); балалар өчен язылган спектакльләргә музыка — Э.Блайтонның «Атаклы үрдәк баласы Тим» (1986), М.Супонинның «Сөзгәк кәҗә» (1987), Т.Миңнуллинның «Акбай» (1989), Н.Исәнбәтнең «Былтыр кысты» (1990) әсәрләренә көйләр, татар шагыйрьләре шигырьләренә язылган җырлар һәм романслар. 2006 елда Татар опера һәм балет театрында А.ның «Шагыйрь мәхәббәте» операсының премьерасы була (Р.Харис либреттосы, реж. М.Панджавидзе, дир. В.Соболев, төп партияләрне Ә.Агади, В.Ганиева башкара. Бу операның куелуы ТРның муз. театр тарихында зур вакыйга булып кабул ителә. Әсәр милли традицияләргә таянып язылган һәм музыка теленең үзенчәлеге, мелодикасының байлыгы б-н аерылып тора. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2008).

*Әд.:* Миңнуллин Р. Үзе яшь, үзе талантлы // Шагыйрь генә булып калалмадым. К., 1998; Сайдашева З. Резеда Ахиярова. К., 1989; Яхонтова Е. Следуя «закону искренности» // Советская музыка. 1991. № 5; Сафиуллина Л. Тукай на оперной сцене: Лирико-драматургическая фантазия «Любовь поэта» // Казань. 2006. № 10/11.

*З.Н.Сәйдәшева.*

**АХМАДУ́ЛИН** (Әхмәдуллин) Евгений Валерьевич (21.4.1944, Ростов өлкәсе Новочеркасск ш.), журналист, филол. фән. д-ры (2001), проф. (2003). Новочеркасск хим.-технол. техникумын (1963), Ростов ун-тын (1974) тәмамлый. Волжск химкомбинатында (1964), станоклар төзү з-дында (1967–71) инженер булып эшли. 1980 елдан Ростов ун-тында укыта, журналистика каф. мөдире (2002). Бер үк вакытта Новочеркасск шәһәр газетасында бүлек мөдире (1970–80), «Известия Северо-Кавказского научного центра высшей школы» ж-лының баш мөхәррир урынбасары

(1985–90), «Приазовский край» г-тасының баш мөхәррире (1991–93), «Журналист» нәшрияты директоры (1993–95), Россия Журналистлар берлегенең Ростов өлкә оешмасы идарә рәисе урынбасары (1996–2002). «Кыскача журналистика теориясе курсы» («Краткий курс теории журналистики», Ростов н/Д., 2006) уку ярдәмлеге авторы.

Х е з м.: Печать Дона в годы первой русской революции. Ростов н/Д., 1985; Правительственная печать России (конец XIX в. — февр. 1917 г.). Ростов н/Д., 2000; Пресса политических партий России начала XX века: Издания консерваторов. Ростов н/Д., 2001; Пресса политических партий России начала XX века: Издания либералов. Ростов н/Д., 2001.

**АХМАДУ́ЛИНА** (Әхмәдуллина) Белла (Изабелла) Әхәт кызы (10.4.1937, Мәскәү), шагыйрә. Казан ун-тының шәрәфле д-ры (2007). М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (1960, Мәскәү). Әсәрләре 1954 елда басыла башлый. А. шигъриятенә тирән фәлсәфилек, нечкә психологизм хас. Шигырьләрендә кеше җанының дөньявилык б-н гаять дәрәҗәдә катлаулы мөнәсәбәте чагыла. Иҗатында табигать зур акылга ия, үзе бер бөек дөнья булып гәүдәләнә, лирик герой шуны аңларга омтыла. А.ның поэзиясендә гармониягә тартылу көчле, шул ук вакытта аңа ирешүнең мөмкин булмавын аңлау сизелә. Шигъри фикерләвенә метафоралар байлыгы, муз. аһәңлелек хас. Бу үзенчәлекләр А.ның «Кыл» («Струна», 1962), «Калтырану» («Озноб», 1968), «Музыка дәресләре» («Уроки музыки», 1969) дип исемләнгән беренче шигъри җыентыкларында һәм соңгы елларда чыккан «Шәрехләүче аваз» («Звук указующий», 1995), «Гомер мизгелләре» («Миг бытия», 1997) җыентыкларында да ачык күренә. А.ның Казан б-н туганнары аша бәйләнеше бар. Әнисе ягыннан әбисе — А.М.*Стопанин*ың сеңлесе. Әтисенең чыгышы Казан татары Әхмәдуллага барып тоташа. Аның турында «Минем шәҗәрәм» («Моя родословная», 1964) поэмасында: «кысык күзле ыруында аның күзе кысыграк икән, һәммәсенең шуңа исе киткән» («в узкоглазом племени своём так узкоглаз, что все давались диву»), — диелә. Үзе турында ул: «Керсез азиатлык рухы миндә арлы-бирле йөри, кыенсынып» («Незапятнанный дух азиатства тяжело колобродит во мне»), — дип яза. Бөек Ватан сугышы елларында А. Казанда яши. Аерым шигырьләрендә Шәрекъ традициясе тәэсире сизелә. СССРның һәм РФнең Дәүләт бүләкләре лауреаты (1976, 2004). Халыклар дуслыгы, 3 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 3 т. М., 1977; Избранное: Стихи. М., 1988; Стихотворения. М., 1988.

*Әд.:* М у с т а ф и н Р. «Всем, кто есть, прихожусь близнецом»: Мир поэзии Б.Ахмадулиной // Татарстан. 1992. № 5–6.

*Т.Г.Прохорова.*



Б.Ә. Ахмадулина.



А.О. Ахманов.

**АХМА́НОВ** Алексей Осипович (9.3.1897, Казан губ., Казан өязе Алат а. — 17.11.1949, Минск), генерал-лейтенант (1941), Сов. Союзы Герое (18.4.1945). Казан пехота курсларын (1920), Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясен механикалаштыру һәм моторлаштыру хәрби академиясен (1935), Химик саклану хәрби академиясен (1938, Мәскәү), К.Е.Ворошилов исем. Югары хәрби академияне (1948, Мәскәү) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1918 елдан Кызыл Армиядә: Гражданнар сугышында Юденич, Деникин армияләренә каршы сугыша. Бөек Ватан сугышы алдыннан танк дивизиясе җитәкчесе, 1941 нең июненнән 23 нче танк корпусы командиры. Яссы-Кишинёв операциясендә (1944), Будапешт өчен барган сугышларда (1945) батырлык күрсәтә. 1948 дән Белоруссия хәрби округының бронетанк һәм механикалаштырылган гаскәрләре командующие. Ике Ленин, ике Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Кутузов орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Г а р а е в М. Ахманов Алексей Осипович // Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

**АХМА́ТОВ** Михаил Николаевич (8.6.1823, Әстерхан губ., Әстерхан өязе Началово а. — 31.3.1891, С.-Петербург), дәүләт эшлеклесе, яшерен советник (1873). Татар морзалары нәселеннән. Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1845). 1846–47 елларда Әстерхан губернасы дворяннары башлыгы канцеляриясендә эшли. 1847–50 дә Әстерхан хәрби губернаторы карамагында махсус вазифалар үтәүче чиновник. 1851 дән С.-Петербургта: 1867 гә кадәр Эчке эшләр министрлыгында; 1868–70 тә Финанс министрлыгында махсус вазифалар үтәүче чиновник, 1870–74 тә Финанс министрлыгы советы әгъзасы. Казан ун-тында укучы ярлы студентларга стипендияләр һәм ярдәм өчен 170 мең сум акча бирә. 1895–1917 елларда студентларга А. исем. стипендия түләнә.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Историческая объяснительная записка наименования казанских улиц. К., 1899; Преподаватели, учившиеся и служившие в Казанском университете (1804–1904 гг.): Материалы для истории университета / Сост. А.И.Михайловский. К., 1901. Ч. 1.

**АХМА́ТОВА** (псевд., чын фамилиясе Горенко) Анна Андреевна (11.6.1889, Одесса ш.- 5.3.1966, Мәскәү өлкәсе Домодедово ш., С.-Петербург янындагы Комарово пос. җирләнгән), шагыйрә, тәрҗемәче. Псевдонимы татар морзалары нәселеннән булган әбисенә нисбәтле. Бу турыда А. «Көндәлек битләре»ндә («Листки дневника») һәм «Кара балдак турында әкият»тә («Сказка о чёрном кольце», 1940) искә ала: «Әбием, татар карчыгы // Бүләк сирәк була иде кулларыннан // Зәһәрләнә иде кайвакытта // Чукындырылган булганымнан» («Мне от бабушки-татарки // Были редкостью подарки // И зачем я крещена // Горько гневалась она...»). Иҗатының төп үзенчәлекләре: тасвирлауда төгәллек һәм аныклык, стильдә ачыклык һәм гадилек, шигырьнең сюжетка корылуы, сөйләм теле интонациясе, рухи кичерешләрнең ышандыру көче беренче җыентыкларында ук («Кич» — «Вечер», 1912; «Дисбе» — «Чётки», 1914; «Ак төркем» — «Белая стая», 1917) сизелә. 1910–20 елларда мәхәббәт темасы иҗатында үзәк урынны ала. Алга таба тематика һәм жанр колачы киңәя, фәлсәфилек һәм гражданлык үзен нык сиздерә башлый («Алты китаптан» — «Из шести книг», 1940; «Геройсыз поэма» — «Поэма без героя», 1940–62; «Вакыт чабышы» — «Бег времени», 1965). А. иҗатына дөньяны аңлауда драматик кискенлек хас. 1941 нең октябрендә Чистай шәһәренә эвакуацияләнә (озакламый Ташкентка күчеп китә). 78 телдән 150 шагыйрьнең, ш.и. Г.Тукай, М.Җәлил, Ф.Кәрим әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә.



А.А. Ахматова.

Ә с ә р.: Вечер. Стихи. М., 1988; Сочинения: В 2 т. М., 1990; Чётки. Стихи. М., 1990.

*Әд.:* Ж и р м у н с к и й В. Творчество Анны Ахматовой. Л., 1973; П а в л о в с к и й А. Анна Ахматова: Жизнь и творчество. М., 1991.

*Т.Г.Прохорова.*

**АХМАТО́ВИЧ** Осман (1899, Литва, Виленщинадагы Бергалишики ш. — 1988), химик-органик, Польша ФА әгъзасы (1961). Польша-Литва татарларыннан. 1916–19 елларда Петроград тау ин-тында, 1919 да Вильно ун-тында, 1928–30 да Оксфорд ун-тында укый; 1925–28, 1930–33 тә Вильно ун-тында эшли; 1934–39, 1953–64 тә Варшава ун-тында, проф. (1939); 1945–52 дә Лодзь шәһәрендә политехника ин-тында, 1952 дә — ректор. 1953–60 та Польша Халык Респ-касының югары белем бирү министры урынбасары. 1964–69 да Лондонда Польша культурасы ин-ты директоры. Стрихнин һәм бруцин алкалоидларының структурасын тикшерә, дигидрострихнидинны таркатуга ирешә. Польша терр-ясендә үсемлекләрнең физиол. актив кушылмаларын тикшерә. Плауннар, сары һәм ак су лилиясенең элек билгеле булмаган алкалоидларын, уймак чәчәкнең кристаллик гликозидларын бүлеп чыгара һәм структурасын ачыклый. Клаватин алкалоидының структурасын билгели, тиобинуфаридин һәм неотиобинуфаридинны бүлеп чыгарып һәм тикшереп, алкалоидларның күкертле яңа классын (1960–62), ача. Кайбер хим. реакцияләр механизмын, башлыча, карбонилцианид реакциясен тикшерә.

**АХТАЙ**, елга, к. *Актай.*

**АХТО́НОВ** Валентин Александрович (6.10.1931, Тәтеш р-ны Льяш а. — 15.12.1998, Тәтеш ш.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Чуаш совет-партия мәктәбен (1960, Чабаксар ш.),

КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (1966, Горький ш.) тәмамлый. 1944–51 елларда Тәтеш р-нында колхозда эшли. 1960–66 да партия эшендә, 1966–79 да Югары Ослан р-нының «Куралово» с-зы директоры. Аннан соң Тәтеш шәһәрендә хуҗалык җитәкчесе вазифаларын башкара. Хезмәтне оештыруның яңа ысулларын, терлекчелектә авыр эшләрне механикалаштыруны башлап гамәлгә кертүче. Ул эшләгән вакытта «Куралово» с-зы алдынгы тәҗрибә мәктәбенә әверелә, ел саен а.х. продукцияләрен әзерләүдә дәүләт планнары арттырып үтәлә, берничә тапкыр РСФСР МСның Күчмә Кызыл Байрагына лаек була. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Октябрь Революциясе орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АХУ́Н** (фарсы. آخوند — остаз, әфәнде), югары дини зат, мөселманнарда сайлап куелган иң югары рухани дәрәҗә. Урта Идел буенда 16–17 йөзләрдән мәгълүм. А. түбәнрәк дәрәҗәдәге руханиларның эшчәнлеген тикшереп тору, яңа мәчетләр төзү мәсьәләләрен карау, хакимият һәм мөселман мәхәлләләре б-н арадашлык итү вазифаларын башкара. Оренбург мөселман Диния нәзарәте оешкач, сайлап куела торган А. вазифасы бетерелә, зур уңышларга ирешкән җамигъ мәчетләрнең имамнарына Диния нәзарәте яисә Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан дәрәҗәле исем рәвешендә генә бирелә башлый. Төгәл билгеләнгән юридик статусы булмау А.ны кыен хәлгә куя. 19 йөзнең икенче яртысында — 20 йөз башында А. исемен йөрткән дин эшлеклеләре билгеле бер төбәктә (гадәттә, берничә волость) мөселманнар арасында өлкән рухани булып саналалар. Алар Диния нәзарәте һәм мәхәллә җитәкчеләре арасында арадашчы вазифасын үтиләр. Эчке Россиядә 1887 дә — 60, 1916 да 220 А.була. Күренекле татар А.нары — Җ.*Абызгилдин*, М.*Бигиев*, Г.*Баязитов*, Ш.*Мәрҗани*.

*Әд.:* Азаматов Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII — XIX вв. Уфа, 1999; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1999.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**АХУ́Н** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 28 *км* көньяктарак, Башкортстан Респ-касы чигендә. 2002 елда 268 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 18 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинник катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, төрле кәсеп б-н шөгыльләнә, казна өчен печән кабул итү пунктларында, тирә-юньдәге тегермәннәрдә эшли. Мәчет 19 йөз башында төзелә, 1831 дән аның каршында мәктәп эшли башлый. 20 йөз башында авылда икмәк кибете була. Авыл җәмәгатенең имана җире: 1884 тә — 1130, 1896 да — 1069, 1913 тә 1292 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында А.да «Кызыл Сөн» к-зы оештырыла, 1950 елларда ул эреләндерелгән «Гранит» к-зы б-н берләшә. Хәзерге вакытта — «Ахун» ҖЧҖндә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 114, 1859 да — 252, 1870 тә — 322, 1884 тә — 680, 1906 да — 568, 1913 тә — 680, 1920 дә — 631, 1926 да — 568, 1938 тә — 495, 1949 да — 375, 1958 дә — 352, 1970 тә — 522, 1979 да — 431, 1989 да — 279 кеше.



С.С.А х у н. 1. «С.Сәйдәшев бюсты». Мәрмәр. 1957; 2. «Җәлил». Бронза. 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

**АХУ́Н** Садри Сәлах улы (16.3.1903, Екатеринбург ш. — 21.6.1990, Мәскәү), сынчы, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1944, 1950), ТАССРның халык рәссамы (1949). Чиләбедә мәдрәсә (1915) һәм коммерция уч-щесен (1919), Урал сәнгать-сәнәгать техникумын (таш кисү эшләре бүлеге, 1927), Ленинград пролетар сынлы сәнгать ин-тын (скульптура бүлеге, 1931) тәмамлый. Р.Р.Бах, А.Т.Матвеев, Л.В.Шервуд шәкерте. 1931–51 елларда Казан сәнгать уч-щесендә укыта, 1949 дан скульптура бүлеген җитәкли. 1951 дән Мәскәүдә яши. Мәскәү технол. ин-тының композиция каф. мөдире, проф. (1966–74), ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1936) һәм рәисе (1940–50).

Беренче профессиональ татар сынчыларының һәм 1930–50 дә совет скульптура сәнгатендә әйдәп баручы осталарның берсе булarak, милли сынлы сәнгать үсешенә зур өлеш кертә. А. иҗаты югары профессиональлеккә, татар халкы сәнгате һәм рус реалистик скульптурасы (П.К.Клодт, Ф.П.Шубин, П.П.Трубецкой), ш.у. Европа сәнгате (О.Роден һ.б.) традицияләрен чагылдыручы мөстәкыйль идея-образ концепциясенә нигезләнә. А. станлы скульптурага өстенлек бирә, гипс, мәрмәр, агач, фарфор кулланып, портрет һәм тематик композиция жанрларында эшли. Психологик портрет өлкәсендә танылган оста татар, рус һәм дөнья мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре образларының тулы бер галереясын — Г.Тукай (1929, 1938), Һ.Такташ (1931), К.Насыйри (1941), Н.Җиһанов (1941–45) һ.б. бюстларын; Р.Роллан барельефын (1938, А. аның б-н актив рәвештә хат алыша); гипста «Анри Барбюс», «Ленин», «Энгельс» барельефларын (1938–40), мәрмәрдән С.Җ.Сәйдәшев (1957), А.М.Бутлеров (1965), М.Горький (1968), Анджела Дэвис (1971), Рабиндранат Тагорның (1974) сынлы портретларын һ.б. иҗат итә. Вафатларыннан соң Һ.Такташ, Г.Камал, С.Айдаров, Ш.Камалның битлекләрен ала. Казан паркларындагы «Дөньяда хезмәт хакимлек итәчәк!» һәм «Балыкчы» фонтаннары, «Динамо» стадионы каршындагы «Теннисчы кыз» һәм «Ядрә атучы» фигуралары (барысы да 1934–37), Татар акад. театры интерьерындагы Г.Камал барельефы (1941–45) кебек монументаль бизәлеш сәнгате әсәрләре авторы.

А. Сов. Союзы Геройлары М.Воронков, И.Ижукин (икесе дә — 1945), Муса Җәлил (1957), Әхмәтхан Солтанның (1974) портрет-бюстларын монументаль скульптура жанрында иҗат итә. В.И.Ленин һәйкәле авторы (1957, Череповец ш.). А. тарафыннан (сынчылар Л.Кербель, В.Писаревский һәм арх. Л.Павловский б-н берлектә) ясалган һәм 1958 дә Казанда куелган Г.Тукайның монументаль бронза һәйкәле аеруча уңыш казана. А. Казанда яшәгән елларында станлы жанрда күп кенә композицияләр иҗат итә. Аларның тематикасында, образларында, форманың декоратив бирелешендә милли үзенчәлекләр чагылыш таба. Останың материалны эшкәртүдәге югары культурасы, фактуралы әвәләү динамикасы, купшы формалар, детальләрне җентекләп бирүе образларның поэтик һәм музыкаль гармониясен тудыра. «Лачын белән ауда», «Дала җыры» (икесе дә — 1938–40) кебек станлы жанр композицияләрендә А. татар милли киемнәрен, бизәк үрнәкләрен, урта гасырлардагы татар халкына хас үзенчәлекләрне чагылдыра. Шәрекъ темасы Г.Низаминың «Арысланны үтерүче Хөсрәү» һәм «Мәҗнүн газельләр арасында» (Бакудагы Низами музее; икесе дә — 1939, скульптура) әсәрләрендә чагылыш таба. А. шәкертләре арасында В.М.Маликов, Н.И.Гаделов, Р.Х.Нигъмәтуллина бар. Бөтенсоюз, Рәссамнар берлегенең Мәскәү оеш-



С.С.Ахун остаханәдә «Лачын белән ауда» скульптурасын эшли. 1938–40 еллар.



С.С. А х у н. Г.Тукай һәйкәле. Бронза, кара лабрадорит. 1958. Казан (Л.Е.Кербель, Л.М.Писаревский б-н берлектә).

масы күргәзмәләрендә катнаша (1950–80). Урал асылташларыннан (яшма, малахит, зөбәрҗәт, еланташ, ахак) уеп эшләнгән әсәрләр циклы өчен Парижда үткән халыкара күргәзмәнең Зур алтын медале б-н бүләкләнә (1925). Әсәрләре Казанда ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, М.Горькийның әдәби-мемориаль музеенда һ.б. саклана.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Скульптор Садри Ахун // Искусство. 1936. № 1; Б р е н н е р т В. Садри Ахун. К., 1945; Народные художники Татарской АССР. К., 1980.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АХУ́НДОВ** Мирза Фәтали (псевд. Сәбухи) (30.6.1812, Әзәрбайҗан Респ-касы Шәке ш., хәзерге Нуха ш. — 26.2.1878, Тифлис), әзәрбайҗан язучысы, мәгърифәтче, публицист, философ, җәмәгать эшлеклесе. Ганҗә шәһәрендә мәдрәсә тәмамлаганнан соң, укуын Шәке шәһәрендәге рус уч-щесендә дәвам иттерә. Төрки телләрдән тыш, гарәп, фарсы һәм рус телләрен яхшы белә. Шәрекъ һәм Көнбатыш мәдәният дөньясының күп кенә күренекле шәхесләре б-н аралаша, Казандагы татар укымышлылары б-н хатлар алыша. Әдәби иҗат эшчәнлеге 1830 елларда башлана. Беренче иҗат җимеше — «Пушкин үлеменә» (1837) дигән романтик поэма-мәрсиясе, урта гасыр Шәрекъ поэзиясе кануннарына таянып, фарсы телендә язылa (мәрсия 1962 елда Зәки Нури тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә). А. төрки әдәбиятлар, Якын Көнчыгыш әдәбиятлары тарихында Европача типтагы драматургиягә нигез салучы булып санала. 19 йөз уртасында А. патриархаль-феодаль чынбарлыкны, артталыкны, искегә ябышып яту, иҗтиһадсызлыкны мәгърифәтчелек идеяләре күзлегеннән тәнкыйтьләгән 6 комедия иҗат итә: «Ибраһим Хәлил мулла, алхимик, фәлсәфи таш иясе» (1850), «Мусье Жордан, ботаник вә дәрвиш Мәстәлишаһ, мәшһүр сихерче» (1850), «Ленкоран ханлыгының вәзире» (1850), «Юлбарысны җиңгән аю» (1851), «Карун мажаралары» (1852), «Тәбриз шәһәренең гаделлек яклаучылары» (1855). Комедияләрен А. рус теленә үзе тәрҗемә итә, алар ш.у. француз, инглиз, немец, фарсы һ.б. телләргә дә тәрҗемә ителә. 1864–65 тә А. Көнчыгыш халыкларының иҗтимагый-икътисади, рухи-мәдәни яктан артта калу сәбәпләрен ачуга багышланган «Һиндстан шаһзадәсе Кемал ад-Дәүләнең Персия шаһзадәсе Җәлал ад-Дәүләгә өч хаты һәм соңгысының ул хатларга җавабы» исемле фәлсәфи трактатын яза. А. әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеменә караган хезмәтләр авторы буларак та билгеле («Тәнкыйди сәхифәләр», «Шигърият һәм чәчмә әдәбият турында» һ.б.). Халыкны мәгърифәткә якынайтуда, аңа дөрес тәрбия бирүдә әдәби жанрлардан иң тәэсирлесе итеп ул романны һәм драманы саный; әдәби әсәрнең эчтәлеге б-н шәкли ягы бербөтен яңгыраштa булырга тиеш, дигән фикерне алга сөрә; иҗатта сюжетларны реаль тормыштан алырга чакыра, язу стилендә иске үрнәкләргә, традицион образларга ябышып ятуны, шигъриятьтәге купшылыкны тәнкыйтьли. А. Төркия академиясендә гарәп алфавитын латин алфавитына алыштыру турында үзе эшләгән проектны игълан итә. А. иҗаты Идел төбәге, Урта һәм Кече Азиядәге төрки әдәбиятларның реалистик юлдан үсешенә уңай йогынты ясый. Г.Камал фикеренчә, А. әсәрләре яшь татар театры һәм драматургиясенең формалашуы процессында «озак вакытларга кадәр зур азык булып килде». Үз вакытында көндәлек татар матбугатында («Вакыт», «Шура», «Совет әдәбияты» һ.б.) А.ның тормышы һәм иҗаты турында Р.Фәхретдин, Б.Шәрәф, С.Рәмиев, Г.Камал, Н.Юзиев кебек күренекле әдип һәм галимнәрнең мәкаләләре басыла.

Ә с ә р.: Избранные философские произведения. Баку, 1982; Комедии. Проза. Поэзия: Литературно-критические статьи. Баку, 1987.

*Әд.:* К а м а л Г. Әзәрбайҗан драматургы Мирза Фатали Ахундов // Кызыл Татарстан. 1928. 11 март; А з и з Ш а р и ф. Мирза Фатали Ахундов: Жизнь. Художественное творчество. Эстетика. // История литературы народов СССР. М., 1986; Ю з и е в Н. Высокая духовность писателей сближает народы // Әдәбият чыганаклары һәм текстология. К., 1982.

*Р.К.Ганиева.*

**АХУНҖА́НОВ** Алмаз Әсхәт улы (20.12.1937, Саба р-ны Кече Шыңар а.) балалар хирургы, уролог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТАССР һәм РФнең атказ. табибе (1977, 1997), Россия Медицина-техника фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы (1999), СССРның атказ. уйлап табучысы (1989). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006). ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (1997). 1961 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1963 тән Казан мед. ин-тында фәнни-пед. эштә, 1996 дан дипломнан соң белем бирү ф-тында балалар хирургиясе һәм урология курслары мөдире, 2000 нән балалар хирургиясе һәм курсы мөдире, бер үк вакытта 1971 дән А. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Казанның баш балалар хирургы. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының гемодиализ һәм бөерне күчереп утырту буенча Республика балалар үзәге җитәкчесе (1993 тән). Тикшеренүләре балаларда сидек бүлеп чыгару органнарының тумыштан килә торган аномалияләре үсешен һәм обструктив авыруларын диагнозлауга, хирургик дәвалауга; балалар хирургиясе һәм урологиясендә оператив ярдәм күрсәтү һәм дәвалау өчен хирургик һәм диагноз кую инструментларын һәм аппаратларын эшләүгә; бөерне күчереп утыртуда һәм балаларда хроник бөер зәгыйфьлеген дәвалауда экстракорпораль детоксикация ысулын куллануга карый. А. балаларда сидек системасының тумыштан килә торган обструкциясен хирургик дәвалау һәм диагноз куюның 10 нан артык ысулын, 30 төрле мед. инструменты, ш.и. уродинамик тикшерүләр үткәрү өчен 13 аппарат эшли. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Фәнни-гамәли эшчәнлектәге казанышлары һәм урология үсешенә керткән өлеше өчен акад. Н.А.Лопаткин исем. бүләк лауреаты. ТР Дәүләт бүләге балалар хирургиясендә яңа технологияләр эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. СССР ВДНХсының көмеш һәм өч бронза медале белән бүләкләнә.

Х е з м.: Неотложная диагностика важнейших хирургических заболеваний детского возраста: Учеб. пособие для студентов и молодых врачей. К., 1976 (автордаш); Обследование ребёнка с хирургическими заболеваниями: Учеб. пособие для студентов. К., 1975 (автордаш); Клинические задачи по детской хирургии: Учеб. пособие для студентов. К., 1979 (автордаш).

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997; Профессор Ахунзянов Алмаз Асхатович // Казан. мед. журн. 1997. № 6; Лечение нейрогенной дисфункции мочевого пузыря у детей // Детская хирургия. 2005. № 3.

**АХУНҖА́НОВ** Әнвәр Мәхмүт улы (3.2.1914, Уфа губ. Бөре ш. — 19.5.1986, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1967), проф. (1969), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1984). Ленинград ун-тын тәмамлый (1937). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–52 елларда Казан пед. ин-тында, 1955–59 да СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1960 тан Казан ун-тында. Рус һәм татар телләрен чагыштырма өйрәнүдә эзлекле бер система булдыра, икетеллелек шартларында барлыкка килгән интерференция күренешенең үзенчәлекләрен билгели. Хезмәтләре гомуми тел белеме, контрастив грамматика, лексикография, чагыштырма лексикология, икетеллелек мәсьәләләренә карый. Русча-татарча сүзлекләр төзүдә катнаша. А.ның «Гомуми тел белеме» («Общее языкознание», 1981) дәреслеге СССР ВДНХсының көмеш медаленә лаек була. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сопоставительное изучение национального своеобразия лексических значений. М., 1963; Русские заимствования в татарском языке. К., 1968; Двуязычие и лексико-семантическая интерференция. К., 1978; Контрастивная грамматика: Морфология русского и тюркских языков. К., 1987.

**АХУНҖА́НОВ** Галимҗан Хәкимҗан улы (25.8.1925, Чаллы кантоны Карман а. — 25.4.2002, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1977). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1955). 1958 елга кадәр Арча р-ны Казанбаш урта мәктәбендә эшли. 1961–89 да СССР

ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Хезмәтләре татар теленең фразеологиясе, лексикографиясе һәм лексикологиясенә карый.

Хезм.: Татар теленең идиомалары. К., 1972; Фразеология как раздел татарского языкознания // Вопр. татарского языкознания. К., 1971.

**АХУНҖА́НОВ** Илдус Габделгани улы (23.4.1930, Ижевск ш. — 16.3.1990, Казан), әдәбият тәнкыйтьчесе. Казан ун-тын тәмамлый (1953). «Совет әдәбияты» ж-лында, 1958–64 елларда ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение комитетында, Казан кинохроника студиясендә эшли. Мәкаләләре 1950 елларда басыла башлый. Алар М.Җәлил, Ф.Кәрим, Ә.Фәйзи, С.Хәким, ш.у. Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, В.Г.Короленко, Н.А.Островский, У.Шекспир, М.Сервантес һ.б. язучылар иҗатына багышлана. 1970 елларда Россия халыклары әдәбиятларының үзара бәйләнеше һәм йогынтысы проблемаларын тикшерә. «Художник һәм аның сүзе» (1978) исемле мәкаләләр җыентыгында М.Рәфыйков, Ш.Анак, Р.Мостафин, Р.Кутуй, Д.Вәлиев, Р.Солнцев иҗатлары анализлана.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**АХУНҖА́НОВ** Хәмзә Закир улы (3.2.1918, Казан губ., Мамадыш өязе Кече Шыңар а. — 9.10.1978, Казан), хирург, мед. фән. канд. (1954). И.В.Домрачев һәм А.В.Вишневский шәкерте. 1942 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1943–62 дә шунда ук гомуми хирургия кафедрасында эшли (бүленеп, 1951–54 тә Ирандагы Кызыл Хач Совет хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире), бер үк вакытта Казанның баш хирургы. 1962–68 дә Казан ГИДУВы ректоры, 1968 дән Казан мед. ин-тында. А. сидек куыгының нейроген функциясе бозылу мәсьәләләрен, ашказаны-эчәк анастомозы җөйләре сүтелү сәбәпләрен өйрәнә, аларны булдырмауга караган тәкъдимнәрен кертә. Диагноз кую һәм операцияләр техникасын яхшырту өчен күп кенә оригиналь инструментлар ясый (эчәк, ашказаны һ.б.ның тамырлары микроциркуляциясен өйрәнү приборы). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: К механизму иннервации моторной деятельности мочевого пузыря теплокровных животных. К., 1952.

**АХУ́НОВ** Гариф (Гарифҗан) Ахунҗан улы (18.9.1925, Арча кантоны Өчиле а. — 4.6.2000, Казан; Арчада җирләнгән), язучы, җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1985), ТРның халык язучысы (1993), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1952). «Совет әдәбияты» ж-лында эшли (1951–56), ТАССР Язучылар берлеге Әлмәт бүлегенең җаваплы сәркәтибе (1963–65, 1967–68), «Казан утлары» ж-лының баш мөхәррире (1971–74), ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе (1974–84), бер үк вакытта РСФСР Язучылар берлеге сәркәтибе (1975–84) вазифаларын башкара. Әсәрләре 1951 елда басыла башлый. Беренче күләмле әсәре — студент яшьләр тормышыннан алынган «Яшьлек яме» повесте 1956 да дөнья күрә. Татарстан нефтьчеләре тормышын яктырткан «Хәзинә» романы (1963; рус теленә тәрҗемәсе «Клад», 1963; Свердловск киностудиясендә шул исемдә нәфис фильм төшерелә, 1977) һәм «Чикләвек төше» повесте (1973; рус теленә тәрҗемәсе «Ядро ореха», 1982; 1973 тә сәхнәләштерелә) өчен ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була (1973). «Канатлар кая илтә?» (1967), «И кадерле туган як» (1971, автордашы М.Зарипов), «Йолдызлар калка» (1980) исемле очерклар һәм документаль повестьлар, «Утлар яна учакта» (1976) дип аталган пьесалар, «Чишмәләр белән сөйләшү» (1985) дип исемләнгән әдәби-тәнкыйть мәкаләләре җыентыклары авторы. А. әсәрләренең геройлары — нефтьчеләр, авыл хезмәтчәннәре, төрле оешмаларның җитәкчеләре, иҗат интеллигенциясе вәкилләре. Тарихи тематикага мөрәҗәгать итеп, А. 1930 елларда Березники шәһәрендә химия з-ды төзелеше турында «Ардуан батыр» документаль повестен (1974; 1980 дә сәхнәләштерелә), 20 йөзнең 1 нче яртысында татар җәмгыятендә булып узган драматик вакыйгаларны яктырткан «Идел кызы» дилогиясен яза (1–2 кит., 1978–86, рус-



Гариф Ахунов.


чага тәрҗемәсе «Дочь Волги», 1992). Драматург сыйфатында «Чулпы җыры» (1959; шул ук елда куела), «Тынгысыз йөрәк» (1959, автордашы Ф.Мостафин; шул ук елда куела) пьесалары, Ш.Камалның «Акчарлаклар» повесте буенча эшләнгән шул исемдәге инсценировка (1971 дә куела) авторы буларак та мәгълүм. А.ның хәзерге заман әдәби процессына багышланган аналитик мәкаләләре, язучыларның һәм сәнгать эшлеклеләренең иҗат портретлары республика матбугатында, үзәк басмаларда дөнья күрә. М.А.Шолохов, А.Н.Островский, А.С.Макаренко, В.А.Закруткин һ.б. әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. А.ның повестьлары һәм хикәяләре рус, украин, әзәрбайҗан, үзбәк, кыргыз, казакъ, башкорт, удмурт, чуаш, мари, якут, даргин телләренә тәрҗемә ителә. 1974–84 елларда СССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Әсәр.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1981–84; Сайланма әсәрләр: 5 томда, К., 2005; Сайланма әсәрләр (Мәктәп китапханәсе сериясе, Т. 36). К., 2005.


*Әд.:* Галимуллин Ф. Чишмә җыры // Инешләр Иделгә кушыла. К., 1985; Г.Ахунов: Истәлекләр (Г.Ахунов турында замандашлары). К., 2005. *Р.Х.Сверигин.*

**АХУ́НОВ** Мәсәбих Фәтхелислам улы (3.3.1928, Башкортстан Респ-касының Илеш р-ны Югары Мончар а.), график, РСФСРның атказ. рәссамы (1976). Казан сәнгать уч-щесендә белем ала (1950–51). Воронеж телевидениесендә, «Коммуна» г-тасында рәссам булып эшли (1958–66). Рәссамнар берлегенең Воронеж оешмасы әгъзасы (1965), идарә рәисе (1970–72; 1974–78), СССР Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы (1972–81). Эстамп, бигрәк тә үзенең иҗади индивидуальлеген чагылдырган линогравюра өлкәсендә танылган оста. Образларны тасвирлаганда А.ның сурәтләү алымнарына төгәллек һәм фикер бөтенлеге, формаларны гәүдәләндерүдә хәрәкәтчән ритм һәм масштаблар контрастлылыгы хас. Гравюра техникасында һәм карандаш б-н башкарылган әсәрләрендә күп планлы күренешләр, форманың төгәл төзелеше, рәсемнең ачыклыгы б-н үзенчәлекле. А. әсәрләренә хас лирик һәм эпик образлылык кешеб-н табигать арасындагы якынлык, хезмәт, авыл тормышы, шәһәр һәм индустрия тема-

М.Ф.Ахунов. Линогравюралар. 1. «Көз». «Агачлар турында риваять» сериясеннән. 1978; 2. «Эти йорты тәрәзәсе». «Икмәк» сериясеннән. 1979; 3. «Басу». «Барысыннан да кадерлерәк» сериясеннән. 1984; 4. «Битюг елгасы». «Туган ил» сериясеннән. 1993.









ларына багышланган пейзажларда чагылыш таба. «Ленин эзләре буйлап» линогравюралар сериясе (1964–81): «Казанда В.И.Ленин музей-йорты», «Казан университеты» (1964), «Казан Кремле» (1965) һ.б.; «Кара туфраклы төбәк индустриясе» (1969–74) һәм «Россиянең индустриаль ритмы» (1975–77), «Агачлар турында риваять» (1978) линогравюралары циклы, «Икмәк» (1979), «Россия — шагыйрьләр җире» сериясе (1980), «Россиягә багышлау» (1989–90) автобиографик серияләре һ.б. авторы.



М.Ф. Ахунов.

Болгариядә һәм Швециядә узган графика һәм плакат күргәзмәләрендә (1973), графикларның Монголиядә (1976), Италия (1976,1977), Сүрия (1978), Тунис (1979), Көнбатыш Германия (1980,1982), Исландия



М.Ф. А х у н о в. «Рудникка юл». «Россиянең индустриаль ритмнары» сериясеннән. Линогравюра. 1976.

(1985), Португалия (1986), Берлин (Интерграфика — 1987), Канадада үткәрелгән халыкара күргәзмәләрдә (1988); Бөтенсоюз («Совет Россиясе», Мәскәү, 1970 тән; эстамп, Уфа ш., 1974, 1984; Ростов, 1978), төбәкара («Кара туфраклы төбәк», 1969 дан) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Воронежда (1978, 1983, 1988, 1993, 1998), Мәскәү (1982, 1988), Уфа (1987), Ирландия (1991), Финляндия (Маннергейм галереясы, 1993), Липецкида (1998) уза. «Мәскәү — Россия башкаласы» линогравюралар сериясе өчен «Почёт билгесе» ордены, Россия сәнгать академиясенең көмеш медале (1998) һ.б. медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Масабих Ахунов. Графика: Каталог выставки. М., 1988; Интерграфика-87: Альбом междунар. выставки графики. Берлин, 1987.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**АХУ́НОВ** Наил Мирсәет улы (5.11.1930, хәзерге Биектау р-ны Калинин а. — 5.8.1989, Минск), генерал-лейтенант (1977). М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1965, Мәскәү), СССР Хәрби Көчләре Генштабы академиясен тәмамлый (1972, Мәскәү). 1951 елдан Кавказ арты, Себер хәрби округларында, Көньяк гаскәрләр төркемендә, Белоруссия хәрби округында хезмәт итә; 1976 дан 7 нче танк армиясе командующие. 1981 дән Урта Азия хәрби округы командующие урынбасары. 1984 тән Варшава килешүе дәүләтләре Берләшкән коралллы көчләренең идарә органнарында эшли. Ленин, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**АХУ́НОВА** Наилә Гарифҗан кызы (12.6.1959, Әлмәт ш.), шагыйрә. Рус телендә яза. Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тын тәмамлый (1986). 1983–94 елларда Казан төзүче-инженерлар ин-ты, Казан мед. ин-ты, сәүдә, медицина хезмәткәрләре мәдәният сарайлары китапханәләрендә эшли. 1994–97 дә Казан мед. ун-тының күптиражлы «Казанский медик» г-тасында мөхәррир. 2000–02 дә «Татарские края» г-тасында, «Казанская афиша» ж-лында хәбәрче, 1993 тән «Зонтик» балалар ж-лында баш мөхәррир урынбасары. 1997 дән Казан мед. ун-ты каршындагы «Белая ворона» исемле әдәби оешма б-н җитәкчелек итә. «Ерактагы яктылык» («Далёкий свет», 1995), «Әбиләр чуагы» («Бабье лето», 1997), «Таган» («Качели», 2004), «Кичке кояш» («Вечернее солнце»), «Тәрәзә» («Окно», икесе дә 2005) исемле шигъри җыентыклар, балалар өчен язылган «Исәнме, Керпе!» («Здравствуй, Ёжик!», 2004) пьесасы, «Тормыш төсендәге карлыгач» («Ласточка цвета жизни», Казан кинохроника студиясе, 2006) документаль фильмының сценарий авторы. А. шигъриятенә нечкә лиризм, көчле образлылык, төгәл детальләр, форма аныклыгы хас. Шигырьләре татар теленә тәрҗемә ителә. А. Р.Харис, Н.Хәсәнов, В.Монасыйпов әсәрләрен, татар халык әкиятләрен рус теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* А х м е т о в а Я. Живут в Казани «белые вороны»:Эскиз портрета // Идель. 2000. № 1.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**«АХЫРЗАМА́Н КИТАБЫ́»**, дини нәсыйхәт әдәбияты истәлеге. «Тәкый гаҗәб китабы» исеме б-н дә мәгълүм. Сөләйман *Бакыргани* язган дип санала. Китап урта гасырлар суфичылык әдәбияты традицияләрендә, башлыча, Ә.Ясәви хикмәтләре тәэсирендә язылган. Әсәрдә Ахырзаман көне (Кыямәт), бакый дөньядагы тормыш тасвирлана. 19–20 йөз башында «А.к.»нда күтәрелгән идеяләр татар зыялылары арасында бәхәсләр китереп чыгара. Әсәрдә бирелгән мәгълүматлар Кыямәт көнен яңадан шәрехләүне һәм теоретик яктан яңача аңлатуны таләп итә. Г.Чокрыйның «А.к.»на үзгәрешләр кертеп һәм аңлатмалар биреп язган «Замимә Назыйр» (1864) әсәре бу бәхәсләрне хәл итүгә бер омтылыш була. «А.к.» — 20 йөз башына кадәр татар халкы арасында күп укылган китапларның берсе. 1847 елдан башлап күп тапкырлар нәшер ителә. 1897 дә Казанда рус телендә басылып чыга.

*Әд.:* Ахырзаман китабы. К., 2000; Борынгы татар әдәбияты. К., 1963; Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. Т. 1; М а л о в Е. Книга о последнем времени (или о кончине мира) // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1897–98. Т. XIV, вып. 1–2.



Н.М. Ахунов.



В.А. Ачалов.

**АЧА́ЛОВ** Владислав Алексеевич (13.11.1945, Әтнә р-ны Атамыш а.), генерал-полковник (1989), Казан Югары танк командирлары уч-щесен (1966), Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (1973) һәм СССР Хәрби Көчләре Генштабы академиясен (1984, Мәскәү) тәмамлый. 1966 елдан бронетанк гаскәрләрендә, 1973 тән һава-десант гаскәрләрендә югары командирлык вазифаларын башкара. 1984 тән танк армиясе командующие урынбасары, командующие. 1988 дән Ленинград хәрби округында штаб башлыгы. 1989 да СССР Һава-десант гаскәрләре командующие. 1990–91 дә СССР Оборона министры урынбасары. 1992–93 тә РФ ЮС Президиумы каршындагы аналитик үзәк җитәкчесе. РФ ЮС депутаты (1990–93). Кызыл Йолдыз, 1 нче, 2 нче, 3 нче дәрәҗә «СССР Коралллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Всероссийское офицерское собрание: вчера, сегодня, завтра. К., 1998.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**АЧКА́СОВА** Людмила Сергеевна (28.9.1922, Тамбов губ. Хлыстово а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1985), проф. (1986). Казан ун-тын тәмамлый (1945). 1948 елдан шунда ук укыта. Хезмәтләре совет чоры рус әдәбияты тарихына, 20 йөз рус әдәбиятында романтизм тарихына, К.Г.Паустовский иҗатына карый.

Х е з м.: О романтизме в советской литературе // Филологические науки. 1970. № 2; Гуманизм в творчестве К.Паустовского. К., 1972; Человек как нравственная ценность в эстетике К.Паустовского. К., 1977.

**АЧЛЫ́К**, теге яки бу төбәктә халык төркеменең азык-төлеккә мохтаҗлык кичерүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән социаль афәт. А.ның ике төре мәгълүм: күзгә күренеп торганы (абсолют А.) һәм яшерен (чагыштырмача А., ачлы-туклы җан асрау, азык рационында яшәү өчен кирәкле компонентлар җитмәү). А., аерым алганда, а.х.нда җитештерүнең кискен кимүенә китергән төрле көтелмәгән бәла-казалар, гадәттән тыш табигать шартлары (су басулар, озакка сузылган корылык, циклоннар һ.б.), ш.у. сугышлар һ.б. вакыйгалар нәтиҗәсендә башланып китә.

Хроник А. нәтиҗәсендә башланган үлем-китемнең күләмен билгеләү кыен, чөнки ул еш кына үлем б-н турыдан-туры бәй-

ләнмәгән, әмма кешеләрнең күпләп авырып китүенә (организмның гомуми хәлсезләнүе, ябыгуы — кахексия, дистрофия, маразм һ.б.) китерә, читләтеп тәэсир итә. Аксым җитмәүдән аеруча балалар, бигрәк тә күкрәк сөте имгән чорда һәм гомеренең беренче елларында, ш.у. йөкле хатын-кызлар һәм бала имезүче аналар газап чигә.

Безнең төбәктә А. турындагы беренче хәбәр 16 йөз ахыры — 17 йөз башындагы *Болгавыр заман* чорына карый. Казан ханлыгын рус дәүләте яулап алганга кадәр төбәк халкы арасында А. булуы турында мәгълүматлар теркәлмәгән. Идел буе Болгар дәүләтенең 1229 елда Владимир-Суздаль кенәзлегендәге ачлыктан интегүче халыкка азык-төлек б-н ярдәм итүе билгеле (Н.М.Карамзин мәгълүматларына караганда, аларга ашлык төялгән 30 кораб җибәрелә). 18–19 йөзләрдә бөлдергеч нәтиҗәләргә китергән А.еллары булгалап торган. Аларның иң фаҗигалесе 1891–92 еллардагы А. 1891 нең җәе явым-төшемсез килә, Казан губернасында крәстиян хуҗалыкларының күбесендә игеннәр уңмый. 1891 дә бөртекле төп культураларның уңышы дисәтинәгә уртача 10–11 пот тәшкил итә (арыш — 15,1; бодай — 10,2; солы — 10,1; арпа — 6,6 пот). 1891–92 дә губерна халкының 70 % тан артыгы А.тан интегә. Кешеләр алабута, кычыткан, имән чикләвеге, мүк һ.б. б-н тукланырга мәҗбүр була.

Табигатьтәге экологик тотрыксызлык иген уңмауга китерә. А. вакытында үлем-китем фаҗигале төс ала. Казан губернасы һәм Татарстан җирендә мондый фаҗигаләр 1907, 1911, 1920, 1921–22, 1922–23, 1927–28 дә кабатлана. 1921–22 дә булган иң кискен азык-төлек кытлыгы вакытында а.х. продукциясе җитештерүдә туган кыенлыклар икътисади кризис б-н туры килә. Төрле мәгълүматлар буенча, 1921–24 тә А.тан һәм авырулардан 400 меңнән 600 меңгә кадәр кешенең гомере өзелә (к. *Ачлык (1921–22)*). Игеннәрнең уңмавы нәтиҗәсендә 1922 һәм 1923 елларда респ-ка халкы азык-төлек кытлыгына дучар ителә. Бер кешегә елына уртача 3 пот чамасы (48 *кг*) икмәк туры килә. 1923 нең 1 февраленә Татарстанда 1 млн. тирәсе кеше, 1924 нең 1 мартына 0,5 млн. нан артык кеше А.тан интегә. А.тан үлү һәм шешенү очраклары була. 1921–22 дәге А. нәтиҗәләре Татарстан халкы тормышында үзен озак еллар дәвамында сиздерә. 1920–1930 еллар башында уздырылган аграр үзгәртеп корулар — ирексезләп күмәкләштерү, кулаклар катлавын бетерү, авыл халкыннан ашлыкны тулысынча тартып алу, крәстиян хуҗалыклары өчен иген салымы кертелү аркасында Татарстанда азык-төлеккә мохтаҗлык кичерелә. Бу елларда илдә авырулар һәм А.тан үлүчеләрнең күп булуын совет хөкүмәте инкарь итәргә тырыша. Нәтиҗәдә, төрле мәгълүматларга караганда, бу елларда 100 меңнән алып 200 меңгә кадәр кеше һәлак була. Бөек Ватан сугышы елларында һәм сугыштан соңгы чорда а.х.да җитештерүнең кискен кимүе азык-төлек товарларын сату күләменең кимүенә һәм төп азык-төлек продуктларына бәяләрнең үсүенә китерә. Халыкның күпчелеге азык-төлекне кыйммәт бәядән сатып ала алмый. Мондый хәл Татарстанда А.ның яшерен төрен китереп чыгара. Хөкүмәт тарафыннан вакытында тиешле чаралар күрелми, кылган гамәлләре дә халык ихтыяҗын канәгатьләндерми, шәһәрдә икмәкне карточкалар б-н бүлү дә нәтиҗә бирми. Казакъстанда чирәм җирләрне үзләштерү башлангач (1953–54 еллар), авыл халкының ярдәмче хуҗалыклары өчен кертелгән төп салымнарны (ит, сөт, йон, йомырка һ.б. салымнар) гамәлдән чыгару (1953) һәм колхозчылар хезмәтенә акчалата аванс түләү (1964) нәтиҗәсендә республика халкын азык-төлек б-н тәэмин итү бераз яхшыра, А.ның яшерен төре (аксым җитмәү, авитаминоз, рахит һ.б.) беркадәр кими. Кешеләр азык-төлек җитмәгәнгә генә түгел, сатып ала алмаганга да А. кичерәләр. 1980–90 елларда республика халык хуҗалыгын реформалаштыру б-н бәйле эшчәнлекнең кискен активлашуы икътисадка көчле инфляция басымы ясый, бу исә азык-төлеккә бәяләрнең күтәрелүенә китерә. Ачлы-туклы җан асрау күренешләре, кешеләрнең туклану рационында яшәү өчен мөһим компонентларның җитмәве сизелерлек төс ала. Тиешенчә тукланмау нәтиҗәсендә армиягә чакырыласы яшьләрнең бер өлеше РФ Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итү өчен яраксыз дип табыла. А. Татарстан халкында үлем-китемнең югары дәрәҗәдә калуына сәбәп булып тора.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**АЧЛЫ́К** (1921–22), Татарстанда 1921 елның көзендә башлана. А. афәтенә 2 млн. нан артык кеше дучар була. А.тан бигрәк тә Арча, Мамадыш, Минзәлә, Зөя, Спас, Тәтеш һәм Чаллы кантоннары халкы интегә. А.тан интегү сәбәпләре акрынлап арта бара. Беренче бөтендөнья сугышы а.х.на зур зыян китерә (эшләүче халык саны азая, ат, дуңгыз, сарыкларның саны кими, азык-төлек запасы тотылып бетә). 1917–20 елларда сәнәгый һәм кустарь пр-тиеләрне, җирне дәүләтләштерү Татарстан халкын читкә китеп эшләү һ.б. кәсепләр б-н шөгыльләнү мөмкинлегеннән мәхрүм итә. Гражданнар сугышы елларында терлекнең күпчелек өлеше тартып алына яки корылыклы 1920 ел нәтиҗәсендә азык җитмәүдән кырыла. 1920 дә иген уңмау һәм чамадан тыш зур *продразвёрстка* (10 млн. поттан артык, ягъни ашлыкның тулай җыемының 35%) халыкта җан башына икмәк куллануны 3 потка кадәр киметә. Уңайсыз һава шартлары (язның иртә һәм коры килүе, май-июнь айларында явым-төшемнәрнең булмавы), а.х.нда җитештерүнең дәүләт тарафыннан алып барылуына бәйле рәвештә, крәстиян җирләренең соңга калып һәм сыйфатсыз чәчелүе 1921 дә иген уңмауның төп сәбәбе булып тора. Ашлык җыемы күләме 1921 дә, 1913 б-н чагыштырганда, 94% ка кими (112 млн. поттан 6,4 млн. потка кала). 1921 дә бөртекле төп культураларның уртача уңышы дисәтинәгә 2–3 пот (арыш — 2, бодай — 2,9, солы — 2,4, арпа — 2,9 пот) тәшкил итә. Кешеләр алабута, имән чикләвеге, кычыткан, үлән һәм агач яфраклары, мүк һ.б. ашарга мәҗбүр була. Көнлек ризыкта аларның күләме 60% тан артып китә. Халык соңгы терлеген суя, мәчеләр, этләр һ.б. җәнлек һәм хайваннарны ашауга кадәр барып җитә. Вакыйгаларның шаһиты, Казандагы «АРА» оешмасы җитәкчесе, Америка язучысы Д.Р.Гайльдс: «Мин булырга туры килгән күп кенә авылларда йортларның дүрттән өче бушап калган, башка йортларда да тормыш билгеләре күренми; кайчандыр йөзләрчә һәм меңнәрчә кеше яшәгән бу урыннарда үле тынлыкны бозарлык эт өрүе дә, әтәч тавышы да, мәче мыраулавы да ишетелми иде», — дип яза. Икенче шаһит М.Солтангалиев: «Татарстан республикасының 22 млн. пот икмәк биргән, ел ярым дәвамында Советлар Федерациясенең бөтен Көнбатыш Армиясен азык-төлек б-н тәэмин итеп торган крәстияннәре соңыннан — 1921 ел ачлыгында кешеләр ашау һ.б. афәтләр дәһшәтен кичерде», — дип яза.

1921 нең көзендә Татарстанда ачларга ярдәм итү комиссиясе — Татпомгол оештырыла. 1921 нең ахырында ТАССР азык-төлек салымыннан азат ителә. 1921 нең көзендә республикага чәчүлек өчен 2692286 пот арыш һәм бодай кайтарыла (аның 347102 потын бүләргә өлгермиләр) һәм 419 мең дис. (35,7%) җиргә орлык чәчелә. 1921–22 дә республика өчен Украинада (254972,4 пот), Брянск (102006,2), Владимир (106739,3), Гомель (269418), Курск (198851,1), Минск (357078,2), Орёл (109221,7), Петроград (5005), Псков (307234,2), Рыбинск (205187,4), Смоленск (279013), Тверь (99963,1), Череповец (157986,1), Ярославль (112039,3) губерналарында һ.б. төбәкләрдә бодай, солы, арпа, карабодай, тары, борчак, вика, кукуруз, ногыт борчагы, көнбагыш, җитен, киндер орлыклары әзерләнә, ш.у. чит илләрдән 203523 пот бодай, 8034,4 пот солы, 27901,4 пот арпа сатып алына. Крәстияннәргә һәм күмәк хуҗалыкларга 4606557 пот сабан культуралары орлыгы (сабан җирләренең 632 мең дис.се — 62% чәчелә), 502 мең пот орлыклык бәрәңге, 2988 мең пот уҗым культуралары орлыгы (уҗым җирләренең 80 % ы чәчелә) таратыла. 1922 дә Татарстанга 8 млн. поттан артык азык-төлек китерелә. Илнең ачлык афәте кичермәгән төбәкләренә (Урта Азиягә, Себергә һ.б.) 210 меңнән артык кеше озатыла. Ачка интегүчеләрне дәүләт һәм җәмәгатьчелек хисабына ашату оештырыла. Ләкин бу чаралар гына җитеп бетми. Республиканың ачлыктан интеккән халкына ярдәмгә чит илләрдәге иҗтимагый оешмалар (к. «АРА», *Халыкара эшчеләр хәйрия оешмасы*) җәлеп ителә. Татарстан терр-ясендә җәмәгать туклану пунктлары, азык-төлек, кием-салым, сабын һ.б. өләшү урыннары оештырыла, халыкка мед. ярдәме күрсәтелә. 1922 нең 1 июленә бирелгән мәгълүматлар буенча, җәмәгать ашханәләрендә 1,6 млн.нан артык кеше туклана.

А. елларында Татарстан халкы 400–600 мең кешегә кими. А., авырулар һ.б. сәбәпләр нәтиҗәсендә Тәтеш кантоны 66 мең кешесен (халыкның 35%), Спас кантоны — 48 мең (26%), Чистай кантоны — 79 мең (21%), Зөя кантоны — 35 мең (22%), башка кантоннар үз халкының 5–10% ын югалта. Татарлар саны — якынча 25% ка, руслар — 11% ка, башкалар 15% ка кими. 1921–22 дә 86 мең крәстиян хуҗалыгы (16,2%) юкка чыга; чәчүлек җир-

ләренең мәйданы 700 мең дис. (39,8%) кими; сукалар саны — 40695 (31,7%), сабаннар — 66225 (38%), тырмалар — 105133 (35,6%) ургычлар — 537 (21,6%), җилгәргечләр һәм сортларга аеру машиналары 3246 данәгә (17,4%) азая. 1917 ел б-н чагыштырганда атлар һәм мөгезле эре терлек саны — 65% ка, сарыклар һәм кәҗәләр — 91% ка, дуңгызлар 97% ка кими. 1922 дә республикада 400 мең баш ат җитешми; бер крәстиян хуҗалыгына уртача 0,6 арба, 0,4 сука, 0,3 сабан, 0,6 тырма, 0,5 чалгы һәм 2 урак туры килә; а.х.ның җитештерүче көчләре таркала, аларны торгызу озак елларга сузыла. Ш.у.к. *Ачлык*.

*Әд.:* Таһиров И.Р. Ачлык фаҗигасе // Мирас. 1996. № 4; Сабиров Р.А. Деревня Татреспублики после голода 1921. К., 1922; Ермолаев В.М., Шараф Г.Ш., Хасанов М.А. Очерки по экономической географии Татреспублики. К., 1931; Климов И.М. Помощь Советского правительства и великого русского народа трудящимся Татарской республики в борьбе с голодом 1921–1922 годов // Уч. зап. Казан. ун-та. 1954. Т. 114, кн. 5; шулук. Образование и развитие Татарской АССР (1920–1926). К., 1960; Белокопытов В.И. Лихолетье: Из истории борьбы с голодом в Поволжье. 1921–1922 гг. К., 1976; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; Шайдуллин Р.В. Крестьянские хозяйства Татарстана: проблемы и пути их развития в 1920–1928 гг. К., 2000.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**АЧЫ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Макса суы буенда. 2002 елда 155 кеше (руслар — 69%, татарлар — 30%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Спас исеме б-н дә билгеле. 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 дә А.да мәчет төзелә, 1889 да аның каршында чиркәү-приход мәктәбе ачыла. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 180,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 102 ир заты; 1859 да — 135, 1897 дә — 154, 1908 дә — 149, 1920 дә — 203, 1926 да — 214, 1938 дә — 267, 1949 да — 264, 1970 тә — 202, 1979 да — 144, 1989 да — 150 кеше.

**АЧЫ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 55 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оша суы буенда. 2002 елда 157 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1710 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.да Во имя Сошествия Св.Духа чиркәве (1896 да төзелә), земство мәктәбе, 2 су тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1022 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чишмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 718, 1897 дә — 758, 1908 дә — 794, 1920 дә — 815, 1926 да — 874, 1938 дә — 817, 1949 да — 561, 1958 дә — 424, 1970 тә — 335, 1979 да — 246, 1989 да — 164 кеше.

**АЧЫ́К ГРУНТ**, яшелчә яки декоратив үсемлекләр утыртылган ачык җир мәйданы. А.г. бу культураларның үсентеләре чәчелә торган *ябык грунт* б-н турыдан-туры бәйләнгән. Салкынга чыдам яшелчә культуралары (кишер, чөгендер, суган, гәрәнкә, редис, сельдерей, петрушка орлыклары, кәбестә үсентеләре) А.г.ка кар эрегәннән соң, туфракның уртача темп-расы 5–10 °С ка җиткәч утыртыла яисә чәчелә. Җылы яратучы культураларның орлыклары (кыяр, кабак, ташкабак, фасоль, помидор, борыч, баклажан һ.б.) үсентеләре язгы кыраулардан зарарланмасын өчен соңрак чәчелә. ТРда А.г.тагы яшелчә культураларының төп өлеше — 75% кадәр (2005) халыкның шәхси хуҗалыкларында үстерелә.

А.г.та яшелчәләрне товарлыклы җитештерү ТРда, башлыча, а.х. оешмаларының сугарулы җирләрендә тупланган. 2006 елда бирелә 2241 *га* мәйдандагы А.г.та 50,2 мең *т* яшелчә җитештерелә: Лаеш р-нында — 15,4, Яшел Үзән — 7,8, Тукай — 15,4, Биектау — 4,6, Түбән Кама — 2,2, Бөгелмә р-нында 1,6 мең *т*. 1920 дә А.г.та 1,3 мең *га* яшелчә культуралары була. Чәчүлек мәйданнарның (мең *га*), тулай җыем (мең *т*), 1940–2006 елларда алынган уңыш күрсәткечләре (*ц/га*): 1940 та — 15,7, 94,7 һәм 63; 1960 та — 11,7, 100,4 һәм 88; 1980 дә — 15,7, 197,0 һәм 127; 2000 дә — 12,2, 201,9 һәм 166; 2006 да — 13,1, 283,5 һәм 227.

Ш.у.к. *Яшелчәчелек.*

*И.Н.Афанасьев.*

**АЧЫКОРЛЫКЛЫЛА́Р** (Pinophyta, яки Gymnospermae), орлыклы үсемлекләрнең иң борынгы бүлеге. Югары девон чорыннан билгеле. Төньяк ярымшарда киң таралганнар. Чәчәкле үсемлекләрдән аермалы буларак, орлык яралгысының ачык урнашуы — А. ның төп үзенчәлеге (исеме шуннан алынган). Чәчәкләре юк. Берничә классны берләштерә; ылыслылар классы аеруча киң таралган. Ылыслыларның барлык төрләре дә диярлек агачлар. Сабакларының аркылы кисемендә юка кабыгы, нык үсеш алган үзагачы һәм тулы үсеш алмаган үзәге аерылып тора. А. үзагачы нигездә трахеидлардан гыйбарәт. Күп төрләренең кабыгында һәм үзагачында сумала, эфир майлары һ.б. матдәләр б-н тулган каналлар бар. Ылыслыларның күпчелеге каты яфраклы, энәсыман һәм уңайсыз һава шартларында да коелмый. ТРда өч семьялыкка кергән үсемлекләр — наратчалар (нарат, чыршы, ак чыршы, карагай), кипарисчалар (артыш) һәм кызылчалар (дала кура җиләге) очрый. Декоратив үсемлекләр. Ылыслыларның үзагачы — төзү материалы, кәгазь җитештерү өчен чимал. Медицинада нарат бөреләре, ак чыршы мае кулланыла.

**АЧЫКЫ́Й** (Picris), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан ике һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 лап төре билгеле, Европада, Азиядә, Урта диңгез буенда һәм Төньяк Америкада киң таралган. ТРда бер төре — сары А. (P.hieracioides) һәр р-нда очрый. Коры болыннарда, аланнарда, көньяк сөзәклекләрдә үсә. 30–100 *см* озынлыктагы үсемлек. Сабагы туры, кырлы, каты төкләр б-н капланган. Аскы яфраклары озынча, ланцетсыман, сабактагылары эллипс-ланцетсыман. Чәчәкләре ачык сары төстә, кәрзиндә, калкансыман-себеркәчле чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше — орлыкча. Июль-август айларында чәчәк ата. А.да алкалоидлар бар. Халык медицинасында бәвел кудыру, үт кудыру, авыртуны басу өчен файдаланыла. Баллы үсемлек.

**АЧЫ́Т КҮЛЕ́**, Идел алды төбәгендә. Элеккеге су юлында сакланып калган күл. Зөя елгасының уң як тугаенда, Югары Ослан р-нының Карамышиха авылыннан 0,5 *км* көньяктарак. Су өслегенең мәйданы 8,44 *га*. Озынлыгы 1590 *м*, иң зур киңлеге 180 *м*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**АШ ТОЗЫ́**, таш тоз, ашамлык һәм техник продукт; табигатьтә *галит* минералы рәвешендә очрый. Ике халәттә киң таралган: каты — NaCI ның (% ларда) уртача микъдары таш тозда — 92–98,8, утырмаларда — 77–95; эремәләрдә — диңгез суында — 0,6 (Каспий диңгезе), 2,7 (Җир шары океаны), тозлы күлләрнең табигый эремәсендә — 7,3 (Баскунчак күле, РФ), 25,9, (Хуҗа-Мумын күле, Төркмәнстан Респ-касы), җир асты минераль суларында — 5 тән күбрәк (к. *Җир асты сулары*). Кулланылышына карап азык-төлек (тулаем җитештерүнең 50% ы), техник (40%) һәм терлек азыгы (10%) тозына бүленә. А.т.н чыгару, табигатьтәге тозлы сулардан һәм диңгез суыннан табигый рәвештә һәм заводта парга әйләндерү юлы б-н алалар. Дөнья күләмендә елына 190–215 млн. *т* А.т. җитештерелә, төп җитештерүчеләре — АКШ, Кытай, Германия һәм Россия (елына 8–10 млн. *т*) һ.б. РФдә тоз чыгару Башкортстанда (Бөтенроссия җитештерү күләменең 40%), Әстерхан (23%), Иркутск (13%), Оренбург (4%) һәм Волгоград (4%) өлкәләрендә һ.б. регионнарда гамәлгә ашырыла.

ТР терр-ясендә А.т. җитештерү өчен яраклы булган гидроминераль чималның ике төре ачыкланган: палеозой утырмаларының җир асты тозлы сулары һәм нефть промыселы тондыру бассейннарының җыелма сулары. Татарстанның көнбатышында (Зөя а. янында) 90 нан алып 200 *м* га кадәр тирәнлектә, составында 62 *г/л* га кадәр һәм көнчыгышында (Азнакай, Әгерҗе һәм Минзәлә р-нарында) якынча 600 *м* тирәнлектә 27 дән алып 280 *г/л* га кадәр NaCI булган тозлы сулар ачыкланган. 1,2 *м* га кадәр калынлыктагы таш тоз катламнары һәм линзалары Яшел Үзән, Биектау, Питрәч, Лаеш р-ннарында һәм Казан тирәсендә табылган, ТР халык хуҗалыгының А.т.на еллык ихтыяҗы 160 мең *т* дан артыграк, ш.и. азык-төлек өчен 70 мең *т*, тер-

лек азыгы өчен 50 мең *т* дан артык һәм техник максатларда 40 мең *т* чамасы. Барлык А.т. ТРга Оренбург, Әстерхан өлкәләреннән һәм Украинадан кертелә.

А.т. халык хуҗалыгының күп тармакларында: азык-төлек сәнәгатендә, терлекчелектә, медицинада, химиядә (Na, CI, HCI, инсектицидлар, хәрби максатларда агулы матдәләр һ.б. ясау өчен), күн, нефть (бораулау измәләре өчен) сәнәгатендә һ.б. киң кулланыла.

*Әд.:* Минеральное сырьё. Соли минеральные: Справ. М., 1999.

*Ю.В.Баталин, А.К.Вишняков.*

**АШ-БУҖИ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 757 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ашалча-Буҗи исеме б-н дә билгеле. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.-Б.да мәчет була. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Күкшел волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 10 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 446, 1884 тә — 497, 1920 дә — 679, 1926 да — 577, 1938 дә — 529, 1949 да — 473, 1958 дә — 450, 1970 тә — 611, 1979 да — 513, 1989 да — 613 кеше.

**АША́ РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 2792 *км*$^2$. Үзәге — Аша шәһәре (Чиләбедән 377 *км* көнбатыштарак). Халкы — 67,3 мең кеше (2006), ш.и. 5,9 мең татар. Татарлар күбесенчә Аша (2,8 мең кеше), Миньяр (900), Сим (1,4 мең) шәһәрләрендә һәм Кропачево (400), Ук (100 гә якын) посёлокларында яши. Аша шәһәрендә татар-башкорт мәдәни үзәге, 1992 дән Миньяр шәһәрендә «Дуслык» татар-башкорт үзешчән коллективы бар. 2001 дән Ук посёлогы китапханәсе базасында «Ирәндек» татар-башкорт мәдәни үзәге эшли. Үзәк каршында ислам нигезләрен һәм Коръән укырга өйрәнү курслары оештырыла. 1991 дән мәчет эшли. Һәр елны Миньярда Сабантуй үткәрелә. А.р.нда ел саен «Халыклар дуслыгы» фестивале уздырыла, анда ТРның үзешчән сәнгать коллективлары да катнаша.

**АШАБА́Ш** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казансу елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 167 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 17 йөз урталарыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.та мәчет, мәктәп, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 444,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 54 ир заты; 1859 да — 185, 1897 дә — 367, 1908 дә — 458, 1920 дә — 428, 1926 да — 524, 1938 дә — 441, 1949 да — 372, 1958 дә — 368, 1970 тә — 323, 1979 да — 277, 1989 да — 193 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**АШБУЛА́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Минзәлә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,2 *км*, бассейнының мәйданы 36 *км*$^2$. Минзәлә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Бакчасарай авылыннан көнбатыштарак, тамагы Белопахотный посёлогыннан 1,6 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 61 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 34%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 138 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Кагыйдә буларак, А. ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*$^3$/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елгада 452 мең *м*$^3$ күләмле буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**АШИ́К (ГАШЫ́ЙК) ПАША́** (Âşik Paşa) (псевд.; чын исеме — Али) (1271, Кир ш., Төркия — 1332, шунда ук), төрек телле суфи шагыйрь. Төркиянең Караман шәһәре хөкемдары Мөхлис әмирнең улы. «Гарибнамә» («Чит-ят илдә яшәүче китабы»), «Мәгърифәтнамә» («Мәгърифәт китабы») поэмалары, «Диван-е Ашик Паша» («Ашик Пашаның шигырьләр мәҗмугасы») һ.б. әсәрләр авторы. Суфичылык тәгълиматы рухында язылып, ун баб-бүлектән торган һәм һәр бабы тагын унар дастанны эченә алган «Гарибнамә» поэмасы татар халкы арасында элек-электән кулъязма нөсхәләрдә киң таралган. Кыпчак теле тәэсирендә оешкан борынгы гомум әдәби төрки телдә язылганлыктан, татар укучыларына поэма тәрҗемәсез дә җиңел аңлашылган. Поэманың тулырак дип исәпләнгән 16 мең юл чамасындагы күчермә нөсхәләре С.-Петербург, Ташкент, Баку фәнни китапханәләрендә, 12 мең юл чамасындагы күчермәләре Мисыр, Төркия, Англия һәм Венгрия мирасханәләрендә саклана. Поэманы беренче фәнни өйрәнүче шәркыятьчеләрдән австралияле И.Гаммер-Пургшталь, төрек галиме Ф.Купрелезадә исемнәрен атап китәргә мөмкин. Бу эшкә китап белгече Ә.Булатов та үзеннән өлеш кертә (аның архивы ТР ФАнең Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты фондында саклана).

*Әд.:* Шәйхелисламов З.Р. «Гарибнамә» дастаны // Әдәби мирасның яңа катламнары. К., 1990; Дмитриева Л.В. Ленинградские рукописи «Гариб намэ» Ашик Паши // Проблемы востоковедения. 1960. № 1; Гарбузова В.С. Поэты средневековой Турции: Учеб. пособие. Л., 1963; Юзеев А. Татарская философская мысль конца XVIII–XIX веков. К., 1998. Кн. 1.

*З.Р.Шәйхелисламов.*

**АШИ́К УМАР (ГАШЫ́ЙК ГОМӘ́Р)** (1621, Кизләү ш., Кырым ханлыгы — 1707, шунда ук), кырымтатар шагыйре. Туган шәһәрендәге «Җомга җамигъ» мәдрәсәсендә белем ала, шагыйрь Кәфәви Сәет Әбделкәрим Шәриф җитәкчелегендә Шәрекъ әдәбияты тарихын һәм теоретик нигезләрен тирәнтен өйрәнә. Яшүсмер чагыннан шигырьләр яза башлый. Иҗат юнәлеше формалашуына суфи шагыйрь Җәләлетдин Руминың йогынтысы зур була. Остазы Кәфәви Сәет вафатыннан соң, мәдрәсәне ташлап, дөнья гизәргә чыгып китә, 8 елга якын туган иленнән читтә — Төньяк Кавказда, Персия, Төркия илләрендә яши. Бик күп газәл һәм мәхәббәт шигырьләре авторы, талантлы чичән-импровизатор буларак та таныла. Шигъри иҗаты 18 йөз татар шагыйрьләренә сизелерлек йогынты ясый. Кульязма мирасы Төркия китапханәләрендә саклана.

Әсәр.: Шиирлер, гъазеллер. Тошкент, 1988, 1 кит.; 1990, 2 кит.

*Әд.:* Адабиёт хрестоматиясе. Тошкент, 1971; Elçin Ş. Âşik Ömer. Ankara, 1999.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**АШИ́НА** (aşina), Төрки каганлыкларда һ.б. төрки дәүләти берләшмәләрдә идарәче ыруг атамасы. Атаманың этимологиясе төрлечә аңлатыла. Борынгы кохар (согди) телендә ул «күк», ягъни борынгы төркиләр берләшмәсе «күк түрек» мәгънәсенә туры килә дип фаразлана. Борынгы кытай язмасында А.ның төрки риваятьләрдә хуннарның (сөннәрнең) идарәче кабиләсе исеменнән алынганлыгы әйтелә. Бу ыруг б.э.ның 1 нче меңьеллык башында Көнчыгыш Төркестанда яшәгән, соңрак Алтай тауларының монголлар биләгән тарафына кысрыклап чыгарылган. Монда алар күп кабиләләрне берләштерәләр һәм 5 йөздә «төрек» исеме б-н танылган берләшмәне җитәклиләр. 551 елда оештырылган Төрки каганлык башлыклары да, соңрак оешкан Көнчыгыш һәм Көнбатыш төрки каганлыклар идарәчеләре династиясе дә А. ыругыннан була. Урта гасырлар төрки дәүләтләрендә дә (Хәзәр каганлыгы һ.б.) А. идарәче ыруг булып санала. Кыпчакларның Асән (Ашин) ыругы берләшмәсе 13 йөздә Икенче Болгар патшалыгын аякка бастыруда төп рольне уйный.

*Әд.:* Бичурин Н.Я. Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.–Л., 1950; Гумилёв Л.Н. Древние тюрки. М., 1993; Кляшторный С.Г. Степные цивилизации Европы. СПб., 1997; Liu Mau-tsai. Die chinesischen achrichten zur Geschichte der Ost-Turken. Wiesbaden, 1958.

*И.Л.Измайлов.*

**АШИРБӘ́КОВ** Әхмәтрәшит Рәшит улы (1914, хәзерге Төмән өлкәсенең Төмән р-ны Турай а. — 28.1.1944, Украина ССР, Бердичев ш.), Сов. Союзы Герое (17.11.1943), рядовой. Бөек Ватан сугышына кадәр тракторчы булып эшли. 1941 елның июленнән Кызыл Армиядә, 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 737 нче аерым кабельле элемтә ротасында линияләр караучы

(3 нче гв. танк армиясе). Брянск, Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 24–25 сентябрендә армия командующие б-н гаскәрләр арасында өзлексез элемтә тәэмин иткәндә батырлык күрсәтә. Бердичев шәһәре янында барган сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Ә.Р. Аширбәков.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои земли Тюменской. Свердловск, 1975; Днепр — река героев. Киев, 1983; Золотые звёзды Полесья. Киев, 1985.

**АШИ́РОВ** Киамил Бәкер улы (8.8.1912, Харьков ш. — 2006, Самара), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1962), проф. (1968), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1972), СССРның мактаулы нефтьчесе (1972). Әзәрбайҗан индустриаль ин-тын тәмамлый (1935). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947–75 елларда СССР Нефть сәнәгате министрлыгының «Гипровостокнефть» ин-тында (Куйбышев ш.) нефть чыганакларын эшкәртү бүлеге башлыгы, 1961 елдан директор урынбасары. 1975 тән Самара техника ун-тында, нефть һәм газ чыганакларын файдалану һәм геол. каф. мөдире (1991 гә кадәр). Россия геологлары Т.М.Боргест һәм А.Л.Карев б-н берлектә нефть чыганаклары формалашуының хәзер дә дәвам итүен, океан трансгрессияләре һәм бозлык чорларының сәбәпләрен фаразлый. Куйбышев өлкәсендә нефть чыганакларын блоклы системаларда эшкәртүне фәнни дәлилләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнаша. Катламлы нефтьләрнең газ б-н туендырылуы, «газ бүреге» формалашуы б-н балчыклы каплавычларның зурлыгы арасындагы бәйләнешне ачыклый. Идел-Урал төбәгендә нефть-газ хасил иткән беренчел утырмаларның доманик фациясе токымнарына бәйлелеген ачыклый. Нефть чыганакларын сыгылмалы һәм гравитацион режимда, В.Е.Титов б-н бергә — эретелгән газ режимында циклы эшкәртү технологиясен тәкъдим итә. СССР ФАнең Микробиология ин-ты хезмәткәрләре б-н бергә нефть ятмаларының күкертле водород б-н зарарлануын бетерү тәкъдимен гамәлгә ашыра. Ленин премиясе (1966), 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геологическая обстановка формирования нефтяных и газовых месторождений Среднего Поволжья. М., 1965; Новый подход к стратегии разработки нефтяных месторождений // Нефтяное хоз-во. 1994. № 11–12; О реальных возможностях научно-технического прогресса в нефтедобывающей отрасли // Геология, геофизика и разраб. нефтяных месторождений. 1998. № 12.

**АШИ́РОВ** Рафаил Зәки улы (15.6.1946, Мордва Респ-касы, Дубенск р-ны Ломати а.) хирург, сәламәтлек саклау эшлеклесе, мед. фән. д-ры (2001), Мордва АССР һәм РФнең атказ. табибе (1990, 1994), 1969 елда Ярославль мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Саранск шәһәренең мед. оешмаларында эшли. 1993 тән Мордва Респ-касы сәламәтлек саклау министры. А.нең хезмәтләре перитонит вакытында әчәклекнең структур-функциональ халәтен, әлеге авыруның патогенезында липид гомеостазы бозылуының ролен өйрәнүгә багышланган. А. липидларны тикшерүнең биохимик ысулларын тәкъдим итә (автордаш). 1993 тән Мордва Респ-касы Дәүләт җыены депутаты.

Х е з м.: Активность фосфолипаз и липопероксисление при перитоните. Саранск, 1997. Ч. 2; Влияние антиоксидантов на морфофункциональное состояние печени при перитоните. Материалы Всеросс. науч.-практич. конф. СПб., 1998.

**АШЛАМАЛА́Р**, туфрактагы туклыклы матдәләрне туплый торган яисә үсемлекләр өчен туклану элементлары булып хезмәт итүче органик һәм минераль матдәләр. Туфракның уңдырышлылыгын арттыра, аның туклану, су, җылылык һәм һава режимын яхшырта; а.х. культураларының уңышына һәм продукциясенең сыйфатына уңай тәэсир итә. А. *органик ашламаларга* (тирес, торф, компост, сапропель, кош тизәге), сидераль (*яшел ашламалар*), органик-минераль, известьле (доломит оны) һәм стандарт *минераль ашламалар* (азотлы, фосфорлы, калийлы), катлаулы минераль, *микроашламалар* (молибденлы, бор, акбур, кобальт, цинклы һ.б.), *бактериаль ашламаларга* (ризоторфин, агрофил, ризоагрин, фитоспорил, ризоплан, флавобактерин) бүленә. 1 *кг* тулы минераль А.ны (азот, фосфор, калий) ТР шартларында куллану уңышның сизелерлек артуына китерә: ашлык уртача 4,4 *кг*, бәрәңге 21,5 *кг*, яшелчә 38 *кг* га арта. ТРда известьле А. (34 известь карьеры), аммиак селитрасы (Яңа Менделеев хим. з-ды), бактериаль А. («Казанский тепличный — К°» с-зы) җитештерелә.

А.ны, аларның туфрак һәм үсентеләрдәге хим. процессларга, уңыш алуга тәэсирен өйрәнү б-н *агрохимия* фәне шөгыльләнә. А.ны рациональ куллану максатларында ТРда агрохимия хезмәте булдырылган (к. *Авыл хуҗалыгын химияләштерү, Ашламалар системасы*). Үсемлекләргә һәм туфракка иң зур файданы, гадәттә, органик һәм минераль А.ның кушылмалары бирә, алар туфракның хим., физик-хим., физ. һәм микробиол. үзлекләрен яхшырта. А.ны оптималь дозаларда күп тапкырлар кертү һәм туфракны культуралаштыруның башка ысуллары (эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү һ.б.) туфрак ясалу процессының юнәлешен үзгәртергә һәм яңа туфрак төрләре (төрчәләре) — югары уңдырышлылыгы б-н аерылып торучы антропоген туфраклар формалашуга китерергә мөмкин. А.ны дөрес куллану үсемлекләр үсешенә уңай тәэсир итә. А. кулланунын нәтиҗәлелеге а.х. культураларының биол. үзенчәлекләренә, туфракта туклану элементлары булуга, дымлылыкка, туфрак эремәсенең реакциясенә һ.б. бәйле. Югары нәтиҗәләргә сугару шартларында ирешелә. А. һәм сугаруның ярашуы үсемлекләрнең суны һәм туклыклы матдәләрне аз тотуына китерә. 1 *т* тирес керткәннән соң беренче елда ашлыктан 0,2–0,3 *ц*, бәрәңгедән 1–1,5 *ц*, кукурузның яшел массасыннан 3–4 *ц* өстәмә уңыш алына. Җиңел туфракларда да органик һәм минераль ашламалар бергә кертелгәндә уңыш арта. Моннан тыш, органик А. туфракны гумус (черемә) б-н баеталар, ә бу минераль А.ның артуына шартлар тудыра. Яхшы уңыш өчен шактый күләмдә туклыклы матдәләр таләп иткән интенсив сортлар үстергәндә бу алымның әһәмияте арта. Татарстан туфракларын зур масштабта агрохимик тикшерүләр республиканың барлык а.х. пр-тиеләре өчен дә туфракның уңдырышлылыгын күтәрүче программалар һәм агрохимик карталар булдырырга мөмкинлек бирә, алар һәр басу һәм а.х. культурасы буенча А. куллану ысулын күрсәтә. 2006 елда ТР буенча А.ның кулланылышы (мең *т*): известьле А. — 165,7 мең гектарга 1229,8; органик А. — 97 мең гектарга 3698,5; минераль А. — 2446,3 мең гектарга 172,6 (тәэсир итүче матдә) тәшкил итә.

Ш.у.к. *Сидерация*, *Туфракны известьләү*.

*И.Н.Афанасьев.*

**АШЛАМАЛА́Р СИСТЕ́МАСЫ**, авыл хуҗалыгы культураларының биологик үзенчәлекләрен һәм планлаштырылган уңышны, ш.у. туфрак, климат, хуҗалык-оештыру шартларын, *ашламаларның* үзенчәлекләрен һәм тәэсирен, аларны кулланугa киткән чыгымнарның кайтарылу дәрәҗәсен исәпкә алып, *органик, минераль ашламаларны* һ.б.ны куллану тәртибе, чәчү әйләнешендә культуралар арасында ашламаларны бүлүнең күпьеллык планы. ТРда А.с. тирес кертү, *туфракны известьләү,* комплекслы агрохимик культуралаштыру, пар җирләрен *сидерацияләү*, уҗым һәм күпьеллык үләннәрне тукландыру, гранулланган фосфорлы һәм катлаулы минераль ашламаларны рәтләп кертү, чәчүлекләрне һәм орлыкларны микроашламалар һәм бактериаль ашламалар (ризоторфин, агрофил, ризоагрин, фитоспорил, ризоплан, флавобактерин, планриз һ.б.) б-н эшкәртүне күздә тота. Ашламаларның тулаем күләме аерым культураларга бер яисә берничә тапкыр кертелә. Монда, кагыйдә буларак, көзге сукалау һәм чәчү вакытларында кертелгән ашлама, вегетация чорында үсемлекләрне тамырдан һәм тамырдан тыш тукландыру исәпкә алына. Ашламаларны күмдерү ысулы һәм аларны кертү сроклары — туфрак эшкәртү системасы, сугарулы игенчелектә — сугару системасы б-н тыгыз бәйләнгән. Ашламаларны фәнгә нигезләнеп куллану а.х. продукциясенең сыйфатын яхшырта һәм уңдырышлылыкны тәэмин итә (мәс., аксымны арттыра һәм аминокислоталар составын яхшырта).

ТРда А.с.н эшләү һәм аларны аерым культураларга кертү б-н В.П.*Мосолов*, Б.И.*Горизонтов*, А.А.*Җиһаншин*, М.З.Гайнетдинов, И.А.*Гайсин*, Г.Д.*Аверьянов*, В.Н.Мещанов, Р.С.*Шакиров*, Л.Р.*Шәрифуллин*, Ф.Х.*Шакиров*, Е.И.Ломако, И.Т.Храмов, Т.Х.Ишкәев һ.б. галимнәр шөгыльләнә. Республикада 1964 елда башланган туфракны тоташ агрохимик тикшерү һәм һәрбер а.х. пр-тиесенә әчелек, гумус составы, алмаш фосфор һәм калий картограммаларын бирү А.с.ның нәти-

җәлелеген күтәрүдә уңай роль уйный. 2005 елга туфракны агрохимик тикшерүнең 6–7, кайбер хуҗалыкларда 8 туры уздырыла, шуның нәтиҗәсендә һәрбер а.х. пр-тиесенә туфракның уңдырышлылыгын күтәрү программасы, шуңа өстәп әчелек, алмаш фосфор, калий һәм гумус составының картограммасы тапшырыла, ягъни продуктлылыкны күтәрү программасын тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр б-н җирләрнең уңдырышлылыгы динамикасы һәм торышы турындагы мәгълүмат бирелә. Ш.у.к. *Авыл хуҗалыгын химияләштерү*.

*Әд.:* Горизонтов Б.И. Удобрения на поля // Агитатор. 1963. № 15; Колоскова А.В. Агрофизические свойства почв Татарии. К., 1968; Мещанов В.Н. Известкование кислых почв Татарии. М., 1982; Гайсин И.А. Микро-, макроудобрения в интенсивном земледелии. К., 1989; Шакиров Р.С. Земное плодородие. К., 1989; Зиганшин А.А. Современные технологии и программирование урожайности. К., 2001; Основные подходы к разработке программ «Плодородие». К., 2002; Слагаемые эффективного агробизнеса: обобщение опыта и рекомендации. Часть I. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*И.Н.Афанасьев.*

**АШЛА́Н** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Озынлыгы 13,6 *км*, ТР чикләрендә — 9 *км*. Бассейнының мәйданы 53 *км*$^2$. Елга башы — Мари Респ-касының Үрнәк посёлогы янында, тамагы Яшел Үзән р-нындагы Әйшә урманчылыгының сазланган урынында. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 65%. Елга бассейны Идел елгасы үзәненең сул як ярындагы киртләч рельефлы өлешендә. Язгы ташу чорында А. елгасы Ильинка күленә коя. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун көнлегендә башлана. Кагыйдә буларак, елга ноябрь башында туңа.

**АШЛЫ́**, урта гасырлар (11–13 йөзләр) Идел буе Болгар дәүләте шәһәре (рус чыганакларында — Ошель). Феодаль округның эре сәяси һәм икътисади үзәге. Риваятьләрдә һәм кайбер тарихи язмаларда болгарларның борынгы шәһәре буларак теркәлгән. Аны Искәндәр Зөлкәрнәйн (Александр Македонский) нигезләгән дигән хата фараз да бар. 1220 елда А.га кенәз Святослав Всеволодович җитәкчелегендәге рус гаскәрләре һөҗүм итә. Озак кына каршы торганнан соң, А. алына һәм яндырыла. Кайбер галимнәр *Богдашкино шәһәрлеген* А. җимерекләре б-н тиңлиләр.

*И.Л.Измайлов.*

**АШЛЫ́К ӘЗЕРЛӘ́Ү ҺӘМ ЭШКӘРТҮ́**, халык хуҗалыгы тармаклары. Аларның үсеше, бер яктан, хезмәт бүленеше, халыкның шәһәрләргә тупланувы, шәһәрләр һәм сәнәгать үзәкләренең саны артуы б-н, икенче яктан — ашлыкның озак саклауга яраклылыгы һәм аңардан товар запаслары һәм резервлары булдыру мөмкинлеге б-н бәйле. Археол. һәм язма чыганаклардан күренгәнчә, Урта Идел буенда иген үстерү һәм әзерләү Идел буе Болгар дәүләтендә җирле халыкның төп шөгыле булган. Идел буе Болгар дәүләтеннән Владимир-Суздаль җирләренә икмәк сату очраклары билгеле (1223). Бодай, арпа, тары үстерелә; ашлыкны идән асты чокырларында, келәтләрдә саклыйлар, агач һәм таштан (известьтән) эшләнгән кул тегермәннәрендә тарттыралар, бөртек угыч, ярма яргыч һәм килеләрдә төяләр. Икмәк Казан ханлыгының иң төп товары була. Мәскәүдәге Швеция сәүдә компанияләрендә хезмәт итүче швед комиссары (факторы) И. де Родес үзенең «1663 елда рус сәүдәсе турында уйланулар»ында («Размышления о русской торговле в 1663 г.») Казан төбәген Россия базарларын иген б-н тәэмин итүче өлкәләр арасында алдынгы урыннарның берсенә куя. Игеннең чирек (10 пот арыш, 6 пот солы) Мәскәүдә 1 сум булганда, Казанда 12–25 тиен була. 1857 елда Казанда товар әйләнеше 248 мең сум көмеш булган 88 кибет эшли. 1852–58 дә Казанга китерелгән арыш, бодай, солы, арыш оны һ.б. 2 млн. сум көмеш, ә аннан чыгарылган икмәк — 1,6 млн. сумлык була. Икмәк б-н сату итү бу елларның сәүдә әйләнешендә 2 һәм 3 нче урыннарны алып тора. Бодай — Урта Иделнең кара туфраклы регионнарыннан, арыш, борчак, солы, карабодай, нигездә, Казан губернасының кара туфраклы булмаган өлкәләреннән кертелә һәм Казан, Чистай, Спас, Алабуга, Мамадыш, Тәтеш шәһәрләре аша су транспорты б-н С.-Петербург, Әстерхан һ.б. шәһәрләргә җибәрелә. Пароходчылык үсеше нәтиҗәсендә Казан Төньяк-Көнчыгыш Россиядә икмәк белән сәүдә итүче иң эре үзәккә әверелә. 19 йөзнең 2 нче яртысында Казанның 3 пристанендә ел саен уртача 900 судно төяла һәм бушатыла. 1868 дә пристань аша 33 млн. пот икмәк уза. 1871 дә Казанда 28 млн. пот икмәк һәм он сатыла. 19 йөз ахырына губернаның ашлык базарында иң эре сәүдәгәрләр арасында Алабуга (И.И. һәм И.Г.*Стахеевлар*, Башкировлар), Чистай (В.Л.*Челышев*, С.Х.Чукашёв), Казан (И.Н.*Журавлёв*, В.И.Романов) сәүдәгәрләре һ.б. була.

20 йөз башында Казанда 10 эре товарлыклы ашлык фирмасы эшли, шуларның эре 4 се он җитештерү һәм сату б-н шөгыльләнә (М.Н.Окошников, Фоминнар, Сусловлар һәм армияне он б-н тәэмин итүче Я.Ф.*Шамов*). 1908 дә Казан губернасында 2567 тегермән була, аларда 5331 кеше эшли һәм 46 млн. пот ашлык эшкәртелә. Бу күрсәткечләр буенча губерна Россия империясендә алдынгы урыннарның берсен алып тора. Он тарттыруның бәясе үзәк Россиядәгегә караганда 2–4, Көнбатыш Европадагыга караганда 8 тапкыр кимрәк була, шул сәбәпле онның, бигрәк тә арыш онының, Россиядә тиңдәше булмый. Россия базарларына җибәрелгән барлык арыш онының өчтән бер өлешен, экспортка чыгарылганның барысын да диярлек (якынча 6 млн. пот) Идел-Кама төбәге бирә. Чит илгә җибәрелгән арыш онына пошлина зур булу сәбәпле, бөртекле арыш онга караганда күбрәк чыгарыла.

1912 дән Идел-Кама төбәгендә генә түгел, хәтта Россиянең башка регионнарында да икмәк базары тулысынча диярлек сәүдәгәр Стахеевлар кулында була, алар Россиядә иң эре Рус-Азия, Петербург халыкара һәм Идел-Кама коммерция банклары б-н тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыралар. Ашлыкны җыеп эшкәртү һәм саклау алымнары бик гади булганлыктан, дөнья базарына чыгарылган игеннең чүплелеге 5–10% (АКШта элеваторда саклау системасы кертелү сәбәпле, бу күрсәткеч 0,5% тан артмый) тәшкил итә. Татарстан терр-ясендәге беренче — Бөгелмә, Чаллы элеваторлары — 1914 һәм 1917 елларда Россиянең Дәүләт банкы акчасына төзелеп, файдалануга тапшырыла. 1915 тә 9,7 млн. пот ашлык сатып алына, ш.и. 3 млн. пот солы, 6,7 млн. пот арыш һәм арыш оны. 1 нче Бөтендөнья сугышы һәм Совет властеның беренче елларында дәүләтнең ашлык әзерләү сәясәте тамырдан үзгәрә һәм *продразвёрстка* формасын ала, 1921 дә ул *продналог* б-н алыштырыла. 1924 тән ашлык сатып алуда базар законнары киң тарала, 1928 дән контракт буенча алына. 1932–33 тә МТС эшләре өчен мәҗбүри рәвештә ашлык тапшыру һәм натуралата түләү (җитештерелгән а.х.продукциясе б-н түләү) кертелә, ул салым түләү б-н тәңгәлләшә, дәүләтнең үзәкләштерелгән ашлык ресурсларын булдыруның төп формасына әверелә. 1932 дә ТАССР, РСФСРда беренче булып, еллык дәүләт планын үти, 24,7 млн. пот ашлык (планга карата 101,2%) әзерли, шул саннан МТСлар өлешенә — 7,5 млн., колхозларга — 9,4 млн., аерым хуҗалыкларга 7,4 млн., совхозларга 0,4 млн. пот туры килә. Татарстанда 1920 еллардан башлап А.х. һ э. эшен оештыруны гамәлгә ашыручылар: губсовнархозның аерым бүлеге (1920 дән), он тарттыру һәм ярма ярдыру сәнәгатенең Казан губ. дәүләт идарәсе (1921), «Хлебопродукт», «Татмельтрест», «Хлебцентр», «Сибторг» пр-тиеләре һәм СССР Дәүләт банкының Казан конторасы (1922–26), «Татхлебсоюз» һәм «Татхлебживсоюз» (1927–31), «Заготзерно» Татарстан өлкә конторасы (1932 дән), алар барлык ашлык кабул итү пунктлары челтәрен берләштерә һәм ашлык әзерләүне контрактлы нигездә башкара.

1933 кә «Заготзерно» системасында 4 элеватор, 25 линияле һәм станцияләр янындагы, 15 эчкәреге ашлык кабул итү пунктлары һәм барлык җирле он тарттыру пр-тиеләре эшли. 1936 да кулланучыларны ашлык б-н тәэмин итүне яхшырту өчен 8 сату базасы, 1941 дә өстәмә 227 ашлык кабул итү пункты ачыла. 1956 да РСФСР Ашлык әзерләү министрлыгының эштән туктатылган Вәкаләтле конторасының («Уполминзаг») матди базасы тулысы б-н «Заготзерно» системасына тапшырыла. Нәтиҗәдә республика «Заготзерно»сына 25 төп кабул итү пункты, 6 элеватор, 2 сату базасы, әрҗәләр ремонтлау һәм механика остаханәләре, автобаза, матди-техник тәэминат склады һәм 389 эчкәреге ашлык кабул итү пункты керә. 1957 дә «Заготзерно» пр-тиеләре һәм «Росглавмука» конторасы базасында Татарстан республикасы икмәк продуктлары җитештерү идарәсе оештырыла һәм ул 1995 кә кадәр эшли. 1958 дә мәҗбүри тапшыру һәм натуралата түләү бетерелә һәм дәүләткә ашлык әзерләү сатып алулар тәртибендә үтәлә башлый. 1990 елларда базар икътисадына күчү б-н ашлык әзерләү пр-тиеләрен акционерлаштыру башлана. 1995 тә «Татарстан икмәк кабул итү һәм ашлык эшкәртү предприятиеләре» холдинг компаниясе» АҖ («Татархлебопродукт») оештырыла, аңа 10 элеватор, 5 икмәк продуктлары комб-ты,

15 ашлык кабул итү пр-тиесе, сату базасы, матди-техник тәэминат һәм комплектлау базасы булган 33 акционерлык җәмгыяте керә. 2002 елга компаниядә 1244 млн. сумлык төп фондлар, 1794 мең *т* сыйдырышлы паспортлаштырылган ашлык саклау урыннары, тәүлеклек җитештерүчәнлеге (*т* да) түбәндәгечә булган куәтләр исәпләнә: ашлык киптергечләр — 67000, сортлы ашлык тегермәннәре — 2281, арышны көрпәдән аеру тегермәннәре — 365; ярма заводлары — 394, катнаш азык з-длары — 2497. Төп җитештерүчеләр: сортлы бодай, көрпәсеннән аерылган һәм иләнгән арыш оны, манный ярмасы — «Казаньзернопродукт», «2 нче Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты», «Чаллы икмәк продуктлары», «Печище икмәк продуктлары комбинаты», «Чистай элеваторы», «1 нче Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты» һәм «Арча элеваторы» акционерлык җәмгыятьләре; арпа, борчак ярмалары — «Чаллы икмәк продукты», «Чаллы элеваторы»; карабодай, солы ярмалары («Геркулес») — «1 нче Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты» һәм Буа р-нының «Свияга» ябык акционерлык җәмгыяте; катнаш азыклар — «Казаньзернопродукт», «Чаллы икмәк продукты», «1 нче Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты», «Чистай элеваторы» һәм «Нурлат элеваторы» акционерлык җәмгыятьләре.

Республикада азык-төлек базарын үстерү шартларын яхшырту максатында 1996 да ТРның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршында ТРның Азык-төлек корпорациясе, «Татфондбанк» каршында «Татзернопродукт» АҖ һәм «Алтын башак» компаниясе булдырыла, алар 2002 дән бодай, арпа һәм арышны экспортка чыгара башлыйлар.

Татарстан а.х. пр-тиеләре тарафыннан уртача еллык сатылган ашлык (мең *т* да):

| Еллар | Ашлык | Еллар | Ашлык |
|---|---|---|---|
| 1956–60 | 577,8 | 1981–85 | 1139,8 |
| 1961–65 | 871,1 | 1986–90 | 586,2 |
| 1966–70 | 1218,6 | 1991–95 | 741,5 |
| 1971–75 | 765,8 | 1996–2000 | 924,8 |
| 1976–80 | 881,5 | 2001–2005 | 1752,2 |

2000–2005 ел нәтиҗәләре буенча республика районнары арасында ашлык сату буенча беренче урынны Нурлат р-ны алып тора.

2004 тә ТРда он тарту — ярма һәм катнаш азык сәнәгатендә 37 пр-тие эшли, аларда 3389 кеше хезмәт итә, 4047 млн. сумлык продукция җитештерелә. Милек формалары буенча ТРның он тарту — ярма һәм катнаш азык сәнәгате пр-тиеләре хосусый (73%), дәүләт (18,9%), катнаш (8,1%), пр-тиеләргә аерыла (2004). 2005 елда «Икмәк кабул итү һәм ашлык эшкәртү предприятиеләре» холдинг компаниясе» «Татарстан сөте» АҖ икмәк кабул итү предприятиесе» идарәсе итеп үзгәртелә, 2006 дан «Вамин-Татарстан» АҖ икмәк кабул итү предприятиесе» идарәсе.

ТРның он тарту — ярма ярдыру һәм катнаш азык сәнәгатенең төп капиталына инвестицияләр 1997 дә — 19, 1998 дә — 24,7, 1999 да — 28,7, 2000 дә 105 млн., 2001 дә — 225,9, 2002 дә — 22,7, 2003 тә — 9,9, 2004 тә — 27 млн. сум тәшкил итә.


1986–2005 тә республикада елына уртача он һәм катнаш азык җитештерү (мең *т* да):

| Еллар | Он | Катнаш азык |
|---|---|---|
| 1986-90 | 1080 | 715 |
| 1991-95 | 1208 | 774 |
| 1996-2000 | 877 | 389 |
| 2001–2005 | 301 | 246,2 |

*Әд.:* История Татарской АССР. К., 1966; Твоя профессия // Знание. 1982. № 8; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала. К., 1995; Шайдуллин Р.В. Крестьянские хозяйства Татарстана: проблемы и пути их развития в 1920–1928 гг. К., 2000; Хвала рукам, что пахнут хлебом. К., 2001.

*И.Н.Афанасьев.*

**АШМА́РИН** Николай Иванович (22.9.1870, Казан губ. Ядринск ш. — 26.8.1933, Казан), тел галиме, тюрколог, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1929). Лазарев исем. Шәрекъ телләре ин-тын тәмамлый (1894, Мәскәү). 1895–1919 елларда Казанда: 1899 га кадәр Казан керәшен татар мәктәбендә татар теле, 1919 га кадәр Казан укытучылар семинариясендә география укыта; 1901–17 дә татар, чуаш телләрендәге басмаларны нәшер итү эшләре ком-тында цензор. 1917 дән Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография ин-тында профессор. 1920–23 тә Халык мәгарифе гамәли ин-тында (Сембер ш.), 1923–26 да Әзәрбайҗан ун-ты Шәрекъ ф-тының тюркология каф. мөдире (Баку), 1926–31 дә Көнчыгыш пед. ин-тында (Казан). А. чуаш телен, аның халык авыз иҗатын һәм чуаш халкы тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә, чуашлар килеп чыгышының болгар теориясен яклый. Чуаш теле сүзлеген төзи. Татар әдәбияты беленмәннән фәнни хезмәт авторы (1901, хезмәт татар телендә 1913 тә кабат басыла).



Н.И. Ашмарин.

Хезм.: Очерки литературной деятельности татар-мухамедан в 1880–1895 гг. К., 1901; Опыт исследования чувашского синтаксиса. К., 1903. Ч. 1; Симбирск, 1923. Ч. 2; Подражание в языках Среднего Поволжья. Баку, 1925; Словарь чувашского языка. К.-Чебоксары, 1928–50. Вып. 1–17.

*Әд.:* Егоров В.Г. Н.И.Ашмарин как исследователь чувашского языка (к 100-летию со дня рождения). Чебоксары, 1970; шул ук. Н.И.Ашмарин — основоположник чувашского языкознания: Сб. статей. Чебоксары, 1971; Федотов М.Р. Н.И.Ашмарин: Краткий очерк о жизни и деятельности. Чебоксары. 1995.

*А.Е.Никифоров.*

**АШМАСО́В** Гакыйль Билал улы (27.7.1884, Самара губ., Мәләкәс өязе Әбдери а. — 1942, Новосибирск өлкәсе), сәяси эшлекле, педагог. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала (1904 елга кадәр). 1904–07 елларда балалар укыта, 1907–17 дә Әбдери авылы имамы, мәчет каршында җәдитчә укытыла торган «Үрнәк» мәдрәсәсен ача. 1910 нан соң Социалист-революционерлар партиясе тарафдары, крәстияннәр арасында сәяси-агарту эшләре алып бара. 1918–19 да Самара губернасы Мөселманнар эшләре комис-ты мәгариф комиссары. Гражданнар сугышында катнаша, 1919–20 дә Идел буе татар укчыларының 1 нче аерым бригадасында сәяси бүлек хезмәткәре, Төркестанда үзбәк укчылар бригадасының сәяси бүлеге башлыгы. 1921–23 тә Төркиядә дипломатик эштә (Артвин шәһәрендә СССР консуллыгы хезмәткәре). 1923–25 тә Самарада татар-башкорт пед. техникумы директоры (бүленеп, 1924–25 тә Ростов шәһәрендә балалар йорты директоры). 1925–27 дә ТАССР Мәгариф халык комис-тында Үзәк сәяси-агарту оешмасы (Главполитпросвет) рәисе урынбасары. *Татарстан Республикасы Китап палатасы*н оештыручылардан һәм аның беренче директоры (1927–32). 1932 дән пед. эштә: Казан тимер юл техникумында директор, Казан совет төзелеше техникумында, финанс-икътисад ин-ты рабфагында, фельдшер-акушерлар мәктәбендә укыта. Репрессияләр чорында кулга алынудан котылу өчен, 1937 нең сентябрендә Үзбәкстан ССРның Әндиҗан шәһәренә китә, укытучы булып эшли. Мәгариф һәм мәдәният өлкәләрендә методик ярдәмлекләр авторы. Репрессияләр чоры корбаны (1938). Үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Клуб эшчеләре өчен кулланма. К., 1926; Үзлегеңнән уку. Авылдагы үзлегеңнән өйрәнү түгәрәкләре өчен уку, язу һәм хисап дәреслеге. К., 1929; Выставка произведений печати Книжной палаты за 1928 г. К., 1929.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**АШПА́Й** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 9 *км* төньяктарак, Туйма елгасы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. 17 йөздә марилар нигез сала, 18 йөздә татарлар килеп урнаша. Авыл Иделбай исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык б-н шөгыльләнә, тирә-як авылларда эшләп көн күрә. 1920 гә кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостена керә. 1920–21 елларда Вотск автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1795 тә — 21 ир заты; 1836 да — 120, 1859 да — 170, 1870 тә — 182, 1887 дә — 239, 1911 дә — 380, 1920 дә — 333, 1926 да — 317, 1938 дә — 336, 1949 да — 245, 1958 дә — 168, 1970 тә — 107, 1979 да — 38, 1989 да — 12 кеше.

**АШЫГЫ́Ч МЕДИЦИ́НА ЯРДӘМЕ́ КҮРСӘТҮ́ ХЕЗМӘТЕ́**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында; кеше сәламәтлегенә һәм тормышына куркыныч туган вакытта (һәлакәтләр, көтелмәгәндә авырып китү, тиешле вакыттан алда бала тудыру һ.б.) тиз арада мед. ярдәме күрсәтү системасының махсус хезмәте. Вазифалары — кичектергесез шартларда диагноз кую, беренче ярдәм күрсәтү, һуш китүдән саклау ысуллары, тромбоэмболик авыруларны кисәтү, терминаль һәм психоневрологик ярдәм һ.б., шулай ук авыруларны стационарга китерү. А.м.я.к.х. хастаханәләрдәге ашыгыч медицина ярдәме бүлекләре, ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү станцияләре (АМЯКС) тарафыннан башкарыла.

АМЯКС — дәвалау-профилактика үткәрү учреждениесе, кешеләргә һәлакәт урынында яисә стационарга илтү юлында тәүлек дәвамында ашыгыч мед. ярдәме күрсәтә. АМЯКСның функциональ эшен хәрәкәттәге бригада (фельдшер, табиб, интенсив дәва үткәрү бригадасы) башкара.

Казан АМЯКС 7 район станциясеннән гыйбарәт, республика районнарында ашыгыч мед. ярдәме бүлекләре (район үзәк хастаханәсенең бүлекчәләре) хезмәт күрсәтә. Ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү хастаханәләре Казанда һәм Чаллыда бар.

Европада беренче АМЯКС Венада оештырыла (1881). Россиядә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы фикерне башлап медицина д-ры Аттенгофер әйтә, беренче станцияләр Мәскәүдә (1888) һәм С.-Петербургта (1889) ачыла, бу эш полиция табибләре карамагында башкарыла. Һәр станциядә бәйләү материаллары, инструментлар, медикаментлар һәм носилка б-н тәэмин ителгән, Кызыл Хач рәсеме төшерелгән атлы карета була.

1902 елда Казанда табибләр төркеме (Н.Н.Беляев, Р.А.Лурия, В.А.Перимов, П.М.Дмитриевский) тырышлыгы б-н шәһәр халкына «Ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү» бригадасы оештырыла; бу эшкә 13 белгеч тартыла, бригадада терапевт һәм хирург була; «Ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү табибләре җәмгыяте» төзелә, ул җәмәгать эше тәртибендә, әгъзалык түләүләре хисабына эшли. Ярдәм күрсәтү түләүле була, гонорарлар җәмгыятьнең актив әгъзалары арасында бүленә. 1905 тә җәмгыять эше туктала, 1912 дә яңадан башлана. Шәһәрдә яңадан эшли башлаган җәмгыять файдасына язылу оештырыла, устав нигезендә һәр теләгән кеше әгъза була ала, ә әгъзалык взносы 1 елга 1 сум тәшкил итә. Шамовлар гаиләсе тапшырган акчага пар ат һәм янгын сүндерү арбасы алына, һәм ул ашыгыч ярдәм каретасы итеп көйләнә. АМЯКС Рыбно-Лядская урамындагы кибетчеләр клубында урнаша. 1913 тә Россиядә 7 шәһәрдә, ш.и. Казанда АМЯКС эшли. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, станцияләр эше туктала. 1919 да Мәскәү шәһәр советының Табиблек-санитария коллегиясе бүлеге (рәисе Н.А.Семашко) Шереметьев хастаханәсе базасында АМЯКС ачу турында карар кабул итә. Шул ук вакытта табиб Д.Косматов җитәкчелегендә Казандагы АМЯКС эше яңадан торгызыла һәм хастаханәләргә тимгелле тиф б-н авыручыларны китерү оештырыла. Авыруларга ярдәм күрсәтү тәүлек дәвамында алып барыла, 3 табиб, 3 фельдшер, 1 санитар, 2 кучер эшли. Татар һәм Ягодная бистәләрендә станцияләр ачыла. 1922 дә АМЯКС мөстәкыйль учреждение буларак аерылып чыга (Казанда ашыгыч ярдәм күрсәтү оешмасы эшчәнлеге башлану). Елга 1 мең чакыру һәм 2 мең мөрәҗәгать канәгатьләндерелә. 1928 дә Казан ГИДУВында (хәзер Казан мед. академиясе) станция эшли башлый. 1936 да Казанда һәм шәһәр тирәсендә (15–18 *км* ераклыкта) хезмәт күрсәтү алып барыла, ике ат, җиде автомобиль, яңа туган балалар өчен аерым бер автомобиль булдырыла; елга 25 мең чакыручыга хезмәт күрсәтелә. Хастаханәләрдә кабул итүне тәртипкә салу буенча буш урыннар саны исәпкә алына. 1940 та станциядә 45 табиб, 27 автомобиль була. Сугыштан соңгы елларда хезмәт күрсәтү камилләштерелә. 1950 елларда бригадалар саны арттырыла, мед. хезмәткәрләренең осталыгын үстерүгә игътибар юнәлтелә. АМЯКСта яраларны бәйләү эше башлана, 1 нче һәм 5 нче хастаханәләргә, травматология һәм ортопедия фәнни тикшеренү ин-тына хирургиягә караган авыруларны китерү башлана; 12 нче хастаханәдә кичектергесез хирургия ярдәме кирәк булган авыруларны кабул итү башлана, АМЯКС карамагына «өйдә ярдәм күрсәтү» хезмәте күчерелә, диспетчерлар хезмәте берләштерелә. 1960 елларда бала табучы хатыннарны хастаханәгә илтү тәртипкә салына (2 акушерлар бригадасы), шиналар кую өчен махсус бинтлар, фаҗига очрагы өчен сумкалар йөртү гамәлгә кертелә, психиатрлар посты оештырыла; Дәрвишләр бистәсендә АМЯКС филиалы ачыла. АМЯКСта кардиология һәм йөрәктәге тромбоэмболик авырулар өчен махсус бригадалар оештырыла, Неговский ысулы б-н йөрәккә массаж ясау гамәлгә кертелә, һуш китүдән дәвалау өчен махсус бригада, агулануларга каршы, балалар реанимациясе, неврология, анестезиология бригадалары оештырыла. Барлык санитария автомобильләре мобилизация чаралары, дәвалау-диагноз кую, наркоз-сулыш алу аппаратлары, лаборатория җиһазлары, медикаментлар, инструментлар, бәйләү материаллары б-н тәэмин ителә. Шәһәр стационарлары авыруларны кабул итә. Психоневрологик һәм терминаль авырулар (үлем алды халәтендәге) өчен махсус бригадалар оештырыла.

1966 да Казан шәһәренең 500 урынга исәпләнгән 15 нче хастаханәсе ачыла, ул АМЯКСның күп вазифаларын үз өстенә ала.

1980 еллар башында тар профильдәге бригадалар югары сыйфатлы мед. хезмәте күрсәтүгә сәләтле интенсив терапия бригадалары итеп үзгәртелә. 1985 тә адм.-хуҗалык бүлеге, автомобильләр өчен гаражлары булган типик үзәк станция сафка баса. Халыкка ашыгыч мед. ярдәме оештыруның яңа этабы 1986 да 15 нче шәһәр клиник хастаханәсен шәһәр ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсе итеп үзгәртүдән башлана. Бу хастаханә хәзер — 10 бүлеге һәм хезмәт күрсәтү урыны булган, күп профильле стационар, Казан мед. ун-ты, Казан. мед. академиясенең 5 кафедрасы өчен клиник база.

Биредә ел саен 13–15 мең хирургик һәм 14 меңнән артык амбулатор авыруга кичектергесез һәм планлы ярдәм күрсәтелә, 6 мең операция башкарыла. 1990 елларда кискен миокард инфарктын дәвалауда беренче тапкыр тромболитик дәва (стрептодеказа препараты) ысулы гамәлгә керә, нәтиҗәдә авырудан терелүгә ышанычы булмаган авыруларны да савыктыруга ирешелә. Казан мед. академиясе — «Ашыгыч ярдәм табибе», Казан мед. ун-ты «Кичектергесез неврология» буенча табибләрнең белемен күтәрү курслары алып бара. Казан шәһәр ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсе — ТРның зур дәвалау учреждениеләреннән берсе, 2004 елда 90 табиб, 200 урта мед. хезмәткәре, 300 дән артык хезмәт күрсәтү персоналы эшли. Ел саен 300 мең кешегә ш.и. һәлакәткә дучар булган 33–35 мең кешегә (авыр җәрәхәтләр, агуланулар һ.б.) ашыгыч һәм кичектергесез ярдәм күрсәтелә.

Чаллы шәһәр ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсе 4 нче шәһәр хастаханәсе нигезендә оештырыла. 1980 нән хастаханә шәһәр ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсе статусы ала. 9 корпуслы (760 урынга исәпләнгән стационар) бу мед. шәһәрчеге, шәһәр һәм Кама аръягы районнары халкына тәүлек буе ашыгыч ярдәм күрсәтә. Хастаханәдә 16 бүлек эшли: кабул итү — диагноз кую, реанимация (кардиореанимация блогы б-н), пешүдән дәвалау (пластик операцияләр), 2 терапия (токсикология, неврология, аллергология палаталары), 2 хирургия, нейрохирургия, бит-яңак хирургиясе, нефрология (ясалма бөер), офтальмология (өлкәннәр һәм балалар өчен), кардиология, 2 травматология (3 нче җәрәхәтләрне дәвалау пункты), урология, гинекология (барлык төр ашыгыч ярдәм). Кама аръягы бөердән тыш кан чистарту ысуллары һәм бөерләр күчереп утырту төбәк үзәге эшли, бөер күчереп утырту операцияләре үткәрелә, гемодиализ б-н 100 пациент дәвалана. Чаллы шәһәр ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсе елга 20 мең авыруны стационарда дәвалый, 7,5 меңнән артык ашыгыч ярдәм күрсәтә; травмпунктта 30 мең кеше мөрәҗәгате канәгатьләндерелә; 2004 тә 1425 кеше, ш.и. 173 табиб, 800 дән артык урта медицина хезмәткәре эшли. Төрле елларда баш табибләр — И.Г.Ишкинеев (1974–89), 1984 тән — Е.В.Лушников.

ТРда 10 мөстәкыйль АМЯКС бар, 11 кече станция, 52 бүлек, ике шәһәр ашыгыч мед. ярдәме станциясе эшли; ашыгыч мед. ярдәме хезмәте елга 1 млн. 80 мең тапкыр ярдәмгә чыга, бу системада 1400 табиб, 2500 урта медицина хезмәткәре исәпләнә.

*Әд.:* Лисевич М. История Казани глазами эрудитов. К., 2000.

*Н.Э.Галиев, Е.А.Ефремов, Р.Г.Исхакова.*

**АШЫ́Т** елгасы, Көнбатыш Кама алды төбәгендә. Иләт елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 83 *км*, бассейнының мәйданы 1087 *км*². Елга башы Арча р-ның Ашытбаш авылыннан 2,5 *км* көньяктарак, Әтнә һәм Биектау р-ннары терр-ясеннән ага, тамагы Мари Респ-касы терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 155 *м*, тамагыныкы — 81 *м*. Елганың су җыелу мәйданы елга үзәнлекләре б-н киң сөзәк тау тезмәләренә бүлгәләнгән калкулыклы тигезлектән гыйбарәт. Елга үзәне асимметрияле (уң яктагы сөзәклекләре беркадәр текәрәк), шуның аркасында эрозия шактый тирән уелган. Елга тугае ачык беленә, түбән агымдагы үзәне сазланган. Елга юлы бормалы. 19 кушылдыгы бар, уң кушылдыкларыннан иң зурлары: Оры (14,2 *км*), Шашы (14,8 *км*), Үртәм (17,8 *км*), Өлә (17 *км*); сул кушылдыгы — Симет (24,1 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Елга режимы 1932–35 елда Потаниха авылы янындагы гидрологик постта өйрәнелә. Режимда җәйге һәм кышкы саегулар һәм ташу вакытлары (еллык су агымының 80–90% ы шушы чорга туры килә) билгеләнә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы

180 *мм*, ташу агымы катламы 140 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун көнлегендә башлана. Җәйге саегулар тотрыклы, кайвакыт яңгырлар ташкыны б-н үзгәрә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,575 $м^3/с$. Кышкы саегулар боз ката башлау вакытына, гадәттә, ноябрьдә башларына туры килә. Кыш азагына бозның калынлыгы 65 *см* га җитә. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы; язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын



Ашыт елгасының урта агымы.

һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 450 *мг/л* ка кадәр (елга тамагында 1100 *мг/л* га кадәр). Елгада гомуми күләме 4,9 млн. $м^3$ булган 11 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. Әтнә р-нында А. бассейнында аеруча саклана торган терр-я — *Ашыт* комплекслы табигать тыюлыгы (1997) урнашкан.

**АШЫ́Т**, Әтнә р-нындагы комплекслы табигать тыюлыгы. Олы Әтнә һәм Түбән Бәрәскә авылларыннан төньяктарак урнашкан. 1997 елда *Ашыт* елгасы үзәнлеген тәшкил иткән табигать компонентларын саклау максаты б-н оештырыла. Мәйданы 2,7 мең *га*. Территориясенә Ашыт елгасының югары агымындагы 2–3 *км* киңлектәге тугае, Шашы елгасы тамагыннан (көнчыгышта) Үртәм елгасы тамагына (көнбатышта) барып тоташкан өлешләре керә. Рельефы — елга үзәннәре, сызалар һәм ерымнар б-н бүлгәләнгән калкулыклы тигезлек. Сөзәклекләрнең түбән өлешендә чишмәләр агып чыга. Үсемлекләр дөньясы суда-җирдә үсә торган кыяклы үләннәрдән гыйбарәт; сирәк үсемлек төрләре: ак төнбоек, сары төнбоек. Поши, кабан дуңгызы, төлке, бурсык, үр куяны һәм ак куян, Америка чәшкесе, көзән, ондатра саклана. Кошларның 112 төре, ш.и. ТРның Кызыл китабына кертелгән 15 төре билгеле: сазлык ябалагы, зур саз шөлдие, ысылдавык аккош, болын карчыгасы, бытбылдык, кызылаяк шөлди, үлән шөлдие һ.б. ТР терр-ясендә беренче тапкыр зур шөлдиләрнең күпләп оялавы ачыклана. Су баса торган сай сулыклар күп төрле казсыман кошларның язгы күчү чорында тукталу урыны булып тора (соры каз, ындыр казы, ак маңгайлы каз, кыр үрдәге һ.б.).

*А.С.Әюпов.*

**АШЫТБА́Ш** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 30 *км* төньяктарак, Ашыт елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 624 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1678 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында авыл Сенные Покосы дип атала. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.та мәчет, мәктәп, су тегермәне, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2167,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 120 ир заты; 1859 да — 762, 1897 дә — 919, 1908 дә — 1117, 1920 дә — 1163, 1926 да — 1158, 1938 дә — 1235, 1949 да — 952, 1958 дә — 752, 1970 тә — 882, 1979 да — 678, 1989 да — 572 кеше.

*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**АЭРО**... (грек. aḗr — һава).

**АЭРО́Б ОРГАНИ́ЗМНАР**, а э р о б л а р (аэро... һәм bios — яшәү), ирекле кислород булганда гына нормаль тереклек эшчәнлегенә сәләтле организмнар. Сулыш алу аларга энергия бирүче төп гамәл булып тора. А.о.га һава кислороды хисабына яшәүче югары төзелешле һәм ш.у. түбән төзелешле организмнар керә. А.о. облигат һәм факультатив төркемнәргә аерыла. Беренче төркемгә кислородсыз нормаль яши алмаучы микроорганизмнар, икенче төркемгә матдәләр таркалганда барлыкка килгән энергиядән (әчү энергиясе) файдаланучы микроорганизмнар керә. Шул сәбәпле алар әйләнә-тирә мохиттә кислород концентрациясе җитәрлек булмаганда да, калдык матдәләр әчегәндә барлыкка килгән энергия хисабына һәм продуктлар окисьлашканда да яши алалар. Аммоний һәм нитратлар ясаучы һ.б. А.о.ның эшчәнлеге үсемлекләрнең туклану шартларын яхшырта һәм аларның уңышын арттыра.


Аэроб һәм анаэроб организмнарның аермасы — беренчеләренең яшәве өчен кислородның чик концентрациясе бик югары (кислородның парциаль басымы 10–15 *атм.*), ә икенчеләре өчен бик аз (5–10 *мм*) булуында. Кислородның парциаль басымын максимумнан югары күтәрү организмнарның һәлакәтенә китерә.


*Ф.С.Зыятдинов.*


**АЭРОДИНА́МИКА** (*аэро*... һәм грек. dynamis — көч), аэромеханиканың бер бүлеге, җисем өслегеннән ягалап аккан газның (ш.и. һаваның) хәрәкәт итү законнарын һәм шуның нәтиҗәсендә барлыкка килә торган көчләрне өйрәнә. Механика, физика һәм термодинамика законнарына таяна. А.ның гамәли бүлекләре: 1) очкыч аппаратлар А.сы; 2) сәнәгать А.сы. А.да туры мәсьәлә — рәвешләре билгеле очкыч аппаратларның, аларның аерым өлешләренең һәм төрле корылмаларының аэродинамик сыйфатламаларын билгеләү һәм кире мәсьәлә — бирелгән аэродинамик сыйфатламалары буенча ягалап ага торган җисемнең рәвешен билгеләү мәсьәләләре чишелә. Хәзерге А.ның башланып китүе Н.Е.Жуковский, С.А.Чаплыгин, Л.Прандтль хезмәтләренә бәйле. Казан галимнәре 1930 елларда аэродинамик тикшеренүләр б-н Казан ун-тының аэродинамика бүлегендә (1931), аннары аэродинамика лабораториясе һәм кафедрасы ачылгач Казан авиация ин-тында (1932) кызыксына башлыйлар. Теоретик А.га, ш.у. тотрыклылык, оптимальләштерү, төрле аэродинамик процесслар б-н идарә итүгә караган тикшеренүләр (Н.Г.Четаев, Г.В.Каменков, С.Г.Нужин, Г.Н.Фёдоров) алып барыла.

А.га караган беренче хезмәтләр биплан һәм полипланнар аэродинамикасын (С.Г.Нужин, 1935), Карманның өермә юллары тотрыклылыгын (Г.В.Каменков, 1933) исәпләүгә багышланган. 1940–1950 еллар башында чикләнгән үлчәмле канатның, кыска канатларның, уксыман канатларның, зур һәм артык зур почмак ясап хәрәкәт итү канатларының һәм тирбәнүче канатларның аэродинамик көчләрен һәм моментларын исәпләү ысуллары (С.Г.Нужин, Г.В.Каменков, Н.М.Монахов, Т.К.Сиражетдинов) эшләнә. Шул ук елларда кысылмаучан һәм үзле булмаган сыеклыктагы тавыш тизлегенә кадәр булган кысылучан (С.Г.Нужин) һәм тавыш тизлегенә якын (А.И.Богомолов) яссы параллель агымнарда канат профильләренең ягалап агу теориясе эшләнә. 1944 елда Г.Г.Тумашев тарафыннан аэродинамиканың кире мәсьәләсе — басымның канат өслегендә таралышы буенча канат профилен төзү мәсьәләсе куела һәм чишелә. Бу хезмәт очкыч аппарат канатларына караган күп кенә тикшеренүләрне башлап җибәрүгә нигез сала. 1950 еллар уртасында О.П.Сидоров әйләнү җисемен кысылмаучан сыеклык ягалап агуын тикшерә. 1950 ел-

Аэродинамик өйрәтү торбасы.







1. Аэродинамик торба; 2. Аэродинамик Т-1К торбасында күпер моделен сынау.

ларда М.Х.Бикчәнтәев һәм Г.И.Костычев профиль рәшәткәләренең һәм канат профильләренең җир өстенә якын ягалап агуларына караган тикшеренүләр уздыралар. 1960 елларда Н.В.Куршев, Ю.В.Кожевников, Т.К.Сиражетдинев, А.А.Афанасьев, О.Г.Диваков һ.б. А.ның оптимальләштерү һәм очу динамикасы мәсьәләләрен һәм һава агымын өрдереп тутыру-чыгару юлы б-н сыеклык һәм газның чик катламы теориясен тикшергәндә вариация ысулларын һәм Л.С.Понтрягинның максимум принцибын кулланалар. Шул ук елларда сыеклык хәрәкәтенең тотрыклылыгын, ягулык багындагы сыеклык тирбәнешен стабильләштерү һәм идарә итү, плазма шнуры тирбәнүенең стабильләшүен һәм тотрыклылыгын гидродинамик якынча тикшергәндә А.М.Ляпунов функцияләрен төзү ысуллары эшләнә (Т.К.Сиражетдинов, В.А.Петров, А.А.Соловьёв, И.П.Ультриванов һәм Е.Г.Павлов). 1970 еллар башыннан В.Г.Павлов, З.Х.Ногманов, В.В.Жерехов, К.Г.Гәрәев һ.б. сыеклык агымының үзлекләрен төркемнәргә бүлеп өйрәнә һәм самолёт канатын аэродинамик проектлаштыру мәсьәләсен тикшерә. Хәрби һәм гражданлык авиациясе самолётларын, ракета техникасын, автомобильләрне аэродинамик тикшерү тәҗрибәләре Казан техника ун-тының аэродинамик торбасында алып барыла.

*Әд.:* Аржанников Н.С., Мальцев В.Н. Аэродинамика. М., 1935; Каменков Г.В. О вихревом сопротивлении. М., 1935, Ч. 2; Четаев Н.Г. Устойчивость движения. М., 1962; Куршев Н.В. Оптимальные задачи динамики полёта. К., 1967; Сиразетдинов Т.К. Оптимизация систем с распределёнными параметрами. М., 1977; шул ук. Устойчивость систем с распределёнными параметрами. Новосиб., 1987; Дегтярёв Г.Л., Сиразетдинов Т.К. Теоретические основы оптимального управления космическими аппаратами. М., 1986; Нугманов З.Х. Численный метод расчёта обтекания профиля вязким несжимаемым потоком. К., 1993.

*Т.К.Сиражетдинов.*

**АЭРОКЛУ́Б**, 1933 елның май аенда гражданлык һәм хәрби авиация өчен белгечләр әзерләү максатында ОСОАВИАХИМ карары б-н Казанда оештырыла. 1964 тән ДОСААФның укыту-авиация үзәге, 1992 дән «ТР Милли аэроклубы» дәүләт пр-тиесе. 2002 дән ТРның РОСТО үзәк аэроклубы. А.ны оештыручылар: Б.М.Бикиев, Н.Е.Брусков, А.С.Будрин, М.Н.Вальков, А.Л.Кармин, А.У.Кузьмин, У.Х.Мостафин, А.Н.Павлов (А.ның беренче җитәкчесе), С.Ф.Сәләхов һ.б. Базасы: туфраклы очу кыры булган «Коркачык» аэродромы (Биектау р-ны) авиатехника паркы (Ан-2, Ил-103, Як-52, Л-29, Ми-2). Татарстанда беренче тапкыр самолёттан парашют б-н сикерү 1934 нең 12 июнендә Казанда башкарыла. Парашют спорты үсешенең башлангыч чорында А.С.Будрин, Задубровская (парашют б-н сикерүче беренче хатын-кыз), К.Кайтанов, Г.И.Суховерков, Харламов һ.б. инструкторлар эшли. 1935 тә 9 кешедән торган 1 нче очучылар төркеме чыгарыла. Алар арасында татарлардан беренче очучы хатын-кыз Сания Яруллина була. Бөек Ватан сугышына кадәр аэроклуб һәм аның филиаллары (Чистай ш. һәм Казан авиация ин-ты каршында) 400 дән артык очучы, 120 очучы-инструктор, 240 планёрчы, 1500 парашютчы-спортчы, 116 авиамодельче әзерли. Казан аэроклубын тәмамлаучылар арасында Сов. Союзы Геройлары М.П.Девятаев, А.С.Калашников, Б.М.Васильев, К.В.Новосёлов, Г.Р.Павлов, Л.М.Соколов, Б.С.Чекин, Н.Н.Аржанов, Г.К.Мосолов, П.М.Никифоров һәм ике тапкыр Сов. Союзы Герое Н.Г.Столяров; СССР, Россия һәм дөнья чемпионнары-рекордчылары: В.Матасов, Р.Мортазин, А.Поляков, А.Бакулин, С.Зайцев, В.Лягин, Т.Пересекина, Ю.Левчик (авиация спорты), М. Алексеева, А.Гудина, Л.Мельников, Х.Йосыпов (парашют спорты), Л.Алдошин (авиамодель спорты) бар. 1992 дән А. эшчәнлегенең төп төрләре: һәвәскәр очучылар, парашютчылар, дельтапланчылар әзерләү һәм аларның чыгышларын оештыру, ш.у. һавадан газүткәргеч торбаларны күзәтү, авиация ярдәмендә хим. эшләр башкару.



«Коркачык» аэродромы.

**АЮ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 16 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Брустан елгасы буенда. 2002 елда 444 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1725 тән мәгълүм. 1940 елларга кадәр авылның русча исеме — Медведево күбрәк кулланылган. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр, башкорт-вотчинниклар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә. Игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык б-н шөгыльләнә; алпавыт утарында көнлекче булып эшлиләр. 1773–75 еллардагы крәстияннәр сугышы вакытында авылга Пугачёв отрядыннан 200 ләп кеше килеп урнаша. 1795 тә авыл җәмәгатенең файдалануда — 247, 1884 тә — 432, 1913 тә 930 дис. җире була. 1929 да А.да Калинин исем. колхоз оештырыла, 1960 та «Рассвет» колхозы, 1973 тән — «Якты Юл» совхозы составында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Мәлкән волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 186 ир заты; 1859 да — 334, 1870 тә — 371, 1897 дә — 529, 1913 тә — 700, 1920 дә — 708, 1926 да — 632, 1938 дә — 593, 1959 да — 647, 1970 тә — 779, 1979 да — 662, 1989 да — 452 кеше.

**АЮ́ БАЛАНЫ́**, шифан (Sambucus), зелпечәләр семьялыгыннан кечерәк агачлар, куаклар һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төре урта һәм субтропик поясларда (Көньяк Америкадан башка) киң таралган. ТРда бер төре — Кызыл А.б. яки тәлгәшле А.б. (S. racemosa) үсә. Куе ботаклы, 2–2,5 метр биеклеккә кадәр үсә торган куак. Йорт-койма буйларындагы ышык урыннарда, киң яфраклы урман кулэгәлекләрендә үсә. Яфраклары пычкы читле, очлы, каурыйсыман, парсыз яки өчәр-өчәр булып урнашкан. Сабак очындагы чәчәклек тәлгәшләре исле. Чәчәкләре вак, башта яшькелт-сары, соңрак саргылт-ак төскә керә. Май–июнь айларында чәчәк ата. Чәчәкләре нектарсыз, әмма чебеннәр, вак коңгызлар, умарта кортлары чәчәкләрдән туклыклы серкә җыялар. Җимешләре кызыл төстә, сусыл, июльдә өлгерә, ашарга яраксыз.



Кызыл аю баланы.

*Ф.З.Вәлиев.*

**«АЮ́ БЕЛӘ́Н ХАТЫ́Н»**, әкият, татар халык иҗатында хайваннар турындагы әкият-

ләргә караган мифологик әсәр. Хатын-кыз аю аягына кадалган шырпыны чыгара, аю аңа умартасы б-н бал алып килә. Татарларның борынгы бабаларының хайваннар, үсемлекләр һәм табигать күренешләренә кеше сыйфатларын бирүен чагылдырган антропоморфик ышануларын тасвирлый.

**АЮ́ ҖИЛӘГЕ́** (Arctostaphylos), арчанчалар семьялыгыннан мәңге яшел куаклар ыругы. 70 ләп төре билгеле, Төньяк ярымшарда киң таралган. Россиядә бер төре — гади А.ж. яки аю колагы (A. uva-ursi) үсә. ТРда Кама алды төбәкләрендә сирәкләнгән коры нарат урманнарында, кисентеләрдә очрый. 30–80 *см* озынлыктагы куакчык. Сабаклары куе коңгырт кабыклы, нык тармаклы. Яфраклары — тыгыз кабыклы, озынча, өсте ялтырый, куе яшел төстә. Чәчәкләре — вак, алсу төстә, сабак очларындагы аска караган кыска чукларга җыела. Җимеше — өнчыл җимеш йомшагы булган шарсыман кызыл каты төш, куе кызыл төстәге 1–5 төшчеге була. Майда чәчәк ата. Җимешләре июльдә өлгерә. Яфракларында гликозидлар, дуплау матдәләре, А һәм С витаминнары бар. Яфракларының төнәтмәсен бөерләр һәм сидек юллары ялкынсынганда эчәләр, ш.у. диатез, җәрәхәтләр, үлекле яралар булганда ванна ясыйлар. Гади А.ж. тышкы яктан нарат җиләгенә охшаган, әмма ул җәелеп киткән ян үсентеләре б-н аерыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**АЮ́ ТАБАНЫ́**, аю көпшәсе (Aconitum), казаякчалар семьялыгыннан күпьеллык үсемлекләр ыругы. 300 гә якын төре Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә бер төре — биек аю көпшәсе (A. excelsum) очрый. Урман аланнарында, елга буйларында үсә. Салкынга чыдам, туфракка таләпчән түгел. 100–200 *см* озынлыктагы үсемлек. Тамыры бүлбесыман, төерле. Сабагы туры, ботаклы. Яфраклары эре, бармаксыман бүленмәле яисә телмәле. Чәчәкләре — соргылт-тоныкмиләүшә төсле, сирәк кенә ак, сабак очындагы куе чукка җыелган. Җимешләре — өч кырлы күп орлыклы табакча. Май-июнь айларында чәчәк ата. Күбесенчә орлыктан үрчи. Тамырларында һәм шулай ук җир өстендәге өлешләрендә шактый микъдарда алкалоидлар бар. Халык медицинасында бизгәк авыруларына каршы һәм невралгия вакытында авыртуны басу өчен кулланыла. Агулы, аның б-н сарык һәм кәҗәләр еш агулана.

**«АЮ́ УЛЫ́ АТЫЛӘХМӘТГӘРӘ́Й»**, татар халык әкияте, фольклорда хайваннар турындагы әкиятләргә караган мифологик әсәр. Себердә язып алынган; вариантлары татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә теркәлгән. Хайван, кеше б-н гаилә мөнәсәбәтләренә кереп, ыруг башлыгы булып киткән, дигән борынгы тотемистик ышануларны чагылдыра.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Беренче китап. К., 1977; Татарское народное творчество. К., 1999.

**АЮКА́ЕВ** Ренат Исхак улы (3.2.1937, Үзбәкстан ССРның Бохара өлкәсе, Свердлов р-ны Агар а.), су чистарту технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1981), проф. (1983), Карелия АССРның атказ. фән эшлеклесе (1987). 1964 елда Мәскәү политехника ин-тын тәмамлый. 1964 тән Куйбышев инженер-төзүчеләр ин-тында, 1977 дән Петрозаводск ун-тында су б-н тәэмин итү, гидравлика һәм су кудыру каф. мөдире. Су чистарту технологиясен эшли. Хезмәтләре табигый һәм тотылган суларны чистартуга, күп күзәнәкле материалдан эшләнгән бөртекле су чистарту фильтрларын яхшыртуга карый.

Хезм.: Производство и применение фильтрующих материалов в технологии очистки воды. Л., 1985.

**АЮКӨЙДЕРГӘ́Н** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 36 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы чигендә. 2002 елда 185 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Мәчет. 16 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, А.дә мәчет була. 20 йөз башында мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1170,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Тояба волостена керә. 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 84 ир заты; 1859 да — 524, 1897 дә — 1020, 1908 дә — 1445, 1920 дә — 1192, 1926 да — 907, 1938 дә — 995, 1949 да — 618, 1958 дә — 364, 1970 тә — 399, 1979 да — 304, 1989 да — 200 кеше.

**АЮКҮБӘЛӘКЛӘ́Р** (Arctiidae), төн күбәләкләре семьялыгы. 7 меңнән артык төре билгеле, Россиянең Европа өлешендә 50 ләп төре очрый. Күбесенчә ачык һәм чуар төстәге күбәләкләр, кайберләреннән тыш, уртача зурлыктагы юан гәүдәле. Түше еш кына ачык төстә, күренеп торган тимгелләре һәм сызыклары бар. Ата затларның мыеклары тараксыман, хортумчыгы кыска. Күбәләк кортлары куе төк б-н капланган, күбесенчә үләнчел үсемлекләр б-н тукланалар. Күбәләкләр эңгер-меңгердә һәм төнлә актив, сирәк төрләре көндез оча, мәс., канлы аюкүбәләк. Татарстан терр-ясендә еш очраучы А.: Кайя аюкүбәләге (Arctia coja L.) гадәти — төнлә утка очып килә; еш кына болын аюкүбәләге (Diacrisia sannio L.) һәм бака яфрагы аюкүбәләге (Parasemia plantaginis L.) — дымлы болыннарда яшиләр. Күп төрләре сирәгәя бара. ТРның Кызыл китабына кертелгән А.: авыл аюкүбәләге (Epicallia villica L.), канатларының җәеме 50–60 *мм*, алгы канатлары кара төстә, ак тимгелләре бар, арттагылары сары төстә, кара тимгелле. Май-июнь-июль айларында оча, күбәләк кортлары кара төстә, башлары кызыл, бака яфрагы, кычыткан һ.б. үләнчел үсемлекләрдә яшиләр. Аюкүбәләк Герның (Caallimorpha quadripunctaria P.) канат җәеме 50–55 *мм*, алгы канатлары кара төстә, кыйгач ак сызыклары бар, арттагылары кызыл төстә, кара түрткеләре бар, июль-августта көндез дә оча, күбәләк кортлары кара яки соры төстә, аркасында сары яки кызгылт-сары сызыгы һәм як-ягында кызгылт-сары сөялле сары сызыклары бар, бака яфрагы, тукранбаш, кырлыган һ.б. үсемлекләрдә яшиләр; хуҗабикә аюкүбәләк (Pericallia matronula L.), канат җәеме 70–80 *мм*, куе көрән төстә, июнь-июльдә оча, ш.у. аюкүбәләк Геба (Ammobiota hebe L.), бикә аюкүбәләк (Panaxia dominula L.), кызыл тимгелле аюкүбәләк (Utetheisa pulchella L.) һәм сары аюкүбәләк (Arctia flavia) бар.

*С.Г.Гордиенко.*

**АЮЧИКЕРТКӘЛӘ́Р** (Gryllotalpidae), турыканатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. 46 төре билгеле, РФ дә — 3, Татарстан терр-ясендә 1 төре — гади А. (Gryllotalpa gryllotalpa) очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 35–50 *мм*, көрән-коңгырт төстә, аркасының өске өлеше нык үскән, канат өслекләре кыска, канатлары ярылы, озын; алгы очлыклары — җир казу, уртадагылары һәм арттагылары йөрү өчен җайлашкан. Зур бөҗәкләр һәм личинкалар туфракта яши, сирәк кенә туфракның өске катлавында да күренә. Гади А.



очу сәләтен югалтмаган һәм җенси активлык чорында, чикерткә тавышы чыгарып, төнлә оча. Зур бөҗәк һәм урта яшьтәге личинка кышлый. Кышлаганнан соң, май–июнь айларында ана бөҗәк җирне 10–25 *см* тирәнлектә казып, йомшартып, ояга керү юлы, өн ясый һәм шунда 300 гә кадәр йомырка сала. 10–20 тәүлектән соң туган личинкалар башта бергә яши, аннан соң үрмәләп тарала; аларның үсеше 12–14 ай дәвам итә. Җир асты юллары салып, гади А. төрле үсемлекләрнең җир асты өлешләре, ш.у. вак бөҗәкләр, суалчаннар һ.б.ш. б-н туклана. А.х. культураларына һәм урман питомникларындагы, күбесенчә сулыклар янындагы һ.б. дымлы урыннардагы чәчүлекләргә зур зыян китерә. Көрәш чаралары: чокыр һәм канаулар казып тозак салалар; тирән итеп туңга сөрәләр; туфракны карботион һәм дихлорэтан б-н эшкәртәләр; үсентене күчереп утыртканчы, 2–3 *см* тирәнлектә агуланган җим күмәләр.

**АЯ́З ИЛЕ́** (Мамонино) авылы, Биектау р-нында, Сола елгасы (Казансу елгасының уң кушылдыгы) буенда, Биектау тимер юл станциясеннән 16 *км* төньяктарак. 2002 елда 194 кеше (татарлар — 50%, руслар — 45%). Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Вознесенский, Аяз исемнәре б-н дә билгеле. 1961 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында А.И.ндә Вознесение чиркәве (1784 тә төзелә, архит-ра истәлеге), земство уч-щесе, 2 су тегермәне, 4 бакалея, 2 сыра, шәраб кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1428,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Сабакин волостена керә.

1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 171 ир заты; 1859 да — 400, 1897 дә — 554, 1908 дә — 518, 1920 дә — 647, 1926 да — 750, 1938 дә — 682, 1949 да — 450, 1958 дә — 401, 1970 тә — 272, 1989 да — 195 кеше.

**АЯ́З КҮЛ**, Көнчыгыш Кама аръягындагы иске су юлында сакланып калган күл. Ык елгасының сул як тугаенда, Эстәрле елгасы тамагыннан өстәрәк, Азнакай р-нының Түбән Эстәрле авылыннан 0,7 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Ике күлдән тора. Су өслегенең мәйданнары 1 *га* һәм 0,3 *га*. Озынлыклары 350 һәм 170 *м*, иң зур киңлекләре 40 һәм 30 *м*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**АЯ́К КИЕМЕ́**. Татарлар элек-электән күн аяк киемен өстен күргән. Йомшак һәм югары сыйфатлы күннән эшләнгән юфть, сәхтиян итек, башмак, читек-кәвеш, чүәкләрне элек аларның борынгы бабалары — Идел болгарлары кигән. Моңа 10–13 йөзләрдә тегелгән аяк киемнәренең сакланып калган кисәкләре шаһит: болгар осталары күнгә басып һәм чигеп бизәк төшергәннәр, төсле күн һәм металл фигуралар ябыштырганнар. 19–20 йөзләр чигендә Казан һәм Казан арты аяк киеме тегүчеләренә дөньякүләм дан китергән күн каю техникасы болгар нәфис һөнәрчелегенә барып тоташа. Күн каю һөнәре сәнгате хәзер дә үсүен дәвам итә. Милли үзенчәлекле аяк киемнәрен — бизәкле читекләрне, чүәкләрне бүген дә теләп алалар, *Арча милли аяк киеме җитештерү берләшмәсе* осталары дистәләрчә буын читекчеләренең эшләрен лаеклы дәвам иттерәләр. Татарларда басылган йоннан эшләнгән киез аяк киемнәре — киезката көндәлек аяк киеменнән саналган, киез итек кышын киелгән. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында татарларда гына түгел, Идел һәм Урал буйларында яшәүче башка халыклар арасында да кунычларына бизәк төшерелгән ак төсле Кукмара киез итекләре киң тарала. Тарихи мәгълүматларга караганда, юкә кайрысыннан эшләнгән аяк киемнәре күчеп килгән болгарларга җирле халыктан — фин-угорлардан үтеп кергән. Сирәк кенә очракларда татарлар эш вакытында чабата кигәннәр. Аяк киеме тула оек б-н, киндердән тукылган ыштырлар чолгап, очлары бизәкләп чигелгән киндер һәм җитен аяк чолгаулары б-н киелгән.

*Әд.:* Гулова Ф.Ф. Татарская национальная обувь (искусство кожаной мозаики). К., 1983; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000; Саттарова Л.И. Казанская узорная кожа. М., 2004.

*Ф.Ф.Гулова.*

**АЯ́К КИЕМЕ́ ҖИТЕШТЕРҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, җиңел сәнәгать тармагы. Күн, киез, мех, ясалма материаллардан аяк киеме җитештерүне гамәлгә ашыра. Идел буе Болгар чоры традицияләренә барып тоташа (к. *Читек*, *Каюлы күн һөнәрчелеге*, *Аяк киеме тегү кәсепчелеге*), алга киткән җирле кустарь һәм шәһәр һөнәрчелеге җирлегендә оештырыла. Күн олтанлыклар Пумпов заводында эшләнгән. Беренче специальләшкән пр-тиеләр 19 йөзнең 2 нче яртысында оештырыла. 1864 елда Казанда Е.Е.Сафронов уллары б-н бергә киез аяк киеме остаханәсе ача (1895 тән — ф-ка). 1867 дә Кукмара авылында бертуган Комаровларның киез һәм тула аяк киеме тегү остаханәсенә нигез салына, 1871 дән «Бертуган Комаровларның фабрикада эшләнгән киез һәм тула аяк киеме сәүдә йорты» (к. *Кукмара киез итек-киез комбинаты*). 1897 дә шунда ук киез аяк киеме җитештерү буенча «Бертуган И.Д. һәм Н.Д.Родыгиннар ширкәте» оеша. 19 йөз ахырында Казан губернасында М.И.Галиев, Абдуллин, Фәйзуллин һ.б. сәүдәгәрләрнең бизәкләп чигелгән аяк киеме җитештерү остаханәләре эшли. Татарстанда күн аяк киеме җитештерү шул пр-тиеләр традициясенә нигезләнеп башланып китә. 1916 да Казанда сәүдәгәрләр В.Г.Шабанов, Н.М.Зобнин, С.В.Жулин тарафыннан армия өчен аяк киеме җитештерүгә көйләнгән «Поляр» аяк киеме ф-касына нигез салына (к. «*Спартак*»). Киез басканда тарау һәм талку, аяк киеме йөзлеге өчен күн әзерләгәндә күнне өлгеләп кисү һәм тегү машиналары, пар һәм дизель двигательләре кулланылу нәтиҗәсендә А.к.җ.с. механикалаштырыла башлый.

1918–20 дә А.к.җ.с. пр-тиеләре, дәүләт карамагына күчерелгәннән соң, берләштерү юлы б-н эреләндереләләр: Кукмарадагылар — «Красный текстильщик», Казандагылар «Спартак» ф-калары булып берләшә. Индустрияләштерү елларында иң эре Казан киез итек-киез комб-ты (к. «*Валком*»), ясалма материаллардан аяк киеме өчен детальләр җитештерү буенча беренче ясалма күн ф-касы (к. «*Казан ясалма күн заводы*») төзелә; бөтән пр-тиеләр яңартып корыла. 1928–1940 та аяк киеме җитештерү күләме 500% тан арта, киез һәм фетрдан — 3,8, күннән 3,5 млн. пар аяк киеме җитештерелә. Бөек Ватан сугышы башлангач, Мәскәү һәм Гомель шәһәрләренең аяк киеме ф-калары җиһазлары һәм кешеләре б-н Казанга эвакуацияләнә, А.к.җ.с. пр-тиеләре фронт өчен продукция эшләп чыгаруга керешә. Казан «Спартак» күн аяк киеме һәм Казан мех комб-тларында илебездә беренче буларак (1941) унтлар һәм мех итекләр тегелә. Шуннан соңгы елларда җитештерү эшләре механикалаштырыла һәм конвейерлаштырыла, яңа технологияләр кертелә, ясалма материаллар кулланыла. Гамәлдәге пр-тиеләрнең куәтләре киңәйтелә, Чистай, Мамадыш һәм Йошкар-Ола шәһәрләрендә «Спартак» җитештерү берләшмәсенең фабрикалары төзелә. Күн һәм киез аяк киеме эшләп чыгару күләме тиңдәшле рәвештә: 1960 та — 8,6 һәм 4,5; 1970 тә — 12 һәм 4; 1980 дә — 10 һәм 3,9; 1990 да — 11,2 һәм 3,27 млн. пар тәшкил итә. 1985 тә «*Түбәнкаманефтехим*» җитештерү берләшмәсендә поливинилхлорид пластик аяк киеме кою үзләштерелә. 1980–90 елларда Вьетнам Респ-касы пр-тиеләре б-н берлектә Татарстан пр-тиеләре җитештергән продукция Польша, Куба, Монголиягә чыгарыла.

Хәзерге вакытта республикада күн аяк киемнәрен — «*Спартак*» АҖ, «*Милли аяк киеме*» фәнни-җитештерү берләшмәсе, киез аяк киемен — «Татвойлок» (Казан) җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять һәм «Кукмара киез итек-киез комб-ты», мехтан — «Мелита», «Спартак» АҖ, резинадан — «Завод эластик» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять; ш.у. «Казан ясалма күн заводы» АҖ аяк киеме материаллары һәм детальләре эшләп чыгара. Аяк киемнәрен ш.у. «Татреспотребсоюз» системасындагы кооператив пр-тиеләр һәм Казан, Чаллы, Лениногорск, Әлмәт, Чистай, Азнакай шәһәрләре, Арча, Кукмара посёлоклары, Мөслим һәм Сарман р-ннары фирмалары да җитештерә. Менделеев шәһәрендә «Менде-Росси» уртак Россия-Австрия аяк киеме пр-тиесе оештырыла. 2005 тә барлыгы 567,1 мең пар күн аяк киеме, 920 мең пар киез аяк киеме, 178,1 мең пар балалар аяк киеме җитештерелә. Ш.у.к. «*Киез итек-киез җитештерү*».

**АЯ́К КИЕМЕ́ ТЕГҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́**, Казан губернасында күн аяк киемнәре тегү кәсепчелеге 19 йөздә Зөя, Казан, Лаеш, Мамадыш, Спас, Тәтеш, Чабаксар өязләрендә киң таралган була. Күпчелек очракта ул крәстияннәр ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен җитештерелә. Мамадыш өязенең Яңа Чүриле волосте, Казан өязенең Алат, Балтач, Мәмсә, Мәңгәр һ.б. волостьлары, Вятка губернасының Арбор, Сәрдекбаш, Шода волостьлары, Сембер губернасының Сөнгәләй өязе татар авыллары итекчеләренең аяк киемнәрен заказга эшләүләре мәгълүм. Алар, башлыча, милли аяк киемнәре (читек, күн кәвеш һ.б.) тегкәннәр. Бу кәсепчелек б-н Казан губернасының Мамадыш, Спас, Чистай, Тәтеш өязләре, Вятка губернасының Малмыж өязе Күкшел волосте һәм Оренбург губернасы авыллары кәсепчеләре танылa. Казан шәһәре А.к.т.к. үзәге булып санала. Бу кәсепчелек б-н аерым гаиләләр шөгыльләнгән. Казанда бу эш аерым операцияләргә бүлеп башкарыла: берәүләр өлге кисә, кемнәрдер аны тегә һ.б. Ярыммануфактура ысулында оештырылган мондый эшне шәһәр тирәсе авыл осталары да башкарган. Төп җитештерелгән товар: күн итек, читек, күн кәвеш, күн ката. 1890 елларда Казан губернасында бу кәсеп б-н шөгыльләнүче 2741 кеше теркәлгән. Ш.у.к. *Күн эшләү һөнәрчелеге*.

*Әд.:* Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (сер. XIX – нач. XX вв.). К., 1995.

# Ә

**ӘБДЕ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 38 *км* көнчыгыштарак, Нысы елгасы буенда. 2002 елда 300 кеше (руслар — 60%, татарлар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 16 йөзнең 2 нче яртысында татарлар нигез сала. Руслар Ә.гә 17 йөзнең 2 нче яртысында Комаровка авылыннан күчеп утыралар. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 17 йөз ахырларында Ә.дә православие приходы була. 1818 дә таштан Троица чиркәве төзелә (архит-ра истәлеге). 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; земство мәктәбе (1871 дә ачыла), 2 тимерчелек, 3 май язу йорты, казна шәраб кибете һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2446 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы Мамадыш өязе Әбде волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир заты; 1859 да — 817, 1897 дә — 1012, 1908 дә — 915, 1920 дә — 1029, 1926 да — 791, 1949 да — 413, 1958 дә — 436, 1970 тә — 511, 1979 да — 473, 1989 да — 352 кеше.

*Әд.:* Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1904.

**ӘБДЕРӘЗӘ́КОВ** Али Касыйм улы (21.12.1912, Сембер губ., Сөнгәләй өязе Зөябаш а. — 1989, Алтай крае, Целинный а.), Сов. Союзы Герое (22.2.1944), сержант (1943). Авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый (1935), зоотехник булып эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армиядә, 1942 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, сапёрлар батальоны отделениесе командиры (6 нчы армиянең 333 нче укчылар дивизиясе). Воронеж, Көньяк-Көнбатыш, 3 нче һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Кырымны, Польша, Украинаны азат итү, Берлинны алу сугышларында (1945) катнаша. 1943 нең 26 ноябрендә Каневск авылы тирәсендә Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Алтай краенда зоотехник булып эшли. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



А.К.Әбдерәзәков.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Алёшкин А.М. Сердцем на амбразуру. Иркутск, 1976; Боевая слава Алтая. Барнаул, 1978.

**ӘБДЕРӘЗӘ́КОВ** Габделхак Әсфән улы (4.9.1915, хәзерге Ульянов өлкәсенең, Иске Кулаткы р-ны Иске Кулаткы а. — 2.1.1984, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе. Мокша а.х. техникумын (1934), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (1953) тәмамлый. 1934–35 елларда Көнбатыш Себер краеның Чувын р-ны җир бүлегендә зоотехник. 1935 тән хезмәт ияләре депутатларының Куйбышев өлкәсе Иске Кулаткы р-н советында: 1935–38 дә өлкән зоотехник, 1938–39 да җир бүлеге мөдире, 1939–42 дә район башкарма ком-ты рәисе. 1942–44 тә ВКП(б)ның Иске Кулаткы райкомы 1 нче секретаре, 1944–46 да ВКП(б)ның Ульянов өлкә ком-тында совхозлар бүлеге мөдире, 1946–47 дә шунда ук терлекчелек буенча өлкә ком-ты секретаре урынбасары. 1947–48 дә ВКП(б) ҮКнең а.х. идарәсендә кадрлар бүлеге инспекторы, 1948–54 тә КПСС ҮКнең а.х. бүлегендә, 1954–59 да КПСС ҮКнең а.х. бүлегендә РСФСР буенча инструктор. 1959–66 да ТАССР МС рәисе, 1966–79 да РСФСР авыл хуҗалыгы министры урынбасары. ТАССР (1959–67), РСФСР (1959–63), СССР (1962–66) ЮСлары депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘБДЕРӘФЫЙ́КОВ** Измаил Габделкадыйр улы (15.4.1912, Казан — ?), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Краснодар май-маргарин һәм май сәнәгате ин-тының Казан филиалын тәмамлый (1935). 1935–36 елларда Казан май комб-ты җитәкчесе. 1936–39 да Казан кетгут җитештерү з-дында цех башлыгы, баш инженер урынбасары. 1941–46 да Пенза артиллерия-миномёт уч-щесенең сәяси бүлеге башлыгы урынбасары, 1946–53 тә КПСС-ның Татарстан өлкә ком-тында: җиңел сәнәгать бүлеге инструкторы (1946–49), мөдир урынбасары (1949–52), 1952–53 тә мөдир. 1953–59 да ТАССР азык-төлек сәнәгате министры. 1960 тан ТАССР ХХСның Сөт һәм ит сәнәгате идарәсендә (1963–64 тә Урта Идел ХХС) баш инженер. 1964–72 дә «Татарстан ит җитештерү» берләшмәсе ген. директоры.

*Е.Б.Долгов.*

**ӘБДЕРӘШИ́ТОВ** Альфрет Хәйрулла улы (18.7.1940, Казакъстан ССР, Чимкент ш.), сынчы. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2006). Алма-Ата сәнгать уч-щесен (1962), халык рәссамы Х.Нәүрузбаев остаханәсен тәмамлый. 1965 елдан Казанда. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1987). Портрет һәм монументаль скульптура жанрында эшли. Станлы скульптура әсәрләре — «Казакъстан чабаны» (карагач, 1962), «М.Җәлил һәм Н.Җиһанов»




А.Х.Әбдрәшитов. «Эрьзя». Төс бирелгән агач. 1973. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

(чүкелгән бакыр, 1981), «Мәрҗани» (гипс, 1999), «Г.Тукай» (бронза, мәрмәр, 2004), «Хәйдәр Бигичев» (гипс, 1999), «Туфан Миңнуллин» (бронза, 1999), «Салих Сәйдәшев» (агач, 2000), «Илдар Зарипов» (гипс, 2000). Монументаль әсәрләре — Сов. Союзы Геройлары М.Сыртланова (бетон, 1980, Казан), В.Н.Липатов (чүкелгән бакыр, 1981, Казан) һәйкәл-бюстлары, «Ана» һәйкәле һәм аның тирәсенә Сов. Союзы Геройлары бюстлары куелган мемориаль скульптура ансамбле (бетон, 1997–98, Мамадыш ш.), комп. Ф.Яруллин (2000, Мамадыш ш.), драматург Т.Гыйззәт (2004, Әгерже ш.), шагыйрь Һ.Такташ (2005, Сыркыды а., Мордва Респ-касы) һ.б. Ә.нең иҗат алымнарына төгәллек, образның үзенчәлеген җентекләп тасвирлау, портрет охшашлыгын төгәл чагылдыру хас. Мәскәүдә үткән бөтенсоюз («Без коммунизм төзибез», «Социализм сагында», 1986, 1988) һәм бөтенроссия («СССРның 60 еллыгына», «Фән һәм космос тынычлык сагында», 1983, 1989) күргәзмәләрендә, «Зур Идел» төбәкара күргәзмәләрендә (1970–90), Казанда (1960–90), Алма-Атада үткән



А.Х.Әбдрәшитов. «Мәрҗани». Төсле гипс. 1999.



А.Х. Ә б д р ә ш и т о в. «Н.Г.Җиһанов портреты». Бронза, кою. 1980. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

(1960) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәсе 2000 дә Казанда уза (улы Адель Әбдрәшитов б-н берлектә). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Казакъстан Респ-касы Дәүләт сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Ш а һ и н у р Ш.С. Тамчыда чагылган кояш // Казан. 1997. № 1–2; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. К., 1984; Альфрет Абдрашитов. Скульптура: Каталог персональной выставки. К., 1991; Альфрет Абдрашитов, Адель Абдрашитов. Скульптура: Каталог выставки. К., 2000. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ӘБДЕРӘШИ́ТОВ** Вадим Йосыф улы (19.1.1945, Украина ССР, Харьков ш.), кинорежиссёр. РФнең халык артисты (1992). Мәскәү физ.-техника ин-тын (1967) һәм Бөтенсоюз кинематография ин-тын (1974) тәмамлый, М.И.Ромм һәм Л.А.Кулиджанов остаханәсендә укый. 1974 елдан «Мосфильм» киностудиясендә эшли. 1974 тә Г.И.Горин хикәясе нигезендә «Потаповны туктатыгыз» («Остановите Потапова») дигән беренче фильмын (диплом эше) төшерә, ул вакытлы матбугатта уңай бәяләнә. «Яклау өчен сүз» («Слово для защиты», 1976), «Борылыш» («Поворот», 1978), «Төлкеләр аулау» («Охота на лис», 1980), «Поезд туктады» («Остановился поезд», 1982), «Планеталар парады» («Парад планет», 1984), «Плюмбум яки Хәтәр уен» («Плюмбум или Опасная игра», 1986), «Хезмәтче» («Слуга», 1988), «Армавир» (1991), «Пассажир өчен пьеса» («Пьеса для пассажира», 1995), «Биюче вакыты» («Время танцора», 1997) фильмнарының режиссёры. Барлык фильмнары да кинодраматург А.Миндадзе б-н хезмәттәшлектә төшерелә. Иҗатының төп темасы — җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләр процессында кешенең әхлакый яктан формалашуы. Ә. фильмнары на документаль сюжет б-н куркыныч социаль күренешләрнең, чын тормыштагы вакыйгаларның мәҗаралы элементлар б-н үрелеп баруы, социаль-психол. анализ һәм ныклы гражданлык позициясе хас. Ә. фильмнары күп кенә халыкара һәм ил күләмендәге фестивальләрдә күрсәтелә. Казанда үткәрелгән мөселман киносы фестивальләрендә жюри әгъзасы буларак катнаша. РСФСР, СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1984, 1991).

*Әд.:* С а в и ц к и й Н. Разговор начистоту. М., 1987; А с т а ф ь е в Ю. Послесловие // Искусство кино. 1998. № 5 (автордаш); Кино: Энцикл. словарь. М., 1986.

**ӘБДЕРӘШИ́ТОВ** Рамзес Тәлгать улы (5.9.1940, Мәскәү), җитештерүне автоматлаштыру гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1982), проф. (1983). РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998). 1962 елда Оренбург а.х. ин-тының механикалаштыру ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1974–87 дә электротехника каф. мөдире. Бер үк вакытта Оренбург политехника ин-тында: ректор (1983–87), 1989 дан автоматика һәм җитештерүне автоматлаштыру каф. мөдире. 1997 дән Инновацияләр ин-ты директоры, 2000 нән инновацион проектлар б-н идарә итү каф. мөдире. Хезмәтләре ясалма интеллектны системалы анализлауга һәм гамәли мәсьәләләргә, идарә системаларын аналитик конструкцияләүгә карый. ВДНХның алтын медале б-н бүләкләнә. Уйлап табуларга 18 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Формально-эвристический метод решения транспортных задач // Актуальные вопр. механизации с.-х. пр-ва. А.-А., 1979; Аналитическое конструирование регуляторов и его роль в планировании работ по автоматизации с.-х. машин // Исследования и разраб. в обл. автоматизации с.-х. техники: Тр. Всесоюз. науч.-исслед. ин-та с.-х. машиностроения. 1980. Вып. 100.

*Әд.:* Кто есть кто: Справ. Оренбург, 1998.

**ӘБДЕРӘШИ́ТОВ** Рамис Салих улы (4.11.1934, Саратов өлкәсе Хвалынск ш. — 17.11.1988, Мәскәү), мед. хезмәте генерал-майоры (1980). 1954 елда Казан хәрби авиация-техника уч-щесен һәм 1964 тә С.М.Киров исем. Хәрби медицина академиясен (Ленинград) тәмамлый. 1964–68 елларда — санитария батальоны (Чиләбе өлкәсе Чибәркүл ш.), 1970–75, 1982–87 дә — дивизия, 1975–79 да — Себер хәрби округы (Новосибирск ш.), 1979–82 дә Балтыйк буе хәрби округы (Рига) мед. хезмәте башлыгы. 1987 дән СССР Оборона министрлыгының Үзәк хәрби медицина идарәсе башлыгы урынбасары. Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘБДИ́ЕВ** Рифгать Фәез улы (22.12.1926, Башкортстан АССРның Кырмыскалы р-ны Бозаяз а.), философ, кибернетика белгече, филос. фән. д-ры (1996). Уфа авиация ин-тын тәмамлый (1948). 1948–52 елларда «Уралмаш» з-дында (Свердловск ш.) әйдәп баручы инженер-конструктор. 1955–77 дә СССР Оборона министрлыгының Үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсе Болычево ш.) фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм уйлап табу эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, космик аппаратларны очыруда, ш.и. Совет-Америка «Союз-Аполлон» программасын гамәлгә ашыруда катнаша. 1978–82 дә СССР Дәүләт стандарты каршындагы ВНИИМАШ фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (Мәскәү). 1983–96 да Мәскәү урманчылык техникасы ин-тында укыта. 1995 тән РФ Тышкы эшләр министрлыгының Дипломатия академиясендә. Хезмәтләре катлаулы процесслар б-н идарә итүне камилләштерү, мәгълүмати цивилизация фәлсәфәсенә карый. Ә. тарафыннан 100 гә якын прибор һәм система эшләнә һәм гамәлгә кертелә, 24 ачышына авторлык таныклыгы ала.

Х е з м.: Философия информационной цивилизации. М., 1994.

**ӘБДРИ́ЕВ** Әхмәтгәрәй Шакирҗан улы (4.10.1923, Буа кантоны Иске Шәйморза а. — 4.12.2004, шунда ук), Соц. Хезмәт Герое (1971). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1944–50 елларда туган авылында колхозчы, партоешма секретаре, колхоз рәисе булып эшли; 1950–55 тә партия эшендә. 1955–88 дә Чүпрәле р-ны XXII партсъезд исем. к-з рәисе. Аның җитәкчелегендә колхоз а.х. культураларыннан югары уңыш алуга (бөртеклеләрдән гектарыннан 20 *ц* дан артык, шикәр чөгендереннән — 250 *ц*) һәм терлекчелектә җитештерүчәнлекнең артуына ирешә, күчле матди-техник база, социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла. Колхозчыларның 3 нче һәм 4 нче Бөтенсоюз съезды делегаты, колхозлар берләшмәсе әгъзасы (1950–85), 1959–63 елларда ТАССР ЮС депутаты. Өч Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а н б и к о в а А. Абдреев Ахметгарей Шакирзянович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ӘБЕЛГАЗЫ́Й БАҺАДУ́Р ХАН** (1603, Үргәнеч — 1664, шунда ук), Хива дәүләте ханы (1643–63), тарихчы. Арал диңгезе төбәгендәге үзбәкләр б-н үзара сугыш-бәрелешләрдән соң хан дип игълан ителә. Озак еллар дәвамында күрше төрекмән, калмык кабиләләренә һәм Бохара ханлыгына каршы мөстәкыйльлек өчен сугышлар алып бара. 1663 елда тәхеткә улы Ануш Мөхәммәдне утырта. 2 тарихи хезмәт авторы: «Угызлар шәҗәрәсе» («Шәҗәрә-и гузия», 1659–61) һәм «Төркиләр шәҗәрәсе» («Шәҗәрә-и төрк», 1663–64). Бу хезмәтләрдә Евразия кыйтгасында 13–17 йөзләрдә яшәгән төрки халыкларның тарихы, кайбер кабиләләрнең килеп чыгышы, риваятьләре, яшәү урыны тасвирлана.

Х е з м.: Родословная туркмен / Пер. А.Г.Туманского. Асхабад, 1897; Родословное древо тюрков / Пер. и предисл. Г.С.Саблукова // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. К., 1905–06. Т. 21, вып. 5–6.

*Әд.:* К о н о н о в А.Н. «Родословная туркмен». Сочинение Абу-л-Гази, хана хивинского. М.–Л., 1958.

**ӘБЕЛХА́Н** Хәлил (Әбелханов Хәлиулла) Габделвәли улы (1887, Сембер губ., хәзерге Чуаш Респ-касы, Батыр р-ны Шыгырдан а. — 6.1.1919, Казан), язучы, журналист, педагог. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен, 1909 елда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. 1910–12 елларда хәзерге Башкортстан Респ-касының Кыйгы р-ны Идрис авылы рус-татар мәктәбендә, 1912–14 тә Казан губернасының Тәтеш өязе Ындырчы авылында балалар укыта. 1912 дән «Шура», «Мәктәп», «Мәгариф» ж-лларында, «Йолдыз», «Кояш», «Корылтай» г-таларында актив язышa. Татар мәктәпләрендә җәдитчә укыту ысулын пропагандалаучы. «Ак юл» ж-лында балалар өчен хайваннар, җәнлекләр турындагы хикәяләрен бастыра (соңыннан алар класстан тыш

уку китабы буларак аерым җыентыкта нәшер ителә). Җәдитчелек хәрәкәтенең аерым җитешсез якларын тәнкыйтьләгән «Ысулы җәдиткә каршы беренче адым» (1911) исемле китап авторы. 1917 дән соң Казан губернасының мәгариф оешмаларында эшли.

*Әд.:* Хәлил Әбелхановның вафаты: Некролог // Эш. 1919, 8 гыйн.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**ӘБЕЛХА́НОВ** Садыйк Фәхретдин улы (15.3.1915, хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең, Кызыл Октябрь р-ны Семёновка а. — 27.9.1943, Днепропетровск өлкәсенең Солянск р-ны Войсковый пос.), Сов. Союзы Герое (19.3.1944, вафатыннан соң), сержант (1943). 1938 елдан Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында катнаша (1939–40). 1942 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1248 нче танкка каршы истребительләр полкында (12 нче армия) туп төзәүче. Көньяк-Көнбатыш фронты гаскәрләре составында Сталинград сугышында катнаша (1942–43). 1943 нең сентябрендә Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә, уңъяк ярда плацдарм өчен сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Туган авылында мәктәп һәм урам Ә. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Тюльников Л.К. Герои Советского Союза — горьковчане. Г., 1981; За Отчизну, свободу и честь. Г., 1984. Кн. 6.

**ӘБЕЛХА́НОВ** Эдуард Кыям улы (11.9.1938, Новосибирск ш. — 11.9.2005, Казан), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1963). 1963–98 дә «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү үзәгендә: инженер, әйдәп баручы инженер, бүлек башлыгы, 1987 дән баш инженер һәм бер үк вакытта (1995 тән) директор урынбасары. 1998–2001 дә Казан электроконструкцияләр з-ды директоры урынбасары. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге радиолокация өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: О взаимодействии энергетических временных и пространственных характеристик прямых и отражённых сигналов в САЗО // Вопр. специальной радиоэлектроники: Науч.-техн. сб. М., 1979. Вып. 4 (автордаш); Классификация методов защиты отражённых сигналов // Вопросы специальной радиоэлектроники: Науч.-техн. сб. М., 1980. Вып. 8 (автордаш.).

**ӘБЕЛХӘЕ́Р** (псевдоним булуы да ихтимал) (19 йөзнең 2 нче яртысы), шагыйрь. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. «Һәза китаб-е мәснәви» (Казан, 1882) исемле шигырьләр (мәснәвиләр) җыентыгы авторы. Ике тезмә әсәре Акмулла шигырьләре б-н бергә Троицк шәһәре имамы һәм мөдәррисе Мөхәммәдшәриф Шиһабетдин угылы әл-Карасуви 1872 елда күчереп язган кулъязма җыентыкка урнаштырылган (табылуы 1981 дә). *Мәснәви* калыбында язылган 104 юллы беренче тезмә: «Керүбән ялгызым ошбу базарә...» — дип, икенчесе (икеюллык шигырь): «Аһ, бу юлның озакындан...» — дип башлана. Ә.нең шигырьләре ватандарлык хисләре һәм иҗтимагый уй-фикерләр б-н сугарылган, шигъри алымнарында һәм бигрәк тә образлар, характерлар бирелешендә Акмулла һәм Һибәтулла Салихов шигырьләренең көчле тәэсире сизелә.

Әсәр.: Һәза китаб-е мәснәви. К., 1882.

*Әд.:* Госманов М.Г. Акмулла мирасын өйрәнүгә яңа материаллар // Поэт-просветитель Акмулла. К., 1983; Татар әдәбияты тарихы. 2 т. К., 1985.


*Р.Ә.Әхмәтов.*



Ә.Ш.Әбдриев.



С.Ф.Әбелханов.



Х.Г.Әбҗәлилов.

**ӘБЕЛХӘЕ́Р ХАН** (1412 тирәсе — 1469, Сыгнак ш.), татар ханы. Җүчи нәселеннән, Дәүләтшәех угланның улы. 1420 елларда Күк Урданың уң канаты идарәчесе итеп сайлана, Себер ханлыгын нигезләүче Хаҗимөхәммәд ханга буйсына. *Баракъ хан* вафатыннан соң (1428/29), Шәйбан хан нәселеннән булган Җумадык б-н бергәләп, Күк Урданың сул канатын үзенә буйсындырырга ниятләп, Хаҗимөхәммәд ханга каршы сугыш башлый. Җатар — Җалкын тирәләрендәге бәрелештә җиңелә. 1430 елда Хаҗимөхәммәд үз көчләре б-н Арал тарафына киткәч, кыпчак-нугай морзалары баш күтәрә, ханлык башкаласы Чимга Тураны яулап ала, Әбелхәерне хан дип, мангыт (нугай) морзасы Ваккасны бәкләр бәге дип игълан итәләр. Шул ук елда Ә.х. Хаҗимөхәммәд көчләрен җиңүгә ирешә, ханны әсир итә һәм үтертә. Тиздән Хаҗимөхәммәд уллары Әхмәд б-н Мәхмүд, көч туплап, Ә.х.ны Себер ханлыгыннан куалар. Ә.х. 1431 дә Харәземгә басып керә, хәзерге Казакъстанның төньягындагы һәм үзәк өлешендәге ыруг-кабиләләрне бергә туплап, Күк Урдага буйсынмаган күчмә үзбәкләр дәүләтен нигезли. 1440–43 тә Хаҗитархан идарәчесе *Мостафага* каршы сугыша, аны тәхетеннән кууга ирешә. Күк Урданың сул канатында өстенлеккә ирешү өчен Аксак Тимер варислары б-н көрәшә, 1446 да Түбән Сырдәрья буендагы Җәнд, Сәүрән, Сыгнак шәһәрләрен яулап ала. Сыгнакны күчмә үзбәкләр дәүләте башкаласы итә. 1450 елларда үз хакимиятен ныгыту нияте б-н Ваккасны үтертә. Мангыт-нугайлар һ.б. аксөякләр моңа канәгатьсезлек белдерәләр. Ә.х. дәүләтенең авыр хәлдә калуын белгән ойратлар (калмыклар) гаскәре Үз-Тимер тайша җитәкчелегендә 1454 тә илгә басып керә, Сыгнак янәшәсендәге Күк Кушанах авылы тирәсендәге зур бәрелештә хан көчләрен җиңүгә ирешә. Дәүләтне көчсезләндергән солых килешүе төзелә. Гәрәй җитәкчелегендә мангытлар гаскәре һәм Җанибәк җитәкчелегендә казакъ урдалары аерылып чыга. 1468 дә Ә.х., көч туплап, Магулстанга яуга чыга, юлда вафат була. Сыгнакта җирләнә. Ә.х.га буйсынган урдалар шуннан соң Арал диңгезенең көнчыгыш тарафында күчмә тормыш алып баралар, вакыт-вакыт Урта Азия өлкәләренә һөҗүм иткәлиләр.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Бартольд В.В. Абулхайр-хан // Сочинения. М., 1964. Т. 2.

*И.Л.Измайлов.*

**ӘБЕРЧЕ́Н** (Columba palumbus), күгәрчен кошлар семьялыгыннан. Европа, Азия һәм Төньяк-Көнбатыш Африкада аланлы якты урманнарда яши. Күчмә кош. ТР терр-ясендә апрель аеннан күренә. Гәүдәсенең озынлыгы 40 *см* га кадәр, авырлыгы 450 *г* га җитә. Каурыйлары күгелҗем төстә. Томшык төбе кызыл. Муенының як-ягында 2 ак тап, канатларында ак сызык бар. Оясын биек агачның ян ботакларына һәм куәсәсе янына ясый. 2 ак йомырка сала. Үсемлек орлыклары, кайвакыт җиләк, яфрак һәм бөре, әкәм-төкәм һ.б. вак умырткасызлар б-н туена. Спорт сунарчылыгы объекты. ТРда Ә. саны кими.

**ӘБҖӘЛИ́ЛОВ** Хәлил Гали улы (17.9.1896, Оренбург губ., Шарлык өязе Мостафа а. — 18.3.1963, Казан), драма актёры. ТАССР, РСФСР, СССРның халык артисты (1944, 1950, 1957). Хезмәт эшчәнлеген 1906 елда башлый. 1916 да Оренбургтагы «*Ширкәт*» татар театр труппасына керә. 1918–20 дә Оренбург шәһәрендәге «Көнчыгыш театры»н оештыручыларның берсе, анда актёр, режиссёр. 1920–22 дә Бохара һәм Хива шәһәрләрендә үзбәк театрларын оештыруда катнаша, 1923–24 тә Әстерхан театрында эшли. 1924–28 дә Бохара киностудиясендә «Үлем манарасы» (атаман Курбаши), «Рават шакаллары» (Абдул Нәби бай), «Мәчет гөмбәзләре астында», «Өсте ябулы фургон», «Махау авырулылар», «Икенче хатын» һ.б. фильмнарда төшә. 1928 дә Казанга Татар акад. театрына чакырыла. Татар сәхнәсенең әйдәп баручы осталары янында ул яңа система буенча эшләргә өйрәнә, рольнең психол. тирәнлеген һәм тышкы кыяфәттәге аерым детальләрнең төгәллеген үзләштерә. Актёр беренче рольләреннән үк зур уңышка ирешә — Боцман («Разлом», Б.Лавренёв, 1928), Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи, 1929), Карт артельщик («Козгыннар оясында», Ш.Камал, 1929). Эчке үзгәрешләрне бирү техникасын эшләгәндә Ә. үз героена хас һәр гамәлнең логикасын өйрәнә, көчле тәэсир итү чараларын эзли, бигрәк тә тискәре характерлы геройларны гәүдәләндергәндә гипербола һәм ачык буффонада алымнарын киң куллана. Аның башкаруында Сиражетдин роле гротесклы фигурага әверелә («Банкрот», Г.Камал, 1933), музыкант Миллер роле чын трагизм б-н уйнала («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер, 1934). Алдагы эшләрендә актёр төп игътибарын образның эчке тормышын тәфсилләп эшләүгә юнәлтә. Профессор Мамлок (шул исем. әсәр, Ф.Вольф, 1935), Яков Бардин («Дошманнар», М.Горький, 1936) рольләре ышандырырлык итеп башкарыла.







Х.Г. Ә б җ ә л и л о в: 1. Хуҗа Насретдин («Хуҗа Насретдин», Н. Исәнбәт); 2. Биктимер («Ташкыннар», Т. Гыйззәт); 3. Лир («Король Лир», У. Шекспир) рольләрендә.

Бу чорда Ә. авыл крәстияне Биктимер образын («Ташкыннар», Т.Гыйззәт, 1937) уйнап зур уңышка ирешә. Бу образ аша халыкның үзаңы үсүе, рухи яңарышы процесслары һәм геройның эчке дөньясының үзгәрүе күрсәтелә. 1939 да Ә.ка ТАССРның атказ. артисты исеме бирелә. Ул иҗат иткән Хуҗа Насретдин образы (шул исем. спектакль, Н.Исәнбәт, 1940) заманында зур вакыйга буларак кабул ителә, бу роль өчен Ә. РСФСРның атказ. артисты исеменә лаек була (1940). Аның башкаруында Хуҗа Насретдин зирәклек һәм оптимизм, тапкырлык, халык рухының җиңелмәслеге үрнәге булып гәүдәләнә. Ә. башкарган Лир образы («Король Лир», У.Шекспир, 1944) үзенә бер төрле үзенчәлеккә ия. Король образы өстендә эшләгәндә, фәлсәфә һәм лириканы бергә кушып, аның тормышны танып белү процессындагы газаплануларын, тиз ышанучан атаның яраткан кызлары тарафыннан алдануын тану фаҗигасен актёр гаять оста чагылдыра. Насретдин, Биктимер, Лир рольләрендә Ә. катнашкан спектакльләр 1957 дә Мәскәүдә үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында күрсәтелә. Актёрның Мисбах ролен («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин, 1958) башкаруы да бик югары бәяләнә. Татар сәхнә сәнгатенең иң зур осталарыннан берсе буларак, Ә.ның үз иҗаты күп еллар буе театрның үсеш дәрәҗәсен билгели. Актёр иҗат иткән һәр образ тирән фикер, социаль характеристиканың төгәллеге, гражданлык пафосы б-н аерылып тора. Комик гротеск чараларына һәм күтәренке трагизмга бертигез дәрәҗәдә ия булган хәлдә, К.С.Станиславский системасы буенча психол. анализлау осталыгын һәм милли башкару культурасы традицияләрен иҗади һәм табигый рәвештә файдалана. Ә. Казан һәм республиканың иҗтимагый һәм мәдәни тормышында актив катнаша: 1941–53 елларда Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге рәисе, Бөтендөнья Тынычлык советының Совет комитеты әгъзасы. 1947–59 да ТАССР ЮС депутаты. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1958). Казанның Горький урамындагы 1940 елдан Ә. яшәгән 17/9 йортка мемориаль такта куела, шәһәрнең бер урамына аның исеме бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Башка рольләре: Акбердин («Кандыр буе», К.Тинчурин), Чадов («Тормыш чакыра», В.Билль-Белоцерковский), Яго («Отелло», У.Шекспир), Клоун («Салют, Испания!», А.Афиногенов), Шмага, Кучумов («Гаепсездән гаеплеләр», «Котырган акчалар», А.Островский), Кәрим бай («Бәхетсез егет», Г.Камал), Гыйльманов («Миңлекамал», М.Әмир), Захар Бардин («Дошманнар», М.Горький).

*Әд.:* К р ы ж и ц к и й Г. Корифей татарского театра // Театр. 1959. № 4; Народные артисты. К., 1980; К у м ы с н и к о в Х.Л. Халил Абжалилов. К., 1984. *Х.Л.Кумысников.*

**«ӘБИЛӘ́Р ЧУАГЫ́»** (сөйләм телендә «чуак» — явымсыз, аяз һава), көзнең бер мизгеле; җылы һава агымнарының вакытлыча «кире кайтуы» сәбәпле, берничә көннән алып 2–3 атнага кадәр сузылган кояшлы, җылы, коры һәм тыныч һава торышы. ТР терр-ясендә «Ә.ч.» һәр елны диярлек беренче кыраулардан соң, сентябрьнең икенче, кайвакыт октябрьнең беренче яртысында күзәтелә. Уртача датасы — 14–21 сентябрь. Ул җылы һава күчешен тудыручы тотрыклы көньяк антициклоннары б-н бәйле. Көндез һава темп-расы сентябрьдә 20–25°С, октябрь башында 15–20°С ка кадәр күтәрелергә мөмкин. Кайбер елларда «Ә.ч.» азагында җимеш агачлары кабат чәчәк ата.

**ӘБЛӘ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 20 *км* төньяктарак, Касыйм елгасы буенда. 2000 елда 71 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, он тарту, кап сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.дә су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 211,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 11 ир заты; 1859 да — 91, 1897 дә — 158, 1908 дә — 217, 1920 дә — 200, 1926 да — 243, 1938 дә — 265, 1949 да — 190, 1958 дә — 183, 1970 тә — 153, 1989 да — 83 кеше.

*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ӘБЛӘ́ЗОВ** Камил Алим улы (31.8.1954, Волгоград өлкәсе, Камышлы р-ны Дворянское а.), эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе, иганәче, тарих фән. канд. (2004), ТРның атказ. икътисадчысы (2003). 1987 елда «Яз» кооперация берләшмәсен (Саратов ш.) оештыра, аның рәисе вазифаларын башкара. 1991 дән «Нарат» АҖ президенты. Бер үк вакытта 1997 дән Бөтендөнья Татар. конгрессы башкарма ком-ты әгъзасы, 2002 дән рәис урынбасары һәм Татар. федераль милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары; ТРның Саратов, Пенза һәм Волгоград өлкәләрендәге сәүдә-икъдисад вәкиллеге рәисе, 2005 тән инвестицияләр һәм милли мәсьәләләр буенча Саратов губернаторы киңәшчесе. Татар иҗтимагый сәяси-агарту оешмалары советы әгъзасы буларак, шул төбәктә яшәүче татар халкының мәгърифәтен, мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертә, аларга матди яктан ярдәм итеп килә. Саратов шәһәрендә һәм шул өлкәнең Биктимер, Кечебәт, Татар Такае һ.б. авылларында мәчетләр төзелешенә акчалата булыша. 1992 дә Ә.ның хәйриясенә Саратовта татар гимназиясе ачыла һәм эшләвен дәвам итә. Хезмәтләре 20 йөзнең беренче 30 еллыгында Татарстан авылларындагы дөньяви, дини мәктәпләрнең эшчәнлеген һәм яңа совет уку йортларына укытучылар әзерләү мәсьәләләрен өйрәнүгә карый. Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Деятельность учителей по повышению образовательного и культурного уровня крестьянства Татарстана (1920–1929 гг.). К., 2004; Мусульманское религиозное образование в деревне Татарстана (1917–1929 гг.). К., 2004 (автордаш); Система народного просвещения в деревне Татарстана в 1920-е гг. К., 2004.

**ӘБЛӘ́ЗОВ** Рәүф Әхмәт улы (19.6.1935, Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Камка а.), конструктор, мәгълүмат эшкәртү системалары гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1985), проф. (1988). 1962 елда Горький политехника ин-тын тәмамлаганнан соң, Черкассы шәһәрендә фәнни-тикшеренү һәм пед. эштә: 1966 дан «Сокол» Үзәк КБсында, 1975 тән баш конструктор, 1986 дан «Фотоприбор» з-ды директоры. 1988 дән Инженерлык-технол. ин-тында машиналар төзү технологиясе каф. мөдире, 1992 дән Бизнес б-н идарә итү ин-ты ректоры (хәзер Урта Европа икътисад һәм менеджмент ун-ты). Хезмәтләре фотомәгълүматны тиз эшкәртүгә карый. Космик аппаратлар өчен уникаль приборлар төзи; оптик-механик системалар коруның теоретик принципларын нигезли. Уйлап табуга 25 таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1978). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кто есть кто на Украине. Киев, 1997.

**ӘБЛӘ́ЗОВ** Фәхретдин Рәхмәтгали улы (1913, Әстерхан губ., Енотаев өязе Грачи а. — 1958, шунда ук), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), өлкән сержант (1945). 1935–38 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә. 1942 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронт-



Ф.Р.Әбләзов.

ларында, 904 нче укчылар полкы отделениесе командиры (59 нчы армиянең 245 нче укчылар дивизиясе). Ленинград һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Ленинград (1944), Карелия муентыгындагы сугышларда, Польша һәм Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1945 нең 30 гыйнварында Котовице (Польша) шәһәре тирәсендә Одер елгасын кичкәндә барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң туган авылында эшли. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; В созвездии славы. Волгоград, 1976; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 3.

**ӘБЛИ́ЕВ** Мөхәммәт Шәриф улы (15.7.1900, хәзерге Кама Тамагы р-ны Даныш а. — 1941), прозаик, драматург. 1922 елдан Кызыл Армия сафларында. 1926 да Казанда берләштерелгән татар-башкорт хәрби мәктәбен, 1928 дә Мәскәүдә хәрби-сәяси курсларны тәмамлый. Урта Азиядә 1932 гә кадәр политрук, соңыннан рота командиры. 1936 да Ленинград хәрби-сәяси академиясен тәмамлаганнан соң, Казандагы укчы полкта инструктор, соңыннан хәрби комиссар. 1939–40 та совет-фин сугышында катнаша. Укчы дивизиянең сәяси бүлеге җитәкчесе сыйфатында Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән фронтның алгы сызыгында сугыша, күп тә үтми, һәлак була. Беренче әсәрләре 1920 еллар башында басыла. Ә. — «Минем дустым сугышта» (1922) хикәясе, «Итекче кызы» (1928), «Ком улы» (1929) повестьлары, «Ике туй» (1925), «Лейтенант» (1940) пьесалары авторы. Ә.не драматург буларак танытkан әсәр — «Шәмсекамәр» драмасы (1936). Ул Татар акад. театрында 1938 дә, кабат 1998 дә куела, Татарстанның башка театрларында да уйнала. Пьесада рев-циягә кадәрге татар авылы тормышы, татар хатынының фаҗигале язмышы тасвирлана.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Гиниятуллина А.К. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**ӘБРА́РОВ** Вагыйз Нургали улы (3.9.1943, Ульянов өлкәсенең Инза р-ны Шлемасс а.), электрон техника гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1990), проф. (1994). 1968 елда Ульянов политехника ин-тын тәмамлаганнан соң, Ульянов механика з-дында эшли, аннары Мәскәү радиотехника, электроника һәм автоматика ин-тында өлкән инженер. 1981 дән Мәскәү приборлар төзү һәм мәгълүмат ун-тында. Хезмәтләре микродулкын диапазонында махсус техника, автоматикада электроадгезияле универсаль җайланмалар төзүгә; электрон техника эшләнмәләрен җитештерүдә югары экологик чиста технологияләр эшләүгә карый. СССР ВДНХның алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Бесприклеечная технология и энергоматериалосберегающие устройства автоматизированных линий. М., 1991; Электроадгезионные захваты и закрепляющие устройства гибких производственных систем. М., 1991; Автоматизация технологии производства электронной техники. М., 1992.

**ӘБРА́РОВ** Раил Нургали улы (9.3.1937, Ульянов өлкәсенең Инза р-ны Шлемасс а.), генерал-майор (1978). Ульянов танк уч-щесен (1960), Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Хәрби бронетанк гаскәрләре академиясен (1971, Мәскәү) тәмамлый. 1975 елдан Белоруссия хәрби округының танк берләшмәсе командиры урынбасары. 1976 дан мотоукчылар берләшмәсе командиры, 1980 нән Ерак Көнчыгыш хәрби округы армиясе берләшмәсе командиры урынбасары. 1984–94 елларда М.В.Фрунзе исем. Хәрби академиянең (Мәскәү) каф. башлыгы урынбасары, ф-т башлыгы. Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә «СССР Хәрби Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ӘБУ БӘКЕ́Р** Әхмәт угылы (12 йөз), бакырчы, Болгарда металлны нәфис эшкәртү остасы. Аның исеме Биләр шәһәрлеге археол. казылмаларында табылган бронза йозакка 1146–47 елларда чокып язылган. Йозак сигез



Әбу Бәкер Әхмәт угылы. Бронза йозак. 1146–47 еллар. ТР Милли музее.

кырлы призма формасында, стильләштерелгән ат (эт) сурәте рәвешендә ясалган, үсемлексыман рәсем һәм «Әбү Бәкер Әхмәт углы эше. Моның иясенә бетмәс-төкәнмәс дан, вә иминлектә танылу, вә олуг бәхет, вә бөеклек, вә муллык», — дигән гарәп язуы б-н уемлап бизәкләнгән. Моңа охшаш йозаклар казу эшләре вакытында Болгар һәм Биләр шәһәрлекләрендә, ш.у. Херсонес шәһәрлегенең 9–10 йөзләргә караган хәзинәләре арасында табылган.

*Әд.:* Малов Р. Замок из Билярска с арабской надписью // Зап. коллегии востоковедов при Арабском музее. Л., 1926; Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951.

**ӘБУ́ ХӘНИФӘ́** (أبو حنيفة) ән-Ногман бине Сабит (699, Гыйрак, Куфә ш. — 767, шунда ук), дин галиме, Хәнәфиләр мәзһәбенә нигез салучы. Гыйрак дин галиме Хаммад бине Али Сөләйман шәкерте. Куфә һәм Басра шәһәрләренең абруйлы факыйһләреннән саналган. Ә.Х.дән ислам дине гыйльменең язма традициясе башлана, ислам дине тәгълиматына кагылышлы беренче хезмәт аныкы дип санала. Ә.Х.нең вәгазьләре, әйткән фикерләре һәм сорауларга биргән җаваплары шәкертләре тарафыннан теркәп барылган. Соңрак бу язмалар китаплар итеп туплана, аларның авторы булып Ә.Х. санала. Ә.Х.неке дип саналган иң билгеле әсәрләр — дин кагыйдәләре бәян ителгән «Әл-Фикъһ әл-Әкбәр» (к. *Гакыйдә*) һәм Ә.Х. тарафыннан үз тәгълиматын нигезләү өчен кулланылган хәдисләр тупланган җыентык «Әл-Мөснад». Әлеге хезмәтләргә һәм Ә.Х. фикерләренә таянып, шәкертләре аның исеме б-н аталган мәзһәб төзиләр.

Х е з м.: Аль-Фикх аль-Акбар. Величайшее знание. К., 1999; Трактаты. М., 2001.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.



Г.Д. Әбүбәкеров.



М.Ә. Әбүбәкеров.


**ӘБУ́-Л ГАЛӘ́ ХӘМИ́Д БИНЕ́ ИДРИ́С әл-БОЛГАРИ́** (? — 1107 дән соң), Болгар шәһәре казые. Мөселманнар арасында дин белгече буларак таныла. Шәкерте *Сөләйман бине Дауд әс-Саксини Сувари* аны «барлык имамнарның шәехе» дип атый. Дингә, фәлсәфәгә караган хезмәтләренең аерым өлешләре генә сакланган.

**ӘБҮБӘКЕ́Р бине ИБРАҺИ́М әл-КАЗАНИ́** (18 йөз), язучы һәм дин эшлеклесе. Вятка губернасының Малмыж өязе Яңгул авылы мәдрәсәсендә Мәсгуд бине Мөхәммәдтән белем ала. Казанның Беренче җәмигъ мәчете имам-хатибы. Оренбург мөселман Диния нәзарәте төзелгәч, мөфти М.Хөсәенов тәкъдиме б-н казый итеп билгеләнә һәм бу урынга берничә тапкыр сайлана. Идел буе һәм Урал төбәге мөселманнары арасында зур абруй казана. «Тәкъсимнамә» («Кисәкләргә бүлү турында әсәр») китабы (1781) һәм Казан төбәге тарихына кагылышлы хезмәтләр авторы.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. Т. 1; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**ӘБҮБӘКЕ́РОВ** Гәрәйша Дәүләтша улы (24.8.1927, Норлат р-ны Акҗегет а.), шахтёр, Соц. Хезмәт Герое (1971). Тау-металлургия техникумын тәмамлый (1974, Свердловск). 1956–74 елларда Свердлов өлкәсе Дегтярск шәһәрендә бакыр рудасы чыгару шахтасында эшли, шахтёрлар бригадасы җитәкчесе (1958 дән). 1975–93 тә профсоюз эшендә. Герой исеме төсле металлургия җитештерү өлкәсендә ирешкән югары уңышлары өчен бирелә. Япония б-н барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша (1945). Ленин, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘБҮБӘКЕ́РОВ** Мәннаф Әбүбәкер улы (26.8.1926, Казакъстан ССР, Зәйсан ш. — 19.4.1945, Германия, Франкфурт-Одер ш.), Дан орденының тулы кавалеры (25.8.1944, 17.2.1945, 15.5.1946), өлкән сержант. 1943 ел-





Ф.Х.Әбүбәкеров. Р.Н.Әбүлханов.

дан Кызыл Армиядә. 1943 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 375 нче танкка каршы көрәшүче аерым артиллерия дивизион тупчысы (69 нчы армиянең 312 нче укчы дивизиясе). 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре б-н Белоруссия һәм Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1944 нең 20 августында Пулавы шәһәре (Польша) өчен барган сугышта яралы хәлендә дошманның пулемёт расчетын, сугыш кирәк-яраклары складын шартлата; 1945 нең 16 гыйнварында Ново-Воля торак пункты (Польша) янында барган бәрелештә яралы хәлендә дошманның 2 пулемёт ноктасын юк итә; 1945 нең 17 апрелендә Лебус шәһәре (Германия) өчен барган сугышта дошманның орудиесен һәм 4 пулемётын сафтан чыгара, күзәтү пунктын җимереп, батырлык күрсәтә.

*Әд.:* В а к у р о в И.Д. Солдатская слава. М., 1971. Кн. 3; Б е л а н П.С., П о т а п о в А.В., Ч е с т н о в С.И. Доблесть солдатская. А.-А., 1974; И с а к о в И.Н. Звёзды славы Киргизии. Фрунзе, 1975; Их подвиг будет жить в веках. Фрунзе, 1985; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ӘБҮБӘКЕ́РОВ** Наил Кадыйр улы (30.5.1919, Төркестан АССР, хәзерге Үзбәкстан Респ-касы Коканд ш. — 6.12.1998, Ташкент), биохимик, химия фән. д-ры (1961), Үзбәкстан ССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1979). Урта Азия ун-тын (1941, Ташкент) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 дан Үзбәкстан ССР ФАндә, Үсемлек матдәләре химиясе ин-тында: 1956–80 дә гликозидлар химиясе лаб. мөдире, 1956–65 тә һәм 1980–83 тә директор урынбасары. 1979–84 тә Үзбәкстан ССР ФА Химия-технол. фәннәре бүлегенең академик-секретаре урынбасары. Хезмәтләре табигый һәм физиологик актив матдәләр химиясенә карый. Ә. җитәкчелегендә кардиотоник тәэсирле дәвалау чаралары эшләнә һәм мед. практикасына кертелә: олиторизид, эризимозид, апобиозид, строфантин ацетаты; фрутицин седатив препараты; псорален, псоберан фотосенсибильләштерүче препаратлар; тонус күтәрә торган экдистен һ.б. Табигый йөрәк агликоны узаригенинны, стероид гормоннарның аналогларын синтезлый. Ә. тарафыннан гликозидларның иммуномодульләштерүчән, гонадотропик, гиполипидемик актив төрләре табыла. Үзбәкстан ССРның Бируни исем. Дәүләт бүләгенә лаек була (1967). Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий исем., 1, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, Югославия Соц. Федератив Респ-касының 2 нче дәрәҗә «Партизан йолдызы» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Химия сердечных гликозидов в Советском Союзе: Обзор // Химия природных соединений. 1971. № 5; Успехи синтеза карденолидов: Обзор // Химия природных соединений. 1978. № 3; Гликозилирование кардиостероидов: Обзор // Химия природных соединений. 1984. № 5.

*Әд.:* Наиль Кадырович Абубакиров. Таш., 1989.

**ӘБҮБӘКЕ́РОВ** Фоат Хәмит улы (2.11.1944, Үзбәкстан ССР, Наманган ш.), скрипкачы, дирижёр, композитор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986), ТРның халык артисты (1996). Казан консерваториясен (Н.Брауде классы, 1968) тәмамлый. 1972 елдан Татар акад. театрының оркестр җитәкчесе һәм музыка бүлеге мөдире. Республика драма театрлары спектакльләренә язылган музыка һәм музыкаль бизәлешләр авторы: Татар акад. театрында — «Килә ява, килә ява» (З.Хәким), «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин), «Гаугалы гаилә» («Суббота, воскресенье, понедельник», Э. де Филиппо); Әлмәт татар драма театрында — «Таһир-Зөһрә» (Ф.Бурнаш), «Синнән башка юк тормыш» (А.Гыйләҗев); Казан курчак театрында — «Акбай маҗаралары» (Т.Миңнуллин); Казан яшьләр театрында — «Беркем ышанмас» («Никто не поверит», Е.Полонский). Татар драматурглары әсәрләре нигезендә куелган телевизион постановкаларга музыка иҗат итә (мәс., «Ташкыннар», Т.Гыйззәт). «Ап-ак ромашкалар» (Аманулла шигыре), «Зәңгәр кыңгыраулар» (Ә.Баян шигыре) дигән популяр җырлар авторы. Кыллы квартет һәм камера ансамбльләренең Бөтенроссия конкурсы дипломанты (1966).

**ӘБҮЗӘ́Р МӘЧЕТЕ́**, Чаллы шәһәрендәге җамигъ мәчет. 1993 елда арх. В.А.Манукян, Т.Г.Улатова, инж.-конструктор В.П.Евсеев проекты б-н төзелә. Комсомол урамындагы Нуретдин мәдрәсәсе комплексында урнашкан. Төньяк тарафында җиргә утыртылган манаралы, гөмбәзле мәчетләр төренә керә. Композициясен яссы түбәле турыпочмаклы бина, гөмбәзле зал, биек чатырлы өч катлы манара хасил итә. Бина эчендә ирләр һәм хатын-кызлар өчен гыйбадәт заллары, вестибюль, эш бүлмәләре бар; ирләр залы 1 нче катта, хатын-кызлар залы тәрәзәләр б-н яктыртылган эргә катта урнашкан. Мәчетнең тышкы бизәлешендә Шәрекъ архит-расы йогынтысы чагыла. Өскә таба тараеп, баскычсыман яруслы манарасы һәм гөмбәзе Болгар шәһәре архит-расы монументаль корылмаларын хәтерләтә. Тышкы бизәлешендә гранит, мәрҗән кабырчыгы, ялтыравык плитәләр һ.б. материаллар кулланылган.



Әбүзәр мәчете.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ӘБҮЗӘ́РОВ** Разак Абдрахман улы (16.6.1932, Казакъстан ССРның Алма-Ата өлкәсе, Андреев р-ны Лепсинск а.), педагог, пед. фән. д-ры (1984), проф. (1984). Алма-Ата пед. ин-тын тәмамлый (1953), Алма-Ата өлкәсенең авыл мәктәпләрендә укыта, директор булып эшли. 1970 елдан Төньяк Казакъстан гуманитар ун-тында, 1971–96 да рус телен укыту методикасы каф. мөдире (Уральск ш.). 1995 тән Г.Тукай исем. Уральск иҗтимагый үзәге рәисе. Хезмәтләре милли мәктәпләрдә рус телен укытканда төбәкне өйрәнү материалларыннан файдалану методикасына карый.

Х е з м.: Краеведение-лингвострановедение как источник дидактического материала для работы по развитию русской речи. А.-А., 1990; Интенсивный курс русского и татарского языков. Уфа, 1995.

**ӘБҮЗӘ́РОВ** Рафаэль Хаҗи улы (1.1.1951, Буа р-ны Килдураз а.), зоотехник, Дәүләт бүләге лауреаты (2003), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1992), а.х. фән. канд. (1998). Казан вет. ин-тын (1972), Саратов югары партия мәктәбен (1990), Казан юридик ин-тын (РФ Юстиция министрлыгының Россия хокук академиясе ф-лы) (2003) тәмамлый. 1972 елда Татарстан дуңгызчылык с-злары трестында зоотехник булып эшли, 1973–74 тә Татарстан Куллanучылар берлегендә өлкән зоотехник. 1974–75 тә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында. 1975 тән Буа р-нында, а.х. терлекләрен ясалма орлыкландыру буенча җитештерү пр-тиесендә баш зоотехник (1976 га кадәр). 1976–83 тә Буа кошчылык ф-касында, 1983–84 тә Буа район башкарма ком-тының а.х. идарәсендә баш зоотехник, 1984–85 тә КПССның Буа райкомында а.х. бүлеге мөдире, 1985–91 дә секретарь, 2 нче, 1 нче секретарь, Буа район башкарма ком-ты рәисе, 1991–2005 тә Буа р-ны хакимият башлыгының 1 нче урынбасары, Буа р-н башкарма ком-ты җитәкчесе, 2007 дән Буа муниципаль р-ны башлыгы. Дәүләт бүләге «Буа р-ны а.х. производствосында ТРдагы агроминераль чималны кулланып ресурс саклаучы технологияләрне гамәлгә кертү» хезмәте өчен бирелә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ӘБҮЗӘ́РОВ** Хаҗиәхмәт Кәрибулла улы (20.5.1924, Тәтеш кантоны Урта Лашчы а. — 22.10.1983, Буа р-ны Түбән Наратбаш а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Казан югары партия мәктәбен тәмамлый (1959). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–54 елларда Буа р-ның совет органнарында, район г-тасы редакциясендә эшли, 1959–78 дә «Коммунизм» к-зы рәисе. Ул җитәкчелек иткән елларда колхозда бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 25 *ц* га җитә, ит җитештерү 4 тапкыр арта.

3200 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән комплекс, социаль һәм мәдәният объектлары төзелә. Колхоз мөгезле яшь терлек үстерү һәм симертүгә көйләнгән эре хуҗалыкка әверелә. Ленин, «Почёт билгесе», 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘБУ́ЗОВА** Фатиха Фәттах кызы (19.6.1934, Мордва АССРның Темников ш.), нефть һәм газ технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1977), проф. (1979), БАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1978, 1985). 1957 елда Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, Башкортстан нефть продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында. 1965 тән Уфа нефть ин-тында, 1979–94 тә җылылык техникасы каф. мөдире. Хезмәтләре нефтьне төп үткәргеч торба буйлап куганда һәм саклаганда җылылык-масса алмашына, табигатьне һәм җылылыкны саклау технологияләрен эшләүгә, нефтьнең табигый кимүе нормасын фәнни дәлилләүгә карый. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Потери нефтепродуктов и нефтей от испарения из подземных резервуаров. М., 1966 (автордаш); Транспорт и хранение нефти и газа. М., 1975 (автордаш); Борьба с потерями нефти и нефтепродуктов при их транспортировке и хранении. М., 1981 (автордаш); Техника и технология транспорта и хранения нефти и газа. Уфа, 1994 (автордаш).

**ӘБУЛМӘМБӘ́ТОВ** Роберт Шәрифҗан улы (25.2.1942, Оренбург өлкәсенең Зиянчура р-ны Юлкотлы а. — 27.4.2002, Казан), драма актёры, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1966), Татар акад. театры труппасына алына. Күбесенчә муз.-драматик спектакльләрдә катнаша. Ул башкарган Хәлил, Бакый рольләре («Галиябану», «Ак калфак», М.Фәйзи) театр җәмәгатьчелеге тарафыннан югары бәяләнә. Ш.у. лирик рольләр дә башкара: Газиз («Күк капусы ачылса», Х.Вахит), Амур («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Витторио («Бәйрәм кичендә», Э. де Филиппо), Альфред («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Исәнбай («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт). 1977 елдан Татар акад. театрында директор урынбасары, 1981 дән директор вазифаларын башкара, 1984 тән Татар драма һәм комедия театры директоры.

**ӘБУЛХА́НОВ** Рифат Назыйм улы (6.7.1956, Казан), балет артисты, ТАССРның халык артисты (1990). Мәскәү акад. хореография уч-щесен (1975, педагоглар — Л.Т.Жуков, М.Э.Лиепа) һәм Казан ун-тын тәмамлый (1988). 1975–98 елларда Татар опера һәм балет театрының балет солисты. Төп партияләре: Принц, Меркуцио («Золушка», «Ромео һәм Джульетта» С.Прокофьев), Зигфрид, Дезире («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Былтыр («Шүрәле», Ф.Яруллин), Артынов («Анюта», В.Гаврилин) һ.б. Ә.ның артистлык үзенчәлеге партнёрлык осталыгында, кыю стильдә биюендә чагыла.

**ӘВЕРНӘ́ УТЫ́** (Senecio), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан үләнчел үсемлекләр, куаклар һәм куакчыклар ыругы. 1,5 меңнән артык төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Америкада очрыйлар. ТРда 12 төре үсә. Аеруча киң таралганнары: кырәк яфраклы канария (S. erucifolius), Яков Ә.у. (S. jacobaea). Татар канариясе (S. tataricus), гади Ә.у. (S. vulgaris), ябышкак Ә.у. (тузгакбаш) (S. viscosus) — республика флорасының сирәк очрый торган төрләре. Елга ярларында, болыннарда, куак араларында, далалы сөзәклекләрдә үсәләр. Бер, ике һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, биеклеге 15 тән алып 200 *см* га кадәр. Сабаклары шәрә яки төкчәле. Яфраклары чиратлашкан, эллипс формасында, бөтен читле, каурыйсыман аерчалы яки телмә. Чәчәкләре сары, кызгылт сары, кызыл яки шәмәхә төстә, күпсанлы кәрзиндә, куе булмаган калкансыман — себеркәчле чәчәк төркеменә җыелган. Җимешләре — бүрекчәле сырлы орлыкчалар. Май–июльдә чәчәк аталар, җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Гади Ә.у. — дару үләне. Орлыкларында алкалоидлар, тамырында флавоноидлар, дуплау матдәләре, С витамины, калий һәм кальций тозлары бар. Халык медицинасында Ә.у. тамырларыннан ясалган төнәтмә кан туктату өчен, ш.у. ашказаны һәм эчәк авырулары, бронхиаль астма вакытында файдаланыла. Декоратив. Терлек азыгы. 4 төре ТР ның Кызыл китабына кертелгән.

**ӘВЕРНӘ́ ЧӘЧӘКЛЕЛӘ́Р**, кәбестәчәләр (Cruciferae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Үләнчел үсемлекләр, сирәгрәк — лианалар һәм куаклар. 380 ләп ыругы, 3 меңнән артык төре билгеле, бөтен җир шары буйлап таралганнар, әмма күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында үсәләр. ТРда 39 ыругы һәм 80 төре билгеле. Бер, ике һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Кайбер культуралы үсемлекләренең тамырлары тамыразык рәвешендә. Яфраклары чиратлашкан, бөтен яки телмә, төпчек яфраксыз, гади яки тармак төкчәле. Чәчәкләре сары, ак, аксыл шәмәхә һәм алсу төстә, чукка, сирәгрәк калкансыман, чатырсыман яки башсыман чәчәк төркеменә җыелган. Касә һәм таҗ яфракчыклары 4 әр, алар аркылы-торкылы урнашкан (исеме шуннан), касә яфракчыгы кайвакыт төбенә таба капчыксыман (нектар туплау өчен җайланма) рәвештә. Җимеше — ике якка ачыла торган, күп орлыклы кузак яки кузакча. Кайвакыт җимешләре чикләвексыман, ярылмый торган (мәсәлән, катран төрләренеке). Күп төрләре — кәбестә, редис, шалкан, торма, керән һ.б. яшелчә буларак үстерелә. Майлы үсемлекләр сыйфатында горчица, рапс, шепкән үрчетелә. Сарыбаш, йөрәк уты, көтүче сумкасы, ябышкак үлән һ.б. — дару үләннәре; шеббуй, ахшам миләүшәсе — декоратив үсемлекләр. Күп төрләре баллы (эт кавысы, кыргый торма, йөрәк уты), аш тәмләткечләр (горчица, керән); чүп үләннәре (көтүче сумкасы, ярут, чалгычут, сарыбаш). 13 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ӘВЕРНӘЛЕ́ ҮРМӘКҮ́Ч** (Araneus diadematus), аранеидлар семьялыгыннан үрмәкүч. Ана затларының озынлыгы 20–25 *мм*, ата затларының — 10–11 *мм*. Төсе тонык көрәннән алып кара көрәнгә кадәр. Башкүкрәкнең уртасында һәм кырыенда кара сызыклары бар. Аяклары аксыл, кара төстәге боҗралы. Корсагы озын, өске өлешендәге ак таплар әвернә сурәте хасил итә (исеме шуннан). Урман төре. Татарстанның барлык терр-ясендә дә очрый. Лишайниклы һәм мүкле, нарат җиләкле наратлыкларда, чыршылыкларда яши. Ерткыч. Агач һәм куак ботаклары, кайвакыт биек үлән сабаклары арасына тәгәрмәчсыман вертикаль җәтмә үрә, аңа эләккән бөҗәкләр (гадәттә чебеннәр) Ә.ү.кә азык булып торалар. Аталану һәрвакыт ана зат җәтмәсендә «туй биюләре» б-н уза. Ана Ә.ү. 5–6 кузы сала, аларның һәркайсында 15 тән алып 1 меңгә кадәр йомырка була. Ешрак йомыркалар яки кузыдагы нимфалар, сирәгрәк — җенси җитлекмәгән үрмәкүч кышлый. Язын яшь үрмәкүчләр кузыдан чыга, башта төркемләп яшиләр, ә аннары, таралып, ау җәтмәләре үрә башлыйлар.

**ӘГЕ́Р** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Курайлы Елга елгасы буенда. 2002 елда 116 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, куян асрау. Клуб. 1750 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре һәм башкорт-вотчинник катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.дә мәчет була, 20 йөз башында аның каршында мәктәп эшли. 1920 гә кадәр авыл Самара губернасының Бөгелмә өязе, Эстәрлетамак волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 115, 1856 да — 264 ир заты; 1897 тә — 705, 1920 дә — 869, 1926 да — 499, 1938 дә — 404, 1949 да — 328, 1958 дә — 294, 1970 тә — 263, 1979 да — 203, 1989 да — 109 кеше.

**ӘГЕРҖЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Иж елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 31,3 *км*, ТР чикләрендә 6 *км* чамасы. Бассейнының мәйданы 138 *км*$^2$. Әгерҗе р-нында Можга калкулыгы буйлап ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әгерҗе шәһәреннән 2,8 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 195 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 29%. Елганың 2 *км* дан 4 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар, барысы да ТРдан читтә ага. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 95 *мм*, ташу вакытында су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен









Әгерҗе шәһәре. 1. Карл Маркс урамы; 2. Мәчет; 3. Әгерҗе тимер юл төйнәлешенең беренче тимер юлчыларына багышланган монумент; 4. Тимер юл вокзалы бинасы.

400–500 *мг/л*. Су ресурслары сугару һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**ӘГЕРҖЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәнәвез елгасының уң кушылдыгы (Эстәрле, Ык елгалары бассейны). Озынлыгы 6 *км*, бассейнының мәйданы 12,8 *км*$^2$. Азнакай р-нында, Бөгелмә — Бәләбәй калкулыгы аша ага. Елга башы Әгерҗе авылыннан 3,6 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы әлеге авылның төньяк-көнчыгышында. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 195 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Ә. елгасының 0,4 һәм 4 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Суы бик каты (6–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Елгада гомуми күләме 945 мең *м*$^3$ булган 2 буа бар.

**ӘГЕРҖЕ́**, район карамагындагы шәһәр, Әгерҗе р-ны үзәге. ТРның төньяк-көнчыгыш төбәгендә, Казаннан 304 *км* ераклыкта, Удмурт Респ-касы чигендә, Әгерҗе елгасы буенда урнашкан. Казан, Екатеринбург, Ижевск, Акбаш юнәлешләре тимер юлларының эре транспорт төйнәлеше. Мәйданы — 8,6 *км*$^2$. 2006 елда 18,6 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 52,9%, руслар — 35,4%, удмуртлар — 6,7%) яши. Тимер юл остаханәләре, төзү материаллары з-ды, сөт-май комб-ты, ашлык кабул итү пр-тиесе, типография, 4 урта, 1 балалар музыка мәктәбе, 2 һөнәри уч-ще, төбәкне өйрәнү музее, үзәк район хастаханәсе. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. 20 йөз башында Ә.дә волость идарәсе урнаша; 1 мәктәп һәм 2 мәчет була. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Әгерҗе волосте үзәге, 1921 дән — ТАССРның Әгерҗе кантоны үзәге, 1924 тән — Алабуга кантоны башкарма комитетына буйсынган шәһәр. 1926 да шәһәрләр исемлегеннән алына. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе р-ның административ үзәге. 1928 дән эшчеләр посёлогы төренә кертелә, 1938 нең 28 августында район карамагындагы шәһәр итеп үзгәртелә. ТАССРда адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, 1963 нең 1 февраленнән Алабуга шәһәр советы хакимияте карамагында, 1964 нең 4 мартыннан — яңадан район үзәге. Халык саны: 1859 да — 2340, 1890 да — 2758, 1920 дә — 4543, 1926 да — 7339, 1938 дә — 12376 кеше, 1959 да — 20,3, 1979 да — 18,9, 1989 да — 19,7 мең кеше.

*Әд.:* Сабиров Р.М. По городам Татарии. К., 1976.

**ӘГЕРҖЕ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәнәвез елгасы буенда. 2002 елда 521 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау; анда яшәүчеләрнең бер өлеше нефть сәнәгатендә эшли. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1758 дә Әгерҗе авылы ясаклы татарлары нигез сала. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 да Ә.дә мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр авыл Самара губернасының Бөгелмә өязе Азнакай волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 190 ир заты; 1859 да — 425, 1897 дә — 894, 1926 да — 913, 1938 дә — 1072, 1949 да — 680, 1958 дә — 582, 1970 тә — 659, 1979 да — 618, 1989 да — 472 кеше.

**«ӘГЕРҖЕ́»**, республиканың балаларны туберкулёздан дәвалау санаторие, 50 урынга исәпләнгән, Әгерҗе тимер юл станциясеннән 4 *км* ераклыкта, Иж-Бубый авылы янында урнашкан. 1944 елда ачыла. Туберкулёз микобактериясе йоктырган 7 яшьтән 14 яшькә кадәрге балаларның сулыш әгъзаларын дәвалау б-н шөгыльләнә. Ел буе эшли, дәвалау вакыты 90–180 көн.

*Әд.:* Блюмштейн З.Н. Курорты и санатории Татарстана. К., 1973.

**ӘГЕРҖЕ́ АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, Әгерҗе р-нының көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы 30,9 мең *га*, ш.и. урманнар — 6,8 мең *га*, сазлыклар — 400 *га*. Кырыкмас, Бимә, Кады, Ары-Казы, Кумырсы, Шехостан елгалары ага. Елга кондызын һәм суерны саклап калуда уңайлы шартлар булдыру өчен 1984 елда оештырыла. 1999 да 30 баштан артык кондыз теркәлә. Татарстанда елга-су камасы даими яши торган бердәнбер урын. ТРның Кызыл китабына кертелгән хайван төрләреннән җизбаш, гади кара елан, зур каракош, елга каракошы, яр чыпчыгы, көрән аю очрый.

**ӘГЕРҖЕ́ КАНТОНЫ́**, 1921–24 елларда ТАССРда административ-территориаль бүленеш берәмлеге. Респ-каның төньяк-көнчыгышында урнашкан. Мәйданы 890 *км*$^2$. Халкы 41,2 мең кеше, ш.и. татарлар — 70,9%, руслар — 16,9%, марилар — 8,6%, удмуртлар — 3,6% (1922). Үзәге — Әгерҗе авылы. 93 торак пунктны, 5 волостьны (Әгерҗе, Исәнбай, Иске Чыкалда, Көчек, Сарсак-Умга) берләштергән. 83 тегермән (1 се пар б-н эшли), 28 ярма ярдыру, 24 ашлык киптерү пункты була. Халкы, нигездә, игенчелек б-н шөгыльләнгән, 10 мең баш чамасы мал асраган. 48 мәктәп, 8 китапханә, 3 халык йорты, 1 клуб эшләгән. 1924 тә бетерелә, биләмәсе *Алабуга кантонына* кушыла.

*Әд.:* Агрызский кантон за первый год своего существования. К., 1922.



**ӘГЕРҖЕ́ РАЙОНЫ́**, ТРның төньяк-көнчыгышында урнашкан, Удмурт Респ-касы б-н чиктәш. Төньяк-көнчыгыш Кама буе икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1796,6 *км²*. 21 авыл җирлеген, 72 авыл торак пунктын берләштерә. Үзәге — Әгерҗе шәһәре. Халкы — 2006 елда 36,4 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 58,9%, руслар — 24%, марилар — 8,2%, удмуртлар — 6,6%). Шәһәр халкы — 18,6 мең кеше, авылларда 18,5 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км²* га 21 кеше. Район 1927 нең 14 февралендә оештырыла. 1921 дә биләмәсе, элеккеге Вятка губернасыннан алынып, ТАССР га бирелә. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. Оешкан вакытында Ә.р.на 1 посёлок советы, 25 авыл советы, 29422 кеше (татарлар — 21137, руслар — 6958) яшәгән 105 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 612 *км²*, халкы — 38 мең кеше, 22 авыл советы, 64 торак пункт була. 1960 та район 597,1 *км²* җир били, составында 10 авыл советы, 56 торак пункт исәпләнә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Ә.р. таркатыла, биләмәсе Алабуга р-нына бирелә. 1964 нең 4 мартында, элеккеге *Красный Бор районы* терр-ясе дә кертелеп, Ә.р. яңадан торгызыла. 1966 елгы мәгълүматларга караганда, мәйданы — 1799 *км²*, халкы — 54500 кеше, 21 авыл советы, 105 торак пункт исәпләнә. 2005нең 26 гыйнварында муниципаль р-н дип үзгәртелә. Ә.р.ның рельефы — калкулыклы тигезлек: көнбатыш өлешендә биеклеге 200 *м* га кадәр булган Можга калкулыгы тармагы, көнчыгышта биеклеге 230 *м* га кадәр булган Сарапул калкулыгының көньяк чиге үтә. Район терр-ясеннәнКама елгасы (Түбән Кама сусаклагычы), Иж елгасы һәм аның кушылдыклары Бубый, Чаж, Кырыкмас елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл соры, соры урман, кәсле көлсу туфраклы. Терр-ясенең 20,8% ын урманнар алып тора. Известьташ, мергель, балчык, ком, торф ятмалары бар. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Иж минераль су чыганаклары, «*Катнаш наратлык*» ландшафтлы табигать истәлеге, *Әгерҗе аучылык тыюлыгы*, «*Кичкетаң*» комплексы табигать тыюлыгы. Район терр-ясендә борынгы тимер дәверенә караган 30 дан артык археологик истәлек табыла. Ә.р. — нигездә, а.х. р-ны. Мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау, умартачылык тармаклары нык үсеш алган. А.х. җирләре 97,0 мең *га* били, ш.и. 70 мең *га* сөрүлек җир. Арыш, сабан бодае, арпа, солы, борчак игелә; бәрәңге үстерелә. А.х. товарлары җитештерүчеләр җаваплылыгы чикләнгән «Ак Барс» Әгерҗе агрофирмасы җәмгыятенә берләшә. Район үзәгендә, Исәнбай, Красный Бор һәм Тирсә авылларында сәнәгать пр-тиеләре урнашкан. *Әгерҗе урман хуҗалыгы* эшли. Ә.р. җиреннән Казан–Екатеринбург, Әгерҗе–Акбаш тимер юллары, Әгерҗе–Красный Бор автомобиль юлы уза. Красный Бор авылында пристань бар. Районда 42 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 4302 укучы укый), ш.и. 16 башлангыч, 1 тулы булмаган урта, 24 урта, 1 музыка мәктәбе, 1 бакча-мәктәп, 2 һөнәри уч-ще, 33 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 45 клуб, 34 китапханә, 187 урынлы 2 хастаханә, 3 дәвалау амбулаториясе, 45 фельдшер-акушерлык пункты эшли. Әгерҗе шәһәрендә — Төбәк тарихын өйрәнү һәм Салагыш авылында тарих музейлары бар. Татарча «Әгерҗе хәбәрләре», русча «Агрызские вести» г-талары нәшер ителә.




**ӘГЕРҖЕ́ РАЙОНЫ́ ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Әгерҗе шәһәрендә, муниципаль музей, 1997 елның 18 декабрендә ачыла. Фондларның нигезен 1960–1980 елларда төбәк тарихчысы В.И.Репин туплаган коллекция тәшкил итә. Бер катлы агач бинада урнашкан. Экспозиция мәйданы 65 *м²*. Төп фонд 1260 саклау берәмлегеннән тора. Экспозиция өч залны били. Этнография бүлеге төбәктә яшәүче халыкларның — татар, рус, удмурт, мариларның көнкүрешен (эш кораллары, йорт кирәк-яраклары, өс киемнәре) чагылдыра. 20 йөз башы татар крәстияннәре өйләре һәм 20 йөз уртасы авыл йортларының эчке күренешләре урнаштырылган. Кибет интерьеры торгызылган. Өченче зал — күргәзмәләр залы, җирле рәссамнар иҗатына багышланган, биредә ел саен музей фондларыннан һәм шәхси коллекцияләрдән оештырылучы берничә вакытлы күргәзмә уздырыла. Музей фондларында Бөек Ватан сугышы ветераннары, ш.и. Сов. Союзы Геройлары А.К.*Абдрахманов*, З.Х.*Солтанов*, Б.С.*Шабалин*, Г.Н.*Шәмсетдинов*; Дан орденының тулы кавалеры Р.Х.*Гайнуллин*; язучылар Т.К.*Гыйззәт*, Ю.Ш.*Әминов*; артистлар Л.М.*Аитов*, Ш.И.*Әсфәндиярова*, В.Г.*Шәрипова* һ.б.ларның документлары, бүләкләре һәм фотосурәтләре тупланган. Иң мөһим




Әгерҗе районы тарихы музее.

экспонатлар арасында Дан орденының тулы кавалеры Р.Х.Гайнуллинның исемле сәгате, драматург Т.К.Гыйззәтнең пиджагы, урындыгы, фотоаппараты, шагыйрь Д.Г.Гобәйдинең фонаре бар.

Музей ел саен Халыкара музейлар (18 май), Җиңү (9 май), Ватанны саклаучылар (23 февр.) көннәрен билгеләп уза.

**ӘГЕРҖЕ́ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Әгерҗе р-ны терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда 23578 *га* мәйданда Красный Бор урман хуҗалыгы буларак оештырыла (1939 да урман хуҗалыгына җирле урманнар кушыла), 1969–71 дә Красный Бор урман сәнәгате хуҗалыгы, 1971–91 дә Әгерҗе урман сәнәгате хуҗалыгы. 2006 ел башына Ә.у.х.ның гомуми мәйданы 44126 *га*, ш.и. урман мәйданы — 40383 *га*. Түбәндәге урманчылыкларны үз эченә ала: Әгерҗе — 8973 *га*, Девәтернә — 6282 *га*, Красный Бор — 15552 *га*, Шаршады — 13319 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Әгерҗе шәһәрендә. Эшләүчеләр саны 321 кеше.

1 нче төркем урманнар 23617 *га* мәйданны били, ш.и. «*Катнаш наратлык*» табигать истәлеге — 49 *га*, кыйммәтле промысел балыкларының уылдык чәчү урыннарын саклаучы тыюлык урман полосалары — 7522 *га*, су объектлары ярлары буенча тыюлык полосалары — 1062 *га*, саклый торган урманнар — 14540 *га* һ.б. 2 нче төркем, ягъни файдаланыла торган урманнар 20509 *га* мәйданны алып тора. Урман культураларының мәйданы 12188 *га*. Ылыслы (47%) һәм йомшак яфраклы (48%) токымнар күпчелекне тәшкил итә. Нарат 13313 *га* мәйданда, уртача яше — 42 ел, агач запасы 2781,2 мең *м³*. Чыршы — 5479 *га*, уртача яше — 40 ел, агач запасы 730 мең *м³*. Ак чыршы — 250 *га*, уртача яше — 61 ел; карагай — 15 *га*, уртача яше — 29 ел. Йомшак яфраклы токымнардан: каен — 7531 *га*, уртача яше — 38 ел, агач запасы 1065,1 мең *м³*, усак — 5948 *га*, уртача яше — 29 ел; юкә — 3250 *га*, уртача яше — 49 ел; кара зирек — 2094 *га*, уртача яше — 29 ел. Каты яфраклылардан: имән — 1062 *га*, карама һәм элмә — 886 *га*. Ә.у.х. өчен урманнарның төрле типтагы төркемнәре хас, алар арасында иң әһәмиятлеләре: катнаш наратлыклар (39,8%), яшел мүкле наратлыклар (21,6%), катнаш чыршылыклар (14,6%), өрәңгеле-юкәле имәнлекләр (12,9%), тубылгылы зireклекләр (4%). Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 39,5%, урта яшьтәгеләре — 34,3%, өлгереп килүчеләре — 13,5%, өлгергәннәре һәм картайганнары — 12,5%. Утыртмаларның уртача яше — 38 ел, уртача



М.З.Әгъләмов.



Н.Х.Әгъләмов.



Ф.Х.Әгълетдинов.

бонитет классы 1; уртача тыгызлыгы 0,74. Красный Бор урманчылыгында 1908 һәм 1913 елларда 60 *га* мәйданда утыртылган урман участоклары урман культураларын җитештерү үрнәге булып тора. Бу утыртмалар — 1а класс бонитетлы, тыгызлыгы 0,8, запасы 420–450 *м³/га*, 20 елдан соң ышанычлы табигый яңартылуга сәләтле. Агачның гомуми запасы 6351,7 мең *м³*, уртача запасы 157 *м³/га* тәшкил итә. Бер елга уртача артым 155,8 мең *м³*. Урман кисү 50,6 мең *м³* күләмдә билгеләнә, ш.и. ылыслы урман хуҗалыгы буенча — 16 мең *м³*. Ел саен урманны карау максатыннан 1100 *га* мәйданда чистарту эшләре башкарыла, 13,5–15 мең *м³* эшкә яраклы агач әзерләнә, 140 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла, ш.и. 100 *га* мәйданда урман утыртыла. А.х. җирләренең 40 *га* мәйданында, комлыкларда, ерганак битләрендә һ.б. уңайсыз урыннарда саклагыч утыртмалар 2001 елга кадәр булдырылган. Ярдәмче сәнәгый җитештерүдә төп продукция ассортиментын агач материаллары, агачтан эшләнгән әйберләр, бүрәнә һ.б. эшләнмәләр тәшкил итә. Аз күләмдә сувенир эшләнмәләр җитештерү оештырылган. Урман хуҗалыгы үсешендә ТРның атказ. урманчылары В.Ф.Захаров һәм Ф.П.Тихомировның өлешләре зур.

*И.Н.Зарипов, Т.В.Мартынова.*

**ӘГЪЗА́МОВ** Флорит Имамәхмәт улы (11.2.1936, Башкортстан АССРның Чакмагыш р-ны Бикмәт а. — 4.12.2005, Казан), журналист, тәрҗемәче, тарих фән.канд. (1971), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). Казан ун-тын (1959) һәм КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1971) тәмамлый. 1960 елдан «Социалистик Татарстан» г-тасында эшли (1963–66 да бүлек мөдире, 1966–68, 1971–72дә баш мөхәррир урынбасары). Мәкаләләре «Республика Татарстан», «Мәгърифәт» г-таларында, «Татарстан» һ.б. ж-лларда басыла. Очерклар, рецензияләр, фельетоннар авторы. Кайбер мәкаләләре болгар, чех, кытай һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән. Иҗтимагый-сәяси, әдәби-публицистик һәм фәнни-популяр әдәбият әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1972 дән Казан ун-тында: журналистика каф. мөдире, бер үк вакытта 1986 дан филол. ф-ты, 1990 нан — журналистика ф-ты, 1994–2001 дә журналистика, социология һәм психология ф-ты деканы, 1990–98 дә татар журналистикасы каф. мөдире. ТРда журналистика белемен үстерүгә зур өлеш кертә. Татарстан журналистларының Хөсәен Ямашев исем. республика бүләге лауреаты (1982). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Яшәү көче. К., 1977; Үзәктә — кеше. К., 1982; Гуманизм советской журналистики. К., 1984; Тукай — журналист. К., 1986; Журналистское исследование активности личности. К., 1989.

*Әд.:* Бөек остаз ядкаре // Татарстан. 2005. № 12; К а р и е в а Л. Күңелдә син мәңгегә, бөек остаз! // Татарстан. 2006. № 2; П и в о в а р о в а Л. Он между нами жил // Республика Татарстан. 2006. 11 февр.

**ӘГЪЛӘ́МОВ** (Әгъләметдинов) Мөдәррис Зөфәр улы (13.10.1946, Зәй р-ны Бишсубашы а. — 26.11.2006, Казан), ТРның халык шагыйре (2006). Казан ун-тында укый. 1968–73 елларда Тукай р-ны Яңа Гәрдәле урта мәктәбендә тарих фәнен укыта. 1974 тән профессиональ язучы сыйфатында әдәби иҗат эше б-н шөгыльләнә. Әсәрләре 1959 дан басыла башлый. «Кыңгырау» (1970), «Учак урыннары» (1973), «Исәнме, йөрәк!» (1978), «Киләчәккә кайту» (1987), «Мин әйттем...» (1991), «Иман тәрәз шакый» (1996), балалар өчен язылган «Без, без, без идек» (1980) исемле шигырь җыентыклары авторы. Ә. поэзиясенә нечкә лирика б-н югары публицистик рухның үрелеше, уйлар ташкыны, лирик герой кичерешләренең тирәнлеге хас. Иҗатындагы төп мотивлар — туган җиргә, аның үткәненә мәхәббәт, замандашларының эчке дөньясы б-н тирән кызыксыну. Шагыйрьнең үзенчәлеге бигрәк тә кыска шигырьләрендә ачык күренә. Поэтик детальләр аша ул халык язмышы турында фәлсәфи гомумиләштерүләр ясарга омтыла. Мәхәббәт лирикасы да үзенә генә хас табышлары, хисләрнең сафлыгы, нәзакәтлелеге белән аерылып тора. Шигырьләре төгәл ритмикалы, шома, йөгерек телле. Аларда афоризм булып яңгырарлык тирән мәгънәле, тапкыр гыйбарәләр күп. Ә. сюжетка корылган озын шигырьләр, балладалар, поэмалар язу юнәлешендә дә уңышлы эшли. «Сугышлыда сугыш беткән көн» (1972), «Заман язган язмыш» (1987) балладалары, «Тукайдан хатлар» (1972–85), «Акмулла арбасы» (1981) поэмалары шундыйлардан. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1992). Зәй шәһәренең бер урамы Ә. исемен йөртә.

Ә с ә р.: Кан тамырын кистем. К., 2001.

*Әд.:* Х ә к и м С. Хәерле сәгатьтә! // Социалистик Татарстан. 1968. 17 нояб.; Г а л и у л л и н Т.Н. Йөгер, каләм! // Шагыйрьләр һәм шигырьләр. К., 1985; Ф ә й з у л л и н Р. Туңма, туган! // Мәдәни җомга. 1996. 22 нояб. *Р.Н.Даутов.*

**ӘГЪЛӘ́МОВ** Нәгыйм Харислам улы (15.8.1932, Башкортстан АССРның Мишкә р-ны Олы Шады а.) монтажчы. Соц. Хезмәт Герое (1977), РСФСРның атказ. төзүчесе (1973). 1951–58 елларда Чита өлкәсе, Чиләбе, Уфа шәһәрләре сәнәгать пр-тиеләрендә эшли. 1958–92 дә Чаллы шәһәре «Спецатоммонтаж» тресты идарәсендә монтажчы, монтажчылар бригадасы җитәкчесе. Павловск (Башкортстан АССР), Хоабин (Вьетнам Соц. Респ-касы.), Түбән Кама ГЭСлары, Зәй ГРЭСы, Түбән Кама нефтехимия комб-ты, шин з-ды, ТЭЦ, КамАЗ төзелешләрендә катнаша. Герой исеме Кама зур йөк автомобильләре җитештерү з-длары комплексының 1 нче өлешен төзүдә ирешкән югары уңышлары өчен бирелә. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең шәрәфле гражданы.

*Әд.:* Батыр набирает высоту. К., 1974; К а л и м у л л и н Дж. Аглямов Нагим Харисламович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ӘГЪЛЕТДИ́НОВ** Фәйзулла Хаҗи улы (15.3.1915, хәзерге Мөслим р-ны Бүләк а. — 29.10.1988, Туймазы ш.), Сов. Союзы Герое (23.10.1943), өлкән сержант (1943). 1936–38 елларда Кызыл Армиядә Хәсән күле янындагы сугышта катнаша (1938). 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, взвод командиры ярдәмчесе, сержант (40 нчы армиянең 309 нчы укчылар дивизиясе 955 нче укчылар полкы). Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 22 сентябрендә Днепрны кичкәндә һәм уңъяк ярда плацдарм яулаганда батырлык күрсәтә. 1946 дан партия һәм дәүләт эшләрендә. Ленин, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Башкортстан Респ-касында Бакалы авылының бер урамына Ә. исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2; Р а к и п о в Ш.З. Хранить вечно. К., 1980.

**ӘГЪЛИ́ЕВ** Хәйдәр Миңнемөхәммәт улы (3.9.1959, Саба р-ны Керәнле а.), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук агрохимия һәм туфрак белеме кафедрасында эшли. 1993–2004 елларда Саба р-нының «Керәнле» коллектив пр-тиесендә баш агроном (2004 елдан «Мичән» крәстиян-фермер хуҗалыгы). А.х. культураларының уңдырышлылыгын күтәрә торган сыек ашлама составын эшләү һәм производствога кертүдә катнаша. Уйлап табуга патенты һәм авторлык таныклыгы бар. ТР Дәүләт бүләге «Күп максатларда кулланыла торган хелат комплекслы микроашламалар эшләү һәм производствога кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ӘДӘБИ́ АЛЫНМАЛА́Р**, язучы тарафыннан халык иҗаты яки бүтән язучы әсәрләренең идеясен, темасын, сюжет схемасын, сәнгати ысулларын файдалану.

Ә.а. куллану татар әдәбиятына да хас. Урта гасыр татар әдәбиятында, гомумән, иҗади башлангыч икенче планда була; язучы үз бурычын мәгълүм сюжет һәм мотивларны үзенчә эшкәртеп файдалануда, аларны яңа әчтәлек б-н тулыландыруда, билгеле сәнгати алымнарны кабат яңартуда һ.б. күрә. Тема һәм сюжетлар чыганагы булып фарсы-таҗик һәм гарәп әдәбияты әсәрләре тора: Фирдәүси, Гомәр Хәйям, Низами, Сәгъди, Руми һ.б. Әйтик, Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэма-

сы — Низаминың шул исемдәге поэмасының ирекле тәрҗемәсе. Сәйф Сараиның «Гөлестан би-т-төрки» поэмасы фрагментлары Сәгъди «Гөлестан»ының аерым өлешләренә нәзыйрә буларак язылган. Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» фәлсәфи поэмасы нигезенә Гаттарның киселгән баш риваяте б-н бәйле булган «Җөмҗөмәнамә»поэмасы сюжеты салынган. Гаттар поэзиясенең образлары һәм мотивлары Мәхмүд Болгари, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Каргалый һ.б. әсәрләрендә дә кабатлана. «Мең дә бер кичә» җыентыгына кергән гарәп әкиятләре персонажлары, сюжетлары, символик детальләре һ.б. сәнгати компонентлары татар әдәбиятында 20 йөз башына кадәр яшәп киләләр. Мәс., К.Насыйриның «Гөлрөх һәм Камәрҗан» романы «Мең дә бер кичә»гә кергән «Кәмареззаман вә Саидаи Будур» хикәясенә барып тоташа. Шулай ук аның «Кырык вәзир» әсәренең үзәгендә — «Шаһзадә һәм җиде вәзир» («Мең дә бер кичә») циклының бер үк персонажы — үги анасы тарафыннан нахакка рәнҗетелгән шаһзадә. 19 йөздә татар язучыларының һинд мәдәнияте б-н кызыксынуы көчәя. Борынгы һинд мифлары һәм әкиятләре тупланмасы «Панчатантра» әүвәл урта иран (пәхләви) теленә «Кәлилә вә Димнә» исеме б-н тәрҗемә ителә. 8 йөзнең 2 нче чирегендә әл-Мокаффәгъ аны шактый үзгәртүләр, өстәмәләр б-н гарәпчәгә күчерә. Бу ядкәр мөселман Көнчыгышына гына түгел, ә бөтен дөньяга таныла. Андагы әсәрләрнең фарсы һәм гарәп версияләре нигезендә яңа әсәрләр барлыкка килә. 1880 нче елларда Г.Фәезханов тарафыннан тәрҗемә ителгән «Кәлилә вә Димнә»нең варианты яңа мотивлар, детальләр, оригиналь драматик ситуацияләр, образларның үзенчәлеге б-н аерылып тора һәм ул татар мәдәниятендә чагыштырмача мөстәкыйль идея-эстетик әһәмияткә ия була. Татар әдәбияты үзе дә Ә.а.ның чыганагы булырга мөмкин. Мәс., Сәйф Сараиның берничә шигыре — үзенең замандашлары (Тугълы Хуҗа, Хәсән Угылы, Харәзми һ.б.) газәл һәм касыйдәләренә язылган нәзыйрәләр.

20 йөз татар әдәбиятында Ә.а.ның асылы үзгәрә. Ул әдәби аллюзия рәвешен алып, нинди дә булса сәнгати феноменга, традициягә, теге яки бу язучының иҗатына, культуралар төренә һ.б. ишарә булып тора. Г.Тукай, Н.Думави, Ш.Бабич, С.Рәмиев шигъриятендә классик гарәп поэзиясеннән килгән кояш, ай яктысы, йолдызлар, бакча, шәм һ.б. символик образлар очрый; Г.Исхакыйның «Теләнче кыз» романы героинясы Кол Гали поэмасының герое Йосыф б-н чагыштырыла, андагы бай татар хатын-кызларының очрашу күренеше «Кыйсса-и Йосыф»тагы ситуацияне хәтерләтә. Татар язучылары әсәрләрендә рус һәм Көнбатыш Европа авторлары А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Л.Н.Толстой, У.Шекспир, Д.Байрон, Г.Гейне һ.б. иҗаты, А.Шопенгауэр, Ф.Ницше, В.Соловьёв фәлсәфәсе б-н төрле типтагы багланышлар (ш.и. Ә.а. характерындагы да) күзәтелә, мәс., аңлы рәвештә әдәби-сәнгати үрнәк тудыру (Г.Тукайның «Пушкиннан», «Шагыйрьгә (Михаил Юрьевич Лермонтов хәзрәтләренең бер нәсыйхәте)» шигырьләре), үз әсәренә бүтән текстның өзекләрен (Гали Рәхим әсәрләрендә Ф.Ницшедан цитаталар) кертү һ.б. Ә.а. әдәби процессның бер күренеше булып, шул чор өчен актуаль традициягә ишарә ясыйлар. Ә.а.ны башка автор язган әсәрне үзенеке итеп чыгаруга корылган плагиаттан аерырга кирәк.

*Әд.:* Нигматуллин Э. Раздвигая века и границы: К вопросу о связях татарской литературы первой трети XX в. с литературами Западной Европы. К., 1978; Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизации в историческом развитии татарской и русской литератур. К., 1997.

*Х.Й.Миңнегулов, В.Р.Әминова.*

**ӘДӘБИ́ БАГЛАНЫШЛА́Р ҺӘМ Ү́ЗАРА ЙОГЫНТЫЛА́Р**, әдәбиятлар арасында бер әдәбиятның икенчесе тәҗрибәсен үзләштерүендә чагыла торган үзара мөнәсәбәтләр. Татар һәм Шәрекъ Ә.б.һ.ү.й. чал тарихка барып тоташа. Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларында ук Идел буеның Шәрекъ илләре б-н сәүдә, икътисади, сәяси һәм мәдәни мөнәсәбәтләре интенсив үсеш кичерә. Ислам дине б-н бергә (хәзәрләр аны 737 елда, болгарлар 922 дә кабул итә) Идел буена һәм Урал төбәгенә гарәп теле, әдәбияты, фәне үтеп керә һәм тарала башлый, Коръән иң күп укыла һәм хөрмәт ителә торган китапка әверелә. 11 йөздән төрки-татар әдәбиятына фарсы-таҗик әдәбиятының йогынтысы арта башлый. Шәрекъ әдәбиятының күп өлеше төрки-татарлар тарафыннан оригиналда укыла, 1917 гә кадәр белемле, мәдәниятле һәр кешегә гарәп һәм фарсы телләрен белү фарыз булып санала. әл-Мәгарри, Фирдәүси, Гаттар, Низами, Гомәр Хәййам, Сәгъди, Руми, Нәвои кебек урта гасыр Шәрекъ шагыйрьләренең әсәрләре татарларга яхшы таныш була. Танылган төрки-татар һәм татар әдәбияты ядкәрләре (Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф»ы, Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Сәйф Сараиның «Китаб-е Гөлестан би-т-төрки»е, Кормашиның «Кыйсса-и Таһир илә Зөһрә»се, Дәрдмәнд шигырьләре һ.б.) Шәрекъ мәдәнияте б-н тыгыз бәйләнгән. Татар шигырь төзелеше гарәп-фарсы *гарузы* йогынтысында формалаша. Күп кенә идеяләр, сюжет, мотив, образ, жанр, сурәтләү чаралары ш.у. Шәрекъ б-н бәйле. Шәрекъ телләре аша татар укучысына Һиндстанның («Панчатантра» — «Кәлилә вә Димнә» аша, «Шукасаптати» — «Тутыйнамә» аша), антик Грециянең (Аристотель, Платон хезмәтләре) борынгы язма ядкәрләре килеп ирешә. Үз чиратында, урта гасыр фарсы (Насыйр Хөсрәү, Нәсими, Хөҗәнди), госманлы төрек (Әхмәди) авторлары әсәрләрендә Болгар, Сарай һ.б. Идел буе шәһәрләре танылган фәнни-мәдәни үзәкләр буларак телгә алыналар. 13–14 йөзләрдәге татар әдәбиятының госманлы һәм иске үзбәк әдәбиятына булган йогынтысы ш.у. бәхәссез. Төрек, үзбәк, таҗик һ.б. Шәрекъ халыклары милли мәдәниятләренә күп кенә татар әдәбияты эшлеклеләре үзләреннән гаять зур өлеш кертә. Акмулла, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Г.Тукай исемнәре Урта Азия һәм Кавказ халыкларына яхшы таныш.

Рус-татар Ә.б.һ.ү.й.рының барлыкка килүе 19 йөзгә карый. Ләкин бу чорда әле татар мәдәниятенә фәкать рус мәдәнияте йогынтысы турында гына сүз алып барып була. Рус-татар Ә.б.һ.ү.й.ның үсүендә мәгърифәтче Хәлфиннәр, Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, К.Насыйри һ.б.ның роле гаять зур була. Рус язучыларының идея-сәнгати тәҗрибәсе әдәби тәнкыйть, тәрҗемә, нәзыйрә, әдәби-теоретик концепция, оригиналь сәнгать әсәрләрен тудыру кебек формаларны үзләштереп тормышка ашырыла.

20 йөз башы татар әдипләренең дөньяны сәнгати күзаллаулары, фикерләү алымнарының нык үзгәрүендә рус әдәбияты б-н булган багланышлар да сәбәп була. Бу чорда төрле юнәлешләр һәм мәктәпләр: мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди реализм, романтизм, натурализм, модернизм бергә яшәп килә һәм үзара элемтәдә тора. Татар поэзиясе һәм прозасы башка төрле жанрлар б-н баетыла, яңа типтагы драматургия барлыкка килә, поэтикада автор шәхесе өстенлек ала. Рус әдәбиятындагы охшаш күренешләр б-н типологик якынлык эстетик концепция югарылыгында, охшаш темалар һәм проблемалар, геройларның типлары, сурәтләү чаралары системасы дәрәҗәсендә сизелә. Татар әдипләре: Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Н.Думави, С.Сүнчәләй, Г.Камал, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Хәнәфи, Гали Рәхим, Һ.Такташ һ.б., төрле юнәлешләрдә, агымнарда һәм стильләрдә иҗат итә, форма өлкәсендә тәҗрибәләр үткәрә, милли әдәбиятны яңа сәнгати кыйммәтләр б-н баеталар.

А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.В.Гоголь, Л.Н.Толстой, И.С.Тургенев, А.Н.Островский, А.П.Чехов, Л.Андреев, М.Горький иҗаты татар язучылары аеруча игътибарлы. Яңа рус милли поэзиясенең нигезен салып, аның классик стилен тудырган А.С.Пушкин үзенчәлекле мәдәни-эстетик миссия үти. Аның сәнгати-эстетик ачышларының (тарихилык, реализм, халыкчанлык), җәмгыяви-әхлакый идеалларының татар әдәбиятына йогынтысы гаять дәрәҗәдә тирән, төрле яклы һәм югары иҗади потенциалга ия була. Татар романтикларына Лермонтов иҗатының *гыйсъянчылык* һәм ирек сөю рухы, ялгызлык һәм дөнья б-н трагик дәрәҗәдә килешмәү мотивлары якын була. Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Г.Исхакый һ.б., Тургенев һәм Толстойның төрле формадагы психологик анализлары б-н кызыксынып, иҗатларында Тургеневның «серле психология»сенә, Толстойның «күңел диалектикасы»на хас булган принципларны һәм алымнарны файдалана башлыйлар. Л.Толстой татар әдәбиятына, үзенең әдәби әсәрләреннән тыш, ш.у. публицистик һәм дини хезмәтләре б-н дә йогынты ясый; А.Н.Островский исә рус милли театрына нигез салучы һәм драматик интригалар төзүдә яңа принциплар үткәрүче буларак өйрәнелә. Сатирик типиклаштыру осталыгы, чынбарлык һәм фантастиканы, көлке б-н кайгыны бергә алып баруы б-н Н.В.Гоголь үзенә җәлеп итә. А.П.Чехов эстетик фикерләүгә чынбарлыкны тасвирлауның үзенчәлекле формаларын ачучы, деталь, «подтекст», «рух» остасы, драматург-новатор булып үтеп керә. Татар әдипләренең иҗади эзләнүләренә ш.у. М.Горький да үзенең темалары, геройлары-

ның социаль изүгә каршы юнәлтелгән җиңү, шәхес иреге идеяләре б-н якын була.

Совет чорында рус һәм татар әдәбиятларында беренче планга зур эпик жанрлар чыга, охшаш стиль агымнары формалаша. Рус теленнән — татар теленә, татар теленнән рус теленә тәрҗемәләр системалы рәвештә эшләнә башлый, һәм шуның б-н татар әдәбияты Европа әдәби процессына кереп китә. Рус-татар әдәби бәйләнешләре 20 йөзнең өченче унъеллыгында, яңача өйрәнү алымнарын (интертекстуаль, структур-семиотик) таләп итеп, югарырак дәрәҗәгә күтәреләләр.

19 йөз уртасыннан башлап, татар язучыларының Көнбатыш Европа әдәбияты б-н кызыксынуы арта, һәм ул татар әдәбиятын баетуга, дөньяга карашны тирәнәйтүгә, мәгълүматның артуына, әдәби осталыкның үсүенә, татар җәмгыятенең дөнья әдәбияты б-н танышуына китерә. Көнбатыш Европа әдәбияты б-н татар укучысы, башлыча, төрек һәм рус тәрҗемәләре аша таныша. 20 йөз башында бер төркем тәрҗемәчеләр барлыкка килә, алар арасында язучылар И.Богданов, Д.Гобәйди, Г.Камал, Р.Рәкыйби, Г.Рәфыйкый, С.Сүнчәләй, М.Галәү һ.б. була. В.Шекспир, Дж.Байрон, В.Гюго, Мольер, И.В.Гёте, Г.Гейне, Ф.Шиллер, Ж.-Ж.Руссо әсәрләре аеруча зур популярлык казана. Байрон һәм Гейне рев. романтизм, Шекспир конфликтның кискенлеге һәм катлаулыгы б-н җәлеп итсәләр, Гёте һәм Гейне лирикасында татар укучысы табигатькә якын торган идеаль геройны күрә, халыкның рухи көченә ышаныч таба. Бу чорда татар әдәбиятында иҗтимагый, фәлсәфи, әхлакый, тәрбияви, фәнни проблемалар һәм жанр төрләре (драматургиядә — трагедия, комедия, драма, водевиль, мелодрама; прозада — повесть, новелла, лирик проза; поэзиядә — баллада, сонет, әкият, поэма һ.б.) күзәтелә. Көнбатыш Европа әдәбияты (Мольер, Р.Роллан, А.Сент-Экзюпери, Ж.Верн, Р.Л.Стивенсон, Э.Войнич, Г.Маркес, Ж.Амаду һ.б.) б-н кызыксыну совет чорында да кимеми.

Татар мәдәнияте, үз чиратында, чит ил галимнәре, язучылары, наширләрендә кызыксыну уята. 20 йөз башында Көнбатыш Европа басмаларында татарларга багышланган мәкаләләр күренә башлый. Мәс., Германиядә («Deutsche Rundschau», 1907, № 132) А.Вамбериның «Татарларның мәдәни омтылышлары» исемле мәкаләсе, Англиядә («Russian Review», 1914, № 1) татар әдәбиятына багышланган мәкалә, Г.Тукайның тәрҗемәи хәле һәм берничә шигыре басыла. Бу игътибар совет чорында да сүрелми. 1968 дә Немец библиография ин-ты тарафыннан дөньяга чыгарылган лексиконда (энциклопедиядә) татар язучылары (Г.Тукай, К.Насыйри, Ш.Камал, М.Гафури, Г.Ибраһимов, Г.Бәширов, М.Җәлил, К.Нәҗми һ.б.) турында мәгълүматлар бар. 20 йөздә чит илләрдә татар диаспорасы барлыкка килүе уңаеннан татар әдәбияты һәм публицистикасы халыкара аренага ешрак чыга башлый. Татар мәдәниятен дөньяви киңлеккә чыгаруның яңа формалары барлыкка килә. 1920 елларда төрек иҗтимагый-сәяси фикере үсешенә Й.Акчура һәм Г.Исхакый публицистикасы зур йогынты ясый. Шәрекъ белгечләре Э.Вимбуш, А.Беннигсен, М.Беннигсен-Броксап хезмәтләре аша киң катлау Көнбатыш Европа галимнәре һәм сәясәтчеләре татар әдәбияты тарихы б-н таныша. Алар татар мәдәниятенә багышланган һәм шул чорда СССРда тыелган хезмәтләрне Көнбатышта кабат бастырып чыгара. Г.Исхакый, М.Гафури, Г.Тукайның СССРда тыелган аерым әсәрләрен пропагандалауда *«Азатлык» радиостанциясе* зур роль уйный. 2000 дә Лондонда инглиз телендә «Татар поэзиясенең тарихи антологиясе» (төз. һәм тәрҗ. Р.Бохараев һәм Д.Мэттьюс) дөнья күрә. Татар язучыларының әсәрләре Төркия, Һиндстан, Англия, АКШ, Германия һ.б. илләрдә нәшер ителә.

*Әд.:* Нигматуллин Э. Раздвигая века и границы. К., 1977; Халит Г. Портреты и проблемы. К., 1985; Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. К., 1997.

*Х.Й.Миңнегулов, Э.Г.Нигъмәтуллин, В.Р.Әминова, Р.Г.Бохараев.*

**ӘДӘБИ́ ЖАНР**, тарихи формалашкан, сюжет һәм стиль үзенчәлекләре б-н аерылып торган әдәби әсәр төре. Беренче булып әдәби әсәрләрне өч төргә — эпос, лирика һәм драма төрләренә Аристотель аера. Тора-бара бу өч төр тагын да ваграк төрләргә бүленә. Эпик жанрларга — эпопея, роман, повесть, хикәя, новелла, очерк, эссе; лирик жанрларга — ода, элегия, эпитафия һ.б. кертелә. «Урталыкта калган» лиро-эпик жанрларга баллада, поэма, мәсәл керә. Драматик жанрларга драма, комедия, трагедия, водевиль һ.б.ны кертәләр. Соңрак Ә.ж. төшенчәсе әдәби әсәрнең үз төре б-н тәңгәлләштерелә. Ә. ж.ларны төрләргә бүлү процессы әле дә дәвам итә. 20 йөздә жанрның яңа билгеләмәләре барлыкка килә: «криминаль роман», «лирик эпиграмма» һ.б. Рус поэзиясендә төп Ә.ж.лар классицизм дәверендә — антик әдәбият, прозада — Көнбатыш романнары һәм повестьлары йогынтысында формалаша. Татар поэзиясендә Ә.ж.лар, гарәп поэзиясе формаларын һәм гарәп-фарсы поэтикасын үзләштереп, урта гасырларда ук барлыкка килә (ш.и. *касыйдә*, *газәл*, *мәдхия*, *робагый* һ.б.). Татар прозасында Ә.ж.лар системасы рус әдәбияты йогынтысында формалаша. Татар әдәбиятының үзенчәлекле үз жанрлары да бар: *нәсер*, *бәет*.

*Әд.:* Хатипов Ф. Эпик жанрлар. К., 1973; Пронин В.А. Теория литературных жанров. М., 1999; Шарипов А. Зарождение и становление системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII–XIV вв.). К., 2001.

*В.Х.Ганиев.*

**ӘДӘБИ́ ИЯРҮЛӘ́Р**, к. *Тәкълид.*

**ӘДӘБИ́ ТӘНКЫ́ЙТЬ**, әдәби иҗат төре, әдәбият белеменең бер тармагы, әдәби әсәргә фәнни-эстетик анализ ясау һәм бәя-аңлатма бирү. Татар әдәби тәнкыйте, иҗтимагый-эстетик фикерләү формасы һәм мөстәкыйль фән буларак, 1905–07 еллар рев-циясеннән соң, татар вакытлы матбугаты барлыкка килгәч формалаша. Р.Фәхретдинов, Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Исхакый, Г.Камал, Җ.Вәлиди, Г.Баттал, Н.Гасрый, Г.Кәрам, Г.Ибраһимов һ.б.ларның мәкаләләрендә һәм рецензияләрендә Ә.т.кә теоретик нигез салына, әдәбиятның чынбарлыкка мөнәсәбәте, халыкчанлыгы һәм милли үзенчәлеге кебек мәсьәләләр ачыклана, аның үз жанрлары барлыкка килә. Әдәбият теориясе һәм тарихының төп принциплары, төп кагыйдәләре Ә.т. кысаларында хәл ителә. 20 йөз татар совет әдәби тәнкыйте тарихы берничә этапка бүленә: 1917–34, 1935–55, 1956–71, 1972–85, 1985 елдан соң. 1918–30 елларның беренче яртысында әдәби тәнкыйть һәм әдәбият теоретиклары Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Г.Сәгъди, Г.Гали, һ.б.ның игътибары иҗади ысул һәм совет әдәбияты әсәрләрендә тасвирланган геройларның асылын аңлау, соц. җәмгыятьтә әдәбиятның урынын билгеләү мәсьәләләренә юнәлтелә. 1930 елларда матур әдәбиятта сыйныфлар идеологиясенең әһәмиятен күпертеп карау әдәби тәнкыйтьтә вульгар социологизм юнәлешенең көчәюенә китерә (Г.Толымбай, Х.Наум, С.Каратай, Ф.Мөсәгыйт). Шәхес культы һәм «сыйнфый көрәшнең кискенләшүе» теориясе хакимлеге шартларында сәләтле язучыларның күбесе репрессияләнә һәм Сталин концлагерьларында юк ителә. 1935–55 елларда Г.Халит, Х.Хәйри, Х.Госман, М.Гайнуллин, Г.Кашшаф иҗатында вульгар социологизм йогынтысыннан арыну тенденциясе күзәтелә, әдәби мирасны өйрәнүдә яңа этап башлана. Аларның иҗади эзләнүләре кыюрак һәм күпкырлырак була бара. 1950 еллар уртасыннан татар әдәби тәнкыйтенең һәм әдәбият тарихының аз өйрәнелгән һәм моңарчы тыелган проблемаларына игътибар көчәя. Г.Халит, И.Нуруллин, Й.Нигъмәтуллина, Н.Юзиев, М.Хәсәнов, Р.Мостафин, З.Мәҗитов, А.Әхмәдуллин, М.Мәһдиев, Т.Галиуллин, Ф.Хатипов, Ф.Мусин, Р.Ганиева татар милли әдәбиятының күп гасырлык бай тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. 1970–80 елларда Ә.т.тә проза буенча Ф.Хатипов, Ф.Миңнуллин, Ф.Мусин, Р.Бикмөхәммәтов, Ф.Галимуллин; драматургиядә А.Әхмәдуллин, Н.Ханзафаров, Һ.Мәхмүтов; поэзиядә Х.Госман, Г.Халит, Н.Юзиев, Т.Галиуллин, Мансур Вәлиевләр актив эшли. 1980 нче еллар уртасыннан башлап татар әдәбияты узган юлны һәм аның бүгенгесен гыйльми нигездә яңача бәяләү, Ә.т.нең совет чорында формалашкан бәяләмәләрен һәм тенденцияләрен яңадан карап чыгу мөмкинлекләре туа, татар милли әдәбияты тарихының төрле чорларын яңа концептуаль нигездә өйрәнүгә юл ачыла.

*Әд.:* Мәһдиев М. Реализмга таба: XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре. К., 1989; Миңнуллин Ф. Балта кем кулында? К., 1994; Галимуллин Ф.Г. Эстетика һәм социологизм. К., 1998; Галиуллин Т. Шәхесне гасырлар тудыра. К., 2003; Закирҗанов Ә. Заман белән бергә. К., 2004; Мухамадиев Р. Проблемы формирования татарской литературной критики (1905–1917). К., 1982.

*Т.Ш.Гыйләҗев.*

**ӘДӘБИ́ ТӘРҖЕМӘ́**, бер телдә язылган әсәрне, аның стилистик үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклап калырга тырышып, икенче телгә күчерү. Оригиналь иҗаттан аермалы буларак, Ә.т.гә оригиналга бәйлелек хас. Ә.т. — оригиналь әсәргә карата икенчел күренеш, ул иректе, төгәл һәм тәңгәл булырга

мөмкин. Татар әдәбиятында Ә.т. милли әдәбиятның бер өлешен тәшкил итә. Татар теленә беренче Ә.т.ләр (ирекле тәрҗемәләр) урта гасырларда ук барлыкка килә. Мәс., Котб, Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын тәрҗемә иткәндә, аның төп идея эчтәлеген, сюжетын һәм образларын, гомуми композициясен һәм кайбер поэтик формаларын саклап калып, шул ук вакытта әсәрне төркиләр тормышына, аларның дөньяны аңлауларына яраклаштыра. Шуңа күрә, «Хөсрәү вә Ширин»нең төркичәсен, бүгенге мәгънәдән чыгып, тәрҗемә дип атап булмый, бер үк вакытта ул оригиналь әсәр дә түгел, аны ярыморигиналь, ярымтәрҗемә әсәр дип атарга мөмкин. Котбның тәрҗемә принципларын дәвам иткән урта гасыр шагыйре Сәйф Сараи да Сәгъдинең «Гөлестан»ын төгәл тәрҗемә итми, ул аны кыскарта, үзгәртә: яңа мотивлар һәм вариацияләр кертә, үзенчәлекле сурәтләү чаралары куллана. Нәтиҗәдә, аның «Гөлестан би-т-төрки»е мөстәкыйль әдәби ядкәргә әверелә. Гадәттә, милли әдәбиятларның үсеш чорына (татар әдәбиятында 19 йөзнең ахыры — 20 йөзнең башы) тәрҗемәнең активлашуы хас була һәм алар оригиналь әсәрләр кебек үк кабул ителәләр. Бу чорда традицион рәвештә Шәрекъ әдәбияты әсәрләре: «Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә» (Г.Фәезханов тәрҗ.), Низаминың «Ләйлә вә Мәҗнүн»е (М.Максуд тәрҗ.), «Мең дә бер кичә»се (Ф.Халиди тәрҗ.) һ.б. тәрҗемә ителә. Шул ук вакытта рус әдәбиятына карата да кызыксыну уяна башлый. Татар теленә И.И.Хемницер, И.И.Дмитриев, И.А.Крылов әсәрләре тәрҗемә ителә. К.Насыйри — Л.Н.Толстой әкиятләрен, И.А.Крылов мәсәлләрен, Т.Яхин — А.С.Пушкин, А.Н.Афанасьев әкиятләрен, М.Өметбаев А.С.Пушкинның «Бакчасарай фонтаны»н тәрҗемә итә. 20 йөз башында татар әдәбиятына рус һәм төрек әдәбиятлары аша Көнбатыш Европа әдәбияты әсәрләре керә башлый. Мәс., француз әдәбияты татарларга төрек әдәбияты аша килеп ирешә. Татар теленә тәрҗемә ителгән беренче Көнбатыш Европа әдәбияты әсәре — Д.Дефоның «Робинзон Крузо» романы (С.Максуди тәрҗ., 1898). 20 йөз башында Ф.Әмирхан Г.-Х.Андерсен әкиятләрен, Р.Рәкыйби Г.Мопассанның «Милон атакай» («Папаша Милон») хикәясен, С.Рәмиев Ф.Шиллерның «Перчатка» балладасын, Н.Думави Вольтерның «Мегаполис» повестен, Г.Камал Мольерның «Саран» («Скупой») пьесасын, А.Дюма-улының «Камелияле ханым» («Дама с камелиями») романын һ.б. тәрҗемә итәләр. Тәрҗемәләрдә, башлыча, рус әдәбияты: А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.В.Гоголь, И.С.Тургенев, А.П.Чехов, А.Н.Островский, Л.Н.Толстой, М.Горький һ.б. әсәрләре өстенлек итә. Актив тәрҗемәчеләр: Г.Исхакый, Г.Тукай, С.Рәмиев, Г.Камал, С.Рахманкулов, И.Багданов, Г.Рахманколый һ.б. Тәрҗемәләр, кагыйдә буларак, ирекле рәвештә эшләнә. Күп очракта оригиналь әсәрнең авторы яки исеме күрсәтелми (мәс., «Шиллердан» дип кенә язалар). Аерым очракларда укучы тәрҗемәне тәрҗемәченең үз әсәре итеп кабул итә. Татар теленнән рус теленә дә тәрҗемәләр эшләнә. Мәс., үзе исән вакытта ук Г.Тукайның кайбер шигырьләре П.А.Радимов тарафыннан рус теленә күчерелә. 1930 елларда рус теленә Ш.Усманов хикәяләре, М.Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары, 1940 елларда М.Әблиевнең «Шәмсекамәр», Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», Г.Камалның «Беренче театр» пьесалары, Ш.Камалның «Матур туганда» романы, Г.Тукайның, Һ.Такташның күп кенә шигырьләре, А.Алиш әкиятләре тәрҗемә ителә. 1960 еллар башына рус теленә тәрҗемәләр күбәя, М.Гафури, К.Нәҗми, Ә.Фәйзи, Г.Кутуй, М.Җәлил, Г.Әпсәләмов, М.Әмир, С.Хәким, Ә.Ерикәй, Г.Бәширов әсәрләре тәрҗемә ителә. Совет чоры татар Ә.т. өлкәсендә чын мәгънәсендә «алтын чор» булып танылa, бу дәвердә татар әдәбиятын күп кенә тәрҗемәләр б-н баеткан тәрҗемә мәктәбе барлыкка килә. К.Басыйров, С.Әдһәмова, И.Гази, С.Фәйзуллин, А.Шамов, К.Миңлебаев, Р.Даутов, В.Зыятдинов, Ф.Гайнанова, Я.Халитов, Т.Нурмөхәммәтов, С.Ибраһимова, Л.Хәмидуллин (прозада); Ә.Фәйзи, Ф.Бурнаш, Ә.Исхак, Н.Арсланов, С.Баттал, Ш.Маннур, Ә.Ерикәй, Ә.Давыдов, М.Ногман, З.Нури, М.Шабаев, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим (поэзиядә); З.Солтанов, Г.Шамуков (драматургиядә) үзләрен татар теленә тәрҗемә итү осталары итеп танытаалар. 1960 еллар башына классик рус һәм совет әдәбияты әсәрләренең бик күбесе тәрҗемә ителә. Татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү өлкәсендә Г.Шәрипова, Г.Хантимерова, Р.Фәизова, Ә.Бадюгина (прозада); А.А.Ахматова, С.Н.Иванов, А.А.Тарковский, Д.С.Самойлов, С.И.Липкин, Р.Д.Моран, В.Ганиев, М.Д.Зарецкий, Н.Н.Беляев, Г.А.Паушкин, Р.Харис, Р.Бохараев, Р.Кожевникова, Л.Н.Григорьева (поэзиядә) эшли. Бу чор Ә.т.гә тәңгәл тәрҗемәгә омтылу хас. Рус классик әдәбиятыннан тыш, совет әдәбияты үрнәкләре дә тәрҗемә ителә: А.Н.Толстой, В.Я.Шишков, А.А.Фадеев, М.А.Шолохов, Д.А.Фурманов, Н.А.Островский, И.Г.Эренбург, В.Ф.Панова, К.Г.Паустовский, Н.Ф.Погодин, К.М.Симонов, М.М.Пришвин, А.Т.Твардовский, Н.С.Тихонов; балалар әдәбиятыннан С.Т.Аксаков, П.А.Бажов, В.Г.Короленко, С.Я.Маршак, С.В.Михалков, А.Л.Барто, В.В.Бианки, А.П.Гайдар, Б.С.Житков, В.А.Каверин, Л.А.Кассиль, В.П.Катаев, Н.Н.Носов һ.б. әсәрләре. 1990 еллардан башлап, илнең икътисади хәленә бәйле рәвештә, тәрҗемә эшчәнлеге сүлпәнәя төшә.

*Әд.:* Б а й р а м о в а Л.К. Татарстан: языковая симметрия и асимметрия. К., 2001; Н и г м а т у л л и н Э.Г. Диалог литератур: Указ. переводов произведений русской литературы на татарский язык. К., 2002; М и н н и б а е в К.С. Перевод — это искусство. К., 2004.

*К.С.Миңлебаев.*

**ӘДӘБИ́ ТЕЛ**, гамәлдә сөйләм һәм язма тел рәвешендә яшәп, төрле стильләрдә кулланылып, халыкның иҗтимагый һәм мәдәни тормышындагы барлык өлкәләрне тәэмин иткән, диалектларны берләштереп һәм гомумиләштереп, тарихи-традицион җирлектә нормалашкан үрнәк дәрәҗәдәге тел формасы. Ә.т. нормалары телнең үсеше нәтиҗәсендә формалаша. Тарихи үзгәреп торган, тел чараларын сайлау һәм куллану кагыйдәләре җыелмасы булган нормалар язма ядкәрләрдә ачык чагыла. Ядкәрләр гасырлар дәвамында теге яки бу халыкның сөйләмендә барлыкка киләләр һәм Ә.т.нең беренчел формасы булып саналалар.

Милләтләр барлыкка килгәнче тел нормаларында тотрыксызлык, Ә.т.нең сөйләм һәм язма төрләре арасында шактый зур аерма була. Милли чорга кадәрге төрки Ә.т. үсешендә феодализм дәверенә хас гомуми закончалыклар (чит телне язма-китап Ә.т.е итеп куллану) күзәтелә. Мәс., озак вакытлар иран һәм төрки халыкларның Ә.т. — классик гарәп теле була.

Борынгы төрки чорда нормалашкан татар Ә.т.енә хас фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләр 5–8 йөзләр язма ядкәрләрендә теркәлеп калган. Идел буе Болгар дәүләте оешкан һәм чәчәк аткан чорда (9 йөз — 13 йөзнең 1 нче яртысы) иске татар теленең җирле нормалары формалаша башлый. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» (1236) поэмасы, 1245 елда төзелгән глоссарий һәм «Коман мәҗмугасы» («Кодекс Куманикус», 1303) әлеге процесста зур роль уйныйлар. Идел буе Болгар дәүләте таркалганнан соң (13–14 йөзнең 2 нче яртысы) кыпчак теленә нигезләнгән, иске татар Ә.т.енә якын төрки Ә.т. үсеп чыга. Бу телдә Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342), Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353), Рабгузиның «Кыйссас әл-әнбия» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар», 1311), Сәйф Сараиның «Китаб-е Гөлестан би-т-төрки» (1391) әсәрләре иҗат ителә. Казан ханлыгы чорында (14–16 йөзләр) Идел буенда иске татар Ә.т.енең лексик, фонетик һәм грамматик нормалары формалаша. Бу телдә Мөхәммәдъяр, Колшәриф поэмалары һ.б. әсәрләре иҗат ителә. Авторлар тел-сурәтләү чараларыннан һәм халыкның сөйләменнән уңышлы файдаланалар. Казан ханлыгы чорында функциональ стильләрдән — публицистик, фәнни, эпистоляр, эш кәгазьләре стиле формалаша. 17–18 йөзләрдә Ә.т. нормаларының, функциональ стильләрнең үсеше тагын да көчәя. Мәүла Колый, Утыз Имәни Ә.т.не халыкның җанлы сөйләменә якынайту идеясен алга сөрәләр. 18–19 йөзләрдә татар телен өйрәнү һәм фәнни үзләштерү башлана; төрле дәреслекләр төзелә, телнең лексик байлыгы, аваз һәм грамматик төзелеше өйрәнелә. Халык авыз иҗаты әсәрләрен туплау һәм нәшер итү эше алып барыла (М. Иванов, Ә.Ваһапов, С.Күкләшев, В.В.Радлов, Н.Ф.Катанов һ.б. хезмәтләре). 19 йөз уртасында халык сөйләм телендә язылган әсәрләр барлыкка килә. Иске татар әдәби нормаларыннан милли Ә.т. гә күчеш чоры Г.Кандалый исеме б-н бәйле. Татар буржуаз милләте формалашу (19 йөз ахыры — 20 йөз башы) татар Ә.т.енең үсешенә зур этәргеч бирә. Ә.т. халык сөйләм теленә якыная, язма һәм сөйләм нормалары унификацияләнә (язма һәм сөйләм төрләр бердәй нормаларга китерелә) һәм аралашуның төрле өлкәләренә үтеп керә. Телнең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик һәм стилистик үзенчәлекләре, диалектизмнар, гади сөйләм гыйбарәләре һ.б. нормалаша. 1905–07 елгы рев-циядән соң Казан, Петербург, Мәскәү, Оренбург, Уфа, Уральск, Әстерхан, Сембер һ.б. шәһәрләрдә татар телендә газета-жур-

наллар нәшер итеlә башлый. Бу үз чиратында татар Ә.т.енең бердәм нормалары формалашуда мөһим роль уйный. Татар мәгърифәтчеләре К.Насыйри, Г.Ильяси, З.Бигиев, Ф.Халиди, язучылар Г.Тукай, Х.Ямашев, Г.Коләхмәтов, М.Гафури, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал һ.б. әсәрләрендә халык сөйләм телен классик язу теле элементлары б-н аралаштырып, татар Ә.т.е нормаларын барлыкка китерүгә һәм кабул итүгә зур өлеш кертәләр.

Татар Ә.т. нигезен урта диалект тәшкил итә. Ш.у. анда көнбатыш диалектының кайбер сөйләшләренең тел материалы да шактый урын алып тора. Ә.т. Уралда һәм Көнбатыш Себердә яшәүче татарлар теленә хас төрле диалекталь формаларны да үз эченә ала. Ш.у.к. *Татар теле*.

*Әд.:* Җ ә л ә й Л. Татар әдәбияты теле һәм матур әдәбият стиле турында // Совет әдәбияты. 1964. № 11; Х а к о в В.Х. Татар әдәби теле тарихы. К., 1993; З а к и е в М.З. Некоторые вопросы развития татарского литературного языка // Вопросы татарского языкознания. К., 1965. Кн. 2; В и н о г р а д о в В.В. Проблема литературных языков и закономерностей их образования и развития. М., 1967; История татарского литературного языка (XIII — первая четверть XX в.). К., 2003.

*В.Х.Хаков.*

**ӘДӘБИ́ ТҮГӘРӘКЛӘ́Р ҺӘМ ОЕШМАЛА́Р**. 1920 еллар башыннан татар язучыларын бер оешмага берләштерү, яңа төр иҗади оешмалар төзү омтылышлары ясала. 1923 елда К.Нәҗминең актив катнашында «Завод» исемле әдәби түгәрәк оештырыла, Ш.Усманов «Часовой» исемле әдәби берләшмә төзи. 1924 ел башында Казан коммунистларының үзәк клубы каршында «Октябрь» исемле зур әдәби берләшмә барлыкка килә. 1924 нең апрелендә Г.Кутуй һәм Г.Толымбайский б-н бергә язучыларның бер өлеше «Октябрь»дән чыга һәм мөстәкыйль «*Сулф*» берләшмәсен оештыра (тиздән таркала). Вакытлы матбугатта барлык язучыларны бер оешмага җыю мәсьәләләре ешрак күтәрелә башлый. Г.Нигъмәти совет язучылары җәмгыятен төзергә тәкъдим итә, ә Г.Ибраһимов аны оештыруның төп принципларын эшли. ВКП(б) өлкә комитетының матбугат бүлегендә 1927 нең 9 февралендә бу мәсьәлә буенча киңәшмә уздырыла һәм анда язучылар оешмасын төзү турында карар әзерләү өчен Г.Ибраһимов, Ф.Бурнаш, Г.Толымбай, Г.Нигъмәти катнашында комиссия төзелә. 1928 нең 5 маенда *Татар совет язучылары оешмасы* төзелә (1932 нең февраленә кадәр яшәп килә). *Татар пролетар язучылары ассоциациясе* (ТАПП) дә 1928 нең 27 сентябреннән 1932 нең 16 маена кадәр генә яшәп кала, ВКП(б) ҮКнең «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында» дип аталган карары чыкканнан соң, ул таратыла. 1920 еллар ахырында Крәстиян язучылар берлеге төзелә, соңрак ул Колхоз-пролетар язучылары берлеге итеп үзгәртелә (1932 дә таратыла). *Кызыл Армия һәм Флот әдәби оешмасының татар секциясе* (ТАТЛОКАФ) 1930–32 елларда эшли. ВКП(б) ҮКнең 1932 ел 23 апрель карарында «совет власте платформасын хуплаган һәм социалистик төзелештә катнашырга омтылган барлык язучыларны бердәм берлеккә туплау» зарурлыгы ассызыкланганнан соң, республика язучыларының беренче съездына актив әзерлек башлана. Съезд 1934 нең 25–29 июлендә уза, язучылар оешмасы ТАССР Язучылар союзы дип атала башлый. 1991 елдан *Татарстан Республикасы Язучылар берлеге*.

*Н.Г.Гыйззәтуллин.*

**ӘДӘБИЯ́Т БЕЛЕМЕ́**, матур әдәбиятның барлыкка килүен, үсешен, аның асылын, функциясен, тарихи-әдәби процесс закончалыкларын, тикшерү принципларын һәм ысулларын өйрәнә торган фән. Хәзерге Ә.б. катлаулы һәм динамик дисциплиналар системасыннан гыйбарәт. Ә.б.нең төп өч тармагына аеруча игътибар ителә: *әдәбият теориясе* әдәбият төзелеше һәм үсешенең гомуми законнарын өйрәнә; әдәбият тарихы әдәбиятның үткәнен процесс яки бу процессның аерым бер моменты буларак тикшерә; *әдәби тәнкыйть* иҗтимагый һәм әдәби күзлектән чыгып, хәзерге һәм үткән дәверләр әдәбияты мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. 20 йөз галимнәре (Д.С.Лихачёв, А.Л.Гришунин, В.Е.Хализев, Н.Г.Юзиев һ.б.) Ә.б.нә текстлар тарихын, аларның чыганакларын өйрәнү, әсәрләрне тергезү һәм аныклау эше б-н шөгыльләнә торган *текстологияне* дә кертәләр.

Ә.б.нең мөһим бер өлешен — әсәрләр структурасы һәм аларның бөтенлеге, язучылар иҗаты, әдәби юнәлешләр, ш.у. әдәби дәверләр турындагы өлешен поэтика фәне хасил итә. Поэтика Ә.б.нең төп тармаклары б-н нык бәйләнештә: әдәбият теориясе кысаларында — ул гомуми поэтика, ягъни теләсә нинди әсәрнең төзелеше турындагы фән; әдәбият тарихы яссылыгында — әдәби структураларның һәм аларның аерым өлешләренең үсешен өйрәнә торган тарихи поэтика; әдәби тәнкыйтьтә поэтика принциплары аерым бер әсәрне анализлаганда, аның төзелеш үзенчәлекләрен ачыклаганда чагыла. Ә.б.ндә стилистика да шундыйрак урын били.

Әдәби архив фәне, библиография, эвристика (атрибуция), палеография, дипломатика һәм сфрагистика, текстология, текстны аңлату, шәрехләү поэтикасы һ.б. Ә.б.нә ш.у. ярдәмче дисциплиналар буларак керә.

Татарларда, башка халыклардагы кебек үк, Ә.б. төшенчәләренең башлангычлары бик борынгы заманнарда мифологик күзаллаулар рәвешендә барлыкка килгән. Ислам дине кабул ителгәннән соң, гарәпләрдәге сүз сәнгате хакындагы фән — бәлягать — татар Ә.б.нең төп чыганакларыннан берсенә әверелә. Соңрак гарәп поэтикасы йогынтысында Шәрекъ фикер ияләре (әл-Фәраби, Әбүгалисина, Ибне Рөшд) хезмәтләрендә төрки *гарузы* формалаша башлый. Ләкин татарларда әдәбият үзе әдәби фикерләүнең яшәү формасы булып кала бирә. Авторлар әзер үрнәккә, элгәре иҗат ителгән әсәрләргә ияреп, охшатып язганнар. Еш кына әдәби әсәрләрнең үзләрендә үк Ә.б.нә караган аерым мәгълүмат урын алган. Урта гасырлар әдәбият һәм сәнгать фикерендәге табигый синкретизм Ә.б.нә караган махсус хезмәтләргә булган ихтыяҗны беркадәр каныгатьләндергән.

Татар Ә.б. мөстәкыйль фән булып 19 йөздә формалаша. Татар тарихына, фольклорына, этнографиясенә караган материаллар туплау һәм бастырып чыгару б-н берррәттән, милли әдәби ядкәрләрне барлау эше башлана. Ш.Мәрҗани хезмәтләре («Вафийәт әл-әсләф вә тәхийәт әл-әхләф» — «Элгәреләр һәм аларның киләсе буынга сәламнәре», 1883, кульязма; «Мөкаддимә әл-Вафийәт әл-әсләф вә тәхийәт әл-әхләф», 1883; «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» — «Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр», 1885–1890) библиография һәм аңлатмалар бирү характерында була. «Мөкаддимә әл-Вафийәт ...» хезмәтендә Мәрҗани Ә.б.нең берничә юнәлешен аерып күрсәтә: мәган (сүзләрнең үзенчәлекле урнашуы нигезендә логик яктан дөрес әчтәлек төзү); бәян (бер үк мәгънәне төрлечә бирү алымнары); бәдыйг (сүзнең матурлыгы, образлылыгы); гаруз (шигырь төзелеше). Поэзиягә багышланган бүлектә Шәрекъ поэзиясенең синкретик характерда булуы ассызыклана, сәнгатьнең типологиясе бирелә, әдәбиятның үзенчәлекләре һәм төп кануннары күрсәтелә. «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә «Нәһҗ әл-фәрадис» — «Оҗмахларның ачык юлы», «Бәдәвам» кебек төрки-татар ядкәрләре беренче мәртәбә тикшерелә, Болгар дәвере ядкәре буларак, Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» поэмасына бәя бирелә, Г.Утыз Имәни, Таҗетдин Ялчыгол, Һибәтулла ишан, Гали Чокрый, Мәхмүд әз-Заһид һ.б. татар шагыйрьләре турында мәгълүмат китерелә.

Мәгърифәтче галим К.Насыйри хезмәтләрендә Ә.б. мәсьәләләре аерым урын алып тора. «Кырык бакча» китабында (1880) автор татар халык әдәбияты үрнәкләре б-н таныштыра, фольклорның поэтик жанрлары турында мәгълүмат бирә, халык авыз иҗаты ядкәрләрен фәнни әйләнешкә кертүдә канунчылыкны шик астына куя. К.Насыйри фольклор текстының структурасы мәсьәләсен күтәрә, аерым әсәрләрне бәяләү критерийлары хакында сүз кузгата. «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» — «Әдәби мәҗлес йомгаклары» китабында (1884) Г.Утыз Имәни һәм Г.Кандалыйның аерым әсәрләренә ритмик һәм метрик анализ ясый. Күчмә сюжетлар принцибын кулланып, кайбер мифлар һәм әкиятләрнең чыганакларын ачыкларга омтыла «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре», 1896; «Казан татарлары әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» — «Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов» (1900, П.С.Поляков тәрҗемәсе).

20 йөз башында татар телендә вакытлы матбугат барлыкка килү әдәби тәнкыйтьнең мөстәкыйль тармак буларак аерылып чыгуына һәм үсешенә китерә. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Кәрам, Г.Гобәйдуллин һ.б. тәнкыйди мәкаләләрендә татар әдәбиятының вазифасы һәм сыйфаты, киләчәктә үсеш юллары мәсьәләләре күтәрелә. Нәкъ менә 1905–09 елларда вакытлы матбугат битләрендә әдәби тәнкыйть кысаларында әдәбият теориясенә (Г.Ибраһимов, Г.Исхакый һ.б.) һәм тарихына (Ф.Кәрими, Ф.Әмирхан һ.б.) нигез салына. Беренче фәнни хезмәтләр дөньяга чыга. Әдәбият тарихыннан — Җ.Вәлиди-

нең «Татар әдәбиятының барышы» (1912), әдәбият теориясеннән Г.Сәгъдинең «Мохтәсар кавагыйде әдәбия»се — «Кыскача әдәбият кагыйдәләре», (1911) һ.б. басылып чыга. 20 йөз башында әдәбият теориясе һәм әдәби тәнкыйть мөстәкыйль фәннәр буларак оешалар.

1920–30 елларда татар Ә.б.ндә эзләнүләр өч юнәлештә алып барыла: 1) татар әдәбиятының тарихы, аны чорларга бүлү, тәнкыйть (Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Г.Сәгъди, Г.Ибраһимов); 2) иҗтимагый-сәяси тарихның бер тармагы буларак әдәбият (Җ.Вәлиди, Г.Баттал); 3) Ә.б.нең аерым мәсьәләләре: төрләр һәм жанрлар, стиль, метод, юнәлешләр, әдәби процесс, укучыларның әсәрләрне кабул итү психологиясе һ.б. (Г.Нигъмәти, Х.Вәли, Г.Толымбай). Татар әдәбияты тарихы фән буларак формалаша.

Бу елларда катлаулы сәяси, идея-эстетик көрәш шартларында өстенлек иткән марксистик Ә.б. төп игътибарны сәнгатьнең иҗтимагый статусына, аның сыйнфый һәм идеологик көрәштәге роленә юнәлтә.

1940–50 елларда әдәбият белгечләре (М.Гайнуллин, Г.Халит, Х.Хәйри, Г.Кашшаф, Б.Гыйззәт) әдәби әсәрләрне бәяләүдә сыйнфый караш кысаларыннан чыгу юлын эзлиләр. Бу чорда аерым язучылар (Г.Ибраһимов, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, Һ.Такташ һ.б.) иҗатын өйрәнүгә кагылышлы әһәмиятле хезмәтләр языла.

1960–80 елларда татар Ә.б. әдәбият тарихының төрле чорларына кагылышлы гомумиләштерү характерындагы теоретик хезмәтләр барлыкка килү б-н үзенчәлекле: борынгы һәм урта гасырлар (Г.Таһирҗанов, Ф.Фасеев, Н.Хисамов, Р.Ганиева, Х.Миңнегулов һ.б.); 19 йөз (М.Гайнуллин, М.Гайнетдинов һ.б.), 20 йөз башы (И.Нуруллин, М.Хәсәнов, Ш.Садретдинов һ.б.), 1917 елдан соңгы дәвер әдәбияты (Г.Халит, Г.Кашшаф, Р.Мостафин, Ф.Миңнуллин һ.б.); ш.у. тарихи поэтика мәсьәләләрен (Н.Исәнбәт, Х.Госман, Н.Юзиев һ.б.), аерым төрләр һәм жанрлар теориясен һәм тарихын өйрәнүгә игътибар бирелә (А.Әхмәдуллин, Т.Галиуллин, Ф.Хатипов, Ф.Мусин, Н.Ханзафаров, Ф.Ибраһимова, Р.Сверигин һ.б.). Кайбер галимнәр семиотика (Й.Нигъмәтуллина), структурализм (А.Яхин) кысаларында тикшеренүләр алып баралар. 1985–2001 елларда алты томлы «Татар әдәбияты тарихы» дөнья күрә, анда татар әдәбияты һәм Ә.б. тарихына гомуми анализ бирелә.

1990–2000 еллар татар әдәбиятының аерым чорлары буенча (Х.Миңнегулов, Ә.Шәрипов, М.Гайнетдинов,Т.Галиуллин, Р.Исламов, Ф.Бәширов һ.б.) һәм аерым иҗатлар тарихына кагылышлы (М.Хәсәнов, Н.Хисамов, Ф.Мусин, Ә.Сәхапов, Р.Ганиева һ.б.) хезмәтләр языла. Текстология (М.Әхмәтҗанов һ.б.) һәм атрибуция (З.Рәмиев һ.б.) махсус игътибар үзәгенә алына. Моннан тыш, татар эстетик-фәлсәфи фикерендәге Ренессанс (Р.Ганиева, Й.Нигъмәтуллина, А.Сәяпова һ.б.), татар шигырь сәнгатенең тарихы (М.Бакиров), Ә.б.нең кайбер тармаклары үсеше (Р.Мөхәммәдиев, Ф.Галимуллин, Д.Заһидуллина, Э.Галиева, Т.Гыйләҗев һ.б.) хакындагы карашлар җәелдерелә.

*Әд.:* Гыйззәтуллин Н. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т. 5. К., 1989; Галимуллин Ф.Г. Эстетика һәм социологизм К., 1998; Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман. К., 2000; Мусин Ф. Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т. 6. К., 2001. Т. 6; Галиева Э.Р. Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. К., 2002; Основы литературоведения. М., 2000. *Д.Ф.Заһидуллина.*

**ӘДӘБИЯ́Т ТЕО́РИЯСЕ**, *әдәбият белеме* бүлеге, матур әдәбиятның фундаменталь сыйфатларын өйрәнә, аны анализлау методологиясен эшли торган фән. Ә.т. әдәби әсәр иҗат ителүнең асылын һәм гомуми закончалыкларын, әдәбиятның үсеш тарихын, аның иҗтимагый-эстетик вазифаларын, төп әдәби сыйфатларын, шулай ук аны кабул итү үзенчәлекләрен өйрәнә. Ә.т.нә түбәндәге мөһим фәнни дисциплиналар керә: 1) әдәбият гносеологиясе; 2) әдәбият онтологиясе; 3) әдәбият морфологиясе; 4) поэтика, семиотика һәм риторика; 5) рецептив эстетика; 6) герменевтика һәм аксиология; 7) тарихи поэтика һәм әдәбият тарихы диалектикасы; 8) әдәби культурология.

Татар әдәбият белеме чыганакларының берсе — гарәп тел-әдәбият белеме (бәлягать). Урта гасыр кануныңның төп кагыйдәләрен һәм принципларын үзенә туплаган фәнни-теоретик фикерләүнең бу катламы төрки телле шагыйрьләр өчен фәнни өскорма һәм теоретик кулланма була. Урта гасырларда татарларда әдәбият үзе теоретик күзаллауларның яшәү һәм үсешенең бер төре булып хезмәт итә. Авторлар үз әсәрләрен инде иҗат ителгән, кулланма булып хезмәт иткән әсәрләр үрнәгенә ияреп язалар. Әсәрнең структурасына кергән әдәби-теоретик мәгълүмат төрле характерда була: сәнгатьнең максаты һәм төп вазифалары, әдәбият типологиясе аңлатыла, жанр исемнәре күрсәтелә, әдәбият, метрика, сүз-сөйләм чаралары, әдәби иҗат турындагы фикерләр китерелә һ.б.

Милли әдәбиятның махсус фәлсәфи-эстетик концепциясен эшләү Ш.Мәрҗани эшчәнлеге б-н бәйле («Мөкаддимә әл-Вафийәт әл-әсләф вә тәхийәт әл-әхләф» — «Элгәреләр һәм аларның киләсе буынга сәламнәре»). 1882 елда К.Насыйри татар теленә фарсы әдәбият белгече Кайкавусның «Кабуснамә» поэтик трактатын тәрҗемә итә һәм аны шәрехли. Китапта әдәби әсәргә куела торган таләпләр, тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре, әдәби төрләр һәм жанрлар турында мәгълүмат китерелә. Бу хезмәт әдәбият белемендәге «өчтелле» үсеш чорына нокта куя. Моннан соң милли әдәбият Ә.т. б-н якыная башлый. К.Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» — «Әдәби мәҗлес йомгаклары» (1884) исемле трактатында Ә.т. мәсьәләләренә аерым бүлек багышлана. Анда татар әдәбиятының барлыкка килүе һәм вазифалары турында сүз алып барыла, фольклор һәм әдәби әсәрләргә (мәс., Г.Кандалыйның «Сәхипҗамал» поэмасына) ритмик һәм метрик анализ бирү омтылышы ясала.

Татар Ә.т. фән буларак 20 йөз башында формалаша. Аның беренче этабы (1907–13) «җәмгыятьчеләр» мәктәбе б-н бәйле. Алар методологик нигез итеп мәдәни-тарихи мәктәп концепциясен сайлыйлар, аны милли әдәбият үзенчәлекләренә туры китереп үзгәртәләр. Татар әдәбиятының гносеология, онтология һәм поэтика мәсьәләләре хәл ителә. «Җәмгыятьчеләр» мәктәбенең танылган вәкилләре арасында Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Ф.Кәрими, Г.Сәгъди, Гата Исхакый һ.б. була. «Җәмгыятьчеләр» концепциясе Г.Сәгъди хезмәтләрендә («Мохтәсар кавагыйде әдәбия» — «Кыскача әдәбият кагыйдәләре», 1911; «Мохтәсар кавагыйде әдәбиягә гыйлавә» — «Кыскача әдәбият кагыйдәләренә өстәмә», 1911; «Әдәбият ысуллары», 1912; «Әдәбият мөгаллиме», 1913) һәм милли әдәбият мәсьәләләренә багышланган күпсанлы мәкаләләрдә чагылыш таба. «Җәмгыятьчеләр» фикеренчә, әдәби әсәрләр укучыны яшәргә өйрәтергә, тәрбияләргә, милли тормышның актуаль сорауларына җавап бирергә, татар җәмгыятен камилләштерүдә катнашырга тиеш була. Алар әдәбиятны милләтнең халәтен билгели торган бер документ итеп карыйлар, аның төп вазифасы — кешенең әхлагын милли идея б-н тыгыз берлектә тәрбияләү, дип саныйлар. «Файда» принцибы аерым әдәби әсәргә яки әдәби процесска бәя биргәндә төп кыйммәткә әверелә.

Ә.т. формалашуының икенче этабы (1913–16) «рухиятчеләр» мәктәбе барлыкка килү б-н бәйле. Аның нигезләре Г.Баттал («Нәзарияте әдәбия» — «Әдәбият теориясе», 1913), Г.Ибраһимов («Әдәбият дәресләре», 1916), Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин, Н.Хәлфин һ.б.ның хезмәтләрендә салына. Алар концепциясенә беркадәр рус Ә.т.нең психологик юнәлеше һәм немец рухи-тарихи мәктәбе йогынты ясый. «Рухиятчеләр» мәктәбенең төп үзенчәлеге — әдәбиятны шәхеснe эчке яктан үзгәртүгә сәләтле «рух хакындагы сәнгать» буларак кабул итү. Әдәбият гносеологиясе һәм морфологиясе мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә. Әдәби әсәргә бәя биргәндә төп кыйммәт булып «матурлык» принцибы тора.

1917 дән соңгы революцион үзгәрешләр тәэсирендә әдәбият теоретикларының күбесе (Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти һ.б.) 19 йөздә әдәбият белемендә өстенлек иткән, әдәби әсәрне һәм әдәби процессны бәяләүдә мәдәни-тарихи мәктәп кысаларында эшләнгән принципларга әйләнеп кайталар. Нәтиҗәдә яңа, формаль тарихи мәктәпкә якын булган тәгълимат барлыкка килә. 1930 еллар башында татар Ә.т.ндә марксистик-ленинчыл эстетика тәмам урнаша (Г.Сәгъди, «Әдәбият теориясе», 1939). Ленинчыл чагылыш теориясе, әчтәлеккә нисбәтле категорияләр (сыйнфыйлык, партиялелек, халыкчанлык), азатлык хәрәкәте концепциясе әдәбият фәненең нигезен хасил итә. Алгы позицияләргә тарихилык принцибы чыга. Теория мәсьәләләре күбесенчә татар әдәбияты тарихы һәм тәнкыйте кысаларында карала башлый. Үз чиратында, Ә.т. кагыйдәләр һәм законнар җыелмасы буларак кабул ителә. Тарихи поэтика һәм әдәбият тарихы диалектикасы үсеш ала.

1970 еллар башында гына татар әдәбиятының теоретик нигезләрен өйрәнүдә үзгәрешләр тәгаенләнә. И.Нуруллин, Х.Госман, М.Мәһдиев, З.Мәҗитов, Ф.Ганиева һ.б. күренекле әдәбият галимнәре катнашында языл-

ган «Әдәбият теориясе» (т.1–3, 1977–80), «Әдәбият теориясенә кереш» (1987) хезмәтләре дөнья күрә. Аларда әдәби иҗатның эстетик һәм милли үзенчәлекләре ассызыклана. Шигырь төзелеше (Х.Госман, Х.Курбатов, М.Бакиров) һәм иҗат методлары мәсьәләләренә (Г.Халит, Р.Ганиева, Т.Галиуллин, А.Әхмәдуллин) аерым игътибар бирелә. Әдәбият онтологиясе һәм гносеологиясе мәсьәләләре исә элеккечә марксистик-ленинчыл тәгълимат кысаларында каралып килә. Тарихилык принцибы да үз көчендә кала: яңа иҗади формалар, әдәби процессның үзгә юнәлешләре яңа иҗтимагый һәм эстетик мәнфәгатьләрдән чыгып аңлатыла.

20–21 йөзләр чигендә татар Ә.т.ндә, әдәби иҗатның интернациональ һәм милли закончалыкларын берләштереп, совет чорының казанышларын саклап калырлык (беренче чиратта, әдәби әсәрне һәм әдәби процессны бәяләү критерийлары б-н бәйле рәвештә) концепция эзләү күзәтелә.

*Әд.:* З а һ и д у л л и н а Д. Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). К., 2000; Х а т и п о в Ф.М. Әдәбият теориясе. К., 2002; Теория литературы. Т. 1. Литература. М., 2005.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ӘДӘБИЯ́Т ҺӘМ НӘШРИЯ́Т ЭШЛӘРЕ́ БАШ ИДАРӘСЕ́** (Главлит), вакытлы матбугат басмаларының, радио һәм телевидение тапшыруларының эчтәлеген, театрлар, концерт-тамаша залларының репертуарын тикшерүне (цензураны) тәэмин итү буенча махсус оешма. 1922 елның июлендә ТАССР Мәгариф халык комис-ты каршында оештырыла. 1953 тә — ТАССР МС карамагындагы Матбугатта хәрби һәм дәүләт серен саклау идарәсе, 1965 тә ТАССР МС каршындагы Матбугатта дәүләт серләрен саклау идарәсе итеп үзгәртелә. 1922 дә, идарәнең җитәкчесе һәм сәркәтибеннән тыш, штаттан тыш вәкилләр ин-ты кертелә. ТАССРда алар 27 кеше була, 21 е — кантоннарда, 2 се — Татар нәшрияты, 3 есе — Газета-журналлар нәшрияты (Гажур), 1 се — «Красная Татария» г-сы редакциясе каршында. Идарә каршында *Академик үзәк*, РСФСР Эчке эшләр халык комис-ты каршындагы Баш сәясәт идарәсе, *Сәнгать эшлеклеләренең профессиональ союзы* (РАБИС), *Баш сәясәт-агарту комитеты* вәкилләреннән торган Репертуарлар комиссиясе оештырыла.

ВКП(б) ҮК Политбюросының 1931 ел 5 апрель карары һәм РСФСР ХКСның 1931 ел 6 июнь карары б-н барлык журналлар редколлегияләренә җаваплы сәяси мөхәррир вазифасы кертелә.

Газета, журнал, китап, карта, плакатлар, театр афишалары һ.б. идарә мөһере б-н генә басмага кабул ителә.

Идарә ел саен РСФСР әдәбият һәм нәшрият эшләре Баш идарәсе алдында хисап тота, ә көндәлек эшчәнлеген КПСС өлкә ком-тының агарту-аңлату (агитация) бүлеге б-н килештереп алып бара.

1980 еллар ахырында, үзгәртеп кору, иҗтимагый тормышның демократияләшүе һәм хәбәрдарлык ныгый барган заманда бетерелә.

*Г.С.Сабирҗанов, Х.А.Габделкаюмов.*

**ӘДӘ́М** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Әдәмсу елгасының сул кушылдыгы (Кече Чирмешән елгасы бассейны). Озынлыгы 15,3 *км*, бассейнының мәйданы 120,5 *км²*. Аксубай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Иске Чуаш Әдәмсуы авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Иске Татар Әдәмсуы авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 145 *м*, тамагыныкы — 112 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 33%. Ә. елгасының 0,4 *км* дан 6,6 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена (алар өлешенә 96% туры килә). Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Елганың үрге агымы кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 83 *мм*, ташу вакытындагы агым катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,011 *м³/с*. Язын суы каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада гомуми күләме 960 мең *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ӘДӘМСӘ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 10 *км* төньяктарак, Кичү елгасы буенда. 2002 елда 729 кеше (татарлар — 73%, руслар — 26%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Клуб. Китапханә. 1740 елларда Шыгырдан авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кичү Әдәмче исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында җамигъ мәчет, тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1915 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостена керә. 1920 дән ТАССР ның Чистай кантонында. 1959 да Ә.гә Рус Өтәшкәсе авылы кушыла. 1930 елның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 110 ир заты; 1859 да — 1333, 1897 дә — 2536, 1908 дә — 2731, 1920 дә — 2909, 1926 да — 1922, 1989 да — 735 кеше.

**ӘДӘМСУ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 12,1 *км*, бассейнының мәйданы 161 *км²*. Аксубай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Такталы авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Түбән Кондрат авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 107 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 24%. Ә. елгасының 0,8 *км* дан 15,3 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар, иң зурысы — Әдәм елгасы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Елганың үрге агымы кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 83 *мм*, ташу вакытындагы су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга декабрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,017 *м³/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ӘДИАТУ́ЛЛИНА** Әлмира Лотфулла кызы (псевд. Әлмира Саръяз) (8.7.1938, Башкортстан АССРның Илеш р-ны Сәеткол а.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1962 елда «Совет мәктәбе», 1964 тән «Азат хатын» (1991 елдан «Сөембикә», 1990–93 тә җаваплы сәркәтип) ж-лларында, 1993–94 тә «Бәйсезлек» г-тасында эшли. 1994–98 дә ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә матбугат эшләре җитәкчесе. Бер үк вакытта Татар иҗтимагый үзәге каршындагы Солдат ата-аналарын яклау ком-ты рәисе. 1997 дән «Мөслимә» г-тасы мөхәррире. Бер үк вакытта ТР мөселманнары Диния нәзарәте карамагындагы Мөселман хатын-кызлар ассоциациясе рәисе. Мәкаләләре «Ялкын», «Сөембикә» ж-лларында, «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан» г-таларында басыла. Күпчелек мәкаләләре яшь буынга хәрби-патриотик һәм әхлакый тәрбия бирү, татар халкының рухи хәзинәләрен яңадан тергезү мәсьәләләренә багышлана.

Ә с ә р.: Яшүсмер, синә // Ватанга тугрылык. К., 1979; Нигез ташлары // Ана бәхете. К., 1983; Сыерчыклар бездә кышлый // Көзге ачы җилләрдә. К., 1988.

*Әд.:* Ә м и р х а н о в М. Яктының җаны җәннәт // Сөембикә. 1998. № 7.

**ӘДҺӘ́МОВ** Алмас Мәхмүт улы (Александр Михайлович) (23.4.1923, Чистай кантоны Яңа Ибрай а.), генерал-майор (1978). Свердловск пехота уч-щесен (1941), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1951, Мәскәү) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Совет Армиясендә командирлык вазифаларын башкара. 1973–87 елларда СССР Оборона министрлыгының Баш инспекциясендә өлкән инспектор. Ике Кызыл Йолдыз, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2001.

**ӘДҺӘ́МОВ** Равил Искәндәр улы (31.7.1937, Казан), мәгълүмат технологияләре гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1982), проф. (1984), ТАССРның атказ. фән һәм техника (1985), РФнең атказ. фән (2002) эшлеклесе. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1961). 1963 елга кадәр Оренбург машиналар төзү з-дында эшли. 1963 тән (бүленеп, 1966–76 да Авиация технологияләре фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лы әйдәп баручы конструкторы, сектор башлыгы, 1985–87 дә КПСС-ның Татарстан өлкә ком-тында фән һәм уку

йортлары бүлеге мөдире) Казан техника ун-тында: проректор (1987–92), двигательләр җитештерү технологиясе каф. мөдире (1999 дан).

Хезмәтләре җитештерүнең технологик процессларын комплекслы автоматлаштыруга һәм двигательләрне электрон хисаплау машиналары кулланып сынауга карый. СССРда беренчеләрдән булып авиация двигательләрен сынау өчен автоматлаштырылган системаларны һәм оптималь технологик процесслар төзү мәсьәләсен күтәрә һәм хәл итә; автоматлаштырылган технологияләрне математик һәм имитацияләп модельләштерүне гамәлгә ашыра (1966). Автоматик сынау процессын компьютерда өйрәтү комплексларын эшли. 1985–88 дә ТАССР ЮС депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Автоматизация мелкосерийного машиностроительного производства и качество продукции. М., 1983; Автоматизированные испытания в авиастроении. М., 1989.

*Әд.:* Казанский авиационный институт / Под ред. Ю.В.Кожевникова. М., 1986; Казанский авиационный институт / Под ред. Г.Л.Дегтярева. М., 1992.

**ӘДҺӘ́МОВА** Гөлчәчәк Мирзаһит кызы (31.8.1927, Аксубай р-ны Яңа Ибрай а.), педагог, филол. фән. канд. (1963), ТАССР, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1978, 1985). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1951). 1951–57 елларда Биектау р-ны Мүлмә урта мәктәбендә завуч, директор. 1958 дән Казанда: 1962–63 тә Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир урынбасары, 1963–87 дә РСФСР Мәгариф министрлыгы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лында, 1988–2001 дә Казан пед. көллиятендә. Татар әдәбиятыннан дәреслекләр, программалар һәм укытучылар өчен методик кулланмалар авторы, хрестоматияләр төзүче.

Х е з м.: Әдәбият дәресләрендә укучыларны комплекслы тәрбияләү. К., 1981; VII класста әдәбият дәресләре. К., 1986; Изучение родных литератур в национальных школах РСФСР. К., 1982 (автордаш).

**ӘДҺӘ́МОВА** Сәрвәр Сабир кызы (5.4.1901, Оренбург губ. Троицк ш. — 10.11.1979, Казан), язучы, тәрҗемәче. Томск (1920–23), Казан (1929–31) ун-тларында укый. 1925 елда балалар өчен язылган беренче пьесасы дөнья күрә. «Дуслар» (1948, рус теленә тәрҗемәсе «Друзья», 1959), «Минем апалар» (1953), «Тубалбаш» (1958) исемле хикәя җыентыкларында яшь геройларның үзара дуслыгы, кыюлыгы һәм тапкырлыгы сурәтләнә. 1979 да «Тормыш сынавы» дигән истәлекләр китабы басылып чыга. Ә. иҗатында әдәби тәрҗемә эше зур урын алып тора. Аның тәрҗемәсендә М.Горькийның 6 томлык «Сайланма әсәрләр»е (1947–53), А.С.Пушкинның «Мәрхүм Иван Петрович Белкин хикәяләре» (1936), Л.Н.Толстойның «Алпавыт иртәсе» (1935), «Кавказ әсире» (1947), Д.Дефоның «Робинзон Крузо» (1936), В.Василевскаяның «Салават күпере» (1944), М.Ауэзовның «Абай» романы (1957) һ.б. әсәрләр татар укучысына барып ирешә. Нахакка репрессияләнә (1938); 1940 елда аклана.

Ә с ә р.: Хикәяләр, истәлекләр. К., 1971; СИБЛАГтан хатлар // Әдәби мирас. К., 1996.

*Әд.:* Ә х м ә т А. Язучы һәм тәрҗемәче // Совет әдәбияты. 1951. № 4; Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Г и н и я т у л л и н а А.К. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.


*Ф.Г.Галимуллин.*

**ӘҖӘКҮ́Л** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы ярындагы пристань. 2002 елда 340 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Катнаш терлек азыгы әзерләү з-ды. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 1722 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, көймәләр ясау б-н шөгыльләнә, елга пристаньнарында ялланып көн күрә. Мәчет турында беренче тапкыр 1831 дә телгә алына. 1917 дә монда земство мәктәбе эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1510 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында Ә.дә «Урал» к-зы оештырыла, 1958 дә ул «Үзәк» к-зы составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Такталачык волостенда була. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 231, 1859 да — 409, 1870 тә — 443, 1884 тә — 441, 1906 да — 411, 1913 тә — 580, 1926 да — 590, 1938 дә — 934, 1949 да — 538, 1958 дә — 446, 1970 тә — 323, 1979 да — 303, 1989 да — 359 кеше.

**ӘҖЕ́М** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 211 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзнең 2 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.дә мәчет, җил тегермәне, ярма ярдыру тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1289 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1859 да — 480, 1897 дә — 899, 1908 дә — 1045, 1926 да — 490, 1938 дә — 446, 1949 да — 320, 1958 дә — 333, 1970 тә — 367, 1979 да — 314, 1989 да — 249 кеше.

**ӘҖЕ́М МӘЧЕТӘ́**, Казанда 19 йөз татар дини архит-расы истәлеге. Пләтән бистәсендә урнашкан. 1887–90 елларда сәүдәгәр М.М.*Әҗимов* иганәсенә милли романтик юнәлештәге эклектика формаларында төзелә. Архитекторы билгесез. Манарасы җиргә утыртылган; ике заллы мәчетләр төренә керә. Бер катлы кирпеч мәчет. Аерым ишеге булган тәрәзәле эргә каты хуҗалык максатларында файдаланылган. Почмаклары түгәрәкләнгән турыпочмаклы бина дүрт кыеклы сәзәк түбә б-н капланган, көньяк диварында биш кырлы михраб чыгынтысы, төньягында 51 *м* биеклектәге өч катлы манарасы урнашкан. Беренче зал б-н манара арасындагы өчпочмаклы вестибюльнең ян-ягында мәчеткә ишегалдыннан һәм урамнан керү ишекләре бар. Вестибюль б-н заллар үзара анфилада ысулында тоташкан, алар дагасыман тәмамланган биек а́ркалы тәрәзәләр аша яктыртыла. Зур залның яссы түшәмен дүрт төз колонна күтәреп тора. Тышкы бизәлешендә Шәрекъ-мөселман мотивлары өстенлек итә. 1930 еллардан бирле Ә.м. эшләми, бинасы төрле оешмаларга бирелә. 1990 да мөселманнарга кайтарыла. Ә.м.нең фасадларын яңарту, интерьерларын үзгәртеп кору арх. Р.В.Билалов проекты б-н башкарыла (1990–92). Михраб уемы үсемлек рәвешендәге бизәкләр һәм ташка чокып язылган Коръән аятьләре б-н бизәлгән, эргә катында хатын-кызлар өчен гыйбадәт кылу залы һәм мәдрәсәнең дәрес бүлмәләре урнашкан.




Әҗем мәчете. Казан. 1887–90. 1. 20 йөз башы фотосы; 2. Төп гыйбадәт залы. Хәзерге күренеш.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Х а л и т о в Н. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Н.Х.Халитов, Х.Г.Надыйрова.*

**ӘҖИ́МОВ** Йосыф Исмәгыйль улы (12.6.1936, Казан), химик-технол. процесслар б-н идарә итү гыйлеме белгече, техн. фән. д-ры (1986), проф. (1988), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), шунда ук эшли. 1980 елдан Казан фин.-икътисад ин-тында технол. каф. мөдире. Хезмәтләре хим. кибернетика өлкәсенә карый. Сферик дары табу технологиясенең матем. моделен һәм автоматик идарә итү системасын эшли һәм гамәлгә кертә. Фазалар бүленеше чикләренең үзгәрүле шартларында гетероген полимер системалардагы процессларны матем. модельләү методикасын тәкъдим итә. 1990 нан экология, табигатьтән

файдалану, полимер материаллар җитештерү калдыкларын эшкәртүнең заманча технологияләре проблемалары б-н шөгыльләнә.

Х е з м.: Разработка АСУТП производства сферических порохов. М., 1982; Природопользование. К., 1999.

**ӘҖИ́МОВ** Мортаза Мостафа улы (1819, Казан — 30.10.1887, шунда ук), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре, нәселдән күчмә шәрәфле граждан (1870). Атасы Мостафа Нәзир улы (1780 — 25.8.1865) 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре була. Аның тарафыннан 1833 елда нигезләнгән кытат һәм бәз-тукыма ману ф-калары вафатыннан соң улына кала. 1870 тә Ә. крахмал ясау з-дын нигезли (елына уртача 2,5 мең пот крахмал җитештерелә). Зәңгәр мәчет каршындагы мөселман мәхәллә мәктәбе өчен флигель төзетә. Ә. ярдәмендә Казандагы иң матур таш мәчет һәм аның каршындагы мәдрәсә бинасы төзелә (к. *Әҗем мәчете*). Вафатыннан соң гаиләсе бөлгенлеккә төшә, улы Мөхәммәтша (12.4.1874 — ?) 1899 да мещаннар катлавына күчерелә.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Азимовы, братья Мишкины и другие // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1996. № 3/4; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998. *Л.М.Свердлова.*

**ӘҖИ́МОВ** Рәшит Сиражетдин улы (15.10.1915, Әстерхан губ., Царево өязе Келәнче а. — 2.2.1981, Казан), хокук белгече, хокук фән. д-ры (1972), проф. (1973). Казан юридик ин-тын тәмамлый (1938). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–52 елларда Казан юридик ин-тында укыта. 1952 дән Казан ун-тында: 1952–67 дә юридик ф-т деканы, 1961 дән гражданлык хокукы һәм мәхкәмә эшләрен карау процессы каф. мөдире.

Хезмәтләре гражданлык, хезмәт, хуҗалык хокукына карый. Урта мәктәпләр өчен хокук белеме дәреслеге авторы.

Х е з м.: Понятие, правовая природа и правосубъектность межколхозных организаций. К., 1965; Межколхозные организации и объединения по строительству и регулирование отношений с их участием. К., 1974. *Е.Б.Долгов.*

**ӘҖМӘ́К**, к. *Васильево.*

**ӘҖМӘКӘ́Й** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Шилнә елгасы буенда. 2002 елда 163 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1773 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында авыл Пустошь Исекеева, Азьмекеево исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, җайдаклар өчен камчы үрү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.дә мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне була. 20 йөз башында монда икмәк кибете урнаша. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Макарьев волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1795 тә — 80 ир заты; 1859 да — 580, 1897 дә — 962, 1913 тә — 1207, 1922 дә — 990, 1926 да — 793, 1938 дә — 723, 1949 да — 663, 1958 дә — 486, 1970 тә — 488, 1979 да — 385, 1989 да — 189 кеше.

**ӘҖМӘ́Р** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 55 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Актай елгасы буенда. 2002 елда 365 кеше (татарлар — 69%, руслар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә эшли. 1656 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Татар Әҗмәре исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык, мичкә ясау, агач эше, арба көпчәкләре ясау, җеп эрләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.дә почта станциясе, этап йорты, мәчет (1863 тә төзелә), мәктәп, 2 тегермән, йон тетү урыны, 3 ярма яргыч, 6 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1245,5 дис. тәшкил итә. 1914 тә авылда рус-татар мәктәбе ачыла. 1950 елларда Ә.гә Куйбышев сусаклагычы киңәю зонасына кергән Христофоровка авылы халкы күчеп утыра. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Спас өязе Николо-Пичкас волостена керә. 1920 дән ТАССР ның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935–91 дә — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 68 ир кеше; 1859 да — 352, 1897 дә — 772, 1908 дә — 872, 1920 дә — 936, 1926 да — 905, 1938 дә — 885, 1949 да — 612, 1958 дә — 813, 1970 тә — 676, 1979 да — 569, 1989 да — 437 кеше. Авыл янында *Әҗмәр комплексы* саклана.

*Әд.:* Спасские сказания. К., 2003.

**ӘҖМӘ́Р АВЫЛЛЫГЫ́**, археологик истәлек; 10–13 йөзләрдәге болгар торулыгы. Спас р-ны Әҗмәр авылыннан 2,5 *км* көнбатыштарак урнашкан. *Әҗмәр комплексы* составына керә. 1961 елда Е.П.Казаков тарафыннан ачыла. Мәйданы — 600 мең *м*². Торак һәм хуҗалык корылмалары, һөнәрчелек остаханәләре калдыклары тикшерелә. Зур күләмдә табылган хезмәт һәм сугыш кораллары, көнкүреш һәм бизәнү әйберләре, ат дирбиясе һәм кием-салым детальләре халыкның игенчелек, терлекчелек, балыкчылык һәм төрле һөнәр-



**Әҗмәр авыллыгы.** 1. Әҗмәр авыллыгыннан табылган бронза матрица. Идел буе болгарлары. 10 йөз ахыры – 11 йөз; 2. Каешка беркетелә торган алтынланган көмеш тагылмалар. Идел буе болгарлары. 10 йөз ахыры – 11 йөз; 3. Урта Азиядә төсле металлдан эшләнгән әйберләр һәм аларга охшатып ясалган эшләнмәләр; 4. Бронза асылма; 5. Каеш җыелмасы тагылмалары. Төсле металл; 6. Ук очлыклары; 7. Көнкүреш әйберләре (1–18): йозак, бронза; йозак ачкычлары, бронза; тартмачык тоткычлары, тимер; йөзекләр, бронза һәм көмеш; көзгеләр, бронза.

ләр б-н шөгыльләнүен күрсәтә. Е.П.Казаков фаразынча, 10 йөз ахыры — 11 йөздә Ә.а. Идел-Чулман юлында төп сәүдә пунктларының берсе булган, күпсанлы табылдыклар — үлчәү детальләре, төрле формадагы кечкенә герләр (200 данәдән артык), көмеш дирһәмнәр һәм Көнбатыш Европада сугылган тәңкәләр, Шәрекъ илләреннән, Русьтан, Чулман алды төбәгеннән китерелгән әйберләр һ.б. нәкъ шул хакта сөйли. Монгол яуларыннан (1236) соң авыл бушап кала.

*Әд.:* к. Әҗмәр комплексы мәкаләсе ахырында.


**ӘҖМӘ́Р КО́МПЛЕКСЫ** (археол.). Актай елгасының сул ярында Спас р-нының Әҗмәр авылы янында урнашкан. Беренче мәртәбә Ә.к.ның истәлекләре 1946 елда Н.Ф.Калинин, соңрак Е.П.Казаков (1961 дән), А.Х.Халиков һәм Е.А.Халикова (1974) һ.б. тарафыннан тикшерелә. Балчык, сөяк һәм металлдан эшләнгән әйберләрнең күптөрле комплексында чагылыш тапкан таш гасыр торулыкларын, Буралы курган, Ананьино, Имәнкискә, Болгар археол. культураларына нисбәтле каберлекләрне үз эченә ала. Әҗмәр IV каберлегендә Казан яны культурасына караган 21 кабер (якынча б.э.к. 10–9 йөзләр) өйрәнелгән. Әҗмәр VII каберлегендә Ананьино культурасына мөнәсәбәтле 39 кабер тикшерелгән (б.э.к. 8 йөз), әлеге культура халкының катлаулы җирләү йоласын чагылдырган корбан бирү комплексы, «Мәрхүмнәр йортлары» калдыклары, каберләр өстенә куелган зур ташлар, каберләрдә балчык савыт-саба, көнкүреш кирәк-яраклары, корал, ат дирбиясе әйберләре табылган. IX Әҗмәр каберлегендә Имәнкискә культурасына караган 90 кабер (6–7 йөзләр) тикшерелгән, мәет яндыру эзләре ачыкланган, балчык савыт-саба калдыклары һ.б. әйберләр табылган. Идел буе Болгар дәүләте чорыннан мөселман каберлекләре, «Кызлар каласы» буларак мәгълүм шәһәрлек, ш.у. берничә торулык, ш.и. *Әҗмәр авыллыгы* сакланган. Ә.к. терр-ясе Куйбышев сусаклагычын төзегәндә җимерелә; 1961 дән ел саен Әҗмәр авылы янында саклау-коткару эшләре башкарыла.

*Әд.:* Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье. К., 1986; К а з а к о в Е.П. Булгарское село X–XIII веков низовий Камы. К., 1991; ш у л у к. Измерский VII могильник // Памятники древней истории Волго-Камья. К., 1994; ш у л у к. Измери — главный торговый пункт Волжской Болгарии (конец 10–11 вв.) // Славяне, фино-угры, скандинавы, волжские булгары. СПб., 2000.

*Е.П.Казаков.*


**ӘҖМӘ́Т** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2002 елда 127 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 1906 да нигез салына. 1911 елгы мәгълүматларга караганда, халкы игенчелек б-н бергә киез итек басу б-н дә шөгыльләнә. 1917 гә кадәр авыл җәмәгатенең имана җире 802 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында Ә.тә «Әҗмәт» к-зы оештырыла, 1950 елларда ул «Таң» к-зына кушыла. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Такталачык волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1913 тә — 458, 1922 дә — 534, 1926 да — 519, 1938 дә — 410, 1949 да — 277, 1958 дә — 296, 1965 тә — 293, 1970 тә — 276, 1979 да — 234, 1989 да — 137 кеше. Авыл янында борынгы *Әҗмәт каберлеге* урыны сакланган.







**Әҗмәр комплексы.** 1. VII Әҗмәр каберлеге: 1 — ышкы, мәрмәр; 2 — ук очлыгы, сөяк; 3 — кыска саплы сөңге очлыгы, чакматаш; 4 — сөяк эшләнмәләр; 5 — авызлык, бакыр; 6 — калак, бакыр; 7–8 — тәгәрмәч чөйләре, сөяк; 9 — сөяк эшләнмәләр; 10–11 — чигә чулпылары, бакыр; 12 — авызлыкның йөгәнгә беркетелә торган өлеше, сөяк; 13–14 — сөяк казыклар; 15 — сөңге очлыгы, тимер. 2. Бронза кинжал. Ананьино культурасының VII Әҗмәр каберлеге. 3. Төсле металлдан бизәнү әйберләре. Кушнаренко культурасының XII Әҗмәр каберлеге. 9–10 йөзләр арасы. Элгәре Болгар чоры.



Әҗмәт каберлегендәге әйберләр комплексы: 1–2. Пыяла муенсалар; 3. Сердолик муенса; 4–14, 17. Бронза һәм көмеш эшләнмәләр; 15. Тимер пычак; 16, 18. Керәч савытлар.

**ӘҖМӘ́Т КАБЕРЛЕГЕ́**, *Чиялек культурасы* истәлеге, Актаныш р-ны Әҗмәт авылы янында урнашкан. 1971–76 елларда Е.П.Казаков тарафыннан өйрәнелә. 12–15 йөзләргә караган 100 мөселман кабере тикшерелә, алар 2 төркемгә бүленә. 1 нче төркемдә (әүвәлге чор) мәетләрнең башы көньяккарак борылган хәлдә көнбатышка каратып күмелгән, мәҗүсилек йоласы элементлары (утка табыну) сакланган. Кайбер каберләрдә мәеткә киерелгән битлек кисәкләре, үрелмә бизәкләр төшерелгән савыт-саба, бизәнү әйберләре, Үзбәк хан чоры акчалары һ.б. табыла. 2 нче төркемдә (соңрак чор) мәетләрнең башы төньяккарак борылган хәлдә көнбатышка каратып күмелгән. Кабердә әйберләр табылмый. Кайбер тикшеренүчеләр фаразынча, 1 нче төркемгә кертелгән каберләр Көньяк Уралдагы ислам динен кабул иткән һәм, ассимиляцияләнеп, Идел-Урал тирәләрендә яшәгән төрки халыклар составына кергән угыр кабиләләренә карый дип санала.

*Әд.:* К а з а к о в Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1977; Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989. № 638.

*Е.П.Казаков.*

**ӘҖМӘ́ТОВ** Миңлебай Габдерәшит улы (1792 — 1858), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, кәҗүл күне җитештерү з-ды хуҗасы. Үз з-ды җитештергән күннәр б-н сәүдә иткән. 1839–44 елларда Казан шәһәре башлыгы, 1844 тә Татарлар ратушасы ратманы (башлыгы). Аның эшен улы Мортаза (1824 — ?) дәвам иттерә: баштарак 1 нче гильдия сәүдәгәр, 1874 тән мещаннар катлавына күчерелә.

**ӘҖМИ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәллә елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,3 *км*, бассейнының мәйданы 45,7 *км*$^2$. Азнакай р-ны терр-ясе буйлап ага. Елга башы Кызыл Сукачы авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы

Әлки авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагыныкы — 148 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 62%. Елганың 0,7 дән алып 3 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1–3 *л/с·км²*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр.

**ӘЗӘРБАЙҖА́Н** (Әзәрбайҗан Республикасы). Мәйданы — 86,6 мең *км²*. Халкы — 8113 мең кеше (2001). Башкаласы — Баку шәһәре. Әзәрбайҗан җиренә татарлар 19 йөзнең 1 нче яртысында килеп урнаша башлыйлар. 19–20 йөзләрдә Баку нефть-газ ятмалары сәнәгый районында эш башлангач, 1920–30 елларлардагы нэп, индустрияләштерү һәм күмәкләштерү чорында монда Идел-Урал төбәгеннән халык күпләп килеп урнаша. Ә. да Кавказдагы иң зур татар җәмгыяте (1989 елгы халык исәбе буенча — 28019 кеше) барлыкка килә. Татарларның 98%ы — шәһәрләрдә, ш.и. Бакуда 24,3 мең кеше яши. 1970 еллар ахырыннан татар халкы кими бара, 1990 еллар башында эмиграция массакүләм төс ала. Татарларны һәм Татарстанны Ә. б-н тарихи, сәяси, икътисади, фәнни, мәдәни һ.б. элемтәләр бәйләп тора. Борынгы татар әдәбиятына *Низами Ганҗәви* иҗаты, яңа чор татар шагыйрьләренә (С.Рәмиев, Н.Думави һ.б.) С.*Нәсими* әсәрләре сизелерлек йогынты ясый. 1906 елда С.-Петербургта татар һәм әзәрбайҗан телләрендә «*Дума*» г-тасы нәшер ителә. 1908 дә Кавказда Г.*Кариев* җитәкчелегендә составында әзәрбайҗан артистлары, репертуарында әзәрбайҗан авторларының (к. *Казан-Кавказ мөселман артистлары ширкәте*) пьесалары да булган татар театр труппасы гастрольләре булып үтә. СССР төзелгәч, Татарстан б-н Ә. арасындагы традицион мәдәни һәм хуҗалык-икътисади бәйләнешләр тагын да үсә. Ә. һәм татар галимнәре уртак тырышлыгы б-н гарәп язуыннан латин графикасына күчүнең төп мәсьәләләре хәл ителә (к. *Яңалиф*), Бакуның фәнни ин-тлары һәм югары уку йортларында атаклы татар галимнәре Г.С.*Гобәйдуллин*, С.А.Габдерәшитов, Х.И.Әмирханов һ.б.; М.Азизбәков исем. Ә. театрында СССРның халык артисты М.Й.*Даутова* эшли. 1930–38 дә Бакуда атна саен татарча «*Баку эшчесе*» г-тасы нәшер ителә. 1940 елларда Ә. Татарстанның нефть сәнәгате өчен кадрлар әзерләү үзәге була. *Татарстан нефть машиналары төзү институты* Ә. нефть машиналары төзү фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык ин-тының Казан филиалы буларак оештырыла. 1993 тән Бакуда ТРның Ә.дагы тулы вәкаләтле вәкиллеге эшли; «Туган тел» татар мәдәни җәмгыяте (1990 нан), «Әзәрбайҗан татар җәмгыяте» (1996 дан), «Әзәрбайҗан–Татарстан» татар җәмгыяте гамәлдә. Ш.Мәрҗани исем. Татар хәйрия фонды бар. Казанда «Әзәрбайҗан» милли-мәдәни автономиясе (2000 нән) эшли.

*А.И.Ногманов.*

**ӘЗИ́** (Азеево) авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 85 *км* көньяктарак, Әзи елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 360 кеше (руслар — 71%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 19 йөз башында Әзи Пүчинкәсе исеме б-н Вятка губернасының Сарапул өязе Козловка волостеның Нарядово авылы крәстияннәре нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сумала кайнату б-н шөгыльләнә, Самара губернасына көнлекле эшкә йөри. 1920 гә кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостена керә. 1921 дән — ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 489, 1887 дә — 779, 1920 дә — 1114, 1926 да — 656, 1938 дә — 798, 1949 да — 568, 1958 дә — 721, 1970 тә — 570, 1989 да — 394 кеше.

**ӘЗИ́** (С а л а г ы ш) елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Ижның сул кушылдыгы. Озынлыгы 23 *км*, бассейнының мәйданы 174 *км²*. Әгерҗе р-нында Сарапул калкулыгыннан ага. Елга башы Әзи авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак, тамагы Салагыш авылыннан көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 55 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 54%. Түбән өлешендә елга тугае сазланган. Иң зур кушылдыклары Чушкан һәм Сангас (уң кушылдыклар). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,46 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле елга башында 0,1 *л/с·км²* дан түбән агымында 1–3 *л/с·км²* га кадәр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 46 *мм*, ташу вакытындагы су катламы 40 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,036 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елганың су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**әл-ӘЗҺА́Р** (әл-Җамигат әл-Әзһар — الأزهار جامعة), Каһирәдәге мәчет һәм ислам ун-ты. Мәчет 972 елда төзелә. Мәчет каршында 996 да ачылган мәдрәсә 11 йөз ахырында бөтен мөселман дөньясына мәгълүм булган университет тибындагы уку йортына әверелә. Хәзерге вакытта әл-Ә. — барлык мөселман илләре өчен дин әһелләре әзерләүче эре үзәк. Әл-Ә.да Исламият тикшеренүләре академиясе, дини ин-тлар һәм оешмалар эшли. Анда күп кенә татар зыялылары: Г.Баруди, Г.Баттал, М.Бигиев, З.Кадыйри, З.Камали, татар мәдәниятенең башка эшлеклеләре укыган. 1990 еллардан әл-Ә.да татар руханиларын укыту традициясе яңартыла. Татарстанның кайбер дини уку йортларында әл-Ә. ун-ты укытучылары һәм аны тәмамлап кайткан мөгаллимнәр укыта.

**ӘЙДИ́** (Әйделдинов) Тәүфикъ Рамазан улы (1.5.1941, Мәскәү өлкәсенең Шатура р-ны Туголесский Бор пос. — 2.4.2001, Казан, Биектау р-ның Әлдермеш авылында җирләнгән), язучы, ТССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Казан ун-тын (1973), СССР Язучылар берлеге каршындагы югары әдәби курсларны (1985, Мәскәү) тәмамлый. 1985–97 елларда «Казан утлары» ж-лында эшли, 1997–98 дә «Татарстан» ж-лының баш мөхәррире урынбасары. 1998 дән «Аваз» хосусый нәшрияты директоры. Әсәрләре 1967 дән басыла башлый. «Яңа уен» (1988), «Дачада» (2000) исемле хикәя җыентыклары, «Божра» детектив повесте (1978), «Елан угы» (1991), «Иблискә ришвәт» (2000) маҗаралы романнары, татарлар һәм кардәш халыкларның тормышына, татар мәдәниятенең халыкара багланышларына караган «Исәнме, Гагаузстан» (1991), «Йөртә безне язмышлар» (1992), «Дунай буендагы кардәшләр» (1994) документаль повестьлары авторы. «Кайда да кадерле» (1984), «Безгә ни булды?» (1991) җыентыкларындагы эссе һәм публицистик мәкаләләре татар халкының күренекле вәкилләренә, татарларның милли яңарыш проблемаларына һәм үзаңы үсешенә багышланган. Болгария, Германия, Кипр, Румыния илләренә сәяхәтләре вакытында туган кичерешләре «Оҗмах утравы» (1999), «Кардәшләр кочагында» (2000) җыентыкларында тупланган. Төрки телле әдәбиятлар вәкилләреннән С.Моратбәков, А.Сатаев, Ә.Мохтар, Ү.Һашимов әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Г о с м а н о в  М. Жанрның язмышы һәм яңаруы // Казан утлары. 2001. № 1.

**ӘЙЙҮ́Б ХАН** (? — 1117), кыпчаклар берләшмәсе идарәчесе. Кыпчак ханы Асин (Асән) улы, бөек кенәз Ю.*Долгорукийның* каенатасы, кенәз Андрей Боголюбскийның бабасы. Днепр буйларында яшәгән бурчаглы (бурҗоглы) төрки кабиләләр берләшмәсеннән чыккан. Владимир Мономах б-н сугышлар алып бара; 1107 елда солых төзелә, Ә.х. бөек кенәзнең улы Ю.Долгорукийга кызын бирә. Киев кенәзе б-н бергә Идел буе Болгар дәүләтенә яу б-н килеп, бер каланы камаган вакытта һәлак була (агуланган дип фараз ителә).

Чыг.: Лаврентьевская летопись // Полн. собр. соч. русских летописей. М., 1962. Т.1.

*Әд.:* Б а с к а к о в  Н.А. Тюркская лексика в «Слове о полку Игореве». М., 1985; П л е т н ё в а  С.А. Половцы. М., 1990.

**ӘЙЛӘ́Н-БӘЙЛӘ́Н**, татар халык уены. Уйнаучылар кулга-кул тотышып түгәрәк буенча җырлап һәм биеп йөриләр. Катнашучылар лирик, шаян, йола һ.б. җырлар, *такмаклар* башкаралар. Җырлар һәм биюләр күмәк яки парлы булырга мөмкин. Ә.-б. бәйрәмнәрдә, яшьләр кичәләрендә, *аулак өйләрдә*; җәен — болында, басу капкасы яки клуб янында, кышын йорт эчендә уйналган. 20 йөз уртасына кадәр Ә.-б. авыл яшьләренең популяр уены була. Хәзерге көннәрдә мәктәпкәчә яки кече яшьтәге мәктәп балалары уеннары буларак сакланган.

*Әд.:* Татар халкының җырлы-биюле уеннары. К., 1968; Н а д и р о в  И.Н. Татар халкының йола поэзиясе, уен җырлары, бию такмаклары // Татар

халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; Ягъфәров Р. Татар халкының уен фольклоры. К., 2002.

*И.Н.Надыйров.*

**ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ́ МОХИТНЕ́Ң ПЫЧРАНУЫ́** (антропоген фактор), табигый мохит (һава, су, туфрак) сыйфатының хуҗалык яисә бүтән төрле эшчәнлек нәтиҗәсендә үзгәрүе, зарарлы тәэсирнең билгеләнгән нормадан артуы, кеше сәламәтлегенә, үсемлекләр, хайваннар дөньясына, матди байлыкларга куркыныч тудыруы. Ә.-т.м.п. химик, физик, механик, акустик, җылылык, ис факторларына бүлеп карала. ТРда һавага чыгарылган пычрак матдәләрнең гомуми күләме елга 500–520 мең *т* тирәсе тәшкил итә. 38 мең чамасы стационар пычрату чыганагы булган сәнәгать пр-тиеләре (800 дән артык), ел саен һавага 300 мең *т* тирәсе зарарлы матдәләр чыгара, мәс., 2005 тә — 254 мең *т*, 2003 тә — 275 мең *т*, 2001 дә — 293 мең *т*. Чыгарылган барлык пычратучы матдәләрнең ягулык комплексына — 44%, җылылык электрстанцияләренә — 14%, химия һәм нефть химиясе комплексына — 28,2%, машина төзелеше пр-тиеләренә — 5,2, төзелеш комплексларына 2,8% ы туры килә. Газ чистарту һәм тузан тоткарлау җайланмалары зарарлы матдәләрнең уртача 50% ын зарарсызландыра: машина төзелешендә — 75%, химия һәм нефть химиясе сәнәгатендә — 74%, төзелеш индустриясендә — 90%, урман һәм агач эшкәртүдә — 58%, җиңел сәнәгатьтә — 43%, җылылык комплексында — 39%, җылылык энергетикасы комплексында һәм авыл хуҗалыгында — 8%, торак-коммуналь хуҗалыкта — 55%.

Автотранспорт ш.у. атмосфера һавасын пычрату чыганагы булып тора: ТРда соңгы елларда дәүләт, коммуналь һәм коммерция автотранспортыннан һавага чыгарылган пычрак матдәләрнең тулай күләме бер елга 200–250 мең *т* (2005 тә — 199 мең *т*, яки ТР буенча һавага чыгарылган пычрак матдәләрнең 43,5% ы). 2005 елга автотранспорттан һавага чыккан зарарлы матдәләр Казанда — 74,7%, Бөгелмәдә — 73,9%, Әлмәттә — 47,6%, Чаллыда — 76,8%, Чистайда 82,6% тәшкил итте. Соңгы 5 елда һавага чыккан зарарлы матдәләр б-н Ә.-т.м.п. дәрәҗәсе Казанда, Чаллыда, Түбән Камада кимрәк яки гигиена таләпләренә туры килә.

Республикада, сәнәгать, авыл һәм коммуналь хуҗалыклар үсеше б-н бәйле рәвештә, су ресурсларын куллану һәм суның пычрануы да арта бара. Соңгы вакытта ел саен төрле ихтыяҗлар өчен 1 млрд. $м^3$ дан күбрәк су алына (2005 тә — 865,97 млн. $м^3$, ш.и. җир өсте су чыганакларыннан — 724,61 млн. $м^3$, җир асты суларыннан — 141,37 млн. $м^3$). 2005 елда җитештерү ихтыяҗларына 419,96 млн. $м^3$, хуҗалык-көнкүрешкә — 257,3 млн. $м^3$, а.х. сугаруга — 23,43 млн. $м^3$, сугаруга 2,34 млн. $м^3$ күләмдә файдаланыла. Файдаланылган суның күп өлеше (700 млн. $м^3$ ка якыны) соңгы елларда су объектларына агызыла. 2005 елда ташландык суларның сыйфаты түбәндәгечә иде: нормативлар нигезендә чистартылган сулар юк, чистарту процессы узмаган норматив — чиста сулар 125,5 млн. $м^3$, пычранган агым сулар — 528,93 млн $м^3$ (ш.и. җитәрлек чистартылмаганы — 504,18, бөтенләй чистартылмаганы — 24,75) тәшкил итә. 2005 тә Татарстанның су объектларына агым сулар б-н 13,1 *т* нефть продуктлары (2003 тә 60 *т*), 4,5 мең *т* йөзмә матдәләр (6,2 мең *т*), 413 мең *т* сульфат (80 мең *т*), 30,4 мең *т* хлорид (48 мең *т*), 925,5 *т* фосфат (704 *т*), 204,9 *т* нитрит (271 *т*), 25,7 *т* актив өслекле матдәләр (33 *т*), 6,2 мең *т* нитрат һәм 83,7 *т* тимер ага. Шуңа бәйле рәвештә, республика халкын яхшы сыйфатлы эчәргә яраклы су б-н тәэмин итү проблемасы актуальләшә. Химик күрсәткечләре буенча тикшерүләрдә санитария-гигиена таләпләренә туры килмәүче эчәргә яраклы дип саналган су күләме 2005 тә 2,7% булса, микробиологик күрсәткечләре буенча — 2,6% булган. Бу очракта җир асты суларыннан файдалану әһәмияткә ия (халыкны су б-н тәэмин итү сыйфатын һәм ышанычлылыгын арттыру проблемасын хәл итүдә төп юл). 2005 тә ТР халкын хуҗалык һәм эчәргә яраклы су б-н тәэмин итү системасында җир асты сулары 88,5% туры килә. Әмма аларның сыйфаты нык аерыла. Иң яхшы сыйфатлы җир асты сулары Көнбатыш Кама арьягында, түбән сыйфатлы сулар Идел алды төбәгендә билгеләнә, иң начар җир асты сулары — Әлмәт р-нында.

Соңгы еллар дәвамында республикада радиацион-экологик хәл тотрыклы булып кала, табигый гамма-фон тиешле санитария нормаларыннан артмый (6–14 мкР/сәг). Ләкин радиацион аварияләр килеп чыгуга потенциаль куркыныч тудыручы объектлар бар: «Татнефть» АҖ, Л.Я.Карпов исем. химия з-ды, Казан «Радон» специальләшкән радиация куркынычсызлыгы комб-ты, «Чистай «Восток» сәгать заводы» АҖ, Казан «Ясалма каучук» з-ды, «Татхимфармпрепаратлар» химия-фармацевтика җитештерү берләшмәсе һ.б.

Татарстанда җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килү һәм аларның әйләнеше актуаль экологик проблемаларның берсе булып тора. 2005 тә аларның гомуми күләме 12,042 млн. *т* тәшкил итә, ш.и. 9,191 млн. *т* — терлекчелек, 2,073 млн. *т* — сәнәгать, 0,777 млн *т* — көнкүреш калдыклары. Бигрәк тә күп күләмдә калдыклар тупланышын (мең *т* ларда): кара металл — 213,9; ташландык сулар утырмасы — 147,5; куркыныч матдәләр б-н пычранган фильтрларда һәм йоткычларда үткәрелгән масса — 135,5; төзелеш — 134,7; нефть һәм газ табу — 72,1; агач эшкәртү — 62,8; химия — 46,7; синтетик һәм минераль буяулар — 6,9 тәшкил итә. Яңа калдыкларның 62,52 мең *т* зарарсызландырыла, 2012,2 мең *т* файдалану өчен пр-тиеләргә җибәрелә. 736,5 мең *т* калдык пр-тиеләрдә озак сроклы саклауга урнаштырылган.

Чыг.: Государственный доклад о состоянии природных ресурсов и охраны окружающей среды РТ в 2005 году. К., 2006.

*М.М.Гыймадиев.*

**ӘЙЛӘНЧЕ́К КОҢГЫЗЛА́Р** (Gyrinidae), ерткычлар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. 800 дән артык төре бар, Татарстанда 4 төре билгеле. Кара аяклы (Gyrinus marinus Gill) һәм сары аяклы (G. natator L.) әйләнчек коңгызлар киң таралган. Зурлыгы 4–7 *мм*, кара төстә, гадәттә, өсте нык ялтырый, канат өслекләренең очы тупасланган. Алгы аяклары озын, эләктереп ала торган, уртадагылары һәм арттагылары йөзүгә җайлашкан. Күзләре баш чыгымы б-н бүленгән. Өстәгесе һавада күрү, астагысы су астында күрү өчен хезмәт итә. Җыелган һәм ага торган сулыкларда яшиләр. Бөҗәкләр арасында иң әйбәт йөзүчеләр. Еш кына су өслеге буенча тиз әйләнеп һәм боргаланып йөзәләр (исеме шуннан алынган), куркыныч янаганда чумалар. Ерткычлар. Вак бөҗәкләр һ.б. умырткасызлар б-н тукланалар. Личинкасы нәзек һәм озынча, озынлыгы 14 *мм* га кадәр, саңаклары б-н сулый, су төбендә яки үсемлекләр арасында суда үсә, ерткыч. Сулык ярындагы дымлы туфракта курчакка әверелә.

*Әд.:* Жадин В.И., Герд С.В. Реки, озера, водохранилища СССР, их фауна и флора. М., 1961; Бей-Биенко Г.Я. Общая энтомология. М., 1966; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977.

*Н.Ш.Әхмәтҗанова, С.М.Шәфигуллина.*

**ӘЙРӘ́Н**, 1) әчетелгән сөттән әзерләнгән алкогольсез эчемлек, төрки халыкларда киң таралган. Ә.не татарлар салкын суга *катык* болгатып ясыйлар; чәч юу өчен косметика чарасы буларак та файдаланыла; 2) май язганда бүленеп чыга торган сыеклык (гөбе суы).

**ӘЙТЕ́М**, фольклор жанры, образлы тәгъбир, әйберне, күренешне яки аларның нинди дә булса бер ягын кыска һәм төгәл чагылдыра торган сүзәйләнмә. Ә. *мәкальгә* якын. Мәкаль кебек үк, Ә. дә ритмга һәм рифмага салынган булырга мөмкин, әмма, аннан аермалы буларак, аның гомумиләштерүче тәрбияви мәгънәсе юк. Күп очракта Ә. мәкальгә әверелгәнче киңәйтелгән булырга мөмкин: «Кырмыска оясына таяк тыгу» — «Кырмыска оясына таяк тыкмыйлар». Ә.нең төп функцияләре — әйтелгән фикерне халык тәҗрибәсенә таянып куәтләү, сөйләм телен тасвирлы-эмоциональ бизәү. Татар фольклористикасында озак вакытлар мәкаль һәм Ә. бер-берсеннән аерылмаган һәм бер үк җыентыкларга һәм антология бүлекләренә кертелгән. Беренче тапкыр, мөстәкыйль жанрлар буларак, алар Н.Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» (т. 1–3, 1959–67) җыентыгында күрсәтелә. Ике мөстәкыйль жанр буларак, төрле татар Ә.нәре һәм мәкальләренең охшашлыгын яки аермасын сурәтләү, формалаштыру проблемасы Х.Ш.Мәхмүтов төзегән «Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр» (1987) җыентыгында һәм андагы фәнни аңлатмаларда теоретик яктан тагын да тирәнрәк ачып бирелә. *Ф.И.Урманчеев.*

**«ӘЙТҮКӘ́»** (Әйтмөхәммәт исеменнән кечерәйтелгән), Бараба татарлары арасында киң таралган фаҗигале мәхәббәт турындагы халык җыры. Ф.Әхмәтова, Ф.Урманчеев һ.б. тарафыннан язып алына. Күпсанлы легендалар һәм риваятьләр буенча, җырның герое Әйтүкә 19 йөз ахырында — 20 йөз башында хәзерге Новосибирск өлкәсе Чанов р-нының

Тармакүл авылында яшәгән; ул үзе хезмәт иткән байның кызын — тирә-юньдәге иң матур Фатыйманы яраткан. Аның өчен Әйтүкә калым түли алмый, һәм бу ике гашыйк казакъ далаларына качып китәргә мәҗбүр була. Күп еллар ил гизеп йөреп, туган якларына әйләнеп кайтканнан соң, Фатыйманың абыйлары һәм пристав аларны кулга ала һәм авылларына алып кайта. Әйтүкәне камчы б-н кыйнарга җыеналар. Картларның берсе: «Улым, сине үз җырларың гына коткара алыр», — дип әйтә. Әйтүкәнең Фатыймага булган мәхәббәте һәм гашыйкларның авыр язмышы турындагы җырларның үзәк өзгеч моңы аны җәзадан азат итә, ләкин Фатыймадан мәңгегә аера.

*Әд.:* Урманчеев Ф. Тарихи җырлар // Казан утлары. 1969. № 3; Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ӘЙШӘ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 9 *км* көнчыгыштарак, Казан — Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2002 елда 3080 кеше (руслар — 50%, татарлар — 42%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, яшелчәчелек. Урта мәктәп. Музыка мәктәбе. Мәдәният йорты. Китапханә. 1780 дә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.дә 3 җил тегермәне һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 561,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Ильинский волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 19 ир заты; 1859 да — 221, 1897 дә — 380, 1908 дә — 404, 1920 дә — 517, 1926 да — 587, 1938 дә — 594, 1958 дә — 811, 1970 тә — 1157, 1979 да — 2180, 1989 да — 2802 кеше.

Ә. янында ел саен бард җыры фестивальләре уза.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**ӘЙШИЯ́З** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 11 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үртәм елгасы буенда. 2002 елда 244 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.дә мәчет, 2 су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 613,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Краснококшай (1919 га кадәр — Царёвококшай) өязе Күлле Киме волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 308, 1897 дә — 409, 1908 дә — 426, 1920 дә — 520, 1926 да — 474, 1938 дә — 537, 1949 да — 441, 1958 дә — 349, 1970 тә — 374, 1979 да — 306, 1989 да — 261 кеше.

**ӘКӘ́М-ТӨКӘМНӘ́Р**, к. *Корсагаяклылар.*

**ӘКБӘ́РОВ** Ренат Фазыл улы (13.6.1939, Казан), нурлар ярдәмендә диагноз кую белгече, мед. фән. д-ры (1990), проф. (1993), ТРның атказ. табибе (1994), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2005). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1962). 1962–81 елларда Петропавловск-Камчатский, Казан мед. оешмаларында эшли. 1981 дән ГИДУВта (хәзер Казан мед. академиясе). Хезмәтләре нурланыш ярдәмендә авыруларга, ш.и. ашказаны рагы башлангычына диагноз куюга, ашкайнату юллары үсеше аномалияләренә, сидек чыгару системасын, гепатопилородуоденаль зоналарны өйрәнүгә карый.

Хезм.: Рентгенодиагностика функциональных изменений желудочно-кишечного тракта у детей, обусловленных родовыми повреждениями позвоночника и спинного мозга. Л., 1989 (автордаш); Комплексная лучевая диагностика редких хирургических заболеваний пищеварительного тракта у детей. К., 1994 (автордаш).

*Әд.:* Павлухин Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**ӘКБӘ́РОВ** Фоат Галимҗан улы (2.8.1944, Балтач р-ны Борбаш Сәрдегәне а.), вет. табибе, вет. фән. канд. (1987). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996), ТРның атказ. вет. табибе (1999). 1973 елда Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлый, шунда ук эшли. 1988 дән эпизоотология каф. доценты. Хезмәтләре терлекләрдәге йогышлы авыруларга каршы көрәш мәсьәләләренә карый. Дәүләт бүләге мөгезле эре терлекләрдә һәм дуңгызларда туберкулёз авыруына диагноз кую, профилактика һәм дәвалау буенча чаралар комплексын эшләгән өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘКИ́ АЛАНЫ́** авылы, Казан шәһәренең Совет р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2002 елда 17 кеше (руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Башта Казан авыл р-нында, 1938 елның 4 августыннан — Юдино, 1950 нең 16 маеннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында, 1984 нең 15 октябреннән Казан шәһәренең Совет район советы карамагында. Халык саны: 1938 дә — 61, 1949 да — 50, 1958 дә — 51, 1970 тә — 28, 1989 да — 17 кеше.

**ӘКИ́** авылы, Казан шәһәренең Совет р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 10 *км* көньяк-көнбатыштарак, Киндерле елгасы буенда. 2000 елда 490 кеше (1989 елгы халык исәбе буенча, руслар — 55%, татарлар — 43%) яши. Автотранспорт пр-тиесе. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1550 еллар ахырыннан — рус авылы. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яке исеме б-н дә билгеле. 16 йөздән халкы — сарай, 18 йөз ахыры — 19 йөзнең 1 нче яртысында удел крәстияннәре катлавына керә. 1560 еллардан Ә. Царицыно авылы приходына карый. 18 йөздә халкының төп шөгыле — игенчелек, терлек үрчетү һәм Казан урамнарын түшәү өчен таш вату. Моннан тыш, тимерчелек нык үсеш ала. 20 йөз башында Ә.дә чиркәү-приход мәктәбе (1890 да ачыла), җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Воскресенский волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1950 нең 16 маеннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. 1998 нең 25 ноябреннән Казан шәһәренең Совет район советы карамагында. Халык саны: 1646 да — 76, 1782 дә — 136 ир заты; 1859 да — 556, 1897 дә — 683, 1920 дә — 742, 1926 да — 838, 1938 дә — 834, 1949 да — 800, 1958 дә — 561, 1970 тә — 574, 1989 да — 499 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ӘКИЯ́Т**, халык авыз иҗаты жанры, уйдырмаларга нигезләнгән тылсымлы, маҗаралы яки көнкүреш характердагы эпик, күбесенчә прозаик әсәр. Бик борынгы заманнардан бирле мифологик образларны, тотемик һәм анимистик күзаллауларны, үлгән ата-бабаларга табынуны һ.б. саклый. Гадәттә, речитатив б-н әйтелә яки ниндидер көйгә җырлана торган шигъри өстәмәләр дә була.

Татар халык Ә.ләре 3 жанрга бүленә: 1) тылсымлы; 2) көнкүреш; 3) хайваннар турындагы Ә.ләр. Бу төрләр дә берничә төркемгә бүленә: 1) чын мәгънәсендә тылсымлы: «Ак бүре», «Аучы егет» һ.б., мифологик: «*Үги кыз*», «*Зөһрә*» һ.б., баһадирлар турындагы: «*Камыр батыр*», «*Турай батыр*» һ.б.; 2) гыйбрәтле: «*Зирәк карт*», «Саран белән Юмарт» һ.б., авантюралы: «Патша һәм Карак», «Ярлы Билал» һ.б., сатирик: «*Тапкыр кыз*», «Кыю Шомбай» һ.б., юмористик: «Хәйләкәр патша», «Карт белән ялкау егет» һ.б.; 3) кыргый хайваннар турындагы: «Төлке белән Бүре», «Торна белән Төлке» һ.б., йорт хайваннары турындагы: «*Кәҗә белән Сарык*», «Хәйләкәр әтәч» һ.б., кыргый һәм йорт хайваннары турында: «Мәче белән Аю», «Ач эт белән Бүре» һ.б.

Бу төркемнәр, үз чиратында, тагын да вак төркемнәргә бүленәләр. Татар фольклористикасында 2 мең чамасы татар халык Ә.е исәпләнә. Бөтен Ә.ләрнең 46% ын тылсымлы һәм көнкүреш, 8% ын хайваннар турындагы Ә.ләр тәшкил итә. 1990 еллар ахырында татар халык Ә. сюжетларының белешмәсен төзү эше башлана.

Беренче исәпләүләр буенча, аларның саны 450 гә җитә. 378 сюжет халыкара белешмәләрдә теркәлгән, ш.и. 66 — хайваннар турында, 159 — тылсымлы, 155 — көнкүреш турындагы (бу төркемгә Ә.ләрдә очраган 78 мәзәк тә керә) сюжетлар. Татар Ә.ләрендә аеруча популяр сюжетлар: тылсымлы: «Еланны җинүче» (67 язма), «Үле гәүдә» (56), «Кыйммәтле тире» (41), «Киек сөте» (40), «Ир югалган (яисә урланган) хатынын эзли (хатын ирен эзли)» (33) һ.б.; көнкүреш: «Зирәк кыз» (39) һ.б.; хайваннар турындагы: «Бүре буа янында» (10), «Җүләр Бүре» (8), «Ата мәче һәм кыргый хайваннар» (8) һ.б.

Татар халык Ә.ләре б-н беррәттән Көнчыгыш телләреннән тәрҗемә ителгән «*Бабурнамә*», «*Кәлилә вә Димнә*», «Тутыйнамә», «Мең дә бер кичә», «Арҗи-Бурҗи», «Веталның егерме биш хикәясе», «Кырык вәзир» һ.б.; русчадан — «Сауны хаста күтәрер» («Битый небитого везёт»), «Комсыз карчык — алтын балык» («Жадная старуха — золотая рыбка») һ.б. Ә.ләр зур популярлык казана.

Татар халык Ә.ләрен туплауда, бастырып чыгаруда һәм фәнни өйрәнүдә татар галимнәре К.Насыйри, Г.Фәезханов, фольклорчылар Х.Бәдигый, Ф.Әхмәтова, Л.Җамалетдинов, Х.Ярми, Х.Гатина; язучылар Гали Рәхим, Г.Толымбайский, Г.Бәширов, Э.Касыймов, педагог Т.Яхин һ.б.; рус тюркологлары В.В.Радлов, П.А.Поляков, филолог М.И.Иванов, тел белгече А.Г.Бессонов, әдәбият белгече М.А.Васильев; венгр тюркологлары Г.*Балинт*, И.*Кунош*, Көнчыгышны өйрәнүче Ж.Какук, фин тюркологы Х.Паасонен һ.б. зур хезмәт куя.

Беренче татар Ә.ләре (8 текст) 1842 елда М.И.Ивановның «Татар хрестоматиясе» («Татарская хрестоматия») китабында басылып чыга. Ә.ләрнең иң тулы басмасы — «Татар халык иҗаты» җыентыгында (313 текст татар һәм 262 текст рус телләрендә). Татар халык Ә.ләре болгар, венгр, кытай, монгол, словен һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән.

*Әд.:* Җамалетдинов Л. Әкиятләр // Фольклор жанрларын анализлау. К., 1986; шул ук. Сюжетный состав сказок // Поэтика татарского фольклора. К., 1991; шул ук. Сюжеты и мотивы татарских сказок о животных (опыт создания систематического указателя) // Типология татарского фольклора. К., 1999; Карамуллин А.Г. Татарский фольклор: Аннотированный указатель литературы: В 2 ч. К., 1993.

*Л.Ш.Җамалетдинов.*

**ӘКРА́М АВЫЛЫ́ КУЗГАЛЫШЫ́**, 1842 елда Казан губернасы Козьмодемьян, Цивиль, Чабаксар, Ядрин өязләре крәстияннәренең алпавытлар кысуына, хөкүмәтнең иген уңышы булмаган еллар өчен дип ашлыклата өстәмә салым түләү («общественная запашка») кертүенә, чиновниклар башбаштаклыгына каршы күтәрелеше. Җитәкчеләре: С.Афанасьев, В.Григорьев, С.Ильбрас, С.Палатай, С.Семёнов, Ю.Туктагулов һ.б. 1841 дә шул өязләрнең дәүләт крәстияннәре арасында, аларны патша крәстияннәре департаменты карамагына крепостнойлар йөкләмәсен үтәргә күчерәләр икән, дигән хәбәр тарала. Крәстияннәр үзләрен дәүләт крәстияннәре катлавында калдыруны таләп итәләр һәм җәмәгать фондына ашлыклата җыем-салым түләргә, бәрәңге утыртырга мәҗбүр итүләргә каршы булалар. Шул сәбәпле 1842 нең язында баш күтәрәләр. Апрель урталарына чуалышлар 200 дән артык авылны колачлый. Аларга каршы гаскәри отрядлар җибәрелә, Цивиль, Чабаксар өязләрендә беркадәр тәртип урнаштырыла. Ядрин, Козьмодемьян өязләрендә халык кузгалышы аеруча көчле була. 1842 нең 16 маенда Ядрин өязенең Мунъял авылы янәшәсендә берничә мең крәстиян кораллы гаскәр б-н бәрелешә; атыш вакытында 14 кеше яралана, 400 кеше кулга алына. 1842 нең 18–19 маенда Козьмодемьян өязе Әкрам авылында Козьмодемьян һәм Ядрин өязләреннән килгән берничә мең крәстиян туплана. Крәстияннәргә таралырга һәм хакимиятләрнең таләпләренә буйсынырга кушыла. Полковник Поль җитәкчелегендәге отряд б-н бәрелештә 30 дан артык крәстиян яралана, 464 кеше кулга алына. Кулга алынганнарны коткару өчен 20 майда Әкрам авылы янына Козьмодемьян, Чабаксар, Ядрин өязләреннән килгән берничә мең крәстиян җыела.

Баш күтәрүчеләр тар-мар ителә: 8 кеше үтерелә, 200 дән артык кеше яралана. Йөзләрчә крәстиян суктырыла, 300 дән артык кеше крепостнойлык хезмәтенә, рекрутлыкка бирелүгә хөкем ителә, 34 кеше каторгага җибәрелә.




*Әд.:* Григорьев П.Г. Волнения чувашского крестьянства в 1841–42 гг. // Зап. Чувашского науч.-иссл. ин-та языка, литературы и истории. Чебоксары, 1941. Вып. 1; Восстание чувашского крестьянства в 1842 г. Чебоксары, 1942; История Чувашской АССР. Чебоксары, 1983. Т. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ӘКРЕ́Н ЙӨРҮЧЕЛӘ́Р** (Tardigrada), умырткасыз хайваннар тибы. 400 дән артык төре бар, Татарстан терр-ясендә 34 төре билгеле, ләкин аларның саны 45 кә кадәр булуы ихтимал. Дымлы мүктә, үсемлек калдыкларында, төче сулыкларда, ләмле комда һәм чуерташта, ш.у. җир өстендәге үсемлекләрнең сулы элпәләрендә яши. Гәүдәләре 0,1–1,2 *мм* озынлыкта, таза, аз сегментлы, 4 пар бүлгәләнмәгән гади очлыклары бар. Төзелешләре буенча буынтыгаяклыларга якын, ләкин алар гадирәк. Кан әйләнеше һәм газ алмашы әгъзалары юк. Бер күзәнәкле сүүсемнәр, бөтерелчек суалчаннар, нематодалар һ.б. вак организмнар б-н тукланалар. Ә.й.нең корсагаяклы моллюсклар ашказаннарында яшәүче паразит формалары билгеле. Яшерен яшәү рәвеше алып баралар. Уңайсыз шартларда кутикуляр капламы астында шарсыман циста стадиясендә яки бик нык сусызландырганда коры «мичкә» стадиясен барлыкка китерәләр. Мондый халәттә 10 елдан артык яшәргә сәләтле, –272°С ка кадәр суытуга, +150°С ка кадәр җылытуга түзәләр, бу вакытта кислород куллану 600 мәртәбә кими. Мондый анабиотик фазаларны исәпләгәндә, алар 60 елдан да артык яшәргә мөмкин.

*Әд.:* Бисеров В.И. Определительная таблица пресноводных тихоходок СССР // Зоол. журн. 1989. Т. 67, вып. 6; Barnes R.S.K., Calow P., Olive P.J.W. The Invertebrates: a new synthesis // Blackwell Sci. USA. 1993.

*Р.М.Сабиров.*

**ӘЛӘ́М**, кече байрак, байрак, гаскәр башлыгы билгесе. Формасы (турыпочмаклык, өчпочмак һ.б.), төсе, бизәге махсус билгеләнгән, бер кырыеннан сапка беркетелгән тукыма. Борынгы заманнарда сөңге сабына яисә сугышчы баш киеменә дә (алпакка) беркетелгән. Символик һәм изге мәгънәгә ия дәүләт эмблемасы булган. Гаскәр башлыклары Ә.е, гадәттә, озынча турыпочмаклык рәвешендә эшләнгән, гаскәр б-н идарә иткәндә кулланылган (туплану урынын күрсәткән, тегеяки бу әмерне тапшыру өчен файдаланылган). Ә.не, гадәттә, баш полк саклаган, аның юкка чыгуы (егылуы) җиңелү билгесе саналган. Хан Ә.еннән кала һәр бәкнең, идарәченең үз нәсел тамгасы төшерелгән, башлыча, өчпочмак рәвешендәге Ә.е булган. Шул Ә.нәр гаскәри берәмлекләр санын белдергән. 12–13 йөз болгарлары Ә.нәре, башлыча, яшел төстә, аларга ыруг тамгалары төшерелгән һәм Коръәннән алынган кәлимәләр алтын җепләр б-н чигелгән булган. 13–16 йөзләрдә Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында Җучиләр тамгасы б-н мөселман символлары төшерелгән күк һәм яшел төстәге Ә.нәр кулланышта йөри. 14–16 йөзләрдә эре полкларда Ә. «хорунга» дип аталган. Соңрак бу атама рус һәм полякларга «хоругвь» буларак килеп кергән.

*Әд.:* Измайлов И.Л. Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии X — начала XIII вв. К. — Магадан, 1997.

*И.Л.Измайлов.*

**ӘЛБӘДӘ́Н** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 14 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2002 елда 109 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда 2 авыл — Керәшен Ә.е һәм Рус Ә.е буларак билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт һәм алпавыт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә, Казанда урман һәм икмәк б-н сату итә. 20 йөз башында Керәшен Ә.ендә чиркәү-приход мәктәбе, 2 икмәк кибете, 3 вак-төякләр кибете; Рус Ә.ендә икмәк кибете һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең керәшеннәр яшәгән өлешендә имана җире — 497, рус өлешендә 27 дис. тәшкил итә. 1930 да Ә.дә «Үрнәк» к-зы (1950 дән — Мичурин исем.) оештырыла, 1960 та «Марс» к-зы (1979 елдан — Гаврилов исем., 1997 дән — а.х. товарлары җитештерү кооперативы) составына керә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Сәләнгеш волосте, 1920 дән — ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 151 ир заты; 1859 да — 332, 1897 дә — 688, 1908 дә — 676, 1926 да — 680, 1949 да — 677, 1958 дә — 676, 1970 тә — 579, 1979 да — 393, 1989 да — 190 кеше. Ә. — Советлар Союзы Герое П.М.*Гавриловның* туган авылы.

**«ӘЛГАСРЕЛҖӘДИД»**, к. *«әл-Гаср әл-җәдид»*.

**ӘЛДЕРМЕ́Ш** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 12 *км* төньяктарак, Сая елгасы буенда. 2002 елда 526 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Олы Әлдербеш, Әлдербеш-Казак исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 18 йөз ахырында Казан сәүдәгәре И.Апанаев иганәсенә авылда агач мәчет (1829 да яна, 1832 дә яңадан төзелә) салына. Мәчет каршында мәктәп эшли. 20 йөз башында Ә.тә 2 тимерче алачыгы, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1741,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 183 ир заты; 1859 да — 1161, 1878 дә — 1065, 1908 дә — 1083, 1920 дә — 913, 1926 да — 1059, 1938 дә — 1299, 1949 да — 889, 1958 дә — 838, 1970 тә — 787, 1989 да — 564 кеше. Ә. — композитор Ә.З.*Бакировның* туган авылы.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**«ӘЛДЕРМЕШТӘ́Н ӘЛМӘНДӘ́Р»**, Т.Миңнуллинның 2 пәрдәле пьесасы. 1976 елда иҗат ителә, 1976 ның 26 октябрендә Татар акад. театрында беренче тапкыр күрсәтелә; реж. М.Сәлимҗанов, рәссамы Ә.Зарипов, комп. А.Монасыйпов. Әлмәндәр ролендә Ш.Биктимеров, Әҗәл — Р.Шәрәфиев, Искәндәр — Д.Ильясов, И.Баһманов; Евстигней ролендә — Г.Надрюков, Һ.Солтанов; Әммия — Г.Нигъмәтуллина, Н.Ихсанова; Хәмдебану — Р.Җиһаншина, В.Минкина; Гөлфирә ролендә А.Гайнуллина, Р.Мотыйгуллина һ.б. Пьесаның нигезенә үлем фәрештәсе Газраил тарафыннан 90 яшьлек картны алып китәргә җибәрелгән Әҗәл б-н хәйләкәр, шаян, зирәк акыллы авыл карты арасындагы мажаралары эченә алган риваять салынган. Халык



Г.Камал исем. Татар акад. театры спектакленнән күренеш. 1976.

характерының ныклыгын, күп сынаулар кичереп тә, оптимизмын һәм яхшылыкның өстен чыгуына ышанычын югалтмавын күрсәткән тормышчан һәм фәлсәфи бу спектакль хәзерге заман татар театр сәнгатенең иң зур казанышларыннан берсе дип танылa, Татар акад. театры репертуарында утыз елдан артык иң популяр спектакльләрдән санала һәм сәхнәдә уйнала. 1979 да пьеса авторы Т.Миңнуллин, спектакльне сәхнәгә куючы М.Сәлимҗанов һәм Әлмәндәр ролен башкаручы Ш.Биктимеров РСФСРның К.С.Станиславский исем. Дәүләт бүләгенә лаек булалар. 1983 тә һәм 2006 да спектакль Мәскәүдә, 1984 тә — Үзәк телевидениедән, 1996 да — Хельсинкида (Финляндия) гастрольләр вакытында театрларда күрсәтелә. Пьеса ш.у. Хәмзә исем. Үзбәк акад. т-рында (Ташкент), рус теленә Ю.Мочалов тарафыннан «Белая ворона» исеме б-н тәрҗемә ителеп, Түбән Новгород, Мичуринск, Мурманск, Воронеж, Йошкар-Ола, Новокузнецк шәһәрләре театрларында куела.

*Әд.:* Силина И. Два вечера у камаловцев // Театр. 1979. № 5; Иляловa И. Театр имени Камала. К., 1986.

**ӘЛИФБА́**, алфавит, башлап укырга-язарга өйрәтү өчен дәреслек. Хәрефләр, хәреф тезмәләре, иҗекләр, цифрлардан, грамматик мәгълүмат, танып белү характерындагы һәм тәрбияви текстлардан, иллюстрация материалларыннан тора.

Беренче болгар-татар әлифбалары (гарәп алфавитының беренче хәрефе әлиф һәм икенче хәрефе ба исеменнән алынган) Идел буе Болгар дәүләте мәктәп һәм мәдрәсәләрендә төзелә башлый. Андый укыту әсбаплары Алтын Урда һәм Казан ханлыгы халыкларында һәм соңрак та — 1927 елда латин графикасы нигезендәге алфавит (к. *Яңалиф*) кергәнче файдаланыла һәм даими камилләштерелә. Халык арасында киң таралган Ә.лар арасында 18 йөзнең 2 нче яртысында *Мортаза Котлыгыш* б-н *Ишнияз бине Ширнияз* тарафыннан язылган кульъязма Ә.лар билгеле.

Сакланып калган беренче басма Ә.лар 19 йөз башы *мәктәпләре* өчен язылган. 1802 дә Казан ун-ты типографиясендә 11 мең данә тираж б-н Мортаза Котлыгышның «Шараит әл-иман» («Иман шарты») әлифбасы басыла. Аннан соңгы елларда башлап укырга-язарга өйрәтү, ш.и. җәдиди мәдрәсәләр өчен Галимҗан Барудиның («Сәвад хан» — 1 нче баскыч укыту өчен дәреслек, 1891), Мөхәммәтвәли Мөхәммәтрәхим Әл-Чистайның — «Иказ әл-вилдан» («Балаларны уяту» — 2 нче баскыч укыту өчен, 1891), Әхмәтһади Максудиның «Мөгаллим әүвәл» («Беренче дәреслек», 1892), «Мөгаллим сәнин» («Икенче дәреслек» — соңгы баскыч укыту өчен, 1902) Ә. дәреслекләре төзелә. Ә.Максуди әлифбалары 1892–1917 елларда күп тапкырлар нәшер ителә һәм Россиянең барлык төрки телле халыклар мәктәпләрендә кулланыла. 19 йөз ахырында Имаметдин Сәйфуллинның «Яңа әлифба» (1892), Шакирҗан Таһириның «Бәдьә әт-тәгълим. Мөкаммәл әлифба» («Башлангыч белем бирү өчен тулы әлифба», 1893) исемле беренче рәсемле әлифбалары дөнья күрә. Күп әлифбаларда математикадан башлангыч мәгълүмат бирелгән бүлек — әбҗәд (саннарны гарәп алфавиты хәрефләре б-н билгеләү) аерылып торган. Алар арасында Каюм Насыйри китаплары — «Иҗек (Ибтидаи сабакка шөругъ кыйлгучы балаларга иҗек танытмак өчен бер тәҗрибәдер)» («Укырга-язарга өйрәнергә керешүче балаларга иҗек өйрәтү», 1895); «Иршад әл-әхибба илә тәгълими әл-әлифба» («Әлифба өйрәнүче балаларга нәсыйхәт», 1891) һ.б. бар.

Татар әлифбаларының бер төре — рус гимназияләрендә укучыларны татар теленә өйрәтү өчен уку ярдәмлекләре. 1778 дә Сәгыйть Хәлфин тарафыннан «Хәреф һәм иҗекләре тулы тасвирланган татар теле әлифбасы» («Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов») нәшер ителә. 1787 дә аның «Әлифбаи татар» дәреслеге басыла. 1809 да Ибраһим Хәлфиннең «Гарәп укуы кагыйдәләре белән татар теленең алфавиты һәм грамматикасы» дәреслеге; 1859 да Г.Ваһаповның «Мөгаллим әүвәл фи тәгълим лисан әл-гарәп вә әл-фарси әт-татари» («Гарәп, фарсы, татар телләрен башлап өйрәнүчеләр өчен ярдәмлек») дәреслеге; 1887 дә Мирсалих Бикчуринның «Татарларга русча, русларга татарча сөйләшергә һәм үзлегеннән укырга өйрәткеч» («Татарско-русский и русско-татарский самоучитель») уку ярдәмлеге чыга. 19 йөз ахыры 20 йөз башында мәктәптә укыту системасын































**Әлифба**. 1. С.Х. Хәлфин. Татар теле әлифбасы. 1778. Тышлык; 2, 3. Ә.Н. Максуди. Мөгаллим әүвәл (Беренче укытучы). 1892. Тышлык, куш бит; 4. К. Насыйри. Балаларны иҗекләп укырга өйрәтү китабы (Иҗек...). 1895. Тышлык; 5. Г.М. Баруди. 1 нче баскыч укыту дәреслеге (Сәвадхан). 1907. Тышлык; 6, 7. Ш.Ә. Таһиров. Рәсемле татарча фонетик әлифба. 1914. Тышлык, бит; 8. М.Х. Корбангалиев, Х.Бәдигый. Әлифба; 1937. Тышлык; 9. М. Фазлулла. Зурлар өчен әлифба. 1941. Тышлык; 10, 11. Р.Г. Вәлитова, С.Г. Вагыйзов. Әлифба. 1993. Тышлык, бит.

үзгәртеп кору сәбәпле (к. *Җәдитчелек*) «яңа алымлы» дәреслекләр, ш.и. укытуның авазлар методына нигезләнгән Ә.лар барлыкка килә. 1893 тә Мөхәммәтзакир Ишмөхәммәтовның «Әлифбага җитәкче» уку ярдәмлеге, 1908 дә Хәбибрахман Зәбиринең «Рәсемле әлифба»сы басыла. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан керәшен татарлар өчен Ә. лар булдырыла. Алар педагог-миссионер Н.И.Ильминский тарафыннан кириллица нигезендә төзелә: «Кенәгә» («Книгя», 1862); «Керәшен татарлар өчен әлифба» («Букварь для крещенных татар», 1871); «Язу урята торган книга» (1906). Гомуми башлангыч белем бирүне гамәлгә кертү һәм олылар арасында наданлыкны бетерү өчен татар Ә.лары төзү 1920 еллар ахыры 30 еллар башында аеруча киң колач ала. Г. Шәрәф һәм Ш.Алексеевның «Беренче адым» (1923), «Якты юл» (1926), «Яңа тормыш» (1928) әлифбалары нәшер ителә. Латин графикасына күчү б-н (к. *Латин язуы*) Гыймад Нугайбәк һәм Мөхәммәтхан Фазлуллинның «Яңа әлифба»сы (1926) нәшер ителә. Шуннан соң татар мәктәпләре өчен Ә.лар РСФСР ПФА тикшеренүләре, ш.у. Россиянең рус булмаган башка халыклар телендә шундый ук уку ярдәмлекләре эшләү тәҗрибәсе исәпкә алып төзелә.

1950 еллардан татар мәктәпләрендә Г.Сәйфуллин, соңрак Р.Вәлитова, С.Вагыйзов әлифбалары буенча укытыла. Рус телле балалар өчен 1998 дән башлап Ф.Йосыпов б-н Л.Новикова язган «Әлифба» («Татарский букварь») ел саен чыгарыла.

*Әд.:* Кәримуллин Ә.Г. Китап дөньясына сәяхәт: Татар басма сүзенең сәхифәләреннән. К., 1979; Ибраһимов Ф. Белем әлифбадан башлана: Татарча уку-язуга өйрәнү методикасы һәм татар әлифбалары тарихы. К., 1994; Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**«ӘЛИФБА» МУЗЕЕ**, Арчада, 1999 елда Арча пед. көллиятендә ачыла, 2001 дән ТР Мәдәният министрлыгы карамагындагы мөстәкыйль музей, 2006 дан «Казан арты» муниципаль әдәбият-музей берләшмәсенең ф-лы. Арча пед. көллияте бинасының янкормасында урнашкан. Экспозициянең мәйданы 120 *м²*, коллекцияләрендә 1226 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция өч залны били, язуның борынгы заманнардан алып бүгенге көннәргә кадәр барлыкка килүен һәм үсешен, дөнья халыкларының укырга-язарга өйрәнүен чагылдыра. Беренче залда татар әлиф-



«Әлифба» музее. Экспозициядән фрагмент. Дөнья халыклары әлифбалары.



«Әлифба» музее. Ә.Максуди әлифбалары: «Мөгаллим әүвәл», 1903; «Мөгаллим сәнин», 1914.

басының кулъязма вариантларыннан башлап үсеш тарихы күрсәтелә. *Кышкар* мәдрәсәсенең, мәктәпнең 19 йөзнең 50–60 елларындагы уку классы интерьерлары, Арча пед. көллияте укытучыларының, ш.у. татар сыйныфлары өчен дистәләрчә басмада чыккан «Әлифба» дәреслеге авторлары С.Г.*Вагыйзов* һәм Р.Г.*Вәлитованың* эш тәҗрибәләре яктыртылган экспозицияләр урын алган. Икенче зал дөнья халыкларының әлифбалары б-н таныштыра. Өченче залда Ә.Н.*Максудиның* Х.Р.*Курбатовка* бүләк язуы б-н тапшырылган «Мөгаллим әүвәл» әлифбасы үзәк урынны алып тора.

Аеруча мөһим экспонатлар арасында дөнья халыклары әлифбалары коллекциясе (265 саклау берәмлеге), С.Г.Вагыйзов һәм Р.Г.Вәлитованың шәхси әйберләре, дәреслекләре бар. Музейны оештыручылар: И.Г.Сәгъдиев, Х.Ф.Хәйруллин.


«Ә.»м.да ел саен Г.Тукайның туган көне (26 апр.), Халыкара музейләр көне (18 май), Белем көне (1 сент.) уздырыла.

**ӘЛКӘ́Й** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 31 *км* көнбатыштарак, Мәллә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 595 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1748 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.дә мәчет була. 20 йөз башында монда 2 мәчет, мәктәп, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3967,2 дис. тәшкил итә. 1929 да Ә.дә К.Маркс исем. к-з оештырыла. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлкәй волостенда үзәге була. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 376 ир заты; 1859 да — 899, 1897 дә — 1843, 1920 дә — 1901, 1926 да — 1516, 1938 дә — 1555, 1949 да — 1025, 1958 дә — 895, 1970 тә — 1017, 1979 да — 876, 1989 да — 565 кеше.

**ӘЛКИ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бола елгасы буенда. 2002 елда 279 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Клуб. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 да Ә.дә мәчет була, 1870 тә 3 су тегермәне һәм 3 ярма ярдыру тегермәне эшли. 20 йөз башында монда 2 су тегермәне, мануфактура һәм 4 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1381 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Әлки волостена керә. 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 146 ир заты; 1859 да — 547, 1897 дә — 957, 1908 дә — 1108, 1920 дә — 1145, 1926 да — 691, 1938 дә — 715, 1949 да — 546, 1958 дә — 522, 1970 тә — 596, 1979 да — 414, 1989 да — 277 кеше.

*Әд.:* Буа ягым — Тау ягым = Буинские просторы. К., 2000.

**ӘЛКИ́ РАЙОНЫ́**, ТРның көньягында урнашкан, Самара һәм Ульянов өлкәләре б-н чиктәш. Көнбатыш Кама аръягы икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1726,8 *км²*. 21 авыл җирлеген, 71 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Базарлы Матак авылы. Халкы — 2006 елда 21,3 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 64,1%, чуашлар — 19,7%, руслар — 15,4%). Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км²* га 12 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Спас өязе, 1920–30 елларда ТАССРның Спас кантонында. 1937 гә кадәр район үзәге булып Түбән Әлки авылы тора. Оешкан вакытында Ә.р.на 47 авыл советы, 56262 кеше (татарлар — 29684, руслар — 14993, башка милләт халыклары — 11585) яшәгән 99 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1031 *км²*, халкы — 28 мең кеше, 23 авыл советы, 52 торак пункт була. 1956 ның 7 декабрендә Ә.р.на таркатылган *Юхмачы районының*, 1960 та *Кузнечиха районының* бер өлеше керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Ә.р. таркатыла, биләмәсе Куйбышев р-нына бирелә. 1965 нең 12 гыйнварында район яңадан торгызыла, мәйданы — 1895 *км²*, халкы — 43 мең кеше; 21 авыл советын, 85 торак пунктны берләштерә. 2005 елның 26 гыйнварында Ә.р. муниципаль р-н дип үзгәртелә. Терр-ясенең рельефы — тигезлек (биеклеге 120–180 *м*). Кече Чирмешән елгасы һәм аның кушылдыклары, Актай, Бизнә һ.б. елгалар ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, көлсу кара, карасу соры һәм соры урман туфраклы. Терр-ясенең 18,4%ы урманнар б-н капланган. Базарлы Матакта кирпеч сугу өчен кулланыла торган балчык чыгарыла. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Кече Чирмешән елгасы, *Татар Әхмәте торфлы сазлыгы*. Район терр-ясендә бронза дәверенә, *Имәнкискә культурасына*, Болгар чорына караган 160 тан артык археологик истәлек табыла. Ә.р.ны — нигездә а.х. р-ны. Терлекчелек тармагы нык үсеш алган. 2005 тә а.х. җирләре 125,3 мең *га* били, ш.и. 100,6 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, көзге бодай, арыш, арпа, солы, борчак, тары игелә. 2006 да районда «Кызыл Шәрекъ — Агро» Әлки ф-лының 10 җитештерү отряды




һәм 4 крәстиян-фермер хуҗалыгы исәпләнә. Район үзәгендә, Түбән Әлки һәм Юхмачы авылларында зур булмаган сәнәгать пр-тиеләре урнашкан. Урман хуҗалыгы эшли. Ә.р. җиреннән Алексеев–Югары Колок, Болгар–Базарлы Матак автомобиль юллары уза. Районда 33 гомуми белем бирү мәктәбе (2006/07 уку елында 3110 укучы укый), ш.и. 3 тулы булмаган, 29 урта, 1 мәктәп-гимназия, музыка мәктәбе, 40 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 50 клуб, 36 китапханә, 151 урынлы 3 хастаханә эшли. Татарча «Әлки хәбәрләре», русча «Алькеевские вести» г-талары нәшер ителә.

**ӘЛКИ́ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Әлки һәм Спас р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1996 елда оештырыла. Ә.у.х. составына Болгар урман хуҗалыгының Базарлы Матак, Чернореченское һәм Юхмачы урманчылыклары, Октябрьский урман хуҗалыгының Чуаш Борнае урманчылыгы керә. Гомуми мәйданы 36911 *га*, ш.и. урман б-н капланган мәйдан — 35241 *га*, аларның 5332 *га* урман культуралары алып тора. Урман хуҗалыгы дирекциясе Базарлы Матак авылында. 2006 елның 1 гыйнварына эшләүчеләр саны 175 кеше. 1 нче төркем, нигездә, саклый торган урманнар — 8784 *га*. Чуаш Борнае урманчылыгында сазлык флорасы һәм фаунасы комплексыннан гыйбарәт табигать истәлеге (мәйданы 15 *га*) — *Татар Әхмәте торфлы сазлыгы* булеп алына. 2 нче төркем — файдаланыла торган урманнар — 28127 *га* мәйданда. Йомшак яфраклы токымнар 77% тәшкил итә: каен (6671 *га*, 898,8 мең $м^3$ агач запасы), усак (12705 *га*, 1976 мең $м^3$), юкә (6564 *га*, 1207,4 мең $м^3$). Ылыслы агачлар терр-янең 13%ын тәшкил итә: нарат — 3152 *га*, чыршы — 1390 *га*, карагай — 3 *га*. Каты яфраклылардан: биек каусәле имән — 1550 *га*, тәбәнәк каусәле имән — 1232 *га*, өрәңге — 700 *га*, карама 22 *га* мәйданда үсә. Терр-янең шактый өлешен яшь һәм урта яшьтәге утыртылган агачлар били (34 һәм 33%), өлгереп килүчеләре — 14%, өлгергәннәре һәм картайганнары — 19%. Утыртылган агачларның уртача яше — 37; Бонитетның уртача классы — 1,5; уртача тыгызлылыгы — 0,71. Ә.у.х. терр-ясендә урман типларының 10 төркеме үсә, алар арасында аеруча киң таралганнары — өрәңге-юкәле имәнлекләр (76%) һәм катнаш наратлыклар (11%). Агач запасы 4888,2 мең $м^3$, бер елга гомуми уртача артым 145,1 мең $м^3$. Урман кисүнең исәпләнгән еллык күләме — 67,4 мең $м^3$, ш.и. ылыслылар буенча — 0,9 мең $м^3$. 13,3 мең $м^3$ күләмдә сыйфатлы агач әзерләү б-н бергә 1320 *га* мәйданда чистарту эшләре башкарыла, 160 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла, ш.и. 80 *га* мәйданда урманнар утыртыла. А.х. җирләрендә 2005 елга кадәр ел саен 25 *га* мәйданда саклагыч утыртмалар, 15 *га* мәйданда юл буе полосалары утыртыла.

**ӘЛМӘ́Н РАЙОНЫ́**, *Курган өлкәсенең* көньяк-көнбатыш өлешендә. Мәйданы — 2486 $км^2$. Үзәге — Әлмән авылы (Курган шәһәреннән 178 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 14561 мең кеше (2002), ш.и. 3528 татар. Башлыча, алар Әлмән (2050 кеше), Иванково (246), Вишняково (300), Өчкүл (286), Тузово (95), Алакүл (351) авылларында яшиләр. 2005/2006 уку елында Ә.р.ның 2 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. 1981 елдан район үзәгендә татар фольклор үзешчән коллективы эшли. Ә.р.нда шагыйрьләр М.*Гатау*, Ж.Х.*Юмаев*, журналист Ж.Г.*Байбулатов* туган.

**ӘЛМӘНДӘ́Р** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 352 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.дә мәчет була. 20 йөз башында монда 2 су тегермәне һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1515 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 170 ир заты; 1859 да — 717, 1897 дә — 998, 1908 дә — 1176, 1920 дә — 1082, 1926 да — 579, 1938 дә — 739, 1949 да — 528, 1958 дә — 450, 1970 тә — 505, 1979 да — 437, 1989 да — 367 кеше.

**ӘЛМӘ́Т**, республика карамагындагы шәһәр, Әлмәт р-ны үзәге. ТРның көньяк-көнчыгыш өлешендә (Казаннан 279 *км*), Дала Зәе елгасының урта агымы буенда, Әгерҗе–Акбаш тимер юлындагы Әлмәт станциясеннән 13 *км* көнчыгыштарак. Автомобиль юллары төйнәлеше. Мәйданы — 38,6 $км^2$. Халкы — 141,7 мең кеше (2006), 2002 елгы халык исәбен алу буенча, татарлар — 53,1%, руслар — 40,1%, чуашлар — 2,2%, мордвалар — 1,6%. Халык депутатларының Ә. шәһәр советына шәһәр тибындагы Түбән Мактама посёлогы буйсына. Әлмәт — ТР нефть сәнәгатенең иң эре үзәге. Нефть һәм газ чыгарыла («Татнефть» АҖ һәм аның бүлекчәләре: «Әлмәтнефть», «Елховнефть», «Ямашнефть» НГДУлары һ.б.). Нефть чыгару сәнәгате өчен машина һәм җиһазлар җитештерелә. Батырма электр насослары, торба, газ эшкәртү, «Нефтемаш», шин ремонтлау, кирпеч сугу, асфальт-бетон, балчык порошогы, тимер-бетон, эре панельле йортлар төзелеше з-длары һ.б. Агач эшкәртү, руда булмаган һәм төзелеш материаллары комб-тлары. Мебель ф-касы. Азык-төлек сәнәгате (кондитер, макарон ф-калары, сөт-сыр ясау комб-ты, икмәк, консерв, ликёр-аракы, алкогольсез эчемлекләр з-длары) һәм җиңел сәнәгать (*«Алсу»* ф-касы). Ә. — *«Дуслык»* магистраль нефть үткәргеченең һәм ш.у. Түбән Новгород, Пермь, Самара һ.б. нефть үткәргечләренең башланган урыны. Нефть ин-ты, муниципаль ун-т. Физик тәрбия, сәүдә-икътисад, политехника техникумнары. Медицина, музыка, мәдәният һәм сәнгать уч-щеләре, 31 гомуми белем бирү, 2 сәнгать, 3 музыка, 2 балалар сәнгать мәктәбе. Татар драма театры. Әлмәт милли-мәдәни үзәге, «Нефтьче» мәдәният сарае, Укучылар сарае. Картиналар галереясы. Төбәк тарихын өйрәнү, фольклор-этнография, техник иҗат һәм язучы С.Сөләйманова музейлары. 13 китапханә. Ә. тарихы 1720 еллар тирәсендә нигезләнгән Әлмәт авылыннан башлана. 18–19 йөзләрдәге икенче исеме — Әлмәт-Муллино. Ул 18 йөз ахырында эре торак пунктка әверелә. Почта бүлеге һәм аракы кибете була, мәчет һәм тимерчелек эшли. 19 йөз уртасыннан монда Самара губернасының Бөгелмә өязе 1 нче станының становой фатиры, 1860 еллардан волость идарәсе урнаша. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре, типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә. Игенчелек, терлек үрчетү, чыпта-кап сугу, сәүдә итү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.тә 3 мәчет, 2 мәдрәсә, земство хастаханәсе, почта-телеграф бүлекчәсе, почта станциясе, ярма ярдыру пар тегермәне эшли; чәршәмбе саен базар, һәр елның 20–26 декаб-


Әлмәт шәһәренең гомуми күренеше.









Әлмәт шәһәре. 1. Картиналар галереясы; 2. «Юбилейный» спорт сарае; 3. Төзүчеләр проспекты.

рендә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4416 дис. тәшкил итә. 1926 елга кадәр Ә. — Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлмәт волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — район үзәге. Ә.нең киләчәктәге үсеше монда нефть чыганаклары табылу һәм эшкәртелү б-н бәйле. 1952 нең 25 мартында Әлмәт авылы шәһәр тибындагы Әлмәт



Әлмәт шәһәренең 2 нче җамигъ мәчете. 1877.

посёлогы итеп үзгәртелә, 1953 нең 3 ноябреннән — шәһәр. Ә.нең архит-ра йөзен шәһәр терр-ясен үзләштерү этапларын чагылдыручы төрле типтагы төзелешләр формалаштыра. Ә.нең тарихи-архит-ра мирасына 2 нче җамигъ мәчет бинасы (1877), бай утары һәм кечкенә кибетләр (19 йөз ахыры — 20 йөз башлары), район советы бинасы (1920 еллар) керә. 1950 елларда үзәк кварталларның



Әлмәт шәһәрендә Татарстан нефтьчеләренә һәйкәл.

төп өлешен алып торган 1–2 катлы щитовой, штукатурланган йортлар урынына 2 катлы таш тораклар һәм җәмәгать биналары (Техника йорты (1955–60), «Россия» кинотеатры (1959) һ.б.) үсеп чыга. 1960 елларда шәһәрнең Ленин исем. үзәк мәйданы, Чупай известьташыннан төзелгән 3–4 катлы биналары б-н Ленин урамы барлыкка килә. 1970 елларда бу урамның дәвамында күп катлы яңа микрорайоннар төзелә. 1990 еллар архит-расы индивидуаль һәм комплекслы булуы б-н аерылып тора. Торак төзелешендә аерым йортлар күбрәк. Дини архит-ра *Әлмәт мөселман дини мәгърифәт үзәге*, православие кәшәнәсе (часовня) (1999) һ.б.дан гыйбарәт. Әлмәт бистәләрендә стадион, ипподром, чишмә комплексы, «Ана» скульптура композициясен үз эченә алган «Сабантуй» гомумшәһәр җәмәгать-спорт комплексы төзелә. Халык саны: 1782 дә — 176 ир заты; 1795 тә — 700, 1859 да — 1518, 1889 да — 2347, 1908 дә — 2228, 1920 дә — 2778, 1926 да — 1924, 1938 дә — 2844, 1949 да — 3078 кеше, 1959 да — 48,6 мең, 1970 тә — 87, 1979 да — 109,4, 1989 да — 136,4 мең кеше.

*Әд.:* Сабиров Р.М. По городам Татарии. К., 1976; Наш Альметьевск: Сборник. Наб.Челны, 1993.

**ӘЛМӘ́Т** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 8 *км* көнчыгыштарак, Кәүҗияк елгасының уң кушылдыгы Сарсаз буенда. 2002 елда 497 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. «Сарман» катнаш терлек азыгы з-ды. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Әлмәт-Муллино исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре, типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.тә мәчет, мәдрәсә, 2 су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт-Муллино волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 159 ир заты; 1897 дә — 1239, 1920 дә — 1730, 1926 да — 1173, 1938 дә — 1002, 1958 дә — 650, 1970 тә — 806, 1979 да — 666, 1989 да — 450 кеше. Ә.тә тарихчы һәм дин галиме *Морад Рәмзи* туган.

**ӘЛМӘ́Т АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, Әлмәт р-нының төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы 24,1 мең *га*, ш.и. урманнар — 10,8 мең *га*. Тыюлык терр-ясе аша Дала Зәе, Урман Зәе, Урсалы елгалары ага. 1971 елда кәҗәболаннар санын арттыру максатыннан оештырыла. Тыюлыкта ш.у. поши, кабан дуңгызы, селәүсен, сусар, ак куян яши.

**ӘЛМӘ́Т КАРТИ́НАЛАР ГАЛЕРЕ́ЯСЫ**, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее филиалы (1987 елдан). 1975 тә ачыла. Оештыручысы һәм директоры (1987 гә кадәр) Г.А.Стефановский; аның инициативасы б-н ТАССР Рәссамнар берлеге һәм Мәдәният министрлыгы, «Татнефть» берләшмәсе тарафыннан сатып алынган һәм бүләк итеп бирелгән 300 ләп әсәрдән коллекция туплана. Башта галерея 1 нче балалар сәнгать мәктәбендә эшли, 1985 тән махсус төзелгән яңа бинада урнаша. Экспозиция мәйданы (4 залны кертеп) 670 $м^2$ га якын, вакытлы күргәзмәләр залы 170 $м^2$. Ә.к.г. комплексына 2 нче балалар сәнгать мәктәбе керә (1989 да оешкан), аның өчен галерея бинасына янкорма төзелә. Коллекциядә 1000 нән артык саклау берәмлеге исәпләнә, ш.и. 476 — рәсем сәнгате, 232 — графика, 45 — сынлы сәнгатькә караган коллекцияләр. Җирле мәдәни ландшафтның үзенчәлекле табигатен чагылдырган, Татарстанның, татар халкының һәм районның хәзерге тормышын, тарихы б-н бәйле образларын, сюжетларын сурәтләгән, Әлмәт шәһәре төзелешен һәм нефть табылган урыннарны өйрәнү темаларын яктырткан картиналар, сынлы сәнгать әсәрләре куелган. Араларында 19 йөз рәссамнарының (Л.Х.Лагорио, А.М.Кокорев), СССРның халык рәссамы Н.Н.Жуков, рәсем сәнгате академиклары Х.Г.Якупов һәм П.П.Соколов-Скаль, Татарстан рәссамнары Б.И.Урманче, И.К.Зарипов, А.Ә.Абызгилдин, Р.Х.Нигъмәтуллина, С.О.Лывин, Н.Д.Кузнецов, Л.А.Фәттахов, И.М.Хәлиуллов, Х.Х.Хәйдәров, ш.у. татар үрнәкләре төшерелгән декоратив-гамәли сәнгать (күн мозаикасы һ.б.) әсәрләре бар. Ә.к.г. ф-лы Сарман р-нының Җәлил посёлогында ачыла (1981). Күчерелмәле өстәл календаре, «Әлмәт картиналар галереясы рәсем сәнгате җыентыгы» (Әлмәт, 2000) басмалары галерея тырышлыгы б-н дөнья күрә.

*Әд.:* Муратшин Х. Альметьевск // Художник. 1976. № 9; Ларин В. Приобщение к прекрасному // Нефтяник. 1977. № 5.


*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*


**ӘЛМӘ́Т МЕДИЦИ́НА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында. 1990 елда ачыла. Дәвалау оешмалары өчен махсус урта белемле медицина хез-

мәткәрләре әзерли. Укыту көндезге һәм кичке формада алып барыла. Эшләү дәверендә уч-щедә 1 меңнән артык белгеч әзерләнә. 2006 да 29 укытучы эшли, көндезге бүлектә 327, кичкедә 25 студент укый; белгечлекләр — дәвалау хезмәте, шәфкать туташлары хезмәте.

**ӘЛМӘ́Т МӨСЕЛМА́Н ДИНИ́ МӘГЪРИФӘ́Т ҮЗӘГЕ́**, Р.Г.Галиев исемендә («Ринат»), мәчет. Мәгърифәт тарату максатында салынган биналар б-н бер комплекс хасил итә. 1990–99 елларда арх. Ф.М.Мәүлетов, А.М.Җамалиев, инженерлар С.С.Абдуллин, В.И.Маслова, А.А.Гәрәев проекты б-н төзелә. Әлмәт шәһәренең төньяк өлешендә, Бигәш елгасы буенда урнашкан. Билгеләнгән мәйданының төньяк-көнбатышка таба авышлыгы — 10 *м*. Буйга сузылган өч, дүрт катлы кирпеч бина. Төп ишеге төньяк фасадында, аңа монументаль мәрмәр баскыч алып менә. Бинаның көньягы квадрат формасында. Почмакларына очлары чатырланган сигез кырлы манаралар утыртылган (36,2 *м*); яссы түбәсенең үзәгендә — диаметры 18 *м* лы биек гөмбәз, ул алтын йөгертелгән тутыкмас корыч б-н капланган. Бинаның бу өлешендә 1200 кеше сыйдырышлы, аслы-өсле тәрәзәле, гөмбәзне күтәреп торучы металл конструкцияләр б-н ныгытылган гыйбадәт кылу залы урнашкан. Бинаның көньяк өлеше төньяк өлешенә караганда таррак. Аның 2 нче катын — киңәшмә заллары, өске һәм әргә катларын ярдәмче бүлмәләр алып тора. Ике өлешенең дә 1 нче катында 120–140 кешегә исәпләнгән аудиторияләр урнашкан. Бинаның төньяк өлешендә, үзәккә табарак, гөмбәзле биек манара калкып тора (53,5 *м*). Фасадлары өстә дага рәвешендәге уемнар б-н төгәлләнә. Манара балконнары, кечкенә консольләр һәм манара гөмбәзләре яшел төстә. Гыйбадәт кылу залының диварлары, түшәме, гөмбәзе тоташ келәм сыман бизәкле плитәләр б-н капланган. Гөмбәз барабанындагы тәрәзәләр һәм залның өске тәрәзәләре төсле витражлар б-н бизәлгән. Залны 5 зур бәллүр люстра яктырта. Үзәкне төзүгә зур өлеш керткән шәхес — «Татнефть» АҖнең шул еллардагы ген. директоры Р.Г.Галиев исеме б-н аталган. Мәчет каршында Әлмәт ислам мәдрәсәсе, дини әдәбият китапханәсе эшли.

*Х.Г.Надыйрова.*




1. Әлмәт мөселман дини мәгърифәт үзәге;
2. Төп гыйбадәт залы.

**ӘЛМӘ́Т МУ́ЗЫКА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Мәдәният министрлыгы карамагында. 1964 елда ачыла, 1974 тән Ф.З.Яруллин исемендә. Укыту көндезге бүлектә алып барыла. 1992 дә татар бүлеге оештырыла. Эшләү дәверендә 1 меңнән артык белгеч әзерләнә, алар арасында: ТРның атказ. артистлары Г.Казанцева, К.Сатиев, А.Фәйзуллин, ТРның атказ. сәнгать эшлеклеләре В.Әхмәтшин, И.Закиров, Ф.Шиһапов. 2005 тә 69 укытучы эшли, 204 студент укый; белгечлекләр — инструменталь башкару, вокал, хор дирижёры.

**ӘЛМӘ́Т МУНИЦИПА́ЛЬ ХЕЗМӘ́Т ИНСТИТУТЫ́**, югары уку йорты. 1996 елда муниципаль ун-т буларак ачыла, оештыручысы Әлмәт шәһәр хакимияте. 2001 дән муниципаль ин-т, 2006 дан дәүләт ин-ты итеп үзгәртелә һәм хәзерге исемдә. Икътисад, филология, психология, информатика һәм мәгълүмат системалары, квалификацияне күтәрү һәм кадрлар әзерләү ф-тлары эшли. Укыту филология, лингвистика, психология, икътисад, аграр икътисад, мәктәпкәчә тәрбия педагогикасы һәм методикасы, дәүләт һәм муниципаль идарә итү белгечлекләре буенча алып барыла. 2006 елга көндезге бүлектә — 440, читтән торып уку бүлегендә, нигездә, түләүле формада 510 студент укый. 120 укытучы, ш.и. Казан, Чаллы, Алабуга шәһәрләреннән килеп эшли, аларның 1се фән д-ры, 11е фән кандидаты. Фәнни-тикшеренү үзәге, психол. тикшеренүләр, экологик белем бирү мәсьәләләре лабораторияләре бар. 1996 дан ректоры — Д.С.Ягъфәрова.

**ӘЛМӘ́Т НАСОСЛА́Р ЗАВОДЫ́**, к. *«ӘЛНАС»*.

**ӘЛМӘ́Т НЕФТЬ ИНСТИТУТЫ́**, РФ Энергетика министрлыгы карамагында. 1956 елда И. М. Губкин исем. Мәскәү нефть һәм газ сәнәгате ин-тының уку-укыту-консультация пункты буларак ачыла, 1958 дән читтән торып уку ф-ты филиалы, 1959 дан кичке ф-т. 1992 дән Мәскәү ин-ты составындагы ин-т, 1995 тән мөстәкыйль уку йорты.


2005 тә нефть һәм газ, инженерлык механикасы, энергетика һәм автоматика, икътисад идарәсе, көндезге һәм читтән торып уку ф-тлары эшли. Укыту нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү һәм файдалануга тапшыру, нефть һәм газ скважиналарын бораулау, машиналар төзү, нефть һәм газ промыселлары машиналары һәм җайланмалары, сәнәгать җылылык энергетикасы, сәнәгать җайланмалары һәм технологик комплексларда электропривод һәм автоматика, технологик процессларны һәм житештерүне автоматлаштыру, икътисад һәм хезмәт социологиясе, предприятиедә икътисад һәм идарә итү белгечлекләре буенча алып барыла. Көндезге бүлектә — 2495, кичке бүлектә — 727, читтән торып уку булегендә 1263 студент укый. Укытучылар коллективында якынча 188 кеше, ш.и. 16 фән д-ры һәм 76 фән кандидаты эшли. 2001 дә аспирантура ачыла. Эшләү дәверендә 5,5 мең белгеч әзерләгән, алар арасында: М.Ш.Залятов, Ә.К.Мөхәммәтҗанов, Ш.Ф.Тәхаутдинов, «Татнефть» берләшмәсенең күп кенә башка җитәкче хезмәткәрләре бар. Институт ректорлары: В.Н.Матвеев (1992–99), 1999 дан — А.А.Емекеев.

**ӘЛМӘ́Т ПОЛИТЕ́ХНИКА ТЕ́ХНИКУМЫ**. 1964 елда Казан төзелеш техникумының Әлмәт кичке филиалы буларак ачыла. 1966 дан — Әлмәт төзелеш техникумы, 1993 тән хәзерге исемендә, 1994 тә Әлмәт нефть техникумы б-н берләштерелә. 1968–80 дә Бөгелмә шәһәрендә, техникумның кичке ф-лы эшли. Эшләү дәверендә 14 меңнән артык белгеч әзерләнгән. Техникумны тәмамлаучылар арасында: Х.А.Баһманов, Р.Ф.Вәлиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин. 2005 тә 1518 студент — көндезге, 733 кеше читтән торып уку бүлегендә укый, 90 укытучы эшли. Ә.п.т. икътисад, бухгалтерлык исәбе һәм контроль, автомобиль транспортына техник хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау, күтәрү транспорты, төзелеш, юл төзү машиналарын һәм җайланмаларын эксплуатацияләү һәм ремонтлау, биналар һәм корылмалар төзү һәм алардан файдалану, нефть һәм газ ятмаларын эксплуатацияләү, электр һәм электромеханика җайланмаларыннан файдалану, аларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, сәнәгать җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, нефть һәм газ скважиналарын бораулау, йөк ташуны оештыру һәм автомобиль транспорты хәрәкәте б-н идарә итү белгечләре әзерләп чыгара.

**ӘЛМӘ́Т РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк-көнчыгышында урнашкан. Мәйданы — 2500,2 *км*²; 35 авыл, 1 шәһәр (штп Түбән Мактама) җирлеген, 96 торак пунктны берләштерә. Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы икътисади р-нына керә. Үзәге — Әлмәт шәһәре. Халкы — 2006 елда (район үзәген һәм аңа караган торак пунктларны кертмичә) 50,5 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57,3%, руслар — 30,8%, чуашлар — 6,8%). Шәһәр халкы — 9,4, авылларда 41,1 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 16 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Самара губернасының Бөгелмә өязенә, 1920–30 да ТАССРның Бөгелмә кантонына керә. Оешкан вакытында районга 29 авыл советы, 44460 кеше (татарлар — 37703, руслар — 3012, башка милләт халыклары — 3745) яшәгән 63 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1121 *км*², халкы — 35,4 мең кеше, 23 авыл советы, 52 торак пункт

була. 1959 да Ә.р.на таркатылган *Акташ районының* бер өлеше керә. 1960 та район 2114 *км²* җир били, составында посёлок советы, 23 авыл советы, 104 торак пункт исәпләнә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Ә.р.на Азнакай р-ны, Зәй, Яңа Чишмә һәм Беренче Май р-ннарының бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 5126 *км²*, халкы — 115 мең кеше, 47 авыл советы, 243 торак пункт керә. Республикада адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, 1965 нең 12 гыйнварында Ә.р. терр-ясе 3167 *км²* га кадәр кими, халкы — 83,8 мең кеше, 32 авыл советы, 170 торак пункт кала. 1972 нең 1 ноябреннән авыл советларының кайберләре яңа оештырылган Зәй р-нына күчә. 2005 елның 26 гыйнварында Ә.р. муниципаль р-н дип үзгәртелә. Районның рельефы — тирән елга үзәннәре б-н ергаланган калкулыклы тигезлек (биеклеге 200–328 *м*). Кушылдыклары б-н Дала Зәе һәм Кичү елгалары ага. Җире селтесезләнгән, карбонатлы һәм типик кара, карасу-соры урман туфраклы. Терр-ясенең 24,7%ы урманнар б-н капланган. Нефть, газ, известьташ, доломит ятмалары бар. Аеруча саклаулы табигать терр-яләре: Дала Зәе елгасы, *Акташ упкыны* күле, *Чыршы һәм карагай урман культуралары*, *Әлмәт аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә бронза дәверенә һәм урта гасырлар чорына караган 70 тән артык археологик истәлекләр табыла. Сәнәгать пр-тиеләре күбесенчә район үзәгендә һәм шәһәр тибындагы Түбән Мактама посёлогында урнашкан. Шәһәр тибындагы Рус Акташы посёлогында кирпеч з-ды һәм икмәк кабул итү пр-тиесе, Яңа Троицкий авылында крахмал-патока з-ды бар. Әлмәт һәм Кәләй урман хуҗалыклары эшли. Районның барлык терр-ясендә нефть чыгарыла. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, җәнлек үрчетү, кошчылык тармаклары нык үсеш алган. 2005 тә а.х. җирләре 147,3 мең *га* били, ш.и. 104,5 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае һәм көзге бодай, арыш, арпа, солы, борчак, карабодай игелә; шикәр чөгендере үстерелә. 2005 тә районда 12 а.х. пр-тиесе, ш.и. Әлки «Кызыл Шәрекъ–Агро» ААҖ ф-лы, 1 ААҖ, 5 ҖЧҖ, 5 а.х. товарлары җитештерү кооперативы, 2 ярдәмче хуҗалык исәпләнә. Ә.р. җиреннән Әгерҗе–Акбаш тимер юлы, Казан–Оренбург, Чаллы–Әлмәт–Бөгелмә, Әлмәт–Сарман һ.б. автомобиль юллары уза. Район терр-ясендә төрле якка үткәргеч торбалар челтәре сузылган. Ә.р.нда (Әлмәт шәһәрен дә кертеп) 76 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 23771 укучы укый), ш.и. 4 башлангыч, 12 тулы булмаган урта, 57 урта, музыка мәктәбе (Яшьләр пос.), 34 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 53 клуб, 47 китапханә, 1819 урынлы 11 хастаханә эшли. Риза Фәхретдин (Кичүчат а.), Елховой авылы (Иске Баграж-Елховой а.) тарихы музейлары бар. Татарча «Әлмәт таңнары», русча «Знамя труда» г-талары нәшер ителә.

*Әд.*: Из истории Альметьевского региона. К., 1999.




## ӘЛМӘ́Т СӘҮДӘ́-ИКЪТИСА́Д ТЕ́ХНИКУМЫ

**ӘЛМӘ́Т СӘҮДӘ́-ИКЪТИСА́Д ТЕ́ХНИКУМЫ**, махсус урта уку йорты. 1968 елда совет сәүдәсе техникумы буларак оештырыла, 1992 дән коммерция техникумы, 1996 дан хәзерге исемдә. 2005 тә 713 студент — көндезге бүлектә, 230 кеше читтән торып укый, 39 укытучы эшли; белгечлекләр — азык әзерләү технологиясе һәм җәмәгать туклануын оештыру, сәүдә эшен оештыру һәм азык-төлек товарлары белеме, коммерция эшчәнлеген оештыру.

**ӘЛМӘ́Т ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ**, 1944 елда *колхоз-совхоз театры* буларак ачыла, 1951 дән драма театры, 1985 кә кадәр күчмә театр. Баштагы чорда мәдәният йортында урнаша, 1973 тә театрга яңа спектакльләр әзерләү өчен аерым эш бинасы бирелә, 1985 тә мәдәният йорты бинасы театр өчен үзгәртеп җиһазландырыла. Труппа Казан театр уч-щесен тәмамлаучылардан һәм үзешчән сәнгатьтә катнашучылардан оеша. 1950 елларда труппага шул вакытта ябылган Мамадыш һәм Буа татар театрларыннан һәм Башкортстан АССРдан кайбер актёрлар да килеп кушыла. Алар арасында К.Еникиев, Н.Кимова, Х.Маннурова, Н.Дәүләтшина, Х.Рамазанов, Г.Хәбибов, Т.Җаббарова була. Реж. Ә.Галиев тарафыннан куелган беренче спектакльләр — «Кайту» (Р.Ишморат, 1944), «Миңлекамал» (М.Әмир, 1945) репертуарның нигезен тәшкил итә, яңа коллективның иҗат мөмкинлекләрен күрсәтә. Республиканың нефть районнары эшчәннәренә хезмәт күрсәтү максатында оештырылган театр репертуар кытлыгы кичерә, «производство» темасына язылган пьесалар әзләргә мәҗбүр була. 1946–50 дә коллективны җитәкләгән баш реж. К.Халәпов Н.Гайсинның «Давыллар эчендә» (1948), «Таһир Биккинин» (1950), Э.Шамилнең «Егет сүзе» (1948), Г.Сәгыйдуллинның «Вәгъдә» (1948), А.Әхмәтнең «Серләр» (1949), чуаш драматургы Г.Харлампьевның «Язгы моңнар» («Весенние мелодии», 1951), үзенең «Бәйрәм алдыннан» (1948) пьесаларын сәхнәләштерә. Бу пьесалар югары сәнгать дәрәҗәсенә ирешкән әсәрләр булмыйлар һәм коллективның иҗади үсешенә этәргеч ясамыйлар. 1950–54 тә театр репертуары А.Афиногеновның «Машенька» (1952, реж. Т.Кичубаев), А.Арбузовның «Яшьлек белән очрашу» («Встреча с юностью», 1952, реж. С.Булатов), И.Франконың «Урланган бәхет» («Украденное счастье», 1951, реж. Г.Йосыпов), Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1953, реж. Т.Кичубаев) пьесалары б-н баетыла. 1954–58 дә театрның баш режиссёры булып С.Булатов эшли. Аның тарафыннан Ш.Камал («Томан арты», 1955), С.Кальметов («Соңгы очрашу», 1955; «Ышанычлы юлдаш», 1956), М.Хәсәнов («Нурихан», 1955; «Рамай», 1957), Ф.Бурнаш («Яшь йөрәкләр», 1957) пьесалары буенча куелган спектакльләр актёрлар өчен житди иҗат мәктәбенә әверелә. Театрны 1963–66 да җитәкләгән Г.Йосыпов коллективның профессиональ кадрлар б-н тәэмин итүгә, актёрлык осталыгын үстерүгә зур өлеш кертә. Ул эшләгәндә театрда студия оештырыла. Аны тәмамлаган К.Вәлиев, Д.Кузаева, Л.Солтанова, А.Мусина, Җ.Исмәгыйлов соңыннан театрның әйдәп баручы актёрлары булып танылалар. Театр репертуарында драматурглар Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, Т.Миңнуллин, Ш.Хөсәенов пьесалары куела башлый, режиссёрлар тәрбияләнә, коллективның әхлакый-эстетик позициясе билгеләнә. 1969–72, 1975–83 тә театрны Г.Хөсәенов җитәкли. Аның тарафыннан Г.Мөсрәповнең «Козы көрпеш һәм Баянсылу» (1969), Ч.Айтматовның «Анам кыры» («Материнское поле» повесте буенча, 1971, 1977); баш рольдә Д.Куза-





Әлмәт татар драма театры.





Әлмәт татар драма театры. Спектакльләрдән күренешләр: 1. М. Фәйзи, «Ак калфак» (1964); 2. Ч. Айтматов, «Анам кыры» (1971); 3. К. Гольдони, «Трактирщица» (1975).

ева уңышлы уйный), Ш.Бикчуринның «Тальян моңы» (1972), К.Гольдониның «Тылсымлы кыз» («Трактирщица», 1975), А.Гыйләҗевнең «Кар астында кайнар чишмә» (1976), Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» (1978, драматург, реж. Г.Хөсәенов, төп рольне башкаручы Д.Кузаева ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек булалар, 1979), Ж.Ануйның «Антигона» (1980) әсәрләре буенча куелган спектакльләр театрны яңа биеклеккә күтәрә, коллективның иҗади җитлеккәнлеген күрсәтә. Театр репертуары драматурглар Ф.Садриев, Ю.Сафиуллин, Р.Хәмид, Р.Мингалим пьесалары б-н баетыла. Театр ш.у. татар һәм рус классиклары пьесаларына, СССР һәм чит илләрнең шул заман драматурглары пьесаларына да мөрәҗәгать итә. 1980 елларда Р.Абдуллаев тарафыннан куелган К.Тинчурин («Җилкәнсезләр», 1984), Б.Л.Васильев («Ә таңнар гүзәл тынлыкта иде» — «А зори здесь тихие», 1985), Н.Фәттах («Сармат кызы Сәринә», 1986), реж. Р.Фатыйхов һәм Г.Ширгазин сәхнәләштергән Р.Хәмид («Майның унбишләрендә», 1984) пьесалары җәмәгатьчелектә аеруча киң яңгыраш таба. Коллектив К.Тинчурин исем. театр фестивалендә (1992) «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш, реж. З.Туишева) спектакле б-н уңыш казана. 1990 елларда күрсәтелгән аеруча мөһим спектакльләр — Ф.Бүләковның «Дүрт әби һәм Әхмәди» (1992, реж. З.Туишева), Г.Камалның «Банкрот», Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрләре. Театр Татарстанның нефть төбәгендә чын мәгънәсендә мәдәният үзәгенә әверелә, республикадан читтә дә киң танылa, репертуарында татар әдәбияты классиклары һәм хәзерге заман авторлары б-н беррәттән рус һәм чит ил язучылары А.Островский, М.Горький, А.Арбузов, Л.Леонов, Д.Флетчер, Ж.Ануй, И.Франко, А.Макаёнок h.б. авторларның исемнәре дә лаеклы урын ала. Кайбер спектакльләрне Х.Сәлимҗанов, П.Исәнбәт, Ф.Бикчәнтәев, Б.Ибраһимов, Ф.Ибраһимов h.б. куя. Театр труппасында ТРның халык, РФнең атказ. артисты К.Вәлиев, ТРның халык, Башкортстанның атказ. артистлары Ф.Зарипов, Р.Салихова, ТРның халык артисты Л.Солтанова, ТРның атказ. артистлары Р.Минханов, С.Минханова, Р.Таһиров, Р.Фәйзуллина, Х.Фәйзуллин, И.Мөхәммәтов, Д.Әбүнәгыймова, Н.Исмәгыйлева, Н.Нәҗипова, артистлар А.Харисова, Н.Галләмов, Ф.Сибгатуллин, З.Халикова, Ф.Бикморатова h.б. эшли; төрле елларда баш режиссёрлар: З.Туишева, К.Вәлиев; 2005 тән — Г.Каюмов.

Әлмәт татар драма театры. Спектакльләрдән күренешләр: 1. Г. Камал, «Банкрот» (1994); 2. М. Кәрим, «Җырланмаган җыр» (2000).

Соңгы елларда куелган спектакльләр: «Җырланмаган җыр» (М.Кәрим), «Тигезсезләр» (Ф.Әмирхан), «Көтмәгәндә, уйламаганда», «Узып барышлый ...», «Парлы ялгызлар» (Д.Салихов), «Туй күлмәге» (М.Гыйләҗев) h.б.

*Әд.:* Татар совет театры. К., 1975; Р ә х и м о в Җ. Әлмәт татар дәүләт драма театры. 50 ел. Әлмәт, 1994; Г ы й м р а н о в а Д. Әлмәт драма театрына 60 яшь // Сәхнә. 2004. № 5; Г ы й м р а н о в а Д. Сценическая жизнь Альметьевска // Әлмәт-Альметьевск. К., 2003.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ӘЛМӘ́Т ТОРБАЛА́Р ЗАВОДЫ́**, металлургия сәнәгате пр-тиесе, Әлмәт шәһәрендә урнашкан. Мәйданы 62 *га*. Эшчеләр саны 1138 кеше (2005). Кече һәм уртача диаметрлы (10–220 *мм*) электр б-н эретеп ябыштырылган корыч , ш.и. коррозиягә каршы һәм җылылык үткәрми торган өслекле торбалар эшләп чыгару буенча специальләшә. 1966 елда спираль җөйле торбалар әзерләү буенча Әлмәт кыр базасы буларак төзелә. 1991 елдан Ә.т.з., 1994 тән АҖ. 2002 дән «Берләшкән металлургия компаниясе» АҖ составында (Мәскәү). 1966 да заводның беренче чиратының — җитештерүчәнлеге елына 8 мең *т* 159–426 *мм* диаметрлы спираль җөйле торбаларны электр б-н эретеп ябыштыра торган ике станлы цех эшли башлый. Аннан соңгы елларда шундый ук 4 стан (1969) һәм югары ешлыклы эретеп ябыштыру ысулы б-н юка стеналы спираль җөйле торбалар әзерли торган 6 стан (1985) өчен җитештерү корпуслары төзелә. 1980 дә Россиядә беренче тапкыр заводта торбаларны тышкы яктан полиэтилен б-н тышлау производствосы оештырыла. 1986 да торбаларның эчке өслеген коррозиядән саклау үзләштерелә. 1992–96 да пр-тие техник яктан яңадан җиһазландырыла. Туры җөйле торбалар җитештерү буенча заманча торбалы станнар (10–76, 102–220, 20–76, 10–35), төргәкле прокатны буйга кисә торган агрегат файдалануга тапшырыла. Нәтиҗәдә җитештерү куәте елына 300 мең *т* торбага җитә. Завод даими рәвештә продукцияне төрләндерә, аның сыйфатын яхшырта, технологик процессларны камилләштерә, Россиянең әйдәп баручы фәнни-тикшеренү ин-тлары б-н хезмәттәшлек итә. 2002 елда 18 төр үлчәмдәге (аркылы киселеме турыпочмаклык һәм квадрат формасында, үлчәмнәре 20х20 дән алып 100х100 *мм* га кадәр) профильле торбалар җитештерүне, 2005 тә торбаларны өч кат полиэтилен б-н тышлауны үзләштерә. Ә.т.з. эшләп чыгарган продукция-



Әлмәт торбалар заводы продукциясе. Спираль җөйле торбалар.

нең техник яктан эшләнеше Россия һәм чит ил стандартларына туры килә. Төп продукция Россия төбәкләренә җибәрелә. Завод җитәкчеләре: П.Г.Рязанов (1965–71), С.С.Гришанин (1971–73), И.Г.Чеков (1973–89). 1989 елдан ген. директор — А.М.Токарев.

*А.И.Шипилов, Г.Я.Мәүлетова.*

**ӘЛМӘ́Т ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**. Берләштерелгән Дәүләт музее ф-лы буларак 1993 елда ачыла, 2001 дән ТР Милли музее ф-лы, 2006 дан муниципаль музей. 9 катлы йортның 1 нче катында урнашкан. Экспозиция мәйданы 361,3 *м²*, төп фондында 2017 саклау берәмлеге исәпләнә. Әлмәт төбәге тарихына багышланган экспозиция 4 залны били. Төбәкнең борынгы тарихын Көнчыгыш Кама аръягыннан җыелган, неолит дәвереннән урта гасырлар ахырына кадәрге вакыт арасына караган археологик табылдыклар чагылдыра. Палеонтологик табылдыклар, Тайсуган хәзинәсе әйберләре дә (хезмәт һәм сугыш кораллары, ат дирбиясе детальләре һәм казан) күрсәтелә. Татар өе интерьеры көнкүреш кирәк-яраклары, өс киемнәре, төбәк халкының 19 йөз ахыры — 20 йөз башына нисбәтле зәркән бизәнү әйберләре б-н таныштыра. Ш.у. шәһәрнең танылган шәхесләре: Социалистик Хезмәт Геройлары Ә.В.*Вәлиханов*, Н.Г.*Драцкий*, Р.С.*Саттаров*, Ә.Ш.Сафиуллин; язучылар Ә.М.*Маликов*, С.Г.*Сөләйманова*, язучы, композитор Р.Н.*Вәлиуллин* һ.б.ның мемориаль әйберләре һәм документлары урнаштырылган. Экспозициянең Бөек Ватан сугышына багышланган бүлегендә якташлар, ш.и. Сов. Союзы Геройлары М.Ә.*Әхмәдуллин*, Н.Е.*Токарликов*, турындагы материаллар, «катюша»лар дивизионы командиры Б.А.Йосыповның шәхси документлары, совет





Әлмәт төбәк тарихы музее: 1. Күргәзмә залы; 2. Татар өе күренеше (19 йөз ахыры — 20 йөз башы).

һәм немец солдатларының каскалары һ.б. куелган. «Монда минем Ватанымның башы» бүлеге Көнчыгыш Кама аръягының Көньяк-Көнчыгыш өлеше фаунасы б-н таныштыра. Хайваннар дөньясы далада һәм урманнарда, кечкенә елгалар буйларында яшәүче хайваннарның карачкыларында чагылыш таба. Ш.у. Идел буе халыкларының милли костюмнары күрсәтелә, өй эченең бер өлеше — чәй эчү почмагы күренеше тәкъдим ителә.

Аеруча мөһим экспонатлар арасында 19 йөз ахырында тукылган әйберләр коллекциясе (100 саклау берәмлеге), археологик табылдыклар коллекциясе (100 саклау берәмлеге) бар.

**ӘЛМӘ́Т УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Әлмәт, Зәй, Лениногорск һәм Бөгелмә р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда 27005 *га* мәйданда оештырыла. 1935 тә Сарман һәм 1940 та Акташ урман хуҗалыклары б-н берләштерелә. 2006 елның 1 нче гыйнварына урман фондының гомуми мәйданы 50179 *га*; ш.и. урман б-н капланган мәйдан — 42948 *га*. 4 урманчылыкны үз эченә ала: Акташ — 6354 *га*, Поташ Аланы — 16680 *га*, Миңлебай — 14474 *га* һәм Кама-Исмәгыйль — 12671 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Әлмәт шәһәрендә. Эшләүчеләр саны 87 кеше.

1 нче төркем урманнар 25972 *га* мәйданны били, ш.и. яшел зоналар — 13486 *га*, эрозиягә каршы урманнар — 4925 *га*, саклый торган урманнар — 7133 *га*, *Бохарай наратлыгы* табигать истәлегенең бер өлеше — 245 *га*, юл буйларында саклаучы полосалар — 183 *га*. 2 нче төркем, ягъни файдаланыла торган урманнар 24207 *га* мәйданны алып тора. Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 22%, урта яшьтәгеләре — 35%, өлгереп килүчеләре — 17%, өлгергәннәре һәм картайганнары — 26%. Уртача запасы 159 *м³/га*, еллык уртача артым 140,6 мең *м³*. Ылыслы агач токымнары урман мәйданының 18% ын тәшкил итә. Нарат 6412 *га* мәйданда үсә, уртача яше — 39 ел, агач запасы 1104,1 мең *м³*. Катнаш, яшел мүкле һәм өрәңгеле наратлыклар күпчелекне тәшкил итә. Чыршы утыртмалары 1180 *га* мәйданда, уртача яше — 25 ел, запасы — 119,5 мең *м³*. Катнаш һәм имәнле чыршылыклар таралган. Каты яфраклы утыртмалар урман мәйданының 11,5% ын тәшкил итә, алардан имән 5850 *га* мәйданда, уртача яше — 60 ел, агач запасы 654,3 мең *м³*. Юкә 11869 *га*, яше — 65 ел, запасы 2467,9 мең *м³*. Өрәңгеле һәм өрәңгеле-юкәле имәнлекләр күпчелекне тәшкил итә. Ә.у.х. терр-ясендә йомшак яфраклы токымнар аеруча киң таралган (урман мәйданының 63%): каен 6924 *га* да үсә, уртача яше — 57 ел, агач запасы 1004,4 мең *м³*, усак (8399 *га*, 40 яшь, 1301,6 мең *м³*). Башка токымнардан соры һәм кара зирек, тирәк, агачсыман һәм куаксыман тал очрый.

Төп файдалану буенча еллык урман кисү күләме 38 мең *м³* тәшкил итә (2003 тә 16% үзләштерелә). Урманны карау максатыннан чистарту эшләре барышында 5,2 мең *м³* чамасы эшкә яраклы агач әзерләнә. 70% лап урман кисентесе йомшак яфраклы токымнар б-н яңартыла. 15 *га* лы урман питомнигында нарат, чыршы, каен, имән һ.б. токымнарның үсенте һәм чәчкеннәре үстерелә. Утырту материалы үз хуҗалыгында урманнар торгызу өчен кулланыла һәм башка регионнарга җибәрелә. 2004 тә 135 *га* мәйданда урман культуралары утыртыла, ш.и. нарат — 83 *га*, чыршы — 34 *га*, тирәк — 18 *га*. Һәр ел саен 165 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла, ш.и. 150 *га* мәйданда урманнар, 25 *га* мәйданда урман полосалары һ.б. саклагыч утыртмалар булдырыла. Ә.у.х. ярдәмче сәнәгый җитештерү б-н шөгыльләнә, халык хуҗалыгы товарлары җитештерә. 1966–90 елларда урман хуҗалыгы директоры булган П.Н.Сафоновка «ТРның атказанган урманчысы» исеме бирелә.

**ӘЛМӘ́Т ФИ́ЗИК КУЛЬТУ́РА ТЕ́ХНИКУМЫ**. 1966 елда нигез салына. Эшләү дәверендә техникумда 5 меңгә якын белгеч әзерләнә, алар арасында танылган спортчылар: О.В.Данилова, Ф.М.Сәләхиев, Россиянең халыкара класслы спорт остасы Р.Гайнанов, А.Гыйсмиев, Ф.Солтанова, И.Чернов һ.б. 2005 тә 32 укытучы эшли, алар арасында: РФнең атказ. тренеры Р.С.Сафин, М.Н.Чинкин; 372 студент укый; физик культура белгечлеге бирелә, мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә, мәктәпләрдә, хезмәт коллективларында эшләү өчен физкультура укытучысы-оештыручы, микросоциумнарда балалар, яшьләр һәм өлкәннәрнең ялын оештыручы-педагог, валеология укытучысы һ.б. төрле өстәмә белгечлек бирелә.

**«ӘЛМӘ́Т ЭШЕ́»**, 1931–32 елларда булган мәхкәмә эше. Әлмәт р-нында икмәк әзерләү барышында законнарны һәм хөкүмәт карарларын бозуда, крәстияннәрне җәберләү, мөлкәтләрен конфискацияләү һәм өстәмә салымнар салуда, дин тотучыларны һәм хатын-кызларны мыскыллауда гаепләнгән 20 дән артык кеше кулга алына. Мәхкәмә утырышлары 1931 елның 26–30 декабрендә һәм 1932 нең 1–4 гыйнварында Әлмәт авылында, шул елның 18–19 гыйнварында Казанда уздырыла. Сөләй авыл советы рәисе С.Гарифуллин, аның урынбасары М.Габдрахманов, икмәк әзерләүгә ярдәм итү комиссиясе әгъзасы И.Баһаветдинов, район профсоюз оешмасы рәисе Ш.Булгаков контрреволюцион саботаж оештыруда гаепләнәләр һәм үлем җәзасына хөкем ителәләр. Әлмәт р-ны башкарма комитеты рәисе Сабир Салманов, район прокуроры Л.Вәлиев, район милициясе башлыгы Салих Салманов һ.б. гаепләнүчеләр төрле елларга төрмәгә ябылуга хөкем ителәләр, 1 кеше аклана.

*Әд.:* «Альметьевское дело». Трагические страницы из истории крестьянства Альметьевского района (конец 20-х — начало 30-х гг.): Сб. док. и материалов. К., 1999.

*Ә.Г.Галләмова.*

**ӘЛМӘ́Т-БӨГЕЛМӘ́ СӘНӘГА́ТЬ ТӨЙНӘЛЕШЕ́**, ТРның көньяк-көнчыгышында урнашкан. Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Азнакай, Баулы шәһәрләрен, Актүбә, Уруссу, Карабаш, Рус Акташы шәһәр тибындагы посёлокларын үз эченә ала. Төйнәлешнең барлыкка килүе 1940 еллар азагыннан бу төбәк-

тә зур нефть һәм иярчен газ ятмаларын ачуга, аларны сәнәгый эшкәртә башлауга бәйле. 1960 еллар уртасында нефть чыгару сәнәгате һәм аның инфраструктурасы б-н бергә биредә сәнәгый пр-тиеләр, яңа посёлоклар, шәһәрләр үсеп чыга. Шушы елларда төйнәлеш формалашып җитә, аның төп пр-тиеләре, транспорт һәм төзелеш оешмалары нефть һәм газ чыгару сәнәгатенә хезмәт күрсәтә башлый. 1970 елда Ә.-Б. с. т. җитештергән тулаем продукция кыйммәтенең 4/5 өлеше нефть сәнәгатенә туры килә. Биредә 1960–80 елларда төрле профильдәге 30 лап сәнәгый пр-тие төзелә, 10 нан артык эре төзү-монтаж һәм махсус төзү оешмалары булдырыла, шәһәр һәм эшчеләр посёлокларының социаль инфраструктурасы формалаша. Сәнәгатьнең төп тармаклары: нефть һәм газ чыгару, машиналар төзү һәм металл эшкәртү, төзелеш материаллары җитештерү, азык-төлек сәнәгате, җиңел сәнәгать, урман һәм агач эшкәртү. Кара металлургия, химия һәм фарфор-фаянс җитештерү пр-тиеләре бар. Нефть сәнәгатенең төп нигезе булып «*Татнефть*» АҖ пр-тиеләре тора. 1970 елга нефть чыгаруның еллык күләме 100 млн. *т* га җитә. Ш.у. иярчен нефть газы чыгару күләме дә арта бара: 1960 елда — 1,3 млрд $м^3$, 1975 тә — 4,4 млрд. $м^3$. 1956 да *Миңлебай газ эшкәртү заводының* беренче чираты сафка баса. 1970 еллар азагыннан нефть чыгару күләме кими бара (1990 еллар уртасыннан елына 23–24 млн. *т*). Үзара технологик бәйләнештә булган җитештерү өлкәләрен вертикаль интеграцияләү буенча эшләр башлана. 1995 тә Кичү нефть эшкәртү з-ды сафка бастырыла. 1990 еллардан төбәктә «Татнефтепром» АҖ эшли башлый, зур булмаган нефть ятмаларын эшкәртүче кече нефть компанияләре барлыкка килә («РИТЭК», «Геология», «СМП-2000» һ.б.). Ә.-Б.с.т. нең машиналар төзү өлкәсендәге күпчелек пр-тиеләре нефть, приборлар төзү һәм автомобиль сәнәгате өчен җиһазлар, приборлар, комплектлау детальләре җитештерә. Алар арасында: *Бөгелмә механика заводы*, «*Әлнас*» (Әлмәт насослар заводы), *Әлмәт торбалар заводы*, Әлмәт «*Нефтемаш*» з-ды, Бөгелмә һәм Лениногорск «Нефтеавтоматика», Лениногорск «Автоспецоборудование» з-длары. Машиналар төзү пр-тиеләре Ә.-Б.с.т. тулай продукциясенең 25% ын җитештерә. Эре төзелеш оешмалары — «*Татнефтегазстрой*» АҖ, «Востокмонтажгаз», «Татнефтепромстройматериалы» һ.б. эшли. Алар тарафыннан Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Баулы шәһәрләре, 10 нан артык эшчеләр посёлогы, 150 эре җитештерү һәм социаль-көнкүреш объектлары, җитештерү пр-тиеләре, нефть-газ сәнәгате объектлары төзелә. Төбәктә 16 төзү материаллары сәнәгате пр-тиесе — тимер-бетон эшләнмәләр заводлары, төзү конструкцияләре комбинатлары, стена материаллары җитештерү пр-тиеләре, кирпеч заводлары һ.б. бар.

Азык-төлек һәм эшкәртү пр-тиеләреннән 2 ит комб-ты, 3 ашлык продуктлары комб-ты, 2 спирт һәм аракы-ликёр з-ды, 5 сөт комб-ты, кондитер ф-касы, икмәк з-длары һ.б. эшли. Урман, агач эшкәртү, химия һәм җиңел сәнәгать пр-тиеләренең төбәк икътисадында урыны зур түгел. 2006 ның 1 гыйнварына шәһәрләрдәге халык саны 391 мең кеше (ТР халкының 10,4%). Сәнәгатьтә 43 мең кеше (ТР сәнәгатенең 10,4%), аларның 43% ы нефть сәнәгате пр-тиеләрендә, 27% ы машиналар төзү, 10% ы азык-төлек, 6,7% ы төзү материаллары сәнәгатендә эшли.

Ә.-Б.с.т. терр-ясендә «*Дуслык*», Миңлебай-Түбәнкүл-Курск-Кромы (Украина) һ.б. нефть үткәргечләре башлана. Тышкы элемтәләрне Ульянов–Бөгелмә–Уфа, Акбаш–Круглое Поле–Әгерҗе тимер юлы, «Бөгелмә» аэропорты тәэмин итә. Автомобиль юллары челтәре киң урын алган. Төбәкнең пр-тиеләре һәм оешмалары 30 дан артык ерак һәм якындагы чит илләр б-н икътисади-сәүдә, фәнни-техник элемтәдә тора. Чит ил фирмалары катнашындагы уртак пр-тиеләр эшли («Татойлгаз», «Татех», «Лататекс»). «Татнефть» акцияләре Лондон һәм Нью-Йорк фонд биржаларында теркәлгән. Чит илләргә Әлмәт насослар з-ды «Әлнас», Миңлебай газ эшкәртү з-ды продукцияләре чыгарыла. ТР экспортының 50–65% ы Ә.-Б.с.т.нә туры килә. Геологик-эзләнү һәм проект-тикшерү эшләренең фәнни нигезләрен ТатНИПИнефть һәм «Татнефтегеофизика» оешмалары башкара. Төбәк өчен кадрларны Әлмәт нефть ин-ты, Әлмәт муниципаль ун-ты һ.б. уку йортлары әзерли.

*Әд.:* Князев С.Л., Гатиатуллин Н.С., Аражеев Г.П. Нефть и газ Республики Татарстан: Сб. док., цифр и материалов: В 3 т. М., 1993; Наш Альметьевск. Наб.Челны, 1993; Нефть Татарстана: Дела и люди. К., 1993; Мустафин М.Р., Хузеев Р.Г. Всё о Татарстане. К., 1994; Из истории Альметьевского региона. Альметьевск, 1999.

*М.Р.Мостафин, К.Ф.Фәсхетдинов.*



**«ӘЛМӘТНЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть-газ чыгару идарәсе (НГДУ). Нефть чыганакларын өйрәнү һәм эшкәртү, нефть чыгару, әзерләү, сату, нефть һәм газ сәнәгате объектларын төзү һәм алардан файдалану б-н шөгыльләнә. Әлмәт шәһәрендә урнашкан. 3800 кеше эшли (2005). 1952 елда «Бөгелмәнефть» нефть-газ чыгару трестының 2 нче нефть промыселы (хәзерге «Лениногорскнефть» НГДУы) җирлегендә «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару тресты буларак оештырыла, 1954 елдан нефть промыселы идарәсе, 1970 тән «Ә.» НГДУы. Нефть һәм газ чыгаручы 6 цехны, нефтьне комплекслы әзерләү һәм суыртучы 2 цехны, катламнарның басымын нормада тоту цехын, нефть кабул итү һәм җибәрү цехын, төп производствога хезмәт күрсәтүче 10 цехны, технологик транспорт идарәсен, торак-коммуналь хуҗалыгын үз эченә ала. Уку-укыту пункты, спорт-сәламәтләндерү үзәге, ял базасы бар. *Ромашкино нефть чыганакларын*ың үзәк һәм төньяк-көнбатыш өлешләрен эшкәртә. Нефть чыгару объектларына терриген девонының 4 мәйданы (Миңлебай, Әлмәт, Төньяк Әлмәт, Берёзовка), түбән карбон утырмаларының терригенлы (№№ 8, 24) һәм карбонат ятмалары (№№ 221,224) керә. Ш.у. терригенлы һәм карбонатлы девонның вак ятмалары эшкәртелә. Девон, Бобриков горизонты терриген утырмаларының сәнәгати-нефтьле объектлары һәм Бохарай нефть чыганагы карбонының Турнейск катламы карбонат коллекторлары эшкәртелүгә тапшырылган. Күпчелек ятмалар катламнардагы басымны су тутыру юлы б-н нормада тотып эшкәртелә. Нефть бирүчәнлекне арттыру өчен катламнарга гидродинамик, физ.-хим., геол.-физик һ.б. прогрессив тәэсир итү ысуллары кулланыла. Бу ысуллар б-н табылган нефть ел буе чыгарылган барлык нефтьнең өчтән бер өлешеннән артыгын алып тора. 1958 дә «Ә.» НГДУы бер тәүлеккә чыгарылган нефть (31782 *т*) күләме буенча Россиядә 1 нче урынны били. Нефть чыгаруның иң югары еллык күрсәткече — 21,8 млн. *т* (1968). Беренче 100 млн. *т* — 1963 елга, 200 млн. — 1968 гә, 300 млн. — 1973 кә, 500 млн. — 1988 гә чыгарыла. 2006 елның 1 гыйнварына барлыгы 571,5 млн. *т* нефть чыгарыла. Чыгарылган продукциянең сулылыгы 78,5%. Насос б-н суырту скважиналарның төп эшләү алымы булып тора.



«Әлмәтнефть» НГДУының административ бинасы.

Нефть җыю системасы герметиклаштырылган, аны комплекслы әзерләүдә 2 җайланма эшли. Кулланучыларга җибәрелә торган продукциянең әзерлеге 100% ка җитә. Шәһәр төзүче идарә буларак, «Ә.» — Әлмәт шәһәрендә һәм Әлмәт р-нында торак йортлар, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре, спорт, социаль-мәдәният объектлары төзетә. 1971 дә «Ә.» НГДУы Ленин ордены б-н бүләкләнә. Аның күп кенә эшчеләре хөкүмәт бүләкләренә лаек була: 3 кеше — Соц. Хезмәт Герое, 1 кеше — Дан орденының тулы кавалеры, 1 кеше — СССР Дәүләт бүләге лауреаты, 2 кеше — ТР Дәүләт бүләге лауреаты, 21 кешегә — РСФСРның, 46 кешегә ТРның атказ. нефтьчесе, 1 кешегә — РФнең атказ. геологы, 1 кешегә — РФнең атказ. икътисадчысы, 3 кешегә РФнең атказ. энергетигы дигән мактаулы исемнәр бирелә. 12 кеше Ленин, 83 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 5 кеше — Халыклар Дуслыгы, 84 кеше — «Почёт билгесе», 44 кеше — 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. «Ә.» идарәсе җитәкчеләре: Е.А.Мазанов (1952–55), Р.Ш.Мингәрәев (1955–56), А.Д.Обносов (1956–63), А.В.Вәлиханов (1963–65), Л.М.Кузнецов (1965–67), Р.Т.Булгаков (1967–72), Г.М.Әхмәдиев (1972–77), Р.Г.Галиев (1977–83), Ш.Ф.Тәхәветдинов (1983–85), М.Ш.Җәләтов (1985–2005), М.З.Таҗиев (2005 тән).

*Әд.:* Әлмәтнефть-Альметьевнефть (1952–1992): Люди. Цифры. Факты. Альметьевск, 1992; «Әлмәтнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе — Нефте-



Н.У.Ә л м и е в. 1. «Ут эчендәге агач». Офорт. 1982; 2. «Ат чабуы турында хатирәләр». Офорт. 1977; 3. «Күзгеләр» (Цирк)». Офорт. 1977; 4. «Шүрәле». Офорт. 1981.

газодобывающее управление «Альметьевнефть». К., 1992; Ордена Ленина нефтегазодобывающее управление «Альметьевнефть» ордена Ленина производственного объединения «Татнефть» им.В.Д.Шашина. К., 1977.

*Р.Х.Әмирханов, Н.М.Ершова, Ш.Л.Таипов, Ф.Т.Хәмитова.*

**ӘЛМӘ́ТОВ** Александр Дәүләт улы (18.1.1940, Киев ш. — 1982, Мәскәү), спортчы (алкалы хоккей), СССРның атказ. спорт остасы (1963). СССР (1959–61, 1963–66), Европа (1960, 1963–67), дөнья (1963–67), Олимпия уеннары (1964) чемпионы, Европа (1961), СССР (1967) чемпионатларында көмеш медаль, СССР (1962), дөнья (1960–61) чемпионатларында, Олимпия уеннарында (1960) бронза медаль, СССР кубогы (1964, 1966–67) иясе. 1958–67 елларда ЦСКА командасында уйный, 220 уенда катнаша, 212 алка кертә. 1959–67 дә СССР җыелма командасында чыгыш ясый; дөнья чемпионатларында һәм Олимпия уеннарында 50 уенда катнаша, 37 алка кертә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* В и к т о р о в В. Чистое время // Это хоккей. М., 1971; Х а в и н Б.Н. Всё об олимпийских играх. М., 1979.

**ӘЛМӘ́ШЕВ** Исхак Мөхәммәтҗан улы (1892–1937), драма актёры, режиссёр, педагог. Хезмәт Батыры (1925). Сәхнә эшчәнлеген 1912 елда «Нур» труппасында башлый, Оренбург, Чиләбе шәһәрләре татар театр труппаларында эшли, Г.Камал, Г.Исхакый, С.Рәмиев, Ф.Шиллер, Ж.-Б.Мольер, А.Островский пьесаларында уйный. 1919–28 дә Оренбург губернасының халык мәгарифе бүлегендә сәнгать секциясен җитәкли. 1930 елларда Оренбург шәһәрендә пед. эштә. Репрессияләр чоры корбаны.

**ӘЛМИ́ЕВ** Надир Усман улы (1946, Казан), график, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1998). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1965). 1971 елдан Татарстан китап нәшриятында рәссам. 1985 тән ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы һәм 1991–92 дә идарә рәисе. Башлыча, станлы графика (офорт, акварель), китаплар һәм журналлар бизәү өлкәсендә эшли. Төп әсәрләре: «Коррида» исемле гравюралар һәм офортлар циклы (1969; 1980), «Мимнар» (1971), «Йөгереш хатирәләре» (1981–92) офортлар цикллары, «Шүрәле» офорты (1981), «Алтай иле» акварельләр сериясе (1996–97, 40 бит), Р.Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн» (1971), С.Хәкимнең «Чәчәкләр коела» (1973), Р.Кутуйның «Күзге ирек» (1981) шигырьләр җыентыкларына һ.б. әсәрләргә иллюстрацияләр авторы. И.Ф.Стравинский балетларына декорация эскизлары (1972–73) ясый, Г.В.Свиридов музыкасына «Кечкенә триптих» дип аталган беренче совет төсле музыка фильмының (1975, СКБ «Прометей» студиясе), беренче татар документаль-публицистик «Җәлил, көрәш сәхифәләре» (1976, Казан кинохроника студиясе), «Космик соната» (1982) телефильмнарының рәссамы. Ә. иҗатына изгелек һәм явызлык, яктылык һәм караңгылык, җимерү һәм төзү кебек мәңгелек категорияләр хакында фәлсәфи фикерләү, форманы сурәтләгәндә киеренке динамика һәм экспрессив тасвирлау, әсәрләр төзелешенә бөтенлек, катлаулылык хас. Халыкара «Краков бьеннале»ндә (1989), бөтенсоюз («Эстамп», 1973 тән), республика («Театр рәссамнары», «Эстамп һәм плакат», 1970 тән) күргәзмәләрендә, бөтенсоюз «Яктылык һәм музыка» фестивалендә (Казан, 1983 һәм 1987) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1978, 1983, 1996, 1997, 2006), Лондонда (1994, 1996), Истанбулда (1996) уза. Ә. әсәрләре Мәскәүнең А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда, Казан музейларында, чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана. Б.Урманче бүләге лауреаты (2005).

*Әд.:* Эстамп. Н.Альмеев: Каталог выставки. К., 1983; Н.Альмеев: Альбом. К., 1996; Альмеев Н. Реминсценции. Божественная комедия Данте Алигьери. Каталог выставки. К., 2006.

*Т.В.Голубцова.*

**ӘЛМИ́ЕВ** (Альмеев)Усман Гафият улы (24.4.1915, Казан губ., Зөя өязе Акъегет а.), җырчы (лирик тенор), ТАССРның атказ. (1945) һәм халык артисты (1957). Зөя авылы балалар йортында тәрбияләнә. 1932–35 елларда Татар сәнгать техникумында, бер үк вакытта Казан музыка техникумында (Е.Ковелькова классы); 1935–38 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (вокал буенча С.Друзякина классында, актёрлык осталыгына Ф.Каверинада) укый. 1938–58 дә Татар опера һәм балет театрында, 1958–68 дә Татар филармониясендә солист. Татар композиторларының операларында төп партияләрне башкара: Җик һәм Урмай, Хәйдәр, Нияз Уралов, Канзафаров («Алтынчәч», «Намус», «Шагыйрь», «Җәлил», Н.Җи-

У.Г.Ә л м и е в 1. Галимҗан (Т.Гыйззәт һәм Җ.Фәйзинең «Башмагым» комедиясе); 2. Кирәмәт (Н.Җиһановның «Качкын» операсы) рольләрендә.




һанов), Бәдри («Галиябану», М.Мозаффаров), Самат (шул исем. опера, Х.Вәлиуллин). Популяр муз. комедияләрдә төп рольләрне башкара: Әскәр («Аршин мал алан», Г.Гаҗибәков), Кето («Кето һәм Котэ», В.Долидзе), Галимҗан («Башмагым», Җ.Фәйзи). Артистның уңышы сәхнәдә үзен иркен тотуы, тавышының тәэсирле булуы, образларны ышандырырлык итеп тудыруы һәм ачып бирүе б-н бәйле. Аның башкару стиленә тирәнтен индивидуальләштерү, характерларны төгәл сурәтләү, образларны оригиналь чагылдыру хас. Эстрада концертларында татар халык җырларын тирән хис б-н башкарып, тамашачы күңелен яулый. Җырчы репертуары татар композиторлары һәм СССР халыклары җырларыннан тора. Ул — Җ.Фәйзинең «Урман кызы», Ф.Яруллинның «Соңгы көрәшкә», Р.Яхинның «Кил, чибәрем» җырларын беренче башкаручы. «Татарстан» ДТРК фондында аның башкаруында 90 нан артык җыр һәм арияләр язмалары саклана. Музыкант-башкаручыларның Бөтенроссия конкурсы лауреаты (1944).



У.Г.Әлмиев.

*Әд.:* К у т у й Г. «Ирек» операсы // Совет әдәбияты. 1940. № 5–6; Р а х м а н к у л о в Ш. Өч премьера турында // Совет әдәбияты. 1945. № 7; Ш у м с к а я Н. Из концертных залов // Советская музыка. 1961. № 2; Народные артисты. К., 1980.

*Ф.Ш.Салитова.*


**ӘЛМИ́НОВ** Байназар Мостафа улы (14.8.1909, Самара губ., Бозаулык өязе Кызыл Мәчет а. — 31.10.1976, Казан), график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). Татарлардагы традицион көмеш каралту техникасы кулланып эшләгән зәркән осталары нәселеннән. Татар-башкорт техникумын (1930, Уфа ш.), Пенза сәнгать-педагогия техникумын (1934) тәмамлый. 1934–35 елларда Куйбышев шәһәрендә «Кызыларместец» г-тасында рәссам булып эшли, 1935 тән Татарстан китап нәшриятында бизәлеш мөхәррире, 1947 дән бизәлеш редакциясе мөдире. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1939). Китап графикасы өлкәсендә әйдәп баручы осталарның берсе. Ш.Камалның «Акчарлаклар», «Таң атканда» романнарына, «Сулган гөл», «Бәхет эзләгәндә», «Уяну» хикәяләренә (1940–1949) һ.б. рәсемнәр ясый. Әдәби әсәрләрнең сюжет-хикәяләү юнәлешен, тарихи һәм этнографик үзенчәлекләрен җентекләп чагылдыра. 1936 дан Г.Тукай әсәрләрен иллюстрацияләү б-н шөгыльләнә («Шигырьләр», 1936; «Шигырьләр. Әкиятләр», 1941; «Шүрәле», 1937, 6 басма, 1969). 300 дән артык китап бизи, шулар арасында татар фольклоры һәм әдәбияты әсәрләре, дәреслекләр бар («Әлифба», 1960 елларда берничә тапкыр басыла).

Бөек Ватан сугышы елларында Ә. татар рәссамнарыннан беренчеләрдән булып антифашистик агитация плакатлары яза («Калдырма!», 1940 еллар; «Фашизмның канлы сатраплары», 1941; «Икмәк — фронтка», 1943). 1943 тә «Сугыш эпизодлары» дип аталган графика сериясе почта открыткалары итеп бастырыла. Станлы нәкышь өлкәсендә дә эшли, жанрлы композицияләр, тушь, гуашь һәм акварель б-н язылган пейзаж һәм портретлар авторы. Психологик портрет остасы; татар мәдәнияте эшлеклеләре образларының тулы бер галереясын иҗат итә (Ш.Камал, Җ.Фәйзи, С.Сәйдәшев, Н.Арсланов, Н.Дәүли, С.Хәким, Р.Фәйзуллин, Р.Кутуй; документаль материаллар нигезендә — К.Насыйри, Ф.Әмирхан һ.б.). Бөтенсоюз («РСФСР өлкәләре, автономияле республикалары һәм союздаш республикалар рәссамнары әсәрләре», 1944) һәм төбәкара («Идел буе рәссамнары әсәрләре», Идел буе шәһәрләрендә, 1943–45; 1947; 1950; 1953; 1956; 1958) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1944–45, 1955 тә Казанда уза. «7 рәссам истәлегенә» дип аталган төркем күргәзмәсе Ә.нең вафатыннан соң — 1980 дә үткәрелә. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукай музей-комплексында, Алабуга шәһәрендәге И.И.Шишкин музей-йортында саклана.

*Әд.:* Персональная выставка работ Б.Альменова: Каталог. К., 1945; Персональная выставка работ Б.Альменова: Каталог. К., 1955; Ч е р к а с о в а Н.В. Изобразительное искусство Советского Татарстана. М., 1957; Я к у п о в Х.А. Памяти Байназара Альменова // Здравствуй, книга!К., 1989.

*М.Е.Ильина.*

**ӘЛМӨХӘММӘ́ДОВ** Газиз Салих улы (29.10.1895, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Көергәзе р-ны Мораптал а. — 10.7.1938, Уфа ш.), җырчы (лирик тенор), композитор, муз. фольклор җыючы, Башкортстан АССРның халык артисты (1929). 1908–22 елларда Ташкентта яши. 1914 тән Идел буе, Урал алды, Урта Азия, Себер шәһәрләрендә концертлар б-н чыгыш ясый. Аның репертуарына рус һәм чит ил композиторларының җырлары, романслары, арияләре, татар, башкорт халык җырлары һәм проф. музыкасы үрнәкләре, үз әсәрләре керә. 1922 дән Казанда яши. С.Габәши һәм В.Виноградов б-н берлектә беренче татар опералары «*Сания*» (Ф.Әмирхан либр., 1925) һәм «*Эшче*»не (М.Гафури либр., 1930) иҗат итә. Зыя һәм Нигъмәт партияләрен беренче булып үзе башкара. Ә.нең башка әсәрләре арасында С.Габәши һәм В.Виноградов б-н берлектә иҗат ителгән «Яңалиф» (1928), «Ун ел» маршлары (1929), «Дәһшәтле җил» (С.Бикчурина шигыре), «Көймәләр» (Ә. шигыре), «Агыйдел ярында» (М.Марат шигыре) җырлары бар. 1929 да Ә. Уфага күчеп китә, анда концерт эшчәнлеген дәвам иттерә, Милли мәдәният фәнни-тикшеренү ин-ты б-н хезмәттәшлек итә, Башкорт филармониясе һәм Мәскәү консерваториясе каршында Башкорт опера студиясен оештыруда актив катнаша. Татар һәм башкорт муз. мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертә.



Г.С.Әлмөхәммәдов.

1938 дә репрессияләнә һәм атып үтерелә; 1957 дә аклана. 1994 тә Уфадагы музыка мәктәп-гимназиясенә аның исеме бирелә.

Х е з м.: В борьбе за создание башкирской советской музыки. Уфа, 1933.

*Әд.:* Д а в ы д о в а Э.М. Әлмөхәмәтов Ғәзиз Сәлих улы // Башкортостан: Кыҫкаса энцикл. Өфө, 1997; А т а н о в а Л. Жизнь как песня. Уфа, 1973; Газиз Альмухаметов и Султан Габаши в Казани: Материалы и док. Уфа, 1995.

**ӘЛМӨХӘММӘ́ДОВ** Мәҗит Ифат улы (4.10.1904, Уральск ш. — 13.7.1971, Ташкент, Казанда җирләнгән), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1950), проф. (1951), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1967). 1934 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1935 тән Казан пед. ин-тында, 1937 дән матем. анализ каф. мөдире. Хезмәтләре тирбәнүләр теориясенә, хәрәкәт тотрыклылыгы мәсьәләләрен чишүгә карый. Дифференциаль тигезләмәләрдәге сыйфат теориясенең кире мәсьәләләрен тәкъбирли һәм чишә, чикле цикллар теориясе, катлаулы типтагы һәм югары класслы махсус ноктадар теориясенә кагылышлы хезмәтләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Об условиях наличия особой точки типа центр // Изв. Казан. физ.-матем. об-ва. 1937. Т. 9; Полупериодические функции с конечным базисом // Изв. вузов. Математика. 1959. № 5; Обратная задача качественной теории дифференциальных уравнений // Изв. вузов. Математика. 1963. № 4; О конструировании дифференциального уравнения, имеющего своими предельными циклами заданные кривые // Изв. вузов. Математика. 1965. № 1.

*Әд.:* Мазит Ифатович Альмухамедов // Дифференциальные уравнения. Минск, 1972. Т. 8, № 3.

*И.Х.Мөдәррисов.*

Б.М.Ә л м и н о в. 1. Г.Тукайның «Су анасы» поэмасына иллюстрация. Акварель, тушь. 1966; 2. Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасына иллюстрация. Акварель, тушь. 1966. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.





**«ӘЛНА́С»**, нефть машиналары төзү предприятиесе. Әлмәт шәһәрендә урнашкан. Мәйданы — 24,5 *га*. 3500 кеше эшли (2005). 1974 елда Әлмәт батырма эл. насослары з-ды буларак нигез салына. Заводның беренче корпуслары 1978 дә эшли башлый. 1979 да беренче эл. двигателе җыела. Аннан соңгы елларда заводны төзү һәм реконструкцияләү дәвам итә. 1982 дән батырма эл. насосларын серияләп җитештерү башлана. 1989 да Әлмәт насослары — «ALNAS» сәүдә маркасы теркәлә. 1980–86 да завод «Бөгелмәнефтемаш» җитештерү берләшмәсе составына, 1986–90 да «Борец» фәнни-җитештерү берләшмәсенә (Мәскәү), 1990–92 дә «Нефтеком» (Мәскәү) берләшмәсенә керә. 1993 тә «Әлмәт батырма насослар заводы» АҖ итеп үзгәртелә. 1997 дән «Әлмәт насослар заводы». АҖ. 2000 нән «ӘЛНАС». АҖ составында бер үк исемдәге «Ә.» з-ды (баш пр-тие), 14 бүлендек һәм «Ә.» з-дына буйсынган җәмгыятьләр бар, шуларның 5есе ТР терр-ясендә эшли. «Ә.» АҖнең төп эшчәнлеге — нефть чыгару өчен комплектлы батырма җайланмалар (насослар) һәм алар өчен запас частьләр җитештерү. «Ә.» — Россиядә бу төр продукцияне җитештерүче иң зур завод, эшләп чыгарылган продукциянең якынча 60% ы аның өлешенә туры килә. Пр-тие тарафыннан җиһазлар комплектларының 3 меңнән артык төре эшләнгән (2005). «Ә.» составында кою, пресслау, механика, җыю, автомат, төргәкләү кебек төп җитештерү цехлары эшли. Производство санлы программалар б-н идарә ителә торган станоклар, автоматлаштырылган линияләр, югары төгәллектәге тиз йөрешле пресслар б-н җиһазландырылган. Завод эшләп чыгарган җайланмалар б-н 2500 *м* га кадәр тирәнлектән тәүлегенә 2000 *м*³ га кадәр нефть суыртырга һәм теләсә нинди климат шартларында эшләргә мөмкин. Күпчелек узеллар оборона һәм космос сәнәгатендә кулланыла торган чыдам материаллардан эшләнә. Эшләнү сыйфаты ягыннан күп кенә узелларга һәм детальләргә чит илләрдә дә тиңдәшләр юк. Модульле эшләнешле булуы завод продукциясен дөньядагы теләсә нинди нефть скважинасында кулланырга мөмкинлек бирә. Пр-тиедә эшләнмәләргә сервис хезмәте күрсәтү оештырылган. Продукция сыйфаты ИСО-9001, ISO/TS 16949: 2002 халыкара сертификатлары б-н расланган. «Ә.»та автомобильләр җитештерү сәнәгате өчен тормоз дискларын эшләп чыгару оештырылган. Завод «Россиянең иң яхшы предприятиеләре» исем. Бөтенроссия конкурсында җиңүче (2000, 2002). Сыйфат буенча РФ Хөкүмәте бүләге (1998), «Европа стандарты» халыкара бүләге (2005), Россиянең «югары социаль нәтиҗәлелекле оешмасы» исем. конкурс дипломы (2005) б-н бүләкләнә. Россия һәм БДБ илләренең нефть чыгару пр-тиеләре «Ә.» продукциясенең төп кулланучылары. «Ә.» Һиндстан, Ирак, Иран, Сүрия, Индонезия һ.б. илләр б-н эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырган. Завод эшчеләреннән 1 кешегә — Халыклар дуслыгы, 2 кешегә — «Почёт билгесе», 3 кешегә — 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары; 9 кешегә ТРның атказ. машина төзүчесе, 2 кешегә — ТРның атказ. транспорт хезмәткәре, 2 кешегә — ТРның атказ. икътисадчысы, 1 әр кешегә — ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре һәм ТРның атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре исемнәре һ.б. хөкүмәт бүләкләре бирелә. Завод җитәкчеләре: А.В.Кунгуров (1974–78), А.К.Бикташев (1978–80), Н.Ф.Феоктистов (1980–81), А.Н.Мельников (1981–82), А.И.Прошечкин (1982–2001), А.В.Лукин (2002 дән).

*Әд.:* Дела и люди Альметьевского насосного завода (1978–1998). Альметьевск, 1998.





«Әлнас». 1. Әзер продукция склады; 2. Җыю цехы.

**ӘЛШӘ́Й РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 13 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 2415 *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Раевка посёлогы (Уфадан 125 *км* көньяктарак). Халкы — 48398 кеше (2002). Татарлар саны: 1939 да — 23127, 1970 тә — 23716, 1979 да — 19881, 1989 да — 18927, 2002 дә 16290 кеше. Ә.р. составында 3 шәһәр тибындагы посёлок (Раевка, Аксёнов, Шафранов), 115 авыл, ш.и. 31 татар, 1 татар-башкорт, 1 татар-рус авылы бар. Иң зур татар авыллары — Торынтаеш (1424 кеше), Ыслак (1237), Гайнәямак (1165), Никифар (1090). Иң борынгылары — Никифар (1742 елдан мәгълүм), Иске Васильевка (1746), Уразмәт (1747), Торынтаеш (1760), Югары Әүрез (1765), Түбән Әүрез (1778). 2004/2005 уку елында Ә.р.ның 11 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 8 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татарча «Әлшәй хәбәрләре» г-тасы нәшер ителә. Ә.р.нда Дан орденының тулы кавалеры Х.Х.*Абдрахманов*, Россия Герое Р.Р.Иксанов, БР ФАнең мөхбир әгъзасы Н.Ф.*Каһарманов*, вет. фән. д-ры Х.В.Әюпов, мед. фән. д-рлары Х.М.*Насыйров* һәм Ф.Г.*Садыйков*, икътисад фән. д-ры У.З.Сафин, пед. фән. д-ры М.Г.*Тайчинов*, а.х. фән. д-ры С.Н.Тайчинов, шагыйрь Шамил *Анак* туган.

**ӘЛШИ́** (Әлшәй) авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 22 *км* көньяктарак, Чынлы елгасы буенда. 2002 елда 717 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөз уртасында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.дә чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе эшли. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостена керә. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 443, 1859 да — 306, 1897 дә — 961, 1913 тә — 1514, 1920 дә — 1265, 1926 да — 1486, 1938 дә — 1595, 1949 да — 1422, 1958 дә — 1537, 1970 тә — 1955, 1979 да — 1813, 1989 да — 759 кеше.

**«ӘМАНӘ́Т»**, Петроградтагы нәшрият һәм басмаханә. 1917 елның җәендә кооператив нәшрият буларак ачыла, шул ук елны анда 1 нче Бөтенроссия мөселманнар съезды материаллары басыла. Басмаханәдә Совет хөкүмәтенең беренче декретлары — Солых турында декрет, Җир турында декрет һ.б. басылып чыга, 1918 нең гыйнварыннан татар телендә «Чулпан» г-тасы нәшер ителә. Шул ук елда нәшрият таркала һәм басмаханә (мөдире З.А.Рәхимов) Төньяк өлкә коммунистлар берлеге Милләтләр эше комис-тының мөселманнар бүлегенә, ә ноябрь аенда РКП(б)ның Төньяк өлкә мөселман-коммунистлар бюросы карамагына тапшырыла, «*Эшче*» исеменә үзгәртелә.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

**ӘМӘКӘ́Й** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 38 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2002 елда 509 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1705 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.дә волость идарәсе урнаша, мәдрәсәле 2 мәчет, 17 кечкенә кибет эшли; дүшәмбе саен базар, һәр елның ноябрендә ярминкә үткәрелә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 1161, 1897 дә — 1447, 1920 дә — 1788, 1926 да —

1357, 1938 дә — 1150, 1949 да — 812, 1958 дә — 744, 1970 тә — 760, 1979 да — 668, 1989 да — 508 кеше.

**ӘМЕРБА́ЕВ** Вилҗан Мәүлет улы (25.4.1931, Казакъстан ССР, Талды-Курган ш.), математик, Казакъстан Милли ФА академигы (1988; 1972 елдан мөхбир әгъзасы), 1954 тә Казакъстан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1962 дән Махсус хисаплау үзәгендә (Мәскәү) бүлек мөдире. 1972–76 да Казакъстан ССР ФА Математика һәм механика ин-тының директор урынбасары, 1988–93 тә санлы мәгълүматлар анализы һәм синтезы лаб. мөдире. 1976–79 да Мәскәү гражданнар авиациясе инженерлары ин-тында югары математика каф. мөдире, 1979–88 дә һәм 1993 тә Мәскәү электрон техника ин-тында югары матем. каф. проф., бер үк вакытта 1987–93 тә Казакъстан Милли ФАнең физика-математика фәннәре бүлегендә академ. секретарь. Хезмәтләре арифметик кодлаштыру теориясенә (теорияне төзи), Лаплас һәм Фурьеның интеграль рәвешүзгәртүләрен санча үзгәртү ысулларына, ерактан торып зондлау чараларының сизгерлеген алгоритмик ысуллар б-н күтәрүгә карый. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1991). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы машинной арифметики комплексных чисел. А.-А., 1979; Численный анализ лагеровского спектра. А.-А., 1982; Параллельные вычисления в комплексной плоскости. А.-А., 1984.

**ӘМИ́НОВ** Әхтәм Әмин улы (1918, хәзерге Башкортстан Респ-касының Миякә р-ны Әнәч а. — 1942), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1941). Шигырьләре «Яшь сталинчы», «Яшь ленинчы» г-таларында, «Пионер каләме» ж-лында басыла. Әсәрләре «Туган ил» (1938), «Очкыннар» (1940), «Алар сафта» (1961) җыентыкларына кертелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Калуга өлкәсенең Сухиничи, Мещовск шәһәре янында барган сугышларда каты яралана, шул ярадан вафат була.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ӘМИ́НОВ** Габделмәнгыйм Шәкүр улы (15.2.1908, Хәзерге Волгоград өлкәсе Савинка а. — 3.8.1968, Казан), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1948), проф. (1949), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1957). Н.Г.*Четаев* шәкерте. 1932 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1933 тән Казан авиация ин-тында (бүленеп, 1936–41 дә Казан ун-тының теоретик механика кафедрасында), бер үк вакытта 1956–58 дә Казан төзүче-инженерлар ин-ты профессоры. Хезмәтләре аэродинамикага, аналитик механикага, үзгәрүчән массалы механик системаларның хәрәкәт тотрыклылыгына һәм хәрәкәтнең дифференциаль тигезләмәләренә карый. К.Э.Циолковский һәм И.В.Мещерскийның үзгәрүчән массалы каты җисем хәрәкәте динамикасына һәм тотрыклылыгына караган идеяләрен үстерә; гомуми рәвештәге механик системаларда хәрәкәт тотрыклылыгының яңа критерийларын чыгара; ракетодинамикага теоретик нигез сала; Пуанкаре-Четаевларның үзгәрешләре төркемләнгән механика төзү буенча фундаменталь тикшеренү нәтиҗәләрен үстерә; кәкре фәзаларда тотрыклылык теориясе аппаратын төзи. Ленин, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Об устойчивости некоторых механических систем // Тр. Казан. авиационного ин-та. 1950. Вып. 24; Некоторые вопросы движения и устойчивости твёрдого тела переменной массы. Математика и механика // Тр. Казан. авиационного ин-та. 1959. Вып. 48; К динамике однородно-изменяемого тела. Математика и механика // Тр. Казан. авиационного ин-та. 1975. Вып. 169.

**ӘМИ́НОВ** Гесиод Абдулла улы (19.2.1939, Удмурт Респ-касы Ижевск ш.), психолог, педагог, психол. фән. д-ры (1978), проф. (1980), Башкортстан АССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1962). 1965–74 елларда Казан ун-тының психофизиология лаб. мөдире. 1980–2005 елларда Башкортстан ун-тының психол. каф. мөдире, бер үк вакытта 1993 тә Башкортстан Респ-касы Сәламәтлек саклау министрлыгы баш психологы. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: психофизиология, нейропедагогика.

Х е з м.: Математические методы в инженерной психологии. Уфа, 1982; Инструментарий пенитенциарного психолога. Уфа, 1996; Образование: гибкие технологии. Уфа, 1996.


**ӘМИ́НОВ** Ибнеәмин (1832, Тәтеш өязе Исәк а. — 6.11.1861, С.-Петербург), педагог-каллиграф. 1855 елдан Петербург ун-тының шәрекъ телләре ф-тында шәрекъ каллиграфиясен укыта. Шәркыятьче галим А.К.Казимбәк аның турында: «Әминовның әлеге сәнгатькә (каллиграфиягә) сәләте шулкадәр игътибарга лаек, ул хәзер үзенең язуы б-н Казан каллиграфы Мәхмүдовны узып китү генә түгел, хәтта Мәхмүдовка билгеле булмаган төрек язулары буенча да искиткеч белемнәр туплады», — дип яза.

*Әд.:* В е с е л о в с к и й Н.И. Список профессоров и приват-доцентов факультета восточных языков бывшего Петербургского Императорского, ныне Петроградского университета с 1819 г. П., 1916; Г р и г о р ь е в В.В. Императорский С.-Петербургский университет в течение первых пятидесяти лет его существования. Историческая записка, составленная по поручению Совета университета. СПб., 1870; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1974.

**ӘМИ́НОВ** Илшат Юныс улы (27.7.1963, Казан), журналист. Казан ун-тын тәмамлый (1985). 1985 елдан ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитетының телевидение студиясендә (хәбәрче, мөхәррир). 1991–96 да Казан ун-тының журналистика, социология һәм психол. ф-ты укытучысы. 1996–98 дә Казанда «Эфир» телекомпаниясенең яңалыклар хезмәте директоры. 1998–2002 дә «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе (ДТРК) директоры. 2002 дән «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе ген. директоры.

*Әд.:* Ш ә й д у л л и н а Н. Илшат Әминов һәм аның компаниясе // Татарстан. 1999. № 1.

**ӘМИ́НОВ** Линар Кәшиф улы (26.8.1937, хәзерге Яшел Үзән р-ны Норлат а.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1975), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1998), ТРның атказ. фән эш-



Ф.Г.Әминов.


леклесе (2004). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. С.А.Альтшулер шәкерте. 1962 дән теоретик физика кафедрасында, проф. (1978). Хезмәтләре каты җисемнәрдә спин-челтәр релаксациясенә карый. Ике баскычлы релаксация процесслары теориясен төзи (к. *Орбах-Әминов процессы*); кристалларда күзәтелә торган люминесценциянең мультиплетара тармаклану коэффициенты анизотропиясе сәбәпләрен ачыклый; диэлектрик Ван Флек парамагнетикларында релаксация күренешләре теориясен җентекләп төзи. Медальләр б-н бүләкләнә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006).

Х е з м.: К теории спин-решёточной релаксации в парамагнитных ионных кристаллах // Журн. эксперим. и теоретической физики. 1962. Т. 42; Ядерный магнитный резонанс в редкоземельных ван-флековских парамагнетиках // Успехи физ. наук. 1985. Т. 147 (автордаш); Физика и спектроскопия лазерных кристаллов. М., 1986 (автордаш); Магнитный резонанс и релаксация в диэлектрических кристаллах редкоземельных соединений // Sov. Sci. Rev. A. Phys. 1990. Т. 14 (автордаш); Магнитные свойства неметаллических соединений лантанидов // «Handbook on the Physics and Chemistry of Rare Earths». Amst. 1996. Т. 22 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**ӘМИ́НОВ** Фәйзерахман Габдрахман улы (10.8.1908, Пермь губ. Көнгер ш. — 20.11.1984, Ленинград), график, нәкышьче. ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1972), РСФСРның атказ. рәссамы (1984). Пермь сәнгать техникумын (1933), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архитектура ин-тын, нәкышь сәнгате проф. Р.Р.Френц остаханәсен (1948) тәмамлый. 2 нче Урал опера театрында бизәлеш рәссамы булып эшли. 1933 елдан Ленинградта яши. 1950 еллар ахырына кадәр тематик картина, пейзаж жанрларында иҗат итә, портретлар сериясен, ш.и. Бөек Ватан сугышы каһарманнары портретларын («Капитан А.А.Янбулат», «Хирург Ф.Х.Кутушев», «Доктор Ш.Г.Шәрәф», «Л.В.Мочалов»), 1959 елда драматик сюжетлы «Салават Юлаев», «Муса Җәлил», «Иптәшләрнең хушлашуы» картиналарын яза. Ә. иҗатында татар әдәбияты һәм фольклоры геройларының образлары чагыла. 1960 та Г.Тукай әсәрләре мотивлары нигезендә акварельләр сериясен: «Су анасы» поэмасы, «Кәҗә белән Сарык» әкияте; «Таз» шигыренә график эшләр (тушь, каләм) иҗат итә. Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасына багышланган иллюстрацияләрдә (1960 еллар) Ә. татар китап графикасы традицияләренең рус рәссамнарының 20 йөз башы, аерым алганда, символик-романтик рухтагы «Сәнгать дөньясы»





Ф.Г.Ә м и н о в. 1. Г.Тукайның «Су анасы» поэмасына иллюстрация. Акварель. 1960; 2. Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасына иллюстрация. Акварель. 1967; 3. «Су буе». Киндер, темпера. 1969; 4. «Урак өсте». 1971. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.





(«Мир искусства») агымы вәкилләренең иҗади казанышлары югарылыгына күтәрелүенә ирешә. Урман поэтикасы б-н сугарылган Шүрәле образы күз алдына күкрәп үскән агачлар һәм үләннәр дөньясы фонында тылсымлы фантазияләр чагылышы булып килеп баса. 1960 еллар ахырыннан Ә.нең нәкышь эшләрендә дә әдәби тематика төп урынны алып тора. Г.Тукайның шигъри дөньясы, халыкның күркәм йолалары һәм бәйрәмнәре «Хуҗа Насретдин» (1967); «Сак-Сок» (1968); «Сабан туе» (1970) әсәрләрендә, «Г.Тукай Кырлай авылында» (1969) һәм «Г.Тукай Кырлайда» (1970); «Тукай үзенең әкият персонажлары арасында» (1972); «Г.Тукай Петербургта» (1974) композицияләрендә, панноларында, триптихларында чагылыш таба. Ә. акварельгә тартым казеин нигезле темпера техникасын якынрак күрә. Татар чигешләрен, каюлы күн бизәкләрен хәтерләткән фантастик үсемлекләр, чәчәк, үлән композицияләре моңга бай татар җыры б-н охшаш («Салкын чишмә», 1968; «Су буе», 1969; «Кырлай» 1971).

Халыкара (Будапешт, 1949), бөтенсоюз күргәзмәләрендә катнаша. Вафатыннан соң әсәрләре С.-Петербургта һәм Казанда уздырылган «ТАТАРТ» төбәкара күргәзмәләрендә (1991) күрсәтелә. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1972, 1979), Пермьдә (1995, вафатыннан соң) уза. Ә. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Яңа Кырлайдагы Г.Тукай музей-комплексында (мөстәкыйль экспозиция), Ташкентның А.Нәвои исем. Әдәбият музеенда, С.-Петербургның тарих музеенда, Пермь картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Ә м и н о в Ф. Үзем турында // Азат хатын. 1972. № 9; Аминов Ф.А. Выставка произведений. Каталог. Л., 1976.

*Р.Г.Шаһиева.*

**ӘМИ́НОВ** Халит (18 йөз), 1773–75 елллардагы Крәстияннәр кузгалышында катнашучы, Е.И.Пугачёв армиясе полковнигы. 1774 елның 19 июленнән Б.*Канкаев* кушуы буенча Арча даругасы авылларында баш күтәрүчеләр отрядларына кешеләр туплау, дезертирларны аулау эшен башкарган. Шуннан соңгы язмышы ачыкланмаган.

**ӘМИ́НОВ** Юныс Шәрип улы (1.12.1921, Әгерҗе кантоны Салагыш а. — 3.12.1982, Әлмәт ш.), драматург, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1981). Бөек Ватан сугышында катнаша. Армиядән кайткач, Әгерҗе р-ны мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Алабуга пед. ин-тын (1953) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1961) тәмамлый. Әсәрләре 1950 еллар башында басыла башлый. Ә.ның «Язылмаган законнар» (1956) драмасы киң танылa. Минзәлә татар драма театры куелышында ул Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында күрсәтелә (1957). Аның «Гөлчәчәк» (1956), «Тамырлар» (1961), «Сатучылар» (1961), «Үҗым бозавы» (1966), «Минем җинаятем» (1968) пьесалары авыл кешеләре һәм интеллигенция вәкилләре алдында торган әхлакый проблемаларга багышлана. «Кан кардәшләр» (1972), «Очрашырбыз, Гөлсылу!» (1980) драмаларында, «Сафура бураннары» (1975) комедиясендә, «Кондырлы кодачасы» (1981) трагикомедиясендә шәһәр тормышы, нефтьчеләр көнкүреше чагыла. Ә. әсәрләре геройларына хезмәт сөючәнлек, самимилек, халык традицияләренә ихтирамлы мөнәсәбәт хас. Күпчелек пьесалары Минзәлә, Казан, Әлмәт театрлары, ш.у. Башкортстанның Салават, Сибай халык театрлары сәхнәләрендә уйнала. Медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Гөлҗәннәтнең җәннәте. Пьесалар. К., 1973; Драмалар, комедияләр. К., 1981; Очрашырбыз, Гөлсылу! Сәхнә әсәрләре. К., 1984.

*Әд.:* Г ы й л ә җ е в А. Ак нур белән // Казан утлары. 1971. № 12; Ә х м ә д у л л и н А. Кешелекле иҗат // Дөреслеккә ирешү юлында. К., 1993.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**ӘМИ́НОВА** Ася Васильевна (1.3.1942, Горький өлкәсе, Лысково ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1991), проф. (1994). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, чагыштырмалылык һәм гравитация теориясе каф. мөдире (2003 тән). Фәнни эшчәнлеген А.З.Петров җитәкчелегендә башлап җибәрә. Төп хезмәтләре псевдориманча күплекләрне проекцияләп чагылдыру теориясенә карый. Ә. тарафыннан псевдориманча метриканы гомуми геодезик билгеләү турындагы классик геометрия проблемасы чишелә; Ли алгебралары буенча проекция хәрәкәтенең күп үлчәмле фәза-вакыт күптөрлелекләре төркемләнә, Ли проблемасы хәл ителә, дифференциаль тигезләмәләр системасының проектив-геометрик теориясе үстерелә. 1987 дән ел саен уздырыла торган «Петров укулары»н — яшь галимнәрнең «Волга» Халыкара җәйге мәктәп-семинарын оештыручы һәм җитәкләүче, 1995 тән шул семинарда тупланган материаллар аның тарафыннан «Теоретик һәм математик физика теориясеннән лекция язмалары» («Лекционные заметки по теоретической и матем. физике»), 1998 дән «Кыр теориясенең иң яңа проблемалары» («Новейшие проблемы теории поля») серияләрендә бастырып чыгарыла.

Х е з м.: Псевдоримановы многообразия с общими геодезическими // Успехи матем. наук. 1993. Т. 48, № 2; Алгебры Ли инфинитезимальных проективных преобразований лоренцовых многообразий // Успехи матем. наук. 1994. Т. 50, № 1; Проективная геометрия систем дифференциальных уравнений второго порядка // Матем. сб. 2006. Т. 197, № 7.

**ӘМИ́НОВА** Әлмира Әсхәт кызы (10.3.1942, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1995), проф. (1996). РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1965), 1969 елдан шунда ук милли мәктәптә рус телен һәм әдәбиятын укыту (2005 тән чагыштырма филология һәм культурара коммуникацияләр) кафедрасында эшли, 2000 нән каф. мөдире. Хезмәтләре чагыштырма-тарихи һәм чагыштырма тел белеменә карый.

Х е з м.: Из истории слов. К., 1981; Глагольные синонимы русского языка. К., 1988; Производный глагол в сопоставительном аспекте (на материале русского и татарского языков. К., 1993; Современный русский язык. К., 2005 (автордаш.).

**ӘМИ́НОВА** Әлфия Иршат кызы (23.6.1962, Казан), балалар табибе, гастроэнтеролог, мед. фән. д-ры (2004). Пермь мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1985), Пермь өлкәсе клиник хастаханәсендә, 1986 елдан Пермь мед. академиясенең факультет педиатриясе, 1993 тән балалар авырулары кафедраларында эшли. Хезмәтләре балалар гастроэнтерологиясе мәсьәләләренә карый. Ә. җәрәхәт ясалуга бирешүчән балалардагы хроник дуоденит авыруының барышы җәрәхәт ясалуга бирешмәүчән балаларныкыннан аермалы булуын ис-

батлый, авыруны дәвалау схемасын тәкъдим итә.

Х е з м.: Состояние адаптационного отдела вегетативной нервной системы у детей с хроническим гастродуоденитом, проживающих в экологически неблагополучных условиях // Терапевтическая гастроэнтерология. 2002. № 4; Клинико-лабораторные особенности хеликобактерной инфекции у детей // Эксперим. и клиническая гастроэнтерология. 2004. № 1.

**ӘМИ́НОВА** Гүзәл Габделбарый кызы (16.11.1964, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2005). 1989 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында инженер-программист булып эшли. 1995 тән Казан хим.-технол. ун-тында, хим.-технол. процесслар һәм аппаратлар каф. проф. (2005 тән).

Ә. фазалар бүленешенең күчмә чикләре б-н полимер материалдан эреткеч аерып чыгару, ясалма каучук алуны дегазацияләү, төрле каталитик системаларда бутадиенны полимерлаштыру барышында матем. модельләштерү процессларын гамәлгә ашыра. Алынган полимерның структурасын тикшерә, гамәлдәге бутадиен каучук җитештерүнең оптималь режимын исәпләп чыгара. Җылы алмашу һәм химик әверелешләрнең үзара тәэсир итешү процессларын модельләштерүнең, ш.у. молекуляр-масса үзенчәлекләре бирелгән бутадиен каучукның синтезлануын күзәтүнең теоретик нигезләрен тәкъбирли. Тикшеренү нәтиҗәләре «Түбәнкаманефтехим» АҖдә зур тонналы эшләнмәләр җитештергәндә файдаланыла.

Х е з м.: Определение механизма процесса полимеризации бутадиена на кобальтосодержащем катализаторе // Журн. прикладной химии. 2002. Т. 75. Вып. 7 (автордаш); Разработка математической модели процесса синтеза каучука в присутствии этилена и толуола // Теоретические основы химической технологии. 2005. Т. 39. № 6 (автордаш); Оптимальные параметры ведения процесса полимеризации бутадиена при синтезе каучука СКДН // Теоретические основы химической технологии. 2006. Т. 40. № 1; Математическое моделирование полимеризационных процессов в химической технологии: Учеб. пособие. К., 2007 (автордаш).

**ӘМИ́НОВА** Роза Мөхәммәт кызы (15.2.1938, Оренбург ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1991), проф. (1999), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960) , Б.А.Арбузов һәм Ю.Ю.Сәмитов җитәкчелегендә химия ф-тында эшли, 1991 елдан хим. физика кафедрасының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре ТМРның спектраль параметрлары теориясе һәм аларны квантлы химия алымнары б-н исәпләүгә, органик кушылмалар молекулаларының магнитик сыйфатлары б-н электрон һәм фәзаи төзелеше арасындагы үзара бәйләнешне өйрәнүгә карый. Илдә беренчеләрдән булып органик химиядә ТМР параметрларын өйрәнүнең квант химиясе алымнарын кертә. Кушылмаларның төш магнит экранлашуын һәм магнит кабул итүчәнлеген бәяләргә мөмкинлек бирә торган квант химиясе модельләрен эшли.

Х е з м.: О природе «аномальных» химических сдвигов в некоторых гетероциклах на основе неэмпирических расчётов и локализации // Теоретическая и экспериментальная химия. 1987. Т. 23, № 2 (автордаш); Динамические процессы внутримолекулярной перегруппировки с переносом протона в окиси азометина // Журн. органической химии. 2004. Т. 40, вып. 6 (автордаш); Gauge-invariant atomic orbital calculations of intramolecular chemical shifts due to localized molecular fragments // J.Molec. Structure (Teochem). 1989. V.183.

**ӘМИ́Р** (гарәп. أمير — әмер бирүче, боеручы), 1) Шәркый мөселман илләрендә — хаким, дәүләт башлыгы (хөкемдар), хәрби җитәкче. Гарәп хәлифәтләрендә беренче хәлифәләр вакытында һәм Омейяләр династиясе хакимлек иткәндә (661–750) Ә. дип, гадәттә, басып алынган өлкәләрнең башлыкларын — аерым гаскәрләрнең командующийларын атаганнар. Габбаси династиясе чорында (9–10 йөзләр) Ә. — хәлифәләрнең бәйсезлеген таныган феодаль хакимнәр. Гарәп хәлифәтеннән фәкать язмача гына бәйсезлекләрен саклап калган элеккеге башлыклар, яисә үзләренең дәүләт берәмлекләрен төзегән мөстәкыйль хакимнәр (Сафавийлар, Газнәвийләр һ.б.) әмирләр булган. 10 йөздә бәйсез хакимнәрне Ә. дәрәҗәсе б-н бергә солтан дип йөртә башлаганнар. 10 йөз ахыры — 11 йөз башында феодаль хуҗаларны, төрле дәрәҗәдәге хәрби башлыкларны (Сәлҗуклар, Айюбийлар дәүләтләрендә һ.б.) Ә. дип йөрткәннәр. 20 йөздә гарәп дәүләтләрендә (мәс., Согуд Гарәбстанында) Ә. — хакимлек итүче династия принцлары; 2) Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында — нәсел башлыгы, олыс хакиме, җир биләмәләре хуҗасы. Алтын Урдада, аннан соң Урта Азия һәм Иранда монгол басып алуларыннан соң Ә. дип монгол һәм төрек нәсел биләмәләре — олысларның башлыкларын атап йөртә башлаганнар (бәк яки нойон мәгънәсендә үк). Ә. титулын Аксак Тимер йөрткән — Тимериләр династиясе принцларын Әмирзадә (Ә.нең улы) дип йөрткәннәр, шуннан кыскартылган «мирза» («морза») атамасы барлыкка килгән. 18 йөз ахырыннан башлап, Бохара ханлыгы хакимнәре үзләрен Ә. дип йөртә башлаганнар.

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. М., 1923.

**ӘМИ́Р** (Әмиров) Мирсәй (Мирсәяф) Мәсәлим улы (6.1.1907, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Мәләвез р-ны Җиргән а. — 1.6.1980, Казан), прозаик, драматург, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1945). М.Горький исем. Әдәбият ин-тында укый (1939–41, Мәскәү). 1928–29 елларда «Кызыл яшьләр» г-тасында һәм «Авыл яшьләре» ж-лында җаваплы сәркәтип. 1931–32 дә ТатЛОКАФ идарәсе сәркәтибе, 1933–35 тә — «Чаян» ж-лы сәркәтибе. 1936–37 дә Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлеге мөхәррире. 1937–39 да нахакка гаепләнә. 1941–44 тә ТАССР ХКС каршындагы Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире. 1943 тә — «Ватан өчен» фронт г-тасында әдәби хезмәткәр һәм хәрби хәбәрче. 1926 да авыл яшьләренең язмышы турындагы «Дуслар һәм дошманнар» исемле беренче хикәясе «Авыл яшьләре» ж-лында басыла. Авылдагы социаль каршылыклар тасвирланган «Безнең авыл кешесе» (1933) повесте һәм күмәкләштерү алдыннан яшьләрнең авылда рухи яңарыш өчен көрәше турындагы «Агыйдел» лирик-романтик повесте (1936; рус теленә тәрҗемәсе «Агидель», М., 1948) Ә. иҗатында яңа этапның башлангычын билгели. 1940 елларда Ә. Бөек Ватан сугышы вакытында совет кешеләренең батырлыгын сурәтләгән очерклар һәм хикәяләр, «Исәндәме?..» (1942) җыентыгын, «Партизан Иван» (1942) пьесасын бастыра. «Миңлекамал» (1944; шул ук елда куела) һәм «Тормыш җыры» (1946; 1947 дә куела) драмаларында кырыс елларның авырлыкларын үз җилкәләрендә күтәргән һәм барлык кыенлыкларны җиңеп чыккан татар хатын-кызларының реалистик образларын тудыра. «Җыр дәвам итә» (1947; 1948 дә куела), «Наилә» (1947; шул ук елда куела) пьесалары сугыштан соңгы авыл проблемаларына багышлана. «Гөлшаян» комедиясендә (1958; шул ук елда куела) үз мәхәббәте өчен көрәшүче хатын-кыз образы бирелә. Бөек Ватан сугышы елларында Казан галимнәре тормышын сурәтләгән «Профессор Саматов» пьесасы (1949), гаилә һәм мәктәп арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдырган «Минем хатын» комедиясе (1955; шул ук елда куела), гражданнар сугышы елларында авылдагы кискен каршылыклар турындагы «Хөррият» героик драмасы (1960, шул ук елда куела) б-н Ә. татар сәхнә әдәбияты үсешенә сизелерлек өлеш кертә. Аның пьесалары Татар һәм Башкорт акад. театрлары сәхнәләрендә уңыш б-н бара. Ә.нең күпсанлы хикәяләре — «Кысыр хәсрәт» (1954) җыентыгы, ш.у. «Пар күгәрчен» (1929), «Хикмәтуллинның манёврда күргәннәре» (1931), «Балыкчы ялганнары» (1971; рус теленә тәрҗемәсе «Рыбацкие байки», 1973) повестьлары, фельетоннары юмор б-н сугарылган. Җиңел, йөгерек телдә язылган кечкенә хикәяләре («Батыр» җыентыгы, 1968 һ.б.) Ә.не талантлы балалар язучысы итеп таныта. Ә.нең сугыштан соңгы еллардагы иҗат казанышлары «Ялантау кешеләре» (1954), аның дәвамы булган «Саф күңел» (1959) романнарында чагыла. Соңыннан «Саф күңел» (1964) исеме б-н басылып чыккан бу дилогия сугыш чоры чынбарлыгының киң панорамасын күз алдына китереп бастыра, совет кешеләренә хас ихтыярлылык, фронтта да, тылда да фидакарьлек күрсәтү калку итеп тасвирлана. «Җан көеге» (1969) повестенда Ә. дезертирның рухи ярлылыгын, мөртәтлеген, куркаклыгын фаш итә. «Үзебез турында» (1971) дип аталган китабында аның әдәбият, сәнгать турындагы мәкаләләре, сайланма чыгышлары, иҗат портретлары, пародияләре тупланган. Ә.нең «Без бәләкәй чакларда» (1979), «Үсә төшкәч» (1981) дип исемләнгән автобиографик повестьлары әдип тормышының 1914–1929 еллар арасын колачлый. Трилогиянең дәвамы булган «Кичә


Мирсәй Әмир.

турында бүген» әсәре 2002 елда гына басылып чыга. Ә. ш.у. И.С.Тургенев, В.Г.Короленко, А.Е.Корнейчук, Б.Л.Горбатов, Г.Гулиа әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Ә. иҗтимагый-сәяси тормышта актив катнаша. 1937, 1961–68 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, 1963–71 дә РСФСР ЮС депутаты, 1963–67 дә РСФСР ЮС Президиумы рәисе урынбасары, 1967–71 дә РСФСР ЮС рәисе урынбасары. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1974; «Агыйдел» повесте буенча эшләнгән шул исемдәге пьеса өчен). Ленин, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1966–67; Әсәрләр: 3 томда. К., 1987–88; Грехи моей молодости. М., 1968; Курай. М., 1978.

*Әд.:* Х а т и п о в Ф. Мирсәй Әмир. К., 1964; М у с и н Ф. Мирсәй Әмир // Чор белән аваздаш. К., 1983; М и ң н у л л и н Ф. Талантлар юлы // Балта явызлар кулында. К., 1994; Б и к м у х а м е т о в Р. Чистая душа // Литературная Россия. 1967. 6 янв.; Г о р б у н о в а Е. Перед лицом новой действительности. М., 1974; М у с т а ф и н Р. Образ времени. К., 1981.

*Р.Х.Сверигин.*

**ӘМИ́Р** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 11 *км* төньяктарак, Олы Сөлчә елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 347 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.дә мәчет була. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 1518,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кармалы волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә, 1924 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 354, 1886 да — 607, 1926 да — 795, 1949 да — 716, 1958 дә — 616, 1970 тә — 721, 1979 да — 592, 1989 да — 412 кеше.

**ӘМИРИ́** (Әмиров) Гайнан Гыймазетдин улы (25.8.1911, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Яңавыл р-ны Яңа Уртавыл а. — 1.10.1982, Уфа ш.), шагыйрь, прозаик, публицист, РСФСРның, БАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1969, 1976). Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1939). 1930–32 елларда «Коммуна» (Уфа ш.) г-тасында эшли, 1933–35 тә Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1940–50 елларда Башкортстан Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-тында, 1955–57 дә «Әдәби Башкортстан» ж-лы редакциясендә эшли. 1930 елларда тел байлыгы б-н аерылып торган, башкорт авылы тормышын тирән психологизм б-н тасвирлаган «Яңы уйҙар» (1932) исемле очерклар китабы, «Кәмһетелгән Шәмсетдин, трудденһеҙ Нуретдин» (1935) исемле лирик-публицистик поэмасы дөнья күрә. Ә. поэзиясенең публицистик пафосы Бөек Ватан сугышы елларында фольклор-җыр мотивлары б-н баетыла. «Һалдат йөрәге» (1944) җыентыгына кергән «Батырҙар йыры», «Волга йыры», «Ерән ҡашҡа аткайым» җырлары аеруча популярлык казана. «Йәшәү шатлығы» (1950), «Йәшәү — яныу» (1953), «Йәҙҙең бер тамсыһы» (1964) исемле җыентыкларында сугышчы-фронтовикның тыныч тормышка кайту темасы, хезмәт романтикасы чагылыш таба. Ә. нең 1960–70 еллар иҗатында яшәү-үлем, кешенең тормыштагы урыны турындагы уйланулары тирән фәлсәфи яңгыраш таба (рус теленә тәрҗемәләре «Августовские звёзды» җыентыгы, 1981). Башкорт халкының милли герое турындагы «Салауат күпере» (1970–75) поэма-монологы башкорт поэзиясендә күренекле урын ала. «Мораҙым» (1961) исемле повестенда Ә. милли традицияләрнең һәм гореф-гадәтләрнең бүгенге тормыш шартлары б-н каршылыкка килүен кискен рәвештә тасвирлый. Ә. балалар өчен «Август төнөндә» (1936), «Байрак сөән» (1938), «Алтын» (1940) исемле хикәяләр җыентыклары, «Трупкасы ҡарт» (1941), «Вәли» (1947), «Дала әкиәте» (1960) исемле шигырь китаплары яза. Ә. — М.Гафуриның «Кара йөзләр» повесте (В.Галимов б-н берлектә, 1937), «Таштуғай» (1940) легендасы буенча эшләнгән инсценировкалар авторы. Очерклары һәм эсселары тупланган «Ак елкән» (1971) исемле җыентыгында татар һәм башкорт әдәбияты һәм сәнгате әһелләре портретлары урын алган. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Һайланма әҫәрҙәр: 2 томда. Өфө. 1961–62; Толпарҙар. Өфө, 1976.

*Әд.:* А г и ш С. Башкорт язучысы Г.Әмиригә 50 яшь // Совет әдәбияты. 1961. № 9.

*Р.К.Әмиров.*

**ӘМИРИ́** (Әмиров) Кәрим Хөсәен улы (1893, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Тәтешле р-ны Бүл-Кайпан а. — 28.1.1962, Казан), язучы. Авыл мәдрәсәсендә белем ала. Уфа, Пенза губерналарындагы татар авылларында укытучылык итә. 1918 елдан Казанда: укытучы, соңыннан «Эш», «Кызыл Армия», «Татарстан» г-талары редакцияләрендә корректор һәм әдәби хезмәткәр булып эшли. 1919 дан Уралда һәм Кузбасста татар эшчеләре өчен чыгарылган газеталарда хезмәт итә. Казанга кайтып, Татарстан китап нәшриятында эшли. Беренче әсәрләре 1913 тә «Шура» ж-лында басыла. Иҗатының иң актив чоры 1920–30 елларга туры килә. «Даһи» (1918), «Идел буенда» (1919), «Сулган чәчәк» (1921), «Бабай» (1922) поэмалары социаль көрәш рухы б-н сугарылган. «Йосыф белән Зөләйха» (1922) трагедиясе, «Печән базары» (1925), «Казан кызы» (1925), «Габдрахман мулла» (1926) комедияләре, «Пайтәхет җәлладлары» (1925) драмасы татар театрларында уйнала. 1930 елларда балалар өчен күп яза. Аеруча популяр әсәрләре — «Ак кәҗә» (1938) юмористик поэмасы, «Урал баласы» (1930), «Музыкант» (1938) хикәяләре. Нахакка репрессияләнә. 1956 да аклана.

Ә с ә р.: Таң вакыты. Сайланма әсәрләр. К., 1969.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**ӘМИ́РОВ** Гаян Суфиян улы (23.2.1916, Башкортстан Респ-касының Мишкә р-ны Бабай а. — 1.2.1993, Ташкент), тел галиме, филол. фән. д-ры (1968), проф. (1981). Бөек Ватан сугышында катнаша. Башкорт пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. 1962–70 елларда Омск пед. ин-ты проректоры, бер үк вакытта хәзерге рус теле каф. мөдире. 1970–76 да Казакъ пед. ин-тының хәзерге рус теле каф. мөдире, 1976–82 дә Казакъ ун-ты профессоры, 1982–88 дә Ташкент ун-тының рус теле каф. мөдире. Г.Тукай әсәрләренең телен өйрәнү иҗади эшчәнлегенең төп юнәлеше булып тора. Шуның нәтиҗәсендә кульязма хәлендәге «Г.Тукай теле сүзлеге» эшләнә. Хезмәтләре рус һәм татар телләренең чагыштырма грамматикасына, лексикографиягә карый. Кызыл Байрак ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, 3 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Из сопоставительного синтаксиса русского и татарского языков. К., 1961; Непокорная земля (воспоминания). А.-А., 1975.

**ӘМИ́РОВ** Кафил Фәхрази улы (24.5.1949, Тәмте р-ны Нариман а.), хокук белгече, 2 класс дәүләт юстиция киңәшчесе (2004), филос. фән. канд-ты (1990), проф. (2001). ТРның атказ. хокук белгече (1997). Харьков юридик ин-тын тәмамлый (1972). 1972–73 елларда Сарман р-ны прокуратурасында тикшерүче, 1973–80 дә ТАССР Прокуратурасының өлкән тикшерүчесе, 1980–89 да Казан шәһәре Вахитов р-ны прокуроры урынбасары, 1989–92 дә Казан шәһәре прокуроры урынбасары. 1992 дән ТР прокуроры урынбасары, 1997 дән 1 нче урынбасары, 2000 нән ТР прокуроры. Бер үк вакытта 1980 нән Казан технол. ун-тында укыта, 2001 дән хокук белеме каф. мөдире. Хезмәтләре хокук фәлсәфиясенә, прокурор күзәтчелегенә, Казан тарихына карый. Хокук белеме дәреслеге, «Русча-татарча юридик сүзлек»не төзүче (1996).

Х е з м.: Хокук белеме нигезләре. К., 1998; Хокук саклау хезмәтендә эш кәгазьләре. К., 1999; Защита человека от преступлений и злоупотребления властью. К., 1994 (автордаш); Казань: где эта улица, где этот дом?: Справ. улиц города Казани. К., 1995; Основы правоведения. К., 1998; Составление обвинительного заключения. К., 2001; Документационное обеспечение предварительного расследования. К., 2001.

**ӘМИ́РОВ** Кашшаф Сафиулла улы (7.4.1922, хәзерге Ульянов өлкәсе, Иске Кулаткы р-ны Яңа Кышлау а. — 28.9.1996, Лениногорск ш.), драматург. Бохара пед. ин-тында укый. 1945–50 елларда Үзбәкстанда бухгалтер, аннан соң мәктәпләрдә укытучы, уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. Ташкентта юридик курслар тәмамлаганнан соң (1950 елга кадәр), Таҗикстанда хокук саклау органнарында хезмәт итә. 1953–60 та Дүшәмбедә чыга торган республика газеталарында фотохәбәрче вазифаларын башкара. 1960 тан Лениногорск шәһәрендә яши. Ә.нең «Уяну»(1966), «Суд алдыннан» (1972), «Шөгер моңнары» (1973), «Вөҗдан әмере» (1978), «Әй, язмыш,

язмыш» (1983) пьесалары Казан, Әлмәт, Бөгелмә, Әстерхан, Оренбург, Наманган, Хива шәһәрләренең профессиональ һәм халык театрлары сәхнәләрендә куела. Илебездә генә түгел, чит ил театрларында да куелган, әфган кызы б-н совет солдатының фаҗигале мәхәббәтен тасвирлаган «Зөлфия» (1983; рус теленә тәрҗемәсе «Страна пылающего солнца», 1983) пьесасы Ә.кә зур уңыш китерә.

Ә с ә р.: Шөгер моңнары. Пьесалар. К., 1987.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ӘМИ́РОВ** Марс Басыйр улы (2.2.1939, Башкортстан АССР, Фёдоровка р-ны Балыклы а.) галим-агроном, а.х.фән. д-ры (1993), проф. (1995). Башкортстан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Башкортстан АССР Фёдоровка р-нының «Путь Ленина» к-зында һәм район а.х. производство идарәсендә баш агроном булып эшли. 1966–2004 тә Башкортстан аграр ун-тында. Хезмәтләре Көньяк Урал алды регионының бүгенге игенчелек системаларында туфракның уңдырышлылыгын кайтару теориясе һәм технологиясе проблемаларына, ш.у. магистраль торба үткәргечләр төзелеше вакытында зыян күргән җирләрне яңадан торгызуның (рекультивацияләүнең) яңа технологиясен эшләүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Научные основы севооборотов для интенсивного земледелия Башкирии. Ульяновск, 1991.

**ӘМИ́РОВ** Наил Баһаулла улы (4.3.1950, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1994), проф. (2002), ТРның атказ. табибе (2004). Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1976), 1 нче Республика клиник хастаханәсендә табиб-терапевт булып эшли. 1979 елдан Казан мед. ин-тының терапия факультеты кафедрасында. 1982–86 елларда СССРның Вьетнамдагы илчелегендә (Хошимин ш.) табиб-терапевт. 1986 дан 2 нче Казан ГИДУВында терапия кафедрасында, 1988 дән 2 нче Республика клиник хастаханәсендә табиб-терапевт. 1991 дән Казан мед. ин-тының 4 нче эчке авырулар кафедрасында. 1994–96 да РФнең Төньяк Вьетнам Респ-касындагы вәкиллегендә (Ханой ш.) өлкән табиб-терапевт. 1999 дан Казан мед. ун-тының терапия ф-тында, бер үк вакытта Регионара клиник-диагностика үзәгенең диагноз кую һәм Казан мед. ун-тының (2003 тән) гомуми табиблек (гаилә медицинасы) кафедрасында бүлек мөдире. 2002 елдан «Вестник МКДЦ» ж-лының баш мөхәррире. Фәнни тикшеренүләре лазер терапиясен эшләүгә, ш.и. пневмония, озакка сузылган бронхит авыруы, системалы склеродермиягә диагноз кую һәм комплекслы медикаментоз-лазер терапиясенә, йөрәккә кан килү бозылышын дәвалауга, күзәнәк мембраналары үткәрүчәнлеген һәм йөрәккә кан килү бозылышын комплекслы дәвалаганда микроциркуляцияне өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Микроциркуляция и диффузная способность лёгких у больных системной склеродермией и хроническими неспецифическими заболеваниями лёгких // Казан. мед. журн. 1988. № 5; Механизмы терапевтического лазерного воздействия в клинике внутренних болезней // Казан. мед. журн. 2001. № 5; Применение низкоинтенсивного лазерного излучения в комплексном лечении ишемической болезни сердца // Рос. кардиологический журн. 2002. № 5 (автордаш).

**ӘМИ́РОВ** Наил Хәбибулла улы (5.4.1939, Казан) гигиена белгече, мед. фән.д-ры (1984), проф. (1985), РМФАнең мөхбир әгъзасы (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1962 елда Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлый. 1964 тән шунда ук эшли, 1981 дән хезмәт һәм һөнәри авырулар каф. мөдире, 1984 тән проректор, 1989 дан ректор. В.П.Камчатнов шәкерте. Тикшеренүләре караңгы урыннарда эшләүчеләрнең нерв системасы һәм психоэмоциональ халәте күрсәткечләрен өйрәнүгә, канцероген һәм мутаген матдәләр тәэсире куркынычын бәяләүгә, автотранспорт йөртүчеләрнең организмы картаюга сәнәгать факторларының тәэсиренә, ш.у. сәламәтлекнең скрининг резервына һәм кече яшьтәге балаларны комплекслы сәламәтләндерү системасында «Винибис» препаратын куллануны фәнни дәлилләүгә (ТР Дәүләт бүләге, 1999) багышлана. Ә. җитәкчелегендә мед. ин-ты күп профильле һәм күпкырлы белем бирә торган югары уку йорты итеп үзгәртелә, 1994 тә университет статусы ала. Яңа ф-тлар (социаль хезмәт, менеджмент һәм югары белемле шәфкать туташлары), фармация һәм шәфкать туташлары белгечлеге буенча читтән торып уку формасы кертелә. Ә. Бөтенроссия гигиена белгечләре җәмгыяте, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы коллегиясе әгъзасы, «Медицина труда», «Казанский медицинский журнал», «Научные новости», «Неврологический вестник» ж-ллары коллегияләре мөхәррире.

Х е з м.: Одночисловая гигиеническая оценка производственных факторов малой и средней интенсивности при их комплексном воздействии // Гигиена труда и профзаболеваний. 1984. № 2; Производственная вертеброневрология. К., 1993 (автордаш); Факторы производства и репродуктивно-демографический процесс. К., 1994 (автордаш); Заболеваемость женщин, работающих на канцерогенных предприятиях // International journal on immunorehabilition. 1998. № 8.

*Әд.:* Член-корреспондент РАМН, профессор Наиль Хабибуллович Амиров // Казан. мед. журн. 1999. № 2.

**ӘМИ́РОВ** Рәиф Кадыйм улы (3.11.1941, Башкортстан Респ-касы, Балтач р-ны Начар а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1986), проф. (1987), Башкортстан Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1992). Бөре пед. ин-тын тәмамлый (1963), 1968–73 елларда шунда ук укыта. 1974 елдан Башкортстан пед. ин-тында, 1980–83 тә декан, 1983 тән әдәбият каф. мөдире. Хезмәтләре башкорт әдәбияты тарихына карый. Беренче булып башкорт әдәбиятында әдәби һәм публицистик жанрларның барлыкка килүе тарихын, халык өметләрен чагылдыручы күренеш булärак *чичән*нәр һәм абызлар иҗатын өйрәнә. Ә.нең актив катнашлыгында «Башкортстанның татар язучылары» исемле китаплар сериясе оештырыла, Башкортстанда татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихын өйрәнү һәм торгызу эше алып барыла. 1994 тән Башкортстан Респ-касының Татар язучылары берлегенең идарә рәисе.



Н.Х.Әмиров.

Х е з м.: Чтобы шагнуть в завтра. Уфа, 1982; Летопись современности. Уфа, 1985; Ступени жизни. М., 1989; Становление. Уфа, 1996.

**ӘМИ́РОВ** Рәсим Зәкәрия улы (28.2.1923, Башкортстан Респ-касы, Бүздәк р-ны Бүздәк а.), физиолог, мед. фән. д-ры (1964), проф. (1970), СССРның атказ. уйлап табучысы (1982). Мәскәүдәге 1 нче мед. ин-тын тәмамлый (1946). 1952 елдан Мәскәүдә: Колак, тамак, борын үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында, электрофизиология лаб. мөдире. 1960 тан А.Н.Бакулев исем. Йөрәк-кан тамырлары хирургиясе фәнни-тикшеренү ин-тында, 1964 тән СССР МФА каршындагы Туклану фәнни-тикшеренү ин-тында, 1969–85 тә Үзәк курортология һәм физиотерапия фәнни-тикшеренү ин-тының клиник физиология бүлеге мөдире. Тикшеренүләре электрографиягә багышлана. Кардиотопография (йөрәк потенциаллары урыннарын билгеләү) ысулына нигез салучы, бу ысул күп илләрдә гамәли кулланыш таба. Йөрәктәге электр кыры үзгәрешенең яңа күрсәткечләрен ачыклый. Ә.тарафыннан дипольнең түгәрәк буенча хәрәкәте һәм йөрәк авырулары вакытында үзгәрүе дәлилләнә. Авыруларга диагноз кую мөмкинлеген үстерүче 50 яңа күрсәткечне аерып күрсәтеп, 10 карта төзи.

Х е з м.: Электрокардиотопография. М., 1965; Интегральные топограммы потенциалов сердца. М., 1973.

**ӘМИ́РОВ** Фазыл Фәйзерахман улы (26.1.1914 — 7.7.1979, Ташкент), хирург, мед. фән. д-ры (1958), проф. (1958), Үзбәкстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1971). 1938 елда Ташкент мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук оператив хирургия кафедрасында эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша, фронт эвакогоспиталенең баш хирургы була. 1946 дан Ташкент мед. ин-тында, 1958 дән топографик анатомия һәм оператив хирургия каф. мөдире. СССРда беренчеләрдән буларак трахея һәм бронхларда пластик операция ясау методикасын эшләүгә керешә. Эксперименталь бронхологиягә нигез салучыларның берсе. СССРда беренче тапкыр хайваннарда оригиналь экспериментлар үткәрә, трахея һәм бронхларда аллопластик операцияләр ясалган урында трахеяның яңадан барлыкка килгән регидлы нигезенең бер генә төрле эластик җепселле челтәр тәшкил итәргә тиешлеген исбатлый. Трахея һәм бронхлар өчен тантал, поликапролактан һ.б. материаллардан протезлар эшли. Трахеяда һәм бронхларда хирургик операцияләр эшләгәне һәм аларны клиникада гамәлгә керткәне өчен СССР Дәүләт бүләге бирелә (1974). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пластические операции на трахее и бронхах. Таш., 1962; Реаэрация ателектазированного лёгкого. Таш., 1966; Обезболивание при операциях на трахее и бронхах. Таш., 1968.

**ӘМИ́РОВ** Шәүкәт Сабир улы (9.5.1947, Чиләбе өлкәсе Миасс ш.), балалайкачы, педагог, РСФСРның атказ. артисты (1989), проф. (1992). 1971 елда Урал консерваториясен (Свердловск ш.) тәмамлый. 1980–90 елларда — Урал, 1990 нан Казан консерваторияләре укытучысы, 1990–95 тә проректор, 1996–99 да халык уен кораллары каф. мөдире. 1999 дан Екатеринбург шәһәрендә укыта һәм концерт эшчәнлеге алып бара. Шәкертләре арасында бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреатлары һәм дипломантлары Л.Бикбулатова, О.Вайспекер, И.Корепанов, Р.Таҗетдинов, Р.Ханиев бар. Ә. халык көйләрен, классик һәм хәзерге заман муз. әсәрләрен башкара. Халык уен кораллары репертуарын татар композиторлары әсәрләре б-н баетуга зур өлеш кертә. Актив концерт эшчәнлеге алып бара, ТР һәм РФ шәһәрләрендә гастрольләрдә була, радио-телевидениедән чыгышлар ясый. Эстрада артистларының бөтенсоюз (2 нче урын, 1974), Халык уен коралларында башкаручыларның 2 нче бөтенроссия (1 нче урын, 1979) конкурслары, Италиянең Кастельфидардо шәһәрендә үткән халыкара конкурс лауреаты («Гран-при», 1993, 1994).

*Әд.:* П е р е с а д а А. Из истории балалаечного исполнительства. Краснодар, 1987; В о л ь ф о в и ч В. Музыканты Южного Урала. Челябинск, 1991; Я к о в л е в В. К 50-летию Шауката Сабировича Амирова // Народник. 1997. № 2.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**ӘМИ́РОВА** Сәвия Солтан кызы (31.7.1944, Таҗикстан ССРның Ленинабад р-ны Тыкели руднигы), электротехник, педагог, техн. фән. канд. (1980), пед. фән. д-ры (1996), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). Казан хим. — технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында инженер булып эшли. 1973 елдан Түбән Кама шәһәре махсус урта белем бирү уку йортларында укыта, 1979 дан Түбән Кама хим.-технол. ин-тында, 2000 нән электротехника каф. мөдире. Хезмәтләре югары уку йортлары педагогикасы, электротехника мәсьәләләренә карый, электротехникада уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Теория и практика самоорганизации. К., 1996.

**ӘМИРХА́Н** Фатих (Мөхәммәтфатих) Мөхәммәтзариф улы (1.1.1886, Казан — 9.3.1926, шунда ук), язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе. М.*Әмирхановның* улы. 1895–1905 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый; үзлегеннән рус телен һәм әдәбиятын өйрәнә. 1905–07 еллардагы рев-ция йогынтысында *«әл-Ислах»* исемле шәкертләр оешмасы эшчәнлегендә катнаша. Ә.ның тормышы һәм иҗаты гаять дәрәҗәдә катлаулы. 1907 ел башында Мәскәүдә нәшер ителә торган беренче балалар журналы «Тәрбият әл-этфаль»нең мөхәррире булып эшли. Шул ук елда Ә.ны паралич суга, калган гомерен әдип инвалид коляскасында үткәрергә мәҗбүр була. 1907–09 да «әл-Ислах» г-тасы мөхәррире.



Фатих Әмирхан.

1912 дән актив рәвештә «Кояш» г-тасы һәм «Аң» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә.

20 йөз башындагы вакыйгалар һәм катаклизмнар язучыда дөньяга синкретик караш, Шәрекъ һәм Гареб фәлсәфи системалары тәэсирендә формалашкан мәгърифәтчел, рев.-демократик, социалистик карашлар тууга китерә.

Ә. — татар әдәбиятында тәнкыйди реализмга нигез салучыларның берсе. Әдипнең иҗади эзләнүләре реализм кысалары б-н генә чикләнми. Ул романтик рухтагы әсәрләр дә яза, импрессионизм, экспрессионизм, акмеизм кебек модернистик агымнар даирәсендә дә үзен кыю һәм сәләтле экспериментатор буларак таныта. Әдәбиятка Ә. үзенең «Гарәфә көн төшемдә» (1907) исемле романтик рухта язылган хикәясе б-н килеп керә. Мәгърифәтче әдип буларак, ул татар җәмгыятенең феодаль торгынлыкта яшәвен тәнкыйтьли, милли яңарыш идеалларын яклап чыга. 20 йөз башы татар сатирик әдәбиятының классик әсәренә әйләнгән «Фәтхулла хәзрәт» (1909) повестенда Ә. искелек тарафдарларын фаш итә. Шул ук елда язылган «Яшьләр» пьесасында язучы татар яшьләренең кадимчелеккә нисбәтле искелектән арыну теләген, шәхес иреген, европача белем алу хокукын яклап чыга, әсәрдә татар яшьләренең идеаллары һәм омтылышлары тасвирлана. «Татар кызы» (1909) хикәясендә, экзистенциализм һәм экспрессионизм алымнарын оста кулланып, татар хатын-кызын ире кулындагы уенчыкка, ә соңыннан «тере мәеткә» әверелүдән, феодаль-патриархаль изелүдән коткару проблемасы күтәрелә. Фабуланың — өзекләр, композициянең схема рәвешендә бирелүе, героиняның Яшәү б-н Үлемнең шартлы чигендә торуын күрсәтү модернистик әдәбиятның төрле алымнарын куллану ысулы аша гомумиләштерелә. «Хәят» (1911) романтик повестенда автор балачактан ук рус мәдәниятен күреп үскән татар кызының рухи драмасын тасвирлый. Әдипнең төп игътибары искe кануннарга буйсынып яшәргә мәҗбүр булган героиняның рухи дөньясын күрсәтүгә юнәлдерелгән. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы әдәбиятында киң таралган аталар б-н балалар арасындагы конфликт автор тарафыннан ш.у. романтизм рухында күзаллана. Повестьта матурлык эстетикасы, тирән лиризм, табигать һәм мәхәббәт культы өстенлек итә; психол. анализның портретлар, эчке монологлар, пейзажны тасвирлау кебек формалары уңышлы кулланыла. Риваятьләр нигезендә язылган «Ай өстендә Зөһрә кыз» (1913), «Сөембикә» (1913), «Картада оттырылган Зөлхәбирә» (1913), «Бер хәрабәдә» (1913) исемле романтик хикәяләр циклында милли үзаңның үзенчәлекләре чагылыш таба. Тәмамланмый калган, тоташ сюжеты һәм шунлыктан динамик



Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан. 1908.

рәвештә үсә баручы конфликты булмаган «Урталыкта» (1911–12) романында укучы татар яшьләренең, интеллигенциянең тормышка карашында тамырдан үзгә фикерләр күзәтелә. Романның төп герое Хәсән Арсланов, татар яшьләренең бер өлешенә хас булган катгыйлыкны (радикализмны) хупламаган кебек, кадимчеләр идеологиясен дә кабул итми. Геройның бай рухи дөньясы милли мәдәният язмышы турында уйланулар б-н тулы. «Тигезсезләр» (1914) психологик драмасында язучы, А.П.Чехов драматургиясенә хас импрессионистик стильне иҗади кулланып, сәнгатьчә бай образлар аша дөньяда кешеләрнең тигезсезлеге, мәхәббәтнең яклауга мохтаҗ булуы, кеше бәхетенең нечкәлеге хакында уйлана. Пьеса тормышны ышандырырлык итеп сурәтли, геройларның рухи тормышын күпкырлы итеп күрсәтә, үзенчәлек-



«әл-Ислах» г-тасы редакциясендә (сулдан уңга): В. Бәхтияров, К. Бәкер, Ф. Әмирхан, И. Әмирхан, Г. Тукай. 1908.



Ф. Әмирханның «Урталыкта» романының тышлыгы (1912).

ләре б-н эпик әсәрне хәтерләтә. Хикәяләү стиле авторның күпсанлы ремарклары, татар җәмгыятенең икътисади нигезләрен үзгәртү, европача мәгариф системасы, хатын-кыз эмансипациясе турындагы фикерләрнең текстка оста кертелүе, мәхәббәт, әдәбият, тел, музыка, сынлы сәнгать, рус мәдәнияте хакында диалоглар б-н тыгыз үрелеп бара. «Габделбасыйр гыйшкы» (1914), «Сәмигулла абзый» (1916) һ.б. хикәяләрендә акмеизм алымнарын куллану очраклары күзәтелә.

Ә. ның тәнкыйди мәкаләләренең күбесе Г.Тукай («Габдулла Тукаев шигырьләре», 1908; «Азмы какканны вә сукканны...», 1913) һәм Г.Исхакый («Гаяз», 1907; «Алдым-бирдем», 1907; «Зиндан», 1908; «Зөләйха», 1917) иҗатларының дөньяга караш һәм сәнгать үзенчәлекләрен, З.Һади, Ф.Кәрими, Я.Вәли, М.Гафури, С.Рәмиев, Г.Коләхмәтовның аерым әсәрләрен анализлауга багышлана. 1917 елгы Февр. инкыйлабын Ә. «Богаулар өзелде» дигән публицистик мәкаләсе б-н хуплап каршы ала. Окт. инкыйлабыннан соң язучы «Кызыл Армия», «Эш», «Татарстан», «Татарстан хәбәрләре», «Шәрекъ кызы», «Безнең юл» г-таларында һәм ж-лларында языша. «Марксист» псевдонимы б-н публицистик мәкаләләр бастыра, республиканың иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында актив катнаша. Шул ук вакытта 1924 тә язылган «Шәфигулла агай» (1991 дә басылып чыга) исемле сатирик хикәясендә Ә. эшчеләр сыйныфы вәкилләренең большевиклар идеологиясе тәэсирендә гамьсез роботларга әверелүен, гасырлар буе яшәп килгән милли традицияләрдән һәм гомумкешелек кыйммәтләреннән ваз кичүен күрсәтә. Романтик рухта язылган «Тәгъзия» (1922) хикәясендә яшәү һәм үлем турындагы дини-фәлсәфи фикерләүләр урын ала. Халык арасында «татарның язмышын хәл итүче» буларак бәяләнгән Ә. исәтлегенә күпсанлы әдәби һәм публицистик әсәрләр багышланган.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1957–58; Әсәрләр: 4 томда. К., 1984–86; Избранное: Рассказы и повести. М., 1975.


*Әд.:* Х и с м ә т у л л и н Х. Фатих Әмирхан: Тормышы һәм иҗаты турында кыскача популяр очерк. К., 1961; С а й г а н о в А.Д. Фатих Әмирхан әсәрләренең библиографиясе һәм язучы турында фәнни әдәбият. (1906–1972). К., 1972; Г а й н у л л и н М. Татар әдипләре. К., 1978; Н у р у л л и н И.З. Фатих Әмирхан. К., 1988; Краткая литературная энциклопедия. М., 1962. Т. 1; С а й г а н о в А. У истоков эстетики реализма: Эстетика Фатиха Амирхана и её место в развитии татарской реалистической литературы. К., 1982; М а г д е е в М. Фатих Амирхан: Краткий очерк о жизни и творчестве писателя. К., 1986; Идейно-эстетическое наследие Фатиха Амирхана: Межвуз. сб. науч. тр. К., 1989; Н у р у л л и н И.З. Прометей из Ново-Татарской слободы. К., 1991.

*Р.К.Ганиева.*

**ӘМИРХА́Н Ф. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**. Татар әдәбияты классигы Ф.*Әмирханның* шәхси китаплар тупланмасы. Китапханәдә язучы тарафыннан төзелгән 800 гә якын исемдәге басманың исемлеге саклана. Шактый зур өлешен тарих, география, фәлсәфә, иҗтимагый-сәяси әдәбият китаплары биләгән. Атаклы шәхесләргә багышланган тарихи-биографик монографияләр дә булган. Китапханә татар, рус, чит телләрдәге китаплардан һәм күп кенә матур әдәбият әсәрләреннән торган. Алар арасында: Н.В.Гогольнең (6 том), Л.Н.Толстойның (13 том), И.А.Бунинның (10 том) тулы әсәрләр җыентыклары; А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, В.Г.Короленко, Д.Бедный, Дж.Голсуорси, Ж.Верн, Г.Сенкевич һ.б.ның әсәрләре булган. Китаплар җыелмасына Борынгы Рим тарихы буенча Тит Ливийның «Патшалар дәвере» («Эпоха царей»); Н.И.Кудрявцевның «Рим хатын-кызлары» («Римские женщины») һ.б., Франция революциясе турында Н.И.Кареевның «Бөек француз революциясе» («Великая французская революция»), Париж коммунасы турында документлар җыентыгы һ.б.) хезмәтләре кергән. Мөһим урын Шәрекъ фәлсәфәчеләре Ибне Рөшд, әл-Мәгарри, әл-Фараби, әл-Әфгани хезмәтләренә; Ш.Мәрҗани җыентыкларына, К.Насыйри, Г.Тукай, татар әдәбиятының башка эшлеклеләре әсәрләренә, татарча журналлар һәм газеталар тупламаларына; халыкара революцион хәрәкәт тарихы турындагы әдәбиятка, анархистлар хәрәкәте лидерлары җыентыкларына (П.Кропоткинның «Эволюция факторы буларак үзара ярдәм» («Взаимная помощь как фактор эволюции»), М.Бакунинның «Кырлар, фабрикалар һәм остаханәләр» («Поля, фабрики и мастерские») бирелгән. Китапханәдә К.Маркс һәм Ф.Энгельсның «Коммунистлар партиясе манифесты» («Манифест коммунистической партии»)), К.Маркснның «Франциядә гражданнар сугышы» («Гражданская война во Франции»), В.И.Ленинның «Коммунизмда балаларча «суллык» авыруы» («Детская болезнь «левизны» в коммунизме»), «Гот программасын тәнкыйтьләү» («Критика Готской программы») һ.б. басмалар булган. Халыкара коммунистик хәрәкәт лидерлары К.Цеткин, Ф.Меринг, В.Либкнехт, А.Бабель биографияләре, совет властеның беренче декретлары тупланган. Язучының дәфтәреннән күренгәнчә, аның җыелмасында танылган Америка китапханә белгече М.Дьюинең «Унарлы классификация» («Десятичная классификация») дип аталган китабы да була. Ф.Әмирхан, мөгаен, аңа таянып үзенең китапханәсен тәртипкә китерергә ниятләгәндер.

*Әд.:* Х и с а м о в А. Ф.Әмирханның шәхси китапханәсе // Совет әдәбияты. 1986. № 3.

*Г.Р.Габделганиева.*



И.З.Әмирханов.

**ӘМИРХА́НОВ** Ибраһим Зариф (Мөхәммәтзариф) улы (5.9.1889, Казан — 3.11.1938 шунда ук), хокук белгече, сәяси эшлекле. Ф.*Әмирханның* энесе. 1906 елга кадәр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. Шәкертләрнең Казандагы сәяси-иҗтимагый «*әл-Ислах*» яшерен оешмасы җитәкчеләренең һәм шул исемдәге газета чыгаручыларның берсе. Бәйрутта Америка колледжын тәмамлый (1913). 1914 тән Казанда укытучы булып эшли. 1916–17 дә рус армиясендә унтер-офицер дәрәҗәсендә хезмәт итә. 1918 дән Казанда халык судьясы, 1919 да Казан губерна башкарма ком-тында азчылык милләтләр б-н эшләү бүлеге мөдире, 1922–23 тә ТАССР өлкә мәхкәмәсе һәм трибуналы әгъзасы. 1924–26 да Согуд Гарәбстанында СССР илчелеге секретаре. 1927–35 тә ТАССРның Юстиция халык комис-ты коллегиясе һәм Югары мәхкәмәсе әгъзасы. 1937 нең 23 декабрендә кулга алына. Репрессияләр корбаны, атарга хөкем ителә (к. «*Уң троцкийчы милләтчеләрнең Совет хакимиятенә каршы оешмасы» эше*). Үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* С а й д а ш е в а М. Амирханов И.З. // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3; Книга жертв политических репрессий. К., 2000. Т. 1.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ӘМИРХА́НОВ** Марат Әмирхан улы (22.4.1933, Актаныш р-ны Кәзкәй а.), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1955). 1970–87 елларда «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе, бүлек мөдире, 1987 елдан «Сөембикә» ж-лының баш мөхәррире урынбасары булып эшли. Әсәрләре 1980 еллар уртасыннан басыла башлый — балалар өчен «Таш һәйкәл» (1987) исемле повесть һәм хикәяләр, «Чулманның ак йолдызы» (1988) дигән очерклар җыентыклары дөнья күрә. «Каргыш» (1993) повестенда 40 нчы еллар буынының тормышы, сугыштан кырыслanып кайткан егетнең язмышы яңача ачыла. «Дөя муены» (1996) повесте татар әдәбиятында сирәк очрый торган сатира жанрында язылган. Автор төп героеның мажаралары аша тормышның тискәре якларын тасвирлый. «Тәкъдир» (1999) романының төп темасы — 20 йөз ахырында татар халкының милли үзаңы яңару. «Тояк эзе» (2003) романы, «Мөкәррәмә» (2004), «И, кылган догам минем» (2006) повестьларында гыйбрәтле кеше язмышларын фәлсәфи-психологик яктан ача. Ә. юмористик хикәяләрендә 1990 елларда илдә барган үзгәрешләр чорында күзәтелгән житешсезлекләрне, көлкеле ситуацияләрне сурәтли.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 2004.

*Әд.:* Г ы й л ә җ е в А. Бәрәкалла, Әмирхан // Мәдәни җомга. 1997. 4 апр.; Ә х м ә т җ а н о в М. Килер бер көн. К., 1998.

**ӘМИРХА́НОВ** Мөхәммәтзариф Хөсәен улы (10.1.1853, Казан — 24.6.1921, шунда ук), дин эшлеклесе. Ф.*Әмирханның* атасы. Башлангыч белемне атасында һәм Казан өязе Югары Курса авылы мәдрәсәсендә ала. 1872–74 елларда Казан өязендәге Норлат авылында Мостай əн-Норлати җитәкләгән мәдрәсәдә укуын дәвам итә. 1875 тә, имам-хатиб һәм мөдәррис дәрәҗәсе алу өчен имтихан тапшырганнан соң, Казанда атасы беренче имам булып торган Иске Таш мәчеткә — 9 нчы җамигъ мәчеткә — икенче имам итеп билгеләнә. 1893 тән шул ук мәчеттә беренче имам вазифасын үти. Бу вакытта Ә. Казанда абруйлы дин эшлеклесе булып таныла. Мәгариф өлкәсендәге үзгәртүләрне актив яклый. Җәдит мәдрәсәләре өчен дәреслекләр авторы. Россия мөселманнары арасында киң таралган 2 томлы Коръән тәфсире «Әл-Фәваид»ны («Файда») әзерләүдә һәм нәшер итүдә катнаша (1870–80).

Х е з м.: Әхадисе нәбәвыядән. К., 1909; Әхадисе Кодсия. К., 1909.

*Әд.:* Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Исторические зарисовки. К., 2005.

**ӘМИРХАНО́В** Равил Госман улы (9.1.1946, Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Иске Кулаткы а. — 3.9.2006, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1968). 1968–71 елларда Балтач һәм Питрәч р-ннарында балалар укыта. 1974 тән СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында гыйльми хезмәткәр. 1997 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында яңа һәм иң яңа тарих бүлеге мөдире. Ә.ның тикшеренүләренең үзәк темасы — татар матбугатының үсеш тарихы: беренче тапкыр ул 1905–17 еллардагы барлык татар вакытлы матбугатына киңәйтелгән характеристика бирә. Аның аерым хезмәтләре татарлардагы халык мәгарифе, рев-циягә кадәрге һәм совет чорындагы милли уку йортлары проблемаларына багышлана. Ә.ның фәнни мәнфәгатьләре даирәсенә 1905–07 еллардагы Россия рев-циясе тарихы, аның б-н бәйле татарларның иҗтимагый-сәяси фикере, мәдәнияте үсеше, дәүләтчелек тарихы, төрле этапларда татар халкының милли азатлык көрәше, вөҗдан иреге, этникара никах һ.б. мәсьәләләр керә. Ә. — Х.Әмирхан, Г.Баруди, Ә.Вәлиди, Г.Еникиев, С.Максуди, Г.Исхакый, Р.Фәхретдин һ.б. турындагы күп кенә биографик мәкаләләр авторы; аларның биографияләрендә элек билгеле булмаган шактый зур яңалыклар ачыла. Р.Фәхретдинов, Ә.Вәлиди хезмәтләрен яңадан бастыруга әзерли. Ә. Татар энциклопедиясендә татар халкы һәм аның матбугаты тарихына багышланган мәкаләләр авторы.

Х е з м.: Иманга тугрылык. К., 1997; Татарская демократическая печать (1905–1907 гг.). М., 1988; Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Исторические зарисовки. К., 2005.

*Әд.:* Амирханов Равиль Усманович (Равиль Амирхан) // Тюркологи современного Татарстана: Справ. М., 1997; Страницы истории татарского народа и Татарстана в новое и новейшее время. К., 2007.

**ӘМИРХА́НОВ** Рашат Мәхмүт улы (20.5.1939, Үзбәкстан ССР, Бохара ш. — 14.12.2000, Казан), философ, филос. фән. канд. (1982). Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1965 елдан Электрофизика ин-тында техник, өлкән инженер. 1974 тән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1993 тән иҗтимагый фикер тарихы һәм исламият бүлеге мөдире. 1997 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында шул ук исемдәге бүлек мөдире. Хезмәтләре татар иҗтимагый фикере тарихына карый.

Х е з м.: Общественная и философская мысль в Татарии начала XX в. М., 1990 (автордаш); Татарская социально-философская мысль средневековья (XIII — середина XVI вв.): В 2 кн. К., 1993.

**ӘМИРХА́НОВ** Рәхмәтулла (1805, Казан өязе Яңа Кишет а. — 1876, Казан), мәгърифәтче, язучы-тәрҗемәче, нашир. Казанда мәдрәсәдә укый, үзлегеннән рус телен үзләштерә. Казан шәһәре татар бистәләре ратушасында тәрҗемәче булып эшли. Бер үк вакытта сәүдә һәм наширлек эше б-н шөгыльләнә. Татарларда китап басу эшенең аякка басуы нигездә Ә. исеме б-н бәйле. Үз акчасына «Зөбдәт əн-нәсаих» («Иң яхшы киңәшләр», 1849), «Гакаид-е мәнзумә» («Иманлылык шигырьләре», 1856) кебек укыту-тәрбия китапларын һәм үз әсәрләрен бастырып, авыл мәктәпләренә бушлай тарата. Кол Галинең атаклы «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының Утыз-Имәни әзерләгән беренче басмасын (1839), беренче татарча календарьны дөньяга чыгара («Горрәнамә», 1841). Төрек шагыйре Ибраһим Хаккыйның «Мәгърифәтнамә» китабын (1845), «*Тутыйнамә*» исемле хикәятләр җыентыгын (1851) татар теленә тәрҗемә итеп бастыра, пәйгамбәрләр турындагы «Кыйссас әл-әнбия» җыентыгын басмага әзерли. Кайбер китапларда укучыларга мөрәҗәгать рәвешендә язылган үз шигырьләрен дә урнаштыра. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтендә аның берничә сатирик парчасы үрнәк итеп китерелә. Ә.гомеренең соңгы елларында бөлә һәм хәерчелектә вафат була.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ӘМИРХАНО́В** Хөсәен Әмирхан улы (1814, Казан — 17.1.1893, шунда ук), дин эшлеклесе, тарихчы. Ф.*Әмирханның* бабасы. Чистай, Казан, Бохара мәдрәсәләрендә укый. 1846 елда Казанга кайта, 1849 дан Яңа Татар бистәсендә *Иске таш мәчет* имамы. «Әмирхания» мәдрәсәсендә укыта. Мөселман дөньясы тарихында эз калдырган шәхесләргә багышланган тарихи-библиографик хезмәтләр авторы. Татар телендә Коръән тәфсире «әл-Фәваид»ны язучы (1870–80 еллар).

Х е з м.: Тәварихе Болгария. К., 1883; Нөҗүмет-тәварих. СПб., 1884; Шәҗәрәи галия фи бәян әл-әнсаб. К., 1884; Тәварихе биладә рәбига, ягъни Мәккә вә Мәдинә вә Бәйтелмөкаддәс вә мөкам Хәлили-әр-рахманның фиһристе. К., 1870–80.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Ә м и р х а н Р. Казанлы Әмирханнар // Казан утлары. 1997, № 10.

*Р.Г.Әмирханов.*

**ӘМИРХА́НОВА** Наилә Әнвәр кызы (14.12.1940, Ташкент ш.), электрохимик, техн. фән. д-ры (1985), проф. (1987), БАССРның атказ. химигы (1984), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан ун-тын (1962) тәмамлый. 1965 елдан Уфа авиация ин-тында, 1986 дан гомуми химия каф. мөдире. Хезмәтләре кызуга чыдамлы эретмәләрне һәм композицион материалларны электрохимик юл б-н төгәл үлчәмле итеп эшкәртүгә, электролит-плазмалы шомарту һәм тирәнтен чистарту теориясенә һәм практикасына карый. Югары тыгызлыклы ток тәэсирендә анодта полярлашу процессларының кинетикасын һәм механизмын тикшерә, металл һәм эретмәләрнең югары тизлекле эрүчәнлеге закончалыкларын һәм механизмын өйрәнә. Кызуга чыдам материалларны һәм төрле эретмәләрне электрохим. эшкәртү технологияләрен эшли.

Х е з м.: Электрохимическое поведение индия в растворах гидроокиси калия // Электрохимия. 1966. Т. 2, вып. 7 (автордаш); Исследование обрабатываемости молибденового сплава ВМ-1 при высоких плотностях тока // Электронная обработка металлов. 1975. № 4 (автордаш); Теоретические основы электрохимической размерной обработки. Уфа, 1984.

**ӘНӘ́К** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 49 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2002 елда 239 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәдәният йорты. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында Ә. халкы баш күтәрүчеләр ягында көрәшә. Мәчет турында беренче тапкыр 1848 дә искә алына. 1884 тә авылдагы крәстияннәрнең — 1878, 1913 тә 1143 дис. җирләре була. 1931 дә Ә.тә «8 Март» исем. к-з оештырыла, ул 1934 тә авылның барлык 74 хуҗалыгын берләштерә. 1950 елларда авыл Пучы һәм Яңа Пучы торак пунктлары б-н бергә эреләндерелгән «Үзәк» (хәзерге Нур Баян исем.) к-зы составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 152, 1870 тә — 532, 1884 тә — 587, 1906 да — 670, 1913 тә — 695, 1920 дә — 595, 1926 да — 354, 1938 дә — 382, 1949 да — 247, 1958 дә — 240, 1970 тә — 219, 1979 да — 143, 1989 да — 80 кеше.

Ә.тә ТРның беренче Президенты М.Ш.*Шәймиев* туган.

**ӘНДЕРЕ́Ш** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 35 *км* көнчыгыштарак, Дусай елгасы буенда. 2002 елда 36 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1920 еллар башында нигез салына. ТАССРның Минзәлә кантоны Әмәкәй волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 295, 1938 дә — 297, 1949 да — 221, 1958 дә — 196,

1970 тә — 182, 1979 да — 114, 1989 да — 45 кеше.

**ӘНҖЕРӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Вятканың сул кушылдыгы. Озынлыгы 44,4 *км*, бассейнының мәйданы 252,8 *км²*. Алабуга р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Көек авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы Иске Әнҗерә авылыннан 5 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Ә. елгасының 0,8 *км* дан 12 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар, иң зурлары — Шаршала (8,5 *км*) һәм Вонюшка (12 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км²*. Елга үзәне асимметрияле (уң як ярлары текәрәк), яхшы эшкәртелгән, эрозия уемы шактый тирән. Тугае ачык беленә. Елга юлы бормалы. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 13%. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Гидрологик режимында еллык агымның 68%ы ташу вакытына туры килә. Елга режимы 1962–93 елларда Яковлево авылы янындагы гидрологик постта өйрәнелә. Су биеклегенең уртача еллык тирбәлеше 4 *м* чамасы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 140 *мм*, ташу агымы катламы 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Яковлево авылы янында уртача еллык су чыгымы 0,91 *м³/с*. Макс. су чыгымы 102 *м³/с* (1970). Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,25 *м³/с*. Җәйге саегу кайвакыт яңгыр ташкыннары б-н бозыла. Кышкы саегу елга бозлана башлаган вакытта, гадәттә, ноябрьнең беренче көннәрендә башлана. Бозлануның уртача дәвамлылыгы 143 көн. Кыш азагына бозның калынлыгы 85 *см* га җитә. Бозның иң зур калынлыгы 147 *см* (1967). Ташу вакытында суның болганчыклыгы 2800 *г/м³*. Елга алып килгән утырмаларның уртача еллык күләме 82 мең *т*. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада гомуми күләме 2113 мең *м³* булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**ӘНИ́С** (Carum), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан ике яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 лап төре билгеле, Евразиядә таралганнар. ТРда бер төре — гади Ә. (C.carvi) барлык районнарда да очрый. Урман аланнарында, болыннарда, юл буйларында үсә. 30–60 *см* озынлыктагы икееллык үләнчел үсемлек. Сабагы шәрә, буынтыклы. Яфраклары чиратлашкан, озынча, ике-өч кат каурыйсыман өлешләргә киселгән, астагылары — озын саплы, өстәгеләре — утырма. Чәчәкләре вак, ак төстә, катлаулы чатырга җыелган. Җимешләре — хуш исле орлыкчалар. Май-июньдә чәчәк ата. Июль-август айларында җимеш бирә. Эфир майлы үсемлек; орлыкларында 3–7% эфир мае, флавоноидлар, аксымнар, май бар. Медицинада аппетитны ачу өчен, җимешләре азык-төлек сәнәгатендә һәм кулинариядә кулланыла. Баллы үсемлек.

**«ӘНИСӘ́»**, бию *такмагы* (19 йөз уртасы). Татарлар тупланып яшәгән барлык төбәкләрдә киң таралган. Мәхәббәт-көнкүреш сюжетына корылган, тулы рифмалары шомартылган, ритмы яшьләр биюенә хас. «Ә.» текстының Татарстан авылларында яшәп килгән үзара охшаш өч варианты булуы мәгълүм. «Ә.»нең ноталы язмасы беренче мәртәбә А.С.Ключарёвның «Татар халык көйләре» (1955) җыентыгында басыла.

*Әд.:* Б ә д и г ы й Хуҗа. Халык әдәбияты: Табышмаклар, такмаклар, такмазалар. К., 1913; Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980.

**ӘҢГЕРӘ́К УТЫ́**, (Echium), кыярчалар семьялыгыннан бер, ике һәм күпьеллык үләннәр, сирәгрәк — куаклар ыругы. 50 ләп төре билгеле, Евразиядә һәм Африкада таралганнар. ТРда бер төре — гади Ә.у. (E.vulgare) барлык районнарда да очрый. Коры тау битләрендә, басуларда, юл буйларында үсә. 30–80 *см* озынлыктагы икееллык үләнчел үсемлек. Тамыры орчыксыман. Сабагы туры, яфраклары кебек үк кыска төкләр һәм сирәк озынча кыллар б-н капланган. Яфраклары чиратлашкан, кыяклы-пычаксыман. Чәчәкләре зәңгәр төстә, берьяклы бөтеркәдә, себеркәчле чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше вакланган, өлгергәндә 4 кара чикләвеккә аерыла. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–август айларында өлгерә. Үсемлекнең барлык өлешләрендә дә алкалоидлар, сапониннар, С,Е витаминнары, каротин бар. Халык медицинасында яфрак һәм чәчәкләренең төнәтмәсе тынычландыру, какырык чыгару, яра төзәтү өчен файдаланыла. Чүп үлән. Баллы үсемлек.

**ӘПСӘЛӘ́М** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ык елгасы буенда. 2002 елда 884 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, мөгезле эре терлек асрау; төзелеш материаллары һәм конструкцияләре комб-ты. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 да мәчет, 1910 да 2 су тегермәне эшли; шимбә саен ярминкә үткәрелә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире (Димтамак авылын да кертеп) 5199 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостена керә. 1920 дән ТАССР ның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1795 тә — 135 ир заты; 1859 да — 637, 1886 да — 604; 1897 дә — 807; 1926 да — 925, 1938 дә — 1098, 1949 да — 728, 1958 дә — 724, 1970 тә — 689, 1979 да — 757, 1989 да — 941 кеше.

**ӘПСӘЛӘ́М** т и м е р ю л р а з ъ е з д ы п о с ё л о г ы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлының Урыссу–Октябрьский тармагы буенда. 2002 елда 32 кеше (татарлар) яши. 1950 елларда нигез салына. Башта Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1970 тә — 51, 1979 да — 46, 1989 да — 20 кеше.



Г.С. Әпсәләмов.

**ӘПСӘЛӘ́МОВ** Габдрахман Сафа улы (28.12.1911, хәзерге Мордва Респ-касы, Ковылкино р-ны Иске Аллагол а. — 7.2.1979, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (1940, Мәскәү) тәмамлый. 1937 елда «Совет әдәбияты» ж-лында «Маһинур» исемле беренче хикәясе, 1940 та аерым китап булып балалар өчен «Киләчәк безнеке» пьесасы, 1941 дә «Бәхет кояшы» исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыга. 1941 елның августыннан Ә. фронтта: миномёт расчёты командиры, разведчик, хәрби хәбәрче булып хезмәт итә. Бөек Ватан сугышы геройлары турында хикәяләр һәм очерклар сериясен бастыра: «Мәңгелек дан» (1942), «Кыска дулкында» (1943), «Үлемнән көчлерәк» (1943), «Зәңгәр иртә» (1943) һ.б. Ә.нең таланты сугыштан соңгы иҗатында аеруча киң ачыла. Мавыктыргыч сюжетлы, совет минёрларының дошман тылындагы көрәшен сурәтләгән «Ак төннәр» (1947; рус теленә тәрҗемәсе «Белые ночи», 1949) повесте, героик романтика, югары патриотик рух б-н сугарылган «Алтын Йолдыз» (1949; рус теленә тәрҗемәсе «Орлята», 1952), «Газинур» (1951; рус теленә тәрҗемәсе 1954) романнарын иҗат итә. Сугыш темасы «Мәңгелек кеше» (1960; рус теленә тәрҗемәсе «Вечный человек», 1964), «Агыла болыт» (1980) романнарында да дәвам ителә. Бер эшче гаиләнең буыннар тарихын сурәтләгән «Сүнмәс утлар» (1958; рус теленә тәрҗемәсе «Огонь неугасимый», 1959; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1959), мед. хезмәткәрләре, галимнәре тормышыннан «Ак чәчәкләр» (1965; рус теленә тәрҗемәсе «Белые цветы», 1968), укытучыларга багышланган «Яшел яр» (1968; рус теленә тәрҗемәсе «Зелёный берег», 1975), В.И.Ленинның Казан чоры революцион эшчәнлегенә багышланган «Күк күкрәр» (1975) романнары, студентлар арасындагы дуслыкны яктырткан «Миңа унтугыз яшь иде» (1972), иҗат кешеләренең уй-кичерешләрен бәян иткән «Идел хикәяте» (1968) повестьлары әдип иҗатының күпкырлы һәм үзенчәлекле булуын күрсәтә. Ә. ш.у. В.В.Короленко, А.П.Гайдар, Э.К.Казакевич, Н.С.Лесков, А.А.Фадеев, Д.Н.Мамин-Сибиряк, М.М.Пришвин әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Ә. әсәрләренең күпчелеге рус телен-

дә һ.б. телләрдә дөнья күрә. 1962–66 елларда СССР ЮС депутаты. Ленин, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 6 томда. К., 1968–72.

*Әд.:* Г ы й н и я т у л л и н а А.К. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1970; М у х а м е д о в а Г.С. Абдурахман Абсалямов. К, 1971; М у с т а ф и н Р. Литературные портреты. К., 1986.

*Р.Г.Сверигин.*

**ӘПСӘЛӘ́МОВ** Минзакир Әпсәләм улы (10.11.1896, Казан губ., Мамадыш өязе Югары Утар а. — 10.6.1981, Мәскәү), генерал-майор (1940), хәрби фән. д-ры (1955). Беренче Бөтендөнья, Гражданнар, совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. М.В.Фрунзе исем. хәрби академияне (1922, Мәскәү) тәмамлый. 1927–31 елларда Аерым Кавказ армиясенең разведка бүлеге мөдире; СССРның Төркиядәге (1922–27), Ирандагы (1933–37) хәрби атташесы. 1950–60 та СССР Кораллы Көчләре хәрби академиясендә укыта. Хезмәтләре хәрби стратегия һәм оператив осталык теориясенә карый. Ленин, өч Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К о л п а к и д и А., П р о х о р о в Д. Империя ГРУ: В 2 т. М., 2000.

**ӘПСӘЛӘ́МОВ** Мифтах Шаһи улы (1889, Оренбург губ. Орск ш. — 31.12.1927, Казан), драма актёры. Хезмәт Батыры (1926). Сәхнә эшчәнлеген Орск шәһәрендә татар театр труппасында башлый. 1920 елда З.Солтанов һәм К.Тинчурин җитәкчелегендәге Самара татар драма һәм музыка студиясендә укый, 1922–27 дә Татар акад. театры труппасында. Актёрга сәхнәдә үзенең барлык иҗат мөмкинлекләреннән оста файдалану, чагылдыру чаралары колачының киңлеге, ш.у. персонажларның эчке дөньясына тирән үтеп керә белү хас. Ул башкарган аеруча күренекле образлар: Иван Грозный («Иван Грозныйның үлеме», А.Толстой, 1923), романтик, бунтарь Стенька Разин («Степан Разин», В.Каменский, 1925), кочле сатирик Гайнетдин («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт, 1924), Юныс хаҗи («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Шакирҗан («Качыгыз, шартлый!», К.Тинчурин), Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Фәтхулла («Тигәнәк», Ә.Рахманкулов).

*Әд.:* С ә л и м җ а н о в Х. Артист язмалары. К., 1966.

**ӘРӘ́** елгасы, Идел алды төбәгендә. Зөянең сул кушылдыгы. Озынлыгы 44,2 *км*, ТР чикләрендә — 16 *км*. Бассейнының мәйданы 368 *км²*. Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Чуашстан Респ-касы терр-ясендә, тамагы Яшел Үзән р-нының Прибой посёлогыннан 3 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Калкулыклы тигезлекләр буйлап ага, түбән өлешендә елга тугае сазланган. Елга үзәне асимметрияле. Үзән сөзәклекләре сызалар һәм ерымнар б-н нык бүлгәләнгән. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 11%. Ә. елгасының 0,6 *км* дан алып 8,7 *км* га кадәр озынлыктагы 25 кушылдыгы бар, алар арасында иң зурысы Бүшәрмә елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,1–0,25 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана, коры елларда елганың түбән агымы кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 77 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,058 *м³/с*. Ел дәвамында суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елга бассейнында гомуми күләме 761 мең *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**ӘРӘ́** күле, Идел алды төбәгендә. Элеккеге елга юлында сакланып калган күл. Зөя елгасының сулъяк тугаенда, Яшел Үзән р-нындагы Городище авылыннан көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 14,6 *га*. Озынлыгы 2730 *м*, иң киң урыны 230 *м*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**ӘРӘ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 47 *км* көньяк-көнбатыштарак Чуаш Респ-касы чигендә. 2002 елда 120 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 җамигъ мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1291,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивиль өязе Яңа Кавал волостена керә. 1920 дән ТАССР ның Зөя кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 243 ир заты; 1859 да — 1195, 1897 дә — 1798, 1908 дә — 1921, 1920 дә — 1599, 1926 да — 1085, 1989 да — 179 кеше.

**ӘРӘМӘ́ ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Sylviidae), чыпчыксыманнар отрядыннан сайрар кошлар семьялыгы. 420 ләп төре билгеле, Антарктиданы исәпләмәгәндә, бөтен җир шары буйлап таралганнар. ТРда 6 ыругка керүче 23 төре бар: *нарат чыпчыклары, камыш чыпчыклары*, бакча чыпчыклары, кәрлә тургайлар, әрәмә чыпчыклары һ.б. Агач һәм куак биотопларда, яр буйларындагы үләнле әрәмәлекләрдә оялыйлар. Бакчаларда һәм паркларда яшиләр. Күчмә кошлар. Сары башлы кәрлә тургай ел дәвамында яши. Ә.ч озынлыгы 12–15 *см*, авырлыгы 8 *г* нан алып (нарат чыпчыгы) 34 *г* га кадәр (камыш чыпчыгы) авырлыкта. Соры, коңгырт, яшькелт-сары төстә булалар. Кечкенә башлы, нечкә туры томшыклы. Канатлары төрле зурлыкта. Түгәрәкләнеп килгән яисә киртләч койрыклы. Ә.ч. яшерен тормыш алып баралар, аларны сайраулары буенча, фәкать оялау һәм бала чыгару вакытында гына күрергә мөмкин. Әлеге кошларның оялары ясалуы һәм урнашуы буенча күптөрле. Күбесенчә — ачык, касәсыман. Җирдән биек түгел — агач һәм куакларның куыш кәүсәсендә (әрәмә чыпчыклары) яки озын үлән сабаклары арасында (камыш чыпчыклары) урнашалар. Нарат чыпчыклары җир өстендәге ояларын яннан керә торган куыш формасында ясыйлар. 4–7 йомырка салалар. Камыш һәм нарат чыпчыклары бары тик хайван азыклары: бөҗәкләр һәм аларның личинкалары, үрмәкүчсыманнар, вак моллюсклар б-н, ә калганнары җиләкләр һәм вак чүп үлән орлыклары б-н тукланалар. Зарарлы бөҗәкләрне юк итәләр. Август ахырында Ә.ч. кышлау өчен очып китә башлыйлар.

**ӘРЕКМӘ́Н**, т и г ә н ә к (Arctium), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 лап төре билгеле, Евразиянең урта поясында таралган. ТРда 5 төре бар. Зур Ә. (A. lappa), вак Ә. (A. minus), төкле Ә. (A. tomentosum), катнаш Ә. (A. mixtum) барлык районнарда да; имәнлек Ә. (A. nemorosum) Кама алдында һәм Кама аръягында очрый. Киң яфраклы урманнарда, сулыклар ярында, ташландык җирләрдә, чүплекләрдә, юл буйларында үсә. 60–180 *см* озынлыктагы үсемлекләр. Тамырлары зур, үзәкле, итләч. Сабаклары юан, кабыргалы, төкчәле. Яфраклары йөрәккә охшаган, озын саплы. Чәчәкләре аксыл шәмәхә — куе кызыл төстәге шарсыман кәрзиннәр, тышлары чәнечкеле каты яфракчыклардан тора. Кәрзиннәр өске өлештәге калкансыман себеркәчкә



җыелган. Җимешләре — соргылт көрән төстәге кыска бүрекчәле орлыкча, алар хайваннар йонына, киемгә һ.б. ш. га җиңел ябыша һәм шул вакытта таралалар. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Тамырларында — инулин, органик кислоталар, сумалалы матдәләр, эфир мае, яфракларында витаминнар, лайла, каротин, эфир мае бар. Тамырларыннан ясалган төнәтмәсе халык медицинасында бәвел кудыру һәм тир чыгару өчен кулланыла. Бадәм һәм зәйтүн маенда тотылган тамыр төнәтмәсен, ягъни «тигәнәк мае»н чәч ныгыту өчен файдаланалар. Яфраклары бактерияләргә каршы һәм җәрәхәтне төзәтү үзлекләренә ия. Баллы үсемлекләр. Имәнлек Ә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ӘРЕ́М** (Artemisia), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан үләнчел яки ярым куакчыл үсемлекләр ыругы. 400 ләп төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарда очрыйлар. ТРда 18 төре бар. Дару Ә. (A. abrotanum), ачы Ә. (ак Ә.) (A. absinthium), иссез Ә. (эстрагон) (A. dracunculus), дала Ә. (A. campestris), кара Ә. (алабута Ә.) (A. vulgaris) һ.б. киң таралган. Далалы болыннарда, сөзәклек, ташландык җирләрдә, чүпле урыннарда, яшелчә бакчаларында үсә. Сабагы туры, 1,5 *м* га кадәр озынлыкта, үзенә генә хас көчле исе бар.



Каурыйсыман телмә яфраклы. Чәчәкләре сары төстә, сабак очындагы шарсыман кәрзиннәрдә урнашкан. Яфраклары һәм сабаклары кыска, куе төкләр б-н капланган, шул сәбәпле үсемлек көмешсыман соры төстә. Җимешләре — көрән төстәге озынча вак орлыкчалар. Июль–сентябрьдә чәчәк аталар. Җимешләре июль-август айларында өлгерә. Орлыклардан үрчи. Дару Ә., ачы Ә., кара Ә. — дару үләннәре. Яфракларын һәм чәчәк атучы сабак очларын кулланалар. Аларда эфир мае, гликозидлар, флавоноидлар, дуплау матдәләре, C һәм K витаминнары, сумалалар бар. Аппетит ачу һәм сәламәтлекне ныгыту өчен, ялкынсынуга каршы файдаланыла. Ачы Ә., иссез Ә., кара Ә. тәмләткеч буларак кулланыла. Маршалл Ә. (A. marschalliana) — комнарны ныгытучы үсемлек. Эре чәчәкле Ә. (A. macrantha) һәм тозлак үләнсыман Ә. (A. salsoloides) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ӘРЕ́М** посёлогы, к. *Варкләд.*

**ӘРЛӘННӘ́Р** (Cricetinae), кимерүчеләр отрядыннан имезүчеләр ассемьялыгы. 390 төре билгеле, Австралиядән тыш, барлык континентларда да яшиләр. ТР терр-ясендә 3 төре — гади әрлән (Cricetus cricetus) республиканың барлык терр-ясенә таралган; соры әрлән (Cricetulus migratorius) Идел алды һәм Кама аръягы төбәкләрендә; Эверсман әрләне (Allocricetulus eversmanni) Кама аръягының көнчыгыш р-ннарында очрый. Коры үзәнлек болыннарда, урман буйлары, юл кырыйлары, бакчалар һәм яшелчә кишәрлекләрендә яшиләр. Гәүдәсе 22 *см* га, койрыгы 10 *см* га кадәр озынлыктагы, 650 *г* га кадәр авырлыктагы вак кимерүчеләр. Таза гәүдәле, юан муенлы, очлы башлы. Мехы тыгыз, шома, аз гына ялтырый. Аксыл соры яки көрән сорыдан алып куе коңгырт төсләрдә булырга мөмкин. Соры әрләннәрнең гәүдәсе 13 *см* дан артмый һәм сырты куе соры, корсагы аксыл яки соргылт була. Эверсман әрләне гади әрләннән өстенең җирән коңгырт, корсагының ак төстә булуы һәм күкрәгендә кара таплар булуы б-н аерыла. Җир өсте хайваннары. Ялгыз яшиләр, шактый катлаулы өн казыйлар. Ә. өннәрен чыгу урыныңдагы туфрак өеменнән белү җиңел, анда гадәттә кибәк һәм чүп-чарлар сибелгән була. Эңгер-меңгер вакытта һәм төнлә активлар. Кышын йокыга талалар. Март ахырында — апрельдә уяналар. Ана әрләннәр елына 2 оя — 3–18 әр бала тудыра. Үләнчел үсемлекләр һәм аларның орлыклары б-н туклана. Кышка запас әзерли. Кыр һәм бакча культураларына зарар китерәләр. Елак карчыгалар, ябалаклар, козгыннар һ.б. кошлар, ш.у. көзән һәм ас — әлеге кимерүчеләрнең куркыныч дошманнары. Эверсман әрләне һәм соры әрлән ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ӘРЛӘНСЫМАННА́Р** (Cricetidae), кимерүчеләр отрядыннан имезүчеләр семьялыгы. 600 ләп төрне берләштерүче 100 ләп ыругы билгеле; Австралия, Африка һәм Азия тропиклары, Исландия һәм Антарктидадан тыш, барлык континентларда да таралганнар. ТР терр-ясендә ике ассемьялыкка кергән 12 төре — *әрләннәр* (3 төр) һәм *кыр тычканнары* (9 төр) бар. Яфраклы һәм катнаш урман, кыр, болыннарда, сулыклар янында очрыйлар. Үзенчәлекле итеп казыган өннәрендә яшиләр. Гәүдәсе 35 *см* га, койрыгы 23 *см* га кадәр озынлыкта, авырлыгы 650 *г* га кадәр җитә. Арткы аяклары алдагыларына караганда озынрак, биш бармаклы, каты тырнаклы. Су б-н бәйләнешлеләренең арткы аякларында йөзү ярылары бар. Күп төрләренең йон капламы тыгыз һәм йомшак, аркасы ачыктан алып куе коңгыртка кадәр, корсагы ачык коңгырт төстә; кайвакыт аркасының уртасыннан буй-буй кара сызык үтә. Бер елда 18 гә кадәр бала була. Күп төрләре 1–2 ел яши. Үсемлекләр б-н туклана. Күбесе а.х. культураларына зарар китерә. Кайберләре (су күсесе) вак һөнәрчелек өчен әһәмиятле. Ә. арасында йогышлы авырулар (түләмә, чума, лептоспироз) таратучылар очрый. Дала чуары, соры әрлән, Эверсман әрләне ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ӘРМӘ́Н БИСТӘСЕ́**, Казанның көньяк-көнчыгыш өлешендә текә калкулык башында урнашкан була (хәзерге Ульяновлар, Достоевский, Вишневский, Волков, Калинин урамнары тирәлегендә). 14–16 йөзләрдә барлыкка килә. Әрмән сәүдәгәрләре һәм һөнәрчеләре яшәгән. 18 йөз башында *Кирпеч сугучылар бистәсенә* кушыла. Үз каберлеге була. 19 йөз ахырында элекке Ә.б.ндә (хәзерге Калинин урамының көнбатыш өлешендә) 14–16 йөзләргә караган әрмәнчә язулы 4 кабер ташы табыла.

*Әд.:* Высоцкий Н.Ф. Следы древнего армянского кладбища в Казани // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. К., 1900. Т. 6, вып. 1; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

**ӘРМӘ́Н КОЛО́НИЯСЕ**, урта гасырларда (13–15 йөзләр) Болгар шәһәренең көнбатыш читендә урнашкан әрмәннәр бистәсе. Кайбер тикшеренүчеләр фаразынча, Ә.к. Идел яры буйлап сузылган (3 *км*) була. Берәүләр аны монголларның Кавказ артын яулау сугышы (1220 еллар) вакытында Әрмәнстаннан качып килүчеләр салган, икенчеләр монгол яуларына кадәр барлыкка килгән дип саный. Ә.к. Алтын Урда чорында (13–14 йөзләр) зур үсешкә ирешә. Беренче тапкыр Ә.к. 1712 елда дъяк Михайлов тарафыннан тасвирлана, ул Болгар шәһәрлеге чигендә «Грек палатасы» дип аталган борынгы бина хәрабәләре сакланганын, анда әрмәнчә язулы ташлар утыртылган зират урнашканын билгеләп үтә. Соңрак бина ташларын җирле халык үз кирәгенә ташып бетерә. 1721 дә Пётр I Болгар хәрабәләре б-н танышып йөргәндә анда әрмәнчә язулы христиан кабер ташлары таба, 1722 дә алар Васильев фамилияле әрмән тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителә һәм И.И.Лепёхин тарафыннан бастырып чыгарыла. 1862 дә француз шәркыятьчесе М.И.Броссе аларның язылу вакытын ачыклый (1321, 1335). Ә.к. археол. тикшерү 1916 да В.Ф.Смолин, 1945 тә А.М.Ефимова һәм А.П.Смирнов тарафыннан үткәрелә. Ә.к. терр-ясендә күк төстәге балчык савытлар, 13–14 йөзләрдә сугылган Алтын Урда акчалары, 16–17 йөз шомартылган көмешсу-кара чүлмәкләре һ.б. табыла. 1945 тә уздырылган казу эшләре вакытында 113 христиан кабере тикшерелә. Антрополог М.М.Герасимов, кабердән чыккан баш сөякләренә нигезләнеп, Ә.к.ндә яшәүчеләрнең портретларын реконструкцияли. Арада гарәп язулы ике кабер ташы да була. Каберләрдә алтын һәм көмеш алкалар, бөҗра рәвешле һәм энҗе куелган асылмалар, алтын-көмеш җепләр б-н чигелгән биючә кешеләр сыннары, үсемлек бизәкләре, гарәп хәрефләре төшкән парча һәм ефәк тукымалар табыла.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары // Тр. Гос. ист. музея. М., 1951. Вып. 19; шул ук. Армянская колония города Булгара // Материалы и исслед. по археологии СССР. М., 1958. № 61; Айдаров С.С., Аксёнова Н.Д. Великие Булгары: Путеводитель по Булгарскому историко-архитектурному заповеднику. К., 1983.

*П.Н.Старостин.*

**ӘРНӘ́Ш** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 17 *км* көнбатыштарак, Орнаш-Чишмә елгасы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, агач эше б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.тә мәчет була. 20 йөз башында монда мәктәп, 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Авыл җәмгатенең имана җире 775,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 68 ир заты; 1859 да — 384, 1885 тә — 507, 1897 дә — 556, 1908 дә — 399, 1920 дә — 536, 1926 да — 488, 1949 да — 287, 1958 дә — 216, 1970 тә — 124, 1979 да — 78, 1989 да 7 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.



А.Ә.Әсәдуллин.



А.Н.Әсәдуллин.

**ӘРТӘ́ РАЙОНЫ́**, *Свердловск өлкәсенең* көньяк-көнбатыш өлешендә. 1923 елда оештырыла. Үзәге — шәһәр тибындагы Әртә посёлогы (Екатеринбургтан 203 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 32,7 мең кеше (2002), ш.и. 2,7 мең татар. Күбесенчә Әҗегол (884 кеше), Манчаж (260), Усть-Манчаж (Манчак-Тамак) (177), Поташ (115), Әртә-Шигер (415), Бакый (327), Биккенә (259), Бикмәт (173), Торна (195) авылларында яшиләр. Әҗегол авылында төбәк Татар мәдәни үзәге һәм татар театры эшли. 1999/2000 уку елыннан Ә.р.ның 4 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә.

**«ӘСАМИ́ КӨТЕ́Б»** («أسام الكتب» — «Китаплар исемлеге»), татар нәшрияты, китап сәүдәсе ширкәтләре тарафыннан реклама тәртибендә даими чыгарылып килгән китаплар исемлеге басмалары. Төрле нәшрият-сәүдә ширкәтләре төрле исем б-н («Әсами көтеб», «Мәгариф» басмаханәсе; «Әламилә көтеб», «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсе; «Муккамаль самаиль көтеб», Кәримовләр басмаханәсе) чыгара торган бу басмаларда китап сату, заказ б-н китап соратып алу шартлары, нәшриятларның китап соратып алучыга татар телендәге теләсә нинди китапны җибәрергә бурычлы булуы һ.б. хакында мәгълүматлар да бирелгән. «Ә.к»ләр еш кына Мәкәрҗә, Эрбет кебек ярминкәләр вакытына каратып махсус чыгарылган. Кайбер басмаларда татар китап кибетләрендә булган башка телдәге китаплар исемлегенә дә урын бирелгән. Беренче «Ә.к»ләр, 1870 елларда күренә башлап, 20 йөз башында татар нәшриятлары һәм китап сату ширкәтләренең эшчәнлеге киңәюгә бәйле рәвештә таралыш ала. 1917 елга кадәр 100 гә якын шундый «Ә.к»ләр басылып чыкканлыгы мәгълүм.

*Әд.:* Кәримуллин Ә.Г. Китап дөньясына сәяхәт. К., 1979; шул ук. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

**ӘСГЕЛЛӘ́Р**, борынгы болгарлар берләшмәсенә кергән төрки кабиләләрнең берсе. 9–10 йөзләрдә Ә.нең Урта Идел буенда яшәгәнлеге мәгълүм. Чыгышлары Урта Азиядәге чигил (ишкил) кабиләләренә бәйле дип уйланыла.

**ӘСӘДУ́ЛЛИН** Альберт Әхәт улы (16.10.1949, Казан), виолончелист, педагог, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык артисты (1999). 1973 елда Казан консерваториясен тәмамлый, 1976 дан шунда ук укыта, бер үк вакытта 1980 нән Казан консерваториясенең кыллы квартеты, 1996 дан ТРның Дәүләт квартеты солисты. Квартет составында Россиядә һәм чит илләрдә үткән концертларда катнаша. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1987), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2002).


**ӘСӘДУ́ЛЛИН** Альберт Нурулла улы (1.9.1948, Казан), җырчы (тенор), РСФСРның атказ. (1988), ТРның халык артисты (1998). Казан сәнгать уч-щесен (1968) һәм И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архитектура ин-тының архит-ра ф-тын (1974) тәмамлый. Шул ук елда «Поющие гитары» вокаль-инструменталь ансамбле солисты була. 1975 елда А.Журбинның (Ю.Дмитрин либр.) «Орфей һәм Эвридика» исемле беренче совет рок-операсында төп партияне, Р.Гринблатның «Фламанд легендасы» («Фламандская легенда», Ю.Ким либр.), А.Васильевның «Ярыш» («Гонки», Ю.Дмитрин либр.) рок-опералорында төп партияләрне беренче булып башкара. Ә. репертуарында милли традицияләрне заманча популяр көйләр стиле б-н бәйләүче тарихи сюжетка корылган татар җырлары бар. Казанда Р.Кәлимуллинның «Еракгагы кәккүк авазы» (И.Юзеев либр., 1989) рок-операсында, «Мәһди» муз. тамашасында (М.Шәмсетдинова либр. һәм музыкасы, 1989) төп партияләрне башкара. Ә. катнашында Мәскәүнең «Мелодия» фирмасы «Җыр белән гомер итик» («С песней по жизни», 1978), «Орфей һәм Эвридика» («Орфей и Эвридика», 1980), «Мин кайтырмын» («Я вернусь», 1981), «Җырлый Альберт Әсәдуллин» («Поёт Альберт Асадуллин», 1989), «Чагылыш» («Отражение», 1989), «Мәһди» («Магди», 1989) һ.б. дисклар чыгара. Аерым концерт программалары б-н чыгышлар ясый. Россия һәм чит илләрдә (Польша, Финляндия, Германия, Һиндстан һ.б.) гастрольләрдә була. Сочи шәһәрендә совет җырларын башкаручыларның бөтенроссия (1 нче бүләк, 1978), Ленинград шәһәрендә эстрада артистларының бөтенсоюз (1 нче урын, 1979) конкурслары, Болгариядә уздырылган «Алтын Орфей» халыкара конкурсы (1 нче бүләк, 1979) лауреаты.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ӘСӘДУ́ЛЛИН** Габдулла Шаһи улы (28.11.1926, хәзерге Яшел Үзән р-ны Күгеш а. — 7.5.2004, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1996). Ташкент пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Үзбәкстан ССРның Нәманган шәһәрендә урта мәктәптә укытучы булып эшли. 1957–58 елларда Татарстан укытучылар белемен күтәрү ин-тында методист, 1958–63 тә СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр, 1963–91 дә РСФСР Мәгариф министрлыгы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лында өлкән фәнни хезмәткәр. 1993 тән ТР ФАнең Тарих ин-ты каршындагы Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгендә әйдәп баручы хезмәткәр. Рус мәктәпләре өчен татар теле, татар мәктәпләре өчен рус теле дәреслекләре һәм аларны укыту методикасына караган хезмәтләр авторы.

Хезм.: Первоначальное обучение русскому языку в татарской школе. К., 1978; Обучение связной русской речи в начальных классах татарской школы. К., 1985.

**ӘСӘДУ́ЛЛИН** Илдус Шәүкәт улы (13.2.1947, Казан), архитектор, ТАССРның атказ. архитекторы (1984). Казан төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), «Татаргражданпроект» ин-тында архитекторлар төркеме җитәкчесе, проектларның баш архитекторы, ин-тның архит-ра буенча баш белгече булып эшли. 1986–88 елларда Алабуга шәһәренең баш архитекторы. 1988–90 да Казан шәһәренең баш архитекторы урынбасары. 1990–91 дә ТССРның Төзелеш дәүләт ком-ты (Госстрой) рәисе, 1991–95 тә ТРның Төзелеш һәм архит-ра дәүләт ком-ты рәисе, 1995–96 да — ТР төзелеш һәм архит-ра министры урынбасары. 1996 дан архитектура-иҗат остаханәсе җитәкчесе. Ә. проектлары б-н Казанда күпкатлы торак йортлар (1975, 1992), «Татнефтепроводстрой» трестының адм. бинасы (1986) төзелә, Вишневский урамы реконструкцияләнә (1976), Чистай шәһәрендә сәнгать мәктәбе бинасы салына (1983). Ә. катнашында



И.Ш.Әсәдуллин. Чехов урамындагы биек торак йорт. Казан. 1990 еллар.

Алабуга шәһәренең ген. планы (1986–88), ТР Шәһәр төзелеше кодексы вариантларының берсе, ТР торак реформасы концепциясе (1995), Казан шәһәрендә тузган торакны бетерү программасы, Чистай шәһәре төзелеше уставы (1995–96) эшләнә. ТР Архитекторлар берлеге әгъзасы (1980).

**ӘСӘДУ́ЛЛИН** Ринат Сөләйман улы (26.2.1934, Әстерхан өлкәсенең Краснодар р-ны Красный Яр а.), генерал-майор (1982). Полтава зенит ракеталары уч-щесен (1958), Киев югары артиллерия инженерлары уч-щесен (1969) тәмамлый. 1972 елдан зенит-ракета гаскәрләрендә часть командиры урынбасары, 1973 тән — командиры. 1975–89 да Карпат буе хәрби округында Һава һөҗүменнән саклау гаскәрләре башлыгы урынбасары. Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ӘСӘ́Й** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 14 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасы буенда. 2002 елда 542 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.дә мәчет була, 1910 да 3 мәчет, 3 мәктәп, 3 су тегермәне эшли. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 2944 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Азнакай волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 250 ир заты; 1859 да — 794, 1897 дә — 1450, 1920 дә — 1771, 1926 да — 1236, 1938 дә — 1299, 1949 да — 744, 1958 дә — 605, 1970 тә — 687, 1979 да — 554, 1989 да 495 кеше.

**ӘСӘКӘ́Й РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 2369 *км²*. Үзәге — Әсәкәй авылы (Оренбургтан 544 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 22379 кеше (1989), ш.и. 11161 татар. Районда 11 татар авылы, барлык халыкның 50% тан артыгын татарлар тәшкил иткән катнаш 6 торак пункт бар. Иң зур татар авыллары: Иске Колшәрип (1004 кеше), Яңа Солтангол (840), Иске Солтангол (427), Котлый (748). Борынгылары (18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына) — Әсәкәй, Иске Солтангол, Иске Колшәрип, Котлый. Бу авыллар Яңа Мәскәү юлы төзелә башлагач барлыкка килә. 1917 гә кадәр Ә.р. терр-ясендә 12 мәчет, 5 мәктәп, татар-рус земство мәктәбе эшли. 1930 еллар урталарында татарча «Кыр ударниклары» г-тасы нәшер ителә. Совет чорында районның 15 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. 1993 тән ТИҮ бүлекчәсе эшли, 1998 дә ул Милли-мәдәни автономия итеп үзгәртелә. 1990 еллар башыннан атнага 3 тапкыр татарча радиотапшырулар алып барыла, ТР телевидениесе тапшырулары кабул ителә. Бу районда Советлар Союзы Герое Я.Ә.*Әхмәтшин* туган.


**ӘСӘ́Н** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юлы станциясеннән 32 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр юк. 16 йөз ахырында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мич чыгару, баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.дә мәчет, мәдрәсә, тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 857,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 75 ир заты; 1859 да — 627, 1878 дә — 796, 1897 дә — 850, 1908 дә — 895, 1920 дә — 748, 1926 да — 879, 1938 дә — 598, 1949 да — 535, 1958 дә — 359, 1970 тә — 297, 1989 да — 5 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ӘСӘ́Н-ЕЛГӘ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 9 *км* көньяктарак, Оштырма елгасының уң кушылдыгы янында. 2002 елда 386 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет — 18 йөз ахыры архит-ра истәлеге (к. *Әсән-Елга мәчете*). 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Асан-Илга исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ә.Е.да мәчет, мәктәп, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1417,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән Елга волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 151 ир заты; 1859 да — 586, 1897 дә — 797, 1908 дә — 818, 1920 дә — 815, 1926 да — 792, 1938 дә — 606, 1949 да — 542, 1958 дә — 488, 1970 тә — 436, 1979 да — 379, 1989 да — 346 кеше.

**ӘСӘ́Н-ЕЛГА́ МӘЧЕТЕ́**, Кукмара р-ны Әсән-Елга авылындагы татар халык архит-расы истәлеге. Халык осталары тарафыннан 18 йөз ахырында төзелгән дип фаразлана. Урамдагы йортлар рәтендә урнашкан. Түбә уртасында манарасы булган, ике заллы, әргә катка утыртылган бер катлы агач мәчет. Турыпочмаклы бина өч анфилада бүлемен берләштерә: төп гыйбадәт кылу залы (ул бинаның яртысын алып тора), кече зал һәм вестибюль. Мәчет ишеге көнчыгыш фасадта урнашкан. Чишенү бүлмәсе һәм төп катка алып менүче баскыч — вестибюль астында, аскы өйнең төньягында. Аскы өйнең калган өлеше хуҗалык максатларында файдаланылган. Ишек өстендә тәрәзәләнгән веранда, ул ике колоннага таяна һәм ике кыеклы түбә б-н капланган. Консоль рәвешендәге михраб чыгынтысы көньяк диварда урнашкан. Дүрт кыеклы биек түбәдән сигез кырлы өч катлы манара күтәрелә. Мәчет юан бүрәнәдән буралган һәм, фаразланганча, 19 йөздә такта б-н тышланган. 1990 еллар уртасында Р.В.Билалов проекты б-н реставрацияләнә.

*Әд.:* Айдарова-Волкова Г.Н. Архитектурная культура Среднего Поволжья 16–19 веков. К., 1997.



Әсән-Елга мәчете. 18 йөз ахыры.

**ӘСӘ́НОВ** Нагайбәк (? — ?), 1773–75 еллардагы крәстияннәр кузгалышында катнашучы. Минзәлә өязе Чалпы авылы (хәзер Азнакай р-нына керә) старшинасы. Е.И.Пугачёв отрядына 1773 ел ахырында килеп кушыла. В.И.*Торнов* тарафыннан 900 кешелек отряд башында Зәй кальгасын алырга дип җибәрелә. А.*Асеев* б-н бергә Зәйне камау операциясенә җитәкчелек итә. 1774 нең 15 гыйнварында аларның берләштерелгән отряды кан коюсыз гына Зәй кальгасын кулга төшерә. 17 гыйнварда, Ю.Бибиков җитәкчелегендәге эзәрлекләү полкы б-н бәрелештән соң, баш күтәрүчеләр кальганы ташлап китәргә мәҗбүр була. Ә.нең шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в Пугачёвском восстании. К., 1973; Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ӘСӘ́РОВ** Хәбиб Кәрим улы (15.3.1913, Казан губ., Чистай өязе Кизләү а. — 1983, Мәскәү), агрохимик — туфрак белгече, а.х. фән. д-ры (1967), проф. (1967). Акад. Д.Н.Прянишниковның шәкерте. Казан а.х. техникумын (1932), К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен (1937) тәмамлый. 1937–39 елларда ТАССРның А.х. халык комис-тында эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1944 тән Мәскәү а.х. академиясендә укыта. Фәнни хезмәтләре кәсле-көлсу туфракларда кузаклы культуралар игүдә известь һәм фосфорит онын куллануга карый. А.В.Шестаков (1964); В.М.Клечковский һәм А.В.Петербургский (1975); Б.А.Ягодин (1982) мөхәррирлегендә басылган «Агрохимия» дәреслеге авторларының берсе. 1956–58 дә агрохимия буенча өч томлык монография яза (кытай теленә тәрҗемә ителә һәм КХРда нәшер ителә). «Почёт билгесе» ордены, 12 медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Учебное пособие по анализу ядохимикатов. М., 1954; Люпины. М., 1960; Практикум по агрохимии для старших классов сельских школ. М., 1966.

**ӘСГА́ТЬ МОХТА́Р** (Мохтаров) (23.12.1920, Төркестан АССР, Фирганә ш. — 17.4.1997, Ташкент), язучы, тәрҗемәче, Үзбәкстан ССРның халык язучысы (1980). Үзбәк телендә яза. Урта Азия дәүләт ун-тын тәмамлый (1942, Ташкент). Әндиҗан пед. ин-тында укыта (1942–45), «Ёш ленинчы» (1945–48), «Кизил Ўзбекистон» (1945–60) г-таларында эшли. Үзбәкстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркәтибе була (1957–69). «Шарк юл-

дузи» (1960–65) һәм «Гүлистон» (1969–80) ж-ларының, «Ўзбекистон адабиёти ва санъати» г-тасының (1981–82) баш мөхәррире. Әсәрләре 1938 елдан басыла башлый. Ә.М. — «Булат коючы» («Пўлат куювчи», 1947), «Зур юлда» («Катта йўлда», 1949) поэмалары, «Хөрмәтле кардәшләрем» («Ҳамшаҳарларим», 1949), «Рәхмәт, сөеклем» («Раҳмат, меҳрибоним», 1954), «99 миниатюра» (1962) шигъри җыентыклары, «Елгалар кушылган җирдә» («Дарёлар туташган жойда», 1950), «Каракалпак кыйссасы» («Кора-қалпоқ киссаси», 1958) повестьлары, «Апа-сеңелләр» («Опа-сингиллар», 1955), «Туу» («Туғилиш», 1961), «Дәвер минем тәкъдиремдә» («Давр менинг тақдиримда», 1964), «Чинар» («Чинор», Үзбәкстан ССРның Хәмзә исем. дәүләт бүләге, 1968, татарча басмасы — 1976), «Күзгә йокы кермәгәндә...» («Тундаликлар...», 1997) романнары, берничә пьеса, А.Пушкин, М.Лермонтов, А.Блок, К.Симонов, У.Шекспир, Ф.Шиллер, Софокл әсәрләренең тәрҗемәләре авторы. Үзбәкстанда татар әдәбиятын актив пропагандалаучы буларак, вакытлы матбугатта Г.Тукай, М.Җәлил, Г.Әпсәләмов, Х.Такташ иҗаты турында мәкаләләр бастыра, Т.Тукай (1946, 1961, 1986) һәм М.Җәлил (1958, 1982) шигырьләре җыентыкларын басмага әзерли (төзүче, кереш сүз авторы һәм кайбер шигырьләрнең тәрҗемәчесе). Ә.М. әсәрләре рус, инглиз, белорус, украин, кытай, румын, һинди, урду һ.б. телләргә тәрҗемә ителә.

Ә с ә р.: Танланган асарлар. Тошкент, 1958; Танланган асарлар: 4 томлик. Тошкент, 1971–73; Чинар. К., 1976. *Р.Р.Мусабәкова.*

**ӘСПЕ́** (Asparagus), әспечәләр семьялыгыннан күпьеллык үләннәр, ярымкуаклар һәм лианалар ыругы. 150 ләп төре билгеле, күбесенчә Евразиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — дарулы Ә. (A.officinalis) барлык р-ннарда да очрый. Болыннарда, далалы сөзәклекләрдә, куак араларында үсә. Күпьеллык үләнчел үсемлек, озынлыгы 60–100 *см*. Тамырчасы юан, куе, үрмәле, баусыман өстәмә тамырлары бар. Сабаклары туры. Яфраклары беленер-беленмәс кенә күренә, аксыл, тәңкәсыман, яфрак куентыкларыннан 3–6 шар җепсыман яшел бәбәкләр — кладодийлар үсеп чыга. Ике өйле үсемлек, кайбер бәбәкләрдә ата, ә башкаларында фәкать ана чәчәкләр генә барлыкка килә. Чәчәкләре чагыштырмача зур түгел, сабында 1–2 шәр чәчәк була. Чәчәк тирәлеге кыңгыраусыман, яшькелт. Җимешләре — шарсыман кызыл җиләкләр. Май-июльдә чәчәк ата. Җимешләре август-сентябрьдә өлгерә. Орлыклардан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Составында аксым, углеводлар, төрле витаминнар, шикәр, минераль тозлар булганлыктан, яшь итләч бәбәкләре ашарга яраклы. Тамырча һәм тамырларында сапониннар, кумарин, эфир мае, каротин, өлгергән җимешләрендә шикәр, май, алкалоид билгеләре бар. Халык медицинасында яшь бәбәкләр төнәтмәсе һәм пешкән тамыр суы йөрәк авыртканда, сидек юллары ялкынсынганда кулланыла. Бакчаларда культуралаштырылган формаларын үстерәләр. Баллы үсемлек.

**«ӘСТЕРХА́Н ДӘҮЛӘ́Т ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ»**, сәнгать хезмәткәрләренең айлык нәфис журналы. 1928–29 елларда Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Я.Вәлишин, К.Гобәйдуллин, Ш.Госманов, Ә.Мәҗитов, К.Тинчурин һ.б. авторларның мәкаләләре еш басыла. Журнал театр тормышын, артистларга яшь алмаш әзерләү мәсьәләләрен яктырта, укучыларны яңа спектакльләр б-н таныштыра. Рубрикалары: «Театр тарихыннан», «Репертуар», «Сәхнәдә яшьләр».

**ӘСТЕРХА́Н ӨЛКӘСЕ́**, РФдә урнашкан. Каспий буе түбәнлегенең төньяк-көнбатыш өлешен, Идел-Актүбә тугайлыгын һәм Идел тамагын били. Мәйданы — 44,1 *км²*. Халкы — 1005,3 мең кеше, ш.и. 70,6 мең татар (2002). Үзәге — Әстерхан шәһәре. Ә.ө. — төрки халыклар яшәгән иң борынгы төбәкләрнең берсе. Аның биләмәсе Төрки һәм Хәзәр каганлыкларына, Алтын Урдага, Нугай Урдасына, *Әстерхан ханлыгына* кергән. Урта Идел буе халыклары монда 17 йөздән килеп урнаша башлый. 1722 елда Әстерханда Адмиралтейство төзелү уңаеннан Казан татарларының зур төркеме Каспий буена килеп утыра, икенче өлеше монда 1722–23 тә *Иранга Пётр I яуларында* катнашучылар буларак килеп эләгә. Екатерина II нең Ставрополь төбәгенә халыкны ирекле күчереп утырту турындагы указыннан соң (1782) Ә.ө. терр-ясендә яңа татар авыллары барлыкка килә. 1782–91 дә Буа һәм Тәтеш өязләреннән күчеп утырган халык хәзерге Черноярск р-нының Ташлыяр авылына һәм аның пүчинкәсе Линейный авылына нигез сала. Шул ук чорда Кече Чапурники, Зинзилә, Камыш Борын, Кече Барханчак авыллары барлыкка килә; татарлар ш.у. Сотенный, Средний һәм Казачий (Актүбә р-ны) утарларына килеп урнашалар. 19 йөз башыннан бу өлкәдәге татарлар саны мишәрләр (нигездә, Пенза губернасының Чембар өязе халкы) һәм качкын солдатлар күчеп утыру исәбенә арта. 1830 елларда алар — Бәхтияр, Яңа Әскәр; 1840 елларда Саратов мишәрләре Нариман р-нының Биштүбә, Яңа Күчергән, Лятошинка авылларына нигез сала. 1861 елгы реформадан соң төрекмән авылы Куликовы Копанига Тамбов губернасының Бастан авылыннан (хәзерге Рязань өлкәсе Сасово р-ны) җирсез татар крәстияннәре күчеп утыра. 1864 тә Линейный авылы пүчинкәсе — Төрекмән авылы барлыкка килә. 1918 дә төрле төбәкләрдән күчеп утырган татарлар Яңа Болгар авылына (Икрянин р-ны) нигез салалар. Хәзерге вакытта Ә.ө.ндә 3 татар торак пункты һәм 21 катнаш торак пункт бар. Нариман (гомуми яшәүчеләр санының 22,4%) һәм Идел буе (32,6%) р-ннарында татарлар башка халыклар б-н тупланып яшәсәләр, Актүбә, Черноярск, Икрянин, Лиман р-ннарында алар аерым төркемнәр булып яшиләр. 1917 гә кадәр Әстерхан шул төбәктәге татарларның мәдәни һәм иҗтимагый тормышының төп үзәкләреннән берсе була. Шәһәрдә аерым Казан татарлары бистәсе оеша. 1764–1917 дә *Әстерхандагы Беренче ир балалар гимназиясе* эшли, анда 1789 да татар теле классы ачыла. 1892 дән «Низамия» мәдрәсәсе эшли башлый. «*Азат халык*» (1917–19), «*Ирек*» (1917), «*Ислах*» (1907), «*Тартыш*» (1917–19), «*Идел*» (1907–14; 1991 дән яңадан чыга башлый) г-талары нәшер ителә. «*Азат ханым*» (1917–18), «*Мәгариф*» (1909), «*Туп*» (1907) һ.б. журналлар дөнья күрә. 1907 елдан татар халык театры (к. *Әстерхан татар драма театры*) эшли. 1919 да *Әстерхан татар театр студиясе* оештырыла. 1980 еллар ахырыннан Ә.ө.ндә татар халкының мәдәни традицияләрен яңарту процессы бара. «Дуслык» татар милли-мәдәни җәмгыяте һәм аның каршында «Өмет» яшьләр үзәге (1989 дан), Мөселман мәдәни-хәйрия үзәге (1995 тән), «Кызан», «Ялкын» фольклор ансамбльләре, «Мирас» балалар сәнгать студиясе эшли. 40 мәчет бар. 1990 еллар башыннан «Лотос» телерадиокомпаниясе атна саен татарча «Туган тел» тапшыруы чыгара. 17 мәктәптә татар теле өйрәнелә (1997). 1 нче Әстерхан пед. уч-щесендә һәм Әстерхан дәүләт ун-тында татар бүлеге бар. 1992 елның 30 маенда «Татарстан Республикасы һәм Әстерхан өлкәсе арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешү»гә кул куелды (1997 дә килешүнең срогы озайтылды). Ә.ө.ндә Татар мәдәнияте көннәре уздырылды (1992 нең маенда). 1999 дан Әстерхан б-н Казан шәһәрләре арасында дуслык мөнәсәбәтләрен үстерү программасы гамәлгә ашырыла. *В.М.Викторин.*

**ӘСТЕРХА́Н ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ** (ӘТДТ), 1907 елда һәвәскәр актёрлар түгәрәге буларак оештырыла. Аңа нигез салучылар — З.Садыйкова һәм Г.Коләхмәтов (Гафур *Коләхмәтовның* бертуганы). Халык алдында куелган беренче спектакль — Х.Зәбиринең «Төшенү яхуд указ бәласе» пьесасы. Әстерхан рус драма театры актёры И.Гыйззәтуллин-Дубровин тарафыннан куелган бу спектакль 1907 елның 13 гыйнварында Кышкы шәһәр театры бинасында күрсәтелә. Рольләрне башкаручылар арасында Ш.Гайфи, А.Мәзини, Җ. һәм З.*Байкиннар*, З.*Солтанов* була. Шул ук елның көзендә Г.Камалның «Бәхетсез егет», Я.Вәлинең «Оят, яки күз яше» пьесалары буенча куелган спектакльләр шәһәрнең татар интеллигенциясе һәм рус театры актёрлары тарафыннан хуплап каршы алына. 1908 дә «*Казан-Кавказ мөселман артистлары ширкәте*», «*Сәйяр*» һәм Г.Кариев, Г.Араблинский катнашындагы башка танылган татар театр труппаларының Әстерхандагы гастрольләре Әстерхан театры актёрларының проф. осталыгы үсешенә сизелерлек йогынты ясый, репертуарның баюына ярдәм итә. 1914 тә труппа З.Солтанов җитәкчелегендәге «Татар драма артистлары ширкәте» дип үзгәртелә. 1917 елга кадәр бу театр сәхнәсендә Г.Камал, С.Рәмиев, И.Богданов, Я.Вәли, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, әзәрбайҗан драматурглары Н.Нариманов, С.Ганизадә, Г.Ахвердов пьесалары, рус һәм дөнья классикасы әсәрләре куела. Труппа составында төрле елларда С.Рәмиев, Б.Абдуллин-Нугаев, Х.Туйбахтин, Г.Адаков, Р.Бабаев, Г.Мәхмүдов, Х.Мөхәммәдова, С.Сафиуллина, З.Беляева, М.Даутова һ.б. эшли. 1917 дә Әстерханда ике татар театр труппасы барлыкка килә: беренчесе — составында Г.Уральский, Камал Сәла-

хетдинов (*Камал III*), И.Кугушев, Г.Әлмәшев, Г.Капкаев булган «Мөселман эшче яшьләр драма түгәрәге»; икенчесе — коммерсант Харис Мөхәммәдовның акчалата ярдәмендә яшәгән, составына режиссёрлар сыйфатында Җ.Байкин һәм Г.Адаков, актёрлар С.Байкина, С.Сафиуллина, З.Байкин, М.Даутова, Г.Мәхмүдов, Б.Абдуллин-Нугаев, Х.Таһирова кергән «Мохтарият» (икенче исеме «Бәйсез») труппасы. Спектакльләр Кышкы театр бинасында куела. 1918 дә бу коллективлар базасында Әстерхан татар театры оештырыла. 1919 да З.Солтанов аның каршында *Әстерхан татар театр студиясен* булдыра. Театрда М.Мутин, Камал I, Х.Уразиков, Х.Әбҗәлилов, К.Тинчурин, Ф.Камалова, К.Шамил, Г.Йосыповлар эшли. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Респ-касы төзелү һәм Казанда Беренче үрнәк татар театры барлыкка килү сәбәпле 1920–21 дә Әстерхан театрының күп кенә актёрлары Казанга күчеп китә. 1922–23 тә Г.Уральский, И.Кугушев, Г.Ильясов, Г.Мәхмүтов һ.б. актёрлар ӘТДТга кире кайта. З.Солтанов яңадан театрның сәнгать җитәкчесе була, театрга «Вулкан» кинотеатры бинасы бирелә. 1928 дә театр дәүләт театры статусы ала. 1930 елларда театрда Н.Арапова, Р.Кушловская, Г.Байкина, Г.Йосыпов, Г.Надрюков, Н.Гатин, реж. С.Булатов, Г.Йосыпов һ.б. эшли. Театр репертуарында Г.Камал, Ш.Камал, К.Тинчурин, Т.Гыйззәт, Н.Исәнбәт, Г.Коләхмәтов, А.Н.Островский пьесалары урын ала. 1937 дә театрларның өлкә смотрында ул 2 нче урынны яулый, спектакльләр тамашачы һәм вакытлы матбугатның даими игътибары үзәгендә була. Бөек Ватан сугышы елларында театр труппасы Әстерхан филармониясе каршындагы сәнгать бригадасы дәрәҗәсенә кадәр кыскартыла һәм 1950 еллар башына кадәр шулай эшли. 1959 да Татар халык театры итеп үзгәртелә. Аның труппасында элекке проф. театрның кайбер актёрлары эшли. Халык театры актёрлары арасында: Р.Абдуллаев, Л.Абдуллаева, З.Досаева, Р.Усманов һ.б.

*Әд.:* М ә х м ү т о в Һ. Әстерхандагы татар театры // Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; ш у л у к. Әстерханда татар театры // Мирас. 1994. № 1–3, 7–12; 1995. № 1–8.

*Ю.А.Благов.*

**ӘСТЕРХА́Н ТАТА́Р ТЕА́ТР СТУ́ДИЯСЕ**, татар профессиональ театры өчен актёрлар әзерли торган беренче уку йорты. 1919 елда Әстерхан Мәгариф халык комис-ты карамагындагы Мөселман эшләре бүлеге каршында эшли. *Әстерхан татар драма театры* базасында Г.Айдарскийның актив катнашлыгында оештырыла. Сәнгать җитәкчесе З.*Солтанов*. Педагоглары — реалистик сәнгать мәктәбен үткән, актёр кадрларын тәрбияләүдә тәҗрибә туплаган күренекле рус актёрларының берсе, Әстерхан рус драма театрының баш режиссёры Е.О.Любимов-Ланской һәм шул театрның актёрлары М.А.Кирсанова, К.Г.Решимов, И.Г.Парамонов проф. татар актёрларын тәрбияләүгә нигез салалар. Студияне тәмамлаучылар арасында М.*Даутова*, С.Байкина, Гата *Уральский II*, *Камал III* бар.

**ӘСТЕРХА́Н ТАТАРЛАРЫ́**, татар халкының этно-территориаль бер төркеме. Башлыча *Әстерхан өлкәсендә* яшиләр. Юрт татарлары, кундра татарлары һәм карагашларга бүленәләр (элегрәк «өч йорт», «йемеш» һ.б. исем йөртүче татарлар да булган). Үзара аралашулары уртак татар телендә. Юрт татарлары б-н карагашлар сөйләмендә нугай теле йогынтысы нык сизелә. Мөселман-сөнниләр. Ә.т. этногенезында хәзәр, кыпчак, нугай, Азов төбәге болгарлары, төркиләшкән татлар, Урта Азиядән чыккан төркиләр һәм Һинд-Европа тел берлегенә керүче кабиләләр катнашкан. Ә.т.ның оешу процессында Алтын Урда дәүләте, ул таркалгач барлыкка килгән *Әстерхан ханлыгы* һәм *Нугай Урдасы* мөһим роль уйнаганнар. Ә.т. этнокультурасы үсешендә ш.у. Идел-Урал төбәге татарларының



Әстерхан татарлары гаиләсе. Рәссам Муане. 1858.

да өлеше зур була. Аларның Әстерхан губернасына күпләп күченүләре 17 йөз — 20 йөз башына туры килә. Идел-Урал төбәгеннән чыккан татарлар бу губернада 18 йөз ахырына 13,2% булса, 19 йөзнең 30 нчы елларында 17,4%, 20 йөз башына андагы татарларның өчтән бер өлешеннән күбрәген тәшкил иткән.

19 йөзнең 2 нче яртысыннан Идел-Урал төбәге, Себер һәм Ә.т. арасындагы уртаклык һәм якынлык бердәм татар халкын барлыкка китерә (к. *Татарлар*).

Ә.т.ның төп хуҗалык итү тармаклары үзенчәлекле климат шартларында яшәүгә бәйле: Әстерхан өлкәсенең көньягында алар, башлыча, мал асрый, бакчачылык-яшелчәчелек һәм балык тоту б-н шөгыльләнә. Өлкәнең төньягында, нигездә, Идел-Урал төбәгеннән күченгән татар авылларында, игенчелек алга киткән. Игенчелектә беренче урында тары, аннары бодай, арыш, солы игелә. А.х.нда ат һәм үгез кулланыла. Көлтәләрне элек ат яки үгездән таптатып суктырганнар. Яшелчәлектә төп культуралар — карбыз б-н кавын, бакчачылыкта йөзем һ.б. культуралар үстерелгән. Яшелчә һәм бакча җирләре башлыча сугарылулы булган. Ә.т.ның иң әһәмиятле хуҗалык тармагы булып мал үрчетү санала. Ат, дөя, сарыклар ел әйләнәсе көтүлекләрдә асралган. Хуҗалык эшендә күбрәк дөя һәм үгезләр файдаланылган. Йорт кошлары чагыштырмача аз үрчетелгән. Идел елгасы тармаклары һәм Каспий диңгезе буенда яшәүчеләр балыкчылык б-н көн күргән. Балыкны, аның уылдыгын Әстерханга яисә Ставропольгә илтеп сатканнар, аннан ашлык, он, башка кирәк-яраклар алып кайтканнар. Ә.т.ның бер өлеше көймә ясау һәм төзекләндерү остаханәләрендә, тоз чыгару, тире иләү, күн әйберләр җитештерү артельләрендә эшләгән. Бөлгәннәре баерак авылдашларына яки күрше рус авылы крәстияннәренә ялланган, Каспий буе балык тоту, Бакудагы нефть чыгару промыселларында эшләгән. Ә.т. авыллары аерым урам-тыкрык тәртибендә төзелгән, йорт-куралар иркен итеп, зур гаиләләргә һәм ишле мал-туарга исәп тотып корылган (бер йортта яшәүчеләр саны 20–25 кешегә җиткән). Бай гаиләләр җәйләүләрдә дә утарлар тоткан, үзләре һәм ялчылары шунда мал-туар асраган яки яшелчә үстергән, бакчалар тоткан. Губернаның төньяк һәм төньяк-көнбатыш тарафындагы Ә.т. күрше рус казаклары, калмыклар б-н аралашкан, алыш-биреш иткән. Көтүлекләрдә, яшелчә бакчаларында эшләүчеләр вакытлыча гади шалашларда (хаша) яки киез тирмәләрдә яшәгән. Карагашлар, кундра татарлары 20 йөз башына кадәр ярым күчмә тормыш иткән. Аларның кышкы тораклары да еш кына эчтән-тыштан балчык б-н сыланган, камыштан үрелгән яки җиргә казып эшләнгән. Казанлык-учаклар өйләрдән бераз читтәрәк, ишегалдында корылган, башка төр каралты-кура, келәт ише корылмалар булмаган диярлек. Мал-туар өчен кишәрлекләр киртәләнгән. Карагашлар ипи-күмәчне, башлыча, тандырда (җиргә казып эшләнгән мичтә) пешергән. Ә.т.ның кышкы өйләре нигездә бүрәнәдән, кайбер очракларда саман кирпеченнән төзелгән, өй эчендә казанлы аерым учагы булган татар миче чыгарылган. Өй җиһазлары: өстенә киез яки юка тукыма палас, камыш җәймә җәелгән сәке, тәбәнәк өстәл (куна), такта киштәләр, сандык, *чаршау* кашагалар, *чыбылдык*, тәрәзә пәрдәләре (фәрлә), чигүле сөлгеләр. Баерак гаиләләрдә келәмнәр һ.б. булган.

Ә.т.ның һәр төркеме үзенчәрәк киенә һәм бизәнү әйберләре куллана. 19 йөз ахыры — 20 йөз башыннан мондый үзгәлек хатын-кыз киемендә генә саклана. Карагаш хатын-кызларының өске киеме киң җиңле халат (каптал) яки җиңсез халат рәвешендә (казаки каптал) була. Киң таралган баш киеме — *тастар*; кызлар, гадәттә, 2 яулык яба, аскы яулыкның бер очы арканы каплап тора, өске яулыкның очлары баш түбәсендә бәйләнә. Карагаш кызларының туй киеме: өстен шлауш яки кимешәк, күп кенә асма металл бизәкләрдән торган баш бәйләвече (мөезбек), гадәттә, чигүле яки аппликацияле, цилиндр рәвешле, тукымадан тегелгән биек баш киеме (саукеле) һәм аның өстенә бөркәнелгән тастар. Юрт татар кызларының бәйрәмчә баш киеме — түгәрәк биек кандыз бүрек, өсте күннән. Ә.т., гадәттә, сары сафьян итек (читек) кия, итек балтыры ука тасма б-н каймалана яки бәрхеттән эшләнә. Казан татарлары кигән *читек* һәм *калфаклар*, башлыча, 19–20 йөз арасында шәһәрдә яшәүче Ә.т.на гына хас була. Ә.т. киеменең тагын бер үзенчәлеге — төрле бизәнү әйберләренең, аеруча металлдан


эшләнгәннәренең күплегендә. Идел-Урал төбәге татарларыннан аермалы буларак, Ә.т.нда үзенчәлекле асылма чигәлекләр, муен, күкрәк каплавычлары кулланыла. Бер үк әйберләрнең кулланылышы дә үзгәрәк. Мәс., түгәрәк колак алкалары йөз алкасы буларак та йөртелә (борынга киертелә), чәчүргечләрне фәкать кызлар гына куллана; затлы металл кисәкләре беркетелгән тукыма билбауларны (кысак) хатын-кызлар да, ирләр дә бәйли.

Ә.т.ның иң олы бәйрәмнәре — Ураза бәйрәме һәм Корбан бәйрәме. Яңа ел бәйрәме *Нәүрүзне* алар «әмәл» дип атыйлар һәм иске стиль буенча 10 мартта, язны каршылау бәйрәме б-н бергә үткәрәләр: кырга чыгып намаз укыйлар, йола боткасы пешереп ашыйлар, ат чабышлары, көрәш оештыралар. Кайбер мишәр гаиләләре исә язын, пасханың беренче көненә туры китереп, «Кызыл йомырка» бәйрәмен, көзен, карбыз уңышы җыеп алынгач (һәм сатылгач), «Зиярәт бәйрәме»н уздыралар. Бу көндә ир-атлар җыелышып зиратка килә; «зиярәт намазы» укыла, аннан соң авылда күмәк бәйрәм табыны уздырыла; төрле ярышлар: ат чабышлары, көрәш, капчык киеп чабу уеннары үткәрелә; гармун (саз), думбра, скрипкада (нәхрада) уйнау, күмәкләп җырлау, шөлдерле барабанны кага-кага биюләр башлана, мылтыктан һавага атулар кабатланып тора. Ә.т. ризыкларында ит, күбрәк сарык ите, балык, яшелчә өстенлек итә. Бәйрәм табынына пылау китерелә һәм камырдан әзерләнгән төрле ризык куела.

Элегрәк заманнарда Ә.т., башлыча, үз этник төркемнәре вәкилләре б-н никахлашуны хуп күргән. Туй алды һәм туй йолалары барлык төркемнәрдә дә диярлек бертөрлерәк булган. Ләкин үзенчәлекләр дә күзәтелгән: карагашларда калым күләме зуррак булган, яшьләрнең беренче кавышу төнен уздыру өчен кыз атасы аерым ак тирмә (үргә, карачүй) куйдырган. Кундра һәм юрт татарларында исә булачак килен иренең туганнарының кулын үбәргә тиеш булган. Аларда



Карагаш татарлары киеме.
19 йөзнең 2 нче яртысы.
Әстерхан тарих-архит-ра музей-саклаулыгы.



Әстерхан татарлары киеме. 19 йөзнең 2 нче яртысы.
Әстерхан тарих-архит-ра музей-саклаулыгы.

туй табынына башта пылау яисә итле дөге бәлеше (нугай бәлеше) куелган. Юрт татарларында яшь килен, Урта Идел буе татарларындагы кебек үк, ир йортына керер алдыннан учак аша сикереп чыгарга («пакьләнергә») тиеш булган.

Хәзерге вакытта Ә.т.ның гореф-гадәтләре, культура һәм хуҗалык итү традицияләре нык үзгәрә. 1930 еллардан башлап руслашу күренешләре күзәтелә. Ул күренеш аеруча 1960–80 елларда үзен нык сиздерә. Көнкүрештәге зур үзгәрешләр урбанизация нәтиҗәләре б-н дә бәйле. 1990 еллардан Ә.т.ның этномәдәни традицияләре яңадан торгызыла башлый.

*Әд.:* Р ы ч к о в П. Введение к Астраханской топографии. М., 1774; Г м е л и н С.Г. Путешествие по России для исследования трёх царств природы. Путешествие от Черкасска до Астрахани и пребывание в сем городе. СПб., 1777. Ч. 2; Г е о р г и И.Г. Описание всех обитающих в Российском государстве народов. О народах Татарского племени. СПб., 1799. Ч. 2; Ф а в и н с к и й. Хозяйственное описание Астраханской и Кавказской губерний по гражданскому и естественному их состоянию в отношении к земледелию, промышленности и домоводству. СПб., 1809; Р ы б у ш к и н М. Записки об Астрахани. М., 1841; Н е б о л ь с и н П.И. Инородцы Астраханской губернии: Заметки о кундровских татарах // Вестн. Русского геогр. об-ва, 1851. Ч. 2; ш у л у к. Очерки Волжского низовья. СПб., 1852; Г а д ж и е в а С.Ш. Материальная культура ногайцев в XIX — начале XX вв. М., 1976; Астраханские татары. К., 1992.

*Ф.Ф.Гулова.*

**ӘСТЕРХА́Н ХАНЛЫГЫ́**, урта гасырлар татар феодал дәүләте. Алтын Урда дәүләте таркалуы дәверендә үзәге Хаҗитарханда булган олыс һәм аңа чиктәш төбәкләр җирлегендә 1460 елларда барлыкка килә. Олысның мөстәкыйльлеккә йөз тотуы беркадәр иртәрәк, Хаҗитархан идарәчәсе *Мостафа* үз исеменнән акча суктыра башлаган дәвердән (1430 еллар ахыры — 1443) күзәтелә, әмма Мәхмүтнең (1508) улы Әбделкәрим вакытында мөстәкыйль дәүләт булып әверелә. Башкаласы — Хаҗитархан шәһәре. Биләмәсенә Түбәнге Идел буе һәм Каспийның төньяк-көнбатышындагы өлешчә дала як һәм уң яр буе төбәкләре кергән. Төп халкы татарлар һәм нугайлар (к. *Әстерхан татарлары*); алар күчмә тормыш алып баручы аксөякләргә (хан, солтан, әмир, бәк, морзалар) һәм салым түләүче *кара халык*ка бүленгән. Халкының төп шөгыле: күчмә терлекчелек, һөнәрчелек һәм сәүдә итү. Ханлык б-н идарә итү рәвеше Алтын Урда чоры тәртипләренә нигезләнә: баш хөкемдар — хан, ул хан диванына кергән карачы бәкләр ярдәмендә идарә итә. Хәрби хезмәттә торучы аксөякләр һәм дин әһелләре үз вазифаларын үтәү һәм үз җир биләмәләре кереме исәбенә яшиләр. Дәүләт дине — ислам.

Ә.х. ш.у. Казан ханлыгы, рус кенәзлекләре сәүдәгәрләренең Урта Азия, Кавказ арты илләре һәм гарәп илләре б-н алып барган сәүдәсеннән дә беркадәр керем алган. Ханлык биләмәсенең зур булмавы һәм бәк-морзаларның үзара тынышып тормавы аркасында, Ә.х. көчле күршеләреннән бәйлелеккә эләгә. 1470 елларда Ә.х. Олы Урда ханнары йогынтысын кичерә. 16 йөз башында *Миңлегәрәй* хан Олы Урданы тар-мар иткәч, Ә.х. Кырымга йөз тотарга мәҗбүр була. Ханлык эшләренә Кырым ханнары да, нугай бәкләре дә тыкшына. 16 йөзнең 30 нчы елларында Әстерхан ханнары Казан ханлыгына Рус дәүләтенә каршы көрәштә ярдәм итәләр, нугайлар һәм Кырым татарлары рус җирләренә яу чапканда катнашалар. Кырым ханнары басымына каршы тору өчен Ә.х. ханнары, Казан, рус кенәзлекләре һәм Төркия б-н килешү төзергә омтылып карасалар да, уңышка ирешә алмыйлар. 1533 елда *Габделрахман хан* Рус дәүләте б-н килешү төзи. 1547 дә




Кырым ханы Сәхибгәрәй, Ә.х.ын руслар йогынтысыннан йолып алу нияте б-н, Хаҗитарханга һөҗүм итә, 1546 да тәхеткә утырган Ямгурчы ханны куып җибәрә. Ямгурчы Ә.х. тәхетенә кабат 1550 дә утыра. Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң (1552), Нугай Урдасы б-н Ә.х.нда русларга йөз тотучы көчләрнең йогынтысы көчәя. 1554 дә кенәз Ю.И.Шемякин җитәкчелегендәге рус гаскәре нугайлар б-н берлектә Хаҗитарханны сугышып ала. Ямгурчыны тәхеттән төшереп, русларга йөз тотучылар Дәрвиш Галине хан итеп билгелиләр. 1555 тә Дәрвиш Гали, Кырым йогынтысына бирелеп, Рус дәүләтенә каршы чыга. Кырым ханлыгының ярдәменә (700 кырым татары һәм 300 төрек янычары, туплар, пищальләр) карамастан, 1556 да И.Черемисин һәм М.Колупаев җитәкчелегендәге стрелецлар һәм казаклар гаскәре Хаҗитарханны басып ала һәм, Ә.х. Рус дәүләтенә буйсындырыла.

Ә.х. ханнары: Мәхмүд (1460–1470), Касыйм (1470–1508), Габделкәрим (1508–1514),

Җанибәк (1514–1521), Шәех Әхмәд (1521–1525 яки 1528), Касыйм (?-1532), Исламгәрәй (1531–32), Ак Күбәк (1532–33, 1545–46, 1550–51), Габделрахман (1533–37, 1539–45), Ямгурчы (1546–50, 1551–54), Дәрвиш Гали (1537–39, 1554–56).

Чыг.: Полное собрание русских летописей. М., 1965. Т. 13–14.

*Әд.:* Смирнов Н.А. Россия и Турция в XVI–XVII вв. М., 1946. Т. 1; Кушева Е.Н. Народы Северного Кавказа и их связи с Россией. М., 1963; Степанов И.В. Астраханское ханство // БСЭ. 3 изд. М., 1970. Т. 2; Алишев С.Х. Завоевание татар Русским государством // Материалы по истории татарского народа. Казань, 1995; Трепавлов В.В. История Ногайского ханства. М., 2001; Мухамедьяров Ш.Ф. Астраханское ханство // Очерки распространения исламской цивилизации. М., 2002. Т. 2; Зайцев И.В. Астраханское ханство. М., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**ӘСТЕРХАНДАГЫ́ БЕРЕНЧЕ́ ИР БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ** (1912 елга кадәр Әстерхан гимназиясе), 1788 елдан эшләп килүче әсасый халык уч-щесе җирлегендә 1806 да ачыла. 1835–43 тә директоры М.С.*Рыбушкин* була һәм гимназияне Идел буенда иң алдынгы гимназияләрнең берсенә әверелдерә. 1890 га кадәр аны ел саен 3–9 кеше генә тәмамлый, 1900 елларда чыгарылыш 20 кешегә җитә. Халыкның милли составына бәйле рәвештә, укучыларның күпчелек өлешен әрмәннәр һәм калмыклар тәшкил итә, 20 йөз башыннан казакъ һәм Әстерхан татарлары да (һәр елны 1–2 кеше) була.

Әсасый халык уч-щесендә татар («төрек») теле 1788–99 да, гимназиядә 1817–21 дә һәм 1832–65 тә өйрәнелә (1833–64 тә аны М.*Бердиев* укыта). 1817–65 тә укучылар фарсы телен дә өйрәнәләр. Гимназияне тәмамлаучылар арасында тюрколог Л.З.*Будагов*, астроном И.М.*Симонов*, педагог И.Н.*Ульянов* кебек күренекле кешеләр дә бар.

*Әд.:* Остроумов Т. Исторический очерк Астраханской 1-й мужской гимназии за время с 1806 по 1914 год. Астрахань, 1916.

**ӘСФӘНДИЯ́РОВ** Закир Лотфирахман улы (20.12.1918, хәзерге Башкортстан Респ-касының Гафури р-ны Үтәк а. — 4.1.1977, Казакъстан ССРның Балхаш ш.), Сов. Союзы Герое (1.7.1944), өлкән сержант (1944). 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1943 елның июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 322 нче гв. танкка каршы артиллерия полкында туп командиры (Балхаш шәһәр советы исем. 8 нче танкка каршы артиллерия бригадасы). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Украина, Польша, Чехословакияне азат итү сугышларында, Берлин операциясендә (1945) катнаша. Черкасск өлкәсенең Монастырищенский р-ны Цибулёв авылы (Укр. ССР) янында барган сугышта батырлык күрсәтә. 1946 дан запаста. Көнчыгыш Коңгырад посёлогында эшли. Балхаш шәһәренең мактаулы гражданы. Ленин, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2; Ракипов Ш.З. Хранить вечно. К., 1980.

**ӘСФӘНДИЯ́РОВ** Рөстәм Измаил улы (18.9.1937, Әстерхан ш.), анатом, мед. фән. д-ры (1974), проф. (1975). Әстерхан мед. ин-тын тәмамлый (1960). Шунда ук анатомия кафедрасында эшли. 1983 елдан Әстерхан мед. академиясенең анатомия каф. мөдире. Ә.ның тикшеренүләре нормаль онтогенез этапларында һәм атмосферада күкерт микъдары күп тапкыр артканда әгъзалар һәм тукымаларның структур үзгәрешенә карый. Сулыш алу һәм кан әйләнеше әгъзаларының критик формалашуын ачыклый. Кеше һәм хайваннарның артериаль системасында кан агышының бөтерелеп әйләнешен китереп чыгара торган кан тамырлары системасы төзелешен алдан билгеләү турында фикер әйтә. Йөрү-хәрәкәтләнү аппаратындагы тумыштан килгән деформацияләрнең экспериментал ь моделен ясый (1972). «Экологик морфология» фәнни юнәлеше җитәкчеләреннән берсе. Әстерхан өлкәсе Вәкаләтле җыенының 1 нче, 2 нче чакырылыш (1994–97 һәм 1997 дән) депутаты (социаль, сәясәт комиссиясе рәисе).

Хезм.: Врождённый вывих бедра в свете анатомо-эмбриологических исследований. Астрахань, 1974.

**ӘСФӘНДИЯ́РОВА** Шаһсәнәм Ибраһимбәк кызы (8.2.1926, Үзбәкстан ССРның Термез ш. — 27.10.1996, Казан), драма актрисасы, педагог, ТАССРның халык, РСФСРның атказ. артисты (1970, 1977). Ташкент хореография уч-щесен тәмамлаганнан соң (1940), Нәвои исем. опера һәм балет театрында эшли, 1942–43 елларда Казан муз. уч-щесендә, 1944–49 да Театр сәнгате дәүләт ин-тының (ГИТИС, Мәскәү) Татар студиясендә укый. 1949 дан Казан Яшь тамашачылар театрының татар труппасында, 1950 дән Татар акад. театрында. Татар сәхнәсенең атаклы осталары традицияләрен дәвам иттерүче, әйдәп баручы актрисаларның берсе. Ә. иҗатына образны индивидуальләштерү, характерны бөтен тирәнлеге б-н ачарга омтылу, тышкы бизәкләрне төгәл бирергә тырышу, көчле хисси характер хас. Аның иҗат колачы гаять киң. Ә. хискә бирелүчән Луиза образын да («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер, 1950), үзе чая, үзе тәвәккәл Надежданы да («Соңгылар», М.Горький, 1952), көчле сатирик пландагы Эсмеральда («Зифа», Н.Исәнбәт, 1954), Дилбәр («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин, 1958),



З.Л.Әсфәндияров.



Ш.И.Әсфәндиярова.

Лидия («Котырган акчалар», А.Н.Островский, 1962) образларын да бер үк дәрәҗәдә ышандырырлык итеп башкара. Актрисага зур уңыш китергән рольләрнең берсе — Ч.Айтматовның «Кызыл яулыклы гүзәлкәем» (1966) повесте буенча куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендәге Хәдичә образы. Рухы сындырылган, ләкин бирешмәгән хатын-кызның нечкә күңеле Ә. тарафыннан хисләрнең бай төсмерләре аша ачыла (ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1967). Хатын-кыз язмышы һәм хатын-кыз характеры темасын үстереп һәм баетып, Клея («Эзоп», Г.Фигейреду, 1967), Юлия Тугина («Соңгы корбан», А.Н.Островский, 1968) рольләре б-н актриса югары осталыкка ирешә. Шул ук вакытта ул якты, ачык театраль формаларга омтыла, бу бигрәк тә көлкеле рольләр уйнаганда сизелә. Персонажның эчке дөньясын бөтен нечкәлекләре б-н тәфсилләп ачып, Ә. үз геройларының һәр гамәлен дәлилли. Тормышчанлык Ә. тудырган образларда лирик дулкынлану күтәренке, романтик хисләр б-н табигый рәвештә үрелеп бара. 1965–96 да Казан консерваториясендә һәм 1962–91 дә Казан театр уч-щесендә укыта.

Башка рольләре: Дездемона («Отелло», У.Шекспир), Хупҗамал («Без аерылышмабыз», Ш.Шаһгали), Мәрҗән («Гөлҗамал», Н.Исәнбәт), Татьяна («Дошманнар», М.Горький), Огудалова («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский), Калугина («Хезмәттәшләр», Э.В.Брагинский, Э.В.Рязанов), Песочинская («Сагыш», А.Галин).

*Әд.:* Камалетдинова Р. Шаһинәлек: Иҗат портреты // Сөембикә. 1996. № 3; Әхмәтова Ч. Шаһа апа // Шәһри Казан. 1996. 8 март; Сагындыра // Татар иле. 2001. 7 февр.; Шакиржано-






Ш.И.Әсфәндиярова Эсмеральда («Зифа», Н.Исәнбәт) (сулда), Клея («Эзоп», Г.Фигейреду) рольләрендә.



Г.Ә. Әсхәдуллин.



Ф.Ф. Әсхәдуллин.

ва Л. Сагыну // Шәһри Казан. 2006. 17 февр.; Гыйманова Д. Сәхнә таҗын кигән Шаһа // Мәдәни җомга. 2006. 3 март; Народные артисты. К., 1980; Иллялова И. Артисты театра им. Г.Камала. К., 1996.

*И.Иллялова.*

**ӘСХӘДУ́ЛЛИН** Галимулла Әсхәдулла улы (14.4.1928, Арча кантоны Мирҗәм а.), фрезерчы, Соц. Хезмәт Герое (1974). 1974–89 елларда С.П.Горбунов исем. Казан авиация җитештерү берләшмәсендә эшли. Герой иселме самолёт төзелеше өлкәсендәге югары унышлары, югары хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эшләп чыгару нормаларын яхшы сыйфат б-н һәрвакыт арттырып үтәве, технология процессларын камилләштерүе өчен бирелә. СССР ЮС депутаты (1974–84). Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Низамов И. Асхадуллин Галиулла Асхадуллович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1980; Промышленность и рабочий класс Татарии. К., 1986; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой славы — наши земляки. К., 2003.

**ӘСХӘДУ́ЛЛИН** Фидус Фәез улы (12.12.1941, Башкортстан АССРның Яңавыл р-ны Яңавыл пос.), атом пар җитештерү җайланмаларына хезмәт күрсәтү остасы, Соц. Хезмәт Герое (1977). 1964–2004 тә Мурманск диңгез пароходчылыгында. Герой исеме Төньяк полюс тирәсенә «Арктика» атом бозваткычының эксперименталь рейсын әзерләү һәм тормышка ашыруда күрсәткән хезмәтләре өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘТӘМБИ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ютазының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,8 *км*, бассейнының мәйданы 56,4 *км²*. Ютазы р-нында Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елга башы Ташкичү авылыннан 2,8 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Иске Урыссу авылыннан 1,2 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 275 *м*, тамагыныкы — 105 *м*. Су җыелу мәйданынының урманлылыгы 21%. Ә. елгасының 6 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1–0,25 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 60 *мм*, ташу агымы катламы 40 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга, ка-гыйдә буларак, ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 *м³/с*. Үрге агымында елга кибә. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Елгада күләме 303 мең *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**ӘТӘ́С** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шәбез елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 191 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1831 елгы мәгълүматларга караганда, Ә. тә мәчет була. 1884 тә авыл җәмәгатенең имана җире — 2456, 1896 да — 2810, 1913 тә 2181 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 208, 1834 тә — 400, 1859 да — 560, 1897 дә — 565, 1906 да — 736, 1913 тә — 644, 1920 дә — 527, 1926 да — 441, 1938 дә — 395, 1949 да — 259, 1958 дә — 251, 1970 тә — 259, 1979 да — 248, 1989 да — 198 кеше.

**ӘТӘ́Ч ГӨМБӘЛӘРЕ́** (Cantharellus), әтәч гөмбәләре семьялыгыннан эшләпәле гөмбәләр ыругы. 70 ләп төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралганнар. ТРда бер төре — сары, яки гади Ә.г. (C. cibarius) очрый. Ылыслы һәм яфраклы урманнарда төркем-төркем булып, сирәк кенә ялгыз үсә, июльдән октябрьгә кадәр очрый. Каен, чыршы, нарат б-н микориза хасил итәләр. Эшләпәсе йомырка сарысы төсендә, диаметры 4–10 *см*, яшь вакытта кабарынкы, соңрак батынкы, бүрәнкәсыман, төбенә бик нык бореккән. Эшләпәсенең аскы ягында юан, дихотомик тармакланган җыерчыклары, төбенә таба кими бара. Йомшагы аксыл, резинкасыман сыгылмалы. Сабы цилиндрсыман, күп очракта төбенә таба тарайган, тоташ, шома, эшләпәсе б-н бер төсле, озынлыгы 3–5 *см*, калынлыгы 0,5–1,5 *см*. Споралары төссез. Хуш исе һәм «кортламавы» б-н аерылып тора. Бик күп күләмдә B, һәм $PP_1$ витаминнары, микроэлементлар бар. Ашарга яраклы.

**ӘТӘ́Ч САЗЫ́**, Көнбатыш Кама алдындагы күл. Нокса б-н Мишә елгалары арасында, Питрәч р-нының Көек авылыннан 0,8 *км* көньяктарак урнашкан. Су өслеге мәйданы 2,4 *га*, шуның 0,68 гектарын йөзмә утрау алып тора. Күләме 40 мең *м³* чамасы. Озынлыгы 250 *м*, иң киң җире 140 *м*, уртача тирәнлеге 1,4 *м*, иң тирән урыны 2,5 *м*. Ясалуы — карстлы-суффозион. Формасы озынча түгәрәккә якын. Көнбатыш яры биегрәк. Тирә-яны урыны-урыны б-н сазланган. Атмосфера явым-төшемнәре һәм грунт сулары исәбенә туена. Суы гидрокарбонат-хлорид-натрийлы, бик йомшак, аз минеральләшкән. Хуҗалык-көнкүреш һәм ял итү максатларында файдаланыла.


**ӘТНӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Ашыт елгасының (Иләт елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 8,4 *км*, бассейнының мәйданы 34,7 *км²*. Әтнә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Кече Әтнә авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы Олы Әтнә авылыннан 3,5 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 102 *м*. Елганың су җыелу терр-ясендә урман үсемлекләре очрамый диярлек. Ә. елгасының 2,4 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1–0,25 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык кимүе б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 161 *мм*, ташу агымы катламы 140 *мм*. Елга тамагында урта биеклектәге суларның уртача күпьеллык чыгымы 0,006 *м³/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**ӘТНӘ́** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 38 *км* төньяктарак, Киров өлкәсе чигендә. 2002 елда 282 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 1782 дә Олы Әтнә авылы кешеләре нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1036 дис. тәшкил итә. 1897 дә Ә.дә мәчет төзелә, 1910 да мәктәп ачыла. 1931 дә «Кызыл маяк» к-зы оештырыла, 1959 дан ул — «Кама» к-зы бүлекчәсе. 1990 нан Ә. «Авангард» (1997 дән — җитештерү кооперативы) к-зы составында. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Шода волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1795 тә — 99, 1834 тә — 180, 1859 да — 327, 1920 дә — 912, 1926 да — 879, 1938 һәм 1970 тә — 307, 1979 да — 249, 1989 да — 247 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**ӘТНӘ́ РАЙОНЫ́**, ТРның төньяк-көнбатышында урнашкан. Мари Респ-касы б-н чиктәш. Казан икътисади р-нына керә. Мәйданы — 681,4 *км²*. 12 авыл җирлеген, 46 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Олы Әтнә авылы. Халкы — 2006 елда 13,9 мең кеше (татарлар). Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км²* га 22 кеше. Район 1930 ның 10 августында Тукай р-ны буларак оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Казан һәм Краснококшай (1919 га кадәр — Царёвококшай) өязләренә, 1920–30 да ТАССРның Арча кантонына керә. Оешкан вакытында районга 58 авыл советы,

61402 кеше (татарлар — 60333, руслар — 1069) яшәгән 81 торак пункт керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 елның 10 февралендә терр-ясе Тукай (1938 нең 25 мартыннан — Әтнә) һәм Кызыл Юл (үзәге — Яңа Кенәр а.) р-ннарына бүленә. 1940 та Ә.р.ның мәйданы — 676 *км²*, халкы — 36,7 мең кеше, 28 авыл советы, 54 торак пункт була. 1959 ның 12 октябрендә Ә.р. Тукай (1956 ның 18 июленә кадәр — Кызыл Юл) р-ны б-н кушыла (район үзәге — Олы Әтнә а.). ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Тукай р-ны таркатыла, биләмәсе Арча р-нына бирелә. 1990 ның 25 октябреннән Ә.р. — яңадан мөстәкыйль адм. берәмлек. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль р-н дип үзгәртелә. Рельефы — калкулы тигезлек (уртача биеклеге — 210 *м*), шактый эрозияләнгән һәм ергаланган. Ашыт елгасы һәм аның кушылдыклары Үртәм, Шашы, Симет елгалары ага. Җире күбесенчә аксыл-соры




урман һәм кәсле көлсу туфраклы. Терр-ясенең 3,4% ы урманнар б-н капланган. Балчык, бут ташы, известьташ һәм торф ятмалары бар. Аеруча саклаулы табигать терр-ясе — Ашыт елгасының югары агымы буендагы тугай. Ә.р. — нигездә, а.х. р-ны. Мөгезле эре терлек һәм сарык асрау тармаклары нык үскән. 2005 тә а.х. җирләре 59,7 мең *га* били, ш.и. 48,4 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак игелә; бәрәңге үстерелә. 2005 тә районда 15 а.х. пр-тиесе, ш.и. 1 совхоз, 13 а.х. товарлары җитештерү кооперативы, җаваплылыгы чикләнгән оешма исәпләнә. Район үзәгендә сәнәгать пр-тиеләре урнашкан. Ә.р. җиреннән Казан–Олы Әтнә һәм Олы Әтнә–Арча автомобиль юллары уза. Районда 35 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 1905 укучы укый), ш.и. 21 башлангыч, 4 тулы булмаган урта, 10 урта мәктәп; Тукай а.х. техникумы, 19 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, Әтнә халык театры, 42 клуб, 20 китапханә, 154 урынлы хастаханә эшли. Татарча «Әтнә таңы» г-тасы нәшер ителә.

**ӘТРӘКЛЕ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 36 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мөшек елгасының сул кушылдыгы Әтрәкле янында. 2002 елда 296 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1703 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1773–75 елгы крәстияннәр сугышында Ә. авылының 32 кешесе баш күтәрүчеләр ягында старшина Өметкул Тәфкилев отрядында сугыша. Чыганакларда мәчет турында беренче тапкыр 1836 да искә алына, аның каршында мәктәп эшли. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.дә 2 су тегермәне була. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире — 6379, 1913 тә 3714 дис. тәшкил итә. 1920 елларда Ә. авылы халкының бер өлеше Яңа Әтрәкле (хәзерге Мөслим р-ның Ташъелга а.) авылына күчеп утыра. 1929 да «Кызыл Тау» артеле оештырыла, 1930 да ул колхоз итеп үзгәртелә. 1951 дә Ә. халкы эреләндерелгән «Урал» к-зы составына керә. 1918 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда. 1918–20 дә — шул ук өязнең Әтрәкле волосте үзәге. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 233, 1859 да — 643, 1870 тә — 752, 1884 тә — 893, 1897 дә — 993, 1906 да — 1051, 1913 тә — 1227, 1920 дә — 1094, 1926 да — 545, 1938 дә — 517, 1949 да — 328, 1958 дә — 347, 1970 тә — 401, 1979 да — 355, 1989 да — 262 кеше.

**ӘТРӘ́Ч КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Тәтеш р-ны Олы Әтрәч авылы янындагы археологик тупланма. Ә.к. истәлекләре 19 йөзнең 2 нче яртысында табыла, беренче тапкыр 1949 елда Н.Ф.Калинин тарафыннан тикшерелә. Ә.к.на Идел буе Болгары, Алтын Урда заманнарыннан калган авыллыклар, каберлекләр һ.б. археол. истәлекләр керә. Ә.к.ның нигезен «Мең өйле Шунгат» исемле болгар авыллыгы һәм 14 йөзнең 1 нче яртысына караган каберләр сакланган «Изгеләр каберлеге» тәшкил итә. Ә.к. мәйданында җучиләр дәвере акчалары хәзинәсе, алтын-көмештән эшләнгән зәркәнчелек әйберләре табыла.

*Әд.:* Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ КФАН СССР за 1945–1952 гг. К., 1954; Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье. К., 1985.


**ӘУЛИ́Я** (гарәп. أولياء — вәли сүзенең күплек саны — изге). Коръәндә «үз канаты астына алу», «кемнеңдер яклавында булу», хәдисләрдә — Аллаһка «якын булу» мәгънәсендә кулланыла. 9–11 йөз суфичылык әдәбиятында Ә. образы дини йолалар башкаруда һәм Коръән гыйлемендә камиллеккә ирешкән зат буларак сурәтләнә; Ә.ләргә иң яшерен серләр (әл-гайб) билгеле һәм Аллаһны күрү мөмкинлеге бирелгән, дип исәпләнелә. Ш.у. аларда изгелек һәм пәйгамбәрлек (нүбүвват) сыйфатлары булуы да мөмкин дип каралган. Әл-Гарәбинең изгелек — пәйгамбәрлекнең бер чагылышы, изгенең пәйгамбәрлеккә ия булуы да, булмавы да мөмкин, пәйгамбәр исә һәрвакыт изге, дигән өйрәтүе киң таралган.

Гади халык арасында Ә.ләр могҗиза иясе, *бәрәкәт* алып килүче, яклаучы, эштә уңыш китерүче буларак хөрмәт казаналар. Халыкка якын торулары, башка диннәргә ихтирам б-н караулары, гомерләрен дәрвишлектә үткәрүләре сәбәпле, Ә.ләр еш кына рәсми дин әһелләренә караганда зуррак абруйга ия булалар. Алла рәхмәтенең изгеләргә генә иңеп калмыйча, гади бәндәләргә дә күчә алуына ышану изгеләр культының киң таралуына китерә. Ә.нең үлеменнән соң аңа иңгән бәрәкәт юкка чыкмый, аңа бәйле бар нәрсәдә (кабере, шәхси әйберләре һ.б.) сакланып кала, дигән караш яши.

Идел-Урал татарлары арасында Болгар шәһәренең урта гасырларга караган истәлекләренә, Алексеев р-ны Биләр авылы янындагы Балым хуҗа тавына (Хуҗалар тавына) барып табыну киң таралган. Казанда табыну урыны булып Аргы Кабанның биек ярындагы болгар зираты санала. Хаҗ кылып, намаз укып, корбан китергәннән соң авырулардан савыгырга, бәладән котылырга һ.б. теләкләргә ирешергә мөмкин, дип ышану Ә.ләргә табынуның нигезен тәшкил итә. Ш.у.к. *Изге урыннар*.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*



И.В.Әухәдиев.

**ӘУХӘДИ́ЕВ** Ильяс Вәкъкас улы (26.10.1904, Казан губ. Түбән Шашы а. — 3.2.1968, Казан), дирижёр, скрипкачы, педагог. ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939) һәм халык артисты (1965). 1926 елда Ташкент музыка уч-щесен, 1931 дә Ленинград консерваториясенең скрипка классын тәмамлый. Муз. белемен үстерүдә аңа А.Глазунов зур йогынты ясый. 1931 дән Татар акад. театры оркестрында эшли һәм Казан музыка техникумында укыта. 1936–41 дә һәм 1948 дән Казан музыка уч-щесе директоры; Татарстанда проф. музыка белеме бирүне үстерүгә зур өлеш кертә. Татарлардан беренче опера һәм симфония оркестрлары дирижёры. 1941–44 тә Татар опера һәм балет театры дирижёры, бер үк вакытта 1941–48 дә директоры. Ул бу театрда П.Чайковскийның «Евгений Онегин», Н.Римский-Корсаковның «Патша кәләше» («Царская невеста»), Дж.Вердиның «Травиата», «Риголетто» һ.б. классик әсәрләре буенча куелган спектакльләргә дирижёрлык итә. Аның катнашында «Шүрәле» балеты (Ф.Яруллин), «Башмагым» муз. комедиясе (Җ.Фәйзи) беренче тапкыр сәхнәләштерелә. 1950–60 елларда халык арасында симф. музыканы пропагандалау



М.С.Әүхәдиев.

юнәлешендә актив эш алып бара. Казанда студентлар оркестры б-н җитәкчелек итә, респ-каның нефть районнарында районара симф. оркестрлар оештыра. Концерт программаларына Ф.Шопен, П.Чайковский, С.Сәйдәшев («Шәрекъ балеты») һ.б.ның әсәрләрен кертә. Ә. җитәкләгән симф. оркестр концертларында музыкантлар И.Бочкова, В.Пиккайзен, Ю.Ситковецкий, М.Яшвили һ.б. катнаша.

*Әд.:* К а й б и ц к а я Г. Ильяс Әүхәдиев — музыкант // Казан утлары. 1974. № 7; Народные артисты. К., 1980.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ӘҮХӘДИ́ЕВ** Ирек (Эрик) Ильяс улы (11.4.1937, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТАССРның атказ. физик тәрбия хезмәткәре (1987). СССРның спорт остасы (1959). 100 *м* га йөгерүдә ТР рекордчысы (10,4 секунд — 1959). 1961 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1964 тән Казан пед. ин-тында, 1970 тән физик тәрбия каф. мөдире. 1977–80, 1983–88 елларда Волгоград физкультура ин-тының Казан ф-лында. 1988 дән Казан мед. академиясендә, 1993 тән дәвалау физкультурасы һәм табиблек күзәтчелеге каф. мөдире, 1997 дән реабилитология, спорт медицинасы каф. мөдире. Хезмәтләре спорт физиологиясенә һәм физик тәрбиягә табиблек күзәтчелеге проблемаларына карый.

Х е з м.: Организационная структура физкультурно-оздоровительной работы с физически ослабленными учащимися. М., 1986; Уроки физического воспитания в специальной и подготовительной медицинских группах. М., 1986.

**ӘҮХӘДИ́ЕВ** Минрәхмәт (Минсәхмәт) Сәхәбетдин улы (6.6.1923, Красноярск краеның Минусинск р-ны Знаменка а.), Дан орденының тулы кавалеры (16.8.1944, 25.10.1944, 27.6.1945), старшина. «Минусинскдорстрой» юл төзү оешмасында эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышында катнаша: 67 нче укчы полкның миномёт расчеты командиры (3 нче гв. армиянең 273 нче укчы дивизиясе). Брянск, Белоруссия һәм 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Мәскәү (1941–42), Сталинград (1942–43) сугышларында, Белоруссия, Украина һәм Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1944 нең 30 июлендә Көнбатыш Буг елгасын кичкәндә дошманның 9 ут ноктасын юк итә; 1944 нең 1–14 сентябрендә Ополе шәһәреннән (Польша) көньяк-көнбатыштарак барган бәрелешләрдә дошманның 5 пулемёт ноктасын сафтан чыгара; 1945 нең 22–23 февралендә Бреслау шәһәре (Германия, хәзерге Вроцлав шәһәре, Польша) янындагы бәрелештә дошманның танкка каршы тубын һәм пулемётын юк итеп, батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Черногорск шәһәрендә (Красноярск крае) шофёр булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы. Красноярск, 1984; Р о щ и н И.И. Солдатская слава. М., 1988. Кн. 7; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ӘҮХӘДИ́ЕВ** Фәрит Габетдин улы (20.8.1947, Арча р-ны Чембулат а.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1991), проф. (2006), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук, 1993 тән Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1999 дан матем. бүлеген җитәкли. Хезмәтләре функцияләрнең геом. теориясенә, изопериметрик тигезсезлекләргә һәм кырый мәсьәләләргә карый. Тоташ мохит механикасының кырый мәсьәләләрен чишү өчен геометриянең конформлы чагылдыруны куллану юлларын эшли. Сен-Венан куйган мәгълүм мәсьәләне — бөтерелү катылыгы коэффициентының геом. эквивалентын табу турындагы мәсьәләне чишә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Об инъективности в области открытых изолированных отображений с заданными граничными свойстами // Докл. АН СССР. 1987. Т. 292, № 4; Конформные отображения и краевые задачи. К., 1996; Конформные отображения, удовлетворяющие граничному условию равенства метрик // Докл. РАН. 1996. Т. 347, № 3; Вариационные конформно-инвариантные неравенства и их приложения // Докл. РАН. 1998. Т. 359, № 6; Решение обобщений задачи Сен-Венана // Мат. сб. 1998. Т. 189, № 12.

**ӘФГА́Н-МӨХӘММӘ́Д СОЛТА́Н ТӘКИЯСЕ́**, Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендәге төрбә, татар архитектурасы истәлеге. 1649 елда Рязань осталары тарафыннан Касыйм ханнары гаиләсе өчен төзелә. Болгар-татар архит-расы традицияләрендә төзелгән ике бүлемле кирпеч төрбә. Гөмбәзләр б-н капланган, тышкы ягыннан парапет биеклегенә кадәр туфрак б-н күмелгән бер катлы турыпочмаклы бина. Ишек порталы, кечкенә тәрәзә йөзлекләре, купшы кәрнизләр һәм почмаклардагы пилястралар бизәлешендә рус архит-расындагы кирпечтән бизәк ясау элементлары кулланылган.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. Спб., 1863. Ч. 1; Х а л и т Н. Очерки по архитектуре Ханской Казани. Гипотезы. Факты. Размышления. К., 1999.

**әл-ӘФГАНИ́ ҖАМАЛЕТДИ́Н** (1839–97, Әфганстан, Кабул ш.), дин, сәясәт эшлеклесе. 1869 елга кадәр Әфганстан әмирләрендә хезмәт итә. 1871–79 да Мисырның иҗтимагый һәм сәяси тормышында катнаша. 1879 да Александрия (Мисыр) шәһәрендә «Яшь мисырлылар җәмгыяте»н төзи. Актив сәясәт эшчәнлеге өчен Мисырдан сөрелә. 1884 тә Парижда М.*Абду* б-н берлектә *панисламизм* идеяләрен пропагандалаучы «әл-Урва әл-вуска» («Тыгыз элемтә») атналык г-тасын нәшер итә. 1880 еллар ахырында Россиягә килә. Ә.Җ.нең дини-реформаторлык идеяләре 19 йөз ахыры — 20 йөз башында мөселман дөньясы иҗтимагый хәрәкәтләре һәм партияләре эшчәнлегендә чагылыш таба һәм Г.Баруди, Г.Баязитов, М.Бигиев, Р.Ибраһимов, Р.Фәхретдин һ.б. татар фикер ияләренең дөньяга карашлары формалашуга зур йогынты ясый.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ӘФЛӘТУ́НОВ** Әнвәр Шиһап улы (11.1.1930, Буа ш. — 3.11.1963, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1961). Казан ун-тын тәмамлый (1954). 1957 елдан шунда ук татар теле һәм әдәбияты кафедрасында эшли. Хезмәтләре татар диалектологиясе һәм фонетикасы өлкә-

**Әфган-Мөхәммәд Солтан тәкиясе мәкаләсенә.** Әфган-Мөхәммәд Солтан төрбәсе. Касыйм шәһәре. 1649.
1. Гомуми күренеше; 2. Тәрәзә йөзлеге; 3. Ишек өстендәге уем.







сенә, Башкортстан татарларының тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: БАССРның көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнарында яшәүче татарлар сөйләшендәге фонетик үзенчәлекләр. К., 1959; Фонетика современного татарского языка. К., 1962; Словесное ударение в татарском языке // Материалы итоговой конференции Казанского университета. К., 1962.

**ӘФЛӘТУ́НОВ** Радик Әбүзәр улы (24.8.1952, Әлмәт ш.), инженер-технолог, ТРның атказ. нефтьчесе (1995), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). 1979 елда Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый. «Татнефть» АҖдә эшли: 1970–73, 1977–84 тә «Әлмәтнефть» НГДУында, 1973–77 дә Исәпләү үзәгендә; 1984 тән «Елховнефть» НГДУында, 1991 дән баш инженер. Дәүләт бүләге «Эксплуатацияләү колоннасын саклау һәм төзекләндерү өчен технологияләр һәм техник чаралар комплексын эшләү һәм сәнәгатьтә киң куллану» дигән хезмәте өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ӘФЛӘТУ́НОВ** Юрий Фәүзи улы (8.6.1946, Башкортстан АССР, Бөре ш.), контр-адмирал (1993). С.О.Макаров исем. Тын океан югары хәрби диңгез уч-щесен (1969, Владивосток ш.), Сов. Союзы маршалы А.А.Гречко исем. Хәрби диңгез академиясен (1984, Ленинград) тәмамлый. 1969–74 елларда Кара Диңгез флотында торпеда һәм десант катерлары командиры. 1972 дән Балтыйк флотында десант корабы командиры, десант кораблары дивизионы штабы башлыгы һәм бригада командиры. 1988–2001 дә флот штабы башлыгы урынбасары. Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Нахимов, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткәне өчен», «Хәрби хезмәтләре өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ӘХӘ́ТОВ** Айдар Габделхәй улы (20.6.1957, Төмән өлкәсенең Тубыл ш.), икътисадчы, эколог, икътисад фән. д-ры (1998). 1979 елда Башкорт ун-тын, 1995 тә Халыкара административ идарә итү ин-тын (АКШ), 1996 да Балтыйк экология, сәясәт һәм хокук ин-тын (С.-Петербург) тәмамлый. 1986–89 да «КамАЗ» җитештерү берләшмәсендә әйләнә-тирә мохитне саклау лаб. инженеры, башлыгы. 1989–92 дә халык депутатларының Чаллы шәһәр советы башкарма ком-тында экология һәм табигатьне саклау бүлеге башлыгы, Чаллы шәһәренең баш экологы. 1992–94 тә Кама экология фонды президенты — ген. директоры, 1994–95 тә ТР экология фондының Кама буе бүлеге директоры, 1997–99 да Казан технол. ун-тында икътисад каф. профессоры, бер үк вакытта 1998–99 да ТР финанс министры урынбасары, Затлы металлар һәм ташларның дәүләт фондын оештыру һәм саклау буенча ТР Департаменты директоры, 1999–2001 дә Халыкара сәнәгать банкы идарәсе рәисенең 1 нче урынбасары, «Рослеспром» (Мәскәү) ачык АҖнең ген. директор урынбасары. 2000 нән Россия хокук саклау органнары хезмәткәрләре ассоциациясенең (Мәскәү) вице-президенты. Фәнни-тикшеренүләренең төп юнәлешләре әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалануның икътисади механизмнарына карый. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–2000 дә ТР халык депутаты, 1995–98 дә ТР ЮСның экология иминлеге, табигый ресурслар һәм табигатьтән файдалану даими комиссиясе рәисе урынбасары, 1995–2000 дә ТР ЮСның экология буенча депутатлар фракциясе рәисе.

Х е з м.: Разработка и реализация экономического механизма природопользования. К., 1991; Разработка и совершенствование экономических методов управления природопользованием в условиях перехода к рынку. К., 1992; Дифференциальная рента и экономическая оценка минеральных ресурсов. М., 1996; Ресурсы нефти и газа России на рубеже веков (экономические и эколого-экономические аспекты). М., 1998 (автордаш).

**ӘХӘ́ТОВ** Габделхәй Хөррәм улы (8.9.1927, Минзәлә кантоны, Пучы волосте Иске Айман а. — 25.11.1986, Чаллы ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1965), проф. (1970), Казан пед. ин-тын тәмамлый (1951). 1954 елдан Тубыл пед. ин-тының татар теле, 1958 дән Башкорт ун-тының татар теле һәм әдәбияты, 1980 нән Алабуга пед. ин-тының татар филол. каф. мөдире. Хезмәтләре төрки телләрнең диалектология, фразеология, лексикология һәм полисемиясен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Хәзерге татар теленең лексикологиясе. К., 1979; Диалект западно-сибирских татар. Уфа, 1968; Лексикология современного татарского литературного языка. К., 1979; Фразеологический словарь татарского языка. К., 1982.

*Әд.:* Г а р д а н о в Х.Ш. Остазларның өйрәнгече була // Казан утлары. 1977. № 5; Ш ә р и ф у л л и н Ф.Ә. Ярдәмчел дә, таләпчән дә ул // Совет мәктәбе. 1977. № 9.

**«ӘХБА́Р»** («أخبار» — «Хәбәрләр»), иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. *«Иттифакъ әл-мөслимин»* партиясе органы. 1907 елның 10 декабреннән 1908 нең 30 июленә кадәр Казанда татар телендә атнага 2–3 тапкыр нәшер ителә. Барлыгы 85 саны чыга. Мөхәррирләре Х.Фәйзи-Чистапули, Б.Шәрәф. Газетада Г.Гыйсмәти, Н.Думави, Г.Ибраһим, Ф.Хәкимов һ.б. авторларның язмалары басыла. «Ә.» укучыларны илдәге һәм дөньядагы сәяси хәлләр б-н таныштыра, 1 нче Дәүләт думасы эшен яктырта, а.х. торышы турында материаллар бастыра, халык мәгарифе мәсьәләләрен күтәрә, наданлыкны бетерү проблемаларына аеруча зур игътибар бирә. Газета битләрендә иске ысуллар б-н эшләүче мәдрәсәләрне үзгәртү һәм яңа мәктәпләр ачу турында кискен бәхәсләр алып барыла. Татар язучылары әсәрләреннән өзекләр, татар халкы тарихына, әдәбият һәм сәнгать торышына кагылышлы мәкаләләр басыла. Рубрикалары: «Сәяси яңалыклар», «Думада», «Авыл тормышы», «Әдәби яңалыклар» һ.б.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**ӘХМӘ́Д БИҖА́Н** (Ahmed Bican) Язычы оглы (15 йөз), төрек шагыйре. Язучы Сәләхетдин Кятибнең улы. Ә.Б. һәм аның абыйсы, шагыйрь Мөхәммәд Чәләби, суфилар шәехе Хуҗа Бәйрәмнең мөридләре булалар. Суфилар ритуалындагыча яшәү рәвеше алып барып, Ә.Б. үзен тәмам хәлсезләнү дәрәҗәсенә китереп җиткерә. «Биҗан» (гарәпчә — җансыз) кушаматы алуы да шул халәте б-н бәйле. Ә.Б. үзенең абыйсы Мөхәммәд Чәләби тарафыннан гарәп телендә язылган «Мәгариб әз-заман» («Заман кояшының батышы») исемле әсәрен 1460 елда төрки телгә ирекле тәрҗемә итә һәм аны «Әнвар әл-гашикыйн» («Гашыйклар нуры») дип атый. Шул исем б-н әсәр 19 йөзнең 2 нче яртысында татарлар арасында киң таралыш ала һәм Казанда күп тапкырлар басылып чыга. Ә.Б. фарсы галиме Зәкәрия әл-Казвининың «Гаҗаиб әл-мәхлүкат» («Гаҗәеп җан ияләре») китабы нигезендә иҗат ителгән шул исемдәге әсәр (1453) һәм оригиналь иҗат җимеше «Дөрр-е мәкнүн» («Энҗеләр тезмәсе») әсәре авторы буларак та билгеле. Әсәрләрнең өчесе дә дини эчтәлеккә ия, аларда пәйгамбәр һәм хәлифәләрнең эш-гамәлләре, ислам шәригатенең нигез кагыйдәләре хикәяләр рәвешендә бәян ителә.

Ә с ә р.: Әнварүл-гашикыйн. К., 1898.

*Әд.:* А б и л о в Ш.Ш. Татарская литература XV — XVI вв. (эпоха Казанского ханства) // Средневековая татарская литература (VIII — XVIII). К., 1999; Islam Ansiklopedisi. Ist., 1978. 2 cilt.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ӘХМӘ́Д ХАН** (? — 1481), Олы Урда ханы (1460 еллар башыннан). Кече Мөхәммәд хан улы. Тәхеткә Кырым ханы Хаҗигәрәй ярдәмендә Сәед Әхмәд ханны Днепр буйларына куып җибәргәннән соң утыра. Ә.х. идарә иткән елларда Олы Урданың иң куәтле чоры була. Ә.х. күрше дәүләтләр б-н сәяси арадашлыкны җанландыра: 1470–71 елларда Бөек Литва кенәзлеге короле Казимир IV б-н солых килешүе төзи; 1471–74 тә Венеция б-н сөйләшүләр алып бара, Төркия б-н көрәштә аңа ярдәм итәчәгенә ышандыра; 1476 да Төркия б-н арадашлык мөнәсәбәтләре урнаштыра. Ә.х. Алтын Урда дәүләте куәтен кабат торгызырга омтыла. Рус сугышчылары зур көймәләрдә төшеп Сарай әл-Җәдидне талап, яндырып киткәннән соң, Ә.х. 1472 дә рус җирләренә яу б-н бара, Алексин шәһәрен ала. Казимир IV вәгъдә иткән ярдәм килмәгәч, шуннан кире борылып китә. 1476 да Кырымга һөҗүм итә, Миңлегәрәй ханны төшереп, Кырым тәхетенә үз кешесе Җанибәкне утырта. Шул рәвешле Алтын Урданың байтак өлешендә үз хакимиятен урнаштыруга ирешкәч, 1476 да Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III кә идарәчелек ярлыгын килеп алырга һәм Урдага ясак түләүне яңартырга кирәклеген белдерә. Иван III бу таләпләрне кире каккач, Мәскәү кенәзлеге б-н сугышка әзерләнә башлый. Шул арада Миңлегәрәй хан Төркия ярдәмендә Кырымга әйләнеп кайта (1479), Казан тәхетенә Мәскәүгә йөз тотучылар вәкиле утыртыла, Мәскәү, Казан, Кырым, Төркия бердәмлеге (коалициясе) барлыкка килә. Әстерхан ханы да Казан сәясәтенә кушылгач, Ә.х.ның таянычлары кими. 1479 да Ә.х., ниһаять, берничә ел дәвам иткән көрәштән соң, көнчыгыштагы күршесен — күчмә үзбәкләр ханы Шәех Хәйдәр гаскәрен җиңүгә ирешә. Аннары Әстерхан ханлыгы өстеннән бәйлелек урнаштыра, Казимир IV б-н килешүен яңарта. 1480 нең 2 нче яртысында Мәскәү кенәзлегенә яуга чыга. Ләкин Угра елгасын кичә алмый, Иван III көчләре тарафыннан һө-

җүм туктатыла (к. *Угра буендагы капма-каршы тору*). Миңлегәрәй хан да Литва җирләренә һөҗүм итә. Ул тарафтан ярдәм килү тоткарлана. 11 ноябрьдә Ә.х. көчсезләнгән гаскәре б-н кире борылып китәргә мәҗбүр була. 1480–81 нең кышында Олы Урдага каршы Себер ханы Ибакъ һәм нугай морзалары Муса, Ямгурчының берләштерелгән көчләре һөҗүм итәләр. Дон елгасы буендагы кучмә станында Ә.х. үтерелә.

*Әд.:* Базилевич К.В. Внешняя политика русского централизованного государства во 2-ой половине 16 в. М., 1952; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Алексеев Ю.Г. Освобождение Руси от ордынского ига. М., 1989.

*И.Л.Измайлов.*

**ӘХМӘ́Д ХУҖА́ әс-САРАИ́** (14 йөзнең 2 нче яртысы), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. Тумышы б-н Идел буе төбәгеннән. Гарәп һәм фарсы телләре мөгаллиме, әдәби иҗат б-н шөгыльләнә. Алтын Урда дәүләтенә Аксак Тимер һөҗүме вакытында (14 йөзнең 90 нчы еллары) әсир төшеп, Сәмәркандшәһәренә озатылган дип фараз ителә. Иҗат мирасыннан Сәйф Сараиның «Китаб-е Гөлестан би-т-төрки» кулъязма җыентыгында урнаштырылган газәл жанрындагы бер шигыре («Дилбәремнең ул сәдәфдик агъзында дөр бар ирер... » — «Дилбәремнең энҗе кабыгыдай авызында энҗеләрдәй тешләре бар...») б-н мәгълүм. Иҗаты һәм тормышы аз өйрәнелгән.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихыннан студентларның практик дәресләре өчен материал. К., 1967; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.; Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

**ӘХМӘ́Д әш-ШӘФИГЫ́Й** (أحمد الشافعي), (тулы исеме Әхмәд ибне Гали әл-Гаскыйлани әл-Мисрый әш-Шәфигый) (28.2.1372, Каһирә — 1449, шунда ук), гарәп галиме, әдип. Палестинада укып белем ала, соңыннан үзе дә хәдистән дәресләр бирә. 1408 елдан Мисырдагы *әл-Әзһар* һәм Гомәр мәчетләре имамы. Алтын Урда б-н мәмлүкләр Мисыры арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләрне яктырткан «Китаб-е анба әл-гомр би әбна әл-әмр» («Чорның балалары турында акылсызларга хәбәр») исемле тарихи китап авторы. Кулъязма нөсхәләре Британия музеенда (Лондон), Париж милли китапханәсендә һәм Европаның башка архивларында саклана. Әдипнең дини-дидактик эчтәлекле «Мөнәббиһат» («Фикерләр уяткыч») исемле әсәре Касыйм шәһәренең зыялы бер кешесе тарафыннан 1630 да татар теленә тәрҗемә ителә һәм 1905, 1915 тә Казанда аерым китап булып басыла.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 т.; Тизенгаузен В. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1; Марджани Ш. Вафият аль-аслаф ва тахият аль-ахлаф / Пер. с араб. А.Н.Юзеева. К., 1999.

*Р.Ф.Исламов.*

**ӘХМӘДБИ́К** (18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башы), шагыйрь. 1970 елларда Ленинградның Дәүләт тарих архивында табылган кулъязма шигырьләр җыентыгының авторы дип уйланыла. Шигырьләр 1786–1804 елларга карый. Эчтәлеге б-н алар хаҗга бару һәм Мәккә шәһәренә сәяхәт кылу вакыйгаларына багышланган. Шигырьләрнең икесе — «Аерылышу» («Әл-видагъ») һәм «Һәр сәхәр вакътында калкып гизәрди...» («Вәйс әл-Караный»), тәмам халыклашып, Рамазан ае көннәрендә кичке намаздан соң мәчетләрдә көйләп әйтелә торган булган. Ә.нең иҗатында дини һәм дөньяви мотивлар аралашып бара, автор социаль һәм рухи ярлылыкны тәнкыйть итә, җәмгыятьне сафландыру идеяләрен алга сөрә. Шул үзенчәлекләре б-н Ә. иҗаты татар шигърияте үсешендәге мөһим бер яңалык буларак тәкъдир ителә. Ә.нең аерым шигырьләре, авторы күрсәтелмичә, 1905 тә Казанда «Илаһи җыентык» («Мәҗмуга-и илаһи») исеме б-н басылып чыга. Ә.нең биографиясенә кагылышлы мәгълүматлар сакланмаган.

*Әд.:* Гайнетдинов М.В. XIX йөз татар әдәбияты тарихына яңа материаллар // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 т.; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ӘХМӘДИ́** (Ahmedi) (тулы исеме Таҗеддин Әхмәд бине Ибраһим бине Хызыр Әхмәди Гирмияни) (1334, Төркия, Гирмияни ш. — 1413, шунда ук, Амасья ш.), төрек шагыйре. Яшьлегендә мәмлүкләр Мисырына барып, тарих, фәлсәфә, теология, философия, медицина һ.б. фәннәрне тирәнтен өйрәнә, шагыйрьләр, галимнәр, ш.и. Алтын Урдадан чыккан кешеләр б-н аралаша. Төркиягә әйләнеп кайткач, солтан Баязид Йылдырым һәм аның уллары б-н элемтә урнаштыра. Бик күп әдәби әсәрләр авторы: шигырьләр тупланмасы «Диван» (8 мең бәйт), «Җәмшид вә Хөршид» дигән романтик мәхәббәт поэмасы (күләме — 5 мең бәйт), медицинадан трактат «Әрвахларны сафландыру» («Тәрвих әл-әрвах», 4 мең бәйт), шигъри логатьлек «Әдәплелек дәрәҗәсе» («Миркат әл-адаб») һ.б. Ибне Синаның (Әбүгалисина) «Табиблек гыйлеме кануннары» («Канун әт-тыйбб») хезмәтен, Фәридеддин Гаттарның «Серләр китабы» («Әсрарнамә») әсәрен төрек теленә тәрҗемә итә. Аеруча күләмле әсәрләреннән — 12 йөз шагыйре һәм фикер иясе Низаминың «Искәндәрнамә» поэмасына охшатып иҗат иткән шул ук исемдәге шигъри әсәрен (күләме — 8250 бәйт) 1389 елда тәмамлый. Авторның үз заманының төрле проблемаларын, кеше тормышы, яшәү мәгънәсе, укыту-тәрбия мәсьәләләре турында әхлакый-фәлсәфи уйлануларын эченә алган бу поэма, кулъязма нөсхәләр рәвешендә татарлар арасында киң таралып, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту әсбабы итеп файдаланыла. Поэмадан зур бер өзекне С.Кукляшев, укыту материалы буларак, үзенең «Диван-е хикайә әт-татар» (Казан, 1859) исемле хрестоматиясенә урнаштыра. Поэманың аерым кулъязма күчермәләре Казан, С.-Петербург һ.б. шәһәрләрнең архив һәм китапханә фондларында саклана.

*Әд.:* Миңнегулов Х.Й., Садретдинов Ш. XIX йөз татар хрестоматияләре. К., 1982; Асланов В.И. Ахмеди и его «Искандер-наме» // Народы Азии и африки. 1966. № 4; Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика: Вопросы взаимосвязей и поэтики. К., 1993.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**ӘХМӘДИ́ЕВ** Гариф Кирам улы (25.2.1912, Казан губ., Чистай өязе Татар Ялтаны а. — 6.4.1991, Казан), инженер-механик. 1935 елда Казан авиация ин-тын һәм 1950 дә СССР Сәнәгать авиациясе академиясен (Мәскәү) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1938–52 дә Казан пр-тиеләрендә, 1952–76 да Мәскәү вертолёт з-дының Казан ф-лында әйдәп баручы конструктор, директор урынбасары (1958 дән) һәм директор (1962–67). Хезмәтләре һәм уйлап табулары вертолётлар төзү һәм эшләп чыгаруга карый. Яңа авиация техникасы төзегән өчен СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1977). Октябрь Революциясе ордены, өч «Почёт билгесе» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘДИ́ЕВ** Илдар Каюм улы (22.5.1935, Казан), график, нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1985). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1955). «Азат хатын» (1961–66, 1970–77), «Чаян» (1969–70) ж-лларында баш рәссам, Сәнгать фондында (1977–83) эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). Республикада әйдәп баручы график рәссамнарның берсе, акварель әсәрләре, линогравюралар, китаплар өчен ясалган рәсемнәр һәм иллюстрацияләр авторы. 1962–64 елларда Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романына, 1968 дә — Г.Кутуйның «Тапшы-





И.К.Әхмәдиев. 1. «КамАЗ юллары». «КамАЗ» сериясеннән. Линогравюра. 1973–79; 2. «Чаллы тәрәзәләре». «КамАЗ» сериясеннән. Линогравюра. 1976–79.





И.К.Ә х м ә д и е в. 1. «Казаным», 1980 еллар; 2. «Без башка юлдан барачакбыз». 1987. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

рылмаган хатлар» повестена, 1971–75 тә — «Чаллы җирендә» китабына иллюстрацияләр ясый. Х.Туфанның «Юкмыш бабай малае» (1966), Җ.Тәрҗемановның «Лобачевскийның яшьлеге» (1968) кебек балалар китаплары өчен иҗат ителгән рәсемнәре аеруча уңышлы булып санала. Станлы графика өлкәсендә акварель, линогравюра, картондагы гравюра техникасында эшли («Продотряд», 1964–70; «КамАЗ» сериясе, 1976–79). «Аналарга тынычлык» (1978), «Чишмәләрне саклыйк» (1981) плакатлары, карикатуралар авторы. 70 еллар башыннан иҗатында нәкышь әсәрләре зур урын алып тора, КамАЗ төзүчеләренә багышланган «Скреперчылар» (1973), «Безнең бригада», «Туй истәлеге», (1974), «Тәфтиләү» (1976) картиналарын яза. Халыкара «Тынычлык өчен көрәштә сатира» (Мәскәү, 1969, 1973, 1977), Парижда совет сәнгате (1977), бөтенсоюз («Ут сызыгында сатира», Мәскәү, 1967, 1975), бөтенроссия (1967 дән) күргәзмәләрендә һәм төбәкара («Зур Идел», 1964 тән) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә 1977 дә (Э.Б.Гельмс б-н берлектә), Казанда (1960, 1965, 1982, 2003, 2005), Лениногорскида (1983) күрсәтелә. Ә. әсәрләре Габрово шәһәренең сатира һәм юмор музеенда (Болгария), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Яңа Кырлайдагы Г.Тукай музей-комплексында һ.б. саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; ш у л у к. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**ӘХМӘДИ́ЕВ** Марсил Гомәр улы (13.5.1939, Апас р-ны Апас а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1998), проф. (1999). ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1983). 1973 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1963–75 елларда Казанда һөнәри-техник белем бирү системасында (производствога өйрәтү мастеры, техник уч-ще директоры урынбасары, директоры), 1975–78 дә Таҗикстан ССР Спорт ком-ты рәисе ярдәмчесе. 1978–86 да Казан укыту курслары комб-ты директоры, 1986–89 да ТАССР Һөнәри-техник белем бирү дәүләт ком-ты рәисе урынбасары, 1989–92 дә ТР Мәгариф министрлыгының укыту-методик тәэминат бүлеге башлыгы, 1992–95 тә Татарстан агробизнес һәм кадрларны яңадан әзерләү ин-ты директоры, 1995–99 да ТР ФАнең Социаль-икътисад һәм хокук фәннәре ин-тының икътисад бүлеге мөдире, 1999 дан Казан социаль-юридик ин-ты проректоры, 2003 тән Көнчыгыш икътисад, гуманитар фәннәр, идарә итү һәм хокук ин-тының Казан ф-лы директоры. Фәнни тикшеренүләре базар икътисады шартларында агросәнәгать комплексын реформалаштыруга карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Региональные особенности развития сельскохозяйственных предприятий в условиях рынка и рыночных отношений. К., 1993; Научные принципы и организационные основы формирования многоукладного сельского хозяйства в условиях рыночных отношений в АПК. К., 1994; Организация и эффективность ведения крестьянского (фермерского) хозяйства. К., 1994; Развитие сельскохозяйственных предприятий в Республике Татарстан. М., 2001.

**ӘХМӘДИ́ЕВ** Нур Гариф улы (14.12.1946, Азнакай р-ны Әсәй а.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). Казан ун-тын (1970), М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны (1987, Мәскәү) тәмамлый. 1971–73 елларда ВЛКСМның Азнакай р-н ком-ты секретаре, 1979–83 тә — «Азнакайнефть» НГДУының укыту курслары комб-ты директоры, 1987–93 тә ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җаваплы сәркәтибе. 1994 елдан «Татнефть» АҖнең «Хәзинә» г-тасы мөхәррире. Балалар өчен язылган беренче шигырьләре һәм хикәяләре 1970 еллар башында «Ялкын» ж-лында, «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» г-таларында басыла. «Аһәң» (1980), «Ак бишегем» (1987), «Яралы күк» (1994), «Күзгә-күз» (1996), «Чакматаш» (2002), «Абага чәчәге» (2006) шигъри җыентыклары, балалар өчен «Бал яңгыры» (1984), «Күктә ничә йолдыз бар?» (1991), «Аксак төлке» (1994), «Атларым-колыннарым» (1997) дип аталган маҗаралы повестьлар, хикәяләр, мәхәббәт турында повестьлары, юмористик-сатирик хикәяләре тупланган «Амбирак» исемле җыентык авторы. Ә. әсәрләрендә җирдә барган вакыйгаларга, гаилә тормышына, хезмәткә үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Аның геройлары — тормыш сөючән, оптимист кешеләр.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 2001–2002.

*Әд.:* А ф з а л Г. Шагыйрьнең уңышы // Ватаным Татарстан. 1995. 24 янв.; Г а м б ә р Н. Каеннар яктысында // Казан утлары. 1996. № 12.


*Г.М.Габделхакова.*

**ӘХМӘДИ́ЕВ** Рифкать Гали улы (31.7.1939, Буа ш.), нефтьче, техник фән. канд. (1970). Патрис Лумумба исем. Халыклар дуслыгы ун-тын тәмамлый (1966, Мәскәү). 1973–81 елларда Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тында эшли. 1981 дән Ухта техника ун-тында: бораулау каф. мөдире (1981–83, 1989–92), проректор (1983–89). Бер үк вакытта 1990 нан Аномаль геол. һәм климатик шартларда табигать ресурсларын үзләштерү һәм файдалану проблемалары ин-ты директоры (Коми Респ-касы, Ухта ш.). Аның җитәкчелегендә аз токсинлы бораулау эремәләре, катламнарны ачуның сыйфатын һәм скважиналарның тотрыклылыгын күтәрү технологияләре, дисперс системаларда физик-химик процессларны өйрәнү өчен приборлар һәм оригиналь методикалар эшләнә һәм гамәлгә кертелә. «Бораулау измәләре фильтрлануы процессларының коллекторлар үткәрүчәнлеген үзгәртүгә тәэсире» («Влияние процессов фильтрации буровых растворов на изменение проницаемости коллектора» 1975, В.М.Подгорный б-н автордаш) дигән хезмәте инглиз теленә тәрҗемә ителә һәм АКШта басылып чыга (1977).

Х е з м.: Особенности бурения скважин в глинистых породах / ВИНИТИ // Итоги науки и техники. Сер. Разработка нефтяных и газовых скважин. 1977. Т. 9; Химия промывочных и тампонажных жидкостей. М., 1981.

**ӘХМӘДИ́ЕВ** Фаил Габделбәр улы (10.5.1950, Балтач р-ны Таузар а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1985), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2001), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан хим.-технол. ин-тында эшли. 1975 тән Казан архитектура-төзелеш ун-тында, 1985–2003 тә гамәли матем. каф. мөдире, проф. (1987); бер үк вакытта 1996–2003 тә Казан хакимияте башлыгы урынбасары, Казан гуманитар-пед. ун-тының проректоры (2003 тән). Хезмәтләре гетероген мохиттәге технол. процессларны системалы анализлауга карый. Күп фазалы һәм реологик катлаулы мохиттә гидромеханик һәм җылылык-масса алмашу процессларын бердәм исәпләү ысулларын, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү процессларының оптималь проектлаштыруның мәгълүмати технологиясен, химия һәм төзелеш өчен күп функцияле материаллар булдыру технологиясен эшли; төп физ.-хим. параметрлар флуктуациясен исәпкә алып, дисперс системаларны эшкәртү процессларын матем. модельләштерү ысулын тәкъдим итә. «Түбәнкаманефтехим» АҖдә химик технологияләрнең теоретик нигезләрен эшләгән, пропилен оксиды, стирол һәм бутилкаучук җитештерүне камилләштергән өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1994). Милли көрәш буенча РФ, РТ чемпионы (1970, 1972). Милли көрәш буенча Казан шәһәр федерациясе рәисе (1991), «Фән һәм тел» ж-лының баш мөхәррире (1997 дән).

Х е з м.: О моделировании процесса массообмена с учётом флуктуаций физико-химических параметров // Инженерно-физ. журн. 1982. Т. 43, № 2;



Ш.Г.Әхмәдиев.



Г.Г.Әхмәдиева.

Новые методы расчёта конкретных гидромеханических процессов химической технологии с использованием уравнений механики гетерогенных сред // Докл. АН СССР. 1984. Т. 274, № 4; Моделирование и реализация способов приготовления смесей // Журн. Всесоюзного хим. общ-ва. 1988. Т. 43, № 4.

**ӘХМӘДИ́ЕВ** Фәтхерахман Габдрахман улы (15.11.1930, Балык Бистәсе р-ны Тәберде Чаллысы а. — 3.9.1981, Казан), композитор, баянчы. 1951 елда С.Сәйдәшевнең киңәше һәм фатихасы б-н Казан музыка уч-щесенә укырга керә, композиция буенча Ю.В.Виноградов классында белем ала. Хәрби хезмәткә алыну сәбәпле укуы бүленә. Соңрак Балык Бистәсе р-нының Котлы Бөкәш мәктәбендә укыта, клубта баянчы һәм музыка түгәрәге җитәкчесе булып эшли. 60 нчы еллардан Казанда яши. Җитен комб-тында татар хоры җитәкчесе һәм баянчысы була. С.Садыйкова җитәкләгән хорда баянчы вазифасын башкара, клубларда, ял йортларында чыгышлар ясый.

Бу елларда Ә. моңлы, күңелгә ятышлы җырлар яза, алар арасында «Җәйнең аяз матур таңнарында» (Ә.Ерикәй шигыре), «Кама буе — туган як», «Ак болытлар», «Солдатлар» (Р. Әхмәтҗанов шигырьләре), «Бер карадым күзләреңә», «Күңелләрем сине эзли» (халык сүзләре), «Мин килермен каршыңа» (М.Латыйфуллин шигыре), «Җырлыйм әнием турында» (Г.Зәйнашева шигыре), «Ромашкалар» (Х.Туфан шигыре). «Мәңге яшисе килә», «Чистай вальсы»н композитор үз шигырьләренә яза. 50–70 елларда аның җырлары халык арасында аеруча киң таралыш ала, алар И.Шакиров, Ә.Авзалова, Г.Рәхимкулов кебек күренекле җырчылар репертуарына керә, бәйрәмнәрдә, яшьләр җыеннарында аның җырларын яратып җырлыйлар. Ә. композиторлар берлеге әгъзасы булмау сәбәпле, аның җырларын халыкка җиткерүдә зур кыенлыклар була. Котлы Бөкәштә Ә.нең музей-йорты эшли.

Ә с ә р.: Мәңге яшисе килә: Җырлар җыентыгы. К. 1966.

*Әд.:* С а л ь м у ш е в Р. Фәтхерахман Әхмәдиевнең тормышы һәм иҗат портретына штрихлар // Яшьлегебез музыкасы. К., 2003.

*С.Рәимова.*

**ӘХМӘДИЕ́В** Шәһит Гыймадетдин улы (29.12.1888, Казан губ., Чистай өязе Татар Ялтаны а. — 12.8.1930, Казан), сәясәт эшлеклесе, язучы. 1801–07 елларда «Хөсәения» һәм «Галия» мәдрәсәләрендә белем ала, алардан шәкертләр хәрәкәтендә катнашкан өчен куыла. 1908–09 да Тубыл губернасында балалар укыта. 1910 елдан Казанда әдәбият өлкәсендә эшчәнлек алып бара. 1917 дә Татар приказчиклары җәмгыятен оештыручыларның берсе, «*Аваз*» г-тасы мөхәррире. Империалистик сугышка каршы мәкаләләр авторы. 1908–17 дә эсер-максималистлар идеяләрен яклый, 1917 дән большевиклар тарафдары, 1919 да РКП(б) сафларына керә. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче корылтаенда катнаша (1917). Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18), туфракчылар фракциясе әгъзасы. 1918–19 да Казан губернасы халык мәгарифе комиссары, «Эш» г-тасы мөхәррире, Эчке Россия мөселманнарның мәгариф эшләре комиссары урынбасары, бер үк вакытта Казан губернасы Гадәттән тыш комиссиясе әгъзасы, «Кызыл Армия» г-тасы мөхәррире; Г.Ибраһимов б-н бергә «*Мәгариф*» ж-лын оештыручыларның берсе. 1920–21 дә Төркестан АССРда: «Кызыл Шәрекъ» г-тасы мөхәррире, халык мәгарифе комиссары, Төркестан АССР ҮБК әгъзасы. 1921 нең көзендә Казанга кайта, Идел буендагы ачлык вакытында халыкка ярдәм оештыруда катнаша. *Гыйльми үзәкне* оештыручыларның берсе. 1922–24 тә Профессиональ союзларның Татарстан советында мәдәният бүлеге мөдире. РСФСРның БҮБК, ТАССРның ҮБК әгъзасы. 1924–26 да ТАССР мәгариф халык комиссары. 1925–27 дә СССР ҮБК әгъзасы. Советларның 11 нче Бөтенроссия һәм 2 нче Бөтенсоюз съездлары делегаты (1924). 1917–21 дә басылган хикәяләре татар хезмәт ияләренең авыр тормышын, татар хатын-кызларының ирексез хәлен күрсәтүгә багышланган; әкиятләрендә дуслыкка, табигать матурлыгына дан җырлана. Г.Тукай, С.Рәмиев әсәрләренә, «Сәйяр» һәм «Нур» театр труппалары эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр авторы.

Х е з м.: Шәһит Әхмәдиев әсәрләре. К., 1930; Сайланма әсәрләр. К., 1959.

*Әд.:* С а б и р о в С. Кайнар йөрәкле көрәшче // Казан утлары. 1968. № 12; ш у л у к. Ахмадиев Ш.Г. // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2; Общественно-политичекий деятель Ш.Ахмадиев. К., 1988.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ӘХМӘДИ́ЕВА** Ганҗә Галим кызы (20.2.1937, Азнакай р-ны Әсәй а.), Соц. Хезмәт Герое (1980), ТАССРның атказ. төзүчесе (1977). 1955–92 елларда «Татэнергострой» төзү-монтаж трестында эшли. Герой иseме нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгатен үстерүдә, «Түбәнкаманефтехим» җитештерү берләшмәсендә изопрен каучук җитештерү комплексын төзү һәм үзләштерүдә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Электр станцияләре һәм электр техникасы сәнәгате эшчеләре профсоюзлары ҮК әгъзасы. Ленин, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С а г и т о в Т. Ахмадиева Ганзя Галимовна // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984; Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ӘХМӘДИЙӘ́** (гарәп. أحمدية), дини җәмгыять. Һиндстанда Мирза Голәм Кадиани (1835–1908) тарафыннан нигезләнә. Аның синкретик характердагы тәгълиматы Коръәнгә һәм мөселман (сөнни) традицияләренә таяна. Ә. тарафдарлары үз җәмгыятьләренә нигез салучыны Муса һәм Гайсәдән соң илаһилыкка ирешкән соңгы пәйгамбәр, Алладан вәхи кабул итүче дип саныйлар. Ул үзенә мөселманнарның Мәһдие, христианнар Мессиясе, һиндларның Кришнасы сыйфатларын туплаган дип исәплиләр. Ә. Коръәнне һәм исламның төп таләпләрен (хаҗ, зәкать, җиһад һ.б.) рациональ караштан торып аңлата. Ә. тарафдарлары көндәлек тормышта мәгърифәтчелеккә, үз тәгълиматларын таратуга, сәүдә ширкәтләре оештыруга, актив сәяси һ.б. эшчәнлеккә зур игътибар бирәләр. Дөньяның күп кенә илләрендә Ә. җәмгыятьләре бар һәм алар, нигездә, ике төркемгә (кадианнар һәм лахорчылар) бүленгән. Күп кенә ислам илләрендә Ә. мөселман җәмгыяте булып саналмый. Ислам дөньясы лигасы Ә.не исламга каршы агым дип белдерә. Татарстанда Ә. җәмгыяте 1992 елда теркәлә.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ӘХМӘДИ́ШИН** Кәлимулла (1872, хәзерге Апас р-нының Танай-Турай а. — 1952, шунда ук), әкиятче. Эш эзләп Екатеринбург, Самара, Пермь, Түбән Новгород, Саратов, Әстерхан, Баку шәһәрләрендә була. Шул вакытта аңарда халык авыз иҗаты б-н кызыксыну уяна. 1930 елларда туган авылына кайта. 1936 елда Г.Толымбай аңардан 25 (Танай-Турай а.), 1947 дә Х.Ярми 10 әкият (шунда ук) язып ала. Аларның күбесе татар фольклорының «Татар халык иҗаты» басмасына (т. 1–13, 1976–93) кертелә.


*Х.Х.Гатина.*

**ӘХМӘДУ́ЛЛИН** Азат Гыйльмулла улы (13.10.1932, Саба р-ны Байлар Сабасы а.), әдәбият галиме, тәнкыйтьче, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1956). Тубыл пед. ин-тында укыта (1956–58), Татарстан радиокомитетында эшли (1958–61). 1963–81 елларда СССР ФА нең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1972 елдан директор урынбасары булып эшли. 1981 дән Казан ун-тында, с 1988 дән профессор, 1999 га кадәр татар әдәбияты каф. мөдире. Бер үк вакытта 1999–2004 тә Казан пед. ун-тында укыта, 2000–2004 тә татар әдәбияты каф. мөдире. Хезмәтләре татар драматургиясе һәм театры тарихына, Г.Камал, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, М.Фәйзи, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Т.Гыйззәт, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, Х.Вахит, Т.Миңнуллин һ.б. татар язучылары, драматурглары иҗатларына карый. Урта мәктәп өчен әдәбият дәреслекләре авторы (1970 елдан бирле 15 басма чыга). Әдәби терминнар тупланган «Әдәбият белеме сүзлеге»н (1990) төзүче.

Х е з м.: Ничек сурәтләргә сине, замандаш?: (Бүгенге татар драматургиясенең актуаль проблемалары турында). К., 1976; Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; Офыклар киңәйгәндә. К., 2002; Татарская драматургия. М., 1983; Күңелләрне уятып: хәзерге татар драматургиясе. К., 2007.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Г а л и м у л л и н Ф.Г. Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин // Татарстан галимнәренең биобиблиографиясе. 2002.


И.И. Әхмәдуллин.


М.Ә. Әхмәдуллин.

**ӘХМӘДУ́ЛЛИН** Исмәгыйль Ибраһим улы (18.6.1927, Чистай кантоны Иске Кади а. — 12.7.1995, Чирмешән р-ны, шунда ук), комбайнчы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Минзәлә совхоз-техникумын тәмамлый (1976). 1954–69 елларда Чирмешән р-ны Тукай исем. к-зда комбайнчы, 1969–88 дә рәис урынбасары, колхоз рәисе була. 1966 елгы сезонда 450 *га* да бодай урдыра, 9065 *ц* икмәк суктыра. Герой исеме бодай, арыш һ.б. бөртекле һәм азык культуралары уңышын күтәрүдәге уңышлары, техниканы югары җитештерүчән куллануы өчен бирелә. СССР ЮС депутаты (1966–70). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И ш к а е в А. Ахмадуллин Исмагил Ибрагимович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ӘХМӘДУ́ЛЛИН** Мотыйк Әхмәтҗан улы (1910, хәзерге Әлмәт р-ны Урсалабаш а. — 18.12.1974, Әлмәт ш.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), сержант (1944). 1932–34 елларда Кызыл Армиядә. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, сержант, сапёрлар отделениесе командиры (46 нчы армиянең 51 нче инж.-сапёр бригадасы). Карелия, Көньяк-Көнбатыш, 3 нче һәм 2 нче Украина фронтлары составында Карелия муентыгындагы бәрелешләрдә, Украинаны, Молдавияне, Венгрияне азат итү сугышларында катнаша. 1944 нең 4–5 декабрендә Эрчи шәһәре тирәсендә (Будапешт янында) Дунай елгасын кичкәндә һәм сул ярда плацдарм булдыру өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. 1946 дан Әлмәт шәһәрендә яши. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

**ӘХМӘДУ́ЛЛИН** Рәзим Хәбибулла улы (9.1.1950, Сарман р-ның Иске Минзәләбаш а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1972). 1972–92 елларда һәм 2000 нән «Түбәнкаманефтехим» АҖдә: мастер-технолог, смена һәм җайланмалар башлыгы, цех башлыгы урынбасары һәм башлыгы (1987–92 дә һәм 2000 нән). 1992–95 тә «Химотех» фәнни-җитештерү фирмасының ген. директор урынбасары, ген. директоры. 1995–96 да «Инкам» ҖЧҖ директоры, 1996–99 да «Вихрь» ҖЧҖнең техник мәсьәләләр буенча директоры (Түбән Кама ш.). 1999–2000 дә «Ригона» фәнни-җитештерү фирмасында менеджер (Чаллы ш.). Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге түбән олефиннар, бутадиен һәм бензол җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм егәрлеген арттыру буенча комплексы эшләрнең фәнни һәм практик нигезен эшләгәне һәм аларны җитештерүгә керткәне өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘДУ́ЛЛИН** Хәбибулла (Хәйбулла) (1875–1942), скрипкачы. Проф. татар скрипкачылары сәнгате традицияләрен дәвам иттерүчеләрнең берсе. 19 йөз ахырында Г.*Зайпин*да скрипкада уйнау дәресләре ала, чәйханә, ярминкә, трактирларда уйный. Милли музыка уен коралларында уйнаучыларның беренче концертларын оештыручылардан. 20 йөз башындагы беренче татар әдәби-муз. кичәләрендә, концертларда катнаша, инструменталь ансамбльләрдә (ш.и. «Сәйяр» труппасы каршында), Мөселман хәрби комис-ты һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясе оркестрларында уйный, грампластинкаларга татар халык көйләрен башкаручы солист һәм ансамблист буларак языла. 1918–23 елларда Казан кинотеатрларында уйный, 1933–36 да Татар акад. театрының колхоз ф-лында, 1936 дан Татарстан радиосында эшли. Халык көйләрен һәм Татарстан композиторлары әсәрләрен башкара. Оригиналь әсәрләр (башлыча, инструменталь пьесалар) авторы. Арадан бигрәк тә «Аккош» маршы зур популярлык казана.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**ӘХМӘДУ́ЛЛИНА** Люция Мәҗит кызы (20.6.1941, Казан), балалар табибәсе, ТРның һәм РФның атказ. табибе (1984, 1988). 1965 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1965 тән Казан хастаханәләрендә табибә, 1974 тән Россия Кызыл Хач җәмгыятенең Татарстан төбәк оешмасы рәисе.

**ӘХМӘДУ́ЛЛИНА** Фирая Юныс кызы (18.8.1936, Казан), педагог, пед. фән. канд. (1974), проф. (1994). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1959–67 дә Казан мәктәпләрендә рус теле укыта. 1967 дән Казан а.х. ин-тында, 1972 дән Казан пед. ун-тының милли мәктәпләрдә рус теле укыту кафедрасында, 1990 нан каф. мөдире. Татар мәктәпләрендә рус теле укыту методикасы буенча ярдәмлекләр һәм фәнни хезмәтләр авторы. ТРның атказ. укытучысы (1986), РФнең югары проф. белем мәктәбенең мактаулы хезмәткәре (2001).

Х е з м.: Методика обучения русским глаголам движения в татарской школе. К., 1982; Учебник русского языка для 6 класса татарской школы. К., 1992; Картина как средство развития речи татарских школьников. К., 1999; Теория и практика организации урока русского язык в татарской школе. К., 2003.

**ӘХМӘЛДИ́НОВ** (Әхмәлетдинов) Фазылҗан Фазлый улы (15.4.1918, хәзерге Башкортстан Респ-касының Кушнаренко р-ны Әхмәт а. — 29.4.1979, шунда ук), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), өлкән сержант (1944). 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында (1939–40) катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 9 нчы аерым гв. разведчиклар ротасының отделение командиры (11 нче гв. армиясенең 11 нче гв. укчылар дивизиясе). Көнбатыш, Брянск, Балтыйк буе, 2 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү яны (1941–42), Белоруссияне, Балтыйк буен азат итү сугышларында, Көнчыгыш Пруссия операциясендә (1945) катнаша. 1944 нең 13 июнендә Аметус шәһәре (Литва) янында барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Әхмәт урта мәктәбе (Башкортстан) директоры урынбасары булып эшли. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Ф.Ф. Әхмәлдинов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1968. Кн. 3; А л ё ш к и н А.М. Сердцем на амбразуру. Иркутск, 1983.

**ӘХМӘ́РОВ** Алмас Фазыл улы (27.1.1927, Лениногорск р-ны Иске Иштирәк а.), приборлар төзү технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1978), проф. (1980), ТАССРның атказ. уйлап табучысы (1989), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2002). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, Оренбург шәһәрендәге авиация з-дында инженер-технолог, техник бүлек башлыгы булып эшли. 1953 тән Казан техника ун-тында, очкыч аппарат приборлары һәм автоматлары җитештерү каф. мөдире (хәзерге стандартлаштыру, сертификация һәм менеджмент технологиясе каф.) (1960–90), каф. профессоры (1991). Бер юнәлештә кәкре детальләргә, ике юнәлештә кәкре күчәр симметрияле детальләргә, цилиндр сыман пружиналарга форма бирү процесслары теориясен һәм исәпләү нигезләрен эшли. Материалларны сынау, форма бирү, ныгыту, эшләнмәләрне стабильләштерү һәм тикшерүнең яңа ысулларын һәм чараларын эшли. Медальләр б-н бүләкләнә. Уйлап табуларга 37 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Исследование процессов гибки с растяжением деталей одинарной кривизны // Казан. авиац. ин-т. 1957. Вып. 36; Упруго-пластические расчёты при сложном нагружении // Изв. вузов. Авиационная техника. 1969, № 3; Основы теории и расчёта процессов изготовления деталей приборов методами холодной штамповки. К., 1981 (автордаш).

**ӘХМӘ́РОВ** Баян Вәли улы (19.4.1914, хәзерге Актаныш р-ны Күҗәкә а. — 27.10.1992, Менделеев р-ны Турай а.), Менделеев р-ның «Кама» к-зы рәисе (1958–83). Минзәлә укытучылар әзерләү мәктәбен тәмамлый (1930). 1930–40 елларда укытучы, мәктәп директоры, халык мәгарифенең район бүлеге инспекторы булып эшли. 1940–57 дә Совет Армиясендә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ул җитәкчелек иткән елларда кол-



Г.Н.Әхмәров.



И.Г.Әхмәров.



К.Ш.Әхмәров.

хоз алдынгы хуҗалыкка әверелә, 1980 еллар башында бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 20 *ц* га, 1 сыердан савым 3000 *кг* га җитә. Җитештерүнең барлык тармакларында заманча материаль-техник база булдырыла, социаль-көнкүреш объектлары төзелә. Ә. Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘ́РОВ** Гайнетдин Нәҗметдин улы (1864, Казан губ., Зөя өязе Наратлы а. — 20.9.1911, Казан), тарихчы, этнограф, педагог. 1881–85 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә укый. 1885–1903 тә Алабуга өязе Биектау авылында, Тәтеш шәһәрендә балалар укыта, 1903 тән Казанда, 1905–11 дә Иске Татар бистәсендә мәдрәсә мөгаллиме. 1893 тән Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә әгъза-хезмәткәр, 1904 тән хакыйкый әгъза булып тора. Татар халкы тарихына караган этнография һәм археология мирасын туплаучы. Идел буе Болгары шәһәре Суарның урынын билгели. Казанда *Шәрекъ клубын* оештыручыларның берсе. 1908–09 да Шәрекъ клубында Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы тарихларына багышланган лекция-чыгышлар ясый. Аның тарихка караган кайбер хезмәтләре «Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете» ж-лында нәшер ителә (мәс., «О языке и народности мишарей», «Свадебные обряды казанских татар», «Тептяри и их происхождение» һ.б.). Тел белеменә мөнәсәбәтле хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Болгар тарихы. К., 1909; Казан тарихы. К., 1910; Хөсне хат нәмүнәсе. К., 1911; Кыйраәт төрки. К., 1911; Избр. труды. К., 1998.

*Әд.:* Гайнетдин Әхмәров: тарихи-документаль җыентык. К., 2000.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**ӘХМӘ́РОВ** Җанбәк Шиһабетдин улы (2.2.1921, Казан), вет. микробиологы, вет. фән. д-ры (1972), проф. (1976), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1978), СССРның атказ. уйлап табучысы (1985). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Тукай р-ны «Красный Ключ» с-зында баш вет. табибе. 1957 елдан Казан вет. ин-тында, 1972–84 тә микробиология лаб. мөдире. 1984–91 дә Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү вет. ин-тында түләмәне өйрәнү лаб. мөдире. Хезмәтләре а.х. терлекләрендә некробактериоз, дуңгыз рожасы, тилчә, түләмә авыруларын өйрәнүгә карый. А.х. терлекләрендә түләмәгә люминесцент ысул б-н диагноз кую ысулын эшли. 38 авторлык таныклыгы бар. 18 тәкъдиме а.х. производствосында гамәлгә кертелә. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана: (К 120-летию вуза). К., 1993; Казанская государственная академия ветеринарной медицины: (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ӘХМӘ́РОВ** Ибраһим Вәлиулла улы (17.4.1912, хәзерге Удмурт Респ-касы, Балезин р-ны Кестым а. — 16.12.1987, Удмурт Респ-касының Глазов ш.), педагог, Удмурт АССРның атказ. укытучысы, һәвәскәр астроном. 1928 елдан укый-яза белмәүчелекне бетерүдә актив катнаша, Кестым авылы урта мәктәбендә физика, математика һәм астрономия укытучысы (1972 гә кадәр) булып эшли.



Комета ачканы өчен Бөтендөнья астрономия җәмгыятенең Зур медале (алгы һәм арткы ягы).

Күк йөзен өйрәнә. 1939 да комета ача (к. *Әхмәров–Юрлов–Хассель кометасы*), шул ачышы өчен Бөтендөнья астрономия җәмгыятенең Зур медале б-н бүләкләнә (рәсемне к.). Мәктәптә астрономия түгәрәге оештыра һәм укучылар б-н бергә 3 нче Халыкара геофизика елының Үзәк Милли комитеты биремнәре буенча көмешсыман болытларны һәм төньяк балкышын күзәтә.

*Әд.:* К а с и м о в Х. Влюблённые в небо // Красное знамя. 1989. 12 апр.

**ӘХМӘ́РОВ** Исхак Габдулла улы (7.4.1901, Оренбург губ. Троицк ш. — 19.7.1976, Мәскәү), разведчик, полковник (1948). 1921 елга кадәр Казанда яши. 1 нче Мәскәү ун-тын тәмамлый (1926). Тышкы эшләр халык комис-тында эшли. 1930 дан СССР ОГПУ оешмасында, 1932 дә ОГПУның чит илләр бүлегенә күчерелә. 1935 кә кадәр Урта Азия, Төркия, Кытайда разведка хезмәтендә. 1935–45 тә АКШта яши, совет разведкасы агентурасын җитәкли, сәяси, фәнни-техник, хәрби мәгълүматлар туплау б-н шөгыльләнә. Икенче Бөтендөнья сугышы барышына хәлиткеч тәэсир ясаган «Снег» операциясе планын уйлап табучыларның берсе (нәтиҗәдә АКШ б-н Япония арасында низаг тудырыла һәм шул сәбәпле СССР б-н Япония арасында сугыш куркынычы юкка чыгарыла). 1946–55 тә СССР Дәүләт иминлеге ком-тының чит илләрдә яшерен разведка эшләрен башкару бүлеге башлыгы урынбасары. 1955 тән шул ук комитетның Югары мәктәбендә укыта. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ветераны внешней разведки России. М., 1995.

*И.З.Минһаҗева.*

**ӘХМӘ́РОВ** Касыйм Шабан улы (24.1.1923, Саратов өлкәсенең Дергачёв р-ны Алтата а. — 6.6.1951), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), өлкән лейтенант (1946). Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (1942). 1942 елның июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 383 нче укчылар полкы взводы командиры (60 нчы армиянең 121 нче укчылар дивизиясе). Воронеж, Үзәк, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск шәһәрен (1943), Украина, Белоруссия, Польша һәм Чехословакияне азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 4 сентябрендә Чумаково авылы (Конотоп шәһәреннән көнчыгыштарак) янында барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң СССР Оборона министрлыгының офицерлар составы белемен күтәрү курсларын тәмамлый (1945). 1946 дан запаста. Ленин, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Приуралья. Уральск, 1965; Герои Советского Союза — казахстанцы. А.-А., 1968. Кн. 1.

**ӘХМӘ́РОВ** Нияз Үзбәк улы (24.1.1945, Казан), невропатолог, генетика белгече, мед. фән. д-ры (1993). Ү.Ш.*Әхмәров* улы. 1968 елда Казан мед. ин-тын һәм 1971 дә Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый. 1971–76 елларда Республика клиник хастаханәсенең неврология бүлеге табибе. 1980 нән Казан мед. ун-тында, 1988 дән нормаль физиол. каф. каршындагы «Традицион медицина» курслары мөдире. 1976 да Республика клиник хастаханәсендә Татарстанда беренче медик-генетик консультация һәм 1981 дә проф. В.М.Сироткин б-н берлектә «Медик һәм клиник генетика» курслары оештыра. Тикшеренүләре нейрофизиология, невропатология, психологиягә, генетика, традицион медицинага, фән методологиясенә карый. Яңа туган балаларның рефлексларын тикшерә һәм язып чыга, клиник бәяләү алгоритмнарын әзерли. Кеше тәненең меридиональ системасының тумыштан килгән үзенчәлекләренә диагноз кую мөмкинлеге бирә торган кул чугы һәм аяк табанының дерматоглифик сурәтләрен яңача клиник бәяләү юлларын эшли. Ә. «Novitas. Яңа фәнни концепцияләр, идеяләр, гипотезалар» ж-лын (Ү.Ш.Әхмәров б-н берлектә) оештыручы һәм аның мөхәррире. Ш.у. әдәбият белеме б-н шөгыльләнә, Г.Тукай шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Введение в бионику. К., 1984 (автордаш); Стигматы человеческой кожи. К., 1984; Притчи дервишей. К., 1995; Механизмы лечебных эффектов восточной акупунктуры. К., 1991; Г.Тукай. Переводы: Сб. К., 1996.

**ӘХМӘ́РОВ** Рәшит Насыйп улы (19.2.1940, Казакъстан ССР Чимкент өлкәсенең Куш Агач а.), биолог, биол. фән. д-ры (1989), проф. (1998). Ташкент ун-тын тәмамлый (1969). 1972 елдан Үзбәкстан Респ-касы ФАнең Үсемлекләр физиол. ин-тында, 1989 дан Зо-

ология һәм паразитология ин-тында күзәнәк биологиясе һәм хайваннар биоэнергетикасы лаб. мөдире. Хезмәтләре җылы һәм салкын канлы хайваннардагы гибернация механизмнарын, аларның табигый факторларга һәм интоксикацияләргә чыдамлылыгын өйрәнүгә карый. Организмда суббазаль алмашу һәм яшәү шартларына яраклашуны тәэмин итүнең яңа концепциясен барлыкка китерә.

Х е з м.: Температурный стресс и развивающийся организм. Таш., 1993; Теплокровность организма и её энергетические механизмы. Таш., 1994 (автордаш); Гипометаболическое состояние у грызунов и рептелий при естественной спячке. Таш., 1995.


**ӘХМӘ́РОВ** Рәшит Хәмзә улы (10.10.1939, Кыргызстан ССР, Ош ш. — 17.8.1996, Казан). «Татфлот» суднолар йөртү компаниясе ген. директоры (1993 елдан). Новосибирск су транспорты инженерлары ин-тын тәмамлый (1965). 1965–67 дә Новосибирск ремонт-эксплуатация базасында инженер-конструктор, мастер, механик ярдәмчесе, 1967–69 елларда Елга регистрының Көнбатыш-Себер инспекциясендә инженер-инспектор, 1969–70 тә Обь пароходчылыгының сәнәгать пр-тиеләренә хезмәт күрсәтү бүлегендә баш механик. 1970–76 да Елга флоты министрлыгы Үзәк КБның Новосибирск ф-лында стандартлаштыру һәм контроль нормалар бүлеге мөдире. 1976–91 дә Агыйдел елга пароходчылыгында (Уфа ш.). 1991–93 тә Казан елга порты башлыгы. Уйлап табуга таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘ́РОВ** Сәхибгәрәй (Павел) Николай улы (1862, Казан губ. Зөя өязе — 10.10.1900, Казан), педагог, миссионер, тәрҗемәче. Крәстиян гаиләсеннән. 1880–91 елларда Казанда *«Касыймия»* мәдрәсәсендә укый һәм укыта, иң белемле ислам дине белгечләреннән санала. 1891 дә миссионер Е.А.Малов йогынтысында православие динен кабул итә. 1891 дән Казан руханилар академиясендә татар теле һәм ислам тәгълиматын укыта. Дини мәктәпләр тарихы б-н шөгыльләнә. Аның бу темага караган бастырылмаган материалларыннан Е.А.Малов, Я.Д.Коблов, М.А.Машанов үз хезмәтләрендә файдаланалар. Изгеләр тормышын татар теленә тәрҗемә итә («Святой мученик Авраамий Болгарский», 1898; «Житие и труды Преподобных отцов наших Мефодия и Константина, нареченного Кирилла, учителей словенских», 1899).


**ӘХМӘ́РОВ** Үзбәк Шиһаб улы (21.11.1913, Казан), физиолог, невропатолог, биол. фән. д-ры (1967), проф. (1971). Тимер юл транспорты инженерларының Мәскәү электромеханика ин-тын (1939), Казан мед. ин-тын (1950) тәмамлый. 1939–41 елларда СССР Юл хәрәкәте халык комис-тының Юллар һәм төзелеш фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү), 1941–45 тә СССР Сугыш кирәк-яраклары халык комис-тының Калинин исем. з-дында (Казан) инженер-конструктор. 1946–49 да СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында. 1953–61 дә врач-невропатолог, Казан ГИДУВында нерв авырулары каф. ассистенты. 1961–88 дә Казан ун-тының радиоэлектроника кафедрасында, бионика проблемалары лабораториясен оештыра һәм җитәкли. 1988–91 дә Бөтенсоюз төзелеш материаллары фәнни-тикшеренү ин-тының сәнәгый бионика лабораториясендә. Хезмәтләре теоретик һәм клиник нейрофизиология, невропатология һәм бионикага карый. Беренчеләрдән булып биониканың методологик мәсьәләләрен өйрәнә (1978); табигате биологик булмаган ясалма системаларда тереклекнең үзлекләрен, принципларын, закончалыкларын торгызу ысуллары һәм юллары турындагы фән буларак, бионикага фәнни билгеләмә бирә, фәннәр системасында аның алымнарын, бурычларын һәм урынын билгели. Ә. җитәкчелегендә, «Көч-вакыт» классик нейрофизиология закончалыгына нигезләп, катлаулы системаларны анализлауның «чикле» характеристикалар методы исемен алган алымы уйлап табыла. Эшләнгән бу алым (нервлар һәм мускулларны тикшерү алымы кебек үк) эшләтеп җибәрүче (чикле) җайланмалар өчен аз энергия сарыф итә торган, тәртипле, адекват режимны табарга мөмкинлек бирә. 1996 дан «Novitas. Новые научные концепции, идеи, гипотезы» ж-лын оештыручы (улы Н.Ү.Әхмәров б-н берлектә). «Бионикага кереш» («Введение в бионику», 1984) дәреслеге автордашы.

Х е з м.: Фактор времени при одиночном раздражении возбудимых биосистем. К., 1963; Методологические вопросы бионики. К., 1977; Бионические системы изучения пороговых характеристик возбудимых биосистем. К., 1978.

**ӘХМӘ́РОВ** Чыңгыз (Мөхәммәтчыңгыз) Габдрахман улы (12.5.1912, Оренбург губ. Троицк ш. — 13.3.1995, Ташкент), нәкышьче, график, монументаль сәнгать рәссамы, сәнгать фән. кандидаты (1949), проф. (1970), Үзбәкстан ССРның һәм ТРның халык рәссамы (1964, 1992). Мәгърифәтче, Троицкида мөселман мәктәпләре оештырган Г.Әхмәровның улы. Пермь сәнгать техникумын тәмамлый (1930). 1930–35 елларда Сәмәрканд шәһәрендә яши, «Яңа юл» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә, Сәнгать әсәрләре иҗат итү оешмасында («Изофабрика») рәссам булып эшли. 1935 елда В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тына укырга керә, сугыш башлану сәбәпле аны 1942 дә Сәмәркандта тәмамлый. И.Э.Грабарь, В.А.Фаворский, Н.М.Чернышов, Л.А.Бруни шәкерте. 1949, 1955–57 дә Мәскәү Югары нәфис сәнәгать уч-щесендә (элеккеге Строганов уч-щесе) укыта. 1950 еллар башыннан Ташкентта яши. Респ-ка сәнгать уч-щесендә укыта (1952–1954), 1970–72 дә Театр һәм сәнгать ин-тында монументаль нәкышь кафедрасы һәм бер үк вакытта (1968–70) Ташкент политехника ин-тында рәсем һәм нәкышь кафедралары мөдире. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1949). Үзбәкстанда монументаль сәнгатькә нигез салучы. 1944–47 дә архит-ра акад. А.В.Щусев б-н берлектә А.Нәвои исем. Ташкент опера һәм балет театры диварларын бизи, әлеге эшендә Шәрекъ миниатюрасы һәм фрескалары традицияләренә таяна, аларны Европа нәкышь алымнары һәм хәзерге заман сәнгатенең стиль тенденцияләре б-н баета. 1953 тә Мәскәү метросының «Киев бөҗрасы» станцияләре өчен мозаика паннолары һәм фрескалар эшләүдә катнаша. Үзбәкстанда Ә.нең төп монументаль эшләре: Үзбәкстан ФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-ты вестибюле бизәлеше (1968–69), Ташкент Әдәбият музееның лирика залы (1968), Сәмәркандта Олугбәк музее һәм «Йолдыз» чәйханә-ресторны (1969–70), Хореография уч-щесе һәм Гамәли сәнгать музее фойелары (1987–88) бизәлеше, Ташкент метросының «Нәвои» станциясендә керәч панно. Замандашлары портретлары («Р.Тимерова», 1961; «А.Һидоятов», 1964; «Шагыйрә Зөлфия», 1965; «Майя Плисецкая», 1977; «Рудольф Нуриев», 1993 һ.б.), чит илләргә сәяхәтләр ясау тәэсирендә язылган график эшләр, рәсемнәр авторы. 1955–56 да Татар опера һәм балет театры фойесында һәм «Музалар залы»нда диварларны («Бию», «Музыка», «Нәкышь» аллегорик композицияләре), 1957 дә



Ч.Г.Әхмәров.



Ч.Г.Ә х м ә р о в «Сынлы сәнгать». М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры фойесындагы фреска. 1955-56.



Ч.Г.Ә х м ә р о в. «Кыз портреты». Темпера. 1950 еллар.

Казан елга порты фасадын мозаикалар б-н бизи. «Татар хатыны» (1968), «Йосыф һәм Зөләйха» картиналарын яза. 1980 еллар ахырыннан татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә багышланган әсәрләр иҗат итә (С.Сараи поэмасы нигезендә «Сөһәйл вә Гөлдерсен», «Мәрҗани Урта Азиядә», «Борынгы фреска» («Сөембикә б-н Үтәмешгәрәй») картиналары; Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Гафури, З.Мәүледова һ.б. портретлары, «Чыңгызхан портреты», Ф.Әмирханның «Хәят», «Ана һәм бала», «Татар бию» һ.б. әсәрләренә иллюстрацияләр сериясе һ.б.).



Ч.Г.Ә х м ә р о в. «Кәләш». «Гөлшегән» (Ангрен ш.) ял йорты ашханәсендәге «Сәгъди туе» стена рәсеменнән бер күренеш. Темпера, левкас. 1976.

Үзеннән соң бай архив, мемуарлар һәм «Нәсәфәт юлында» дигән кульъязма китабын калдыра. Халыкара күргәзмәләрдә (Италия, Франция, Германия, Канада, Бельгия, Һиндстан, Япония һ.б.), бөтенсоюз һәм республика күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә (1967), Ташкентта (1967, 1987), Казанда (1990, 1992, 1994) күрсәтелә. Ә. әсәрләре Третьяков галереясында, Шәрекъ халыклары сәнгате музеенда (Мәскәү), Үзбәкстан, Казакъстан һәм Татарстан музейларында саклана. СССР Дәүләт бүләге (1948), Үзбәкстан ССРның Хәмзә исем. Дәүләт бүләге (1968) лауреаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. 2006 да Ташкент шәһәрендә ул яшәгән йортка истәлек тактасы куела.

*Әд.:* У м а р о в А. Чингиз Ахмаров. Таш., 1974; Искусство Советского Узбекистана. 1917–1972. М., 1976; Чингиз Ахмаров: Живопись. Таш., 1979; Д о к у ч а е в В.Н. Чингиз Ахмаров: Образы Востока. М., 1984.

*Р.Һ.Такташ, Р.Г.Шаһиева.*

**ӘХМӘ́РОВ** Шаһбазгәрәй Измаил (Исмәгыйль) улы (12.3.1853, Казан губ. Чистай өязе — 1.4.1900, Казан), педагог һәм җәмәгать эшлеклесе. Морзалар нәселеннән. Казанда Икенче ир балалар гимназиясен (1874), Казан ун-тын (1878) тәмамлый. 1876–1900 елларда Казанда Татар укытучылар мәктәбендә рус теле укытучысы, 1881 дән инспектор (директор). Бер үк вакытта 1896 дан Казан шәһәр думасы гласные. Шәһәр уч-щесе укытучысы М.Иманаев б-н берлектә рус-татар уч-щеләре өчен «Рус теле» («Русское слово», 1895) исемле дәреслек төзи. Дәреслек күп тапкырлар нәшер ителә һәм 1924 елга кадәр кулланыла. Татар мәктәбенең дөньяви характерда булуы һәм рус теленең Идел буе халыклары арасында мәдәни багланышлар чарасы буларак таралуы тарафдары була.

Х е з м.: Синтаксический разбор глагола в казанско-татарском наречии. К., 1895; Казанское мусульманство // Городской и сельский учитель. 1897. № 3.

**ӘХМӘ́РОВ** Шиһаб (Шиһабетдин) Шәрәфетдин улы (30.12.1882, Сембер губ., Буа өязе Түбән Задур а. — 30.4.1966, Казан), педагог, журналист. Буа мәдрәсәсендә белем ала. 1901–07 елларда Казан губернасының авыл мәктәпләрендә татар теле укыта. 1908–18 дә Казанда «*Сабах*» нәшриятында эшли, җаваплы вазифалар башкара, бер үк вакытта 1913–14 тә «*Мәктәп*» ж-лы мөхәррире. 1920–22 дә Татсоюз идарәсе әгъзасы, 1923–29 да «Общество взаимного кредита» банкы идарәсе рәисе урынбасары. Шул ук вакытта Ә. ерактагы аз җирле татар авылларын (ш.и. Кызыл Байрак а.) Идел яры буенарак күчерүне оештыручы һәм башлап йөрүче. *Шәрекъ клубын* оештыручыларның берсе. Татар телендә әлифбалар, татар китапларын бастыру тарихына караган хезмәтләр авторы. 1912 дән Ә. гаиләсендә татар проф. музыкасына нигез салучыларның берсе С.*Сәйдәшев* тәрбияләнә. 1929 да Ә. репрессияләнә; 1959 да аклана.

Х е з м.: Мөнтабәгъ әлифба. К., 1909; Матбагачылык тарихы. К., 1909; Тукай һәм Сәйдәш // Казан утлары. 1966. № 4.

*Әд.:* К ә р и м у л л и н Ә.Г. Беренче татар китаплары // Казан утлары. 1967. № 5; ш у л у к. У истоков татарской книги. К., 1971; Ш ә р и ф у л л и н Ф.Ә. Журналыбызның беренче редакторы (Ш.Әхмәровның тууына 120 ел тулу уңае белән) // Мәгариф. 2002. № 12.

**ӘХМӘ́РОВ–Ю́РЛОВ–ХА́ССЕЛЬ КОМЕ́ТАСЫ**, озак периодлы комета. 1939 елның 15 апрелендә һәвәскәр астрономнар И.В.*Әхмәрев* һәм С.Н.Юрлов (Удмуртия АССР), ш.у. 16 апрельдә Норвегия астрономы О.Хассель тарафыннан ачыла. Үзенең ачышы турында И.В.Әхмәров Кестым авылыннан Пулково обсерваториясенә телеграмма җибәрә; шуннан соң 30 минутлар үтүгә Воткинск шәһәреннән метеоролог С.Н.Юрлов яңа комета күзәтә. 36 сәгатьтән соң аны О.Хассель дә күрә (Хокзунд ш.). Ачылган вакытта комета бик якты, гади күз б-н яхшы күренерлек, башы күк төстәге томанлык рәвешендә, койрыгы 4° тан озынрак була. Комета парабола буенча хәрәкәт итә. Кояш тирәли әйләнү вакыты 7000 ел. Халыкара астрономия берлегенең Үзәк бюросы карары б-н Ә.-Ю.-Х. кометасы дигән исем бирелә.

*Әд.:* К а с ы й м о в а М. Әхмәров кометасы // Татар иле. 1997. № 25; Как была открыта комета Ахмарова-Юрлова-Хасселя // Земля и Вселенная. 1982. № 5; Ахмаров Ибрагим Валиуллович // Красное знамя. 1987. 25 дек.

*Е.Д.Кондратьева.*

**ӘХМӘ́Т** (Әхмәтов) Абдулла Сафиулла улы (25.3.1905, хәзерге Курган өлкәсенең Притобольный р-ны Звериный (Звериноголовск) а. — 28.10.1976, Казан), прозаик, драматург. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1936). Әсәрләре 1925 елдан «Сабан һәм чүкеч» г-тасында (Свердловск ш.) басыла башлый. 1932 дә Казанга күчеп килә. 1936–41 дә «Совет әдәбияты» ж-лы хезмәткәре, Казан химия-технол. техникумында һәм музыка мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Алга, дошман өстенә!» фронт г-тасында әдәби хезмәттәшлек итә. 1946–51 дә Татарстан дәүләт нәшриятында яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире, 1952–61 дә «Пионер» ж-лы җаваплы мөхәррире. Беренче очерклары һәм хикәяләре «Кара баганалар» җыентыгында (1931) басыла. Балалар өчен язылган «Йолдыз» (1935), «Солдат балалары» (1948), «Яңа дуслар» (1954) исемле хикәяләр җыентыклары, Татарстанда нефть сәнәгате барлыкка килү турында «Кара алтын» (1947), «Яшәү көче» (1951) дигән очерк китаплары авторы. «Серләр» (1948), «Егет сүзе» (1954) пьесалары Казан, Уфа, Бөгелмә, Екатеринбург театрларында куела, рус һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителә. Ә. татар халык иҗаты әсәрләре тупланган «Халык иҗаты» (1938, 1940; Х.Ярми б-н бергә), «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» (1942), «Мәкальләр» (1948), «Табышмак әйтәм — табыгыз» (1949) җыентыкларын төзүче. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1964; Пьесалар. К., 1981; Рассказы. К., 1974.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Советские детские писатели: Биогр. словарь. М., 1961.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**ӘХМӘ́Т бине́ РӘФЫ́ЙК әс-СӘМАКЫ́Й** (?-1835 яисә 1836), дин белгече һәм эшлеклесе. Г.Курсави шәкерте. Уфа губернасындагы Сәмәк авылы мәчете имамы һәм мәдрәсә мөдәррисе. Хезмәтләре ислам дине гыйлеменең төрле өлкәләренә карый.

**ӘХМӘ́Т** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында. Олы Сөлчә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 7,1 *км*, бассейнының мәйданы 10,6 *км²*. Аксубай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Әхмәт авылының көньяк читендә, тамагы Покровка авылыннан көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 135 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. 0,4 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,25 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында суының артуы һәм җәен саегуы б-н үзенчәлекле. Челләдә елга кибә. Суы бик каты (9–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ӘХМӘ́Т** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 29 *км* көньяктарак, Әхмәт елгасы буенда. 2002 елда 104 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Аксубай р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь,

1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 180, 1949 да — 140, 1958 дә — 156, 1970 тә — 213, 1979 да — 173, 1989 да — 120 кеше.

**ӘХМӘ́Т** (Акмөхәммәт) авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Лашчы елгасы буенда. 2002 елда 181 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.тә мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, тимерче алачыгы, 3 җил тегермәне, мануфактура һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1160,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында; 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 123 ир заты; 1859 да — 615, 1897 дә — 935, 1908 дә — 1038, 1920 дә — 1032, 1926 да — 646, 1938 дә — 683, 1949 да — 500, 1958 дә — 515, 1970 тә — 444, 1979 да — 470, 1989 да — 249 кеше.

*Әд.:* Буа ягым — Тау ягым = Буинские просторы. К., 2000.

**ӘХМӘ́Т** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зичә елгасы буенда. 2002 елда 240 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балта эше б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы крәстияннәр сугышында җирле халык, коралы отряд оештырып, пугачёвчылар ягында көрәшә. 1844 тә Ә. тә агач мәчет (1904 тә кирпеч бинасы торгызыла, архит-ра истәлеге) төзелә. Мәчет каршында мәдрәсә эшли. Ә. халкының бер өлеше православие динен тота. 1870 еллар ахырында авылда миссионерлык мәктәбе ачыла, 19 йөз ахырында агач чиркәү төзелә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1565 дис. тәшкил итә. 1929–30 елларда Ә. тә «Дон» к-зы оештырыла, 1950 дән ул «Якты йолдыз» (1998 дән — а.х. товарлары җитештерү кооперативы) к-зына керә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1795 тә — 145 ир заты; 1859 да — 506, 1870 тә — 603, 1913 тә — 1271, 1926 да — 817, 1938 дә — 753, 1949 да — 560, 1958 дә — 427, 1970 тә — 470, 1979 да — 391, 1989 да — 222 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ӘХМӘ́Т** посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Брустан елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 30 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 1820 дә Сембер губернасының Ардатов өязеннән һәм Түбән Новгород губернасының Сергач өязе Алексеевка авылыннан күчеп килгән руслар нигез сала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә (торак пунктның исеме аның беренче хуҗасы — корнет Ф.Ф.Әхмәтов фамилиясеннән алынган). Акрынлап монда Куян авылыннан татарлар килеп урнаша башлый. Крәстияннәр игенчелек, терлек асрау, ит сату һ.б. б-н шөгыльләнәләр. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.тә җил тегермәне була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 88 дис. тәшкил итә. 1907 дә крәстияннәр, ширкәт оештырып, алпавыт А.Н.Исаевтан тагын 190 дис. җир сатып алалар. 1931 дә, ике уңышсыз омтылыштан соң, колхоз оештырыла, 1950 дә ул «Дружный», соңрак «Победа» к-зы составына керә. Хәзерге вакытта «Гигант» к-зының бер бүлекчәсе. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Матвеевка волостенда була. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1834 тә — 179, 1859 да — 106, 1870 тә — 188, 1913 тә — 135, 1921 дә — 152, 1926 да — 139, 1938 дә — 145, 1949 да — 89, 1958 дә — 66, 1970 тә — 83, 1979 да — 69, 1989 да — 39 кеше.


**ӘХМӘ́Т** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 12 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе чигендә. 2002 елда 200 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1920 еллар башында нигез салына. Рус чыганакларында Ахметкино исеме б-н дә мәгълүм. ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1926 да — 254, 1938 дә — 270, 1949 да — 220, 1958 дә — 208, 1970 тә — 302, 1979 да — 233, 1989 да — 138 кеше.

**ӘХМӘ́Т** т и м е р  ю л  р а з ъ е з д ы посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар, руслар) саны 10 нан ким. 1951 дә нигез салына. Халык саны: 1958 дә — 85, 1970 тә — 31, 1979 да — 24, 1989 да — 11 кеше.

**ӘХМӘ́Т ЭЛЕКТРОМЕХА́НИКА ЗАВОДЫ́**, Буа р-ны тимер юл разъездының Лашчы посёлогында урнашкан. 90 кеше эшли (2005). 1958 елда Әхмәт МТСы (1953 тә нигез салына) җирлегендә оештырыла. 1995 тән АҖ. Завод 0,4–110 кВ көчәнешле электротапшырулар линиясе һәм элемтә линиясе өчен корыч җайланмалар җитештерә; механика һәм тимерчелек цехлары, баш механик һәм энергетик бүлекләре, инструментлар, транспорт һәм төзелеш участоклары бар. Җитештерү заманча җиһазландырылган. Төп кулланучылары РФнең энергетика һәм элемтә пр-тиеләре. Чимал б-н Чиләбе, Магнитогорск, Череповец металлургия комб-тлары тәэмин итә. Завод җитәкчеләре: В.П.Пстыгин (1964–68), М.Ф.Вафин (1970–75), М.Ш.Насретдинов (1979–87 һәм 1991 дән), Ф.Л.Салиев (1987–90), В.П.Сергеев (1990–91).

**ӘХМӘТВӘЛИ́ЕВ** Расих Хасип улы (24.12.1956, Башкортстан АССРның Чишмә р-ны Бикәй а.), нәкышьче, Башкорт пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1981). 1991–92 дә АКШта. Рәссамнарның «Чыңгызхан» иҗат берләшмәсе әгъзасы (1990 нан), Рәссамнар берлеге әгъзасы (1993). Аның «Бикәй киче» (1990), «Уралга кошлар кайта» (1990), «Малайлар» (1991), «Идел буйлап





Р.Х. Ә х м ә т в ә л и е в. 1. «Иртә. Җайдаклар». 1990. «Шәрекъ» фондының «Мирас» галереясы (Уфа); 2. «Әңгер-меңгер. Тәрәзә янындагы кыз». 1993.

сәяхәт» (1992) картиналары образларның ассоциативлыгы, абстракт сәнгать тәэсире, нәкышь фактурасының катлаулылыгы б-н аерылып тора. Төп әсәрләрен («Июнь, 1993»; «Үтеп баручы кызлар», «Малай һәм хатын», 1994; «Якты кич», 1996; «Рәссам һәм муза», «Классикага иярү», 1996) Шәрекъ ислам мәдәниятенә хас декоративлык принциплары б-н 20 йөз башы Көнбатыш нәкышь казанышлары, аерым алганда, аның авангард юнәлеше (В.В.Кандинский, Пауль Клее) традицияләрендә иҗат итә. Ә. иҗатының лейтмотивы — төрки Җайдак — Евразия хәтер сакчысының серле образы («Җайдак», «Күккә очучы җайдак», икесе дә — 1994; «Онытылган төрки җайдак» (1995); «Карт җайдак, яшь җайдак», 1997).

1990 еллар ахырында Ә. төсләрнең үзенчәлекле төсмерләр ритмикасы б-н киңлек һәм

вакыт иркенлеге аша ачылган әсәрләр иҗат итә («Актан киенгән кыз», 1999; «Зөяктән хат», 1999; «Фонтан янындагы ике кыз рәсемен ясаучы рәссам», 2000). Халыкара (Австрия, 1992, 1993; Будапешт, 1994; Истанбул, 1996), төбәкара (*ТАТАРТ* — С.-Петербург, 1991; Казан, 1991) күргәзмәләрдә, Мәскәүдә ел саен үткәрелә торган халыкара сәнгать салоннары күргәзмәләрендә (1996 дан) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Уфа (1997), Мәскәү (1998) шәһәрләрендә күрсәтелә. Әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясында, М.В.Нестеров исем. Сәнгать музеенда (Уфа), «Казан» Милли-мәдәни үзәгенең Милли мәдәният музеенда, «Туран» фондында (Казан), Россиядәге һәм чит илләрдәге аерым шәхесләр коллекцияләрендә саклана. 2002 дән Франциядә яши.

*Әд.:* Восток и Запад: Каталог выставки. Уфа, 1994; Современное изобразительное искусство Башкирии: Каталог выставки. Уфа, 1997; Мусина Р. Всадник, уходящий в небо // Культура. 1998. 16 апр.; Расих Ахметвалиев. Живопись: Каталог выставки. М., 1998; «Чингисхан»: Альбом. СПб., 1999.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Р.Г.Шаһиева.*

**ӘХМӘТВӘЛИ́ЕВ** Фәхразый Миңлевәли улы (5.11.1926, Самара өлкәсенең Челно-Вершинск р-ны Денискино а.), генерал-майор (1976). Тбилиси артиллерия уч-щесен (1945), М.И.Калинин исем. Хәрби артиллерия академиясен (1961, Ленинград), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясен (1970, Мәскәү) тәмамлый. 1971–77 елларда Кавказ арты хәрби округының артиллерия һәм ракета гаскәрләре башлыгы урынбасары, башлыгы. 1977–83 тә Европадагы Көньяк гаскәрләр төркеменең артиллерия һәм ракета гаскәрләре башлыгы. 1983–88 дә М.И.Калинин исем. Хәрби артиллерия академиясендә факультет башлыгы. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ӘХМӘТГАЛИ́ЕВ** Ильяс Ибраһим улы (2.2.1927, Казан — 1.2.1993, шунда ук), механика һәм автоматик идарә итү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1977), проф. (1978). 1951 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1968 дән автоматик идарә итү каф. мөдире. 1979 дан Ленинград авиация приборлары төзү ин-ты профессоры. Хезмәтләре автоматик идарә итүнең нәсызыкча системалары тотрыклылыгына һәм синтезына карый. Бәйләнешләре антисимметрик кисешкән ике каналлы автоматик идарә итү системасы теориясен, нәсызыкчалыгы күп төрле системаларның вертикаль һәм горизонталь декомпозициясен берьюлы тикшерү теориясен төзи; тотрыклылыкны тикшерү, бирелгән үзлекләре буенча системаларны синтезлау һәм аларның тарту өлкәләрен бәяләү өчен эйлерча диярлек матрицалар аппаратын эшли. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Матричные методы анализа нелинейных систем управления. Л., 1982; Синтез нелинейных систем автоматического управления с применением ЭВМ. Л., 1984; Оценки решений дифференциальных уравнений. К., 1993.

**ӘХМӘТГАЛИ́ЕВ** Мөхәммәт Ибраһим улы (21.2.1920, Казан — 27.8.1943), шагыйрь. 1938–41 елларда Казан пед. ин-тының биол. ф-тында укый. Шигырьләре 1935 тән басыла. Балалар өчен язган шигырьләре «Яшь ленинчы» г-тасында, «Пионер каләме» ж-лында, «Шат балалык» (1938), «Очкыннар» (1940) кебек күмәк җыентыкларда дөнья күрә. 1942 елда фронтка китә, Смоленск тирәсендә барган сугышларда һәлак була.

Әсәр.: Балык тотканда. К., 1957; Тегүче куян. К., 1959; Елак батыр. К., 1960; Әгәр кайта алмасам, онытмагыз // Казан. 1996. № 2.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ӘХМӘТГАЛИ́ЕВ** Хәсән Әхмәтгали улы (5.5.1942, Минзәлә р-ны Иске Абдул а.), Тукай р-нының «Татарстан» с-зы директоры (1973–93), ТАССРның атказ. икътисадчысы (1984). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1970). Ул җитәкчелек иткән елларда с-зда бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 12 *ц* дан 33 *ц* га кадәр арта, 1 савым сыердан 3400 *кг* сөт алына. 1992 елда җитештерүнең рентабельлелеге 66% була. А.х. культураларын игүдә интенсив технология кертелә, терлекчелек һәм игенчелектәге авыр эшләр механикалаштырыла, хуҗалык эчендә аренда кулланыла. Социаль һәм мәдәният объектлары төзелә. 1983 тә совхозга КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКнең күчмә Кызыл Байрагы тапшырыла. Халыклар Дуслыгы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘТҖА́Н БОЛГАРИ́** (тулы исеме Әхмәтҗан бине Шәмсетдин әл-Абави әс-Самари әт-Тубыли) (1826, хәзерге Лениногорск р-ны Сарабиккол а. — 1890 нан соңрак, Тубыл ш.), шагыйрь, дин эшлеклесе, туган авылында имам булып торган. Г.Утыз Имәнинең кияве. 1871 елда нахак шикаять б-н кеше үтерүдә гаепләнә, гомерлеккә Тубыл шәһәре төрмәсенә утыртыла. 1886 да җирле татар-мөселман җәмәгате үтенече б-н төрмәдән чыгарыла. 1889 елдан Тубыл шәһәре янындагы Ишай авылының (хәзер юк) имам-хатибы һәм мөдәррисе. Ә.Б. иҗат мирасыннан төрмәдә чакта татар, гарәп, фарсы телләрендә язган шигырьләр җыелмасы, моннан тыш, күп кенә шигъри хатлар, вафат булган замандашлары яисә туганнары (мәс., Утыз Имәнинең җәмәгате һәм улы, үзенең кызы Мәрвәрелҗиһан) истәлегенә язган мәрсияләр һ.б. жанрдагы әсәрләр сакланып калган. Арада мәхәббәт лирикасы да зур урын алып тора. Ә.Б. «Ләйлә вә Мәҗнүн» кыйссасының татарча версиясе авторы буларак та билгеле. Ә.Б.ның поэзиясе фәлсәфи уйланулар һәм суфичылык мотивлары б-н сугарылган, шигъри стилендә Утыз Имәни поэзиясенең тәэсире нык сизелә. Кульъязмалары ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының Кульъязмалар һәм текстология бүлеге фондында саклана.


*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли // Казан утлары. 1997. № 1.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ӘХМӘТҖА́Н бине ӘМИРХА́Н әл-УШМАВЫЙ** (1783 тирәсе — 1813), дин белгече. Г.*Курсави* шәкерте һәм фикердәше. Казан арты мәдрәсәсендә укый, белемен Каһирә уку йортларында камилләштерә. Дин гыйлеменә караган күпсанлы хезмәтләрендә, Ш.Мәрҗани раславынча, *фикъһ* һәм гарәп телен өйрәнүнең яңа ысулларын тәкъдим итә. Кульъязма китапларының язмышы билгесез.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**ӘХМӘТҖА́Н бине ГАБДЕРӘХИ́М әл-БОЛГАРИ́** (1800 тирәсе — 1848, июль), шагыйрь, хаттат. Г.*Утыз Имәни*нең улы. Тимәш авылында яши һәм иҗат итә (хәзерге Лениногорск р-ны Ромашкино а.). «Гөлшән-е әнвар» («Гөлләр бакчасы») һәм «Кыйссас әл-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы», 1845–46), «Мирьат әл-әхлак» («Әхлак көзгесе») шигъри җыентыкларына кергән дини



«Мәҗмуга»ның бер бите. Төсле язу карасы, каз каурые һәм корыч каләм. 1890 еллар.

сюжетлы тәрбияви шигырьләр авторы. Хаттатчылык осталыгын атасы нигез салган мәдрәсәдә үзләштерә. Гарәп язуының тәгълек имлясы б-н атасының фарсы һәм гарәп телләрендәге «Морад әл-гарифин» («Мәгърифәтлеләрнең максаты», 1820–30), «Мәҗмуга» («Әдәби җыентык», 1845–46), «Төхфәт әл-әхбаб» («Дусларга бүләк», 1840 еллар) һ.б. әсәрләрен күчереп яза. Кульъязма битләрен үсемлек рәвешендәге орнаментлар б-н бизи, текстны кысалау өчен алтын йөгертелгән кайма, гарәп язуының детальләрен көчәйтү максатыннан кызыл тушь куллана. Ә. әсәрләре ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты архивында һәм Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсендә саклана.

*Әд.:* Исәнбаев С. 19 нчы йөз татар әдәбияты тарихына бер материал // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1959; Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли // Казан утлары. 1997. № 1.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Әшрәф Госман улы (12.3.1927, Башкортстан АССР, Дәүләкән



Ә.Г. Әхмәтҗанов.

р-ны Яңа Мерәс а. — 16.12.1986, Дәһли; Мәскәүдә җирләнгән), халыкара сәясәт журналисты, тарих фән. канд. (1969). Г.Утыз Имәни нәселеннән. Бөек Ватан сугышында катнаша. Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1956), СССР ФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-тында фәнни хезмәткәр. 1958–60 елларда Бхилаи (Һиндстан) металлургия комб-тында урду һәм һинд телләреннән тәрҗемәче. 1963–68 дә «Азия и Африка сегодня» ж-лында (Мәскәү) эшли. Фәнни мәкаләләрен Иранда, ТАССның (1968–73), шунда ук, Төркия һәм Әфганстанда (1976–80) һәм Һиндстанда (1983–86) «Известия» г-тасының үз хәбәрчесе булып эшләгәндә туплаган материаллары нигезендә яза. Хезмәтләре Якын Көнчыгыш һәм Азия илләренең фәлсәфәсенә, диненә, яңа һәм иң яңа тарихына, милли проблемаларына, сәяси һәм икътисади хәлләренә, мәдәниятенә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Политическая идеология индусских религиозно-общинных партий // Общественно-политическая и философская мысль Индии. М., 1962 (автордаш); Деятельность мусульманских общинных организаций в современной Индии // Краткие сообщения Института народов Азии (АН СССР). 1964. № 75; Иран, каким я его видел? М., 1990.

*Әд.:* Биобиблиографический словарь отечественных востоковедов. М., 1995; З а м а н о в а Г.Р. Ашраф Ахмедзянов и его книга «Иран, каким я его видел?» // Россия и Иран. Иранистика в Татарстане: Сб. статей. М., 2001.

*Г.Р.Заманова.*

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Госман Нигъмәтҗан улы (23.6.1925, Әтнә р-ны Югары Бәрәскә а. — 27.10.2005, Казан), актёр, радио режиссёры, шагыйрь, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1976). Бөек Ватан сугышында катнаша. Татар театр техникумын тәмамлый (1949). 1949–60 елларда Татар акад. театрында актёр. Төп рольләре: Мирхәйдәр («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Шәйхулла («Тормыш җыры», М.Әмир), Заһри («Шәмсекамәр», М.Әблиев). 1960–86 да ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында, 1965–86 да һәм 1995 тән радио режиссёры. Х.Сәлимҗанов, Г.Хөсәенов, Ш.Мәҗитов кебек татар театр эшлеклеләренең традицияләрен дәвам иттереп, татар радиосында радиодрама жанрын үстерүгә зур өлеш кертә. Радиода куйган төп радиоинсценировкалары: «Улым белән очрашу» (1963, Ч.Айтматов), «Көн яктысында» (1965, Э.Казакевич), «Рапад белән Ямгуҗай» (1970, А.Хәлим), «Олы юлның каены» (1984, И.Юзеев), «Кыйссаи Йосыф» (1980, Кол Гали), «Бәхәс» (1993, Җ.Рәхимов), «Колшәриф» (1993, Ә.Рәшит), «Каракош» (1994, Ә.Баян), «Кызлар хатлары» (1999, А.Гыйләҗев). Аның шигырьләренә Ф.Әхмәтов, Р.Еникиев, Н.Җиһанов, Ш.Мәҗитов, Ф.Яруллин һ.б. композиторлар тарафыннан көйләр языла. Н.Җиһановның «Качкын» операсы либреттосын рус теленә тәрҗемә итә (клавиры 1982 дә басыла). Әкиятләр, әдәби әсәрләр, Казан кинохроника студиясе өчен тулы метражлы нәфис фильмнарның сценарийларын татарчага тәрҗемә итә. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Үзешчән театр. К., 1957 (автордаш).

*Г.Р.Заманова.*

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Җәүдәт Касыйм улы (6.1.1939, Алексеев р-ны Кыр Шонталасы а.), Алексеев р-нының «Зур Тигәнәле» а.х. кооперативы (1996 елга кадәр «Разумовский» с-зы) директоры (1975–2000), ТАССРның атказ. механизаторы (1985). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Вахитов исем. к-зда баш инженер булып эшли, 1972–75 тә Алексеев ремонт-техника станциясендә баш инженер. Ул җитәкләгән елларда «Разумовский» с-зында бөртеклеләрнең 1 *га* дан уңышы 15,5 *ц* дан 32 *ц* га һәм аннан да күбрәккә күтәрелә, 1 сыердан савылган сөт 2600 *кг* нан (1970 тә) 4200 *кг* га кадәр җитә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Зәйнетдин Низаметдин улы (21.9.1897, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Гафури р-ны Ялгыз Каен а. — 30.1.1990, Уфа), Сов. Союзы Герое (23.9.1944), ефрейтор (1944). 1942 елга кадәр колхозда эшли. 1942 нең гыйнварыннан Кызыл Армиядә, 1943 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 134 нче аерым гв. сапёрлар батальоны сапёры (1 нче гв. танк армиясенең 11 нче гв. танк корпусы). Төньяк-Көнбатыш, Воронеж, 1 нче Украина, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украинаны, Польшаны азат итүдә, Берлинга һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. 1944 нең 30 июлендә Көнбатыш Буг елгасын кичкәндә Сокаль шәһәре (Львов өлкәсе) янында барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Уфа шәһәрендә яши. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2; Звёзды доблести боевой. Львов. 1968; А л е щ е н к о Н.М. Долг и подвиг. М., 1981.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Илдус Хәниф улы (19.6.1950, Баулы р-ны Татар Кандызы а.), драма актёры, ТРның халык артисты (1996). Ленинград театр һәм кинематография ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), Татар акад. театры труппасында эшли. Драматик характерларны тирәнтен ачуы, югары сөйләм культурасына ия булуы актёрга татар драматургиясендә хәтердә калырлык образлар тудырырга ярдәм итә. Шундыйлардан Рәүф («Ике килен-килендәш», Х.Вахит), Шәйхел («Татар хатыныниләр күрми», Г.Ибраһимов), Закир, Сираҗетдин («Бәхетсез егет», «Банкрот», Г.Камал), Тукай («Без китәбез, сез каласыз», Т.Миңнуллин), Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Әхмәтҗан («Зөләйха», Г.Исхакый), Субра («Идегәй», Ю.Сафиуллин) һ.б. Диоген («Баскетболист», М.Гыйләҗев), Мкртыч («Ханума», А.Цагарели) кебек рольләрдә аның иҗат үзәнчелеге гротеск дәрәҗәсенә җитә. Т.Миңнуллинның «Алты кызга бер кияү» пьесасы буенча куелган спектакльдәге Рәхмәтулла образында актёр олы яшьтәге бухгалтерның тышкы яктан көлкеле булып күренгән характеры астындагы кешелеклелеген дә, ш.у. эчке киеренкелеген дә ачып бирә. 1988 елда Ч.Айтматов повесте буенча куелган «Ахырзаман» спектаклендә башкарган Бастон роле өчен Ә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләгенә лаек була. Тел үзенчәлекләрен тирән тоя белүе актёрга нәфис сүз сәнгатен камил үзләштерергә мөмкинлек бирә. Концертларда, радио һәм телевидениедә Г.Тукай шигырьләрен һәм аның әсәрләреннән төзелгән поэтик композицияләр укый (ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 2000). Татар акад. театры сәхнәсендә аның тәрҗемәсендә У.Шекспирның «Антоний һәм Клеопатра», «Ромео һәм Джульетта» әсәрләре куела.

*И.И.Илялова.*



З.Н. Әхмәтҗанов.



И.Х. Әхмәтҗанов.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Ислам Галиәхмәт улы (15.4.1948, Буа р-ны Норлат а.), журналист, публицист, тарих фән. канд. (1999), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). Казан ун-тын (1972), Ленинградтагы Югары партия мәктәбен (1986) тәмамлый. 1972 елдан «Социалистик Татарстан» г-тасы редакциясендә эшли. 1978–82 дә «Татарстан яшьләре» г-тасының баш мөхәррире. 1982 дә Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан өлкә ком-тында оештыру эшләре бүлеге мөдире. 1983–84 тә «Социалистик Татарстан» г-тасының үз хәбәрчесе, 1986–89 да җаваплы сәркәтибе. 1990–92 дә «Татарстан хәбәрләре» г-тасында баш мөхәррир урынбасары. 1992–99 да ТРның матбугат һәм мәгълүмат министры. 1999 елдан «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ген. директоры. Хезмәтләре Татарстанда массакүләм мәгълүмат чаралары үсешенә, журналистика проблемаларына, татар теленең хәзерге торышына, бүгенге заман геройларының эчке дөньясын ачып бирүгә карый. Татарстан Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. республика (1978) һәм СССР Журналистлар берлеге (1991) бүләкләре лауреаты, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мамадыш — яңарышта. К., 1989; Буа ягым — Тау ягым. Буинские просторы. К., 2000; Туган туфрак кадере (автордаш). К., 2003; Свобода доступа к информации // Татарстанская модель: Мифы и реальность. К., 1997; Сабантуй (автордаш). К., 2006.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Кәрам Нуриман улы (5.1.1932, Чирмешән р-ны Бәркәтә а.), агро-

ном-галим, икътисадчы, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1991). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1972). 1958–66 елларда Чирмешән р-ның «Чишмә» к-зында баш бухгалтер, 1966–92 дә колхоз рәисе. Ул җитәкләгән елларда колхозның матди-техник базасы ныгытыла: авыр хезмәт процесслары механикалаштырылган терлекчелек биналары, ашлык һәм терлек азыгын эшкәртү һәм саклау базалары, техника ремонтлау мастерскойлары, а.х. машиналарын, тракторлар һәм автомобильләрне кую урыннары, 420 *га* сугарулы җирләр булдырыла. Колхоз хисабына бөтен уңайлыклары булган фатирлар, социаль-көнкүреш һәм мәдәният объектлары төзелә, авылларга газ кертелә, 23 *км* сууткәргеч торбалар сузыла, 23 *км* каты өслекле юллар, 100 номерга исәпләнгән телефон станциясе һ.б. төзелә. Бөртекле ашлык игү 20% ка, шикәр чөгендере — 50% ка, ит һәм сөт җитештерү 2 тапкырдан күбрәккә арта. Ә. 1980–85 тә РСФСР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Марат Халикъ улы (13.10.1932, Казан), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1971), проф. (1973), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1984), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1980). 1956 елда Новосибирск тимер юл транспорты инженерлары ин-тын (хәзер Себер тимер юллар ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1971 дән — теоретик механика, 1984 тән төзелеш механикасы каф. мөдире, бер үк вакытта 1974–83 тә ин-т ректоры. Хезмәтләре теоретик һәм гамәли механикага карый; конструкцияләрнең һәм машиналарның мөһим элементларындагы көчәнешләрне һәм деформацияләрне тикшерү өчен фотосыгылма каплам ысулын эшли. Тимер юл объектларының ныклыгы проблемасын тикшерә. Дәүләт бүләге полярлаштыру — оптика ысулын үстерү буенча тикшеренүләр циклын эшләгәне өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Поляризационно-оптические методы механики деформируемого тела. М., 1973; Сопротивление материалов. Новосиб., 1997; Основы прикладной теории упругости и пластичности. Новосиб., 2000.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Марсель Ибраһим улы (26.3.1939, Шөгер р-ны Шөгер а.), әдәбият галиме, археограф, филол. фән. д-ры (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1972 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли, 1986 дан ин-тның (1997 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының) кулъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсен җитәкли. Г.Ибраһимов (т. 1–9, 1974–2000), Һ.Такташ (т. 1–3, 1980–83), Ф.Әмирхан (т. 1–4, 1984–86) әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә катнаша. Татар мәдәнияте тарихы проблемаларын өйрәнүдә үзен күпкырлы фәнни тикшеренүче буларак таныта; әдәбият белеме һәм текстология өлкәсенең актуаль мәсьәләләренә багышланган язмалар авторы. Хезмәтләре милли шәҗәрәләр, татар әдәбияты, теле, фольклоры, сәнгате, эпиграфикасы, кулъязма китабы тарихына карый. Аның тарафыннан 3500 дән артык кулъязма китап, 320 шәҗәрә, 1500 тарихи документ җыела һәм тасвирлана.

Х е з м.: Мөхәммәдъяр һәм аның чоры. К., 1997; Дастаннар китабы. К., 1999; Татар кулъязма китабы. К., 2000; Үлгәннәрнең каберен бел. К., 2000; Татарские шеджере (Исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах по спискам XIX–XX вв.). К., 1991; Память о предках татар Поволжья и Приуралья: (Судьба татар ногайской орды); К., 2007.

*Әд.:* Ә м и р х а н Р. Мәрҗанинең рухи варисы // Мирас. 1997. № 3.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Мәхмүт Рәхимҗан улы (псевд. М.Рәхимов) (14.2.1927, Башкортстанның Салават р-ны Нәсибаш а.), журналист, язучы, педагог, пед. фән. канд. (1973), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1950). 1950–59 елларда Әгерҗе шәһәрендә урта мәктәптә тарих укытучысы. Язмалары 1955 тән басыла башлый. 1959–70 тә «Совет мәктәбе» ж-лында бүлек мөдире. 1973–88 дә Казан пед. ин-тында укытучы, доцент. Балаларны гаиләдә һәм мәктәптә тәрбияләү мәсьәләләренә, халык педагогикасы һәм иҗтимагый-сәяси темаларга багышланган язмалары «Казан утлары», «Мәгариф», «Мирас», «Идел», «Татарстан» ж-лларында һәм республика г-таларында басыла. Татарстан радиосында сәяси темаларга тапшырулар алып бара. Мәкаләләре рус, немец, грек, поляк, болгар, корея һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. Халыкара Кол Гали исем. (1999), ТР Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләкләр лауреаты (1994).

Ә с ә р.: Без яшәгән якларда. К., 1969; Укучыларга идея-политик тәрбия бирү. К., 1978; Укучыларга әхлак тәрбиясе бирү. К., 1981; Гаиләдә әхлак тәрбиясе. К., 1985; Килер бер көн... К., 1998; Тормыш мизгелләре. К., 2002; Яманны юлдаш итмә. К., 2007.

*Әд.:* Я р у л л и н Ф. «Килер бер көн...» // Мирас. 1999. № 11; Ә м и р х а н о в М. Сөбханалла, күз тимәсен! // Мәдәни җомга. 2007. 9 февр.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Миңнехан Газиз улы (25.8.1931, Мамадыш р-ны Акман а.), әдәбият галиме, пед. фән. д-ры (1996), проф. (1997), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). Мамадыш (1948–63), Казан (1963–71) урта мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1971 елдан Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан филиалында эшли, 1977 дән Казан пед. ин-тында, 1988–99 да әдәбият каф. мөдире, 1999 дан рус, чит ил әдәбиятлары һәм аларны укыту методикасы каф. профессоры. Хезмәтләре татар мәктәпләрендә рус әдәбиятын укыту методикасына карый. Татар мәктәпләрендә һәм милли мәктәпләрдә рус әдәбиятын укыту дәреслекләре һәм хрестоматияләр авторы.

Х е з м.: Изучение литературных взаимосвязей в татарской школе. К., 1979; Вопросы преподавания русской литературы в национальной школе. Л., 1982 (автордаш); Уроки внеклассного чтения в 4–7 классах национальных школ. Л., 1985 (автордаш).

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Рәшит Хәниф улы (14.4.1941, Баулы р-ны Татар Кандызы а. — 5.1.1995, Казан), шагыйрь, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1969–74 елларда ТАССР Мәдәният министрлыгында инспектор, «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» г-таларында әдәби хезмәткәр, 1980 нән «Казан утлары» ж-лы редакциясендә. Әсәрләре 1950 еллар ахырында басыла башлый. «Хыялларым үзем белән» дип аталган беренче шигъри җыентыгы 1965 елда дөнья күрә. Шигырьләренә нечкә лиризм, образлар байлыгы, шигъри интонацияләрнең кискенлеге хас. «Ак канатлар» җыентыгында (1972) яшь кешенең уйланулары һәм кичерешләре, аның хезмәткә һәм җәмгыять алдында торган бурычларына мөнәсәбәте тасвирлана. Лирик герой — үз идеаллары булган, үз халкының киләчәгенә ышанган кеше. 1980 елларда милли психологияне, халыкның ирек сөючән рухын чагылдырып язган шигырьләре Ә.ка аеруча зур популярлык китерә («Җан яктысы» (1980), «Кавышыр көн» (1985), «Йөрәк бәйрәме» (1988), «Моңлану» (1991), «Ачлык мәйданы» (1994) җыентыклары). Популяр җыр текстлары авторы. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (1992).

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: Шигырьләр һәм поэмалар. К., 1998; Сәфәр ае. К., 2001.

*Әд.:* Т у ф а н Х. Өметләрне аклады // Казан утлары. 1971. № 9; Б а т у л л а Р. Акчарлакның сагышы // Казан утлары. 1996. № 1.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Роберт Вәли улы (1.4.1935, Балык Бистәсе р-ны Балык Бистәсе а.), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1962–63 елларда Татар опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире, 1964–98 дә «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Яңа аваз», «Заман-Татарстан», «Шәһри Казан» г-таларында әдәби хезмәткәр. 1958 дә «Егерменче яз» исемле беренче шигырь җыентыгын бастыра. Ә.ның шигырьләренә форма һәм интонациянең оригинальлеге, лирик герой фикерләвенең киеренкелеге, хисләрнең нечкәлеге, романтик күтәренкелек хас. «Йолдызстан» (1964), «Еллар яна» (1968), «Сәгать суга» (1970), «Таң шәһәре» (1974), «Июнь иле» («Страна Июнь», рус теленә тәрҗемә, М., 1979), «Хәтер елгасы» (1980), «Гомер тирәге» (1985), «Орчык җыры» (1988), «Тургай тәрәзәсе» (1995), «Татар иртәсе» (2004) һ.б. шигъри җыентыкларында Ә. замандашларының бай эчке дөньясын тирән чагылдырган нечкә хисле лирик булып танышла. Ә. иҗатының үзенчәлеге әдипнең идея-әхлак позициясендә, дөньяга фәлсәфи карашында чагыла. Ә. татар поэзиясендә баллада жанрын үстерүгә шактый өлеш кертә («Таш елады», «Гармун турында баллада», «Яралы арыслан» һ.б.). Ә.ның кайбер шигырьләре, көйгә салынып, халык арасында популяр җырга әверелә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2001).

Ә с ә р.: Идел-йорт: Шигырьләр, поэмалар. К., 1972; Җәяүле күбәләк: Сайланма әсәрләр. К., 1990; Таш аргамак: Поэмалар, балладалар. К., 2005.

*Әд.:* К у к у ш к и н Р. Канатлы дөнья. К., 1984; Ю н ы с М. Альбатрос язмышы. К., 2002.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Фоат Шәйхетдин улы (3.2.1944, Кама Тамагы р-ны Олы Кариле а.), онколог, мед. фән. канд. (1983). РФнең атказ.

табибе (1995). 1968 елда Казан. мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан мед. оешмаларында эшли. Проф. М.З.Сигал шәкерте. 1976 дан Казан мед. ун-тында, 1998 дән онкология курслары мөдире, бер үк вакытта (1989 дан) Казан хакимияте каршындагы Сәламәтлек саклау идарәсенең баш онкологы. Тикшеренүләре ашказаны, бавыр, ашказаны асты бизе, үңәч, юан һәм туры эчәкләр рагы авыруларын хирургик дәвалауга, сөт бизләрендә рак авыруы вакытында әгъзаларны саклап калу операцияләре үткәрү; кичектергесез хирургик ярдәм күрсәтү мәсьәләләренә карый. ТР онкологлар җәмгыяте рәистәше (1996 дан).

Х е з м.: Гастроэктомия и резекция желудка по поводу рака. К., 1987; Расширенная лимфаденэктомия при операциях по поводу рака желудка // Методич. рекомендации Мин-ва здравоохранения. К., 1989.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Шамил Сабир улы (7.3.1941, Арча р-ны Курса Почмак а.), җырчы, ТАССРның халык артисты (1985). Казан музыка уч-щесен тәмамлаганнан соң (1967), ТАССР Җыр һәм бию ансамблендә солист, 1998 елдан хор төркемендә педагог-репетитор булып эшли. Хор өчен эшкәртелгән татар халык җырларын («Туган тел», Г.Тукай шигыре; «Уракчы кыз», Н.Исәнбәт шигыре; «Уел», «Кара урман», «Рәйхан» һ.б.), татар композиторлары Р.Яхин («Сорнай моңы», М.Хөсәен шигыре), А.Монасыйпов («Хәдичә», М.Җәлил шигыре) әсәрләрен һәм муз.-хореографик композицияләрдә («Аулак өй») ялгыз башкара. Уникаль киң диапазонлы, сирәк очрый торган тембрлы лирик баритон тавышка ия. Ә.ның башкару манерасы интонацияләрнең чисталыгы, милизмнарга бай булуы б-н аерылып тора.

*Әд.:* А х у н о в Г. Җыр йөрәктә туа // Әсәрләр. К., 1984. Т. 4; Х ә к и м С. Җырларның «Кызыл китабында» // Яшә, борчулы җаным. К., 1988.

*В.Горшков.*


**ӘХМӘТҖА́НОВ** Шамил Халикъ улы (13.5.1941, Казан — 31.1.2008, шунда ук), инженер-аэродинамик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1963). 1964–67 елларда Омск моторлар төзү з-дында инженер, бүлек мөдире. 1967 дән Казанда нефть чыгаруга бәйле сәнәгать һәм фәнни-конструкторлык оешмаларында әйдәп баручы инженер, баш технолог. 1994 тән ТатНИИнефтемаш АҖдә баш белгеч. Уйлап табу һәм ачышлар өлкәсендәге уңышлары өчен РФнең 3 патенты һәм 8 таныклыгы бирелә. «Экологик чиста технологияләр эшләү һәм файдалануга кертү, вакланмаган тузган шиннарны утильләштерү өчен сәнәгатьтә модульле җайланмалар комплексын җитештерүне оештыру» дигән хезмәте өчен ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге бирелә (2002).

*Л.Х.Хәмидуллин.*

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Юныс Әхмәтҗан улы (28.2.1927, Теләче р-ны Олы Кибәхуҗа а. — 12.2.1984, Казан), аш-су остасы. 1944 елдан җәмәгать туклануы системасында: 1951 дән Казан ашханәләре һәм кафеларында производство мөдире, 1968 дән Татар ашлары йортының производство мөдире. Татар халкының традицион милли ризыкларын әзерләү рецептларын туплый, эшкәртә һәм бастырып чыгара. Ленин, Халыклар Дуслыгы орденнары, СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең алтын медале б-н бүләкләнә.



Р.В.Әхмәтҗанов.



Ш.С.Әхмәтҗанов.



Д.Р.Әхмәтов.

Х е з м.: Татар ашлары. К., 1961; Табигать хәзинәсеннән ашлар. К., 1973; Татарская кухня. К., 1969.

**ӘХМӘТЗӘКИ́ бине́ САФИУЛЛА́ эл-АЛИ́Ш эл-МОРАСАВИ́** (1898–1995), дин эшлеклесе. Казан губернасы Чистай өязендәге «Кизләү» мәдрәсәсендә белем ала, шул өязнең Мораса авылына имам итеп билгеләнә. 1930 еллардан дини эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр була, Казанда төрле пр-тиеләрдә эшли. 1978–95 елларда Мәрҗани мәчетенең имамы. 1980 дә СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте казые һәм Голәмалар Шурасы әгъзасы итеп сайлана. Төбәктә абруйлы дин белгечләренең берсе була, күп шәкертләр әзерли.

**ӘХМӘ́ТОВ** Айдар Мансур улы (22.4.1968, Мәскәү), балет артисты, ТРның халык артисты (1995). 1986 елда Мәскәү акад. хореография уч-щесен тәмамлый. Мәскәүнең балет коллективларында: 1986–89 елларда һәм 1991 елдан «Балет театры»нда, 1989–90 да «Мәскәү шәһәр балеты»нда, 1990–91 дә «Хореография классиклары» труппасында солист. Р.Нуриев исем. халыкара классик балет фестивальләрендә чыгышлар ясый (1992–96). Татар опера һәм балет театрының балет труппасы б-н чит илләргә гастрольләргә чыга. Хореографик партияләре арасында: Альберт («Жизель», А.Адан), Солор («Баядерка», Л.Минкус), Көрд («Гаянэ», А.Хачатурян), Былтыр («Шүрәле», Ф.Яруллин), Зигфрид («Аккош күле», П.Чайковский), Базиль («Дон Кихот», Л.Минкус). Ә. иҗатына оста бию техникасы, «канатлы» сикерүләр, тәэсирле пластика хас. Халыкара конкурслар лауреаты: Америка (көмеш медаль, 1990), Франция (көмеш медаль, 1990), Финляндия (көмеш медаль, 1991), Япония (көмеш медаль, 1991), Италия (алтын медаль, «Гран-при», 1992), Люксембург (алтын медаль һәм «Гран-при», 1993).

**ӘХМӘ́ТОВ** Әрит Гариф улы (28.10.1932, Свердловск), тренер, судья (йөзү), РСФСРның атказ. тренеры (1984), Бөтенсоюз категорияле судья (1985), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1992). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1953). 1960 елдан тренерлык эшендә, Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә йөзү буенча өлкән тренер (1967–77), «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә һәм Профсоюзлар спорт җәмгыятендә (1977–92), бер үк вакытта 1960–80 елларда ТАССР, РСФСР, СССР җыелма командаларында тренер. Шәкертләре арасында — И.А.Нечаева.

**ӘХМӘ́ТОВ** Дамир Рәхми улы (17.8.1936, Сарман р-ны Хуҗи а.), Соц. Хезмәт Герое (1966). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1977). 1952 елдан Теләнче Тамак МТСында комбайнчы. 1959–67 елларда «Мәгариф» к-зында. Герой исеме техника куллануда югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. 1969–85 тә Сарман р-нының «Үрнәк» к-зы рәисе, 1985–96 да Мортыштамак авыл советы рәисе. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х ә й р у л л и н Х.Г. Хуҗида үскән батыр. К., 1972; Татарстанның Социалистик Хезмәт Геройлары (1938–78): Док. очерклар. К., 1980.

**ӘХМӘ́ТОВ** Илгизәр Җәләл улы (1.1.1929, Кукмара р-ны Олыяз а.), зоолог, биол. фән. д-ры (1985), проф. (1990), Үзбәкстан Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1999). Урта Азия ун-тын тәмамлаганнан соң (1956, Ташкент), Үзбәкстан терлекчелек ин-тында эшли. 1967 елдан Үзбәкстан ССР ФАнең Зоология һәм паразитология ин-тында, 1977–85 тә Физиол. ин-тында, 1987 дән Сырдәрья пед. ин-тында (Гөлстан ш.) гомуми биол. каф. мөдире. Хезмәтләре экологиягә һәм чүлдә тереклек итүче имезүче хайваннарның физиологиясенә карый. Тикшеренү нәтиҗәләре буенча канның биохимик үзенчәлегенә характеристика бирә, эссе климат шартларында яшәүче кимерүчеләрнең йокыга талган, авыру һәм эмоциональ стресслар алган һ.б. халәтләрдә калкансыман бизләрендә функциональ активлык үзенчәлекләрен ачыклый, сезонлы биоритмнары бозылганда, сөйрәлүчеләр һәм кимерүчеләрдә физиол. функцияләр үзгәрешен күрсәтә. Тауда тереклек итүче имезүче хайваннарны өйрәнү һәм саклау ысулларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Спячка животных и функция щитовидной железы // Общая биология. 1975. Т. 36, № 6 (автордаш); Лабораторные и дикие грызуны. Таш., 1981; Эколого-физиологические особенности рептилий и грызунов аридной зоны. Таш., 1985; Нутриеводство. Таш., 1988.

**ӘХМӘ́ТОВ** Исхак (18 йөз), 1773–75 елларда крәстияннәр кузгалышында катнашучы, Е.И.Пугачёв армиясе полковнигы. 1760 еллар урталарына кадәр Казан өязе Кавал авылында, аннары Оренбург губернасы Мостафа авылында яши. 1773 елның көзеннән Оренбург шәһәрендә; ноябрь башларында губернатор И.А.Рейнсдорп аны эш б-н ген.-майор В.А.Кар карамагына җибәрә. Ә. баш күтәрүчеләр ягына чыга. 1774 нең март ахырлары — апрель башларында аның Татищев кальгасы, Каргалы бистәсе һәм Сакмар шәһәрчеге

тирәләрендәге патша гаскәре б-н бәрелешләрдә катнашуы мәгълүм. 1774 нең маенда Уклы-Карагай кальгасын ала; Е.И.Пугачёв әмере б-н аңа полковник дәрәҗәсе бирелә. Шул елның июлендә Казанны алуда һәм подполковник И.И.Михельсон җитәкчелегендәге хәрби корпуска каршы сугышта катнаша; Казан өязендә баш күтәрүчеләрнең яңа отрядын туплый. Кулга алына һәм сөргенгә озатыла.

*Әд.:* Алишев С.Х. Пугачёв полковнигы // Казан утлары. 1984. № 7; шул ук. Татары Среднего Поволжья в Пугачёвском восстании. К., 1973.

**ӘХМӘ́ТОВ** Марат Гакыйф улы (1.7.1937, Казан), скрипкачы, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1976). Казан консерваториясен (Брауде классы, 1961), Мәскәү консерваториясе каршындагы аспирантураның башкаручылар бүлеген (солист-башкаручы белгечлеге буенча Д.Цыганов классын) тәмамлый (1964). 1964 елдан Казан консерваториясендә укыта, кыллы уен кораллары каф. проф. (1993). Ансамблист һәм солист-скрипкачы буларак, концерт эшчәнлеге алып бара. Репертуарында тематик концерт программалары, ш.и. И.С.Бах, Л.Бетховен, И.Брамсның скрипкада ялгыз башкару өчен, скрипка һәм фортепиано өчен тулы циклы сонаталары, П.Чайковский, Б.Барток, Р.Билаловның скрипка һәм оркестр өчен концертлары бар. М.Мозаффаров, Р.Яхин, З.Хәбибуллинның скрипка өчен язылган әсәрләрен беренче башкарып, республикада һәм аннан читтә зур уңыш казана. 1957 дә Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә, Зур симф. оркестрга кушылып, А.Леманның скрипка өчен концертын башкара. Финляндия, Германиядә гастрольләрдә була. Музыкант-башкаручыларның 2 нче Бөтенроссия конкурсы дипломанты (1961).


*Ф.Ш.Салитова.*

**ӘХМӘ́ТОВ** Марат Готыф улы (16.6.1954, Арча р-ны Хәсәншәех а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1992). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1976). 1976–78 елларда Балтач р-ны Чапаев исем. к-зының баш вет. табибе, 1978–83 тә «Алга» к-зы рәисе, 1983–85 тә КПСС район ком-ты секретаре, 1985–90 да 1 нче секретаре, 1990–91 дә халык депутатларының район советы башкарма ком-ты рәисе, 1991–99 да Балтач р-ны хакимияте башлыгы. 1999 елдан ТР премьер-министры урынбасары — ТР а.х. һәм азык-төлек министры. 1995–99 да ТР халык депутаты. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000).

**ӘХМӘ́ТОВ** Мәхмүт Әхмәт улы (30.1.1934, Әтнә р-ны Ары (Ислетар) а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСР Дәүләт бүләге лауреаты (1990). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1957). 1960–67 елларда — «Мөслим» с-зында, 1967–78 дә Мөслим р-ны а.х. идарәсендә баш вет. табибе. 1978–94 тә «Михайловский» азык чөгендере орлыгы җитештерү берләшмәсе ген. директоры, бер үк вакытта «Михайловский» с-зы директоры. Дәүләт бүләге Н.К.Мәҗитов конструкциясе буенча төзелгән модуль-блоклы туфрак эшкәртү комплексын эшләүдә катнашкан һәм аны производствода киң куллануга керткән өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘ́ТОВ** Наил Җиһангир улы (5.7.1954, Әлмәт ш.), геолог, ТРның атказ. геологы (1997), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001), техн. фән. канд. (2004). Мәскәүдә Нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1976). 1976–92 елларда «Елховнефть» НГДУында: скважиналарны тикшерү операторы, инженер-геолог, өлкән геолог, нефть чыганакларын үзләштерүнең геол., технол. бүлекләре башлыгы (бүленеп, 1978–79 да ВЛКСМның Әлмәт шәһәр ком-ты секретаре). 1992–99 да «Татех» уртак пр-тиесе геологы. 1999 дан «Татнефть» АҖнең нефть һәм газ чыганакларын үзләштерү технол. идарәсендә бүлек башлыгы. Дәүләт бүләге «Эксплуатация колоннасын саклау һәм төзекләндерү өчен технол. комплекслар һәм техник чараларны эшләү һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ӘХМӘ́ТОВ** Наил Сибгат улы (27.11.1926, Киров өлкәсенең Малмыж ш. — 2.12.2006, Казан), химик, педагог, химия фән. д-ры (1969), ТР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1992), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1974, 1980). 1948 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук нәорганик химия кафедрасында эшли, проф. (1969), каф. мөдире (1974–97). 1953–55 тә Тяньцзинь политехн. ин-тында (Кытай Халык Респ-касы) укыта. 1957–63 тә технол. ф-тының читтән торып уку-укыту деканы, 1967–87 дә Казан хим.-технол. ин-ты каршындагы югары һәм махсус урта уку йортлары укытучыларының белемен күтәрү ф-ты деканы. Хезмәтләре нәорганик һәм координацион химиягә карый. Ә. (шәкертләре б-н берлектә) агалтынлы металлар (палладий, агалтын, родий) кушылмаларының интермедиат каталитик актив формаларын синтезлау һәм өйрәнүнең фәнни юнәлешләрен билгели. Кыйммәтле металл — көмешне экономияләргә мөмкинлек биргән, көмеш фотосурәтләрне күчешле металларның комплекслы кушылмаларын кулланып эшләгән сурәтләр б-н алмаштыру проблемасын хәл итә. Югары һәм урта мәктәптә химия белемен камилләштерүгә зур өлеш кертә. Химик матдәләрнең үзлекләрен аңлау өчен җирлек булып торган структур, термодинамик һәм кинетик күзаллауларга нигезләнгән «Гомуми һәм нәорганик химия» дәреслеген төзи. 1960 еллардан югары уку йортларында (ш.и. чит илләрдә дә) шушы дәреслек буенча укытыла, 4 басмасы дөнья күрә (дари, латыш, эстон, инглиз, гарәп телләренә тәрҗемә ителә). Ә. — инглиз, гарәп телләрендә басылган «Нәорганик химиядән лаборатор эшләр һәм семинарлар өчен күнегүләр» дигән уку әсбабы автордашы. Аның тарафыннан 40 дәреслек һәм уку әсбабы, ш.и. урта мәктәпнең 8–9, 10–11 сыйныфлары өчен химия дәреслекләре языла. Алар бүгенге фәннең алдынгы идеяләренә нигезләнә, укытучыларны үзләренең проф. осталыкларын күтәрүгә этәрә, укучыларның иҗади фикерләвен үстерүгә һәм химик экспериментлар үткәрү б-н кызыксынуын арттыруга ярдәм итә. Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз хим. җәмгыятенең Татарстан респ-касы бүлекчәсе рәисе (1971–73). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.


Н.С. Әхмәтов.

Хезм.: Неорганик химия. К., 1994; Электродные потенциалы и кристаллографическое направление // Тр. Казан. хим.-технол. ин-та. 1954–55. Вып. 19–20; Электродные потенциалы монокристаллов цинка в водных растворах // Журн. прикладной химии. 1956. Т. 29, № 8 (автордаш); Неорганическая химия: Учеб. М., 1969.

*Әд.:* Сплав учёного и педагога // Научный Татарстан. 1996. № 4; Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ӘХМӘ́ТОВ** Рәшит Рәкыйп улы (12.1.1954, Горький өлкәсенең Арзамас-16 ш.), журналист. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1982), шунда ук идарә ителә торган икътисади объектлар динамикасы һәм социол. тикшеренүләр лабораторияләрендә инженер булып эшли. 1987–92 елларда Татарстан халык фронты иҗтимагый хәрәкәте рәисе, «Народный фронт» г-тасы баш мөхәррире. 1992 дән «КРИС» г-тасында (хезмәткәр, 1995–97 дә баш мөхәррир урынбасары). 1999 дан «Звезда Поволжья» (Казан) г-тасын оештыручы һәм баш мөхәррире. Республика вакытлы матбугатында басылган мәкаләләрендә ТРда барган иҗтимагый-сәяси процессларга анализ ясый, федерализм һәм милләтара мөнәсәбәтләргә кагылышлы проблемалар күтәрә. 1990–95 тә Россия Демократик партиясенең Татарстан бүлеге рәисе. ТР Журналистлар берлеге бүләкләре лауреаты (1996, 2000).

**ӘХМӘ́ТОВ** Рөстәм Фәһим улы (17.5.1950, Украина ССР Житомир ш.), спортчы (җиңел атлетика, биеклеккә сикерү), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1971), пед. фән. канд. (1980). Киев физик культура ин-тын тәмамлый (1973). Житомир пед. ин-ты доценты (1983). СССР (1971), Европа (1971) чемпионы, Олимпия уеннарында катнаша (215 *см* биеклеккә сикерә: 8 нче урын, 1972), СССР халыклары спартакиадасы чемпионы (1975).

*Әд.:* Илдарханов И.Г. Олимп тавына ничек менәргә. К., 1980; Лонской В. Что вам сказать про высоту. М., 1972.

**ӘХМӘ́ТОВ** Тәлгат Гакыйф улы (14.11.1941, Казан), пианист, дирижёр, ТАССРның атказ. артисты (1987). Казан консерваториясенең В.Г.Апресовта фортепиано (1966) һәм Н.Рахлинда опера-симф. оркестрлар дирижёрлыгы (1972) классларын тәмамлый. 1972 елдан Татар опера һәм балет театрында, бер үк вакытта (1979 елдан) Казан консерваториясенең опера классында дирижёр. «Севилья чәчтарашы» («Севильский цирюльник», Дж.Россини), «Трубадур» (Дж.Верди), «Евгений Онегин», «Аккош күле» («Лебединое озеро»), «Йокыга талган гүзәл» («Спящая красавица», П.Чайковский), «Золушка», «Ромео һәм

Джульетта» (С.Прокофьев), «Шүрәле» (Ф.Яруллин), «Башмагым» (Җ.Фәйзи), «Ерактагы кәккүк авазы» (Р.Кәлимуллин) һ.б. опера, балет спектакльләре дирижёры. ТРның Дәүләт симф. оркестры б-н дирижёр буларак, татар композиторлары һәм рус, чит ил классикасы әсәрләре б-н пианинода аерым чыгышлар ясый. Танылган башкаручылар В.Ганиева, З.Сөнгатуллина, Ю.Борисенко, Р.Ибраһимов, Ш.Монасыйпов, И.Шакировлар б-н бергә концерт эшчәнлеге алып бара. Россия, БДБ илләре шәһәрләрендә, Германиядә гастрольләрдә була (1997, 1998, 1999).

**ӘХМӘ́ТОВ** Тимерхан Габдулла улы (30.7.1934, Алабуга р-ны Морт а.), химик-технолог, техн. фән. д-ры (1981), проф. (1987). ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1977), СССР һәм РФнең шәрәфле химигы (1984, 1997). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Л.Я.Карпов исем. Менделеев химия з-дында: 1972 елдан баш инженер, 1983 тән директор. 1985 тән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре нәорганик матдәләр (ш.и. аеруча чиста матдәләр) технологиясенә карый. Ярлы фосфоритлардан катлаулы фосфор-калий-магнийлы ашламалар ясау технологиясен, Татарстан җир асты тозлыкларыннан һәм нефть суларыннан йод, бром, натрий гидроксиды һәм натрий карбонаты, поташ һәм микроэлементлар табу технологиясен эшли. Алюминий оксидын (лейкосапфир, рубин, алюмоиттрийлы гранат монокристалларын үстерү өчен чыганак материал) табу ысулын; алюмомагний шпинелен, махсус корыч өслеген электроизоляцион каплам б-н каплау өчен тотрыклы магнезий суспензияләрен табу ысулын тәкъдим итә. Ә. тәкъдим иткән чиста алюминий, бакыр һ.б. төсле металлар җитештерү өчен 10 нан артык флюс составлары ВАЗ һәм КамАЗда, кайбер чит ил пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Күкертнең төрле модификацияләрен һәм аның кушылмаларын җитештерү (Л.Я.Карпов исем. Менделеев химия з-дында, Березники хим. комб-тында һ.б. гамәлгә кертелә), ш.у. барийның органик һәм нәорганик кушылмаларын табуның фәнни нигезләрен эшли. Консервантларның яңа буынын — яшел массаны силослау өчен азык баеткычлары, яшелчә һәм сенажны саклау өчен антиоксидантлар эшләү технологиясен гамәлгә кертә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. Э.Касыймовның «Томан аша» (1968), «Һаваларда тургай» (1973), «Чулман — оныклар дәрьясы» (1976) романнары геройларының прототибы.

Х е з м.: Аналитические методы контроля в производстве бариевых и сульфитных солей. М., 1974 (автордаш); Химия и технология соединений бария. М., 1974; Химическая технология неорганических веществ. М., 1998 (автордаш).

*Әд.:* Казанский химико-технологический институт: вчера, сегодня, завтра. К., 1990. Ч. 2.

**ӘХМӘ́ТОВ** Фасил Әхмәтгали улы (23.5.1935, Кукмара р-ны Салтык-Ерыклы а. — 6.9.1998, Казан), композитор, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977, 1981), РСФСР һәм ТРның халык артисты (1992, 1995). Казан консерваториясенең музыка теориясе һәм композиция ф-тын тәмамлый (А.Леман классы, 1962). 1957–61, 1969–75 елларда Казан музыка уч-щесендә, Казан консерваториясендә муз. теориясе фәннәрен укыта, 1962–64 тә Татарстан



Ф.Ә. Әхмәтов.

китап нәшриятында һәм ТАССР МС каршындагы радиотелевидение ком-тында муз. тапшырулар редакциясенең өлкән редакторы. Ә. татар симфониясе үсешенә зур өлеш кертә. «Фәрит Яруллин истәлегенә» симф. поэмасы композиторга танылу китерә. Аның иҗатында элегрәк тә сурәтләнгән трагик образлар ярдәмендә «Казан» фа минор симфониясендә татар халкының тарихи язмышы темасы (1552 елда Казан ханлыгының яулап алынуы) тагын да үстерелә. Ә.нең симф. әсәрләренә тормышчанлык хас («Татарстан», «Сабантуй», бәйрәм увертюралары, инструменталь концертлар һ.б.). Камера-инструменталь әсәрләре татар музыка сәнгате стилистикасын һәм образлылыгын баета, татар көйләренең полифоник үсеш алымнары б-н кушылуына ярдәм итә. Кыллы квартет өчен партитасында, Тынлы агач музыка уен кораллары өчен квинтетында, кыллы квартетларында композиторның муз. фикерләве, кешенең төрле рухи халәтен бирү осталыгы аеруча ачык чагыла. Ә.нең җыр мирасы гаять бай. Аның моң байлыгы мәхәббәт хисләре б-н сугарылган романсларында, лирик җырларында бигрәк тә ачык чагыла. Җырлары моңы, ихласлыгы, тәэсирле интонацияләре б-н аерылып тора («Назлы гөлкәем», Я.Кәрим шигыре; Х.Вахитның «Талак, талак» спектакленнән «Гөләндәм җыры»; «Таң йолдызы», М.Ногман шигыре; «Мәхәббәтем эзлим», Д.Камалетдинова шигыре). Күп җырларында традицион темалар авторның иҗади эзләнүләре, яңалык, гармоник буяуларның камиллеге оригиналь интонацияләр б-н кушыла.

Ә.нең иҗади стиль үзенчәлеге татар халык музыкасының дөнья муз. культурасы принциплары б-н кушылуында чагыла. Аның иҗади стилен интонация ягыннан ачык көй төзелеше, оркестр һәм гармоник чараларны җентекле сайлавы, образларның киң диапазонлы — шаян җырлардан алып киң драматик үсешле муз. спектакльләргә һәм трагик симфония, камера-инструменталь әсәрләргә кадәр үсеше билгели. Ә.нең әсәрләрен танылган башкаручылар һәм муз. коллективлар үз репертуарларына еш кертә. Композиторның симф. музыкасын В.Дударова, Ф.Мансуров, Н.Рахлин җитәкчелегендәге төрле оркестрлар башкара. РСФСРның М.Глинка һәм ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләкләре лауреаты (1975, 1988). Аеруча танылган әсәрләре: «Чишмә җыры» исемле симф. һәм вокаль-симф. кантата (М.Җәлил шигыре, 1964), «Фәрит Яруллин истәлегенә» исемле симф. поэма (1969), халык уен кораллары оркестры өчен «Легенда» (1970), «Казан симфониясе» (1976), кыллы оркестр һәм орган өчен «Хатирә» поэмасы (1982), симф. оркестр өчен «Сабантуй» (1985), фортепиано һәм оркестр өчен концерт (1983), скрипка һәм оркестр өчен концерт (1991), колоратуралы сопрано һәм симф. оркестр өчен «Ак җыр» (1992) һ.б.; камера-инструменталь әсәрләре: кыллы уен кораллары өчен 3 квартет (1960, 1969, 1982), виолончелистлар ансамбле өчен «Уйлану» (1972) һ.б.; драма спектакльләренә язган музыка, 130 дан артык җыр һәм романс.

*Әд.:* Л а т ы й п о в Ә. Еллар һәм җырлар // Совет мәктәбе. 1976. № 7; К а с а т к и н а Г. Обновление традиций // Советская музыка. 1970. № 10; Б а р а н к и н Е. Фасиль Ахметов // Музыка России. М., 1975. Вып. 2; Р а и м о в а С. Фасиль Ахметов // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; С а й д а ш е в а З. Мир музыки Фасиля Ахметова: От песни к симфонии // В мире татарской музыки. К., 1995; Ш а м с у т д и н о в а Ф.Я. Фасиль Ахметов. К., 2002.

*З.Н.Сәйдәшева.*

**ӘХМӘ́ТОВ** Фәрхи Шәйхи улы (1889, Уфа губ., Бәләбәй өязе Гобәй Карамалы а. — 17.2.1938, Казан), журналист. Уфа шәһәрендә «Галия» мәдрәсәсендә белем ала. 1918–21 елларда Уфада нәшер ителгән «Көрәш» г-тасы хезмәткәре. Гражданнар сугышы елларында Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе сәяси бүлеге тарафыннан чыгарылган «Кызыл яу» г-тасының мөхәррире. 1920–30 да «Урал» г-тасы редколлегиясе әгъзасы, аннан соң баш мөхәррире (Эстәрлетамак ш.), «Азат Себер» г-тасы мөхәррире (Омск ш., аннан соң Новосибирск ш.); «Эшче» г-тасында (Мәскәү) хезмәттәшлек итә. Язмаларында ТАССРның икътисади һәм мәдәни тормышын, совет фәне казанышларын яктырта, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрен күтәрә. 1929–32 дә «Кызыл Татарстан» г-тасы баш мөхәррире. 1932 дән дәүләт эшендә, 1935–37 дә ТАССР Җир эшләре халык комис-ты инспекторы. Репрессияләр корбаны (к. «*Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел оешмасы*» *эше*).

*Г.Г.Хәсәнова.*

**ӘХМӘ́ТОВ** Шамил Исиятулла улы (7.8.1942, Мордва АССР, Кадешкин р-ны Латышовка а.), агроном-галим, а.х. фән д-ры (1996), проф. (1997), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1992). Мордва ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук укыту-тәҗрибә хуҗалыгы директоры булып эшли, 1975 елдан а.х. ф-ты деканы урынбасары, 1980 нән декан, 1994 тән директор, бер үк вакытта 1998 дән Аграр ин-тның агрохимия һәм туфрак белеме каф. мөдире. Хезмәтләре интенсив игенчелек, химияләштерү чараларын озак еллар куллануның туфрак уңдырышлылыгына һәм әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүенә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основные вопросы земледелия Мордовии: Учеб. пособие. Саранск, 1986; Опыт минимализации обработки почвы в Мордовии // Земледелие. 1990. № 2; Средства химизации и биопродуктивности почвы. Саранск, 1996.

*Әд.:* История Мордовии в лицах: Биогр. сб. Саранск, 1997.



З.С.Әхмәтова.

**ӘХМӘ́ТОВА** Дания Заһретдин кызы (25.5.1946, Яшел Үзән ш.), педагог, пед. фән. д-ры (1998), проф. (2001), ТРның атказ. укытучысы (1992). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), укытучылык эшендә, 1990–98 елларда Яшел Үзән ш. мәктәп-комплексының ген. директоры. 1998 дән Казанда: Татарстан-Америка региональ ин-ты проректоры, 1999 дан Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тында пед. каф. мөдире. 2004 тән дистанцион укыту буенча проректор. Хезмәтләре мәктәп комплексын формалаштыру һәм аның эшчәнлеге мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Педагогический коллектив учебно-воспитательного комплекса. М., 1995; Школа-комплекс как социально-педагогическая система. К., 1997.

**ӘХМӘ́ТОВА** Зөләйха Саттар (Габделсаттар) кызы (13.3.1904, Чиләбе ш. — 2.1.1988, Мәскәү), хормейстер, педагог, ТАССРның атказ. артисткасы (1939). Мәскәү консерваториясен тәмамлый (1934). 1934–37 елларда Башкорт сәнгать техникумында уку-укыту бүлеге мөдире һәм укытучы. 1937 дән, оешкан көненнән алып, 1959 га кадәр ТАССР Җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе. Бер үк вакытта 1941–44 тә Татар филармониясе директоры һәм сәнгать җитәкчесе. Оештыру сәләте, нечкә сәнгати тоемлавы ансамбльне оештыруда һәм аның иҗади формалашуында хәлиткеч роль уйный. Ә. бу коллективта эшләгән елларда ансамбльнең үзенчәлекле стилен табу, милли сәнгатьне иҗади үстерү, сәхнәдә татар музыкасы һәм бию фольклорының яңа үрнәкләрен булдыру юнәлешендә актив эзләнүләр алып бара һәм аларны гамәлгә ашыра. Ә. ансамбльнең репертуарын халык сәнгатенең иң яхшы үрнәкләреннән һәм композиторлар А.Ключарёв, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи һ.б.ларның әсәрләреннән туплый. Хор төркеме б-н 300 ләп әсәр өйрәнелә. Талантлы педагог буларак, солистларга иҗади яктан формалашырга һәм осталыкларын үстерергә ярдәм итә. Ә. җитәкчелегендә ансамбль бөтенроссия (1939, 1945), бөтенсоюз (1957) смотр һәм конкурсларында зур җиңүләр яулый; ил буйлап беренче гастрольләре уңышлы үтә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*В.Н.Горшков.*

**ӘХМӘ́ТОВА** Лидия Алексеевна (17.10.1962, Новосибирск өлкәсенең Татар р-ны Кочневка а.), җырчы (лирик сопрано), педагог, ТРның халык артисткасы (2004). Казан консерваториясен вокал буенча Ә.Заһидуллина классында тәмамлый (1992). 1991–2004 елларда ТРның Кинематография дәүләт оркестры солисты, 2004 тән Казан пед. ун-тының вокал каф. укытучысы. Россия шәһәрләрендә, чит илләрдә (Австрия, Финляндия, Германия, Балтыйк буе илләре һ.б.) гастрольләрдә була. Җырчының репертуарын татар композиторлары, рус һәм чит ил классик вокаль музыка әсәрләре тәшкил итә. Ә. татар халык җыр сәнгатен өйрәнү һәм популярлаштыру буенча зур эш алып бара. «Нәүруз моңнары» (1993), «Татар җыры» (1991) халыкара (җырлар авторы һәм башкаручы буларак), «Голоса России» (1990) бөтенроссия, вокалистларның С.Сәйдәшев исем. респ-ка конкурслары (1993) лауреаты.

**ӘХМӘ́ТОВА** Людмила Исхак кызы (3.9.1937, Казан), пианист, педагог, ТАССРның халык артисткасы (1989). Казан консерваториясен тәмамлый (1960), шунда ук концертмейстер булып эшли. 1965 елдан камера ансамбле каф. укытучысы, бер үк вакытта 1987 дән Татар опера һәм балет театры концертмейстеры. 1994 тән Мәскәүдәге «Яңа опера» («Новая опера») театрында концертмейстер. Россиянең һәм Татарстанның мәшһүр җырчылары, музыкантлары б-н берлектә ансамбльләрдә, концертларда, радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый; музыкант-башкаручыларның халыкара, бөтенсоюз һәм бөтенроссия конкурсларында концертмейстер буларак катнаша. Татар опера һәм балет театры труппасы һәм солистлары б-н бергә Чехословакиядә, Германиядә гастрольләрдә була, Төркиядә Төрки халыкларның 1 нче халыкара фестивалендә (1991) катнаша. Мәскәүнең «Мелодия» фирмасында 4 грампластинка чыгара. Аккомпаниатор буларак, скрипкачыларның 7 нче Бөтенроссия (1985), Ф.И.Шаляпин исем. 2 нче Бөтенсоюз конкурслары (1991) дипломанты.

**ӘХМӘ́ТОВА** Флора Ваһап кызы (23.5.1935, Төмән өлкәсенең Тубыл р-ны Чебурга (Күкрәнде) а. — 16.10.2007, Казан), фольклорчы, филол. фән. канд. (1968), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1997). Төмән пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1964 елдан Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1997 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты фәнни хезмәткәре. Бер үк вакытта 1992 дән Казан консерваториясендә татар фольклоры шигърияте курсларын укыта, доцент. Төп хезмәтләре татар халык авыз иҗаты жанрларын (*эпос, дастан, бәет*), ш.у. Себер татарларының фольклорын өйрәнүгә карый. Татар фольклорының күптомлы «*Татар халык иҗаты*» басмасын төзүчеләрнең берсе, ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1989), «Бакый Урманченың рухи дөньясы» (2005, татар, рус һәм инглиз телендә), «Баки Урманче и татарская культура» (2005, татар һәм рус телләрендә) китапларының автор-төзүчесе.

Х е з м.: Татар эпосы: бәетләр = Татарский эпос: баиты. К., 2005 (соавт.); Габдулла Тукай в творчестве Баки Урманче = Бакый Урманче иҗатында Габдулла Тукай: Альбом. К., 2007.

**ӘХМӘ́ТОВА** Эльза Кадыйр кызы (25.3.1938, Казан), пианист, педагог, проф. (1993), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1976). 1962 елда Казан консерваториясен (А.Леман классы) тәмамлый, шунда ук ассистентура-стажировка уза (1965). 1964 тән махсус фортепиано укытучысы, 1986–91, 1994–96 да махсус фортепиано һәм орган каф. мөдире. Концертларда әсәрләрне аерым башкара, ТРның күренекле җырчылары б-н ансамбльләрдә һәм симфоник оркестрларга кушылып чыгышлар ясый. Репертуарының нигезен Көнбатыш Европа классикасы (В.Моцарт, Ф.Шуберт, Ф.Шопен, Л.Бетховен һ.б.), Татарстан композиторларының әсәрләре тәшкил итә. М.Мозаффаров, Р.Яхин, Р.Билалов һ.б.ның фортепиано өчен язылган әсәрләрен беренче булып башкара. Ә.гә югары башкару культурасы, төрле жанр һәм стильдәге әсәрләрне үзенчәлекле итеп интерпретацияләү хас. ТР композиторларының фортепиано өчен язылган әсәрләре җыентыгын һәм хрестоматиясен төзи.

*Әд.:* Г о б ә й д у л л и н а Р. Музыка дөньясында // Азат хатын. 1967. № 1; Т и м б и к о в а К. Аның йолдызы // Азат хатын. 1971. № 3.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ӘХМӘТХА́НОВ** Сәлимхан Миңнехан улы (1.12.1949, Сарман р-ны Саклаубаш а. — 14.4.2006, шунда ук), «Петровский» агрокомплексы ген. директоры (1997 елдан), ТР һәм РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1993, 1995). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1977). 1976–86 елларда — Мөслим р-нының «Шуган» терлек симертү с-зы, 1987–89 да Сарман р-нының «Петровский» с-зы директоры. 1989 дан яңа оештырылган «Петровский» агрофирмасы ген. директоры. 1993 тән «Петровский» холдинг компаниясе президенты. 1990–93 тә РФ, 1995–99 да ТР халык депутаты, 2000–2003 тә РФ Дәүләт Думасы депутаты.

**ӘХМӘТХА́НОВ** Фәрит Заһир улы (13.6.1955, Балтач р-ны Нөнәгәр а.), агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), ТРның атказ а.х. хезмәткәре (1992). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1983). 1969 елдан Балтач р-нында эшли: «ВЛКСМның 50 еллыгы» к-зында (1971 гә кадәр); Тимирязев исем. к-зда агроном (1976–77); районда агроном-орлыкчылык белгече (1977–83), игенчелек һәм терлек азыгы җитештерү бүлеге башлыгы; А.х. идарәсе башлыгы урынбасары (1983–85); Калинин исем. (1985–87), Рәхимов исем. (1987–96) к-злар рәисе; 1996–2006 да хакимият җитәкчесенең 1 нче урынбасары, бер үк вакытта районның А.х. идарәсе башлыгы, 2006 дан Балтач р-н башкарма ком-ты җитәкчесе. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында терлек азыгы җитештерү системасын эшләү һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘТШИ́Н** Миңлегәрәй Әхмәт улы (1889, Уфа губ., Минзәлә өязе Бикләнә а. — 9.5.1938, Казан), дәүләт эшлеклесе. 1916 елдан Россия армиясендә, Февр. рев-циясеннән соң Көнбатыш фронттагы 65 нче Себер укчылар полкының хәрби-революцион ком-ты рәисе урынбасары. 1918 дә Бикләнгә кайта. РКП(б)ның Минзәлә ком-тын оештыручыларның берсе, өяз башкарма ком-ты рәисе урынбасары, өяз хәрби комиссары. Чех-сло-



М.Ә.Әхмәтшин.

вак корпусы фетнәсен бастырганда Минзәлә коммунистик батальонында 2 нче рота командиры. 1919–21 дә Минзәлә өязендә хәрби-революцион һәм башкарма ком-тлар рәисе. 1920 дә крәстияннәр баш күтәрүен бастыруга җитәкчелек итә (к. «*Сәнәкчеләр» фетнәсе*). 1921–22 дә ТАССР эчке эшләр халык комиссары. 1922 дә Чаллы кантоны а.х. кооперациясендә рәис, икътисад, җир бүлекләре мөдире, 1923–24 тә кантон башкарма ком-ты рәисе, 1924–25 тә РКП(б)ның Чаллы кантоны ком-тының 1 нче секретаре. 1925 тән Казанда яши, а.х. банкы идарәсе рәисе, 1926–27 дә җир эшләре һәм эшче-крәстиян инспекциясе халык комиссары. 1927–29 да ТАССР ҮБК Президиумы рәисе. 1932–38 дә Татарстан кулланучылар берлегендә ревизия комиссиясе әгъзасы, селекция станциясе директоры, ТАССР ХКС каршында дәүләт арбитры. РСФСР БҮБК, СССР ҮБК әгъзасы. Репрессияләр корбаны. 1937 нең 6 августында кулга алына, гаепсезгә репрессияләнә, үлем җәзасына хөкем ителә (к. «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы» эше*); үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Петров Н. Ахметшин М.А. // Борцы за счастье народное. К., 1967.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ӘХМӘ́ТШИН** Хәлиулла Хәйрулла улы (12.11.1912, Уфа губ., Минзәлә өязе Түбән Абдул а. — 1.6.1989, шунда ук), туган якны өйрәнүче, музей хезмәткәре, үзешчән рәссам-нәкышьче һәм сынчы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967). Елхово авылы тарихы музеена нигез салучы (1965); музей 1995 елдан аның исеме б-н атала һәм 1990 ның 1 сентябреннән ТР Милли музее филиалы булып санала. Түбән Абдул, Иске Баграж-Елхово авыллары һәм көньяк-көнчыгыш төбәк тарихына, көнкүрешенә, мәдәниятенә, халык сәнгатенә караган материаллар туплаучы. Музей бинасына төсле гипстан Ә.нең «Халкыма» шигыре б-н мемориаль такта-барельефы урнаштырылган (1996, рәс. Г.Зяблицев). Ә. тумышы б-н урта хәлле крәстияннәрдән, элеккеге «яңа керәшеннәрдән». Җамигъ мәчет каршындагы Түбән Абдул мәдрәсәсендә (1920), урта мәктәптә (1927) белем ала. 1928–30 да Архангельск өлкәсендә һәм Донбасста эшли. Тын океан флотына алына (1934 тән), 1945 тә японнарга каршы сугыша. 1947 дә туган авылына әйләнеп кайта. Клуб мөдире һәм китапханәче булып эшли (1951–52). 1961 дә булачак музейга экспонатлар туплау эшенә керешә, аңа авыл картларын да тарта. Ә. көче б-н оештырылган музей җәмәгать эше тәртибендә эшли. Крәстиян тормышы һәм көнкүрешенә багышланган 14 картина («Сабанда», «Уракчы кыз», «Язгы чәчү», «Урта хәлле крәстиян утары», «Ашлык сугу», «Революциягә кадәрге авыл урамы», «Чишмә ярында», «Мәктәп еллары» (диптих) һ.б.); «Ел фасыллары» пейзажларыннан торган тематик серия (1965–70); агачтан эшләнгән сыннар («Чабатачы Төхфәтулла бабай», 1965; «Әби белән кәҗә», 1966), фанерадан кисеп эшләнгән төсле музей композициясе макетлары («Такта яручылар», «Сабанчылар», 1967; «Бөек Ватан сугышы елларында хатын-кызлар хезмәте», 1985); Шәйдулла Сафиуллинга һәм Әгъләм Юнысовка куелган монументаль һәйкәлләр (икесе дә Түбән Абдулда, 1957), Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашларына багышланган мемориаль такта (1960) авторы. Хайван һәм кош карачкыларын ясау остасы. Ә.әсәрләренә (алар барысы да музей экспонатлары) саф күңеллелек, бизәү алымы б-н иҗат иткән кечкенә күләмле композицияләр, аларның детальләрен җентекләп эшләү, пейзаж фоннарын табигый чагылдыру, төрле төсләр кушылмаларын һәм капма-каршы төсләр гаммасын бирә белү хас. Ә. — шигырьләр авторы. Кызыл Йолдыз, Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Ә.нең график портретын Әлмәт рәссамы В.В.Нагавкин эшли (1996).



Х.Х.Әхмәтшин. Оста сыны эшләнгән даими экспозиция фрагменты. Агач. Елхово авылы тарихы музее.

*Әд.:* Сабитов Г. Юл буенда һәйкәлләр // Карурманның күзләре бар: Хикәяләр, очерклар. К., 1975.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ӘХМӘ́ТШИН** Хәсән Мөбарәк улы (1.1.1920, Арча кантоны Төенбаш а.), хокук белгече, хокук фән. д-ры (1975), проф. (1978), РСФСРның атказ. хокук белгече (1973). Хәрби юридик академия тәмамлый (1945, Мәскәү). 1939–40 елларда Юдино р-ны халык судьясы. 1940–42 дә Байкал арьягы хәрби округында хезмәт итә. 1945–49 да Алма-Ата хәрби гарнизонында хәрби судья. 1952 дән РФ Оборона министрлыгының Хәрби ин-тында (Мәскәү) җинаять эшләре хокукый фәнен укыта, 1978 дән профессор. Хезмәтләре хәрби һәм җинаять эшләре хокукый мәсьәләләренә карый. Югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы.

Хезм.: Советское военно-уголовное законодательство: Теоретические вопросы. М., 1972; Квалификация воинских преступлений. М., 1977.

**ӘХМӘ́ТШИН** Ягъфәр Әхмәт улы (1924, Оренбург өлкәсенең Әсәкә р-ны Кутлуево а. — 17.1.1945, Польша, Карнево пос.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, вафатыннан соң), лейтенант (1942). Краснохолмск хәрби пехота уч-щесен тәмамлый (1942). 1942 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1348 нче укчылар полкы взвод командиры (48 нче армиянең 399 нчы укчылар дивизиясе). Брянск, Үзәк, 1 нче, 2 нче һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск шәһәрен (1943), Украина, Белоруссия, Польшаны азат итү сугышларында катнаша. 1944 елның 3–4 сентябрендә Остров-Мазовецки (Польша) шәһәре янында барган сугышта батырлык күрсәтә. Карнево посёлогы тирәсендәге сугышта һәлак була. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Я.Ә.Әхмәтшин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Рассказы о героях. Челябинск, 1971; Оренбуржцы в боях за родину. Челябинск, 1978.

**ӘХМӘ́ТШИНА** Илиза Заһит кызы (11.5.1938, Актаныш р-ны Чишмә а.), нефть промыселы технологияләре белгече, техн. фән. канд. (1972). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), «Татнефть» берләшмәсенең «Әлмәтнефть» НГДУында нефть әзерләү операторы булып эшли. 1964 елдан нефть һәм газ сәнәгатенең фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру ин-тында (Түмән ш.), 1966 дан нефтьне промыселга әзерләү лаб. мөдире, 1985 тән катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру һәм нефть чыгаруны интенсивлаштыру комплексында бүлек мөдире. Хезмәтләре нефть әзерләү технологияләрен эшләүгә, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру һәм нефть чыгаруны интенсивлаштыруның комплекслы технологияләре өчен югары нәтиҗәле күп функцияле яңа полимер составлар булдыруга карый. Уйлап табуга караган 4 патенты, 35 тән артык авторлык таныклыгы бар. Нефть-газ комплексының Көнбатыш Себер чыганакларында нефть һәм газны әзерләү, ташу, файдалануның яңа алымнарын эшләгән һәм сәнәгый кулланышка керткән өчен СССР МС бүләге (1981) бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Влияние поверхностного натяжения и температуры на отложение солей в нефтепромысловом оборудовании // Нефтяное хоз-во. 1979. № 3; Закономерности формирования сложных солевых осадков // Нефтепромысловое дело. 1981. № 7; Создание универсальных реагентов и их применение в нефтедобыче // XII Международный Менделеевский съезд по общей и прикладной химии: Материалы съезда. Баку, 1981. Т. 4.

*Әд.:* Уманский М.Ю. Твёрдая вода // Газовая пром-сть. 1988. № 3; Зорин Л. Волшебная вода крупным планом // Газовая пром-сть. 1989. № 4; Грайфер В.И. РИТЭК — символ новизны и прогресса // Нефтяник. 1992. № 10.

**ӘХМӘТЬЯ́НОВ** Рифкать Газизҗан улы (10.7.1933, Башкортстан АССР, Иглин р-ны

Турбаслы а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1994). Башкорт ун-тын тәмамлый (1962). 1963 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1995 тән Эстәрлетамак пед. ин-тында, 1997 дән Бөре пед. ин-тында эшли, профессор. Хезмәтләре тюркологиягә, чагыштырма тел белеменә, татар лексикографиясе һәм этимологиясенә карый.

Х е з м.: Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. К., 2003. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М., 1978; Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981; Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1989.

*Әд.:* Х и с а м о в а Ф.М. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков // Советская тюркология. 1979. № 6.

**ӘХМӘТЬЯ́НОВА** Рәйсә Әхтәм кызы (8.9.1950, Украина ССР, Николаев ш.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004), проф. (2002). Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эшли, пластмассалар технологиясе кафедрасында (бүленеп, 1982–84 елларда «Союзнефтепромхим» фәнни-җитештерү берләшмәсендә). Хезмәтләре составында кислород булган функциональ төркемле органик кушылмалар химиясенә, авыр (төп) органик синтез технологиясенә карый. Бутадиен-1,3 һәм 3-метилбутен-1 оксидларын синтезлау закончалыкларын өйрәнә, аларны алу процессларының технологик нигезләрен эшли. Әлеге оксидларны төп органик синтез һәм полимерлар химиясенең яңа продуктлары синтезында файдалану мөмкинлекләрен тикшерә. Изопрен җитештерүне камилләштерү буенча эшләр алып бара.

Х е з м.: Получение и применение 3-метилбутена-1 / ЦНИИТЭнефтехим // Темат. обзор. Сер. Пром-сть синтет. каучука., 1993. Вып. 1 (автордаш); Современные нефтехимические синтезы на основе бутадиена // шунда ук. 1993. Вып. 4 (автордаш); Синтез и свойства ненасыщенных полиэфиров на основе монооксида бутадиена и ангидридов дикарбоновых кислот // Журн. прикладной химии. 1994. Т. 67, № 6.

**ӘХСӘ́НОВ** Илдар Гали улы (27.8.1935, Әлмәт а., хәзерге Әлмәт ш. — 8.7.2003, шунда ук), шагыйрь, журналист. Казан ун-тын тәмамлый (1962). 1955–92 елларда ТРның нефть чыгару пр-тиеләрендә эшли, язмалары район һәм республика матбугатында басыла (1952 дән). 1993 тән «Нефтяник Татарстана» г-тасы хезмәткәре. Татар һәм рус телләрендә яза. «Кыйбла» (1985), «Ак дөнья» (1987), «Җирәбә» (1995) дип исемләнгән китапларында кешенең туган җир алдындагы бурычы, нефть төбәге эшчеләре, шул төбәкнең экологиясе, киләчәк буын, мәхәббәт турындагы шигырьләре тупланган. Әсәрләре гражданлык хисе б-н сугарылган, аларга нечкә лиризм хас. Ә. нең Татарстан Респ-касы нефть төбәге р-ннарының социаль-икътисади хәле, аларның экологиясе проблемаларын күтәргән «20 ел юлда» («20 лет в пути», 1998), «Хәтер офыклары» («Даль памяти», 1998) дип аталган публицистик очерклар җыентыклары социаль әһәмияткә ия.

**ӘХТӘМҖА́Н** Абдулхан (Габделхан) Габдрахман улы (10.12. 1930, Мәскәү), тарихчы, тарих фән. д-ры (1974), проф. (1976), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1999). РФнең атказ. фән эшлеклесе (2001). СССР Тышкы эшләр министрлыгының 1 нче класслы киңәшчесе (1983). СССР Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тын тәмамлый (1954). 1945–49 елларда Мәскәүдә заводта слесарь. 1958 елдан Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-ты укытучысы, 1978 дән Европа илләре һәм Америка тарихы һәм сәясәте каф. мөдире. Бер үк вакытта ин-т нәшриятының баш мөхәррире (1960–62). 1974 тән «Россия-Австрия җәмгыяте» вице-президенты, 1993 тән Россия-Германия дуслыгы лигасы рәисләренең берсе. Хезмәтләре Россиянең Германия һәм Австрия б-н дипломатик мөнәсәбәтләре тарихына карый. Халыклар Дуслыгы ордены, «Австрия Республикасына күрсәткән хезмәте өчен» алтын билге, медальләр б-н бүләкләнә.



А.Г.Әхтәмҗан.

Х е з м.: История международных отношений и внешней политики СССР. М., 1960; От Бреста да Киля. Провал антисоветской политики германского империализма в 1918 г. М., 1963; Раппальская политика. Советско-германские дипломатические отношения в 1922–1932 гг. М., 1974; Объединение Германии или аншлюс ГДР. М., 1994.

**ӘХТӘ́МОВ** Алексей Михайлович (21.3.1946, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1990), проф. (1992). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1970), шунда ук филос. кафедрасында эшли. Хезмәтләре табигатьне фәнни танып белүдә структураны күзаллауларның үзара бәйләнеше һәм идеаллаштыру мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Идеализация в естественно-научном познании. К., 1988; Развитие концептуальных систем химии как уровней идеализации // Тр. Моск. хим.-технол. ин-та. 1989. Вып. 155; Философия в системе культуры. К., 2000.

**ӘХТӘ́МОВ** Әбүсогуд Габделхаликъ улы (1843, Уфа губ. Бәләбәй өязе — 1918 дән соң), хокук белгече, эре җирбиләүче, «*Иттифакъ әл-Мөслимин*» партиясен оештыручыларның берсе. Атасы башкорт-мишәр гаскәре ахуны була. Казанда Беренче ир балалар гимназиясен (1863) һәм Казан ун-тын (1871) тәмамлый. 1871–81 елларда Уфа губернаторы канцеляриясендә махсус вазифалар үтәүче чиновник, Уфа шәһәре мәхкәмәсе тикшерүчесе. 1881–86 да Бәләбәй өязе земство идарәсе рәисе, бер үк вакытта 1885 тә Уфа губернасы земство идарәсе әгъзасы. 1891–93 тә Уфада мәхкәмә тикшерүчесе. 1895–1901 дә Мөселман диния нәзарәтенең (мөфтиятнең) шәрәфле сәркәтибе (Уфа ш.). 1902–17 елларда Уфа округы мәхкәмәсендә антлы вәкил, Бәләбәй өязенең шәрәфле мировой судьясы. Мөселман халыкларының милли-мәдәни яңарышы тарафдары. Уфа губернасы мөселманнары арасында мәдәният-мәгърифәт эшчәнлеге алып бара. 1905 нең августында Түбән Новгород шәһәрендә Бөтенроссия мөселманнарының яшерен уздырылган 1 нче корылтаен оештыручыларның берсе. 1906 да Уфа губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасына депутатлыкка сайлана. Мөселманнар фракциясенең бюро әгъзасы була. Кадетлар партиясен яклый. Дума куып таратылгач, 1906 ның июлендә хөкүмәткә каршы *Выборг өндәмәсе*нә кул куючылардан. Шул сәбәпле Ә. фикердәшләре б-н бергә хөкемгә тартыла, әмма 1907 нең декабрендә узган мәхкәмә утырышы аны аклый. 1914 нең июнендә С.-Петербургта уздырылган 4 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда Уфа губернасы вәкиле буларак катнаша, хөкүмәтнең ислам диненә тотучыларга карашы турында нотык сөйли. Мөселманнар чит кешеләр («инородец») дип саналырга тиеш түгел, илнең тулы хокуклы гражданнары булырга тиеш, ди. Шуннан соңгы еллардагы сәяси эшчәнлеге мәгълүм түгел, 1918 дән соңгы язмышы да ачыкланмаган.

*Әд.:* Т у к т а р о в М.Ф. Беренче, икенче, өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре. К., 1909; И с х а к о в С.М. Ахтямов Абуссугуд // Отечественная история: Энцикл. М., 1994; Мусульманские депутаты Государственной думы России (1906–17): Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Л.М.Айнетдинова, Д.М.Усманова.*


**ӘХТӘ́МОВ** Бари (Габделбари) Шәрифҗан улы (7.6.1910, Казан — 17.1.1999, шунда ук), балет артисты, ТАССРның атказ. артисты (1945). 1930–34 елларда Татар акад. театрының бию төркеме артисты. Зур театр каршындагы Мәскәү хореография уч-щесен (П.Гусев классы) тәмамлый (1939). 1939–69 да Татар опера һәм балет театрының төп солистларыннан берсе. Ә.нең иҗади осталыгы татар композиторлары балетларындагы Былтыр («Шүрәле», Ф.Яруллин, рольне беренче башкаручы), Нур («Зөһрә», Н.Җиһанов), Хан («Алтын тарак», Ә.Бакиров) кебек төп партияләрне башкарганда ачыла. П.Чайковскийның «Аккош күле» (Зигфрид), Б.Асафьевның «Бакчасарай фонтаны» (Вацлав), Р.Глиэрның «Кызыл мәк» (Ма-Ли-Чен) һ.б. балетларда төп хореографик партияләрне башкара. Тиңдәшсез пластикага һәм югары сикерү сәләтенә ия. Артистның шәхси стиле — образларны үтә сизгер тоеп, бөтен тирәнлеге б-н ачып сала белүе, рольләренең гаҗәеп матурлыгы, биюләренең тәэсирле булуы, холкына тәңгәл килүе б-н үзенчәлекле.

*Әд.:* Из истории татарского балета // Татар. акад. театр оперы и балета им. М.Джалиля. К., 1994.

*В.Н.Горшков.*

**ӘХТӘ́МОВ** Ибнеәмин (Биньямин) Әбүсогуд улы (6.11.1877, Уфа ш. — 1941, Мәскәү), хокук белгече, милли сәясәт эшлеклесе. Дворян нәселеннән; Ә.Г.*Әхтәмовның* улы. 1898 елдан Петербург ун-тының физ.-матем. ф-ты студенты. 1899 да студентлар чуалышында катнашкан өчен укудан куыла. 1901 дә «Эшчеләр оешмасы комитеты» эше буенча кулга алына; 3 ай төрмәдә утырганнан соң Уфага сөрелә. Тыелган әдәбият саклаганы өчен Уфада кабат кулга алына. 1903 елдан Социа-


Ә.Г. Әхтәмов.


Ибнеәмин Ә. Әхтәмов.


Ибраһим Ә. Әхтәмов.


С.Ә. Әхтәмов.

лист-революционерлар партиясе әгъзасы. Петербург ун-тының табигать (1907) һәм хокук фәннәре (1910) ф-тларын тәмамлый. Башта Казан округы мәхкәмә палатасында антлы вәкил ярдәмчесе, аннары Уфада антлы вәкил булып эшли. 1911 дә Казанда яшьләрнең революцион түгәрәге җитәкчеләреннән берсе. Уфа губернасыннан 4 нче Дәүләт Думасына депутатлыкка сайлана. Мөселманнар фракциясе сәркәтибе була (1912–17). С.-Петербургта «*Милләт*» г-тасын (1913–15) оештыручылардан һәм наширләреннән берсе. 1914 нең июнендә С.-Петербургта Бөтенроссия мөселманнарының 4 нче корылтаен үткәрүдә катнаша, мөселманнарның дини оешмаларына үзгәрешләр кертү кирәклеге турында нотык сөйли. *Бөтенроссия мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре корылтае*нең президиум рәисе (Петроград, 6–10 дек., 1914), анда Мөселман гаскәриләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүче вакытлы ком-тка әгъза итеп сайлана. Урта Азиядәге 1916 елгы баш күтәрүдә катнашучыларны хөкем итү мәхкәмәсендә (1916 ел, декабрь, Наманган ш.) гаепләнүчеләрне яклаучы буларак катнаша. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң, март аенда, *Россия мөселманнарының вакытлы мәркәз бюросына* сайлана. Уфа губернасы мөселманнары эше буенча Вакытлы хөкүмәтнең комиссары итеп билгеләнә. 1917 нең апрелендә Уфа губернасы мөселманнарының 1 нче корылтае рәисе, май аенда Мәскәүдә уздырылган *Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае* делегаты, анда Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасына әгъзалыкка кандидат итеп күрсәтелә. 1917 нең июлендә Уфа губернасы мөселманнарының 2 нче корылтаенда губерна мөселманнары Шурасы рәисе итеп сайлана. Россиядә яшәүче төрки халыкларның *милли-мәдәни мохтарият*ын яклаучыларның берсе. 1917 нең июль-августында Казанда узган Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче корылтаенда *Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Милли-мәдәни мохтарият нигезләрен эшләү комиссиясе* рәисе урынбасары итеп сайлана. *Милләт Мәҗлесе* депутаты. *Төркичеләр* фракциясе әгъзасы, Милли Идарә рәисе урынбасары (1917–18). Совет хакимиятен кабул итми, *КОМУЧ* тарафдары. КОМУЧ хакимлек иткән вакытта Уфа шәһәре думасы гласные (1918, сент.). Уфаны большевиклар алгач, Милли Идарә вәкилләренең бер өлеше Себердә Кызылъяр (Петропавел ш., хәзер Казакъстанга керә) шәһәрендә эшчәнлеген дәвам иттерә. 1919 елдан Ә. Кызылъярда төрле оешмаларда юрист вазифасын башкара. 1920 еллар урталарыннан Казанда яши, «Яңалиф» ком-ты әгъзасы, латин язуына күчүгә каршылар төркемендә тора. 1931 дән Бакуда — СССР икътисад банкының Әзәрбайҗан конторында икътисад инспекторы. 1936 дан Мәскәүдә — «Росшвейбыт» берләшмәсенең Мәскәү транзит базасы хокук бюросы башлыгы урынбасары; 1940–41 дә СССР Куллanучылары Үзәк берлегендә (Центросоюз) юрист.

*Әд.:* И с х а к о в С.М. Ахтямов Ибниамин // Отечественная история: Энцикл. М., 1994; Мусульманские депутаты Государственной думы России (1906–1917): Сб. док. и материалов. Уфа. 1998; Т а и р о в Н.И. Дальнейшая судьба Ибниамина Ахтямова // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 3/4.

*Л.М.Айнетдинова, Д.М.Усманова.*

**ӘХТӘ́МОВ** Ибраһим Әбүсогуд улы (9.5.1880, Уфа — 1931, Мәскәү), хокук белгече, татар меньшевиклары җитәкчеләренең берсе. Ә.Г.*Әхтәмовнең* улы. 1899 елда Петербург ун-тының Шәрекъ телләре ф-тына укырга керә, 1900 нең октябрендә Казан ун-тының юридик ф-тына күчә. 1902 дә Казанда РСДРПның беренче ком-тын оештыручы һәм аның җитәкчеләренең берсе. 1903 нең язында сәяси эшчәнлеге өчен кулга алына һәм Казаннан сөрелә. 1905–07 дә большевиклар б-н якынлаша. 1906 дан Петербург ун-тының юридик ф-тына кире кайта, аны тәмамлагач, 1917 гә кадәр Уфада антлы вәкил булып эшли. Төрле иҗтимагый оешмалар эшендә катнаша (мәс., «Югары уку йортларында укучыларга ярдәм итү җәмгыяте»ндә идарә әгъзасы, «Уфа губернасы халык университетлары җәмгыяте» әгъзасы һ.б.). Уфа шәһәре думасы гласные (1913–16). Февр. рев-циясеннән соң Уфа губернасы иҗтимагый оешмалары ком-ты һәм РСДРПның берләштерелгән Уфа ком-ты рәисе, Уфа губернасы Эшче һәм солдат депутатлары советы башкарма ком-ты, губернаның азык-төлек ком-ты әгъзасы. Шул елның сентябреннән Уфа шәһәре Меньшевиклар партиясе оешмасы рәисе. РСДРПның апрель конференциясе эшендә (1917) һәм Эшче һәм солдат депутатларының Уфа губернасы советының 2 нче съездында (1917, июль) катнаша. *Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае* (Мәскәү, 1917, май) президиумы һәм Бөтенроссия мөселманнары шурасы әгъзасы. Окт. рев-циясеннән соң совет хакимиятенә каршылар сафына баса. КОМУЧ тарафыннан 1918 нең сентябрендә Уфада уздырылган дәүләт киңәшмәсендә Себер, Урал һәм Идел буе шәһәрләре һәм земстволары вәкилләренең берсе буларак катнаша. Шул чорда Уфа шәһәре думасы гласные (1918, сент.). 1922 елдан Мәскәүдә — СССР Кулланучыларының Үзәк берлеге (Центросоюз) юристы. Язмышының соңгы еллары ачыкланмаган.

**ӘХТӘ́МОВ** Илдар Фоат улы (5.3.1960, Уфа ш.), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТРның атказ. уйлап табучысы (1996). 1983 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1984 тән Татарстан ортопедия һәм травматология ин-тында, 1990 нан Казан мед. академиясенең травматология һәм ортопедия каф. мөдире. 1998 дән Казан мед. ун-тының травматология, ортопедия һәм экстремаль халәтләр хирургиясе каф. мөдире. Тикшеренүләре терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарланган балаларны хирургик дәвалау ысулларын камилләштерүгә һәм балаларда тумыштан килгән төрле формадагы бот сөякләре чыгуын дәвалауга; эре буыннарны эчке протезлауга; оча, бот буыннарының дегенератив дистрофик зарарлануын дәвалауга; патофизиологиягә; биомеханикага, патогенезга, тумыштан зәгыйфь аякларның нормаль үсеш теориясен төзүгә карый. «Оча һәм бот буынын дәвалауда Г.А.Илизаров ысулын куллану» дигән күмәк хезмәтләр циклы өчен Г.А.Илизаров исем. бүләк (1989), «Түбән очлыклары ортопедик авырулы балаларны, торсион патологияне исәпкә алып, хирургик реабилитацияләүнең яңа системасы» исемле хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә (1995).


Х е з м.: Хирургическое лечение врожденного вывиха и подвывиха бедра у детей старше трёхлетнего возраста. К., 1994.

**ӘХТӘ́МОВ** Нильс Рәхимҗан улы (2.6.1931, Буа р-ны Аксу а. — 30.6.1992, Казан), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1976). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Казан авиация җитештерү берләшмәсендә инженер-монтажник, штурман-оператор, өлкән инженер, баш инженер урынбасары (1966–92). Дәүләт бүләге махсус элемтә өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХТӘ́МОВ** Сабир Әхтәм улы (15.6.1926, хәзерге Кукмара р-ны Югары Өскебаш а.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), полковник (1972). 1943 елның ноябреннән Кызыл Армиядә. 1944 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 4 нче гв. мотоукчылар бригадасының танкка каршы ата торган мылтык төзәүчесе (11 нче гв. армиясенең 2 нче гв. танк корпусы). 3 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Белоруссия, Литва, Көнчыгыш Пруссияне азат итү сугышларында катнаша. 1944 нең октябрендә Неммерсдорфны (хәзер Калининград өлкәсе Маяковский а.) штурмлаганда батырлык күрсәтә. Мәскәүдә Җиңү Парадларында катнаша (24.6.1945; 9.5.1995). Сугыштан соң Совет Армиясендә җитәкче вазифаларны башкара, КГБның Югары хәрби ин-тын тәмамлый (1959). 1972 дән запаста. Казанда яши. Ленин, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Х.Б. Әхтәмов.



Ф.К. Әхтәмова.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н  Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Д о б р о т в о р с к и й  Н.П. Герой Советского Союза Сабир Ахтямов. Л., 1965; Г а л и ц к и й  К.Н. В боях за Восточную Пруссию. М., 1970; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

**ӘХТӘ́МОВ** Садыйк Мөхәммәтҗан улы (19.3.1877, Казан губ., Тәтеш өязе Тутай а. — 26.1.1926, Казан), сәяси эшлекле. 1904–05 елларда «Тифлисский листок» г-тасында, 1905–07 дә Түбән Новгород, Харьков типографияләрендә эшли. 1905–07 елгы рев-циядә һәм Окт. рев-циясендә катнаша. 1918 дә Казанда Мөселман комис-тында эшли. Казанны чех-словаклар корпусы һәм КОМУЧның Халык Армиясе гаскәрләреннән азат итү сугышларында катнаша. «Эш» г-тасында мәкаләләр бастыра, шәһәрдә спектакльләр куюны оештыра, алардан кергән акча Сөембикә манарасын төзекләндерүгә тотыла. 1919–20 дә «Кызыл Йолдыз» агитпароходында агитатор-инструктор.

*Әд.:* Х а б и б у л л и н а  Ф. Ахтямов С.М. // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

**ӘХТӘМОВ** Самат Сирай улы (25.5.1933, Әлмәт р-ны Яңа Нәдер а.), а.х.пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1983). Казан кооператив техникумын тәмамлый (1969). 1960–65 елларда авыл куллanучылар җәмгыяте рәисе, 1965–70 тә Әлмәт р-нында партия эшендә. 1970–2003 тә «Ярыш» к-зы рәисе (1996 дан — авыл кооператив хуҗалыгы). Ә. җитәкләгән елларда хуҗалыкта зур терлекчелек комплексы булдырыла, барлык җитештерү тармакларында матди-техник база ныгытыла, а.х. культураларыннан югары уңыш үстерелә, 1 савым сыердан 4800 *кг* нан артык сөт алына. Социаль-көнкүреш һәм мәдәният объектлары, хуҗалыкта эшләүчеләргә уңайлы һәм газ кертелгән 80 нән артык фатир төзелә. 1980–85 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХТӘ́МОВ** Хәсән Бәдыйг улы (1925, Башкортстан АССРның Эстәрлетамак р-ны Аллагуват а., хәзер Васильевка пос. — 30.5.1944, Румыния, Яссы ш.), Сов. Союзы Герое (13.9.1944, вафатыннан соң), рядовой. 1943 елның февраленнән Кызыл Армиядә. 1944 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 857 нче укчылар полкы укчысы (52 нче армиянең 294 нче укчылар дивизиясе). 2 нче Украина фронты гаскәрләре составында Украина, Молдавияне азат итү сугышларында катнаша. Редиул-Алдей авылы (Яссы шәһәре тирәсендә) янындагы сугышта батырлык күрсәтә, 1944 нең 30 маенда граната б-н дошман танкына ташлана. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Славные сыны Башкирии. Уфа, 1968. Кн. 3.

**ӘХТӘ́МОВ** Шакир Әхмәтҗан улы (6.8.1901, Сембер губ., Буа өязе Иске Шәйморза а. — ?), партия эшлеклесе. 1922–24 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә. 1925–31 дә Владимир өлкәсенең Кольчугино шәһәрендәге төсле металл эшкәртү з-дында кочегар. 1931–34 тә Ярославль шәһәрендә резин-асбест комб-тында мәдәни хезмәткәр. 1934–52 дә Буа шәһәрендә: 1934–35 тә КПССның Буа райкомында пропагандист, 1935–38 дә инструктор, 1938–52 дә 1 нче секретарь. 1952–57 дә КПССның Апас райкомында 1 нче секретарь. ТАССР ЮС депутаты (1947–59). Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХТӘ́МОВА** Зәйтүнә Зиннур кызы (21.3.1927, Кама Тамагы р-ны Олы Кариле а.) җырчы (сопрано), ТАССРның атказ. артисткасы (1968). 1951–77 елларда ТАССР Җыр һәм бию ансамбле солисты. Репертуарының күп өлешен татар халык җырлары тәшкил итә. Бигрәк тә озын, сузып җырлана торган «Зөлхиҗә», «Сибелә чәчәк», «Уел», «Бөдрә тал», «Сакмар су» h.б. җырларны зур осталык б-н башкара. Репертуарына С.Сәйдәшев, Ф.Яруллин, Ә.Бакиров, Р.Яхин, А.Ключарёв, З.Хәбибуллин h.б. татар композиторларының җырлары, романслары; Көнбатыш Европа һәм рус композиторларының (Ш.Гуно, М.Глинка, Н.Римский-Корсаков, П.Чайковский) вокаль әсәрләре керә. Ә.ның башкару осталыгы әсәрләрнең поэтик һәм муз. эчтәлеген, тирәнлеген аңлап, аны тыңлаучыларга җиткерә белүе б-н аерылып тора. Җыр һәм бию ансамбле б-н ТАССР, СССР шәһәрләрендә, чит илләрдә (Вьетнам, Монголия, Корея) гастрольләрдә була. Вокалистларның Бөтенроссия конкурсы лауреаты (1951).

*Әд.:* Т а җ и е в а  К. Ансамбль сандугачы // Азат хатын. 1971. № 3.

**ӘХТӘ́МОВА** Роза (Рауза) Зәйдулла кызы (4.6.1947, Свердловск өлкәсенең Ревда ш.), шагыйрә, тәрҗемәче. Казакъ ун-тын тәмамлый (1973). Рус телендә яза. Яшьли сукырая. Алма-Атада яшәп, беренче шигырьләрен матбугатта 1970 елларда бастыра башлый. Ә. — «Көйгән йөрәк» («Обожжённое сердце», 1994), «Язмышлар һәм хакимнәр» («Судьбы и судьи», 1997), «Алтын минем дәшмәвем» («Золотое моё молчание», 2006) исемле шигырь, «Яхшылык кыл» («Сотвори добро», 1993) тәрҗемә, «Күңел күзе» («Свет прозрений моих», 2001), «Хәтер тәрәзәсе аша» («Через окно воспоминаний», 2001) исемендәге очерк һәм хикәя җыентыклары, «Мадам Сидорова» (2004) романы авторы. Казакъ, әрмән, төрек, немец телләреннән, ш.у. татар шагыйрьләреннән М.Хөсәен, С.Сөләйманова, Г.Афзал, К.Булатова, Р.Миңнуллин шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә. 2001 елдан Мурманск өлкәсенең Апатиты шәһәрендә яши.

*Әд.:* Поэт и прозаик Роза Захаровна Ахтямова: (К 60-летию со дня рождения): Библиогр. указ. М., 2007.

**ӘХТӘ́МОВА** Фирдәвес Каюм кызы (21.7.1939, Лаеш р-ны Яушыйк а.), драма актрисасы, ТРның халык артисткасы (1996). Кече театр каршындагы М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесенең Татар студиясен тәмамлаганнан соң (Мәскәү, 1961), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Иҗатында психологизмны татар театры традицияләре б-н органик рәвештә кушу нәтиҗәсендә тышкы кыяфәте б-н үзенчәлекле, ышандырырлык, тормышчан, колоритлы образлар тудыруга ирешә. Актрисага аеруча халыкчан характерлы, гади, саф күңелле, эчкерсез, үз-үзен корбан итәргә әзер торучы хатын-кыз образлары якын. Төп рольләре: Биби («Беренче театр», Г.Камал), Розалия («Соңгы хат», Х.Вахит), Мәйсәрә, Фатыйма, Шәмси («Американ», «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе», К.Тинчурин), Эльмира, Алтынчәч («Дуслар җыелган җирдә», «Әниләр һәм бәбиләр», Т.Миңнуллин), Җәмилә («Бәхетсез егет», Г.Камал), Фатыйма



Ф.К. Әхтәмова Алтынчәч ролендә («Әниләр һәм бәбиләр», Т. Миңнуллин).

(«Өчәү юлга чыктык», Р.Батулла), Софья («Бер төн», Б.Л.Горбатов), Липочка («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский), Абруй («Мәхәббәт турында сөйләшик», И.Зәйниев, 1987), Фирая («Галиябану — сылуым иркәм», Т.Миңнуллин, 2005).

**ӘХТӘ́МОВА** Халидә Сәмигулла кызы (10.2.1930, Мәскәү), скрипкачы, педагог, РСФСРның атказ. артисты (1977). Мәскәү консерваториясен (Д.Ойстрах классы, 1954), шунда ук аспирантура (1957) тәмамлый. 1957 елдан Мәскәү филармониясендә солист. Бер үк вакытта 1971 дән Гнесиннар исем. Россия музыка академиясендә укыта, 1977 дән скрипка һәм альт каф. мөдире, проф. (1984). Репертуарына, башлыча, рус, Көнбатыш Европа классик музыкасы әсәрләрен ала. М.Мозафаров, А.Ключарёв, З.Хәбибуллин, Р.Яхин h.б.ның әсәрләрен башкарып, татар скрипка музыкасының популярлыгын үстерүгә зур өлеш кертә. Россиядә һәм чит илләрдә актив концерт эшчәнлеге алып бара. Ә.га әсәрне тирәнтен тоеп, аны моң б-н сугарып, эчтәлеген, формасын саклап башкару хас. Бухарестта үткән халыкара конкурс лауреаты (1953, алтын медаль).

*Әд.:* М о н а с ы й п о в  Ш. Халидә Әхтәмова // Азат хатын. 1985. № 12; Ф и т х е н г о л ь ц  М.

Выступление скрипачей // Советская музыка. 1959. № 6; Д о м и е в а Ф. Скрипичный вечер Халиды Ахтямовой // Музыкальная жизнь. 1970. № 5.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**ӘХТИЯ́Л** елгасы, Каманың уң кушылдыгы. Көнчыгыш Кама төбәгендә. Озынлыгы 9,3 *км*, бассейнының мәйданы 42 *км²*. Менделеев р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Ташлы авылы, тамагы Ижевка авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 7%. Ә. елгасының 1–3,2 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Уртача күпьеллык ташу агымы катламы 110 *мм*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12 *мг-экв/л* га кадәр). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ӘҺЛИУ́ЛЛИН** Габдулла Әһлиулла улы (25.7.1924, Буа кантоны Югары Балтай а. — 27.3.2000, Казан), хокук белгече, РСФСРның атказ. хокук белгече (1982). Казан юридик ин-тын тәмамлый (1950). 1941–46 елларда Казан моторлар төзү з-дында станокчы. 1950–51 дә ТАССР Юстиция министрлыгында ревизор. 1951–57 дә Казанның Бауман р-ны халык судьясы. 1957–65 тә ТАССРның Югары мәхкәмә әгъзасы. 1965–84 тә ТАССР Адвокатлар коллегиясе президиумы рәисе. 1984–94 тә Казанның Бауман р-ны юридик консультациясе адвокаты.

*Е.Б.Долгов.*

**ӘҺЛИУ́ЛЛИН** Марсель Мотыйгулла улы (5.5.1933, Башкортстан АССР, Бәләбәй ш.), генерал-майор (1982), хәрби фән. канд. (1974). Хәрби интендантлар уч-щесен (1957), Тыл һәм транспорт хәрби академиясен тәмамлый (1970, Ленинград). 1950–60 елларда Урал һәм Ерак Көнчыгыш хәрби округларының тыл штабларында хезмәт итә. 1970–80 дә Ленинградта Тыл һәм транспорт хәрби академиясендә укыта, каф. башлыгы. 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ӘҺЛИУ́ЛЛИН** Мөнир Габдулла улы (27.9.1940, Буа р-ны Кыр Тәүгелдесе а.) журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан ун-тын (1968), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (1975, Мәскәү) тәмамлый. 1960 елдан Кама Тамагы р-нында чыга торган «Кызыл байрак» г-тасында бүлек мөдире, 1963 тән Лениногорск телевидение студиясендә мөхәррир, 1968 дән ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында хатлар бүлеге мөдире. 1969 дан «Кызыл таң» г-тасында бүлек мөдире (Уфа ш.). 1973–96 да «Ватаным Татарстан» г-тасында: хәбәрче, бүлек мөдире, мөхәррир урынбасары, 1990 нан баш мөхәррир. 1997 дән Татарстан китап нәшриятында директор урынбасары. 1999–2003 тә «Татарстан» ж-лында баш мөхәррир урынбасары, 2005–07 дә «Шәһри Казан» г-тасында бүлек мөхәррире. Дәүләт төзелеше, а.х. һәм Татарстанда милләтара багланышлар мәсьәләләренә караган мәкаләләре «Татарстан яшьләре», «Ватаным Татарстан» г-таларында, «Казан утлары», «Сөембикә», «Татарстан» ж-лларында басыла. ТР халык депутаты (1990–95). Татарстан Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. республика бүләге лауреаты (1984).

Ә с ә р.: Ямьле Болак буенда. К., 2003; Җир улы. К., 2003; Мәктәбем — гомер учагым. К., 2004; Зөя буе — туган җирем. К., 2005; Близкие проблемы далёких районов // Вот моя деревня. К., 1986.

*Әд.:* Ә г ъ з а м о в Ф. Күренекле журналист һәм җәмәгать эшлеклесе // Канатлар очканда ныгый. К., 2000.

**ӘҺЛИУ́ЛЛИН** Факил Вәлиулла улы (2.1.1936, Түбән Кама р-ны Тоба а. — 11.8.2001, шунда ук), урманчылык белгече, а.х. фән. д-ры (1983), проф. (1987), Мари Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1992), РФнең атказ. урманчысы (1999). Ленинград урман техник академиясен тәмамлаганнан соң (1964), Яшел Үзән тәҗрибә урман хуҗалыгында урманчы булып эшли. 1966–85 елларда Татарстан тәҗрибә-урман станциясендә, 1971 дән директор урынбасары. 1985 тән Мари техника ун-тында урманчылык каф. мөдире. Хезмәтләре урман белемenә, урманчылык эше, урман таксациясе, экология, табигатьне саклау мәсьәләләренә карый. Урманнарны инвентаризацияләүнең яңа ысулларын өйрәнә һәм җитештерү өлкәсенә кертә, ТРда урман хуҗалыгын оештыру һәм үстерүнең төп кагыйдәләрен эшләүдә катнаша, РФнең Европа өлешендәге урманнар өчен сортимент таблицалары төзи.

Х е з м.: Рекомендации по ведению лесного хозяйства Татарской АССР на зонально-типологической основе. М., 1986 (автордаш); Ельники Волжско-Камского региона и интенсификация хозяйства в них. Саранск, 1991.

**ӘҺЛИУ́ЛЛИН** Хәмит Шәмсетдин улы (20.3.1919, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Благовар р-ны Үдрәкбаш а. — 15.10.1943), Сов. Союзы Герое (30.10.1943, вафатыннан соң), өлкән сержант (1943). 1939 елдан Кызыл Армиядә, 1943 елның февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, сапёрлар взводы отделениесе командиры (65 нче армиянең 106 нчы укчылар дивизиясе 43 нче укчылар полкы). Үзәк фронт гаскәрләре б-н Курск шәһәрен (1943), Белоруссияне азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 25 октябрендә Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Лоев (Гомель өлкәсе) посёлогы янындагы сугышта һәлак була. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1985. Кн. 3.

**ӘҺЛИУ́ЛЛИНА** Фирдәвес Әсәдулла кызы (11.1.1954, Казан), язучы. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (1977, Мәскәү). 1978–79 елларда Казан курчак театрында, 1981–85 тә Татарстан китап нәшриятында, 1996–99 да «Мәдәни җомга» г-тасында эшли. Татар мәдәниятенең күренекле шәхесләре турындагы «Йолдыз язмышы» (1986), «Йөрәкнең соңгы кылы» (2004) китаплары, балалар өчен язылган «Ак күгәрчен» (1990) исемле әкиятләр җыентыгы, лирик шигырьләре тупланган «Кояш баласы» (1999) исемле китаплар авторы. Әсәрләре табигать матурлыгы тәэсирендә туган һәм символик мәгънәгә ия булган поэтик образларга бай. Ә.нең кайбер шигырьләренә көйләр язылган.



Х.Ш. Әһлиуллин.

**ӘҺЛИУ́ЛЛОВ** Нәгыйм Хәлил улы (12.10.1927, Ульянов өлкәсе, Чардаклы р-ны Поповка а.), химик, химия фән. д-ры (1980). Горький ун-тын тәмамлаганнан соң (1956), шунда ук нәорганик хим. каф. каршындагы лаб. мөдире (1960 елга кадәр), Химия ин-тының кушылмалар аеру лаб. мөдире (1962 дән). 1975 тән РФАнең Аеруча чиста матдәләр химиясе ин-тында (Түбән Новгород ш.): аеруча чиста матдәләр технологиясе лаб. мөдире, 1985 тән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре нәорганик химиягә һәм аеруча чиста матдәләр технологиясенә карый. Агымга каршы кристаллаштыру һәм ректификацияләү кулланып, гидрид һәм хлоридлар алу ысулларын эшли. Очучан матдәләрне чистарту өчен югары нәтиҗәле приборлар һәм җайланмалар төзи. Кремний тетрахлоридын оксидлаштырып, аеруча чиста кварцтан эшләнмәләр (кварц торбачыкларын, тигельләрне һәм җепселле яктылык үткәргечләр) алуга ирешә. Тикшеренү нәтиҗәләре Запорожье титанмагний комб-тында, Красноярск төсле металлар з-дында, Пермь хим. з-дында һ.б. пр-тиеләрдә гамәлгә кертелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Получение моногермания особой чистоты // Журн. неорганической химии. 1966. Т. 11 (автордаш); Газохроматографический и масс-спектрометрический анализ тетрабромида кремния // Журн. аналит. химии. 1975. Т. 30, вып. 9 (автордаш); Глубокая очистка хлорида галлия методом противоточной кристаллизации из расплава // Журн. прикладной химии. 1976. Т. 49 (автордаш).

**ӘҺЛУ́ЛЛИН** Илдар Рәүф улы (23.1.1959, Буа р-ны Күл Черкене а.), онколог, мед. фән. д-ры (1999). 1982 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Республика онкология диспансерында эшли, 1988 дән абдоминаль хирургия бүлеге мөдире. Бер үк вакытта 1996 дан Казан мед. академиясендә. Хезмәтләре ашказаны-эчәк юлларында, кече оча сөяге, бавыр, панкреатодуоденаль зонада таралган яман шеш авыруларын хирургик дәвалауга карый. Очлыкларның төп магистраль тамырларын протезлау методикасын гамәлгә кертә. Медицинадагы яңа технологияләрне кулланып, тире-мускулларга пластик операция ясау мето-



Р.Г. Әһлуллин.

дикаларын эшли, сөяк-мускулларга пластик операцияләр алымын киң куллана.

Х е з м.: Панкреатодуоденальная резекция в онкологической практике. М., 1995; Эвисцерация и одномоментная пластика тазовых органов при хирургическом лечении местно-распространённого рака. К., 1999.

**ӘҺЛУ́ЛЛИН** Рәүф Габдулла улы (15.11.1930, Буа р-ны Кыр Тәүгелдесе а. — 12.09.2006, Казан), Соц. Хезмәт Герое (1966). 1947 елдан колхозда эшли. 1956–60 елларда комсомол һәм партия эшендә. КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен читтән торып тәмамлый (1966, Мәскәү). 1960–78 һәм 1988–94 тә Буа р-ның «Память Ленина», 1978–82 дә «Гигант» к-злары рәисе. Ул җитәкчелек иткән чорда «Память Ленина» к-зында бөртеклеләрнең уңышы 12 *ц* дан (1960) 30 *ц* га, шикәр чөгендере 86 *ц* дан 250 *ц* га җитә, 1 савым сыердан 3000 *кг* сөт савып алына, колхозда җитештерүнең рентабельлелеге 10% тан 75% ка күтәрелә, а.х. продуктлары җитештерү буенча дәүләт йөкләмәләре уңышлы үтәлә. Колхозның җитештерү-техник базасы югары үсеш ала. ТАССР (1963–67), СССР (1974–79) ЮСлары депутаты. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б а х т и н П. Аглуллин Рауф Абдуллович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1980.

**ӘЧЕ́Т РАЙОНЫ́**, *Свердлов өлкәсенең* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1966 елның 30 декабрендә оештырыла. Үзәге — шәһәр тибындагы Әчет посёлогы (Екатеринбургтан 176 *км* көнбатыштарак). Халкы — 19132 кеше (2002). Татарлар саны: 1948 елда — 1586, 1967 дә — 2984, 1979 да — 2367, 1989 да — 1817, 2000 дә — 1717, 2002 дә — 2084 кеше. Районда 7 татар авылы бар (2002): Түбән Арый (480 кеше), Гәйнә (504), Ләмте (202), Яманъелга (148), Давыдково (Карши) (118), Көчкилде (85), Калтай (54). Түбән Арый авыллары — 1670 елдан мәгълүм, Гәйнә 1672 дән, Яманъелга 1697 дән, Ләмте 1714 елдан. Көчкилде һәм Давыдково (Карши) авылларына 1735 елда нигез салына. 1917 гә кадәр Ә.р. терр-ясендә 3 мәчет (Гәйнә, Давыдково (Карши), Ләмте авылларында) эшли. Районның 3 мәктәбендә 2006/2007 уку елында татар теле фән буларак укытыла. Класстан тыш татар телендә дуслык һәм «Әбием сандыгы» исемле аулак өй кичәләре үткәрелә. Милли көрәш секциясе эшли. Ел саен Нәүрүз һәм Сабан туе бәйрәмнәре уздырыла. Ә.р.нда Сов. Союзы Герое Н.Х.*Хаҗипов* туган.

**ӘШӘЛЧЕ́ БИ́ТУМ ЧЫГАНАГЫ́**, Татарстанда иң эре чыганакларның берсе. Әлмәт һәм Чирмешән р-ннары терр-ясендә, Түбән Абдул посёлогыннан көнбатыштарак урнашкан. Тектоник яктан Татар гөмбәзенең Көньяк күтәрелешендәге көнбатыш тау битенә карый. 1972 елда ачыла. Битумнарны пласт эченә хәрәкәтчән яну чыганагы кертеп яисә җылылык чыганагы максатында пар һәм һава катнашмасы кудырып, скважина ысулы б-н чыгаралар. Битумнар Пермь һәм югары ташкүмер кисемнәрендә очрый, ләкин аларның төп ятмасы Уфа һәм Казан ярусләры чигендәге утырмаларның комлы катламнарына туры килә. Битумнарның шактый зур ятмалары Сакмар ярусының бушлыклы һәм ярыклы известьташларында һәм доломитларында, аз күләмле ятмалары түбән Казан асъярусының Байтуган горизонтын каплаган токымнарда («уртача спириферлы известьташ»), ш.у. Ассель ярусының һәм югары ташкүмер бүлегенең карбонатлы токымнарында очрый. Төп файдалы горизонтның тирәнлеге 48–110 *м*; калынлыгы 35–41 *м*. Әшәлче чыганагы битумнары мальталар һәм югары үзлелекле нефтьләр классына керә, составында сирәк очрый торган элементлар (V, Ni һ.б) бар; токым массасында коллекторның битумга туенганлыгы 4–12%. Битумлы нефтьтә майлар — 58–70,3%, сумалалар — 20–30%, асфальтеннар — 5–8% чамасы. Чыганак тәҗрибә-сәнәгый эшләнеше хәлендә. Ә.б.ч. битумнары Шөгер нефть-битум з-дында эшкәртелә.

*Б.В.Успенский.*

**ӘШНӘ́К** елгасы, Көнбатыш Кама төбәгендә. Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 36,5 *км*, бассейнының мәйданы 309 *км*$^2$. Елга башы Питрәч р-ның Нептун авылыннан 1,5 *км* көньяктарак, тамагы Балык Бистәсе р-ның Рус Әшнәге авылыннан 1,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елганың түбән өлешләре Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Елганың 13 кушылдыгы бар. Иң зурысы — Ырга елгасы (13,7 *км*) — уң кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Елгаларның гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 160 *мм*, ташу агымы катламы 116 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче декадасында башлана. Ә. ноябрь уртасында туңа. Елганың кайбер урыннары кыш дәвамында катмый. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,4 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (6–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елга бассейнында гомуми су күләме 3,4 млн. *м*$^3$ булган 5 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Табигать истәлеге (1978).



Әшнәк елгасы.

**ӘШНӘ́К** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 24 *км* көньяктарак, Тигәнәле елгасы буенда. 2002 елда 168 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында болгарлар авылы урынында нигез салына. Рус чыганакларында Ошняк исеме б-н дә мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ә.тә мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 җил һәм 1 ярма ярдыру тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 3 вак-төяклә кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1134 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Рамодан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1859 елда — 601, 1920 дә — 1303, 1926 да — 1264, 1938 дә — 931, 1949 да — 499, 1958 дә — 476, 1970 тә — 563, 1979 да — 341, 1989 да — 177 кеше. Ә. тирәсендә 13–14 йөзләр эпиграфик истәлекләре — болгар чорына караган кабер ташлары саклана.

**ӘШНӘ́К КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Балык Бистәсе р-ны Рус, Кече һәм Олы Әшнәк авыллары янында Әшнәк елгасының (Каманың уң кушылдыгы) түбәнге агымында урнашкан. Ә.к. истәлекләрен өйрәнү 19 йөздән алып барыла: 1948 елда — Һ.В. Йосыпов, 1967 дә — Р.С.Габәшев, Е.П.Казаков һ.б. тарафыннан тикшеренүләр үткәрелә. Неолит һәм бронза чорының 5 торулыгын, Идел буе Болгары, Алтын Урда чорларына караган 3 авыллыкны, кабер ташлары булган каберлекне һ.б. истәлекләрне үз эченә ала. Торулыкларда керәч һәм андроноид рәвешле чакматашлы кирәк-яраклар калдыклары (якынча б.э.к. 14–13 йөзләр) табылган. Олы Әшнәк авылында урнашкан зиратта ике кабер ташы сакланган, аларның берсендә куфи язуы бар (1320 ел). Әшнәк комплексының кайбер табылдыклары В.И.*Заусайлов* коллекциясендә урын алган.

*Әд.:* Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; К а з а к о в Е.П., С т а р о с -

тин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

**ӘШНӘ́К-КАЧКАЛА́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әшнәк елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 42 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1889 да ачыла), вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 252,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Анатыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 253, 1897 дә — 278, 1908 дә — 243, 1920 дә — 297, 1926 да — 302, 1938 дә — 296, 1949 да — 258, 1958 дә — 200, 1989 да — 61 кеше.

**ӘШРӘФҖА́НОВ** Харис Әшрәфҗан улы (2.2.1943, Балтач р-ны Сәрдегән а.) журналист, филол. фән. канд. (1998), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан ун-тын (1970) һәм Ленинград Югары партия мәктәбен (1980) тәмамлый. 1962 елдан Балтач р-нында: мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе, рус теле укытучысы, ВЛКСМ райкомында мәктәпләр бүлеге мөдире. 1970 тән ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1974–78, 1980–82 дә Балык Бистәсе р-нында «Октябрь юлы» г-тасы мөхәррире. 1982–85 тә «Татарстан яшьләре» г-тасы мөхәррире. Мәкаләләре «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» г-таларында, «Казан утлары», «Ялкын» һ.б. ж-лларда басыла. 1985–89 да КПССның Татар. өлкә ком-ты инструкторы. 1989–98 дә Татарстан китап нәшрияты, 1998 дән ТР Китап палатасы директоры. Хезмәтләре Татарстанда китап басу эшенең үсешенә, тарихи әдәбият мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Татар китабын бастыруның үсеш перспективалары // Китапка хитаб — Слово о книге. К., 1994; Язучы һәм тарих. Уфа, 1998; Тарихка әдәби сәяхәт. К., 2000; Җылынырга кергән яфрак. К., 2005.

**ӘЮП бине ИСМӘГЫ́ЙЛЬ** әл-Бикләни әл-Буби (1860 еллар, хәзерге Тукай р-ны Бикләл а. — 1910 еллар, хәзерге Әгерҗе р-ны Иж-Бубый а.), хаттат, ташка уеп язу остасы. Ә. тарафыннан эшләнгән берничә кабер ташы Иж-Бубый авылы зиратында саклана. Һәйкәлләр ак таштан, турыпочмаклы итеп, өске өлешләре исә ярымтүгәрәк рәвешендә ясалган. Ташларның алгы ягына гарәп каллиграфиясе б-н нәстәгълик имлясында уелган язулар турыпочмаклы кысалар эченә алынган һәм җепсыман бизәкле тасма б-н әйләндерелгән. Өске, ярымтүгәрәк өлешендә эре хәрефләр б-н Коръән сүрәләреннән догалар урнаштырылган, алар астында мәрхүм турында мәгълүмат бирелгән, бакый дөньяда аның язмышын җиңеләйтү өчен ярлыкау сорап үтенү һәм Аллаһыга ялвару сүзләре язылган. Туу һәм вафат булу еллары һиҗри һәм милади ел исәбе буенча күрсәтелгән. Кабер ташларына Ә. үзенең исемен язып калдырган.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ӘЮ́ПОВ** Абрек Идрис улы (22.2.1936, Юдино р-ны Яңа Тормыш а.), авиация генерал-полковнигы (1993), техник фән. д-ры (1987), проф. (1991), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлар академиясен (1959, Мәскәү), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясе каршындагы Югары оборона курсларын тәмамлый (1990). 1959 елдан Хәрби Һава Көчләренең В.П.Чкалов исем. фәнни-тикшеренү ин-тында. 1987 дән СССР Оборона министрлыгы үзәк аппаратында. 1989–96 да Россия Хәрби Һава Көчләре баш командующие урынбасары, бер үк вакытта 1994 тән РФ Хәрби Һава Көчләренең баш инженеры. 1996 дан «Звезда-Стрела» дәүләт фәнни-производство үзәгенең ген. директоры — ген. конструкторы урынбасары. 1999 дан «Приоритет XXI» Оборона пр-тиеләре фонды президенты. Хезмәтләре, уйлап табулары авиация, ракета, космик техника һәм кораллары өлкәсенә карый. РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1997). 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен», «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ӘЮ́ПОВ** Наил Галиулла улы (1.1.1936, Мөслим р-ны Түреш а.), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1987), РФнең атказ. артисты (1999). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1965), Татар акад. театры труппасына алына. Киң колачлы актёр булуы аңа иҗатының башлангыч чорында ук төрле яшьтәге, төрле характердагы рольләр уйнау мөмкинлеген бирә. Ул «Миркәй белән Айсылу» спектаклендә (Н.Исәнбәт) фаҗигале язмышлы Миркәйне, «Күк капусы ачылса» да (Х.Вахит) шаян Ризванны, «Әни килде»дә (Ш.Хөсәенов) эгоист Ислам рольләрен башкара. Актёрның вокаль мөмкинлекләре булу аңа җырлы образлар башкарырга җирлек тудыра. «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин) спектаклендәге Исмәгыйль образы, башка рольләр кебек, үсеш-үзгәрештә күрсәтелә. Башта аңа шат күңеллелек хас булса, соңыннан ул



Н. Әюпов (Амур) һәм Р. Мотыйгуллина «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т. Миңнуллин) спектаклендә.



А.И. Әюпов.



Н.Г. Әюпов.

котылгысыз фаҗига кичерә. «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин) спектаклендәге Булат Ә. башкаруында гади, җырчы «мәхәббәт герое», ялга кайткан шахтёр егет кенә түгел, ә үз мәхәббәте, бәйсезлеге өчен көрәшүче образ булып гәүдәләнә. Ә. репертуарында ш.у. тышкы яктан тотнаклы, сабыр булып күренгән, шул ук вакытта көчле темпераменты б-н аерылып торган үзенчәлекле герой рольләре дә бар. Ә.ның иҗатына тормышчанлык хас. Репертуарындагы башка рольләре: Ризван («Күк капусы ачылса», Х.Вахит), Хөрмәтуллин («Портфельле кияү», Н.Исәнбәт), Кол Гали («Кол Гали», Н.Фәттах), Мәгънәви («Синең урыныңа кайттым», Р.Хәмид), Кәрим («Бәхетсез егет», Г.Камал), Амур, Хәйрулла, Ишми, Нурислам, Ислам («Диләфрүзгә дүрт кияү», «Без китәбез, сез каласыз», «Ат карагы», «Хушлашу», «Илгизәр + Вера», Т.Миңнуллин), Нугай би («Идегәй», Ю.Сафиуллин).

*И.И.Илялова.*

**ӘЮ́ПОВ** Ринат Мирзахәсән улы (28.3.1964, Питрәч р-ны Шәле а.), актёр, режиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007). Мәскәүдә М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен (1988), Б.В.Щукин исем. Югары театр уч-щесенең режиссёрлык ф-тын (1996) тәмамлый. 1988 елда Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Беренче башкарган рольләреннән үк — Марек («Җәһәннәм биюе», К.Хоинский), Чәчтараш («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Шәмсетдин («Галиябану», М.Фәйзи), Самсон («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир), Тукай («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», М.Гыйләҗев) һ.б. үзен талантлы актёр буларак күрсәтә. 1992 елдан үзе спектакльләр куя башлый: Г.Каюмовның «Кара пута серләре» («Япон әкияте»), «Һинд кызы», Аманулланың (Ә.Камалиев) «Әлепле әртистләре» әсәрләрен сәхнәләштерә. 1995 тән Татар яшьләр театрында (1996–2002 дә, бүленеп, Чаллы татар драма театрында) баш режиссёр. Бу елларда Татар яшьләр театрында «Мәкер вә мәхәббәт» («Коварство и любовь», Ф.Шиллер), «Сак-сок (Р.Батулла), «Алмачуар» (Г.Ибраһимов әсәре буенча), «Печән базары» (Г.Тукай әсәрләре буенча Р.Әюпов пьесасы), «Король Лир» (У.Шекспир); Минзәлә татар драма театрында «Остазбикә» (Г.Исхакый әсәре буенча), «Мөһаҗирләр» (М.Галәү әсәре буенча); Чаллы татар драма театрында «Галиябану» (М.Фәйзи), «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин), «Йосыф һәм Зөләйха» (Кол Гали поэмасы буенча) һ.б. спектакльләр куя. Ә. режис-

сурасына пьесадагы психол. төгәллек б-н эшләнгән реалистик характерларның логик чишелешен дөрес табу, һәр спектакльнең ачык чагылышлы образлылыгына ирешү хас.

*И.И.Илялова.*

**ӘЮ́ПОВ** Харрас Гыйльмегали улы (21.8.1946, Мөслим р-ны Түреш а.), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1972–83 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасы хәбәрчесе. 1983 тән Татарстан китап нәшриятында, 1994–2007 дә баш мөхәррир. Әсәрләре 1962 дән басыла башлый. «Ышаныч» (1980) дип исемләнгән беренче җыентыгында замандашларының бай рухи дөньясы чагыла. «Кояшлы яңгыр» (1983), «Каен балкышы» (1985) китапларында төп тема — авыл һәм аның кешеләре. 1990 еллардан Ә. шигырьләрендә татар халкының рухи традицияләре, туган телне, мәдәниятне саклау мотивлары көчәя. Бу темалар шәхеснең рухи сафлыгы, аның күңел дөньясының бөтенлегә проблемалары б-н тыгыз бәйләнгән. Ә. иҗатында гади генә шигъри юллар бай метафоралар, романтик күтәренкелек, реаль картиналар б-н үрелеп бирелә: («Таң суы», 1987; «Төнге кояшлар», 1989 һ.б.). Ә. шигырьне сюжетка коруга омтыла, бу аның поэмалары һәм балладаларында ачык күренә. Соңгы елларда басылып чыккан «Сабыр савытлары» (1992), «Намаз» (1995), «Ут аркылы сикерү» (2004) җыентыклары шагыйрьнең иҗади үсеш баскычлары булып тора. Шигырьләре рус һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителгән, кайберләре көйгә салынган.

Ә с ә р.: Җәяүле буран: Шигырьләр һәм поэмалар. К., 1996; Йөз яктысы: Шигырьләр, поэмалар. К., 2005.

*Әд.:* Зөлфәт. Тыелгысыз көч сере // Казан утлары. 1996. № 8; Ә х м ә т җ а н о в М. Нәселемнең мин бер тәрәзәсе... // Мәдәни җомга. 1996. 5 июль; В ә л и Р. Гомерләрнең өйлә туры җиткән... // Шәһри Казан. 1996. 23 авг.; Р ә х м ә т у л л и н а Г. Биш вакыт намаз // Шәһри Казан. 2002. 17 май; К а м а л о в а А. Без кояш балалары // Идел. 2004. № 7.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ӘЮ́ПОВ** Хәмит Әюп улы (28.6.1908, Уфа губ., Бөре өязе Шабай а. — 27.11.1980, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. СССР Финанс халык комис-тының Финанс академиясен тәмамлый (1969, Ленинград). 1926 елдан Башкортстан АССРда хуҗалык эшендә: хезмәт ияләре депутатларының Борай р-ны Шабай авыл советы секретаре (1928 гә кадәр), 1928–29 да Байкибаш волосте финанс бүлегендә эш башкаручы, 1929–30 да мөдир; 1930–34 тә Балтач р-ны финанс бүлегенең өлкән инспекторы, 1934–37 дә мөдире. 1939–42 дә ТАССР Финанс халык комис-тында бүлек башлыгы. 1942–43 тә Әгерҗе р-ны Тирсә МТСында сәяси бүлек башлыгы. 1943–50 дә ВКП(б)ның Ютазы, Красный Бор р-н ком-тларының 1 нче секретаре. 1950–51, 1957–69 да ТАССРның финанс министры. 1951–52 дә ТАССР МСның Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе идарәсе башлыгы. 1952–57 дә хезмәт ияләре депутатларының Чистай р-н советы финанс бүлеге мөдире. 1943–50, 1958–69 да ТАССР ЮС депутаты. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

# Б

**БАБА́** (бабай), нәсел-ыруны башлап җибәргән олуг шәхесне, торак урынга нигез салучы мөхтәрәм затны, зирәк ил карты-аксакалны белдерүче төшенчә, ш.у. ихтирамга лаек кешеләргә мөрәҗәгать иткәндә, яисә аларның якты истәлеген олылаганда әйтелә торган сүз. Б. төшенчәсе, гадәттә, хөрмәтле кешенең исеме б-н бергә әйтелә (мәс., «Идегәй» дастанында — Төкләс баба). Татарлар *сөннәткә* утыртучы картларны да Б. дип олылыйлар. Әти-әнинең, якын буын туганнарның атасына «бабай» рәвешендә эндәшү гадәткә кергән, шушы мәгънәдә өлкән яшьтәге хөрмәтле ир-атны белдерүче сүз буларак та кулланыла. Урта диалект сөйләшләрендә ул — каенага, мишәрләрдә һәм бастан татарларында — бичура, керәшеннәрдә — шамакай булып киенгән кәмитче мәгънәсенә дә ия. Б. төрле диалектларда тагын берничә фонетик вариантта очрый: бабый, пабай; кечерәйтү-иркәләү формалары — бабакай, бабач(а); образлы сөйләмдә бабайлар яисә бабалар рәвешендә еш кулланыла. Мәс. «*Баба тел*» гыйбарәсе татар теленең башлангычын, ягъни борынгы төрки тамырларын белдерү өчен кулланыла (туган телне — «ана теле» дип атыйлар). «Бабайлар сүзе» — бабайларның изге васыяте, афоризмнар. Гасырлардан килгән традицияләр, гореф-гадәтләр ш.у. «бабалар сукмагы» сүзтезмәсе б-н аңлатыла.

*Әд.:* Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. К., 1977. 1 т.; Р а м а з а н о в а Д.Б. Термины родства и свойства в татарском языке. К., 1991.

*Ф.Ф.Гулова.*

**БАБА́ ТЕЛ**, нигез тел, генетик бәйләнештә булган телләрнең иң борынгысы. Аның гомуми схемасы, моделе барлык тел материалын чагыштырма-тарихи ысул ярдәмендә өйрәнеп яңадан торгызыла (реконструкцияләнә). Б.т. — диалектларыннан тугандаш телләр (телләр семьялыгы) төркеме барлыкка килгән бердәм тел буларак фаразлана. Б.т.нең элемент һәм формалары — архетиплар, ә аларның хәзерге телләрдәге тәңгәллекләре рефлекслар дип атала. Чагыштырма-тарихи тел белеме ярдәмендә һинд-европа, славян, төрки һ.б. Б.т.ләр яңадан торгызылган. Соңгы глоттохронологик исәпләүләр буенча, борынгы төрки уртаклык (Саян-Алтайның көньяк тайга-дала өлешендә булган) б.э.к. 3 йөздә таркала. Реконструкцияләнгән борынгы төрки лексика меңгә якын сүз берәмлеген (мәс., kün — кояш, көн, kök — күк, зәңгәр, jultuz — йолдыз, aj — ай, jel — җил, jer — җир, at — ат, böri — бүре) эченә ала. Төрки Б.т.нең фонетик системасы 8 кыска һәм 8 озын сузык авазны: a, ä, o, ö, u, ü, i, ï, ā, ǟ, ō, ȫ, ī, ï̄, ū, ǖ (озын сузыклар хәзерге күпчелек төрки телләрдә сакланмаган) һәм 15 тән дә ким булмаган тартык фонеманы берләштерә. Морфологик системада исемнәр өчен — күплекне белдерүче — lar кушымчасы (шулай ук башлангыч үсеш чоры өчен, күрәсең, гомумалтай баба теленнән күчкән — z, -k, -t, -s, -l, -r, -n кушымчалары), тартым кушымчалары -im (1 нче зат берлек санда), -iη/-ig (2 нче зат берлек санда), -i/-si (3 нче зат), biz (1 нче зат күплек санда), -ηïz, -gïz (2 нче зат күплек санда) хас булган. Борынгы төрки дәвер төрләнеш системасы баш килеш (ноль күрсәткече б-н), иялек (in, -iη), төшем (-i, -ig), бирем (-a, -ka), юнәлеш (-ra, -ča, -garu), корал (-in), урын-чыгыш (-da, -dan), уртаклык (-la, -li, -lan) килешләреннән гыйбарәт булган. Саннарда унарлы система өстенлек иткән. Иң борынгы төрки чорда алдагы унлыкка якынайтып санау хас булган (iki otuz — егерме ике). Фигыльләр 1 нче зат берлек санда -bän, -m, 2 нче зат берлек санда -säη, -η, 1 нче зат күплек санда — biz, -k, 2 нче зат күплек санда -siz, -giz кушымчалары б-н төрләнгән. Төрки Б.т.нең синтаксисында гади җөмләләр, буйсынган трансформалар, ягъни иярчен җөмләләрне алыштыра торган сыйфат һәм хәл фигыль формалары өстенлек иткән.

Төрки Б.т.не чагыштырма-тарихи ысул кулланып яңадан торгызу б-н А.М.Щербак, Б.А.Серебренников, Н.З.Гаджиева шөгыльләнгән.

*Әд.:* Общее языкознание. Методы лингвистических исследований. М., 1973; Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: В 4 кн. М., 1984–2001; Т е н и ш е в Э.Р. К понятию общетюркское состояние // Советская тюркология. 1971. № 2.

*Р.А.Закиров.*

**БАБА́НОВ** Юрий Васильевич (12.12.1931, Казан — 30.10.1995, шунда ук), географ-геоморфолог, проф. (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1955). 1956–58 елларда Алтай геол. экспедициясендә (Усть-Каменогорск ш.) эшли. 1958–62 дә Казан ун-тының физик геогр. кафедрасында; 1962–65 тә Төньяк гидротехника һәм мелиорация фәнни-тикшеренү ин-тының Казан гидрология һәм су ресурслары бүлегендә. 1965–95 тә Казан пед. ин-тында, физик геогр. каф. мөдире (1968–81). Хезмәтләре физик география, гидрология, дүртенчел чор геологиясе, геоморфология өлкәләренә карый. Елга үзәннәре төзелеше, сөзәклекләр үзгәреше, рельефның су агымына тәэсире, тигезләнү өслекләре, тектоник структуралар һәм рельеф катламы формалашуның төбәк һәм теоретик проблемаларын тикшерә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ФАнең П.П.Семёнов исем. алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физико-географическое районирование Среднего Поволжья. К., 1964 (автордаш); Асимметрия рельефа: причины и следствия. К., 1979; Формирование и развитие асимметричных склонов речных долин Среднего Поволжья. К., 1989; Природа Республики Татарстан. К., 1993 (автордаш).

*Әд.:* Д е д к о в А.П., Т р о ф и м о в А.М. Потери науки. Юрий Васильевич Бабанов (1931–1995) // Геоморфология. 1996. № 2.

*Т.Г.Чекменёва.*

**БАБАСЫРЛА́Р** (Enterobius), йомры паразит суалчаннар ыругы. Гәүдәсе орчыксыман, ак төстә. Ана затларның озынлыгы — 12 *мм*, ата затларныкы 5 *мм* га җитә. Кеше һәм приматлар эчәгесе паразиты. 20 төре билгеле. Россиядә, ш.у. Татарстанда бер төре — балалар бабасыры (E. vermicularis) киң таралган. Үсеше арадаштан хуҗалардан башка үтә. Ана зат 5 тән алып 17 меңгә кадәр йомырка (озынлыгы якынча 0,05 *мм*) сала, алар 4–6 сәгать эчендә җитлегәләр. Тышкы мохиттә 3 атнага якын яшәргә сәләтле. Кеше инвазион йомыркалар йотып зарарлана; нечкә эчәктә тишелеп чыккан личинкалар юан эчәк башланган урынга күчәләр һәм 2 атнадан соң җенси яктан җитлегәләр. Җитлеккән ана затлар арт юлдан чыга һәм аның тирәли йомырка салып калдырып үлә. Б. 1 айдан артык яшәми, энтеробиоз авыруын китереп чыгара. Тормыш циклының гадилеге, зарарлануның һәм кешенең кабат үз-үзен зарарлауның җиңеллеге аркасында авыру озакка сузыла һәм хроник төс ала.


*О.Д.Любарская.*

**БА́БИЧ** (Бабичев) Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы (2.1.1895, Уфа губ., Бөре өязе Әсән а. — 28.3.1919, Башкортстан АССРның Җәлаир кантоны Җәлаир а.), татар-башкорт шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Авылда әтисе мәдрәсәсендә, аннары «Галия»дә (1911–16, Уфа ш.) белем ала. 15 яшьтән казакъ авылларында һәм Троицк шәһәрендә мөгаллимлек итә. «Аң», «Шура», «Кармак», «Акмулла», «Хөр милләт», «Сүз», «Тормыш», «Ирек» г-та, ж-ларында язышa. 1917 елның көзеннән башкорт милли хәрәкәтендә катнаша, Башкорт Шурасының сәркәтибе итеп сайлана, «Башкорт» г-тасының мөхәррире була. Милли аңны тәрбияләү, әдәби талантларны бергә туплау, башкорт телен һәм әдәбиятын үстерүне максат итеп куйган «Тулкын» әдәби оешмасын төзүдә башлап йөри. 1919 ның 25 февраленнән Башкортстан ревкомының матбугат бүлегендә эшли.

Шигырьләре 1913 тән матбугатта күренә башлый. Аның иҗатында татар, башкорт һәм казакъ әдәбиятларының традицияләре органик рәвештә үрелеп бара. Б. — Тукай мәктәбе шагыйре: Тукай әсәрләренең романтик рәвештә эшкәртелгән темалары, мотивлары, образлары, сюжетлары, әдәби алымнары, стилистик детальләре аның иҗатында чагылыш таба. Поэзиясендә ш.у. Дәрдемәнднең фәлсәфи лирикасы йогынтысында туган аллегорик образлар да күзәтелә. С.Рәмиевнең гыйсъянчылык романтизмы да Б. өчен якын була. Б.ның романтик поэзиясенә хас темалар: табигать, мәхәббәт, сәнгать культы, шә-



Шәехзадә Бабич.



И.К.Бабст.



Е.Н.Багаева.

хес иреген һәм милли-азатлык хәрәкәтен яклау; кадимчелек идеологиясен һәм феодаль торгынлыкны инкарь итү. Аның шигырьләрендә һәм поэмаларында лирик геройның җәмгыятьтә хөкем сөргән әхлакый нормалардан күңеле кайтуы чагылыш таба: «Дөньяга» (1915), «Таң вакыты» (1915), «Мин» (1915), «Мин — даһи» (1916), «Миндә көч» (1917) һ.б. Мәхәббәткә, хатын-кыз матурлыгына багышланган шигырьләре арасында «Гашыйк дустыма» (1910), «Бәнем фәрештәм» (1912), «Кыз» (1916), «Саҗидәгә» (1916), «Тешсез кыз» (1916), «Мәхәббәт тоткыны» (1917), «Матур сыннар» (1917), «Әкълимәгә» (1917), «Мәхәббәт җырлары» (1917), «Кил, чибәр» (1917), «Зөһрәгә» (1917), «Шәмсекамәргә» (1917), «Гыйшык» (1918) һәм «Исемнәр бакчасында» (1917) шигъри циклы бар. Б. хатын-кызларга багышланган шигырьләрендә фольклор һәм классик Шәрекъ поэзиясенә хас исемнәр куллана (Сара, Сәрвәр, Маһирә, Нәфисә, Мәрьям һ.б.). Б.ның романтик поэзиясендә муз. тематика аерым бер урын алып тора. Ул сатира һәм юморга корылган халык җырларын, такмакларын җыя, аларга интерпретация ясый. Кайбер шигырьләре халык көйләренә җырлана: «Шатлык җыры» (1917), «Мәхәббәт җырлары» (1918), «Дим буе җырлары» (1918). Б.ның музыкага карашы «Мандолина» (1914), «Скрипка» (1915), «Канун тыңлаганда» (1915), «Курайкайга» (1918) исемле шигырьләрендә ачык чагыла.

1915–17 елларда Б. татар поэзиясенең җәүһәрләренә әверелгән әсәрләрен иҗат итә. 1916 да язылган «Кандала» һәм «Газазил» поэмалары — Б.ның югары дәрәҗәдәге сатирик әсәрләре. «Газазил» поэмасы — Газазил фәрештәнең җәннәттән куылуы (куылганнан соң *Иблис* дип атала) һәм аның кешеләрне юлдан яздыруы турындагы дини легендаларны сәнгати эшкәртеп, аларга үзенчәлекле төсмер биреп язылган әсәр. Аллаһ һәм Иблис образларында Б. мәңгелек теманы — Изгелек һәм Явызлыкның үзара көрәшен тасвирлый. Поэмада тормышның искергән якларына, догматик схоластикага карата тәнкыйть яшертен көлү, сатира һәм көчле сарказм, үткен юмор һ.б. аша бирелә. Болар барысы да «карнавал көлүе» формасында чагылыш таба. Поэма романтик иронияе, дини-мифологик образларны реаль тормышка бәйләп тасвирлавы б-н кызыклы. «Китабеннас фихәккыльхаувас» исемле, ике йөздән артык танылган шәхескә багышланган эпиграммалардан торган һәм 20 йөз башы татар зыялыларының шаян портретын тудырган җыентыгы — Б.ның ш.у. сатира һәм юмор өлкәсендәге зур уңышы.

Б. иҗатында татар һәм башкорт халыкларының милли азатлык хәрәкәте идеяләре дә киң чагылыш таба. «Хөррият бүләге» (1917) шигырендә революция нәтиҗәсендә татарлар, ниһаять, ireккә ирешер, дигән ышаныч чагыла. Б., Башкортстан Автономияле Респ-касы төзелү идеясен хуплап, башкорт халкы тарихының якты сәхифәләрен күз алдыннан кичерә («Көтмәсдән», 1918; «Байрам», 1918; «Гаскәр маршы», 1918; «Башкортостан», 1918; «Салауат батыр», 1918), Ленинга мәдхия җырлый («Әй, большевик!», 1917). Ул чордагы милли-сәяси хәрәкәтләрне һәм партияләрне хуплап, Б. халык, гади кеше, бигрәк тә «башкортлар өчен бәхетле ил» вәгъдә итүче социалистлар өчен тавыш бирергә өнди («Тупрак», 1917; «Беренсе номерлы список», 1917; «Список №9», 1917), җәмгыятьтәге төрле катлауларның илдә булган вакыйгаларга карата мөнәсәбәтен күрсәтә («Кызыл вәгазь», 1917), канкойгыч сугышны гаепли («Сугыш», 1917; «Кан шәүләләре», 1917).

1918 дән Б. поэзиясе икенче төрле төсмерләр ала. Күтәренке пафосны ирек һәм милли бәйсезлек идеалларының чәлпәрәмә килүе нәтиҗәсендә дөньяны трагик рәвештә кабул итү алыштыра («Сау бул, бәйрәм», «Тапмадым йолдыз», «Юк», 1918). Башкорт халкы кичергән авыр сынауларны тасвирлауга, башкортларның милли азатлык хәрәкәтенә багышланган «Большевиклар белән килешү турында башкорт халкына көйле хитаб» (1919) исемле мөрәҗәгате — Б.ның соңгы зур күләмле публицистик әсәре. Ул анда башкорт милли хәрәкәтенең каршылыклары, Россиядә 1917–19 да хакимият бүлгә юнәлтелгән бәрелешләр турында ачыктан-ачык сөйли. Башкорт халкының азатлык өчен көрәшенең тарихи юлын күз алдында тотып, Б., башкортларга кызыллар ягына чыгу хәерлерәк булыр, дигән фикердә тора. Шул ук вакытта ул большевиклар тарафыннан оештырылган кызыл террор хакында да үз фикерен әйтергә онытмый. Башкорт социалистларының һәм милли хәрәкәт тарафдарларының Дутов һәм Колчак ягына чыгуын «Красная гвардия» вәхшәтендән Башкортстан канга батканга!..» дип аңлата. Кызыл террорны фаш итүче нәкъ менә шушы юллар Б.ның язмышында хәлиткеч роль уйнаган дип фаразлана. «... көйле хитаб» чыгып, бер ай узганнан соң Б. үтерелә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1958; Зәңгәр җырлар. К., 1990; Һайланма әҫәрҙәр. Өфө, 1958; Избранная лирика. Уфа, 1966.

*Әд.:* И б р а һ и м о в Г. Вакытсыз һәлак булды // Әсәрләр: 5 томда. К., 1978; И с ә н б ә т Н. Шәехзадә Бабич // Казан утлары. 1967. № 6; Х а л и т Г. Шәехзадә Бабич // Татар әдәбияты тарихы. К., 1986. 3 т.; М и ң н е г у л о в Х. Шәехзадә Бабич. Олуг талант // Мирас. 1995. № 9. *Р.К.Ганиева.*

**«БА́БИЧ»**, иҗтимагый-сәяси, сатирик, рәсемле журнал. 1922 елда Уфа шәһәрендә айга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 4 саны чыга. Шигаре: «Пролетар эшче-крәстиян галиҗәнапләре — Бөтенроссиянең үз хуҗалары!». «Октябрьский натиск» басмаханәсендә басыла. Наширләре һәм мөхәррирләре И.*Рәмиев*, Д.*Юлтый*, Н.Кадыйров. Журнал үз алдына руханилар, милләтчеләр һәм бюрократлар б-н көрәшүне максат итеп куя. 3 нче һәм 4 нче саннары хакимият тарафыннан конфискацияләнә, хакимияткә каршы пропаганда алып баруда гаепләнеп, журнал чыгудан туктатыла.



«Бабич» журналы.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Г а й н а н о в Р.Р., М а р д а н о в Р.Ф., Ш а к у р о в Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000; Мәдәнейәт фырунтында X йыл: Материалдар йыйынтыгы. Өфө, 1929.

**БАБСТ** Иван Кондратьевич (20.10.1823, Воронеж губ. Коротояк ш. — 6.7.1881, Мәскәү губ., Звенигород өязе Белавино а.), тарихчы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, сәяси икътисад һәм статистика д-ры (1853). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1846). Т.Н.Грановский шәкерте. 1851 елга кадәр Мәскәү балалар ятимханәсендә тарих укытучысы. 1851–57 елларда Казан, 1857–74 тә Мәскәү ун-тларында сәяси икътисад һәм статистика фәне укытучысы, профессор. 1862–63 тә икътисад һәм статистика фәннәреннән Александр II уллары Николай б-н Александрга (булачак Александр III) белем бирә. 1864–68 дә Мәскәүдә Лазарев исем. Көнчыгыш телләре ин-ты директоры. «Вестник промышленности» ж-лы (1860–61) һәм «Акционер» г-тасы (1860–62) наширләренең берсе. 1867–68 дә «Москва» һәм «Москвич» г-таларының икътисад бүлеге мөдире. 1869–78 дә Мәскәү сәүдәгәрләр банкында идарә рәисе, совет әгъзасы. 1861 елгы реформага кадәр крепостнойлык тәртипләрен тәнкыйтьли, сәнәгатьтә буржуаз үзгәрешләргә өстенлек бирүне, Россиядә чит ил капиталын чикләүне яклый. 1856 елның 6 июнендә Казан ун-тында узган тантаналы утырышта сөйләгән нотыгында ул («О некоторых условиях, способствующих умножению народного капитала») Россиядә шәхси милекнең кагылгысыз булырга, казна карамагындагы сәнәгать берәмлекләре аерым эшкуарларга тапшырылырга, сәнәгать, сәүдә оешмалары һәм тимер юллар төзелешенең ирекле рәвештә үсәргә, халык мәгарифенә җитди әһәмият

бирелергә тиешлеге турында сөйли. Конституциягә нигезләнгән монархия тарафдары. Хезмәтләре сәяси икътисад һәм статистикага, Борынгы Греция һәм Рим тарихына карый.

Х е з м.: Курс политической экономии. М., 1859; Письма о путешествии государя наследника цесаревича по России от Петербурга до Крыма. М., 1864 (автордаш); Наше банковское дело. Письма... М., 1873.

*Әд.:* В е н г е р о в С.А. Критико-биографический словарь русских писателей и учёных. СПб., 1891. Т. 2; К а р а т а е в Н.К. Экономические науки в Московском университете (1755–1955). М., 1956; История русской экономической мысли. М., 1958. Т. 1, ч. 2.

**БАБУ́Р** Заһреддин бине Мөхәммәд (14.2.1483, Әндижан ш., хәзерге Үзбәкстан Респ-касы — 26.12.1530, Агра ш., Һиндстан), шагыйрь, тарихчы, Бөек Могуллар империясенә нигез салучы. *Аксак Тимер* нәселеннән; 1494 елда әтисе вафатыннан соң Фирганә тәхетенә утыра. 1504 тә Урта Азияне Шәйбани хан (үзбәкләр дәүләтенә нигез салучы) яулап алгач, илдән куыла. Аз санлы гаскәре б-н Әфганстанга, аннан Һиндстанга юл тота. 1526 да Дәһли шәһәре солтаны Ибраһим гаскәрен тар-мар итеп, Төньяк Һиндстанның идарәчесе була.

Төрки телдә һәм фарсыча язылган күпләгән шигъри әсәрләр (газәлләр, робагыйлар), фикъһ (ислам хокукы), сугыш сәнгате, шигърият, музыкага караган трактат-китаплар һәм автобиографик, тарихи язмаларны эченә алган «*Бабурнамә*» авторы буларак билгеле.

Ә с ә р.: Бабер-наме, или Записки султана Бабера. К., 1857; Бабур-наме. Записки Бабура. Таш., 1993.

*Әд.:* История всемирной литературы. М., 1985. Т. 3; М а л л а е в Н.М. Узбек адабиёти тарихи. Биринчи китоб. Тошкент, 1976.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**«БАБУРНАМӘ́»**, («بابور نامه»)16 йөз тарихи әдәбият истәлеге. Заһретдин бине Мөхәммәд *Бабур*ның 1526–30 еллар арасында төрки телнең чагатай шивәсендә язылган тарихи-биографик хезмәте. Анда автор биографиясенең 1493–1529 елларга караган аерым чорлары (Фирганә әмирлеге тәхете өчен көрәшүе, Сәмәрканд, Ташкент әмирлекләреннән куылганнан соң Һиндстанда үз дәүләтенә нигез салуы), Урта Азия, Әфганстан һәм Һиндстанда яшәүче халыкларның гореф-гадәте, Бабурга чордаш әмир-солтаннарның яшәеш рәвешләре һәм үзара көрәше тасвирлана, Казан ханлыгы да искә алына. «Б.» гади сөйләм телендә язылган, тасвирламалары төгәл, тәэсирле. Кулъязма рәвешендә киң таралган. Россиядә беренче мәртәбә Казанда Н.И.Ильминский тарафыннан 1857 елда нәшер ителә. Русча беренче тәрҗемәсе 1958 дә, соңгысы 1993 тә басыла.

Басм.: Бабер-наме, или Записки султана Бабера. К., 1857; Бабур-наме. Записки Бабура. Таш., 1958, 1993; Бобирнома. Тошкент, 1948.

*Әд.:* К о р - О г л ы Х.Г. Узбекская литература. М., 1968; А з и м д ж а н о в а С.А. Государство Бабура в Кабуле и Индии. М., 1977; А з и м д ж а н о в а С.А. Индийский диван Бабура. Таш., 1996.

*А.М.Ахунов.*

**БА́БУШКИН** Леонид Натанович (2.10.1931, Мәскәү), инженер-конструктор, РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1980), СССР һәм ТР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1978, 2002). 1951 елда Мәскәү авиация техникумын, 1964 тә Мәскәү инженерлык-икътисад ин-тын тәмамлый. 1951–2002 дә Мәскәүдә эшли: 1952 гә кадәр В.М.Мясищев җитәкчелегендәге Махсус КБда, 1952 дән М.Л.Миль исем. Махсус КБда техник-конструктор, әйдәп баручы конструктор, бүлек башлыгы, баш конструктор урынбасары. 2002 дән «Казан вертолёт заводы» АҖдә әйдәп баручы конструктор. Вертолётлар төзү һәм вертолёт комплексларын эл. б-н җиһазландыруга караган 19 уйлап табу патенты бар. Ми-6, Ми-10, Ми-8, Ми-14, Ми-24 вертолётларын төзүдә катнаша. ТР Дәүләт бүләге машина төзүдә яңа техниканы гамәлгә кертүе өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М о р о ш е к Е.М. На вертикальном взлёте. К., 1990; Казанские вертолёты. Полёт продолжается. К., 2000.

**БАВЫ́Р ИМГЕЧЛӘ́Р**, трематодлар классындагы *яссы суалчаннарның* элеккеге атамасы.

**БАВЫРСА́К**, татар халкының милли ризыгы. Махсус әзерләнгән төче камырдан урман яки әстерхан чикләвеге зурлыгында шарчыклар рәвешендә әзерләнеп, кайнап торган майда пешерелә. Табынга өстенә шикәр оны сибеп бирелә. Кайвакыт Б. камырга туралган бавыр катнаштырып әзерләнә. Мишәрләрдә Б., башлыча, «янгелдек» («цигелдек») дип аталган квадрат яисә ромб рәвешендәге печенье буларак мәгълүм. Б. яхшы саклана, шуңа күрә аны элек сәфәргә чыкканда юл азыгы итеп алганнар. Кайбер төбәкләрдә *чәкчәк* дип йөртелә. Б. шарчыкларын сыек бал б-н укмаштырып әзерләнә. Халык йолаларында Б. үзенчәлекле муллык символы булып тора. Элек кияү б-н кәләш өстенә Б. сипкәннәр, аның б-н кәләш каршылаучыларны сыйлаганнар; мишәрләрдә язгы «чеп-чеп» йоласы вакытында Б.ны балаларга өләшкәннәр.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в Ю.Ә. Татар халык ашлары. К., 1959; ш у л у к. Татарские блюда. К., 1961; Х а й р у т д и н о в а Т.Х. Название пищи в татарском языке. К., 1993.

**БАГА́ЕВА** Евдокия Николаевна (8.3.1933, Чистай р-ны Кубас а.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1973). 1952–90 елларда Чистай р-нының Ленин исем. к-зында эшли. Герой исеме терлекчелек продуктлары җитештерүне һәм әзерләүне арттыруда югары күрсәткечләргә ирешкәне һәм хезмәттәге батырлыклары өчен бирелә. Бөтенроссия колхозлар советы әгъзасы (1975). Ике Ленин ордены, медальләр, ш.и. ВДНХның бронза медале б-н бүләкләнә. Чистай шәһәре һәм Чистай р-нының мактаулы гражданы.

*Әд.:* Б у к ш т е й н Л. Багаева Евдокия Николаевна // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**БАГА́ЕВА** Татьяна Вадимовна (17.2.1952, Казан), микробиолог, биохимик, биол. фән. д-ры (1998), проф. (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1973), шунда ук микробиология кафедрасында эшли. Хезмәтләре анаэроб бактерияләр физиологиясе һәм биохимиясенә, углеводородларның микроорганизмнар б-н синтезлануына карый. Б. тарафыннан сульфат редукцияләүче бактерияләрнең күзәнәктән тыш углеводородларны синтезлый алуы, микроорганизмнар ярдәмендә табигатьтә углеводородлар хасил булу һәм углеводород чималы запасларының тулылану мөмкинлеге раслана; бавыр хроматины ДНКазасы активлыгын җайлауда түбән молекуляр төш РНКларының катнашы күрсәтелә. Уйлап табуга түбәндәге таныклыклары бар: «Сыек углеводородлар алу ысулы» («Способ получения жидких углеводородов», 1991), «Нефтьне сыегайтучы культуралы сыеклык алу һәм куллану ысулы» («Способ получения и применения культурной жидкости, разжижающей нефть», 1999). М.Җәлил исем. бүләк лауреаты (1979).

Х е з м.: Сравнительная характеристика внутри- и внеклеточных углеводородов Desulfovibrio desulfuricans // Биохимия. 1994. Т. 59, вып. 1 (автордаш); Определение включения трития в углеводороды Desulfovibrio desulfuricans // Биотехнология. 1997. № 3; Способность сульфатредуцирующих бактерий различных токсономических групп к синтезу внеклеточных углеводородов // Микробиология. 1997. Т. 66, № 6; Углеводороды микроорганизмов и их участие в образовании нефти. К., 2000.

**БАГА́Й** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 12 *км* төньяктарак, Ышналы елгасы буенда. 2002 елда 219 кеше (руслар — 79%). Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1739 да Б. да Владимир Богородица чиркәве төзелә (1848 елгы янгыннан соң 1849 да яңадан салына). 20 йөз башында Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 1 су һәм 4 җил, 1 ярма ярдыру тегермәне, 6 вак-төякләр, шәраб һәм сыра кибетләре була; пәнҗешәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2283 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Зөя кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында.

Халык саны: 1782 дә — 174 ир заты; 1859 да — 949, 1897 дә — 1359, 1908 дә — 1712, 1920 дә — 1569, 1926 да — 1421, 1938 дә — 944, 1949 да — 564, 1958 дә — 420, 1970 тә — 296, 1979 да — 215, 1989 да — 184 кеше.

*Әд.:* Известия по Казанской епархии. К., 1881.

**БАГА́Л** Лев Ильич (24.12.1897, Белозерск ш., хәзерге Вологда өлкәсе — 21.2.1978, Ленинград), химик-технолог, техник фән. д-ры (1950), проф. (1946), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1944). Ленинград ун-тын (1925) тәмамлый. 1929–78 елларда Ленинград технол. ин-тында эшли, 1945–46 да директор урынбасары, 1969 елдан махсус технол. каф. мөдире. Эвакуация елларында (1942–44) Казан хим.-технол. ин-ты директоры урынбасары. Хезмәтләре азотның органик кушылмалары химиясе һәм технологиясенә карый. Алифатик, ароматик һәм гетероциклик рәтләрнең нитро- һәм полинитрокушылмаларын синтезлауның яңа алымнарын эшли. Бу кушылмаларның физ.-химик үзлекләрен һәм реакциягә керә алуларын, тө-

зелешен өйрәнә, ш.у. аларны яңа энергия чыганагы буларак куллану ысулларын тикшерә. Казанда эшләү чорында шартлаткыч матдәләр җитештерүнең чимал базасын киңәйтү проблемасы һәм тринитробензол җитештерү технологиясе өстендә эшли. Уйлап табуга 45 авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1970). Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Химия и технология инициирующих взрывчатых веществ. М., 1975.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БАГАНАЛЫ́**, елга, Көнбатыш Кама аръягында. Кече Чирмешәннең уң кушылдыгы. Озынлыгы 14,7 *км*, бассейнының мәйданы 75 $км^2$. Чистай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Татар Баганалысы авылының көнбатыш читендә, тамагы Түбән Кондрат авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 101 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 24%. Б. елгасының 2 кушылдыгы бар, һәркайсының озынлыгы 3 *км* чамасы. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 $л/с{\cdot}км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 85 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,014 $м^3/с$. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БАГАНАЛЫ́ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́ ПОСЁЛОГЫ,** Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 54 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасының уң кушылдыгы Вәлүл суы буенда. 2002 елда 35 кеше (татарлар) яши. 1940 елларда нигез салына. Башта — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1989 да — 14 кеше.

**БАГДА́НОВ** Әнвәр Ибраһим улы (10.10.1952, Сәмәрканд ш.), невропатолог, мед. фән. д-ры (1990), проф. (1993), ТРның атказ. табибе (2003). 1975 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, 1976 дан шунда ук эшли, 1991 дән неврология һәм рефлексотерапия каф. мөдире. Тикшеренүләре баш мие кан әйләнеше патофизиологиясенә, периферик нерв системасы авырулары клиникасына, көчәя баручы нерв-мускул авыруларын эксперименталь дәвалауга, церебраль паралич авыруларын реабилитацияләү проблемаларына, церебелляр дегенерацияләр һәм сирингомиелия клиникасына карый. 1997 дә Линген шәһәрендәге (ФРГ) симпозиумда тәкъдим ителгән «Соң башланган церебелляр дегенерация вакытында баш әйләнүе» («Головокружения при поздних приобретённых церебеллярных дегенерациях») дигән фәнни хезмәте өчен Б. ка (Г.Р.*Хәлиуллина* б-н бергә) Германиянең һәр ел саен тапшырыла торган «Гедеон-Клиник» бүләге бирелә.

Х е з м.: Общие закономерности изменений сократительных свойств при патологии нервной регуляции скелетных мышц. К., 1989.

**БАГДА́НОВ** Гариф Вагыйз улы (11.12.1889, Казан губ., Спас өязе Зур Тигәнәле а. — 10.8.1955, Казан), педагог, тәрҗемәче. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый (1897–1906), Казан татар укытучылар мәктәбен (1910), Шәрекъ пед. ин-тын (1930) тәмамлый. Туган авылында (1910–17), Казанда Татар пед. техникумында (1917–1926) укыта, Казан пед. уч-щесендә уку-укыту бүлеген җитәкли (1934–46). М.Х.Корбангалиев, Н.К.Мөхетдинов, С.Җәлал авторлашлыгында гомуми белем мәктәпләре укучылары өчен табигать белеме һәм математика дәреслекләре яза. А.Н.Островскийның «Бедность не порок» («Хуҗа һәм приказчик», 1907), Ф.В.Рутковскийның «Ревнивый мужчина» («Көнче ир», 1910) пьесаларын тәрҗемә итә, алар «Сәйяр» труппасы тарафыннан куела.

Х е з м.: Хисап мәсьәләләре: 2 кис. К., 1919 (автордаш); Риязыят дәресләре. К., 1923 (автордаш); Җирнең катлаулары. К., 1926 (автордаш); Бераз укый-яза белүче зурлар өчен хисап дәреслеге. К., 1926 (автордаш); Математика дәреслекләре: 2 кис. К., 1926 (автордаш).

*Әд.:* И б р а һ и м о в Г. Татар әдәбияты (хисап урынында). Әсәрләр. К., 1978. Т. 5.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**БАГДА́НОВ** Идрис (1886–1916 тирәсе), драматург, тәрҗемәче. Тормышы турында мәгълүматлар сакланмаган. Сембер губернасындагы бер авылда туганлыгы, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлагач, Мәскәү университетының юридик ф-тында укуы мәгълүм. Аеруча танылган комедиясе «Помада мәсьәләсе» 1908 елда басыла, әмма цензураның каршы торуы һәм сәхнәләштерү мәсьәләсендә кайбер кыенлыклар килеп чыгу аркасында, пьеса «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1911 дә генә куела. Г.Камал, Г.Кәрам аңа югары бәя бирәләр. Пьеса гражданлык пафосы, кадимчеләргә һәм татар буржуазиясенең реакцион тарафдарларына каршы үткен сатирасы б-н Г.Камалның «Банкрот» (1911), Г.Исхакыйның «Кыямәт» (1910), «Җәмгыять» (1911) пьесалары рәтендә тора. «Зөләйха белән Фатыйма» пьесасы 1908 дә сәхнәләштерелә. Б. билгесез рус авторларының «Хуҗа һәм приказчик», «Югалган хатын» исемле пьесаларын, А.С.Пушкинның «Каменный гость» («Таш кунак») трагедиясен, Л.Н.Толстойның «Крейцерова соната» («Крейцер сонатасы») повестен татарчага тәрҗемә итә. Б.ның тарих б-н кызыксынуы, гыйльми бер утырышта «Казан һәм Казан ханнары тарихы» дип аталган чыгышы хакында «Казан мөхбире» г-тасында хәбәр ителә (1906).

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Татар пьесалары. Антология.К., 1987. 1 кит.

*Н.Г.Ханзафаров.*

**БАГДА́НОВ** Хәмзә Сәлим улы (15.11.1904, Сембер губ., Сөнгәләй өязе Зөябаш а. — 24.6.1988, Ленинград өлкәсе Приозёрск ш.), Сов. Союзы Герое (31.5.1945), полковник (1945). 1923 елдан Кызыл Армиядә. Ульяновск пехота мәктәбен (1926), Ленинград танк гаскәрләре курсын (1929), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1939, Мәскәү) тәмамлый. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче гв. танк армиясенең 6 нчы гв. танк корпусы 22 нче гв. мотоукчылар бригадасы командиры. Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украина, Польша, Чехословакияне азат итүдә, Берлинны алуда катнаша. Берлинны штурмлаганда (1945) батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Сов. Армиясендә хезмәт итә. 1953 тән запастагы полковник. 1954–71 елларда Ленинград шәһәрендә һөнәри техник урта белем бирү уч-щесе (СПТУ) директоры. 1972 дән Приозёрск шәһәрендә яши. Ике Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Х.С. Багданов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ульяновцы в боях за Родину. Саратов, 1964; Б о к о в Ф.Е. Весна Победы. М., 1980.

*Н.И.Таиров.*

**БАГДА́НОВА** Зөләйха Гыйззәтулла кызы (18.9.1886, Казан губ., Казан өязе Орнашбаш а. — 1950), драма актрисасы, режиссёр. Хезмәт Батыры (1926). Татар проф. театрына нигез салучыларның берсе. Сәхнә эшчәнлеген 1909 елда Г.Кариев һәм С.Гыйззәтуллина-Волжская җитәкчелегендәге «*Сәйяр*» труппасында башлый. Г.Камал пьесаларында характерлы образларны гаять үзенчәлекле итеп башкара, аларның социаль асылын ачканда үзен гаҗәеп сәләтле актриса итеп күрсәтә (Гайни — «Бәхетсез егет», Факиһә — «Беренче театр», Мәгълүфә — «Фахишә»). 1912 елдан «Нур» труппасында көлкеле (Нәзифә — «Саран Хәмит», Ж.-Б. Мольер пьесасы буенча; Пешекче хатын — «Хуҗа һәм приказчик», И.Багданов) һәм драматик рольләр (Гөлҗамал — «Ир туганнары», Г.Камал; Сәлимә — «Тигезсезләр», Ф.Әмирхан) башкара. Рус һәм дөнья классикасы пьесалары буенча куелган спектакльләрдә әһәмиятле җитди образлар тудыра: Кабаниха, Галчиха («Яшенле яңгыр», «Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Квашня («Тормыш төбендә», М.Горький), фрау Миллер, леди Мильфорд («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер). Гражданнар сугышы елларында фронт театр труппаларында эшли. 1920 дән Уфа шәһәрендә «Үрнәк» татар театры труппасында, 1923–24 тә Казанда Беренче татар үрнәк театрында. 1924–47 дә Буа татар театрында актриса һәм режиссёр, Буа мәдәният йортында үзешчән театр коллективы җитәкчесе. Ул куйган спектакльләр бөтенсоюз үзешчән сәнгать конкурсларында күрсәтелә, югары бәяләнә.

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988.

*И.И.Илялова.*

**БАГДА́НОВА** Мәдинә Искәндәр кызы (26.12.1908, Бохара ш. — 6.5.1962, Мәскәү),

тюрколог, фольклорчы, филол. фән. канд. (1940). Урта Азия ун-тын тәмамлый (1931, Ташкент). 1931–34 елларда Шәрекъ хезмәт ияләренең Коммунистик ун-тында төрки телләр укыта, бер үк вакытта Бөтенсоюз үзәк яңа алфавит ком-тының төрки телләр секторында эшли. 1935 тә Төрекмәнстан ССРга күчеп китә. 1936 дан Төрекмәнстанда Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Төрекмән теленең алфавитын төзүдә, терминологиясен эшләүдә катнаша, төрекмән фольклорын җыю буенча экспедицияләр оештыра. 1940 та СССР ФАнең М.Горький исем. Дөнья әдәбияты ин-тының СССР халыклары әдәбияты секторында эшли. 1941–44 елларда Кыргыз пед. ин-тында укыта, бер үк вакытта Кыргыз тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-тында (Фрунзе ш.) фольклор һәм «Манас» эпосы секторында эшли. Аның кыргыз фольклорына багышланган хезмәте аерым бүлек булып «Кыргыз совет әдәбиятының очеркы» (Фрунзе, 1943) китабына керә. 1944 тән Мәскәү ун-тында укыта, 1953 тән СССР халыклары әдәбияты каф. мөдире, бер үк вакытта 1957 дән Дөнья әдәбияты ин-тының фольклор секторы мөдире. Анда Б. җитәкчелегендә «СССР халыклары эпосы» («Эпос народов СССР», 1993 елдан «Евразия халыклары эпосы» — «Эпос народов Евразии») сериясен туплау эше оештырыла. Б. үз хезмәтләрендә Урта Азия халыклары әдәбиятларында реалистик традицияләр урнашуга татар һәм рус классик әдипләре иҗатларының йогынтысын тикшерә.

Х е з м.: Очерки киргизской литературы. М., 1947; От фольклора к литературе // Вопр. литературы. 1957. № 1; Роль русской литературы в становлении социалистического реализма в тюркоязычных литературах народов СССР // Взаимодействие и взаимообогащение литератур народов СССР. М., 1961.

*Әд.:* Кыргыз совет энциклопедиясы. Фр., 1943. 1 т.

*В.Х.Ганиев.*

**БАГДА́НОВА** Халидә Галимҗан кызы (8.7.1940, Уфа ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999), проф. (2005). 1966 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физ.-техника ин-тында эшли. 1992 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре акустик физикага һәм магнетизмга карый. 1974 елда куш акустик электрон-төш резонансларын, 1980 дә акустик төш-спин кайтавазын һәм 1977 дә үзлегеннән индукцияләнүче акустик үтә күренүчәнлекне өйрәнү өчен спектрометрлар уйлап таба. 1975 тә беренче мәртәбә куш акустик электрон-төш антиферромагнит резонансын, 1977 дә антиферромагнетикларда акустик төш-спин кайтавазын һәм 1980 дә башка галимнәр б-н берлектә магнетикларда үзлегеннән индукцияләнүче акустик үтә күренүчәнлекне күзәтә. 1986 да төш спиннарының магнетик тәэсирләнүчән сыгылмалы каналын һәм 1999 да төш-спин дулкыннарындагы гаять зур магнитоакустик эффектны ачуда катнаша.

Х е з м.: Наблюдение магнитоакустических солитонов в монокристаллах $KMnF_3$ в окрестности ЯМР // Письма в Журн. эксперим. и теоретической физики. 1980. Т. 32, вып. 10 (автордаш); Магнитоупругий канал возбуждения ядерных спинов в $FeBO_3$ // Журн. эксперим. и теоретической физики. 1993. Т. 103, вып. 1 (автордаш); Взаимосвязь магнитных и структурных фаз в монокристалле манганита $La_{1-x}Sr_xMnO_3$ (x=0,175) // Письма в Журн. эксперим. и теоретической физики. 2004. Т. 84, вып. 5 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**БАГРА́Ж** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Чишмә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 24,2 *км*, бассейнының мәйданы 277 *км*². Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Ерсубай авылыннан 6 *км* көнчыгыштарак, тамагы Кызыл Көч авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 71 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 44%. Б. елгасының 7 кушылдыгы бар, иң зурлары — Югары Баграж (29,2 *км*) һәм Түбән Баграж (11,5 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,48 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–3 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 99 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,26 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Б. бассейнында ТРның табигать истәлеге — *Чыршы һәм карагай урман культуралары, 1910–13 еллар* урнашкан.

**БАГРА́Ж** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Урман Зәе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 21,5 *км*, бассейнының мәйданы 136,1 *км*². Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Баграж авылыннан көньяктарак, тамагы Зәй шәһәреннән көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 225 *м*, тамагыныкы — 68 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 36%. Б. елгасының 0,8 дән алып 5,5 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туену модуле 1,1–3 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,108 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Елгада гомуми күләме 2,3 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БАГРА́Ж** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 47 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасының уң кушылдыгы Баграж суы буенда. 2002 елда 111 кеше яши (чуашлар — 78%, татарлар — 20%). Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек үрчетү, урманчылык. Башлангыч мәктәп. 1920 еллар башында нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Чирмешән волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 65, 1949 да — 157, 1958 дә — 155, 1970 тә — 183, 1979 да — 149, 1989 да — 109 кеше.

**БАГРА́Ж АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**. Зәй р-нының төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 41,8 мең *га*, ш.и. урманнар — 16 мең *га*, күлләр — 400 *га*. Тыюлык терр-ясеннән Зичә, Бастырма елгалары ага. 1987 елда суер һәм кәҗәболаннарны саклау максатыннан оештырыла. Поши, кабан дуңгызы, сирәк төрләрдән селәүсен, сусар саклана.

**БАГРА́Ж-НИКО́ЛЬСКИЙ** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 50 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасының уң кушылдыгы Баграж суы бассейнында. 2002 елда 85 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Клуб. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чана, утын чанасы ясау, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.-Н.да чиркәү, уч-ще, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1767,6 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосыф волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Минзәлә кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 152, 1795 тә — 235 ир заты; 1859 да — 797, 1870 тә — 837, 1897 дә — 1296, 1926 да — 706, 1938 дә — 686, 1949 да — 604, 1958 дә — 423, 1970 тә — 348, 1979 да — 248, 1989 да — 105 кеше.

**БАГЫ́Ш** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 34 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2002 елда 449 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. Мәчет. 1646 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Өченче Чирмешән исеме б-н дә билгеле. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.та мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, тимерчелек, 2 йон һәм тукыма ману остаханәсе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1492,5 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Тояба волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 125 ир заты; 1859 да — 728, 1897 дә — 1220, 1926 да — 1297, 1938 дә — 1267, 1949 да — 923, 1958 дә — 772, 1970 тә — 863, 1979 да — 768, 1989 да — 554 кеше.

**БАГЫШЛА́У**, 1) автор тарафыннан әсәрнең кемгә атап язылуын күрсәткән һәм әдәби әсәрнең башында урнашкан юллар; 2) әсәр ал-



Г.С. Бадамшин.

дында килгән поэтик жанр, гадәттә, лирик шигырь. Антик чорда барлыкка килеп, Б. китапта беренче битнең «бизәге» булып торган. Урта гасырларда Б. — үзенә булышлык һәм матди ярдәм күрсәткән кешесенә авторның ихтирам билгесе булган. Б.ның күбесе мәдхияне хәтерләткән һәм мөстәкыйль сәнгати дәрәҗәгә ия булмаган. Урта гасыр төрки-татар әдәбиятында Котб («Хөсрәү вә Ширин»е Тәнибәк ханга багышлана), Харәзми («Мәхәббәтнамә»се Мөхәммәд Хуҗабәккә), Мөхәммәдъяр («Нуры содур»ы Сәхибгәрәй ханга) әсәрләрендә очрый. Соңыннан Б.ларның күләме кыскара, эчтәлеге тулылана. Аларда сүз авторның мәхәббәте, дустанә мөнәсәбәте турында бара; алар дусларга, туганнарга багышлана. 20 йөз татар әдәбиятында күп кенә әсәрләр тарихи шәхесләргә, мәдәният эшлеклеләренә: Гали Рәхимнең «Догаи Сәйфи»е — язучы Г.Исхакыйга, Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыят»е — язучы Б.Бикбайга, А.Гыйләҗевнең «Урталыкта»сы — режиссёр Г.Йосыповка, Г.Ахуновның «Ардуан батыр»ы — әдәбият галиме Г.Кашшафка, М.Әгъләмовның «Хәтеремдә калыр бу кичә»се — язучы К.Тимбиковага, Р.Гатауллинның «Рәхмәт, тормыш»ы — шагыйрь С.Хәкимгә багышланган һ.б.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Н.М.Йосыпова.*

**БАДА́МШИН** Гариф Сираҗетдин улы (1865, Казан губ., Спас өязе Түбән Чаллы а. — 1939), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. Чистай шәһәре мәдрәсәсендә укый. Чистай өязендә а.х. һәм кызыл мал сату б-н шөгыльләнә, Чистайда галантерея кибете тота. 1905 елда мөселманнар исеменнән хөкүмәт башлыкларына хат (петиция) тапшыру өчен С.-Петербургка җибәрелгән вәкилләрнең берсе. 1 нче (1906) һәм 2 нче (1907) Дәүләт думалары депутаты; трудовиклар төркемен яклый. 1 нче Думада эсерларның җирне социальләштерү һәм аннан тигез файдалану таләбен куйган «33 нең проекты»на имза сала. 2 нче Думада *Мөселман хезмәт таифәсе*н оештыручыларның берсе. 1906 ның декабрендә татарлар арасында хакимиятне гаепләгән *Выборг өндәмәсе*н таратканы өчен Чистайда кулга алына. 1907 нең гыйнварында азат ителә. 1908 нең февралендә тыелган әдәбият саклаганы өчен кабат кулга алына, 1908 нең апрелендә азат ителә. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Туктаров М.Ф. (Усал). Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре. К., 1909; Члены первой Государственной думы. М., 1906; Члены второй Государственной думы. СПб., 1907; Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Р.А.Циунчук.*

**БАДА́МШИН** Эдуард Закир улы (3.6.1932, Казан — 1.6.2000, шунда ук), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. канд. (1963), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1982). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), 1999 елга кадәр шунда эшли, геол. ф-ты деканы (1978–79), газ һәм нефть геологиясе каф. мөдире (1979–87). Татарстан терр-ясендә нефть һәм газ чыга торган р-ннарда (Мәләкәс батынкылыгында һәм Кама-Кинель системасы бөгелешләрендә) разведка-эзләү ысулларын, нефть-газ булу-булмавын ачыклау методикасын эшләүдә катнаша.

Хезм.: Критерии оценки перспектив нефтеносности карбонатных отложений. К., 1978; Закономерности размещения и условия формирования залежей нефти в карбонатных отложениях среднего карбона Татарии. К., 1981 (автордаш); Перспективы поисков нефти в карбонатных отложениях Татарского свода. К., 1982 (автордаш).

**БАДӘ́М**, миндаль (Amygdalus), роза чәчәклеләр семьялыгыннан кечкенә агачлар яки куаклар ыругы. 40 лап төре билгеле, Төньяк ярымшарның субтропик һәм уртача поясларында таралганнар. ТРда бер төре — тәбәнәк Б. (A. nana) Кама аръягында очрый. Еш кына куе әрәмәлекләр хасил итеп далалы сөзәклекләрдә, имәнлек буйларында үсә. Туры ботаклы 1,5 *м* озынлыктагы куак. Кабыгы кызгылт-соры төстә. Яфраклары чиратлашкан, кыяк-ланцетсыман, кырыйдагылары каяу-тешәүле. Чәчәкләре алсу төстә, ялгыз, хуш исле. Апрельдә — майның беренче яртысында чәчәк ата. Җимеше — коры, ачык сары төстәге төш, төк б-н капланган, җәй ахырында өлгерә. Орлыклардан һәм вегетатив юл б-н (тамыр үрентесеннән) үрчи. Яктылык яратучан, кышка чыдам үсемлек. Төтенне, кыркуны яхшы кичерә. Яшелләндерүдә файдаланыла. Баллы үсемлек. Комнарны ныгыта. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БА́ДЕР** Отто Николаевич (1903, Полтава губ. — 1979, Мәскәү), археолог, тарих фән. д-ры (1964), проф. (1965). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1926). 1924 елдан Мәскәүдәге Үзәк сәнәгать тармагы музеенда археол. бүлеге мөдире, соңрак фәнни хезмәткәр, 1931 дән Мәскәү ун-тының Антропология ин-ты гыйльми сәркәтибе. Бер үк вакытта 1927–30 елларда СССР Мәгариф халык комис-ты каршындагы Фән буенча баш идарәнең музей бүлегендә эшли. 1933 тән Матди мәдәният тарихы дәүләт академиясенең Мәскәү бүлегендә өлкән фәнни хезмәткәр, 1939 дан гыйльми сәркәтип. Бөек Ватан сугышында катнаша, халык ополчениесендә сугыша. Түбән Тагил шәһәрендә эвакуациядә вакытта төбәкне өйрәнү музеенда эшли. 1946 дан Пермь ун-тында. 1955 тән СССР ФАнең Археология ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр, бер үк вакытта 1965 тән Мәскәү ун-ты профессоры. Б. берничә археол. экспедицияне, ш.и. Чулман төбәге, Воткинск һәм Түбән Чулман буе экспедицияләрен оештыра һәм җитәкчелек итә. Беренчеләрдән булып *Баланово* һәм *Чулман буе культураларын* аерып тасвирлый. Владимир өлкәсендәге Сунгирь торулыгын ачуы һәм Уралдагы Кап мәгарәсен тикшерүе нәтиҗәсендә Б. дөньякүләм танылуга ирешә. Хезмәтләре Идел буе, Урал төбәге, Кырымның таш һәм бронза гасырлар археологиясенә карый.

Хезм.: Поселения турбинского типа в Среднем Прикамье // Материалы и исследования по археологии СССР. М., 1961. № 99; Балановский могильник (Из истории лесного Поволжья в эпоху бронзы). М., 1963; Бассейн Оки в эпоху бронзы. М., 1970; Сунгирь (верхнепалеолитическая стоянка). М., 1978.

*Әд.:* Кольцов Л.В. Бадер Отто Николаевич // Советская археология. 1980. № 2.

*П.Н.Старостин.*

**БАДЬЯ́НОВ** Владимир Александрович (16.5.1935, Украинаның Бердичев ш.) геолог-нефтьче, геол.-минералогия фән. д-ры (1998), Казан ун-тын тәмамлагач (1958), Нефть сәнәгатенең фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында (Бөгелмә, 1963 елдан лаб. мөдире), «Гипротюменнефтегаз» фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында (Төмән, 1966 дан лаб. мөдире), Нефть сәнәгатенең Себер фәнни тикшеренү ин-тында (Төмән, 1999 дан ген. директор) эшли. Хезмәтләре геологиягә һәм нефть чыгаруга карый. Ромашкино нефть чыганагындагы аерым участокларның геологик яктан бериш булмавын ачыклый. Нефть чыганакларын тикшерүдә компьютерлы модельләштерү ысулын тикшерә.

Хезм.: Совершенствование систем разработки нефтяных месторождений Западной Сибири. Свердловск. 1975 (автордаш). Картирование тектонических нарушений м-ний на графических устройствах ЭВМ // Сб. тр. ЗапСибНИГНИ. 1985. Вып. 65.

**БАДЮ́ГИНА** Әзәлия Исмәгыйль кызы (29.5.1933, Алма-Ата ш.), әдәби тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1957). 1964–89 елларда Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөхәррире. Г.Гобәйнең «Без үскәндә» («Когда мы росли», 1964) повестен, Ә.Фәйзинең «Аучы Мәргән белән Болан кыз әкияте»н («В стране смельчаков», 1966), Х.Мөҗәйнең «Сугыш язмалары»н («Летопись войны», 1978), Ә.Еникинең повесть һәм хикәяләрен («Повести и рассказы», 1982), Ш.Камалның «Таң атканда» («На заре», 1983) романын, Ә.Еникинең «Соңгы китап» («Страницы прошлого», 1999) дигән истәлек-язмаларын, Г.Әпсәләмов, К.Тинчурин, И.Гази, Г.Бәширов, Г.Минский, Г.Гали, А.Расих, Ф.Яруллин, Л.Ихсанова һ.б. язучыларның аерым әсәрләрен, татар халык әкиятләрен, Һ.Атласинның «Себер тарихы»н («История Сибири», 2005) татарчадан русчага тәрҗемә итә.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**БАДЯГАЛА́Р** (Spongillidae), кремний катламлылар отрядының төче су болытсыманнар семьялыгы. Үз эченә 16 ыругны, 94 төрне ала. ТРда 3 төре очрый: күл Б., елга Б. һәм алучан Б. Су астындагы төрле әйберләргә ябышкан яшькелт-коңгырт кабык (елга Б. һәм алучан Б.) яки 20 *см* һәм аннан да биегрәк ботаклы үсенте (күл Б.) хасил итә. Б. скелеты мөгез җепселләр үрелмәсеннән тора, алар арасында органик матдә — спонгин б-н кушылган вак һәм очлы кремнийлы энәчек-



Күл бадягасы.

ләр — спикулалар сибелгән. Б. бүленеп һәм җенси юл б-н үрчиләр. Саклагыч тышча б-н капланган зур күләмле кышкы бөреләр барлыкка китереп, кышка колонияләр корып бетә. Язын алардан яшь болытсыманнар үсеп чыга. Бик вак итеп төелгән коры Б. халык медицинасында мазьлар составында ревматизм һ.б. авыруларны дәвалау өчен файдаланыла.

*Әд.:* Фауна СССР. Губки. М.–Л., 1936. Т. 2, вып. 2.

**БА́ЕВ** Александр Александрович (10.1.1904, Чита ш. — 31.12.1994, Мәскәү), биохимик, химия фән. д-ры (1967), СССР ФА академигы (1970; мөхбир әгъза — 1968) һәм ВАСХНИЛның хакыйкый әгъзасы (1985), Соц. Хезмәт Герое (1981). В.А.Энгельгардт шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын (1927) тәмамлагач, дәвалау эше б-н шөгыльләнә, Буа кантонында туберкулёз диспансеры мөдире. 1930 елдан Казан мед. ин-тында эшли. 1935 тән — СССР ФА Биохимия ин-тында (Мәскәү). 1937 елда репрессияләнә, 1944 елга кадәр Владимир, Соловки төрмәләрендә һәм Норильск лагеренда тоткынлыкта була, табиб булып эшли. 1947–49 да СССР ФА Коми ф-лы биохимия лаб. мөдире (Сыктывкар ш.). 1949 да кабат кулга алына һәм Красноярск краеның Түбән Шадрин авылына сөрелә. 1954 тә акланып Мәскәүгә кайта, Биохимия ин-тында эшли. 1959 дан СССР ФА Молекуляр биол. ин-тында. 1971–88 дә СССР ФА Биохимия, биофизика һәм физиологик актив кушылмалар химиясе бүлегенең академик-сәркәтибе. Төп хезмәтләре биохимия, молекуляр биологиягә карый. Казанда беренче фәнни хезмәтләре авыл халкының туберкулёз б-н авыручанлыгын, армиягә алынучыларның физик үсешен, сәламәтлеген тикшерүгә, туберкулёз таякчыгының биохимик үзлекләре үзгәрүчәнлегенә, аксымны өйрәнүгә һ.б. багышлана.

Б. Казан ун-тының биохимия кафедрасында һәм СССР ФА Биохимия ин-тында (Мәскәү) В.А.Энгельгардт җитәкчелегендә сулыш алу биохимиясе, күзәнәктә аденозинтрифосфор кислотасы әверелешләрен өйрәнү б-н шөгыльләнә. СССР ФА Молекуляр биол. ин-тында нуклеин кислоталары структурасын өйрәнә, 1967 дә валин транспорт рибонуклеин кислотасының (тРНК) беренчел структурасын ача. Бу хезмәтләре дөньякүләм танылу ала, СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1969). Б. тРНК функциональ топологиясен өйрәнүнең принципиаль яңа ысулын («киселгән» молекулалар ысулы) эшли. Фрагментларга таркалган тРНК молекулаларының үзлегеннән функциональ актив ассоциатка җыелу күренешен ача. 1970 елларда яңа юнәлеш — дезоксирибонуклеин кислотасының (ДНК) төзелешен (геннар инженериясе ысулларын үстерү б-н бәйләнешле) өйрәнүне үстерә. Чүпрәләрнең рибосомоль РНКсының беренчел структурасы аның тарафыннан ДНК-кучерелмәсе аркылы аңлатыла. 1980 елларда молекуляр онкология, кеше геномы структурасын һәм функциясен өйрәнү, дәвалау үзлегенә ия булган яңа аксым, гормон, ферментлар һ.б. матдәләрне ясалма рәвештә эшләү б-н шөгыльләнә. СССР ФА каршындагы Биотехнология проблемалары буенча фәнни советны оештыручы һәм аның рәисе (1981). «Кеше геномы» дәүләт фәнни-техник программасы фәнни советы рәисе (1989). «СССР Фәннәр академиясе докладлары» ж-лының баш мөхәррире (1971 дән). Халыкара биохимия берлеге президенты (1976–78). Чехословакия ФА һәм Германия Демократик Респ-касы ФА (1974 тән), Польша ФАнең (1977 дән) чит ил әгъзасы, Венгрия Халык Респ-касы ФАнең шәрәфле әгъзасы (1976 дан), Болгария Халык Респ-касы ФАнең чит ил һәм шәрәфле әгъзасы (1978 дән). Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе ордены, Болгария Халык Респ-касының I дәрәҗә «Кирилл һәм Мефодий» ордены, Чехословакия ФАнең «Фән һәм кешелек алдындагы казанышлары өчен» алтын медале, Грегор Мендель алтын медале һ.б. медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Энзиматический анализ превращений аденозинтрифосфорной кислоты в ядерных эритроцитах в связи с дыханием и гликолизом // Биохимия. 1937. Т. 2; Первичная структура валиновой транспортной РНК 1 пекарских дрожжей // Молекулярная биология. 1967. Т. 1, вып. 5 (автордаш); Функциональные свойства фрагментов молекул валиновой транспортной РНК // шунда ук. Вып. 6. С. 853; Биотехнология — союз науки и производства. М., 1987 (автордаш).

*Әд.:* Видные учёные отечественной медицины и здравоохранения — питомцы Казанского медицинского института. К., 1989; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991; Александру Александровичу Баеву — 90 лет! // Молекулярная биология. 1994. Т. 28, вып. 1.

*В.Г.Абзалова.*

**БАЕ́К** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 38 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Башкортстан Респ-касы чигендә. 2002 елда 433 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1728 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында авыл Байково исеме б-н билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, арба көпчәкләре тугымы ясап сату б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Б. та мәчет һәм 2 су тегермәне була. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 1113,7 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 385, 1897 дә — 769, 1926 да — 803, 1938 дә — 930, 1949 да — 702, 1958 дә — 779, 1970 тә — 850, 1979 да — 711, 1989 да — 477 кеше.

**БАЕМБӘ́ТОВ** Гыйлемдар Солтан улы (сент., 1886, Уфа губ., Бәләбәй өязе Чакмагыш а. — ?), сәясәт эшлеклесе, язучы. 1905 елда с.-д. түгәрәкләре эшендә катнашкан өчен Казан татар укытучылар мәктәбеннән куыла. 1905 нең октябрь-ноябрендә беренче яшерен татар газеталарыннан «Хөррият»не нәшер итүдә



А.А. Баев.



Г.С. Баембәтов.

катнаша. 1907 дә Уфа шәһәрендә яшерен типография оештыра, анда революцион брошюралар бастыра. 1905–18 дә эсерлар партиясендә тора, 1917–18 дә татар-башкорт сул эсерлар оешмасы җитәкчеләренең берсе була. Революцион эшчәнлеге өчен берничә мәртәбә кулга алына, 1909–12 дә Вологда губернасында сөргендә яши. 1915 тә Уфада мөселман куллнучылар җәмгыятен оештыра. 1917–18 дә «Ирек» г-тасында хезмәттәшлек итә, төрки-татарларга терр. мохтарият бирүне яклый; Уфа шәһәр думасы һәм управасы әгъзасы, «Көрәш» г-тасы мөхәррире, Уфа ХХС рәисе урынбасары. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18), «Туфракчылар» фракциясе әгъзасы. 1918 елдан РКП(б) әгъзасы (1930 да партиядән чыга). Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армиядә: чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык армиясенә каршы сугышларда катнаша; «Кызыл яу» г-тасы мөхәррире, Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе сәяси бүлегенең мөселман бүлекчәсе җитәкчесе була. Көнчыгыш фронтның коммунист-мөселманнар конференциясендә *РКП(б)ның Көнчыгыш фронттагы татар-башкорт үзәк бюросы* рәисе итеп сайлана (Сызрань ш., 1919). 1919–20 дә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлек башлыгы, Казан губерна башкарма ком-ты һәм РКП(б) губкомының мөселманнар бюросы әгъзасы. 1920–21 дә Казан хәрби-сәяси агитация курслары мөдире. 1922 дә Мәскәүдә: Шәрекъ халыкларының коммунистик ун-ты лекторы, ВЦСПС инструкторы. 1922 нең ахырыннан Урта Азиядә: Бохара ҮБК һәм Бохара мәгариф нәзараты (халык комис-ты) коллегиясе әгъзасы, РКП(б)ның Урта Азия ҮК каршындагы Ташкент Көнчыгыш матбугаты бюросы мөдире, Профсоюзларның Гомумбохара советы мәдәният бүлеге мөдире һәм «Хасабе сәхифәсе» («Хезмәт сәхифәсе») г-тасы мөхәррире. 1924–25 тә Мәскәүдә Шәрекъ халыкларының үзәк нәшрияты хезмәткәре, 1925–27 дә Башкортстан АССРда ВКП(б)ның Яңавыл волость ком-ты секретаре, 1928–29 да Мәскәүдә Баш сәнгать идарәсе инспекторы, БҮБК каршындагы яңа төрки (латин) алфавиты ком-ты инструкторы. Авыру сәбәпле 1930 дан беркайда да эшләми. 1905–07 еллардагы рев-ция һәм Февр. рев-циясе турында пьесалар, татар телендә «Сәяси экономия» һәм «Тарихи материализм» (1921) уку ярдәмлекләре авторы. В.И.Ленинның кайбер әсәрләрен, Э.Л.Войничның «Овод» («Кигәвен») романын татар теленә тәрҗемә итә. 1932 нең декабрендә кул-



З.Ә. Баембәтова.

га алына, 1933 нең 28 маенда атарга хөкем ителә; үлгәннән соң аклана (к. «*Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел оешмасы*» эше).

Х е з м.: Асылган. К., 1924; Патша төшерәләр. М., 1924.

*Әд.:* Н и з а м о в И. Баимбетов Г.С. // Возвращённые имена: Документальные очерки. К., 1990; Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2001. Т. 2.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**БАЕМБӘ́ТОВ** Альберт Апуш улы (27.11.1938, Приморье крае Благодатний а.), социолог, социол. фән. д-ры (1990), проф. (1991). Ленинград ун-тын тәмамлый (1964). 1964–69 елларда Башкортстан АССР прокуратурасы хезмәткәре. 1969 дан Уфа авиация техник ун-тында: 1972–73 тә социол. лабораториясе инженеры, 1990 елдан социол. һәм политология кафедрасында эшли (1974–90 да фәнни коммунизм каф.). Хезмәтләре социаль процесслар б-н идарә итү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Перспективное планирование экономического и социального развития города. М., 1977 (автордаш); Сущность и причина антиобщественных явлений. Уфа, 1990; Молодёжь в кризисном социуме. М., 1998 (автордаш).

**БАЕМБӘ́ТОВА** Зөһрә Әхтәм кызы (1899, Уфа ш. — 8.12.1986, Мәскәү), партия хезмәткәре, җәмәгать эшлеклесе. Уфа рус-татар уч-щесен, Уфа пед. курсларын тәмамлый (1916). 1916–17 елларда Уфа губернасы Уфа өязенең Арыслан авылы мәктәбендә укыта. 1918 елдан Уфа шәһәрендә, Губерна мөселман комис-ты секретаре, РСФСР Советларының 5 нче съезды делегаты. Гражданнар сугышы елларында Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе сәяси бүлегендә эшли; «Кызыл яу» г-тасын нәшер итүдә катнаша. 1919 елның июнь-сентябрендә РКП(б)ның Уфа губкомы мөселман секциясе секретаре. 1919 ның октябреннән Казанда: РКП(б)ның губерна ком-тында хатын-кызлар бүлеге инструкторы, мөселманнар секциясе секретаре. Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының 2 нче съезды президиумы әгъзасы (нояб.-дек., 1919), Советларның 8 нче Бөтенроссия съезды делегаты (дек., 1920). 1920 дә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында хатын-кызлар бүлеге мөдире. РКП(б)ның 10 нчы съезды делегаты (март, 1921). 1921–23 тә ТАССР ХКС каршындагы социаль тәрбия идарәсе башлыгы, Татарстанда ачларга ярдәм оештыру комиссиясе рәисе. «Коммунист», «На новом пути» ж-лларында хатын-кызларның иҗтимагый эшчәнлеге турында мәкаләләр бастыра. 1924 елдан Бохарада, соңрак Мәскәүдә дәүләт, партия эшендә.

*Әд.:* Б и к т и м и р о в а Т. Баимбетова З.А. // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3; Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2001. Т. 2.

**БАЖА́НОВ** Александр Тихонович (30.8.1898, Казан — 8.1.1983, шунда ук), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1959), проф. (1962), РСФСРның атказ. хокук белгече (1969). Казан ун-тын тәмамлый (1931). 1917–18 елларда Казан артиллерия бригадасында. 1919–22 дә Кызыл Армиядә, 1921 елдан Казан хәрби комис-ты каршындагы гражданнарга гомуми хәрби белем бирү бүлеге башлыгы. 1923–28 дә ТАССР Юстиция халык комис-тының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире, мәхкәмә эшен оештыру һәм күзәтчелек бүлеге мөдире урынбасары. 1926–27 дә һәм 1952 дә Казан ун-тында юридик ф-тны яңадан торгызу эшен башлап йөрүчеләрнең берсе. 1931 дән Казан совет төзелеше ин-тында, 1939–45 тә Алма-Ата юридик ин-тында, 1945–52 дә Казан юридик ин-тында эшли, мәхкәмә-тикшерү ф-ты деканы (1950 гә кадәр), директор вазифаларын башкаручы (1946–47). 1952 дән Казан ун-тында, юридик ф-т деканы (1956 елга кадәр), җинаять эшләре хокукы, процессы һәм криминалистика каф. мөдире (1959–67). Хезмәтләре җинаять эшләре хокукы, хокук тарихына карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Детская преступность в ТАССР. К., 1923; Имущественная преступность и преступники в Татарской республике. К., 1931; Органы юстиции Парижской Коммуны. К., 1971; Суд и правосудие в СССР. К., 1980.

*Е.Б.Долгов.*

**БАЖА́НОВ** Валентин Александрович (10.1.1953, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1988), проф. (1990), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлый (1975) һәм 1993 елга кадәр шунда ук филос. кафедрасында эшли. 1993 тән Ульянов ун-тында филос. каф. мөдире, бер үк вакытта (1995 кә кадәр) гуманитар фәннәр һәм социаль технологияләр ф-ты деканы. Хезмәтләре филос. тарихына, табигыять фәннәренең фәлсәфи проблемаларына карый. Аларда фәнни белемнәрнең чыганаклары тикшерелә, ш.у. аларның рефлективлык дәрәҗәсе һәм төрләренең типлары тәкъдим ителә. Б. хезмәтләрендә математик һәм классик булмаган логиканың үсеше мәсьәләләренә, Россиядәге «университет» фәлсәфәсе үзенчәлекләренә игътибар ителә.

Х е з м.: Проблема полноты квантовой теории: поиск новых подходов (философский аспект). К., 1983; Николай Александрович Васильев (1880–1940). М., 1988; Наука как самопознающая система. К., 1991; Очерки социальной истории логики в России. Ульяновск, 2002; Восприятие британской социально-философской мысли в России. Ульяновск, 2005; История логики в России и СССР. Концептуальный контекст университетской философии. М., 2006.

**БАЖЕ́НОВ** Василий Яковлевич (1787, Ярославль губ. — 25.1.1831, Казан), тарихчы, надворный советник (1830). Ярославль руханилар семинариясен (1806) һәм Петербург пед. ин-тын (1810) тәмамлый. 1810–11 елларда шул ук ин-тта, 1811–20 дә Вятка шәһәре гимназиясендә укыта. Бер үк вакытта 1819–20 дә Вятка губерна уч-щеләре директоры. 1820 елдан Казан ун-тында: гомуми тарих, геогр. һәм стат. ф-тында адъюнкт (1820–22), экстраординар проф. (1822–23), ординар проф. (1823 тән). Бер үк вакытта ун-т каршындагы пед. ин-тында студентлар инспекторы һәм директор (1822–23, 1826–30), Казан Беренче ир балалар гимназиясе директоры (1823–24). Төп хезмәтләре Вятка губернасын геогр.-стат. тасвирлауга (кульъязма), рус халкының гореф-гадәтләрен һәм уеннарын барлауга карый. Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте әгъзасы (1818).

Х е з м.: Свистопляска. Описание поминок и народных игр в окрестностях Вятки. К., 1817; Опыт исторического рассуждения о действиях промысла в устроении царств земных и народов. К., 1823.

*Әд.:* В е н г е р о в С.А. Критико-биографический словарь русских писателей и учёных: От начала русской образованности до наших дней. СПб., 1891. Т. 2; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**БАЖЕ́НОВ** Николай Кириллович (1804, Тула губ. Одоев ш. — 25.6.1848, Казан), төбәк тарихын өйрәнүче, надворный советник (1848). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1825). Мәскәүдә, Тула губернасының Одоев өязендә (1825–29), Олонецк губернасының Лодейное Поле шәһәрендә (1830–31), Новгородта (1831–32), Омскида (1833–34), Себердәге Нерчинск металл эретү з-дында (1834–37), Самара губернасындагы Сергиевск минераль сулар б-н дәвалау курортында (1838–42) һәм Сембер шәһәрендә (1842–44) табиб һәм дәвалау хезмәтен оештыручы булып эшли. 1844–48 елларда Казанда дары з-ды штаб-лекаре, 1848 дә Казан губернасы идарәсендә секретарь. Казанга һәм аның тирә-юненә багышланган очерклар, Себердәге сәяхәтләрен тасвирлаган повестьлар авторы. Беренчеләрдән булып Казан тарихын борынгыдан алып 19 йөз урталарына кадәр тикшерә. Казанда ваба эпидемиясе вакытында кешеләрне үлемнән коткаруда катнаша, авыру йоктырудан вафат була.

Х е з м.: Казанский девичий монастырь. К., 1845; Поездка в деревню Аки. К., 1845; Поездка в Раифскую пустынь. К., 1845; Две поездки. К., 1846; Плавание к Зилантову монастырю и казанскому памятнику. М., 1846; Торжественное примирение или единственный муж и чудное посредничество. Шутка-водевиль. К., 1846; Казанская история. К., 1847. Ч. 1–3; Прекрасный молодой человек: Повесть, взятая из рассказа штаб-лекаря Чацкого. К., 1848.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1847. Ч. 2; З м е е в Л.Ф. Русские врачи-писатели. СПб., 1886. Вып. 1; Русские писатели 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1989.

*Е.Б.Долгов.*

**БАЖИ́РОВА** (Бәширова) Наилә Гыйльметдин кызы (25.3.1955, Казан), нефтехимик, химия фән. канд. (1989), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998). Казан хим.-технол. ин-тын (1978) тәмамлый. 1978–82 елларда һәм 1991 дән Бөтенроссия углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1982–89 да — Нефтехим. синтезы ин-тында

(Мәскәү). Дәүләт бүләге углеводород чималын күкерт кушылмаларыннан арындыру технологиясен һәм катализаторларын эшләгән һәм җитештерүгә керткән өчен бирелә («Татнефть» АҖ дә, «Тенгизшевройл» Рос.-Амер. уртак пр-тиесендә, Россия нефть һәм газ эшкәртү пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). Уйлап табуга 6 патенты бар.

**БАЗА́Р**, ачык урында яисә ябык сәүдә рәтләрендә азык-төлек һәм сәнәгый товарларны ваклап сату урыны. Б. сатучылар өчен махсус җайланган сәүдә рәтләре, инвентарь, лавка, палатка, складлар, саклау камералары, кунакханәләр, транспорт өчен урыннар җыелмасыннан гыйбарәт, анда ш.у. вет.-сан. инспекциясе, хезмәт күрсәтүче персонал була.

Хәзерге Татарстан терр-ясендә Болгар дәүләтенә кадәр дә Б. булган. Идел буе Болгарында сәүдә эшләре, башлыча, натуралата алыш-биреш рәвешендә барган. Һөнәрчеләр үзләре эшләгән тормыш-көнкүреш кирәк-яракларын һәм хезмәт коралларын (сука-тырмә, китмән, ат дирбиясе, кызыл балчыктан яндырып яки агачтан ясалган савыт-саба һ.б.) Б.га алып чыкканнар. Болгар, Биләр, Суар, Ашлы һ.б. шәһәрләрдә сату-алу эшләре киң үсеш алган. Идел буе Болгары Б.ларына Россиядән, гарәп илләреннән, Урта Азия, Иран, Һиндстаннан да товар китерелгән (алтын, бәллүр әйберләр, савыт-саба, икмәк, киҗе-мамык һәм ефәк тукыма, келәмнәр, тәмләткечләр). Казан ханлыгында сәүдә — икътисадның иң әһәмиятле тармакларыннан берсенә, башкала үзе халыкара эре сәүдә үзәгенә әверелә. Сәүдә атавында (19 йөз ахырыннан «Маркиз утравы») ел саен 24 июньдә халыкара ярминкә ачыла. Арча кырында, Сәүдә йортында (Гостиный двор), Болак буендагы Ташаяктада зур Б.лар эшли. Биредә җирле сәүдәгәрләр, ш.у. рус кенәзлекләреннән, Урта Азия, Кавказ һ.б. илләрдән килгән сәүдәгәрләр сату иткән.

Явыз Иван гаскәрләре Казан ханлыгын яулап алганнан соң (1552), Казан татарларына шәһәрдә сәүдә итүне тыя торган фәрман игълан ителә (1686 елда юкка чыгарыла). Крәстияннәргә исә ясак түләгәннән соң гына үз товарларын Сәүдә йорты сәүдәгәрләренә сату рөхсәт ителгән. Губернада сату-алу эшләре күбесенчә авыл һәм шәһәр Б.лары аша гамәлгә ашырылган. 1860 елга Казан губернасында — 125, ш.и. Ядрин өязендә — 17, Чистайда — 14, Чабаксар өязендә 12 Б. гамәлдә була. Тәтеш, Чистай һәм Спас өязләре — икмәк, Козьмодемьян һәм Чабаксар өязләре — агач материаллары, урман җиләкләре, гөмбә, чикләвек Лаеш һәм Мамадыш өязләре елга балыгы сату б-н дан тота. Товарларның күп өлеше ярминкәләр аша сатыла, аларның саны 1863 елда — 33 кә, 1883 тә — 74 кә, 1913 тә 103 кә җитә. 1880 елларда авыл җирләрендә ел саен 50 дән артык, 1900 елларда 90 га якын ярминкә оештырылган. Ә шәһәр ярминкәләренең саны 20 йөз башында кими — 18 дән 13 кә кала. Губернадагы ярминкә товар әйләнешенең 80% ы — шәһәрләргә, ш.и. 72% ы Казанга туры килгән.

20 йөз башыннан Казандагы 15 Б.да еллык акча әйләнеше 400 мең сум тирәсе тәшкил иткән. Николаев, Балык базары, Икмәк базары мәйданнарында — даими Б.лар, Театр һәм Печән базары мәйданнарында якшәмбе Б.лары, болардан тыш, сезонлы һәм бәйрәм алды Б.лары эшләгән.

Гражданнар сугышы вакытында — 1918–20 елларда ирекле сәүдә тыела. Яңа икътисади сәясәт (нэп) чорында сәүдәнең 95% ы чамасы хосусый сәүдәгәрләр кулында була, товарларының күп өлеше Б. аша сатыла.

1931–32 дә хосусый сәүдә тулысынча диярлек бетерелә. Аңа алмашка дәүләт әзерләү оешмалары һәм сәүдә челтәре булдырыла, кулланучылар җәмгыяте җәлеп ителә. Сатып алу һәм Б. бәяләре көйләнә, Б.да сәнәгый товарлар сату тыела. 1932 дә респ-када — 125, ш.и. Казанда 8 Б. эшли. Шул чордан башлап, колхозларга а.х. продукциясен Б.да сату (дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәгәннән соң) рөхсәт ителә.

1971 дә — Казан, Түбән Кама, 1982 дә Норлат шәһәрләрендә беренче ябык Б.лар корыла, 1970–75 тә Б.ларда товар әйләнеше 33,5% ка арта. ТРда халыкка а.х. продукциясе сатуда колхозларның өлеше зур булмый, 1975 тә — 4,8, 1980 елларда 2% тәшкил итә. 1990 елларда ирекле сәүдә рөхсәт ителгәннән соң Б.лар эшчәнлеге җанланып китә. Шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә, кагыйдә буларак, бәйрәмнәр уңае б-н ярминкәләр уздырыла.

1995–2006 да 15 Б. төзелә һәм яңартыла, аларда сатучылар һәм сатып алучылар өчен уңайлы шартлар тудырыла (җылытылган биналар, суыту камералары һәм җайланмалары, сәүдә җиһазлары, склад урыннары, автомобильләрне кую урыннары, видеокүзәтү һ.б.).

ТРда 38,2 мең сату урынына исәпләнгән 176 Б. (азык-төлек, сәнәгать товарлары һәм катнаш) эшли, ш.и. Казанда 35 (13,5 мең сату урыны), Чаллыда 30 (5,3 мең), Түбән Камада 5 (3,7 мең), Әлмәттә 8 (3,2 мең), Чистайда 6 (1 мең), Яшел Үзәндә 4 (1,2 мең), Алабугада 3 (0,5 мең) Б. исәпләнә; башка шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә 13,8 мең сәүдә урыны булган 85 Б. 2006 да Б. гомумсәүдә әйләнешенең 14% ын (1995 тә 33% ын) тәшкил итә. Соңгы елларда Б.ларны сәүдә комплекслары итеп үзгәртү күзәтелә.

*Әд.:* История Казани. К., 1988. Кн. 1; История Татарстана: Учеб. пособие. К., 2001; Мустафин Р.А. О чём рассказали «Писцовые книги» (Казань в середине XVI века) // Татарстан. 2004. № 6. *М.Я.Гаитов, М.З.Гыйбадуллин.*

**БАЗА́Р-КАРАБОЛА́К РАЙОНЫ́**, *Саратов өлкәсендә.* Мәйданы — 2,3 мең *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Базар-Караболак посёлогы (Саратовтан 102 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 34,7 мең кеше, татарлар саны — 2993 кеше (2002): Яковлевка (1775 кеше), Олы Тау (169), Абдуловка (111), Липовка (60), Шняево (21), Землянки (18), Репьевка (198) авылларында яшиләр. 1917 елга кадәр Яковлевка авылында 3 мәчет эшли. Бу авылдагы урта мәктәптә хәзер татар теле фән буларак укытыла. 2002 дән мәчет эшли. Яковлевкада Сов. Союзы Герое И.М.*Кудашев* туган.

**БАЗАРЕ́ВИЧ** Герман Яковлевич (27.11.1930, Мәскәү — 6.10.1993, Казан), хирург, реаниматолог, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1980). 1955 елда Казан мед. ин-тын, бер үк вакытта Мәскәү физкультура ин-тын тәмамлый. 1955–60 та Киров өлкәсендә район хастаханәсе баш табибе. 1961 елдан Казанда, 1967 дән шәһәр онкология диспансерында. 1970–91 дә Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1976–86 да патофизиология лаб. мөдире. Бер үк вакытта 1986 дан Ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү хастаханәсендә һәм 10 нчы шәһәр хастаханәсендә хирург һәм анестезиолог-реаниматолог булып эшли. Хезмәтләре имгәнүләр һәм шок вакытындагы үлем алды халәтенә карый. Б. һәлакәт медицинасының фәнни һәм гамәли нигезләрен, гадәттән тыш хәлләр вакытында дәвалау чараларын эшли. Фехтование буенча СССРның спорт остасы, СССР Кубогы иясе (1963).

Хезм.: Медиаторные системы и функции дыхания при кровопотере и шоке. К., 1973; Медиаторные механизмы регуляции дыхания и их коррекции при экстремальных состояниях. Л., 1979.

**БАЗАРЕ́ВСКИЙ** Хәлил Мостафа улы (25.9.1851, Вильно губ. — ?), ген.-лейтенант (1911), Польша-Литва татарларыннан. Петербургта 1 нче хәрби гимназиядә, 2 нче Константинов хәрби уч-щесендә, Михаил исем. артиллерия уч-щесендә укый. 1870–99 елларда 26 нчы, 10 нчы артиллерия бригадасында хезмәт итә. 1899 да полковник дәрәҗәсе ала һәм 29 нчы артиллерия бригадасының 2 нче дивизионы командиры итеп билгеләнә. 1904–05 елгы рус-япон сугышында катнаша, бригада командиры, 8 нче армия корпусы артиллерия башлыгы вазифаларын башкаручы, 1905 тән Россия армиясе генерал-майоры. 1906–11 дә бригада командиры, 29 нчы пехота дивизиясе командиры вазифаларын башкаручы, 20 нче армия корпусы артиллерия инспекторы вазифаларын башкаручы. 1911 дә отставкага чыга. «Батырлык өчен» сүзләре язылган шәхси алтын корал, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче, 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 нче, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Гришин Я.Я., Шарафутдинов Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

*Я.Я.Гришин.*

**БАЗАРЛЫ́ МАТА́К** авылы, Әлки р-ны үзәге. ТРның көньягында, Казаннан 152 *км* ераклыкта, Ульянов–Уфа тимер юлының Бряндино станциясеннән 72 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Актай елгасы буенда. 2005 елда 5366 кеше (татарлар — 70%, руслар — 22%) яши. Аэропорт. «Әлки» катнаш азык, сөт з-длары, «Чулпан» көнкүреш хезмәте күрсәтү, икмәк комб-тлары, типография. Урта мәктәп, һөнәри уч-ще, музыка мәктәбе, район мәдәният йорты, 2 китапханә. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.М.та волость идарәсе урнаша, Троица чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, аеклык җәмгыяте китапханәсе, мед. һәм вет.



Базарлы Матак авылы. Сәүдәгәр Деляханов йорты (19 йөз ахыры). Хәзерге күренеш.

фельдшерлык пунктлары, су, 12 җил һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, 4 тимерче алачыгы, 4 кирпеч сугу, 3 бакыр-аккургаш йөгертү, май язу, 2 йон тетү, арыш салаты оны ясау биналары, 6 юлаучылар йорты, даруханә, тегү машиналары, шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете, 3 сырауханә, 18 чәйханә эшли. Шимбә саен базар, ел саен Покрау һәм Никола ярминкәләре үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4482 дис. тәшкил итә. 1920 елга



Базарлы Матак авылы. Район мәдәният йорты.

кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волосте үзәге була. 1920 елдан ТАССРның Спас кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Әлки (1937 дән — район үзәге), 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан Әлки р-ны үзәге. Халык саны: 1782 дә — 135 ир заты; 1859 да — 1249, 1897 дә — 1908, 1908 дә — 2048, 1920 дә — 2196, 1926 да — 2084, 1938 дә — 1818, 1949 да — 1580, 1958 дә — 2272, 1970 тә — 2818, 1979 да — 2965, 1989 да — 4175, 2002 дә — 5329 кеше.

**БАЗА́РОВКА** тимер юл разъезды посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2002 елда 194 кеше (руслар — 46%, татарлар — 38%) яши. 1956 елдан мәгълүм. Халык саны: 1958 дә — 68, 1970 тә — 56, 1979 да — 44, 1989 да — 61, 2000 дә — 35 кеше.

**БАЗИДИОМИЦЕТЛӘ́Р**, базидиаль гөмбәләр (Basidiomycetes), махсус үсентеләрендә — базидияләрдә җенси споралары булган иң югары класслы (төзелешле) гөмбәләр. Базидиоспоралар, үсеп чыгып, мицелий — гөмбәлек барлыкка китерәләр. Мицелий субстрат (туфрак, агач, үсемлек сабагы һәм яфраклары) эчендә озак вакыт яши яки үрчү өлеше барлыкка китерә ала. Үрчү өлешләре формалары һәм консистенцияләре ягыннан төрле. Споралы катлау (гимений) түбән төзелешлеләрдә — өске, югары төзелешлеләрдә аскы якта була. Җенессез үрчү (гаплоид вегетатив гифлардан споралар барлыкка килү) сирәк очрый. Базидиаль гөмбәләрнең 30 меңләп төре бар. Паразитларны (тутыксыман, кисәүсыман, экзобазидиумнар, тамыр болытсыманы, көзге баллы гөмбә), сапрофитларны, микориза барлыкка китерүче гөмбәләрне (ак гөмбә, каен гөмбәсе, усак гөмбәсе һ.б.) берләштерә. Б. үсемлек калдыкларын таркаталар, туфрак ясалу процессында һәм матдәләр алмашында катнашалар. Азык буларак кулланыла торган күпчелек гөмбәләр шул класска карый. Кайбер Б. культурада үстерелә (*шампиньон*нар, җәйге баллы гөмбә, ашарга яраклы вольвариелла). Алар төрле биологик актив матдәләргә бай һәм дәвалау максатларында кулланыла (гади весёлка — ревматизм, подагра авыруы вакытында, лангерманниянең үрчү өлеше — шеш булганда). Б. арасында ш.у. үтә зарарлы гөмбәләр дә күп. Паразит гөмбәләр — үсемлекчелеккә, ярым паразитлар (*агач гөмбәләре*) һәм сапрофитлар (*бүрәнә гөмбәләре*) урманнарга һәм агач корылмаларга зыян китерә.

*Әд.:* Жизнь растений. М., 1976. Т. 2.; Хржановский В.Г. Ботаника. М., 1988.

*А.М.Җәлалов.*

**БАЗИЛЕ́ВИЧ** Константин Васильевич (12.5.1892, Киев ш. — 3.3.1950, Мәскәү), тарихчы, тарих фән. д-ры (1952, вафатыннан соң). Михаил исем. артиллерия уч-щесен (1913, С.-Петербург), Мәскәү ун-тын тәмамлый (1922). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1918–21 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә. 1922–29 да Тарих музеенда (Мәскәү), 1936 елдан СССР ФАнең Тарих ин-тында эшли. Бер үк вакытта 1935 тән Мәскәү ун-ты, 1939 дан ВКП(б) ҮК каршындагы Югары партия мәктәбе профессоры. Төп хезмәтләре 13–17 йөзләрдә Россиядәге сыйнфый көрәш, социаль-икътисади мөнәсәбәтләр тарихына карый. Рус дәүләтенең Көнчыгышка кагылышлы сәясәтен өйрәнә; яңа табылган архив мәгълүматлары нигезендә Иван III нең һәм Идел буендагы, Кырымдагы татар дәүләтләре ханнарының эшчәнлекләрен тасвирлый.

Хезм.: В гостях у Богдыхана: Путешествие русских в Китай в XVII в. М., 1927; Образование русского национального государства. Иван III. М., 1946; Ярлык Ахмед-хана Ивану III. М., 1948; Внешняя политика России в период образования централизованного государства, 2-я пол. XV в. М., 1952.

*Әд.:* Черепнин Л.В. Константин Васильевич Базилевич // Уч. зап. Моск. ун-та. 1952. Вып. 56.

*Е.Б.Долгов.*

**БАЗО́ТОВ** Виктор Яковлевич (20.8.1946, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2000), проф. (2001). 1969 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (хәзерге Казан технол. ун-ты), шунда ук укыта, каты химик матдәләр технологиясе каф. мөдире (2000 елдан), хим.-технология инженерлары ф-ты деканы (1996 дан), Хим-технол. инженерлары ин-ты директоры (2001 дән). Хезмәтләре каты органик матдәләрнең өслекле һәм контактлы күренешләренә, органик кристаллик матдәләрнең деформацияләнгән һәм җимерелгән вакыттагы электрофизик һәм эмиссион күренешләрен өйрәнүгә карый. Югары энергия сыйдырышлы каты органик матдәләрнең диэлектрик һәм электрофизик үзлекләрен һәм электрлашу күренешләрен өйрәнә. Органик диэлектрикларда эл. корылмалары барлыкка килү һәм туплану механизмын ача һәм алар өчен югары нәтиҗәле күп функциональ тәэсир итүчән антистатиклар сайлауның яңа юлларын тәкъдим итә. Каты җисемнәр адгезиясенең электрон теориясен үстерүгә мөһим өлеш кертә. Монография һәм 100 дән артык мәкалә авторы; уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БАЗЯ́КОВО** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 34 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасы буенда. 2002 елда 215 кеше (руслар — 82%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөз урталарында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше б-н шөгыльләнә. 1761 дә авылда Тихвин-Богородица чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 20 йөз башында Б.да земство мәктәбе, гариплләр йорты, 5 тегермән, 2 тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли; һәр елның 26 июнендә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл



Базарлы Матак авылы. Гомуми күренеш.

җәмәгатенең имана җире 1412,5 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Спас өязе Николо-Пичкас волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 342 ир заты; 1859 да — 745, 1897 дә — 1037, 1908 дә — 1098, 1920 дә — 1196, 1926 да — 1058, 1958 дә — 363, 1970 тә — 319, 1979 да — 261, 1989 да — 236 кеше.

**БАЙБА́РЫШЕВ** Пётр Михайлович (1894, Казан — 1942), нәкышьче, график. Казан сәнгать мәктәбендә белем ала (1911–18), 1915–16 елларда, укуыннан бүленеп, хәрби хезмәттә була. 1920 дә Кызыл Армиянең Респ-ка запас армиясе штабы сәяси бүлегендә рәсем сәнгате секциясенә җитәкчелек итә. 1921 дә укуын дәвам иттерү өчен Казан сәнгать-техника ин-тына (1935 елдан — Казан сәнгать уч-щесе) җибәрелә. «Пар чүкече»



П.М. Байбарышев. «Кабаре». Төсле ташбасма. 1920 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

һәм «Паратскидагы «Кызыл металлист» заводының тимерчелек цехы» картиналары өчен аңа нәкышьче рәссам дәрәҗәсе бирелә (1923). ТатАХРР (1923) һәм Рәссамнар берлеге әгъзасы (1940). Казан уку йортларында укыта. 1920–30 елларда мәдәният тормышында актив катнаша. «1905 ел» (1922), «Чуаш базары» (1926), «Ленин Октябрьдә» (1940–41) дигән нәкышь әсәрләре, төсле литография, линогравюра, сатирик рәсемнәр, «*Всадник*» графика җәмгыяте басмалары авторы. И.И.Князьков б-н берлектә Казан пионерлар йортын, А.В.Ухтомский исем. тимерьюлчылар клубын һ.б. бизи. Революцион бәйрәмнәр уңаеннан шәһәрне бизәүдә катнаша. Тукыма бизәкләре, көнкүреш әйберләре, костюмнар өчен эскизлар ясый. Татар акад. театры спектакльләре декорацияләре авторы. Казан рәссамнары күргәзмәләрендә катнаша (1918 дән). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Сулф, Леф, ТатАХРР: Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х годов. К., 1990.

**БАЙБИ́КОВ** Искәндәр Мөхәммәт улы (30.7.1944, Ташкент ш.), патологоанатом, мед. фән. д-ры (1988), проф. (1990). 1967 елда Ташкент мед. ин-тын, 1977 дә Ташкент пед. ин-тының чит телләр ф-тын тәмамлый. 1967–76 да Ташкент мед. ин-тында, 1976 дан Үзбәкстан Респ-касы Сәламәтлек саклау министрлыгының Хирургия фәнни үзәгендә эшли. Кеше күзәнәкләренә, тукымаларына һәм әгъзаларына лазер нурлары тәэсирен өйрәнә; биологик актив үзенчәлекле сыеклык алу ысулларын, ашказаны ярыларындагы һәм уникеилле эчәктәге җәрәхәт аша ашказаны сыеклыгының инфильтрацияләнү күренешен ача; корсак куышлыгының үлекләп ялкынсынуын модельләштерү ысулын эшли.

Хезм.: Компенсаторно-приспособительные процессы в кишечнике... М., 1974; Морфологические основы низкой интенсивной лазеротерапии. Таш., 1991; Структурные основы показаний и последствий ваготомии. Таш., 1992.

**БАЙБИ́КОВ** Хөсәен (? — 1919 дан соң), Мәскәү сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. «Кече Эрмитаж» кунакханәсе хуҗасы. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18).

**БАЙБИ́КОВА** Эра Мөхәммәт кызы (1.8.1931, Ташкент ш.), гистолог, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1989). 1955 елда Ленинградта 1 нче мед. ин-тын тәмамлый. 1955 елдан Ташкент мед. ин-тында, 1976 дан Үзәк фәнни-тикшеренү лабораториясенең морфология бүлеге мөдире. Имгәнүләрдән соң тукымаларны савыктыру процессларының структур нигезләрен, нурланыш тәэсиренә эләккән тукымалардагы шул процессларны көчәйтү һәм көйләү юлларын эшли.

Хезм.: Регенерация слизистой оболочки желудочно-кишечного тракта при общем гамма-облучении. Таш., 1960; Вопросы регенерации желудка при иммуносупрессии и медикаментозной корреляции. Таш., 1979; Реактивность слизистого желудка в эксперименте и клинике. Таш., 1979.

**БАЙБУЛА́ТОВ** Җәлил Гыйльман улы (1896–1982), журналист, тәрҗемәче, Үзбәкстан ССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1976). 1919 елда Оренбург губернасы Әлмән авылында җәдитчә мәдрәсә ача, анда укыта. 1920 елдан Урта Азиядә, 1925–28 елларда Үзбәкстан КП(б) ҮКнең матбугат бүлегендә эшли, 1928–31 дә ВКП(б) ҮКнең Урта Азия бюросында матбугат секторы мөдире урынбасары, 1933–35 тә Үзбәкстан партия нәшриятында җаваплы мөхәррир була. 1936 елдан тәрҗемә эшендә.

**БАЙБУ́РИН** Вил Бари улы (2.7.1935, Оренбург ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1985), проф. (1987). РФнең атказ. фән эшлеклесе (1999). 1957 елда Саратов ун-тын тәмамлаганнан соң, «Тантал» фәнни-тикшеренү берләшмәсендә эшли (Саратов ш.), 1969 дан лаб. җитәкчесе. Бер үк вакытта 1987 дән Саратов техника ун-тында автоматлаштырылган идарә итү системалары каф. мөдире, 1992 дән хисаплау техникасын һәм автоматлаштырылган системаларны программа б-н тәэмин итү каф. мөдире. Хезмәтләре үтә югары ешлыклы (СВЧ) диапазонда эшли торган электрон приборларның нәсызыкча теориясенә, технол. процессларны модельләштерү һәм автоматлаштыруга карый. Кисешүче кырларда электрон агымнарның электромагнит дулкыннар б-н тәэсирләшүенең нәсызыкча теориясен төзи. Үтә югары ешлыклы нурланышның дискрет һәм өзлексез мохит б-н үзара тәэсир итешү эффектын кулланып, яңа технол. процесслар һәм җайланмалар, атомнарны күрсәтерлек сканерлаучы зонд микроскопиясе нигезендә каты җисем физикасында һәм молекуляр биологиядә яңа эффектлар ачып, аналитик үлчәү комплекслары төзи. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Математические модели и методы оптимального проектирования СВЧ-приборов. М., 1990; Многофункциональный комплекс сканирующей зондовой микроскопии и его применение. Саратов, 1998; СВЧ-энергия и её применение. Саратов, 1999.

**БАЙБУ́РИН** Җиһангир Нургали улы (20.3.1859, Уфа губ., Уфа өязе Сәфәр а. — 1915), җәмәгать эшлеклесе. Уфада гимназия тәмамлаганнан соң (1883), Казан ун-тының мед. ф-тында белем ала (1883–87). Табиб ярдәмчесе, табиб. 1905 елның ахырында Оренбург шәһәрендә мөселманнар арасында Дәүләт думасына сайлаулар оештыру комиссиясен җитәкли. 1906 елда Оренбург губернасы мөселманнары хәйрия җәмгыяте сәркәтибе, Мөселман халык партиясе рәисе. 1905–06 елларда Бөтенроссия мөселманнарының «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясен оештыру корылтайларында катнаша, партия әгъзасы. Оренбург губернасыннан 3 нче Дәүләт думасына депутат булып сайлана (1907–12), мөселманнар фракциясе, бюджет һәм җир эшләре комиссияләре әгъзасы.

Чыг.: Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–17 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Әд.:* Усманова Д.М. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной думе России (1906–17). К., 1999.

**БАЙБУ́РИН** Наил Габдулла улы (17.7.1956, Уфа ш.), театр рәссамы, нәкышьче, БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). Уфа сәнгать уч-щесен (1975) һәм Уфа сәнгать ин-тының нәкышь бүлеген (1980) тәмамлый (Р.М.Нурмөхәммәтов һәм М.Н.Арсланов шәкерте). 1982 елдан Башкорт курчак театрында бизәүче-рәссам, 1984 тән баш рәссам һәм 1994 тән баш режиссёр. Театр эшлеклеләре берлеге (1984) һәм аның каршында оештырылган Курчакчылар лигасы (1989 дан), Рәссамнар берлеге (1991 дән), рәссамнарның «Чыңгызхан» иҗади җәмгыяте (1990 нан) әгъзасы. Башкорт һәм Свердловск курчак театрларында, Башкортстан Респ-касының Яшьләр театрында, Сибай һәм Уфа рус драма театрларында куелган 40 лап курчак («Рамаяна», 1987; «Лисистрата», Аристофан, 1989) һәм драма («Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин, 1983; «Ак калфак», М.Фәйзи, 1997; «Ак карга» һәм «Ялгыз имән», Г.Байбурин, 1996, 1997) спектакльләренең сәхнә бизәлеше авторы. Б. курчак спектакльләренең («Сарнуш», 1994; «Шүрәленең төнге уеннары», 1996) драматургы, режиссёры һәм рәссамы буларак та мәгълүм. Эксперименталь сәнгать вәкиле, театр плакатлары, «поп-арт» стилендәге нәкышь әсәрләре һәм инсталляцияләр (җыелма объектлар) авторы. Б. иҗатына милли сәнгать элементларының хәзерге Көнбатыш Европа нәкыше алымнары б-н кушылуы хас. Әсәрләрендә әйләнә-тирә мохит



Н.Г.Б а й б у р и н.
1. «Мәрҗән Мәфрүзә». Инсталляция. Агач, металл. Катнаш техника; 2. «Тамга». Инсталляция. Агач, күн, бронза. 1991. «Шәрекъ» фондының традицион һәм заманча сәнгать галереясы. Уфа ш.; 3. «Төн». Катнаш техника. 1997. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. «Тәңре хан илчесе». 1997. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

экологиясе һәм эстетикасы, рухи сафлык проблемалары күтәрелә («Мәрҗән Мәфрүзә», «Китмә, Мөхәррәм», 1988; «Хәтер коесы», 1989; «Китүче», 1990; «Мәхүзә кунакка китте, сыер саварга кеше юк», 1991). Образларының семантикасы борынгы төркиләрнең тотемик мифларына, риваятьләренә нигезләнә. Ат, кояш, ай рәсемнәре тормышның яңаруы һәм яңадан туу идеясен гәүдәләндерә («Дүрт кояш, ике ай», «Тамга», 1991). Б.ның агач, бакыр, бронза, кәгазь, күн, ат тиресе һ.б. кулланып эшләнгән инсталляция жанрындагы әсәрләре табигатьне, бүгенге җәмгыятьтә әхлакый кыйммәтләрне саклау темасына багышлана («Бурсыкның Чабылтау түбәсендәге үз өнендә үлеме», «Ял ит, Сизиф», «Туй» — барысы да 1989 да, «Евразия флейтасы», 2004, Уфа). «Нәүруз бәйрәме» (1997, 1998, Уфа), «Сафлану гыйбадәтханәсе» (1998, Мәскәү), «Чыңгызхан шаһинәсе» (2000, Уфа), «Алтын пайцза», «Бишек җыры» (2006, Каргалы а., Благовар р-ны, Башкортстан) перфоманслары, пьесалар, хикәяләр һәм шигырьләр (татар һәм рус телләрендә), Уфа вакытлы матбугатында сәнгать мәсьәләләренә багышланган публицистик һәм тәнкыйди мәкаләләр авторы.

Мәскәүдә үткәрелгән «Art-Манеж» (1996–2006), «Art-Салон» (1998) күргәзмәләрендә, Бөтенсоюз театр һәм кино рәссамнары күргәзмәсендә (1987), рәссамнарның «Инзәр» берлеге составында Уфада (1989, 1993), Мәскәүдә (1992), «Сары бия» иҗат төркеме б-н — Новосибирскида (1993) һәм «Чыңгызхан» төркеме составында — Уфада (1990, 1995–97), С.-Петербургта (1990, 1991), Казанда (1991, 1992, 1994, 1996), Мәскәүдә (1992, 1994, 1997, 2000), Истанбулда (1994) һ.б. шәһәрләрдә уздырылган күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Уфада уза (1990, 2000, 2001). Әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда (Мәскәү), М.В.Нестеров исем. Сәнгать музеенда (Уфа), «Урал» хәзерге заман сәнгать галереясында, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда һ.б. саклана. Башкорт курчак театрында куелган «Һинд легендасы» спектакле бизәлеше өчен Дж.Неру исем. Халыкара премия б-н бүләкләнә (1998).

*Әд.:* У в а р о в а И. Дороги, которые мы выбираем // Театральная жизнь. 1986. № 11; ш у л у к. Разные амплуа Наиля Байбурина // Рампа. 1997. № 4; У в а р о в а И., П е р ч и х и н а М. Всё как у людей // Театр. 1987. № 2; Г а р б у з А. Заметки о современной живописи в Башкирии // Искусство авангарда: язык мирового общения. Уфа, 1993.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БАЙБУ́РИН** Фәүзи Зәки улы (24.1.1943, Башкортстан АССРның Чишмә р-ны Чишмә а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989), проф. (1990). 1968 елда В.И.Ленин исем. Ленинград югары хәрби-диңгез инженерлары уч-щесен тәмамлаганнан соң, су асты көймәсендә хезмәт итә. 1969–72 дә электромеханика хәрби часте командиры. 1975 тән үзе укыган уч-щедә фәнни-пед. эштә, 1989 дан әчке янулы двигательләр каф. мөдире. Хезмәтләре корабль дизельләренең эшләү процессларын модельләштерү һәм техник нәтиҗәлелеген күтәрүгә карый. Б.ның тикшеренүләре хәрби-сәнәгать комплексы пр-тиеләрендә файдаланыла. Уйлап табуга караган 5 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Правила эксплуатации корабельных дизелей. Л., 1976; Эксплуатационные характеристики корабельных дизелей. СПб., 1990.

**БАЙБУ́РОВ** Каюм Абдулла улы (1907, Ташкент ш. — 1973, Мәскәү), скрипкачы, педагог, РСФСРның атказ. укытучысы (1967). Мәскәүдә А. һәм Н.Рубинштейннар исем. музыка техникумында А.Берлин классында (1923–29), Мәскәү консерваториясендә Л.Цейтлин классында (1929–34) белем ала. Башкару эшчәнлеге 1923 елдан башлана, танылган «Персимфанс» оркестры коллективында уйный. Төркестанда, Россия шәһәрләрендә солист буларак гастрольләрдә йөри, Мәскәү филармониясенең Б.Хайкин җитәкчелегендәге симф. оркестрында уйный. Репертуары П.Чайковский, Н.Паганини, И.Брамс һ.б. әсәрләреннән тора. 1937 дән Мәскәү консерваториясендә (Л.Цейтлин ассистенты), музыка уч-щесендә һәм унъеллык үзәк музыка мәктәбендә эшли башлый. 1940 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерләнү уңаеннан музыка уч-щесе укытучысы һәм Татар филармониясе солисты, Татар опера һәм балет т-ры концертмейстеры булып Казанга кайта. Татар композиторлары әсәрләрен радиога яздыра, скрипка өчен милли репертуар булдыру өстендә эшли (Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетыннан «Анданте» һәм «Вальс» концерт эшкәртмәләре). 1945 тә Б. Мәскәүгә китә, яңадан музыка уч-щесендә, унъеллык үзәк музыка мәктәбендә укыта, скрипка классы буенча бөтенсоюз укыту программаларын төзүдә катнаша. Шәкертләре арасында халыкара конкурслар лауреатлары З.Шаһморзаева, А.Киселёв, А.Аренков һ.б. бар.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**БАЙБУЛӘ́К** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 38 *км* көньяктарак, Игәнә елгасының сул кушылдыгы Инеш суы бассейнында. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 2002 елда 114 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чаллы кантонына керә; 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1926 да — 194, 1949 да — 233, 1958 дә — 136, 1970 тә — 287, 1979 да — 129, 1989 да — 101 кеше.

**БАЙГИЛДИ́ЕВА** Мәрьям Гыймади кызы (1912, хәзерге Мари Респ-касының Татар Тешләсе а. — 4.6.1994, Казан), фармацевт. 1960 елда Мәскәү мед. ин-тын тәмамлый. 1944–51 дә Казан даруханәләр идарәсе, 1959–77 дә ТАССР МСның Баш даруханәләр идарәсе башлыгы. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Дикорастущие лекарственные растения Татарии и их ресурсы. К., 1970 (автордаш).

**БАЙГИ́ЛДИН** Йосыф Мөхәммәтҗан улы (3.7.1913, хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнецк р-ны Пәнделкә а. — 18.12.1989, Казан), химик-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1953). Казан хим.-технол. ин-тын (1938) тәмамлый, 1941 елга кадәр шунда укыта. 1944–57 елларда Тула өлкәсе Алексино химия комб-тында: пр-во башлыгы, директор урынбасары, баш инженер. 1957 елдан Казан хим.-технол. ин-тының хим.-технол. инженерлары ф-ты деканы, 1961–74 тә В.И.Ленин исем. Казан химия з-дында баш инженер, 1975–87 дә Химия продуктлары дәүләт фәнни-тикшеренү ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. Уйлап табуга караган 4 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге махсус машиналар җитештерү технологиясен үстерүгә зур өлеш керткән өчен бирелә. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К а з а к о в В.С. 210 лет на службе Родине. Казанский пороховой завод. К., 1998.

**БАЙГО́Л** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зәй елгасы буенда. 2002 елда 80 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, киез итек басу, балта эше, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарев волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 292, 1870 тә — 308, 1920 дә — 658, 1926 да — 622, 1938 дә — 556, 1949 да — 408, 1958 дә — 275, 1970 тә — 269, 1979 да — 200, 1989 да — 91 кеше.

**БАЙГЫ́Ш**, м ә ч е   б а ш л ы   я б а л а к (Bubo), ябалаклар семьялыгыннан кошлар ыругы. 12 төре билгеле, Евразия, Америка һәм Төньяк Африкада таралганнар. Россиядә бер төре — гади Б. (B.bubo). ТР терр-ясендә сирәк очрый, утрак төр. Биек кәүсәле урманнарда, урман үскән чокырларда яши. 80 *см* га кадәр озынлыкта, ана Б. 3 *кг*, ата Б. 2,5 *кг* чамасы авырлыкта, канат җәеме 180 *см* га җитә. Каурыйлары йомшак, кара тимгелләр һәм тар аркылы сызыклары булган җирәнрәк көрән төстә. Башында тырпаеп торган зур кара каурыйлары — «колаклары» бар. Йомры башлы, йөзе яхшы күренә. Зур күзләре алга карый. Аяклары көчле, тулысынча диярлек каурый б-н капланган, бармаклары аска бөгелгән очлы тырнаклы. Томшыгы кыска, ыргаксыман кәкре. Башы 270 градуска борыла. Очуы салмак һәм тавышсыз. Март ахыры — апрельдә парлашу чорында үзенчәлекле тавышлары ишетелә. Җир өстендә аулак чокырда оялый. 2–3 ак йомырка сала. Төп азыгы — тычкансыман кимерүчеләр (йомран, әрлән, су тычканнары), бака, балыклар. Озак вакыт аучылык хуҗалыгына зыян китерә дип исәпләнә, кырып бетерелергә тиеш була, шуның нәтиҗәсендә бик сирәгәя. Б.ның 70 елга кадәр яшәү очраклары мәгълүм. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БАЙДА́НКИНО** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зәй елгасыннан 2 *км* читтә. 2002 елда 76 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек үрчетү. Клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Черемыш исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1046,5 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарев волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 230, 1870 тә — 334, 1897 дә — 563, 1920 дә — 838, 1926 да — 672, 1938 дә — 626, 1949 да — 528, 1958 дә — 354, 1970 тә — 311, 1979 да — 226, 1989 да — 104 кеше.

**БАЙДА́РКАДА ҺӘМ КАНО́ЭДА ИШҮ́**, су спорты төрләре. Байдаркада ишү — К-1, К-2, К-4 класслы (ишкәкчеләр саны буенча) ишкәкләре беркетелмәгән көймәләрдә агымсыз һәм каршылыклы (слаломлы) суларда узышу. Спортчы тәбәнәк утыргычта хәрәкәт юнәлешенә карап утыра һәм ике калаклы ишкәк б-н ике яклап алмаш-тилмәш ишә.

Казанда байдаркалар («тузиклар») 1927 елда күренә башлый, ә 1928 дә Казанлы Н.Н.Минеев 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында көмеш медаль яулый. Татарстанда Б. һ. к.и. буенча даими ярышлар 1934 елдан ирләр арасында — 500, 1000, 10000 *м* лы, хатын-кызлар арасында 500, 1000 *м* лы дистанцияләрдә уздырыла. 1945 тән яшүсмерләр арасында Казанның шәхси-команда беренчелекләре үткәрелә. 1940 елларның 2 нче яртысында ишкәкчеләр базалары ачыла: Кабан күлендә — «Спартак», «Динамо», «Пищевик», «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятьләре, аларда ш.у. «Медик», «Наука» ирекле спорт җәмгыятьләре; Казансу елгасында «Рубин», «Труд», «Урожай», «Водник» ирекле спорт җәмгыятьләре эшли. Татарстанның җыелма командасы Идел буе (1934–36), милли республикалар (1938–40), РСФСР халыклары (1956, 1959) спартакиадаларында; РСФСР беренчелекләрендә (1949–50, 1954, 1957, 1960, 1965), РФ (2001) җиңеп чыга һәм призлар ала. Татарстанның иң яхшы спортчылары — Профсоюзлар ирекле спорт җәмгыятенең Россия һәм Үзәк советлары, РСФСР, СССР, РФ, Европа, дөнья, Олимпия уеннары беренчелекләрендә чемпионнар һәм призёрлар — Н.С.*Тетёркин*, И.Л.*Феоктистов*, В.М.*Шадрин*, М.Т.*Шубина*, М.Г.Миролюбов («Спартак», 1953), Г.С.Балакирев («Наука», 1961), Ю.П.Корнилов («Динамо», 1967), Ф.Г.Сәлахов («Динамо», 1967, 1969, 1972), А.П.Лукоянов, А.А.Захаров («Динамо», 1972), Т.Әхмәдиев (2001). Иң яхшы тренерлар — Ю.П.Варенников, И.В.Герасимов, Г.Н.Ларионов, В.И.Маркелов, С.М.Панфилов, Ф.Г.Тетёркина, Н.С.Тетёркин, В.М.Шадрин.

Каноэда ишү — С-1, С-2, С-4 классы ишкәкләре беркетелмәгән көймәләрдә тигез суларда узышу (ирләр). Спортчылар бер яктан (С-2 дә — бер яисә ике яклап) бер калаклы ишкәкләр б-н тезләнгән килеш ишәләр. Татарстанда каноэда ишү спорт төре буларак 1952 елдан байдаркада ишү б-н шөгыльләнүче ирекле спорт җәмгыятьләрендә үк үсеш ала. ТРның иң яхшы спортчылары (чемпионнар һәм призёрлар): Р.Сәмигуллин (РСФСР — 1956, СССР — 1955), Л.Ярославцев (РСФСР — 1957), Е.В.Блинов (РСФСР — 1960), М.К.Герасимов (РСФСР — 1960, 1965–66, СССР — 1960, 1965, «Снаговская регата» — 1969), Г.И.Бухарин (СССР — 1954–60, Олимпия уеннары — 1956), Г.Морев, В.Самсонов (СССР — 1968, 1970–71, 1973, 1975), А.Лемасов (РФ — 2000). Иң яхшы тренерлар: А.Бокарев («Спартак»), М.К.Герасимов, А.Косарев («Динамо»).

*Әд.:* М и р о л ю б о в М.Г. Гребля в Татарстане. К., 1999.

**БАЙКА́Л** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 52 *км* төньяктарак, Мари Респ-касы чигендә. 2002 елда 296 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 18 йөздә нигез салына, 1941 елга кадәр Яңа Таулар исеме б-н билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да мәчет, 2 җил һәм 2 су тегермәне, 2 тимерче алачыгы, кибет, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1659,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 516, 1897 дә — 787, 1908 дә — 857, 1920 дә — 1036, 1926 да — 922, 1949 да — 718, 1958 дә — 602, 1970 тә — 506, 1979 да — 417, 1989 да — 333 кеше.

**БАЙКА́Л** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2002 елда 19 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Биектау р-нында, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 130, 1949 да — 132, 1958 дә — 133, 1970 тә — 192, 1989 да — 51 кеше.

**БАЙКИ́ЕВ** Мирзаҗан Курамша (Хөррәмша) улы (1868, Пенза губ. Байки а. — 31.1.1942, Ленинград), сынчы, реставрацияләүче рәссам. Проф. белемле беренче татар сынчысы. Петербургта барон Штиглицның техник рәсем сәнгате уч-щесенең рәсем һәм әвәләп ясау сәнгате бүлеген (1892 яки 1893) тәмамлый. 1892–95 елларда Царское Селода реставратор булып эшли, 1895–97 дә Нарва һәм Вильно шәһәрләрендә яши, 1906 елдан — Эрмитажда реставратор-скульптор. Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, И.Гаспринский, Ф.Әмирхан (барысы да 1917 елга кадәр) портретларын, Ф.Әмирхан, Г.Тукай, М.Вахитов бюстларын иҗат итә.



М.К.Б а й к и е в. Ш.Мәрҗани бюсты. Гипс. 1926. ТР Милли музее.

Ш.Мәрҗани бюсты (гипс, 1926) 1939 дан ТАССР Үзәк музеенда (хәзерге ТР Милли музее) саклана.

*Әд.:* Г а л л ә м М. Татар нәфис һөнәрчесе // Яңалиф. 1927. № 12; И ш м о р а т о в Р. Татар скульпторы Мирзаҗан Байкиев // Безнең юл. 1928. № 10; У р м а н ч е Б.И. Татарстанның сынлы сәнгате // Совет әдәбияты. 1960. № 10.

**БАЙКИ́ЕВ** Рөстәм Фрунзе улы (16.4.1957, Яшел Үзән ш.), биохимик, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1996). 1980 елда Казан мед. ин-тын, 1986 да Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлый. 1980 нән Казан мед. ин-тында, 1994 тән биохимия каф. профессоры. Тикшеренүләре көчле ялкынсынулы одонтоген, гинекология, туберкулёз авыруларына башлангыч чорда радиоспектроскопия (ТМР һәм ЭПР) ысуллары б-н диагноз куюга, шул ук ысуллар б-н биол. мембраналарның динамик үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Б. тарафыннан тукымалар таркалуының диагностика алгоритмы эшләнә.

Х е з м.: Динамические свойства биологических мембран, обладающих гемокоагуляционной активностью. М., 1993; Деструкция тканей и свёртывание крови. К., 1994.


**БА́ЙКИННАР**, драма актёрлары һәм театр эшлеклеләре гаиләсе. *Әстерхан татар драма театрына* нигез салучылар, күп кенә төбәкләрдә, ш.и. Кырым, Кавказ, Урта Азиядә проф. татар театрларын оештыруга һәм үстерүгә зур өлеш кертәләр: 1) **Җәләл Мөхәмматҗан улы** (1886–1954), драма актёры, режиссёр, педагог. 1907 елның 13 гыйнварында Әстерхан шәһәрендә татар театр труппасының беренче чыгышында катнаша. Әстерханда «Вәһабия», Казанда «Касыймия» мәдрәсәләрен тәмамлый, Истанбул шәһәрендә (Төркия) укый, Әстерханда «Шура-и ислам» мәктәбендә укыта. Сәхнә эшчәнлеген 1907 елда башлый, 1908 дә «Казан-Кавказ мөселман артистлары ширкәте» спектакльләрендә катнаша, 1913–14 тә «Сәйяр», 1916 да «Ширкәт» труппаларында, 1917 дән яңадан Әстерхан татар драма театрында. 1922 дә Казанда Беренче татар үрнәк театрында. Соңыннан Әстерхан, Баку шәһәрләре театрларында, Симферополь шәһәрендәге Кырым татар театрында эшли. Драматик һәм комик рольләр башкара (Зыя — «Яшьләр», Ф.Әмирхан; Тихон — «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский; Сибгатулла, Бәдри — «Галиябану», М.Фәйзи; Солтанбәк — «Аршин мал алан», Г.Гаҗибәков), режиссёр буларак спектакльләр куя; 2) **Зөлкарнәй Мөхәмматҗан улы** (псевд. Грабов) (1888–1936), драма актёры, режиссёр. Сәхнә эшчәнлеген 1907 елда Әстерхан татар театры труппасында башлый. 1921–31 дә Симферополь шәһәрендә Кырым татар театрында, Сәмәрканд һәм Ташкент шәһәрләрендә үзбәк театрларында эшли. 1931 елдан яңадан Әстерхан татар драма театрында; 3) **Гөлчәһрә Әхмәт кызы** (7.9.1899, Әстерхан ш. — 24.8.1998, Казан), драма актрисасы, ТАССРның атказ. артисткасы (1957). З.Байкинның хатыны. Сәхнә эшчәнлеген 1920 елда Әстерхан татар драма театрында башлый. 1921–31 дә Симферополь шәһәрендә Кырым татар театрында, Сәмәрканд, Бохара, Ташкент шәһәрләрендә үзбәк театрларында, соңрак Баку шәһәрендә Әзәрбайҗан муз. театрында, Сталинград өлкәсенең Камышино шәһәрендә рус театрында, Мамадыш, Казан татар театр коллективларында эшли. 1945–59 да Татар акад. театры труппасында. Җырлау сәләтенә ия буларак, муз. спектакльләрдә төп рольләрне (Галиябану — шул исем. спектакль, М.Фәйзи; Мәйсәрә — «Зәңгәр шәл», К.Тинчурин; Зөбәрҗәт — «Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), соңыннан өлкән яшьтәге характерлы рольләрне (Әсма — «Казан сөлгесе», К.Тинчурин; Ольга — «Чит кеше күләгәсе», К.М.Симонов һ.б.) башкара; 4) **Сара Нәбиулла кызы** (14.12.1895, Әстерхан ш. — 1972), драма актрисасы, РСФСРның атказ. артисткасы (1940). Җ.Байкинның хатыны. Сәхнә эшчәнлеген 1912 елда Әстерхан татар драма театры труппасында башлый, 1913–14 тә «Сәйяр», 1916 да «Ширкәт» труппасында эшли. 1919 да Әстерхан татар театр студиясендә укый. 1922 дә Казанда Беренче үрнәк татар театрында, 1928–29 да Татар акад. театрында эшли. 1930 елларда Баку шәһәрендә татар театрында, Симферополь шәһәрендә Кырым татар театрында эшли һәм шуннан театр б-н бергә Үзбәкстанга сөрелә. 1944–56 да Әндиҗан шәһәрендә үзбәк театрында эшли, соңыннан Әстерхан шәһәренә кайта. «Галиябану» спектаклендә (М.Фәйзи) Галиябану ролен беренче башкаручы, ш.у. К.Тинчурин (Мәйсәрә — «Зәңгәр шәл»), Ф.Әмирхан (Сара — «Яшьләр»), Г.Исхакый (Әсма — «Хәлфә»), Н.Вәзирова (Сәгадәт — «Фәхретдиннең кайгысы»), Ш.Камал (Камилә — «Хаҗи әфәнде өйләнә»), А.Н.Островский (Полина — «Төшемле урын»), Ф.Шиллер (Луиза — «Мәкер һәм мәхәббәт»), У.Шекспир (Офелия — «Гамлет») пьесалары буенча куелган спектакльләрдә төп рольләрне башкара; 5) **Фатыйма Мөхәммәтҗан кызы** (1897–1925), драма актрисасы. Сәхнә эшчәнлеген 1914 елда Әстерхан татар драма театры труппасында башлый. Характерлы актриса буларак, күбесенчә асрау кыз, гади һәм күп сүзле, шаян карчыклар рольләрен башкара; 6) **Габдрахман Мөхәммәтҗан улы** (1905–44), драма актёры, композитор һәм дирижёр. 1920 еллардан Әстерхан татар драма театрында башта күбрәк музыка уен коралларында уйный торган рольләрне башкара, соңыннан спектакльләргә музыка сайлый, үзе дә яза. 1939–42 елларда Татар акад. театрында оркестр дирижёры. Бөек Ватан сугышында һәлак була; 7) **Зәйни Сәлах улы** (1911–43), рәссам. Җ., З., Ф. һәм Г.Байкиннарның бертуганнарының улы, Әстерхан шәһәрендә сәнгать уч-щесен тәмамлый, Әстерхан татар драма театрында рәссам булып эшли. Бөек Ватан сугышында һәлак була; 8) **Вил Зөлкәрнай улы** (1925), техник-технолог. Г. һәм З.Байкиннарның улы. Әстерхан шәһәрендә хореография уч-щесен тәмамлый. Әстерхан татар драма театры спектакльләрендә катнаша, балалар һәм яшүсмерләр рольләрен башкара. 1937–41, 1947–55 елларда Әстерхан, Севастополь, Казан шәһәрләренең җыр һәм бию ансамбльләрендә биюче.

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1998; М ә х м ү т о в Һ. Әстерхан татар театры // Мирас. 1995. № 11–12; И л я л о в а И. Артисты театра им. Г.Камала: Библиогр. справ. К., 1996.

*И.И.Илялова.*



Гөлчәһрә Байкина.



Зөлкарнәй Байкин.



Сара Байкина.



Җәләл Байкин.

**БАЙКУ́Л**, К а р а м а л ы  к ү л е, Идел янында. Идел елгасының уң ягында урнашкан. Кама Тамагы р-нының Кече Карамалы авылыннан 1,2 *км* көньяк-көнбатыштарак.

Байкүл.



Су өслегенең мәйданы 3,28 *га*. Су күләме 98,4 мең $м^3$. Озынлыгы 340 *м*, иң зур киңлеге 130 *м*, уртача тирәнлеге 3 *м*, иң тирән урыны 5,9 *м*. Карст нәтиҗәсендә хасил булган, озынча түгәрәк. Җир асты сулары исәбенә туена. Суы җиңелчә минеральләшкән (146,2 *мг/л*), бик йомшак (катылыгы 1,46 *мг-экв/л*), болганчык, сары төстә, иссез, гидрокарбонат-сульфат-натрийлы типта. ТРның табигать истәлеге (1978).

**БАЙЛАНГА́Р** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 12 *км* көнбатыштарак, Оштырма елгасының сул кушылдыгы Норма суы буенда. 2002 елда 745 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше, киез итек басу, аркан ишү, сәүдә итү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да мәктәбе булган 2 мәчет, 1 җил, 2 ярма ярдыру тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1961,7 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 162 ир заты; 1859 да — 1095, 1897 дә — 1343, 1908 дә — 1488, 1920 дә — 1431, 1926 да — 1245, 1938 дә — 1090, 1949 да — 1487, 1958 дә — 748, 1970 тә — 814, 1979 да — 730, 1989 да — 665 кеше.

**БАЙЛА́Р** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 42 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Салкынсу елгасы бассейнында. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. 1924 тә нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Кармалы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 70, 1938 дә — 99, 1958 дә — 68, 1970 тә — 63, 1979 да — 34, 1989 да — 12 кеше.

**БАЙЛА́Р** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 1 *км* көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2002 елда 435 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Мәдәният йорты. Китапханә. 1862 дә нигез салына. Башта Яңа Байлар дип атала. Игенчелек һәм терлек үрчетүдән тыш, халкы умартачылык б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 2480 дис. тәшкил итә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет була. 1920 елга кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Бөгелмә кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1889 да — 320, 1897 дә — 573, 1920 дә — 648, 1926 да — 577, 1949 да — 657, 1958 дә — 581, 1970 тә — 639, 1979 да — 578, 1989 да — 474 кеше.

**БАЙЛА́Р МӘЧЕТЕ́**, к. *Апанай мәчете*.





Байлар Сабасы посёлогы. 1. Балалар иҗаты үзәге; 2. Мәчет. 1841.

**БАЙЛА́Р САБАСЫ́** шәһәр тибындагы посёлогы (2004 нең 9 сентябреннән), Саба р-ны үзәге. ТРның төньягында, Казаннан 98 *км* ераклыкта, Казан–Екатеринбург тимер юлындагы Шәмәрдән станциясеннән 22 *км* көньяктарак, Саба елгасы буенда. 2006 елда 7000 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. А.х. техникасы һәм а.х. химиясе пр-тиеләре, сөт-май, азык, «Максат» көнкүреш хезмәте күрсәтү комб-тлары; икмәк, «Саба» катнаш терлек азыгы җитештерү, яшелчә киптерү з-длары, типография. Урта мәктәп һәм музыка мәктәбе, һөнәр уч-щесе. Район мәдәният йорты. 4 китапханә. Район тарихы музее. Ясалма боз мәйданы булган «Нарат» спорт комплексы, балалар иҗат йорты, «Саба дулкыннары» телерадиотапшырулар компаниясе, хастаханә эшли. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Мәмәт Пустоше исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, ювелир әйберләр ясау, тегүчелек, балта, агач эшләре һәм токарьлек һөнәрләре б-н шөгыльләнә. Б.С.нда беренче мәхәллә 1797 дә оеша. 19 йөз уртасында 4 мәхәлләсе булган, һәр мәхәлләдә мәчет һәм мәдрәсә эшләгән. Шулар арасыннан иң атаклысы — 1841 дә Казан сәүдәгәре Г.Г.Юнысов иганәсенә төзелгән беренче мәхәллә мәчете (1995 тә яңадан торгызыла; архит-ра истәлеге). 20 йөз башында Б.С.нда волость идарәсе урнаша; фельдшерлык-медпункты, 2 тимерчелек, су тегермәне, 15 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4451,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 ның 10 августыннан Саба р-ны үзәге. Халык саны: 1782 дә — 269 ир заты; 1859 да — 1665, 1897 дә — 1759, 1908 дә — 1895, 1920 дә — 2000, 1926 да — 2222, 1938 дә — 2905, 1949 да — 2184, 1970 тә — 3211, 1979 да — 4416, 1989 да — 5451, 2002 дә — 7196 кеше.

*Әд.:* Нәҗмиев Т.С., Хуҗин М.Х. Яшә, Саба-Йорт!: Тарихи-публицистик очерк. К., 1999.

**БАЙМӘ́Т** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Кече Үләмә елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 66 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Клуб. 1928 дә Олы Әтрәч авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. ТАССРның Буа кантоны Тәтеш волостена керә; 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 161, 1949 да — 193, 1958 дә — 167, 1970 тә — 187, 1979 да — 112, 1989 да — 91 кеше.

**БАЙМОРА́Т бине МӨХӘРРӘ́М әл-МӘҢГӘРИ́** (? — 1848, Казан), дин эшлеклесе, сәүдәгәр, фабрикалар хуҗасы. Казан артының күренекле дин эшлеклеләре Исхак бине Габделгазиз әл-Кенәридә (?–1835), Габбас бине Габдерәшит әл-Күшәридә (1763–1853) белем ала, ш.у. Бохарада укый. 1813 елда туган ягына кайта һәм Казан губернасы Казан өязенең Мәмсә авылы мәчетенә имам-хатиб итеп билгеләнә. 1838 елдан — Казандагы 6 нчы мәчет имам-хатибы. Мәмсә авылында һәм Казанда мәдрәсәләр тота, аларда мөдәррис булып тора. Шул ук вакытта сәүдә б-н дә шөгыльләнә. Ш.Мәрҗани раславынча, ул — бәхәсләшү рухында язылган күпсанлы публицистик кулъязма әсәрләр авторы.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**БАЙМОРЗА́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 34 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы чигендә. 2002 елда 152 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау.

Байлар Сабасы посёлогы. 1. Район хакимияте бинасы; 2. Мәдәният йорты.







Г.И. Bайморзин.



Г.Я. Баймөхәммәдов.

Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Ислам һәм христиан диннәрен тоталар. 20 йөз башында Б.да мәчет, мәктәп, Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1869 да ачыла), 2 җил һәм 3 ярма ярдыру тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 526,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Тояба волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Тәтеш кантонында; 1927 елның 14 февраленнән — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 69 ир заты; 1859 да — 215, 1897 дә — 491, 1908 дә — 761, 1926 да — 484, 1938 дә — 475, 1949 да — 367, 1958 дә — 360, 1970 тә — 102, 1979 да — 261, 1989 да — 167 кеше.

**БАЙМО́РЗИН** Гаяз Исламетдин улы (1.1.1913, хәзерге Чиләбе өлкәсенең Аргаяш р-ны Галикәй а. — 7.5.1948, Умань, Украина Респ-касы), Сов. Союзы Герое (5.11.1944), майор (1944). Белорецк металлургия техникумында укый. 1936 елдан Кызыл Армиядә. Энгельс хәрби авиация мәктәбен тәмамлый (1940). 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 4 нче гв. авиация дивизиясенең 13 нче гв. авиация полкында эскадрилья командиры урынбасары. 1944 нең октябренә 220 сугышчан очыш ясый. Сугыштан соң Хәрби Һава Көчләрендә командирлык вазифаларын башкара. Авиация һәлакәтендә үлә. Ленин, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. К., 1990; Батырлар китабы — Книга героев. К., 2000; Ради мира на земле. Челябинск, 1975; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1979. Кн. 4.

*В.А.Шагалов.*

**БАЙМӨХӘММӘ́ДОВ** Гобәй Яндәүләт улы (10.7.1925, Оренбург ш. — 20.5.1989, Одесса өлкәсенең Ширяев р-ны Сахалинский а), Дан орденының тулы кавалеры (7.8.1944, 13.4.1945, 15.5.1946), старшина. Оренбург өлкәсендә шофёр булып эшли. 1943 елдан Кызыл Армиядә, 1943 елның августыннан Бөек Ватан сугышында, 986 укчы полк пулемётчысы (57 нче армиянең 230 нчы укчы дивизиясе). 2 нче һәм 3 нче Украина, 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Украина, Молдавия, Румынияне азат итүдә һәм Берлинны алуда (1945) катнаша. Варница авылыннан (Молдавия, 1944 нең 15–17 июле) төньяк-көнбатыштарак, Цеден шәһәреннән (Германия, 1945 нең 3 феврале) көньяктарак барган бәрелешләрдә, 1945 нең 21 апреленнән 2 маена кадәр Берлиндагы урам сугышларында батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Совет Армиясендә 1949 елга кадәр хезмәт итә. Одесса өлкәсенең Ширяев р-ны «Авангард» к-хозында шофёр булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Л о б о д а В.Ф. Солдатская слава. М., 1967. Кн. 2; Д у б р о в Б.И. Солдатская слава. Киев, 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**БАЙРА́К** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 31 *км* төньяктарак, Зичә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 10 кеше (татарлар) яши. 1926 да Кәрәкәс авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Күмәкләштерү елларында Б.та «Байрак» к-зы оештырыла, 1950 дә ул — «Урай», 1959 да «Алга» к-зы (1998 дән — а.х. товарлары җитештерү кооперативы) составында. Нигезләнгән вакыттан бирле авыл ТАССРның Чаллы кантоны Шәңгәлче волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1949 да — 125, 1958 дә — 102, 1970 тә — 74, 1979 да — 57, 1989 да — 21 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**БАЙРА́Ш** (Сәүдек) авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тәтеш–Апас автомобиль юлы буенда. 2002 елда 286 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.та мәчет була. 20 йөз башында мәдрәсә, 6 җил һәм 1 ярма ярдыру тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1512,3 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостена керә. 1920 елдан ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 81 ир заты; 1859 да — 763, 1897 дә — 1336, 1908 дә — 1384, 1926 да — 1604, 1938 дә — 794, 1949 да — 520, 1958 дә — 477, 1970 тә — 423, 1979 да — 345, 1989 да — 266 кеше.

**БАЙРА́ШЕВА** Зөһрә Гәрәй кызы (8.10.1906, Рязань губ., Касыйм ш. — 2.8.1984, Казан), җырчы (лирик сопрано), педагог, ТАССРның халык артисткасы (1967). 1920–21 елларда Мария театры солисты (Петроград) Л.Ф.Нордштремнан вокал дәресләре ала. 1920 дә Казан пед. ин-тының лингвистика бүлегендә һәм Шәрекъ музыка техникумында (Е.Г.Ковелькова классы) укый. 1925 тә С.Габәши, Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградовның беренче татар операсы «*Сания*»дә төп партияне башкара. 1931 дә Мәскәү консерваториясен (ялгыз җырда — В.Н.Петрова-Зайцева, Л.Я.Шор-Плотникова классы, опера буенча — Н.С.Голованов, Л.В.Баратов классы), 1938 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен (Н.Райский классы) тәмамлый. 1931–34 тә Казан радио үзәге һәм Музыка, эстрада һәм цирк оешмалары дәүләт берләшмәсе солисты. 1938–48 дә Татар опера һәм балет театры солисты. Төп партияләре: Маргарита («Фауст», Ш.Гуно), Чио-Чио-Сан (шул исем. оп., Дж.Пуччини), Татьяна («Евгений Онегин», П.И.Чайковский), Бибисара, Саҗидә, Аембикә («Ирек», «Илдар», «Түләк», Н.Җиһанов; беренче башкаручы). Б.ның сәхнә сәнгате оста артистлык, чиста интонацияләр, камил дикция һәм музыкальлелеге б-н аерылып тора. 1947–72, 1983–84 тә Б. Казан консерваториясендә (1955–71 дә ялгыз җырлау каф. мөдире, 1964 тән проф.), 1972–83 тә Уфа сәнгать ин-тында (1972–78 дә шул ук исем. каф. мөдире) эшли. Б. Идел буе һәм Урал төбәге респ-калары өчен вокал буенча кадрлар әзерләүгә зур өлеш кертә. Шәкертләре арасында — И.Шакиров, Э.Җәләлетдинов, И.Ишбүләков, Г.Сәйфуллина, Р.Билалова һ.б. бар. Б. — югары муз. белем алган беренче татар җырчысы һәм педагог-вокалчы. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Опыт работы с национальными певцами в Казанской государственной консерватории // Из педагогического опыта Казан. консерватории. К., 1996.

*Әд.:* Т е р е г у л о в а Х. «Качкын» операсы // Совет әдәбияты. 1939. № 7; К у т у й Г. «Ирек» операсы // Публицистика. К., 1957; Мәңгелек яшьлек // Казан утлары. 1967. № 6; В о р о н о в В. Некоторые методические принципы ведущих педагогов-вокалистов Татарии // Уч. зап. Казан. консерватории. 1970. Вып. 4; Народные артисты. К., 1980.

*Ф.Ш.Салитова.*

**БАЙТИРӘ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бәтке елгасы буенда. 2002 елдан даими яшәүчеләр юк. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында авыл Дмитриевский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1757 дә Б.тә агач (1779 да — таш) Владимир-Богородица чиркәве төзелә. 20 йөз башында монда чиркәү-приход мәктәбе (1888 дә ачыла), аек яшәү рәвеше тәрбияләүче мәктәп, тегермән, тимерчелек, шәраб һәм 5 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1588 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында; 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 242 ир заты; 1859 да — 1162, 1897 дә — 1321, 1908 дә — 1408, 1920 дә — 1178, 1926 да — 1219, 1938 дә — 1077, 1949 да — 681, 1958 дә — 582, 1970 тә — 252, 1989 да — 4 кеше.

**БАЙТИРӘ́К** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы буенда. 2002 елда 150 кеше (татарлар — 82%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Байтирәк Тегермәне исеме б-н да билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.тә чиркәү-приход мәктәбе, су һәм җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 784 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванай волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Чистай кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 25 ир заты; 1859 да — 296, 1897 дә — 519, 1908 дә — 664, 1920 дә — 655, 1926 да — 698, 1938 дә — 559, 1949 да — 404, 1958 дә — 338, 1970 тә — 273, 1979 да — 193, 1989 да — 137 кеше.

**БАЙТИРӘ́КОВ** Габделлатыйф Хәбибулла улы (29.3.1873, Уфа губ., Бәләбәй өязе Ташлыкүл а. — 1951, Уфа ш.), җәмәгать эшлеклесе. 1887 елдан Оренбург татар-башкорт укытучылар мәктәбендә укый. 1894–99 елларда Россия армиясендә хезмәт итә, запаска унтер-офицер дәрәҗәсендә чыга. Дәүләкән урманчылыгында (Уфа губ.) эшли. 1904–05 еллгы рус-япон сугышында катнаша, 1904–07 дә волость старшинасы, Бәләбәй өязе земство җыелышы гласные. 1908–12 дә Бәләбәй өязенең хәрби эшләр идарәсе мөдире. 4 нче Дәүләт думасы депутаты (1912–17), мөселманнар фракциясе әгъзасы. 1917–29 елларда Бүздәк икмәк әзерләү пунктында эшли. Нигезсез гаепләнә һәм 1929–32 дә Архангельск шәһәрендә сөргендә була. Аннан кайткач, Уфа авиация техникумында кассир булып эшли. Вафатыннан соң аклана.

Чыг.: Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Әд.:* Ольшанский Н.Н. Четвёртая Государственная дума. Портреты и биографии. СПб., 1913. *Д.М.Госманова.*

**БАЙТИРӘ́КОВА** Ләйлә Сафа кызы (3.7.1924, Уфа ш.), балалар табибәсе, мед. фән. д-ры (1975). 1948 елда Башкортстан мед. ин-тын тәмамлый. 1950–82 елларда Мәскәү өлкәсенең фәнни-тикшеренү клиник ин-тында эшли, 1982 елдан Н.А.Семашко исем. Балаларга диагноз кую һәм дәвалау үзәге табибәсе (Мәскәү). Хезмәтләре балаларда күз авырулары, тамырлар һәм эндокрин авырулар (гипертония, шикәр авыруы, симерү) вакытында күрү органнарындагы үзгәрешләрне өйрәнүгә карый. Б. тарафыннан шикәр авырулы балаларда офтальмоплетизмография, фотокалиброметрия ярдәмендә күз тамырларында үзгәрешләр башлануына диагноз кую ысуллары эшләнә һәм гамәлгә кертелә; диабет авыруы вакытында күз яшендә шикәр микъдарын билгеләү методикасы эшләнә. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Хезм.: Сложные офтальмоскопические изменения и их диагностика. М., 1965 (автордаш); Проекционная фотокалиброметрия сосудов сетчатки. М., 1975 (автордаш).

**БАЙТУГА́Н** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 97 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Удмурт Респ-касы чигендә. 2002 елда 138 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Клуб. 1762 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, чыпта сугу, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да тегермән була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 497,4 дис. тәшкил итә. 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында, 1921 дән — ТАССРның Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 128, 1887 дә — 158, 1920 дә — 204, 1926 да — 188, 1938 дә — 217, 1949 да — 199, 1958 дә — 188, 1970 тә — 194, 1989 да — 138 кеше.

**БАЙЧУГАВИ́** Гали (19 йөзнең 1 нче яртысы, Казан губ., Лаеш өязе Байчуга а. — ?), шагыйрь, *чичән*. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Дала тормышы б-н яшәгән казакъ халкының милли гореф-гадәтләрен, үзенчәлекле сыйфатларын реалистик төстә тасвирлаган «Кыйсса-и әхвали казакъ» («Ушбу кыйсса казакъның әхвалләрен бәйан идәр» исеме б-н дә мәгълүм) поэмасы авторы. Поэма 1841 елда языла һәм 1879 да Казанда басыла.

*Әд.:* Татар халык мәкальләре. К., 1959. 1 т.; Васильев А.В. Материалы к характеристике взаимных отношений татар и киргизов с предварительным кратким очерком этих отношений. Оренбург, 1898. *М.И.Әхмәтҗанов.*


**БАЙЧУРА́** Үзбәк Шәриф улы (6.1.1923, Казан — 13.3.1996, С.-Петербург), тел галиме, филол. фән. д-ры (1966). Казан юридик ин-тын (1948), Казан пед. ин-тын (1949) тәмамлый. Казан югары уку йортларында, ш.и. Казан ун-тында эшли (1954–59). 1953–63 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1966–71 дә СССР ФАнең Тел белеме ин-тында (Мәскәү). 1972 елдан Ленинград ун-тында. Хезмәтләре татар теленең эксперименталь фонетикасына, тюркологиягә, фин-угор тел белеменә, алтай телләрен өйрәнүгә карый. Б. татар телендә фонемаларны аерып чыгару һәм аларның төзелешен билгеләү критерийларын тирәнтен өйрәнә; рентген рәсемнәре һәм палатограммалар ярдәмендә вокализм һәм консонантизмны сыйфат һәм артикуляция ягыннан тасвирлый; төрки телләрдә сүз басымын өйрәнә.

Хезм.: Эксперименталь фонетика һәм аның практик әһәмияте. Уфа, 1955; Характер ударения в мишарско-татарском диалекте. [У. к.], [Е. к.]; Звуковой строй татарского языка: В 2 ч. К., 1959–61; Грамматика хакасского языка. М., 1975.

**БАЙЧУ́РИН** Гомәр Гыйлаҗетдин улы (1890, Казан губ., Мамадыш өязе Урта Мишә а. — 9.5.1938, Казан), дәүләт эшлеклесе. Чыгышы б-н крәстиян гаиләсеннән. 1906–14 елларда Екатеринбург губернасындагы зөбәрҗәт чыгару прискаларында һәм Кыштым металлургия з-дында эшли. 1915–17 дә Россия армиясендә хезмәт итә. Казанда 1917 елгы Октябрь кораллы күтәрелешендә катнаша. 1917 дә Кызыл Армия өчен кече командирлар әзерләү мәктәбе мөдире. Чех-словаклар корпусы һәм КОМУЧның Халык Армиясе гаскәриләре Казанны алганнан соң, В.М.Азин отрядына килеп кушыла, Казанны азат итүдә катнаша (сент. 1918). 1919 да Төркестан фронтының 2 нче мөселман полкында мәдәни-агарту бүлеге мөдире, хәрби комиссар. 1920–25 тә ТАССР Совхозлар тресты директоры. 1927–30 да ТАССР өлкә Контроль комиссиясе Эшче-крәстияннәр инспекциясе һәм Халык комис-ты рәисе урынбасары, 1930 дан рәисе. 1934–37 дә ТАССР ҮБК Президиумы рәисе. 1937 нең 31 августында кулга алына (к. «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы*» эше). 1938 нең 9 маенда атарга хөкем ителә; үлгәннән соң аклана.



З.Г. Байрашева.



Г.Г. Байчурин.

Хезм.: Советлар һәм аларның масса белән бәйләнеше. К., 1936.

*Әд.:* Сайдашева М. Байчурин Г.Г. // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**БАЙЧУ́РИНА** Африда Заһит кызы (24.9.1950, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры (1996), проф. (2000). 1974 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. Нейротроп антидепрессив, ноотроп һәм транквилизаторлар кебек тәэсирле психотроп препаратлар уйлап табу максатында химик, органик кушылмаларның нейротроп активлыгын өйрәнә. Диазиридиннар классыннан чыгышлы антидепрессантлар табу перспективасын тәҗрибәдә исбатлый, аерым алганда, оригиналь тәэсир итү спектры һәм механизмы булган актив антидепрессив үзенчәлекле кушылма — тетрамезинны ачыклый. Б. «Мебикар» транквилизатор препаратын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә, «Дарулардан файдалану буенча табибләр өчен федераль кулланма» («Федеральное руководство для врачей по использованию лекарственных средств», М., 2000) әзерләүдә катнаша.

Хезм.: Изучение нейротропной активности нового класса полиазотистых гетероциклических соединений — производных диазиридина. К. 1996; Клиническая микробиология. К., 1998.

**БАЙЧУ́РИНА** Заһирә Гали кызы (1890, Вятка губ., Алабуга өязе Тирсә а. — 26.12.1977, Махачкала ш.), шагыйрә. Иж-Бубыйдагы кыз балалар мәктәбендә укый (1901–06). Уфа, Пермь шәһәрләрендә укыта (1907–14). Беренче шигырьләре 1913 елда «Сөембикә» ж-лында басыла. 1913–17 еллардагы иҗаты татар хатын-кызының язмышына багышла-

на, сугышка каршы юнәлдерелгән шигырьләр яза. 1918 дә Казанга күчеп килә. Иҗатының аеруча актив чоры 1918–25 елларга туры килә. «Кызыл Армия» г-тасында, «Безнең юл» ж-лында басылган күпчелек шигырьләренең тематикасы — азатлык, революция, кызылармиячеләрнең батырлыгы, яңа тормыш төзүче хезмәт кешесе. Беренче «Шигырьләр мәҗмугасы» 1923 тә басылып чыга. Аерым шигырьләре «Көрәш җырлары» (1923) күмәк җыентыгына да керә. «Ана сүзе» сайланма җыентыгы 1959 да нәшер ителә.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Өмет йолдызлары. К., 1988; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 2 т.

*М.С.Мәһдиев.*

**БАЙЧУ́РОВА** Хәдичә Хөсәен кызы (18.5.1901, хәзерге Буа р-ны Черки-Бибки а. — 13.12.1977, Казан), агроном, селекция белгече, а.х. фән. канд. (1950). СССРның Дәүләт бүләге лауреаты (1950). Ленинград а.х. ин-тын тәмамлый (1930). 1934–59 елларда Казан (1957 елдан Татарстан АССР) а.х. тәҗрибә станциясенең селекция бүлегендә эшли. Е.Н.Борисова б-н бергәләп



Х.Х. Байчурова.

уҗым арышының яңа «Казан» (1937) сортын чыгара (СССРның 8 өлкә һәм республикасында районлаштырыла һәм якынча 2 млн. *га* мәйданда игелә). Лауреат исеме шул хезмәте өчен бирелә. Хезмәтләре селекциягә, орлыкчылыкка һәм уҗым арышы агротехникасына карый. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Озимая рожь «Казанская». К., 1951; Передовой опыт получения высоких урожаев ржи. К., 1959.

*Әд.:* Лауреат государственной премии Х.Х.Байчурова. К., 1955. *Ф.С.Зыятдинов.*

**БАЙЧЫКЛЫ́ БӘРӘНГӨ́Л**, к. *Красный Баран.*

**БАКА́**, к. *Чулпы.*

**БАКА́ ГӨЛЕ́**, к. *Бегония.*

**БАКА́ КАБЫРЧЫГЫ́** (Seseli), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан бер, ике һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 ләп төре билгеле, Европада һәм Азиядә киң таралган. ТРда 2 төре — берьеллык Б.к. (S. annuum) һәм кискеч Б.к. (S. libanotis) респ-каның барлык төбәкләрендә дә очрый. Куак араларында, болыннарда, сөзәклекләрдә, елга буйларында үсә. Ике һәм күпьеллык үсемлекләрнең озынлыгы 30–100 *см*. Тамыры баусыман, юан. Сабагы цилиндрсыман, очына кадәр яфраклы. Яфраклары күгелҗем-яшел, өч катлы каурыйсыман. Чәчәкләре ак, таҗ яфракчыклары кайвакыт шәмәхә төстәге сеңерчәле, катлаулы чатырда урнашкан. Җимеше — салынкы җимешчек. Июнь–август айларында чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Берьеллык Б.к. халык медицинасында кулланыла. Тамырларында кумарин, хинон; яфракларында һәм чәчәкләрендә флавоноидлар бар. Үлән төнәтмәсе бәвел кудыру һәм яра төзәтү өчен, яңа гына алынган тамырлары дерматозлар вакытында файдаланыла. Кискеч Б.к. — терлек азыгы, баллы, эфир майларына бай үсемлек.

**БАКА́ КҮЛЕ́**, Көнчыгыш Кама алдындагы иске елгадан аерылган күл. Кама елгасының уңъяк яр буе тугаенда, Алабуга р-ның Танай авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 45,12 *га*. Озынлыгы 4510 *м*, иң зур киңлеге 180 *м* (1984).

**БАКА́ ТӘҢКӘСЕ́**, нәрсен (Lemna), нәрсенчәләр семьялыгыннан күпьеллык йөзмә су үләннәре ыругы. 10 лап төре билгеле, бөтен җир шарында таралган. ТРда өч төре — вак Б.т. (L. minor), өч өлешле Б.т. (L. trisulca) барлык районнарда да, кабырчыклы Б.т. (L. gibba) Кама алды төбәгендә очрый. Агымсыз (торгын) һәм әкрен агымлы сулыкларда үсә. Су өстендә йөзеп яки суга күмелеп үсүче вак үсемлекләрнең яшел түгәрәк яки озынча яфраксыман пластинкалары бар, алардан озын тамыр китә. Чәчәкләре бер җенесле, чәчәк тирәлеге юк, 1 җимшәнле һәм 2 серкәчле чәчәк төркемендә. Бик сирәк чәчәк ата. Җимеше ачылмый, капчыксыман, 1–7 орлыгы була. Яфракчыклардан тармакланып үрчи, ябык сулыкларның өсләрен каплап ала. Су кошларына азык.

**БАКА́ ЧЫРШЫСЫ́**, су чыршысы (Myriophyllum), су чыршычалары семьялыгыннан күпьеллык су һәм сазлык үсемлекләр ыругыннан. 45 ләп төре билгеле, бөтен җир шарында таралган. ТРда 2 төре — башаклы Б.ч. (M. spicatum) һәм боҗралы Б.ч. (M. verticillatum) үсә. Тын һәм әкрен ага торган суда үсә. 5–150 *см* озынлыкта. Сабагы көпшәсыман, ботаклы, яфраклар б-н капланган. Яфраклары боҗралы, каурыйсыман телмә җепселле. Чәчәкләре вак, аксыл яки ал төстә, башаксыман чәчәк төркемен хасил итә. Җимеше — күп төш. Июнь–июль айларында чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Күбесенчә кышлаучы бөреләрдән һәм чыбыкчалардан үрчи. Балыкларның уылдык чәчү урыны. Аквариумнарда үстерелә.

**БАКА́ ЯФРАГЫ́**, юлтүшәр (Plantago), бака яфракчалар семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләнчел, сирәк кенә ярымкуакчыл үсемлекләр ыругы. 250 ләп төре билгеле. Җир шары буйлап таралганнар. ТРда 8 төре бар. Зур Б.я. (P. major), ланцетлы Б.я. (юл яфрагы) (P. lanceolata), уртача Б.я. (P. media) респ-каның бөтен терр-ясендә дә очрый. Болыннарда, сөзәклекләрдә, чүпле урыннарда, чәчүлек мәйданнарында үсә. 10–70 *см* озынлыктагы бер һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Ком Б.я.нан (P. arenaria) кала барлык төрләре дә диярлек сабаксыз үсемлекләр. Яфраклары тамыр янындагы розеткада йомыркасыман яки эллиптик формада, туры яки дугасыман, һәрвакыт ачык сеңерчәле. Чәчәкләре вак, көмештәй ак, тар цилиндрик башакка җыелган. Җимеше — күрән орлыклы тартмачык. Май аеннан сентябрьгә кадәр чәчәк аталар. Җимешләре июнь ахырыннан





1. Ланцетлы бака яфрагы; 2. Зур бака яфрагы.

өлгерә. Зур Б.я., уртача Б.я., Урвиллей Б.я. (P. urvillei) — дару үләннәре. Яфракларында гликозидлар, сапониннар, органик кислоталар, эфир мае, минераль тозлар бар. Яфрагыннан ясалган препаратлар ялкынсынуга, склерозга каршы, җәрәхәт төзәтү өчен кулланыла. Зур Б.я., уртача Б.я. — баллы үсемлекләр. Зур Б.я. орлыклары — кошлар өчен азык. Эре Б.я. (P. maxima) һәм Корнут Б.я. (P. cornuti) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БАКАЛА́Р** (Ranidae), койрыксыз җир-су хайваннары семьялыгы. 46 ыругы, 550 дән артык төре билгеле. Көньяк Америка, Көньяк Австралия һәм Яңа Зеландиядән тыш, бөтен җир шары буйлап таралганнар. ТРда ике экологик төркем: яшел, яки су (күл бакасы, буа бакасы һәм ашарга яраклы бака) һәм күрән, яки җир өсте (очлы башлы бака һәм үлән бакасы) бакалары яши. Күл бакасы (R. ridibunda) ачык урындагы сулыкларда, ш.у. респ-каның бөтен терр-ясе буйлап зур урман сулыкларында очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 13,5 *см* га кадәр, авырлыгы 165 *г*. Өсте яшелдән алып куе күрән төстә, аркасында зур түгәрәк кара таплар бар. Корсак ягы ачык төстә, вак тимгелле. Гәүдәнең буена бот һәм балтыр перпендикуляр торган вакытта, балтыр буыннары яңадан каплаланалар. Үкчә төере тәбәнәк. Ата затлар авыз читендә урнашкан сөяլләре һәм кара төстәге резонаторлары б-н аерылып торалар. Май уртасыннан үрчү чоры башлана. Шул вакыттан алып сентябрь урталарына кадәр бөтен сулыкларда да ата бакалар тавышын ишетергә мөмкин. Бер сулыкта берничә йөз Б. җыела. Уылдык бөртекләрен ярдан читтәрәк зур өемләп салалар. Бер ана бака 12 меңгә кадәр уылдык бөртеге чәчә. Метаморфоз 3–4 ай дәвам итә. Тереклегенең 3–4 елында җенси яктан өлгерәләр. Буа бакасы (R. lessonae) бөтен җирдә таралган, әмма респ-каның көнбатыш һәм үзәк өлешендәге тугай һәм урман күлләрендә һәм сазлыкларында күбрәк очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 8 *см* га кадәр. Аркасы ачык

яшел төстә, кара тимгелләре бар. Корсагында кара тимгелләре юк. Балтыр буыннары тоташмыйлар. Арткы аякларының эчке үкчә төере биек. Ата затларының резонаторлары ак төстә. Язын буа бакасы күл бакасыннан соңрак күренә һәм май урталарында ярдан ерак түгел уылдык чәчә. Ана бака 1–1,8 мең йомырка сала, үсеш 130 көн дәвам итә. 2–3 елдан җенси яктан өлгерәләр. Ашарга яраклы бака (R. esculenta) Идел-Кама саклаулыгында очрый. Урман алды сулыкларында яши. Бу төр чыгышы буенча гибрид, күл һәм буа бакалары арасында арадаш билгеләре бар. Эчке үкчә төере күл бакасыныкы шикелле яньчек һәм буа бакасыныкы кебек биек түгел. Ата затларының резонаторлары соры төстә. Балтыр буыннары тиеп кенә торалар. Очлы башлы бака (R. arvalis), респ-каның барлык терр-ясендә, аеруча уйсу болыннарда, күрәнле сазлыкларда, су баса торган һәм киң яфраклы урманнарда яши. Апрельнең 2 нче декадасында күренә. Кышлыкка октябрь аенда күчә. Коры җирдә ялгыз яки чокырларда, агач төпләре астында төркемләп кышлый. Өсте кара көрәннән алып ачык сарыга кадәр төстә, парлашкан вакытта ата бакалар зәңгәрсу яки күк төскә керәләр. Арка уртасы буйлап, кагыйдә буларак, ачык төстәге полоса үтә, ә башының артында А-сыман фигура бар. Бугазы аксыл, еш кына мәрмәр төсле бизәге була. Танавы очлы. Арткы очлыкларын гәүдә буйлап сузганда балтыр буыннары күз-




1. Буа бакасы; 2. Күл бакасы.

ләренә кадәр җитә. Зур затлар иртән иртүк һәм эңгер-меңгер вакытында активлар. Апрель ахыры — май башында үрчиләр. Б.ның башка төрләрендәге кебек үк, бу вакытта ата затларының алгы аякларында махсус «туй» сөялләре килеп чыга. Ана бака уылдыкны берничә өлешләп чәчә, барлыгы 2800 дән артык йомырка сала. Үлән бакасы (R. temporaria) күбрәк Кама алдында һәм Көнбатыш Кама аръягында очрый. Апрель башында уяна, кышлыкка октябрь ахырында күчә. Үлән бакасы очлы башлы бакага караганда берникадәр зуррак һәм авыррак. Гәүдәсенең корсак ягында мозаика рәвешендәге тимгелләре б-н аерылып тора. Ана бака сай сулыкларда 4 меңгә якын йомырка сала. Чукмарбаш 2–3 ай эчендә бакага әйләнә. Яшь бакалар июль аенда коры җирдә күренә башлый. 2–3 елда җенси яктан өлгерәләр.

Б. бөҗәкләр, үрмәкүчләр, яңгыр суалчаннары һ.б. умырткасызлар б-н тукланалар. Күл һәм буа бакасы балык уылдыкларын ашый. Урман өчен зарарлы бөҗәкләрне, ш.у. чебен-черки составына кергән бөҗәкләрне күпләп юк итәләр. Б. промысел җәнлекләренә (кама, чәшке, көзән), ш.у. ерткыч балыкларга (чуртан, җәен), күп кенә кошларга (челән, акчарлак, кыр үрдәге) азык булып торалар.

**БАКАЛТА́Й**, Казансу тамагындагы пристань. 1699 елга кадәр пристаньга китереп бушатылган товарлардан Елантау монастыре файдасына җыем түләтелгән (16 йөздә тоз йөге салымы бер сум, балыкныкы 50 тиен булган). Йөк күләме артып, келәт-амбарларның җитми башлавы, Казансуның саегуы һәм Б. пристаненың сазлыклы җирдә урнашуы сәбәпле, 19 йөз урталарында яңа «Устье» («Үсия») пристане төзелә. «Б.» пристане язгы ташу вакытында гына файдаланыла.

*Әд.:* Свердлова Л.М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БАКАЛЫ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2002 елда 86 кеше (руслар — 81%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 19 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Дмитриевка исеме б-н дә билгеле. 1861 елга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә (алпавыт Е.Н.Аничкова крепостнойлары), игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да укый-язарга өйрәтү мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 508 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Иваново волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Бөгелмә кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 216, 1897 дә — 438, 1920 дә — 522, 1926 да — 489, 1938 дә — 355, 1949 да — 271, 1958 дә — 184, 1970 тә — 206, 1979 да — 91, 1989 да — 67 кеше.

**БАКАЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Дала Зәенең уң кушылдыгы. Озынлыгы 7,9 *км*, бассейнының мәйданы 19,8 *км*$^2$. Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Каменка посёлогыннан 1,8 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Бакалы посёлогыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 94%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–1 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,108 *м*$^3$*/с*. Б. бассейны Әлмәт аучылык тыюлыгының бер өлеше булып тора.

**БАКАЛЫ́** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2002 елда 95 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1927 дә нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлмәт волостена керә; 1930 елның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 66, 1938 дә — 97, 1949 да — 97, 1958 дә — 112, 1989 да — 34 кеше.


**БАКАЛЫ́ РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1951 *км*$^2$. Үзәге — Бакалы авылы (Уфадан 175 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 32327 кеше (2002). Татарлар саны: 1939 да — 24951, 1970 тә — 25709, 1979 да — 20305, 1989 да — 20093, 2002 дә — 16710 (шуларның 4332 се — керәшен) кеше. 98 торак пункт бар, ш.и. 47 татар, 4 татар-башкорт, 3 татар-рус, 1 татар-чуаш авылы. Иң зурлары (1999): Иске Корыч (1863 кеше) Яңа Катай (596), Яңа Урсай (569), Камышлытамак (539), Иске Куян (498), Куштирәк (450), Иске Балыклы (564). 2004/2005 уку елында 20 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла, 16 мәктәптә фән буларак өйрәнелә. Татарча «Авыл таңнары» г-тасы нәшер ителә.

**БАКИ́Р** (Бакиров) Госман Фәтхулла улы (12.3.1896, Казан губ., Казан өязе Югары Курса а. — 12.3.1982, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1966). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1940). 1918–22 елларда Арча төбәге мәктәпләрендә, 1923 тән Казанда укытучы. 1929–37 дә «Мәгариф» ж-лының җаваплы сәркәтибе, 1940–42 дә Татарстан дәүләт нәшриятының дәреслекләр һәм методик кулланмалар секторында җаваплы мөхәррир. Беренче бөтендөнья (1915–17) һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша, 1942–45 тә туп командиры, «Ватан намусы өчен» фронт г-тасы хәбәрчесе. 1945–56 елларда Татарстан китап нәшриятында укыту-пед. әдәбият бүлеге мөдире. Б. ның әдәби әсәрләре 1923 елдан басыла. «Урак өсте» (1930) хикәяләр җыентыгында, «Беренче җиңү» (1928), «Яшәсен яшьләр» (1934), «Сафа балалары» (1935) пьесаларында авыл мәктәпләре укучыларының тормышы сурәтләнә. Фронт көндәлеге, сугыш кичерешләре «Сугышчы истәлегеннән» (1949), «Утлы тегермән» (1966) исемле хикәя җыентыкларында, «Партизан малай» (1953) повестенда чагылыш таба. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Пьесалар. К., 1965; Бормалы юллар. К., 1982; Моя учительница. К., 1975.

*Әд.:* Шәрифуллин Ф. Укытучы, журналист, язучы // Совет мәктәбе. 1966. № 3; Шакир С. Сез әле дә уң флангта // Казан утлары. 1975. № 3.

**БАКИ́РОВ** Абделхәләт Абделлатыйп улы (Александр Александрович) (2.3.1908, Оренбург губ. Троицк ш. — 18.10.1986, Мәскәү), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1950), проф. (1952), Үзбәкстан ССР, РСФСР, Төрекмәнстан ССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1964, 1968, 1969). Җир асты байлыкларының нефтьле һәм газлы булуын алдан билгеләүнең фәнни мәктәбен нигезли. Мәскәү геол.-разведка ин-тын тәмамлый (1940). И.М.Губкин шәкерте. 1931–39 елларда СССРның Баш геол. идарәсендә, 1935 елдан геол. сәнәгате бүлеге башлыгы. 1940–53 тә СССР Нефть сәнәгате министрлыгында: 1940–47 дә Мәскәү геология трестында нефть һәм газ чыганакларын эзләү экспедицияләрен җитәкли, 1947–49 да Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү геол. һәм разведка ин-тының Мәс-



А.А. Бакиров.



Ә.З. Бакиров.

кәү ф-лында директор урынбасары, 1949–53 тә Геол. идарәсе башлыгы урынбасары. 1953–56 да Нефть сәнәгате академиясендә нефть һәм газ геологиясе каф. мөдире. 1956–86 да И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть ин-тында, 1960–78 дә нефть һәм газ эзләүнең теоретик нигезләре һәм разведкасы каф. мөдире. Бер үк вакытта 1984–85 тә СССР Госпланының Дәүләт эксперт комиссиясе рәисе. 1930–40 елларда Идел ГЭСын, Мәскәү метрополитенын һ.б. проектлаштыру б-н бәйле зур гидрогеологик тикшеренүләр оештыруда һәм үткәрүдә катнаша, геол. эзләнүләр, ш.и. Идел буенда нефть эзләү эшләрен җәелдерүнең перспектив планнарын эшли. 1950 елларда А.П.Виноградов, М.Ф.Мирчинк б-н берлектә Рус платформасының, ш.и. Идел-Урал нефть-газ провинциясенең зур тектоник элементлары классификациясен һәм литофациаль карталарын, СССРда нефть һәм газ табыла торган зоналарның беренче җыелма картасын төзи. 1960 елларда углеводородлар тупланмасының бердәм генетик классификациясен өйрәнә, литосферада ятмалар формалашу һәм таралуның генетик бәйләнешләрен ачыклый, нефть-газ геологиясен районлаштыру принципларын билгели. Төрле геол. шартларда нефтьле һәм газлы терр-яләр формалашу һәм урнашу закончалыкларын һәм гомуми законнарын ача. 1950–80 елларда Көнбатыш Үзбәкстан, Көнчыгыш Төрекмәнстан, Көнбатыш Себер һәм Каспий буенда нефть чыганакларын ачу мөмкинлеген теоретик нигезли. 1970–80 елларда нефть һәм газ тупланган зур зоналарның формалашуы һәм урнашуы, аларны эзләү критерийлары закончалыкларын ача, чыганактагы нефть һәм газны күләм ягыннан фаразлау теориясен эшләүгә өлеш кертә. Аның «Нефть һәм газ тупланмаларын эзләү һәм разведкалау ысуллары һәм теоретик нигезләре» («Теоретические основы и методы поисков и разведки скоплений нефти и газа», 1968) дәреслеге француз, поляк һәм гарәп телләренә тәрҗемә ителгән. Ленин (1960), СССР ФАнең И.М.Губкин исем. бүләкләре (1971, 1977) лауреаты. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, өч «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геологические основы прогнозирования нефтегазоносности недр. М., 1973; Геологические условия формирования и размещения зон нефтегазонакопления. М., 1982 (автордаш).

*Әд.:* К а л а м к а р о в Л.В., П а в л и н и ч М.Ф. Профессор А.А.Бакиров (1908–1986). М., 1996.

*Ю.А.Бакиров.*


**БАКИ́РОВ** Әнвәр Закир улы (7.7.1920, Казан — 17.8.2001, шунда ук), композитор, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1969, 1981), ТРның халык артисты (1993). 1940 елда Казан музыка уч-щесен тәмамлый (И.Әүхәдиевта — скрипка, Ю.Виноградовта композиция классы). 1940–46 да Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, 1942 дә Ульянов шәһәренең В.И.Ленин исем. гв. югары танк командирлары уч-щесен, 1952 дә Казан консерваториясен (А.Леманның композиция классы) тәмамлый. 1951–56 да Казан музыка уч-щесендә укыта, 1956–57 дә Татар опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире, 1957–70 тә Казан, Алабуга балалар музыка мәктәпләрендә эшли, Казан, Минзәлә, Чаллы шәһәрләрендә үзешчән сәнгать коллективлары б-н җитәкчелек итә. Б.ның иҗади эшчәнлеге 1937 дә язылган, халыкта киң популярлык казанган «Иртәнге серенада» җыры (Х.Вахит шигыре, беренче башкаручысы — Н.Даутов) б-н башлана. Композиторның иҗаты жанр байлыгы б-н аерылып тора. Симф. һәм инструменталь-камера әсәрләре, виолончель һәм фортепиано өчен сонатинадан башлап, оркестр өчен язылган күләмле әсәрләре («Су анасы» симф. поэмасы, өч балет сюитасы һ.б.) күренекле башкаручылар һәм коллективлар репертуарында ныклы урын ала. Б.ның иң уңышлы әсәре — «Алтын тарак» балеты (1957), яңа редакциясе — «Су анасы» (1971) — Г.Тукайның шул исемдәге әкиятенә нигезләнеп языла. Ул музыкаль образларның байлыгы, композиторның хореография сәнгатенең үзенчәлекләренә тирән үтеп керә алуы нәтиҗәсендә танылган татар балетларының берсенә әверелә. Б. — җыр жанрының остасы. 1950–60 елларда иҗтимагый-сәяси тематика циклын — «Ленин турында җыр» (М.Садри шигыре), «Совет Армиясе турында җыр» (С.Хәким шигыре), «Тынычлык һәм дуслык иле», «Илем лачыны» (Г.Зәйнашева шигырьләре) әсәрләрен иҗат итә. Композиторның лирик җырлары — «Кемгә сөйлим серләремне?» (Ф.Кәрим шигыре), «Әйткән идең» (Х.Туфан шигыре), «Кыр казлары киткәндә» (Р.Гәрәй шигыре) һ.б. аеруча киң танылa. Б.ның иҗатына моң байлыгы, милли чалымнарның ачыклыгы һәм муз. теленең демократизмы, Татарстанда композиторлык сәнгатенә нигез салучыларның иң яхшы традицияләренә тугрылык саклау хас.

Б.ның иҗади һәм җәмәгать эшчәнлеге күпкырлы: ул актив рәвештә муз. мәгърифәтчелек эшчәнлеге алып бара, Татарстан, Идел буе һәм Урал төбәге республика һәм өлкәләренең иҗади һәм фәнни оешмалары б-н хезмәттәшлек итә. Б. беренчеләрдән булып татар гомуми белем бирү мәктәпләрендә музыка укыту методикасын эшләүгә керешә. Төп әсәрләре: «Тукай» операсы (1983, куелмаган); «Тальян моңы» (1962), «Беренче факел» (1970) муз. комедияләре; «Су анасы» симф. поэмасы (1952); «КамАЗ» увертюрасы (1974); балет сюиталары (1975, 1976); ТАССРның 30 еллыгына багышланган кантата (1950); «Кама киңлекләрендә» ораториясе (1972); инструменталь-камера әсәрләре, драма спектакльләренә музыка, ялгыз җырлау һәм хор өчен 300 гә якын җыр. Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1973).

Ә с ә р.: Үзем турында үзем // Азат хатын. 1969. № 8; Җыр һәм музыка дәресләре. К., 1970; Сайланма җырлар. К., 1990.

*Әд.:* Х ә й р у л л и н а З. Әнвәр Бакировка 60 яшь // Казан утлары. 1980. № 7; Р а х м а н к у л о в Ш. Композитор һәм педагог // Совет мәктәбе. 1980. № 7; И с а н б е т Ю. Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

**БАКИ́РОВ ВӘЛИУЛЛА́ ЙОРТЫ́**, Әтнә р-нының Олы Мәңгәр авылында татар архитектурасы истәлеге. Ике катлы, мезонинлы агач йорт. 1838 елда бай җирбиләүче В.Бакиров ампир стилендә төзеткән. Архитекто-




Бакиров Вәлиулла йорты.
Әтнә р-нының Олы Мәңгәр авылы. 1838.
Йортның төп фасады һәм планнары.

ры билгесез. Б.В.й. милли көнкүреш таләпләренә яраклаштырып корылган: йортның җылытыла торган ике ягы төп фасад алдына чыгып торучы киң салкын өйалды б-н аерылган. Өйалдына берничә ишек чыга: (ирләр) ишеге — алгы фасадта, арткысы (хатын-кызлар) — башка фасадларда. 1 нче катта аш-су бүлмәсе, чоланнар, хезмәтчеләр бүлмәсе урнашкан. 2 нче катта өйалдының сул ягында — хуҗа бүлмәсе һәм эш кабинеты б-н ирләр ягы, уңда — хатын-кыз бүлмәләре. 2 нче катның өйалды өстендәге өлешендә — өлкәннәр өчен җылытыла торган бүлмә, ә чарлакта салкын бүлмәләр урнашкан. Бура дивар такта б-н тышланган, почмаклары ярымбаганалар һәм пилястралар б-н бизәлгән. Төп фасад ягыннан чарлакның өч тарафын гадиләштерелгән тоскан ордерының парлы колонналары б-н портик уратып алган. Чарлакның фронтонын ике тирән ярымтүгәрәк уем бүлеп тора, өстендә үзәк буйлап чорма тәрәзәсе урнашкан, ул татарларга хас «нур» тарата торган декоратив ташлар б-н каймаланган. Тәрәзәләре ампир йөзлекләр һәм кәрнизләр астында милли бизәкләр б-н бизәкләнгән. Чарлакның портигы һәм ишегалды фасадындагы балкон култыкса (парапет) б-н әйләндереп алынган. 1946 да арх. И.Г.Гайнетдинов йортның үлчәмен ала. Аның тикшеренүләре ачыклаганча, йорт диварлары — охра б-н, ордер элементлары ак төскә буялган, ябыштырылган сырлы элементлар төрле төсләрдә булган. 2 нче каттагы кунак бүлмәләрендәге мичләр ялтыравык кирәч плитәләр б-н капланган.

*Әд.:* Г а й н у т д и н о в И.Г. Национальные особенности татарского народного жилища // Архитектурное наследство. 1975. № 3.

*Х.Г.Надыйрова.*

**БАКИ́РОВ** Марсель Хәернас улы (10.12.1933, Мөслим р-ны Мөслим а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2002), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). Казан ун-тын тәмамлаган (1956). «Кызыл таң» г-тасында эшли (Уфа ш.). 1966 елдан Казан ун-тында укыта. Хезмәтләре төрки шигырь теориясенә һәм тарихына, төрки-татар шигыре төзелешенә, гомумтөрки шигыренең генезисына һәм борынгы формаларына, фольклор жанрларына, борынгы төркиләрнең этник һәм этномәдәни тарихына карый.

Х е з м.: Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе К., 1979 (автордаш); Гомумтөрки поэзиясенең яралуы һәм иң борынгы формалары. К., 1999; Шигърият дөньясына сәяхәт. Фольклордан классик язма шигырьгә күчеш тарихыннан. К., 1999.

*Әд.:* Российские фольклористы. Справ. М., 1994.

**БАКИ́РОВ** Наил Котлыҗан улы (30.3.1952, Казакъстан ССРның Караганда ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1995). 1974 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА Уфа гыйльми үзәгенең Математика ин-тында, 1996 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре матем. статистикага һәм ихтималлык теориясенең асимптотик ысулларына карый.

Х е з м.: Уточнение асимптотики в принципе инвариантности Донскера-Прохорова для интегральных функционалов // Теория вероятностей и её применение. 1995. Т. 40, вып. 4; Testing non-parametric hypothesis for multivariate data // Mathematical methods of statistics. N.Y., 1994. V. 3, № 3.

**БАКИ́РОВ** Раиф Госман улы (26.8.1926, Казан), хәрби төзүче, техник фән. д-ры (1969), проф. (1971). Россиянең Архитектура һәм төзелеш фәннәре академиясе мөхбир әгъзасы (1999), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987), отставкадагы полковник. 1949 елда Мәскәүдәге В.В.Куйбышев исем. Хәрби инженерлар академиясен тәмамлаганнан соң СССР Оборона министрлыгының төзелеш гаскәрләрендә һәм проектлау оешмаларында эшли. 1956 дан Хәрби инженерлар академиясендә, 1970–80 елларда инженерлык конструкцияләре каф. мөдире. 1988 дән Мәскәү коммуналь хуҗалык һәм төзелеш ин-тында. Хезмәтләре җир асты корылмаларындагы тимер-бетон конструкцияләр динамикасына карый. Автоматлаштырылган һәм компьютер технологияләре кулланып, статик һәм динамик йөкләмәләрне хисаплау, саклау һәм проектлауның вариантлы һәм аналитик вариантлы ысулларын эшли. Шартлауның юнәлешле тәэсире теориясе һәм аны халык хуҗалыгы максатларында (плотиналар төзегәндә) куллану өлкәсендәге хезмәтләре халыкара танылу ала. Уйлап табуга караган 7 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Железобетонные конструкции военно-инженерных сооружений. М., 1980; Материалы и конструкции военно-инженерных сооружений. М., 1992; Динамический расчёт и оптимальное проектирование надземных сооружений. М., 1993.

**БАКИ́РОВ** Рөстәм Сәйфулла улы (25.4.1954, Чүпрәле р-ны Татар Бизнәсе а.), хирург, мед. фән. канд. (2000), ТРның атказ. табибе (1992). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Түбән Кама р-ны үзәк хастаханәсе хирургы. 1984 елдан Казанның 3 нче хастаханәсендә хирургия бүлеге мөдире, 1994 тән 18 нче клиник хастаханәнең баш табибе. Хезмәтләре нурлар б-н диагноз куюга, эндоскопик хирургиягә карый. Б. тарафыннан лапароскопик холецистэктомия эшләү тәҗрибәсе туплана, авыруның катлаулану процесслары өйрәнелә, авыруга профилактика ысулы тәкъдим ителә. Б. үт юлларын, бөерләрне эндохирургик дәвалау ысулларын гамәлгә кертә. Шәһәр клиник хастаханәсендә Б. нурлар б-н һәм эндоскопик диагноз кую үзәкләрен, тәрбиячесез калган психоневрологик авыру балаларны дәвалау бүлеген оештыра. ТР ЮС депутаты (1989–95).

Х е з м.: Эффективность рентгеноэндохирургических методик в диагностике и лечении холедохолитиаза // Сб. тр. 2 Моск. междунар. конгресса по эндоскопической хирургии. М. 1997; Пневмоторакс как осложнение лапароскопической хирургии // Эндоскопическая хирургия. 2001, № 2; Одномоментное лапароскопическое лечение холецистохоледохолитиаза // Эндоскопическая хирургия. 2002, № 3.

**БАКИ́РОВ** Эрнест Абдулла улы (Александрович) (23.5.1930, Түбән Новгород ш.), нефтьче, геол.-минералогия фән. д-ры (1969), проф. (1970), Төрекмәнстан ССРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1980, 1998). И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли: 1965–88 елларда катламга динамик тәэсир итү лаб. мөдире, бер үк вакытта 1974–78 дә нефть һәм газ геохимиясе, геофизикасы һәм геологиясе ф-ты деканы һәм 1978–94 тә нефть һәм газ эзләүнең теоретик нигезләре һәм разведкасы каф. мөдире. 1991 елдан Мәскәү шәһәр хакимиятендә: урынбасар, беренче урынбасар, 1999 дан мэр киңәшчесе. Бер үк вакытта 1999 дан «Мәскәү нефть компаниясе» АҖ президенты. Нефть һәм газ геологиясенең теоретик проблемаларын тикшерүгә зур өлеш кертә, яңа юнәлешне — җир астындагы нефтьле һәм газлы урыннарны комплекслы фаразлау методикасын нигезли, табигый геол. системаларны модельләштерү теориясе авторларының берсе. Аның җитәкчелегендә нефть бирүчәнлекне арттыру максатында нефть катламнарына динамик тәэсир итү ысуллары тикшерелә һәм гамәлгә кертелә. СССРның көньяк өлешендә, аерым алганда, Төрекмәнстан ССРның эпигерцин платформасында нефть һәм газ урнашу закончалыкларына караган фәнни тикшеренүләре табигый газның зур чыганакларын ачуга ярдәм итә. 1963 тә Бразилия терр-ясендә фәнни-тикшеренү эшләре алып бара (Э.И.Тагиев б-н берлектә), шуның нәтиҗәсендә нефть запасларының (Америка белгечләренең бәяләмәсенә капма-каршы) шактый күп булуы исбатлана. СССР ФАнең (1991 дән РФА) И.М.Губкин исем. (1971, 1998), РФАнең В.И.Вернадский исем. бүләкләре (1996) лауреаты. «Почёт билгесе», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нефтегазоносные провинции и области зарубежных стран: Учеб. М., 1971 (автордаш); Применение подземных ядерных взрывов в нефтедобывающей промышленности. М., 1981 (автордаш); Теоретические основы и методы поисков и разведки скоплений нефти и газа. М., 1987 (автордаш).

**БАКТАЧЫ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мари Респ-касы чигендә. 2002 елда 69 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. 16 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бактачыгар исеме б-н билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, 2 мануфактура һәм 1 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 375 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Краснококшай (1919 га кадәр — Царёвококшай) өязе Күлле Киме волостена керә. 1920 дан ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 198, 1897 дә — 345, 1908 дә — 390, 1920 дә — 470, 1926 да — 453, 1938 дә — 494, 1949 да — 327, 1958 дә — 287, 1970 тә — 214, 1979 да — 159, 1989 да — 93 кеше.







Г.А. Б а к у л и н. 1. «Заречье» банкы. Казан. Реконструкция. 1996; 2. Спорт сарае. Казан. Реконструкция. 1998 (М.Г. Хәйруллин б-н берлектә); 3. Мирный посёлогындагы мәчет. Казан. 1998–99.

**БАКТА́Ш** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кичү елгасы буенда. 2002 елда 60 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. 1930 елларда нигез салына. Яңа Чишмә, 1944 елның 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 171, 1949 да — 151, 1958 дә — 129, 1970 тә — 202, 1979 да — 162, 1989 да — 104 кеше.

**БАКТЕРИА́ЛЬ АШЛАМАЛА́Р**, билгеле бер бактерияләр (туфрак микроорганизмнары) культурасына бай булган, а.х. үсемлекләре өчен файдалы препаратлар. Туфракка керткәннән соң азот тупланышын, андагы органик матдәләрнең минераллашуын көчәйтә, үсемлек тамырларының туклануын яхшырта. ТРда ризоторфин препараты киң кулланыла, аңарда һавадагы азотны үзләштерүгә, кузаклы үсемлекләрне тәэмин итүгә сәләтле бүлбе бактерияләренең актив штаммнары бар. Оптималь шартларда кузаклы культураларны игүдә азотка булган ихтыяҗның 2/3 өлеше шул бактерияләр эшчәнлеге исәбенә каплана. Шартлар начарланганда азот үзләштерү коэф. 30% ка кадәр кимергә мөмкин. Бөртекле-кузаклы, күпьеллык кузаклы үләннәрне (клевер, люцерна һ.б.) үстерү туфрактагы азотның азаюын киметә һәм бу — элементның уңай балансын тәэмин итә. Кузаклы культураларга бүлбе бактерияләре б-н прививка ясау (инокуляция) өчен чәчү көнендә орлык ризоторфин б-н эшкәртелә. Орлыкларны агулауны һәм микроэлементлар б-н эшкәртүне бер үк вакытта алып барырга мөмкин. Ачы туфракларны известьләгәннән соң, аларда кирәкле күләмдә микроэлементлар (молибден, бор) һәм дымлылык булганда, ризоторфинның нәтиҗәлелеге күтәрелә. Нәтиҗәлелекләре түбән булу сәбәпле, азотобактерин һәм фосфорабактерин кебек Б.а. соңгы вакытта файдаланылмый.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**БАКТЕРИОЛО́ГИЯ ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү институты.*

**БАКТЕ́РИЯЛӘР** (грек. baktḗrion — таякчык), микроскопик, күбесенчә бер күзәнәкле организмнар төркеме. Б. нең күзәнәкләре шарсыман (кокклар), таякчыксыман (бациллалар, клостридияләр, псевдомонадлар), спиральсыман (вибрионнар, спириллалар, спирохеталар) рәвештә булырга мөмкин; диаметрлары 0,1–10 *мкм*, озынлыклары 1–20 *мкм* (50–100 *мкм* га кадәр). Күбесе хәрәкәтчән, камчылары бар. Еш кына күзәнәкнең гади бүленүе нәтиҗәсендә зур тизлектә үсүләре һәм үрчүләре б-н үзенчәлекле. Б.ләр әзер органик матдәләр үзләштереп (гетеротрофлар) яки органик булмаган матдәләрдән органик матдәләр ясап (автотрофлар) туклана̄лар. Атмосферада кислород булганда да (аэроблар), булмаганда да (анаэроблар) үсүгә сәләтле. Б. космополитларга керә, һәр җирдә диярлек — туфракта, суда, һавада очрый. Табигатьтә матдәләр әйләнешендә, туфракның структурасын формалаштыруда һәм уңдырышлылыгын күтәрүдә, файдалы казылмалар ясалуда һәм таркалуда мөһим роль уйныйлар. Матдәләр алмашындагы күп процесслар, мәс., нитрификация, сульфофикация, закисьләнгән тимер һәм водород оксидлашуы автотроф Б. тарафыннан башкарыла. Гетеротроф Б. органик матдәләрне оксидлаштыруда, углеводларны, пектин матдәләрен, целлюлозаларны әчетүдә, аксымнарны таркатуда һ.б. катнашалар. Б.нең төрле төрләре әчетелгән сөт азыклары, мәс., болгар таякчыгы (Lactobacillus bulgaricus) — *катык*, кымыз; сыр таякчыгы (Lactobacillus casei), термофиль стрептококк (Streptococcus thermophilus) — сыр, йогырт җитештерүдә файдаланыла. Сөт әчетү бактерияләре яшелчә тозлауда, терлекләр азыгы силослауда мөһим роль уйный. Б. ярдәмендә микробиология сәнәгатендә сөт кислотасы, ацетон, спиртлар, аминокислоталар алына. Б. антибиотиклар, витаминнар, ферментлар һ.б. биологик актив матдәләр бүлеп чыгарырга ярдәм итә. Кайбер Б.нең үзенчәлеге, аерым алганда, азотобактер (Azotobacter) һәм төерчек бактерияләренең (Rhizobium) — атмосферадагы молекуляр азотны үзләштерү үзлеге *бактериаль ашламалар* әзерләүдә файдаланыла. Кеше һәм терлекләрдәге күп кенә авыруларны, мәс. чума, ваба, дифтерия, бруцеллёз, туберкулёз, себер түләмәсен патоген Б. китереп чыгара. Кайбер Б. үсемлек авырулары (к. *Үсемлекләрдә бактериаль авырулар*) барлыкка китерә. Б. генетика, биохимия, космик биологиянең гомуми мәсьәләләрен өйрәнү объекты булып тора, биотехнологиядә киң кулланыла.

*Әд.:* Ш л е г е л ь Г. Общая микробиология. М., 1987.

**«БАКУ́ ЭШЧЕСЕ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. Әзәрбайҗан КП(б) ҮК, ҮБК һәм Профсоюзлар советы органы. 1930 елның 28 апреленнән 1938 нең 11 мартына кадәр Бакуда татар телендә нәшер ителә, барлыгы 822 саны чыга. Төрле елларда мөхәррирләре: И.Хәйретдинов, Х.Ризван, Ш.Рәхмәтуллин. Әзәрбайҗан промыселларында эшләүче татарлар өчен чыгарыла. 1930–32 елларда газетаның бер сәхифәсе «Зәрбдар колхозчы» («Алдынгы колхозчы») исемендә үзбәк телендә басыла.

*Т.М.Насыйров.*

**БАКУ́ЛИН** Герман Алексеевич (18.6.1947, Казан), архитектор, ТРның атказ. архитекторы (1994). Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1971). 1971 елдан «Татгражданпроект» ин-тында (1992 дән «Татинвестгражданпроект» фирмасы) эшли, 1975 тән архитекторлар төркеме җитәкчесе, 1982 дән проектларның баш архитекторы, 1988 дән ин-тның баш архитекторы. Архитекторлар берлеге әгъзасы (1980). Б. проектлары б-н Казанда Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залы (1979, иҗат коллективы җитәкчесе), «Татинвестгражданпроект» фирмасы бинасы (1997), Мирный бистәсендә мәчет (1998–99), «Татэнерго»ның хисаплау үзәге (2000), торак йортлар һ.б. төзелә, Алабуга шәһәре хакимияте (1978), ТРның Мәскәүдәге вәкиллеге (1992), Казанда В.И.Качалов исем. Зур драма театры (1991), «Заречье» банкы (1996), Спорт сарае (1998, М.Г.Хәйруллин б-н берлектә) биналары һ.б. үзгәртеп корыла. СССР МС бүләге (1981), ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1981).

**БАКЧА́ КУЛЬТУ́РАЛАРЫ**, кабакчалар семьялыгыннан озын, түшәлмә, тармакланган сабаклы (карбыз, кавын, кабакның кайбер төрләре) үсемлекләр. Килеп чыгышлары тропик һәм субтропик Азия, Африка, Америка илләреннән. Җылы, яктылык яратучан, кырауларга чыдамсыз, вегетация чоры озакка сузыла. Дымны күп сарыф итәләр, әмма тамыр системасы куәтле булганга, чагыштырмача корылыкка бирешмиләр һәм Татарстан шартларында күп су сибү таләп итеЛМИ. Чәчәкләре бишлек тибында, бер өйле, ата һәм ана чәчәкле, умарта кортлары ярдәмендә серкәләнә. Җимеше — күп орлыклы итләч ялган җиләк. Татарстанда төп бакча культурасы булып кабак (Cucurbita) санала. 20 гә якын төре билгеле, ТР терр-ясендә, нигездә, 2 төре үстерелә: гади кабаклар (C. pepo L), бу төргә ш.у. кабакча, патиссон һәм эре кабаклар (C. maxima) керә. Кабак дымлы һәм уңдырышлы туфракны ярата, әмма тармакланып җиргә тиеп торган сабакларыннан өстәмә тамырлар җибәргәнгә, артык су сибү кирәкми. Яфраклары бик зур, төзелеше өч бүлемле, читләре тигез, ә кайберләре телгәләнгән (кабакчаларныкы). Җимешләре бик эре, 5–15 тән 30–40 *кг* га кадәр, төрле формада: яссы түгәрәк, түгәрәк, озынча түгәрәк; соры,




Бакча культуралары. 1. Кабак; 2. Ташкабак; 3. Баклажан; 4. Патиссон; 5. Карбыз; 6. Кавын.

яшел, сары, кызгылт-сары һәм буйлы-буйлы. Җимеш йомшагы аксыл-сарыдан ачык кызгылт төскә кадәр була, күп орлыклы. Составында 15–18% коры матдәләр, 8–10% шикәр, С һәм В төркеме витаминнары, каротин, пектин матдәләре бар. Ашау өчен нигездә пешереп яисә кыздырып кулланыла. Яхшы өлгергән тыгыз кабыклы кабаклар язга кадәр саклана. Эре җимешле сортлары терлек азыгы буларак та кулланыла. Үрентеләрен июнь башында күчереп утырталар (үренте өчен орлыкларын 20–25 көн алдан чәчәләр). Терлек азыгы өчен үстерелә торган кабак һәм кабакчаларны май ахырында ачык грунтка чәчәргә мөмкин.

Карбыз (Citrullus) — иң җылы яратучы, эссегә һәм корылыкка чыдам культура. Аны уңышлы үстерү өчен актив темп-ралар суммасы +2500 °С, кыраусыз көннәрнең дәвамлылыгы 130–150 көннән ким булмаска тиеш, иң оптималь темп-тура +25–30 °С. ТРда карбызны һәвәскәр бакчачылар үстерә; күбесенчә 2–3 *кг* лы вак һәм тиз өлгерә торган сортлары игелә. Яфраклары өч бүлемле, бик нык телгәләнгән. Җимешләре түгәрәк, озынча-түгәрәк, ә җимешенең йомшагы алсу, сусыл һәм баллы. Орлыклары эре, яссы, коңгырт яки кара төстә, җимеш йомшагында тигез таралып урнашалар. Сентябрьдә өлгерә. Үрентеләр ярдәмендә үстерелә (үренте орлыкларын 25–30 көн алдан чәчәләр). Көньякка караган яхшы җылына торган сөзәклекләрдәге (тау битләрендәге) җиңел, уңдырышлы туфракны ярата.

Кавынны да, карбыз кебек үк, һәвәскәр бакчачылар үстерә. Яфраклары өч аерчалы, бүлгәләнгән, кечкенә. Җимешләре озынча-түгәрәк яисә түгәрәк, җимеш йомшагы һәм кабыгы (тышчасы) сары төстә, җимеше бик тәмле, тыгыз һәм хуш исле, өлгергән һәм киптерелгән килеш тә кулланыла. ТРда утырту өчен тиз өлгерешле, озынча-түгәрәк, 1,5–2,5 *кг* лы «Колхозница» сорты кулланыла. Үрентеләрдән үстерелә.

*Әд.:* Овощные и бахчевые культуры. М., 1955; Приусадебное хозяйство. М., 1983; Ш е с т а е в А.Л. Овощные и бахчевые культуры на приусадебном участке. М., 1992.

*В.А.Наумов.*

**БАКЧАСАРА́Й**, Кырым ярымутравындагы шәһәр, Кача елгасына коя торган Черексу буенда урнашкан. 16 йөз башында *Миңлегәрәй хан* тарафыннан нигез салына. 1783 елга кадәр Кырым ханлыгының башкаласы. 17–18 йөзләрдә Кырым ярымутравында эре сәүдә һәм һөнәрчелек үзәге. 1735–39 елларда рус-төрек сугышы вакытында рус гаскәре тарафыннан вакытлыча яулап алына һәм шактый җимерелә, талана. 1783 тән Россия составында. Новороссийск губернасы составына керә, 1802 дән — Таврия губернасында. 1794 тә Б.да 5 тегермән, 20 пекарня, 13 тире эшкәртү йорты, 6 алачык, өс һәм аяк киемнәре тегү, корал ясау остаханәләре, күпләгән вак кибетләр була, аларда ефәк, аяк киеме, металл савыт-саба һ.б. товарлар б-н сату итәләр. Б.да озак вакыт күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Исмәгыйль Гаспринский яши һәм шунда үлә. Биредә ул «Тәрҗеман» г-тасын нәшер итә. 1930 елда Б.да — 10450 кеше (шуларның 7420 се татар; 1944 тә Б.ның Кырым татарлары яшәгән урыннарыннан көчләп куылуга дучар ителә), 1939 да — 10891, 1989 да 25363 кеше яши. Хәзерге вакытта Хан сарае корылмалары ансамбле (16 йөздә Сәхибгәрәй хан заманында төзелә), Гомәр оста 1764 елда төзегән мәшһүр фонтан («Күз яше фонтаны», «Бакчасарай фонтаны»), өлешчә хан төрбәләре, мәдрәсә биналары, гомумән, 16–18 йөз корылмалары сакланган. 1736 да руслар явы вакытында яндырыла, 1750 елларда кабат торгызыла. 1787 дә императрица Екатерина II Б.га килер алдыннан кенәз Г.А.Потёмкин тарафыннан беркадәр үзгәртеп корыла (1917 дән Тарих-археология музее). Хан сарае ансамбленә берничә затлы бина: диван һәм мәхкәмә йорты, хан мәчете, кәнизәкләр



«Бакчасарайдагы Хан сарае күренеше». Е. Корнеев рәсеме буенча С. Химли гравюрасы. Акватинта. 1804.

йорт-бакчасы, ау кошлары манарасы, Зур бакча керә.

*Әд.:* Крикун Е.В. Архитектурные памятники Крыма. Симферополь, 1977; Нагаевская Е.В. Бахчисарай. Симферополь, 1979; Крымскотатарская энциклопедия: в 2 т. Симферополь, 1993–95.

**БАКЧАСАРА́Й** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 17 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда Тайсуган авылыннан күчеп утыручылар Кызыл Игенче авылына нигез сала. ТАССРның Бөгелмә кантоны Габдрахман волостена керә; 1930 елның 10 августыннан — Әлмәт р-нында. Халкы башка җирләргә күчеп китү сәбәпле, 1980 нең 27 ноябрендә авыллар исемлегеннән сызыла. 1997 нең 16 гыйнварында хәзерге исеме б-н теркәлә. Халык саны: 1926 да — 130, 1938 дә — 218, 1949 да — 173, 1958 дә — 158, 1970 тә — 85, 1979 да — 69, 1989 да — 28 кеше.

**БАКЧАСАРА́Й** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 34 *км* төньяк-көнбатыштарак, Киров өлкәсе чигендә. 2002 елда 92 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1929 да нигез салына, ТАССРның Мамадыш кантонына керә; 1930 елның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1938 дә — 112, 1949 да — 91, 1958 дә — 94, 1970 тә — 121, 1979 да — 109, 1989 да — 86 кеше.

**БАКЧАСАРА́Й** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 19 *км* көнбатыштарак, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 65 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 1911 дә нигез салына. 1913 елгы документларда авыл исеме «Тауасты Тәкермән авылының Чермышев отрубы (крәстияннәргә бирелгән шәхси җир кишәрлеге)» буларак очрый. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 315 дис. тәшкил итә. 1925 тә Б.да мәхәллә оеша (1929 елга кадәр эшли) һәм мәчет төзелә. 1928 дә башлангыч мәктәп ачыла. 1929 да шул ук исемдәге колхоз оештырыла. 1950 дән — «Коммунар», 1958 дән Куйбышев исем. к-з составында. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында; 1930 елның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1913 тә — 97, 1920 дә — 98, 1926 да — 143, 1938 дә — 231, 1949 да — 221, 1958 дә — 206, 1970 тә — 228, 1979 да — 153, 1989 да — 84 кеше.

**БАКЧАСАРА́Й** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Аулаш елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 74 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чаллы кантонына керә; 1930 елның 10 августыннан — Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 251, 1949 да — 225, 1958 дә — 181, 1970 тә — 173, 1979 да — 156, 1989 да — 87 кеше.

**БАКЧАСАРА́Й** посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 23 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы яр буенда. 2002 елда 215 кеше (татарлар — 80%) яши. Известь һәм вак таш чыгарыла. Урта мәктәп. 1923 тә нигез салына. ТАССРның Зөя кантонына керә; 1927 елның 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 22, 1938 дә — 84, 1949 да — 85, 1958 дә — 107, 1970 тә — 97, 1979 да — 117, 1989 да — 209 кеше.

**БАКЧАЧЫЛЫК**, үсемлекчелек тармагы, күпьеллык җиләк-җимеш культуралары (җимеш үстерү) һәм декоратив үсемлекләр (декоратив Б.) үстерү. Татарстан терр-ясендә Б. 17 йөз ахырыннан Иделнең уңъяк ярында киң үсеш ала. Иң зур бакчаларга 1706 елда «Архиерей дачасы»нда (хәзер Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты терр-ясе), 1849 да 2 нче номерлы фермада (Казан а.х. аграр. ун-ты), 1852 дә маркиз Паулуччи биләмәсендә (Югары Ослан р-нының Ключище а.) нигез салына. 1920–30 елларда 50% тан артык бакча Югары Ослан, Кама Тамагы, Тәтеш р-ннарында туплана. Тәмте авылында бакчаларның мәйданы 600 *га* тәшкил итә. Бакча урыны итеп чәчәргә (сөрергә) яраксыз текә сөзәклекләр файдаланыла. Орлыклылар (нигездә алмагачлар) — 75%, каты төшлеләр һәм җиләк культуралары 8–10% мәйданны алып тора. Чия һәм слива бакчалары Югары Ослан р-ны терр-ясендә, Идел яры буйлап урнашкан. Алмаларның 40% ын әнис, 23% ын «Хорошавка алая» тәшкил итә; калган сортлар: «Грушовка Московская», «Пудовщина», «Боровинка», «Гади антоновка», кытайка һәм ренетлар. Киң таралган груша сортлары: «Тонковетка», «Бессемянка» һәм аз санда «Бергамот осенний»; чия: «Владимирская», «Растунья», «Поздняя розовая»; слива: «Скороспелка красная», күгән-сливалар һәм сары слива. Тәмте әнисләрен баржага төяп Уралга җибәрә торган булалар. Күмәкләштерү елларында «Һәр колхозга үз бакчасы» дигән лозунг чыгарыла. Җимеш агачларының күп өлеше 1939–40 һәм 1941–42 елгы кышкы салкыннарда өши. Колхоз бакчаларын яңадан торгызу 1944 тән башлана. Махсус бригадалары булган яңа зур бакчалар барлыкка килә (Минзәлә р-нының «Дуслык» к-зы, Югары Ослан р-нының «Путь к коммунизму», «Идел» к-злары). Бер үк вакытта сәнәгать бакчаларын үсентеләр б-н тәэмин итә торган җиләк-җимеш питомниклары барлыкка килә. 1940 еллар ахырына Арча, Буа, Алабуга, Кайбыч, Масловка һәм Норлат җиләк-җимеш питомниклары яңадан торгызыла. 1953 тә Чистай, Октябрь, Шөгер, Бөгелмә, Куйбышев, Казан питомниклары җиләк-җимеш урман питомниклары итеп үзгәртелә. Питомникларны үстерүгә Х.Х.Хәсәнов, Л.А.Токарева, А.М.Сидорцов зур өлеш кертә. 1970 елларда җиләк-җимеш бакчаларының гомуми мәйданы 7 мең гектардан артып китә. «Заря», «Таң», «Масловка» с-зларында (Балык Бистәсе р-ны) 600 *га* мәйданлы җиләк-җимеш бакчалары, «Комсомольский», «Норлат», «Кама Тамагы», «Смена», «Арча», «Бакчачы», «Казан», «Түбән Кама» с-зларында 300–400 *га* лы бакчалар утыртыла. Аларда төп җитештерү процесслары механикалаштырыла, шуның нәтиҗәсендә Б.ның табышлылыгын, продуктлылыгын һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә мөмкин була. Җитештерүне оештыручылар һәм новаторлар: Х.Х.Хәсәнов, В.А.Наумов, П.Ф.Акулин, М.Ш.Вахитов, М.Н.Хәйруллов, Г.П.Васильева, М.Ш.Сәлимҗанов, М.М.Цимберов, А.В.Вәлиуллин, Г.Ш.Шакиров, В.П.Воскресенский, П.В.Боев, Е.Д.Боева. Сәнәгать бакчачылыгының, ш.у. күмәк Б.ның үсешенә 1929 да оештырылган Татарстан зона җиләк-җимеш станциясе ярдәм итә (хәзер Татарстан Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тының җимеш культуралары селекциясе бүлеге). Селекция белгечләре тарафыннан 8 алма сорты (Г.И.Розанова), 20 слива һәм чия сорты (А.М.Тверитинов, Л.А.Севастьянова, В.А.Наумов, Г.Е.Осипов), 3 җиләк культурасы сорты (Н.И.Вакуленко, А.А.Надысева) чыгарыла; Б.ның гамәли мәсьәләләре: су режимы һәм сугару, сөзәклекләрне террасалау юлы б-н бакча участокларын үзләштерү технологиясе, үсешенең башлангыч чорында гибрид чәчкеннәрнең салкынга чыдамлылыгы өйрәнелә; яшел чыбыкчалар утырту юлы б-н чия һәм слива үсентеләре алу технологиясе эшләнә һәм гамәлгә кертелә (Л.А.Севастьянова, М.Ш.Вахитов, П.В.Боев); Б.та гамәлгә кертү максатында җиләк-җимеш сортларының бик күп сортлары өйрәнелә. ТРда җиләк-җимеш үсемлекләренең гомуми мәйданы 23,9 мең *га*, тулай җыем 81,3 мең *т*, уңыш 1 *га* дан 51,6 *ц* (2005). Ш.у.к. *Бакчачылык ширкәте*.

*Әд.:* Передовой опыт садоводов Татарии. К., 1965; Проблемы развития садоводства и ягодоводства в Татарии К., 1981; Токарева Л., Севастьянова Л. Сады и питомники Татарии // Сам хозяин. 1996. № 7.

*В.А.Наумов.*

**БАКЧАЧЫЛЫ́К ШИРКӘТЕ́**, төрле оешма эшчеләренең күмәк бакчачылык эше алып бару максаты б-н иректе берләшүләре нигезендә төзелгән җәмәгать оешмасы. Б.ш.нең оештырылуы һәм эшчәнлеге уставка нигезләнеп гамәлгә ашырыла; аның нигезендә ширкәт әгъзаларының бурычлары һәм хокуклары билгеләнә. Устав күмәк бакчачылык өчен җир биләмәсе бүлеп биргән р-н (шәһәр) хакимиятендә теркәлә. Б.ш. юридик зат булып тора, Дәүләт банкында үзенең агымдагы счёты, мөһере һәм штампы була. Ширкәт эшләрен әгъзаларының гомуми җыелышы тарафыннан 2 елга сайлап куелган һәм башында рәис торган идарә алып бара. Б.ш.нең кереме бакчачыларның керү взносларыннан һәм махсус эшләр үткәрү максаты б-н җыелган акчалардан туплана.

2006 ның 1 гыйнварына ТРда 1531 Б.ш. исәпләнә, аларда җирдән файдаланучы 446129 кеше теркәлгән, гомуми җир мәйданы 28132 *га* (а.х. җирләренең 1% ы) тәшкил итә. 16969 *га* (гомуми мәйданның 60,3% ы) җир гражданнарның шәхси милеге булып тора.

11,2 мең *га* (39,7%) чамасы җир — дәүләт һәм муниципаль милек, ш.и. 4,4 мең *га* — мирас итеп тапшыру хокукы б-н гомерлеккә, 6,6 мең *га* — файдалануга һәм 0,1 мең *га* арендага бирелгән. Барлык җир участокларының 21,9% ы республика буйсынуындагы шәһәрләр, 78,1% ы шәһәр тирәсе һ.б. сәнәгый алга киткән шәһәрләр өлешенә туры килә. Бер җир участогының күләме уртача 0,06 *га* (6 сутый). ТРда Б.ш. исәбе Россиянең ТР буенча күчемсез милек идарәсе һәм аның территориаль бүлекләре тарафыннан алып барыла.

**БАКШАНДЫ́** авылы, Саба р-нында, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2002 елда 19 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 16 йөздә нигез салына. Авылның атамасы 17 йөздә яшәгән Казан өязе алпавыты кенәз Бакшанда исеменә бәйле булуы ихтимал. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, йон тетү, киез итек басу, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да мәчет, вак тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 392,4 дис. тәшкил итә. 1918 дә мәктәп ачыла. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш, 1922 дән Арча кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1859 да — 148, 1897 дә — 289, 1908 дә — 343, 1920 дә — 359, 1926 да — 290, 1938 дә — 256, 1970 тә — 155, 1979 да — 82, 1989 да — 44 кеше.

**БАКШИ́** (санскр. bhikshu — мөгаллим), 6–10 йөзләргә караган борынгы төрки һәм уйгыр язма истәлекләрендә теркәлгән атама. Соңрак «Б.» атамасын монголлар кулланышка кертә. Борынгы төркиләрдә «Б.» Будда дине руханиларына карата кулланылган. Монгол империясе дәверендә язу эшен башкаручы төркиләр дә (алар, башлыча, уйгырлардан булган) шулай аталган, документ-язмалар уйгыр алфавитында башкарылган. 14–17 йөз татар ханлыкларында Б. дип хан диваны сәркәтип-хатчылары аталган. Соңрак «Б.» атамасы шул ук мәгънәне аңлаткан гарәп сүзләре «хафиз», «кәтиб» б-н алыштырыла; «Б.» сүзе, беркадәр үзгәртелеп, төрле төрки халыклар телендә саклана: татарча — «багучы», казакъча «баксы» — күрәзәче, сихерче; төрекмәнчә «бахшы» — халык арасында танылган җырчы, тувалыларда «башкы» — мөгаллим.

*М.Г.Госманов.*

**БАКЫ́ЕВ** Әхмәт Вахит улы (15.1.1939, Башкортстан АССРның Кырмыскалы р-ны Чишмә а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1985), Башкортстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), БАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1989). 1960 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: декан (1969–74), проректор (1974–89), 1989–2000 дә нефть аппаратларын төзү технологиясе каф. мөдире. Бер үк вакытта Башкортстан Респ-касы ФАнең физ.-матем. һәм техник фәннәр бүлеге академик секретаре (1991–95), 1996 дан геол., физ.-матем. һәм техник фәннәр секциясе рәисе урынбасары, 2000 нән җир һәм табигый ресурслар бүлегенең академик секретаре. Хезмәтләре бериш булмаган әйләнмә сүрүләрнең рәвеше үзгәрү һәм җимерелү механикасына, эретеп ябыштыру процесслары теориясенә карый. Уйлап табуга караган 9 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Б.ның тикшеренү нәтиҗәләре аппаратлар төзүдәге рәвеш үзгәртү һәм эретеп ябыштыру операцияләрен үзара алыштыруга кагылышлы күп кенә гамәли мәсьәләләрне чишү мөмкинлеге бирә. Аппаратларның төп детальләрен җитештергәндә аларны тулысынча үзара алыштыруның Б. тарафыннан эшләнгән принципларына нигезләнгән җитештерү технологиясе сәнәгатьтә хром-молибденлы корычларны эретеп ябыштырганда кулланыла.

Х е з м.: Газонефтяное оборудование оболочкового типа. Уфа, 1987; Взаимозаменяемость в аппаратостроении. Уфа, 1990; Технологическое обеспечение точности изготовления днищ нефтехимической аппаратуры. М., 1991 (автордаш); Технология аппаратостроения. Уфа, 1995.

**БАКЫ́ЕВ** Рузалин Зәкуан улы (26.9.1955, Баулы р-ны Яссы-Тугай а.), спортчы (чаңгыда узышу), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1979). Казан пед. ин-тының физ. тәрбия ф-тын тәмамлый (1981). «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә. СССР (1981, 4×10 *км* лы эстафетада), Тугандаш армияләрнең 8 нче спартакиадасы чемпионы (1983, 4×10 *км* лы эстафетада; 15 *км* га узышуда бронза медаль), Дөнья кубогының 2 этабында (1981–82, 30 *км* га узышуда) җиңүче, СССР чемпионатларының 4×10 *км* лы эстафетасында медальләр ала (1983 — бронза, 1984 — көмеш), СССР халыклары спартакиадасында (1982, 50 *км* га узышуда) көмеш медаль ала, СССР Профсоюзлары спартакиадасында (1979–80, 15 һәм 30 *км* га узышуда) 4 тапкыр чемпион була, дөнья чемпионатында катнаша (1978, 13 нче урын). 1987–90 елларда Профсоюзларның Бөтенсоюз ирекле физкультура-спорт җәмгыятендә (Казан), 1990–92 дә — Мәскәү хәрби округы спорт клубында, 1997 дән — «Трудовые резервы» физкультура-спорт комплексында (Мәскәү) тренер. Медаль б-н бүләкләнә.

**БАКЫ́ЕВА** Мөхлисә Мәкәрим кызы (15.9.1931, Башкортстан АССРның Бүздәк р-ны Ярмунча а.), педагог, пед. фән. канд. (1964), проф. (1990), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1976). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Казанның 80 нче урта мәктәбендә, 1964 елдан Казан пед. ин-тының (хәзерге *Татар гуманитар-педагогика университеты*) милли мәктәпләрдә рус теле укыту кафедрасында эшли. Татар мәктәпләрендә рус теле укыту методикасы буенча хезмәтләр һәм укыту ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: О проблемном преподавании русского языка в татарской школе. К., 1978; Внеклассная работа по русскому языку в татарской школе. К., 1982; Преподавание русского языка в нерусских общеобразовательных учреждениях. К., 2000.

**БАКЫ́ЕВА** Надия Зариф кызы (2.4.1912, Сембер ш. — 8.12.1999, Мәскәү), педагог, пед. фән. д-ры (1969), проф. (1970). Горький пед. ин-тын тәмамлый (1935). 1938 елдан СССР Мәгариф министрлыгының Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тында, 1970–87 елларда СССР ПФАнең Милли мәктәпләрдә рус теле укыту фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). Хезмәтләре милли мәктәпләрдә рус теле укыту методикасының теоретик, лингвистик, психол.-пед. нигезләренә, ана теле һәм рус теле укытуның үзара бәйләнеш мәсьәләләренә карый. Мәктәп программаларын эшләүдә, татар мәктәпләрендә укучылар өчен рус сүзләренең тиешле минимумы сүзлекләрен төзүдә катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Изучение русского имени существительного в татарской школе. М., 1960; Методика обучения морфологии русского языка в татарской школе. К., 1961; Научные основы методики обучения грамматическому строю русского языка в национальной школе. М., 1983; Русский язык: Учеб. для 6–7 кл. нац. школ РСФСР. Л., 1989.

**БАКЫ́ЕВА** Рауза Гата кызы (30.9.1907, Акмола ш., хәзер Казакъстан Респ-касының Астана ш. — 25.3.1998, Казан), акушер-гинеколог, мед.фән. д-ры (1961), проф. (1962), ТАССРның атказ. табибәсе (1963). 1932 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, Татарстан мед. оешмаларында эшли. 1941–44 тә Казан госпитальләрендә хирург. 1944 елдан Омск мед. ин-тында укыта, бер үк вакытта Омск шәһәренең баш акушер-гинекологы. 1960–72 дә Казан мед. ин-тының 1 нче акушерлык һәм гинекология каф. мөдире һәм 1962–64 тә дәвалау ф-ты деканы. Фәнни тикшеренүләре бала тудыруны җиңеләйтүгә, токсикоздан интегүче йөкле хатыннарда бала тудырганда кан китүне туктатуга карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Функциональное состояние сосудистой системы при позднем токсикозе беременности. К., 1959; Влияние перенощенной беременности на течение родов и на плод: Материалы юбилейной науч. конф., посвящённой 150-летию со дня основания института (11–13 ноября 1964 г.) // Науч. труды Казан. гос. ордена Трудового Красного Знамени мед. ин-та. 1964. Т. 14.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997; З е ф и р о в А.М., А л ь б и ц к и й В.Ю. Деканы Казанского медицинского университета. К., 1997.

**БАКЫ́ЕВА** Роза Фәрит кызы (11.7.1950, Дүшәмбе ш.), химик, химия фән. д-ры (1998), проф (1999). Казан ун-тын (1972) тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1995 елдан Казан Технол. ун-тында, аналитик химия каф. проф. (1999 дан). Фосфор эфирларының аминнар катнашындагы реакцияләре кинетикасын һәм механизмын, молекула ассоциатларының фосфор кислоталары эфирларын нуклеофиль алмаштыру реакцияләренә тәэсирен тикшерә. Лиотроп сыек кристаллик тирәлекләрне югары эффектив каталитик һәм ингибирлый (тоткарлый) торган системалар җи-

тештерү өчен файдалану мөмкинлеген күрсәтә.

Х е з м.: Кинетика щелочного гидролиза эфиров кислот фосфора в мицеллярной и гексагональной фазах системы цетилдиметилэтиламмоний бромид NaOH/вода // Изв. РАН. Сер. хим. 1998. Т. 48, № 8 (автордаш.); Мицеллярные и жидкокристаллические структуры в реакциях нуклеофильного замещения эфиров кислот тетракоординированного фосфора // Рос. хим. журн. 1999. Т. 42, № 3/4 (автордаш.); Катализ разложения О- (пара-нитро-фенил)-О, О-диметил-тиофосфата с хроманическими мезофазами на основе полимеризованных ионных амфифилов // Кинетика и катализ. 2006. Т. 47, № 1 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БАКЫ́Й ДӨНЬЯ́**, к. *Ахирәт.*

**БАКЫ́Й УРМАНЧЕ́ МУЗЕЕ́**, к. *Урманче Б. музее.*

**БАКЫ́Р ЕЛА́Н** (Coronella austriaca), тузбашсыманнар семьялыгыннан елан. Европада, Көнбатыш Азиядә таралган. ТРда барлык районнарда да очрый, һәркайда диярлек аз санлы. Яфраклы һәм нарат урманнарында яши, күбрәк урман буенда, киселгән урыннарда, агачлы аланнарда очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 60–70 *см*, аркасы саргылт-көрән яки соры көрән төстә, кара тимгелле 2–4 буй-буй рәте бар. Башы буйлап борын тишегенә кадәр күз аша тар кара сызык үтә. Бәбәге түгәрәк (төсе б-н Б.е. ны хәтерләтүче гади кара еланныкы тар, вертикаль). Б.е. көндез актив, кояш яхшы яктырта һәм җылыта торган урыннарны кулай күрә, ә төнлә кимерүчеләр һәм кәлтәләрнең ташландык өннәренә, таш асларына, агач тамырлары арасындагы бушлыкларга, черегән агач төпләренә кача. Октябрь-ноябрьдә йокыга тала, март-апрельдә уяна. Июль-августта ана зат 12–17 *см* озынлыктагы 9–10 бала тудыра. Күбрәк кәлтәләр, кыр, урман һәм җир тычканнары б-н туклана. Табышны таза мускуллы гәүдәсе б-н уралып буа, ә аннан соң йота. 20 елга кадәр яши. Кешене күргәч, гадәттә тыгыз йомгак булып йомарлана, башын шуның эченә яшерә. Б.е. чаккан урын кеше өчен бөтенләй зарарсыз. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БАКЫ́Р КӘЛТӘЛӘ́Р** (Anguis), җизбаш кәлтәләр семьялыгыннан кәлтәләр ыругы. Бер генә төре бар — бакыр кәлтә (җизбаш) (A. fragilis). Европада һәм Көнбатыш Азиядә киң таралган. ТР терр-ясендә киң яфраклы һәм катнаш урманнарда, урман читендә, кисентеләрдә яши. Орчыксыман гәүдәле, 26 *см* га кадәр озынлыкта. Аркасы металлга хас ялтыравыклы коңгырт-көрән төстә, ата кәлтәләрнең аркасында күк һәм карасу төстәге таплары бар. Б.к. еланнан хәрәкәтчел күз кабаклары булуы б-н, ә башка кәлтәләрдән аяксыз булулары б-н аерылалар. Елан кебек боргаланып, акрын шуыша. Күп кенә башка кәлтәләр кебек, эзәрлекләүдән куркып, койрыгын өзеп калдыра. Яңгыр суалчаннары, лайлачлар, күбәләк кортлары б-н туена. Тереләй тудыручылар. Июль ахырында — август башында 90–105 *мм* озынлыктагы 7–12 яшь кәлтә туа. Август аеннан кышлый торган урыннарына шуыша башлыйлар. Берничә дистәләп бергә, имезүчеләрнең өннәрендә, черегән агач төпләрендә кышлыйлар. Б.к. не кайвакыт ялгыш агулы елан б-н бутыйлар. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БАКЫ́Р КОЮ́ ЗАВОДЛАРЫ́**, Идел-Урал буйларында 18 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килгән сәнәгать тармагы. Россия хөкүмәте карары б-н Урта Идел буе һәм Урал төбәге җирле халыкларына металл эшкәртү һәм металлдан ясалган товарлар б-н эш йөртү тыелганлыктан (к. *Тыелган товарлар*), татарлар баштарак бу тармак эшчәнлегендә катнашмаган. Төбәктәге Б.к.з. руслар һәм ышанычлы саналган башка милләт эшмәкәрләре кулында булган: Казан сәүдәгәре А.И.Кобелевның 1763 елда ачкан Пыжман з-ды (Вятка губ., Малмыж өязе Кукмара а., 1766 елда иң югары нәтиҗәгә ирешә — 1704 пот бакыр коя); Тула губернасы сәүдәгәре Иноземцевнең 1751 дә Иштирәк авылында ачкан з-ды (Уфа губ., Минзәлә өязе Иштирәк-Ольгино а.; 18 йөз ахырында аңа меңгә якын крәстиян беркетелгән була. 1865 тә спирт-аракы куу з-ды итеп үзгәртелә); Казан сәүдәгәре И.И.Небогатовның 1734 тә ачылган Шилнә з-ды (Уфа губ., Минзәлә өязе Боровецкий а. янәшәсендәге Шилнә суы буенда; елына 1600 пот бакыр койган); алпавыт К.М.Тәфкилевнең 1760 та ачылган Баржы-Алексеев з-ды (хәзерге Әгерҗе р-ны Баржы суы буенда урнашкан; 1784 тә 841 пот бакыр койган). Бакыр кушылмалы мәгъдән җирле рудниклардан китерелгән. Иноземцевнең Б.к.з. 1775–79 еллар аралыгында 50 мең поттан артыграк бакыр койган. Урта Идел б-н Кама аралыгында урнашкан. Чыганакларга якынрак урнашкан Урал з-длары б-н икътисади ярышта оттыру сәбәпле, Б.к.з. 19 йөзнең 1 нче яртысында эшләүдән туктый.

*Әд.:* З а л к и н д Г.М. История обоснования медеплавильных заводов Татарстана // Тр. об-ва изучения Татарстана. К., 1930. Т. 1; Л ю б о м и р о в П.Г. Очерки по истории русской промышленности. М., 1947.

*И.А.Гыйләҗев.*

**«БАКЫ́Р ӨЧЕ́Н КӨРӘ́Ш»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Красноуральск шәһәр ком-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының шәһәр советы һәм район профсоюзлар советы органы. 1932–34 елларда Свердловск өлкәсенең Красноуральск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

**БАКЫ́Р РУДАЛАРЫ́**, технологик һәм икътисади яктан максатка ярашлы бакыр алу өчен составында бакыр булган минераллар җыелмасы. 170 тән артык минерал билгеле, аларның якынча 17 се бакыр алу өчен кулланыла: сульфидлар һәм сульфотозлар — халькопирит, ковелин һ.б., төсен югалткан рудалар һәм карбонатлар, малахит, азурит. Б.р.ның минераль чимал базасы нигезен бакыр-порфирлы, бакыр-кольчеданлы, бакырлы комлыклар һәм сланецлар; молибден — бакыр-порфирлы, бакыр — цинк-колчеданлы геол.-сәнәгый чыганак типлары тәшкил итә. Б.р., гадәттә, комплекслы, аларда, бакырдан тыш, Fe, Zn, Au, Ag, Pt һ.б. бар. Бакырның бөтендөнья запасы (БДБ дан тыш) 300 млн *т* дан артыграк, ел саен 10 млн. *т* чамасы чыгарыла. Иң күп запаслар — АКШта, Канада, Польша һ.б. илләрдә. Россиядә дистәләрчә чыганак ачыкланган: Уралда, Таймыр һ.б. урыннарда. Татарстан терр-ясендә Б.р. борынгы вакытлардан билгеле «Чудово базлары» дип аталганында 17–18 йөзләрдә 18 бакыр кою заводы урнашкан була. 18 йөздә коелган «чиста» бакырның гомуми күләме 6,4 мең *т* тәшкил итә (елына 192 мең *т* руда чыгарылганда). 20 йөз ахырына Вятка-Кама бакыр-руда полосалары дип аталган чикләрдә (Вятка елгасының уңъяк яры, Көнчыгыш Кама аръягы), югары Пермь утырмаларында составында Cu, Au, Ag, Pt, Pd булган (затлы металл — бакырлы геол.-сәнәгый тип) 25 кечкенә һәм 15 зур ятма ачыклана. Фаразланган ресурслар: Cu — 1,6 млн. *т*, Ag — 3,0 мең *т*, Pt — 40 *т*, Pd һәм Au — 60 шар *т*. Руда яту тирәнлеге — 40–120 *м*. Чыгару ысулы — җир астыннан һәм өстеннән селте б-н эретү. Бакыр сәнәгатьнең электротехника, авиация, күн, мех һ.б. тармакларында кулланыла.

*Әд.:* М и р о п о л ь с к и й Л.М. Медные руды в пермских отложениях ТАССР и их генезис // Уч. зап. Казан ун-та. 1938. Т. 38, кн. 1, вып. 10; Ч а й к и н В.Г., Г л е б а ш е в С.Г. и др. Металлические полезные ископаемые // Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*В.Г.Чайкин.*

**«БАКЫРГА́Н КИТАБЫ́»**, урта гасырлар төрки-татар поэзиясе антологиясе. Якынча 18 йөз ахыры — 19 йөз башында Урта Идел төбәгендә төзелгән. 20 авторның 144 шигъри әсәре тупланган. Авторлар арасында Әхмәд *Ясәви, Колшәриф, Касыйм Шәех,* Кол Гобәйди (Гобәйдулла), Тагый, Фәкыйри, Гарибы, Шәмседдин (Шәмси Гасый) һ.б. бар. Әмма шигырьләрнең күпчелеге Сөләйман *Бакырганинеке* булу сәбәпле, җыентык тора-бара «Б.к.» исеме б-н йөртелә башлый. Китапка кергән шигырьләрнең гади телдә язылуы, муз. аһәңле булуы б-н «Б.к.» халык арасында киң таралган, аны заманында «Кол Сөләйман көе»нә көйләп укый торган булганнар. «Б.к.» күп кенә татар шагыйрьләре иҗатына (Аллаһияр Суфи, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Г.Тукай һ.б.) теге яки бу дәрәҗәдә уңай йогынты ясаган. «Б.к.», басма буларак, беренче мәртәбә 1846 елда дөнья күрә, шуннан соң аның дистәдән артык яңа басмасы чыкканы мәгълүм.

Чыг.: Бакырган китабы. К., 1846; Бакырган китабы: XII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БАКЫРГАНИ́** Сөләйман (Кол Сөләйман, Хәким Ата) (вафаты 1186 елда), суфи шагыйрь. Урта Азиядә яшәгән һәм төрки телдә иҗат иткән. Биографиясенә кагылышлы төгәл мәгълүматлар аз сакланган, булганнарының күбесе риваять рәвешендә. Псевдонимына нигезләнеп, Харәзем дәүләтендәге Бакырган кышлагында туган, Яссы шәһәрендә (хәзерге Казакъстан Респ-касындагы Төркестан ш.) Ә. *Ясәви*дә укыган дип фаразлана, аның вафатыннан соң гомере буе остазы хөҗрәсен саклаучы булып яши. Мәккәгә хаҗ сәфәре кылганлыгы билгеле.

«*Бакырган китабы*» антологиясендәге бик күп шигырьләр, ш.у. «Китаб Хәким ата» («Хәким ата китабы»), «*Ахырзаман китабы*»,

«Хәзрәти Мәрьям китабы» (1887) исемле риваять характерындагы чәчмә әсәрләр авторы. Б. иҗатының тел һәм жанр үзенчәлекләре төрки әдәбиятлардагы халыкчан поэтик традицияләргә якын тора. Шигырьләре хисси-экспрессив тәэсир көченә ия. Б. иҗатының татар шигърияте йогынтысы урта гасырлар болгар-татар әдипләрендә дә (Кол Гали, Мәүла Колый һ.б.), яңа заман шагыйрьләрендә дә, ш.и. Тукай иҗатында нык сизелә. Төрек галиме Фуад Күпрелезадә фикеренчә, Б. шигырьләре Идел буе татарлары арасында гына киң таралган була; мәдрәсәләрдә дәреслек сыйфатында кулланыла.


*Әд.:* Күпрелезадә Ф. Төрек әдәбиятында элек мөтәссәвефләр. Истанбул, 1919; Яхин Ф. Бакырган китабы // Әдәбият чыганакларын барлаганда. К., 1994.

*М.В.Гайнетдинов.*




1. Кувшин. Җиз, чүкеп бизәкләү, гравирлау, кою. 16 йөз уртасы. ТР Милли музее;
2. Кувшин. Җиз, чүкеп бизәкләү. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее;
3. Комган. Бакыр, чүкеп бизәкләү. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Милли музее.

**БАКЫРЧЫ́**, бакырдан һәм аның эретмәләреннән бизәкле әйберләр ясау остасы: чүкеп бизәк төшерү, уемлау, төсле таш беркетү һ.б. ысуллар б-н бакыр эшләнмәләрне бизәүче рәссам. Татарлар арасында Б. һөнәренең тарихи тамырлары борынгы төрки, ш.и. болгар металл эшкәртү осталарының иҗатына нигезләнә. Бакырдан бизәкле әйберләр ясау нәфис һөнәрләр төренә керә. 18 йөз — 20 йөз башында Б. остаханәләре татар авылларының һәм Россия шәһәрләрендәге татар бистәләренең һәрберсендә диярлек була. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Б.лар арасында читкә чыгып эшләү гадәткә керә, алар ясаган әйберләр руслар, чуаш, башкорт, Идел һәм Урал буйларында яшәгән башка халыклар арасында тарала. Б.лар комган, ләгән, савыт-саба, металл б-н тышланган сандык кебек көнкүреш әйберләре, ә 19 йөз ахырыннан — чәйнек, самавырлар ясыйлар. Алар арасында беләзек, балдак, йөзек, төймә, каптырмалар, хушбуй савытлары кебек ир-ат һәм хатын-кыз бизәнү әйберләре ясаучылар да була. Чүкеп бизәкләнгән җәенке формадагы бакыр *комганнар*, ш.у. аларның Казан Б.ларына дан китергән бакырдан һәм җиздән ясалганнары киң тарала. Урта гасырларда эшләнгән комганнарның гаҗәеп үрнәкләре һәм ш.у. Казан ханлыгы чорына караган су көшы кыяфәтендәге чүкеп бизәкләнгән җиз савыт сакланган. Савытның кырыена 15 йөз ахыры — 16 йөз башында яшәгән останың исеме язылган: «Әмин хан бакырчысы Насыйр».



Комган һәм ләгән. Бакыр, чүкеп бизәкләү. 18 йөз ахыры. ТР Милли музее.

20 йөзнең 2 нче яртысында Казан арты авылларында һәм Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәкләрендә бер үк вакытта тимерчелек б-н шөгыльләнүче Б.лар була. Алар авыллардагы тимерчелекләрдә, төрле хуҗалык кирәк-яраклары ясау өчен кызган тимер



Кувшин. Фрагмент.

эшкәртү б-н беррәттән, тузган бакыр әйберләрне яңарталар, гади формалы комганнар ясыйлар (Балтач р-ны Салавыч Сәрдегәне авылында Шәйхетдин оста, Әлмәт р-ны Түбән Абдул авылында Илалетдин Фәрхетдинов, Габдулла Зөфәров, Яңа Нәдер авылында Фоат Хәйруллин һ.б.). Бүгенге көндә Б.ларның һөнәрләре хәзер дә рәссамнарыбыз иҗатында дәвам итә, күбрәк интерьер бизәү әсәрләрен иҗат иткәндә (И.Башмаков, Я.Зиннәтуллин, И.Киселёв, М.Мостафин, А.Сысоев, М.Шәйдуллин), ш.у. көнкүреш әйберләре ясауда (М.Зерзизов, З.Хөсәенов), бакырны уеп бизәкләү, басма, чүкү һәм кою эшендә кулланыла.

*Әд.:* Хәйри Ә. Җиз савытка язылган борынгы язу // Мирас. 1994. № 11–12; Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Художественная керамика и обработка металла // Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990; шул ук. Декоративное искусство Татарстана. К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БАКЫРЧЫ́** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 26 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2002 елда 584 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Бакырчы, Олы Бакырчы исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да мәчет, мәдрәсә, 2 су, 2 ярма ярдыру тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1883,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Тояба волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Апас, 1935 нең 10 февраленнән — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 178 ир заты; 1859 да — 979, 1897 дә — 1701, 1908 дә — 2329, 1920 дә — 1802, 1926 да — 1699, 1938 дә — 1400, 1949 да — 1123, 1958 дә — 1132, 1970 тә — 1191, 1979 да — 1039, 1989 да — 715 кеше.

Б. — Татарстанның халык шагыйре Ш.Г.*Галиевнең* туган авылы.

**БАКЫРЧЫ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 42 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бидәңге елгасы буенда. 2002 елда 376 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Иркәй исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманнар була, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет була. 20 йөз башында монда 3 мәчет, 3 мәдрәсә, 6 сәүдә-сәнәгать бинасы исәпләнә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1152,1 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Сөендек волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Буа кантонында; 1930 елның 10 августыннан — Буа, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш

р-нында. Халык саны: 1859 да — 931, 1910 да — 1368, 1926 да — 1392, 1949 да — 1133, 1958 дә — 765, 1970 тә — 658, 1979 да — 498, 1989 да — 386 кеше.

**БАКЫРЧЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 46 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Республикасы чигендә. 2002 елда 416 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Китапханә. Клуб. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да 2 мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1573,8 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Цивиль өязе Яңа Кавал волостена керә. 1920–21 дә — Чуаш автономияле өлкәсе составында, 1921 елның 22 сентябреннән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 157 ир заты; 1859 да — 1094, 1897 дә — 1330, 1926 да — 762, 1938 дә — 576, 1949 да — 780, 1958 дә — 694, 1970 тә — 630, 1979 да — 576, 1989 да — 440 кеше.

**БАЛ КОРТЫ́** (Apis millifera L.), элпәканатлылар отрядының умарта кортлары өссемьялыгыннан бөҗәк. Ояларда гаилә булып яши, нектар (балга әверелдерелә) һәм үсемлекләр серкәсен җыя. Б.к. ның биол. яше 150 млн. ел чамасы. Балавыз, бал һәм *умартачылыкның* башка продуктлары өчен кеше тарафыннан йортлаштырылган һәм үрчетелә (6 мең ел чамасы). Татарстанда Б.к.ның урта рус урман (кара төстәге) токымы (A.m. mellifera) (татар популяциясе) хуҗалыкта аеруча әһәмиятле санала. Кайвакыт агач куышларында, кыя ярыкларында оялаган кыргыйлашкан гаиләләрдән тыш хәзер табигатьтә яшәми. Күп очракта гаиләдә ырыгны дәвам итүче бер ана корт (җенси органнары үскән ана корт), 50–70 меңгә якын (кайвакыт күбрәк тә) эшче корт (җенси яктан җитлекмәгән, гаиләдә бөтен «эшне» башкаручылар) һәм берничә йөз ата корт (соры кортлар) була. Әлеге затларның 3 формасы да бер-берсеннән морфологик билгеләре буенча да, үзләренең функцияләре б-н дә аерыла. Ана корт эшче һәм ата кортларга караганда зуррак, гәүдәсенең озынлыгы 20–25 *мм*, авырлыгы 280 *мг* чамасы. Ана кортның гаиләдәге функциясе йомырка салудан гына гыйбарәт, шуңа күрә аның балавыз бизләре үсмәгән, аякларында серкә җыю өчен җайланмалары юк, угының төзелеше дә бераз башкачарак. Эшче кортларның гәүдә озынлыгы 12–14 *мм*, авырлыгы 100 *мг*. Аларның органнары яшь кортларны тәрбияләү, гаиләне саклау, күзәнәкләр төзү б-н бәйле төрле функцияләрне башкару өчен җайлашкан. Умарта кортлары өске казналыклары ярдәмендә күзәнәкләрне чистарталар, кәрәзләр ясыйлар, умарталарны чистарталар һ.б.ш. Арткы аякларында хортумчык һәм серкә җыю өчен аппаратлары бар, аларның саклагыч функцияне башкаручы уклары (үзгәргән йомырка салгыч) ана кортныкына караганда ныграк үскән; укның алга юнәлгән тешчеге бар, шуңа күрә чакканда ул ярада кала, һәм корт үлә. Соры кортлар җәй көне генә яши. Гәүдә озынлыклары 15–17 *мм*, авырлыгы 250 *мг* чамасы. Алар аталандыру өчен хезмәт итә, шуңа бәйле рәвештә ана кортны эзләп табу өчен күп кенә җайланмалары бар: ис сизү органнары, канатлары нык үскән, күзләре зур. Җәй ахырында, парлашканнан соң, эшче кортлар ата кортларны куып чыгара, һәм алар үлеп бетә. Ана корт һәм эшче кортлар кышлыйлар; актив халәттә булу сәбәпле, алар ояда исән калырлык температураны саклыйлар. Ояда алты кырлы күзәнәкләрдән ясалган кәрәзләр вертикаль урнаша, аларда токым үрчи һәм азык запасы саклана. Кәрәзләр балавыздан ясала, алар эшче кортларның корсагында урнашкан махсус бизләрдән бүленеп чыга. Эшче кортлар личинкаларны бал катнашмасы һәм эшкәртелгән серкә б-н туендыралар. Ана кортның гомер озынлыгы 4–5 ел (хуҗалыкта файдалану 2 ел), эшче кортларныкы 35–40 тәүлек (кышлаучыларныкы 200 тәүлеккә кадәр). Һәр гаилә сезонга 150–300 *кг* га кадәр бал әзерли.

Б.к. күп кенә кыргый үсемлекләрдән һәм а.-х. культураларыннан нектар һәм серкә җыю барышында аларны серкәләндерүдә беренчел рольне үти.

*Е.А.Сапаев, А.А.Гамзов.*

**БАЛ КОРТЫ́ БЕТЕ́** (Braula coeca), браулидлар семьялыгындагы чебен. Гәүдәсе ялтыравыклы, кызгылт-көрән төстә, озынлыгы 1,4–1,5 *мм*, мыекчыклары саргылт төстә, кара төкләр б-н капланган, кырыйда күзләре һәм канатлары юк. Киң таралган. Бал кортында (еш кына ана корт һәм эшче кортларда) паразитлык итә, эшче кортларның ана кортны һәм нәселне туендырыр өчен җыйган азыклары б-н туклана. Бер умартада 75 ләп чебен булырга мөмкин. Йомыркасын кәрәз капкачларына сала; личинкасы балавыз һәм андагы серкә б-н туена.

**БАЛА́ ТУУГА́ БӘЙЛЕ́ ЙОЛАЛА́Р**. Элек әлеге йолаларда бөтен эшне баланы кабул итеп алучы өлкән яшьтәге кендек әбиләре башкарган; бала туган гаиләдә аларга аерым кадер-хөрмәт күрсәтелгән. Кендек әбисе сабыйның кендеген кискән, аны юындырган, әтисенең күлмәгенә төргән (әтисе яратсын өчен). Әстерхан татарларында баланы әбисенең күлмәк итәге белән ураганнар (аның яшенә җитсен өчен), сәламәт, кайгы-хәсрәтсез үсүен теләп дога укыганнар, авызын бал-май белән майлаганнар («авызландыру» йоласы). Кендек әбисе, баланың беренче чүпрәкләрен юып, чарлактагы яисә идән астындагы туфракка күмгән; ш.у. җен-пәриләрне куркыту өчен бала янына кадак куйган. Кендек әбисе баланы кендегe төшкәнчегә кадәр карау өчен еш кына шул йортта калган. Җиде көн узгач, төшкән кендекне киптереп, чиста чүпрәккә төреп, сакларга куйганнар. Баланың беренче күлмәге («көчек күлмәге») кадерләп сакланган. Гадәт буенча, берничә көн рәттән бәби мунчасы ягылган. Ходай шифалы иткән мунчада ана б-н бала гына түгел, аларның туганнары, күршеләре дә юынган; мунчадан соң тәм-томнар б-н чәй табыны әзерләнгән, бала тапкан хатынның хәлен белергә килүчеләрнең бәби ашлары да шул табынга куелган. Бала табучының әнисе иң абруйлы кунак булып саналган. Ул онысына бәби юрганы, бәби мендәре, табынга кую өчен йола буенча майда кыздырылган баллы камыр ризыгы — «әлбә» алып килгән. Хатын-кызлардан гына торган мәҗлес (бәби ашы, мае, туе), гадәттә, балага исем кушканнан соң уздырылган. Исем кушу йоласына мулла һәм иң якын ир кардәшләр генә чакырылган. Сабыйны, мендәргә салып, мулла каршына китерәләр. Мулла, Коръәннән тиешле доганы укып, өч тапкыр баланың исемен, әтисенең исемен игълан итә һәм метрика кенәгәсенә терки. Аннары кунакларга сый китерелә. Ир бала көтелгән бала булып саналган, чөнки ул — киләчәктә нәселне дәвам иттерүче, гаиләне туендыручы. Малайлар, мөселман гадәте буенча, 7 көннән алып 20 яшькә җиткәнче сөннәткә утыртыла (к. *Сөннәт*). Керәшен татарларда исем кушу христиан дине йоласы буенча уза — бала чукындырыла. Яңа туган баланың беренче 40 көне тормышының иң хәвефле көннәре дип санала. Бу вакыт арасында аны «күз тиюдән» саклыйлар — чит-ятларга күрсәтмиләр, төрле бозыклыктан саклау өчен бишек өстенә миләш, артыш, шомырт ботакчыгы бәйләп куялар. Бала табуга бәйле йолаларның кайберләре хәзергәчә сакланып килә.

*Әд.:* Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; Уразманова Р.К. Семейные обычаи и обряды // Татары. М., 2001. *Ф.Ф.Гулова.*

**БАЛА́КИН** Александр Борисович (8.8.1957, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (2000). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан хим.-технол ин-тында эшли. 1987 елдан Казан ун-тында, чагыштырмалылык теориясе һәм гравитация каф. мөдире (2000–2003). Бер үк вакытта 1994 тән «Дулкын» гравитация-дулкын фәнни-тикшеренү үзәге директоры урынбасары. Хезмәтләре гравитация нурланышы кырындагы иерархияле системаларның релятивистик эволюциясенә карый. Бик тотрыксыз гравитация кырларында релятив кинетик, гидродинамик, электродинамик һәм эластодинамик системаларның эволюция модельләре төркемен тикшерә. Түбән ешлыклы периодик гравитация нурланышын ике контурлы лазер интерферометрлары ярдәмендә детекторлау теориясен төзи.

Хезм.: Лазерно-интерферометрический детектор гравитационного излучения на базе активных рециркуляров. К., 1991 (автордаш); Grawitational radiation and birefringence induced by curvature // Classical and Quantum Gravity. 1977. V. 14, № 10; Inflation in a selfinteracting gas universe // Phyisical Review. D. 1998. V. 58 (автордаш); Cosmological thermodynamics and deflationary gas univese // Physical Review. D. 2001. V. 63. (автордаш); Singular behaviour of electric and magnetic fields // Classical and Quantum Gravity. 2001. V. 18 (автордаш).

**БАЛА́КИРЕВ** Милий Алексеевич (21.12.1836, Түбән Новгород ш. — 16.5.1910, С.-Петербург), композитор, пианист, дирижёр, җәмәгать эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. 1853–55 елларда Казан ун-тының ма-

тем. ф-тында ирекле тыңлаучы. Казанда яшәгәндә музыка дәресләре бирә, аристократлар салоннарында пианист буларак чыгышлар ясый, беренче әсәрләрен яза (Фортепиано, кыллы квартет өчен зур соната, романслар). 1856 да С.-Петербургта, пианист һәм дирижёр буларак, концерт эшчәнлеген башлый. 1860 еллар башында композиторларның тарихта «Көчле төркем» («Могучая кучка»), исеме б-н мәгълүм иҗат берләшмәсен җитәкли (Б.тан башка анда ш.у. А.П.Бородин, Ц.А.Кюи, М.П.Мусоргский, Н.А.Римский-Корсаков керә). 1862 дә Б. хор дирижёры Г.Я.Ломакин б-н бергә С.-Петербургта түләүсез музыка мәктәбе оештыра һәм 1868–73, 1881–1908 елларда аның б-н җитәкчелек итә. 1867–69 да — Рус император музыка җәмгыятенең баш дирижёры, 1883–94 тә Сарай җыр капелласы җитәкчесе. Төп әсәрләре: 2 симфония (1898, 1908), 3 рус халык җыры темасына увертюра (1858), «Тамара» симф. поэмасы (1882), фортепиано өчен «Исламей» Шәрекъ фантазиясе (1869) һ.б.

*Әд.:* Б о б о р ы к и н П.Д. В путь-дорогу. СПб., 1864; М.А.Балакирев: Исследования и статьи. Л., 1961; Балакирев М.А.: Воспоминания и письма. Л., 1962; М.А.Балакирев: Летопись жизни и творчества. Л., 1967.

**БАЛА́КИРЕВ** Николай Александрович (1947, Куйбышев, хәзерге Спас р-ны, Кызыл Таулар а.), җәнлек асрау белгече, а.х. фән. д-ры (1992), проф. (1995), Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе мөхбир әгъзасы (2001). Казан вет. ин-тын тәмамлагач (1975), шунда ук эшли (1987 елга кадәр). 1988 елдан РФ Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кыйммәтле мехлы җәнлекләр һәм куяннар үрчетү фәнни-тикшеренү ин-ты директоры (Мәскәү өлкәсенең Раменский р-ны Родники пос.). Хезмәтләре яңа технологияләр булдыру һәм камилләштерүгә, читлектә кыйммәтле мехлы җәнлекләр һәм куяннар үрчетүдә гадәти булмаган азык-төлек һәм биол. актив өстәмәләр куллануга карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кормление норок. М., 1997; Разведение песца. М., 1999; Нетрадиционные корма и биологически активные вещества в рационах пушных зверей и кроликов. Киров, 2000; Основы норководства. М., 2001; Разведение пушных зверей. М., 2001.

*Әд.:* А в е р ь я н о в М.Г. Край Раменский. Век XX. М., 1998.

**БАЛАКО́ВО РАЙОНЫ́**, *Саратов өлкәсендә*. Мәйданы — 3,1 мең *км*². Үзәге — Балаково шәһәре (Саратовтан 161 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 220,2 мең кеше (2002; ш.и. Балаковода — 200,5 мең). Татарлар район үзәгендә (3408 кеше) һәм Яңа Әләзән авылында (477 кеше) яши. Яңа Әләзәнгә 1820 елларда Пенза губернасының Урта һәм Түбән Әләзән авылларыннан күчеп утыручылар нигез сала. 1940 елга кадәр мәчет, 1962 гә кадәр сигезьеллык татар мәктәбе була. 1998 дән Балаково шәһәрендә «Мирас» татар-башкорт милли-мәдәни үзәге эшли, аның каршында вокаль һәм хореографик коллективлар, студияләр, яшьләр һәм хатын-кызлар клублары бар. Һәр елны Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә. Б.р. һәм Балаково шәһәренең мөселман дини берләшмәсе эшли, мәчет төзелә. Хәзерге вакытта Яңа Әләзән урта мәктәбендә татар теле факультатив дәрес буларак укытыла.

**БАЛАЛА́Р ӘДӘБИЯТЫ́**. Татар телендә балалар өчен махсус язылган беренче әсәрләр 18–19 йөзләрдә барлыкка килә. Татар Б.ә. гомуми әдәби процесс кысаларында үсә. Дини эчтәлекле китаплар («Иман шарты», «Һәфтияк», «Бәдәвам», «Кисекбаш китабы» һ.б.) б-н беррәттән дөньяви (мәс., Габди шигырьләре, Таҗетдин Ялчыголның «Рисалә-и Газизә» — «Газизәгә хат», 1795) һәм дидактик эчтәлекле (Колмөхәммәднең «Мөһиммәт әс-сыйбъян» — «Сабыйларның бурычлары», 1810; «Тәгъриф әл-вилдан» — «Балаларга аңлатма», 1815) әсәрләр дә күренә башлый. С.Хәлфиннең беренче басма «Татар теле әлифбасы» (1778), Аллаһияр Суфиның балалар арасында популяр булган «Сөбәт әл-газиҗин» («Гаҗизләрнең ныклыгы», 1805) китабы, М.Ивановның «Татар хрестоматиясе» (1842), С.Күкләшевнең «Диван-е хикайә әт-татар» (1859) китабы, Казан типографияләрендә дөнья күргән башка басмалар һәм бигрәк тә К.Насыйри китаплары дөньяви татар Б.ә.ның формалашуында һәм үсүендә зур роль уйныйлар. 1860 елда К.Насыйри табигать күренешләре турындагы кыска, мавыктыргыч хикәяләрдән торган «Буш вакыт» исемле җыентык чыгара (соңыннан күп тапкырлар кабатлап басыла). «Кырык вәзир кыйссасы» (1868), «Әбүгалисина кыйссасы» (1872), «Кырык бакча» (1880) китапларында, ш.у. тәрбия һәм әхлак мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрендә балаларны белемле, кызыксынучан, эшчән кешеләр итеп тәрбияләү ихтыяҗын күрсәтә. Балалар өчен В.В.Радловның «Белек» («Знание», 1872), Т.Яхинның «Сабый вә сабыялар өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗәеб булган гыйбрәтләр» (1897) хрестоматияләре, ш.у. Ф.Халиди, Г.Фәезханов әсәрләрен, Г.Рахманколый шигырьләрен рус һәм Шәрекъ телләренә тәрҗемә итү һәм аларны 19 йөз ахырында — 20 йөз башында бастыру нәтиҗәсендә Б.ә.ның тематикасы һәм жанр кысалары киңәя. 1905–07 еллардагы рев-ция аның үсүенә яңадан көчле этәргеч бирә. Балалар өчен махсус көндәлек матбугат барлыкка килә: Мәскәүдә 1907 нең гыйварыннан мартына кадәр беренче татар балалар ж-лы «*Тәрбиятел-этфаль*», Казанда 1908 дә ата-аналар өчен «*Тәрбия*» ж-лы, 1913–16 елларда «*Ак юл*» ж-лы чыга. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Н.Думави, М.Гафури, З.Ярмәки, М.Укмасый, Ш.Әхмәдиев һ.б. балаларга багышлап махсус әсәрләр язалар, «Балалар календаре» (1908) басыла башлый.

Татар Б.ә.ның эчтәлеген һәм жанрларын баетуда, халыклаштыруда Г.Тукай иҗатының роле гаять зур. Үзенә кадәрге һәм замандаш язучыларының реалистик традицияләре нигезендә балалар өчен язган зәвыклы шигырьләре, әкиятләре, мәсәлләре, кыска хикәяләре Б.ә.тын тематик һәм эстетик яктан яңа биеклеккә күтәрә. Әсәрләрендә ул балаларны белемгә, хезмәткә өнди, сәнгать чаралары б-н аларда миһербанлылык, ата-анага, туган телгә, табигатькә карата мәхәббәт тәрбияли. Г.Тукай балалар өчен дәреслекләр һәм хрестоматияләр төзи («Яңа кыйраәт» — «Яңа уку китабы», «Балалар күңеле. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»), иҗаты б-н Б.ә.ның сыйфат ягыннан үзгәрүенә юл ача, балаларга багышланган кешелекле һәм гуманистик әсәрләре б-н үзенә бер шигъри «мәктәп» тудыра. Соңыннан аның традицияләре М.Гафури, Ф.Әмирхан, Н.Думави, З.Ярмәки, М.Укмасый, Ш.Әхмәдиев иҗатларында дәвам иттерелә.

1917 ел вакыйгаларыннан соң балалар язучылары яңа вазгыятьне һәм тематиканы үзләштерә башлыйлар. Беренче пионер оешмалары төзелә (1923), балалар өчен «*Кечкенә иптәшләр*» ж-лы (1924 тән), «*Яшь ленинчы*» г-тасы (1924 тән) чыгарыла башлый. 1920 елларда Б.ә.ның тематикасын нигездә рев-ция һәм Гражданнар сугышы вакыйгалары (М.Гафуриның «Кызыл байрак», Сириннең «Октябрь нурлары», «Кызыл гаскәргә», Һ.Такташның «Караборынның дусты», К.Нәҗминең «Яр буенда учаклар» әсәрләре); балалар ятимлеге (Х.Туфанның «Зәңгәр бүре», Г.Толымбайның «Үксезләр» әсәрләре); мәктәп тормышы (Һ.Такташның «Ләйлә», «Пионерлар маршы», К.Әмиринең «Фабрик баласы», М.Крыймов әсәрләре һ.б.) мәсьәләләре били. Балалар өчен беренче пьесалар языла (С.Әдһәмованың «Авыл тормышыннан бер күренеш», «Хәзер бул!», К.Әминең «Уңган кыз», «Урманда йөрү», М.Фәйзинең «Коммунага», К.Хисаметдиновның «Кызыл чәчәкләр» әсәрләре), беренче спектакльләр куела, әдәби-музыкаль радиотапшырулар эфирга чыга.

1934 тә оешкан ТАССР Язучылар берлегендә Ф.Кәрим җитәкчелегендә Б.ә. секциясе эшли башлый. Б.ә. өлкәсендә әдәби тәнкыйть барлыкка килә. 1930 елларда язылган әсәрләрдә шул чор вакыйгалары тасвирлана: Гражданнар сугышы һәм авыл хуҗалыгын күмәкләштерү елларында олыларга ярдәм итүче балалар образлары туа (Г.Гобәйнең «Маякчы кызы», «Ялгыз йортта», «Каланча», Ә.Айдарның «Ташбай» повестьлары, М.Әмирнең «Батыр исемле малай турында хикәяләр»е). А.Алиш әкиятләре («Сертотмас үрдәк», «Нечкәбил», «Ана әкиятләре» циклы) һәм хикәяләре («Әбиләргә кунакка», «Мин дәү — син кечкенә», «Утлы йомырка», «Уңышсыз рәсем») басыла, аларда төп игътибар балаларны намуслы, эш сөючән, батыр, жаваплылык тоючы, бер-берсенә яхшы иптәш, ватанны һәм табигатьне яратучы шәхесләр итеп тәрбияләүгә юнәлтелә. М.Җәлил балалар өчен язган әсәрләрендә күптөрле темалар күтәрә: белемгә омтылу («Сәгать», «Беренче дәрес»), ватанга мәхәббәт («Җилләр», «Туган ил», «Яңгыр», «Шмидт бабай», «Безнең җыр»), хезмәтне сөю («Уңыш бәйрәме», «Арыш кырында»). Ул сабый балалар өчен дә яза («Бишек җыры», «Маэмай», «Карак песи» әсәрләре). Бөек Ватан сугышы елларында балалар язучыларының күбесе фронтка китә, ләкин Ф.Кәрим («Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Тирән күл», «Ант», «Үлем уены» шигырь һәм поэмалары), А.Әхмәт («Солдат балалары», «Солдат хикәяләре»

җыентыклары), Г.Кутуй («Рөстәм маҗаралары» повесте), М.Җәлил («Суык бабай», «Чыршы җыры») фронтта да балалар өчен актив язуларын дәвам итәләр.

Сугыштан соңгы Б.ә.на темалар һәм жанрлар төрлелеге хас. Ә.Фәйзи («Бал корты», «Кечкенә Апуш»), Ш.Маннур («Миләүшә китабы», «Минем кошкаем», «Ямьле җәй», «Елмаюлы кояш турында»), Н.Исәнбәт («Куянкай», «Мырауҗан агай хәйләсе»), Җ.Тәрҗеманов («Кояшлы иртә», «Ямьле көн», «Шуктуган», «Шаян белән Наян», «Көмешкойрык маҗаралары»), Ә.Бикчәнтәева («Бүләк», «Дәү әнием», «Бакча гөлләре», «Ана йөрәге», «Мин аңлыйм сине», «Хуҗа Насретдин балалар янында»), Ә.Кари («Балаларга бүләк», «Гөлбакча», «Дуслык»), Н.Гайсин («Зәңгәр күктә», «Түтәлләр», «Безнең мәктәп», «Таза Мортаза»), Г.Латыйп («Дусларым минем», «Язлар җитәр»), З.Нури («Син мәктәпкә йөрисең», «Бу безнең китап»), Б.Рәхмәт («Кем көчле», «Нәниләр китабы», «Укыйсым килә», «Ялкау, Иренчәк һәм Кире», «Курчак батыр») иҗатлары аерым урын алып тора.

1950 елларда Д.Аппакова («Йолдызкай», «Шыгырдавыклы башмаклар», «Сөяк саплы пәке», «Сараның башыннан үткәннәре», «Гөлчәчәк белән сандугач», «Сөмбел», «Кечкенә Бану тарихы»), И.Туктар («Нәни хикәяләр», «Җир җиләге»), М.Гали («Каюмның балачагы» повесте) иҗатларында әхлак проблемалары күтәрелә. Совет кешеләренең сугыш кырында һәм тылдагы батырлыклары темалары Г.Бакир («Партизан малай»), Г.Гобәй («Замана балалары», «Маратның язмышы») повестьларында чагылыш таба. Г.Гобәйнең «Без үскәндә» повесте тарихи-революцион тематикага багышланган. Яшүсмернең эчке дөньясы үзенчәлекләрен И.Газиның «Онытылмас еллар» романы гәүдәләндерә, маҗаралы сюжетка корылган әсәрләр — А.Расихның «Бәхет орлыклары» фәнни-фантастик повесте, Г.Галиевнең «Җил кошларны җыя», «Аю агачлар белән сөйләшә» әкиятләре балаларны мавыктырырлык итеп язылган. Балалар өчен драматик әсәрләр иҗат ителә: Д.Аппаковaның «Тапкыр егет», «Илдус», Х.Вахитның «Ышаныч», А.Әхмәтнең «Үги кыз», «Гөлчәчәк», «Өмет йолдызы», Т.Гыйззәтнең «Бердәнбер бала», Г.Бакирның «Ватык звонок», Г.Нәбиуллинның «Алтын нарат», Г.Насрыйның «Ана күңеле» пьесалары дөнья күрә. Б.ә. өлкәсендә әдәби тәнкыйть тә җанлана төшә («Балалар әдәбияты турында», 1957).


1960–80 елларда Б.ә.нда Ш.Галиев исеме б-н бәйле юмористик юнәлеш үсеп китә. Аның изгелек һәм юмор б-н сугарылган шигырьләренә тормышны сөю хисе хас. Шәвәли б-н Камырша образлары аеруча популярлык казана. Балалар поэзиясе өлкәсендә Ә.Исхак, З.Мансур, М.Садри, Ә.Бикчәнтәева, З.Туфайлова, Э.Мөэминова, Г.Нәбиуллин, Р.Миңнуллин, И.Юзеев, Ф.Яруллин, Н.Мадьяров, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалим, Х.Халиков, М.Фәйзуллина, Ә.Габиди, Разил Вәлиев һ.б., прозада — Г.Мөхәммәтшин («Бал чүлмәге», «Ун бәбкә», «Без әле җирдә яшибез» хикәяләре), Җ.Тәрҗеманов («Шуктуган»), И.Туктар («Абыем бүреге», «Алма», «Батырлыкта — матурлык» хикәяләре), Л.Ихсанова («Җир астында җиде көн», «Саралан малайлары», «Космонавтлар урамы», «Очкын», «Наил һәм Фаил» повестьлары), Ф.Шәфигуллин («Тагын икеле», «Командир», «Мин дә үсәрмен әле» хикәяләре, «Өй салуның ние бар», «Ак маңгайлы бүреләр» повестьлары), М.Харисов, Р.Хафизова, Б.Камалов, Р.Бәшәр, Л.Лерон һ.б. зур уңышларга ирешәләр.

1980–2000 еллар Б.ә. тематикасының һәм жанрларының төрлелеге б-н аерылып тора. Балалар өчен Х.Халиков, Җ.Дәрзаман, М.Фәйзуллина, Р.Мингалим, Ф.Яруллин, Л.Лерон, З.Гомәрова, Р.Корбанов, Р.Газизов, Ә.Нигъмәтуллин уңышлы язалар. Г.Тукай, Ә.Фәйзи, Б.Рәхмәт, Ш.Галиев традицияләрен үстереп, онытылмас балалар образларын Р.Миңнуллин иҗат итә. Аның шигырьләрен үзенчәлекле юмор, кешелеклелек, бала психологиясе нечкәлекләрен аңлау, сәнгати камиллек аерып тора. («Олы булсам», «Алмабабай», «Кояш алмасы», «Сөенсеннәр әле сабыйлар» һ.б.). Әкият (Р.Хафизова, Ф.Яруллин, Р.Батулла, Р.Мингалим), хикәя (Гәрәй Рәхим, Н.Фәттах, З.Хәснияр, Л.Сабирова, Ш.Маннапов), повесть (Л.Ихсанова, Б.Камалов, Р.Бәшәр, Җ.Дәрзаман) жанрлары уңышлы яшәп килә. Сугышчан-патриотик тематика — С.Шакир, Ш.Рәкыйпов, Разил Вәлиев, Ш.Мостафин иҗатларында, фәнни фантастика — А.Тимергалин әсәрләрендә, сәяхәтнамә жанры М.Юныс китапларында чагылыш таба; Ә.Баян, Г.Хәсәнов, Ә.Хәсәнов әсәрләре туган табигатькә мәхәббәт хисләре б-н сугарылган. Драматургия өлкәсендә Т.Миңнуллин, Р.Батулла, Р.Мингалим, Р.Корбанов, Н.Фәттах, Гәрәй Рәхим, М.Гыйләҗев, А.Гыймадиев, Р.Гыйззәтуллин һ.б. иҗат итәләр. «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (төз. Н.Исәнбәт, Гәрәй Рәхим, Р.Рахмани, 1980), «Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен» (төз. Н.Исәнбәт, 1984) җыентыгы, Ф.Ибраһимова төзегән «Балалар әдәбияты» (2004) хрестоматиясе татар Б.ә. тарихында күркәм күренеш була. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә Ф.Ибраһимова, Р.Рахмани һ.б. эшли.

*Әд.:* Кукушкин Р. Канатлы дөнья. К., 1984; Ибраһимова Ф. Сабыйларны үз итеп. К., 1998.

*Ә.М.Шәрипов.*

**«БАЛАЛА́Р ДӨНЬЯСЫ́»**, айлык балалар журналы. 1917 елның 1 мартыннан 1918 ел башына кадәр нәшер ителә, барлыгы 8 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире Я.*Хәлили*. Г.Баттал, С.Җәлал, Ш.Әхмәдиев, М.Фәйзи һ.б. авторларның язмалары басыла. Эчтәлеге б-н ул «*Ак юл*» ж-лына якын. Төп максаты — яшь буынга лаеклы тәрбия бирү. Журналда тарихи һәм дини темаларга язылган хикәяләр, табигать турында мәкаләләр, язучыларга, галимнәргә багышланган биографик материаллар урын ала, башваткычлар басыла. Журнал редакциясе шулай ук балалар өчен язылган китаплар бастыруда булышлык күрсәтә.



«Балалар дөньясы» журналы.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Рәми И., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«БАЛАЛА́Р САНАТО́РИЕ»** посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 30 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2002 елда 17 кеше (руслар, татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Башта ТАССРның Зөя кантонына керә. 1927 елның 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 25, 1938 дә — 148, 1958 дә — 165, 1970 тә — 163, 1979 да — 137, 1989 да — 24 кеше.

**БАЛАЛА́Р САНАТО́РИЙЛАРЫ**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының балаларны дәвалау-профилактикалау учреждениеләре. Сәламәтлекне ныгыту өчен табигый шартлар һәм чаралар (климат, минераль сулар, шифалы балчыклар һ.б.) кулланy, билгеле бер төр тукланy режимы, дәвалауны (физиотерапия, дәвалау күнегүләре һ.б.) ял б-н чиратлаштыру күздә тотыла. Авыруларны дәвалау профиле буенча Б.с. гомумсоматик (терапия, сулыш органнары, нерв һәм бүлеп чыгару системалары) һәм махсус (туберкулёзга каршы, психоневрологик) төрләргә бүленә.

1912 елда Казанда һәм 1915 тә Колай волостенда сәламәтлекләре какшаган балалар өчен республика җирлегендә беренче сәламәтләндерү учреждение-колонияләре оештырыла. 1921 дә туберкулёзга каршы профильдәге, елына 1 меңнән артык баланы дәвалау мөмкинлеге булган «*Обсерватория*» санаторие ачыла. 1937 дә балаларны туберкулёздан дәвалау профилендәге «Зәңгәр күл» санаторие оештырыла, 1978 дә ул Юдино посёлогындагы 250 урынлы яңа бинага күчерелә һәм балалар санаториеның исеме «*Каенлык*» («Берёзовая роща») дип үзгәртелә; анда ел саен 800 бала дәвалана. 1941 дә республикада балаларда туберкулёз авыруы ешаю сәбәпле, Әгерҗе шәһәрендә 50 урынлы санаторий ачыла. 1941 дә Буага Мәскәүдән соматик профильле балалар санаторие күчерелә, соңрак ул ревматизмны дәвалау юнәлешендә эшли башлый. 1978 дә ябыла, 1992 дә яңадан ачыла (60 урынлы).

1957 дә Казанда 50 урынлы 2 нче номерлы психоневрологик балалар санаторие ачыла, анда полиомиелит авырулы балалар дәвалана, 1966 дан санаторий гомуми психоневрология авыруларын дәвалау юнәлешендә эшли, 1999 да Азино-2 микрорайонындагы яңа бинага күчерелә. Санаторийда төрле этиологияле церебраль параличны, травмалардан соңгы, астеник, цереброастеник, невроз авыруларын дәвалау эше алып барыла.

Санаторийда энә кадап дәвалау, яктылык, җылылык, электр һәм су б-н дәвалау, дәвалау күнегүләре, хезмәт б-н дәвалау, логопедия, рәсем сәнгате, музыкаль тәрбия, хореогра-

фия кабинетлары, ш.у. техника остаханәләре, компьютер класслары, китапханә эшли. Ел саен 400 бала комплекслы дәва ала.

1960 та Дәрвишләр посёлогында 2 дән 8 яшькә кадәрле балалар өчен терапия профилендә 100 урынлы 1 нче балалар санаторие ачыла, соңрак ул Казан шәһәренең Зорге урамындагы яңа бинага күчерелә. Санаторийда бронх-үпкә һәм кардиология бүлекләре бар. Ел саен 800 бала дәвалана. 1979 да Чаллы шәһәрендә 80 урынлы соматик (ш.и. пульмонология) юнәлешендәге «Айболит» балалар санаторие ачыла. Санаторийда аллергия һәм ревматизм авыруларын һәм бу авырулар китереп чыгарган башка авыруларны дәвалау эше алып барыла. Ел саен 600 бала сәламәтлеген ныгыта. 1982 дә Яшел Үзән шәһәренең урманлы өлешендә 2 дән 15 яшькәчә балалар өчен соматик авыруларны дәвалау буенча 100 урынлы төп санаторий ачыла. Ел саен 700 бала дәвалана һәм бер үк вакытта мәктәптә укый. 1984 тә Түбән Кама шәһәрендә 3 тән — 10 яшькәчә балалар өчен 100 урынлы терапия профилендәге санаторий ачыла. Ел саен 900 гә кадәр бала сәламәтлеген ныгыта. 1988 дә Казанда соматик профильдәге 75 урынлы 4 нче балалар санаторие оештырыла, анда 3 тән 7 яшькәчә балалар дәвалана, санаторий шәһәрнең урман-парклы өлешендә урнашкан. 2 бүлеге: нефрология һәм пульмонология бүлекләре эшли. Ел саен 600 дән артык бала дәвалана. 1996 да 3 тән 10 яшькәчә балалар өчен соматик профильдә эшләүче 75 урынлы Чистай балалар санаторие ачыла. Санаторийның өч бүлеге бар; балалар соматик авырулардан профилактик дәвалау: йоткылык өсте санациясен көйләү гимнастикасы, физиотерапия, энтеросорбция, массаж, йөзү күнегүләре, сөяк-мускул системасын төзәтү, күрүне яхшырту курсларын үтәләр. Санаторийда психоэмоциональ халәтне нормальләштерү кабинеты, дәвалау күнегүләре залы, бассейн, сауна һ.б. бар. Ел саен 750 бала дәвалана.

2003 кә ТРда 1155 урынга исәпләнгән 11 Б.с. (2 республика, 6 шәһәр, 3 район күләмендәге) эшли, елына 8 меңгә кадәр бала дәвалана. *Л.Никольская.*

**БАЛАЛА́Р ҮЛЕМЕ́**, сабыйлар үлеме, бер яше тулмаган балалар үлеме. Халык сәламәтлеге торышын билгеләүче төп күрсәткечләрнең (авырулар, үлем һ.б.) берсе. Б.ү. коэффициентларда (бер яше тулганчы үлгән балалар саны шул ук елда исән туган балалар санына бүлеп, 1000 гә тапкырлана) билгеләнә һәм промиллеләрдә (‰) күрсәтелә.

1990 елда ТРда 1 яше тулганчы 947 бала үлә (Б.ү. коэф. 16,6‰ тәшкил итә). 1991 елдан тормыш шартлары начарлану, аналар һәм балаларны саклау системасы бозылу һ.б. сәбәпләр б-н бәйле рәвештә, гомумән РФдәге кебек, ТРда да Б.ү. арту тенденциясе күзәтелә. 1993 елга Б.ү. коэф. 19,9 ‰ гә кадәр арта. 1990 еллар уртасыннан башлап, Б.ү. күрсәткеченең кимү тенденциясе күзәтелә. 2006 да 1 яше тулганчы 307 бала үлә, Б.ү. дәрәҗәсе 8,2‰ гә кадәр, ягъни 1995 ел б-н чагыштырганда 2 тапкырдан артыкка кими. Гадәттә, үлүчеләр саны авыл җирләрендә шәһәрләрдәгегә караганда күбрәк (табл.). Республика буенча уртача күрсәткечкә караганда, республика буйсынуындагы 4 шәһәрдә һәм 22 районда Б.ү. күрсәткече югарырак.

1993–2006 елларда ТРда балалар үлеме коэффициенты (‰)

| | 1993 | 1994 | 1995 | 1996 | 1997 | 1998 | 1999 | 2000 | 2001 | 2002 | 2004 | 2005 | 2006 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| барлыгы | 19,9 | 18,4 | 18,5 | 17,4 | 16,9 | 15,3 | 14,2 | 14,8 | 12,6 | 11,9 | 11,2 | 8,0 | 8,2 |
| шәһәр | 19,3 | 17,4 | 17,6 | 17,1 | 16,5 | 15,6 | 14,0 | 14,9 | 12,3 | 11,2 | 10,7 | 7,5 | 6,7 |
| авыл | 21,4 | 20,5 | 20,5 | 17,9 | 17,6 | 14,7 | 14,7 | 14,8 | 13,4 | 13,6 | 12,8 | 9,7 | 12,8 |

ТР да Б.ү. дәрәҗәсе, тулаем РФ күрсәткеченнән (2000 дә 15,3‰) беркадәр түбәнрәк булса да, алга киткән дәүләтләр б-н чагыштырганда 2 тапкыр һәм аннан да югары. Б.ү.нең төп сәбәбе булып перинаталь чор (йөклелекнең 28 нче атнасыннан алып бала гомеренең беренче 7 тәүлегенә кадәр) авырулары исәпләнә. 2006 да әлеге сәбәп б-н 167 бала үлә, ә Б.ү. исән туган 10000 балага 44,8 (1995 тә 77,7) бала тәшкил итә. 1995 елдан башлап, тумыштан килгән аномалияләрдән үлүчеләр (56,9 дан алып 2006 елда 9,1 гә кадәр), сулыш органнары авыруларыннан (20,3 тән 7,8 гә кадәр), паразитлардан тарала торган, ш.у. йогышлы авырулардан үлүчеләр саны кими. 2006 елның башыннан Россиядә демографик хәлне тотрыклыландыру, ана һәм бала сәламәтлеген саклау максатыннан төрле чаралар комплексы күрелә башлый. Бала тудыру сертификаты программасы гамәлгә ашырыла, бала тудыру йортларын һәм перинаталь үзәкләрне яңадан җиһазландыру өчен акча бүленеп бирелә. 2007 дән бала тәрбияләгән өчен пособиеләр билгеләнә, гаиләдә икенче яки өченче, дүртенче булып туган балага (әгәр элек алынмаган булса) ана капиталына каралган 250000 сум күләмендә сертификатлар рәсмиләштерелә башлый.

**БАЛАЛА́Р ҮЛЕМЕНӘ́ КАРШЫ́ КӨРӘ́Ш ҖӘМГЫЯТЕ́**, иганәчелек оешмасы. 1909 елда Казанда хәйрия җәмгыяте, алдынгы карашлы җәмәгать эшлеклеләренең, нигездә, табибләрнең ирекле берләшмәсе буларак барлыкка килә. 20 йөз башында Россиядә балалар үлемен һәм авыруларны киметү максатында җәмгыятьләр төзелә. Ана һәм бала сәламәтлеген саклау системасы булмау, халыкның авыр социаль-икътисади шартларда яшәве балалар үлеменең артуына сәбәп була. 1904 тә Россиядә беренче зур җәмгыятьләрнең берсе — «Балалар үлеме белән көрәшү берлеге» төзелә. 1913 тә «Бөтенроссия аналарны һәм яшь балаларны саклауны булдыру» оешмасы раслана.

Казан җәмгыятенең төп максаты — балалар үлеменең сәбәпләрен һәм күләмен өйрәнү, аларга каршы көрәш чараларын эшләү. Б.ү.к.к.җ. ятим балалар йортларына ярдәм итү, балалар азыгы тарату, балаларның ялын оештыру өчен махсус мәйданнар ачу, аналарга консультацияләр бирү эшләрен башкара. Җәмгыять балалар авыруларын булдырмауга багышланган популяр брошюралар нәшер итә. Б.ү.к.к.җ.ндә проф. В.П.*Первушин*, П.И.*Пичугин* (казначей), В.К.*Меньшиков*, Е.М.*Лепский* актив эш алып баралар. Җәмгыять 1915 кә кадәр эшли, шәфкать туташлары һәм табибләр әзерләүдә катнаша, нәтиҗәле санитария-агарту эше алып бара. *Д.Д.Нуретдинова.*

**БАЛАЛА́Р ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘ́Р ГИГИЕ́НАСЫ**, гомуми гигиенаның бер бүлеге, балалар һәм яшүсмерләр организмына тышкы мохит тәэсирен өйрәнә, яшәү өчен уңай шартлар булдыруга, балаларның физик һәм акыл ягыннан үсешен тәэмин итүгә юнәлтелгән гигиена таләпләрен һәм нормативлары эшли.

Б.һ.я.г. нигезләре халык медицинасында ук билгеле булган. Мәктәп гигиенасы, фәнни дисциплина буларак, 20 йөз башында барлыкка килә. Россиядә фәнни гигиенага нигез салучы Мәскәү ун-ты профессоры Ф.Ф.Эрисман тарафыннан класс бүлмәләренә һәм андагы җиһазларга гигиеник таләпләр куела. Фәнни һәм профилактик эш системасы буларак, Б.һ.я.г. үсешенә республикада 1922 елда оештырылган сан.-эпидемиология хезмәте зур өлеш кертә. 1930–50 елларда СССРда мед. фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә, мед. һәм пед. югары уку йортларында балалар гигиенасы бүлекләре булдырыла. 1943 елда Казан мед. ин-тында мәктәп гигиенасы каф. (мөдире А.И.Смирнов) ачыла. Б.һ.я.г. өлкәсендә төп игътибар балаларга физик тәрбия бирүгә, балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә туклануга, гаиләдә көнкүреш культурасын яхшыртуга, балаларда йогышлы авырулар булдырмауга, аларны санаторийларда дәвалауга, һәм ялларын оештыруга юнәлтелә.

1960 елларда Б.һ.я.г. гигиенаның үсеп килүче организмга яраклаштырылган барлык тармакларын берләштергән интеграль фәнгә әверелә. ТРда үсеш алган фәнни юнәлешләр: балаларның физик үсеше һәм авырулары (Ф.Г.Мөхәммәтъяров, О.М.Войдинова, В.В.Трейман, Ф.Г.Тажетдинова, Р.С.Чувашаев, А.Х.Яруллин); балаларның рациональ туклануын оештыру һәм балалардагы геоэндемик авырулар (А.М.Хәкимова, А.Н.Юнысова, Л.Н.Титенок, Т.К.Купче); респ-ка шәһәрләре һәм авылларында экологик мохиткa бәйле рәвештә балалар һәм яшүсмерләр сәламәтлеген кайгырту (А.Х.Яруллин, Ф.Ф.Даутов, Н.В.Скудных, Э.Р.Вәлиева, Н.В.Шатунова, Г.А.Фомин, А.Б.Галләмов); хезмәт һәм һөнәри белем бирү мәсьәләләре (Э.Н.Минһаҗев). 2000 елдан ТРда балалар сәламәтлеге мониторингы эшләнә.

*Әд.:* Сердюковская Г.Н. Социальные условия и состояние здоровья школьников. М., 1979; Сухарев А.Г. Здоровье и физическое воспитание детей и подростков. М., 1991; Валеева Э.Р., Скудных Н.В. Окружающая среда и состояние здоровья детского населения Республики Татарстан. К., 1997; Даутов Ф.Ф., Амиров Н.Х., Галеев К.А. Окружающая среда и здоровье. К., 2001. *А.Х.Яруллин.*

**БАЛАЛА́Р ЯТИМХАНӘЛӘРЕ́** (приютлар), ятимнәрне һәм ярлы гаиләләрдән булган балаларны тәрбияләү һәм укыту өчен ачылган хәйрия йортлары. 17–18 йөзләрдә Б.я., кагыйдә буларак, монастырьлар каршында оеш-

тырылган һәм рәсми статуска ия булмаган. Беренче балалар ятимханәсе 1837 елда Петербургта Демидовларның «Хезмәт ияләрен тәрбиягә алу» йорты каршында эшли башлый. Б.я. турындагы карар (1839) нигезендә караучысыз калган балалар өчен шәхси хәйрия акчасына губерна, өяз, һәм авыл попечительлекләре барлыкка килә. 1844 тә Казанда Император Мәрхәмәт кылу җәмгыятенең балалар ятимханәләре баш попечительлегенә оештырыла. Бу елларда христиан балалары өчен Николай исем.(1844), Александр исем. (1845; 1889 елдан *Александра исем. кыз балалар ятимханәләре*, ш.у. мөселман балалары өчен бертуган *Юнысовлар балалар ятимханәсе* (1844) ачыла. Шуның б-н бергә 19 йөзнең 1 нче яртысында ятим балаларны кайгырту буенча җәмәгатьчелек тырышлыгы бюрократик каршылыкларга очрый. 1860 елларда ятим балаларны тәрбияләү б-н земство органнары һәм җәмәгать хәйрия оешмалары шөгыльләнә башлый. 20 йөз башына императрица Мария учреждениеләре карамагында, алда аталганнардан тыш, Чистай шәһәрендә кызлар өчен — Мария исем. ятимханә; земство һәм шәһәр органнары үзидарәләре карамагында — земство ятим балалар йорты (1870), кыз балалар өчен Мария исем. шәһәр гариплар йортының ятимханәләр бүлеге (1880), Зөя шәһәрендә кыз балалар өчен Ольга исем. ятимханә, Чистай өязенең Кривоозёрки авылында ир балалар өчен ятимханә, Тәтеш шәһәрендә П.Г. Серебряков исем. ятимнәр йорты, Минзәлә шәһәрендә земство ятимханәсе эшли. Җәмәгать оешмалары тарафыннан *Казан сукыр балалар уч-щесе* каршында катнаш ятимханә (1885), Казанда кыз балаларны хезмәткә өйрәтүче Ольга исем. ятимханә (1889), ир балалар өчен Казан аеклар җәмгыяте ятимханәсе (1904), Казан ярлы һәм авыру балаларны тәрбияләү җәмгыятьләренең катнаш Ярлы һәм авыру балалар йорты (1904), Чистайда Ярлыларга ярдәм җәмгыятенең Ярлы ир балалар йорты (1904), *Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятенең* ир балалар ятимханәсе (1905) тотыла. Аерым шәхесләр оештырган фондлардан Алабуга шәһәрендәге Александра исем. ятимханә (сәүдәгәр Ф.Г.Чернов, 1859), Казан епархия уч-щесе каршындагы кыз балалар өчен Ольга исем. ятимханә (О.С.Александрова-Гейнс, 1889) тотыла. Дини оешмалар карамагындагы ятимханәләр: Казан Богородица (18 йөздән) һәм Казан Фёдоровский (1900) монастырьлары каршындагы кыз балалар ятимханәләре, Казанның Смоленск-Дмитриевский чиркәве каршындагы катнаш приход ятимханәсе, Казан рим-католик приходының Ярлыларга ярдәм җәмгыятенең катнаш ятимханәсе. Ятимханәләр б-н, кагыйдә буларак, бай сәүдәгәрләрдән торган попечительлек ком-тлары җитәкчелек итә. Алар нәтиҗәле рәвештә табышларны һәм чыгымнарны, хезмәткәрләрнең намуслылыгын һәм һөнәри осталыгын тикшереп тора. Б.я.дә тәрбияләнүчеләр башлангыч белемне ятимханә каршындагы мәктәпләрдә яисә башлангыч шәһәр уч-щеләрендә ала. Сәләтле балаларга урта уку йортларында белем алу мөмкинлеге бирелә. 20 йөз башында мөселман ятимханәләренең икесендә дә рус-татар башлангыч уч-щеләре эшли. Окт. рев-циясеннән соң ятимханәләр балалар йортлары һәм интернатлар итеп үзгәртелә.

Чыг.: Отчёты Казанского губернского попечительства детских приютов. К., 1845–1916.

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998; С а л и х о в Р.Р. Общественно-политическая деятельность татарской буржуазии Казани (вторая половина XIX и начало XX в.). К., 2001. *Е.В.Липаков.*

**БАЛАЛЫ́КИНА** Эмилия Агафоновна (11.4.1937, Ленинград), тел галиме, филол. фән. д-ры (1986), проф. (1988). ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). РФнең мактаулы югары һөнәри мәктәп хезмәткәре (2004). Вильнюс (1957), Казан ун-тларын (1960) тәмамлый. 1960 елдан Казан ун-тында эшли: 1981–93 елларда чит илдән килеп укучыларга рус телен укыту (1993 тән — хәзерге рус теле), 2005 тән хәзерге рус теле һәм чит тел булларак рус теле каф. мөдире. Бер үк вакытта 1984–87 дә Варшавадагы Рус теле ин-ты директоры. Тикшеренүләренең төп юнәлешләре: хәзерге һәм тарихи-чагыштырма сүз ясалышы, балтыйк-славян телләре бәйланышлары.

Х е з м.: Словообразовательная структура прилагательных в славянских и балтийских языках. К., 1980; Русское словообразование. К., 1985; Приключения слов. К., 1993; Современный русский язык. Морфология. К., 2003. Ч. 1; К., 2006. Ч. 2; Русское адъективное словообразование на балто-славянском фоне. К., 2007.

**БАЛА́Н** (Viburnum), зелпечәләр семьялыгыннан яфрак коючан (мәңге яшел төрләре дә бар) куаклар яки зур булмаган агачлар ыругы. 225 ләп төре бар, Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик поясларында, күбесенчә Евразиядә һәм Төньяк Америкада очрыйлар. ТРда гади Б. (V.opulus) киң таралган. Яфраклы һәм катнаш урманнарда үскән куаклык тибындагы үсемлек, куак араларында, елга буйларында үсә. 1,5–5 *м* озынлыктагы ботаклы, яфрак коючан куак. Кайрысының өслеге яшькелт-соры төстә, җыерчыклы, сирәгрәк очракта шома, соргылт яки аксыл таплы һәм коңгырт вак ясмыкчыклар б-н капланган.



Яфраклары өч аерчалы, көзен ачык сары яки кызгылт төстә. Чәчәкләре ак, калкансыман чәчәк төркеменә җыелган. Җимешләре — зур яссы төшле, кызыл, сары-кызгылт сусыл җимеш. Майның икенче яртысы — июньдә чәчәк ата. Җимешләре август-сентябрь айларында өлгерә һәм куакта озак саклана. Тиз үсүе б-н аерылып тора, авыруларга һәм корткычларга бирешми, салкынга чыдам. Культуралаштырылган һәм яшелләндерүдә файдаланыла. Бакчаларда ап-ак шарсыман төркем чәчәкле төре киң таралган. Чыбыкчадан һәм үсентедән үрчетелә. Медицинада кайрысы һәм җимешләре кулланыла, аларда шикәр, пектин, каротин, С һәм Р витаминнары, микроэлементлар бар. Кайры төнәтмәсен кан туктату өчен файдаланалар. Җимешләре азыкны витаминлаштыру, тир чыгару һәм гомуми ныгыту чарасы буларак файдаланыла, ш.у. урман кошларына азык булып тора. Агачы вак-төяк эшләргә яраклы. Баллы үсемлек.

**БАЛА́Н КҮЛЕ́**, Идел буенда. Гөбенә елгасы бассейнында, Кайбыч р-ның Багай авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 5 *га*. Су күләме 75 мең $м^3$. Озынлыгы 600 *м*, иң зур киңлеге 75 *м*, уртача тирәнлеге 1,5 *м*, иң зур тирәнлеге 3,2 *м*.



Балан күле.

Күл казанлыгы ясалма (казылган). Формасы ураксыман. Суы гидрокарбонат-хлорид-магнийлы, бик йомшак. Үтә күренмәлелеге 88 *см*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла. Ял итү урыны.

**БАЛА́Н ЧЫПЧЫГЫ́**, к а р а б ү р е к (Pyrrhula pyrrhula), тау чыпчыклары семьялыгындагы кош. Евразиянең ылыслы урманнарында яши. ТРның барлык р-ннарында да очрый. Ылыслы, күбрәк нарат урманнарында оялый. Утрак һәм күчеп йөри торган кош. Гәүдә озынлыгы 15 *см* га кадәр, авырлыгы 35 *г*, канат җәеме 28 *см*. Баш түбәсе, муены, канатлары һәм койрыгы кара, аркасы соры, койрык өсте ак, ата Б.ч.ның түше кызыл, анасыныкы көрән төстә. Кыска, юан томшыгы, казналык кырыйларының эчкә бөгелеше орлыкларны тартып алу һәм ваклау өчен җайлашкан. Март аенда Б.ч.лары парлашалар һәм оя коралар. Касә формасындагы ояларын зур булмаган чыршыларда ясыйлар. Ана Б.ч. көрән, кызгылт тимгелле зәңгәрсу-яшел төстәге 4–5 йомырка сала. Үсемлек орлыклары, җиләк-җимеш б-н туклана.

**БАЛА́Н-БУЛӘ́К** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 33 *км* төньяктарак урнашкан. 2002 елда 148 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантонына керә. 1930 елның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең

30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 389, 1949 да — 302, 1958 дә — 286, 1970 тә — 247, 1979 да — 203, 1989 да — 128 кеше.

**БАЛА́НДИН** Пётр Александрович (19.8.1925, Балык Бистәсе р-ны Бәтке а. — 8.7.1994, Казан), театр рәссамы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968). Казан сәнгать уч-щесенең театр бизәлеше бүлеген тәмамлый (1950). Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1952). 1950–85 елларда Татарстан Күчмә театрының баш рәссамы. Театр репертуарындагы спектакльләрнең барысы да диярлек — татар драматургиясе әсәрләре, чит ил, рус, совет авторлары пьесаларын кертеп — аның тарафыннан бизәлә. М.Шамхаловның «Каенана» (1962), С.Алёшинның «Палата» (1963), Т.Закировның «Урман егете» (1964),



П.А. Б а л а н д и н. «Мещаннар» (М.Горький) спектакленә декорация эскизы. 1966. Республика күчмә театры.

Ю.Әминовнең «Умырзаялар» (1964), К.Гольдонинның «Кызык хәл» (1964), Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1965), М.Шәрифуллинның «Агайлар» (1966), Т.Закировның «Яучы» (1966), М.Горькийның «Мещаннар» (Бөтенрос. драма, муз. һәм балалар театрлары спектакльләре смотры дипломы, 1967) әсәрләре буенча куелган һәм «Үзебез сайлаган язмыш» (Т.Миңнуллин, 1973), «Сары чәчәк ата көнбагыш» (А.Гыйләҗев, 1974) спектакльләренә декорацияләр — аның иң уңышлы хезмәтләреннән. Б. үзен спектакльнең төп идеясен киңрәк ачу мөмкинлеге бирүче нәкышь-сәхнә остасы буларак таныта. Республика театр рәссамнары күргәзмәләрендә (1964, 1970), төбәкләрдәге театр рәссамнарының иҗат семинарында (Мәскәү, 1957) катнаша.

*Әд.:* Татар дәүләт драма һәм комедия театры. К., 1980.

**БАЛАНДЫ́Ш** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 16 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2002 елда 483 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, киез итек басу, тегүчелек, баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.та мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2082,6 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 98 ир заты; 1859 да — 814, 1897 дә — 1167, 1908 дә — 1288, 1920 дә — 1287, 1926 да — 1003, 1938 дә — 694, 1949 да — 556, 1958 дә — 450, 1970 тә — 534, 1979 да — 454, 1989 да — 459 кеше.

**БАЛАНҖАР**, к. *Бәләнҗәр*.

**БАЛАНЛЫ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Баланлы елгасы буенда урнашкан. 2002 елда 370 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, тирес кирпече сугып сату һәм олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3386,5 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Карамалы волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 630, 1920 дә — 1215, 1922 дә — 847, 1926 да — 754, 1949 да — 595, 1958 дә — 557, 1970 тә — 649, 1979 да — 553, 1989 да — 386 кеше.

**БАЛАНЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама арьягында. Ыкның сул кушылдыгы. Озынлыгы 12,5 *км*, бассейнының мәйданы 60,5 $км^2$. Мөслим р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Баланлы авылыннан 2,2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Олы Чакмак авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 8%. Б. елгасының 1,5 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 $км/км^2$. Катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 $л/с \cdot км^2$ га кадәр. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,06 $м^3/с$.

**БАЛАНЛЫ́** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Лениногорск–Азнакай автомобиль юлы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 44, 1938 дә — 75, 1949 да — 86, 1958 дә — 47, 1970 тә — 40, 1979 да — 25, 1989 да — 13 кеше.

**БАЛА́НОВО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), бронза дәверендә (б.э.к. 2 нче меңьеллыкның 1 нче яртысы — 11–9 йөзләр) Урта Идел буенда яшәүчеләргә нисбәтле археол. культура. Атамасы Чуаш Респ-касындагы Баланово авылы янында табылган каберлеккә бәйле. Беренче тапкыр О.Н.*Бадер* тарафыннан тасвирлана. Казу эшләре 1933–57 еллар арасында башкарыла. Кайбер тикшеренүчеләр Б.к.н (Фатьяново, Урта Днепр һ.б. б-н беррәттән) бау эзле чүлмәкләр һәм «сугыш балталары культурасына», икенчеләре Фатьяново культурасының җирле төркеме даирәсенә кертәләр. Б.к.н Һинд-Европа тел берлегенә кергән кабиләләр калдырган дип уйланыла. Б.к. халкы терлекчелек, ихтимал, игенчелек б-н дә көн күргән, таштан эш кораллары (балта, сөңге-ук очлыгы, пычак, без, кыргыч, өтерге, чапкыч, ашлык төйгечләр һ.б.) ясаган, арбалардан файдаланган, бакыр эретеп койган



Баланово культурасына караган шомартылган таш балталар. Җыелма. Казан ун-тының археол. музее фондлары.

(балта, сөңге очлыгы, божрасыман колак тагылмалары, алкалар һ.б.), кулдан әвәләнгән түгәрәк төпле шарсыман чүлмәкләр, амфора, башка төрле савыт-саба җитештергән.

Б.к. халкы биек урыннарга салынган авылларда яшәгән, аларны өстәмә рәвештә тирән чокырлар, җир өемнәре б-н ныгыткан. Мәетләр кабергә бөкләнгән килеш күмелгән, кабер өстенә курганнар өелгән; хатын-кыз кабергә — башын көнчыгышка каратып, сул ягы б-н; ирләр башларын төньякка яки көньякка каратып, уң ягы б-н салынган. Б.к. халкы антропологик яктан Фатьяново культурасы халкыннан шактый аерылып торган һәм Урта диңгезнең көнчыгышындагы озынча битле европеоидлар тибына кергән. Татарстан терр-ясендә Б.к. истәлекләре Буа р-нының Козловка, Апас р-нының Шәмбалыкчы авыллары һәм Идел алдының башка урыннарында очрый.

*Әд.:* Б а д е р О.Н. Балановская культура. М., 1963. *Р.С.Габәшев.*

**БАЛАСАГУНИ́** Йосыф Хас-Хаҗиб (1016 — 1021 еллар арасы, Баласагун ш. — 1070 тән соңрак), төрки шагыйрь, Караханилар дәүләте сараенда баш вәзир (олугъ хас-хаҗиб). Карлук-уйгыр шивәсендә язылган һәм төрки халыкларның уртак әдәби ядкәре булган «Кутадгу белег» («Игелекле белем», 1069–70) исемле үгет-нәсыйхәт характерындагы поэма авторы. Шул заманның фәлсәфи мәсьәләләрен тирәнтен яктырткан, фәнни һәм әдәби

кыйммәткә ия булган поэмасы өчен автор хас-хаҗиб — сарай вәзире итеп билгеләнә. Б. төрки телле шигърияттә беренче булып *гаруз* шигъри үлчәм системасын куллана. «Котадгу белег» поэмасы сигез буынлы кыскартылган мөтәкариб ( ·.– ·.– ·.– ·.– ) вәзене б-н язылган 6722 *бәйт*тән, шигъри һәм чәчмә кереш сүзләрдән, 85 бабтан һәм өч бүлекле соңгы сүздән тора. Әсәрнең тоташ сюжеты юк. Башындагы 4 баб, Шәрекъ шигърияте традицияләренә хас булганча, Аллаһыны мактаудан, Мөхәммәд пәйгамбәр, беренче дүрт хәлифә һәм караханилар идарәчесе Табгач Богъра ханга мәдхия укудан гыйбарәт. 5 нче бабта Бруж йолдызлыгы тасвирлана, 6–11 бабларда шагыйрь игелеклелек, акыл, белем һәм сүзнең бөеклеге, мәңгелеге турында фикер йөртә. Поэма әлеге сыйфатларны чагылдыручы персонажларның үзара бәхәсе рәвешендә корылган: Көнтугды, Айтулды, Угдулмыш — Шәрекъ мөселман дөньясының рухи кыйммәтләре саналган Гаделлек, Акыл һәм Бәхетне гәүдәләндерәләр. Дүртенче символик образ — Үзгәрмеш кеше гомеренең кыскалыгы, үлемнең котылгысызлыгы турындагы суфичылык тарафдарлары алга сөргән фикерләрне чагылдыра.

Поэмада Караханилар дәүләтенең иҗтимагый тормышы сурәтләнә, сарай әһелләренең һәм феодаль-клерикаль аксөякләрнең әхлакый йөзе тасвирлана, җәмгыятьнең социаль төзелеше мәсьәләләре күтәрелә. «Котадгу белег» — урта гасырлар төрки әдәбиятында кешенең бөеклегенә дан җырлаучы, дәүләт б-н гадел һәм акыллы идарә итү идеалын чагылдыручы, законны өстен куючы беренче әсәр. Поэмада төрки халык иҗаты үрнәкләре (мәкаль һәм әйтемнәр) зур урын алган. Анда борынгы төрки, һинд-кытай, гарәп-фарсы әдәбиятларындагы әхлакый-этик традицияләр бергә кушылган, төрки әдәбиятта дидактик юнәлешкә нигез салынган. Әсәр Идел буенда һәм Урал төбәгендә татарлар арасында киң тарала. Поэма 20 нче йөзгәчә төрки халыклар әдәбияты үсешенә көчле йогынты ясый. Татар әдәбиятында «Котадгу белег» әсәренең йогынтысы Кол Гали, Мәхмүд Болгари, Котб, Мөхәммәдъяр, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Акмулла, Дәрдемәнд, Г.Тукай, М.Гафури, Г.Исхакый һ.б. әдипләрнең иҗатларында чагылыш таба.

Ә с ә р.: Наука быть счастливым. М., 1971; Благодатное знание. М., 1983.

*Әд.:* В а л и т о в а А.А. К вопросу о фольклорных мотивах в поэме «Кутадгу билиг» // Советское востоковедение. 1958.№ 5; А б и л о в Ш. «Кутадгу билиг» в булгаро-татарской литературе // Советская тюркология. 1970. № 6; Г а н и е в а Р.К. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. К., 1988.

*Р.К.Ганиева.*

**БАЛАХНА́ КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), *неолит* дәверендә (б.э.к. 4 нче меңьеллыкның ахыры — 3 нче меңьеллык), Урта Идел буенда урнашкан археол. культура. Атамасы Түбән Новгород өлкәсенең Балахна шәһәре янындагы туктаулык исеменә бәйле. Өйрәнү 19 йөздән алып барыла. Урта Идел буе истәлекләрендәге уемлы-тарак теше эзле савыт-саба нигезендә 1960 елларда А.Х.*Халиков* тарафыннан тасвирлана. Ш.у. В.В.Никитин, В.П.Третьяков та аларны тикшерә (соңгысы Б.к.ның Урта Идел буенда уемлы-тарак теше эзле аерым культурасы булган дип саный). Б.к. халкы елга, күл буйларында яшәгән, аучылык һәм балыкчылык б-н көн күргән. Яртылаш җиргә иңгән 2–4 турыпочмаклы бүлмәдән торган, учаклы, дивар буйлап сәке сузылган, хуҗалык базлары булган тораклар табыла. Б.к.на очлы һәм түгәрәк төпле, калын стеналы, уемлы-тарак теше эзле бизәк төшерелгән савыт-саба хас. Чакматаштан ясалган сөңге, ук очлыклары, кыргыч, балта, пычак, өтерге һ.б. эш кораллары табыла. ТР терр-ясендә Б.к. истәлекләре Идел, Зөя, Казансу елгалары тирәсендә: Яшел Үзән р-нының Октябрь посёлогында, Займище, Кече Отар авылларында, Дәрвишләр посёлогында очрый.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; Т р е т ь я к о в В.П. Культура ямочно-гребенчатой керамики в лесной полосе европейской части СССР. Л., 1972; Н и к и т и н В.В. Каменный век Марийского края. Йошкар-Ола, 1996.

*Р.С.Габәшев.*

**БАЛАХЧИНО́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 18 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы яры буенда. 2002 елда 76 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек майор А.Е.Лебедевның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 1736 да Б.да таштан Казан Мәрьям ана чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 208 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Лаеш, 1922 дән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 197 ир заты; 1859 да — 571, 1897 дә — 672, 1920 дә — 701, 1926 да — 696, 1949 да — 418, 1958 дә — 436, 1970 тә — 282, 1979 да — 206, 1989 да — 104 кеше.

**БАЛАШО́В** Юрий Анатольевич (16.4.1951, Казан), журналист. Казан ун-тын тәмамлый (1973). Мәкаләләре 1973 елдан «Комсомолец Татарии» г-тасында басыла башлый. 1973–89 елларда Казанда күп тиражлы «За регулярный рейс», «Голос строителя» (1979 дан мөхәррир) г-таларында, 1989–92 дә «Офык» — «Панорама» ж-лында (1989 дан җаваплы сәркәтип, 1991 дән мөхәррир) эшли. «*Казань*» ж-лын оештыручы һәм аның беренче баш мөхәррире (1992 дән). Язмалары ш.у. «Правда» (Мәскәү), «Вечерняя Казань», «Казанские ведомости», «Республика Татарстан» г-таларында басыла. Республика матбугатында ТРдагы иҗтимагый-сәяси һәм тарихи-мәдәни процессларга багышланган репортажлар һәм мәкаләләр б-н чыгыш ясый.

*Әд.:* С а р т а к о в а Т. Кто есть кто сегодня // Читающая Россия. 1994. № 4.

**БАЛДЫ-КЕНӘ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 28 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 180 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, киез итек басу б-н шөгыльләнә; 1910 елларда Казан — Екатеринбург тимер юлы төзелешендә эшли. 20 йөз башында Б.дә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 770,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 176, 1897 дә — 194, 1908 дә — 206, 1920 дә — 228, 1926 да — 244, 1938 дә — 289, 1958 дә — 280, 1970 тә — 295, 1979 да — 226, 1989 да — 187 кеше.

**БАЛЕ́ЗИНО РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* төньягында урнашкан. Мәйданы — 2589,3 $км^2$. Үзәге — шәһәр тибындагы Балезино посёлогы (Ижевск шәһәреннән 150 *км* төньяктарак). Халкы — 38443 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 елда — 4610, 1979 да — 4153, 1989 да — 4154, 2002 дә — 3710 кеше. Кистем, Падера (Паюра), Әхмәди авылларында татарлар барлык халыкның 95% ын тәшкил итә, алар ш.у. Нурызово, Гордино (Уръякала), Биктеш, Югары Кистем авылларында, шәһәр тибындагы Балезино посёлогында һ.б. да яши. Татар авылларыннан иң борынгылары: Кистем (1678 елдан мәгълүм), Падера (Паюра) һәм Әхмәди (17 йөз ахыры — 18 йөз башы). Кистем авылында 19 йөзнең 2 нче яртысыннан мөселман мәктәбе, 20 йөз башында 2 мәчет (берсе — 1901–03 тә төзелгәне — хәзергәчә сакланып калган) була. Кистем һәм Падера (Паюра) авылларында үзешчән сәнгать коллективлары эшли. Кистем авылында Б.р. ның Татар мәдәни үзәге бар, татар мәктәбендә татар этнография бүлмәсе эшли. Гордино авылында 1323 елгы болгар кабер ташы табыла (Казанга җибәрелә). Б.р.нда эшләгәндә З.Ш.*Хәсәнов* Соц. Хезмәт Герое исеменә лаек була, астроном И.В.*Әхмәров* туган.

**БАЛЕ́Т** (итал. balletto, соңгы латин ballo — биим), музыкаль-хореографик сәхнә сәнгате төре. Б.тагы төп сәнгати алым — бию, ул пантомима б-н бергә сюжетны һәм геройларның характерларын чагылдыра. «Б.» төшенчәсе 16 йөзнең 2 нче яртысында Италиядә барлыкка килә һәм баштарак спектакльдәге бию мәгънәсендә кулланыла. 16 йөз ахырында Б. дип музыканы, җыр, сөйләм һәм биюне берләштергән тамашаны атый башлыйлар. 17 йөз дәвамында Б. зиннәтле сарайлар тамашасы характерындагы күренеш буларак, башлыча, Франциядә үсеш ала. 18 йөздә мөстәкыйль сәнгать төренә әверелә. 19 йөзнең 2 нче яртысында Россиядә композиторлар П.И.Чай-









М. Җәлил исем. Татар опера һәм балет театрында куелган балетлардан күренешләр:
1. С. Прокофьев, «Ромео һәм Джульетта»; 2. П. Чайковский, «Йокыга талган гүзәл»; 3. Ф. Яруллин, «Шүрәле»; 4. П. Чайковский, «Аккош күле».

ковский, А.К.Глазунов һәм балетмейстерлар М.И.Петипа, Л.И.Иванов («Йокыга талган гүзәл», «Щелкунчик», «Аккош күле», «Раймонда») иҗатында Б. чәчәк ату чоры кичерә. 1900 елларда балетмейстерлар М.М.Фокин, А.А.Горский балет сәнгатенең яңа эстетик хасиятен булдыралар, аңа хәзерге сәнгать һәм әдәбият идеяләрен кертәләр. 19 йөз ахырында Б. сәнгатенең бөтен дөньяга таралуына С.П.Дягилевның «Рус сезоннары» һәм А.П.Павлова гастрольләре этәргеч бирә. Хәзерге Б. сәнгатенең үсеш этаплары Р.Глиэрның «Кызыл мәк», Б.Асафьевның «Бакчасарай фонтаны», С.Прокофьевның «Ромео һәм Джульетта»сы, А.Хачатурянның «Гаянэ», «Спартак» әсәрләрендә һ.б. да чагыла, аңа стильнең, жанр һәм форманың күптөрлелеге — классикадан алып джаз һәм модерн-балетка кадәр булган төрләрне колачлавы хас.

Проф. татар Б. сәнгате 20 йөзнең 1 нче чирегендә барлыкка килә. Аның тәүге адымнары татар драма театрының үсеше һәм аның сәхнәсендә музыкаль (барыннан да бигрәк С.Сәйдәшев әсәрләре), җырлы һәм биюле пьесалар (Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә», М.Фәйзинең «Галиябану», К.Тинчуринның «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», «Ил», Т.Гыйззәтнең «Наёмщик» һ.б. әсәрләр) куелу б-н бәйле. Татар сәхнә хореографиясе үсешенә С.Габәши, Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградовларның беренче милли «*Сания*» операсы йогынты ясый (1925 елгы редакциядә — балетм. Ю.Муко; 1930 да балетм. Г.Таһиров). 1939 елда Казанда Татар опера һәм балет театры ачылгач, балет сәхнәсендә яңа формалар, муз. һәм пластик милли колорит эзләү активлаша. Г.Таһиров куелышындагы татар сәхнә биюләре Н.Җиһановның «Качкын», «Алтынчәч» (1939, 1941), М.Мозаффаровның «Галиябану» (1940) операларына һ.б.га кертелә. Бер актлы «Яшьләр ялда» спектаклендә беренче тапкыр татар тематикасында балет кую омтылышы ясала (А.Ключарёв музыкасы, биюләрне Г.Таһиров куя). 1945 елның 8 мартында беренче милли балет — Ф.*Яруллинның «Шүрәле»* балетының премьерасы була (Ә.Фәйзи һәм Л.Якобсон либр., балетм. Л.Жуков һәм Г.Таһиров). Төп хореографик партияләрне беренче башкаручылар: Л.Гацулина (Сөембикә), Б.Әхтәмов (Былтыр), В.Романюк (Шүрәле). Соңрак татар балет сәхнәсендә «Шүрәле» берничә тапкыр яңартылып күрсәтелә (1952, балетм. Я.Брунак; 1957, балетм. Л.Бордзиловская; 1970, 1986, 2000, балетм. Л.Якобсон, театр редакциясендә). 1946 да Н.Җиһановның «Зөһрә» балеты (балетм. Ф.Гаскәров) куела. 1950 еллар милли балетның даими үсеш чоры була. Татар опера һәм балет театрында Ә.Бакировның «Алтын тарак» балеты куела (балетм. Л.Бордзиловская, 1957; 1971 елда «Су анасы» исеме б-н 2 нче редакциясе, балетм. И.Смирнов); Р.Гобәйдуллинның «Кисекбаш» (балетм. О.Тарасов, 1958); А.Ключарёвның «Тау акияте» (балетм. Л.Бордзиловская, 1959) балетлары куела. Узган гасырның икенче яртысында сәхнәдә куелган балет спектакльләре — З.Хәбибуллинның «Раушан» (балетм. Е.Дорофеев, 1961; 2 нче редакциясе 1974 тә «Сихерләнгән малай» («Заколдованный мальчик») исеме б-н, балетм. Д.Арипова); Н.Җиһановның «Ике легенда» («Зөһрә», «Нҗери»), балетм. Д.Арипова (1971); А.Монасыйпов музыкасына бер актлы «Үлмәс җыр», балетм. Д.Арипова (1976); Р.Яхин музыкасына «Фидаи», балетм. Л.Исаков (1987) балетлары. Төрле елларда татар балетында төп хореографик партияләрдә биегән артистлар: Б.Әхтәмов, А.Гацулина, Н.Юлтыева, Ә.Нарыков, С.Хәйруллин, Рөстәм һәм Ревдар Садыйковлар, З.Гайфуллина, Г.Калашникова, Г.Бәширова, Ш.Мифтахетдинов, С.Хантимерова, К.Гайнуллин, И.Хәкимова, Н.Сәрвәров, В.Бортяков, В.Яковлев, В.Яруллин, Р.Әбелханов, Е.Щеглова, Е.Кострова, Б.Смагулов, Л.Мөхәммәтгалиева, З.Хәмдиева, Н.Мәһдиева һ.б.

Татар опера һәм балет театры репертуарында милли Б. б-н беррәттән Көнбатыш Ев-

ропа һәм рус классик мирасы, ш.у. хәзерге балет сәнгате әсәрләре дә бар. Татар опера һәм балет театрында куелган «Кыйсса-и Йосыф» («Сказание о Йусуфе»), композиторы Л.Любовский, либретто авторы Р.Харис, балетмейстрлары Н.Боярчиков һәм Г.Ковтун, сәхнәгә куючы А.Злобин, костюмнар — А.Игнатьева, декорация В.Самохин эшләнешендә) балеты 21 гасыр башында Татарстан балет сәнгатенең иң зур казанышы була. Спектакльдә төп партияләрне башкаручылар: Н.Канетов, А.Белов, Б.Смагулов, Е.Щеглова, Е.Кострова, Л.Мөхәммәтгалиева, Д.Мочалов, Д.Алексеева. Балетның нигезенә Кол Галинең төрки халыкларда киң таралган шул исемдәге поэмасы сюжеты салынган. Анда иманга тугрылык, бурыч, әхлак, мәхәббәт кебек гомумкешелек кыйммәтләре турындагы фәлсәфи хикәят музыка һәм хореография чаралары ярдәмендә чагылдырыла. Либретто авторы Р.Харис, композитор Л.З.Любовский, Йосыф партиясен башкаручы Н.Канетов «Хәзерге мәдәниятләр диалогы шартларында милли эпос традицияләрен үстергән өчен» РФ Дәүләт бүләгенә лаек була (2005).

*Әд.:* Горшков В.Н. Из истории татарского балета // Татарский академический театр оперы и балета имени Мусы Джалиля. К., 1994.

*В.Н.Горшков.*

**БА́ЛИНТ** (Balint) Габор (1844 — 1913), венгр тюркологы, татар фольклоры әсәрләрен җыючы һәм нәшер итүче. 1870 елларда татар телен өйрәнү өчен Казанга килә. Казан губернасының Мамадыш, Лаеш, Казан өязләрендәге фольклор экспедицияләре нәтиҗәләре, ш.у. Казандагы фәнни эзләнүләре нигезендә Будапештта «Казан татарларының тел белеме» (1875) җыентыгын бастырып чыгара. Икенче киңәйтелгән басмада (1877) кереш мәкалә һәм керәшен татарларның фольклорына хас үрнәкләр: мәкаль, табышмак, борынгы җыр, бәет, әкиятләр, ш.у. Өй иясе, Су анасы, Шүрәле, Албасты, Убыр һ.б. әкият персонажлары турында мифологик хикәяләр бирелә. 1877 дә чыккан басма керәшен татарлар фольклорының барлык жанр төрләрен туплаган беренче һәм хәзерге көнгә кадәр бердәнбер җыентыгы булып санала.

Хезм.: Kazani-tatar nuelvtanilmanyjk. I Fuzet. Kazani-tatar szovegek. Bdpst., 1877.

*Әд.:* Ярми Хәмит. Татар халкының поэтик иҗаты. К., 1967.

**БАЛКАРАКЛА́Р** (Sphingidae), төнге күбәләкләр семьялыгы. Дөнья фаунасында — 1200 ләп, Татарстанда 20 төре бар. Киң күкрәкле, юан корсаклы, алгы канатлары озынча һәм тар, арт канатлары кыска, орчыксыман гәүдәсе б-н аерылып тора. Бер урында канатларын тиз җилпеп торып, чәчәккә кунмыйча гына нектар суырырга җайлашканнар. Тәңкәканатлылар арасында иң тиз очучылардан санала, тизлекне 60 *км/сәг* кә кадәр җиткерә алалар. Эңгер-меңгердә һәм төнлә активлар, кайбер төрләре көндез дә актив. Күбәләк кортының арткы өлешендә каты мөгезе бар. Б. республиканың барлык терр-ясендә очрый. Бигрәк тә нарат Б. күп. Бу — канатларының ян-якларында нечкә ак кайма һәм аксыл соры сурәт төшкән, соры төстәге зур күбәләк. Июнь-июль айларында оча. Кортлары нарат агачында үсә. Зелпе төклетурасы — көндез очучы Б.ның бер төре. Уртача зурлыкта. Әле яңа гына күбәләккә әверелгәненең канатларында кара тәңкәләр була, ләкин беренче очыштан соң алар коела һәм канатлары кара каймалы үтә күренмәлегә әверелә. Гәүдәсе сары, карасу төстәге сызыклар бар. Тышкы кыяфәте б-н әлеге күбәләк төклетураны хәтерләтә. Күбәләк корты зелпедә үсә. Юкә Б., тирәк Б., йогырт Б. — еш очрый торган төрләре. «Үле баш» исемле Б., сирень Б. һәм көзләч Б. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* к. *Күбәләкләр* мәкаләсендә.

*Н.В.Шулаев, Н.Г.Петров.*

**БАЛЛА́ДА** (франц. ballade, соңгы латин. ballo — биим), поэзиянең лироэпик жанры. Традицион Б. нигезендә героик, тарихи, фантастик яки көнкүрештәге вакыйгалар ята. Аерым үзенчәлекләре б-н (хикәяләү һәм сюжетка ия булуы) Б. поэмага тартым. Хикәяләүченең кичерешләре Б.га тирән тәэсирлелек һәм хислелек өсти. Татар әдәбиятында Б.га нигез салучы булып Г.Тукай тора («Шүрәле», «Су анасы»). 1930 елларда күп кенә Б.лар иҗат ителә, мәс., Ә.Фәйзинең «Дала һәм кеше», «Кара таш ник дәшми?». Соңрак Б. жанрына М.Җәлил («Сандугач һәм чишмә», «Кызыл ромашка»), Ф.Кәрим («Тимер һәм тимерче», «Үлем уены») мөрәҗәгать итәләр. Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда Б. жанры үсешенә Х.Туфан («Упкыннар өстендә»), С.Хәким («Күргәннәр аны», «Сары капкалы йорт»), Ә.Давыдов («Солдат турында баллада») үз өлешләрен кертәләр. Хәзерге татар әдәбиятында Б. жанры Ә.Баян («Төнге бәхәс»), Роберт Әхмәтҗанов («Соңгы танк», «Таш елады», «Фидаи»), М.Әгъләмов («Шагыйрь турында баллада»), Р.Зәйдулла («Каләм турында баллада») һ.б. шагыйрьләр иҗатында уңышлы дәвам иттерелә.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Гыйльманов Г. Татарская баллада. К., 1989.

*Т.Н.Галиуллин.*

**БА́ЛЛОД** Франц Владимирович (1880, Эстониянең Юрьев ш., хәзерге Тарту ш. — 1924 тән соң), археолог, сәнгать белгече. Юрьев (1908–10), Мюнхен (1910–12) ун-тларында укый. 1913 елдан Мәскәү археол. ин-тында Борынгы Мисырны өйрәнү (египтология) каф. мөдире. 1919–22 елларда Казан ун-тында профессор. Алтын Урда шәһәрләрендә (Үкәк, Сарай әл-Мәхрусә, Сарай әл-Җәдид һ.б.) археол. казу эшләренә җитәкчелек итә. 1923 тән Мәскәү ун-тының Археология һәм сәнгать белеме ин-тында. 1924 тән эмиграциядә. Хезмәтләре Борынгы Мисыр, Алтын Урда тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә карый.

Хезм.: Приволжские «Помпеи». М.-П., 1923; Старый и Новый Сарай — столицы Золотой Орды. К., 1923; Очерки истории древнеегипетского искусства. М.-Саратов, 1924; Культура Золотой Орды // Новый Восток. 1924. № 6.

*И.Л.Измайлов.*

**БАЛЛУ́Т** (Lamium), иренчәчәкләләр семьялыгыннан бер, ике яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 лап төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Америкада очрыйлар. ТР терр-ясендә 5 төре бар, алар арасында ак Б. яки сукыр кычыткан (L. album), гиб-



рид Б. (L. hybridum), тимгелле Б. (L. maculatum) — иң киң таралганнары. Урманнарда, куак араларында, чүп үлән буларак, бакчаларда, кеше яши торган җирләрдә үсә. Үсемлекнең озынлыгы 10 нан алып 120 *см* га кадәр. Сабагы туры, кырлы. Яфраклары бөтен, каршыдаш, тешле яки каяу читле. Ак Б. яфраклары кычыткан яфракларын хәтерләтә, әмма чакмый (икенче исеме шуннан). Чәчәкләренең формасы дөрес түгел, кыңгыраусыман көпшә, ак, кызыл, алсу төстә, өске яфраклар куентыгында ялган такыяга җыелган. Җимеше — күп чикләвек. Яздан алып көз азагына кадәр чәчәк аталар. Җимешләре июнь-сентябрь айларында өлгерә. Орлыктан һәм озын шуышма тамырчалардан үрчи, әрәмәлекләр хасил итәләр. Медицинада ак Б. чәчәкләрен кулланалар. Аларда эфир мае, сапониннар, флавоноидлар, С витамины, лайла, дуплау матдәләре бар. Бөрештерү, кан туктату һәм какырык чыгару өчен файдаланыла. Баллы үсемлекләр.

**БАЛЛУТЧАЛА́Р**, к. *Иренчәчәкләләр.*

**БАЛЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Куак елгасының уң кушылдыгы (Чишмә елгасы бассейны). Озынлыгы 8,1 *км*, бассейнының мәйданы 27,2 $км^2$. Лениногорск р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Баллы авылыннан 1 *км* төньяктарак, тамагы Кузьминовка авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 270 *м*, тамагыныкы — 110 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 66%. Б. елгасының 2,9 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 $л/с·км^2$. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 $км/км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,101 $м^3/с$. Б. бассейнында бер буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БАЛЛЫ́ ГӨМБӘЛӘ́Р**, рядовкалылар һәм строфарияләр семьялыкларына караган берничә төр гөмбәнең уртак атамасы. ТР да 4 төре бар: көзге (чын) Б. г. (Armillariella mellea), болын Б.г. (Marasmius oreades), җәйге Б.г. (Kuehneromyces mutabilis), күкертсыман сары ялган Б.г. (Hypholoma fasciculare) киң таралган. Көзге яки чын Б.г. агач төпләрендә һәм тамырларында, ауган агачларда зур төркемнәр булып үсә. Эшләпәсенең диаметры 3–10 *см*, яшь гөмбәнең читләре кабарынкы, эчкә бөгелгән, соңрак, үсүенә карап, ул яссыга әйләнә, кайвакыт уртасында төере була. Тышы көрәнрәк яки коңгырт сары, күп санлы кабырчыклы. Пластинкалары аксыл сары төстә. Сабының өске ягында ак ярылы боҗрасы бар. Йомшагы ак, көпшәк, тәмле гөмбә исе килеп тора. Сентябрь-октябрь айларында өлгерә. Тере агачлар үзагачын бозучы, урман төрләренең куркыныч паразиты булып тора. Гөмбәлек тере үзагачка үтеп керә, агач кайрысы астында тарала, туфрак һәм тамыр-

лар буйлап ул агачтан агачка күчә, урманның бер өлешен корыта. Болын Б.г. болыннарда, көтүлекләрдә, сирәгрәк аланнарда һәм урман буйларында үсә, июньнән сентябрьгә кадәр очрый. Эшләпәсенең диаметры 3–5 *см*, яшь гөмбәнеке конуссыман, соңрак киңәйгән, уртасында җәенке төере бар, саргылт төстә. Төбе тигез, тыгыз, кимерчәкле. Пластинкалары киң, тонык сары төстә, ак ончыл куныклары бар. Гөмбә өлгергәннән соң череми, кибә. Җәйге Б.г. агач төпләрендә, тамырыннан корыган кәүсәләрдә, яфраклы агачларның куышларында үсә, июньнән октябрьгә кадәр очрый. Эшләпәсенең диаметры 4–6 *см*, юка итләч, башта кабарынкы, астан челтәрсыман япма б-н капланган, соңыннан яссы-кабарынкы һәм җәелгән, сары көрән төстә, төбе цилиндрсыман, бөгелгән, коңгырт, кабырчыклы божралы. Ялган Б.г. агач төпләрендә, яфраклы һәм ылыслы токымнарның черегән үзагачларында, июнь ахырыннан сентябрьгә кадәр очрый, еш кына төркем-төркем булып үсәләр. Эшләпәсе юка итләч, саргылт, уртасында караррак, кызгылт яки кызгылт сары төсмерләре бар, яшь гөмбәнеке кыңгыраусыман, соңыннан яссы кабарынкы. Пластинкалары яшькелт төстә, төбе б-н тоташ. Төбе нәзек, 5 *см* чамасы озынлыкта, сары төстә, куыш. Йомшагы ачык сары төстә, ачы. Ялган Б.г. дән тыш барлык төрләре дә ашарга яраклы.

**БАЛЛЫ́ ЧӘЧӘ́К**, ж и т е н с а б а к, с а р ы ч ә ч ә к (Linaria), сыраҗчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 ләп төре билгеле. Төньяк ярымшарның тропиктан тыш өлкәләрендә, күбесенчә Урта диңгез буенда очрыйлар. ТРда бер төре — гади Б.ч. (L. vulgaris) барлык районнарда да таралган. Нарат урманнарында, болыннарда, кырларда, чүпле җирләрдә, юл буйларында үсә. Тамыры — үзәк, юан. Сабагы туры, 90 *см* га кадәр озынлыкта. Яфраклары утырма, чиратлашкан, кыяклы — ланцетсыман, очлы. Чәчәкләре эре, саргылт төстә, чуксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — дискcыман кара орлыклар б-н тулган ике оялы йомыркасыман тартмачык. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август аеннан өлгерә башлый. Бер үсемлек 30 меңгә кадәр орлык бирә. Орлыклардан һәм тамыр үрентеселәннән үрчиләр. Үләндә алкалоидлар, флавоноидлар, органик кислоталар, сапониннар, пектин матдәләре бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсен тир чыгару, үт һәм бәвел кудыру, тире авыруларын дәвалау өчен кулланыла. Баллы, декоратив, агулы, чүп үлән. Яшел үләне — инсектицид.

**БАЛОБА́Н**, к. *Дала лачыны.*

**БАЛО́ЕВ** Арнольд Андреевич (31.3.1939, Новосибирск өлкәсенең Кожевников р-ны Кожевниково а.), мәгълүмат технологияләре гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1994), проф. (1998). 1962 елда Казан авиация ин-тының очкыч аппаратлар ф-тын тәмамлый, 1968 елдан шунда ук автоматика һәм идарә итү кафедрасында эшли. Хезмәтләре бүленгән параметрлы системалар б-н идарә итүгә карый. Халәте тулысынча үлчәнмәгән системалар б-н идарә итү алгоритмын тикшерә, даими коэффициентлы бериш булмаган сызыкча тигезләмәләр системаларын чишүнең яңа формасын чыгара.

Х е з м.: Синтез субоптимального управления при неполном измерении для систем с распределёнными параметрами // Авиац. техника. 1987. № 1; Универсальная форма записи решения систем линейных неоднородных дифференциальных уравнений с постоянными коэффициентами // Изв. вузов. Математика. 1991. № 11.

**БАЛТА́ЕВ** Газиз Минай улы (15.4.1925, Әстерхан өлкәсенең Нариман р-ны Яңа Күчергән а. — 23.11.1988, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (20.8.1944, 2.12.1944, 4.7.1973), сержант. Колхозда эшли. 1943 елдан Кызыл Армиядә. 1943 елның октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, танкка каршы 247 нче аерым тупчы дивизионның орудие расчёты командиры (3 нче удар армиянең 379 нчы укчы дивизиясе). 2 нче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында Балтыйк буен азат итүдә катнаша. 1944 нең 24–25 июлендә Кашино торак пункты (Резекне шәһәреннән көньяк-көнчыгыштарак), 1944 елның 14 сентябрендә Ерцени торак пункты (Эргли торак пунктыннан төньяк-көнчыгыштарак, Мадон р-ны, Латвия), 1944 нең 14 ноябрендә Салдус шәһәре (Латвия) өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. 1944 нең декабреннән туган авылындагы кошчылык ф-касында инженер. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*



Г.М. Балтаев.

**БАЛТА́Й** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ургыды елгасы буенда. 2002 елда 19 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — умартачылык. 1735 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Никольский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә Б. халкы граф Воронцовлар, 19 йөздә алпавыт Кандалинцевлар крепостнойлары була. Крепостной хокук бетерелгәннән соң, авыл җәмәгатенең имана җире 220 дис. тәшкил итә. 1905 тә крәстияннәрнең бер өлеше Сәет авылы халкы б-н берлектә 59 хуҗалыктан торган ширкәт оештыра һәм дворян Чичериннардан 638 дис. җир сатып ала. 1897 дә Б.да чиркәү төзелә. 20 йөз башында земство мәктәбе эшли. 1929 да авылда «Наш труд» к-зы оештырыла, 1950 дә ул — «Авангард», 1954 тә — Хрущёв исем., 1958 дә Куйбышев исем. к-зга керә. 1858 гә кадәр Б. Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Маҗын волостенда, 1858–1902 елларда — Балтай волосте үзәге, 1902–20 дә Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 елның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 149, 1816 да — 218, 1859 да — 414, 1870 тә — 498, 1906 да — 398, 1913 тә — 398, 1920 дә — 434, 1926 да — 391, 1938 дә — 424, 1958 дә — 242, 1970 тә — 197, 1979 да — 123, 1989 да — 18 кеше.

**БАЛТА́Й РАЙОНЫ́**, *Саратов өлкәсендә.* Мәйданы — 1,3 мең *км*². Үзәге — Балтай авылы (Саратовтан 135 *км* төньяктарак). Халкы — 13,4 мең кеше (2002). Татарлар (385 кеше) Балтай, Царёвщина, Садовка авылларында яшиләр. 2000 елдан Б.р. нда татар иҗтимагый оешмасы эшли. Ел саен Сабан туе бәйрәме үткәрелә.

**БАЛТАМА́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 18 *км* көнчыгыштарак, Рангазар елгасы буенда. 2002 елда 32 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1883 тә нигез салына. Революциягә кадәрге чыганакларда Баллы Тамак исеме б-н билгеле. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 531,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт-Муллино волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Сарман р-нында. Халык саны: 1859 да — 180, 1884 тә — 259, 1926 да — 237, 1938 дә — 299, 1949 да — 206, 1958 дә — 180, 1970 тә — 167, 1979 да — 113, 1989 да — 54 кеше.

**БАЛТА́НОВ** Равил Гобәйдулла улы (3.8.1927, Казан — 20.4.1998, шунда ук), философ, филос. фән. д-ры (1974), проф. (1975), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1983). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1954), 1956 елга кадәр шунда ук укыта. 1957 елда Бөтенсоюз юридик ин-тының Казан ф-лында, 1957–59 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында эшли. 1959–74 тә Казан ун-тында укыта. 1974 елдан Казан мед. ун-тында, 1993 кә кадәр — филос. каф. мөдире. Хезмәтләре дин социологиясе, атеизм, Татарстанда ислам дине мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Коръәнне фәнни тәнкыйтьләү. К., 1968; Социологические проблемы в системе научно-атеистического воспитания. К., 1963.

**БАЛТА́НОВА** Гөлнар Равил кызы (16.9.1958, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1994), проф. (1994). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1980). 1984 елдан Казан технол. ун-тында укыта, 1996–98 елларда социаль һәм гуманитар технологияләр ф-тының социаль эшләр каф. мөдире, 1997–98 дә өстәмә белгечлек ф-ты деканы һәм Казанда әл-Бәйт ун-тының (Иордания) Россия бүлекчәсе җитәкчесе. 1998 елдан Казан энергетика ун-тының инженерлык менеджменты каф. мөдире. Хезмәтләре чит илләрдә һәм Россиядә ислам гыйлеме, ислам һәм сәясәт мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Ислам в СССР: анализ зарубежных концепций. К., 1991; Религия в истории и культуре: Учеб. для вузов. М. 2000 (автордаш); Мусульманка. М., 2005; Totalitarian sects and Youth in Modern Russia // Jugend — 2000 jahre nach Gesus. Fr./M., 1996 (автордаш); Sacred journeys. L., 1997 (автордаш).





Балтач посёлогы. 1. М.М.Мөлековның сәүдә йорты бинасы (1914, 1990 еллардагы реконструкциядән соңгы күренеш); 2. М.М.Мөлековның киез итек-киез басу фабрикасы бинасы (19 йөз ахыры – 20 йөз башы).

**БАЛТА́Ч**, шәһәр тибындагы посёлок (2004 елның 9 сентябреннән), Балтач р-ны үзәге. ТРның төньягында, Казаннан 106 *км* ераклыкта, Шушма елгасы буенда, Казан — Екатеринбург тимер юлындагы Шәмәрдән станциясеннән 25 *км* төньяк-көнбатыштарак. 2006 елда 7400 кеше (татарлар) яши. «Мехчы» ачык АЖ, «Балтач» көнкүреш хезмәте күрсәтү, икмәк, май-сөт комб-тлары, кирпеч, «Балтач» терлек азыгы җитештерү з-длары, типография, урта мәктәп, гимназия, балалар сәнгать мәктәбе. Район мәдәният йорты, 2 китапханә. Район үзәк хастаханәсе. «Мигъраҗ» мәчете. 17 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Акман Пустоше исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманчы булып хезмәт итә, игенчелек, терлек үрчетү, киез аяк киеме җитештерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.та 2 мәчет, 2 мәдрәсә, фельдшерлык пункты, шәраб кибете, 2 сыраханә, 10 вак-төякләр кибете, 2 ашханә була; чәршәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2986,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр р-нында, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан район үзәге. Халык саны: 1795 тә — 583, 1859 да — 1073, 1884 тә — 1320, 1897 дә — 1461, 1908 дә — 1554, 1920 дә — 1651, 1926 да — 1576, 1938 дә — 2225, 1949 да — 1668, 1958 дә — 1898, 1970 тә — 2658, 1979 да — 3925, 1989 да — 4887, 2002 дә — 6996 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.



Балтач посёлогы. «Мигъраҗ» мәчете.

**БАЛТА́Ч** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 14 *км* көньяктарак, Эстәрле елгасы буенда. 2002 елда 472 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында Балтач Уразмәтов һәм Казан өязенең Җөри даругасы Туйкә йөзлеге ясаклы татарлары нигез сала. Авылның беренче исеме — «Яңа күчкән Кыпчак авылы». 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре һәм башкорт-вотчинниклар катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.та 2 мәчет, мәктәп, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1840 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Азнакай волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1897 дә — 1047, 1920 дә — 1363, 1926 да — 1148, 1938 дә — 1133, 1949 да — 712, 1958 дә — 514, 1970 тә — 596, 1979 да — 478, 1989 да — 459 кеше.

**БАЛТА́Ч** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 60 *км* көньяктарак, Барҗы елгасы буенда. 2002 елда 59 кеше (татарлар, удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1876 елгы мәгълүматларга караганда, Б.та мәчет була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 356 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Тирсә волостена керә. 1920–21 дә — Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 елдан — ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Красноборд, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 564, 1887 дә — 344, 1920 дә — 593, 1926 да — 795, 1938 дә — 776, 1949 да — 634, 1958 дә — 531, 1970 тә — 458, 1989 да — 82 кеше.

**БАЛТА́Ч** (Юлсубино) авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чошы елгасы буенда. 2002 елда 565 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1619 дан Балтаево исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Елсова Балтачи исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б. та 2 мәчет (1915 нең октябрендә төзелгән беренче җәмигъ мәчетенең бинасы сакланган архит-ра истәлеге), мәдрәсә, 2 тегермән, йон-тукымаману остаханәсе, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1813 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 112 ир заты; 1859 да — 726, 1897 дә — 1173, 1908 дә — 1374, 1920 дә — 1374, 1926 да — 1290, 1938 дә — 1150, 1949 да — 995, 1958 дә — 956, 1970 тә — 1016, 1989 да — 630 кеше. Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин туган авыл.

**БАЛТА́Ч** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 31 *км* көнбатыштарак, Ишем елгасы буенда. 2002 елда 305 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Авыл атамасының 17 йөз уртасында монда утары булган йомышлы татар Балтачы Әмирдәнов исеме б-н бәйле булуы ихтимал. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, кирпеч сугу, балта эшләре, йон тетү, тегүчелек, баш киеме тегү, урман кисү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.та мәчет була. 20 йөз башында монда мәктәп, 2 җил һәм 2 су тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1425,7 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Сөйке волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 82 ир заты; 1859 да — 774, 1884 тә — 1000, 1897 дә — 1013, 1908 дә — 1256, 1920 дә — 1014, 1926 да — 805. 1938 дә — 906, 1949 да — 679, 1958 дә — 614, 1970 тә — 600, 1979 да — 530, 1989 да — 377 кеше.

**БАЛТА́Ч РАЙОНЫ́**, ТРның төньягында урнашкан, Мари Респ-касы һәм Киров өлкәсе б-н чиктәш. Кама алды икътисади р-нына ке-




рә. Мәйданы — 1094,5 *км*². 17 авыл, 1 шәһәр җирлеген, 77 торак пунктны берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Балтач посёлогы. Халкы — 2006 елда 33,4 мең кеше, (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 84,7%, удмуртлар — 12,5%). Шәһәр халкы — 7,4 мең, авыл халкы — 26 мең кеше. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы 1 *км*² га 29 кеше. Район 1932 елның 2 мартында оештырыла. 1920 елга кадәр терр-ясе Казан губернасының Казан өязенә һәм Вятка губернасының Малмыж өязенә, 1920–30 елларда ТАССРның Арча кантонына, 1930–32 дә *Түнтәр районына* керә. Б.р.ның чикләре һәм адм. бүленеше берничә мәртәбә үзгәрә. 1940 та аның мәйданы — 584 *км*², халкы — 25,5 мең кеше, 17 авыл советы, 40 торак пункт исәпләнә. 1958 дә Б.р.на таркатылган Чепья р-ны терр-ясе кушыла. 1960 та район 1094 *км*² мәйдан били, аңа 15 авыл советы, 89 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Б.р. таркатыла, биләмәсе Арча р-нына бирелә. 1965 нең 12 гыйнварында яңадан торгызыла, мәйданы — 1092 *км*², халкы — 31,7 мең кеше, 15 авыл советын, 81 торак пунктны берләштерә. 2005 елның 26 гыйнварыннан муниципаль район дип үзгәртелә. Б.р.ның рельефы — калку тигезлек (биеклеге 170–200 *м*), берничә елга үзәне б-н бүлгәләнә. Терр-ясендә Шушма, аның кушылдыклары Кугубор, Арбор, Көшкәт, Норма елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл-соры һәм соры урман, кәсле көлсу, кәсле карбонатлы туфраклы. Терр-ясенең 10% ы урманлык. Доломит, известьташ, балчык ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: Шушма елгасы, «*Утыртылма урман*» ландшафтлы табигать истәлеге, *Сорнар аучылык тыюлыгы*, *Кара күл*. Район терр-ясендә Казан ханлыгы чорыннан калган 15 ләп археол. истәлек билгеле. А.х. җирләре 89,1 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр 74,7 мең *га* тәшкил итә (2005). Арыш, сабан бодае, арпа, солы, борчак, бәрәңге, җитен, көнбагыш, рапс игелә. Ит-сөт терлекчелеге, сарык, дуңгыз, куян үрчетү алга киткән. 2005 елга районда 23 а.х. пр-тиесе, ш.и. 6 ЖЧЖ, 17 а.х. товарлары җитештерү кооперативы; 2 ярдәмче хуҗалык исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә урнашкан, Карадуган авылында мебель ф-касы эшли. Б.р. терр-ясеннән Казан–Пермь, Балтач–Шәмәрдән автомобиль юллары уза. Районда 54 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 5340 укучы), ш.и. 30 башлангыч, 3 тулы булмаган урта, 20 урта мәктәп; 1 гимназия, балалар сәнгать мәктәбе, 41 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 56 клуб, 34 китапханә, 231 урынлы 3 хастаханә эшли. «Халыклар дуслыгы» (Чепья а.), М.Фәйзи (Шода а.), М.Җәлил, Себер тракты тарихы (Карадуган а.) музейлары бар. Татар телендә «Хезмәт», удмурт телендә «Азьлане» г-талары нәшер ителә.

*Әд.:* Балтач энциклопедиясе. К., 2006. 1 кит.

**БАЛТА́Ч РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* төньягында урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1593 *км*². Үзәге — Иске Балтач авылы (Уфадан 220 *км* төньяктарак). Халкы — 24695 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 елда — 2161, 1979 да — 1942, 1989 да — 14728, 1998 дә — 15776, 2002 дә 3636 кеше. Б.р.нда 80 торак пункт, ш.и. 28 татар, 21 татар-башкорт, 4 татар-мари, 3 татар-удмурт авылы бар. Иң зур татар авыллары (1999): Сәйтәк (998 кеше), Югары Карыш (562), Нөркәй (543), Түбән Карыш (510), Иске Тимкә (554). 2004/05 уку елында Б.р.ның 2 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 38 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татарча «Азатлык» г-тасы нәшер ителә. Югары Карыш авылында халык каһарманы *Батырша*, Сов. Союзы Герое Г.С.*Сәетов*, Дан орденының тулы кавалеры Р.Г.*Тукаев* туган.

**БАЛТАЧИ́ЕВ** Таһир Вәли улы (18.9.1924, Ленинград — 9.8.1997, шунда ук), балет артисты, педагог, БАССР һәм ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1965). 1944 елда Ленинград хореография уч-щесен (педагоглары А.Лопухов һәм А.Писарев) тәмамлый. 1942–65 тә Ленинградтагы С.М.Киров исем. опера һәм балет т-ры балет артисты, 1959 дан педагог-репетитор. Бер үк вакытта 1952–58 дә Ленинград хореография уч-щесендә характерлы бию буенча педагог. Ул биегән партияләр арасында: Шамакай («Щелкунчик», П.И.Чайковский), Ли-Шанфу («Кызыл мәк», Р.Глиэр), Яшь чегән («Ташчәчәк», С.Прокофьев), Измаил, Этруск («Гаянэ», «Спартак», А.Хачатурян), Шайтан («Шүрәле», Ф.Яруллин) бар. Б. иҗатына характерлы биюләрне тәэсирле, зәвыклы башкару хас. Шәкертләре арасында Б.К.*Гайнуллин*, С.*Хантимерова* һ.б. бар.

*В.Н.Горшков.*

**БАЛТАЧИ́ЕВА** Нәимә (Нәгыймә) Вәли кызы (8.3.1915, Петроград — 18.1.1984, Ленинград), балет артисты, педагог, БАССР, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1955, 1965, 1967). Ленинград хореография уч-щесен тәмамлый (1935, А.Ваганова шәкерте). 1935–56 елларда С.М.Киров исем. Ленинград опера һәм балет т-рында балет артисты, 1952–78 дә педагог-репетитор. Ул биегән партияләр арасында: Сапфир, житезлек, Алтын, Көмеш феялары («Йокыга талган гүзәл», П.И.Чайковский), Чәчәк сатучы («Дон-Кихот», Л.Минкус) һ.б. бар. 1941 дә Татар опера һәм балет т-рында эшли, Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетында Сөембикә ролен башкарырга әзерләнә (сугыш башлану сәбәпле әсәр куелмый кала). Биюдә классик хореография элементларын төгәл башкаруы б-н үзенчәлекле. 1946–78 дә Ленинград хореография уч-щесендә педагог. Финляндия, Болгария, Венгрия, Германия (Берлин дәүләт операсы, 1980–84) театрларында эшли. Шәкертләре арасында Р.Симеон (Румыния), Е.Кристова (Болгария), С.*Хантимерова* һ.б. бар.

*Әд.:* Прохорова В. Страницы календаря // Советский балет. 1985. № 4.

*В.Н.Горшков.*

**БАЛТЫРГА́Н** (Heracleum), чатырчәчәкләр семьялыгыннан ике яки күпьеллык үләннәр ыругы. 70 тән артык төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача поясында киң таралган. ТРда бер төре — Себер Б. (H. sibiricum) очрый. Дымлы болыннарда, ташландык җирләрдә, елга буйларында, куак араларында үсә. 60–150 *см* озынлыктагы үсемлек. Тамыры юан, орчыксыман, тышкы яктан саргылт, эче ак. Сабагы кабыргалы, төкле, өске өлеше ботаклы. Яфраклары каурыйсыман яки өчәрле, пластинкалары 20–50 *см* озынлыкта һәм шундый ук киңлектә. Чәчәкләре катлаулы чатырда, яшькелт-сары аерчалы. Җимеше — озынча түгәрәк икеорлыкча. Июль ахыры — август башында чәчәк ата. Орлыклардан үрчи (бер үсемлек 8 меңгә якын орлык бирә). Болын һәм көтүлекләрне чүпли, калган үсемлекләрне басып китә. Яфраклары, сабагы һәм яшь бәбәкләре ашарга яраклы. Яшел өлешләре С витаминына, каротин, аксым, шикәр, дуплау матдәләре, тимер, никель, марганец, бакырга һ.б. бай. Эфир мае булу сәбәпле, Б.ның үзенчәлекле исе бар. Халык медицинасында аппетитны ачу өчен, гастрит һәм тире авыруларын дәвалаганда файдаланыла. Яшь үләннәрен терлекләр яратып ашый. Декоратив, баллы үсемлек.

*Әд.:* Иванова Р.Г. Дикорастущие съедобные растения Татарии. К., 1990.

**БАЛЧЫ́К**, тау токымы, үлчәмнәре 0,01 *мм* дан да кечерәк булган кисәкчекләр өстенлек иткән (>50%) утырма токым; башлыча, балчыксыл минераллардан (каолинит, монтмориллонит, гидрослюдалар һ.б.) тора, су б-н яхшы измә хасил итә, кипкәндә бирелгән формасын саклап кала, яндыргач таш катылыгына керә. Составында 1–2 минерал артык булган Б.лар — каолинит, монтмориллонит, палыгорскит, каолинит гидрослюдалы һ.б., 3 һәм 3 тән артык булган очракта полиминерал дип атала. Балчыксыл минераллардан торган, ләкин үзле булмаган һәм суда җебеми торган токымнар *аргиллитлар* дип атала. Б. борынгы һәм хәзерге сулыкларда төрле тау токымнары һәм минераллар ашалудан барлыкка килгән дисперсияле продуктлар туплану нәтиҗәсендә хасил була. Диңгез, күл, аллювиаль, морена һ.б. Б.лар була. Алар бер-берсеннән минераль составы һәм ш.у. чисталыгы (балчык булмаган эре бөртекле кушымталарсыз) б-н аерылып торалар. Җир шарында Б.лар киң таралган: дүртенчел утырмалардан алып кембрий утырмаларына кадәр (утырма токымнарның яртысы диярлек) очрый; борынгырак утырмалар, кагыйдә була-

рак, метаморфозланган (үзгәргән). Б. сәнәгатьтә һәм а.х.нда киң кулланыла. Аның кулланылышын минераль составына бәйле булган махсус физ. һәм технол. сыйфатлары билгели. Мәсәлән, каолинлы Б.ларның эрү темп-расы югары (1580°С) булу сәбәпле, аларны утка чыдам Б.лар диләр һәм утка чыдам әйберләр эшләүдә, ә эрү темп-расы 1580 нән алып 1350°С ка кадәр булган Б.ларны авыр эрүчән диләр һәм керамика сәнәгатендә (фаянс, плитә, торба, каплау кирпечләре һ.б.) кулланалар. Полиминераль Б.лар, гадәттә, 1350°С тан түбәнрәк темп-рада эри һәм җиңел эрүчән Б.ларга керә, тупас керамика һәм кирпеч сугуда кулланыла. Монтмориллонит һәм палыгорскит Б.лар сорбция, ионнар алмашу, бәйләү, үз хәләнә кире кайту (тиксотроп) сыйфатларына ия, бораулау измәләре, адсорбентлар, металл кою эшләрендә форма ясауда, терлекчелек өчен комбиазык эшләп чыгаруда һ.б. кулланыла.

Татарстанда Б.лар дүртенчел һәм неоген, ш.у. алардан да борынгырак утырмаларда киң таралган. Дүртенчел балчыклар җиңел эрүчән полиминераль Б.ларга керә, шулар арасында *кирпеч сугу балчыклары*ның 50 ләп чыганагы билгеле (Кощак, Түбән Суыксу, Красная Горка). Неоген Б.лары монтмориллонитлы; Биклән, Берёзовский, Югары Нурлат, Тарн-Вар чыганаклары Б.лары форма ясау, бораулау эшләрендә һәм керамзит чималы буларак кулланыла; 1950 еллардан аларны республикада бораулар эшләрендә кулланалар, ш.у. читкә чыгаралар. Апас, Бехтерево һ.б. чыганаклардагы Б.запаслары зур әһәмияткә ия һәм *керамзит* эшләүдә чимал булып тора. Республиканың ташкүмер һәм девон утырмаларында каолин Б.лар бар (эшкәртү өчен уңайсыз, зур тирәнлектә яталар). Нефть чыганакларында алар еш кына нефть катламнарын аерып торучы ролен үти.

*Әд.:* Минеральное сырьё. Глины: Справ. М., 1997; Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*А.А.Сабитов.*

**БАЛЧЫКЛЫ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 34 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Саравыл елгасы буенда. 2002 елда 225 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мич чыгару, штукатурлау, кәрзин һәм читән арба үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да мәчет (1864 тә төзелә), мәктәп, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 903,3 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 89 ир заты; 1859да — 512, 1884 тә — 801, 1897 дә — 824, 1908 дә — 989, 1920 дә — 978, 1926 да — 710, 1938 дә — 571, 1949 да — 398, 1958 дә — 377, 1970 тә — 395, 1979 да — 339, 1989 да — 243 кеше.

**БАЛЧЫКЛЫ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 7 *км* көньяктарак, Алан елгасы буенда. 2002 елда 216 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә, алпавыт утарында ялланып эшли. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да 2 су тегермәне була. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 664,4 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афонасов волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 279, 1884 тә — 398, 1926 һәм 1938 дә — 615, 1949 да — 502, 1958 дә — 423, 1970 тә — 526, 1979 да — 433, 1989 да — 91 кеше.

**БАЛЫ́К БИСТӘСЕ́**, шәһәр тибындагы посёлок (2004 елның 9 сентябреннән), Балык Бистәсе р-ны үзәге. ТРның урта өлешендә, Казан тимер юл станциясеннән 91 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Кама елгасындагы пристань. 2006 елда 7800 кеше (2002 елгы халык исәбен алу буенча, татарлар — 66,4%, руслар — 32,3%) яши. Сөт-май комб-ты, төзү оешмалары. Урта мәктәп, гимназия, һөнәр көллияте. Сугышчан дан, төбәкне өйрәнү музейлары. Мәдәният йорты. Китапханә, РОСТА һәм балалар китапханәләре. Район үзәк хастаханәсе. Мәчет. Казан Мәрьям Ана иконасы храмы. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, зәргәрчелек һәм челтәр бәйләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.Б.ндә Петропавел чиркәве, земство мәктәбе (1867 дә ачыла), хастаханә, ветеринария-фельдшерлык пункты, волость гарипләр йорты, почта-телеграф бүлекчәсе, пароходлар өчен 2 пристань, 2 икмәк кибете, 2 чәйханә, казна шәраб һәм 8 бакалея кибете, 2 сыраханә, трактир, халыкта аек яшәү рәвешен тәрбияләүче ызба-читальня-чәйханә. Дүшәмбе саен — базар, 28 июньнән 3 көн буена ярминкә эшли. Җирле пристаньнардан ел саен 150 меңләп пот товар (башлыча — икмәк) җибәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1484,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Анатыш волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан район үзәге. Халык саны: 1782 дә — 761 ир ат; 1859 да — 621 хатын-кыз; 1897 дә — 1690, 1908 дә — 892, 1920 дә — 1353, 1926 да — 1034, 1949 да — 2156, 1958 дә — 2402, 1970 тә — 3243, 1989 да — 6824, 2002 дә — 7177 кеше.

*Әд.:* Х ә л и у л л и н И. Балык Бистәсе // Мирас. 1993. № 3.

**БАЛЫ́К БИСТӘСЕ́ РАЙОНЫ́**, ТРның үзәк өлешендә урнашкан. Кама алды икътисади р-нына керә. Мәйданы — 2052,1 *км*², 1 шәһәр, 27 авыл (җирле үзидарә советларын), 79 торак пунктны берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогы. Халкы — 28,6 мең кеше (2006), 2002 елгы халык исәбен алу буенча, татарлар — 78,6%,





Балык Бистәсе посёлогы.
1. Район хакимияте бинасы; 2. Мәчет.

Балык Бистәсе посёлогы. Гомуми күренеш.



руслар — 20,6%. Шәһәр халкы — 7,8 мең, авыл халкы — 20,6 мең кеше. Халыкның урнашу тыгызлыгы — 1 *км*$^2$ га 14 кеше. 1927 елның 14 февралендә оештырыла. 1920 гә кадәр ТАССРның Казан губернасы Лаеш өязенә, 1920дән Лаеш кантонына керә. 1930 да 64 авыл советы, 74144 кешесе (татарлар — 42472, руслар — 31672) булган 109 торак пункт була. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 тә Б.Б.р.ның бер өлеше яңа оештырылган *Кызыл Йолдыз районына* бирелә. 1940 та районның мәйданы — 1055 *км*$^2$, халкы — 38,2 мең кеше, 28 авыл советы, 72 торак пункт исәпләнә. 1944 нең 19 февралендә берничә авыл советы Солтан районына (1946 ның 5 июненнән Корноухово р-ны) бирелә. Бетерелгән Корноухово һәм Кызыл Йолдыз р-ннары терр-яләре кире кайтарылганнан соң, Б.Б.р.ның мәйданы — 2098,9 *км*$^2$, аңа 23 авыл советы, 102 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә Б.Б.р. бетерелә, терр-ясе Мамадыш һәм Питрәч р-ннарына бирелә. Кушылганнан соң (12.1.1965) районның мәйданы — 2045 *км*$^2$, халкы — 48,1 мең кеше, 24 авыл советы, 95 торак пункт исәпләнә. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль район дип үзгәртелә. Рельефы — елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән тигезлек (биеклеге 100–190 *м*). Кама елгасы (Куйбышев сусаклагычы) һәм кушылдыклары — Әшнәк, Бәтке, Чошы, Шомбыт елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл-соры, соры урман һәм кәсле-көлсу, көрән-соры туфраклы. Терр-ясенең 23% урманлык. Известьташ, доломит, балчык, комташ, мергель ятмалары бар. Табигать саклаулыклары: Бәтке, Әшнәк, Чошы, Шомбыт елгалары, *Бөрсет акчыршылыклары* ландшафтлы табигать истәлеге, *Карагай урман культуралары* табигать истәлеге, *Мишә аучылык тыюлыгы*, *Шомбыт аучылык тыюлыгы*. 2005 тә а.х. 118,2 мең *га* җир били, ш.и. 87,7 мең *га* сөрүлек җир. Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак, рапс игелә; бәрәңге үстерелә. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, ат асрала. 2005 тә 2 агрофирма, 5 а.х. кооперативы, 1 ачык АҖ, 12 җаваплылыгы чикләнгән ширкәт, 1 ярдәмче хуҗалык, 74 крәстиян-фермер хуҗалыгы эшли. Район үзәге һәм Шомбыт авылында сәнәгать пр-тиеләре эшли. Урман хуҗалыгы бар. Б.Б.р. җиреннән Казан–Уфа автомобиль юлы уза. Кама ярында пристань урнашкан. 52 гомуми белем бирү мәктәбе (2006/07 дә 3753 укучы укый), ш.и. 1 гимназия, 27 урта, 2 тулы булмаган урта, 2 башлангыч мәктәп, агротехника һөнәри лицее, 43 китапханә, 25 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 56 клуб, 3 музей, 231 урынлы 3 хастаханә, 50 фельдшер-акушерлык пункты (2006) эшли. Татар һәм рус телләрендә «Авыл офыклары», «Сельские горизонты» г-талары нәшер ителә.




**БАЛЫ́К БИСТӘСЕ́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогында. 1985 елның 8 маенда җәмәгатьчелек тәртибендә хәрби һәм хезмәт даны музее буларак оеша. 1992 дә төбәк музее, берләштерелгән Дәүләт музее (2001 дән ТРның Милли музее) ф-лы, 2006 дан — муниципаль музей. 2 катлы мәдәният йортының 2 нче катын били. Экспозиция 135 *м*$^2$ мәйдандагы залда урнашкан. Төп фонд 4000 саклау берәмлегеннән тора. Экспозициянең беренче бүлеге борыңгыдан килгән төбәк тарихы: палеонтология, археология коллекцияләре; керәшен һәм Казан татарлары киемнәре; чиркәү җиһазлары, балыкчылык, челтәр бәйләү кирәк-яраклары һәм зәркәнчелек кәсепләре б-н таныштыра. «Бөек Ватан сугышы» бүлегендә Сов. Союзы Геройлары М.С.*Гыйззәтуллин*, С.В.*Давыдов*, В.К.Иванов, А.М.*Меркушев*, И.П.*Петухов*, М.И.*Рыжов*, К.С.*Русаков*, А.Т.*Сергеев*, З.Ш.*Шәймәрданов*, генерал А.Е.Яковлев документлары, фотографияләре, шәхси әйберләре күргәзмәгә куелган. Экспозициянең «Районның данлы кешеләре» бүлегендә шагыйрьләр Р.В.*Әхмәтҗанов*, З.Х.*Бәширова*, К.И.*Сибгатуллин*, М.Г.*Укмасый*, Р.Г.*Фәйзуллин*; артистлар Х.Б.*Җәлалов*, Р.К.*Хәйретдинова*, Р.Ш.*Шәрәфиев*; язучылар Ә.Г.*Гаффар*, В.Н.*Нуруллин*, Ә.Х.*Сафиуллин* турындагы материаллар урын алган.





Балык Бистәсе төбәк тарихы музее. 1. 19 йөз ахыры — 20 йөз башындагы зәркәнчелек эшләнмәләре; 2. Җиякләр һәм энәләр белән бәйләнгән Балык Бистәсе челтәре үрнәкләре, челтәр бәйләү өчен шөлдерләр, 20 йөзнең 1 нче яртысы.

Аеруча мөһим экспонатлар: нумизматика коллекцияләре (борынгы акчалар, медальләр), челтәр үрнәкләре, зәркән әйберләре; чиркәү җиһазлары.

Ел саен Корбан бәйрәме, Халыкара музейләр (18 май), Җиңү (9 май), Өлкәннәр (1 окт.) көннәре үткәрелә.

**БАЛЫ́К БИСТӘСЕ́ ҺӨНӘ́Р-СӘНГА́ТЬ ОСТАХАНӘСЕ́**, уку йорты, зәргәрлек сәнгате остаханәсе. Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгының нәфис сәнәгать учреждениеләре турындагы 1902 елның 12 июнь законына нигезләнеп, 1909 ел, 27 ноябрь Указы буенча көмеш-зәркән җитештерү үзәгендә ачыла. Махсус төзелгән бинага урнаштырыла (проект һәм смета авторы — инженер М.И.Завалишин). 19 йөз азагында Балык Бистәсе авылында зәркән һөнәрчелеге үсеш ала. Остаханә эшләнмәләрнең сәнгать дәрәҗәсен күтәрүгә һәм җирле һөнәрчеләрнең техник осталыгын камилләштерүгә булышлык итәргә тиеш була. Попечительләр комитеты идарәчелегендә (рәисе — А.П.Горталов, Лаеш земство идарәсе рәисе һәм Лаеш дворяннары җитәкчесе; әгъзалары — В.Н. һәм П.Н.Бельковичлар, земство эшлекләре, крестьян Марточкин) тора. Остаханәнең мөдире итеп гамәли сәнгать рәссаме, Строганов сәнгать-техник училищесен тәмамлаган А.К.Триандифилидис куела. Өчьеллык уку курслары гомуми сәнгать белемнәре — рәсем, нәкышь һәм стильләр тарихы, бизәкләү техникасы (укытучылар А.К.Триандифилидис, А.Г.Никитин); осталыкка өйрәнү — чүкеп бизәк төшерү (укытучы А.К.Вагин), тимер чыбык үрү һәм эмаль эшләре (П.А.Чухин), металл кою (П.А.Власов, 1915 тән — П.Е.Еразмов), зәркәнчелек (Г.А.Щетинников) дәресләрен үз эченә ала. Училище тәмамлаган укучыларга ярдәмче мастер, ә 3 елдан соң, башкарылган эшкә хисап бирелгән очракта, мастер исеме бирелә. Остаханәдә кечкенә күләмле әйберләр — ишек тоткалары, китап кисү пычаклары, өстәл кәгазьләре бастыргычы, савыт-саба, шырпы каплары, пасха йомыркалары, шәмдәлләр, ш.у. төрле зәркән әйберләр — беләзек, йөзек, балдак, чулпы, мунчалар, медальоннар һ.б.ш. эшләп чыгарыла. Кирәкле материаллар һәм эш кораллары Мәскәүдән, рәсем ясау әсбаплары Строганов уч-щесеннән кайтартыла. 1917 нең 1 гыйнварына остаханәне 26 укучы тәмамлый, 42 укучы укый.

Остаханә үзенең эшләре б-н Петербургта (1913) үткәрелгән II Бөтенроссия һөнәрчелек-сәнәгать күргәзмәсендә катнаша һәм Зур көмеш медаль б-н бүләкләнә. Остаханә эшләнмәләре Казан губерна земствосының вак сәнәгать һәм һөнәри белем бирү Үзәк музее тупланмасына керә.

Остаханәнең эшчәнлеге Балык Бистәсе һөнәрчелеге эшләнмәләрен төрләндерүгә,

яңа стильләр (модерн һәм псевдорус стиле) үзләштерергә булышлык итә, көмеш һәм зәркән эшендәге техник мөмкинлекләрне киңәйтә.

*Әд.:* Отчет художественно-ремесленной мастерской в с.Рыбная Слобода за 1909/10 уч. год. К., 1910; Список наград, присужденных экспонентам Выставки 1913 г. в С.Петербурге. П., 1914.

*Е.П.Ключевская.*

**БАЛЫКЛА́Р** (Pisces), суда яшәүче умырткалы хайваннар өсклассы. Дөнья фаунасында диңгездә, төче суда яши торган 24 меңләп төр балык исәпләнә, арада үтеп йөри торганнары да бар. Татарстан терр-ясендә 60 ка якын төре (акклиматизация узганнары б-н) билгеле. Алар зурлыгы, төсе, төзелеше б-н аерылалар. Гәүдәләре симметрияле, тәңкәләр яки сөякле калканчыклар (мәрсин балыклар) б-н капланган яисә тәңкәсез (җәен балыгы). Күп кенә Б.ның тиресендә лайла бүлеп чыгара торган биз күзәнәкләре нык үскән. Саңак б-н сулыйлар, кайбер төрләренең (эт балыгы, шиповка) өстәмә сулыш органнары бар; тән темп-расы даими түгел. Скелеты сөякле. Күбесенең гидростатика функциясен үти торган йөзү куыгы бар. Ис сизү, тиеп (капшап) сизү, ишетү һәм күрү сәләтләре яхшы. Тирән суда яшәүче Б.ның аркалары зәңгәрсу яки яшькелт төстә, корсагы һәм яннары көмешсыман. Куаклык һәм ташлар тирәсендәге суда яшәүче Б. гәүдәсендә аркылы сызыклар яки тимгелләр бар, шунлыктан алар күренми диярлек. Б. уылдык чәчеп үрчи. Уылдыкны язын (чабак, бәртәс, чуртан), җәен (табан балык, карабалык), көзен (ала балык) яки кышын (налим) чәчәргә мөмкиннәр. Кайберләре өлешләп, кайберләре барлык уылдыкларын да берьюлы чәчә (мәрсин балыклар, ала балык, чабак). Күп Б. уылдыкны үсемлекләргә (сазан, табан балык һ.б.) яки ташларга (ташбаш балыклар) беркетә. Туклана торган азыгына карап, Б. үсемлекләр б-н туенучылар (фитофаглар), хайваннар б-н туенучылар (зоофаглар), барысы б-н дә туенучыларга бүленә. Үсемлекләр б-н туенучылар үзләре фитопланктонофагларга (ташмаңгай балыклар) һәм макрофитофагларга (ак амур), хайваннар б-н туенучылар — зоопланктонофагларга (сопа, вак балык), бентофагларга (ак күзле корбан балыгы, шыртлака, чөгә балык), ерткычларга (чуртан, судак (сыла), бёрш, җәен, опты) бүленә, ерткычлар арасында каннибализм — үз төрдәшләрен ашау да күзәтелә (алабуга).

ТР терр-ясендә Б.ны түбәндәге төркемнәргә аералар:

1) киң таралган Б., төрле сулыкларда — күлләрдән алып сусаклагычларга кадәр очрыйлар (чуртан, корбан балык, алабуга һ.б.);

2) һәрвакыт зур елгаларда яшәүче Б. (чөгә балык, опты, подуст (түбәнавыз), бёрш һ.б.);

3) зур елгаларның салкын чиста сулы кушылдыкларында яшәүче Б. (керкә балык, хариус, елга ләргесе);

4) күл-буаларда яшәүче Б. (табан балык (кәрәкә), карабалык, күл ләргесе)

Идел һәм Камада сусаклагычлар төзелгәннән соң, Каспий диңгезеннән севрюга һәм укборын, Идел сельде һәм кара аркалы сельд, ак балык, Каспий сөләйман балыгы керми башлый, мәрсин һәм кырпы да сирәгәя. Ак, Балтыйк, Азов һәм Кара диңгезләренең елга системаларын Идел бассейны б-н тоташтыручы каналлар төзелү сәбәпле, төньяктан көньякка яңа төрләр үтеп керә, кайберләре махсус яки очраклы рәвештә кителә һәм сулыкларга чыгарыла. Республика ихтиофаунасында яңа төрләр: чуар балык, вак балык, түгәрәк ташбаш, елга еланбалыгы, энә балык, ротан, цуцик ташбаш барлыкка килә.

Ак амур, ташмаңгай уылдык чәчү-үстерү хуҗалыкларындагы ясалма үстерү чаралары күрү, ш.у. Куйбышев сусаклагычының кайбер акваторияләрендә шушы сулыкка җибәрү өчен балык материалы үстерү максатында күренә башлый.

Б. — азык аксымының төп чыганагы, шунлыктан кешенең туклануында, ш.у. аның хуҗалык эшчәнлегендә әһәмиятле урын алып тора. Б. — ау спорты объекты. 10 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән. Б.ны өйрәнү б-н *ихтиология* фәне шөгыльләнә. Фәнни-гамәли яктан Урта Идел бассейнының балык хуҗалыгын Күл һәм елга балык хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан бүлеге тәэмин итә (1931 елдан).

Илл. 384–385 битләрдә.

*Әд.:* Кузнецов В.А. Рыбы Волжско-Камского края. К., 1999. Ч. 1; Атлас пресноводных рыб России. М., 2003.

*Н.Д.Григорьев.*

**БАЛЫКЛЫ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 19 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2002 елда 345 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 17 йөзнең 1 нче яртысыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта, тимерчелек эшләре, мич чыгару, киез итек басу, сәүдә итү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, 3 ярма ярдыру тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1187,7 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир заты; 1859 да — 743, 1897 дә — 874, 1908 дә — 1106, 1920 дә — 977, 1926 да — 992, 1938 дә — 876, 1949 да — 573, 1958 дә — 515, 1970 тә — 553, 1989 да — 398 кеше.

**БАЛЫКЛЫ́** (Байкал) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 9 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тәмте елгасы буенда. 2002 елда 304 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, өс һәм баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да мәчет, мәдрәсә, 2 су һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1437,9 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 102 ир заты; 1859 да — 664, 1897 дә — 897, 1908 дә — 1058, 1920 дә — 1015, 1926 да — 749, 1949 да — 618, 1958 дә — 505, 1970 тә — 469, 1979 да — 404, 1989 да — 307 кеше.

**БАЛЫКЛЫ́ ЧҮКӘ́Й** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе авылыннан 22 *км* төньяктарак, Укмас елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 343 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.Ч.дә таш мәчет (1897 дә агач мәчет урынына салына; архит-ра истәлеге), мәктәп, 3 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1245 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 маеннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир заты; 1859 да — 444, 1897 дә — 872, 1908 дә — 965, 1920 дә — 1088, 1926 да — 935, 1949 да — 793, 1958 дә — 565, 1970 тә — 585, 1989 да — 398 кеше.

**БАЛЫКЧЫ́ КАРЧЫГА́** (Pandion haliaetus), лачынсыманнар отрядыннан зур ерткыч кош. Семьялыкта бердәнбер төр. Бөтен җир шарында диярлек (Африка һәм Көньяк Америка тропикларында гына юк) таралган. ТР терр-ясендә зур сулыклар янында яши. Күчмә кош. Апрельнең икенче яртысында очып килә. Гәүдәсенең озынлыгы 60 *см* га кадәр, ана кош 2 *кг* га кадәр, ата кош 1,5 *кг* га кадәр авырлыкта. Канатлары тар, канат җәеме 1,3 *м* чамасы. Каурыйлары тыгыз, өстән кара көрән төстә, астан бүксәдән түшенә таба кара сызык сузылган саргылт ак төстә; башы ак диярлек. Баш артында очлы, каурыйлы зур булмаган бүреге бар. Кәчле аяклы, озын тырнаклары бөгелгән. Бармакларының аскы ягы киртләч. Аякларының шундый булуы табышны җитез эләктереп алу һәм нык тоту мөмкинлеген бирә. Күбесенчә балык б-н туклана. Балык булмаганда, кыр тычканнары, ондатра, бакалар б-н туена ала. Биек агач башларында оялый. Аксыл төстәге кызгылт-көрән тимгелле 2–3, сирәк кенә 4 йомырка сала. Кышларга октябрь урталарына таба очып китә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БАЛЫКЧЫЛЫ́К**, балык тоту, балык үрчетү б-н шөгыльләнә торган халык хуҗалыгы тар-

магы. Сәнәгый Б., нигездә, ТРның Куйбышев (286,2 мең *га*) һәм Түбән Кама (70 мең *га*) сусаклагычларында алып барыла. ТРда табигый сулыкларда балык тоту һәм эшкәртү б-н өч балык з-ды («Чистай» ачык АҖ, «Тәтеш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Лаеш» ябык АҖ) һәм сәнәгый балык тотуга рөхсәтнамәсе булган 70 ләп эшмәкәр шөгыльләнә. Табигый сулыклардан тыш, ТР буалы хуҗалыкларда (Арча — 278 *га*, Дим — 50 *га*, Кайбыч — 138 *га*, Үшнә — 60 *га*) сәүдә өчен товарлыклы балык үрчетелә (карп, чуар кушбаш, ак кушбаш). 1970 елда Куйбышев сусаклагычында — 58, 2000 елда 52 төр балык исәпләнә; алар 7 фауна комплексы: Понт-Каспий төче сулык комплексы (карп, корбан балык, кызылканат, опты, җилембалык, судак, карабалык, кушбаш, түбәнавыз, кәлчәк, әсләч, сыла, синец, аккүз, густера), тигезлекле бореаль комплексы (чуртан, алабуга, шыртлака, чабак, күл гольяны, комкорсак, бәртәс, ук борын), тигезлекле югары өченчел комплексы (җәен, сазан, чөгә, мәрсин, кырпы, этләч), бореаль тау итәге комплексы (елга гольяны, сагалак, тупакбаш, таймен, пәрде), Понт-Каспий диңгез комплексы (тюлька, ташбаш, инә диңгез балыгы), Арктика төче сулык комплексы (жумба, пелядь, сыла балык, күл чабагы) һәм тигезлекле Кытай комплексы (ак амур балыгы, ротан, кушбаш) балыкларына бүленә.

2006 елда барлыгы 2224,8 *т* балык тотыла, ш.и. 1647,7 *т* — күл-елга, 1545,5 *т* — Куйбышев, 101,9 *т* — Түбән Кама, 0,3 *т* — Зәй сусаклагычлары балыгы. Буаларда сатуга үстерелгән балыкны тоту һәм сату күләме 577,1 *т*, ш.и. Арча балык хуҗалыгында — 501 *т*, Кайбыч балык хуҗалыгында — 31 *т*, Үшнәдә — 21,5 *т*, Димдә 23,6 *т* тәшкил итә. Үрчетү өчен Арча, Кайбыч буаларына һәм Куйбышев сусаклагычына 62,6 *т* маймыч җибәрелә (2006).



*Әд.:* Калайда М.Л. История и перспективы развития рыбного хозяйства Татарстана. К., 2001.

*Ә.Х.Фазылҗанов, Р.К.Әхтәмова.*

**БАЛЫ́М КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), археология истәлекләре җыелмасы, Лаеш р-ны Зур Отар авылы янында (хәзер Казанның көньяк-көнбатыш чиге) урнашкан. 1879 һәм 1920 елларда Н.Ф.*Высоцкий*, 1951–52 дә Н.Ф.*Калинин* б-н А.Х.*Халиков* тарафыннан тикшерелә. Неолит, энеолит дәверләре һәм бронза гасырына караган 15 туктаулык табыла (Идел-Чулман буе, Волосово, Казан яны, Чиркәскүл культуралары үрнәкләре). Б.к.да неолит, энеолит дәверләре һәм бронза гасыры кешеләре яшәгән торулыклар булуы мәгълүм, аларның үзәк өлешендә учак урыннары табыла. Туктаулыкның урта бер җирен әйләнәсенә ком-известь сибелгән калкурак корбан чалу урыны алып тора. Аның тирәсендә Чиркәскүл культурасына нисбәтле каберләр, башлары көнчыгышка каратып салынган мәет калдыклары табыла. Каберлекләрдән ш.у. чүлмәк-савытлар, бронза әйберләр килеп чыга. Б.к. урнашкан мәйданда чакматаштан, сөяк, балчык һәм бронзадан ясалган 33 меңләп әйбер табыла.

*Әд.:* Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ за 1945–52 гг. // Тр. Казан. филиала АН СССР. К., 1954; Халиков А.Х. Приказанская культура // Свод археологических источников. М., 1980. Вып. 1–24.

*Е.П.Казаков.*

Балым комплексы. Чакматаш һәм керәч әйберләр.
ТР ФАнең археол. тикшеренүләр милли үзәге фондлары.

**БАЛЫМЕ́Р** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 20 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы янында. 2002 елда 164 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. Идел буе Болгары чорыннан мәгълүм. Руслар 17 йөзнең 2 нче яртысында килеп урнаша. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек кенәз Баратаевларның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, поташ з-ды өчен чимал әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да земство мәктәбе, зур пар (1874 тә төзелә), 3 җил һәм 1 ярма ярдыру тегермәне, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете, пристань эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 336 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Спас өязе Өчкүл волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Спас (1935–91 дә — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 47 ир заты; 1859 да — 539, 1897 дә — 890, 1908 дә — 1085, 1920 дә — 1690, 1926 да — 1379, 1938 дә — 936, 1949 да — 644, 1958 дә — 548, 1970 тә — 405, 1979 да — 271, 1989 да — 171 кеше. Авыл янында Балымер археол. комплексы сакланган.


*Әд.:* Памятная книга Казанской губернии на 1863. К., 1862; Памятная книга Казанской губернии на 1866–67. К., 1868; Приволжские города и селения в Казанской губернии. К., 1892.

**БАЛЫМЕ́Р КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), археология истәлекләре җыелмасы, Спас р-ны Балымер авылы янында урнашкан. Б.к. истәлекләрен өйрәнү 19 йөздән башлана (А.А.Спицын, А.Ф.Лихачёв, А.И.Стоянов, П.А.Пономарёв, Н.П.Лихачёв һ.б.). 1954 елда Б.Б.Жеромский шәһәрлектә казу эшләре алып бара, 1961 дә Е.А.Халикова күчмә төркиләрнең 14 йөзгә караган курганлы каберлеген тикшерә. Б.к. истәлекләре нигездә Иделнең биек сулъяк ярында урнашкан. Комплекска берничә авыллык һәм Имәнкискә культурасына нисбәтле «Шолом» (шартлы исем) шәһәрлеге керә; шәһәрлекләр, авыллыклар, курганлы һәм гади каберлекләр 9–10 йөзләрдә яшәгән руслардан (викинглар), болгарлардан һәм 13–14 йөзләрдәге Алтын Урда күчмә төркиләреннән калган дип фараз ителә. Шәһәрлекләрдә ш.у. Ананьино, Имәнкискә һ.б. археол. культуралар катламнары табыла. Руслардан калган курганлы каберлектә мәет яндыру йоласы эзләре очрый. Комплекс терр-ясендә көмеш әйберләр һәм акчалар хәзинәсе табыла.


*Әд.:* Спицын А.А. Заметки из поездки 1898 // Изв. Императорской археологической комиссии. СПб., 1898. Вып. 60; Жеромский Б.Б. Древнеродовое святилище «Шолом» // Материалы и исследования по археологии СССР. 1958. № 61; Халикова Е.А. Археологические исследования в Куйбышевском районе ТАССР в 1961г. // Краткие сообщения Института археологии АН СССР. 1965. Вып. 104; Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье. К., 1986. № 102–115.

*Е.П.Казаков.*

**БАЛЫНГУ́З (ТОРЦК) III АВЫЛЛЫГЫ́**, археологик истәлек. Алексеев р-ны Биләр авылы янындагы 14–15 йөзләргә караган болгар торулыгы. Кече Чирмешән елгасының уңъяк ярындагы Балынгуз тавы итәгеннән аккан инеш буенда урнашкан. Мәйданы 4 *га* тирәсе. *Биләр тарих, археология һәм табигать музей-саклаулыгына* керә. Беренче тапкыр 1983 елда А.Х.Халиков тарафыннан тасвирлана, 1998 елдан Казан ун-ты археол. экспедицияләре тикшеренүләр алып бара. Өлгесе каркаслы-баганалы, эргә өлеше яндырылмаган кирпечтән төзелгән бура торак, хуҗалык корылмалары, 40 *см* киңлектәге 2 багана чокыры, учак урыннары һ.б. табыла. Авыллык мәйданында тегермән ташлары, тимер ук очлыклары, сука тимерләре, йон кыркый торган кайчылар, аркылы балта, кармак, ачкыч, йозак, атлама, таба, чуен казан, бронзадан коелган үлчәү тәлинкәләре, балчыктан һәм шифердан эшләнгән орчык башлары, сөяк сап, поши мөгезе эченә тимер коеп ясалган кистән, кайрак, ат дирбияләре (өзәңге, авызлык, каен тузыннан ясалганияр һ.б.), кытай фарфоры кисәкләре — силадон, пыяла савыт-саба ватыклары, пыяла йөзек һәм мәрҗәннәр, бронза көзгеләр, гәрәбә, затлы тартма кисәкләре, чүлмәк, савыт-саба, Үзбәк




**Балыклар.** 1. Гади ләрге; 2. Кызылканат; 3. Чуар ташмаңгай; 4. Гади опты; 5. Корбан балык; 6. Густера; 7. Көмеш табан балык; 8. Сазан; 9. Ташбаш; 10. Карабалык.




**Балыклар.** 11. Чабак; 12. Кәлчәк; 13. Гади чуртан; 14. Судак; 15. Гади шыртлака; 16. Елга керкәсе; 17. Гади җаен; 18. Чөгә балык.







Балынгуз (Торцк) III авыллыгында табылган әйберләр: 1. Керәч, сөяк әйберләр; 2. Тимер өзәңгеләр, кайчы, сука, бронза көзгеләр. Казан ун-тының Археол. музее фондлары.

(1313–42), Җанибәк (1342–58), Мөрит (1361–63) ханнар заманы акчалары һ.б. әйберләр табыла.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Археологические памятники бассейна р. Черемшан. К., 1990. № 726; В а л и у л и н а С.И., Б е г о в а т о в Е.А. Исследование Билярского городища и памятников в его округе // Научное наследие А.П.Смирнова и современные проблемы археологии Волго-Камья. М., 1999.

*С.И.Вәлиуллина.*

**БАЛЫНГУ́З ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, археологик истәлек. Алексеев р-ны Горки авылы янындагы 13–14 йөзләргә караган болгар шәһәре калдыклары урыны. Кече Чирмешән елгасының биек уңъяк ярында, Биләр шәһәрлегеннән төньякта 3,5 *км* ераклыкта урнашкан. Мәйданы 400 *га* дан артыграк. *Биләр тарих, археология һәм табигать музей-саклаулыгына* керә. Б.ш.н беренче тапкыр 1769 елда Н.П.*Рычков* тикшерә, 1881 дә В.А.Казаринов, 1970 тә Р.Г.Фәхретдинов һ.б. тарафыннан тасвирлана. Б.ш. бөтен яктан үрләр, чокырлар б-н уратылган; шәһәрлекнең көньяк-көнчыгыш өлеше ике рәт ныгытма б-н бүлеп алынган. Көньягында Алтын Урда дәвере мөселман каберлеге бар, Н.П.Рычков анда 14 йөзгә караган бик күп кабер ташлары таба (хәзерге көндә 5 се генә сакланган). Халык телендә бу каберлек «Хуҗалар тавы», «Балым хуҗа», «Мөгаллим хуҗа» дип йөртелә. Зират мәйданында ак таштан һәм кирпечтән төзелгән төрбә калдыклары табыла, алар өлешчә яшел плитәләр б-н бизәлгән. Татар риваятьләре буенча 14–16 йөзләрдә бу төрбәләрдә аксөякләр һәм мөселман дине әһелләре җирләнгән.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. О судьбе Великого города после монгольского нашествия // Из археологии Нижнего Прикамья. К., 1984; Археологические памятники бассейна р. Черемшан. К., 1990; K h a l i k o v A., M u h a m e d s c h i n J. Unpublished Volga Bulgarian insriptions // Acta orientalica Hungaria. Bdpst, 1977. V. 31, f.1.

*Ф.Ш.Хуҗин.*

**БАЛЬЗА́МОВ** Виктор Алексеевич (5.11.1938, Биектау р-ны Бөреле станциясе), җыючы слесарь, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), ТАССРның атказ. машина төзүчесе (1988). 1974 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый. 1956 дан Казан авиация җитештерү берләшмәсендә эшли. Дәүләт бүләге хезмәттәге югары казанышлары өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**БАЛЯ́ЕВ** Асым Айзатулла улы (Алексей Андреевич) (15.8.1923, хәзерге Мордва Респ-касының Ләмберә р-ны Пензятка а. — 25.9.1983, Мәскәү өлкәсе Ногинск ш.). Сов. Союзы Герое (19.3.1944), гв. рядовое. Сугышка кадәр «Волгострой» (Калинин өлкәсе) оешмасында эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә, Бөек Ватан сугышы фронтларында; 78 нче гв. укчылар полкы укчысы. Көньяк-көнбатыш фронты гаскәрләре составында 1943 елның 26 сентябрендә Днепропетровск өлкәсенең Солонянский р-ны Войсковый авылы янында беренчеләрдән булып Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Аларның төркеме дошманның 2 нче линия окопларына бәреп керә. 1945 елда каты яраланып демобилизацияләнә. 1946 дан Ногинскида яши. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Яшәгән йортына (Ногинск ш.) мемориаль такта куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Мордовия: Энцикл. Саранск, 2003. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**БАНАХЕ́ВИЧ** Тадеуш (1.2.1882 — 17.11.1954, Краков ш., Польша). астроном, математик, Краков ФА әгъзасы (1922), Польша ФАнең шәрәфле әгъзасы. 1904 елда Варшава ун-тын тәмамлый. 1910–15 елларда Казан ун-тының В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясендә эшли, анда Айның физик либрациясен өйрәнә, Кояш тотылуын күзәтә һәм рефракция теориясе буенча тикшеренүләр алып бара. 1918 елдан Юрьев ун-ты (Тарту ш.), 1919–54 тә Ягеллон ун-ты (Краков ш.) обсерваторияләре директоры. Хезмәтләре күк механикасына, геодезиягә карый. Краков шәһәрендә астрономик күзәтүләрне матем. эшкәртү өчен «краковиан» матрицасы теориясен төзи. «Acta astronomice» ж-лын (поляк телендә) һәм Польша астрономия җәмгыятен нигезләүчеләрнең берсе (1925). *Халыкара астрономия берлеге* вице-президенты (1935–38).

Х е з м.: О солнечном затмении 17 (4) апреля 1912 г. К., 1912; К теории годовой невязки при определении широты. К., 1915; Три эскиза по теории рефракции // Уч. зап. Казан ун-та. 1915. Т. 82.

**БАНЗА́РОВ** Доржи (1822, Байкал аръягы өлкәсе Кутетуй олысы — 2.3.1855, Иркутск ш.), шәркыятьче галим, Россиядә монгол халыкларын өйрәнүгә нигез салучыларның берсе. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясен (1842), Казан ун-тын (1847) тәмамлый. О.М.Ковалевский шәкерте. 1847–49 елларда С.-Петербургта яши, Азия музеенда эшли: монгол китаплары һәм кулъязмалары каталогын төзи. 1850 дән Көнчыгыш Себер (Иркутск ш.) ген.-губернаторы каршында махсус вазифалар үтәүче. Себергә сәфәрләре вакытында декабристлар б-н аралаша; Н.А.Бестужев аның портретын ясый. Б. диалектология, археол. һәм чыганакларны өйрәнү буенча тикшеренүләр алып бара. Хезмәтләре монгол халыклары телләренә, әдәбияты, тарихы, этнографиясе һәм диненә карый. Б. исеме Улан-Удэ шәһәрендәге Бурятия пед. ин-тына бирелгән.

Х е з м.: Собр. соч. М., 1955.

*Әд.:* П о т а н и н Г.Н. Очерк жизни и деятельности Доржи Банзарова // Банзаров Д. Чёрная вера, или Шаманство у монголов. СПб., 1891; В е н г е р о в С.А. Критико-биографический словарь русских писателей и учёных. СПб., 1891; Р у м я н ц е в Г.Н. Доржи Банзаров как филолог // Зап. Бурят-Монгольского гос. науч.-иссл. ин-та языка, лит. и истории. 1941. Вып. 3–4; К 100-летию со дня смерти Д.Банзарова (материалы научных сессий и статьи). Улан-Удэ, 1955.

*В.Х.Хаков.*

**БА́НК СТА́ВКАСЫ**, акча средстволарын кредит, депозит, заём, кыйммәтле кәгазьләр, ш.у. комиссион керемнәр, чыгымнар һ.б. рәвешендә урнаштырганда яисә җәлеп иткәндә банк тарафыннан алына яки түләнә торган процент күләме. Ссуда проценты ставкасы банкка, башка керемнәр б-н беррәттән, депозитка җәлеп ителгән акча өчен процент түләү, үз аппаратын тотуга киткән операция чыгымнарын каплау, табыш алу мөмкинлеге бирә. Б.с.ның күләме барыннан да элек җәмгыятьтәге төрле икътисади субъектларның ни дәрәҗәдә керемле эшләүләренә, ш.у. банк чыгымнарына бәйле. Банклар процентының күләменә, акча ресурсларына һәм банкларның хезмәт күрсәтүләренә, базар ихтыяҗының ни дәрәҗәдә булуына дәүләти көйләү һ.б. күп кенә факторлар йогынты ясый. СССРда банк кредитының барлык төрләре һәм хуҗалык тармаклары буенча процентлар ставкасы 1988 елга кадәр хөкүмәт тарафыннан үзәкләштерелгән тәртиптә билгеләнә. Процент ставкалары бик түбән була. 1988 елдан соң Б.с.на кагылышлы сәясәт үзгәрешләр кичерә. Озак вакытка бирелә торган кредит буенча Б.с. кыска вакытлыга караганда югарырак куеп билгеләнә башлый. Банкларны коммерцияләү Б.с.ның күтәрелүенә китерә. Банклар эшчәнлегендә операция төрләренә, милли һәм халыкара акча базарларында катнашучыларга бәйле рәвештә куела торган күптөрле процент ставкалары гамәлдә. 1) Рәсми (хисап) ставка — рефинанслау процессында Үзәк банк тарафыннан коммерция банкларына бирелә торган кыска вакытлы ссудаларның проценты. Б.с. акча массасын һәм коммерция банкларының түләү мөмкинлекләрен, ахыр чиктә — икътисадны көйләү инструменты хезмәтен үти, чөнки ул акча капиталының реаль һәм финанс секторына керүен стимуллаштыру яки чикләү юлы б-н банкларның кредит алу мөмкинлекләрен йә арттыра, йә киметә. 1990 елларда чит илләрдә хисап ставкасы — 3 тән 18% ка, РФдә 210 нан 21% ка кадәр тирбәлә. 2) Банкара базар ставкасы — милли һәм халыкара базарларда банкларның

акча капиталын җәлеп итү һәм бер-берсенә бирү проценты. Евровалюта базарында киң файдаланыла торган Лондон банкара ставкасы аерым халыкара кредит алмашу бәяләрен хисаплаганда нигез итеп алына һәм кулланыла. РФдә банкара кредитлар бирү практикасында күптөрле ставкалар кулланыла: кредит ресурсларын җәлеп итү, кредитка биреп тору; урнаштырылган банкара ресурларның фактик ставкасы, сроклы ставкалар һ.б. кулланыла. Гадәттә, банкара кредит ставкалары күләме Үзәк банк ставкасыннан кимрәк була. 1990 елларда РФдә алар 275 тән 7% ка кадәр тирбәлә. 3) Коммерция банкларының эчке кредитлар һәм депозитлар ставкасы — үз клиентларының кредитлары буенча банклар тарафыннан алына һәм депозитлана торган процент. Ул Үзәк банкның хисап ставкасына, бурычка алучының сыйныфына, аның финанс хәленә, кредитның төренә, бирелү вакытына һ.б. карап берничә төргә бүленә. РФ һәм ТРның Б.с. базарга күчә барган чордагы кризис тенденцияләрен чагылдыра. 1990 елларда ул нигезсез югары булуы, икътисадның реаль секторындагы керем дәрәҗәсен исәпкә алмавы, зур сикерешле булуы, тотрыксызлыгы б-н аерыла. Шулай да төбәк банклары эшчәнлегендә мондый күренешләр азрак чагыла.


*Әд.:* Основы банковской деятельности в условиях перехода к рынку. К., 1995; Банки и банковские операции. М., 1997; Экономическая теория. М., 1998; Деньги, кредит, банки. М., 1998; Банковское дело. М., 2000.

*Т.А.Денисенко.*

**БАНКИ́ СУКАЕ́Ш** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 17 *км* төньяктарак, Сукаеш елгасы буенда. 2002 елда 144 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. 18 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Югары Сукаеш исеме б-н дә мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.С.та мәчет була, 1910 да аның каршында мәктәп эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 1054 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Эстәрлетамак волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 64 ир заты; 1856 да — 244, 1897 дә — 426, 1920 дә — 439, 1926 да — 290, 1938 дә — 331, 1949 да — 765, 1958 дә — 603, 1970 тә — 218, 1979 да — 190, 1989 да — 130 кеше.

**БА́НКЛАР** (фр. banque, итал. banco — эскәмия, алыштыру кибете), кредит оешмасы, акча һәм кыйммәтле кәгазьләр б-н төрле төрдәге операцияләр үткәрә, хөкүмәткә, предприятиеләргә, гражданнарга һ.б. банкларга хезмәт күрсәтә. Б.ның төп максаты акча әйләнешен рациональ оештыру, түләүләр һәм өстәмә ресурслар туплауны тәэмин итү юлы б-н икътисад үсешенә булышудан гыйбарәт. Базар мөнәсәбәтләре үсү б-н акча-кредит өлкәсендә көйләү һәм күзәтчелек итү өчен иктисади ихтыяҗ туа. Акча эмиссиясенә һәм кредит учреждениеләренә күзәтчелек итүне гамәлгә ашыручы үзәк Б. шулай барлыкка килә. Алар дәүләт б-н икътисад арасында арадашчыга әвереләләр. Россиядә Дәүләт банкы 1860 елда оеша. Казан губернасында беренче Б. — *Казан шәһәр җәмәгать банкы* — 1848 дә ачыла. Шуннан соң күп кенә Б.ларның Казан бүлекчәләре оеша: Россия Дәүләт Б. (1864), *Идел-Кама коммерция банкы* (1870), *Азов-Дон коммерция банкы* (1871). 1873 елдан Казан сәүдәгәрләр банкы эшли башлый. Болардан тыш, төрле елларда *Дворяннар җир банкының Казан бүлеге*, *Крәстияннәр җир банкының Казан бүлеге* һ.б. гамәлдә була. ВЦИКның 1917 елның 14 декабрендәге декреты б-н Б. дәүләт милкенә күчерелә.

Советлар чорында Б. системасына СССР Дәүләт Б., СССР Төзелеш Б. һәм СССР Тышкы сәүдә Б. кебек универсаль кредит учреждениеләре керә. 1990 елларда ике дәрәҗәдәге Б. системасы формалаша. Беренче дәрәҗәдәгесе — РФнең Үзәк Б. (Россия Б.). Ул кредит оешмалары банкы булып санала һәм аңа банкнотларны монополь эмиссияләү, акча әйләнешен, кредит-банк эшчәнлеген, валюта сферасын көйләү, дәүләт алтын-валюта резервларын саклау хокукы һәм вәкаләте бирелә. РФ субъектларында Россия Б.ы үзенең терр. учреждениеләре — вертикаль идарә итү структурасы булган бердәм система тәшкил итүче Баш идарәләр һәм Милли банклардан гыйбарәт. Татарстанда Татарстан Республикасының Милли банкы эшли. Россиянең икенче дәрәҗәдәге банклар системасын коммерция Б. һәм банкныкы булмаган кредит оешмалары формалаштыра. Алар эшчәнлегенең төп максаты — табыш алу. РФдә Б.ның оештырылуы һәм эшчәнлеге РФнең 2002 елның 10 июлендәге «Россия Федерациясенең Үзәк банкы (Россия банкы) турында»гы һәм 1990 елның 13 февралендәге «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында»гы законнарына нигезләнә. Б. финанс базарында күп төр операцияләр башкара торган универсаль кредит учреждениеләре буларак эш итәләр: төрләре һәм вакытларына карап, күптөрле кредитлар бирү, кыйммәтле кәгазьләр һәм чит ил валюталарын сатып алу, сату һәм саклау; кертемнәргә акча җәлеп итү, исәп-хисап эшләрен гамәлгә ашыру, өченче затлар өчен гарантияләр һәм җаваплылыкны үз өстенә алу йөкләмәләре бирү; арадашчылык итү һәм ышанычнамә аша ышанып эшләү операцияләре



А.А.Баляев.



Т.Банахевич.


алып бару һ.б.ш. Коммерция Б. Россиянең Үзәк Б. лицензиясе нигезендә эш итә. Б. теләсә кайсы хосусый, дәүләти, катнаш милек формасында оештырылырга мөмкин.

РФдә 2006 елның 1 гыйнварына 1356 Б. гамәлдә була һәм банклардан тыш 53 кредит оешмасы, шуларның 27 се ТР терр-ясендә урнашкан. Республиканың иң зур банклары — «Ак барс», «Татфондбанк», «Девон-Кредит», «Казанский», «Спурт».

*Әд.:* Антонов Н.Г., Пессель М.Н. Денежное обращение, кредит и банки. М., 1995; Банковская система России. Настольная книга банкира. Центральный банк России. М., 1995; Банковское дело. М., 1998.

*Н.В.Мезина, Л.А.Ульянова.*

**«БАНКРО́Т»**, Г.Камалның 3 пәрдәле комедиясе (1911). Татар драматургиясе классигының иң уңышлы комедияләреннән берсе. Әсәрдә 20 йөз башы татар сәүдәгәрләренең комсызлыклары, тискәре гадәтләре фаш ителә. Барлык татар театр труппалары репертуарларында да була. Беренче мәртәбә 1911 елның 4 ноябрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан куела. Сиражетдин ролен Г.Кариев, А.Кулалаев, Гөлҗиһанны Г.Болгарская, Җамалетдинне К.Тинчурин, Василий Дмитриевичны В.Мортазин-Иманский башкара. Татар җәмәгатьчелегенең реакцион даирәләре комедияне тискәре каршы алса да, ул җәмгыятьнең демократик катлавының байрагына әверелә. 1912 елда пьеса Әстерхан татар драма театрында куела. Сиражетдин ролен анда З.Солтанов уйный, соңыннан ул бу рольне иң яхшы башкаручыларның берсе булып таныла. 1913–14 ел сезонында комедия «Нур» труппасы (Сиражетдин — К.Шамил, Л.Аитов), 1916 ның сентябрендә «Ширкәт» труппасы тарафыннан куела (Сиражетдин — М.Мутин). Шул вакыттан башлап пьеса Татар акад. театрында еш куела: 1925, 1933 (реж. З.Солтанов), 1935 (реж. С.Вәлиев-Сульва), 1944, 1962 (реж. Х.Уразиков), 1979, 1998 (реж. П.Исәнбәт) елларда. Төп башкаручылар: Сиражетдин ролендә — Х.Әбҗәлилов,



«Банкрот» (Г.Камал) спектакленең бизәлеше. 1933 елгы куелыш. Рәссам П.Т.Сперанский.





Татар академия театры сәхнәсендә «Банкрот» (Г.Камал) спектакле. 1. Спектакльдән күренеш, 1933 елгы куелыш. М.Сульва, Х.Әбҗәлилов, Н.Арапова; 2. Спектакльдән күренеш, 1979 елгы куелыш. Н.Ихсанова, И.Хәйруллин, Г.Камалова, Д.Касыймов, Р.Шәрәфиев.

Р.Бикчәнтәев, Р.Шәрәфиев, И.Әхмәтҗанов; Гөлҗиһан ролендә — А.Масаутова, М.Сульва, Ф.Камалова, Р.Җиһаншина, Н.Ихсанова, Р.Мотыйгуллина, Г.Исәнгулова. 1940 та беренче мәртәбә рус телендә Казан Зур драма театры сәхнәсендә куела (рус теленә Г.Д.Шапиро һәм И.Юзиев тәрҗ.), реж. Б.Э.Ниренбург, консультант З.Солтанов, Сираҗетдин ролендә Н.И.Якушенко уйный. 1994 тә «Б.»ны Әлмәт татар драма театры куя (реж. З.Туишева, Сираҗетдин ролен Р.Таһиров, Гөлҗиһанны Р.Фәйзуллина башкара).

*Әд.:* Хисмәтуллин Х. Г.Камал. К., 1969; Иляллова И. Театр имени Камала. К., 1986; Ингвар И., Иляллова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*И.И.Иляллова.*

**БАНКРОТЛЫ́К** (итал.banco — эскәмия, rotto — ватык), бурычын түләүгә сәләтсезлек, эшмәкәрнең, пр-тиенең түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бурыч йөкләмәләрен үтәүдән баш тартуы; бөлгенлеккә төшү. РФнең 1998 елның 8 гыйнварындагы «Бурычларын түли алмаучылык (бөлгенлек) турында»гы Законында каралганча, пр-тиенең бөлгенлеккә төшүе (Б.лыгы) — ул аның товар (эш бирү, хезмәт күрсәтү) хакын түләү буенча кредиторларның таләпләрен канәгатьләндерә алмавы, бурычлы затның бурычлары мөлкәте бәясеннән артып китүе яки баланс структурасының канәгатьләнмәслек булуы сәбәпле бюджетка һәм бюджеттан тыш фондка мәҗбүри бурычларын түләргә сәләтсез булуы. Пр-тие бурычын түләү вакыты җиткәннән соң да, белә торып кредиторларның таләпләрен өч ай эчендә үтәмәсә яисә үтәргә сәләтсез булса, аның агымдагы түләүләре туктатыла һәм пр-тиенең бөлүе Б.ның тышкы билгесе булып тора. Б.ның төрле формалары, мотивлары булуы мөмкин, ш.и. комсызланып, теләсә нинди юл б-н максатка ирешергә омтылу, эшне ялганга кору һ.б.

СССРда җитештерү чараларына җәмәгать милке урнаштырылгач һәм икътисадны дәүләт тарафыннан планлы нигездә көйләү кертелгәч, 1930 еллар башында пр-тиеләрнең Б.гы мәсьәләсе тулысынча туктатыла. Базар икътисадына күчү һәм төрле милек формаларындагы пр-тиеләр оешу б-н, 1990 еллар башында РФдә яңадан Б. проблемасы барлыкка килә. Б.ны мәгълүм билгеләре күренгәнгә кадәр үк — 1,5–2 ел алдан фаразларга мөмкин. Юридик затлар өчен Б. процедурасы күзәтү, тышкы идарә һәм конкурслы идарәне үз эченә ала. Бурычлы затның бөлгенлеккә төшүен тануларын сорап язган гаризасы кергән көннән мөлкәтне саклап калу максатында күзәтү башлана. Күзәтү эше кредиторларның мәнфәгатьләрен яклауга һәм бурычлы затның хаксыз гамәлләрен чикләүгә юнәлтелә. Күзәтү мировой килешү төзү яисә тышкы (читтән торып) идарә кертү яки конкурслы идарә б-н төгәлләнә. Тышкы идарә пр-тие б-н идарә итү вәкаләтен чит идарәчегә тапшыру юлы б-н бурычлы затның бурычын түли алуына ирешү максатында кулланыла һәм арбитраж мәхкәмәсе тарафыннан кертелә. Бурычлы затның категориясенә бәйле рәвештә тышкы идарә вакыты 18 айдан 10 елга кадәр билгеләнә. Конкурслы идарә кредиторларның таләпләрен керткән өлешләре нигезендә канәгатьләндерү юлы б-н алып барыла һәм бер елдан да артмаска тиеш; арбитраж мәхкәмәсенең аны тагын 6 айга озайтырга хакы бар. 2000 елда ТРда Б. процедурасы аша 295 пр-тие, шулардан күзәтү аша — 50, тышкы идарә аша — 28, конкурс җитештерүе аша 217 пр-тие уза.

Татарстанда Б. мәсьәләсе б-н ТРның Бөлгенлеккә төшү һәм финансны савыктыру эшләре ком-ты шөгыльләнә.

Чыг.: Федеральный закон от 8 января 1998 г. № 6-ФЗ «О несостоятельности (банкротстве)».

*Әд.:* Банкротство предприятия // Директор-Дайджест. 1996. № 10; Ковалёв А.П. Как избежать банкротства? М., 1996; Теория и практика антикризисного управления. М., 1996.

*Ш.М.Вәлитов.*

**БА́ННИКОВ** Андрей Иванович (25.8.1930, Чуаш АССРның Алатырь ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1966), проф. (1967). 1954 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1957–90 елларда шунда ук эшли, 1974 елдан икътисад һәм җитештерүне оештыру каф. мөдире. 1990 нан Казан финанс-икътисад ин-тының җитештерү икътисады һәм маркетинг каф. профессоры, 1998 дән менеджмент каф. профессоры. Хезмәтләре яңа техника өлкәсендәге икътисад проблемаларына, югары мәктәп икътисадына карый.

Хезм.: Планирование научных исследований и разработок. К., 1969; Форма и методические материалы по составлению техпромфинплана предприятия. М., 1981; Исследование и разработка комплексной системы управления научной деятельностью в вузе. М., 1987.

**БАНЫ́КИН** Николай Александрович (1.5.1926, Горький өлкәсенең Богородский р-ны Троица а. — 21.3.2003, Казан), инженер-электрик, «Татэнерго» Татарстан район энергетика идарәсе управляющие (1978–85), ТРның атказ. энергетигы (2000). 1958 елда Бөтенсоюз энергетика читтән торып уку ин-тын тәмамлый (Мәскәү). 1942–45 елларда 144 нче з-дта электромонтёр (Казан). 1949–58 дә Казэнергоның 1 нче ТЭЦында дежур инженер, эл. лабораториясе технигы. 1958–60 та ТАССР Халык хуҗалыгы советының (ХХС) җитештерү бүлегендә өлкән инженер. 1960–78 дә Зәй ГРЭСы директоры; бу вакытта аның барлык 12 энергоблогы да сафка бастырыла, эл. станциясе проектта каралган егәрлегендә эшли башлый (2400 *МВт*), 1976 елның февралендә сәнәгати файдалануга тапшырыла. Илдә беренче тапкыр җиһазларны югары күкертле газ яндыруга әзерләү уздырыла һәм аны энергетик ягулык сыйфатында файдалану тәҗрибәсе туплана. Б. «Татэнерго» энергетика идарәсе управляющие булып эшләгән чорда Түбән Кама ТЭЦ-2 һәм Түбән Кама ТЭЦ-1 дә, КамАЗ ТЭЦында, Казанда ТЭЦ-3 тә яңа егәрлекләр эшли башлый. Электр челтәрләре үсеш ала. Гамәлдәге подстанцияләр, эл. тапшыру линияләре киңәйтелә, яңалары төзелә, авыл җирләрен электрлаштыру буенча зур күләмдә эш башкарыла. 1980–85 тә ТАССР ЮС депутаты. СССР МС бүләге лауреаты (1985). Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994; Лебедев А. Потенциал от души // Респ. Татарстан. 2001. 22 марта.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**БАПТИ́ЗМ** (грек. baptízō — чумдыру, суда чукындыру), протестантлыкның бер юнәлеше. 17 йөзнең 1 нче яртысында Англиядә барлыкка килә һәм 19 йөздә бөтен дөньяга, ш.и. халыкның күпчелеге католик, православие һ.б. диннәр тоткан илләрдә таралып, иң көчле дини хәрәкәтләрнең берсенә әверелә. Б. тәгълиматы тарафдарлары дини серләр, руханилар изгелеге, изгеләр культы кебек тәгълиматларны әүвәлге саф христиан диненә каршы килә дип саныйлар. Библия — дини тәгълиматның бердәнбер чыганагы, Б. тәгълиматына аңлы рәвештә инанган, рухи яктан өлгереп җиткән кешеләр генә чукынырга хаклы дип исәпләнә. Җәмгыять җитәкчеләре, вәгазьчеләр һәм Б. нигезләрен өйрәтүче руханилар приход халкы тарафыннан сайлана. Динсезләр һ.б. диндәгеләр арасында Б. идеяләрен тарату һәркемнең бурычы булып санала.

Россиядә Б. 19 йөз урталарында (Финляндиядә һәм Латвиядә), башлыча, лютераннар — немецлар һәм латышлар арасында барлыкка килә. 1880 еллар башында Украинада һәм Түбән Идел буенда тарала. 19 йөздә Татарстан җирендә Идел буе һәм Балтыйк буе немецлары гына баптист булалар. 1880 еллар урталарында бу конфессия Мордва Каратае авылыннан (хәзерге Кама Тамагы р-ны) Идел буендагы немец авылларына барып эшләп йөрүче крәстияннәр арасына да үтеп керә. 1890 еллар уртасында Б.ны кабул иткән 20 ләп кеше авылдан Себергә сөрелә. 20 йөз башында Б. Казан губернасының башка авылларында да күренә башлый (хәзерге Кукма-

ра р-нының Кашкара а.). 1905–07 еллардагы рев-циядән соң баптистлар үз эшчәнлекләрен активлаштыралар: дәгъватлау җыеннары үткәрелә, дини әдәбият күпләп таратыла. Аларның тарафдарлары Казан эшчеләре арасында да барлыкка килә. Төрле сылтаулар б-н Б. җәмгыятьләре теркәлми. 1910 елдан Б. хәрәкәтенә карата басым яңадан көчәя, хакимият органнарының яңа инструкциясе теркәлү узмаган җәмгыятьләргә төрле чаралар үткәрүне катгый тыя. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, баптистлар пацифизмда һәм Германия файдасына шымчылык итүдә гаепләнә. Шулай да аларның җәмгыятьләре таркатылмый. 1917 елга кадәр Казан губернасында баптистлар саны 200-300 дән артмый. Татарстан җирендә Б. 1920 елларда киң тарала, барлык шәһәрләрдә һәм кайбер авылларда 40 тан артык җәмгыять оеша. 1930 елларда Б. хәрәкәте, башка дини конфессияләр кебек үк, яшерен төс ала. Баптистлар эшчәнлеге 1945 елдан соң гына легальләшә. Алар, Евангелие христианнары б-н берләшеп, Евангелие христиан баптистларның Бөтенсоюз советын оештыралар һәм Казанда теркәлү узалар. 1980 елларга кадәр респ-ка терр-ясендә баптистларның 5–6 легаль һәм, 1960 та Бөтенсоюз советыннан аерылып чыгып, Евангелие христианнары — баптистлар чиркәүләре Советына кергән күпсанлы яшерен җәмгыятьләре эшли. 1980 елларда җәмгыятьләрнең саны арта, 2007 дә Казан, Чаллы, Бөгелмә, Әлмәт шәһәрләрендә, Яшел Үзән р-нының Октябрь авылында һәм Татарстанның башка төбәкләрендә баптистларның 40 ка якын җәмгыяте исәпләнә. Аларның бер өлеше Бөтенроссия советына керә, кайберләре мөстәкыйль рәвештә теркәлә, теркәлү узмаган җәмгыятьләр дә бар.

*Е.В.Липаков.*

**БАРА́БА РАЙОНЫ́**, *Новосибирск өлкәсенең* көнбатышында урнашкан. Мәйданы — 5,3 мең *км*². Үзәге — Барабинск шәһәре (Новосибирскидан 302 *км* көнбатыштарак). Халкы — 17126 кеше (2002). Татарлар саны: 1959 елда — 1,9 мең, 1970 тә — 2,1 мең, 1979 да — 2 мең, 1989 да — 1,9 мең, 2002 дә 798 кеше. Б.р.нда татарлар (бараба татарлары) элек-электән яши. Идел һәм Урал буе татарлары монда 19 йөз ахыры — 20 йөзнең 1 нче чирегендә күпләп килеп урнашалар. Хәзерге вакытта районда бер генә татар авылы — Тандов (183 кеше) бар, 250 ләп татар Яңа Курупкаевка авылында яши.

*Әд.:* Корусенко С.Н., Кулешова Н.В. Генеалогия и этническая история барабинских и кургатско-саргатских татар. Новосиб., 1999.

**БАРАБА́НОВ** Вильям Петрович (27.6.1933, Ленинград ш.), химик, химия фән. д-ры (1973), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1978, 1991), СССРның шәрәфле химигы (1979). В.В.Радлов оныгының улы. 1956 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (хәзерге Казан технол. ун-ты), шунда ук эшли. 1973 тә полимерлар физик химиясе кафедрасын оештыра һәм 2005 кә кадәр җитәкли (1991 дән физик һәм коллоид химия каф.), проф. (1974), бер үк вакытта 1973–89 да ин-тның проректоры. Хезмәтләре полимер электролитларның сусыз һәм сулы эремәләре электрохимиясе өлкәсенә, аларны халык хуҗалыгында практик куллану нигезләрен эшләүгә карый. Б. сусыз эремәләрдә ионнарның үзара тәэсир итешү процессларын өйрәнү эшләре циклын башкара. Полимерның ионлашу схемасын күп стадияле буларак тәкъдим итә, полимерларның катлаулы профильле металл өслекләргә органик һәм сулы органик тирәлектән электроутырма хасил итү ысулын, ш.у. машиналар төзү пр-тиеләренә кертелгән акрил, эпоксид, пиридиний, фторлы һәм амид полимерлар нигезендә коррозиягә каршы торучан эл. изоляцияләүче югары термик чыдам катламнар ясау өчен композицияләр эшли. Б. — суда эрүчән полиэлектролитларны һәм аларның комплексларын пластның нефть бирүчәнлеген арттыру максатыннан су чикләүче материаллар ясау өчен куллануны физ.-хим. нигезләү буенча эшләрнең җитәкчесе. Полиэлектролитларны һәм аларның комплексларын кулланып, биотехнологиядә экологик чиста интенсив процесслар барлыкка китерү өчен югары молекуляр кушылмаларның микроорганизмнар күзәнәкләре б-н үзара тәэсир итешүенең физ.-хим. нигезләрен эшләү буенча фәнни юнәлешкә башлангыч сала. Полиэлектролитларны комплекслар хасил итүче, флокулянт, плёнка барлыкка китерүче буларак, җитештерүдә куллануны нигезли. Б. калдык суларны, бүленеп чыккан газларны чистарту, тузан ясалу процессларын кискен киметү технологияләрен эшли.

Д.И.Менделеев исем. Респ-ка химиклар җәмгыяте рәисе (1987 дән). Халыклар Дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Краткий курс физической химии. М., 1978 (автордаш); Элементоорганические полимерные электролиты // Всесоюз. школа по элементоорганическим полимерам. К., 1984; Электролитическое осаждение органических покрытий // Журн. Всесоз. хим. об-ва им. Д.И.Менделеева. 1988. Т. 33, № 3 (автордаш); Формирование многокомпонентных полимерных покрытий на электроде // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3/4 (автордаш); Растворы полиэлектролитов: Избр. статьи. М., 2003.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000; Синяшин О.Г., Кочнев А.М. Вильям Петрович Барабанов // Рос. хим. журн. 2001. Т. 45, № 2; Профессор Барабанов Вильям Петрович: Биобиблиогр. К., 2003.

**БАРАБА́НОВ** Владимир Иванович (19.5.1937, Балык Бистәсе р-ны Дон-Урай а.), химик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), техник фән. канд. (1967). 1961 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1962 елдан Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1980 нән лаб. мөдире, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2005 тән). Хезмәтләре терлекчелек өчен биологик актив кушылмалар синтезлауга, алдынгы технологияләр эшләүгә һәм вет. дәвалау препаратлары җитештерүгә карый. Уйлап табуга 7 патенты, 85 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге «Йогышсызландыруда, дәвалау-профилактика уздыруда кулланыла торган технол. химик препаратлар уйлап табу, әзерләү һәм гамәлгә кертү» («Изыскание, разработка и внедрение в производство дезинфицирующих, лечебно-профилактических и технологических химических препаратов») дигән хезмәте өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**БАРАБА́НЩИКОВ** Борис Иванович (26.7.1942, Казан), генетик, биол. фән. д-ры (1990), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1965). 1968 елдан Казан ун-тында, 1976 дан генетика кафедрасын оештыручы һәм мөдире. Хезмәтләре микроорганизмнар генетикасы һәм молекуляр генетикага карый. Аның тарафыннан беренче тапкыр печән таякчыгының (Bacillus subtilis) гомологик рекомбинация процессын контрольдә тотучы 5 яңа гены ачыклана. 2 гены клонлана, аларның эчәк таякчыгы (Escherichia koli) геннарына хас гомологиясе исбат ителә. B. subtilis күзәнәкләрендә гомологик рекомбинация процессын үтәүче төп ферментлар җыелмасы буларак, рекомбинасомалар концепциясе тәкъдим ителә. 1991 дән Б. төп генетик процесслар регуляциясендә биологик актив кремний ролен өйрәнү б-н шөгыльләнә. Доцент С.В.Малков б-н берлектә геннар эшчәнлегенең хромосомада — кремнийның биологик актив кушылмалары силикат-ионнар концентрациясенә бәйлелеге турындагы «геном ювенилизациясе (яшәрүе)» гипотезасын тәкъдим итә. Еллар узу б-н мондый ионнар саны акрынлап кими. Бу — геннарның аерым ансамбльләре эшчәнлеге бозылуга һәм организмның картаюына китерә. 1977 дән Селекционерлар һәм генетиклар җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе.

Хезм.: Молекулярные механизмы процессов репарации, рекомбинации и мутагенеза. К., 1986; Молекулярная генетика. К., 1988; Сборник задач по генетике. К., 1988; Хрестоматия по генетике. К., 1988.

**«БАРАБЫ́З»**, татар крәстияннәренең 19 йөз — 20 йөзнең 1 нче чирегендә Казандагы вакытлы кәсебе — ат җигелгән чаналарда кешеләр йөртү, йөк ташу. Кайбер мәгълүматлар буенча, андый кәсеп б-н Казанда берничә мең кеше шөгыльләнгән. Гади йөк чаналары файдаланылган. Утыргыч урынына салам тутырылган түшәкләр, зур капчыклар кулланылган. Һ.Такташның бер шигырендә: «Барабыз»га утырып, теләгән җиргә кошлар кебек очып барабыз», — дигән сүзләр бар.



«Барабыз»лар Казанда.

**БАРАВЫ́Ш** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Суша елгасының сул кушылдыгы (Кама елгасы бассейны). Озынлыгы 13,3 *км*, бассейнының мәйданы 53,3 *км*². Балык Бистәсе

р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Колос авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Тегермән Пүчинкәсе авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 56 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 58%. Б. елгасының 0,8 дән алып 5 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,58 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 154 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,099 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12 *мг-экв/л* дан артыграк). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**БАРАКЧИ́Н** (? — 1257), ханбикә. Бату ханның өлкән хатыны. Тарихчы Рәшидетдин язуынча, алча-татар нәселеннән. Сартак б-н Улакчы ханнар вафатыннан соң (1256/57), Бәркә ханга һәм аның Алтын Урданы Монгол империясенә буйсынудан чыгарырга тырышуына каршы торучы төркемнең җитәкчесе була. Алтын Урда тәхетенә Туда Мәнгуны утырту максатында ярдәм сорап бөек каган Мөнке б-н империянең Иран төбәге ханы Һулагуга мөрәҗәгать итә. Яшерен эшләре ачылгач, җәзалап үтерелә.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1975.

**БАРА́КЪ ХАН** (Барыкъ, Боракъ) (1396 тирәсе — 1428/29), Алтын Урда ханы (1422–26). Коерчак ханның улы. Тимер Котлык б-н Идегәй берләшеп Коерчакны тәхеттән төшергәннән соң (1397), Б.х. Идегәй сараенда тәрбияләнә. Идегәй вафат булгач (1419), Сәмәркандка качып китә, Аксак Тимер оныгы Олугбәк сараенда сыену таба. 1421–22 елларда Олугбәк гаскәре ярдәмендә *Олуг Мөхәммәд хан* б-н Дәүләтбирде көчләрен җиңүгә ирешә, аларны Литва кенәзлеге чикләренә кадәр чигендерә һәм Алтын Урда тәхетен яулап ала. 1425 елда Болгарда үз исеменнән акча суктыра. Олуг Мөхәммәд б-н 1425–26 еллардагы бәрелешләрдән соң Идел аръягына куыла. 1426 да көч туплап, Мәварәэ ән-нәһергә (Амударья б-н Сырдәрья аралыгы өлкәләренә) яу б-н бара, 1427 дә Күк Урда олысын торгызып, Сыгнак шәһәрен башкала итә. Магуллар әмире Солтан Мәхмүт углан гаскәре б-н сугыш барышында һәлак була.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983. *И.Л.Измайлов.*

**БАРА́НОВ** Александр Александрович (15.7.1941, Киров өлкәсенең Шаранта а.), балалар табибе, мед. фән. д-ры (1979), проф. (1982). РМФА академигы (1995). 1964 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1966 елдан шунда ук эшли. 1969 дан Горький педиатрия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1979 дан директор. 1987 дән Мәскәүдә: СССР сәламәтлек саклау министры урынбасары, 1 нче урынбасары, 1992 дән Мәскәү мед. академиясенең балалар авырулары каф. мөдире, бер үк вакытта РМФАнең Балаларны сәламәтләндерү фәнни үзәге директоры. Хезмәтләре балалар гастроэнтерологиясенә, ашказаны-эчәк юлларындагы йогышсыз һәм йогышлы эпидемик авыруларны өйрәнүгә, ана һәм балалар сәламәтлеген саклауның экологик проблемаларына, социаль педиатриягә, балалар сәламәтлеген саклауны оештыруга карый. Казан мед. ун-тының шәрәфле профессоры (1999). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.


Хезм.: Новые организационные формы медицинского обслуживания детей. К., 1993 (автордаш); Репродуктивно-демографические показатели. К., 1994.

**БАРА́НОВ** Владимир Андреевич (15.9.1872, Самара губ., Бөгелмә өязе Югары Микулино а. — 14.2.1942, Казан), астроном һәм гравиметрист. 1895 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1898 елдан шунда ук эшли, проф. (1918 дән). 1918–41 елларда Казан шәһәр астрономия обсерваториясе директоры. Үзгәрүчән йолдызлар торышын күрсәткән ике каталог төзи, кече планеталарны, кометалар, куш йолдызларны күзәтә һәм СССРның Европа өлешенең көнчыгыш р-ннарында җирнең тарту көчен билгеләү буенча күпсанлы тикшеренүләр уздыра.

Хезм.: Определение силы тяжести на Урале и по Волге в 1899, 1900, 1902 и 1903 гг. К., 1907; Измерение двойных звёзд V и VI классов Гершеля. К., 1909; Определение силы тяжести для Казанской и Энгельгардтовской астрономических обсерваторий: Дисс. ... К., 1910.

*Әд.:* Профессор В.А.Баранов // Уч. зап. Казан. ун-та. 1934. Т. 94, кн.6.

**БАРА́НОВ** Владимир Исаакович (21.2.1889, Казан губ., Мамадыш өязе Нырты а. — 3.8.1967, Казан), ботаник, биол. фән. д-ры (1937), проф. (1932), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1945, 1959). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1913), шунда ук эшли. 1918 елдан Томск ун-тында. 1920–29 елларда Себер а.х. ин-тында (Омск ш.) үсемлекләр географиясе һәм экологиясе каф. мөдире. 1929 дан Пермь, 1932 дән Казан ун-тларында ботаника каф. мөдире. Идел елгасы үзәнлегендәге торфлы сазлыкларны, Уфа губернасы Бәләбәй өязендәге көтүлекләрне, үз конструкциясендәге прибор — капилляр-монометрны кулланып, өслекчә актив матдәләрнең үсемлекләр күзәнәгенә йогынтысын өйрәнә. Сфагнум мүкләренең анатомик рәсемнәре атласын төзи. 1913–14 елларда А.Келлер җитәкчелегендә Казан губ. болыннарын тикшерә. 1918–32 дә Көнбатыш Себер, Алтай һәм Монголия терр-ясендә геоботаник тикшеренүләр үткәрә. Соңрак аның географик ландшафтларның зона һәм төбәк үзенчәлекләрен билгеләү ысуллары аларны өйрәнүнең нигезе булып тора. Палеоботаника өлкәсендәге тикшеренүләре б-н Б. киң таныла. 1938 дән башлап Волгоград өлкәсе терр-ясендә Идел елгасы үзәненең палеоген, Көньяк Урал һәм Мөһаҗарның бер үк яшьтәге флоралары, Кама елгасы үзәненең плиоцен, Красноярск өлкәсендәге Кемь елгасы үзәненең акбур чоры һ.б. казылма флораны үзе җыя һәм өйрәнә. 1948–59 да, төп бүлекләрне борынгы ландшафтларның үзенчәлекле реконструкцияләре б-н иллюстрацияләп, югары акбур һәм өченчел (палеоген-неоген) чорлар флорасы буенча берничә хезмәт бастырып чыгара. Югары төзелешле үсемлекләр систематикасы һәм географиясе, палеоботаника буенча картиналар һәм күрсәтмә таблицалар, этюдларның зур коллекциясен төзи (хәзер Казан ун-ты Ботаника музеенда саклана). Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә. Казан ун-тында (биол.-туфрак ф-тында) Б. истәлегенә мемориаль такта куелган (1999).



В.И. Баранов.

Хезм.: Растительность чернозёмной полосы Западной Сибири. Омск, 1927; Пихтовая тайга на северных предгорьях Алтая. Пермь, 1931 (автордаш); Этапы развития флоры и растительности СССР в третичном периоде. Итоги изучения ископаемых третичных флор и проблемы реликтов в современной растительности СССР. М., 1959.

*Әд.:* Беляева М.И., Аксёнова Н.Н. Владимир Исаакович Баранов. К., 1945; Потери науки: Владимир Исаакович Баранов // Изв. Всесоюз. геогр. об-ва. 1968. № 1; Владимир Исаакович Баранов: Научно-библиогр. очерк. К., 1989; Любарский Е.Л., Николаева К.В., Шаландина В.Т. Владимир Исаакович Баранов (к 100-летию со дня рождения) // Ботанический журн. 1992. Т. 77. № 3. *К.В.Николаева.*

**БАРА́НОВ** Геннадий Михайлович (29.4.1941, Ульянов өлкәсенең Инза р-ны Базар Сызганы эшчеләр бистәсе), хокук белгече, иң югары квалификация класслы судья (1996), ТАССР һәм РФнең атказ. хокук белгече (1991, 1995). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1967–72 елларда Казан шәһәре Киров р-ны мәхкәмәсендә халык судьясы. 1972–73 тә ТАССР Югары мәхкәмәсе әгъзасы, 1973–85 тә рәис урынбасары, гражданнар эшләре (1973–75), җинаять эшләре буенча (1975–85) коллегия рәисе. 1985 тән ТР Югары мәхкәмәсе рәисе. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты. Медаль б-н бүләкләнә.

**БАРАНО́ВСКИЙ** Антони-Лонгин Юрьевич (15.3.1854, Ковно губ. — 1922), генерал-майор (1911). Польша-Литва татарларыннан. Вильно шәһәрендә гимназия, Чугуев шәһәрендә пехота юнкерлар уч-щесен тәмамлый (1876). 1907 елдан Россия армиясе полковнигы. Сербиядә барган сугышта (1876), рус-япон сугышында (1904–05, батальон командиры) катнаша. 1909 дан Көнчыгыш Себердәге 25 нче укчылар полкы командиры. 1911 дән отставкада. 1914 тән Беренче бөтендөнья сугышында катнаша (полк командиры). 1919 дан Польша армиясендә, 1920 елгы Совет-Польша сугышында 5 нче поляк армиясенең сугышчан төркеме командиры була. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир ордены, «Батырлык өчен»

алтын корал, Сербия хөкүмәтенең «Батырлык өчен» алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

*Я.Я.Гришин.*

**БАРАНО́ВСКИЙ** Туган-Мирза Александр Давидович (8.1.1847, Август губ. — ?), генерал-лейтенант (1904). Польша-Литва татарларыннан. Петербург хәрби гимназиясен, Константин исем. 2 нче хәрби уч-щене (1865) һәм Ген. штаб академиясен (1874) тәмамлый. 1883 тән полковник, 1897 дән генерал-майор. Рус-төрек (1877–78), рус-япон (1904–05) сугышларында катнаша. 1891–1906 да 4 нче укчы полк, 7 нче Ревель полкы командиры, Варшава кирмәне штабы башлыгы, 27 нче пехота дивизиясенең 2 нче бригадасы командиры, 4 нче Төркестан укчы бригада башлыгы, 72 нче, 12 нче дивизияләр командиры. 1906 ның маеннан отставкада. «Батырлык өчен» дип язылган Георгий алтын коралы, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 нче, 2 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

*Я.Я.Гришин.*


**БАРАТА́ЕВ** Семён Михайлович (3.2.1745, Әстерхан ш. — 30.12.1798, Казан), кенәз, дәүләт эшлеклесе, генерал-майор (1789), тайный советник (1797). 1759 елдан хәрби хезмәттә. Рус-төрек сугышларында катнаша (1768–74, 1787–89). 1786–87 елларда Казанда дары з-ды төзелешенә җитәкчелек итә. 1789–96 да Казан наместниклыгы идарәчесе, 1796–97 дә Казан губернаторы. Казанда шәһәр думасын оештыруда (1789) һәм шәһәр полициясен булдыруда (1796) катнаша. Б. инициативасы б-н Казанда җәмәгать театры ачыла (1791–96).

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003. *Е.Б.Долгов.*


**БАРАТЫ́НСКИЙ** Ираклий Абрамович, к. *Боратынский* И.А.

**БАРАШО́В** Михаил Васильевич (28.9.1897, Вятка губ. Барашово а. — 7.9.1962, Әстерхан ш.), театр рәссамы, график. Казан архит-ра-техника ин-тын тәмамлый (1924), бер үк вакытта скульптура һәм гравёрлык ф-тларында укый. 1924–25 елларда ин-тының укыту-житештерү ташбасма һөнәрханәсе мөдире (анда плакатлар, «*Всадник*» басмалары, *КЭМСТ* афишалары һ.б. басыла). Б. — агитация плакатлары, афишалар, экслибрислар, театр шаржы жанрына караган карикатуралар — «Казан рампасы тирәсендә» (1923), «Кыек күзге» (1923), «Мастфор» («Форегтер мастерское», 1923) серияләре авторы. Б. әсәрләренә персонаж характерын ачыграк күрсәтүдә рәсемнең декоративлыгы һәм пластик яктан төгәл бирелүе, 19–20 йөзләр сәнгатендәге театраль пародия-шарж жанрының классик үрнәкләренә омтылу хас. Ул *Хәзерге заман конструктив-тәҗрибә театрының остаханәсен* (1923–26) оештыручыларның берсе, аның рәссамы һәм актёры. В.Каменскийның «Степан Разин» (1923), С.Третьяковның «Противогазлар» («Противогазы», 1924), И.Пшеничныйның «Тормыш җырчысы» («Жизнепев», 1924), Д.Рид әсәре буенча куелган «Дөньяны тетрәндергән 10 көн» («10 дней, которые потрясли мир», 1925) һ.б. спектакльләрне бизи. Б. сценографиясе театрның конструктив-эксперименталь эстетикасын тирәнтен ача, традицион театраль-декоратив сәнгатькә альтернатива булып тора. Сәхнә бизәлеше тәэсир итү чараларының гадилеге б-н аерыла. Композиция коруда төрле конструкцияләр, станоклар, спектакльнең төп элементы булган мизансцена пластикасы һәм «сукно» б-н бүленгән сәхнә күренешләрен куллану зур роль уйный. Б. — республикада театраль белем бирүне башлап йөри, Татар театр техникумын оештыручыларның һәм анда укытучыларның берсе (1924–26). ТатЛЕФ әгъзасы (1923 елдан), 1924, 1925 елларда уздырылган күргәзмәләрдә катнаша. 1927–32 дә Симферополь, Ялта, Керчь, Севастополь, Хабаровск шәһәрләре театрларында эшли. 1933 тән Әстерхан драма театрының баш рәссамы, аның сәхнәсендә куелган күп кенә спектакльләрне бизи. 1936 дан Әстерхан сәнгать уч-щесендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1936 дан). «Түбән Идел» офортлар сериясен иҗат итә (1951, 1960). Б.ның шәхси күргәзмәләре 1958, 1967 елларда Әстерхан шәһәрендә булып уза.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; Каталог выставки произведений художников Татарии 1920–30-х годов. К., 1990. *Е.П.Ключевская.*



М.В.Б а р а ш о в. В.Каменскийның «Степан Разин» пьесасы буенча куелган спектакльгә костюм эскизы. КЭМСТ. Акварель. 1920 еллар.



М.В.Б а р а ш о в. «Автопортрет. Театр витринасы янында уйлану». Акварель. 1923. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



М.В.Б а р а ш о в. «Кепкалы актриса». КЭМСТ. Ташбасма. 1920 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

**БАРБАРИ́С** (Berberis), барбарисчалар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. 500 ләп төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарда киң таралган. ТРда бер төре — гади Б. (B.vulgaris), ялгыз үсә яки урман буенда, чокыр сөзәклекләрендә куаклыклар хасил итә. Бакча һәм паркларда декоратив үсемлек буларак үстерелә. 50–150 *см* озынлыктагы куе ботаклы куак. Тамыр системасы нык үскән, тамырчасы агачланган шуышма, өч, сирәгрәк биш бүлекчәле, чәнечкеле кырлы чыбыксыман үсентеле. Яфрак читләре вак тешле, бәйләм булып урнашкан. Чәчәкләре вак, аксыл сары төстә, бөгелгән куыш чукта, хуш исле. Җимеше — озынча әче кызыл җиләк. Май–июнь айларында чәчәк ата; август ахыры – сентябрьдә өлгерә. Орлыклардан, үсентедән, куакның бүленүе нәтиҗәсендә һәм чыбыкчадан үрчи. Туфракка талымсыз. Җимешләрендә шикәр, органик кислоталар, минераль тозлар, витаминнар, дуплау матдәләре, яфракларында эфир мае бар. Тамырларыннан мед. препаратлары берберин алалар. Б. яфракларыннан ясалган төнәтмә кан туктату өчен, тән кызышканда, үт кудыру өчен кулланыла һәм антисептик сыйфатка ия. Җимешләрен аппетитны яхшырту, сусаганны басу өчен файдаланалар. Җимешләре азык-төлек сәнәгатендә чи һәм эшкәртелгән хәлдә кулланыла. Баллы.

*Әд.:* Л а в р е н о в а Г.В. Лекарственные травы: Травы, дарящие здоровье. М., 1996. Кн. 1.

**БА́РБАРО** (Barbaro) Иосафат (1413, Венеция ш. — 1494, шунда ук), Венеция сәүдәгәре һәм илчесе. 1436 елда Венециянең Азов диңгезе буендагы колониясенә — Тана (*Азак*) шәһәренә килә һәм анда 16 ел яши; Кара диңгезнең төньяк яр буйларында һәм Кавказда була, сәүдә эшләре б-н шөгыльләнә. Венеция респ-касы хакимлеге кушуы буенча Алтын Урда ханнары б-н элемтә урнаштыра, татарларның тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен өйрәнә. 1452 дә Венециягә кайта, дәүләт оешмаларында эшли. 1463 тә Венеция респ-касының Далмация б-н Албаниядәге рәсми вәкиле. Далмациянең диңгез буе хәрби сагын оештыра, Албания хөкүмәте башлыгы Георгий Скандербекка төрекләр һөҗүменә каршы көрәштә булышлык итә. 1469 да Төркия б-н дипломатик сөйләшүләр алып бару өчен Венециягә чакырып кайтарыла. 1473 тә Төркиягә каршы уртак килешү төзү

нияте б-н Тигр елгасының югары агымындагы Ак Коюнлы төрки-угызлар дәүләте башлыгы Озын Хәсән карамагына зур илчелек б-н бара. Ләкин уңышка ирешә алмый. Венециягә кире кайтканда 1479 да Мәскәүдә була. 1482–85 тә Ровиго шәһәре башлыгы, Венеция респ-касының сенат әгъзасы. Үзенең Көнчыгыш илләрендә күргән-белгәннәре турында кыскача язып калдыра. Анда Алтын Урдада барган тәхет өчен көрәш, Мәскәү б-н Казан мөнәсәбәтләре, Кара диңгезнең төньяк тарафларындагы Төркия сәясәте һ.б. чагылыш таба. Идел буе татарлары б-н Төньяк Кавказда яшәүче нугайларның тормыш-көнкүреше, мәдәнияте, хәрби әзерлеге дә тасвирлана.

Х е з м.: Viaggi fatti de Vinetia alla Tana, in Persia...., publ. da A.Manuzio. Venezia.

*Әд.:* Барбаро и Контарини о России // Пер., комм. и перевод Е.И.Скржынской. Л., 1971.

*И.Л.Измайлов.*

**БАРДА́ РАЙОНЫ́**, *Пермь өлкәсенең* көньягында урнашкан. 1924 тә оештырыла. Мәйданы — 2409 *км*². Үзәге — Барда авылы (Пермь шәһәреннән 165 *км* көньяктарак). Халкы — 27904 кеше (2002). 1989 елгы халык исәбе буенча, башкортлар — 24952, руслар — 2449, татарлар — 1459, 2002 елда 9025 татар яши. Б.р. халкының күпчелеге, рәсми рәвештә башкортлар булып саналса да, татар телендә сөйләшә. Районда 65 торак пункт исәпләнә. Иң зур авыллар (2000): Барда (8844 кеше), Сараш (1659), Елпачиха (Үдик) (1477), Бичурино (Озын Ялан) (1398), Краснояр-1 (1нче Әрҗән) (1230). 1998/99 уку елында Б.р.ның 39 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла. 1918 елдан район театры (1959 елда «халык театры», 1988 дә «үрнәк театр» исеме бирелә) эшли. 1931 дән «Таң» г-тасы нәшер ителә. 1993 тән редакция каршында татар китапларын бастырып чыгаручы нәшрият эшли. «Таң йолдызы» әдәби берләшмәсе бар. Б.р.нда Сов. Союзы Герое Ш.Г.Казанбаев; Дан орденының тулы кавалерлары З.Х.Әминов һәм Ә.Г.Даутов; генерал-майор А.Ф.Карпатов; РМФА акад. А.Т.Алдаров; фән д-рлары: А.Х.Мукатанов һәм И.Г.Юлушев, Г.К.Ибраев, Р.Д.Мөхәммәдъяров, В.М.Турпанова, җырчы-композитор М.Имашев туган.

*Әд.:* Ф а т ы й х о в  Ә. Гәйнә иле. Барда, 1995.

**БА́РДИНА** Гөлшат Абдулла кызы (5.2.1938, Казан), балалар табибәсе, сәламәтлек саклау хезмәткәре, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996), мед. фән. канд. (1996). РСФСР һәм ТРның атказ. табибәсе (1989, 1992). 1962 елда Казан мед. ин-тының педиатрия, 1993 тә социаль хезмәткәрләр ф-тларын тәмамлый. 1962 елдан Казан мед. учреждениеләрендә эшли. 1979–95 тә ТР сәламәтлек саклау министры урынбасары. 1995 тән Казан мед. көллиятендә директор урынбасары. Дәүләт бүләге «Җирле санаторий-курорт учреждениеләре шартларында йөкле хатыннарны сәламәтләндерүне оештыру» («Организация оздоровления беременных женщин в условиях местных санаторно-курортных учреждений») дигән хезмәте өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* П а в л у х и н  Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**БА́РДУ** Карл Вильгельм (Bardou Karl Wilhelm) (1750 еллар, Берлин — 1842 дән соң, шунда ук), немец нәкышьчесе, портретлар, миниатюралар остасы, күбрәк пастель техникасында эшли. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында С.-Петербургта һәм Мәскәүдә, 1812–16 елларда Казанда яши. Энгельгардтлар гаиләсендә сәнгать укытучысы булып эшли. Казанда яшәгән шәхесләрдән А.Ю.Оболенская (1812), Н.В.Колбецкий (1813), Х.П. һәм Е.П.Куприяновлар (1813), А.И.Ильин (1814), Е.П. Энгельгардт (1814), М.Н.Энгельгардт (1814), В.Ф.Горемыкин, П.Ф.Горемыкин, П.Ф. Желтухин (1815), С.А.Москательников (1815), М.П.Ильина (1816), Энгельгардтлар гаиләсе (1816), С.Р.Пятницкая, Нелединцкая-Мелецкая һ.б.ның 20 дән артык портретын яза. Әсәрләре Третьяков галереясында, «Мураново» музей-утарында, Калуга өлкәсе сәнгать музее, Карелия Респ-касы (Петрозаводск ш.), Иваново өлкәсе, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музейларында саклана.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; К а ц м а н  И. Пастельные портреты К.В.Барду в собрании музея-усадьбы «Мураново» // Искусство. 1984. № 7.

**БАРҖЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Иж елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 27 *км*, ТР чикләрендә 6 *км*. Бассейнының мәйданы 172 *км*². Әгерҗе р-нында, Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Барҗы Пельга авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 14%. Б. елгасының 1,5 тән алып 14,5 *км* га кадәр озынлыктагы 11 кушылдыгы бар, иң зурысы — Уса елгасы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,56 *км/км*². Катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 145 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун көнендә башлана. Б. октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,17 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Елганың түбән өлеше *«Кичкетаң»* комплекслы табигать тыюлыгы терр-ясендә. Б. елгасының сул ярында — Балтач авылыннан югарырак ТРның табигать истәлеге — *Катнаш наратлык* урнашкан.





К.В.Б а р д у. 1. «Офицер М.И.Яковлев портреты». Кәгазь, пастель. 19 йөз башы; 2. «Кенәз хатыны Оболенская портреты, кыз фамилиясе Нелединская-Милецкая». Кәгазь, пастель. 19 йөз башы.

**БАРҖЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Иж елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 24,4 *км*, ТР чикләрендә 7,6 *км*. Бассейнының мәйданы 190,8 *км*². Әгерҗе р-нында, Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Барҗы-Умга авылыннан 4,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 27%. Б. елгасының 0,5 тән алып 12,9 *км* га кадәр озынлыктагы 16 кушылдыгы бар, иң зурысы — Кече Уга елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,51 *км/км*². Катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 154 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун көнендә башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,2 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Елга тамагы *«Кичкетаң»* комплекслы табигать тыюлыгы терр-ясе тирәсендә.

**БАРҖЫ́-ПЕЛЬГА́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 62 *км* көньяктарак, Барҗы елгасы буенда. 2002 елда 141 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 17 йөз уртасыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиязннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1887 елгы мәгълүматларга караганда, Б.-П.да су тегермәне була. 1920 елга кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Мушаков волостена, 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсенә керә. 1921 елдан ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык са-

ны: 1859 да — 283, 1887 дә — 364, 1920 дә — 524, 1926 да — 575, 1938 дә — 627, 1949 да — 551, 1958 дә — 613, 1970 тә — 540, 1989 да — 130 кеше.

**БАРҖЫ́-УМГА́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 74 *км* көньяктарак, Барҗы елгасы буенда. 2002 елда 183 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөз уртасыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә, вак-төяк б-н сәүдә итә. 1880 елларда Б.-У.да мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. 1920 елга кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Әсән волостена, 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсенә керә. 1921 елдан ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 555, 1887 дә — 725, 1920 дә — 1055, 1926 да — 1052, 1938 дә — 886, 1949 да — 720, 1958 дә — 576, 1970 тә — 470, 1989 да — 254 кеше. Драматург Т.*Гыйззәт* туган авыл.

**БАРИ́ЕВ** Евгений Илгиз улы (21.11.1966, Чиләбе өлкәсенең Еманжелинск ш.), шахматчы, халыкара гроссмейстер (1989). Олимпия резервы спорт интернат мәктәбендә тәрбияләнә (Мәскәү). Үсмерләр арасында дөнья чемпионы (1982), яшүсмерләр арасында дөнья чемпионатында призлы урынны ала (1986), Бөтендөнья шахмат олимпиадасында җиңүче командада уйный (1994). 1991 елда халыкара рейтингы 4 нче урында була (Г.Каспаров, В.Иванчук, А.Карповтан соң). Күп тапкыр халыкара турнирларда катнаша. 1983 елдан Мәскәүдә яши.

**БАРИ́ЕВ** Марат Мансур улы (9.7.1961, Казан), хакимият эшлеклесе. ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (2006). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1984). 1984–86 елларда Казан авиация җитештерү берләшмәсендә инженер-конструктор. 1986–91 дә ВЛКСМның Ленин райкомы секретаре, 1991–94 тә Казанның Ленин р-нында Яшьләр фонды идарәсе рәисе. 1994–2001 дә ТРның Балалар һәм яшьләр эшләре дәүләт ком-ты рәисе. 2001 дән ТРның Яшьләр эшләре һәм спорт, 2005 тән яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры.

**БАРИ́ЕВ** Нургали Бари улы (1.1.1919, Әтнә р-нының Югары Көек а. — 8.8.1998, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1966). Зөя а.х. техникумын тәмамлый (1938). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–52 елларда Әтнә р-нының өлкән агроурман-мелиорация белгече. 1952–71 дә шул ук районның «Үрнәк» к-зы рәисе. Аның җитәкчелегендә «Үрнәк», респ-када беренчеләрдән булып, миллионер колхозга әверелә: бөртекле культураларның уңышы 2 тапкырдан да күбрәк, ит һәм сөт җитештерү 1,5 тапкыр арта. 1971–77 дә Олы Әтнә авыл советы рәисе. 1963–67 дә РСФСР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1980.


**БАРИ́ЕВ** Радик Әбрар улы (37.7.1961, Украина ССР, Житомир өлкәсенең Олевский р-ны Белокоровичи а.), Россия Герое (2006), полковник (1997), 1 нче класслы хәрби очучы (1987), 1 нче класслы очучы-сынаучы (1999), хәрби фәннәр канд. (2004). Балалык еллары Ирнур авылында үтә (Мари АССР, Бәрәңге р-ны Яңавыл а.). Качино очучылар югары хәрби авиация уч-щесен (1982), Ю.А.Гагарин исем. Хәрби-һава академиясен тәмамлый (1991). 1978 дән Совет армиясе сафларында. 1982–88 елларда Карпат буе хәрби округында: очучы, өлкән очучы, авиация звеносы командиры. 1991 дән Очу-сынау үзәгендә: очучы-сынаучы, өлкән очучы-сынаучы, эскадрилья командиры урынбасары, өлкән инспектор, бүлек начальнигы урынбасары, РФ Оборона министрлыгының дәүләт очу-сынау үзәге (Төньяк Кавказ хәрби округы) башлыгы. Яңа тип самолётларны сынаганда батырлык күрсәтә: 52 типтагы самолётларны һәм аларның модификацияләрен (Су-17, Су-25, МиГ-21, МиГ-23, МиГ-25, МиГ-29, Су-27, Су-30, Су-33, Ту-134, Як-40, Ан-26, Як-130, МиГ-АТ, Су-29КС, Су-34) тулысынча үзләштерә һәм аларда оча. Яңа типтагы тәҗрибә самолётларын сынаганда очуның моңарчы үзләштерелмәгән режимнарын башкара; беренче тапкыр Су-30 самолётыннан бер үк вакытта ике цельгә ата. Перспектив авиация комплексы двигательләренең сугышчан нәтиҗәлелеген күтәрү өчен аларга идарә ителә торган тарту векторлы җайланма кирәклеген беренче тапкыр тактик яктан нигезли. Б. 2005 елда, дөньяда беренче булып, штопор ясап төшүче самолёттан идарә ителә торган ракета б-н цельгә тидерә. Идарә ителә торган тарту векторы кулланыла торган югары манёврлы режимнарда һава сугышы алымнарын кертүнең тактик алымнарын эшли. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

**БАРИ́ЕВ** Риза Хәлирахман улы (18.9.1937, Ленинград), философ, филос. фән. д-ры (1996), проф. (1993). Ульянов хәрби элемтәчеләр уч-щесен (1959), Мәскәү ун-тының филос. ф-тын (1968) тәмамлый. 1959–78 елларда Сов. Армиясендә хезмәт итә. 1978–79 да Һава һөҗүменнән саклану көчләренең Армавир югары хәрби очучылар уч-щесендә, 1979–87 дә Пушкин исем. югары хәрби радиоэлектроника уч-щесендә укыта. 1987 дән С.-Петербург хәрби элемтә академиясендә эшли. Хезмәтләре Идел буе болгарлары тарихына, ш.и. аларның килеп чыгышына кагылышлы фәлсәфи мәсьәләләргә карый.

Х е з м.: История булгаро-татар: основные вехи. СПб., 1992; Философские аспекты этногенеза волжских булгар. СПб., 1996; Философские и естественно-научные основания истории. СПб., 1996.

*Әд.:* Ю з е е в А.Н. Критические заметки о новой книге // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 3/4.

**БАРИ́ЕВ** Ринат Зөфәр улы (19.4.1950, Казан — 17.5.2001, Сан-Карлос, Бразилия), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1985), проф. (1993). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физ.-техника ин-тында эшли, 1993 елдан баш фәнни хезмәткәр. Төп хезмәтләре төгәл чишелә торган модельләрнең стат. механикасына карый. Критик индексларның урыны б-н универсаль булмавы теориясен камилләштерә. Корреляцияле сикерешләр моделен (Бариев моделен) тәкъдим итә һәм төгәл чишә.


Н.Б. Бариев.

Х е з м.: Влияние линейных дефектов на локальную намагниченность плоской решётки Изинга // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1979. Т. 77, вып. 3 (9); Точное решение двумерной вершинной модели небакстеровского типа // Письма в Журн. эксперим. и теорет. физики. 1980. Т. 32, вып. 1; Критические свойства системы вблизи угловой границы // Теорет. и мат. физика. 1986. Т. 69.

*Р.Г.Усманов.*

**БАРИ́ЕВ** Шамил Мәсгуть улы (14.11.1950, Саба р-ны Олы Арташ а. — 11.3.1994, Казан), актёр, ТАССРның атказ. артисты (1986). Ленинград театр һәм кинематография ин-тының Татар театр студиясен тәмамлаганнан соң (1973), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Бер үк вакытта 1979 елдан Казан театр уч-щесендә, 1991 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында режиссёр-педагог. Театр сәхнәсендә Р.Батулланың «Өчәү юлга чыктык» әсәрендәге гаделлек эзләүче, кырыс, аяусыз, тынгысыз Ихлас ролен башкарып, Б. үзен талантлы актёр итеп таныта. Замандашлары рольләрен күп уйный: Ләззәт («Кан кардәшләре», Ю.Әминов), Олег Шорохов («Тәкәббер гашыйклар», А.Кузнецов), колхоз рәисе («Солдат хатыны», Н.Анкилов), Яшәр («Тормыш дулкыннары», Р.Ишморат), Яков («Һаваларда йолдыз», М.Горький) һ.б. 1980 елларда Б. М.Байҗиевның «Кияү белән Кәләш» спектаклендә Кияү образын актёр нечкә психол. алымнар б-н тасвирлый. Шундый ук нечкә зәвык б-н Хәсән («Ләйсән ире Хәсән», Ю.Сафиуллин), Айдар («Зифа», Н.Исәнбәт), Режиссёр («Әлепле әртистләре», Аманулла), Мирвәли, Вардис, Гариф (берьюлы өч төрле образ, «Бәхетлеме син?», М.Садыйкова) образларын иҗат итеп, үз мөмкинлекләрен яңа яссылыкта ача, импровизация сәләтенә ия актёр итеп таныта.

Шигъри җанлы, муз. сәләткә ия актёр һәр рольдә үз күңеленә якын берәр гүзәл яңгырашлы нота таба, һәм нәтиҗәдә геройның эчке матурлыгы ачыла. Шундый образларның берсе — Ч.Айтматовның «Плаха» повесте буенча эшләнгән «Ахырзаман» спектаклендәге Ирназар роле. Бу роль өчен Б. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләгенә лаек була (1988). Радио-телевидение тапшыруларында актив катнаша, концертлар алып бара, еш кына үзе дә җырлары б-н чыгышлар ясый.

*Әд.:* Бариев Р. Жырга әверелгән гомер — мизгел...: (Артист Шамил Бариев). К., 1999.

*Д.Гыйльманова.*

**«БАРЛЫ́К МӨСЕЛМА́Н КОМИССАРИАТЛАРЫНА́»**, Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең Чех-словак хәрби корпусы башлаган фетнә уңаеннан мөрәҗәгате. Барлык мөселман хәрби берәмлекләрен Совет респ-касын якларга чакыра: «Совет республикасы авыр көннәр кичергәндә мөселман пролетариатлар аны якларга тиеш. Кызыл армиянең барлык мөселман берәмлекләре кичекмәстән контрреволюция көчләре белән көрәшкә мобилизацияләнсен. Чакыру-өндәмәләр таратып, Совет оешмалары б-н бердәм булып, Дутовка, чех-словакларга һәм Ивановка каршы барлык көчләрне туплап җибәрегез. Ирек өчен барган бу көрәштә мөселман пролетарийлар, барча пролетарийлар б-н бер сафта торып, үзләренә мактаулы урын яуларга тиеш».

Мөрәҗәгать Мулланур Вахитов тарафыннан язылган, 1918 елның 13 июнендә «Известия» г-тасының «Хөкүмәт карарлары һәм эшләре» бүлегендә һәм 16 июньдә «Знамя революции» г-тасында басылган.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**«БАРЛЫ́К МӨСЕЛМА́Н ХЕЗМӘ́Т ИЯЛӘРЕНӘ́»**, РСФСР Халык Комиссарлары Советы, Хәрби эшләр халык комис-ты, Милләтләр эше буенча халык комис-ты һәм Үзәк мөселман комис-ты исеменнән 1918 елның 15 июнендә «Правда» г-тасында басыла. Мөрәҗәгать тексты чех-словак корпусының баш күтәрүе уңаеннан М.Вахитов тарафыннан язылган. Мөрәҗәгатьтә барлык мөселманнарның эшче һәм ярлы крәстияннәр хакимиятен яклаячагына, мөселман соц. армиясе кызыл байрагы астына тупланачагына ышаныч белдерелә. Революцион хәрәкәт тарихында мөселман пролетарийлары батырлыклары б-н танылырлар, диелә.


*И.Гыйззәтуллин.*

**«БАРЛ́ЫК РОССИ́Я ҺӘМ ШӘРЕ́КЪ МӨСЕЛМА́Н ХЕЗМӘ́Т ИЯЛӘРЕНӘ»**, РСФСР Халык Комиссарлары Советының 1917 елның 20 ноябрендәге (3 декабрендәге) мөрәҗәгате. Беренче өлешендә «Идел буе һәм Кырым татарларына, Себер, Төркестан кыргызларына һәм сартларына, Кавказ аръягы татарлары һәм төрекләренә, Кавказ тау халыкларына һәм чеченнарга» дини ышанулар, дин тоту, гореф-гадәтләрнең ирекле булуы, мөселман милли һәм дини оешмаларының кагылгысызлыгы, мөселман халыкларның хокуклары Совет хакимияте тарафыннан якланачагы белдерелә. Мөселман хезмәт ияләре Россиядә барган соц. рев-цияне хупларга чакырыла. Мөрәҗәгатьнең икенче өлеше Шәрекъ илләре мөселманнарына — фарсы, төрек, гарәп, шулай ук индусларга багышлана. Совет хакимияте элекке патша хөкүмәте тарафыннан төзелгән Иран б-н Төркияне бүлгәләү, Константинополь (Истанбул) шәһәрен яулап алу турындагы яшерен килешүләрнең юкка чыгарылуын, Шәрекъ илләре халкының үз язмышын үзе хәл итәргә хокуклы булуын бәян итә. Алар, залим-изүчеләрне бәреп төшереп, үз илләренә хуҗа булырга чакырылалар. Мөрәҗәгатькә РСФСР ХКС рәисе В.И.Ленин һәм Милләтләр эше буенча халык комиссары И.В.Сталин кул куйган.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**БАРМАКТАМЫ́Р** (Dactylorhiza), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 лап төре билгеле, Евразия, Төньяк Африка һәм Төньяк Американың уртача һәм салкын поясларында таралган. ТР терр-ясендә 5 төре — канлы Б. (D. cruenta), Фукс Б. (D. fuchsii), иткызыл Б. (D. incarnata), тимгелле Б. (D. maculata), Руссов Б. (D. russowii). Мүкле сазлыкларда, сазлыклы болыннарда үсә. Сабаклары туры, гадәттә яфраклы, 15–60 *см* озынлыкта. Тамыр бүлбеләре бармакчалы. Яфраклары яшел яки куе коңгырт-кызгылт тимгелле, ланцетсыман яки кыяк рәвешендә. Чәчәкләре зур түгел, аксыл шәмәхә, алсу, шәмәхә-куе кызыл төстә, тыгыз башаксыман чәчәк төркемендә. Өске касә яфракчыгы һәм ике таҗ яфракчыгы башлык формасында урнашкан. Ирене күбрәк 3 калаклы, яссы. Җимеше — тартмачык. Май–июльдә чәчәк аталар. Күбрәк орлыктан үрчиләр. Бүлбесен какырык куптаруга ярдәм итүче төнәтмә хәзерләү өчен файдаланалар. Декоратив үсемлек буларак үстерелә. Барлык төрләре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БАРМА́Н**, к. *Барсал.*





Барокко. Апанай мәчете. Казан. Фасадларның фигуралы өлешләре.

**БАРО́ККО** (итал. barо́cco — купшы, чуар), 16 йөз ахырында — 18 йөз уртасында Көнбатыш Европа, 18 йөзнең 1 нче яртысында Россия архит-расындагы һәм сәнгатендәге стиль. Б.га Көнбатыш Европа архит-расында фасадларның купшы пластикасы, бизәкләр байлыгы, корылышының катлаулылыгы; ш.у. тантана заллары интерьерларының төрле төстәге уйма сыннар, күпертеп һәм уеп ясалган бизәкләр, рәсемнәр һәм көзгеләр б-н зиннәтләнгән булуы хас. 17 йөз ахырында Көнбатыш Европа Б.сы йогынтысында Мәскәү архит-расында да күпсанлы ордер детальләре күренә башлый. Архит-ра гыйлемендә бу юнәлеш «Нарышкин стиле» («Нарышкин Б.сы») яки «Мәскәү бароккосы» дип атала. Классик архит-ра формалары Б. стиленең рус архит-расында, нигездә, декоратив роль уйнаган, ул биналарның композицион принципларына тәэсир итмәгән диярлек. Бу стильдәге фасад бизәлешенә ике төслелек — кызыл кирпеч дивар һәм ак таштан уеп ясалган детальләр хас. 17 йөз рус архит-расына ш.у. төрле төсләрдәге рәсемнәр б-н бизәлгән фасадлар, шашкасыман түбәләр, тимердән кисеп ясалган бизәкләре һ.б. б-н аерылып торган «Украина» Б.сы да сизелерлек йогынты ясый. Бу стильдәге корылмаларның күләм композициясе һәм фасадлары — симметрия, интерьерлары анфилада принципларына нигезләнә. 18 йөзнең 1 нче яртысындагы «Пётр» яки «Петербург бароккосы» гадилеге, формалар төгәллеге, фасадларның пилястралар яисә ярымбаганалар, уемнар һәм филёнкалар б-н бүлгәләнүе, биналарда максатка ярашлы декоратив скульптуралар б-н аерылып тора. 18 йөзнең 1 нче яртысында арх. П.Зарудный, Ж.-Б.Леблон, Д.Трезини, М.Г.Земцов, И.К.Коробов, П.М.Еропкин эшчәнлеге шушы юнәлештә бара. 18 йөз уртасында архит-ра сынлы сәнгатьнең барлык төрләренә һәм жанрларына мөрәҗәгать итә, скульптура, монументаль һәм декоратив рәсем, гамәли бизәлеш сәнгате мөмкинлекләреннән файдалана. Бу чорда әлеге стильдә император резиденцияләре, сарайлар, утарлар, соборлар, чиркәүләр, монастырьлар төзелә. Ул вакыттагы Б. «Растрелли бароккосы» дип тә атала. Ул бер үзәккә тупланган өч өлешле биналар, сынык яисә сыгылма кыеклы биек түбәләр, фонарьлы һәм тәрәзәле гөмбәзләр б-н үзен-

Барокко. 1. Дурт Евангелист чиркәве. Казан. Арх. В.И. Кафтырев. 1770; 2. Петропавел соборы. Казан. 1724–26; 3. Адмиралтейство конторы. Үзәк портик. Казан. Арх. В.И. Кафтырев. 1774.







чәлекле. Ордер (өч чирекле колонналар һәм нык беркетелгән антаблементлар), парлы яисә сыңар пилястралар, колонналар тезмәсе, бина почмагын китекләндерү һәм китек янына 2 колонна урнаштыру һ.б. — әлеге стиль пластикасының төп үзенчәлекләре. Тәрәзә уемнары турыпочмаклы, озынча түгәрәк, түгәрәк, а́рка рәвешендә. Аларның йөзлекләре, архивольт өстенә сандрик урнаштырып көчәйтелә, араларындагы диварга кабартылган бизәк салына. Диварларның өске өлеше тәрәкләр, фигуралы аттиклар, парапетлар, вазалар, төрле сыннар б-н зиннәтләнә. Гирлянда, валюта, купидон сыннары, битлекләр, бюстлар, герблар кебек уйма бизәкләр фронтоннарны каплап ала, колонналар һәм пилястраларга үрелеп менә. Фирүзә, әфлисун, яшел төсләрдәге диварлар ак төстәге ордер детальләре, колонналарның алтынсу очлары, уйма сыннар, рәшәткәләр һ.б. өчен фон булып хезмәт итә. 18 йөз рус Б.сы вәкилләре: Ф.-Б.Растрелли, С.И.Чевакинский, А.В.Квасов (С.-Петербург); Д.В.Ухтомский, И.Ф.Мичурин, А.П.Евлашев һ.б. (Мәскәү). Төбәкләрдәге Б. дәвере архит-расы «Растрелли бароккосы» б-н чагыштырганда күпкә тыйнаграк. Биредә Көнбатыш Европа архит-расының аерым элементлары гына файдаланыла. Мәскәүдә һәм төбәкләрдә Б. мотивлары җирле традицияләр б-н кушыла. Казан губернасында Б. стиле 18 йөз башында күренә башлый. Аның биредәге үсешендә ике юнәлеш күзәтелә. Беренчесенә 17 йөз рус архит-расыннан ук килгән күләмне традицион планлаштыру, бизәк муллыгы, ачык төсләр хас (*Петропавел соборы*, *Покров чиркәве* манарасы). Баштарак Б. мотивлары шушы төбәктә киң таралган кирпечтән бизәк ясау ысулы б-н яраклаша. Бу күренеш Казандагы Петропавел соборы корылышында аеруча ачык чагылыш таба. Аның иконостасы Б. стилендәге гамәли бизәлеш сәнгате үрнәге булып тора. Төбәктә тыйнаклыгы, яңа заман архит-расының асылын тәшкил иткән ордер формаларын, фасадтагы һәм интерьерлардагы рәсемнәрне, күпертмә бизәкләрне сайлап куллануы б-н үзенчәлекле булган башка юнәлеш өстенлек ала. Бу юнәлеш ш.у. традицион архит-ра формаларын да саклый. Казандагы Мәскәү Чудотворецлары, Кыят авылындагы Богоявление (Буа р-ны), Каймар авылындагы Кирилл-Белоозеро (Биектау р-ны), Ямбакты авылындагы (Тәтеш р-ны) Троица чиркәүләре корылышында традицион «көймә сыман» композиция схемасына Б. формалары кушыла (кыекчалы биек түбәләр, ярусланган гөмбәзләр, икеле һәм өчле суганчалар, күпкырлы шпильләр, а́ркалы һәм алты кырлы уемнар, ярымколонналар, пилястралар, фигуралы бизәк). Тагын да тыйнаграк Б. стилендәге (рустланган пилястралар, тигез дивар фонындагы үзенчәлекле тәрәзә йөзлекләре) яңа тип җәмәгать биналары, уку йортлары, сәнәгать һәм хакимият өчен төзелгән корылмалар аерым бер төркемне тәшкил итә (*Адмиралтейство конторы комплексы*, *Казан чиркәү-укытучылар мәктәбе*, *Казан постау мануфактурасы* биналары һ.б.). Татар бистәләре һәм авыллары архит-расында Б.га милли төсмерләр өстәлә. Бу күренеш бигрәк тә *Апанай мәчете*, *Мәрҗани мәчете*, *Кышкар мәчете*, *Мәчкәрә мәчете*, Зур Бирәзә авылы (Арча р-ны) мәчете төзелешендә аеруча ачык чагылыш тапкан. Татарларда урта гасырлардан ук яшәп килгән күләмле планлаштыру схемасы сакланган хәлдә, мәчетләрнең түбә формасында, фасад һәм интерьерлар бизәлешендә Б. архит-расы мотивлары һәм элементлары кулланылган. Казанда Б. стиленең күренекле тарафдарыннан берсе — *В.И.Кафтырев*.

*Әд.:* История русской архитектуры. СПб., 1994; История русского искусства. М., 1995; Кириченко Е.И. Русский стиль. М., 1997.

*Х.Г.Надыйрова.*

**БАРСА́Л** (Барман, Биләр) (9 йөз ахыры — 10 йөзнең 2 нче яртысы), болгарлар идарәчесе (әмире). 920 елга караган болгар акчалары буенча мәгълүм (алар Сасанилар иле дирһәмнәренә охшаш). Акчага сугылган исем-атаманы кайбер галимнәр «әмир Барсал (Барман)» дип укый (Р.Р.Фасмер, С.А.Янина, В.В.Кропоткин), башкалар, мәс., Ә.Г.Мөхәммәдиев «әмир Биләр» дип, Г.Рисплинг «әмир Йалтабар (илтәбәр)» дип укыйлар һәм аны Алмас илтәбәр улы Микаил бине Җәгъфәр б-н нисбәтлиләр. Б. *барсиллар* кабиләләре берләшмәсе идарәчесе булган, дигән фараз да бар.

*Әд.:* Янина С.А. Новые данные о монетном чекане Волжской Булгарии 10 в. // Материалы и исследования по археологии. М., 1962. № 111; Волжская Булгария и Русь. К., 1986; Мухамадиев А.Г. Древние монеты Поволжья. К., 1990; Rispling G. The Volga Bulgarian imitative coinage of al-amir jaltawar («Barman») and Mikail B. Jafar // Sigtuna Papers. L., 1989.

*И.Л.Измайлов.*

**БАРСИЛЛА́Р** (барсулалар, берсулалар), төрки телле болгар кабиләләре, 5–7 йөзләрдә Төньяк-көнчыгыш Кавказда яшәгәннәр (к. *Болгарлар*). 4 йөздә *һуннар* б-н бергә Урал арьягыннан килгәннәр дип фаразлана. 7 йөзгә караган «Әрмән географиясе»ндә («Армянская география») Б. яшәгән төбәк Түбән Идел буенда теркәлгән. Кайбер тикшеренүчеләр хәзерге Дагстанның Каспий буен Б. яшәгән урын («Барсилия») дип күрсәтәләр. Нигездә, күчмә терлекчелек б-н шөгыльләнгәннәр. Мәҗүсиләр булганнар дип уйланыла. 6 йөз урталарыннан Б. Авар каганлыгына, аннары Төрки каганлыкка, 630 еллардан Хәзәр каганлыгына буйсынганнар. 9–10 йөзләрдә Б.ның бер өлеше Хәзәр каганлыгыннан Урта Идел буйларына күченгән. 10 йөздә «барсула» атамасы Идел буе Болгар дәүләте кабиләләре арасында телгә алына.

*Әд.:* Артамонов М.И. История хазар. Л., 1962; Гадло А.В. Этническая история Северного Кавказа IV–X вв. Л., 1970; шул ук. Этническая группа барсилы // Историческая этнография: традиции и современность. Л., 1983; Golden P.B. Khazar studies. Bdpst, 1980. V. 1–2.

*И.Л.Измайлов.*

**БАРСКО́В** Александр Макарович (26.12.1897, Казан губ., Лаеш өязе Пановка а. — 8.5.1953, Казан), вет. табибе, а.х. фән. д-ры (1942), проф. (1945). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1925), шунда ук эшли; 1945–53 елларда беренче булып үзе оештырган а.х. терлекләрен тукландыру каф. мөдире, бер үк вакытта 1950–53 тә зоотехн. ф-ты деканы. СССР ФАнең Казан ф-лында терлекчелек секторын оештыручыларның берсе һәм беренче җитәкчесе. Хезмәтләре а.х. терлекләрен тукландыру мәсьәләләренә карый. Имгәнгән һәм ачлыктан интеккән атларны тукландыру рационын, мөгезле эре терлек, кошларны минераль азык б-н тукландыру нормаларын эшли. ТРның азык-төлек байлыкларын өйрәнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Повышение продуктивности крупного рогатого скота в колхозах. К., 1950; Организация правильного кормления — основа повышения продуктивности животных. К., 1951.

*Әд.:* Казанский государственный ветеринарный институт имени Н.Э.Баумана (1873–1953): материалы к истории ветеринарного образования в СССР. Кафедра зоогигиены // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та. М., 1956. Т. 63 (юбилейный); Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*А.А.Барсков.*

**БА́РСКОЕ** күле, Көнбатыш Кама арьягында. Идел елгасының биек террасасында, Спас р-ны Отрада авылының көньяк-көнчыгыш читендә. Су өслегенең мәйданы 3,6 *га*. Су күләме 36 мең *м*$^3$. Озынлыгы 400 *м*, иң зур киңлеге 160 *м*, уртача тирәнлеге 1 *м*, иң зур тирәнлеге 2,1 *м*. Күл казанлыгы ясалма (казылган). Суы җиңелчә минеральләшкән, бик йомшак (катылыгы 1,5 *мг-экв/л*), болганчык, сары төстә, иссез, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**БА́РСКОЕ ЕНОРУ́СКИНО** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасы буенда. 2002 елдан даими яшәүчеләр юк. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында авыл «Временнообязанное Енорускино» исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, күн эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.Е.да башлангыч белем бирү мәктәбе, 5 күн эшкәртү остаханәсе, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 151 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 183, 1897 дә — 327, 1908 дә — 340, 1920 дә — 373, 1926 да — 433, 1938 дә — 230, 1949 да — 135, 1958 дә — 104, 1970 тә — 50, 1979 да — 28 кеше. 2001 дә авыллар исемлегеннән сызыла.

**БАРСУЛА́**, к. *Барсиллар*.

**БА́РТЕЛЬС** Мартин Фёдорович (Иоганн Мартин Христиан) (12.8.1769, Брауншвейг ш., Германия — 7.12.1836, Лифляндия губ. Дерпт ш., хәзер Эстониянең Тарту ш.), математик, философия д-ры (1803). Н.И.Лобачевский остазы. 1794 елда Гёттинген ун-тын тәмамлый. 1806 елда Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы дигән исемгә беренче булып лаек була. 1808–20 елларда Казан ун-ты профессоры, 1814 тән физ.-матем. фәннәре бүлеге деканы.

1820 дән Дерпт ун-ты профессоры, 1833 тән ат-каз. профессор. Хезмәтләре матем. анализга һәм геометриягә, математика тарихына, астрономия һәм математик географиягә, сферик тригонометриягә, аналитик механикага карый.

Х е з м.: Vorlesungen uber mathematische Analysis. Dergt, 1833; Vorlesungen uber mathematische Analysis mit Anwendungen auf Geometrie, mechanik und Wahrscheinlichkeitslehre. 1-ter Bd Dorpat, 1833.

*Әд.:* Д е п м а н И.Я. Бартельс М.Ф. — учитель Н.И.Лобачевского. Ист.-матем. иссл. М.–Л., 1950. Вып. 3; В а с и л ь е в А.В. Николай Иванович Лобачевский. М., 1992.

**БА́РТЕР** (ингл. barter — товар алмашу), сәүдәнең акча түләмичә үзара әйберләр яисә хезмәт күрсәтүләр б-н алмашуга нигезләнгән төре. Бердәм шартнамә (контракт) б-н рәсмиләштерелә, анда тәңгәл (эквивалентлы) алыш-биреш ясау, страховка суммасын билгеләү, дәгъваларны хәл итү, санкцияләр куллану, таможнялар хисабын билгеләү һ.б. өчен шартлар тудыру максатында товарга (хезмәт күрсәтүгә) бәя куела. Б. килешүләре, башлыча, тышкы сәүдә әйләнешендә кулланыла. Б.дан файдаланунның төп сәбәбе — валютага бәйле проблемаларга кайтып кала (чит ил валютасының җитмәве, илдә валютаның тотрыксызлыгы һ.б.ш.). Халыкара валютаның түләү мөмкинлекләре кискенләшүе Б. килешүләренең күләме артуына китерә. 1990 елларда РФдә икътисади реформалар башлангач, ирекле бәяләр кертелү сәбәпле, пр-тиеләр һәм оешмаларның әйләнештәге средстволарына килеп туган дефицит — үзара түли алмаучанлыкның барлыкка килүенә һәм шуның нигезендә төбәкләр, ил эчендә хуҗалык итүче субъектлар арасында Б. килешүләренең киң таралуына китерә. Б.ның киңәюе күпчелек очракта пр-тиедә эш хакын түләүнең тоткарлануына, барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салымнар базасын һ.б. күчерүләрне бозып күрсәтүгә, бюджетта акча җитмәүчелеккә китерә, ә бу исә социаль проблемаларны үтәүдә, халык хуҗалыгын инвестицияләүдә җитди проблемалар тудыра. 1999 елда ТР пр-тиеләре тарафыннан сатылган продукциянең гомуми күләмендә Б. өлеше АҖләрдә: «Түбәнкамашин» — 85,1%, «ӘЛНАС» — 62,5%, «Сафьян» — 53,7%, «Л.Я.Карпов исем. химия заводы» — 53,9%, «Вакууммаш»та 45,8% тәшкил итә.

**БА́РТОЛЬД** (Bartold) Василий (Wilhelm) Владимирович (3(15).11.1869, С.-Петербург — 18.8.1930, Ленинград), тарихчы, филолог, шәркыятьче, СССР ФА академигы (1925), Петербург ФА академигы (1913). Россиядә Шәрекъне фәнни өйрәнү мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Балтыйк буеннан күчеп килгән немец гаиләсендә туа. Петербург ун-ты Шәрекъ ф-тының гарәп-фарсы-төрек-татар разрядын тәмамлый (1891). 1891–92 елларда Австро-Венгрия, Германия, Италия, Финляндия, Швейцария ун-тларында шәркыять фәненең үсеше б-н таныша. 1892 елдан Петербург ун-тында, 1905 тән ординар профессор. 1900 дә Шәрекъ ф-ты советы тарафыннан Б.ка Шәрекъ тарихы д-ры гыйльми дәрәҗәсе бирелә. «*Мир ислама*» (1912), «Мусульманский мир» (1917) ж-лларын нәшер итүне оештыручыларның һәм мөхәррирләренең берсе. Бер үк вакытта СССР ФАнең Антропология һәм этнография музее каршындагы Радлов исем. түгәрәк рәисе (1918–30), Россия ФАнең Азия музее каршындагы Шәркыятьчеләр коллегиясе рәисе урынбасары (1921–30). 1 нче тюркология съездын оештыручыларның берсе (Баку ш., 1926), СССР халыкларының алфавитларын гарәп графикасыннан латин графикасына күчерү комиссиясе эшендә катнаша. Урта Азия ун-тын оештыруга (Ташкент, 1918), шәркыять китапханәләрен булдыруга һәм Шәрекъ кульъязмаларын җыюга зур өлеш кертә. Укыту һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге барышында Урта Азия, Кавказ, Урал буе, Якын Көнчыгыш, Көнбатыш Европа һәм Төньяк Америка илләрендә фәнни экспедицияләрдә була. Хезмәтләре Урта Азия, Якын һәм Урта Көнчыгыш, Көнчыгыш Европа халыкларының тарихына, филологиясенә һәм мәдәниятенә, ислам динен һәм Шәрекъне өйрәнүгә карый. Алар арасында «Төркестан монгол яулары чорында» («Туркестан в эпоху монгольского нашествия», ч. 1–2, 1898–1900) исемле хезмәте аерым урын алып тора. Аның өчен Б.ка Шәрекъ тарихы магистры гыйльми дәрәҗәсе бирелә. «Китаби дәдәм Коркут» («Коркут бабам китабы») төрки эпосын анализлый һәм аны рус теленә тәрҗемә итә (1962 дә басылып чыга). Б. тикшеренүләрендә ш.у. Идел һәм Урал буе татарларының урта гасырлардагы тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре дә яктыртыла.



В.В. Бартольд.

Х е з м.: Сочинения: В 9 т. М.–Л., 1963–77.

*Әд.:* У м н я к о в И.И. Аннотированная библиография трудов В.В.Бартольда. Таш., 1926; Я к у б о в с к и й А.Ю. Проблемы социальной истории народов Востока в трудах академика В.В.Бартольда // Вестн. Ленингр. ун-та. 1947. № 12; С м и р н о в Н.А. Очерки истории изучения ислама в СССР. М., 1954; Т у м а н о в и ч П.Н. Описание архива В.В. Бартольда. М., 1976; Л у н и н Б.В. Жизнь и деятельность академика В.В.Бартольда. Таш., 1981.

*М.Г.Госманов.*

**БАРУДИ́** (псевд., фам. — Галиев) Галимҗан Мөхәммәтҗан улы (5.2.1857, Казан губ., Казан өязе Кече Кавал а. — 6.12.1921, Мәскәү; Казанда җирләнгән), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Җәдитчелек хәрәкәтен оештыручыларның берсе. Сәүдәгәрләр нәселеннән. Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә, 1875 елдан Бохарада белем ала. Казанда 1882 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ача, аның мөдәррисе була. Бер үк вакытта 1882–1917 дә (өзеклек б-н) 5 нче җамигъ мәчет (Галиев мәчете) имам-хатибы. 1891 дән ул җитәкләгән мәдрәсәдә яңа ысул б-н укыту кертелә (к. *Җәдитчелек*), дөньяви фәннәрдән дә дәресләр бирелә башлый. Бөтенроссия мөселманнары корылтайларында катнаша, 1906 елдагы корылтайда Диния нәзарәтен үзгәртеп кору комиссиясенең рәисе итеп билгеләнә, «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенең ҮК әгъзасы итеп сайлана; «*Әд-дин вә әл-әдәб*» ж-лы нашире һәм мөхәррире (1906–08, 1913–17). Бер үк вакытта «Идрисов, Галиев һәм К$^{o}$ сәүдә йорты» ширкәттәше (1908 дән «Милләт» ширкәте, китап һәм язу кирәк-яраклары б-н сәүдә иткән). 1907 дә Казанда мәктәп-мәдрәсә укытучылары корылтаен оештыручыларның берсе. Мөселманнар арасында панисламизм фикерен таратуда гаепләнеп кулга алына, 1908 дә Вологда губернасына сөргенгә җибәрелә. Берничә ай сөргендә булганнан соң, хаҗ кылырга рөхсәт алып, чит илгә китә, Мәккә, Мәдинә, Каһирә, Дәмәшкъ, Истанбул, Берлин шәһәрләрендә була. 1910 да Казанга кайта, панисламчылыкка бәйле рәвештә полиция тарафыннан даими күзәтелә, өендә берничә мәртәбә тентү үткәрелә. 1917 дә Бөтенроссия мөселманнарының корылтайларында катнаша; Мәскәүдә узган 1 нче корылтайда Эчке Россия һәм Себер мөселманнары мөфтие итеп сайлана. Милләт Мәҗлесе депутаты (Уфа, 1917–18), Диния нәзарәте рәисе (к. *Милли Идарә*). 1918 елның яз айларында большевиклар хакимияте тарафыннан Милли Идарә оешмалары эшчәнлеге тыелгач, Милли Идарә вәкилләреннән бер төркем, ш.и. Б.да, Петропавел (Кызылъяр) шәһәренә китеп, эшчәнлекләрен дәвам иттерә. 1919 елның мартында Б. Уфага мөфтияткә кайта. Шул елның июнендә берникадәр вакытка ВЧК тарафыннан кулга алына. Азат ителгәннән соң мөфти вазифасын башкаруын дәвам итә. 1921 дә Мәскәүдә ачларга ярдәм оештыру эшләре б-н шөгыльләнә. Мөселман диненә багышланган хезмәтләр, ш.и. гарәп, фарсы, төрки телләрдән тәрҗемәләр авторы. Мәктәп-мәдрәсәләр өчен дин мәсьәләләре, арифметика буенча дәреслекләр, әлифба яза. Замандашлары фикеренчә, Б. тумыштан бик сәләтле, тирән белемле фикер иясе һәм оста оештыручы булган, ватанпәрвәр затлардан саналган.



Галимҗан Баруди.

Х е з м.: Нәмуна-и хисап. К., 1891; Сәвад хан. 25 бас. К., 1891; Лулат саләс. К., 1893; Мәдхаль гарәбия. К., 1893; Сарыф гарәби. К., 1898; Хәтер дәфтәре. К., 2000; Основы ислама. К., 1906.

*Әд.:* А к ч у р а Й. Дамелла Галимҗан әл-Баруди. К., 1907; Б а т т а л Г. Казан төркиләре. К., 1996; Х и с а м е т д и н о в а Л. Галимҗан Баруди һәм «Әд-дин вә әл-әдәб» журналы. К., 2001; Н а д и р Д. Галимджан Баруди — просветитель и реформатор // Татарстан. 1991. № 7; Б и к т е м и р о в а Э.И. Педагогические воззрения и деятельность Галимджана Баруди: Дисс. ... К., 2002; Ю с у п о в М.Х. Галимджан Баруди. К., 2003; B a t t a l - T a y m a s A. Alimcan Barudi. Istanbul, 1958.

*Л.М.Айнетдинова.*

**БАРУДИ́ Г. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**, дин галиме, педагог, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан *Баруди* китапханәсе. Анда 3241 берәмлек басма китап һәм 947 берәмлек кульъязма була. Тупланманың нигезен атасы Мөхәммәтҗан хәзрәттән калган китаплар тәшкил итә, бер өлешен Г.Барудига хатынының абыйсы — «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәр-

рисе һәм остазы Сәләхетдин хәзрәт (Сәләхетдин ибне Исхак әл-Казани) бүләк итә. Г.Баруди үзе Бохарада укыган җиреннән Казанга алып кайткан китаплар хисабына да тулылана. Китап һәм кулъязмалар җыюны ул алга таба да дәвам иттерә. Б.ш.к.ндәге китап һәм кулъязмаларның бер өлешен дини әдәбият тәшкил итә (Коръән басмалары, *тәфсирләр*, *хәдисләр*, *фикъһ* гыйльме турында хезмәтләр һ.б.). Тарихка нисбәтле 232 китап, гарәп һәм фарсы телләре грамматикасына нисбәтле — 187, әдәбиятка — 133, мантыйк, математикага нисбәтле гарәпчә — 2724, фарсыча — 161, татарча — 446 китап һәм кулъязма, русча-татарча, русча-гарәпчә сүзлекләр була. Кулъязмалар арасында Шәрекънең фикер ияләре Ибне Котәйбә (9 йөз) һәм Ибне Бабашадның (11 йөз) гыйльми трактатлары, Нәкышбәндийә тарикате тарафдары Мөхәммәд Парс китапханәсеннән килеп кергән ике кулъязма әсәр — Әбү әс-Сәгадәт ибне әл-Асирнең «Җәмигуль-ысул ли әхадис әр-Рәсүл» дигән хезмәте б-н Әбү әл-Хәсән Гали ибне Әхмәд әл-Вахидинең «Харар әл-Мәгани» дигән кулъязмасы, 13 йөз авторы Абдаллаһ ән-Нәфиси төзегән кулъязмалар җыентыгы, Муса ибне Мөхәммәд әр-Руминың (15 йөз) геометриягә нисбәтле, әд-Дамаминың грамматикага нисбәтле («Гыйльме сарф вә нәхү», 1423) трактатлары, Шәрекъ дөньясының күренекле математигы Мөхәммәд Сабит әл-Мардининең (16 йөз) култамга язмалары, Әбү әл-Хәйр Абдрахман әс-Сөйдинең Багдад тарихына караган кулъязмалар исемлеге һ.б. бар.

Г.Баруди максатчыл рәвештә китапханәсендә Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрен даими җыя барган. Еш кына аларны хаттатлардан күчерттереп алган. Бохарада укыган чагында ук Ахунд Әхмәд ибне Мозаффар исемле мулла 1865–66 еллар арасында аңа Ш.Мәрҗанинең «Әл-Хикм әл-балигъ...» дигән хезмәтен күчереп бирә. 1884 елда «Хашийә әт-Тәүзыйх» («Тәүзыйх» китабына аңлатмалар») әсәренең күчермәсе булдырыла. Ш.Мәрҗанинең басмада чыкмаган «Вафийәт әл-әсләф...» хезмәтенең бердәнбер тулы күчермә нөсхәсе (6 том) Г.Баруди китапханәсендә сакланып кала. 1914 елда Сасна авылында Г.Баруди өчен хаттат Габделхак бине Зыятдин ибне Таҗетдин әл-Иштирәки тарафыннан Әбү әл-Хәсән Гали бине Мөхәммәд бине әл-Газый дигән гарәп галименең «Китабе әт-тәнбих әлә мөшкилят әл-Һидайә» («Һидайә китабының кыен урыннарына күрсәтмә китабы») хезмәте күчерелә.

20 йөз башларында Г.Баруди йортының бер бүлмәсендә 2945 китап булган китапханә ачыла. Андагы китаплардан, нигездә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре файдалана. 1914 елда Б.ш.к. җирлегендә халык өчен ачык китапханә дә оештырыла. Анда 3277 берәмлек басма һәм кулъязма китап була, 1920 елда аларның саны 4288 гә җитә. 1920 дә Б.ш.к.ндәге барлык китап фонды Үзәк Шәрекъ китапханәсенә күчерелә, 1929 да өлешләп Казанның башка китапханәләренә, беренче нәүбәттә Казан ун-тының Фәнни китапханәсенә тапшырыла (анда ул Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең кулъязмалар өлешен баета). Кайбер китап берәмлекләре Татарстан ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты архивында саклана. Б.ш.к.ндәге китапларның бер өлешен (13.7.1923 тә төзелгән исемлек буенча — 101 берәмлек) Г.Баруди Уфа шәһәренә алып китә. Барудиның вафатыннан соң мөфти Риза Фәхретдин һәм казый Кашшафетдин Тәрҗеманиларның тырышлыгы б-н бу китаплар кире Казанга кайтарыла. Б.ш.к.ндә булган барлык китаплар Г.Барудиның шәхси мөһере б-н тамгаланган.

*Н.Г.Гәрәева.*

**БАРУДИ́** (псевд., фам. — Галиев) Габдрахман (9.1.1872, Казан — ?), дин эшлеклесе. Г.*Барудиның* бертуган энесе. 1893 елга кадәр Казанның Галиев мәчете каршындагы мәдрәсәдә белем ала, ш.у. Төркиядә, Согуд Гарәбстанында укый (1893–95). Эшчәнлегенең иң нәтиҗәле чоры 1909–13 елларга туры килә, абыйсы сөргендә вакытта ул 5 нче җамигъ мәчетнең (хәзерге Галиев мәчетенең) имам-хатибы була, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә җитәкчелек итә һәм анда хөкем сөргән хөрлек рухын, укытуда җәдитчелек традицияләрен саклап калуга ирешә.

*Әд.:* Салихов Р., Хайрутдинов Р. Республика Татарстан: памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX вв.). К., 1995.

**БАРУДИ́ САЛИХҖА́Н** (4.7.1862, Казан — 1931), дин эшлеклесе. *Габдрахман* һәм *Галимҗан Баруди*ларның бертуганы. Апанай мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Бохарада укый. Аннан кайткач, мәчеттә — мулла, 1890 нан 10 нчы мәчеттә икенче мулла вазифасын башкара, 1889 дан шул мәчет карамагындагы мәдрәсәне җитәкли. 1908 дә Галимҗан Баруди б-н бергә мөселманнар арасында панисламизмны пропагандалауда гаепләнеп кулга алына һәм Вологда губернасына 2 елга сөргенгә җибәрелә. Аннан соңгы язмышы билгесез. Коръәнне тәҗвид б-н уку һәм гарәп теле грамматикасы дәреслекләре авторы.

Хезм.: Төкъриб-әл-өзһан мин тәҗвид-әл-коръән. К., 1892.

*Әд.:* Хисамутдинова Л.С. Галимҗан Баруди: Жизнь и общественно-политическая деятельность: Дисс. ...К., 2004.

**БАРУДИЯ́ МӘЧЕТӘ́**, к. *Пороховой бистәсе беренче мәчете*.

**БАРЫ́Н**, Казан, Касыйм һәм Кырым ханлыкларында идарәче ыругларның берсе. Татар ханлыкларында аерым бер даруга идарәчеләре булган, шунда үз җир-биләмәләре дә кергән. Гадәттә, ыруг башлыгы хан диваны әгъзасы да булган. Б. ыругы дан-дәрәҗәсе һәм сәяси йогынтысы буенча башка идарәче ыруглардан беркадәр калышкан. 15 йөз ахырында Кырым ханлыгы диванында Б. ыругын мангыт ыругы алыштыра. Татар ханлыклары 16–18 йөзләрдә Россия тарафыннан яулангаңнан соң, Б. ыругы вәкилләре нәсел биләмәләреннән мәхрүм ителә һәм сәясәт даирәсеннән читләштерелә.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследования о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*И.Л.Измайлов.*

**БА́РЫШЕВ** Николай Иванович (19.11.1898, Уфа губ. Эстәрлетамак ш. — 30.10.1937, Мәскәү), сәясәт эшлеклесе. Казан рәссамнар уч-щесен, Чистай прапорщиклар мәктәбен (1917), Кызыл профессорлар ин-тын (Мәскәү) тәмамлый. 1916 елдан РСДРП(б) әгъзасы. Чистай шәһәрендә Совет хакимиятен урнаштыруда катнаша. 1918 елда Чистай өязендә халык мәгарифе бүлеге мөдире, РКП(б)ның Чистай ком-ты рәисе, «За власть Советов» г-тасы мөхәррире. 1919 да Тәтеш өязе, 1920–21 дә Минзәлә кантоны башкарма ком-тлары рәисе. 1921 дә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тының беренче секретаре. 1922 дән ВКП(б)ның Кара диңгез буе, Кубань, Якутия һ.б. өлкә, округ ком-тлары секретаре. 1930 елларда ВКП(б)ның Мәскәү өлкә ком-ты рәисе урынбасары, Мәскәү шәһәр ком-тының мәдәният һәм пропаганда бүлеге мөдире, РСФСР Җир эшләре халык комис-тының Үзәк кара туфраклы өлкә буенча сәяси секторы башлыгы, ВКП(б)ның Саратов край ком-ты секретаре, Саратов өлкә башкарма ком-ты рәисе. ВКП(б)ның 10, 11, 12 съездлары делегаты. БҮБК һәм СССР ҮБК әгъзасы. Репрессияләр чоры корбаны; вафатыннан соң аклана.

*Әд.:* Исаев В. Барышев Н.И. // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*


**БА́РЫШЕВ** Николай Сергеевич (15.4.1936, Арча штп — 29.10.2000, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1972), проф. (1991). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, «ГИПО» Федераль фәнни-җитештерү үзәгендә эшли: 1962 елдан өлкән инженер, 1965 тән өлкән фәнни хезмәткәр, 1973 тән сектор башлыгы, 1987 дән баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре ярымүткәргечләр физикасына һәм ярымүткәргеч приборларга карый. Техникада киң файдаланыла торган тар инфракызыл зоналы материалларда төп рекомбинация процессларын билгели. $A^{IV}B^{VI}$, $A^{III}B^{V}$, $A^{II}B^{VI}$ кушылмалары нигезендә инжекцияле лазерлар һәм нурланыш алгычлары эшли. Медальләр, ш.и. А.А.Лебедев исем. Россия оптика җәмгыяте медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: К теории междузонной ударной рекомбинации в полупроводниках // Физика твёрдого тела. 1961. Т. 3. № 9 (автордаш.); К теории ударной рекомбинации в полупроводниках с примесной зоной // Физика твёрдого тела. 1963. Т. 5, № 2 (автордаш); О тепловом захвате дырок и электронов в сурмянистом индии // Физика и техника полупроводников. 1967. Т. 1, № 8.

*Р.Г.Усманов.*

**БА́РЫШЕВА** Антонина Фёдоровна (26.2.1937, Лаеш р-ны Нармонка а.), токарь, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1977). 1956–92 елларда Казан төгәл машиналар төзү з-дында эшли. Дәүләт бүләге эшләү процессларын камилләштерүгә һәм хезмәтне оештыруның яңа алымнарын һәм формаларын гамәлгә кертүгә өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**БА́СИН** Натан Израилевич (8.10.1925, Украина ССР, Донецк өлкәсе Петровка руднигы), актёр, режиссёр, педагог, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1966). 1949 елда Мәскәү театр уч-щесен тәмамлый. 1949–53 тә Брянск, Магнитогорск шәһәрләре театрларында актёр булып эшли. 1953–57 дә Ташкент театр-сән-



Н.И. Басин.

гать ин-тында укый. 1957–59 да Пермь өлкә драма театрында режиссёр, 1959–62 дә Казан Яшь тамашачылар театрының баш режиссёры, 1963–83 тә Владивосток, Саратов, Кишинёв, Красноярск шәһәрләре театрларын җитәкли. 1983–85 тә Казан Зур драма театрында баш режиссёр, бер үк вакытта 1983–87 елларда Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә доцент, профессор, 1985 тән режиссура һәм актёрлык осталыгы каф. мөдире. Казанда эшләгән елларда 11 спектакль куюга ирешә, ш.и. А.Г.Зак һәм И.К.Кузнецовның «Ике төс» («Два цвета», 1959), В.С.Розовның «Тигезсез



Казан Зур драма театрында «Җилләр шәһәре» спектакленнән (В.М. Киршон) күренеш.

көрәш» («Неравный бой», 1960), А.Н.Арбузовның «Шәһәрдә таң ата» («Город на заре», 1961), Р.Ф.Ишморатның «Алар дүртәү иде» («Побеждённый океан», 1962) һ.б. әсәрләр куела. Б. иҗатының төп принциплары Казан Яшь тамашачылар театрында баш режиссёр булып эшләү чорында формалаша. Бу театр сәхнәсендә куелган спектакльләр пьесадагы төп конфликтларның тулысынча ачылуы, вакыйгаларның киеренкелеге, һәр персонаж хәрәкәтләренең төгәл һәм җентекләп эшләнеше б-н аерылып тора. Спектакльләрдә күп кеше катнашкан күренешләр аерым әһәмияткә ия, аларда һәр катнашучы спектакльнең төп идеясенә һәм конкрет персонажның биографиясенә туры килерлек итеп уйный. Б. Казан Яшь тамашачылар театры каршында студия оештыра. Казан Зур драма театры сәхнәсендә В.М.Киршонның «Җилләр шәһәре» («Город ветров», 1983), Ги де Мопассанның «Соекле дустым» («Милый друг», 1984), Д.Н.Вәлиевнең «Билгесез көн» («День икс», 1984) пьесаларын куя. Күп кенә бөтенсоюз, бөтенроссия театр фестивальләрендә һәм конкурсларда катнашып, лауреат исеменә лаек була; спектакльләр берничә мәртәбә Мәскәүдә күрсәтелә. РСФСР Дәүләт бүләге лауреаты (1982).



Казан Зур драма театрында Н.И. Басин куйган спектакльдән күренеш: «Билгесез көн» (Д.Н. Вәлиев).

*Әд.:* Б л а г о в Ю. Казанский театр юного зрителя. К., 1986; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991; К а л и ш В. Театральная вертикаль. М., 1991; Театральная энциклопедия. М., 1967.

*Ю.А.Благов.*

**БАСКА́К**, 13–14 йөзләрдә Алтын Урда яулаган олыс-өлкәләрдә хан тарафыннан билгеләнгән идарәче. Бәркә хан идарә иткән елларда кертелгән. Б. ясак җыюны, ясак түләүче халык санын исәпкә алуны оештырган, яуланган җирләрдә баш күтәрүләргә каршы үзенең идарәсендәге гаскәргә таянып көрәшкән. 14 йөз башларында рус кенәзлекләрендә Б. идарәчелеге бетерелә, халыктан ясак җыю һәм түләүне оештыру эше җирле кенәз идарәләренә тапшырыла. Бу хокуктан файдаланып, рус кенәзләре үзләре өчен халыктан өстәмә ясаклар да түләтә башлыйлар. Кайбер рус җирләрендә ул тәртип 14 йөз урталарына кадәр саклана (Рязань, Тула төбәкләре).

*Әд.:* Б е р е з и н И.Н. Очерк внутреннего устройства Улуса Джучиева // Тр. Вост. отд-ния Рус. археол. об-ва. СПб., 1864. Т. 18; Н а с о н о в А.Н. Монголы и Русь. М.–Л., 1940; З и м и н А.А. Народные движения 20-х годов XIV в. и ликвидация системы баскачества в Северо-Восточной Руси // Изв. АН СССР. Сер. истории и философии. 1952. Т. 9, № 1; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; V a s a r y I. The Origin of the Institution of the Basqaqs // Acta Orientalia Academiae Scientarium Hungariae. 1978. V. 32.

*И.Л.Измайлов.*

**БАСКА́КОВ** Николай Александрович (9.3.1905, Вологда губ. (хәзерге Архангельск өлкәсе) Сольвычегодск ш. — 1996, Мәскәү), тюрколог, филол. фән. д-ры (1951), проф. (1969), Каракалпак АССР, Төрекмәнстан, Казакъстан ССРларның һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1960, 1962, 1967, 1967). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1929). 1930–31 елларда төрки телләрне өйрәнү максаты б-н Каракалпак АССРның Дүрткүл шәһәрендә фәнни командировкада була. 1931 дән Мәскәүдә: Шәрекъ хезмәт ияләре коммунистик ун-ты каршындагы лингвистик комиссиядә, 1933 елдан Милләтләр үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында, 1937 дән СССР ФАнең Тел белеме ин-тында эшли, бер үк вакытта Шәрекъне өйрәнү ин-тында уйгыр теле укыта. Хезмәтләре гомумтөрки лингвистика мәсьәләләренә, хәзерге төрки телләр һәм аларның диалектларының үсеш закончалыкларына карый. Каракалпак, нугай, алтай телләренең морфологиясен һәм синтаксисын өйрәнә. Совет тюркологлары арасында беренчеләрдән булып ике телле төрки-рус сүзлеге төзи башлый, төрки телләрнең барлыкка килүен һәм тарихи үсешен дәверләргә бүлгән яңа классификация тәкъдим итә. Бөекбритания һәм Ирландиядәге Король Азия җәмгыятенең, Халыкара Урал-Алтай җәмгыятенең, Польша һәм Венгрия шәркыятьчеләр җәмгыятьләренең, Төркия лингвистика җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.



Н.А. Баскаков.

Х е з м.: Уйгурско-русский словарь. М., 1939 (автордаш); Ногайский язык и его диалекты. Грамматика, тексты, словарь. М.–Л., 1940; Ойротско-русский словарь. М., 1947 (автордаш); Каракалпакский язык. Фонетика и морфология. М., 1952; Алтайский язык. М., 1958; Введение в изучение тюркских языков. М., 1962; Русские фамилии тюркского происхождения. М., 1979; Тюркская лексика в «Слове о полку Игореве». М., 1985.

*Әд.:* Ә х ә т о в Г. Атаклы совет тел белгече // Совет мәктәбе. 1985. № 3; Х а м з а е в М.Я. Учёный, достойный почётного звания // Изв. АН Туркм. ССР. Сер. общ. наук. 1962. № 3; С е в о р т я н Э.В. Н.А.Баскаков (К 70-летию со дня рождения) // Советская тюркология. 1975. № 3; 90 лет Н.А.Баскакову. М., 1996.

*В.Х.Хаков.*

**БАСКА́Н** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 52 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасыннан 1 *км* ераклыкта. 2002 елда 256 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1724 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, ярма ярдыру тегермәне, вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 975,8 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир заты; 1859 да — 517, 1897 дә — 633, 1920 дә — 733, 1926 да — 664, 1938 дә — 648, 1949 да — 454, 1958 дә — 430, 1970 тә — 459, 1979 да — 389, 1989 да — 300 кеше.

**БАСКА́РТ** (Паскарт), 13–15 йөзләрдә Идел буе Болгарына чиктәш Урал-тау алды төбәгенең тарихи атамасы. Төп халкы *паскатирлар*. Беренче мәртәбә Плано Карпини б-н Вильгельм Рубрук язмаларында Б. иле яки *Бөек Венгрия* буларак телгә алына; Б. илендә шәһәрләр юк, халкы венгр теленә охшаган телдә сөйләшә, кучмә терлекчелек б-н шөгыльләнә, дип тасвирлана. Б. төбәге халкы соңрак төркиләшә һәм ислам динен кабул

итә. Татарстан җирендә паскатирларга нисбәтле торак урыннар һәм каберлекләр ачыкланган (к. *Чиялек культурасы*).

*Әд.:* Путешествие в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957; К а з а к о в Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978.

*Е.П.Казаков.*

**БАСКЕТБО́Л** (ингл. basket — кәрзин һәм ball — туп), командалы спорт уены, тупны кул б-н өскә эленгән кәрзингә ыргытуга корылган. ТРда Казан («Динамо», «Тимерьюлчы» («Железнодорожник») физкультура коллективларында, Яшел Үзән, Чистай шәһәрләрендә 1920 еллардан үсеш ала. 1923 елда Казанда 2 нче Идел буе олимпиадасы уза, анда Казанның ирләр командасы 1 нче урынны ала, 1928 дә 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында (Мәскәү) Казанның хатын-кызлар командасы РСФСРдагы физкультура




коллективлары арасында 3 нче урынны ала. 1934 тән шәһәр беренчелегенә зурлар арасында, 1936 дан укучылар арасында (оештыручы — А.С.Виноградов) ярышлар уздырыла. Татарстан җыелма командасы (ирләр, хатын-кызлар) — РСФСРдагы 9 автономияле республика спартакиадасында җиңүче була (1939), РСФСР халыклары спартакиадасында көмеш медаль ала (1971). Казан командалары: «Спартак» — ирекле-спорт җәмгыятьләренең үзәк советы беренчелеге призёры (бронза — ирләр, көмеш — хатын-кызлар командалары, 1944), (бронза — ирләр, хатын-кызлар, 1945), РСФСР чемпионы — (хатын-кызлар, 1950), РСФСР кубогы иясе (ирләр, 1950); «Крылья Советов» — Профсоюзларның бөтенсоюз үзәк советы беренчелеге призёры (көмеш — ирләр, хатын-кызлар, 1945); Казан пед. ин-тының «Искра» командасы — РСФСР чемпионы (хатын-кызлар, 1953); Казан университетының «Университет» командасы — «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятенең үзәк советы беренчелегендә җиңүче (ирләр, 1965); Казан авиация ин-тының «КАИ» командасы — РСФСР кубогы (ирләр, 1953) иясе. 1948 елдан даими рәвештә ТР беренчелегенә ярышлар уздырыла. 1950 дә ТРның Баскетбол федерациясе оештырыла. Рәисләре: Р.Ф.Бурнашев (1950–56), В.Т.Белов (1956–66), А.П.Власов (1966–70), В.И.Ромашов (1970–93), Н.К.Сәетгалиев (1993–2002), А.Г.Щербаков — 2002 дән. 1949 дан ТАССР югары уку йортлары беренчелегенә ярышлар уздырыла. 1996 дан Казан командалары РФ чемпионатының югары лигасында уйный — «*УНИКС*» (ирләр, 1997 дән суперлигада), «Технология университеты» (хатын-кызлар, 2000 нән суперлигада) һәм «КамАЗ» (Чаллы, хатын-кызлар, 1999 га кадәр). Танылган уенчылар арасында: ТР, Россия, Европа, дөнья чемпионнары бар: З.З.Алимов, Ю.Г.Бабьялов, Н.В.Бахарев, В.А.Груша, Т.В.Карандашева, И.Д.Красновский, О.Ю.Куховаренко, В.В.Левченко, В.В.Мясников, В.О.Никитин, В.И.Ромашов, Н.Н.*Савощенко*, Э.Н.Ситдыйков, Т.Слиденко (Пыркова), Ю.И.Спиридонов, Р.Г.Уразманов, А.К.Шалабанов. Иң яхшы тренерлар арасында — Л.Ф.*Арсланов*, А.Е.Виноградов, А.П.Власов, С.Т.Ерёмин, М.М.Жилин, Н.Кулешова, В.В.Левченко, А.М.Мусаилов, И.П.*Позняк*, В.И.Ромашов, Н.Н.Савощенко, Д.А.Шувагин. Халыкара категорияле судьялар — Л.Ф.Арсланов, Г.Х.Мөхәммәтҗанов, Н.К.Сәетгалиев.

**«БА́СКЕТ-ХОЛЛ»**, Казандагы баскетбол уйный торган спорт корылмасы. 2002 елда файдалануга тапшырыла (арх. Е.И.Прокофьев, В.П.Логинов). «Б.-Х.» — арасында үтеп йөрү юлы булган ике бина комплексын (гомуми мәйданы 25932 *м*²), төп уен спорт залын (19373 *м*² мәйданлы, 7500 урынлы төп бина), үтеп йөрү юлы булган тренировка спорт залын (6539 *м*² мәйданлы 1500 урынлы), 8 чишенү бүлмәсе, судьялар өчен 4, артистлар өчен 4, грим салу өчен 2 бүлмә, душ кабиналары, сауна, туалетлар, тренажёр залы, мед.-тернәкләндерү үзәге, бильярд уйнау, матбугат-конференцияләре уздыру өчен заллар, теле-радиокомментаторлар кабиналары, фитобар, буфет, персональ 19 ложаны үз эченә ала. «Б.-Х.» бинасында шәһәр, республика, федерация һәм халыкара дәрәҗәдәге чаралар: баскетбол, волейбол, көрәш төрләре, нәфис гимнастика, бокс, гандбол, мини-футбол һ.б. буенча спорт ярышлары, ш.у. күргәзмәләр, ярминкә, концертлар үткәрелә. «Б.-Х.» — «УНИКС», «УНИКС-2» (баскетбол), «Динамо-Таттрансгаз», «Казаночка» (волейбол), «КАИ-Зилант» (гандбол) команда-мастерларның уку-тренировка һәм ярышлар уздыру базасы. «Б.-Х.» каршында «Фан-клуб» яшьләр-иҗтимагый оешмасы, «Миник» һәм «Дюбл» спорт секцияләре (кече яшьтәге мәктәп балалары һәм яшүсмерләр өчен) эшли.



«Баскет-холл».

**БАСМА́**, татар зәргәрчелек сәнгатендә бизәкле махсус калыплардан кул б-н басып юка металлга (алтын, көмеш, бакыр һ.б.) бизәк төшерү ысулы. Гадәттә юка табаклы көмеш, кайвакыт алтын кулланыла, ул бизәк калыбы өстенә салына һәм өстән тимер кысадагы яссы кургаш б-н бастырыла. Б. остасы, әлеге



Бронзадан эшләнгән басма бизәкләр үрнәге. 12–13 йөзләр.

яссы кургашка сугып, бизәкне калай өслегенә күчерә. Калайның калынлыгы бизәк рельефының тирәнлегенә бәйле: бизәк сай чокырланганда ул 3–4 *мм* га, тирәнрәк булганда 6 *мм* га җитә. Бастырылган бизәк уемлау, чүкү, төймәләү, нокталы яисә штрихлы рельеф ясау юлы б-н камилләштерелә. Бизәк еш кына каралтыла, кайвакыт бөртекләү, чәчәк-үсемлек сурәтләре, гарәп язуы б-н баетыла. Көнчыгыш Европада Б. һун (кылыч кынарының басма бизәкле алтын кыршаулары,



Хаситә. Алтын, ахак, яшма. Басма. 14 йөзнең 1 нче яртысы. Эрмитаж.

аеллар) һәм болгар (алтын һәм көмеш көнкүреш әйберләре, савыт-саба, кораллар, камәр еленмәләре, киемдәге аеллар, ат дирбиясе һ.б.) сәнгатендә чагыла. Моны *Перещепин* (Кубрат хан), Надь-Сент-Миклош хәзинәләрендәге әйберләр, Бөек Болгар, Хәзәр каганлыгы, Венгрия, Кырым, Дон буе, Төньяк Кавказ җирләрендәге шәһәрлекләрдәге археол. табылдыклар раслый. Б. ысулы б-н башкарылган иң борынгы әсәрләрдә Евразия далаларында таралган борынгы төркиләр сәнгатенә хас уртак сыйфатлар чагылыш таба. 7–8 йөзләрдә эшләнгән металл әйберләргә *Салтау-Маяк культурасына* караган сәнгать-стиль үзенчәлекләре хас. Элгәреге болгар сәнгатендә, Хәзәр каганлыгындагы кебек үк, билбау очлары, камәр еленмәләре һәм аеллары, күкрәкчәләр, баш киемнәре бизәмәләре, ат дирбияләре Б. ысулы кулланып,

үсемлек һәм җәнлек сурәтләре б-н бизәкләнгән. 10–12 йөзләрдә Б.ның Салтау традицияләре Идел буе Болгарында үсеш ала (шул ук әйберләрдә үсемлек мотивлары һәм «җәнлек стиле»). Идел һәм Дон буйларындагы, Кырым җирләрендәге кыпчак каберлекләрендә табылган әйберләрдә дә бу традицияләрнең йогынтысы сизелә (Б. һәм каралту ысулы б-н үрелгән тасма рәвешендә һәм рельефы кытыршыландырып ясалган ат җигү дирбиясе). *Алтын Урда* дәверендәге Б.га басып бизәк төшерү ысулы б-н беррәттән калып б-н эшләү дә хас. Бу очракта бизәк калыбы металл калайның өстенә, ә яссы кургаш аскы ягына куела. Биләр, Сарай әл-Мәхрусә, Сарай әл-Җәдит, Камай һәм Алтын Урданың башка шәһәрләрендә археологик тикшеренүләр вакытында кабарынкы бизәк һәм гарәп язулары төшерелгән кайрак, сандал, куыш конус рәвешендәге калыплар табыла. Казан ханлыгы чорыннан һәм 17–18 йөзләрдән тирән рельефлы Б. ысулында башкарылган, күпчелеге көмештән эшләнгән түгәрәк һәм овал формадагы куыш эчле (4,5 *см* диаметрда) сәдәфләр сакланган. Алар татар морзаларының камзолларына тагылган. Мондый сәдәфләрне 16–17 йөзләрдә русларның югары катлавы үз киемнәрендә дә куллана. Аларның үрнәкләре Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы, ТР Милли музее фондларында саклана. 18–20 йөзләрдә татар зәркән сәнгатендә Б., нигездә, билбау каптырмасы, беләзек, сәдәф, балдак һәм йөзек, Коръән тартмасы (каптырга) кебек киң таралган бизәмәләр, ш.у. *хәситә*, *изү*, *тезмә*нең бер өлеше булган төрле зурлыктагы һәм формадагы аеллар ясауда кулланыла.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; Даркевич В.Г. Художественный металл Востока VIII–XIII вв. М., 1976; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987; Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БАСМА́НОВ** Алексей Данилович (? — 1570, Мәскәү), хәрби, дәүләт эшлеклесе, окольничий (1552), бояр (1555 яки 1556). Плещеевләр нәселеннән. 1552 елда Казанны яулап алу сугышында Иван IV гаскәренең Зур полкында кече воевода буларак катнаша. Казанга беренче булып бәреп кергән отрядка кенәз М.М.Воротынский б-н бергә җитәкчелек итә (шуның өчен Иван IV аңа окольничий дәрәҗәсе бирә). 1555 тә Тула шәһәре янында Кырым ханы Дәүләтгәрәй гаскәре б-н сугышта да таныла. Ливон сугышы барышында (1558–83) аның җитәкчелегендәге отряд 1558 дә Нарва кирмәнен ала. 1564 тә Рязань шәһәрен Дәүләтгәрәй хан көчләре һөҗүменнән саклауны оештыра. 1562 елдан Иван IV б-н дустанә мөнәсәбәттә, патша хөкүмәтенең фактик җитәкчесе була; опричнина тәртипләрен кертүчеләрнең берсе. А.М.Курбский хәбәр итүенчә, Иван IV әмере б-н үз улы Фёдор тарафыннан үтерелә.

*Әд.:* Скрынников Р.Г. Царство террора. СПб., 1992. *Е.В.Липаков.*

**БА́СОВ** Анатолий Данилович (18.1.1923, Киев ш.), хокук белгече, партия хезмәткәре. Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1949). 1949–52 елларда Казан шәһәре Молотов р-ны халык судьясы. 1952–61 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, 1961–65 тә хакимият һәм сәүдә-финанс органнары бүлеге мөдире урынбасары, 1969–84 тә хакимият органнары бүлеге мөдире. 1965–69 да ТАССР Югары мәхкәмәсе рәисе. 1985–90 да Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе партия ком-тының партия комиссиясе рәисе. 1992 елдан «Татинвестбанк» идарәсе юристконсульты, 1993 тән рәис урынбасары, 1999 дан рәиснең 1 нче урынбасары. 1967–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

**БАСТА́Н ТАТАРЛАРЫ́**, к. *Сасово татарлары.*

**БАСТЫРМА́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Зичәнең сул кушылдыгы (Зәй елгасы бассейны). Озынлыгы 11,1 *км*, бассейнының мәйданы 66 *км*². Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Баграҗ авылыннан 3,8 *км* көнчыгыштарак, тамагы Дүртмунча авылыннан 1,2 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 243 *м*, тамагыныкы — 118 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 59%. Б. елгасының 5,7 һәм 7 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,043 *м*³*/с*. Ел дәвамында суы бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейны Баграж аучылык тыюлыгының бер өлеше булып тора.


**БАСЫ́ЙРОВ** Георгий Васильевич (7.7.1925, Кемерово өлкәсенең Ижмор р-ны Теплоречка а.), Дан орденының тулы кавалеры (11.9.1944, 8.3.1945, 15.5.1946), старшина. Кемерово өлкәсе Юрга шәһәренең ит комб-тында эшли. 1942 елның октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, сержант, 142 нче танк батальонында танк йөртүче-механик (9 нчы танк корпусының 95 нче танк бригадасы). 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Белоруссия (1944), Бобруйск (1944), Минск (1944) һөҗүм операцияләрендә, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1944 нең 27 июнендә Бобруйск шәһәре өчен сугышта, 1945 елның 15 гыйнварында Радом шәһәре (Польша) янында, 1945 елның мартында Массов, Штаргард (Германия) шәһәрләре янында барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Юрга шәһәре машина төзү з-дында мастер булып эшли. 1 нче, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.




Г.В. Басыйров.

*Әд.:* Лобода В.Ф. Солдатская слава. М., 1967. Кн. 2; Фронтовики, наденьте ордена. Кемерово. 1970; Кузбассовцы — полные кавалеры ордена Славы. Кемерово, 1978; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000. *В.А.Шагалов.*

**БАСЫ́ЙРОВ** Зилфәт Рәүф (Габдерәүф) улы (15.9.1927, Актаныш р-ны Иске Кормаш а. — 21.11.2000, Уфа ш.), сынчы, график, Башкортстанның халык рәссамы (2000). Түбән Тагил шәһәрендә Урал гамәли сәнгать уч-щесенең скульптура бүлеген (1955), Мәскәү җирле сәнәгать технол. ин-тының сынлы сәнгать ф-тын (1962) тәмамлый. Пермь өлкәсенең сәнгать эшләнмәләре пр-тиеләрендә эшли (1955–59). 1962–65 елларда В.М.Васнецов исем. Абрамцево сәнгать-сәнәгать уч-щесендә рәсем укытучысы, директор урынбасары була. 1965 елдан Уфада яши. Башкортстан Рәссамнар берлеге әгъзасы (1968) һәм идарәсе рәисе (1985–87), РСФСР Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы (1987–92), бер үк вакытта Уфа нефть ин-тының архит-ра каф. укытучысы (1977–81). Монументаль һәм станлы сынлы сәнгать өлкәсендә Башкортстанның әйдәп баручы рәссамнарыннан. Башкортстанда куелган 30 лап һәйкәл (Дүртөйле авылында, «Дүртөйле чибәрләре», 1974; Октябрь посёлогында «Девон нефтен ачучылар», 1976; Солтанморат авылында «Галимҗан Ибраһимов», 1987 һ.б.), Башкорт опера һәм балет театры бинасы фасадындагы «Терпсихора» һәм «Евтерпа» декоратив сыннары, Үзбәкстанда, Белоруссиядә, Пермь өлкәсендә һәм Татарстанда куелган монументаль сыннар (М.Ардуанов сыны, 1990; Иске Кормаш авылында Мөгаллим Дәүләтьяров истәлегенә мемориаль такта, 1993; Түбән Кама шәһәрендә Бакый Урманче һәйкәле, 1998); станлы портретлар («Айгөл», 1969; «Кинҗә», 1974; «Романтиклар», 1977 һәм 1984; «Акмулла» 1990; «Сөембикә», 1997); ялангач натура композицияләре («Су кызы», 1975; «Су коенучы





З.Р. Басыйров. 1. «Акмулла». Агач. 1990. М.В.Нестеров исем. Башкорт Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Рәссам Бакый Урманче». Түбән Кама шәһәрендәге һәйкәл моделе. Бронза, кою. 1997.

кыз», 1983; «Алтынчәч», 1987; «Камышкай», 1994) һәм 1990 елларда татар фольклорына нигезләнеп вак пластика жанрында таштан, бронза, агач, алюминий һәм бакырдан ясалган композицияләр авторы. Б.ның графикасы тушь, күмер, каләм, пастель һәм акварель техникасы б-н башкарылган жанрлы композицияләрдән һәм пейзажлардан гыйбарәт («Автопортрет», 1968; «Переслав әкияте», 1971; «Акмулла портреты», 1981; «Урман кызы», 1995 һ.б.). Б. — авторлык каталогында басылып чыккан шигырьләр (Уфа, 1998), «Мин үземнең әсәрләремне ничек иҗат иттем» дигән биографик очерклар авторы. 1988 дә Б.ның туган ягында 100 дән артык әсәре (сыннар һәм графика) куелган даими күргәзмәсе ачыла, ш.у. әсәрләре Уфаның М.В.Нестеров исем. сәнгать музеенда, Көнгердәге туган якны өйрәнү музеенда (Пермь өлкәсе) һ.б. саклана. Бөтенсоюз («Хезмәткә дан», Мәскәү, 1976), бөтенроссия («Туган ил буйлап», Мәскәү, 1972; «Совет Россиясе», Мәскәү, 1975), төбәкара («Социалистик Урал», 1971, 1974, 1979, 1985, 1991) һәм республика (Уфа) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Уфада (1978, 1987, 1992, 1998), Березники шәһәрендә (Пермь өлкәсе, 1992), шәһәр тибындагы Актаныш посёлогында (1994, 1997) уза. «Почёт билгесе» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. М.Акмулла исем. республика бүләге лауреаты (1992).

*Әд.:* П и к у н о в а  Г. Песня о Башкирии // Художник. 1969. № 4; Басыров Зильфат Рауфович // Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1.; С у х о в а  Л. Заслуженный художник БАССР Зильфат Басыров. Скульптура, графика: Каталог. Уфа, 1978; Я н б у х т и н а  А. О людях Башкирии // Художник. 1978. № 8; А с а д у л л и н а  А. Известный скульптор Зильфат Басыров // Аманат. 1993. № 7; Зильфат Басыров. Скульптура, графика, поэзия. Уфа, 1998; Художники Башкортостана. XX: Справ. Уфа, 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БАСЫ́ЙРОВ** Кәшфи (Кашшаф) Хәбир улы (17.4.1906, хәзерге Башкортстан Респ-касының Бәләбәй р-ны Мәтәүбаш а. — 16.1.1943), язучы, тәрҗемәче. Бәләбәй пед. техникумын тәмамлый (1927). Кукмарада һәм Казанда мөгаллимлек итә. 1934–42 елларда Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир, әдәби тәрҗемәче була. Беренче хикәяләре 1925 тән «Белем», «Безнең юл», «Совет әдәбияты», «Азат хатын» ж-лларында басыла. «Танышлар» исемле сайланма хикәяләр җыентыгы 1958 дә Казанда нәшер ителә. Татар теленә М.Ю.Лермонтовның «Герой нашего времени» («Безнең заман герое» романын, 1937), К.Г.Паустовскийның «Колхида» (1938) повестен, А.П.Чехов хикәяләрен (1940, 1946), Н.В.Гогольнең «Мёртвые души» («Үле җаннар», 1947) романын, ш.у. В.П.Катаев, А.Серафимович, В.Г.Короленконың кайбер әсәрләрен тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында һәлак була.

*Әд.:* Алар сафта / Төз. С.Шакир. К., 1961; Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**БАСЫ́ЙРОВА** Зифа Җәмил кызы (3.7.1910, Уфа губ., Минзәлә өязе Мөслим а. — 7.2.1979, Казан), драма актрисасы һәм җырчы, ТАССРның атказ. артисткасы (1950). 1936 елда Татар театр техникумын тәмамлый. 1936–61 дә Татар акад. театры актрисасы, 1961–76 да Татар филармониясе солисты. Театр сәхнәсендә башлыча яшүсмерләрнең комик рольләрен башкара: Яша («Әбләй авылы», Ф.Хөсни), Мәхмүт («Миңлекамал», М.Әмир), Гали («Тапкыр егет», Д.Аппакова), Әпсәләм («Каюм Насыйри», М.Гали һәм Х.Уразиков). Муз. драма спектакльләрендә Маһинур, Хәмидә, Наҗия («Бишбүләк», «Чын мәхәббәт», «Изге әманәт», Т.Гыйззәт) кебек төп рольләрне башкара. Б. актив концерт эшчәнлеге алып бара.



З.Җ. Басыйрова.

Җырчы Татарстан композиторлары әсәрләреннән һәм халык җырларыннан бай репертуар булдыра. Халык иҗаты әсәрләреннән *авыл көйләре* жанрындагы җырларны аеруча зур осталык б-н башкара. Аның башкаруында татар халкының «Дөм-дөм», «Мөслим», «Өй артында шомыртым», «Су буйлап» һ.б. җырлары зур популярлык казана. Б. үзенчәлекле актёрлык һәм җырлау сәләтенә ия була. Ике «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Ф.Ш.Салитова.*

**БАСЫ́М**, төрле фонетик чаралар ярдәмендә сөйләмнең теге яки бу кисәген аерып кую. Сегмент берәмлеге б-н функциональ мөнәсәбәт төренә бәйле рәвештә сүз, синтагма (такт) һәм фраза Б.ына бүленә. Б.ның 3 фонетик компонентын аералар (өстенлек иткән компонентка карап Б.ның фонетик тибы билгеләнә): 1) интенсивлыкка мускулларның киеренкелеген арттыру һәм сулыш чыгаруның көчәюе б-н ирешелә (мондый Б. динамик, сирәк экспиратор Б. дип атала); 2) тавыш тонының югарылыгы (музыкаль Б.); 3) озынлык (микъдар Б.). Башка төрки телләрдәге кебек үк татар телендә дә басымлы иҗек көчсез һәм әкрен әйтелә, шуңа күрә аны ишетү кыен. Татар телендә сүз Б. ы даими, күпчелек очракта сүзнең соңгы иҗегенә төшә. Шул ук вакытта ул — хәрәкәтчән Б.: сүзләргә кушымчалар ялганганда сүзнең азагына күчә бара: а́т — атла́р, -атлары́, -атларына́. Кайбер *рус алынмалары* татар теле закончалыкларына яраклашып Б.нарын үзгәртәләр: бо́чка — мичкә́, моча́ло — мунчала́. Ә кайберләре оригиналдагы Б.ны саклыйлар һәм Б. сүзнең азагына төшмәсә, кушымчалар ялганганда үз урынында кала (а́втор — а́вторлар — а́вторларга), әгәр Б. сүзнең азагына төшсә, кушымчалар ялганганда Б. соңгы иҗеккә күчә (сове́т — советла́р — советларга́). Кушма сүзләрдә төп Б. нан тыш өстәмә Б. да була, мәс.: и́лбашы́, я́шүсме́р һ.б. Гадәттә, сүз Б. ының ике фонологик функциясен — сүзне танытту һәм мәгънә аеру функцияләрен билгелиләр. Татар телендә басымның икенче фонологик функциясе — мәгънә аеру күзәтелә. Ул алма́ — а́лма, басма́ — ба́сма кебек омографларда ачык күренә. Б. ның вариативлыгы дигән күренеш тә очрый. Бу — басымның бер үк сүздә төрле урында килә алуы. Вариантларның берсе норматив булырга, икенчесе гади сөйләмдә яки диалектларда гына очрарга мөмкин. Кайчак вариативлык семантик яки стилистик дифференциация белән бәйләнгән була. Б. ның соңгы иҗектә булуы норматив булып исәпләнә, ә сүз башына төшә торган вариатив Б. бу сүзләрне логик яктан аеру өчен хезмәт итә: бү́ген (нәкъ менә бү́ген).

Синтагма һәм фраза Б. синтагма яки фразадагы берәр сүзнең басымын көчәйтү юлы б-н барлыкка килә. Мәс.: Ки́ч иде./ Шатлы́к белән, / нурла́р чәчеп, / а́й ялтырый. / Г.Тукай).

Логик Б. — җөмләдәге бер сүзнең башкаларыннан аерылып торуы. Мәс.: **Илдар киләчәк** җөмләсендә логик Б.ның нинди сүзгә төшүенә карап, субъектка яки килү фактына басым ясала.


*Әд.:* В ә л и д и  Җ. Татар теленең грамматикасы. К., 1919; Татар грамматикасы. К., 1998. 1 т.; Лингвистический энциклопедический словарь. М., 1990; Ш а р а ф  Г. Сонорная длительность татарских гласных. К., 1928.

*М.Ә.Сәгыйтов.*

**БАТА́ЛОВ** Фёдор Алексеевич (11.9.1900, Казан — 1941), Сов. Союзы Герое (9.8.1941), майор (1941, август). 1918 елдан Кызыл Армиядә. Казанда хәрби мәктәпне (1929), Мәскәүдә «Выстрел» югары командирлар курсын (1939) тәмамлый. Гражданнар (1918–20) һәм совет-фин (1939–40) сугышларында катнаша. 1941 елның июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 21 нче армиянең 154 нче укчы дивизиясе 437 нче укчы полкының батальон, полк командиры. 21 нче армия дивизияләре 1941 нең 13 июлендә контрһөҗүмгә ташлана, Жлобин һәм Рогачёв шәһәрләрен, берничә авылны (Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе) азат итә. 1941 нең июль ахырларында 154 нче дивизия полклары чолганышта кала, 1941 нең сентябрь урталарына кадәр камалышта килеш дошман көчләре б-н көрәшә. Каты яраланган Б. шул чакта хәбәрсез югала. Ленин, Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Жлобин шәһәренең бер үзәк урамына Б. исеме бирелгән.

*Әд.:* К а п у с т и н  А.П. Беренче җиңүләр. К., 1995; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Честь, отвага, мужество. Саратов, 1979; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; На-


Ф.А. Баталов.


Е.Н. Батенчук.

вечно в сердце народном. Минск. 1984; К а п у с т и н А.П. Первые победы. Минск, 1989.

*В.А.Шагалов.*

**БАТБАЯ́Н** (Баян) (7 йөз), Азов диңгезе буе болгар кабиләләре идарәчесе (642 тирәсе — 670). *Кубрат ханның* өлкән улы. Атасы вафатыннан соң болгар кабиләләрен җитәкли; хәзәрләр б-н сугыша. 7 йөз урталарында Б. ыруг-кабиләләре хәзәрләр тарафыннан Көнчыгыш Азов тирәләреннән Дон б-н Днепр елгалары арасына кысрыклап чыгарыла, Хәзәр каганлыгына вассаллык рәвешендә буйсындырыла.

*Әд.:* Ч и ч у р о в И.С. Византийские исторические сочинения. М., 1980.

**БАТЕНЧУ́К** Евгений Никанорович (28.2.1914, Украина ССРның Одесса өлкәсе Балта ш. — 30.5.1999, Чаллы ш.), инженер-төзүче, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, Соц. Хезмәт Герое (1981). Якутия АССР, РСФСР, ТАССРның атказ. төзүчесе (1964, 1984, 1989). Мирный (Якутия АССР), Чаллы шәһәрләренең мактаулы гражданы (1971, 1997). 1940 елда Рубежное хим.-технол. ин-тын тәмамлый (Луганск өлкәсе). 1931–35 тә Одесса, Рубежное шәһәрләре сәнәгать пр-тиеләрендә эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Германиядә әсирлектә була һәм шул вакытта 326 нчы хәрби лагерьда Каршылык күрсәтү хәрәкәтен җитәкли (Гемер ш.). 1946–50 дә «Сочигэсстрой» да баш механик, 1950–59 да «Ангарагэсстрой»да баш механик, механикалаштыру идарәсе башлыгы. 1959–71 дә «Вилюйгэсстрой» идарәсе башлыгы. 1971–79 да «Камгэсэнергострой» җитештерү берләшмәсе башлыгы урынбасары, 1979–89 да башлык. Аның җитәкчелегендә Красная Поляна, Иркутск, Вилюй, Түбән Кама ГЭСлары, КамАЗ, КамАЗ ТЭЦы; «Татэлектромаш» з-ды, Чаллы катыргы-кәгазь комб-ты, ш.у. Чаллы, Алабуга, Зәй шәһәрләрендә, Кама Аланы посёлогында торак йортлар, социаль-мәдәният объектлары төзелә. Уйлап табуга өч авторлык таныклыгы бар. 1959–71 дә Якутия АССР, 1971–90 да ТАССР ЮСлары депутаты. СССР МС бүләге лауреаты (1971). Өч Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәрендә «Энергетик» мәдәният йорты каршындагы мәйдан Б. исемен йөртә, һәйкәл куелган (2002); аңа багышлап 20 ләп документаль һәм әдәби әсәр язылган. 2005 елда аның исеме «Якутэнерго»ның Вилюйск ГЭСына бирелә.

Х е з м.: Организационный опыт работы управления механизации строительства на «Ангарагэсстрое». Иркутск, 1957 (автордаш); Зимняя укладка связных грунтов на Крайнем Севере (строительство плотины Вилюйской ГЭС). М., 1968 (автордаш).

*Әд.:* П о л у х и н Ю. Заколдованные берега. М., 1976; В и д р а ш к у Ф. Набережная надежды. М., 1984; Б и з я е в Б. Батенчук Евгений Никанорович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984. Кн. 2; В е ч е р и н П. Батя: Док. повесть о Е.Н.Батенчуке. М., 1998.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**БАТКА́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кече Ирнә елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 83 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.та мәчет һәм мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 421,8 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Сарман р-нында. 1970 елларда Б. составына Югары Баткак авылы керә. Халык саны: 1781 дә — 34 ир заты; 1859 да — 143, 1870 тә — 140, 1926 да — 170, 1949 да — 220, 1958 дә — 135, 1970 тә — 142, 1979 да — 95, 1989 да — 132 кеше.

**БА́ТКИС** Григорий Семёнович (16.6.1945, Украина ССРның Винница өлкәсе Томашполь штп), машиналар төзү һәм механикалаштыру гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2003), РФнең атказ. машина төзүчесе (1998). 1969 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый, «НИИтурбокомпрессор» АҖдә әйдәп баручы конструктор (1973–74), подшипниклар лаб. мөдире (1974–87), майлау һәм тыгызлау системаларын исәпләү-тикшерү һәм конструкторлык бүлеге башлыгы (1987–92), юнәлешнең баш конструкторы — бүлек башлыгы (1992–93), җитештерү буенча директор урынбасары — баш конструктор — бүлек башлыгы (1993–98), җитештерү буенча ген. директор урынбасары (1998 елдан), бер үк вакытта Казан компрессор машиналар төзү з-дында ген. директорның җитештерү, маркетинг һәм тышкы икътисади элемтәләр буенча беренче урынбасары, 2003 елдан Казан технол. ун-тының компрессорлар һәм пневмоагрегатлар каф. профессоры. Хезмәтләре турбомашиналарның шуучан подшипникларын, герметик тыгызлау һәм майлау системаларын өйрәнүгә карый. Сыекчалы ышкылу вакытында югары тизлекле көчне исәпләү ысулларын тәкъдим итә. Эш нәтиҗәләре ТР, РФ һәм Украина компрессорлар төзү пр-тиеләрендә кулланыла. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2005).

*Әд.:* Трибология подшипников и уплотнений жидкостного трения высокоскоростных турбомашин. К., 1998 (автордаш); Высокоскоростные опоры скольжения гидродинамического трения. К., 2004 (автордаш); Торцовые бесконтактные уплотнения роторов компрессорных машин. К., 2004 (автордаш).

**БАТРА́ЕВ** Закир Солтан улы (11.10.1936, Үзбәкстан ССРның Бохара ш.), нәкышьче, график, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). Казан архит.-төзелеш ун-ты профессоры (2005). Казан сәнгать уч-щесен (1959), Ташкент театр сәнгате ин-тының станлы нәкышь бүлеген (1965) тәмамлый. 1966 елдан Казанда яши. 1968 дән Казан төзелеш-архит-ра академиясенең архит-ра ф-тында рәсем һәм нәкышь укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1992), ТР Архитекторлар берлегенең шәрәфле әгъзасы (1995). Пейзаж, портрет, натюрморт жанрларында нәкышь, акварель, гуаш әсәрләре авторы. Төп әсәрләре: «Урта Азия шәһәрләре буйлап» (1965; 1977, 1984); «Алтын божра» (1973; 1975–77); «Һиндстан шәһәрләре» (1983, 1984, 1988–90); «Казан күренешләре» (1977–99), «Идел пейзажлары» (1982) архит-ра пейзажлары серияләре, комп. Р.Еникеев (1989), А.Б.Луппов (1995) һ.б. портретлары. Халыкара (То-










З.С. Б а т р а е в. 1. «Мәрҗани мәчете белән Казан пейзажы». 1994; 2. «Агра. Таҗ-махал». «Һиндстан шәһәрләре» сериясеннән. 1985; 3. «Һималай таулары». «Һиндстан шәһәрләре» сериясеннән. Катыргы, темпера. 2000.

кио, 1991; III Халыкара архитектура рәсемнәре конкурсы, Казан, 2005, I дәрәҗә диплом; Халыкара акварель сәнгате күргәзмәсе, Петрозаводск, 2006, диплом), бөтенсоюз («Туган илнең зәңгәр юллары» һәм «Рәсем күргәзмәсе», Мәскәү, 1979 һәм 1990), төбәкара («Зур Идел», 1975, 2003, 2004), республика (Ташкент, 1965; Казан, 1976–99; Уфа, 1977) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә (1971, 1976, 1985, 1998, 2000) Казанда (1974, 1975, 1985, 1990, 1992, 2000, 2001, 2002, 2005, 2006) уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт картиналар галереясында, Чистай рәсем мәктәбендә, АКШ галереяларында (Сиэтл, Бостон), Япониядә, шәхси коллекцияләрдә (Төркия, Англия, Франция) саклана.

Х е з м.: Методические указания по рисунку: Учеб. пособие. К., 1987.

*Әд.:* Кто есть кто в науке об искусстве. К., 1999; Г о р н и к Г.Л. Творчество, подаренное людям // Идель. 2001. № 12; И л ь и н а М.Е. Прогулка по уходящей Казани // Казань. 2003. № 7.


**БАТРА́С** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Кичүнең уң кушылдыгы (Чишмә елгасы бассейны). Озынлыгы 15,3 *км*, бассейнының мәйданы 79 $км^2$. Елга башы Зәй р-ның Салкын Чишмә авылыннан 2,5 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Әлмәт р-ны Добромыш авылыннан 2,4 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 84 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 34%. Б. ның 0,7 дән алып 3,1 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 $км/км^2$. Туенуы катнаш. Җир асты туендыру модуле 1,1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 135 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче көннәрендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,16 $м^3/с$. Елга тамакларында суы бик каты (9–12 *мг-экв/л*) ш.у. төп агымында каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Б. бассейнында 0,8 млн. $м^3$ күләмле буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БАТТА́Л** Габделбари Габдулла улы (8.12.1880, Самара губ., Бозаулык өязе Яңа Белогор а. — 26.4.1969, Истанбул), тарихчы, филолог һәм журналист, җәмәгать эшлеклесе. Төркиядә яшәгәндә (1925–69) Abdullah Battal-Taymas буларак таныла. Каргалы авылында, Оренбургтагы «Кәрвансарай», Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәләрендә белем ала. 1904 елда укуын дәвам иттерү теләге б-н Каһирәгә бара, анда 1908 елга кадәр гарәп теленнән белемен камилләштерә, гарәпчә нәшер ителүче «әл-Мөкаддәм», «Җәридә» г-талары, «әл-Мәнар» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә. Илгә кайткач, 1908–10 елларда «Вакыт» г-тасында (Оренбург ш.) эшли, гарәп теленнән әдәби, иҗтимагый-фәлсәфи китапларны тәрҗемә итеп бастыра. 1911–12 дә Троицк шәһәре мәдрәсәсендә укыта. Һ.Максуди чакыруы буенча Казанга килә, «Йолдыз» г-тасына сәркәтип итеп билгеләнә (1913–17). Бер үк вакытта «Мәктәп», «Ак юл», «Шура», «Сөембикә» ж-лары б-н хезмәттәшлек итә. Күләмле «Татар тарихы» китабының 1917 елга кадәр 3 басмасы Казанда, 4 нчесе 1938 дә Мукденда; 1996 да «Аргамак» ж-лында (Чаллы) басыла. 1917 елгы Фев. рев-циясеннән соң бер төркем фикердәшләре б-н милли азатлыкка өндәгән «Корылтай» (1917–1918, март), ул ябылгач, «Алтай» (1918, апрель-май) г-таларын нәшер итешә. «Корылтай»га мөнәсәбәтле рәвештә 1918 дә кулга да алына. Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары эшендә актив катнаша. Казаннан сайланган Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18), «Төркичеләр» фракциясе әгъзасы. Милли Идарәгә сайлана, 1918 елның 2 нче яртысында бер төркем Милли Идарә вәкилләре (И.Әхтәмов, Г.Исхакый, Г.Терегулов һ.б.) б-н Себергә чигенә, Кызылъяр шәһәрендә Ф.Туктаров б-н «Маяк» г-тасын чыгара. 1919–20 уку елында Томск пед. курсларында укыта (анда З.*Нуркин* б-н бергә «Уку китабы» дәреслеген нәшер итә). 1920 нең мартында Казанга кайта, кулга алына, җәй башында хезмәт б-н тәрбияләү лагерена җибәрелә. Шул елның августында аннан кача, Баку, Казан, Мәскәү, Петроград шәһәрләрендә ялган документлар б-н яши. 1921 нең җәендә яшерен рәвештә Финляндиягә китә. 3 елдан артыграк анда укыта, үзлегеннән фин, француз телләрен өйрәнә, Төркия, Германия матбугатлары б-н хезмәттәшлек итә. «Казан төркиләре» дигән тарихи хезмәтен яза башлый. 1925 нең ноябреннән Төркиядә яши, Әнкарада Төрек филологиясе ин-тында, 1927 елдан Матбугат мөдирлегендә (соңрак ул Тышкы эшләр министрлыгына буйсындырыла) рус теленнән төрекчәгә тәрҗемәче булып эшли. Шул елларда тарихи «Казан төркиләре», «Россиядән киткән милләтләр» китапларын бастырып чыгара. 1932 дә Истанбулда үткәрелгән Беренче төрки телләр корылтаенда катнаша. 1947 дә төп эшеннән китә һәм Истанбулга килә һәм шунда яши башлый. Шул ук елда аның «Рус ихтилалыннан хатирәләр» китабы басыла. 1930–40 та ул башкарган тәрҗемә хезмәтләрнең иң күренеклеләре: «Ибне Мөһанна лөгате» (1934) һәм 2 томлык «Кыргыз теле сүзлеге» (1945, 1946). Төркиядә нәшер ителүче «Төрек йорты», «Яңа Төркестан», «Төрек теле», «Төрек мәдәнияте» һ.б. газета-журналларда тел, әдәбият, тарих мәсьәләләренә караган күп сандагы мәкалә-очерклары басыла.

Х е з м.: Ислам философлары Мөхәммәд Габдеһ вә Җамалетдин Әфгани. К., 1908; Мәгыйшәт юллары. К., 1908; Габделвәли Яушев, Зәйнулла хәзрәт Рәсүли вә ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый рисаләседер. Оренбург, 1912; Татар тарихы. К., 1912; Назарияте әдәбият. К., 1913; 3 нче басма. К., 1916; 4 нче басма. Мукден, 1938; Өч төрле идарә исулләры: чикләнмәгән монархия, чикләнгән монархия һәм җөмһүрият. К., 1917; Ана теле сарыфы. К., 1918 (автордаш); Сөембикә манарасы хакында. 1917 елда Казанда һәм Уфада Г.Баттал әфәнде тарафыннан укылган лекция. К., 1918; Казан төркиләре. К., 1996; Rusyadan Ayrilan Milletler. Ankara, 1927; Rus ihtilalinden hatiralar. Ist., 1947; Sadri Maksudi Arsal // Dergi. Munih, 1957; Kazanli turk meshurlari. Ist., 1958–59; Kazan turkleri. Ist., 1989.



Габделбари Баттал.



Салих Баттал.

*Әд.:* Габделбарый бине Габдулла бине Мөхәммәтрәхим бине Сәетбаттал // Заман календаре. 1917; Х ә м и д у л л и н Л.Х. Онытылган якын исем // Татарстан. 1996. № 11; С у л т а н б е к о в Б.Ф. «Одиссея» Бари Баттала // Татарстан. 1992. № 5/6.

*Д.М.Госманова.*

**БАТТА́Л** (Батталов) Салих (Салихҗан) Вазыйх улы (5.8.1905, Казан губ., Спас өязе Зур Тигәнәле а. — 12.3.1995, Казан), язучы. Чистай мәдрәсәсендә укый. 1921 елда акча эшләү теләге б-н Мәскәүгә китә. Оренбург очучылар уч-щесен тәмамлый (1929). 1929–35 тә хәрби очучы буларак Брянск һәм Казан авиаотрядларында хезмәт итә, Мәскәүдә Хәрби Һава Көчләренең махсус КБ каршындагы сынау отрядында эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач, Тын Океан флотының авиация частьләрендә хезмәт итә. Әсәрләре 1924 елдан басыла. «Еллар җыры» исемле беренче шигырь җыентыгы 1929 да дөнья күрә. «Очучылар» (1935) романы, «Сигезенчесе кем?» (1965; русчага тәрҗемәсе «Кто же восьмой?», М., 1974) маҗаралы повесте, шигырь һәм поэмалары тупланган «Илем-анам» (1944), «Тылсымлы балдак» (1980), «Төрле еллар мозаикасы» (1983) җыентыклары, «Олы юл буйлап» (икенче исеме «Газзә», 1953; русчага тәрҗемәсе «По столбовой дороге», М., 1956) поэмасы, Гражданнар сугышы елларында татар авылларында социаль үзгәрешләрне, татар крәстияннәренең рухи көчен һәм әхлакый йөзен чагылдырган «Чирмешән якларында» (1967) шигъри роман, «Баштан үткәннәр» (1974) автобиогр. повесть, «Сынау» (1938), «Киртә» (1959), «Яңа өйгә күчкәч» (1959), «Үтеп барышлый» (1960) исемле пьесалар авторы. Б. ның поэзиясе яңача фикерләүгә, ритмик аһәңнәргә, төрле рифмаларга, үз төбәге сөйләшеннән алынган сөйләм берәмлекләренә бай. Прозасы характерларның һәм конфликтның катлаулылыгы, мораль-этик проблемаларның кискен куелышы б-н аерылып тора. Б. А.С.Пушкин, Н.Н.Никитин, В.В.Маяковский һ.б.ның кайбер әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1972–74.

*Әд.:* М ә җ и т о в З. Һәр шагыйрьнең үз тавышы // Сугышчан поэзия. К., 1975; Ф ә й з у л л и н Р. Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т. 4; Б а т у л л а Р. Халыкның үсеше // Татарстан. 1995. № 7, 8.

**БАТТА́Л** (Сәетбатталов) Фәнзаман Сәетбаттал улы (16.2.1939, Минзәлә р-ны Үрсу а.), язучы, публицист. Казан ун-тын тә-


мамлый (1967). 1972–75 елларда халык депутатларының Түбән Кама шәһәр советы башкарма ком-тында бүлек мөдире, 1984–93 тә «Татарстан» дәүләт теле-радиотапшырулар ком-ты хәбәрчесе, 1993–97 дә Татарстан китап нәшрияты мөхәррире. Язмалары 1950 еллар урталарыннан басыла башлый. Әсәрләре сатирик эчтәлеге, үткен, образлы теле б-н аерылып тора. Аларда байлыкка кызыгу, комсызлык, саранлык көлке объектына әверелә. 1990 елларда юмористик хикәяләре тупланган «Сакалыңа ут капса» (1990), «Безнең сурәт» (1993), «Гөнаһ шомлыгы» (1993), «Бака да бата» (1995), «Сигезенче оҗмах» (1999), «Соңарган яз» (2001) җыентыклары, публицистик әсәрләр тупланган «Юлын белгән адашмас» (2000) китабы укучылар арасында популярлык казана.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Фәнзаманнар замалы // Килер бер көн. К., 1998.

**БАТТА́ЛОВ** Мөбарәк Вазыйх улы (15.5.1912. Казан губ., Спас өязе Зур Тигәнәле а. — 8.12.2006, Казан), гобойчы, педагог, ТАССР-ның атказ. артисты (1957). 1937 елда Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка техникумын тәмамлый, 1937–41 дә Мәскәү консерваториясендә укый. 1946–48 дә Казан консерваториясендә (гобой классы) һәм Казан музыка уч-щесендә (1950–60) укыта. 1941–42 һәм 1946–71 елларда Татар опера һәм балет театры оркестры артисты һәм солисты. Татар музыка сәнгатенең күренекле эшлеклеләре б-н бергә чыгыш ясый, С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Ф.Яруллин, А.Ключарёв әсәрләрен һәм татар халык көйләренең гобой өчен эшкәртмәләрен башкара. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**БАТУ́** хан, к. *Батый хан.*

**БАТУЛЛА́** (Батуллин) Рабит (Роберт) Мөхлис улы (26.3.1938, Зәй р-ны Түбән Лоҗы (Олыҗы) а.), ТРның халык язучысы (2008), режиссёр, публицист, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1985). Кече театр каршындагы М.С.Щепкин исем. югары театр уч-щесенең Татар студиясен (1961), ГИТИС каршындагы югары режиссёрлык (1966) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1979) тәмамлый. 1961–63 елларда Татар академ. театры артисты. 1963–65 тә Курчак театры һәм Казан телевидение студиясендә балалар өчен тапшырулар редакциясе режиссёры. 1970–75 тә Казан театр уч-щесендә һәм Казан мәдәният ин-тында укыта. Әдәби иҗат б-н 1960 елларда шөгыльләнә башлый. 1966 да Б.ның балалар өчен язылган «Исемем минем Дүрткүз» дигән беренче китабы дөнья күрә. «Төш вакытында могҗиза» (1966), «Курай уйный бер малай» (1970) пьесалары Казан, Луцк, Омск, Донецк, Саратов, Кемерово, Салават, Махачкала шәһәрләре сәхнәләрендә куела. «Уйларымны кеше белсен» (1969), «Ташламам, җанкисәгем» (1980) җыентыкларына кергән хикәяләре мавыктыргыч сюжетка корылулары, юморга бай булулары б-н аерылып тора. Б. әсәрләренә тормышны фәлсәфи аңлатыр-



Рабит Батулла.

га омтылу хас. 1970 еллар башыннан проф. сәхнә өчен драма әсәрләре иҗат итү өстендә эшли. Яшьләрнең тормыш каршылыкларын җиңеп, мөстәкыйльлеккә омтылуларын романтик күтәренкелек б-н тасвирлаган «Туйлар узгач» (1973) муз. комедиясе, «Өчәү юлга чыктык» (1974) драмасы, «Ярым ятларга кала» (1989) комедиясе һ.б. әсәрләре тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителә. «Кичер мине, әнкәй!» (1979) пьесасы татар драматургиясендә зур уңыш казана. 1986 елда Г.Тукай турында «Сират күпере» исемле тарихи драма яза. Б. үзен эпик әсәрләр язучы буларак та таныта. «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повестенда (1990) замана яшьләре проблемалары күтәрелә. «Сөембикә» (1992) романы (рус теленә тәрҗемәсе «Сююмбике», 2001) Казан ханлыгының соңгы патшабикәсе Сөембикәнең фаҗигале язмышын сурәтләүгә багышланган. Коръән аятьләренең татарча тәфсирен әзерләп бастыра (2000). Әдәбият, сәнгать, милли-сәяси проблемаларга караган публицистик мәкаләләре б-н матбугатта даими басылып килә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2006) лауреаты.

Ә с ә р.: Серле сандык. К., 1983; Сөембикә. К., 1992; Кылдан нечкә, кылычтан үткен. К., 1996; Прости меня, мама! М., 1981.

*Әд.:* Ф ә т т а х Н. Беренче китап һәм балалар әдәбияты // Казан утлары. 1967. № 9; Ә х м ә д у л л и н А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; Х а т и п о в Ф., Тынгысыз җан // Казан утлары. 2008. № 3.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**БАТЫ́ЕВ** Салих Гыйлемхан улы (24.11.1911, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Дөмәй а. — 7.12.1985, Казан), дәүләт эшлеклесе. Казан финанс-икътисад ин-тында укый (1930–33), ВКП(б) ҮК каршындагы югары партия мәктәбен тәмамлый (1950). 1930–31 елларда ВКП(б)ның Башкортстан АССР Бакалы райкомында пропагандист. 1933–36 да Актаныш МТСында сәяси бүлек башлыгының комсомол эше буенча ярдәмчесе, ВЛКСМ-ның Арча райкомы секретаре һәм Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире. 1937–43 тә Казан химия-технол. ин-ты рабфагында укытучы, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында лектор, ТАССР Җир эшләре халык комис-тының сәяси секторы башлыгы урынбасары булып эшли. 1943–47 дә ТАССР МС рәисе урынбасары. 1951–60 та КПСС-ның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 2 нче секретаре, бер үк вакытта КПСС ҮК каршындагы Казан югары партия мәктәбендә партия һәм совет төзелеше каф. мөдире (1957). 1960–83 тә ТАССР ЮС Президиумы рәисе, РСФСР ЮС Президиумы рәисе урынбасары. ТАССР (1947–51, 1955–85), СССР (1958–66), РСФСР (1967–80) ЮС-лары депутаты. Хезмәтләре ТАССРда милли дәүләт төзелеше тарихына карый. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казанда Б. яшәгән йортка мемориаль такта куелган (2006).



С.Г.Батыев.

Х е з м.: Географическая характеристика административных районов Татарской АССР. К., 1972; Татарская АССР: реальность и буржуазные мифы. К., 1977 (автордаш).

**БАТЫ́ЕВА** Эльвира Салих кызы (31.10.1940, Казан), химик, химия фән. д-ры (1978), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994), ТССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 1995). Казан ун-тын (1964) тәмамлый. 1965 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, проф. (1985), 1981–91 дә директор урынбасары, 1989–90 да директор вазифаларын башкаручы, 1991 дән күкертле фосфорорганик кушылмалар лаб. мөдире, 2002 дән баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре фосфор-, күкерт-, азоторганик кушылмалар химиясенә карый. Өчвалентлы фосфор — элемент (азот, кислород, күкерт) бәйләнешенең органик кушылмаларны фосфорлаштыру реакцияләрендә өзелүенең төп закончалыкларын ачыклый, шул реакцияләр б-н идарә итү (кислоталы катализ) ысулларын тәкъдим итә һәм фосфорорганик кушылмаларның максатчан синтезын гамәлгә ашыра. Фосфорның тиол чыгарылмалары химиясендә яңа фәнни юнәлешләрне өйрәнә. Аның тарафыннан синтезланган органик кушылмалар арасында вируска каршы, үсүне көйләүгә, иммунитетны стимуллаштыруга тәэсир итә торган физиол. актив матдәләр, ш.у. авиация сәнәгатендә майлау-суыту материалларына күпфункцияле кушылдыклар сыйфатында файдаланыла торган продуктлар табыла. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Алкилтиоалкилфосфонат. Новый путь синтеза // Докл. АН СССР. 1987. Т. 292, № 2 (автордаш); О разрыве связи P-S в реакциях производных кислот трёхвалентного фосфора // Докл. АН СССР. 1988. Т. 303, № 3 (автордаш); Химия тиопроизводных кислот трёхвалентного фосфора. М., 1990 (автордаш); Синтезы на основе элементного фосфора, серы и их производных // Изв. РАН. Сер. хим. 1993. № 10; Substitution and Addition Reactions in the series of Thioderivatives of Trivalent Phosphorus Acids // Chemistry of Organophosphorus Compounds. M., 1989 (автордаш.).

*Әд.:* Академия наук Республики Татарстан: Справ. К., 2002.

**БАТЫ́Й ЙОРТЫ́ ТАМГАСЫ́**, ике җәпле сәнәк шәкелендәге нәсел тамгасы. Монгол империясе каганнары Мәнгу (1251–58) һәм Арык Буга (1260–64) исеменнән Болгарда сугылган акчаларга төшерелгән.

**БАТЫ́Й ХАН** (Бату, Саин хан) (1207 тирәсе, Монголия — 1256, Сарай әл-Мәхрусә ш.), монгол җиһангиры, Алтын Урда дәүләтен нигезләүче. *Чыңгыз хан* оныгы, *Җүчи* улы. Атасы вафатыннан соң, 1227 елдан аның олысы идарәчесе. 1227 һәм 1229 елларда узган Бөтенмонгол корылтаенда Җүчи ыругы баш-

лыгы һәм Монгол империясенең Көнчыгыш Европа тарафына яу б-н барачак гаскәр башлыгы буларак раслана. 1229 елда Б.х. гаскәрләре Көньяк Урал б-н Идел аръягы төбәкләренә бәреп керә, кыпчаклар б-н саксиннарны тар-мар итеп, җиңүгә ирешә. 1232 дә монголлар Идел буе Болгарына һөҗүм итәләр, ләкин Биләр шәһәре янында җитди каршылыкка очрыйлар. 1235 елдагы бөтенмонгол корылтаенда бөек каган Үгэдэй Б.х.ны Көнбатыш тарафка яу б-н барачак берләштерелгән монгол гаскәренең башлыгы итеп куя. 1236–37 елларда Б.х. җитәкләгән гаскәр кыпчакларны буйсындыра, Саксинны, Идел буе Болгарын (1237), төньяк-көнчыгыштагы һәм көньяк-көнбатыштагы рус кенәзлекләрен яулап ала (1237–40); аннары Венгрия, Польша, Чехия, Болгария җирләренә басып керә (1240–42) (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*). 1241 ел ахырында Б.х. Идел буена әйләнеп кайта, яңа яуланган биләмәләрдә ныклы идарә тәртипләре урнаштыруга керешә. Атасының бертуганы Чагатай вафатыннан соң (1242), Б.х. Чыңгыз нәселенең иң күренекле идарәчесе санала. 1242–56 елларда ул Җүчи олысының Җаек елгасыннан Көнбатышка кадәрге өлеше идарәчесе. Баштарак Болгар шәһәрендә торып идарә итә, шунда Җүчиләрнең беренче акчаларын суктыра. Аннары 13 йөзнең урталарыннан Иделнең түбән агымында Алтын Урда дәүләтенең башкаласы Сарай әл-Мәхрусә шәһәрен төзетә. Б.х. Җүчи олысын 2 канатка — *Ак Урда* һәм *Күк Урдага* бүлә. Күк Урда б-н Җүчинең өлкән улы Урда-Эҗен (Иҗен) һәм аның варислары идарә итә. Б.х. яңа яуланган җирләрдә ясак җыюны оештыра (к. *Урда салымы*), болгар бәкләре һәм рус кенәзләренә үз биләмәләрендә идарә итү ярлыклары бирүне тәртипкә сала. 1251 елда Монгол империясе каганы тәхетенә туганнан туганы Мөнкене утыртуга булышлык итә һәм аңа фактик идарәдәш була; Чагатай олысы б-н дә алар бүлешеп идарә итәләр. Б.х. рус кенәзләренең өстенлек өчен барган үзара көрәшләренә тыкшына, бернichә вак кенәзлекне берләштерүче бөек кенәз ярлыгын Ярослав кенәз уллары Александр б-н Андрейга алмаш-тилмәш биргәләп, аларның тәхет алмашуын тәэмин итү өчен еш кына Хурумшаны гаскәр б-н җибәреп тора. Б.х. католиклар дине башлыгы Рим папасы, әрмән кенәз-патшалары, сәлҗүк төркиләре солтаннары һ.б. ил-өлкә башлыклары б-н илчелек мөнәсәбәтләре урнаштыра. Һөнәрчелек үсешенә һәм сәүдәгә, Идел буе төбәкләрендә шәһәрләр төзелешенә зур әһәмият бирә. Аның тарафыннан Алтын Урданың мөстәкыйль һәм көчле дәүләт булып ныгуына төпле нигез салына.

Чыг.: Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. М.–Л., 1941. Т. 1, ч. 2; Путешествия в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957; Полное собрание русских летописей. М., 1997. Т. 1–2.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Б а р т о л ь д В.В. Батый // Соч. М., 1968. Т. 5; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; ш у л у к. Смерть хана Бату и династическая смута в Золотой Орде в освещении восточных и русских источников (источниковедческие заметки) // Средневековые древности Волго-Камья. Йошкар-Ола, 1992; В е р н а д с к и й Г.В. Монголы и Русь. М.-Тверь, 1997; S p u l e r B. Die Goldene Horde. Die Mongolen in Russland. Lpz., 1943.

*И.Л.Измайлов.*

**БАТЫ́Р**, борынгы төркиләрдә һәм урта гасырларда оста сугышчыга бирелә торган мактаулы исем, титул. Ул дәрәҗәгә һәркем үзе ирешкән, нәселдән килмәгән. Б. атамасы фарсы телендәге баһадур сүзеннән үзгәртелгән дип уйланыла. Төрки каганлыкларда, Чыңгыз хан варислары дәүләтләрендә, татар ханлыкларында һ.б. төрки дәүләтләрдә Б. уртакул аксөякләр титулы. Алар арасыннан югары дәрәҗәле аксөякләр дә чыккан. Соңрак Б. исем кушымтасы (Батыргәрәй) яисә шәхси исем буларак кулланыла (Батырша). Б. татар һ.б. төрки халыклар авыз иҗатында героик эпос-дастаннарның, әкиятләрнең төп каһарманнарының берсе.

*Әд.:* Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Ж и р м у н с к и й В.М. Тюркский героический эпос. Л., 1974; Л и п е ц Р.С. Образы Батыра и его коня в тюркско-монгольском эпосе. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**БАТЫ́Р** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 13 *км* көньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 21 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 92, 1949 да — 103, 1958 дә — 81, 1970 тә — 41, 1979 да — 26, 1989 да — 28 кеше.

**БАТЫ́Р** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 12 *км* төньяктарак, Бөгелмә Зәе елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 283 кеше (татарлар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. 1930 елларда нигез салына. Нигезләнгән вакыттан Бөгелмә р-ны составында. Халык саны: 1938 дә — 169, 1949 да — 198, 1958 дә — 163, 1970 тә — 160, 1979 да — 157, 1989 да — 250 кеше.

**БА́ТЫР** Владимир Викентьевич (17.7.1907, Киев — 4.10.1957, Казан), географ, география фән. канд. (1934). Казан ун-тын тәмамлый (1930). 1931–35 елларда «Камстрой» трестында баш инженер урынбасары, Кама елгасы һәм аның зур кушылдыкларында ГЭС төзелеше өчен плотиналар коруның геол. һәм геоморфологик шартларын тикшерә. 1935 тән Казан ун-тында. Хезмәтләре суффозия процессларына, яр буе сөзәклекләренең морфологиясе һәм динамикасын өйрәнүгә карый. Урта Иделнең яр буе зонасы һәм яр буе сөзәклекләре төзелеше һәм формасына генетик аңлатма бирә. Казан тирәсе күлләренең күл казанлыгы морфологиясен һәм темп-ра режимын, Вятка увалының көньяк өлешендәге түбән Казан утырмалары җир асты суларын тасвирлый. Елгаларның озынлыгын үлчәү методикасын төзи. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Природа Татарии. К., 1947 (автордаш); Рельеф Татарии. К., 1951 (автордаш).

*Әд.:* Д у г л а в В.А. Потери науки: Памяти Владимира Викентьевича Батыра // Изв. Всесоюз. геогр. об-ва. 1958. № 5.

**БАТЫ́Р АТЫ́**, күп кенә Шәрекъ халыкларының мифология, фольклор һәм язма әдәбиятында популяр булган персонаж; шулай ук язмыш символы буларак гәүдәләнә. Ул тугрылыклы ярдәмче, эпик геройның яклаучысы, җитезлекне, уңышлылыкны сурәтли, баһадирны башка дөньяга күчерә ала. Б.а. атларны ияләштергән вакыттан бирле (безнең эрага кадәр мең ел элек) күп кенә халыкларның тотемик хайваны буларак күзалланган. Оча торган атлар турында (*Тулпар*) риваятьләр татарлар арасында да таралган.

Б.а. образының килеп чыгышы Һава (Алтай эпосы «Алтын Бизе»), су асты (тат.-башк. риваятьләре «Акбүзат», «Урал батыр» һ.б.) һәм җир асты (*«Йиртөшлек»*) патшалыклары б-н бәйле. Б.а. баһадирның үткәнен, бүгенге көнен һәм киләчәген белә, аңа янаган куркыныч хәлләр турында искәртә, үлемнән коткара яки үлгәннән соң терелтә. Ләкин баһадир аны башта табарга һәм үзенә буйсындырырга тиеш. Б.а.н җир астыннан табу, күбесенчә, ата-бабаларга табыну б-н бәйле. Аерым очракларда Б.а. үлгән атаның үз каберен саклаучы иң кечкенә улына бүләге булып тора. Төрки-татар героик эпосында баһадирның һәм аның атының бер вакытта туу мотивы (урта гасырларда килеп чыккан) киң таралган. Алар бер-берсеннән башка яши алмаганга күрә, бербөтен булып китәләр кебек. Б.а.ны шул рәвешле тасвирлау төрле арттыруларга корылган. Бу уңайдан, аеруча илаһи чыгышы б-н билгеле һәм асыл сыйфатларга ия булган ак ат макталган.

*Әд.:* П р о п п В.Я. Исторические корни волшебной сказки. Л., 1946; Б е о в у л ь ф . Старшая Эдда. Песнь о Нибелунгах. М., 1975; Авеста в русских переводах (1861–1996). СПб., 1997; Р а к И.В. Мифы древнего и раннесредневекового Ирана. Зороастрийская мифология. СПб., 1998; Семира и Веташ В. Астрология и мифология. СПб., 1998.

*Ф.И.Урманчеев.*

**БАТЫ́Р РАЙОНЫ́**, *Чуаш Республикасында* 1927 елның 1 октябрендә оештырыла. Мәйданы — 943 *км²*. Үзәге — Батыр авылы (Чабаксардан 133 *км* көньяктарак). Халкы — 41,8 мең кеше (2002). Татарлар саны: 1989 да — 10365, 1997 дә — 9506, 2002 дә — 10602 кеше. Татар авыллары: Шыгырдан (Чкалово), Татар Согыты, Кыр Бикшиге, Озын Куак (Долгий Остров), Кызыл Чишмә, Кызыл Камыш, Татар Тимәше, Кече Шыгырдан, Яңа Чепкас; Имәнкисәге (Именево) авылында — чуашлар б-н, район үзәгендә чуашлар, руслар б-н бергәләп яшиләр. Б. р.на татарлар килүе (йомышлы мишәрләр) 16 йөзнең 2 нче яртысында Гөбенә һәм Тәтеш – Темников чик буе ныгытмаларын төзү б-н бәйле. Татар авыллары арасында иң борынгылары: Шыгырдан, Татар Согыты (16 йөз ахыры — 17 йөз башы), Татар Тимәше (1629), Кыр Бикшиге (1650 еллар). Б. р.ндагы авыллар элек мәчетләрнең күп булуы б-н аерылып торган. 1920 елларда Шыгырдан авылында 8, Татар Согытында 3, Кыр Бикшиге авылында 3, Кызыл Чишмәдә (элек Мачар (Начар) Үби дип аталган) 2, Озын Куак авылында 2, Татар

Тимәшендә 1 мәчет булган. Мәчетләр каршында мәдрәсәләр һәм мәктәпләр (иң борынгылары — Шыгырдан авылында, 18 йөздән мәгълүм) эшләгән. Хәзерге вакытта Шыгырданда 4, Озын Куакта 2, Кыр Бикшигендә 2, Татар Согыты, Кызыл Камыш, Татар Тимәше авылларында берәр мәчет эшли. Шыгырдан авылында Чуаш Респ-касы мөселманнарының Диния нәзарәте бинасы урнашкан. Районда «21 гасыр» Татар яшьләре үзәге (Батыр а.; 1999 дан), «Ак Барс» СК (Шыгырдан а.; 1996 дан) эшли. Татар телендә «Авангард» (1952 дән), «Умырзая» (1999 дан), «Вакыт» (1996 дан) г-талары нәшер ителә. Б. р.нда Советлар Союзы Герое Б.С.*Рәхимов* (Озын Куак а.), РФАнең хакыйкый әгъзасы Х.М.*Миначев* (Кыр Бикшиге а.), РМАнең хакыйкый әгъзасы Р.Х.*Шәкуров* (Озын Куак а.), драматург Ф.З.*Бурнаш* (Кыр Бикшиге а.), биол. фән. д-ры Р.А.*Абзалов* (Кызыл Чишмә а.) һ.б. туган.

**БАТЫ́Р-БОЛГАРИ́** (Батыркаева) Луиза Миңнегали кызы (14.8.1953, Свердлов өлкәсенең Арамиль р-ны Бобровка а.), композитор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2006). 1978 елда Казан консерваториясенең композиция классын тәмамлый; Ю.В.Виноградов шәкерте. 1981–93 тә Татарстан китап нәшриятында муз. әдәбият редакторы булып эшли. Иҗатында төп урынны җырлар һәм театр музыкасы, симф. һәм камера-инструменталь әсәрләр алып тора. «Мин сине шундый сагындым» (Ф.Зыятдинова шигыре), «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Кайту» (М.Галиев шигырьләре), «Син бит татар кешесе» (Г.Рәхим шигыре) җырлары аеруча киң танылa. Балалар һәм үсмерләр, төрле яшьтәге аудитория өчен язылган әсәрләре югары эстетик таләпләрне үтә сиземләве б-н аерылып тора. Алар пед., җыр концертларында һәм инструменталь репертуарларда киң файдаланыла. Зур популярлык казанган мюзикллары, муз. комедияләре: «Әйдә барыйк — кызлар карыйк», «Эх, машина-машина» (Р.Вәлиев пьесалары, 1990), «Сихерле урман» (Р.Мингалим пьесасы, 1991), «Бардым күлгә, салдым кармак» (Р.Корбанов пьесасы, 1996) һ.б. Композиторның әсәрләре «Кайту» (1991), «Җырлап узган җәй» (1992), «Яшьлегем канатында» (1993) граммофон дискларында; «Төнге карлар», «Әгәр күзләремә син карасаң», «Туган телдә җырлыйбыз» (1996) аудиокассеталарында; «Якты моңнар» (1988), «Хәрефле шакмаклар» (1997), «Сайра, моңлы сандугач» (2000) исемле ноталы җыентыкларда һ.б. тупланган.

Ә с ә р.: Концерты для скрипки с оркестром (1978), фортепиано с оркестром (юношеский) (1985), Соната для фортепиано (1982), музыка к драм. спектаклям, инструментальные пьесы для фортепиано, скрипки для детей, хоровые произведения, песни и др.

*Әд.:* З а й н е т д и н о в Г. Моң — күңел ачкычы // Азат хатын. 1983. № 3; Ю с у п о в а Р. Сусау // Азат хатын. 1989. № 6.

*Ф.Ш.Салитова.*

**БАТЫРМОРЗА́ЕВ** Зәйнелгабид Нухай улы (1897, хәзерге Дагстан Респ-касы Аксай а. — 8.10.1919, шунда ук, Батайорт а.) кумык язучысы, публицист. Язучы Нухай *Батырморзаевның* улы. Б.ның шәхес булып формалашуына Исхак исемле татар мөгаллиме көчле йогынты ясый, аның киңәше б-н Б. Әстерхан һәм Казан мәдрәсәләрендә укый. Б.ның 1916–17 елларда язылган «Мәдрәсәгә мулла килде», «Муллаларга үч итеп», «Шамхал нүкәре» пьесаларында, «Даниялбәк» драмасында иске карашлар фаш ителә, тау халыкларында яшәп килгән кан үче, байлыгына карап кыз ярәшү кебек гадәтләр, социаль гаделсезлек тәнкыйтьләнә. Драматург Бууларак, Г.Камал иҗаты тәэсирендә формалаша. Туган авылында һәм Әстерханда укыган елларында аның «Бәхетсез егет», «Беренче театр» пьесалары буенча куелган спектакльләрдә уйнавы, соңрак драматургның «Гашыйк», «Безнең шәһәрнең серләре» пьесаларын кумык теленә тәрҗемә итүе мәгълүм. Б. инициативасы б-н «Безнең шәһәрнең серләре» тәрҗемәсе 1918 дә Тимерхан-Шура шәһәре (хәзерге Дагстан Респ-касындагы Буйнак ш.) театры сәхнәсендә уйнала. Шигъри иҗатында («Халыкка», «Халык мәнфәгатен яклаучыга» һ.б. шигырьләр) Г.Тукай поэзиясенең тәэсире сизелә. Б.ның татар шагыйре С.Сүнчәләй шигырьләре турында язган кульязма рецензиясе саклана.

*Әд.:* А л и е в С. Дорога в современность. Махачкала, 1977; А к б и е в С.-М.Х. Связи времён и дружба литератур. Махачкала, 1985.

*Р.К.Ганиева.*

**БАТЫРМОРЗА́ЕВ** Нухай (1869, хәзерге Дагстан Респ-касы Аксай а. — 8.10.1919, шунда ук, Батайорт а.), кумык язучысы, мәгърифәтче, кумык реалистик прозасына нигез салучы, җәмәгать эшлеклесе. Гарәпчә, татарча башлангыч белемне атасыннан ала. Мәдрәсә тәмамлагач мөгаллимлек итә, аннары зәркәнче булып эшли. 1905–07 елларда Әстерхан, Оренбург, Казан шәһәрләрендә яши. Оренбургта «Вакыт» г-тасы редакциясендә, Казанда Кәримовләр матбагасында эшли, «Казан мөхбире» г-тасында языша. 1916–17 дә улы Зәйнелгабид б-н бергә Хәсәүйорт авылында «Таңчулпан» дигән әдәби-драматик түгәрәк оештыра һәм шул исемдә журнал чыгара. «Языкъ Габибатъ» («Бәхетсез Хәбибәт», 1910), «Гарун булан Зубайдат, яда Насипсиз Җанбике» («Һарун белән Зөбәйдә, яки Бәхетсез Җанбикә», 1912), «Давут булан Лайла» («Даут белән Ләйлә», 1914) исемле повестьлар авторы. Аларның татар мәгърифәтчеләре М.Акъегетзадә, З.Бигиев, Р.Фәхретдин, З.Һади әсәрләре йогынтысында язылуы мәгълүм. «Кавказ һәм бөтен Русиядәге хәлләр» поэмасында Г.Тукай поэзиясенең тәэсире нык сизелә. Б. әсәрләрендә татар язучыларын да тирән борчыган милли мәгариф, мөселман хатын-кызларның хокукый хәле мәсьәләләре күтәрелә. Большевиклар б-н элемтә тоткан өчен Б. улы Зәйнелгабид б-н бергә деникинчылар тарафыннан атып үтерелә.

Ә с ә р.: Б а т ы р м у р з а е в Н. Давут булан Лайла. Махачкала, 1965.

*Әд.:* Г а н и е в а Р. Уртак кояшыбыз // Казан утлары. 1966. № 4; Д а ц и е в А. Нухай Батырмурзаев. Махачкала, 1968; А л и е в С. Дорога в современность. Махачкала, 1977; А к б и е в С.-М.Х. Нухай Батырмурзаев и татарские просветители // Связь времён и дружба литератур. Махачкала, 1985.

*Р.К.Ганиева.*

**БАТЫ́РОВ** Равил (Роальд) Исмәгыйль улы (4.10.1931), кинорежиссёр, Үзбәкстан ССРның халык артисты (1977). 1952 елда Ташкент театр-сәнгать ин-тын тәмамлый, аннан соң Югары режиссёрлар курсында укый (Мәскәү). 1963 тә А.Хачатуров б-н берлектә «Синең эзләр» («Твои следы») дигән беренче фильмын төшерә. «Канатта йөрүчеләр» («Канатоходцы», 1965), «26 нчыга атмаска!» («В 26-го не стрелять!», 1967), «Кырык беренче ел алмалары» («Яблоки сорок первого года», 1969), «Сине көтәбез, егет» («Ждем тебя, парень», 1972), «Минем шәфкатьле кешем» («Мой добрый человек», 1973), «Онытылмас җыр» («Незабытая песня», 1974), «Менә дигән хыялый» («Великолепный мечтатель», 1977), «Мәхәббәт һәм ярсу» («Любовь и ярость», Ж.Ристич б-н берлектә; Югославия, 1978), «Менә кайтты бу егет» («Вот вернулся этот парень», 1982) фильмнарын куя. Б. фильмнарының күпчелек геройлары — аның замандашлары, гамәлгә ашмастай хыялларга бирелмичә, лаеклы яшәргә омтылучы гади егетләр. Тормышның асылын аңлатырга тырышып, режиссёр геройларының характерын көндәлек мәшәкатьләр аша ача. Б. фильмнары бөтенсоюз экраннарында күрсәтелә, тамашачылар һәм кино белгечләре тарафыннан югары бәяләнә.

*Әд.:* А б д у л л а е в А., М у х а м е д о в С. Пятьдесят лет узбекского кино. Таш., 1976; Кино: Энцикл. словарь. М., 1986.

**БАТЫРША́** (Галиев Габдулла) (1710 яки 1715, Казан губ., Уфа өязе Карыш а. — 24.7.1762, Шлиссельбург крепосте), 1755–56 елларда татар-башкортларның баш күтәрүләрен оештыручы (к. *Батырша хәрәкәте*). Казан губернасының Уфа өязе Тайсуган авылы (хәзер Әлмәт р-нына керә) һәм Казан өязе Ташкичү мәдрәсәләрендә укый. 1744–45 елларда Оренбург губернасы Илша, 1746–49 да Мөслим авыллары мәдрәсәләре мөгаллиме, 1749–55 тә Карыш авылы мәчете имамы һәм мәдрәсә мөдәррисе. Халык арасында абруе зур була. 1754 тә Себер даругасы ахуны итеп сайлана, ләкин ул вазифаны үтәргә керешми. 1755 елның мартында, баш күтәрүгә хәзерлек чарасы буларак, Урал төбәгендә яшәүче татар, башкорт һ.б. халыкларны коралы көрәшкә күтәрелергә чакырып мөрәҗәгать итә. Б. патша хакимиятенең колониаль сәясәте б-н килешми, мөселманнарны төрлечә кысрыклауга, салымнарның күплегенә, үзидарә мөмкинлекләренең чикләнгәнлегенә каршы чыга. Хәрби хезмәткә бармаска, хакимият йөкләмәләрен үтәмәскә, мөселманнар яшәгән җирләрдә заводлар, кальгалар төзүгә каршылык күрсәтергә, бердәм булырга өнди. Баш күтәрүче мөселманнарга башка мөселман дәүләтләре дә ярдәм кулы сузар дип өметләнә. Императрица Елизавета Петровнага халык кузгалышларын булдырмас өчен, мөселманнар тормышының авырлыкларын бетереп, аларга карата гадел карар-хөкемнәрне торгызу кирәклеге турында хат яза. 1755 елның 1 сентябрендә Б. гаиләсе һәм шәкертләре б-н Карыш авылын таш-

лап китә; байтак вакыт эзәрлекләүләрдән качып йөри. 1756 елның 8 августында Уса даругасы Әҗәк авылында кулга алына, башта гаиләсе б-н Уфага, аннары Оренбург шәһәренә озатыла. Сенат карары нигезендә Б. көчәйтелгән сак астында Оренбургтан Самара-Арзамас-Муром-Владимир-Мәскәү аша С.-Петербургка Яшерен канцеляриягә кителә. 1758 дә Шлиссельбург крепостена ябылуга хөкем ителә. 1762 нең 24 июль төнендә аннан качарга тырыша һәм төрмә сакчылары б-н бәрелештә үтерелә. Башкортстан Респ-касының Балтач р-ны Иске Балтач авылында Б. музее оештырылган, шул авылдагы мәчеткә аның исеме бирелгән. Б. образы Җ.Рәхимовның «Батырша» исемле тарихи романында гәүдәләндерелгән. Ш.у.к. *Батырша хаты.*

*Әд.:* Алишев С.Х. Каһарман бабайлар. К., 1976; шул ук. Батыршаның батырлыгы // Казан утлары. 1986. № 2; шул ук. Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. II половина XVI — XIX вв.) К., 1999; Витевский В.Н. И.И.Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г. К., 1897. Т. 3; Чулошников А.П. Восстание в 1755 г. в Башкирии. М.–Л., 1940; Ислаев Ф.Г. Восстание Батырши. 1755: Ист. очерк. К., 2005; Валиуллин И.Р. Батырша (Абдулла Галиев) // Татарские интеллектуалы: исторические портреты. К., 2005.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БАТЫРША́ ХАТЫ́**, тарихи төрки язма ядкәр, императрица Елизавета Петровнага атап язылган. Борынгы документларны барлау Россия дәүләт архивында берничә исемлектә саклана. Беренче мәртәбә тулысынча 1993 елда Уфада нәшер ителә. Батырша ул хатны Мәскәү төрмәсендә 1756 елның 4–24 ноябрь көннәрендә язган, халык кузгалышының сәбәпләрен аңлаткан (к. *Батырша хәрәкәте*). Батырша ул хатында үз тормышын, халык кузгалышына китергән хәлләрне һәм хәрәкәт барышын бәян итә. Җирле хакимият вәкилләре һәм урындагы гаскәри командаларның башбаштаклыгын сурәтләгән мисаллар китерә, мәхкәмә оешмаларының гаделсезлеген, рус булмаган халыкларны көчләп чукындыруларын фаш итә, ясак түләүне бетерү һәм казнадан мәҗбүри тоз сатып алу хакында 1754 елның 16 мартында игълан ителгән Сенат фәрманы б-н халыкның риза булмавын күрсәтә. Хатта Батырша вөҗдан иреге, диннәргә тигез караш, бер илдә яшәүче халыкларның тигез хокуклы булырга тиешлеге турында мәсьәләләр күтәрә. Б.х. халык әйтемнәре, риваятьләр, мәкальләр кулланып язылуы, монолог, әңгәмә, бәхәс рәвешләре б-н төрләнүе җәһәтеннән дә гыйбрәтле. Б.х. татар халкының тарихы һәм мәдәнияте өчен кыйммәтле язма чыганак булып тора.

Хезм.: Батырша (Габдулла Алиев). Гарызнамә // Мирас. 2000. № 11–12; 2001. № 1; Письмо Батырши императрице Елизавете Петровне. Уфа, 1993.

*Әд.:* Батыршаның патшага язган хаты // Татар әдәбияты тарихы. 1984. Т. 1; Хусаинов Г.Б. Письмо Батырши императрице Елизавете Петровне как историко-литературный источник // Южноуральский археографический сборник. Уфа, 1973. Вып. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БАТЫРША́ ХӘРӘКӘТЕ́**, 1755–56 елларда Оренбург губернасы Нугай һәм Уса даругалары (хәзер Башкортстан Респ-касына керә) татар-башкортларының патша хакимиятенә каршы баш күтәрүе. Социаль-икътисади изүнең көчәюенә, милли-дини кысуларга каршы юнәлтелгән. Сенатның 1754 елның 16 мартындагы фәрманы бу хәрәкәт башланып китүгә төп сәбәпче булган. Фәрман нигезендә ясак түләү бетерелгән, бар халык та тозны казнадан сатып алырга тиеш булган (ул түләнәсе ясак б-н чагыштырганда кыйммәткәрәк төшкән). Хәрәкәтне оештыручы *Батырша* була, ул халыкны ризасызлык белдерергә, корал алып баш күтәрергә чакыра. 1755 елның 15 маенда башлап Нугай даругасы Бөрҗән волосте халкы күтәрелә: җир асты байлыкларын барлау-тикшерү партиясе башлыгы Брагин үтерелә, Сапсал почта станы талана, дәүләти әһәмияткә ия Исәт трактында хәрәкәт туктатыла. Халык күтәрелешен бастыру өчен хөкүмәт Бөрҗән волостена җәза отряды җибәрә; башлап йөрүчеләр кулга алына, җирле идарәчеләрдән старшина һәм сотниклар алыштырыла. Шул елның 8–9 августларында Бөрҗән төбәге халкы яңадан баш күтәрә, яңа билгеләнгән старшина А.Баһапов үтерелә. Озакламый аларга Тангаур, Үсәргән, Бошмас-Кыпчак һ.б. волость кешеләре дә кушыла; Сапсал һәм Баракал почта-ям станцияләре талана, Покровск з-ды яндырыла, башка заводлар һәм почта-ям станнары эшчәнлеге тоткарлана. Җәлаир кальгасыннан Әбҗән-Петровск з-дына җибәрелгән капитан Шпак отрядын баш күтәрүчеләр 18 августта тар-мар итә. 27 августта Уса даругасы Гәйнә волосте авыллары да Б.х.нә кушыла. Ләкин җирле башкорт феодал-старшиналарның каршылыгы, хәрәкәтнең абруйлы җитәкчеләре булмау сәбәпле, Уса даругасы халкы күтәрелеше ныгып китә алмый. Нугай даругасында Б.х. 1756 елның яз айларына кадәр дәвам итә. Халык ризасызлыгын киметү теләге б-н патша хөкүмәте баш күтәрүчеләрнең аерым таләпләрен үтәргә ниятләвен, үз ихтыярлары б-н көрәштән баш тартучыларга җәза кулланылмаячагын белдерә. Б.х.нә Казакъ ханлыгының чик буе өлкәләреннән ярдәм килмәсен өчен, губернатор И.И.Неплюев тарафыннан аерым чаралар күрелә. Идел буе татарлары да Б.х.нә кушылмасын өчен хакимият вәкилләре керәшеннәр б-н бер авылда яшәгән мөселман татарларны авылларыннан күчерми торырга һәм керәшеннәр урынына мөселманнарны хәрби хезмәткә алу тәртибен туктатырга карар кылалар. Мөселманнарга кагылышлы дини мәсьәләләрне карау-тикшерү эше дә, рус руханилары кулыннан алынып, губерна канцеляриясенә тапшырыла. Архиепископ Лука (Конашевич) Казаннан башка шәһәргә күчерелә. 1756 елда мәчетләр төзүгә рөхсәт бирелә.

*Әд.:* Алишев С.Х. Каһарман бабайлар. К., 1976; шул ук. Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. II половина XVI — XIX вв.). К., 1999; Витевский В.А. И.И.Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г. К., 1897, Т. 3; Чулошников А.П. Восстание 1755 г. в Башкирии. М.–Л., 1940; Ислаев Ф.Г. Восстание Батырши. 1755: Ист. очерк. К., 2005.

*И.Р.Вәлиуллин.*



Г.Ә. Батыршин.

**БАТЫ́РШИН** Гыйльфан Әбүбәкер улы (1914, Харьков губ., Голубовка бистәсе, хәзерге Украина Респ-касы Кировск ш., — 11.12.1947), Сов. Союзы Герое (25.10.1938), майор (1945). Лисичанск тау сәнәгате техникумын (Ворошиловград өлкәсе), кече командирлар мәктәбен (1936), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1941, Мәскәү) тәмамлый. 1931–32 елларда «Пишмаш» з-дында (Казан) эшли. 1936 дан Кызыл Армиядә. Посьетск чик сакчылары отрядының манёврлы төркемендә отделение командиры, Хәсән күле янында япон милитаристлары б-н бәрелешләрдә (1938) катнаша. 1938 нең 1 августында Заозёрный биеклеген алу өчен барган бәрелештә батырлык күрсәтә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, Көнбатыш фронтта тылны саклаучы чик буе подразделениесенең отделение командиры. Сугыштан соң Совет Армиясендә командирлык вазифаларын башкара. 1947 дә Токиода Япония хәрбиләрен хөкем итү мәхкәмәсе утырышларында катнаша. Шуннан кайтышлый авиация һәлакәтендә һәлак була. Ленин, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләре б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Рәкыйпов Ш.Җ. Таңнар һаман матурмы? К., 1999; Батырлар китабы — Книга героев. К., 2000; Герои Хасана. М., 1939; Богданов В.Н., Попов В.Т. Золотые звёзды дальневосточных пограничников. Хабаровск, 1968; Кузнецов И.И., Джога И.М. Первые Герои Советского Союза (1936–1939). Иркутск, 1983.

**БАТЫ́РШИН** Илдар Закирҗан улы (16.9.1952, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1975 елда Мәскәү физ.-техника ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан технол. ун-тында эшли, 1998 дән информатика һәм гамәли матем. каф. мөдире. Бер үк вакытта 1999 дан ТР ФАнең Информатика проблемалары ин-тында. Хезмәтләре ясалма интеллектка карый. Анык булмаган охшашлык бәйләнеше нигезендә кластерлап анализлау алгоритмнарының гомуми схемасын тәкъдим итә, химик технол. мәсьәләләре өчен эксперт системалары сүрүен эшли (авторлаш). О.Кайнак (Төркия), И.Рудаш (Венгрия) б-н берлектә һәм А.А.Бикбулатов (Россия) катнашында «йомшак исәпләүләрнең» анекланып бетмәгән оптималь модельләрен төзү буенча яңа юнәлеш тәкъдим итә.

Хезм.: Нечёткие множества в моделях управления и искусственного интеллекта. М., 1986 (авторлаш); Основные операции нечёткой логики и их обобщение. К., 2001.



Н.Х. Батыршин.

**БАТЫ́РШИН** Ирек Гариф улы (13.6.1926, Аксубай р-ны Яңа Ибрай а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1984). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1964–75 тә Аксубай р-ның «Үсәр» к-зын җитәкли, 1978–86 да Югары Ослан р-ның «Луч Октября» с-зы директоры. Б. җитәкчелек иткән елларда «Үсәр» к-зында бөртекле культураларның уңышы 7 *ц* дан 25 *ц* га күтәрелә, аларның кайбер төрләреннән 75 *ц* га кадәр рекордлы югары уңыш алына. Бер сыердан уртача еллык савым 1000 *кг* нан (1964) 3200 *кг* га җитә. Терлекчелек фермалары, а.х. техникасын ремонтлау мастерскойлары, ярдәмче пр-тиеләр, социаль-көнкүреш объектлары төзелә. Колхоз алдынгы тәҗрибә өйрәнү базасына әверелә. Октябрь Революциясе, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БАТЫ́РШИН** Нәкый Хурамша улы (11.4.1932, Башкортстан АССРның Эстәрлебаш р-ны Айдарәле а. — 28.5.2002, Казан) төзүче-инженер, Соц. Хезмәт Герое (1966). Казан пед. (1959) һәм Казакъ политехника (1969) ин-тларын тәмамлый. 1956–71 елларда Казакъстан ССРның Кустанай өлкәсе Соколово-Сарбай тау мәгъдәнен баету комб-тында өлкән прораб, 1971–92 дә «Татагропромстрой» трестының 245 нче механикалаштырылган күчмә колоннасында баш инженер, башлык була. Герой исеме кап. төзелешнең җидееллык (1959–65) планы йөкләмәләрен үтәүдә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**БАТЫ́РШИНА** Светлана Васильевна (17.6.1953, Пермь ш.), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (2001), Свердловск мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), Свердловск тире һәм венерик авырулар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 2002 елдан Казан мед. академиясенең дерматовенерология каф. профессоры. Хезмәтләре эпидемиология, йогышлы җенси авырулар клиникасы һәм диагностикасына карый; дәвалау программалары эшли. Б. тарафыннан урогениталь юлларда хламидия йогышлы авыруларына диагноз кую һәм дәвалау ысуллары (1992, 1998), репродуктив функцияләре бозылган хатын-кызларның урогениталь юлларында хламидия йогышлы авыруларын дәвалау ысуллары (1998) тәкъдим ителә. Уйлап табуга 7 таныклыгы бар.

Х е з м.: Урогенитальный хламидиоз и репродуктивное здоровье женщин: Лечение и реабилитация. К., 2000.

**БАУЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ыкның сул кушылдыгы. Озынлыгы 15,9 *км*, бассейнының мәйданы 101,5 *км*$^2$. Баулы р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Якты Күл авылының төньяк читендә, тамагы Кызылъяр авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 270 *м*, тамагыныкы — 106 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 28%. Б. елгасының 1 дән алып 7 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,19 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–3 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 84 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. Елга буенда шул исемдәге шәһәр урнашкан.

**БАУЛЫ́**, республика карамагындагы шәһәр, Баулы р-ны үзәге. ТРның көньяк-көнчыгыш чигендә урнашкан. Казаннан 369 *км* ераклыкта, Ык елгасының сул кушылдыгы Баулы суы буенда, Ульянов — Уфа тимер юлының Бөгелмә станциясеннән 35 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Б. аша Оренбург автомобиль юлы уза. 2006 елда — 22,9 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 67%, руслар — 21,7%, чуашлар — 4,4%) яши. «Баулынефть» НГДУ, «Татойлгаз» ябык АҖ ф-лы, «Ленагрострой» төзү материаллары комб-ты, җылылык һәм эл. челтәре, «Намус» көнкүреш хезмәте күрсәтү пр-тиеләре, икмәк, сөт з-длары, «Мирас» халык һөнәрләре ф-касы, типография бар. 6 урта һәм 1 музыка мәктәбе, һөнәри лицей; төбәк тарихын өйрәнү музее, 2 мәдәният йорты, 4 китапхanә, ш.и. 2 ф-лы булган балалар үзәк китапханәсе эшли. 2 мәчет. 1755 тә нигез салына.



Баулы шәһәре. М. Җәлил исем. мәдәният йорты.

18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет, 4 су тегермәне була; авыл җәмәгатенең имана җире 3402 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Б. Самара губернасының Бөгелмә өязе Баулы волосте үзәге була. 1920 дән — ТАССРның



Баулы шәһәре. «Гали» мәчете.

Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы р-ны үзәге, 1950 нең 11 гыйнварыннан — шәһәр тибындагы посёлок, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә шәһәр советы карамагында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан район үзәге, 1997 нең 18 сентябреннән — шәһәр. Халык саны: 1795 тә — 168 ир заты; 1859 да — 853, 1897 дә — 1524, 1920 дә — 2047, 1926 да — 1825, 1938 дә — 1855, 1949 да — 3640, 1970 тә — 14,1, 1979 да — 14,6, 1989 да — 20 мең кеше.




Баулы шәһәре. Гомуми күренеш.

**БАУЛЫ́ НЕ́ФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, Татарстанда иң эреләрдән санала, республиканың көньяк-көнчыгышында Баулы р-ны терр-ясендә урнашкан. 1944 елда ачыла. Төп ятма (девон) 1946 да 1 нче скважинаны бораулау нәтиҗәсендә табыла. Бу скважинадан тәүлеккә 300 *т* нефть бирә торган фонтан бәреп чыга. 1950 дән «Баулынефть» НГДУы тарафыннан эшкәртелә. Тектоник яктан Б.н.ч. Татар гөмбәзе Көньяк күтәрелмәсенең Баулы-Туймазы өелмәсенә туры килә. Чыганак күп катлы, күп катламлы. Гөмбәз б-н капланган һәм күп күләмдәге нефтьле 12 ятма булуы ачыкланган. Сәнәгый нефть ятмалары түбән карбон (Алексин һәм Бобрики горизонтлары, Турне ярусы), урта (Иске Оскол һәм Живе яруслары) һәм югары (Пашия горизонты) девон утырмаларында. Баланс запасларының 77,9 %ы терриген (Бобрики һәм Пашия горизонтлары), 20% ы — карбонатлы (башлыча, Турне ярусы) коллекторларда тупланган. Коллектор катламнарның гомуми калынлыгы 2,5–30 *м*. Файдалы катламнар 1199 *м* дан 1858 *м* га кадәрге тирәнлектә ята. Коллекторларның сыйдырышлылыгы (ачык күзәнәклелеге) 11,4–23,1%, фильтрация характеристикасы (үтүчәнлеге) 0,031–0,917 *мкм*$^2$, нефтькә туенганлыгы 0,662–0,878. Газ факторы 15–64 *м*$^3$/*т*, катлам басымы 11,3–17,5 *МПа*, темп-расы 22–35 °С, нефть дебиты тәүлеккә 0,3 тән алып 500 тоннага кадәр. Нефть составында күкерт (югары девонныкы уртача күкертле), парафин, сумалалар күп. Иң күп нефть алуга 1957 дә ирешелә һәм 1962 гә кадәр шул дәрәҗә саклана. 1960 еллар башына кадәр катламның башлангыч басымы югары булу һәм үз вакытында катламга су кертү нефтьне төп $Д_1$ горизонтыннан фонтан ысулы б-н алуны тәэмин итә. 2007 нең беренче гыйнварына 100 млн. тоннадан артык нефть алына. Б.н.ч. — илдә беренчеләрдән булып контур буйлап су кудыру системасы кулланылган чыганак. 1960–90 елларда, дөнья практикасында беренче буларак, скважиналар челтәре тыгызлыгы ятманың нәтиҗәлелегенә һәм нефть бирүчәнлеге коэф. ясаган тәэсирен өйрәнү буенча сәнәгый тәҗрибә уздырыла, нәтиҗәдә скважиналар санын азайтып нефть чыгару күләмен саклап калу мөмкинлеге күрсәтелә. Терриген коллекторларны эффектив (нефть бирүчәнлекне 45% ка җиткереп) эшкәртү проблемасы хәл ителә. Б.н.ч.нда файдалы катламнарга физик-химик тәэсир итү технологиясе буенча (ш.и. циклды тәэсир технологиясе тирәнтен өйрәнелә һәм сынау үтә) һөнәри сынаулар үткәрелә. Катламның забой буе зонасына йогынты ясауның төрле ысуллары сынала.

*Әд.:* Муслимов Р.Х., Абдулмазитов Р.Г. Геологическое строение и разработка Бавлинского нефтяного месторождения. М., 1996.

*Э.З.Бадамшин, Г.Г.Емельянова.*

**БАУЛЫ́ РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк-көнчыгышында урнашкан, Башкортстан Респ-касы һәм Оренбург өлкәсе б-н чиктәш. Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы иктысади р-нына керә. Мәйданы — 1214,2 *км*$^2$. 13 авыл җирлеген, 40 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Баулы шәһәре. Халкы — 2006 елда 14,6 мең кеше (район үзәгендәге халык саның кертмичә), 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57,9%, руслар — 17,4%, чуашлар — 9,3%, удмуртлар — 11,2%. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*$^2$ га 12 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Самара губернасының Бөгелмә өязенә, 1920–30 елларда ТАССРның Бөгелмә кантонына керә. Оештырылган вакытта Б.р.на 43 авыл советы, 116 торак пункт кергән, аларда 51805 кеше яшәгән



БАУЛЫ РАЙОНЫ
1:1 000 000

(ш.и. татарлар 30889, руслар — 11114, башка халыклар — 9802). Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1138 *км*$^2$, халкы — 32 мең кеше, 21 авыл советы, 72 торак пункт исәпләнә. 1960 та район 1131,3 *км*$^2$ мәйдан били, аңа 1 посёлок советы, 11 авыл советы, 65 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февраленнән Б.р. таркатыла, биләмәсе Бөгелмә р-нына бирелә. 1965 нең 12 гыйнварында яңадан торгызыла, мәйданы — 1950 *км*$^2$, халкы — 70,3 мең кеше, 2 посёлок советын, 20 авыл советын, 119 торак пунктны берләштерә. 1991 нең 6 апрелендә район составыннан Ютазы р-ны бүлеп чыгарыла. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль район дип үзгәртелә. Б.р. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы чикләрендә урнашкан. Биеклеге 90 — 340 *м* га кадәр. Район терр-ясеннән Ык, аның кушылдыклары Югары Кандыз, Кандыз, Дим һ.б. елгалар ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, карбонатлы, типик кара туфраклы. Терр-ясенең 16,5% урманлык. Нефть, газ, известьташ, доломит, ком-чуерташ катнашмасы, балчык ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: Ык һәм Дим елгалары, *Салих тавы* ботаника табигать истәлеге, *Бөгелмә аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә 30 дан артык археол. истәлек билгеле. Алар, нигездә, бронза гасырына карый. А.х. җирләре 75,5 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр 53,9 мең *га* тәшкил итә (2006). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, карабодай игелә. Ит-сөт терлекчелеге, сарык асрау алга киткән. 2006 елга районда 13 а.х. оешмасы, 60 фермер хуҗалыгы исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә туплана; Александровка авылында спирт з-ды, «Дим» балык үрчетү хуҗалыгы, урман хуҗалыгы эшли. Б.р. терр-ясеннән Казан–Оренбург, Самара–Чиләбе, Баулы–Азнакай автомобиль юллары уза. Районда 27 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 4755 укучы), ш.и. 2 башлангыч, 6 тулы булмаган урта, 19 урта мәктәп; балалар сәнгать, 2 балалар-үсмерләр мәктәпләре, 16 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе (1500 бала), 25 клуб, 28 китапханә, 346 урынлы 2 хастаханә, төбәк тарихын өйрәнү музее эшли. Татар һәм рус телләрендә «Хезмәткә дан» — «Слава труду» район г-талары нәшер ителә.

**БАУЛЫ́ СЕ́РИЯСЕ**, югары протерозой (рифей һәм венд) тау токымнары комплексы. Татарстан терр-ясендә кристаллик нигезнең батынкы урыннарында (авлакогеннарда) ята. Атамасы 1945 елда М.Ф.Микрюков һәм А.Я.Виссарионова тарафыннан Баулы шәһәре исеменнән чыгып бирелгән. Б.с. кызыл төстәге карбонатлы-балчыклы комсыл токымнардан барлыкка килгән түбән Баулы (рифей) комплексына һәм башлыча балчыклы-комлы токымнардан гыйбарәт булган югары Баулы (венд) свитасына бүленә. Абсолют яше 1650–570 млн ел. Калынлыгы 3 *км* дан артык. Сериянең төп ике бүлекчәсе барлыкка килү вакытлары б-н бер-берсеннән аерылып тору сәбәпле, «Б.с.» атамасы 1960 еллардан кулланылмый башлый.

**БАУЛЫ́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, 1990 елның 1 сентябрендә ТРның Милли музее филиалы буларак ачыла. 2007 елдан муниципаль музей. 2 катлы аерым бинада урнашкан. Экспозиция мәйданы — 420 *м*$^2$. Коллекция 5641 саклау берәмлеген тәшкил итә. Башта күргәзмәләр залына районның пр-тиеләр тарихына караган материаллар һәм сынлы сәнгать әсәрләре куела. 1996 елда район тарихына багышланган экспозиция, 1997 дә төбәк табигате бүлеге ачыла. Музейда Баулы нефтен үзләштерү турында зур документаль коллекция тупланган, ш.у. нефтьчеләр, Бөек Ватан сугышында катнашкан якташлар; язучылардан Р.Мостафин, Ф.Яруллин, М.Хәбибуллин, Р.Әхмәтҗанов һ.б. турында материаллар бар. Музей ел саен Халыкара музейлар (18 май) һәм Белем көннәрен (1 сент.) уздыра.

**БАУЛЫ́ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Баулы һәм Бөгелмә р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда оештырыла (1947–49 һәм 1984–87 елларда Бөгелмә урман хуҗалыгы составында). 2006 елның 1 гыйнварына урман фондының гомуми мәйданы 22741 *га*. 2 урманчылыктан гыйбарәт: Баулы — 11190 *га* һәм Кандыз — 11551 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Баулы шәһәрендә. Эшләүчеләр саны 164 кеше.

1 нче төркем урманнар 13866 *га* мәйданны били, ш.и. яшел зона урманнары — 4211 *га*; 2 нче төркем файдаланыла торган урманнар — 8875 *га*. Урман фонды мәйданының урманлы өлеше 20602 *га*, ш.и. ылыслы агач токымнары 3747 *га* (18,2%), каты яфраклылар — 4311 *га* (20,9%), йомшак яфраклылар 12544 *га* (60,9%) тәшкил итә. Урман хасил

итүче төп токымнар: каен (34,6%), усак (19,5%), имән (14,6%), нарат (14,4%), юкә (6%), өрәңге (5%); сирәк кенә чыршы, карагай, кара зирек һ.б. очрый. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшьләре (30,9%), урта яшьтәгеләре (34,8%), өлгереп килүчеләре (13,9%), өлгергәннәре (18,6%). Урман культуралары 4006 *га* мәйданны тәшкил итә. Б.у.х.нда агачның гомуми запасы 2553 мең $м^3$ тәшкил итә; ылыслылар — 482,5 мең $м^3$ (18,9%), каты яфраклылар — 339,7 мең $м^3$ (13,3%), йомшак яфраклы токымнар 1730,8 мең $м^3$ (67,8%) чамасы. Агачның уртача еллык артымы 66,6 мең $м^3$, ш.и. ылыслы агач токымнары хисабына 14,4 мең $м^3$ билгеләнә. Төп кулланылышы өчен урман кисүнең еллык нормасы 39,9мең $м^3$ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан чистарту эшләре 650 *га* мәйданда башкарыла, шуның б-н бергә 7 мең $м^3$ чамасы эшкә яраклы агач әзерләнә. 160 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла. Ике урман питомнигында утырту материалы — нарат, чыршы, имән, каен, карагай агачлары һәм куаклык токымнары чәчкеннәре үстерелә.

**«БАУЛЫНЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть-газ чыгару идарәсе (НГДУ), нефть һәм газ сәнәгате объектларын төзү һәм файдалану, нефть чыганакларын эшкәртү, нефть чыгару, әзерләү һәм сату б-н шөгыльләнә. Баулы шәһәрендә урнашкан. 1967 кеше эшли (2005). 1947 елда «Туймазынефть» тресты составында эре Баулынефть промыселы буларак оештырыла. 1950 дә аның җирлегендә «Б.» тресты төзелә, 1970 тә НГДУ итеп үзгәртелә. Аның составында 4 нефть һәм газ чыгару цехы, катламнардагы басымны нормада тоту цехы, 7 җитештерү базасына хезмәт күрсәтү цехы, технол. транспорт идарәсе керә. Укыту курслары комб-ты, ял базасы, санаторий-профилакторий эшли. Баулы чыганагының югары продукцияле девон ятмаларын эшкәртү, шуннан соң югары горизонт ятмаларына кертү, ш.у. ТРның Баулы, Бөгелмә, Ютазы р-ннарындагы һәм Оренбург өлкәсенең Төньяк һәм Абдуллин р-ннарында урнашкан 118 ятманы берләштергән 2256 $км^2$ га якын мәйдандагы нефть чыганакларын эшкәртү б-н шөгыльләнә. 1946 да Баулы, 1974 тә Сабанчы, 1968 дә Татар Кандызы, 1974 тә Ромашкино (көньяк мәйдан), 1995 тә Матросов нефть чыганаклары сафка кертелә. Барысы да күп катламлы, күп ятмалы. Күпчелек ятмалар катлам басымын нормада тотып эшкәртелә. Моңа кудыру скважиналарына контур тирәли һәм контур эченә су тутыру юлы белән ирешелә. Нефть бирүчәнлеген арттыру өчен катламнарга һәм скважиналарның забой яны зонасына тәэсир итүнең алдынгы ысуллары кулланыла: физ.-хим., геол.-физ., гидродинамик. Чыгарылган еллык нефтьнең 26% ы шушы ысулга туры килә. Нефть чыгаруда иң югары дәрәҗәгә (4198 мең *т*) 1981 дә ирешелә. 2006 ның 1 гыйнварына барлыгы 166,5 млн. *т* нефть чыгарыла. 2005 елга кадәр 3468 скважина бораулана, шуларның 1600 файдаланыла (насос б-н). Чыгарылган продукциянең сулылык дәрәҗәсе 82%. Нефть әзерләү комплекслы җайланмада алып барыла. Продукциянең әзерлек дәрәҗәсе — 99,8%. Парафин утырымына каршы көрәштә, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыруда заманча ысуллар киң файдаланыла, югары җитештерүчәнлекле үзәктән кугыч эл. насослары, су тутыру һәм сыеклык җыюның оптималь технологиясе, нефть промыселларын комплекслы автоматлаштыру һәм телемеханикалаштыру, җиһазларны тутыгудан комплекслы саклау һ.б. алымнар кулланыла. Бу тармакта беренче булып скважинадан нефть һәм газ җыю һәм җибәрүнең автоматлаштырылган системасы гамәлгә кертелә. «Б.» НГДУында табигатьне саклауга: әчә торган суның сыйфатын яхшыртуга, зарарланган җирләрне яңадан торгызуга, әйләнә-тирә мохиткә килгән техноген зыянны киметүгә юнәлтелгән чаралар уздыруга аеруча әһәмият бирелә.




Девон нефтен ачкан 1 нче номерлы скважина.

«Б.» НГДУында эшләүче күп кенә хезмәткәрләр хөкүмәт бүләкләренә лаек була: 7 кеше — Ленин, 4 кеше — Октябрь Революциясе орденнары, 2 кеше — Дәүләт премиясе б-н бүләкләнә, 31 кешегә «ТРның атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирелә. «Б.» НГДУ җитәкчеләре: А.Д.Обносов (1950–52), Р.Ш.Мингәрәев (1952–55), А.И.Горюнов (1955–62), А.А.Захаров (1962–65), А.П.Аширов (1965–67), Ә.К.Мөхәммәтҗанов (1967–71), И.В.Саблин (1971–81), Н.И.Хисаметдинов (1981–84), Г.Г.Ганиев (1984 тән).

*Әд.:* Путь в полвека. Альметьевск, 1996; Экспериментальная разработка Бавлинского месторождения // Нефтяное хоз-во. 1996. № 12.

*Г.И.Йосыпова.*

**БА́УМАН** Николай Эрнестович (псевд. Грач) (17.5.1873, Казан — 18.10.1905, Мәскәү), революцион хәрәкәт эшлеклесе. Казандагы ир балалар гимназиясенең 6 сыйныфын (1891) һәм Казан вет. ин-тын (1895) тәмамлый. 1889 елда А.М.Стопани б-н бергә марксистик түгәрәк оештыра (к. *Стопанинның социал-демократлар төркеме*). 1892 дә Казан эшчеләренең беренче маёвкасын, вет. ин-ты студентларының яшерен китапханәсен, 1889–95 тә Казанда марксистик түгәрәкләр оештыручыларның берсе. 1893 тән Б. жандармерия идарәсе күзәтүенә алына. Институтны тәмамлаганнан соң, Саратов губернасында вет. табибе булып эшли. 1896 ның октябреннән С.-Петербургта яши, «Эшчеләр сыйныфын азат итү өчен көрәш берлеге» төркемена керә. 1897 ның мартында кулга алына, 1899 ның гыйнварында Вятка губернасының Орлов шәһәренә 4 елга сөргенгә җибәрелә. Аннан чит илгә качып китә. Женевада Россия с.-д.ның «Хезмәтне азат итү» оешмасы сафында. 1900 нең июленнән «Искра» г-тасын нәшер итү һәм тарату эшендә катнаша. «Искра»-ның бүлекчәсен оештыру нияте б-н 1900 нең декабрендә Мәскәүгә җибәрелә. 1902 нең 12 февралендә Киевтә кулга алына, 18 августта Луганск шәһәре төрмәсеннән кача. Сентябрьдә полиция эзәрлекләвеннән качып чит илгә китә. Социал-демократлар партиясенең Брюссельдә башланып, Лондонда дәвам иткән 2 нче съездын әзерләү эшендә катнаша (1903). Шул ук елда Россиягә кайта, РСДРПның Мәскәү ком-ты һәм ҮКнең Төньяк бюросы җитәкчесе була (1903–04). 1904 нең 19 июнендә Мәскәүдә кулга алына, 1905 нең 8 октябрендә азат ителә. Большевиклар оештырган демонстрация вакытында, 18 октябрьдә карагруһчылар тарафыннан үтерелә.



Н.Э. Бауман.

*Әд.:* Новосёлов М.А. Николай Эрнестович Бауман. 1873–1905. М., 1955; Долгий В.Г. Книга о счастливом человеке. М., 1972; Н.Э.Бауман в Казани (1873–1973). К., 1973; Власов П., Скворцов В. Имя, звучащее набатом. К., 1990.

**БА́ХАРЕВ** Вениамин Александрович (19.10.1908, Казан губ., Спас ш. — 10.10.1987, Казан), гидротехник, техник фән. д-ры (1973), проф. (1961), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1969). 1940 елда Мәскәү гидромелиорация ин-тын тәмамлый. 1951 елдан Казан төзүче-инженерлар ин-тында, 1956–61, 1965–83 тә гидравлика һәм санитария техникасы каф. мөдире, 1961–65 тә проректор. Бер үк вакытта 1951–60 та ВЦСПСның хезмәтне саклау Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Хезмәтләре ачык җирдәге сыеклыкларның турбулент (өермәле) агымы гидродинамикасына карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Основы проектирования и расчёт отопления и вентиляции с сосредоточенным выпуском воздуха. М., 1958 (автордаш.); Отопление и вентиляция животноводческих помещений. К., 1964 (автордаш.).

**БАХИ́ТОВ** (Вахитов) Мансур Һидиятулла улы (15.5.1935, Чүпрәле р-ны ЯңаЧүпрәле а. — 23.12.1986, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1985). 1958 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук (1961 дән) пластмассалар технологиясе кафедрасында эшли, 1985 тән каф. мөдире, бер үк вакытта полимерлар ф-ты деканы (1982 дән). Хезмәтләре изоцианат олигомерлары химиясенә карый. Изоцианатларның өч валентлы фосфор кушылмалары катнашында циклик полимерлашуының төп закончалыкларын өйрәнә. 2, 4-толуилендиизоцианатның циклик димерлашуы һәм 1,6-гексаметилендиизоцианатның олигомерлашу алымнарын эшли (сәнәгатьтә кулланыла). Югары термик чыдамлы полиуретаннар синтезлауны гамәлгә ашыра. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Каталитическое превращение изоцианатов в карбодиимиды // Журн. общ. химии. 1974. Т. 44, вып. 4 (автордаш); Исследование циклополимеризации 2,4-толуилендиизоцианата в присутствии триэтил- и триизопропилфосфитов // Высокомолекулярные соединения. 1980. Т. 22В, № 7 (автордаш); Исследование полимеризации 1,6-гексаметилендиизоцианата в присутствии гексаметилтриамидофосфита // Высокомолекулярные соединения. 1981. Т. 23В, № 9 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БАХМЕ́ТЕВ** Алексей Николаевич (1774, Пенза губ., Инсар өязе Рождественский а. — 15.9.1841, Подольск губ., Ямпольск өязе Липовка Тимаковский а.), дәүләт эшлеклесе, инфантерия (пехота) генералы (1823). Борынгы татар дворяннары нәселеннән. 1790 елдан хәрби хезмәттә, рус-швед (1790), рус-француз (1805), рус-төрек (1806–10) һәм Ватан (1812) сугышларында катнаша. 1814–20 елларда Подольскида генерал-губернатор, бер үк вакытта 1816–20 дә Бессарабия өлкәсе наместнигы. 1825–28 дә Казан,



А.Н. Бахметев.

Түбән Новгород, Сембер, Саратов һәм Пенза губерналары ген.-губернаторы. Гомумграждандлык эшләрен башкаручы губернаторлар һәм дәүләт оешмалары өстеннән күзәтчелек итә, эш башында торучыларның җинаятьчел гамәлләрен кисәтә. Мәс., түрәләрнең *лашманнарга* карата эшләнгән җәбер-золымын тикшертә. Кабул ителгән христиан дине кагыйдәләренә буйсынмаучы секталар (мәс., раскольниклар) һәм чукындырылгач яңадан мөселман диненә кайтучылар б-н катгый көрәш чараларын кертүдә актив катнаша. Уку-укыту йортларын үз химаясенә ала; Казан ун-тын тәэсклендерүгә ярдәм итә. Аның заманында Адмиралтейство конторасы Казаннан Әстерхан шәһәренә күчерелә (1826). 1826 ның 27 ноябрендә элекке Казан уку-укыту округы җитәкчесе М.Л. Магницкийны кулга алырга һәм Ревель шәһәренә сөргенгә җибәрергә әмер бирә. 1828 дән Россиянең Дәүләт Советы әгъзасы, Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1826). Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М и х а й л о в с к и й - Д а н и л е в с к и й А.И. Император Александр I и его сподвижники. СПб., 1845. Вып. 40; П е т р о в П.Н. История родов русского дворянства. М., 1991. Кн. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**БАХМЕ́ТЬЕВ** Владимир Матвеевич (14.8.1885, Воронеж губ., Землянск ш. — 16.10.1963, Мәскәү), язучы, публицист. Землянск шәһәрендә өяз уч-щесен тәмамлый (1904). Сәяси эчтәлекле беренче шигырь һәм хикәяләрен 1905 елда «Красный лапоть» (Землянск ш.) ж-лында Уржатский һәм Матвеич псевд. б-н бастыра. 1908 дә революцион эшчәнлеге өчен Барнаул шәһәренә сөргенгә җибәрелә, анда «Алтайское дело», «Обская жизнь» г-таларында хезмәттәшлек итә, «Сибирская новь» г-тасының мөхәррире була. 1915 тә сугышка каршы агитацион әдәбият таратканы өчен кулга алына. Февр. рев-циясеннән соң Томск шәһәр думасында мәгариф бүлеге мөдире. Б.ның башкала матбугатында М.П.Арцыбашев, Б.В.Савинков, Д.С.Мережковский, Ф.К.Сологуб иҗатларына критик реализм күзлегеннән чыгып фикер йөрткән мәкаләләре басыла. Окт. рев-циясеннән соң Б. РКП(б)ның Томск губкомы һәм губерна башкарма ком-ты әгъзасы, Көнбатыш Себер уку-укыту округы комиссары, «Сибирский рабочий» г-тасы мөхәррире. 1919 ның октябреннән Б. эшчәнлеге Казан б-н бәйле: «Знамя революции», бер үк вакытта (1920 ел башыннан) «Деревенские думы» г-талары мөхәррире. 1921 елның мартында РКП(б)ның 10 съездында, милли мәсьәлә буенча комиссия составына керүче бер төркем ТАССР делегатлары б-н бергә, Б. та В.И.Ленин б-н очрашуда, татар әдәбияты һәм матбугаты үсеше мәсьәләләре хакында барган фикер алышуда катнаша. 1920 еллар башында Казан сәхнәсендә уңыш казанган «Таң атканда» («На заре») пьесасының төп герое Казан губерна башкарма ком-ты рәисе И.И.Ходоровский тормышыннан алып язылган «Бер төн» («Одна ночь») хикәясе авторы. 1921 нең октябреннән Мәскәүдә «Пролетарский авангард» һәм «Красная новь» ж-ллары мөхәррире. Бөек Ватан сугышы башлану б-н Б. Казанга күчеп килә һәм СССР Язучылар берлеге Президиумы әгъзасы буларак (1934 тән), Мәскәүдән эвакуацияләнгән язучыларны урнаштыру эшенә җитәкчелек итә. Казан вакытлы матбугатында Б.ның сов. сугышчылары һәм тыл хезмәткәрләренең фидакарьлеген сурәтләгән хикәяләре басыла. Сов. сугышчылары арасындагы хыянәтчелек һәм дезертирлык очракларын тәнкыйтьләгән «Сөйрәлүчеләр нәселеннән»(«Из породы ползучих», «Красная Татария», 1942, 14 гыйн.) мәкаләсе көчле яңгыраш таба. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 3 т. М., 1926–28; Избр. произведения: В 2 т. М., 1957.

*Әд.:* Л и т в и н А. Бахметьев Владимир Матвеевич // Борцы за счастье народное. К., 1967; К л и м е н т о в с к и й В. В.М.Бахметьев // Русские писатели в Татарии. К., 1974.

*К.Н.Куранов.*

**БА́ХМУТОВА** Елена Константиновна (5.6.1897, Пермь губ., Екатеринбург өязе Кочнево а. — 17.2.1957, Казан), тел галиме. Ленинград ун-тын (1924), Ленинград Шәрекъ телләре ин-тын (1926) тәмамлый. 1938 елдан Казан пед. ин-тында. 1940 тан Казан ун-тында, 1945 тән рус теле һәм гомуми тел белеме каф. мөдире. Түбән Кама буеның югары зонасындагы Вятка һәм Владимир-Идел буе сөйләшләренең таралышын өйрәнә. Хезмәтләре Идел буендагы рус сөйләшләренә, Мәскәү дәүләтенең эш телендәге фарсы алынмаларына карый.

*Әд.:* Памяти Е.К.Бахмутовой // Уч. зап. Казан. ун-та. 1961. Т. 121, кн. 3; Библиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета. 1905–1963. К., 1965. Вып. 2.

**БАХРУ́ШИН** Сергей Владимирович (26.9.1882, Мәскәү — 8.3.1950, шунда ук), тарихчы, тарих фән. д-ры (1942), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1939), РСФСР ПФА академигы (1945), Үзбәкстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1943). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1904). В.О.Ключевский шәкерте. 1909 елдан Мәскәү ун-ты приват-доценты, проф. (1927). Бер үк вакытта 1937 дән СССР ФАнең Тарих ин-тында, СССРның 19 йөзгә кадәрге тарихы секторы мөдире (1940 тан). Төп хезмәтләре Россиянең феодализм дәверендәге социаль-икътисади үсеше мәсьәләләренә һәм эчке сәясәтенә, Себернең руслар тарафыннан колонизацияләнүенә, тарихи чыганакларны өйрәнүгә, фән тарихына, тарихи географиягә карый. Татарстан тарихын фән буларак формалаштыруга өлеш кертә: татар җәмгыятендә феодаль мөнәсәбәтләр үсешен өйрәнә, Рус дәүләтенең Алтын Урда һәм Казан ханлыгы б-н үзара бәйләнешләрына кагылышлы мәсьәләләрне тикшерә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1942).

Х е з м.: Очерки по истории колонизации Сибири в XVI–XVII вв. М., 1927; Ясак в Сибири в XVII в. М., 1927; Сибирские служилые татары. М., 1937; Иван Грозный. М., 1942; Научные труды: В 4 т. М., 1952–59.

*Әд.:* Проблемы социально-экономической истории феодальной России. М., 1984; Д у б р о в с к и й А.М. С.В.Бахрушин и его время. М., 1992.

*Е.Б.Долгов.*


**БАХТА́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 22 *км* көньяктарак, Олы Бахта елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 313 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1724 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Степная Кондрата, Баганы исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 4 он тарту һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1102 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 78 ир заты; 1859 да — 596, 1897 дә — 656, 1908 дә — 759, 1920 дә — 977, 1926 да — 990, 1938 дә — 769, 1949 да — 662, 1958 дә — 598, 1970 тә — 538, 1979 да — 415, 1989 да — 273 кеше.



Ә.Б. Баһаветдинов.



Г.Ә. Баһаветдинов.



Г.Б. Баһаветдинов.

**БА́ХТИН** Анатолий Иосифович (25.12.1939, Казан), геолог-минералог, геол.-минералогия фән. д-ры (1982), проф. (1984). Казан ун-тын тәмамлый (1962). 1965 елдан шунда эшли. 1990 нан минералогия һәм петрография каф. мөдире. Чыганакларны эзләү, минераль чималның сыйфатын һәм технол. үзенчәлекләрен бәяләү өчен минералларны кристаллохимик анализлауның оптик-спектроскопик ысулларын уйлап таба. Токым хасил итә торган силикатлар төзелешенең кристаллохимик закончалыкларын билгели. 1996 дан РФАнең Бөтенроссия минералогия җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе.

Х е з м.: Породообразующие силикаты: оптические спектры, кристаллохимия, закономерности окраски, типоморфизм. К., 1985; Оптическая спектроскопия минералов и руд и её применение в геологоразведочных работах. К., 1992 (автордаш).

**БА́ХТИН** Иван Афанасьевич (5.10.1905, Мари Респ-касының Рус Шуе а. — 20.12.1989, Казан), икътисадчы, проф. (1966), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1965). 1939 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1941–44 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында партия эшендә. 1944–86 да Казан финанс-икътисад ин-тында укыта, 1951–1981 дә хуҗалык эшчәнлеген анализлау каф. мөдире. Хезмәтләре сәнәгать һәм төзелеш пр-тиеләрендә икътисади анализлау методикасын камилләштерүгә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анализ хозяйственной деятельности строительной организации. М., 1968; Экономический анализ промышленных предприятий. К., 1976.

**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Әнвәр Бәдретдин улы (27.11.1925, Тәтеш кантоны Әмәкәй а. — 25.10.2002, Казан), дәүләт эшлеклесе. Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1959). 1941–42 елларда ТАССРның Бондюг р-ны МТСында тракторчы булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша; 1950 елга кадәр Сов. Армиясендә хезмәт итә. 1950–51 дә ВЛКСМның Бондюг райкомының 2 нче секретаре. 1953–54 тә КПССның Бөгелмә райкомында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, 1954–57 дә шунда ук ТАССРның МТС зонасы буенча секретарь, 1957–60 та КПССның Бөгелмә шәһәр ком-ты секретаре, 1960–61 дә 2 нче секретаре, 1961–62 дә Азнакай райкомының 1 нче секретаре. 1962–65 елларда ТАССРның Әлмәт колхоз-совхоз җитештерү идарәсе парткомы секретаре. 1965–79 да КПССның Азнакай райкомы, 1979–83 тә Әлмәт шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. 1983–86 да ТАССР ЮС Президиумы рәисе һәм 1985–90 да РСФСР ЮС Президиумы рәисе урынбасары. ТАССР (1963–90), РСФСР (1985–90) ЮСлары депутаты. Ленин, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эффективность производства гречихи: Опыт колхозов и совхозов Азнакаевского р-на Татарской АССР. М., 1979 (автордаш).

*Әд.:* Ровесник века. К., 2001.

**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Гыйльми Әбләз улы (1923, ТАССРның Бөгелмә кантоны Сарабиккол а. — 19.3.1945, Польша), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, вафатыннан соң), сержант (1944). 1942 елдан Кызыл Армиядә. Шул ук елның маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 21 нче армиянең 381 нче укчы дивизиясе 1259 нчы укчы полкында пулемётчы. Көньяк-Көнбатыш, Сталинград, Көнбатыш, Ленинград һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Карелия муентыгындагы бәрелешләрдә һәм Ленинград сугышында (1942–44), Польшаны азат итүдә катнаша. 1944 нең 10 июнендә Карелия муентыгындагы бәрелештә батырлык күрсәтә. Данциг шәһәре (хәзер Польшаның Гданск ш.) янындагы бәрелештә һәлак була. Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. К., 1990; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963.

*В.А.Шагалов.*

**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Гыймаз Баһаветдин улы (11.12.1897, Бондюг пос., хәзерге Менделеев ш. — 10.5.1938), сәясәт эшлеклесе. Казан ун-тының физ-матем. ф-тын тәмамлый (1930). 1914–17 елларда Бондюг з-ды эшчесе. 1917 елда РСДРП(б) сафларына керә. 1918 дә Алабуга шәһәре янындагы сугышларда катнаша, Көнчыгыш фронтның 2 нче армия штабының сәяси бүлеге секретаре ярдәмчесе итеп билгеләнә. 1918–20 дә Казан шәһәр башкарма ком-ты әгъзасы һәм юстиция бүлеге мөдире, кассацион трибунал рәисе. 1921–22 дә ТАССРның юстиция халык комиссары, 1923–25 тә прокурор, 1926–28 дә ТАССР ҮБК Президиумы рәисе урынбасары һәм секретаре, 1928–30 да ТАССР ХКС рәисе урынбасары, эчке эшләр халык комиссары. 1930–31 дә Казан ун-ты, 1931–37 дә Казан химия-технол. ин-ты директоры. Хезмәтләре ТАССРның химия сәнәгатенә һәм юстиция тарихына карый. 1920–37 дә ТАССР ҮБК әгъзасы. Репрессияләр чоры корбаны (к. *«Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы» эше*). Үлгәннән соң аклана.


Х е з м.: Революционная законность в деревне и органы юстиции. Исправительно-трудовая политика Наркомата юстиции. К., 1925; Татария имеет все данные для мощного развёртывания химической промышленности // Красная Татария. 1931. 3 сент.

*Әд.:* З а л я л о в А. Богаутдинов Г.В. // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Минзаһит Зыяфетдин улы (10.12.1951, Әлмәт ш.), спортчы (самбо көрәше), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1974). Чиләбе физ. культура ин-тын тәмамлый (1978). «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә. Иң җиңел үлчәүдә (48 *кг* га кадәр) Европа (1974), СССР (1974) чемпионы, СССР кубогы иясе (1974, 1975, 1977, 1979), СССР чемпионатында көмеш медаль ала (1979), маршал В.К.Блюхер исем. призга үткәрелгән Бөтенсоюз турнирында (1975) һәм Бөтенсоюз студентлар уеннарында (1976) җиңүче. 1978 елдан Чиләбе һәм Әлмәт шәһәрләрендә укыту һәм тренерлык эшендә.

**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Наил Мансур улы (11.2.1962, Чаллы ш.), спортчы (автомобиль спорты), Россиянең халыкара класслы спорт остасы (1997), «Париж — Гранада — Дакар» ралли — марафонында җиңүче (1996, 1998), «Оптик-2000» (1997, Тунис), «Итальян Ба-







Р.М. Б а һ а в е т д и н о в. 1. «Спринт». «Сабан туе» сериясеннән. Акварель. 1978; 2. «Муса Җәлил». 1980; 3. «Ябырылу». «Татар эпосыннан» триптихының уң өлеше. 1989.

жа» (2000, Париж — Дакар — Каир) раллиларында алгы урынны ала. Ралли — марафоннар буенча РФ чемпионы (1997). 1979 елдан «КамАЗ» ачык АЖнең фәнни-техник үзәгендә (Чаллы ш.). Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Мой финиш — горизонт. Крань (Словения), 1998.

**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Рафаэль Мәхмүт улы (10.8.1931, Казан), график, нәкышьче. Казан сәнгать уч-щесен (1957), Киев сәнгать ин-тының графика ф-тын (1963) тәмамлый. Киевта яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1968). Китап графикасы һәм станлы графика өлкәсендә эшли, 200 дән артык китапны бизи һәм аларда рәсемнәрен урнаштыра. Алар арасында 50 томлы «Тарих укытучысы китапханәсе» («Библиотека учителя истории», тушь һәм каләм б-н ясалган рәсемнәр, Киев, 1965–73), М.Ауэзовның «Абай» («Абай», линогравюралар, Киев, 1972), Г.Скарлатоның «Мавыктыргыч география» («Занимательная география», тушь һәм каләм, Киев, 1974); С.Айниның «Партизанның үлеме» («Смерть партизана», акварель, Киев, 1978) китаплары бар. Б. — төсле һәм aклы-каралы линогравюра өлкәсендә танылган оста («Татар шагыйре Муса Җәлил», 1965; «Бөек юл этаплары», 1967; «Сабан туе», 1977, серияләре), офортны коры энә б-н («Т.Лось портреты», 1963), рәсемнәрне каләм һәм тушь б-н («КамАЗ төзелешендә яшьләр», 1976; «Латвия буйлап», 1978) башкара. 1973 елдан акварель техникасына мөрәҗәгать итә һәм тематик серияләр («КамАЗ төзелә», 1973, 1976; «Борынгы елъязмалар», 1982), триптихлар («Безнең аналар», 1974; «Хәтер», 1977), портретлар һәм символик — аллегорик эчтәлекле натюрмортлар иҗат итә.

Б. — Украинада күренекле рәссамнарның берсе; майлы буяу техникасы б-н эшли. Төп әсәрләре: «Муса Җәлил» (1980), «Шагыйрә С.Йовенко портреты» (1981), «Рәссам М.Врубельгә багышлау» (1982), «Спринт (Сабан туенда ярышу)» (1983), «Т.Шевченконың соңгы автопортреты» (1985), «Шагыйрә М.Цветаева» (1984), «Татар рәссамы Бакый Урманче» (1986), «Татар эпосыннан» (триптих: «Төрки амазонкалары», «Ак бүре эзләре буйлап», «Ябырылу», 1989; «Диканька янындагы хутор кичләре» сериясе, 1992–95) һ.б. Аларга эпик, монументаль образлылык, ачык характерлы типажлар, гадәти булмаган ракурслар, төсләр куллануда нәзакәтлелек хас. Нәкышь картиналарының пространство-пластик һәм композицион чишелешендә, Б.ка үзенә генә хас стилистика б-н беррәттән, киндердәге буяуны тырнап, фактуралы өслек хасил итү ысулы кулланылган графика һәм акварель эшләре б-н уртаклык күзәтелә.

Халыкара, Бөтенсоюз («Эстамп күргәзмәсе», Мәскәү, 1967; «Акварель күргәзмәсе», Мәскәү, 1978, 1981; «Туган илнең зәңгәр юллары», Мәскәү, 1979) һәм Украина Респ-касы (1963 тән) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре: Казанда (1986), Киевта (1985, 1991, 2007), С.-Петербургта (1996) була. Әсәрләре Дәүләт Рус (С.-Петербург), Киевтагы Т.Г.Шевченко, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музейларында, чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана. «Татнефть» ААҖ тарафыннан Украинаның мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре өчен оештырылган М.Җәлил исем. бүләк лауреаты (2007).

*Әд.:* Капелюшная Т. Украинский Рафаэль // Дуслык. 2006, № 11; Рафаель Багаутдінов. Графіка. Акварель. Живопись: Каталог виставки творів. Киів, 1985; Rafael Bagautdinov. Kiev, 1996.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Рифкать Шәйфетдин улы (31.7.1938, Мәскәү) монументаль бизәлеш сәнгате рәссамы, график, нәкышьче. В.Мухина исем. Ленинград югары сәнгать-сәнәгать уч-щесенең монументаль сәнгать бүлеген тәмамлый (1962), Г.А.Савинов, К.Л.Иогансен, А.А.Казанцевта укый. 1962–69 елларда Ульянов шәһәрендә яши, 1965 елдан шәһәрнең баш рәссамы булып эшли. 1969 дан Пермьдә яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1970). 1960–80 еллар монументаль бизәлеш сәнгате казанышларын чагылдырган күләмле әсәрләр (мозаика, дивар нәкыше, сграффито, сынчылык, рельеф) — С.-Петербургның Стачка мәйданындагы торак бина диварына ясалган «Революция» панносы, Пермьдә Ю.Гагарин исем. мәдәният сарае фасадындагы «Космос» рельефы һәм «Канатлы фәрештә» сыны, «Звезда» г-тасы редакциясе бинасы диварындагы рельеф һәм Гознак мәдәният сарае диварындагы декоратив композиция һ.б. авторы. Б. бер үк вакытта китап графикасы өлкәсендә дә уңышлы эшли, 40 тан артык китапны бизи, башлыча, Пермь язучылары Л.Давыдычев һәм К.Иванов басмаларын иллюстрацияли. Б.ның станлы рәсемнәрендә сов. дәүләте тарихындагы әһәмиятле вакыйгалар чагылыш таба, көчле рухлы һәм социаль яктан актив шәхесләрнең психол. образлары сурәтләнә. Аларга гомумиләштерелгән пластик форма, композиция төзелешендә тотрыклы логика, «кырыс» колорит хас. «Тимер дивизия» триптихы (1963–65), «Мәскәү, 1941» (1964), «Баш күтәрүчеләр» (1967), «Калий катламнарыннан» (1975) әсәрләре, «Н.Островский» (1966–67), «М.Җәлилнең көрәштәше Р.Хисаметдинов» (1974) портретлары — Б.нең аеруча мөһим әсәрләреннән санала. Чит илләрдә уздырылган күргәзмәләрдә («Яшьләр бьенналесы-5», Париж, 1967; «СССРның яшь рәссамнары», Берлин, Будапешт, Прага, 1967), бөтенсоюз («Тынычлык сагында», 1965; «Совет Россиясе», 1975; «Хезмәткә дан», 1976 һ.б.), төбәкара («Зур Идел», 1964, 1968; «Социалистик Урал», 1969, 1974 һәм «Зур Урал», 1978, 1998) күргәзмәләрендә катнаша.

*Әд.:* Камалов Я. Рифкать Баһаветдинов // Азат хатын. 1977. № 4; Орлова Е. Дворец на Каме // Художник. 1976. № 8; Толстой В.П. Монументальное искусство СССР. М., 1978; Рифкат Багаутдинов: Буклет. Пермь, 1979; Смирнова Н.И. Торец дома украшает город // На стройках России. 1985. № 8; Казаринова Н.В. Художники Перми. Л., 1987.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*


**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Фәрит Бәдретдин улы (15.9.1932, Кама Тамагы р-ны Әмәкәй а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1961). 1959–61 елларда ВЛКСМның Бондюг райкомы 1 нче секретаре. 1961–62 дә КПССның Бондюг райкомы пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, оештыру бүлеге мөдире. 1963–65 тә хезмәт ияләре депутатларының Алабуга шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1965–67 дә КПССның Алабуга шәһәр ком-тында оештыру бүлеге мөдире, 1967–70 тә Түбән Кама шәһәр ком-ты секретаре. 1970–79 да халык депутатларының Түбән Кама шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе. 1979–87 дә ТАССРның сәүдә министры. 1987–94 тә ТРның Бәяләр буенча дәүләт ком-ты рәисе. 1980–90 да ТАССР ЮС депутаты. Түбән Кама шәһәренең шәрәфле гражданы (1981). Хезмәт Кызыл Байрагы,








Р.Ш. Баһаветдинов. 1. «Тимер дивизия». Фрагмент. Темпера. 1965; 2. «Космос». Ю.А.Гагарин исем. мәдәният сарае бинасындагы фриз. (Пермь ш.). Корыч, электр белән эретеп ябыштыру. 1975; 3. «Икар». Ю.А.Гагарин исем. мәдәният сарае фасадындагы панно (Пермь ш.). Корыч, электр белән эретеп ябыштыру. 1975.



Г.М. Баһманов.



И.В. Баһманов.

ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БАҺАВЕТДИ́НОВА** (Богоудинова) Роза Закир кызы (1.3.1945, Украина ССРның Ворошиловград өлкәсе Красный Луч ш.) педагог, пед. фән. д-ры (1996), проф. (1997), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1963–77 елларда комсомол һәм партия эшендә, 1984–86 да Татарстан профсоюзлар өлкә советы секретаре, 1986 дан Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә читтән торып уку бүлеге проректоры, 2003 тән фән эшләре буенча проректор. Хезмәтләре даими белем бирүнең региональ системасын һәм социаль-мәдәни аспектларын өйрәнүгә карый. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә. РФнең Хөкүмәт бүләге лауреаты (2007).

Х е з м.: Организационно-педагогические основы социализации. К., 1994; Многофакторная модель формирования гуманитарной культуры личности студента. К., 1995; Формирование единого культурно-образовательного пространства региона: проблемы и решения. К., 2002.

**БАҺАВИ́** (19 йөзнең 1 нче яртысы), шагыйрь, «*Бүз егет*» дастанының авторы. Шагыйрь турында кайбер мәгълүматлар дастанның үзендә бар. Берничә урында ул үзен «бичара Баһави» дип атый. Әсәрнең кереш өлешендә язылу вакыйгасына тукталып: «Бүз егет» китабыны бер катар күреб идем. Фарси теле берлә язылмыш иде... Үземезнең күңелемез кайгылы көндә «Бүз егет» китабына кайгымыз түкеб... мең дә сикез йөз кырык иkенче елында язып ирдек, Уфа илендә...» — дип күрсәтә. Шуннан башка автор биографиясенә кагылышлы мәгълүмат юк. Бер-берсенә гашыйк ике яшь кешенең фаҗигале язмышын романтик буяуларда сурәтләгән бу дастанның кульъязма нөсхәсен Семипалатинск өязендә (хәзерге Казакъстан Респ-касы) В.В.Радлов таба һәм үзенең «Көньяк Себер һәм Җөнгәр далаларында яшәүче төрки кабиләләрнең халык иҗаты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи», 1870) исемле хезмәтенең 3 нче томында бастырып чыгара. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан «Бүз егет» дастаны татар халкы арасында, ш.у. казакъ, нугай һ.б. төрки телле халыкларда иң яратып укыла яки телдән сөйләнә торган әсәрләрнең берсенә әйләнә. Иң тулы дип исәпләнгән басмасы (К., 1984) РФА Көнчыгыш ин-тының С.-Петербург бүлеге фондында саклана торган кульъязма нөсхәсе нигезендә әзерләнә.

Чыг.: Татар халык иҗаты. Дастаннар. К., 1984.

*Әд.:* Г а й н е т д и н о в М.В. XIX йөз татар әдәбияты тарихына яңа материаллар // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992.

*М.В.Гайнетдинов.*

**БАҺАВИЙЙӘ́**, 1863 елда үзен Баһаулла — пәйгамбәр дип игълан иткән Мирза Хөсәен-Али Нури (1817–92) нигез салган дини тәгълимат тарафдарлары җәмгыяте. Б.нең тамырлары Гыйрактa 1844 тә үзен элек — Баб («Мәһди капусы») дип, соңрак — җирдә гаделлек һәм тигезлек дәвере башлануын белдерү өчен килгән *мәһди* дип игълан иткән Али Мөхәммәд Ширази (1819–50) тәгълиматына барып тоташа. Б.нең төп принциплары «Китаб әл-әкъдәс»та баян ителә.

Б.тарафдарлары Б. тәгълиматы — барлык башка диннәргә алмашка килгән яңа дин, ул көчәйсә, дәүләтләр арасындагы чикләр, милли һәм социаль тигезсезлек бетәчәк, дип исәпләләр, халыкларны үзара дуслыкка, бердәмлек, тигезлек һәм туганлыкка өндиләр. Б. вәкилләре Иранда һәм Шәрекъгтәге башка кайбер илләрдә бар, шулай да аларның күпчелеге Европа һәм Америкада яши. Штаб-квартиралары Хайфа (Израиль) шәһәрендә урнашкан. Казанда нигездә Иранннан чыккан студентлардан торган Б. җәмгыяте 1920 еллардан 1937 гә кадәр эшләп килә; 1989 да яңадан оеша, 1991 дә теркәлә. Аз санлы Б. җәмгыятьләре Казан, Чаллы, Яшел Үзән, Алабуга, Түбән Кама, Чистай шәһәрләрендә бар.

**БАҺАДИР**, к. *Батыр*.

**БАҺА́УОВ** Мирзаян Әсләхетдин улы (28.8.1940, Мөслим р-ны Иске Вәрәш а. — 15.8.2003, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1985). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), Мөслим р-ны а.х. оешмаларында инженер булып эшли; 1975 елдан «Трудовик» тәҗрибә-житештерү хуҗалыгы (1990–92 дә бүленеп) директоры. Аның җитәкчелегендә хуҗалыкның икътисади хәле шактый ныгый, халыкның социаль-көнкүреш тормыш шартлары яхшыра. Республиканың төньяк-көнчыгыш өлешендәге а.х. пр-тиеләрен бөртекле, бөртекле-кузаклы культуралар һәм югары репродукцияле күпьеллык үлән орлыклары б-н тәэмин итүгә, элита орлыклар чыгаруның матди-техник базасын үстерүгә зур өлеш кертә. Җитештерүдә югары нәтиҗәлелеккә ирешкән өчен хуҗалыкка РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байраклары (1979, 1983) бирелә. Б. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**БАҺМА́НОВ** Гәрәй Мәүлетбай улы (7.11.1923, Бөгелмә кантоны Мәсәгут а. — 19.8.1996, Азнакай ш.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1966). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950–88 елларда «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең Азнакай бораулау эшләре идарәсендә вышка монтажлаучылар бригадиры булып эшли. Герой исеме хезмәттә югары күрсәткечләргә ирешкән һәм бораулау вышкаларын монтажлауда комплекслы звенолар ысулын гамәлгә керткән өчен бирелә. Ленин, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. ВДНХның алтын медале б-н бүләкләнә. Азнакай шәһәрендәге бер урамга Б. исеме бирелә (1997), туган авылында бюст куела (1996).

*Әд.:* Н и з а м о в И. Багманов Гарай Маулетбаевич // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**БАҺМА́НОВ** Ирек Вәли улы (6.1.1932, Әлмәт р-ны Әлмәт а.), драма актёры, педагог, ТАССРның халык артисты (1982). Төньяк флотта хезмәт иткәннән соң, 1958 елда Казан Зур драма театры каршындагы студиягә укырга керә. 1961–64 тә Респ-ка күчмә театры труппасында, 1964 тән Татар акад. театрында. Бер үк вакытта 1996 дан Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта. Башта үзенчәлекле характерлы яшь герой рольләрендә уйный (Фәйзулла — «Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш; Җантай — «Гүзәлем Әсәл», Ч.Айтматов; Инсаф — «Әни килде», Ш.Хөсәенов). Актёрның иҗади үзенчәлеге үткен характерлы, шул ук вакытта тирән психологик



И.В.Б а һ м а н о в «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т. Миңнуллин) спектаклендә Искәндәр ролендә (сулда – Ш. Биктимеров).

рольләр башкарганда тулырак ачыла (Ризположенский — «Агай эне, ак мыек», А.Н.Островский; Искәндәр — «Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин). Актёрга хас әчке гармония, йомшак темперамент һәм зыялылык, нечкә, ягымлы юмор кайвакытта үткен сатира б-н бергә кушыла, бу аңа персонаж характерының гомумиләштерелгән социаль асылын тирәнтен ачып бирергә, истә калырлык образлар тудырырга ярдәм итә. Геройларның тормышчан тышкы кыяфәте Б.ның катлаулы эчке дөньясы б-н тулыландырыла. Төп рольләре: Саттар, Фәһим, Рәфис, Алексей, («Монда тудык, монда үстек», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз», «Илгизәр + Вера», Т.Миңнуллин), Василий Павлович («Боз астында дулкын», Ә.Рахманкулов), Чатбаев («Ахырзаман», Ч.Айтматов), Мишка, Мөәзин («Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», К.Тинчурин), Новожилов («Бер төн», Б.Горбатов), Шәйхеразый («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев), Валера («Шәҗәрә», Т. Миңнуллин). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г ы й м р а н о в а Д. Ирек — илнең солтаны // Мәдәни җомга. 2002. 1 февр.; С а ф и у л л и н Ә. Сәхнәдә үткән тормыш // Ватаным Татарстан. 2002. 11 гыйн.; Г ы й м р а н о в а Д. Ни белән үлчәнә гомер? // Ватаным Татарстан. 2007. 12 гыйн.

*И.И.Илялова.*

**БАЧМА́Н ХАН** (Басман хан) (1210 тирәсе — 1239/40 тирәсе), Көньяк Урал б-н Көнчыгыш Каспий аралыгында яшәгән йәмәк кабиләләре идарәчесе, монгол яуларына каршы көрәш оештыручы (к. *Бачман хәрәкәте*). Илбарилар ыругы вәкиле. Ил-җирләрен монголлар басып алгач, халык күтәрелешен оештыра, әсир ителә һәм җәзалап үтерелә. Б.х. исеме татар, нугай һ.б. төрки халыклар арасында таралган риваять һәм шәҗәрәләрдә саклана.

*Әд.:* Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1; Ахинжанов С.М. Кыпчаки в истории средневекового Казахстана. А.-А., 1989; Плетнёва С.А. Половцы. М., 1990; Golden P.B. Cumanica II: The olberli (olperli): The Fortunes and misfortunes of Inner Asian clan // Archivum Eurastae medii aevi. 1986. V. 6.

*И.Л.Измайлов.*

**БАЧМА́Н ХӘРӘКӘТЕ́**, 1237–40 елларда Урта һәм Түбән Идел буйларында йәмәк һәм ас кабиләләренең монгол яуларына каршы баш күтәрүе. Җитәкчеләре Бачман хан б-н Качыр Углы. Баш күтәрүчеләр Идел аръягы б-н Көньяк Урал аралыгында элеккеге йәмәк дәүләтчелеген торгызмакчы булалар. Монголларның аерым гаскәри берәмлекләрен җиңгәннән соң, 1239/40 елда боларга каршы Мөнке б-н Бучек җитәкчелегендә зур гаскәр җибәрелә. Түбән Идел буендагы сугышлар барышында тар-мар ителә.

*Әд.:* Ахинжанов С.М. Кыпчаки в истории средневекового Казахстана. А.-А., 1989; Плетнёва С.А. Половцы. М., 1990; Golden P.B. Cumanica II: The olberli (olperli): The Fortunes and misfortunes of Inner Asian clan // Archivum Eurastae medii aevi. 1986. V. 6.

*И.Л.Измайлов.*

**БАШ АРХИ́В ИДАРӘСЕ́**, ТР Министрлар Кабинеты карамагындагы идарә. 1919 елның февралендә Казан губернасы архивларын саклау комиссиясе буларак оештырыла. 1920 дән ТАССР Мәгариф халык комис-тының Татарстан Үзәк архивы, 1921 дән ТАССРның Үзәк архив идарәсе, 1939 дан ТАССР НКВДсының архив бүлеге, 1942 дән ТАССР НКВДсының дәүләт архивлары бүлеге, 1946 дан ТАССР Эчке эшләр министрлыгының архив бүлеге, 1962 дән ТАССР МС каршындагы архив бүлеге, 1980 нән ТАССР МС каршындагы архив идарәсе, 1992 дән ТР МК каршындагы архив идарәсе, 1996 ның мартыннан хәзерге исемдә. Архив эшләренә дәүләти җитәкчелекне гамәлгә ашыра. ТРда Архив фондына документлар туплау, исәпкә алу, саклау эшләрен оештыра. ТР МК каршындагы Б.а.и.нә *Татарстан Республикасы Милли архивы*, *Татарстан Республикасының Тарихи-сәяси документларны саклау дәүләт үзәк архивы*, *Татарстан Республикасының аудио-визуаль документлар дәүләт үзәк архивы*, *Татарстан Республикасының аерым шәхесләргә бәйле документлар саклау үзәге*, ТРның шәһәр һәм район хакимиятләренең 44 архив бүлекчәсе, «Архивист» дәүләт пр-тиесе керә. ТРның архивлар фонды 4,5 млн. саклау берәмлеген тәшкил итә (1997). Җитәкчеләре — И.А.Стратонов (1919–21), Е.И.Черньшёв (1921–24), А.П.Жаков (1924–26), М.И.Борисов (1926–27), Р.В.Яхкинд (1927), М.А.Зайцев (1927–29). Ә.Җ.Габдерәшитов (1930), Е.И.Медведев (1930–34), А.И.Ямпольская (1935–53), Х.С.Сәлимов (1953–55), Н.Б.Таҗетдинов (1955–62), Д.И.Васильев (1962–64), Ф.М.Байчурина (1965–71), Т.М.Прохорова (1971–93), Д.Р.Шәрәфетдинов (1993–2005), Д.И.Ибраһимов (2005 тән). Матбугат басмалары — «Татарстан Социалистик Совет Республикасы Үзәк архивы язмалары» («Записки Центрального архива Татарской Социалистической Советской Республики»), «*Гасырлар авазы*» — «*Эхо веков*» ж-ллары.

*Әд.:* Бобков В.Н. К истории документальных собраний церковных учреждений Казани // Отечественные архивы. 1993. № 1; Димитриева А.М., Цыганова О.Г. Бесценные источники для научных исследований (государственной архивной службе Республики Татарстан — 80 лет) // Научный Татарстан. 1998. № 4; Шарафутдинов Д.Р. Дом истории, дом памяти // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 1/2; шул ук. Татарстан и Турция. Архивное сотрудничество // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 1/2; Шамсутдинова Р.Г. Архивное дело в Татарстане в конце XIX — 30 годы XX вв.: Дис.... К., 2001.

*Д.Р.Шәрәфетдинов.*

**БАШ КИЕМНӘРЕ́**. Идел буе — Урал алды татарларының Б.к., традицион өс киеменең бер өлеше буларак, борынгы төрки-болгар мәдәниятеннән һәм киемнәреннән аерылгысыз. Татарларның Б.к.нең үзенчәлекләре Идел-Урал төбәгендә яшәүче күрше халыкларның, ш.у. Шәрекъ мөселман халыкларының мәдәни традицияләре йогынтысында формалаша. Татар Б.к. нең милли-сәнгати үзенчәлекләре, тарихи дәверләр һәм аерым төбәкләр б-н бәйле вариантларының күптөрлелеге хатын-кыз киемнәрендә аеруча ачык чагылыш таба. Хатын-кыз Б.к.нең ике төре — япма һәм башлык — борынгы заманнарда ук өстенлек ала. Япмалар — *бөркәнчек, түгәрәк яулык, өрпәк, тастар* — 19 йөз ахырына киң кулланылыштан чыга. 19 йөзнең 1 нче яртысыннан үзләренең формалары (квадрат, өчпочмаклы, сөлге сыман), бизәлү ысуллары (чигү, аппликация, бизәклән туку) һәм бәйләп йөрү җәһәтеннән үзенчәлекле әлеге Б.к.нә күпләп җитештерелгән яулыклар һәм шәлләр алмашка килә. Эчтән бөркәнелгән ситсы яулыкларны («француз яулык») өлкән яшьтәге хатын-кызлар — ике очын ияк астыннан, кызлар һәм яшь хатыннар баш артыннан бәйләп йөргән. Ефәк трикотаждан челтәрле шәлләр кешелеккә бәйләнгән: яшь хатыннар һәм кызлар аны *калфак* өстеннән бөркәнгән, ә өлкән яшьтәге бай хатыннар шәл өстеннән мех башлык — «камчат бүрек» кигән. Мәрҗән, сәйлән, укалап чигелгән бәрхет калфаклар 1920 елларга кадәр мөселман хатын-кызлары арасында киң таралган. Калфакларның борынгы төрләрен — бәйләнгән ак калфак, бәрхет «чәчәк калфак»ны 19 йөз ахырларына кадәр керәшен кызлары гына кия. Кияүдәге керәшен хатыннары берничә элементтан торган *сурәкә*, ә мәлки төркеме керәшеннәре тастар кигән. Соңгысының аерым төрләре Касыйм татарларында, мишәрләрнең кайбер төркемнәрендә 20 йөз башларына кадәр саклана. Тастар җыелмасының Болгар дәвереннән үк килгән иң борынгы вариантларының бер өлешен акча тәңкәләре, мәрҗән, сәйлән чигеш б-н капланган башлык — *кашпау* тәшкил иткән һәм ул Ләмберә мишәрләрендә 19 йөз урталарында да кулланылган. Хатын-кыз Б.к.ннән аермалы буларак, ир-ат Б.к.нең аерым төбәкләргә бәйле үзенчәлекләре күп түгел. Алар фәкать кешенең кайсы катлауга керүен, байлыгын чагылдырган, шәһәр яисә авыл мәдәниятенә, ислам яки христиан диненә нисбәтле булуын белдергән. 20 йөз башына кадәр кыйммәтле тукымалардан, затлы мехтан тегелгән Б.к.н халыкның бай катлавы гына кигән. Ислам диненең үзенчәлекле символлары булган *түбәтәй һәм чалма* — керәшен татарлар көнкүрешенә үтеп кермәгән. Мөселман татарларга хас эчке Б.к. — *түбәтәй*не борынгы яугирләр шлем эченнән кигән, ул дүрт чөйсыман ялгаулы ярымтүгәрәк башлык сыман итеп сырылган. Аны Казан татарлары «тәкыя», мишәрләр — «кәпәч» дип атый. 20 йөз урталарына кадәр ир-ат җәй айларында — сарык йонынннан басылган кырлы эшләпә һәм кышын бүрек кигән. Цилиндрсыман мех башлыкның «Мәскәү бүрек», «данадар бүрек» фасоннары, кисек конус рәвешендәге «кәләпүш» дип аталган түбәтәйләр киемнәрнең шәһәрчә стиле йогынтысында таралыш ала. 19–20 йөзләр чигендә татар зыялылары арасында чуклы төрек фәсләре модага керә. Балалар Б.к. олыларныкына охшаш итеп тегелгән, ләкин алар өчен ачыграк төстәге материаллар кулланылган һәм баерак итеп бизәлгән, хәтта кышкы башлыклар да чигелә торган булган. Малайлар 3–4 яшьтән үк түбәтәй кия башлаган. Кызлар кешелеккә яулык бәйләгән, буй җиткәч — кәтәҗи калфак кигән. 19–20 йөзләр чигендә өс киеменең европалашуы башлана һәм ул 20 йөз урталарына татар халкы көнкүрешеннән традицион Б.к.н кысрыклап чыгара. 20 йөз ахырындагы милли мәдәният яңарышы нәтиҗәсендә этник символлар булып торган аерым милли кием элементларының, ш.и. түбәтәй һәм калфак кебек Б.к.нең көнкүрешкә әйләнеп кайтуы күзәтелә. Ш.у.к. *Бүрек*.

*Әд.:* Воробьёв Н.К. Казанские татары. К., 1953; Завьялова М.К. Татарский костюм. К., 1966; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

*Ф.Ф.Гулова.*

**БАШ КИЕМНӘРЕ́ ТЕГҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́**, Казан губернасында 18–19 йөзләрдә киң таралган кәсепчелек тармагы. Аеруча Казан, Мамадыш, Тәтеш өязләре авылларында артельләргә тупланып эшләү киң таралган. Казан өязендәге Урта Аты авылы Б.к.т.к. үзәге буларак дан тоткан. Җитештерелгән баш киемнәре, җирле базарлардан тыш, Мәкәрҗә ярминкәсендә сатылган. 1911 елда Б.к.т.к. б-н 169 хуҗалыкта 322 кеше шөгыльләнүе теркәлгән. Алар тарафыннан кышкы һәм җәйге баш киемнәре җитештерелгән. Ш.у.к. *Бүрек*, *Калфак*, *Түбәтәй*.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала. К., 1995.

**БАШ СӘЯСИ́-АГАРТУ́ КОМИТЕТЫ́** (Главполитпросвет), 1920 елның 12 ноябрендә РСФСР Мәгариф халык комис-ты кар-

шында бүлек һәм бер үк вакытта РКП(б) ҮК органы буларак оештырыла. Рәисе — Н.К.Крупская. Төп бурычы — дәүләтнең коммунистик идеяләрне пропагандалавы б-н җитәкчелек итү. Аның карамагына совет-партия мәктәпләре тапшырыла. Главполитпросвет РКСМның сәяси-агарту органнарын, ВЦСПСның мәдәният бүлекләрен, Пролеткульт, Дәүләт нәшриятын, Центропечать, Мәгариф халык комис-ты бүлекләре эшчәнлеген күзәтүдә тота. Татарстан сәяси-агарту ком-ты (Татглавполитпросвет) 1921 нең башында оештырыла. Төрле елларда аның б-н Ш.*Әхмәдиев*, М.*Борындыков*, И.*Рәхмәтуллин* һ.б. җитәкчелек итә. 6 бүлектән тора. Мәдәният-агарту оешмалары өчен белгечләрне 4 совет-партия мәктәбе, *Татар коммунистлар университеты* һәм кыска вакытлы курслар әзерли. Татглавполитпросвет карамагында 1921 дә — 3356, 1922 дә 556 сәяси-агарту учреждениесе исәпләнә. Татарстандагы 1921–22 еллардагы ачлык вакытында китапханәләр саны кискен кимү сәбәпле, 1922 дә Татглавполитпросвет җитәкчелегендә — 272, 1923 тә — 337 күчмә китапханә оештырыла. Агитация-пропаганда, вакытлы матбугат, нәшрият, мәдәният-агарту учреждениеләре эшчәнлегенә җитәкчелек итүне, наданлыкны бетерү өчен мәктәпләр һәм өлкәннәр өчен курслар ачуны, эшчеләр ун-тлары һ.б. оештыру эшләрен берләштерә һәм аларга юнәлеш бирүне гамәлгә ашыра. 1930 да ТАССР Мәгариф халык комис-тының массалар б-н эшләү секторы итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Культурная революция в Татарии (1917–1937 гг.). К., 1986.

*Л.М.Айнетдинова.*

**БАШ-АРБА́Ш** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шыяның (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 19,4 *км*, бассейнының мәйданы 106 *км*². Елга башы Кукмара р-ның Хәсән посёлогыннан көньяктарак, тамагы Мамадыш р-ның Тулбай авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 76 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 26%. Б.-А. елгасының 1,1 дән алып 9,3 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,62 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1–3 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 110 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,11 *м*³/*с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Б.-А. бассейнында ТРның табигать истәлеге *Порфирьев ак чыршылыгы* урнашкан.

**БАША́К КОҢГЫЗЛАРЫ́**, икмәк коңгызлары (Anisoplia), пластинкамыеклылар семьялыгыннан коңгызлар ыругы. Россиянең Европа өлешендә 30 га кадәр, Урта Идел буенда 7 төре билгеле. Б.к. өчен тар калак сөяге барлыкка китерүче (баш өлешендә өскә нык сузылган) конуссыман калкан характерлы, ул шулай итеп кыяклыларның кабыкларын ачуга җайлаша. Б.к.ның күбесе бөртекле культураларны зарарлый: Татарстан терр-ясендә иң күп зыянны икмәк Б.к. (A. austriaca) китерә, ул кара туфраклы полосада киң таралган. Гәүдәсенең озынлыгы 12–15 *мм*, яшькелт-кара төстә, асты ачык төкле, канат өсләре җирән, калкан янында дүртпочмаклы тимгелләр бар. Кыяклыларның (бигрәк тә бодай, арыш һәм арпа) өлгереп килүче бөртекләре б-н туклана, йомшак бөртекләрне ашый, ә катыларын башактан чыгара һәм җиргә коя. Личинкалары туфракта яшиләр, черемә һәм үсемлекләрнең вак тамырчыклары б-н туеналар. Үсеш циклы 2 ел тәшкил итә. Личинка стадиясендә кышлый.

*А.К.Жеребцов.*

**БАШИ́ЛОВ** Иван Яковлевич (17.11.1892, Кашин ш., хәзерге Тверь өлкәсе — 20.8.1953, Мәскәү), химик-технолог, металлург, техник фән. д-ры (1935), проф. (1931), Россиядә радий һәм сирәк металлар сәнәгатен оештыручыларның берсе. Петроград политехника ин-тында укый, 1919 да Бондюг авылында (хәзер Менделеев ш.) эксперименталь радий з-ды эшен оештыру (В.Г.*Хлопин* тәкъдиме буенча) зарурлыгыннан чыгып, укуын өзә. 1920–21 дә бу завод б-н җитәкчелек итә. 1924 тә Мәскәүдә Гамәли минералогия ин-тында (1935 тән Бөтенсоюз минераль чимал ин-ты) сирәк элементлар лабораториясен оештыра һәм җитәкли (1938 гә кадәр). Бер үк вакытта 1930 да Мәскәү нечкә химик технол. ин-тында сирәк һәм чәчелгән элементлар химиясе һәм технологиясе кафедрасын оештыра, 1932 дән Сирәк металлар ин-тында (Мәскәү) фәнни җитәкче була. Хезмәтләре сирәк һәм радиоактив элементлар химиясе һәм хим. технологиясе, аларны җитештерүне оештыруга карый. Радий, уран һәм ванадийны үзебезнең ил чималыннан табу технологиясе схемасын тәкъдим итә һәм (1921, В.Г.Хлопин б-н берлектә) радийның беренче препаратларын эшләп чыгара. Сирәк металларны табу ысулларын, ак алтынны аффинажлау (чистарту) технологиясен эшли. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1948). 1938 дә репрессияләнә, Бөек Ватан сугышы елларында аклана.

Хезм.: Технология радиоактивных руд. Л., 1927; Редкие элементы и их использование. М., 1930; Введение в технологию редких элементов. М.–Л., 1932.

*Әд.:* Глебова В.И. О радии и его промышленности. М.–Л., 1932; Большаков К.А., Звягинцев О.Е., Сажин Н.П. И.Я.Башилов [некролог] // Журн. прикладной химии. 1954. Т. 27, № 6.

**БАШКА́ ЧЫГАРУ́**, татар халкы йоласы. Өйләнгән өлкән улларны, мал-мөлкәттән өлеш бүлеп, яңа йорт җиткереп, төп йорттан аерып чыгару, «башкалану» дип тә атала. Башта Б.ч. гаиләдәге барлык утрак һәм күчмә милекнең хуҗасы булган ата кешенең улына үз йортын салу, тормыш-көнкүрешен, хуҗалыгын оештыру өчен үз утарының һәм мөлкәтенең бер өлешен бүлеп бирүен аңлаткан. Әмма гаиләнең төп милке — сөрүлек җир, печәнлекләр, эш хайваннары, төп авыл хуҗалыгы кораллары — бүленмәгән. Товар-акча мөнәсәбәтләре үтеп керү хосусый милекчелек үсеше зур булмаган гаиләләр барлыкка китерә. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында ук инде иң якын кардәшләрнең 3–4 буынын берләштергән традицион зур гаилә бүленүгә йөз тота. 19 йөз ахырында башка чыгучы яшьләргә ата гаиләсенең төп милкеннән дә өлеш бүлү гадәткә керә. Яшь гаиләләрнең мөстәкыйльлеккә, үз хуҗалыкларын оештырырга омтылуы кайвакыт каршылыклар да китереп чыгарган: аеруча урта хәлле һәм бай гаилә башлыклары уртак милекне бүлешергә бик үк риза булмаган. Б.ч. турындагы карар еш кына гаиләнең аерым вәкилләре арасында каршылыклар б-н кабул ителгән. 1920 елларның 2 нче яртысыннан, хәлле хуҗалыкларга дәүләтнең икътисади басымы көчәю сәбәпле, зур гаиләләрнең бүленү очраклары ешая. Мәҗбүри күмәкләштерү, илдә кулакларны сыйныф буларак юк итү, хосусый җирбиләүчелекне бетерү җәелеп киткән 1930 еллар башында да бу процесс дәвам итә. Әлеге вазгыятьтә бик күпләр өчен Б.ч. дәүләт эзәрлекләвеннән саклану чарасы булып тоела. Ләкин 20 йөзнең 2 нче яртысында татар яшьләре арасында үз тормышларын оештыру мәсьәләсен мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә омтылу гадәткә керә һәм Б.ч. йоласы элеккеге икътисади, социаль мәгънәсен югалта.

*Әд.:* Хисамутдинов Г.М. Общественные отношения // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Загидуллин А.А., Мухамедова Р.Г. Семейно-родственные отношения // шунда ук; Мусина Р.Н. Семья и семейный быт // Татары. К., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**БАШКИРЁВ** Тимофей Антонович (18.2.1915 — 13.10.1988, Казан), йогышлы авырулар белгече, эпидемиолог, мед. фән. канд. (1963), ТАССРның атказ. табибе (1959). 1943 елда Мәскәү мед. ин-тының хәрби ф-тын тәмамлый. 1946–70 тә хәрби госпитальләрдә (1949 дан Германиядә, 1952 дән Казанда) эшли. 1970–86 да Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Хезмәтләре бөердәге синдромлы геморрагик бизгәкне — аның зарарлау формаларын өйрәнүгә, Урта Идел төбәкләрендә геморрагик бизгәкнең табигый чыганакларын, авыруның патогенезын, клиникасын ачыклауга, диагноз куюга һәм дәвалауга карый. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Клинико-серологические параллели при Ку-лихорадке // Материалы науч.-практич. совещания. Проблемы зоонозов (бруцеллёз, лептоспироз, сибирская язва, Ку-лихорадка). Пятигорск, 1964; О новых очагах геморрагической лихорадки с почечным синдромом в Среднем Поволжье // Тезисы докладов итоговой науч. конф. КНИИЭМ. К., 1959.

*Әд.:* Казанский научно-исследовательский институт эпидемиологии и микробиологии (1900–1975). К., 1974; Павлухин Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**БАШКИ́РОВ** Алексей Иванович (24.7.1915, хәзерге Спас р-ны Иж-Борискино а.), Дан орденының тулы кавалеры (25.12.1943, 9.4.1945, 15.5.1946), старшина. Туган авы-

лында колхозда бригадир булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, орудие төзәүче, 128 нче гв. тупчы полкы орудие расчёты командиры (8 нче гв. армиянең 57 нче гв. укчы дивизиясе). 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Донбасс һөҗүм операциясендә (1943), Днепрны кичүдә (1943), Украина, Белоруссия, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1943 нең 30–31 октябрендә Новопокровка торак пунктыннан төньяк-көнбатыштарак Днепрның уңъяк ярында барган бәрелешләрдә, 1945 нең 29–30 гыйнварында Шверин шәһәре (хәзерге Сквежина ш., Польша) янында, Мюнхберг шәһәрен алуда һәм 1945 нең апрель ахырында Берлин урамнарында барган сугышларда батырлык күрсәтә. Сугыштан соң туган авылында МТС бригадиры. 1969 дан Тольятти автомобиль з-дында эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Л о б о д а В.Ф. Солдатская слава. М., 1963. Кн. 1; Ш е в ч е н к о Н.Я. Звёзды славы. К., 1969; Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**БАШКИ́РОВ** Алексей Степанович (1885–1963), архитектура тарихы белгече, археолог. 1919–45 елларда СССР ФАнең Матди мәдәният тарихы академиясендә эшли (Мәскәү). 1922 елдан ТАССРдагы Гыйльми үзәк, Шәрекъ халыклары ин-ты һәм Шәркыятьчеләр фәнни ассоциациясе оештырган болгар-татар мәдәниятен өйрәнү экспедицияләрендә, Биләр шәһәрлеген археол. тикшерүләрдә катнаша. Хезмәтләре Идел буе һәм Кавказ шәһәрләре тарихын һәм мәдәниятен, Кара диңгезнең төньягындагы антик чор шәһәрләре төзелешен өйрәнүгә, Кырым, Төньяк Кавказ һәм Идел буе шәһәрләре мөселман архит-расын тикшерүгә карый.

Х е з м.: Историко-археологический очерк Крыма. Симферополь, 1914; Прошлое Крыма. Исторический эскиз. М., 1923; Выставка материалов Таманской экспедиции. М., 1927; Памятники булгаро-татарской культуры на Волге. К., 1928.

**БАШКИ́РОВ** Иван Сергеевич (28.7.1900, Казан — 30.4.1980, ГФР, Франкфурт-Майна ш.), зоолог, публицист. А.А.*Першаков* шәкерте. 1922–27 елларда Казан ун-тында укый. Казанда зоопарк оештыруны башлап җибәрүче, 1928–31 дә аның директоры. 1931–35 тә Идел-Кама сунарчылык промыселы биологик станциясендә директор урынбасары. Татарстанда кыйммәтле мехлы җәнлекләр асрау мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. 1935–37 дә Кавказ саклаулыгында (Краснодар крае). 1937–43 тә Кырым саклаулыгында өлкән фәнни хезмәткәр, зоология секторы мөдире. 1944 тән Германиядә. 1947–51 дә Мароккода, Үсемлекләрне саклау ин-тында фәнни хезмәткәр. 1952 дән ГФРда качакларга ярдәм итү буенча Берлин ком-ты рәисе урынбасары, 1954 тән Халык-хезмәт союзы каршындагы СССРны өйрәнү ин-ты хезмәткәре, аның «Посев» һәм «Грани» басма органнарында эшли. Хезмәтләре зоология, зоогеография, сунарчылык, җәнлекчелек, үсемлекләрне саклау өлкәсенә карый. Б. СССРда зубрлар санын арттыру эшен оештыручы һәм башлап җибәрүчеләрнең берсе; 1937 дә беренчеләрдән булып Кырымда зубрлар үрчетү эшен башлый.

Х е з м.: Очерк охотничьего промысла в Татарии // Работы Волжско-Камской биол. станции. 1931. Вып. 31 (автордаш); Биология и промысел крота в Татарии // Работы Волжско-Камской биол. станции. 1934. Вып. 3 (автордаш); Реликтовые элементы в фауне Жигулей // Биол. Моск. об-ва испытателей природы. Отд. биологии. 1935. Т. 44, вып. 5; Кавказский зубр. М., 1940; Le moineau au Maroc. RABAT. 1953.

*Әд.:* Г а р а н и н В.И. Из истории Казанской школы экологов. А.А.Першаков и его окружение // Чтения памяти Виктора Алексеевича Попова. К., 1997; Иван Сергеевич Башкиров (28 июля 1900 г. — 30 апреля 1980 г.) // Актуальные проблемы герпетологии и токсинологии: Сб. науч. тр. Ин-та экологии волжского бассейна. Тольятти, 2000. Вып. 4.

*В.И.Гаранин.*

**БАШКИ́РОВ** Иван Сергеевич (1926, Мамадыш кантоны, хәзерге Саба р-ны Завод-Нырты а. — 5.2.1945, Польша), Сов. Союзы Герое (27.2.1945, һәлак булганнан соң), сержант (1944). 1943 елдан Кызыл Армиядә. 1944 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 47 нче армиянең 143 нче укчы дивизиясе 487 нче укчы полкында пулемётчы. 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Белоруссияне һәм Польшаны азат итүдә катнаша. 1945 нең 15 гыйнварында Летьоново шәһәре (Польша) янында Висла елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Дейч-Кроне (хәзер Польшаның Валч шәһәре) шәһәр-крепостен алу өчен барган сугышта һәлак була. Ленин, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. К., 1990; Батырлар китабы. — Книга героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963.

*В.А.Шагалов.*

**БАШКИ́РОВ** Шамил Шаһиҗәли улы (1.1.1927, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1971), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1980), Казан ун-тының атказ. проф. (2004). 1951 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Мари пед. ин-тында эшли. 1955–56 елларда Казан авиация, 1957–60 та Казан пед. ин-тларында. 1960 тан Казан ун-тында, 1969–93 тә каты җисем физикасы каф. мөдире, проф. (1971). Хезмәтләре электрон һәм төш магнит резонансы теориясенә, төш гамма-резонансы теориясенә, ферримагнитизмны тикшерүдә Мёссбауэр эффектын куллануга карый. Ике валентлы бакыр кушылмаларында электрон һәм төшнең спин-фонон тәэсирләшүе теориясен, тимер төркемендәге ионнарның квадруполь электрик тәэсир итешү теориясен төзи. Мёссбауэр спектрының көчеше һәм интенсивлыгы матдәнең магнитлану дәрәҗәсенә бәйлелеген теориядә исбатлый һәм тәҗрибәдә раслый. Катлаулы ферримагнит кушылмалардагы магнит микроструктурасын һәм алмашып тәэсирләшү параметрларын билгеләү методикасын эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.



А.И.Башкиров.



Советлар Союзы Герое И.С.Башкиров.

Х е з м.: Парамагнитная решёточная релаксация в гидратированных солях двухвалентной меди // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1958. Т. 34; О поляризации ядерных моментов и ширине линии ядерного резонанса в кристаллах солей $Cu^{2+}$ // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1958. Т. 35 (автордаш.); О влиянии оптического излучения на электрическое квадрупольное взаимодействие ядра парамагнитного иона // Письма в журн. эксперим. и теоретической физики. 1966. Т. 3 (автордаш); Влияние обменного взаимодействия магнитных ионов на интенсивность мёссбауэровского спектра // Физика твёрдого тела. 1967. Т. 9 (автордаш.); Эффекты квантовой интерференции гамма-излучения при кроссинге-антикроссинге ядерных уровней в радиочастотном поле // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2006. Т. 84, вып. 4 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**БАШКИ́РОВ** Шаһиҗәли Гали улы (1894, Казан губ., Мамадыш өязе Оштырма-Камышлы а., хәзерге Кукмара-р-нының Камышлы а. — 9.5.1938, Казан), хакимият-хуҗалык җитәкчесе. Рус-татар уч-щесен (1913), Казан ун-тының рабфагын (1922), Казан пед. ин-тын (1930) тәмамлый. 1918 елда Камышлыда ярлылар ком-ты секретаре, 1918–21 дә Кызыл Армиядә (курсант, татар запас батальоны командиры). 1922 дән Буа шәһәрендә ВКП(б)ның кантон башкарма ком-ты рәисе, кантон ком-ты секретаре. 1924 тән ТАССРның сәүдә халык комитеты урынбасары, 1926 дан ТАССРның Эшче-крәстияннәр инспекциясе халык ком-ты урынбасары, 1927 дән Татселькредитсоюз рәисе, 1928 дән ТАССРның юстиция халык комиссары, 1929 дан ТАССРның Авыл хуҗалыгы кооперациясе идарәсе рәисе, 1930–33 тә Татпромсоюз рәисе, 1934 тә Татарстан дәүләт нәшрияты идарәсе рәисе һәм бер үк вакытта ВКП(б) өлкә ком-тының а.х. бүлеге мөдире. 1934–37 дә ТАССРның мәгариф халык комиссары, бер үк вакытта «Мәгариф» ж-лы һәм «Уку ударнигы» г-тасы мөхәррире. 1938 дә уң оппозициядә катнашуда гаепләнә һәм үлем җәзасына хөкем ителә. 1957 елда аклана.

*Әд.:* Т о м р о в Н.И. Башкиров Шагивали Галеевич // Возвращённые имена. К., 1990.

*Н.И.Таиров.*

**БАШКИ́РОВА** Лариса Георгиевна (17.4.1938, Әзәрбайҗан ССРның Кировабад ш.), җырчы (лирик-колоратуралы сопрано), педагог, РСФСРның атказ. (1981), ТРның халык (1995) артисткасы. 1964 елда Казан консерваториясен (В.А.Лазько классы) тәмамлый. 1964–94 тә Татар опера һәм балет театры солисты. Төп партияләре: Розина


Л.Г. Башкирова.

(«Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Адина («Мәхәббәт эчемлеге», Г.Доницетти), Леонора, Джильда, Виолетта («Трубадур», «Риголетто», «Травиата», Дж.Верди), Маргарита («Фауст», Ш.Гуно), Лейла («Энҗе эзләүчеләр», Ж.Бизе), Мими («Богема», Дж.Пуччини), Антонида («Иван Сусанин», М.Глинка), Марфа («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Татьяна («Евгений Онегин», П.Чайковский). Б. ш.у. классик һәм заманча репертуардагы муз. комедияләрдә һәм оперетталарда төп партияләрне җырлый. Үзенчәлекле вокал һәм актёрлык осталыгы, әсәрләрнең стилистикасына


Л.Г. Башкирова Чио-Чио-сан ролендә (Дж. Пуччининың шул исем. операсында).

тирән үтеп керүе б-н истә кала торган якты сәхнә образлары тудыра. Б. актив концерт эшчәнлеге алып бара. 1994 елдан Малайлар хоры гимназиясендә укыта (Казан), бер үк вакытта 1995 тән мимика ансамбле җитәкчесе.

*Р.Такташ.*

**«БАШКНИ́ГА»**, пай кертү тәртибендә оешкан китап басу-сату ширкәте. 1922 елның октябрендә Уфа шәһәрендә оештырыла. Устав нигезендә оештыручылары — Башкортстан дәүләт нәшрияты, Башкортстан Җир эшләре халык комис-ты, Башкортстан Сәламәтлек саклау халык комис-ты, Башкортстан Кулланучылар берлеге һ.б. Асылда, дәүләт оешмалары пайчы булып катнашкан дәүләти-кооператив тибындагы нәшрият. Аңа респ-када нәшрият эшен торгызу һәм үстерү, тематик планнар нигезендә барлык фән тармаклары буенча китаплар, брошюралар, дәреслекләр, фәнни-популяр әдәбият, газета-журналлар чыгару, урыннарда китап кибетләре, киосклар ачу, үзендә һ.б. нәшриятларда басылган китап продукциясен халык арасында тарату бурычы йөкләнә. Эшчәнлегенең башлангыч чорында күбрәк Татарстан китап нәшриятында басылган татарча китапларны сату б-н шөгыльләнә. 1923 елдан Башкорт дәүләт нәшрияты б-н берлектә үзе дә татарча китаплар бастырып сата. Полиграфия базасы Уфа һәм Эстәрлетамак шәһәрләрендәге вак басмаханәләрне берләштерү юлы б-н оешкан, өстәмә рәвештә Казан басмаханәләре һәм хәреф коюостаханәләреннән китертелгән җиһазлар, татарча хәрефләр б-н ныгытылган «Октябрьский натиск» («Октябрь кысымы») дигән басмаханә. Әмма аның үзенә кергән барлык заказларны үтәү мөмкинлеге булмый, шуңа күрә аларның бер өлеше Казан матбагаларында башкарыла. «Б.»ның китап басу өлкәсендәге эшчәнлеге, бигрәк тә беренче елларда, нигездә, татар китабын бастыруга кайтып кала. Анда ел саен 20 дән алып 50 гә кадәр исемдә татарча китап басыла. Алар арасында иҗтимагый-сәяси, педагогика, методика, табигать, филология буенча китаплар, Г.Әхмәров, М.Гафури, М.Мәһдиев төзегән дәреслекләр, матур әдәбияттан Н.Исәнбәт, М.Гафури, С.Рәмиев һ.б. язучыларның әсәрләре бар. 1929 елда «Б.» Башкортстан дәүләт нәшриятына кушыла.

*Әд.:* А х у н з я н о в Т.И. Печать советской Башкирии. Уфа, 1967. Т. 1; Г у з а и р о в Р.Г. Первые годы деятельности Башкирского книжного издательства (1919–1922) // Книга: иссл. и материалы. 1973. Сб. 26; К а р и м у л л и н А.Г. Книги и люди. К., 1985; ш у л у к. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

**БАШКО́РТ ТЕЛЕ́**, башкорт халкы теле, төрки телләрнең кыпчак төркеменә карый. Башкорт телендә сөйләшүчеләр Башкортстан Респ-касында, Чиләбе, Оренбург, Самара, Саратов, Курган, Свердловск, Пермь, Төмән өлкәләрендә һәм ТРда яшиләр. Башкорт әдәби теле татар теленә якын. Төп төрки сүзләрдә ***ч*** фонемасы (башкорт телендәге **с** авазына туры килә) булмау, үзенчәлекле **һ** (сүз башында гомумтөрки **с** авазына туры килә), **ҙ** (сүзнең уртасында һәм ахырында **з**, кайвакыт **д** авазы урынына кулланыла) һәм **ҫ** авазлары булуы б-н характерлана. Морфологик яктан башкорт теле агглютинатив телләргә керә. Хәзерге башкорт телендә 9 сузык һәм 26 тартык аваз бар. Аңа *сингармонизм* хас: **у**рм**а**нд**а**рҙ**а** (урманнарда), **һ**ө**йл**ә**йҙ**ә**р** (сөйлиләр, сөйләшәләр), б**ө**г**ө**нг**ө**н**ө**ң (бүгенгенең, хәзергенең), т**о**рм**о**ш**о**н**о**ң (тормышының). Б.т.ндә сүзнең тамыры этимологик яктан моносиллабик. Сүз ясалышының ике төп ысулы хас — синтетик һәм аналитик ысуллар. Башкорт теле ике диалекттан тора: көнчыгыш (кувакан) һәм көньяк (юрматы) диалектлары. 1920 елларга кадәр башкортлар татар әдәби теленнән файдалана. Язу гарәп алфавитына, 1927 елдан соң латин графикасына, 1939 елдан кириллицага нигезләнә, башкорт телендәге үзенчәлекле авазларны белдерү өчен 9 хәреф өстәлә (ө, ү, ә, ҙ, ҡ, ң, ҫ, һ, ғ). Ш.у.к. *Башкортлар*.

*Әд.:* Д м и т р и е в Н.К. Грамматика башкирского языка. М.–Л., 1948; Ю л д а ш е в А.А. Башкирский язык // Языки народов мира. Т. 2. Тюркские языки. М., 1966; Грамматика современного башкирского литературного языка. М., 1981; Очерки истории башкирского литературного языка. М., 1989.

**БАШКО́РТ-МИШӘ́Р ГАСКӘРЕ́** (Башкорт гаскәре), 1798–1865 елларда Россиянең Оренбург, Самара һәм Вятка губерналары чикләрендә казаклар гаскәре тәртибендә оештырылган (иррегуляр) атлы гаскәр. Көньяк-көнчыгыш чик буйларын саклауда катнашу өчен оештырыла. Баштарак 16 кантонга бүленә, шуларның 11 е башкорт һәм 5 се мишәр кантоны. Аерым Оренбург корпусы командирына буйсына. Гаскәрдә 20 яшьтән алып 50 яшькәчә булган башкорт һәм мишәр-татарлар чиратлашып хезмәт иткән, 1855 елдан алар сафына *типтәр* һәм *бобыльләр* дә кергән (шул елдан Б.-м.г. Башкорт гаскәре дип кенә атала башлый). Гаскәргә беркетелгән кешенең үз аты, ияре, коралы булган, өйдән аерылып чик буе сагына баручыны бернечә йорт берләшеп озаткан. Чик буе сагында тору 6 ай дәвам иткән (бер команда кайткач, икенчеләр киткән). Б.-м.г. матди яктан башкорт һәм мишәрләр исәбенә тәэмин ителгән (җан башыннан 25 тән 75 тиенгә кадәр). Хезмәт урынына киткәндә һәр гаскәригә җәмәгать 8 пот он һәм 1 пот ярма бүлеп биргән. 1798–1848 елларда Оренбург чик буен саклау өчен ел саен 5,5 меңгә кадәр кеше җибәрелгән. Ш.у.Себер чик буен сакларга, Себер һәм Златоуст трактына һәм Россиянең көнбатышындагы Бессарабия чик сызыгын сакларга да Б.-м.г.нән командалар җибәрелгән (1828–33). Ш.у. алар Казан, Мәскәү, С.-Петербург кебек шәһәрләрдә полиция вазифасын башкаруга да җәлеп ителгәннәр. 1805 елда Җаек казаклары, 1823 тә Касли һәм Кыштым з-длары эшчеләренең баш күтәрүләрен бастыруда да катнашалар. 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813–14 еллардагы Көнбатыш Европа явында Б.-м.г.нең 20 полкы, 1828–29 дагы рус-төрек, 1839 еллардагы Хива һәм Казакъ ханлыкларын яулау һәм 1853–56 еллардагы Кырым сугышларында 2 шәр полк катнаша. 1865 елда таркатыла. Б.-м.г. командирлары: генерал-майор С.Т.Циолковский, генерал-майор Н.В.Балкашин, генерал-майор Г.В.Жуковский, полковник Н.П.Беклемишев һ.б.

*Әд.:* А с ф а н д и я р о в А.З. Введение кантонной системы управления в Башкирии // Из истории Башкирии. Уфа, 1968.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БАШКО́РТ-ТАТА́Р КУЗГАЛЫШЛАРЫ́**, 17 йөз ахыры — 18 йөзнең 1 нче яртысында Урал б-н Урта Идел аралыгында патша хакимияте уздырган колониаль сәясәткә каршы баш күтәрүләр. Милли-дини чикләү һәм кысулар, салым түләүдәге гаделсезлек, җирле идарәчеләрнең башбаштаклыгы Казан губернасы Уфа провинциясенең Казан, Нугай, Усы һәм Себер даругаларында яшәүче татар, башкорт, мари, мордва, удмуртлар арасында ризасызлык тудыра. Кузгалышта катнашучыларның күпчелеге крәстияннәр була. Татар-башкорт феодалларының да бер өлеше читтә калмый. Баш күтәрүчеләрнең төп таләбе: җир биләү тәртипләренең элеккечә калуы, дин тоту иреге, салым күләмен киметү, җирле чиновникларның башбаштаклыгын чикләү һ.б.

**1681–84 еллар кузгалышы**. Казан, Нугай, Усы һәм Себер даругаларын биләп ала. 1681 елның 16 маенда чукынмаган морзалар һәм эре җир биләүче татарларның утарларын һәм җирләрен алу, христиан динен кабул иткән очракта аларны кайтарып бирү турында патша фәрманы чыгу сәбәпле башланып китә («Указ об отписке у мурз и татар поместий и

# УРТА ИДЕЛ ҺӘМ УРАЛ ЯНЫ ХАЛЫКЛАРЫ КҮТӘРЕЛЕШЛӘРЕ (1681-1755)



вотчин, и о выгодах, какие принявшим христианскую веру представляются»). Баш күтәрүчеләр җитәкчесе — Сәет Ягафәров. 1681 нең июль ахыры — август башында Нугай һәм Себер даругаларында аерым төркемнәр оеша; 1682 нең язында алар берничә кальгага һөҗүм итәләр, Уфа шәһәрен камыйлар, Самара шәһәре тирәләрендә дә җитәләр. 1682 нең июнендә хәрәкәткә Казан, Көнгер, Югары Тура өязләренең татар һәм башкортлары да кушыла. Кузгалышны бастыру Казан воеводасы П.В.Шереметьевка йөкләнә, Мәскәүдән Д.А. һәм П.И.Барятинскийлар җитәкчелегендә өстәмә көчләр җибәрелә. Шул елның июнь башында Уфа воеводасы Конкординов үз карамагындагы көчләр б-н Чулман һәм Ык елгалары аралыгында баш күтәрүчеләргә каршы чыга, тик уңышка ирешә алмый. Хакимият 1681 нең 16 маенда игълан ителгән фәрманның кулланыштан төшәчәген һәм фетнәдән баш тартучыларны гафу итәчәген белдерә. Баш күтәрүчеләр арасында таркаулык башлана, аларның бер өлеше хакимият таләбенә буйсыну турында хат юллый. Сәет Ягафәрев җитәкчелегендәге өлеше көрәшне дәвам иттерә. 1682 дә аларга калмыклар отряды да кушыла, бергәләп Минзәлә б-н Уфаны камап алалар. 1683 ел башында хакимият тарафыннан күрелгән чаралар нәтиҗәсендә калмыклар фетнәдә катнашудан баш тарталар. Кыш айларында тынып торган кузгалыш 1683 нең язында кабат көч ала: баш күтәрүчеләр Казан даругасында Чулман буендагы берничә кальгага, Нугай даругасында нығытылган Тозчылар шәһәрчегенә (Солеваренный городок) һөҗүм итәләр, Вознесенск монастырен яндыралар. Кузгалышны бастыру өчен хөкүмәт кенәз Ю.С.Урусов җитәкчелегендә гаскәр җибәрә. Баш күтәрүчеләр б-н бәрелешләрдә ул берничә җиңүгә ирешә, соңгы бәрелеш 1684 тә Богородский авылы янында була.

**1704–11 еллар кузгалышы**. Казан, Нугай, Себер һәм Усы даругаларын, Казан губернасының Казан өязен биләп ала. Фетнәнең сәбәбе: 1704 елның октябрендә игълан ителгән өстәмә салым кертү, җир-биләмәләрнең бер өлешен казнага күчерү һәм халык санын исәпкә алу турындагы патша фәрманы була. Кузгалыш җитәкчеләре: Алдар тархан Исәнгилдин, Дөмәй Ишкәев, Күчүм Түләкәев, Иман батыр, Исмәгыйль абыз һ.б. 1705 нең башында Минзәлә һәм соңрак Уфа тарафларында А.Сергеев җитәкчелегендә җәза отрядлары булып китә, Казан, Нугай, Усы һәм Себер даругаларында атлар җыялар. Казан, Нугай даругалары халкының бер өлеше моңа каршы короллы баш күтәрә. 1706 елның язында фетнәчеләр Чулман аръягындагы берничә кальгага, Тозчылар шәһәрчегенә һөҗүмнәр оештыралар, Самара, Саратов тирәләрендә дә хәрәкәт итәләр. Баш күтәрүчеләр Кырым ханы б-н Төрек солтанының ярдәменә ышаналар, ләкин өметләре акланмый. 1707 нең октябрь–ноябрьләрендә феодаллар А.Исәнгилдин б-н К.Түләкәев туплаган көчләр Хохлов командалык иткән патша полкын җиңүгә ирешә. Уфа шәһәре, Чулман аръягы кальгалары камала, Зәй кальгасы яулап алына. Шул елның декабрь урталарында фетнәчеләр, Чулман аша чыгып, Көнгер, Вятка һәм Казан өязләре җирендә хәрәкәт итә, Алабуга, Сарапул шәһәрләренә һөҗүмнәр оештырыла. 1708 нең гыйнвар ахыры — февраль башында Казанга һөҗүм башлый. Кенәз П.И.Хованский җитәкчелегендәге эзәрлекләүче гаскәри көчләр аларга каршы чыга, баш күтәрүчеләрне Чулман аръягына чигенергә мәҗбүр итә. Шул елның язында баш күтәрүчеләр б-н хакимият вәкилләре арасында җитди сөйләшүләр башлана. Хакимият фетнәчеләрне гафу итәргә һәм өстәмә салым җыюны кертмәскә сүз бирә. Бу вакытта Биләр, Сергиевск, Самара тирәләрендәге фетнәчел отрядлар хәрәкәтләрен дәвам иттерә. 1708 нең җәй урталарында кузгалыш басыла. Ләкин 1709 ның яз айларында ул кабат дөрләп кабынып китә, чөнки хакимият башлыклары үз вәгъдәләрен үтәми. Май аенда Урал аръягында хәрәкәт зур көч ала, баш күтәрүчеләргә каракалпаклар да ярдәм итә. Шул елның җәендә Исет, Миасс, Теча елгалары буенда урнашкан авыл, бистә-завод һәм монастырьларга һөҗүмнәр ясала, талау-яндырулар ешая. Ел ахырына гына кузгалыш басыла, әмма 1710 ның май аенда кабат хәрәкәткә килә. Шул елның көзендә генә кузгалыш җитәкчеләре хакимият алдында баш иярgә мәҗбүр булалар. 1711 нең җәендә Казан һәм Нугай даругалары баш күтәрүчеләре кабат Уфага яу оештырып карый. Хөкүмәт яңа кертелгән салымнан баш тартырга, башбаштаклык кылучы урындагы җитәкчеләргә карата чаралар күрергә мәҗбүр була. Халык кузгалышы әкренләп басыла.

**1735–40 еллар кузгалышы**. Казан, Нугай, Усы һәм Себер даругаларын биләп ала. Төп сәбәбе: 1735 нең июнендә Үр елгасының Җаекка кушылган урынында Оренбург кальга-шәһәрен төзергә керешү була. Кузгалыш җитәкчеләре: Килмәк абыз Нурушев, Акай Күчүмов, Йосыф Арыков, Төлкечура Аллагулов, Бәпәни Торыпбирдин, Алданҗыенгол Котлыхуҗин, Миңнегол Юлаев һ.б. 1735 нең июлендә Нугай һәм Казан даругаларында, Уфа тирәләрендә короллы чыгышлар башлана; баш күтәрүчеләр Табын кальгасына, аннары Яңа Чишмә, Зәй, Минзәлә кальгаларына һөҗүм итәләр. Шул елның августында хәрәкәт Чулман буйларына тарала. Баш күтәрүне бастыру өчен ген.-лейтенант А.И.Румянцев җитәкчелегендә гаскәр җибәрелә. 1735 нең көзендә Себер даругасы халкы баш күтәрә. Декабрьдә алар Верхояицк һәм Оренбург кальгаларына азык-төлек китерү юлларын ябалар, 1736 ның гыйнварында хөкүмәт гаскәрен Верхояицк кальгасын калдырып китәргә мәҗбүр итәләр. Баш күтәрүчеләргә каршы 22 мең кешедән торган җәза отрядлары җибәрелә. 1736 ның март–май айларында алар тарафыннан берничә мең фетнәче үтерелә. Шул елның көзендә кузгалыш туктала. Әмма халыкның авыр хәле, йөкләмә-бурычларның арта торуы 1737 нең яз башыннан Себер һәм Нугай даругаларында яңадан баш күтәрүләргә китерә. Җәй җиткәч, Усы даругасы кешеләре дә күтәрелә. Фетнәчеләр Красноуфимск кальгасы, Көнгер, Бөре шәһәрләре тирәсендә хәрәкәт итәләр, Богданов, Табын кальгаларына һөҗүмнәр оештыралар. Усы шәһәрен камыйлар. 1737 нең көзендә хакимият вәкилләре б-н элек кулга алынган җитәкчеләрне азат итү һәм халык өстенә йөкләнгән салымнарны киметү килешүе төзелә. Ләкин ул килешүләр үтәлми (шул елны Килмәк абыз, А.Күчүмов, Й.Арыков тотылып, башкалага озатыла). 1738 нең язында баш күтәрүчеләр Чибәркүл, Чиләбе, Красноуфимск кальгаларына, Ревда з-дына һөҗүм итәләр. Җәза отрядлары тарафыннан үткәрелгән даими эзәрлекләү, кулга алу, җәзалаулар 1738 нең көзендә хәрәкәтнең басылуына китерә. 1739 елның августында Т.Аллагулов җитәкчелегендә күтәрелгән кузгалыш уңышсыз тәмамлана. 1740 та Себер һәм Нугай даругаларының бер өлешендә кабат бердәм күтәрелеш күзәтелә. Хәрәкәтне киңрәк җәелдерү өчен күтәрелеш башлыклары халык телендә Карасакал кушаматы алган җитәкче Миңнегол Юлаевны «Солтангәрәй хан» дип белдерәләр. Шул елның март-июнь айларында баш күтәрүчеләрнең төп көчләре тар-мар ителә. Меңләгән кеше яу кырында үлә, берничә меңе тоткынлыкта җәзалап үтерелә. Ш.у.к. *Батырша хәрәкәте*.

*Әд.:* Добромыслов А.И. Башкирский бунт в 1735, 1736 и 1737 гг. // Труды Оренбургской учёной архивной комиссии. Оренбург, 1900. Вып. 8; Бикбулатов С. Башкирские восстания и татары // Вестник научного общества татароведения. 1930. № 9/10; Устюгов Н.В. Башкирское восстание 1737–39 гг. М.–Л., 1950; Акманов И.Г. Башкирские восстания в XVIII в. Уфа, 1987; шул ук. Башкирские восстания XVII-нач. XVIII вв. Уфа, 1993; Алишев С.Х. Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. II пол. XVI–XIX вв.). К., 1999.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БАШКОРТЛА́Р**, Башкортстан Республикасының төрки телле төп халкы. Башкортлар саны: РФдә — 1673,4 мең кеше (2002), Башкортстан Респ-касында — 1221,3 мең, ш.у. Чиләбе, Оренбург, Төмән, Свердловск, Курган өлкәләрендә, Татарстан Респ-касында, РФнең башка төбәкләрендә, ш.у. Россиядән читтә (1989 елгы мәгълүматлар буенча). — Казакъстанда (41,8 мең), Үзбәкстанда (34,8 мең), Украинада (7,4 мең), Таҗикстанда (6,8 мең), Төрекмәнстанда (4,7 мең), Кыргызстанда (4,1 мең) яшиләр. *Башкорт теленда* сөйләшәләр. Татар һәм рус телләре дә киң кулланыла. Күпчелеге мөселман-сөнниләр (к. *Сөнниләр*).

Б. атамасы язма истәлек-чыганаклардан 9–10 йөзләрдән мәгълүм (Ибне Фазлан һ.б.). Б. этногенезына кагылышлы 2 төрле караш озак еллар дәвамында яшәп килде. В.Н.Татищев, Д.Шлёцер, Д.Месарош, С.А.Токарев һ.б. аларны төркиләшкән угыр-мажарларга, В.М.Флоринский, В.В.Вельяминов-Зернов, В.Н.Витевский, П.С.Назаров, Д.Н.Соколов, С.И.Руденко һ.б. төркиләргә кертәләр. 20 йөздә С.И.Руденко, Н.К.Дмитриев, Р.Г.Кузиев, Җ.Г.Киекбаев һ.б.ның гыйльми эзләнүләреннән Б.ның килеп чыгышында, этник-мәдәни шәкелләнешендә, Башкортстан җирләрендә элек-электән яшәгән фин-угыр һәм иран телле сармат кабиләләреннән тыш, хәлиткеч компонентлар буларак, төрки телле бәҗәнәк, болгар, кыпчаклар, 13–15 йөзләрдә Алтын





1. Башкорт гаиләсе тирмәдә. Урал арты. 20 йөз башы. СССР халыклары этнографиясе дәүләт музее фототекасы; 2. «Башкортлар хәрби походта». Рәссам А.О. Орловский, 19 йөз.

Урда дәүләтенең төрки һәм монгол кабиләләре дә катнашкан дигән караш туа. 10 йөздән Б. Идел буе Болгарына, 13 йөз урталарыннан Алтын Урдага буйсыналар. 15 йөзнең 2 нче яртысыннан, Алтын Урда дәүләте таркалганнан соң, Б. биләмәләре 3 өлешкә бүленә: бер өлеше — Казан ханлыгына, икенчесе — Нугай Урдасына, өченчесе Себер ханлыгына керә. Татар ханлыклары Мәскәү дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң, 16 йөзнең 2 нче яртысында Б.ның көнбатыш өлеше рус патшасына буйсына һәм Рус дәүләтенә «ирекле кушылу»ның төп шарты итеп башкорт аксакаллары җир биләү тәртибенең элеккечә калуын (һәр ыруг үз җир-биләмәсенә хуҗа), үз гореф-гадәтләре һәм диннәре саклануын куялар. Оренбург губернасын оештыру комиссиясе башлыгы сенатор И.К.*Кириллов* Б.ны, «башкирец» дип атау 16 йөзнең 2 нче яртысыннан гадәткә кергән, дип яза. Күршеләре тарафыннан Б. 17 йөзгә кадәр «иштәк» дип тә йөртелә.

Рус дәүләтенә кушылган дәвердә Б. аз санлы халык була, социаль һәм мәдәни үсеш дәрәҗәсе буенча алар Казан ханлыгы яулангannan соң Урал буйларына килеп урнашкан халыклардан калыша. Соңрак Б. саны вотчиналы җир биләүгә («асабалы җир биләү хокукы»), шул сәбәпле матди өстенлекләргә ия булырга һәм милли үзенчәлекләрен сакларга омтылган халыклар — «башкорт катлавына» язылган татар, чуаш, марилар һ.б. исәбенә арта (к. «*Вотчиналы башкортлар*»). Патша администрациясе дә моны хуплый. Мәс., Екатерина II исеменә юлланган бер документта: «Биләмәләребездә күп хатынлылык нәтиҗәсендә әледән-әле ишәюче явызлардан саклану максатында караклардан алынган җирләрне язып теркәү һәм аларны элек-электән тугры хезмәт итүче русларга һәм йомышлы татар-мишәрләргә өләшү, шул рәвешле Казан татарларын башкалар белән кушу Император галиҗәнапларының мәнфәгатенә кулайрак булыр», — диелә. Патша хакимиятенең яңа яуланган җирләрне колонияләштерү, халыкны көчләп чукындыру, руслаштыру сәясәте Башкортстан халыкларында аяусыз каршылык тудыра. Б. озак еллар дәвамында татарлар, казакълар һ.б. б-н бергә социаль, милли һәм дини изүгә каршы көрәшәләр (к. *Башкорт-татар кузгалышлары*, *Батырша хәрәкәте*).

Б.ның формалашуында һәм үсешендә татар һәм рус халыклары б-н этник һәм мәдәни бәйләнешләрнең роле зур була. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Б. иҗтимагый-сәяси көрәшкә актив кушылалар. Шул елның ахырында Оренбургта узган Бөтенбашкорт корылтаенда Башкорт мохтарияты оештырыла (җитәкчесе Ә.Вәлиди). *КОМУЧ* идарәчелегенә таянган бу милли автономиянең хәрби берәмлекләре башта Сов. хакимиятенә каршы көрәшәләр. Б.ны үз ягына тартырга теләгән Сов. хөкүмәте 1918 нең март-май айларында Татар-Башкорт Респ-касын төзүгә багышланган киңәшмәләр уздыра (к. *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы*). 1919 ның февралендә башкорт милли хәрәкәте җитәкчеләре Сов. хакимияте б-н килешү төзиләр. Шул килешү нигезендә 1919 ның 23 мартында Башкортстан Совет Социалистик Автономияле Республикасы (БАССР) («Кече Башкортстан») оештырылуы игълан ителә, 1919–22 дә аның башкаласы Эстәрлетамак шәһәре була. ТАССР оешкан дәвердә (1920, май) элекке Уфа губернасының көнбатышындагы татарлар күпләп яшәгән Бәләбәй, Бөре һәм Уфа өязләре халыкларына кайсы респ-кага керү хокукын сайлау мөмкинлеге тудырылачагы белдерелгән була. Ләкин тиздән үзәктә ТАССР йогынтысын чикләргә омтылу сәясәте өстенлек ала, референдум үткәрелми, бу өязләрнең биләмәләре БАССРга бирелә. 1922 нең июненнән башкала Уфага күчерелә. Милли автономия барлыкка килү Б.ның милли-мәдәни үсешен һәм бердәм этнос булып оешуын тизләтә. 1990 ның октябрендә БАССРның ЮС Башкортстан Совет Социалистик Республикасын суверен дәүләт дип игълан иткән декларация кабул итә (1992 нең февраленнән *Башкортстан Республикасы*).

Ярым күчмә тормышта яшәгән Б.ның традицион хуҗалык тармагы — терлекчелек. Алар ат, сыер, сарык, көньяк-көнчыгыш төбәкләрдә яшәүчеләр дөя асрыйлар. 18 йөздән башлап, терлекчелектән тыш, иген үстерүгә дә әһәмият бирелә. Игенчелек хәзерге Башкортстан Респ-касының төньяк-көнбатышында яшәүчеләрнең төп хуҗалык тармагына әверелә, 20 йөз башыннан барлык төбәкләрдә дә өстенлек ала. Җир эшкәртү, чәчү тәртипләре әкренләп күршеләрдәге утрак тормышлыларда кабул ителгән өч еллык чәчү әйләнеше системасына нигезләнә. Башлыча язгы бодай, солы, көздән арыш чәчәләр, ярма культураларыннан тары һәм карабодай, техник культуралардан җитен, киндер игелә. Соңрак яшелчәчелек барлыкка килә. Кыргый умартачылык (чолыкчылык) һәм аучылык элек Б. тормышында зур урын алып торган. Сунарчылыкның күмәкләп башкарылган төрләренә өстенлек бирелгән: камалган җәнлекне ат өстендә килеш чукмар б-н «сугып» алу, ау бөркете-лачыннардан файдалану. Аучылык һәм балыкчылык Б. тормышында ярдәмчел роль уйный. Б.га хас төп һөнәрләр элек терлекчелеккә һәм ауга бәйле булган; йоннан әйберләр бәйләү, киез басу, тукыма туку, тире эшкәртү, агачтан әйберләр ясау, тимерчелек, зәргәрчелек һ.б. Башкорт җирләрендә бакыр, кургаш, алтын, затлы ташлар чыгарылган, казакъ биләмәләре б-н чиктәш Иләк елгасы буенда тоз базлары булган. 17 йөз башларында Б. җирендә бу казылма байлыкларны күпләп эшкәртү-җитештерү күзәтелә, завод-фабрикалар төзелә. 18 йөзнең 1 нче яртысында Б. җире Россиянең иң алга киткән мәгъдән чыгару һәм металлургия үзәгенә әверелә. Аларда эшләү өчен Россиянең төрле төбәкләреннән эшчеләр китерелә. Б.ның бер өлеше дә мәгъдәнле урыннарны эзләү, мәгъдән чыгару, заводларга чимал ташу, агач кисү һ.б. эшләргә җәлеп ителә.

Күчмә тормышлы Б. кыш айларында кышлау йортларында, җәй-көз айларында, башлыча, киез тирмәләрдә яшәгән. Ел фасылына һәм мал көтүлекләренә бәйле рәвештә «язгы йорт», «йәйләү», «көзге йорт» урыннары билгеләнгән. Утрак тормышка күчү барышында даими яшәү урыннары барлыкка килә. 18–19 йөзләргә кадәр кышлак-авыллар берничә кардәш гаиләне берләштергән бер нәселгә караган, тәртипсез рәвештә бер киртә эченә тупланган була һәм шул нәселгә билгеләнгән җир-биләмәнең уртасындарак, елга-күл буйларында урнаша. Соңга табарак утрак авыллар күбәя, алар зурая, урам-тыкрык тәртибе кертелә, аерым нәсел вәкилләре аларның бер өлешенә генә (урам, оч) урнашалар. 18–19 йөзләрдә берничә милләт вәкилләрен берләштерүче зур авыллар да оеша. Волость идарәләре, базар-ярминкәләр еш кына шундый авылларда урнаша. Кечерәк авыллар 10–20 йорттан торса, зурларында аларның саны 200–300 гә җитә.

Аерым ыруглар тарихына бәйле рәвештә көньяк һәм көнчыгыш Б.да 20 йөзнең 20 нче елларына кадәр 2 төрле тирмәләр — ярымшар рәвешендәге гомум төрки төре һәм монголлардагыча очлаеп килгәннәре файдаланыла. Урманга бай төньякта яшәүчеләрнең кышлау өе — бүрәнәдән, дала ягындагыларныкы саманнан, кисәкле кәстән яки балчыктан төзелә. Бүрәнә өйләр чоланлы, баераклары бер чолан б-н тоташтырылган 2,3,4 өйле була. 2 катлы бүрәнә өйләр дә очрый. Кайбер урыннарда андый өйләрнең аскы катында кыш көне мал асрала. Мал-туар, умарта кортлары, кошлар өчен, гадәттә, өстәмә корылмалар ко-

рыла. Дала ягы авылларында мал-туар аерым киртәлектә тотыла, кыш айлары өчен читәннән абзар-араннар үрелә. Өйләрнең түр башында, гомум төркичә — сәке, мич. Тәрәзә, мич тирәләренә пәрдә, кашагалар эленә, сәке, сандык өсләренә суккан палас, бизәкле киезләр ябыла. Идел-Урал аралыгындагы Б. тормыш-көнкүрешендә электән утрак тормышлы башка милләт вәкилләренең гореф-гадәтләре дә киң таралыш ала. Б.да ир-ат киеме: үсемлек сүсеннән тукылган күлмәк, балагы итек балтырына тыгыла торган киң төпле ыштан-чалбар. Өске киемнәр: камзул яки туры гәүдәле, киңәйтелгәнрәк чабулы чапан, җилән, көз-кыш өчен постау чикмән, иләнгән сарык тиресеннән тегелгән тун, толып. Баш киемнәре кешенең яшенә, социаль хәленә карап: түбәтәй, киез эшләпә, мал-җәнлек тиресеннән тегелгән йөнтәс «башкорт бүреге», яки түгәрәк илтер бүрек. Аяк киеме: күн яки киез итек, читек, күн башмак, көз-кыш айлары өчен йонлы ягы эчкә куеп тегелгән иләнгән тиредән аяк киеме яки киез ката. Идел-Урал аралыгы төбәкләрендә җәй айларында чабата кигәннәр. Б.да ир-атның өс-баш киеме, итек-читеге еш кына төсле һәм төрле рәвешле укалы тасма-бизәкләр б-н бизәлгән була.

Хатын-кыз киеме: бизәкләр б-н баетып тегелгән озын җиңле, бөрмәле киң озын итәкле күлмәк, еш кына аның өстеннән чигүле тасма б-н каймаланган яки чигеп бизәкләнгән алъяпкыч, бәрхет камзул, затлы җилән («елән»), төсле постаудан тегелгән, укалы тасма һәм көмеш тәңкәләр б-н бизәлгән чикмән. Яшьрәк хатыннар юка алтын-көмеш калайчыклар б-н бизәлгән күкрәкчәләр кигәннәр (төньяк һәм төньяк-көнчыгышта алар «муйынса», көньяк-көнчыгышта «сөлтәр», Дим елгасы буйларында «һакал» дип йөртелә. Арка яктан бизәкле «иңһәлек» б-н бергә киелә). Җиләннәр, туннар бәйрәм киеме саналган. Кызлар башында сәйлән-мәрҗәннәр б-н бизәп чигелгән, алпак кебек очлаеп килгән «такыя», сәйлән һәм кабырчык каурыйлар б-н бизәлгән калфак булган. Көньякта башкорт хатыннары башларына мәрҗәннәр тегелгән, көмеш асылмалар, тәңкәләр тагылган «кашмау» кигәннәр. Ул арка ягына да салынып төшкән. Урал-тауның арьягында башкорт хатыннары башларына укалап, мәрҗән-сәйләннәр тезеп чигелгән, вак көмеш тәңкәләр тагылган киң баш капламалары — «кушъяулык» бәйләгәннәр. Хатын-кызлар ш.у. затлы җәнлек мехыннан тегелгән бүрек тә киеп йөргәннәр. Урал арьягы башкорт хатын-кызлары аякка «ката» яки «сарык» дип аталган кием кигән. Андый итекнең башлары күннән тегелә, ак туладан эшләнгән кунычы кызыл постау яки комач аппликацияләр, башка төр бизәкләр б-н бизәлә. Хатын-кызның өс киеме төрле рәвештәге көмеш кисәкчекләре, тәңкәләр, мәрҗән, затлы ташлар (фирүзә, ахак) б-н мул бизәлә; колак алкалары, йөзек, беләзек, кием каптырмалары һәм чәчүргечләре дә шундый ук затлы әйберләр кулланып эшләнә. Б.ның гадәти ризыгы ит, сөт һәм он, ярмадан әзерләнә. Аларга сунарчылыктан кергән ризыклар, балык, бал, кыр-урман җиләк-җимеше, тәмләткеч үләннәр өстәлә. Ат һәм сарык итләренә өстенлек бирелә (бишбармак, куллама). Ит шулпасында яисә сөттә пешерелгән салма («һалма»), өйрә, төрле ярмадан боткалар әзерләнә. Сөзмәдән кышлыкка дип күп итеп корт («корот»), ат итеннән какланган тутырма, какламан кош итләре әзерләнә. Көндәлек ризыкта төче күмәчнең берничә төре, 18 йөздән башлап әче камырдан пешерелгән ипи кулланыла. Махсус үстерелгән яшелчә ризыклары, бәрәңге куллану Б. арасында XX йөздә генә гадәткә керә. Элек көндәлек эчемлек буларак әйрән, мәҗлесләрдә кымыз, әчеткән бал, үргән арпадан ясалган буза кулланылган.

Дини йолаларга бәйле Ураза һәм Корбан бәйрәмнәренә кадәр Б.ның берничә авыл бергә үткәргән иң олы бәйрәме *җыен* («йыйын») була. Элек ул ыруг җыены булган; 18 йөзгә кадәр хәзерге Башкортстан биләмәсенә кергән 4 даруга җыеннары үткәрелүе мәгълүм. Җыеннар җәй урталарында уздырылган, анда, бәйгеләрдән, бәйрәм уеннарыннан, мәҗлесләрдән тыш, ыругның гомуми мәсьәләләре дә хәл ителгән, сәүдә алыш-биреше һәм кыз бирү-алу (гаилә кору) килешүләре төзелгән. Җитди сәбәпләр булганда чираттан тыш җыеннар да җыелган. Болардан тыш, кайбер төбәкләрдә *Сабан туйлары*, Бәйге, Мәйдан уеннары да уздырылган. Хатын-кыз һәм балалар кошлар кайту көнен — Каргатуй бәйрәмен билгеләп үткән. Барлык төркиләргә хас башка дини-милли бәйрәмнәр дә булган. Җыен-йола бәйрәмнәрендә төрле уеннар, бәйге-көрәшләр, күмәк ашау-эчү оештырылган. Мөселман дине төсмерләре кергән дини һәм йола бәйрәмнәре каберлекләргә җыелып бару, күмәкләп дога укулар б-н тәмамланган. Болардан тыш, төрле гаилә йола-мәҗлесләре уздырылган (туйлар, бала тууны билгеләп үтү, үлем-китем йолаларын үтәү һ.б.).

*Әд.:* Руденко С.И. Башкиры: историко-этнографические очерки. М.–Л., 1955; Кузеев Р.Г. Происхождение башкирского народа: этнический состав, история расселения. М., 1974; шул ук. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала: Этногенетический взгляд на историю. М., 1992; Мажитов Н.А. Южный Урал в VII–XIV вв. М., 1977; Бикбулатов Н.В. Башкиры // Народы Поволжья и Приуралья. М., 1985; Народы России. М., 1994; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX в.). К., 1999; Башкиры: Этническая история и традиционная культура. Уфа, 2002; История Башкортостана с древнейших времён до наших дней. Уфа, 2004. Т. 1; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2005. Т. 1.

**«БАШКОРТСТА́Н»**, газета, к.*«Кызыл таң»*.

**«БАШКОРТСТА́Н КООПЕРА́ТОРЫ»**, икътисади журнал. «Башсоюз» кулланучылар җәмгыяте берлеге органы. 1922–24 елларда Уфада айга 2 тапкыр (1922 елда — рус, 1923 тән татар телендә) нәшер ителә. Мөхәррире Р.*Алуши*. Журнал кооперация идеяләрен пропагандалый, илнең икътисади хәлен анализлауга аерым игътибар бирә. Журналда крәстияннәр арасында а.х. белемнәрен һәм алдынгы тәҗрибәне тарату, күмәк хуҗалык итү формаларын тормышка ашыру турындагы материалларга зур урын бирелә.

*Әд.:* Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать (1905–1924). К., 1999; Мәдәнейәт фырунтында X йыл. Материалдар йыйынтыгы. Өфө, 1929.

**БАШКОРТСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, Россия Федерациясендә. Урал алдына һәм Көньяк Урал сөзәклекләренә урнашкан (1919 елның 23 мартында төзелә). Мәйданы — 143,6 мең *км*². Башкаласы — Уфа шәһәре. Халкы — 4104336 кеше (2002), ш.и. 990,7 мең (1939 да — 777,2, 1959 да — 768,6, 1970 тә — 944,5, 1979 да — 940,4, 1989 да — 1120,7 мең) татар яши. Б.Р. терр-ясе — татарлар өчен гадәти төпләнү урыны. Республиканың төньяк-көнбатыш өлеше Идел буе Болгар дәүләте, Казан ханлыгы йогынтысында була, 1550–80 елларда *Казан өязенә* керә. 1708–28 һәм 1731–34 тә Б.Р. терр-ясе (Уфа провинциясе) *Казан губернасына* буйсына.

Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татарларның күпчелеге, патша хөкүмәтенең дин тотуга, җиргә һ.б. хокукларын чикләү сәбәпле, яшәү урыннарын ташлап китәргә мәҗбүр була. Татарларның Урал алдына күченүләрендә төп фактор — башкорт халкы б-н этник, тарихи-мәдәни тугандашлык. Бу чорда татарлар күпләп республиканың төньяк-көнбатыш р-ннарына (Уфа өязенең Усы һәм Казан *даругалары* терр-ясе) килеп урнаша. *Асаба башкортлар* аларга үз җирләрендә кердәшләр (припущенниклар) буларак төпләнергә рөхсәт итәләр, һәм татарлар башкортларга йөкләтелгән ясакның бер өлешен үзләре түләргә тиеш була. Үз авылларын оештырудан тыш, татарлар башкорт авылларына да килеп урнаша, һәм тора-бара бу авылларның күбесе татар авылы булып китә. 17 йөзнең 70 елларыннан башлап Башкортстан терр-ясендә шәһәр-крепостьларда һәм чик буйларында хезмәт итү өчен Түбән Новгород һәм Касыйм төбәкләреннән күченгән йомышлы татарлар (*мишәрләр*, рус тарихи чыганакларында мещеряклар) шактый күбәя. 18 йөзнең 2 нче чирегендә татарлар миграциясенең Урал алдына икенче зур дулкыны хөкүмәтнең 1740–50 елларда Урта Идел һәм Урал буе халыкларын салым б-н изү һәм *христианлаштыру сәясәте* б-н бәйле. Бу чорда стихияле рәвештә күбесенчә ясаклы татарлар күченә. Яңа җирдә алар *типтәрләр* социаль төркеменә кушыла һәм 18 йөз ахырында бу төркемнең этник йөзен билгеләли. Болардан тыш Б.Р. терр-ясендә татарларның ямчы, лашман (к. *Лашманнар*), сәүдәгәр катлаулары оеша. Алар, кайдан килүләренә карап, берничә төргә бүленәләр: казанлылар, алатырлылар, төмәннәр (Темников ягыннан килүчеләр), һ.б. Күченгән татарлар үзләрендәге утрак тормышның мәдәниятен, игенчелектәге алдынгы хезмәт күнекмәләрен, терлекне абзарда асрау кебек яңалыкларны һәм ш.у. традицион кәсепчелек: күн, металл, агач эшкәртү, зәркәнчелек, тукучылык кәсепләрен Башкортстан җиренә алып килә. Алар, үз чиратында, җирле халыктан аучылык, кортчылык, балыкчылык, җәйләүле көтүчелекнең үзенчелекләрен үзләштерәләр. 17 йөз — 18 йөзләр ахырында патша хөкүмәтенең социаль-икътисади, дини һәм милли җәберләүләренә каршы *Башкорт-татар кузгалышларында*, *Батырша хәрәкәтендә*, Е.И.*Пугачёв* җитәкчелегендәге *Крәстияннәр кузгалышында* (1773–75), Башкортстанда яшәүче башка халыклар б-н бергә, татарлар

да катнаша. 1798 дә *Башкорт-мишәр гаскәренә* — татарларның бер өлеше (мишәрләр), 1855 тә типтәрләр килеп кушыла. Казан милли-мәдәни, дини һәм сәяси үзәк булган кебек, Уфа да татар халкы тарихында аерым бер урын алып тора. 1798 дә монда Уфа Диния мөселман кануннары җыены (к. *Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте*) оештырыла, аның утырышчылары, гадәттә, Казан губернасы татарлары була. 1906 да татар, башкорт, казакъ һ.б. төрки телле мөселман халкының иң эре мәгърифәт учагы — «*Галия*» мәдрәсәсе төзелә. 20 йөз башында шәһәрдә татар китапханәсе һәм китап сату конторасы эшли. 1906–07 дә татар телендә «*әл-Галәме әл-Ислами*» г-тасы нәшер ителә, 1912–22 дә татар драма театры эшли. 1917 елгы Февраль рев-циясеннән соң Башкортстандагы татарлар иҗтимагый-сәяси тормышка актив кушылалар. 1917–18 елларда Уфада төрки-татарларның милли парламенты — *Милләт Мәҗлесе* эшли. 1918 дә татар-башкорт хөкүмәтен — *Идел-Урал Штатын*, соңрак *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасын* төзү омтылышы була. Совет чорында Башкортстан АССР дәүләтенең идарә органнарын формалаштыруда һәм аларның эшчәнлегендә, икътисадның күп тармакларын (бигрәк тә нефть, химия һәм нефтехимия сәнәгате), сәламәтлек саклау һәм халык мәгарифе системаларын, фән, мәдәният, сәнгать, матбугат чараларын үстерүдә татарлар мөһим роль уйный. 1960–70 елларда республикада татар теленең йогынтысын чикләү, татарларны хөкүмәт һәм партия органнарындагы югары җаваплы урыннардан, матбугат чараларыннан, вузлардан, мәдәният учреждениеләреннән һ.б. өлкәләрдән кысрыклау һәм башкорт кадрлары б-н алыштыру тенденциясе урнаша. Бу шартларда татарларның бер өлеше формаль рәвештә үзен башкорт дип танырга мәҗбүр була. 1990–2000 еллар башында татарларны кысрыклау сәясәте яңа төс ала: күп кенә татар мәктәпләре һәм мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре ябыла һәм башкорт учреждениеләре итеп үзгәртелә. Татарлар, руслар һәм башкортлар сан ягыннан бер үк дәрәҗәдә булуга карамастан, татар теленә дәүләт теле статусы бирелми. 2002 елгы халык санын алу нәтиҗәләрен бозып күрсәтү аркасында республикада башкортлар саны татарлар исәбенә шактый артты. Болар барысы да Б.Р.нда яшәүче татарларга һәм ике республика арасындагы мөнәсәбәтләргә тискәре йогынты ясый. Хәзерге вакытта Башкортстанда татарлар күпчелекне тәшкил иткән 1000 нән артык торак пункт исәпләнә. Дүртөйле шәһәрендә, Бакалы, Бүздәк, Кыйгы, Эстәрлебаш, Чакмагыш, Чишмә р-ннарында татарлар барлык халыкның 50% тан артыгын тәшкил итә. Б.Р.нда 2 татар гимназиясе (Уфа, Бәләбәй ш.) эшли. 2005/2006 уку елында 715 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла, 404 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары Башкортстан дәүләт ун-тында, Эстәрлетамак, Бөре дәүләт педагогика ин-тларында әзерләнә. Соңгы икесендә һәм Бәләбәй педагогика көллиятендә мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә татар төркемнәре өчен тәрбиячеләр һәм татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф укытучылары әзерлиләр. Башлангыч сыйныф укытучыларын ш.у. Кушнаренко пед. уч-щесе, Уфаның 1 нче номерлы, Бәләбәй, Нефтекамск, Туймазы пед. көллиятләре; мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре өчен тәрбиячеләрне Эстәрлетамак пед. көллияте әзерли. 1991 дә «Башкортстан» Дәүләт телетапшырулар компаниясе структурасында татар телендә тапшырулар редакциясе оештырыла; татар халык педагогикасы мәсьәләләренә багышланган «Рәйхан», татар фольклоры турында «Сәйран» телевизион программалары, «Башкортстандагы татарлар» документаль фильмы эшләнелә. «Дуслар авазы» программасында Казан, Оренбург һ.б. төбәкләрдән тапшырулар татар телендә алып барыла. Радиоэфирга татар телендә «Бизәкләр», «Шигърият минутлары», «Әдәби укулар», «Сезнең өчен очрашулар», «Юлдаш» тапшырулары даими чыга. Б.Р.нда 46 татар халык иҗаты коллективы (2002), ш.и. 24 театр коллективы, 11 бию, 5 фольклор, 5 хор һәм 2 инструменталь ансамбль эшли. Татар балалар иҗаты үсә бара. Аеруча нәтиҗәле эшләүче коллективлар: Борай р-ны мәдәният йорты каршындагы «Энҗеләр» ансамбле, Кушнаренко, Дүртөйле балалар музыка мәктәпләренең хор коллективлары, Чакмагыш балалар сәнгать мәктәбенең «Күбәләкләр» бию ансамбле, *Чакмагыш районының* Тузлыкуш авылы мәдәният йорты каршындагы балалар фольклор ансамбле. 1991 дән *Нефтекамск* шәһәрендә Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы катнашында ел саен яшь башкаручыларның төбәкара «Дуслык моңы» татар һәм башкорт җырлары фестивале һәм «Азатлык» татар яшьләре берлеге б-н бергә республика (2001 дән — төбәкара) «Нәүрүз гүзәле» конкурсы уздырыла. Ике елга бер мәртәбә Уфада татар җырын башкаручыларның «Туган тел» конкурсы оештырыла. «Илһам чишмәләре» дип аталган шигырь бәйрәме, Г.*Тукай*, М.*Җәлил*, Ф.*Кәрим*, Ә.*Даутов* истәлекләренә багышланган кичәләргә халык яратып йөри. Б.Р.нда Татар иҗтимагый үзәге (Уфа, 1989), Башкортстан татарлары конгрессы, Башкортстан Республикасының татар язучылары берлеге, Башкортстанның «Азатлык» татар яшьләре берлеге (1990), «Мирас» татар иҗтимагый үзәге (Эстәрлетамак ш., 1990), Идел-Урал татар демократик партиясе (1991), «Нур» татар театры (Уфа), Татар драма театры (Туймазы ш.), татар морзалар җәмгыяте (1993) эшли. Татар телендә 3 республика, 5 шәһәр һәм 22 район вакытлы матбугаты нәшер ителә. ТР б-н Б.Р. арасында икътисади һәм мәдәни бәйләнешлар күптәннән килә. Татарстанда чыгарылган нефтьнең шактый өлеше Башкортстан пр-тиеләрендә эшкәртелә. 1991 һәм 1997 елларда ике республика арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела. Татар һәм башкорт мәдәнияте үзара мөнәсәбәтләр һәм даими бер-берсен тулыландыру исәбенә үсә. Башкортларның мәгариф, сәламәтлек саклау һәм фәннең төрле өлкәләре үсешендә *Казан университетының* һәм Казандагы башка уку йорларының роле зур. Күп кенә күренекле татар шәхесләре: татар һәм башкорт әдәбияты классиклары — *Акмулла*, М.*Гафури*, дин галиме, тарихчы Х.*Габәши*, шагыйрьләр: Ш.*Бабич*, Н.*Нәҗми*, И.*Юзеев*, Р.*Миңнуллин*, композитор С.*Габәши*, язучылар: Ә.*Еники*, Г.*Ибраһимов*, Н.*Исәнбәт*, Н.*Фәттах*, җырчылар Г.*Әлмөхәммәдов* һәм Ф.*Кудашева*, балетмейстер Ф.*Гаскәров* драматург Р.*Ишморат*, әдәбият галиме Н.*Юзиев* һ.б.ның тормыш юлы Б.Р. б-н бәйле.

*Әд.:* Асфандияров А.З. История сёл и деревень Башкортостана: В 7 кн. Уфа, 1990–1997; Башкортостан: Краткая энциклопедия. Уфа, 1996; Сафин Ф.Г. Вопросы этнической и языковой идентификации тюркского населения Республики Башкортостан. К., 2005; Якупов Р. Татары // Ватандаш. Уфа, 1999. № 8.

*А.И.Ногманов.*

**БАШКОРТСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ ТАТА́Р ЯЗУЧЫЛАРЫ́ БЕРЛЕГЕ́**, һөнәри, иҗтимагый, иҗади оешма. 1993 елда Уфа шәһәрендә татар мәдәнияте һәм әдәбияты үсешенә ярдәм итү, татар телендә китаплар бастыру һәм Башкортстан Респ-касында татар теленең яшәвенә шартлар тудыру максаты б-н оештырыла. 1994 тә 1 нче съезды була. Берлек ярдәмендә «Башкортстанның татар әдипләре» (баш. ред. С.Сафуанов) сериясеннән китаплар басыла. 2005 нең 1 гыйнварына 25 әгъза исәпләнә. Идарәнең рәисе — Рәиф Әмиров.

**«БАШКОРТСТА́Н ХӘБӘРЛӘРЕ»**, газета, к. «*Кызыл таң*».

**БАШКУ́РОВ** Рөстәм Шакир улы (16.5.1927, Горький өлкәсенең Сергач р-ны Камкино а. — 5.4.1967, Казан), әдәбият белгече, филол. фән. канд. (1958). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1950), 50–60 нчы елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре, башлыча, Г.Тукай тормышына һәм иҗатына, татар һәм рус әдәбиятларының бәйләнешларына карый.

Хезм.: Тукай һәм рус әдәбияты. К., 1958; История татарской советской литературы (автордаш). К., 1965; Навсегда в сердце народа (Жизнь и творчество Габдуллы Тукая) (автордаш). К., 1966.

*Әд.:* Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблигр. словарь. К., 1970.

**«БАШЛАНГЫ́Ч МӘКТӘ́П»**, журнал, к. «*Мәгариф*».

**«БАШЛА́П УКУ́ ГӘЗИТЕ́»**, к. «*Культармеец газеты*».

**«БАШМАГЫ́М»**, шаян эчтәлекле халык җыры. Татарлар күпләп яшәгән барлык төбәкләрдә дә мәгълүм, шактый вариантлары бар. Татар җырларына хас булмаган диалогка нигезләнә. Текст беренче тапкыр фин галиме Һ.Паасоненның «Татар җырлары...» («Татарские песни, собранные и переведённые Х.Паасоненом», 1901, Хельсинки) исемле китабында татар һәм немец телләрендә басылган. Җырның эчтәлеге: егет кызның башмагын яшерә, кыз аны кире кайтаруын үтенә. «Б.»ның кайбер вариантларында башмагын югалткан кызның кайгыруы һәм аны табарга омтылуы турында мөнәҗәт формасында сөйләнә. «Б.» темасына беренче сәхнә



Җ.Фәйзинең «Башмагым» муз. комедиясе Татар опера һәм балет театры куелышында. 1. Гомуми күренеш; 2. Ф.Насретдинов — Галимҗан, М.Рахманкулова — Җиһан (уэктә), Ә.Галимова — Сәрвәр рольләрендә.

әсәрен Х.Ибраһимов яза, һәм ул комедия 1920 елларда Оренбург сәхнәсендә куела. Комп. Җ.Фәйзи б-н драматург Т.Гыйззәт «Б.» җырының сюжетын һәм көен шул исемдәге муз. комедия иҗат иткәндә файдаланалар.

*Әд.:* Б ә д и г ы й Хуҗа. Халык әдәбияты. Бәетләр. К., 1913.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«БАШМАГЫ́М»**, музыкаль комедия, 3 пәрдәдә. Җ.Фәйзи музыкасы, Х.Ибраһимовның шул исемдәге пьесасы буенча Т.Гыйззәт либреттосы. Беренче татар муз. комедиясе. Премьерасы 1942 елның 1 мартында Татар опера һәм балет театрында була (дирижёры И.Әүхәдиев, реж. С.Вәлиев-Сульва, баш рольләрдә: Галимҗан — Ф.Насретдинов һәм Сәрвәр — Г.Кайбицкая). Әсәрнең сюжеты нигезендә — алтын б-н чигелгән югалган башмакларны эзләү вакыйгасы. Комедиядә революциягә кадәрге татар сәүдәгәрләренең көнкүреше яктыртыла. Төп геройлары — гашыйк парлар, бай, әмма күңел теләмәгән кияү, димче хатын һәм спектакльдәге башка традицион типажлар. «Б.»да яшь буын вәкилләренең искергән тәртипләр б-н көрәше сурәтләнә. Комедия юморга, хискә, җырлы-биюле күренешләргә, якты-лирик көйләргә бай. Спектакльнең төп муз. образы — татар халык җыры «*Башмагым*». Әсәрнең муз. драматургиясе Сәрвәр б-н Галимҗанның уңай образларын тасвирлаучы шатлыклы, якты лирик көйләрне тискәре персонажлар Кәрим бай һәм Гафуровларның сатирик портретларын күрсәтүче музыкага капма-каршы куюга корылган. «Б.» халык җырлары интонацияләренә нигезләнгәнгә күрә матур, аһәңле музыкасы б-н аерылып тора. «Б.» комедиясе СССР театрлары сәхнәләрендә рус, үзбәк, тува, казакъ телләрендә зур уңышлар б-н куела. Татар муз. театры репертуарына иң еш кертелгән спектакльләрнең берсе.

*Әд.:* Г и р ш м а н Я. Опера, балет, музыкальная комедия // Музыкальная культура Советской Татарии. М., 1959; Х а л д е е в а Д. Файзи Джаудат // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; С а л и т о в а Ф. Начало пути (1939–50) // Татарский академический театр оперы и балета им. Мусы Джалиля. К., 1994.

**БАШМА́К**, татар милли аяк киеме. Йомшак яисә каты табанлы, башы б-н арткы өлеше бергә кушылмыйча, аерым-аерым табаны кырыена гына тоташтырып тегелә. 19 йөздә Б.ны, нигездә, шәһәр халкы (ир-атлар — өйдә, хатын-кызлар бәйрәмдә) кигән. Ирләр өчен төсле күннән, бизәкләмичә, ә хатын-кызларга купшы бизәкләр кертеп тегелә. Бәрхет яисә хәтфәдән (еш кына яшел, зәңгәр, куе кызыл төстә) тегелә, баш ягына мәрҗән, сәйлән, төрле төстәге ефәк, алтын-көмеш җепләр



Хатын-кыз башмагы. 19 – 20 йөзләр. Укалап чигү. ТР Милли музее.

б-н чәчәк бәйләме яки аерым чәчәк рәвешендәге бизәк төшерелә. Б. тегүдә кулланыла торган үзенчәлекле алым — «*күн мозаикасы*» — төрле төстәге сафьян бизәк кисәкләрен типчеп яки чигеп барудан гыйбарәт. Бормалы геометрик фигуралардан җыелган бизәкләр аяк киеменең башына да, арткы өлешенә дә типчелә. Б. тегү б-н, башлыча, Казан һәм Казан арты осталары шөгыльләнә; кисү һәм тегүне — ир-атлар, бизәк мозаикасын типчеп урнаштыру, бәрхет туфлиләргә чигеш салуны хатын-кызлар башкарган. Б. элек-электән яратып киелгән, татарларда гына түгел, рус аксөякләре арасында да бәйрәм киеменең бер өлеше булып торган. 18 йөз ахырында, беренче аяк киеме җитештерү мануфактуралары барлыкка килгәч, бизәкле Б.ның популярлыгы үсә, аның б-н сәүдә итү арта. Әүвәлге үрнәктәге һәм яңа фасонлы Б. (үкчәле, артсыз) Урта Азиядә һәм Казакъстанда, ш.у. Көнбатыш Европа илләрендә тарала. Татар аяк киеме Оренбург, Касыйм, Бохара, Торжок шәһәрләрендә дә җитештерелә башлый. 20 йөзгә кергәндә әлеге үзенчәлекле нәфис кәсепчелек аерым төбәкләрдә генә сакланып кала. Хәзерге вакытта татар аяк киемнәре, ш.и. Б. *Арча милли аяк киеме җитештерү берләшмәсендә* генә тегелә. Ш.у.к. *Күн эшләнмәләр мануфактуралары.*

*Әд.:* З а л к и н д Г.М. Кустарная промышленность Татарстана. История и процесс производства обуви и головных уборов. К., 1931; В о р о б ь е в Н.И. Казанские татары. К., 1953; Г у л о в а Ф.Ф. Татарская национальная обувь (искусство кожаной мозаики). К., 1983; С у с л о в а С.В., М у х а м е д о в а Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

*Ф.Ф.Гулова.*

**БАШМА́КОВ** Ибраһим Йосыф улы (1893, Пенза губ., Инсар өязе Үрләдем а. — 5.10.1913, Оренбург ш.), шагыйрь. «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа ш.) укый. «Вакыт» г-тасы, «Шура» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә, шунда ук беренче шигырьләрен һәм тәрҗемәләрен бастыра. Аерым шигырьләре «Яңа әдәбият» (1914, төз. Г.Ибраһимов һәм Г.Баттал), «Көрәш җырлары» (1923, төз. Ф.Бурнаш) җыентыклары-на, «Татар поэзиясе антологиясе»нә (1956, 1992) кертелгән.

*Әд.:* Б ә к е р К. Ибраһим Башмаков (вафат) // Вакыт. 1913. 10 окт.; Мәрхүм шагыйрь: (Яшь шагыйрь Ибраһим Башмаковның үлүе турында) // Аң. 1913. № 20; История татарской советской литературы. М., 1985.

**БАШМАКО́В** Игорь Николаевич (11.5.1943, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд ш.), бизәлеш сәнгате рәссамы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). Мәскәү югары сәнгать-сәнәгать уч-щесен (элек Строганов исем.) тәмамлаганнан соң (1975), ТР сәнгать фондында эшли, 1979–82 елларда — баш рәссам, 1985 тән «Ирек» иҗат остаханәсе (Казан) рәссамы. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1983). Б. металл пластикасы, скульптура, зәркән сәнгате әсәрләре иҗат итә. Җәмәгать биналары интерьерлары (металлдан дивар паннолары, яктырткычлар, эмблемалар, төрле композицияләр) бизәлеше авторы. Әсәрләренең тематикасы һәм жанрлары күптөрле: анималистика, иске Казанның архит-ра күренешләре, символик-аллегорик композицияләр, татар фольклоры образлары. Әсәрләре абстракт элементларның реалистик формалар б-н үрелеп баруы, композицияләрнең динамикалы булуы б-н аерылып тора. Төп әсәрләре: Мәскәүдәге Олимпия авылындагы рестораннар комплексы өчен люстра (1975), Лейпциг шәһәрендәге Халыкара сәүдә-сәнәгать ярминкәсендә СССР павильонының ТАССР экспозициясендә карта рәвешендәге панно (1980); Әфганстанда һәлак булган сугышчылар истәлегенә Чистай шәһәрендә «Торналар» дип исемләнгән һәйкәл (1989); «Казан — шагыйрьләр каласы» декоратив рельефлар сериясе (1990); Казан ипподромы капкасы алдында «Җайдак» сыны (1993); Раифа монастыре диварында манара очындагы «Быргыда уйнаучы фәрештә» дип аталган (1998) сын; Казанның Тукай мәйданында «Су анасы» дип исемләнгән фонтан сыны (1998) һәм монументаль бизәлеш композициясе (1999); Казанда уздырыла торган Ф.Шаляпин исем. фестивальгә багышланган истәлек медальләре сериясе (1980–90 еллар); Г.Тукай әсәр-



И.Н. Б а ш м а к о в. «Табигать». Декоратив панно. Бакыр, җиз. 1980 нче еллар.

ләре мотивларына нигезләнгән фигуралар б-н бизәлгән шәмдәлләр сериясе (1999), Казан ун-тының тарих ф-теты бинасы каршындагы «Шар» фонтан-сыны, Казан метрополитенының «Сукно бистәсе» станциясендәге декоратив фонарьлар сериясе (2005), «Корстон» кунакханә-сәүдә комплексы бинасы каршындагы «Җил» сыны (2007) бөтенсоюз («Без коммунизм төзибез», 1981), бөтенроссия (РСФСР монументаль рәссамнарның 3 нче күргәзмәсе, 1977) һәм респ-ка (1968 дән) күргәзмәләрендә, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамнарының Сиэтл шәһәрендә үткәрелгән халыкара симпозиумында (АКШ, 1994) катнаша.

Әсәрләре ТР Дәүләт сәнгать музеенда, «Казан» милли-мәдәни үзәгенең Милли мәдәният музеенда, ТР Милли музеенда, Россиядәге һәм чит илләрдәге (Польша, АКШ) шәхси тупланмаларда саклана. Б.Урманче исем. республика бүләге лауреаты (2003).

*Е.П.Ключевская.*

**БАШМАКОВЛА́Р КИТА́П БАСУ́ һӘМ КИТА́П САТУ́ ШИРКӘТЕ́.** 1890 елда Казан сәүдәгәре Н.Я.Башмаков нигез сала. 1890 еллар уртасыннан, Казаннан тыш, Мәскәү һәм С.-Петербург шәһәрләрендә дә филиаллары була. Фәнни, пед. һәм популяр әчтәлектәге китаплар бастыру б-н шөгыльләнә. Алар арасында Казан ун-ты галимнәренең хезмәтләре: В.М.Бехтеревның «Неврология гыйлеменең хәзерге үсеше турында» («О современном развитии неврологических знаний», 1893), А.Смирновның «Табигать һәм сәнгатьтәге матурлык турындагы эстетика фәне» («Эстетика как наука о прекрасном в природе и искусстве», 1894), Г.Ф.Шершеневичның «Рус гражданлык хокукы дәреслеге» («Учебник русского гражданского права», 1911) һ.б. Бертуган Башмаковлар ярдәмендә Казан ун-ты каршындагы Невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыятенең матбугат басмасы «Неврологик вестник»ның беренче ике саны чыга. Башмаковларның китап кибетендә фәннең төрле өлкәләренә караган китаплар, географик карта, атласлар сатыла, Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә нәшер ителә торган газета-журналларга язылу мөмкинлеге була. Үзләрендә басылган китапларның исемнәре сәүдә һәм нәшрият каталогларында күрсәтелә.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895.

*Г.Г.Габделганиева.*


**БАШМАКЧӘЧӘ́К**, к ә к к ү к ч и т е г е (Cypripedium), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 ләп төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Американың уртача зонасында киң таралган. Тамырчасы калын, үрмәләүче. Туры сабаклы, 3–4 эллиптик формадагы очлы яфраклы. Чәчәкләре ялгыз, эре, төрле төстә, түбәнге аерчасы кабартылган башмак формасында (исеме дә шуннан). Җимеше — тартмачык. ТРда 3 төре бар. Чын Б. яки Венера Б. (C. calceolus), — бер яки ике, сирәк кенә өч



Эре чәчәкле башмакчәчәк.

чәчәкле, 20–50 *см* озынлыктагы үсемлек, кызыл тимгелле ачык сары иренчәле, кызгылт-сары төстәге, ванилин исе килә торган калган яфраклары чәчәклек янында. Көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш р-ннарда очрый. Үндырышлы, известьле токымнар б-н тушәлгән дымлы туфракларда яхшы үсә. Эре чәчәкле Б. (C.macranthon) — куе кызыл аерчалы аксыл шәмәхә яки шәмәхә-алсу төстәге чәчәге булган 20–40 *см* озынлыктагы үсемлек. Биектау, Минзәлә һәм Тукай р-ннарында очрый. Тимгелле Б. (C. guttatum) — 15–30 *см* озынлыкта, чәчәге ак тимгелле куе кызыл төстә. Барлык төрләре дә май уртасы — июльдә чәчәк ата, орлыклары август аенда өлгерә. Орлыклардан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Б. — декоратив үсемлек. Аны үстерү б-н Казан зооботаника бакчасы, ш.у. чәчәк үстерүче һәвәскәрләр шөгыльләнә. 3 төре дә сирәгәеп бара, ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Определитель растений Татарской АССР. К., 1979; Красная книга Республики Татарстан. К., 1995.




Г.С. Баштанюк.

**БАШТАНЮ́К** Геннадий Сергеевич (22.10.1949, Курск өлкәсенең Хомутовск р-ны Хомутовка а.), профсоюз эшлеклесе, Соц. Хезмәт Герое (1986). Мәскәүдә һөнәри-техник уч-ще тәмамлый (1967). 1967–68 елларда Мәскәүнең 1 нче ситсы һәм 1970 тә тукыма мануф-каларында, 1970–72 дә Мәскәү өлкәсе Орехово-Зуево шәһәренең «Карболит» з-дында слесарь булып эшли. 1972–86 елларда КамАЗда: 1975 тән башта — көйләүче-слесарьлар, соңыннан — ремонтчы-слесарьлар бригадиры. 1986–89 да Профсоюзларның Татарстан өлкә советы рәисе. 1990–92 дә СССР ВЦСПСында эшли, соңрак Профсоюзларның гомуми конфедерациясе рәисе урынбасары була. 1986–90 да ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**БАШЧЫ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 50 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2002 елда 241 кеше (татарлар — 64%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау, умартачылык. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сурково исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, бакчачылык б-н шөгыльләнә; читкә китеп, Сембер губернасының якынрак урнашкан өяз авылларында кара эшче, приказчик, йөк ташучы, такта яручы, балта остасы булып эшли. 1894 тә Б.да чиркәү-приход мәктәбе ачыла. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 2059,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Сөендек волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930





И.Н. Б а ш м а к о в. 1. «Җайдак». Бакыр. 1993; 2. Декоратив скульптура. Бакыр. 1995. «Казан» санаторие.



Г. Баязитов.



Әхсән Баян.

ның 10 августыннан — Буа, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 996, 1897 дә — 1672, 1910 да — 1538, 1920 дә — 1464, 1926 да — 1435, 1938 дә — 1046, 1949 да — 612, 1958 дә — 499, 1970 тә — 401, 1979 да — 338, 1989 да — 238 кеше.

**БАЯЗИ́ТОВ** Гатаулла (1846, Рязань губ., Касыйм өязе Төмәнсу а. — 21.4.1911, С.-Петербург), дин галиме, публицист. Башлангыч белемне атасы мәдрәсәсендә ала. Укуын Касыйм шәһәре янындагы Чутай авылының «Байморат» мәдрәсәсендә, соңрак Казан губернасы Казан өязенең Кышкар авылы мәдрәсәсендә дәвам итә. Чутай авылына кайтып, мәдрәсәдә мантыйк һәм фәлсәфә укыта. 1871 елда С.-Петербургка чакырыла, анда 2 нче мөселман мәхәлләсен җитәкли, соңрак хәрби ахун итеп билгеләнә. Бер үк вакытта Россия Тышкы эшләр министрлыгы Азия департаментының Көнчыгыш телләр бүлегендә тәрҗемәче һәм төрки телләр укытучысы була, С.-Петербургның төрле уку йортларында, ш.и. Пажлар корпусында ислам дине нигезләрен укыта. 1880 елларда, татар һәм рус телләрендә «Һәфтә» («Атна») г-тасы чыгарырга рөхсәт сорап, хакимияткә мөрәҗәгать итә. Үтенече кире кагылгач, башка г-талар чыгарырга омтылыш ясый. Бу үтенечләре дә кире кагыла. 1905 тә «*Нур*» г-тасын гамәлгә куя, аның нашире һәм мөхәррире була. Б. 1881 дә үк С.-Петербургта мәчет салырга рөхсәт сорап хакимияткә мөрәҗәгать итә. 1906 да хөкүмәт тарафыннан расланган мәчетне төзү өчен Махсус иганә җыю комитетын җитәкли. 1910 да Петербург җамигъ мәчете нигезенә беренче таш салу тантанасы була.

1880–90 да язган хезмәтләре Россиядә һәм чит илләрдә (төрек һәм француз телләренә тәрҗемә ителә) танылу ала. Аның «Эрнст Ренан чыгышына тәнкыйть» (СПб., 1883) китабы күренекле француз галиме Э.Ренанның, ислам б-н тәгәл фәннәр яраклаша алмый, дигән идеяләренә каршы чыга. Б. ислам тәгълиматының мантыйкка һәм фәнни гыйлемнәргә каршы килмәвен исбатлый, Э.Ренанның исламны җитди фәнни методологиягә нигезләнмичә тикшерүен тәнкыйть итә. «Исламның фәнгә һәм башка диндәгеләргә карата мөнәсәбәте» китабында (СПб., 1887) Б. башка дин вәкилләренә карата ихтирам исламның әсаси принципларының берсе булуын дәлилли. Мөселманнарның рухи халәтен татар җәмгыятенең эчке ихтыяҗларыннан, ш.у. Россиядә барган вакыйгалардан чыгып бәяли.

Х е з м.: Магомет как пророк. СПб., 1887; Ислам и прогресс. СПб., 1898.

*Әд.:* А м и н о в Д.А. Татары в Санкт-Петербурге. СПб., 1994; М у х а м е т ш и н Р. Гатаулла Баязитов // Исторические портреты. Татарская интеллигенция и духовная культура. К., 2000.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**БАЯЗИ́ТОВ** Кеазыйм Садыйк улы (12.4.1948, Таҗикстан ССРның Ленинабад өлкәсе Табатар а.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре. Казан авыл хуҗалыгы ин-тын тәмамлый (1974). 1967–77 елларда Аксубай р-нында эшли: «Үсәр» к-зы комсомол оешмасы секретаре, 1969–74 тә ВЛКСМ райкомында бүлек мөдире, секретарь, 1 нче секретарь, 1975–77 дә «Татсельхозводстрой» тресты-ның ПМК-122 башлыгы. 1977–80 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1980–87 дә Кама Тамагы р-ны халык депутатлары сов. башкарма ком-ты рәисе. 1987–92 дә Кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе урынбасары, 1992–96 да рәисе. 1996–2002 елларда ТРның Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 2002–04 елларда «Татарстан стандартлаштыру, метрология һәм сертификация үзәге» федераль дәүләт идарәсендә директор урынбасары, 2004 тән ТРда Техник көйләү һәм метрология буенча федераль агентлыкның Идел буе төбәкара идарәсенең дәүләт күзәтүе буенча территориаль инспекция башлыгы. ТРның Мактау грамотасы, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Больше века на службе людям: из истории потребительской кооперации Республики Татарстан. К., 1995 (автордаш); Защита прав потребителей в Республике Татарстан. К., 1999.

**БАЯЗИ́ТОВ** Мөхәммәдсафа Гатаулла улы (1885, С.-Петербург — 26.12.1937, Казан), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Г.Баязитовның улы. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә (Казан) һәм Петербург ун-тының Көнчыгыш телләре ф-тында белем ала. 1911 елдан С.-Петербургның 2 нче мәхәлләсе имамы, соңрак С.-Петербург ахуны һәм Петербург хәрби округы имамы, шул ук вакытта хәрби уку йортларында ислам мөгаллиме, Россия Тышкы эшләр министрлыгы тәрҗемәчесе. 1911 дән «*Нур*» г-тасының мөхәррире һәм нашире. 1914 тә С.-Петербургта Бөтенроссия мөселманнарының «Сыйрател-мөстәкыйм» («Туры юл») берлеген оештыра һәм аның җитәкчесе була. Әлеге берлек, замандашлары фикеренчә, «үтә консерватив» карашларны алга сөрә. Б. 1915 нең июлендә Оренбург мөселманнар Диния нәзарәте мөфтие итеп билгеләнә, бу хәл мөселман җәмәгатьчелегендә һәм 4 нче Дәүләт думасының мөселман фракциясе әгъзалары арасында ризасызлык тудыра, матбугатта Б.ка карата тәнкыйть мәкаләләре басыла. 1916 да Б. Уфада Диния нәзарәтенең рәсми басмасы — «*Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи* Ырынбургыя» ж-лын чыгаруны яңарта. 1917 дә Февр. рев-циясеннән соң, Уфа иҗтимагый оешмалары ком-ты карары б-н, март уртасына кадәр өендә ябып тотыла. 1918 дән Петроград мәчете имамы. Репрессияләр корбаны.

**БАЯЗИ́ТОВ** Рөстәм Мәхмүт улы (17.12.1946, Владивосток ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1999). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физ.-техника ин-тында эшли, 1999 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 2003 тән интенсив радиация тәэсирләре лаб. мөдире. Хезмәтләре каты җисемнәргә ионнар кертү һәм аларны импульслы нурланыш б-н үзгәртүгә карый. Импульслы яктылык, электрон, ион нурланышлары көлтәләре б-н тәэсир иткән тотрыксыз темп-ра кырларын хисаплау методикасын эшли. Ярымүткәргеч материалларны һәм структураларны импульслап эшкәртүне оптимальләштерү ысулын тәкъдим итә. И.Б.Хәйбуллин б-н берлектә *лазер нурында чыныктыру* күренешен ача (1973). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1988).

Х е з м.: Локальный лазерный отжиг ионно-легированных полупроводниковых слоёв // Физика и техника полупроводников. 1975. Т. 9, № 10 (автордаш); Модификация структуры и электрическая активация примеси при наносекундном лазерном отжиге имплантированного кремния // Физика и техника полупроводников. 1988. Т. 22, № 1 (автордаш); Формирование слоёв кубического карбида кремния на кремнии непрерывными и импульсивными пучками ионов углерода // Журн. техн. физики. 2003. Т. 73, № 6; Pulsed particle beam treatment of implanted silicon // Vacuum. 1992. V.43, № 5–7 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**БАЯЗИ́ТОВА** Флёра Сәет кызы (2.1.1942, Балтач р-ны Иске Салавыч а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1999), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1964 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1996 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты). Хезмәтләре диалектология, этнолингвистикага, татар теле тарихы һәм татар халкының рухи мәдәниятенә, традицион гаилә һәм календарь йолаларына карый.

Х е з м.: Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. К., 1997; Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. М., 1986.

*Әд.:* Кто есть кто в изучении народов и национальных проблем России. М., 1995; Тюркологи Татарстана. М., 1997.

**БАЯЗИ́ТСКИЙ** (Вәлиев) Зәки Вәли улы (1889–1959, Казан), драма актёры, режиссёр, театр эшлеклесе. Хезмәт Батыры (1926). 1908 елдан «Сәйяр» труппасы актёры. Татар проф. театрының формалашуында һәм үсешендә сизелерлек роль уйный. Ирләр һәм хатын-кыз рольләрен башкара: Нәгыймә («Банкрот», Г.Камал), Феклуша («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Җаббар («Ачлык кушты», Я.Вәли), Әхмәт («Яшьләр», Ф.Әмирхан) һ.б. 1914–16 елларда «Төркестан» үзбәк труппасы җитәкчесе А.Авлони чакыруы буенча Ташкентта режиссёр һәм актёрлык осталыгы буенча педагог булып эшли. 1917 дә «Нур» труппасында актёр һәм режиссёр. Гражданнар сугышы елларында фронт театр труппаларында эшли. 1923–24 тә Татар театр техникумының беренче директоры, 1924–26 да Татар дәүләт театры (хәзерге Татар акад. театры) директоры. Б. җитәкчелегендә даими эшли торган беренче проф. татар театр труппасы формалаша, театр бинасы яңартыла (элекке Сәүдәгәрләр җыены, хәзерге Яшь

тамашачылар театры). 1938 дә репрессияләнә, 1954 елда аклана.

*И.И.Илялова.*

**БАЯН**, к. *Батбаян.*

**БАЯ́Н** (13 йөз), болгар бәге. 1235–36 елларда монголлар ягына чыга. Монголлар Идел буе Болгарын яулап алып, көнбатышка юнәлгәч, алар баскынлыгына каршы күтәрелгән халык кузгалышына җитәкчелек итә (к. *Баян белән Җик кузгалышы*). Шул көрәш барышында һәлак була.

*Әд.:* Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. М.–Л., 1941. Т. 2; Рашидаддин. Сборник летописей. М.–Л., 1960. Т. 2; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Е г о р о в В.Л. Историческая геофрафия Золотой Орды в 13–14 вв. М., 1985; Х а л и к о в А.Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. К., 1994.

**БАЯ́Н** (Баянов) Әхсән Фәтхелбаян улы (8.12.1927, хәзерге Башкортстан Респ-касының Илеш р-ны Әшмән а.), язучы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988), ТРның халык шагыйре (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1956), 1962 елга кадәр «Социалистик Татарстан» г-тасында хәбәрче, әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, 1962–66 елларда «Казан утлары» ж-лының җаваплы сәркәтибе, 1977–81 дә баш мөхәррир урынбасары вазифаларын үти. Әсәрләре 1950 елларда басыла башлый. Аның «Диңгез шавы» (1959), «Мират» (1963), «Әйт сүзеңне, яшьлек!» (1965), «Сез аңларсыз мине» (1971) китапларында тупланган лирик һәм фәлсәфи шигырьләрендә, балладаларында заман, яшәеш проблемалары, җәмгыятьтә кешенең роле турындагы фикерләре чагылыш таба. «Җәй — яшел кош» (1976), «Елларга сәяхәт» (1977), «Ак канатлар» (1983), «Кызыл ут» (1994) исемле шигырь һәм поэма җыентыкларында — шагыйрь замандашларының кичерешләре, яшәү мәгънәсе һәм аның матурлыгы, Туган иле һәм халкы, милләтнең үзбилгеләнеше өчен көрәше, рухи яңарышы һәм бәйсезлеге турындагы уйланулары б-н уртаклаша. Аның «Дүрт монолог» (1968), «Аязучан болытлы һава» (1978) повестьлары күңел җылылыгы, лиризм б-н сугарылган. «Яшьлегемне эзлим» (1966, рус теленә тәрҗемәсе «Ищу молодость», М., 1971), «Тау ягы повесте» (1972, рус теленә тәрҗемәсе «Повесть Горной стороны», 1978), «Төлке тоту кыен түгел» (1975) повестьларында тормышта үз урынын эзләүче, халык традицияләренә тугрылык сакларга омтылган яшь кеше образы чагыла. «Ут һәм Су» (1971), «Таш китап» (1981) романнары Кама буендагы гигант төзелеш картиналарын гыйбрәтле язмышлар аша сурәтли; төбәкнең экологик проблемаларына багышланган «Урланган ай» повесте өчен Б. Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була (1999). Б.ның прозасы романтик шартлылыгы, метафораларга һәм символик образларга бай булуы б-н аерылып тора. Б.ның драматургиясе дә үзенчәлекле. «Күзләре нинди иде» (1965), «Зәңгәр кыңгыраулар» (1972) психол. драмаларында хәзерге заман кешесенең әдәп-әхлак проблемалары үзәккә алына. «Һәйкәл» (1970), «Алтын кашбау» (1989) трагедияләре тарихи вакыйгаларга нигезләнеп язылган. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Кызыл ут. К., 1999; Сайланма әсәрләр: 5 томда. К., 2002; Тәкәрлек сагышы. К., 2007.

*Әд.:* Г а л и м у л л и н Ф. Шагыйрьнең прозасы // Казан утлары. 1994. № 5; Ә х м ә т җ а н о в М. Җирдә Прометей бар // Мәдәни җомга. 2000. 4 февр.; М у с т а ф и н Р. Человек и его дело // Литературное обозрение. 1979. № 6.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**БАЯ́Н БЕЛӘ́Н ҖИК КУЗГАЛЫШЫ́**, 1238–44 еллар тирәсендә болгарларның монгол баскыннарына каршы көрәше. Аның турында кыскача мәгълүмат Рәшидеддин, Юлиан һәм П.Карпини язмаларында теркәлгән. Вакыйга булган еллар төрлечә фаразлана: А.Х.Халиков б-н Р.Г.Фәхретдинов фикеренчә, ул 1238–40 елларга, В.Л.Егоров язуынча, 1243–44 кә туры килә. Монгол гаскәренең төп көчләре Идел буе Болгарын калдырып, рус кенәзлекләре б-н Көнбатыш Европа илләрен яуларга киткәч, монда калган баскын көчләргә каршы баш күтәрүләр башлана; җитәкчеләре *Баян* һәм *Җик* бәкләр була. Монголларның Сөбедәй җитәкчелегендәге гаскәре тарафыннан бу көчләр бастырыла. Баян б-н Җик һәлак була.

*Әд.:* Рашидаддин. Сборник летописей. М.–Л., 1960. Т. 2; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Е г о р о в В.Л. Историческая география Золотой Орды в 13–14 вв. М., 1985; Х а л и к о в А.Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. К., 1994.

*И.Л.Измайлов.*

**БАЯ́Н** (Баянов) Нур Галим улы (15.5.1905, Уфа губ., Минзәлә өязе Әнәк а. — 23.4.1945, Австрия), шагыйрь. Татар-башкорт хәрби мәктәбендә укый (1923–25). «Кызылармеец» г-тасында әдәби хезмәткәр (1928), «Колхоз яшьләре» ж-лы сәркәтибе (1929–30), Чаллы р-н газетасы мөхәррире (1930–32) булып эшли. 1932–38 елларда ТАССР Язучылар берлегенең оештыру ком-тында инструктор, Татарстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир. «Уракчы кызлар», «Җимерелгән окоплар» исемендәге беренче шигырь җыентыклары 1928 елда басылып чыга. Иҗатында Һ.Такташ йогынтысы сизелә. «Шлем кигәч», «Пост янында», «Әхмүшкә» кебек романтик рух, публицистик пафос б-н язылган шигырьләрендә Гражданнар сугышы, Кызыл Армия сугышчыларына дан җырлана. «Клеверлы кырлар» (1929), «Яңгырлы төн» (1933), «Гөләндәм» (1939), «Җимерелгән дворец янында» (1940) поэмалары авыл һәм шәһәр хезмәтчәннәренә багышлана. Б.ның Ватанны саклаучылар турындагы шигырьләре «Яшь сакчылар» (1934), «Ватан җыры» (1936), «Язгы төн» (1939) исемле җыентыкларга кертелгән. Б. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә, полк партия оешмасын җитәкли, дивизия газетасы мөхәррире, сәяси эшләр буенча полк командиры урынбасары була. Б.ның сугыш чоры поэзиясе патриотизм, совет халкының җиңүенә ышаныч б-н сугарылган (әсәрләренең бер өлеше югалган). Подполковник Б. Австрияне азат итү өчен барган сугышларның берсендә һәлак була. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1948; Шигырьләр, поэмалар. К., 1960; Гөләндәм. К., 2005.

*Әд.:* Х ә й р и Х. Шагыйрь Нур Баян // Әдәбият һәм тормыш. К., 1958; Ю з и е в Н. Тугры улың, халкым, мин сиңа // Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. К., 1969.

*З.М.Мәҗитов.*

**БАЯ́НОВ** Хәбиб Әгъләм улы (8.2.1950, Азнакай р-ны Кәкре Елга а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССР ның атказ. агрономы (1979). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), «Кәкре Елга» а. х. җитештерү кооперативында (1992 елга кадәр — колхоз, 1992–98 дә «Марс» катнаш пр-тиесе, 1998–2003 тә «Баянов һәм К°» күмәк ширкәте): агроном, баш агроном (1976 дан), рәис (1986–93, 1995–1997), директор (1993–95), ген. директор (1998 дән). Б. җитәкчелегендә дуңгыз үрчетү һәм симертү өчен 2 мең башка исәпләнгән бина, ашлык саклау амбары яңартып корыла, 20 тракторга исәпләнгән ремонтлау мастерское, 500 *м*² лы запас частьләр складı, машиналар өчен бина-мәйдан, 200 башка исәпләнгән мөгезле эре терлек симертү бинасы, 4240 *м*² мәйданлы 49 торак йорт, 25 урынлы балалар бакчасы, 2 мәчет, 26 *км* газ үткәргеч; 7666 *м*² мәйданда 11 аерым котельный, 10,1 *км* каты өслекле юл; плотина төзелә, 774 *га* җир сугарыла торган ителә, 341 авыл йортына һәм механика мастерскоена газ кертелә. 2001–05 тә 1991–95 б-н чагыштырганда хуҗалыкта ашлык җитештерү 28% ка, кишер-чөгендер — 11,5% ка, сөт — 56,9% ка арта. Табышлылык 10% тәшкил итә. Б. медаль, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьева.*

**БАЯ́НОВ** Эльбрус Әхсән улы (3.9.1958, Казан), спортчы (фехтование), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1979). Казан дәүләт пед. ин-тын тәмамлый (1982). Спорт б-н 1968 елда тренер Ф.*Хәсәновта* шөгыльләнә башлый. Шәхси һәм команда ярышларында СССР (1985, 1987, 1989), яшьләр арасында дөнья (1978) чемпионатларында, Бөтендөнья универсиадасында (1979), Дөнья чемпионатында (1981) җиңүче, Европа кубогына үткәрелгән бәйгедә көмеш медаль (1987) ала. 1982–92 дә һәм 1996 дан ТР Эчке эшләр министрлыгына караган оешмада хезмәт итә. 1992–96 да 3 нче балалар-яшүсмерләр олимпия әзерлеге махсус спорт мәктәбендә тренер. «Кылыч чыңы» («Сабельный звон», 1979) исемле китап авторы.

**БӘБИ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Симгә елгасы буенда. 2002 елда 20 кеше (татарлар) яши. 17 йөздә Олы Кариле авылыннан күчеп утыручылар нигез салган булуы ихтимал. 18–19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1849 да Б.дә мәчет төзелә, аның каршында мәктәп эшли. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1001,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең



М.Б. Бәдретдинов.



Ф.З. Бәдриев.

1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир заты; 1859 да — 392, 1882 дә — 595, 1897 дә — 666, 1909 да — 734, 1920 да — 725, 1926 да — 450, 1938 дә — 277, 1949 да — 172, 1958 дә — 137, 1970 тә — 114, 1979 да — 78, 1989 да — 36 кеше.

**БӘБКИ́** авылы, Буа районында, Буа шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2002 елда 34 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөз башыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.дә Троица чиркәве, мәчет, чиркәү-приход мәктәбе, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр, 1 шәһәр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1242 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Фролово волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир заты; 1859 да — 579, 1908 дә — 1329, 1920 дә — 1181, 1926 да — 1005, 1989 да — 86 кеше.

**«БӘДӘВА́М»** (гарәп. بدوام — кабатлана торган), дини әдәбият ядкәре. Авторы мәгълүм түгел. Шигъри калыпта язылган.

Кайбер фаразлар буенча, Идел буе Болгар дәүләте чорында иҗат ителгән. Китапта искә алынган мәҗүсилек йолаларына һәм гадәтләренә каршы көрәшкә чакыру шуңа ишарәли. «Б.» 17–18 йөзләрдә язылган дигән фикер дә яшәп килә. Китапның исеме аның буеннан-буена кушымта сыйфатында кабатланып килгән «бәдәвам» сүзеннән алынган. Куплетның өч юлы үзара рифмалашып килә, дүртенче юлы барлык куплетлар өчен дә бертөрле: «Аллаһ дигел бәдәвам!» («Аллаһы исемен һәрвакыт зурла!»). Ихластан Ислам динен кабул итәргә өндәве, дәртле үгетләү үзлегенә ия булуы һәм теленең ачык аңлаешлылыгы, гадилеге б-н китап татарлар арасында кулъязма һәм басма рәвештә киң тарала. Казанда беренче мәртәбә 1846 елда нәшер ителә. Татар мәктәпләре һәм мәдрәсәләрендә дәреслек сыйфатында файдаланыла.

*Әд.:* Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы. К., 1922.

**БӘДЕРТДИ́НОВ** Владимир Арифулла улы (10.4.1947, Калинин өлкәсе Вышний Волочёк ш.), контр-адмирал (1989), хәрби фән. канд. (1997). Су асты югары хәрби диңгез уч-щесен (1970, Ленинград), Хәрби диңгез академиясен (1985, Ленинград) тәмамлый. 1980 елдан су асты крейсеры экипажы командиры, 1983 тән Тын Океан флоты су асты көймәләре берләшмәсе командиры урынбасары. 1990 нан РФ Хәрби диңгез флотының укыту үзәге башлыгы. Кызыл Байрак, Батырлык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**БӘДИГЫ́Й** Хуҗа Габделбәдигъ улы (1887, Казан губ., Мамадыш өязе Югары Бөрсет а. — 1940, Казан), тел галиме, фольклорчы. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый (1908), СССР ФАнең Ленинград Көнчыгышны өйрәнү ин-тында белемен күтәрә (1926–30). 1918–26 елларда Татар пед. техникумында һәм Казан мәктәпләрендә укыта, Академүзәктә эшли. 1930 дан Казан пед. ин-тында, 1938 дән профессор. Татар теленең фонетик, грамматик, лексик нормаларын өйрәнә. Хезмәтләре татар әдәби теле тарихына карый. Татар фольклоры җыентыкларын төзи. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар теле дәреслекләре авторы. Репрессияләр корбаны.

Х е з м.: Ана теле нәхүе. К., 1917; Ана теле сарыфы. К., 1919; Ана теле дәреслеге. К., 1919; Татар теле. Морфология. К., 1933.

*Әд.:* Хаков В.Х. Профессор Х.Бәдигый // Ватаным Татарстан. 1987. 30 дек; шул ук. Хуҗа Габделбәдигъ улы Бәдигый // Мәдәни җомга. 1997. 19 дек. *В.Х.Хаков.*

**БӘДРЕТДИ́НОВ** Миңнулла Бәдретдин улы (1901, хәзерге Башкортстан Респ-касының Тәтешле р-ны Чургылды а. — 29.9.1943), Сов. Союзы Герое (19.3.1944, вафатыннан соң), сержант (1943). Гражданнар сугышында катнаша. 1941 елга кадәр туган авылында колхозда эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 78 нче гв. укчы полкы укчысы (6 нчы армиянең 25 нче гв. укчы дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш һәм Воронеж фронтлары гаскәрләре составында Харьковны саклауда (1942), Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 26–29 сентябрендә Днепр елгасын кичкәндә Днепропетровск өлкәсенең Солонянский р-ны Войсковое авылы янында каһарманлык күрсәтә; уңъяк ярда плацдарм булдыру өчен барган бәрелештә һәлак була. Ленин, Кызыл Байрак орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1979. Кн. 4; Днепр — река героев. Киев, 1983. *В.А.Шагалов.*

**БӘДРЕТДИ́НОВ** Фәрит Таҗи улы (22.2.1951, Зәй р-ны Бура Киртә а.), спортчы (мотоцикл һәм автомобиль спорты), СССРның спорт остасы (1990), ТРның атказ. спорт остасы (1996). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1979). Автоспорт б-н 1968 елда шөгыльләнә башлый. Мотокросста (1978–79), автокросста (1996 — ВАЗ-2108 автомобилендә, 1997, «багги»), кышкы тректа (1997, 2000) һәм ипподромда (1978) узышу буенча Татарстан чемпионатларында җиңүче. Автокросста (1991–96, «багги»), кышкы тректа (1977, 2000) узышу буенча Россия чемпионы. Автокросс буенча (1990, «багги») СССР чемпионатында бронза медаль ала. 1979 елдан «КамАЗ» ачык АҖдә мастер, 1981 дән АвтоВАЗ махсус автомобильләр үзәгендә өлкән мастер, 1983 тән Эчке эшләр министрлыгының Зәй һәм Чаллы шәһәрләре оешмаларында, 1995 тән «КамАЗ» ачык АҖ корылмаларын саклаучы милиция бүлеге башлыгы (полковник, 1999).

*Әд.:* Покорение Высокой Горы. К., 1999.

**БӘДРИ́ЕВ** Илдар Борһан улы (2.7.1957, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (2001), проф. (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли, хисаплау математикасы кафедрасы проф. (2001 дән). Хезмәтләре матем. модельләштерүгә, матем. физиканың сызыкча булмаган мәсьәләләрен чишүнең санлы алымнарына карый. Кысылмаучан сыеклыкны чик градиентлы өзеклек законы буенча фильтрлауның сызыкча булмаган стационар мәсьәләләре модельләрен; челтәрле йомшак тышчалар теориясенең стационар матем. модельләрен; псевдомонотон операторлы вариатив тигезсезлекләр чишүнең итерацион алымнарын төзи һәм тикшерә.

Х е з м.: Методы двойственности в прикладных задачах. К., 1987 (автордаш.); Исследование сходимости итерационных методов решения некоторых вариационных неравенств с псевдомонотонными операторами // Дифференциальные уравнения. 2001. Т. 37, № 7 (автордаш.); Приближённые методы решения стационарных задач теории фильтрации с предельным градиентом и мягких оболочек // Актуальные проблемы математического моделирования и информатики. К., 2002.

**БӘДРИ́ЕВ** Фәез Зәйнетдин улы (19.12.1938, Минзәлә р-ны Бикбау а. — 17.1.2001, Минзәлә ш.), драма актёры, ТРның халык артисты (1995). Сәхнә эшчәнлеген 1959 елда Минзәлә драма театрында баянчы булып башлый. Берничә кечерәк рольдә уйнап, үзен эпизодик рольләр остасы итеп таныта. Табигый күзәтүчәнлеге, тормышны белүе, геройларның үз-үзләрен тоту манерасын чагылдырганда төгәл детальләр табу сәләте, тавышының тәэсирле, матур интонациясе актёрга бернич нечкә штрих б-н табигый, ышандырырлык образлар тудырырга ярдәм итә. Бигрәк тә олырак яшьтәге һәм характерлы рольләр ышандырырлык килеп чыга, ш.у. яшь геройларны да уйный. Рольләре: Миргали («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт), Илдар («Айгөл иле», М.Кәрим), Заһит («Һәйкәл», Ә.Баян), Илдус («Куендагы елан», Ә.Мирзаһитов), Гозәер («Август алмалары», Ә.Гаффар), Наил («Исемсез утрауда», М.Галиев), Мирсәлим («Гарасат», Г.Сабитов), Тиран («Соңгы төн», И.Юзеев), Ишан («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин). Х.Вахитның «Кияүләр» спектаклендә Җамали ролен башкаруы өчен К.Тинчурин исем. 2 нче Республика театр фестивале лауреаты исеменә лаек була (1992). Еш кына Минзәлә театры спектакльләренең музыканты һәм композиторы сыйфатында чыгыш ясый («Гармун һәм скрипка», Т.Миңнуллин; «Мәхәббәт яңгыры», Ф.Яруллин; «Беренче мәхәббәт», Х.Вахит һ.б.).

*Д.Гыймранова.*

**БӘДРИ́ЕВА** Илүсә Әхмәт кызы (19.12.1940, Алабуга р-ны Морт а.), драма актрисасы, ТАССРның халык артисткасы (1985). Алабуга мәдәни-агарту уч-щесен тәмамлаганнан соң (1959), Минзәлә татар драма театрына чакырыла, шуннан бирле аның сәхнәсендә 80 нән артык роль башкара. Якты, көчле сәләткә ия актриса буларак, баш рольләрдә уйный. Актрисаның уйнаган героинялары б-н эчке тәңгәллеге, тормыш хәлләренең охшашлыгы замандаш хатын-кызларның халыкчан, ышандырырлык образларын тудырырга, аларның рухи ихтыяҗларын ачарга, шәхес булып җитешүләрен, татар милләтенең рухи матурлыгын күрсәтергә ярдәм итә. Төп рольләре: Чәчәк («Чәчәкләр коела», Г.Сәгыйдуллин), Нурсәнә («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Айгөл («Айгөл иле», М.Кәрим), Лениза («Һәйкәл», Ә.Баян), Раушан («Борчулы минутлар», З.Шаһиморатов), Сөмбел («Гарасат», Г.Сабитов), Амель («Кара розалар», С.Җамал), Хәнифә («Качаклар», Н.Исәнбәт), Зифабану («Күч», К.Тинчурин), Василиса («Мария», А.Д.Салынский), Нина («Бусага», А.А.Дударев).



И.Ә. Бәдриева.

*Д.Гыймранова.*

**БӘДЫ́ЙГОВ** Габделхак Бәдигъ улы (7.8.1906, Самара губ., Бөгелмә өязе Яңа Шалты а. — 1978, Казан), сәясәт һәм профсоюз эшлеклесе. Татар пед. техникумын (1930), К.А.Тимирязев исем. Бөтенсоюз а.х. академиясен (1936) тәмамлый. 1937–39 елларда Зөя а.х. техникумында укыта. 1941–52 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында эшли; 1944 тән а.х. бүлеге мөдире. 1952–53 тә КПССның Чистай өлкә ком-ты 2 нче секретаре; 1953–54 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында а.х. бүлеге мөдире; 1954–57 дә секретарь. 1957–65 тә Профсоюзларның Татарстан өлкә советы рәисе. 1947–67 дә ТАССР ЮС депутаты, 1959–63 тә ТАССР ЮС рәисе. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М и р с и я п о в Т.А., Ф о м и н А.А. Профсоюзы Республики Татарстан: История, опыт, проблемы (1905–1995 гг.). К., 1995.

**БӘЕРЛЕ́** (Бәрле) авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 28 *км* төньяктарак, Шуман елгасы буенда. 2002 елда 87 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөздә нигез салына. Авыл башта Бөреле дип атала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сүс, киндер сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 тимерчелек, 3 җил һәм 1 ярма ярдыру тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 727,4 дис. тәшкил итә. 1912 дә А.Н.Раеваның шәхси мәктәбе ачыла. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Арча кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 165 ир заты; 1859 да — 237, 1897 дә — 294, 1920 дә 396, 1926 да — 350, 1938 дә — 420, 1949 да — 225, 1958 дә — 200, 1970 тә — 114, 1989 да — 79 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**БӘЕ́Т** (гарәп. «بيت» — ике юллы), эпик, лиро-эпик һәм лирик шигъри әсәр. Татар әдәбияты белемендә: а) язма һәм сөйләм формаларындагы, көйләп яки көйсез әйтелүче ике юллы шигырьдән торган, тәмамланган шигъри әсәр (2 дән 500 строфага кадәр); б) татар халкының шигъри иҗат жанры (Урта Идел буе татарлары иҗатының лиро-эпик төре). Жанр буларак, 14–15 йөзләрдә барлыкка килә.

Эчтәлеге б-н Б. конкрет тарихи вакыйгаларга һәм тормыш-көнкүреш хәлләренә бәйле. Тематикасы буенча күптөрле, мәс., хәрби-тарихи, солдат бәетләре, крәстиян чуалышлары, хатын-кызларның авыр тормышы, фаҗигале язмышлар турындагы бәетләр, сатирик, юмористик бәетләр һ.б. Әлеге жанрның беренче үрнәкләре — «Шәһри Болгар бәетләре» һәм «Казан тарихы». Аларда 13–14 йөзләрдәге фаҗигале вакыйгалар бәян ителә. Б. эпик фольклор традицияләренә нигезләнә: мәс., «Шәһри Болгар бәетләре», «Казан тарихы» һәм «Ханәкә солтан бәете» персонажлары арасында төркиләр эпосы образлары Чура батыр (Шорабатыр) һәм Ханәкә солтан зур урын алып торалар. Б. жанрының барлыкка килүендә һәм формалашуында ш.у. экияти-мифологик традицияләр дә зур роль уйнаган («Сак-Сок бәете»). Борынгы төрки (6–8 йөзләр) һәм борынгы Шәрекъ ядкәрләрендәге кебек үк, Б.ләрнең күбесенә беренче заттан хикәяләү хас.

Жанрның чәчәк атуы Россиядә һәм татарлар яшәгән төбәкләрдә фаҗигале вакыйгаларга бай булган 19 йөзгә туры килә. Бу чор Б.ләре традицион рәвештә берничә тематик төркемгә бүленә: тарихи-сугыш темасына багышланган Б.ләр («Рус-француз сугышы бәете»); хатын-кызлар язмышына кагылышлы Б.ләр; крәстиян, солдат, батрак, эшчеләрнең авыр тормышын чагылдырган Б.ләр; җир һәм ирек, милли һәм дини азатлык өчен көрәш турындагы Б.ләр (*«Урта Тигәнәле бәете»*, «Урта Әләзән бәете», «Чынлы бәете»).

Б. жанры үсеше 20 йөздә дә дәвам итә. 1920 еллардан 1990 еллар башына кадәр иҗат ителгән Б.ләр: а) Гражданнар сугышы чоры бәетләре; б) 1920–30 еллар бәетләре; в) Бөек Ватан сугышы чоры бәетләре; г) сугыштан соңгы еллар бәетләре төркемнәренә бүленә.

Гражданнар сугышы чоры Б.ләре дәвернең кискен каршылыкларын чагылдыра, җәмгыятьнең төрле катлау вәкилләре арасында барган канлы бәрелешләр турында сөйли («Гражданнар сугышы бәете», «Җаек суын кичкәндә», «Кызыл көрәшчеләр бәете»). Аларга киеренке характердагы хикәяләү, публицистик пафос, төгәл ритм һәм ачык чагылышлы рифмалар хас.

20–30 еллардагы Б.ләрдә чорның төп конфликтлары большевиклар һәм аларның дошманнары арасында барган көрәш корбаннары булган аерым кешеләр язмышы аша сурәтләнә («Мирсәет бәете», «Тәзкия матур» һ.б.). Б. жанры аеруча Бөек Ватан сугышы елларында зур үсеш ала. Сугыш шартларында язма әсәрләр иҗат итү кыенлаша һәм халык иҗатының сөйләм формалары өстенлек ала. Сугыш еллары Б.ләрен 2 жанр төркеменә бүләргә мөмкин: лиро-эпик һәм лирик бәетләр. Лиро-эпик Б.ләр әдәби үзенчәлекләре буенча традицион тарихи-сугыш темасына багышланган Б.ләргә һәм Гражданнар сугышы Б.ләренә якын торалар («Кызыл сугышчы бәете», «Мәскәүне саклау бәете»).

Лирик Б.нең барлыкка килүенә геройның катлаулы эчке дөньясын ачып салуны таләп иткән заман сәбәпче; жанрның үсешендә Б. бары тик эпик яки лиро-эпик хикәяләү алымы б-н чикләнә алмаган чор башлана. Халык лирикасының һәм язма поэзиянең иҗади принциплары тиз үзләштерелә. Сугыш еллары лирик Б.ләре төрле жанрлар — Б.ләр, халык җырлары һәм язма поэзиянең үзара бәйләнеше шартларында барлыкка килә («Салих улым», «Ана бәете», «Мин әтине онытмыйм» һ.б.).

20 йөзнең соңгы елларындагы фаҗигаләр, сугышлар, кораллы бәрелешләр Б. жанрының киләчәк үсешен билгели.

*Әд.:* Г а б д е л б ә д и г ъ Х у җ а. Халык әдәбияты. Бәетләр. К., 1935; Бәетләр. К., 1960; У р м а н ч е е в Ф. Совет чоры бәетләре // Казан утлары. 1966. № 6; Я р м и Х. Татар халкының поэтик иҗаты. К., 1967; У р м а н ч е е в Ф. Халык авазы. Татар халык бәетләре тарихыннан очерклар. К., 1974; Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983; Бәетләр. К., 2000; У р м а н ч е Ф. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. К., 2002.

*Ф.И.Урманчеев.*

**БӘҖӘНӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ыкның уң кушылдыгы. Озынлыгы 35,1 *км*, бассейнының мәйданы 308 *км*$^{2}$. Елга башы Мөслим р-нының Исәнсеф авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Актаныш р-ны Илтимер авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 69 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 3%. Б. елгасының 2 дән алып 8 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*$^{2}$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,25–1 *л/с·км*$^{2}$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 65 *мм*, ташу агымы катламы 54 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,1 *м*$^{3}$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 2,3 млн. *м*$^{3}$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БӘҖӘНӘКЛӘ́Р**, 8–9 йөзләрдә Идел аръягында оешкан төрки кабиләләр берләшмәсе. 9 йөзнең 2 нче яртысында Хәзәр каганлыгы аша сугышып үтеп, Көнчыгыш Европага ки-

леп төпләнәләр: Кара диңгезнең төньяк далаларын Дунай тамагына кадәр биләп алалар. Төп шөгыльләре — күчмә терлекчелек. Тәңрегә табынучылар. Ханнар тарафыннан идарә ителгәннәр. Яугир халык буларак, күрше дәүләтләрне (Венгрия, Русь һ.б.) еш борчыйлар; Византиягә йөз тоткан елларда Хәзәр каганлыгына каршы, хәзәрләр яклы булганда, Византиягә каршы яуларда катнашу очраклары мәгълүм. 965 елда Киев кенәзе Святослав б-н бергә Хәзәр каганлыгын тар-мар итүдә катнашалар. 1036 елда бөек кенәз Ярослав Мудрый Киев янында Б.не җиңә. Бер үк вакытта аларны көнчыгыштан килүче кыпчаклар б-н угызлар (рус язмаларында — түркләр) кысрыклый. 11 йөзнең урталарында Б. Карпат таулары тарафына, Дунайның урта агымы төбәкләренә күченергә мәҗбүр булалар. Шунда төпләнү өчен аларга 1040–90 елларда Византия көчләре б-н аяусыз көрәшергә туры килә. Византия дәүләте, кыпчаклар б-н берләшеп, Б.не җиңүгә ирешә. Б.нең бер өлеше кабат рус кенәзлеге чик буйларына әйләнеп кайта, анда каракалпаклар берләшмәсен (рус язмаларында «чёрные клобуки») оештыруда катнаша. Соңрак кыпчакларга кушылып бетә. Балкан төбәгендә калган Б. шундагы халыклар арасында ассимиляцияләнә.

*Әд.:* Плетнёва С.А. Древности Чёрных клобуков. М., 1973; шул ук. Печенеги и гузы на Нижнем Дону. М., 1990.

*И.Л.Измайлов.*

**БӘҖГӘРДЛӘ́Р**, к. *Мажарлар.*

**БӘЗӘКӘ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 12 *км* көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычы ярында. 2002 елда 764 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, кәрзин үрү, балыкчылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.дә 2 мәчет (1860 һәм 1875 тә төзелә) эшли. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Салагыш волостена керә. 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән — ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 августыннан — Бондюг, 1963 нең 1 феврaленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1795 тә — 334 ир заты; 1859 да — 1552, 1892 дә — 1877, 1920 дә — 2708, 1926 да — 2179, 1938 дә — 2248, 1949 да — 1611, 1958 дә — 1533, 1970 тә — 1656, 1979 да — 1222, 1989 да — 781 кеше.

**БӘЙ**, к. *Бәк.*

**БӘЙДӘНӘ́**, сугышчы киеменең бер төре. Көбә күлмәктән яссы металл боҗраларының эрелеге б-н аерылган, көбә күлмәк һ.б. кием өстеннән киелгән. Кыска җиңле; алдан ерык чабуы тезгә чаклы төшеп торган. Шәрекъ дөньясында 12–13 йөзләрдән мәгълүм; Алтын Урдада, Казан һ.б. татар ханлыкларында 14–16 йөзләрдә киң кулланылган.

*Әд.:* Кирпичников А.Н. Военное дело на Руси XIV — XV вв. Л., 1976.


*И.Л.Измайлов.*

**БӘЙЛӘ́Ү**, 1) кул яки машина б-н бәйләнгән тукыма яки эшләнмәләр җитештерү. Б. татар халкында традицион рәвештә өйдә башкарыла торган кул эше санала. Манылмаган сарык йонынннан 5 инә б-н оекбаш, бияләй, шарф Б. элек тә, хәзерге вакытта да аеруча киң таралган. 20 йөз башларына кадәр татар хатын-кызлары ак йоннан бәйләнгән, лунычларына еш кына төрле төстәге җепләр кушылган оек киеп йөргәннәр. Керәшен хатын-кызлары, нигездә, сәүдә итү максаты б-н бәйләгән; аларда ак йон яки киже-мамык җептән бәйләнгән оексыман баш киеме — «ак калфак» 20 йөз башларына кадәр кулланышта була. Элек ир-атлар да кыска лунычлы оекбаш кигән һәм еш кына аларны үзләре үк ыргак энә б-н бәйләгәннәр. Хатын-кызлар ш.у. ыргак энә б-н челтәр ашъяулык, тастымал, чигеш араларын, чаршау, сөлге, алъяпкыч, кулъяулык каймаларын бәйләгән (челтәр бәйләгәндә җияк кулланылмаган). Оренбург татарларында, нагайбәкләрдә хатын-кызлар элек-электән кәҗә мамыгыннан шәл Б. б-н дан тота. Бу һөнәрне алар җирле казакълардан үзләштергән. 19 йөз уртасыннан Оренбург губернасының көньяк өязләрендә мамык әйберләр җитештерү кәсепчелек рәвешен ала. Татар хатын-кызлары соры һәм көрән төстәге, бизәкләнгән каймалы калын шәлъяулык, оекбаш, пирчәткә бәйли, соңрак ак төстәге данлыклы юка челтәр яулыклар җитештерү җәйга салына. 19 йөзнең 2 нче яртысында эшмәкәрләр мамыктан әйбер Б. кәсепчелеген Әстерхан, Пенза, Рязань губерналарында оештыра, соңрак бу эш хәзерге Татарстан терр-ясендә дә тарала. Хәзерге вакытта мамыктан Б. аеруча Арча, Әтнә, Кукмара, Балык Бистәсе, Саба р-ннарында үсеш алган; биредә кәҗә мамыгы б-н беррәттән йорт куяны мамыгын да кулланып, традицион мамык шәл бәйлиләр. Шәлнең каймасы буйлап ромб, түгәрәк, туры, чалыш бормаланган сызыклар рәвешендәге гади геометрик фигуралардан торган бизәк композиция сузыла. Кул эшләре осталарында һәр бизәкнең үз атамасы бар: «каз тәпие», «кош теле», «кәрәз», «тәсбих», «токмач», «чыршы» һ.б. Татарларга, төрле төсләр кулланып, фактуралы бизәкләр б-н Б. 20 йөзнең 2 нче яртысында гына үтеп керә; ясалма җепләр кулланып, йон күлмәк, пуловер, башлыклар бәйләү гадәткә керә. Хәзерге вакытта Б. өчен кирәкле җепләр, энә, ыргак, бәйләү машиналары сайлап алу мөмкинлеге зур. Шул ук вакытта ТР трикотаж ф-каларында җитештерелгән әйберләрнең төрләре арта бара (к. *Трикотаж сәнәгате*).



Бәйләнгән оек. 20 йөз башы.

Мамык шәл бизәкләре үрнәкләре.



*Әд.:* Рахимова Р.К. Татар теленең һөнәрчелек лексикасы. К., 1983; Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997; Халиков Н.А. Промыслы и ремесла татар Поволжья и Урала. К., 1998; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

*Ф.Ф.Гулова.*

**«БӘЙНӘЛМИЛӘ́Л»** («بين الملل» — «Интернационал»), айлык иҗтимагый-сәяси, фәнни һәм нәфис журнал. Төркестан һәм Урта Азия коммунистик ун-тлары, Төркестан партия мәктәбе, Иске һәм Яңа шәһәр (Ташкент) мөселманнары техникумының эшчеләр ф-тлары органы. 1923 елда Ташкент шәһәрендә нәшер ителә. Җаваплы мөхәррире Ш.Абзанов. Иң актив авторлары: К.Габидов, Ш.Гыйльми, Г.Сәгъди. Журналда даими рәвештә рәсми документлар басыла. Һәр санда дөньядагы сәяси хәлләр, аларда революцион пролетариатның роле турында тулы мәгълүмат бирелә. Илнең икътисади һәм мәдәни тормышы, фән казанышлары, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, әдәбият һәм сәнгать проблемалары яктыртыла.

*Әд.:* Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Ш. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000.

*Г.Г.Шәйдуллина-Хәсәнова.*

**БӘЙРӘКӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ыкның сул кушылдыгы. Озынлыгы 24 *км*, бассейнының мәйданы 154,9 $км^2$. Ютазы р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Бәйрәкә авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Иске Каразирек авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 23%. Б. елгасының 5 тән алып 11 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 $л/с{\cdot}км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ба-

шында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,214 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 1,2 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БӘЙРӘКӘ́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бәйрәкә елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 1507 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. А.х. техникасы һәм химиясе пр-тиеләре. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Хастаханә. Китапханә. Мәчет. 17 йөздән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.дә 3 мәчет эшли. 3 нче җәмигъ мәчет каршындагы *«Гобәйдия» мәдрәсәсе* 19 йөз ахырында Самара губернасындагы иң зур һәм атаклы уку йортларының берсе була. 20 йөз башында авылда 5 мәчет, 5 су һәм 1 ярма ярдыру тегермәне була; пәнҗешәмбе саен базар эшли. 1906 да Б. крәстиян чуалышларының үзәге була (к.*Бәйрәкә крәстияннәре кузгалышы*, ш.у.к. *Бәйрәкә мөселман тәрәкъкый пәрвәрләр җәмгыяте*). Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6910 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1795 тә — 806 ир заты; 1859 да — 2528, 1886 да — 2565, 1897 дә — 4064, 1922 дә — 4334, 1926 да — 3719, 1938 дә — 2387, 1949 да — 1783, 1958 дә — 2009, 1970 тә — 2159, 1979 да — 1937, 1989 да — 1510 кеше. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге — 5 нче җамигъ мәчет, «Гобәйдия» мәдрәсәсе биналары комплексы. Авыл зиратында 17–19 йөздә куелган кабер ташлары саклана.

**БӘЙРӘКӘ́** тимер юл разъезды посёлогы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 34 *км* көнбатыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар, татарлар) саны 10 нан ким. 1930 елларда нигез салына. Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1949 да — 117, 1958 дә — 104, 1970 тә — 81, 1979 да — 24, 1989 да — 13 кеше.

**«БӘЙРӘКӘ́»**, Ютазы районындагы күмәк хуҗалык. 1991 елда «Коммунизмга» (1950 дә «Авангард», «Зирекле елга», Куйбышев исем. к-зларны кушу нәтиҗәсендә төзелгән) һәм «Яңа юл» к-злары җирлегендә берләштерү юлы б-н оештырыла. Үзәк утары — Бәйрәкә авылы, 531 йорт исәпләнә, 1506 кеше яши, шуларның 349 ы — күмәк хуҗалыкта эшләүчеләр. А.х. җирләренең мәйданы — 7219 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 6309 *га* (2002). Бөртекле ашлык, ит һәм сөт җитештерү буенча специальләшкән хуҗалык. Барлык чәчү мәйданының яртысын бөртекле культуралар алып тора. «Б.» а.х. культураларыннан тотрыклы уңыш ала. 1990 еллардагы үзгәртеп кору чорында хуҗалык мөгезле эре терлекләрнең, ш.и. сыерларның баш санын саклап кала ала. 2002 дә а.х. җирләренең 100 *га* исәбенә 68 *ц* ит, 510 *ц* сөт җитештерелә, 1 сыердан уртача савым 4679 *кг* тәшкил итә. Җитештерү объектлары типовой проект б-н төзелә, фермаларга комплекслы механикалаштыру кертелә. Барлык җитештерү участоклары асфальт юллар б-н тотыштырылган, авылга тулысынча газ кертелгән. Авылда 3 балалар бакчасы, урта мәктәп, хастаханә эшли. Үзе җитештергән продукцияне сату өчен хуҗалыкның 3 кибете бар (икесе — Башкортстан Респ-касының Октябрь ш.ндә). Җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен хуҗалыкка а.х. һәм әзерләүләр хезмәткәрләре һәм эшчеләре профсоюзы ҮКнең Истәлекле Байрагы тапшырыла (1973); хуҗалыкның 5 әгъзасына СССР орденнары, 6 кешегә РФ һәм ТРның атказ. хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә. 2003 елда «Б.» хуҗалыгы җирлегендә «Нур» крәстиян-фермер хуҗалыгы булдырыла.

**БӘЙРӘКӘ́ КРӘСТИЯННӘРЕ́ КУЗГАЛЫШЫ́**, Самара губернасы Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылы (хәзер ТРның Ютазы р-нына керә) халкының 1906 елның 14–17 июль көннәрендә алпавыт Ждановның һәм урындагы түрәләрнең кысуларына каршы баш күтәрүе. Кузгалышның сәбәпләре: җиргә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итәргә тиешле 1 нче Дәүләт думасының куып таратылуы. Башлап йөрүчеләре — солдат хезмәтеннән кайткан А.Габдрахманов, Г.Канәфиев, М.Насыйров, В.Җаббаров. Алар урманга да хуҗа булган алпавыт Ждановның ашлык амбарын таларга, агачларын кисәргә һәм җирен басып алырга өндиләр. 14 июльдә рөхсәтсез урман кисү башлана. Җирле хакимият вәкилләре башбаштаклыкны туктатырга тырыша. 17 июльгә билгеләнгән авыл җыенында халык аларга буйсынудан баш тарта. Авылга полиция отряды, аннары Самара губернаторы урынбасары Ф.Кошко җитәкчелегендә гаскәриләр җибәрелә. Алар б-н бәрелештә 12 кеше яралана һәм үтерелә. 74 кеше хөкемгә тартыла, хәрәкәтне җитәкләүчеләр һәм аңа актив катнашучылар берничәшәр елга ирекләреннән мәхрүм ителә; 8 кеше аклана.

*Әд.:* Хасанов Х.Х. Революция 1905–1907 гг. в Татарии. М., 1965.


**БӘЙРӘКӘ́ МӘДРӘСӘСЕ́**, к. *Гобәйдия мәдрәсәсе.*

**БӘЙРӘКӘ́ МӨСЕЛМА́Н ТӘРӘКЪКЫ́Й ПӘРВӘРЛӘ́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, иҗтимагый хәйрия-мәгариф оешмасы. Самара губернасы Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылында 1907 елның маенда оештырыла. Башлап йөрүчеләре М.Гобәйдуллин, М.Мөхәммәдкәримов, А.Мөхәммәтҗанов һ.б. Максатлары: мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укытуның заманча үзгәрешенә ирешү һәм ярлы-мохтаҗларга ярдәм итү. 1910 да җәмгыять тарафыннан мөселман мәктәпләре укытучыларының белемен күтәрү курслары, 1911 дә һөнәри белем бирү мәктәбе ачыла. Эшчәнлеге 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң туктала.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**БӘЙРӘКӘТАМА́К** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 20 *км* төньяктарак, Бәйрәкә елгасы буенда. 2002 елда 343 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1919 да Бәйрәкә авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1922 дә — 400, 1926 да — 416, 1938 дә — 484, 1949 да — 405, 1958 дә — 354, 1970 тә — 468, 1979 да — 351, 1989 да — 312 кеше. Авыл янында борынгы *Бәйрәкәтамак каберлеге* урыны саклана.

**БӘЙРӘКӘТАМА́К КАБЕРЛЕГЕ́** (археол.), археологик истәлек; Алтын Урда дәверендәге (XIV йөз) мәҗүсиләр каберлеге калдыклары. Ютазы р-ны Бәйрәкәтамак авылы янында урнашкан. Тулысынча диярлек җимерелгән бу каберлек төзү эшләре барышында табыла. 1972–74 елларда Е.П.Казаков тарафыннан тикшерелә. Каберлектә тимер кайчылар, балчыктан ясалган орчык башлары,




Бәйрәкәтамак каберлегендә табылган әйберләр.
1–2. Орчык тоткыч, балчык; 3. Бизәк, көмеш; 4, 5, 7. Көзгеләр, бронза; 6. Кайчы, тимер.
ТР ФА Тарих ин-тының Археол. эзләнүләр милли үзәге фондлары.

бизәкле көмеш тегелмәләр, 3 бронза көзге табыла. Көзгеләрнең берсенә бизәкләр, икенчесенә фантастик җәнлекләр, өченчесенә кытайлар сюжетын хәтерләткән композиция ясалган — аждаһалар арасында дүрт фикер иясе утыра. Тикшеренүчеләр фикеренчә, Б.к. табылдыклары болгарлар б-н аралашкан кыпчак кабиләләренә карый.

*Әд.:* Казаков Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978.

*Е.П.Казаков.*

**БӘЙРӘ́МОВ** Фәрит Дәүләт улы (10.4.1947, Арча р-ны Кызылъяр а.), системалы анализ һәм автоматик идарә итү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1992), проф. (1993), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2002). 1971 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1980 нән Кама политехника ин-тында (хәзерге Кама инженерлык-икътисад академиясе), 1991 дән теоретик һәм гамәли механика каф., 2002 дән теоретик механика һәм материаллар каршылыгы каф. мөдире. Хезмәтләре таралган параметры бүленгән системаларның тотрыклылыгы һәм оптимальлегенә карый. Җилдән энергия алу җайланмалары конструкцияләрен төзи. Фәнни тикшеренүләренең нәтиҗәләре самолёт канаты тирбәнешләрен тотрыклыландыру өчен кулланыла. КамАЗда асылмалы конвейер арбаларының параметрларын сайлау өчен Б. методикасы кулланыла.

Х е з м.: Устойчивость и оптимальная стабилизация систем с распределёнными параметрами. М., 1995; Теоретическая механика. Наб.Челны, 1996.

*Әд.:* С а ф у а н о в И. Труженики науки // Аргамак. 1995. № 8.

**БӘЙРӘ́МОВА** Луиза Кәрим кызы (1.1.1935, хәзерге Әгерже р-ны Исәнбай а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1984), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), Арча р-нында урта мәктәптә укыта. 1960 елдан Казан ун-тында. Хезмәтләре чагыштырма тел белеменә, контрастив лингвистикага, икетеллелеккә, тәрҗемә белеменә, лингвистик аксиологиягә, тел универсалийлары һәм уникалийлары теориясенә карый.

1990 еллардан Татарстан тел моделендә социолингвистик симметрия һәм асимметрия, республикада икетеллелек үсешенә ярдәм итүче мәгълүмати һәм лингвистик факторларның тарихи, мәдәни мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Сүзлекләр, югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы.

Х е з м.: Русско-татарский фразеологический словарь языка В.И.Ленина. К., 1980; Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. К., 1997; Татарстан: языковая симметрия и асимметрия. К., 2001; Введение в контрастивную лингвистику. К., 2004; Ориентализмы в лексике и фразеологии болгарского языка (в сопоставлении с татарским языком). К., 2007.

*Әд.:* Г е о р г и е в а С. Л.К.Байрамова. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков // Съпоставително езикознание. София, 1998. Вып. 22, кн. 1–2; Г е р д А.С. Л.К.Байрамова. Татарстан: языковая симметрия и асимметрия // Филол. науки. 2002. № 2; Кто есть кто. К., 2002.

**БӘЙРӘ́МОВА** Фәүзия Әүхәди кызы (5.12.1950, Саба р-ны Сабай а.), язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, тарих фән. канд. (2006). Казан театр уч-щесен (1971) һәм Казан ун-тын (1989) тәмамлый. 1973–75 елларда ТАССР МС каршындагы телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында режиссёр ярдәмчесе, 1987–90 да Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөхәррире. 1980 елларның 2 нче яртысыннан публицистик язмалары респ-ка газеталарында күренә башлый. «Болын» исемле беренче җыентыгы 1986 да басыла. Балаларга атап язылган, Идел буе Болгары һәм татар халкы тарихын чагылдырган хикәяләр китабы («Сәнгать дөньясына сәяхәт», 1989), повесть һәм новеллалары тупланган «Моң» җыентыгы (1991), «Кара урман» романы (1997), «Безне онытмагыз» (1998) исемле пьесалар китабы, «Дәверләр күчешендә» (1998), «Хаҗ көндәлеге» (1999), «Заман. Милләт. Кеше» (2000), «Туфаннан таралган татар» (2003) дип аталган публицистик мәкаләләр җыентыклары, «Күңел карлыгачлары» (2000), «Соңгы намаз» (2000), «Ахырзаман афәте» (2002) повестьлары, Һ.Такташ иҗатына багышланган «Мишәрнең бөек улы» (2001) китабы, «Алыплар илендә» романы (2003), «Бәхет ачкычы» җыентыгы (2004), «Кырык сырт» романы (2006) һ.б. укучыларга билгеле. Б. әсәрләренең төп темасы — кеше һәм табигать, шәхес һәм коллектив, ныклы тормыш позициясе сайлау һәм характер формалашу, кеше күңелендәге үзгәрешләрне җентекләп күзәтү. *Бөтентатар иҗтимагый үзәге* лидерларыннан берсе (1989–91) һәм «*Иттифакъ*» партиясен оештыручы (1991 дән аның рәисе), Төрки халыклар ассамблеясы рәисе урынбасары (1991 дән), *Милли Мәҗлес* рәисе (1994–97). 1990–95 тә ТР ЮС депутаты.



Ф.Ә. Бәйрәмова.

*Әд.:* З ө л к а р н ә й Ф. Яшәеш һәм иҗат // Чакма чакмый ут чыкмый. К., 1991; Р ә ш и т Ә. Милләтнең сөеклесе // Заман. 2000. 15 дек.; Х ә л и м А. Гаделлек сагында // Мирас. 2000. № 12.

*А.Н.Хәлим.*

**БӘЙРӘМНӘ́Р**, төрле ритуалларга, гореф-гадәтләргә, йолаларга бәйле җәмәгать тантаналары. Татар халык Б.енең күпчелеге бик борынгы заманнарда мәҗүси аграр-көнкүреш җирлегендә барлыкка килә. Казан татарларының ике зур бәйрәме — *Сабан туе* һәм *Җыен* игенчелек б-н бәйле борынгы ел фасыллары йолаларына барып тоташа. Туй, туган көн, яңа йортка күчү һ.б. — традицион гаилә Б. Татарларның бәйрәм культурасы дини һәм дөньяви Б.не дә үз эченә ала. Корбан гаете, Ураза гаете һәм Мәүлид — фарыз мөселман Б.еннән санала. Керәшен татарлар христиан бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр. Ш.у.к. *Мөселман бәйрәмнәре*, *Православие бәйрәмнәре*.

**БӘЙТ** (гарәп بيت), фарсы һәм төрки телле поэзиядә ике юллы шигырь формасы. Җиде иҗекле шигырь юлларына нигезләнгән шигъри форма. Алар, аерым бер тәртиптә төркемләнеп, дүртәр юллы строфа тәшкил итәләр. Шәрекъ классик поэзиясендә *газәл, касыйдә, мәснәви, робагый* һ.б. кайбер жанр төрләре Б. нигезендә төзелгән. Алар бер-берсеннән рифмалар системасы һәм Б.ләрнең санына карап аерыла. Жанр үзенчәлегенә карап, Б.ләр рифмалы яки рифмасыз булырга мөмкин. Мәс., газәл һәм касыйдәдә беренче Б. рифмалы, шуннан соңгы Б.ләрдә исә икенче шигъри юл беренче Б.нең икенче юлы б-н рифмалаша бара (аа, ба, ва...).

Күрәсең, бу болыт берлә гомерлеккә
кояш бергә;
Шулай бергә бугай шатлык та хәсрәт
канлы яшь берлә.

Бу — Г.Тукайның «Шатлык вә хәсрәт» исемле 4 бәйтле шигырендәге ахыргы Б. Шигырь *гаруз* системасындагы сигез стопалы тоташ (һазәҗе һазаҗе мөсәммәне салим): мөфагыйлун, мөфагыйлун, мөфәгыйлун, мөфагыйлун ( .-: .-: .-: .-: ) үлчәмендә язылган.

*Әд.:* К у р б а т о в Х.Р. Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика. К., 1984; Т а б р ӣ з ӣ В. Джам и мухта ар (Трактат о поэтике). М., 1959; Х а м р а е в М.К. Основы тюркского стихосложения. А.-А. 1963; T a s s y M.K. Rhetorique et prosodie des langues de l'orient musulman. Paris, 1873; W e i l G. Grundriss und Sustem der altarabishen Metrum. Wiesbaden, 1956.

*Х.Р.Курбатов.*

**БӘК** (бәй, би), төрки халыкларда ыруг, кабилә башлыкларының (соңрак эре феодалларның — бәкләр бәге, даруга бәге, түмән бәге, олыс бәге һ.б.) дәрәҗәле исеме-титулы. Б. тәшенчәсе 7–8 йөзләргә караган борынгы төрки язмаларда теркәлгән. Җүчиләр олысында һәм татар ханлыкларында 14–17 йөзләрдә әлеге титул еш кулланыла. Гарәпләрнең — әмир, русларның кенәз дәрәҗәләренә тиң атама. Мондый титулга нәселдән нәселгә күчеп ия булучылар да, берәр төрле олы хезмәт күрсәтүгә яки югары дәүләти вазифа башкаруга мөнәсәбәтле рәвештә тәгаенләнүчеләр дә булган. Мәс., Үзбәк хан ислам динен кабул иткән монгол аксөякләренә (нойоннарга) Б. титулы биргән. Татар ханлыкларында Б. титулына олыс, даруга (өлкә, төбәк) идарәчеләре, хан диваны әгъзалары (*бәкләр бәге, карачы бәк*) лаек булган. Нугай Урдасында Б. (би) — нәселдән нәселгә күчкән ил-дәүләт идарәчеләренең — морзаларның дәрәҗәле исеме. Б. титулын йөртүчеләр тора-бара эре дворяннар катлавына кергән. Шәрекъ һәм Төньяк Африка илләрендә Б. сүзе төрле дәрәҗәдә һәм мәгънәдә хәзер дә кулланышта. Татарлар арасында Б. хәзер исем кушымчасы буларак кулланылыла: Әмирбәк, Бәктимер, Галимбәк һ.б.

*Әд.:* Б а р т о л ь д В.В. Бег // Соч. М., 1968. Т. 5; У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*М.Г.Госманов.*

**БӘКӘБЕ́З** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 33 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2002 елда 53 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1782 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Б.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1738,6 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1859 да — 547, 1897 дә — 769,

1920 дә — 869, 1926 да — 383, 1938 дә — 378, 1949 да — 231, 1958 дә — 223, 1970 тә — 205, 1979 да — 145, 1989 да — 79 кеше.

**БӘКЕ́Р** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөбәй елгасы буенда. 2002 елда 27 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1919 да Мортаза авылыннан (хәзер Баулы р-нында) күчеп утыручылар нигез сала. 1920 елга кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александров волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1920 дә — 84, 1926 да — 143, 1938 дә — 197, 1949 да — 226, 1958 дә — 173, 1970 тә — 121, 1979 та — 71, 1989 да — 42 кеше.

**БӘКЕ́Р** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 36 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2002 елда 690 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Мәчет. «Бәкер» курорты. 1760–80 елларда Иске Иштирәк авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бәкер-Иштирәк исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.дә мәчет, җил тегермәне була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1507 дис. тәшкил итә. 1931 дә «Чишмә» к-зы оештырыла, 1950 дә ул Куйбышев исем. к-з бригадасы итеп үзгәртелә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кузай волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1795 тә — 43 ир заты; 1859 да — 117, 1897 дә — 689, 1926 да — 673, 1938 дә — 623, 1949 да — 619, 1958 дә — 649, 1970 тә — 696, 1979 да — 605, 1989 да — 642 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзиналәр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**«БӘКЕ́Р»**, ләм б-н дәвалау курорты, Лениногорск р-нының Бәкер авылы янындагы Чишмә елгасының уңъяк ярында урнашкан (Казаннан 300 *км*, Куйбышев тимер юлының Бөгелмә станциясеннән 70 *км* ераклыкта). 1933 елда табиб М.Игнатьев тырышлыгы б-н ачыла. Төп табигый дәвалау чаралары: күкертле-водородлы торф ләме, «Мацеста» тибындагы сульфидка бай минераль су. Бәкер сазлыгы ләменең шифалы үзенчәлеге күптәннән билгеле. Курортта нерв системасы (үзәк һәм вегетатив нервлар, полиневрит, остеохондроз, радикулит, пликсит), йөрү-хәрәкәтләнү системасы (полиартрит, артроз, остеомиелит, сынган сөякләрне дәвалау), ирләр һәм хатын-кызларның җенси органнарын (балага узмау, ялкынсыну һәм эндокрин патологияләр), тире авырулары (псориаз, экзема, чәч авырулары һ.б.), ашкайнату органнары һәм сидек юллары авыруларын (уретрит, цистит, простатит һ.б.), пешкән яраларны, авыз куышлыгы авыруларын дәвалау үткәрелә. «Б» курортының 400 урынга исәпләнгән өч дәвалау корпусы бар, диагноз кую лабораториясе, функциональ диагноз кую кабинетлары, ләм һәм физик күнегүләр б-н дәвалау заллары, физиологик дәвалау бүлеге эшли. Дәвалау комплексы ләм (аппликация, гальваник), душ, ванналар, ингаляцияләр, диетик тукланулардан гыйбарәт. Ял итүчеләргә клуб, китапханә, уку залы, уен һәм ял бүлмәләре, спорт мәйданчыклары, терренкур, сауна, бассейн хезмәт күрсәтә. Ел буе эшли.



«Бәкер» курорты. Ләмле минераль күл.



«Бәкер» курорты.

*Әд.:* Б л ю м ш т е й н З.Н. Бакировские серные грязи. К., 1935; Визитная карточка объединения «Татарстанкурорт». Мы и наше дело. К., 1998.

*Ф.И.Ибраһимов.*

**БӘКЕ́Р** (Бәкеров) Кәбир Кәрим улы (1885, Оренбург губ., Зобачи (Түбән Әзерки) а. — 1944, Куйбышев ш.), журналист, драматург, театр тәнкыйтьчесе. Гарәп, фарсы, төрек телләрен яхшы белгән. 1905 елдан «Нур» (С.-Петербург), аннары Казанда «әл-Ислах» г-таларында эшли. 1910 нан 3 нче Дәүләт думасында мөселман депутатлар фракциясе сәркәтибе. 1 нче Балкан сугышы вакытында С.-Петербургта эшләгән бер төркем шәфкать туташлары б-н Төркиягә бара, яралы сугышчыларны тәрбияләүдә катнаша (1912). 1913 елда Казанга кайта, 1914–17 дә Оренбург шәһәрендә, «Вакыт» г-тасында эшли. Февр. рев-циясеннән соң Ташкентта «*Олугъ Төркестан*» г-тасын оештыра; ул чыгудан туктагач, «Правда Востока» г-тасында эшли. Төркестан мөселманнары корылтаенда катнаша. 1920 елларның 1 нче яртысында Төркестанда совет хакимиятен урнаштыруда катнашкан татар гаскәрләрендә хәрби мулла вазифасын башкара. Соңга таба Ташкентта сәүдә эше б-н шөгыльләнә, зәркән әйберләр кибете тота. 1926 да Себергә сөрелә. Сөргеннән туган якларына кайткач, кабат кулга алына (1930) һәм үлем җәзасына хөкем ителә, ләкин, хөкеме үзгәртелеп, Соловки сәяси лагерена озатыла. Гомеренең соңгы елларында Куйбышев (хәзерге Самара) шәһәрендә яши һәм заводта эшли. «Чөн тамь, яхуд татар мәдрәсәсендә атна кич» (1912), «Тарихи пьеса» (1912) пьесалары; «Ахун хәзрәтнең вафаты» (1912), «Кара тап» (1912), «Җанлы курчаклар» (1919) хикәяләре; «Тукай Петербургта» (1914) истәлеге, татар театры һәм әдәбиятына багышланган күп санлы тәнкыйди һәм публицистик мәкаләләр авторы.

Ә с ә р.: Мувәккать хөкүмәтнең тәдбирләре. Оренбург, 1917.

*Әд.:* Кәбир Бәкер: Тууына 100 ел // Казан утлары. 1980. № 8; Б а т у л л а Р.М. Яралы бүре: Кыйсса // Идел. 1996. № 5–6.

*Р.М.Батулла.*

**БӘКИ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 36 *км* көнбатыштарак, Олы Шаһиян елгасы буенда. 2002 елда 36 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1920 елларга кадәр авыл рәсми документларда Бикеево-1 һәм Бикеево-2 дип аталган татар һәм рус өлешләреннән тора. 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр татарлар — дәүләт крәстияннәре, руслар алпавыт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, тегүчелек, түбә ябу эшләре б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; мәчет (сакланган бинасы 1911 дә төзелгән; архит-ра истәлеге), мәктәп, чиркәү-приход мәктәбе, авыруларны кабул итү бүлмәсе, су тегермәне, сырәханә, шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Чәршәмбе саен — базар, һәр елның 18–20 июнендә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең берләштерелгән имана җире 509,9 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында Б.дә Будённый һәм Фрунзе исем. к-злар оештырыла, 1948 дә алар Маркс-Ленин исем. (1962 дән — К.Маркс исем.) к-зга, 1964 тә Г.Тукай исем. күмәк хуҗалыкка керә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Кариле волосте үзәге була. 1920 елдан ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 81 ир заты; 1859 да — 382, 1897 дә — 530, 1908 дә — 601, 1920 дә — 582, 1926 да — 488, 1938 дә — 348, 1949 да — 259, 1958 дә — 177, 1970 тә — 103, 1979 да — 78, 1989 да — 46 кеше. 1773–75 еллардагы крәстияннәр кузгалышының күренекле җитәкчеләреннән берсе Г.*Давыдов* туган авыл.

**БӘКЛӘ́Р БӘГЕ́**, Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында хан диваны башлыгы (гарәп илләрендәге өлкән әмиргә тиң). Күрше дәүләтләр б-н рәсми аралашу хатларында Б.б. ханның төп ярдәмчесе сыйфатында да теркәлгән. Гадәттә, олыс, даруга бәкләре арасыннан билгеләнгән. Б.б. ханлыкта хәрби, илчелек, җәмгыятьнең югары мәхкәмә эшләре өчен җаваплы булган. Кайвакыт ханлык б-н идарә итү вазифасын да башкарган. Алтын Урда дәүләтендә Нугай, Котлыбуга, Инак, Котлыг Тимер, Мамай, Идегәй, Тугла бәкләр, Казан ханлыгында Колмөхәммәд, Булат Ширин, Нурали иң атаклы Б.б. булган.

*Әд.:* Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в 13–14 вв. М., 1985. *И.Л.Измайлов.*

**БӘЛӘБӘ́Й РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* көньяк-көнбатышында. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1911 *км*². Үзәге — Бәләбәй шәһәре (Уфадан 180 *км* көньяк-көнбатыштарак). Б.р.ның халкы — 103196 (2002), ш.и. Бәләбәйдә (посёлоклар б-н бергә) 85836 кеше. Татарлар саны: 1970 елда — 20570, 1979 да — 25257, 1989 да — 28743, 2002 дә — 23588, ш.и. Бәләбәйдә (посёлоклар б-н бергә) — 20282 кеше. Б.р.нда 90 торак пункт, шуларның 9 ында күбесенчә татарлар яши. Иң зур авыллар: Мәтәүбаш (733 кеше), Пахарь (467), Байморза (396), Яңа Сарай (294). Бәләбәйдә элек-электән татар телендә халыкка аң-белем бирү традициясе яшәп килә. 1900 дә шәһәр уч-щесе каршында рус-татар уч-щеләре өчен укытучылар әзерләү сыйныфы ачыла. 1920 елдан Бәләбәй пед. уч-щесе татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерли. 1920 дән 1964 елга кадәр шәһәрдә татар-башкорт мәктәбе эшли. 1992 дә ачылган балалар бакчасы-мәктәптә татар теле укытыла, 1998 дән татар-башкорт һәм татар-чуаш балалар бакчалары эшли. 1995 тә татар гимназиясе ачыла, 1999 дан шәһәр фәнни-методик үзәгендә (Башкорт пед. ун-ты филиалы) татар филологиясе ф-ты эшли. 2005/06 уку елында Б.р.ның 4 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 22 мәктәптә фән буларак өйрәнелә. 7 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесендә татар телен өйрәнү төркемнәре оештырылган. 1989 дан Бәләбәйдә — Татар иҗтимагый үзәге (ТИҮ) бүлеге, 1995 тән — Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының җирле бүлекчәсе, 1999 дан татарларның җирле Милли-мәдәни мохтарияты эшли. 1989 дан ТИҮ бүлеге каршында «Туган тел» фольклор төркеме оештырыла. 1989–93 тә шул ук исемдә бюллетень чыгарыла. 1998 дән татар, башкорт, чуаш, рус поэзиясе бәйрәме — «Илһам чишмәләре» үткәрелә. Б.р.нда 17 вокаль, 4 хореографик, 2 инструменталь, 6 театр, 8 фольклор татар үзешчән сәнгать коллективлары эшли. Иң популярлары: «Хыял», «Акчарлак», «Умырзая», «Дуслык» татар халык театры. Бәләбәйдә татарча «Бәләбәй хәбәрләре» г-тасы нәшер ителә. Язучылар Ф.*Кәрим*, Г.*Кашшафның* тормышы һәм эшчәнлеге шушы район б-н бәйләнгән. Б.р.нда РФАнең мөхбир әгъзасы К.М.*Салихов*, Сов. Союзы Геройлары Г.Ә.*Мәҗитов*, М.Х.*Сыртланова* (Бәләбәй ш.), Дан орденының тулы кавалеры Ә.Х.*Вәлишин* (Мәтәүбаш а.) туган.

*Әд.:* Аминов Т.И. Из истории народного образования в Белебеевском уезде Уфимской губернии // История образования и педагогики Башкортстана. Уфа, 1966; Аминев Т.И., Максимова Т.К., Насыйров А.Б. Город Белебей. Белебей, 1981; Курганов Д., Федин П. На алтарь Победы. Ратные подвиги белебеевцев. Белебей, 2000.

**БӘЛӘБӘ́Й СВИ́ТАСЫ**, төче сулыклар фаунасы калдыклары кушылган ком-балчыклы кызыл төсле катламнар; яше ягыннан ТРның көнчыгыш р-ннарындагы *Казан ярусына* тиңдәш. М.Э.Ноинский тарафыннан (1932) Бәләбәй шәһәре (Башкортстан Респ-касы) янында билгеләнә.

**БӘЛӘНҖӘ́Р** (Бәрәнҗәр), Төньяк Кавказда урта гасырлардагы (7–10 йөзләр) шәһәр, Дагстанның диңгез буе төбәгендә урнашкан була. Беренче мәртәбә 7 йөздә гарәп язмаларында телгә алына. 630 елларда төрки *бәрәнҗәрләр* берләшмәсенең башкаласы, аннан соң Хәзәр каганлыгында эре сәүдә һәм иҗтимагый-сәяси үзәкләрнең берсе (10 йөз ахырларына кадәр). Соңрак үз әһәмиятен югалта. Археол. калдыклары хәзерге Буйнак шәһәре (Дагстан Респ-касы) янәшәсендә булырга тиеш дип фаразлана.

*Әд.:* Артамонов Н.И. История хазар. Л., 1962; Магомедов М.Г. Образование Хазарского каганата. М., 1983; Новосельцев А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990; Golden P.B. Khazar studies. Bdpst, 1980. V.1–2.

**БӘЛЕ́Ш**, татар халкының милли ризыгы. Әче яки төче камырдан өсте томалап пешерелә торган зур, түгәрәк камыр ашы. Эченә җиләк-җимеш, яшелчә, балык яки ит б-н бәрәңге, ит б-н ярма, җимеш б-н ярма һ.б. салына. Б. мәҗлес табынына шулпалы аштан соң яки чәй янына куела. Ит һәм бәрәңге б-н пешерелгән Б.кә шулпа салына (шулпалы Б.) һәм ул табынга куелгач кына өлешләргә бүленә. Зур Б.тән тыш, һәркемгә аерым бирелә торган вак бәлеш һәм туйлар өчен үтә вак итеп махсус пешерелгән «кияү бәлеше» дә була.

*Әд.:* Әхмәтҗанов Ю.Ә. Татар халык ашлары. К., 1959; шул ук. Татарские блюда. К., 1961; Татарская кулинария. К., 1981.

**БӘЛҖӘМИ́Н**, урта гасырлардагы (13–14 йөзләр) Алтын Урда шәһәре, Идел б-н Дон елгалары арасында урнашкан була. Идел буе төбәген Урта һәм Үзәк Азия, Кавказ арты илләре б-н бәйләүче зур сәүдә үзәге. Б. көньяктан биек җир-балчык ныгытма б-н уратып алынган була (ул ныгытманың Алтын Урдадагы тәхет чуалышлары чорында төзелгән булуы ихтимал). Шәһәр 1395 елда Аксак Тимер явы вакытында җимерелә. Археол. калдыклары хәзерге Волгоград өлкәсе Дубовка шәһәреннән 2 *км* чамасы төньяктарак урнашкан. Борынгы бер картада (к. *Пициганолар портоланы*) Б. урынында «базар» сүзе теркәлгән. Археологлар Б. шәһәрен ш.у. рус язмаларында телгә алынган Водянское городище б-н тиңлиләр. Аны беренче мәртәбә 1888 дә Саратов гыйльми комиссиясе өйрәнә, 1914 тә — Саратов губернаторы кенәз А.А.Ширинский-Шихматов җитәкчелегендәге экспедиция, 1967 дә исә Идел буе археол. экспедициясе (Г.А.Фёдоров-Давыдов һ.б.) тикшерә.

*Әд.:* Егоров В.Л., Полубояринова М.Д. Археологические исследования Водянского городища в 1967–1971 гг. // Города Поволжья в средние века. М., 1974; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в 13–14 вв. М., 1985. *А.Ә.Борһанов.*

**БӘЛИ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 18 *км* көнчыгыштарак, Бәрле елгасы буенда. 2002 елда 203 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында башлангыч белем бирү мәктәбе, җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 544,5 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗәл волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 104 ир заты; 1859 да — 294, 1897 дә — 524, 1908 дә — 664, 1920 дә — 598, 1926 да — 508, 1938 дә — 504, 1949 да — 357, 1958 дә — 404, 1970 тә — 357, 1979 да — 309, 1989 да — 217 кеше.

**«БӘЛЛУ́Р КАЛӘ́М» — «ХРУСТА́ЛЬНОЕ ПЕРО́»**, к. *Татарстан Республикасының Журналистлар берлеге бүләкләре*.

**БӘРӘКӘ́Т** (гарәп. بركة — киңлек, муллык). Коръәндә бәян ителгәнчә, Аллаһ үзе — Б. чыганагы, һәм Ул әлеге сыйфатны пәйгамбәрләренә һәм аларның якыннарына да иңдерә ала. Аллаһ тарафыннан иңдерелгән Коръән дә Б. чыганагы булып тора.

Коръәннең Б.кә кагылышлы өлешләре исламият галимнәре тарафыннан даими рәвештә өйрәнелә. Изгеләр, пәйгамбәрләр аркылы Б. гади кешеләргә дә җиткерелә ала. Изгеләр яисә алар җирләнгән урыннар, аларның шәхси әйберләре һ.б. Б. чыганагы булырга мөмкин (к. *Әулия*, *Изге урыннар*). Аллаһ Б.енә Мәккәгә хаҗ кылганда Кәгъбәтулла ташына уң кулны куеп ирешеп була дип санала, Б. теләү — мөселманнар арасында сәламләшүнең мөһим бер элементы. Б. төшенчәсе иминлек теләү мәгънәсендә дә кулланыла.

**БӘРӘ́Н** (Рәҗәп) елгасы, Көнбатыш Кама аръягында. Кече Чирмешәннең уң кушылдыгы. Озынлыгы 17,3 *км*, бассейнының мәйданы 149,9 *км*². Алексеев р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Александровка авылыннан 2 *км* төньяктарак, тамагы Арбузов-Баран авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 92 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 32%. Б. елгасының 0,7 дән алып 8,8 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 95 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БӘРӘНДӘЙЛӘ́Р**, 11–13 йөзләрдә Көнчыгыш Европада күчмә төркиләр кабиләләре. Рус елъязмаларында 11 йөз ахыры — 13 йөз

башында телгә алыналар. Кара диңгездән төньякта яшиләр. Элегрәк угыз кабиләләре берләшмәсенә кергән булулары ихтимал. Күчмә терлекчелек б-н шөгыльләнәләр. 12–13 йөзләрдә аларның шәһәрләре дә була. Якынча 1146 елда Б., бәҗәнәк, түрк һ.б. күчмәләр б-н бергә, рус кенәзлеге йогынтысында булган һәм чик буен саклау хезмәтен үтәгән каракалпаклар этносәяси берләшмәсенә керәләр. Киев кенәзләре б-н бергә кыпчакларга һәм үзара көрәшүче башка рус кенәзләренә каршы сугышларда катнашалар. 13 йөзнең 1 нче яртысында, бу җирләргә монголлар һөҗүме башлангач, Б.нең бер өлеше Болгария б-н Венгрия җирләренә күченә, калганнары Алтын Урдага буйсынган төркиләргә кушыла.

*Әд.:* Голубовский П.В. Печенеги, торки и половцы до нашествия татар // Университетские известия. Киев, 1883. № 1; Расовский Д.А. Печенеги, торки и берендеи на Руси и в Угрии // Seminarium Konda Kovianum. Прага, 1933. № 6; Кудряшов К.В. Половецкая степь. М., 1948; Плетнёва С.А. Древности чёрных клобуков. М., 1973. *И.Л.Измайлов.*

**БӘРӘНҖӘ́Р**, к. *Бәләнҗәр*.

**БӘРӘНҖӘРЛӘ́Р** (бәләнҗәрләр), төрки телле болгар (угыр) кабиләләре (к. *Болгарлар*). 7 йөзгә караган гарәп чыганакларында телгә алына. 4 йөздә һуннар б-н бергә Урал арьягыннан Төньяк Кавказга күчеп килгәннәр дип фаразлана. 6 йөзнең 2 нче яртысыннан Төрки каганлыкка буйсынганнар. 630 елларда Каспий диңгезенә коя торган Терек б-н Сулак елгалары арасында Б. дәүләте оешкан һәм шәһәр нигезләнгән. 630 еллар ахырында ул дәүләт Хәзәр каганлыгына буйсындырылган. 9–10 йөзләрдә бу кабиләләрнең бер өлеше Биләр шәһәре тирәләренә күчеп утыра һәм Идел буе Болгар дәүләте халкы булып китә. Кайбер галимнәр Б.не 14 йөздә Кама арьягыннан Иделнең көнбатыш тарафына күчеп утырган һәм үз шәҗәрәсе, нәсел тамгасы булган «бараж» кавем-ыругы б-н тиңлиләр.

*Әд.:* Ковалевский А.П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Хар., 1956; Артамонов Н.И. История хазар. Л., 1962; Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII — XVIII вв. К., 1972; Гадло А.В. Этническая история Северного Кавказа IV — X вв. Л., 1979; Магомедов М.Г. Образование Хазарского каганата. М., 1983; Новосельцев А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990; Golden P.B. Khazar studies. Bdpst., 1980. V. 1–2. *И.Л.Измайлов.*

**БӘРӘҢГЕ́** (Solanum tuberosum), паслёнчалар семьялыгындагы паслён ыругыннан күпьеллык бүлбеле үсемлек; крахмаллы яшелчә культурасы. Азык, терлек азыгы буларак һәм техник максатларда үстерелә. 2 төре игелә: андий Б.се (S. andigenium) — Көньяк Американың төньяк өлешендә күптәннән үстерелә, Чили бәрәңгесе яки бүлбеле Б. (S. tuberosum). Соңгысы, берьеллык культура буларак, уртача климатлы зоналарда (ш.и. ТРда) киң таралган. Б. бүлбесеннән 50–80 *см* биеклектә 3–6 яшел яки миләүшә (антоциан) төстәге сабаклы куакчыл үсемлек үсеп чыга. Беренче яфраклар үсеп чыккан сабак куеныннан җир астында 15–20 *см* га кадәр озынлыктагы бәбәкләр барлыкка килә, алар, очка таба юанаеп, яңа бүлбеләр хасил итә. Бүлбеләрдә спираль буенча урнашкан күзчекләрдә 3–4 әр бөре була. Гадәттә, урта бөре шытып чыга, ул зарарланган очракта гына башкалары шытып үсә башлый. Б. бүлбеләре йомры, озынча һ.б. формада була; эче ак, тышкы ягы ак, сары, ал-кызгылт, зәңгәрсу төстә. Тамыр системасы чуксыман, чагыштырмача зәгыйфь үсешле. Б. вегетатив юл б-н, башлыча, бүлбеләрдән (селекция максатында орлыктан) үрчетелә. Генератив юл б-н үрчетелгән Б.нең продуктлылыгы ким була. Үсемлекне очыннан, күзчекләреннән, шытымнан, сабагыннан да үрчетергә мөмкин. ТР элиталы орлыкчылыгында үсемлек тукымасыннан файдаланып та (мерисистема ысулы) үрчетәләр. Б. бөреләре туфракта 5–8°С җылылык булганда шыта башлый. Тишелеп чыгу өчен иң уңай темп-ра 15–20°С, фотосинтез, сабак, яфрак үсү, чәчәк ату өчен 16–22°С. Б. бүлбеләре



төнге темп-ра 10–13°С булганда яхшы үсә. Югары темп-рада (төнлә 20°С һәм аннан да югары булса) Б. нең җылылык үзлекләре бозыла. Темп-ра –2°С тан түбәнрәк булса, Б. үсемлеге кыраудан зарарлана. Б. нең транспирация (суны парга әйләндерү) коэф. уртача 400–500. Чәчәк ату чорында, сабаклары иң нык үсеп, бүлбеләр барлыкка килгән вакытта, Б.гә иң күп дым һәм тукландыру таләп ителә. Б. уңышы 200–250 *ц/га* булганда, үсемлек туфрактан 100–175 *кг* азот, 40–50 *кг* фосфор, 140–230 *кг* калий ала. Б. үстерү өчен кара туфрак, соры урман туфрагы, кәсле көлсыман, механик составы буенча комсыл, җиңел һәм уртача балчыксыл туфрак кулай санала.

Б. уртача 76,3% судан һәм 23,7% (макс. 36,8% ка кадәр) коры матдәдән, ш.и. 17,5 % (макс. 29,4% ка кадәр) крахмал, 0,5% шикәр, 1–2% (макс. 4,6 % кадәр) аксым, 1 % чамасы минераль тозлардан тора. Б. — С, $B_1$, $B_2$, $B_6$, РР, К витаминнары һәм каротиноидлар чыганагы. Азык-төлек сәнәгатендә Б. дән крахмал, киптерелгән һәм кыздырылган бәрәңге (чипсы), бәрәңге боламыгы, суытылган Б. (гарнир өчен, биточки, котлет һ.б.), бәрәңге лачаулары, саго һ.б. җитештерелә. Крахмал — патока һәм спирт җитештерү сәнәгате өчен чимал. 17,6% крахмаллы 1 *т* Б. дән 112 *л* спирт, 55 *кг* сыек углекислота, 0,39 *л* аракы мае (сивушное масло) яки 1500 *л* барда яки 170 *кг* крахмал, 1000 *кг* сыгынты (мезга) яки 80 *кг* глюкоза, 65 *кг* гидрол һ.б. продуктлар алырга мөмкин. Б. спирты — фармацевтика, парфюмерия һәм аракы-шәраб сәнәгатендә, крахмалы кондитер һәм туку сәнәгатендә файдаланыла. Б. — терлек азыгы. Органик матдәләрнең үзләштерелүе (83–97%) буенча, башка тамыразыклар кебек, Б. дә үсемлек азыклары арасында алдынгы урыннарның берсен били. Бер мәйдан берәмлегеннән уртача гына уңыш алынганда да, үлән һәм орлык культураларына караганда Б. туклыклы матдәләрне күбрәк бирә. Югары уңыш бирә торган, киң таралган культура буларак, икенче икмәк булып санала. Ашлык уңмаган 1920–21 дә һәм Ватан сугышы елларында республика халкын азык б-н тәэмин итүдә мөһим урын тота.

Татарстан терр-ясендә беренчеләрдән булып Б.нең «Трофим» сорты үстерелгән дип санала; 1840 еллардан Дәүләт милке б-н идарә итү министрлыгының Төньяк-Көнчыгыш өйрәнү фермасына (хәзерге Казан аграр ун-тының өйрәнү хуҗалыгы) кайтарылган «Фермерский», «Василёк» һәм «Профессор Маркет» сортлары үстерелә. 20 йөз башында «Новый Микадо», «Суттона», «Царская корона», «Карл Давинг», «Свитязь», «Профессор Вольтман», «Брокер», «Бояр» һ.б., соңрак «Ранняя Роза», «Вольтман», «Берлихинген», 1940 еллардан — «Пестречинский», аннары «Гатчинский» һ.б. сортлар үстерелә. Татарстанда Б.нең иртә өлгерешле «Пушкинец» (1993), «Каратоп» (1998), «Рубин» (2000), «Ароза» (2000), «Удача» (2002); уртача иртә өлгерешле «Невский», «Дезире» (1997), «Адретта» (1998), «Чародей» (2000), «Сказка» (2005), «Дина» (2005), «Джулиана» (2005); уртача өлгерешле — «Ресурс» (1993), «Лиу» (1998), «Петербургский» (2005); уртача соң өлгерешле — «Лорх» (1938) сортлары үстерелә. Б. төрле авыруларга бирешүчән: гөмбә авырулары — *фитофтороз*, макроспориоз, кутыр; бактериаль — караяк, боҗрасыман черек; вируслы — «тимгелле тап», яфракның бөтерелүе һ.б.; бәрәңге бүлбесендә һәм сабакта була торган нематодалы (йомры) суалчаннар б-н зарарлана. Корткычлардан *колорадо коңгызы*, каты корт, ялган каты корт, аю чиркерткә, болын күбәләге, гамма-күбәләк, лайлалы әкәм-төкәм иң куркынычлылардан санала. Ш.у.к. *Бәрәңге үстерүчелек*, *Үсемлекләрне саклау*.

*И.Н.Афанасьев.*

**БӘРӘҢГЕ́ РАЙОНЫ́**, *Мари Республикасының* төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1931 елда (1931 гә кадәр — Татар р-ны) оештырыла. Мәйданы — 792 *км*$^2$. Үзәге — шәһәр тибындагы Бәрәңге посёлогы (Йошкар-Ола шәһәреннән 110 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 19200 кеше (2002), ш.и. татарлар 9500 кеше. Алар күбесенчә Бәрәңге посёлогында (6000 кеше), Мазарбашы (1000), Портянур (1000), Куянавыл (600), Яңавыл (600), Лаҗы (275), Хәсән Пүчинкәсе (100), Олыкыр (90), Искеавыл (75), Портчара (75) авылларында яшиләр. 20 йөз башында Бәрәңгедә 4 мәчет, земство мәктәбе, китапханә эшли. Хәзерге вакытта районның 5 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә, «Наша жизнь» район г-тасының татарча кушымтасы нәшер ителә. Портянур авылында — драма коллек-

тивы, Бәрәңгедә «Альянс» вокаль-инструменталь ансамбле эшли. Районда 6 мәчет, ш.и. Мазарбашы авылында җамигъ мәчет (1829 да төзелә; архит-ра истәлеге) бар. 2003 һәм 2004 елларда Б.р.нда Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә, 2005 тә К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театры артистлары гастрольләре була. Һәр елны Б.р. һәм ТР ның Арча р-ны укучылары арасында «Дуслык учаклары» үткәрелә. Бу районда Советлар Союзы Геройлары: Ә.Г.*Гайсин*, Х.Х.*Хөсәенов*, шагыйрь М.Г.*Гаязов* туып-үскәннәр; М.Җәлилнең көрәштәше Г.Кормашның тормыш юлы Б.р. б-н бәйле.

**БӘРӘҢГЕ́ ҮСТЕРҮЧЕЛЕ́К**, ашамлык, терлек азыгы буларак һәм техник максатларда бәрәңге үстерү буенча үсемлекчелек тармагы. Б.ү. Көньяк Америка индеецлары тарафыннан бик борынгыдан башлана. Европада бәрәңге башта Испаниядә үстерелә башлый (1565). Россиягә бәрәңге 17 йөз ахырында Голландиядән китерелә, ләкин, хуҗалык өчен кирәкле культура буларак, ул 1760 еллар ахырында гына тарала башлый. 1764 елда бәрәңге Новгород губернасында, Арзамас, Елец, Владимир провинцияләрендә, Мәскәү тирәсендәге Кашира өязендә, Төньякта — Каргополь, Олонец шәһәрләрендә кечерәк мәйданнарда үстерелә. Сенатның «Илдә бәрәңге үстерүчелекне башлау турында»гы указы (19 гыйнв. 1765) нигезендә Россиядә Б.ү. бик тиз тарала. Шул ук елда Сенат губерналарга «Җир алмасын, ягъни потетес — бәрәңге үстерү турында» кулланма һәм 58 мичкәгә тутырып (шуның 2 се Казан губернасына билгеләнә) 464 пот 30 кадак (7424 *кг*) бәрәңге җибәрә. Казан губернасында бәрәңге үстерә башлау турында мәгълүмат беренче мәртәбә Казан, Зөя, Тәтеш, Чистай, Мамадыш, Чабаксар, Козьмодемьян өязләре дворяннар башлыкларының Имп. ирекле икътисад җәмгыятенә (1802) җибәргән рапортларында күрсәтелә, анда бәрәңгенең яшелчә бакчаларында ашамлык һәм терлек азыгы буларак үстерелүе, сабакларының мөгезле эре терлеккә, атларга ашатылуы турында хәбәр ителә. Бәрәңге дүртпочмаклап казылган чокырларда, базларда һәм идән асларында саклана.

Казан губернасында Б.ү.нең җәелүенә Казан икътисадчылар җәмгыяте оештырылу (1839) ярдәм итә, ул оешма 1840 та өязләргә бәрәңге үстерү, аны саклау турында күрсәтмә тарата, 1841 дә Казан янында Төньяк-Көнчыгыш өйрәнү фермасын (хәзерге Казан аграр ун-тының өйрәнү хуҗалыгы) оештыруга ирешә. Анда бәрәңге үстерү тәҗрибәләре үткәрелә: 1847–85 тә — арыштан бушаган җиргә, 1886–1925 тә клевердан соң бәрәңге утыртыла. 1848–1925 тә фермада бәрәңгенең 1 дисәтинәсеннән алынган уңыш 704 пот тәшкил итә (117,3 *ц/га*). 1866 да Казан губернасында 10 мең *га* тирәсе мәйданга 94,9 мең чирек бәрәңге утыртыла, 302,6 мең чирек җыеп алына.

Бәрәңге җирләре арта бара, 1913 елга алар 36,5 мең гектарга җитә. Бәрәңге мәйданнарының күпләп арттырылуы Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышы елларына туры килә.

ТРда бәрәңге житештерү үсеше (1928–2006)

| Еллар | Утырту мәйданы, мең *га* | Уңдырышлылык, *ц/га* | Тулай җыем, мең *т* |
|---|---|---|---|
| 1928 | 131,8 | 80 | 1057,8 |
| 1940 | 148,9 | 46 | 684,5 |
| 1960 | 193,6 | 79 | 1521,9 |
| 1970 | 166,1 | 155 | 2580,4 |
| 1980 | 142,9 | 156 | 2202,3 |
| 1990 | 124,3 | 105 | 1310,8 |
| 2000 | 104,3 | 87 | 909,0 |
| 2006 | 97,0 | 180 | 1745,3 |

1970–80 елларда бәрәңгенең күп өлеше Урта Азия респ-каларына, Әстерхан, Волгоград өлкәләренә һәм, өлешчә, Кубага җибәрелә. Бәрәңгедән алынган иң югары уңыш та (1 *га* дан 155–156 *ц*) шушы чорга туры килә. ТР а.х. продукциясе тулай бәясенең 9,9% тан (2000) 18,7% ка (1988) кадәрен, тиндәшле рәвештә үсемлекчелектән кергән тулай бәянең 35,6% тан 19% ка кадәрен бәрәңгедән ала; Б. утыртылган мәйдан гомуми чәчүлекләрнең 3,6–3,9% ын тәшкил итә. Бәрәңге хәзергә кадәр халыкның шәхси һәм ярдәмчел хуҗалыкларында алыштыргысыз а.х. культурасы булып кала: мәс., 2006 да яшелчә бакчаларының 87,2 мең гектарында бәрәңге үстерелә. 2006 да а.х. оешмаларында Б.ү. 9,8 мең *га* мәйданда (чәчүлекләрнең 0,39% ында) алып барылган, рентабельлелеге 1999 да — 87,7%, 2000 дә — 42,4%, 2001 дә — 30,4%, 2002 дә — 38%, 2003 тә — 45,5%, 2006 да — 12% булган. Кукмара, Арча, Лаеш, Балтач, Биектау, Түбән Кама, Тукай, Теләче р-ннары а.х. пр-тиеләре иң күп бәрәңге җитештерүчеләр булып санала, алар өлешенә 2006 да тулаем ТРда барлык а.х. оешмалары җитештергәннең 86,8% ы туры килә.

2006 да бәрәңгенең уңдырышлылыгы Кукмара р-нында — 210, Лаешта — 260, Түбән Камада — 291, Балтачта — 224 *ц/га* тәшкил итә, ТР буенча уртача уңыш — 186 *ц/га*.

ТРда галимнәр В.П.*Мосолов*, А.Ф.*Демидович*, С.А.*Ильин*, Н.И.Благовещенский, В.А.Доронин, М.К.Кучин, М.Д.Исаев, В.П.*Владимиров*, Ф.Ф.*Җамалиева* Б.ү.нең фәнни нигезләрен эшләүгә үзләреннән зур өлеш кертә. Туфракны яхшылап эшкәрткәндә һәм ашламаларны дөрес итеп кулланганда, Татарстан шартларында бәрәңге, күп еллар буе монокультура буларак үстерелсә дә, югары уңыш бирә ала, ТРда бәрәңге җитештерүнең интенсив технологиясе киң кулланышка кереп бара, ул органик һәм минераль ашламаларны тулысынча кертүне, туфракны чәчүгә кадәр һәм чәчүдән соң кистереп эшкәртүне, уңышны комбайннар ярдәмендә җыеп алуны, җыелган уңышны эшкәртүне, орлыклык һәм ашау өчен саклана торган бәрәңгене актив җилләтүне һ.б. күздә тота. ТР Идел буе Федераль округында иң күп бәрәңге җитештерүче төбәк булып тора. 2005 тә бу культураның тулай җыемының 18,1% ы, сатуның 20,0% ы ТР өлешенә туры килә.

Чыг.: Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2003; Сельское хозяйство Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2007.

*Әд.:* И с т и с Ф. История разведения картофеля в России // Журн. М-ва внутр. дел. СПб., 1848. Ч. 21; Ч е р к а с о в В.Н. Об истории картофеля. М., 1953; М о с о л о в В.П. Агротехника картофеля при посадке верхушками // Соч. М., 1955. Т. 5; Л е х н о в и ч В.С. К истории культуры картофеля в России // Материалы по истории земледелия в СССР. М.–Л., 1956. Сб.2; Д е м и д о в и ч А.Ф. Картофель в Татарии. К., 1957; Л о р х А.Г. О картофеле. М., 1960; И л ь и н С.А., Б л а г о в е щ е н с к и й Н.И. Картофель в Татарии. К., 1970; Картофель. М., 1970; З а и к и н Д.В. Агрономическая тетрадь. Возделывание картофеля по интенсивной технологии. М., 1986; Х а л и к о в Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX вв.). К., 1995; В л а д и м и р о в В.П. Картофель. К., 1999. Эффективность возделывания картофеля в Поволжском регионе. Тетюши, 2003.

*И.Н.Афанасьев.*

**«БӘРӘҢГЕ́ ФЕТНӘЛӘРЕ́»**, Россиядә 1840–43 елларда дәүләт крәстияннәренең кузгалышы. Хөкүмәтнең «иген уңышы көтелмәгән еллар өчен өстәмә салым» төре («общественная запашка») кертүе сәбәпле, Владимир, Вятка, Оренбург, Пермь губерналары өязләре удел крәстияннәренең 1834 елдагы кузгалышы әле тынып та өлгермәгән вакытта дәүләт милке министры П.Д.Киселёв (1837–56) яңа реформалар тәкъдим итә. Ш.и. дәүләт крәстияннәре авылларында да «общественная запашка» өлешен булдыру каралә һәм шуңа дип билгеләнгән җир-басуларга бәрәңге утыртылырга тиеш дип табыла (1837–41). Иген уңышы көтелмәгән еллар өчен күмәк ашлык запасы («ашлык кибетләре») булдыру, шул ук максаттан чыгып бәрәңге утырту кирәклеге һәм җирле администрацияләрнең башбаштаклыгы дәүләт крәстияннәре арасында ризасызлык тудыра. Иң беренче булып Урал төбәге, Урта һәм Түбән Идел буе губерналары һәм Төньяк өлкәләре крәстияннәре кузгала. Шул ук вакытта, дәүләт крәстияннәрен патша гаиләсенә беркетелгән удел крәстияннәре идарәсе карамагына күчерәләр икән, дигән коткы таралуы да кузгалышның көчәюенә китерә. «Б.ф.»ндә Вятка, Пермь, Оренбург, Саратов, Вологда, Мәскәү, Рязань, Тамбов, Тубыл һ.б. губерналарда 500 меңнән артыграк крәстиян катнаша. Алар киләчәк өчен билгеләнгән запас ашлыгын тапшырудан, бәрәңге утыртудан һ.б. төр өстәмә салым түләүдән баш тарталар, җирле түрәләрне кыйнау, авыл старосталарын һәм старшиналарны алыштыру, фетнәне бастырырга дип җибәрелгән гаскәри командаларга корал тотып каршы тору очраклары була.

Казан губернасында «Б.ф.» Козьмодемьян, Цивиль, Чабаксар, Ядрин өязләрендә күтәрелә (к. *Әкрам авылы кузгалышы*). 1842 елның маенда Ядрин өязе Мунъял, Козьмодемьян өязе Әкрам авыллары янында крәстияннәр б-н хөкүмәт гаскәри берәмлеге арасында кораллы бәрелеш була. Нәтиҗәдә крәстияннәр җиңелә, йөзләгән кеше суктырыла, 300 дән артык кеше крепостной ителә һәм рекрутлыкка бирелә, 34 кеше сөргенгә җибәрелә. 1843 елда Казан губернасы Лаеш өязе крәстияннәре дә бәрәңгене мәҗбүри утыртырга кушуга каршы күтәреләләр. Башлап йөрүчеләргә карата мәхкәмәдә эш ачыла, калганнарына полиция җәза чаралары куллана. «Б.ф.» кабатлану сәбәпле, хөкүмәт 1843 елның көзендә

бәрәңге утыртырга мәҗбүр итүче карарны юкка чыгара.

*Әд.:* Токарев С.В. Крестьянские картофельные бунты. Киров, 1939; Григорьев П.Г. Волнения чувашского крестьянства в 1841–1842 гг. // Записки Чувашского науч.-иссл. ин-та языка, литературы и истории. Чебоксары, 1941. Вып. 1; Григорьев П.Г., Семёнов Р.С. Восстание чувашского крестьянства в 1842 г.: Сб. архивных док. Чебоксары, 1942; Дружинин Н.М. Государственные крестьяне и реформы П.Д.Киселёва. М., 1958. Т. 2.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БӘРКӘ́ ЙОРТЫ́ ТАМГАСЫ́**, кеше скелеты шәкелендәге нәсел тамгасы. 13 йөзнең 60–70 елларында Болгарда һәм Кырымда сугылган акчаларда очрый.

**БӘРКӘ́ ФӘКЫЙҺ** (тулы исеме Бәркә бине Бәрәкыйз бине Кандуз бине Идеге әл-Кыпчакый) (14 йөзнең 2 нче яртысы), төрки-татар шагыйре, *фәкыйһ*, хаттат. Чыгышы б-н Идел буеннан. Яшьлегендә хуҗасы Алтынбуга б-н мәмлүкләр Мисырына күчеп китә, Искәндәрия шәһәрендә укый. 1383 елда Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын күчереп язып, күчермәсенең ахырына 51 *бәйттән* (икеюллыктан) торган һәм үзенең чит җирдә яшәгәндә кичергән авыр тормышын тасвирлаган шигырен урнаштыра. Б.Ф. билгесез бер авторның шәригать кануннарына, фикъһ мәсьәләләренә багышланган «Китаб-е иршад әл-мөлүк вә-с-сәлятыйн» («Патша һәм солтаннарны хак юлга өндәү китабы», Искәндәрия, 1387) исемле хезмәтен гарәп теленнән төрки телгә тәрҗемә итә. Тәрҗемәнең кулъязма нөсхәсе хәзер Истанбул шәһәрендәге Айя Суфия мәчете китапханәсендә саклана. 1992 дә тәрҗемә төрек галиме Р.Топарлы кереш сүзе б-н Әнкарада аерым китап булып басылып чыга.

Әсәр.: Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: Ике кисәктә. К., 1969; Irsadul-Muluk ves-Selatin // Hazirlayan: R. Toparli. Ankara, 1992.

*Әд.:* Миңнегулов Х. Котб иҗаты. К., 1976; Исламов Р.Ф. Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар. К., 1998.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**БӘРКӘ́ (Бәрәкә́) ХАН** (1209 тирәсе — 1266), 1256/57 елдан Алтын Урда ханы. *Җүчи ханның* улы, *Бату ханның* кече туганы. Бату б-н бергә Идел буе Болгарына, рус кенәзлекләренә, Польша, Венгрия дәүләтләренә оештырылган яуларда катнаша (1236–42). 1240 елларда Төньяк Кавказ төбәгендә олыс идарәчесе. Алтын Урданы Монгол империясеннән аеру сәясәтен яклый. Бату хан, Алтын Урдада Б.х. йогынтысын чикләргә теләп, 1252 еллар тирәсендә аны Идел арьягындагы ераграк олыска идарәче итеп билгели. Аңа чаклы Бату аны, туганнан туганы *Мөнке ханны* империя тәхетенә куюда катнашу сылтавы б-н, *Каракорымга* җибәргән була (1251). *Сартак* һәм *Улакчы* ханнарның бер-бер артлы вафат булуыннан соң (1256), Сарай аксөякләре һәм Мөнке каган каршылыгын җиңеп, Алтын Урда тәхетенә утыра. Үзенә каршы торучылар башлыгы булган *Баракчин*ны (Батуның өлкән хатыны) һәм аның фикердәшләрен җәзалап үтертә. Б.х. идарә иткән дәвердә Алтын Урда дәүләтендә ислам дине йогынтысы көчәя, мәктәп-мәдрәсәләр ачуга, мәчетләр төзүгә, мөселман руханиларының Сарай тирәсенә туплануына мөмкинлекләр туа. Шул ук вакытта башка дин тотучылар да кысрыкланмый, дәүләт башкаласы Сарай әл-Мәхрусәдә христианнарның епархиясе ачыла (1261). Б.х. идарәсе вакытында Алтын Урдада тәүге тапкыр Җүчиләр тамгасы б-н акча сугыла башлый, халык саны исәпкә алына, акча-үлчәү берәмлекләренә үзгәреш кертелә, салым түләү тәртибе камилләштерелә. Яуланган ил-дәүләтләргә идарә итүче *баскаклар* билгеләнә. Сәүдә, һөнәрчелек алга китә, яңа шәһәрләр төзелә (ш.и. яңа башкалага нигез салына). Б.х. чорында Алтын Урда Монгол империясеннән аерылып чыгу юлына баса, чит мәмләкәтләр б-н мөстәкыйль сәясәт алып бара башлый. 1258–59 елларда Б.х. Литва, Польшага, Волынь кенәзлегенә һ.б. илләргә яу б-н бара. 1258 елда монгол ханы Һулагу Үзәк Азия өлкәләрен яулап ала һәм Монгол империясеннән бәйсез үз олысын оештырган була. 1262 дә Б.х. аңа каршы сугыш ача. Ләкин әмир Нугай җитәкчелегендәге гаскәре шул елның ноябрендә җиңелә. 1263 нең гыйнварында Б.х. Төньяк Әзәрбайҗанда Һулагу гаскәрен җиңүгә ирешә. Яу барышында Сәлҗүк төрекләре һәм Мисырда идарә итүче мәмлүкләр б-н илчелек мөнәсәбәтләре урнаштыра. Соңрак Б.х. Мисыр б-н аралашуга комачаулаучы Византиягә һөҗүм итә һәм аның башкаласы Константинопольне камый (1265). Шул ук елларда Б.х.ның көнбатышта Дунай буе Болгариясенә һәм көнчыгышта Җүчиләрнең Урта Азиядәге җирләрен басып алган чагатай ханы Алгуга каршы яуга йөрүе мәгълүм. Кавказ таулары арьягына оештырылган явыннан (1265–66) кайтканда вафат була.

Чыг.: Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1; Полное собрание русских летописей. М., 1997. Т. 1–2.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Бартольд В.В. Беркай // Соч. М., 1968. Т. 5; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система 12–15 вв. М., 1983; Фёдоров-Давыдов Г.А. Смерть хана Бату и династическая смута в Золотой Орде в освещении восточных и русских источников (источниковедческие заметки) // Средневековые древности Волго-Камья. Йошкар-Ола, 1992.

*И.Л.Измайлов.*


**БӘРКӘТӘ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2002 елда 891 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Гремячка исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Б.дә 2 мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 3630,8 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волостена керә. 1920 елдан ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән — Чаллы, 1924 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 1253, 1870 тә — 1384, 1897 дә — 2061, 1926 да — 1490, 1949 да — 1839, 1958 дә — 1816, 1970 тә — 2094, 1979 да — 1745, 1989 да — 1085 кеше.

**БӘРКЛӘ́Т** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Иж елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 15,2 *км*, бассейнының мәйданы 64,1 *км*². Әгерҗе р-нында, Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Варкләд посёлогыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Түбән Көчек авылыннан 3,4 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 66 *м*. Су белән тәэмин итү мәйданының урманлылыгы 6%. Б. елгасының 0,7 дән алып 3 *км* га кадәр озынлыктагы 13 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,63 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км*² дан (үрге агымында) 1–3 *л/с·км*² га кадәр. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 109 *мм*, ташу агымы катламы 82 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун көне эчендә башлана. Б. елгасы октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елгада күләме 1 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**БӘРЛЕ́** елгасы, Идел алды төбәгендә. Бәрле елгасының уң кушылдыгы (Зөя елгасы бассейны). Озынлыгы 17 *км*, бассейнының мәйданы 122 *км*². Кайбыч р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Плетени авылыннан көньяк-көнбатыштарак, тамагы Олы Кайбыч авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Б. елгасының 0,3 тән алып 6,8 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,49 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су мул һәм җәен бик сай булуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 116 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,11 *м*³*/с*. Ел дәвамында суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Б. бассейнында ТРның табигать истәлеге — *Кайбыч имәнлекләре* урнашкан.

**БӘРЛЕ́** елгасы, Идел алды төбәгендә. Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 48 *км*,

бассейнының мәйданы 385 *км*². Кайбыч р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Зур Подберезье авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы Борындык авылыннан 2 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 14%. Б. елгасының 2 дән алып 17 *км* га кадәр озынлыктагы 12 кушылдыгы бар, иң зурысы — Бәрле елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*². Б. үзәне трапециясыман. Елга юлы бормалы, киң тармакланмаган, киңлеге 5–8 *м*. Елга режимы 1948–53 елларда Олы Кайбыч авылы янындагы суүлчәгеч постта өйрәнелә. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су мул һәм җәен бик сай булуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу агымы катламы 86 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,19 *м*³/*с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–600 *мг/л*. Б. бассейнында гомуми күләме 2 млн. *м*³ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Корноухово авылыннан Иске Чәчкаб авылына кадәрге участокта елга Кайбыч аучылык тыюлыгы терр-ясеннән ага. Б. елгасы — ТРның табигать истәлеге (1978).



Бәрле елгасы Борындык авылы янында.

**БӘРЛЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында. Сәләнгеш елгасының уң кушылдыгы (Олы Сөлчә, Олы Чирмешән елгалары бассейны). Озынлыгы 11,9 *км*, бассейнының мәйданы 48,5 *км*². Нурлат р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Бутаиха посёлогыннан 3 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Мамык авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 86%. Б. елгасының 1 дән алып 2,9 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,46 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,25 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су мул һәм җәен бик сай булуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 95 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м*³/*с*. Суы бик каты (язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20 *мг-экв/л* дан артыграк). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БӘРЛЕГУЖА́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 17 *км* көнбатыштарак, Карамалы елгасы буенда. 2002 елда 180 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Җирле риваятьләргә караганда, 18 йөз башында Ташкирмән авылыннан (хәзер Лаеш р-нында) күчеп утыручылар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кариле, Кече Бәрлегужа исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, авылда мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, 2 җил һәм су тегермәне, май язу йорты, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1156,4 дис. тәшкил итә. 1899 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да, мөселманнардан тыш, керәшен татарлар да (17 хуҗалыкта 66 кеше) яши. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостена керә. 1920 елдан ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 96 ир заты; 1859 да — 372, 1884 тә — 565, 1897 дә — 650, 1908 дә — 766, 1920 дә — 805, 1926 да — 507, 1938 дә — 575, 1949 да — 440, 1958 дә — 365, 1970 тә — 304, 1979 да — 271, 1989 да — 209 кеше.

**БӘРТӘ́С** (Leuciscus idus), карплар семьялыгындагы балык. Евразия елгаларында яши. ТР терр-ясендә барлык зур елгаларда һәм чиста, агым сулы күлләрдә таралган. Гәүдәсе кабарынкы һәм озын, ян-яктан җиңелчә кысылган, озынлыгы 60 *см* га кадәр, авырлыгы 1,4 *кг* га якын. Авызы зур түгел. Корсак өлеше көмешсыман, тамак асты һәм корсак йөзгечләре кызгылт төстә. Тәңкәләре циклоид, вак, алтынсу, саңак каплавычларында аеруча сизелә. Яшәвенең 4–6 елында җенси яктан җитлегә. Су 6–8 °С ка кадәр җылынгач, апрель–май айларында уылдык чәчә. Бу вакытта Б.ләр зур төркем булып җыелалар. Уылдыкны комлы яки ташлы төпкә (елгаларда) яки картайган су үсемлекләренә (күлләрдә) берьюлы салалар. Бер балык 11 меңнән алып 120 меңгә кадәр уылдык чәчә. Вак әкәм-төкәмнәр, төрле личинкалар, бөҗәкләр, су үсемлекләре бәбәкләре б-н тукланалар. Авырлыгы 400–500 *г* га җиткәч, вак балыкларны ашый башлый. Промысел балыгы.

**БӘРХЕ́Т ГӨЛЕ** (Tagetes), кашкарыйчалар семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләнчел, декоратив үсемлек. 35 төре билгеле. Төрле форма һәм зурлыктагы (2–10 *см* диаметрда) туры Б. г., авыш Б. г., катмарлы һәм катмарсыз, оешма чәчәкле, юка яфраклы Б. г. сортлары үстерелә.

РФ терр-ясендә Мексика Б. г. (T. patula) — сары, кызгылт яки кызгылт-сары чәчәкле, үзенчәлекле исле, тәбәнәк буйлы үсемлек киң таралган. Татарстан шартларында Б.г. 25–60 *см* биеклектәге куаклыклар хасил итә. Башлыча, йорт янында һәм күмәк бакчаларда үстерелә. Б. г.н орлыктан үрчетәләр, апрель башында теплицага чәчәләр, май ахырында үсентеләрне ачык грунтка күчереп утырталар.

Июльдән көзге кырауларга кадәр чәчәк ата. Клумба, бордюр, газоннардагы декоратив төркемнәр өчен файдаланалар.

*Әд.:* К и с е л е в Г.Е. Цветоводство. М., 1964.

**БӘТКЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Каманың сул кушылдыгы. Озынлыгы 10,6 *км*, бассейнының мәйданы 21,9 *км*². Тукай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Кызыл Юл посёлогыннан 1 *км* көнбатыштарак, тамагы Бәтке авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Б. елгасының 2,1 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,64 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км*² га кадәр. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су мул һәм җәен бик сай булуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 66 *мм*, ташу агымы катламы 40 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*³/*с*. Ел дәвамында суы бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр.

**БӘТКЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама алды төбәгендә. Каманың уң кушылдыгы. Озынлыгы 32,3 *км*, бассейнының мәйданы 375 *км*². Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Арыш авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Балык Бистәсе авылыннан 2 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Елга бассейны аз гына көньякка авышкан калкулыклы тигезлек. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 13%. Б.нең 17 кушылдыгы бар, иң зур уң кушылдыклары — Пановка (11,4 *км*) һәм Атмас (19,5 *км*) елгалары. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Б.нең үзәне асимметрияле елга тамагы өлешендә киңлеге 2–3 *км* га кадәр, сулъяк ярлары биек һәм текә. Тугае тар. Елга юлы бормалы, киңлеге 6–8 *м*. Елганың тирәнлеге 1 *м* га кадәр, сай урыннарда 0,2–0,4 *м*. Елга режимы 1935–88 елларда Яншык авылы янындагы су үлчәү постында өйрәнелә. Елга күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле елганың өске агымында 5–10 *л/с·км*², елга тамагына таба 0,26–0,5 *л/с·км*² га кадәр. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Язгы ташу вакытына еллык су агымының 70% чамасы туры килә. Яншык авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәлеше 2,7 *м* (макс. 4,3 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы

190 *мм*, ташу агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 83 *см* га җитә. Елга тамагында суның иң аз вакыттагы уртача күпьеллык чыгымы 0,067 $м^3/с$. Яншык авылы янында уртача еллык су чыгымы 0,99 $м^3/с$ тәшкил итә. Суның иң зур чыгымы — 128 $м^3/с$ — 1979 елның язында билгеләнә. Суы сульфат-гидрокарбонат-кальцийлы, язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–250 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Ташу вакытында елгада суның болганчыклыгы 1500 $г/м^3$ га җитә. Елга утырмаларының уртача еллык агымы 50 мең *т* га тигез. Б. бассейнында гомуми күләме 1,8 млн. $м^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Б. бассейнының уңъяк яр буе Мишә аучылык тыюлыгына керә. Б. — ТРның табигать истәлеге (1978).

**БӘТКЕ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе авылыннан 7 *км* төньяктарак, Бәтке елгасы буенда. 2002 елда 213 кеше (татарлар — 55%, руслар — 39%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 елга кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. Беренче православие храмы 1593 елларда төзелә. 18 йөз башында 2 агач чиркәү була, алар 1704–11 еллардагы башкорт күтәрелеше вакытында яндырыла. 20 йөз башында волость идарәсе (1861 дә ачыла) урнаша, Михаил-Архангел чиркәве (1797 дә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе, аеклык җәмгыятенең уку ызбасы, су тегермәне, май язу з-ды, 2 тимерчелек, 2 сыраханә, 1 шәраб, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1199 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 412 ир заты; 1859 да — 558, 1897 дә — 643, 1908 дә — 914, 1920 дә — 975, 1926 да — 850, 1949 да — 296, 1958 дә — 228, 1970 тә — 249, 1989 да — 237 кеше.

*Әд.:* Малов Е. Село Бетьки. К., 1868.


**БӘТКЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 13 *км* көнбатыштарак, Кама елгасы буенда. 2002 елда 3749 кеше (руслар — 48%, татарлар — 44%) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек, терлекчелек. Төзү материаллары з-ды. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н дә билгеле. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан халкы дәүләт (элек — икътисади, 1764 елга кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балта эше б-н шөгыльләнә; якын тирәдәге пристань һәм елга судноларында ялланып эшли. 1817 дә Б.дә Владимир-Богородица чиркәве төзелә. 20 йөз башында приход уч-щесе, йон-тукымаману з-ды, 3 су һәм 1 җил тегермәне була; җомга саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5647,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостена керә. 1920 елдан ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1795 тә — 594 ир заты; 1859 да — 1824, 1870 тә — 1995, 1897 дә — 1835, 1913 тә — 2165, 1926 да — 1416, 1938 дә — 1363, 1949 да — 1047, 1958 дә — 1434, 1970 тә — 1782, 1979 да — 2234, 1989 да — 2601 кеше.

**«БӘХЕТСЕ́З ЕГЕ́Т»**, Г.Камалның 5 пәрдәле беренче драма әсәре (1 нче редакциясе — 1898; 2 нче редакциясе — 1907). Әсәрдә чын кешелек хисләре б-н байлык артыннан куу һәм дини хорафатларның килешмәүчәнлеге беренче планга куела. Автор үз заманына хас бозыклыкларны фаш итә. Драма татар драматургиясе һәм театры үсешендә аерым бер урын алып тора. «Б.е.» барлык татар театры труппалары репертуарларына кертелә. Беренче тапкыр спектакльне Уральскида 1908 елның 12 гыйнварында «Сәйяр» труппасы куя (Закир ролен В.Мортазин-Иманский, Кәрим байны Г.Кариев, Гайшә, Гайни рольләрен С.Гыйззәтуллина-Волжская, Камалины А.Кулалаев, Җәмилә ролен Ф.Шаһимәрдәнова башкара). 1908 нең мартында «Яшьләр» труппасы тарафыннан куела, анда Кәрим байны Ширалиев (Г.Коләхмәтов), Гайшәне Мурадова (С.Коләхмәтова), Гайнине Галиева уйный; 1908 нең 23 маенда спектакль «Казан-Кавказ мөселман артистлары ширкәте» тарафыннан Тифлис шәһәрендә куела, Кәрим бай ролен Г.Араблинский, Гайшә һәм Гайни рольләрен С.Гыйззәтуллина-Волжская башкара. 1909 ның язында һәм 1911 нең җәендә пьесаны Баку шәһәрендә әзәрбайҗан артистлары куя (Закир — Г.Араблинский), 1916 ның 18 ноябрендә даими эшләүче «Нур» труппасы тарафыннан куелган спектакльнең премьерасы була (Закирны Г.Казанский, Кәрим байны Л.Аитов, Гайшә һәм Гайнине С.Гыйззәтуллина-Волжская уйный). Аннан соңгы елларда «Б.е.» Татар акад. театрында күп тапкырлар куела (1940, реж. Ш.Шамильский; 1955, Ш.Сарымсаков; 1984, П.Исәнбәт). Төп башкаручылар: Закир ролендә — Ш.Шамильский, И.Хәйруллин, Н.Юкачёв; Кәрим бай — З.Солтанов, Х.Әбҗәлилов, Р.Шәрәфиев, Н.Эюпов; Гайшә, Гайни — А.Галиева, А.Гайнуллина, Р.Юкачёва; Маһри — Н.Арапова, Г.Камская, Г.Камалова; Биби — Ф.Камалова, Ш.Әсфәндиярова, В.Минкина.


*Әд.:* Татар совет театры. К., 1975; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Иляловa И. Театр имени Камала. К., 1986.

*И.И.Илялова.*

**БӘХТӘ́Р** (фарсы. begter), сугышчы киеме; озынча-тар металл кисәкләре үзара тимер божралар ярдәмендә беркетелеп эшләнә. Кайбер Б. калайларына көмештән төрле үсемлек сурәтләре яки Коръән аятьләре төшерелә. Вак тимер божралардан (көбәдән) эшләнгән җиңле яки җиңле һәм чабулы Б.ләр дә очрый. Б. ике яктан каптырылып куела. Авырлыгы 10–12 *кг* чамасы. Шәрекъ илләрендә 15 йөздә барлыкка килә. 15–17 йөзләрдә татар ханлыкларында киң кулланыла.



1



2

Бәхтәр. 1. Гомуми күренеш; 2. Үрү рәвеше.

*Әд.:* Горелик М.В. Монголо-татарское оборонительное вооружение второй половины XIV — начала XV вв. // Куликовская битва в истории и культуре нашей Родины. М., 1983.

*И.Л.Измайлов.*

**БӘХТИ́ЕВ** Фатих Хафиз улы (7.12.1905, Саратов губ., Кузнецкий өязе Урта Әләзән а. — 2.9.1982, шунда ук), агроном, селекция белгече, а.х. фән. д-ры (1947), проф (1954). Н.И.Вавиловның шәкерте. Саратов а.х. ин-тын тәмамлый (1931). 1925–26 елларда Саратов губерна комсомол ком-ты инструкторы. 1931 елдан Түбән Идел крае Анненков р-нының Разметнин МТСында агроном. 1935–40 та Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тының арпа секциясе мөдире (Ленинград). 1940–43 тә а.х. тәҗрибә станциясендә терлек азыгы җитештерү төркеме җитәкчесе, 1942 дән директоры (Мурманск ш.). 1943–49 да Бөртекле ашлык хуҗалыгы ин-тының бөртекле-кузаклы культуралар лаб. мөдире (Мәскәү өлкәсе). 1949 да яңадан Ленинградка кайта: 1949–70 тә СССР ФАнең Ботаника ин-тында эшли, 1960 тан Ботаника музее мөдире, бер үк вакытта 1952–57 дә пед. ин-тында укыта. 1970–73 тә СССР ФАнең Төп ботаника бакчасында эшли. Арпаның «Кубанец», «Нутанс 7805», «Паллидум 6699», «Колхозный Голозёрный 7» сортларының авторлашы. Хезмәтләре арпаның экологиясе, филогениясе һәм селекциясе мәсьәләләренә, аның яңа систематикасын, формалашу закончалыкларын ачык-

лау һәм өйрәнүгә карый. Н.И.Вавилов исем. бүләккә лаек була (1970).

Х е з м.: Проблемы экологии, филогении и селекции ячменей. М.–Л., 1953; Ячмень. М.–Л., 1955; Очерки по истории и географии важнейших культурных растений. М.–Л., 1962; Важнейшие плодовые растения. М., 1970; Николай Иванович Вавилов 1887–1943. Новосиб., 1987.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**БӘХТИ́ЕВ** Юсеф (Йосыф) Җәфәр улы (19.4.1963, Пенза өлкәсе Городище р-ны Урта Әләзән а.), агроном, икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2007). Пенза а.х. ин-тын тәмамлый (1985). 1985 елдан «Городищенский» с-зында бүлекчә җитәкчесе булып эшли башлый. 1992–97 дә «Рус Ишиме» с-зында: баш агроном, директор урынбасары (1996 дан); 1997–2000 дә «Яңа Ишим» җитештерү кооперативы рәисе. 2000 нән Пенза ун-тында: менеджмент каф. доценты, профессоры. Хезмәтләре авыл хуҗалыгында җир салымы проблемаларына, ш.у. а.х. техникасы базарына карый.

Х е з м.: Кооперативы и интеграция в сельском хозяйстве. М., 2005; Рынок сельскохозяйственной техники. Теоретические и методологические основы развития и регулирования. М., 2006; Демонополизация рынка сельскохозяйственной техники. Вопросы теории и методологии. М., 2005; Рынок сельскохозяйственной техники: проблемы и решения. М., 2007 (автордаш).

*Ф.С.Зыятдинов.*

**БӘХТИ́ЕВ ЙОРТЫ́**, Казанда татар архит-расы истәлеге. 1893–96 елларда сәүдәгәр М.А.Бәхтиев акчасына төзелә. Иске татар бистәсенең Юнысов мәйданында урнашкан. Биш диварлы ике катлы агач йорт, төньягында баскыч мәйданчыгы өчен кирпечтән янкорма салынган. Бура диварлар такта б-н



М.А. Бәхтиев йорты. Казан. 1893–96.

тышланган, почмаклары һәм үзәк өлешендәге тәрәзә аралары ярымбаганалар б-н бизәлгән. Уеп бизәкләнгән тәрәзә йөзлекләре эскәк рәвешендә төгәлләнә. Фасадындагы бизәкләр б-н чуарланган биек кәрнизгә өч чарлак тәрәзәсе урнашкан. Урамга караган ягы классицизм юнәлешенең эклектика формаларында башкарылган һәм анда татар халык архит-расы мотивлары кулланылган. 2007 дә Б.й. янды.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа. К., 1995. *Х.Г.Надыйрова.*

**БӘХТИЗИ́Н** Әхтәм Мөсәллим улы (21.1.1895, Уфа губ., Бәләбәй өязе Югары Әтәш а. — 15.8.1943, Орёл өлкәсе Карачев ш.), Кызыл Армия командиры, полковник (1939). 15 яшеннән шахтада ат йөртүче булып эшли.



Ә.М. Бәхтизин.

Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, өлкән унтер-офицер, Георгий орденының тулы кавалеры. 1918 елдан Кызыл Армиядә. Гражданнар сугышында катнаша. 1918–19 елларда Көнчыгыш фронтта 2 нче армиянең 28 нче укчы дивизиясендә рота, батальон командиры. Көньяк һәм Төркестан фронтларында укчы полкларда хезмәт итә. Киев һәм Мәскәүдә командирлар әзерләүче югары хәрби курсларны, Казанда татар-башкорт хәрби мәктәбен тәмамлый (1927–33). 1933–40 та Благовещенск ныгытылган р-нында 107 нче аерым укчы батальон командиры, 169 нчы укчы полк командиры ярдәмчесе, 284 нче, 662 нче укчы полклар командиры. 1938 елда Хәсән күле янында японнар б-н бәрелештә, 1940 та совет-фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында Югары башкомандующий ставкасы каршындагы контроль төркемендә хезмәт итә, 323 нче гвардияче укчы дивизия командиры. Орёл өлкәсе Карачев шәһәрен азат иткәндә һәлак була. Ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И с х а к о в В.М. Бахтизин. Уфа, 1982.

*Р.Ә.Нәбиев.*

**БӘХТИ́ЗИН** Назиф Раян улы (31.12.1927, БАССРның Бөре кантоны Яңа Аташ а.), үсемлекчелек һәм агроэкология белгече, Башкортстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). Башкортстан Респ-касында үсемлекчелек һәм агроэкология белгечләре мәктәбенә нигез салучы. Башкортстан а.х. ин-тын тәмамлый (1951). 1951–61 елларда Уфа югары партия мәктәбендә а.х. каф. мөдире һәм укытучы. 1961–79 да Башкортстан а.х. ин-тында: 1961–64 тә проректор, 1964–73 тә ректор, 1968–79 да үсемлекчелек каф. мөдире. 1979–88 дә Башкортстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында ген. директор (хәзерге Башкортстан игенчелек һәм селекция фәнни-тикшеренү ин-ты), 1989–2003 тә баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре биоэкология, уҗым арышын интенсив технология нигезендә игү, а.х. культуралары уңышын программалаштыру мәсьәләләренә карый. Уҗым арышы һәм бодай игүнең тотрыклы һәм югары уңыш алуны тәэмин итә торган экологик яктан зарарсыз технологияләрен эшли. Б. Башкортстан игенчелек һәм селекция фәнни-тикшеренү ин-ты каршында Селекция үзәген оештыручы (1984). 17 монография авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХның көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Углубление пахотного слоя чернозёмов и серых лесных почв Башкирии. Уфа, 1955; Сорные растения Башкирии и меры борьбы с ними. Уфа, 1958; Озимая пшеница в Башкирии. Уфа, 1980; Почвозащитная система земледелия в Башкирии. Уфа, 1987; Биоэкология и интенсивная технология возделывания озимой ржи. Уфа, 1992; Экологический императив сельского хозяйства. Уфа, 1999.

*Әд.:* Библиография научных трудов Н.Р.Бахтизина. Уфа, 1997; М и р к и н Б.М. Главный агроном республики // Вестн. АН Респ. Башкортстан. 1997. № 4; И с м а ғ и л о в Р., Н у р л ы ғ а я н о в Р. Тирбәлә арыштарың... // Агиҙел. 1997. № 12.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**БӘХТИ́ЗИН** Рамил Назиф улы (30.3.1955, Уфа ш.), математик, физ.-матем. фән д-ры (1992), проф. (1994). 1977 елда Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң, Уфа нефть техникасы ун-тында эшли, 1995 елдан матем. модельләштерү каф. мөдире, бер үк вакытта 1999 дан икътисад һәм менеджмент ф-ты деканы. Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләрне төркемләп анализлауга, кайтма кырый мәсьәләләр теориясенә һәм гамәли математикага карый. Җылылык-масса күчеше процессларын тикшерү нигезендә нефть-газ чыгару юлын билгеләү ысулын эшли, нефть-газ чыгару, нефть ташу һәм эшкәртү процесслары, нефть-газ комплексы икътисады өчен матем. модельләү куллана.

Х е з м.: Этюды о моделировании сложных систем нефтедобычи. Уфа, 1999 (автордаш); Групповой анализ уравнений течения тиксотропной жидкости // Прикладная математика и механика. 1989. Т. 53, вып. 2.

*Әд.:* Кто есть кто в нефтяном комплексе России. СПб., 1997; Уфимский нефтяной технический университет. Доктора наук, профессора. М., 1997.

**БӘХТИ́ЗИНА** Әминә Хәлил кызы (26.4.1906, Уфа ш. — 1997, Үзбәкстан Респ-касы, Бохара ш.), җырчы (лирик сопрано). Варшава консерваториясен тәмамлаган пианист Э.Щульц классында укый. Сәхнәдә беренче тапкыр җиде яшендә чыгыш ясый (тамашачыларга аны Ш.Бабич тәкъдим итә). Җырчы иҗатына Г.Ибраһимов, С.Кудаш, С.Сүнчәләй, Д.Юлтый зур йогынты ясый. Әдәби-муз. кичәләрдә, концертларда татар, башкорт һ.б. Шәрекъ халыклары җырларыннан торган репертуар б-н чыгыш ясый. 1926–30 елларда Казанда яши, С.Габәши, Г.Әлмөхәммәдов, В.Виноградовның «*Сания*» операсын сәхнәләштерүдә һәм концерт программаларында катнаша (ш.и. С.Сәйдәшевнең әсәрләрен автор уйнавына кушылып башкара). 1935 елга кадәр Идел буе, Урал, Себер, Урта Азия шәһәрләре буйлап гастрольләрдә йөри. 1935 елдан Бохара шәһәрендә яши.

*Әд.:* Г о б ә й д у л л и н Х. Җырчы хатлары // Азат хатын. 1978. № 7.

*З.Ш.Хәйруллина.*

**БӘХТИО́ЗИН** Рөстәм Фәрит улы (23.08.1957, Казан), нурлар ярдәмендә диагноз кую белгече, мед. фән. д-ры (1996). 1980 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1983 елдан Республика мед. диагностикасы үзәгендә, 1990 нан магнит-резонанслы компьютер томографиясе бүлеге мөдире. Бер үк вакытта 1989 дан Казан мед. академиясендә, 1997 дән интервенцион һәм диагностик радиология курслары мөдире. 1998 дән Мәскәүдә. Хезмәтләре өлкәннәр һәм балаларда бавыр һәм үт юллары, умырткалык һәм баш мие авыруларына ультратавыш һәм магнит-резонанс ярдәмендә диагноз кую мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Клиническое применение магнитно-резонансной томографии с контрастным усилением. М., 1996 (автордаш); Магнитно-резонансная томография в диагностическом алгоритме при очаговых поражениях печени. К., 1996; Руководство по ультразвуковой диагностике. М., 1998.

**БӘХТИО́ЗИН** Фәрит Шакир улы (17.9.1930, Казан), хирург, мед. фән. канд. (1973), ТРның атказ. табибе (1994). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Мари АССРның Кушенер р-ны хастаханәсендә хирург, 1955 елдан баш табиб. 1960 тан Казан травматология һәм ортопедия ин-тында. 1968 дән Казан мед. ин-тының травматология, ортопедия һәм нейрохирургия курслары булган хәрби-кыр хирургиясе кафедрасында, 1987 дән Республика балалар клиник хастаханәсенең балалар хирургиясе кафедрасында. Хезмәтләре травматология, ортопедия, йөрү-хәрәкәт системасы авыруларын дәвалауга карый.

Х е з м.: Метод контрастной артографии с диодом при повреждениях менисков коленного сустава. К., 1964; Повреждение менисков коленного сустава. К., 1990.

**БӘХТИЯ́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Симет елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 226 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бәхтияр Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 18 — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, 2 җил һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 539,8 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Арча кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 44 ир заты; 1859 да — 315, 1897 дә — 554, 1908 дә — 549, 1920 дә — 533, 1926 да — 490, 1938 дә — 453, 1949 да — 359, 1958 дә — 253, 1970 тә — 264, 1979 да — 257, 1989 да — 231 кеше.

**БӘХТИЯ́РОВ** Әхмәтвафа Гали улы (9.12.1881, Саратов губ., Хвалынск өязе Зимница а. — 1960, Казан), журналист. Зимница авылы мәдрәсәсен тәмамлый, Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Г.Тукай б-н Ф.Әмирханның дусты һәм көрәштәше. Шәкертләрнең яшерен оешмасы «*әл-Ислах*» ком-ты эшендә актив катнаша. 1907–09 елларда «*әл-Ислах*» г-тасы мөхәррире. Газетада актуаль темаларга караган материаллар бастыра, мөселман дини мәктәпләрен үзгәртеп кору мәсьәләләрен күтәрә. 1909 дан Казанда «Аят мәктәбе» укытучысы. 1950 елларда эшче яшьләр мәктәбендә укыта.

**БӘХТИЯ́РОВ** Камил Ибраһим улы (21.6.1934, Мәскәү), логик, филос. фән. д-ры (1989), проф. (1990). Мәскәү төзелеш инженерлары ин-тын (1957), Мәскәү ун-тының механика-матем. ф-тын (1965) тәмамлый. 1971 елдан Хәрби химик саклану академиясендә һәм Мәскәү а.х. инженерлары ин-тында югары матем. кафедраларында эшли. Хезмәтләре логикада арифметика ысуллары куллану юлы б-н Лейбниц проблемасын хәл итүгә — логик фикерләрне исәпләүләргә кайтарып калдыруга карый, һәм алар компьютер программаларында чагылыш таба.

Х е з м.: Многоаспектный подход в логике и теории познания // Философские науки. 1988. № 8; Умозаключения на персональных компьютерах. М., 1989; Многомерность истины // Философские науки. 1991. № 4.

**БӘХТИЯ́РОВ** Сабир Сәлман улы (псевд. Бухаров, Борисов, Бельский) (28.12.1913, Уфа губ., Уфа өязе Бильяз а. — 2003, Мәскәү), журналист. Казан сов. төзелеше ин-тын (1936) һәм ВКП(б) ҮК каршындагы Мәскәү югары партия мәктәбен (1946) тәмамлый. 1936 елдан Казанда ВЛКСМ райкомы секретаре. 1939 дан Сахалин өлкәсендә журналист («Советский Сахалин» г-тасында) һәм партия эшлеклесе. 1946–58 елларда «Правда» г-тасының ТАССР буенча үз хәбәрчесе. Мәкалә, репортаж, очеркларында Татарстандагы сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни мәсьәләләр б-н таныштыра. 1958–63 тә «Чаян» ж-лы мөхәррире. 1963–66 да «Социалистик Татарстан» — «Советская Татария» г-таларының берләштерелгән редакциясендә хәбәрче. Сатирик һәм юмористик хикәяләре, фельетоннары Бөтенсоюз радиосыннан яңгырый, «Правда», «Литературная газета», «Советская Россия» г-таларында, «Крокодил» ж-лында басыла. Фотоальбомнар төзүче («ТАССР», 1960; «Казань», 1960). ТАССР Журналистлар берлеген оештыручыларның берсе.

Ә с ә р.: Когда плачут сваты. К., 1955; Зрячие слепцы. М., 1961; Ничипоры // Оружием смеха. М., 1961; Заколдованное место. К., 1963.

*Әд.:* Жанры советской газеты. М., 1959; Н а в о з о в А. Поговорим о репортажах // Советская печать. 1959. № 6.

*Г.Р.Заманова.*

**БӘХТИЯ́РОВА** Сания Мифтах кызы (20.1.1949, Ленинград), нәкышьче. В.А.Серов исем. Ленинград сәнгать уч-щесен (1969), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тының нәкышь бүлеген (1976) тәмамлый. 1976 елдан С.-Петербургта «Олимп» студиясе сәнгать җитәкчесе һәм В.Ф.Загоненконың иҗат остаханәсе әгъзасы. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1979). Тематик картиналар, натюрмортлар һәм композицион портретлар авторы: «Туганым белән автопортрет» (1978, СССР Рәссамнар берлеге дипломы), «Соңгы угыл» (1979), «Шагыйрь Г.Тукай» (1981), «Бәхилләшү. Муса Җәлил» (1982), «Зәңгәр шәлле ана портреты» (1980), «Чорлар бәйләнеше» (1985); 8 өлештән торган «Татар халкының традицияләре һәм йолалары» циклы (1989–1991); «Дүртенче буын» (1995), «Күл буенда» һәм «Җил» (2000), «Самавырлы натюрморт» (2007) картиналары һ.б. Б. әсәрләренең лирик-романтик юнәлеше образларны ачудагы конкретлык һәм хикәяле тасвирлау б-н аралаша, аларда халыкчан сюжетлар җентекләп сурәтләнә. Б. әсәрләренә теманы тирән эчтәлекле итеп ачу, реалистик һәм үзенчәлекле язу манерасы хас, болар формаларның пластик контурларында, пейзаж фоннарында, яктылык һәм һава тирәлегенең бирелешендә ачык чагыла. Халыкара күргәзмәләрдә (Япония, 1979, 1981; Польша, 1980; Финляндия, 1980; Франция, 1989, 1991, 1993), бөтенроссия («Туган ил буйлап», Мәскәү, 1981; «Петербург-Мәскәү», Мәскәү, 2000) күргәзмәләрендә, төбәкара бө-

С.М.Б ә х т и я р о в а. 1. «Чәй янында». 1989. Франция; 2. «Әби сандыгы». 1989; 3. «Бал белән каршылау». 1989. Франция.



1



2



3

тентатар «ТАТАРТ» күргәзмәсендә (С.-Петербург, Казан, 1991), 2000 нән — ел саен үткәрелүче «С.-Петербург рәссамнары», «Рәссамнар-шагыйрьләргә» (Г.Тукайның тууына 120, М.Җәлилнең тууына 100 ел тулу уңаеннан. С.-Петербург, 2006) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре С.-Петербургта (1975, 1987, 1988, 1989, 1994, 1999), Кохтла-Ярве (Эстония, 1988), Сланцы (1988, 1994), Колпино (1988) шәһәрләрендә уза. Әсәрләре Шәһәр тарихы музеенда (С.-Петербург), «Казан» Милли-мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Тамбов картиналар галереясында, «Андреев йорты» галереясында (Франция, Версаль), Сәнгать академиясе музеенда (Мәскәү) саклана.

*Әд.:* Изотов Ю. Во имя семьи // Культура и жизнь. 1981. № 5; Бахтиярова Сания. Выставка произведений: Буклет. Л., 1988; Сания Бахтиярова. Выставка произведений: Буклет. Кохтла-Ярве, 1988.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БӘХТИЯ́РОВА** Чулпан Нәкыйп кызы (6.11.1926, Казан), музыка белгече, сәнгать фән. канд. (1964), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977). 1951 елда — Казан консерваториясен, 1964 тә КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясенең әдәбият һәм сәнгать теориясе ф-тын тәмамлый. 1953–58 дә Татар филармониясенең әдәби-муз. бүлегендә сәнгать җитәкчесе, 1959–61 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында мәдәният бүлеге инструкторы. 1964–71 дә Казан пед. ин-тында укыта, 1968 дән музыка теориясе һәм тарихы каф. мөдире. 1971 елдан Казан консерваториясендә, 1973–86 да фәнни эшләр буенча проректор. Төп хезмәтләре музыка сәнгатендә миллилек һәм интернациональлек мәсьәләләренә, татар композиторлары иҗатына карый.

Хезм.: Фахри Насретдинов. К., 1957; Фарид Яруллин. К., 1960; Обновление народно-национальной традиции // Национальное и интернациональное в литературе и искусстве. М., 1964; Национальное и интернациональное в татарской музыке // Музыка и современность. М., 1967. Вып. 6; Татарская музыка // Музыкальная энцикл. М., 1981. Т. 5.

**БӘЧЕ́К** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы чигендә. 2002 елда 196 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.тә мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, 2 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1020,3 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Зөя кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 148 ир заты; 1859 да — 575, 1897 дә — 680, 1908 дә — 843, 1926 да — 1043, 1938 дә — 924, 1949 да — 585, 1958 дә — 547, 1970 тә — 496, 1979 да — 395, 1989 да — 268 кеше.

**БӘШӘ́Р** (Бәшәров) Рәшит Гаффар улы (7.10.1949, Кукмара р-ны Яңил а.), шагыйрь. Казан ун-тын (1972) һәм Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны (1989, Мәскәү) тәмамлый. 1972–77 елларда Лениногорск р-ны мәктәпләрендә укыта. 1979 елдан Чаллы шәһәре пр-тиеләрендә, район газеталары редакцияләрендә эшли. 1991–95 тә «КамАЗ» нәшрияты (Чаллы ш.) мөхәррире. 1996–2000 дә «Аргамак» ж-лында татар прозасы һәм поэзиясе бүлеге мөхәррире, җаваплы сәркәтип. Әсәрләре 1965 тән басыла башлый. Балаларга атап язылган, аларны кечкенәдән үк намуслы, кешелекле, ихлас булырга, хезмәтне яратырга, табигатьне сакларга, аны баетырга, тереклек дөньясы б-н дус булырга чакырган «Әйлән-бәйлән» (1975), «Бәйрәм» (1977), «Яшел океан» (1981), «Җиләк малай» (Чаллы, 2002), «Кояшлы яңгыр» (2003) исемле шигырь җыентыклары, Себер табигатенең хозурлыгы турындагы «Ак әкият» (1986), әкият-легендаларда сөйләнгән Зөһрә кыз турындагы «Ай кызының зәңгәр чиләге» (1990) исемле поэма китаплары авторы. «Иртәгә дә яшисе бар» (1989), «Ачык капка» (2004) җыентыкларына тупланган повестьларында Б. яшүсмерләрне тәрбияләү проблемаларын яктырта; кайвакыт тормышта чын дөреслек булып күренгәннең дә ялган булып чыгуын фаш итә. Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исем. бүләге иясе (2000).

Әсәр.: Сандугачлы бишек. К., 2000.

*Әд.:* Сафин Ф. Күңелдәге кызыл миләшләр // Казан утлары. 1999. № 10.

*Г.М.Габделхакова.*

**БӘШӘ́РОВ** Марат Галимҗан улы (22.8.1974, Мәскәү), киноактёр. М.С.Щепкин исем. Мәскәү театр уч-щесен тәмамлый (1998). 1991 елда Мәскәүдәге «Современник» театрында О.Уайлдның «Кентервилль өрәге» («Кентервилльское приведение») повесте буенча куелган шул исемдәге спектакльдә герцог Сэсил ролендә беренче тапкыр чыгыш ясый. Кинода беренче тапкыр 1995 тә Н.Михалковның «Кояштан интеккәннәр» («Утомлённые солнцем») фильмында уйный. Уч-щене тәмамлаганнан соң, күбесенчә кинофильмнарда катнаша, төрле пландагы 30 лап роль башкара. Беренче рольләре үк — юнкер Палиевский («Себер чәчтарашы» — «Сибирский цирюльник», 1998, реж. Н.Михалков), Игорь Зварыгин («Ворошилов укчысы» — «Ворошиловский стрелок», 1999, реж. С.Говорухин) — аны танылган актёрлар рәтенә куя. Мишка Крапивин («Туй» — «Свадьба», 2000, реж. П.Лунгин, Россия һәм Франция б-н бергә эшләнгән), Иван Столбов («Чик буе. Тайгадагы роман» — «Граница. Таёжный роман», 2001, реж. А.Митта) рольләре дә актёрга популярлык китерә. Б. мөлаем тышкы кыяфәте, тирән хислелеге, төрле хәлләрдә дә табигый булып кала алуы б-н аерылып тора. Ул Э.Рязанов («Тын чоңгыллар» — «Тихие омуты»), Д.Фәйзиев («Төрек гамбиты» — «Турецкий гамбит»), Р.Нахапетов («Минем зур әрмән туем» — «Моя большая армянская свадьба»), Г.Кончаловский («Консервлар» — «Консервы») һәм чит ил кинорежиссёрларыннан М.Хебберджент («Пыяла» — «Стекло», 2003, Бөекбритания), С.Содерберг («Тәңкә» — «Чешуя», 2003, АКШ) фильмнарында уйный. Берничә бәйсез театр проектында катнаша, ш.и. А.Грибоедов пьесасы буенча реж. О.Меньшиков тарафыннан куелган «Акыллылык бәласе» («Горе от ума») спектаклендә Загорецкий ролен башкара. Кино сәнгате өлкәсендә РФнең Дәүләт бүләге лауреаты (2002).

*Е.П.Алексеева.*

**БӘШИРИ́** (Бәширов) Зариф Шәрәфетдин улы (5.5.1888, Казан губ., Цивиль өязе Чүти а. — 21.10.1962, Уфа ш.), язучы, тәрҗемәче, журналист. Татар, уйгыр, үзбәк телләрендә яза. Мулла гаиләсеннән. 1898–1902 елларда Буа шәһәрендә, Акъегет авылында (хәзерге Яшел Үзән р-ны) мәдрәсәдә укый; 1907 дә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1908 дә Оренбургка күченә, «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсендә корректор, «Чүкеч» ж-лында сәркәтип булып эшли. 1909 дан Пенза һәм Тамбов губерналары авылларында укыта; 1913 тән Капал шәһәрендә (хәзерге Казакъстан Респ-касы). 1917 дән Алма-Ата шәһәрендә газета һәм журналлар редакцияләрендә эшли, 1918–19 да Жаркент шәһәрендә халык мәгарифе бүлеге мөдире; соңрак Урта Азия дәүләт ун-тында (Ташкент) үзбәк, уйгыр телләрен һәм әдәбиятын укыта. 1930–32 дә Б. Донбасста яши һәм эшли. 1933 тән Уфа шәһәрендә яши. 1938 дә репрессияләнә. Срогын башта Колымада, аннан соң Башкортстан АССРның Бәләбәй р-нында тутыра. Акланганнан соң (1956) Уфада яши. Б. киң күләмле шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, повестьлар, очерклар, мәкаләләр авторы. «Думага хитап» исемле беренче шигырьләренең берсен «Казан мөхбире» г-тасында бастыра. Аннан соңгы елларда шигырьләрен «Бәянелхак», «Казан мөхбире», «Вакыт», «Йолдыз» г-таларында, «Шура» ж-лында бастыра. «Милләт кайгысы» (1907), «Тутый тавышы» (Оренбург, 1908), «Җуаткыч, йә Уяткыч» (Оренбург, 1909), «Хиссият бишекләре» (1913) һ.б. шигъри җыентыклар авторы. Төп темаларын татар халкын мәгърифәткә өндәү, социаль тигезсезлекне тәнкыйтьләү, томаналыкны, фанатизмны фаш итү, гади халык язмышы, лирика тәшкил итә. 1909–10 да «Шура» ж-лында мишәрләр һәм чуашлар тормышы турында этнографик очерклар бастыра (соңрак аерым китаплар булып чыга). Б. балачак истәлекләренә нигезләнеп язылган «Чуаш кызы Әнисә» (1910), «*сәнәкчеләр» фетнәсе* турында «Каракош явы» (1958, башкорт телендә) повестьлары, балалар өчен язылган «Шаян Фәһим» (1919), «Ефәк күлмәк» (1928) хикәяләре авторы. Ташкентта үзбәк телендә язылган һәм басылган Б. хикәяләре үзбәк әдәбиятында проза жанры үсешендә зур роль уйный. Кайбер шигырьләре «Зариф Бәшири шигырьләре» (1927) җыентыгына кертелгән. Б. чуаш, үзбәк, уйгыр әдәбияты хрестоматияләрен төзи. Тормышының соңгы елларында 20 йөз башы Казан, Оренбург әдәби тормышы турында истәлекләр китабы өстендә эшли. 1968 дә мемуарларның «За-

мандашларым белән очрашулар» исемле кыскартылган варианты дөнья күрә. Ике проза романы һәм шигъри романы басылмый кала.

Х е з м.: Сайланма әсәрләр. К., 1958; Замандашларым белән очрашулар. К., 1968.

*Әд.:* Р ә м и е в З. Иҗаты игътибарга лаек // Социалистик Татарстан. 1988. 12 май; Тукайлар замандашы // Казан утлары. 1998. № 6; Г и н и я т у л л и н а А.К. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

*З.З.Рәмиев.*

**БӘШИ́РОВ** Әнвәр Кәлимулла улы (4.8.1924, Архангельск ш. — 19.3.2000, Казан), сынчы. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1954), Львов гамәли һәм декоратив сәнгать ин-тында белем ала (1954–55). 1950 елдан Казанда. ТАССР Сәнгать фондында эшли (1959–89). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). 1960–90 елларда әйдәп баручы татар сынчыларының берсе. Станлы портретлар, һәйкәлләр, мемориаль корылмалар авторы; портретлар, әкият-фольклор һәм тарих темаларына гипстан, агач, мәрмәр, бронза, бакыр, граниттан композицияләр иҗат итә. Б.ның талантлы сынлы портрет жанрында аеруча ачык чагылыш таба. Әлеге әсәрләрдәге образлар чишелешенә психол. характеристиканы һәм оригиналь композицияне берләштерүче бөтенлек хас: («Гражданнар сугышында катнашкан С.А.Копылов», 1964; «Советлар Союзы Герое М.Девятаев», 1966; «Рәссам М.Усманов», 1972; «Колхоз көтүчесе», 1979, «Тукай», 1982 һ.б.). 1960–70 елларда станлы бизәлеш әсәрләре иҗат итә: «Ай кызы» (1965 һәм 1979); «Безнең сугышчан яшьлек» (1974); «Бабай» (1979). Б. Җәлил посёлогында куелган М.Җәлил (1964), Нур Баян исем. к-зда куелган шагыйрь Нур Баян (мәрмәр, 1968), РСФСРның атказ. укытучысы Е.Г.Ласточкина (Казандагы аның исем. мәктәптә, бетон, 1973), ТАССР Эчке эшләр министрлыгы интерьерындагы Ф.Э.Дзержинский (гипс, 1979) һәйкәл-бюстлары; Алабуга шәһәрендә һәм Лаеш эшчеләр посёлогында, ТРның башка районнарында һәм шәһәрләрендә Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга куелган һәйкәлләр (Г.А.Зяблицев б-н берлектә, 1970 еллар), Казандагы биналарның диварларында Т.Гыйззәт, С. Садыйкова, Н.И.Якушенко (1997), Р.Г.Нәҗметдинов, А.П.Курынов (1995–98) истәлегенә урнаштырылган мемориаль такталар авторы. Бөтенсоюз («Тынычлык сагында», «Туган ил сагында», Мәскәү, 1965; 1973), төбәкара («Зур Идел», 1970; 1980 һ.б.) күргәзмәләрдә, 16 автономияле республика күргәзмәсендә (Мәскәү, 1971), С.-Петербургта «ТАТАРТ» күргәзмәсендә (1991) катнаша. Шәхси күргәзмәсе Казанда 1984 елда була. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда саклана. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медаль б-н бүләкләнә.






Ә.К.Б ә ш и р о в. 1. «Советлар Союзы Герое М.Девятаев». Бронза, гранит. 1964–65. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее;
2. «Катюша портреты». Алюминий, коелма. 1978. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

*Әд.:* Искусство автономных республик Российской Федерации. Л., 1973; Червонная С.М.Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**БӘШИ́РОВ** Гомәр Бәшир улы (7.1.1901, Казан өязенең Арча волосте Яңасала а. — 7.5.1999, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның халык язучысы (1986). Авыл мәдрәсәсендә укый, 1919 елдан укытучылык итә. 1920–24 тә Кызыл Армия сафларында; 1920 дә Сиваш — Перекоп өчен барган сугышларда катнаша. 1924 тә армия хезмәтеннән кайткач, Эчке эшләр халык комис-тының Казандагы берьеллык махсус мәктәбендә укый, соңыннан 1929 га кадәр Арча кантоны милиция органнарында эшли, 1932 дә Балтачта һәм Дөбъязда халык тикшерүчесе, халык судьясы хезмәтен башкара. 1932 дән Казанда: «Кызыл Татарстан» г-тасы хәбәрчесе (1936 га кадәр), «Совет әдәбияты» ж-лының җаваплы сәркәтибе (1938 гә кадәр). 1941 дә Татарстан дәүләт нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөхәррире, 1941–42 дә (Г.Кашшаф һәм И.Гази б-н бергә) «Совет әдәбияты» ж-лының җаваплы сәркәтипләренең берсе, 1942–44 тә ТАССР ХКС каршындагы Радиолаштыру һәм радиотапшырулар ком-тында баш мөхәррир.

Б. әдәбиятка 1930 еллар башында килә. 1930–40 елларда Г.Разин исеме б-н таныла. «Канлы бармаклар» исемле беренче хикәясе 1931 дә Мәскәүдә «Ударниклар» ж-лында басыла. Б.ның алдагы иҗатына да хас булганча, туган ил темасын яктырткан «Соңгы сугыш» дигән беренче китабы 1934 тә Казанда нәшер ителә. Әдипнең сугышка кадәрге иҗат биографиясендә иң күренекле урын тоткан «Сиваш» повесте (1937) Кызыл Армия сугышчыларының 1920 дә Сивашны кичкәндәге батырлыклары турында. Б. совет халкының фашист илбасарларына каршы героик көрәшен чагылдырган «Намус» (1947; рус теленә тәрҗемәсе «Честь», 1949) романын сугыш барган көннәрдә яза башлый. Шул чор татар авылын сурәтләп, автор үз халкының бай рухи дөньясын ачып бирә. Романның төп герое — фидакарь, көчле рухлы, кешелекле, эчкерсез Нәфисә — сугыштан соңгы татар әдәбиятында иң уңышлы хатын-кыз образларыннан берсе булып таныла. Роман татар укучылары арасында гына популярлык казанып калмый, СССР халыклары телләренә дә тәрҗемә ителә һәм 1951 елда СССР Дәүләт бүләгенә лаек була. Төрле елларда романның рус телендә унлап басмасы (1 млн. нан артык гомуми тираж б-н) дөнья күрә, инглиз, француз, немец, испан, кытай, венгр, поляк, чех, болгар һ.б. телләргә тәрҗемә ителә.



Зариф Бәшири.



Гомәр Бәширов.

1960–70 еллар — Б. иҗатында яңа этап. Бу елларда татар әдәбияты шактый югары иҗади биеклеккә күтәрелә, язучылар, узган чор әдәбиятының проблемаларын кабат күздән кичереп, яңалыкны яктыртырга омтылалар, әдәби эзләнүләр тирәнрәк, киңрәк колач ала. Яңа шартларда Б., «Туган ягым — яшел бишек» (1967; рус теленә тәрҗемәсе «Родимый край — зеленая моя колыбель», М., 1972) повесте б-н революциягә кадәрге үткәнгә мөрәҗәгать итеп, үз балачагы чорындагы татар авылы тормышын хәтердә яңарта. Повестька халыкның рухи яшәешен чынбарлыктагыча сурәтләү хас. Бу әсәр татар әдәбиятында яңа күренеш була, чөнки 1917 елдан алып элеккке тормыш чиктән тыш берьяклы, кагыйдә буларак, тискәре яктан гына яктыртыла. Б. үзенең повестенда революциягә кадәрге татар авылының күп гасырлардан килгән традицияләргә, гореф-гадәтләргә, белемгә омтылу, китапка хөрмәт б-н карау кебек мәңгелек кыйммәтләргә нигезләнгән бай рухи тормыш б-н яшәвен сурәтли. Бер үк вакытта Б. замандашларының рухи-әхлакый асылына игътибар юнәлтә. «Намус» романы б-н «Туган ягым — яшел бишек» повестеның логик дәвамы булып «Җидегән чишмә» (1977) романы тора. Әлеге әсәрендә Б. бу проблеманы кешенең үзен чолгап алган табигать б-н үзара мөнәсәбәте аша ача. Әдип фәнни-техник үсеш заманында кешеләрнең үз-үзләрен тотышын әхлакый яктан бәяләүдә моңа бик әһәмиятле, хәтта хәлиткеч фактор итеп карый. Ул татар әдәбиятында беренчеләрдән булып табигатькә сакчыл караш мәсьәләсен күтәреп чыга. Аның фикеренчә, табигать байлыкларына битараф булу — кеше язмышына да салкын карау дигән сүз. Бу проблемада милли аспектның да йогынтысы бар — роман геройларының табигатькә мөнәсәбәте менталитетка бәйле үзенчәлек б-н аңлатыла.

Б. күп еллар дәвамында халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю һәм өйрәнү эшчәнлеге алып бара. Ул туплаган һәм әдәби яктан эшкәртүкән халык әкиятләре, җырлары, мәзәкләре күптомлы «Татар халык иҗаты» басмасында, «Мең дә бер мәзәк» (1963; рус теленә тәрҗемәсе «Тысяча и один мэзэк», 1989), «Туган тел мәзәкләре» (1995) китапларында дөнья күрә. Әхлакый-психологик «Күзгә ачы җилләрдә» (1984), «И язмыш, язмыш» (1990, Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1996), «Сарут» (1990) повестьлары гуманистик идеяләр б-н сугарылган, аларда тормыш, бүгенге көн турында уйлануларзур урын алып тора, кискен

социаль проблемалар күтәрелә. Тәмамланмаган «Гыйбрәт» (2000) романы вакыт, авторның үзе турындагы уйлануларга нигезләнә.

Әдәби иҗаттан тыш, Б. җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, 1953–58 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары. ТАССР ЮС (1951–55), ике чакырылыш СССР ЮС (1954–62) депутаты була. Күпкырлы иҗтимагый һәм иҗади эшчәнлеге өчен Ленин ордены, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, Октябрь Революциясе, Халыклар дуслыгы орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1981–84.

*Әд.:* Җ ә л ә л и е в а М. Гомәр Бәширов. К., 1959; А х у н о в Г. Җир һәм күңел җырчысы // Әдәби язмышлар. К., 1970; К а м а л о в Б. Халкым үстергән Алып // Заман. 1996. 5 янв.

*Ф.М.Мусин.*

**БӘШИ́РОВ** Заур Әхмәдулла улы (17.2.1945, Якутск ш. — 18.7.2006, Казан), радиоэлектроника гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1993), проф. (1995), ТАССРның атказ. уйлап табучысы (1989). 1971 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1975 елдан Казан техника ун-тында. 1996 дан Казан энергетика ун-тында электротехниканың теоретик нигезләре каф. мөдире. Хезмәтләре очраклы вибропроцессларны имитацияләү системаларына һәм анализлауга карый. Б. эшләгән виброакустик тикшерү приборлары һәм технол. процесслар б-н автоматлаштырып идарә итү системалары РФ һәм ТРның күп кенә пр-тиеләрендә гамәли кулланыла. Уйлап табуга караган 50 ләп авторлык таныклыгы бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996).

Х е з м.: Имитация и компенсация эксплуатационной вибрации. М., 1996 (автордаш); Проектирование и оптимизация комплекса аппаратуры и уплотнения измерительной информации в кабельных телевизионных сетях // Измерительная техника. 1994. № 5.

**БӘШИ́РОВ** Зөфәр Гомәр улы (3.1.1937, Казан), фоторәссам, журналист. Документаль фото өлкәсендә нәтиҗәле эшләүче фотографларның берсе. Казан дәүләт ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), Төрекмәнстан ССРдагы Красноводск шәһәрендә инженер-синоптик (1960–62), Казандагы хәрби заводларның берсендә инженер (1962–80) булып эшли. 1972–75 тә «Яңалыклар» матбугат агентлыгының (АПН) Казандагы штаттан тыш хәбәрчесе. 1980–93 тә Татарстан китап нәшриятында фотограф, бизәлеш редакторы вазифаларын башкара. 1997–98 дә Татар энциклопедия ин-тының өлкән фәнни хезмәткәре. Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы (1987). Беренче фоторәсемнәре 1949 да күренә башлый. 1964 тән «Волга» фотоклубы әгъзасы. 1970 елларда Б.ның фоторәсемнәре «Правда», «Известия», «Советская культура» үзәк г-талары битләрендә, АПНның халыкара басмаларында басыла. Б.ның әсәрләре арасында төп урынны татар халкының тарихы, мәдәниятенә, әдәбият, сәнгать өлкәсендәге күренекле эшлеклеләрнең тормышы һәм иҗатына багышланган фоторәсемнәр серияләре биләп тора; ул, татар рәссамнарының сынлы сәнгать, Идел ягы табигате күренешләре төшерелгән һ.б. фоторәсемнәрне авторлык һәм коллектив альбомнарына туплау б-н бергә, аларны төзүче буларак та катнаша. «Волга» фотоклубының респ-ка күргәзмәләрендә, «Наша современность» фотоклублары арасында уздырылган 5 нче бөтенсоюз конкурсының иң яхшы фоторәсемнәр (Ленинград, 1971), «Кеше һәм табигать» бөтенсоюз нәфис фоторәсемнәр (Новокузнецк, 1978), В.И.Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган халыкара документаль һәм нәфис фоторәсемнәр (Мәскәү, 1969) күргәзмәләрендә, халыкара нәфис фоторәсемнәр салонында (Катовице, Польша, 1969) катнаша.





З.Г.Б ә ш и р о в. 1. «Тегермәннән кайту». Балтач р-ны, Янгул авылы. 1972; 2. «Сәгъди абзый йортында». Кырлайда Габдулла Тукай музее. 1984.

Х е з м.: Бакый Урманче: Альбом. К., 1982; Габдулла Тукай: Фотоальбом. К., 1986; Татарстан. Табигать һәйкәлләре: Фотоальбом. К., 1994; Муса Җәлил. Моабит дәфтәрләре. К., 2000; Дәрдемәнд: Фотоальбом. К., 2003; Онытылмас йөзләр: Фотоальбом. К., 2005; Волга. Боль и беда России: Фотоальбом. М., 1989; Г.Тукай. Фотоальбом: К 120 летию со дня рождения. К., 2006.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БӘШИ́РОВ** Радик Миңнехан улы (7.1.1935, Башкортстан АССРның Кыйгы р-ны Кыйгы а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1982), Башкортстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы (1995), БАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1976, 1994). 1959 елда Башкорт а.х. ин-тын (хәзерге Башкорт аграр ун-тын) тәмамлый (Уфа ш.). 1965 елдан шунда ук эшли: 1967–73 елларда тракторлар һәм автомобильләр каф. мөдире, 1971–72 дә а.х. механикалаштыру ф-ты деканы, 1973–84 тә проректор, проф. (1983), 1988–99 да ректор, 2000 нән автотрактор двигательләре һәм җылылык техникасы каф. мөдире. Хезмәтләре автотранспорт дизельләренең ягулык бирү системаларына карый. Плунжер парының һәм кугыч клапаннарның тыгызлыгын тикшерү өчен яңа ысуллар һәм приборлар эшли; күп кенә насос һәм форсункалар конструкцияләрен төзи. Б. хезмәтләре автотрактор дизельләрен сериялэп җитештергәндә файдаланыла. Уйлап табуга караган 10 лап авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Надёжность топливной аппаратуры тракторных и комбайновых дизелей. М., 1978 (автордаш); Скоростные характеристики топливоподающих систем тракторных дизелей. Ульяновск, 1976; Топливные насосы распределительного типа. М., 1975 (автордаш).

**БӘШИ́РОВ** Рәдиф Исхак улы (3.1.1929, Казан — 20.4.1996, Махачкала ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1977), проф. (1989), Дагстан АССРның атказ. фән эшлеклесе (1979). 1952 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА Дагстан гыйльми үзәгенең Физика ин-тында эшли (Махачкала ш.): 1959–92 елларда ярымүткәргечләр һәм ярымүткәргеч приборлар лаб. мөдире, бер үк вакытта 1986–92 дә директор урынбасары, 1992 дән баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре ярымүткәргечләр физикасына һәм югары басым физикасына карый. Үтә көчле магнит кырларындагы ярымүткәргечләрдә гальванотермомагнит күренешләрен беренчеләрдән булып тикшерә. Ландау кимәлләрендәге спин таркалышының магнито каршылыгының квант осцилляциясенә тәэсир итүен беренче булып ачыклый. Термоэлектр йөртү көченең квантлаучы магнит кырында кискен артуын ачыклый. Ярымүткәргечләрдә магнетофонон резонанс барлыкка килүне күрсәтә, германийның бериш җылынмаган электрон-тишемле плазмасын кулланып эл. тогын турайткыч ясау мөмкинлеген дәлилли. Дагстан Респ-касы Дәүләт бүләге лауреаты (1994).

Х е з м.: Квантовые осцилляции магнетосопротивления в n-Jn Sb в сильных импульсных магнитных полях // Докл. АН СССР. 1963. Т. 148 (автордаш); Влияние спинного расщепления на эффект Шубникова — де-Гааза в антимониде индия // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1964. Т. 47 (автордаш); Новый класс полупроводниковых диодов // Журн. техн. физики. 1984, Т. 54 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**БӘШИ́РОВ** Фәрит Кәрим улы (30.11.1958, Арча р-ны Шекә а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1981). 1984–2003 елларда — ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. 2004 елдан «Матбугат йорты» полиграфия-нәшрият комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятендә эшли. Хезмәтләре 20 йөз башы татар прозасын өйрәнүгә, бүгенге көн әдәби процессы мәсьәләләренә, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, К.Тинчурин һ.б. иҗатларына карый.

Х е з м.: Сөйлә, калəм! К., 2001; XX йөз башы татар прозасы. К., 2002.

**БӘШИ́РОВА** Диләрә Кәбир кызы (7.10.1926, Казан), йогышлы авырулар белгече, мед. фән. д-ры (1974), проф. (1976), ТРның атказ. табибәсе (1996). 1949 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1953 елдан Казан мед. академиясендә, 1971–2004 елларда йогышлы авырулар каф. мөдире. Йогышлы авыруларның клиник иммунологиясе, корсак тифы, дизентерия, вируслы гепатит һ.б. авыруларның патогенезында һәм аларны дәвалауда иммунитетның күзәнәк механизмнары әһәмиятен тикшерә. Беренче булып корсак тифы, дизентерия һ.б. йогышлы авырулар клиникасында антибиотиклар б-н дәвалаганда лимфоцитларның функциональ торышын өйрәнүгә бәйле тикшеренүләрдә бластлы трансформация ысулын гамәлгә кертә (1977). Б. тарафыннан иммун хәтер тупланган күзәнәкләр формалашуы исбатлана һәм йогышлы авырулардан соң иммунитетны үстерүдә аларның роле ачыклана, левомицетинның иммуносупрессив эффекты ачыклана (1983); азыкка аллергияле балаларда вируслы гепатитның барышы һәм тәмамлануы өйрәнелә, бу исә азыкка аллергияне гепатитның хроник формаларын китереп чыгара торган фактор дип санарга мөмкинлек бирә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Клинико-иммунологические аспекты инфекционных болезней. Л., 1983; Иммунные реакции в патогенезе брюшного тифа. Л., 1989; Вирусные гепатиты и беременность // Практическое руководство. К., 1995. Т. 1.

*Әд.:* Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина (1920–1990). К., 1990.

**БӘШИ́РОВА** Зәйнәп Хуҗихан кызы (5.10.1903, Лаеш өязе Балтач а. — 8.7.1984, Казан), шагыйрә. Мәскәү журналистика ин-тын тәмамлый (1928). 1928–30 елларда «Эшче» (Мәскәү) г-тасында эшче яшьләр бүлеге мөдире, 1931–34 тә Горький өлкәсе Кызыл Октябрь р-нында чыккан «Октябрь коммунасы» г-тасында мөхәррир булып эшли. 1935–37 дә Татарстан дәүләт нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторында өлкән мөхәррир. 1938–58 дә китапханәче хезмәтен башкара. Шигырьләре 1920 еллар вакытлы матбугатында еш басыла. «Очкыннар» (1921), «Яшь инкыйлабчы җырлары» (1923) исемле шигырь җыентыклары авторы.

*Әд.:* Г а й н у л л и н М. Зәйнәп Бәширова // Совет әдәбияты. 1963. № 8; Ф ә й з у л л и н Р. Авылдаш // Казан утлары. 2003. № 10.

**БӘШИ́РОВА** Илида Басыйр кызы (23.11.1938, Оренбург өлкәсенең Матвеев р-ны Иске Әшер а.) тел галиме, филол. фән. д-ры (2000), проф. (2001), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1961). 1961–63 елларда Куйбышев өлкәсендә урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1966 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1996 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты). 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар әдәби теле стилистикасын һәм тарихын өйрәнә.

Х е з м.: Сүз белән сурәт ясау. К., 1974; Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле. К., 1979; Җидегән чишмә моңы. К., 1995; Татар әдәби теле тарихы: 19 гасыр ахыры — 20 йөз башы әдәби теле. Исем категорияләре һәм фигыль наклонениеләрендә әдәби норма, норма вариантлыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык. К., 1999; Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология. Татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. К., 2006.

**«БӘЯНЕЛХА́К»** («بيان الحق» — «Хакыйкатьне бәян итү»), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. 1906 елның 31 мартыннан 1914 нең апреленә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә. 1912 елга кадәр атнага 2–3 тапкыр, аннан соң көн саен, барлыгы 1307 саны чыга. Төрле елларда нашир-мөхәррирләре: Ә.Сәйдәшев, *М.Сәйдәшев*, Ш.Иманаев. Газетада С.Рәмиев, Р.Рәкыйби һ.б. авторлар языша. «Б» — дини-консерватив характердагы басма, һәм ул демократик матбугат әһелләре тарафыннан каты тәнкыйтьләнә. Ш.у. вакытта анда прогрессив караштагы материалларга да шактый урын бирелә. «Б.» динне һәм милләтчеләр мәнфәгатьләрен яклый, татар халкының көнкүреш үзенчәлекләрен, милли традицияләрен саклау кирәклегенә әһәмият бирә. Аның битләрендә халыкның мәдәни тормышы, театр, музыка һәм әдәбият яңалыклары киң яктыртыла, бик күп белдерүләр, сәүдә игъланнары басыла.


بيان الحق

НОЧЬ ЛЮБВИ

МАДАМЪ ШЕРИ

«Бәянелхак» газетасы.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; ш у л у к. Әдәби сүзлек // Татарстан. 1992. № 7/8; Г а й н у л л и н М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«БӘЯНЕЛХА́К» БАСМАХАНӘСЕ́**, шул исемдәге газетаны бастыру өчен сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшев тарафыннан 1907 елда Казанда ачыла. Шул ук елда басмаханәдә китаплар да нәшер ителә башлый. 1912 елга кадәр 75 исемдә китап бастырып чыгара (гомуми тиражы — 220100 данә). Алар арасында: Гөлнар ханымның (О.С.Лебедева) «Мөслимәләр хөррияте» (1907), Заһир Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1908) романы, «Сәгыйть Рәмиевнең шигырьләре» (1909); Ф.Әмирхан, М.Идриси, Ш.Иманаевларның дәреслек китаплары, авыл хуҗалыгы, ветеринария, медицина, гыйльме тәрбиядән Ибраһим Терегулов тәрҗемәсендә популяр брошюралар, Г.Баруди, М.Түнтәриләрнең дини-фәлсәфи хезмәтләре һ.б. Басмаханәдә ш.у., «Бәянелхак» г-тасыннан тыш, «Казан мөхбире» (кушымтасы б-н бергә) г-тасы да басылып таратыла. Төп заказчы нәшриятлар — «Китап», «Милләт», «Юл». 1912 елда Ә.Я.Сәйдәшев вафатыннан соң «Б.» б. аның бертуганы М.Я.Сәйдәшев кулына күчә. Шул ук елда китап басулар да туктый. 1914 елда басмаханә ябыла.



Ф.Г. Бегишев.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; ш у л у к. Книги и люди. К., 1985.

**БЕ́БУТОВ** Валерий Михайлович (6.12.1885, Царицын ш. — 2.11.1961, Мәскәү), режиссёр, РСФСРның атказ. артисты (1934), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1945). 1911 елда Петербург ун-тының тарих-филология ф-тын тәмамлый. Театр белемен В.Э.Мейерхольд җитәкчелегендә ала. 1940 елларга кадәр Мәскәү театрларында — Мәскәү Сәнгать театрында (1912–17), Эшчеләр оешмаларының сәнгать-агарту берлеге театрында (1917–18), «Романеск» театрында (1922 дә оештыра һәм җитәкли), Муз. буффонада (тамаша) театрында (соңрак Муз. комедия театры, 1924 тән аның җитәкчесе), Мәскәү оперетта театрында, Зур театрда спектакльләр куя. 1941–45 тә Татар опера һәм балет театрында сәнгать җитәкчесе булып эшли, Ж.Бизеның «Кармен» (1942), Н.Җиһановның «Илдар» (З.Сафин б-н берлектә, 1942), А.С.Даргомыжскийның «Су кызы» («Русалка», 1943), Н.Җиһановның «Түләк» (1945) операларын, Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» муз. драмасын (Җ.Фәйзи музыкасы, 1941) куя. Б. ш.у. Татар акад. театрында Лопе де Веганың «Печән өстендәге эт» («Собака на сене», 1942) әсәрен, У.Шекспирның «Король Лир» трагедиясен (1944) һ.б.ны сәхнәләштерә. Б.ның режиссёрлык стиле классик опера һәм драма әсәрләрен үзенчәлекле, иркен, динамик рәвештә сәхнәләштерүгә б-н аерылып тора.

*Әд.:* И л я л о в а И.И. Театр имени Камала. К., 1986; С а л и т о в а Ф.Ш. Начало пути (1939–50) // Татарский академический театр оперы и балета имени Мусы Джалиля. К., 1994; Музыкальная энциклопедия. М., 1973. Т. 1.

**БЕ́ГИШЕВ** Фәйзерахман Гариф улы (11.11.1911, Рязань губ. Әҗе а. — 16.8.1987, Мәскәү), нефтьче-геолог, ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1961), СССРның мактаулы нефтьчесе (1971). Казан ун-тын (1936), Нефть сәнәгате академиясен (1952, Мәскәү) тәмамлый. «Куйбышевнефть»нең бүлек җитәкчесе (1945–49), баш геологы (1949–50). «Татбурнефть» (1950–57), «Татнефть» (1957–66) берләшмәләренең баш геологы. СССР Нефть сәнәгате министрлыгының «Главвостокнефтедобыча» идарәсе башлыгы урынбасары (1966–70). Б. — Татарстанда геол. хезмәтен оештыручыларның берсе. Аның җитәкчелегендә бик күп нефть чыганаклары ачыла һәм Ромашкино, Яңа Елховой, Бондюг һ.б. чыганакларда нефть чыгарыла башлый. Контурлап су тутыру ысулы б-н Ромашкино нефть чыганагын яңача эшкәртү системасын уйлап тапканы

өчен Ленин бүләге бирелә (1962). Ленин, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О состоянии разработки Ромашкинского месторождения // Нефтяное хозяйство. 1958. № 9; Регулирование процессов разработки горизонтов $Д_1$ Ромашкинского месторождения // Геология нефти и газа. 1963. № 10.

**БЕГЛО́ВА** Садыя Ариф кызы (15.8.1923, Рязань өлкәсенең Каверин р-ны Зур Студенец а. — 10.10.1992, Казан), хокук белгече, ТАССРның атказ. хокук белгече (1985). Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1954). 1950–51 елларда Казанда ВКП(б)ның Бауман райкомы инструкторы, 1951–54 тә ТАССРның юстиция министры урынбасары. 1954–57 дә КПССның Әлмәт шәһәр ком-ты секретаре. 1957–58 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор, 1958–60 та хакимият һәм сәүдә-финанс органнары бүлеге мөдире урынбасары. 1960–65 тә Казанда КПССның Бауман райкомы 1 нче секретаре. 1965–69 да хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1969–85 тә ТАССР Югары мәхкәмәсе рәисе. 1963–85 тә ТАССР ЮС депутаты.

*М.М.Мәүләтшин.*

**БЕГО́НИЯ**, м и ң л е  г ө л, к а р а б о д а й  г ө л е, б а к а  г ө л е (Begonia), бегониячәләр семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Бер- һәм күпьеллык үләннәр (сирәгрәк — куаклар, лианалар, эпифитлар һәм суккулентлар). Бүлбеле, яфраклы, куаклы, һәрвакыт чәчәк атучы һ.б. төрләргә бүленә. 1000 ләп төре билгеле. Чыгышы — Азия, Көньяк Америка, Африка тропиклары. Яфраклары асимметрик, төрле төстә, зурлыкта, формада. Кайбер төрләренең яфраклары гаҗәеп бизәкләр б-н капланган һәм йонтәс. Чәчәкләре ут төсле кызыл, кар кебек ак, күптөрле төсмерле алсу төстә, яшькелт, сирәгрәк — сары һәм кызгылт-сары төстә, куентыклы чәчәк төркеменә җыелган, дөрес булмаган формалы. Татарстанда кайбер төрләре бүлмәләрдә декоратив итеп үстерелә: Б. рекс яки король Б.се (B. rex Putz), балтырган яфрагы сыман Б. (B. heracleifolia Cham. et Schlecht.), һәрвакыт чәчәк атучы Б. (B. semperflorens Link), лотос яфраклы Б. (B. nelumbifolia Cham. et Schlecht). Орлыклардан, бүлбеләрдән, сабак һәм яфраклы чыбыкчалардан, чәчәк сабыннан үрчетеләләр. Туры кояш нурына һәм һаваның корылыгына түзә алмый.

**БЕДНОДЕМЬЯ́Н РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсендә*, (Пензадан 162 *км* төньяк-көнбатыштарак) Үзәге — Беднодемьяновск шәһәре. Халкы — 13827 кеше (2002), татарлар — 247 кеше. Татар Шелдаисы (Татар Шылтайсуы) (1641 дә нигез салына) авылында 1917 елга кадәр мәчет һәм ир балалар өчен мәдрәсә эшли, мәчет Аккүл авылында да (1957 гә кадәр — Таракановка) була. 1956 елга кадәр Татар Шелдаисы мәктәбендә татар теле укытыла. Хәзерге вакытта монда мәчет эшли. Аккүл авылында актёр, режиссер, драматург К.Г.*Тинчурин* туган.

**«БЕДНЯ́К»** («Ярлы»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан шәһәр советы, аннан соң РКП(б)ның Казан губкомы органы. 1918 елның 10 декабреннән 1919 ның 23 сентябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 200 саны чыга. Крәстияннәргә һәм кызылармиячеләргә бушлай таратыла. Җаваплы мөхәррирләре А.Барщевский, Ю.Мальцев. Атаклы Казан журналистлары В.Я.Введенский, П.А.Радимов, Ю.А.Фемидин, шагыйрьләр С.Оков, П.Н.Ионов, А.Бамунер актив язышалар. Адмирал А.В.Колчак армиясе һөҗүме башлангач, 1919 ның 19 апреленнән газета чыгудан туктый. Редакция хезмәткәрләре Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясе тарафыннан чыгарыла торган «Красный воин» г-тасы редакциясенә күчерелә. 1919 ның маенда «Б.» г-тасы яңадан чыга башлый. Анда Совет хакимиятенең декретлары, карарлары, өндәмәләре, РКП(б)ның 8 нче съезды материаллары басыла. «Б.» хөкүмәтнең аграр һәм азык-төлек тармагы сәясәте, ярлылар ком-тлары эше, хәрби техника яңалыклары б-н таныштыра, Кызыл Армиягә ярдәм итәргә өнди. Рәсми документлардан тыш, илнең эчке һәм халыкара тормышы турындагы материалларга да урын бирелә. Төп рубрикалары: «Хезмәт дөньясында», «Авыллар буйлап», «Кызыл Армия тормышы», «Партия тормышы», «Халык хуҗалыгы», «Яктылыкка һәм белемгә таба».

*Әд.:* Л и т в и н А.Л. Из истории борьбы местной печати за победу на Восточном фронте в 1918–1919 гг. // Из истории местной периодической печати. К., 1960; Н а с ы р о в Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975.

*Г.Р.Заманова.*

**«БЕЗ»**, газета, к. «*Казан мөхбире*».

**БЕЗБОРО́ДОВ** Лев Петрович (11.9.1955, Тула өлкәсе, Богородицкий р-ны Кузовка а.). 1999 елдан «ЦБС Аутомотив Елабуга» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең Рос.-Чехия уртак пр-тиесе ген. директоры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). 1982 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Кама политехника ин-тында (Чаллы ш.) өлкән инженер булып эшли. 1986–99 да «ЕлАЗ» җитештерү берләшмәсендә: цех җитәкчесе, 1991 дән директор урынбасары. Дәүләт бүләге (2000) автомобильләр төзү сәнәгате өчен яңа ПВХ-пластизольләр җитештерүне уйлап тапканы һәм гамәлгә кертүе өчен бирелә.

**БЕЗЕЛДӘВЕ́К ЧЕБЕННӘ́Р**, ч ә ч ә к  ч е б е н н ә р е (Syrphidae), чебеннәр семьялыгы. 4,6 меңнән артык төре бар, Россиядә — берничә йөз, Татарстан терр-ясендә 100 дән артык төре билгеле, ләкин төрләр составы җитәрлек өйрәнелмәгән. Гәүдәсенең озынлыгы 5–25 *мм*, сары, ак, кызыл яки кара төстәге ачык буй-буй сызыклары яки тимгелләре бар. Кайберләре чагучы элпәканатлыларга: шөпшә, бал корты яки төклетурага охшаган. Чәчәк нектары б-н туенулары сәбәпле зур Б.ч. үсемлекләрне серкәләндерәләр; канатлары б-н тиз җилпенеп, читкә тиз очып китүләре һәм яңадан үләнчел үсемлек һәм куак чәчәкләренә очып килүләре, һавада озак хәрәкәтсез, элеп куйган кебек тора алулары б-н аерылалар. Б.ч. личинкаларының яшәү рәвеше төрлечә: үсемлек б-н туенучылар каткан кабык астында, агач куышларында, үсемлек тукымаларында яши, суган Б.ч. (Eumerus) личинкалары суганчаларны зарарлыйлар, аларның үзәген ашыйлар; сапрофаглар таркалу продуктларына бай булган суда яшиләр. «Күсесыман»нар дип аталучы Eristalis ыругы чебене личинкаларының корсак очында 15 *мм* га кадәр озынлыктагы сулыш көпшәсе бар; ерткычлары үсемлекләрдә яшеренмиләр, башка тигез канатлыларның личинкаларын һәм гөмбәләрен юк итәләр, кайберләре бөҗәк-ксилофагларның йөрү юлларында, төклетура, кырмыска һәм шөпшә ояларында туеналар.

*Әд.:* Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1966; Р о с с Г., Р о с с Ч., Р о с с Д. Этномология. М., 1985.

*С.М.Шәфигуллина.*

**БЕ́ЗИНА** Александра Константиновна (15.2.1932, Мәскәү өлкәсенең Коломна ш.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1982), проф. (1983), ТССРның атказ. фән. эшлеклесе (1991). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), шунда ук эшли, 1992–97 елларда гражданнар хокукы һәм процессы каф. мөдире. Хезмәт хокукы өлкәсендә тикшеренүләр авторы.

Х е з м.: Судебная практика и развитие советского трудового законодательства. К., 1971; Вопросы теории трудового права и судебная практика. К., 1976; Индивидуально-договорное регулирование труда. К., 1984 (автордаш); Судебная практика в механизме правового регулирования трудовых отношений. К., 1989.

**«БЕЗНЕ́Ң БАЙРА́К»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты органы. 1922 елның 18 октябреннән 1924 нең 28 мартына кадәр Казанда атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 72 саны чыга. Төрле елларда җаваплы мөхәррирләре: Г.*Мансуров*, Ф.*Бурнаш*, Ш.Рәмзи. Актив язышучы авторлар: К.Әмири, М.Мөштәри, И.Рәхмәтуллин, С.Фәхри, А.Хәлим. Газета илдәге һәм чит илләрдәге сәяси хәлләрне яктырта, яшьләргә белем бирү мәсьәләләрен күтәрә, татар әдәбияты, театры һәм вакытлы матбугат торышы турында язмалар бастыра. «Б.б.» «партия юлыннан тайпылганы, милләтчелеккә тартым материаллар бастырганы өчен» РКП(б) ҮК тарафыннан тәнкыйтьләнә. Рубрикалары: «Сәясәт дөньясында», «Чит илләрдә», «Совет Россиясендә», «Партия тормышыннан», «Фән һәм дин», «Халык мәгарифе», «Икътисад» һ.б.

**«БЕЗНЕ́Ң ИЛ»**, газета, к. «*Ил*».

**«БЕЗНЕ́Ң ТАВЫ́Ш»**, иҗтимагый-сәяси газета. *Бөтенроссия мөселманнары вакытлы Хәрби Шурасы*, аннан соң *Бөтенроссия мөселманнары Хәрби Шурасы* органы. 1917 елның 29 маеннан 1918 нең 26 февраленә кадәр Казанда атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 88 саны чыга. Мөхәррире Г.*Монасыйпов*. Ф.Әмирхан II, Г.Дәүләтшин, С.Җәлал һ.б. авторлар язышa. «Б.т.» большевиклар диктатурасына кискен каршы чыга, хәрби матбугатка милли азатлык рухы бирергә омтыла, татар халкының милли үзбилгеләнү хокукы идеяләрен алга сөрә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«БЕЗНЕ́Ң ТЕЛӘ́К»**, иҗтимагый-сәяси аналык газета. Оренбург мөселман хәрби комитеты органы. 1917 елның декабреннән 1918 нең 20 гыйнварына кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 12 саны чыга. «Вакыт» басмаханәсендә басыла. Мөхәррире С.Гайфи. Ил һәм дөнья хәлләрен яктырта, мөселман җыеннары хисапларын бастыра, хәрби хәрәкәтләрне туктатырга өнди, татар вакытлы матбугатын фактларны бозып күрсәтүдә гаепли. Рубрикалары: «Дөньяда», «Оренбургта», «Фронт яңалыклары» һ.б.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

*Г.Г.Хәсәнова.*

**«БЕЗНЕ́Ң ФИКЕ́Р»**, иҗтимагый-сәяси газета. *Бөтенроссия мөселманнары милли шурасының* Самара бүлеге органы. 1918 елда Самара шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Шәһәрне чех-словак корпусы частьләре басып алганнан соң, Кызыл Армия гаскәрләренең Самараны кире кайтаруына кадәр чыгарыла. Самара губерна басмаханәсендә басыла. Шигарьләре: «Көч — гыйлемдә һәм берләшүдә!» «Яшәсен Учредительный собрание!», «Яшәсен милли-мәдәни мохтарият!».

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000;

**«БЕЗНЕ́Ң ЮЛ»**, иҗтимагый-сәяси газета. Татар-башкорт сул эсерлар партиясенең Уфа губкомы органы. «*Ирек*», «*Солдат теләге*» һәм «Авыл халкы» г-таларының берләшүеннән барлыкка килә. 1917 елның 21 сентябреннән 1918 нең 28 мартына кадәр Уфада татар телендә нәшер ителә, барлыгы 36 саны чыга. Төрле вакытта мөхәррирләре: Г.*Ибраһимов*, М.Әхмәров, Ш.*Сүнчәләй*. Актив язышучылары М.Гафури, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Алпаров, Г.Әлмөхәммәдов, И.Рәмиев, Г.Баембәт һ.б. Газета материалларында Окт. рев-циясе солдат, эшче һәм крәстияннәрнең фидакарь көрәше нәтиҗәсе дип бәяләнә. «Б.ю.» Россиянең федератив төзелеше, җирне гомумиләштерү мәсьәләләрен, җирле мохтарият оештыру идеяләрен яклый. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлар Советлары эшчәнлеген яктырта, 1 нче Бөтендөнья сугышы фронтларындагы сугыш хәрәкәтләре хроникасын биреп бара, халыкка белем бирү мәсьәләләрен күтәрә. Рубрикалары: «Илдә», «Уфада», «Фронтта» һ.б.

*Әд.:* Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000.

*Г.Г.Хәсәнова.*

**«БЕЗНЕ́Ң ЮЛ»**, журнал, к.«*Казан утлары*».

**БЕ́ЙБУТОВ** Әнвәр Мәҗит улы (7.3.1912, Тифлис ш. — 28.3.1994, Мәскәү), драма актёры, режиссёр, педагог, РСФСРның халык артисты (1965). СССРның халык артисты, җырчы Рәшид Бейбутовның бертуганы. Сәхнә эшчәнлеген 1932 елда Баку эшче яшьләр театрында башлый, 1934–38 дә Тифлис яшь тамашачылар театры актёры. 1938–42 дә ГИТИСта (Мәскәү) күренекле режиссёр А.Д.Попов классында укый. 1942–54 тә — Новосибирск, Ульянов, Хабаровск шәһәрләре театрларында режиссёр. 1954–59 да Казан Зур драма театрында баш режиссёр. Казанда Б. 13 спектакль куя. А.Н.Арбузовның «Ил гизүләр» («Годы странствий», 1954), М.Н.Елизарованың «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» («Юность Буревестника»), Ф.Шиллерның «Дон Карлос» (икесе дә 1955 тә), М.Горькийның «Егор Булычов һәм башкалар» («Егор Булычов и другие»), «Карт» («Старик»); Р.Ф.Ишморатның «Үлмәс җыр» (өчесе дә 1956 да), Н.Ф.Погодинның «Өченче патетик» («Третья патетическая», 1958), Л.Н.Толстойның «Караңгылык золымы» («Власть тьмы», 1959) әсәрләре буенча куелган спектакльләр киң катлау җәмәгатьчелек тарафыннан аеруча зур танылуга ирешә, шәһәрдә генә түгел, илнең театр тормышында мөһим вакыйга буларак кабул ителә. Образның тормыш чынбарлыгы б-н очрашкандагы үсеше һәм формалашу процессы, кеше язмышының социаль проблемалары режиссёр тарафыннан бөтен төрлелеге һәм каршылыклары аша ачыла («Ил гизүләр», «Дон Карлос», «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге», «Үлмәс җыр»). Горькийның «Карт» пьесасын куеп, Б. әсәрнең сәхнә тарихын шактый баета, аның фәлсәфи эчтәлеген яңача ача, баш геройның характеры артына яшерелгән социаль хәлләрнең глобальлеген күрсәтә. Б.ның иң яхшы спектакльләре лирик һәм героик-романтик сыйфатларның бергә кушылуы, гражданлык һәм революцион пафос, тамашачыга эмоциональ тәэсир итү көче, кырыс тормыш чынбарлыгы, аны аһәңле итеп күрсәтә белүе б-н аерылып торалар. Режиссёр Б. куйган спектакльләрдә үзләренең иң күренекле рольләрен уйнаган Г.П. Ардаров, Н.С. Провоторов, Е.В.Лисецкая кебек актёрлар талантының яңа үзенчәлекләре ачыла. Б. Казан Зур драма театры каршындагы студияне яңадан торгыза. Аны тәмамлаучылар арасында РСФСРның халык артистлары В.Габаев, В.Кешнер, Ю.Федотов һ.б. бар. Б. куйган спектакльләр Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында күрсәтелә (1957). Шуннан соңгы елларда Б. Ростов-Дон, Баку шәһәрләре театрларын җитәкли, Мәскәү цирк уч-щесендә һәм Мәскәү мәдәният ин-тында укыта.



Ә.М. Бейбутов.

*Әд.:* Ингвар И., Иляловa И. Русский театр в Казани. К., 1991; Театральная энциклопедия. М., 1967.

*Ю.А.Благов.*


Зур драма театрында Ә.М. Бейбутов куелышындагы спектакльләрдән күренешләр:
1. «Карт» (М. Горький); 2. «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» (М.Н. Елизарова).





**БЕКА́СОВ** Василий Александрович (24.8.1898, Кострома губ., Галич өязе Кишкино а. — 25.5.1975, Казан), спортчы, Татарстанда физ. культура һәм спортны пропагандалаучы һәм оештыручы, СССРның атказ. спорт остасы (1942). Команда составының Баш хәрби гимнастика, фехтование мәктәбен (1919, Петроград), Татар-башкорт хәрби командир-инженерлар мәктәбен (1929, Казан) тәмамлый. Чаңгыда узышу, күп төр ярышлар, ирекле көрәш, йөзү, җиңел атлетика буенча ТАССР чемпионы (1923–28). Казан хәрби-инженерлар мәктәбендә (1919–24), Команда составының татар-башкорт хәрби-инженерлар мәктәбендә (1924–29) физик әзерлек буенча төп өйрәтүче, Казан ун-тында физ. тәрбия каф. мөдире (1929–39), ТАССР Хәрби комис-тының 5 нче бүлегендә өлкән инструктор (1940–55). Ленин, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. 1970 еллар ахыры — 80 еллар башында «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең өлкә советы Б. исем. призга хәрби хезмәткә алынучылар арасында Бөтенсоюз ГТО комплексы буенча ярышлар уздыра.

**БЕКЕ́ТОВ** Андрей Николаевич (1822, Пенза губ. Яңа Бекетовка а., хәзерге Пенза өлкәсе, Колышлей р-ны Алферьевка а. — 3.2.1895, Казан), хирург, медицина д-ры (1848). 1844 елда Петербург мед. хирургиясе академиясен тәмамлый. 1844–48 дә — Мәскәү, 1848–82 дә Казан ун-тларында эшли. 1860 елдан мед. ф-ты госпиталь хирур-



Н.Н. Бекетов.

гиясе клиникасының беренче директоры һәм профессоры, Җәмәгать тәрбиясе приказы хастаханәсендә (соңрак — губ. хастаханәсе) госпиталь хирургиясе каф. мөдире. Казанда беренче булып хирургик операция ясаганда авыртуны басу өчен хлороформ куллана (1848).

Х е з м.: Паховая грыжа. К., 1848; О произвольном вывихе коленной чашки // Военно-мед. журн. 1850; Практические замечания о Казанской тифозной эпидемии // Моск. мед. журн. 1852.

*Әд.:* Казанский медицинский институт, 1814–1989. К., 1989. Ч. 1.

**БЕКЕ́ТОВ** Николай Николаевич (1.1.1827, хәзерге Пенза өлкәсе Алферьевка а. — 13.12.1911, С.-Петербург), физик-химик, Петербург ФАнең хакыйкый әгъзасы (1886 дан), Россиядә физ. химиягә нигез салучыларның берсе. Казан ун-тын (1849) тәмамлый. 1849–53 елларда Петербург мед.-хирургия академиясендә Н.Н.Зинин лабораториясендә эшли, 1854–55 тә Петербург, 1855–86 да Харьков ун-тларында (1859 елдан проф.). 1886 дан Петербург ФАнең химия лабораториясендә, бер үк вакытта Югары хатын-кызлар курсларында укытучы. Фәнни эшчәнлеген органик матдәләрне (Н.Н.Зинин б-н берлектә) югары темп-раларда тикшерүдән башлый, органик кушылмаларның яңа классыннан бензуреид һәм ацетуреидны синтезлый. Реакция юнәлешенең реагентларның хәленә һәм тышкы шартларга бәйлелегенә караган берничә теоретик кагыйдә тәкъдим итә. Бер металлның икенчеләре б-н этеп чыгарылуын өйрәнә. Басым астында металларның водород б-н алмаштырылу күренешен ача, магнит һәм цинкның башка металл тозларыннан башка металларны этеп чыгаруын билгели. Металларны оксидларыннан алюминий ярдәмендә кайтару юлын ача, шуның б-н фәндә һәм сәнәгатьтә мөһим әһәмияткә ия булган алюминотермиягә нигез сала. Б. Россиядә беренче термохим. лабораторияләр оештыра, аларда үзенең шәкертләре б-н хим. якынлык буенча тикшеренүләр үткәрә, селтеле металларның оксидлары һәм хлоридлары барлыкка килгәндәге җылылыкны билгели. Б. беренче булып физ. химияне мөстәкыйль фән һәм укыту дисциплинасы итеп кертә, аның тәкъдиме б-н Харьков ун-тында физ.-химия бүлеге оештырыла, анда лекцияләр уку б-н беррәттән практик эшләр һәм физ.-хим. тикшеренүләр дә үткәрелә. Рус физ.-хим. җәмгыятенең президенты (1889–90, 1896–97, 1900, 1902, 1903, 1911).

Х е з м.: Избранные произведения по физической химии. Хар., 1955.

*Әд.:* Х о т и н с к и й Е.М. Академик Николай Николаевич Бекетов: Очерк о жизни и деятельности. Хар., 1950; Б е л я е в А.И. Николай Николаевич Бекетов — выдающийся русский физико-химик и металлург. М., 1952; Т у р ч е н к о Я.И. Николай Николаевич Бекетов. М., 1954.

**БЕКМА́НИЯ** (Beckmannia), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләннәр ыругы. ТРда бер төре — гади Б. (B. eruciformis), Идел алды һәм Кама аръягында су баса торган болыннарда очрый. Озын, үрмә тамырчалы үсемлек. 80–100 *см* озынлыкта. Сабагының түбәнге өлеше бүлбесыман кинәйгән. Яфраклары кыяклы, яссы, ян-яклары кытыршы. Чәчәк төркеме — 30 *см* га кадәр озынлыктагы берьяклы кушма башак. Җимеше — бөртекчә. Июнь-июль айларында чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Печәнлек һәм көтүлек җирләре өчен файдалы. Барлык а.х. терлекләре дә ашый, культуралы үсемлекләргә дә кертергә мөмкин. Үлән капламында уңайлы шартлар булганда 10 елдан артык саклана.

**БЕКСИ́ЕВ** Шәүкәт Гаяз улы (29.8.1929, Куйбышев өлкәсенең Куйбышев р-ны Тимәш а.), агроном, яшелчәчелек белгече, а.х. фән. д-ры (1970), проф. (1974). Сәмәркand а.х. ин-тын тәмамлый (1951). 1957–79 елларда Төньяк-Көнбатыш а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1979 елдан Россия пед. ун-тында (С.-Петербург). Хезмәтләре яшелчә үстерү технологиясе һәм селекциясенә карый. Иң тиз өлгереш һәм иң югары уңыш алу теориясен эшли. Помидорның бик тиз өлгерешле «Невский», «Фонтанка», «Миңҗамал», «Гаяз Бексиев», «Ниночка» һ.б. иртә өлгерешле һәм югары уңышлы сортлары авторы. ВДНХның көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә (1964, 1965).

Х е з м.: Овощеводство Северо-Западной зоны. Л., 1974; Раннее овощеводство Нечернозёмной зоны. Л., 1978; Огород. Л., 1987; Выращивание ранних томатов. Л., 1989; Петербургское усадебное огородничество. СПб., 1996; Огурцы. СПб., 1997; Томат. СПб., 1997; Овощные культуры мира. СПб., 1998. Большая энциклопедия огородничества. СПб. 1999; Ранее овощеводство. СПб., 2006.

**БЕЛА́ВИН** Владимир Алексеевич (15.10.1934, Казан — 27.12.2006, ш.у.), радиотехника гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1976), проф (1983), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993). 1958 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1978 елдан радиоидарә каф. мөдире. 1985–88 елларда СССР ПФАнең Профтехпедагогика фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире (Казан). 1990 нан Казан энергетика ун-тында идарәле информация системалары каф. мөдире, 1990–95 тә электроэнергетика һәм 1995–96 да энергия б-н тәэмин итү ф-тлары деканы. Хезмәтләре электрохимик мәгълүмат үзгәрткечләре һәм өйрәтү комплекслары проблемаларына карый. Резистор — сыешлык структураларның техник схемалары нигезләрен эшли, осциллографлы полярография ысулын тәкъдим итә, гидродинамик агым параметрларын үлчәү аппаратурасы эшли, виртуаль реальлекне модельләштерүче пед. программа чараларын гамәлгә кертә. Уйлап табуга караган 30 лап авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Осциллографическая полярография с параллельной регистрацией катодных и анодных полярограмм // Журн. аналитической химии. 1970. Т. 15, № 5; Использование явлений, описываемых уравнением диффузии для построения устройств задержки, фазавращателей и фильтров // Изв. вузов. Радиотехника. 1974. Т. 17, № 5; Экспериментальные исследования радиоизлучения факела горения реактивного двигателя // Прикладная физика. 1997, № 4 (автордаш).

**БЕЛАШО́В** Василий Юрьевич (8.7.1956, Ленинград), физик, физ.-мат. фән. д-ры (1998), проф. (2005). 1978 елда академик С.О.Макаров исем. Ленинград югары диңгез инж. уч-щесен тәмамлый, Магадан шәһәрендә СССР ФА Ерак Көнчыгыш фәнни үзәгенең Төньяк-Көнчыгыш комплекслы фәнни-тикшеренү ин-тында (1987 елдан Космофизик тикшеренүләр һәм радиодулкыннар таралу ин-ты) эшли, 1999 дан сейсмология һәм петрофизика лабораториясенең баш фәнни хезмәткәре. 2000 нән Казан энергетика ун-тында, сәнәгать пр-тиеләрен электр б-н тәэмин итү (2001 дән), пр-тиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең электр җиһазлары һәм электр хуҗалыгы (2005 тән) кафедралары мөдире.

Хезмәтләре кояш-җир бәйләнешләре өлкәсенә карый; түбән ешлыклы табигый нурланышлар морфологиясен һәм спектр-вакыт структурасын ешлыкларның зур диапазонында өйрәнә. Дисперсиясе көчсез һәм сызыкча булмаган күп кенә физик тирәлекләрдә (мәс., Җирнең атмосферасында, ионосферасында һәм магнитосферасында, «сай» судагы дулкыннарда һ.б.) ике һәм өч үлчәнешле сызыкча булмаган дулкыннар һәм солитоннар динамикасын сурәтли торган сызыкча булмаган өч үлчәнешле дифференциаль тигезләмә (Белашов-Карпман тигезләмәсен) чыгара. Өч үлчәнешле тигезләмәнең чишелеше буларак, өч үлчәнешле тотрыклы солитон структураларны таба һәм аларның тотрыклылыгын аналитик юл б-н исбатлый. Зур тизлекле магнит-тавыш дулкыннары бәйләменең үзеннән-үзе фокуслануы һәм тавыш таралу күренешләре б-н бер үк вакытта бәйләмнең сызыкча булмаган тотрыклашуы һәм стационар таралуы мөмкинлеген күрсәтә; моннан алда санча күзәтелгән күренешне — кояш тотылу һәм кояш терминаторы фронтларының дулкынлы «хәбәрчеләрен» сызыкча булмаган солитон сыман ялгыз дулкыннар фронты алдыннан йөгерә торган рәвештә генерацияләү күренешен тәҗрибәдә теркәүгә ирешә.


Х е з м.: Об устойчивости двумерных и трёхмерных солитонов в слабо диспергирующих средах // Докл. АН СССР. 1991. Т. 320, № 1; Уравнение КП и его обобщения: Теория, приложения. Магадан, 1997; Неодномерные нелинейные волны в реальных средах с дисперсией. К., 2002; Солитоны как математические и физические объекты. К., 2006 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**БЕЛӘЗЕ́К**, кыршау рәвешендәге өзек бөҗра, гадәттә, беләккә киелә торган бизәмә. Татар хатын-кызлары арасында аеруча киң таралган зәркән эшләнмәләренең берсе. Көмештән, еш кына алтыннан яисә алтын йөгертеп, кайбер очракларда алтын һәм көмеш эретмәсеннән, ә гадиләре бакыр һәм аның эретмәләреннән (бронза, җиз һ.б.) ясала. Гадәттә, ике кулга да 2–3 әр Б. киелгән. Ш.у. Б.ләр парлы итеп тә ясалган, бай татар хатыннары берничә пар Б. йөрткән. Б. борынгы заманнардан ук мәгълүм. Татарстан җирендә Абашево, Ананьино, Буралы Курган һ.б. археол. культуралар табылдыклары арасында бронза







Беләзекләр. Көмеш. 1. Тезмә (19 йөз); 2. Үрмә; 3. Яссы (14–15 йөзләр). ТР Милли музее фондлары.

Б.ләр бар. Хәзерге вакытка кадәр сакланган үрнәкләрнең иң борынгылары (гади геометрик фигуралар б-н бизәкләнгән, асылташ, төсле пыяла, гәрәбә кашлы Б.ләр) әүвәлге болгар дәверенә карый. Идел буе Болгар дәүләтендә тоташ Б., 2–3 (сирәгрәк 4–5–6) алтын йөгерткән яисә көмеш чыбыктан үреп эшләнгән Б., ш.у. бөртекләү юлы б-н каймаланган асылташ кашлы шатоннардан ясалган чылбырлы Б., һәм төрле төстәге пыяла кисәкләреннән ясалган Б. аеруча киң тарала (к. *Бутаиха хәзинәсе*). Алтын Урда дәверендә Б. бизәлешендә җепкырлау, каралтылган алтын яки көмеш йөгертү, уемлау, чүкү, басма ысуллары б-н ясалган чәчәк-үсемлек һәм гарәп язмаларыннан бизәкләр кулланыла (к. *Җукәтау хәзинәсе*). Очларында арыслан (к. *Карашәм хәзинәсе*), кайбер очракларда елан башы сурәтләнгән Б.ләр аеруча киң тарала. Мондый Б. татарларда 20 йөз башына кадәр кулланылышта йөри. 18 йөз — 20 йөз башында эшләнгән татар Б.ләре тоташ (2–6 *см* киңлектәге сыгылмалы бербөтен пластинадан эшләнгән Б.) һәм җыелма (берничә металл чыбыктан үреп ясалган һәм җепкыр б-н бизәлгән Б.) төрләргә бүленә. Җыелма Б.ләр бер-берсенә шарнир, махсус божралар ярдәмендә ялганган бербөтен яисә җепкырланган аеллардан тора; 18 йөздә мондый Б.ләр, гадәттә, 2–7 эре өлештән җыела, 19 йөз — 20 йөз башында аеллар кечерәк итеп ясала, аларның саны арта. Б.ләр үзара божралар б-н ялганучы асылташлар яисә аеллар чылбыр рәвешендә, кайбер очракларда берничә рәтле итеп тә җыела. Сәйлән яисә мәрҗән б-н тегелгән тукыма тасмасының очларына каптырма куеп ясалган «энҗе беләзек» — татар Б.ләренең үзенчәлекле төре. Гадәттә, Б.ләр чәчәк, үсемлек, җәнлек сурәтләре, геометрик рәсемнәр, Коръән аятьләреннән алынган гарәпчә язма, догалар б-н бизәлә, кайвакыт аларга иясенең исеме языла. Б.ләрнең бизәлеше күпертмә һәм яссы *җепкыр, каралту,* уемлау, басма, *чүкеп бизәк төшерү, бөртекләү* ысуллары б-н, асылташлар кулланып башкарылган. Эрерәк асылташлар (ахак, топаз, аквамарин һ.б.) беләзек буйлап тезелә һәм, гадәттә, алар ваграк асылташлар (фирүзә, хризолит, рубин, мәрҗән, тау бәллүре һ.б.) б-н каймалана. Киң Б.ләрдә бизәкләр уртадан — киң, чит-читтән тар кайма булып сузыла. Тар Б.ләрдә исә бизәк уртадан гына уздырыла.

Татар Б.ләре Идел буйларында һәм Урал төбәгендә, Урта Азиядә һәм Казакъстанда яшәгән халыклар, аеруча башкортлар һәм казакълар арасында киң тарала. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында, татар һәм Урта Азия үрнәкләренә ияреп, рус зәркәнчеләре дә күпләп Б. җитештерү эшен үзләштерәләр (Казан губ., Лаеш өязенең Балык Бистәсе а.). Аларның эшләнмәләре, башлыча, Түбән Новгород, Минзәлә, Эрбет ярминкәләрендә сатыла, Казан татарлары арасында ихтыяҗ тапмый.

20 йөз башында, яссы Б.тән гайре, Б.нең барлык төрләре дә модадан чыга. Каралту юлы б-н бизәлгән яссы Б.ләр ясау Саба р-ны авыллары көмешчеләре тарафыннан (Х.Ганиев, Ф.Хисамиев) 1980 елларга кадәр дәвам иттерелә. Бу төр Б.ләрне күпләп җитештерү 1960–70 елларда Саба р-ны Шәмәрдән бистәсендә җайга салына. Татар Б.ләренең традицион формалары һәм бизәлеше хәзерге заман проф. зәркәнчеләр иҗатында яңа үсеш ала (С.Шәкүров, В.Ковалевский, И.Фазылҗанов, Л.Хисамиева, Р.Әлмәнов, Е.Бакакин, И.Васильева, Т.Соловьева һ.б.). Ш.у.к. *Бизәнү әйберләре, Зәргәрчелек сәнгате, Зәргәрчелек һөнәрчелеге.*

*Әд.:* Калинин Н.Ф. Булгарское искусство в металле. К., 1945; Воробьев Н.И. Казанские татары. К., 1953; Суслова С.В. Женские украшения казанских татар 19 — начала 20 вв. М., 1980; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920 — начало 1990-х гг.). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БЕЛӘ́ШЕВ** Аллаяр (19 йөз ахыры, Рязань губ. Әҗе а. — ?), язучы, төбәк тарихчысы. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. 20 йөз башында Урта Азиядә мөгаллимлек итә. 1915 елда «Шура» ж-лында беренче шигырьләре басыла. Шул ук елда «Көйле сүзләр бәйләме» дигән шигъри җыентыгы дөнья күрә. Төркестанда яшәүче халыкларның этнографиясенә һәм тарихына багышланган күп кенә мәкаләләр һәм туган авылының тарихи үткәнен бәян иткән «Әҗе авылы хакында» (1924) исемле китап авторы. Шул китапта китерелгән библиографик белешмәгә караганда, Б. дистәдән артык исемдә фәнни-популяр һәм әдәби әсәр язган.

Әсәр.: Төркестан мөселманнары // Шура. 1914. № 22; Көйле сүзләр бәйләме. К., 1915; Әҗе авылы хакында. К., 1924; Өмид (Шигырьләр) // Мирас. 1998. № 4.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БЕЛЕЛЮ́БСКИЙ** Николай Аполлонович (1.3.1845 — 4.8.1922), инженер, төзелеш механикасы һәм күперләр төзү белгече. 1867 елда Петербург тимер юл инженерлар ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, проф. (1873 елдан). Бер үк вакытта Петербург тау ин-тында, Хатын-кызларның политехника курсларында укыта. Б. проектлары б-н Россиядә күп кенә тимер юл күперләре һәм тоннельләр төзелә, шулар арасында — Идел (Сызраньда, 1879 — шул вакытка Европадагы иң озын күпер, һәм Зөядә, 1913), Днепр, Обь, Агыйдел һ.б. елгалар аша салынган зур күперләр (к. *Күперләр*). Металл торык конструкцияләрен яхшыртуга мөһим өлеш кертә. Б. Россиядә материаллар каршылыгын сынау буенча беренче лаб. б-н җитәкчелек итә. Аның җитәкчелегендә тимер-бетон эшләрне башкару нормалары һәм техник шартлары билгеләнә (1905–08). Б.ның «Төзелеш механикасы курсы» («Курс строительной механики», 1985) дәреслеге бу фән буенча рус телендәге беренче тулы курс булып санала. 1912 елдан үзле матдәләр, металлар һ.б. материалларны сынау ысулларын эшләү буенча халыкара җәмгыять президенты.

Хезм.: Литое железо. СПб., 1885; Строительная механика. СПб., 1897; Расчёт сооружений, подвергшихся действию переменной нагрузки. СПб., 1903.

*Әд.:* Прокофьев И.П. Николай Аполлонович Белелюбский. Люди русской науки. М., 1948. Т. 2; Бобков А.С. Николай Аполлонович Белелюбский // Строит. пром-сть. 1955. № 12.

**«БЕЛЕ́М АЧКЫЧЫ́»**, газета, к. *«Эшче»*.

**«БЕЛЕ́М» ҖӘМГЫЯТЕ́**, иҗтимагый, мәдәни агарту һәм белем бирү оешмасы. 1947 елның июлендә бер төркем галимнәр тәкъдиме б-н Бөтенсоюз сәяси һәм фәнни белемнәр тарату җәмгыяте буларак оештырыла, 1963 тә Бөтенсоюз «Белем» җәмгыяте дип үзгәртелә, 1991 дән — хәзерге исемдә.

Төп максатлары: белем тарату, гражданнарга өзлексез белем бирү, Россиянең икътисад, фән-техника, социаль һәм гуманитар өлкәләрдә алдынгы илләр дәрәҗәсенә күтәрелүенә булышлык итү. «Б.» җ. оешмалары РФнең 70 субъектында эшли, күп кенә төбәкләрдә өзлексез (өстәмә) белем бирү мәгариф учреждениеләре бар. «Б.» җ. оешмалары һәм учреждениеләре кадрларның квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү буенча курслар һәм семинарлар үткәрә, чит телләрне өйрәнү, компьютер үзләштерү курслары, халыкның төрле төркемнәренең мәнфәгатьләре һәм мавыгулары буенча (йорт эшләрен һәм бакча хуҗалыгын алып бару, медицина белемнәре нигезләре, этика, сөйләү осталыгы) лекцияләр, консультацияләр үткәрә, хәзерге заманның күпләгән мәсьәләләренә багышланган очрашулар оештыра. Җитәкче органы — совет, даими эшләүче органы — идарә. Җәмгыять б-н президент җитәкчелек итә.

Татарстанда «Б.» җ.нең республика оешмасы 1949 елда А.Е.*Арбузов*, Б.А.*Арбузов*,

Г.Х.*Камай*, Б.Л.*Лаптев*, Е.П.*Бусыгин*, А.В.*Талантов*, Я.Ш.*Шәрәпов* тырышлыгы б-н төзелә. Республиканың барлык шәһәр һәм авылларында җәмгыятьнең оешмалары эшли, хезмәт коллективларында башлангыч оешмалары төзелә. 1984 тә республика оешмасында 34 мең кеше (1 академик, 308 фән докторы, 2295 фән кандидаты, 14 мең укытучы, 5,5 мең инженер, икътисадчы һәм техник, 2600 чамасы а.х. белгече, 900 пр-тие, совхоз һәм колхоз җитәкчесе, 1 мең чамасы производство алдынгысы һәм новаторы) исәпләнә. Оештырылганнан башлап, аның сафларында СССР ФАнең 6 академигы һәм мөхбир әгъзасы, 400 ләп фән докторы, 3000 нән артык фән кандидаты эшли. Идарә тарафыннан йөзләрчә лекция, семинарлар, конференцияләр уздырыла. 1980 нән 1982 гә кадәр Татарстан Республикасы «Б.» җ. лекторлары 600 меңнән артык лекция, шул исәптән дәүләт һәм хокук мәсьәләләре буенча елга уртача 73 мең, халыкара хәлләр буенча — 50 мең, икътисад, сәнәгать, транспорт һәм төзелеш буенча — 18 мең, медицина буенча — 71 мең, а.х. буенча 26 мең лекция укылган. Лекция эшчәнлеге 26 тематик юнәлештә гамәлгә ашырыла, аларның һәрберсенең үз структурасы һәм еш кына 10–20 шәр таррак тематик юнәлеше була. Җәмгыять әгъзалары тырышлыгы б-н республикада актив рәвештә Фән көннәре үткәрелә, агарту максатларында галимнәр пр-тие, колхоз һәм совхозларга, мәктәпләргә һ.б. урыннарга чыга. Республика оешмасы идарәсе Мәскәү, Ленинград, Көнчыгыш Европа галимнәре белән тыгыз элемтәдә тора. «Б.»ж.нең республика оешмасы әгъзалары Россиянең татарлар яшәгән төбәкләренә (Төмән, Оренбург һ.б. өлкәләргә) лекцияләр б-н баралар. Республикага лекцияләр укырга СССР ФА, АКШ һәм Канада институты, Азия һәм Африка институты галимнәре, илнең төп музейлары хезмәткәрләре һ.б. килә. «Б.»ж. лекторлар әзерләүгә зур игътибар бирә. Аларның квалификациясен күтәрү максатында республика, район һәм шәһәр, шул исәптән фәнни тармаклар буенча семинарлар, катлаулы һәм актуаль проблемаларга багышланган консультацияләр, лекция пропагандасының гомуми методикасы мәсьәләләре буенча дәресләр үткәрелә. Беренче буын лекторлар әзерләүнең төп формасы — яшь лекторлар мәктәпләре була. Аларда дәресләрне Казан, Мәскәү, Ленинград галимнәре үткәрә. 1980 елда КПСС өлкә ком-тының Казандагы Сәяси мәгариф йорты базасында «Б.»ж.нең 5 ф-тлы лекторлык осталыгы ун-ты ачыла (1991 елга кадәр эшли). Аның максаты — лекторларның белемен күтәрү. Татар телендә сөйләүче лекторлар әзерләнә. Лекция пропагандасының дәрәҗәсен күтәрүдә һәм эшләлеген актуальләштерүдә, лекторларның теоретик һәм методик әзерлеген яхшыртуда фәнни-методик советларга зур роль бирелә (республика оешмаларында 17 фәнни-методик совет эшли, аларга 300 кеше керә).

Хәзерге чорда республика оешмасы бухгалтерлар, укытучылар, мәктәп балалары һ.б. өчен курслар оештыра. «Б.» ж. каршында Казан мәктәпләре укучылары өчен Кызыклы очрашулар клубы эшли, ТР ФА базасында даими рәвештә күренекле галимнәрнең яшьләр б-н очрашулары уздырыла.

Казан вузлары укытучылары В.Г.Саркин, Б.М.Константинов, Н.А.Гаделшина (хәзер Казан мед. ун-ты), Й.В.Бурнашева, Э.С.Рәхмәтуллин (Казан ун-ты), Е.А.Красильникова, У.Б.Билалов (хәзер Казан технология ун-ты), Я.Ш.Шәрәпов (хәзер Казан техника ун-ты) Татарстан респ-ка оешмасының лекторлары була. Төрле елларда «Б.» ж. республика оешмасы рәисләре: А.Е.Арбузов, Б.А.Арбузов, Г.Х.Камай, А.П.Студенцов, А.В.Талантов, Я.Ш.Шәрәпов, Р.А.Нугаев, А.Н.Тимофеев (2001 дән).

*Әд.:* В о л о д и н Л.А., Т и м о ф е е в А.Н. Лекционная пропаганда: методика, опыт, мнения. К., 1984.

*Л.М.Айнетдинова.*

**«БЕЛЕМНЕ́К»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби журнал. РКП(б) Татарстан өлкә ком-тының керәшен секциясе органы. 1921 елның сентябреннән 1922 нең гыйнварына кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барлыгы 3 саны чыга. 1 нче Дәүләт басмаханәсендә (элеккеге «Өмед») басыла. Җаваплы мөхәррире Д.Касыймов. Актив авторлары: Г.Белугин, М.Михайлов һ.б. Илдәге һәм дөньядагы сәяси хәлләрне яктырта, авыл тормышы турында язмалар, керәшен татарларның яшь язучылары әсәрләрен бастыра. Рубрикалары: «Сәяси бүлек», «Авыл хуҗалыгы», «Педагогика», «Әдәбият», «Яңалыклар» һ.б.

*Әд.:* Г а й н а н о в Р.Р., М а р д а н о в Р.Ф., Ш а к у р о в Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000.

**БЕ́ЛИХОВ** Дмитрий Васильевич (8.4.1898, Кострома ш. — 10.9.1979, Казан), зоолог, гидробиолог, биол. фән. д-ры (1971), проф. (1973). Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Казан ун-тын тәмамлый (1924). 1926 елдан Казан пед. ин-тында эшли, 1947–70 тә зоология каф. мөдире. Хезмәтләре су организмнары экологиясенә һәм Куйбышев сусаклагычы бассейнындагы гидробионтларны өйрәнүгә карый. Су үсемлекләрен терлекчелектә куллану турындагы теорияне үстерә. Алтын Мөгез култыгындагы эчәк б-н сулаучыларның яңа Balanoglossus proterogonius төрен тасвирлый (1927). Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О потамопланктоне Волги // Уч. зап. Казан. ун-та. 1936. Т. 96, кн. 7; Санитарно-биологическое исследование рек Исети, Чусовой и Волги в зоне Куйбышевского водохранилища. К., 1964.

**БЕЛИ́ЦКИЙ** Владимир Евгеньевич (7.8.1948, Казан), архитектор, ТССРның атказ. архитекторы (1991). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1971). 1971 елдан архитектор, 1972 дән Казан архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең проектларны тикшерү бүлеге башлыгы. Б. проектлары б-н Яшел Үзән шәһәрендә тимер юл вокзалы (1978), поликлиника (1978), Юдино бистәсендә тимер юлчылар профилакторие (1981), торак йорт, хакимият биналары, вокзал мәйданында почта ташу идарәсе корпусы (1980–1997), Казанда «*Хозәйфә ибне әл-Ямәни*» мәчете (1997) һ.б. биналар төзелә.





В.Е. Б е л и ц к и й. 1. Почта йөртү идарәсенең административ корпусы. Казан. 1997; 2. «Хозәйфә ибне әл-Ямәни» мәчете. Казан. 1997.

**БЕ́ЛКИНО** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы буенда. 2002 елда 235 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, буяу-бизәк төшерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да земство мәктәбе, су тегермәне, тимерчелек, икмәк, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 962,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 520, 1897 дә — 774, 1908 дә — 804, 1920 дә — 771, 1926 да — 754, 1949 да — 374, 1958 дә — 342, 1970 тә — 280, 1979 да — 295, 1989 да — 241 кеше.

**БЕ́ЛО-БЕЗВО́ДНЫЙ** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасы буенда. 2002 елда 1126 кеше (руслар — 50%, татарлар — 42%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, җәнлек үрчетү. Төзү пр-тиесе. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. 17 йөз ахырында Раифа пустыне вотчинасы буларак нигез салына. Башта ул Безводный Пүчинкә-

се дип атала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — икътисади, 1764 елга кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, тегүчелек, тимерчелек, итек тегү, пыяла ясау б-н шөгыльләнә. 1883 тә земство мәктәбе ачыла. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 916,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Ильинка волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Арча кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 47 ир заты; 1859 да — 304, 1897 дә — 565, 1908 дә — 549, 1920 дә — 743, 1926 да — 725, 1938 дә — 646, 1949 да — 457, 1958 дә — 305, 1970 тә — 442, 1979 да — 783, 1989 да — 1082 кеше.

**БЕЛО́В** Валерий Иванович (28.1.1947, Казан), спортчы, тренер (бокс), СССРның спорт остасы (1968), РСФСР, СССРның атказ. тренеры (1988, 1989). «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә. ТАССР чемпионы (1968), СССР кубогы иясе (1970), СССР чемпионатында көмеш медаль ала (1971). 1988–91 елларда СССР җыелма командасында тренер. Шәкертләре арасында: К.Цзю — Европа чемпионы (1989, 1991), дөнья чемпионы (1991); Е.Белоусов — Европа чемпионы (1991). 1994 елдан илнең бокс федерациясе каршында тренер, 1997 дән Чаллы шәһәрендәге физкультураны үстерү буенча региональ үзәктә өлкән тренер.

**БЕЛО́В** Тимофей Андреевич (13.2.1907, Самара губ., Бөгелмә өязе Тимәш а. — 22.12.1978, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан ун-тын тәмамлый (1936). 1936–37 елларда Казанда урта мәктәп директоры. 1937–39 да башлангыч һәм урта мәктәп хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан өлкә ком-ты рәисе урынбасары, 1939–41 дә рәисе. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–54 тә ТАССР социаль тәэминат министры. 1954–55 тә КПССның Шөгер райкомы 1 нче секретаре. 1956–67 дә ТАССР МС каршындагы КГБ секретариаты башлыгы. 1947–51 дә ТАССР ЮС депутаты. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**БЕЛО́ВКА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 22 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2002 елда 378 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чистай кантоны Көтеш волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 474, 1938 дә — 525, 1949 да — 391, 1958 дә — 442, 1970 тә — 607, 1979 да — 538, 1989 да — 360 кеше.

**БЕЛОГО́РСКАЯ** Елизавета Викторовна (19.08.1925, Иркутск ш. — 1.1.2003, Казан), балалар табибәсе, мед. фән. д-ры (1968), проф. (1970), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1980). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1949). 1955–93 елларда шунда ук эшли, 1968–90 да балалар авырулары каф. мөдире. Б. тарафыннан сулыш юлларындагы вируслы йогышлы авырулар һәм пневмониянең этиологик төзелеше, яңа туган балаларда пневмония авыруының көчәю сәбәпләре өйрәнелә; ялкынсынулы йогышлы һәм пневмония авырулары вакытында иммунитет күрсәткечләре тикшерелә.

Х е з м.: Актуальные проблемы неонатологии // Казан. мед. журн. 1984. Т. 65, № 6; Детские болезни. М., 1988 (автордаш); Кишечная колиинфекция у детей раннего возраста // Науч. тр. Казан. мед. ин-та. 1967. Т. 24.

*Әд.:* Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989. Ч. 1.

**БЕЛОЗЁРОВА** Галина Александровна (7.05.1944, Киров өлкәсе, Малмыж ш.), микробиолог, вет. фән. д-ры (1993). Киров а.х. ин-тын тәмамлый (1970). 1970–72 елларда Киров өлкәсенең Нолинский кошчылык ф-касында вет.табибе. 1972 елдан Казан вет. ин-тында. 1984–99 да Бөтенроссия фәнни тикшеренү вет. ин-тында. Хезмәтләре мөгезле эре терлекләрдәге бруцеллёз авыруына каршы вакцина эшләүгә һәм бу авыруга диагноз кую ысулларын камилләштерүгә карый. Бруцеллёзга каршы 82-ПЧ штаммыннан алынган яңа вакцина (пенициллин — B. abortus 82 вакцина штаммының сизгер варианты) авторы. Вакцина эпизоотик авыруларга югары дәрәҗәдә каршы торучанлыгын күрсәтте.

**БЕЛОКЛО́КОВ** Николай Борисович (15.05.1961, Кемерово өлкәсенең Прокопьевск ш.), Россия-Чехия уртак пр-тиесе «ЦБС Аутомотив Алабуга» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ген. директоры урынбасары (1999 дан), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), Бийск хим. комб-тында (Алтай крае) эшли. 1987–88 елларда «КамАЗ» җитештерү берләшмәсендә бюро, бүлек башлыгы. Дәүләт бүләге автомобиль сәнәгате өчен яңа ПВХ — пластизолләр җитештерүне оештырганы өчен бирелә.

**БЕЛОКУ́РОВ** Владимир Вячеславович (25.6.1904, Казан губ., Югары Ослан өязе Түбән Ослан а. — 28.1.1973, Мәскәү), драма актёры, режиссёр, педагог, СССРның халык артисты (1965). Сәхнә эшчәнлеген 1918 елда Казанда И.Н.Певцов труппасында башлый. 1920–22 дә Казан Зур драма театры каршындагы В.С.*Зотов* һәм З.М.*Славянова* җитәкчелегендәге Казан губ. драма студиясендә (1922 дә — «Халык мәгарифе югары институты теоциклы») укый, аны тәмамлагач, 1922–24 тә шул ук театрда эшли. Шут, Кудряш («Василиса Мелентьева», «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Николай Зубов («Павел I», Д.С.Мережковский), Лебедев («Идиот», Ф.М.Достоевский), Паншин («Дворяннар оясы», И.С.Тургенев), Сперанский («Савва», Л.Н.Андреев), Яша («Чия бакчасы», А.П.Чехов), Коростылёв («Тормыш төбендә», М.Горький) һ.б. рольләрне башкара. Тәнкыйтьчеләр ул уйнаган образларның төгәллегенә,



В.В. Белокуров.

колоритлылыгына игътибар итәләр. 1923–24 тә Татар театр техникумында укыта. 1924 тән Мәскәүдә, Революция театрында (хәзерге В.Маяковский исем. театр), 1936 елдан МХАТ труппасында шактый рольләр башкара. Кинода Валерий Чкалов (шул исем. фильм, 1941), Чаплыгин («Жуковский» фильмы, СССР Дәүләт бүләге, 1951) һ.б. рольләрне башкара. Таганрог шәһәре драма театрында берничә спектакль куя.

*Ю.А.Благов.*

**БЕЛОНО́Г** Валерий Михайлович (13.12.1938, Украина ССРның Днепропетровск ш.), машиналар төзелеше технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. канд. (1985), проф. (1994). 1964 елда Куйбышев авиация ин-тын тәмамлый. 1956 дан Сызрань шәһәрендә эшли. 1965 тән КМПОда: 1981–85 тә һәм 1992–2006 да ген. директор урынбасары, 1985–92 елларда ОКБ «Союз» тәҗрибә з-ды директоры. Хезмәтләре авиация сәнәгате эшләнмәләрен импульслы формалаштыру ысулларына, аз серияле машиналар җитештерүне автоматлаштыруга карый. Үтә югары тизлектә штамплау ысулын эшли (бергәләп). Авиация техникасын проектлаштыру технологияләрен автоматлаштыра. Украина ССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Автоматизация мелкосерийного машиностроительного производства и качество продукции. М., 1983; Пластичность и резание металлов. М., 1994; Теория резания металлов: Учеб. пособие. К., 1994.

**БЕЛОНО́ГОВ** Виктор Анатольевич (18.9.1965, Минзәлә р-ны Воровский исем. совхоз пос.), географ-эколог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), геогр. фән. канд. (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1989), шунда ук эшли. Хезмәтләре елгалардагы ионлы агымның күпьеллык үзгәрүчәнлеген анализлауга, җир өсте сулары сыйфатын экол. нормалаштыру, хуҗалык эшчәнлегенең әйләнә-тирә мохиткә тәэсир итүен өйрәнүгә карый. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касының көньяк-көнбатышында табигатьне саклау чараларын планлаштыру һәм тормышка ашыру максатыннан геоинформацион системалар эшләгәне өчен бирелә. «Экологический консалтинг» ж-лының баш мөхәррире.

Х е з м.: Улучшение окружающей среды на рубеже тысячелетий — состоявшаяся реальность // Тр. XI съезда Рус. геогр. об-ва. СПб., 2000. Т. 2 (автордаш); Многолетний мониторинг и вероятностно-статистический анализ как наиболее объективный подход к решению проблемы нормирования качества поверхностных вод // Водное хоз-во России. 2001. № 3; О роли ОВОС в системе мер по управлению окружающей средой // Экол. консалтинг. 2001. № 1.

**БЕЛОПА́ХОТНЫЙ** посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 9 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2002 елда 64 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә Кама аръягы саклану сызыгына килеп урнашкан йомышлы крәстияннәр нигез сала. 19 йөзнең 30 нчы елларында алар дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 1903 елга кадәр Б.ның дин тотучылары — Минзәләнең Николай соборы приходына, соңрак Иске Ашпала авылының Покрау чиркәве приходына керә. Өязнең башка торак пунктларыннан аермалы буларак, посёлок халкы җир б-н тәэмин ителә (1913 тә 6 хуҗалыкта — 10–15, 7 сендә — 20–30, 8 ендә — 30–40, 6 сында — 40 тан артык дис. җирләре була). Күмәкләштерү елларында Б.да «Буревестник» к-зы оештырыла. 1950 елдан — «Будённовец» күмәк хуҗалыгында, хәзер «50 лет Татарии» с-зы составында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Мәҗын волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1870 тә — 96, 1913 тә — 197, 1920 дә — 227, 1926 да — 248, 1938 дә — 223, 1949 да — 154, 1958 дә — 156, 1970 тә — 138, 1979 да — 88, 1989 да — 61 кеше.

**БЕЛОПУ́ХОВ** Валерий Матвеевич (28.9.1950, Свердловск өлкәсенең Пурулымский р-ны Верховино а.), анестезиолог-реаниматолог, мед. фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). 1973 елда Төмән мед. ин-тын тәмамлый. 1973 тән Каменск-Уральск шәһәрендә эшли. 1976 елдан Казан мед. академиясендә, 1992 дән анестезиология һәм реаниматология каф. мөдире. Хезмәтләре акушерлыкта, гинекология һәм неонатологиядә анестезия һәм реанимациягә; төрле хирургик операцияләрдә натрий оксибутираты б-н төп анальгетиклар һәм анестетикларны бергә куллануга карый.

Х е з м.: Механизм и значение перидуральной блокады в профилактике и компенсации гемореологических нарушений. К., 1992.

*Әд.:* Казанская государственная медицинская академия (1920–1995). К., 1997.

**БЕЛОРУ́ССИЯ** (Беларусь Республикасы), Көнчыгыш Европадагы дәүләт. Мәйданы — 207,6 мең *км*$^2$. Башкаласы — Минск. Халкы — 10409 мең кеше (1998). Б. җиренә (Бөек Литва кенәзлеге чорында) татарлар 1397 елдан урнаша башлый. Башта алар Лида, Крево, Новогрудок тирәсендә төпләнәләр. 15 йөздә Троки — Кырык Татар, Пружаны, Мерашляны, Лососня шәһәрләре янына татарлар килеп утыра. Татар халкы Клецк тирәсендәге сугыштан (1506) соң күпкә арта, чөнки 3000 татар Бөек Литва кенәзлеге гаскәрләре тарафыннан әсирлеккә эләгә һәм Б. нең төрле шәһәрләренә таратыла (бу чорда Минскида Татар бистәсенә нигез салына). 15 йөз ахыры — 16 йөз башында Новогрудок, Минск, Лида, Ошмян өязләрендә татар байларының зур биләмәләре барлыкка килә. 16 йөз ахырында татарлар иске белорус телендә сөйләшә башлыйлар, ләкин ислам диненен саклыйлар. 1561 елда Бөек Литва кенәзе Жигимонт-Август татар аксөякләренә шляхталык грамотасы тапшыра. 18–19 йөзләрдә татарларның күпчелеге һөнәрчеләр катлавына керә, шәһәрләрдә (20 йөз башына кадәр Минск бистәсендә Зур, Кече Татар урамнары саклана) татар бистәләре барлыкка килә. 1917 елдан соң Б. б-н Идел буе — Урал алды татарлары арасындагы элемтәләр ныгый. Ачлык чорында (к. *Ачлык 1921–22*) Б. дән Татарстанга күпләп азык-төлек китерелә. Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан көнбатыш өлкәләрдән эвакуацияләнгәннәрне, ш.и. күренекле белорус мәдәнияте эшлеклеләрен (к. *Я.Купала*) кабул итә. 1941 елның июнендә Б. б-н Польша чигендәге Цехановец шәһәре тирәсендә немец гаскәрләренең һөҗүмен ТАССР ЮС Президиумы исем. 86 нчы укчы дивизия тоткарлый, Брест крепостен саклауга *П.М.Гаврилов* җитәкчелек итә. Белорус партизаннары арасында С.Әминов, Ш.Бәдретдинов, *Ә.Җ.Гайсаров*, Р.Г.Заһирова, Т.Моратов, З.Ш.*Нури*, С.Хәлиуллов, С.Хафизов һәм татар халкының башка вәкилләре дә була. Минск яшерен оешмасы эшендә И.К.*Кабушкин* катнаша. Б. не азат итү сугышларында ТАССРда төзелгән частьләр (к. *Витебск исемендәге укчы дивизия*, *Орша исемендәге укчы дивизия*), меңләгән татар һәм татарстанлылар (к. В.Г.*Булатов*, Д.И.*Горбунов*, П.И.*Малкин*, Ш.Ф.*Маннанов*, Г.Г.*Морзаханов*, П.И.*Наумов*) батырлык күрсәтәләр. 1 нче, 2 нче Белоруссия фронтлары сәяси идарәләре тарафыннан татарча «Кызыл армия» (к. «*Кызыл сугышчы*») һәм «*Фронт хакыйкате*» г-талары нәшер ителә. Сугыштан соңгы чорда Татарстан б-н Б. арасындагы икътисади, фәнни һәм мәдәни элемтәләр тагын да ныгый. Республикабыз Б. гә сугыш елларында зыян күргән мәдәният, халык мәгарифе учреждениеләрен торгызуда булыша. Белоруссия Хәрби округы гаскәрләрендә генераллар — А.О.*Ахманов*, Р.Н.*Әбраров*, Ф.Г.*Булатов*, М.Н.*Галиев*, М.Ә.*Гәрәев*, К.Ш.*Камалов*, Г.И.*Мөхәммәтҗанов*, күп кенә татар һәм татарстанлы солдатлар, офицерлар хезмәт итә. 16 йөздә Б. дә яшәүче татарлар саны 40 меңләп, 17 йөздә — 100 меңләп, 20 йөз башында — 20 меңләп, 1989 да 12,5 мең кешегә җитә. Татарлар, башлыча, Минск, Гродно, Ивье, Ловчицы, Новогрудок шәһәрләрендә яшиләр. 17 йөздә Б. терр-ясендә — 16, 1795 тә — 23, 1939 да — 19, 1997 дә 4 мәчет (Ивье, Новогрудок, Слоним, Смиловичи) эшли. 15 мөселман җәмгыяте бар. Минск, Гродно, Ивье, Слоним, Смиловичи шәһәрләрендә якшәмбе татар мәктәпләре эшли. «әл-Китаб» белорус татарлары берләшмәсе (Минск, 1989 дан), Гродно татарлары мәдәни үзәге, Беларусь Респ-касының Мөселман дини җәмгыяте (1994 тән), Ислам мәдәнияте үзәге (Ивье) бар. Белорус телендә «Жизнь» г-тасы (Минск), «Бәйрәм» ж-лы (Минск, 1991 дән), рус телендә «Әл-Ислам» ж-лы (Минск) нәшер ителә. Ш.у.к. *Польша-Литва татарлары*.

*Әд.:* К р и ч и н ь с к и й Л.К. Библиографические материалы о татарах Польши, Белоруссии и Украины. П., 1917; Г р и ш и н Я.Я. Польско-Литовские татары (наследники Золотой Орды). К., 1995; Д у м і н С.У., К а н а п а ц к і І.Б. Беларускія татары мінулае і сучаснасць. Минск, 1993.

*А.И.Ногманов.*

**БЕЛОСТО́ЦКАЯ** Әлфия Хөсәен кызы (18.5.1941, Свердловск ш.), архитектор, ТРның атказ. архитекторы (1996). Казан төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), «Гипрокаучук» ин-тының Уфа ф-лында архитектор булып эшли. 1966–87 елларда — «Гипронииавиапром» ин-тының Казан бүлегендә архитектор, өлкән архитектор. 1988 елдан — «Казан Промстройпроект» ин-тында баш архитектор. Татарстан Архитекторлар берлеге әгъзасы (1977). Б. проектлары б-н Казан техника ун-тының 7 нче уку бинасы (1980), Казан моторлар төзү берләшмәсенең җитештерү һәм административ биналары (1983), «Казан Промстройпроект» ин-ты бинасы (1997), Татарстан Респ-касы Президенты аппаратының вәкилләр кабул итү бинасы (1999), торак йортлар һ.б. объектлар төзелә. Б. ш.у. Казанда вертолёт, оптика-механика, медицина инструментлары, авиация җитештерү берләшмәләрендә, Саратов авиация з-дында, Салават, Менделеев, Чистай, Яшел Үзән шәһәрләрендәге күп кенә җитештерү корпуслары проектларының авторы.

Ә.Х. Б е л о с т о ц к а я. 1. Казан техник ун-тының 7 нче уку бинасы. 1980; 2. «Казан Промстройпроект» ин-ты бинасы. 1997; 3. Казан Кремлендә ТР Президенты аппаратының вәкилләр кабул итү корпусы. 1999.


1


2


3

**БЕЛОСТО́ЦКИЙ** Юрий Вячеславович (17.4.1922, Таулы Алтай авт. өлкәсе, Чой р-ны Ынырга а. — 20.10.1983, Казан), язучы. Чиләбе хәрби очучылар уч-щесен тәмамлый (1941). 1942–45 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Свердловск (1945), Казан (1946–47), Кострома (1947–49) шәһәрләрендә спорт, ДОСААФ оешмаларында эшли. 1949–54 тә «Северная правда» г-тасы (Кострома) журналисты. 1955 тән кабат Казанда: «Советская Татария» г-тасында бүлек мөдире, 1969–76 да Язучылар берлегендә әдәби консультант. 1950 елларда яза башлый. «Кырлар өстеннән самолёт оча» («Самолёт идёт над полями», 1954), «Катлаулы вираж» («Крутой вираж», 1957), «Тревога буенча күккә күтәрелү» («Вылет по тревоге», 1978), «Канатка канат куеп» («Крылом к крылу», 1982) повестьлары Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышлана. Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* З а р и п о в М. Киңрәк колач белән // Казан утлары. 1975. № 11; Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**БЕЛОУ́С** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2002 елда 141 кеше (татарлар — 59%, руслар — 39%) яши. Түбән Кама сусаклагычы яр буендагы Белоусово пристане. 1920 елларда нигез салына. Урман хуҗалыгы. Клуб. Башта Белоус кордоны дип атала. ТАССРның Чаллы кантоны Чаллы волостена керә. 1930 елның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1926 да — 4, 1938 дә — 84, 1958 дә — 188, 1970 тә — 129, 1979 да — 187, 1989 да — 128 кеше.

**БЕЛОУ́СОВ** Бәкер Җаббар улы (2.5.1897, Сембер губ., Сөнгәләй өязе Зөябаш а. — 1920, Үргәнечтә җирләнгән). Граждannар сугышында катнашучы. 1907–18 елларда Сембер губернасында авылдашлары Акчуриннар фабрикаларында эшли. 1918 елда Сембер губернасы башкарма комитетында, Сембер Гадәттән тыш комиссиясе, РКП(б) губкомы каршындагы мөселман секциясе әгъзасы. 1919 да Сембер шәһәре милиция идарәсе башлыгы. 1919 ның җәеннән Кызыл Армиядә: Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, 2 нче, соңыннан 1 нче аерым Идел буе татар укчылары бригадаларының сәяси комиссары, БҮБКнең «Кызыл Шәрекъ» агитпоезды хезмәткәре. Караком чүлендә басмачылар отряды б-н бәрелештә һәлак була.

*Әд.:* Ю с у п о в А. Бякир Белоусов: Док. повесть. К., 1969; К а с и м о в Г. Б.Д.Белоусов // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

**БЕЛОУ́СОВ** Василий Игнатьевич (1.1.1919, Вятка губ., Алабуга өязе Бондюг а. — 6.3.1981, Менделеев ш.), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), капитан (1948). Кече лейтенантлар курсын (1942), Республика партия мәктәбен (1953, Казан) тәмамлый. 1939 елга кадәр Л.Я.Карпов исем. химия з-дында (Бондюг штп) эшли. 1939 дан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышында: 6 нчы понтон-күпер бригадасы 15 нче понтон-күпер батальонының понтон взводы командиры. Көнбатыш, Воронеж һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Смоленскины (1941), Мәскәүне саклауда (1941–42), Украинаны, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда катнаша. Днепр елгасын кичкәндә Киев өлкәсе, Борисполь р-ны Гусеницы авылы янында (25.9 — 10.10.1943) батырлык күрсәтә. Сугыштан соң 1948 гә кадәр Сов. Армиясендә хезмәтен дәвам иттерә. 1948–53 тә Л.Я.Карпов исем. химия з-дында эшли, 1953 тән шунда ук партия эшендә. 1963 тән КПССның Менделеев шәһәр ком-тында. Ленин, 1 нче, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



В.И. Белоусов.

*Әд.:* Советлар Союзы геройлары — якташларыбыз. К., 1990; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1982.

*В.А.Шагалов.*

**БЕ́ЛЬДЕР** Михаил Абрамович (3.3.1909, Подольск губ. Сатанов ш. — 17.5.1983, Казан), химик-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949). Казан хим.-технол. ин-тын (1932) тәмамлаганнан соң, Мәскәү өлкәсенең Рошаль шәһәрендә эшли. 1937 елдан 40 нчы з-дта (хәзерге В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесе) лаб. башлыгы, баш инженер, 1949 дан Хим. продуктлары дәүләт фәнни-тикшеренү ин-тында баш инженер, баш технолог, баш консультант. Уйлап табу буенча 100 гә якын авторлык таныклыгына ия. Дәүләт бүләгенә пироксилин дарылар җитештерүнең өзлексез эшли торган линиясен төзегәне өчен лаек була (1949).

**БЕ́ЛЬКОВИЧ** Игорь Владимирович (2.10.1904, Казан губ., Цивиль өязе Иске Урмар а. — 30.5.1949, Казан), астроном, физ.-матем. фән. д-ры (1949). 1927 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1928 дән В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә эшли, 1941 дән астрономия бүлеге мөдире. Халыкара астрономия берлеге комиссиясе әгъзасы (1948). Хезмәтләре Айның рәвешен һәм әйләнүен өйрәнүгә карый. Айның даими физик либрациясенең даимилеген билгели. Айдагы бер кратерга Б.исеме бирелә.

Х е з м.: Определение силы тяжести в области Вятских Увалов и на Урале в 1931 г. // Уч. зап. Казан. ун-та. 1932. Т. 92; Результаты обработки наблюдений покрытий звёзд Луною за 1939–40 гг. // Бюл. Астрон. обсерватории им.В.П.Энгельгардта. 1943. № 23 (автордаш); Физическая либрация Луны. К., 1949.

*О.И.Белькович.*

**БЕ́ЛЬКОВИЧ** Николай Николаевич (1866, Лаеш өязе Надеждино утары — 1920, Лаеш ш.), рәссам, педагог, җәмәгать эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. Казан реаль уч-щесен һәм Сәнгать академиясен (СА) тәмамлап, САнең урта уку йортларында рәсем предметын укыту хокукы ала (1894). Казан сәнгать мәктәбен оештыручыларның берсе һәм аның беренче мөдире (1895–98), шул ук вакытта элементар рәсем сыйныфы б-н җитәкчелек итә. Б. катнашында нәкышь, гравюра, архит-ра бүлекләре ачыла, музей, китапханә оештырыла, ел саен «Җирле һәм башка шәһәрләр рәссамнарының периодик күргәзмәләре»н үткәрүгә башлангыч салына (1896–1916). Архит-ра бүлеге җитәкчесе К.Л.Мюфке б-н берлектә мәктәп өчен махсус бина төзетү максатында субсидияләр алуга ирешә. Педагог буларак, укучылар арасында зур абруй казана, Н.И.*Фешин*, К.К.Боратынская (Алексеева) һ.б.ның иҗади шәхес булып җитлегүенә хәлиткеч йогынты ясый. 1898 елдан СА студентлары инспекторы була. 1905 тән соң дәүләт хезмәтеннән китә. Профессиональ сәнгать белеме тарату б-н шөгыльләнә, Казан губерна земствосы идарәсендә әгъза булып тора, Халыкара вак сәнәгать һәм һөнәри белем күргәзмәсе ком-ты




Н.Н. Белькович. Н.И. Фешин ясаган портрет. Кәгазь, күмер. 1890 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

(Казан, 1909), Казан губерна земствосының Үзәк вак сәнәгать һәм һөнәри белем музее комиссиясе әгъзасы. 1917 дән Лаеш өязе халык мәгарифе бүлеге инспекторы, Лаеш урта мәктәбендә рәсем укыта. Б. портретлары Н.И.Фешин (1895), Г.Фирсов (1898, Е.Мазин б-н берлектә) тарафыннан язылган.

Х е з м.: О значении профессионального образования и средства к его распространению среди населения Казанской губернии: Доклад техническому совету Казанской губ. земской управы. К., 1906.

*Е.П.Ключевская.*

**БЕ́ЛЬКОВИЧ** Олег Игоревич (29.12.1934, Казан), астроном, физ.-матем. фән. д-ры (1988), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). 1957 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук радиоастрономия проблемалары лабораториясендә эшли. 1970–95 тә В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә: директор урынбасары, директор (1970–91), 1991 елдан метеорлар бүлегенең баш фәнни хезмәткәре. 1995 тән проф., 1997 дән Казан ун-тының Яшел Үзән ф-лында теоретик һәм эксперименталь физ. каф. мөдире. Хезмәтләре Кояш системасында метеор матдәсенең таралуын фәнни тикшерүгә һәм метеорлар радиолокациясенә карый. Бөтенсоюз астроно-



Г.А. Белявский.



М.И. Беляева.

мия-геодезия җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе (1977–85), СССР ФАнең «Метеорлар» эш төркеме рәисе урынбасары (1979–91), Халыкара астрономия берлеге әгъзасы (1976 дан). Халыкара метеорлар оешмасы әгъзасы (1991 дән), Европа астрономия җәмгыятен нигезләүче һәм аның әгъзасы (1992 дән).

Х е з м.: Статистическая теория радиолокации метеоров. К., 1971.

**БЕЛЯ́ВСКИЙ** Георгий Александрович (26.11.1905, Тверь губ., Великие Луки өязе Милолюб а. — 20.8.1983, Мәскәү ш.), инженер-инструментчы. Авиация сәнәгатен оештыручыларның берсе, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949), Соц. Хезмәт Герое (1966). Ленинград төгәл механика һәм оптика техникумын тәмамлый (1928). 1932–55 елларда 22 нче з-дта цех башлыгы, баш технолог (Мәскәү, Казан), 1956–65 тә Воронеж шәһәренең 64 нче з-дында директор, 1965–71 дә СССР Авиация сәнәгате министрлыгында 6 нчы Баш идарә җитәкчесе урынбасары (Мәскәү). Герой исеме авиация сәнәгатен үстерүгә керткән хезмәтләре өчен бирелә. СССР Дәүләт бүләгенә авиация сәнәгатенең барлык тармакларын яңа биеклеккә күтәрергә мөмкинлек тудырган Ту-104 очкычын җитештерүне үзләштерү һәм камилләштерүгә керткән хезмәте өчен лаек була. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БЕЛЯ́ЕВ** Айдар Рәис улы (11.12.1965, Казан), спортчы (автомобиль спорты), Россиянең халыкара класслы спорт остасы (1997). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1989). «КамАЗ-Мастер» командасы штурманы. «Мастер-ралли–95» (Париж–Мәскәү–Улан-Батыр–Пекин), «Мастер-ралли–96» (Париж–Дакар) раллиларында катнаша. «Мастер-ралли–96» (Париж–Ульянов–Улан-Батыр) раллиендә призлы урын ала, «Мастер-ралли397» (Париж–Сәмәрканд–Мәскәү), «Оптик–2000» (Тунис, 1997) раллиларында җиңүче, йөк автомобильләре ралли-марафонында дөнья кубогы ала (1997). РФнең Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Медаль б-н бүләкләнә.

**БЕЛЯ́ЕВ** Әхәт Габделхак улы (18.11.1918, Казан губ., Тәтеш өязе Уразлы а.), мәдәният эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967). Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1964). Хезмәт эшчәнлеген 1937 елда кинопрокатта техник буларак башлый. 1947–53 тә Казанда «Татарстан» (1950 гә кадәр «Электро») кинотеатры директоры, 1953–83 тә Таткинопрокат директоры. Республикада фильмнарны прокатка бирү эшен камилләштерүгә, кинотеатрлар репертуарын яхшыртуга зур өлеш кертә; кинопрокат системасында фәнни-популяр, док.-хроникаль фильмнардан файдалану буенча методик күрсәтмәләр эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, «СССР кинематография отличнигы» мактау билгесе б-н бүләкләнә. Б.ның исеме ТР Мәдәният хезмәткәрләре профсоюзы өлкә ком-тының Мактау китабына кертелә.

**БЕЛЯ́ЕВ** Владимир Павлович (7.12.1929, Вологда өлкәсенең Великий Устюг р-ны Малинино а. — 6.2.2000, Түбән Кама ш.), инженер-төзүче, «Татэнергострой» төзелеш-сәнәгать берләшмәсе башлыгы (1979–95), РСФСРның атказ. төзүчесе (1982). Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданины (1989). Ленинград политехника ин-тын тәмамлый (1955). 1956 дан «Куйбышевгидрострой» төзелеше идарәсендә (Зәй ш.). 1963 тән «Татэнергострой» төзелеш-сәнәгать берләшмәсендә: 4 нче төзелеш-монтаж идарәсендә баш инженер, җитештерү бүлеге башлыгы, управляющий урынбасары (1965 тән), төзелеш идарәсендә баш инженер (1967–79). Аның катнашында һәм җитәкчелегендә Түбән Кама нефть химиясе комплексы, Түбән Кама шәһәре төзелә. 4 млн. $м^2$ торак йорт, 45 мәктәп, 114 балалар бакчасы, хастаханә һ.б. файдалануга тапшырыла. 1980–90 да ТАССР ЮС депутаты. СССР МС премиясенә лаек була (1973). Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БЕЛЯ́ЕВ** Гавриил Ефимович (псевд.: Г.Бикмәтле, Г.Камский, Г.Восточный) (26.2.1903, Уфа губ., Минзәлә өязе Драгун-Бикмәт а. — 1973, Казан), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1965). 1923–25 елларда Мәскәүдә Коммунистик ун-тта укый. Журналистлык эшен 1922 дә Казанда «Кинәш» г-тасында башлый, аннан соң Самара хәрби округында чыга торган «Красноармеец» г-тасында эшли. 1936 дан «Стахановец» шәһәр г-тасы мөхәррире (Таҗикстан ССР, Ленинабад ш.). 1941–45 елларда «Знамя артиллериста» фронт г-тасының хәрби хәбәрчесе, мөхәррире. 1946–56 да Казанда «Кызыл Татарстан» г-тасында сәнәгать һәм транспорт бүлеге мөдире, 1958–61 елларда «Коммунист Татарии» ж-лында җаваплы сәркәтип.

**БЕЛЯ́ЕВ** Дмитрий Фёдорович (26.10.1846, Рязань губ., Спас өязе Тройцы а. — 10.3.1901, С.-Петербург), филолог, тарихчы, грек филол. д-ры (1878), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1894), хакыйкый статский советник (1886). Рязань руханилар семинариясен (1867) һәм Петербург ун-тын (1871) тәмамлый. 1871–74 елларда Петербург ун-тында укыта. Казан ун-тының грек филол. каф. доценты (1877–78), ординар проф. (1878–80), рим филол. каф. ординар проф. (1880–83) һәм 1883–97 дә тарих-филол. ф-ты деканы. Хезмәтләре Византия тарихы һәм мәдәниятенә, грек филологиясенә һәм борынгы телләрне укыту методикасына карый.

Х е з м.: К вопросу о мировоззрении Еврипида. К., 1878; История алфавита и новое мнение о происхождении глаголицы. К., 1886; Byzantina. Очерки, материалы и заметки по византийским древностям: В 3 кн. СПб, 1891–93.

*Әд.:* Шестаков С.П. Д.Ф.Беляев // Журн. М-ва нар. просвещения. 1901. № 7; Биографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

*А.В.Скоробогатов.*

**БЕЛЯ́ЕВ** Ислам Габделхак улы (14.3.1926, Тәтеш кантоны Уразлы а. — 21.11.1986, Казан), шагыйрь, журналист. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1954 елдан «Яшь сталинчы» г-тасы редакциясендә (1958–59 да баш мөхәррир). 1959–64 елларда КПСС өлкә ком-тында инструктор, 1964–67 дә РСФСР Кинематография дәүләт ком-тының Казан кинохроника студиясендә баш мөхәррир, 1967 дән Татарстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир. «Кояшлы таулар» (1966), «Кояш законы» (1969), «Язгы яшен» (1976) исемле шигырь җыентыклары авторы. Б.ның поэзиясендә авыл б-н бәйле балачак кичерешләре, романтик омтылышлар өстенлек итә. Күп кенә лирик әсәрләрендә, ш.и. «Чәчәк куям» (1978) җыентыгына тупланган истәлек-очеркларында авторның Бөек Ватан сугышы елларына карашы, һәлак булган яшьтәшләрен, якташларын сагыну хисе, туган җиргә мәхәббәте чагыла. «Солдат төймәсе» (1974; рус теленә тәрҗемәсе «Степные тетради», 1982) повесте булган вакыйгаларга нигезләнеп язылган. Б. сценариесе буенча 1966 елда «Габдулла Тукай» документаль фильмы төшерелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*З.З.Рәмиев.*

**БЕЛЯ́ЕВ** Николай Николаевич (23.9.1937, Ярославль ш.), шагыйрь, тәрҗемәче. ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан ун-тының геол. ф-тын (1961), М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый (1975, Мәскәү). Геолог, геофизик, журналист, ТРның Язучылар берлеге әдәби консультанты (1989–92) булып эшли. «Аралар авазы» («Голоса расстояний», 1967; тулыландырылган варианты, 1998), «Җил» («Ветер», 1969), «Юллар чаты» («Перекрёсток», 1972), «Казан дәфтәре» («Казанская тетрадь», 1980), «Меңьяфрак» («Тысячелистник», 1984), «Лирика» (1987), «Карлыгач эзе» («След ласточки», 2001) шигъри җыентыклар авторы. Б. поэзиясенә эчкерсезлек, әхлакый аныклык, этика проблемаларын хәл иткәндә компромисска бармау хас; аерым очракларда публицистикага тартылу бар. Шигырьләре б-н ул үзенең шәхси кичерешләрен һәм социаль рухын һәрвакыт нечкә аңлый торган замандашына мөрәҗәгать итә. Казанга, Татарстанга багышланган шигырьләр шагыйрь иҗатында аерым урын алып тора. Рус теленә Дәрдемәнд, Х.Такташ, С.Хәким, Х.Туфан, И.Юзеев, Ш.Галиев, Р.Харис шигырьләрен тәрҗемә

итә. 1992 елдан Владимир өлкәсенең Собин р-ны Ворша авылында яши.

*А.Э.Скворцов.*

**БЕЛЯ́ЕВ** Николай Яковлевич (1842, Калуга ш. — 22.9.1894, Казан), дин галиме, дин гыйлеме д-ры (1878), проф. (1879). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1868), шунда ук эшли, 1885 елдан инспектор. Православие һәм католик чиркәүләрен якынайту тарафдары. Төп хезмәтләре католик дине канууннарын һәм элгәреге католиклар хәрәкәтен өйрәнүгә багышлана. Хезмәтләре Көнбатыш Европа телләренә тәрҗемә ителә һәм иске католик, англикан чиркәүләре басмаларында дөнья күрә. Казанда Көнбатыш диннәрен фәнни яктан өйрәнү юнәлешенә нигез сала. Шәкертләре арасында В.А.*Керенский*, П.А.*Юнгеров* бар.

Х е з м.: Догмат папской непогрешимости К., 1882; Краткие заметки по поводу заграничнорусской апологии папства. К., 1889.

**БЕЛЯ́ЕВ** Рәис Кыям улы (13.1.1935, Аксубай р-ны Яңа Татар Әдәмсуы а. — 25.7.1996, Казан), партия һәм хакимият хезмәткәре, проф. (1992). Казан ун-тын (1959), Казан финанс-икътисад ин-тын (1967) тәмамлый. 1958 дән Казан ун-тының ВЛКСМ ком-ты секретаре. 1960–61 дә ВЛКСМның Казан шәһәре Совет райкомы 1 нче секретаре, 1963–65 тә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре; 1965–70 тә КПССның Казан шәһәре Бауман райкомы 1 нче секретаре, 1970–84 тә КПССның Чаллы шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. Бу елларда шәһәрдә КамАЗ төзелеше алып барыла. 1984–87 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1987–96 да Казан мәдәният һәм сәнгать академиясе ректоры. 1967–75 тә, 1985–90 да ТАССР ЮС, 1975–85 тә РСФСР ЮС депутаты, 1995–96 да ТР халык депутаты. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең бер проспекты Б. исемен йөртә.

Х е з м.: Камский автогигант, стройка и люди. К., 1974; КамАЗ: формирование трудового коллектива. М., 1975; Подвиг на Каме. К., 1978.

**БЕЛЯ́ЕВ ПҮЧИНКӘСЕ́** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 5 *км* көнбатыштарак, Ушма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 17 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 1 нче яртысында Красная Горка авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 531,1 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Красная Горка волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 167, 1897 дә — 252, 1908 дә — 216, 1920 дә — 215, 1926 да — 268, 1938 дә — 151, 1949 да — 120, 1958 дә — 74, 1970 тә — 53, 1979 да — 36, 1989 да — 7 кеше.

**БЕЛЯ́ЕВ РАЙОНЫ**, *Оренбург өлкәсенең* үзәк өлешендә. Мәйданы — 3,7 мең *км*². Үзәге — Беляевка авылы (Оренбургтан 110 *км* көнчыгыштарак). 2002 елда 20,1 мең кеше яши, ш.и. 1620 татар. Район терр-ясенә татарлар 18 йөз ахырында килеп урнашалар. Башлыча, алар Алабайтал (487 кеше), Донской (139), Беляевка (365) авылларында яши. 1917 гә кадәр Алабайтал авылында (татарлар бирегә 1818 дә килеп урнаша) 2 мәчет (берсенең бинасы сакланган), мәдрәсә була. 1991 дән мәктәптә татар телен өйрәнү буенча факультатив дәресләр үткәрелә. Районда берничә татар үзешчән коллективы бар. Хәзерге вакытта Алабайтал авылында элек юкка чыгарылган мәчет торгызылган, Беляевка авылында мөселманнарның Оренбург мөфтияте дини берлеге эшли.

**БЕЛЯ́ЕВА** Маргарита Ильинична (30.12.1912, Чистай ш. — 10.11.2004, Казан), микробиолог, биол. фән. д-ры (1952), проф. (1952), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1963, 1973). Казан ун-тын тәмамлый (1934) һәм шунда ук эшли (1976 елга кадәр). 1963 елда шеш һәм вирусларга каршы микробиологик матдәләр эзләү буенча проблемалы фәнни-тикшеренү лабораториясен оештыра һәм җитәкли (1976 га кадәр). Бер үк вакытта 1969 елдан үзе оештырган микробиология каф. мөдире. 1977–89 да СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында, 1987 елга кадәр микроорганизмнар физиологиясе лаб. мөдире. Б. бактериаль ферментларның структурасын, функциясен һәм тәэсир итү механизмнарын тикшерү буенча яңа фәнни юнәлешне нигезли. Хезмәтләре водород һәм сульфат редукцияләүче бактерияләр физиологиясенә һәм биохимиясенә, бактерияләр нуклеазаларына карый. Бөек Ватан сугышы елларында һәм тыныч вакытта киң кулланылыш алган ампулалы кетгутны стерильләштерү технологиясен эшли. Генетик инженерия, биотехнология һәм мед. өчен микроб нуклеазалары препаратлары һәм охшаш ферментлар алуда катнаша. 1958 дән Бөтенсоюз микробиология җәмгыяте Казан бүлегенең оештыручысы һәм рәисе. СССР МС премиясе лауреаты (1987). «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. Луи Пастер (Франция) исем. истәлек медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Бактериальные нуклеазы. М., 1969; Нуклеазы микроорганизмов. М., 1974 (автордаш); Биосинтез микроорганизмами нуклеаз и протеаз. М., 1979 (автордаш).

**БЕ́ЛЯК** Тамерлан Сөләйман улы (1.6.1857, Седлецк губ. — ?), генерал-майор (1915). Польша-Литва татарларыннан. С.-Петербургта 1 нче хәрби гимназияне, Михаил исем. артиллерия уч-щесен тәмамлый (1876). Рус-төрек (1877–78), рус-япон (1904–05) сугышларында катнаша. Батарея командиры. 1910 елда полковник дәрәҗәсе ала, 3 нче Көнчыгыш Себер артиллерия бригадасының 1 нче дивизионы командиры итеп билгеләнә. Соңрак 18 нче артиллерия бригадасының 2 нче дивизионы командиры. 1915 елда отставкага чыга. «Батырлык өчен» тамгалы Георгий алтын коралы, 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Н.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

*Я.Я.Гришин.*

**БЕ́ЛЯК** Юзеф (1741, Польша, Новогрудок воеводасы Ловчицы а. — 1794). Польша хәрби эшлеклесе, генерал-майор (1772). Польша-Литва татарларыннан. Җидееллык сугышта катнаша (1756–63). 1761 елдан хорунжий чинында, 1762 дән полковник. 1764–72 елларда татар полкы, 1790 нан 3 татар полкын берләштергән бригада командиры. Полякларның 1794 елгы баш күтәрелешендә катнаша.

*Я.Я.Гришин.*

**БЕЛЯКО́В** Юрий Матвеевич (31.3.1937, Казан), инженер-механик, «Казан оптика-механика заводы» җитештерү берләшмәсе ген. директоры (1987–94), техник фән. канд. (1973). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1960). Казан моторлар төзү-проектлау бюросында (ОКБ «Союз») эшли: инженер, әйдәп баручы конструктор, баш конструктор урынбасары. 1986–87 елларда гамәли оптика ин-ты (ГИПО) директоры. 1994 елдан Казан техника ун-тының оптик-электрон системалар каф. мөдире. Аның җитәкчелегендә төрле максатларда кулланыла торган оптик-электрон приборларны серияләп җитештерү эшләнә һәм оештырыла. Хезмәтләре двигательләр һәм лазер нурланышы генераторларын төзү өлкәсенә карый. Уйлап табуга патентлары, 84 авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге бирелә (1984). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**БЕЛЯ́КОВО** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 37 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 17 йөз башында Б. тирәсендәге җирләр Казан Спас Преображение монастырена бирелә һәм монда рус крәстияннәре килеп урнаша. 20 йөз башында земство мәктәбе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 668 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1646 да — 81, 1782 дә — 59 ир заты; 1859 да — 245, 1897 дә — 334, 1908 дә — 384, 1920 дә — 390, 1926 да — 405, 1949 да — 270, 1958 дә — 240, 1970 тә — 131, 1979 да — 68, 1989 да — 20 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**БЕЛЯ́ЛОВ** (Билалов) Рафаэль Нури улы (1.2.1940, Казан — 26.12.1999, шунда ук), композитор, пианист, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980). 1966 елда Казан консерваториясен тәмамлый (А.С.Леманның композиция һәм фортепиано класслары, шунда ук 1969 да ассистентура-стажировка үтә). 1966 дан Казан консерваториясендә музыка



Р.Н.Белялов.

теориясен укыта һәм композиция классын алып бара. Шәкертләре арасында Р.*Абдуллин*, Р.*Ахиярова* һ.б. Төрле жанрларда — вокаль, инструменталь, театр өчен язылган әсәрләр авторы. Б.ның иҗат эшчәнлегендә инструменталь әсәрләр, аерым алганда, фортепиано өчен сонаталар, сюиталар, фортепиано дуэтлары өстенлек итә. Композитор татар инструменталь концерты үсешенә зур өлеш кертә. 1966 да диплом эше итеп үзенең беренче Фортепиано концертын яза. Б.ның яшь музыкантлар өчен язылган фортепиано һәм оркестр өчен бер кисәктән торган концерт-каприччиосы татар музыка сәнгатендә әлеге жанрдагы беренче үрнәк булып тора. Б.ның скрипка һәм оркестр өчен язылган драматик конфликтлы, трагик эчтәлектәге, масштаблы, дүрт өлешле концерт симфониясе зур казаныш буларак бәяләнә. Б. татар музыкасына заманча динамизм, ашкынучан үсеш элементлары кертә һәм шуның б-н милли характерлы образлылык һәм сурәтләү чараларының чикләрен киңәйтә. Б. музыкасына көчле хәрәкәт энергиясе, токката моторикасы, лирик хыяллар һәм тирән фикер хас; аның әсәрләрендә дөньяны шатлыклы, оптимистик рухта кабул итү, шаянлык еш кына тирән сагыш аһәңнәре, уйчанлык б-н чиратлаша. Композитор иҗатының жанр-интонация чыганаклары күп төрле. Б. иҗатында татар халкының муз. традицияләре (композитор үз әсәрләрендә еш кына халык көйләрен куллана), хәзерге заман композиторлык технологиясе мөмкинлекләре фактура-фигурация модельләре, джаз ритм формулалары б-н бергә үрелеп бара. 20 йөз сәнгате өчен актуаль булган академик һәм эстрада жанрларының кушылуы Б.ның күп кенә әсәрләренә хас: шуңа күрә алар киң катлау тыңлаучыларына аңлаешлы. Композиторның җырлары төрле җыр конкурсларында уңышлы дип танылa (М.Хөсәен, Г.Кутуй шигырьләренә язылган «Ак шәһәр» һәм «Батырлык турында баллада» җырлары һ.б.).

Б., үз әсәрләрен пианист буларак башкарып, республика, РФ һәм БДБ илләре шәһәрләрендә уңышлы чыгышлар ясый. Аның әсәрләре күп милли концертларда һәм пед. репертуарларда төп урынны ала. Аларны башкаручылар арасында пианистлар М.Сиражетдинов, Ф.Хәсәнова, Э.Монасзон, скрипкачылар Ш.Монасыйпов, М.Әхмәтов, җырчы Р.Ибраһимов, дирижёрлар Н.Рахлин, Ф.Мансуров һ.б. бар.

Композиторның әсәрләре халыкара конкурсларда һәм фестивальләрдә («Европа-Азия», 1994, 1998, 2000) башкарыла. Япониядә уздырылган фортепиано дуэтлары өчен композицияләр халыкара конкурсларында Б. әсәрләре ике тапкыр мактаулы диплом һәм медальләр б-н бүләкләнә (1995, 1999). Халыкара фортепиано дуэтлары ассоциациясе әгъзасы (1995). Б. музыка культурасы үсеше мәсьәләләренә караган язмалар авторы. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә (1991).

Төп әсәрләре: «Джесси Найслэнд» мюзиклы (1996; үз либр.); баритон, хор һәм симф. оркестр өчен «Татарстан — туган йортыбыз» вокаль-симф. кантатасы (1999); Фортепиано концерты (1966); Фортепиано һәм оркестр өчен концерт-каприччио (1970); Скрипка һәм оркестр өчен концерт-симфония (1974); Скрипка һәм оркестр өчен концерт-каприччио (1984); Концерт-рапсодия (1978), Концерт сюитасы (1987); Татар рапсодиясе (1997); Латыш рапсодиясе (1998); С.Рахманиновка багышлау (1998); фортепиано өчен сонаталар (1961, 1999); Скрипка һәм фортепиано өчен соната (1963); Скрипка һәм фортепиано өчен фольклор-сюита (1980); Виолончель һәм фортепиано өчен өч Татар сюитасы (1981); җырлар, романслар, татар халык җырларына эшкәртмәләр һ.б.

Х е з м.: Балалар һәм моң // Совет мәктәбе. 1981. № 1; Тамырлары — халыкта // Казан утлары. 1981. № 3; Сихерле көзгедә чагылган язмыш // Казан утлары. 1983. № 2; Альберт Леман // Народные артисты. К., 1980.

*Әд.:* Г у р а р и й С. Диалоги о татарской музыке. К., 1984; А л м а з о в а Т. Рафаэль Белялов // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

*Т.А.Алмазова..*

**БЕЛЯ́НКИНО** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 12 *км* көньяктарак, Киндерле елгасы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 17 йөзнең 2 нче яртысында дворян Одинцовлар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иверский, Белянино исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә. Авыл зур булмаса да, 18–19 йөзләрдә аның берьюлы 7–8 хуҗасы була. Игенчелек һәм терлек үрчетүдән тыш, халкы Казандагы төзү эшләре өчен бут ташы әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б. да 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 64 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощак волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Арча кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 102 ир заты; 1859 да — 181, 1897 дә — 186, 1908 дә — 143, 1920 дә — 183, 1926 да — 155, 1949 да — 146, 1958 дә — 141, 1970 тә — 67, 1989 да — 10 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**БЕМБИ́КС** (Bembix), казучы шөпшәләр семьялыгыннан бөҗәкләр ыругы. Уртача зурлыктагы ялгыз шөпшәләр. Барлыгы 20 дән артык төре билгеле. Татарстан терр-ясендә бердәнбер төре — борынлы Б. (B. rostrata L.) очрый. Гәүдә озынлыгы 18–25 *мм*. Күкрәге кара, корсагында яшькелт-сары сурәт була. Гәүдәсе һәм корсагының төкләре чагыштырмача кыска. Өске ирене нык сузылган, өчпочмак формасында. Урман буйларында, урман аланнарында, агачлар утыртылган чокыр һәм сызаларда, парк, скверларда яши. Җирдә оялый, үлән капламы сирәк булган яхшы җылытылган участокларда җиңел, комлы туфракта ешрак очрый. Ана Б. туфракта өн казый һәм төбенә йомырка сала. Йомыркадан чыккан личинканы ана Б. үзе чагып үтергән чебеннәр һәм кигәвеннәр б-н туендыра. Зур борынлы Б. ТРның Кызыл китабына кертелгән. Илл. к. *Элпәканатлылар*.

*Е.А.Сапаев.*

**БЕМИ́Т**, кәгазь калдыклары, битум һәм балчык нигезендә әзерләнгән түбә ябу материалы. Уртача климат шартларына яраклаштырып төзелгән авыл йортлары түбәсен ябуда кулланыла. Б. житештерү ТРда 1970 елларда Ютазы р-ны Урыссу шәһәр тибындагы посёлогындагы бемит з-дында башлана. Б. җитештерү күләме 1980 дә — 1230, 1990 да — 2182, 1997 дә — 65,4, 1999 да — 100 мең $м^2$ тәшкил итә.

**БЕНДЕ́ЦКИЙ** Александр Григорьевич (16.1.1911, хәзерге Черкасск өлкәсе Золотоноша ш. — 1.5.1943), язучы, тәрҗемәче. 1932 елдан Казанда яши. Әсәрләре 1930 еллар ахырында басыла башлый. Иҗаты: «Ул кайтыр» («Он вернётся», 1938) повесте, «Ватан сугышы әлифбасы» («Азбука Отечественной войны», 1940) шигъри җыентыгы, «Ил намусы өчен» («За честь родной страны», 1941) шигырьләр һәм җырлар җыентыгы. Г.Тукай, А.Алиш, Г.Кутуй, С.Хәким шигырьләрен, әкиятләрен рус теленә тәрҗемә итә. Агитбригада б-н сугышчылар алдында чыгыш ясаганда һәлак була.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Г и н и я т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**БЕ́НДИКОВ** Степан Михайлович (25.5.1907, хәзерге Украинаның Киев өлкәсе Вышгород р-ны Югары Дубечня а. — 6.5.1961, Яшел Үзән р-ны Васильево штп), Сов. Союзы Герое (31.5.1945), полковник (1946). Турксиб төзелешендә эшли. 1929 елдан Кызыл Армиядә. Артиллерия уч-щесен (1932), офицерларның югары артиллерия мәктәбен (1946) тәмамлый. Совет-фин сугышында (1939–40) катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 2 нче гв. танк армиясенең 198 нче артиллерия бригадасы 1007 нче артиллерия полкы командиры. Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Чернигов-Припять (1943) һәм Корсунь-Шевченко (1944) операцияләрендә, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда катнаша (1945). 1945 нең 16–21 апрелендә Б. җитәкчелегендәге полк Берлин операциясе барышында, Кюстрин плацдармында дошман оборонасын өзүне тәэмин итеп, батырлык күрсәтә. 1946 дан запастагы полковник, ТРның Васильево посёлогында яши. Ленин, Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — казахстанцы. А.-А., 1968. Кн. 1; Боевые звёзды киевлян. Киев, 1983.

*В.А.Шагалов.*

**БЕНЕВОЛЕ́НСКИЙ** Пётр Иванович (1.2.1897, Новгород ш. — 14.2.1955, Казан), фтизиатр, мед. фән. д-ры (1943), проф. (1952). 1924 елда Ленинград мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Ленинград мед. югары уку йортларында, 1941–49 да Сов. Союзы Маршалы А.А.Гречко исем. Хәрби диңгез мед. академиясендә эшли. 1950 елдан Казан стоматология ин-тында. 1952 дән Казан ГИДУВының йогышлы авырулар каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре эчәк төркемендәге патоген микроорганизмнар бактериологиясе, туберкулёз микробиологиясе һәм патогенезына карый. Туберкулёз һәм туберкулёз булмаган авырулар вакытында бактериологик бациллемияне тикшерү ысулларын камилләштерә.

Х е з м.: Туберкулёзная бациллемия при туберкулёзе и нетуберкулёзных заболеваниях. Л., 1945.

**БЕ́ННИГСЕН** Александр (20.3.1913, С.-Петербург — 2.6.1988, Париж), тарихчы, философия д-ры. 1919 елда Б.нар гаиләсе Россиядән күчеп китә. 1924 елдан Франциядә яши. Югары коммерция, Шәрекъ телләре мәктәпләрен (Париж) тәмамлый. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында француз армиясендә хезмәт итә, францызларның Каршылык хәрәкәтендә катнаша. 1946 дан Франция хөкүмәте каршындагы Россиягә кагылышлы документлар бүлеге мөдире. 1950 еллардан Югары тикшеренүләр ин-тында; гарәп илләреннән читтә ислам дине таралышы каф. мөдире (Париж). 1971–83 тә Чикаго ун-ты профессоры. Хезмәтләрендә төп игътибарны Россия империясенең һәм СССРның мөселман халыклары тарихына һәм аларның милли-дини үзенчәлекләрен өйрәнүгә юнәлтә. 1970 елларда Төркия архивларында сакланган Кырым ханлыгы тарихы чыганакларын бастырып чыгара. Җәдитчелек, татар милли хәрәкәте, М.Солтангалиев эшчәнлеге тарихын, ш.у. Россиядә 1920 елга кадәрге мөселман матбугатын өйрәнүгә өлеш кертә.

Х е з м.: Мусульмане в СССР. Париж, 1983; Les mouvements nationaux chez les musulmans de Russie: Le «sultangalievisme» au Tatarstan. P., 1960 (автордаш); La presse et la mouvement national chez les musulmans de Russie avant 1920. P., 1964 (автордаш); Muslim national communism in the Soviet Union: a revolutionary strategy for the colonial world. Chi., 1979 (автордаш); Sultan Galiev. La pere de la revolution tiers-mondiste. P., 1986 (автордаш).

*К.Ноак.*

**БЕНТОНИТЛА́Р**, бентонит балчыклар (атамасы АКШтагы Форт-Бентон геологик формациясе исеменнән), 60% ы монтмориллонит (М.) төркеме минералларыннан торган балчыксыл токымнар. Үзлелек дәрәҗәсе, адсорбция һәм катализ активлыгы югары. Б. вулканик токымнарда (туф һәм көлдә) диңгез суы яисә гидротермаль эремәләр йогынтысында барган химик үзгәрү процесслары, ш.у. алюмокремнийлы гельләрнең кристаллашуы һәм сай диңгез култыкларында, күлләрдә балчыксыл минераллар (нигездә монтмориллонитлар) туплану нәтиҗәсендә хасил була. Гадәттә, тыгыз (таш кебек), кулга тотып караганда майлы. Төсе актан алып карага кадәр, ешрак зәңгәрсу, сары һәм яшькелт төсмердә була. Дымлы хәлдә ябышучан һәм үзле. Селтеле (натрийлы һәм кальций-натрийлы) һәм селтеле җир Б.лары (кальцийлы, магний-кальцийлы, кальций-магнийлы) төрләренә бүленә. Монтмориллонит минераллары төркеменнән тыш (бейделлит, сапонит һ.б.), Б. составына гидрослюдалар, катнаш катламлы минераллар һәм бик аз күләмдә каолинит, палыгорскит, цеолитлар, кристобалит, кальцит, кварц, кыр шпатлары керә. ТР терр-ясендәге чыганакларда Б.га, 80–90% ы монтмориллонитлардан һәм 10–20% ы гидрослюдалардан торган, токым хасил итүче кальций-магнийлы монтмориллонит яисә катнаш катламлы минераллы балчыкларны кертәләр. Даими рәвештә Б.да гидрослюдалар (10–30%), каолинит (5–30%) һ.б. була. Б.ның дөньякүләм запаслары 4 млрд. *т.* дан артык; запаслары иң күп (млн. *т*) илләр — Кытай (2400), АКШ (800), Төркия (400), Россия (124).

Казан губернасы терр-ясендә неоген утырмаларындагы Б. турындагы беренче мәгълүматлар И.И.Лепёхин (1771–72), А.А.Штукенберг (1880) һ.б. хезмәтләрендә чагыла. Татарстанда Б.ның үзенчәлекләрен һәм составын өйрәнү, эзләнү эшләре алып бару, ачышлар — геологлар В.Г.Соболев, В.В.Щепин, М.П.Верясова, Н.В.Кирсанов, У.Г.Дистанов, А.А.Сабитов һ.б. исемнәре б-н бәйле. Татарстан терр-ясендә Б.ның һәм аларга якын балчыкларның билгеле запаслары 65 млн. *т* (РФ запасларының яртысыннан күбрәк) тәшкил итә; фаразланган ресурслар 60 млн. *т* тирәсе (1998). Запас балансларында 12 чыганак исәпкә алынган, аларның өчесе иң эреләрдән санала: *Биклән бентонит балчыклар чыганагы* (Тукай р-ны), Берёзовка (Нурлат р-ны) һәм Олы Аты (Түбән Кама р-ны) чыганаклары. Тарн-Вар һәм Югары Нурлат (Нурлат



Биклән чыганагыннан бентонит балчыклар.

р-ны) форма ясагыч Б. чыганаклары республика, Биклән чыганагы — федераль әһәмияткә ия. Б. табигый һәм җыелган су агынтыларын, нефть продуктлары, желатин, дару сывороткаларын, майларны чистартуда, су үткәрмәүчән цемент эшләп чыгаруда, авыл хуҗалыгында (терлек азыгына өстәмәләр, биостимуляторлар, ашламалар) һ.б. максатларда кулланыла. Б. кертү туфракның биологик активлыгын көчәйтә, аның потенциаль әчелеген киметә, үсемлекләрнең фосфор һәм калийны үзләштерү сәләтен, бөртеклеләрнең уңышын (16,8 *ц/га* га кадәр) арттыра, аксым сыйфатын яхшырта. Татарстанда Б. керамзит чуерташ, формалар ясау һәм бораулау эшләрендә кирәкле балчык оны, бораулау измәсе әзерләү өчен кулланыла.

*Әд.:* Минеральное сырьё. Глины: Справ. М., 1997.

*А.А.Сабитов.*

**БЕНЬКО́В** Павел Петрович (8.12.1872, Казан — 16.1.1949, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд ш.), нәкышьче, педагог, Үзбәкстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939). Казан сәнгать мәктәбен (1901), САнең Югары сәнгать уч-щесен (Д.Н.Кардовский остаханәсе) чит илләргә командировкаларга йөрү хокукы б-н тәмамлый (1906). Парижда Жюльенның шәхси академиясендә шөгыльләнә, Испаниядә һәм Италиядә эшли (1906–1908). 1909 елда Б. рәссам дәрәҗәсе ала. Казан сәнгать мәктәбендә укыта (1909–18; 1922–29). Казан (1913 — 1920 елларның 1 нче яртысы), Омск, Иркутск (1919–21) театрларында бизәлеш



П.П.Беньков. В.Э.Вильковиская ясаган портрет. Ксилография. 1920–24.


рәссамы булып эшли. АХРР (1922), ТатАХРР (1923 тән) әгъзасы. 1929 елдан Үзбәкстанда: Бохара, Хива шәһәрләрендә, 1930 дан — Сәмәркандта яши. Сәмәрканд сәнгать уч-щесендә укыта (1949 да уч-щегә аның исеме бирелә). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1935 тән).

Б. — пейзаж, портрет, жанрлы һәм нәкышьле театр декорациясе, төсләр чишелешен үзенчәлекле хәл итү остасы. Аның иҗаты сәнгать концепциясенең бербөтенлеге, пленэр нәкышь принципларын үстерүдәге эзлеклелеге, рус һәм Көнбатыш Европа классик рәсем сәнгатенә нигезләнгән югары проф. культурасы б-н аерылып тора. Иҗатының Казан чорында «Иделдә кич» (1913); «Иделдә», «Идел иртәсе», «Ташёвка» («Ташкабак»), «Идел киңлеге» (1914), «Террасада», «Көзге яфраклар» һ.б. пейзаж серияләрен тудыра, аларда төс һәм яктылык нюанслары нечкәлеге язу фактурасының динамикасы б-н үрелеп бара. Б. портретлары образның ихласлыгын тудыручы иркекле композиция һәм шул ук вакытта модельнең эчке халәтен тирәннән чагылдыру б-н характерлы («Артистка Баева портреты», 1925; «Траубенберг портреты», 1926; «Т.А.Фирсова портреты», 1927; «Г.Ибраһимов портреты» һ.б.). 1920 елларда Б.ның кайбер әсәрләрендә АХРРның нәкышь сәнгатендә көнкүреш һәм этнографик теманы ачуга юнәлдерелгән программасы чагылыш таба: «Эшчеләрнең тормышы һәм көнкүреше», «СССР халыкларының тормышы һәм көнкүреше» һ.б. әсәрләр, «Татар карты», «Йөкче татар портреты», «Эрләүче татар хатыны», «Милли бәйрәм киемендәге татар хатыны» (барысы да — 1920 еллар) портретлар сериясе һ.б. Аларда детальләрнең этнографик төгәллеге характерның типик









П.П. Беньков. 1. «Йөкче татар портреты». 1920 еллар; 2. «Террасада». 20 йөз башы; 3. «Т.А. Фирсова портреты». 1927; 4. «Г.Ибраһимов портреты». 1926. Барысы да — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

үзенчәлекләрен сәнгатьчә гомумиләштерү б-н үрелеп бара.

Рәссамның театр декорациясе сәнгатенә мөрәҗәгать итүе опера спектакльләре куелышын югары дәрәҗәгә күтәрергә омтылган П.И.Пономарёв антрепризасы б-н бәйле. Б. — типик декорацияләр җыелмасы б-н генә канәгатьләнеп калмыйча, спектакльнең сәнгатьчә бербөтен бизәлешен тудырган театр рәссамнарының берсе. 1910 елларда үзенчәлекле сәнгать алымнары б-н Ж.Бизенең «Кармен», М.И.Глинканың «Иван Сусанин», Дж.Вердиның «Аида» әсәрләре буенча куелган спектакльләрне һ.б. бизи; татар театры сәхнәсендә М.Фәйзинең «Галиябану» (1913), Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә» (1914), К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (1915), Г.Хәмиднең «Һинд кызы» (1916) әсәрләре һ.б. Б. бизәлешендә куела. Зур драма театрында рәссам В.Маяковскийның «Мистерия-буфф»ын (1923), А.Островскийның «Бирнәсез кыз»ын (1923) бизи.

Б. — 1930–40 еллардагы Үзбәкстан тормышының сурәтле елъязмасын тудыручы, бу республиканың проф. сынлы сәнгатенә нигез салучыларның берсе. Аның «Бохарадагы түбәле базар» (1923), «Су ташучылар белән Хәүз» (1932), «Йөзем җыю» (1947) һ.б. пейзажлы-жанрлы, турыдан-туры натурадан пленэрда иҗат ителгән композицияләре көнкүреш күренешләренең матурлыгын һәм характерын, Урта Азиянең архит-ра һәм табигать үзенчәлекләрен чагылдыра, шул ук вакытта рәссамның казанышларын иң югары колористик яссылыкта күрсәтә. Б. иҗатында портрет жанры зур урын алып тора («Хива кызы», 1931; «Дутарлы кыз», 1947 һ.б.). Б. ш.у. тарихи-революцион темаларга картиналар яза. Б. үзенең күпьеллык пед. эшчәнлеге б-н сынлы сәнгать өлкәсендә осталар әзерләүгә зур өлеш кертә.

Б. С.-Петербургта (1903 тән), Казанда (1914–28), Мәскәүдә (1922 дән) уздырылган, ш.и. бөтенсоюз күргәзмәләрендә, Үзбәкстанда (1934 тән) үткәрелгән күргәзмәләрдә катнаша. Б.ның шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә, Казан, Ташкент, Сәмәркандта (1960–62) уза. Әсәрләре чит ил күргәзмәләрендә куела (Италия, 1912; Һиндстан, 1952).

Б. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Үзбәкстан сәнгать, Шәрекъ халыклары сәнгате (Мәскәү), Туган як тарихын өйрәнү (Бохара), Тарих, мәдәният һәм сәнгать (Сәмәрканд) һ.б. музейларда саклана. Б.ның портреты З.М.Ковалевская тарафыннан языла (1945).

*Әд.:* Никифоров Б.М. Павел Петрович Беньков. М., 1967; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1.

*Е.П.Ключевская.*

**БЕР ҺӘМ ИКЕЕЛЛЫ́К ЧҮП ҮЛӘННӘ́Р**, бер вегетация чорында үсеп, орлыклары өлгергәч корый торган үсемлекләр. ТРда киң таралган. Орлыктан үрчиләр. Үзенчәлекләренә карап төркемнәргә бүленәләр: эфемерлар, язгы, кышкы, көзге һәм икееллыклар. Эфемерлар (*йолдызак*) — кыска вегетация чорында (0,5–2 ай) һава шартларына бәйле рәвештә бер сезонда берничә буын бирүгә сәләтлеләр.

Язгы чүп үләннәрнең орлыклары иртә язда туфрак 4–6 °С ка кадәр җылынгач тишелә торган иртә өлгерешлеләргә (*кара солы, кыргый киндер,* чәчүлек горчица, кыргый торма, ак алабута һ.б.), орлыклары туфрак 14–16 °С ка кадәр җылынгач тишелә торган соң өлгерешлеләргә (*тавык тарысы*, тычкан тарысы, песи тарысы һ.б.) бүленә. Кышкы чүп үләннәрнең (*кукчәчәк, кандала үләне, көтүче сумкасы*, иссез ромашка, *ярут* һ.б.) вегетация чоры шул ук елның иртә язында тәмамлана, ә вегетация чоры җәй-көздә тәмамланучылар — салкынга чыдам үсемлекләр. Көзге чүп үләннәр — *сусән*, сарыбаш. Тишелү вакыты нинди булуга карамастан, аларның генератив үрчү органнары барлыкка килсен өчен яровойлашу чоры (көзге сезонда темп-ра төшүе) кирәк. Икееллык чүп үләннәр (*сары кандала үләне, ак кандала үләне*, гади ябышкак һ.б.) ике тулы вегетация чорында үсәләр. Беренче елда яфрак таралгысын барлыкка китерә, тармаклана, туклыклы матдәләр туплый, ә икенче елда үсеп җитә һәм җимеш бирәләр.

Бу чүп үләннәргә каршы көрәш чаралары: агротехник (чәчү әйләнешен саклау, туфракны төп эшкәртү системасында алдан камыллы җирне йомшарту, орлыклар тишелгәнче һәм тишелгәннән соң тырмалау, туңга сөрелгән җирне көзге культивацияләү һ.б.), химик (2,4 Д гербицидларын — виолен, виолен супер, ларен, лонтрил 300 һ.б. куллану), саклык чаралары (орлыклык материалны чистарту, басу читендәге чүп үләннәр чәчәк атканчы уру, чүпле участокларны үз вакытында чистарту, дөрес чәчү вакытын, исулларын, нормаларын билгеләү, чүпләнгән терлек азыгын файдалану алдыннан тарттыру һәм йомшарту, карантин чараларын үтәү, складларны чиста тоту, тиресне өемнәрдә яисә стандарт саклау урыннарында саклау).

*Әд.:* Земледелие. М., 2000.

*Н.Б.Прохоренко.*

**БЕ́РВИ** Василий Фёдорович (1793–1859), физиолог, медицина д-ры (1827). 1816 елда Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлый. 1816–23 елларда Россиянең Төньяк Америкадагы компаниясе табибе. 1832–58 дә Казан ун-тында; 1832 елдан профессор, анатомия, физиология, мәхкәмә медицинасы, 1837 дән физиология һәм гомуми патология каф. мөдире, 1836–41 дә һәм 1853–57 дә мед. ф-ты деканы. Хезмәтләре антропологиягә карый.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Зефиров А.Л., Альбицкий В.Ю. Деканы Казанского медицинского университета. К., 1997.

**БЕРГ** Лев Германович (18.5.1896, Казан — 30.3.1974, шунда ук), химик, химия фән. д-ры (1943), проф. (1947), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1956). А.Я.*Богородский* шәкерте. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1919), Казан ун-ты физ.-матем. ф-тының химия бүлегендә ирекле тыңлаучы була. 1919–30 елларда Казан вет. ин-ты химия кафедрасында эшли. Сусыз литий гипохлориты табу шартларын өйрәнә, су — литий хлораты системасының термик анализын үткәрә. 1930–34 тә Гомуми химия лабораториясендә (Ленинград), 1934 елдан — СССР ФА Гомуми һәм нәорганик химия ин-тында (Мәскәү). 1950 дән Казанда, СССР ФАнең Казан ф-лы Химия ин-тында бүлек мөдире (1962 гә кадәр). Бер үк вакытта 1953–59 да Казан ун-тының нәорганик химия каф. мөдире һәм термография буенча проблемалы лаб. җитәкчесе. Хезмәтләре нәорганик һәм аналитик химия, галургия, термик анализга карый. Хлор оксикислоталарын өйрәнү өлкәсендәге эшләре өчен Б. Рус физ.-химия җәмгыятенең М.Г.Кучеров исем. бүләгенә лаек була. Б. җитәкчелегендә вакуум шартларында дифференциаль-термик анализлау һәм бер үк вакытта электр үткәрүчәнлекне һәм газ бүленеп чыгуны исәпкә алуның комплекслы ысулы эшләнә.

Тозлы һәм ярымүткәргечле системаларны, үзле материалларны һәм ашламаларны куллану мәсьәләләрен өйрәнү б-н шөгыльләнә. Б. хезмәтләре химия, геология, металлургия буенча тикшеренүләрдә термографик ысулның киң таралуына ярдәм итә. Б. СССР ФА каршында Термик анализ буенча фәнни советны оештыруда катнаша, СССР МС каршында термик анализ ком-ты рәисе (1962 дән). Термик анализ буенча беренче Халыкара конференцияне (1965, Абердин ш., Шотландия) оештыручыларның берсе. Термик анализ буенча халыкара конфедерациянең беренче президенты (1965–68). Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Термографический метод определения твёрдых фаз в кратных точках многокомпонентных систем // Изв. сектора физ.-хим. анализа Ин-та общей и неорганич. химии АН СССР. 1940. № 14, 175 (автордаш.); Термография. М.–Л., 1944 (автордаш.); Введение в термографию. М., 1969; Практическое руководство по термографии. К., 1976 (автордаш); Chapter 11 Simple Salts (343–361), Chapter 16 Simple Minerals (463–475) // Differential Thermal Analysis. L., 1970.

*Әд.:* Т е й т е л ь б а у м Б.Я. Лев Германович Берг и его вклад в развитие термического анализа // Тр. Всерос. конф. по термическому анализу и калометрии (к 100-летию Л.Г.Берга). К., 1996; B u r m i s t r o v a N.P. In commemeration of L.G.Berg // Journal Termal analysis. 1975. V. 7.

**БЕРГО́ЛЬЦ** Савелий Соломонович (1904, Киев — 18.7.1974, Баку), дирижёр, проф. (1943), ТАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939, 1956). 1925 елда скрипка һәм концертмейстерлык класслары буенча Киев консерваториясен тәмамлый, Житомир, Киев опера театрлары оркестрларында эшли, 1935 тән дирижёр. Татар опера һәм балет театрының беренче музыка җитәкчесе һәм баш дирижёры (1938). Аның җитәкчелегендә театрда беренче мәртәбә Н.Җиһановның «Качкын», «Ирек» (1939, 1940), М.Мозаффаровның «Галиябану», Дж.Пуччининың «Чио-Чио-Сан» (икесе дә 1940 та) опералары куела. Б. үзенең югары профессионализмы һәм башкару культурасы б-н Татар опера һәм балет театры коллективының иҗади үсешенә өлеш кертә. 1943 тән Свердловск опера һәм балет театры режиссёры, бер үк вакытта Свердловск консерваториясе профессоры. 1953 тән — Самара, 1965 тән Баку театрлары баш дирижёры. 1967–74 тә Әзәрбайҗан консерваториясендә эшли.

*Әд.:* Ш е б у е в Г.А. Воспоминания для будущего. Самара, 2002.

**БЕРДИ́ЕВ** Мөгалләм (19 *г.*), педагог. Әстерхан шәһәре Татар бистәсе мещаннарыннан. Казан мәдрәсәләренең берсендә укый. 1833–64 елларда Әстерхандагы Беренче ир балалар гимназиясендә татар теле, ш.у. төрле елларда фарсы һәм гарәп телләре укыта.

*Әд.:* О с т р о у м о в Т. Исторический очерк Астраханской 1-й мужской гимназии за время с 1806 по 1914 год. Астрахань, 1916.

**БЕ́РДНИКОВ** Владимир Владимирович (2.5.1923, Казан — 12.11.2003, шунда ук), машиналар гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1976), проф. (1977). 1947 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый. 1950–62 елларда С.Орджоникидзе исем. з-дта лаб. башлыгы, 751 нче з-дның КБсында конструктор, бригада башлыгы, 1962 елдан Казан авиация ин-тында, 1975–90 да машиналар һәм механизмнар теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре гидравлик чылбырлар, пневмогидроприводлар һәм пневмогидроавтоматиканың гамәли теориясенә карый. Уйлап табуга караган 6 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Прикладная теория гидравлических цепей. М., 1977; Математическое моделирование механизмов шасси самолётов // Пневматика и гидравлика. М., 1990. Вып. 15 (соавт.).

**БЕ́РДНИКОВ** Евгений Александрович (21.10.1936, Баку ш.) химик-органик, химия фән. д-ры (1989), проф. (2002). Казан ун-тын (1959) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1995 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре күкерт һәм фосфорның чиксез кушылмалары, галогенкарбон кушылмалар химиясенә карый. Күкертле һәм фосфорлы туендырылмаган яңа органик кушылмалар синтезлый, аларның электрохимик үзлекләрен тикшерә. Сульфонил һәм фосфон группаларының аерылып винил кушылмалар барлыкка китерү мөмкинлеген күрсәтә. Винилфосфоний тозларын, винилфосфонатлар, гомохиноннарны синтезлау ысулларын эшли. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Электрохимическое восстановление винилсульфонов в протогенной среде // Журн. общей химии. 1974. Т. 44, вып. 69 (автордаш); Третичные амины в реакциях нуклеофильного замещения с изомерными β-бромвинилсульфонами // Журн. органической химии. 1982. Т. 18, вып. 4 (автордаш); Синтез и превращения 2-амино-5-метоксикарбонил-6-фенил-6Н-1,3,4-тиадиазина // Химия гетероциклических соединений. 1996. Вып. 9 (автордаш).

**БЕ́РДНИКОВ** Илья Степанович (12.7.1839, Вятка губ., Слобода өязе Коса а. — 30.9.1915, Казан), дин хокукы галиме, дин гыйлеме д-ры (1881). Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1864), шунда ук эшли, 1869–1911 елларда дин хокукы каф. профессоры, 1882–86 да ректор ярдәмчесе. Бер үк вакытта 1885 елдан Казан ун-тында профессор, 1881 һәм 1909 да Б. руханилар академияләренең яңа уставларын төзүдә катнаша, 1907–09 да чиркәү реформасын әзерләүгә зур өлеш кертә. Хезмәтләре дин-чиркәү хокукы тарихына, җәмгыятьтә чиркәүнең тоткан урынын өйрәнүгә карый. Дин-чиркәү хокукы дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Государственное положение религии в Римско-Византийской империи. К., 1888; Краткий курс церковного права православной греко-российской церкви. К., 1888; Основные начала церковного права православной церкви. К., 1902.

*Әд.:* Юбилейное торжество в академии в день пятидесятилетия деятельности И.С.Бердникова // Православный собеседник. 1915. Ч. 1; Л а п и н П. Илья Степанович Бердников. Некролог // Православный собеседник. 1915. Ч. 3; К р а с н о ж е н М. Профессор И.С.Бердников // Византийское обозрение. Львов, 1917.

**БЕРЕЖНО́Й** Александр Николаевич (10.7.1925, Казан), җылылык физикасы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989), проф. (1991). 1948 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1953–2003 тә Казан технол. ун-тында, 1974–85 тә инженерлык графикасы каф. мөдире. Хезмәтләре газлар диффузиясе һәм масса күчерү проблемасына карый. Б. үзара диффузия коэфф-тын тәҗрибәдә билгеләүнең 2 стандарт ысулын эшли (1991, автордаш) һәм, бинар пар-газ системаларын тәҗрибәдә тикшереп, стандарт белешмә мәгълүматлар ала (1987–92, автордаш), алар РФнең Дәүләт стандарты тарафыннан аттестацияләнә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Применение метода подобия при исследовании процессов переноса массы // Журн. физ. химии. 1960. Т. 24 (автордаш); Уравнение обобщённой зависимости для вычисления коэффициента взаимной диффузии парогазовых систем // Журн. техн. физики. 1983. Т. 53 (автордаш); Экспериментальные методы определения коэффициентов взаимной диффузии в газовой фазе. М., 1986 (автордаш).

**БЕРЕ́ЗИН** Илья Николаевич (19.7.1818, Пермь ш. — 22.3.1896, С.-Петербург), шәркыятьче галим, проф. (1854). А.К.Казимбәк шәкерте. Казан ун-тын тәмамлый (1837), шунда ук эшли, проф. (1845–55). 1855 елдан Петербург ун-ты профессоры. Дагстан, Кавказ арты, Иран, Төркиягә сәяхәт кылганнан соң (1842–45), Шәрекъ илләрен, аларның табигатен, көнкүрешен һәм гореф-гадәтләрен шул заман өчен иң яхшы тасвирлаган «Шәрекъ буйлап сәяхәт» («Путешествие по Востоку», т. 1–2, 1850–52) исемле хезмәтен бастырып чыгара. Себер татарлары шивәләрен өйрәнү максатында Оренбург губернасына (1846) һәм Тубыл шәһәренә җибәрелә. Болгар шәһәрлеген өйрәнү нәтиҗәләре буенча «Идел янындагы Болгар» («Булгар на Волге», 1853) китабын бастыра.

Фәнни казанышлары һәм хезмәтләре югары бәяләнә: 1854 елда Казан ун-тының ординар профессоры итеп раслана. Б. тәрҗемәләр әзерли һәм «Шәрекъ тарихчылары китапханәсе»н («Библиотека восточных историков», 1849–54), хан ярлыклары текстларын бастырып чыгара (1850–72), Россиядә беренче фарсы теле дәреслеге булган «Фар-



И.Н. Березин.

сы теле грамматикасы»н («Грамматика персидского языка», 1853) төзи. Россия әдәбият сөючеләр җәмгыяте (1847) һәм Нумизматлар җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1848), Париждагы (1849), Лейпцигтагы (1849) Азия җәмгыятьләре мөхбир әгъзасы. Петербургта яшәгән елларында Б. Рәшидетдиннең «Елъязмалар җыентыгы»н бастырып чыгара, басмада чыганакның рус теленә тәрҗемәсен һәм үз искәрмәләрен урнаштыра; ш.у. «Төрек хрестоматиясе»н («Турецкая хрестоматия», т. 1–3, 1857–90) һәм «Рус энциклопедия сүзлеге»н («Русский энциклопедический словарь», т. 1–16, 1873–79) нәшер итә. Б. — Шәрекъ текстологиясенә, филологиясенә, төрки һәм фарсы халыклар тарихына караган хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Внутреннее устройство Золотой Орды (по ханским ярлыкам). СПб., 1850; Очерки внутреннего устройства Улуса Джучиева. СПб., 1864.

*Әд.:* С а м о й л о в и ч А.Н. И.Н.Березин как тюрколог // Зап. Коллегии востоковедов при Азиатском музее АН СССР. Л., 1925. Т. 1; Ш о ф м а н А.С., Ш а м о в Г.Ф. Восточный разряд Казанского университета (краткий очерк) // Очерки истории русского востоковедения. Л., 1956; М а з и т о в а Н.А. Изучение Ближнего и Среднего Востока в Казанском университете. К., 1972; Б а р т о л ь д В.В. И.Н.Березин как историк // Соч. М., 1977. Т. 9.

*М.Г.Госманов.*

**БЕРЕ́ЗИН** Николай Борисович (18.5.1956, Киров өлкәсенең Оричев р-ны Березины а.), электрохимик, химия фән. д-ры (2000), проф.(2002). 1978 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук инновацион технологияләр кафедраара лаб. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре цинкның глицинат комплексларын кайтару кинетикасына һәм механизмына карый, металл һәм эретмәләр электроутырымы хасил булу процессларында комплекс ясалу һәм импульс тогының ролен өйрәнә. Гетеротөшле, гетеролигандлы комплексларның һәм импульслы ток параметрларының гальваник капламнарга металл һәм нәметаллар кушу процессларына тәэсир итү закончалыкларын билгеләп. Бу процесслар өчен электролитлар эшләүгә яңа юллар тәкъдим итә.

Х е з м.: Роль объёмного и поверхностного комплексообразования при электроосаждении импульсным током цинк-хромовых, цинк-никелевых и никель-фосфорных покрытий // Электроосаждение металлов и сплавов.: Сб. науч. трудов МХТИ. М., 1991 (автордаш); Электроосаждение сплава цинк-хром импульсным током // Защита металлов. 1993. Т. 29, № 1 (автордаш); Электроосаждение металлов и сплавов из водных растворов комплексных соединений. К., 2006 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БЕРЕ́ЗИНА** София Иосифовна (21.8.1916, Киров өлкәсенең Оричев р-ны Березины а. — 13.4.1997, Казан), электрохимик, химия фән. д-ры (1978), проф. (1984). Казан ун-тын (1941) тәмамлый. 1941–44 елларда СССР ФА Гомуми һәм нәорганик химия ин-тында (Казан), 1946–94 тә — РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли (1972–86 да электрохимия лаб. мөдире). Хезмәтләре металл һәм металл эретмәләрне эл. тогы ярдәмендә утырымга төшерүгә карый. Металл һәм эретмәләрнең анодта эрү һәм катодта утырымга төшү процессларында комплекслар ясалуның һәм протонлы тәэсирнең ролен өйрәнә. Лигандларны, координацион актив анионнарны протонлауда һәм протонсызлауда, координацион сфераны үзгәртүдә һәм металл комплексларының электрохим. активлыгын үзгәртүдә протонлы тәэсирнең төрле яклы булуын билгели. Электродлы процесслар кинетикасы б-н эремәдәге һәм электрод тирәсендәге комплекслар составының үзара бәйләнешен билгели. Эремәләрдә һәм электрод яны катламында водород ионнары концентрациясен үзгәртү юлы б-н комплексларның составын үзгәртүгә нигезләп, электролитик эретмәләрнең үзлекләрен һәм составын көйләүнең яңа ысулын тәкъдим итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологические материалы по электрохимической обработке металлов. К., 1952; Интенсификация процессов электроосаждения металлов и сплавов регулированием комплексообразования и протонного влияния // Прикладная электрохимия. Теория, технология и защитные свойства гальванических покрытий. К., 1989; Роль протонирования и депротонирования комплексов при катодном соосаждении металлов // Электроосаждение металлов и сплавов. М., 1991 (автордаш).

**БЕРЕЗНИКИ́ ШӘҺӘРЕ́**, *Пермь өлкәсендә*, Пермь шәһәреннән 176 *км* төньяктарак урнашкан. Халкы — 173,1 мең кеше (2002). Татарлар саны: 1979 елда — 8876, 2002 дә — 6610 кеше. Беренчел археол. чыганаклар татарларның борынгы бабаларының хәзерге Б.ш. тирәсендә 11 йөздән үк урнаша башлавын раслый. Алар тоз чыгарганнар һәм аны кайнатканнар, бакыр рудасы эреткәннәр, сату иткәннәр. Даими татар авыллары 1552 елдан соң гына барлыкка килә. 20 йөз башыннан 1927 елга кадәр татарлар химия сәнәгате төзелешен олаулар һәм ат караучылар б-н тәэмин итеп торалар. 1927–41 елларда Б.ш.ндә М.*Ардуанов* эшли. 1949–60 та Б.ш.ндәге төзелешкә 40 меңләп татар килә. 1949–84 тә В.И.Ленин исем. мәдәният сарае каршында татар үзешчән сәнгать коллективы эшли. 1991 дән мәчет эшли. 2000 дә Россия мөселман Үзәк Диния нәзарәтенең Пермь мөфтияте Березники мөхтәсибәте оештырыла. 1997 дә татар-башкорт мәдәни үзәге ачыла. Аның каршында татар һәм башкорт халыкларының телен, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү оештырылган; үзешчән сәнгать түгәрәге, бу халыкларның иҗат музее эшли. 1998 дән Сабантуй бәйрәме үткәрелә. Б.ш.ннән Татарстан Респ-касына калийлы һәм азотлы ашламалар китерелә.

**«БЕРЕ́К»** («Шәкертләр берлеге»), 1905–06 елларда Казан шәкертләренең яшерен иҗтимагый-сәяси оешмасы. Оештыручылары «*Таң йолдызы*» г-тасы тирәсендә тупланган, эсерларга якын торган татар яшьләре: Ф.Туктаров, Г.Исхакый, Ш.Мөхәммәдъяров, Х.Ямашев һ.б. (нигездә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре). Максатлары: уку-укыту тәртибенә заманга хас үзгәрешләр кертү, мәдрәсәләрдә китапханә булдыру, төрле курс һәм түгәрәкләр оештырырга ирек алу, татарларга милли-мәдәни мохтарият төзергә һәм Учредительләр җыенын җыярга рөхсәт бирелүен таләп итү. Оешма әгъзалары фикеренчә, татар халкының мәктәп-мәдрәсәләрен тотуны хөкүмәт һәм земство идарәләре үз өсләренә алырга тиеш. «Б» әгъзалары шәкертләр арасында революцион фикер тараталар, татар либераллары һәм «*әл-Ислах*» оешмасы вәкилләре б-н бәхәскә керәләр. Милли мәгарифкә кагылышлы мәсьәләләрдә «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясе программасы б-н килешәләр. Россиянең эсерлар партиясе йогынтысында булалар. 1906 елда «Б» тарала.

*Әд.:* И б р а һ и м о в Г. Татарлар арасында революция хәрәкәтләре. К., 1925; К у р б а н о в Т.Я. Татарские учителя и татарская учащаяся молодёжь Поволжья и Приуралья в период буржуазно-демократической революции 1905–07 гг. // Из истории педагогики в Татарии. К., 1967.

**БЕРЕ́К** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 30 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 5 *км* ераклыкта. 2002 елда 82 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1920 елларда ТАССРның Зөя кантоны составында нигез салына. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 179, 1938 дә — 370, 1949 да — 247, 1958 дә — 237, 1970 тә — 155, 1979 да — 131, 1989 да — 75 кеше.

**БЕРЕНЧЕ́ АЕРЫ́М ИДЕ́Л БУЕ́ ТАТА́Р УКЧЫЛАРЫ́ БРИГА́ДАСЫ**. Бригаданы оештыруда Үзәк мөселман хәрби коллегиясе башлап йөри. Бу эшкә Республика революцион хәрби советының (РВСР) 1919 елның 10 март карары һәм Идел буе округ хәрби комис-тының 1919 ның 24 март боерыгы нигезендә керешелә. Штаб, элемтә ротасы һәм 1 нче полк — Казанда, 2 нче полк — Самара шәһәрендә, 3 нче полк Алатырь шәһәрендә оештырыла. Бригаданы командирлар составы, мәдәни-агарту эше хезмәткәрләре белән тәэмин итүдә Үзәк мөселман хәрби коллегиясе, Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының үзәк бюросы, губерна һәм өязләрнең коммунистик мөселман оешмалары җитди булышлык күрсәтә. Башта ул Мөселман бригадасы дип атала, 1919 ның май-июнендә — Аерым Идел буе татар укчылары бригадасы, 1919 ның июнь-декабрендә — Беренче аерым Идел буе татар укчылары бригадасы, 1919 ның декабрь — 1920 нең маенда — Беренче Төркестан укчылар бригадасы, 1920 нең май — 1922 нең июлендә — Дүртенче Төркестан укчылар бригадасы, 1922 нең июленнән Дүртенче Төркестан укчылар дивизиясе дип йөртелә. Бригада командирлары — Ю.И.Ибраһимов, И.И.Тальковский, хәрби комиссарлар — Ш.Х.Усманов, Б.Д.Белоусов, Я.Ж.Чанышев. 1919 ның июлендә бригада фронтка

кил. Көнчыгыш фронтның Беренче армиясе составында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, адмирал А.В.Колчак армиясенә каршы сугыша, 1919 да Совет Төркестаны камалышын өзүгә зур өлеш кертә. Аннары Төркестанга җибәрелә, Фирганәдә, 1920 дә Бохара операцияләрендә, Җидесуда басмачыларга каршы сугышларда катнаша. Бригада составында Татар җиңел артиллерия дивизионы сугыша (командиры — К.Якубов, хәрби комиссарлары — А.А.Рәҗәпов, М.Шаһидуллин һ.б.).

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**БЕРЕНЧЕ́ А́РМИЯ**, 1918–19 елларда *Көнчыгыш фронт* карамагындагы эре хәрби берләшмә. 1918 елның 19 июнендә оештырыла. Командующийлары: А.И.Харченко, М.Н.Тухачевский, Г.Д.Гай, Г.В.Зиновьев; штаб башлыклары: Р.Шимунич, И.Н.Захаров, Н.И.Корицкий, Ф.П.Шафалович. Б.а. карамагында Вольск, Пенза пехота, Оренбург, 24 нче, 25 нче, 49 нчы укчы, 3 нче Төркестан кавалерия дивизияләре, Инза революцион дивизиясе сугыша. 1918–19 елларда Б.а. баш күтәргән чех-словак корпусы, КОМУЧның Халык Армиясе һәм адмирал А.В.Колчак җитәкчелегендәге армияләр б-н сугыш бәрелешләрендә катнаша, Көнчыгыш фронтның башка гаскәри берәмлекләре б-н бергә Сембер, Хвалынск, Сызрань, Самара, Эстәрлетамак, Оренбург шәһәрләрен азат итә. 1919 елның язгы айларында Эстәрлетамак һәм Оренбург юнәлешләрендә Колчак гаскәрләре һөҗүменә каршы тора, җәй башында үзе һөҗүмгә күчә һәм дошман көчләрен эзәрлекләүдә катнаша. 1919 ның августында Б.а. Төркестан фронты карамагына күчерелә. Шул елның июль аенда *Беренче аерым Идел буе татар укчылары бригадасы* Б.а.гә ярдәмгә җибәрелә. 1919 ның март ахырларында Б.а.нең сәяси бүлеге каршында мөселманнар секциясе оештырыла. Ул секция татар телендә эш алып барырлык сәяси кадрлар туплау, укыту һәм гаскәри берәмлекләргә беркетү, аларда партия ячейкалары булдыру эшләре б-н шөгыльләнә. Татар-башкорт телләрендә әдәбият һәм матбугат тарату, урыннарда әдәби-мәдәни кичәләр оештыру, митинглар уздыру, армия күләмендә театр труппасы булдыру, «*Кызыл йолдыз*» г-тасын нәшер итү дә шушы секция тарафыннан башкарыла.

**БЕРЕНЧЕ́ БОЛГА́Р ПАТШАЛЫГЫ́**, Балкан ярымутравының төньяк өлешендә оешкан борынгы дәүләт (681–1018). Төп халкы болгарлар һәм славяннар. Азак төбәгендәге *Бөек Болгар дәүләтеннән Аспарух хан* җитәкчелегендә күчеп килгән болгарлар тарафыннан оештырыла. 8 йөз башларында Б.б.п. биләмәсе Дунай елгасы буеннан Иске Планина тауларына чаклы һәм Кара диңгез буе Искыр елгасына кадәр була. Башкаласы баштарак — Плиска, 893 елдан — Преслав шәһәре. Халкы иген игү, терлек асрау һәм һөнәрчелек б-н шөгыльләнгән. Патшалык халкы болгар аристократларыннан (боил, багаин һ.б.) һәм ирекле славян игенчеләреннән торган. 8 йөз урталарында идарәче ыруглар (Дуло, Укил, Угаин) арасында тәхет өчен барган низаг аркасында патшалык көчсезләнә. Корум хан (803–14) идарә иткәндә Б.б.п. кабат көчәеп, күтәрелеп китә. Корум хан көнчыгышта авар, көньякта Византия көчләрен җиңүгә ирешә, Константинопольне камауда тота (811–14). Варисы Омуртаг хан (814–31) аның уңышлы башлангычын дәвам итә, Паннонияне һәм Македониянең бер өлешен яулап ала. Чукынганда Борис I патша исемен алган хан дәверендә — 865 елда — Б.б.п.нда дәүләт дине буларак христиан дине кабул ителә. Патшалыкның иң куәтле чоры Симеон патша идарә иткән елларга туры килә (894–927); ул үзенә «болгарлар белән греклар патшасы» титулын ала. Византиянең даими басымы һәм күрше венгрларның һаман борчып, тынгысызлап торуы, җирле феодалларның үзара көрәш-бәрелешләре 10 йөз урталарына куәтле Б.б.п.ның какшавына китерә. 967–71 дә аны яулау өчен Византия императоры Иоан Цимисхий б-н Киев кенәзе Святослав арасында көрәш башлана, патшалыкка һөҗүм итүләр ешая. Самуил патша идарә иткән елларда гына беркадәр тотрыклылыкка ирешелә (976–1014). 1018 дә Византия патшалыкны үзенә буйсындыра.

*Әд.:* Раннефеодальные государства на Балканах VI–XII вв. М., 1985; История на България. Първа Българска държава. София, 1981; Петров П. Образование на Българската държава. София, 1981.

*И.Л.Измайлов.*

**БЕРЕНЧЕ́ БӨТЕНДӨНЬЯ́ СУГЫШЫ́** (1.8.1914 — 11.11.1918), Европаның ике төркемгә берләшкән дәүләтләре — Германия-Австрия блогы һәм Антанта (Англия, Франция, Россия һ.б.) арасындагы сугыш. Сугышта 1,5 млрд. кеше яшәгән 38 дәүләт катнаша. Йогынты өлкәләренә, чимал чыганакларына, сәүдә мәйданнарына, колонияләргә ия булу, дөнья б-н хакимлек итү өчен барган сәяси көрәш барышында каршылыкларның кискенләшүе нәтиҗәсендә башланып китә. Б.б.с. елларында Казан губернасы гаскәрләрне төрле кирәк-ярак һәм сугышчылар б-н тулыландыру буенча гомумроссия базасына әверелә. 1914 елда гына да Казан губернасында 5 мобилизация уздырыла. Сугышның беренче 1,5 елында губерна халкы 22% ка кими (1914 тә 2850101 кеше яшәгән булса, 1916 да 2227726 кешегә кала). *Казан хәрби округына* ай саен 800 рота (200 меңләп кеше) мобилизацияләү бурычы йөкләнә. 1914–17 елларда Казан губернасыннан гына да 290 меңнән артык кеше мобилизацияләнә. 1916 да губерна терр-ясендә *Туксан дүртенче запас укчылар полкы* һәм *Туксан бишенче запас укчылар полкы* оештырыла һәм урнаштырыла. Губернаның сәнәгате фронт ихтыяҗлары өчен хәрби продукция житештерүгә күчерелә. Казандагы 43 пр-тие (15500 эшче) хәрби заказларны тәэмин итә. Алафузов пр-тиеләре армия өчен кием-салым һ.б. кирәк-ярак җитештерә. А.Д.Шабановның — күн, бертуган Крестовниковларның химия з-длары фронт өчен эшлиләр. 1915 елның июнендә Казан шәһәр думасы инициативасы б-н Казан хәрби сәнәгать ком-ты оештырыла (җитәкчесе итеп Казан шәһәре башлыгы В.Д.Боронин сайлана), аның бүлешлыгы б-н пр-тиеләр арасында хәрби заказлар бүленә. Шундый ук ком-т Чистайда да эшли. Сугыш елларында фабрика һәм заводларда хатын-кызлар һәм үсмерләр хезмәте киң файдаланыла: Казанда хатын-кызлар хезмәтенең өлеше 50% чамасы (Алафузов пр-тиеләрендә 60% ка кадәр) тәшкил итә. Билгеләнгән вакыттан күбрәк эшләү гадәти күренешкә әверелә: Шабанов остаханәләрендә эш көне еш кына тәүлеккә 18 сәгатькә, Бондюг химия з-дында 15–16 сәгатькә җитә. Чимал, ягулык китерү кыенлыклары, тимер юл һәм су транспортлары эшендә таркаулык хөкем сөрү сәбәпле, халык ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә корылган пр-тиеләр еш кына бөлә һәм ябыла (мәс., Набоков һәм Веретенниковның такта яру ширкәте, Морозовның һәм Веселовның ярма яру з-длары). 1916 елның 1 гыйнварыннан 1 апрелендә кадәр чорда Казанда гына да 9 завод ябыла. Нәтиҗәдә халыкны иң кирәкле әйберләр б-н тәэмин итү чикләнә. Болар халыкта ризасызлык китереп чыгара: губерна шәһәрләрендә һәм авыл җирләрендә күпләгән халык чыгышлары булып уза. Авыл хуҗалыгында хәл елдан-ел катлаулана бара: чәчүлек җирләренең мәйданы, терлекләрнең саны кими, уңыш түбәнәя (бөртекләләрнең уңышы һәр дисәтинәдән 59 поттан 30 потка төшә).

Хөкүмәт карары б-н Казанда яралы сугышчыларны эвакуацияләү буенча округ пункты урнаша. 1914 нең 2 августында губерна земствосының 87 нче гадәттән тыш җыелышында «Земство берлегенең авыру һәм яралы сугышчыларга, сугышка алынучылар гаиләләренә ярдәм итү буенча Казан губерна комитеты» оештырыла (рәисе Н.А.Мельников), бүлекчәләре өязләрдә дә барлыкка килә. Ком-т яралы сугышчыларны хастаханәләргә урнаштыра, хәрбиләргә мед. ярдәме күрсәтүне оештыра, госпитальләрне хуҗалык кирәк-яраклары б-н тәэмин итә. Земство берлеге акчасына губернада 932 урынлы 22 лазарет ачыла, 109 ятакка исәпләнгән 8 лазарет шәхси иганәләр исәбенә эшли.

1915 нең ахырында Казанда 2568 урынга исәпләнгән 33 госпиталь эшли. Сугышның беренче көннәрендә үк Казан шәһәр думасы яралыларга һәм сугышка алынучылар гаиләләренә ярдәм итү мәсьәләсе буенча гадәттән тыш утырыш уздыра. Дума инициативасы б-н запастагылар һәм сугышка алынучылар гаиләләренә акчалата ярдәм күрсәтелә, шәһәр ашханәләрендә балаларны бушлай ашату оештырыла, ярлылар өчен махсус ашханәләр ачыла. Запастагыларның гаиләләрен тәэмин итү өчен Дума 2 ел эчендә 400 мең сум бирә. Сугыш елларында Казан шәһәре башлыгы В.Д.Боронин җитәкчелегендә авыру һәм яралы сугышчыларга ярдәм күрсәтүче шәһәр ком-ты (ул иганә акчаларын пособиеләр бирүгә, хәйрия ашханәләре ачуга һ.б. максатларга тота), ш.у. госпитальләрне җиһазландыру ком-ты үз эшчәнлекләрен җәелдерәләр. Земство һәм шәһәр думаларыннан тыш, губернада шәхси хәйрия оешмалары челтәре барлыкка килә. Казанның үзендә 1914 тә 150 дән артык шундый оешма исәпләнә. Сугышның беренче елында Гомумземство берлеге, Гомумшәһәр берлеге, Кызыл Хач җәмгыяте, Сәүдәгәрлек-биржа җәмгыяте инициативасы б-н губерна терр-ясендә 8590 ятак-

ка исәпләнгән 144 дәвалау оешмасы ачыла. 1915 нең 1 сентябренә Кызыл Хач җәмгыяте тарафыннан губерна халкыннан җыелган иганә акчалары 201 мең сумнан артып китә. Губерна земствосы инициативасы б-н гариплләр йорты төзү өчен 40 мең сум акча туплана. Сугыш елларында еш кына Казан урамнарында хәйрия акчалары җыю оештырыла, махсус көннәр, мәс., әйберләр җыю өчен «Кызыл Хач» көннәре уздырыла. 1915 нең июненә кадәр урамнарда махсус уздырылган 10 көн эчендә 176 мең сум акча җыела.

Казанга көнбатыш губерналардан төрле оешма һәм сәнәгать пр-тиеләре күчерелә. 1915 нең җәендә качаклар килә башлый. Август-сентябрь айларында Казанга гына да көн саен качаклар төялгән 4–5 эшелон кайта. Губерна 60 меңгә якын качакны кабул итә. Губерна терр-ясенә хәрби әсирләр дә кителә: аларның беренче төркеме (1013 кеше) 1914 нең декабрендә килә, шәһәр янындагы Паратск з-дына урнаштырыла.

Сугыш башланганнан соң, Россия мөселманнары хөкүмәткә тәләктәшлек белдерәләр: аларның патриотик рухтагы берничә манифестациясе (мәс., Казанда) була, 1915 нең гыйнварында 4 нче Дәүләт думасындагы мөселман фракциясе, сугышка карата мөнәсәбәтен белдереп, рәсми мөрәҗәгать б-н чыга, анда Россиядә яшәүче мөселман халыкларының сугышны тиз арада һәм җиңү б-н тәмамлау өчен хөкүмәткә һәрьяклы булышлык итәчәге игълан ителә. 1914 нең декабрендә 4 нче Дәүләт думасындагы мөселман фракциясе инициативасы б-н Петроградта мөселман иҗтимагый оешмаларының Бөтенроссия съезды үткәрелә (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Делегатлар фронтка ярдәм итү һәм мөселман хәйрия җәмгыятьләре эшчәнлеген җайга салу б-н бәйле мәсьәләләрне тикшерәләр. Корылтайда мөселман иҗтимагый оешмаларының яралы сугышчыларга ярдәм күрсәтү буенча Вакытлы ком-ты оештырыла. Солдатлар һәм аларның гаиләләре файдасына Ком-т тарафыннан җәмгысе 50 мең сум чамасы акча җыела. 1916 ның җәендә фронтка Ком-т тарафыннан Россия мөселманнарының санитар отряды оештырылып җибәрелә, аны А.Сыртланова җитәкли. 1915 тә Оренбургта һәм Казанда Польша һәм Литвадан килгән мөселман качакларга ярдәм итү җәмгыятьләре оештырыла. 1917 елгы Фев. рев-циясеннән соң мөселман хәрбиләре арасында Россия армиясендә махсус мөселман гаскәри берәмлекләр булдыру эше башлана, шул максат б-н мөселман хәрбиләрнең 1 нче Бөтенроссия корылтае чакырыла (1917 нең 17–26 июле, Казан). Ул корылтайда кичекмәстән милли гаскәри берәмлекләр оештыра башлау турында карар кабул ителә.

1917 дә сугышка каршы хәрәкәт киң колач ала башлый. Һәр җирдә демонстрация һәм митинглар уздырыла, төп таләпләрнең берсе «Бетсен сугыш!» лозунгында чагыла. Россия мөселманнары арасында сугышка каршы оешмалар барлыкка килә (к. *Мөселманнар комитеты*).

1918 нең 3 мартында Россия Брест шәһәрендә Германия б-н аерым килешү (Брест солыхы) төзи, бу хәл Россиядәге кайбер сәяси көчләр арасында ризасызлык тудыра (к. *Сул эсерлар*). Сугыш 1918 нең ноябрендә Антантаның җиңүе б-н тәмамлана. Солых шартлары Парижда Тынычлык конференциясендә әзерләнә (бүленүләр б-н 1919 ның 18 гыйнварыннан 1920 нең 21 гыйнварына кадәр бара), аның эшендә *Милләт Мәҗлесе* вәкилләреннән С.Максуди, Г.Исхакый, Ф.Туктаров катнаша. Делегация җитәкчесе С.Максуди конференциядә катнашучыларга Идел буе һәм Урал төбәге төрки-татарларының Милли-мәдәни мохтарият конституциясенең маддәләре кертелгән меморандум б-н мөрәҗәгать итә. 1920 нең апрелендә делегацияне Франция премьер-министры А.Мильеран кабул итә.

Чыг.: У милосердия древние корни (Благотворительность и милосердие в Казани в годы Первой мировой войны. 1914–1917). Сб. документов и материалов. К., 2003. Кн. 2.

*Әд.:* Медведев Е.И., Григорьев А.Н., Булатов М.Р. Об Октябрьском вооруженном восстании в Казани в 1917 году: Сб.статей. К., 1948; Ежов Н. Военная Казань в 1917 г. К., 1954; Ионенко И.М., Тагиров И.Р. Октябрь в Казани. К., 1967; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

*Л.М.Айнетдинова.*

**БЕРЕНЧЕ́ КАЗА́Н СОВЕ́Т МӨСЕЛМА́Н ЗАПА́С ПЕХО́ТА ПО́ЛКЫ**, Көнчыгыш фронтның Казан бүлеге Революцион хәрби советының 1918 ел 24 сентябрь карары һәм Казан губерна хәрби комис-тының 1918 ел 25 сентябрь боерыгы б-н оештырыла. Командиры — Х.З.Габидуллин. Полк составында 1 нче мөселман коммунистлар батальоны (командиры Т.Гайнуллин, комиссары И.Ш.Галиев), Беренче татар-башкорт укчылары батальоны да була. Өченче батальон мобилизацияләнгән сугышчылардан төзелә. Полк Көнчыгыш фронтка 1065 кешелек 5 рота озата. Казан губ. хәрби комис-тының 1918 нең 14 октябрь боерыгы нигезендә 2 нче пехота полкы итеп 4 нче Петроград дивизиясенә кушыла.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**БЕРЕНЧЕ́ МАЙ** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 14 *км* көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы янәшәсендә. 2002 елда 111 кеше (татарлар — 60%, руслар — 39%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920–30 елларда нигез салына. Оештырылган вакытыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1938 дә — 75, 1989 да — 75 кеше.

**БЕРЕНЧЕ́ МАЙ** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 21 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бәйрәкә елгасы буенда. 2002 елда 275 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. 1950 елларда нигез салына. Беренче исеме — Вахитов исем. с-зның 3 нче бүлеге посёлогы, 1964 нең 15 сентябреннән хәзерге исемен йөртә. Оештырылган вакытыннан — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1989 да — 246 кеше.

**БЕРЕНЧЕ́ МАЙ** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 30 *км* көньяктарак, Мишә елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 36 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1940 елларда нигез салына. Оештырылган вакытыннан — Тәкәнеш, 1963 елның 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1989 да — 57 кеше.

**БЕРЕНЧЕ́ МАЙ** посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 44 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оша елгасы буенда. 2002 елда 14 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган вакытыннан — Ширәмәт, 1963 елның 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1989 да — 8 кеше.

**«БЕРЕНЧЕ́ МАЙ»** колхозы, Саба р-нында. 1930 елда Югары Шытсу авылында оештырыла.1958 дә бу колхозга «Илшат» (Түбән Шытсу), «Кызыл Яшьләр» (Мамалай), «Кызыл Көч» (Елыш), «Мәскәү» (Сатлыган Ключ), «Кызыл Батыр» (Чәбки-Саба) к-злары берләштерелә. 1995 тә Мамалай авылындагы колхоз бригадасы мөстәкыйль хуҗалык булып аерылып чыга. Колхоз үз эченә 5 торак пунктны ала: Югары Шытсу, Елыш, Сатлыган Ключ, Чәбки-Саба һәм үзәк утары Түбән Шытсу авылы (2004 тә барлыгы 312 хуҗалык, 866 кеше, ш.и. 220 се а.х. җитештерүендә эшләүчеләр). Колхозның 3745 *га* а.х. җирләре, ш.и. 3313 *га* сөрү җирләре бар; 1 гектар бөртекле культуралардан 37,4 *ц*, бәрәңгедән 165 *ц* уңыш алына. Мөгезле эре терлек саны 1236 баш (ш.и. сыерлар 315 баш), 1470 баш дуңгыз, 278 баш сарык, 70 баш ат. 1 сыердан 3710 *кг* сөт алына, мөгез эре терлекнең уртача тәүлеклек артымы 759 *г*. 100 *га* а.х. җирләренә күчереп исәпләгәндә 312 *ц* сөт, 77,4 *ц* ит җитештерелә. Хуҗалык РСФСР МС һәм ВЦСПСның Күчмә Кызыл Байрагы б-н (1986), КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКнең Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1985). Хуҗалык эшчеләре дәүләт бүләкләре б-н бүләкләнә, ш.и. 6 кешегә ТАССР һәм ТРның атказ. хезмәткәре исеме бирелә, 2 кешегә ТАССР һәм ТР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, 1 кешегә Ленин ордены, 10 кешегә Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кешегә «Почёт билгесе», 4 кешегә 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» орденнары; 13 кешегә медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының 1 алтын, 3 көмеш, 1 бронза; медальләре бирелә. Төрле еллардагы хуҗалык җитәкчеләре: Г.Х.Хуҗин (1958–72), Р.А.Сөнгатуллин (1976–2007) һ.б. 2004 тә «Б. м.» к-зы «Б. м.» исем. крәстиян-фермер хуҗалыгы итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Нәҗмиев Т., Әхмәтҗанов И. Туган туфрак кадере. К., 2003.


*И.Н.Афанасьев.*

**БЕРЕНЧЕ́ МАЙ МӘЙДАНЫ́** (Иван мәйданы), Казандагы иң борынгы мәйданнарның берсе. 16–18 йөзләрдә Кремльнең Спас манарасы каршында сәүдә һәм хакимият мәйданы буларак формалаша. Анда сәүдә рәтләре һәм кибетләр, төрмә, канцелярия урнаша. Мәйданның төньяк өлешен Кремльдән аерып торган тирән яр аша Спас манарасы кар-

шында — агач күпер, ә 18 йөздә таш күпер салына. Көньяк өлешендә башта төрмә, 17 йөз ахырыннан, мәйдан киңәйтелгәннән соң, «Гостиный двор» урнаша. Башта Спас, 17 йөздән Иван мәйданы (мәйданның көнбатыш өлешендәге Иоанн-Предтеча ирләр монастыре исеменнән) дип атала. Берничә гасыр дәвамында мәйданны өч гөмбәзле уникаль Иоанн-Предтеча храмы бизәп тора. В.И.Кафтырев тарафыннан эшләнгән ген. план нигезендә үзгәртелгәннән соң, мәйдан камилрәк төс ала. Анда беренче «Гостиный двор» төзелә (1770, арх. В.И.Кафтырев). Мәйданга көньяктан Спас (хәзер Кремль ур.), көнбатыштан — Зур Проломный урамына төшү юлы тоташа. Б.М.м.н көнчыгыштан торак йортлар чикләп тора. 18 йөз уртасында яр күмелә һәм күпер сүтелә, мәйданда императрица Екатерина II нең Казанга килүе хөрмәтенә триумфаль а́рка төзелә; 1835 елдан Б.М.м.нда Казан шәһәр думасы урнаша, 1895 тә император Александр II һәйкәле куела, Казан шәһәре фән-сәнәгать музее ачыла (1895, И.Н.Колмаков тарафыннан), мәйданга чуерташ түшәлә. Казан депутатлар советының 1918 ел 30 апрель карары б-н исеме Беренче Май мәйданы итеп үзгәртелә. 1966 да герой шагыйрь Муса Җәлил монументы куела (скульп. В.Е.Цигаль, арх. Л.Г.Голубовский), мәйданның планы үзгәртелә, Бауман урамына төшә торган таш баскыч төзелә.

*Әд.:* Амиров К.Ф., Ахметзянов И.М., Шакиров Ф.М. Казань. Исторические зарисовки. К., 1997.

*Х.Г.Надыйрова.*



Казан. Беренче Май мәйданы. Хәзерге күренеш.

**БЕРЕНЧЕ́ МАЙ НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, Алабуга һәм Тукай р-ннары терр-ясендә Кама елгасы үзәнендә, ш.и. елга юлында урнашкан. 1958 елда ачыла. 1964 тән нефть чыгарыла. Үлчәмнәре 26,5×10 *км*. Сәнәгый нефтьле катламы 19 *м*. Нефть югары девон утырмаларының комлыклары һәм алевролитларында. Катламнар калынлыгы 1,5–12,6 *м*, алар 1,6–1,8 *км* тирәнлектә яталар. Башлангыч катлам басымы 160–171 атм., темп-ра +35 °С. Нефть үзенчәлекләре: үзлелеге 6 *МПа*, чагыштырма авырлыгы 0,876 *г/см*$^3$, күкертлелеге 1,9 %, сумалалылыгы 1,8%, парафинлылыгы 4,1%, газ факторы 32–34 *м*$^3$/*т*. Нефть чыгышы тәүлеккә 0,4–12 *т*, элегрәк тәүлегенә 170 *т* га җиткән. Чыганак терр-ясен Түбән Кама ГЭСы сулары басу сәбәпле, эксплуатацияләү скважиналары дамба тирәли мәйданчыкларда һәм 5 махсус мәйданда урнашкан. Чыганакта 200 дән артык скважина эшли. Нефть чыгаруны «Прикамнефть» НГДУ башкара. Җир астыннан барлыгы 45 млн. *т* чамасы нефть алынган. Чыганак нефть чыгаруны төгәлләү стадиясендә.

*Г.С.Габделмәҗитева.*

**БЕРЕНЧЕ́ МАЙ РАЙОНЫ́**, ТАССР да. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — Түбән Кәминкә, 1938 дән Чирмешән авыллары. Район терр-ясе 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязенә һәм Самара губернасының Бөгелмә өязенә, 1920 дән ТАССР ның Бөгелмә кантонына керә. Оештырылган вакытында Б.М.р.на 30 авыл советы, 42229 кешесе (татарлар — 24143, руслар — 9491, башка халыклар — 8595) булган 60 торак пункт керә. 1940 та районның мәйданы — 1487 *км*$^2$, халкы — 47 мең кеше, 28 авыл советы, 71 торак пункт исәпләнә. Адм. берәмлекләрнең саны кимү сәбәпле, 1956 да районда — 23, 1960 та 12 авыл советы кала. 1963 нең 1 февралендә Б.М.р. бетерелә, биләмәсе Әлмәт, Лениногорск, Октябрь р-ннарына бирелә.

**БЕРЕНЧЕ́ СОВЕ́Т МӨСЕЛМА́Н ПЕХО́ТА ПО́ЛКЫ**, К.Туйбахтин исемендә. 1918 елның 30 сентябрендә Әстерхан шәһәрендә Аерым мөселман кызыл социалистик батальоны җирлегендә оештырыла. Полк составы ирекчеләр, мобилизацияләнгәннәр һ.б. гаскәри берәмлекләрдән күчкән кызылармиячеләр исәбенә тулыландырыла. Полкта, башлыча, Әстерхан, Самара, Саратов, Казан, Сембер, Пенза, Түбән Новгород, Вятка, Рязань губерналарыннан кешеләр хезмәт итә, аларның күпчелеген татарлар тәшкил итә. Өч батальоннан тора, пулемётчылар командасы, гренадерлар, атлы разведчиклар, ординарецлар, музыкантлар һәм уку-укыту эше командалары була. Барлыгы 1110 кешедән тора. Каспий-Кавказ фронтының 12 нче армиясе составында полк генерал А.И.Деникин армиясенә каршы сугышларда катнаша.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**БЕРЕНЧЕ́ ТАТА́Р УКЧЫЛАРЫ́ ПО́ЛКЫ**, М.Вахитов исемендә, Бөтенроссия баш штабының Идел буе хәрби округы комис-ты боерыгы (1919 ел, 12 февр.) нигезендә Казанда оеша. Командиры — И.А.Әхмәров, командир ярдәмчесе А.С.Сабитов, хәрби комиссары Г.С.Касыймов. 31 мартта Үзәк мөселман хәрби коллегиясе полкка М.М.Вахитов исемен бирү турында карар кабул итә. Беренче аерым Идел буе татар укчылары бригадасы составына кушыла. Ныгытылган Казан р-ны барлыкка килгәч, 1919 елның апрель ахырында Казан крепосте дивизиясенең 2 нче бригадасы составына кертелә. 1919 ның 13 маенда полк Көнчыгыш фронтның резервына күчерелә һәм Самарага, аннан — Оренбург тирәсенә җибәрелә. 1919 ның 17 июнендә полк, Оренбургка бару юлларын саклап, Белогорка һәм Матвеевка авыллары янында дошманның күпсанлы көчләренә каршы канкойгыч сугышлар алып бара. 2,5 мең кызылармияче һәм командирлар составыннан 200 кеше генә исән кала. Алар Самарага күчерелә, *Беренче аерым Идел буе татар укчылары бригадасының* башка гаскәри берәмлекләре шунда тупланган була. Монда полк тулыландырыла һәм алга таба шушы бригада составында хәрәкәт итә.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**БЕРЕНЧЕ́ ТАТА́Р ҮРНӘ́К ТЕА́ТРЫ**, к. *Татар академия театры.*

**БЕРЕНЧЕ́ ТАТА́Р-БАШКО́РТ ПЕХО́ТА БАТАЛЬОНЫ́**, Мәскәүдә Үзәк мөселман комис-ты хәрби бүлегенең 1918 ел 1 апрель һәм Мәскәүдәге Шәһәр р-ны хәрби комис-тының 1918 ел 15 апрель боерыклары нигезендә оештырыла, Документларда күрсәтелгәнчә, Б.т.-б.п.б. революцияне, пролетариатны һәм Совет властен саклауга, Татар-Башкорт Совет Республикасын төзүгә булышлык итәргә тиеш була. Командиры — Х.Александрович, комиссарлары — Минһаҗ Конов, М.Б.Корбанаев (Гобәйдуллин). Батальон ирекле сугышчылардан туплана. Татар һәм башкортлардан тыш, аңа үзбәкләр, казакълар һәм төрки халыкларның башка вәкилләре дә языла. 1918 нең 11 июнендә батальон комиссар М.Б.Корбанаев командалыгында Мәскәүдән Самарага юнәлә, әмма бу шәһәрнең дошман кулына төшүе сәбәпле, Казанда туктала. Алга таба батальон баш күтәргән чех-словак корпусы гаскәри берәмлекләренә һәм КОМУЧның Халык Армиясенә каршы Сызраньда (1918, июль), Казанда (1918, авг.) сугыша, Казанны, Буа һәм Тәтеш өязләрен дошманнан азат итүдә катнаша. 1918 нең декабрендә таратыла.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**БЕ́РЕСНЕВ** Виктор Владимирович (6.5.1941, Киров өлкәсенең Санчурск р-ны Санчурск пос. — 31.7.2005, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1987), проф. (1990). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1963). 1967–69 да Синтетик каучук өчен мономерлар фәнни-тикшеренү ин-тында (Ярославль ш.) эшли. 1969 дан Казан технол. ун-тында, 1996 дан органик һәм нефтехим. синтез технологиясе кафедрасында проф. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясе һәм технологиясе, нефтехимия, нечкә органик синтез, лак-буягыч материаллар мәсьәләләренә карый. Майлагыч майларга присадкалар, полимер модификаторлар һәм лак-буягыч материаллар алу ысулларын эшли. Төп тикшеренүләре җитештерү технологиясендә, нечкә органик синтезда озон куллануга; полимерларның структураларын һәм үзлекләрен өйрәнүгә, функциональ группалы олигомерлар табуга багышланган. Уйлап табуга 41 авторлык таныклыгы бар. Фәнни эшләнмәләре «Түбәнкаманефтьхим», «Синтезкаучук» (Тольятти ш.), «Химудобрения» (Мәскәү өлкәсенең Воскресенск ш.),

«Азот» (Череповец ш.) һ.б. АЖләренә кертелгән.

Х е з м.: Озонирование сополимеров изобутилена с диенами в растворе и химические превращения олигоизобутиленов // Plaste und kautschuk, 1975. № 5 (автордаш); Деструкционный метод определения структуры полимеров на примере реакции озонолиза бутилкаучука // Карбоцепные полимеры. М., 1977 (автордаш); Исследование механизма действия антиокислительных присадок к смазочным маслам на основе олигоизобутиленов с концевыми функциональными группами // Изв. по химии Болгар. АН. 1985. Т. 18, № 4 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БЕРЁЗОВАЯ ГРИ́ВА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы янында. 2002 елда 64 кеше (руслар — 80%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ватага исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — икътисад, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Николай чиркәве (1904 тә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе, 5 тегермән, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2950,9 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Спас өязе Николо-Пичкас волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Спас кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 231 ир заты; 1859 да — 1058, 1897 дә — 1442, 1908 дә — 1495, 1920 дә — 1582, 1926 да — 1529, 1938 дә — 530, 1949 да — 353, 1958 дә — 390, 1970 тә — 309, 1979 да — 173, 1989 да — 76 кеше.

**БЕРЁЗОВАЯ ГРИ́ВА** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кама елгасы буенда. 2002 елда 41 кеше (руслар — 76%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1724 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балык тоту б-н шөгыльләнә, елга суднoларында матрос булып эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 520 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 139, 1870 тә — 191, 1920 дә — 218, 1926 да — 257, 1938 дә — 303, 1949 да — 277, 1958 дә — 140, 1970 тә — 119, 1979 да — 84, 1989 да — 48 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 35 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шонталы исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында башлангыч белем бирү мәктәбе (1891 дә ачыла), 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1122 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Спас өязе Алан волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Спас кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 239 ир заты; 1859 да — 469, 1897 дә — 626, 1908 дә — 709, 1920 дә — 915, 1926 да — 786, 1938 дә — 381, 1949 да — 205, 1958 дә — 191, 1970 тә — 188, 1979 да — 114, 1989 да — 53 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы Ямаш суы буенда. 2002 елда 27 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чаллы кантоны Акташ волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 319, 1938 дә — 307, 1949 да — 269, 1958 дә — 218, 1970 тә — 188, 1979 да — 115, 1989 да — 33 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 55 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы янәшәсендә. 2002 елда 215 кеше (руслар — 72%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1930 елларда нигез салына. 1959 елның 18 декабренә кадәр — «Беренче Май» с-зының 2 нче бүлекчәсе посёлогы. Акташ р-нына керә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1958 дә — 132, 1979 да — 301, 1989 да — 167 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казансу елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2002 елда 750 кеше (татарлар — 57%, руслар — 41%) яши. Техника-ремонт пр-тиесе. Башлангыч мәктәп. 1960 елның 9 маенда торак пункт буларак теркәлә. Биектау р-нына керә, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1970 тә — 758, 1989 да — 834 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 5 *км* төньяктарак, Бөгелмә Зәе елгасының сул кушылдыгы Бөгелмә суы янында. 2002 елда 630 кеше (татарлар — 49%, руслар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1960 елның 16 февралендә торак пункт буларак теркәлә. Халык саны: 1970 тә — 317, 1979 да — 346, 1989 да — 578 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** (Каенлы) авылы, Лаеш р-нында, шәһәр тибындагы Лаеш посёлогыннан 26 *км* төньяктарак, Мишә елгасыннан 2 *км* читтә. 2002 елда 64 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Авыл 1602 дән мәгълүм. Башта Тәгәнеч дип атала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек дворян Комаровларның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да земство мәктәбе була, тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 286,7 дис. тәшкил итә. 1920 дән ТАССР ның Лаеш кантонында. 1927 нең 17 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең декабреннән Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 67 ир-ат; 1859 да — 163, 1897 дә — 287, 1908 дә — 330, 1910 да — 368, 1920 дә 420, 1926 да — 527, 1938 дә — 240, 1949 да — 278, 1958 дә — 292, 1970 тә — 215, 1979 да — 138, 1989 да — 75 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 6 *км* ераклыкта. 2002 елда 26 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 1914 тә нигез салына. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Омар волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Мамадыш р-нында. Халык саны: 1926 да — 257, 1938 дә — 321, 1949 да — 270, 1958 дә — 193, 1970 тә — 181, 1979 да — 142, 1989 да — 66 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 16 *км* көнбатыштарак, Аксумла елгасы буенда. 2002 елда 29 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 18 йөз ахырында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1129 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркин волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 503, 1897 дә — 428, 1908 дә — 438, 1926 да — 442, 1938 дә — 359, 1949 да — 281, 1958 дә — 159, 1970 тә — 180, 1979 да — 39, 1989 да — 45 кеше.

**БЕРЁЗОВКА** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 18 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы янында. 2002 елда 37 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 18 йөз уртасында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 912 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванай волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 100 ир заты; 1859 да — 329, 1897 дә — 440, 1908 дә — 654, 1920 дә — 596, 1926 да — 570, 1938 дә — 226,

1949 да — 108, 1958 дә — 98, 1970 тә — 130, 1979 да — 97, 1989 да — 39 кеше.

**БЕРЁЗОВКА МИНЕРА́ЛЬ БУЯ́У РУДАЛАРЫ́ ЧЫГАНАГЫ́**. ТРда иң эре чыганакларның берсе. Лаеш р-ны Берёзовка авылыннан төньяк-көнбатышка таба 1,5 *км* читтә урнашкан. Мишә елгасы тугае өстеннән киңәеп киткән (400–500 *м* га кадәр) беренче киртләчкә туры килгән урында бер яктан сазлыкка, икенче яктан инешкә килеп тоташа. 1949 елда ачылган. 1999 дан чыгарулар алып барыла. Сәнәгать запаслары 1,3 мең *т* тәшкил итә ($Fe_2O_3$ уртача 55,24% һәм ятманың уртача калынлыгы 0,25 *м* булганда). Чыганак аркылы юнәлештә беркадәр сузынкы, мәйданы 5480 $м^2$, ш.и. сәнәгать чикләренә аның 4100 $м^2$ ы туры килә. Чыганак терр-ясенең шактый зур түбәнге өлешендә руда ятмасы калынлыгы 0,10–0,15 тән 1,2–1,5 *м* га кадәр булган кара торф, соры, соры-коңгырт балчыксыл туфраклар б-н капланган. Чыганакта руда җисеменең калынлыгы 0,02–0,03 тән 0,6–0,7 *м* га кадәр үзгәрә һәм уртача 0,25–0,30 *м* тирәсе тәшкил итә. Рудалар кара торф, сазлык известе һәм караңгы соры балчыксыл туфрак белән түшәлгәннәр. Руда җисеменең төзелеше бериш түгел: кисемнәрдә ике, сирәк кенә өч катлам аерылып тора. Руда җисеменең минералогик составы — гётит-гидрогётит (70–90%), гумус һәм органик матдәләр (10–30%). Чыганак рудалары өч төркемгә: минераль составы буенча — гётит-гидрогётитлы, гётит-гематитлы; $Fe_2O_3$ күләме (% ларда) буенча — 30, 30–50 һәм 50–70 кә кадәр; төсе буенча — саргылт, карасу кызыл һәм кызгылт сары төсләргә бүленәләр. Технологик һәм буяу үзлекләре буенча алар технологик төргә берләштерелгән. Алына торган буяуларның сыйфаты югары. Еллык чыгару 150 *т* (1999).

*И.В.Дьячков.*

**БЕРЁЗОВКА РАЙОНЫ́**, *Пермь өлкәсенең* көньяк-көнчыгышында урнашкан. 1924 елның 27 февралендә оештырыла. Мәйданы — 1977,2 $км^2$. Үзәге — Берёзовка авылы (Пермьнән 136 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 18247 кеше (2006). Татарлар саны: 1926 да — 3016, 1979 да — 4342, 2000 дә — 2270, 2006 да — 3129 кеше. Районда татарлар яши торган 13 торак пункт бар, шуларның иң зурлары: Чокыр Авыл (431 кеше) һәм Ванькино (320). Иң борынгылары: Чокыр Авыл, Иссинәй (1675 тән мәгълүм), Татар Тазы (1679) авыллары. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Б.р.нда 7 мәчет була. 1898 дән Чокыр Авылында татар земство уч-щесе эшли. 1930 елларда районда 6 татар мәктәбе була. 1999/2000 уку елында 2 урта һәм 3 башлангыч мәктәптә татар теле укытыла. «Сельская Новь» район г-тасында «Шауба» исемле махсус сәхифә даими чыга. Районда буш вакытны оештыру буенча методик үзәк каршында «Умырзая» ансамбле эшли. Б.р.нда татар халкының милли традицияләрен саклап — «Нәүрүз», ел саен Сабантуй бәйрәмнәре үткәрелә.

**БЕРИ́М** Герш Осиевич (2.3.1948, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1990). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан а.х. академиясендә эшли, 1988 елдан физика һәм матем. каф. мөдире. 1995 тән Кампинас (Бразилия), 1997 дән Эрланген-Нюрнберг (Германия) ун-тлары профессоры. Хезмәтләре алмашынулы-бәйләнешле спин системаларының магнит резонансы теориясенә һәм бер үлчәмле спин системалары динамикасына карый. Изинг спин системалары өчен магнит резонансы спектры һәм формасы сызыкларын, термостат б-н контакт булганда магнитландыру кинетикасы һәм динамикасының алмашыну энергиясен тикшерә. Изинг системаларына гына хас күп кенә үзенчәлекле үзлекләрне ачыклый.

Х е з м.: Магнитный резонанс изинговских магнетиков. М., 1982 (автордаш); Теория магнитного резонанса в модели Изинга // Журн. эксперим. и теоретической физики. 1974. Т. 66 (автордаш); Некоторые аспекты динамики обобщённой модели Изинга в поперечном поле // Журн. теоретической и мат. физики. 1984. Т. 58 (автордаш); Динамика неоднородных возбуждений в одномерных спиновых системах // Журн. эксперим. и теоретической физики. 1992. Т. 102.

**БЕРИ́М** Осия Иовлевич (1908, Украина, Хмельницкий ш. — 1985, Казан), төзелеш инженеры, ТАССРның атказ. төзүчесе (1978). Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1936), Казандагы оборона з-дының проект бүлегендә эшли. 1946 елдан — ТАССР Министрлар Советы архит-ра һәм төзелеш идарәсенең архитектура-планлаштыру остаханәсендә инженер-конструктор, конструкторлык, техника бүлекләре башлыгы булып эшли. 1954 тән «Татаргражданпроект» ин-ты баш инженеры. СССР архитекторлар берлеге әгъзасы (1955). КПССның өлкә ком-ты конференц-залы (1979–81; хәзерге ТР Дәүләт Советы бинасы), Казан циркы (1967, Е.Ю.Брудный һәм В.Д.Панова б-н берлектә), «Татарстан» кунакханәсе (1970, М.Д.Нәдершин б-н берлектә) төзелешендә төзү конструкцияләре, 1960–70 елларда Татарстанда киң файдаланылган җиңеләйтелгән бетон фундаментлар исәпләмәләре һ.б. авторы. Хезмәтләре конструкцияләү, биналар төзү, корылмаларның ныклыгы һ.б. мәсьәләләргә карый. СССР МС бүләге лауреаты (1971). Медальләр б-н бүләкләнгән.

**БЕ́РКУТОВ** Александр Максимович (11.11.1911, Казан губ., Спас өязе Яңа Мордово а. — 26.1.1962, Сочи ш.), Сов. Союзы Герое (2.8.1944), подполковник (1946). 1931 елдан Кызыл Армиядә. Ворошиловград хәрби авиация очучылары мәктәбен тәмамлый (1935). Халхин-Гол елгасы буендагы бәрелешләрдә (1939) һәм совет-фин сугышында катнаша (1939–40). 1942 елның августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 101 нче гв. истребительләр авиация полкы (4 нче һава армиясенең 329 нчы истребитель авиация дивизиясе) штурманы. Төньяк Кавказ, Кавказ арты һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Кавказ сугышында, Кырым, Украина, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда катнаша. 1944 нең мартына 332 сугышчан очыш ясый, 68 һава сугышында катнаша, шәхсән үзе дошманның 15 самолётын бәреп төшерә. Сочи шәһәрендә яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



А.М. Беркутов

*Әд.:* Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. — Казан, 1990; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои боёв за Крым. Симферополь. 1972; Герои битвы за Кавказ. Цхинвал, 1975; Герои огнённых лет. Ярославль. 1985.

*В.А.Шагалов.*

**БЕ́РКУТОВ** Валентин Михайлович (10.2.1926, Кукмара р-ны Нырья а.), педагог, пед. фән. д-ры (1992), проф. (1995), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Бөек Ватан сугышында катнаша.Казан пед. ин-тын тәмамлый (1954). 1960 елдан Казан финанс-икътисад ин-тында эшли, 1966 дан Казан югары танк уч-щесендә; 1973 тән СССР ПФАнең Гомуми пед. фәнни-тикшеренү ин-тының Казан дидактика лабораториясендә, 1976–94 елларда Казан вет. ин-тында. 1995 тән Казан пед. ун-ты профессоры. Хезмәтләре матем. белемнәр һәм татарларда матем. укыту тарихына карый.

Х е з м.: Народный календарь и метрология булгаро-татар. К., 1987; Развитие математического образования булгаро-татар. К., 1997; Татарның мәшһүр математиклары. К., 1999; Из истории математического образования в Татарстане. К., 2003.

**БЕРЛӘ́Ш** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 30 *км* төньяктарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2002 елда 18 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1949 да — 162, 1958 дә — 140, 1970 тә — 110, 1979 да — 90, 1989 да — 34 кеше.

**БЕРЛЕ́К** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 24 *км* көньяктарак, Дим елгасының сул кушылдыгы Сулы суы буенда. 2002 елда 54 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантонының Бөгелмә волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 86, 1938 дә — 173, 1949 да — 165, 1958 дә — 130, 1970 тә — 144, 1979 да — 93, 1989 да — 68 кеше.

**БЕРЛЕ́К** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2002 елда 20 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1927 дә Үтәмеш авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. ТАССРның Буа кантоны Олы Тархан волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябрен-

нән — Тәтеш р-нында. Халык саны: 1926 да — 147, 1938 дә — 192, 1949 да — 211, 1958 дә — 175, 1970 тә — 127, 1979 да — 77, 1989 да — 40 кеше.

**«БЕРЛЕ́К»**, большевистик юнәлештәге татар социал-демократлары оешмасы. 1917 елның мартында Баку шәһәрендә «Идел буе мөселманнарының Милли Шурасы» каршында оештырыла. 1917 елның 4 октябреннән мөстәкыйль оешма. Җитәкчеләре: М.Х.Терегулов, Х.Х.Сәйфи. 150 ләп кешене берләштерә. Татар эшчеләре арасында сәяси һәм мәдәни-агарту эшләре алып бара. Шәһәрдә совет хакимияте төшерелгәч, 1918 нең августыннан соң коммунистларның «Гуммет» оешмасы составына керә. Әгъзаларының бер өлеше Әстерхан шәһәренә эвакуацияләнә.

*Әд.:* Очерки истории Коммунистической партии Азербайджана. Баку, 1963; Тагиров И.Р. В борьбе за власть Советов. К., 1977.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**БЕРЛЕ́К-МИХА́ЙЛОВКА** (Берлек) авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы бассейнында. 2002 елда 109 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Алпавыт Колчуриннар йорты — 19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге. Хәзерге Б.-М. 1964 нең 23 апрелендә Берлек (1920 елларда нигез салына) һәм Михайловка (19 йөзнең 1нче яртысында нигез салына) авыллары кушылудан барлыкка килә. 1920 елга кадәр Михайловка авылы Казан губернасының Чистай өязе Иске Максим волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Чистай кантонында. 1930 елның 10 августыннан ике торак пункт та — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1859 да — 98, 1897 дә — 289, 1908 дә — 324, 1920 дә — 379, 1926 да — 397, 1938 дә — 397, 1949 да — 268; Б.-М.да 1970 тә — 391, 1979 да — 297, 1989 да — 102 кеше.

**БЕ́РЛИН** Александр Александрович (27.9.1940, Мәскәү), химик, химия фән. д-ры (1974), РФА мөхбир әгъзасы (1994). Мәскәү физ.-техн. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), РФАнең Хим. физика ин-тында эшли, лаб. мөдире (1978 елдан), проф. (1980), бүлек мөдире (1989 дан), директор урынбасары (1994 тән), директор (1996 дан). Бер үк вакытта 1982 дән Мәскәү физ.-техн. ин-тында, 1994 тән Россия хим.-технол. ун-тының Мәскәү югары химия көллиятендә. Хезмәтләре югары-молекуляр кушылмалар һәм композицион материаллар физикасы һәм химиясе, каты җисемнәр һәм сыеклыклар структурасын һәм үзлекләрен компьютерлы модельләү проблемаларына карый. Турбулент агымнарда югары тизлекле хим. реакцияләрнең макрокинетикасы теориясен төзи, торбалы реакторларны исәпләү ысулын һәм изобутиленның олиго- һәм сополимерларын, полиизопрен һәм дивинил-α-метилстирол каучукларны, метилэтилкетонны эшләүнең, этиленны хлорлау һәм гидрохлорлауның ресурс һәм энергия саклаучы технологияләрен эшли. Түбән кайнаучы артык җылытылган антипиренлы капсулаларның микрошартлавы тәэсирендә полимер матрицаның сибелү (дисперсияләү) күренешен ача, полимерларның янучанлыгын киметү юлларын эшли, түбән янучан яңа полимер материаллар кертә. Композицион полимер материалларның таркалуы һәм тиңдәшле ныклык характеристикалары механизмын өйрәнә, матрицада пластик деформацияләрнең ролен ача. Бу эшләр нигезендә яңа материаллар ясый һәм ныгытылган пластик массаларның һәм тулыландырылган полимерларның үзлекләрен яхшырта. Компьютерлы модельләү ысуллары б-н Б. эрү һәм пыялалауга, кристаллик халәттән пыяла ясалуга күчүгә караган конденсатланган халәт физикасы өлкәсендә яңа нәтиҗәләргә ирешә. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2001), РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2004). Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Кинетика полимеризационных процессов. М., 1978 (автордаш.); Принципы создания композиционных полимерных материалов. М., 1990 (автордаш); Новые унифицированные энерго- и ресурсосберегающие высокопроизводительные технологии повышенной экологической чистоты на основе трубчатых турбулентных реакторов. М., 1996 (автордаш).

**БЕРНА́РД-ДУБЯ́ГО КОМЕ́ТАСЫ**. 1923 елның 11 октябрендә табиб Бернард (Мадрид, Испания) һәм аңа бәйсез рәвештә 1923 елның 14 октябрендә А.Д.Дубяго (Казан) тарафыннан ачыла, соңгысы хәтта аның орбитасын да исәпләп чыгара. Ачкан вакытта комета диаметры 8 почмакча минут хасил иткән түгәрәк томанлык хәлендә була. Кояш янынан узганнан соң, ул Кояш системасыннан чыгып китә.

**БЕРНО́ВЫЕ КОВАЛИ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 45 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Солонка елгасы буенда. 2002 елда 11 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шыгай исеме б-н дә билгеле. 1861 елга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Вознесение чиркәве, земство мәктәбе, 2 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 490 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июненнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1859 да — 287, 1897 дә — 436, 1920 дә — 456, 1926 да — 549, 1938 дә — 427, 1949 да — 239, 1958 дә — 142, 1979 да — 60, 1989 да — 25 кеше.

**БЕСПА́ЕВ** Хәлил Абделхак улы (15.2.1933, Казакъстан ССРның Семипалатинск өлкәсенең Күкпекте р-ны Күкпекте а.), геолог-геохимик, геол.-минералогия фән. д-ры (1984), проф. (1994). Казакъстан тау-металлургия ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), «Казолово» руда идарәсендә (Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе) эшли. 1957–64 елларда Алтай тау-металлургия фәнни-тикшеренү ин-тында (Усть-Каменогорск ш.). 1964–69 да Казакъстан ССР ФА президиумының гыйльми секретаре, академик-секретаре урынбасары, Казакъстанның Җитештерү көчләрен өйрәнү советы рәисе урынбасары. 1969 дан гыйльми секретарь, 1971 дән минералогия һәм геохимия лаб. мөдире, 1995 тән Казакъстан Респ-касы ФА һәм Фәннәр министрлыгының Геология фәннәре ин-ты директоры, 2003 тән баш фәнни хезмәткәр. Сирәк һәм затлы металлар металлогениясе һәм руда геологиясе өлкәсендә фәнни юнәлешләрне, Казакъстанның тау токымнары пр-тиеләре эшли торган р-ннарында чимал базаларын арттыру һәм минераль чималларны комплекслы куллану буенча тикшеренүләрне җитәкли. Казакъстан җыелма геол. картасын төзүче мөхәррирләрнең берсе (1996). Аның җитәкчелегендә файдалы казылмалар буенча 32 томда «Казакъстанның минераль ресурслары» белешмәлеге һәм карталар җыелмасы төзелә («Минеральные ресурсы Казахстана». Алматы, 1995–99). Б. кытай белгечләре б-н берлектә Кытай һәм Казакъстан терр-ясе чикләрендә Көньяк-Көнбатыш Алтай металлогениясен һәм геологиясен өйрәнә. «Геологик корреляциянең халыкара программасы» («Международная программа геологической корреляции» (ЮНЕСКО)) буенча фәнни тикшеренүләрдә катнаша. Казакъстан Респ-касының Дәүләт бүләге (1995) лауреаты. «Чыганакны беренче ачучы» билгесе (1997) б-н бүләкләнә.

Хезм.: Геохимия серебра сульфидных месторождений Центрального Казахстана и Рудного Алтая. А.-А., 1975 (автордаш); Геология и металлогения Юго-Западного Алтая (территория Казахстана и Китая). Алматы, 1997 (автордаш); Условия образования месторождений меди, свинца, цинка и железа. Алматы, 1999.

*Әд.:* Национальная Академия наук Республики Казахстан. Алматы, 1996.

**БЕСПА́ЛОВ** Виктор Иванович (12.8.1925, Томск ш.), кинорежиссёр, ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1976, 1984). Республикада әйдәп баручы кинорежиссёрларның берсе, документаль кинолар төшерү остасы. Хезмәт юлын 1941 елда Новосибирск шәһәрендә оборона з-дында токарь булып эшләүдән башлый. 1944 тә Новосибирскида «Красный факел» театры каршындагы студиягә укырга керә. 1944–46 да Мәскәүдә Бөтенсоюз кинематография ин-тының режиссёрлык ф-тында, 1946–49 да Новосибирск пед. ин-тының тарих ф-тында укый. 1949–60 та урта мәктәптә тарих укытучысы, Новосибирск укытучылар белемен күтәрү ин-тында класстан тыш эшләр кабинеты мөдире. 1960–70 тә Новосибирск телевидение студиясендә режиссёр, кинорежиссёр, баш режиссёр булып эшли, бер үк вакытта 1965–67 дә Югары режиссёрлар курсларында укый (Мәскәү). 1970–86 да Казан телевидение студиясендә кинорежиссёр. Төбәк үсешенең актуаль проблемаларына караган 20 дән артык док., муз. фильмнар төшерә. Б. төшергән Татарстан турындагы фильмнар сериясе («Совет Татарстаны» — «Советский Татарстан», 1970; «Республикам минем, Та-

тарстан» — «Республика моя, Татарстан», 1975; «Нефть тудырган шәһәр» — «Город, рождённый нефтью», 1983), Кама автогиганты турындагы («КамАЗ башлана» — «КамАЗ начинается», 1971; «Яр Чаллы. Комментарийлы портрет» — «Набережные Челны. Портрет с комментариями», 1979; «КамАЗ — икенче сулыш» — «КамАЗ — второе дыхание», 1980) шул заманның мөһим кинодокументлары булып тора. «Татар гармуннары» («Татарские гармошки», 1971), «Нәҗип Җиһанов музыкасы» («Музыка Назиба Жиганова», 1972), «Кырлай» (1974) фильмнары Б. ның сәнгать нечкәлекләрен, иҗатның табигатен тирәнтен аңлап эшләвен күрсәтә. Кино төшерү остасының һәр хезмәте югары профессиональлеккә, бай эчтәлек, эмоциональ тәэсир итү көченә ия. Б.ның күп кенә фильмнары СССР Дәүләт телерадиокомитеты тарафыннан халыкара алмаштыру фондына кертелә, Үзәк телевидение экраннарында күрсәтелә. Бөтенсоюз телевидение фестивальләрендә катнашып дипломнар ала. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1977).

*Ю.А.Благов.*

**БЕСПА́ЛОВА** Александра Николаевна (1.9.1924, Саратов өлкәсенең Балаков р-ны Кунья-Сарма а.), механизатор, дуңгыз караучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Авыл хуҗалыгын механикалаштыру курсларын тәмамлый (1943). 1943–53 елларда Алексеев р-ны «Красный Восток» с-зында тракторчы, 1953–79 да дуңгыз караучы булып эшли. Герой исеме хезмәттә ирешкән югары казанышлары өчен бирелә. ТАССР ЮС депутаты (1967–71). Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Алексеев р-нының Мактаулы гражданы.

*Әд.:* П у ц к о в а З. Беспалова Александра Николаевна // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**БЕССО́НИХА** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 43 *км* көнбатыштарак, Вятка елгасыннан 2 *км* читтә. 2002 елда 24 кеше (руслар) яши. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 287,3 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Красная Горка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Мамадыш, 1958 нең 19 июленнән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 117, 1897 дә — 186, 1908 дә — 259, 1920 дә — 226, 1926 да — 249, 1938 дә — 222, 1949 да — 182, 1958 дә — 144, 1970 тә — 81, 1979 да — 35, 1989 да — 25 кеше.

**БЕССО́НОВ** Александр Григорьевич (1848, Вятка ш. — 1917), тел галиме, этнограф, татар һәм башкорт әкиятләрен җыючы. Казан һәм Оренбург уку йортларында укыта. Хезмәтләре төрки халыклар филологиясенә, фольклорына һәм этнографиясенә карый. Б. Урал буе халыклары фольклорын җыйган беренче күренекле галим. Б. диалектологиягә караган хезмәтләрендә, зур фактик материалга таянып, татар теленең диалектлар системасындагы сөйләшләренең урынын билгели. Рус геогр. җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1909), Екатеринбург табигать белемен сөючеләр җәмгыяте әгъзасы.

Х е з м.: О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам. К., 1881.

*Әд.:* Җ а м а л е т д и н о в Л. Алтын медальле әкиятләр // Социалистик Татарстан. 1983. 29 апр.

*Д.Б.Рамазанова.*

**БЕССО́НОВ** Иннокентий Платонович (21.9.1814, Иркутск губ. Енисейск ш. — 1863 елдан соң), архитектор, архит-ра академигы (1844). 1836 елда Петербург сынлы сәнгать академиясен тәмамлый. 1837–63 тә Казан губернасы архитекторы. Бер үк вакытта Казан уку-укыту округы архитекторы. Б. проектлары б-н Казанда Икенче ир балалар гимназиясе (1847), ун-тның иске клиникасы (М.П.Коринфский проектын үзгәртә, 1848), «Гостиный двор» (1847, арх. Х.В.Крамп б-н берлектә) бинаалары үзгәртеп корыла, Никола-Вешняковский (1849–53, арх. А.К.Ломан б-н берлектә) һәм Никола чиркәүләре,








И.П.Б е с с о н о в. 1. Икенче ир балалар гимназиясе бинасы. Казан. Реконструкция. 1847; 2. Университетның иске клиникасы. 1848.

Спас-Преображение монастыре манарасы (1858), торак йортлар төзелә. 1845–53 тә шәһәр театры төзелешенә җитәкчелек итә. Классицизмның соңгы дәвере һәм эклектика юнәлешендә эшли.

Х е з м.: О разных породах строительного леса, находящегося в Казанской губернии и способы потребления его в дело // Зап. Имп. Казан. экон. об-ва. 1854. Ч. 2, кн.5.

*Әд.:* М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999. *Л.М.Мортазина.*

**БЕССО́НОВА** Людмила Александровна (24.6.1946, Чиләбе өлкәсенең Агапов р-ны Магнитогорск а.х. тәҗрибә станциясе пос.),



В.И. Беспалов.



А.Н. Беспалова.

философ, филос. фән. д-ры (1998), проф. (2002). Чиләбе пед. ин-тын тәмамлый (1968). 1968–84 елларда Чиләбе өлкәсе Кыштым шәһәренең урта һәм махсус урта белем бирү уку йортларында укыта. 1984–2000 дә Глазов пед. ин-тында эшли, 1996–98 дә пед. ф-ты деканы, 1998 елдан филос. каф. мөдире. 2000 нән Татарстанның Бизнеска булышлык итү ин-тында филос. каф. мөдире. Төп хезмәтләре фәлсәфи антропологиягә һәм аң фәлсәфәсенә карый.

Х е з м.: Мистицизм: истоки, проблемы, реалии. М., 1997; Мистицизм как феномен культуры. М., 1998.

**БЕССО́НОВО** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 42 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов өлкәсе чигендә. 2002 елда 222 кеше (мордвалар — 67%) яши. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 1678 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балта эше, йон эрләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәктәп, берничә йон эрләү остаханәсе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2107,5 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Ундора волостена керә. 1939 нең мартында, Куйбышев өлкәсеннән алынып, ТАССРның Олы Тархан р-нына бирелә. 1959 ның 12 октябреннән — Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 1043, 1910 да — 1983, 1949 да — 1028, 1958 дә — 842, 1970 тә — 532, 1979 да — 364, 1989 да — 235 кеше.

**БЕСТУ́ЖЕВ ТОКЫМЛЫ́ МӨГЕЗЛЕ́ ЭРЕ́ ТЕРЛЕ́К**, 18 йөз ахыры — 19 йөз башында Сембер губернасында (хәзерге Ульянов өлкәсе) С.П.Бестужев тарафыннан шортгор, голланд, симменталь һ.б. токымнарны җирле токым б-н кушылдырып, яңа токым чыгарыла. Эре, озынча буйлы, таза гәүдәле, нык сөякле терлек. Б.т.м.э.т. Татарстанда, Башкортстанда, Самара һәм Ульянов өлкәләрендә күпләп асрала. Терлекләр ачык кызыл һәм карасу кызылның төрле төсмерләрендә. Гәүдәсенең аскы өлешендә, имчәк һәм маңгайда ак төстәге тамгалары очрый. Үгезләр 750–900, сыерлар 500–550 *кг* авырлыкта. 3000–4500 *кг* сөт савып алына, сөтнең майлылыгы — 3,8 — 4,1%. Тиз үсеп җитүче токым. Симертү чорында яшь үгезләр, 1 *кг* артымга 8 — 8,6 азык берәмлеге сарыф итеп, тәүлеккә 700–850 *г* арта. Сугым терлегеннән 60% ит алына. 1970–80 елларда ТР хуҗалыкларындагы барлык терлекнең 29% ын Б.т.м.э.т. тәш-



Бестужев токымлы мөгезле эре терлек.

кил итә. 2000 елның 1 гыйнварына Б.т.м.э.т.ләр саны 9,5 мең баш (2,6%). 2005 тән алып бу токым Татарстанда үрчетелми, аны яхшырак саналган айршир һәм голштин токымнары алыштыра.

*Әд.:* Эрнст Л.К., Дмитриев Н.Г., Ларонян И.А. Генетические ресурсы сельскохозяйственных животных в России и сопредельных странах. СПб., 1994; Дунин И.М., Карамаев С.В., Зимин Г.Я. Совершенствование бестужевского скота. М., 1998.

*Р.А.Хәертдинов.*

**БЕ́ТЕВ** Пётр Павлович (21.12.1926, хәзерге Казакъстан Респ-касы Петропавловск ш. — 26.3.2002, Казан), драма актёры, РСФСР-ның халык артисты (1983). 1945–51 елларда Кемерово өлкәсенең Анжеро-Судженск шәһәре театры каршындагы студиядә укый, бер үк вакытта шул театрда эшли. 1951–53 тә Ачинск шәһәре театрында, 1953–65 тә Кемерово, 1965–66 да Тамбов өлкәсе драма театрларында, 1966–2002 дә Казан Зур драма театрында актёр. Казан сәхнәсендә рус һәм дөнья классикасыннан, хәзерге заман драматургиясеннән 90 нан артык роль башкара. Үткән сатирик характердагы персонажларны чагылдырган социаль портретлар тудыру остасы: Победоносиков («Мунча», В.Маяковский, 1967), Нуретдин («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин, 1969), Мамаев («Акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский, 1977), Варравин («Эш», А.В.Сухово-Кобылин, 1986). Б. барыннан да элек үз герое характерының эчке чын халәтен, аның тирә-юньне, дөньяны ничек аңлавын күрсәтергә омтыла. Максим Петров («Традицион җыен», В.С.Розов, 1967), Шохин («Зыковлар», М.Горький, 1968), Карт («Көйсезләнгән сәфәр», А.Гыйләҗев, 1977), Табунов («Карагыз, кем килгән!», В.К.Арро, 1983) образларын тудырганда, гәүдәләндерү чараларын үтә аз, әмма оста кулланып, рухи дөньясын тулысы б-н ачуга ирешә. Классик драматургия образлары өстендә эшләгәндә, геройның үз-үзен тотышындагы тирән тамырларны эзләп табу, актёрга бу образларны заманга якынайту, тамашачыга аңлаешлы итү мөмкинлеге бирә: Молоков («Төшемле урында», Д.Н.Мамин-Сибиряк, 1970), Дулебов («Талантлар һәм аларга табынучылар», 1974), Дудукин («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский, 1981), Павел Петрович Кирсанов («Аталар һәм балалар», И.С.Тургенев, 1979), Редозубов («Варварлар», 1972), Иван Коломийцев («Соңгылар», М.Горький, 1983), герцог Норфолк («Һәр заман кешесе», Р.Болт, 1986), Джордж Талбот («Мария Стюарт», Ф.Шиллер, 1990) — моның ачык мисаллары. Замандашлар рольләрен башкарганда Б. аларның төрлелеген, язмышларының катлаулылыгын, рухи байлыгын һәм эчкерсезлеген күрсәтергә омтыла. Григорий («Безнең бурычлар», Э.Я.Володарский, 1973), Архипов («Ил гизүләр», А.Н.Арбузов, 1974), Воронин («Разведчик Шиловның соңгы эше», В.Черных, 1979), Хлынков («Имеш-мимешләр», А.Д.Салынский, 1981), Грохотало («Ак таулар турында төш», В.П.Астафьев, 1982) образларында Б. катлаулы язмышларны гәүдәләндерә. Кронштадт матросы Расколупа («Ике яңгыр арасында», А.П.Штейн, 1969) һәм Алып баручы («Беренче атлы армия», В.В.Вишневский, 1970) образларында аерым кеше язмышы б-н ил язмышының аерылгысызлыгы аеруча ачык һәм ышандырырлык итеп бирелә. Актёрның иҗат палитрасына төсләрнең күптөрлелеге хас: тирән психологизм, кырыс тотнаклылык, хискә бай темперамент, нечкә лиризм, йомшак юмор — бу сыйфатлар җыелмасы образларга күп мәгънәлелек, олпатлык бирә: Ипполит («Бервакыт Яңа ел кичендә», Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов, 1969), Самсонов («Яр», Ю.В.Бондарев, 1979), Эфраим Кэбот («Карамалар төбендәге мәхәббәт», Ю.О́Нил, 1982), Либеро Бокка («Күзгә вакыйга», А.Николаи, 1992).



П.П. Бетев.



П.П.Бетев: 1. Максим Петров (В.С. Розов, «Традицион җыен»); 2. Победоносиков, сулда — П.С. Маслов (В.В. Маяковский, «Мунча») рольләрендә.

*Әд.:* Путинцев И. Три роли Петра Бетева // Театральная жизнь. 1960. № 17; Ингвар И., Иляловa И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**БЕТЛӘ́Р** (Anoplura, яки Siphunculata), имезүчеләрдә паразитлык итүче ялган хортумлылар отряды. 200 ләп төре билгеле, Татарстанда 8 төре тасвирланган. Гәүдәсе ромбсыман, зурлыгы 2,5 тән алып 5 *мм* га кадәр, тыгыз, саргылт-соры төстә; баш, күкрәк һәм корсак өлешләренә бүленә. Күкрәгендә хәрәкәтчел тырнаклы өч пар кыска аяклары бар. Авыз аппараты тирене тишеп суыруга җайлашкан. Б.нең төкерек бизләре бүлентеләре кеше һәм хайваннарда кан оешуны тоткарлый. Тулы булмаган әверелеш юлы б-н үсә торган бөҗәкләр. Ана Б. тәүлегенә 3 тән алып 15 кә кадәр, ә үз гомеренә (1,5 айга кадәр) барлыгы 50 дән алып 350 гә кадәр йомырка (серкә) сала. Кеше тәнендә 3 төре паразитлык итә, кием Б. (Pediculus vestimenti), баш Б. (P. capitis) һәм касык Б. яки площица (Phthirius inguinalis). Б. тешләгән урын кычыта, кашу нәтиҗәсендә тире тупаслана, үлекли. Б. — паразитар тиф, волын яки траншея бизгәге, түләрәмә авыруларын таратучылар.

*Әд.:* Павловский Е.Н. Руководство по паразитологии человека. М.–Л., 1948; Соснина Е.Ф. Итоги изучения вшей в Волжско-Камском крае // Материалы итоговой науч. конф. зоологов ВКК. К., 1970.

*В.А.Бойко.*

**БЕТО́Н** (фр. bêton), ташлы ясалма композицион төзелеш материалы, үзле матдә, гадәттә, цемент б-н катнашкан тутырылмалардан тора. Катнашма, әзер булганчы, бетон катнашмасы дип атала. Составы Б.ның үзлегенә карата куелган таләпләргә туры килә. Б. үзлекләрен көйләү һәм бәйләүче үзле матдәләрне экономияләү өчен өстәмәләр кулланыла: пластифик, стабильләштерүче, һава тотучы, күбек, газ булдыручы, кату вакытын көйләүче, тыгызлаучы, киңәйтүче, тутыгудан саклаучы, суны этәрүче, буяучы, бактерицид, инсектицид, вакланган минераль матдәләр. Җыелма тимер-бетон һәм бетон җыелма детальләр, блоклар, панельләр һ.б. әйберләр, ш.у. җыелма монолит, монолит тимер-бетон һәм бетон корылмалар әзерләүдә киң кулланыла. ТРда тыгызлыгы 2100–2400 $кг/м^3$ булган авыр Б., тыгызлыгы 500–1800 $кг/м^3$ лы җиңел Б. (газобетон, күбекле бетон, керамзитлы бетон), тыгызлыгы 2100–2300 $кг/м^3$ лы асфальт-бетон җитештерелә. Б. җитештерүче төзелеш материаллары пр-тиеләре Казанда, Чаллы, Әлмәт, Зәй, Алабуга, Бөгелмәдә эшли. Б. җитештерү күләме 1960 да — 412, 1970 тә — 876, 1980 дә — 1354, 1991 дә — 2390, 1995 тә — 1030, 1999 да — 610 мең $м^3$.

*Әд.:* Микульский В.Г. Строительные материалы. М., 1996.

**«БЕТСЕ́Н НАДАНЛЫ́К»**, газета. РСФСР Мәгариф халык комис-тының Татар-башкорт бюросы каршындагы наданлыкны бетерү буенча Бөтенроссия гадәттән тыш ко-


миссиясе органы. 1925–27 елларда Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә.

**БЕХ** Николай Иванович (2.1.1946, Украина ССРның Житомир өлкәсе Коростень ш.), металлург, «КамАЗ» АҖнең президенты, ген. директоры (1991–97), техник фән. канд. (1992). Киев политехника ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), Волжск автомобиль з-дында эшли (Тольятти ш.): металлургия производствосында инженер-технолог, бюро башлыгы, бүлек башлыгы урынбасары, баш инженер. 1980–84 елларда «КамАЗ» җитештерү берләшмәсенең Кама кою з-дында директор. 1984–87 дә «Кама трактор заводы» җитештерү берләшмәсендә ген. директор (Алабуга ш.). 1987–91 дә «КамАЗ» АҖдә ген. директор. Аның катнашында КамАЗның кою з-дында чүкелгән чуенны алыштырырлык модификацияле югары чыдамлылыклы чуен үзләштерелә; вермикуляр графитлы чуеннар эшләнә. Аның җитәкчелегендә КамАЗ автомобильләре техник яктан камилләшә, аз литражлы «Ока» автомобильләрен җитештерү оештырыла. 1997 елдан Мәскәүдә эшли һәм яши. 40 тан артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты, 1989–91 дә СССР халык депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Высокопрочный чугун в автомобилестроении. М., 1988 (автордаш).

**БЕ́ХТЕРЕВ** (Саралы) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 9 *км* төньяктарак, Көрен елгасы буенда. 2002 елда 712 кеше (руслар — 71%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1929 ның 27 маена кадәр — Саралы, рев-циягә кадәрге чыганакларда Введеньевский исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, киез итек басу, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1800 — 10 елларда Петропавел чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 5648,6 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Трёхсвятский волостена керә. 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга р-нында. Халык саны: 1887 дә — 1303, 1926 да — 1288, 1958 дә — 452, 1970 тә — 484, 1979 да — 524, 1989 да — 497 кеше. Атаклы рус неврологы һәм психиатры В.М.*Бехтерев* туган авыл.

**БЕ́ХТЕРЕВ** Владимир Михайлович (20.1.1857, Вятка губ., Саралы а., хәзер ТРның Алабуга р-ны Бехтерев а. — 24.12.1927, Мәскәү), невропатолог, психиатр, психолог, физиолог, морфолог, җәмәгать эшлеклесе, мед. д-ры (1881). Россия психиатрлары мәктәбенә нигез салучы, эксперименталь һәм клиник психол. өлкәсендәге тикшеренүләрне башлап җибәрүче. 1878 елда Петербург мед. академиясен тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1882 елдан Германиядә стажировка үтә. 1885–93 тә Казан ун-тында профессор, психиатрия каф. мөдире. 1893 тән С.-Петербургта, Хәрби-мед. академиясендә, 1897 дән Женева мед. ин-ты профессоры, 1908 дән үзе оештырган Психоневрология ин-ты директоры; 1918 дә үз тырышлыгы б-н оештырылган Баш мие һәм психик эшчәнлекне өйрәнү ин-тын (соңрак Бехтерев исем. Баш миен өйрәнү дәүләт рефлексология ин-ты) җитәкли. Казанда төбәк психиатрия хастаханәсе каршында акылга зәгыйфьләр клиникасы, бер үк вакытта Россиядә беренче психофизиологик лаб. оештыра, анда физиолог *Н.А.Миславский* б-н берлектә баш миенең төрле өлешләре функцияләрен тикшерү б-н шөгыльләнә. 1882 дә Казан невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыятенә, «Неврологический вестник» ж-лына нигез сала. Б.ның иң мөһим хезмәтләре ми кабыгы үзәкләренең йөрәк иннервациясенә, тамырларга, ашказанына һ.б. эчке әгъзаларга тәэсирен ачыклаудан, организмдагы вегетатив процессларның ми кабыгы тарафыннан көйләнүен эксперименталь өйрәнүдән, үзәк нерв системасын анатомик һәм физиол. тикшеренүләрдән гыйбарәт. Бромидлар һәм адонис кушылган микстура — *Бехтерев микстурасын* тәкъдим итә. Б. хезмәтләренең үзәгенә кеше проблемасы куелган, бу мәсьәләне хәл итүне ул баш мие эшчәнлеген өйрәнгәндә, анатомия, физиол. һәм психол. чаралары комплексына нигезләнеп, кеше шәхесе тәгълиматын төзүдә күрә; кеше тәрбияләүне һәм аның тормышындагы аномалияләрне чишүне шушы тәгълиматка таянып алып баруны күздә тота. Шулай эшләгәндә кеше һәм җәмгыять турында комплекслы фән — рефлексология фәне формалашырга тиеш була. Б.ның фәнни мирасында җенси тәрбия, яшь балаларның холкы, ш.у. гипнозның тәэсир итү көче турындагы хезмәтләре мөһим урын алып тора. Б. арка һәм баш миенең үткәргеч юлларын ача; тирә-юньдә тотрыклылык һәм ориентлашуның анатомик-физиол. нигезләрен, күрү, хәрәкәтләнү үзәгенең һәм эчке әгъзалар бизләренең функцияләрен ачыклый. Баш миендә фәндә моңарчы билгеле булмаган катламнарны беренче булып тасвирлый, нерв авыруларына диагноз куйганда мөһим үзенчәлекле рефлекс, симптом, синдромнарның тышкы билгеләрен күрсәтә һәм шул чирләрне дәвалау ысулларын эшли. 600 гә якын басма хезмәт калдыра, аларның күбесе чит телләргә тәрҗемә ителә һәм дөньякүләм танылa. Казан шәһәренең бер урамына Б. исеме бирелә, анда Б.ның бюсты куела, ш.у. аның исемендәге клиника бар. Алабуга шәһәрендә Б.ка һәйкәл куела (2007).



В.М. Бехтерев.


Х е з м.: Основы учения о функциях мозга: В 7 т. СПб., 1903–07; Объективная психология: В 3 т. СПб., 1907–10; Общая диагностика болезней нервной системы: В 2 ч. СПб.,1921. Общие основы рефлексологии человека. М.-П., 1923.

*Әд.:* О с и п о в В.П. В.М.Бехтерев. М., 1947; М я с и щ е в В.Н. К 100-летию со дня рождения В.М.Бехтерева (1857–1957) // Журн. неврологии и психиатрии им. Корсакова. 1959. Т. 57, вып. 1; История советской психологии. М., 1967.

*Д.М.Менделевич.*

**БЕ́ХТЕРЕВ В.М. ҺӘЙКӘ́Л-БЮСТЫ́**, Казанда. 2005 елның 24 августында Волков урамындагы бинага психиатрлар фәнни мәктәбен нигезләүче күренекле рус галиме истәлегенә куела. Авторлары — скульптор М.М.Гасыймов, арх. Г.А.Бакулин.

Галим-табибкә соклану хисләре тәэсирендә сынчы аның куәтле интеллектуаль көчен һәм үткен акылын ачып биргән. Зурайтылган сын калыбында В.М.*Бехтеревның* характер үзенчәлекләре, аның күпьяклы шәхес булуы чагыла, рух күтәренкелеге һәм образның монументаль бөеклеге сиземләнә. Бюст дүрткырлы биек постаментта, йөзе б-н Бехтеревның актив катнашында оештырылган психоневрология хастаханәсе бинасына каратып урнаштырылган.



Бехтерев В.М. һәйкәл-бюсты. Казан. 2005. Скульптор М.М.Гасыймов. Арх. Г.А. Бакулин.


*А.И.Новицкий.*

**БЕ́ХТЕРЕВ МИКСТУ́РАСЫ**, тынычландыру өчен кулланыла торган дару препараты. В.М.*Бехтерев* эпилепсияне дәвалау өчен тәкъдим итә. Язгы янар чәчәк (Adonis vernalis) үләненнән әзерләнгән төнәтмә, натрий (калий) бромиды һәм кодеинфосфат катнашмаларыннан тора. Неврозлар, неврастения, истерия, йокысызлык, гипертония, хорей һ.б. нерв авыруларын дәвалаганда кулланыла.

*Әд.:* Краткая медицинская энциклопедия. М., 1972. Т. 1.

**БЕ́ХТЕРЕВ КЕРАМЗИ́Т БАЛЧЫКЛАРЫ́ ЧЫГАНАГЫ́**, Алабуга р-нының Бехтерев авылы янында. 1953 елдан нефть бораулау эшләре ихтыяҗларында эшкәртелә башлый. Сәнәгать запаслары 3,0 млн. *т* дан артык (2007). Өске катлам токымнарының калынлыгы — 1,3 — 5,1 *м* (урт. 2 *м*), файдалы катлам — 2 — 17 *м* (урт. 8,3 *м*); вак дисперслы балчыкта $SiO_2$ — 54,34 %, $Al_2O_3$ — 24,03 % һ.б. Сыгылмалылыгы югары (1 нче класс), күләмчә авырлыгы — 1,81–1,9 *г/см*³, чагыштырма авырлыгы 2,8–2,85 *г/см*³. Соң неоген яшендәге балчыклар бораулау измәләре әзерләү һәм керамзит җитештерү өчен яраклы. Б.к.б.ч. — *Биклән бентонит балчыклар чыганагының* резерв базасы булып тора.

**БЕ́ЧКО-ДРУ́ЗИН** Владимир Кузьмич (1824 — 23.4.1898, Казан), архитектор. 1841–49 елларда Петербург төзелеш уч-щесендә укый. 1849 елдан Казан төзелеш һәм юл комиссиясендә архитектор ярдәмчесе. 1863–98 дә Казан уку-укыту округы архитекторы. Бер үк вакытта 1882–94 тә Казан шәһәре архитекторы вазифаларын башкара, 1882–94 тә Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты архитекторы, бер үк вакытта 1885–86 да Казан ун-ты архитекторы. Эклектика юнәлешендә эшли. Б.-Д. проектлары б-н Казанда керәшен татарларның Үзәк мәктәбе (1870–71), укытучылар семинариясе (1871–72), Д.Д.Лисицин кибетләре (1872),



В.К.Бечко-Друзин. Д.Д.Лисицин кибетләре. Казан. 1872.

Икенче ир балалар гимназиясенең чиркәүле янкормасы (1874), Н.М.Мельников (1875), Перимов (1879), А.М.Ямбикова (1889) йортлары, үз йорты (1881), Алабуга шәһәрендә реаль (1882) һәм удел (1888, үзгәртеп кору) уч-щеләре биналары һ.б. төзелә.



В.К.Бечко-Друзин. Икенче ир балалар гимназиясенә чиркәү белән янкорма. Казан. 1874.

1867 дән Казан икътисад җәмгыяте, 1898 дән Казандагы ярлыларга ярдәм итү җәмгыяте идарәсе әгъзасы.

*Әд.:* Муртазина Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999. *Л.М.Мортазина.*

**БЕ́ЧКО-ДРУ́ЗИН** Степан Владимирович (20.7.1860, Казан — ?), архитектор, инженер. 1890 елда Петербург гражданлык инженерлары ин-тын тәмамлый. 1890–98 дә Казан





С.В.Бечко-Друзин. 1. С.М.Марко йорты. Казан. 1906; 2. Беренче ир балалар гимназиясе бинасы. Чистай шәһәре, 1908–09.

земство управасы инженеры. Бер үк вакытта Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында (1894–95), Дары з-дында (1896–1900), Казан уку-укыту округында (1898–1917) архитектор булып эшли. 1914 тән техник фәннәр укыта, 1918 дән Казан сәнәгать уч-щесенең төзелеш инженерлары ф-тында декан, 1922 дән политехника ин-тында, 1927 дән индустриаль техникумда эшли. Б.-Д. проектлары б-н Түбән Осланда чиркәү (1899) һәм Сергей Радонежский чиркәве янкормалары (1907–08), Казанда С.М.Марко йорты (1906) һәм сәнәгать уч-щесе бинасы (1899–1900), Чистайдагы Беренче ир балалар гимназиясе бинасы, тегермән комплексы (1902–13), Тәтештә хатын-кызлар гимназиясе бинасы (1907), торак йортлар һ.б. төзелә. Эклектика, неоклассицизм, модерн юнәлешләрендә эшли.

*Әд.:* Муртазина Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999. *Л.М.Мортазина.*

**БЁРШ** (Stizostedion volgensis), с у л а, алабугасыманнар семьялыгыннан судаклар ыругы балыгы. Каспий, Азов һәм Кара диңгез бассейннарында, ТРда Зөя, Кама, Мишә һ.б. елгаларда, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында очрый. Озынлыгы — 25–45 *см*, авырлыгы 250 *г* нан 1,4 *кг* га кадәр. Тышкы кыяфәте б-н судак балыгына бик охшаган, ләкин казык тешләре булмавы, саңак һәм «яңаклары» вак кытыршы тәңкәле булуы б-н (судакныкы бөтенләй шәрә) аерылып тора. Җенси өлгерү вакыты 3 нче яки 4 нче елга туры килә. Апрель ахырыннан майга кадәр агым суда уылдык чәчә. Башлыча, вак балык һәм кысласыманнар б-н туклана. Промысел балыгы.

**БИ**, к. *Бәк.*

**БИ КҮЛЕ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2002 елда 790 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп.Мәдәният йорты. Китапханә. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Абдрахманово, Абдрахманово Степное, Биляр Озеро исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, бөгеп мебель ясау, кәрзин үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 җәмигъ мәчет (3 нче җәмигъ мәчетнең 1905–06 да төзелгән бинасы сакланылган; архит-ра истәлеге. Хәзер дә эшли), 2 мәдрәсә, җил тегермәне, 2 ярмаяргыч, 6 вак-төяк-ләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2109 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир заты; 1897 дә — 1823, 1908 дә — 2151, 1920 дә — 2472, 1926 да — 1045, 1938 дә — 1055, 1949 да — 882, 1958 дә — 947, 1970 тә — 1302, 1979 да — 1200, 1989 да — 785 кеше.

**БИА́РМИЯ** (Бьярмия), Көнчыгыш Европаның төньяк-көнчыгышындагы тарихи өлкә. 9–13 йөзләргә караган Скандинавия илләре язма һәм дастани чыганакларыннан мәгълүм (сагалар, географик һ.б. төр хезмәтләр).

Б. җире затлы җәнлек тиреләре, күннәр, көмеш, мамонт һәм морж тешләре-мыеклары б-н сәүдә итү урыны саналган. Скандинавия викингларының анда ауга һәм яуга баруы да әйтелә. Б. халкы, башлыча, ау һәм балык тоту б-н шөгыльләнгән. Б. җиренең төгәл урыны билгеле түгел. Кайбер галимнәр (С.К.Кузнецов, М.И.Фасмер, Т.Н.Джаксон) аны Ак диңгезнең көнбатыш яр буйларында, икенчеләре (Д.В.Бубрих, И.П.Шаскольский) Ладога күле б-н Карелия тирәсендә урнашкан дип язалар; Кама елгасы буендагы (К.Вилкуна) яки Идел буе Болгары чикләренә якын җирдәге өлкә, диючеләр дә (Э.Квален, М.З.Зәкиев) бар. А.Тальгрен, А.И.Попов, Е.А.Мельникова, Г.В.Глазырина Б. биләмәсен Двина һәм Ак диңгез буйларындагы җирләрнең бер өлкәсе б-н тиңлиләр. Б. атамасының килеп чыгышына карата да төрле фикер йөри: Д.В.Бубрих, К.Вилкуна, В.В.Пименов аны фин сүзе «permaa»дан («арткы җир», «чит өлкә»), башкалар фин телендәге permi сүзеннән (күчеп йөрүче карел сәүдәгәре) барлыкка килгән дип саныйлар.

Чыг.: Снорри Стурлусон. Круг земной. М., 1980; Мельникова Е.А. Древнескандинавские географические сочинения. М., 1986; Джаксон Т.Н. Исландские королевские саги о Восточной Европе (с древнейших времён до 1000 г.). М., 1993; Глазырина Г.В. Исландские викингские саги о Северной Руси. М., 1996.

*Әд.:* Кузнецов С.К. К вопросу о Биармии // Этнографическое обозрение. 1905. № 2–3; Тиандер К.Ф. Поездки скандинавов в Белое море. СПб., 1906; Рыдзевская Е.А. Древняя Русь и

Скандинавия в IX–XIV вв. М., 1978; Д ж а к с о н Т.Н., Г л а з ы р и н а Г.В. Русский Север в древнескандинавской письменности: локализация Бьярмии. XVIII–XIX вв. // История и культура Архангельского Севера: Досоветский период. Вологда, 1986; З а к и е в М.З. Татары. Проблемы истории и языка. К., 1995; T a l l g r e n A.M. Biarmia // Eurasia Septentrionalis Antiqua. Helsinki, 1931. Vol. 16.

*И.Л.Измайлов.*

**БИБА́Й ЧАЛЛЫСЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Актай елгасының уң кушылдыгы Чаллы суы буенда. 2002 елда 155 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Клуб. 17 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Татар Бибай Чаллысы, Бизәй Чаллысы исемнәре б-н дә билгеле. 18 – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.Ч.нда мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1269,4 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Спас өязе Рамодан волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Спас кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 67 ир заты; 1859 да — 432, 1897 дә — 671, 1908 дә — 674, 1920 дә — 813, 1926 да — 648, 1938 дә — 547, 1949 да — 462, 1958 дә — 442, 1970 тә — 434, 1979 да — 348, 1989 да — 189 кеше.

**БИБИГӨЛҖАМА́Л** (19 йөз), шагыйрә. Кайбер мәгълүматларга караганда, Б. — билгесез бер шагыйрьнең псевдонимы. Иҗаты аз өйрәнелгән. Проза катыш шигъри формада язылып, эчтәлеге б-н «Таһир илә Зөһрә» дастаны сюжетын хәтерләткән һәм шигъри юлларында халык авыз иҗаты үрнәкләре (мәхәббәт җырлары, хатлар) киң файдаланылган «Бигайәте мәгъшукнамә» («Чиксез гашыйклык китабы») исемле әсәр авторы. 1888–1915 еллар арасында әсәрнең бик күп басмалары дөнья күрә.

Ә с ә р.: Бигайәте мәгъшукнамә. К., 1888.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Я х и н Ф. XIX гасыр кыйссасы «Бидгать-намә» // Әдәби мирас. К., 1996. 3 кит.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БИ́БИКОВ** Илья Богданович (1738 — 25.2.1805), дәүләт һәм хәрби эшлекле, генерал-поручик (1786), тайный советник, сенатор (1792). 1754 елдан хәрби хезмәттә; Җиделлык (1756–63) һәм рус-төрек (1768–74) сугышларында катнаша. 1780–83 елларда Казан губернаторы. 1782 елгы чума авыруы вакытында Казан губернасы халкына мед. ярдәме күрсәтүне оештыра. Аның идарәсе чорында Казанда «Әмирхания» мәдрәсәсе (1780), Татар ратушасы (1781) ачыла, Мамадыш, Спас һәм Чистай шәһәрләр рәтенә кертелә (1781). Губерна Казан наместниклыгы итеп үзгәртелә (1782), дәүләт идарәләре һәм оешмаларында шуңа бәйле үзгәрешләр үткәрелә. 1784–90 елларда Новгород-Северск



И.Б. Бибиков.

наместниклыгы идарәчесе. 1792–98 дә һәм 1801 елдан Сенатның 6 нчы департаментында хезмәт итә.

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Российская родословная книга. СПб., 1857. Ч. 4.

*Е.Б.Долгов.*

**БИ́БИШЕВ** Марат Шакир улы (14.2.1929, Сарман р-нының Нөркәй а.), төзүче-инженер, «Чаллы шәһәр төзелеше» проект-төзелеш берләшмәсендә ген. директор (1973–94), ТАССР, РФнең атказ. төзүчесе (1983, 1994). РФ Архитекторлар берлеге әгъзасы (1983). Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1952). 1952–73 елларда Якутск, Әлмәт, Зәй, Алабуга шәһәрләренең төзелеш оешмаларында эшли. Аның җитәкчелегендә «Чаллы шәһәр төзелеше» берләшмәсе Чаллы, Алабуга, Казан шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Кама Аланы посёлогында һәм авыл районнарында 6,5 млн. $м^2$ дан артык торак йорт, социаль-мәдәни биналар, гыйбадәтханәләр төзи. Блок-секцияләрдән торган 100 модификациядән дә артык торак биналар төзү үзләштерелә. Аның катнашында җитештерү-технол. комплектлаштыру базасы — йортлар төзү конвейеры булдырыла. 1994 елдан «ЭКАФ» эксперт-бәяләү фирмасы ген. директоры (Чаллы ш.). Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. СССР МС бүләге лауреаты (1976). Ленин, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Механизация работ на строительстве жилых домов // Механизация стр-ва. 1980. № 5; Опыт работы Набережночелнинского ДСК // Энергетическое стр-во. 1982. № 9; Снижение межзерновой пористости керамзитобетона // Жилищное стр-во. 1986, № 6 (автордаш).

*Әд.:* Челнинские известия. 1994. 24 февр.; Чаллы-йорт. Память пламенных лет. Наб. Челны. 1998.

**БИБЛИОГРА́ФИЯ БЕЛЕМЕ́**, библиографик эшчәнлек турындагы белем (библиография төзү, библиографик хезмәт күрсәтү, библиография б-н шөгыльләнүче оешмалар эшчәнлеге). Китапханәче кадрлар әзерли торган уку йортларындагы төп фәннәрнең берсе. Татарстанда библиография эшенең үсеше П.П.Васильев, Ф.М.Суворов, Е.И.Шамурин, Ә.Г.Кәримуллин исемнәре б-н бәйле. Бу эш б-н *Татарстан Республикасы Китап палатасы* хезмәткәрләре, китап сөючеләр (к. *«Китап дуслары» түгәрәге*) шөгыльләнә. Б.б.нең алга таба үсешенә 1969 елда Казанда Ленинград мәдәният ин-тының ф-лы ачылу (хәзер Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты) һәм Ә.Г.Кәримуллинның бу өлкәдәге хезмәтләре зур этәргеч ясый.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Библиографическая работа библиотеки Казанского университета // Советская библиогр. 1955. Вып. 40; К о р ш у н о в О.П. Библиографоведение: Общ. курс. М., 1990; С а ф и у л л и н а З.А. Тестовая библиотечно-библиографическая диагностика читателей. М., 1994; Д у н а е в а Т.Г. Проблемы национальной библиографии. К., 1995.

**БИ́БЛИЯ** (борынгы грек. biblı́a — китап), яһүди һәм христиан диннәрендә Изге Китап сыйфатында канунлаштырылган борынгы язмалар җыентыгы. Ислам Б.не Изге Китап буларак таный, ләкин аңа мөрәҗәгать итми. Б. Иске Гаһед (Ветхий Завет) һәм Яңа Гаһед (Новый Завет) дип аталган ике өлештән тора. Беренчесе христиан дине барлыкка килгәнче үк язылган китапларны берләштерә, ул б.э.к. 3 йөздә формалашып җитә. Иске Гаһед 3 бүлектән гыйбарәт. «Канун» (яһүдчә — Тора) дип аталган беренче бүлеккә Муса пәйгамбәрнең 5 китабы, икенче — «Язмалар» («Писания») бүлегенә яһүд халкының борынгы тарихын бәян итүче 13 китап керә, өченче — «Зәбур» («Псалтырь») бүлегендә христианнарда һәм яһүдиләрдә гыйбадәт кылуның мөһим бер өлеше булып торган дини шигырьләр тупланган. Иске Гаһед унбер яһүд пәйгамбәренең ачышлары бәян ителгән «Пәйгамбәрләр» китабы б-н йомгаклана. Яһүдиләр Иске Гаһеднең яһүд телендәге текстын изге дип саныйлар. Христианнар исә б.э.к. 2 йөздә Александрия шәһәрендә тәрҗемә ителгән грек телендәге текстны (аның төзелеше һәм тексты яһүдиләрнекеннән бераз аерыла) кануни дип таныйлар. Иске Гаһед латин, борынгы славян һ.б. телләргә нәкъ менә грек теленнән тәрҗемә ителә. Яңа Гаһед фәкать христианнарда гына изге булып санала. Ул 27 китаптан — Гайсанең тормышы һәм тәгълиматы, Изге Хәвариюннар (апостоллар) гамәлләре бәян ителгән 4 Инҗилдән (Евангелие; мәгънәсе — «изге хәбәр»), Хәвариюннарның 21 хатыннан һәм Иоанн Богослов ачышыннан гыйбарәт. Яңа Гаһеднең тексты грек телендә язылган.

Рус православие чиркәве Б.нең 9 йөздә Кирилл һәм Мефодий тарафыннан тәрҗемә ителгән борынгы славян телендәге текстын файдалана. Христиан динендәге башка милләт вәкилләре үз телләренә тәрҗемә ителгән Б.не кулланалар. Б.не рус теленә 19 йөз башында тәрҗемә итә башлыйлар. 1810 елларда Яңа Гаһед тәрҗемә ителә. Шулай да аның 1860–70 еллардагы тәрҗемәсе — «Синодаль» гына чиркәү тарафыннан рәсми рәвештә раслана, аны рус протестантлары да куллана.

Б.нең төрле китапларын татар теленә тәрҗемә итү омтылышы күп тапкырлар ясала. 1785 тә кенәз А.Шейдяков Матфейга инҗан Инҗилне тәрҗемә итә, ләкин ул чиркәү җитәкчелеге тарафыннан хуплау тапмый. 1803–05 тә, патша Александр I күрсәтмәсе б-н, Исхак Хәлфин митрополит Платонның





«Острог» Библиясе. И. Федоров басмасы. А.М. Вилькин коллекциясеннән. ТР Милли музее.

(Левшинның) Б.дән күпсанлы өзекләр кергән Катехизисын тәрҗемә итә. Ул гарәп сүзләрен күп куллана, Б. персонажларын Коръәндәге исемнәре б-н атый. Ихтимал, шул сәбәпле басма киң таралмый.

1818 дә миссионер Джон Митчелл һәм Әстерхан рухание Дмитрий Лебедев тәрҗемәсендә «Зәбур», 1820 дә Яңа Гаһед тулысынча татар телендә басылып чыга һәм киң таралыш ала. 1824 тә Б.не тәрҗемә итүне һәм бастыруны финанслаучы Библия җәмгыяте ябыла һәм бу юнәлештәге эшләр туктала. 1832 дә Казан руханилар семинариясе укытучысы, рухани Дмитрий Анисифоровның Б.дән күләмле өзекләр кертеп татар телендә (гарәп имлясы б-н) язылган «Христиан дине тәгълиматы нигезләре» («Начатки христианского учения») дигән китабы басылып чыга.

Б.не татар теленә тәрҗемә итүнең яңа этабы 1847 дә Николай I Фәрманыннан башлана. Составына шәркыятьче галимнәр Г.К.Казимбәк, Г.С.Саблуков, Н.И.Ильминский кергән махсус комиссия төзелә. 1851 дә Г.К.Казимбәк тарафыннан һәм Н.И.Ильминский катнашында тәрҗемә ителгән Иоанн Златоуст Литургиясе, причащение кануны, причащение догалары, 1852 дә Г.С.Саблуков тәрҗемәсендә (Н.И.Ильминский төзәтмәләре б-н) Догалык (Часослов) текстлары әзерләнә. Әлеге гыйбадәт китапларына Б.дән бик күп өзекләр кертелә. Соңрак Яңа Гаһед тулысынча татар теленә тәрҗемә ителә: Инҗил тәрҗемәсе (1855) — Г.К.Казимбәк, Апостол тәрҗемәсе (1860) Г.С.Саблуков тарафыннан эшләнә. 1868 дә Казан рухание А.Д.Ясницкий тәрҗемәсендә «Зәбур» басылып чыга. Шуннан соңгы тәрҗемәләр, башлыча, Н.И.Ильминский исеме б-н бәйле. Ул гарәп теленнән кергән сүзләрдән һәм Коръәннән алынган исем-атамалардан баш тарта. Текстлар Н.И.Ильминский тарафыннан керәшен татарлар өчен кириллицага нигезләнеп төзелгән алфавит б-н гади халыкка аңлаешлы телдә басыла. 1863 тә — Бытие китабы, 1864 тә — Сирах улы Гайса Китабы (канунлаштырылмаган), 1866 да — Матфейга иңгән Инҗил, 1891 дә «Псалтырь» («Зәбур») һәм Инҗил тулысынча басылып чыга. Тәрҗемәләр Н.И.Ильминский тарафыннан В.Т.Тимофеев б-н берлектә башкарыла. 1907 дә Т.Е.Егоров һәм Р.П.Даулей тәрҗемәсендә Изге Хәвариюннарның гамәлләре китабы нәшер ителә. Е.А.Малов гарәп шрифты б-н татар телендә басылган «Библия һәм Коръән тәгълиматлары Адәм турында» (1885), «Библия һәм Коръән тәгълиматлары Муса кануннары турында» (1889), «Библия һәм Коръән тәгълиматлары Ибраһим турында» (1908) дигән китапларында ш.у. Иске Гаһеднең беренче китаплары тәрҗемәләрен тулысынча диярлек китерә, Инҗилдән күләмле өзекләр бирә. 1990 елларда Казан епархиясе Н.И.Ильминский, В.Т.Тимофеев тәрҗемәсендәге Инҗил һәм «Зәбур» китапларын, 2000 дә Хәвариюннар хатларының яңа тәрҗемәсен бастырып чыгара. Православие чиркәве б-н бергәттән протестантлар да Б.не татар теленә тәрҗемә итү юнәлешендә эш алып баралар. Библияне тәрҗемә итү ин-ты (Стокгольм) тарафыннан 1972 дә Инҗил һәм «Зәбур» (Н.И.Ильминский тәрҗемәсенә нигезләнеп), 1985 тә — яңа тәрҗемәдәге Инҗил һәм Изге Хәвариюннарның гамәлләре, 1995 тә — Иоаннга иңгән Инҗил, 2000 дә Яңа Гаһед тулысынча нәшер ителә. Православие чиркәве — Н.И.Ильминский тарафыннан төзелгән алфавиттан (к. *Ильминский алфавиты*), протестантлар хәзерге татар алфавитыннан файдалана.

ТРда Б. һәм аның аерым бүлекләренең тарихи һәм сәнгати әһәмияткә ия булган күп кенә текстлары, ш.и.: Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсендә: 1501 елда Казанда язылган әрмән Инҗиле кулъязмасы, Иван Фёдоров «Апостол»ы (1564, Россиядәге басылган елы күрсәтелгән беренче басма китап); ТРның Милли музеенда 14 йөз ахыры Тверь Инҗиле (пергаментка язылган кулъязма); «Острог» Библиясе (1581, славян телендәге беренче тулы басма текст), Ефрем Инҗиле (1606, басма, кулдан эшләнгән уникаль рәсемнәр б-н бизәлгән) саклана.

*Әд.:* Ильминский Н.И. Опыт переложения христианских вероучительных книг на татарский и другие инородческие языки в начале текущего столетия. К., 1883; Знаменский П.В. О татарских переводах христианских книг. К., 1894; Прокопьев К.П. Переводы христианских книг на инородческие языки в первой половине 19 в. Исторический очерк. К., 1904.

*Е.В.Липаков.*

**БИВО́ЙНО** Вадим Евгеньевич (8.1.1920, Тула өлкәсе Товарково а. — 19.9.1991, Казан), инженер-технолог, Казан вертолётлар җитештерү берләшмәсе ген. директоры (1980–84). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1944). 1941–43 елларда Казан авиация з-дында технолог, өлкән технолог. 1944 елдан Казан вертолётлар җитештерү берләшмәсендә: баш технолог (1948–60), баш инженер (1960–75), директор (1975–80). Б. Ми-1, Ми-4, Ми-8, Ми-14, Ми-17 вертолётларын эшләүгә, аларның модификацияләрен үзләштерүгә һәм серияләп җитештерүгә зур өлеш кертә. 1965 һәм 1977 дә Ми-8 вертолёты Франциянең Ле Бурже бистәсендә Халыкара авиация һәм космик техника салонына куела. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге бирелә (1971). Ленин, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанские вертолёты: полёт продолжается. К., 2000.

**БИГӘ́Ш** (Иске Гришкино) авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак Туйма елгасының уң кушылдыгы Юраш суы буенда. 2002 елда 546 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Юграш исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында Б. тә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, китапханә, су тегермәне, икмәк, аракы кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1411,1 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостена керә. 1921 дән ТАССР ның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1836 да — 285, 1859 да — 379, 1887 дә — 788, 1905 тә — 1009, 1920 дә — 1087, 1926 да — 1057, 1989 да — 583 кеше.

**БИГЕ́Ш** авылы, Зәй районында, Зәй тимер юл станциясеннән 25 *км* төньяктарак, Аулаш елгасы буенда. 2002 елда 455 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 17 йөз ахыры — 18 йөз башында хәзерге Мамадыш р-нының Комазан һәм Кирмән авылларыннан күчеп утыручылар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Аулаш исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чыпта сугу, тимерчелек, агачтан савыт-саба ясау б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, 2 мәчет һәм су тегермәне була. 1913 тә җирле мәдрәсә һәм мәктәптә 160 укучы укый. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1185 дис. тәшкил итә. 1930 да «Яңа юл» колхозы оештырыла, 1950 дә ул «Урай» күмәк хуҗалыгы составына керә. 1959 елдан — «Алга» к-зының (1998 дән — а.х. товарларлы җитештерү кооперативы) үзәге. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февра-

леннән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1795 тә — 96 ир заты; 1859 да — 517, 1913 тә — 1291, 1920 дә — 1052, 1926 да — 960, 1938 дә — 899, 1949 да — 681, 1958 дә — 531, 1970 тә — 746, 1979 да — 591, 1989 да — 398 кеше. ТР ФАнең беренче президенты академик Мансур *Хәсәнов* туган авыл.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**БИГИ́ЕВ** Габдерәшит Муса улы (23.12.1917, Омск губернасының Чанов өязе Олы Тибис а., хәзер Новосибирск өлкәсенең Чанов р-ны), металлург, техник фән. д-ры (1963), проф. (1964), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1978). 1941 елда Магнитогорск тау-металлургия ин-тын тәмамлый, 1946 елдан шунда ук эшли, 1954–60 елларда декан, 1958–91 дә корыч җитештерү каф. мөдире, 1960–70 тә проректор. Хезмәтләре өзлексез корыч эретү процессларын матем. модельләштерүгә карый. Металлургиядә кокссыз чуен коюга һәм өзлексез корыч эретү процессларына нигезләнеп, кара металл алуның принципиаль яңа җитештерү-технол. схемасын тәкъдим итә һәм фәнни дәлилли. 10 китап, ш.и. дәреслекләр авторы. Уйлап табуга караган 28 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Магнитогорск шәһәренең почётлы гражданы (1989).

Х е з м.: Основы математического описания и расчёты кислородно-конверторных процессов. М., 1970 (автордаш); Математическое описание и расчёт сталеплавильных процессов. М., 1982; Непрерывные сталеплавильные процессы. М., 1986; Металлургия стали: Учеб. М., 1988.

**БИГИ́ЕВ** Заһир Ярулла улы (1870, Ростов-Дон ш. — 1902, шунда ук), язучы, публицист. Татар әдәбиятында реалистик роман жанрына һәм публицистикага нигез салучыларның берсе. Ахун гаиләсендә туа, Муса *Бигиев*нең абыйсы. Ростов-Дон шәһәрендә рус мәктәбен тәмамлый, 1886–91 елларда Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укый. 1891 елдан башлап гомеренең ахырынача Ростов-Дон шәһәрендә мулла булып тора. 1893 тә Урта Азия халыкларының тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен өйрәнү максатында Төркестан буйлап сәяхәт кыла. Берничә тапкыр С.-Петербургта, Мәскәүдә, Кырымда була. Рус, төрек, Көнбатыш Европа әдәбиятларын тирән белгән, берничә чит телдә сөйләшкән. Уналты яшендә Б. беренче әсәрен — «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» («Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә», 1887) романын яза. Өч елдан икенче романы — «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар», 1890) басылып чыга. Бу романнарда әдип 19 йөзнең 2 нче яртысындагы татар тормышының төрле социаль катлауларын тасвирлый, җәмгыятьтәге комсызлык, икейөзлелек, эчкечелек кебек ямьсез күренешләрне тәнкыйтьли, гуманистик позициядән торып үзенең әхлакый идеалларын бәян итә. 1891–92 дә язылган «Катыйлә» («Үтерүче хатын») һәм «Мөртәд» романнары басылмыйча кала, аларның кулъязмалары сакланмаган. Б.нең «Мавәра ән-нәһердә сәяхәт» («Ике елга арасында сәяхәт», нәшер ителүе — 1908) исемле юлъязма китабы татар әдәбияты тарихында публицистика жанрындагы иң күренекле әсәрләрнең берсе булып исәпләнә. Анда ул 1893 тә Идел буе, Каспий һәм Төркестанга ясаган сәяхәте тәэсирләрен, Төркестан халыкларының авыр тормыш фаҗигаләрен, Россиянең колониаль сугышларына каршы көрәш күренешләрен, бер уңайдан татар халкының язмышы турында уй-фикерләрен бәян итә.



Заһир Бигиев.

Ә с ә р.: Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә. К., 1887; Гөнаһе кәбаир. К., 1890; Мавәре ән-нәһердә сәяхәт. К., 1908; Повестьлар. К., 1960; Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. К., 1979; Зур гөнаһлар: романнар, сәяхәтнамә. К., 1991.

*Әд.:* Г а й н у л л и н М.Х. Татар әдипләре (иҗат портретлары). К., 1978; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; М и ң н е г у л о в Х. «Исмең синең милләт яшәдекчә яшәр» // Мирас. 1995. № 11/12.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**БИГИ́ЕВ** Муса (Муса Җарулла) (1873 яки 1875, Ростов-Дон ш. — 1949, Каһирә), дин галиме, публицист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе. Ахун гаиләсендә туа. Башлангыч дини гыйлемне гаиләдә ала, беркадәр вакыт Казанның Апанай мәдрәсәсендә укый, Ростов-Дон шәһәрендә реаль лицей курсын тәмамлый. Шуннан соң укуын Бохарада дәвам итә, гарәп һәм фарсы телләре, фикъһ һәм фәлсәфә буенча дәресләр ала, математика һәм астрономияне өйрәнә; Евклид, Пифагор һәм Архимед (аларның математикага кагылышлы кайбер трактатларын рус теленнән татар теленә тәрҗемә итә), Р.Декарт, Ф.Бэкон хезмәтләре б-н таныша. 1896 елда Каһирәдәге әл-Әзһар ун-тына укырга керә. Ләкин андагы укытуның сыйфаты б-н ризалашмыйча, Коръән тарихын үзлегеннән өйрәнә. Соңрак Мәккә һәм Мәдинәдә белем ала. Һиндстанга сәяхәт кыла, анда исламият галимнәре б-н аралаша, дин гыйлеме мәсьәләләренә кагылышлы бәхәсләрдә катнаша. 6 ай дәвамында Диюбент ун-тында, Бомбейда укый. Каһирәгә кайткач, Коръән тарихын өйрәнүне дәвам итә, «Тарих әл-Кур'ан вә әл-Мәсахиф» («Коръән һәм аның тәфсирләре тарихы») дигән трактат бастырып чыгара.

1904 тә Россиягә кайта һәм Петербург ун-тының юридик ф-тына ирекле тыңлаучы булып керә. 1905 тә журналистлык эшчәнлеген башлый, Р.Ибраһимов б-н берлектә С-Петербургта «*Өлфәт*» г-тасын оештыра. Ул ябылгач, Казанга күчә һәм 1909 га кадәр «әл-Лөзүмият» («Кирәкле булу»), «Әдәбият гараби илә гыйлем Исламия» («Гарәп әдәбияты һәм Ислам гыйлеме») дигән фәнни хезмәтләрен нәшер итә. Аларда мәдрәсәләрдә кулланылган дин гыйлеме һәм фикъһ дәреслекләре тәнкыйтьләнә, Исламның әдәби, фәлсәфи һәм дин гыйльменең бай мирасыннан тулырак файдаланырга тәкъдим ителә. 1909 ның башында Казанда басылган Коръәндә басмаханәләр тарафыннан җибәрелгән хаталарны төзәтү мәсьәләсен күтәрә. Бу тәкъдим җәмәгатьчелектә теләктәшлек таба. Махсус төзелгән комиссия Истанбул, Каһирә, Һиндстанда басылган Коръәннәрдә дә шундый ук хаталар булуын ачыклый һәм чит илләрдәге исламият галимнәренә махсус мөрәҗәгать җибәрә. 1909 дан Б. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә диннәр тарихы, психол., гарәп теле тарихы, фикъһ дәресләре бирә, шәкертләр арасында урта гасыр ислам фикер ияләренең Аллаһ шәфкатьлелегенең универсальлеге хакындагы идеяләрен тарату б-н шөгыльләнә һәм, Коръән б-н Сөннәттә китерелгән дәлилләргә нигезләнеп, Тәмугъның мәңгелек түгеллеген, Алла мәрхәмәтенең чиксез булуын, шул сәбәпле төрле дин тотучыларның, хәтта мәҗүсиләрнең дә ахыр чиктә кичерелачәген исбатлый. Лекцияләре «Шура» журналында басылып чыкканнан соң, исламият галимнәре арасында кайнар бәхәсләр туа. 1910 да Б. Финляндиядә була, кояш баемый торган якларны күрү тәэсиреннән «Озын көннәрдә руза» дигән китап яза. Анда ул, Коръәнгә нигезләнеп, төньяк киңлекләрдә Рамазан аенда ураза тоту мәҗбүри булмавын, махсус сәдака — фидиянең ураза тотуга бәрабәр икәнлеген бәян итә;



М. Бигиев.

«беренче гөнаһ» өчен Хаува түгел, ә Адәм гаепле, хатын-кыз ир-атның кабыргасыннан яратылмаган, бу фәкать аның нәфис һәм нәзберек табигатен чагылдыру өчен кулланылган әдәби алым гына, дип раслый. Шул ук елларда Р.Фәхретдин үтенече б-н ислам хокукы мәсьәләләренә багышланган махсус журнал проектын эшли һәм, шушы эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак, «Кавагыйде фикъһия» («Фикъһ кагыйдәләре») дигән хезмәте дөнья күрә. 1912 дә Коръәннең татар теленә тәрҗемәсен нәшер итү өчен әзерли, әмма аны бастыру мөфти карары б-н тыела. 1915 тә, мөселманнарның 1905–1906 елларда узган корылтайлары документларын кертеп, «Исляхат әсаслары» («Реформа нигезләре») җыентыгын туплый (сәяси әзәрлекләүләр аркасында ул басылмый кала). 1916 да Б.нең «Зәкать» һәм «Шәригать әсаслары» («Шәригать нигезләре») дигән фундаменталь хезмәтләре дөнья күрә. Шул ук елда ул, хатын-кызларның тулы хокуклылыгын танырга һәм мөселман җәмәгатьчелеге тормышында аларның абруен күтәрергә чакырып, махсус программа тәкъдим итә. Аның шушы өлкәдәге теоретик эзләнүләре «Коръән Кәрим аять кәлимәләре хозурында хатын» (Берлин, 1933) дигән китабында чагылыш таба. Әлеге хезмәт Ислам дөньясында тулысынча хатын-кыз мәсьә-


ләләренә багышланган беренче *фәтва* булып тора. Трактатның төп фикере — хатын-кызны түбәнсеткән җәмгыять беркайчан да алгарышка ирешә алмаячак дигән караштан гыйбарәт. Б.нең Россиядә басылган соңгы хезмәтләренең берсе — «Фикъһ әл-Коръән». Ул ш.у. мөселман уку йортлары өчен яңа типтагы укыту программасы төзү б-н дә шөгыльләнә, үз мәдрәсәсен ачарга җыена. Большевиклар режимының ачыктан-ачык басымына карамастан, Б. царизм дәверендә үк башлаган мөселман халыкларын сәяси яктан азат итү көрәшен дәвам иттерә. Ул — «*Иттифакъ әл-мөслимин*» фиркасен оештыручыларның берсе. 1920 елларда мөселманнарның барлык мөһим корылтайларында катнаша. 1923 тә Берлинда аның «Ислам әлифбасы» буларак танылган «Ислам милләтләренә» дигән китабы басылып чыга. Анда Б. марксизмны кискен тәнкыйтьли, аның мөселманнарга һәм исламга карата дошман булуын исбатлый. Китап асылы б-н Н.И.Бухаринның «Коммунизм әлифбасы»на җавап булып тора. Бу хезмәте өчен Б. төрмәгә ябыла. Бары тик дөнья җәмәгатьчелеге басымы нәтиҗәсендә генә иреккә чыгарыла.

1930 дан соң чит илләрдә яши һәм фәнни эшчәнлеген дәвам итә, исламның төрле мәсьәләләренә караган (башлыча, гарәп телендә) күп хезмәтләр яза. Б. *тәкълид* б-н тәкфирне гамәлдә куллануга һәм *каләмгә* каршы чыга, Ибне Рөшд һәм әл-Газәли кебек фикер ияләренең күп кенә идеяләренә карата шик белдерә, *иҗтиһад* итү хокукын яклый һәм традицион ислам тарафдарларын тәнкыйтьли. Шул ук вакытта дини ислахчыларның радикаль канатын Көнбатышка сукырларча иярүдә, мөселманнарга ят булган кыйммәтләрне үзләштерүдә гаепли. Көнбатышның тормыш итү өчен файдалы фән, техника, сәнгать казанышларын кабул итәргә, ләкин ислам дөньясы өчен яраксыз һәм зарарлы рухи кыйммәтләреннән баш тартырга чакыра. Мөселман җәмгыяте яшәешен шәригать нигезендә корырга өнди. Ул еллардагы геополитик вазгыятьне дөрес бәяләп, 1 нче бөтендөнья сугышы ахырында ук дөньяны яңадан бүлешү өчен яңа сугыш булачагын һәм Көнбатыш цивилизациясен кризис көтәчәген алдан әйтә. Б. бөтен гомерен исламның әсаси кыйммәтләрен кайтаруга багышлый һәм яшәешне шуларга нигезләнеп кору принциплары б-н яши. Аның дин гыйлеменә кагылышлы идеяләре һәм дини-фәлсәфи фикерләре бөтен мөселман дөньясына тарала.

Х е з м.: Озын көнләрдә руза. К., 1911; Рәхмәте илаһия борһанлары. Оренбург, 1911; Бөек мәүзугъларда уртак фикерләр. СПб., 1914; Ислам милләтләренә дини, әдәби, иҗтимагый вә сәяси мәсьәләләр вә тәдбирләр хакында. Берлин, 1923; Коръән Кәрим аять кәлимәләре хозурында хатын. Берлин, 1933; Избранные труды: В 2 т. К., 2005.

*Әд.:* Т а й м а с Г.-Б. Муса Ярулла Биги: Тормышы, эшчәнлеге вә әсәрләре. К., 1997; Р а х и м к у л о в а М.Ф. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург, 1997; Т о г а н З.В. Воспоминания. М., 1997. Кн. I; Х а й р у т д и н о в А. Последний татарский богослов. К., 1999; G o r m e z M. Musa Carullah Bigiev. Ankara. 1992.

*А.Г.Хәйретдинов.*



Х.А.Бигичев.

**БИ́ГИЧЕВ** Хәйдәр Аббас улы (16.6.1949, Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Чүмбәли а. — 13.11. 1998, Казан), җырчы (драматик тенор), ТАССРның халык артисты (1980), РСФСРның атказ. артисты (1986). 1979 елда Казан консерваториясен (В.А.Воронов классы) тәмамлый. 1977 дән Татар опера һәм балет театрында әйдәп баручы солистларның берсе. Үзенең иҗат эшчәнлеге дәверендә татар композиторларының сәхнәдә куелган барлык муз. сәхнә әсәрләрендә төп партияләрне башкара. Мәс., Җик, Җәлил («Алтынчәч», «Җәлил», Н.Җиһанов), Самат (шул исем. опера, Х.Вәлиуллин), Закир («Кара йөзләр», Б.Мөлеков), Батырҗан («Наёмщик», С.Сәйдәшев) һ.б. Б. ш.у. рус һәм чит ил классик опера спектакльләрендә Хозе («Кармен», Дж.Бизе), Самозванец («Борис Годунов», М.Мусоргский), Германн («Пики дамасы», П.Чайковский) һ.б. партияләрендә уңышлы чыгышлар ясый. Дж.Вердиның «Отелло» операсында Отелло партиясе — җырчының башкару осталыгының иң югары баскычы булып кала. Үзенең муз. сәхнә эшчәнлеге, концерт эстрадасында, телевидение һәм радиода даими чыгышлары б-н киң танылa. Татарстан композиторларының күп кенә яңа вокаль әсәрләрен беренче булып башкара, тамашачыга татар халык җырларының хасиятен үтә сизгер тоемлап тапшыра. Киң диапазонлы, кабатланмас матур тембрлы тавышка, матур буй-сынга ия булган Б.ның иҗаты югары профессиональлеге, төрле жанрдагы һәм стильдәге әсәрләрне бертигез дәрәҗәдә сәнгатьчә башкару осталыгы б-н аерылып тора. Аның башкару манерасына сирәк очрый торган академизм б-н халык җыр традицияләренең үзара гармониялe рәвештә кушылуы хас. 1970–90 елларда иң популяр татар проф. башкаручыларының берсе. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1984).



Х.А. Б и г и ч е в Җәлил ролендә (Н.Г.Җиһановның «Җәлил» операсы).

*Әд.:* Китмә, сандугач! (Хәйдәр Бигичев ядкаре / Төз. Р.Фәттахов). К., 1999.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*

**БИГЛО́В** Әкрам (Мөхәммәдәкрам) Мөхәммәтҗан улы (1871–1919), сәяси һәм хәрби эшлекле, полковник. Дворяннар нәселеннән; Оренбург губернасында эре җирбиләүче (850 дис.). Оренбург кадетлар корпусын тәмамлый. Бәләбәйдә земство идарәсе рәисе була. Уфа губернасыннан 2 нче Дәүләт думасына депутат итеп сайлана (1907), мөселман фракциясен оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе. Бюджет комиссиясе әгъзасы. Думада кадетлар партиясе фракциясе тарафдары. Җир мәсьәләсе каралганда башкортларга күчмә терлекчелек алып бару өчен үз җир биләмәләрен калдыруны яклый. 3 нче Дәүләт думасына сайлаулар вакытында хөкүмәткә каршы караштa булганы өчен сайлану хокукыннан мәхрүм ителә. 1 нче бөтендөнья сугышы башлангач, армиягә алына; 1917–18 елларда Казанда 95 нче мөселман укчылар полкы командиры. Окт. рев-циясен кабул итми, аңа каршы көрәшүчеләр сафына баса. «*Болак арты республикасы*»на бәйле вакыйгаларда актив катнаша. 1919 да адмирал А.В.Колчак армиясендә 16 нчы татар укчы полкы командиры. Сугыш барышында һәлак була.

*Әд.:* Т у к т а р о в Ф.Ф. (Усал). Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре. К., 1909; Члены второй Государственной думы. СПб., 1907; Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Д.М.Госманова.*

Х.А. Б и г и ч е в: 1. Отелло (Дж. Вердиның шул исемдәге операсы); 2. Германн (П.И. Чайковскийның «Пики дамасы» операсы) рольләрендә.



1



2

**БИДӘҢГЕ́** елгасы, Идел алды төбәгендә. Килнаның сул кушылдыгы (Зөя елгасы бассейны). Озынлыгы — 29,9 *км* (ТР чикләрендә — 21,9 *км*), бассейнының мәйданы — 268 *км*$^2$. Елга башы — Ульянов өлкәсе терр-ясенең чигендә, тамагы Тәтеш р-нының Салман авылыннан көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге — 140 *м*, тамагыныкы — 79 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы — 3%. Б. елгасының 4 тән алып 18 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар, иң зурысы — Тархан елгасы. Елга челтәренең тыгызлыгы — 0,29 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле — 0,11–0,25 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы — 78 *мм*, ташу агымы катламы — 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы — 0,06 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Б. бассейнында Тәтеш аучылык тыюлыгы урнашкан.

**БИДГА́ТЬ** (гарәп. بدعة — яңа гадәт, башлап җибәрү, яңалык кертү). Б. төшенчәсе әүвәлге ислам чорында Госман хәлифәне (644–56) Мөхәммәд пәйгамбәр тәгълиматына һәм гамәлләренә каршы килүче тәртипләр кертүдә гаепләп чыккан шигыйлар һәм хариҗитлар дини-сәяси төркемендә барлыкка килә. Соңрак Б. догматика өлкәсенә үтеп керә һәм полемик әдәбиятта «буталу», «адашу» мәгънәсендә киң кулланылыш таба, шулай да сүзнең мәгънәви кысалары төгәл билгеләнмәгән. Бер үк гамәл яки фикер төрле дини юнәлеш вәкилләре тарафыннан йә «кабул итәргә ярамый торган, тыелган яңалык», «ялгышу» яки «исламга тугрылык саклау» дип бәяләнергә мөмкин. Татар дини әдәбиятында Б. мәсьәләсе Урта Иделгә ислам үтеп кергән заманнардан бирле актив рәвештә тикшерелә. 18 йөздән башлап татар дин әһелләре Г.Утыз-Имәни, Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, М.Бигиев, З.Камали һ.б. үз хезмәтләрендә Б. мәсьәләсенә зур игътибар бирәләр. Изгеләрнең каберләрен зиярәт кылу, мәрхүмнәрне вафат булганнан соң 3,7, 40 көннән, бер елдан искә алу кебек халык йолаларын Б. буларак бәяләү күренеше еш кына бәхәсләр уята.

*Әд.:* Бидгать яки Дәлилсез гыйбадәтләр. К., 1999. Бидаат, или Лжепоклонство. К., 2001.

**БИЕКЛЕ́К** күле, Идел алды төбәгендәге элекке күл урыны. Зөя елгасының уңъяк ярындагы тугаенда, Югары Ослан р-нының Чулпан авылыннан 0,2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы — 5,08 *га*, аларның 0,56 *га* мәйданын йөзмә «үлән-утраулар» (сплавина) тәшкил итә. Озынлыгы — 830 *м*, иң зур киңлеге — 130 *м*.

**БИЕКТА́У** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Мөвиҗә елгасы буенда. 2002 елда 206 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сатуга көрәк ясау б-н шөгыльләнә, атлар б-н сату итә. 1887 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет һәм мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 508 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Тирсә волостена керә. 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 елдан — ТАССРның Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында, 1927 елның 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1887 дә — 593, 1920 дә — 988, 1926 да — 797, 1938 дә — 905, 1958 дә — 426, 1970 тә — 288, 1989 да — 222 кеше. Тел галиме, педагог М.*Корбангалиев* туган авыл.

**БИЕКТА́У** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе авылыннан 47 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасы буенда. 2002 елда 827 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Казан тегү ф-касы ф-лы. 18 йөздә нигез салына. 1940 елның 16 апреленә кадәр Көчек дип атала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Көчек Чаллысы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, су тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3558,1 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 969, 1897 дә — 1629, 1908 дә — 1854, 1926 да — 1655, 1949 да — 1514, 1958 дә — 1545, 1970 тә — 1587, 1989 да — 886 кеше.

**БИЕКТА́У** тимер юл станциясе посёлогы, Биектау р-ны үзәге. ТРның төньяк-көнбатыш төбәгендә, Казаннан 27 *км* ераклыкта, Казан–Екатеринбург тимер юлы буенда. 2002 елда 2936 кеше (татарлар — 54%, руслар — 43%) яши. Сөт, икмәк з-длары. Урта мәктәп. Район мәдәният йорты. Музыка



Биектау тимер юл станциясе посёлогының үзәк өлеше.

мәктәбе. 2 китапханә. 1930 елларда нигез салына. 1935 елның 10 февраленнән — Биектау р-ны үзәге. 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан район үзәге. Халык саны: 1958 дә — 852, 1970 тә — 2519, 1989 да — 2656 кеше.

**БИЕКТА́У** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 2 *км* көньяктарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. 2002 елда — 7998 кеше (татарлар — 53%, руслар — 46%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. «Казан авыл хуҗалыгы техникасы», «Биектау машина-трактор станциясе» АҖләре. Урта мәктәп, гимназия, район музыка мәктәбе ф-лы. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Чиркәү. 16 йөзнең 2 нче яртысында Казан ханлыгы чорындагы Байгыш авылы урынында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. Халкы башта Казан Успение Елантавы монастырена карый, 1764 тә экономик разрядка күчерелә, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек һәм терлек үрчетүдән тыш, умартачылык, тимерчелек, пыяла кую, итек тегү, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, этап йорты була. Рождество-Богородица чиркәве (1881–86 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1870 тә ачыла), җил тегермәне, 8 тимерчелек, сыраханә, 1 шәраб һәм 8 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең

Биектау р-нының Биектау авылы. 1. Гомуми күренеше; 2. «Биектау» сәүдә-күңел ачу комплексы.





имана җире 2084,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Сабакай волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 142, 1782 дә — 154 ир заты; 1859 да — 979, 1897 дә — 950, 1908 дә — 1043, 1920 дә — 1032, 1926 да — 1227, 1938 дә — 1219, 1949 да — 1025, 1958 дә — 1154, 1970 тә — 1728, 1989 да — 6446 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885. Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1916. Вып. 3; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**БИЕКТА́У** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогоннан 14 *км* көнбатыштарак, Ютазы елгасы буенда. 2002 елда 61 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 21, 1938 дә — 112, 1949 да — 127, 1958 дә — 116, 1970 тә — 80, 1979 да — 66, 1989 да — 48 кеше.

**БИЕКТА́У РАЙОНЫ́**, ТРның төньяк-көнбатышында урнашкан; Мари Респ-касы б-н чиктәш. Казан икътисади р-нына керә. Мәйданы 1668 *км*². 30 җирле үзидарә советын (ком-тын), 128 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Биектау тимер юл станциясе посёлогы. Халкы — 2006 елда 46,2 мең кеше, 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 63,6%, руслар — 34,2%. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 28 кеше. Район 1935 елның 10 февралендә оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Казан һәм Лаеш өязләренә, 1920–27 дә ТАССРның Арча һәм Лаеш кантоннарына, 1927 дән Арча кантонына, 1930–35 тә Казан авыл р-нына, Дөбъяз, Питрәч, Арча р-ннарына керә. Район чикләре һәм адм. бүленеше берничә мәртәбә үзгәрә. 1940 та аның мәйданы — 626 *км*², халкы — 29,7 мең кеше, 20 авыл советы, 68 торак пункт исәпләнә. 1959 ның 26 мартыннан Б.р. составына таркатылган Столбище р-ның бер өлеше кушыла. 1960 та мәйданы 982,3 *км*² тәшкил итә, аңа 19 авыл советы, 112 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Б.р. таркатыла, биләмәсе Арча, Яшел Үзән, Питрәч р-ннарына бирелә. Яңадан торгызылганнан соң (12.1.1965), мәйданы 1727 *км*² тәшкил итә, халкы — 64,8 мең кеше, 29 авыл советын, 164 торак пунктны берләштерә. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль район дип үзгәртелә. Б.р.ның рельефы — күтәренке тигезлек (биеклеге 82–210 *м*), елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән. Терр-ясендә Илләт, аның кушылдыгы Ашыт, Казансу һәм кушылдыклары Сола, Шәмәк, Солонка, Киндерле елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл-соры




һәм соры урман, кәсле көлсу туфраклы. Терр-ясенең 17,3%ы урманлы. Доломит, известьташ, комлы балчык, ком, ш.и. пыяла җитештерү комы, торф ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: Казансу елгасы, *Кәрәкәле күле*, *Кара күл*, *Мунчала күле*, *Эстачи* (Остачы) *сөзәклеге*, *Семиозёрка урманы* табигать истәлекләре, *Зәңгәр күлләр* табигать тыюлыгы, *Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы*. Район терр-ясендә, нигездә, Казан ханлыгы чорына караган 100 ләп археол. истәлек билгеле. Б.р.нда Коркачык җитештерү-төзелеш комб-ты, Коркачык икмәк кабул итү пр-тиесе, сөт продуктлары (Биектау тимер юл станциясе пос., Дөбъяз а.), спирт (Усад, Алат), кирпеч җитештерү з-длары, Казан пр-тиеләре һәм оешмалары бүлекчәләре, *Исләйтар урман хуҗалыгы* эшли. А.х. җирләре 121,1 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр 83,8 мең *га* тәшкил итә (2005). Сабан бодае, арыш, солы игелә; яшелчә, бәрәңге үстерелә. Ит-сөт терлекчелеге, җәнлек үрчетү алга киткән. 2006 елга районда 19 а.х. пр-тиесе: 1 совхоз, 9 а.х. товарлары җитештерү кооперативы, 7 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, 2 ачык АҖ, 6 ярдәмче хуҗалык исәпләнә. Район терр-ясеннән Казан — Екатеринбург тимер юлы, Казан — Пермь, Казан — Уфа автомобиль юллары уза. Районда 61 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 5818 укучы), ш.и. 23 башлангыч мәктәп, 11 тулы булмаган урта, 27 урта мәктәп; 3 музыка мәктәбе, һөнәр уч-щесе, 47 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 65 клуб, 50 китапханә, 259 урынлы 3 хастаханә; Өбрә авылында Салих Сәйдәшев музее эшли. Рус һәм татар телләрендә «Высокогорские вести» — «Биектау хәбәрләре» р-н г-талары нәшер ителә. Б.р. терр-ясендә «Биектау», «Усад» автоспорт комплекслары урнашкан.

**БИЕ́Р** (Пүчинкә-Сутер) авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 17 *км* көньяк-көнчыгышрак, Оча елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 327 кеше (удмуртлар — 67%, татарлар — 32%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Клуб. 19 йөздә нигез салына. Революциягә кадәрге рус чыганакларында Починок Сутырях исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б. дә ярма ярдыру тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 617,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш,1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 35 ир заты; 1859 да — 220, 1897 дә — 286, 1908 дә — 286, 1920 дә — 314, 1926 да — 335, 1989 да — 234 кеше.

**БИЁ́Р** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 22 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 11 кеше (татарлар) яши. 1770 еллардан мәгълүм. Башта Кече Семён-Головина дип атала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1869 да Б. гә Чуча авылыннан (хәзер Питрәч р-нында) руслар килеп урнаша. 20 йөз башында монда Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 386,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Б. Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостена керә. 1920 дән — ТАССР ның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир заты; 1859 да — 105, 1897 дә — 151, 1908 дә — 174, 1920 дә — 209, 1926 да — 239, 1938 дә — 220, 1949 да — 68, 1958 дә — 60, 1970 тә — 44, 1979 да — 45, 1989 да — 20 кеше.

**БИЕ́Ш** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 7 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2002 елда 346 кеше (руслар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Халкы 18–19 йөзнең 1 нче яртысында дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Иоанн Предтеча чиркәве, земство мәктәбе, 5 җил һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, 2 май язу йорты, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1954,6 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 159 ир заты; 1859 да — 777, 1897 дә — 1228, 1908 дә — 1475, 1926 да — 405,

1938 дә — 857, 1958 дә — 665, 1970 тә — 576, 1979 да — 638, 1989 да — 381 кеше.

**БИҖАДЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Сөннең сул кушылдыгы. Озынлыгы — 25 *км*, бассейнының мәйданы — 159 *км*². Актаныш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Богады авылыннан 2,5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Аеш авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге — 140 *м*, тамагыныкы — 66 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы — 12%. Б. елгасының 4 һәм 6 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,24 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле — 0,51–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы — 70 *мм*, ташу агымы катламы — 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы — 0,05 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын — 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 1,2 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.


**БИЗӘЛЕ́Ш СӘНГАТЕ́**, нәфис сәнгатьнең бер тармагы, кеше яшәешенең көнкүреш мохитен формалаштыручы иҗат төре. *Монументаль бизәлеш сәнгатен*, *гамәли бизәлеш сәнгатен* (халык нәфис кәсепчелеген кертеп), бизәү сәнгатен (бәйрәмнәр, күргәзмә һәм музей экспозицияләре, витриналар һ.б.ның сәнгатьле бизәлеше) берләштерә; сәнгати сәнәгать һәм *дизайн* б-н бәйләнештә; авыл осталары, шәһәр һөнәрчеләре һәм проф. рәссамнар иҗатын колачлый. Б.с. әсәрләре ансамбльнең бер өлеше буларак иҗат ителә, аларда сәнгатьнең берничә төре синтезлана. Татар халкында Б.с.нең тарихи тамырлары Евразиянең далалы һәм урман-далалы җирләрендә яшәгән кабиләләр мәдәниятенә, 4–5 йөзләр чигендәге һуннарның сәнгать истәлекләренә (корал һәм ат дирбиясе, зәргәрчелек эшләнмәләре үрнәкләре: алтын йөгертелгән әйберләр, кызыл һ.б. төстәге пыяла кашлы бизәмәләр), 6–7 йөзләрдәге Көнчыгыш һәм Көнбатыш төрки каганлыкларына (корал, көнкүреш кирәк-яраклары, бизәмәләр һәм монументаль сыннар), Бөек Болгарга (Перещепин — Кубрат хан хәзинәсе һәм Сент-Миклош хәзинәләрендәге алтын һәм көмеш эшләнмәләр һ.б.), Хәзәр каганлыгына (ташны, сөякне уеп эшләнгән әйберләр, металлны нәфис эшкәртү һәм керәч сәнгате әйберләре) барып тоташа.

Б.с.нең урта гасырлардагы үсеше әүвәлге болгарлар (8–10 йөзләр), Идел буе Болгар дәүләте (10 йөз — 13 йөз башы), Алтын Урда (13–14 йөзләр), Алтын Урдадан соңгы татар ханлыклары (15–16 йөз уртасы) дәверләренә бүлеп өйрәнелә. *Олы Тархан каберлегендә*, *Танкеевка каберлегендә* табылган археол. әйберләрдә, нәфис керәч эшләнмәләрдә, бизәмәләрдә, металлдан ясалган көнкүреш кирәк-яракларында чагылыш таба; Салтау-Маяк культурасының Урта Идел вариантында үсеш ала. Монголларга кадәрге дәвер һәм Алтын Урда дәвере Б.с., авыл һәм шәһәр нәфис кәсепчелегенең бер тармагы буларак, *ислам сәнгатенең* стиль принциплары йогынтысында үсеш ала. Аеруча монументаль архит-ра биналарын бизәү (ташка һәм гипска уеп кисү, майоликалы һәм мозаикалы тышламалар һ.б.), гамәли бизәлеш сәнгате әсәрләре иҗат итү (керәч, торевтика, зәргәрчелек сәнгате, сөяккә уеп кисү) б-н бәйләнгән төрләрдә югары үсешкә ирешә. Бу чор Б.с. әсәрләре арасыннан дөньякүләм билгеле үрнәкләр сакланып калган (Болгар шәһәрендәге архит-ра истәлекләре, үрдәк фигуралы болгар чигә асылмалары, Алтын Урдада эшләнгән «*Мономах бүреге*» һ.б.). Болгар дәүләте һәм Алтын Урда дәверләре Б.с. стиле үзенчәлекләре Казан һ.б. татар ханлыклары сәнгатендә дәвамлы рәвештә үсә. Шәһәр дөньяви мәдәниятенең һәм Шәрекъ бароккосы дип аталган стильне чагылдыручы шәһәр һөнәрчелеге традицияләре хакында монументаль архит-ра бизәгенең сакланып калган фрагментларына (уеп бизәкләнгән таш детальләр, алебастр плитәләр), уеп язылган кабер ташлары һәм Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында сакланган *Казан бүреге*, алтын җепкыр каптырмалар кебек зәргәрчелек сәнгатенең уникаль үрнәкләренә карап фикер йөртергә мөмкин. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан, Казан һәм Әстерхан ханлыклары яулап алынып, Рус дәүләтенә кушылганнан соң, татар Б.с. фәкать халык иҗаты формаларында гына яшәп кала, чөнки шәһәрләрдәге һөнәрчелек үзәкләре таркала, Б.с. әсәрләрен кулланучы һәм үстерүче югары катлау юкка чыга. Б.с.нең монументаль архит-ра б-н бәйләнгән төрләре, нәфис керәч (татарларның чүлмәк балчыгы чыга торган урыннардан куылуы сәбәпле), кыздырып металл эшкәртү (рәсми рәвештә тыела) һәм, гомумән, югары зәвыклы элитар эшләнмәләр җитештерү кебек кәсепләр үсеше туктала. Б.с.нең зур үсеш алган традицияләре шәһәр сыман борынгы татар үзәкләрендә (Арча, Саба, Җөри) һәм алар тирәсендәге авылларда яшәп кала.

Рус Б.с. хәзерге Татарстан җирләренә 16 йөз урталарында үтеп керә; ташка һәм агачка архит-ра бизәге ую, дивар нәкыше, әвәләп һәм чынаяк кирпечтән ясалган бизәк (Казандагы һәм Зөядәге православие гыйбадәтханәләре, гражданлык биналары), чиркәү әйберләрен укалап чигү, көнкүрештә кулланылган керәч әйберләр (савыт-саба, кикрикле кош башы рәвешендәге борынлы комганнар һ.б.), металлны нәфис эшкәртү (көмеш һәм бакыр кою, чәкәнләү, уемлау) һәм зәркән сәнгате (каралту, җепкыр, финифть) үсеш ала (к. «*Казан көмешчеләре*»). 18 йөз башыннан Б.с. гомумрус мәдәниятенең тарихи стильләр (барокко, классицизм, ампир, модерн, экликтика) һәм җирле провинциаль үзенчәлекләр б-н этапларын кичерә. Ташка уелган рельефлы һәм алебастрдан әвәләп ясалган бизәк, күпертмә бизәк, нәкышь, бина фасадларындагы агачка уелган бизәкләр, иконостасларны алтынлау, тәрәзә һәм ялтыравык йөгертелгән керәчтән мич тышлыклары һ.б. (Казан, Алабуга, Чистай, Спас, Зөя шәһәрләрендәге һәм Казан губернасының башка өяз үзәкләрендәге чиркәүләр һәм гражданлык корылмалары) монументаль бизәлеш төрләре — моның ачык мисалы. Гамәли бизәлеш төрләреннән нәфис савыт-саба, мичләр һәм идән тышлаулары ясауда керәч һөнәрчелеге (Кокшан керәч з-ды), «кустар» нәфис кәсепчелек (Чабакса тимерчеләре, Балык Бистәсе зәркәнчеләре, Питрәч чүлмәкчеләре), ш.у. рус халык сәнгатенең тегү, чигү, туку, агачны уеп кисү һәм бизәкләү кебек төрләре үсеш ала.

Татар Б.с. тарихында 18 йөз урталарыннан 19 йөз урталарына кадәрге чор чәчәк ату дәвере буларак билгеләнә. Әлеге чорда Б.с. феодализм дәвере казанышларын саклаган авыл шартларында үскән халык мәдәнияте һәм гореф-гадәтләрнең үзара йогынты ясау шартларында үсә, бу исә классик формаларның барлыкка килүе өчен җирлек бирә. Б.с. әсәрләре матди-нәфис кәсепчелекнең барлык тармакларында да иҗат ителә, нәтиҗәдә мәдәнияттә милләткүләм традицияләр формалашуга этәргеч туа. 18 йөз урталарыннан 19 йөз урталарына кадәрге чорда милли татар киемнәре, татар өйләренең эчке һәм тышкы бизәлеше, Б.с. әсәрләренең милли бизәкләр һәм төсләр кануннары формалаша. Каюлы күн, зәргәрчелек, укалап һәм элмәкләп чигү, туку, хаттатчылык кебек сәнгать төрләрендә татар осталарына хас ысуллар үсеш ала. Б.с. нең классик формалары Идел буе һәм Урал төбәге татарларының шәһәр мәдәнияте нигезендә барлыкка килә. Казан һәм Казан артының һөнәрчелек алга киткән, нәфис кәсепчелек ширкәтләре булган борынгы авыллары Б.с. үзәкләренә әверелә. Бу исә татар халкының барлык этник төркемнәренең (Идел буе, Урал төбәге һәм Көнбатыш Себер), ш.и. башкортларның һәм беркадәр күләмдә казакъларның ихтыяҗларына җавап бирүче эшләнмәләрне күпләп җитештерү мөмкинлеген ача. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан татарлар яшәгән урыннарда шәһәр нәфис һөнәрчелеге яңарыш кичерә.

19 йөз урталарыннан Б.с.нең авыл һәм шәһәр өе кәсепчелеге рәвешендә яшәп килгән аерым төрләре нәфис һөнәрчелек дәрәҗәсенә күтәрелә. Аларга каюлы күн һәм бизәкле киез итекләре, ирләр һәм хатын-кызлар өчен укалап чиккән баш һәм аяк киемнәре, киез һәм тукылган келәмнәр җитештерү керә. Б.с.нең традицион төрләре татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә (Идел буенда һәм Урал алды төбәгендә, Көнбатыш Себердә һәм Кырымда) киң тарала. Зәркән бизәмәләр, чигелгән бизәкләр, тукыма әйберләр, бакырдан һәм җиздән ясалган эшләнмәләр, *шәмаилләр* һ.б. гаммәви һөнәрчелек продукциясе рәвешендә җитештерелә. Әлеге эшләнмәләргә күпмилләтле төбәктә һәм ерак җирләрдә — Казакъстан, Урта Азия, Себердә ихтыяҗ зур булганлыктан, аларны җитештерү күп кенә авылларда халык өчен әһәмиятле кәсепчелеккә әверелә. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан 20 йөз башларына кадәр гомуммилли Б.с. әйберләренең күпләп җитештерелүе бердәй кабатланган формаларны барлыкка китерә. Б.с.нең сәнгати-эстетик системасы форма-















**Бизәлеш сәнгате**. 1. Болгар савытлары. Алтын. Чүкеп бизәкләү, гравирлау. 6–7 йөзләр. Сент-Миклош хәзинәсе (Венгрия); 2. Ялтыравык йөгертелгән чынаяк кирпеч. Фрагмент. Майолика. 13–14 йөзләр. ТР Милли музее; 3. Кабер ташының бер өлеше. Таш. Кисеп бизәкләү. 13–14 йөзләр. Болгар тарих-архит. музей-тыюлыгы; 4. Әҗем мәчете манарасы. Фрагмент. Ташны кисеп бизәкләү, коелма металлда чүкеп ясау. 19 йөз. Казан; 5. Мотаһир Яхъя. «Таҗсыман шамаил». Пыяла, май, фольга. Рәсем сәнгате. 20 йөз башы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Авыл өенең фронтон уемы. Агач. Кисеп беркетү. Әтнә р-нының Олы Әтнә авылы. 1960 еллар; 7. Авыл өенең эчке күренеше. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. Арча р-ны Яңа Кырлай авылы музее. Реконструкция; 8. ТР Язучылар берлеге бинасы янындагы бизәкле рәшәткә (М.Оконошников йорты). Металл. Чүкеп ясау. Чабакса тимерчелек һөнәрчелеге. 20 йөз башы. Казан; 9. Бизәкле мендәр. Каюлы күн. Чигү. 19 йөз ахыры. Сергиев-Посад Дәүләт тарих-сәнгать музей-тыюлыгы; 10. Казан татарларының аксөяк хатын-кызлары киеме. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее; 11. Намазлык. Киҗе-мамык тукыма, йон җеп. Чигү, келәм җөе. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. Яңа Чишмә р-ны Зирекле авылының халык иҗаты һәм көнкүреше музее; 12. «Казан — Татарстан башкаласы». Казан шәһәр яны тимер юл вокзалы фасадындагы сграффито. Фрагмент. Рәссамнар С.М.Бубеннов, Р.А.Килдебәков, В.К.Фёдоров. 1967; 13. Ваза. Ялтыравык йөгертелгән керәч, әвәләп ясау. Рәссам Х.Н.Латыйпов. 1980 еллар; 14. «Табигать». Бизәлмә панно. Бакыр, җиз, эретеп ябыштыру. Рәссам И.Н.Башмаков. 1980 еллар; 15. «Тормыш агачы» дивар панносы. Күн, мозаика. Рәссам С.Ю.Гарбузова. 2000.

лашуда ислам сәнгате принциплары, рус һәм Европа сәнгатенең классицизм, барокко, ампир стильләре мөһим роль уйный (таш һәм агач биналар бизәүдә, зәргәрчелек сәнгатендә, өс киеме тегүдә, келәм тукуда һ.б.).

19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар Б.с.нә капиталистик сәнәгать үсеше, традицион дини һәм милли мәдәниятнең Европача модернизацияләнүе тәэсир итә. Ике яклы процесс бара: бер яктан, һөнәрче хезмәтенең унификацияләнүе нәтиҗәсендә эшләнмәләрнең формалары гадиләшсә, икенче яктан, Европа модаларының үтеп керүе традицияләрнең гаммәвиләшү юнәлешендә үзгәрүенә китерә. Бу исә Б.с.нең күп кенә төрләре, башлыча, традицион интерьер һәм өс киемнәренең искергән формалары юкка чыгуга сәбәп була. Шул ук вакытта рәссамның индивидуаль иҗатына нигезләнгән проф. сәнгатьнең мәдәниятә мөстәкыйль бер төр булып формалашуы өчен алшартлар туа. Европаның модерн һәм эклектика кебек стильләре үсеш ала (мәчетләр һәм байлар йортлары бизәлешендә, күн каю сәнгатендә, зәркән бизәмәләрдә, тукымаларда һ.б.).

1920 еллар башыннан совет дәүләтенең идеологик һәм икътисади сәясәте традицион Б.с.не юкка чыгу дәрәҗәсенә җиткерә. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында авыл икътисадын тамырдан үзгәртеп кору барышында кустар һөнәрчелекнең кооперативларга берләшүе нәтиҗәсендә, Татарстанда нәфис һөнәрчелек һәм кәсепчелек югары үсеш алганнан соң, аның бетүгә йөз тотуы һәм күп кенә төрләренең юкка чыгу процесслары башлана. Проф. иҗат төре буларак, Б.с. «сул» юнәлештәге ТатЛЕФ һәм Сулф (Сул фронт) рәссамнарының идея программаларында һәм проектларында, Казан ирекле иҗат остаханәләренең уку программаларында, рәссамнар Ф.Таһиров, Ф.Гаврилов, К.Чеботарёв, А.Платунова, Д.Фёдоров, В.Кудряшев һ.б. иҗатында күзәтелә. Иҗтимагый биналарның интерьерларын бизәү проектлары, гаммәви агитация (татар өйләре өчен «агитка», шәһәрне революцион бәйрәмнәргә бизәү, күргәзмә экспозицияләре һ.б.) кебек төрләре өстенлек ала. Яңа социалистик көнкүреш өчен каралган, «производство сәнгате» идеяләрен чагылдырган утилитар эшләнмәләрнең үрнәкләре булдырыла (В.Лаптев, Г.Сатонина, И.Никитин, П.Байбарышев һ.б. иҗатлары). Әлеге әсәрләр 1924 елда Б.с. рәссамнары өчен әһәмияткә ия булган «Казан, алга!» күргәзмәсендә күрсәтелә. 1930–50 елларда Б.с. «социалистик реализм» идеологиясен чагылдыра; юлбашчыларның портретлары, хакимият атрибутлары һ.б. татар Б.с.нең бизәкләр системасына туры килмәгән официоз сюжет мотивлары (мех һәм күн мозаикалар кергән эшләнмәләр, аппликацияләр, чигелгән әйберләр, агачка бизәк төшерү һ.б.) пәйда була. Ләкин шушы елларда да Б.с.нең кайбер төрләре (ташка, бетонга, агачка уеп бизәк ясау, алебастрдан әвәләп бизәк ясау) иҗтимагый биналар һәм торак йортлар бизәлешендә кулланыла (ВДНХдагы ТАССР павильоны, Казанда Опера һәм балет театры, ТАССР халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе биналары комплексы). Аларда рус классик архит-расы принциплары (18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысы) татар милли архит-расындагы (аерым алганда, Болгар, Алтын Урда архит-расындагы), татар йортларындагы бизәлеш формалары б-н бергә яраштырыла. Интерьерлардагы рельеф гипс бизәкләр, киндердә башкарылган сынлы паннолар, фреска һәм темпера нәкышьләре, зиннәтле җиһазлар һ.б. кулланыла (арх. И.Гайнетдинов, Р.Мортазин, И.Вәлиев, рәссамнар С.Ахун, Ч.Әхмәров, П.Сперанский, В.Ламмерт һ.б. иҗаты). 1950 еллар башыннан бизәү сәнгате үсә башлый: бу интерьерларны проектлауда, агитацион паннолар, күргәзмә экспозицияләре иҗат итүдә, бәйрәмнәрне бизәүдә эшләүче рәссамнар иҗатында күзәтелә (А.Кашаев, Д.Булат, А.Крылов, И.Игъламов, Н.Байбурин, П.Тужилкин һ.б.).

1960 еллардан Б.с. яңа сулыш ала: шәһәрләрдә төзелешнең үсүе — Б.с.нең монументаль бизәлеш төренә, киң кулланылыштагы нәфис эшләнмәләргә ихтыяҗ артуга — гамәли бизәлеш сәнгате үсешенә этәргеч бирә. Яңа этапта көнкүрешнең төп нигезен һәм мохитнең ансамбльләшүен раслаучы стиль юнәлеше формалаша; Россия югары уку йортларын тәмамлаган яшь буын рәссамнар тырышлыгы б-н Б.с. өлкәсендә профессиональ иҗат барлыкка килә (Н.Артамонов, С.Бубеннов, Р.Килдебәков, М.Килдебәкова, Е.Киселёва, В.Ковалевский, С.Кузьминых, М.Шәйдуллин, С.Шәкүрова, Б.Шубин, А.Спориус, А.Сысоев, В.Федоров һ.б.). 1970 еллар ахыры — 80 еллар уртасы — Б.с.нең күтәрелеш дәвере: аның дивар мозаикасы, витраж, батик, гобелен, кием модельләү, керәч, фарфор һәм фаянс җитештерү кебек яңа төрләре барлыкка килә. Рәссамнарның зур коллективлары Казанда гына түгел, Чаллыда, Түбән Кама, Лениногорски, Бөгелмә һ.б. шәһәрләрдә оеша. 1983 тә беренче тапкыр Б.с.нең респ-ка күргәзмәсе үткәрелә, анда 81 авторның 276 эше күрсәтелә.

ТРда Б.с. үсешенең хәзерге этабы (1990 еллар башыннан) милли сәнгать, татар һәм ислам мәдәнияте традицияләрен үзләштерү аша милли формаларга омтылу, ш.у. дизайн һәм төзелеш өлкәсендә авангард тенденцияләрен эзләү б-н аерылып тора. Б.с. өлкәсендә профессиональ рәссамнар б-н беррәттән, традицион һөнәрләрне үстерүче, халык осталары, нәфис кәсепчелектә махсус һөнәри-техник белемле осталар һәм үзешчән рәссамнар да эшли. Алар милли сувенирлар, бүләкләр, күргәзмә әсәрләре җитештерүче төрле ширкәтләргә берләшәләр («Туран» фонды, чикләнгән җаваплылыктагы «Экосин» ширкәте, «Презент» ябык АҖ, «Традиция» фонды, «Болгари» остаханәсе һ.б.). Авыл өйләре бизәлешендә агачка уелган бизәк, күптөрле төсләр б-н буяу, тукуның иң гади төрләре, чигү, зәркән бизәмәләренең кайбер төрләре көнкүрештә яшәп килә. Каюлы аяк киеме («Арча милли аяк киеме» ачык АҖ — к. *Каюлы күн* һөнәрчелеге), керәчтән ясалган курчаклар («Актүбә уенчыгы» ачык АҖ) җитештерү, рус һәм татар традицияләренә нигезләнгән бизәкләп туку (*Алексеев бизәкләп туку фабрикасы*) халык нәфис кәсепчелеге формаларында үсешен дәвам итә. Б.с.нең күн эшкәртү (күн каю һ.б.), уникаль нәфис текстиль (батик, гобелен, чигү, алтын җепләр б-н тегү), зәргәрчелек сәнгате, металлны нәфис эшкәртү, өс киеме сәнгате, агач ую, керәч һ.б. төрләре (И.Башмаков, И.Васильева, И.Гайнетдинов, Н.Галәвиева, С.Гарбузова, А.Глебова, Н.Кумысникова, Х.Латыйпов, Л.Липина, О.Марсова, Д.Рәхмәтуллина, Л.Сафина, И.Фазылҗанов, Л.Фәсхетдинова, С.Федотов, Х.Шәрипов һ.б. иҗатларында), монументаль бизәлеш төрләре буларак — дивар рәсемнәре, мозаика, гипсны уеп бизәкләү, тукыма паннолар һ.б. (А.Абзгилдин, Р.Вахитов, Р.Гыйләҗев, Р.Круглянова, К.Сафиуллин, Ә.Фәтхетдинов һ.б. иҗатларында) актив рәвештә үсә. Базар икътисады формалашкан чорда бизәүче рәссамнар (Р.Абаев, З.Низаметдинов һ.б.) һәм дизайнерлар (И.Артамонов, Р.Исхаков, С.Михайлов, Ш.Мотыйгуллин, Р.Мөхәммәтҗанов, Р.Сафиуллин һәм «17 төркеме», А.Чебинёв һ.б.) иҗатында сәнәгать һәм интерьер дизайны аеруча мөһим урын алып тора.

*Әд.:* Дульский П.М. Казань XVI–XVII–XVIII столетиях. К., 1943; Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Червонная С.М. Искусство Татарии. История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-х – 1990-х годов). К., 1995; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарстана. К. 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БИЗӘНЎ**, 1) кешенең йөзен-кыяфәтен яхшырту чаралары һәм ысуллары. Дәвалау (к. *Халык медицинасы*) һәм декоратив косметикага бүленә; 2) тән тиресен, чәчне, тешне һ.б.ны тәрбияләү чарасы. Татарларда тышкы матурлык һәм камиллек үрнәгенә омтылу Көнчыгыш мөселман халыкларындагы тән гүзәллегенә һәм тән тазалыгына мөнәсәбәтле гореф-гадәтләрнең көчле тәэсире б-н тыгыз бәйләнгән. Килеш-килбәткә карашларның, ш.у. тәнне тәрбияләү өчен Б. чаралары, тәртипләре һәм әйберләре җыелмасының уртак, охшаш булуы да шуны дәлилли. Халык көнкүрешен өйрәнүче барлык белгечләр дә татарларның чисталык ератуларын билгеләп үткәннәр; этник аңында тән б-н бергә өс-башны, торакны пөхтә тоту зарурлыгы ныгыган. Атна саен мунча керү, көн дәвамында күп тапкырлар тәһарәт алу гадәткә әйләнгән. Әлбәттә, тышкы матурлыкка аеруча хатын-кызлар әһәмият бирүчән. Декоратив косметикадан, нигездә, алар файдалана. Сайлап алу өчен төрледән-төрле итеп җитештерелгән нәзакәтле *бизәнү әйберләре* (хушбуй, иннек, кершән һ.б.) татар кызлары арасында XIX йөз азагында кулланыла башлый. Аңа кадәр алар Урта Азия һәм Кытай һөнәрчеләре кулы б-н әзерләнгән косметикадан файдаланганнар. Татар археологлары тарафыннан табылган Б. әйберләрен саклау савытлары, әйтик, хуш исле сулар салынган кечкенә шешәләр Көнчыгыш косметикасының Идел



**Бизәнү әйберләре.** 1. Төймәләр. Алтын. Җепкыр. 15–16 йөзләр; 2. Кадама. Көмеш, җепкыр. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы; 3. Алка. Көмеш, алтынлау, фирәзә. Җепкыр, кырлау. 19 йөз; 4. Аел. Көмеш, алтынлау, гәүһәр. Гравирлау, чүкеп ясау, кырлау. 19 йөз; 5. Яка чылбыры. Көмеш, алтынлау, җәүһәр. Җепкыр, кырлау, басма. 19 йөз; 6. Хаситә. Тукыма, көмеш, алтынлау, җәүһәр, чылбыр, тәңкәләр. Җепкыр, басма, кырлау. 18 йөз; 7. Тезмә. Тукыма, тәңкәләр, чулпы. Көмеш, җепкыр. 19 йөз ахыры. Барысы да ТР Милли музеенда саклана.

буе Болгарында киң куланылышта булуын дәлилли. Б. әйберләрен төрле яшьтәге шәһәр һәм авыл хатын-кызлары файдаланган. Аерма шунда гына — байлар аларны көн саен, ярлылар исә бәйрәм вакытларында гына кулланган. Татар кызлары бит-муеннарына бераз су кушылган кургашлы яки борынгыдан «упа» дип йөртелгән ак буяу сөрткәннәр. Биткә алсулык йөгертү өчен кершән ягылган, кашлар ба́сма б-н каралтылган, керфекләргә һәм күз кабакларына сөрмә тартылган. Хатын-кызлар, аеруча өлкәннәр арасында теш каралту гадәте дә булган. Моның өчен авызны читтән кайтарылган «таш колы» (тимер касмагына пестә агачы орысы кушып эшләнгән) яки имән чикләвеге төнәтмәсе б-н чайкаганнар. Кына тырнакларны кызыл-сары төскә керткән. Хушбуй сыйфатында хуш исле экзотик әйберләр — мускус, рәйхан, алсу май сөрткәннәр. Баш түбәсеннән туры юл ачып, ике толымлы итеп үрелгән чәчне ныгыту өчен аңа махсус иннек яки ширбәт сөрткәннәр. Чәч куе һәм озын булып үссен өчен баш катык б-н юылган. Б. әсбапларына кечкенә көзге, куе тешле агач яки сөяк тарак, колак чистарткыч, эскәк, сөрмәлек, хуш исле сабын кисәге (Казан сабын кайнату з-ды җитештергән) һ.б. кергән.

*Әд.:* Ф у к с К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. К., 1844; ш у л  у к. О татарских женщинах // Казан губ. ведомости. 1844. № 1; В о р о б ь е в Н.И. Казанские татары. К., 1953.

*Ф.Ф.Гулова.*

**БИЗӘНҮ́ ӘЙБЕРЛӘРЕ́**, киң мәгънәдә — бизәү кирәк-ярагы; тар мәгънәдәге аңлатмасы күбрәк таралган: кешенең кыяфәтенә зур тәэсирлелек, аның өс-башына, аеруча бәйрәм, йола киемнәренә өстәмә үзенчәлек бирүче бизәкле эшләнмәләр (күп очракта зәркән әйберләр). Б.ә. элек-электән күп төрле вазифа үти: кешенең тышкы кыяфәтен зәвыклы итеп бизәүдә аларның роле саклана; Б.ә. аның җәмгыятьтә тоткан урынын, социаль хәлен чагылдыра (хакимлек һәм байлык дәрәҗәсен күрсәтә, шуңа күрә гадәттә сирәк очрый торган зәркән Б.ә., тагып йөрүгә караганда, туплана килә, аннан соң мирас ителә). Күп кенә халыкларда Б.ә.н бөти — саклау чарасы сыйфатында йөртү традициясе сакланган; хәзерге көнгә кадәр Б.ә. этник үзенчәлекле билге буларак кулланыла, ягъни алар нәсел, ыру тамгасы рәвешендә, костюмнар комплексы б-н бергә — кешенең нинди дә булса милләткә (халыкка), дингә, терр-ягә мөнәсәбәте билгесе, яше һәм гаилә хәле күрсәткече булып хезмәт итә. Татар Б.ә.нең тамырлары Идел буе Болгары, Алтын Урда, татар ханлыкларында, аеруча Казан ханлыгының халык көнкүреше һәм нәфис-һөнәрчелек традицияләренә барып тоташа. Эшләнү үзенчәлекләре буенча алар шартлы рәвештә ике төркемгә бүленә: 1) сатып алынган яки кушып эшләнгән Б.ә. — зәркәнче осталар тарафыннан кыйммәтле һәм ярымкыйммәтле металлардан, таштан ясалган алкалар, йөзекләр, беләзекләр, аеллар, каптырмалар һ.б.; 2) һәвәскәрләр ясаган Б.ә. — гадәттә хатын-кыз иҗаты әйберләре — кул астындагы төрле материаллардан (галантерея товары, вак акчалар, зәркәнчелек продукциясеннән һ.б.) әзерләнә. Җирле сәнгать традицияләре кысаларында хатын-кызлар үзләренә тукыма җирлегендә шәхси Б.ә. — муенсалар, хаситәләр эшләгәннәр. Татар гамәли-бизәлеш сәнгате хәзинәсе проф. зәргәрчеләрнең гүзәл әсәрләре б-н генә түгел, халык осталары тарафыннан кулдан эшләнгән Б.ә.нең югары сәнгать дәрәҗәсенә ия булулары б-н дә бай. Яшь кешенең балигъльк яшенә җитүен мәгълүм Б.ә. б-н чагылдыру татарлар арасында да таралган. 19 йөздә ир-атлар (ш.и. югары катлау вәкилләре) бармакларына мөһерле, асылташ кашлы йөзекләр кигәннәр, билләренә аеллы каешлар буганнар; Б.ә.н кәләшләренә, хатыннарына, кызларына бүләк иткәннәр. Бай тормышлы татарлар бүләк итү өчен алтыннан яки алтын йөгертелгән югары сыйфатлы көмештән, фирәзә, ахак, аметист, тау бәллүре б-н инкрустацияләнгән Б.ә.н Казанда (нигездә, Яңа татар бистәсендә) һәм Казан артында (хәзерге Арча, Мамадыш, Саба р-ннары авылларында) яшәүче, чоку-уемлау, бөтерү, кою, чүкү, җепкыр кебек һөнәри алымнарны камил белгән атаклы милли зәргәрчеләргә (көмешчеләргә) кушып эшләткәннәр. Б.ә.нең күпчелеге түбән сыйфатлы көмештән әзерләнгән: аларны җирле тимерчеләрнең эшләнмәләре, завод-фабрикаларда җитештерелгән арзанлы товарлар тәшкил иткән. Татар Б.ә.н күпләп җитештерү 19 йөз ахырында Казан губернасының Лаеш өязе

Балык Бистәсе авылы зәргәрчеләре тарафыннан җайга салына. Хатын-кыз Б.ә. гаять күптөрле: баш бәйләвечләре (баш хәситәсе, *маңгай тәңкәсе*), колак *алкалары*, тукымадан эшләнгән чәч тасмалары (*тезмә*, чәч тәңкәсе), толым асмалары (*чулпы*), яка каптырмасы (яка чылбыры), тукыма күкрәкчә (*тамакса, хәситә*), брошкалар (тәңкәле булавка, кашлы инә); кул бизәмәләре — *беләзек, йөзек,* балдак; төрле *каптырмалар* һәм төймәләр. Тукымага асылташлар, көмеш тәңкәләр, зәркән аеллар, укалы тасмалар, аппликацияләр беркетелгән Б.ә. буенча татар халык костюмындагы этнотерриториаль үзенчәлекләрне ачыклап була. Әмма кулдан эшләнгән әлеге зур күкрәкчәләр, бәйләвечләр һ.б. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында модадан чыга башлый. Көндәлек тормышта кулланыла торган иң популяр Б.ә.нең стиле үзгәрә. Челтәр алкалар (татар сыргасы), киң беләзекләр, зур кызыл асылташлы йөзекләр, тәңкәләр, аеллар тагылган авыр толым асмалары кулланыштан чыга; куышлап коелган «айлы» гади алкаларга, каралтылган көмеш чыбыктан үрелгән тар беләзекләргә ихтыяҗ арта, толым асмаларының иске төрләрен чулпылар алыштыра. Б.ә.нең традицион җыелмасы үзәктән ерактагы авылларда, читтә яшәүче керәшен татарларда, мишәрләрдә озаграк саклана. Әмма 20 йөз уртасында һәр төбәктә диярлек Б.ә. сәнәгать җитештергән бериш эшләнмәләр тарафыннан кысрыклап чыгарыла. 20 йөз ахырыннан башлап, Татарстанның проф. рәссамнары, аерым халык осталары милли костюмнарны, Б.ә.н камилләштерү юнәлешендә шактый уңышлы эшлиләр. Ш.у. к. *Зәргәрчелек сәнгате, зәргәрчелек һөнәрчелеге*.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Суслова С.В. Женские украшения казанских татар середины 19 — начала 20 вв. М., 1980; шул ук. Ювелирное дело // Татары. М., 2001; Валеев Ф.Х. Нородное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990; Рамазанова Д.Б. Названия одежды и украшений в татарском языке. К., 2002.

*Ф.Ф.Гулова.*

**БИЗГӘ́К АВЫРУЫ́**, макрофагаль-моноцитар система (организмны саклау системасы) күзәнәкләре һәм эротроцитларның күп өлеше зарарлануы сәбәпле, кешенең антропоз, протозой, трансмиссив инвазия халәте, бизгәк өянәге, анемия һәм гепотопиленомегалия күренеше. Киң таралган авыру. Б.а.ның яман формалары: церебраль формадагы менингизм, коматоз халәт; гемоглобин азаю янсә көчле гемолиз һәм гемолитик сары гемоглобинур б-н бәйле кара су бизгәге; йогышлы — агулану шогы халәтендәге, алгид формасы, бөер зәгыйфьлегенең көчәюе; фиброз панкреатит (сеңерләр авыруы).

Б.а.н китереп чыгаручы — Plasmodiumның гади төрләре (P. vivax, P. malariae, P. ovale, P. falciparum). Авыру чыганагы — паразит йөртүче, канында плазмодий гаметоцитлары булган, бизгәкнең беренчел һәм көчле билгеләре булган авыру кеше.

1696 елда Женева табибе Мортон авыруны мөстәкыйль төр итеп аерып чыгара һәм дәвалау өчен хин агачы кайрысын куллануның файдасын исбатлый (Перу индееңларына агачның бу сыйфаты мәгълүм була). 1717 дә Италия табибе Ланцизи бизгәк килеп чыгуның сазлы урыннар б-н бәйләнешен раслый. Француз А.Лаверан авыру чыганагын тасвирлый (1830). И.И.Мечников авыру чыганагын Protozoa тибына нисбәтли (1887). Р.Росс авыруның күчү юлларын ачыклый (1897), Ф.И.Гизе дәвалау өчен хинин кристаллын булдыра (1816). 20 йөз уртасында хлорохон синтезлаштырыла. 1908 дә Казан губернасында 100 мең кеше, 1920 елларда 71 меңнән, 1924 тә 209 меңнән артык кеше Б.а. б-н авырый. 1935 тә авыручыларның саны 225134 кешегә җитә, 1950 елларда ул 400 гә кала. 1955 тә Бөтендөнья сәламәтлек җәмгыяте (БСҖ) бизгәкне бетерү буенча глобаль программа кабул итә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, дөньяда авыру ике тапкыр кими. Хәлнең кискенләшүе БСҖ тарафыннан бизгәк б-н көрәшүнең күпьеллык программасын кабул итүгә китерә. Хәзерге вакытта ТРда авыру очраклары юк. 1990 нан авыру читтән керә дип санала.

Б.а. профилактикасы — плазмодий-черки-кеше биоценозын өзүдән гыйбарәт: Росс ысулы б-н черкиләрне юк итү яисә кешене алардан аеру, Кох ысулы б-н кеше организмындагы чыганакларны юк итүдән гыйбарәт. Зарарланган районда шәхси саклану җайланмаларын булдыру зарур.

Казан Дәүләт мед. ун-ты галимнәре тарафыннан республикада бу авыруның таралуы өйрәнелгән (С.С.Зимницкий, А.Б.Агафонов, Б.А.Вольтер, Д.К.Бәширова, Д.Ш.Еналиева) һәм профилактика чаралары эшләнелгән.

*Әд.:* Резник А.Е. Лечение малярии в условиях Казани. К., 1950.

*В.Х.Фазылов.*

**БИЗГӘ́К ҮЛӘНЕ́**, авран (Gratiola), сыраҗчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 ләп төре билгеле, күбесенчә Җир шарының уртача һәм салкын поясларында киң таралган. ТРда бер төре — дарулы Б.ү. (G. officinalis) Казан шәһәре, Яшел Үзән, Әгерже, Спас, Түбән Кама, Минзәлә р-ннары терр-ясендә очрый. Дымлы болыннарда куак араларында, сирәк кенә елга тугае сулыкларында үсә. 15–60 *см* озынлыктагы үсемлек; тамырчасы шуышма, буынтыклы, кабырчык б-н капланган. Сабагы туры, гади яки ботаклы, өске өлеше дүрт кырлы. Яфраклары каршыдаш, ланцетсыман, очлы, утырма. Чәчәкләре ялгыз, куыш, чәчәк сабы нечкә озын. Таҗы ак яки алсу, бөтен яки җиңелчә уелган өске иренчәле. Җимеше — күп санлы орлыклы, очлы, көрән-күксел тартмачык. Май ахырыннан көзгә кадәр чәчәк ата, июльдән җимеш бирә. Орлыклардан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Агулы. Үсемлекнең җир өстендәге өлешендә гликозидлар, сапониннар, дуплау матдәләре һәм алма кислотасы бар. Халык медицинасында эч йомшарту һәм бәвел кудыру өчен, ш.у. бавыр һәм талак, хроник тире авыруларын дәвалауда файдаланыла.

*Әд.:* Пастушенков Л.В., Пастушенков А.Л., Пастушенков В.Л. Лекарственные растения. Использование в народной медицине и быту. СПб., 1998.

**БИЗНӘ́** елгасы, Идел алды төбәгендә. Сураның уң кушылдыгы. Озынлыгы — 97,7 *км* (ТР терр-ясендә — 14,3 *км*), бассейнының мәйданы — 1298 *км*$^2$ (ТРда — 198,3 *км*$^2$). Елга башы — Чүпрәле р-ны Чуаш Бизнәсе авылының көньяк чигендә, тамагы — Чуаш Респ-касы терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге — 182 *м*, тамагынныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы — 10%. Б. елгасының 2 дән алып 14 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең катылыгы — 0,18 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле — 0,26–1 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы — 120 *мм*, ташу агымы катламы — 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы — 0,09 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын — 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Б. бассейнында гомуми күләме 0,9 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**БИЗНӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында. Иделнең сул кушылдыгы. Озынлыгы — 38,8 *км*, бассейнының мәйданы — 805 *км*$^2$. Елга башы — Әлки р-ның Татар Төгәлбае авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Спас р-ның «КИМ» с-зы посёлогы янында. Елга башының абс. биеклеге — 143 *м*, тамагынныкы — 53 *м*. Б.нең су җыелу мәйданы — ерымнар һәм сызалар б-н киселгән дулкынсыман тигезлек. Су җыелу мәйданының урманлылыгы — 6%. Б. елгасының 5 тән алып 17,2 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар, иң зурысы — Наясолка елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы — 0,18 *км/км*$^2$. Б.нең үзәне асимметрияле, уңъяк битләре биек (35 *м* га кадәр) һәм текә. Тугае ике яклы, тоташ, тигез, 100–200 *м* киңлектә, болынлыклы. Елга юлы бормалы, киңлеге — 7–10 *м*. Елга тирәнлеге киң җирендә — 1–1,5 *м*, сай җирдә — 0,3–0,7 *м*. Елга режимы 1954 елдан башлап Антоновка авылы янындагы постта өйрәнелә. Агым тизлеге сай җирдә — 0,51–1 , киң җирендә — 0,2–0,3 *м*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле — 0,51–1 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Елга башыннан Кошки авылына кадәр елга кибә. Язгы ташу күләме еллык су агышының 70% чамасын тәшкил итә. Антоновка авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәлеше — 1,6 *м* (макс. 3 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы — 140 *мм*, ташу вакытындагы су катламы — 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 84 *см* га җитә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы — 0,322 *м*$^3$*/с*. Антоновка авылы янында уртача еллык су чыгымы 0,82 *м*$^3$*/с* тәшкил итә. Иң зур чыгым — 197 *м*$^3$*/с*



Бизнә елгасы.
Спас р-нының Никольский авылы янында.

1963 елның язында билгеләнә. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын — 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен — 400–500 *мг/л*. Суның болганчыклыгы 1400 *г/м*³ га җитә. Елга утырмаларының уртача еллык күләме 38 мең *т* га тигез. Б. бассейнында гомуми күләме 3,1 млн. *м*³ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**БИЗНӘ́ КРӘСТИЯННӘРЕ́ КУЗГАЛЫШЫ́**, крепостнойлык тәртипләренә каршы оештырылган крәстияннәр хәрәкәте. 1861 елгы Крәстиян реформасына җавап рәвешендә Казан губернасының Спас өязе Рус Бизнәсе авылында 1861 нең апрелендә башланып китә (хәзер Спас р-ны Антоновка а.). Җитәкчесе Антон Петров (к. *Сидоров* А.П.). Кузгалышта актив катнашучылар А.Андреев, Д.Гаврилов, И.Николаев һ.б. Крәстияннәр крепостной булудан тулаем азат ителергә телиләр, җир биләмәләре аларга тулысынча бирелергә тиеш дип саныйлар. 1861 елның апрель башында Рус Бизнәсе крәстияннәре, шул елның 19 февралендә игълан ителгән крепостнойлыктан азат ителү тәртип-кагыйдәләренең эчтәлеген аңлатып бирүне үтенеп, А.Петровка мөрәҗәгать итәләр. Әлеге документны А.Петров авылдашлары мәнфәгатьләренә якын килердәй итеп укып аңлата: крәстиянгә тулы ирек бирелгән, барлык җирләр дә хәзер аларныкы булырга тиеш, ди. Мондый хәбәр, авылдан-авылга күчеп, тиздән Спас, Лаеш, Чистай өязләре, ш.у. чиктәш Самара, Сембер губерналары крәстияннәре арасында тарала. Рус Бизнәсенә меңләгән рус, татар, чуаш крәстияннәре җыела башлый. Алпавыт җирләрендә эшләр туктала, кайбер урыннарда алпавыт ашлыгын бүлү, урманнарны кисү күренешләре, авыл түрәләрен куып җибәрү, алыштыру очраклары күзәтелә. Документның эчтәлеген А.Петров дөрес аңлатмаган, дип, аны аңлатырга тырышулар, таралыгыз, дип үгетләүләр нәтиҗә бирми. Рус Бизнәсе янына җыелган 5 меңләп кеше үзләренә тулы ирек бирүне, җирне өләшүне таләп итә. Алпавытлар утарларын калдырып кача башлый. 12 апрельдә авылга А.С.Апраксин җитәкчелегендә Тарутин полкының ике ротасы килә. Апраксин җыелган халыкка таралырга боерык бирә. Крәстияннәр таралмыйлар. Коралсыз халыкка төбәп ут ачыла. Рәсми мәгълүматларга караганда, 178 кеше үлә һәм яралана. Чынлыкта яраланучылар саны 350 дән артып китә. Байтак кеше мәйданда суктырыла, тоткын ителә. А.Петров кулга алына, хәрби-кыр мәхкәмәсе карары нигезендә 19 апрельдә атып үтерелә. Рус Бизнәсендәге канлы вакыйга тиздән киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм була. Казанның *Куртина чиркәвендәге панихида* уздырыла, анда проф. *А.П.Щапов* хөкүмәтнең эш-гамәлләрен гаепләп нотык сөйли. Б.к.к. һәм аларга каршы күрелгән чаралар турында С.-Петербург матбугатында, Лондонда А.И.Герцен чыгарган «Колокол» г-тасында хәбәрләр басыла.

1986 елда Антоновка авылында Антон Петровка һәйкәл куела.

Чыг.: Бездненское восстание 1861 г.: Сб. док. К., 1948.

*Әд.:* У с т ю ж а н и н Е.И. Бездненское восстание 1861 г. // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1941. Вып. 4; В у л ь ф с о н Г.Н. Жаждали воли. К., 1986.

**БИЙ КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алды төбәгендәге күл. Мишә һәм Идел елгалары субүләрендә, Лаеш р-нының бер үк исемдәге авылы уртасында урнашкан. Су өслегенең мәйданы — 4,2 *га*. Су күләме — 90 мең *м*³ чамасы. Озынлыгы — 250 *м*, макс. киңлеге — 225 *м*. Уртача тирәнлеге — 2,6 *м*, макс. тирәнлеге — 4,5 *м*. Күл карст процесслары эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы катлаулы. Суы бик йомшак, аз минеральләшкән, гидрокарбонат-сульфат-натрийлы. Төсе саргылт. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**БИК** Вадим Иосифович (26.04.1894, Симферополь ш. — 6.01.1967, Саратов ш.), анатом, мед. д-ры (1935), проф. (1935). 1919 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый; студентлык чорында Кызыл Хач җәмгыяте отрядында табиб, Зөя, Казан һ.б. шәһәрләрдә тимгелле тифны дәвалау баракларында мөдир булып эшли. 1920 елдан Казан мед. ин-тында, 1932 дән нормаль анатомия каф. мөдире. 1938–65 елларда Саратов мед. ин-тында шул ук исемдәге каф. мөдире. Сөяк, кан йөреше һәм нерв системалары үзгәрүчәнлеген, пульманологияне, баш мие артерияләре анатомиясен, анатомия тарихын тикшерә. Фәнни хезмәтләре коллатериаль кан әйләнешенә, антропологиягә багышланган. Б. тарафыннан Казан мед. ун-тының нормаль анатомия кафедрасында борынгы чордан алып 20 йөз урталарына кадәрге анатомия тарихына караган киң колачлы экспозиция оештырыла. Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Учебный музей Казанского анатомического института. К., 1927; Сподилолизис. К., 1934.

*Әд.:* В а л и ш и н Э.С. Казанский период жизни и деятельности профессора Вадима Иосифовича Бика // Макро- и микроморфология: Межвузовский сб. науч. работ. Саратов, 1999. Вып. 4.

*Э.С.Вәлишин.*

**БИК-ҮТИ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы чигендә. 2002 елда 345 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 16 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, мәчет, аның каршында мәктәп була. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, тимерчелек, мануфактура һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2453,4 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Әлки волостена керә. 1920 елдан ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 577, 1897 дә — 830, 1908 дә — 1245, 1920 дә — 1221, 1926 да — 965, 193 дә — 928, 1949 да — 745, 1958 дә — 632, 1970 тә — 783, 1979 да — 742, 1989 да — 323 кеше.

**БИКӘСА́З** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 156 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 1907–09 елларда нигез салына. Башта Яңа Бикәсаз дип атала. 1914 тә мәчет төзелә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1913 тә — 41, 1926 да — 104, 1938 дә — 462, 1949 да — 461, 1958 дә — 387, 1970 тә — 309, 1979 да — 268, 1989 да — 113 кеше.

**БИКӘ́ШЕВ** Камил Абдулла улы (26.8.1943, Мордва АССРның Ширингуш р-ны Горенка а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1986), проф. (1990), РФнең атказ. хокук белгече (1996). Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1968), Мәскәүдә эшли: 1968–75 елларда СССР ФАнең Диңгез транспорты ин-тында, 1975–80 дә Дөнья икътисады һәм халыкара бәйләнешләр ин-тында. 1980–89 да Балык хуҗалыгы икътисады ин-тының сектор мөдире. 1989 дан Мәскәү юридик академиясендә халыкара хокук белеме каф. мөдире. Хезмәтләре халыкара диңгез, экология хокукы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: ФАО и правовые вопросы охраны живых ресурсов открытого моря. М., 1986; Мировое рыболовство: вопросы международного сотрудничества. М., 1990; Оформление морских происшествий. М., 1991.

**БИКБА́ЕВА** Әлфия Исхак кызы (23.11.1926, Киров өлкәсе Малмыж ш.) оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1970), БАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1976, 1985). 1949 елда Башкорт мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1966–91 елларда колак, тамак һәм борын авырулары каф. мөдире. Бер үк вакытта Башкортстан АССР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш оториноларингологы. Респ-када беренче булып Ишетүне яхшырту үзәге (Уфа ш.) оештыра. Тикшеренүләре озена этиологиясе һәм патогенезы, бугаз күчереп утырту проблемаларына, урта колак патологиясендә вируслар ролен ачыклауга, фронтитларга, баш сөяге эчендәге отоген катлауланууларга диагноз кую, дәвалау һәм аларны фаразлауга, тонзилоген интоксикация һәм ревматизмга дифференциаль диагноз кую мәсьәләләренә, оториноголик патологияне дәвалауда лазер куллануга карый. Урта һәм эчке колак патологиясе булган авыруларны тикшерүнең

комплекслы электрофизиологик ысулларын эшли; озена барлыкка килүнең оригиналь концепциясен тәкъдим итә һәм бу авыруны патогенетик дәвалауны гамәлгә кертә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электрофизиологические исследования в динамике отогенных внутричерепных осложнений. Уфа, 1986; Лечение химических ожогов пищеварительного тракта. Уфа, 1985 (автордаш).

**БИКБА́У** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 24 *км* көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2002 елда 725 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысыннан мәгълүм. 18 йөзнең уртасына кадәр ике авылны — Бикбау һәм Бикбау-Якуб авылларын берләштерә; 1902–32 еллардагы рәсми чыганакларда ике торак пункт — Беренче Бикбау, Икенче Бикбау буларак теркәлә. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 елларда-гы крәстияннәр сугышында пугачёвчылар отрядында Б. авылыннан 65 кеше катнаша. Беренче мәчет 1760 та төзелә, 1815 тә 3 мәчет була. 1842 елгы мәгълүматларга караганда, беренче мәчет каршында — мәдрәсә (18 йөз ахырында ачыла), калган икесе каршында мәктәпләр эшли. 19 йөз ахырында 3 җил тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5224 дис. тәшкил итә. 1921–22 елларда-гы ачлык нәтиҗәсендә Б. халкы күпкә кими. Күмәкләштерү чорында авылда «Корыч» к-зы оештырыла, 1956 да ул, күп үзгәртеп корулардан соң, «Җиңү» күмәк хуҗалыгы үзәге, 1961 елдан — «Гигант» к-зы үзәге була. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Минзәлә, 1954 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1747 дә — 65 ир заты; 1795 тә — 660, 1858 дә — 1592, 1870 тә — 1812, 1897 дә — 2069, 1913 тә — 2898, 1920 дә — 2740, 1926 да — 2377, 1938 дә — 2443, 1958 дә — 2124, 1970 тә — 2170, 1979 да — 1891, 1989 да — 971 кеше.

**БИКБО́В** Дамир Мансур улы (9.9.1945, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. икътисадчысы (1995). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1973). 1970–76 елларда Казан химия комб-тында, 1976–84 тә Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү берләшмәсендә баш бухгалтер урынбасары, 1985–87 дә Казан төгәл машиналар төзү з-ды баш бухгалтеры. 1987–89 да ТАССР МСның комплекслы икътисади һәм социаль үсеш бүлеге мөдире урынбасары. 1989–91 дә Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсенең ген. директор урынбасары. 1991–92 дә ТР Дәүләт мөлкәте б-н идарә итү дәүләт ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 1995–96 да ТР Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру дәүләт ком-ты рәисе. 1996–98 дә ТРның икътисад министры. 1998–99 да ТР Дәүләт мөлкәте б-н идарә итү дәүләт ком-ты рәисе. 1999 дан Татфондбанк идарәсе рәисенең 1 нче урынбасары, банкның финанс директоры.

**БИКБО́В** Евгений Архипович (14.8. 1914, хәзер Чиләбе өлкәсе, Нагайбәк р-ны Остроленский пос. — 14.7.1983, шунда ук), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. сержанты. 1929–36 елларда туган авылы колхозында, 1938–42 дә Эчке эшләр халык комис-тының Нагайбәк р-ны бүлекчәсендә эшли. 1936 дан Кызыл Армиядә. Хәсән күле янында япон гаскәрләренә каршы сугышта катнаша (1938). 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 25 нче гв. танк бригадасы автоматчыларының моторлаштырылган батальонында отделение командиры (11 нче гв. армиянең 2 нче гв. танк корпусы). 3 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Белоруссия (1944) һәм Көнчыгыш-Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 30 июнендә Черневки авылы янында Березина елгасын кичкәндә (Белоруссия ССР, Минск өлкәсе Борисовский р-ны) батырлык күрсәтә: Б. командалыгындагы солдатлар каршы як ярда яна торган күпергә кереп, өч дзотны басып алалар, кул сугышы б-н дошманның күп көчен юкка чыгарып, батальонга елга аша кичеп чыгарга булышлык итәләр. 1945–47 дә Нагайбәк р-ны милициясе бүлегендә участок милиционеры, 1954 тән Югары Урал урман хуҗалыгының Арсин урманчылыгында эшли. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, СССРның Югары Совет Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.


Е.А. Бикбов.

*Әд.:* Челябинская область: Энцикл. Челябинск, 2003. Т. 1; Х а к и м о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

*М.З.Хәбибуллин.*

**БИКБО́В** Равил Зөфәр улы (28.6.1948, Свердловск ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Свердловск тау казылмалары (1972) һәм Свердловск халык хуҗалыгы (1983) ин-тларын тәмамлый. 1972–77 елларда «Уралгипроруда» проектлау ин-тында инженер-конструктор, 1977–89 да Урал электротехника з-дында инженер, бүлек мөдире, 1989–90 да «Уралчерметавтоматика» ин-ты директоры, 1990–92 дә «Европа-Азия» фәнни-тикшеренү ин-тлары һәм тәҗрибә пр-тиеләре ассоциациясе ген. директоры. 1992–95 тә Урал төбәге галимнәре, кәсәбәчеләре һәм сәнәгатьчеләренең «Якташ» берлеге президенты. 1996 елдан ТРның Екатеринбург шәһәре һәм Свердловск өлкәсендәге вәкаләтле вәкиле.

**БИКБУЛА́Т БӘК** (? — 1563), Себер ханлыгы идарәчесе (1520 еллардан). Ядегәр бәк б-н бергә идарә итә. 1563 елда аларның көчләре Күчүм хан тарафыннан тар-мар ителә. Б.б. кулга алына һәм үтерелә.

*Әд.:* О к с ё н о в А. Сибирское ханство до эпохи Ермака. Томск, 1888; М и л л е р Г.Ф. История Сибири. М.–Л., 1957. Т. 1; История Сибири. Л., 1966. Т. 1.

**БИКБУЛА́Т ХАН** (? — 1391/92 тирәсе), 1391/92 елда Алтын Урда ханы. Ырыс ханның оныгы. 1379–87 елларда Туктамыш хан кул астында хезмәт итә, Тәбриз шәһәренә яу б-н барган (1386/87) гаскәр әмирләренең берсе. 1387 елда Туктамышка каршы яшерен эш алып баручы Идегәй төркеменә кушыла. 1391 елның июнендә Туктамыш хан гаскәре Кондырча буендагы сугышта Аксак Тимер тарафыннан тар-мар ителгәннән соң, Б.х. тәхеткә утыра. Үз исеменнән акча суктыра. Шул елның августында Туктамыш хан аны тәхеттән бәреп төшерә. Б.х. Кырымга качарга мәҗбүр була һәм озакламый шунда үтерелә.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.


*И.Л.Измайлов.*

**БИКБУЛА́ТОВ** Әхмәт Сабир улы (7.7.1926, Ташкент — 1997, Киев), ген.-майор (1977). Ташкент танк уч-щесен (1952), Бронетанк гаскәрләренең хәрби академиясен (1961, Мәскәү) тәмамлый. 1944 елдан СССР Кораллы Көчләрендә. 1968–88 елларда Киев хәрби округында танк гаскәрләре берләшмәсе командиры урынбасары, округның һәм СССР Кораллы Көчләренең Көнбатыш гаскәрләре төркемендә бронетанк гаскәрләре идарәсе башлыгы. 1988 дән Украина Оборона министрлыгы ин-тында. Ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**БИКБУЛА́ТОВ** Илдар Галимнур улы (4.11.1953, Башкортстан АССР, Белорецк ш.), рәссам, Башкортстан Респ-касының атказ. рәссамы (1999). Уфа сәнгать ин-тын, Р.М.*Нурмөхәммәтов*ның нәкышь остаханәсен тәмамлый (1978). 1980 елдан Башкортстан Респ-касының Сәнгать фондында эшли, 1991–92 дә аның баш рәссамы, 1993–96 да Башкорт пед. ин-тында укыта. Рәссамнар берлеге (1986), «Чыңгызхан» (1990) һәм «Җиделек альянсы» (1989) рәссамнар иҗат төркеме әгъзасы. Уфада яши.

Б. иҗатында төп темаларның берсе — Уфаның татарлар яшәгән өлешендәге борынгы урамнарын, ямьле табигать урыннарын чагылдырган шәһәр пейзажы күренешләре. Шә-


И.Г. Б и к б у л а т о в. «Мәчет һәм бакча». 1992.

һәрдә сакланып калган берданбер борынгы мәчет образы югалган хәтернең яңару символына әверелә («Уфа офыклары», «Борынгы шәһәр», «Уфа мәчете», «Шәһәр. Уфа мәчете», барысы да — 1989; «Кызарып кояш баеганда», 1990; «Зәңгәр кич», 1991; «Мәчет һәм бакча», «Кич», һәр икесе — 1992; «Уфа тирәсе», 2000, «Авыл киче» (2003)). Психологик портретлар остасы Б. тарихи эшлеклеләр галереясын («Г.Тукай Уфада», 1986) һәм замандашлары образын — сугыш батырлары («Башкорт кавалерия дивизиясе сугышчысы М.Вәлиев», 1985; «Советлар Союзы Герое С.Х.Бикиев», 1985; «Ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәев», 1987), эшчеләр («Электромеханик Д.С.Мөхияров», 1978); «Механизатор Ш.Гәрәев», 1984), рәссамнар («Минем дусларым — рәссамнар Р.Харисов һәм Н.Латфуллин», 1987; «Әхмәт Лотфуллин портреты», 1998), актерлар («РСФСРның атказанган артисты И.Йомагулов», 1981; «БАССРның халык артисты Н.Ирсаева портреты», 1985), туганнар һәм дуслары портретларын («Карт инәй портреты», 1974; «Нәнәй», 1975; «Улым портреты», 1981; «Гүзәл Алишева», 1987, «Рәссам Наил Латфуллин портреты» (2000), «Әнкәй портреты» (2003)) иҗат итә. Бөтенроссия («Тынычлыкны якладык, тынычлыкны саклarбыз», Мәскәү, 1985), зона («Социалистик Урал» — Төмән, 1979; Свердловск, 1985; «Урал 8» — Уфа, 1997), «Татарт» төбәкара (С.-Петербург, Казан, 1991) күргәзмәләрдә катнаша. Уфада персональ күргәзмәләрен (1992, 2003) оештыра. Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкорт дәүләт сәнгать музеенда, «Казан» Милли мәдәни үзәк музеенда, шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Агишева Г. Шаги // Смена. 1985. № 3; Назаров М. Илдар Бикбулатов. Живопись: Буклет. Уфа, 1992; Валиева-Сөләйманова Г. Рәссамның урыны түрдән // Казан утлары. 1993. № 8; Художники Башкортостана. XX в.: Справ. Уфа, 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БИКБУЛА́ТОВ** Сөнгатулла Нигъмәтулла улы (1886, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Балыклыкүл а. — 1955, Казан), дин эшлеклесе. 1896–1906 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый (Оренбург ш.), сәүдәгәр М.Хөсәеновның матди ярдәме б-н әл-Әзһәр ун-тында белем алырга Каһирәгә җибәрелә. 1906–10 да «Татар-төрек шәкертләре» җәмгыятен оештыручыларның берсе һәм аның сәркәтибе. 1911 дән «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта, гарәп теле һәм әдәбияты, ислам тарихы дәресләре бирә. Бер үк вакытта 1912 дән Оренбург мөселман шәкертләренә иганәчелек итү җәмгыяте әгъзасы, рәисе урынбасары. Оренбург төрки-татар мөгаллимнәре җәмгыятен оештыручыларның берсе (1917). Окт. рев-циясеннән соң «Хөсәения» мәдрәсәсеннән үзгәртеп оештырылган Татар халык мәгарифе ин-тында эшли. 1924 тән Бохара мәгариф ин-ты укытучысы, 1926–48 дә Казанның төрле уку йортларында татар тарихы һәм этнографиясе, гарәп теле, география фәнен укыта. 1920–30 елларда Татар халкын өйрәнү фәнни җәмгыяте, «Худосызлар» («Алласызлар», Сәмәрканд), «Фән һәм дин» (Мәскәү) ж-ллары б-н хезмәттәшлек итә. Хезмәтләре гарәп теленә, ислам дине һәм татар халкы тарихына карый. Б.тарафыннан төзелгән гарәп теле дәреслеге татар мәктәпләрендә киң кулланыла, ул 1917 елдан соң да берничә тапкыр нәшер ителә. Исламга кагылышлы кайбер хезмәтләре Япониядә дөнья күрә. 1990 елларда Б.ның кайбер китаплары яңадан басыла.

Хезм.: Хәзрәти Мөхәммәд. К., 1914; Мәбдә әл-кыйраәт: 3 кис. К., 1913–15; Дин дәресләре: 4 кис. К., 1916; Мәбдә ән-нәхү. К., 1916; Дүрт хәлифә. 1 кис. Әбү Бәкер вә Гомәр дәвере. К., 1918.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**БИКБУЛА́ТОВА** Мәрьям Закир кызы (12.12.1910, Казан губ., Чабаксар өязе Янгилде а. — 4.6.1990, Казан), гамәли бизәлеш сәнгате остасы, татар халык иҗаты әсәрләрен җыючы һәм пропагандалаучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1940). Кукмара, Тымытык, Мөслим р-ннарында мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә эшли, 1933 елдан — Казанда. Б. татар халкы иҗаты әсәрләрен җыя, татарларның кулдан туку һәм чигү сәнгате үзенчәлекләрен өйрәнә. Аппликация, алтын, энҗе, сәйлән б-н чигү (калфаклар), ука һәм ефәк б-н тамбурлы чигү, чүпләмле туку (сөлгеләр, эскәтерләр, ашъяулыклар), йонлы паласлар һәм келәмнәр туку ысулларын үзләштерә. 1967 дән, татар бизәкләре мотивларына нигезләнеп, тукыма, кәгазь һәм фольга чәмчәләр б-н декоратив паннолар иҗат итә. Татар милли бизәкләре үрнәкләренең рәсемнәре бирелгән «Чигәргә өйрәнегез» дигән китап авторы. 1957 дән бөтенсоюз һәвәскәр рәссамнар әсәрләре күргәзмәләрендә (Мәскәү, 1965, 1967; Харьков, 1970), төбәкара — «Зур Идел» (1967, 1970), 16 автономияле респ-ка күргәзмәсендә (Мәскәү, 1971), «Совет Татарстаны» (Ленинград, 1960, 1972), респ-ка халык иҗаты һәм гамәли бизәлеш сәнгате күргәзмәләрендә катнаша. Эшләре ТРның Милли музеенда һәм ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда саклана.





М.З.Бикбулатова. 1. Чигелгән сөлге. Фрагмент. Киҗе-мамык тукыма, тоташ чигү. 1970 нче еллар; 2. Декоратив панно. Кәгазь, аппликация. 1980 нче еллар башы.

Хезм.: Учитесь вышивать. К., 1970.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Татарии: Биогр. справ. К., 1975.

*М.Е.Ильина.*

**«БИКБУЛАТОВНЫ́Ң С.-ПЕТЕРБУ́РГТА КАСЫ́ЙМ ТАТАРЛАРЫНА́ ЯРДӘ́М ИТҮ́ ҖӘМГЫЯТЕ́»**, җәмәгать оешмасы. 1867 елның гыйнварында С.-Петербургта оештырыла. Башлап йөрүчесе — Х.Х.Бикбулатов-Касыймлы. Төп максаты: үзара берләшеп җәмгыятьнең мохтаҗ әгъзаларына матди ярдәм итү, Рязань губернасы Касыйм шәһәрендә ятим балалар һәм ярдәмчесез калган картлар өчен ятим-мохтаҗлар йортлары ачу. 1880 елларда эшчәнлеге туктала.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**БИКҖА́НОВ** (Бикҗанов) Ибраһим Паскаевич (17.11.1895, хәзерге Рязань өлкәсенең Касыйм р-ны Болотце а. — 17.12.1988, Казакъстан ССР, Алма-Ата ш.), генерал-майор (1940). Кавалериядә команда составын камилләштерү (Новочеркасск ш., 1925), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академия каршындагы командирлар дивизиясе (Мәскәү, 1947) курсларын тәмамлый. Беренче бөтендөнья, Гражданнар сугышларында катнаша (унтер-офицер — кавалерист). 1918 елдан Кызыл Армия сафларында. 1918 дә Көньяк фронтта — взвод, 1919–20 дә кавалерия полкы командиры, Урта Азиядә милләтчел хәрби төркемнәр (басмачылар) б-н сугышларда катнаша. 1923–24 тә кавалерия уч-щесендә курсантлар эскадроны б-н җитәкчелек итә. 1926–29 да кавалерия полкы штабы башлыгы. 1930–38 дә 160 нчы кавалерия дивизиясе командиры. 1939–1941 дә Көнбатыш махсус хәрби округында 6 нчы механикалаштырылган корпусның 29 нчы моторлаштырылган дивизиясе командиры. Бөек Ватан сугышы башлангач, немец гаскәрләренең көчле һөҗүме Б. җитәкчелегендәге дивизиягә дә туры килә. 1941 нең 17 июлендә Б. үзенең документларын, хәрби киемен җиргә күмеп, гади киемдә зур булмаган командирлар төркеме б-н фронт сызыгына юнәлә. 1941 нең 25 июлендә Заболотье авылы (Бобруйск ш. янында) тирәсендә дошман б-н бәрелештә әсирлеккә эләгә. Башта Пуховичи шәһәре янындагы, соңрак Замостье лагерьларына (Польша) җибәрелә. Монда ул 1942 нең апреленә кадәр берүзе генә тотыла, аннары Хаммельбург (Германия) лагерена озатыла. Бер елдан соң Б. генераллар төркеме б-н Вайсенбург (Германия) крепостена күчерелә. 1945 нең 4 маенда Америка армиясе частьләре тарафыннан азат ителә. Бер ай дәвамында Париждагы совет хәрби миссиясендә репатриацияләү үтә, аннары Мәскәүгә кайтарыла һәм НКВД органнарында тикшерелә. 1945 нең декабрендә Кызыл Армия сафларына кире кайтарыла. 1947–50 елларда Алма-Ата

ун-тында хәрби каф. башлыгы. 1950 дән — авыру сәбәпле, отставкада. Ленин ордены, Ике Кызыл Байрак, Бохара респ-касының ике Кызыл ай, Үзбәкстанның Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Хакимов М.С., Сафаров М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

*М.З.Хәбибуллин.*

**БИККИ́НИН** Ирек Дамир улы (25.3.1956, Мордва Респ-касының Ләмберә р-ны Татар Таулы а.), журналист, җәмәгать эшлеклесе. Мордва ун-тының а.х. механикалаштыру (1982) һәм филол. (1990) ф-тларын тәмамлый. 1972–82 елларда Саранск кабель з-дында, Ләмберә р-нының Чапаев исем. с-зында эшли. 1982–92 дә Саранск экскаватор з-дында инженер-конструктор, маркетинг бүлеге җитәкчесе. 1992–97 дә яңа идеяләрне тормышка ашыру буенча «Опыт» («Тәҗрибә») консультация фирмасы директоры урынбасары. 1997 дән «Татар газетасы» («Татарская газета», Саранск ш.) һәм 1999 дан газетаның Интернеттагы татар, рус, инглиз телләрендә электрон сериясенең баш мөхәррире. Мәкаләләре «Праздник», (Минск ш.), «Ватандаш» (Уфа ш.) ж-лларында басыла. Аларда Мордва Респ-касында яшәүче татар-мишәрләр тарихы, мәдәнияте һәм ислам проблемалары яктыртыла. Мордва Респ-касында беренче мишәр фольклоры җыентыгын («Рәхмәт, әни!», 1996) һәм Һ.Такташ шигырьләре җыентыгын («Туган илгә кайту» — «Возвращение на родину», 2000) төзеп бастыра. 1991 елдан Мордва Респ-касының «Якташлар» татар мәдәни җәмгыяте советы рәисе. 2007 дән Мордва Респ-касының мөселман Диния нәзарәте юристы. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Тюркизмы в английском языке // Вестник Мордов. ун-та. 1991. № 4; Татары Мордовии // Российская провинция: история, культура, наука. Саранск, 1998.

*Әд.:* История Мордовии в лицах: Биогр. сборник. Саранск, 1999. Кн. 3; Мордовия: Энцикл. Саранск, 2001.

**БИККИ́НИН** Наил Барый улы (20.9.1931, Казан — 20.4.2007, Мәскәү), философ, филос. фән. д-ры (1978), РФАнең мөхбир әгъзасы (1991; 1987 дән СССР ФАнең мөхбир әгъзасы). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1954). 1958–63 елларда шунда укыта. 1963–66 да «Коммунист» ж-лында, 1966–87 дә КПСС ҮКнең пропаганда бүлегендә эшли. 1987 елдан «Коммунист» ж-лының, 1991 дән — «Свободная мысль» ж-лының баш мөхәррире. Хезмәтләре сәяси аң һәм сәяси эшчәнлекне, мәдәни бәйләнешләрне өйрәнүгә, чынбарлыкны чагылдыру формасы буларак идеологиянең асылын ачыклауга, хәзерге җәмгыятьтәге социаль үзгәрешләрне тикшерүгә карый. 1989–91 дә СССР ЮС депутаты.

Х е з м.: Культура как социальное явление. М., 1983; Политическое сознание. М., 1985.

**БИККИ́НИН** Ренат Айса (Гайсә) улы (9.3.1979, Саранск ш.), спортчы, (грек-рим көрәше), Россиянең халыкара классы спорт остасы (2000). РФнең атказ. тренерлары В.Ф.Зотов һәм А.П.Таракановның шәкерте. Мордва ун-тының геогр. ф-тын тәмамлый (2001). Шәхси беренчелектә Дөнья кубогы (2001); Европа кубогы (2002), Россия кубогы (2003); халыкара турнирларда (2000, «Ралусалу истәлегенә», Эстония; 2000, «Хаparanды кубогы», Швеция; 2001, Румыния) җиңүче. Студентларның дөнья беренчелегендә (2000, Токио); И.Поддубный исем. халыкара турнирда (2001, Мәскәү) көмеш медаль ала. 1997 елдан Саранск шәһәренең балалар, яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер.

**БИККИ́НИН** Фәйзи (Фәйзерахман) Бикмөхәммәт улы (1.10.1898, Казан — 29.3.1968, шунда ук), халык музыка уен коралларында уйнау остасы (гармун, скрипка), ТАССРның атказ. артисты (1963). 1915 елдан эстрадада (ш.и. татар «Сәйяр» драма труппасының инструменталь ансамблендә) скрипкачы һәм концерт гармуннарында уйнаучы буларак чыгышлар ясый. 1918 елда С.Сәйдәшев б-н бергә Буа шәһәрендә театр-музыка студиясен оештыруда катнаша. 1930–37 дә Татар радиосында, 1937–63 тә Татар филармониясендә эшли. Төрле конструкцияле гармуннарда виртуоз уйнау сәләтенә ия була. Репертуарына татар халкының борынгы «Әллүки», «Зиләйлүк», «Кара урман», «Уел», «Тәфтиләү» көйләре, татар композиторлары әсәрләре, төрле халыкларның көйләре һәм биюләре керә. Уфа, Ташкент, Алма-Ата һ.б. шәһәрләрдә гастрольләрдә була. Бөек Ватан сугышы елларында концерт бригадалары составында Балтыйк буенда, Польша, Германиядә чыгышлар ясый. Традицион татар музыка уен коралларында уйнау осталыгын камилләштерүгә зур өлеш кертә. Ел саен Ф.Биккинин исем. «Уйнагыз, гармуннар» гармунчылар фестивале уздырыла (1991 дән).

**БИККИ́НИН** Хикмәт Мифтах улы (6.12.1888, Сембер губ., Буа өязе Кече Салтык а. — 18.7.1929, Согуд Гарәбстаны, Хиҗаз провинциясе), педагог, дипломат. Чыгышы б-н крәстиян гаиләсеннән. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә (1912 елга кадәр), Каһирә ун-тында (1912–14) укый, Шәрекъ хезмәт ияләренең коммунистик ун-тын тәмамлый (1926, Мәскәү). 1914–16 елларда Казан һәм Оренбург мөселман уку йортларында гарәп теле укыта. 1916–17 дә Россия армиясендә: Румын фронтының 240 нчы запас пехота полкында хезмәт итә. 1917–18 дә Әшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Тәтеш шәһәр советы башкарма ком-ты әгъзасы. 1919–22 дә Кызыл Армиядә: Казанда сәяси курслар башлыгы һәм укытучысы. 1923 тә Казанда И.Гаспринский исем. гомуми белем бирү мәктәбе мөдире. 1926 дан СССРның Согуд Гарәбстанындагы вәкаләтле вәкиллеге хезмәткәре.

**БИККО́Л** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 18 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе чигендә. 2002 елда 468 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Клуб. Китапханә. Мәчет. 18 йөздә Зирекле һәм Төрнәс авылларыннан күчеп утыручылар нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1778 дә — беренче, 1883–86 да — икенче, 1905–06 да өченче мәчет (хәзерге көнгәчә сакланган; архит-ра истәлеге) төзелә. Мәчетләр каршында мәдрәсәләр эшли. 20 йөз башында җил һәм ярма ярдыру тегермәне, мануфактура, вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1707 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Максимка волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 548, 1897 дә — 1086, 1920 дә — 1538, 1926 да — 1177, 1938 дә — 831, 1949 да — 702, 1958 дә — 698, 1970 тә — 819, 1979 да — 656, 1989 да — 410 кеше.

**БИККО́ЛОВ** Әкъдәс Закир улы (2.3.1927, Бөгелмә ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1968), БАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1968). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли, нефть химиясе, химик технол. каф. мөдире (1962–94). Хезмәтләре нефть эшкәрткәндә һәм нефть химиясендә экстракция процессларын, күп компонентлы нефть системаларында фазалар тигезләнешен тикшерүгә карый. Аның тарафыннан поляр эреткечләрдә нефть фракцияләренең сайланып эрү механизмы өйрәнелә, сайланмалылык һәм эретү үзлеге кебек файдалану сыйфатларының уртак тәэсирен исәпкә алып, экстрагент сайлап алу ысулы эшләнә. Сайланулы эреткечнең нәтиҗәлелеген, аның физ.-химик үзлекләрен исәпкә алып, алдан әйтергә мөмкинлек бирә торган формуланы тәкъдим итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Растворимость компонентов нефти. Уфа, 1979; Теоретические основы определения равновесных свойств многокомпонентных систем: Учеб. пособие. Уфа, 1980; Основы промышленной экологии в химической технологии: Учеб. пособие. Уфа, 1990; Органические нефтяные отложения и их утилизация. Уфа, 1997 (автордаш).

**БИККО́ЛОВ** Ибраһим Җамалетдин улы (1884 яки 1885, Сембер губ., Буа өязе Яңа Тинчәле а. — 1938), җәмәгать эшлеклесе. педагог, публицист. К.Җ.*Бикколовның* энесе. Буа һәм Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә белем ала. «әл-Ислах» хәрәкәтендә катнаша (1905–06). 1906–13 елларда Томск шәһәрендә укыта, бер үк вакытта «Шура», «Мәктәп», «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» ж-ллары һәм «әл-Ислах», «Сибирия», «Йолдыз», «Ил» г-талары б-н хезмәттәшлек итә. Гомуми белем бирү уку йортлары, хатын-кызлар мәктәпләре ачу тарафдары. 1917 нең сентябрендә Сембер шәһәрендә «Җөмһүрият» г-тасын чыгара. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18). 1920 еллар башында Уфа шәһәрендә совет мәктәпләре оештыруда катнаша. 1923–27 дә Казан театр техникумында татар теле укыта. 1929 елдан Урта Азиядә — Сәмәркәнд шәһәренең күн з-дында тәрҗемәче. Башлангыч сыйныфлар өчен дәреслекләр авторы; халык хуҗалыгына караган хезмәтләрне татар теленә тәрҗемә итә. 1930 да репрессияләнә (к. «*Солтангалиевчеләрнең Мәскәү эше*» эше); үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Мәктәптә тән тәрбиясе. К., 1926.

*Әд.:* Ибраһимов Г. Яңа имзалар вә яшь күәтләр // Йолдыз. 1915. 29 апр.; Рәми И. Вакытлы татар матбугаты. Альбом (1905–1925). К., 1926.

*Ф.И.Ибраһимова.*



К.Җ. Бикколов.

**БИККО́ЛОВ** Илдус Әюп улы (23.1.1949, Чирмешән р-ны Бәркәтә а.), аппаратчы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1987), ТРның атказ. химигы (1997). 1968–2003 тә «Түбәнкаманефтехим» АҖдә. Дәүләт бүләге хезмәттә югары уңышларга ирешкәне, чимал, машина һәм җиһазлардан файдалануны яхшыртуга зур өлеш керткәне өчен бирелә. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары б-н бүләкләнә.

**БИККО́ЛОВ** Касыйм Җамалетдин улы (1868, Сембер губ., Буа өязе Яңа Тинчәле а. — 21.6.1937, шунда ук), тарихчы, язучы, педагог. 1885 елдан Әстерхан губернасы Киләче авылы мәдрәсәсе мөгаллиме. 1905 тән Яңа Тинчәле авылы мулласы (1930 елларда муллалыктан китеп тора, репрессияләнә, берничә ел Уфада сөргендә була). 20 йөз башы авылы турында әдәби әсәрләр, ислам тарихы буенча очерклар, уку әсбаплары, Яңа Тинчәле, аның тирә-ягындагы авыллар тарихы, халкының этник составы, аларга беренче нигез салучыларның шәҗәрәләре, мәчетләр тарихы һ.б. бәян ителгән «Яңа Тинчәле авылы тарихы» исемле кульязма хезмәт авторы (1926; Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсендә саклана).

Х е з м.: Ат караклары. К., 1907; Алтынбай агай. К., 1908; Төркестан. К., 1908; Сабирҗан агай. К., 1909; Татар ханнары. К., 1911; Балаларга үрнәк. К., 1912; Хаҗи. К., 1912; Пәйгамбәрләр тарихы. К., 1911–12; Ислам тарихы. К., 1918.

*Әд.:* Г о с м а н о в М.Г. «Җәяүле тарихлар» да була... // Татарстан. 1994. № 7/8; ш у л у к. Каурый каләм эзеннән. К., 1994; Ш а й х и е в Р.А. Татарская народно-краеведческая литература XIX–XX вв. К., 1990.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**БИККО́ЛОВ** (Бикулов) Нурхәтим Зариф улы (10.2.1937, Куйбышев өлкәсенең Похвистнев р-ны Яңа Мансур а.), нәкышьче, монументаль сәнгать рәссамы. Сталинабад (Дүшәнбе) сәнгать уч-щесен (1961) һәм Харьков сәнгать ин-тының монументаль нәкышь бүлеген (1968) тәмамлый. Б.В.Косарев һәм В.С.Ермилов шәкерте. 1969 елдан Самара шәһәрендә яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1975).


Б. жанрлы нәкышь, пейзаж һәм портрет остасы. «Чишмә янында» дигән беренче эше үк (1969, жанрлы нәкышь элементлары булган пейзаж) Б.ның иҗат юнәлешен, аның татар авылы темасына, күләмле гомумиләштерүләргә тартылуын чагылдыра. Яшәешнең поэтик картинасы ш.у. авыл кешеләре тормышына багышланган әсәрләрендә гәүдәләнә («Ак атлар», 1969; «Көтү каршылау», «Бәйрәмгә әзерләнү», 1975; «Кырда», 1979; «Көтүче сайлау», 1986). Б. халык сәнгате алымнарын, шартлы, ш.у. реалистик сурәтләү чараларын куллана. Хатын-кыз гүзәллеге темасы «Гүзәл кыз портреты» (1977), «Дөньяның бердәмлеге» (1989), «Сок елгасында» (1990), «Табигать чакыруы» (1990), «Диңгез буенда» (1992), «Кызым портреты» (2006–07), «Нимфа» (2007), «Чегән кызы портреты» (2007) картиналарында ачыла. 1990 елларда Б. мифологиягә мөрәҗәгать итә — әкият образлары аның картиналарының геройларына әверелә («Моң»,



Н.З. Б и к к о л о в. «Көтү каршылау». 1986.

1989; «Шүрәле һәм алиһәләр», 1990; «Яз җитте», 1993; «Су анасы», «Убырлы», 1990 еллар, «Төн», 2007). Б. монументаль нәкышь өлкәсендә дә актив эшли — җәмәгать биналарын бизи. Бу юнәлештә «Гаилә бәхете», «Яшьлек» (1984, Өйләнешүчеләр салоны), «Омтылыш» (1987, Никахлашу сарае) — барысы да Самара шәһәрендә; «Сәламәтлек», «Гүзәллек», «Җыр» (1987, Куйбышев мед. ин-ты интерьеры) әсәрләрен иҗат итә.

1969 дан бөтенсоюз, бөтенроссия күргәзмәләрендә, төбәкара күргәзмәләрдә («Зур Идел») катнаша. Шәхси күргәзмәләре Самарада (1972, 1974, 1986, 1996, 2003), Казанда (2002) Похвистневода (2004) уза. Әсәрләре Самара сәнгать музеенда, Татарстан сынлы сәнгать музеенда (Казан), Пахвистнев районы музеенда, «Комацо» (Япония) галереясында һәм чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.



Н.З. Б и к к о л о в. 1. «Бәйрәмгә әзерләнү». 1975; 2. «Кыз һәм ат». 1993.

*Әд.:* Нурхатим Бикулов: Каталог персональной выставки. М., 1984; Историко-культурная энциклопедия Самарского края: Персоналии. Самара, 1993.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова..*

**БИККО́ЛОВ** Шаһингәрәй Бикчәнтәй улы (1846–1920), матбагачы, китап басу остасы. 1858 елдан Казан ун-ты басмаханәсендә хәреф җыю һөнәрен үзләштерә. 1869 елда И.Ф.Готвальд тәкъдиме б-н Петербург ФА басмаханәсе матбагасына күчерелә. 1875 тә Казанга кайтканнан соң, шәһәрнең төрле басмаханәләрендә хезмәт итә. Үзбәк милли матбагасына, үзбәкчә китап басу эшенә нигез салучыларның берсе.

*Әд.:* Ю л д а ш е в З. Развитие книгоиздательского дела в Узбекистане. Таш., 1969; К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарского книгопечатания: От начала возникновения до 60-х годов XIX века. К., 1992.

**БИКЛӘ́Н** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бикләнелгасы буенда. 2002 елда 1279 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, мөгезле эре терлек асрау; бентонит балчык карьеры. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1724 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сарсаз, Бичурин исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, урман кисү, балта эше һәм итек тегү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Б.дә мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне була. 20 йөз башында 3 мәчет, 1 мәдрәсә, 3 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3434,7 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостена керә. 1920 елдан ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1795 тә — 143 ир заты; 1859 да — 1050, 1870 тә — 1304, 1897 дә — 2226, 1913 тә — 2886, 1926 да — 2435, 1938 дә — 1934, 1949 да — 1429, 1958 дә — 1470, 1970 тә — 2014, 1979 да — 1715, 1989 да — 1348 кеше.

**БИКЛӘ́Н** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Каманың сул кушылдыгы. Озынлыгы — 12,2 *км*, бассейнының мәйданы — 60,9 *км²*. Тукай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Бикләнавылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы — Бәтке авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге — 162 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы — 3%. Б. елгасының 0,5 тән алып 6,2 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы — 0,44 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле — 0,1 *л/с·км²* га кадәр. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда

еллык су агымының уртача күпьеллык катламы — 80 *мм*, ташу агымы катламы — 73 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа, апрель уртасында боздан арчыла. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы — 0,015 $м^3/с$. Ел дәвамында суы бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын — 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен — 1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында күләме 280 мең $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БИКЛӘ́Н БЕНТОНИ́Т БАЛЧЫКЛА́Р ЧЫГАНАГЫ́**, Татарстанда иң эреләренең берсе. Тукай р-нының Биклән авылы янында, Чаллыдан 15 *км* көньяк-көнбатышта. 1950 елда ачыла, 1956 елдан эшкәртелә. Сәнәгать запаслары 28,5 млн. *т* (2006), еллык чыгарылышы 150 мең *т* (2005). Файдалы катламы неоген утырмаларында. Төп компонентлары: монтмориллонит (40–50 %), гидрослюдалар һәм каолинит, комсыл-алевролитлы материалда — кварц, чакма ташы, мусковитның катламлы кисәкчекләре, пирит, магнетит, гранит һ.б. Биклән бентонит балчыклары Татарстан, Көнбатыш Себер нефть бораулау пр-тиеләре тарафыннан бораулау измәсе ясауда, коеп ясалган зур әйберләр эшләүдә форма чималы итеп, югары сыйфатлы керамзит әйберләр ясауда, химия сәнәгатендә (адсорбент, ш.и. эшкәртелгән майларны кире үз хәленә кайтару), терлекләрне үстерү өчен биостимулятор сыйфатында, фармакологиядә, резина-техник әйберләр җитештерүдә файдаланыла. Чыганак нигезендә Әлмәттә 1957 елдан балчык порошогы з-ды эшли.

**БИКМА́ЕВ** Шамил Зәкәрия улы (1.10.1941, хәзерге Мордва Респ-касы, Ләмберә р-ны Аксёново а.), җәмәгать эшлеклесе, эшмәкәр, меценат, Мордва Респ-касының атказ. эшмәкәре (2001), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2003). Икътисад фән. канд. (1978). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1967). 1957 дән колхозда эшли; 1959–60 та шахтёрлар мәдәният сараенда (Караганда) сәхнә эшчесе; 1960 елдан «Сарансккабель» з-дында: слесарь, техник-конструктор, технолог, өлкән инженер-конструктор; 1966 дан Саранск «Биохимик» комб-тында өлкән инженер, механик, цех башлыгы, баш механик булып эшли. 1976–89 да төзү-монтаж идарәсе җитәкчесе. 1989 дан Саранск «Монтажник» фәнни-җитештерү кооперативы (хәзер «Монтажсервис» ЯАҖ) рәисе. Мордва Респ-касы ЮС (1990–94), Мордва Респ-касы Дәүләт җыелышы (1998 дән) депутаты. Мордва Респ-касы Җәмәгать Советы палатасы әгъзасы (2006 дан). Мордва Респ-касы җитәкчесе киңәшчесе (1998 дән). Б. Мордва Респ-касында беренче эшмәкәрләрдән һәм АҖләрне оештыручылардан; «Якташлар» татар мәдәнияте җәмгыятен оештыручыларның берсе (1991 дән). Мордва Респ-касы татарлары милли-мәдәни автономиясенең Аксакаллар Шурасы рәисе (2002 дән). Саранск «Арина» җәмәгать хәйрия фондының попечительләр советы рәисе (2000 нән). «Бердәм Россия» партиясенең Мордва төбәк бүлекчәсе сәясәт советы әгъзасы (2001 дән). «Меценат» исемә ия, медальләр б-н бүләкләнгән; «Меценат 2000» дигән мактаулы исем бирелгән.

Хезм.: Методика определения напряжённости планов // Некоторые вопросы исследования технологии антибиотиков и кровезаменителей. Саранск, 1975; Применение ротационно-импульсного аппарата для интенсификации процесса экстрагирования пенициллина // Химико-фармацевтический журн. М., 1974. № 7.

*Әд.:* История Мордовии в лицах. Саранск, 1994; Всё о Мордовии. Энцикл. словарь. Саранск, 2004; Саранск-Казань: узы дружбы: Книга-альбом. Саранск, 2005; Золотая книга наций. М., 2006. Т. 2.

**БИКМӘ́Ч** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 15 *км* көнчыгыштарак, Казанчы елгасы буенда. 2002 елда 105 кеше (марилар — 57%, татарлар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1928 дә Яңа Усы авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. ТАССРның Минзәлә кантоны Мөслим волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1938 дә — 217, 1949 да — 249, 1958 дә — 184, 1970 тә — 214, 1979 да — 188, 1989 да — 117 кеше.

**БИКМӨХӘММӘ́Д** (17 йөзнең ахыры — 18 йөзнең 2 нче яртысы), язучы. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Касыйм морзасы Галикәй Аталыкның «Галикәй Аталык васыйәтнамәсе» китабыннан көлеп, пародия рәвешендә язылган «Хәрамнамә» (1690) әсәре авторы. Юрау китабы «Фалнамә» (1690) кульязмасы да аның тарафыннан күчерелгән дигән фикер бар.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БИКМӨХӘММӘ́ТОВ** Закирҗан Миңнемулла улы (27.3.1963, Кукмара р-ны Чишмәбаш а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), а.х. фән. канд. (2004), ТР а.х. атказ. хезмәткәре (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1989). 1998 елдан Кукмара р-нының «Заветы Ильича» к-зы рәисе, 1999 дан Теләче р-нының Ленин исем. тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы директоры, 2003 тән «Россельхозакадемия» Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының директор урынбасары, 2005 тән 104 нче һөнәри уч-ще директоры (Саба р-ны). Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында азык җитештерү системасын эшләү һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**БИКМӨХӘММӘ́ТОВ** Исмәгыйль (? — 1801 тирәсе), Оренбург сәүдәгәре, сәяхәтче. 1751–52 елларда Н.Сәфәров, Я.Агъфәров һ.б. б-н сәүдә кәрванында Һиндстанга мал-туар алып бара. Кайтышлый Мәккәдә, Дәмәшкъта була. Кайтыр юлга акчасы беткәч, Истанбулда сәүдә эшенә яллана. Россиягә чама б-н 1784 тә генә кайтып җитә. «Исмәгыйль ага сәяхәте» юлъязмасы авторы (кульязмасы сакланмаган). Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсендә сәяхәтнамәнең берничә күчермә нөсхәсе бар. Сәяхәтнамә өч өлештән тора: Урта Азия аша Әфганстан, Иран, Гыйрак юлы; Һиндстан буйлап сәяхәт кылу; ислам дине үзәкләрендә (Гарәбстанда) йөреп, мөселманнар өчен изге урыннарга зиярәт кылу һәм Төркия аша туган илгә әйләнеп кайту. Сакланган нөсхәләрдән иң тулысын Г.С.Саблуков «Ике хаҗиның рихләтнамәсе» («Путешествие двух паломников», 1862) исеме б-н бастырып чыгара. Соңрак сәяхәтнамәне Ризаэтдин Фәхретдин дә нәшер итә («Исмәгыйль ага сәяхәте», 1903 ел).

*Әд.:* Усманов М.А. Записки Исмаила Бекмухамедова о его путешествии в Индию // Ближний и Средний Восток. М., 1967; Алеева А.Х. Путешествие Исмаил-ага в Индию. К., 1993.

*М.В.Гайнетдинов.*

**БИКМӨХӘММӘ́ТОВ** Роберт Гата улы (11.1.1929, БАССРның Илеш р-ны Илеш а. — 28.8.1995, Мәскәү), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, филол. фән. д-ры (1983), проф. (1987). Рус, татар, башкорт телләрендә яза. Казан ун-тын тәмамлый (1952). Беренче хезмәтләре 1948 дә басыла. 1956 елдан Мәскәүдә яши. 1956–59 елларда СССР ФАнең М.Горький исем. Бөтендөнья әдәбияты ин-тында эшли. 1960–61 дә «Дружба народов» ж-лында баш мөхәррир урынбасары. 1962 дән Мәскәү ун-тының әдәбият тарихы кафедрасында укытучы, милли әдәбият секторы мөдире. Г.Ибраһимов, М.Җәлил, Г.Тукай, Ш.Бабич, Ә.Фәйзи, Һ.Такташ, Х.Туфан, Ә.Ерикәй, С.Хәким, М.Әмир иҗатларын өйрәнә. Хезмәтләренең төп темасы — бөтендөнья мәдәнияте җирлегендә СССР халыкларының милли әдәбиятлары, әдәби процессны өйрәнүдә тарихи-чагыштыру методологиясе, әдәбиятларның бер-берсенә йогынтысы закончалыклары. «Поэзиябезнең үлмәс чәчәкләре» (1960) китабы татар поэзиясенең күп гасырлык үсеш тарихына багышлана. Кайбер хезмәтләре инглиз, немец, поляк телләрендә басылган.

Хезм.: Дорога остаётся. М., 1969; Орбиты взаимодействия. М., 1983; Муса Джалиль. Личность, творчество, судьба. М., 1989.

*Әд.:* Шариф А. Не в том ключе // Пути развития советской многонациональной литературы. М., 1967; Ломидзе Г. На уровень новых задач // Вопросы литературы. 1977. № 10.

*В.Х.Ганиев.*

**БИКМӨХӘММӘ́ТОВА** Зирәк Умәр (Гомәр) кызы (6.8.1935, Кыргызстан ССРның Ыссык-Күл өлкәсе Тамга а.), биолог, биол. фән. д-ры (1976). Урта Азия ун-тын тәмамлый (1958, Ташкент). Үзбәкстан ССР ФА ин-тларында эшли; 1985 елдан Физиология һәм биофизика ин-тында лаб. мөдире. Төп хезмәтләре биомембраналар аша ионнарның молекуляр транспорт механизмнарына һәм күзәнәк эшчәнлеген җайлау механизмнарына карый.

Хезм.: Гормональная регуляция транспорта ионов. Таш., 1975.

**БИКМӨХӘММӘ́ТОВА** Хаува Сафиулла кызы (1.09.1921, хәзерге Чиләбе өлкәсенең Златоуст ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1973), проф. (1974), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). 1944 елда Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1973 елдан топографик анатомия һәм ашыгыч ярдәм хирургиясе каф. мөдире. Инфаркт кичерүнең төрле вакытларында әгъзалар һәм системалардагы морфофункциональ үзгәрешләрне өйрәнә һәм кайтма булмаган па-

тологик реакцияләрне булдырмый калу ысулларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Хирургическое лечение коронарной болезни. Воронеж, 1972.

**БИКМУ́ЛЛИН** Альберт Лотфулла улы (31.7.1939, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1994), ТАССР һәм РСФСРның атказ. икътисадчысы (1988, 1995). 1963 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1962–68 елларда Казан пр-тиеләрендә инженер булып эшли. 1968–70 тә ТАССР Статистика идарәсенең Хисаплау үзәге директоры урынбасары. 1970–79 да Бөтенсоюз насос машиналары төзү технологиясе фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында проектлар баш инженеры, лаб., бүлек мөдире, 1979–93 тә Статистик мәгълүмат системасы фәнни-тикшеренү һәм проект-технол. ин-тының Идел-Вятка ф-лы директоры. 1994 елдан ТРның Мәгълүматлаштыру академиясе президенты. Хезмәтләре хисаплау өлкәсендә мәгълүмат технологияләрен модельләштерү һәм эшләүгә, мәгълүматлаштыруның бердәм дөнья системасына тәңгәл килә торган федераль һәм региональ системаларын, челтәрләрен төзүгә һәм үстерүгә карый. Б. халык хуҗалыгының төрле тармаклары өчен автоматлаштырылган хисаплау системалары төзи һәм гамәлгә кертә.

Х е з м.: Основы прикладной теории научно-технического прогнозирования. М., 1976; Имитационное моделирование систем обработки данных бухгалтерского учёта. К., 1992.

**БИКМУРА́З** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* ераклыкта. 2002 елда 434 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1623 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык, йомырка җыеп сату б-н шөгыльләнә, урман кисүче булып эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 641,6 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырыңгы волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 229, 1859 да — 435, 1897 дә — 722, 1913 тә — 828, 1920 дә — 850, 1926 да — 784, 1938 дә — 680, 1949 да — 633, 1958 дә — 528, 1970 тә — 694, 1979 да — 719, 1989 да — 398 кеше.

**БИКМУ́РЗИН** Азат Шәүкәт улы (1.1.1969, Казакъстан ССРның Караганда өлкәсе Шахта ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1990), «Түбәнкамнефтехим» АҖдә: пиролиз аппаратчысы, смена башлыгы, участок башлыгы, цех башлыгы урынбасары, башлыгы (1998 дән), этилен з-ды директоры (2003 тән). Дәүләт бүләге түбән олефин, бутадиен һәм бензол җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм егәрлеген арттыру буенча комплекслы эшләрнең фәнни һәм практик нигезен эшләгәне һәм аларны җитештерүгә кертүгә кертүгә өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**БИКМУ́РЗИНА** Флюра Габдрахман кызы (1.7.1939, Әлки р-ны Иске Салман а.), актриса, телевидение режиссёры, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990), ТРның халык артисткасы (1993). Казан Зур драма театры каршындагы студияне (1961), Казан пед. ин-тын (1968), Бөтенроссия телевидение һәм радиотапшырулар хезмәткәрләре ин-тын (Мәскәү, 1982) тәмамлый. Актёрлык эшчәнлеген 1959 елда Татар акад. театрында башлап җибәрә. Төп рольләре: Фирүзә («Умырзаялар», Ю.Әминов), Назирә («Киек каз юлы», А.Гыйләҗев). 1961 елдан «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясендә режиссёр ярдәмчесе, 1974 тән телевидение режиссёры, 1998 дән мәгълүмат һәм иҗтимагый-сәяси программалар дирекциясе баш режиссёры. Бер үк вакытта 1964–65 елларда телевидениедә татар телендә балалар өчен «Бергәләп җырлыйк» дигән муз. тапшырулар алып бара. Казан телестудиясендә куелган спектакльләрдә баш рольләрне башкара: «Король Лир» телефильмында Корделия (У.Шекспир, реж. В.Мурзин, 1964); «Сандугач сары булмый» телеспектаклендә Ана (Р.Батулла, реж. Ә.Зарипов, 1989). 1980–90 да Үзәк телевидение өчен ТАССРның иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышын чагылдырган еллык йомгаклау тапшыруларын әзерли. «Кеше һәм закон», «Сезнең позициягез», «Пропагандист һәм заман» һ.б. тапшырулар циклларын, ш.у. күренекле сәясәт һәм культура эшлеклеләре турындагы «Ихлас» видеофильмнар циклын гамәлгә ашыручы режиссёр.

**БИКНАРА́Т** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 39 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мари Респ-касы чигендә. 2002 елда 201 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 524,5 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Краснококшайск (1919 га кадәр — Царёвококшай) өязе Сотнур волостена керә. 1920–21 дә Мари автономияле өлкәсе составында. 1921 елның 22 сентябреннән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1803 тә — 80, 1959 да — 201, 1897 дә — 393, 1908 дә — 480, 1922 дә — 429, 1926 да — 572, 1938 дә — 660, 1949 да — 551, 1958 дә — 433, 1970 тә — 380, 1989 да — 214 кеше.

**БИКТАҺИ́РОВ** Искәндәр Исмәгыйль улы (12.10.1951, Чирмешән р-ны Югары Чыгтай а.), җырчы, ТРның халык артисты (2000). 1980 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый, 1982–84 тә Казан консерваториясендә З.Хисмәтуллина классында белем ала. 1975–81 дә ТР Җыр һәм бию ансамбле хоры артисты, 1981–95 тә Татар филармониясе эстрада бүлегенең солист-вокалисты, 1995 елдан Казан шәһәр филармониясе солисты. Җырчының репертуарында татар халык җырлары (ш.и. Г.Тукай шигырьләренә) мөһим урын алып тора. Б. үз иҗатында, татар халык җырларының үзенчәлеген тирәннән аңлап, аларны башкаруда яңа алымнар эзли; аңа фольклор музыкасының бөтен нечкәлеген тоеп, халык лирикасын күпьяклап ачу сәләте хас. «Әллүки», «Зиләйлүк», «Туган тел», «Тәфтиләү», «Уйлану», «Хатлар язам» кебек күп кенә татар халык җырлары Б. башкаруында яңача яңгыраш ала, аеруча популярлык казана. Б.ның репертуарына ш.у. татар композиторлары С.Сәйдәшевнең «Уяньсыннар кырлар» (Ә.Фәйзи шигыре), З.Хәбибуллинның «Айлы төн» (Ә.Ерикәй шигыре), Р.Яхиннның «Җырларым» (М.Җәлил шигыре), С.Садыйкованың «Татарстан — минем республикам» (Н.Дәүли шигыре), Л.Батыр-Болгариның «Ак яулыклы әнием» (Н.Касыймов шигыре), Р.Ахиярованың «Әй, җанаш» (Р.Харис шигыре) һ.б. җырлары керә. Җырчы үзбәк, таҗик, казакъ, төрекмән, гарәп, ш.у. рус җырларын да башкара. Б. радио һәм телевидениедә дә чыгышлар ясый («Татарстан» ДТРК фондында аның 50 дән артык язмасы бар), Идел буе, Урал, Себер шәһәрләрендә, Мәскәүдә, С.-Петербургта һәм чит илләрдә концертлар б-н гастрольләрдә була.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*

**БИКТА́ШЕВ** Евгений Михайлович (Гаделша Мәхмүт улы) (30.5.1939, Саратов өлкәсенең Екатеринино р-ны Галахово а.), композитор, РФнең халык артисты (1997), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). 1964 елда Саратов музыка уч-щесен тәмамлый. «Сандугач» җыр һәм бию ансамблен оештыручы һәм аның сәнгать җитәкчесе (Саратов ш.). 1982–90 да Саратов өлкә филармониясенең «Музыка үзәге» иҗат төркеме җитәкчесе, 1996 елдан «Идел буе» өлкә концерт оешмасы җитәкчесе һәм Саратов Композиторлар берлеге рәисе. Б.ның иҗатында төп урынны җырлар алып тора. Б. җырлары (ш.и. М.Җәлил, Г.Зәйнашева шигырьләренә) Россиянең оркестрлары, ансамбльләре һәм танылган җырчыларының репертуарларына керә, радио, телевидениедән яңгырый, грампластинкаларга языла. Б. — симф., камера-инструменталь, камера-вокаль һәм хор әсәрләре, татар, рус, чуаш, мордва җырларының хор өчен эшкәртмәләре, рус һәм татар шагыйрьләре шигырьләренә җырлар цикллары авторы. Алар арасында: «Җир йокысы» (Г.Тукай поэзиясе мотивлары буенча скрипка һәм фортепиано өчен соната), «Сабан туе» (рус халык уен кораллары оркестры, хор һәм солистлар өчен татар сюитасы), «Язмыш чыганаклары» («Истоки судьбы») (беренче симфония), «Иркен тормыш» («Раздолье») (Саратов гармуннары һәм баян өчен концерт), «Идел буе таҗы» («Венец Поволжья») (рус халык уен кораллары оркестры, солистлар һәм хор өчен 2 нче сюита) һ.б. Саратов шәһәренең шәрәфле гражданы (1996).

**БИКТА́ШЕВ** Нәкый Габделкәрам улы (19.3.1926, БАССРның Дуан р-ны Үлкунды а. — 29.10.1984, Чаллы ш.), нәкышьче, график, педагог. Казан сәнгать уч-щесен тәмам-





Н.Г.Б и к т а ш е в. 1. «Мәскәү университетында укучы Гана студенты». 1959;
2. «Г.Тукай портреты». 1984. Икесе дә ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

лый (1949), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тының графика бүлегендә укый (1951–54). 1954–78 елларда Казан сәнгать уч-щесендә укыта, Сәнгать фондында эшли. 1979 дан Чаллыда. Сәнгать уч-щесендә укыта (1980 нән). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). Б. — портрет остасы. Бу жанрдагы әсәрләре: «Әсгать Җиһаншин» (1962), «Монтажчы кыз» (1969), «Муса Җәлил» (1971), «Социалистик Хезмәт Герое газ үткәрүче И.Шәйхетдинов» (1979); «Муса Җәлил Тиммерманс белән Моабит төрмәсендә» (1984); «Х.Уразиков», «М.Ш.Бибишев» (1980 еллар). Көнкүреш жанрындагы картиналары: «Уку вакытында» (1956), «Юлда» (1964), «Безнең бригада» (1967), «Эштән соң» (1974). Ә.Фәйзинең «Тукай» романына (1957), М.Галинең «Каюмның балачагы» (1958) китабына иллюстрацияләр, плакатлар авторы. Б. Чаллының сәнгать тормышына сизелерлек йогынты ясый. Кама аръягы шәһәрләрендә эшләүче күп кенә рәссамнарны һәм бизәүчеләрне әзерләүгә өлеш кертә.

Бөтенроссия («Автономияле респ-калар рәссамнары әсәрләре», Мәскәү, 1971), төбәкара («Зур Идел», 1967, 1980) һәм республика (1957 дән) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Казандагы М.Горький әдәби-мемориаль музеенда, Чаллы картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

**БИКТА́ШЕВ** Һабил Хаҗи улы (23.5.1957, Куйбышев өлкәсенең Шонталы р-ны Татар Абдекәе а.), спортчы (дзюдо), СССРның атказ. спорт остасы (1984). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Самара ш.). Авыр үлчәүдә Европа (1983, 1985), СССР (1988) чемпионы, Игелекле уеннарда (1986), «Дружба-84» һ.б. халыкара ярышларда җиңүче, Европа чемпионатында (1984) көмеш, дөнья чемпионатында (1985) бронза медальләр ала. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә (1984). 1970 елдан Самара шәһәрендә яши.

**БИКТӘ́Ш** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шушма елгасы буенда. 2002 елда 218 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. 18 йөз ахырында Дорга, Югары Чура, Яңгул авылларыннан күчеп утыручылар нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Халкы (керәшен татарлар) Чепья авылы православие приходына керә. 1903 елда Покрау чиркәве (1918 дә яна) ачыла. 1881 елдан миссионерлык мәктәбе эшли, 1913 тә ул земство мәктәбе итеп үзгәртелә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 521,1 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сизнер волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Арча кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1834 тә — 158, 1859 да — 174, 1884 тә — 363, 1897 дә — 419, 1910 да — 518, 1920 дә — 619, 1926 да — 509, 1938 дә — 508, 1958 дә — 244, 1970 тә — 282, 1979 да — 255, 1989 да — 238 кеше.

**БИКТИМЕ́РОВ** Әхмәтҗан (19 йөз ахыры, хәзерге Яшел Үзән р-ны Бакырчы а. — 23.05.1915, Томск губ. Тайга ш.), язучы, журналист. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Урта Азия, Себер, Монголия һәм Төньяк Кытай буйлап озак сәяхәт итә, сәүдә эшләре б-н шөгыльләнә; Самара, Бозаулык, Ташкент, Коканд, Томск шәһәрләрендә яши. 1907–08 елларда Ташкентта «Шөһрәт» г-тасында эшли, «Асия» («Азия») исемле г-та чыгара, «Фикер», «Бәянелхак», «Сибирия», «Идел» г-таларында языша, «Шура» ж-лында төрки халыкларның тарихы, мәдәнияте, тормыш-көнкүреше турында күп кенә мәкаләләр бастыра, арада педагогикага, медицинага багышланганнары да бар. «Үткән мәхәббәт» (Оренбург, 1905), «Ятим Сабир, яхуд Бай кызы» (К., 1907), «Хәлфә» (Эстәрлетамак, 1912) исемле проза китаплары, мәктәпләр өчен «Русия тарихы» (К., 1914) дәреслеге авторы.

Ә с ә р.: Үткән мәхәббәт. Оренбург, 1905; Төркестан вилайәте // Шура. 1908. № 6,8,12,13,23,24; 1909. № 2,6,10; Хәлфә. Эстәрлетамак, 1912; Русия тарихы. К., 1914.

*Әд.:* Г.М.Г. Идарәгә мәктүб // Кояш. 1915. 7 июнь; Ә м и р х а н Ф. Сайланма әсәрләр. К., 1986. 4 т.

*З.З.Рәмиев, М.И.Әхмәтҗанов.*

**БИКТИМЕ́РОВ** Үзбәк Габдрахман улы (12.8.1926, Төньяк Казакъстан өлкәсенең Петропавловск ш. — 22.6.1997, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, терлек азыгы җитештерү өлкәсе галиме. Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1952), Әтнә МТСында директор һәм баш агроном булып эшли. 1957 елдан ТАССР а.х. министрының беренче урынбасары, 1959 дан — министр. 1962–64 тә Минзәлә терр-ясендә колхоз-совхозлар идарәсе башлыгы. 1964–69 да Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясе, 1969–71 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1971–87 дә Казан вет. ин-тының терлек азыгы җитештерү һәм ботаника каф. мөдире. Хезмәтләре үлән катнашмаларының рациональ составын һәм культуралы болыннарны сугару режимын өйрәнүгә карый. «Кыен кыр» («Трудное поле», 1986), «Иясез җир» («Ничейная земля», 1992) исемле фәнни-популяр китаплар авторы. ТАССР ЮС депутаты (1959–67). Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Орошаемые сенокосы и пастбища Татарии. К., 1979; Системы земледелия Татарской АССР. К., 1982 (автордаш); Орошение: три укоса гарантировано. К., 1983.

**БИКТИМЕ́РОВ** Шәүкәт Хәсән улы (28.10.1928, Казан), драма актёры, ТАССР, РСФСР, СССРның халык артисты (1968, 1970, 1977). Татар театр техникумын тәмамлаганнан соң, Татар акад. театры труппасына алына (1949). Эшли башлавының беренче елларында ук төрле пландагы рольләрне уйнап, характерларның аерым типик сыйфатларын, үзенчәлекләрен, образларның психологиясен ачарга омтыла. Токай («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Леон («Хатынны ничек кулга алырга», Ф.Бомонт, Дж.Флетчер), яшүсмер егет Микола («Мартын Боруля», И.К.Карпенко-Карый), Мелузов («Талантлар һәм аларга табынучылар», А.Н.Островский), намуслы, үз эшенә фанатикларча бирелгән Галин («Габбас Галин», Ш.Камал), тыйнак, ярдәмчел, йомшак күңелле, шул ук вакытта бәйсез характерлы Тәлгат («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит) Б. башкаруында бер-берсеннән аерылып торган, үзенчәлекле образлар буларак гәүдәләнәләр. Ч.Айтматовның «Кызыл яулыклы гүзәлкәем» әсәре буенча куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендәге Байтимер образы Б. иҗатында борылыш ноктасы булып тора. Актёр гуманизм сыйфатларын туплаган, киң колачлы шәхес дәрәҗәсендәге гаҗәеп тормышчан образ тудыра. Дульчин («Соңгы корбан», А.Н.Островский, 1968), Ислам («Әни килде», Ш.Хөсәенов, 1970), Ишан («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин, 1970) кебек сатирик образларны башкарганда Б. талантының өр-яңа яклары ачыла. Ислам образы тамашачы алдына хыянәт һәм ялган, үзен генә кайгыртуны тормыш принцибы итеп алган мещанлык үрнәге буларак килеп баса; икейөзле, мәкерле Ишан татар Тартюфы булып чыга. Б. башкарган Кривохатский («Бер төн», Б.Л.Горбатов, 1974) һәм Фаюнин («Ябырылу», Л.М.Леонов, 1980) рольләре масштаблылык, герой характерына, аның артында торган социаль вакыйгаларның асылына төшүнең тирәнлеге б-н аеры-



Ш.Х. Биктимеров.

лып торалар. Актёр эзлекле рәвештә үз персонажының характерын ача бара: яхшы ниятле, юаш, урта кул кеше гадәттән тыш эшлекле, энергияле, чәрелдек тавышлы түрәгә әверелә, ул бургомистр булган очракта шәһәрнең киләчәге турында манифест игълан итәргә хыяллана (Кривохатский). Б. тудырган Әлмәндәр («Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин, 1970) образы милли сәхнәдә күренекле вакыйга буларак кабул ителә. Актёр бу образда чын халыкчан типны гына күрсәтеп калмый, бәлки анда халыкның чын җанын, үлемсезлеген, рухи сәламәтлеген, вөҗданлылыгын, горурлыгын, патриотизмын, уен-көлке, юмор яратуын чагылдыра. Әлмәндәр образында бер үк вакытта Хуҗа Насретдин һәм Дон Кихот, Шомбай һәм Тиль Уленшпигельләр сыйфатлары чагыла. Актёрның бу эше «Театр» ж-лында (Мәскәү, 1984, № 2) «Шәүкәт Биктимеровның «йолдызлы сәгате» («Звёздный час» Шауката Биктимерова») дип бәяләнә. Тактабашев («Портфельле кияү», Н.Исәнбәт, 1985), Акчурин («Без китәбез, сез каласыз», Т.Миңнуллин, 1982), Кнуров («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский, 1983), пастор Мандерс («Өрәк», Г.Ибсен, 1998) образларында актёр осталыкның камиллегенә, бизәкләрнең нечкә эшләнешенә ирешә. Аның рольләре башкаруында гадилек, сурәтләү алымнарын сайлаганда кыскалык, төгәллек, гримны бик аз куллануы эчке темпераментның чиктән тыш киеренкелеге һәм психологик яшәешнең төгәл логикасы б-н бергә кушыла. Б.ның геройлары аларның һәр адымын игътибар б-н күзәтергә генә түгел, уйларга да мәҗбүр итәләр. Актёр иҗатына хас булган чын мәгънәсендәге интеллект, хисләренең тирәнлеге, тәэсирле фикерләве аның сәнгатен милли театрларның иң мөһим казанышлары рәтенә куя. Б. кинода (Нуришанов — Г.Ахунов романы буенча Свердловск киностудиясендә куелган «Хәзинә» фильмы, 1977), телевизион фильмнарда һәм спектакльләрдә төшә, радиода языла. ТАССРның Г.Тукай исем. (1967) һәм РСФСРның К.С. Станиславский исем. (1979) дәүләт бүләкләре лауреаты. ТАССР (1975–80) һәм СССР (1985–90) ЮСлары депутаты.

Башка рольләре: Фридун («Тау чәчәге», Х.Уразиков), Биктимер («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Таһир («Азатлык», М.Әмир»), Сәетгәрәй («Гөлҗамал», Н.Исәнбәт), Заһит («Бертуган Таһировлар», Ф.Хөсни), Фәрхад («Фатыйма Сабри», С.Җамал), Таштимер («Эңгер-меңгер», А.Гыйләҗев), Бәхтияр,



Ш.Х. Б и к т и м е р о в Кнуров ролендә (А.Н. Островский, «Бирнәсез кыз»), уңда — И.Х. Әхмәтҗанов.

Сибгат («Канкай угылы Бәхтияр», «Ат карагы», Т.Миңнуллин), Колошин («Булмас димә — дөнья бу», А.В.Вампилов), Пантолоне («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Туктамыш («Идегәй», Ю.Сафиуллин) һ.б.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; И л я л о в а И. Театр им.Камала. К., 1986; ш у л у к. Шаукат Биктимиров. К., 1993.

*И.И.Илялова.*

**БИКТИМЕ́РОВА** (Биктимерия) Галимәтелбәнат (1876, Казан өязе Кышлау а. — 30.11.1906, Рязань губ., Касыйм өязе Яубаш а.), язучы, мөгаллимә, җәмәгать эшлеклесе. Мулла нәселеннән. Түбән Оры авылында (хәзер Арча р-ны) атасы Лотфулла ахун тарафыннан ачылган кыз балалар мәктәбендә белем ала, 16 яшеннән шул мәктәптә мөгаллимә була. 1895 елда кияүгә чыгып, иренең Касыйм өязендәге туган авылы Яубашка күчеп китә. Шул ук елда Яубашта кызлар мәктәбе ача. Иҗат эшенә дә яшьтән керешә. Хатын-кызның гаиләдәге урыны, ятим балалар тәрбияләү алымнары, кыз балаларда укуга омтылыш уяту мәсьәләләренә багышланган «Тәргыйб әл-бәнат» («Кыз балаларны кызыксындыру», 1892), «Хөсн әл-васыйа» («Гүзәл тәрбияче», 1895), «Мөгашәрәт әдәбе» («Аралашу әдәбе», С.-Петербург, 1895) китаплары авторы. Б. әсәрләрендә чәчмә форма шигырьләр б-н аралашып бара. 1905–06 да көндәлек матбугатта языша, хатын-кызларны белемгә, актив җәмәгать эшләренә өндәгән публицистик мәкаләләрен бастыра.


*Әд.:* Б у р н а ш е в а З. Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан. К., 1971; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Галимәтелбәнат Биктимерия (1876–1906) // Өмет йолдызлары. К., 1988.

*М.В.Гайнетдинов.*

**БИКТИМЕ́РОВА** Рәйсә Габдулла кызы (26.1.1956, Казан), анатом, физиолог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1995). 1979 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң Казан ГИДУВында эшли. 1984 тән Казан пед. ун-тында, 1995 тән анатомия, физиология һәм кешенең сәламәтлеген саклау каф. профессоры. Әйләнә-тирә пычрануның бөер патологиясе төзелешенә һәм авыру таралуга тәэсирен өйрәнә, эпидемиологик һәм социологик күрсәткечләрдән файдаланып, авыруны комплексны тикшерү методикасын төзи, югары дәрәҗәдә этилацетатлы районнарда нефрологик профильле авырулар барлыкка килүнең куркыныч чиген һәм гломерулонефритның көчәюендә антропоген йогынтының тәэсирен ачыклый.

Х е з м.: Зависимость почечной патологии от неблагоприятного влияния загрязнений атмосферы в условиях крупного промышленного города // Казан. мед. журн. 1993. № 4. (автордаш); Формирование нефрологической патологии в крупном промышленном городе и пути профилактики заболеваемости в условиях интенсивного загрязнения окружающей среды. Саратов, 1994.

**БИКЧӘНТӘ́ЕВ** Әхмәт Һади улы (20.2.1911, Казан өязе Олы Мәңгәр а. — 12.2.1985, Казан), архитектор, проф. (1976), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1969), РСФСРның атказ. архитекторы (1976). 1931 елда Казан сәнгать техникумын тәмамлаганнан соң, Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында, 1934–37 дә Ленинград коммуналь төзелеш ин-тында укый. 1939–45 тә Кызыл Армия сафларында, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1938–39, 1945–47 дә Казанның Баш архитекторы идарәсе каршындагы архитектура-планлаштыру остаханәсендә эшли. 1947 дән Казан төзелеш инженерлары ин-тында, 1966–79 да архитектур проектлау каф. мөдире. Б. проектлары б-н Казан авиация ин-тының үзәк корпусы үзгәртеп корыла (1939, В.А.Дубровин б-н берлектә, хәзер Казан техника ун-тының 1 нче уку бинасы), ш.у. Казан төзелеш инженерлары ин-тының уку биналары(1967–76, хәзер Казан архит-ра төзелеше ун-ты), Казан үзәгендә торак йортлар төзелә. Биектау р-ны Шәпше авы-





Ш.Х. Б и к т и м е р о в: 1. Фәрхад (С. Җамал, «Фатыйма Сабри»), уңда — Ф.С. Ильская); 2. Әлмәндәр (Т.Г. Миңнуллин, «Әлдермештән Әлмәндәр», уңда - Р.Г. Җиһаншина) рольләрендә.



Ә.Һ. Б и к ч ә н т ә е в. Казан төзүче-инженерлар институтының төп бинасы. 1967.

лындагы корылмалар проекты авторы (1973, Х.Х.Ихсанов б-н берлектә; СССР МС бүләге бирелә, 1973). Совет неоклассицизмы һәм рациональ архит-ра юнәлешләрендә эшли. ТАССРда авыл төзелешенә кагылышлы хезмәтләре бар. 1967–1970 тә СССР Архитекторлар берлегенең Татарстан бүлеге рәисе.

Х е з м.: Планировка и застройка сельских населённых мест ТАССР. М., 1964; Сельское строительство в ТАССР. М., 1969.

*Т.Р.Закирова.*

**БИКЧӘНТӘ́ЕВ** Илдар Әхмәт улы (6.12.1946, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1997), проф. (2000), РФ югары мәктәбенең атказ. хезмәткәре (2003). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан төзүче-инженерлар ин-тында эшли. 1975 тән Казан ун-тының дифференциаль тигезләмәләр кафедрасында. Хезмәтләре югары тәртиптәге дифференциаль тигезләмәләр өчен һәм Риманча өслекләр өчен кырый мәсьәләләрне тикшерүгә карый. Теләсә нинди укмашмаган Риманча өслекләрдә аналитик функцияләр теориясенең төп кырый мәсьәләләрен тикшерү ысулларын эшли, даими коэффициентлы югары дәрәҗәдәге сызыкча дифференциаль тигезләмәләр өчен кырый мәсьәләләрнең чишелеш формуласын, ш.у. сингуляр интеграл операторларның әйләндерү формуласын һәм ачык Риманча өслек өчен Клиффорд теоремасының аналогын уйлап таба.

Х е з м.: Дифференциальные краевые задачи для эллиптических систем первого разряда на римановых поверхностях // Дифференциальные уравнения. 1987. Т. 23, № 10; Задача Римана и конечнолистной римановой поверхности бесконечного рода // Матем. заметки. 2000. Т. 67, вып. 1: Интегральные операторы И.Н.Векуа на римановой поверхности // Матем. заметки. 2001. Т. 69, вып. 1.

**БИКЧӘНТӘ́ЕВ** Илдар Гомәр улы (30.9.1946, Казан — 6.11.2003, Казан), физик, физ.-матем. фән. канд-ты (1977), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физ.-техника ин-тында эшли. Хезмәтләре сыек кристалларны ЭПР ысулы б-н тикшерүгә карый. ТР Дәүләт бүләге магнитлы сыек кристаллар ачышы өчен бирелә.

Х е з м.: Парамагнитные жидкокристаллические металло-комплексы // Радиоспектроскопия конденсированных сред. М., 1990 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**БИКЧӘНТӘ́ЕВ** Рәфкат Әхмәтҗан улы (10.2.1924, Казан — 27.1.1975, шунда ук), драма актёры, режиссёр, педагог. ГИТИС каршындагы Татар студиясен тәмамлаганнан соң (1949, Мәскәү), Казан Яшь тамашачылар театрының татар труппасында эшли. 1950–71 елларда Татар акад. театрында актёр һәм режиссёр, 1971 дән Республика кучмә театрында (хәзерге Татар драма һәм комедия театры) режиссёр. 1965–70 тә Казан театр уч-щесендә укыта. Зур талантлы актёр буларак, рольне әзерләгәндә характерның каршылыкларын ачарга, тискәре якларын күрсәтергә, аңа карата кызгану хисе уятырга омтыла; образда комик һәм трагик башлангычларны берләштереп, шәхеснең катлаулылыгы, кабатланмас характеры турында уйландыра (Абдулич — «Качаклар», Н.Исәнбәт; Никомино — «Бәйрәм кичендә», Э. де Филиппо; Җантай — «Гүзәлем Әсәл», Ч.Айтматов). Психологик реализм тарафдары буларак, ачыктан-ачык эксцентрика, гротеск алымнарын куллана, характерны көтелмәгән хәлләрдә күрсәтә: Сиражетдин («Банкрот», Г.Камал) һ.б. Режиссёрлык эшчәнлеген Татар акад. театры сәхнәсендә башлый: М.Әмирнең «Минем хатын» (1955), Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт» (1960), «Рәхим итегез» (1961), «Кайда соң син?» (1963), «Күк капусы ачылса» (1967) пьесаларын куя. Бу спектакльләр ачык театральлек, бәйрәмчә тантаналылык, тәэсирле оптимизм б-н аерылып торалар. А.Гыйләҗев пьесасы буенча куелган «Җиргә тапшырылган серләр» (1967) спектакле җитди уйлануларга һәм бер үк вакытта нечкә лиризмга бай. Республика күчмә театрында М.Кәримнең «Айгөл иле», Я.Ялунерның «Әтиең мин синең» («Я твой отец»), Р.Батулланың «Туйлар узгач», В.С.Розовның «Ситуация», С.Җамалның «Хөрмәне бушка бирмиләр» әсәрләрен сәхнәгә куя. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1960).

*Әд.:* Рәфкат Бикчәнтәев: Истәлекләр. К., 2006.

*И.И.Илялова.*

**БИКЧӘНТӘ́ЕВ** Фәрит Рәфкат улы (21.5.1962, Казан), режиссёр, драма актёры, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Р.Ә.*Бикчәнтәев* б-н Н.Х.*Гәрәева*ның улы. 1983 елда Казан театр уч-щесен, 1990 да ГИТИСның (Мәскәү) М.И.Кнебель һәм Л.Е.Хейфец классында режиссёрлык ф-тын тәмамлый. Театр уч-щесендә укыганда Татар акад. театрында яшьләр рольләрендә уйный (Нәмыйк — «Шәһәрдә җәй көннәре», Анар, Шәрәф — «Асылъяр», М.Фәйзи; Леандро — «Болан патша», К.Гоцци; Наил — «Туй алдыннан», Х.Вахит; Гөлүс — «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз», И.Юзеев; Алмазбулат — шул исем. спектакль, Ю.Сафиуллин). Татар акад. театрында режиссёр буларак беренче куйган спектакле — М.Гыйләҗевнең «Бичура» әсәре (1989). Рухи проблемаларны күтәргән бу спектакль оригиналь формасы, катлаулы, кинаяле (метафорик) теле б-н аерылып тора. 2002 елдан Татар акад. театрында баш режиссёр. Б. режиссурасына төрле алымнар куллану, штамплардан катгый рәвештә китәргә, һәр пьесаның үз стилен, үз формасын табарга омтылу хас. Б. куйган спектакльләрдә актёрның герой образыннан беркадәр читкә китүе («Акбаш вакыйгасы», Т.Гыйззәт, 1990), ирекле импровизация («Казан егетләре», М.Гыйләҗев, 1990), кырыслык һәм ачыктан-ачык хыялга бирелү («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир, 1991), үтә нечкә төсмерләр ярдәмендә актёрларның ансамбль булып уйнавына ирешү («Хушыгыз», Т.Миңнуллин, 1993) күзәтелә. Психологик реализм мәктәбе традицияләрендә тәрбияләнгән, тәэсирле анализ ысулларын үзләштергән Б. актёрның импровизация осталыгын, фантазиясен ачарга омтыла. Милли традицияләрне иҗади аңлаган хәлдә, аларны заманча чагылдыру ысулларын таба. Б. куйган әсәрләр арасында «Асылъяр» (М.Фәйзи, 1991), «Боз астында дулкын» (Ә.Рахманкулов, 1992), «Биюче» («Учитель танцев», Лопе де Вега, 1995), «Килен, каениш һәм башкалар» (Г.Камал, 1996), «Җирән чәчән белән Карачәч Сылу» (Н.Исәнбәт, 1999) «Кара чикмән» («Чёрная бурка», Г.Хугаев, 2002), «Шулай булды шул» (Т.Миңнуллин, 2003), «Телсез күке», З.Хәким, 2004), «Өч сеңел» («Три сестры», А.П.Чехов, 2006) спектакльләре бар. Татар театрының 100 еллык юбилее алдыннан театрга нигез салучыларның берсе Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяга багышланган «Гөлҗамал» спектаклен куя. 1990 елдан Б. Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта. Студентлары б-н куйган «Акчарлак» («Чайка», А.П.Чехов, 1994) һәм «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин, 1995) спектакльләре Аугсбург шәһәрендә (ГФР, 1996) халыкара театр фестивалендә күрсәтелә. Б. шулай ук Казан Зур драма театры («Весельчаки», Н.Саймон, 1997), Уфа «Нур» татар драма театры («Көз», Г.Исхакый, 1995, «Нәүрүз» халыкара театр фестиваленең «Иң яхшы режиссура өчен» призы, 1998) сәхнәләрендә спектакльләр куя. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1998).

*И.И.Илялова.*




Ф.Р. Бикчәнтәев.



Татар академия театрында Ф.Р. Бикчәнтәев куйган «Кара чикмән» (Г.Хугаев) спектакленнән күренеш.

**БИКЧӘНТӘ́ЕВ** Ярхәм Гәрәй улы (6.12.1922, хәзерге Чуаш Респ-касы, Козловка р-ны Янгилде а. — 12.12.2000, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (18.1.1944, 6.9.1944, 27.2.1958), старшина. Туган авылында к-зда эшли. 1942 елдан Бөек Ватан сугышында катнаша, 549 нчы укчы полк автоматчысы (3 нче гв. армиянең 259 нчы укчы дивизиясе). 1 нче һәм 4 нче Украина, 1 нче Балтыйк буе фронт-



Я.Г. Бикчәнтәев.

лары гаскәрләре составында Кырым, Украинаны азат итүдә, Шяуляй (1944), Мемельгә (1944) һөҗүм итү операцияләрендә катнаша. 1943 нең 23 декабрендә Новотроицкий авылы (Запорожье өлкәсе Орехов р-ны) янындагы бәрелештә, 1944 нең 1–9 майларында Севастополь һәм 1944 нең 26–27 июлендә Шяуляй (Литва) шәһәрләре өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. 1946 да Янгилдегә әйләнеп кайта, кырчылык бригадиры булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Н и к о л а е в А.Н. Боевая слава Чувашии. Чебоксары, 1975; Солдатская слава. К., 1976; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**БИКЧӘНТӘ́ЕВА** Әминә Әхмәт кызы (26.1.1913, Казан — 18.4.1986, шунда ук), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1938). 1941–51 елларда авыл мәктәпләрендә укытучы, «Яшь ленинчы» г-тасында әдәби хезмәткәр, ТАССР МС каршындагы Радиолаштыру һәм радиотапшырулар к-тында балалар редакциясе мөхәррире, 1952–55 тә Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлегендә мөхәррир. Әсәрләре 1938 дә басыла башлый. 1958 дән әдәби иҗат эше б-н профессиональ рәвештә шөгыльләнә. Балаларга багышланган һәм «Бүләк» дип аталган беренче шигырь җыентыгы 1940 та дөнья күрә. «Бакча гөлләре» (1949), «Бүген һәм иртәгә» (1954), «Дачада» (1954), «Беренче чәчәкләр» (1960), «Яз бүләкләре» (1962) исемле шигырь китаплары зур популярлык казана. «Ана йөрәге» (1959), «Мин аңлармын сине» (1966) повестьларында гаиләдә һәм мәктәптә яшүсмерләрне тәрбияләү проблемасы күтәрелә. Б. әсәрләренең төп темасы — туган җир табигатенең матурлыгы, кешедә намус, вөҗданлылык, балалар б-н әти-әниләрнең үзара мөнәсәбәте. Б.ның шигырьләре, хикәя һәм повестьлары әниләрнең балаларга карата булган җылылык, самимилек, ихласлык хисләре б-н сугарылган. ТАССРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1983).

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1963; Без өмет йолдызлары. К., 1973; Минем танышларым. К., 1983.

*Әд.:* Ш ә р ә ф и Г. Күңелдәге эзләр // Азат хатын. 1982. № 12; К у к у ш к и н Р. Ә.Бикчәнтәева турында // Канатлы дөнья. К., 1984.

*Г.М.Габделхакова.*

**БИ́КЧӘНТӘ́Й бине ИБРАҺИ́М эс-САБАВИ́** (1741–1801), дин эшлеклесе. Казан өязе Бәрәскә авылының имам-хатибы һәм мәдрәсә мөдәррисе. Оренбург мөселманнар Диния нәзарәтенең тәүге казыйларыннан берсе.

**БИКЧУРА́Й** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе авылыннан 47 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбит елгасы буенда. 2002 елда 235 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 17 йөзнең 1нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чураш исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәктәп, тегермән, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1287,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 35 ир заты; 1859 да — 374, 1897 дә — 580, 1908 дә — 702, 1920 дә — 720, 1926 да — 630, 1938 дә — 684, 1958 дә — 492, 1970 тә — 508, 1989 да — 276 кеше.

**БИКЧУ́РИН** (Бекчурин, Бещерин) Миндияр (1740–1821), Россия дипломаты, тылмач. 1760 елларда Оренбург губернасы канцеляриясендә төрки телләр тылмачы. 1780–81 дә Бохара ханлыгына җибәрелгән Россия илчелеге башлыгы. 1819 дан Хива ханлыгындагы Россия илчелегендә тылмач. Кулдан язылган рус, гарәп, фарсы, мишәр, кыргыз, казакъ, үзбәк сүзләре тупланган лөгатьлек авторы («Русско-арабско-персидско-мещеряцко-киргизско-хивинско-бухарский глоссарий»). «Барлык телләрнең һәм сөйләмнәрнең чагыштырма сүзлеге»н («Сравнительные словари всех языков и наречий», 1787–89) төзегәндә П.С.Паллас Б.ның әлеге кульязмасыннан файдаланган.

Х е з м.: Начальное руководство к изучению арабского, персидского и татарского языков, с наречиями бухарцев, башкир, киргиз и жителей Туркестана. Оренбург, 1859.

*Әд.:* К о н о н о в А.Н. История изучения тюркских языков в России. Л., 1982; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1989.

*С.М.Михайлова..*

**БИКЧУ́РИН** Мирсалих Мирсәлим улы (1820, Оренбург ш. — 7.3.1903, шунда ук), шәркыятьче, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, хакыйкый статский советник. Морзалар нәселеннән. 1838 елда Оренбургтагы Неплюев хәрби уч-щесен тәмамлагач, Оренбург чик буе комиссиясе канцеляриясендә тәрҗемәче (драгоман) булып эшли. 1841–78 дә Неплюев кадетлар корпусында гарәп, фарсы, татар телләре укыта, бер үк вакытта (1850–69) Оренбург чик буе комиссиясе каршында казакъ балалары өчен ачылган мәктәптә татар һәм казакъ теле дәресләре алып бара. 1870 елларда Оренбург генерал-губернаторы канцеляриясендә тәрҗемәче һәм хәрби гимназиядә укытучы булып эшли. Рус гаскәрләренең 1865, 1866, 1871–73 тә Урта Азиягә яулары вакытында тәрҗемәче буларак катнаша. «Гарәп, фарсы, татар телләрен һәм кыскача аңлатма б-н Оренбург өлкәсендәге башкорт, кыргыз шивәләрен өйрәнү буенча һәм аңа рус-фарсы-татар сүзләре, сөйләшләре, язмалары кушымтасы булган башлангыч кулланма» («Начальное руководство к изучению арабского, персидского и татарского языков с кратким объяснением существующих в Оренбургском крае наречий башкир и киргизов и приложением к нему русско-персидско-татарских слов, разговоров и прописей», К., 1859) исемле уку әсбабы авторы. Анда, чагыштырма лексик-грамматик материалдан тыш, Шәрекъ халыклары фольклоры һәм язма әдәбиятыннан аерым үрнәкләр дә урнаштырыла. Рус география җәмгыятенең Оренбург бүлеге хакыйкый әгъзасы; 1890 еллардан Оренбург Гыйльми архив комиссиясе рәисе. 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Начальное руководство... К., 1859; Туркестанская область. Заметки статского советника М.С.Бекчурина... К., 1872.


*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х., С а д р е т д и н о в Ш. XIX йөз татар хрестоматияләре. К., 1982; М и н н е г у л о в Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1989.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**БИКЧУ́РИН** Тәлгат Низаметдин улы (20.9.1932, Башкортстан АССРның Яңавыл р-ны Эткенә а.), нефтьче, техник фән. канд. (1973), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1980), РСФСРның атказ. рационализаторы (1977). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Әлмәт бораулау эшләре идарәсендә; 1978–88 елларда баш инженер, 1988–96 да идарә башлыгы. 1996–2006 да «Горизонт» фәнни-житештерү берләшмәсендә директор урынбасары (Әлмәт ш.). Фәнни хезмәтләре скважиналар төзү барышындагы процессларның закончалыкларын өйрәнүгә багышлана. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1969, 1983). Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Совершенствование режимов бурения долотом уменьшенного диаметра. М., 1968 (автордаш); Изоляция зон поглащений. К., 1971 (автордаш).

**БИКЧУ́РИН** Шамил Мотыйгулла улы (3.1.1928, Әлмәт р-ны Миңлебай а. — 17.1. 1991, Лениногорск ш.), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). М.Горький исем. Әдәбият ин-тының югары әдәби курсларын тәмамлый (1967, Мәскәү). 1952–58 елларда «Әлмәтнефтьтөзелеше» трестында ташчы, 1958–62 дә «Ильич васыятьләре» шәһәр г-тасында (Лениногорск ш.) сәнәгать бүлеге мөдире. Беренче әсәре 1957 дә «Совет әдәбияты» ж-лында басыла. «Ташлы тауда» (1959) һәм «Истәлекле таш» (1961) җыентыкларына кертелгән хикәя һәм очерклары татар авылы тормышындагы үзгәрешләр, нефтьчеләр, төзүчеләр, энергетикларның хезмәт казанышлары турында. «Тальян моңы» муз. комедиясе (1961 дә куела) һәм «Бергә — гомергә» (1963; 1964 тә куела) драмасы тамашачыларда зур кызыксыну уята. Киң җәмәгатьчелеккә Б. 1972 дә «Казан утлары» ж-лында (№ 5–7) басылган «Каты токым» романы б-н таныла. Нефтьчеләр тормышына һәм алар-





Р.В.Б и л а л о в.
1. «Мәдинә» мәчете. Казан. 1995–97;
2. «Казан нуры» мәчете. Казан. 1999.

ның мактаулы хезмәтенә багышланган бу роман 1974 тә аерым китап булып — татар телендә, «Твёрдая порода» исеме б-н рус телендә басылып чыга; 1976 да ВЦСПС президиумы һәм СССР Язучылар берлегенең махсус бүләгенә лаек була. Роман словак, украин телләренә тәрҗемә ителә. 1981 дә «Казан утлары» ж-лында Б.ның ш. у. нефтьчеләр тормышыннан алып язылган икенче күләмле әсәре — «Тирән катлам» (рус теленә тәрҗемәсе — «Глубокий пласт», 1983) романы басыла. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М и ң н у л л и н Ф. Прозаның гражданлык йөзе // Якты юллар. К., 1975; Г а л и м у л л и н Ф. Тирән катламнарны ачканда // Казан утлары. 1980. № 4; Б и к м у х а м е т о в Р. Дни и ночи буровой // Литературное обозрение. 1974. № 9; В о р о н о в В. Привычная естественность // Литературная газета. 1975. 3 дек.; М у с т а ф и н Р. Человек и коллектив // Дружба народов. 1975. № 7.

*Ф.М.Мусин.*

**БИКЧУ́РИН** Шәфигулла Вәлиулла улы (17.09.1893, хәзерге Алексеев р-ны Урта Тигәнәле а. — 24.10.1961, Казан), терапевт, сәламәтлек саклауны оештыручы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. табибе (1945, 1955). 1918 елда Кызыл гвардия сафларына алына, командир медиклар курсларын тәмамлый. 1920 дә демобилизацияләнә һәм губерна сәламәтлек саклау оешмаларында эшли башлый. 1922–28 елларда Татарстан Сәламәтлек саклау халык комис-ты коллегиясе әгъзасы. 1928–33 тә Казан ун-тының мед. ф-ты студенты (1930 елдан Казан мед. ин-ты), бер үк вакытта Казан мед. ин-ты директоры урынбасары. 1933 тән ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары урынбасары, бер үк вакытта респ-каның Баш дәүләт сан. инспекторы. Бөек Ватан сугышы елларында Казандагы эвакогоспитальләр бүлеге башлыгы. 1955 тән Республика клиник хастаханәсе баш табибе. Ленин, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах, К., 1997.

*Я.Г.Павлухин.*


**БИЛАЛЕТДИ́НОВ** Зиннәтулла Хәйдәр улы (13.3.1955, Мәскәү), спортчы (алкалы хоккей, сакчы), СССРның атказ. спорт остасы (1978), РСФСРның атказ. тренеры (1992). РФнең атказ. тренеры (2000). Мәскәү өлкә пед. ин-тын тәмамлый (1980). Европа (1978, 1979, 1981–83, 1985–87), дөнья (1978, 1979, 1881–83, 1986), Олимпия уеннары (1984) чемпионы. СССР (1977–80, 1985–87), дөнья чемпионатларында (1987), Олимпия уеннарында (1980) көмеш медальгә лаек була. СССР (1974, 1985, 1981–83, 1988), дөнья (1985) чемпионатларында бронза медаль ала. СССР (1976) һәм Канада (1981) кубоклары иясе. 1973–88 елларда «Динамо» (Мәскәү, 558 уен, 63 алка), СССР җыелма командаларында (77 уен, 8 алка) уйный. 1988–93 тә «Динамо»да (Мәскәү) тренер һәм 1997–2001, 2002–2004 тә баш тренер, 1993–97 дә «Виннипег Джетс», «Финикс Кайотис», «Чикаго Блэк Хоукс»та (НХЛ), 2001–2002 дә «Лугано»да (Швейцария) тренер, 2004 тән «Ак Барс» хоккей клубында (Казан) баш тренер. 2006 елда Б. җитәкчелегендә «Ак Барс» командасы РФ чемпионатында алтын медаль яулый, 2007 дә Европа чемпионнары кубогын алуга ирешә. Халыклар дуслыгы һәм ике «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**БИЛА́ЛОВ** Рәфыйк Вәгыйз улы (5.3.1950, Казан), архитектор, реставратор, ТАССРның атказ. архитекторы (1987). Казан төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлый (1971). 1971 елдан Татарстан Мәдәният министрлыгының махсус фәнни реставрацияләү-җитештерү остаханәсендә архитектор, фәнни-тикшеренү бүлеге җитәкчесе, 1985–89 да баш архитектор. 1989 дан Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагындагы «Реконструкция» иҗади архитектура-проектлау фирмасы җитәкчесе. Бер үк вакытта 1990 нан Татарстан архитекторлар берлеге каршында «Рафарх» дигән хосусый иҗат остаханәсе тота. Татарстан Архитекторлар берлеге әгъзасы (1978). Тарих-архитектура өлкәсендә тикшеренүләр, Арча р-нының Яңа Кырлай һәм Кушлавыч авылларында Г.Тукайның тормыш юлына һәм эшчәнлегенә бәйле йортларны һәм утарларны реставрацияләү һәм үзгәртеп кору проектлары (1984–86), Болгар шәһәрлегендәге истәлекләрне реставрацияләү һәм музей оештыруның генераль планы (1985–86) авторы; *Шамил йорты* (Г.Тукайның әдәби музее итеп үзгәртеп кору, 1985–87), Арча р-нының Яңа Кырлай, Өчиле, Чиканас авылларындагы 19 йөз мәчетләре (1990 еллар), *Әҗем мәчете* (1990–92), Казандагы К.Насыйри йорты (1983–85, яңадан кору), *Әсән Елга мәчете* (1985–86), *Печән базары мәчете* (1990–1995), *Кышкар мәчете* (1992), *Дворяннар җыены бинасы* (1998 дән үзгәртеп кору), Казан шәһәр думасы биналары һ.б. аның проектлары б-н реставрацияләнә. Б. проектлары б-н Нурлат шәһәрендә (1988), Кукмара эшчеләр бистәсендә (1990 еллар башы), Дәрвишләр бистәсендә (1992), Теләчедә (1997), Казанда («*Мәдинә*», 1995–97, «Казан нуры», 1999) мәчетләр төзелә.

*Х.Г.Надыйрова.*



Р.В.Б и л а л о в. Әҗем мәчетенең төп бинасы интерьеры реконструкциясе. 1990–92.



Р.В.Б и л а л о в. Печән базары мәчетенең төп залы интерьеры реконструкциясе. 1990–95.

**БИЛА́ЛОВ** Үмәр (Гомәр) Билал улы (10.7.1922, хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең Сергач р-ны Пица а. — 23.8.1996, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1979), проф.(1980), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1982, 1988). 1940–46 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә, Япония б-н сугышта катнаша (1945). Мәскәү юридик ин-тын тәмамлый (1950). 1950–53 тә Казан юридик мәктәбендә укытучы, директор урынбасары, директор. 1954 тән КПССның Татарстан өлкә ком-тында фән һәм мәдәният бүлеге инструкторы. 1956–59 да Казан пед. ин-тының марк-



Р.Г. Билалова.

сизм-ленинизм кафедрасында, 1959 дан Казан ун-тының КПСС тарихы кафедрасында укыта. 1980–89 елларда Казан технол. ун-тында КПСС тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Идел буе респ-каларында халык хуҗалыгын индустрияләштерүгә һәм эшчеләр сыйныфы тарихына карый. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Начало социалистических преобразований в экономике Казанской губернии (окт. 1917 — авг. 1918 гг.). К., 1961; Руководство хозяйственным строительством в Татарии в годы Гражданской войны (1918–1920 гг.). К., 1963; Индустриализация Татарской АССР. 1926–1941. К., 1968; Руководство Коммунистической партии социалистической индустриализацией в национальных республиках Среднего Поволжья (1926–1940 гг.). К., 1978; Алимбековы. К., 1986 (автордаш).

**БИЛА́ЛОВА** Рәисә Гайсә кызы (23.2.1925, Казан — 6.10.2003, шунда ук), җырчы (колоратуралы сопрано), педагог, ТАССРның халык артисткасы (1964). 1952 елда Казан консерваториясен (К.Е.Цветов классы) тәмамлый. 1962 дә СССРның халык артисты Г.Гаспарянда стажировка уза (Мәскәү). 1952–82 дә Татар опера һәм балет театры солисты. 1979–99 да Казан пед. ун-тының музыка ф-ты укытучысы. Киң диапазонлы тавышка ия, аңа лирикага бай колоратураларның виртуозлыгы хас була. Төп партияләре: Розина («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Джильда («Риголетта», Дж.Верди), Джульетта («Ромео һәм Джульетта», Ш.Гуно), Марфа («Патша кәләше», Н.А.Римский-Корсаков), Алтынчәч (шул исем. опера, Н.Җиһанов), Сәрвәр («Башмагым», Җ.Фәйзи), Гөлйөзем («Наёмщик», С.Сәйдәшев һәм А.Ключарёв), Нәсимә («Тальян моңы», Ә.Бакиров). Концерт программалары б-н Мәскәүдә, Ленинград, Баку, Ташкент һәм СССРның башка шәһәрләрендә чыгышлар ясый. «Татарстан» ДТРК фондында җырчы башкаруында вокаль әсәрләрдән 40 ка якын язма саклана. Яшьләр һәм студентларның Варшавада узган Бөтендөнья фестивалендә катнаша (1955). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* З ә й н а ш е в а Г. Сандугач // Казан утлары. 1970. № 8; Народные артисты. К., 1980.





Р.Г. Б и л а л о в а: 1. Алтынчәч (Н.Г.Җиһанов, «Алтынчәч» операсы, 1956–57); 2. Джульетта (Ш.Гуно, «Ромео һәм Джульетта») рольләрендә.

**БИЛӘ́Р** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында. Кече Чирмешәннең сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,8 *км*, бассейнының мәйданы 43,7 *км*². Алексеев р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Биләр авылыннан 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы әлеге авылдан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 93 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 23%. Б. елгасының 1,5 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы — 88 *мм*, ташу агымы катламы 83 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,027 *м³/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Б. бассейны *Биләр тарих, археология һәм табигать музей-саклаулыгының* бер өлеше булып тора.

**БИЛӘ́Р** (Бүләр), урта гасырлар (10–15 йөзләр) болгар шәһәре, Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда урнашкан. Идел буе Болгарының эре сәяси, рухи, мәдәни һәм сәүдә-һөнәрчелек үзәге. Археологик калдыклары ТРның Алексеев р-ны Биләр авылы янында (к. *Биләр шәһәрлеге*). Төрки *биләрләр* кабилә берләшмәсе нигезләгән шәһәр дип фаразлана. Рус елъязмаларында беренче мәртәбә 1164 елда Чирмешән елгасы буендагы Бөек шәһәр («Великий город») буларак (кенәз Андрей Боголюбскийның Бряхим-Ибраһим шәһәренә һөҗүм итүенә бәйле рәвештә) телгә алына. Б.нең иң югары үсеш алган чоры 12 йөзнең 2 нче яртысы — 13 йөз башларына туры килә. Кайбер тарихчылар (А.Х.Халиков, Ф.Ш.Хуҗин һ.б.) Б.не 12 йөздән башлап Идел буе Болгарының башкаласы булган дип, икенче бер галимнәр (А.П.Смирнов, Р.Г.Фәхретдинов, И.Л.Измайлов һ.б.) аны Болгар шәһәреннән кала 2 нче урында торган хәрби-сәяси үзәк дип саныйлар. Дошман көчләре берничә мәртәбә Б.не яндырып, талап китәләр. Шәһәргә 1183 тә — рус кенәзләренең *Всеволод III Большое Гнездо* җитәкчелегендә берләштерелгән гаскәре, 1232 дә һәм 1236 да монгол гаскәрләре һөҗүм итәләр. (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*). 1236 да Бату хан гаскәре Б.не яулап, җимереп киткәннән соң, урыны күчерелеп, шәһәр яңадан төзелә. 13 йөз ахырында Б.дә Алтын Урда акчалары сугыла. Шәһәр Алтын Урдага кергән болгар бәклегенең сәяси һәм икътисади үзәгенә әверелә (к. *Биләр III авыллыгы*). Татар халкы фольклорында (мәс., «Туйбикә мәдрәсәсе», «Кырык кыз бәете» һ.б.) Б. шәһәренә бәйле тарихи вакыйгалар чагыла.

Чыг.: Летописец Переяславля Суздальского. М., 1851; П р и с е л к о в М.Д. Троицкая летопись. М.–Л., 1950; Полное собрание русских летописей. М., 1965. Т. 1,2,4,5,13,15,18,24,25.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. О столице домонгольской Булгарии // Советская археология. 1973. № 3; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. О столице домонгольской Булгарии // Советская археология. 1974. № 2; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; ш у л у к. Биляр — столица домонгольской Булгарии. К., 1991; И з м а й л о в И.Л. 1183 год. Крестовый поход на Волгу // Родина. 2000. № 3; Х у з и н Ф.Ш. Булгарский город X — нач. XIII вв. К., 2001.

*И.Л.Измайлов.*

**БИЛӘ́Р** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 50 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 2181 кеше (руслар — 77%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. А.х. техникасы пр-тиесе. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. 2 китапханә. *Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы,* А.Е.Арбузов мемориаль музее. 1654 тә, болгар җирендәге Биләр шәһәре урынында Кама аръягы чик буендагы ныгытмаларның берсе буларак нигез салына. Беренче булып Ахтач кальгасыннан гаиләләре б-н укчылар килеп урнаша, аларга хезмәт хакын акчалата түгел, ә Б. тирәсендәге җирләр б-н түлиләр. 18–20 йөз башында бистә булып исәпләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элек *игенче солдатлар*) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чүлмәк ясау, йон-тукыма ману кәсепчелеге б-н шөгыльләнә. 1654 тә православие приходы барлыкка килә, 1877–92 елларда Михаил-Архангел чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; банк, телефон станциясе, Халык мәгариф министрлыгының 2 сыйныфлы уч-щесе, земство уч-щесе, чиркәү-приход мәктәбе, пар тегермәне, кибет, 30 лап вак-төякләр кибете, 2 сыраханә эшли, пәнҗешәмбе саен базар, ярминкәләр (13 июль һәм 14 сент.) үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 10026 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Биләр волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Биләр р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 3524, 1897 дә — 6103, 1908 дә — 7516, 1920 дә — 6768, 1926 да — 5564, 1938 дә — 4475, 1949 да — 3019,






Биләр III авыллыгы әйберләре: 1. Төсле пыяла йөгертелгән чүлмәк; 2. Төсле пыяла йөгертелгән фаянс савыт; 3. Төсле пыяла йөгертелгән фаянс бәйрәм савыты; 4. Сөяк тартмачык. Казан ун-тының Археол. музее фондлары.

1958 дә — 3271, 1970 тә — 2813, 1979 да — 2402, 1989 да — 2083 кеше.

**БИЛӘ́Р III АВЫЛЛЫГЫ́**, археологик истәлек; Алтын Урда дәвере (чама б-н 13 йөзнең 2 нче яртысы — 14 йөзнең 1 нче яртысы) болгар торулыгы калдыклары. Алексеев р-ны Биләр авылының төньяк-көнбатышында, Биләр һәм Кече Чирмешән елгалары арасында урнашкан. 1964 елда Казан археологы Р.Г.*Фәхретдинов* тарафыннан ачыла. Мәйданы 107 мең $м^2$ дан зуррак. 1971 дә торулыкның көнчыгыш читендә 14 йөзгә караган 38 көмеш тәңкәдән торган хәзинә табыла. Биләр б-н «Изгеләр чишмәсе»н тоташтырган автомобиль юлын төзегәндә (1994) авыллык зур зыян күрә. 1994–98 дә Казан галимнәре саклау чаралары үткәргән вакытта (1995–96 да Самара өлкәсе тарих-төбәкне өйрәнү музее хезмәткәрләре дә катнаша) Б.III.а.нда торак һәм хуҗалык корылмалары калдыклары табыла (металл кою мичләре, тандырлар һ.б.). Ваграк табылдыклар арасында ук башлары, шарнирлы кайчылар, элмә йозак ачкычы, өзәңгеләр, тимер эшләнмә калдыклары, орчык башлары, кайрак кисәкләре, бронза көзгеләр, аждаһа сурәте уелган сөяк бил каешы тартмачыгы, бакыр акча (Үзбәк хан заманы) бар. Б.III а. ндагы ватылмыйча сакланган 3 чүлмәк савыт аерым әһәмияткә ия: кобальт катнаш фирүзә төсендәге эретмә йөгертелгән киң авызлы савыт; калку кобальт бизәк төшерелгән күптөсле касә; штамповка бизәкле соры кувшин. Авыллыкта табылган затлы савыт-саба һәм аксөякләрнең башка төрле көнкүреш әйберләре Алтын Урда дәвере шәһәрләренә хас мәдәни үзенчәлекләр булып тора. Табылдыкларның күплеге, бигрәк тә эретмә йөгертелгән гади чүлмәк савытлар, бер яктан, монголларга кадәрге болгар мәдәнияте б-н тыгыз бәйләнешләр булуы хакында сөйләсә, икенче яктан, Алтын Урда дәверенең башлангыч чорында барган катлаулы миграция күренешен чагылдыра.

*Әд.:* Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. К., 1975; Археологические памятники бассейна реки Черемшан. К., 1990; Х а л и к о в А.Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. К., 1994; В а л и у л и н а С.И. Парадная посуда золотоордынского Биляра (по результатам раскопок Билярского III селища) // Гуманитарные науки: проблемы и аспекты изучения. К., 1997; ш у л у к. Исследования золотоордынского Биляра // Научное наследие А.П.Смирнова и современные проблемы археологии Волго-Камья. М., 2000.

*С.И.Вәлиуллина.*

**БИЛӘ́Р АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, комплексы. Аксубай, Алексеев һәм Нурлат р-ннары терр-ясендә. Мәйданы — 12,9 мең *га*, ш.и. урманнар — 10,6 мең *га*. Тыюлык терр-ясе аша Әдәм, Сосновка елгалары ага. 1967 елда аучылык кәсебе фаунасын (поши, кабан дуңгызы, кәҗәболан, суер, божыр, көртлек) саклауны көчәйтү максатыннан оештырыла.

**БИЛӘ́Р РАЙОНЫ́**, ТАССРда 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — Биләр авылы. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас һәм Чистай өязләренә, 1920–30 елларда ТАССРның Спас һәм Чистай кантоннарына керә. Оештырылган вакытта Б.р. 41 авыл советын, 88 торак пунктны берләштерә. Халкы — 48303 кеше, ш.и. руслар — 23024, татарлар — 21202 кеше. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә мәртәбә үзгәрә. 1940 ка аның мәйданы — 1173 $км^2$, халкы — 32,7 мең кеше, 30 авыл советы, 58 торак пункт исәпләнә. 1958 дә Б.р. биләмәсенә таркатылган *Тельман районының* бер өлеше кушыла. 1960 та район 1357,9 $км^2$ мәйдан били, аңа 13 авыл советы, 63 торак пункт керә. ТАССРда адм. бүленешләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Б. р. таркатыла, биләмәсе Чистай һәм Октябрь р-ннарына бирелә.

**БИЛӘ́Р ТАРИ́Х-АРХЕОЛО́ГИЯ ҺӘМ ТАБИГА́ТЬ МУЗЕ́Й-САКЛАУЛЫГЫ́**, дәүләт карамагында, Болгар тарих-архитектура саклаулыгын үзгәртеп кору нәтиҗәсендә 1992 елда Алексеев р-нында барлыкка килә (ТР МКның 14.8.1992 ел карары). Гомуми мәйданы — 2470 *га*, музей-саклаулык мәйданы — 391 $м^2$, күргәзмә-экспозиция мәйданы — 201 $м^2$. Музейның төп фондында 74468 саклау берәмлеге исәпләнә, ш.и. археологиягә караганнары — 73661, нумизматикага — 107, этнографиягә — 187, гамәли сәнгатькә — 22, графикага — 1, сынлы сәнгатькә — 2, фотографиягә — 387, документлар — 7. Табылдыкларның бер өлеше ТР Милли музеенда, Финляндия Милли музеенда һ.б. урыннарда саклана. Музей-саклаулык *Биләр тарих-археология музееен*, *Биләр шәһәрлеген*, *Балынгуз шәһәрлеген*, Горки һәм Никола-Баран шәһәрлекләрен, *Зур Тигәнәле каберлеген*, табигать-ландшафт һәм тарих-мәдәният һәйкәлләрен, христиан зиратындагы А.М.Бутлеров кәшәнә-часовнясын (Бутлеровка а.), акад. А.Е.Арбузов музей-йортын (Биләр а.), «Хуҗалар тавы»ндагы мәҗүсиләрдән калган «Изгеләр чишмәсе»н үз эченә ала. Саклаулыкка кергән тарих-археология объектлары болгар архитектурасының 10 йөз уртасына — 13 йөз башына караган уникаль үрнәкләрен тәшкил итә.




Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы әйберләре: 1. Болгар түгәрәк савыты; 2. Әвәләп ясалган түгәрәк төпле савыт.



Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгында табылган тимер әйберләр.

Саклаулык 18 йөзнең беренче яртысыннан өйрәнелә һәм тикшерелә. 1960 еллардан *археологик казу эшләре* барышында саклаулыкның архит. истәлекләрен барлау, ә 1970–80 еллардан аларда реставрация эшләре алып барыла. Саклаулыкка кергән кайбер истәлекләр (мәс., «Изгеләр чишмәсе») мөселманнарның табыну урыны, ш.у. ял итү, туризм объекты булып тора.

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Исследования Великого города. М., 1976; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Биляр — столица домонгольской Булгарии. К., 1991; Хузин Ф.Ш. Великий город на Черемшане. Стратиграфия. Хронология. Проблема Биляра-Булгара. К., 1995.

*И.М.Нестеренко.*

**БИЛӘ́Р УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Алексеев, Әлки, Аксубай, Яңа Чишмә һәм Нурлат р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда оештырыла. 1936–66 елларда — Баганалы урман хуҗалыгы. 2006 елның 1 гыйнварына урман фондының гомуми мәйданы — 50648 *га*. 5 урманчылыкны үз эченә ала: Алексеев — 7740 *га*, Баганалы — 11947 *га*, Биләр — 10102 *га*, Зур Алан — 9163 *га* һәм Кызыл Юл — 11696 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Алексеев р-нының Биләр авылында. Эшләүчеләр саны 162 кеше.

1 нче төркем урманнар 14368 *га* мәйданны били (барлык мәйданның 28,4%), алар арасында: саклау урманнары (11830 *га*), эрозиягә каршы (934 *га*), су саклау урманнары (1017 *га*), аеруча саклау терр-яләре (587 *га*). 2 нче төркем — хуҗалыкта файдаланыла торган урманнар — 36280 *га* мәйданда. Урман фонды мәйданының урманлы өлеше 48280 *га*, ш.и. ылыслы агач токымнары — 2320 *га* (4,8%), каты яфраклылар — 4864 *га* (10,1%), йомшак яфраклылар 41096 *га* (85,1%). Чагыштырмача тигез җирләрдә 1 нче ярусында сирәк кенә имән һәм каен агачлары үскән юкә-усак урманнары һәм калкулыклы тигезсез урыннарда күпләп имән үскән имән-юкә урманнары киң таралган. Урман хасил итүче төп токымнар: усак (53%), юкә (20%), биек каүсәле (7%) һәм тәбәнәк каүсәле (2,5%) имән, каен (10,8%), нарат (3,5%); сирәк кенә кара зирек, өрәңге, чыршы очрый. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшьләре (28,7%), урта яшьтәгеләре (33,7%), өлгереп килүчеләре (19,1%), өлгергәннәре (18,5%). Урман культуралары 2466 *га* мәйданны тәшкил итә. Урманның Куйбышев сусаклагычындагы утраудагы мәйданчыгы «*Ивановский наратлыгы*» табигать тыюлыгы булып санала. Б.у.х.нда агачның гомуми запасы — 8577,2 мең $м^3$. Йомшак яфраклыларга — 7502,7 мең $м^3$ (87,5%), каты яфраклыларга — 645,5 мең $м^3$, ылыслыларга 429 мең $м^3$ туры килә. Агачның уртача еллык артымы 203,5 мең $м^3$ (ш.и. 8,9 мең $м^3$ — ылыслы агач токымнары хисабына). Төп куллану өчен урман кисүнең еллык нормасы — 144,1 мең $м^3$. Урманны карау максатыннан чистарту эшләре 1140 *га* мәйданда башкарыла, шуның б-н бергә 55,4 мең $м^3$ эшкә яраклы агач әзерләнә. 100–150 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла. Урман хуҗалыгының даими эшләүче питомнигында 1,5 млн. нан артыграк агач-куак токымнары үсентесе һәм чәчкене үстерелә. 20 дән артыграк төрдәге халык хуҗалыгы товарлары: пиломатериаллар, штакетник, бура, әрҗәләр һ.б. (2004 елда — 1,2 млн. сумлык товар) җитештерелә.


*Е.А.Гуськов.*

**БИЛӘ́Р ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, археологик истәлек; урта гасырларның болгарлар шәһәре калдыклары (к. *Биләр*). Беренче тапкыр Б. ш. 18 йөздә Н.П.Рычков һәм В.Н.Татищев тарафыннан тасвирлана, 19 йөздә М.С.Рыбушкин, А.И.Артемьев, И.А.Износков, В.Г.Казаринов һ.б. тикшерә. Шәһәрлек мәйданында табылган әйберләрдән мул коллекция туплана. Б.ш.ндә 1915–16 елларда П.А.Пономарёв һәм М.Г.Худяков археол. казу эшләре алып бара, 1928 дә бу эшне А.С.Башкиров дәвам итә. 1967 дән Б.ш.ндә А.Х.Халиков планлы тикшеренү эшләре башлап җибәрә, соңрак аларны Ф.Ш.Хуҗин һ.б. дәвам итә. Б.ш. тигез җирдә урнашкан, мәйданы төньяктан Балынгуз тавына килеп тоташа. Б.ш.нең ике сызык булып сузылган тышкы һәм эчке ныгытмалары булган. Тышкы ныгытмаларның озынлыгы 10 *км* дан артып китә (урлар һәм чокырлар), эчкесенеке 5 *км* чамасы (ш.у. урлар һәм чокырлар). Тышкы шәһәрнең мәйданы — 490 *га*, эчкесенеке — 130 *га*. Заманында үзәге (цитадель) бүрәнәдән салынган диварлар б-н әйләндереп алынып, эчендә ак таш мәчет, кирпеч биналар, саманнан төзелгән тораклар, зират һ.б. булган. Эчке шәһәрдә гади өйләр, һөнәрче осталары калдыклары да очрый (тимер эретү-эшкәртү, бакыр эретү-кою, сөяктән, пыяладан кирәк-ярак ясау остаханәләре һ.б.). Шәһәр тышында да өйләр б-н остаханәләр күп булган, анда ш.у. зур-зур каберлекләр дә табыла (кайберләренең мәйданы 20–30 *га* җитә). Чүлмәкчеләр бистәсе дә шәһәр тышында урнаша, анда ике катлы чүлмәк яндыру мичләре табыла. Табылдыкларның муллыгы шәһәрнең Шәрекъ, Көнбатыш илләре, Балтыйк буе, Русь б-н сәүдә алып баруы хакында сөйли. Ш.у.к. *Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы.*

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; шул ук. Культура Биляра. Булгарские орудия труда и оружие X–XIII вв. М., 1985; Хузин Ф.Ш. Великий город на Черемшане. Стратиграфия. Хронология. Проблема Биляра-Булгара. К., 1995.

*Ф.Ш.Хуҗин.*

**БИЛӘРКҮ́Л** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасының иске үзәне буенда. 2002 елда 663 кеше (руслар — 51%, чуашлар — 43%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Абдрахманово, Би Күле, Преображенский исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 18 йөздә православие приходы барлыкка килә, 1870 тә Спас-Преображение чиркәве төзелә (1930 елларда ябыла, 1990 да яңартып корыла һәм яңадан ачыла). 20 йөз



Биләркүл авылы.
Спас-Преображение чиркәве. 1870.

Биләр шәһәрлеге. 1. Үр һәм канаулар; 2. Таш корылма калдыклары; 3. Ак таштан салынган бинаның реставрацияләнгән нигезе.
Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы фондлары.







башында фельдшерлык пункты, земство мәктәбе, җил тегермәне, 2 тимерчелек, май язу, күн эшкәртү йортлары, 2 вак-төякләр, 1 шәраб кибете, 2 сыраханә була; шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1123 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Максимка волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир заты; 1859 да — 314, 1897 дә — 474, 1908 дә — 504, 1920 дә — 708, 1926 да — 645, 1938 дә — 570, 1949 да — 479, 1958 дә — 611, 1970 тә — 853, 1979 да — 752, 1989 да — 573 кеше.

**БИЛӘРЛӘ́Р**, Идел буе Болгарында яшәгән төрки кабилә берләшмәсе. *Биләр* шәһәре һәм шул төбәктәге өлкә әлеге этник төркем исеме б-н аталган. 10 йөзнең 2нче яртысында Б.нең бер өлеше Венгриягә күчеп китә һәм анда Пешт шәһәрен нигезли (к. *Билла*, *Боксу һәм Хәтәни*). 13 йөз Көнбатыш Европа чыганакларында (Плано Карпини, Вильгельм Рубрук һ.б.) Идел буе Болгарын да «Биләр иле» дип атау очраклары күзәтелә. Б. этнонимы Идел буе Болгарында 10–14 йөзләрдә кулланышта була.

Чыг.: Путешествие в Восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957; Мухаметшин Д.Г., Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники города Булгара. К., 1987.

*Әд.:* Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**БИЛӘҮ́ (БЕЛЁВ) ЯНЫНДАГЫ́ СУГЫ́Ш** (5 декабрь 1437 ел), Олуг Мөхәммәд хан б-н Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II Тёмный гаскәрләре арасында булган орыш. Алтын Урда тәхете өчен барган көрәштә Олуг Мөхәммәд хан 1437 елның көзендә Сәед Әхмәд тарафыннан җиңелә һәм 3 мең чамасындагы гаскәре б-н чик буендагы Биләү шәһәренә таба чигенә. Кышны Биләүдә чыгарга ниятләп, кальга-шәһәр тирәсен «бозлап катыра», калын боз кантарлары кистереп, ныгытма төзетә («здела себе ледян град...»). Василий II, ханны үз биләмәсеннән куып чыгарырга уйлап, бертуганы Юрийның уллары Дмитрий Шемяка б-н Дмитрий Красный кенәзләр җитәкчелегендә 40 меңлек гаскәр җибәрә. Олуг Мөхәммәд хан кочләре баштарак беркадәр югалтуга дучар була, солых килешүе тәкъдим ителә. Рус гаскәре башлыклары килешүдән баш тарталар, «бозлап катырылган ныгытма»га һөҗүмне көчәйтәләр. Хан атлылары кинәттән алар өстенә ябырыла, рус сугышчыларының байтагы һәлак була, калганнары куркып чигенә һәм кача. Рус елъязмачысы бу вакыйганы «татарове... побиша рать рускую ... бояр и князей множество» («татарлар... рус гаскәрен... күп кенә боярларны һәм кенәзләрне кырдылар»), дип теркәп куйган. Олуг Мөхәммәд, бу бәрелештә зур җиңүгә ирешсә дә, Биләүдә озакка тоткарланмый. 1438 ел башында аның Түбән Новгородка (икенче берәүләр фикеренчә — Казанга) таба китеп баруы мәгълүм.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Зимин А.А. Витязь на распутье. Феодальная война в России XV в. М., 1991.

*И.Л.Измайлов.*

**БИЛГЕ́ КАГА́Н** (кытайча транскрипциядә Могилянь) (683 тирәсе — 734), 716 елдан Төрки каганлык идарәчесе. Котлыкъ каган улы, *Күлтәгиннең* агасы. 683 тән *шад* титулын йөртә. Әтисенең бертуганы Капыган каган идарә иткәндә энесе Күлтәгин б-н Төргәш (699) һәм Кыргыз каганлыкларына (709) яу б-н бара. 716 елда Күлтәгин ярдәме б-н каганлык тәхетенә утыра. Төрки каганлык күршеләре уйгыр, татар, карлук, кидань кабиләләре б-н сугыша; 718, 720–21 дә Тан империясе көчләрен җиңүгә ирешә, солых килешүе төзи. Аксөякләр фетнәсе вакытында һәлак була. Тәхеткә Күлтәгиннең бертуганы улы Йуллугтәгин (Иҗан каган, 734–39) утыра; ул Б.к. б-н Күлтәгингә багышланган ташъязмалар яздыра, һәйкәлләр куйдыра. Ул язмаларда Б. к. б-н Күлтәгин дәверендә башкарылган эш-гамәлләр тасвирлана (к. *Күлтәгингә куелган һәйкәлташ*).

Чыг.: Радлов В.В., Мелиоранский П.М. Древнетюркские памятники в Кото-Цайдане // Сб. трудов Орхонской экспедиции. 1897. Вып. 4; Бичурин Н.Я. Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.–Л., 1950; Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии. М.–Л., 1959.

*Әд.:* Кляшторный С.Г. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. М., 1964; Гумилёв Л.Н. Древние тюрки. М., 1993; Кляшторный С.Г., Савинов Д.Г. Степные цивилизации Евразии. СПб., 1997; Узбекистон миллий энциклопедияси. Тошкент, 2002. 4 т.

*И.Л.Измайлов.*

**БИЛДА́НОВ** (Вилданов) Абдулла (3.1.1911, хәзерге Ульянов өлкәсе, Иске Майна р-ны Татар Урае а. — 6.9.1978, Ульянов өлкәсе Димитровград ш.), Дан орденының тулы кавалеры (5.5.1944, 6.9.1944, 24.3.1945), кече лейтенант. Комсомольск-Амур шәһәренең промысел союзында товар белгече булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 435 нче укчы полкның рота старшинасы (22 нче армиянең 208 нче укчы дивизиясе). 1 нче һәм 2 нче Балтыйк буе һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Балтыйк буен, Молдавияне, Румынияне азат итүдә катнаша. 1944 нең 22 апрелендә Торошино авылы (Псков өлкәсе, Псков р-ны) янында; 1944 нең 5 августында Плявинас торак пункты (Латвия) янында; 1944 нең 5 нче октябрендә Мемель-Тильзит (хәзерге Клайпеда-Советск) тимер юлы янында барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Мәләкәс шәһәрендә (хәзерге Димитровград ш.) ит комб-тында тәэминат бүлеге мөдире булып эшли. Медальләр б-н бүләкләнә. Б. туып-үскән авылда аңа һәйкәл һәм Димитровград шәһәренең Каһарманнар аллеясында бюст куелган.

*Әд.:* Защищая отечество. Саратов, 1975; Честь, отвага, мужество. Саратов, 1979; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**БИЛИНГВИ́ЗМ**, к. *Икетеллелек*.



А. Билданов.

**БИ́ЛИЧ** Ида Лейбовна (13.03.1917, хәзерге Украина Респ-касының Шепетовка ш.), гастроэнтеролог, мед. фән. д-ры (1967), проф. (1968). 1942 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, 1946 елдан шунда ук эшли. 1981–99 елларда Казандагы 1 нче хастаханә табибәсе. Бер үк вакытта Казанның баш терапевты, «Казан» санаторие һәм «Иж минераль сулары» курорты консультанты. Тикшеренүләре ашказанында ашкайнату әгъзалары патологиясенә, бу патологиядә алмашу һәм нейромедиатор процессларның роленә, санаторий-курорт ярдәмен оештыруга карый. Б. тарафыннан ашкайнату органнарын (аерт ашказаны һәм юан эчәк) авыру организмындагы процессның индивидуаль характерына һәм реакциясенә яраклаштырып дәвалау ысуллары камилләштерелә. ТРда һәм Идел буе төбәгендә гастроэнтерология хезмәтен оештыруда башлап йөрүче.

Хезм.: Лекарственный препарат ксимедон для лечения язвенной болезни желудка и двенадцатиперстной кишки. К., 1967; Николай Константинович Горяев. К., 1971; Ацетилхолин и серотонин в норме и патологии желудочно-кишечного тракта. К., 1977 (автордаш).

**БИЛЛА́, БОКСУ́ һәм ХӘТӘНИ́**, 10 йөз болгар бәкләре. 10 йөзнең 2 нче яртысында үз сугышчылары б-н венгрлар кенәзе Такшонега (947–72) хезмәткә яллаланалар. Дунай елгасының сул яры буенда аларга җир биләмәләре бүлеп бирелә. Шунда алар Пешт кальгасын нигезлиләр (хәзерге Будапешт шәһәренең көнчыгыш өлеше). Б.,Б. һәм Х. турында мәгълүмат билгесез венгр авторының 12 йөздә төзегән хезмәтендә («Венгерский Аноним») сакланып калган.

*Әд.:* Археология Венгрии. М., 1986, Anonymus. Gesta Hungarorum. Scriptores rerum Hungaricarum. Budapest, 1937. V. 1.

**БИЛЧӘ́Н** (Sonchus), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Чүп үлән. Европа, Азия һәм Африкада үсә торган 70 ләп төре билгеле. ТРда 5 төре: кыр Б., баткаклык Б. (топяной О.), кытыршы Б., яшелчә Б. саз Б. Иң күп таралганы — кыр Б., күп тамыр үрсеннәре бирүче күпьеллык чүп үлән, һәр җирдә үсә. Барлык а.х. культуралары (бигрәк тә сабан ашлыгы һәм сызма культуралар) чәчүлекләрендә, бакча, печәнлек һәм көтүлекләрдә үсә. Вегетатив юл б-н (3 *см* озынлыктагы тамыр, дымлы урыннарда сабак өземтеләре б-н) һәм орлыктан үрчи; бер үсемлек 20 меңгә кадәр орлык бирә, 3 *см* һәм аннан да тирәнгә эләккән орлыклар шытым бирми. Көрәш чаралары: башта 2 кабат йомшарткан җирне тирән итеп сөрү, чүп үләннең яфрак ялгысы бар-

лыкка килгәч, утау; парга сөрелгән җирне һәм сызма культуралар араларын вакытында эшкәртү; гербицидлар куллану (2,4Д, 2м-4х, полидима, тордон 22К һ.б.); эшкәртергә уңайсыз җирләрдән чүп үләннәрне бетерү (чабып ташлау, чәчәк атканчы һәм орлыкланганчы гербицидлар сиптерү. Терлек яратып ашый. Баллы үсемлек.

**БИЛЬБЕ́РГИЯ** (Billbergia), бромелиесыманнар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Күпьеллык үлән. 50 ләп төре билгеле. Чыгышы — тропик Америка. Яфраклары тыгыз, кыяклы яки каешсыман, читләре вак тешле, су җыела торган бүрәнкә яки көпшәсыман яфрак таралгысына тупланган. Чәчәк янында алсу, кызыл яки кызгылт сары төстәге күпсанлы яфраклар башаксыман чәчәк төркемендә төгәлләнә, туры яки иенке сабаклы. Яфракларының матур, төсләренең ачык булуы һәм озак чәчәк атуы сәбәпле, Б.не Татарстанда декоратив бүлмә гөле итеп үстерәләр. Культура буларак аеруча киң таралганнары: иенке Б. (B. nutans Wendl.), Сандерс Б.се (B. Saundersii hort. Bull.), буй-буй Б. (B. Zebrina Lindl.). Вегетатив ысул б-н үрчетелә. Б. талымсыз, һава корылыгын яхшы кичерә, күләгәгә чыдам.

**БИМА́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 96 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Удмуртия Респ-касы чигендә. 2002 елда 589 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөз уртасыннан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, такта яру б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1775,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Бимә волостена керә. 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 449, 1887 дә — 606, 1920 дә — 754, 1926 да — 715, 1938 дә — 806, 1949 да — 669, 1958 дә — 727, 1970 тә — 773, 1989 да — 591 кеше.

**БИМӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Кырыкмасның сул кушылдыгы (Иж елгасы бассейны). Озынлыгы 58,3 *км*, бассейнының мәйданы 441 *км*². Әгерҗе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Красный Бор авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Иске Эсләк авылыннан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 85 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 9%. 21 кушылдыгы бар, иң зурлары — Олы Пеләмәш (14,5 *км*) һәм Кумырлы (15,3 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәенык саегуы б-н характерлана. Исәнбай авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәлеше 2,9 *м* чамасы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 116 *мм*, ташу агымы катламы 98 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун көне эчендә башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Кыш азагына бозның калынлыгы 96 *см* га җитә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,275 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Б. бассейнында гомуми күләме 2,1 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Бассейнның күп өлеше Әгерҗе аучылык тыюлыгына керә.

**БИМӘ́** авылы, Лаеш р-нында, шәһәр тибындагы Лаеш посёлогыннан 30 *км* төньяктарак, Мишә елгасыннан 1 *км* ераклыкта. 2002 елда 188 кеше (руслар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 16 йөз ахырыннан — рус авылы. 1632 дә дворян А.Брутков васыяте буенча Казан Спас-Преображенье монастырена бирелә. 1764 тә халкы монастырь крәстияннәреннән — экономик разрядка, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. Игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Параскева Пятница чиркәве (1895 тә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе, уку йорты, 2 җил һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1523,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Лаеш р-нында. Халык саны: 1646 да — 58, 1763 тә — 60, 1782 дә — 95 ир заты; 1859 да — 450, 1897 дә — 659, 1908 дә — 661, 1920 дә — 741, 1926 да — 725, 1938 дә — 336, 1949 да — 200, 1958 дә — 281, 1970 тә — 449, 1979 да — 339, 1989 да — 238 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**БИМӘ́Р** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасының югары агымы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 1829 да Бимәр һәм Кириловка авылларыннан (хәзер Биектау р-нында) күчеп утыручылар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Бимәр, Апайкина Гарь исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тегүчелек, гөмбә җыеп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство уч-щесе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 561,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 177, 1897 дә — 237, 1908 дә — 288, 1920 дә — 327, 1926 да — 381, 1938 дә — 430, 1958 дә — 220, 1970 тә — 157, 1979 да — 55, 1989 да — 4 кеше.

**БИМӘ́Р** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2002 елда 359 кеше (руслар — 78%) яши. Автотранспорт пр-тиесе. Клуб. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Бимәр исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек һәм терлек асрау б-н беррәттән тегүчелек, сарык тиресе эшкәртү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1108,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакин волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 24, 1782 дә — 248 ир заты; 1859 да — 661, 1897 дә — 659, 1908 дә — 791, 1920 дә — 890, 1926 да — 1411, 1938 дә — 1056, 1958 дә — 856, 1970 тә — 685, 1989 да — 562 кеше.

*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**БИО**... (грек. bios — тормыш),

**БИОГЕОГРА́ФИЯ** (*био*... һәм *география*), үсемлекләр, хайваннар, гөмбәләр бергәлекләренең, аларның төр, ыруг һәм башка таксономик берәмлекләренең Җир шарында таралу закончалыкларын өйрәнүче фән. Биологик ресурсларны саклау һәм алардан рациональ файдалануның теоретик нигезен тәшкил итә. Аерым тармаклары: билгеле бер терр-я яисә акваториядәге үсемлек һәм хайван төрләрен билгеләүче я з м а Б. (флористик һәм фаунистик Б.); таксоннарның Җир өсте буйлап таралу сәбәпләрен өйрәнүче каузаль Б.; терр-я яки акваториянең районлашуын өйрәнүче чагыштырма Б.; организмнарның таралуына этәргән тарихи шартларны өйрәнүче тарихи Б.; организмнарның экологик үзенчәлекләре һәм аларның таралышы арасындагы бәйләнешне билгеләүче экологик Б.

Б.нең төп бүлекләре (зоогеография һәм ботаник география) 18 йөзнең ахыры — 19 йөзнең 1 нче яртысында флора һәм фаунаны өйрәнү максатында оештырылган күпсанлы экспедиция тикшеренүләренә нигезләнеп формалаша башлый (А.Гумбольдт, А.Уоллес, Ф.Склетер һ.б.). Россиядә И.Г.Борщовның «Арал-Каспий төбәгенең ботаник географиясе буенча материаллар» («Материалы по ботанической географии Арало-Каспийского края», 1865) исемле китабы Б.гә кагылышлы беренче хезмәтләрдән санала. Соңрак Е.В.Вульфның «Үсемлекләрнең тарихи географиясенә кереш» («Введение в историческую географию растений», 1933), И.П.Ильинскийның «Җир шарының үсемлекләр дөньясы» («Растительность земного шара», 1937), В.В.Алёхинның «Үсемлекләр географиясе» («География растений», 1938) хезмәтләре барлыкка килә. Беренче Б. дәреслекләре авторлары: А.Н.Бекетов — «Үсемлекләр географиясе» («География растений», 1896) һәм А.М.Никольский «Җир һәм хайваннар дөньясы (хайваннар географиясе)» —

(«Земля и мир животных (география животных)», 1905).

Б.нең үсешенә Казан галимнәре дә өлеш кертә. С.И.Коржинский Россиянең һәм Урта Азиянең үсемлекләр дөньясы, Уралдагы реликт (сакланып калган) үсемлек төркемнәре турындагы гомуми җыентыкларны булдыра. Ул, беренчеләрдән булып, Рус тигезлегендәге туфрак-үсемлек зоналарының динамик үзгәрешләрен күрсәтә. П.Н.Крылов Үзәк Россиянең Түбән Новгород, Вятка, Казан һ.б. губерналары буйлап экспедицияләр оештыра, Себернең ботаника-география районнарын билгели. А.Я.Гордягин Көнбатыш Себердә, Пермь, Казан, Уфа, Оренбург, Акмулла губерналарында ботаник-географик тикшеренүләр үткәрә, урман һәм дала үсемлекләре дөньясының үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнә. В.И.Баранов Казан губернасы болыннарын, Көнбатыш Себер урман-даласын, Кузнецк Алатавы итәген тикшерә, Көнбатыш Себер һәм Уралның геоботаник карталарын төзү б-н шөгыльләнә. Э.А.Эверсман Көньяк Урал, Идел аръягы далалары, Казакъстан һәм Урта Азия ярымчүл һәм чүлләре буйлап сәяхәт итә һәм терр-яне өйрәнүдә беренче тапкыр ландшафт ысулы куллана. М.Д.Рузский Казан губернасының балыклар, сөйрәлүчеләр һәм җир-су хайваннары, кошлар, бөҗәкләр (аеруча кырмыскалар) фаунасын, Урал, Көнбатыш Себер, Казакъстан, Тибет, Монголия, Төрекмәнстан, Кавказ фаунасын тикшерә. М.Н.Богдановның «Идел буеның кара туфраклы полосасы, Урта һәм Түбән Идел үзәненең кошлары һәм җәнлекләре» («Птицы и звери чернозёмной полосы Поволжья, долины Средней и Нижней Волги», 1871) монографиясендә зур төбәк фаунасын тарихи-географик анализлауга беренче омтылыш ясала. Соңрак Петербург ун-тында ул Россиянең Мурманскидан Кавказга кадәр булган фаунасын тикшерә һәм эволюцион зоогеография юнәлешенә нигез салучыларның берсе була. В.А.Попов Идел-Кама ягының умырткалылар фаунасын өйрәнә һәм бу терр-янең зоогеографик районнарын билгели (1960). 1970 елда ул А.К.Рөстәмов б-н бергә Б.нең хайван төрләре таралышындагы кеше эшчәнлегенә бәйле үзгәрешләрне һәм бу процессның закончалыкларын өйрәнүче яңа антропоген зоогеография юнәлешен билгели.

*Әд.:* Э в е р с м а н Э.А. Естественная история Оренбургского края. Оренбург — К., 1840 — 66. Ч. 1–3; К о р ж и н с к и й С.И. Ботанико-географический очерк Казанской губернии // Тр. Об-ва естествоисп. Казан. ун-та. 1888.Т.18, вып. 5; Р у з с к и й М. Муравьи России // Тр. Об-ва естествоиспытателей Казан. ун-та. 1905. Ч. 1. Т. 38, вып. 4–6; 1907. Ч. 2. Т. 40, вып. 4; П о п о в В.А. Млекопитающие Волжско-Камского края. К., 1960; Н е й л У. География жизни. М., 1973; Л е м е Ж. Основы биогеографии. М., 1976; В т о р о в В.П., Д р о з д о в Н.Н. Биогеография материков. М., 1979; В о р о н о в А.Г., Д р о з д о в Н.Н., М я л о Е.Г. Биогеография мира. М., 1985; В о р о н о в А.Г. Биогеография с основами экологии. М., 1987.

*В.И.Гаранин.*

**БИОГЕОЦЕНО́З** (*био*..., *гео*... һәм грек. koinós — гомуми, уртак), Җир өслегенең биотик һәм абиотик компонентлары составы чагыштырмача бертөрле, компонентлары һәм таралышы чикле булган өлеше; билгеле бер матдә (*биомасса*) әйләнешенә, энергия агымына, информация тапшырылу күренешләренә бәйле. «Б.» төшенчәсе, Җир өслегенең билгеле бер участогындагы бертөрле табигый элементлар берлеге буларак, 1940 елда совет геоботанигы В.Н.Сукачёв тарафыннан өйрәнелә. Биотик өлеше (биоценоз) автотроф (фотосинтез һәм минераль элементлар үзләштерү юлы б-н органик матдә хасил итүче продуцентлар — башлыча яшел үсемлекләр), гетеротроф (әзер органик матдәләрдән файдаланучы хайваннар — консументлар) һәм деструкцион (үлек органиканы минераль кушылмаларга кадәр таркатучы редуцентлар — башлыча, микроорганизмнар) компонентлардан тора. Абиотик өлеше (яшәү тирәлеге — биотоп) — туфрак капламы, җир өсте һәм грунт сулары, кояш энергиясе һәм ш.у. атмосфераның җиргә якын катламы (климат үзенчәлекләре б-н) берлегеннән гыйбарәт. Һәр Б. — үзен төзүче компонентларының озак вакытлы *адаптация*се б-н бәйле үсеш тарихы булган динамик, үзкөйләнүчән табигый комплекс булып тора. Б. үзенең структур-функциональ төзелеше буенча «экосистема» төшенчәсенә якын, ләкин бу төшенчә, бигрәк тә чит илләрдә, киңрәк мәгънәдә кулланыла — төрле зурлыктагы: аквариумнан алып сулыкка һәм урманда черегән агачтан алып *биосферага* кадәр пространствоны биләүче системаларны аңлата. Ягъни, экосистемалар пространствода иреклe, ә Б. — конкрет терр-ядә чикләнгән. Биосфераның элементар структура берәмлеге булган Б.ларның күплеге планетаның биогеоценотик капламын хасил итә. Табигый-территориаль комплексларны системалы дәрәҗәдә өйрәнү регионның һәм гомумән биосфераның экологик куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүдә зарури шарт булып тора.

*Әд.:* С у к а ч ё в В.Н. Основы теории биогеоценологии // Юбилейный сб. АН СССР. М., 1947; Этапы и темпы становления прибрежных биогеоценозов. М., 1978; А л е й н и к о в а М.М., П о р ф и р ь е в В.С., У т р о б и н а Н.Н. Парцеллярная структура елово-широколиственных лесов востока Европейской части СССР (Волжско-Камский заповедник). М., 1979; Летопись природы ВКГПЗ, 1960–99; Структура островных экосистем Куйбышевского водохранилища. М., 1980.

*В.А.Бойко.*

**БИОГРА́ФИКА** (*био*... һәм ...*графика*), биографияләрнең (тәрҗемәи хәлләрнең) теоретик, методик һәм чыганак ысулларын гыйльми өйрәнү өлкәсе. Генеалогия, геральдика, биобиблиография һ.б. тарихи юнәлешләр б-н турыдан-туры бәйле. Биографияләр энциклопедик характерда, тарихи, иҗат портреты, сәнгати әсәр шәкелендә булырга мөмкин. Б.ның тарихы борынгы Греция һәм Рим дәверләренә барып тоташа (Плутархның «Чагыштырма тәрҗемәи хәлләр»е, Тацитның «Агриколаның тормышы», Светонийның «Унике хөкемдарның тәрҗемәи хәлләре» һ.б.). Россиядә әлеге жанр изгеләрнең тормышы турындагы язмалар һәм елъязмалар б-н бәйле. Аерым әдәби жанр буларак 18–19 йөзләрдә формалаша: Н.И.Новиковның «Рус язучылары турында тарихи сүзлек тәҗрибәсе» («Опыт исторического словаря о русских писателях», СПб., 1772), Д.Н.Бантыш-Каменскийның «Рус җиренең истәлекле шәхесләре сүзлеге» («Словарь достопамятных людей русской земли», М., 1836) һ.б. Казан җирлегендә беренче русча биографик хезмәтләр 19 йөзнең 2 нче яртысында нәшер ителә башлый: 1856 елда А.Г.Пупаревның «Казан губернаторлары» («Казанские губернаторы») китабы чыга; 1869 елгы Казан календарендa П.П.Васильевның 1866–68 дә вафат булган Казан галимнәре һәм язучылары, 1885 елгы календарьда Н.К.Горталовның Казан епархиясе чиркәү әһелләре турында биографик мәгълүматлар урнаштырыла. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында төбәк тарихчысы Н.Я.Агафоновның «Идел аръягы вивлиофикасы» («Заволжская вивлиофика», 1887), «Казан тарихыннан» («Из Казанской истории», 1906), «Казан һәм казанлылар» («Казань и казанцы», 1–2 чыг., 1906–07) исемле китаплары дөнья күрә.

Татар мәдәниятендә биографик әсәрләр жанры ш.у. ерак гасырлардан билгеле. Насретдин *Рабгузиның* 1311 дә төрки телдә язып тәмамланган һәм әүвәл кулъязма нөсхәләрдә таралып, 1859 елдан башлап күп мәртәбәләр Казанда китап булып басылган «Кыйссас әл-әнбия» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар») әсәре аеруча популярлык казана. Мөхәммәд пәйгамбәрнең, хәлифәләрнең тормыш һәм эш-гамәлләре турында тәфсилле мәгълүматлар татар халкы арасында күп гасырлар буе укылып килгән «Мөхәммәдия» (15 йөз), «Нәһҗ әл-фәрадис» («Оҗмахларның ачык юлы», 14 йөз), «Алты бармак» (17 йөз) кебек дини-дидактик әдәби әсәрләрдә һәм хәдис җыентыкларында да бәян ителә.

Б.ның алга таба үсеше Ш.Мәрҗани исеме б-н бәйле. Аның алты томлы гарәпчә «*Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф*» («Әлгәреләр һәм аларның киләсе буынга сәламнәре») хезмәтендә 7–19 йөзләрдә яшәгән Шәрекъ мөселманнарының һәм татар халкының дин, тарих, мәдәният, фән һ.б. өлкәләрдә исем казанган меңнән артык шәхеснең биографиясе бирелә. «*Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар*» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле 1885 һәм 1890 елларда басылган ике томлы татарча хезмәтендә исә автор 17–19 йөзләрдә Идел — Урал, Оренбург төбәкләрендә яшәп, хезмәтләре б-н халыкка исемнәрен таныткан татар-мөселман эшлеклеләренең биографияләрен урнаштыра. 20 йөз башында Ш.Мәрҗанинең бу эшен Риза Фәхретдин дәвам иттерә: 1900–08 еллар арасында аның дүрт томлы «*Асәр*» исемле зур тарихи һәм биобиблиографик хезмәтенең ике томы басылып чыга (1200 дән артык тарихи шәхеснең кыскача биографик белешмәләре). Шул ук авторның Шәрекънең күренекле фикер ияләре, шагыйрьләре, фәлсәфәчеләре тормышын яктырткан аерым китаплары: «Ибне Рөшд» (Казан, 1905), «Әбү Галә әл-Мәгарри» (Оренбург, 1908), «Имам Газали» (Оренбург, 1910), «Мөхәммәд пәйгамбәр» (Оренбург, 1912); Оренбург миллионеры-химаяче Әхмәт Хөсә-

еновның тәрҗемәи хәле турында «Әхмәд бай» (Оренбург, 1910), төрек әдибе Әхмәд Мидхәт турында «Әхмәд Мидхәд» (Оренбург, 1916) китаплары, «Мәшһүр хатыннар» (Оренбург, 1903) исемле күләмле җыентык һ.б. басыла. Бу елларда башка авторларның да аерым шәхесләрнең биографияләренә багышланган китаплары дөнья күрә: Й.Акчураның «Дамелла Галимҗан Баруди»е (1907), Ш.Хәмидинең «Голәмә тарихы» (1908), Г.Батталның «Ислам фәйләсуфләре Мөхәммәд Габдеһ, Җамалетдин Әфгани» (1908), Ф.Туктаровның «1, 2, 3 нче Думада мөселман депутатлары» (1908), Борһан Шәрәфнең «Гани бай» (Оренбург, 1913), Г.Батталның «Габделвәли Яушев» (Оренбург, 1913), Ш.Мәрҗанинең 100 еллык юбилееna чыгарылган «Мәрҗани мәҗмугасы» (1915), 1917 дә «Рәсүлия» мәдрәсәсен оештыручы Зәйнулла Рәсүлинең 100 еллыгына багышланган җыентык һ.б. биографик китаплар шулар җөмләсеннән.

1917 дән соң, бигрәк тә 1960–70 елларда, төп игътибар партия-дәүләт эшлеклеләренең, революционерларның тормыш юлларын һәм эшчәнлекләрен яктыртуга юнәлтелә. В.Ленинның, И.Сталинның стандартлаштырылган биографияләреннән тыш, матбугатта революция хәрәкәтләрендә актив катнашкан тарихи шәхесләргә багышланган күп кенә биографик китаплар, әдәби-документаль әсәрләр (татарча, русча һәм татар теленә тәрҗемәдә) дөнья күрә. «Халык бәхете өчен көрәшүчеләр» (1–3 кит., 1967–83; татар һәм рус телләрендә); «Советлар Союзы Геройлары — Татарстан уллары» («Герои Советского Союза — сыны Татарии», 1963), «Советлар Союзы Геройлары — безнең якташлар» («Герои Советского Союза — наши земляки», 1–3 кит., 1982–85), «Дан орденының тулы кавалерлары — безнең якташлар» («Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки», 1986), өлешчә «Кайтарылган исемнәр» («Возвращённые имена», 1990) — шул төр басмалардан. Сан ягыннан 20 йөздә әдәбият-сәнгать өлкәсе шәхесләренә багышланган биографик китаплар өстенлек итә. Җ.Вәлидинең рус телендә 19 йөз һәм 20 йөз башы татар әдәбияты, тарихы, тәгълим-тәрбия өлкәсендә эш күрсәткән шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләреннән кыскача мәгълүматларны эченә алган «Идел буе татарларының тәгълим-тәрбиясе һәм әдәбиятыннан очерклар» («Очерки образованности и литературы поволжских татар», М-Пб., 1923) китабы басылып чыга. Бу китап һәм Л.Толстойның 100 еллыгына багышланган «Л.Н.Толстойның бөек хатирәсе. Казан университеты» («Великой памяти Л.Н.Толстого. Казанский университет», 1928) җыентыгы, Гата Исхакыйның «Әдәбият юллары» (1920), Г.Ибраһимовка 40 яшь тулу уңае б-н 1927–28 дә чыккан басмалар — совет дәверенең беренче чирегендә мәйданга килгән биографик китапларның тәүге үрнәкләре. 1940–41 дә «Казанның атаклы кешеләре тормышы» сериясендә нәшер ителгән ике китап, «Орденлы Татарстанның алдынгы интеллигенциясе» (1941), Гази Кашшафның «Шәриф Камал» (1940), Мөхәммәт Галинең «Г.Камал» (1941) биографик китаплары басыла.

1950–80 еллар аралыгында күренекле татар язучылары, композиторлары, рәссамнары, артистларының биографияләренә һәм иҗат эшчәнлекләренә багышланган дүрт дистәдән артык исемдә китап дөнья күрә: «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә И.Нуруллинның «Габдулла Тукай» (1977; татар һәм рус телләрендә) һәм «Фатих Әмирхан» (1988), Х.Хәйринең «Һади Такташ» (1984), Р.Низамиевның «Фәрит Яруллин» (1990) китаплары, М.Хәсәновның берничә басмада «Галимҗан Ибраһимов» (1964), М.Госмановның «Хөсәен Фәезхановның якты хыялы» («Заветная мечта Хусаина Файзханова», 1980) монографияләре; Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Акмулла, Г.Коләхмәтов, М.Гафури, М.Җәлил, Һ.Такташ, Н.Исәнбәт һ.б. турында документаль-биографик хезмәтләр басыла. Болардан тыш, әдәбият-сәнгатьнең аерым тематик төрләренә нисбәтле биобиблиографик җыентыклар, белешмәлекләр барлыкка килә: А.К.Гыйниятуллинаның «Татар совет язучылары» (1958), «Писатели Советского Татарстана» (1958, 1970); В.А.Климентовскийның «Татарстан АССРда рус язучылары» («Русские писатели в Татарской АССР», 1951); З.Хәйруллинаның «Совет Татарстаны композиторлары» (1957), М.Гайнуллинның «Татар әдипләре» (1978); «Халык артистлары» («Народные артисты», 1980); С.М.Червоннаяның «Совет Татарстаны рәссамнары» («Художники Советской Татарии», 1984); М.Нигъмәтҗановның «Совет Татарстаны композиторлары һәм музыка белгечләре» («Композиторы и музыковеды Советского Татарстана», 1986); Р.Н.Даутов, Н.Б.Нуруллинаның «Совет Татарстаны язучылары» (1986); И.Иляловaның «Г.Камал театры артистлары» (1996; татар һәм рус телләрендә) һ.б. нәшер ителә. 1990 еллардан, үткәнгә һәм тарихи шәхесләргә карата объектив караш урнаша башлагач, Совет дәверендә онытылуга дучар ителгән күп кенә әдәбият-сәнгать, иҗтимагый-сәясәт, гыйлем-тәрбия эшлеклеләренең абруйлы исемнәре яңадан торгызылды, аларның тормышы һәм эшчәнлекләре, калдырган кыйммәтле мираслары хакында документаль чыганакларга нигезләнеп язылган биобиблиографик хезмәтләр мәйданга килде: Г.Баттал-Таймас «Муса Ярулла Биги» (Истанбул, 1958); «Бертуган Максудилар. Тормышы, иҗаты һәм хезмәтләре» (1999); Й.Акчура «Дамелла Галимҗан Баруди» (1997); «Садри Максуди» (1996); Г.Зәбиров «Максуд баба һәм Максудилар» (2003); М.Йосыпов «Галимҗан Баруди» (2003); «Ризаэтдин Фәхретдин» (1999); Н.Таиров «Акчуриннар» («Акчурины», 2002) һ.б. Ш.у. бу елларда Я.Г.Павлухинның Татарстан табибләренә багышланган җыентыгы «Татарстан медицинасы тарихы — шәхесләрдә» («История медицины Татарстана в лицах», 1997), Л.М.Свердлованың «Казан сәүдәгәрләре: эшләре һәм шәхесләр» («Купечество Казани: дела и люди», 1999), И.Рәминең үзе исән чакта идеологик сәбәпләр аркасында матбугатка чыга алмый калган һәм хәзер Р.Даутов тарафыннан тулыландырылган «Әдәби сүзлек» (2001) белешмәлеге, Р.Н.Даутовның «Балачак әдипләре» (1–3 кит., 2002–05) китаплары, «Әфганстан сугышы корбаннарының хәтер китабы — Книга памяти жертв войны в Афганистане» (1999), «Батырлар китабы — Книга Героев» (2000) һ.б. икетелле белешмәлекләр нәшер ителә. Татарстан һәм татар халкының 7 меңнән артык күренекле шәхесе турында мәгълүматларны эченә алган «Татар энциклопедия сүзлеге» (2002; рус телендә «Татарский энциклопедический словарь», 1999) басмасы, русча «Татарская энциклопедия» томнары (1–3 т., 2002–06) исә татар Б. өлкәсе үсешендә яңа бер мөһим этап булып тора.

*И.А.Новицкая, Р.Н.Даутов.*

**БИОЛО́ГИЯ** (*био...* һәм *...логия*), терек табигатьне өйрәнүче фәннәр җыелмасы. «Б.» термины 1802 елда бер-берсеннән бәйсез рәвештә француз натуралисты Ж.-Б. Ламарк һәм немец табигать белгече Г.Р.Тревиранус тарафыннан тәкъдим ителә. Фәнни яктан Б. тереклекне һәр яктан — тереклек ияләренең һәм аларның табигый бергәлекләренең төзелешен, функциясен, таралуын, килеп чыгышын һәм үсешен, ш.у. аларның үзара һәм терек булмаган табигать б-н бәйләнешләрен өйрәнә.

Классик Б. фәннәре — *зоология* һәм *ботаника* борынгы заманнардан ук билгеле. Аларның үсеше, ш.у. *анатомия* буенча беренче уңышлар 15–17 йөзгә туры килә. Микроскоп булдырылгач (17 йөз), цитология, *микробиология*, эмбриология һәм *гистология* фәннәре барлыкка килә, аларның үсеше өчен мөмкинлекләр ачыла. 18 йөздә Б.дә тере организмнарның табигый классификациясе системасы төзелә (К.Линней, 1735), *кеше* һәм *хайван*, *үсемлекләр физиологиясе* өлкәсендәге беренче хезмәтләр күренә башлый. 19 йөз күп кенә ачышлар һәм фундаменталь нәтиҗәләр б-н билгеле. Алар арасында иң мөһимнәреннән — күзәнәк теориясе (Т.Шванн, 1839) һәм эволюция тәгълиматы (Ч.Дарвин, 1859). 20 йөз уртасында даими камилләшә барган техника һәм тикшеренү ысуллары нәтиҗәсендә яңа биологик фәннәр — *генетика*, индивидуаль үсеш биологиясе, *биохимия*, *биофизика* һ.б. үсеш ала. 20 йөзнең иң зур казанышлары: нәселдәнлекнең хромосома теориясен нигезләү, генетик информацияне саклаучы дезоксирибонуклеин кислотасының (ДНК) структурасын ачыклау, *фотосинтез* физика-химиясен белү, эволюциядә мутация процессларының ролен билгеләү.

Россиядә Б.гә кагылышлы беренче билгеле хезмәтләрдән Петербург ФА академигы К.Ф.Вольфның эмбриология өлкәсендәге эшләре санала. Ул беренче тапкыр организмнарда яралгы үсешенең эзлекле рәвештә яңа форма барлыкка китерүен, ягъни, эпигенез икәнлеген күрсәтә. 19 йөзнең 1 нче чирегендә эпигенез идеясе Россия академиклары Х.И.Пандер һәм К.М.Бэр хезмәтләрендә фәнни раслау таба. 19 йөзнең 60 нчы елларында А.О.Ковалевский һәм И.И.Мечников умырткасыз организмнар үсешенең элгәре стадияләре умырткалы хайваннар яралгысының

формалашу үзенчәлекләре б-н шактый дәрәҗәдә бертөрле булуын күрсәтә. Умырткасыз һәм умырткалы хайваннарның яралгы яфракчыклары гомологиясе идеясе хайваннар дөньясы эволюциясе турындагы тәгълиматның мөһим өлешенә әверелә. Россия биологлары казанышлары арасында иң мөһимнәре: югары нерв эшчәнлеге турындагы тәгълимат нигезләрен булдыру (И.М.Сеченев, 1863), вирусларны (Д.И.Ивановский, 1892), икеләтә аталану процессын (С.Г.Навашин, 1898) ачу, шартлы рефлекслар турындагы тәгълимат (И.П.Павлов, 1903), аксымнар химиясен өйрәнү (А.Я.Данилевский һ.б.), тереклекнең килеп чыгышы теориясен (А.И.Опарин, 1924), биогеохимия һәм биосфера турындагы тәгълиматны (В.И.Вернадский, 1926) булдыру, биополимерларның матрицалы синтезы принципларын (Н.К.Кольцов, 1927), биогеоценология формалашуын (В.Н.Сукачёв, 1942), биоэнергетика нигезләрен (В.А.Энгельгардт, В.П.Скулачёв) тасвирлау, аксым биосинтезының молекуляр механизмнарын һәм рибосомалар структурасын (А.С.Спирин һ.б.), ш.у. рибонуклеин кислотасының структурасын һәм функциясен (А.А.Баев) өйрәнү.

Татарстанда Б. фәненең үсеше Казан ун-ты тарихы б-н бәйле. 1805 елдан К.Ф.Фукс, табигать тарихы һәм ботаника кафедрасы мөдире буларак, ун-тта беренче курс студентларына «Табигать тарихы» («Натуральная история») курсларын укыта башлый. Яңа устав кертелгәннән соң (1835–36), ун-тта медицина ф-ты, философия ф-тында зоология һәм ботаника каф. оештырыла. Россиядә һәм чит илләрдә Казан зоология фәнни мәктәбе киң таныла. Аның тарихын башлаучылардан Э.И.Эйхвальд, Э.А.Эверсман, М.Н.Богданов, М.Д.Рузский, Н.П.Вагнер, О.А.Ковалевский, В.В.Заленский, А.А.Остроумов һ.б. күрсәтергә мөмкин. Систематик фаунистика, экологик фаунистика, эмбриология буенча тикшеренүләр, ихтиология-гидробиология һәм эволюцион морфология кебек фәнни юнәлешләргә нигез салу алар исеме б-н бәйле. Ихтиология-гидробиология юнәлеше ун-тның умырткалылар зоологиясе каф-сында туа һәм үстерелә. Куйбышев сусаклагычы төзелгәннән соң (1955–57), кафедра галимнәре (Х.М.Корбангалиева, В.А.Кузнецов һ.б.) бу уникаль сусаклагычның гидробиологик режимы, балыклар өеренең формалашу үзенчәлекләрен ачыклый. Эволюцион морфология юнәлешен умырткасызлар зоологиясе каф. галимнәре М.М.Усов, Э.А.Мейер һәм Н.А.Ливанов нигезли. Н.А.Ливановның «Хайваннар дөньясының эволюция юллары» («Пути эволюции животного мира», 1945; 2 изд., 1955) исемле, зоологиядә киң танылыш тапкан хезмәтендә хайваннар дөньясының төп типларының барлыкка килү үзенчәлекләре беренче тапкыр буларак экологик яктан карала. Хәзерге вакытта бу юнәлешне кафедра галимнәре дәвам итә (А.И.Голубев һ.б.).

Казан геоботаника фәнни мәктәбе киң таныла. С.И.Коржинский һәм А.Я.Гордягин үсемлекләр эксперименталь экологиясенә һәм фитоценологиягә нигез сала, Урта Идел һәм Көньяк Уралның флорасын, үсемлекләр дөньясын өйрәнү максатында киң күләмле экспедицияләр оештыра. Университет ботаниклары СССРның палеоген-неоген һәм дүртенчел чор флорасын (В.И.Баранов, М.М.Ятайкин, В.Т.Шаландина), урман һәм дала үсемлекләре дөньясындагы үзара мөнәсәбәтләрне өйрәнүгә, геоботаниканың яңа юнәлеше — агрофитоцинологиянең үсешенә зур өлеш кертә.

19 йөзнең 2 нче яртысы башында Казан ун-тының медицина ф-тында Ф.В.Овсянников тарафыннан Россиядә беренчеләрдән буларак эксперименталь физиология лабораториясе оештырыла. Төзелүе б-н бу лаборатория ун-тта эксперименталь мед. фәннәре үсешенә һ.б. — гистология (К.А.Арнштейн), фармакология (И.М.Догель), психофизиология (В.М.Бехтерев), эксперименталь патология (В.В.Пашутин) лабораторияләре оештырылуда этәргеч этап була. Университет вегетатив һәм соматик функцияләрнең нерв системасы ярдәмендә һәм химик җайлану механизмнарын өйрәнүдә физиология фәнни мәктәбенең формалашу үзәгенә әверелә. Казан физиология мәктәбенең 19 йөз ахырындагы иң зур казанышлары: күз бәбәгенең парадоксаль киңәю күренешен ачу һәм аныклау (И.Г.Навалихин, Н.О.Ковалевский, Н.А.Миславский, В.В.Чирковский); вегетатив ганглийларның рефлектор функциясен (Н.М.Соковкин, В.М.Рожанский) һәм кайбер эчке органнарның сиземләү иннервациясен (нервлар б-н тәэмин ителүен) (А.Е.Смирнов, Д.В.Полумордвинов) ачу; сулыш алу үзәге тупланган урынны һәм аның функциональ структурасын билгеләү (Н.А.Миславский); эчке секреция бизләре эшчәнлегендә нерв системасының ролен ачу (Н.А.Миславский, М.Н.Чебоксаров һ.б.). 20 йөз башында Казан ун-тының физиология мәктәбе Европада иң яхшы электрофизиология лабораторияләренең берсе булып тора. Биредә электрокардиограмманың төп элементлары ачыклана, хәрәкәтләнү аппаратында (А.Ф.Самойлов) һәм вегетатив төеннәрдә (А.В.Кибяков) ярсыну үткәрүнең химик механизмнары ачыклана, нерв-мускул тукымалары эшчәнлегендә кальций ионнарының роле билгеләнә (И.Г.Валидов). 20 йөзнең 2 нче яртысында өзлексез һәм синаптик структураларда медиаторларның роле дәлилләнә (И.Н.Волкова, Л.Н.Зефиров, Г.И.Полетаев һ.б.). Корсак куышлыгы әгъзалары авыруларыннан саклаучы рефлексларны (Л.Н.Зефиров, О.С.Кочнев, В.И.Алатырев), кеше һәм хайван организмнарында хәрәкәт б-н идарә итү проблемаларын (В.И.Алатырев) өйрәнү буенча тикшеренүләр алып барыла. Хәзерге вакытта нейрофизиология проблемалары киң өйрәнелә. Синаптик структураларда медиаторны азат итүнең нечкә механизмнары, медиаторның төрле мембрана рецепторлары б-н бәйләнеше үзенчәлекләре, ярсынучан күзәнәкләрнең биологик актив матдәләр ярдәмендә җайлану механизмнары билгеләнә (Г.И.Полетаев, А.Л.Зефиров, Е.Е.Никольский, Р.Ә.Гыйниятуллин, Е.М.Волков). Казан физиология мәктәбенең башка юнәлешләреннән зоофизиология (И.Г.Навалихин, К.Р.Викторов, В.Л.Лысов), кардиология (М.А.Кисилёв, Л.М.Рахлин, О.Д.Курмаев, Л.Г.Әмиров, Ф.Г.Ситдыйков), хезмәт физиологиясе (М.А.Юровская, К.Р.Викторов, И.А.Аршавский, М.А.Кисилёв) үсеш ала.

1920 еллар башыннан Казан ун-тында, ш.у. 1946 дан СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында үсемлекләрдә су режимын өйрәнү буенча яңа юнәлеш ачыла; күзәнәкләрдә су-ның халәте һәм үсемлекләрдә су алмашы — су йөрешенең термодинамикасы һәм механизмнары турындагы тәгълимат булдырыла (А.М.Алексеев, И.Г.Сөләйманов, Н.А.Гусев, А.А.Җәләлов, А.В.Анисимов, Ф.Д.Самуилов, Л.П.Хохлова). 1960 елларда фотосинтез экологиясе, биохимиясе һәм энергетикасын өйрәнү юнәлеше барлыкка килә. Углеродның фотосинтездан соңгы үзгәреше һәм фотосинтез барышында энергия әверелеше үзенчәлекләре ачыклана (И.А.Тарчевский). 1980 еллардан Россия ФАнең Казан фәнни үзәге Биохимия һәм биофизика ин-тында генетик аппаратның эшчәнлеген һәм үзгәрүчән яшәү шартлары тәэсиренә җайлашу сәләтен көйләп торучы үсемлек күзәнәкләрендәге сигнал системалары өйрәнелә (И.А.Тарчевский, А.Н.Гречкин, Ф.Г.Кәримова, Н.Н.Максютова, Л.Х.Гордон).

19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казанда илдә беренчеләрдән буларак микробиология фәне үсеш ала. Аның башында күренекле галимнәр Ф.Брауэль, Н.В.Сорокин, И.Г.Савченко, Н.В.Высоцкий, А.М.Аристовский һ.б. тора. 1950–70 елларда Казан ун-тында тикшеренүләрнең төп ике фәнни юнәлеше: бактериаль ферментларның структурасы, функциясе һәм эш механизмы (М.И.Беляева, И.Б.Лещинская, В.Г.Винтер һ.б.); әйләнә-тирә мохитне пычратучы табигый булмаган кушылмалардагы микроблар метоболизмы (Р.П.Наумова) билгеләнә.

1969 да Казан ун-тында СССРда беренче булып табигатьне саклау кафедрасы (В.А.Попов), ә соңрак аның базасында экология ф-ты ачыла. Бу юнәлештә кеше эшчәнлегенең җир өсте экосистемаларына караган үзгәрешләрен теоретик һәм гамәли аспектларда өйрәнүгә өлеш кертелә (В.А.Попов, В.А.Бойко һ.б.). Б. әйдәп баручы табигать фәненә әверелә барган саен, Татарстанда теоретик һәм гамәли Б. мәсьәләләрен тормышка ашыручы фәнни һәм белем бирү учреждениеләре арта бара (ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-ты, Казан мед. академиясе, Казан мед. ун-ты, Бөтенроссия ветеринария ин-ты, Казан авыл хуҗалыгы академиясе һ.б.).

*Әд.:* История биологии с древнейших времён до начала XX века. М., 1972; История биологии с начала XX века до наших дней. М., 1975; Биологический энциклопедический словарь. М., 1986.

*А.И.Голубев.*

**БИОМА́ССА** (*био*... һәм *масса*), биогеоценоздагы теге яки бу организмнарның тере матдәләре күләме; масса берәмлегенә мәйдан (*г/м*²) яки күләм (*г/м*³) берәмлегенә чагыштырмасы һ.б. б-н билгеләнә. Иң мөһим экологик терминнарның берсе. Тере матдәнеңчи, коры яки көлсезләндерелгән халәтендә

исәпләнә. Экосистемаларда энергия агымын өйрәнгәндә Б.ны да энергия берәмлекләре (мәс., *Дж/м*$^2$) б-н билгелиләр. Б. ның үсемлекләргә, хайваннарга яки микроорганизмнарга нисбәтле булуыннан чыгып, фитомасса, зоомасса һәм микроорганизмнар массасын билгелиләр. Туклану чылбырындагы роленә карап, продуцентлар (органик булмаган кушылмалардан органик матдәләр хасил итүче автотрофлар һәм хемотрофлар), консументлар (органик матдәләр б-н тукланучы гетеротрофлар) һәм редуцентлар (органик матдә калдыкларын органик булмаган кушылмаларга әверелдерүче организмнар) Б.сын аерып йөртәләр. Җирнең гомуми Б.сы якынча 1,8·10$^{18}$ *г* коры матдә (*биосфера* массасының 0,0001%ы) яки 30·10$^{21}$ *Дж* тәшкил итә. Күпчелекне фитомасса (97–99%) алып тора; хайваннар өлешенә фәкать 1–3% кына туры килә. Зоомассаның төп чагыштырма авырлыгы (90–95%) умырткасыз организмнарга туры килә.

ТР терр-ясендә урман һәм урман-дала зоналарында урнашкан урманнар Б.сы өстенлек итә. Агачларның коры фитомассасы (*ц/га* ларда): чыршылыкларда — 513–3179, наратлыкларда — 807–2799, имәнлекләрдә — 690–5038, юкәлекләрдә — 1585–2250, каенлыкларда — 898–2499, усаклыкларда — 1863–3048. Шуның б-н бергә үзагачка — 60–83%, тамырларга — 14–34%, калганы — ылыска яки яфракларга туры килә. Ылыслы урманнарның уртача зоомассасы (*г/м*$^2$ ларда) — 6,8, катнаш урманнарныкы — 8,1, киң яфраклыларныкы — 18,4; урманнарның һәр төрендә микроорганизмнар массасы — 250, 200 һәм 120.

Мишә елгасы үзәне болыннарының фитомассасы чи матдәдә — 105 һәм зоомассасы 2,8 *ц/га* тәшкил итә. Барлык хайваннар Б.сының 98,9% ы — умырткасызларга, 0,8% ы — җир-су хайваннарына, 0,2% ы — кошларга, 0,1% тан кимрәге тычкансыман кимерүчеләргә туры килә.

Су экосистемаларында Б., башлыча, планктон (су катламында яшәп, агымнарга каршы тора алмаучан) һәм бентос (грунтта һәм сулыклар грунтында яшәүче) организмнарыннан гыйбарәт. Куйбышев сусаклагычында фитопланктон Б.сы 0,2–80 (су яшелләнгәндә 2000 гә кадәр), зоопланктонныкы — 0,2–7, инфузорияләрнеке — 0,1–24 *г/м*$^3$, зообентосныкы — 1,4–85 *г/м*$^2$. «Б.» төшенчәсе биоценоз продуктлылыгы (Б.ның артым бирү тизлеге) б-н аның составындагы организмнар һәм аларның бергәлекләрен бәяләгәндә, туклану чылбырларын анализлаганда һәм Б. пирамидасы төзегәндә, ш.у. кешенең хуҗалык эшчәнлеген фаразлаганда кулланыла. Бу мәсьәләләрне өйрәнү, хәл итү өстендә ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-ты, Казан ун-ты, Татар гуманитар-пед. ун-ты һ.б. эшли. Аерым биогеоценозлар Б.сын өйрәнүдә В.С.Порфирьев, М.В.Марков, Е.Л.Любарский (үсемлек бергәлекләре), М.М.Алейникова (туфрак мезофаунасы), Н.М.Минһаҗева, В.А.Яковлев, Ә.Н.Сәләхетдинов (гидробионтлар) зур өлеш керттеләр.

*Әд.:* Справочник по охране природы. М., 1980; Реймерс Н.Ф. Природопользование. М., 1990; Зелёная книга Респубики Татарстан. К., 1993; Криволуцкий Д.А. Почвенная фауна в экологическом контроле. М., 1994.

*С.И.Кадошников.*

**БИОМЕДЭ́ТИКА**, биологик медицина этикасы, әхлакый нормалар, табиблек кагыйдәләре, медицинаның хокукый һәм социаль мәсьәләләре, кешенең хайваннарга һәм үсемлекләргә мөнәсәбәте турындагы тәгълимат. Б. традицион мед. этикасы һәм биоэтика нигезендә барлыкка килгән. Б. принциплары борынгы дәвердә формалашкан. Мед. этикасының мөһим мәсьәләләре Гиппократ хезмәтләрендә (б.э.к. 4 йөз) төгәл билгеләнгән, анда табиб б-н җәмгыять, авырулар, авыруның туганнары б-н табибләрнең үзара мөнәсәбәтләре, табиблек ялгышлары һ.б. бәян ителгән. «Биоэтика» терминын Америка биологы В.Р.Поттер 1969 елда гамәлгә кертә. Б. үсеше табибнең авыруга карата гадәти патерналистик мөнәсәбәтенең алар арасындагы тулы мәгълүматлы һәм киңәшү характерындагы мөнәсәбәтләр моделе б-н бәйле. Б.ның төп бүлеге — гамәли һәм фәнни эшчәнлек барышында табибнең үз-үзен тоту принципларын нигезләүче деонтология. Медицина практикасына яңа технологияләр кертелү гадәти мед. этикасы кысаларында чишеп булмый торган өр-яңа әхлакый һәм хокукый проблемалар китереп чыгара. Фәннең, гамәли эшчәнлекнең, хокукый контрольнең мед. өлкәләрендәге тикшеренүләрдәге роле үсә (кеше б-н экспериментлар үткәрү, геннар инженериясе, яңа репродуктив технологияләр, системалар һәм органнарны күчереп утырту, психиатрия, эвтаназия, мед. этикасы стандартлары һ.б.) ; сәламәтлек саклау системасында социаль гаделлек проблемасына игътибар арта. Мөстәкыйль дисциплина буларак, Б. 1980 еллардан Көнбатыш Европа һәм АКШ ун-тларында өйрәнелә. Россиядә беренче булып 1998 дә Казан мед. ун-тында мед. тарихы курслары б-н бергә биомедэтика һәм мед. хокукы кафедрасы оештырыла.

*Әд.:* Иванюшкин А.Я. Профессиональная этика в медицине: философские очерки. М., 1990; Гиппократ. Избранные книги. М., 1994; Большая медицинская энциклопедия. М., 1978. Т. 7.

*В.Ю.Альбицкий.*

**БИО́НИКА** (грек. bíon — тереклек берәмлеге, сүзгә-сүз тәрҗемәсе — яшәүче), хәрәкәтнең гади формалары нигезендә төзелгән ясалма системалардагы материя хәрәкәтенең биол. рәвешен, аерым принципларын, үзенчәлекләрен, закончалыкларын кабатлау юллары һәм ысуллары турындагы фән. Сыйфатламалары тере системалар сыйфатламаларына якын булган яңа машиналар, приборлар, төзелеш конструкцияләрен һәм технологик процессларны булдыру өчен организмнарның төзелеш һәм тереклек итү үзенчәлекләрен өйрәнә. Перспектив юнәлешләре: хисаплау техникасын камилләштерү, сизгеч һәм эзләп табу системаларын эшләү, яңа төзелеш конструкцияләре булдыру максаты б-н, кеше һәм хайваннарның нерв системасын, аларның сизү органнарын, хайваннар файдалана торган ориентация һәм локация ысулларын, ш.у. тере организмнарның морфологик үзенчәлекләрен өйрәнү һ.б. 1960 елда Дайтонда (АКШ, Огайо штаты) «Тере прототиплар — яңа технологиягә ачкыч» девизы б-н Б. буенча беренче симпозиум булып уза, ул рәсми рәвештә яңа фән барлыкка килүне таный. Шул вакыттан АКШта һәм Көнбатыш Европа илләрендә бионик тикшеренүләр киң җәелә.


Россиядә беренче бионик тикшеренүләр 1961 дә Казан, Горький, Ленинград, соңрак Мәскәү, Ростов һәм Томск ун-тларында башлана. Казан ун-тында физика ф-тының радиоэлектроника каф. каршында бионика төркеме оештырыла, 1963 тә ул Б.ның фәнни-тикшеренү лабораториясе, 1965 тән Б.ның проблема лабораториясе итеп үзгәртелә. Ү.Ш.Әхмәров җитәкчелегендә физиологиядә «көч-озаклык» закончалыгы дип аталган нерв һәм мускулларның ярсыну чиген өйрәнү буенча тикшеренүләр үткәрелә. Әлеге закончалыкның универсаль булуы, аның тере организмнарга гына түгел, ә табигате биологик булмаган системаларга да хас икәне беренче тапкыр аңлатыла. Күп кенә техник һәм технологик модельләрдә адекват режим дип аталган (тере системаларның эшчәнлек режимы аналогиясенә таянып) аеруча уңайлы режим мөмкинлеге күрсәтелә. Моннан тыш, физиологик законның табигате биологик булмаган модельләрдә киң кулланылуы чиктәш режимда эшләүче катлаулы системаларны анализлауның принципиаль яңа — «чик характеристикалар ысулы»н эшләү мөмкинлеге ачыла. 1970–80 елларда Ү.Ш. һәм Н.Ү.Әхмәровлар тарафыннан Б.ның методологик мәсьәләләре ачыклана, аның төп аңлату аппараты, гомуми фәннәр системасындагы урыны, классификациясе һ.б. билгеләнә. Б. өлкәсендәге тикшеренүләр өч этапка бүленә: биологик — тере организмның теге яки бу үзенчәлеген, закончалыгын өйрәнү; теоретик-матем. — биологик этаптагы мәгълүматларны гомумиләштерү, аларны формалаштыру, модельләр, функциональ схемалар төзү; техник гамәлдәге макетны инженерлык ягыннан эшкәртү, техник гамәлгә кертү. 1977 нең 17–20 маенда Казанда «Биониканың методологик мәсьәләләре»нә багышланган Бөтенсоюз симпозиумы уздырыла. Казан архитектура-төзелеш ун-тында архит-ра Б.сы өлкәсендә тикшеренүләр алып барыла. Пәрәвез, моллюсклар, диңгез хайваннары кабырчыгы төзелеше принципларына, ш.у. үсемлекләр күзәнәкләрендәге эчке басым — тургор үзенчәлегенә нигезләнгән тент, пневматик төзелеш корылмалары һәм полимер материаллардан каты тышча булдыру проектлары төзелә (Ю.И.Блинов, В.С.Сладков, И.Х.Мифтахетдинов, Е.М.Удлер). Кайбер тәкъдимнәр республиканың архитектура-төзелеш практикасында чагылыш таба («Идел» яшьләр лагерендагы иҗтимагый үзәк, Әлмәт шәһәрендәге сәүдә павильоннары һ.б.). И.Х.Мифтахетдинов тарафыннан хайван һәм үсемлекләрнең тышкы формалашу һәм үсү закончалыкларына нигезләнгән катлаулы гиперболик тышча («үзлегеннән формалашу принцибы») әзерләүнең яңа ысулы эшләнә (РФ нең 5 патенты алына). 1988 дә Казанда җитештерүне бионикалаштыру мәсьәләләренә, сәнәгать өлкәсендә биониканы тирәнтен өйрәнү-

гә багышланган беренче бөтенсоюз конференциясе уздырыла.

*Әд.:* Ахмеров У.Ш. Фактор времени при одиночном раздражении. К., 1963; шул ук. Методологические вопросы бионики. К., 1977; Исследования по бионике: В 4 вып. К., 1972–84; Лебедев Ю.С. Архитектурная бионика. М., 1977; Бионические аспекты изучения пороговых характеристик возбудимых биосистем. К., 1978; Материалы симпозиума по методологическим вопросам бионики. К., 1978; Ахмеров У.Ш., Ахмеров Н.У. Введение в бионику. Учеб. пособие. К., 1984; Научно-техническая конференция «Вопросы бионизации производства», 13–14 ноября 1986 г.: Тез. докл. К., 1986; Ахмеров Н.У. Закономерности одиночного порогового раздражения нервов и мышц. К., 1999; Мифтахутдинов И.Х. Оболочки отрицательной кривизны в архитектуре и строительстве: Учеб. пособие. К., 2000; Bionics symposium in Dauton. 13–15 Sept. 1960. Dauton, 1960.

*Ү.Ш.Әхмәров.*

**БИОСЕ́НСОРЛАР**, җайланмалар; алардагы биологик материал (ферментлар, тукыма, бактерия, чүпрә, антиген-антитәнчекләр, липосома, органелла, рецепторлар, ДНК) кергән сизгер катлам билгеләнә торган компонентның булуын турыдан-туры сизә һәм шушы компонентның концентрациясенә функциональ бәйле сигнал тудыра. Б. әйләнә-тирәне һәм кеше сәламәтлеген саклау мәсьәләләрен хәл иткәндә, биотехнологияләрдә кулланыла. Конструкциясе буенча Б. үзара тыгыз




Биосенсорның принципиаль схемасы.
1. Эремә;
2. Биокатлам;
3. Физик үзгәрткеч (электрод);
4. Үлчәү җайланмасы.

бәйләнештәге биохимик һәм физик үзгәрткечләрдән тора. Биохимик үзгәрткеч биологик элементны тану функциясен үти (к. рәсем), уникаль үзлекләргә ия булган биоматериал югары төгәллек б-н катнашмадагы кирәкле кушылманы билгели, бу биохимик реакция б-н бергә бара. Физик үзгәрткеч реакция продуктларын махсус аппаратура ярдәмендә билгели.

Физик үзгәрткечләр: электрохимик, спектроскопик, термик, пьезоэлектрик һ.б. төрле була. Барыннан да ешрак, өслегенә биоматериал катламы капланган электродта — потенциал (потенциометрик Б.) яки электрод өслегендә билгеләнергә тиешле матдәнең биоматериал китереп чыгарган әверелеш продукты реакциясе электр тогы (амперометрик Б.) тудыра торган электрохимик үзгәрткечләр кулланыла. Оптик җепсел Б. да физик үзгәрткеч биокатлам тирәсендәге яктылык йотылу үзгәрешен билгели. Ферментлар яки ферментлы материаллар нигезендәге аналитик җайланмалар беренче тапкыр 1960 елларда барлыкка килә. Соңрак «биосенсор» (яки «биочип») төшенчәсе әйләнешкә керә. Функциональ яктан Б. тере организм тапшыргычлары — биорецепторлар б-н охшаш, алар тирәлектән алынган бөтен төр сигналларны электр сигналына әйләндерәләр. Ферментлар нигезендәге Б. күбрәк таралган. Шундый җайланмалар арасында зур сайлаучанлыкка ия булган субстрат Б. һәм аеруча сизгер ингибиторлы Б. башкалардан аерылып торалар. Билгеләнә торган концентрациянең иң түбән чиге $10^{-11}$ *моль/л* дәрәҗәсенә җитә. 1980 елларда Казан ун-тында Б. өлкәсендә интенсив тикшеренүләр башлана (Г.К.Будников һ.б.). Холинэстераза ферменты нигезендәге электрохимик Б. аеруча зур кызыксыну тудыра, алар ингибиторларны — әйләнә-тирә пычраткычларын билгеләү өчен кулланыла. Бу Б. микрокомпонентлар: селтеле, селтеле-җир һәм авыр металлар ионнары, актив өслекле кушылмалар һәм холинэстераза ингибиторлары (шул исәпкә пестицидлар да керә) барлыгын сизә. Б.ның сизгерлеге һәм сайлаучанлыгы холинэстераза кертелгән матрицаны, физик үзгәрткечне сайлап алып һәм реакция тирәлеге составын оптимальләштереп көйләнә. Сизгерлек һәм сайлаучанлыкны максатчан көйләү Б.ны конкрет аналитик бурычны хәл итүгә яраклаштырырга, экологик-аналитик мониторинглар үткәргәндә пычраткычларның аерым төркемнәрен билгеләүнең сыйфатын күтәрергә мөмкинлек бирә. Холинэстеразлы алмаш мембраналар б-н эшләүнең гадилеге һәм үрнәк (проба) әзерләүнең гадиләштерелгән ысуллары Б.ны үрнәк алган җирдә, кыр шартларында кулланырга мөмкинлек бирә. Холинэстераза Б. кайбер антигеннарны билгеләү өчен дә файдаланыла. Мондый Б. да биологик сизгер мембрана бергә тупланган (мәс., нитроцеллюлоза матрицасына) холинэстераза һәм антитәнчекләрдән тора. Антиген б-н антитәнчекнең мембранада узучы иммунохимик реакциясе холинэстеразаның активлыгы үзгәрүе буенча контрольдә тотыла.

*Әд.:* Биосенсоры: основы и приложения. М., 1992; Биосенсоры как новый тип аналитических устройств // Соросовский образовательный журн. 1995. № 12; Биосенсоры для определения ингибиторов ферментов в окружающей среде // Успехи химии. 1999. Т. 68. № 12.

*Г.К.Будников.*

**БИОСФЕ́РА** (*био*... һәм сфера), барлыкка килүе һәм эволюциясе тере организмнар эшчәнлегенә бәйле булган Җир тышчасы. Беренче тапкыр «Б.» термины Австрия геологы Э.Зюсс тарафыннан тәкъдим ителә (1875), ул Б.ны планетаның тышкы күренешен билгели торган «тереклек сүрүе» буларак фаразлый. Б. турындагы тулы тәгълимат В.И.Вернадский тарафыннан төзелә. Ул Б. — «тере матдәнең яшәеш өлкәсе» (1965) дигән билгеләмә бирә, тере организмнар эшчәнлеге планетар күләмдәге көчле геохимик фактор буларак чагыла. Б. 3,5–4,5 млрд. еллар элек барлыкка килә. Якынча 2 млрд. еллар элек Җирнең беренчел атмосферасында яшел үсемлекләрнең фотосинтез эшчәнлеге нәтиҗәсендә ирекле кислород барлыкка килү һәм аның туплана башлавы Б. эволюциясендә мөһим вакыйга була. Фотосинтез процессы барышында кояш энергиясеннән һәм атмосферадагы углекислый газдан файдаланып, яшел үсемлекләр (автотрофлар) үз органик матдәләрен арттыралар, ә бу, үз чиратында, калган тере организмнар (гетеротрофлар һәм деструкторлар) өчен энергия һәм азык чыганагы вазифасын башкара. Органик матдә барлыкка килү, туплану һәм таркалу процесслары нәтиҗәсендә барган тере организмнар эшчәнлеге матдә һәм энергиянең өзлексез әйләнешен китереп чыгара. Б. атмосфераның озон экранына кадәр 20–25 *км* биеклектәге түбән өлешен, литосфераның коры җирдә 2–3 *км* һәм океан төбендә 1–2 *км* тирәнлектәге өлешен (җылылык барьерына кадәр), ш.у. тулысынча гидросфераны (елгалар, күлләр, диңгезләр, океаннар) үз эченә ала. Б.ның гомуми биеклеге 40 *км* га җитә. Б.ның тере матдәсе үзара билгеләнгән, барыннан да бигрәк, трофик (азык) бәйләнешендәге организмнар комплексы җыелмасыннан (биоценозлар) гыйбарәт. Моннан тыш, тере организмнар комплексы тирә-як мохиткә бәйле, аның б-н бергә динамик системалар — *биогеоценозлар* һәм Җирнең биогеоценотик капламын хасил итәләр.

Б. эволюциясе барышында үсемлек һәм хайван организмнарының сыйфат составы һәрвакыт үзгәреп тора. Шулай да Б.ның теләсә кайсы үсеш этабында тере матдәнең бердәм эшчәнлеге үзенә җитәрлек мохит шартларын һәрвакыт саклап кала. 20 йөздә үзенең даими үсә барган ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен техник яктан коралланганда, В.И.Вернадский әйткәнчә, кеше «зур геологик көч»кә әйләнә, Б. үсешендә «Б. — кеше» системасындагы каршылыкларның көчәюе б-н сыйфатланучы яңа этап башлана. 19 йөз ахырында кешелек дөньясы Б.дагы беренчел биологик продукциянең 1% ын гына кулланган, һәм бу яшәү мохитенең үзгәрүенә тәэсир итмәгән; 20 йөз ахырында куллану 6–8% ка җитә, бу исә әйләнә-тирә мохит халәтен саклап калу мөмкинлеге чигеннән уннарча тапкыр артык. Халык санының арта баруы, аның яшәү чикләренең даими киңәюе, табигый ресурсларны рациональ кулланмау — ландшафтларда биологик күптөрлелекнең кимүенә, экологик тигезлекнең бозылуына, биота генофондының ярлылануына китерә торган төп факторлар. Акыллы эшчәнлек «кешелек дөньясы — табигать» системасы эволюциясенең әйдәп бара торган факторына әйләнгән вакытта, 1944 елда В.И.Вернадский Б.ның ноосферага (грек. noos — акыл) күчүе турындагы тәгълиматны тәкъдим итә. Ноосферада кеше төр буларак сакланып калсын өчен, җәмгыять үзе барлыкка килгән һәм үсеш алган Б. тибын сакларга тиеш. Әйләнә-тирә мохит буенча Стокгольмда үткәрелгән 1 нче Халыкара конференциядә (1972) киләчәк буын язмышы өчен дөнья бергәлегенең борчылуы белдерелә. Шуннан соңгы 2 дистә еллар буена БМОның Әйләнә-тирә мохит буенча халыкара комиссиясе, Бөтендөнья күзәтү ин-ты һ.б. кысаларында хәзерге цивилизациянең якын киләчәктә мөмкин булган экологик кризисы проблемаларына багышланган интенсив тикшеренүләр алып барыла. Халыкның урнашу мәсьәләсе буенча Каһирәдә үткәрелгән Халыкара конференциядә (1994) иҗтимагый-икътисади үсеш, демография һәм әйләнә-тирә мохитнең тыгыз бәйләнгәнлеге раслана, ресурслардан рациональ файдалану нигезендә җәмгыять б-н табигатьнең үзара бәйләнешләренең яңа үрнәкләрен эзләргә ке-

решү зарурлыгына аеруча басым ясала. Тотрыклы үсеш стратегиясендә табигый терр. комплекслар оештыру һәм коруны камилләштерә торган хуҗаларча экологик мөнәсәбәт һәрвакыт актуаль булып кала. Табигый саклаулыклар фондын һәм саклаулы табигать терр-яләрен эченә алган экологик каркас андый комплексларның мәҗбүри состав элементы булып тора. Аларга Б.да биотөрлелекне саклау һәм экологик тотрыклылыкны тәэмин итүнең төп функцияләре йөкләнә. Җирнең биогеоценотик катламының 30%тан да ким булмаган өлеше үзенең табигый халәтенә якынрак, мәйданнарның 3–5% ы аеруча саклаулы табигать терр-яләре (табигый саклаулык фонды) булырга тиеш.

Татарстанда 1950 еллар ахырында СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында Б.ның элементар берәмлекләре — биогеоценозларны өйрәнү эшләре башлана. 1960–70 тә Куйбышев сусаклагычы тирәсендәге биогеоценозларның формалашу шартлары өйрәнелә. Идел-Кама табигать саклаулыгында урман биогеоценозлары компонентларының халәте даими күзәтеп торыла. 1988–94 тә ТР ФА Табигать системалары экологиясе ин-ты хезмәткәрләре тарафыннан Куйбышев сусаклагычы утраулары биогеоценозларының (экосистемаларның) төзелешен өйрәнүне оештыру буенча комплекслы тикшеренүләр үткәрелә, 1997 дә республикадагы аерым табигый терр-аль комплексларның типик биогеоценозларын өйрәнү башлана.

*Əд.:* В е р н а д с к и й В.И. Химическое строение биосферы Земли и её окружения. М., 1965; ш у л у к. Биосфера. М., 1967; Этапы и темпы становления прибрежных биогеоценозов. М., 1978; Г о р ш к о в В.Г. Энергетика биосферы и устойчивость состояния окружающей среды // Итоги науки и техники / ВИНИТИ. Сер. Теоретические и общие вопросы географии. М., 1990. Т. 7; Концепция развития мировой системы — проблема выбора // Евразия. Экологический мониторинг. 1996. № 2; Особо охраняемые природные территории Республики Татарстан // Экологические аспекты биологии и медицины: Сб. науч. тр. Татарского отд-ния Рос. экологической академии. К., 1998.

*В.А.Бойко.*

**БИОФИ́ЗИКА**, б и о л о г и к ф и з и к а, төрле дәрәҗәдә оешкан биологик системаларда бара торган физик һәм физик-химик процессларны өйрәнүче фән. Молекуляр, күзәнәк, катлаулы биологик системалар Б.сы (тукымалар, организм һәм организмнар бергәлеге дәрәҗәсендә биологик процессларның үзара көйләнүен һәм үзара тәэсирләшүен тикшерә) аерып өйрәнелә.

Б. физик химия, физика, математика ысуллары һәм идеяләре б-н биологик якын килүне берләштерү һәм үзара тәэсирләшү юлы б-н үсә. 17 йөздә организм функцияләрен өйрәнгәндә (кан әйләнеше, тавыш һәм яктылыкны кабул итү һ.б.) механика законнарын куллану омтылышы ясала. Б.ның төп үсеш этаплары хайван тукымаларындагы электр күренешләрен ачу (Л.Гальвани), физиологик акустика һәм оптика үсеше (Г.Гельмгольц), тере организмнар механикасы һәм энергетикасы, ярсынуның ион теориясен төзү (П.П.Лазарев) б-н бәйле. 20 йөз башында Казан ун-тында электрокардиография буенча үткәрелгән А.Ф.Самойлов тәҗрибәләре (йөрәк эшчәнлегенең биоэлектрик потенциалларын теркәү) беренче биофизик эшләр исәбенә керә. 20 йөздә Б. радиобиология, биоэнергетика, фотобиология һ.б. юнәлешләргә аерыла. 1919 елда Мәскәүдә Биологик физика ин-ты ачыла (П.П.Лазарев), 1961 дә 1 нче Халыкара биофизика конгрессы уздырыла (Стокгольм, Швеция).

Татарстанда Б.ның формалашуы 1960 елларда биологиядә, аеруча физиологиядә тикшеренүләрнең физика ысулларын гамәлгә кертү б-н бәйле. СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында Н.А.Мальцев җитәкчелегендә тере тукымаларда арка һәм молекуляр система параметрларын үлчәү мөмкинлеге бирә торган (релаксация вакыты, үзлегеннән диффузияләнү коэфф.) ТМР — релаксометр җайланмасы төзелә. Шуннан соң күзәнәкләрдә су торышын тикшерүнең беренче нәтиҗәләре алына һәм тукымалардагы суның төзелеше һәм динамик параметрлары җансыз системалардагы параметрлардан аерылмавы исбатлана (Л.Н.Абецедарская, Ф.Г.Мифтахетдинова, В.Д.Федотов). 1970 елларда СССРда беренче мәртәбә магнит кырының импульс градиенты б-н ТМР — диффузометр эксперименталь җайланмасы эшләнә. Тукымалардагы суның диффузион күчешенә комплекслы сыйфатлама бирелә, плазмодесмалар буенча агымнарга аерыла (А.В.Анисимов), ион каналларының эшләү механизмнары турында яңа мәгълүматлар алына (Г.А.Великанов). Вакытлы диэлектрик спектроскопия ысулы үсә (Ю.Д.Фельдман, Ю.Ф.Зуев, В.М.Вәлитов), шуның нигезендә 1980 еллар ахырыннан аксымнар хәрәкәтен һәм гидратациясен тикшерүләр алып барыла. ТМР — релаксация ысулы б-н $10^2-10^{12}$ *Гц* ешлыклардагы диапазонда аксымнарда күп кенә релаксацион күчешләр табыла һәм сан ягыннан сыйфатлама бирелә (В.Д.Федотов, А.Г.Крушельницкий, Н.П.Обухов, Р.А.Задиханов). Аксымда конформацион хәрәкәтләр б-н билгеләнә торган ферментның актив үзәгендәге электр кыры флуктуацияләре параметрлары һәм ферментатив реакцияләр тизлеге арасындагы сан ягыннан бәйләнеш ачыклана (А.Э.Ситницкий). Электрның үзара бәйләнеше хисабына аксымнарның үзара ориентлашуы нәтиҗәсендә хасил булган эремәләрдәге глобуляр аксымнарда Броун хәрәкәте анизотропиясе табыла (В.Д.Федотов, А.Г.Крушельницкий, И.В.Ермолина). 1990 еллардан мембраналы модель системаларындагы биологик актив кушылмалар (нигездә ферментлар) хәрәкәтенең молекуляр механизмнары тикшерелә (С.Ю.Зуев).

1970 еллардан Казан а.х. академиясенең үсемлекләр физиологиясе кафедрасында үсемлек тукымаларындагы суның торышын өйрәнү буенча тикшеренүләр үткәрелә. Әйләнә торган һәм лаборатор координатлар системаларындагы үсемлек тукымаларында протон релаксациясе вакыты, орлыкларда метаболик процесслар баруы һәм күзәнәк структуралары үсеше уңае б-н шыткан орлыклардагы су торышы өйрәнелә (Ф.Д.Самуилов, В.И.Никифорова, Е.А.Никифоров). Үсемлек күзәнәкләрендә төрле фракциядәге су булуы күрсәтелә һәм аның күләме бәяләнә. Нык бәйләнгән суның, бозның торышын, ш.у. орлык тукымалары ультраструктурасындагы протоннарның хәрәкәтчәнлеген характерлаучы күренеш — әйләнә торган координатлар системасында ТМР ысулы б-н $10^3-10^5$ *Гц* ешлыгындагы гадәттән тыш акрын молекуляр хәрәкәт ачыклана. Түбән темп-ралы үлчәнеш буенча су молекулаларының сыек халәттән каты халәткә фаза күчеше теркәлә, орлыклардагы суның $-40$ °С кадәр темп-рада катмавы билгеләнә.

Татарстанда Б.ның интенсив үсеш юнәлешләренең берсе — периферик һәм үзәк синапсларда ярсуының күчеш процессларын тикшерү. Шундый тикшеренүләрнең үзәге — Казан мед. ун-ты. 1960 елларда Г.И.Полетаев тарафыннан беренче мәртәбә микроэлектродлы тикшерүләр технологиясе гамәлгә кертелә, 70 еллар башында синаптик процессларның квантлы анализы ысулы кулланыла. Соңрак аның шәкертләре тарафыннан синаптик аппаратның иң төп принциплары ачыклана. Нерв — мускул синапсында ацетилхолинның постсинаптик мембрананы ярсытып кына калмавы, бәлки махсус рецептор структураларының активлыгын көчәйтеп, хәрәкәтләнүчән нерв очларында медиаторның шуннан соңгы порцияләрне азат итүенә йогынты ясавы ачыклана; шундый модульләүнең молекуляр механизмнары билгеләнә (Е.Е.Никольский, Э.А.Бохараева). Нерв очларыннан медиатор бүленеп чыгуның импульсив булмаган формасы — нәквант секрециясе тикшерелә, нерв очларында тупланган махсус актив транспорт системаларның эшчәнлеге б-н бәйле молекуляр механизм өйрәнелә, хәрәкәтләнү нервлары зарарланганда нәквант секрециясенең беренче чиратта бозылуы күрсәтелә (Е.Е.Никольский, В.А.Воронин). Җылы канлылар синапсларында газсыман арадашчы N0ның медиаторның нәквант чыгышын, аның квантлы чыгышына тәэсир итми генә, сайлап модульләштерүе (М.Р.Мохтаров, Е.Е.Никольский, А.Х.Уразаев), шул ук вакытта салкын канлылар синапсларында N0ның квант секрециясенә тәэсир итүе ачыклана (А.Л.Зефиров, Р.Р.Хәлиуллина). Субсинаптик зонадагы мишень-күзәнәкләрнең билгеле бер дәрәҗәдәге тикторышын саклауда нәквант секрециясенең физиологик роле билгеләнә. Квант медиаторлары секрециясенең вакыт буенча үзгәрүе ярсынуның синаптик күчеш модуляциясендәге иң мөһим пресинаптик механизмнарның берсе булуы тәҗрибәдә исбатлана (Э.А.Бохараева, Е.Е.Никольский). Умырткалыларның хәрәкәтләндерү нерв очларында АТФ өчен махсус рецепторлар булуы, аларның синаптик күчешне үзгәртә алуы ачыклана (Р.Э.Гыйниятуллин, Е.М.Соколова).

1960–80 елларда Казан вет. ин-тында фоно-һәм электрокардиография, реография, электроэнцефалография, радиотелеметрия ысуллары б-н төрле төр хайваннарның йөрәк-кан юллары эшчәнлегендәге электр күренешләре тикшерелә (Г.П.Новошинов, Р.Х.Тукшаитов). 1970 еллардан агулану һәм инфек-

ция тәэсирендә хайваннар организмында бара торган биофизик процессларны тикшерү эшләре үткәрелә (Г.П.Новошинов, М.Я.Тремасов, П.К.Сметов). Фосфорорганик пестицидлар һәм микотоксиннарның мембанотроп эффекты механизмы, аларның синаптик структураларның функциональ торышына тәэсир итү үзенчәлекләре турында мәгълүматлар алына, патологияләр вакытында «кечкенә» җылылык эффектларының роле ачыклана. Тикшеренү нәтиҗәләре пестицидлар һәм микотоксиннар индикациясе һәм антидот терапиянең биологик чараларын эшләүдә нигез булып тора. «Вирус-күзәнәк» тәэсирләшүенең матем. моделе эшләнә (Ф.Б.Тәхаутдинов). 1990 еллар башыннан Бөтенроссия вет. ин-тында кан күзәнәкләренең электрокинетик үзенчәлекләре (Р.Я.Гыйльметдинов), хайваннар организмының инфекциялә авырулар вакытындагы иммунодефицит халәте тикшерелә (Г.Х.Ильясова, Р.Х.Юсупов).

Б.ның чикләре шактый дәрәҗәдә шартлы; тикшеренү объекты һәм ысуллары буенча ул молекуляр биология, биоорганик химия, биохимия б-н тыгыз бәйләнгән, еш кына алар б-н бергә физик-химик биология фәненә дә керә. Б.ның күп кенә юнәлешләре гамәли әһәмияткә ия (биологик мед. приборлары ясау, мед. диагностикасы, тикшеренүләрне үткәрү техникасын камилләштерү һ.б.).

*Әд.:* С а м у и л о в Ф.Д., Н и к и ф о р о в Е.А., Н и к и ф о р о в а В.И. Исследование состояния воды в тканях растений методом ядерного спинового эха // Докл. АН СССР. 1971. Т. 196, № 3; ш у л а р у к. Исследование ядерной магнитной релаксации протонов в растительной ткани во вращающейся и лабораторной системах координат // Докл. АН СССР. 1976. Т. 229, № 4; Т у к ш а и т о в Р.Х., Н о в о ш и н о в Г.П. Биофизические основы ветеринарной реовазографии. К., 1975; А н и с и м о в А.В., Р а т к о в и ч С. Транспорт воды в растениях. Исследование импульсным методом ЯМР. М., 1992; Г и л ь м у т д и н о в Р.Я., Р а в и л о в А.З., Т и т о в В.В. Клеточный электрофорез при изучении инфекционной патологии сельскохозяйственных животных. К., 1992; Ф е д о т о в В.Д., Ш н а й д е р Х. Структура и динамика полимеров. Исследование методом ЯМР. М., 1992; В е л и к а н о в Г.А., Н у р и е в И.Х., Ц е н ц е в и ц к и й А.Н. Электрическое возбуждение вакуоли непосредственно внутри протопласта, изолированного из клеток высшего растения // Биологические мембраны. 1996. Т. 13, № 4; The role of non-quantal release of acetylcholine in regulation of postsynaptic membrane electrogenesis // J. of Physiol. Paris. 1995. V.89; Effect of nitric oxide and O synthase inhibition on nonquantal acetylcholine release in the rat diaphragm // Eur. J. of euroscience. 2000. 12.

*Р.Х.Тукшаитов, В.Д.Федотов.*

**БИОХИ́МИЯ**, б и о л о г и к  х и м и я, тере материянең химик составын, тере организмнарның тереклек итү эшчәнлегендәге химик процессларны өйрәнүче фән. «Б.» термины 1903 елда немец тикшеренүчесе К.Нейберг тарафыннан кертелә. Б. тармаклары: статик Б. — тере организмнарның химик составын анализлый; динамик Б. — матдәләр бергәлеген тикшерә; функциональ Б. — тереклек итү эшчәнлегендәге химик процессларны өйрәнә. Тикшерү объектына карап, Б.не кеше Б.се, хайваннар Б.се, үсемлекләр Б.се һәм микроорганизмнар Б.сенә бүләләр. Халык хуҗалыгы өчен төрле чимал эшләп чыгару, саклау һәм эшкәртү ихтыяҗы техник һәм сәнәгый Б. үсешен китереп чыгара. Фармакология, фармация, токсикология, молекуляр биология, молекуляр генетика, биотехнология — Б. һәм физиология фәннәренә таяна. Кеше һәм хайван авыруларына диагноз кую күп очракта биохимик тикшеренүләргә нигезләнә.

Икмәк пешерү, сыр кайнату, шәраб әчетү һ.б. биохимик процесслар бик борынгы заманнардан ук билгеле булса да, Б. фән буларак 19 йөз ахырында гына формалаша. Аның үсеше органик химия, физиология һәм медицина казанышлары б-н бәйле: аспаргин кислотасы амидын ачкан француз галиме Л.Н.Воклен (1806), крахмалның шикәрләнүен раслаган Россия химигы К.С.Кирхгоф, мочевинаны синтезлау юлы б-н китереп чыгарган немец химигы Ф.Вёлер (1828), мускуллар составындага креатинны тасвирлаган француз химигы М.Шеврёль (1835), скелет мускулларында сөт кислотасы булуын күрсәткән, гликоген бүлеп чыгарган немец химигы Ю.Либих (1850), химик әчетү теориясе авторы — француз физиологы К.Бернар (1835), май төзелешен һәм аны синтезлауны гамәлгә ашырган француз химигы П.Э.Бертло (1853–54), нуклеин кислоталарын ачкан швейцар табибе И.Ф.Мишер (1868), аксым үзлекләрен һәм төзелешен билгеләгән немец тикшеренүчеләре Ф.Хоппе-Зейлер, Э.Абдергальден б-н Э.Фишер (1916), органик химиянең нигезен — органик кушылмаларның химик төзелеше теориясен төзегән рус химигы А.М.Бутлеров (1870) һ.б. хезмәтләрендә Б. нең нигезе салына.

Татарстанда Б.нең формалашуы *Казан химия фәнни мәктәбенең* үсеше б-н тыгыз бәйләнгән. 1863 тә А.М.Бутлеровның эшлекле ярдәме нәтиҗәсендә А.Я.Данилевский тарафыннан Казан ун-тының мед. ф-тында дөньяда беренче мед. химиясе һәм физикасы каф. оештырыла, соңыннан биол. химиясе каф. дип үзгәртелә, анда аксымнарның төзелешен һәм үзлекләрен тикшерү эшләре башлана. Бу юнәлештәге эшләрне аның шәкертләре А.Я.Щербаков б-н А.А.Панормов дәвам иттерә. 1866 да Б. лабораториясе оештырыла һәм биохимикларның Россия мәктәбе формалаша башлый. 1929 дан Казан ун-тында (1930 дан Казан мед. ин-ты) Б. кафедрасын В.А.Энгельгардт җитәкли. 1931 дә аның тарафыннан аэроб организмнарның тереклек эшчәнлеге энергетикасы нигезен хасил иткән оксидлы фосфорильләнү күренеше ачыла. Д.М.Зөбәеров кеше каныңдагы тромбинның актив ферментын ача (1961) һәм организмда канның туктаусыз оешу теориясен төзи. Аның тарафыннан (В.Н.Тимербаев, С.В.Кисилёв һәм И.В.Соболева б-н берлектә) тромбопластинның супермолекуляр төзелеше исбатлана, протромбин һәм X факторының тәэсир итешү үзенчәлеге өйрәнелә. Ультрафильтрациядән файдалану юлы б-н кеше һәм терлекләр каныңдагы микровезикуляция процессын күрсәтә, йөрәк-кан тамырлары, йогышлы һәм хирургик авырулар, лейкоз һәм йөклелек патологиясен объектив бәяләүнең кулай ысулын тәкъдим итә. Шул хезмәтләре өчен Д.М.Зөбәеровка РФнең Дәүләт бүләге бирелә (1991).

Терлекләр Б.се буенча тикшеренүләр Казан вет. медицинасы академиясенең Б. кафедрасында (1924 тән) һәм Бөтенроссия вет. ин-тының Б. лабораториясендә (1960 тан) үткәрелә. Аксымнар, углевод һәм липидларны һәрьяклап тикшерү нигезендә С.И.Афонский тарафыннан биокомплекслы (хелат) кушылмалар турында тәгълимат барлыкка китерелә. Шуннан соң Х.Ш.Казаков һәм аның шәкертләре тарафыннан биоген металларның (бакыр, кобальт, марганец, цинк) аминокислоталар һәм төрле биолигандалар б-н хелат кушылмаларын синтезлау системалары эшләнә; аларның организмнарның саклагыч көчләренә йогынты ясавы, терлекләрнең һәм кошларның продуктлылыгын арттырудагы, яшь терлекләрне саклаудагы роле (Э.В.Тен, Н.М.Машковцев, Э.М.Шәмсетдинов һ.б.), дуңгыз балаларында анемия, энзоотик базед авыруларын булдырмый калуга тәэсир итүе (Л.П.Логинов, М.Ю.Метлякова) өйрәнелә. Микро- һәм макроорганизмнарның молекуляр механизмнарына тәэсир итешүе, йогышлы авыруларны китереп чыгаручыларның антиген төзелеше, диагноз кую ысуллары өйрәнелә. Аксым һәм нуклеин кислоталарының синтез вирусы б-н индукцияләнгән күзәнәк һәм тилчә вирусының үзара тәэсир итешүе тикшерелә (Н.Җ.Хаҗипов, Р.П.Тюрикова), түләмә авыруын барлыкка китерүченең антиген төзелеше өйрәнелә (В.П.Коксин). Шундый тикшеренүләр нигезендә диагноз куюның тизләтелгән яңа ысуллары эшләнә. Мөгезле эре терлекләрдә бруцеллёз авыруын китереп чыгаручының антиген үзенчәлеге тикшерелә һәм инфекциягә каршы вакцина штаммы куллануга кертелә (В.П.Корунов, Н.К.Кириллов, Н.Ш.Зәйниев). Мөгезле эре терлек туберкулёзының үзенчәлекле антигены табыла, шуның нигезендә анализлауның иммунофермент ысулы эшләнә (А.А.Нуруллин, Т.Р.Якупов, В.И.Шилова). АУФ штаммыннан листериозга каршы вакцина табуның технол. параметрлары (М.А.Алимов), диагноз куюның молекуляр-генетик алымнары — полимераз чылбыр реакциясе, ДНК — зонд б-н тикшерү, листериоз, түләмә, Ауески авырулары, мөгезле эре терлекләрдә туберкулёз китереп чыгаручыларның ДНК рестракцион анализы алына (Т.Х.Фәизов, К.В.Усольцев). Мөгезле эре терлекләрдәге туберкулёз авыруына диагноз кую ысулларын камилләштерүләре өчен Н.Җ.Хаҗипов б-н Р.П.Тюриковага ТР Дәүләт бүләге бирелә (1996).

ТРда үсемлекләр Б.се үсеше Казан галимнәренең фотосинтез өлкәсендәге өйрәнүләре б-н бәйле. Коршак төркеменнән (АКШ, 1965) бәйсез рәвештә 1960 та Ю.С.Карпилов тарафыннан (Казан а.х. ин-ты) фотосинтез вакытында углерод метаболизмының принципиаль яңа юлы — «кооператив фотосинтез» ачыла; И.А.Тарчевский (Казан ун-ты) тарафыннан стресслар тәэсирендә углеродның фотосинтетик метаболизмындагы үзгәреш-

ләрнең үзенчәлеге билгеләнә (1965 тә аның тарафыннан Казан ун-тында Б. кафедрасы торгызыла һәм үсемлекләр Б.сенә караган эшләр дәвам иттерелә); А.М.Алексеев үсемлек күзәнәкләрендә азот, углевод һәм фосфор алмашуын, В.Е.Петров хлоропластларда АТФ барлыкка килү һәм электрон йөрешен, фотомикрокалориметрияне, Л.П.Хохлова үсемлек күзәнәкләрендәге цитоскелет аксымнарының көйләгеч ролен тикшерә. РФА КГҮнең Биофизика һәм биохимия ин-тында үсемлек күзәнәкләрендәге сигнал системаларына (И.А.Тарчевский), үсемлек липидларына һәм көйләгеч оксилипиннарга (А.Н.Гречкин), күзәнәк энергетикасы һәм аның ион йөреше б-н бәйләнешенә (Л.Х.Гордон), углеродның фотосинтез метаболизмына (В.И.Чиков), икенчел арадашчылар б-н физиол.-биохим. процессларны көйләүгә (Ф.Г.Кәримова), уңайсыз факторлар тәэсирендә үсемлекләрдәге аксымнар алмашуына (Н.Н.Максютова), пигментлар метаболизмына (Ю.Е.Андрианова), үсемлекләрнең күзәнәк тышчаларындагы полисахарид метаболизмына (В.В.Лозовая, Т.А.Горшкова) караган эшләр башкарыла. А.Н.Гречкин б-н И.А.Тарчевскийга үсемлек күзәнәкләрендәге липоксигеназ сигнал системаларына багышланган хезмәтләр циклы өчен ТР ФАнең В.А.Энгельгардт исем. бүләге бирелә (1999).

1950 еллардан Казан ун-тында микроорганизмнар Б.се буенча тикшеренүләр алып барыла. Микроб ферментлары — нуклеаз, протеиназ, фосфатаз, хитиназлар өйрәнелә (М.И.Беляева), ферментларның молекуляр, физик-химик һәм каталик үзенчәлекләре тикшерелә (В.Б.Лещинская, Ф.Г.Куприянова-Ашина, Б.М.Куриненко). Сәнәгый җитештерү өчен яңа ферментлар алуның нәтиҗәле технологияләре тәкъдим ителә һәм эшләнә. 1960 еллардан яңа юнәлеш — экологик куркынычлык б-н янаучы табигый булмаган кушылмалар метаболизмын өйрәнү юнәлеше үсеш ала (Р.П.Наумова). Тикшеренү нәтиҗәләре химия һәм нефть химиясе пр-тиеләрендә кулланылган суларны чистарту технологиясен эшләргә, сәнәгый газ һәм каты калдыкларны зарарсызландырырга һәм файдаланырга ярдәм итә.

Казан галимнәре Россиядә һәм чит илләрдә Б. үсешенә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр. Аларның күбесе башка шәһәрләрдә Б. кафедраларын җитәкли: С.М.Максимович — Варшава һәм Ростов ун-тларында, В.В.Вормс — Саратов ун-тында, А.Н.Поляков — Новочеркасск вет. ин-ты һәм Куйбышев мед. ин-тында, С.И.Афонский — Мәскәү вет. академиясендә. В.А.Энгельгардт б-н А.А.Баев фәнни эшчәнлекләрен Мәскәүдә СССР ФАнең Биохимия ин-тында дәвам иттерәләр, соңрак В.А.Энгельгардт үзе оештырган Молекуляр биология ин-тын җитәкли.

*Әд.:* Б у л а н к и н И.Н. А.Я.Данилевский — основоположник отечественной биохимии. Хар., 1950; А ф о н с к и й С.И. Биохимия животных. М., 1970; Г и з а т у л л и н Х.Г., Х а з и п о в Н.З. Взаимодействие вируса ящура с клеткой. К., 1973; В и д е р г а у з М.С. Цветопись. М., 1980; Н а у м о в а Р.П. Микробный метаболизм неприродных соединений. К., 1985; Т а р ч е в с к и й И.А., М а р ч е н к о Г.Н. Биосинтез и структура целлюлозы. М., 1985; Воспоминания о В.А.Энгельгардте. М., 1989; Л е щ и н с к а я И.Б. Нуклеазы бактерий. К., 1991; Х а з и п о в Н.З. Достижения молекулярной биологии в животноводстве и ветеринарии. К., 1997.

*Д.М.Зөбәеров, Н.Җ.Хаҗипов, Ф.Г.Кәримова, И.Б.Лещинская.*

**БИРӘЗӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Казансуның уң кушылдыгы. Озынлыгы 19,2 *км*, бассейнының мәйданы 95,8 *км*². Арча р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Чиканас авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Зур Бирәзә авылыннан 1 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 159 *м*, тамагыныкы — 87 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 7%. Б. елгасының 0,3 тән алып 11 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар, иң зурысы — Иске йорт елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км*/*км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 *л*/*с*·*км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 133 *мм*, ташу агымы катламы 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун көне эчендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,08 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв*/*л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв*/*л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг*/*л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг*/*л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БИРГЕ́ КАБА́Н**, Т ү б ә н К а б а н, Казан шәһәренең үзәк өлешендә, *Кабан* күлләре системасындагы күл. Су өслегенең мәйданы 48 *га*. Су күләме 3120 мең *м*³. Озынлыгы 1800 *м*, киңлеге 120 дән алып 325 *м* га кадәр, уртача тирәнлеге 6,5 *м*, иң тирән урыны 12 *м*. Килеп чыгышы буенча Б.К. карст эшчәнлеге нәтиҗәсендә тирәнәйгән Идел елгасының элеккеге урыны булып исәпләнә. Күл сузынкы формада, борылмалы ярлары өеп ясалган грунт б-н тигезләнгән. Б.К. б-н Аргы (Урта) Кабан күле Ботаника ермагы аша кушыла. Суы каты, нык минеральләшкән, гидрокарбонат-кальцийлы, составында сульфатлар һәм хлоридлар бик күп. Күл өчен начар газ режимы — кислород җитешмәү, күкертле водород булу, биоген, органик һәм башка пычраткыч матдәләрнең булуы хас. Флора-фаунасы бик ярлы, күл «үле» сулык дип исәпләнә (1980). Савыктыру чаралары үткәрү нәтиҗәсендә биотик бергәлек өлешчә торгызыла. Сирәк төрләрдән су чаяны, ихтиофаунада чабак, алабуга, җилембалык, кызылканат, көмеш табан балыклары очрый. Б.К. ял итү максатларында файдаланыла. Монда спорт көймәләре базалары урнашкан, су спорты төрләре буенча ярышлар уздырыла. 1998 елдан ял итү теплоходлары йөри. Иске Татар Бистәсе ягыннан күл буе яры төзекләндерелә.



Бирге Кабан күле.

*Н.М.Минһаҗева.*

**БИРГЕ́ ЯМА́Ш** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ямаш суы (Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы) буенда. 2002 елда 615 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1785 нең октябрендә нигез салына. Халкы башта алпавыт крәстияннәре катлавына керә, 1831 дә ирекле икмәк игүчеләр төркеменә күчерелә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2300 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Урсалы волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1924 тән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Әлмәт р-нында. Халык саны: 1816 да — 185, 1859 да — 350, 1889 да — 780, 1910 да — 1079, 1926 да — 1054, 1989 да — 538 кеше.

**БИРДЕБӘ́К** (? — 1388), Алтын Урда бәге, 1387 елдан Казан бәклеге идарәчесе. Исеме Керемшай һәм Гөлстан әл-Җәдидтә сугылган акчалардан мәгълүм (аларда Б. үзен «Гадел солтан» дип белдерә). Чулман елгасыннан төньяктарак урнашкан болгар җирләрендә идарә иткән. Чулманның сул ярындагы җирләр һәм Идел буйлары Туктамыш ханга буйсынган, ә Б. аңа каршы торучылар сафында булган дип фараз ителә. 14 йөз рус елъязмаларында да Б.кә караган мәгълүматлар очрый.

*Әд.:* М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.

*Ә.Г.Мөхәммәдиев.*

**БИРДЕБӘ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, район үзәге — Балык Бистәсе авылыннан 46 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Шомбыт елгасы буенда. 2002 елда 165 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бирдебәк Чаллысы исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.тә мәчет була. 20 йөз башында су тегермәне, 2 йон-тукыма ману остаханәсе, 2 ярма ярдыру тегермәне, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 470 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында; 1927

нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир заты; 1859 да — 260, 1897 дә — 489, 1968 дә — 549, 1920 дә — 655, 1926 да — 577, 1938 дә — 520, 1958 дә — 326, 1970 тә — 359, 1989 да — 204 кеше.

**БИРДЕБӘ́К ХАН** (1310 тирәсе — 1359), Алтын Урда ханы (1357/58 дән). *Җанибәк хан*ның улы. 1357 елда атасы б-н бергә Әзәрбайҗанга яуга бара. Шул яу барышында атасы вафат булгач (кайберәүләр фикеренчә, аның үлеменең сәбәпчесе ул үзе була), Сарай әл-Җәдидкә әйләнеп кайта, бәкләр бәге Туглы бәк ярдәмендә тәхеткә утыра. Үз хакимиятен ныгыту максатыннан бертуганнарын һәм тәхеткә өмет итәрдәй башка җучиләрне үтертеп бетерә. Сарай аксөякләре ярдәменә таянган *Кулнә* хан тарафыннан тәхеттән куыла.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1975; Куликовская битва. М., 1980.

**БИ́РЖА** (лат. bursa — сумка, акча янчыгы), товарларны, финанс инструментларын һәм чит ил валюталарын күпләп сату-алуны оештыручы һәм даими эшләүче базар. Беренче тапкыр товар һәм валюта сату Б.лары 15–16 йөзләрдә Италиядә (Венеция, Генуя, Флоренция) барлыкка килә. 16 йөздә дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләре (бурыч йөкләмәләре) б-н сәүдә итү эшләре башлана. 1566 елда Лондонда Король товар һәм вексель Б.сы, 17 йөз ахырында Лондон фонд биржасы оеша. Товарлар һәм кыйммәтле кәгазьләр сату буенча хәзерге көнгә кадәр эшләп килгән универсаль Амстердам Б.сы 17 йөз башында оештырыла. 1817 дә АКШ та Нью-Йорк фонд Б.сы ачыла.

Россиядә беренче Б. Пётр I күрсәтмәсе буенча 1703 тә С.-Петербургта ачыла, 18 йөз ахырында Мәскәүдә оеша. Казанда беренче Б. 1868 дә барлыкка килә. 1914 тә Россиядә 115 универсаль Б. исәпләнә. Кыйммәтле кагәзьләр б-н сәүдә итү гамәле ХКСның 1917 елгы 23 декабрь декреты б-н бетерелә. 1922–30 да Б.лар базарны көйләүче дәүләт органы сыйфатында эшли. 1930 да СССРда Б.лар эшчәнлеге туктатыла. 1990 еллар башында Б.лар яңадан эшкә керешә. 1995 тә ТРда иң эре Б.лар: Идел-Кама универсаль һәм Казан инвестиция фондлары биржалары.

Товар Б.сы — товар базарында күпләп сату-алуны оештыручы. Монда килешү сроклары фонд Б.сына караганда озаграк дәвам итә (нигездә — 6, кайчакта 24 ай). Икътисадның монополияләштерелүе б-н товар Б.ларының мөстәкыйльлеге чикләнә (монополияләр, Б.ларны читләтеп, товар б-н күбрәк үзләре сәүдә итәләр). РФдә «Биржа товарлары һәм биржа сәүдәсе» турындагы закон 1992 нең 20 февралендә кабул ителә. 2007 дә РФдә, ш.и. ТРда нефть, нефть продуктлары һәм газ б-н сату итүче биржалар барлыкка килә, аларда исәп-хисап рубльләрдә алып барыла. Фонд Б.сында акцияләрне, корпоратив облигацияләр, опционнар, дәүләт заёмнары облигацияләре һ.б. финанс инструментларын сату-алу гамәлгә ашырыла. Анда кыйммәтле кәгазьләр курсы формалаша. Эре акционерлык компанияләренең акцияләре Нью-Йорк һәм Лондон Б.ларында бәяләнә (аерым алганда, «Татнефть» АҖ акцияләре Нью-Йорк Б.сында сатыла). 2006 да Нью-Йорк биржасында Россиянең 6, ә Лондон биржасында 16 компаниясенең кыйммәтле кәгазьләре урнаштырыла.Килешүләр күләме артуга карамастан, фонд Б.ларының роле чагыштырмача кими, чөнки эре банклар кыйммәтле кәгазьләрне үз клиентларына сату һәм тарату б-н үзләре шөгыльләнә. Чит ил валюталары



Казан биржасы. 1905.

һәм алтын б-н сату итүне дә банклар үзләре башкара; элегрәк аларны гамәлгә ашыру өчен фонд Б.лары каршында валюта Б.лары оештырылган. Россиядә фонд Б.ларының эшчәнлеге 1991 нең 28 декабрендә расланган «РСФСРда кыйммәтле кәгазьләрне чыгару һәм әйләнешкә кертү һәм фонд биржалары турындагы нигезләмә» б-н көйләнә. 1996 да РФнең «Кыйммәтле кәгазьләр турында»гы федераль законы кабул ителгәч, шуңа туры китереп, фонд Б.сы коммерциясез партнёрлык формасында оештырыла. 1998 дә ТРда «Казан советының фонд сәүдәсе» оеша, Б.лар саны 6 дан (1992) 1 гә кала. Аның төп эш юнәлешләре: кыйммәтле кәгазьләр б-н сәүдә итүне оештыру, аларның базар бәяләрен билгеләү, кыйммәтле кәгазьләрнең Б.лардагы әйләнеше турында мәгълүмат тарату, Б. әгъзаларының һөнәри дәрәҗәләрен тиешле югарылыкта тоту.

Чыг.: Федеральный закон от 22.04.96 № 39-АР «О рынке ценных бумаг».

*Әд.:* Банки, биржи, валюты современного капитализма. М., 1986; Миркин Я.М. Ценные бумаги и фондовый рынок. М., 1995.

*Ф.И.Харисова.*

**«БИРЖЕВА́Я И СЕЛЬСКОХОЗЯ́ЙСТВЕННАЯ ГАЗЕ́ТА КА́МСКО-ВО́ЛЖСКОГО КРА́Я»** («Идел-Кама төбәгенең биржа һәм авыл хуҗалыгы газетасы»), сәүдә һәм икътисади газета. 1899 елның гыйнварыннан 1904 нең 4 мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә (1903 тә чыкмый). Нашире һәм мөхәррире Н.А.Ильяшенко. Күпчелек авторлар «Казанский телеграф» г-тасы хезмәткәрләре. Газета битләрендә Россиянең сәүдә һәм мануфактуралар департаменты, Казан округы юллары идарәсе боерыклары басыла, сәнәгать һәм а.х. күргәзмәләре, ярминкәләр, төбәктә сәүдә эшләренең торышы турында мәгълүматлар бирелә. Газетада ш.у. сәнәгать, сәүдә, авыл хуҗалыгы, транспорт үсеше турында шәһәр һәм земстволың хисап материаллары да бирелеп бара, биржа һәм акционерлар җәмгыятьләре җыелышлары турында хәбәрләр басыла.

*Г.Р.Заманова.*

**БИРНӘ́**, татар халкы йоласы; кияүгә чыкканда кызга әти-әнисе яки туганнары бүлеп бирә торган мал-мөлкәт. Аңа кәләшнең шәхси әйберләре, урын-җир (түшәк, мендәр, юрган һ.б.), ашъяулык, тастымал кебек көнкүреш кирәк-ярагы керә. Б. гаиләнең матди мөмкинлекләреннән чыгып бирелә. *Калымнан* аермалы буларак, аның күләме һәм сыйфаты хакында яучылаганда да, ярәшкәндә дә алдан сөйләшенми. Авылларда хәллерәк ата-ана, әйберләргә өстәп, еш кына берничә баш терлек (бозау яисә сарык) биргән, ә ярлы гаиләләрдә кәләш өчен өс киеме һәм бизәнү әйберләре кияү исәбенә алынган. Б.нең шактый зур өлеше киленнең кул эшләре әйберләреннән туплана, алар, нигездә, бүләк өчен әзерләнә. Йола кушканча, зөфаф киченнән соң кәләш кияүгә чуар тукымадан тегелгән ыштан («кияү ыштаны»), чигүле күлмәк («кияү күлмәге»), чигүле ыштыр («кияү ыштыры»), түбәтәй, тәмәке янчыгы, кулъяулыклар бүләк итә. Яшь килен иренең туганнарына бүләккә (Темников татарларында — «бирнә котлау» йоласы вакытында) сугылган һәм чигелгән сөлгеләр, намазлыклар, өлкән яшьтәге хатын-кызларга күкрәкчәләр, тастарлар биргән. Туй ахырында «өй киендерү» йоласы башкарылган — килен сандыгындагы кул эшләре әйберләре б-н иренең өй эче бизәлгән. Б. киленнең уңганлыгын, дәрәҗәсен күрсәтә һәм аңа карата булачак мөнәсәбәтне билгели. Шәригать кануннарынча, Б. кәләшнең шәхси милке булып исәпләнә; талак әйтелгән очракта ир аны хатынга тулысы б-н кайтарып бирергә тиеш була. 20 йөз дәвамында татар халкының туй йолалары шактый үзгәреш кичерә, ләкин кәләшне Б. б-н озату йоласы саклана; хәзерге вакытта Б. нигездә сатып алынган әйберләрдән туплана.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа. К., 1984.

*Ф.Ф.Гулова.*

**БИРЮКО́В** Семён Алексеевич (? — 1968), Гражданнар сугышында катнашучы. Никополь һәм Херсон шәһәрләре пр-тиеләрендә эшли. 1916 ел ахырында Россия армиясенә алына. 1917 дә Петроградтагы Окт. кораллы күтәрелешендә катнаша. 1918 дән Казанда: К.Маркс исем. Интернациональ батальонны оештыручы һәм командиры. 1918 нең августында Казанны чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык Армиясе гаскәрләреннән саклауда катнаша. Казан Кызыл Армия частьләре тарафыннан алынганнан соң, 1нче Казан совет укчылар полкы комиссары итеп билгеләнә. 1919 ның язында Көньяк фронтка җибәрелә. 1920–40 елларда Мәскәүдә хуҗалык эшендә.

*Әд.:* Ханин Л. Бирюков Семён Алексеевич // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**БИРЮ́ЛИН** Александр Иванович (8.12.1929, Алексеев р-ны Левашево а. — 21.6.1992, Казан), токарь, Соц. Хезмәт Герое (1988).



А.И. Бирюлин.

1947–92 елларда В.И.Ленин исем. Казан фәнни-житештерү пр-тиесендә эшли. Герой исеме производствода гаять зур уңышларга ирешкәне һәм йөкләмәләрне уңышлы үтәгәне өчен бирелә. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**БИРЮЧЕ́ВКА** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бөгелмә Зәе елгасы буенда. 2002 елда 390 кеше (татарлар — 33%, руслар — 59%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; нефть-газ чыгару. Урта мәктәп. Клуб. 19 йөзнең 1нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек алпавыт Елачичлар крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында аракы куу з-ды, су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1866 да — 430, 1898 дә — 355, 1897 дә — 520, 1920 дә — 296, 1926 да — 248, 1938 дә — 253, 1949 да — 199, 1958 дә — 148, 1970 тә — 239, 1979 да — 130, 1989 да — 255 кеше.

**БИСӘ́Р** елгасы, Идел алдында. Үләмәнең сул кушылдыгы (Зөя елгасы бассейны). Озынлыгы 9,5 *км*, бассейнының мәйданы 33,2 *км*². Тәтеш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Кушкуй авылыннан 2 *км* көньяктарак, тамагы Олы Бисәр авылыннан 1,5 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 84 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 9%. Б. елгасының 1,1 һәм 2,8 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 145 *мм*, ташу агымы катламы 130 *мм*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,015 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л* га кадәр.

**БИСЕРМӘННӘ́Р** (үзатама), удмуртларның этнографик төркеме. 1926 елда халык санын исәпкә алганда Б. 10 меңнән артыграк теркәлгән (шуннан соң алар аерым исәпләнми, удмуртлар санына керә). Удмуртия Респ-касының төньяк-көнбатыш өлешендә, башлыча, Нократ кушылдыгы Чыпца елгасы буенда Юкамен, Глазов, Балезин, Яр р-ннары, ш.у. Киров өлкәсенең Слобода р-ны терр-ясендә яшиләр. 20 ләп авылда Б. генә яши, 41 торак пунктта өлешчә удмурт, татар, руслар да бар. Төрки тел үзенчәлекләрен катнаштырып, удмурт телендә сөйләшәләр. Идел б-н Чулман арасында яшәүче Б. хакында 13–15 йөзләргә караган рус елъязмаларында мәгълүматлар бар, 17 йөз документларында Чыпца буенда көн күрүчеләр теркәлгән (еш кына аларны «чуаш» дип тә язалар). 1678 гә караган язмаларда 4 бисермән авылында 73 йорт булуы, анда 337 ир-ат яшәве, 1717 елгы язмада 18 авылдагы 100 йортта 432 ир-ат теркәлгән. 18–19 йөзләрдә Б.нең удмурт, татарлар (к. *Нократ татарлары*) б-н уртак торак урыннары барлыкка килә. Б.нең төп шөгыльләре — игенчелек: арыш, арпа, солы, җитен, киндер игәләр. Чолыкчылык б-н көн күрүчеләр, авылдан вакытлыча китеп, а.х. эшләрен башкаручылар яки үз атлары б-н йөк ташучылар да күп була. Вак һөнәрчелек Б. арасында киң таралмаган. 1930 елларга кадәр җирдән авыл җәмәгате тәртибендә файдаланганнар, еш кына берничә кече авыл бер җәмәгатькә берләшкән. 20 йөзнең 1 нче чирегенә чаклы зур бер гаилә булып (балаларны аерып чыгармыйча, берничә гаилә бергә тупланып) яшәү тәртибе саклана. Милли яктан катнаш гаиләләр сирәк очрый. Б. яшәгән авыллар һәм утарлар урам-тыкрык рәвешендә планлаштырылган. Б.гә 2 якка кыек түбәле бүрәнә өйләр, 2 катлы бүрәнә амбар-келәтләр (бер катлылары сирәк очрый) хас. Ишегалдының 2 нче өлешендә мал абзары, утары һәм мунча урнаша. Өй һәм каралты-кура төзелеше удмуртларныкы рәвешендәрәк.

Хатын-кыз киеме: туры тар күкрәкчәле, бөрмәле киң итәкле итеп киндер тукымадан тегелгән, күкрәк, җиң тирәләре чигеп һәм тар тасмалар тегеп, бай итеп бизәлгән күлмәк; киң төпле, аяк тубыгына чаклы төшеп торучы балаклы ыштан, алъяпкыч. Шулар өстеннән каптырмасыз халат рәвешендәге өске кием киелә. Муен, күкрәк тирәли (кыеклап) төрле тәңкә, каурый, сәйлән б-н бизәлгән тасмалар тагыла, кул-бармаклар беләзек, йөзекләр б-н бизәлә. Б.нең хатын-кыз киеме чуаш хатын-кызлары киеменә тартым.



Бисерманнәрнең бәйрәм киеме. 20 йөз уртасы.



Бисермән хатын-кызы киеме. 20 йөз башы.

19 йөз ахыры — 20 йөз башы Б. ир-аты өс киемендә шул чор удмурт һәм рус ир-атлары киеменнән аерма юк: алача киндер тукыма һәм постау өстенлек итә.

Б. табыны гадәти крәстиян ризыгыннан торган; ит фәкать бәйрәм ашы саналган. Мөселманнар кебек үк, дуңгыз итен 20 йөз башларына кадәр кулланмаганнар, хәзер дә йола үтәү табыннарына куймаска тырышалар. Б. фольклоры йола үтәгәндә, бәйрәмнәрдә башкарыла торган махсус җырларны, әкият һәм табышмакларны үз эченә ала. Халык бәйрәмнәре нигездә җир эшкәртүгә бәйле календарь бәйрәмнәреннән гыйбарәт. Аларның иң олысы, мөһиме булып язгы сабан бәйрәме «Акаяшка» санала. Дингә карашлары бик үзенчәлекле, катлаулы. 18 йөздән башлап христиан диненә табынсалар да, элгәреден килгән мәҗүсилек йолаларын да үтиләр, ислам динен дә хөрмәт итәләр. Һәр елны авылга мулла китертеп дога кылдыру, үлем-китем булганда да мулла чакыру, беренче көтү чыккан көндә мөселман дине әһеленә сәдака бирү (он, ярма һ.б.) гадәткә кергән. 1990 еллардан башлап халыкның үз этник йөзен сакларга омтылышы көчәя. 1990 да Глазов шәһәрендә Б.нең матди һәм мәдәни үзенчәлеген, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерүне, халык саны исәбен алганда аерым этник төркем буларак теркәлүне күздә тоткан милли үзәк — «Бисермән халкы җәмгыяте» оештырыла. 1992 нең июнендә Удмуртия Респ-касы ЮС Президиумы «Бисермән халкының тарихи исемен кайтару турында» карар кабул итә. Б. Россия халыклары исемлегенә (реестрына) кертелә.

*Әд.:* Б е л и ц е р В.Н. К вопросу о происхождении бесермян // Тр. Ин-та этнографии. 1947. Т. 1; Т е п л я ш и н а Т.И. Язык бесермян. М., 1970; И с х а к о в Д.М. Татаро-бесермянские этнические связи как модель взаимодействия булгарского и золотоордынско-тюркского этносов // Изучение преемственности этно-культурных явлений. М., 1980; Р о д и о н о в В.Г. Этнокультурные черты и история бесермян как свидетельство болгаро-чувашской преемственности // Болгары и чуваши. Чебоксары, 1984; В л а д ы к и н В.Е., Х р и с т о л ю б о в а Л.С. Удмурты // Народы Поволжья и Приуралья. М., 1985; Народы России: Энцикл. М., 1994; Удмуртская Республика: Энцикл. Ижевск, 2000.

**БИСМИЛЛА́** (гарәп. بسم الله — Аллаһ исеме белән), «Бисмил-л-ләһи-р-рахмәни-р-рахим» (мәрхәмәтле, рәхимле Аллаһ исеме белән) гыйбарәсенең баш өлеше. Коръән *сүрәләренең* барысы да диярлек Б. б-н башлана. Мөселманнарда күп гасырлар дәвам иткән гадәт буенча, бу сүзнең илаһи кодрәте бар, дигән фикер урнашкан һәм ул гыйбадәт кылганда, берәр эшкә керешкәндә әйтелә; хат, рәсми кәгазьләр башында языла, еш кына архит-ра корылмаларындагы язуларда очрый. Көндәлек тормышта туган телләре гарәп теле булмаган мөселманнар, ш.и. татарлар да, гыйбарәнең башындагы Б. сүзен аерым рәвештә дә еш әйтәләр.

**БИСТӘ́ ХАЛКЫ́**, 10–18 йөзләрдә Россиядә шәһәр тибындагы торак урыннарда (посад, слобода) һәм шәһәр бистәләрендә яшәүче вак сәүдәгәр, кәсәбәчеләр һәм һөнәрчеләр катлавы. Русча «посад» сүзе элеккерәк заманда шәһәрләрнең сәүдә-сәнәгатькә мөнәсәбәтле өлеше мәгънәсендә йөргән. Посад-бистә халкы салым түләгәндә, җәмгыяви эшләрне башкарганда аерым бер җәмәгать тәшкил иткән, йөзлек, иллелек һәм унлыкларга бүленгән. Салымнар, җәмгыяви бурыч үтәү йөкләмәләре башта йөзлекләргә бүлеп бирелгән. Һәр йөзлекнең үз исәп-хисап дәфтәре булган, йөзлеккә керүчеләр анда 3 төркемгә бүленеп йөртелгән: таза тормышлылар, урта хәллеләр һәм ярлыраклар. Тарихчы А.А.Кизеветтер фикеренчә, бу бүленеш гаилә милкенең күләменә карап билгеләнгән. 1555–56 елларда Б.х. җәмәгатьләрендә үзидарә тәртибе кертелә. Йөзлекләр б-н идарә итү, салым җыю, катлаулы булмаган мәхкәмә эшләрен карау, гражданлык мәсьәләләрен хәл итү өчен махсус идарә — земство йорты Б.х.ның гомуми җыелышында сайлап куела. Бу идарәгә бистә-посадның старосталары, танылганрак кешеләре һәм җирле казыйлар («целовальниклар» — тәре үбеп ант иткән чиновниклар) сайланган. Земство йорты башлыгы «баш староста»га йөзлек, иллелек, унлык старосталары буйсынган. Сабан исәбеннән түләнә торган төп салымны («посошный окуп») баш староста җыйган. Целовальниклар кеше исәбеннән җыеласы салымны бүлүдә катнашкан. Өстәмә салым төрләрен (кабаклар кереме, тамгачы-таможнячылар һ.б. кереме) җыю-билгеләү өчен аерым җаваплы кешеләр билгеләнгән. Канцелярия эшләрен сайлап куелган дьяк башкарган. Түрәләр бер елга сайланган. Унлык, иллелек, йөзлекләргә керүчеләр исемлеге төзелгән, шулар нигезендә салым-биремнәр бүленгән. Салым, керемнәр җыйганда җитешмәүчелек ачыкланса, исемлек төзүчеләр җавап биргән. Б.х. сайлап куйган үзидарә б-н килешмәгән очракта, воевода аларны расламаган, сайланучылар исемлеген үзгәртү хокукына ия булган. Яшәгән урыныннан качып китүчеләрне хөкүмәт оешмалары эзәрлекләгән.

1679 елдан башлап Б.х. салымны сабан башыннан түгел, йорт саны исәбеннән түләргә тиеш була. Шул сәбәпле азрак салым түләргә теләгән ишле гаиләле йортлар саны күбәя. Үлгән йорт хуҗасының баласы булмаган очракта, бу йортка аның башка туганнарының күчеп яшәү очраклары ешая; вафат булучының хатыны, мирасының 1/4 өлешен саклаган хәлдә, яңа гаилә составына керә торган була. Йорт тотардай туганнары булмаган очракта, үлүченең милке җәмәгать карамагына тапшырыла. 1679 дан Б.х. үзидарәсе Стрелецлар приказы карамагына керә. Бөлгенлеккә төшкән Б.х. салым түләүчеләр катлавына күчерелә. Бистә-посадлардан күчерелүчеләрдән торган аерым авыллар да булган.

Казан төбәгендә Б.х. 16 йөзнең 2 нче яртысында теркәлгән. Ул вакытта Казан бистәләре Россиядә иң зурлардан саналган, аларда 500–600 ләп йорт исәпкә алынган. Аларда күпчелеге ярлылар яшәгән (1 хәлле гаиләйортына 50 ярлы йорт, 1 урта хәллегә 10 ярлы йорт туры килгән). Сәнәгать үсешенә бәйле рәвештә Б.х.на булган ихтыяҗ арта. Казан төбәгендә аларның саны, башлыча, хәрби хезмәттән кайткан солдатлар (стрелецлар, тупчылар һ.б.) исәбенә тулыландырылган. 1565–1646 еллар аралыгында Казанда Б.х. икеләтә арта. Мәс., 1646 елгы исәпкә алу дәфтәрендә 2869 йорт хуҗасының 2540 ы Б.х. буларак теркәлгән; ш.и. татар бистәсендәге 105 йорт хуҗасы Б.х. буларак салым түләгән. Элек Б.х.на хас булган салым-керемнәр түләүдән азат ителгән ямчы, аучы гаиләләрен дә 1646 дан шул катлауга теркиләр. 1649 дагы кануннар кабул итү комиссиясе карары б-н элек салым түләүдән азат ителгән башка төр шөгыль ияләре дә Б.х. катлавына күчерелә. Шәһәрдә яшәүче сәнәгатькәр, һөнәрче, алыш-биреш б-н көн күрүчеләр, бобыльләр, чиркәү хезмәткәрләре һәм крәстияннәр Б.х. буларак язылалар. Шуннан соң, мәс., Царёвококшайск шәһәрендә Б.х. буларак теркәлгән йортлар саны 30 дан 50 гә арта. 1775 елгы фәрман б-н салым түләү тәртибе үзгәртелә, шәһәр-бистәләр халкы *мещаннар*, гильдияләргә теркәлгән сәүдәгәрләр һ.б. катлауларга бүленә. 1785 елгы Жалованная грамота буенча сәүдәгәр, мещаннар, һөнәрчеләр һ.б. милеккә ия булу тәртибенчә 6 разрядка бүленә. Бик аз милекле Б.х. дәрәҗәсендәгеләрнең күпчелеге 6 нчы разрядка керә. Соңрак аларның күбесе мещан катлавына кушыла.

*Әд.:* З о р и н А.Н. Горожане Среднего Поволжья во второй половине XVI — начале XX вв.: Историко-этнографический очерк. К., 1992; ш у л у к. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001.

**БИТАМА́Н КҮЛЛӘРЕ́**, Көнбатыш Кама алдындагы элеккеге күл урыннары төркеме. Ашыт елгасының сулъяк ярдагы тугаенда, Биектау р-нының Олы Битаман һәм Кече Битаман авыллары арасында урнашкан 5 түгәрәк күлдән тора. Су өслегенең мәйданы 0,04 тән алып 0,6 *га* га кадәр. Уртача тирәнлеге 3 *м*, иң тирән урыны 4,5 *м*. Барлык күлләре дә агымсыз. Туенуы катнаш. Суы җиңелчә минеральләшкән, йомшак, гидрокарбонат-кальцийлы типта, болганчык, күп микъдардагы йөзмә матдәләр бар. Күлләрнең яр буендагы зонасы су-сазлык үсемлекләре каймасы б-н әйләндереп алынган (сары төнбоек, су кәбестәләре, чатырлы сусак, укъяфрак). Табан балык һәм ондатралар яши. Су умырткасызларының сирәк төрләреннән таяксыман ранатра очрый. Күлләр эвтрофинлашкан, кырыйларыннан үсемлекләр б-н каплана бара (1998 елда каплану дәрәҗәсе 20–25% тәшкил иткән).

*Н.М.Минһаҗева.*

**БИТИ́К** (битек, бөти) (кытайча «пити» — язу өчен кулланылган нечкә пумалага бәйле сүз), язу, хат, документ, китап. 1) Борынгы төрки язма истәлекләрдә әфсенләү бөтие буларак кулланышы да теркәлгән; 2) Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында 14–16 йөзләрдә, башлыча, бүтән дәүләт башлыкларына хан исеменнән юлланган хат яисә хан идарәсендәге кешеләргә җибәрелгән документ-язма. 15–16 йөзләрдә «Б.» төшенчәсе гарәп-фарсы теленнән кергән «хат», «намә» сүзләре б-н алыштырыла; 3) хәзерге вакытта татарлар арасында Б. догалык язуы яки дога бөтие мәгънәсендә кулланыла. Ш.у.к. *Битикче.*


*М.Г.Госманов.*

**БИТИКЧЕ́**, язу эшләрен башкаручы, сәркәтип. *Битик* сүзеннән ясалган. 11 йөзгә караган уйгыр язмаларында теркәлгән. Соңрак монголларда да кулланыла. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында 14–16 йөзләрдә хан диваны сәркәтипләре, язу эшләрен башкаручы башка түрәләр Б. дип йөртелгән («диван битикчеләре» һ.б.).

*Әд.:* Б а р т о л ь д В.В. Битикчи // Сочинения. М., 1968. Т. 5; У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

**БИТЛӘНГЕ́Р** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Өске елгасы буенда. 2002 елда 346 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Мәчет. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Акцыбово, Аксуфи исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.дә мәчет, 2 вак-тәяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 728,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәүш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 32 ир заты; 1859 да — 358, 1897 дә — 634, 1908 дә — 638, 1920 дә — 717, 1926 да — 764, 1949 да — 591, 1958 дә — 462, 1970 тә — 510, 1979 да — 419, 1989 да — 364 кеше.

**БИ́ТУМНАР** (лат. bitumen — тау сумаласы). «Б.» атамасы өч мәгънәдә йөри: 1) генетик атама — нефтьләр һәм нафтоидлар рәтендәге каустоболитлар (нефтьләр, асфальтлар һ.б.). Чыгышлары үзләрен сыйдыручы токымнарга карата икенчел. Алар өчен эрүчәнлек мәҗбүри билге түгел; 2) аналитик атама — битумоидлар — органик эреткечләр ярдәмендә, токымнан яисә хәзерге утырмалардан алына торган табигый органик матдәләр тупланмасы; 3) техник атама — табигый асфальт-




1. Шөгер чыганагы битумы; 2. Түбән Казан утырмаларындагы битум катнаш комташ.

лар, нефть, торф, күмер эшкәртү продуктлары, техник чимал буларак кулланылалар.

Табигый һәм ясалма (техник) Б.га бүленәләр.

1. Табигый Б. — беренчел углеводородлардан торган табигый органик кушылмалар; каты, балавызсыман яисә аз агышлы үзле хәлдә булалар. 6 төп класска бүленәләр: мальталар, асфальт, асфальтит, керит, антраксолит һәм озокеритлар. Гамәлдә, физик-химик процесслар нәтиҗәсендә, нефть ятмаларының таркалу һәм яңача формалашу продуктларын табигый Б.га кертәләр. Тыгызлыклары 965 тән 1500 *кг/м*³ га кадәр. Табигый асфальт Б.ының кайбер төрләре күкерткә (10–15 % тан да артык), металларга (V, Ni, U, Co, Mo, Rb һ.б.) бай. Ванадийлы, уранлы һ.б.сәнәгый Б. чыганаклары билгеле. СССРда асфальт Б.ы 1930–70 елларда Идел буенда (ш.и. Татарстан терр-ясендә — *Шөгер битум чыганагы*, Беренче Май чыганагы һ.б.), Көнбатыш Казакъстанда, Грузия, Коми АССР, Карпат буенда һәм Урта Азиядә чыгарылды. Табигый Б. тупланмасының стратиграфик колачы бик киң — кембрийгача чордан алып хәзерге утырмаларга кадәр таралган. Табигый Б. борынгы заманнардан бирле кулланыла. Б.э.к. 3 мең еллар элек Вавилонда һәм Мисырда табигый Б. кулланып эшләнгән корылмалар булганы билгеле. Соңрак табигый Б.ны күп илләрдә төзелештә, медицинада, лаклар сыйфатында һ.б.максатларда куллану очраклары була. 18 йөз ахырында Канадада табигый Б. чыганакларын сәүдә ихтыяҗларыннан чыгып эшкәртергә омтылып караганнар. 19 йөз уртасында Европада һәм АКШта беренче асфальт тротуарлар салына; Казанда алар 20 йөз башында барлыкка килә. Аерым ятмалардагы запаслар йөзләрчә млн. *т* га, битум туплану зоналарында — берничә млрд. *т* га җитә. Сәнәгать үсеше алга киткән һәм үсеп килүче илләрдә Б.ның исәпләнгән һәм перспектив запаслары 580 млрд. *т* тәшкил итә (шуның 71% ы — Канадага, 27% ы Венесуэлага туры килә). Җир шарында елга 100 млн. *т* дан артык Б. чыгарыла. Россиядә аның төп ресурслары (90% чамасы) Көнчыгыш Себердә (Оленёк чыганагы) һәм Татарстанда. Аз күләмдә табигый Б. Самара, Ульянов өлкәләрендә, Казакъстан, Урта Азия, Әзәрбайҗанда очрый.

ТРда табигый Б. ятмалары, башлыча, Пермь утырмаларында — Сакмар һәм Казан ярусларының карбонатлы коллекторларында, Уфа ярусының комлы катламнарында урнашкан. Б.га баерак урыннар — Мәләкәс батынкылыгы, Татар гөмбәзе Көньяк калкулыгының көнбатыш, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш битләре; азрак очраган урыннар — Татар гөмбәзенең Көньяк һәм Төньяк күтәрелмәләре чигендә. Татарстанда 430 Б. ятмасын үз эченә алган 90 Б. чыганагы билгеле, ш.и. 40 чыганак тикшерелгән. Иң эреләре — *Әшәлче битум чыганагы, Мордва Карамалысы битум чыганагы*, Түбән Карамалы һәм Подлесный чыганаклары. Аерым чыганакларда Б. запасы 1–2 дән алып 10–15 *млн. т* га кадәр исәпләнә. Татарстанның Пермь утырмаларындагы Б. төрле дәрәҗәдә оксидлашкан, үзлелеге югары булган (440–600 мең *МПа·с*) углеводородлар катнашмасыннан гыйбарәт; ярымсыек яисә каты хәлдә, күкерт микъдары югары — 3,7–7%, майлар — 5,8–88%, сумалалар — 8,7–57%, асфальтеннар — 3,3–61%. Б. чыгымы токым авырлыгына карата 1–20%, токым микъдарына карата 40–98%. Табигый Б. рудник (карьер яисә шахта) һәм пластара (скважина) ысуллары б-н алына. Татарстан терр-ясендә табигый Б.ның төп ятмалары, җылыту ысуллары кулланып, скважина аша алына. Б.ны чыгаруның отышлы юллары — еллык җитештерүчәнлеге 50–200 мең *т* га җиткән, ягулык яисә лаклар, буяу, өстәмә кушылма, сульфон, сульфоксидлар эшләп чыгаручы кече заводлар төзү һәм урыннарда Б.ны эшкәртүне киңәйтү. Табигый Б. юл төзү эшләрендә, синтетик нефть, җиңел фракцияләр, катмый торган майлар, лаклар, буяулар, сумалалар, гидроизоляция материаллары, пластмассалар эшләп чыгаруда, нефть коксы һәм химик элементлар (күкерт, никель, ванадий, титан һ.б.) алуда, энергетика, металлургия һәм а.х. тармакларында кулланыла. ТРда чималны «Татавтодор» берләшмәсе пр-тиеләре Спиридоновка битумлы комташ һәм Васильево битумлы доломит чыганакларыннан алалар. Елына дистәләрчә мең *т* токым алына. Табигый Б. чыгару күләмен арттыру перспективасы алардан нефть һәм нефть продуктлары алу процессын үзләштерү һәм камилләштерүгә бәйле.

2. Ясалма (техник) Б. — гадәттә, каты яисә үзле халәттәге матдәләр; башлыча, авыр нефть калдыкларыннан (мазут, гудрон һ.б.) алына. Каты нефть Б.ы рубероид ясауда, ярым катылары — гидроизоляция материаллары, асфальт һ.б. эшләп чыгаруда, сыеклары юл төзелешендә кулланыла. Сәнәгатьтә кулланылганның 90% ы ясалма Б.га туры килә.

*Әд.:* Пермские битумы Татарии. К., 1976; Повышение эффективности освоения нефтяных месторождений Татарии. К., 1985; К л у б о в Б.А., Ш а р г о р о д с к и й И.Е. Минеральное сырьё. Сырьё битумное: Справ. М., 1998; Химия и геохимия пермских битумов Татарстана. М., 1999.

*Р.Х.Мөслимов.*

**БИ́ЦЮТКО** Константин Яковлевич (26.10.1866, Минск губ. — 13.5.1916), генерал-лейтенант (1916). Польша-Литва татарларыннан. 2 нче Мәскәү кадет корпусын, 3 нче Алексеевск хәрби уч-щесен (1886) һәм Ген. штаб академиясен (1892) тәмамлый. 1886–89 елларда 18 нче кыр артиллерия бригадасында хезмәт итә. 1892–1907 дә Россия армиясе частьләрендә штабның өлкән адъютанты, штаб офицеры, штаб башлыгы. 1903 елдан полковник, 1913 тән генерал-майор. 1904–05 еллардагы Рус-япон сугышында катнаша. 1907–14 тә 63 нче Углич пехота, Кишинёв пехота резерв, 5 нче Калуга пехота полклары командиры; 1 нче Төркестан армия корпусы штабы башлыгы. Беренче бөтендөнья сугышында 29 нчы армия корпусы штабы башлыгы, аннары 3 нче Кавказ укчылар дивизиясе командиры. «Батырлык өчен» язулы Георгий алтын коралы, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

**БИЧУРА́** (бисүрә, бисура), татар һәм башкорт мифологиясе персонажы; рух (Көнбатыш Себер татарларының кайбер этник төркемнәрендә Б.ны «сары цац» — «сары чәч» дип йөртәләр). Татарларда башына борынгы баш киеме (өрпәк) кигән, кыска буйлы хатын-кыз кыяфәтендә күзаллана. Б. өйнең идән астында яки мунчаларда яши, дип санала, ләкин, *өй иясеннән* аермалы буларак, барлык өйләрдә дә очрамый. Үзенә карата ихтирам таләп итә, шуңа күрә аңа аерым урын бүлеп биргәннәр һәм ризык б-н махсус савыт, кашык калдыра торган булганнар. Б. шаяра-шуклана: мич моржасының эшермәсен ача, тавышлана, шакылдый, әйберләрне яшереп куя. Кайчак йоклаган кешене куркыта — аның өстенә ята, итекләрне, утыннарны куелган урыныннан алып ташлый. Б.ның кеше тормышындагы уңай яки тискәре роле йорт хуҗасы һәм Б. арасында булган үзара мөнәсәбәтләргә бәйле: алар әйбәт булса, Б. хуҗага баерга ярдәм итә, «үз өенә» акча, кайчак күршеләрнең кыйммәтле әйберләрен алып кайта.

Үзенә карата булган мөнәсәбәттән канәгать булмаса, Б. өзлексез шаяруы б-н кешеләрне газапларга, хәтта аларны өйдән чыгып китәргә мәҗбүр итәргә дә мөмкин.

Мишәрләр Б.ны бераз башка төрле күз алдына китерәләр: аны явыз рух — пәриләр төре дип саныйлар.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Н а с ы р о в К а ю м. Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Зап. Имп. Русского Географического общества по отделению этнографии. 1880. Т. 6; К о б л о в Я.Д.

Мифология казанских татар // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. 1910. Т. 26, вып. 5.

*Ф.И.Урманчеев.*

**БИЧУ́РИН** Абдулла Хәлил улы (5.5.1911, Саратов губ. Татар Пәлдәңкәсе а. — 15.1.1986, Казан), генерал-майор (1964). 1933–35 елларда НКВД гаскәрләренең кавалерия полкында хезмәт итә, отделение командирлары мәктәбен тәмамлый. 1935–39 да Магнитогорск пед. ин-тында, Дәүләт иминлеге баш идарәсенең (ГУГБ) Свердловск крайара мәктәбендә укый. 1946 да Бөтенсоюз юридик ин-тын (Мәскәү) тәмамлый. 1939–43 тә СССР НКВД–ГУГБ Мәскәү Кремле коменданты идарәсенең аерым сак батальоны 1 нче ротасы командиры. 1943–46 да СССР НКВД–НКГБ ның махсус мәктәбендә укыту эшендә. 1946–58 дә МВД–МГБ–КГБның 5 нче Идарәсендә оператив эштә. 1959 дан ТАССР Дәүләт иминлеге комитеты рәисе урынбасары, 1961–81 дә — рәис. Б. Республика Дәүләт иминлеге органнарын үзгәртеп коруда, М.Җәлилне һәм аның антифашистик көрәштәге тарафдарларын аклауда актив катнаша. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз һ.б. орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Т и т о в Л.Н. Человек и профессионал // КГБ вчера, сегодня... К., 1997.

**БИЧУ́РИН** Әмир Имам улы (3.5.1935, Красноярск ш.), контр-адмирал (1981). С.О.Макаров исем. Тын океан югары хәрби диңгез уч-щесен (1960, Владивосток ш.), В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (1970, Мәскәү) тәмамлый. 1976–83 елларда Кара диңгез флоты хәрби кораблар берләшмәсенең сәяси бүлеге җитәкчесе. 1983 тән Севастополь югары хәрби диңгез инженерлары уч-щесендә факультет башлыгы урынбасары. 1987–90 да СССР Хәрби диңгез флотының Фәнни-тикшеренү базасы башлыгы урынбасары. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**БИЧУ́РИН** Мирза Имам улы (30.3.1940, Красноярск ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1990), проф. (1992), Лодзь техника ун-тының атказ. фән. эшлеклесе (Польша, 1998). 1963 елда Томск радиоэлектроника һәм электрон техникасы ин-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли. 1974 тән Новгород политехника ин-тында, 1990 нан радиоаппаратуралар технологиясе һәм проектлаштыру каф. мөдире. 1993 тән Новгород ун-тында шул ук исемдәге каф. мөдире һәм физ.-техника ф-ты деканы. Хезмәтләре магнит һәм магнит-электрон күренешләре физикасына, электродинамикага һәм үтә югары ешлыклы техникага карый. ЭПРда электр кыры эффектының феноменологик һәм микроскопик, магнитлыгы тәртипкә китерелгән мохиттә резонанслы магнитоэлектрик эффект теорияләрен төзи (автордаш); үтә югары ешлыклы магнитоэлектрик фаза әйләндергеч тәкъдим итә (автордаш).

Х е з м.: К расчёту влияния внешних электрических полей на спектры ЭПР редкоземельных ионов // Тр. Томского ин-та радиоэлектроники и электронной техники. 1967. Т. 6; Влияние внешнего электрического поля на СТС спектра ЭПР $Mn^{3+}$ в $CdWO_4$ // Письма в журн. эксперим. и теоретической физики. 1968. Т. 8 (автордаш); К расчёту кристаллического поля в шеелите // Физика твердого тела. 1969. Т. 11 (автордаш.).

**БИЧУ́РИН** Никита Яковлевич (монахлыкта — Иакинф) (29.8.1777, Казан губ., Цивиль өязе Акулево а. — 11.5.1853, С.-Петербург), шәркыятьче галим, илебездә синология фәненә нигез салучы, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1828). Казан руханилар акад. тәмамлый (1799), шунда ук 1802 елга кадәр грамматика һәм риторика укыта. 1800 дә монахлык кабул итә. 1802–07 дә Иркутск Вознесение монастыренда архимандрит, монастырь башлыгы, Иркутск руханилар семинариясе ректоры, Тобол руханилар семинариясендә укыта. 1807–21 дә Пекинда Рус рухи миссиясе башлыгы. Пекиннан кайткач, миссия эшен зәгыйфьләндерүдә, таркатуда гаепләнә, архимандрит дәрәҗәсеннән төшерелә һәм 1823 тә Валаам монастырена сөргенгә җибәрелә. 1826 да Александр Невский лаврасына күчерелә, бер үк вакытта Россия Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында тәрҗемәче булып эшли. 1835 тә Кяхта шәһәрчегендә Россиядә беренче буларак кытай телен өйрәнү уч-щесы ача. Хезмәтләре Кытай чыганакларына таянып язылган монгол һәм төрки халыклар тарихына, этнографиясенә, кытай халкы тарихы, мәдәнияте һәм фәлсәфәсенә карый. Үз китапханәсенең зур өлешен (китаплар һәм кулъязмалар) Казан руханилар академиясенә бүләк итә (1849). Париждагы Азияне өйрәнү җәмгыяте әгъзасы (1831). Петербург ФАнең Демидов исем. бүләгенә дүрт мәртәбә (1834, 1839, 1843, 1849) лаек була.

Х е з м.: Записки о Монголии. СПб., 1828. Т. 1–2; Описание Тибета в нынешнем его состоянии. СПб., 1829. Ч. 1–2; Описание Чжунгарии и Восточного Туркестана в древнем и нынешнем состоянии. СПб., 1829. Ч. 1–2; История Тибета и Хухунора. СПб., 1833. Ч. 1–2; Китайская грамматика. СПб., 1833; Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. СПб., 1851. Ч. 1–3; История первых четырех ханов из дома Чингисова. СПб., 1829; Историческое обозрение ойратов или калмыков с XV столетия до настоящего времени. СПб., 1834; Статистическое описание Китайской империи. СПб., 1842. Ч. 1–2; Китай в гражданском и нравственном состоянии. СПб., 1848. Ч. 1–4.

*Әд.:* А л и е в А.А. Великий русский синолог // Вестн. АН Казахской ССР. 1957. № 8; Н.Я.Бичурин и его вклад в русское востоковедение (К 200-летию со дня рождения): Материалы конф. М., 1977. Ч. 1–2; Д е н и с о в П.В. Жизнь монаха Иакинфа Бичурина. Чебоксары, 1997.

*Р.М.Вәлиев.*

**БИШАЛА́Б** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 39 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Шәһиян елгасы буенда. 2002 елда 37 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә Иске Казиле авылы пүчинкәсе буларак нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Казыево-Бишалап исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, агач хәзерләү, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 2 җил һәм 1 ярма ярдыру тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 644 дис. тәшкил итә. 1920 дә Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Кариле волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 118 ир заты; 1859 да — 428, 1884 тә — 665, 1897 дә — 635, 1908 дә — 688, 1920 дә — 584, 1926 да — 343, 1938 дә — 232, 1958 дә — 201, 1970 тә — 163, 1979 да — 116, 1989 да — 45 кеше.

**БИШБАЛТА́ БИСТӘСЕ́**, 18 йөзнең 1 нче чирегендә Казанның төньяк-көнбатыш чигендә оешкан торак урын. Казансу елгасы тамагының сул ярында урнаша. Шундагы Адмиралтейство идарәсенә мөнәсәбәтле рәвештә (к. *Казан адмиралтействосы*) рәсми язмаларда Адмиралтейство бистәсе исемендә йөри. 15–16 йөзләрдә бу урында Бишбалта атамалы татар авылы булган, халык телендәге атамасы шуннан килә. Авылда агач эшкәртү остаханәләре эшләгән, кораблар төзелгән һәм төзекләндерелгән, Казансу елгасы тамагында сәүдә флоты урнашкан дип фараз ителә. 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөздә бу җирләр Успение (Елантау) монастырена караган. 1718 елдан Адмиралтейство төзелеше башлангач, Б.б. оештырыла. Биредә кораб төзүчеләрнең, матрос, лоцманнарның торак йортлары, Адмиралтейство б-н бәйле җитештерү биналары — «пумпа-насос» з-ды, күн эшкәртү з-ды, порт-верфь, сызымнар конторасы, адм. корылмалар, мәктәп була. 20 йөз башыннан шәһәр чикләренә керә.

*Әд.:* К а л и н и н Н.Ф. Казань. К., 1952; История Казани. К., 1988. Кн. 1; Б и к б у л а т о в Р., М у с т а ф и н Р. Казань и её слободы. К., 2001.

*И.Л.Измайлов, Г.А.Милашевский.*

**БИШБАТМА́Н** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2002 елда 67 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Б.да Преображение Господня чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, май язу йорты, 11 җил тегермәне, тимерчелек, шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2784,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында; 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 415 ир заты; 1859 да — 1105, 1897 дә — 1686, 1920 дә — 1871, 1926 да — 2044, 1938 дә — 1318, 1949 да — 657, 1958 дә — 608, 1970 тә — 349, 1979 да — 214, 1989 да — 46 кеше.

**БИШБҮЛӘ́К РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасы*ның көньяк-көнбатышында 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 2134 *км*². Үзәге — Бишбүләк авылы (Уфадан 230 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 27999 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 12058, 1979 да — 10727, 1989 да — 9722, 2002 дә — 7374 кеше. 92 торак пункт, ш.и. 18 татар, 3 татар-башкорт, 3 татар-чуаш авылы бар. Иң зур татар авыллары (1999): Кыңгыр-Мәнәвез (1402 кеше), Ает (1301), Усаккичү (917), Елбулактамак (786). Иң борынгылары: Кунаккол (1746), Усаккичү (1746), Кыңгыр-Мәнәвез (1761), Ает (1766), Мәнәвез-Мәскәү (1782). 2004/2005 уку елында 10 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла, 10 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татарча «Якты юл» г-тасы нәшер ителә. Б.р.нда татар шагыйре Ф.*Кәрим* (Ает а., 1971 дә музей-йорты ачыла), Советлар Союзы Герое Х.Г.*Гаделшин* (Ает а.), дипломат К.Г.*Хәкимов* (Дүсән а., музей-йорты), нәкышьче Р.Ф.*Имашев*, ген.-майор Р.Г.*Кәлимуллин*, атаклы нефтьче А.Г.*Вахитов* туган.

*Әд.:* С е м ё н о в А.Ф. Из истории родного края. Бижбулякский район. Бижбуляк, 1993; ш у л у к. Бижбуляк: прошлое и настоящее. Бижбуляк, 1998.

**БИШЕНЧЕ́ А́РМИЯ**, 1918–20 елларда *Көнчыгыш фронт* карамагындагы эре хәрби берләшмә. 1918 елның 16 августында оештырыла. Командующийлары: П.А.Славен, Ж.К.Блюмберг, М.Н.Тухачевский, Г.Х.Эйхе. Штаб башлыклары: А.К.Андерсон, П.И.Ермолин, Я.К.Ивасиов, Г.Я.Кутырев. Б.а. составына 1 нче Смоленск, 4 нче Петроград пехота һәм 2 нче, 5 нче, 24 нче, 25 нче, 26 нчы, 27 нче, 30 нчы, 31 нче, 35 нче, 51 нче, 59 нчы, 62 нче укчы, 13 нче, Берләштерелгән кавалерия дивизияләре керә. 1918–1920 башында баш күтәргән чех-словак корпусы, КОМУЧ Халык Армиясе һәм адмирал А.В.Колчакның армияләренә каршы сугыша. *Казанны азат иту операциясе*ндә катнаша; 1918 нең 10 сентябрендә Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясе Арча төркеме һәм Идел буе хәрби флотилиясе б-н бергә Казанны аклардан азат итә. 1918 нең көзендә һәм кышында Б.а. көнчыгыш юнәлешендә сугыша, Бөгелмә, Уфа шәһәрләрен азат итә. 1919 ның март-апрель айларында А.В.Колчак армиясе басымы нәтиҗәсендә, Уфаны калдырып, Богырыслан, Бөгелмә тарафына чигенә. Апрель-май айларында Көнчыгыш фронт һөҗүмгә күчкәч, Б.а. Богырыслан шәһәрен азат итү операциясендә катнаша; 1919 ның июль — 1920 нең гыйнвар аралыгында Златоуст, Чиләбе, Петропавел, Омск, Томск, Красноярск шәһәрләрен яулаша. 1920 нең 15 гыйнварында Көнчыгыш фронт таркатылганнан соң, Б.а. турыдан-туры Республика Революцион хәрби советына (РРХС) буйсындырыла. 1919 да Б.а. өчен татар-башкорт сугышчыларын әзерләп озату бурычы армиянең махсус резерв бүлекчәсенә (май-октябрь) һәм 1 нче запас полкның татар-башкорт батальонына (апрель-декабрь) йөкләнгән була. 1919–20 дә Б.а.нең сәяси бүлеге каршында мөселман солдатлар секциясе эшли, «Кызыл яу» г-тасы нәшер ителә.

**БИШМӘ́Т**, татар халкында элекке вакытта киң таралган өс киеме. Куе төстәге фабрика материаллыннан — постаудан, кайбер очракларда плюштән тегелгән. Гадәттә, Б. ир-ат һәм хатын-кыз өчен бер үк төрле — арка буе тоташ, билле, тар утыртма якалы, озын җиңле итеп эшләнә. Сул чабуы уң яктагысы өстенә ята һәм төймәләнә, якаларына каптырма куела. Б.ләр билләрендәге өч яисә биш бөрмәгә карап аерыла: өчбилле Б., бишбилле Б. Б.кә охшаш өс киемен Идел буе һәм Урал алдында яшәүче башка халыклар, ш.у. Урта Азия һәм Төньяк Кавказ халыклары да кигән.

*Әд.:* В о р о б ь е в Н.И. Казанские татары. К., 1953; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; С у с л о в а С.В., М у х а м е д о в а Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

**БИШМУНЧА́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 22 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Урсалы елгасының сул кушылдыгы Камы суы буенда. 2002 елда 796 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1730 елларда нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр, башкорт-кердәшләр, дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Мәчет беренче тапкыр 1762 дә искә алына, 1866 да — икенче, 1908 дә өченче мәчет төзелә. Мәчет каршында мәктәпләр эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 3899 дис. тәшкил итә. 3 су тегермәне, земство станциясе була. 1920 елларда Б.дан күчеп утыручылар Ак Чишмә, Кама-Елга авылларына нигез сала. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт р-нында. Халык саны: 1795 тә — 324 ир заты; 1859 да — 1062, 1883 тә — 1336, 1889 да — 1598, 1897 дә — 2038, 1910 да — 2887, 1920 дә — 2377, 1926 да — 2177, 1938 дә — 1801, 1949 да — 1208, 1958 дә — 1099, 1970 тә — 1061, 1979 да — 930, 1989 да — 700 кеше.

**БИШНӘ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 38 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 637 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 994,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән — Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1859 да — 254, 1897 дә — 427, 1908 дә — 462, 1920 дә — 531, 1926 да — 563, 1938 дә — 390, 1949 да — 244, 1958 дә — 253, 1970 тә — 301, 1979 да — 418, 1989 да — 661 кеше.

*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**БИШСУБА́Ш** (Пусташит) авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зәй елгасы бассейнындагы Инеш суы буенда. 2002 елда 174 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. Рев-гә кадәрге чыганакларда Пустошь, Пустошь-Ашыт, Югары Биеш исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 835,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостена керә. 1920 дән — ТАССР ның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 286, 1870 тә — 356, 1897 дә — 642, 191 дә — 872, 1920 дә — 913, 1926 да — 727, 1989 да — 210 кеше.

**БИШЬЯФРА́К** (Comarum), роза чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләннәр яки куаклар ыругы. 2 төре билгеле; Төньяк ярымшарның салкын һәм уртача поясларында таралган. ТРда бер төре — саз Б. (саз утчәчәге) (C.palustre) барлык р-ннарда да очрый. Сазлыклы болыннарда, елга, күл буйларында үсә. 30–100 *см* озынлыктагы күпьеллык үләнчел үсемлек. Тамырчасы озын, үрмәләүче. Сабагы җәелгән, өскә таба күтәрелә, үзәгендә тамырланучан. Яфраклары парсыз каурыйсыман, яфракчалары озынча-овал сыман, чите тешле, өстән куе яшел, астан ачык яшел төстә, төкчәле. Чәчәкләре куе кызыл төстә, сабак очында 2–5 әр булып урнашкан, калкансыман чәчәк төркемендә. Җимеше — күп чикләвек. Июнь-июль айларында чәчәк ата. Җимешләре август-сентябрьдә өлгерә. Тамыр һәм тамырчаларында флавоноидлар, дуплау матдәләре, эфир мае, сумалалар, органик кислоталар бар. Җир астындагы өлеше халык медицинасында ашказаны авыртканда, кан киткәндә файдаланыла. Җәрәхәтне төзәтү өчен тәнгә сөртәләр. Баллы, сирәгәя баручы үсемлек.

**БЛА́ГОВ** Юрий Алексеевич (10.2.1937, Югары Ослан р-ны Югары Ослан а.), педагог, режиссёр, театр тәнкыйтьчесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын (1959) һәм Щукин исем. Мәскәү театр уч-щесенең режиссёрлык ф-тын тәмамлый (1974). 1959–67 елларда Казанда урта мәктәптә тарих укытучысы. 1967–70 тә Казан Зур драма театры актёры һәм режиссёры, 1971–74 тә Казан мәдәният ин-ты укытучысы; шунда ук 1973 тә Казанда беренче тапкыр Б.Брехтның «Тереза Каррар мылтыклары» («Винтовки Терезы Каррар») пьесасын сәхнәләштерә. 1975–88 дә Казан Яшь тамашачылар театрында әдәби бүлек мөдире һәм режиссёр, бер үк вакытта театр каршындагы студиядә һәм Казан театр уч-щесендә укыта. 1993 тән Казан Зур драма теа-

трында музей мөдире. Казан яшь тамашачылар театрында «Минем дустым, Колька!» («Мой друг, Колька!», А.Г.Хмелик, 1978), «Король Матиуш Беренче» («Король Матиуш Первый», Я.Корчак, 1979); «Алёша Пешков» (И.А.Груздев, О.Д.Форш, 1986) һәм Казанда беренче тапкыр «Сид» (П.Корнель, 1986), «Турбиннар көннәре» («Дни Турбиных», М.А.Булгаков, 1987), «Төлке һәм йөзем җимеше» («Лиса и виноград», Г.Фигерейдо», 1997); Казан Зур драма театрында — «Барысы да бетте» («Всё кончено», Э.Олби; Г.Н.Прытков б-н берлектә, 1994) спектакльләрен куя. Яшь тамашачылар театрында «кече сәхнә» оештыра һәм анда Ф.М.Достоевскийның «Мескен кешеләр» («Бедные люди», 1984), В.В.Каменскийның «Степан Разин» (1983) әсәрләрен куя. Б. режиссурасына пьесаның төп идеясен, авторның стилен тәгәл итеп, тулысынча ачарга, сурәтләнгән дәвернең тарихи дөреслегенә игътибарлылык, чынбарлыкны тамашачыны җәлеп итәрлек, аһәңле итеп күрсәтергә омтылу хас. Б. Казандагы театрлар тарихына, актёрлар һ.б. театр эшлеклеләренә багышланган очерклар, мәкаләләр, рецензияләр авторы. Медальләр, ш.и. И.Г.Гердер Алтын медале (ГДР) б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Народные артисты. К., 1980 (автордаш); Казанский театр юного зрителя: Очерки истории. К., 1986; «... получил прозвище Казанский» (П.М.Медведев и казанский театр в кон. 60-х – 80-е гг. 19 в.). К., 1998; «Казанский сын саратовского цехового» (Народный художник ТАССР В.С.Никитин). К., 2000; «Кешнер и К°». К., 2001; Казанская антреприза Собольщикова-Самарина. К., 2004; В содружестве с Мельпоменой. К., 2004; КЭМСТ и театральная жизнь Казани 1920-х гг. К., 2005; «Казанский помещик» Александр Каширин. К., 2006.

*И.И.Илялова.*

**БЛАГОВА́Р РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасында.* 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 1639 *км*². Үзәге — Языков авылы (Уфадан 70 *км* көнбатыштарак). Халкы — 25770 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 елда — 6138, 1979 да — 6048, 1989 да — 14520, 2002 дә — 5955 кеше. 86 торак пункт, ш.и. 53 татар, 19 татар-рус, 5 татар-башкорт авылы бар. Иң зур татар авыллары (1999): Иске Кучәрбай (1462 кеше), Кашкалаша (605), Балышлы (593), Өдрәкбаш (569), Шарлык (521); Таң посёлогы (735), Үрге Каргалы (183). 2004/2005 уку елында 12 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла, 23 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татарча «Хезмәт байрагы» г-тасы нәшер ителә. Халык язучысы Ә.*Еники* туган (Үрге Каргалы а.).


**БЛАГОВЕ́ЩЕН РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасы*ның үзәк өлешендә. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 2324 *км*². Үзәге — Благовещенск шәһәре (Уфадан 42 *км* төньяктарак). Халкы — 48850 (2002), ш.и. Благовещенскида — 32989 кеше. Татарлар саны: 1970 елда — 7345, 1979 да — 9835, 1989 да — 12329, 2002 дә 4951 кеше. 90 торак пункт, ш.и. 9 татар, 13 татар-рус, 5 татар-башкорт авылы бар. Иң зур татар авыллары (2002): Иске Илек (422 кеше), Биштин (227), Ишмән (243). 2005/2006 уку елында 7 мәктәптә татар теле укытыла.

**БЛАГОВЕ́ЩЕНИЕ КАФЕДРА́ЛЬ СОБОРЫ́**, Казанда рус дини архит-расы истәлеге. 1555–62 елларда Казан Кремленең төньяк өлешендә Псков осталары И.Я.Постник һәм И.Ширяй җитәкчелегендә элеккеге агач чиркәү (1552) урынына ак таштан төзелә. Башта ул биш шлемсыман гөмбәзле, алты баганалы, өч апсидалы була, корылышында Псков, Владимир, Мәскәү архит-ра мәктәпләре йогынтысы чагылыш таба. Гөмбәзләре тәрәзәле барабаннар өстендә утыра; үзәк барабан,



Благовещение соборы. 19 йөз ахыры фотосы.

тромплар аша, баганаларга таяна. Апсидалар һәм барабаннар бизәлешендә борынгы рус архит-расы элементлары кулланылган. 17 йөз уртасында соборның көньяк-көнбатыш ягына биш катлы түгәрәк нигезле чаң манарасы салына. Б.к.с. бернечә мәртәбә яна һәм үзгәртеп корыла. 1691 дә тәрәзәләре зурайтыла. 1736 да почмакларындагы шлемсыман гөмбәзләре сугансыман, ә үзәктәгесе — кырланган грушасыман итеп үзгәртелә, гыйбадәтханәнең көнбатыш ягына бер катлы ашханә, ә көньяк һәм төньяк фасадларында ярымтүгәрәк апсидалы янкорма чиркәү төзелә. 1841–46 да арх. Ф.И.Петонди проекты б-н собор төньяк-көнбатыштан һәм көньяктан ике катлы ашханә б-н киңәйтелә, элеккеге ашханә һәм болдыр сүтелә. 1841 дә янкорма төзегән вакытта Казанның беренче архиепископы Гурийның җир асты хөҗрәсе табыла, ул соңрак дин тотучылар өчен табыну урынына әверелә. 1906–09 да бинаның интерьеры арх. Ф.Н.Малиновский проекты б-н электр һәм үзәкләштерелгән җылыту системасы кертү өчен үзгәртеп корыла. Янгыннардан соң эчке диварындагы фрескалар бернечә тапкыр яңартыла (гөмбәз астында 17 йөзгә караган фрескаларның фрагментлары саклана), 1870 тә эчке диварлары майлы буяулы рәсемнәр б-н бизәлә (1913 тә рес-



Благовещение соборы. 2002 елгы фото.

таврацияләнә). Соборда Казанның барлык архиерейлары, ш. и. изгеләштерелгән Гурий, Герман, Гермоген, Адриан хезмәт иткән. Б.к.с. нда Казанда вафат булган архиерейларның җәсәдләре куелган, аларның 11е үзәк гыйбадәтханәдә һәм янкормаларда, 7се подвалда җирләнгән. Соборда Пётр I, Екатерина II, А.Н.Радищев, А.С.Пушкин, С.В.Рахманинов һ.б. күренекле шәхесләр була. 1918 дә собор ябыла, мәдәни истәлекләре һәм милке конфискацияләнә. 1922 дә чаң манарасы сүтелә. 1921–29 да яңарышчылар соборы булып тора, 1929 да яңадан ябыла. Совет чорында биредә республика архивы саклана. 1996 да Казан епархиясе карамагына тапшырыла, реставрацияләнә. 2005 елның августында кабат ачыла.

*Әд.:* Я б л о к о в А.П. Кафедральный Благовещенский собор в Казани. К., 1909; О с т р о у м о в В.П. Казань: Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978; Казань в памятниках истории и культуры. К.,1982; Республика Татарстан: Православные памятники. К., 1998.

*Х.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.*

**БЛАГОВИ́ДОВ** Фёдор Васильевич (1865, Сембер губ. — ?), тарихчы, чиркәү тарихы д-ры (1902). П.В.Знаменский шәкерте. Казан руханилар академиясен тәмамлый (1889), шунда ук укыта, 1899 елдан рус гражданлык җәмгыяте тарихы каф. профессоры. 1911 дән Тифлис шәһәрендә Хатын-кызлар югары курслары директоры. Хезмәтләре чиркәү тарихына карый. Докторлык диссертациясе Изге Синод прокурорлары эшчәнлегенә багышлана һәм галимнәр, чиркәү әһелләре арасында бәхәсләр тудыра. Консерватив руханилар Б.ны дин нигезләрен бозып күрсәтүдә һәм либерализмда, яңалык кертүдә гаеплиләр.

Х е з м.: Русское духовенство в отношении к народному образованию в царствование Александра II. К., 1892; Обер-прокуроры Св. Синода в XVIII и первой половине XIX в. К., 1899.

*Е.В.Липаков.*

**БЛАГОДА́РОВКА** посёлогы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 21 *км* көнбатыштарак, Чабаксар елгасы буенда. 2002 елда 87 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Вольная Алькина исеме б-н дә билгеле. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 81, 1897 дә — 144, 1908 дә — 189, 1920 дә — 187, 1926 да — 202, 1938 дә — 163, 1949 да — 140, 1958 дә — 68, 1970 тә — 83, 1979 да — 133, 1989 да — 76 кеше.

**БЛАГОДА́ТНЫЙ** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Түбән Ямаш елгасы буенда. 2002 елда 259 кеше (татарлар — 61%, руслар — 29%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 дә нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 183,

1938 дә — 267, 1949 да — 239, 1958 дә — 222, 1970 тә — 183, 1979 да — 175, 1989 да — 111 кеше.

**БЛАГОДА́ТНЫЙ** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 75 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2002 елда 554 кеше (татарлар — 43%, руслар — 42%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Keче Сосновка исеме б-н дә билгеле. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында; 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән — Яңа Чишмә, 1984 нең 3 июленнән Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 71, 1897 дә — 46, 1908 дә — 67, 1920 дә — 185, 1926 да — 218, 1938 дә — 276, 1949 да — 253, 1958 дә — 197, 1970 тә — 228, 1979 да — 176, 1989 да — 209 кеше.

**БЛАЖКО́** Нина Ивановна (15.7.1915, Украинаның Запорожье өлкәсе Мелитополь ш. — 13.6.1982, Казан), географ-икътисадчы, геогр. фән. д-ры (1966), проф. (1969). Одесса ун-тын тәмамлый (1939). 1944–55 елларда Луганск, 1955–56 да Одесса пед. ин-тларында, 1956–64 тә Одесса ун-тында укыта. 1964 тән Казан ун-тында, 1967–77 дә икътисади геогр. каф. мөдире. Фәнни хезмәтләре географик һәм терр. системаларга, аларның төзелеше һәм үсеше мәсьәләләренә карый. Ул шәһәрнең матрицалы моделен төзү һәм шәһәр үсеше дәрәҗәләрен билгеләү ысулларын тәкъдим итә. Вузлар өчен язылган «Географиядә математик ысуллар» («Математические методы в географии», 1976) исемле уку әсбабы авторларының берсе.

Х е з м.: Математико-географические методы моделирования городских поселений. К., 1970 (автордаш).

**БЛИЗНО́ВА** Валентина Васильевна (16.12.1926, Казан — 24.11.2005, шунда ук), драма актрисасы, педагог, ТАССРның атказ. артисткасы (1957). 1946–69 елларда Казан яшь тамашачылар театры труппасында эшли. Театр каршындагы студиядә укый. Башлыча, яшүсмерләр рольләрен башкара. Актриса тудырган образлар психологик яктан ышандырырлык дөреслеге, тәэсирле матур тышкы кыяфәтләре б-н балалар характерын чагылдыруның зур казанышы булып торалар: Катя («Варислар», А.Я.Бруштейн), Ира («Өйгә кайтасым килә», С.В.Михалков), Козетта («Читкә кагылганнар», В.Гюго), Лена («Кызчык этисен эзли», Е.С.Рысс), Кечкенә юлбасар («Кар королевасы», Е.Л.Шварц), Ваня Солнцев («Полк улы», В.П.Катаев), Винни-Пух (шул исем. пьеса, А.Милн). Шактый гына әкият геройлары образларын тудыра: Машенька («Иван-да-Марья», В.А.Гольдфельд), Анюта («Анюта күзләре», Т.Г.Ян); хәзерге заман драматурглары, рус һәм дөнья классиклары пьесалары буенча куелган спектакльләрдә характерлы рольләрне башкара: Малолеткова («Гүзәл кызлар», А.Д.Симуков), Катя Сорокина («Хәерле сәгатьтә!», В.С.Розов), Сашенька Лукина («Куркыныч сызыкта», В.А.Любимова), Оксана («Шәһәрдә таң ата», А.Н.Арбузов), Манефа («Акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский), Люба («Соңгылар», М.Горький). Актриса иҗатына ачык эмоциональлек, тамашачыда персонажлар тормышы б-н тирән кызыксыну уяту хас. Б. Казан Яшь тамашачылар театрының әйдәп баручы, аның иҗат йөзен билгеләүче актрисаларның берсе була. 1969–89 да Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында укыта.

*Әд.:* Б л а г о в Ю.А. Казанский театр юного зрителя: Очерк истории. К., 1986.

*Ю.А.Благов.*

**БЛИНО́В** Алексей Фёдорович (12.10.1930, БАССРның Караидел р-ны Байкы а.) нефтьче, техник фән. канд. (1963), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1979). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Бөтенсоюз нефть фәнни-тикшеренү ин-тында өлкән инженер, экспедиция башлыгы. 1956 елдан ТатНИПИнефтьтә: 1964–69 да нефть ятмаларын эшкәртүне проектлаштыру лаб. мөдире, 1972–75 тә респ-каның көнчыгышындагы нефть табу мәйданнарын эшкәртү секторы мөдире, 1975–81 дә Ромашкино нефть чыганагын, 1981–2000 дә нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү лабораторияләре мөдире. 1969–71 дә Алжирда эксперт, өлкән инженер булып эшли. Скважиналарда гидродинамик тикшеренүләр, Алжир (Хасси-Мессауд чыганагы), Әзәрбайҗан, Көнбатыш Себер һәм Татарстан нефть чыганакларын эшкәртүнең рациональ системаларын проектлаштыру һәм анализлау эшләре алып бара.

Х е з м.: Промысловые исследования скважин М., 1964 (автордаш); Исследование совместно эксплуатируемых пластов. М., 1971 (автордаш).

**БЛИНО́В** Леонид Павлович (20.6.1928, Башкортстан АССРның Караидел р-ны Байкы а. — 10.10.1998, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1976), проф. (1977), РСФСРның атказ. икътисадчысы (1982). ТРның атказ. фән эшлеклесе (1992). 1960 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1967 елдан шунда ук эшли: 1968–78 елларда икътисад ф-ты деканы, 1978–84 тә финанс каф. мөдире, 1984–93 тә фәнни эшләр буенча проректор, 1993 тән кафедрада профессор. Хезмәтләре а.х. пр-тиеләрендә капитал салудан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру чараларына һәм анализлауга, халык хуҗалыгына инвестицияләр кертүнең финанс-икътисади проблемаларына карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экономическая эффективность капитальных вложений в сельское хозяйство. К., 1967; Эффективность капитальных вложений и основных фондов в совхозах. К., 1973; Финансово-кредитные проблемы сельскохозяйственного производства. К., 1975; Финансовые рычаги и эффективность производства. К., 1982 (автордаш).

**БЛИНО́В** Лорэнс Иванович (4.9.1936, Казан), композитор, педагог, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). Казан консерваториясенең композиция классын (А.С.Леман классы) тәмамлый (1966). 1965 елдан Казан музыка мәктәпләрендә музыка теориясе һәм композиция укыта. Балалар өчен Б. оештырган композиторлык классларында Р.Ахиярова, И.Байтирәк, С.Беликов һ.б. шөгыльләнә. Поэтик әсәрләр һәм тәрҗемәләр, философиягә караган хезмәтләр авторы. Төп әсәрләре: өч симфония, кыллы квартет, орган өчен дүрт партит, камера-инструменталь һәм вокаль әсәрләр, драма спектакльләренә музыка.

*Әд.:* К а з а н с к а я Л. Лорэнс Блинов // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

**БЛИНО́ВА** Эльмира Гафур кызы (9.8.1955, Казан), язучы. Рус телендә яза. Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1979). 1980 елларда яза башлый. «Сабантуй» (1984), «Шәһәр агачлары» («Городские деревья», 1985) шигырь һәм «Зинһар өчен, игелекле булыгыз!» («Будьте добры, пожалуйста!», 1989) проза җыентыклары авторы. Б. әсәрләренең стиле гадилеге һәм нәфислеге, лирик тәэсир итүчәнлеге б-н аерылып тора. Балалар өчен язылган шигырьләренә эчкерсез юмор, баланың рухи дөньясына үтеп керергә омтылу хас. 1991 елдан Израильдә яши.

**«БЛОКНО́Т АГИТА́ТОРА»**, журнал, к. «*Офык*».

**«БЛОКНО́Т ПРОПАГАНДИ́СТА И АГИТА́ТОРА»**, журнал, к.«*Офык*».

**БЛОМ** Георгий Иванович (3.9.1918, Латвия, Ронненбург ш. — 3.6.2002, Түбән Новгород ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1979), РСФСРның атказ. геологы (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1941), «Волгогеология» АҖдә (Түбән Новгород ш., элекке Урта Идел экспедициясе) эшли, 1972–88 елларда баш геолог. Идел буе һәм Кама алды төбәкләренең мезозой һәм палеозой утырмаларының стратиграфиясе, палеографиясе һәм тектоникасы буенча танылган белгеч. Аның тарафыннан Урта Идел буе һәм Кама алдының геологик карталарын төзү, фосфоритлар, җир асты сулары, титан-цирконий чәчелмәләре һ.б. файдалы казылмаларны эзләү һәм разведка эшләре алып барыла. «Геология СССР» басмасы 11 нче томының бернчә бүлеге авторы һәм фәнни мөхәррире. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Каталог местонахождений фаунистических остатков в нижнетриасовых отложениях Среднего Поволжья и Прикамья. К., 1968; Нижний триас Русской платформы. К., 1969.

**БЛО́СФЕЛЬД** Георгий Иоакимович (1798, Курляндия, хәзерге Латвия, Якобштат ш., — 8.1.1884, Чехия, Теплица ш.), мәхкәмә медицинасы белгече, медицина д-ры (1820). 1820 елда Берлин ун-тын тәмамлый. 1820 елдан Курляндия мед. учреждениеләрендә, 1830 дан Рига хәрби госпиталендә эшли. 1839–65 тә Казан ун-тының мәхкәмә медицинасы, полиция медицинасы, мед. тарихы, гигиена һәм токсикология каф. мөдире һәм профессоры. Хезмәтләре мәхкәмә медицинасына, полиция медицинасына, мед. тарихына карый. Б. — Россиядә беренче мәхкәмә медицинасы дәреслеге авторы (1847).

Х е з м.: Начертание судебной медицины для правоведов, приспособленное к академическим преподаваниям в российских университетах. К., 1837; Судебная токсикология, особенно в техническом и моральном отношениях. К., 1856.

*Әд.:* Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**БЛОХИ́Н** Александр Сергеевич (31.3.1916, Казан — 10.6.1972, шунда ук), техник-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). Казан авиация техникумын тәмамлаганнан соң (1935), Казан авиация з-дында эшли: агрегат цехы башлыгы (1950 дән), производство башлыгы урынбасары (1968 дән). Дәүләт бүләге самолётлар җитештерүдә стапель һәм универсаль җайланмалар конструкцияләрен яңа технол. процесслар кулланып җыю өчен яңа ысул эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БЛУ́ДОРОВ** Александр Павлович (15.4.1902, С.-Петербург — 10.6.1975, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1966). Казан ун-тын тәмамлый (1931). Кызыл Армия сафларында хезмәт итә (1919–22). 1931–45 елларда Башгеолтрест һәм Татгеолтрест геол. партияләре башлыгы. Бер үк вакытта 1932–37 дә Казан ун-тында укыта. 1947 елдан ВНИИгеолнерудта гомуми геология бүлеген җитәкли. Б. файдалы казылмалар, төзелеш материаллары, янучан сланецлар, күмер һ.б. чыганакларның геологик һәм структур төзелеше карталарын төзү һәм разведкалау, ТАССР шәһәрләрен су б-н тәэмин итү, Кама плотинасы, Куйбышев гидроузелы өчен инженерлык-геологик тикшеренү эшләрен алып бара, Идел буеның девон ятмалары стратиграфиясен өйрәнә. Рус платформасының көнчыгыш өлешендәге сәнәгый ташкүмер ятмаларының контурын билгели һәм күмер чыганакларының запасын исәпли. Аның җитәкчелегендә Татарстан терр-ясендәге күмерне җир астында газлаштыру эшләре гамәлгә ашырыла. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Прикамский угленосный бассейн // Угольные месторождения СССР. М., 1947; Атлас палеозойских углей Татарии, Башкирии, Удмуртии и Куйбышевской области. М., 1961.

**БЛЮМШТЕ́ЙН** Зелиг Нисонович (6.11.1894, Вятка губ., хәзерге Удмурт Респ-касы Сарапул ш. — 19.10.1986, Казан), биохимик, биол. фән. д-ры (1937), проф. (1938), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Казан ун-тын тәмамлый (1924). Медицина (1924–30) һәм биология (1924–49, 1934 елдан биол. химия каф. профессоры) ф-тларында. 1930–61 елларда Казан мед. ин-тында. 1929 да Казан ГИДУВының үзәк лаб. каршында кан микрохирургиясе бүлеген оештыра. 1936 да Казан мед. ин-тында мөстәкыйль физик һәм коллоид (1954 тән ш.у. органик) химия кафедрасы һәм лаборатория оештыра, 1961 елга кадәр җитәкчелек итә. 1920 еллар ахырыннан Татарстанның бальнеология һәм курорт ресурсларын өйрәнә; Иж минераль чыганаклары һәм Бәкер күкертле ләмнәренең дәвалау-профилактик әһәмиятен исбатлый. Б.ның биологик объектларда йод микъдарын тикшерүгә багышланган хезмәтләре су һәм туфракта микроэлементлар составын өйрәнүгә нигез булып тора, ТР терр-ясендә кайбер авыруларның (эндемик зоб һ.б.) таралу төбәкләрен билгеләүгә ярдәм итә. Бер үк вакытта 1921–41 дә «Казанский медицинский журнал» редакциясендә эшли. 1925–48 дә «Учёные записки Казанского университета» ж-лында җаваплы сәркәтип. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Подземные воды Приказанского района по данным съёмки 1932 года. Опыт химической характеристики. К., 1932; Исследования Ижевских минеральных источников. К., 1938; Бакировские серные грязи. К., 1940; Краткий очерк бальнеографии Татарии // Тр. Казан. гос. мед. ин-та. 1945. Вып. 2; Курорты Татарии. К., 1970.

*Д.М.Зөбәеров.*

**БЛЮ́ХЕР** Василий Константинович (19.11.1889, Ярославль губ. Барщинка а. — 9.11.1938), хәрби җитәкче, Сов. Союзы маршалы (1935). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, кече унтер-офицер. 1915 елда каты яралганудан соң, хәрби хезмәттән азат ителә, Сормово суднолар төзү з-дында эшли. 1916 да Казанга килә, Остерманның механика остаханәсенә урнаша. Л.А.Смоляков (Раскин) җитәкләгән революцион түгәрәк һәм РСДРП әгъзасы. 1917 нең февраленнән Самара шәһәрендә 102 нче запас полкта; полк ком-тына һәм солдат депутатларның шәһәр советына, октябрьдә Самара шәһәренең хәрби-революцион ком-тына сайлана. 1917 нең август–сентябрендә Казанда була. Самара эшче һәм солдат депутатлары советы кушуы буенча, азык-төлек мәсьәләсен хәл итүдә катнаша. 1917 нең ноябрь ахырыннан — Уралда. 1918 нең мартыннан атаман А.И.Дутовның ак казаклар гаскәрен тар-мар итүдә катнашкан Көнчыгыш отрядны җитәкли. Август-сентябрьдә — Кызыл Армиянең Көнчыгыш фронты гаскәрләре б-н берләшү өчен Оренбург төбәгеннән Урал буйлап 1500 чакрым яу юлы узган Көньяк Урал партизан армиясе башкомандующие. 1920–21 дә Б. җитәкчелегендәге 51 нче укчы дивизия Каховка плацдармын саклауда һәм Перекопны штурмлауда батырлык күрсәтә. 1921–22 дә Ерак Көнчыгыш респ-касының Революцион халык армиясе хәрби министры һәм башкомандующие, Волочаев операциясенә җитәкчелек итә. Гражданнар сугышыннан соң 1 нче корпус командующие, Ленинградтагы ныгытылган район башлыгы. 1924–1927 дә Гуаньчжоуда Кытай революцион хөкүмәтенең баш хәрби киңәшчесе. 1927–29 да Украина хәрби округы гаскәрләре командующие ярдәмчесе. 1929 дан Кызыл Байраклы Аерым Ерак Көнчыгыш армиясе командующие. 1921–24 тә БҮБК әгъзасы, 1930–38 дә СССР ҮБК әгъзасы. 1934–38 дә ВКП(б) ҮК әгъзалыгына кандидат. 1937 дән СССР ЮС депутаты. Ике Георгий тәресе һәм Георгий медале, биш Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. Репрессияләр корбаны; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Статьи и речи. М., 1963.

*Әд.:* И о н е н к о И.М., Т а г и р о в И.Р. Блюхер в Казани. Новые документы о пребывании легендарного полководца в нашем городе (август-сентябрь 1917 г.) // Советская Татария. 1965. 27 янв.; Д у ш е н ь к и н В.В. От солдата до маршала. М., 1966; Н а ф и г о в Р., Л и т в и н А. Казанские большевики в 1914–17 гг. // Коммунист Татарии. 1966. № 10; Б л ю х е р Г. С Василием Константиновичем Блюхером — шесть лет // Воен.-ист. журнал. 1989. № 3.



В.К.Блюхер.

**БОБКО́В** Михаил Владимирович (26.12.1959, Яшел Үзән ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Яшел Үзән механика техникумын (1976), Мари политехника ин-тын (1986) тәмамлый. 1980 елдан «Серго исем. завод» җитештерү берләшмәсе» федераль унитар пр-тиесендә: инженер-конструктор, әйдәп баручы инженер-конструктор, бүлек башлыгы урынбасары, баш конструктор бүлегендә бюро башлыгы. Дәүләт бүләге донор канын һәм аның компонентларын югары сыйфатлы итеп саклау һәм куллануны тәэмин итә торган яңа буын суыту техникасын эшләгәне һәм мед. практикасына керткәне өчен бирелә.

**БОБОРЫ́КИН** Пётр Дмитриевич (15.8.1836, Түбән Новгород ш. — 12.8.1921, Италия, Лугано ш.), язучы, драматург, әдәби тәнкыйтьче. «Эшкуарлар» («Дельцы», 1872–73), «Кытай шәһәрчеге» («Китай-город», 1882), «Василий Тёркин» (1892) романнары, повестьлар, пьесалар, мемуарлар, мәкаләләр авторы. 1853 елда гимназия тәмамлый һәм Казан ун-тының юридик ф-тына укырга керә. А.М.Бутлеров, М.Я.Киттары лекцияләрен тыңлый, химия фәнен мавыгып өйрәнә. 1855 тә Дерпт ун-тының химия бүлегенә күчерелә. Беренче әдәби тәҗрибәләре гимназиядә укыган елларга туры килә. Казанда яшәгән чоры «Хәерле юлга!» («В путь-дорогу!», 1862–64) автобиографик романында — яшь кешенең үсү-формалашуы турында һәм «Ярты гасыр эчендә» («За полвека», 1906–13, «Русская мысль» ж-лында, соңыннан китап булып 1929 да басыла) дигән истәлекләрендә тәфсилләп сөйләнә. Б. әсәрләре детальләрнең төгәл тасвирлануы, тормыш-көнкүреш шартларының җентекләп сурәтләнүе б-н үзенчәлекле. Аларда Казан ун-ты укытучылары (Д.И.Мейер, Н.А.Иванов, А.М.Бутлеров, Е.Ф.Аристов), студентлар тормышы, спектакльләр кую, баллар һәм дворяннар җыелышлары турында бәян ителә.

Ә с ә р.: Избранные сочинения. М., 1982; Воспоминания: 2 томда. М., 1965.

*Әд.:* К р а с о в с к и й В. Проблемы натурализма в русской литературе и творчество П.Д.Боборыкина // Из истории русского реализма конца XIX — начала XX века. М., 1986.

*Л.Е.Бушканец.*

**БОБРО́В** Евгений Александрович (24.1.1867, Рига ш. — 12.3.1933, Ростов-Дон ш.), философ, әдәбият галиме, хакыйкый статский советник (1912). 1885–86 елларда Казан,

1886–89 да Юрьев (Дерпт) ун-тларында укый, тарих-филол. һәм филос. бүлекләрен тәмамлый. 1893–1903 тә Казан ун-тында, 1903–15 тә Варшава ун-тында укыта. 1917 елдан соң Ростов ун-тының атказ. профессоры. Хезмәтләре персонализм һәм панпсихизм идеяләрен таратуга һәм популярлаштыруга багышлана. «Тәнкыйди индивидуализм» дип исемләнгән үз филос. системасын эшли. Рус филос. гыйлеме тарихын өйрәнә, «Россиядә философия» («Философия в России», т.1–6, 1899–1902) дигән хезмәт яза. Б. — Д.В.Веневитинов, В.С.Печерин, А.И.Полежаев һ.б. турында биографик китаплар, ш.и. Казан язучылары һәм шагыйрьләре (Е.А.Боратынский, Г.П.Каменев) иҗатларына багышланган күпләгән хезмәтләр авторы. Б. күп еллар дәвамында Г.П.Каменев язмышын өйрәнү һәм иҗади мирасын барлау б-н шөгыльләнә, аның сайланма әсәрләренең академик басмасын әзерли (басылып чыкмый), шагыйрьнең архивын туплый. Үзе дә шигырьләр һәм автобиографик әсәрләр яза.

Х е з м.: Этические воззрения графа Л.Н.Толстого и философическая их критика. Юрьев, 1897; Философия и литература. К., 1898; Литература и просвещение в России XIX в.: В 4 т. К., 1901–02; Философские этюды: В 4 т. Варшава, 1911; История новой философии. Варшава, 1915; Пушкиниана. Ростов н/Д., 1919.

*Әд.:* Б е л я е в М. Работы Е.А.Боброва по истории русской литературы и просвещения // Изв. Северо-Кавказского гос. ун-та. 1928. Т. 3 (16); Л е п ё х и н М.П. Бобров Е.А. // Русские писатели 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1989. Т. 1; Ф и р с о в а Л.В. Бобров Е.А. // Русская философия: Словарь. М., 1995.

*Э.Н.Вәлиев.*

**БОБРОВИ́ЦКИЙ** Иосиф Ефимович (14.8.1904, Батуми ш. — ноябрь, 1986, Казан), график. Әзәрбайҗан югары сәнгать мәктәбен тәмамлый (1926). 1935 елдан Казанда яши. Бөек Ватан сугышында катнаша. Рәссамнар (1942) һәм Журналистлар (1962) берлекләре әгъзасы. 1945–53 елларда «Татрәссам» берләшмәсендә эшли. Көнкүреш, хәрби, халыкара темаларга карикатуралар, сәяси плакатлар, китап иллюстрацияләре һәм газета рәсемнәре авторы. Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан сәнгать фондында, «Сатира тәрәзәләре» («Окна сатиры») нәшриятында агитацион плакатлар чыгаруны оештыручыларның берсе (1941–43, 1945). Төп әсәрләре: «Вышка» г-тасы (Баку, 1929–35), «Чаян» ж-лы (1936–41; 1951–85) өчен сатирик рәсемнәр, «Ватан сугышы әлифбасы» китабына рәсемнәр (Н.Сокольский һәм А.Бендецкий б-н автордаш, 1941); станлы графика — «Прага. Иске шәһәр» (1945); «Казан сугыш көннәрендә» (1941–43); А.М.Горькийның «Егерме алты һәм берәү» («Двадцать шесть и одна», 1947), «Хуҗа» («Хозяин», 1948) хикәяләренә иллюстрацияләр; бизәү эшләре — Казандагы М.Горький әдәби-мемориаль музее һәм Ульянов шәһәрендәге төбәкне өйрәнү музее (1960 еллар), Алабуга шәһәрендәге И.И.Шишкин музей-йорты (1964) өчен экспозиция эскизлары, кору рәсемнәре. Казанны бәйрәмчә бизәү (1946–47), Политик мәгариф йорты вестибюле бизәлеше (Казан, 1960 еллар) проектлары һ.б. авторы. Халыкара («Сатира — тынычлык өчен көрәштә», 1969; 1973; 1974; 1977), бөтенсоюз («Журналист-рәссамнар күргәзмәсе», Мәскәү, 1975); төбәкара («Идел буе рәссамнары», 1943–45; 1947; «Зур Идел», 1967); республика (1942 дән) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТРның Милли музеенда һәм ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, М.Горький әдәби-мемориаль музеенда, Габрово шәһәренең сатира һәм юмор музеенда (Болгария), Әлмәт шәһәрендәге картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Е л ь к о в и ч Л.Я. Художники «Чаяна» (сатира). Л., 1960; Ф а й н б е р г А.Б. Политический плакат казанских художников. К., 1965; ш у л у к. Художники Татарии. Л., 1983.

*Г.А.Могильникова.*

**БОБРО́ВНИКОВ** Николай Алексеевич (1854, Казан — 1921, шунда ук), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе. Ориенталист-галим А.А.Бобровниковның улы, Н.И.Ильминскийның тәрбиягә алган улы. Казан ун-тын тәмамлый (1877). 1878 елдан Казан укытучылар семинариясендә (1891 дән директор), 1906–1912 елларда Оренбург уку-укыту округында попечитель. 1912 дә Халык мәгарифе министрлыгы күрсәтмәсе буенча Казакъстан һәм Урта Азиядәге мөселман уку йортларында укыту эшләренең куелышын өйрәнә. *Ильминский системасын* тормышка ашыруга ярдәм итә, либераль карашлар тарафдары була, миссионерлык практикасында полиция алымнарына каршы чыга. Б. җитәкчелегендә Казан губернасында гомуми башлангыч белем бирүгә күчү программасы эшләнә. 1919–21 дә Казан ун-тының Көнчыгышны өйрәнү комиссиясе рәисе. Хезмәтләре халык мәктәпләрендә математика укыту методикасына, гомуми дидактикага, халык мәгарифе, мөселман дини мәктәпләре проблемаларына карый.

Х е з м.: Что такое хороший урок. К., 1898; Инородческое население Казанской губернии. К., 1899; Итоги народного образования за 1900 год. К., 1901; Русско-туземные училища, мектебе и медресе Средней Азии. СПб., 1913.

*Әд.:* Х а н б и к о в Я.И. Русские педагоги Татарии и их роль в развитии просвещения и педагогической мысли татарского народа (из истории русско-татарских педагогических связей). К., 1968.


*Р.Р.Исхакова.*

**БОБРО́ВСКИЙ** Аркадий Аркадьевич (22.1.1896, Киров өлкәсенең хәзерге Свечинский р-ны Круглыжский а. — 1973, Казан), урманчылык белгече, а.х. фән. канд. (1954), ТАССРның атказ. урманчысы (1968). 1925 елда Казан а.х. һәм урманчылык ин-тын тәмамлый. 1926–29 да өлкә урман энтомологы, өлкән урман инспекторы, 1929–31 дә Төньяк-Көнчыгыш урманнарның (Казан) энтомологик партиясе мөдире, 1931–37 дә СССР Урман хуҗалыгы халык комис-ты Баш урман саклау идарәсенең Урта Идел үсемлекләрне саклау станциясенең урман фәнни-тикшеренү төркеме җитәкчесе; 1937–41 дә Татарстан урман хуҗалыгы идарәсендә өлкән инженер — урман патологиясе белгече. 1946–60 та Татарстан урман тәҗрибә станциясе директоры; бер үк вакытта 1946–52 дә Раифа тәҗрибә урман хуҗалыгы директоры, 1949–53 тә Казан а.х. ин-ты укытучысы. Хезмәтләре нарат агачларын корткычлардан саклаганда инсектицидлар куллануга, кыр ышыклау урман полосаларындагы зарарлы бөҗәкләр һәм гөмбә авыруларын өйрәнүгә, урманнарны корткычлардан саклау чаралары системасын эшләүгә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**БОБЫЛЬЛӘ́Р**, 15 йөз — 18 йөз башларында Россиядә халыкның феодалларга буйсынган катлавы (халык телендә — фәкыйрь, ялгызак, йорт-җирсез кешеләр). «Б.» төшенчәсе беренче мәртәбә Псков елъязмасында очрый (1500). 16 йөздән Б.нең авылларда хосусый игенчелек, шәһәрләрдә һөнәрчелек, сәүдә итү б-н шөгыльләнүләре яки ялланып эшләүләре мәгълүм. 1599 елгы елъязмаларда — ясак түләмәүчеләр, 1621 елдан сөрү җирләрен эшкәртмәүчеләр Б. дип аталган. Б. бер авыл җәмәгатеннән икенчесенә ирекле күчү хокукына ия булган. Җирләрен эшкәртмәгән Б. төрле кәсеп-һөнәр үзләштергән, бер өлеше бистә-калаларда яшәгән. Крәстияннәр б-н чагыштырганда Б. оброкны ешрак түләгән. Араларында мал-мөлкәтле Б. дә булган. 1680 нән соң Б.гә урыннан урынга күчеп йөрү мөмкинлеге бетерелә, 1724 тән җан башыннан салым түләү кертелү б-н алар крәстияннәргә тиңләштерелә.

Казан төбәгендә 16 йөз ахырыннан Б. ясаклылар, патша сарае һәм монастырь крәстияннәре буларак телгә алына. Баштарак Рус дәү-





И.Е.Бобровицкий. 1. Карикатура «Убыр кош (АКШ бюджеты)». Акварель, тушь. 1960 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Ялкаулар! Әле дә клубны төзеп бетермәгәнсез! Кышын тавыкларны кая куярга тиеш мин?». Акварель, тушь. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

ләтенең үзәк төбәкләреннән фәкыйрьлеккә төшеп күчеп килгән рус крәстияннәре салым түләүдән өлешчә яисә тулысынча азат ителгән. Б. саны бөлгенлеккә төшкән җирле халыклар исәбенә арта барган. Б.нең сөрү җирләрен, болыннарны, печәнлекләрне, урманнарны арендага алу очраклары билгеләп үтелә. 16 йөз ахыры — 17 йөзнең 1 нче чирегендә сарай крәстияннәре арасында Б. саны 15% чамасы тәшкил иткән. 1685–87 елларда хосусый милекчеләр арасында Б. — 10,5%, сарай кешеләре арасында 18% тәшкил иткән, крәстияннәрдә 68% тан да артып киткән. Бобыльләр йортында уртача 2,1 кеше яшәгән. 1646 елгы писцовый кенәгә мәгълүматлары буенча, Казанда 357 бобыль йорты булган. Бистәләрдә яшәүче 95 татар да Б. буларак теркәлгән. Б. катлавына керүчеләр саны төбәктәге гомуми халык санының 15% ыннан артмаган. Социаль-икътисади хәлләре буенча Б. *типтәрләргә* якынрак торган.

*Әд.:* Сербина К.Н. К вопросу о бобылях // Акад. Б.Д.Грекову ко дню семидесятилетия: Сб. статей. М., 1952; Греков Б.Д. Крестьяне на Руси. М., 1954; Т. 2.; Шапиро А.Л. Эволюция бобыльства в России в XVIII в. // Ежегодник по аграрной истории Вост. Европы. М., 1958; Ермолаев И.П., Липаков Е.В. Крестьяне дворцовых сёл Казанского уезда в конце XVI — первой четверти XVII века. (По материалам дозорных и переписных книг) // Исследования по истории крестьянства Татарии дооктябрьского периода. К., 1984.

*Л.М.Айнетдинова.*

**«БОГАДЫ́»**, Актаныш р-нындагы авыл хуҗалыгы кооперативлары берләшмәсе. 1953 һәм 1960 елларда «К.Маркс», «Электро», С.М.Киров исем., «Каенлык», «Эшче», «Ленинский прилив», «Яңалиф» к-зларын берләштерү юлы б-н төзелгән «Коммунизмга» к-зын кабат үзгәртү нәтиҗәсендә 1994 елда оештырыла. 2001 дә «Б.» составына 432 шәхси хуҗалыгы булган 6 авыл керә, 1097 кеше яши, ш.и. 300 кеше хуҗалыкта эшли. Үзәк утары — Иске Богады авылы. А.х. җирләренең мәйданы — 6731 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 6136 *га*, печәнлек — 75 *га*, көтүлек — 520 *га*. Җитештерүнең төп тармаклары — игенчелек, мөгезле эре терлекчелек һәм дуңгызчылык. 1970 еллардан башлап «Б.» бөртекле ашлык культураларыннан югары уңыш үстерә: 1982 дә — 1 *га* дан 31,1 *ц*, 1994–97 дә — 34,3, 2000 дә — 40,4, 2001 дә 64,4 *ц* уңыш алына.

Агросәнәгать комплексы пр-тиеләрен үзгәртеп кору елларында «Б.» а.х. продукциясе җитештерү дәрәҗәсенең кимүенә юл куймый. 1999 да 1554 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 570 баш сыер), 910 дуңгыз, 70 баш сарык исәпләнә. А.х. җирләренең 100 *га* исәбенә 30 *ц* ит, 224 *ц* сөт җитештерелә. 1 савым сыердан 2645 *кг* сөт алына. «Б.» «Татарстан элиталы орлыклар» ассоциациясенә керә һәм орлыкчылык хуҗалыгы санала, районның бүтән хуҗалыклары өчен бөртекле культураларның элиталы һәм югары уңыш бирә торган орлыкларын үстерә.

Җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен «Б.» га өч тапкыр КПСС ҮКнең, СССР ЮС Президиумы, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКнең күчмә Кызыл Байрагы бирелә (1975, 1977, 1978), Бөтенсоюз Мактау тактасына кертелә (1978); 4 тапкыр СССР ВДНХсы дипломнары б-н бүләкләнә. «Б.» берләшмәсендә а.х. тармакларын алып баруда алдынгы технологияләр куллану буенча республика семинарлары уздырыла. Намуслы хезмәтләре өчен 18 кеше орден һәм медальләр б-н бүләкләнә, 6 кешегә ТР һәм РФнең атказ. а.-х. хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә. Авыллар төзекләндерелә, һәр йортка газ кертелә, кирәкле социаль-көнкүреш объектлары б-н тәэмин ителә. 17 ел дәвамында (1969–86) хуҗалык б-н К.Г.*Гарипов*, 1990 елдан ТРның атказ. а.х. хезмәткәре И.М.Мирзаянов җитәкчелек итә. 2002 дә «Б.» җирлегендә а.х. җитештерү кооперативы оештырыла.

**БОГА́ТЫЙ КЛЮЧ** (Байчишмә) авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 25 *км* көньяктарак, Сола елгасы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (чуашлар) саны 10 нан ким. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантонына керә; 1930 елның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1926 да — 31, 1938 дә — 108, 1949 да — 150, 1958 дә — 107, 1970 тә — 114, 1979 да — 67, 1989 да — 10 кеше.

**БОГАТЫРЁВ** Василий Семёнович (ноябрь 1871, Тверь губ. Максимовка а. — 28.1.1941, Ленинград), сынчы, педагог. Б.ның сәләтен сынчы М.М.Антокольский күреп ала, аның үтенече б-н Б. СА каршындагы Югары сәнгать уч-щесенә кабул ителә (1893), аны В.А.Бикләмишев остаханәсе буенча чит илгә пенсионерлык командировкасы алу (1900–02) хокукы б-н тәмамлый (1899). «Әкият» сыны өчен сынчы рәссам дәрәҗәсе ала. Сынчы М.Я.Харламов б-н берлектә С.-Петербург Этнография музее өчен «Россия халыклары» фризын иҗат итә (1902–08). 1909–26 елларда Казан сәнгать мәктәбенең скульптура бүлеген җитәкли. 1919 елдан Казан архит-ра-сәнгать остаханәләре коллегиясе әгъзасы, 1924 тән уку-укыту бүлеге мөдире. ТатАХРР әгъзасы (1923), Казанда монументаль сәнгатьне пропагандалау планын тормышка ашыруда катнаша: Александр II һәйкәле пьедесталына вакытлыча урнаштырылган «Металл коючы» (1921, 1 Май мәйданында), М.Вахитов (элеккеге Юнысов мәйданында) һәйкәлләре, «Иоанн Креститель» (1897), «Автопортрет» (1900), «Катенька портреты» (1912), «Римский-Корсаков портреты» (1912), «Л.Н.Толстой портреты» (1913), «Н.И.Фешин портреты» (1913), «Байракны тартып алу», «Әсирләр» (1914), «Бүре» (1915), «Шахтада» (1920 еллар), «П.И.Чайковский бюсты» (1920), «В.И.Ленин портреты» (1924) һ.б. әсәрләр авторы. 1926 дан Б. Ленинградта яши, 1934 тән И.Е.Репин исем. нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тында укыта. Б.ның иҗади һәм



В.С.Богатырёв. «Н.И.Фешин портреты». Гипс. 1913. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

педагогик эшчәнлеге Татарстанда сынлы сәнгатьнең формалашуына һәм үсешенә, респ-када һәм аннан читтә сынчы рәссамнар әзерләүгә сизелерлек йогынты ясый. Күренекле сынчылар О.В.Арбузова, Г.А.*Козлов*, К.*Зале*, В.В.*Кудряшов* һ.б. — Б. шәкертләре. 1897 дән СА, Күчмә сәнгать күргәзмәләре ширкәте, җирле һ.б. шәһәрләр рәссамнарының даими күргәзмәләрендә, Казанда уздырылган Беренче һәм Икенче дәүләт күргәзмәләрендә, Ленинградта уздырылган «Юбилей күргәзмәсе»ндә (1917–27) һ.б. катнаша.

Б. әсәрләре СА музеенда (С.-Петербург), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана. Н.И.Фешин тарафыннан Б.ның портреты эшләнә. 3 нче дәрәҗә Изге Станислав, 3 нче дәрәҗә Изге Анна орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Ключевская Е.П. Из истории скульптурного отде-





В.С.Богатырёв. 1. Казанның элекке 1 Май мәйданындагы «Металлчы эшче» һәйкәле. Гипс. 1921; 2. Казанның элекке Юнысов мәйданындагы М. Вахитов һәйкәле (арх. Д. Фёдоров). Гипс. 1922.



Е.Б. Богачёв.

ления Казанской художественной школы // Вопр. худож. образования. Л., 1985. Вып. XXXIX.

*Е.П.Ключевская.*

**БОГАТЫРЁВ** Сергей Георгиевич (6.9.1929, Киров өлкәсенең Уржум р-ны Богатыри а. — 18.9.1995, Яшел Үзән р-нының Бело-Безводный а.), химик-технолог, В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесендә ген. директор (1975–94), техник фән. канд. (1980). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1954). 1954–95 елларда (бүлениеп) В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесендә: мастер, остаханә башлыгы, директор (1967–75), консультант. Аның җитәкчелегендә пр-тиедә яңа эшләнмәләр булдырыла, күп кенә техн. процесслар камилләштерелә. Б. энергетик матдәләр алуның яңа технологияләрен һәм шулар нигезендә оборона сәнәгате өчен яңа төр әйберләр эшләүдә катнаша. 1960–61 дә В.И.Ленин исем. химия з-ды партоешма секретаре, 1961–66 да КПССның Казан шәһәре Киров райкомының 1 нче секретаре, 1966–67 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире. 1966–71 дә ТАССР ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1976, 1991). Ленин, Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ-КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БОГАЧЁВ** Евгений Борисович (25.8.1941, Курск өлкәсенең Суджа р-ны Яңа Ивановка а.), ТР Милли банкы рәисе (1993 тән), икътисад фән. д-ры (1998), РСФСРның атказ. халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре (1984), ТРның атказ. икътисадчысы (1999). Казан авиация (1965) һәм Казан финанс-икътисад (1975) ин-тларын тәмамлый. 1964–70 елларда Казан «Экран» җитештерү берләшмәсендә эшли, 1968 дән директор. 1970–85 тә ТРның халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министры урынбасары, 1985–93 тә министр. Ул җитәкләгән елларда министрлык көнкүреш хезмәте күрсәтүдәге үсешне ел саен 12–15% ка арттыра. 1980–90 елларда республикада 35 яңа көнкүреш хезмәте күрсәтү объекты файдалануга тапшырыла. Гомуми күрсәткечләр буенча Татарстан РСФСРда 1984 тәге 56 нчы урыннан 1990 да 13 нче урынга күчә. Б. Милли банкның һәм аның карамагындагы тармак учреждениеләренең матди-техник базасын дөнья стандартына туры килерлек итеп үстерүгә һәм техник яктан җиһазландыруга зур игътибар бирә. Хезмәтләре банк системасын камилләштерү проблемаларына карый. 1985–89 да — ТАССР ЮС, 1990–93 тә РФ ЮС депутаты. УНИКС баскетбол клубы президенты (1998 елдан). «Почёт билгесе», «Дуслык» һ.б. орденнар б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проблемы совершенствования банковской системы и ее информационное обеспечение. М., 1998.

*Әд.:* Банк на все времена. Берлин, 1997; Ф а з у л л и н а Г. Совместный проект. Татарстан // Эксперт. 1998. № 11.

**БОГДА́НОВ** Алексей Петрович (28.10.1923, Саратов өлкәсенең Төрекләр а.) химик, химия фән. д-ры (1976), проф. (1979), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1990). 1952 дә Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. 1975–90 да пластмасса эшкәртү технологиясе каф. мөдире, технол. ф-ты деканы (1968–71), полимерлар ф-ты деканы (1971–82). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмаларны модификацияләү һәм пластификацияләүгә карый. Алыштырылулы дикарбон кислоталар нигезендә полиэфир сумалалар хасил булуның кинетик законченлыкларын тикшерә. Дикарбон кислоталарның алыштырылган ясалмалары, ш.и. пластификаторларның бинар катнашмалары б-н, поливинилхлорид, целлюлоза триацетаты, целлюлоза нитратлары һ.б. уртача нык чылбырлы полимерларны пластификацияләү процессларын өйрәнә. Технологик һәм файдалану үзлекләрен яхшырту максатында полиэтилен, эпоксиуретаннар һәм эпоксид сумалаларын полиизоцианатлар һ.б. кушылмалар б-н модификацияли. Полиэтилен һәм эпоксиуретаннарның күп кенә үзгәртелгән композицияләрен эшли, аларның кайберләре адгезион (ябышучан) капламнар сыйфатында җитештерүгә кертелә. Аның хезмәтләре нигезендә олигоэпоксиуретан б-н пластификацияләнгән целлюлоза триацетатыннан ясалган кино һәм фото плёнкаларының тәҗрибә партиясе чыгарыла. Бөек Ватан сугышында катнаша, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз һәм «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые физические свойства поливинилхлоридных плёнок в зависимости от длины радикалов пластификаторов // Высокомолекулярные соединения. 1968. Т. 10, № 6 (автордаш); Некоторые вопросы модификации ацетобутирата целлюлозы алкоксинитрофталатами // Изв. вузов. Химия и химическая технология. 1978. Т. 21, № 8 (автордаш); Полимерные композиционные материалы: Учеб. пособие. К., 1980 (автордаш); Физико-химические и механические свойства полимеров: Учеб. пособие. К., 1990 (автордаш).

*Әд.:* У р а з а е в Г. Всегда на передовой // Кировец. 1975. № 1–2; Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БОГДА́НОВ** Зәкуан Сафа улы (1.10.1891, Уфа губ., Бәләбәй өязе Имай-Карамалы а. — 22.2.1956, Казан), җир төзүче, геодезист. Уфа җир эшләре уч-щесен (1914), Омск а.х. һәм сәнәгать ин-тын (1922), Казан а.х. һәм урманчылык ин-тын (1924) тәмамлый. 1915–30 елларда Уфа, Омск, Казан махсус урта уку йортларында укыта (1925 тән). 1926 дан Казан урман технологиясе ин-тында эшли, 1930 дан — Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тының геодезия каф. доценты, мөдире. 1941 дән Казан ун-тында, бер үк вакытта Казан пед. ин-тында, 1946 дан Казан нефть сәнәгате инженер-төзүчеләр ин-тының геодезия каф. мөдире. Берничә тапкыр ф-т деканы итеп сайлана. Техникум һәм вузлар өчен геодезия буенча татар телендә беренче дәреслек, җир төзелеше, геодезия буенча терминологик сүзлекләр, методик кулланмалар авторы. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Geodezia. К., 1935. Ч. 1; Научные геодезические термины. К., 1935; Методы разбивки гражданских сооружений. К., 1953; Сравнительный анализ ошибок нивелирования. К., 1953.

**БОГДА́НОВ** Модест Николаевич (7.9.1841, Сембер губ., Сызрань өязе Рус Бекшанкасы а. — 16.3.1888, С.-Петербург), орнитолог, зоогеограф. Казан ун-тын тәмамлый (1866). Зоология каф. каршында профессорлар Э.А.Эверсман һәм Н.П.Вагнер җитәкчелегендә умырткалылар зоологиясе б-н шөгыльләнә. «Идел буеның кара туфраклы полосасында Урта һәм Түбән Идел үзәнендәге кошлар һәм җәнлекләр» («Птицы и звери чернозёмной полосы Поволжья и долины Средней и Нижней Волги» (СПб., 1871) исемле хезмәте өчен зоология магистры дигән гыйльми дәрәҗә бирелә. Казан ун-ты каршындагы Табигатьне өйрәнүчеләр җәмгыятенә (1869) нигез салучыларның берсе, аның сәркәтибе һәм казначее. 1872 елдан Петербург ун-тында. Хива фәнни экспедициясендә (1873) катнаша. Амударья елгасында балыкчылык промыселы оештыруны тәкъдим итә, Урта Азия далаларында ит өчен терлекчелек һәм атларны көтүдә йөртеп асрауның файдалы булуын күрсәтә. Мурманск яр буеның, Идел буе, Кавказ, Арал-Каспий төбәкләренең фаунасын өйрәнә. Эволюцион зоогеографиягә нигез салучыларның һәм Россиядә популяр зоология әдәбиятын башлап җибәрүчеләрнең берсе. Кешеләр б-н бергә яшәүче хайваннар турында «Дөньяви сорыкортлар» («Мирские захребетники» (СПб., 1923) китабы авторы.

Х е з м.: Птицы Кавказа. СПб., 1879; Сорокопуты русской фауны и их сородичи // Зап. Имп. АН. 1881. Т. 39, № 1; Очерки природы Хивинского оазиса и пустыни Кызыл-Кум. Таш., 1882; Из жизни русской природы. М., 1960; Перечень птиц Российской империи. СПб., 1884. Вып. 1.

*Әд.:* Критико-биографический словарь русских писателей и учёных. СПб., 1895. Т. 4; Б а н и н а Н.Н., К о в а н ь к о Г.Н. Модест Николаевич Богданов. Л., 1972.

**БОГДАНО́ВИЧ** Үзбәк Якуб улы (17.7.1921, Чистай ш.), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1971), проф. (1971), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1975, 1980). 1952 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, ТР ФАнең «Савыктыру травматологиясе һәм ортопедиясе» фәнни-тикшеренү үзәгендә эшли, 1960–87 елларда директор, 1987–97 дә профессор-консультант. Бер үк вакытта (1962–87) ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында баш травматолог-ортопед. Б. җитәкчелегендә донор канын саклау өчен сөяк тукымасын әзерләү һәм консервацияләү лабораторияләре оештырыла; зарарланган һәм авырткан кул чукларын дәвалау,

реанимация һәм анестезиология бүлекләре, лазер б-н дәвалау кабинеты ачыла, яңа дәвалау корпусы төзелә. Тикшеренүләре имгәнүләрне булдырмауга, сынган сөякләрне хирургик дәвалауга, травматология һәм ортопедиядә ТМР, лазер куллануга, мед. тарихына багышлана. Б. умырткасы зарарланган авыруларны дәвалау өчен тарттыру пластинасы, бот сөяге сынганда металл стержень куюны тәкъдим итә. Тумыштан килгән ялган буыннарны дәвалау методикасын эшли (1963). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лечение переломов с применением антихолинэстеразных препаратов. К., 1969; Организация специализированной травматолого-ортопедической помощи населению СССР // Казан. мед. журн. 1979. № 3.

*Әд.:* У.Я.Богданович (К 50-летию со дня рождения) // Ортопедия, травматология и протезирование. 1971. № 9.

**БОГДАНО́ВИЧ** Якуб Сөләйман улы (1883, Гродно ш. — 2.11.1937, Мәскәү), педагог. Белорус татарларыннан, 1905 елда Петербург ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый, 1917 гә кадәр Гродно шәһәре урта уку йортларында укыта. 1917 дән Симферополь шәһәрендә Татар укытучылар семинариясендә, 1922 дән Мәскәүдә милли мәктәпләр инспекторы, 1924 тән Симферополь шәһәре мәктәпләрендә, 1926 дан Казанда махсус урта уку йортларында укыта, 1931 дән Казан мед. ин-тының рус теле каф. мөдире. 1937 елның 23 апрелендә «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы*» эше буенча кулга алына. Татар мәктәпләрендә рус теле укыту методикасы буенча хезмәтләр, уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Методика обучения рус. языку в татар. и башк. школе. К., 1930; Красная звезда: Рабочая книга по рус. языку в 4 года обучения татар и башк. школ 1 ступени. К., 1932. Ч. 1–2.

**БОГДА́ШКИНО** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2002 елда 358 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1683 елдан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе, 7 җил һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, йон тетү йорты, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1832,6 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Пролей-Каша волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 88 ир заты; 1859 да — 638, 1897 дә — 1198, 1908 дә — 1546, 1920 дә — 1571, 1926 да — 1289, 1938 дә — 1130, 1949 да — 894, 1958 дә — 870, 1970 тә — 768, 1979 да — 587, 1989 да — 391 кеше. Авыл янында *Богдашкино шәһәрлеге* урыны саклана.

**БОГДА́ШКИНО ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, археологик истәлек. Тәтеш р-ны Богдашкино авылы янында 10–13 йөзләрдәге болгарлар шәһәре калдыклары саклана. 1909 елда Г.Н.Әхмәров тарафыннан ачыла, беренче тапкыр 1949–50 елларда — Н.Ф.Калинин, 1954 тә — Т.А.Хлебникова, 1980 елларда И.Л.Измайлов тарафыннан тикшерелә. Мәйданы 77 *га.* Б.ш. 2 биек ур һәм 3 тирән чокыр б-н ныгытылган эчке шәһәрдән һәм тәбәнәгрәк ур һәм 2 рәт чокыр б-н әйләндереп алынган тышкы шәһәрдән гыйбарәт. Шәһәрлек мәйданында 10 йөзгә нисбәтле мәҗүсиләр каберлеге урнашуы аның әүвәлге болгарлар чорында барлыкка килүен күрсәтә. Б.ш. археол. комплексында кулдан әвәләнгән һәм яндырып эшләнгән чүлмәк ватыклары, сугыш һәм эш кораллары, бизәнү әйберләре һ.б. табыла. Торак йортлар, һөнәрчелек әйберләре калдыклары (чүлмәк, тимердән эшләнгән әйберләр), 11–13 йөзләргә нисбәтле мөселман каберлекләре сакланып калган. Шәһәр 13 йөз урталарына кадәр җимерелгән дип фаразлана. Тикшеренүчеләр Б.ш.н елъязмадагы Ашлы (Ошель) каласы б-н бәйлиләр.

*Әд.:* К а л и н и н Н.Ф., Х а л и к о в А.Х. Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. // Тр. Казан. филиала АН СССР. К., 1954; К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

*И.Л.Измайлов.*

**БО́ГОВ** Андрей Алексеевич (1.5.1958, Бөгелмә ш.), микрохирург, мед. фән. д-ры (1998). 1981 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1988 елдан «Савыктыру травматологиясе һәм ортопедиясе» фәнни-тикшеренү үзәгендә, 1998 дән пластик һәм реконструктив микрохирургия бүлеге мөдире. Б., беренче булып, төзәтелмәслек дәрәҗәдә зарарланган өске очлыклар реабилитациясендә скелет мускулларын микрохирургик аутотрансплантацияләү мөмкинлекләрен өйрәнә. Тикшеренүләре периферик нерв системасы имгәнүгә, очлыкларга реконструктив хирургия үткәргәндә тукымаларны микрохирургик аутотрансплантацияләүгә һәм Г.А.Илизаров аппаратын куллануга карый. Клиника практикасына периферия нервларын озынайту ысулын кертә. 1983 тә Казанда беренче тапкыр Б. тарафыннан бармаклар һәм очлыклар сегментларының яраксыз имплантатларын алыштыру микрохирургиясе гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Микрохирургия в лечении необратимых повреждений верхних конечностей, применение метода микрохирургии и аппарата Г.А.Илизарова. М., 1997; Лечение методом дистракции повреждений периферических нервов предплечья // Казан. мед. журн. 1997. Т. 78 (автордаш).

**БОГОДА́РОВКА** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 36 *км* көньяктарак, Ык елгасыннан 3 *км* ераклыкта. 2002 елда 80 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 19 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Богодаровка һәм Укумень (якын тирәдәге күл һәм сазлык исемнәреннән алынган) атамалары б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, арба ясау б-н шөгыльләнә, алпавыт Чичериннарга а.х. эшләренә яллана. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 195 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында Б.да «Красный пахарь» к-зы оештырыла, 1957 дә «Урожайный» с-зы составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостена карый. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1858 дә — 340, 1870 тә — 397, 1884 тә — 424, 1913 тә — 518, 1922 дә — 480, 1926 да — 364, 1938 дә — 382, 1959 да — 289, 1970 тә — 257, 1979 да — 161, 1989 да — 82 кеше.

**БОГОЛЮ́БОВ** Алексей Николаевич (8.3.1874, Казан — ?), тел галиме. Казан ун-тын тәмамлый (1907). 1913–21 елларда шунда ук эшли (1918 дән профессор). Б. әдәби телләрне утилитар-практик, филологик һәм лингвистик аспектлардан чыгып өйрәнүне методологик яктан дәлилли; телне теоретик-методологик яктан тикшерү зарурлыгын күрсәтә, коллектив фикер коралы һәм социальләштерү чарасы буларак, сөйләмне анализлауга нигезләнгән лингвистик система тәкъдим итә. Хезмәтләре рус телен укыту методикасына карый.

Х е з м.: О частях речи: К лингвистической методологии. К., 1913; Об изучении литературных языков. Методологический очерк. К., 1914.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**БОГОЛЮ́БОВ** Алексей Петрович (16.3.1824, Новгород губ., хәзерге Ленинград өлкәсе Померанье а. — 7.11.1896, Париж, С.-Петербургта җирләнгән), диңгезче офицер, рәссам, җәмәгать эшлеклесе, Сынлы сәнгать академигы (1858). А.Н.Радищевның оныгы. Диңгезче кадетлар корпусын тәмамлый (1840), флотта хезмәт итә. 1853 тә Баш диңгез штабы рәссамы сыйфатында хәрби хезмәттән азат ителә. Петербург СА педагоглары М.Н.Воробьев һәм Б.П.Виллевальдедә белем ала (1850–53). СА пенсионеры (1854–60), СА профессоры (1861). Рус хәрби диңгез флотының 18–19 йөзләрдәге җиңүләренә багышлап, зур тарихи-сәнгати әһәмияткә ия булган әсәрләр иҗат итә. Европа сәнгатендә 19 йөзнең 2 нче яртысында формалашкан реалистик пленэр пейзаж принципларын үстерә. 1861, 1863, 1866, 1869 елларда патша тәхете варислары даирәсендә Идел һәм Кама буйлап Чистай шәһәренә кадәр сәяхәтләрдә катнаша. Абыйсы Н.П.Боголюбов тарафыннан төзелгән «Идел Тверьдән Әстерханга кадәр» («Волга от Твери до Астрахани», (СПб., 1862) дип аталган юлкүрсәткечкә иллюстрацияләр ясый, Мәскәү коллекционеры В.А.Кокорев заказы б-н Идел буе шәһәрләре күренешләре чагылган берничә картина, ш.и. «Казан күренеше» (1861), «Казансу ташыганда» (1862) әсәрләрен яза, ш.у. сәфәр вакытында «Варисның Россия буйлап сәяхәте альбомы» өчен берничә йөз данә рәсем, ш.и. Казан губернасы чикләрендә Идел һәм Кама елгалары күренешләрен чагылдырган рәсемнәр ясый. 18–19 йөзләрдә рус сәнгатендә формалашкан Идел-Кама пейзажлары иконографиясен шактый баета. 1873 тән күбесенчә Франциядә яши. Венада (1873), Парижда





А.П. Б о г о л ю б о в. 1. «Казан күренеше». 1861; 2. «Казанның ташу вакытында Бишбалта бистәсе ягыннан күренеше». 1861. Рус музее.

(1878) узган бөтендөнья күргәзмәләренең рус сәнгате бүлеге комиссары һәм жюри әгъзасы. Рус рәссамнарының Парижда Үзара ярдәмләшү җәмгыятен оештыруда (1878) башлап йөри һәм әлеге җәмгыятьнең рәисе була. Сәнгать академиясен демократик һәм реалистик принципларда үзгәртеп коруда, Күчмә сәнгать күргәзмәләре ширкәте эшчәнлегендә хәлиткеч роль уйный (1873 тән әгъза). Саратов шәһәрендә сәнгать музеена (1885) һәм сәнгать уч-щесенә (1897) нигез салучы. Б.ның портретлары М.А.Чижов, И.Е.Репин, И.Н.Крамской, Л.А.Бернштам, А.О.Шарлемань, В.В.Матэ тарафыннан языла.

Б. әсәрләре Третьяков галереясында, Рус музеенда, Үзәк хәрби-диңгез музеенда, ш.у. Россиянең һәм якын чит илләрнең 40 тан артык сәнгать музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм ТР Милли музеенда саклана. Данеброк кавалерлык ордены (Дания, 1867), «Франц-Иосиф йолдызы» ордены (Австрия, 1873), Шәрәфле легион орденының командор хачы (Франция, 1878) б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Воспоминания. СПб., 1895; Записки моряка-художника. Саратов, 1996.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; О г а р ё в а Н.А. Летопись жизни и деятельности художника А.П.Боголюбова. Саратов, 1988.

*Е.П.Ключевская.*

**БОГОЛЮ́БОВ** Аркадий Михайлович (1875, Самара губ., Никольск өязе Улика а. — 1952, Тәтеш ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1937), РСФСРның атказ. табибе (1940). 1899 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. 1899 дан Казан губернасы Краснококшай өязе пыяла ф-касында сәламәтлек саклау пункты табибе, 1902 дән земство табибе, 1919 дан район хастаханәсе (Тәтеш ш.) баш табибе. Тикшеренүләре трахоманы дәвалауга һәм аны булдырмауга, хирургия практикасындагы катлаулы очракларга карый. Татарстанның Социалистик төзелеш батыры (1934). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Тәтеш шәһәрендәге бер урам аның исемен йөртә.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**БОГОЛЮ́БОВ** Виктор Леонидович (7.4.1874, Казан — 7.3.1935, Мәскәү, Казанда җирләнгән) хирург, медицина д-ры (1904), проф. (1911). Проф. В.И.Разумовский шәкерте. 1898 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук ф-т хирургиясе кафедрасында, 1911–13 тә Саратов ун-тының гомуми хирургия кафедрасында, 1913–35 тә Казан ун-тында эшли, 1913 тән топографик анатомия һәм оператив хирургия, 1917–27 дә гомуми хирургия, 1927 дән госпиталь хирургиясе каф. мөдире, бер үк вакытта 1923–35 тә Казан ГИДУВының гомуми хирургия каф. мөдире. 1920 дә 1 нче шәһәр хастаханәсенең хирургия бүлеге җирлегендә пропедевтик хирургия клиникасы оештыра. Тикшеренүләре пластик хирургиягә карый. Минең зарарланган урынына май тукымасын күчереп утырту өчен — орхиодопексия, карындагы туры мускуллар аерылганда корсакка батырылган җөй салып, аларны үз хәленә кайтару-савыктыру ысулларын тәкъдим итә. Ампутация вакытында кул-аякның гәүдәдә калган өлешен каплау өчен сөяк тукымасы, касык каналын ямау өчен тире, гастропексия, нефропексия һ.б. куллана. Хезмәтләре гомуми хирургиягә, күкрәк бизләре, ашказаны асты бизләре, йөрәк һәм йөрәк яны капчыгы авыруларын дәвалауга карый. Гомуми хирургия буенча дәреслек авторы (1923).

Х е з м.: Общая хирургия. К., 1923. Т. 1; Личность врача в медицине. К., 1928; О преподавании хирургии в высшей медицинской школе. К., 1929; Неотложная хирургия. М., 1931.

*Әд.:* Ш у б и н В.Н., И з м а й л о в Г.А. Профессор Виктор Леонидович Боголюбов. К., 1986.

**БОГОЛЮ́БОВ** Михаил Фёдорович (6.9.1922, Кострома өлкәсенең Галич ш. — 18.6.2004, Казан), театр эшлеклесе, ТАССР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1968, 1991). 1937 елдан Галич шәһәрендә киномеханик. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–52 елларда Казан авиация з-ды клубы директоры, 1952–61 дә Татар филармониясе, 1961–76 да Татар опера һәм балет театры, 1976–93 тә Казан циркы директоры. Үзе җитәкләгән коллективларның матди-техник базаларын ныгытуга, югары квалификацияле иҗади кадрлар әзерләүгә, гастрольләр географиясен киңәйтүгә зур өлеш кертә.

**БОГОЛЮ́БОВ** Николай Иванович (20.5.1840, Вятка губ. Малмыж ш. — 20.8.1893, Казан), хирург, медицина д-ры (1872). 1864 елда Казан ун-тынның мед. ф-тын тәмамлый, 1865–87 елларда шунда ук эшли, 1883 елдан факультет хирургиясе каф. профессоры һәм мөдире. Хезмәтләре күкәйлек туберкулёзы вакытында мәни чыгару юлларына микрохирургик операцияләр ясауга карый.

Х е з м.: Об углекислоте в желчи. К., 1872; Краткий отчет по хирургической факультетской клинике за 1883. К., 1884.

**БОГОЛЮ́БОВ** Николай Николаевич (13.1.1870, Самара губ. Богырыслан ш. тирәсендә — 4.3.1951), опера режиссёры, педагог, РСФСРның атказ. артисты (1927). 1911–17 елларда Петроградның Мария театрында куючы-режиссёр, соңрак Одесса, Баку, Тифлис, Свердловск, Горький һ.б. шәһәрләр театрларында баш режиссёр. 1923–28 дә Әзәрбайҗан, 1928 дән Тифлис, Одесса консерваторияләре профессоры. 1894 һәм 1901–05 елларда Казанда эшли. Казан опера театрында аның тарафыннан Дж.Мейерберның «Гугенотлар» («Гугеноты»), «Африка кызы» («Африканка»), Р.Вагнерның «Лоэнгрин», Ш.Гуноның «Фауст», «Ромео һәм Джульетта», Дж.Вердиның «Риголетто», «Травиата», «Бал-маскарад», «Аида», Л.Делибаның «Лакме», Ж.Массненың «Вертер», Дж.Пуччининың «Тоска», М.Глинканың «Патша өчен тормыш» («Жизнь за царя»), «Руслан һәм Людмила», А.Рубинштейнның «Демон», «Купец Калашников», А.Серовның «Юдифь», П.Чайковскийның «Евгений Онегин», «Мазепа», «Чародейка», «Пики дамасы» («Пиковая дама»), Н.Римский-Корсаковның «Кар кызы» («Снегурочка»), «Моцарт һәм Сальери», «Патша кәләше» («Царская невеста») һ.б.ның опералары сәхнәләштерелә. Опера либреттолары сериясен һәм «Шәрекъ халыклары музыкасы хакында берничә сүз» («Несколько слов о музыке восточных народов») исемле кереш сүзен басмага үз аңлатмалары б-н татар телендә әзерли. Б. татар телендә опера турындагы

беренче басманы — А.Бородинның «Князь Игорь» операсын (либретто) дөньяга чыгара.

Ә с ә р.: «Князь Игорь» А.П.Бородина. К., 1902; Полвека на оперной сцене. Театральные мемуары. М., 1957; Шестьдесят лет в оперном театре. М., 1967.

*Әд.:* К а н т о р Г.М. Музыкальный театр в Казани XIX — начала XX века. К., 1997.

**БОГОМО́ЛОВА** Мария Ивановна (16.4.1932, Тамбов өлкәсенең Тамбов р-ны Красносвободный а.), педагог, пед. фән. д-ры (2003). 1961 елда Тамбов пед. ин-тын тәмамлый. 1952 дән Эстония, Тамбов өлкәсенең мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә, 1971 дән Ульянов пед. ин-тында, 1992 дән Чаллы пед. ин-тында, проф. (1996). Хезмәтләре мәктәпкәчә тәрбия, балаларны интернациональ рухта тәрбияләү проблемаларына карый.

Х е з м.: Интернациональное воспитание дошкольников. М., 1988; Индивидуальный подход к детям в историческом развитии. Наб. Челны, 1996; Проблема преемственности между детским садом и школой в вопросах воспитания и обучения. К., 1997.

**БОГОРО́ДИЦА ПУ́СТЫНЕ** (Раифа Богородица пустыне), архитектура истәлеге. Яшел Үзән р-ны терр-ясендә Раифа посёлогы янындагы Раифа күле буенда урнашкан. Казанга 1613 елда Мәскәүнең Чудов монастыреннан килгән монах Филарет тарафыннан нигезләнгән скит урынында 1661 дә барлыкка килә. 1662 дә Казан митрополиты Лаврентий II иганәсенә агач гыйбадәтханәләр салына, шуларның берсе Синайда һәм Раифада шәһит киткән изгеләр чиркәвенә бәйле монастырь исеме б-н атала. 1689 елгы янгыннан соң Мәскәү янындагы Яңа Иерусалим монастыреннан төзүче иеромонах Герман чакырыла һәм аңа Тихвин һәм Яңа Иерусалим монастырьлары үрнәгендә яңартып төзү бурычы куела. 1690–1717 дә монастырь ансамбле нигездә төзелеп бетә. 1739 да монастырьда 15 гыйбадәтханә (янкормаларын да кертеп), икешәр катлы өч флигель (настоятельләр һәм борадәрләр торагы, ашханә), 5 манаралы дивар исәпләнә. 19 йөздә берничә тапкыр үзгәртеп корыла, соңгы корылмалар 20 йөз башында төзелә. 1670 тә патша Алексей Михайлович указы б-н монастырьга Кама буендагы — Свиногорье, 1674 тә аның тирәсендәге җирләр бирелү нәтиҗәсендә, урманнар сакланып калган, хәзер алар *Идел-Кама саклаулыгындагы* Раифа үзәген тәшкил итә. Казан митрополитлары Тихон, Лаврентий һ.б., аерым шәхесләрдән М.Н.Кудрявцев, М.Т.Атлашкин, Н.И.Киселёва һ.б. монастырьга даими рәвештә иганә кертәләр. 1724 тән монастырь карамагында китапханә, хастаханә эшли, 1865 тә урман дачасы төзелә, ботаникадан беренче коллекцияләр җыела. 1914 тә монастырь янында Беренче бөтендөнья сугышы инвалидлары өчен бистә салына. Җәй айларында монастырь кунакханәсендә Казан сукырлар уч-щесендә укучы балалар ял итә. Б.п. 1703 елгы Швеция б-н сугыш, 1812 елгы Ватан сугышы иҗтыяҗларына иганә кертә. Казанда һәм Васильево авылында часовнялары, Зөядә утары була. Монастырь 1918 дә ябыла. 1919 да урман дачасында Казан ун-тының урман ф-ты урнаштырыла. 1924 тә Зур Ключи авылыннан волость башкарма ком-ты, хастаханә һәм мәктәп Раифага күчерелә. 1929 да монастырь гыйбадәтханәләрендә гыйбадәт кылу тыела. 1933 тә «Раифада яшерен рәвештә гыйбадәт кылуда» гаепләнеп, биш монах, бер монах булырга әзерләнүче (1997 елда изгеләштереләләр) һәм ике гыйбадәт кылучы хөкем ителә, атып үтерелә. 1933 тән монастырь терр-ясендә ОГПУның балалар хезмәт коммуна-колониясе (1938 дән — ябык типтагы) урнаша, Бөек Ватан сугышы елларында эвакуацияләнеп килгән төрмә мәхбүсләре тотыла, 1953 тә Казаннан балигъ булмаган җинаятьчеләр колониясе күчерелә. 1990 да монастырь Казан епархиясенә кайтарыла. 1992 дән Б.п.нда реставрация эшләре алып барыла. 1993 тә монастырь хоры оештырыла, аның квартеты 1998 дә Польшада узган халыкара рухани музыка конкурсы лауреаты була. 1994 тә ятим балалар йорты ачыла. 1999 да Казандагы Мәскәү Чудотворецлары чиркәве, кәшәнә, өлкән поп йорты кергән утар, Яшел Үзән р-ның Ильинский һәм Зур Ключи авылларындагы чиркәүләр монастырьга тапшырыла. 2007 дә Түбән Кама р-ның Кушай авылында Раифа монастыреның утары ачыла. Яшел Үзән шәһәрендәге утарда төзелеш эшләре дәвам итә.



Богородица пустыне. Фото. 1879. Чиркәүләр күренеше (сулдан уңга): Троица соборы (1699), Грузия Богородица соборы (арх. М.П.Коринфский, 1835-42), Синайда һәм Раифада шәһит киткән изгеләр чиркәве (1708–09, реконструкция, арх. А.Г.Невинский, 1892; Ф.Н.Малиновский, 1897).

Ансамбльдә 17 йөз архит-расының архаик чалымнары һәм Псков-Новгород архит-расының тагын да борынгырак традицияләре, кайбер корылмаларның архит-расында Мәскәү бароккосы, классицизм, псевдорус стильләре элементлары чагыла. Ансамбль планында Б.п.ның 2 *га* зурлыгындагы мәйданы көньяк-көнчыгыштан төньяк-көнбатышка таба сузылган бишпочмакны хәтерләтә. Монастырь дивар б-н уратып алынган, гадәттәгечә, 5 манаралы, почмактагылары — түгәрәк, капка өстендәгесе турыпочмаклы нигезгә куелган. Монастырь корылмалары матур иркен асимметрик ансамбль хасил итә. Көнчыгыш дивардагы капка Казан юлына таба карый. Күл ягындагы икенче капка монастырьның көньяк фасадында аерылып тора. Өченче капка — төньяк диварда, ишегалдының хуҗалык өлешендә урнашкан. Монастырь уртасындагы Троица соборы б-н Синайда һәм Раифада шәһит киткән изгеләр чиркәве ансамбль композициясенең үзәген тәшкил итә. 1690–1717 елларда корылган манаралы диварлар — барокко стиле элементлары б-н бизәлгән, рус крепостной архит-расы истәлеге. Чаң манарасы, борадәрләр бинасы һәм София чиркәве диварлар б-н тоташкан. Биш манараның өчесе — төньяк-көнбатыш, көньяк-көнчыгыш, көньяк-көнбатыш (1996 елда реставрацияләнә) яктагылары — безнең көннәргәчә сакланган. Диварлар өсте «карлыгач



Богородица пустыне. Литография. 1902.



Богородица пустыне. 17–20 йөзләр. 1. Гомуми күренеш; 2. Грузия Богородица соборы (арх. М.П. Коринфский. 1835–42); 3. Көньяк почмак манара. 17 йөз ахыры – 18 йөз башы; 4. Көньяк-көнбатыш манара-гыйбадәтханә (17 йөз ахыры – 18 йөз башы); 5. Чиркәүләр күренеше (сулдан уңга): Троица чиркәве (арх. Ф.Н.Малиновский, 1904–10), Грузия Богородица соборы (арх. М.П.Коринфский, 1835–42), Синайда һәм Раифада шәһит киткән изгеләр чиркәве (1708–09, 1892–97).

койрыгы» рәвешендә чыгынтылы. Диварларның эчке периметры түбәле агач галерея б-н әйләндереп алынган, хәзер сакланмаган. Борадәрләр бинасы б-н София чиркәве — 17–18 йөзләр дини һәм гражданлык архит-расы истәлеге. Баштарак гыйбадәтханә Ходай бәндәсе Алексий исеме б-н, борадәрләр торагы «Алексий хөҗрәләре» дип атала. 1794–95 елларда тузган гыйбадәтханә полковник хатыны Н.И.Киселёва иганәсенә төзекләнделә һәм каты газаплар чиккән Изге София, аның кызлары Вера, Надежда, Любовь рухына багышлана, бинага «Киселёв хөҗрәләре» исеме бирелә. Европа терр-ясендәге иң кечкенә бу чиркәүгә нибары 7 кеше сыйган. Төрле зурлыктагы ике бина — баганасыз, тәрәзәле барабан һәм сигез яфраклы таҗ рәвешендәге гөмбәз б-н төгәлләнгән өч катлы София чиркәве һәм дүрт кыек түбә б-н капланган ике катлы борадәрләр торагы асимметрик композиция хасил итә. Фасадларының бизәлешендә 18 йөз ахырына хас бизәкләү элементлары: фризлар, ике рәтле ширинкалар, а́ркасыман тезмәләр, «әтәч кикриге» рәвешендәге бизәкләнгән тәрәзә йөзлекләре файдаланылган. Синайда һәм Раифада шәһит киткән изгеләр чиркәве һәм аның Россиядәге Яңа шәһитләр рухына багышланган янкормасы — 18–19 йөзләр дини архит-расы истәлеге. 1892–97 дә губерна арх. А.Г.Невинский һәм Ф.Н.Малиновский проекты б-н үзгәртеп корыла. Чиркәүнең ике катлы ашханәсе, хөҗрәләре һәм бер катлы ашханәсе булган. Бизәлешендә баскычсыман кәрнизләр, пилястралар, яссы чыгынтылар файдаланылган, тәрәзә өсләре барокко стилендә очланган. Грузия Богородица соборы — дини архит-ра истәлеге, монастырьның төп табыну объекты — Грузия Мәрьям Ана иконасы. 1835–42 дә мещан Д.Орлов, сәүдәгәр Л.И.Колычев һ.б. иганәсенә арх. М.П.Коринфский проекты б-н төзелә. Икона урынын А.Г.Стародгородский, иконалары — Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе укытучысы, рәссам А.С.Терновский тарафыннан ясала (сакланмаган). Алты баганалы, бер апсидлы ярымшар рәвешендәге гөмбәз түбәле соңгы чор ампир стилендәге гыйбадәтханә хачсыман нигезгә корылган. Фасадлары фронтоннар, көнбатыш ягы бер катлы янкорма б-н төгәлләнә. Изге архистратиг Михаил чиркәве б-н чаң манарасы 1889–1903 тә сәүдәгәр М.П.Атлашкин иганәсенә монастырьның көньяк-көнчыгыш ягындагы дивар өстенә салына. Беренче ике катында гыйбадәтханә, беренче ярусы а́ркалы. Өченче өске катка чаңнар куелган, түбәсе гөмбәзле. Яңа *классицизм* стилендә төзелгән, вертикаль доминант (50 *м*). Троицкий соборы 1904–10 да Ф.Н.Малиновскийның 1890 еллардагы проекты б-н төзелә. Озынча хач рәвешендәге нигезгә корылган, өч апсидлы, биш гөмбәзле, гөмбәз асты куышлыгы (18×18 *м*) баганасыз. Ашханәгә түбә б-н капланган баскычтан керелә, үзәк өлеше гөмбәзле. Псевдорус юнәлешенең эклектика формаларында төзелгән, фасадлары филенкалар, а́ркалар һәм уйма фигуралар тезмәсеннән гыйбарәт кыршаулар б-н бизәлгән. 1995 тә реставрацияләнә. Монастырь ансамбле гаять зур булуы б-н аерылып тора. Борадәрләр бинасы — торак йортлар архит-расы истәлеге, ике һәм өч катлы, 17 йөздә монастырьның көнбатыш ягында төзелә, берничә тапкыр үзгәртеп корыла. Фасадлары барокко стилендәге уемнар, баскычсыман кәрнизләр б-н бизәлгән. Архимандрит йорты, 19 йөзнең 2 нче яртысына хас торак архит-расы истәлеге, псевдорус юнәлешенең эклектика стилендә төзелгән. Ишегалдында янкормасы булган бер катлы йорт, фасадларының бизәлешендә күп баскычлы кәрниз, көймәсыман сандриклар, кашагалар файдаланылган.

*Әд.:* М а л о в Е. Казанская Раифская Богородицкая пустынь. К., 1880; Справочная книга Казанской епархии. К., 1909; Раифский Богородицкий мужской монастырь: Путеводитель Георгия Фролова. К., 1997; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. К., 1999. Т. 1.

**БОГОРО́ДИЦКИЙ** Василий Алексеевич (7.4.1857, Царёвококшайск ш., (хәзерге Йошкар-Ола ш.) — 23.12.1941, Казан) тел галиме, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1915), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1925), СССР-ның атказ. фән эшлеклесе (1930). Б. — Казан лингвистика мәктәбе вәкиле, *Бодуэн де Куртенэ* шәкерте, Казан ун-тын тәмамлый (1880). Казан ун-ты (1888–1922), Казан пед. ин-ты (1922 елдан) профессоры. 1880 еллар-

да Казан ун-ты каршында Россиядә беренче эксперименталь фонетика лаб. оештыра, яңгырашлы сөйләмнең физиологик кына түгел, акустик характеристикасын да өйрәнү зарурлыгы идеясен алга сөрә һәм дәлилли («Эксперименталь-фонетик билгеләр б-н бәйле гомумрус әйтелешенең физиология тәҗрибәсе» — «Опыт физиологии общерусского произношения в связи с экспериментально-фонетическими данными», 1909; «Эксперименталь фонетика курсы» — «Курс экспериментальной фонетики», вып. 1–3, 1917–22). Б. беренчеләрдән булып татар телен эксперименталь-фонетик яктан өйрәнә башлый; аналогия, дифференцияләштерү, гадиләштерү, морфема чикләре үзгәрү нәтиҗәсендә сүзнең морфологик элементлары арасындагы чикләрнең тарихи үзгәреше турындагы тәгълиматны үстерә. Хезмәтләре гомуми һәм чагыштырма тел белеменә, роман-герман филологиясенә, төрки тел белеменә, рус теле грамматикасына һәм диалектологиясенә карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Введение в тюрко-татарское языкознание. К., 1922; Фонетика татарского языка в связи с другими языками. К., 1926; Фонетика русского языка в свете экспериментальных данных. К., 1930; Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. К., 1933; Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. К., 1934.

*Әд.:* Библиографический указатель трудов В.А.Богородицкого // Тр. ин-та языкознания АН СССР. 1953. Т. 2; М и р о н о с и ц к а я А.Н. Василий Алексеевич Богородицкий. Жизнь и научная деятельность // шунда ук. 1953. Т. 2; З л а т о у с т о в а Л.В. Научная деятельность В.А.Богородицкого // Уч. зап. Казан. ун-та. 1959. Т. 119, кн. 5; А н д р а м о н о в а Н.А., Б а й р а м о в а Л.К. В.А.Богородицкий. К., 1981.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**БОГОРО́ДСКИЙ** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 19 *км* көнбатыштарак, Нокса елгасы буенда. 2002 елда 656 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 16 йөзнең 2 нче яртысында Сафаров Пүчинкәсе авылы буларак нигез салына, 17 йөз башыннан хәзерге исемдә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Успенский исеме б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элек — экономик, 1764 кә кадәр монастырь крәстияннәре) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, яшелчәчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 17 йөз башында православие приходы оештырыла. Соңгы чиркәү (Успение Пресвятой Богородицы чиркәве) 1883–88 елларда төзелә. 20 йөз башында земство һәм чиркәү-приход мәктәбе (1870 тә ачыла), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1733 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 135 ир заты; 1859 да — 417, 1884 тә — 571, 1920 дә — 929, 1926 да — 1013, 1949 да — 543, 1958 дә — 528, 1970 тә — 468, 1979 да — 490, 1989 да — 578 кеше.

*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**БОГОРО́ДСКИЙ** Алексей Яковлевич (26.10.1870, Казан — 1943, шунда ук), физик-химик, химия фән. д-ры (1937), проф. (1937), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1940). Ф.М.*Флавицкий* шәкерте. Казан ун-тын (1894) тәмамлагач, шунда ук эшли: 1912 дән профессор, 1917 дән нәорганик химия каф. мөдире. 1930 дан Казан химия-технол. ин-тында шул ук исемдәге каф. мөдире. Хезмәтләре эретелгән тозларның физик химиясенә карый. Студент вакытында ук литий хлориды һәм бромиды, соңрак иодидының гидрат формаларын тикшерә. Б. криогидратларның механик катнашма икәнлеген тәҗрибәдә дәлилли. Термохимиягә кагылышлы хезмәтләрендә калориметрик тикшеренүләр өчен беренче булып Дюар савытын куллана һәм кайбер термометрик үлчәүләр үткәрә. Эретелгән натрий, калий, литий нитратларының электролизын тикшерә һәм электр үткәрүчәнлеген өйрәнә. Аның тарафыннан калий, натрий һәм литий хлоридлары эремәләренең, аерым алганда, куе һәм аеруча куе концентрацияләренең җылысыешлыгын билгеләү эшләре башкарыла. 1918 елда пыяла з-дларын эшләтеп җибәрүдә, ш. и. химик приборлар һәм савыт-саба өчен пыяла җитештерүне оештыруда катнаша. 1920 елларда Бондюг химия з-дын ябуга каршы чыга. Күп еллар буена Б. 40 нчы з-дта (хәзер В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү берләшмәсе) консультант була, ТАССР Дәүләт план комитеты каршындагы Химияләштерү ком-ты эшендә катнаша. Б. — Оборона, авиация һәм химия төзелешенә булышлык итүчеләрнең респ-ка җәмгыятен оештыручыларның берсе. Бондюг химия техникумына аның исеме бирелә.

Х е з м.: Исследование гидратных форм хлористого и бромистого лития // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1893. Т. 25; К вопросу о криогидратах // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1896. Т. 28.; Материалы по электрохимии неорганических соединений в так называемом огненно-жидком состоянии. К., 1905; К вопросу о количественном определении таллия объёмным путём // Журн. общей химии. 1931. Т. 1 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БОГОРО́ДСКИЙ МӘГАРӘСЕ́**, к. *Кама Тамагы спелеологик системасы.*



В.А.Богородицкий.



А.Я.Богородский.

**БОГОРО́ДСКИЙ** Яков Алексеевич (1841, Тамбов губ. — 31.7.1920, Казан), тарихчы, дин гыйльме д-ры (1884). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1868), 1870–1907 елларда шунда ук эшли, проф. (1880). Хезмәтләре борынгы Палестина, яһүд халкының Библия чоры тарихына һәм Библиядәге космогоник мәгълүматларны өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Еврейские цари. К., 1906; Начало истории мира и человечества по первым страницам Библии. К., 1906.

**БОГОСЛО́ВСКИЙ** Михаил Иванович (1.1.1844, Тамбов өязе Экстали а. — 4.7.1915, Казан), дин белгече, дин гыйльме д-ры (1895). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1870), 1871 елдан шунда ук эшли, Изге Яңа Гаһед (Новый Завет) Китабы каф. проф. (1886). Хезмәтләре Яңа Гаһед эчтәлеген тасвирлауга карый. Экзегетика фәнни мәктәбенә нигез салучы. Шәкертләре арасында — *Никанор* (Н.Т.Каменский), П.А.*Юнгеров*, Н.В.*Петров*.

Х е з м.: Идея Царства Божия в Ветхом и Новом Завете. К., 1887; Детство Господа нашего Иисуса Христа и Его Предтечи по Евангелиям св. Апостолов Матфея и Луки. Историко-экзегетическое исследование. К., 1893; Общественное служение Господа нашего Иисуса Христа по сказаниям святых евангелистов. К., 1908.

*Әд.:* Е в с е в и й. М.И.Богословский. Обзор учёной и учёно-литературной деятельности. К., 1916.

**БОГОТО́Л РАЙОНЫ́**, Красноярск краеның көньягында. Мәйданы — 2,95 мең *км*$^2$. Үзәге — Боготол шәһәре (Красноярскидан 252 *км* көнбатыштарак). Халкы — 29,7 мең кеше (2001), ш.и. 110 татар Шулдат авылында яши. 1930 елларга кадәр мәчет эшли, 1960 елга кадәр укыту татар телендә алып барыла.

**БОГОЯВЛЕ́НИЕ ЧИРКӘВЕ́**, Казанда рус дини архит-расы истәлеге. Шәһәрнең тарихи үзәгендә урнашкан. 1741 елда сәүдәгәрләр И.А.Михляев һәм С.А.Чернов иганәсенә тө-


Богоявление чиркәве. Казан. 1741. 1. Ф. Бибин фотосы. 1890; 2. Хәзерге күренеше.



1



2



Богоявление чиркәве. Чаң манарасы. Арх. М.Д. Михайлов. 1895–97.

зелә. Гыйбадәтханә композициясенең үзәген рус бароккосы стилендә 5 гөмбәзле, баганасыз, 3 апсидлы чиркәү, ашханә һәм 3 катлы чаң манарасы тәшкил итә. Чаң манарасы чатырына тавыш юллары уелган, 3 нче катның ярусы ярымтүгәрәк рәвешендә төгәлләнгән һәм а́ркасыман уемнары ярымколонналар б-н ныгытылган. Тузу сәбәпле чаң манарасы 1909 да сүтелә.

4 кыеклы түбә б-н капланган, аслы-өсле тәрәзәле, шакмаксыман бина Псков архит-расына хас итеп бизәлгән һәм биек барабаннарга утыртылган очлысыман 5 гөмбәз б-н төгәлләнә. Диварлары чыгымтылар б-н бүлгәләнгән, өске өлеше а́ркасыман уемнар б-н бизәлгән, тәрәзәләре ярымтүгәрәк йөзлекләргә утыртылган. Б.ч. бизәлешендә борынгы рус архит-расы б-н барокко стиле элементлары файдаланылган. Капкаларны бизәүдә дә барокко мотивлары чагыла. 1895–97 дә сәүдәгәр И.С.Кривоносов иганәсенә арх. М.Д.Михайлов проекты б-н Апостол Андрей Первозванный капка өсте чиркәвенең чаң манарасы корыла. Чаң манарасы — борынгы рус һәм төбәк архит-расы элементлары катнашкан эклектика формаларында фигуралы кирпечтән һәм ак таштан чиркәү мәйданында төзелә. Ике катлы дүрткырлы зур корылманың аскы ярусындагы а́рка калдырылган, 2 нче каттагы гыйбадәтханә, катлаулы түбә б-н ябылган, урам һәм ишегалды ягы манаралары өстенә челтәрле хачлар урнаштырылган. 2 чаң кагу ярусы чаң манарасы өстеннән калкып торган. 1920–39 елларда Б.ч. рус православие чиркәвенең кафедраль соборы вазифасын үти. 1939 да ябыла. Гөмбәзләре һәм почмаклардагы барабаннары сүтелә. Чиркәү коймалары һ.б. корылмалар җимертелә. Чаң манарасы астындагы а́рка томалап куела. Б.ч. 1996 да православие җәмгыятенә кайтарыла. 1999 да а́рка яңадан ачыла. 1873 елда Б.ч.ндә Ф.И.Шаляпин чукындырылган. 2001–03 тә гөмбәзләре һәм почмаклардагы барабаннар торгызыла.

*Әд.:* М а л о в Е.А. Историческое описание церквей г. Казани. К., 1884. Вып. 1; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Республика Татарстан: Православные памятники. К., 1998.

*Т.В.Пашагина.*

**БОГОЯВЛЕ́НСКИЙ** Александр Феоктистович (27.1.1908, Киев — 26.7.1985, Казан) химик, химия фән. д-ры (1954), проф. (1955), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1958). Ф.И.Богоявленскийның улы. Шостка хим.-технол. ин-тын (1930) тәмамлый. 1934 елдан Казан ун-тында, нәорганик химия каф. мөдире (1945–53). 1953 тән Казан авиация ин-тының гомуми химия кафедрасында. Тимернең кайтарылу реакцияләре кинетикасын өйрәнә. Җиңел металларның коррозиясе һәм анодлы пассивлаштыру юлы б-н аларны саклау буенча фәнни юнәлешне үстерә. 1956 да кафедра каршында электрорадиохимик тикшеренүләр лабораториясен оештыра һәм СССРда беренчеләрдән булып анодлы оксидлашу процессларын өйрәнү өчен радиоактив изотоплар куллана. Фазалы анод оксидларын формалаштыруда электролит анионнарының ролен дәлилли һәм металларның анодлы капламнарының төзелеш үзенчәлекләрен, химик составын һәм үзлекләрен ачу теориясен төзи. Шул теория нигезендә аның тарафыннан төрле пр-тие һәм дәвалау учреждениеләре файдалана торган радиоактив аппликаторлар эшләнә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анодная защита металлов. М., 1964; Курс химии. М., 1971. Ч. 2 (автордаш); Анодная обработка металлов // Справ. по электрохимии. Л., 1981 (автордаш).

*Әд.:* Александр Феоктистович Богоявленский // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1983. Т. 26, № 2.

**БОГОЯВЛЕ́НСКИЙ** Владимир Феоктистович (18.3.1931, Украина ССРның Сумы өлкәсе Шостка ш.), терапевт, мед. фән. д-ры (1972), проф. (1972), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1976). 1955 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1960 елдан Благовещенск (Амур өлкәсе) мед. ин-тында эшли. 1964 тән Казан мед. ин-тында, 1970–83 елларда 1 нче госпиталь терапиясе каф. мөдире һәм бер үк вакытта 1972 дән фәнни эшләр буенча проректор. 1983–87 дә Әстерхан мед. ин-ты ректоры. 1988 дән Казан мед. академиясенең 2 нче терапия каф. профессоры. Б. атеросклероз б-н авыручыларның организмындагы төп алмашу процессын, эчке һәм тышкы сулыш функциясе халәтен, гемокоогуляция һәм микроциркуляциясен (МЦ) өйрәнә. МЦ торышын Книзели-Блох — Дитцель буенча билгеләү модификациясен эшли, хәзер бу ысулны илебезнең күпчелек тикшеренүчеләре куллана. Коагулемиясе һәм сулыш алу функциясе бозылган атеросклероз авырулы кешеләрдә МЦне көйләүнең 5 дәрәҗәсе ачыла. Озакка сузылган вакытында (А.Н.Копылов б-н берлектә) диагноз куйганда МЦнең фаразланган тотрыклы үзгәрешләрен һәм лактатдегидрогеназ фракциясе спектрындагы тайпылышларны ачыклый. Резус конфликтлы йөкле хатыннар һәм аларның гемолитик авырулы яңа туган балалары микроциркуляциясендәге закончалыклы үзгәрешләрне (Б.Г.*Садыйков* б-н берлектә) тасвирлый; бу исә резус-конфликт барышы вариантларын аерымларга һәм идарә итүле патогенетик дәвалау эшләре башкарырга, авыруның язмышын фаразларга мөмкинлек бирә. Атеросклероз һәм йөрәк ишемиясе авыруларына диагноз куюга һәм дәвалауга караган авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Диагностика и неотложная помощь при острых состояниях и отравлениях. Л., 1967 (автордаш); Профессор С.С.Зимницкий — врач, ученый, патриот. К., 1970; Диагностика и доврачебная помощь при неотложных состояниях. Л., 1985; Растения и здоровье. Применение лекарственных растений в терапевтической практике. К., 1998 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Владимир Феоктистович Богоявленский // Казан. мед. журн. 1991. № 5.

**БОГОЯВЛЕ́НСКИЙ** Феоктист Иванович (8.10.1880, Кострома өлкәсенең Межа а. — 11.9.1954, Казан), химик, проф. (1939). 1904 елда — Дерпт ун-тын, 1909 да Киев политехника ин-тын тәмамлый, 1918 гә кадәр шунда ук эшли. 1919 дан күн эшкәртү һәм сабын кайнату з-дларында, тәмәке ф-касында (Чернигов өлкәсе Остёр ш.) производство мөдире, бер үк вакытта 1924–25 тә Чернигов коoп. втуз-техникумы директоры. 1925–32 дә Шостка хим.-технол. ин-тының (Украина ССР, Сумы өлкәсе) нәорганик һәм аналитик химия кафедрасын җитәкли. 1932 дән Казанда: Казан ун-тының нәорганик химия каф. мөдире (1932–39), Казан мед. ин-тының нәорганик һәм аналитик химия (1935–54), бер үк вакытта Казан стоматология ин-тының химия кафедралары мөдире (1939–52). Хезмәтләре тукымалар җитештерү технологиясенә, экстракциягә, аналитик химиягә карый. Кызыл конго буягычын, бакыр оксиды ионнарының аналитик үзлекләрен тикшерә, ш. у. тимер һәм бакыр ионнарының микъдарын билгели. Мерваны балавыз алу өчен чимал буларак тәкъдим итә. Хезмәтләре тукыма җитештерү сәнәгатенә һәм Казан балавыз экстракция з-дында гамәлгә кертелә (1935–41 дә заводның фәнни консультанты). Бөек Ватан сугышы елларында шартлагыч терекөмеш һ.б. шартлаучан матдәләрне анализлау буенча СССР Оборона министрлыгы з-длары өчен махсус эшләр башкара. Мерсерланган целлюлозаның дымлануын һәм гистерезисын өйрәнү нигезендә И.Ф.Богоявленский б-н берлектә госпитальләрдә бәйләгеч гипс итеп файдаланылган марляны яңадан эшкә яраклы итү ысулын эшли. Казандагы дәвалау учреждениеләре һәм госпитальләре өчен барий сульфаты әзерләүне һәм чистартуны оештыра. Югары һәм урта уку йортлары өчен гомуми химия һәм сыйфат анализы дәреслекләре авторы. «Бюллетень Шосткинского химико-технологического института» фәнни ж-лын нигезләүче һәм аның баш мөхәррире (1925–33).

Х е з м.: О преподавании аналитической химии в высшей школе // Изв. Киевского политехн. ин-та. 1912. Т. 6, вып. 2; Экспериментальное исследование красного конго // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1912. Т. 46; Учебник качественного анализа для высших учебных заведений и средних технических училищ. Киев, 1913; Мерва как сырьё для получения

воска // Пчеловодство. 1935. № 10; Підручник якісного аналізу. Хар., 1934.

*Әд.:* А м и р о в Н.Х., А б д у л л и н И.А. 70-летие кафедры неорганической химии Казанского государственного медицинского университета // Казан. мед. журн. 1999. № 2.

**БОГЫРЫСЛА́Н РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньяк-көнбатышында. Мәйданы — 2907,5 *км*². Үзәге — Богырыслан шәһәре (Оренбургтан 360 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 77416 (2002), ш.и. Богырысланда — 53893 кеше. Татарлар саны — 6403 кеше (2002); Чишмәбаш авылында һәм Алга, Йолдыз посёлокларында яшиләр, район үзәге халкының шактый өлешен тәшкил итәләр (2002 дә — 5407 кеше). Богырысланда татар җәмәгатен 19 йөз ахырында Богырыслан өязенең тирә-як авылларыннан күчеп утыручылар оештыра. Татарлар, башлыча, приказчиклар, калайчылар булып эшли, сәүдә итә. 1917 елга кадәр шәһәрдә 2 мәчет, мәдрәсә һәм мәктәп, 1920 еллардан 1962 гә кадәр татар мәктәбе була. 1930 елларда рус-татар-башкорт пед. техникумы эшли, татарча «Кыр уракчылары» г-тасы нәшер ителә. 1989 да Богырысланда ТИҮнең «Туган тел» бүлеге оештырыла. Г.Тукай исем. мәдәният йорты, татар китапханәсе, «Чулпан» рус-татар балалар бакчасы эшли; 1990 еллардан 2 мәктәптә татар халкы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү дәресләре кертелә, татар якшәмбе мәктәбе эшли, «Болгар» ААҖ каршында «Батыр» татар милли көрәш мәктәбе оештырылган. Сабантуй бәйрәмнәре үткәрелә. Шәһәрдә җамигъ мәчет эшли. Шәһәрнең 3 урамы татар шагыйрьләре һәм язучылары Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил исемнәрен йөртә. Районның Совет авылында Сов. Союзы Герое А.М.Хәйретдинов туган.

**БОДА́Й** (Triticum), кыяклылар семьялыгыннан берьеллык үсемлек ыругы; ТРда игелә торган төп азык культураларының берсе. Җитештерү өчен әһәмиятле 2 төре бар: йомшак яки гади Б. һәм каты Б. Гибридлаштыру юлы б-н күпьеллык Б. сорты уйлап табылган. Ужым Б. көз көне, сабан Б. яз көне чәчелә һәм югары уңыш бирә (двуручка). Вегетация чорында ужым Б. өчен уртача тәүлеклек темп-ралар суммасы 2100 °С, сабан Б. өчен — 1300 °С тирәсе таләп ителә. Ужым Б. җитештерүдә аның кышкы шартларга яраклаштырылган һәм корылыкка чыдам булуы мөһим. Сабан Б. корылыкка чыдамрак. Аның вегетация чоры 70–100 тәүлек, ә ужым Б.ныкы — көзен 45–50, яз һәм җәен 75–100 тәүлеккә сузыла. Б. үзлегеннән серкәләнә, аны игү өчен уңдырышлы туфрак, чиста басу кирәк. Арыштан аермалы буларак, Б. кара туфракта әйбәтрәк үсә. Б.ның күпчелек төрләренең туган җире — Кавказ арты илләре. *Ибне Фазлан, Ибне Рустә* фикерләренә караганда, *Идел буе Болгар дәүләтендә* әле 10 йөздә үк культуралы үсемлекләр арасында Б. (Борай бодае) алдынгы урын тота. Элек-электән Казан губернасының кайбер авылларында Б. шактый зур мәйданнарда игелгән, мәс., Зөя өязенең Татар Борнашы авылында 1890 да язгы чәчүгә бирелгән басуның яртысы файдаланылган. 19–20 йөзләрдә, сабан уйлап табылганнан соң, таза хәлле крәстияннәр Б. чәчүлекләрен шактый киңәйтәләр. Б.ның бернichә төрле сорты игелә башлый. Губернаның төньяк өлешендә Б.ның йомшак сортлары «Русская», «Гирка», «Красноколоска», «Саксонка», «Самарка», «Остистая» һ.б. игелә. Көньяк өязләрдә каты сортларга өстенлек бирелә, мәс., «Арнаутка», «Белотурка», «Белоколоска» һ.б., алар өчен, йомшак сортлардан аермалы буларак, чирәм җирләр кулай санала. Бөгелмә өязенең электән сөрелеп килгән җирләрендә Б.ның «Русская» һәм «Саксонка» сортлары, яңа җирләрдә — «Белотурка» сорты игелә. 19 йөз уртасында уңдырышлы чирәм җирләрдә Б. уңышы чәчелгән орлыкка караганда 15 тапкыр артыграк (15 сам), ә электән сөрелеп килгән җирләрдә 2–5 сам гына тәшкил итә. Шуның өчен дә аны Казан губернасының кысыр яткан җирләр сакланып калган көньяк һәм көньяк-көнчыгыш р-ннарында игәләр. Чирәм җирләрне эшкәртә башлаганнан соң, электән сөрелеп килгән, иске, чүп баскан җирләргә Б. чәчү күпкә киметелә. 19 йөз ахырында Казан губернасында сабан бодаеның тулай җыемы уртача (мең чиректә): 1870–74 тә — 258, 1875–79 да — 155, 1880–84 тә — 176, 1885–90 да 186 мең чирек тәшкил итә. 1909–11 дә ул 46,4–61 мең *га* җирдә игелә. Ужым Б. барлык мәйданның 2,5% ын били.



Бөртекле культураларның тулай җыемында Б.ның чагыштырма өлеше (% ларда): 1913 елда — 2,8, 1920 — 5,2, 1940 — 48,7, 1960 — 69,3, 1980 — 46,8, 1990 — 26,4, 2000 — 32,3, 2006 — 45,6%. 1960 еллар уртасыннан респ-када Б. җитештерүнең интенсив технологияләрен кертүгә, яхшылап ашлау, корылыкка, салкынга, табигатьнең башка уңайсыз факторларына чыдам, авыруларга, зарарлы бөҗәкләргә бирешмәүчән, сөрлекмәүчән, югары уңыш бирүчән, озак саклanучан сортлар игүгә зур игътибар бирелә; йомшак ужым Б. сортларыннан «Казанская 84» (1992), «Мешинская 2» (1993), «Безенчукская 380» (1997), «Казанская 285» (1999), «Казанская 560» (2002), «Волжская-100» (2004); йомшак сабан Б.ның «Памяти Азеева» (2001), «Омская 32» (2002), уртача өлгерешле «Люба» (1988), «Прохоровка» (1997), «Керба» (1998), «Әмир» (2001), «Омская 33» (2002); «Тулайковская 10» (2003), «Дебют» (2003), «МИС» (2003), «Казанская юбилейная» (2004), «Эстер» (2004); каты сабан Б.ның «Безенчукская 182» (1993) сортлары игелә.

Ужым Б. күпьеллык үләннәрдән бушаган һәм ашланган кара парга, сабан Б. арыш, кукуруз, кузаклылардан бушаган мәйданнарга чәчелә. Б. корткычларына (орлык күбәләге, гессен һәм швед чебеннәре, яшелкүз, зыянлы ташбака һ.б.), үсемлек авырулары (ашлык кисәве, ашлык гөмбәсе, ончыл чык) һәм чүп үләннәргә (билчән, кара солы һ.б.) каршы махсус агротехник, технологик, биологик, химик чаралар кулланыла. Игеннәр аерым ысул б-н һәм турыдан-туры комбайн б-н урдырыла. Б. игүнең агротехник технологиясен, аның селекциясен эшләүгә, орлыкчылыкны яхшыртуга галимнәр *П.М.Тихонов, А.А.Җиһаншин, А.К.Вершинин,* О.Х.Дергачёва, К.Г.Шәмсетдинова, *Э.Ф.Ионов, Э.Д.Неттевич, К.Г.Азиев,* У.Г.Лотфуллин һ.б. зур өлеш кертә.

*Әд.:* Х а л и к о в Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX – начало XX вв.). К., 1995; З и г а н ш и н А.А. Современные технологии и программирование урожайности. К., 2001. Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. К., 2005. Ч. 1.

*И.Н.Афанасьев.*

1913–2006 елларда Татарстанда бодайның чәчүлек җирләре, уңдырышлылыгы, тулай җыемы

| Еллар | Чәчүлек җирләре (мең *га*) | | | Уңдырышлылык 1 *га* дан *ц* да | | Тулай җыем (мең *т* да) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | ш. и. | | | | Барлыгы | ш. и. | |
| | | ужым | сабан | ужым | сабан | | ужым | сабан |
| 1913 | 74,8 | ... | 74,8 | ... | 7,2 | 53,9 | ... | 53,9 |
| 1920 | 44,6 | ... | 44,6 | ... | 3,6 | 16,3 | ... | 16,3 |
| 1928 | 106,3 | ... | 106,3 | ... | 7,8 | 83,0 | ... | 83,0 |
| 1940 | 639,7 | ... | 639,7 | ... | 7,0 | 450,6 | ... | 450,6 |
| 1960 | 748,7 | 5,1 | 743,6 | 10,2 | 10,8 | 805,5 | 5,2 | 800,3 |
| 1970 | 929,9 | 46,7 | 883,2 | 15,9 | 16,6 | 1539,5 | 74,4 | 1465,3 |
| 1980 | 940,6 | 108,6 | 832,0 | 11,4 | 16,7 | 1513,8 | 124,0 | 1389,5 |
| 1990 | 580,8 | 26,4 | 554,4 | 30,8 | 17,6 | 1054,4 | 81,3 | 973,1 |
| 2000 | 554,4 | 59,3 | 495,1 | 28,6 | 20,3 | 1165,6 | 166,4 | 999,2 |
| 2006 | 705,6 | 110,8 | 584,8 | 34,4 | 28,8 | 2064,0 | 381,4 | 1682,6 |

**БОДУЭ́Н ДЕ КУРТЕНЭ́** Иван Александрович (Baudouin de Courtenay) (1.3.1845, Польша, Радзымин ш. — 3.11.1929, Варшава), тел галиме, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1897), Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы. Казан (1875–83), Юрьев (1883–93), Краков (1893–99), Петербург (1900–18), Варшава (1918–19) ун-тлары профессоры. Б. де К. — теоретик, чагыштырма һәм славян тел белеменнән зур белгеч; фонемалар һәм фонетик чиратлашулар теориясенә беренче булып нигез сала, диахрония һәм синхрониянең чикләрен билгели. Катлаулы теоретик проблемаларны: тел системасы һәм төзелеше, тел баскычлары һәм аларның төп берәмлекләре (фонема, морфема, синтагма



И.А. Бодуэн де Куртенэ.

һ.б.); тел статикасы һәм динамикасы, аның гамәлдә булуы һәм үсүе, телләр типологиясе һәм конвергенциясе (тел категорияләренең бер-берсенә туры килүе яки якынаюы) һ.б. тикшерә. Казан галимнәре б-н бергә фонология, морфонология, сүз ясалышы теориясенә, лингвистик типология һәм лингвистик универсалийлар теориясенә нигез сала. Җанлы телләрне өйрәнү методикасын һәм тел күренешләрен өйрәнүнең чагыштырма хронологиясе алымын тәкъдим итеп, лингвистика фәне методологиясен баета. Тел белемендә эксперименталь алым кулланууны дәлилли. Билгеле бер дәрәҗәдә 20 йөздә тел белеменең үсеш юлларын билгели, психолингвистика, социолингвистика, квантитатив лингвистика һ.б. формалашуына булышлык итә. В.И.Дальнең «Кулланыштагы бөек рус теленең аңлатмалы сүзлеге»нең («Толковый словарь живого великорусского языка», 1903–09) 3 нче басмасы мөхәррире. Б. де К. шовинизмның һәм милләтчелекнең төрле формаларына, ш.и. аларның телдә чагылуына каршы була; халыкларның милли горурлыгын яклап чыга. Хезмәтләре гомуми һәм славян тел белеменә, рус, поляк телләрен тикшерүгә карый. Дәүләт федерализмы идеяләрен яклаган «Автономиядә милли һәм территориаль үзенчәлек» («Национальный и территориальный признак в автономии», 1913) китабы авторы.

Х е з м.: Избранные труды по общему языкознанию: В 2 т. М., 1963; Письма Бодуэна де Куртенэ в Казанский университет // Уч. зап. Казан. ун-та. 1995. Т. 131; Dziela wybrane: T. 1–6. Warsz., 1974–83.

*Әд.:* Б о г о р о д и ц к и й В.А. Казанский период профессорской деятельности И.А.Бодуэна де Куртенэ. Варшава, 1932; Бодуэн де Куртенэ и современная лингвистика. К., 1990; Бодуэн де Куртенэ: теоретическое наследие и современность // Уч. зап. Казан. ун-та. 1995. Т. 131.

*Г.А.Николаев.*

**БОЕРГА́Н** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 19 *км* көньяктарак, Чилчә елгасы буенда. 2002 елда 773 кеше (чуашлар — 60%, татарлар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөз уртасында нигез салына. 19–20 йөзнең 1 нче яртысында рәсми чыганакларда ике торак пункт — Татар Боерганы һәм Чуаш Боерганы буларак телгә алына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.да мәчет була. 20 йөз башында чиркәү, 2 мәчет, 2 мәктәп, Халык мәгариф министрлыгы мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2191,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 895, 1897 дә — 1985, 1913 тә — 2352, 1920 дә — 2210, 1926 да — 2098, 1938 дә — 1880, 1949 да — 843, 1958 дә — 1597, 1970 тә — 1691, 1979 да — 1679, 1989 да — 857 кеше.

**БОЕРГА́Н** т и м е р ю л р а з ъ е з д ы п о с ё л о г ы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 10 *км* көньяктарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. 1943 тә нигез салына. Беренче көннән үк Буа р-нында. Халык саны: 1958 дә — 4, 1970 тә — 17, 1979 да — 9, 1989 да — 6 кеше.

**БОЕРГА́Н** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычы ярында. 2002 елда 455 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1714 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, йон тетү, тире эшкәртү, чабата үрү, арба көпчәкләре һәм балчык савыт-саба ясау, дегет кайнатып сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 768 дис. тәшкил итә. Бу чорда мәчет (1835 еллар тирәсендә ачыла), почта станциясе, җил тегермәне эшли. 1931 дә «Үрнәк» к-зы оештырыла, ул үзенә 28 хуҗалыкны берләштерә. 1950 дән — «Кама» к-зы составында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 64, 1816 да — 141 ир заты; 1859 да — 351, 1870 тә — 325, 1884 тә — 433, 1896 да — 399, 1906 да — 573, 1913 тә — 580, 1920 дә — 597, 1926 да — 342, 1938 дә — 391, 1959 да — 289, 1970 тә — 350, 1979 да — 529, 1989 да — 506 кеше.

**БОЕРГА́Н СӘЕ́Т** (16 йөз), Казан ханлыгының дин һәм дәүләт эшлеклесе, сәет. 1546 елга кадәр Казан ханлыгы мөселман руханилары башлыгы. Казан аксөякләре Мәскәүдә Иван IV б-н алып барган сөйләшүләрдә катнаша. 1546 да Сафагәрәй хан сәясәтенә каршы чыга (к. *Казан фетнәсе*). Соңрак Нугай якларына качарга мәҗбүр була. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*С.Х.Алишев.*

**БОҖРАЛЫ́ СУАЛЧАННА́Р** (Annelida), икенчел тән куышлыгы (целом) булган суалчаннарның иң зур югары оешкан тибы. 6 классны үз эченә ала: беренчел Б.с., күп төкле Б.с. (полихетлар), *аз төкле суалчаннар* (олигохетлар), *сөлекләр*, эхиуридлар һәм сипункулидлар. Дөнья фаунасында 8 меңләп төре билгеле. Татарстан терр-ясендә, гадәттә, 2 класс вәкилләре: аз төкле суалчаннар (*яңгыр суалчаннары*, энхитреидлар) һәм сөлекләр очрый. Б.с. озынлыгы берничә *мм* дан алып 2,5 *м* га кадәр. Гәүдәсе 3 өлешкә бүленгән: баш, тән (буыннардан тора) һәм аналь калак. Буыннар саны берничә йөзгә җитәргә мөмкин. Һәрбер буынтык организмның мөһим система өлешләрен үз эченә ала. Б.с. өчен буынтыклы икенчел куышлык (целом) хас, ул куышлык сыеклыгы б-н бергә «гидравлик скелет» ролен үти, ш.у. эчке секреция бизләре бүлеп чыгарган төрле продуктлар, кислород һәм углекислый газ йөрү урыны булып тора. Б.с. ның махсус хәрәкәтләнү органнары параподияләре бар. Аз төкле суалчаннарда төкләр генә була. Күп төрләре гәүдәнең юкка чыккан өлешләрен яңадан торгызу сәләтенә ия. Җенси һәм җенси булмаган юл б-н үрчиләр.

*А.К.Жеребцов.*

**БОЗ КАРА́У**, елгада боз кузгалганда яр буенда үтә торган күңел ачу гадәте, к. *Ташу карау*.

**БОЗ КАТУ́**, агым су яки сулык өслеге туңу һәм хәрәкәтсез боз хасил булу процессы; елга, күл, сусаклагычларда боз капламы саклану вакыты.

Татарстанда сулыкларның туңуы республиканың төньяк өлешендә октябрь ахыры — ноябрьнең беренче көннәрендә, көньяк өлешендә ноябрьнең беренче декадасында күзәтелә. Башта сулыкның юка өске катлавында һәм, иң элек, яр тирәсендә сай һәм тын урыннарда артык суыну нәтиҗәсендә (су темп-расы су кату ноктасыннан бераз түбәнрәк) боз кристаллары барлыкка килә. Аннан соң кристаллар, үзара һәм ярларга ябышып катып, боз полосалары (яр буе бозлары) яки агым буйлап йөзүче юка боз пластинкалары ясый. Салкын һавада боз пластинкалары һәм су эченнән калкып чыккан боз тупланмалары зур боз кисәкләренә әверелә, елгаларда көзге *боз киту* башлана. Елганың югары өлешендә бозлар тоткарлана һәм бер-берсенә ябышып ката. Тыгылган урыннан түбәндәрәк, агым көчле урыннарда, Б.к. соңрак, салкыннар көчәйгәч башлана. Кече елгалар, кагыйдә буларак, зурларына караганда иртәрәк туңалар, аларда боз капламы яр буе бозлары кушылу нәтиҗәсендә хасил була һәм шуңа күрә ул, гадәттә, тигез, чагыштырмача шома өслекле. Һава температурасы торышына карап, яр буе бозлары барлыкка килүдән алып Б.к. вакыты арасы кечкенә күлләрдә тәүлектән ким, кечкенә елгаларда 2–3 көн, Түбән Кама һәм Куйбышев сусаклагычларында 1–1,5 атна һәм аннан да артыграк булырга мөмкин. Бозлану чоры һәм бозның калынлыгы кыш озынлыгына һәм аның температурасы режимына, кар капламына, җил режимына, сулыкларның үзенчәлекләренә бәйле. Бозлану чоры уртача 130–155 көн тәшкил итә. Б.к. чоры су объектларының боздан арчылуы, елгаларда *боз киту* б-н бер үк вакытта була торган язгы су ташу башлану б-н тәмамлана.

**БОЗ КИТУ́**, елгаларда боз кисәкләренең һәм боз кырларының хәрәкәте. Көзге һәм язгы Б.к. аерып йөртелә. Көзге Б.к. вакытында



Иделдә боз китү.

елгада йөзүче бозларның формалашуы яр буендагы боз китекләренең, вак боз, сулы кар, боткасыман боз массаларының (шуганың) бер-берсенә ябышып катуы сәбәпле килеп чыга (к. *Боз кату*). ТР терр-ясендә зур һәм уртача зурлыктагы елгаларда күзәтелә; кечкенә Б.к. кечкенә елгаларда булмый. Кайвакыт йөзеп баручы бозларның тупланмасы хасил була, ул үз чиратында елганың югары өлешендә су биеклеге күтәрелүгә китерә, әмма елгаларның бу вакытта аз сулы булуы аркасында бу күтәрелүләр зур булмый. Көзге Б.к. вакыты, елгадагы суның муллыгына турыдан-туры бәйле рәвештә, берничә көннән алып бер айга кадәр һәм аннан да күбрәккә сузылырга мөмкин. Яр буйларында һәм сай урыннарда боздан арчылган тар су юллары барлыкка килү б-н, кышкы боз капламы җимерелә башлый һәм язгы Б.к. күзәтелә. Елга ачылу алдыннан боз капламы берникадәр юка булган тиз агымлы урыннарда ачык киңлекләр хасил була. Кар сулары агып төшеп, су биеклеге күтәрелү сәбәпле, боз капламының да биеклеге күтәрелә, ул ватыла һәм агым буенча түбәнгә таба хәрәкәт итә башлый. Үзенең куәте буенча язгы Б.к. көзге Б.к.не узып китә, чөнки анда күп күләмле су һәм боз шактый зур тизлек белән хәрәкәт итә. Елганың тар юлларында, утраулар янында, текә борылышларда зур бозлар өелеп, тоткарлыклар барлыкка килә. Бу үз чиратында көчле су ташуларга һәм елга тирәсендәге җирләрне су басуга китерә. Язгы Б.к. төбенә кадәр катa торган кечкенә яки су биеклеге күтәрелеше зур булмаган елгаларда, карның әкрен эрүе сәбәпле, сирәк күзәтелә. Язгы Б.к. кечкенә елгаларда 7 көнгә, зур елгаларда 10 көнгә кадәр сузылырга мөмкин.

*Әд.:* Давыдов Л.К., Дмитриева А.А., Конкина Н.Г. Общая гидрология. Л., 1973.

**БО́ЗИН** Анатолий Алексеевич (3.1.1953, Мамадыш р-ны Бөрсет а.), спортчы, тренер (грек-рим көрәше), Россиянең атказ. спорт остасы (2003). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1981). М.М.*Сәхәбетдиновның* («Урожай» ирекле спорт җәмгыяте) шәкерте. СССР чемпионатларында бронза (1976–79), көмеш (1980), алтын (1981) медальләр ала. Иң җиңел һәм җиңел үлчәүләрдә Профсоюз спортчылары арасындагы бәйгедә дөнья (1981), Бөтендөнья универсиадасында (1977) җиңүче, Европа чемпионатында көмеш (1977–78), бронза (1979) медальләр яулый. 1983–86 елларда ТАССРның Спорт һәм туристлык дәүләт ком-ты үзәк СКда өлкән тренер. 1986 дан Казан вет. медицинасы академиясендә физ. тәрбия каф. укытучысы, 2004 тән каф. мөдире.

**БО́ЙКО** Владимир Андреевич (11.3.1933, Белоруссия ССРның Могилёв ш.), зоолог, эколог, биол. фән. д-ры (1975), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1955). 1955–85 елларда Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-тында, 1974 елдан табигый-төбәк инфекцияләре лаб. мөдире. 1985–93 тә РФА КГҮнең Биология ин-тында экология бүлеге мөдире, 1988 дән директор урынбасары. 1993 тән ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-тында җир өсте экосистемалары бүлеге мөдире һәм директор урынбасары, 2006 дан биомониторинг лабораториясенең баш фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре җир өсте экосистемаларының структур-функциональ оешу мәсьәләләренә һәм аларның антропоген үзгәрешләренә, аеруча саклаулы табигать терр-яләре челтәрен камилләштерүгә; экологиягә, гомуми һәм гамәли паразитологиягә карый. Урта Идел буенда беренчеләрдән булып талпан энцефалиты һәм бөер авыруы синдромлы геморрагик бизгәк һәм табигый чыганакларның биологик комплексларын өйрәнә, ландшафтларның антропоген трансформациясе тәэсирендә кеше һәм хайван авыруларының табигый чыганаклы паразитар системалары оешуның үзгәрү закончалыкларын ачыклый. ТРның Кызыл китабын (1995), ТРның аеруча саклаулы табигать терр-яләре дәүләт реестрын (1998) төзүчеләрнең берсе һәм баш мөхәррире урынбасары. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Геморрагическая лихорадка с почечным синдромом в Среднем Поволжье. К., 1989 (автордаш); Эктопаразиты птиц в Среднем Поволжье. К., 1991 (автордаш); Природные очаги зооантропонозов в трансформированных ландшафтах Республики Татарстан во 2-й половине 20 в. К., 2001 (автордаш); Экология г.Казани. К., 2005 (автордаш).

*Әд.:* Рубцова Р. Путь в незнаемое // Советская Татария. 1964. 13 мая; Аграновский А. А лес растёт. М., 1973.

**БОЙЧУ́К** Сергей Васильевич (14.9.1966, Казан), терапевт, аллерголог, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2007). 1989 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1992 дән Казан мед. ун-тында патологик физиология кафедрасында. Хезмәтләре аллергология, патофизиология, иммунология һәм вирусология мәсьәләләренә карый. Аның тарафыннан атопик авырулар вакытында лимфоцитларда күзәнәкләрнең программалаштырылган һәлакәте (апоптоз) механизмнары тикшерелә һәм аларның озакка сузылуының төп сәбәпләре ачыла.

Хезм.: Изучение механизмов апоптозов лимфоцитов периферической крови больных бронхиальной астмой // Аллергология. 2001. № 1 (автордаш.); Новые аспекты репликации ВИЧ-1: роль эндотелиальных клеток и ВИЧ-1 белка Nef // Медицинская иммунология. 2004. № 6 (автордаш).

**БОКС** (ингл. box — сугу), спорт төре, ике спортчы арасында аерым кагыйдәләргә нигезләнгән йодрык сугышы. Татарстанда Казанның «Көч һәм сәламәтлек» спорт җәмгыятендә үсеш ала (1911). Б. секциясенә («Динамо» физкультура коллективы — 1926, Үзәк физ. тәрбия йорты — 1929) нигез салучылар һәм аның беренче әгъзалары: Б.Бусыгин, Ю.Рузский, В.Брагин, И.Сергеев, П.Мосевич. 1928 елдан Казан шәһәре, 1956 дан ТАССР беренчелегенә ярышлар уздырыла. Татарстанның боксчылар җыелма командасы (1920–30 еллар) РСФСР (1928), СССР (1930), 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында (1928, Мәскәү, Б.Бусыгин финалчы), Профсоюзларның Бөтенсоюз үзәк советы беренчелегенә (1935) уздырылган ярышларда катнаша. Бөек Ватан сугышына кадәр Б. «Динамо», «Медик», «Локомотив», «Крылья Советов», «Спартак» спорт җәмгыятьләрендә, Казан авиация ин-тында, Кызыл Армия йортында алып барыла. ТАССРның иң яхшы боксчылары: Р.Белов, А.Борисов, В.Дмитрошкин, А.Карпов, Б.Карпов, Г.Кожин, А.Янченко. Бөек Ватан сугышы елларында Б. яшүсмерләр арасында пропагандалана. Татарстан боксчылары җыелма командасы СССР яшүсмерләр беренчелегендә бронза (1944) һәм көмеш (1945) медальләр ала. 1944 тән республика боксчылары РСФСР, СССР, Европа, дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарында катнаша. *В.М.Емельянов* — Олимпия уеннарында бронза медаль ала (1964), А.К.*Хәмәтов* — дөнья чемпионы (1989), А.Андрианов — Европа чемпионы (1970), В.Индюков (1972), Ф.Ә.*Гатин* (1990) — СССР чемпионнары, Г.Архипов — СССРның 1 нче яшүсмерләр беренчелегендә җиңүче, Г.Давыдов, З.Шакиров — көмеш медаль алучылар (1944). РСФСР чемпионатларында җиңүчеләр һәм медальләр алучылар: В.Фузеев (1956), Г.Севастьянов (1958), В.А.*Рылов* (1958–60), Э.Еркин (1961), В.Шабанов (1962, 1964, 1966), Р.Хәбибуллин (1962). Б. «Ракета» СКда, «Локомотив», В.В.Маяковский исем. һ.б. физкультура коллективларында пропагандалана. Иң яхшы тренерлар: И.А.Газизов, В.С.Дмитрошкин, В.В.*Краснов*, И.Я.Полтаржицкий, С.М.*Ромодановский*, В.А.Рылов, И.В.Чернавин. Халыкара категорияле судьялар: М.З.Вәлиуллин, Е.Ф.Королёв.

**БОКСУ́**, к. *Билла, Боксу һәм Хәтәни.*

**БОЛА́** елгасы, Идел алдында. Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 117,9 *км* (ТР чикләрендә — 32 *км*), бассейнының мәйданы 1587 *км*². Елга башы Чуаш Респ-касы терр-ясендә, Буа р-нының Исәк авылыннан Бик-Үти авылына кадәрге җирдә Чуаш Респ-касы чиге буйлап ага, тамагы Апас р-ның Дәүләки авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 208 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Б.ның су җыелу уры-

ны — ерымнар, сызалар һәм кушылдык елга үзәннәре б-н нык бүлгәләнгән калку тигезлек. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 6%. Елганың 35 кушылдыгы бар, аларның алтысы ТР терр-ясендә; иң зурлары — Чирмешән (32,8 *км*) һәм Кече Бола (41 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 28 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Елга үзәнлеге трапеция сыман, киңлеге урта агымда 2–4 *км*, түбән агымда — 6 *км* га кадәр. Тугае ике яклы, киңлеге 0,2–4 *км*. Елга юлы бормалы, киңлеге 2 дән алып 14 *м* га кадәр. Елга тирәнлеге сай җирендә 0,2 *м*, киң җирендә 1–3 *м* чамасы. Елга режимы 1950 елдан башлап Апас р-ның Чәтбаш авылы янындагы су үлчәү постында өйрәнелә. Җир асты туендыру модуле



Бола елгасының түбән агымы.

0,11–3 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Чәтбаш авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәлеше 5,1 *м* (макс. 5,9 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 95 *мм*, ташу вакытындагы су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Урыны б-н боз капламы тотрыксыз. Кыш ахырына бозның калынлыгы 67 *см* га җитә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,84 *м*$^3$*/с*. Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–100 *мг/л* га кадәр. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Б. бассейнында гомуми күләме 3 млн. *м*$^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**БОЛА́К**, Казан шәһәре уртасындагы канал (элек — инеш). Озынлыгы 1565 *м*, киңлеге 32 *м*. Гомуми юнәлеше — көньяк-көнчыгыштан төньяк-көнбатышка таба. Каналның ярлары авыш, кәсләнгән, каналның башланган һәм тамак өлешендә бетон стена. Су биеклеге даими түгел, көйләп торыла.

Борынгы Б. инешенең озынлыгы 2,3 *км*, киңлеге 60–70 *м* булган, Түбән Кабан күленнән агып чыгып, Казансу елгасына 2 култык ясап койган. Култыкларның берсе — баткак ярлы Черек Б. кальганы көнбатыш яктан саклауда мөһим урын тоткан (соңрак күмелгән). Инешнең төп су юлы — Олы Б. Казан ханы Габделлатыйф идарә иткән дәвердә (1495–1502) турылап тирәнәйтелгән дип фаразлана. Канал төзү шәһәрнең түбән өлешен киптерү, су б-н тәэмин итү, су юлыннан товарлар йөртү һ.б. мөһим мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеге биргән. Язын Иделдә су ташыганда көчле ташкын Казансу елгасы аша Болакка бәреп кергән, аннан Түбән Кабан күленә юнәлгән. Агымның көчле булуы һәм юнәлешенең үзгәреп торуы инеш һәм Кабан күлләре суының чистаруына булышкан. 17–19 йөзләрдә Б. суының биеклеге плотиналар һәм шлюзлар б-н көйләнгән. Б.ка сәүдә көймәләре кергән, канал ярларына күпләгән причаллар, келәтләр салынган; һәр язда сәүдә ярминкәләре уздырылган. Б. ярлары буйлап йортлар, мунчалар тезелеп киткән, су тегермәннәре эшләгән. Шул вакытта Б. тирәләренә халык та күченеп утыра башлый, һәм 19 йөздә юынтык сулар, көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар ташлау нәтиҗәсендә каналның халәте кискен үзгәрә, ул сууҫемнәр б-н каплана, җәен кибә, 1800 һәм 1815 елллардагы янгыннар вакытында суы бөтенләй бетә. Соңрак каналның имән түшәлмәсе 1,5 *м* га якын калынлыктагы ләм б-н каплана. Б.ны төзекләндерү проектлары тәкъдим ителә (күмеп, аллея булдыру, Мишә елгасыннан һәм якын тирәдәге күлләрдән су кудыру һ.б.). Б.ның төбе, чистартылмыйча гына, берничә тапкыр агач һәм таш б-н түшәлә. Куйбышев сусаклагычы төзелү уңае б-н шәһәрнең түбән өлешен су астында калудан саклау өчен, 1955–56 елларда Б. тамагы күмелә һәм Казансу елгасыннан саклагыч дамба б-н аерып куела. Б.ны сусаклагыч б-н тоташтыручы 546 *м* озынлыктагы җир асты суүткәргече (Идел-Болак каналы) салып калдырыла (гадәттә, ул ябык тора). Каналда су биеклеген көйләү максатында Түбән Кабаннан Б.ка һәм аннан Казансуга су кудыру станцияләре корыла. 1990 елларда Б. ярлары төзекләндерелә, төбе чистартыла, вак таш түшәлә, ярларына кәс җәелә, суга төшү баскычлары, фонтаннар төзелә, канал чуен коймалар б-н корып алына һ.б. Б. — Казанның тарихи өлешендә мөһим шәһәр төзелеше факторы булып тора (к. *Болак ярлары*).

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани., 1895; К а з а н с к и й М.В. О питьевой воде в г. Казани. К., 1904; К а з а к о в И. К вопросу оздоровления озера Кабан и протока Булак // Труд и хоз-во. 1929. № 5; С е м е н т о в с к и й В.Н., В о р о б ь ё в Н.И. Физико-географические экскурсии в окрестностях Казани: Пособие для учителей и самообразования. К., 1940; К а ш т а н о в С.Г. Подземные воды г.Казани. К., 1974; М и н г а з о в а Н.М., К о т о в Ю.С. Казанские озёра: Исторический обзор. К., 1989.

*Н.М.Минһаҗева, Ф.В.Салихова.*

**БОЛА́К** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында. Шонталының сул кушылдыгы (Кама елгасы бассейны). Озынлыгы 9,3 *км*, бассейнының мәйданы 31 *км*$^2$. Алексеев р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Мордва Болагы авылыннан 3,6 *км* көньяктарак, тамагы Тигәнәле Болагы авылыннан 2,8 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 155 *м*, тамагыныкы — 76 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 12%. Б. елгасының 1,7 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,25 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,041 *м*$^3$*/с*. Суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9 *мг-экв/л* дан артыграк). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л* га кадәр.

**«БОЛА́К АРТЫ́ РЕСПУ́БЛИКАСЫ»**. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советы б-н татар милли-демократик көчләренең татар халкының дәүләти үз билгеләнүен (милли мохтариатын) игълан итү өчен көрәшкән көннәрендә барлыкка килгән төшенчә. 1918 елның гыйнварында Казан советы инициативасы б-н татар халкының *Идел-Урал Штатын* рәсмиләштерү омтылышына каршы тору өчен *Идел-Урал төбәге Советлары съезды* чакырыла. Совет җитәкчеләре, съездның Идел-Урал өлкәләрендә яшәүче милләтләрнең Идел-Урал Совет Респ-касы рәвешендә үзбилгеләнү мөмкинлеге турындагы карары б-н килешмичә, *Казан Совет Эшче-Крәстиян Республикасын* төзергә һәм аның гадәттән тыш органы булган *Революцион штабын* оештырырга карар кылалар (1918 ел, 26 февр.). Идел-Урал Штатын рәсми игълан итү Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 2 нче корылтаенда 1918 елның 1 мартына билгеләнгән була. Революцион штаб 28 февральгә каршы төндә корылтай президиумы башлыкларыннан И.Алкин, Җ.Алкин, Г.Токымбәтов һәм Й.Мозаффаровларны кулга ала. Казан татарлары, моңа ризасызлык белдереп, 1918 нең 28 февралендә урамнарга чыгалар. 10 мең чамасы кеше катнашкан демонстрация, кулга алынучыларның ирекка чыгарылуын таләп итеп, Казан советына вәкилләр җибәрә. Ләкин аларның таләбе үтәлми. *Вәисиләр хәрәкәте* штабы урнашкан урында да халык җыелган була. Хәрәкәт җитәкчесе Гайнан Вәисов, килеп туган мондый вазгыятьне үзара килешеп хәл итәргә кирәк, дип белдерә. Бер провокатор тарафыннан ул атып үтерелә. Берничә көннән соң Бөтенроссия мөселман гаскәриләре корылтае эшен шәһәрнең татарлар яшәгән өлешендә — Болак артында, 95 нче запас укчы полк казармасында дәвам иттерә. Революцион штаб шәһәрнең бу өлешен «Болак арты республикасы» дип белдерә (атама авторы Казан советы әгъзасы Л.Р.Милх), аны үзенә буйсынган гаскәри көчләр б-н камый башлый. Корылтайда *Мөселман халык комиссариатын* оештыру һәм Г.Монасыйпов җитәкчелегендә Мөселман революцион штабын төзү карары кабул ителә. Корылтай карары б-н «*Идел-Урал өлкәсе*» г-тасы нәшер ителә башлый. Казан Халык Комиссарлары Советы, өстәмә хәрби көчләр туплап, шәһәрнең Болак арты өлешен камап алуга ирешә һәм 1918 нең 27 мартында Мөселман революцион штабына бер тәүлек дәвамында коралсызлану ультиматумын куя. Ультиматумда билгеләнгән вакыт үткәч, 28 март көнне төштән соң Кызыл Армия отрядлары, ш.и. Мәскәүдән яңарак кына килгән матрослар отряды,

«Б.а.р.» урнашкан тарафка туп һәм пулемётлардан ата-ата һөҗүмгә күчә. Аз санлы милли гвардия дружиналары коралсызландырыла. Татар милли демократия лидерлары кан коюдан баш тарталар, алар йогынтысында булган гаскәри берәмлекләр, ш.и. запас полк сугышчылары үз казармаларында кала. «Тәртипсез атышуларга чик кую» һ.б. чаралар күрү өчен «Шәһәрнең татарлар яшәгән өлешенең Вакытлы революцион штабы» оештырыла, ул Мөселман халык комис-ты һәм Мөселман революцион штабы вәкилләрен кулга ала, аларның өйләрендә һәм эш урыннарында тентүләр үткәрә. Большевик Л.Р.Милх «Б.а.р.»ның юкка чыгарылуы турында 1918 нең 1 апрелендә Мәскәүгә хәбәр итә. *Хәрби Шура* вәкилләре б-н Казан Совет респ-касы башлыклары арасындагы катлаулы сөйләшүләрдән соң кулга алынган корылтай җитәкчеләре азат ителә, Хәрби Шура тарафыннан оештырылган мөселман гаскәри берәмлекләре Казан хәрби округына буйсындырыла. Хәрби Шура җитәкчелеге киләчәктә Идел-Урал Штатын гамәлгә ашыру чараларына керешмәскә сүз бирә. РСФСР ХКСның 1918 нең 24 март декреты б-н Хәрби Шура эшчәнлеге тыела. Декретта ш.у. *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасын* төзү тәртибе дә игълан ителә. 1918 нең апрелендә *Милли Идарәне* тарату фәрманы чыгарыла. Шул рәвешле 1917 елда Бөтенроссия мөселман корылтайларында оештырылган һәм сайланган барлык төрки-татар милли-демократик идарә оешмалары май аенда тәмам гамәлдән чыгарыла. «Б.а.р.» — татар халкының милли азатлык һәм үз дәүләтчелеген торгызу омтылышы тарихындагы иң фаҗигале бер этап. Бу вакыйга барышында татарларның милли-демократик юл б-н сайланган барлык оешмалары бетерелә, үзара килешү тәртибендә милли үзбилгеләнү мөмкинлеге тормышка ашырылмыйча кала. «Б.а.р.» тирәсендә барган вакыйгалар большевикларның милли федераль дәүләт төзелешенә булган мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. 1930 елларда башланган сәяси репрессияләр вакытында милли-демократик оешмалар эшчәнлегендә катнашу иң зур гаеп санала. Совет тарих фәнендә «Б.а.р.» вакыйгалары татар милли буржуазия вәкилләренең Совет хакимиятенә каршы оештырылган көрәше буларак бәяләнә.

*Әд.:* Вәлиев Р.К. Болак арты республикасы. К., 1999; Сагидуллин М. Татарские трудящиеся на путях Великого Октября. К., 1931; Мухарямов М.К. Октябрь и национальный вопрос в Татарии. К., 1958; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; шул ук. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000.

*Р.К.Вәлиев.*


**БОЛА́К ТИМЕ́Р**, к. *Булат Тимер бәк.*

**БОЛА́К ЯРЛАРЫ́**, Казан шәһәрендә. Канал ярлары яшел чирәм б-н капланган, кырыйлары бизәкле чуен рәшәткәләр б-н тотып алынган, урыны-урыны б-н бетон стеналар утыртылган. Казан ханлыгы чорында Болак саклану сызыгы булып хезмәт иткән. 1552 елга кадәр инешнең уң яры буйлап Казан ханлыгы (посад) агач диварлар б-н әйрылган (1530 да төзелә). Болакны көймәләр йөрешле хәлгә китерү юнәлешендәге беренче эшләр турында мәгълүматлар 15 йөз ахыры — 16 йөз башларына карый. Б.я.ндагы, шәһәр кальгасы дивары янында Таһир мунчасы була. Болак тамагына якынрак җирдә «Ташаяк» ярминкәсе урнаша. Атамасы базар салымы җыю өчен куелган таш савыттан килеп чыккан дип фаразлана. 17–18 йөзләрдә Болак күперләре күтәртелә торган итеп агачтан салынган була. Аларның берсе, шул күперне төзеткән сәүдәгәр Жарковский фамилиясе б-н аталганы, 1815 елгы янгын вакытында янып бетә. 1730 да Болакның уң ярындагы диварлар сүтелә һәм алар урынында торак йортлар, көймәләрдә китерелгән товарларны саклау өчен күпсанлы келәт-складлар төзелә. 19 йөз башыннан ел саен май аенда ярминкә («Язгы биржа») үткәрү гадәте яңартыла. Б.я.нда күңел ачулар оештырыла, цирк мәйданчыклары, кибетләр, төз чатырлар, келәтләр тезелеп китә. Нәтиҗәдә бернichә гасыр



Реаль училище яныннан Болак һәм Романов күпере күренеше. 20 йөз башы фотосы.


эчендә Болак җыелма сулар каналына әверелә һәм 19 йөз башында аны чистарту мәсьәләсе килеп туа. Шул максаттагы проектларның берсе 1807 дә инженер Щевякин тарафыннан эшләнә. Анда канал төбен чистарту, ярларын ныгыту һәм төзекләндерү күздә тотыла, ләкин, акча җитмәү сәбәпле, проект гамәлгә ашмый кала. 1829–30 елларда каналга П.Г.Пятницкий проекты б-н үзгәрешләр кертелә: төбе чистартыла һәм тирәнәйтелә, яр битенә кәс җәелә, яңа агач күперләр салына. 1853 тә, Шәһәр думасы карары б-н, Болак суын пычрак ләмнән чистарту өчен аның төбенә чуерташ түшәлә. Ләкин, алдан чистартылмаганлыктан, аның төбе күтәрелә, нәтиҗәдә су агымы акрыная һәм ләм тагын да ныграк утыра. 19 йөз башында Болак тирәсендә таш йортлар һәм келәтләр, складлар салына башлый. 19 йөзнең 2 нче яртысында төзелгән җәмәгать биналары, гыйбадәтханәләр, торак йортлар, Реаль уч-ще (1878, арх. Х.Г.Пашковский), Казандагы Икенче ир балалар гимназиясе, Никольский единоверлар чиркәве (1858–62), җәмәгать мунчалары һ.б. б-н Болак буе комплексы тәмам формалашып җитә. 19 йөз ахырында Болак буе урамнарына таш түшәлә, ике яктан трамвай юллары салына. Шул ук вакытта каналга су кертү һәм аның биеклеген көйләп тору өчен Болакның Түбән Кабан күленә тоташкан урынында буа һәм су җибәрү каналлары төзелә. 1914 тә Шәһәр думасы инженер Еншның,



Болак һәм а́ркалы күпер күренеше. Арх. Ү.Г.Алпаров, М.К.Игъламов. 1940 еллар ахыры – 1950 еллар башы.

Болакны юан торба эчендә калдырып, өстен җир б-н тигезләү проектын раслый. 1915 тә эшкә дә керешелә, ләкин акча җитмәү сәбәпле туктатыла. 20 йөз башында Болакта 6 күпер була. Күл б-н тоташкан урындагы беренче күпер «Татар күпере» дип атала, 1905 елда ул 2 нче трамвай юлы салу өчен киңәйтелә. 2 нчесе (Университет урамында), 3 нчесе (Казандагы Икенче ир балалар гимназиясе янында), 4 нчесе — Романов күпере (Реаль уч-ще янында) — агачтан салына, 5 нчесе — Лебедев күпере (шәһәр башлыгы фамилиясе б-н аталган) — таштан (1907, арх. Л.К.Хрщонович дип фаразлана), 6 нчысы — Кузнечный күпере (әлегрәк бу тирәдә тимерче алачыгы булган) — агачтан төзелә. Ул тагын бер трамвай юлы үткәрү өчен киңәйтелә (Гостиный двор, хәзерге Чернышевский урамында).

1928 дә Болакны яңадан үзгәртеп кору эшенә керешәләр. Казан шәһәр башкарма ком-ты каршындагы махсус ком-т инженер Енш проектын гамәлгә ашыруны дәвам иттерергә дигән карар кабул итә. Беренче һәм икенче күпер арасына торба салына, ләкин, ләм тыгылу сәбәпле, 1929 да эш туктатыла. 1930 еллар уртасында Болакның тарихи йөзен саклап калу өчен яңа проект барлыкка килә (инженер А.Доценко, «Ленгипрогор» ин-ты). 1936–38 дә ермак тирәнәйтелә, чирәм-



Болакның хәзерге күренеше.

ле ярлары төзекләндерелә, Идел-Болак суүткәргече һәм су кудыру станциясе корыла башлый. Бөек Ватан сугышы елларында эш тукталып тора.

Сугыштан соң, ташу вакытында Түбән Кабан күле суының биеклеген көйләү өчен, Болак башында һәм тамагында су җибәрү капкалары төзелә. 1940–50 елларда Б.я. арх. Ү.Г.Алпаров һәм М.К.Игъламов проекты б-н үзгәртелә, чуеннан коелган рәшәткәләр корыла, агач күперләр бетоннары б-н алыштырыла. 1950 елларда Куйбышев ГЭСы төзелеше вакытында шәһәрне су басудан саклау максатыннан канал тамагы б-н Казансу елгасы арасына дамба өйдерелә, дамба астына 2,5 *м* киңлектәге суүткәргеч салып калдырыла. Идел б-н исә Болак 1 *м* диаметрлы борынгы җир асты суүткәргече аша тоташа. Гадәттә, ул эшермә ярдәмендә ябылып тора. Каналда һәм күлләр системасында суны даими биеклектә тоту өчен Болак тамагына һәм Урта Кабан күле буена 2 су кудыру станциясе корыла (к. *Болак*). 1970 елларда каналны үзгәртеп корунын «Ленгипрогор» ин-ты эшләгән яңа проектта, Болакны күмәргә һәм төбеннән тизйөрешле автомагистраль үткәрергә тәкъдим ителә. Проект кире кагыла, чөнки Б. шәһәрнең дренаж системасында мөһим урын алып тора. 1975–77 дә каналның уң ярыннан җылы кудыру магистрале үткәрелә, чирәмле яр урынына бетонланган диварлар салына (арх. Ю.В.Гребнёв). 1980 еллардан Болакны үзгәртеп кору б-н «Казгражданпроект» ин-ты (арх. Ү.Г.Алпаров, Р.Ш.Дустиев җитәкчелегендәге авторлар коллективы) шөгыльләнә. 1990 еллар башында каналның Казан циркы янындагы өлеше төзекләндерелә. 1990 еллар ахырында Болакка фонтаннар урнаштырыла. Үзгәртеп кору эшләре дәвам иттерелә.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *О.Н.Авксентьева.*

**БОЛАМЫ́К** посёлогы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 5 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2002 елда 30 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Акимбетово исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә, алпавыт утарында ялланып эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 488,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт Мулла Иле волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. 1967 нең 26 октябрендә, Мортыштамак авылы б-н кушылу сәбәпле, авыллар исемлегеннән сызыла. 1997 нең 18 сентябрендә аерым торак пункт буларак яңадан теркәлә. Халык саны: 1816 да — 32 ир заты; 1859 да — 192, 1870 тә — 142, 1913 тә — 261, 1920 дә — 286, 1926 да — 249, 1938 дә — 212, 1949 да — 118, 1958 дә — 83 кеше.

**БОЛА́Н** (? — 740 тирәсе), Хәзәр каганлыгы идарәчесе (шад). 721–22 елларда гарәпләр һөҗүменә каршы сугышуы, җиңелүе һәм Сәмәндәр б-н Бәләнҗәр шәһәрләрен калдырып китүе мәгълүм. Соңрак, көч туплап, гарәпләргә каршы чыга, гарәп-мөселманнардан явызларча үч алуы б-н таныла. Аксөяк-вассаллары б-н көрәш барышында, үз хакимиятен ныгыту максатында, яһүдиләр динен кабул итә. Үзара көрәш вакытында һәлак булган дип фаразлана. Оныгы *Обадия каган* заманында хәзәр аксөякләре арасында яһүдиләр дине киң тарала.

Чыг.: К о к о в ц е в П.К. Еврейско-хазарская переписка в X в. Л., 1932.

*Әд.:* А р т а м о н о в М.И. История хазар. Л., 1962; Н о в о с е л ь ц е в А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990.

**БОЛА́Н КОҢГЫ́З**, мөгезләч (Lucanus cervus), мөгезле коңгызлар семьялыгыннан иң эре коңгыз. Ана коңгызның озынлыгы 28–45 *мм*, ата коңгызныкы, өске казналарыннан башка, 30–55 *мм*, алар б-н 75 *мм* га кадәр. Ата коңгызның өске казналары һәм канатлары аксыл-коңгырт, ана коңгызныкы кара төстә. Ана коңгыз агач куышына, черек агач төпләренә яки агач төбе янындагы туфракка эре (2,2 *мм* га кадәр), озынча йомырка сала, личинкалары черек үзагач б-н туена. Личинкалары С сыман, коңгырт башлы, аяклары яхшы үскән, гәүдәсенең арка ягы шома һәм аның очында характерлы ике сөяле бар. Личинкалар 5 ел чамасы үсә, зур личинканың озынлыгы 13,5 *см* га җитә. Б.к. урман зонасының көньягында һәм урманлы далада, нигездә имән урманнарында очрый. Июль һәм август айларында коңгызлар каты безелдәп имән агачы башлары тирәсендә очалар, еш кына агач согы агып торган урын өчен, ш.у. ана коңгызлар өчен үзара сугышалар. Татарстан терр-ясендә Б.к. ын Идел-Кама саклаулыгының Саралан һәм Раифа бүлемтегендәге имәнлекләрдә, Тәтеш, Мамадыш һ.б. р-ннардагы киң яфраклы имән агачыннан сок аккан вакытта күрергә мөмкин. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*А.К.Жеребцов.*

**БОЛА́Н ҮЛӘНЕ́**, к а р д а р и я (Cardaria), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлек ыругы. 8 төре билгеле, Евразиядә таралган. ТР терр-ясендә борычлы Б.ү. (C. draba) төре үсә. Читтән кергән үсемлек. Көнбатыш Кама арты һәм Идел алды терр-яләрендә очрый. Тимер юл буйларында, чүп-чар җыелган урыннарда, торак пункт тирәләрендә үсә. Кыска, тармакланган калкансыман ботаклы, биеклеге 20–50 *см* булган үсемлек. Тамырчасы үрмәле. Тамырга якын яфраклары чыбыкчалы, уемтылы, озынча, киң сабаклы, утырып торган шикелле, ланцетсыман. Чәчәкләре вак, ак, хуш исле, калкансыман куе чәчәк төркеменә урнашканнар. Җимеше — кабарынкы ялан капкачлы кузакчык. Май–июньдә чәчәк ата. Июнь аенда җимеш бирә. Үсемлек составында алкалоид, кумарин, флавоноид, C, B, витаминнары, каротин бар. Җимешендә май табылган. Халык медицинасында зәңгелә авыруына каршы Б.ү.нең төнәтмәсе, җимешләре һәм яфраклары тире авырулары вакытында кулланыла. Орлыгы тәмләткеч үзлегенә ия һәм борычны алыштыра ала.

**«БОЛГАВЫ́Р ЗАМА́Н»**, рус патшалыгында 16 йөз ахыры — 17 йөз башындагы вакыйгаларның гомумиләштерелгән атамасы. Казан төбәгендә «Б.з.»да төрле кузгалыш-хәрәкәт күзәтелә: татар, мари, чуаш халыкларының милли ирекккә омтылышлары, рус крәстияннәренең феодалларга каршы, феодалларның өстенлек өчен үзара көрәшләре көчәя. Элекке Казан ханлыгы биләмәсендә дә берничә урында халык кузгалышы башлана (к. *Казан җирләрендә халык кузгалышлары*). Бу вакытта Казан өязе воеводалары булган В.П.*Морозов*, Б.Я.*Бельский*, дьяклар Н.М.*Шульгин* һәм С.Я.Дичков Польшаның Россиягә интервенциясенә каршы да, патша Василий Шуйскийны яклап та активлык күрсәтмиләр, үзәктә барган вакыйгалардан читтәрәк торалар. Казанлыларның Лжедмитрий II не тануы турында да мәгълүмат юк. Бу чорда Казан төбәге үзәктән аерым яши, сәяси тотрыксыз чор кичерә. 1609 елның көзендә халык кузгалышы тагын көчәя. Шул елның ахырында һәм 1610 ел башында Зөя каласы камалыш хәлендә кала. 1610 елда Василий Шуйский тәхеттән төшерелә, хакимият җиде бояр кулына күчә («семибоярщина» чоры). Август башында үзәктән килгән чапкыннар казанлыларны Ф.И.Мстиславский җитәкчелегендәге боярларга ант итәргә боерсалар, август ахырында инде Польша короле Сигизмунд улы Владиславны Россия патшасы итеп чакыралар. Воевода, бояр Б.Д.Бельский җитәкчелегендә кайбер феодаллар Мәскәү боярларына турылыклы булуларын белдерә, дьяк Н.Шульгин тирәсенә тупланучылар аларга каршы чыга. Халыкның салым-җыем түләүдән интеккән күпчелеге үз хокукын даулап күтәрелә. «Яңа елъязма»да («Новая летопись») билгеләп үтелгәнчә, Н.М.Шульгин, шушы форсаттан файдаланып, Б.Д.Бельский төркеменә каршы фетнә оештыра. Воевода яклыларның күпчелеге юк ителә, Б.Бельский Кремль диварыннан ташлап үтерелә. 1611 нең 7 гыйнварында Мәскәүдән дьяк А.Евдокимов килә, берләшеп, полякларга каршы чыгарга өнди. Казан халкы җавап итеп 9 гыйнварда Лжедмитрий II гә тугрылык турында ант итә. Лжедмитрий II нең 1610 ның декабрендә вафат булуы турында Казанда әле белмиләр. Бу вакытта кайбер рус феодаллары Казан төбәген мөстәкыйль дәүләт итәргә хыялланган дип тә фаразлана (ул идея авторының Н.Шульгин булуына сылтама бар). Башта Лжедмитрий II гә ант итүләре, соңрак аннан һәм мәскәүлеләрдән баш тартырга ниятләүләре үзенә күрә бер авантюралы адым булса кирәк. 1611 дә Түбән Новгородтан һ.б. шәһәрләрдән вәкилләр киләләр, казанлыларны интервентларны куып җибәрергә, Мәскәүне азат итү өчен берләшергә чакыралар. Воевода казнасында акча булмау сәбәпле, ясаклылардан өстәмә салым җыярга карар кылына. Бу карар ясаклылар арасында ризасызлык тудыра. Шуңа да карамастан, воевода М.П.Морозов, зур булмаган ополчение туплап, башкалага таба юнәлә. Ул киткәч, Казанда җитәкче булып Н.Шульгин кала. 1611 нең августында Казан митрополиты Ефремга түбәнновгородлылар аша патриарх *Гермогенның* казанлыларны Лжедмит-

рий II нең улына һәм М.Мнишекка ант итмәскә үгетләгән мөрәҗәгате җиткерелә. Шуннан соң Н.Шульгин элекке ниятеннән кайта, патриотик көчләргә каршы килергә батырчылык итми. Ләкин әле Казан һәм аңа буйсынулы шәһәрләр вакыйгалар барышын читтән күзәтүгә өстенлек бирәләр, Мәскәү тәхетенә «чын патша» утыруын көтәләр. Түбән Новгородта К.Минин б-н Д.Пожарский икенче ополчение туплыйлар, ярдәм итүне сорап, Казанга сарай хезмәтчесе И.Биркинны җибәрәләр. Н.Шульгин, И.Биркин б-н сүз куешып, ярдәмгә көч тупларга ашыкмый. Түбән Новгород ополчениесе яуга кузгалгач кына И.Биркин отряды юлга чыга. Түбәнновгородлылар аны Ярославль шәһәре янында көтеп алалар. Казан отряды анда да икегә бүленә: Н.Шульгин әмерен үтим, дип, И.Биркин аның бер өлеше б-н кире борылып китә. Отрядның татар бәк-морзаларыннан торган, «татар башлыгы» Л.Мясной б-н 150 стрелецка баш булган П.Неелов җитәкчелегендәге өлеше Мәскәүне азат итүдә катнаша. Сакланып калган язмалардан ш.у. казанлы И.С.Левашев б-н морза Келәүле Мөрәлиев һ.б.ның Мәскәү сугышында катнашуы мәгълүм. Казан феодалларының тотрыксызлык сәясәте Михаил Фёдоровичны патша тәхетенә тәгаенләү көннәренә кадәр дәвам итә. Мәскәүне азат итүдә катнашкан Л.Мясной б-н П.Неелов та, Казанга әйләнеп кайтуга, Н.Шульгин әмере б-н төрмәгә ябыла.

1613 елгы Земство җыенында патша тәхетенә Михаил Фёдор (Филарет) улы Романовтан кала элекке ханнар нәселеннән булган берничә татар бәк-морзасы да тәкъдим ителә. Н.Шульгин Земство җыены карары б-н килешмәвен, Михаилны патша итеп танымавын белдерә. Арзамастан Казанга кайтып, фетнә әзерләргә ниятли. Бу вакытта Казан түрәләре яңа патшаны тану турында ант биргән булалар. Н.Шульгинны Зөя каласында кулга алалар, Мәскәүгә озаталар. Шуннан ул Себергә сөргенгә җибәрелә.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Казанский край в смутное время. К., 1891; Е р м о л а е в И.П. Казанский край во второй половине XVI–XVII вв. К., 1980; ш у л у к. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. К., 1982; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

**БОЛГА́Р**, урта гасырлардагы (10–16 йөзләр) болгарлар шәһәре, Иделнең сул ярыннан 5 *км* читтә, Чулман елгасы кушылган урыннан түбәнрәк урнашкан була. Хәрабәләре хәзерге Спас р-ны Болгар шәһәре янында (к. *Болгар шәһәрлеге*). Б. 10 йөздән гарәп галимнәре (Ибне Рустә, әл-Җәйхани һ.б.) хезмәтләрендә, 14 йөздән рус елъязмаларында телгә алына. Көнчыгыш Европадагы эре сәяси-сәүдә һәм һөнәрчелек үзәкләреннән берсе, Идел буенда ислам динен таратуга зур өлеш керткән шәһәр. Баштарак әмирлек, 10 йөз башыннан *Идел буе Болгар дәүләте*, 13 йөз урталарыннан *Болгар бәклеге* башкаласы була (ш.у.к. *Биләр*).

920–998 елларда Б.да болгар идарәчеләре исеменнән акча суктырыла. 12 йөз урталарында, рус кенәзләренең һөҗүм-яулары ешаю сәбәпле, Б. элеккеге сәяси һәм икътисади әһәмиятен югалта төшә, сәяси үзәк Биләргә күчә. 1236 да Б.ны Бату хан гаскәре яулап ала, өлешчә җимерә, яндыра. 1240 елларда яңадан торгызыла һәм Бату хан нигезләгән Алтын Урданың беренче башкаласы булып тора. 14 йөз ахырларына чаклы Б. Алтын Урдада акча суктыру үзәкләренең берсе санала. 1250 еллардан Идел буендагы иң эре сәүдә һәм һөнәрчелек үзәкләреннән берсе. Б. шәһәренең иң югары үсеш дәвере 14 йөзгә туры килә (җәмәгать биналары, мәчетләр төзелә, һөнәр-кәсепчелек зур үсеш ала). *Алтын Урдада тәхет чуалышлары* вакытында, 1361 дә, Б.га Алтын Урда әмире *Булат Тимер Бәк* баш була. 1367 дә аны төшереп, шәһәрне әмир Хәсән үз кулына ала. 1370 һәм 1376 елларда, Мамай әмерен үтәп, Мәскәү кенәзе Дмитрий Иванович гаскәрләре Б.га яу б-н килә һәм шәһәргә җитди зыян китерә. 14 йөз ахыры — 15 йөз башларында, Алтын Урда көчсезләнгәч, Б.га рус кенәзлекләре һөҗүмнәре ешая. 1366, 1374 тә шәһәрне рус *ушкуйниклары*, 1399, 1429 һәм 1431 дә рус кенәзләре гаскәрләре басып алып, талап-җимереп китәләр. Шул ук чорда Урта Идел төбәгендә Казан каласының сәяси һәм икътисади яктан күтәрелә баруы Б.ның әкренләп элекке әһәмиятен югалтуына китерә. 15–16 йөзләрдә Б. Казан ханлыгының рухи һәм икътисади үзәкләренең берсе булып кала. Татар ханлыклары Рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң, татарлар Б. шәһәреннән көчләп куыла. 18 йөз башында Б. биләмәсендә Успение ирләр монастыре нигезләнә һәм аның янәшәсендә руслардан Б. авылы барлыкка килә. 17–18 йөзләрдән башлап бүгенге көнгә кадәр элекке шәһәр урыны мөселманнарның зиярәт кылу үзәкләренең берсе буларак билгеле.

Чыг.: Летописец Переяславля Суздальского. М., 1851; П р и с е л к о в М.Д. Троицкая летопись. М.–Л., 1950; Полное собрание русских летописей. М., 1965. Т. 1, 2, 4, 5, 13, 15, 18, 24, 25.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи-әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Б е р е з и н И.Н. Болгар на Волге. К., 1853; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Е г о р о в В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985; Город Болгар: Очерки истории и культуры. М., 1987; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994; Х а л и к о в А.Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. К., 1994; Х у з и н Ф.Ш. Болгарский город X – нач. XIII вв. К., 2001.

*И.Л.Измайлов.*

**БОЛГА́Р** елгасы, Көнчыгыш Кама арьягында. Урсалының уң кушылдыгы (Дала Зәе елгасы бассейны). Озынлыгы 9,8 *км*, бассейнының мәйданы 29,8 *км*$^2$. Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Болгар-1 авылыннан 2,3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Яңа Кәшер авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 221 *м*, тамагыныкы — 121 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 36%. Б. елгасының 0,7 һәм 1,6 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 105 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,13 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр.

**БОЛГА́Р**, район карамагындагы шәһәр, Спас р-ны үзәге. ТРның көньяк-көнбатышында, Казаннан 140 *км* ераклыкта, Идел елгасының (Куйбышев сусаклагычының) сулъяк ярында, Ульянов–Уфа тимер юлының Чардаклы станциясеннән 71 *км* төньяктарак. Мәйданы — 8 *км*$^2$. Халкы — 2006 елда 8,5 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 79,4%, татарлар — 16,9%). Ит, икмәк комб-тлары, икмәк кабул итү пр-тиесе, тегү ф-касы. 2 урта һәм 1 сәнгать мәктәбе, 3 интернат-мәктәп, һөнәри лицей. Мәдәният йорты, 2 китапханә, төбәк тарихын өйрәнү музее. Мәчет. Чиркәү. 17 йөзнең 40 елларыннан Никольский (Чертыково) авылы буларак мәгълүм. 1781 елдан Спас дип атала башлый һәм өяз шәһәре статусын ала. 1917 гә кадәр он тарту үзәге була һәм күрше өязләр өчен товарларны күчереп төяү урыны булып хезмәт итә. 20 йөз башында шәһәр пристане аша һәр елны 2,5 млн. пот йөк ташыла. Бу чорда Б.да изге Троица чиркәве, гариплләр йорты, хастаханә, китапханә, банк, 3 уч-ще; 19 су һәм

Болгар шәһәре. 1. Район мәдәният йорты; 2. Элемтә йорты; 3. Район үзәк хастаханәсе.









җил, 10 ярма ярдыру тегермәне, 1 туңмай эретү з-ды, 2 кирпеч сугу йорты, 70 ләп вак кибет һәм склад-амбарлар була. Якшәмбе саен базар эшли, июньдә зур ярминкә үткәрелә. 1926 да — Татар Спасы, 1935 нең 1 апрелендә — Куйбышев, 1991 нең 4 октябрендә Болгар дип үзгәртелә. Идел ГЭСын төзегәндә су астында каласы булганга күрә, 1950 еллар уртасында элеккеге урыныннан (Бизнә елгасы тамагы тирәсендә) 23 *км* көнбатышкарак тулысынча күчерелә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Спас өязе үзәге, 1920 дән ТАССРның шул ук исемдәге кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1859 да — 1607, 1897 дә — 2779, 1926 да — 3561; 1939 да — 6,2 мең, 1959 да — 7 мең, 1989 да — 8,4 мең кеше. Шәһәр янында *Болгар шәһәрлеге* урыны саклана.

*Әд.:* С а б и р о в Р.М. По городам Татарии. К., 1976.

**БОЛГА́Р** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 65 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы бассейнында. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. 1924 тә нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантонының Чыршылы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 114, 1949 да — 253, 1958 дә — 131, 1970 тә — 116, 1979 да — 58, 1989 да — 18 кеше.

**БОЛГА́Р** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 1 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2002 елда 223 кеше (руслар) яши. 18 йөз башында Успение монастыре (1712 еллар тирәсендә элеккеге Болгар шәһәрлеге урынында төзелә) каршындагы бистә буларак нигез салына, шуңа да авылның икенче исеме — Успенский. Халкы — монастырь, 1764 елдан — икътисади, соңрак дәүләт крәстияннәре катлауларына керә; игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балык тоту, бакчачылык, кирпеч сугу, тимерчелек, балта, буяу эшләре б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Успение чиркәве (1732–34 елларда сәүдәгәр И.А.Михляев иганәсенә төзелә), иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, земство мәктәбе (1886 да ачыла), 8 җил һәм 4 ярма ярдыру тегермәне, 3 тимерчелек, 9 кирпеч з-ды, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6013,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Өчкүл волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 294 ир заты; 1859 да — 1655, 1897 дә — 2455, 1908 дә — 2835, 1920 дә — 2649, 1926 да — 1689, 1938 дә — 947, 1949 да — 795, 1958 дә — 520, 1970 тә — 487, 1979 да — 381, 1989 да — 279 кеше.

*Әд.:* Приволжские города и селения в Казанской губернии. К., 1892.

**БОЛГА́Р** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Түбән Кама–Кама Аланы автомобиль юлы буенда. 2002 елда 259 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Клуб. Китапханә. Мәчет. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чаллы кантонында, 1930 елның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 187, 1938 дә — 469, 1949 да — 376, 1958 дә — 381, 1970 тә — 522, 1979 да — 452, 1989 да — 265 кеше.

**БОЛГА́Р-1** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Болгар елгасы буенда. 2002 елда 74 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 1918 дә Яңа Кәшер авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Самара губернасының Бөгелмә өязе Урсала волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 269, 1938 дә — 385, 1949 да — 301, 1958 дә — 201, 1970 тә — 216, 1979 да — 139, 1989 да — 25 кеше.

**БОЛГА́Р-2** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 57 *км* төньяктарак, Урман Зәе елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 58 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, мөгезле эре терлек асрау. 1923–24 тә Күтәмәле авылыннан (хәзер Сарман р-нында) күчеп утыручылар нигез сала. ТАССРның Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 221, 1938 дә — 256, 1949 да — 254, 1958 дә — 183, 1970 тә — 188, 1979 да — 116, 1989 да — 56 кеше.

**БОЛГА́Р БӘКЛЕГЕ́** (әмирлек) (Болгар олысы), Идел-Чулман елгалары аралыгында урнашкан адм.-терр. берәмлек. Монголлар явыннан соң, элекке *Идел буе Болгар дәүләте* җирлегендә 13 йөздә барлыкка килә. *Алтын Урда* ханнарына вассаллык буйсынуында була. Биләмәсенә Чулман буеның көнбатыш өлеше һәм Иделнең көнбатыш яр буйлары кергән дип фаразлана. Башкаласы — *Болгар*. Төп халкы болгарлар, кыпчаклар һәм фин-угырлар. Терлекчелек һәм игенчелек төп шөгыльләре санала. Бакыр, җиз кою, тимер эшкәртү, балчыктан керамик әйберләр ясау, тире иләү, күн эшкәртү остаханәләре булган, зәркәнчелек һ.б. кәсепчелекләр алга киткән. Алтын Урданың барлык олыс-өлкәләре рус кенәзлекләре һәм Балтыйк буе илләре б-н сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырган. Халкының күпчелек өлеше ислам динен тоткан. Б.б. идарәчесе, әмир яки бәк, Алтын Урда ханнары биргән ярлык нигезендә идарә итә, хакимлеге чикләнгән була. Алтын Урдада тәхет чуалышлары вакытында, 1360 елларда, җирле аксөякләрнең сәяси һәм икътисади мөстәкыйльлеккә омтылышы күзәтелә. 1361 елда *Булат Тимер бәк* мөстәкыйль Болгар әмирлеген оештыра. 1367 дә рус кенәзлеге гаскәре б-н сугышта җиңелгәннән соң, бәклек тәхетенә җирле идарәче итеп *Хәсән бәк* утыртыла. Алтын Урдадагы таркаулык дәверендә Б.б. Алтын Урда ханнары һәм рус кенәзләренең басымы астында яши, яу-һөҗүмнәргә дучар була. 1370 дә Мамай әмир әмере б-н Суздаль кенәзе Дмитрий җитәкчелегендәге рус-татар гаскәре яу б-н килергә ниятләгәч, Хәсән бәк үзен Мамай кул астында дип танырга, тәхетен аның вәкиле Мөхәммәд Солтан б-н бүлешергә мәҗбүр була. 1366 һәм 1374 елларда Б.б. биләмәләре рус елга ушкуйниклары тарафыннан талана, җимерелә. 1376 да Б.б.нә Мәскәү кенәзе Дмитрий Иванович (Донской) зур яу б-н килә (к. *Болгарга 1376 елгы яу*). 1380–1410 еллар аралыгында Б.б. хәрби көчләре Алтын Урдага яу б-н килүче Аксак Тимер һәм рус кенәзлекләре гаскәрләренә каршы сугышларда Туктамыш хан һәм Идегәй ягында торып катнашалар. Б.б. 1391 дә Новгород кенәзе һәм 1399 да Мәскәү кенәзе яуларына каршы тора. Мәскәү кенәзлеге тарафыннан 1429, 1431 елларда оештырылган яулар һәм аксөякләрнең үзара көрәш-бәрелешләре нәтиҗәсендә 15 йөз башында Б.б. тәмам көчсезләнә. 1438 елдан соң ул Казан ханлыгына керә.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Материалы по истории Татарии. К., 1948; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Город Болгар: Очерки истории и культуры. М., 1987.

*И.Л.Измайлов.*

**БОЛГА́Р БЕЛӘ́Н РУС КЕНӘЗЛЕКЛӘРЕ́ СУГЫШЛАРЫ́**, 10–13 йөзләрдә рус кенәзләре Идел буе Болгары биләмәсенә берничә зур яу оештыралар. 985 елда Болгар иленә Киев бөек кенәзе *Владимир I* яу б-н килә. Ләкин ул уңышка ирешә алмый, яу ике арада беренче мәгълүм солых төзү б-н тәмамлана. Владимир-Суздаль кенәзлеге оешкач, 12–13 йөзләрдә Идел буе Болгарына һөҗүмнәр ешая. 1120 елда Владимир-Суздаль кенәзе Юрий Долгорукий зур гаскәр б-н килә, каршы торучы көчләрне тар-мар итә, берничә торак пунктны яулап ала. Кенәзнең бу һөҗүме кайнатасы *Әййүб ханның* (кыпчаклар идарәчесе) болгарлар тарафыннан үтерелүе б-н бәйле дигән фикер дә яши. Ю.Долгорукийның улы кенәз Андрей Боголюбский Владимир-Суздаль кенәзлеге б-н идарә иткән елларда болгарлар яшәгән төбәкне яулау омтылышы көчәя. Идел-Ука төбәге мордваларын буйсындыргач, 1164 тә кенәз Идел буйлап корабларда болгарлар иленә басып керә, Чулман тамагына кадәр җитә, Ибраһим (рус язмаларында Бряхимов) шәһәрен яулап ала, яндыра. 1171/72 нең кыш айларында кенәз Мстислав Андреевич гаскәре Муром һәм Рязань кенәзлекләре хәрби дружиналары б-н бергә Иделнең уңъяк ярындагы болгарлар җиренә һөҗүм итә, 1 шәһәр һәм 6 авылны яулап ала. Болгарларның 6–7 мең кешелек гаскәре исә русларның берләштерелгән гаскәрен Ука елгасы тамагына кадәр эзәрлекләп бара. 1183 нең җәендә Владимир-Суздаль кенәзлеге идарәчесе *Всеволод III Большое Гнездо*, үзенә союздаш Киев, Смоленск, Көньяк Переяславль, Рязань, Муром кенәзләре гаскәрләрен берләштереп, зур гаскәр б-н Болгар иленә — Биләр шәһәренә һөҗүм итә. 6–7 меңлек гаскәр Чулман тамагында көймә-кораблардан төшә, Тухчин шәһәрен камый. Әмма өч көн камап та ала алма-


гач, Биләргә таба китә. Якын-тирә авыл, шәһәрләрдән ярдәмгә килгән болгарлар шәһәрне яуларга ирек бирмиләр, баскын көчләрне камап алалар. Ун көн дәвамында капма-каршы торганнан соң үзара солых төзелә. Ләкин кенәз Всеволод III тиздән килешүне боза, 1185 тә болгарлар җиренә Городец шәһәре воеводасы җитәкчелегендә гаскәр туплап җибәрә. Ул гаскәр берничә авылны басып ала, талый. 1205 тә Всеволод III кабат Идел буйлап күпләгән көймә-корабларда һөҗүм итә, елга буендагы торак пунктлар талана. 1220 елда Владимир-Суздаль кенәзе Юрий Всеволодович, болгарларның Устюг шәһәренә булган һөҗүменә каршы, үз туганы кенәз Святослав җитәкчелегендә болгарлар иленә яу оештыра. Бу гаскәр 15 июньдә *Ашлы* шәһәрен басып ала һәм аны тәмам яндыра. Ашлыга оештырылган һөҗүмнән соң ике арада килешү төзелә (к. *Болгар-рус килешүләре*). Шушы яу-сугышлар нәтиҗәсендә Идел буе Болгары Югары Идел, Сура елгасы буйларында үз йогынтысындагы биләмәләрен югалта. Ш.у.к. *Болгарларның рус кенәзлекләренә яулары*.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; П о н о м а р ё в П.А. Данные о городах Камско-Волжской Булгарии. Ошель и её следы // Изв. об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 10, Вып. 3; С м и р н о в А.П., Волжские булгары. М., 1951; Х а л и к о в А.Х. Волжская Булгария // История Татарской АССР. К., 1968. Т. 1; К у ч к и н В.А. О маршрутах походов древнерусских князей на государство волжских булгар в XII – первой трети XIII вв. // Историческая география России. X – начало XX вв. М., 1975; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; ш у л у к. Волжская Булгария и Русь. К., 1986; И з м а й л о в И.Л. 1183 год. Крестовый поход на Волге // Родина. 2000. № 3.


*И.Л.Измайлов.*

**БОЛГА́Р БИЗӘЛЕ́Ш СӘНГАТЕ́**. Тарихы өч чорга — Болгар дәвере башлары (8–10 йөзләр), Болгар дәүләте (10 йөз — 13 йөзнең 1 нче яртысы) һәм Алтын Урда (13 йөзнең


















**Болгар бизәлеш сәнгате**. 1. Муенса. Көмеш, җепкыр. 10–12 йөзләр. ТР Милли музее; 2. Аждаһа рәсеме төшерелгән көмеш йөгертелгән бизәк. Бронза, кою. 10–12 йөзләр. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы. Археология музее; 3. Үрдәк сыны урнаштырылган чигә асылмасы. Алтын, җепкыр, бөртекләү. 10–12 йөзләр. ТР Милли музее; 4. Аждаһа рәсеме төшерелгән асылма. Җиз. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы. Археология музее; 5. Коръән тартмачыгы. Алтын, фирүзә, җепкыр. 14–15 йөзләр. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Балчыктан ясалган тоткалы чүлмәк. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы. Археология музее; 7. Бизәкле майолика . Фрагмент. 13–14 йөзләр. ТР Милли музее; 8. Кабер ташы. Фрагмент. Яссы рельефлы уеп ясалган бизәк. 14 йөз башы. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы.

2 нче яртысы — 15 йөзнең башы) дәверләренә бүленә. Б.б.с. борынгы Үзәк Азия кабиләләре, урта гасырлар башында яшәгән *һуннар*, сарматлар, Көнбатыш Төрки каганлыгы, Бөек Болгар, Хәзәр дәүләте тарихи-мәдәни мирасы нигезендә барлыкка килә. Б.б.с. күчмә дала тормышы һәм утрак игенчелек цивилизациясенең үзара тәэсирләшүе шартларында, *Салтау-маяк культурасының* көчле йогынтысы нәтиҗәсендә үсеш ала. Аның сәнгать традицияләре формалашуга Азак һәм Кара диңгез буе шәһәрләренең эллиник мәдәнияте, ш.у. Кавказ арты һәм Иран сәнгате зур тәэсир ясый. Элгәре Болгар дәвере сәнгатенә караган җирләү йоласы әйберләре (ат дирбиясе, корал, хәрби кием детальләре, савыт-саба, бизәмәләр һ.б.) Олы Тархан, Танкеевка һ.б. каберлекләрдә табыла. Аларда борынгы төркиләрнең мәҗүсилек б-н бәйле мифологиясе, дөньяга карашлары чагылыш тапкан. Табылдыклар хайван, үсемлек сурәтләре, геометрик рәсемнәр, әкияти мотивлар б-н бизәлгән, кайберләрендә борынгы Көньяк Себер, Үзәк Азия мәдәнияте йогынтысы сизелә. Б.б.с.нә гомумиләштелергән реализм (хайваннарның стильләштерелгән рәсемнәре) чалымнары кергән үзенчәлекле «җәнлек стиле» хас. Каз, үрдәк, этәч, канатларын җәйгән ике башлы фантастик кош сурәтләре еш очрый.

Болгар дәүләте чорында Б.б.с. ислам мәдәнияте йогынтысында формалаша. Металлны нәфис эшкәртү, зәркәнчелек, керач, сөяккә уеп бизәк ясау сәнгате югары үсеш ала. Идел буе Болгар дәүләтендә феодалларның сарайлары, җәмәгать йортлары, дини биналар, кирмән корылмаларының күпләп төзелүе монументаль архит-ра үсешенә, аның бизәлеше камилләшүгә этәргеч бирә, соңрак калку сын рәвешендә кабарынкы итеп ташка уеп эшләнгән канатлы барс, бөркет, арыслан, гыйфрит сыннарының мотивлары Владимир-Суздаль Русе чиркәү архит-расына үтеп керә.

Зәркән сәнгатенең нечкә металл җепселләрне бөтереп (к. *Җепкыр*) һәм *бөртекләү* ысулы кулланып (к. *Болгар чигә асылмасы*), асылташлар беркетеп эшләнгән гаҗәеп үрнәкләре саклана. Көмешне *каралту, чүкеп бизәк төшерү, уемлау, ташны уеп бизәү, басма* ысуллары кулланыла (мәс., к. *Бутаиха хәзинәсе*). Металл әйберләр (йозаклар, зиннәтле балталар, аеллар һ.б.) җәнлек сурәтендәге вак фигуралар һәм орнаментлар б-н бизәлә. *Маклашеевка җәйдаклары* кеше сынын сурәтләүнең уникаль үрнәге булып тора. *Керач* сәнгате җитештерү технологиясенең югары баскычына күтәрелә; мөгезе бөгәрләнгән тәкә, ат, эт, поши, аю, үрдәк башы рәвешендәге савытларның борыннары һәм тоткалары, төрле формадагы кувшиннар, хумнар, тәлинкә, лампа, уенчыклар һ.б. безнең көннәргәчә сакланган.

13 йөзнең 2 нче яртысы — 15 йөз башында Б.б.с. Алтын Урда мәдәниятенең шушы төбәк төре буларак үсеш ала. Анда Якын һәм Ерак Көнчыгыш мөселман илләренең, аеруча Кече Азия сәлҗүкләренең һәм Мисыр мәмлүкләренең күпшы, бай бизәкле сәнгатенә хас типтагы һәм формадагы әйберләр, бизәлеш үрнәкләре һәм композицияләре күренә башлый (лалә чәчәге, пальма яфрагы рәвешендәге бизәкләр, «бәхет төене» дип аталучы үрмә бизәкләр, гарәп язмасы, ташъязма бизәкләр һ.б.). Асылташлар кулланып, алтын һәм көмештән зиннәтле әйберләр җитештерү киң тарала. Алар арасында Алтын Урда сәнгатенә хас үтә юка челтәрле һәм алтын яки көмеш йөгертелгән җепкыр б-н эшләнгән зәркән бизәмәләре, нәфис металлдан ясалган сарай җиһазлары (савытлар, кубоклар, савыт-саба), корал, ат дирбиясе бар (к. *Җукәтау хәзинәсе, «Мономах бүреге», Зәргәрчелек сәнгате*). Архит-ра сәнгатендә ташка, алебастрга бизәк ую, аны кою ысуллары югары үсеш ала, монументаль биналарның эчке бизәлешендә төсле майолика, мозаика, дивар нәкыше кулланыла. Алтын Урда дәвере Б.б.с. үзенчәлекләре кабер ташларындагы уелмаларда, бизәкләрдә, каллиграфик язуларда ачык чагылыш таба (к. *Эпиграфика ядкәрләре*).


Б.б.с. әсәрләре Киев Русенә, Владимир-Суздаль Русенә, Якын һәм Ерак Көнчыгыш, Балтыйк буе, Көнбатыш Европа илләренә озатыла, Көньяк Уралда һәм Себердә тарала. Б.б.с. славян һәм фин-угыр халыклары сәнгатенә йогынты ясый. Аның традицияләре Идел-Урал татарларының зәргәрчелек, *ташка уеп бизәк ясау* сәнгатендә, агачтан салынган торак йортларның, күн әйберләрнең бизәлешендә үсеш ала. Ш.у.к. *Идел буе Болгар дәүләте.*

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Плетнёва С.А. От кочевий к городам. Салтово-маяцкая культура. М., 1967; Валеев Ф.Х. Орнамент Казанских татар. К., 1969; Шулук. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Валеева Д.К. Искусство волжских булгар (X — начало XII вв.). К., 1983; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БОЛГА́Р ДИҢГЕЗЕ́**, Кара диңгезнең борынгы атамаларыннан берсе. 8–10 йөзләрдә гарәп географлары хезмәтләрендә теркәлгән (әл-Мәсгуди һ.б.). 10 йөздә Хәзәр диңгезе буларак та телгә алына.

**БОЛГА́Р ҖАМИ́ГЪ МӘЧЕТЕ́**, Болгар шәһәрендә Алтын Урда дәверенә караган болгар архит-расы истәлеге. 13 йөзнең 60 елларында төзелә. Болгар шәһәренең төньяк өлешендә (хәзерге Болгар тарих-архит-ра музей-саклаулыгы терр-ясендә) урнашкан үзәк мәчет. Ян терәкләре, тышкы ишеге портал рәвешендә булган һәм асимметрик манаралы залы көнчыгыш тарафына каратылган мәчетләр тибына керә. Турыпочмак рәвешендәге бина башта 32×34 *м* мәйдан биләгән, а́ркадасын һәм дүрт кыеклы такта түбәсен 5 рәт урнашкан квадрат сыман 20 багана күтәреп торган. Төп фасадына а́ркалы тышкы ишек рәвешендәге портал б-н манара тоташкан. Штукатурланган таш диварлары а́ркаларның басымын күтәрү өчен тышкы яктан контрфорслар б-н ныгытылган. Таш нигез астына имән субайлар кагылган, диварларны ныгыту өчен алар эченә имән бүрәнәләрдән ниргәләр салынган. Интерьерының көньяк диварында ташка уеп ясалган бизәкләр б-н каймаланган михраб урнашкан. «Зур манара» дип аталган 24 *м* биеклектәге эленке манарасы аста — зуррак, өстә кечерәк күләмле цилиндр формасындагы 2 өлештән торган куб рәвешендәге нигездән күтәрелгән 8 кырлы аскы яруска утыртылган. Өске кече цилиндр тирәли түгәрәк галерея урнашкан, аңа эчтән винт рәвешендәге баскыч тоташкан. Аскы цилиндрның үзәк өлешенә Коръән аятьләре уеп язылган. Манара безнең көннәргәчә сакланган Кече манараны хәтерләтә, тик ул аннан 2 тапкыр биегрәк булган. Бинасының тузуы сәбәпле 13 йөз ахырында Б.җ.м. беренче мәртәбә үзгәртеп корыла: диварлары яңартыла, көнбатыш һәм өлешчә төньяк диварлары буйлап 10 багана урнаштырыла (антресоль галереясын күтәрү өчен, дип фаразлана), квадрат сыман баганалар сигез кырлы колонналар





Болгар җамигъ мәчете. Болгар шәһәре. 1. 14 йөз башы мәчет планының график реконструкциясе. Арх. С.С. Айдаров. 1990 еллар башы; 2. Хәзерге күренеше.



Болгар җамигъ мәчете. Зал колоннасы. 13 йөз ахыры – 14 йөз башы. Хәзерге күренеше.

б-н алыштырыла, көнчыгыш һәм көнбатыш фасадлары биш кырлы декоратив уемнар б-н бизәлә, яңа идән җәелә. 14 йөз башында Б.җ.м. икенче тапкыр үзгәреш кичерә: дүрт почмагында да баскычлы нигезгә утыртылган кальга манаралары төзелә, колонналары 6 рәт итеп урнаштырыла (һәр рәттә 6 шар), ян-як фасадларда 2 ишек, 4 тәрәзә уела, тышкы ишекләрнең өчесенә дә эчке яктан тамбурлар корыла, манаралары туф б-н тышлана. Б.җ.м. корылышында Кавказ арты, Кырым, Кече Азия, Урта Азия архит-расы һәм җирле төзелеш сәнгате элементлары бергә кушылган. Мәчет Булат Тимер явы (1361) һәм Фёдор Пёстрый һөҗүме (1431) вакытында шактый зыян күрә, 15–18 йөзләрдә тулысынча җимерелә. Манарасы 1841 елда хәзинә эзләүчеләрнең казуы нәтиҗәсендә ишелә. 1964–67 дә проф. А.П.Смирнов җитәкчелегендәге археол. казу эшләре барышында Б.җ.м. хәрабәләре туфрактан арындырыла, консервацияләнә һәм аерым өлешләре С.С.Айдаров проекты б-н реставрацияләнә: җимерелүдән саклау өчен диварлары юка таш катламы б-н тышлана, манараларының берсе тимер-бетон түбә б-н каплана, колонналар, тәрәзә йөзлекләре, капительләрнең фрагментлары һ.б. элекке урыннарына урнаштырыла. 1994–2001 дә Зур манара торгызыла. Мәчет хәрабәләре Болгар тарих-архит-ра саклаулыгының үзәген тәшкил итә.

*Әд.:* Башкиров А.С. Памятники булгаро-татарской культуры на Волге. К., 1928; Смирнов А.П. Археологические исследования Соборной мечети (Четырёхугольника) в Великих Булгарах // Советская археология. 1966. № 1; Айдаров С.С., Аксёнова Н.Д. Великие Булгары. К., 1975; Айдаров С.С. Архитектурные комплексы средневекового Булгара // Архитектурное наследство. 1976. № 24.

*С.С.Айдаров.*

**БОЛГА́Р эл-ҖӘДИ́Д** (Яңа Болгар), Казан бәклегендәге шәһәр. 15 йөзнең 1 нче яртысында сугылган акчалардан мәгълүм. «Болгар» дип тамгаланган акчалар 15 йөз башында, Шадибәк хан идарә иткәндә (1399–1407) һәм Булат Солтан заманында (1407–10) сугылган. Кайберләрендә «Болгар» сүзеннән соң «әл-Җәдид» дип тә өстәлгән. Бу шәһәргә кагылышлы башка мәгълүмат әлегә юк.

*Әд.:* Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.

*Ә.Г.Мөхәммәдиев.*

**БОЛГА́Р эл-ҖӘДИ́Д**, к. «*Болгар милли конгрессы*».

**БОЛГА́Р КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), Урта Идел һәм Чулман буенда 8 йөз — 13 йөзнең 30 еллары арасындагы археологик культура. Беренче тапкыр 19 йөзнең 2 нче яртысында аерып күрсәтелә (А.Ф.Лихачёв, К.И.Невоструев, С.М.Шпилевский һ.б.). Атамасы Болгар дәүләтенең төп халкын күздә тотып бирелә. Б.к. Кушнаренко, Ломоватово, Полом, Салтау-Маяк һ.б. археол. культуралар нигезендә 7–9 йөзләрдә барлыкка килә. 10 йөзләрдә Идел буе Болгар дәүләтенең оешуы, шәһәрләр үсеп чыгу, ислам динен кабул итү аркасында бердәм дәүләт мәдәнияте барлыкка килә, бу, үз чиратында, Б.к.ның әүвәлге чорларына хас мәдәни-тарихи үзенчәлекләрнең сүрелеп калуына китерә. 10 йөз ахыры — 13 йөзләрдә Б.к. Европа һәм Азиянең урта гасырлар цивилизациясе йогынтысында була. Идел буе Болгарын монголлар яулап алганнан соң (1236), кайбер үзгәрешләр кичерә һәм алга таба Б.к. Алтын Урда мәдәниятенең төбәк варианты буларак яши.

Б.к. халкы игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балыкчылык, аучылык, һөнәрчелек б-н көн күргән (к. *Идел буе Болгар дәүләте*). Анда металлургия (эш һәм сугыш кораллары: балталар, сука тимерләре, пычак, хәнҗәр, ук һәм сөңге очлыклары, кылычлар, ат дирбиясе һ.б. табыла) һәм сәүдә (сәүдә кирәк-яраклары, тәңкә акча, Шәрекъ, Урта Азия, Русь һәм Көнбатыш Европа илләреннән китерелгән әйберләр) зур үсеш ала.

Б.к. шәһәрләр, торулыкларның күп булуы б-н үзенчәлекле. Аның терр-ясендә 200 дән артык шәһәр (Болгар, Биләр, Суар, Богдашкино, Алексеев, Балынгуз, Җүкәтау, Луково, Хулаш, Юлово һ.б.) һәм 800 дән артык авыл урыны табыла. Болгарлар яшәгән торулыкларда археол. казу эшләре үткәргәндә (культуралы катлам 1–1,5 *м*) агач, кирпеч һәм ак таштан төзелгән ярымземлянкалар, өйләр, тораклар, мәһабәт җәмәгать биналары (мәчетләр, кәрвансарайлар, мунчалар һ.б.), төрбәләр, хуҗалык корылмалары (чүлмәк яндыру, металл эретү мичләре, һөнәрчелек остаханәләре) калдыклары һ.б. табыла. Шәһәрләрдә су үткәрү корылмалары, кала чикләрен ныгыткан балчык өемнәр, бүрәнә диварлар, ш.у. Болгар чоры Казанының ак таштан корылган дивар калдыклары эзләре табыла.

Б.к. керамикасы күп төрлелеге б-н аерылып тора (кувшин, чүлмәк, җамаяклар, кружка, зур-зур хумнар һ.б.). Мәетләр каберләргә күмелә, 7–9 йөзләргә нисбәтле каберлекләрдә мәҗүсиләр йоласы күзәтелә (төрле әйберләр, ат культы элементлары һ.б.). 10 йөздән мөселманча җирләү тәртибе кертелә (мәетнең башын көнбатышка каратып уң ягы б-н салу, йөзен Мәккәгә таба бору, кабердә әйберләрнең табылмавы). Зур Тигәнәле, Олы Тархан, Танкеевка һ.б. каберлекләр өйрәнелгән. Б.к. истәлекләрен өйрәнү 18 йөзнең 1 нче яртысыннан алып барыла (П.И.Рычков, П.С.Паллас, А.Ф.Лихачёв, В.Ф.Смолин, Н.Ф.Калинин, А.П.Смирнов, В.Ф.Каховский, А.Х.Халиков, Е.А.Халикова, Т.А.Хлебникова, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Р.Г.Фәхретдинов, Е.П.Казаков, Г.И.Матвеева, Н.А.Кокорина, Ф.Ш.Хуҗин, И.Л.Измайлов һ.б.).

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Халиков А.Х., Генинг В.Ф. Ранние болгары на Волге. М., 1964; Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. К., 1975; Валеева Д.К. Искусство волжских булгар (X — начало XIII вв.) К., 1983; Хлебникова Т.А. Керамика памятников Волжской Болгарии: К вопросу об этнокультурном составе населения. М., 1984; Халикова Е.А. Мусульманские некрополи Волжской Булгарии X — начала XIII вв. К., 1986; Город Болгар: Очерки ремесленной деятельности. М., 1988; Казаков Е.П. Булгарское село X–XIII веков низовий Камы. К., 1991; Город Болгар. Ремесло металлургов, кузнецов, литейщиков. К., 1996; Хузин Ф.Ш. Болгарский город X — начала XIII вв. К., 2001.

*И.Л.Измайлов.*

**«БОЛГА́Р» МӘЧЕТЕ́**, Казанда мөселман гыйбадәтханәсе. Казансу елгасының уң ягында урнашкан. 1991–93 елларда арх. В.П.Логинов һәм Е.И.Прокофьев проекты б-н төзелә. Рационализм архит-расы формаларындагы кирпеч бина. Ирләр һәм хатын-кызлар заллары аерым керү юллары б-н төрле катларда урнашкан. Диагональ-асимметрик рәвештә утыртылган манаралы, ике катлы, гөмбәзле мәчет. Ирләр һәм хатын-кызлар залына керү ишекләре урта өлешенең төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш почмакларында урнашкан. 1 нче катны хатын-кызлар һәм ирләр өчен бүлмәләр,



«Болгар» мәчете. Казан.
Арх. Е.И. Прокофьев, В.П. Логинов. 1991–93.

хатын-кызлар өчен гыйбадәт залы, баскыч мәйданчыгы алып тора. Үзәк баскыч алгы ирләр залы һәм эш бүлмәләре урнашкан 2 нче катка күтәрелә. Мәчетнең көньяк диварында почмаклары киртләчләндерелгән квадрат нигезле михраб чыгынтысы урнашкан. 2 нче каттан 8 кырлы чатыр б-н тәгәлләнгән 35 *м* биеклектәге 3 яруслы манарага менү баскычы башлана. Ирләр залына ачыла торган, диагональ буйлап сузылган дүрт кырлы биек гөмбәз иң зурысыннан санала. Башка өлешләренең яссы түбәләрен парапетлар каплый. 1997 дән мәчет каршында мәдрәсә эшли, аның өчен махсус бина салынган.

*Әд.:* Татарстан мәчетләре — Мечети Татарстана / Сост. Надырова Х.Г., Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**БО́ЛГАР МИЛЛИ́ КОНГРЕССЫ́** (1990 елның июненә кадәр «Болгар әл-Җәдид»), иҗтимагый-сәяси оешма. 1988 елның 27 августында Казанда татар интеллигенциясе вәкилләре (Р.Кадыйров, Ф.Нуретдинов һ.б.) инициативасы б-н оештырыла (1989 ның 21 мартында рәсми теркәлә). Б. м.к. президенты Г.З.Хәлилов (1990 нан). Иң югары идарә органы — Җыен; башкарма органы — Вәкилләр советы (30 кеше) һәм Идарә (15 кеше). Басма органы — «Болгар иле» г-тасы (1990–92, Оренбург ш., мөхәррире Р.Шәрипов). Оештыру съезды 1990 ның 8–9 июнендә Казанда уза: СССРның төрле шәһәрләреннән 23 оешма вәкилләре (150 кеше) катнаша. Устав һәм программа кабул ителә. Программасында: болгар халкының һәм аның





«Болгар» номерлары. Казан. Арх. П.И. Романов. 1866.
1. Ф. Бибин фотосы. 1890; 2. Реконструкция. 20 йөз башы.

мәдәниятенең милли-дәүләти яңарышы, татарларга «болгар» атамасын кайтару һ.б. Оешма әгъзалары Татарстанны «Болгар иле» яки «Болгарстан» дип үзгәртү, Татарстанның тулы бәйсезлеге, Татарстан һәм Башкортстан терр-яләрен бердәм дәүләткә берләштерү фикерен яклыйлар (Б. м.к. идеологлары башкортларны мөстәкыйль халык дип түгел, «көнчыгыш болгарлар» дип исәпләр). Филиаллары Оренбург, С.-Петербург, Чаллы, Болгар шәһәрләрендә һ.б. торак пунктларда ачыла. 1987 дә хәрәкәт лидерлары «татар» атамасы турында матбугатта бәхәс оештыралар; 1988 нең 24 сентябрендә «Без — болгарлар» лозунгы б-н митинг уздырыла. 1989 ның язында Б. м.к. секция хокукында Татар иҗтимагый үзәге составына керә.

*Әд.:* Т о р о п о в Д. Татарстан: партии и общественные организации. К., 1993; Политическая система Республики Татарстан. К., 1995; Т е р е н т ь е в а И.В., Б е л я к о в Р.Ю., С а ф а р о в М.Ф. Политические партии и движения Республики Татарстан. К., 1999.

*Л.М.Айнетдинова.*


**«БОЛГА́Р» НОМЕРЛАРЫ́**, Казанда татар архит-расы истәлеге. 1866 елда сәүдәгәр И.И.Апаков иганәсенә табыш йорты сыйфатында П.И.Романов проекты б-н эклектика формаларында төзелә. Подваллы, 3 катлы таш бина Печән базары комплексындагы кварталның чыгынты почмагын алып тора. Беренче катында урам яктан керешле кибетләр һәм ишегалдыннан керешле торак бүлмәләр урнашкан. Өске катларга ишегалды ягындагы янкормалардан баскычлар менә. Торак бүлмәләргә ишегалды фасады буйлап сузылган һәм баскычлар б-н тоташкан ачык галереялар аша керелә. Тышкы бизәлешендә классицизм элементлары кулланылган. Фаразланганча, 20 йөз башларында йорт үзгәртеп корыла һәм шуның нәтиҗәсендә бинаның планы, ярымтүгәрәк баскыч читлекләре, галереялар үзгәреш кичерә. Йортның Евангелистлар (хәзерге Татарстан) һәм Мәскәү урамнары чатына чыккан почмагы өстенә бинага милли романтизм рухындагы флюгерлы чатыр һәм металлдан чүкеп ясалган култыксалы балкон урнаштырыла. Үзгәртеп корылганнан соң, «Болгар» номерларын тоту өчен Ф.Әхмәдуллин бинаның бер өлешен арендага ала. 1906–16 да Б.н.да *«Йолдыз»* г-тасы редакциясе эшли, 1907 дә «Шәрекъ клубы», 1908 дә «әл-*Ислах*» г-тасы редакциясе урнаша. Б.н.нда төрле вакытларда Г.*Тукай* (1907–12), М.*Вахитов* (1909–13), *В.Мортазин-Иманский* (1909–14) һәм татар халкының башка күренекле шәхесләре яши. Совет чорында бина торак һәм китапханә өчен файдаланыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Х.Г.Надыйрова.*

**БОЛГА́Р ОЛЫСЫ́**, к. *Болгар бәклеге.*

**БОЛГА́Р ТАРИ́Х-АРХИТЕКТУ́РА МУЗЕ́Й-САКЛАУЛЫГЫ́**, дәүләт карамагында, ТАССР МСның «Татарстан АССРда Болгар шәһәрлеге нигезендә дәүләт тарих-архитектура саклаулыгы булдыру» (1969, 14 апрель) һәм «ТАССРда архитектура истәлекләрен саклау һәм төзелеш алып бару зоналарын билгеләү» (1969, 7 ноябрь) карарлары нигезендә Спас р-ны терр-ясендә оештырыла. Башта аның составына Болгар һәм Суар шәһәрлекләренең археол. һәм тарихи-мәдәни истәлекләре, Биектау р-нының Камай авылындагы, Алексеев р-нының Биләр авылындагы, Болгар шәһәрендәге төбәкне өйрәнү музейлары керә. 1992 елда үзгәртеп кору барышында аннан *Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы, Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы* аерып чыгарыла. Хәзерге көндә саклаулыкның гомуми терр-ясе 550 *га*, ш.и. саклау зонасы 505 *га* мәйданны алып тора. Музейның гомуми мәйданы 1742 $м^2$, шуның 789,4 $м^2$ өлешен күргәзмә-экспозицияләр били. Музейның төп фондында 87236 саклау берәмлеге-экспонат исәпләнә, шулардан 55888 берәмлек — археология, 10839 ы — нумизматика, 1047 се — этнография, 77 се — гамәли сәнгать, 81 е — сынлы сәнгать, 242 се — графика, 10 ысы — скульптура ядкәрләре, 13735 е — фотосурәт, 4966 сы документларга карый. Саклаулыкта табылган әйберләрнең бер өлеше Тарих музеенда (Мәскәү), Эрмитажда (С.-Петербург), ТР Милли музеенда, Финляндиянең Милли музеенда (Хельсинки), Болгар шәһәре тарих музеенда һ.б. урыннарда саклана. Саклаулык составына *Ага Базар, Әрмән колониясе, Болгар шәһәрлеге, Суар шәһәрлеге, Танкеевка каберлеге* һ.б. археол. объектлар, ш.и. Рабига күле, Туйбикә коесы, Габдрахман сәхәбә коесы керә.

ТР Мәдәният министрлыгы карамагындагы музей-саклаулык федераль әһәмияткә ия, ТРда аеруча мөһим тарихи-мәдәни объект булып санала. 1998 дә саклаулык истәлекләре комплексы ЮНЕСКОның бөтендөнья мәдәният мирасы исемлегенә кертелә. Болгар истәлекләре комплексы нигезендә төрле фәнни-тикшеренү һәм тарихи-төбәкне өйрәнү эшләре алып барыла. Саклаулыктагы истәлекләрне өйрәнү, тикшеренү эшләре 18 йөзнең 1 нче яртысыннан башлана. 19 йөз уртасыннан археол. казу, 1950 еллардан тарихи-архитектура тикшеренүләре, 1960 тан



Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы.
Зур манара.Реконструкция. 2001.

реставрацияләү эшләре алып барыла. Комплекста *Болгар җамигъ мәчете, Көнчыгыш төрбә,* Төньяк төрбә, Ак пулат, Кара пулат, Көнчыгыш пулат, Кызыл пулат, Кече манара, Хан төрбәләре һ.б. архит. истәлекләре калдыклары саклана. Музей-саклаулык комплексына кергән истәлекләр мөселманнарның зиярәт кылу урынына әверелә.





Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы.
1. Үзәк күренеше; 2. Саклаулыкның Төньяк төрбәсендәге кабер ташлары.

*Әд.:* Ш м и д т А. Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. К., 1827; Б е р е з и н И.Н. Булгар на Волге. К., 1853; С м о л и н В.Ф. По развалинам древнего Булгара: Спутник экскурсанта. Обзор развалин древнего города. К., 1926; ш у л у к. Охрана и ремонт булгарских развалин в прошлом. К., 1927; Ф е х н е р М.В. Древние архитектурные памятники России. Великие Булгары. Свияжск. Казань. М., 1978; М у х а м е т ш и н Д.Г. Великие Булгары: Путеводитель. М., 1982; А й д а р о в С.С., А к с ё н о в а Н.Д. Великие Болгары: Путеводитель по Булгарскому историко-архитектурному заповеднику. К., 1983; Болгар: Путешествие в прошлое. М., 1983.

*И.М.Нестеренко.*

**БОЛГА́Р ТЕЛЕ́**, 2–4 йөзләрдә төрки халыклар берләшмәсенә (*һуннар* атамасы б-н мәгълүм) кергән һәм 7 йөздә Азак буйларында *Бөек Болгар* дәүләтенә нигез салган кабиләләр теле.

Бөек Болгар дәүләте таркалгач (7 йөз уртасы), Б.т.ндә сөйләшүчеләрнең бер өлеше — Дунай (Дунай болгарлары), икенче өлеше Дон буйларына һәм Көнбатыш Кавказга, өченче өлеше Урта Идел һәм Түбән Кама буйларына күченеп китә (к. *Болгарлар*).

Тугандаш шивә һәм диалектларны үз эченә алган Идел болгарлары теле Алтай телләре семьялыгының төрки телләр төркеменә керә. Аның кайбер формалары урта гасыр язма истәлекләрендә (Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» поэмасы, болгар кабер ташъязмалары (к. *Эпиграфика ядкәрләре*), Урта Идел һәм Көньяк Урал топонимнарында, татар, башкорт, чуаш телләрендә һәм аларның диалектларында саклана. Б.т.нең аерым лексемалары *Ибне Фазлан* сәяхәтнамәсендә (10 йөз) теркәлгән. Мәхмүд Кашгари «Диван-е лөгать әт-төрк» дигән сүзлегендә болгар, суар, бәҗәнәк һәм кыпчак телләренең фонетик һәм лексик яктан үзара якын булуларын күрсәтә, «Чигил һәм башка төрки кабиләләргә хас **д**ª авазы рус җирләре һәм Византия б-н чиктәш болгар, суар, ямәк, кыфчак телләрендә з булып әйтелә»,— дип яза. Б.т.нә сингармонизм хас (арпа, бугдай, йазы, токуз, сүзлә). Татар теле галиме Л.Җәләй төрки телләрдәге болгар төркеменең түбәндәге үзенчәлекләрен күрсәтә: а) борынгы төрки **з** урынына **й** кулланыла: ка**з**гы–ка**й**гы, а**з**ак–а**й**ак; б) ротацизм күренеше хас, ягъни **з** урынына **р** кулланыла: котка**з**–котка**р**; в) ирен-ирен **w** авазы хас, ирен-теш **в** авазы юк; г) дифтонглар кулланыла: ба**г**–ба**у**–б**әй**; сү**зл**ә–с**өй**лә; д) тартыклар саңгырау һәм яңгырауларга тулысынча бүленә; е) **ш-л** тәңгәллеге хас: **иш–ил** (халык, ил) һ.б.

Башка телләрдәге кебек, Б.т.ндә грамматик-семантик яктан исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, бәйлек һәм теркәгеч кебек сүз төркемнәрен аерып күрсәтергә мөмкин; язма истәлекләрдә хикәя һәм боерык фигыль формалары очрый.

Б.т. агглютинатив телләргә керә. Андагы сүзләр структур элементларның: моносемантик тамыр һәм аффиксларның кушылуыннан гыйбарәт; аффиксларның ялгану тәртибе башка төрки телләрдәгечә: atasundan-атасыннан, qardaşlarina–кардәшләренә, kutaruban–күтәрүдән. Сүз ясалышының иң киң кулланылган ысулы — аффиксация; ялгызлык исемнәр ясалышында кушма сүзләр дә очрый: Котлыбарс (котлы+барс), Айтимер (ай+тимер), Көнтугды (көн+тугды). Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән болгар текстлары гарәп язуы (куфи һәм сөлес язу төрләре) б-н язылганнар. Б.т. лексикасында шактый урынны *гарәп алынмалары* били. 19–20 йөз башында Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, С.М.Шпилевский, И.Н.Березин, Р.Фәхретдин, Г.Әхмәров һ.б. татарлар б-н болгарлар арасында генетик бәйләнеш барлыгын күрсәтәләр. Алар фикеренчә, татарларның бабалары болгарлар булган. 1946 елның апрелендә СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты б-н берлектә оештырылган СССР ФАнең Тарих һәм философия бүлегенең махсус утырышы Казан татарларының килеп чыгышына багышлана. Әлеге караш Л.Җ.Җәләй, А.П.Смирнов, Н.И.Воробьев, Т.А.Трофимова, Н.Ф.Калинин, Х.Г.Гыймади чыгышларында яклау таба. Бу концепцияне алга таба үстерүгә Һ.В.Йосыпов, М.З.Зәкиев һ.б.ның тикшеренүләре зур өлеш кертә.

19 йөзнең 2 нче яртысында татар галиме Х.Фәезханов 2 нче стиль болгар эпиграфик истәлекләрендә чуаш теленә хас элементлар барлыгын ачыклый. Соңрак Н.И.Ильминский, Н.И.Ашмарин, аннан соң Н.А.Баскаков, Н.И.Егоров, М.Р.Федотов, чит ил галимнәреннән А.Рона-Таш, О.П.Притцак һ.б. тикшеренүләрендә болгар-чуаш концепциясе алга сөрелә. Әлеге концепциядә каралганча, чуаш телен формалаштырган компонентлар арасында Б.т. төп компонентларның берсе булып тора.

Б.т. *Идел буе төрки теленең* барлыкка килүендә һәм үсешендә мөһим роль уйный.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1897; Х а к о в В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. К., 1972; З ә к и е в М.З. Татар халкы теленең барлыкка килүе. К., 1977; ш у л у к. Төрки-татар этногенезы. М., 1998; Ф е й з х а н о в Х. Три надгробных болгарских надписи // Изв. Имп. археол. об-ва. СПб., 1863. Т. 4; И л ь м и н с к и й Н.И. О фонетических отношениях между чувашскими и тюркскими языками // Изв. Имп. археол. об-ва. СПб., 1865. Т. 5; А ш м а р и н Н.И. Болгары и чуваши // Изв. об-ва археол., истории и этнографии при Казан ун-те. 1902. Т. 18, вып. 1–3; Происхождение казанских татар. К., 1948; Ю с у п о в Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.–Л., 1960; Б а р т о л ь д В.В. Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов. М., 1968. Т. 5; Б а с к а к о в Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М.–Л., 1969; Х а к и м з я н о в Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978; З а к и е в М.З., К у з ь м и н - Ю м а н а д и Я.Ф. Волжские булгары и их потомки. К., 1993.

**БОЛГА́Р УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Спас һәм Әлки р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда Спас урман хуҗалыгы буларак оештырыла. 1936–92 елларда — Куйбышев урман хуҗалыгы. 2006 елның 1 гыйнварына урман фондының гомуми мәйданы 18532 *га*. 2 урманчылыкны үз эченә ала: Никольский — 9473 *га* һәм Спас — 9059 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Болгар шәһәрендә. Эшләүчеләр саны 130 кеше.

1 нче төркем урманнарның мәйданы 16559 *га* (89,4%), алар арасында: су саклагыч урманнар (10593 *га*), яшел зона урманнары (2160 *га*), саклаучы урманнар (3336 *га*), эрозиягә каршы урманнар (470 *га*). 2 нче төркем (файдаланыла торган) урманнар — 1973 *га*. Урман фонды мәйданының урманлы өлеше 16786 *га*, ш.и. ылыслы агач токымнары — 3866 *га* (23%), каты яфраклылар — 2466 *га* (14,6%), йомшак яфраклылар — 10305 *га* (61,4%), куаклар — 149 *га*. Урман хасил итүче төп токымнар: юкә (21,1%), каен (20,4%), нарат (17,2%), усак (15,6%), имән (14,4%), сирәк кенә чыршы, карагай, өрәңге, соры һәм кара зирек очрый. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшьләре (30%), урта яшьтәгеләре (32,7%), өлгереп килүчеләре (17,3%), өлгергәннәре (18,8%), картайганнары (1,1%). Урман культуралары 3104 *га* (18,5%) мәйданны тәшкил итә. Б.у.х.нда агачның гомуми запасы 2620,1 мең $м^3$ тәшкил итә; ылыслыларга 675,8 мең $м^3$, каты яфраклыларга 260,3 мең $м^3$, йомшак яфраклыларга 1680,9 мең $м^3$ туры килә. Агачның уртача еллык артымы 62,4 мең $м^3$, ш.и. 14,2 мең $м^3$ ылыслы агач токымнары хисабына. Төп кулланылыш өчен еллык урман кисү 19,5 мең $м^3$ тәшкил итә. Урманны чистарту эшләре 680 *га* мәйданда башкарыла, шуның б-н бергә 4,1 мең $м^3$ га якын эшкә яраклы агач әзерләнә. Һәр ел саен 100–120 *га* мәйданда урман торгызу (агач утырту) эшләре алып барыла. Кыр саклау һәм юл буе полосалары булдырыла. Спас урман хуҗалыгының урман питомнигында (мәйданы 13 *га*) 1,8 млн. үсенте һәм чәчкен үстерелә. Питомникка «Югары культуралы урман питомнигы» дигән исем бирелгән. Урман хуҗалыгының ярдәмче сәнәгый цехларында товарлыклы продукция җитештерелә (2004 елда 0,1 млн сум).

*В.Л.Дёмин.*

**«БОЛГА́Р ХАННАРЫ́ ИСЕМЛЕГЕ́»**, борынгы болгарларга нисбәтле тарихи язма истәлек. Билгесез автор тарафыннан борынгы славян телендә язылган. Анда 153 елдан алып 8 нче йөзнең 2 нче яртысына кадәр яшәгән борынгы болгар кабиләләре идарәчеләре һәм *Бөек Болгар дәүләте* ханнары, аларның яшәү һәм идарә итү даталары, нинди ыругка нисбәтле булулары теркәлгән (идарә итә башлау елларының борынгы болгарча атамасы да кертелгән). Ядкәр ике өлештән тора. Беренчесендә *Дулу* ыругының борынгыдан килү тарихы, ул ыругка *Аттила* б-н улы Ирнәкнең керүе бәян ителә. 2 нче өлештә *Аспарух* һәм аның варислары исемлеге теркәлгән. «Б.х.и.» 19 йөздә рус тарихчысы А.Н.Попов тарафыннан табыла.

*Г.М.Дәүләтшин.*

**БОЛГА́Р ЧИГӘ́ АСЫЛМАСЫ́**, 10–12 йөзләрдә Идел буе Болгар дәүләте зәркәнчеләре тарафыннан көмештән, сирәгрәк очракларда алтыннан коелган хатын-кыз бизәмәсе. Баш бәйләвеченә чигәләр ягыннан дүртәр итеп эленгән. Әүвәлге болгар чорында киң таралган бизәнү әйбере. Вак бөртекләү ысулы б-н бизәлгән һәм мәрҗән бөртекләре тезелгән бөҗра — Б.ч.а.ның төп үрнәге булып тора. 2–2,5 *см* диаметрлы бөҗрага җепкыр һәм


бөртекләү ысулы б-н бизәлгән, имән чикләвегенә охшаган бердән алып өчкә хәтле «куык» киертелгән. Соңрак өч «куыклы» бөжрага очларына бөртекләү ысулы б-н бизәлгән шундый ук «куык» беркетелгән эленмә чылбырлар да өстәлгән. «Куык» юка металлдан әзерләнгән ике өлештән, бер-берсенә җепкыр ярдәмендә беркетелеп, буынтыклап ясалган, өслеге бөртекле өчпочмак һәм пирамидалар б-н бизәлгән. Мондый бөжраларның диаметры 4,5–8 *см*, аларга киертелгән «куык»ларның зурлыгы 2–3 *см* булган. «Куык» шуып йөрмәсен өчен, бөжрага җепкырлы чыбык уралган. Б.ч.а.ның җепкырдан ясалган, бөртекләү ысулы б-н бизәлгән, үрдәк сыны кертеп эшләнгән үрнәкләре мөкәммәллекләре б-н аерылып тора. Үрдәк муенына аның илаһилыгын чагылдырган «изге» муенса тагылган. Мондый муенса сасанилар дәверендәге Иран нәфис металл сәнгате әсәрләренә хас. Томшыгына «балчык» ябышкан үрдәк сынчыгы гаилә иминлеген, йорт бөтенлеген һәм бәхетне гәүдәләндергән. Борынгы татар риватендә җир дөнья океаны төбеннән үрдәк томшыгына ияреп чыккан балчыктан яралган дип фаразлана. Үрдәк сынлы Б.ч.а. б-н Дагстан зәркәнчеләре тарафыннан кошчык сыны куеп ясалган чигә бизәмәләре арасында беркадәр охшашлык бар. Ләкин соңгылары, Болгар осталарыныкы нечкә һәм катлаулы җепкыр б-н эшләнгән бизәмәләреннән аермалы буларак, кою юлы б-н, уемлап һәм каралтып ясалган һәм аларда асылмалар кулланылмаган.

Б.ч.а.ның башка төрләре бөртекләү ысулы б-н бизәлгән имән чикләвеге рәвешендә ясала. Аларның ике төре — озынча түгәрәк рәвешендәге бөжрага мәрҗән тезелгәннәре (әүвәлге Болгар сәнгатендә үк булган) һәм турыпочмакка тартык бөжраның бөртек астына вак асылмалар куелганнары очрый. Б.ч.а.ның Эрмитаждагы махсус Көнчыгыш фондында, Мәскәүдәге Тарих музеенда, ТР Милли музеенда, Болгар тарих-архитектура саклаулыгында тупланган үрнәкләре дөнья сәнгате шедеврлары рәтендә тора.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Ефимова А.М. Бутаевский клад ювелирных изделий волжских булгар // Советская археология. 1960. № 1; Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БОЛГА́Р ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, археологик истәлек. Идел буе Болгар дәүләтенең Болгар шәһәре калдыклары. Тикшеренүләр 18 йөз башыннан алып барыла. 1712 елда, Успение ирләр монастыре төзелә башлагач, дьяк Михайлов Б.ш. ндәге корылмаларны беренче тапкыр барлап чыга. 1722 дә патша Пётр I Б.ш.ндә була, андагы архит-ра калдыкларын һ.б. истәлекләрне саклау чаралары күрергә боера. 1722–32 дә полковник Н.Савенов б-н геодезист И.Крапивин Б.ш.нең топографик тасвирламасын төзиләр, 1768 дә шундый ук эшне Оренбург экспедициясендә катнашучылар (П.С.Паллас һ.б.) башкара. 19 йөздә Б.ш. истәлекләре Ф.И.Эрдман, П.П.Свиньин, Н.Н.Кафтанников, Н.И.Второв, И.Н.Березин, К.И.Невоструев, А.Ф.Риттих, С.М.Шпилевский һ.б. хезмәтләрендә тасвирлана. Б.ш. күренешләре Андре Дюранд гравюраларында, Н.Г. һәм Г.Г.Чернецовлар рәсемнәрендә, арх. А.К.Шмидт үлчәмнәрендә һ.б. чагылыш таба. 1864 елдан Б.ш.ндә ара-тирә казу эшләре алып барыла. В.Г.Тизенгаузен, В.Г.Казаринов, А.А.Штукенберг, П.А.Пономарёв, С.И.Покровский, Б.Е.Крелленберг, П.И.Кротов, М.М.Хомяков, В.Ф.Смолин, М.Г.Худяков, А.С.Башкиров, А.Ф.Адлер һ.б. галимнәр шәһәрлектәге аерым истәлекләрне, каберлекләрне тикшерү эшләре үткәрә. 1938 дән А.П.Смирнов тарафыннан системалы рәвештә тикшеренүләр уздырыла (1973 кә кадәр). Бу эштә төрле елларда Н.Ф.Калинин, А.М.Ефимова, М.Д.Полубояринова, Ю.А.Краснов, М.Г.Крамаровский, П.Н.Старостин һ.б. галимнәр катнаша. Нәтиҗәдә 20 мең $м^2$ мәйданда тикшеренү эшләре үткәрелә.




Болгар шәһәрлеге. 1. Вал һәм чокыр-канау; 2. Ак пулат.



Болгар шәһәрлеге. Керәч савыт. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы фондлары.

Б.ш. Мелёнка инеше б-н тирән ерым арасында барлыкка килгән борын өстендә урнашкан. 10 йөздә Болгар шәһәре ныгытмалары 2 рәт тышкы чокыр-канау һәм эчке чокыр-канау кырыеннан узган бүрәнә диварлардан торган. Шәһәрлекнең көнбатышында диварлар б-н ныгытылмаган авыл да булган. Монгол яулары алдыннан шәһәрлекнең 300 мең $м^2$ мәйданы яңа урлар, чокыр-канаулар б-н уратып алына. Болгарны Батый хан явы басып алганнан соң (1236), ныгытмалар юк ителә, 14 йөз урталарында яңадан торгызыла (8 *км* озынлыктагы ныгытмалар 4 млн. $м^2$ мәйданны уратып алган). Каланың көньяк-көнбатыш капкасы янында Кече шәһәр төзелә. Иделгә чыккан борында сәүдә пристане һәм *Ага Базар* торулыгы үсеп чыга. Шәһәр тышында да берничә болгар торулыгы, *Әрмән колониясе* була. 13–14 йөзләрнең 2 нче яртысындагы таш биналар: Җамигъ мәчет, Төньяк төрбә, Көньяк төрбә, Кече манара, Хан төрбәсе, Ак, Кызыл, Кара пулатлар һ.б. саклаган. Б.ш. мәйданында ш.у. тимер эретү-эшкәртү, сөяк, күн эшләнмәләр җитештерү, тимерчелек һәм чүлмәк яндыру остаханәләре һ.б. корылмалар табыла. Тораклар агачтан, яндырылмаган һәм яндырылган кирпечтән төзелгән, гадәти мичләрдән тыш идән астыннан ягып җылытыла торган мичләр кулланылган. Катлаулы гидротехник корылмалар калдыклары сакланган: су өйләргә чүлмәк торбадан китерелгән, йортлар канализация б-н тәэмин ителгән. Табылдыклар Болгарның киң сәүдә бәйләнешләре булуы хакында сөйли (Түбән Идел шәһәрләрендә җитештерелгән затлы керамика, Сүрия, Византия, Русь кебек илләрдән китерелгән пыяла савыт-саба, Иранннан металл савытлар, Кытайдан фарфор, Балтыйк буеннан гәрәбә, рус кенәзлекләреннән килгән бизәнү әйберләре һ.б. табыла). Ш.у.к. *Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы*.



Болгар шәһәрлеге. Кувшин, яндырылган балчык. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы фондлары.



Болгар шәһәрлеге. Сөяк сап. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы фондлары.

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Якубовский А.Ю. К вопросу об исторической топографии Итиля и Болгар в 9 и 10 веках // Советская археология. 1948. Т. 10; Смирнов А.П. Древние Булгары // Тр. Гос. ист. музея. 1951. Вып. 19; Фахрутди-

н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Город Болгар. Очерки ремесленной деятельности. М., 1988; Город Болгар. Ремесло металлургов, кузнецов, литейщиков. М., 1996; Х у з и н Ф.Ш. Булгарский город X – нач. XIII вв. К., 2001; Z i m o n y i I. The Origins of the Volga Bulghars. Szeged, 1990.

*Ф.Ш.Хужин.*

**БОЛГА́Р-РУС КИЛЕШҮЛӘРЕ́**, 1) Идел буе Болгары б-н Киев Русенең бөек кенәзе Владимир I арасындагы килешү. «Повести временных лет» елъязмасында хәбәр ителгәнчә, аркадашлары бәҗәнәк-төркләр б-н болгарларга каршы яу б-н килгәннән соң (985), кенәз Владимир I болгарларның икътисади яктан өстенлеген таный («... все они в сапозех») һәм алардан ясак түләтеп булмаячагын аңлый («им дани нам не даяти, поидем искать лапотников»), үзара килешү төзергә тәкъдим итә. Килешүгә «колмак суга батканчы, таш су өстенә калыкканчы» турылыклы булырга дип ант ителә; 2) Идел буе Болгар дәүләте б-н Киев Русе арасында чама б-н 1006 елда ике илнең дә сәүдәгәрләренә төрле шәһәрләрдә ирекле рәвештә сәүдә итү хокукы бирелүе турында төзелгән килешү (авыл җирләрендә сәүдә итү мөмкинлеге каралмаган). Аның нигезендә ике дәүләтнең сәүдә, мәдәният һәм сәясәт өлкәсендә үзара мөнәсәбәтләре ныгый. Бу килешү турындагы мәгълүмат борынгы рус елъязмалары б-н эш иткән В.Н.*Татищев* хезмәтендә урын алган; 3) Идел буе Болгары б-н Владимир-Суздаль кенәзлеге арасындагы 1221 елгы килешү. Болгарлар русларның Устюг шәһәрен (1218) һәм рус гаскәре болгарларның Ашлы шәһәрен (1220) яулап алу сугышларыннан соң килешү төзелә. Килешүдә әйтелгәнчә, Ука елгасы буенда урнашкан кайбер мордва авыллары рус кенәзлеге йогынтысына күчә; 4) 1229 елгы Идел буе Болгары б-н Владимир-Суздаль кенәзлеге арасындагы килешү (1229). Идел буе төбәгендә үзара мөнәсәбәтләрне билгели, әсирләр алмашу, сәүдәгәрләр б-н балыкчыларга ике ил арасында ирекле эш йөртү мөмкинлеге бирә. Бу килешү Владимир-Суздаль кенәзе Юрий Всеволодовичның Ука б-н Сура елгалары арасындагы мордва җирләрен үз йогынтысына алу өчен башлаган сугышыннан соң 6 елга дип төзелә. Әлеге килешү Рус кенәзлегенә ачлык афәтеннән котылу чарасы булса (берничә ел иген уңмаган рус иленә болгарлар 1229 елда зур күләмдә ашлык озаталар), болгарларга 1229, 1232 еллардагы монгол яуларына оешкан төстә каршы тору мөмкинлеге бирә.

Чыг.: Повесть временных лет. М.–Л., 1950. Ч. 1–2; Полное собрание русских летописей. М., 1949. Т. 2; М., 1962. Т. 1, вып. 2.


*Әд.:* П е ш т и ч С.Л. О «договоре» Владимира с волжскими болгарами 1006 года // Ист. зап. 1946. № 18; Т а т и щ е в В.Н. История Российская. М.–Л., 1963. Т. 2; П а ш у т о В.Т. Внешняя политика Древней Руси. М., 1968; Р ы б а к о в Б.А. Киевская Русь и русские княжества XII–XIII вв. М., 1982; Волжская Булгария и Русь. К., 1986.

*И.Л.Измайлов.*

**БОЛГАРГА́ әл-МОКТӘДИ́Р ИЛЧЕЛЕГЕ́ (921–23)**, гарәп илчелегенең Идел буе Болгар дәүләтенә килүе. *Бохарага* һәм *Багдадка Алмыш хан илчелегенә* җавап рәвешендә оештырылган. Максаты: халифәт хакимияте даирәсен киңәйтү, ислам дине таралышын ныгыту һәм Хәзәр каганлыгына каршы бердәмлек килешүе төзү. Илчелек җитәкчесе Сәһсән (Сусан) әр-Расси, сәркәтибе Ибне Фазлан, төрки кавемнән чыккан хәрбиләр Тәкин һәм Барс. Илчелек 922 елның 12 маенда Идел буе Болгарына килеп җитә, Алмыш илтәбәр б-н очраша,



В.Л.Лаптев. «Багдад илчесенең Болгарга килүе». 1949. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Б. Урманче. «Ибне Фадланның Болгарга килүе». 1973. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

аңа әл-Моктәдир хәлифәнең хатын һәм бүләкләрен тапшыра. Багдадтан илчелек килү болгарларның ислам динен рәсми рәвештә дәүләт дине буларак кабул итүенә этәргеч була.

*Әд.:* К о в а л е в с к и й А.П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков. 1956; Z e k i V.T. Ibn Fadlans Reisbericht. Lpz., 1939.

*И.Л.Измайлов.*

**БОЛГАРГА́ 1376 ЕЛГЫ́ ЯУ́**, Мәскәү бөек кенәзе Дмитрий Ивановичның (булачак Донской) бу явы Алтын Урда алдында көч күрсәтергә тырышуы дип фаразлана. 1376 елның башында Мәскәү гаскәре Болгар чикләрен үтеп керә. Болгар бәклеге б-н бу вакытта *Хәсән бәк* һәм *Мөхәммәд Солтан* идарә итә. Аларның чик сагындагы атлы гаскәре җиңелә. Мәскәү көчләре Болгарны камап ала, шәһәргә якын булган авылларны талый, яндыра. Яхшы ныгытылган Болгарны саклаучылар бирешми, туплардан, *арбалетлардан* атып, дошманга каршы нык тора. Солых төзелә, Болгар йолым түләргә һәм Мәскәү түрәләрен (вәкилләрен) кабул итәргә ризалык бирә.

*Әд.:* Полное собрание русских летописей. М.–Л., 1949. Т. 25; П р и с е л к о в М.Д. Троицкая летопись. М.–Л., 1950.

*И.Л.Измайлов.*

**БОЛГАРИ́ МӨХӘММӘ́Д** (әш-шәех Мөхәммәдкәрим әл-Болгари) (19 йөз уртасында вафат), татар лексикографы. Биографиясе һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Бохарада укыган. Уку дәверендә Идел-Кама төбәгеннән чыккан шәкертләр өчен «Лөгате төрки вә фарси вә гарәби» («Татарча-фарсыча-гарәпчә сүзлек») төзи. Сүзлек 16 йөз татар лексикографы Б.*Хаҗи* нигез салган традицияләргә таянып төзелә. Ул 12 меңгә якын сүзне үз эченә ала. Кульъязма Казан ун-ты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

*Әд.:* Тюркское языкознание // Описание рукописей Науч. б-ки им. Н.И.Лобачевского. К., 1962. Вып. 9; Рукописи татарских писателей и ученых. Ч. 3 // Описание рукописей Науч. б-ки им. Н.И.Лобачевского. К., 1968. Вып. 12.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БОЛГАРИ́ СӘҮБӘ́Н** (Сәүбән ибне Ногман әл-Болгари әл-Җияши) (19 йөз урталары), шагыйрь. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Шигырьләр һәм үгет-нәсыйхәт характерындагы риваятьләр тупланган «Мәншаэ әр-рижа» («Өмет итү чыганагы», 1866) исемле дини-дидактик кулъязма китап авторы. Кульъязма Казан ун-ты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

*Әд.:* Ф ә т х и А. Кулъязмалар тасвирламасы. К., 1968. 12 чыг.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**БОЛГАРЛА́Р**, урта гасырларда Көнчыгыш Европада яшәгән төрки кабиләләрнең җыелма атамасы. Огур-болгар кабиләләре иң элек тарихчы Приск Панийскийның 463 елга караган язмаларында телгә алына (огур, сарагур һәм оногур язылышында). Килеп чыгышлары Үзәк Азиядә һәм Көньяк Себердә яшәгән огур (төрки-телес) кабиләләренә бәйле дип фаразлана. Үз җирләреннән Көнчыгыш Европа тарафына алар жуаньжуаньнар (төрки аварлар) басымыннан соң күченәләр. 5–6 йөзләрдә бу кабиләләр утигур һәм кутригур кабиләләре б-н бердәмлек оештыра, Дунай тамагыннан алып Көнбатыш Кавказга хәтле булган мәйданны биләгән башка һун кабиләләрен ассимиляциялиләр. 6 йөзнең 2 нче

яртысында үзара сугыш-көрәштән һәм Византия дәүләте б-н барган бәрелешләрдән соң, Б. берләшмәсе көчсезләнә, утигур һәм кутригур кабиләләре Көнчыгыш Европага бәреп кергән аварлар (абарлар) тарафыннан Дунай б-н Карпат таулары арасында оешкан Авар каганлыгына буйсындырыла. 576 еллар тирәсендә Төньяк Кавказда яшәгән Б.ны Төрки каганат басып ала. Төрки дәүләтләр чигендә гомер иткән огур-болгар кабиләләре озакламый унногундур кабиләсенең *Дуло* ыругы тирәсендә берләшә. 635 елда бу кушма кабиләләр Орган (Ураган) хан һәм аның бертуганының улы *Кубрат хан* җитәкчелегендә аварларны җиңүгә ирешәләр, *Бөек Болгар дәүләтен* төзиләр. Шул дәвердән Б.ның этносәяси һәм рухи күтәрелеше күзәтелә, дәүләтчелек традицияләре барлыкка килә (к. «*Болгар ханнары исемлеге*»). Кубрат хан вафатыннан соң (640–60 еллар арасы), Бөек Болгар дәүләте таркала башлый. 7 йөз ахырында болгар кабиләләрен хәзәрләр яулап ала. Б.ның бер өлеше Дунай елгасы буйларына күченә (к. *Беренче Болгар патшалыгы*), икенче өлеше Паннония б-н Төньяк Италия җирләрендә урнаша, соңрак өченче өлеше Урта Идел буйларында төпләнә. Төньяк Кавказ б-н Дон аралыгында яшәп калганнары Хәзәр каганлыгына буйсыналар (рус һәм Византия елъязмаларында алар «кара болгарлар» буларак теркәлгән). Урта Идел буена Б. күченгәндә, анда этник яктан якын төрки һәм фин-угыр кабиләләре яшәгән. Болгар-огурлар б-н бергә Урта Идел буена өлешчә алан-хәзәрләр (барсиллар һәм бәрәнҗәрләр), төркиогур – савирлар һәм Үзәк Азиядән чыккан әсәгел кабиләләре дә күченгән, Б.ның Идел-Чулман аралыгына күченеп утыруын дәлилләүче фактлардан Бураково Шилов, Брусянский каберлекләрендәге археол. материалларны күрсәтергә була. Идел-Чулман буенда төпләнгән Б. берләшмәсенә кергән кабиләләрдән *Алмыш илтәбәр* җитәкләгән (рус чыганакларында «көмеш Б.» исемен алган) кабилә көчлерәк булып чыга. 910–70 елларда Урта Идел буенда Болгар һәм Суар әмирлекләре оеша. Хәзәр каганлыгы таркалганнан соң, Болгар әмирлеге суарларны да үзенә буйсындыра (980 еллар тирәсе), һәм *Идел буе Болгар дәүләте* оештырыла. 10 йөздә Идел буе Болгарына угыз-бәҗәнәк, кыпчак, бортас һәм мажар кабиләләренең дә бер өлеше килеп кушыла. Алар әкренләп бердәм болгар халкын тәшкил итәләр. Б.ны берләштерүдә Идел-Чулман төбәгендә 8 йөз башларыннан тарала башлаган ислам диненең йогынтысы да зур була. Идел буе Болгары Шәрекъ илләре б-н якын элемтә урнаштыра, Багдад хәлифәлеге илчелеге килгәннән соң, 922 елдан ислам дине рәсми дин булып санала башлый. Урта гасырларда Б. яшәгән төбәктә шәһәрләр барлыкка килә, шәһәр тибындагы мәдәният үсеш ала башлый, аерым диалектларны берләштергән бердәм сөйләм теле формалаша (уртак угыз-кыпчак сөйләме нигезендә). Шул рәвешле уртак әдәби болгар теле туа (к. *Болгар теле*). Болар барысы да мөселман дине традицияләренә хас булган милли-сәяси үзаң һәм бердәм мәдәният барлыкка килүгә булышлык итә (к. *Болгар культурасы*). Идел буе Болгарының шушы юнәлештәге үсеше монгол яулары нәтиҗәсендә беркадәр тоткарлана. 1230–40 елларда монголлар Идел буе Болгарына берничә мәртәбә һөҗүм итәләр һәм 1240 еллар башында аның биләмәсен *Җучи олысына* (Алтын Урдага) кушуга ирешәләр. Б.ның, аеруча аксөякләрнең, бер өлеше Алтын Урда этносына кушыла, гомуми, этносәяси тәңгәллек барлыкка килә. 16–18 йөзләрдә, татар ханлыкларын руслар яулап алганнан соң да, Б. мөселман дине йогынтысында калыплашкан үзаңнарына турылыклы булып калалар. Алар болгар этник үзатамасы б-н бергә үзләрен «мөселман», «казанлы», «татар» дип тә атыйлар. 18–19 йөзләрдә «болгар» сүзе этник атама буларак кулланыштан төшеп кала, социаль утопия күренеше буларак кына саклана: илаһи шәһри Болгар һ.б. (к. *Болгар милли конгрессы*; *Вәисиләр хәрәкәте*).

*Әд.:* Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978; шул ук. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. М., 1987; Гадло А.В. Этническая история Северного Кавказа IV–X вв. Л., 1979; Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. К., 1989; Алишев С.Х. Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. XVI – нач. XIX вв. М., 1990; Новосельцев А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990; Кляшторный С.Г., Савинов Д.Г. Степные империи Евразии. СПб., 1994; Материалы по истории татарского народа. К., 1995; Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар в VI – первой четверти XV в. К., 2000; Golden P.B. Khazar Studies. Bdpst, 1980. V.1; Zimonyi I. The origins of the Volga Bulghars. Szeged, 1990.

*И.Л.Измайлов.*

**БОЛГАРЛАРНЫ́Ң РУС КЕНӘЗЛЕКЛӘРЕНӘ́ ЯУЛАРЫ́.** 11–13 йөзләрдә Идел буе Болгары Урта Идел төбәгендә һәм Идел буе сәүдә юлында үз мәнфәгатен яклау өчен күрше рус кенәзлекләре тарафыннан даими рәвештә сугыш хәрәкәтләренә тартыла. Киев кенәзлеге көчләренең Ука елгасы буена үтеп керү омтылышын туктату өчен болгарларның атлы гаскәре 1088 елда Муром шәһәрен яулап ала. 1107 елда кораб-көймәләрдә Суздальгә яу б-н баралар һәм шәһәр тирәсендәге авылларны талыйлар. Шәһәрне камауда тотсалар да, яулап ала алмыйлар. Суздаль кенәзе Юрий Долгорукий б-н Волын кенәзе Изяслав үзара көрәшкәндә болгарлар Изяславка ярдәмгә киләләр. Болгар гаскәре корабларда барып Ярославль шәһәренә һөҗүм итә (1152). Ләкин, Ростов шәһәре тарафыннан ярдәмче көчләр килүе сәбәпле, болгарлар уңышка ирешә алмыйча чигенәләр. Болгарларның Югары Идел буендагы Ярославльгә һөҗүм итүеннән соң, рус кенәзләре шәһәрләрен ныгыту өчен Городец кальгасын, Устюг шәһәрен төзиләр. Русларның Югары Чулман буйларын, *Нократ җирләрен* яулауга омтылышларын туктатыр өчен болгар гаскәре, 1218 елда кораб-көймәләрдә барып, Устюг шәһәрен ала.

*И.Л.Измайлов.*

**БОЛГА́РСКАЯ** Гөлсем (Мостафина Өммегөлсем) Муса кызы (19.11.1891, Казан – 10.1.1968, шунда ук), драма актрисасы, ТАССРның халык (1923), РСФСРның атказ. артисткасы (1925). Сәхнә эшчәнлеген 1910 елда «Сәйяр» труппасында башлый. Татар актрисаларының беренче буыны вәкиле, профессиональ татар театрын формалаштыруда һәм башкару осталыгының милли традицияләрен үстерүдә зур роль уйный. Г.Камал, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Г.Исхакыйның драма һәм комедияләрендә күп кенә сәхнә образларын беренче башкаручы була. Табигый күзәтүчәнлеге, тормышны тирәнтен белүе, сәхнәдә үзен кыю тотуы аңа беренче рольләреннән үк үзен гаять сәләтле актриса итеп күрсәтергә ярдәм итә, театр тәнкыйтьчеләре дә моны таный. Г.Камал пьесалары буенча куелган спектакльләрдә ул башкарган Хәмидә («Бүләк өчен»), Асрау кыз, Гайшә, Гайни («Бәхетсез егет»), Сәрбиҗамал («Фахишә»), Гафифә («Беренче театр»), Гөлҗиһан («Банкрот») образлары, конкрет тормыш детальләре б-н баетылып, аерым социаль типлар сыйфатында беркетелеп, драматург иҗат иткән характерларны чагылдыруның классик үрнәге дәрәҗәсенә күтәрелә. Г.Тукай, Г.Коләхмәтов, Г.Камал, Г.Исхакыйларның демократик һәм мәгърифәтчелек идеяләрендә тәрбияләнгән актриса үз героиняларының көлкеле кыланышлары артында кырыс чынбарлык, кискен социаль каршылыклар, яңа, алдынгы идеяләр б-н иске консерватив тормыш рәвеше арасындагы көрәш киеренкелеге ятканлыгын күрә һәм күрсәтә белә. Күпкырлы сәләте, тормыш дөреслегенә тайпылышсыз тугрылыгы драматик һәм көлкеле рольләрне бертигез дәрәҗәдә ышандырырлык итеп уйнау мөмкинлеге бирә. Б. башкарган Шәфика («Мескен бала», Н.Кәмал), Маһисылу («Ачлык кушты», Я.Вәли), Сәлимә («Тигезсезләр», Ф.Әмирхан), Гөлҗамал («Надиршаһ», Н.Нариманов), ш.у. Луиза («Мәкер һәм мәхәббәт», Ф.Шиллер), Катерина, Полина, Кручинина («Яшенле яңгыр», «Төшемле урын», «Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский) рольләре җәмгатьчелектә зур яңгыраш таба, актриса аларда хатын-кыз язмышының драматик, кайчакта фаҗигале дә язмышын уңышлы ача. Аерым ал-

Г.М. Болгарская: 1. Гайни («Бәхетсез егет», Г. Камал); 2. Җиһан («Ак калфак», М. Фәйзи) рольләрендә.





ганда, А.Н.Островскийның «Яшенле яңгыр» (1914) әсәрендә хатын-кызның дини хорафатларга һәм гасырлар буена килгән гореф-гадәтләр коллыгына каршы протестын гәүдәләндерү үрнәге булган Катерина образын башкару аеруча уңышлы дип табыла. 1917–18 дә башкарган «Зөләйха» («Яшь гомер», Г.Коләхмәтов), Татьяна («Мещаннар», М.Горький), Раневская («Чия бакчасы», А.П.Чехов) рольләрендә Б. героиняларының рухи кичерешләрен, язмышларында заманның социаль тетрәнүләрен чагылдырып, аларны бөтен тирәнлеге б-н ачып сала һәм үзенең җитлеккән сәхнә остасы булуын күрсәтә.

1918 елдан РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты каршындагы Үзәк мөселман хәрби коллегиясе тарафыннан оештырылган драма труппасында эшли. Гражданнар сугышы елларында хәрби клубларда чыгышлар ясый. 1920 дә «Сәйяр» труппасы, актёрлары б-н бергә соңрак Татар. акад. театрына әверелгән Беренче татар үрнәк театры составына керә, шул рәвешле бу театр коллективлар арасында әзлеклелек урнаштыруга булышлык итә. Сәхнә реализмына тугрылык саклап, актриса К.Тинчуринның Хәдичә, Зөһрәбикә («Беренче чәчәкләр», 1921), Рауза («Соңгы сәлам», 1922), Гөлнур әби («Сүнгән йолдызлар», 1924), Бәдига («Кандыр буенда», 1932) кебек образларында, ш.у. Ф.Бурнаш, Т.Гыйззәт, Ш.Усманов әсәрләренең героиняларын башкарганда авторларның стилен нечкә тоемлый һәм дөрес ачып бирә; Зәйнәп («Дошманнар», Ф.Сәйфи-Казанлы, 1921), Караулова («Чит кеше баласы», В.В.Шкваркин, 1934), Полина («Дошманнар», М.Горький, 1936) рольләрендә авторларның фикер тирәнлеген, психологик төсмерләрне ачык күрсәтүгә ирешә. Актрисаның иҗат биографиясендә Т.Гыйззәт пьесалары буенча куелган спектакльләрдәге образлар (Мәрфуга — «Бишбүләк», 1938, 1949; Хәзинә — «Изге аманәт», 1946; Ханзафа — «Ташкыннар», 1937, 1949; Гыйльмениса — «Чаткылар», 1944, 1947) һәм А.Н.Островский, М.Горький, У.Шекспир әсәрләрендәге поэтик пафос, нәфислекнең тормыш дөреслеге б-н табигый кушылуын чагылдырган героиняләр аерым урын алып тора. Милли театр мәктәбенең зур остасы буларак, ул татар театрының яңа этикасын гамәлгә ашыра. Киң җәмәгать эшчәнлеге алып бара.

*Әд.:* Шәрәфиев Ф. Г.Болгарская. К., 1957; Гыймранова Д. Гөлсем Болгарская. К., 1981; Народные артисты. К., 1980.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**БОЛГА́РСКИЙ** Андрей Владимирович (27.8.1886, Казан — 27.11.1967, шунда ук), җылылык техникасы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1944), проф. (1944), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1944, 1967). 1914 елда Петербург технол. ин-тын тәмамлый. 1920 дән Казан хим.-технол. ин-тында, соңрак Казан а.х. һәм урманчылык ин-тында эшли. 1932 дән Казан авиация ин-тында, 1932–64 тә җылылык техникасы каф. мөдире, 1964 тән шунда ук каф. профессоры. Хезмәтләре дымлы газлардагы термодинамик процесслар теориясенә һәм аның техник мәсьәләләрдә кулланылуына карый. Газ дымлылыгының вакуум насосларының һәм ягулык парга әйләнгәндә һава компрессорының куәтенә, карбюраторның эшләвенә тәэсир итүен тикшерә. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Влажный газ. М., 1951; Рабочие процессы в жидкостно-реактивных двигателях. М., 1953 (автордаш); Термодинамика и теплопередача. М., 1975 (автордаш).

**БОЛГА́РСКИЙ** Борис Владимирович (5.8.1892, Казан — 3.4.1980, шунда ук), пед. фән. д-ры (1955), проф. (1958), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1962). 1917 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1918 дән Барнаул шәһәре урта мәктәбендә матем. укытучысы. 1919 дан Казанда. 1921 дән Казан ун-тының рабфак укытучысы, 1932–71 дә Казан пед. ин-тында матем. анализ кафедрасында. Матем. тарихы һәм матем. белем бирү буенча хезмәтләр, уку ярдәмлекләре, мәсьәләләр җыентыклары авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Казанская школа математического образования. К., 1966. Ч. 1–2; Очерки по истории математической мысли. Минск, 1979.

*Әд.:* Б.В.Болгарский: К 90-летию со дня рождения // Математика в школе. 1984. № 2.

**БОЛГА́РСКИЙ** (Фәйзуллин) Габделбари Фәтхулла улы (1884–1927), драма актёры. Хезмәт Батыры (1926). Мәдрәсәдә укый. Сәхнә эшчәнлеген 1908 елда «Сәйяр» труппасында башлый. Проф. татар театрына нигез салучыларның берсе. Гражданнар сугышы елларында фронт театр труппаларында, ш.и. Чиләбе шәһәрендә, 1921–23 тә Уфа шәһәрендәге татар театр труппасында, 1923–24 тә Казанда Беренче татар үрнәк театрында эшли. Буа татар театрын оештыручыларның берсе (1924–26). Беренче татар спектакльләрендә хатын-кызлар рольләрен башкара: Маһри, Мәһүпҗамал, Биби («Бәхетсез егет», «Бүләк өчен», «Беренче театр», Г.Камал), Шәрифә («Яшь хатын», Д.Таждаров), Газби («Ямьсез тормыш», Ф.Сәйфи-Казанлы), Мәрьям («Яшьләр», Ф.Әмирхан), Феклуша («Өйләнү», Н.В.Гоголь). Ш.у. характерлы рольләрне дә уйный: Добчинский («Ревизор», Н.В.Гоголь), Шәнгәрәйский («Артист», Г.Кариев), Җаффар («Надиршаһ», Н.Нариманов) һ.б.

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988.

*И.И.Илялова.*

**БО́ЛДЫРЕВ** Василий Николаевич (27.12.1872, Воронеж ш. — 27.2.1946), фармаколог, мед. д-ры (1904). И.П.Павлов шәкерте. Хәрби мед. академиясен тәмамлый (1898, С.-Петербург). 1899 елдан шунда ук эшли. 1909–18 елларда Казан ун-ты профессоры һәм фармакология каф. мөдире. Россиядә беренче буларак, фармакология дәресләре үткәрүне гамәлгә кертә, уникеилле эчәк лайлалы сүрүенең ялкынсынуын китереп чыгаручы факторны — ашказаны асты бизе һәм ашказанының рефлектор эшчәнлеген тикшерә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында буылдыргыч газларның токсикологик механизмын, агуланучыларга беренче ярдәм күрсәтү чараларын өйрәнә, шәхси һәм күмәк саклану чараларының һәркем файдалана



Г.М.Болгарская



И.П.Болодурин.

алырлык нәтиҗәле ысулларын эшли. 1917 дә Баш артиллерия идарәсе тарафыннан Лондон һәм Парижга командировкага җибәрелә, анда ул газдан саклану чаралары турында лекцияләр укый. Чит илдә вафат була.

Хезм.: Периодическая деятельность пищеварительного аппарата вне пищеварений, с точки зрения биологии и медицины. К., 1913; Немецкие удушливые газы и меры борьбы с ними. М., 1917; Работа у Ивана Петровича Павлова // Казан. мед. журн. 1925. № 3.

*Әд.:* Студенцова И.А., Романова Е.Б. Профессор Василий Николаевич Болдырев — заведующий кафедрой фармакологии Казанского университета // Казан. мед. журн. 1999. № 2.

**БО́ЛДЫРЕВ** Матвей Фролович (1839–1903), терапевт, мед. д-ры (1871). 1872–98 елларда Казан ун-тында эшли. 1887 елдан шәхси терапия каф. профессоры һәм мөдире. Рус-төрек сугышында (1878) катнаша. Хезмәтләре ларингология мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Сосуд и нервы слизистой оболочки гортани. К., 1871; О холере: Доклад съезду земских врачей. К., 1885.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**БОЛОДУ́РИН** Иван Петрович (1.2.1905, Казан губ., Чистай өязе Иске Чишмә а. — 28.9.1943), Сов. Союзы Герое (15.1.1944, вафатыннан соң), сержант. 1943 елга кадәр Иркутск өлкәсендә урман хуҗалыгында эшли. 1943 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 234 нче укчы полкның пулемётчылар отделениесе командиры (61 нче армиянең 76 нчы гв. укчы дивизиясе). Үзәк фронт гаскәрләре составында Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 28 сентябрендә Днепр елгасын кичкәндә Чернигов өлкәсе, Репки р-ны Мысы авылы янында батырлык күрсәтә. Уңъяк ярда плацдарм өчен барган сугышта һәлак була. Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. Кузнецов И.И. Золотые звёзды иркутян. Иркутск, 1982; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Подвиги их бессмертны. Хабаровск, 1985.

*В.А.Шагалов.*

**БО́ЛОЗНЕВ** Василий Васильевич (1.1.1898, Архангельск өлкәсенең Приозёрный р-ны Зехново а. — 24.10.1978, Воронеж ш.), генерал-майор (1943). Укытучылар семинариясен (1916, Петрозаводск ш.), Алексеевск хәрби уч-щесен (1917), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1927, Мәскәү) тәмамлый. Беренче бөтендөнья, Гражданнар, Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1941 елның 22 июненә кадәр Балтыйк буе аерым хәрби округы-

ның 27 нче армиясе штабы җитәкчесе. 1941 нең августында авыр яралана. 1943 тән Харьков хәрби уч-щесе җитәкчесе. 1944 нең 12 августында ачылган *Казан суворовчылар хәрби уч-щесенең* беренче башлыгы. 1946 дан Таҗикстан, 1948–58 дә Воронеж ун-тларының хәрби кафедралары җитәкчесе. Ленин, ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Это было, было... Йошкар-Ола, 1991; Насыбуллин М.Ш., Хронусов А.В. Детство и юность в алых погонах. К., 1995; Белов А.А. Мы — из Казанского суворовского. М., 1999.

**БО́ЛТИН** Баим Фёдорович (1580 еллар, Арзамас ш. — 1654 тән соң, Мәскәү), хәрби, дәүләт эшлеклесе. Руслашкан татар дворяннары нәселеннән. Арзамас шәһәрендә хезмәт итә. «Болгавыр заман»да Урта Идел буендагы сугыш хәрәкәтендә һәм Әстерханда казаклар атаманы И.М.Заруцкийга каршы яуда катнаша. 1614–15 елларда Казанда стрелецлар башлыгы, *Җангали хәрәкәтен* (1615–16) бастыруда катнаша. 1627–31 дә Олы Сарай приказы дьягы. Аннары Себер шәһәрләре (Тубыл һ.б.) воеводасы була. 1641 елдан патша конюшнялары идарәчесе («ясельничий»), 1652 дән стольник (патша сараенда хезмәт итүче). Эре җир биләүче: Ярославль, Ростов һәм Арзамас өязләрендә утарлары була. «Столяр» (яки Карамзин) хронографы — истәлекләр рәвешендәге елъязмалар һ.б. язма тупланмалар авторы. Хронограф «Болгавыр заман» тарихына, 1606–11, 1615–16 елларда Идел буе җирле халыкларының баш күтәрүләренә караган кыйммәтле чыганак булып тора. Аны Н.М.Карамзин Мәскәүдә билгесез балта остасыннан (столярдан) сатып ала һәм фән дөньясына кертә, шунлыктан хронограф аның исеме б-н аталган.

*Әд.:* Платонов С.Ф. Столяров хронограф и его автор // Сб. статей, посвящённых В.О.Ключевскому. М., 1909.

*Е.В.Липаков.*

**БО́ЛТИННАР**, руслашкан татар дворяннары нәселе. Нәсел башында Алтын Урдадан чыккан Котлыбаш (Котлыбуга) морза тора. Ул 14 йөздә рус кенәзлегендә хезмәт итә башлый. Аның улы Михаил «Болт» кушаматын йөрткән, шуннан фамилия ясалган дип фараз ителә (беренче булып Болтин фамилиясендә аның улы Матвей теркәлгән). Матвей улы Семён 1490 елда Костромада воевода. Котлыбаш морзаның бер оныгы — Григорий Иванович бөек кенәз Иван III сараенда хезмәт итә, 1473 тә *Әхмәд хан* сараена илче итеп җибәрелә. Шул нәселдән Андрей-Алай Б. Казанга яу б-н килгәндә 1548 дә һәлак була. Илче оныгы Михаил Андреевич Иван IV заманында Зөядә һәм Тәтештә воевода (1575–79), аннары Даниядә илчелек башлыгы. Икенче буын вәкиле Афанасий Васильевич Б. 1587–88 дә Зөя өязе, Иван Б. 1602–03 тә Казан өязе һәм Пётр Б. 1619 да Җөри даругасы җир-биләмәләре тасвирламасын эшлиләр. Будай (Будан) Б. Ливон сугышында (1558–83) катнаша. Баим Болтинның бертуганы Аверкий Фёдорович 1644 тә Саратовта, 1652–56 елларда Томскида воевода. Екатерина II заманында Иван Никитич Б. (1735 елда Казанда туган) генерал-майор, хәрби коллегия прокуроры була. Тарихчы буларак та абруй казана, патшабикәнең тарихи хезмәтен аңлатмалар өстәп нәшер итүдә катнаша (1792), Ле Клеркның Россия тарихына багышланган хезмәтенә карата җитди шәрехнамә яза (1788). Казан төбәгендә башка Б.ның да җирләре, крепостной крәстияннәре булган: 17 йөз башына кадәр Степан Б. Фёдоровский авылына хуҗа; Яков Б. утары 1637/38 дә Яңасала, Андрей Б. утары 1645 тә Чардак авылларында теркәлгән. Морза оныгы Матвей Михайловичтан соңгы бер нәсел тармагы Иван III заманыннан башлап Хрущ фамилиясе б-н таныла. Ш.у.к. *Болтин* Б.Ф.

Чыг.: История родов русского дворянства. СПб., 1886. Т. 2.

*Д.Г.Мостафина.*

**БОЛЫ́Н**, күпьеллык, нигездә, мезофиль (уртача дымлану шартларына җайлашкан) үләнчел үсемлекләр барлыкка китергән үсемлекләр бергәлеге тибы. Б.да шартлар күбесенчә үләннәр өчен уңайлы, башка тереклек формалары, агачлар һәм куаклар өчен әйбәт түгел. Б. төрләре: материк (кашлак Б. һәм сазламык Б.) язгы ташу сулары басмый торган субүләр һәм террасаларда урнаша; су баса торган, яки тугай Б. — елга тугайларында киң таралган; субальп һәм биек тау болыннары — урман чигеннән өстәрәк тауларда урнаша. Б. өчен кыяклылар һәм кузаклылар (азык буларак аеруча кыйммәт), ш.у. төрле үләнлелек хас. Барлык Б.нар өчен гомуми күренеш — туфракның өске катламында тамырлы туфрак, ягъни үлән тамырлары һәм тамырчаларыннан торучы чирәм хасил булу. Б.да үсемлекләрнең җир астындагы органнары массасы җир өстендәге органнар массасыннан 3–5 тапкыр һәм аннан да күбрәккә артык.

ТРда Б.нарның гомуми мәйданы 1 млн. *га* дан күбрәк. Аеруча киң таралганнары кашлак Б.нары, күбесенчә икенчел, ягъни бетерелгән урманнар урынында формалаша, урманның яңаруына көтү йөртү яки печән чабу комачаулый. Субүләрләрдә һәм төрле авышлыктагы сөзәклекләрдә күбрәк очрый. Печән чабу яки көтү йөртү нәтиҗәсендә үсемлек массасы кими, туфраклар ярлылана бара. Аз уңышлы (коры масса уңышы уртача 1 *га* дан 7 *ц*), нигездә көтү йөртү өчен файдаланыла. Үсемлекләр дөньясы чагыштырмача корылыкны яратучан. Күбрәк солыча, тар яфраклы йонча, сирәк кенә кылганнар, нечкә сабаклар үсә. Сазламык Б.нар чагыштырмача азрак. Сөзәклекләр итәгендә һәм грунт сулары чыккан түбәнлекләрдә урнаша.

Күбрәк болын солычасы, күрәннәр, кырчыл, Лобель аксыргагы үсә. Артык дымлы һәм түмгәкле булганлыктан, файдалану өчен уңайсыз. Кечкенә елга үзәннәре өчен, антропоген тәэсирләр көчле булмаганда, печән чаба торган кечкенә-кечкенә тугай Б.нары хас. Аеруча типик тугай Б.нары Кама-Криуш тугаенда (Алабуга шәһәреннән ерак түгел), Каманың сулъяк яры тугаенда Зәй һәм Чишмә елгасы тамакларында, Мишә елгасы тугаенда һәм аның түбән агымында сакланганнар. Бигрәк тә кындырак, сарут, кырчыл, төлкекойрык, кузаклылардан тукранбаш, тычкан борчагы үсә. 1 *га* дан 12–30 *ц* печән уңышы алына.

Б.нар печән чабу һәм көтү йөртү өчен файдаланыла. Продуктлылыгын арттыру өчен аларны культуралаштыралар: куаклардан чистарталар, түмгәкләрне кистерәләр, чирәмен йомшарталар, ашлама кертәләр, өстәмә рәвештә файдалы үләннәр чәчәләр һ.б.ш., дым җитмәгән очракта сугаралар, кирәгеннән артык дымланганда киптерәләр.

Ш.у.к. *Болынчылык*.

*Әд.:* Марков М.В. Избранные труды. К., 2000.

**БОЛЫ́Н РОМА́ШКАСЫ**, к. *Ак чәчәк*.

**БОЛЫ́Н СОЛЫЧАСЫ́** (Festuca pratensis), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругының бер төре. Таркау куаклы, уртача өлгерешле, көздән чәчеп үстерелә торган үсемлек. Республиканың һәр төбәгендә болыннарда, аланнарда һәм урман буйларында кыргый рәвештә үсә. А.х.нда культуралы печәнлекләр һәм көтүлекләр булдыру өчен файдаланыла. Б.с. 60–70 мең *га* җирдә игелә. ТРда 1976 елдан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының Л.А.Киселёва җитәкчелегендәге галимнәр коллективы тарафыннан чыгарылган «Казанская» сорты районлаштырыла. Б.с.ның 1 гектарыннан 3,5–4,5 *т* печән чабыла, иң күп уңышны беренче 2–3 елында бирә. Көчле тармакланучан, уңай шартлар туры килгәндә 20–30 лап кыска үсенте чыгара, вегетация чорында алар 4–5 тапкыр үсеп чыга ала. Кышкы салкынга чыдам. Балчыксыл субасар җирләрдә яхшы үсә. Ташу сулары астында 3 атнага кадәр чыдый. Кылчыксыз кындыракка караганда Б.с. көтүлекләрдә озаграк саклана һәм яшел массасын терлекләр яратып ашый. Биеклеге 1,2 *м* га кадәр җитә торган нечкә сабаклы үсемлек, башка төрләре б-н чагыштырганда суда эрүчән углеводлар микъдары артык (10–12 % ка кадәр), һәм бу терлекләр өчен шикәр-протеин нисбәтен яхшырта. 3 кат чабыла торган җирдә 1 *кг* коры массаның туклыклылыгы 0,75–08 азык берәмлегенә җитә. Орлык продуктлылыгы югары — 3–4 *ц/га* һәм аннан да күбрәк, орлыгы июль урталарында өлгерә. Чәчү нормасы 20–25 *кг/га*, 1 *см* тирәнлеккә чәчелә. Азотлы ашламаларны ярата.



*Әд.:* Справочник по кормопроизводству. М., 1993; Шайтанов О.Л. Подбор многолетних трав и травосмесей для организации зелёных и сырьевых конвейеров на орошаемых землях Среднего Поволжья: Дис. ... М., 1995.

*О.Л.Шайтанов.*

**БОЛЫ́Н ЯГЫ́**, 16 йөзнең 2 нче яртысында элекке Казан ханлыгы биләмәләренең көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш өлеше атамасы. Ул җирләрдә, нигездә, ясаклы мари халкы яшәгән (рус чыганакларында алар «болын ягы кешеләре» яки «болын ягы чирмешләре» буларак теркәлгәннәр). 16 йөзнең 60 елларында

Б.я. Казан өязенә кергән. Шул ук йөзнең 50 нче, 70–80 елларында Б.я. баш күтәрү үзәкләренең берсенә әверелә. Аларга каршы тору өчен монда Кокшайск (1573), Цивильск һәм Уржум (1584) кальгалары төзелә.

Чыг.: Полное собрание русских летописей. СПб., 1914. Т. 20, ч. 2; М., 1965. Т. 13, ч. 29.

*Әд.:* К а ш т а н о в С.М. Земельно-иммунитетная политика Русского правительства в Казанском крае в 50-х годах XVI в. (по актовому материалу) // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1970. Вып. 80; Разрядная книга 1550–1563 гг. М., 1975; Е р м о л а е в И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. Управление Казанским краем. К., 1982. *Д.Г.Мостафина.*

**БОЛЫ́Н-БАЛЫКЧЫ́** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 8 *км* төньяктарак, Зөя елгасы буенда. 2002 елда 331 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысыннан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.-Б.да мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, тимерчелек, 5 җил һәм 1 ярма ярдыру тегермәне, 2 йон һәм тукыма ману остаханәсе, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1880,1 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостена керә. 1920 елдан ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 137 ир заты; 1859 да — 706, 1897 дә — 1180, 1908 дә — 1369, 1920 дә — 1471, 1926 да — 1203, 1938 дә — 944, 1949 да — 771, 1958 дә — 597, 1970 тә — 455, 1979 да — 347, 1989 да — 340 кеше.

**БОЛЫ́Н-САЗЛЫ́К ТУФРАКЛАРЫ́**, туфрак тибы, туфракның өсте грунт сулары б-н даими һәм өстәмә рәвештә дымлану, ел саен язгы ташу вакытында су басу шартларында формалаша. Күрән, күрән-куга һәм курак (башаклы камыш) баскан яссы тигезлекләрнең тирән уйсулыкларында һәм елга террасаларында хасил була. Туфракның су режимы тотрыклы түгел, язгы ташу сулары күләменә карап, ел саен үзгәрә. Коры вакытларда туфрак тозлана (әгәр грунт сулары минеральләшкән булса) яки сазлык ләме барлыкка килә (әгәр грунт сулары аз минеральләшкән булса); үсемлекләр япмасында дымга таләпчән булмаган төрләр күренә. Явым-төшем күп булган елларда ләмләнү дәвам итә һәм торф туплана. Б.-с.т. профилендә берничә *см* дан алып 10–15 *см* га кадәр органоген горизонтны ($A_0$) аерып күрсәтәләр, аннан соң гумуслы ($A_1$) яки черемәле-гумуслы ($A_0A_1$) горизонт ята, калынлыгы 35–60 *см*, тутыккан таплар катнаш куе соры төстә. Түбәнрәк яткан күчеш горизонтында (Bg) соргылт-күгелҗем тондагы глейлану билгеләре күренә. Кайтарылу процессларының киеренке үсеше һәм артык дымлану б-н бәйле рәвештә, төпкә таба балчыклану ныгый, шуның нәтиҗәсендә ана токым глейланган масса (Cg) яки глей массасы (G) барлыкка китерә.

ТРда Б.-с.т. 28 мең *га* (гомуми мәйданның 0,4%) мәйданны били. Күбрәк Кама аръягы, Ык, Дала Зәе, Олы һәм Кече Чирмешән елгалары һәм аларның кушылдыклары үзәннәрендә таралганнар. А.х. тармагында файдаланыла торган иң зур мәйданнар Актаныш, Тукай, Нурлат, Әлки, Әлмәт, Түбән Кама р-ннарында. Туфракның механик составы балчыксыл һәм авыр комсу балчыксыл. Туфракның гумусы 5,4–11,8%. Тирәлек реакциясе нейтраль яки аз селтеле. Астиплары: черемәле Б.-с.т. һәм ләмле Б.-с.т. Печән чабу һәм көтүлекләр өчен файдаланыла. Туфракны киптерү эшләре алып барган очракта җиләк-җимеш, яшелчә һәм бөртекле культуралар үстерергә мөмкин. *Ф.Г.Борһанов.*


**БОЛЫНЧӘ́Й** (Lysimachia), нәүрүзгөлчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 ләп төре билгеле, күбесенчә урта пояста киң таралган. ТРда 2 төре — тәңкәяфрак Б., (L. nummularia) һәм гади Б. (L.vulgaris). Барлык р-ннарда да дымсу болыннарда, яр буйларында үсә. Тәңкәяфрак Б. — 30–60 *см* озынлыктагы үсемлек. Сабагы шуышма, кисешкән урынында тамырланган. Яфраклары капма-каршы урнаша, кыска саплы, кабарынкы сирәк төрткеләре бар. Чәчәкләре эре, ачык сары төстә, кыска чәчәк сабында берәмләп яки икешәрләп яфрак куентыгында урнашкан. Гади Б. түшәлмә туры сабаклы, 50–120 *см* озынлыктагы үсемлек. Яфраклары ланцетсыман озынча, киң озынча түгәрәк, өске ягы төрткеле бизләр б-н чуарланган. Чәчәкләре ачык сары төстә, себеркәчле чәчәк төркемендә. Җимеше — шарсыман тартмачык. Июнь-июль айларында чәчәк ата. Тамырланган бәбәкләрдән һәм орлыклардан үрчи. Дару үләннәре. Җир өстендәге өлешендә C витамины, дуплау матдәләре, сапониннар бар. Тонусны күтәрү өчен һәм көзән җыеруга каршы кулланыла. Халык медицинасында тонәтмәсе ревматизм, подагра, эчке кан китүләр вакытында файдаланыла. Баллы. Буяу матдәләре бар.

**БОЛЫНЧЫ́Л** (Deschampsia), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 ләп төре билгеле, салкын һәм уртача поясларда таралганнар. ТРда бер төре — кәс Б. яки елан теле (Д. caespitosa) барлык районнарда да очрый. Уйсу болыннарда, урман аланнарында, үләнле сазлык һәм сулык читләрендә үсә. Куе, тыгыз кәс барлыкка китерә, кыска тамырчалы, 30–120 *см* озынлыктагы кыяк. Яфрак пластинкасы яссы, очлы кабыргалы, кыягы озын, очлы. Чәчәк төркеме — көмеш төсендәге башаксыман себеркәч, җәелеп үскән кытыршы сабаклы. Җимеше — бөртекчә. Июнь–июльдә чәчәк ата. Орлыклардан үрчи. Көтүлекләрдәге яшь үләнен мөгезле эре терлек, атлар һәм сарыклар яратып ашый. Чәчәк бәйләмнәре өчен дә кулланыла.

**БОЛЫНЧЫЛЫ́К**, 1) табигый терлек азыгы җирләренең уңдырышлылыгын күтәрү, культуралы печәнлекләр һәм көтүлекләр булдыру һәм алардан рациональ файдалану б-н шөгыльләнүче үсемлекчелек тармагы; болын-көтүлек хуҗалыклары б-н идарә итү системасы; 2) болын-көтүлек хуҗалыкларының теоретик нигезләрен эшләүче фән. Б.ның төп бурычы — үлән үсемлекләреннән мөмкин кадәр күбрәк көтүлек азыгы, печән һәм башка терлек азыгы алу. Б.та терлек азыгы җитештерүнең бер өлеше табигый печәнлекләрне яхшырту һәм өстәмә чәчүле печән җирләре, көтүлекләр әзерләү чараларын үз эченә ала. 19 йөз ахырында Казан геоботаника мәктәбе барлыкка килә. Аңа нигез салучылардан С.И.*Коржинский*, А.Я.*Гордягин* һәм П.Н.*Крылов* Казан губернасының үсемлекләр дөньясын өйрәнәләр. Төп геоботаник тикшеренүләр 1930 елдан үткәрелә башлый һәм 1932 гә республиканың барлык терр-ясен колачлый. Казан ун-ты профессоры М.В.*Марков* тарафыннан ТАССРның болыннары картасы төзелә (1934) һәм «Татарстан болыннары» китабы языла (1946).

Татарстан а.х. тәҗрибә станциясендә (1969 дан *Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты*) Б. буенча эшләр алып барыла, 1920 дә биредә болын терлек азыгы җитештерү бүлеге төзелә, су баса торган Б. буенча Усад тәҗрибә кыры оештырыла. 1920–30 елларда әлеге кырда республиканың табигый терлек азыгы җирләрен яхшырту ысулларын өйрәнү максаты б-н тикшеренүләр үткәрелә. 1969 дан бүлектә сугарулы игенчелек һәм терлек азыгы җитештерү буенча эшләр алып барыла. 1969–78 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында М.М.Маликов, Ф.Х.*Хәбибуллин*, Ф.Н.*Сафиуллиннар* тарафыннан эшләнгән культуралы печәнлекләр һәм көтүлекләр булдыру һәм аларны куллану технологиясе 1976 да СССР ВДНХсының бронза медаленә лаек була. 2000 нән болын терлек азыгы җитештерү бүлеге табигый һәм культуралы печәнлек-көтүлекләрне торгызудагы ресурс — энергия сакланышлы технологияләрне камилләштерү буенча фәнни тикшеренүләр алып бара. Б.ның теоретик мәсьәләләрен хәл итүдә ш.у. Казан а.х. академиясе һәм Казан вет. медицинасы академиясе галимнәре дә катнаша.

ТРда беренче тапкыр печәнлек һәм көтүлек, сазлык, куаклык һ.б. көтү йөртү һәм печән чабу өчен файдаланылган җирләрдә тулы күләмле тикшеренүләр үткәрелә. Башкарылган эшләр нәтиҗәсендә 224 мең *га* мәйдандагы эрозияләнгән сөрү җирләре печәнлек һәм көтүлекләр итеп калдырыла. Республикада печәнлек һәм көтүлекләрнең гомуми мәйданы 1056 мең *га*, ягъни барлык а.х. җирләренең 23% ын тәшкил итә. Печәнлек җирләре соңгы 20 елда 180 мең *га* га кимегән (нигездә Куйбышев сусаклагычы җәелүе нәтиҗәсендә). 2007 нең 1 гыйнварына печәнлек һәм көтүлекләр гомуми а.х. мәйданының 1055,5 мең гектарын (24,2%) алып тора; шуларның 133,7 мең гектарын — печәнлекләр, 921,8 мең гектарын көтүлекләр (печәнлек һәм көтүлекләрнең 87,3% ы) тәшкил итә. Табигый терлек азыгы җирләренең нигезен 527 мең *га* мәйданда үзәнлек болыннары (гомуми печәнлек һәм көтүлек мәйданының 50% ы) алып тора. ТРда а.х. җирләренең сөрелгәнлек дәрәҗәсе бик югары — 75,8%, моңа сөзәк тау битләрендәге болыннар да керә, ә калган мәйданнар — вак контурлы, нык тапталган көтү-



К.Г. Боль.

лекләр (мәйданы — 302,1 мең *га* — 30,2%). Төбе коры үзән һәм чокыр-чакырлардан торган болыннар — 55,7 мең *га* (5,3%).

Татарстан өчен куе ерымнар челтәре характерлы. Үсемлекләрнең төп төрләренә — меңъяфрак һәм тәңкәяфрак катнаш төрле үләннәр, сарут — кындырак, арышбаш — сарут төрләре керә. Киптерелгән массага күчереп исәпләгәндә, 1 *га* га 7–12 *ц* уңыш туры килә. Яхшы сыйфатлы терлек азыгы. Уйсу болыннар исә түбән субүләрләрдә, киң инкү, коры үзәннәрдә, су басмый торган елга үзәннәрендә урнашкан, барлыгы — 88,5 мең *га* (8,4%), төпләре сазланган, түмгәкләнгән. Үсемлек төрләре: болынчыл һәм кызылсолычалар, сусәнле печән һәм болынчыллар. Уртача уңышы 1 *га* дан 10–12 *ц*, терлек азыгы буларак уртача һәм түбән сыйфатлы. Су баса торган болыннар кече һәм урта зурлыктагы елга үзәннәрен алып тора. Алар коры һәм дымлы болыннарга бүленә, 159 мең *га* мәйдан (15,1%) били. Коры болыннардагы үсемлек төрләре — төрле үлән һәм йончалар, сарут, кындырак һәм кызыл солыча, дымлыларында — сарут, кырчыл, кындырак.

Печәнлекләрдә 1 *га* дан 14–24 *ц*, көтүлекләрдә 8–12 *ц* уңыш чыга. Терлек азыгы уртача һәм яхшы сыйфатлы. Сазлыклы болыннар 15,8 мең *га* мәйданны (1,5%) алып тора. Болынчыл — кыяклы һәм камышлы үлән төрләре өстенлек итә. Терлек азыгы буларак сыйфаты түбән. Печәнлекләрдә, киптереп исәпләгәндә, уртача уңыш 16,7 *ц/га*, көтүлекләрдә 7,4 *ц/га*. Үлән капламы тапталган болыннарны яңарту өчен, чирәм өслегеп сөреп, бу җиргә ТР туфрак климаты шартларына яхшы ук яраклашкан күпьеллык үлән төрләреннән һәм сортларыннан (люцерна, болын клеверы, кылчыксыз талкыш, айравык) яңа үлән катламы үстерелә. 30–40% ын терлек азыгы үләннәре алып торган болыннарның үлән капламын табигый флораны мөмкин кадәр саклап калу ысуллары кулланып яхшырталар (үләннәрне авыр тырмалар б-н дисклап өстәп чәчү, туфракны капламсыз йомшартудан соң, ш.у. яңа төр чәчкечләр ярдәмендә турыдан-туры чирәмгә чәчү). Культуралы болыннардан вегетация чорында өзлексез яшел масса алу өчен төрле өлгерешле үлән капламнары (иртә, уртача, соң өлгерешле) булдырыла.

*Әд.:* Зелёная книга Республики Татарстан. К., 1993; Государственный доклад о состоянии земель в Республике Татарстан в 1995 году. К., 1996; Основные направления развития кормопроизводства РФ на 2010 г. М., 2001; М а л и к о в М.М. Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002.

*А.А.Габдрахманов, М.М.Маликов.*

**БОЛЫТЛЫЛЫ́К**, күзәтү урыны яки билгеле бер терр-я өстендәге болытлар җыелмасы. Беркадәр таррак мәгънәдә күк йөзенең болытлар б-н каплану дәрәҗәсен Б. дип атыйлар. Б. нульдән алып (болытсыз күк) 10 га кадәр (бөтен күк йөзе болытлар б-н капланган) баллар б-н билгеләнә. Шуның белән бергә күк йөзенең өч төп торышын аерып күрсәтәләр: аяз (0–2 балл), ярым аяз (3–7) һәм болытлы (8–10). Гомуми Б. (барлык биеклекләрдәге күренә торган болытлар) һәм түбәнге Б. (аскы чиге җир өстеннән 2 *км* дан кимрәк булган болытлар) аерып карала. Болытларның халыкара классификациясе 10 төп форманы үз эченә ала: каурыйсыман, каурыйсыман-өем, каурыйсыман-катламлы, биек өем, биек катламлы, катламлы, катламлы-өем, катламлы-яңгыр, өем һәм яңгырлы-өем.

ТРда түбәнге Б. өстенлек итә, ул болытларның гомуми күләменең ел буена уртача 65% ын, апрельдән июньгә кадәр 60% тан кимрәген, октябрьдән декабрьгә кадәр 70% тан күбрәген тәшкил итә. Гомуми Б.ның уртача еллык күрсәткече 7 баллга якын, түбәнге Б. — 4,5 балл һәм көньякка таба кими. Иң югары Б. — көз азагына, иң түбәне җәйге айларга туры килә. Елына гомуми Б. буенча 30–35, түбәнге Б. буенча 90–120 көн аяз була. Аяз күк йөзе апрельдән августка кадәр ешрак күзәтелә: гомуми Б. буенча 30–35%, түбәнге Б. буенча 50–65%. Елына гомуми Б. буенча 140–165, түбәнге Б. буенча 45–85 көн болытлы була. Октябрьдән гыйнварга кадәр болытлы күк йөзе кабатлануы гомуми Б. буенча 70% һәм түбәнге Б. буенча 50%. Б.ның тәүлеклек үзгәреше, көндезге сәгатьләрдә өем болытлар барлыкка килүе һәм үсеше өчен уңайлы шартлар туу сәбәпле, елның җылы вакытында ачыграк чагыла. Елның салкын вакытында күпчелекне катламлы болытлар тәшкил итә, иртәнге һәм көндезге сәгатьләрдә болытлы була. Атмосфера фронтлары үткән вакытта еш кына катламлы — яңгыр һәм биек катламлы болытлар күзәтелә.

Б. һава торышы һәм климат формалашуда, атмосфераны кушылмалардан чистартуда әһәмиятле роль уйный. Ул радиация процессларын көйли, температура режимына һәм явым-төшемнәргә йогынты ясый.

*Әд.:* Научно-прикладной справочник по климату СССР. Сер. 3. Л., 1988. Вып. 12.

*Э.П.Наумов.*

**БОЛЬ** Карл Генрихович (1.7.1871, С.-Петербург — 25.3.1959, Казан), вет. патологоанатомы, вет. фән. д-ры (1934), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1924, 1930). Казан вет. патологоанатомнары мәктәбенә нигез салучы. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1895), шунда ук эшли, 1912 елдан ординар проф., 59 ел дәвамында (1900 дән) патологик анатомия каф. мөдире, бер үк вакытта 1921–24 елларда Казан ун-тының мед. ф-тында һәм 1922–30 да ГИДУВта шул ук исемдәге каф. җитәкчесе, 1918–38 дә Казан вет. ин-ты, 1932–37 дә Казан вет. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1924 тә мөгезле эре терлектә паратуберкулёз авыруын беренче булып ачыклый һәм авыруның патоморфологиясен тасвирлый. Ялкынсыну процессларының, кан әйләнеше бозылуларының, сөяк сынуларының оригиналь классификациясен эшли, а.х. терлекләрендә була торган күп кенә йогышлы авыруларга хас патоморфологик үзгәрешләрнең үзенчәлекле комплексын төзи. Котыру, йогышлы энцефаломиелит һ.б. авырулар патоморфологиясен, патогенезын, аларга диагноз кую юлларын тикшерә. Россиядә беренче «Йорт хайваннары һәм кошларының патологик анатомиясе нигезләре» («Основы патологической анатомии домашних млекопитающих и птиц», 1913; 5 басма, 1961) дәреслеге авторы. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу о паталогоанатомических изменениях спинного мозга при чуме собак. К., 1899; Воспаление // Уч. зап. Казан. ун-та. 1929; Основы патологической анатомии сельскохозяйственных животных. М., 1961 (автордаш.).

*Әд.:* В и к т о р о в К.Р. Нашим дорогим юбилярам: О юбилеях профессоров И.П.Попова, В.И.Логинова, С.П.Мамадышского, Н.П.Рухлядова, Л.С.Сапожникова, К.Г.Боля // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1926. Т. 37, вып. 1; История Казанского государственного ветеринарного института имени Н.Э.Баумана. К., 1973; Казанский государственный ветеринарный институт имени Н.Э.Баумана (1873–1953): Материалы к истории ветеринарного образования в СССР. Казанская школа ветеринарных паталогоанатомов // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та. М., 1956. Т. 63 (юбилейный).

*О.Н.Гыйльметдинова.*

**БОЛЬНИ́ЦА КА́ССАЛАРЫ**, к. *Хастаханә кассалары.*

**БОЛЬЦА́НИ** Иосиф Антонович (18.9.1818, Берлин — 13.2.1876, Казан), физик, физика һәм химия д-ры (1858). Элементар белемне шәһәр мәктәбендә ала. 20 яшендә Дациароның Россиядәге сәүдә йортында приказчик була. Казан сәүдә лавкасында аны проф. А.Ф.Попов күреп ала һәм математика б-н кызыксынуын белә. Шуннан соң аңа белем бирү б-н Н.И.Лобачевский җитәкчелек итә. Ике елда (1842–43) Б. Казанда гимназиянең тулы курсын үзләштерә, имтихан тапшырып, Родионовларның затлы нәсел кыз балалар ин-тына укытучы булып урнаша. 1846 елдан Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә укытучы булып эшли. 1852 елда Б. Казан ун-тында имтихан тота, 1853 тә матем. фәннәре магистры дигән дәрәҗә ала һәм 1854 тә — математика, 1855 тә физика кафедраларына адъюнкт итеп билгеләнә. 1859 дан экстраординар, 1860 тан ординар профессор, 1868–71 елларда физ.-матем. ф-ты деканы. Бер үк вакытта Казан ун-ты каршындагы метеорология обсерваториясе җитәкчесе. Хезмәтләре физика һәм химия өлкәсенә карый.

Х е з м.: Математические исследования о распределении гальванических токов в телах данного вида. К., 1854; Теория Якобиевых функций и эллиптических интегралов // Уч. зап. Казан ун-та. 1856. Кн. 3/4.

*Әд.:* Библиографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Р.Г.Усманов.*

**БОЛЬШАКО́В** Кирилл Андреевич (24.12.1906, Рязань өлкәсе Ряжск ш. — 27.12.1992, Мәскәү), химик-нәорганик, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1958), Россиядә си-

рәк элементлар сәнәгатенә нигез салучыларның берсе. 1930 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1930 елдан Мәскәүдә: Дәүләт сирәк металлар фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире (1930–47), бер үк вакытта Мәскәү нечкә химик технологияләр ин-тында (1933 тән), 1958–71 елларда ректор. Хезмәтләре сирәк очрый торган һәм сибелгән элементларны аерып чыгару, чистартуның физик-химик нигезләренә карый. Илдә чыгарылучы полиметалл рудаларыннан кобальт табу технологиясен эшли. Керчь чыганагы тимер рудаларыннан һәм Урал титанмагнетитларыннан ванадий аерып алу технологиясен эшләүдә катнаша. Сибелгән элементларны (галлий, индий, таллий, рений һәм германий), аеруча чиста матдәләр һәм ярымүткәргеч материалларны аерып алу технологиясенең теоретик нигезләрен эшли. Сөрмә һәм висмутны утырымлы эретү ысулы б-н табу, кобальт-никель рудаларын һәм аларны эшкәртү продуктларын хлорлаучы һәм сульфатлаштыручы яндыру процессларын, сирәк элементлар кушылмаларын эремәләрдән утырымга төшерү шартларын өйрәнә. Аның редакциясендә югары уку йортлары өчен «Сирәк һәм сибелгән элементлар химиясе һәм технологиясе» («Химия и технология редких и рассеянных элементов», т. 1–2, М., 1965–69) дигән дәреслек чыгарыла. СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1941, 1953). Ике Ленин ордены һ.б. б-н бүләкләнә.

**БОЛЬШАКО́В** Фёдор Андреевич (1864, Казан губ., Тәтеш өязе Сөйке а. — 1934, Казан), Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре. Иделнең уңъяк яры буенда табигый таш чыгаруны һәм аны Казанда сатуны оештыра. Хәзерге Кама Тамагы р-ны Сөйке авылы янәшәсендә гипс чыгару руднигын нигезли һәм аның хуҗасы була.

**«БОЛЬШЕВИ́К ТАТА́РИИ»**, журнал, к. *«Коммунист Татарии»*.

**БОЛЬШЕВИКЛА́Р**, РСДРПдагы сәяси агым (фракция) вәкилләре (1917 елның апреленнән мөстәкыйль сәяси оешма). «Б.» төшенчәсе РСДРПның 2 нче съездында (17.7 — 10.8.1903, Брюссель-Лондон), партиянең җитәкче органнарын сайлауларда В.И.Ленин тарафдарлары тавышларның күпчелеген алганнан соң барлыкка килә (шуннан — «Б.»), аларга каршы вәкилләр азчылыкны ала (*меньшевиклар*). 1917–52 елларда «Б.» термины партиянең рәсми исеменә керә — РСДРП(б), РКП(б), ВКП(б). 1952 дә ВКП(б)ның 19 нчы съездында кабул ителгән карардан соң, ул *Советлар Союзы Коммунистлар партиясе* дип атала башлый. Б. үзләрен эзлекле марксистлар дип исәплиләр, рев-ция юлы б-н бару реформалардан отышлырак, 20 йөз башында Россиядә капитализм һәм крепостнойлык калдыклары арасында туган каршылыклар, буржуазиянең сәяси көчсезлеге һәм реакционлыгы җәмгыятьне пролетариат мәнфәгатьләрендә тамырдан үзгәртеп кору өчен башка мөмкинлекләр калдырмый, дип саныйлар. Б., Россиядә капитализмның авылга үтеп керүе, Россия халкының капитализм чорында төрле катлауларга бүленүе югары дәрәҗәгә ирешә, шул сәбәпле дөньядагы капитализм системасы социализмга күчүгә әзер, дип уйлыйлар. Бөтендөнья рев-циясе һәм Россиянең анда катнашуы өчен объектив шартлар өлгереп җитте, дип тулысынча ышаналар. Җәмгыятьтә эшчеләр сыйныфының әйдәп баручы көч булуы һәм пролетариат диктатурасы идеясен күтәрәләр. Аграр мәсьәләдә алар җирләрне тулысынча дәүләт карамагына тапшыруны яклыйлар. Большевизм Россиядәге революцион хәрәкәттә радикаль юнәлешнең дәвамы була, ул үзендә народниклык идеологиясенең каршылыклы элементларын һәм Бөек француз рев-циясе тәҗрибәсен туплый. Б. пролетар рев-цияне әзерләүдә һәм уздыруда партиянең җитәкче роле турындагы идеяне игълан итәләр; профессиональ революционерларның катгый рәвештә үзәкләштерелгән оешмасы нигезендә берләшеп, яшерен эшчәнлек алып баруга һәм хакимиятне кулга төшерүгә сәләтле партия оештыру тарафдарлары булалар. Б.ның Казан ком-тында актив әгъзалар — В.В.Адоратский, А.Я.Аросев, Н.П.Брюханов, Н.Е.Вилонов, А.П.Бржезовский, С.А.Лозовский, В.А.Тихомирнов, А.И.Догадов, А.П.Комлев, Н.А.Семашко, Н.Е.Сапрыгин, С.Н.Гассар, Х.М.Ямашев һ.б.

*Әд.:* Очерки истории партийной организации Татарии. К., 1973; Нафигов Р.И., Литвин А.Л. Малоизученные страницы истории Казанской организации РСДРП(б) // Коммунист Татарии. 1980. № 5.

*Л.М.Айнетдинова.*

**«БОЛЬШЕВИКЛА́Р СҮЗЕ́»**, газета. ВКП(б)ның Златоуст шәһәр ком-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның шәһәр советы органы. 1932–35 елларда Златоуст шәһәрендә (Чиләбе өлкәсе) татар һәм казакъ телләрендә нәшер ителә.

**«БОЛЬШЕВИКЛА́Р ЮЛЫ́»**, газета. КПССның Касыйм шәһәр ком-ты һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы органы. 1919–65 елларда Касыйм шәһәрендә (Рязань өлкәсе) татар телендә нәшер ителә.

**«БОЛЬШЕВИ́ЧКА»**, газета. Төрле елларда төрле оешмалар тарафыннан чыгарыла: Татарстан тегү сәнәгате эшчеләре һәм хезмәткәрләре; Тегүчеләр берлегенең Татарстан бүлеге; ВКП(б)ның Пролетар райкомы, Швейтрест һәм Тегүчеләр берлегенең Татарстан бүлеге; ВКП(б)ның Киров райкомы, Швейтрест һәм Тегүчеләр берлегенең Татарстан бүлеге һәм Татарстан Швейтресты; ТАССР Җиңел сәнәгать халык комис-ты һәм Тегүчеләр профсоюзының Татарстан ком-ты газетасы була. 1929–41 елларда Казанда рус һәм татар телләрендә нәшер ителә. 1932–33 тә «Тегүче» исемендә чыга. Төрле елларда җаваплы мөхәррирләре: Ф.Биткин, А.Аитова, П.Гущин, М.Фролов. «Б». илдәге һәм чит илләрдәге сәяси хәлләрне яктырта, җирле сәнәгать һәм а.х. проблемаларын күтәрә, тегү сәнәгатенең техник югарылыгын, продукциянең сыйфатын яхшырту мәсьәләләрен даими рәвештә алга куя. Рубрикалары: «ТАСС хәбәр итә», «Вакытлы матбугат битләреннән», «Мактау тактасы», «Политмәктәп укучыларына ярдәмгә» һ.б.

*Г.Шәйдуллина-Хәсәнова.*

**БОЛЬШЕРЕ́ЧЬЕ РАЙОНЫ́**, *Омск өлкәсенең* көнчыгышында. 1924 елның 24 сентябрендә оештырыла. Мәйданы — 4,3 мең *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Большеречье посёлогы (Омскидан 204 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 34037 кеше (2002), ш.и. 3828 татар. Алар, башлыча, Үләнкүл (756 кеше), Кошкүл (374), Куйгалы (285), Яланкүл (245), Чарналы (244), Чеплярово (240), Олы Мурлы (234), Тусказан (192), Каракүл (93) авылларында яшиләр. Иң борынгы авыллар: Чарналы һәм Тусказан, алар турында беренче тапкыр 5 нче ревизия документларында (1795) телгә алына. 7 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. «Болгар» (Большеречье пос.) һәм «Наза» (Үләнкүл а.) татар фольклор төркемнәре эшли. 1999 елдан җирле телевидение татар телендә «Иртыш таңнары» тапшыруын күрсәтә. Б.р.нда тарих фән. д-ры *Ф.Т.Вәлиев* туган.

**БОНДАРЕ́НКО** Александр Иванович (9.9.1922, Украина Респ-касының Винница өлкәсе Слободище а. — 20.8.1997, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленинград тимер юл транспорты инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), Муром тимер юл станциясе башлыгы урынбасары, Казан тимер юл станциясе башлыгы урынбасары, Казан тимер юл хәрәкәте хезмәтенең техник бүлеге башлыгы булып эшли. 1955 елдан Казанда партия эшендә: 1957–59 елларда КПССның Бауман райкомы секретаре, 2 нче секретаре, 1959–61 дә КПСС шәһәр ком-тының сәнәгать-транспорт бүлеге башлыгы, 1961–62 дә партиянең Идел буе райкомы 1 нче секретаре, 1962–65 тә КПСС Казан шәһәр ком-тының 2 нче секретаре. 1965–85 тә халык депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе. Казанда торак һәм сәнәгать төзелешен оештыруга, шәһәрне төзекләндерүгә сизелерлек өлеш кертә. ТАССР (1963–67), РСФСР (1967–85) ЮСлары депутаты. Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм өч Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казандагы бер урам аның исемен йөртә.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БО́НДЮГ**, шәһәр тибындагы посёлок, к. *Менделеев*.

**БО́НДЮГ БУТ ТАШЫ́ ЧЫГАНАГЫ́**, ТРда иң эреләренең берсе. Менделеев шәһәренең төньягында. 1931 елда ачылган, 1958 елдан эшкәртелә. Запаслары 1,1 млн. *м*³ (1995). Түбәнказан асъярусы известьташларының ике катламы билгеле. Аскы катлам 7,6–25 *м* тирәнлектә, аксыл сары, яшерен кристаллы, тыгыз төзелешле, чатнак известьташлар; катлам калынлыгы 0,3–2,3 *м*. Өске катлам — тишекле, саргылт-соры төстәге чатнак известьташлардан гыйбарәт, калынлыгы 2,0–9,3 *м*. Чыганак капкачының калынлыгы 3,8–18,5 *м*. Известьташларның сыйфаты: вакланган таш өеме массасы 951–1176 *кг/м*³; уртача тыгызлыгы 1,99–2,31 *г/см*³; көпшәклелеге 11,7–28,9%; су сеңдерүчәнлеге 5,7–7,6%; чыдамлылык чиге 11,5–25,8%; салкынга чыдамлылыгы 25 циклдан соң 3,1–8,7%; катырак токымнардан вакланган

таш чыгышы 82,7–93% тәшкил итә. Уртача химик составы (%ларда): $CaCO_3$ — 94,9, $MgCO_3$ — 1,32, $SiO_2$ — 1,89, $Fe_2O_3 + Al_2O_3$ — 0,75, $K_2O + Na_2O$ — 0,13.

**БО́НДЮГ НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, ТРда иң эреләренең берсе. Респ-каның төньяк-көнчыгышында Менделеев р-ны терр-ясендә. 1955 елда ачылган, 1958 елдан «Примкамнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе тарафыннан эшкәртелә. Чыганак мәйданы 17,5×5,75 *км*. Тектоник яктан Татар гөмбәзе Төньяк күтәрелешенең көньяк-көнчыгыш яссылыгына туры килә. Сәнәгый нефть югары девонның кын (төп катлам) һәм пашия горизонтларындагы комлы алевролит катламнарында тупланган. Геол. запаслары 104 млн. *т*, алына торганы — 61,7 млн. *т*. Катламнар ятмасы уртача 1650 *м* тирәнлектә, нефть җыела торган урыннарның биеклеге 35 *м*, нефть ятмасының биеклеге 30 *м* чамасы. Коллекторларның сыйдырышлылыгы (ачык көпшәклелеге) 19%, фильтрация характеристикасы (үтешлелеге) 0,600 *мкм*². Катлам басымы 17.2 *МПа*, темп-расы 35 °С, газ факторы 38,8 *м*³/*т*, нефть чыгышы тәүлеккә уртача 6 *т*. Нефтьнең үзлелеге түбән (6,05 *МПа·с*), күкертле (1,9%), парафинлы (3,9%). 1978–81 елларда чыганак мәйданының 50% ы Түбән Кама сусаклагычы астында кала. Чыганакның бу өлеше дамба б-н бүлеп алынган; бораулау эшләре дамба буендагы мәйданчыкларда һәм махсус корылмалар ярдәмендә алып барыла. 1962 елга кадәр чыганак тыгыз су басымлы режимда эшли, 1962 елдан басымны катлам контуры тирәли тәэмин итү һәм контур эчендә продуктлылыгы төрле булган зоналарга бүлү ысуллары кертелә башлый. Хәзер чыганакны үзләштерүнең соңгы стадиясе бара. 2000 елның 1 гыйнварына 59,7 млн. *т* нефть алынган. Нефтьнең еллык иң күп чыгышы (1972) 2,8 млн. *т* чамасы. 1999 елда 0,4 млн. *т* нефть алынган.

*Г.С.Габделмәҗитова.*

**БО́НДЮГ РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — шәһәр тибындагы Бондюг посёлогы. 1921 елга кадәр терр-ясе Вятка губернасына, 1921 елдан ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантоннарына керә. 1931 нең 20 гыйнварында таркатыла, биләмәсе Алабуга р-нына кушыла. 1935 нең 10 февралендә яңадан торгызыла. 1940 елга Б.р.ның мәйданы — 730 *км*², халкы — 40,3 мең кеше, 25 авыл советы, 58 торак пункт исәпләнә. 1960 та район 741,8 *км*² мәйдан били, аңа 1 посёлок советы, 10 авыл советы, 59 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә таркатыла, биләмәсе Алабуга р-нына бирелә.

**БО́НДЮГ ХИ́МИЯ ЗАВОДЫ́**, к. *Химия заводы.*

**БОНИТЕТЛА́У** (лат. bonitas — яхшы сыйфатлы), 1) туфракны Б. — аның табигый уңдырышлылыгын, конкрет климат шартларында а.х. культураларының мәгълүм бер дәрәҗәдә уңыш бирү мөмкинлеген тикшерү нигезендә җир мәйданнарының сыйфатын чагыштырмача (баллар б-н) бәяләү. Б. җирне икътисади бәяләү, *җир кадастрын* алып бару өчен кирәк. Респ-када беренче мәртәбә туфракны Б. 1960 еллар уртасында Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты тарафыннан «Волгогипрозем»ның Татарстан ф-лы б-н берлектә үткәрелә; аның материаллары адм. р-ннарда, һәр колхоз һәм совхозда а.х. культуралары җитештерү һәм әзерләү күләмен планлаштырганда файдаланыла. 1972 дә туфракны Б. РФ өчен бердәм методика буенча уздырыла. Сөрүле җирләрнең бонитет баллары 25 тән (Яшел Үзән р-ны) 80 гә кадәр (Чүпрәле р-ны), респ-када уртача балл 65 тирәсендә тирбәлә. Респ-ка җир кадастры үзәгенә фәнни учреждениеләр катнашында туфракны Б. эше йөкләнгән; 2) а.х. терлекләрен Б. — аларны нәсел килеп чыгышы, тышкы төзелеше, продуктлылыгы, үрчү сәләте, нәсел сыйфаты турындагы мәгълүматлар, токым һәм продуктлылык сыйфатлары нигезендә комплекслы бәяләү. Нәселле терлек үрчетү эшендә кулланыла. Терлекләрне Б. эше ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Нәсел үрчетү эше баш идарәсенең методик җитәкчелегендә хуҗалыклардагы зооветеринария белгечләре тарафыннан башкарыла. Ел саен респ-кадагы мөгезле эре терлек һәм дуңгызларның 80% ы чамасы, сарыкларның 70% тан артыгрэгы бонитетлана. Б. нәтиҗәләре буенча терлекләр нәсел үрчетү тупланмасына сайлап алына, товарлыклы төркемгә җибәрелә яисә яраксызга чыгарыла.

*Әд.:* Бонитет земли и экономика. К., 1978; Показатели племенной работы хозяйств Республики Татарстан. К., 1997.

*Г.Х.Хәбибрахманов, А.Х.Фазылҗанов.*

**БОРАГА́НСКИЙ** Ильяс Мирза улы (22.4.1852, Бакчасарай ш., Кырым — 1920 еллар ахыры), нашир, китап басу остасы, педагог. 1867–74 елларда Төркиядә укый, матур язу (каллиграфия), рәсем ясау, ташка, металлга сурәт төшерү һөнәрләрен үзләштерә. Россиягә кайткач, төрле шәһәрләрдәге басмаханәләрдә металлга һәм пыялага язма текстлар төшерү, каллиграфия б-н шөгыльләнә. 1882 елда С.-Петербургта төпләнеп, 1894 тә хосусый татар матбагасы оештыра (к. *Бораганский И.М. басмаханәсе*). Оста каллиграф, Шәрекъ телләрен үзләштергән белгеч буларак, 1898–1908 елларда Петербург ун-тында төрек-татар телләрен һәм Шәрекътәге матур язу ысулларын укыта. 1920 елларда Башкортстанда китап басу эшен оештыруга якыннан катнаша.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; шул ук. Книги и люди. К., 1985.

**БОРАГА́НСКИЙ И.М. БАСМАХАНӘСЕ́**, С.-Петербургта. Татар китаплары бастыру максаты б-н, 1894 елда «И. Бораганский К°» ширкәте буларак ачыла. Эшчәнлегенең беренче чорында басма хәрефләре булмый, китапларны ташбасма (литография) ысулы б-н нәшер итә. 1895 елның ахырыннан китаплар хәреф җыю ысулы б-н генә басыла. 20 йөзнең башына кадәр 60 исемдә китап (гомуми тиражы 270 мең данә), 1900–10 елларда 128 исемдә (гомуми тиражы 418240 данә) татарча, гарәпчә, фарсыча, казакъча, русча иҗтимагый-сәяси, фәнни, әдәби, дини китаплар, төрле белешмәлекләр бастырып чыгара. Алар арасында И.Бораганский тарафыннан эшләнгән гарәпчә язу үрнәкләре китабы, Әбдүш Ваһаповның «Татарларга русча һәм русларга татарча үзөйрәткеч»е, К.Насыйри әкиятләре, Ф.Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902), К.Мотыйгыйның «Бәхетле Мәрьям» әсәре (1903), Абай шигырьләре (1909), Петербург ФА һәм Петербург ун-ты шәркыятьче галимнәренең хезмәтләре һ.б. бар. Басмалар бизәлеш һәм полиграфик эшләнеш ягыннан югары сыйфатлы була. Ширкәтнең пайчысы, соңрак И.Бораганскийның компаньоны булып «Нур» г-тасы нашире Г.*Баязитов* хезмәттәшлек итә, аерым очракларда басмаханә үзе дә «Нур»исемендә эшли. Мөселман матбугатына әзәрлекләүләр көчәю сәбәпле, 1911 елдан татарча китаплар бастырудан туктый, 1917 елга кадәр фәкать рус телендәге китапларны гына бастыра. 1919 елда атлы башкорт бригадасы карамагына бирелә, анда татар телендә «Салават» г-тасы басыла. 1920 дә басмаханә Эстәрлетамак шәһәренә күчерелә, 1920–22 елларда анда татар телендә барлыгы 30 исемдә җир эшләре, ветеринария буенча китаплар, дәреслекләр, матур әдәбият әсәрләре, ш.и. Ш.Бабичның «Башкорт халкына хитаб»ы, Г.Бикчуринның «Инкыйлаб шигырьләре» басыла. 1922 ел азагында Уфа шәһәренә күчерелә, «Октябрь басымы» («Октябрьский натиск») басмаханәсенең нигезен тәшкил итә. Ш.у.к. «*Башкнига*».

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; шул ук. Татарская книга пореформенной России. К., 1983; шул ук. Становление и развитие татарской советской книги (1917–1932). К., 1989.

*Г.Г.Габделганиева.*

**БОРА́Й**, к. *Бодай.*

**БОРА́Й РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* төньяк-көнбатышында. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1820 *км*². Үзәге — Борай авылы (Уфадан 152 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 28320 кеше (2002). Татарлар саны: 1939 да — 20393, 1970 тә — 12332, 1979 да — 6442, 1989 да — 15102, 2002 дә — 2689 кеше. Районда 95 торак пункт, ш.и. 27 татар, 4 татар-башкорт авылы. Иң зур татар авыллары (1999): Чалкак (1065 кеше), Яңа Кизгән (616), Мулла (466), Кулай (461). Иң борынгы авыллар: Берләч (1650 дән мәгълүм), Үләй (1650), Шүнәк (1657), Мулла (1657), Шабай (1682–87). 2004/2005 уку елында 31 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татарча «Алга» г-тасы нәшер ителә. Чалкак авылында композитор С.*Габәши* кабере сакланган. Б.р.нда Сов. Союзы Геройлары С.Н.*Майский* (Бигәнәй а.), Т.Б.Гыйләҗетдинов (Бәзрәк а.); Татарстанның халык артисткасы җырчы Х.С.*Тимергалиева* (Котлыяр а.); нәкышьче Р.З.*Харисов* (Иске Карагыш а.) туган.

**БОРАТЫ́НСКИЙ** (Баратынский) Александр Николаевич (4.7.1867 — 18.9.1918, Казан), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1912). Е.А.Боратынскийның оныгы. С.-Петербургта хокук белеме уч-щесен тәмамлый (1889). 1890 елдан Казан округы мәхкәмәсендә 1 нче җинаять-

ләр карау бүлегендә секретарь ярдәмчесе, 1891 дән Чистай шәһәренең 2 нче бүлекчә судьясы, 1893–97 елларда Сембер округы мәхкәмәсе прокуроры урынбасары. 1901–02 дә Казан округы мәхкәмәсендә шәрәфле җәмәгать судьясы. 1899–1917 дә Казан һәм Царёвококшай өязләре дворяннары башлыгы. Бөтенроссия земство эшлеклеләре съездында катнаша (1904). Казан губернасыннан 3 нче Дәүләт думасына депутат булып сайлана (1907–12). Мәгариф өлкәсендә актив җәмәгать эшлеклесе: Мария исем. кызлар гимназиясенең тышкы идарәчеләре һәм Укытучылар семинариясе советлары әгъзасы. Л.Н.Толстойның Ясная Поляна мәктәбе үрнәгендә авыл мәктәпләре оештыручы. Казанда Зур Лядская урамындагы Боратынскийлар өендә земство укытучыларының очрашуларын оештыра. 1915 елдан *Питрәч һөнәр-сәнгать остаханәсе* советы җитәкчесе. «Дусларыма истәлеккә» («Друзьям на память», 1914) исемле шигырьләр җыентыгы авторы, «Казанның сәнгать хәзинәләре» (1916) күргәзмәсен оештыручыларның берсе. «Унҗиденче октябрь берлеге»нең Казан ком-ты әгъзасы. Император Александр III истәлегенә чыгарылган көмеш медаль, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

1918 елның сентябрендә ВЧК органнары тарафыннан кулга алына һәм атып үтерелә.

*Әд.:* Б о р а т ы н с к а я О. Баратынка // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 1/2.

*Л.М.Айнетдинова.*

**БОРАТЫ́НСКИЙ** (Баратынский) Евгений Абрамович (19.2.1800, Тамбов губ. Мара а. — 29.6.1844, Неаполь ш., С.-Петербургта җирләнгән), шагыйрь. Беренче шигырьләре 1819 елда басыла. «Эда», «Зур мәҗлесләр» («Пиры», 1826), «Бал» (1828), «Кәнизәк» («Наложница», 1831) поэмалары, «Шигырьләр» («Стихотворения», 1827, 1835), «Эңгер-меңгер» («Сумерки», 1842) шигырь җыентыклары авторы. Шигъриятенең төп юнәлеше — фәлсәфи лирика. Казан һәм Казан губернасы Б. тормышында һәм иҗатында билгеле бер эз калдыра: ул Казан алпавыты Л.Н.Энгельгардт кызы Анастасиягә өйләнә, алпавыт утары урнашкан Каймар авылында (хәзер Биектау р-нына керә) еш була. Казанга беренче килүендә (1831 июнь — 1832 июнь) җиде-сигез шигырь (ш.и. Н.М.Языков б-н А.А.Фукска багышланган шигырьләр) һәм «Йөзек» («Перстень») повестен, эпиграммалар иҗат итә. Казанга икенче килүендә, 1833 елның 6 сентябрендә монда А.С.Пушкин б-н очраша (А.С.Пушкинның Е.И.Пугачёв эзләре буйлап сәяхәт кылган вакыты). Б.ның Казанга 1834 елның ноябрендә килү ихтималы да фаразлана. Б.ның Казаннан һәм Каймар авылыннан язган 30 лап хаты сакланган. Казан турындагы тәэсирләре түбәндәге юллардан мәгълүм: «провинция шәһәре башкаладан җанлырак», «Монда, Мәскәүгә хас булмаганча, җанлану сизелә...». 1977 дә Казанда Б.га багышланган музей ачыла.

Ә с ә р.: Разума великолепный пир: О литературе и искусстве. М., 1981; Стихотворения. Письма. Воспоминания современников. М., 1987.

*Әд.:* З а г в о з к и н а В.Г. Е.А. Боратынский и Казань. К., 1985; П е с к о в А.М. Летопись жизни и творчества Е.А.Боратынского. 1800–1844. М., 1998.

*И.В.Завьялова.*

**БОРАТЫ́НСКИЙ** (Баратынский) Ираклий Абрамович (12.2.1802, Тамбов губ., Кирсанов өязе Вяжля а. — 22.4.1859, С.-Петербург), дәүләт эшлеклесе, хәрби, генерал-лейтенант (1853), сенатор (1857). Е.А.Боратынскийның бертуганы. С.-Петербургта Пажлар корпусын (дворян балалары өчен хәрби уку йортын) тәмамлый (1819). 1819 елдан хәрби хезмәттә, 1828–29 да рус-төрек сугышында, 1830–31 дә Польшадагы фетнәне бастыруда, 1840–42 дә Кавказны яулау сугышында катнаша. 1842–46 да Ярославльдә, 1846–57 дә Казанда хәрби губернатор, гражданлык эшләре б-н идарә итү дә аңа карый. Б. заманында Казан б-н Бишбалта арасында өем юл (дамба) (1847), Кремльдә губернатор сарае (1848), яңа театр бинасы (1851) һәм рухани хатын-кызлар әзерләү уч-щесе (1852–53) төзелә. Ун-т ишегалдында Г.Р.Державинга һәйкәл куела (1847). 1848 елда Казан руханилар академиясе яңа бинага күчерелә. Губернада балалар ятимханәләре эшчәнлегенә уңай шартлар тудырырга тырыша. Аның булышлыгы б-н Казанда рус телендә «Записки Казанского императорского экономического общества» (1854–61) һәм «Православный собеседник» (1855) ж-ллары нәшер ителә башлый.

*Әд.:* Б о р а т ы н с к и й М.А. Род дворян Боратынских. М., 1910; Д о л г о в Е.Б. Казанский губернатор Ираклий Боратынский // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1997. № 1/2.

*Е.Б.Долгов.*

**БОРАТЫ́НСКИЙ** (Баратынский) Николай Евгеньевич (26.11.1835, Мәскәү — 7.4.1898, Казан өязе Шушар а.), шагыйрь. Е.А.Боратынскийның улы; Казан һәм Царёвококшай өязләре дворяннары башлыгы (1865–72), Казандагы беренче кыз балалар гимназиясенең тышкы идарәчеләре советы рәисе (1865–82). Николай исем. кавалеристлар уч-щесен тәмамлый (1854); лейб-гвардиячә Павловск полкында өч ел хезмәт иткәннән соң отставкага чыга (1857), Казанда яши башлый. Бертуганы Лев б-н бергә әтиләренең шигырьләрен, хатларын, башка төр язмаларын туплыйлар, аңа аңлатмалар язалар (Казанда 1884 тә нәшер ителә). Казанда Зур Лядской урамындагы Боратынскийлар утарында шагыйрь Е.А.Боратынский кулъязмаларының, китаплары һәм архивының зур өлеше туплана. Б. 1865–70 елларда Казан губерна дворяннары башлыгы була. Беренче кыз балалар гимназиясе укучылары өчен стипендия билгели. Россия дворяннары эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр һәм «Дусларыма истәлеккә» («Друзьям на память», 1882) исемле шигырь җыентыгы авторы. Хатыны Ольга Александровна (1844–1918) мәгълүм шәркыятьче галим М.*Казимбәкнең* кызы була. 2 нче дәрәҗә Изге Станислав ордены, 1853–56 елгы сугыш истәлегенә чыгарылган медаль һәм Иран хөкүмәтенең 2 нче дәрәҗә Арыслан һәм Кояш ордены б-н бүләкләнә.

*И.В.Завьялова.*



Е.А. Боратынский.




И.А. Боратынский.

**БОРАТЫ́НСКИЙ Е.А. ӘДӘБИ́ МУЗЕЕ́**, Казанда. 1977 елда рус теле укытучысы һәм төбәкне өйрәнүче В.Г.Загвозкина инициативасы б-н мәктәп музее буларак ачыла. 1981 дә, М.Горький әдәби-мемориаль музее ф-лы буларак, респ-каның Дәүләт музее челтәренә кертелә. 1983 тә ТАССРның Берләштерелгән дәүләт музее составына керә. Ике бинада — 34 нче мәктәптә һәм Боратынскийларның 1918 елга кадәр шагыйрьнең варислары яшәгән шәһәрдәге утары флигелендә (арх. Ф.И.Петонди, 1830 еллар) урнашкан. Музейда өч экспозиция: даими рәвештә эшләүче «Боратынскийның тормышы һәм иҗаты» (34 нче мәктәптә, 1977 дән, сәнгать проектының авторы М.Б.Стриженов, Мәскәү) һәм алышынып торучы «Гаилә альбомы битләре» (1991–1999, сәнгать проекты авторы В.А.Нестеренко), «А.С.Пушкин һәм Казан» (1999–2000, сәнгать проекты авторы С.И.Матвеев) экспозицияләре эшли. Алар арасында Е.А.Боратынскийның 1831–33 елларда Казан төбәгендә булуын чагылдырган «Казан» һәм «Каймар» бүлекләре аерым урын алып тора. Музей коллекциясенә Е.А.Боратынскийның мемориаль әйберләре, шагыйрьнең үзе исән чагында чыккан шигъри җыентыклары, 19–20 йөзләргә караган



Е.А. Боратынский музее. Казан.



Боратынский Е.А. музее. Казан. «А.С. Пушкин һәм Казан» экспозициясеннән фрагмент.

китаплар, картиналар, гравюралар, Казан сәнгать мәктәбе рәссамнары Н.Сапожникова, А.Фомин, И.Денисов, чуаш рәссамы М.Спиридонов, Е.А.Боратынский варислары иҗат иткән әсәрләр керә. Кульъязмалар фондында Боратынскийларның гаиләсе, Казан губернасындагы агарту эшчәнлеге турындагы материаллар тупланган; фондлар составында Боратынскийларның дус-ишләренең, туганнарының (А.А.Дельвиг, А.К.Казимбәк һ.б.) шәхси әйберләре коллекциясе (барлыгы — 4900 саклау берәмлеге) саклана. Музей Е.А.Боратынскийның һәм аның варисларының 19–20 йөз башында Казан губернасы һәм Казанның мәдәни тормышы б-н бәйле иҗатын, тормышын, утарның көнкүреш тарихын өйрәнү б-н шөгыльләнә. Музей ел саен (1994 тән) галимнәр, музей хезмәткәрләре, Казан, Мәскәү һ.б. шәһәр китапханәләре һәм архивлары хезмәткәрләре катнашында «Боратынский утарында әдәби укулар» дип аталган кичәләр үткәрә.

*Әд.:* Загвозкина В.Г. Школьный музей Е.А.Боратынского // Литература в школе. 1980. № 1; шул ук. Е.А.Боратынский и Казань. К., 1985; шул ук. Литературные тропы: поиски, встречи, находки. К., 1991; Завьялова И., Мирзина Н., Скворцова Е. Свет зеленой лампы: Листая страницы семейного альбома Боратынских // Казань. 1997. № 8/9; Завьялова И., Скворцова Е. «Мы пьём чай часом раньше нежели в Москве ...» // Родина. 1997. № 12.

*И.В.Завьялова.*

**БОРА́Ш** (Бараш), (? — 1507 дән соң), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, сәет, Казан ханлыгының мөселман руханилары башлыгы (1491–1507). Тарихи чыганаклардан күренекле дәүләт эшлеклесе һәм хәрби җитәкче буларак та мәгълүм. 1491 елда Зур Урдага каршы көрәш алып барган Кырым ханы Миңлегәрәйгә ярдәмгә килгән Казан гаскәре башлыгы була. Казан ханы Мөхәммәдәминнең Иван III кә юллаган ярлыгында (1492) хан илчесе буларак искә алына. 1497 дә Габделлатыйфны Казан ханы итеп билгеләү турында Мәскәү б-н сөйләшүләр алып бару аңа йөкләнә. 1507 дә Б. — Мөхәммәдәмин ханның Мәскәүдәге илчесе, ш.у. Василий III б-н сөйләшүләр алып бара. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Исхаков Д.М. Сеиды в позднезолотоордынских государствах. К., 1997.

**БОРБА́Ш** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Бөренең сул кушылдыгы (Вятка елгасы бассейны). Озынлыгы 18,6 *км*, бассейнының мәйданы 66,7 *км*². Кукмара р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Тырыш авылыннан 0,6 *км* төньяктарак, тамагы Зур Сәрдек авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 8%. Б. елгасының 0,5 тән алып 1,6 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,40 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымы төшүнең уртача күпьеллык катламы 108 *мм*, ташу агымы катламы 97 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче декадасында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м*³*/с*. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, язын йомшак (1,5 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача салкын (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 0,4 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БОРБА́Ш** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бөре елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 861 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чыпта-кап сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1499,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Кукмара, 1939 ның 22 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 867, 1897 дә — 1188, 1908 дә — 1264, 1920 дә — 1308, 1926 да — 1242, 1938 дә — 1184, 1949 да — 1010, 1958 дә — 871, 1970 тә — 980, 1979 да — 949, 1989 да — 815 кеше.

**БОРБА́Ш СӘРДЕГӘНЕ́** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 18 *км* көнчыгыштарак, Бөре елгасы буенда. 2002 елда 256 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Сәрдек, Сәрдегән исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 696,9 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1932 елның 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 195, 1897 дә — 411, 1908 дә — 482, 1920 дә — 891, 1926 да — 523, 1949 да — 397, 1958 дә — 258, 1979 да — 302, 1989 да — 257 кеше.

**БОРДЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Зичәнең уң кушылдыгы (Зәй елгасы бассейны). Озынлыгы 15,7 *км*, бассейнының мәйданы 104,3 *км*². Елга башы Тукай р-нының Мусабай-Завод авылы янында, тамагы Зәй р-ның Бура Киртә авылыннан 1 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 97 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Б. елгасының 1 дән алып 9,6 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 69 *мм*, ташу агымы катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,065 *м*³*/с*. Суы бик каты (язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 2,6 млн. *м*³ булган 5 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Түбән агымда Б. *Баграж аучылык тыюлыгы* терр-ясеннән ага.

**БОРДЫ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 23 *км* көньяктарак, Борды елгасы буенда. 2002 елда 509 кеше (татарлар — 77%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1678 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 2332,8 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында Спас чиркәве (1888 дә сәүдәгәр Д.И.Стахеев иганәсенә төзелә), кәшәнә, Халык мәгариф министрлыгы мәктәбе, икмәк кибете, 2 су һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, 2 тимерче алачыгы, шәраб, 3 бакалея кибете эшли. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостена керә. 1920 елдан ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1795 тә — 214 ир заты; 1870 тә — 838, 1897 дә — 1221, 1920 дә — 1716, 1926 да — 1378, 1938 дә — 1326, 1949 да — 877, 1958 дә — 852, 1970 тә — 883, 1979 да — 665, 1989 да — 533 кеше.

**БОРДЫБА́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 26 *км* көньяктарак, Борды суы буенда. 2002 елда 188 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә, Кама буендагы пристаньнарда эшли. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 1012,5 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 2 су һәм 2 ярма ярдыру тегермәне, икмәк һәм 3 бакалея кибете була. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1870 тә — 519, 1897 дә — 1021, 1920 дә — 1347, 1926 да — 714, 1938 дә — 868, 1949 да — 877, 1958 дә — 461, 1970 тә — 486, 1979 да — 370, 1989 да — 208 кеше.

**БОРЕ́ВСКИЙ** Борис Владимирович (10.9.1938, Мәскәү өлкәсенең Пушкино ш.), гидрогеолог, геол.-минерология фән. д-ры

(1987), проф. (1988), РФның атказ. геологы (1998), РСФСР, ТР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1990, 2004). Мәскәү геол.-разведка ин-тын тәмамлагач (1961), Мәскәүдә эшли: Икенче гидрогеол. идарәсендә гидрогеологик партияләр һәм экспедицияләрдә, 1968 елдан Бөтенсоюз гидрогеология һәм инженерлык геологиясе фәнни-тикшеренү ин-тында, 1991 дән «Гидрогеология һәм геоэкология компаниясе» АҖ ген. директоры. ТР Дәүләт бүләгенә Татарстан терр-ясе гидрогеол. шартларында төче җир асты сулары запасларын эзләү һәм бәяләү методикасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен лаек була. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Оценка запасов подземных вод: Учеб. М., 1989 (автордаш).

**БОРЕ́ЙКО** Наталья Павловна (5.11.1950, Киров өлкәсенең Котельнич ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1996), ТРның атказ. химигы (2006). Мәскәү хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1973). «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли, ингибирлау (химик реакцияләр тизлеген киметү) лаб. башлыгы (1979 дан), фәнни-технол. үзәгенең директор урынбасары (1997 дән). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмаларның химик технологиясенә һәм оксидлаштыру ысуллары б-н табыла торган ясалма каучук җитештерү өчен мономерлар бүленеп чыгу процессларында өстәмә реакцияләрне булдырмауга карый. Винилароматик мономерлар полимерлаштыруны, стиролны термополимерлаштыруны, диметилформамидны гидролизлауны, изопренның үзлегеннән полимерлашуын һ.б. ингибирлау ысулларын эшли; технологик эшләнмәләре производствога кертелгән. Ленин комсомолы (1978), СССР Дәүләт (1989) бүләкләре лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Автоколебательный механизм образования ингибитора в процессе полимеризации стирола в присутствии фенолов // Докл. АН СССР. 1982. Т. 264, № 6; Ингибирование окислительной полимеризации стирола фенолами. Автоколебательный режим // Высокомолекулярные соединения. 1984. Т. 26А, № 3.

**БО́РИН** Александр Вульфович (25.2.1906, Киев — 1.7.1977, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1972). Шостка хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1932), Шостка кинотасма җитештерү ф-касында эшли. Казан техфотопроект фәнни-тикшеренү ин-тын оештыручыларның берсе, 1941–56 һәм 1969–76 елларда фәнни-тикшеренү лаб. мөдире, 1956–69 да ин-т директоры урынбасары. Хезмәтләре химик-фотографик процесслар теориясе һәм практикасына карый. Яктылыкка сизгер системаларны синтезлау, аларның оптик-сенситометрик күрсәткечләрен полиметин органик буягычлар ярдәмендә сенсибилләштереп яхшырту б-н шөгыльләнә. Б. җитәкчелегендә В.В.Куйбышев исем. Казан химия з-дында (хәзер «Тасма-Холдинг» АҖ) фототехник, инфрахроматик тасмалар, кинематография һәм аэрофотография һ.б. өчен югары сизүчән негатив тасмалар эшләнә һәм производствога кертелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Процессы старения и сохраняемость фотографических материалов. М., 1976.

**Б О Р И С Е́ Н К О** Юрий Владимирович (9.10.1940, Комсомольск-Амур ш.), җырчы (бас), педагог, ТАССРның (1980) һәм Каракалпакстан АССРның (1979) халык артисты, РСФСРның атказ. артисты (1984). 1971 елда Новосибирск консерваториясен тәмамлый. 1968–73 елларда Новосибирск опера һәм балет театры, 1973 елдан Татар опера һәм балет театры солисты. Бер үк вакытта 1980 нән Казан консерваториясендә ялгыз җыр классында укытучы. Төп партияләре: Базилио («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Мефистофель («Фауст», Ш.Гуно), Филипп («Дон Карлос», Дж.Верди), Тегермәнче («Су кызы», А.Даргомыжский), Борис, Пимен, («Борис Годунов», М.Мусоргский), Кончак, Галицкий («Князь Игорь», А.Бородин), Гремин, Кочубей, Рене («Евгений Онегин», «Мазепа», «Иоланта», П.Чайковский), Журавлёв («Җәлил», Н.Җиһанов). Югары вокал һәм актёрлык осталыгына, көчле һәм матур тембрлы тавышка, сәхнә образларын истә калырлык итеп иҗат итә алу сәләтенә ия. Ш.у. күп төрле стильдәге һәм жанрдагы камера җырчысы буларак танылa.



Ю.В. Борисенко.





Ю.В. Б о р и с е н к о : 1. Мефистофель (Ш. Гунонның «Фауст» операсы); 2. Борис Годунов (М.П. Мусоргскийның «Борис Годунов» операсы) рольләрендә.

*Әд.:* Т а к т а ш Р. Второй Шаляпинский // Муз. жизнь. 1983. № 10; И с т о м и н а Л. X международный фестиваль им. Ф.Шаляпина // Муз. жизнь. 1991. № 12–13. *Р.И.Такташ.*

**БОРИ́СКИНО** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2002 елда 493 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1710 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1488,6 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Спас өязе Түбән Әлки волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Спас кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 98 ир заты; 1859 да — 530, 1897 дә — 966, 1908 дә — 1154, 1920 дә — 1120, 1926 да — 813, 1938 дә — 692, 1949 да — 518, 1958 дә — 695, 1970 тә — 826, 1979 да — 708, 1989 да — 552 кеше.

**БОРИ́СКИНО** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 70 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 530 кеше (руслар — 63%, татарлар — 30%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1924 тә Яңа Алан авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Башта Борисовка дип атала. ТАССРның Чаллы кантонының Кузай волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 81, 1938 дә — 74, 1949 да — 194, 1958 дә — 478, 1970 тә — 471, 1979 да — 395, 1989 да — 378 кеше.

**БОРИ́СОВ** Анатолий Сергеевич (13.3.1949, Казан), геофизик; геол.-минер. фән. д-ры (2004); проф. (2005), ТРның атказ. геологы (2000), РФнең мактаулы казылма байлыклар разведчигы (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук геол. ф-тында эшли (1993 тән декан). 1978–82 елларда Алжир углеводлар һәм химия милли ин-тында укыта. Хезмәтләре палеомагнетизмны, геомагнит кырының нечкә структурасын, сейсмоакустиканы өйрәнүгә карый. Скважиналарда сейсмоакустик тикшеренүләр методикасын һәм аппаратурасын, утырма токымнарны магнетик-минерологик һәм палеомагнетик тикшерүләр технологиясен эшли. Пермь һәм голоцендагы геомагнит кырының нечкә структурасын өйрәнә. Геология белеме бирү системасының стандартларын эшләүдә катнаша. Хәзерге күл утырмаларын палеомагнетик тикшеренүләр технологиясе авторы.

Хезм.: Магнито-минералогические и палеомагнитные исследования красноцветов. К., 1989; Вариации геомагнитного поля в Центральной Европе за последние 12 тысяч лет по данным исследования донных отложений озера Нарочь (Белоруссия) // Физика Земли. 2003. № 3.

**БОРИ́СКОВО КАБАНЫ́**, к. *Югары Кабан.*

**БОРИ́СОВ-БОРОЗДИ́Н** Никита Васильевич (? — 1576 дан соң), язу эшләрен башкаручы (писец), окольничий (1564 тирәсе). Борынгы дворяннар нәселеннән. 1564–68 елларда Д.А.Кикин б-н бергә Зөя, Казан шәһәрләре һәм бистәләренең тасвирламасын төзи, Казан, Зөя өязләрендә җир-биләмә бүленешләрен үлчәп, алар турында мәгълүмат туплый. 1554–55, 1573–74 елларда Казан төбәгендә җирле халыкның баш күтәрүен бастыруда катнаша.

**БОРИСОГЛЕ́БСКИЙ** авылы, Казан шәһәренең Авиатөзелеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 18 *км* ераклыкта, Казансу елгасы буенда. 2000 елда 451 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1599 да нигез салына. 17 йөздә патша сарае авылы булып исәпләнә,



Борисоглебский авылы.
Борисоглебский чиркәве. 1889-97.

соңрак алпавыт биләмәләре барлыкка килә һәм крәстияннәр китерелә. Игенчелек һәм терлек үрчетүдән тыш, тәгәрмәч ясау, киез итек басу, тимерчелек, Казанда яшелчә, ит сату б-н шөгыльләнәләр; су тегермәннәрендә эшлиләр. Беренче агач чиркәү — 1600 дә, соңгысы — Борисоглебский чиркәве (таштан) 1889–97 елларда төзелә (1993 тә яңадан эшли башлый; архит-ра истәлеге). 1861 дә кыз балалар мәктәбе ачыла, 1870 тә Кадыш авылындагы удел идарәсе мәктәбе монда күчерелә. 1888 дә алар бергә кушылып, яңа земство мәктәбе барлыкка килә. 20 йөз башында 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 814,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Каймар волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 елның 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 12 июленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 ноябреннән — Биектау, 1998 нең 25 ноябреннән Казан шәһәренең Авиатөзелеш р-н советы карамагында. Халык саны: 1646 да — 123, 1782 дә — 152 ир заты; 1859 да — 552, 1897 дә — 659, 190 дә — 766, 1920 дә — 778, 1926 да — 928, 1938 дә — 1023, 1949 да — 1000, 1958 дә — 1225, 1970 тә — 977, 1989 да — 488 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1916. Вып. 3; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**БОРИСОГЛЕ́БСКИЙ КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Әлеккеге су юлында сакланып калган күл. Казансу елгасының уң яры тугаенда, *Борисоглебский* һәм Голубое Озеро авыллары арасында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 3 *га*, су күләме 60 мең $м^3$. Гомуми озынлыгы 750 *м*, уртача киңлеге 40 *м*, уртача тирәнлеге 2 *м*, иң тирән урыны 3,5 *м*. Дагасыман формада. Күл ике урында юл өемнәре б-н бүленә. Тотрыклы рәвештә җир асты сулары б-н туена; көньяк өлештән Казансу ягына су чыгымы якынча 0,3 $м^3/с$ булган инеш агып чыга. Суы ачык яшел төстә, үтә күренмәле. Күлнең фитопланктонын яшел, кремнийлы (диатом) һәм зәңгәрсу-яшел суүсемнәр билгели, югары төзелешле үсемлекләрдән гади курак, вак бака тәңкәсе, куе яшел мөгезьяфрак һәм Канада элодеясе өстенлек ала. Күлдә табан балык һәм кара балык бар. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла. *Н.М.Минһаҗева.*


**БО́РМУСОВ** Алексей Фёдорович (16.3.1885, Тамбов губ. Салазар а. — 1.2.1973, Алабуга ш.), хор дирижёры, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939). Казан рус-әҗнәби укытучылар семинариясен тәмамлый, Казан музыка уч-щесендә скрипка, музыка теориясе һәм композиция классларында укый. Казан музыка уч-щесендә хор дәресләре һәм теоретик фәннәр укыта (1908–45), бер үк вакытта Казан керәшен татарлар мәктәбендә рус теле һәм хор дәресләре, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында дөньяви җыр дәресләре алып бара. 1945–50 һәм 1955–56 елларда Казан консерваториясендә, музыка мәктәпләрендә дәресләр бирә. ТАССР Җыр һәм бию ансамбленең беренче хормейстеры, хор коллективлары җитәкчесе буларак, камера ансамбльләре составында концерт эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. Рус һәм татар халык җырларын хор өчен эшкәртә. Шәкертләре арасында А.Ключарёв, Җ.Фәйзи, З.Хәбибуллин бар. *Э.А.Браун.*

**БОРНА́ЕВ** Мөхәммәтсадыйк Корбангали улы (20.1.1826 — 4.5.1898), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре (1869), җәмәгать эшлеклесе, нәселдән күчмә шәрәфле граждан. Борынгыдан килгән Арча шәһәре сәүдәгәрләре нәселеннән. Күн эшләү һәм сабын кайнату з-длары, комач туку ф-касы, Уфа губернасы Минзәлә өязендә 500 дис. җир биләмәсе хуҗасы була. Казанда флигельләре һәм кибете булган 2 йорт тота. Затлы җәнлек тиреләре һәм сабын б-н сәүдә итә. Казанның иң бай эшмәкәрләреннән исәпләнгән. 1857–60 елларда Казан җинаять эшләре мәхкәмә палатасы утырышчысы. 1869 да шәрәфле җәмәгать судьясы. 1871–98 дә Казан шәһәр думасы гласные. 1872 дә үз нәселе исеме б-н аталган мәчет (к. *Борнай мәчете*) төзелешенә акча бирә. Сукыр балалар уч-щесе бинасын төзүгә булышлык итә. Актив иганәчелек һәм җәмәгать эшчәнлеге нәтиҗәсендә «Тырышлык өчен» («За усердие») алтын медаленә лаек була. Улы Ибраһим Казанда «Б.Субаев, И.Борнаев һәм М.Сәйдәшев сәүдә йорты» хуҗаларыннан берсе (1888; уртак капиталы 300 мең сум), Б.Апанаев б-н бергә сабын кайнату з-дын да арендалый.

*Әд.:* Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1994. *Л.М.Свердлова.*

**БОРНА́Й** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында. Атаның уң кушылдыгы (Кече Чирмешән елгасы бассейны). Озынлыгы 15,4 *км*, бассейнының мәйданы 76,8 $км^2$. Әлки р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы «Спорная Колчуринская дача» табигый чигендә, Чуаш Борнае авылыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Ярәп авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 95 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 29%. Б. елгасының 0,4 тән алып 1 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,24 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 $л/с·км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче декадасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 $м^3/с$. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500– 700 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 0,6 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БОРНА́Й МӘЧЕТЕ́** (Өченче җамигъ мәчет), Казанда татар дини архит-ра истәлеге. Иске Татар бистәсендә урнашкан. 1799 елда янган агач мәчет урынына сәүдәгәр М.К.*Борнаев* иганәсенә арх. П.И.Романов проекты б-н 1872 дә төзелә. Башта ул бер катлы, бер заллы, турыпочмак рәвешендәге михраблы бина була. 1895 тә (фаразлanганча, Н.Ф.Малиновский проекты б-н) бинаның төньягында янкорма салына, нәтиҗәдә мәчетнең озын-



Борнай мәчете. Казан. Арх. П.И.Романов, Ф.Н.Малиновский. 1872–95. 20 йөз ахыры фотосы.

лыгы 2 тапкыр арта һәм өч катлы манара төзелә. Хәзерге вакытта өч катлы манаралы, түбәсе дүрт кыеклы, ике заллы, турыпочмаклы нигезгә корылган бер катлы кирпеч бина, вестибюль һәм үзара тоташкан ике гыйбадәт залыннан тора. Ишеге төньякта манараның түбәнге катында урнашкан. Заллары а́рка рәвешендәге биек тәрәзәле. Михраб а́ркасының өске ягы дага рәвешендә эшләнгән. Тышкы ишек тамбурының сул ягында — манара баскычы, уң ягында хуҗалык бүлмәсе урнашкан. Манараның аскы өлеше биек шакмак рәвешендә, тәрәзәле өске катлары сигез кырлы итеп төзелгән, гөмбәз б-н тәгәлләнә. Залның диварлары почмакларда һәм тәрәзә араларында кессонланган ярымбаганалар, ә манарасы уеп бизәкләнгән терәүләр, уемнар, кирпечтән ясалган бизәкләр, профильләнгән кәрнизләр б-н бизәлгән. Мәчетнең тышкы бизәлешендә татар, шәрекъ-мөселман һәм рус архит-расы элементларын кертеп эклектика стиле кулланылган. Б. м. 1930 елларда ябыла, 1994 елдан кабат эшли башлый.

*Әд.:* Х а л и т о в Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991.

**БОРНА́К** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шушма елгасы буенда. 2002 елда 613 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1678 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Бурнаковский исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, вак-төякләр сату б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 1509,8 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында 2 мәчет (1880 һәм 1906 да төзелә) эшли. 1920 елга кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Яңгул волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1766 да — 254, 1811 дә — 380 ир заты; 1859 да — 724, 1884 тә — 1539, 1920 дә — 1720, 1926 да — 1494, 1938 дә — 1229, 1949 да — 802, 1958 дә — 623, 1970 тә — 727, 1979 да — 681, 1989 да — 585 кеше.

**БОРНА́Ш** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 23 *км* көнчыгыштарак, Коры Үләмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 274 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1646 елдан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, он тарту, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 9 җил һәм 1 ярма ярдыру тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1948,2 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Кариле волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 147 ир заты; 1859 да — 719, 1897 дә — 1350, 1908 дә — 1510, 1920 дә — 1400, 1926 да — 833, 1938 дә — 801, 1949 да — 555, 1958 дә — 460, 1970 тә — 530, 1979 да — 423, 1989 да — 291 кеше.

**БОРНА́Ш** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 18 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 3 *км* читтә. 2002 елда 33 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Надежда исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 969,1 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 275, 1897 дә — 533, 1908 дә — 617, 1920 дә — 616, 1926 да — 707, 1938 дә — 629, 1949 да — 406, 1958 дә — 316, 1970 тә — 188, 1979 да — 124, 1989 да — 54 кеше.

**БОРНА́ШЕВ** Марат Вәли улы (6.1.1947, Ташкент), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1986). 1971 елда Мәскәү физ.-техника ин-тының радиотехника һәм кибернетика ф-тын тәмамлый. 1974 елдан РФАнең Мәгълүмат тапшыру проблемалары ин-тында эшли (Мәскәү), 1985 тән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре матем. статистикага, мәгълүмат һәм кодка салу теориясенә, сигналларны тоту һәм бәяләүгә карый. Мәгълүмат теориясенең берничә классик мәсьәләсен чишә, кире элемтә каналының ышанычлылык функциясен таба, төрле асимптотик таркату ысулларын эшли.

Х е з м.: Передача информации по дискретному каналу с обратной связью. Случайное время передачи // Проблемы передачи информации. 1976. Т. 12. № 4; Асимптотические разложения оценок параметра сигнала в белом гауссовском шуме // Матем. сб. 1977. Т. 104, № 2; О минимально достижимой среднеквадратической ошибке при передаче параметра по каналу с белым гауссовским шумом // Проблемы передачи информации. 1985. Т. 21, № 4; О функции надёжности квантового канала связи // Проблемы передачи информации. 1998. Т. .34, № 2.

**БОРНА́ШЕВ** Мөхәммәдгариф (19 йөз ахыры, Рязань губ., Сасово өязе Әҗе а. — 20 йөзнең 1 нче яртысы), язучы. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. 1924 елга кадәр Мәскәүдә яши. «Вокугат фи 1900 сәнә әл-милади» («Милади белән 1900 ел вакыйгалары», СПб., 1902) китабы авторы. Балалар өчен дә яза. Татар матбугатында бәхәсләрдә катнаша, чыгышлар ясый, Рәшит Ибраһимовның җәмгыяви һәм дини-фәлсәфи карашларына каршы чыга.

Ә с ә р.: Рашид казый // Шура. 1917. № 14.

*Әд.:* Б ә л ә ш е в А. Әҗе авылы хакында. К., 1924. *А.М.Ахунов.*


**БОРОВЕ́ЦКИЙ** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән төньяктарак, Шилнә елгасы буенда. 2002 елда 123 кеше (руслар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Вознесенский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, арба һәм чана ясау, урман кисү, умартачылык б-н шөгыльләнә.



Боровецкий авылы. Вознесение чиркәве, 1889.

20 йөз башында Вознесение чиркәве (1872–89 елларда сәүдәгәр Д.И.*Стахеев* иганәсенә төзелә; архит-ра истәлеге), земство уч-щесе, су тегермәне, шәраб һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4519,9 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Макарьевка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы (1976 ның 20 апреленнән Тукай) р-нында. Халык саны: 1724 тә — 219, 1795 тә — 381 ир заты; 1859 да — 1368, 1870 тә — 1398, 1897 дә — 1387, 1913 тә — 1660, 1920 дә — 1594, 1926 да — 1362, 1938 дә — 749, 1949 да — 593, 1958 дә — 398, 1970 тә — 654, 1979 да — 576, 1989 да — 205 кеше. Авыл тирәсендә *Боровецкий чишмәләре* табигать истәлеге саклана.


**БОРОВЕ́ЦКИЙ ЧИШМӘЛӘРЕ́**, табигать истәлеге. Чаллы шәһәренең төньяк читендә (Боровецкий авылы). 1987 елда билгеләнә. Мәйданы — 5 *га*. Шилнә елгасы тамагындагы чишмә. Су чыгымы 300 *л/мин*, эчү өчен



Боровецкий чишмәләре.

файдаланыла. 1990 еллар ахырында Б.ч. төзекләндерелә. Табигать истәлеге терр-ясендә Вознесение чиркәве урнашкан (1989).

**БОРОВИ́К** Роман Владимирович (3.7.1942, Псков өлкәсе Пыталово а.) вет. вирусологы, вет. фән. д-ры (1980). 1963 елда Латвия а.х. академиясен (Елгава ш.) тәмамлый. 1965 елдан Казан вет. ин-тында эшли, 1980 нән ви-



Г.П. Боровиков.



М.М. Бородай.

русология лаб. мөдире. 1981 дән Бөтенсоюз гамәли микробиология фәнни-тикшеренү үзәгенең (Мәскәү өлкәсе Серпухов ш.) директор урынбасары, 1993 тән директоры. Хезмәтләре вирусологиягә, иммунология һәм биотехнологиягә карый. Күзәнәк һәм гумораль иммунитетларны өйрәнүдә яңа ысуллар уйлап таба, хламидиозны булдырмау өчен вакцина һәм «легионерлар» авырулары китереп чыгаручыларны билгеләү өчен антитәнчекле иммунофермент диагностика җиһазлары эшли. СССР (1986), ТР (1995) Дәүләт бүләкләре лауреаты. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

*Н.З.Хаҗипов.*

**БОРОВИКО́В** Геннадий Петрович (1936, Свердлов өлкәсенең Байкал р-ны Боровиково а.), Соц. Хезмәт Герое (1981). Серов металлургия техникумын (Свердлов өлкәсе) тәмамлый. 1961–72 елларда Серов ферроэретмәләр з-дында металл эретүче, өлкән эретүче булып эшли. 1972–2000 дә КамАЗда металл эретүчеләр бригадиры. Электр дугалы эретү мичендә беренче тапкыр соры чуен коюда катнаша (1976). 1976 да Б. бригадасы 8 ай эчендә 5,5 мең *т* югары сыйфатлы чуен коя (план 4,5 мең *т*). Герой исеме КамАЗның 2 нче чиратын төзегәндә күрсәткән хезмәттәге батырлыгы өчен бирелә. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* П е р в о в а И., Л у к ь я н о в Г. Боровиков Геннадий Петрович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой славы — наши земляки. К., 2003.

**БОРО́ВКА** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Урман Чишмәсенең уң кушылдыгы (Чишмә елгасы бассейны). Озынлыгы 12,3 *км*, бассейнының мәйданы 65,9 *км*². Лениногорск р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Аккүл авылыннан 1,8 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Глазово авылыннан 1 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагыныкы — 150 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 55%. Б. елгасының 0,7 дән алып 1,8 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,22 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1–5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 124 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,107 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12 *мг-экв/л* дан артыграк). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**БОРОДА́Й** Михаил Матвеевич (1853, Полтава ш. — 2.8.1929, Иркутск ш.), антрепренёр. Театр эшчәнлеген Полтава шәһәрендә Н.Н.Дюков антрепризасында башлый, аннан соң Харьков шәһәрендә (1873–86) администратор сыйфатында дәвам итә, 1880–82 елларда П.М.*Медведев* җитәкчелегендә эшли. 1886 елның җәендә Воронеж шәһәрендә актёрлар ширкәтенең җаваплы җитәкчесе, 1886–89 да Харьковта антреприза тота, гамәлдә бөтен эшләрнең хуҗасы була: труппа туплый, репертуарны билгели, шәһәр хакимияте б-н эш алып бара. 1893–1901 дә Казанда һәм Саратовта антреприза тота. П.М.Медведев традицияләрен дәвам иттереп, ике труппа — опера һәм драма төркемнәре оештыра. Алар шәһәрләрдә ялтышар сезон эшлиләр. Башлыча тәҗрибәле һәм провинциядә танылган актёрларны җәлеп итә. Казандагы труппада А.И.*Каширин*, П.В.Самойлов, М.М.Петипа, П.М.Шувалов, М.И.Барышева-Свободина, А.А.Немирова-Ральф, Ж.Т.Агарёва-Инсаровалар эшли; Н.Н.Литовцева, В.И.*Качалов* хезмәт эшчәнлекләрен монда башлыйлар; М.Г.Савина, М.В.Дальский, В.Н.*Давыдов*, М.И.Писарев гастрольләргә киләләр; Ю.М.Юрьев 1897 нең җәендә Казанда беренче булып Чацкий һәм Хлестаков рольләрен башкара. Казанда эшләгән елларында Б.ның драма труппасы А.Н.Островскийның 24 пьесасын, Н.В.Гогольнең 5 әсәрен, ш.и. «Үле җаннар» («Мёртвые души»), Л.Н.Толстойның «Караңгылык патшалыгы» («Власть тьмы») һәм «Мәгърифәт җимешләре» («Плоды просвещения») пьесаларын, А.П.Чеховның — 4, У.Шекспирның 10 пьесасын, Софоклның «Эдип», Ж.Расинның «Фёдра», С.В.Ковалевская, В.И.Немирович-Данченко, А.И.Сумбатов-Южин, Г.Ибсен, Г.Гауптман, Э.Ростан әсәрләрен сәхнәгә куя. Опера б-н җитәкчелек итүгә иң яхшы дирижёр һәм режиссёрларны — Е.Д.Эспозито, *И.О.Палицын* һәм *Н.Н.Боголюбовны* җәлеп итә. Казанда бу елларда 20 ләп опера, ш.и. М.П.Мусоргскийның «Борис Годунов», А.Г.Рубинштейнның «Маккавейлар» («Маккавеи»), П.И.Чайковскийның «Пики дамасы» («Пиковая дама»), Р.Вагнерның «Тангейзер», В.-А.Моцартның «Дон Жуан», Дж.Вердинең «Дон Карлос» һ.б. опералар куела, репертуарда, башлыча, рус опералары урын ала. 1899 да А.С.Пушкинның тууына 100 ел һәм Казанда опера куела башлауга 25 ел тулу уңаеннан гастрольләргә Ф.И.*Шаляпин* чакырыла. Б. шәһәр приютлары, мохтаҗлыкта яшәүче студентлар өчен хәйрия спектакльләре куюны, гимназия укучыларына бушлай билет таратуны гамәлгә кертә, театрның тәрбияви ролен игътибар үзәгендә тотып, шәһәр читендә яшәүчеләрне, хезмәт кешеләрен театрга җәлеп итәргә тырыша. 1901–07 елларда Киев, 1910 нан Иркутск шәһәрләрендә антреприза тота.

*Әд.:* С и н е л ь н и к о в Н.Н. Шестьдесят лет на сцене. Хар., 1935; К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; Театральная энциклопедия. М., 1961. Т. 1; К а н т о р Г.М. Музыкальный театр в Казани в XIX – нач. XX вв. К., 1997.

*Ю.А.Благов.*

**БОРОДИ́Н** Александр Афанасьевич (25.7.1954, Хабаровск крае Сов. Гавань ш.), спортчы (янгын сүндерүнең гамәли ярыш төрләре), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1981). Иваново янгын сүндерү техник уч-щесен (1979), Волгоград физкультура ин-тының Чаллы ф-лын (1992) тәмамлый. «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә (Казан) тәрбияләнә. РСФСР (1975–84), СССР (1979, 1981, 1983), Европа (1981) чемпионы. СССР (1979) рекордчысы. Халыкара ярышларда җиңүгә ирешә (1979, Германия). 1974 елдан Казанда яши.

**БОРОДИ́Н** Александр Ильич (19.7.1950, Липецк өлкәсенең Становлян р-ны Лесные Локотцы а.), генерал-майор (1994), техн. фән. канд-ты (1998), РФнең атказ. хәрби белгече (1999). Тула югары артиллерия уч-щесен (1970), М.И.Калинин исем. Хәрби артиллерия академиясен (1982, Ленинград) тәмамлый. 1970–80 елларда Тула артиллерия уч-щесендә курсантлар взводы командиры. 1980–89 да Урта Азия хәрби округында: аерым ракета дивизионы командиры, округның ракета һәм артиллерия гаскәрләре штабының өлкән офицеры, ракета гаскәрләре берләшмәсе командиры. 1989–93 тә Көнбатыш гаскәрләр төркемендә ракета бригадасы командиры. 1993 елдан С.-Петербург хәрби артиллерия ун-тының Казан ф-лы башлыгы. Хезмәтләре ракета һәм авиация двигательләрен файдалану өлкәсенә карый. Артиллерия һәм ракета техникасын файдалану һәм ремонтлау буенча дәреслек-кулланмалар авторы. Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватан алдындагы хезмәтләре өчен», «Хәрби хезмәтләр өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Основы войскового ремонта вооружения и техники РВ и А сухопутных войск: Учеб. К., 1998 (автордаш); Основы электрооборудования и метрологическое обеспечение артиллерии: Учеб. К., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**БОРО́К** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зәй елгасыннан 1 *км* ераклыкта. 2002 елда 158 кеше (руслар — 56%, татарлар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балык тоту һәм балык тоту кирәк-яраклары ясау б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире 1692,4 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында Апостол Андрей Первозванный чиркәве (1888 дә сәүдәгәр А.П.Землянов иганәсенә төзелә), башлангыч белем бирү мәктәбе (1892 дә ачыла) эшли. 1920 елга кадәр Уфа губернасының

Минзәлә өязе Сухарево волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 415, 1897 дә — 642, 1920 дә — 887, 1926 да — 669, 1938 дә — 905, 1949 да — 642, 1958 дә — 429, 1970 тә — 307, 1979 да — 210, 1989 да — 127 кеше.

**БОРО́К УРМА́Н ДА́ЧАСЫ**, ландшафтлы табигать истәлеге. Түбән Кама р-ны терр-ясендә, Борок авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак. 1977 елда билгеләнә. Мәйданы — 1030 *га*. Кама тугаеның бер өлешен, Прость күлен, елганың биек киртләчендә һәм аның сөзәк битләрендәге урман массивын (Түбән Кама урман хуҗалыгындагы Болгар урманчылыгының 1–9 кварталлары) били. Рельеф һ.б. физик-географик шартларга бәйле рәвештә табигый-терр. комплекслар һәм урман типларының сазлыклы-болынлы сөзәк тугайлыклар, киң яфраклы урман һәм кыяклы-күп төрле үсемлекле болыннар, киртләч таулар тезмәсе куак-күрән баскан сазлыклар б-н алышынуы күзәтелә. Сөзәклеккә күтәрелә барган саен үлән үскән юкә-имәнлекләр кара җиләкле нарат, куаклы нарат һәм сәрдә-күрәнле юкә катнаш нарат урманнары б-н алмашына. Дюналы рельефлы киртләч өстендә кызыл бөрлегән, нарат җиләге һәм мүк яки кызыл бөрлегән һәм кыяклылар үскән далалы нарат урманнары сакланган. Урман массивының көнбатыш өлешендә өрәңге, элмә катнаш имән һәм юкә агачлары үсә. Көчле рекреация шартларында Б.у.д.нда хәзергә кадәр сакланып калган киң яфраклы токымнар катнаш нарат җиләкле-мүкле һәм кара җиләкле-мүкле катлаулы наратлыклар, чикләвек куаклы юкәлекләр Кама аръягы урман-дала зонасының төньяк чигендә формация реликты булып тора. Б.у.д. флорасында 300 ләп төр югары төзелешле үсемлек исәпләнә. Шулардан 54 төре, ш.и. дала чиясе, дүңгәләк, кырпулы лалә, дарулы валериана (песи үләне), йокы үләне, кыңгырау чәчәкләрнең эре чәчәкле төрләре (яфраклы шәфталу, яфраклы кычыткан, киң яфраклы, оеш һ.б.), башаклы бүре бөресе, чатырлы кырлык куга (сусак), кошкунмас агач һ.б.) яңарту-торгызу шартларында саклауга зарур. 16 төр үсемлек ТРның Кызыл китабына кертелгән: саз акканаты, төньяк линней үләне, болын канәфер чәчәге, җыерчыклы мәче борчагы, сары һәм себер сусыны, шуышма үргәләк, сарана лаләсе, песи борчагы, өчьяфрак кондыз үләне, чатырлы кышсөяр, түгәрәк каешъяфрак, бизгәк үләне, бүре җиләге, яссы һәм чукмарсыман күкерт үләне. Фаунасы аз өйрәнелгән; сөйрәлүчеләрдән кара елан очрый.


Борок урман дачасы.

*Әд.:* Гаранина И.И., Тайсин А.С. Борковская лесная дача: Ботанико-географический очерк // Чтения памяти Виктора Алексеевича Попова. К., 1997.

*И.И.Гаранина, Ә.С.Тайсин.*

**БОРО́НИН** Виталий Петрович (23.8.1927, Ульянов өлкәсенең Иске Майна р-ны Волостниковка а. — 9.2.2002, Казан), геолог-геофизик, геол.-минералогия фән. канд. (1957), РФ югары мәктәбенең атказ. хезмәткәре (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1949), шунда ук эшли, 1962–79 елларда геофизик разведка ысуллары каф. мөдире. Палеомагнит лабораториясен оештыручы һәм аның җитәкчесе (1963–90). Казан тау токымнары магнетизмы һәм палеомагнетизмы фәнни мәктәбен оештыручы. Б.В.Буров һ.б. б-н берлектә Рус платформасының көнчыгыш өлеше, ш.и. ТР терр-ясенең түбән триас һәм югары пермь җирле һәм төбәк палеомагнит шкалаларын төзи. Г.М.Исаев һ.б. б-н берлектә Татарстан терр-ясенең гравитацион һәм геомагнит кырларының җыелма картасын төзи (1957), ТРның кембрийга кадәрге кристаллик нигезенең эчке төзелеше схемасын сурәтли (1960), Кама аръягы фундаментында Аксубай — Ромашкино бөҗралы структурасын ача (1973). Структураларда аварлык көченең локаль минимумнар сәбәбе буларак, ТР утырма токымнарының нефтьле һәм газлы структураларында токымнар тыгызлыгының катламнар буенча зональ булуын билгели (1957).

Хезм.: Некоторые данные о послойной зональности плотности в карбонатных породах Татарии и её значение для поисков структур с помощью гравиразведки // Докл. АН СССР. 1959. Т. 28, № 1; Методика палеомагнитного изучения красноцветов. К., 1979 (автордаш); Геофизическое изучение кристаллического фундамента Татарии. К., 1982 (автордаш); Кольцевые структуры земной коры Волжско-Камской антеклизы. К., 1983 (автордаш); Magnetic Field and the Processes in the Earths Interior. Prague, 1983.

**БОРРЕЛИО́З**, Лайм авыруы, иксод талпаннары боррелиозы, системалы талпанлы кайтма тиф, буынтыгаяклылар аша күчә торган йогышлы, табигый чыганаклы авыру; тирене, нерв системасын, йөрү-хәрәкәтләнү аппаратын (буыннарны) зарарлый, яңадан кабатлануы һәм озакка сузылуы б-н үзенчәлекле. Сезонлы булуы күзәтелә (яз-көз). Авыруны китереп чыгаручы — спирохета (Borrellij burgdorferi) уртача климат поясында табигый чыганакларда (ш.и.Татарстан терр-ясендә) яши; авыруны йөртүчеләр — иксодлы урман бетләре; кыргый һәм йорт хайваннарында (кимерүчеләр, кош, эт, сыер, сарыкларда һ.б.) паразит булып яшиләр. Спирохеталар кеше әгъзасына талпаннар селәгәе б-н үтеп керә. Инкубация вакыты 3–30 көн. Б.ның 3 чоры билгеле: йогу, неврологик билгеләр күренү, буыннар патологиясе. Авыруның яңадан кабатлануы мөмкин. Диагноз кую өчен авыруның 2–3 атнасыннан башлап уңай серологик реакцияләр ясау. Дәвалаганда антибиотиклар кулланыла. Авыруны кисәтүдә гадәти булмаган — механик (урманда йөргәндә махсус саклану киеме һәм аяк киеме) һәм химик (бөҗәкне куркыту препаратлары) чаралар кулланыла, аны булдырмауның махсус ысулы юк.

20 йөз башында Казан губернасында ел саен кайтма тиф авыруы теркәлгән. Татарстанда 1950 еллардан бирле массакүләм авыру буларак күзәтелми, аерым очраклары гына бар.

*Әд.:* Системный клещевой боррелиоз (Болезнь Лайма). М., 1977; Маннанова Г.Н. Клинико-иммунологическая характеристика клещевых иксодовых боррелиозов. К., 1998; Фазылов В.Х. Клинико-эпидимиологические особенности боррелиозов в РТ. К., 1998.


*В.Х.Фазылов.*

**БОРТАСЛА́Р**, Урта һәм Түбән Идел буйларында яшәгән кабиләләр берләшмәсе. 8 йөз ахыры — 9 йөз Шәрекъ язмаларында (әл-Калби, ибне Рустә, ибне Хаукәл, әл-Мәсгуди һ.б.) һәм 13 йөздән рус елъязмаларында телгә алыналар. Галимнәр Б. этносын билгеләүдә бертөрле фикергә килә алмыйлар: алар төркиләр, фин-угырлар яки аланнар булган, дип фаразлаучылар бар. Ш.у. Б.ның кайсы археол. культурага якын торулары да ачыкланмаган. Н.Ф.*Калинин* аларны — *Имәнкискә культурасына*, А.Е.Алихова, С.А.*Плетнёва* — борынгы мордва культурасына, Г.Е.Афанасьев — *Салтау-Маяк культурасы* варианты булган Алан культурасына, Е.П.*Казаков* Турбаслы культурасына карый дип белдерә. Соңгы дәвердәге тикшеренүчеләрдән А.Х.*Халиков*, Г.Н.Белорыбкин һ.б. Б. культурасын Армиево археол. төркемәнә караган ядкәрләр б-н тиңлиләр. Б. иген иккән, терлек асраган, киек-җәнлек аулаган, умартачылык б-н шөгыльләнгән. Мех әйберләр һәм бал б-н сәүдә иткән. Б.ның идарәчеләре — аксакаллар. 8 йөз — 10 йөз башларында Хәзәр каганлыгына буйсынганнар; болгарлар һәм бәҗәнәкләр б-н бәрелешләре мәгълүм. 10 йөз ахырларында болгарлар тарафыннан яулап алына һәм аларның биләмәләре Идел буе Болгарына керә. 12 йөздә чама б-н Сура елгасы буенда Бортас әмирлеге яшәгән, башкаласы Бортас шәһәре булган. Б. биләмәсе 1237 елда монголлар гаскәре тарафыннан яулап алына. 13 йөзгә караган рус язма чыганакларында («Слово о погибели Русской земли» һ.б.да) Б. Идел буе халыклары буларак теркәлә. Рус әдәби истәлекләрендә ш.у. Б.ның *Куликово кыры сугышында* Мамай ягында торып сугышуы бәян ителә. Алтын Урда таркалганнан соң, Сура елгасы буе биләмәләре һәм халыклары әкренләп Рус дәүләтенә буйсындырыла. 17 йөздән башланган рус акт-документларында Б. сүзе этник катлау атамасы (термины) буларак теркәлгән, сукалы татар, татар-мишәр һәм бисермән (мөселман) сүзләренә синоним рәвешендә кителелгән. Б. татар, бигрәк тә мишәр этник культурасын формалаштыруда катнашалар. Хәзер дә Татарстан биләмәсендә Б. исем-атамасына бәйле күп кенә топонимик исемнәр саклана. Мәс., Кама Тамагы р-нында Бортас, Кайбыч р-нында Имәнле Бортас авыллары бар.

Чыг.: Хвольсон Д.А. Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омар ибн Даста. СПб., 1869; Заходер Б.Н. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. Горган и Поволжье в IX–X вв. М., 1962.

*Әд.:* Азизова А.Е. К вопросу о буртасах // Советская этнография. 1949. № 1; Смирнов А.П. К вопросу о буртасах // Краеведческие записки (Ульяновский областной краеведческий музей). Ульяновск, 1958. Вып. 2; Васильев Б.А. Проблема буртасов и мордвы // Тр. Ин-та этнографии АН СССР. Новая Серия. 1960. Т. 13; Попов А.Н. Названия народов СССР. Введение в этнонимику. Л., 1973; Добродомов М.Г. Этимология этнонима «буртас» // Ономастика Поволжья. Саранск, 1986; Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. К., 1989; Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени. К., 1998; Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар в VI — первой четверти XV вв. К., 2000.

*И.Л.Измайлов, Р.В.Шәйдуллин.*



В.Н. Бортяков.

**БОРТЯКО́В** Виталий Николаевич (15.11.1949, Яшел Үзән ш.), балет артисты, педагог, ТАССРның халык артисты (1984). 1968 елда Пермь хореография уч-щесен тәмамлый (педагоглар — Л.В.Асауляк һәм Ю.И.Плахт). 1968–94 тә Татар опера һәм балет театры солисты. Хореографик партияләре арасында Альберт («Жизель», А.Адан), Зигфрид, Дезире («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Ромео («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Модест Петрович («Анюта», В.Гаврилин), Былтыр, Шүрәле («Шүрәле», Ф.Яруллин) һ.б. бар. Б. лирик-драматик амплуадагы актёр, гротесклы һәм характерлы рольләрне башкара. 1 нче Бөтенсоюз опера һәм балет театрларының яшьләр иҗаты смотрында (1976, Минск), «Россиянең яшь балеты» (1978–84), «Киев язы» (1979), «Россия йолдызлары» (1986) бөтенсоюз балет фестивальләрендә катнаша. Италия, Франция, Португалия, Германия, Япония, Сенегал, Марокко, Нигерия, АКШта гастрольләрдә була. 1977–78 елларда һәм 1983 тән классик бию буенча Казан хореография уч-щесе педагогы, бер үк вакытта 1984 тән Татар опера һәм балет театрында педагог-репетитор.

*В.Н.Горшков.*

**БОРҺА́Н** Сафа Вафа улы (14.12.1899, «Серебряный» приискасы, хәзерге Свердловск өлкәсенең Исовск р-ны — 3.8.1937, Казан), журналист. Верхотурье шәһәрендә укытучылар әзерли торган курсларда укый. 1917 елның сентябреннән 1920 нең гыйнварына кадәр татар мәктәпләрендә укыта. Мәскәүдә Шәрекъ хезмәт ияләре коммунистик ун-тын тәмамлаганнан соң (1924), Уфа шәһәрендә РКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-ты матбугат бүлеге мөдире итеп җибәрелә. «Яңа авыл», «Яшь юксыл», «Башкортстан» г-таларында языша. 1926–28 елларда Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир. 1926–27 дә Казанда «Безнең юл», «Җитәкче», «Тамашачы», «Фән һәм дин», «*Яңалиф*» ж-лларында язмалары басыла. «Яңалиф» җәмгыятен оештыручыларның берсе. 1928 нең октябрендә «Кызыл Татарстан» г-тасының баш мөхәррире итеп билгеләнә. 1930 да милләтчелектә гаепләнеп, «Красная Татария» г-тасына күчерелә: 1931 дә бүлек мөдире, 1933–35 тә мөхәррир урынбасары (бүленеп), 1932 дә «Крылья Советов» г-тасында баш мөхәррир. 1936 дан «Известия» г-тасының ТАССР буенча махсус хәбәрчесе, атеистик һәм яшьләр темаларына мәкаләләре, очерклары, фельетоннары басыла. 1936 елның октябрендә «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы*» эше буенча гаепләнеп кулга алына. Вафатыннан соң аклана.

*Әд.:* Судьба журналиста // Вечерняя Казань. 1989. 26 авг.

*Г.Г.Шәйдуллина-Хәсәнова.*

**«БОРҺАНЕ́ ТӘРӘКЪКЫ́Й»** («برهان ترقى» — «Алгарышка дәлил»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. 1906 елның май аеннан 1911 нең февраленә кадәр Әстерхан шәһәрендә татар һәм гомумтөрки телләрдә нәшер ителә; даими басылмый, барлыгы 266 саны чыга. Төрле елларда мөхәррир-наширләре:




«Борһане тәрәкъкый» газетасы.

М.*Исмәгыйлов-Ширванский*, Н.*Гасрый*. Газетада татар халкының иҗтимагый-сәяси, рухи-мәдәни мәнфәгатьләре яктыртыла. Н.Гасрый мөхәррирлек иткән елларда социаль-икътисади мәсьәләләргә киң урын бирелә. «Б.т.» хакимият һәм цензура тарафыннан эзәрлекләнә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек. К., 2001.

**БОРҺАНЕДДИ́Н ИБРАҺИ́М бине́ ЙОСЫ́Ф әл-БОЛГАРИ́** (? — 1204), болгар табибе һәм дин эшлеклесе. Болгар шәһәрендә яшәгән. Ислам диненә һәм медицинага багышланган «Борһанетдин язмалары» («Рисалә-и Борһаниһе»), «Гади дарулар» хезмәтләре авторы. Башка авторлар хезмәтләрен шәрехләве дә билгеле: «Әдәб» китабына аңлатмалар» («Хашийяте «Адаб» әл-моназарәт»), «Диалектика фәнендә ән-Нәсәфи уңышлары» («Фосул ән-Нәсәфи гыйльм әл-җәдәл»).

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура. К., 1990.

*Г.М.Дәүләтшин.*

**БОРҺА́НОВ** Альберт Әхмәтҗан улы (12.7.1956, Чиләбе өлкәсе, Коншак р-ны Усть-Багаряк (Түбән) а.), тарихчы, тарих фән. канд. (1992). Чиләбе пед. ин-тын тәмамлый (1978). 1978–84 елларда Төркмәнстан ССРның Тарих ин-тында фәнни хезмәткәр. 1986–88 дә Төркмәнстан ССР Мәдәният министрлыгының «НИСА» дәүләт тарихи-археол. музей-тыюлыгы археология секторы мөдире һәм директор урынбасары. 1988–94 тә Төркмәнстан ФА Тарих ин-тының Археол. казу эшләре үзәгендә эшли. Урта Азия, Урал һәм Төньяк Кара диңгез буйларында археол. казу эшләрендә катнаша. 1994–95 тә Иске Казан тарихи-мәдәни һәм табигый музей-тыюлыгы директоры урынбасары. 1995 тән ТР ФА Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының, 1997 дән ТР ФА Тарих ин-тының археология бүлеге, археол. тикшеренүләр үзәге өлкән фәнни хезмәткәре, бер үк вакытта 1995 тән Казан ун-тының археология һәм этнология каф. доценты һәм 1998 дән Татар гуманитар ин-ты доценты, 2001–05 тә проректоры. 2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-ты тарих һәм этноархеология каф. мөдире, проф. (2006). Б. инициативасы б-н Казан арты төбәгендә Тарихи истәлекләрне өйрәнү һәм саклау буенча гыйльми совет төзелә. Б. шул советның рәисе урынбасары. ТР ФА Тарих ин-тының Казан арты тарих-археол. экспедициясе Б. җитәкчелегендә Биектау, Арча, Саба, Кукмара, Лаеш р-ннарында, Казанда, ш.у. Алтын Урданың Сарай әл-Мәхрусә шәһәрлегендә археол. казу эшләре алып бара. Россия археол. җәмгыятенең Идел-Урал үзәге әгъзасы, Россия Табигать фәннәре академиясенең (РТФА) археология һәм антропология секциясе рәисе. Әфганстанда сугыш хәрәкәтләрендә (1979–81) катнаша. Медальләр, Әфганстан Респ-касы, СССР ЮС Президиумының (1998), Төркмәнстан Респ-касының (1994) Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. Хезмәтләре Урта Азия һәм Идел буеның урта гасырлар археологиясе һәм тарихына багышлана. Бөтентатар конгрессы башкарма ком-ты президиумы әгъзасы.

Хезм.: Древности Амуля (Область Амуля в древности и раннем средневековье). Ашхабад-Ылым, 1993; Древняя история // Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999; Древности Предволжья. К., 2003; Страноведение: История и культура Ирана. К., 2004; Древний Лебап: В 2 т. К., 2005; Золотоордынские памятники Поволжья. К., 2005.

*Әд.:* Гасырлар тирәнлегенә яшеренгән хәтер. Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы // Бәдертдинов Х.Ф. Татарстаннан читтәге татар галимнәре. К., 2006. 2 кис.; Guide to Scholars of the Histori and Culture of Central Asia. Harvard, 1997.

**БОРҺА́НОВ** Әбрар Хәмит улы (22.2.1912, Казан губ. Олы Кошман а. — 15.5.1990, Казан), моторист, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1940–73 елларда Казан авиация з-дында эшли, самолётларны сынау очышларына әзерли. Герой исеме 1959–60 еллар планын үтәүдә зур уңышларга ирешкәне һәм яңа техника

үзләштергән өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Горник Г. Бурганов Абрар Хаметович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой славы — наши земляки. К., 2003.

**БОРҺА́НОВ** Әгъдәс Хөсәен улы (17.10.1920, Бөгелмә кантоны (хәзерге Лениногорск р-ны Сарабиккол а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1990), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1995). Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тын тәмамлый (1946, Мәскәү). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947–48 елларда Маргилан шәһәре хезмәт ияләре депутатлары башкарма ком-ты секретаре, 1948–49 да Фирганә шәһәр прокуратурасы тикшерүчесе (Үзбәкстан). 1949–51 дә Таҗикстан ССР МС каршындагы Сәнәгый хезмәттәшлек идарәсендә юрист-консультант. 1951–53 тә Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тының Сталинабад ф-лында өлкән укытучы, директор. 1953–58 дә Таҗик ун-тында, 1958–59 да Казан авиация ин-тында укыта. 1959–60 та КПССның Татарстан өлкә ком-тында мәктәпләр һәм фән бүлеге мөдире. 1960–61 дә Казан пед. ин-тында марксизм-ленинизм каф. мөдире. 1961–73 тә Казан ун-тында, 1973–79 да Мәскәү гражданнар авиациясе инженерлары ин-тында укыта. 1979 елдан Мәскәү консерваториясендә, 1981–85 тә марксизм-ленинизм каф. профессоры. 1987 дән Россия гуманитар ун-тында (Мәскәү): КПСС тарихы (1988 гә кадәр), 1988–90 да сәяси икътисад һәм фәнни коммунизм, 1990–92 дә икътисад һәм социаль-сәяси фикер, 1992–93 тә икътисади тәгълиматлар тарихы, 1993–97 дә философия һәм хуҗалык социологиясе, 1997–98 дә — икътисади теорияләр, 1998 дән социология кафедралары профессоры. Хезмәтләре Окт. рев-циясе, совет крәстияннәре тарихына, философиягә һәм милек социологиясенә, милли-мәдәни мохтарият, Россияне һәм Татарстанны реформалаштыру мәсьәләләренә карый. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Подъём материального благосостояния крестьянства — важнейшее условие укрепления союза рабочих и крестьян. Сталинабад, 1957; Лучше правда. К., 1990; Социализм и перестройка. М., 1990; Россия перед выбором: «Восток?», «Запад?», «Особый путь?». К., 1995; Откуда и куда идешь, Россия? М., 1996; Философия и социология собственности: Русские и татарские реалии. М., 2002; Книга, задуманная как «некоммутистический манифест гражданского мира» или «мечта идиота». М., 2007.

**БОРҺА́НОВ** Рәис Әбрар улы (1.12.1960, Апас р-ны Иске Чәчкаб а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2005), проф. (2007). Казан ун-тының тарих ф-тын тәмамлый (1988). Хезмәт эшчәнлеген 1978 елда Апас р-нының «Правда» к-зында башлый, 1979–81 елларда «КамАЗ»ның Тимерчелек з-дында слесарь булып эшли. 1988–93 тә КПССның Апас һәм Кайбыч райкомнары инструкторы. 1993 тән «АлАЗ» җитештерү берләшмәсендә әйдәп баручы икътисадчы, бер үк вакытта Алабуга пед. ин-тында укытучы. 2005 елдан Россия сәүдә-икътисад ун-тының Казан ин-тында (ф-лында) дөнья икътисады каф. профессоры. Хезмәтләре базар мөнәсәбәте шартларында икътисади концентрация мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Экономические основы предпринимательства. К., 2001; Экономическая концентрация: сущность и проявления в конкурентной среде. К., 2003; О положительных и отрицательных эффектах экономической концентрации // Маркетинг. 2003. № 2; Кластеризация экономики региона в преддверии вхождения в ВТО // Актуальные проблемы экономики и права. 2007. № 3.

*Әд.:* Туган җирем — Кайбычым (Кайбицы — край мой родной). Науч.-популярное изд. К., 2007.

*Ф.С.Зыятдинов.*


**БОРҺА́НОВ** Тәбриз Гыйльметдин улы (2.9.1951, Лениногорск р-ны Иске Иштирәк а.), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). ТРның атказ. химигы (2007). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1981). 1971 елдан «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли. 1977 гә кадәр экстракцияләү аппаратчысы, 1977–93 тә экстрактив ректификацияләү юлы б-н нефтьтән газны аеру цехы башлыгы урынбасары, СКИ-3 з-дының полимерлаштыру цехы башлыгы, 1993–2000 дә баш инженер урынбасары, директор урынбасары, 2000 нән ясалма каучук җитештерү з-ды директоры. Аның җитәкчелегендә ясалма олигопиперилен олиф, ясалма этиленпропилен каучук, автомобиль ягулыгы компонентлары (КАТ-1, КАТ-К) җитештерү гамәлгә кертелә. 20 дән артык ачышка авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге «Россиядә беренче күптонналы унификацияләнгән этиленпропиленлы каучук җитештерүне үзләштерү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**БОРҺА́НОВ** Тимерхан Борһан улы (11.7.1925, Минзәлә кантоны Вәрәшбаш а. — 2.12.2004, Казан), партия, хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казанда Югары партия мәктәбен тәмамлый (1958). 1943–50 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә, Бөек Ватан сугышында Япония гаскәрләренә каршы сугыша (1945). 1950–51 дә Мөслим р-ны а.х. бүлегендә бухгалтер-инструктор, 1951–52 дә Мөслим р-ны Михайловск с-зында партия оешмасы секретаре. 1952–54 тә КПССның Мөслим райкомында партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары бүлеге мөдире. 1958–61 дә секретарь, 1961–63 тә КПССның Тукай райкомы беренче секретаре. 1963–77 дә Арча р-ны халык депутатлары советы башкарма ком-ты рәисе. 1977–86 елларда ТАССР социаль тәэминат министры урынбасары. ТАССР ЮС депутаты (1963–67, 1971–75).


*Әд.:* Ахунов Г.А. Тимерханның күргән-кичергәннәре. К., 1999.

**БОРҺА́НОВА** Лариса Әгъдәс кызы (13.5.1950, Таҗикстан ССР, Дүшәмбе ш.), социолог, социол. фән. д-ры (1998), проф. (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1972), 1975–76 елларда шунда ук эшли. 1976 елдан Казан технол. ун-тында, 1980 нән дәүләт идарәсе, тарих һәм социол. кафедрасында эшли. Хезмәтләре 19–20 йөзләр Америка социологиясенә карый.

Хезм.: Ранняя американская социология. К., 1997; Становление социологии как учебной дисциплины в американских университетах // Социально-политический журнал. 1998. № 1; Институционализация социологии в США // Социол. исследования. 1998. № 1.



Әбрар Х. Борһанов.



Әгъдәс Х. Борһанов.

**БОРҺА́НОВА** Нажия Борһан кызы (12.11.1924, Тәтеш кантоны Әмәкәй а. — 14.11.2001, Казан, Кама Тамагы р-нында күмелгән), тел галиме, филол. фән. канд. (1953). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1947). 1952–86 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. Хезмәтләре татар теле грамматикасы, фразеологиясе һәм диалектологиясенә карый. Татар теле диалектларын: Карин (Киров өлкәсе), Глазов (Удмуртия Респ-касы), Бәрәңге (Мари Респ-касы) һәм Казан арты сөйләшләрен өйрәнү максатында экспедицияләр оештыра. «*Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре а́тласы*» һәм «Татар теленең диалектологик сүзлеге»нең (1969) фәнни мөхәррирләре һәм төзүчеләренең берсе.

Хезм.: Русча-татарча фразеологик сүзлек. К., 1959 (автордаш); Особенности говора Нагорной стороны ТАССР // Материалы по диалектологии. К., 1953; Временные формы глагола изъявительного наклонения в заказанских говорах // Материалы по татарской диалектологии. К., 1974; Из истории формирования фонетических особенностей татарских говоров Заказанья // Источниковедение и история тюркских языков. К., 1978.

**БОРЧА́К** (Pisum L.), кузаклылар семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; *бөртекле-кузаклы культура*. 6–7 төре бар, Россиянең Кавказ һәм Европа өлешендә 2 төре үсә. ТРда, башлыча, ак чәчәкле, ачык төстәге орлыклы игүле Б. (P. sativum) үстерелә. Югары аксымлы азык (ярма, он, яшел борчак, ярдырылган борчак) һәм терлек азыгы (яшел масса, сенаж, ашлык, салам) үсемлеге. Орлыкларында 25–30% протеин, 50–56% углевод, 1,5% май, 3,5% клетчатка бар. Б. ашлыгы катнаш азык сәнәгатендә киң кулланыла. 1 азык берәмлегенә күчереп исәпләгәндә, 150 *г* нан артык үзләштерелә торган протеин туры килә. ТРда Б.ның уртача уңышы — гектардан 18–20 *ц*. Югары уңышлы чәчүлекләре туфракны азотка баета: 1 гектардан уңыш 20 *ц* булганда — 50 *кг* га, 30 *ц* булганда — 70 *кг* га. Районлаштырылган һәм Дәүләт реестрына кертелгән сортлар: «Неосыпающийся 1», «Чишминский 95», «Казанец», «Труженик», «Татарстан 2». Казан селекция станциясендә «Казанский 38» сорты чыгарылган, бу сорт 1960–70 елларда зур мәйданнарда игелә. Азот туплауга сәләтле булганлыктан, Б. бүтән үсемлекләр өчен кыйммәтле элгәр булып тора. Уртача өлгерешле сортлар өчен вегетация чоры

68–86 көн. Б. өчен иң яхшы туфрак — ачылыгы аз балчыксыл һәм һава б-н яхшы туендырылган нейтраль туфрак. Фосфорлы һәм калийлы ашламаларны күбрәк үзләштерә, РК нормасы 1 гектарга 140 *кг* га кадәр. Аркылыга-буйга яисә тар рәтле алым б-н чәчәләр, орлыкларны чәчү нормасы 1,5–3,5 *ц/га*, чәчү тирәнлеге 4–10 *см*. Б.ны нигездә аеры ысул б-н июль ахырында җыялар. Корткычлары — борчак коңгызы, борчак бете, борчак җимешашары; авырулары — аскохитоз, күгәрек, ончыл чык (к. *Авыл хуҗалыгы үсемлекләре авырулары*). ТРда Б. үстерү һәм җыюның интенсив технологиясе производствога кертелгән (Р.Р.Хөсәенов, А.А.Җиһаншин, Ә.М.Шалыгина, И.С.Возовик һ.б.). 2005 елга ТРда чәчү мәйданы 55,8 мең *га*, уңышы 1 гектардан 21,7 *ц*. 1980 елларда республикада Б. чәчү мәйданы 550 мең *га* га җитә. Алдынгы хуҗалыклар 1 гектардан 40–45 *ц* уңыш алалар.

*Әд.:* Зиганшин А.А., Шакуров В.З. Возделывание зернобобовых культур. К., 1953; Макашева Р.Х. Горох. Л., 1973; Боднор П.В., Лавриненко Г.Т. Зернобобовые культуры. М., 1977.

*Г.Г.Җиһаншин.*

**БОРЧАКЛЫ́ ЯЗ** (Борчаклы Өяз) авылы, Теләче р-нында, Нырсы елгасының югары агымы буенда, Теләче авылыннан 23 *км* көньяк-көнчыгыштарак. 2002 елда 21 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 2 нче яртысында Субаш авылыннан чыккан керәшен татарлар нигез сала. Соңыннан монда Лаеш өязенең Комаровка, Мамадыш өязенең Урта Мишә һәм Чиябашы, Чистай өязенең Сосново-Вражск авылларыннан рус крәстияннәре күчеп килә. Игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, яшелчәчелек б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында Б.Я. да Вознесение чиркәве (1890 да салына), земство мәктәбе (1879 да ачыла), 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 951 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 тән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1859 да — 356, 1897 дә — 625, 1908 дә — 741, 1926 да — 657, 1938 дә — 501, 1949 да — 332, 1958 дә — 249, 1970 тә — 168, 1979 да — 76, 1989 да — 26 кеше.


**БОРЧАЛА́Р** (Aphaniptera, яки Suctoria, яки Siphonaptera), кан суыручы канатсыз бөҗәкләр отряды. Кошлар һәм имезүчеләрнең күп төрләренең вакытлы паразитлары. Төрле чыганаклар буенча, дөнья фаунасында 1050 дән алып 1800 гә кадәр төр санала. ТРда 44 төре билгеле, шуларның 15 е күпсанлы һәм киң таралган. Алар арасында кеше (Pulex irritans), мәче һәм эт (Ctenocephalides felis һәм Ct. canis), вак имезүчеләр (Ceratophyllus penicilliger, C. turbidus, Leptopsilla bidentata), кош борчалары (Ceratophyllus gallinae, C. styx, C. hirundinis) бар. Зурлыгы 3 тән алып 7 *мм* га кадәр. Сарыдан алып куе коңгырт төскә кадәр. Гәүдәсе ян-яктан кысылган, нык хитинланган, күп санлы төкләр һәм нечкә чәнечкеләр б-н капланган һәм хайваннар йонында, кош каурыйлары арасында күчүгә җайлашкан. Канатлары юк. Башында бер пар гади күзе (Б.ның кайберләре сукыр), өч буынлы бер пар мыекчасы бар, авыз аппараты кисеп-кадап суыра торган. Өч күкрәк сегментына өч пар аяк ялгана. Арткы пар аяклары озынрак һәм алар сикерүгә җайлашкан. Кан б-н генә туена. Ана Б. кеше һәм хайваннар яши торган урыннарда 0,5 *мм* зурлыктагы озынча түгәрәк ак йомыркалар сала. Оялда 3 тән алып 5 кә кадәр йомырка була (Б. үз гомерендә 450 гә кадәр йомырка сала ала). Алардан җитлеккән борча тизәкләре (чөнки аларда органик калдыклар һәм эшкәртелеп бетмәгән кан була) б-н туенучы хәрәкәтчән суалчансыман личинкалар чыга. Үсеш процессында личинкалар өч тапкыр кабыкларын алыштыра, үсешнең соңгы стадиясендә пәрәвез кузысы б-н чорналган хәрәкәтсез курчакка әйләнәләр. Б. ның гомер озынлыгы берничә айдан 3 елга кадәр. Б. — чума, түләрәмә, талпан энцефалиты, сальмонеллёз, пастереллёз, бруцеллёз һ.б. авыруларны таратучылар.

*Әд.:* Сазонов О.Н. Блохи // Переносчики возбудителей природноочаговых болезней. М., 1962; Назарова И.В. Блохи Волжско-Камского края. М., 1981. *В.А.Бойко.*

**БОРЫЛЫ́К** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ургыдының сул кушылдыгы (Минзәлә елгасы бассейны). Озынлыгы 11,9 *км*, бассейнының мәйданы 60,2 *км*$^2$. Минзәлә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Тәкермән авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Хуҗамәт авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 162 *м*, тамагыныкы — 85 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 13%. Б. елгасының 1,5 тән алып 6,1 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 117 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,055 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12 *мг-экв/л* дан артыграк). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 700 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында күләме 0,7 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БОРЫ́Н ПЛА́СТИКАСЫ (РИНОПЛА́СТИКА)**, к. *Гусынин ринопластикасы.*

**БОРЫНГЫ́ ТӨРКИ́ РУН ЯЗУЫ́**, 6–10 йөзләрдә яшәгән борынгы төрки кабиләләр язуы. Үзәк Азиядә һәм Себердә кулланылган Б.т.р.я. (*Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре*) Көнчыгыш Европада кулланылган рун язмаларыннан аерылып тора. Орхон язмаларының серен Дания тел галиме В.Томсен ача (1893). Әлеге язуларны Россия тюркологы В.В.Радлов та өйрәнә; ул 1894 елда Россия Фәннәр академиясенә 8 йөздә язылган Күлтәгин язмасын укуы турында белдерә һәм үзенең ачышын академиягә тәкъдим итә. Иң борынгы рун алфавиты согдий язуы җирлегендә барлыкка килә, ә ул, үз чиратында, арамей язуына барып тоташа. Согдий язуы төрки телләрнең фонетик һәм морфологик төзелешенә җайлашу процессында зур үзгәрешләр кичерә. Рун язуының барлыкка килү урыны һәм вакыты әлегә ачыкланмаган. Белгечләр фикеренчә, рун язуы өч үсеш баскычы үтә: 1) архаик ядкәрләр — Җидесу (6–8 йөзләр) һәм Енисей (6–10 йөзләр); 2) классик (Төрки каганлык ядкәрләре, 8 йөзнең 1 нче яртысы); 3) соңгы (Уйгыр каганлыгы (8–9 йөзләрнең 2 нче яртысы) һәм Көнчыгыш Төркестан (9 йөз) ядкәрләре). Рун алфавиты морфологик принципка нигезләнгән һәм фонемаларның дифференциаль билгеләре системасын чагылдыра. Алфавитта, региональ һәм хронологик вариантларын да кертеп, 40 тан артык графема бар. Б.т.р.я.ның үзенчәлеге — күпчелек веляр һәм палаталь тартыкларның мөстәкыйль хәреф парлары бар. Сигез сузык биш тамга б-н белдерелә. Сүзләрнең калын яки нечкә сузык б-н әйтелеше тартык аваз өчен нинди хәреф кулланылуга бәйле. Б.т.р.я — консонант язу системасы. Язулар горизонталь юлларда урнашкан, өстән аска һәм уңнан сулга укыла. Енисей һәм Орхон ядкәрләренең графикасы аерыла. Бу ядкәрләрнең фонетик системасына хас гомуми билге — аларның төрки телләрнең д-төркеменә каравы. Борынгы рун



Рун язуы үрнәге.

ядкәрләрен өйрәнү дәверендә текстлар тюркологлар (В.В.Радлов, П.М.Мелиоранский, С.Е.Малов, В.Томсен, В.Банг, Х.Н.Оркун һ.б.) тарафыннан төрлечә укыла. Моның сәбәпләре — Б.т.р.я. ядкәрләренең бер-берсеннән хронологик ераклыгы һәм борынгы төркиләр теленең авазлар системасы турында фаразлы күзаллаулар яшәүгә бәйле. Рун язуыннан тыш, борынгы төркиләр манихей һәм брахми шрифтларыннан да файдаланганнар. Идел буенда рун язуы үрнәкләре ташларда, тәңкәләрдә, металл көпшәләрдә табыла.

*Әд.:* Мөхәммәди Ә. Һуннар һәм Туран язмалары. К., 2002; Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951; Кононов А.Н. Грамматика языка тюркских рунических памятников (VII–IX вв.). Л., 1980; Thomsen W., Steins A. Manusckripts in Turkisch «Runic» Seript from Miran and Tun-huang, London, 1912; Radloff W. Die altturkischen inschriften der Mongolei, Neue Folge. St.-Pb., 1897.

*В.Х.Хаков.*

**БОРЫНГЫ́ ТӨРКИ́ ТЕЛЛӘ́Р**, борынгы һәм урта гасырлардагы (7–15 йөз) төркиләрнең юкка чыккан телләре; ике төргә: халык сөйләме һәм әдәби телләргә аерылалар. Борынгы төрки кабиләләрнең һәм халыкларның сөйләм теле чагылган ядкәрләр аз сакланган. Безнең көннәргә кадәр килеп җит-

кән текстларның күбесе әдәби тел ядкәрләре булып тора.

Әдәби Б.т.т.нең иң элгәре үрнәкләре — төрки рун язулары теле (7–9 йөз) (к. *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре*). Борынгы төрки *койне* угыз һәм уйгыр кабиләләре теле җирлегендә формалаша. Әдәби телгә хас булганча, аңа эшкәртелгәнлек, төрле этник һәм социаль катламнар тарафыннан кулланылуы сәбәпле, күпмедер дәрәҗәдә функциональ-стилистик вариантлык хас. Иң әһәмиятле ядкәрләр: Тоньюкук (8 йөз), Күлтәгин (732), Билге каган (735) ташъязмалары. Төрки телле халыкларга билгеле *борынгы уйгыр теле* җирлегендә кайбер әдәби телләр формалаша. Аның тәэсирендә 11–12 йөздә Караханилар мөселман дәүләте территориясендә уйгыр әдәби теле оеша. Бу телдә (уйгыр һәм гарәп графикасында) А. Йүгнәкинең «Һибат әл-хакаикъ» («Хакыйкатьләр бүләге»), Й.Баласагуниның «Котадгу белег» («Игелекле белем»), Мәхмүд Кашгариның «Диван-е ләгать әт-төрк» («Төрки сөйләшләр җыентыгы») һ.б. язылган.

13–14 йөзләрдә Алтын Урда терр-ясендә, Сырдәрьянең түбән агымыннан көнбатышка таба «харәзм төркие» дип аталган әдәби тел барлыкка килә, аның нигезендә җирле кыпчак һәм угыз кабиләләре теле ята. Рабгузиның «Кыйссас әл-әнбия» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар»), Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се һ.б. гарәп һәм өлешчә уйгыр язуы ядкәрләрен тәшкил итә.

Урта гасырлар төрки әдәби телләре үсешендә, соңгы этап буларак, *чыгтай теле* барлыка килә. Аның нигезендә 16–19 йөзләрдә төрки әдәби телнең төбәк вариантлары, ш.и. *Идел буе төрки теле* формалаша.

Моннан тыш, 13–14 йөзләрдә кулланылыш даирәсе тар булган әдәби Б.т.т билгеле: Идел буе эпитафия (гарәп графикалы) язмаларының *болгар теле* (к. *Эпитафия*); Мисыр һәм Сүрия ядкәрләре язмаларында кулланылган мәмлүк-кыпчак әдәби теле; Кече Азия һәм Кавказ арты ядкәрләренең сәлҗүк теле. 13–15 йөзләрнең кыпчак сөйләм теле (к.*Кыпчак теле*) латин графикасында язылган «Кодекс Куманикус» һәм Каменец-Подольскида табылган әрмән язулы суд актларында да чагылыш тапкан.

Б.т.т.не Россия һәм чит ил галимнәреннән В.В.Радлов, С.Е.Малов,А.Н.Кононов, А.Н.Бернштам (рун язма истәлекләре), В.К.Мюллер, А.А. фон Ле Кок, П.Циме (борынгы уйгыр текстлары), Р.Арат, Б.Аталай, С.М.Моталлибов (караханилар дәвере текстлары), Р.Нур, Ә.Н.Нәҗип, Ә.И.Фазылов (харәзм ядкәрләре), А.Вамбери, Дж. Клосон (чыгтай тел белеме) һ.б. өйрәнә.

*Әд.:* Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951; Древнетюркский словарь. Л., 1951; Тенишев Э.Р. Языки древне- и среднетюркских письменных памятников в функциональном аспекте // Вопр. языкознания. 1979. № 2; Кононов А.Н. Грамматика языка тюркских рунических памятников VII–IX вв. Л., 1980.

*Р.А.Закиров.*

**БОРЫНГЫ́ УЙГЫ́Р ТЕЛЕ́**, борынгы уйгырлар теле; 8–14 йөзләр язма ядкәрләрендә чагылган *борынгы төрки телләрнең* берсе. 9 һәм 13 йөзләр уртасында Көнчыгыш Төркестандагы Кочо уйгыр дәүләтенең (хәзерге Кытай Халык Респ-касының Синьцзян-Уйгыр автономияле р-ны) рәсми теле. Телнең әдәби формасы 8 йөз ахырында Турфан дәүләтендә уйгыр элементлары б-н баетылган рун истәлекләре теле нигезендә формалаша. Кульязмаларда «төрк уйгыр теле» (төрки уйгыр теле) дип аталган Б.у.т. грамматик һәм лексик системаларга бай һәм төрле стильләргә (дини, матур әдәбият, фәнни, эш кәгазьләре, эпистоляр) ия, башка төрки халыкларга яхшы мәгълүм һәм бик популяр булган; соңрак әдәби телләрнең төрле вариантлары формалашуга тәэсир иткән. Текстларда чагылган тел аерымлыклары нигезендә Б.у.т.ндә шартлы рәвештә n- һәм j- диалектлары дип аталган ике диалект аерылып чыга. Б.у.т.нең үзенчәлекләре: кайбер позицияләрдә тел уртасы спирант j урынына тел алды йомык d кулланылу; хәзерге төрки телләрдә югалган, хәзерге заман сыйфат фигыль ясый торган -yma/-gmä һәм киләчәк заман сыйфат фигыль ясый торган -dači/-däči формантлары булу; -dan/-tan чыгыш килеш аффикслары куллану. Борынгы уйгырлар согдий язуыннан һәм аның уйгыр дип аталган җайлаштырылган вариантыннан, ш.у. манихей һәм брахми шрифтларыннан файдаланганнар; берникадәр күләмдә рун, тибет, эстрангело язулы ядкәрләр дә очрый. Иң әһәмиятле язма ядкәрләр: «Алтун йаруг» («Алтын балкыш») сутрасы (10 йөз), Кытай сәяхәтчесе Сюань-Цзян биографиясенең уйгыр версиясе (10 йөз), күпсанлы юридик документлар (8–14 йөзләр).

*Әд.:* Малов С.Е. «Памятники древнетюркской письменности». М.–Л., 1951; Насилов В.М. Язык тюркских памятников уйгурского письма XI–XV вв. М., 1971; Тенишев Э.Р. Система форм существования древнеуйгурского языка // Функциональная стратификация языка. М., 1985.

*Р.А.Закиров.*

**БОРЫНДА́Й** (13 йөзнең 1 нче яртысы), монгол яугире. 1236–41 елларда *Бату хан* б-н бергә Идел буе Болгары, Төньяк-Көнчыгыш һәм Көньяк Русь кенәзлекләре җирләрен, Польша б-н Венгрияне яулауда катнаша. 1240–41 дә Сүбәдәй баһадир б-н бергә болгарларның монголларга каршы баш күтәрүен бастыручы (к. *Баян белән Җик кузгалышы*, 1238–41). 1258 дә үзенә буйсынган рус кенәзе Василько Романович б-н бергә — Литвага, 1259 да Көньяк-Көнбатыш Русь җирләренә һәм Польшага яуга бара.

*Әд.:* Хәлиуллин И. Болгарларның баш күтәрүе һәм Сүбәдәйнең буйсындыру походы (1238–1240) // Совет мәктәбе. 1989. № 7; Пашуто В.Т. Очерки по истории Галицко-Волынской Руси. М., 1950.

*И.Х.Хәлиуллин.*

**БОРЫНДЫ́К**, Азия борындыгы (Tamias sibiricus), кимерүчеләр отряды тиенсыманнар семьялыгыннан имезүче җәнлек. Евразиянең урман массивларында киң таралган. ТР терр-ясеннән Б. ареалының көньяк чиге үтә. Башлыча, Кама алдында, яфраклы агач төрләре катнаш чыршы-ак чыршы урманнарында, ш.у. Кама аръягында Кызыл Тау урман массивында очрый. Һәркайда аз санда. Гәүдә озынлыгы 17 *см* га, койрыгы 12 *см* га кадәр, авырлыгы 100 *г* чамасы. Йон капламы соргылт-җирән төстә, аркасында буй-буй 5 кара-көрән сызык бар. Түше аксыл яки ак. Көндез актив. Ылыслылар, сирәгрәк яфраклы агачлар, үләнчел үсемлек орлыклары, бөреләре, җиләкләр, ш.у. бөҗәкләр (башлыча, коңгызлар), моллюсклар б-н туена. Кышка азык әзерли (уртача 3–4 *кг*). Агач тамырлары яки черегән кәүсә астына ясаган өне Б.ның сыену урыны булып тора. Кышның күп өлешен йоклап үткәрә. Кар эреп, ачылган урыннар күренгәч кенә Б. өненнән чыга. Б. — моногамик хайван. Көзен парлар барлыкка килә, икенче елның язына гына үрчиләр (парлашу — апр. уртасында). Бер пар Б. 5–6 бала тудыра. Сунарчылык хуҗалыгында Б. зур роль уйный, чөнки алар б-н кыйммәтле мех бирә торган ерткыч җәнлекләр туклана. Җим әзерләве б-н орлык таратуга, агач үсемлекләре таралышына ярдәм итә. Мехы кыйммәтле түгел. Б. Идел-Кама саклаулыгында һәм «Түбән Кама» милли паркында саклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Попов В.А., Лукин А.В. Животный мир Татарии. К., 1988.

*П.К.Горшков.*

**БОРЫНДЫ́К** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бәрле елгасы буенда. 2002 елда 661 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б.та мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, почта-телеграф бүлекчәсе, почта станциясе, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2592 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 259 ир заты; 1859 да — 1067, 1897 дә — 1689, 1908 дә — 1920, 1920 дә — 1749, 1926 да — 1755, 1938 дә — 1767, 1949 да — 1308, 1958 дә — 1193, 1970 тә — 1216, 1979 да — 1123, 1989 да — 835 кеше.

**БОРЫНДЫ́К** тимер юл станциясе посёлогы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 45 *км* көнчыгыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2002 елда 533 кеше (чуашлар — 65%, татарлар — 25%) яши. А.х. техникасы һәм а.х. химиясе пр-тиеләре, нефть базасы. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1943 тә нигез салына. Будённый р-нына керә, 1957 елның 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1989 да — 567 кеше.

*Әд.:* Субаев Р.С. Чүпрәле: узган еллар, үткән юллар (Район тарихыннан очерклар). Чүпрәле, 2000.

**БОРЫНДЫ́КОВ** Микъдәт Юныс улы (15.1.1896, Саратов губ., Кузнецк өязе Дёмино а. — 1965, Үзбәкстан ССР Сәмәрканд ш.), сәясәт эшлеклесе. Казан татар укытучылар мәктәбен (1915), Чугуев хәрби уч-щесен (1916) тәмамлый. 1917 елда Россия армиясендә, прапорщик. 1917 нең декабрендә большевикларга кушыла, 1918–29 да ВКП(б) әгъзасы. 1918 дә Пермь губернасы мөселман хәрби коллегиясе рәисе, 1919 да губернаның милләтләр эше бүлегендә нәшрият мөдире, татарча чыккан «Коммунист» г-тасы мөхәррире, татар коммунистларының Вятка губернасы бюросы әгъзасы. 1920–21 елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең хәрби җитәкчесе (Казан). 1921–22 дә Мәскәүдә: Бөтенроссия баш штабында оештыру идарәсенең Көнчыгыш бүлеге башлыгы, Эшче-крәстияннәр инспекциясе һәм милләтләр эшләре халык комиссарының шәхси секретаре. 1922–24 тә ТАССР мәгариф халык комиссары, 1925–27 дә СССР Дәүләт банкының Татарстан бүлеге җитәкчесе, 1927–29 да «Кожсиндикат»ның Татарстан бүлеге директоры. ТАССР ҮБК президиумы әгъзасы, галимнәрнең көнкүрешен яхшырту комиссиясе рәисе, «Безнең юл» ж-лы мөхәррире. 1930 да нахакка кулга алына һәм 5 елга хезмәт лагерена озатыла, иреккә чыкканнан соң, Архангельск шәһәрендә яши: 1938 дә хезмәт колониясе уку-укыту комб-ты директоры. 1938 нең июлендә кабат кулга алына (к. «*Милләтчеләрнең Совет хакимиятенә каршы оешмасы» эше*); 8 елга хөкем ителә; иреккә чыккач, Сәмәркандта пед. эштә була. 1989 елда вафатыннан соң аклана.



М.Ю. Борындыков.

*Әд.:* Султанбеков Б.Ф., Малышева С.Ю. Трагические судьбы: Науч.-популярные очерки. К., 1996; Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2001. Т. 2.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**БОТА́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 38 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бота елгасы буенда. 2002 елда 380 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. Китапханә. Троица чиркәве. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Бота исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, олаучылык, чабата үрү, таш чыгару б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 3323,5 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында таш чиркәү, земство мәктәбе, 2 икмәк кибете, 2 тимерче алачыгы, 3 май язу йорты, 2 су тегермәне, 4 бакалея һәм 1 шәраб кибете эшли. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостена керә. 1920 елдан ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 296, 1834 тә — 550, 1859 да — 773, 1870 тә — 886, 1897 дә — 1528, 1912 дә — 1978, 1920 дә — 2015, 1926 да — 1796, 1938 дә — 1292, 1949 да — 1161, 1958 дә — 961, 1970 тә — 778, 1979 да — 449, 1989 да — 266 кеше.

**БОТА́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Кичүнең уң кушылдыгы (Чишмә елгасы бассейны). Озынлыгы 10 *км*, бассейнының мәйданы 70,2 $км^2$. Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Бота авылыннан 3 *км* төньяктарак, тамагы Илтән-Бота авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 217 *м*, тамагыныкы — 100 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 37%. Б. елгасының 1,9 һәм 5,2 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,55 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1,11–3 $л/с{\cdot}км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 99 *мм*, ташу агымы катламы 67 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Ноябрьнең беренче көннәрендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,077 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**БОТА́НИКА** (грек. bótan[illegible] — үсемлекләргә бәйле, үлән, үсемлек), үсемлекләр турындагы фән, *биологиянең* төп бүлекләреннән берсе. Фәннең үсемлекләр морфологиясен, анатомия, систематика, экологиясен, флористика, *палеоботаника*, *геоботаника* һ.б. тармакларын берләштерә. Ашарга яраклы һәм дару үсемлекләре турында мәгълүмат тупланган беренче ботаник текстлар б.э.к. 3 меңьеллык ахырында барлыкка килгән (Шумер, Вавилон, Ассирия, Мисыр, Кытай). Б.ның үсеш алуы Аристотель һәм Теофраст (аны «Б.ның атасы» дип йөртәләр) хезмәтләреннән башлана. Б. үсемлекләр турындагы белемнәрнең төзек системасы буларак 18 йөздә (башлыча, К.Линней хезмәтләрендә) формалаша. Россиядә дә Б. фәне шул вакыттан актив үсеш ала. Аның үсешендә Казан ун-ты галимнәренең дә өлеше бар. 1804–35 елларда К.Ф.Фукс, В.И.Тимьянский, Э.А.Эверсман Б. курсыннан лекцияләр укыйлар. 1806 да ун-тта *Ботаника бакчасы* оештырылу К.Ф.Фукс исеме б-н бәйле. 1836 да ботаника кабинеты һәм гербарийга (к. *Ботаника музее*) нигез салучы проф. П.Я.Корнух-Троцкий җитәкчелегендә Б. кафедрасы оештырыла. Шул вакыттан Казан губернасы флорасын өйрәнү эшләре башланып китә. 1860 еллар ахырыннан Идел-Кама төбәгендә һәм Россиянең башка регионнарында флористика һәм туфрак-геоботаника өлкәсендә тикшеренүләр үткәрелә башлый, Казан геоботаника фәнни мәктәбе оеша һәм үсеш ала (Н.Ф.Леваковский, П.Н.Крылов, С.И.Коржинский, А.Я.Гордягин). 1930 еллар ахырыннан В.И.Баранов җитәкчелегендә палеоботаника юнәлеше формалаша. Аның шәкертләре (Л.М.Ятайкин, К.В.Николаева, В.Т.Шаландина) тарафыннан үсемлекләрнең казылма серкәләрен өйрәнү буенча күп кенә тикшеренүләр уздырыла. В.И.Баранов, М.В.Марков, В.С.Порфирьев СССРның палеоген-неоген һәм антропоген флорасын һәм үсемлекләр дөньясын, болын, сазлык һәм урман үсемлекләре бергәлекләренең структурасын, Н.П.Арискина мүкләрне өйрәнүгә өлеш кертә. 1940–50 елларда Татарстан терр-ясендә фитопатологик тикшеренүләр үткәрелә (Н.П.Арискина), үсемлекләрнең җенси һәм җенессез үрчү процессларын өйрәнүче эмбриологик фәнни юнәлеш формалаша (Н.Г.Афанасьева, А.Г.Смирнов). 1950 еллардан вегетатив таралышлы (аеруча озын тамырчалы) үсемлекләр морфологиясен, экологиясен һәм аларның бергәлекләрдәге ролен ачыклау буенча тикшеренүләр алып барыла. Үсемлекләрнең вегетатив үрчүенең экологиясе өйрәнелә, озын тамырчалы һәм шуышма үсемлекләр таралышының нигездә туфракның дымлылык режимына бәйлелеге дәлилләнә (Е.Л.Любарский). 1960 еллардан Казан ун-тының Б. кафедрасы 1940 елларда Т.Т.Работнов башлап җибәргән ботаник популяция (үсемлекләр популяциясе экологиясе) өлкәсендәге тикшеренүләр буенча илдә төп үзәкләрнең берсенә әйләнә. Ценотик популяцияләрне морфоструктура һәм күләмле-структур анализлау принциплары һәм ысуллары эшләнә. Үсемлекләрнең вегетатив үрчүе һәм вегетатив таралышының ценопопуляция тыгызлыгына һәм фитоценозның йомылу дәрәҗәсенә бәйлелеге ачыклана. 1960–70 елларда проф. М.В.Марков җитәкчелегендә Казан а.х. ин-ты һәм Казан ун-ты Б. кафедралары хезмәткәрләре тарафыннан эксперименталь геоботаника өлкәсендә үсемлекләрнең фитоценозларда үзара мөнәсәбәтен өйрәнү буенча фәнни эшләр циклы үткәрелә. Шул ук елларда басу үсемлекләре бергәлекләрен һәм аларда үсемлекләрнең үзара мөнәсәбәтен өйрәнә торган яңа фәнни юнәлеш — агрофитоценология барлыкка килә. Вузара беренче бөтенсоюз киңәшмәсендә (1967, Казан ун-ты) агрофитоценологиянең эчтәлеге, төп проблемалары билгеләнә, теоретик нигезләре формалаштырыла (М.В.Марков һ.б.). 1970 еллардан сәнәгый Б. мәсьәләләре өйрәнелә. Яфраклы-сабаклы мүкләрне (1978), трахеидлы үсемлекләрне (1979), лишайникларны (1982) билгеләгечләр, Татарстан флорасы буенча сүзлек-белешмә (1988) нәшер ителә, ТРның Кызыл китабы өчен сирәк очрый торган һәм бетеп баручы үсемлекләрнең исемлеге төзелә (1955). Б. өлкәсендәге фундаменталь тикшеренүләр үсемлекчелекне, урманчылыкны, үсемлекләр экологиясен үстерүгә зур этәргеч ясый.

*Әд.:* Баранов В.И. Этапы развития флоры и растительности в третичном периоде на территории СССР. М., 1959; Базилевская Н.А., Белоконь И.П., Щербакова А.А. Краткая история ботаники. М., 1968; Ятайкин Л.М., Шаландина В.Т. История растительного покрова в районе Нижней Камы с третичного времени до современности. К., 1975; Афанасьева Н.Г. Эмбриология вероник. К., 1976; Марков М.В. Ботаника в Казанском университете за 175 лет. К.,

1980; С м и р н о в А.Г. Женский гаметофит покрытосеменных и его эволюция. К., 1982.

*Е.Л.Любарский.*

**БОТА́НИКА БАКЧАСЫ́,** Казан ун-тының фәнни тикшеренү, мәдәни-агарту һәм уку-укыту ярдәмче оешмасы. Россиядә иң борынгыларның берсе. К.Ф.Фукс инициативасы һәм И.Ф.Яковкинның эшлекле булышлыгында 1806 елда «Тенишев» һәм «комендант» бакчалары урынында оештырыла (хәзер бу участокта — китапханә, астр. обсерватория биналары, яңа Б.б.ның лаборатория корпусы). Б.б.ның нигезен җирле һәм читтән китерелгән (интродукцияләнгән) үсемлек коллекцияләре тәшкил итә. Б.б. да 1808 елда үләнчел үсемлекләрнең, куак һәм агачларның 252 төре, 1810 елда 800 гә якын төре исәпләнә. Аның терр-ясендә 2 оранжерея һәм теплица була. Б.б. коллекциясен тулыландыруда В.И.Тимьянский, И.М.Смирнов, Э.И.Эйхвальд зур өлеш кертә. 1823 тә орлыклар исемлеге төзелә һ.б. ботаника бакчалары б-н алмашу башланып китә. Б.б. алып торган участок кысан, ярлы туфраклы һәм рельефы буенча уңайсыз булып чыга. 1824 тә директор Э.И.Эйхвальд тарафыннан Б.б. мәйданын киңәйтү мәсьәләсе куела. Моның өчен 1829 елда ун-т Кабан күле буенда, Архангел шәһәр яны бистәсендә 6500 кв. сажин (2,96 *га*) җир участогы сатып алына, һәм ул урын 1832 дә тулысынча ун-тка беркетелә. 1834 тә бу участокта Б.б. оештырырга дигән боерыкка кул куела. Шул ук елда А.А.Бунге җитәкчелегендә бакчага нигез салу эшләре һәм 5 заллы таш оранжерея төзелеше башланып китә, бу эшләр 1836 да тәмамлана. 1839 да Б.б. янәшәдән участоклар сатып алу нәтиҗәсендә зурая. Экзотик үсемлекләр коллекциясен дә кертеп, 1841 дә 4 меңгә якын үсемлек төре исәпләнә. 1885 тә 700 данәсе П.Н.Крылов тарафыннан Томск шәһәренә күчерелә һәм Томск ун-ты каршындагы Себер ботаника бакчасының нигезе булып тора. 1895 елга Б.б. коллекциясе оранжерея үсемлекләренең 5273 үрнәген үз эченә ала. Алар арасында тропик үсемлек төрләре, 300 дән артык җимеш агачы һәм 1700 гә хәтле куак һәм үлән була. Төрле елларда Б.б.нда ботаник һәм геологлар И.Я.Корнух-Троцкий, Н.Ф.Леваковский, П.Н.Крылов, В.А.Ротерт, В.В.Лепёшкин һ.б. эшли. Гражданнар сугышы чорында Б.б. зур зыян күрә, коллекциянең шактый өлеше юкка чыга. 1921–26 елда энтузиастлар көче б-н күпмедер өлеше яңадан торгызыла, әмма бакча фәнни оешма исемен югалта. 1931 дә шәһәргә бирелә, акча түләп килүчеләрне җәлеп итү өчен, хайваннар тоту оештырыла, шул сәбәпле Б.б. зообothаника бакчасы итеп үзгәртелә (*к. Казан зооботаника бакчасы*). 1984 тә Казан ун-ты каршында яңа Б.б. оештырыла, аңа Биектау р-ның Кече Клыки һәм Константиновка авыллары арасындагы 175 *га* җир мәйданы бүлеп бирелә. Ул үз эченә табигый болынлык фрагментын, характерлы үсемлекләр бергәлеге булган ерым-сызалар системасын, югарыгы өлешендә нарат агачларын ала. Б.б. эшчәнлегенең төп юнәлеше булып азык-төлек, терлек азыгы, дәвалау һәм декоратив үзлекләренә ия булган әһәмиятле үсемлекләрнең экологиясен һәм күчереп утыртуның физиологик-биохимик механизмнарын өйрәнү-тикшеренүләр тора.

*Әд.:* Отчёт Императорского Казанского Университета и учебного округа за 17 лет с 1827 по 1 января 1844 по управлению тайного советника Мусина-Пушкина. К., 1844; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; ш у л у к. История Императорского Казанского Университета за первые сто лет существования (1804–1904). К., 1905–06. Т. 3, 4; Э с м о н т М. Казанский Ботанический сад // Тр. Студенческого науч. кружка любителей природы. К., 1929. Вып. 3.

**БОТА́НИКА МУЗЕЕ́,** Казан ун-тының биол.-туфрак ф-ты составындагы кафедрара фәнни уку-укыту бүлеге. Музей статусын 1997 елда ала. Ун-тның төп бинасында урнашкан, бүлмәләрнең гомуми мәйданы 170 $м^2$. Коллекция 100 меңнән артык саклау берәмлеген үз эченә ала. 1991 гә кадәр коллекция ботаника кафедрасында саклана; 1991 дән зоология музее составында ботаника бүлеге оештырыла, 1997 дән хәзерге исемендә.

Музей коллекцияләренең туплана башлавы К.Ф.Фукс исеме б-н бәйле. Аның тарафыннан, бигрәк тә Урал экспедициясендә (1801) җыелган материаллар, кенәз Г.А.Потёмкин-Таврический җыелмасының 1798 елда Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенә тапшырылган бер өлеше Казан ун-ты табигать тарихы кабинетында ботаника бүлегенең төп өлешен тәшкил итә. 1816 елга коллекциядә 177 үрнәк исәпләнә. 1836 да П.Я.Корнух-Троцкий зур коллекция — аббат де Грандидье (1500 гә якын нөсхә), Ф.И.Рупрехт (6500 нөсхә) тупланмаларын сатып ала. Аннан соңгы елларда гербарий күп кенә ботаникларның җыелмалары б-н тулыландырыла: Н.М.Мартьянов (1400 нөсхә, 1870–75), П.Н.Крылов (3677 нөсхә, 1877–78), Ю.К.Шелль (2835 нөсхә, 1877–78), С.И.Коржинский (800 нөсхә, 1884–87), А.Я.Гордягин (1500 нөсхә, 1855–1916), В.И.Баранов (1200 нөсхә, 1913–27), Л.Н.Васильева (2800 нөсхә, 1927–36).

85 мең саклау берәмлеген үз эченә алган югары төзелешле үсемлекләр гербарие — Б. м.нда иң зур коллекцияләрнең берсе. Бу гербарий ТР һәм Урта Идел буе терр-яләренең тулы флорасыннан, ш.у. БДБның күп кенә р-ннарында узган экспедиция җыелмаларыннан тора. К.С.Мережковский тарафыннан 19–20 гасырлар арасында төзелгән лихенологик гербарий Идел буе, Кырым, Россиянең төньяк р-ннарыннан, ш.у. Австрия, Франция, Италия, Греция һ.б. терр-ялардән җыелган 22 меңнән артык лишайник үрнәген үз эченә ала. Лишайникларның күпчелек төрләре дөньякүләм коллекцияләрнең төп эталоны булып саналган типлар б-н күрсәтелгән. Гөмбәләр коллекциясе 7 мең нөсхәне үз эченә ала. 2 меңгә якын мүксыманнар бар. Суүсемнәр коллекциясендә — 200 гербарий яфрагы, 70 саклау берәмлеге теркәлгән. Музей фондында В.И.Баранов тарафыннан җыелган кайназой чоры палеоген утырмаларындагы 2 меңгә якын борынгы үсемлекнең эзе, төрле физик-географик р-ннардагы элеккеге (палео) һәм хәзерге ландшафтларны сурәтләгән 167 рәсем һәм этюд саклана. Музейда ш.у. ТР һәм Урта Идел буендагы ботаник тикшеренүләр тарихы буенча кулъязмалар, фоторәсемнәр, басмалар бар. Музей материаллары нигезендә Татарстан терр-ясендә үсә торган яфрак сабаклы мүкләр (1978), көпшәле (трахеидлы) үсемлекләр (1979), лишайниклар (1982) турында белешмәлекләр басылып чыга.

*Әд.:* М а р к о в М.В. Ботаника в Казанском университете за 175 лет. К., 1980; С и т н и к о в А.П., Б а й б а к о в Э.Ю., П о т а п о в В.Б. Гербарий Казанского государственного университета // Бот. журн.. 1996. Т. 81, № 7; Ф о м и ч ё в а Н.Л. О поездках Карла Фукса на Урал и их научно-историческом значении. К., 1996.

*С.Е.Любарский.*

**БОТУЛИ́ЗМ** (лат. botulus — колбаса), көчле бактериаль инфекция, үзәк һәм вегетатив нерв системасын нык зарарлавы (нерв күзәнәкләренә экзотоксин тәэсире б-н бәйле), гастроэнтерит синдромы б-н үзенчәлекле. Б. б-н авыручы кеше тирә-юньдәгеләр өчен куркыныч түгел. «Б.» термины Голландия галиме Э. ван Эрменгем тарафыннан 1896 елда кертелә. Б. ны китереп чыгаручы — клостридиум ботулинум (серологик A, B, C, D, E, F, G тибындагы Clostridium botulinum) туфракта тарала, химик һәм физик тәэсиргә бирешми: 7 төрдәге термолабиль токсин — гаять көчле табигый нейротроп агу чыганагы; 0,3 *мкг* дозасы кешене үтерә. Туфрак, җылы канлы хайваннар, балыклар эчәклеге инфекциянең табигый туплану урыны һәм чыганагы ролен үти, бирелә авыру кузгатучылар туплана һәм тизәк б-н тышкы мохиткә эләгә. Кешенең авырып китү билгеләре ашказаны һәм эчәклекнең лайлалы тышчасы аша канга үтеп кергән агулар тәэсиреннән башлана; нерв системасының аерым өлешләре зарарлана; агу ашказаны-эчәк ферментлары тәэсирендә таркалмый. Авыру килеп чыгуның төп сәбәбе — өй шартларында консервланган ашамлыклар (яшелчә, җиләк-җимеш, гөмбәләр), санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен бозып әзерләнгән казылык, каклаган ит, балык һ.б., ш.у. туфрак б-н пычранган ашамлык куллану. Б. б-н йорт хайваннары да авырый. Казан мед. ун-тының йогышлы авырулар кафедрасында В.Я.Давыдов тарафыннан Б.га заманча диагноз кую һәм дәвалау ысуллары эшләнә (1970 елдан). Татарстанда ботулотоксин б-н агулануның аерым очраклары күзәтелә.

*Әд.:* П я т к и н К.Д. Микробиология. М. 1980; Справочник-путеводитель практикующего врача. 2000 болезней от А до Я. М., 1999.

*В.Х.Фазылов.*

**БО́УФАЛ** Владислав Францевич (12.7.1853, Гродно губ. — 20.11.1914, Одесса ш.), генерал-лейтенант (1914), Изге Георгий ордены кавалеры. Польша-Литва татарларыннан. С.-Петербургта юнкерлар уч-щесен тәмамлый. 1877–78 еллардагы рус-төрек сугышында кече офицер, 1900 елда Көньяк Маньчжуриягә һөҗүм итүдә һәм 1904–05 тә рус-япон сугышында батальон һәм бригада командиры буларак катнаша. Беренче бөтендөнья сугышында 4 нче укчы бригада командиры, 3 нче Гренадёрлар дивизиясе башлыгы. 3 нче, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 3 нче, 4 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче 3 нче дәрәҗә Изге Ста-

нислав, 4 нче дәрәҗә Изге Георгий орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Гришин Я.Я., Шарафутдинов Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

*Я.Я.Гришин.*

**БОХА́Н РАЙОНЫ́**, Усть-Урда Бурят автономияле округында. 1925 елда оештырыла. Мәйданы — 3,7 мең *км²*. Үзәге — Бохан посёлогы (Усть-Урда посёлогыннан 85 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 26897 мең кеше (2002). Татарлар саны: 1979 да — 1049, 1989 да — 996, 2002 дә — 995 кеше. Алар, башлыча, Бохан посёлогында һәм Хартирин, Хохорск, Укыр, Тараса, Яңа Ида, Заглик авылларында яшиләр. Б.р.на татарлар 1910 елларда килеп урнашалар. Татарлар саны 1936 һәм 1955 тә ТРның хәзерге Мамадыш р-ны авылларыннан күчеп утыручылар исәбенә арта. 1930–50 дә Укыр авылында татар мәктәбе була. Хохорск авылында «Дуслык» татар фольклор ансамбле эшли, Тараса авылындагы белем комплексында татар теле курслары оештырыла.

**БОХА́Р** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 70 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасының уң кушылдыгы Вятка суының югары агымы буенда. 2002 елда 14 кеше (татарлар) яши. 1924 тә Урмышлы авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. ТАССРның Бөгелмә кантоны Чыршылы волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 204, 1949 да — 380, 1958 дә — 177, 1970 тә — 158, 1979 да — 78, 1989 да — 38 кеше.

**«БОХАРА́ ӘХБАРЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1920–23 елларда Бохара шәһәрендә атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире К.Юлдаш. Актив авторлары: Х.Габдулла, С.Касыймов, Г.Мөхетдинов, Ф.Хуҗаев һ.б. Көнчыгыш илләрендәге сәяси хәлләрне яктырта, яшьләргә белем бирү, аларның иҗтимагый тормыштагы урыны мәсьәләләрен күтәрә, матур әдәбият үсешен яктыртуга аерым игътибар бирә. Рубрикалары: «Көнчыгыш илләрендә», «Бохара яңалыклары», «Яшьләр тормышы» һ.б.

**БОХАРАГА́ ҺӘМ БАГДАДКА́ АЛМЫ́Ш ИЛТӘБӘ́Р ИЛЧЕЛЕГЕ́**, 920–21 елларда болгарларның Урта Азия илләре һәм Багдад хәлифәлеге б-н үзара мөнәсәбәтләр урнаштыруга омтылышы. *Габдулла бине Башту* җитәкчелегендәге илчелекнең бурычы Урта Азия мөселман илләре һәм әл-Моктәдир хәлифә б-н Хәзәр каганлыгына каршы булган бердәмлек төзү, ярдәм итүләрен үтенү була. Сөйләшү барышында Идел буе Болгарына хәлифәлекнең илчелеге җибәреләчәге турында килешенә (к. *Болгарга әл-Моктәдир илчелеге)*.

*Әд.:* Ковалевский А.П. Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу 921–922 гг. Харьков, 1956.

*И.Л.Измайлов.*

**БОХАРА́ЕВ** Анастас Әхмәт улы (24.8.1948, Брянск ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физ.-техника ин-тында эшли, 2000 елдан өлеклләр физикасы һәм химиясе лаб. мөдире, бер үк вакытта Казан ун-тының оптика һәм нанофотоника каф. профессоры (2006 дан). Хезмәтләре пыялалардагы радиация үзәкләренә, каты җисемнәрне зондлы микроскопия ысулы б-н үзгәртүгә карый. Беренче мәртәбә 1975 тә пыялаларның төс үзәкләрендәге өч үлчәмле голограмманы язып ала, 1991 дә ионнар б-н бәрдереп алынган үтә вак металл кисәкчекләрен лазер нурында чыныктыру эффектын ача. Сыеклык б-н каты җисем чигендә барган химик һәм фотохимик процессларны өйрәнү өчен атом-көч микроскопиясе ысулын эшли. Микро- һәм макроструктураларның артык магнитлану процессын күзәтү өчен үтә вак магнит-көч микроскопиясе ысулын үстерә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Запись трёхмерной голограммы на радиационных центрах окраски в стекле // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1975. Т. 1 (автордаш); Исследование с помощью туннельной и атомно-силовой микроскопии поверхностей, модифицированных ионными и лазерными пучками // Успехи физ.наук. 1996. Т. 166 (автордаш); Изучение с помощью атомно-силового микроскопа in situ кинетики жидкостного химического травления субмикронных плёнок диоксида кремния // Микроэлектроника. 1999. Т. 28, № 5 (автордаш); Прецизионные измерения магнитострикции в никелевых структурах, используемых для получения магниторезистивных наноконтактов // Письма в Журн. эксперим. и теорет. физики. 2006. Т. 32, вып. 19 (автордаш).

**БОХАРА́ЕВ** Зөфәр Гариф улы (7.4.1945, Казан), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1969). 1968–72 елларда Казанда ВЛКСМның Бауман райкомы секретаре, 1972–76 да ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире, секретарь. 1976–79 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор. 1979–94 тә «Казан яшьләр үзәге» АҖ директоры. 1994–95 тә «Казан Кремле» фонды директоры. 1995–2001 дә ТРның Кинематография дәүләт ком-ты рәисе.

**БОХАРА́ЕВ** Равил Рәис улы (18.10.1951, Казан), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1974). Беренче шигырьләре 1970 елларда рус телендә языла. «Гасыр билгеләре» («Приметы века», 1974), «Ботагына бәйләнгән алма» («Яблоко, привязанное к ветке», 1977), «Август билгесе» («Знак Августа», 1981), «Чәчәкләр чоры» («Время цветов», 1985), «Тукай даирәсендә» («Вокруг Тукая», 1989), «Аек мәҗлесләр» («Трезвые пиры», 1990), «Очсыз-кырыйсыз поезд» («Бесконечный поезд», 2001), «Казан карлары» («Казанские снега», 2004) шигырь җыентыклары авторы. Г.Тукай һәм М.Җәлил шигырьләрен рус теленә тәрҗемә иткәне өчен Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләгенә лаек була (1986). 1991 елдан Лондонда яши. Проза әсәрләре арасында аеруча әһәмияткә ия булган һәм авторның кеше гомеренең тирән мәгънәсен аңлауга омтылуын чагылдырган китаплары — «Аллаһ үзе генә белгән юл» («Дорога Бог знает куда», 1999), «Ак манара» («Белый минарет», 2006). Канада, Англия,



Р.Р. Бохараев.

Һиндстан, Германия, Венгрия, Италия, Төркия матбугатында басылган татар, инглиз, венгр телләрендәге шигырьләр, татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә багышланган хезмәтләр, ТР Президенты М.Ш.Шәймиев турындагы китап авторы. Инглиз тикшеренүчесе-лингвисты Д.Мэттьюс б-н берлектә инглиз телендә «Татар поэзиясенең тарихи антологиясе»н әзерләп (кереш сүз, комментарийлар, югга-юл тәрҗемә авторы), Лондонда бастырып чыгара (2000). «Тимер борчак» (Татар академия театрында 2005 тә куела), Казан курчак театрында куелган «Ике акча турында әкият» («Сказка о двух монетах», 2005) һәм «Апушның сихри төшләре» («Волшебные сны Апуша», 2006) пьесалары авторы. 1992 дән Би-би-си, «Голос Америки» («Америка тавышы») һәм «Свобода» («Азатлык») радиостанцияләрендә Татарстанга, татар мәдәниятенә багышланган тапшырулар алып бара. Б. иҗатына көчле образлылык, тарихи дөреслек, тирән фәлсәфә, киеренке әхлакый һәм дини эзләнүләр хас.

Ә с ә р.: Президент Минтимер Шаймиев и модель Татарстана. Курзон-Блиц, Лондон-СПб., 2000; «Quest», quaternion (four different wreaths of sonnets in English, Hungarian, Russian and Tatar languages). Islam International Publications Ltd., Surrey, England, 1994; Islam in Russia: the Four Seasons, monograph, Curzon Publishers Ltd. London, England, 2000.

*Әд.:* Шевелёва И. О книге Р.Бухараева «Редкий дождь» // Новый мир. 1982, № 1; Соложенкина С. Разлуки нет... // Литературное обозрение. 1986, № 7.

*Р.Ә.Мостафин.*


**БОХАРА́ЕВ** Рәис Гата улы (24.4.1929, Томск ш.), математик, техник фән. д-ры (1968), физ.-матем. фән. д-ры (1981), проф. (1972), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1979), Казан ун-тының атказ. проф. (2004). 1952 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1960 елдан Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тының хисаплаулар теориясе бүлеге мөдире, 1968–81 елларда Казан ун-ты каршындагы Мәскәү электрон идарә ителүче машиналар ин-тының бүлек мөдире, 1970–97 дә теоретик кибернетика каф. мөдире. Хезмәтләре геометриягә, матем. кибернетика, информатика, техник кибернетикага карый. Казанда матем. кибернетиканың фәнни юнәлешенә нигез салучы (1962). Биаффин өлеклләр һәм биаксиаль фәзалар конгруэнциясе теорияләрен тикшерә. Ихтималый машиналар сериясенең прототибын — ихтималый процессор проектын төзи, СССРда беренче булып ихтималый автоматлар төшенчәсен кертә (1964), аны анализлау һәм синтезлауның төп теоретик проблемаларын тикшерә; стохастик булмаган телнең үрнәген төзи һәм стохастик телләрне күзаллау критерийларын тасвирлый. Модельләүче электрон машина идеясен тәкъдим итә. ЭВМда җыр көйләрен язу прог-

раммасын (бергәләп), абстракт матем. тикшеренүләрне автоматлаштыру системасын, ЭВМ б-н диалог алып баручы лингвистик процессор төзи, татар телен компьютер технологияләренә кертүгә актив булышлык күрсәтә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы теории вероятностных автоматов. М., 1985; Вероятностные автоматы и процессоры. М., 1986; Семантический анализ в вопросно-ответных системах. К., 1991 (автордаш).

**БОХАРА́Й** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 43 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Ирнә елгасы буенда. 2002 елда 458 кеше (руслар — 53%, татарлар — 47%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп. Клуб. Китапханә. Санаторий-профилакторий. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Марьино исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство уч-щесе (1896 да ачыла), май язу йорты, алпавыт В.В.Молоствовның ат з-ды эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1248 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында (1929–30) Б.да «Верный путь» к-зы оештырыла, 1958 дә Калинин исем. (1963 тән — Куйбышев) к-з составына керә, 1998 дә «Бохарай» а.х. товарлары җитештерү кооперативы итеп үзгәртелә. 1920 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда. 1920 елдан — ТАССР-ның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Сарман, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 421, 1897 дә — 703, 1913 тә — 659, 1920 дә — 732, 1926 да — 614, 1938 дә — 489, 1949 да — 350, 1958 дә — 373, 1970 тә — 302, 1979 да — 259, 1989 да — 404 кеше.

**БОХАРА́Й НАРАТЛЫГЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге (1989 елдан). Зәй (Бохарай авылыннан көнчыгыштарак) һәм Сарман (Баткак авылыннан төньяктарак) р-нннары терр-ясендә. Мәйданы 444 *га*. Бөгелмә яссы калкулыгының төньяк сөзәклекләрен алып тора. Азнакай һәм Әлмәт урман хуҗалыкларының урман бүлемтекләрен били. Истәлекнең төп өлеше махсус утыртылган төрле яшьтәге нарат урманнарыннан гыйбарәт. Аерым участокларда наратның яше 130 дан артып китә (1860 елларда утыртылган агачлар). Утыртмалар 1 класс бонитетлы, куелыгы 0,6–0,9, кәүсәнең диаметры — 36 *см* га,



Бохарай наратлыгы.

агачларның биеклеге 28 *м* га җитә. Өрәңгеле-каенлы имәнлекләр, өрәңгеле һәм тубылгылы каенлыклар, төрле үләнле юкәлекләр, күрәнчәле усаклыкларның табигый массивлары сакланган. Куаклыкта чикләвек һәм кабар агачы киң таралган. Яхшы сыйфатлы сулы чишмәләре күп. Б.н. терр-ясендә «Ромашкино» шифаханәсе урнашкан.

**әл-БОХАРИ́** Мөхәммәд бине Исмәгыйль әл-Җуфи (810, Бохара ш. — 870 Сәмәрканд ш. янындагы Хартан а.), исламият галиме. Озак еллар дәвамында Гарәп хәлифәлегенең төрле төбәкләренә сәяхәтләр кыла, хәдисләр гыйльмен үзләштерү максатыннан шул заманның күренекле дин галимнәре б-н аралаша. әл-Б. ислам дөньясында киң танылган хәдисләр җыентыгы — күптомлы «Әл Җамигъ әс-Сахих» («Ышанычлы хәдисләр җыелмасы») китабы авторы. Әлеге җыентыкны төзегәндә әл-Б. 1000 дин галиме б-н киңәшә, 600 мең хәдисне тикшерә, 200 мең хәдис язып ала, шулар арасыннан үзе дөреслеккә туры килә дип исәпләгән 7397 хәдисне сайлап ала. Шул заманда ук «Әс-Сахих» *фикъһ* өлкәсендә мөһим кулланма буларак таныла. 1917 елга кадәр әл-Б. туплаган хәдисләр Казанда берничә тапкыр басыла. 1990 еллардан «Әс-Сахих»ның тулы булмаган вариантлары татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.

Х е з м.: Ас-Сахих. М., 1998.

**БОХАРИ́ ТӨРКИЛӘ́Р** (Себер бохарилары) (үзатамалары бохарлык, сарт, үзбәк), Себердә яшәүче бер төркем төрки халыкның җыелма атамасы. 1897 елгы Бөтенроссия халыкларын исәпкә алу вакытында Б.т. 11 мең кеше, 1926 да 15 меңнән артыграк кеше теркәлгән.



Себер татар-бохари хатын-кызының традицион киеме. Реконструкция. Этнограф С.В.Суслова. Рәссам Л.Ф.Фәсхетдинова.

Шуннан соң аерып исәпкә алынмаганнар. Б.т. төркеменә Урта Азия ханлыкларыннан 15–17 йөзләрдә Көнбатыш Себергә күчеп килгән төрки халык вәкилләре варислары керә (үзбәк, уйгыр, казакъ, каракалпак һ.б.). Алар арасында булган аз сандагы таҗиклар да халык санын исәпкә алу вакытында үзләрен Б.т. дип теркәткәннәр. Б.т. хәзерге Омск, Төмән, Томск өлкәләрендә аерым авылларда һәм Төмән, Тубыл, Тара, Томск һ.б. шәһәрләрдә яшиләр. Баштарак Россия хакимияте аларны ирекле рәвештә Россия гражданлыгына кучкән чит ил кешеләре буларак таный һәм кайбер өстенлекләрдән файдалану мөмкинлеген тудыра (ирекле рәвештә күчеп йөрү, Россия империясе чикләрендә пошлина түләмичә сәүдә итү һ.б.). Б.т.нең үз адм. идарә оешмалары булган («команда», волость), алар башында авыл старосталары, волость старшиналары («волость башлыгы») торган. Игенчелек, терлекчелек, сәүдә, һөнәрчелек б-н көн күргәннәр. Күн эшкәртү, келәм-палас туку һ.б. төр әйберләр җитештерү сәнәгатен үзләштергәннәр. Урта Азиядән һәм Кытайдан китерелгән товарларны Себер өлкәләрендә һәм Россиянең башка төбәкләрендә дә сатуны оештырганнар. Себер төбәгендә ислам дине таралуына һәм *Себер татарлары*ның этник культурасы формалашуга йогынтылары бар. 20 йөз урталарыннан бердәм этнотерриториаль Себер татарлары катлавына керәләр.

*Әд.:* А в д е е в И.И., С т р у к о в а И.П. Тобольские и тюменские татары: Ист.-этногр. очерк. Омск, 1937; А л е к с е е в М.П. Сибирь в известиях западно-европейских путешественников и писателей. Иркутск, 1941; З и я е в Х. Узбеки в Сибири. Таш., 1968; И с х а к о в а С.М. О языке сибирских бухарцев // Общественные науки в Узбекистане. 1968. № 5; В а л е е в Ф.Т. Западно-сибирские татары. К., 1980; ш у л у к. Сибирские татары: Культура и быт. К., 1993; Т о м и л о в Н.А. Тюркоязычное население Западно-Сибирской равнины в конце XVI — первой четверти XIX вв. Томск, 1981. *Ф.Т.Вәлиев.*



С.И. Бочаров.

**БОЧАРО́В** Сергей Иванович (22.3.1925, Архангельск өлкәсенең Коношск р-ны Лухтонга бистәсе. — 28.1.1983, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), старшина (1945). Фабрика-завод уч-щесен тәмамлаганнан соң, Казан авиация з-дында эшли. 1942 елның сентябреннән Кызыл Армиядә. Шул ук елның октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 21 нче армиянең 120 нче укчы дивизиясе 538 нче укчы полкының разведка взводы разведчигы. Дон, Көнбатыш, Ленинград һәм Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43), Смоленск сугышларында (1943), Ленинград камалышын өзүдә, Польша һәм Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1945 нең 23 гыйнварында Одер елгасын кичкәндә Грошовице авылы (Польша) янында каһарманлык күрсәтә. Сугыштан соң Мәскәүдә яши һәм эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Золотые звёзды северян. Архангельск, 1971; А н д р е е в С.А. Совершённое ими бессмертно. М., 1976. *В.А.Шагалов.*

**БОЧКО́В** Василий Михайлович (2.3.1909, Украинаның Запорожье өлкәсе, Мелитополь р-ны Янчекрак а. — 30.8.1993, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1976), проф. (1968). 1938 дә Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1959–84 тә каты химик матдәләр технологиясе каф. мөдире.

Хезмәтләре каты җисемнәр һәм органик кристаллар физикасы һәм алдан билгеләнгән үзлекле шартлаткыч матдәләр ясауга карый. Илдә беренче булып шартлаткыч матдәләр кристалларын үстерүнең үзенчәлекле ысулларын һәм алардан төрле вазифалы шартлаткыч составлар әзерләү технологияләрен эшли. Алар халык хуҗалыгында, ш.и. нефть һәм газ чыгаруны интенсивлаштыру максатларында куллану өчен эшләнә. Монография, 250 дән артык фәнни хезмәт авторы, ш.у. 32 уйлап табуга авторлык таныклыгына ия. Бөек Ватан сугышында катнаша. 3 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский химико-технологический институт вчера, сегодня, завтра. К., 1990. Ч. 2; Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БОЧКО́В** Николай Дмитриевич (18.1.1917, Түбән Новгород губ., Түбән Новгород өлкәсенең Заветлужск р-ны Зур Алан а. — 11.7.1986, Яшел Үзән ш.), инженер-конструктор, Ленин бүләге лауреаты (1965). 1940 елда Ленинград корабльләр төзү ин-тын тәмамлый, акад. А.Н.Крылов исем. Үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында (Ленинград) эшли. 1945–49 да Горький Үзәк КБ-51 дә, 1949 елдан Яшел Үзән проект КБнда: механика бүлеге башлыгы, корабльләрнең механик җайланмалары, системалары һәм төзелешләре буенча баш конструктор урынбасары. Су асты көймәләренә каршы корабльләр өчен югары нәтиҗәле энергетик җайланмалар һәм суднолар төзелешенең башка кайбер әйберләрен эшләүдә катнаша. Ленин бүләге махсус машиналар төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Уйлап табуга караган 12 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БОЯ́РСКИЙ** Пётр Михайлович (4.6.1870, Полтава губ., Лубенск өязе Тимки а. — 21.4.1944, Хорватия, Загреб ш.), дәүләт эшлеклесе, статский советник (1912). Петербург ун-тын тәмамлый (1893). 1893–94 елларда Юстиция министрлыгында, 1894–98 дә Сенатның җинаять-кассация департаментында хезмәт итә. 1898–1900 дә Чернигов округ мәхкәмәсе прокуроры урынбасары. 1900–04 тә Лубенск өязенең земство башлыгы, 1904–06 да Полтава губернасында күченеп килүчеләр һәм җир эшләре идарәсе әгъзасы. 1906–12 дә Саратовта вице-губернатор, 1912–13 тә — Гродно, 1913–17 дә Казан губерналары губернаторы. Ул губернатор булганда 1914 тә Казан кулланучылар җәмгыяте, 1915 тә Казан хәрби-сәнәгать ком-ты оештырыла. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Казан губернасында ир-атларны армиягә мобилизацияләү, фронтны азык-төлек һәм фураж б-н тәэмин итү, эвакуацияләнүчеләрне һәм санитар частьләрне урнаштыру, хәрбиләрнең гаиләләренә ярдәм оештыру, бәяләрне көйләү б-н шөгыльләнә, товарларның кыйммәтләнүенә каршы көрәшә. 1914 елдан авыру һәм яралы сугышчыларга ярдәм итү буенча Казан ком-ты, 1917 дә Казан очучылар җәмгыяте рәисе. Казанда Инвалидлар йортын төзүгә (1915), «Камско-Волжская речь» г-тасын яңадан чыгара башлауга (1916) булышлык итә. Казан губернасы гыйльми архив комиссиясен төзүгә (1916) ярдәм күрсәтә. Февр. рев-циясеннән соң вазифаларыннан читләштерелә. 1917–18 елларда Пятигорск, аннан соң Полтава шәһәрләрендә яши. Новороссийскида Россия Кызыл Хач җәмгыятенең баш вәкиле ярдәмчесе була. 1920 елдан Югославиядә эмиграциядә яши: 1921–36 да Загреб шәһәрендә Россия Кызыл Хач җәмгыяте рәисе; бер үк вакытта 1930–35 тә Загреб шәһәрендәге Рус иҗтимагый оешмалары берләшмәсе рәисе.

*Е.Б.Долгов.*



П.М. Боярский.

**БӨГӘЛЧӘННӘ́Р**, ике канатлы бөҗәкләр отрядыннан өч семьялык: ашказаны Б. (Gasterophilidae), борын-бугаз Б. (Oestridae), тире асты Б. (Hypodermaticae). 100 гә якын төре билгеле. Гәүдәсе төкләр б-н капланган, кайберләре төксез дә була. Җитлеккән Б.нең авыз органнары үсеш алмаган, һәм алар тукланмый. Озак яшәмиләр. Күп төрләренең личинкалары — кеше һәм имезүчеләрнең эндопаразитлары. Татарстан терр-ясендә 3 төре киң таралган. Ашказаны ат бөгәлчәне (G. intestinalis) — гәүдәсенең озынлыгы 12–15 *мм*; йомыркасын терлекнең иреннәре б-н кагыла торган урыннарына сала. Личинкалар турыдан-туры яки азык б-н ашказанына үтә, җитлеккәнче шунда кала; тышкы якка экскрементлар б-н чыга. Борын-бугаз сарык бөгәлчәне (O. ovis) — гәүдәсенең озынлыгы 10–12 *мм*; сарыкларда һәм кәҗәләрдә паразитлык итә. Терелә́й тудыручы ана затлар личинкаларын терлекнең борын тишегенә сиптерә. Личинкалар баш эченә (маңгай куышлыгы, йоткылык өстенә) үтеп керә, аларның паразитлык итүе терлекнең бик нык арыклануына китерә. Тире асты үгез бөгәлчәне (H. bovis) — гәүдәсенең озынлыгы 12–14 *мм*; мөгезле эре терлектә паразитлык итә. Йомыркасын терлекнең төкләренә беркетә. Личинкалар хайван организмына тире капламы аша керә һәм анда үсә. Йон кою алдыннан, икенче стадиядә, терлек аркасындагы җитлеккән личинкалар, тишек тишеп, тире астыннан тышка чыгалар һәм курчакка әйләнү өчен җир астына төшәләр.


**БӨГЕЛДЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Зәйнең сул кушылдыгы (Кама елгасы бассейны). Озынлыгы 8,4 *км*, бассейнының мәйданы 31 *км*$^2$. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Перцовка авылының көнбатыш читендә, тамагы Икенче Бөгелде авылыннан 1,9 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 64 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 48%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,25 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 75 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,016 *м*$^3$*/с*. Суы бик каты (язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Елга Зәй автоагрегат з-дының агынты суларын кабул итүче буларак файдаланыла (елга 6 млн. *м*$^3$ га кадәр).

**БӨГЕЛМӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Бөгелмә Зәе елгасының сул кушылдыгы (Дала Зәе елгасы бассейны). Озынлыгы 16,4 *км*, бассейнының мәйданы 56,3 *км*$^2$. Бөгелмә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Бөгелмә шәһәренең көнбатыш читендә, тамагы Кече Бөгелмә авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 332 *м*, тамагыныкы — 213 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 32%. Б. елгасының 1,7 дән алып 4,8 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1,1–3 *л/с км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 147 *мм*, ташу агымы катламы 111 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,075 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000–2000 *мг/л* га кадәр. Елга Бөгелмә шәһәренең агынты сулары б-н пычранган. Шәһәрнең Б. бассейнында урнашкан пр-тиеләре җир асты чыганакларыннан бер елга 3 млн. *м*$^3$ чамасы су алалар. Б. бассейнында 0,1 млн. *м*$^3$ күләмле буа бар. Су ресурслары сәнәгать һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.


**БӨГЕЛМӘ́**, республика карамагындагы шәһәр, Бөгелмә р-ны үзәге. ТРның көньяк-көнчыгышында, Казаннан 333 *км* ераклыкта, Бөгелмә — Бәләбәй калкулыгы битендә, Бөгелмә Зәе елгасы чыганагы буенда. Ульянов — Уфа тимер юлындагы станция. Аэропорт. Автомобиль юллары үзәге (Казан — Оренбург

һ.б.). Мәйданы — 26 *км*². Халкы — 2006 елда 91,6 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 59,5%, татарлар — 32,2%, мордвалар — 2,3%, чуашлар — 2,1%). Б. — ТРда эре нефть сәнәгате үзәге. Нефть сәнәгатенең фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-ты, «Татнефтегеофизика» җитештерү берләшмәсе, механика, «Нефтеавтоматика», электротехника, ремонт-механика, тимер-бетон, кирпеч, фарфор з-длары; мебель ф-касы; төзелеш конструкцияләре комб-ты. Җиңел сәнәгать (трикотаж, аяк киемнәре, тегү пр-тиеләре), азык-төлек сәнәгате (сыра, ликёр-аракы, икмәк з-длары, сөт, ит, ашлык продуктлары комб-тлары) нык үскән. Һөнәр-пед. көллияте, машина төзү техникумы, мед. һәм пед. уч-щеләре, 18 гомуми белем бирү мәктәбе. Рус драма театры, Яшьләр сарае, район мәдәнияты йорты. Балалар музыка һәм сәнгать мәктәбе, 10 китапханә. Төбәк тарихын өйрәнү, чех язучысы Я.*Гашек* музейлары. Б. 1736 елдан татар авылы буларак мәгълүм. 1741–45 дә авыл урынында Бөгелмә бистәсе барлыкка килә, ясаклы крәстияннәр, сөргендәге һәм отставкадагы солдатлар килеп урнаша. Земство конторасы оештырыла һәм төбәкнең башка бистәләре аның карамагына күчә. 1773–75 еллардагы крәстияннәр кузгалышы чорында Бөгелмә бистәсендә хөкүмәт гаскәрләре башкомандующие ген.-аншеф А.И.Бибиков штаб-квартирасы урнаша. 1781 дә Б. Уфа наместниклыгының өяз шәһәре статусын ала һәм хәзергечә атала башлый, 1796 да — Оренбург, 1850 дә Самара губернасы составына керә. 19 йөз башыннан регуляр план буенча төзелә. Географик торышы уңайлы, шәһәр аша Уфадан һәм Оренбургтан Казанга илтүче олы юллар узу сәбәпле, Б. эре сәүдә үзәгенә әверелә. 19 йөз ахырында һәр ел саен 3 ярминкә үткәрелә, шулардан 14–26 сентябрьдә уздырыла торган Воздвижение ярминкәсе Урал буенда эшләп килүче башка ярминкәләр арасында акча әйләнеше буенча иң эреләрдән санала. Ярминкәләрдә атлар, мөгезле эре терлек, эшкәртелмәгән тире, Бохара товарлары, чәй, дөя йонынннан тукылган постау, күннән ясалган әйберләр һ.б. сатыла. 1890 да Б.дә 5 чиркәү (ш.и. 2 се — Казан Богородица хатын-кызлар монастыре каршында), 1323 бина, 2 сыйныфлы хатын-кызлар, шәһәр һәм приход уч-щеләре, шәһәр җәмәгать банкы, җәмәгать бакчасы, земство китапханәсе, фотография, почта-телеграф конторасы, почта һәм земство станциясе, 37 кечкенә завод (13 кирпеч сугу, 12 чүлмәк ясау, 6 май язу, 3 аракы, 1 сыра кайнату, күн, сарык тиресе эшкәртү з-длары) була. 1911 дә шәһәр аша тимер юл уздырыла. 1920 елга кадәр — Самара губернасының Бөгелмә өязе үзәге, 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә р-ны үзәге. 1953 нең 21 февраленнән 1953 нең 30 апреленә кадәр — Бөгелмә өлкәсе үзәге. 1974 тә «Ленгипрогор» ин-ты (Ленинград) Б.нең беренче ген. планын эшли. 1960–90 елларда, «ТатНИПИнефть» ин-ты бинасы (1963), Техника йорты (1967), «Яшьлек» спорт комплексы (1975), «ВНИИнефть» ин-ты бинасы (1979), «Яшьләр сарае» (1994), «Бөгелмә» кунакханәсе (1981), картлар йорты (1997) һ.б. төзелә. Шәһәрнең үзәк өлешендә 19–20 йөзләр тарихи-мәдәни мирасын саклап калу программасы тормышка ашырыла. Архит-ра истәлекләре: реальный уч-ще бинасы (19 йөзнең 2 нче яртысы), сәүдәгәр Ш.Л.Хәкимов төзеткән биналар комплексы (20 йөз башы), Литвинов, Латыйпов, Елачич (19 йөзнең 2 нче яртысы), Климов (20 йөз башы) йортлары һ.б. Халык саны: 1897 дә — 7,6 мең, 1926 да — 14,2 мең, 1938 дә — 24,5 мең, 1959 да — 61 мең, 1970 тә — 72 мең, 1979 да — 80,2 мең, 1989 да — 89,6 мең кеше.

*Әд.:* Наш город Бугульма: Фотоальбом. Бугульма, 1970; Город счастливой судьбы. 200 лет Бугульме: Исторический очерк. К., 1981.









Бөгелмә шәһәре. 1. Мәчет. 19 йөз ахыры; 2. Никола соборы. 19 йөз ахыры; 3. Сәүдәгәр Ш.Л.Хәкимов йорты. 20 йөз башы; 4. «Яшьләр сарае». 1990 еллар башы.

Бөгелмә шәһәре. Торак микрорайоннар. 1980–90 еллар.



**БӨГЕЛМӘ́ АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**. Бөгелмә р-нының көньяк-көнчыгыш һәм Баулы р-нының көнбатыш өлешләрендә урнашкан. Мәйданы 45,9 мең *га*, ш.и. урманнар — 13,6 мең *га*, күлләр — 200 *га*. Тыюлык терр-ясеннән Дим, Кандыз, Сулы елгалары ага. 1982 елда кәҗәболан һәм сөркә-байбакларны саклауны көчәйтү максатыннан оештырыла. Поши, кабан дуңгызы, ак куян, үр куяны, селәүсен, суер, көртлек, соры көртлек һ.б. саклана.

**БӨГЕЛМӘ́ ЗӘЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Дала Зәенең уң кушылдыгы. Озынлыгы 52 *км*, бассейнының мәйданы 753 *км*². Елга башы Ефановка авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Бөгелмә р-нының Карабаш штп янында. Урта агым-

да — Түбән Ямаш елгасы тамагыннан Ямаш елгасы тамагына кадәр — Б.З. Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башының абс. биеклеге 305 *м*, тамагыныкы — 117 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 22%. Б.З. елгасының 1,2 дән алып 20,6 *км* га кадәр озынлыктагы 23 кушылдыгы бар, иң зурлары: Бөгелмә (16,4 *км*) — сул кушылдык, Дырды-Гыз (11,7 *км*), Ямаш (18,8 *км*) һәм Түбән Ямаш (20,6 *км*) — уң кушылдыклары. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,22 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Карабаш авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәлеше 2,5 *м* (макс. 2,8 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 130 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ун көнендә туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 75 *см* га җитә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,769 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 2000 *мг/л* га кадәр. Б.З. бассейнында — Карабаш сусаклагычы, ш.у. гомуми күләме 6,5 млн. *м*³ булган 7 буа бар. Су ресурслары сәнәгать һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**«БӨГЕЛМӘ́» ИТ КОМБИНАТЫ́**, азык-төлек сәнәгате пр-тиесе. Бөгелмә шәһәрендә урнашкан; 98 кеше эшли (2005). Терлек һәм кошларны суюга әзерләү һәм сую эше башкарыла, ит, казылык, ярымфабрикатлар, терлек майлары, терлек азыгы җитештерелә. 1929 елда терлек сую бинасы буларак нигез салына. 1932 елдан — Бөгелмә ит комбинаты. 1940 елда казылык цехы һәм суыткыч төзелә. Елына 2800 *т* ит һәм 70 *т* казылык әйберләре эшләп чыгарыла. 1960 елларда Б.и.к. киңәйтелә: бер үк вакытта 4950 *т* продукция саклый ала торган суыткычлар, сую өчен конвейер линиясе булган итне беренчел эшкәртү цехы, ит әвәләү линиясе һәм казылык эшләп чыгару өчен махсус җайланмалары булган казылык цехы, механикалаштырылган агымлы линияле кош итен эшкәртү цехы, пар казаннары бинасы төзелә. 1992 елда пилмән ясау һәм төрү линияләре, ш.у. йомырка меланжын эшләп чыгару линияләре корыла. 1990 елларда пр-тие яңартыла, 1996 елда «Б.»и.к. АҖ итеп үзгәртелә. 2005 елда 381 *т* ит һәм субпродуктлар, 345 *т* казылык, 268 *т* ярымфабрикатлар җитештерелә. Б.и.к. 1960–80 елларда Куба, Италия, Франция, Германиягә сары май, субпродуктлар, дуңгыз тиресе, төрле эшләнмәләр өчен сөяк чыгара. 1970 елларда комб-тта сөяк һәм мөгездән сувенирлар ясау цехы эшли. Пр-тие җитәкчеләре: И.Ф.Афанасьев (1929–33), С.К.Пахомов (1945–51), И.П.Агапов (1951–53), А.Н.Бибарцев (1953–57), В.С.Заглядов (1959–64), Ф.М.Гусев (1964–70), Ю.П.Коченьков (1971–84), Е.Г.Уланов (1984–96), 1999 дан — З.Ф.Гаделшин (1999–2000), В.А.Ганиева (2004 тән).

*Г.Я.Мәүлетова.*

**БӨГЕЛМӘ́ КАНТОНЫ́**, 1920–30 елларда ТАССРда адм.-тер. бүленеш берәмлеге. Респ-каның көньяк-көнчыгыш чигендә урнашкан. Үзәге — Бөгелмә шәһәре. Самара губернасының Бөгелмә өязенә кергән 26 волость җирлегендә оештырыла. Мәйданы 8769 *км*² (1926). Халкы 257608 кеше, ш.и. татарлар 56,2%, руслар 32,9%, мордвалар 4,4%, чуашлар 3,9% (1926). Шәһәрдә яшәүчеләр — 14302, авылда яшәүчеләр 243306 кеше. Халкының гомуми тыгызлыгы 1 *км*²га 29,4 кеше, авыл җирендә 27,7 кеше. 1926 елда 693 авыл торак пункты була, алар 14 волостька бүленә: Азнакай, Әлки, Әлмәт, Баулы, Бәйрәкә, Бөгелмә, Габдрахман, Михайловка, Попов, Салих, Тымытык, Чирмешән, Чыршылы, Шөгер (1929). Металл эшкәртү, азык-төлек җитештерү сәнәгате була. 1926 да Б.к.нда сәнәгатьтә һәм һөнәрчелектә 3174 эшләүче теркәлгән. Халыкның күпчелеге а.х. тармагында эшли — 1928 дә 52907 крәстиян хуҗалыгы була. 1925 тә 100 а.х. кооперативы исәпләнә. Сөрү җирләре мәйданы 414 мең *га* чамасы (1928). 1916 да Б.к. биләмәсендә арыш — 124162, солы — 40077, карабодай — 36127, тары — 21508, борай — 17415, бодай — 8095, бәрәңге — 1342 *га* да һәм беркадәр техник культуралар игелгән. 552168 баш мал асралган, ш.и. 133083 баш мөгезле эре терлек, 76154 — ат, 314236 — сарык, 9886 — кәҗә, 18809 баш дуңгыз. 1927 дә 219 мәктәп, ш.и. 210 башлангыч мәктәп эшли. 1930 да ТАССРның районнарга бүлү чорында Б.к. Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Тымытык, Шөгер р-ннарына бүленә.




Чыг.: Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928–29. Т. 3, 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике. К., 1928–29; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БӨГЕЛМӘ́ ЛИКЁР-АРАКЫ́ ЗАВОДЫ́**, азык-төлек сәнәгате предприятиесе; «Татспиртпром» АҖ филиалы. Бөгелмә шәһәрендә урнашкан. 203 кеше эшли (2005). Завод составында чистарту-юу-бүлеп тутыру, ликёр ясау, савытлар әзерләү, продукция җибәрү цехлары бар. Елына 1500 мең дал аракы, 70 мең дал ликёр-аракы әйберләре җитештерә (2005). Завод ассортиментында — якынча 8 исемдәге ликёр-аракы әйберләре (аракы, төнәтмә, бәлзәм төрләре). 1904 елда Казан шәраб склады буларак нигез салына. Гражданнар сугышы елларында продукция эшләп чыгару туктатыла, 1923 елда яңадан эшли башлый.

1950–60 елларда завод үзгәртеп корыла: җитештерү мәйданнары киңәйтелә, куәте үстерелә, продукция әзерләү һәм аны агызып тутыру җиһазлары куела. 1980 еллар башында яңа автоматлаштырылган агызып тутыру линиясе, штамплау-бөкеләү автоматлары, этикетка ябыштыру, шешә юу машиналары һ.б. сафка кертелә. 1997 дә Италия фирмаларының технол. җиһазлары куела. 2005 тә агызып тутыру цехы һәм пыяла савытлар әзерләү бүлеге файдалануга тапшырыла. Продукциянең күләме 1959 елда — 421 мең, 1975 тә — 1392 мең, 1998 дә 930,6 мең дал тәшкил итә. Эчемлекләр борынгы рецептлар һәм завод белгечләренең Азык биотехнологиясе фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү) б-н берлектә эшләгән рецептлары буенча әзерләнә. Заводның үз артезиан скважинасы эшли, молекуляр дәрәҗәдә күп этаплы су чистартуның комплекслы системасы гамәлгә кертелә. ISO 9001:2000 халыкара стандарты таләпләренә туры китереп сертификацияләнгән сыйфат менеджмент системасы эшли. 1996–2006 да завод продукциясе халыкара һәм бөтенроссия күргәзмә конкурсларында алтын, көмеш, бронза медальләргә лаек була («Бугульминская», «Восток-Люкс», «Встречи без галстука» аракылары, «Доктор Перцефф» төнәтмәсе һ.б., «Бөгелмә» бәлзәме). Завод алкогольле продукция җитештерү буенча 1 нче халыкара конгресс (Нью-Йорк, 1996) һәм «Россия регионнары-98» күргәз-



Бөгелмә ликёр-аракы з-ды. Администрация бинасы.

мә-ярминкә дипломнары б-н бүләкләнә. Пр-тиенең төрле еллардагы җитәкчеләре: П.И.Январёв (1970–85), В.Н.Локтев (1985–99), Ф.Ю.Гатин (1999–2004), М.В.Котельников (2004 тән).

*Г.Я.Мәүлетова.*

**БӨГЕЛМӘ́ МАШИНАЛА́Р ТӨЗҮ ТЕ́ХНИКУМЫ**, 1989 елда нефть сәнәгате өчен җиһазлар җитештерү һәм ремонтлау пр-тиләренә кадрлар әзерләү өчен оештырыла. 2005 тә белгечлекләр: машиналар төзү технологиясе, сәнәгать җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, нефть сәнәгатендә электр һәм электромеханика җиһазларыннан файдалану һәм ремонтлау, хисаплау техникасын һәм автоматлаштырылган системаларны программалар б-н тәэмин итү, машиналар төзү икътисады, бухгалтерлык исәбе һәм контроль. Көндезге бүлектә якынча 650, кичке бүлектә 80, читтән торып уку бүлегендә 180 студент укый. Укытучылар коллективында 47 кеше эшли. Эшләү елларында 1200 дән артык белгеч әзерләнгән.

**БӨГЕЛМӘ́ МЕДИЦИ́НА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1935 елда шәфкать туташлары мәктәбе буларак ачыла, 1939 елдан фельдшер-акушерлык мәктәбе, 1952 дән хәзерге исемдә. 2005 елда белгечлекләр: дәвалау, шәфкать туташлары, акушерлык эше. Көндезге бүлектә якынча 291 студент укый. Пед. коллективта 68 кеше эшли. Эшләү елларында 9 меңнән артык белгеч әзерләнгән.

**БӨГЕЛМӘ́ МЕХАНИ́КА ЗАВОДЫ́**, нефть-газ чыгару һәм эшкәртү, нефть-химия һәм энергетика машиналары төзелеше пр-тиесе. Бөгелмә шәһәрендә урнашкан. Предприятие 41 *га* мәйдан били. 2100 кеше эшли (2005). 1954 елда төзелеш җайланмаларын ремонтлау буенча Бөгелмә механика з-ды буларак нигез салына. 1956 дан хәзерге исемдә. 1976–92 дә «Бөгелмәнефтемаш», «Казанкомпрессормаш» берләшмәләре составында була. 1992 дән «Татнефть» АҖ составында. 1957–60 елларда тракторлар өчен асылмалы җайланмалар, нефть скважиналарын ремонтлаганда торбаларны күтәрү-төшерү өчен күчерелмә мачталар, нефть скважиналарын бораулау өчен ОН-3А, ОН-9–13 маркалы күчәрле насослар, бораулау җайланмалары өчен запас частьләр эшләп чыгара. 1960 тан нефть аппаратурасы (җылылык алмашу, һава б-н суыту аппаратлары, газ сепараторлары, һава җыю җайланмалары, суыткычлар, конденсаторлар һ.б.), нефть промыселы җиһазлары (төркемләп үлчәү җайланмалары, пар генераторлары, штангалы скважина насосларының чылбырлы күчергечләре һ.б.), сыешлык җиһазлары (газ һәм сыеклык өчен цилиндрик сыешлык аппаратлары, җир асты сыешлыклары, сыеклык аеру аппаратлары һ.б.), торбаүткәргеч арматура (шарлы кран, басым көйләгеч, торбаүткәргеч детальләре) җитештерү буенча специальләшә. Соңгы елларда эчке һәм тышкы яктан коррозиягә каршы өслек б-н капланган торбалар, эчке яктан полимер б-н капланган насос-компрессор торбалар, эчке яктан полимер б-н капланган эретеп ябыштырылган корыч торбаүткәргеч детальләр эшләп чыгару үзләштерелә. Б. м.з. җитештергән продукциянең төп кулланучылары — Россиянең үзәк өлешендә, Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Себердә, якын чит илләрдә урнашкан нефть-газ чыгару тармагы пр-тиеләре, нефть-газ эшкәртү заводлары. Санаторий-профилакторие, турбазасы, спорт комплексы бар. Завод җитәкчеләре арасында: М.А.Антипов (1956–57), В.И.Розенберг (1957–60), Л.И.Лебский (1961–62), М.И.Новиков (1963–87), Р.Ш.Салихов (1987–88), Ю.М.Ильин (1988–2005), С.А.Мартынов (2005 тән).


*Г.Я.Мәүлетова.*

**БӨГЕЛМӘ́ ӨЛКӘСЕ́**, ТАССРда административ-территориаль бүленеш берәмлеге буларак, 1953 елның 21 февралендә СССР ЮС Президиумы Указы б-н оештырыла. Үзәге — Бөгелмә шәһәре. Аның биләмәсенә Азнакай, Актаныш, Акташ, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Ворошилов, Калинин, Красный Бор, Матвеев, Минзәлә, Мөслим, Сарман, Тымытык, Шөгер, Ютазы, Яңа Писмән р-ннары керә. 1953 елның 30 апрелендә бетерелә.





Бөгелмә механика з-ды продукциясе. 1. Каплавыч-торбалы җылылык алмаштыргычлар; 2. Төркемле үлчәү җайланмасы.




**БӨГЕЛМӘ́ ӨЯЗЕ́**, 1850–1920 елларда Самара губернасында адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Үзәге — Бөгелмә шәһәре. Б.ө. терр-ясе баштарак Казан губернасына буйсына; 1735 елдан яңа оешкан Оренбург губернасында Богырыслан, Бозаулык һәм Ставрополь өязләре б-н аерым бер провинция тәшкил итә. 1735–70 елларда Бөгелмә бистәсенә Зәй, Иске һәм Яңа Чишмә, Тиинск кальгаларындагы *игенче солдатлар* күчереп утыртыла; 1741–45 тә ныгытмалар төзелә; рус һәм башка милләт вәкилләре яшәгән волостьлар б-н идарә итү өчен земство конторасы оештырыла. 1744 елда Минзәлә өязе б-н бергә Бөгелмә бистәсе Сенатка буйсындырыла. 1781 елның 23 декабрендә бистәгә өяз шәһәре статусы бирелә һәм ул биләмәсендәге җирләр б-н бергә Уфа наместниклыгының Уфа өлкәсенә беркетелә. 1796 елның 31 декабрендә Б.ө. биләмәсе Оренбург губернасына, 1850 нең 6 декабреннән Самара губернасына күчерелә. Б.ө. төньякта һәм төньяк-көнбатышта — Казан губернасы Чистай өязе һәм Уфа губернасы Минзәлә өязе б-н, көнбатышта — Чистай өязе, көньякта Самара губернасы Богырыслан өязе, көнчыгышта Уфа губернасы Бәләбәй өязе б-н чиктәш була. Б.ө. аша аккан елгалар: Дала һәм Урман Зәе, Чишмә, Ык (кушылдыклары Дим, Кандыз, Эстәрле), Сок, Кондырча, Богырыслан, Камышлы, Олы Чирмешән һ.б. 19 йөз ахырында гомуми мәйданы 10,8 мең кв. чакрым (губерна мәйданының 8,5% ы). Халкы 368,9 мең кеше, ш.и. татарлар 35,3%, руслар 31,9%, мордвалар 12,5%, башкортлар 9,9%, чуашлар 8,5% (1908). 4 станга, 38 волостька бүленә. 1 нче станга Азнакай, Әлмәт, Әлки, Каратай, Микулин, Минзәләбаш, Тымытык, Эстәрлетамак, Яңа Нәдер волостьлары керә. Үзәге — Әлмәт авылы. 2 нче стан үзәге — Чирмешән кальгасы, аңа Варварино, Костюнкино, Мордва Афонькәсе, Мордва Ивановкасы, Мордва Карамалысы, Тимәш, Түбән Чыршылы, Чатырлы, Шонталы, Югары Карамалы волостьлары керә. 3 нче стан үзәге — Рыково авылы, аңа Александров-

ка, Баулы, Димескәй, Ивановка, Керәшле, Салих, Спас, Сумароков, Чәкән волостьлары керә. 4 нче стан үзәге — Борискино авылы, аңа Әбдекәй, Богоявленск, Борискино, Борисоглебский, Добрино, Елизаветинка, Кузайкино, Спиридоновка, Сходнево, Яңа Писмән волостьлары керә. Б.ө. халкы, нигездә, игенчелек (арыш, солы, арпа, бодай, карабодай игелә), терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. Һөнәрчелектә мунчала әзерләү, бау ишү, арба-чана, сандык һ.б. төр агач әйберләр, балчык савыт-саба ясау киң тарала. Халыкның бер өлеше төзелеш кирәгенә таш чыгара, йон тетә, киез итек баса һәм киез әвәли, балык тота. Читкә китеп эшләүчеләр, үз ат-олавы б-н көнлекчелектә йөреп көн күрүчеләр дә була. Б.ө.ндә 19 йөздә А.Ф.Елачичның 3 спирт, 2 шәраб ясау һәм сыра кайнату з-длары, Д.В.Давыдовның сабын кайнату, А.Фёдоровның күн з-длары, бертуган Мишкиннарның постау туку ф-касы б-н сәүдә йорты һәм 2 ат з-ды эшли. Бөгелмәдә, Әлмәт, Керкәле, Түбән Шалты, Елизаветинка, Петровка, Иске Куак, Чәкән, Чирмешән авылларында ярминкәләр уздырыла. Өяздән ашлык, йон, дуңгыз мае, киез, ат, үгез һәм сарыклар читкә сатуга чыгарыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында Б.ө.ндә 10 земство, 18 чиркәү мәктәбе, мәчетле һәрбер татар авылында мәктәп, эрерәкләрендә мәдрәсәләр эшли (барлыгы 117 уку йорты). Бөгелмәдәге 3 өяз уч-щесендә 80 ләп укучы, 2 сыйныфлы кызлар мәктәбендә 60–70, ир балалар чиркәү мәктәбендә 12 бала белем ала. 20 йөз башында өяздә 45 мәктәп (ш.и. 27 татар мәктәбе) була. Берничә хәйрия җәмгыяте (1880 елларда оешкан Изге Николай исем., Бәйрәкә крәстияннәре җәмгыяте һ.б.) эшли, 1892 елда балалар ятимханәсе ачыла. Б.ө. 1920 ел урталарында бетерелә, волостьларының күпчелек өлеше *Бөгелмә кантонына* беркетелә.

*Д.Г.Мостафина.*

**БӨГЕЛМӘ́ ПЕДАГО́ГИЯ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**. 1984 елда оештырыла. Эшләү елларында 4 меңнән артык белгеч әзерләнгән. 2005 тә 77 укытучы эшли, көндезге бүлектә 482 студент, читтән торып укыту бүлегендә 135 студент укый; белгечлекләр — башлангыч сыйныф укытучылары (татар һәм рус мәктәпләрендә), мәктәпкәчә белем бирү (татар һәм рус мәктәпкәчә оешмаларында); өстәмә белгечлекләр — татар теле һәм әдәбияты, инглиз теле укытучылары. 1992–96 елларда Әлмәт шәһәрендә ф-лы эшли.

**БӨГЕЛМӘ́ РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк-көнчыгышында урнашкан, Самара һәм Оренбург өлкәләре б-н чиктәш. Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1408,6 *км*². 17 авыл һәм 1 шәһәр җирлеген (Карабаш штп), 63 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Бөгелмә шәһәре. Халкы 2006 елда 22,1 мең кеше (район үзәгендәге халык санын кертмичә) (2002 елгы халык саны буенча татарлар 49,2%, руслар 38,6%, чуашлар 5,5%). Шәһәр халкы — 5,0 мең, авылларда 17,1 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 16 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 елга кадәр терр-ясе Самара губернасының




Бөгелмә өязенә, 1920–30 да ТАССРның Бөгелмә кантонына керә. Оештырылган вакытта 1 шәһәр советы, 43 авыл советы, 213 торак пункт исәпләнә, аларда 61217 кеше (ш.и. руслар 55277, татарлар 3609, башка халыклар 2331 кеше) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә мәртәбә үзгәрә. 1940 елга аның мәйданы — 1290 *км*², халкы — 50,8 мең кеше, 19 авыл советы, 108 торак пункт исәпләнә. 1960 та 1459,4 *км*² мәйдан били, аңа 1 посёлок советы (шәһәр тибындагы Карабаш пос.), 15 авыл советы, 117 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 елның 1 февралендә Б.р.на Баулы һәм Ютазы р-ннары кушыла. Районның мәйданы — 3924 *км*², халкы — 71,6 мең кеше исәпләнә, ул 39 авыл советын, 258 торак пунктны берләштерә. ТАССРда адм. бүленешнең үзгәрүе нәтиҗәсендә, 1965 нең 12 гыйнварында Б.р. терр-ясе 1419 *км*² га кала, халкы — 28,2 мең кеше тәшкил итә, аңа 15 авыл советы, 103 торак пункт керә. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль район дип үзгәртелә. Б.р. республиканың иң югары өлешендә урнашкан (абс. күрсәткеч — 376 *м*). Терр-ясе буйлап Дала Зәе, аның кушылдыгы Зәй (Карабаш сусаклагычы), Дим елгалары ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, карбонатлы һәм типик кара туфраклы. Нефть, төрле балчык ятмалары бар. Терр-ясенең 18,7% ы урманнар б-н капланган. Саклаулы табигать объектлары: Дим, Дала Зәе, Ютазы елгалары; *Спас чишмәләре*, *Петровка наратлары*, *Карабаш тавы*, *Татар Димескәе аланы*, *Яңа Александровка сөзәклеге* табигать истәлекләре; *Адонис урманы* табигать тыюлыгы, Казанка ботаника һәм Бөгелмә аучылык тыюлыклары бар. Район терр-ясендә, нигездә, бронза гасырына караган 15 археол. истәлек билгеле. А.х. җирләре 100,9 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр 72,3 мең *га* тәшкил итә (2005). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, карабодай игелә; яшелчә үстерелә. Ит-сөт терлекчелеге, дуңгызчылык, кошчылык, сарык үрчетү, җәнлекчелек үсеш алган. 2006 елга районда 11 а.х. пр-тиесе: 1 дәүләт унитар пр-тиесе, 3 крәстиян-фермер, 40 кече фермер хуҗалыгы бар. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә һәм шәһәр тибындагы Карабаш посёлогында урнашкан. Нефть чыгарыла. Урман хуҗалыгы. Б.р. терр-ясеннән Ульянов — Уфа тимер юлы, Казан — Оренбург, Самара — Чиләбе, Бөгелмә — Азнакай һ.б. автомобиль юллары уза. Районда (Бөгелмә шәһәрен дә кертеп) 52 гомуми белем бирү мәктәбе (2005/06 уку елында 13469 укучы), ш.и. 11 башлангыч, 2 тулы булмаган урта, 35 урта мәктәп; 3 коррекция мәктәбе, 9 югары уку йорты филиалы, 3 башлангыч һәм 5 урта һөнәри уку йорты, 1 сынлы сәнгать, 1 сәнгать мәктәбе, 24 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 37 клуб, 30 китапханә, 1121 урынлы 7 хастаханә эшли. 3 музей бар. Рус һәм татар телләрендә «Бугульминская газета», «Бөгелмә авазы» район г-талары нәшер ителә.

**БӨГЕЛМӘ́ РУС ДРА́МА ТЕА́ТРЫ**, 1898 елда Бөгелмә шәһәрендә салынган Халык йортыннан башлангыч ала. Аның б-н составына земство вәкилләре дә кергән театр комиссиясе җитәкчелек итә. Халык йортының үз костюмнары, декорацияләре, китапханәсе була, анда даими рәвештә җирле һәвәскәр һәм гастрольгә килгән проф. драма һәм опера труппаларының спектакльләре күрсәтелә, әдәби-муз. кичәләр, балалар өчен Яңа ел чыршысы бәйрәмнәре һ.б. чаралар үткәрелә. Һәвәскәр театр түгәрәге 1930 елларга кадәр эшли, 1935 тә аның нигезендә колхоз-совхоз театры оештырыла (директоры — Е.М.Волков, актёрлар арасында Н.Адлеровский, А.Богатырёв, В.В.Ермолаев, Э.К.Асланова, В.Хазова була). ТАССР Халык комис-тының театр бүлеге боерыгы б-н театрга проф. актёрлар һәм режиссёрлар җибәрелә (М.В.Аренский, В.В.Чарский һ.б.). Театрның сугышка кадәрге репертуарында В.П.Катаевның «Чәчәкләр юлы» («Дорога цветов»), В.В.Шкваркинның «Чит кеше баласы» («Чужой ребёнок»), А.Е.Корнейчукның «Платон Кречет», В.М.Киршонның «Какшамас көч» («Чудесный сплав»), А.Н.Островскийның «Агай-эне, ак мыек» («Свои люди — сочтёмся!»), «Кичеккән мәхәббәт» («Поздняя любовь») әсәрләре була. 1942–44 елларда Н.А.Ольшевская



Бөгелмә рус драма театры.





Бөгелмә рус драма театры спектакльләреннән күренешләр: 1. А.Н.Островский, «Кайнар йөрәк» (Курослепов — Б.М.Кольцов, Градобоев — И.А.Кузнецов, Хлынов — Е.В.Тимофеев). 1963; 2. К.Б.Минц, «Батыр солдат Ярослав Гашек». 1983; 3. Д.Патрик, «Сәер Сэвидж ханым». 1996.

(бу елларда театрда сәхнә машинисты ярдәмчесе булып эшләгән, соңыннан СССРның халык артисты А.Баталовның әнисе) тарафыннан К.М.Симоновның «Рус кешеләре» («Русские люди»), Л.М.Леоновның «Ябырылу» («Нашествие»), Б.А.Лавренёвның «Борылыш» («Разлом») пьесалары куела. Театрның сугыштан соңгы елларда ирешкән уңышлары, нигездә, баш режиссёрлар — РСФСРның атказ. артисты В.И.Плещунов (1957–62), РСФСР һәм Дагстан АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе П.В.Джапаридзе (1970–78), ш.у. составында ТАССРның халык артисты И.А.*Кузнецов*, ТАССРның атказ. артистлары В.Я.Апраксин, Н.И.Карнаков, А.Н.Ларина, У.Н.Потапенко, Е.В.Тимофеев, К.П.Чумакова, актёрлар А.Я.Ган, Д.Н.Галина, В.И.Бухало, Ю.К.Сметаниннар булган сәләтле коллектив эшчәнлегенә бәйле. Репертуары рус һәм дөнья классикасы, ш.у. хәзерге заман драматургиясе әсәрләреннән төзелә. 1950–60 елларда куелган күренекле спектакльләр: Б.С.Ромашовның «Утлы күпер» («Огненный мост»), М.А.Кац, А.Г.Ржешевскийның «Олеко Дундич» (реж. А.П.Струнин), Н.Ф.Погодинның «Кремль курантлары» («Кремлёвские куранты», реж. Л.Ф.Шумилин), И.М.Соболевның «Хуҗа» («Хозяин»), А.Е.Корнейчукның «Эскадраның һәлакәте» («Гибель эскадры»), Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил» (реж. В.А.Барский), Ф.Бикчәнтәева һәм А.Баһаветдиновның «Икмәк Мәскәүгә бара» («Хлеб идет в Москву»; Бөгелмә шәһәрендәге 1918 елгы вакыйгалар турында; реж. В.И.Плещунов). 1970 елларда В.Гюгоның «Мария Тюдор», Б.Н.Полевойның «Кыргый ярда» («На диком бреге»), Э.Войнич романы буенча «Кигәвен» («Овод»), Т.Миңнуллинның «Ир-егетләр», С.И.Антоновның чех язучысы Ярослав Гашекның Гражданнар сугышы елларында Бөгелмә шәһәрендә булуы турында «Күңелем Россиядә» («Сердцем с Россией») әсәрләре куела. Бу елларда театр республика авылларында елга 200 ләп спектакль күрсәтә, шәһәр театры статусы ала, Бөгелмәнең мәдәни тормышы үзәгенә әверелә. Ике тапкыр (1959, 1973) театр коллективы иҗат отчёты б-н Казанда чыгыш ясый. Аннан соңгы елларда М.А.Ворфоломеевның «Юл өзеклеге» («Распутица»), А.З.Ставицкийның «1937» (1987, 1988, реж. Е.В.Сидоров), А.А.Дударевның «Бусага» («Порог»), Н.Р.Эрдманның «Үзен үзе үтерүче» («Самоубийца») (1988, 1989, реж. А.И.Ларичев), Ж.Ануйның «Кара кәләш» («Чёрная невеста», 1993, реж. А.И.Ларичев) һәм С.Мрожекның «Бөкре кеше» («Горбун», 1994, реж. В.В.Гален) әсәрләре куела. Театрның баш режиссёрлары: К.А.Петров (1984–86), Е.В.Сидоров (1986–89), А.И.Ларичев (1989–94). Театр труппасында ТРның халык артисты Р.И.*Сәлимов*, ТРның атказ. артистлары И.В.Демидов, Н.Д.Качкина, Т.Н.Молодкина һ.б. эшли, директоры — В.П.Юдин (1995 тән). Театр 2008 елдан А.В.Баталов исемен йөртә.

*Әд.:* Е ф р е м о в А.В. Город счастливой судьбы. Бугульма, 1981.

*Ю.А.Благов.*

**БӨГЕЛМӘ́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Музей оештыру омтылышы 1919–24 елларда башлана, 1929 да ачыла. 1933 тә Бөгелмә МТСының сәяси эшләр бүлеге карамагына тапшырыла. Бөек Ватан сугышы елларында ябыла, бинасы балалар йортына бирелә. 1946 да яңадан торгызыла, 1982–2006 елларда ТРның Милли музее ф-лы. 2007 дән муниципаль музей, 1989 да экспозицияне үзгәртеп кору һәм кап. ремонт эшләре башкарыла. 19 йөз ахырында алпавыт Елачин һәм сәүдәгәр Климовларга караган 2 бинада урнашкан. Экспозиция мәйданы — 796 *м*², музей коллекцияләре 18,5 мең саклау берәмлеген тәшкил итә. Экспозиция төбәк (18 йөзнең 2 нче яртысыннан) һәм Бөгелмә бистәсе барлыкка килгәннән алып 20 йөз ахырына кадәрге Бөгелмә шәһәре тарихын чагылдыра. Палеонтология әйберләре (мамонт тешләре һәм сөякләре) куелган; төбәк табигате бүлеге җирле флора һәм фауна үрнәкләре б-н таныштыра; энтомология (бөҗәкләрне өйрәнү) коллекцияләре урын алган. Этнография бүлегендә татар, чуаш, мордва, рус халыкларының көнкүреш әйберләре, а.х.кораллары, йорт кирәк-яраклары һәм җиһазлары, өс киемнәре, халыкның декоратив-гамәли сәнгать әйберләре бар. 19 йөздә Бөгелмәдә уза торган ярминкәләр тарихы буенча интерьер комплекслары фрагментлары күрсәтелә. Бөек Ватан сугышына багышланган бүлектә сугышта катнашкан бөгелмәлеләрнең шәхси әйберләре, хатлары, сугыш кораллары үрнәкләре һ.б. бар. Фотографияләрдә, документларда, Бөгелмә пр-тиеләре тарафыннан чыгарылган продукция үрнәкләрендә хәзерге шәһәр тарихы чагыла. Музейның этнография, нумизматика коллекцияләре аеруча кыйммәткә ия.




1. Бөгелмә төбәк тарихы музее; 2. «Бөгелмә өязендә ярминкә» экспозициясе.

Музей ел саен Белем (1 сент.), Халыкара музейлар (18 май), өлкәннәр (1 окт.), Бүләкләр кабул итү (июнь) көннәрен уздыра.

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. К., 1999. Т. 1.; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 1.

**БӨГЕЛМӘ́ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск һәм Ютазы р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда оештырыла. 2006 елның 1 гыйнварына урман фондының гомуми мәйданы 43814 *га*. 4 урманчылыкны үз эченә ала: Актүбә — 9569 *га*, Бөгелмә — 9795 *га*, Петровка — 9890 *га* һәм Ютазы — 14560 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Бөгелмә шәһәрендә. Эшләүчеләр саны 72 кеше.

Урманнарның 90% тан күбрәге 1 нче төркемгә карый, алар арасында: аеруча саклана торган терр-яләр — 167 *га*, яшел зона урманнары — 4313 *га*, саклаучы урманнар — 35351 *га* (юл буендагы саклау полосаларын да кертеп — 870 *га*). 2 нче төркем (файдаланыла торган) урманнар 3983 *га* мәйданны алып тора, алар Актүбә урман хуҗалыгы терр-ясендә урнашкан. Урман фонды мәйданының урманлы өлеше 38713 *га*, ш.и. ылыслы агач токымнары — 8214 *га* (21,2%), каты яфраклылар — 6749 *га* (17,4%), йомшак яфраклылар 23750 *га* (61,3%) тәшкил итә. Урман хасил

итүче төп токымнар: каен (39,4%), усак (16%), имән (16%), нарат (18,7%), юкә (4,6%); сирәк кенә өрәңге, чыршы, карагай, аксыл зирек, агачсыман тал һ.б. очрый. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшьләре (27,3%), урта яшьтәгеләре (26,8%), өлгереп килүчеләре (23,3%), өлгергәннәре (21,3%). Урман культуралары 8242 *га* мәйданны били. Петровка урманчылыгындагы өлгергән табигый нарат урманының сөзәкле участоклары «*Петровка наратлары*» табигать истәлеге дип йөртелә. Язгы адонис һәм үсемлекләрнең башка сирәк төрләре популяцияләре «*Адонис урманы*», «*Яңа Александровка сөзәклеге*» — табигать тыюлыкларында (икесе дә Бөгелмә урманчылыгы терр-ясендә) саклана. Б.у.х.нда агачның гомуми запасы 5174,7 мең $м^3$; ш.и. ылыслылар — 1076,5 мең $м^3$, каты яфраклылар — 666,4 мең $м^3$, йомшак яфраклылар 3431,8 мең $м^3$ тәшкил итә. Агачның уртача еллык артымы 121,9 мең $м^3$, ш.и. 25,7 мең $м^3$ — ылыслы токымнар хисабына. Төп кулланылыш буенча урман кисүнең еллык нормасы 72 мең $м^3$ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан чистарту эшләре 505,1 *га* мәйданда башкарыла, шуның б-н бергә 17,4 мең $м^3$ эшкә яраклы агач әзерләнә. Урман торгызу эшләре 400 *га* мәйданда алып барыла, ш.и. 160 *га* мәйданда урман культуралары утыртыла. 9,76 *га* мәйданы булган төп питомникта 2,5 млн. ылыслы токымнар чәчкене үстерелә. Урман хуҗалыгында 30 лап төрдәге халык хуҗалыгы товарлары (2003 елда — 6,3 млн. сумлык) җитештерелә. Урман хуҗалыгы директоры И.К.Сингатуллинга, урманчылар Р.А.Иксанов һәм Р.А.Галиуллинга ТРның атказ. урманчысы дигән мактаулы исем бирелгән.

*А.А.Вакатов.*

**«БӨГЕЛМӘ́ ФАРФОРЫ́»**, түбән температуралы фарфордан әйберләр эшләп чыгару предприятиесе. Бөгелмә шәһәрендә урнашкан. 472 кеше эшли (2005). 1976 елда Бөгелмә фарфор з-ды буларак нигез салына, 1993 тән «Б.ф.» АҖ. Заводта 8 агымлы механикалаштырылган линия эшли, формага салу, киптерү, төзәтү, глазурьлау (ялтыравык йөгертү) һәм яндыру процесслары тулысынча автоматлаштырылган. Газ ягулыгы б-н 4 роликлы мич эшли. Завод составында масса әзерләү, мичтә формалаштыру цехлары, әйберләрне киңәйтелгән комплектацияләү участогы, газ хуҗалыгы, үзәк лаборатория бар. 1986 елга кадәр җәмәгать туклануы пр-тиеләре өчен тәлинкәләр эшләп чыгара.



«Бөгелмә фарфоры» АҖ продукциясе.

1987–90 да җитештерү технологияләре һәм җиһазлар яңартыла. Әйберләрнең товарлыклы эшләнешен яхшырту өчен ефәк трафаретлы басу, төсле ялтыравык бизәкләр кулланыла. 1990 елларда завод үзгәртеп корыла. «Б.ф.» аш, чәй, кофе сервизлары, комплектлы җыелмалар, аш-су савыт-сабалары, микродулкынлы мичләр өчен савыт-саба җыелмалары, нәфис әйберләр, төсле фарфордан сувенирлар эшләп чыгара. Заводта җитештерелгән продукция РФ төбәкләренә, Дания, Франция, Швециягә чыгарыла. Биредә эшләүчеләрдән 1 кеше — «Почет билгесе», 3 кеше Хезмәт Даны орденнары, 2 кеше медальләр б-н бүләкләнә. Завод җитәкчеләре арасында: Б.З.Бикчәнтәев (1976–79), Л.К.Кульмамиров (2001–06), И.Р.Сәләхов (2006 дан).


*Әд.:* Бугульминский фарфоровый завод // Коммерческий вестн. 1986. № 24; Алексеева В. Бугульминский фарфор: вчера, сегодня, завтра // Советская Татария. 1990. 19 апр; Кульмамиров Л. Кувшин и журавль // Идель. 1998. № 8.

**БӨГЕЛМӘ́ ҺӨНӘРИ́-ПЕДАГО́ГИЯ КӨЛЛИЯТЕ́**, РФ Фән һәм мәгариф министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1963 елда һөнәри-техник уч-щеләр һәм мәктәпләр өчен хезмәт укытучылары әзерләү максатында оештырыла, 1997 дән хәзерге исемдә. 2005 елда белгечлекләр: технологияне һөнәри укыту, хокук белеме, икътисад һәм бухгалтерлык исәбе. Көндезге бүлектә 755 тән артык, читтән торып уку бүлегендә якынча 380 студент укый. Пед. коллективта 45 кеше эшли, эшләү елларында 4 меңнән артык белгеч әзерләнгән.

**БӨГЕЛМӘ́ ЭЛЕВА́ТОРЫ**, бөртекле ашлык әзерләү, саклау һәм эшкәртү предприятиесе. Бөгелмә шәһәрендә урнашкан. 300 кеше эшли (2005). 1914 елда Бөгелмә өязе элеваторы буларак нигез салына һәм Дәүләт банкы карамагында була. Силос башнясы 9500 *т* бөртекле ашлык сыйдырышлы булган. Предприятиедә кул хезмәте өстенлек иткән. Киптерү агрегатлары булмаганлыктан, элеваторга коры һәм чистартылган ашлык кына кабул ителгән. 1960 та Б.э. һәм он тарту з-ды Бөгелмә он тарту комб-ты итеп берләштерелә. 1966 дан хәзерге исемдә. 1994 тән АҖ, 1999 дан Б.э. «Разгуляй» компаниясе күзәтчелегенә күчә. Предприятиедә төп юлга чыгара торган тимер юллар бар; ашлык кабул итү, үлчәү, киптерү, чистарту һәм төяү өчен заманча җайланмалар б-н җиһазландырылган. 30 һәм 60 *т* лы автомобиль күтәргечләре һәм үлчәүләре төзелгән. 150 *т* лы тимер юл үлчәве бар. Машиналар һәм җайланмалар б-н идарә итү автоматлаштырылган. Производство куәтләре елына бер үк вакытта 122 мең *т* га кадәр бөртекле ашлык саклау, һәр тәүлектә 6 мең *т* га кадәр ашлык кабул итү, ашлык киптергеч аша якынча 3,5 мең *т* ашлык чыгару, 3,5 мең *т* га кадәр ашлык төяп җибәрү мөмкинлеге бирә. Бөртекле ашлык б-н тәэмин итүче хуҗалыклар — Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск р-нныры а.х. пр-тиеләре. Предприятие җитәкчеләре арасында: Д.И.Нырков (1948–53), М.Я.Шурупов (1955–60), М.Я.Стрельник (1960–66), Н.С.Цуркан (1966–76), Н.Ф.Сәфәров (1976–91), Л.А.Корытин (1991–95), С.А.Богомолов (1995–96), А.А.Касыймов (1998–2000), С.А.Батыр (2001–04), Д.В.Әхмәтҗанов (2004 тән).

*З.А.Гыйззәтуллина.*

**БӨГЕЛМӘ́ ЯССЫ́ КАЛКУЛЫГЫ́**, *Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының* төньяк-көнбатыш өлеше. ТРның көньяк-көнчыгышында урнашкан һәм ТР чикләрендә рельефы иң биек (381 *м* га кадәр) булу б-н аерылып тора. Татар тектоник гөмбәзенең кристаллик нигезе Көньяк гөмбәзгә туры килә. Пермь системасының югары бүлеге известьташ, комташ,



Бөгелмә яссы калкулыгы күренеше.

балчык һәм мергельләрдән, елга үзәннәре балчыкларыннан гыйбарәт. Б.я.к. ның рельефы киртләчләнеп бүленгән төрле биеклектәге 2 денудацион тигезлек б-н (280–360 һәм 200–240 *м*) билгеләнә. Чишмә, Зәй, Ык елгалары һәм аларның кушылдыклары үзәннәре б-н калкулык аерым увалларга бүлгәләнгән. Шулар арасында — Азнакай шәһәре тирәсендәге *Чатыр тау* саклаулыгы. Елга үзәннәрендә *сөзәклекләр асимметрия*се. Түбән Пермь һәм Казан ярусы известьташы һәм гипсларында *карст* күренешләре күзәтелә. Рельефының биек булуы сәбәпле темп-ра түбәнрәк (гыйнварда уртача –15 °С тирәсе), явым-төшемнәр күләме күбрәк (530 *мм* га кадәр). Б.я.к. урман-дала зонасында урнашкан. Үзәннәрдәге туфрак катламының күп өлеше селтесезләнгән кара туфрактан, елгалар арасы соры урман туфрагыннан гыйбарәт. Соңгы 200 ел эчендә урманлылык 2,5 тапкыр кимегән һәм хәзерге вакытта 18% тәшкил итә. Нефть, битум һәм төзелеш чималлары чыганаклары бар. Чишмә елгасы үзәнендә «*Бәкер*» ләм б-н дәвалау курорты эшли. Б.я.к.нда Бөгелмә, Әлмәт, Лениногорск, Баулы шәһәрләре урнашкан.

*А.П.Дедков.*

**БӨГЕЛМӘ́-БӘЛӘБӘ́Й КАЛКУЛЫГЫ́**, Көнчыгыш Европа тигезлегенең көнчыгышындагы иң биек калкулык. Татарстан һәм Башкортстан респ-калары, Самара һәм Оренбург өлкәләре чикләрендә Идел, Кама һәм Агыйдел елгалары субүләрләрен хасил итә. Башкортстанның Бәләбәй шәһәре тирәсендәге биеклеге 420 *м*, Татарстанда (Оренбург өлкәсе чигендә) 381 *м*. Пермь системасының известьташ, мергель, балчык һәм комташларыннан гыйбарәт. Елгалар арасында төрле биеклектәге 2 денудацион тигезлек (300–400 һәм 200–240 *м*) бусагаланып аерылып тора. Елга үзәне сөзәклекләре асимметрияле, көньяк һәм көнбатышка караганнары текәрәк.


Сөзәклекләр уалуга чыдам токымнар (известьташ һәм комташлар) б-н катлау-катлау булып тармакланган. Бу токымнарның ныклыгы ерымнарга киңәергә ирек бирми. Бүрәнкәсыман упкыннар һәм мәгарәләр рәвешендәге карст формалары киң таралган. Б.-Б.к.нан көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш Иделгә Олы Чирмешән, Сык; төньякка таба Камага Чишмә, Зәй, Ык; төньяк-көнчыгышка таба Агыйделгә Сөн, Чирмәсән, Дим елгалары коя. Нефть, төзелеш чималлары (известьташ, балчык, ком, вак чуерташ) чыганаклары бар. Б.-Б.к.ның Татарстанның төньяк-көнбатышындагы өлеше *Бөгелмә яссы калкулыгы* буларак билгеле.

*А.П.Дедков.*

**БӨДӘЙЛИ́** Мәхмүт Кашфелһади улы (3.4.1895, Казан губ., Мамадыш өязенең Ямаш а. — 15.4.1975, Казан), журналист, язучы, җәмәгать эшлеклесе. Троицк мәдрәсәсендә белем ала. 1912 елда «Энергия» басмаханәсендә татар телендәге «Акмулла», казакъ телендәге «Айкап» ж-лларының хәреф җыючысы. Журналистлык эшен 1914 тә «Вакыт» г-тасы, «Акмулла» һәм «Шура» ж-лларының Төркестан буенча үз хәбәрчесе сыйфатында башлап җибәрә. 1917 дә 11 нче армиянең мөселман гаскәриләре советы рәисе һәм «Иптәш» исемле армия г-тасы мөхәррире. 1918 дә «Мамадыш тавышы» дигән өяз г-тасы чыгаруны оештыра. 1919 да Шәрекъ халыклары коммунистик оешмасының 2 нче, РСФСР Советларының 7 нче съезды делегаты. 1920 дә Бөтенроссия ҮБКның «Кызыл Шәрекъ» агитпоезды чыгарган шул исемдәге газета мөхәррире. 1920–22 елларда Төркестанда: Бохара Халык Совет җөмһүриятенең матбугат халык комиссары, бер үк вакытта Төркестанның милләтләр эше буенча халык комиссары урынбасары, Харәзем Халык Совет җөмһүриятендә РСФСРның Гадәттән тыш илчесе. 1922 дән ТАССРда дәүләт эшендә: сәламәтлек саклау һәм юстиция халык комиссарлары урынбасары, «Резинотрест»ның Казан бүлеге идарәчесе. «Кызыл Татарстан» г-тасы мөхәррире, «Чаян» ж-лын оештыручыларның берсе һәм беренче мөхәррире, «Кызыл Шәрекъ яшьләре» ж-лы редколлегиясе әгъзасы. Читтән торып Казан ун-тының физ.-матем. ф-тында укый. Б.нең беренче әдәби әсәрләре 1926 елда «Кигәвен», «Бакыр күз» псевдонимы б-н күренә башлый. Сатирик һәм юмористик әсәрләр җыентыклары, фәнни-популяр брошюралар авторы. 1929 елда «*солтангалиевчелек*»тә гаепләнә һәм ВКП(б) сафыннан чыгарыла. 1930 да ОГПУ коллегиясе карары б-н 5 елга ирегеннән мәхрүм ителә. 1938 дә тагын 8 елга хөкем ителә. Җәза срогын тутыргач, Коканд шәһәрендә яши. 1949 да яңадан кулга алына һәм сөргенгә җибәрелә. 1955 тә азат ителә. Җинаять эшләре составы булмау сәбәпле, Б.гә карата ачылган эш СССР Югары Судының җинаять эшләре коллегиясе тарафыннан 1957 дә туктатыла, 1989 да тулысынча аклана.

Ә с ә р.: Саз бизгәге. К., 1924; Тубылгы чыбыклары. К., 1926; Замана көлкеләре. К., 1927; Тормыш төпчекләре. К., 1928; Юмор һәм сатира. К., 1966.

*Әд.:* Рухы сынмаган көрәшче // Казан утлары. 1995. № 4; Гимадиев У.И. Сила сатирического слова. К., 1987; Магдеев М. Изгой двадцатого столетия // Идель. 1992. № 3–4; Мустафин Р. Вечный скиталец: Встречи с Махмудом Будайли // Республика Татарстан. 2001. 22 нояб.



М.К. Бәдәйли.

**БӨЕ́** (Lycosa singoriensis), бүре-үрмәкүчләр семьялыгындагы үрмәкүч. Чүл, дала һәм урман-дала зоналарында таралган. Татарстан терр-ясендә аның ареалының төньяк чиге үтә. Чистай, Түбән Кама, Яшел Үзән, Югары Ослан, Буа р-ннарында күренә. Гәүдәсенең озынлыгы 25–35 *мм.* Төсе көрәннән алып карага кадәр диярлек. Җирдә 50 *см* га кадәр тирәнлектә, пәрәвез б-н түшәлгән вертикаль оя ясап яши. Дымлы туфракны өстен күрә. Кышка оясын тирәнәйтә һәм керү юлын җир б-н каплый. Агулы, аның тешләве каты авырттыра һәм шеш чыгара; агуы кеше өчен куркыныч түгел. Кубрәк бөҗәкләр б-н туклана, шуның б-н файдалы. Табышын төнлә — оясыннан чыгып, көндез керү юлы янында сагалап торып аулый. Парлашу җәй ахырында үтә. Яшь һәм аталанган ана затлар кышлыйлар. Җәй башында ана үрмәкүч йомыркасын пәрәвез кузысына сала һәм аны бик тырышып саклый. Йомыркадан чыккан яшь үрмәкүчләр берничә көн әниләре аркасына ябышып йөри. Татарстан терр-ясендә Б. таралуны чикләүче факторлар: ареал чиге, кешенең актив хуҗалык эшчәнлеге, умырткалы һәм умырткасыз хайваннар арасында дошманнары (гөберле бака, кәлтә, казучы шөпшә, җайдак бөҗәкләр һ.б.) күп булу. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БӨЕ́К БОЛГА́Р ДӘҮЛӘТЕ́**, 7 йөзнең 1 нче чирегендә (630 еллар) болгар кабиләләре төзегән беренче дәүләти берләшмә. Азак диңгезенең төньяк һәм көнчыгыш яр буйларын, Төньяк Кавказның көнбатыш өлешен биләгән. Көнбатыш Төрки каганлыгы таркалган вакытта болгарлар *Дуло* ыругы җитәкчелегендәге унногур кабиләсе б-н берләшәләр. 7 йөз башында ул берләшмә Авар каганлыгына керә. 635 елда болгарлар идарәчесе Орган (Ураган) хан һәм аның бертуганының улы *Кубрат хан* Азак диңгезе буенда үз кабиләләрен берләштерәләр, аварлардан азат булган Б.Б.д. төзиләр. Бу дәүләти берләшмә Византия ягында торып аварларга каршы һ.б. сугышларда катнаша. Шул хезмәтен бәяләү йөзеннән Византия императоры Ираклий Кубратка патрикий титулы бирә.

Б.Б.д. башкаласы — *Фанагория* (Фәнәһар) шәһәре. Төп халкы төрки телле огур-болгар кабиләләре (кутригур, утигур, унногундур һ.б.). Иң куәтле дәверендә дәүләт биләмәсе Кубань елгасыннан Днепр ярларына чаклы җәелгән. Халкының бер өлеше җир эшкәртү б-н көн күргән, күпчелеге терлек асрау б-н шөгыльләнгән. Фанагориядә һ.б. шәһәрләрдә һөнәрчелек һәм сәүдәгәрләр тә үсеш алган. Кубрат хан вафатыннан соң (660 еллар), Б.Б.д. таркала башлый. Дәүләт биләмәсенең зур өлешен хәзәрләр яулап ала (к. *Хәзәр каганлыгы*). Б.Б.д. чорында болгарларда уртак этник сәяси үзаң үсеше күзәтелә, дәүләт таркалганнан соң төрле тарафка таралган болгарлар үз этник йөзен һәм рухи-мәдәни үзенчәлекләрен саклап калалар, яңа ватаннарында дәүләтчелек төзү традицияләрен дәвам иттерәләр (к. «*Болгар ханнары исемлеге*», *Идел буе Болгар дәүләте*, *Беренче Болгар патшалыгы*).

*Әд.:* Мерперт Н.Я. К вопросу о древнейших болгарских племенах. К., 1957; Артамонов М.И. История хазар. М., 1962; Генинг В.Ф., Халиков А.Х. Ранние болгары на Волге. М., 1964; Гадло А.В. Этническая история Северного Кавказа IV–X вв. Л., 1979; Чичуров И.С. Византийские исторические сочинения. М., 1982; Новосельцев А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990; Плетнёва С.А. Очерки хазарской археологии. М.-Иерусалим, 2000; Golden P.B.Khazar Studies. An historic-philological inguiry into origins of the Khazars. Bdpst, 1980. V. 1–2.

*И.Л.Измайлов.*




**БӨЕ́К ВАТА́Н СУГЫШЫ́**, 1941–45 елларда совет халкының фашистлар Германиясенә һәм аның союздашларына (Венгрия, Италия, Румыния, Финляндия һ.б.) каршы азатлык сугышы, Икенче бөтендөнья сугышының иң әһәмиятле өлеше. Сугыш вакытында Татарстан Кызыл Армияне тәэмин итүче төп базаларның берсенә әверелә. Сугыш барган тарафлардан республикага 70 тән артык завод-фабрика күчерелә. Аларның күпчелеге Казанда урнаша: С.П.Горбунов исем. Мәскәү авиация з-ды, Мәскәү һәм Воронеж машина төзелеше з-длары, Балашиха шәһәреннән юю-механика з-ды, Мәскәү һәм Гомель шәһәрләренең аяк киеме тегү ф-калары, Шостка шәһәреннән кинотасма һәм Ленинградтан фото кәгазьләре эшләү ф-калары, Киевтан теш дәвалау бораулары з-ды, Бежецк шәһәреннән автомобиль гаражлары җи-



1. Казан кетгут з-дында җылы киемнәр җыю. 1941; 2. 16 нчы з-дта (хәзерге КМПО) комсомол яшьләр бригадасының авиация моторларын җыю вакыты; 3. Казанның 237 нче номерлы з-дында (хәзерге КОМЗ) үсмер малай И. Чередилин кыру станогында эшли. 1943 елның феврале; 4. Буа р-ны «Коминтерн» к-зының яңа ашлык олаулары. 1944; 5. Татарстан хезмәтчәннәре акчасына төзелгән танк колоннасын фронтовикларга тапшыру. 1944; 6. Татарстан колхозчылары делегациясе Кызыл Армиягә самолётлар тапшыра; 7. Француз партизаннары отряды. Байрак йөртүче — Минзәлә р-ны колхозчысы Р.Боков; 8. Казан, 9 май, 1945 ел.

һазлары з-ды, Кунцеводан һәм Одессадан күн эшләнмәләр з-длары һ.б. төр оешмалар. Казанга СССР ФА президиумы һәм академиягә караган 33 фәнни ин-т, СССР Дәүләт банкы, СССР Финанс халык комис-ты һ.б. үзәк оешмалар эвакуацияләнә. Ш.у. Алабуга, Чистай, республиканың башка шәһәрләре һәм районнарына да кайбер җитештерү пр-тиеләре һәм аерым оешмалар күчерелә. Татарстанга 226 мең кеше, ш.и. 15 мең ятим бала эвакуацияләнә. Республикада 50 дән артык хәрби госпиталь оештырыла, аларда 334 мең яралы сугышчы дәвалана, шуларның 207 меңе дәваланып сугышка озатыла. Сугыш башланган көннән респ-каның барлык пр-тиеләре сугыш кирәк-ярагы җитештерүгә җайлаштырыла. Кинотасмалар җитештерү ф-касы самолёттан фотога төшерүгә яраклы тасмалар чыгаруны үзләштерә; автомобиль гаражлары өчен җиһаз җитештерүче, язу машиналары чыгаручы, ясалма күн җитештерүче һ.б. з-длар миналар, гранаталар һ.б. төр корал җитештерүгә күчерелә. Мех комб-ты җылы комбинезоннар, бүрек, тун, мехлы аяк киемнәре (унтылар), башка фабрикалар хәрби кием, маскировка халатлары, парашютлар тегәләр. Татарстаннан фронтка 11 меңнән артыграк У-2 (По-2) самолёты төзеп озатыла, уникаль Пе-2 һәм Пе-8 бомбардировщиклары, операцияләр өчен кетгут җепләр эшләнә. Республикада барлыгы 600 дән артыграк исемдә корал, кием-салым һ.б. җитештерелә. Сугыш елларында Татарстанда 22 яңа завод-фабрика сафка бастырыла, ш.и. Казанда техник резина әйберләр, техник май җитештерү, механика, подшипник җитештерү з-длары, Алабуга, Бөгелмә, Мамадыш, Чистай, Зеленодольск (Яшел Үзән) шәһәрләрендә ит комб-тлары, җеп эрләү, күн итек тегү, киез итек басу ф-калары, консерв з-ды, эл. станциясе һ.б. эшли башлый. Яңа төр сәнәгать тармагы ачыла — 1943 елдан Бөгелмә төбәгендә нефть чыгарыла башлый. Татарстан эшчеләренең, инженер һәм техникларының сугыш елларындагы фидакарь эшчәнлеге СССР хөкүмәте тарафыннан югары бәяләнә, 4200 кеше орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Республикада а.х. тармагында бик авыр шартлар туа: авылларда ир-ат, бигрәк тә механизаторлар калмый диярлек, автомобильләр, тракторлар да өлешчә мобилизацияләнә. Берничә дистә мең ат фронтка озатыла. Шул сәбәпле сөрү җирләре мәйданын 1 млн. гектардан артыкка киметергә туры килә, ш.и. бодай басулары мәйданы икеләтә кыскара. 1942–45 тә иген уңышы 2,5 мәртәбә кими. Мал азыгы тиешле күләмдә җитештерелмәү сәбәпле дуңгызлар саны 2,5, атлар 2 мәртәбәгә кимetelә. Шуңа да карамастан, Татарстан игенчеләре бу елларда дәүләткә 131 млн. пот ашлык, 39 млн пот бәрәңге һәм яшелчә, 56 млн. пот ит, 200 млн. *л.* сөт, 500 мең поттан артыграк йон һәм дистәләгән мең пот май, бал, дуңгыз мае, 11 млн. пот печән һ.б. тапшыралар. Республика галимнәре дә сугыш б-н

бәйле фәнни эзләнүләргә иң зур игътибар бирәләр. ТАССР Дәүләт план комиссиясе карамагында 1941 дә *Фәнни-техник совет* оештырыла. Максаты — халык хуҗалыгы һәм оборона өчен әһәмиятле булган теоретик, икътисади һәм оештыру мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнү, фронт һәм тыл ихтыяҗларын үтәү өчен Татарстанның җирле ресурсларын барлау. А.Е.Арбузов оптик приборлар җитештергәндә бик әһәмиятле булган матдәләрне кулланышка кертә, Б.А.Арбузов синтетик каучукның салкынга чыдамлыгын арттыруга ирешә. Н.А.Ливанов азык-төлек җитештергәндә аксым һәм витаминнарны саклаучы технология тәкъдим итә. С.Н.Ушаков җитәкчелегендәге төркем оборона сәнәгатендә кулланышлы яңа төр пластмасса эшләп чыгара. Г.Х.Камай җитәкчелегендә яңа төр кетгут җепләре эшләү технологиясе үзләштерелә. Табиб-галимнәр А.В.Вишневский, В.А.Гусынин, Б.Л.Мазур, А.Н.Мурзин, И.М.Русецкий, Н.В.Соколов, Л.И.Шулутко һ.б. яралы сугышчыларны уңышлы дәвалау чараларын күрәләр. Яңа дарулар һәм дәвалау җайланмалары булдыруда А.Д.Бейлинсон, П.Н.Кашкин, А.Э.Озол, Н.Р.Стрелков һ.б. актив эшли. А.х. тармагында яңа фәнни-гамәли уңышларга ирешүчеләрдән А.А.Абдулбаниев, Х.Х.Байчурова, Е.Н.Борисова, Ш.В.Вәлиев, П.С.Зубков, Г.И.Попов, Н.П.Попов, А.П.Студенцов, П.М.Тихонов, И.В.Үтәй, В.Г.Чагин, З.Х.Шәрәф эшчәнлеге мәгълүм.

1941 елның көзеннән *СССР Фәннәр Академиясе оешмаларының Казан төркеме* эшли. Республикадагы сәнәгать пр-тиеләре эшчәнлегенә ярдәм итү максатында ФА ин-тлары галимнәреннән берничә комиссия оештырыла. *Фән-техника комиссиясе* эшендә бу вакытта Казанда яшәгән атаклы галим-конструкторлар: В.П.Глушко, С.П.Королёв, В.М.Петляков, А.Н.Туполев, С.А.Чаплыгин һ.б. катнаша, алар республикада җитештерелә торган хәрби техниканы камилләштерүгә зур өлеш кертәләр.

Республиканың иҗат интеллигенциясе дә халыкны җиңүгә рухландыруга зур өлеш кертә. Язучылар яу кырындагы һәм тылдагы батыр каһарманнарга багышлап патриотик эчтәлекле әсәрләр иҗат итәләр. М.Әмир, Г.Әпсәләмов, Г.Бәширов, И.Гази, Ә.Еники, Ә.Исхак, Ш.Камал, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, Ш.Мөдәррис, К.Нәҗми, Г.Насрый һ.б. әсәрләре Казанда һәм фронт г-таларында басылып тарала. Татар телендә нәшер ителүче армия һәм фронт г-таларында А.Әхмәт, Г.Әпсәләмов, Ә.Ерикәй, Г.Галиев, Р.Ишморат, Г.Кутуй, Ш.Маннур, М.Максуд, Ә.Фәйзи. М.Садри, А.Шамов һ.б. эшли. Татарстан композиторлары да сугыш елларында 108 әсәр иҗат итәләр, ш.и. 72 әсәр сугыш темасына багышлана. С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, А.Ключарёв, З.Хәбибуллин иҗат иткән муз. әсәрләр батырлыкка, дошманны җиңүгә өндиләр. Илбасарлар б-н көрәш темасын чагылдырган беренче милли балет авторы Ф.Яруллин яу кырында взвод командиры буларак сугышка һәм һәлак була. Татарстан рәссамнары Г.В.Житков, Г.П.Катков, И.И.Князьков, И.А.Новосёлов, Н.М.Сокольский, В.К.Тимофеев һ.б. хәрби-патриотик темага багышлап яңа хезмәтләр тудыралар. Х.Якупов, Л.Фәттахов һ.б. рәссамнар яу кырында дошманга каршы көрәшә, сугыш мизгелләрен сурәтләгән әсәрләрен шунда иҗат итәләр. Татарстан театрларында Бөек Ватан сугышы темасын яки тыл хезмәтчәннәре батырлыгын чагылдырган пьесалар куела. К.Симоновның «Рус кешеләре» («Русские люди»), А.Корнейчукның «Фронт», Р.Ишморатның «Кайту», Н.Исәнбәтнең «Мәрьям», М.Әмирнең «Миңлекамал», Т.Гыйззәтнең «Төнге сигнал», «Изге әманәт» әсәрләре рус һәм татар театрлары сәхнәләрендә уйнала. Сугыш темасына багышлап Н.Җиһановның «Илдар», М.Юдинның «Фәридә» опералары иҗат ителә. Театр һәм эстрада сәхнә осталары, 18 бригадага берләшеп, 11 фронт сугышчылары алдында 2 меңнән артык чыгыш ясыйлар.


НАКАЗ

Зеленодольск шәһәре хезмәтчәннәренең үз акчаларына төзелгән «Сталинец» бронекатеры командасына наказы. 1944.

Республика хезмәт ияләре яу кырындагыларга һәр төр ярдәмне дә даими оештыралар. Сугыш башланып бер ай үткәч, мәскәүлеләр *Оборона фондын* оештыру тәкъдиме б-н чыгалар. Татарстан халкы да бу башлангычны хуплый. 1941 елның ахырына кешеләрнең өстәмә эш вакытында эшләп алган акчасы яки тапшырган кыйммәтле әйберләре исәбенә бу фондка 16 млн. сумнан артыграк акча, 26 *кг* чамасы көмеш һәм 796 *г* алтын эшләнмәләр җыела. 1943 ел ахырына гомуми сумма 51 млн сумга җитә. Республика халкы сугышчыларга җылы киемнәр туплауда да актив катнаша. 1941–42 елларда фронтка 23 мең кыска тун, 54 мең пар киез итек, 59 мең сырган чалбар б-н сырма, 106 мең пар эчке җылы кием, күп санда бәйләнгән оекбаш, бияләй һ.б. әйберләр озатыла. Сугыш дәвамында барлыгы 10 млн. берәмлек җылы кием җыеп җибәрелә. Сугыш башланган беренче айлардан ук фронтка хәрби техника төзү өчен акча, кыйммәтле әйберләр туплау хәрәкәте җәелдерелә. Казан тимер юлчылары үз исәпләренә «Кызыл Татарстан», «Чапаев», «Куйбышев» исем. броняլы поездлар төзиләр, аларның экипажларын да үзләре туплап фронтка озаталар. Яшел Үзән шәһәре хезмәт ияләре үз исәпләренә броняланган 2 кораб төзиләр һәм аларны коралландыралар. Республика халкыннан җыелган байлык исәбенә *танк колонналары* һәм *Урта Дон бомбардировщиклар авиация дивизиясе* өчен берничә эскадрилья туплап җибәрелә. Сугыш елларында хәрби техника һәм корал җитештерү өчен республика халкыннан җыелган байлык 380 млн. сум тәшкил итә. Моннан тыш, заемга язылу рәвешендә тупланган акча 1 млрд. 576 мең сум була. 1943 тән башлап барлык сәнәгать-җитештерү оешмаларының планнан арттырып эшләнгән продукциясе башкомандующий фондына күчерелү хәрәкәте җәелдерелә. Ул хәрәкәтне Татарстан хезмәт ияләре дә хуплыйлар. 1944 нең 1 гыйнварына республика сәнәгать оешмалары, 104 млн. сумлык өстәмә продукция җитештереп, шул фондка тапшыралар. Республика колхозчылары да бу хәрәкәттән читтә калмый. Мәс., 1944 нең февраленә Кайбыч р-ны хуҗалыклары Кызыл Армия фондына 1 млн. 300 мең сум акча кертәләр. Республика а.х. оешмалары җәмгысы ул фондка дип меңләгән пот ашлык, бәрәңге, ит-май һ.б., ш.и. 62 млн. сум акчалата кертем бирәләр. Яу кырында сугышчыларга шәхси ярдәм итүнең бер төре почта аша башкарыла. 1942 елны каршылау алдыннан хәрәкәттәге армия сугышчыларына атап 500 мең сумлык посылка, 1942–44 еллар дәвамында 10 млн. 600 мең сумлык күчтәнәч-посылкалар җибәрелә. Республиканың шундый күчтәнәчләр җибәрүне оештыручы



Төньяк-Көнбатыш фронтта катнаш концерт бригадасы составында татар артистлары. 1943. Беренче рәттә (сулдан уңга): нәфис сүз остасы Е.Краевская, Г.Камал исем. Татар театры артисткасы Р.Җиһаншина, Татар филармониясе артистлары З.Измайлова, баянчы Н.Ширкин; Икенче рәттә (уңнан 2 нче) Казан музыка учщесе студенткасы Н.Халанова.

комиссиясе исеменә халыктан 38,2 млн сум акча керә. 1943–44 тә сугышчылар гаиләсенә ярдәм итү фонды да эшли, ул фондта 13 млн. сум акча, азык-төлек һәм кием-салым туплана. Яу кырында сугышучы якташларның рухын күтәрү максатында күмәкләп хатлар язышу җайга салына. Фронттагы якташлар исеменә аерым сәнәгать пр-тиеләре, оешмалар, колхозчылардан күмәк хатлар җибәрелә, аерым гаскәри берәмлекләр б-н ул коллективлар арасында шулай дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырыла. Бөтен респ-ка халкы исеменнән язылган *«Фронтовик татарларга хат» (1942)* үзәк матбугатта һәм барлык фронт газеталарында басылып чыга. Якташ сугышчыларның «Татар халкына җавап хаты»да татар һәм рус телләрендә чыгучы вакытлы матбугат битләрендә урын ала (1943, март), 1944 тә аерым брошюра рәвешендә дөнья күрә.

Татарстанда сугышның беренче көннәреннән үк хәрби әзерлек эшенә зур игътибар бирелә. Оборона дәүләт ком-тының 1941 елның 16 июль карарын үтәп, гаскәри резервларны укыту-өйрәтү өчен Гомуми укыту курслары оештырыла, ОСОАВИАХИМ эшчәнлеге җанландырыла. 1941–45 тә Гомуми укыту курсларында 186 мең кеше, ОСОАВИАХИМда 163655 кеше укчы-сугышчы һ.б. төр хәрби һөнәргә өйрәнеп чыга; 1,9 млн. кеше хәрби һава һәм химик һөҗүмгә каршы тору серләрен үзләштерә. Кызыл Хач һәм Кызыл Ярым ай җәмгыятьләре 6590 кешене шәфкать туташлары һәм санинструкторлар булырга укыта, 943 мең кеше санитарлык оборонасына әзерлек («Готов к санитарной обороне», «Будь готов к санитарной обороне») программаларын үти. Республика физкультура оешмаларында 250 мең кеше кул сугышы осталыгына, йөзүче һәм чаңгычы булырга өйрәнә. Зурлардан алып мәктәп балаларына чаклы һәркем диярлек шушындый әзерлек укуларына җәлеп ителә. Татарстаннан Кызыл Армия сафларына 560 меңнән артыграк кеше мобилизацияләнә. Тылда дошман һөҗүменнән саклану корылмаларын төзелешендә тагын 100 меңнән артыграк кеше катнаша (к. *Казанны саклау корылмалары*).

Б.В.с. елларында Татарстанда берничә хәрби дивизия һәм бригада оештырылып яу кырына озатыла: *Витебск исемендәге укчы дивизия, унсигезенче укчы дивизия, сиксән алтынчы мото-укчылар дивизиясе, Звенигород исемендәге гвардия укчылары дивизиясе, Орша исемендәге укчылар дивизиясе, Остров исемендәге укчылар дивизиясе, йөз кырык җиденче укчы дивизия, Фастов исемендәге танк бригадасы* һ.б. Язмышлары Татарстан б-н бәйле бер төркем хәрбиләрнең сугышлар алып бару таланты Б.В.с. чорында ачыла һәм югары бәяләнә. Генераллар *А.О.Ахманов, Ф.Г.Булатов, В.Г.Бурков, В.Н.Гордов, А.Ф.Казанкин, А.В.Кирсанов, И.Н.Конев, З.Й.Котлин, Г.Б.Сафиуллин, Я.Ж.Чанышев* һ.б. Татарстанда туганнар.

*Партизаннар хәрәкәтендә* дә безнең якташлар батырларча катнаша. Вакытлыча яулап алынган төбәкләрдә дошманга каршы кыю сугышучылар арасында И.Заикин, И.К.Кабушкин, З.Ш.Нури (Белоруссиядә), Н.А.Барышев, К.Галләмов, Т.Гайнанов (Кырымда), Г.С.Әмиров, А.Ш.Бикбаев, Б.Х.Кадыйрмәтов, Хаҗәт Садров (Смоленск өлкәсендә) һ.б. була. Франция Каршылык хәрәкәтендә дә күп кенә якташларыбыз катнаша: Р.Боков, М.Ф.Гайсин, В.П.Игнатьев, З.К.Камалов, Р.Н.Рылова, Ә.Г.*Утәшев*, З.Шәмигулов һ.б. Казанда югары юридик белем алган Даян Мурзин Чехословакиядә партизаннарның интернациональ бригадасы командиры була. Бу бригада составында якташларыбыз Н.В.Сметанин (комиссары), К.Әминов, К.Батуллин, Ш.Бикбулатов, Б.Г.Мәдъяров, М.Н.Мифтахов, А.Г.Мостафин, Г.С.Усманов, Г.Шәйхуллов һ.б. сугыша. Югославиядә ш.у. бригада комиссары Г.Г.Малов, Польшада М.С.Атаманов («Мишка Татар») һ.б. уртак дошманга каршы батырларча сугышалар. Фашистларның хәрби әсирләр лагерьларында булган хәлдә каршылык хәрәкәтен оештыруда катнашып танылган шәхесләрдән генерал Д.М.Карбышев, М.Хәйретдинов (язучы Х.Мөҗәй), Г.Нуретдинов исемнәре һәм *Идел-Урал легионын* таркату өчен көрәшкән җәлилчеләр төркеме (к. *Җәлилчеләр*) бөтен дөньяга мәгълүм.

Дошман тарафыннан вакытлыча оккупацияләнеп, совет гаскәрләре азат иткән өлкәләр, районнар халкына 1942 нең язында башлап ярдәм итү хәрәкәте киң җәелә. Өй кирәк-яраклары, кием-салым, хуҗалык итү җиһазлары, уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку әсбаплары җыеп озатыла. Татарстан халкы Сталинград шәһәренең Дзержинск р-нын, Сталинград өлкәсенең Бородищенск һәм Красноармейск р-ннарын, Орёл һәм Донбасс шәһәрләрен торгызуда булышлык итү бурычын үз өстенә ала.

Немец-фашист илбасарлары б-н батырларча сугышкан 200 дән артыграк якташыбызга Советлар Союзы Герое исеме бирелә (Н.Г.*Столяров* бу югары дәрәҗәгә 2 мәртәбә лаек була), 100 меңнән артыграк татарстанлы орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә. 50 сугышчы Дан орденының тулы кавалеры дәрәҗәсенә ирешә. 300 меңнән артыграк татарстанлы яу кырында ятып кала, аларның тулы исемлеге *«Хәтер китабы»* («Книга Памяти») томнарында китерелә.

Чыг.: Г ы й л ь м а н о в Җ.И. Без сугышта юлбарыстан көчлебез. К., 1989; Татария в период Великой Отечественной войны (1941–1945 гг.): Сб. док. и материалов. К., 1963.

*Әд.:* С а б и р з я н о в Г.С. По законам дружбы и братства. К., 1974; Г и л ь м а н о в З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–45 гг. К., 1977; ш у л у к. Трудящиеся Татарии на фронтах Великой Отечественной войны. К., 1981; К а б и р о в а А.Ш. Республика Татарстан в годы Великой Отечественной войны (1941–1945 гг.). К., 1998; Татарстан в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. К., 2000.

*В.Ф.Телишев.*

**БӨЕ́К ВАТА́Н СУГЫШЫНДА́ ҺӘЛА́К БУЛГАННА́Р ҺӘЙКӘЛЕ́** (Казан), к. *Җиңү паркы.*

**БӨЕ́К ВЕ́НГРИЯ** (Magna Hungaria), венгрларның тарихи ватаны. Б.В. хакындагы мәгълүматлар венгр риваятьләрендә һәм тарихи чыганакларда (Anonymus. «Gesta Hungarorum» — «Венгр Анонимы хроникасы» һ.б.) сакланган. Бер легендада Б.В.нең скифлар биләмәсенә кергән бер өлкә булуы, Аттила нәселеннән булган юлбашчы Альмосның, бер сугышта җиңелүдән соң, үз халкының бер өлешен әлеге өлкәдән Дунай елгасы буена — Карпат таулары иңкүлегенә алып китүе турында әйтелә. 1235 елда доминиканлылар монахы *Юлиан* Көнчыгыш Чулман аръягына (яки Урал буйларының көнбатышына) сәяхәт итә һәм анда «ватаннарында яшәп калган» венгрларны очрата. Гарәп-фарсы сәяхәтчеләре дә 13 йөзнең 2 нче яртысында венгрларның элекке ватаны саналган *Баскарт* өлкәсен (гарәпчә «бәҗгәрд»тән үзгәртелгән дип фаразлана) шушы төбәктә дип күрсәтәләр. Көнбатыш Европа сәяхәтчеләре Плано Карпини, В.Рубрук, венгр тарихчылары, археологлары һәм тел белгечләре А.Вамбери, К.Цегледи, З.Гомбоц, К.Маккартни, Д.Немет, Ю.Мелих һ.б. Б.В. Төньяк Кавказ, Урта Азия һәм Көньяк Урал төбәкләрендә урнашкан дип исәплиләр. Археологлар (А.Х.Халиков, Е.А.Халикова, Н.А.Мәҗитов, Е.П.Казаков, В.А.Иванов) һәм тарихчы-этнологлар (И.Эрдели, И.Диенеш, И.Фодор, Р.Г.Кузиев, Д.Кришто, В.П.Шушарин һ.б.) алып барган тикшеренүләр нәтиҗәсендә, Б.В. угыр-маҗарлар, ш.и. венгрлар яшәгән, Көньяк Урал буйларын һәм Кама аръягының көнбатышын биләгән өлкә булган, дигән фикер ныгып урнашты. Бу караш Кушнаренко, Караякуп, Чиялек һ.б. археологик культуралар комплексларында табылган әйберләр б-н дәлилләнә. Урта гасырларда авторлар әлеге урыннарда «маҗар-бәҗгард-паскатир» халкы атамаларын йөртүчеләр яшәвенә ишарә итәләр.

Чыг.: А н н и н с к и й С.А. Известия венгерских миссионеров XIII–XIV вв. о татарах и Восточной Европе // Ист. архив. 1940. № 3; Путешествия в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957; Э р д е л и И. Извлечение из хроники Венгерского Анонима // Вопр. археологии Урала. Свердловск-Ижевск, 1967. Вып. 7; Anonymus. «Gesta Hungarorum». Bela kiraly jeggyzojenek konyve a magyarok cselekedeteirol. Bdpst., 1977; Die «Gesta Hungarorum» des anonymen Notars. Die älteste Darstellung der ungarischen Geschichte. Unter Mitarbeit von Veszpremy. L., 1991.

*Әд.:* Проблемы археологии и древней истории угров. М., 1972; Х а л и к о в а Е.А. Magna Hungaria // Вопр. истории. 1975. № 7; ш у л у к. Ранневенгерские памятники Нижнего Прикамья и Приуралья // Советская археология. 1976. № 3; К а з а к о в Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978; ш у л у к. Культура ранней Волжской Болгарии. М., 1992; Х а л и к о в А.Х. Новые исследования Больше-Тиганского могильника (о судьбе венгров, оставшихся на древней Родине) // Проблемы археологии степей Евразии: Советско-венгерский сб. Кемерово, 1984; С е д о в В.В. Венгры в Восточной Европе // Финно-угры и балты в эпоху средневековья. М., 1987; Проблемы древних угров на Южном Урале. Уфа, 1988; К у з е е в Р.Г. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала (Этногенетический взгляд на историю). М., 1992; Ш у ш а р и н В.П. Ранний этап этнической истории венгров: Проблемы этнического самосознания. М., 1997; И в а н о в В.А. Древние угры-мадьяры в Восточной Европе. Уфа, 1999; G o m b o c z Z. Die Bulgarisch – turkische Lehnwörter in der ungarischen Sprache. Hels., 1912; D i e n e s I. Les Hongrois con-

querants. Bdpst., 1972; B a t h a A. Hungarian Society in the 9-th and 10-th centuries. Bdpst., 1975; C h a l i k o v a E.A., C h a l i k o v A.H. Altungarn an der Kama und im Ural. Das Gräberfeld von Bolshie Tigani. Bdpst., 1981; F o d o r I. In search of a new Homeland. Bdpst., 1982.

*И.Л.Измайлов.*

**«БӨЕ́К ТАТА́РИЯ»** («Татария», «Тартария»), тарихи-географик атама. 16–17 йөзләрдә Көнбатыш Европа географлары һәм картографлары (С.Герберштейн, Д.Горсей, Д.Флетчер һ.б.) хезмәтләрендә «Б.Т.» атамасы төрки-монгол халыклары яшәгән Идел буе, Көньяк Себер һәм Үзәк Азия далаларына карата кулланыла. Кайбер очракларда «Б.Т.» атамасы Россия һәм үзәге Казанда урнашкан Урта Идел буйларын билгеләү өчен кулланылган. 18 йөз ахырыннан Җунгар ханлыгы б-н Монголия терр-ясе дә «Б.Т.» дип аталган (Гербилон һ.б.).

*Әд.:* К л ю ч е в с к и й В.Д. Сказание иностранцев о Московском государстве. П., 1918; Английские путешественники в Московском государстве в 16 в. Л., 1937; Г о л ь м а н М.И. Изучение истории Монголии на Западе (XIII — середина XX вв.). М., 1988.

*И.Л.Измайлов.*

**«БӨЕ́К ЧОР»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби, рәсемле журнал. ТАССР Язучылар берлегенең оештыру комитеты тарафыннан 1933–35 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә. *«Колхоз яшьләре»* һәм *«Атака»* ж-лларын берләштерүдән барлыкка килә; танылган язучылар И.Гази, Н.Баян, С.Гыйльфан, Ф.Кәрим, Г.Иделлеләрдән торган редакция коллегиясе җитәкли. Газетада респ-каның мәдәни тормышын яктыртуга аерым игътибар бирелә. Татар язучылары әсәрләреннән өзекләр, ТАССР, совет һәм чит илләрнең күренекле мәдәният эшлеклеләре турында материаллар, (Г.Ибраһимов, А.Серафимович, К.Станиславский, Стендаль һ.б.), Казан театрлары эше турында мәкаләләр басыла. «Б.ч.» битләрендә ш.у. хөкүмәт карарлары, рәсми документлар урын ала, беренче бишьеллык нәтиҗәләре, совет сәнәгате, фәне, а.х. өлкәләрендә ирешелгән уңышлар яктыртыла. Рубрикалары: «Яңалыклар», «Ленин васыятьләре үтәлә», «Истәлекле даталар» һ.б.

**БӨЕ́К ШӘҺӘ́Р**, к. *Биләр.*

**БӨЕ́Р СИНДРОМЛЫ́ ГЕМОРРА́ГИК БИЗГӘ́К**, көчле вирус авыруы, табигый чыганаклы, вирус таралышы, бизгәк көчәю, эчке агулану, бигрәк тә бөерләрдә тамырлар тышчасы зарарлану, тромбогеморрагик синдром көчәю б-н аерылып тора. Авыру кузгатучылар Bunyaviridae төренә карый. Корея геморрагик бизгәген китереп чыгаручы Hantaan вирусы (чыганагы Ерак Көнчыгышта, табигатьтә, 1934 елда Көньяк Корея, Кытай, Япониядә табыла, вирус йөртүче — кыр тычканы), эпидемик нефропатияне — Европа вариантын китереп чыгаручы Puumala вирусы (Россия, Финляндия, Швеция, Бельгия терр-ясендә, табигатьтә табылган) киң таралган. 1982 дән, Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы карары б-н, вирусның төрле вариантлары гомуми атама (БСГБ) б-н теркәлә. Йогышлы авыруның вируслы табигате СССР МФА академигы А.А.Смородинцев тарафыннан 1940 та исбатлана. Авыру 1950 елларда тасвирлана, 1976–78 дә вирус аерып алына. 2002 дә ТРда БСГБ б-н авыру 100 мең кешегә 10,3 очрак тәшкил итә, уртача авыр формаларда уза, үлем очрагы — 0,37%.

БСГБ Татарстан галимнәре тарафыннан 1960 еллардан башлап Казан мед. ун-ты һәм Казан мед. академиясенең йогышлы авырулар кафедрасында актив өйрәнелә (Т.А.Башкирёв, И.Г.Закиров, Д.К.Бәширова, Э.В.Горловская һ.б.).

*Әд.:* Б а ш к и р ё в Т.А. О дифференциальной диагностике геморрагической лихорадки с почечным синдромом в Среднем Поволжье // Казан. мед. журн. 1965. № 5; Ш у в а л о в Е.П. Инфекционные болезни. М., 1995; Клинико-эпидемиологические особенности ГЛПС в Республике Татарстан // Казан. мед. журн. 1999. № 3.

*В.Х.Фазылов.*

**БӨҖӘ́К ЧӘЧӘГЕ́** (Jasione), кыңгырау чәчәклеләр семьялыгыннан икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 төре бар, Европада һәм Кече Азиядә киң таралган. ТРда бер төре — тау Б.ч. (J. montana). Яшел Үзән һәм Югары Ослан р-ннарында очрый. Якты нарат урманнарында коры комлы туфракта, коры болыннарда үсә. 30–45 *см* озынлыктагы үсемлек. Тамыры орчыксыман, аз тармакланган. Сабаклары астан куе яфраклы, төкчәле, яфраксыз чәчәк сабына күчә торган. Яфраклары чиратлашкан, кыяклы-ланцетсыман, очлы, кырыйларыннан дулкынсыман яки бернникадәр бөдрә. Чәчәкләре вак, зәңгәрсу төсле, тыгыз шарсыман чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше — тартмачык. Июнь–июль айларында чәчәк ата. Орлыклардан үрчи. Яктылыкны ярата. Дару үләне (төнәтмәсе кан туктату һәм бәвел кудыру өчен файдаланыла). Баллы, декоратив үсемлек. Сирәгәеп бара торган төр. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БӨҖӘКЛӘ́Р** (Insecta), буынтыгаяклылар тибындагы хайваннар классы. Җирдәге хайваннарның борынгы (девоннан билгеле), иң күп санлы һәм төрле төркеме. 1 млн. чамасы төре билгеле, чынбарлыкта 1,5–2 млн. нан да ким булмавы ихтимал; Антарктидадан башка барлык континентларда да таралганнар. Татарстан терр-ясендә 25 меңгә якын төре исәпләнә (җитәрлек өйрәнелмәгән). Озынлыгы 0,2 *мм* дан алып 33 *см* га кадәр. Б.нең гәүдәләре өч өлештән: баш, күкрәк һәм корсактан тора. Тышкы яктан беркадәр каты хитин япма б-н капланган, ул тышкы скелет ролен үти һәм суның парга әйләнүенә комачаулый. Гәүдәнең хәрәкәтчәнлеге аның буынтыклар яки сегментлар сериясенә бүлгәләнүеннән килә, алар арасындагы хитин япма нечкә һәм сыгылмалы. Башында бер пар катлаулы, яки фасетлы һәм гади яки кечкенә күзләр бар. Мыекчаларының төзелеше гаять күптөрле һәм алар еш кына бүленешнең мөһим систематик билгесе булып хезмәт итәләр: җепсыман, кылсыман, муенсасыман, тешәүле, тараксыман, чукмарсыман, орчыксыман, пластинкалы, буынлы, каурыйлы һ.б. Еш кына мыекчалар төзелешендә җенси диморфизм күзәтелә: ата бөҗәк мыекчалары, ана затныкына караганда, ныграк үскән була. Авыз органнарының төзелеше, төрле туклану юлларына яраклашканлыктан, төрле була. Авыз аппаратының башлангыч тибы — кимерүче, ул каты азык — органик калдыклар, тере үсемлек һәм хайван азыгы кисәкләре б-н туклануга җайлашкан; таракансыманнар, турыканатлылар, коңгызлар өчен хас. Авыз органнарының башка типлары кимерүчеләрнең үзгәрешләр кичерүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Сыек азык б-н туклануга күчкән формаларның авыз органнары хортумчыклы суыручы авыз аппаратына әверелә. Авыз органнары аермалары буенча Б.не суыручы типтагы 2 төркемгә берләштерергә була: суыручылар (сыек азык субстратны тишмичә алына) һәм чәнчеп суыручылар (азык субстратны тишеп алына). Суыручы Б. (элпәканатлылар, тәңкә канатлылар, кан суырмаучы парканатлар) нектар һәм сыек органик азык, чәнчеп суыручы Б. (тигезканатлылар, кандалалар, трипслар, бетләр, борчалар һәм кан суыручы парканатлылар) үсемлекләрнең күзәнәк сыекчасы һәм хайваннар каны б-н тукланалар. Б.нең күкрәге 3 сегменттан — алгы, урта һәм арткы күкрәктән тора. Һәрбер сегментның берәр пар аягы, ә канатлы формаларының урта һәм арткы күкрәгендә ш.у. берәр пар канат бар. Яшәү рәвешенә һәм ярашу дәрәҗәсенә тәңгәл рәвештә күп кенә аяк типлары барлыкка килгән. Иң гадәти һәм иң аз ярашкан аяклар — йөрү һәм йөгерү өчен. Аючикерткәләр һәм кайбер коңгызларның алгы аяклары — казуга, суфи чикерткәләрнең алгы аяклары эләктереп алуга җайлашкан. Сикерүгә җайлашу арткы аякларны көчле юан ботлы сикерүче аякларга үзгәртә (турыканатлылар, яфрак борчачыклары — коңгызлар һ.б.) Су Б.нең арткы аяклары йөзүгә җайлашкан — киңәйгәннәр, кырыйларыннан төкләр б-н капланганнар. Урта пар аяк яраклашмый, чөнки ул һәрвакыт йөрүдә һәм йөгерүдә катнаша, һәм шунлыктан үзенең элеккеге функциясен аз үзгәртә. Корсагы 11 сегменттан тора, ләкин күбесенең сегмент саны 5–6 га кадәр кимегән. Ата бөҗәкләрнең популяция органнары, ә ана бөҗәкләрнең йомырка салгычлары үскән була. Б.нең күбесе трахея ярдәмендә атмосфера һавасы сулый; күрү, ис, тәм сизү, ишетү сәләтләренә ия. Б.нең үсеше өч яки дүрт фазадан гыйбарәт: йомырка, личинка, курчак (барысыныкы да түгел) һәм имаго (җитлеккән бөҗәк). Фаза саны буенча үсешнең 2 метаморфоз тибын аералар — тулы булмаган әверелеш (3 фаза) һәм тулы әверелеш (4 фаза, курчак стадиясен дә кертеп) юлы. Тулы булмаган әверелешле Б. личинкалары тышкы яктан зур бөҗәкләр б-н охшаш яшәү рәвеше алып бара. Личинкаларның тулы әверелеш юлы б-н үсешенә кабык салу да хас, шуның нигезендә гәүдә зурая һәм тышкы яктан үзгәрешләр хасил була. Кабык салулар саны өч (чебеннәр) яки дүрт-биштән алып (турыканатлылар, кандалалар, коңгызлар, күбәләкләр һ.б.) 25 кә кадәр (көнлекчеләр) үзгәрә. Б.нең күбесе — җир өстендә яшәүчеләр, күп кенә төрләре личинка фазасында яки барлык фазаларда да төче сулыкларда яшиләр; күбесе туфрак б-н бәйләнгән. Аларның үз-үзен тотышы катлаулы: азык эзләүдә ялгышмау, нәсел турында кайгырту,

еракка күчүләр, функцияләр бүленеше (умарта кортлары) һ.б. Б. матдәләрнең биол. өзлексез әйләнешендә һәм туфрак ясалуда зур роль уйный, үсемлекләрне серкәләндерә, кыйммәтле азык продуктлары һәм чимал (бал, балавыз, ефәк) бирә. Икенче яктан, Б. а.-х., урман һәм декоратив үсемлекләргә, азык продуктларына, агачка зарар китерә, кеше һәм хайваннарда төрле авыру кузгатучыларны күчерә. Б. дөньясының күптөрлелеген һәм үзенчәлеген, корткычларга каршы көрәш чараларын комплексы фән — энтомология өйрәнә. Соңгы вакытта, табигать биоценозларының кеше тарафыннан бозылуы нәтиҗәсендә, Б. санының кимүе күзәтелә. Б.нең 114 төре ТР ның Кызыл китабына кертелгән (2006; 1 нче бас. — 100 төр).


*Әд.:* Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1966; Я х о н т о в В.В. Экология насекомых. М., 1969; Ш о в е н Р. Мир насекомых. М., 1970; Ф а б р П. Насекомые. М., 1975; Историческое развитие класса насекомых. М., 1980; Редкие насекомые. М., 1982; Жизнь животных. М., 1984. Т. 3; Р о с с Г., Р о с с Ч., Р о с с Д. Энтомология. М., 1985; Красная книга Республики Татарстан. К., 2006.

*С.М.Шәфигуллина.*

**БӨККӘ́Н**, татар халкының милли ризыгы. Озынча түгәрәк яисә уракка охшаш формадагы бәлеш, әче яки төче камырдан мичтә пешерелә. Тышы урталай бөкләнеп, кырыйлары чеметеп ябыштырыла. Эченә, гадәттә, баллы булмаган ашамлык әйберләр (кәбестә, бәрәңге, ит, ярма, кабак, кишер) салына, туй мәҗлесләре өчен эченә корт, киптерелгән җимешләр салып, баллы Б. дә пешергәннәр.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в Ю.Ә. Татар ашлары. К., 1961; Х а й р у т д и н о в а Т.Х. Названия пищи в татарском языке. К., 1993.

**БӨРӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Вятка елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 48,4 *км* (ТР чикләрендә — 45 *км*), бассейнының мәйданы 678 *км*². Елга башы Балтач р-ының Борбаш авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кукмара р-ны терр-ясеннән ага, тамагы Киров өлкәсенең Түбән Бөре авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 162 *м*, тамагыныкы — 58 *м*. Б.елгасының су җыелу урыны — сызалар һәм кушылдык елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән калку тигезлек. Су җыелу мәйданының урманлылыгы күләме 11%. Б.нең 28 кушылдыгы бар, иң зурлары — Кенә (10,8 *км*) — уң кушылдык; Борбаш (18,6 *км*), Олы Китән (19,2 *км*), Кече Китән (18,2 *км*) сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,69 *км/км²*. Елга үзәне асимметрияле: сулъяк сөзәклекләре биек һәм текә, уң яктагылары — тәбәнәгрәк. Үзәнлек битләре күпсанлы тирән һәм тар ерымнар б-н ергаланган. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле үрге агымнарда 1–3 *л/с·км²*, елга тамагына таба 0,11–0,25 *л/с·км²* га кадәр. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 111 *мм*, ташу вакытындагы су катламы 96 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче декадасында башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,36 *м³/с*. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л* га кадәр. Б.е. бассейнында гомуми күләме 4,5 млн. *м³* булган 8 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.



Бөре елгасы. Кукмара р-ны Күкшел авылы янында.

**БӨРӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Кенәнең сул кушылдыгы. Озынлыгы 3,2 *км*, бассейнының мәйданы 19,4 *км²*. Кукмара р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Иштуган авылының көньягындагы чишмәләр, тамагы Иске Кенә-Юмья авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 116 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Б. елгасының 1,8 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,25 *км/км²*. Туенуы катнаш. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км²*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,065 *м³/с*.

**БӨРӘ́ РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* төньяк-көнбатышында. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1787 *км²*. Үзәге — Бөре шәһәре (Уфадан 102 *км* төньяктарак). Халкы — 61,08 мең (2006), ш.и. Бөредә 43226 кеше яши. Татарлар саны: 1970 тә — 8095, 1979 да — 7875, 1989 да — 8833, 2002 дә — 9043 кеше. 78 торак пункт, ш.и. 6 татар авылы: Яңа Яндыз (310 кеше), Шестыков (204), Аккаен (51), Үрнәк (20); 3 татар-башкорт авылы: Үгез (486 кеше), Үрге Лачынтау (297), Яңа Баеш (113). Татарларның күпчелеге Бөре шәһәрендә (2002 дә — 7683 кеше) яши. Район үзәгендә татар җәмәгатьчелеге съезды башкарма ком-ты һәм «Садко» шәһәр мәдәният йорты каршында «Өмет» милли-мәдәни клубы эшли. 1994 тән Бөре дәүләт социаль-педагогика академиясенең филология ф-тында татар теле һәм әдәбияты белгечләре әзерләнә. 2005/2006 уку елында 3 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла, 8 шәһәр, 7 авыл мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә.

**БӨРЕЛЕ́** т и м е р ю л р а з ъ е з д ы п о с ё л о г ы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 11 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Екатеринбург тимер юлы буенда. 2002 елда 123 кеше (руслар — 60%, татарлар — 37%) яши. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1949 да — 106, 1958 дә — 70, 1970 тә — 173, 1989 да — 89 кеше.

**«БӨРЕЛЕ́»**, Биектау р-нындагы агрофирма. 1930 елда «Кроликовод-1» җәнлек с-зы буларак оештырыла, 1936–94 тә — «Бөреле». Үзәк утары — «Бөреле» җәнлек с-зы поселогы. 1994 тән агрофирма. 1993 тә хуҗалыкка «Россия» к-зы, «Вперёд» с-зы, 1995 тә «Коркачык» күмәк пр-тиесе, «Тукай» ярдәмче хуҗалыгы, 1998 дә «Дружба» с-зы кушыла. А.х. җирләренең мәйданы 17079 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 13842 *га*. Хуҗалыкта 1898 эшче исәпләнә (1998). Төп җитештерү тармагы — мех җәнлекчелеге. «Б.» бу тармакны Татарстанда башлап җибәрүче, оештырылган көненнән алып читлектә җәнлек үрчетүне үстерү буенча әһәмиятле урын алып тора. Республикада оештырылган яңа җәнлек с-зларының эшчеләре аның базасында өйрәнү узалар. 1950 елларда биредә куяннарның кара-көрән (Ф.В.Никитин) һәм көмешсыман (И.И.Калевский) токымнары, көмешсыман-кара төлкенең промысел типлары чыгарыла, кешләрне читлектә асрау үзләштерелә. Җәнлек үрчетү — хуҗалыкның табыш бирә торган тармагы булып тора.

1990 елларда үзенә шактый колхоз һәм совхозлар кушылу нәтиҗәсендә «Б.» агрофирмасы күп тармаклы хуҗалыкка әверелә һәм җәнлекчелек продукциясеннән тыш, товарлыклы бөртекле ашлык, бәрәңге, яшелчә, ш.у. респ-ка өчен гадәти терлекчелек продукциясе әзерли.

«Б.» — югары культуралы игенчелек хуҗалыгы. А.х. җирләренең 100 *га* исәбенә 57,0 *ц* ит, 443 *ц* сөт җитештерелә (2000). Агрофирманың барлык җитештерү тармакларында заманча матди-техник база булдырылган, кыйммәтле мехларны беренчел эшкәртүдә сәнәгати сую башкарыла. Эшчеләр өчен кирәкле социаль-көнкүреш шартлары тудырылган: кибет, җәмәгать туклануы пр-тиеләре, кием-салым һәм баш киемнәре тегү ательелары, 2 балалар бакчасы, 6 мәдәният йорты, 2 хастаханә, 8 гомуми белем бирү һәм бер музыка мәктәбе эшли.

Җәнлекчелек тармагындагы уңышлары өчен 1971 елда хуҗалык Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм СССР ВДНХсының 4 дипломы б-н бүләкләнә. 1999 да «Б.» агрофирмасы җирлегендә «Җаббаров һәм К°» ышанычлылык ширкәте булдырыла, 2001 дә — «Бөреле» ЯАҖ, 2003 тә «Бөреле нәсел заводы» ААҖ оештырыла.

**БӨРЕЛЕ́ ҖӘНЛЕ́К СОВХОЗЫ́** посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2002 елда 2314 кеше (руслар — 50%, татарлар — 47%) яши. Халкының төп шөгыле — җәнлек үрчетү. Урта мәктәп һәм музыка мәктәбе. Мәдәният йорты. Китапханә. 1930 да нигез салына. Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963

нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1949 да — 1252, 1958 дә — 1604, 1970 тә — 1864, 1989 да — 1988 кеше.

**БӨРЕШЛЕ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 24 *км* көнбатыштарак, Юраш елгасы буенда. 2002 елда 178 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ибраш-Бөрешле исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, читкә китеп эшләү (Пермь губернасында утын кисү) б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б. дә тегермән, 1887 дә миссионерлык уч-щесе була. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире 1634,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Грахов волостена керә. 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны. 1859 да — 365, 1887 дә — 740, 1926 да — 1029, 1938 дә — 524, 1949 да — 418, 1958 дә — 386, 1970 тә — 356, 1979 да — 206, 1989 да — 126 кеше.

**БӨРКӘНЧЕ́К**, элекке заманда кәләшнең туй вакытында ябына торган зур яулык-япмасы. Кулдан тукылган ак юка тукымадан яки төсле киндердән (кызыл Б.), соңрак фабрика тукымасыннан әзерләнгән. Б.нең маңгай өлеше еш кына тәңкәләр, ука тасма б-н бизәлгән. Мәлки керәшеннәрендә туй япмасы вак көмеш тәңкәләр б-н сырылган тәкыяга итәкләндереп тегелгән. Б. туй киемнәре өстеннән бөркәнелгән һәм ияк астыннан тасма б-н бәйләнгән. Б. кәләшнең йөзен чит күзләрдән каплап торган, шул рәвешчә ул күз тиюдән саклый дип исәпләнгән. Б. туй йоласы үтәү өчен дә кулланылган: мәс., керәшен татарларда кияүгә чыккан кызның туганнарыннан берсе, кәләш янына Б. астына кереп, аңа «кәләш еглавы»н («әтәкәм җырлау») башкарырга булышкан. Чепья татарларында, мишәрләрдә һәм керәшеннәрдә «бөркәнчек ачу» йоласы булган, Б.нең бер читен уклау ярдәмендә күтәреп, туй кунакларына яшь киленнең йөзе күрсәтелгән, бу аның ир ягына кабул ителүен аңлаткан. 20 йөз башында, милли киемнәрнең башка бик күп элементлары б-н бергә, Б. тә кулланылыштан чыга. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан кәләшнең баш киеме сыйфатында фата куллану гадәткә керә.

*Әд.:* Мухаметшин Ю.Г. Татары — кряшены. М., 1977; Пермские татары. К., 1983; Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа. К., 1984; Приуральские татары. К., 1990; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

**БӨРКЕ́Т**, сәмруг кош (Aquila chrysaetos), карчыга кошлар семьялыгыннан эре ерткыч кош. Төньяк ярымшарның барлык урыннарында диярлек таралган. ТР терр-ясендә 20 йөзгә кадәр гадәти төр булып саналган, 1990 еллар ахырында 10 лап пар оя кора. Апрель аеннан октябрь аена кадәр очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 90 *см* га кадәр, канат җәеме 2 *м* га җитә, авырлыгы 6,5 *кг* га кадәр. Ана кошлар ата кошларга караганда шактый зуррак. Куе көрән, корсак



тирәсе ачыграк төстә. Башы һәм муены алтынсыман җирәнрәк. Койрыгы озын, түгәрәк, яшьләренеке — ак. Аяклары нык, бармакларына кадәр төкле, каты тырнаклы. Биек карт агач башларында оялый. Көрән тимгелле 1–2 аксыл йомырка сала. Тоткынлыкта үрчи ала. Имезүчеләр (куяннар, йомраннар, кайвакыт төлке һәм этләр), үләксә, сирәк кенә кошлар б-н туена. Кимерүчеләрне юк итүе б-н файда китерә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БӨРКЕ́Т КАНАТЫ́** (Pteridium), астәңкәчәләр семьялыгыннан абагалар ыругы. Ыругның бердәнбер төре — гади Б.к. (P.aquilinum) бөтен җир шары буйлап таралган һәм ТР терр-ясенең барлык р-ннарында да очрый. Нарат һәм катнаш урманнарда, коры комлы туфракта үсә. 45–120 *см* озынлыктагы күпьеллык үләнчел үсемлек, кара-коңгырт төстәге нык ботакланучан озын шуышма тамырчалы. Яфраклары — ялгыз, каты, ике яки өч каурыйсыман телмәләр. Яфрак сабының аскы өлеше киселешендә ачык күренеп торган күп тамырлы бәйләмнәр формалары б-н ике башлы бөркетне хәтерләтә (исеме шуннан). Һәрбер парлы яфрак төбендә баллы сыекча бүлеп чыгарыла, кырмыскаларны җәлеп итә торган нектарлыгы бар. Спорангияләре бөгелгән яфрак чите б-н капланган. Споралары август-сентябрьдә өлгерә. Тамырчадан үрчи. Тамырчасында 46% ка кадәр крахмал, дуплау матдәләре, сапониннар, алкалоидлар бар. Дәвалау үзлекләренә (бөрештерә һәм суалчан куа) ия. Декоратив, агулы үсемлек.



И.Б. Бөркетов.

**БӨРКЕ́ТОВ** Ибраһим Билал улы (1918, хәзерге Ульянов өлкәсенең Барыш р-ны Калда а. — 4.12.1943), Сов. Союзы Герое (13.11.1943), кече лейтенант (1943). 1938 елга кадәр туган авылында колхозда эшли. 1938 дән Кызыл Армиядә. 1943 тән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 40 нчы армиянең 337 нче укчы дивизиясе 616 нчы сапёрлар батальонында взвод командиры. Воронеж фронты гаскәрләре составында Курск сугышында (1943) һәм Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 16 сентябрендә Полтава өлкәсе Хорошки авылы янындагы бәрелешләрдә һәм 1943 нең 28 сентябрендә Черкас өлкәсе Каневск р-ны Зарубинцы авылы янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Яу кырында һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. Казан, 1990; Батырлар китабы. К., 2000; Ульяновцы в боях за Родину. Саратов. 1964.

*Н.И.Таиров.*

**БӨРСЕ́Т** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Каманың уң кушылдыгы. Озынлыгы 52,3 *км*, бассейнының мәйданы 552 $км^2$. Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Әрнәш авылыннан 3 *км* төньяктарак, тамагы Яңа посёлогыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 173 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Елга бассейны ерымнар һәм сызалар б-н нык

«Бөреле» агрофирмасы. 1. Кара-көрән куян; 2. Ак төлке; 3. Көмешсыман-кара төлке.









Бөрсет елгасының түбән агымы.

кисешкән калкулыклы тигезлек. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 34%. Б. елгасының 2 *км* дан алып 22,8 *км* га кадәр озынлыктагы 32 кушылдыгы бар, иң зурысы — Сон елгасы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*$^2$. Б.нең үзәне асимметрияле сул як яр битләре, биек һәм текә, елга тамагы өлешендә үзәннең киңлеге 2–3 *км* га кадәр. Тугае тар. Елга юлы бормалы, киңлеге 5–8 *м*. Елганың тирәнлеге 1–1,5 *м* га кадәр, сай урыннарда 0,3–0,7 *м*. Елга режимы 1935 елдан башлап Урманчы авылы янындагы су үлчәү постында өйрәнелә. Агым тизлеге сай урыннарда 0,5–1 *м/с*, тирән урыннарда 0,2–0,3 *м/с*. Елга күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–5 *л/с·км*$^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н сыйфатлана. Язгы ташу вакытына еллык су агымының 70% чамасы туры килә. Урманчы авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәлеше 3,3 *м* (макс. 4,9 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 170 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче декадасында башлана. Елга ноябрьнең беренче декадасында туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 65 *см* га җитә. Елга тамагында су иң аз вакыттагы уртача күпьеллык чыгымы 1,43 *м*$^3$*/с*. Урманчы авылы янында уртача еллык су чыгымы 2,55 *м*$^3$*/с* тәшкил итә. Суның иң зур чыгымы — 274 *м*$^3$*/с* — 1979 елның язында билгеләнә. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 150–250 *мг/л*, кышын һәм җәен 600 *мг/л* га кадәр. Ташу вакытында елгада суның болганчыклыгы 1500 *г/м*$^3$ га җитә. Елга утырмаларының уртача еллык күләме 130 мең *т* га тигез. Б. бассейнында гомуми күләме 1,9 млн. *м*$^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Б. бассейнында ТРның табигать истәлеге *Бөрсет акчыршылыклары* урнашкан. Елга ТРның табигать истәлеге дип билгеләнгән (1978).

**БӨРСЕ́Т** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 62 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кама елгасы буенда. 2002 елда 120 кеше (руслар — 59%, татарлар — 37%) яши. Урта мәктәп. Пристань. «*Бөрсет*» ял йорты. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Мамадыш кантоны Омар волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1926 да — 32, 1970 тә — 107, 1979 да — 82, 1989 да — 97 кеше.

**«БӨРСЕ́Т»**, ял йорты, Кама елгасының уңъяк ярында, Бөрсет урман хуҗалыгына кушылып китә торган нарат паркында урнашкан (Чистай шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак). 1920 елларда нигез салына. Ял йортыннан көнбатышка таба Бөрсет елгасы тамагының сулъяк ярында урман күле җәелгән. «Б.» 600 урынга исәпләнгән 5 катлы бинаны били. Ял итүчеләргә комлы яр,



«Бөрсет» ял йорты. Торак корпус.

көймәләр станциясе, тренажёрлар, балалар һәм спорт мәйданчыклары, уку залы б-н китапханә, бильярд бүлмәсе һ.б. тәкъдим ителә. Савыктыру чаралары: физиотерапия, массаж, фитобар. Май аеннан октябрьгә кадәр эшли.

*Әд.:* Блюмштейн П.Н. Курорты Татарии. К., 1970.

**БӨРСЕ́Т АК ЧЫРШЫЛЫКЛАРЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге. Балык Бистәсе һәм Мамадыш р-ннары терр-ясендә урнашкан. 1972 елда теркәлә. Кама урман хуҗалыгының Кама һәм Бөрсет урманчылыклары





«Бөрсет» ял йорты. Пляж.

массивында урнашкан; ак чыршы ареалының көньяк чиге Себер ак чыршылары б-н катнашкан аерым кварталларны били. Мәйданы — 170 *га*. Кама елгасының төп яр битләрендәге Пермь чорының карбонатлы комсыл балчыкларында ак чыршы катнаш киң яфраклы урманнар үскән 2 участоктан һәм Бөрсет елгасының югары террасасы битләрендәге ком утырмаларында нарат, каен һәм усак урманнары б-н аралаш үскән ак чыршы — киң яфраклы урман участогыннан гыйбәрәт. Киң яфраклы агач токымнарыннан — юкә, элмә, өрәңге һәм имән, куаклардан — шомырт, миләш, чикләвек һ.б., үләнчел үсемлекләрдән — сәрдә, йончыл күрән, күпьеллык зибык уты, калканлы абага, тайтояк, яссы будра, кызыл бөрлегән, каен җиләге, кымызлык үсә. Чыршы һәм ак чыршы 120 ел үсә, кәүсәсенең диаметры — 0,6 *м*, куелыгы 0,7–0,8 *м* га кадәр җитә. Сирәк очрый торган җәнлекләрдән — борындык күренгәли. Б.а.ч.ларына антропоген факторларының тәэсире көчле.

*Әд.:* Порфирьев В.С. Вопросы изучения и охраны лесного растительного покрова Татарской АССР и сопредельных территорий // Охрана природы и биогеоценология. К., 1975.

**«БӨРСЕ́Т» ҖӘНЛЕ́К СОВХОЗЫ́** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 56 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2002 елда 933 кеше (татарлар — 68%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, җәнлек үрчетү. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 19 йөздә нигез салына. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1970 тә — 912, 1979 да — 810, 1989 да — 811 кеше.

**БӨРСЕ́Т-СУКАЧЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 44 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасыннан 1 *км* читтә. 2002 елда 278 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. Клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз рус чыганакларында Кокачей исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире



**Бөртекләү.** 1. Чәч толымы бизәге — чулпы. Көмеш, фирүзә, пыяла. Җепкыр, бөртекләү, алтын йөгертү. 19 йөз. ТР Милли музее; 2. Чигә асылмасы. Электрум. Җепкыр, бөртекләү. 10–12 йөзләр. ТР Милли музее; 3. Бил каешы каптырмасы. Алтын. Җепкыр, бөртекләү. 15–16 йөзләр. Дәүләт Корал палатасы; 4. Бөти савыты. Көмеш, фирүзә, кою. 18–19 йөзләр. ТР Милли музее.

640,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 75 ир заты; 1859 да — 399, 1897 дә — 579, 1908 дә — 677, 1920 дә — 690, 1926 да — 707, 1938 дә — 762, 1949 да — 497, 1958 дә — 459, 1970 тә — 437, 1979 да — 394, 1989 да — 309 кеше.

**БӨРТЕ́К (АШЛЫ́К) КОҢГЫЗЛАРЫ́** (Bruchidae), коңгызлар семьялыгы. Өске кат канатлары кыскарак түгәрәк вак коңгызлар. Башы озынча, күкрәгенә таба юнәлгән. Личинкалары күбесенчә кузаклы үсемлек орлыкларында яши. Дөнья фаунасында 1200ләп, Россия терр-ясендә 100 дән артык төре билгеле. Татарстанда кузаклы культураларга бик нык зыян китерүче борчак коңгызы (Bruchus pisorum) киң таралган (борчакны зарарлый). Б.к. 4,5–5 *мм* озынлыкта, кара төстә, сары һәм ак төкчәле. Өске канатларын арткы як өлешендә аерым тимгелләргә бүленгән ак төкчәле кыйгач тасмасы бар; өске кат канат очында карасу төстәге фонда кечкенә генә 2–3 аксыл табы бар. Зур коңгызлар чәчәкнең серкәсе һ.б. өлешләре б-н туеналар һәм уңышка зыяннары тими. Ана коңгыз камчысыман 2 үсентеле, 0,8 *мм* чамасы озынлыктагы, сары төстәге озынча түгәрәк йомырка сала. Личинкасы 5–6 *мм* озынлыкта, аксыл сары төстә, кечкенә, эчкә баткан башы гәүдәсенең калынайган күкрәк өлешендә. Казналыклары кызгылт көрән төстә, гәүдәсе шәрә, фәкать күкрәгенең аскы өлеше кыска төк б-н капланган. Коңгызлар салам эскертләрендә, үсемлек калдыклары арасында, агач кайрылары астында, ашлык амбарларында, борчак өемнәрендә кышлыйлар. Борчак коңгызы орлыкны боза: үсеш дәверендә личинка орлыкның туклыклы өлешен, ягъни эчен ашап бетерә, орлык шыту сәләтен югалта, моннан тыш, личинка экскрементларында кеше һәм хайваннар сәламәтлегенә зыян китерә торган алкалоид контаридин бар, шуңа күрә зарарланган орлыкны азык буларак кулланырга да, хайваннарга ашатырга да ярамый.
*А.К.Жеребцов.*

**БӨРТЕКЛӘ́Ү**, зәргәрчелек сәнгатендә бизәмә әйберләр өслегенә алтын яисә көмеш бөртекләрен эретеп ябыштыру ысулы; зәргәрчелек техникасының бер төре. Татар халкында бөртек ясау һәм аны бизәмә өслегенә ябыштыру техникасы «арпалау» дип тә йөртелгән. Бер үк зурлыктагы бөртекне күпләп ясау өчен оста, гадәттә, бер үк калынлыктагы һәм озынлыктагы металл чыбыкны цилиндр калыпка урый, аннан соң хасил булган спиральне кискәли. Бер төрле зурлыктагы әлеге чыбык кисәкләрен эскәк ярдәмендә агач күмере өстендәге түгәрәк чокырларга урнаштыра һәм эретү лампасы ялкынын юнәлтә, эрегән чыбыклар бөртек булып катып кала. Гадәттә, бөртек җепкыр бизәк очына яисә бөтен бизәлеш өслегенә ябыштырыла, әйберне өлешчә тасма рәвешендә бөртекләү бизәге б-н каймалый; борынгы бизәмә үрнәкләрендә бөртекләү өчпочмак, ромб һәм кабарынкы пирамидалар рәвешендәге бизәкләр хасил итә.

Б. борынгы һәм элгәреге болгар дәверләренә караган археол. казылмаларда ук очрый. Кырымдагы һун каберлекләрендә (бөртекләү б-н бизәлгән мичкә формасындагы чигә асылмалары), Көнчыгыш Европа терр-ясендә табылган зәргәрчелек әсәрләренең бизәлеше болгар Б. сәнгатенә якын. Болгарларның бөртекләп бизәү ысулы Төньяк Кара диңгез буендагы грек шәһәр-колонияләренең антик зәркән сәнгатенә дә хас (алан-сарматларның куыш каберләре, скиф курганнары). Идел буендагы казу эшләре вакытында 8–12 йөзләрдәге болгар бизәмәләрен хәтерләткән өчпочмаклар, пирамидалар рәвешендә бөртекләп бизәлгән зәркән әйберләре (имән чикләвеге формасындагы асылмалар муенсалар, алкалар, чигә асылмалары) Днепр буендагы курганнарда (Серогоз курганнары), ш.у. Тамань ярымутравында, Херсонеста, Пантикапей, Ольвия, Феодосия курганнарында, Кырымдагы Бөек Болгар һәм Хәзәр каганлыгы дәверенә караган башка каберлекләрдә табыла. Алтыннан һәм электрумнан үрдәк сыны кебек итеп эшләнгән чигә асылмалары Идел буе болгарларында Б. ысулы б-н эшләнгән бизәмәләрнең гүзәл үрнәге булып тора (алар Эрмитаж, Мәскәүдәге Тарих музее, ТР Милли музее фондларында саклана). Алтын Урда дәвере зәркән эшләнмәләре арасында Б. бөти каптырмаларында, *беләзекләрдә*, йөзекләрдә һ.б.да асылташлар б-н каймаланган буй-буй сызыклы, өчпочмаклы бизәкләр рәвешендә очрый. Казан ханлыгы дәвереннән сакланып калган уникаль әйберләрдә (Мәскәүдә Корал палатасы, С.-Петербургта Россия халыклары этнография музее фондларындагы *Коръән тартмачыгы*, камәр, каптырмалар) Б. *җепкырны* матурлата, баета торган ысул буларак кулланылган. Б. чәчәк гонҗәсе рәвешендә җепкыр очларына, металл җепселләр арасына ябыштырыла. 18 йөз — 20 йөз башы татар сәнгатендә Б. *яка чылбырлары*, *чулпы*, *беләзек*, алка, сәдәфләр, зәркән аеллар һ.б. бизәлешендә фәкать җепкыр б-н бергә кулланыла. Йөзекләрдәге бөртекләр аларның читләрен каймалый һәм еш кына түгәрәк, озынча түгәрәк яисә квадрат рәвешендәге асылташ оясын уратып ябыштырыла. Коръән тартмачыклары өстендә Б. буй-буй сызыклар һәм чәчәк гонҗәләре рәвешендә урнаштырыла. Бөтеркәле Б. бизәкләренең популярлыгы *күпертмә җепкыр* техникасы барлыкка килүгә этәргеч бирә. Б. хәзерге заман зәргәрчелек эшләнмәләре муенсалар, беләзекләр, йөзекләр, алкалар бизәлешендә кулланыла.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Ефимова А. Бутаевский клад ювелирных изделий волжских булгар // Советская археология. 1960. № 3; Виноградов В.Б. Сарматы северо-восточного Кавказа. Грозный, 1963; Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; Шулук. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Татарская филигрань: в контексте генезиса и развития ювелирного искусства // Из истории татарского народного искусства. К., 1995.
*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**БӨРТЕКЛЕ́ АШЛЫ́К КУЛЬТУ́РАЛАРЫ**, нигездә бөртекле ашлык алу өчен игелә торган үсемлекләрнең мөһим төркеме. Бу культураларның орлыклары азык-төлек һәм терлек азыгы буларак әһәмиятле, он тарту, ярма яру, катнаш азык сәнәгате өчен чимал булып тора. Ашлык эшкәртү продуктлары икмәк

пешерүдә, макарон һәм кондитер әйберләр, ашамлык концентратлар, консервлар, ш.у. сәнәгатьнең сыра кайнату һәм спирт җитештерү тармакларында кулланыла. Б.а.к. шартлы рәвештә берничә бүлекчәгә бүленә: икмәк культуралары — арыш, бодай; терлек азыгы — арпа, солы, кукуруз, сорго һ.б.; кузаклылар — борчак, вика, ясмык, нут, соя, фасоль һ.б.; ярма культуралары — карабодай, тары һ.б. Барлык төр кыяклыларның да тамыр системасы чуксыман, сабаклары эче куышлы төенләнешләр б-н бүленгән. Арыш, бодай, туры, арпа, солы җылыга артык таләпчән түгел, алар шытып чыкканда берничә вак тамыр (корешок) барлыкка килә; кукуруз, карабодай, тары, сорго җылыга таләпчән, аларга бер генә кечкенә төп ясала. Чәчәк төркеменә карап башаклыларга (арыш, бодай, арпа) һәм себеркәчләргә (солы, тары, сорго) аерыла. Үсеш һәм вегетация чоры дәвамлылыгына карап Б.а.к. уҗым һәм сабан культураларына бүленә.

Татарстанда Б.а.к. уңышы (1 *га* җирдән *ц* ларда): 1925–29 елларда — 5,9, 1933 тә — 8,9, 1937 дә — 11,9, 1980 еллар ахырында — 20, табигать шартлары уңай килгән 1997, 2001, 2002, 2003, 2004, 2006 елларда — 35,1, 35,8, 35,2, 34,9, 27,5, 29,2. 20 йөздә игенчелекнең фәнни алымнарын (алмаш чәчү әйләнеше, җирнең сөрү катламын тирәнәйтү, басуларга тирес һәм минераль ашламалар кертү, җирле шартларга яраклаштырылган сортлы орлыклар чәчү һ.б.) куллану нәтиҗәсендә традицион культураларның (арыш, солы һ.б.) уңдырышлылыгын арттыру гына түгел, туфракның уңдырышлылыгын күтәрү хисабына даими игелеп килгән культураларның ассортиментын тулыландыру мөмкинлеге дә бирә. Уңдырышлы «бодай» туфрагы таләп иткән һәм 1920 елларда сөрү җирләренең 2,2% ын гына биләгән сабан бодае 2001–06 да мөһим азык культурасына (14,5–17%) әверелә. Шуның нәтиҗәсендә бодай күмәче халыкның туклану рационында төп урынны алып тора. Б.а.к. игү буенча кыр эшләре нигездә тулысынча механикалаштырылган. Бодай, арыш, солы, арпа күбесенчә *интенсив технологияләр* нигезендә игелә. Чәчүлекләрнең кабул ителгән структурасын саклау һәм аларның уңышын күтәрү максатын күздә тотып, зона, агроландшафт, басу шартларына яраклаштырылган игенчелек системалары үзләштерелә, сортларның составы яхшыртыла, һәр культураның үзенә генә хас агротехника алымнары камилләштерелә. Алдынгы хуҗалыкларда сабан бодаен ашланган, туңга сөрелгән, борчактан, күпьеллык үсемлекләрдән бушаган туфракка чәчәләр; туңга сөрү, чәчү алдыннан туфракны эшкәртү системаларын саклыйлар, югары уңыш алуга исәпләп кирәк кадәр ашлама кертәләр, иртә срокта зона өчен районлаштырылган, чәчү нормасы буенча шытуга сәләтле 5–6 млн. орлык чәчәләр; чәчүлекләрне авырулардан, зарарлы бөҗәкләрдән һәм чүп үләннәрдән саклау чараларын күрәләр. Уҗым культураларын (арыш, бодай) чәчкәндә туфракка исәпләнгән нормада ашлама кертәләр, җирнең сөрү катлавын чүп үләннәрдән арындыралар (чиста пар җирләрен катламлы эшкәртү юлы б-н), чәчү өчен яраклы сортлар сайлап алалар, чәчү срогын төгәл үтиләр. Калку урыннарда кышын кар тоталар, иңкүрәк җирләрдәге уҗымнарны, череп борсымасын өчен, көздән фундазол яки башка шуңа охшаш препаратлар б-н эшкәртәләр. Язын тырмалыйлар, кирәк булса, өстәмә тукландыру үткәрәләр.

ТРда бөртекле ашлык культуралары уңышы (1 *га* дан *ц* ларда)

| Культура | 2001 | 2002 | 2003 | 2004 | 2005 | 2006 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Уҗым бодае | 37,6 | 41,3 | 32,2 | 27,5 | 28,1 | 34,4 |
| Арыш | 40,5 | 40,1 | 37,9 | 23,9 | 25,6 | 29,4 |
| Сабан бодае | 36,8 | 34,0 | 39,5 | 27,6 | 28,5 | 28,8 |
| Арпа | 38,9 | 37,7 | 39,9 | 31,8 | 34,3 | 30,7 |
| Солы | 35,7 | 35,2 | 37,4 | 28,4 | 28,3 | 27,7 |
| Кукуруза | 59,6 | 40,7 | ... | — | 63,9 | 57,8 |
| Тары | 17,9 | 18,6 | 23,1 | 21,2 | 24,0 | 20,6 |
| Карабодай | 11,8 | 11,5 | 13,5 | 11,8 | 13,4 | 12,7 |

Чыг.: Сельское хозяйство Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2007.

*Әд.:* Растениеводство. М., 1997; Зиганшин А.А. Современные технологии и программирование урожайности. К., 2001; Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*А.А.Җиһаншин.*

**БӨРТЕКЛЕ́ АШЛЫ́К ХУҖАЛЫГЫ́**, бөртекле ашлык җитештерү, бүлү һәм сату; а.х.ның иң мөһим тармакларыннан берсе. ТРның үсемлекчелектән алган тулай продукциясе кыйммәтенең чагыштырма өлеше (% ларда): 1996 да — 33,2, 1997 — 54,7, 1998 — 22,5, 1999 — 29,7, 2000 дә — 53,4% тәшкил итә. 1913 елда Татарстанда (хәзерге чикләрендә) бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар 2404,8 мең *га* җир били (барлык чәчү мәйданының 96,5% ы), шуннан 1905,7 мең *т* ашлык җыела, 1 *га* җирдән 7,9 *ц* уңыш алына. Төп җитештерүчеләр — вак крәстиян хуҗалыклары. А.х.ын күмәкләштергәннән соң Б.а.х. киңәйтелгән масштабта үсеп китә. Бөртекле ашлык культуралары (мең га да): 1934 тә — 2926,2; 1940 — 2633,7; 1960 — 2306,2; 1990 — 2393,6; 2000 — 1543,6; 2006 да — 1547,9 (чәчү мәйданының 52,7%ы) мәйданда игелә. Соңгы елларда бөртекле ашлык культураларын чәчү структурасында уҗым бодае, арпа, карабодайның чагыштырма өлеше арта, арыш, солы, борчакныкы кими.

ТРда бөртекле ашлык культураларының чәчү мәйданы структурасы (гомуми мәйданга карата % ларда)

| Культуралар | 1960 | 1991–95 | 1996–2000 | 2006 |
|---|---|---|---|---|
| | | 1 елга уртача | | |
| Уҗым культуралары, ш.и. | 42,3 | 29,4 | 23,8 | 18,4 |
| бодай | 0,2 | 5,3 | 4,0 | 7,1 |
| арыш | 42,1 | 24,1 | 19,8 | 11,3 |
| Язгы культуралар, ш.и. | 57,7 | 70,6 | 76,2 | 81,6 |
| бодай | 32,4 | 27,5 | 34,5 | 37,8 |
| кукуруза | ... | 1,7 | 1,2 | 1,0 |
| арпа | 17,9 | 16,2 | 20,4 | 29,4 |
| солы | 12,2 | 10,5 | 10,0 | 5,2 |
| тары | 1,8 | 0,5 | 1,1 | 0,5 |
| карабодай | 2,9 | 3,1 | 2,9 | 2,3 |
| борчак | 4,6 | 9,1 | 4,4 | 3,5 |

ТРда Б.а.х. авыл хуҗалыгының техник яктан тәэмин ителеше, механикалаштыру, химияләштерү, җирләрне химик мелиорацияләү, орлыкчылыкны, селекцияне яхшырту, сортларны яңарту, үсемлекләрне чүп үләннәрдән, зарарлы бөҗәкләрдән, авырулардан саклау чараларын куллану, заманча технологияләр, уңыш алуны программалаштыруны кертү нигезендә үстерелә.

2006 ел ахырына ТРның а.х. пр-тиеләрендә 16,7 мең трактор, 4,5 мең сабан, 4 мең ашлык урып-җыю комбайны, 2,3 мең теземнәргә салу ургычы, 7,7 меңнән артык чәчү машинасы, 1,1 мең ашлык киптерү, 1,4 мең орлык чистарту һәм чистарту-киптерү комплексы исәпләнә. 1 комбайнга 386 *га* җир туры килә. 2006 да а.х.ның энергия б-н тәэмин ителеше, 1 елга 1 кешегә күчереп исәпләгәндә, 47,9 ат көче тәшкил итә, һәр 100 *га* чәчүлек җиргә 205 *ат көче* туры килә (1980 дә тиңдәшле рәвештә 22,2 һәм 210 ат көче). 2001–06 да респ-када 903,8 мең *га* ачы туфраклы җиргә 6 млн 770 мең *т* известьле ашлама кертелгән. 2006 да 1 *га* җиргә 69 *кг* файдалы минераль ашлама кертелгән. Уңышны күтәрүгә сортлы орлык чәчү (100%, ш.и. 78% районлашкан сортлар); чәчү стандартының 1 нче һәм 2 нче класслы орлыкларын чәчү (89%); элиталы (аерым үсемлекләрнең иң яхшы төрләре) һәм югары (1–5) репродукцияләре (79%); орлыкларны инкрустацияләү (100%); 2062 мең *га* да чүп үләннән, 787 мең *га* мәйданда зарарлы бөҗәкләрдән, 414 мең *га* да авырулардан үсемлекләрне хим. саклау чаралары үткәрү нәтиҗәсендә ирешелә. 2006 да ашлыкның тулай җыемы 4 млн. 501,2 мең *т* тәшкил итә, җан башына 1202 *кг* ашлык туры килә (1980 дә — 940, 1960 та — 812, 1920 дә — 230 *кг* булган).

ТРда бөртекле ашлыкның тулай җыемы (мең *т*)

| Культуралар | 1960 | 1980 | 2000 | 2006 |
|---|---|---|---|---|
| Бөртекле культуралар, барлыгы | 2317,2 | 3232,2 | 3612,8 | 4522,7 |
| шулардан: | | | | |
| уҗым бодае | 5,5 | 124,0 | 166,4 | 381,4 |
| арыш | 1056,3 | 454,2 | 855,4 | 513,5 |
| язгы бодай | 800,3 | 1389,5 | 999,2 | 1682,6 |
| арпа | 39,9 | 565,4 | 867,3 | 1420,5 |
| солы | 214,5 | 250,3 | 155,7 | 224,2 |
| тары | 23,8 | 10,3 | 20,0 | 14,8 |
| карабодай | 20,3 | 55,9 | 65,0 | 45,1 |
| борчак | 86,9 | 347,1 | 98,6 | 99,5 |

Бөртекле ашлык культуралары уңышы (1 *га* җирдән *ц* ларда): 1920 елда — 3,9, 1940 — 7, 1980 — 10, 1990 — 13,5, 2000 — 23,4, 2006 — 29,2. 2005 тә иң югары уңышны (1 *га* җирдән *ц* ларда) Нурлат р-ны — 48, Балтач — 34,8, Актаныш — 37,4, Буа — 39,2 р-ннары җыеп алды. ТРда ашлык җитештерү буенча иң югары чагыштырма күләмгә (%ларда) Буа — 4,87, Арча — 4,4, Нурлат — 4,86, Актаныш — 4,04 р-ннары ирешә. 2000, 2001, 2002, 2003, 2004, 2005 һәм 2006 елларда Татарстан ашлык җитештерү буенча Идел буе федераль округында 1 нче урынны алып тора, РФнең тулай ашлык җыемында ТРның өлеше 5,02, 6,56, 5,91, 6,86, 4,92, 5,28 һәм 5,29% тәшкил итә. 2001–06 елларда уртача еллык ашлык сату 1 млн. 490 мең *т*, яки тулай җыемның 35,2% ын тәшкил итә. 2006 да 1 млн

731,3 мең *т* ашлык сатылган, ш.и. бодай — 52,9%, арыш — 13,9%, арпа — 25,4%, солы — 1,1 %, тары — 0,01%, карабодай — 0,43%, борчак — 1,8% ын алып тора. Ш.у.к.: *Ашлык әзерләү һәм эшкәртү*.

Чыг.: Республика Татарстан 1920–2000: Стат. сб. К., 2001; Сельское хозяйство Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2007.

*Әд.:* З и я т д и н о в Ф.С. Ресурсный потенциал агропромышленного комплекса: анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001; Слагаемые эффективного агробизнеса: обобщение опыта и рекомендации — земледелие и растениеводство. К., 2005.

*И.Н.Афанасьев.*

**БӨРТЕКЛЕ́-КУЗАКЛЫ́ КУЛЬТУ́РАЛАР**, кузаклы үсемлекләр семьялыгыннан үләнчел үсемлекләр, аксымга һәм аминокислоталарга бай бөртекле ашлык һәм терлек азыгы буларак игелә. Б.к.к.ның җир өстендә үсә торган сабаклары өчен кирәкле азотны һавадан ала, туфракта элек тупланган азот запасы аннан соң чәчеләсе культуралар өчен саклана, шуның өстенә, тамырлары бүлбе бактерияләре б-н кушылып, туфрактагы азот күләмен арттыра.

ТРның туфрак-климат шартлары борчак, ясмык, вика, чина игү өчен дә уңай. Фасоль, сояның иртә өлгерешле сортлары, ш.у. терлек азыгы борчагы, ногыт, люпин үсәргә мөмкин.

Бер бөртек борчакның коры матдәсендә уртача 27,8% аксым, викада — 33,7, ясмыкта — 30,4, чинада — 28,7, фасольдә — 24,3, сояда — 39, нутта — 24,5, тар яфраклы люпинда 32,3% аксым туплана. Соя б-н люпин — майлы культуралар. Борчакның 1 *кг* азык берәмлегенә 181 *г* үзләштерүле протеин туры килә, викада — 189, люпинда — 245, ногытта — 211 *г*. Борчакның майсызландырылган коры аксымында 11,42% аргинин, 2,48% гистидин, 1,17% триптофан, 4,66% лизин, 1,63% метионин туплана. Бөртекле-кузаклыларның саламы да аксымга бай, бөртекле кыяклыларга караганда 2–3 тапкыр артыграк. Шуның өчен дә углеводлы азыкларда 1 азык берәмлегендәге протеин микъдарын зоотехния нормаларына туры китерү өчен аларга кузаклыларны кушалар.

2006 елда ТРда кузаклы культуралардан борчак (51,9 мең *га*) һәм орлык өчен вика катнашмалары (25,2 мең *га*) зур мәйданнарда игелә. Борчакның «Труженик» (1984 тән), «Казанец» (1996 дан), «Таң» (2001 дән), «Флагман» (2004), «Венец» (2005) сортлары, «Татарстан 2» (терлек азыгы итеп 2001 дән), язгы виканың «Луговская 83» (1988), «ЛОС 5» (2000); уҗым викасының «Юбилейная» (1978) сортлары Татарстанда игелүгә тәкъдим ителә. Борчакны кузаксыз культуралар уңышын җыеп алганнан соң, йомшартылган, тирән итеп туңга сөрелгән, югары уңыш алуга исәпләп кирәк кадәр фосфорлы, калийлы һәм өчтән бер өлеш азотлы ашламалар кертеп, 1 нче класслы орлыкны уртача балчыксыл туфракка 6–8 *см* тирәнлектә күмдереп чәчәләр, чәчү нормасы — 1 *га* мәйданга шытуга сәләтле 1,2–1,3 млн орлык. Чәчүлекләрне амбар коңгызыннан, үлән бете һәм төш корткычыннан саклау чаралары үткәрелә. Уңыш кузаклыларны урып-җыю өчен җайлаштырылган комбайннар ярдәмендә җыела. Вика үстергәндә, туфракны яхшылап әзерләү һәм ашлаудан башка, катнаштырыла торган культуралар нисбәтенә игътибар итәргә кирәк. Солылы вика иккәндә 1 *га* җиргә шытуга сәләтле 2,5 млн вика, 1,25 млн солы орлыгы алына. Кошчылык яки дуңгызчылык өчен югары дәрәҗәдә протеинлы бөртек катнашмасы 2,5:3,75 млн. нисбәттә чәчелә. Чәчүлек өчен орлык кузакның түбәнге яруслары балавызсыман өлгерештә булганда җыела. Орлык теземнәрдә яхшы өлгерә. Борчакның 80–90%ы өлгергәч, сөрлекмәгән чәчүлекләрне турыдан-туры комбайн б-н урдырырга мөмкин.

*Әд.:* Б о д н а р П.В., Л а в р и н е н к о Г.Г. Зернобобовые культуры. М., 1977; З и г а н ш и н А.А. Современные технологии и программирование урожайности. К., 2001.

*А.А.Җиһаншин.*

**БӨРЧЕКЛЕЛӘ́Р** (Pisidiidae), төче сулыкларда яшәүче ике кабырчыклы моллюсклар классы. Ике кабырчыклылар классының иң кечкенә төрләре, гәүдә озынлыгы 20 *мм* га (еш кына 5 *мм*) кадәр җитә. Кабырчыгы озынча түгәрәк яки йомыркасыман. Агымсулы һәм агымсыз сулыкларда таралган. Б. нең систематикасы җитәрлек дәрәҗәдә эшләнмәгән, шунлыктан ТР терр-ясендә төрләрнең төгәл саны билгесез. Гадәти төрләре — P. amnicum, P. nitidum, Euglesa henslowana, E. casertana. Балыкларга азык булып торалар.

*Әд.:* Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977.

**БӨТЕНДӨНЬЯ́ ТАТА́Р КОНГРЕССЫ́ КОРЫЛТАЙЛАРЫ́**, татар халкы вәкилләре корылтайлары. Татар милләтен берләштерү һәм аның яшәешен яңарту максатында оештырылалар.

**1 нче корылтай** 1992 елның 19–21 июнендә Казанда уза, 1000 нән артык делегат, ш.и. Австралия, Германия, Төркия, Финляндиядән килгән татарлар катнаша. 15 секция эшли. Милли мөстәкыйльлеккә омтылу; татар теленең, мәдәниятенең һәм мәгарифенең яңарышына ирешү; татарларның этник бөтенлеген саклау; Татарстанның читтә яшәүче татарлар б-н сәяси, икътисади рухи элемтәләрен киңәйтү һәм үстерү һ.б. мәсьәләләр тикшерелә. Резолюциядә милли яңарыш байрагы астында бөтен дөньяга таралган татарларның бердәмлеген саклау зарурлыгы ассызыклана, ТРның дәүләт суверенлыгын ныгыту өчен законлы омтылышына теләктәшлек белдерелә. Бөтендөнья халыкларына һәм дәүләтләренә, Берләшкән Милләтләр Оешмасына ТРның дәүләт суверенлыгын тану турында мөрәҗәгать кабул ителә. Бөтендөнья Татар конгрессы *Башкарма комитеты* сайлана (рәисе И.Р.Таһиров).

**2 нче корылтай** 1997 нең 27–30 августында Казанда уза, 700 дән артык делегат, ш.и. Австралия, АКШ, Канада, Румыния, Төркия, Финляндиядән килгән татарлар катнаша. 5 секция эшли, 3 «түгәрәк өстәл» оештырыла. Милли мәдәният, мәгариф һәм фән үсеше, татар диаспоралары тормышы, латин графикасына күчү мәсьәләләре һ.б. тикшерелә. Резолюциядә Россия б-н цивилизацияле килешүләр нигезендә татар халкының дәүләтчелеген торгызу процессын дәвам иттерү, ТРның икътисади, фәнни-техник һәм рухи потенциалын, халыкара абруен үстерү һәм ныгыту, Татарстаннан читтә яшәүче татарларга ярдәм итү, Казанда Татар дәүләт милли ун-тын ачу, татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү, латин графикасына күчү, Берләшкән Милләтләр Оешмасына Бөтендөнья Татар конгрессын дәүләти булмаган халыкара оешма рәвешендә теркәүне үтенеп һәм ТР Дәүләт Советына Б.Т.к.к.ның Башкарма комитетын ТР парламентында фикер алышу хокукы б-н катнаштыруны сорап мөрәҗәгать итү, «Татар дөньясы» г-тасын оештыру (2002 нең июленнән чыга) зарурияты ассызыклана. Берләшкән Милләтләр Оешмасының Социаль-икътисади берлегендә Бөтендөнья Татар конгрессына консультатив статус бирелүен, Россия Халыклары ассамблеясын канунлаштыруны, латин алфавитына күчү һәм гражданлык турында канун булдыруны үтенеп БМОга, РФ президенты Б.Н.Ельцинга, ТР президенты М.Ш.Шәймиевкә мөрәҗәгатьләр кабул ителә, Б.Т.к.к.ның яңа Башкарма ком-ты сайлана.

**3 нче корылтай** 2002 елның 28–30 августында Казанда уза, 562 делегат, ш.и. АКШ, Германия, Төркия, Финляндия, Чехия, Швеция, Әзәрбайҗан, Балтыйк буе респ-калары, Белоруссия, Казакъстан, Украина, Үзбәкстаннан килгән татарлар катнаша. 3 секция эшли: 1) татар халкының фәне, мәгарифе, мәдәнияте; 2) хәзерге мәдәният һәм татар яшьләре; 3) Татарстанның эшлекле партнерлары. Корылтайның лозунгы: «Без бердәм, бүленмәс милләт». Тикшерелгән төп мәсьәләләр: ТРның статусы һәм Россиядә федерализм үсешенең киләчәге; татар б-н башкорт халыклары арасындагы мөнәсәбәтләр; халык санын исәпкә алу; милли-мәдәни мохтариятлар яшәеше. Резолюциядә татар милләтенең алга барышын, үсешен билгеләгән гомумфедераль программа булдыру, «Яңа гасыр» телевидение каналында яшьләр өчен махсус тапшырулар оештыру һәм татар яшьләренең «Интернет-портал»ын булдыру зарурияты ассызыклана. Шушы мәсьәләләр буенча татар халкына һәм РФ президенты В.В.Путинга мөрәҗәгатьләр кабул ителә. Б.Т.к.к.ның Башкарма ком-ты һәм яңа рәисе — Р.З.Закиров сайлана.

**4 нче корылтай**. 2007 елның 13–15 декабрендә Казанда үтә. 765 делегат катнаша, аларның 175е — Татарстаннан, 414е — Россия төбәкләреннән, 174е — 32 чит илләрдән (ш.и. Төркия, Финляндия, Литва, Польша, Румыния, Кытай, Германия, АКШ һ.б.). РФ президенты В.В.Путин корылтай делегатларына котлау җибәрә; анда, корылтай Россиядә милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга ярдәм итәр, киң мәдәни диалог, ватандашлар б-н элемтәләрне ныгыту өчен яңа мөмкинлекләр ачар, дип билгеләп үтелә. Корылтайда чыгыш ясап, ТР президенты М.Ш.Шәймиев, Бөтендөнья татар конгрессы — халкыбыз тарихында иң абруйлы иҗтимагый-сәяси милли оешмаларның берсе, ди. 3 секция эшли: 1) татар халкының үзенчәлеген һәм рухи мирасын саклауда фәннең,

мәгариф һәм мәдәниятнең роле; 2) татар иганәчелеге традицияләре һәм милли яңарышта беренче бизнес-бергәлекнең роле; 3) бүгенге дөньяда татар яшьләре. «Түгәрәк өстәлләр» янында Татарстанның Россиянең башка төбәкләре һәм чит илләр б-н сәүдә-икътисади хезмәттәшлеге мәсьәләләре тикшерелә. Корылтайда кайбер кичектергесез, барыннан да элек милли мәгариф һәм яшьләрне рухи-әхлакый тәрбияләү өлкәсенә кагылышлы бурычлар билгеләнә; резолюция кабул ителә. Бу документта, РФнең күп төбәкләренә, якын һәм ерак чит илләргә таралган татар халкының мәдәниятен, телен, үзенчәлекләрен саклауда Татарстан төп рольне уйный, гамәлдәге законнар нигезендә бу юнәлештә ул билгеле бер чаралар күрә, РФнең төбәк һәм федератив хакимиятләре органнары б-н эшлекле хезмәттәшлекнең уңайлы мөнәсәбәтләрен булдыра, диелә. Корылтай халыкның этномәдәни тәңгәллеген, туган телне, милли мәгарифне, мәдәниятне саклауны, ш.у. яшь буынны ата-бабаларыбызның традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен хөрмәт итү рухында тәрбияләүне бөтендөнья татар бергәлегенең төп бурычлары итеп саный. Резолюциядә РФдә гражданлык җәмгыятенең демократик ин-тларын һәм чын федератив мөнәсәбәтләрне саклау һәм үстерү; РФ составында хокукый демократик дәүләти берәмлек буларак, ТРның РФ б-н 2007 елгы Шартнамәсендә, РФ һәм ТР конституцияләрендә нygытылган статусын саклау һәм күтәрү; татар милләтенең милли-мәдәни тәрәккъыятендә ТРның әйдәп баручы ролен һәм җаваплылыгын нygыту; татар халкын этномәдәни үстерүнең перспективалы максатчан программасын эшләү; РФ төбәкләрендә һәм чит илләрдә татар милли-мәдәни үзәкләрен булдыру һәм үстерү; Казанда тиешле инфраструктуралы гомуммилли Ватандашлар йортын булдыру; татар яшьләре арасында аеруча туган телне үзләштерү, ана телен куллану өлкәсен киңәйтү, заманча шәһәр яшьләре милли субкультурасын формалаштыру эшен көчәйтү; татар телен читтән торып өйрәтү системасын; гомуммилли мәгълүмати-мәдәни киңлек булдыру максатларында татар телендә спутниклы һәм кабельле телерадиотапшыруларны, ш.у. Интернетта татар телле сегментны үстерү һ.б.ны корылтай зарури бурыч дип күрсәтә.

Делегатлар ш.у. татар һәм башкорт халыкларына, РФ президенты В.В.Путинга мөрәҗәгатьләр кабул итә. Аларның беренчесендә татар һәм башкорт халыклары арасындагы дуслыкны, хезмәттәшлекне нygыту мәсьәләләре куела. Президентка мөрәҗәгатьтә «Мәдәният» дәүләт телетапшырулар каналында Россия халыклары тормышын яктырта торган даими мәдәни тапшырулар булдыру хакында Бөтендөнья татар конгрессының 3 нче корылтаеннан соң президент фәрманының үтәлмәвенә; РФ Дәүләт Думасы тарафыннан «Мәгариф турында»гы Федераль кануннан мәктәпләрдә туган телне һәм Россия халыкларының тарихын өйрәнергә мөмкинлек биргән региональ компонентның төшереп калдырылуына (2007 елның 14 ноябре законы, № 309–ФЗ) ризасызлык белдерелә. Күп кенә төбәкләрдә милли мәктәпләргә мәгариф структуралары тарафыннан җитәрлек игътибар булмавы күрсәтелә. Корылтай, халыклар арасындагы үзара татулыкны саклап калу, нygыту өчен Россия этносларын, аларның телен һәм мәдәниятен үстерергә, милли мәктәпләргә уңай шартлар тудырырга кирәк, дип саный. Делегатлар РФнең аерым төбәкләрендә ксенофобия һәм милли җирлектә түзә алмаучылык очракларының ешаюына борчылу, андый тискәре күренешләрне бетерү өчен дәүләт органнары үтемле чаралар күрерләр, дигән ышаныч белдерәләр.

Чыг.: Бөтендөнья татар конгрессы: стенографик хисап (беренче чакырылыш. Татар һәм рус телләрендә). К., 1992; Милләтне берләштерү юлында: материаллар җыентыгы. К., 2007; Из дневника Исполнительного комитета Всемирного конгресса татар. К., 1997; Устав международной общественной организации «Всемирный конгресс татар». К., 1997; Всемирный конгресс татар (второй созыв). 28–29 августа 1997 год. К., 1998.

*И.Р.Таһиров.*

**БӨТЕНДӨНЬЯ́ ТАТА́Р КОНГРЕССЫ́ БАШКАРМА́ КОМИТЕТЫ́**, иҗтимагый-сәяси оешма. 1992 елның июнендә Казанда Бөтендөнья татарларының 1 нче конгрессы карары нигезендә координацияләүче орган буларак оештырыла. Конгрессның 5 елга сайланган даими эшләүче, юридик хокукка ия җитәкче органы. Башкарма ком-т елга бер мәртәбә җыела. Еллык җыелышлар арасында аның эшен Б.т.к.б.к. әгъзаларыннан сайланган Бюро башкара. Бюро утырышлары ай саен уздырыла. Башкарма ком-т рәисе ком-т әгъзалары тарафыннан 5 елга сайлана. Ул Башкарма ком-т һәм Бюро утырышларын уздыра, үзенең урынбасарлары, төркемнәре, комиссияләр, советлар эшчәнлеген координацияли, дәүләт, җәмәгать оешмалары һәм халыкара структуралар утырышларында Бөтендөнья Татар конгрессы вәкиле буларак катнаша ала. Б.т.к.б.к. аппаратында ТР районнары, РФ һәм БДБ илләренең татарлар күпләп яшәгән өлкәләре һәм төбәкләре, чит илләрдә яшәүче татар диаспоралары б-н элемтә тотучы һәм эшләүче бүлекләр бар. Максаты — татар милләтенең бердәмлеген тәэмин итү, татарларның һ.б. халыкларның үзбилгеләнү хокукына ирешү, милли тел һәм мәдәният, гореф-гадәт үзенчәлекләрен саклау чараларын күрү, татарларга кагылышлы этнотөбәк мәсьәләләрен чишүдә арадашчылык хезмәтен үтәү, татар диаспораларының үзара һәм үзәк б-н бәйләнешен булдыру һ.б. Башкарма ком-т шушы максатларга кагылышлы мәсьәләләрне өйрәнү-тикшерү хокукына ия һәм, вазгыять таләп иткәндә, арадашчылык эшчәнлеге алып барырга хаклы. Б.т.к.б.к. Татарстан Респ-касының РФ төбәкләре һәм чит илләр б-н үзара бәйләнеше процессында шунда яшәүче татарларның милли-мәдәни үсешенә һәм бердәмлегенә кагылышлы чаралар үткәрә, милли-мәдәни хәрәкәтләргә җитәкчелек итә. Башкарма ком-т РФ төбәкләрендә, БДБ илләрендә һәм АКШ, Австралия, Финляндия, Төркия, Германия, Канада, Кытай, Польша, Румыния, Япония һ.б. илләрдә яшәүче татарларның милли хәрәкәтләре б-н элемтәдә тора. Татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә *Милли-мәдәни мохтарият* оештыруда актив катнаша. Милләткә кагылышлы мәсьәләләрне урыннарда хәл итү өчен Б.т.к.б.к.ның Бюро җитәкчелеге РФдә һәм БДБ илләрендә күчмә утырышлар уздыра. Соңгы дәвердә андый утырышлар РФнең Екатеринбург, Ульянов, Саратов, Пермь, Тольятти, С.-Петербург шәһәрләрендә һәм Белоруссия (Минск), Казакъстан Респ-каларында, АКШта, Төркиядә уздырыла, аларда татар милләте яшәешенә һәм үсешенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән карарлар кабул ителә. РФнең төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдә 150 дән артык татар җәмгыяте һәм берләшмәсе эшли (2004). Башкарма Комитет рәисләре: И.Р.Таһиров (1992–2002), Р.З.Закиров (2002 елдан).

*Әд.:* Терентьева И.В., Беляков Р.Ю., Сафаров М.Ф. Республика Татарстан: политические партии, движения, лидеры. К., 2001.

*И.Р.Таһиров.*

**БӨТЕНПО́ЛЬША МӨСЕЛМАННАРЫ́ ГМИ́НАСЫ ВӘКИЛЛӘРЕ́ СЪЕЗДЫ́**, 1925 елның декабрендә Вильно (Вильнюс) шәһәрендә уздырыла. 58 делегат катнаша. Съездда *Речь Посполита мөселманнары берлеге*, *Речь Посполита татарларының мәдәни-агарту берлеге* оештырыла, Польша татарлары мөфтие (*Я.Шынкевич*) сайлана. Съезд Польша-Литва татарлары мөфтиятенең Кырым мөфтиятеннән аерылып чыгуы турында игълан итә.

*Я.Я.Гришин.*

**БӨТЕНПО́ЛЬША МӨСЕЛМАННАРЫ́ КОНГРЕССЫ́**, 1938 елның 31 гыйнварыннан 1 февраленә кадәр Вильно (Вильнюс) шәһәрендә уздырыла. Польша татарлары мөфтияте тарафыннан чакырыла. 38 делегат катнаша. Рәисләре: О.Крычиньский, Я.Шынкевич. Польша татарларының дини тормышын яңарту, дини йолаларны башкаруны бердәй итү мәсьәләләре һ.б. карала. Б. м.к.нда *Югары мөселман коллегиясе* сайлана.

*Я.Я.Гришин.*

**БӨТЕНРОССИ́Я ВЕТЕРИНАРИ́Я ИНСТИТУТЫ́**, фәнни-тикшеренү ин-ты (БВФТИ). 1960 елда Казанда СССР А.х. министрлыгының Казан ветеринария фәнни-тикшеренү ин-ты буларак оештырыла (1989–92 дә — Бөтенсоюз, 1992 дән Бөтероссия ин-ты); 1996 елдан Хайваннарны токсикологик, радиобиологик һәм биологик яктан саклауны тәэмин итүче баш фәнни учреждение, 2004 тән Хайваннарның токсикологик һәм радиацион куркынычсызлыгы буенча федераль үзәк. Дәүләт ихтыяҗлары өчен аеруча куркыныч микроорганизмнарны саклаучы төп фәнни оешма; әйләнә-тирә мохит объектларында, патологик материалда, илебездә һәм чит илләрдә җитештерелгән азык-төлектә, фураж чималында радиоактив зарарлануны, көчле тәэсирле агулы матдәләрне, бактериаль чараларны ачыклау һәм билгеләү алымнарын эшләү буенча махсус үзәк. Патогенлылыгы 3–4 нче төркемнәргә караган микроорганизмнар б-н эшләү, бу өлкәдә югары белемле җитәкче хезмәткәрләр һәм белгечләрнең белемнәрен камилләштерү, радиоактив матдәләр булган комплексларны файдалану хокуклары расланган лицензияләре бар. Институт хайваннарда йогышлы авыруларга каршы дарулар һәм дәвалау

чараларын эшли, житештерә һәм аларны гамәлгә кертә. 1993, 1996, 1999 елларда РФ Дәүләт стандарты тарафыннан а.х. һәм дару чималларын, азык-төлек продукциясен сертификацияләүче бәйсез сынау үзәге, радиацияне тикшерү лабораториясе буларак тәгаенләнә. Үзәк агулы матдәләрнең хайваннар организмына төрле дәрәҗәдә тәэсир итү механизмын, аларның агулануына диагноз кую, дәвалау һәм булдырмау алымнарын эшләү юнәлешендә теоретик, эксперименталь һәм полигон тикшеренүләр үткәрә. Институтта хайваннарны токсин матдәләр б-н агуланудан, көчле агулы матдәләрнең хәвефле дозаларыннан саклауны тәэмин итүче озак вакытка исәпләнгән тәэсирле дәвалау-профилактика антидотлары, агулы матдәләрне билгеләүнең үтә сизгер экспресс-ысуллары эшләнә, трофик чылбырның барлык буыннарында да техноген һәм табигый токсин матдәләргә күзәтү (мониторинг) алып барыла. Токсикологик тикшеренүләр үсешенә К.Х.Морозовский, Г.Н.Коржевенко, И.М.Шермергорн, Е.И.Трутнев һ.б. зур өлеш кертә. Химик-токсикологик тикшеренүләрдә илебездә һәм чит илләрдә эшләнгән югары төгәллекле җиһазлар кулланыла. РФдә һәм БДБ илләрендә тиңе булмаган махсус диоксин корпусында катлаулы тикшеренүләр уздырыла. Ветеринар күзәтү объектларындагы һәм әйләнә-тирә мохиттәге токсикантлар микъдарын контрольдә тоту максатында экспресс һәм үтә сизгер ысуллар тәкъдим ителә (Р.Д.Гәрәев, К.Х.Папуниди, М.Я.Тремасов, А.В.Иванов һ.б.). Көчле тәэсирле химик токсин матдәләрнең тәэсирен бетерү өчен махсус рецепторалар эшләнә (Р.Д.Гәрәев, П.К.Сметов, К.Х.Папуниди, Ю.В.Студенцов, В.И.Барабанов, Н.Н.Жестков һ.б.лар, 1975–90). Экотоксикантлар — хлорлы һәм фосфорлы-органик пестицидларның, авыр металларның, микотоксиннарның, диоксинның һ.б.ларның терлек азыгында һәм суда рөхсәт ителгән чикләрдәге тупланышын һәм минималь микъдарын билгеләү юнәлешендәге тикшеренүләр зур фәнни-гамәли әһәмияткә ия (А.В.Иванов, М.Я.Тремасов, Ю.А.Зимаков, В.А.Новиков, Н.Г.Шаңгәрәев, А.И.Сергейчев һ.б.лар). Хайваннарны кичекмәс очракларда тиз арада хәрәкәтсез калдыру һәм кан чыгармыйча үтерү максатында миорелаксант — «адилин-супер» эшләнә һәм киң кулланылышка кертелә (Р.Д.Гәрәев, В.И.Барабанов, 1988). Радиобиологик комплекс эшли. Хайваннарны радиациядән саклау ысулы тәкъдим итә (В.А.Киршин, В.В.Мосин, Ф.П.Фролов, Н.Җ.Хаҗипов һ.б. СССР Дәүләт бүләге лауреаты исеменә лаек булалар, 1979). Цитоплазма антигены нигезендә озак вакытка исәпләнгән тәэсирле биопротектор (радиовакцина) эшләп чыгару технологияләре булдырыла; нурланыш алган хайваннар канында радиозарарлану нәтиҗәсендә барлыкка килгән антигеннарны молекуляр-биологик һәм иммунохимик тест-системалар кулланып билгеләү юлы б-н нурланыш авыруына диагноз кую ысулы эшләнә, радиациядән зарарланган хайваннарның итен +17°С тан +28°С ка кадәрге шартларда 9 ай дәвамында саклаганда сыйфатлылык тәэмин итү ысулы сынала (Я.М.Корбангалиев, Г.В.Конюхов, Р.Д.Гәрәев һ.б.лар, 2002).

Институт эшчәнлегенең мөһим юнәлеше — кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авыруларга диагноз кую, дәвалау, кисәтү чараларын һәм алымнарын эшләү буенча фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр алып бару. Бруцеллёз, хламидиоз, некробактериоз, парагрипп-3, йогышлы ринотрахеит, рото-коронавирус инфекцияләре һ.б. авыруларга каршы югары нәтиҗәле вакциналар эшләү һәм гамәлгә кертү (Х.Х.Абдуллин, Х.Г.Гыйззәтуллин, А.В.Селиванов, Г.З.Равилов, А.В.Иванов, Р.Х.Йосыпов, К.Х.Камалов, К.М.Салмаков, Х.З.Гаффаров, Х.Н.Макаев, Р.Х.Хәмәдиев, Ф.М.Хөсәенов, Х.Д.Хужин,



Бөтенроссия ветеринария институты биналары.

В.В.Естифеев һ.б.). Социаль яктан куркыныч инфекцияләрне кисәтү чараларын эшләү буенча алып барылган тикшеренүләр ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә (1997) лаек була. 1984–2007 елларда барысы 350 дән артык препарат һәм фәнни-техник документ эшләнә һәм гамәлгә кертелә, алар төрле дәрәҗәдәге, ш.и. халыкара күргәзмәләрнең 28 дипломы һәм сертификаты б-н билгеләнә, уйлап табуларга 238 дән артык авторлык таныклыгы һәм патент бирелә. 100 дән артык хезмәткәр СССР ВДНХсының (Бөтенроссия күргәзмәләр үзәгенең) алтын, көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә. Соңгы елларда тикшеренүләр киң җәелдерелә, йогышлы авырулар китереп чыгаручы вирусларның вирулент һәм вакцина штаммнарын γ-нурлар б-н эшкәртеп яңа буын вакциналар эшләнә. Башлыча, Халыкара фәнни-техник үзәк (ISTC) аша чит илләрдән инвестицияләр җәлеп итү буенча актив эш алып барыла. Халыкара 3 проект, ш.у. РФА, РАХФА, ТР ФАнең вакытлыча оештырылган иҗат коллективлары көче б-н фәннең өстенлекле тармакларын үстерү программалары гамәлгә ашырыла. Югары квалификацияле фәнни кадрларны әзерләү һәм аттестацияләү буенча тәҗрибә тупланган, фәнни мәктәп барлыкка килгән. 21 лабораториядә 100 дән артык хезмәткәр (ш.и. 22 фән д-ры, 73 фән канд.) эшли; шулардан РФ һәм ТРның атказ. фән эшлеклесе — 15, ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты — 4, СССР МС бүләге лауреаты — 1, РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре — 1, ТРның атказ. ветеринария табибе һәм атказ. а.х. хезмәткәре — 5 кеше.

БВФТИ җитәкчеләре: Е.Н.*Павловский* (1960–62), Х.Г.*Гыйззәтуллин* (1962–74), Н.Җ.*Хаҗипов* (1974–84), Г.З.*Равилов* (1984–2004), А.В.Иванов (2004 тән).

*А.В.Иванов.*

**БӨТЕНРОССИ́Я МӨСЕЛМАННАРЫ́ ХӘРБИ́ ШУРАСЫ́** (Хәрби Шура, ВОШура), мөселман гаскәриләренең югары сәяси оешмасы. Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 1 нче корылтае карары б-н 1917 елның июлендә Казанда оештырыла (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Хәрби округ, армия, флот һәм аерым гаскәри берәмлекләр вәкилләреннән һәм корылтайда билгеләнгән 12 бәйсез әгъзадан торган. Рәисе — И.Алкин, рәис урынбасарлары — Г.Токымбәтов, Ә.Әсәдуллаев (соңрак аны А.Якубовский алыштыра), әгъзалары: Җ.Алкин, Г.Монасыйпов, М.Солтангалиев, К.Якубов, Т.Мәмлиев, С.Кугушев, А.Таһиров, Ю.Абдерахман, Г.Гобәйдуллин, Х.Әбелханов һ.б. Генерал Л.Г.Корнилов җитәкчелегендәге фетнәне бастыруда актив катнашкан өчен Вакытлы хөкүмәт 1917 нең сентябрендә Б. м.х.ш.на армияләрдә мөселман гаскәри берәмлекләрен төзергә, 1918 нең гыйнварына кадәр тылдагы берничә запас полкны мөселманнардан тупларга рөхсәт бирә. Б. м.х.ш. тырышлыгы б-н тиз арада Оренбург шәһәрендә 1 нче, Уфада 2 нче, Бәләбәй шәһәрендә 6 нчы мөселман укчы полклары, Петроградта гвардияле катнаш полк, Финляндиядә 2 мөселман батальоны (соңрак полк буларак таныла) һ.б. оештырыла. Хәрәкәттәге армия, корпус, дивизия, полкларда һәм төрле хәрби округларда, гарнизоннарда 300 дән артыграк мөселман хәрби ком-тлары төзелә. Хәрби Шураның үзәге (Ставкасы) Казанда урнаша, Петроградта һәм *Милли Шура* карамагында бүлекләре ачыла. Хәрби Шура әгъзалары татар халкының милли азатлык хәрәкәтендә актив катнашалар. Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 2 нче корылтае барышында Хәрби Шура җитәкчеләреннән И.Алкин, Җ.Алкин, Г.Токымбәтов һәм Й.Мозаффаров Совет хакимияте тарафыннан кулга алына. Б. м.х.ш. корылтай утырышында үз мәнфәгатен яклау өчен Мөселман революцион штабын оештыру карарын кабул иттерүгә ирешә, аның җитәкчесе итеп Г.Монасыйпов билгеләнә. Корылтай делегатлары б-н бергә Хәрби Шура да эшчәнлеген Казанның Болак елгасы аръягында (мөселманнар яшәгән өлештә) дәвам итә (к. «*Болак арты республикасы*»). Казан советы үз утырышында «Болак арты республикасы»н куып тарату турында карар кабул итә, туплар б-н коралланган кызылгвардияче көчләр һөҗүмгә күчәләр. Хәрби Шурага буйсынган гаскәри берәмлекләр коралсызландырыла. РСФСР Милләтләр эше халык комис-тының 1918 елның 24 март Декреты б-н Хәрби Шураның үзәк оешмасы, шул елның 24 апрель карары б-н Хәрби Шураның Мәскәү бүлеге, 22 май карары б-н Милли Шура карамагындагы бүлеге бетерелә. Б.м.х.ш.ның матбугат органнары: «*Безнең тавыш*» һәм «*Известия Всероссийского мусульманского военного Шуро*» («Бөтенроссия мөселманнары Хәрби Шурасы хәбәрләре») г-талары.

*Әд.:* Давлетшин Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; Тагиров И.Р. Очерки истории

Татарстана и татарского народа (XX в.). К., 1999; Илиас Алкин — общественный деятель, военачальник, учёный: Док. и материалы. К., 2002.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**БӨТЕНРОССИ́Я МӨСЕЛМА́Н ГАСКӘРИЛӘРЕ́ КИҢӘШМӘСЕ́**, 1917 елның 27–30 апрелендә Мәскәүдә уза. Казан һәм Мәскәү Мөселман хәрби комитетлары тарафыннан чакырыла. 100 ләп делегат катнаша. Җыелышның рәисе — И.Алкин. Киңәшмәдә Россия армиясе составында мөселман гаскәри берәмлекләрен төзү-туплау мәсьәләсе карала. *Бөтенроссия мөселманнарының Вакытлы Хәрби Шурасы* сайлана.

**БӨТЕНРОССИ́Я МӨСЕЛМАННАРЫ́ КОРЫЛТАЙЛАРЫ́**, 1905–18 елларда Россия мөселманнарының милли, социаль-сәяси һәм дини проблемаларын хәл итү, аларның мөстәкыйль идарә итү идеяләрен тормышка ашыру, мәгарифкә кагылышлы проблемаларны чишү, Россия мөселманнарының мәнфәгатьләрен вәкиллекле хакимият органнарында якларлык сәяси оешма төзү мәсьәләләренә багышлап уздырылган җыеннары. Мөселман иҗтимагый-сәяси эшлеклеләре инициативасы б-н оештырыла. Б.М.К. эшендә Россиядә яшәүче мөселманнар — татар, әзәрбайҗан, башкорт һ.б. халыкларның вәкилләре катнаша. Корылтайларда «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясе, *Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасы*, *Бөтенроссия мөселманнарының Хәрби Шурасы* һәм *Милләт Мәҗлесе* оештырыла, Россия мөселманнарының мөһим проблемаларын хәл итү турында килешүгә ирешелә.

**Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае,** 1905 елның 15 августында Түбән Новгород шәһәрендәге ярминкә вакытында «Густав Струве» пароходында яшерен рәвештә уза. 120 ләп кеше, ш.и. Й.Акчура, Ә.Әхтәмов, Р.Ибраһимов, Г.Тупчыбашев һ.б. катнаша; И.Гаспринский рәислек итә. Көн тәртибендәге мәсьәләләр: мөселманнарның мәгарифен һәм мәдәниятен үстерү чараларын билгеләү, *Ильминский системасына* карата уртак мөнәсәбәт булдыру; Дәүләт думасына мөселман депутатларны сайлауны оештыру; мөселманнарның дини-рухи, хокукый-иҗтимагый һәм икътисади ихтыяҗларын бәян итеп, патша исеменә хат юллау һ.б. Корылтайда Россия мөселманнарының «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен төзү турында карар кабул ителә; корылтай Россиядә яшәүче барлык халыкларның гражданлык, сәяси һәм дини хокукларының тигез булырга тиешлеген яклый, фикерләр әйтелә; мәгърифәтчелек эшчәнлеген киң җәелдерү кирәклеге көн тәртибенә куела. Шушы максатларга ирешү өчен урыннарда җирле җыеннар оештырырга тәкъдим ителә. Корылтайда сул сәяси карашта торучы яшьләр (Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Ш.Мөхәммәдъяров һ.б.) б-н күпчелекне тәшкил итүче либерал карашлы вәкилләр (Г.Тупчыбашев, Й.Акчура һ.б.) арасында бәхәс туа. Сул карашлылар уң тарафта булган либералларның Россия мөселманнары җәмгыятендә сыйнфый каршылык юк дип белдерүләре б-н килешмиләр. Г.Исхакый оештырылачак «Иттифакъ әл-мөслимин»не дә мөселманнарның мәдәни берләшмәсе рәвешендә генә күзалларга кирәклекне таләп итә һәм, ул оешма Россиядәге мөселман халыкларының тырышлыгын, мәгарифне, мәдәниятне һәм милли үзаңны үстерү юлында берләшергә тиеш, дип белдерә.

**Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае,** 1906 ның 13–23 гыйнварында С.-Петербургта яшерен рәвештә уздырыла. 100 гә якын делегат, ш.и. Й.Акчура, Р.Ибраһимов, С.Максуди, Г.Тупчыбашев катнаша. 1 нче Дәүләт думасына сайлауларда бердәм сәяси платформа булдыру, «Иттифакъ әл-мөслимин» сәяси партиясе оештырылуы турында рәсми рәвештә белдерелә, аның Уставы һәм программасы раслана. Партиянең алдан әзерләнгән программасына кайбер делегатлар (Г.Исхакый һ.б.) тарафыннан үзгәрешләр тәкъдим ителү сәбәпле, ул вакытлыча гына кабул ителә. Партиянең киләчәк эшчәнлеге, оештырылу рәвеше һәм сәяси тактикасы мәсьәләсендә җитди бәхәс кузгала. Сул карашта булган делегатлар сыйнфый көрәш көчәя барган вакытта гомуммөселман сәяси партиясенең эшне уңышлы башкарачагына шик белдерәләр. Делегатларның күпчелеге 1 нче Дәүләт думасына сайланасы мөселман депутатларының саны, мөселман халкының гомуми саныннан чыгып, билгеле бер нисбәттә булырга тиеш дигән карашны хуплый. Сайлаулар барышында һәм Дума эшчәнлегендә мөселман депутатлар кадетлар партиясе мәсләгенә йөз тотачак дигән карар кабул ителә.

**Бөтенроссия мөселманнарының өченче корылтае,** 1906 елның 16–21 августында Түбән Новгородта рәсми рәвештә уза. 800 ләп делегат, ш.и. Й.Акчура, Р.Ибраһимов, И.Гаспринский, С.Алкин, Һ.Максуди катнаша. Рәис: Г.Тупчыбашев. Корылтайны уздырыга рөхсәт алу өчен берничә делегат исеменнән эчке эшләр министрына үтенеч хаты юллана, анда башлыча дин тотуга кагылышлы мәсьәләләр (Мөхәммәд пәйгамбәр күрсәткән юлдан тайпылуларга каршы көрәш һ.б.), мәдрәсәләрдә заманча үзгәрешләр кертү, мөселманнар дини идарәсен үзгәртеп кору кирәклеге турында гына сүз барачагы әйтелә. «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен оештыруда башлап йөргән алдынгы карашлы делегатлар (И.Гаспринский, Й.Акчура һ.б.) корылтай эшчәнлеген бу мәсьәләләргә генә багышлауга каршы ризасызлык белдерәләр, утырышларда катнашмаска булалар. Корылтай алдыннан узган фикер алышуда килешүгә ирешелә. 1905 нең 17 октябрендә игълан ителгән Манифестка бәйле рәвештә көн тәртибе киңәйтелә. Утырышлар барышында делегатлар мөселман милли азатлык хәрәкәтенә мөнәсәбәтләренә карап 3 төркемгә бүленәләр: консерваторлар, либераллар һәм сул карашта торучылар. «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенең программасы кабул ителә, 15 кешедән торган ҮК сайлана. Төп мәсьәләләр буенча 8 пунктлы карар раслана: 1) 2 нче Дәүләт думасын чакыруны тизләтүгә һәм 17 октябрь Манифестында игълан ителгән ирек-хөрриятнең тормышка ашырылуына ирешергә; 2) халык мәгарифе системасын тулаем үзгәртеп корырга: 8 яшенә җиткән барлык малай һәм кызларны башлангыч мәктәптә мәҗбүри укытуны кертергә; барлык мөселман уку йортларында уку-укытуны бердәй программа нигезендә ана телендә башкарырга, рус теле аерым предмет буларак укытылырга, барлык югары сыйныфларда, мөмкинлек булганда башлангыч сыйныфларда да, төрек теле өйрәнелергә тиеш. Бердәй уку-укыту программасын тизрәк булдыру өчен Россия шәһәрләрендә 1907 нең маенда укытучылар җыеннарын, шул елның августында Казанда Бөтенроссия мөселман укытучылар корылтаен уздыру карала. Мөселман уку йортларын хөкүмәт һәм земство оешмалары финансларга тиеш; уку йортлары эшчәнлегенә күзәтчелек итүне сайлаулы коллегия башкаруына тапшырырга кирәк, диелә (бу пункт шундый 33 тәкъдимне үз эченә ала); 3) мөселманнар диния идарәсе эшчәнлегенә үзгәрешләр кертергә: мөфти һәр 5 ел саен сайлап куелырга; мөселман һәм православие дин әһелләре б-н бертигез хокукка ия булырга; мөселманнарга кагылышлы барлык мәхкәмә эшләрен хәл итү Мәхкәмәи Исламиягә тапшырылырга, аларны караудан дәүләт оешмалары азат ителергә; Россиядә мөселманнарның иң югары сайлаулы вазифа үтәүчесе — Рәисүл Голяма булдырылырга, аңа мөселманнар гозерен белдерү өчен турыдан-туры император җәнапларына мөрәҗәгать итү хокукы бирелергә тиеш, диелә (бу пункт 13 тәкъдимне үз эченә ала). Делегатлар исеменнән Россия МС рәисе адресына Дәүләт думасы эшли башлаганчы мөселманнарга кагылышлы законнар кабул ителмәсен дигән мөрәҗәгать тә басыла. Кавказда мөселманнар б-н әрмәннәр арасындагы ызгыш-бәрелешләргә карата мөнәсәбәт белдерелә — ике халыкның да руханиларына һәм зыялыларына мәсьәләне кан коймыйча хәл итү кирәклеге турында мөрәҗәгать кабул ителә. Чираттагы корылтайны 1907 елның 10 августында Түбән Новгородта үткәрү билгеләнә.

**Бөтенроссия мөселманнарының дүртенче корылтае,** 1914 елның 15–25 июнендә С.-Петербургта уза. 30 лап делегат (башлыча, 4 нче Дәүләт думасы депутатлары) катнаша. «Иттифакъ әл-мөслимин» оешмасының барлыгын белдерү максатында оештырыла. Түбәндәге мәсьәләләр карала: мөселман кануннарына үзгәрешләр кертү, мөселман дини оешмаларының искеләрен яңарту, яңаларын булдыру. Дәүләт думасындагы мөселманнар фракциясе вәкилләренә мөселманнар күтәргән мәсьәләләр турында Россия хөкүмәтенә хәбәр итү һәм мөселманнар делегациясен Думада кабул итүне оештыру бурычы йөкләнә.

Бөтенроссия мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре җыены 1914 елның 6–10 декабрендә Петроградта уза. 70 ләп делегат катнаша. 4 нче Дәүләт думасы мөселманнар фракциясе тәкъдиме б-н чакырыла. Яраланган сугышчыларга ярдәм оештыру мәсьәләсе карала. Җыелышның җитәкчеләре: Ибне Әхтәмов, М.Әсәдуллаев, Г.Мөфтизадә һ.б. Кабул ителгән карарлар: Бөтенроссия мөселманнары исеменнән Кавказ фронтында заманча җиһазландырылган санитария отрядын оештыру һәм тоту; җирле мөселман

җәмәгать оешмаларында хәйрия акчасын җыю өчен ком-тлар булдыру. Шушы мәсьәләләрне хәл итүне оештыру өчен Россия мөселман җәмәгать оешмаларының ҮК сайлана (Ибне Әхтәмов, М.Әсәдуллаев, Г.Мөфтизадә, З.Шамил, Г.Сыртланов, Һ.Максуди һ.б.).

**Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае,** 1917 елның 1–11 маенда Мәскәүдә уза. 900 ләп делегат катнаша. Президиумга барлык мөселман төбәкләреннән 12 кеше, ш.и. И.Алкин, И.Әхтәмов, М.Бигиев, Х.Габәши, Г.Исхакый, Ф.Кәрими сайлана. Корылтай Россия мөселманнарының Вакытлы Мәркәз бюросы инициативасы б-н чакырыла. Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр: Россиянең киләчәктәге эчке дәүләт төзелеше мәсьәләсе; сугышка мөнәсәбәт белдерү; мәгариф, дин мәсьәләләрен карау; мөселман гаскәри берәмлекләрен оештыру; җир бүленеше мәсьәләсе; хатын-кыз хокукы мәсьәләсе; эшчеләр сыйныфы мәсьәләсе; Учредительләр җыенына мөнәсәбәт; Россия мөселманнарының Олуг Милли Шурасына сайлаулар (к. *Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасы*). Делегатлар 9 секциягә бүленеп эшли. Россиянең киләчәктәге эчке дәүләт төзелеше мәсьәләсе тикшерелгәндә җитди бәхәс туа. Ә.Цаликов, М.Рәсүлзадә, Зәки Вәлиди, Һ.Максуди һ.б. докладчылар берничә вариант тәкъдим итәләр. Кавказ, Төркестан һәм Казакъстан вәкилләренең күпчелеге милли мохтариатларны берләштергән федератив дәүләт төзү кирәклеген белдерә. Казан төбәге делегациясе вәкилләре унитар дәүләт составында милли-мәдәни мохтарият төзү яклы булалар. Озакка сузылган бәхәсләрдән соң түбәндәге карар кабул ителә: Россиядә бергә тупланып яшәүче мөселманнар мәнфәгатенә демократик рухлы, терр., милли-федератив башлангычлар рәвешендәге дәүләт төзелеше җавап бирә, ә билгеле бер терр-яләре булмаган милләтләр милли-мәдәни мохтарият төзелешеннән файдаланырга тиешләр дигән карарны 446 делегат хуплый, 271 делегат каршы тавыш бирә. Ә.Цаликовның сугышны дәвам итү-итмәүгә багышланган чыгышыннан соң делегатларның күпчелеге кан коюны туктату кирәклеген, Эшче һәм солдат депутатларының Петроград Советы тәкъдим иткәнчә, беркем тарафыннан да йолым-контрибуцияләр түләтмичә, халыкларның үзбилгеләнүе нигезендә солых килешүе төзүне хуплый. Вакытлы хөкүмәтнең сугыш максатларын бәян иткән 27 март мөрәҗәгатен, империалистик сәясәткә омтылышын мөселманнар хупламый. Мәгариф һәм мәдәният мәсьәләләре тикшерелгән утырышның карары: башлангыч белем бирү түләүсез һәм һәр бала өчен мәҗбүри булырга, укыту ана телендә алып барылырга, рус теле аерым фән буларак укытылырга тиеш (бу пункт 24 тәкъдимне эченә ала; алар, нигездә «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен оештыруга багышланган 3 нче корылтайда кабул ителгәннәргә туры килә). Хәрби-гаскәри төзелеш мәсьәләләре тикшерелгәндә делегатлар полковник И.Галиев б-н Казан гарнизоны мөселман ком-ты рәисе урынбасары Г.Монасыйпов чыгышларында әйтелгән тәкъдимнәрне хуплыйлар: мәҗбүри хәрби хезмәт үтәү тәртибе бетерелергә; армия сакланган очракта, ул милли гаскәри берәмлекләрдән торырга тиеш; аерым мөселман гаскәри берәмлекләре оештырылырга, солдатлар үзләре яшәгән төбәктә генә хезмәт итәргә тиеш һ.б. Ислам диненә кагылышлы мәсьәләләр тикшерелгәндә С.Алкин б-н К.Тәрҗемани тәкъдимнәренә өстенлек бирелә: Диния нәзарәтен (Оренбург Мөселман Рухият җыенын) үзгәртеп кору һәм Вакытлы Рухият идарәсен (мөфтиятне) сайлау һ.б. Җир мәсьәләсенә кагылышлы утырыш бик бәхәсле уза. Ш.Мөхәммәдьяров докладыннан соң корылтай делегатлары җирнең халыкка түләүсез бүлеп бирелергә тиешлеге турында карар кабул итәләр. Шул ук вакытта эре җирбиләүчеләргә җирле үзидарәләр билгеләгән күләмдә йолым хакы түләнергә тиешлек тә карала. Үз көче б-н җир эшкәртүче шул җирнең хуҗасы булырга, җир б-н сәүдә итү тыелырга тиешлеге турындагы тәкъдимнәр кабул ителә. Җир бүленеше мәсьәләсен хәл итү Учредительләр җыены узганчы чигерелеп торырга тиеш, хәзергә исә Бөтенроссия крәстияннәре съезды карары нигезендә эш йөртүне хупларга кирәк, диелә. Җиргә кагылышлы карар-тәкъдимне раслаудан Башкортстан б-н Төркестан вәкилләре баш тарта. Ш.у. Төркестан һәм Кавказ төбәге вәкилләре хатын-кызларга сайлау хокукы бирүгә дә каршы чыга. Күпчелек тавыш б-н корылтайда мөселман хатын-кызларының көндәлек тормышта һәм сәясәттә ир-ат б-н тигез хокукка ия булырга тиешлеге, сайлау вакытында аларга аерым урыннар билгеләнергә кирәклеге белдерелә; күп хатын б-н тору бетерелергә, хатын-кыз иреннән аерылу хокукына ия булырга, 16 яшьтән өйләнү-кияүгә чыгу рөхсәт ителергә тиеш дигән карар кабул итә. Эшчеләр сыйныфына кагылышлы мәсьәләдә шул сыйныф вәкиле булган Н.Мохтаров тәкъдимнәре раслана: 8 сәгатьлек эш көне билгеләү, эшченең иминлеген тәэмин итү һәм мед. ярдәме күрсәтү чыгымнарын эшкә яллаучыдан түләтү, эшчеләрнең җәмгыять-оешмалары хокукы, эшкә яллаучының эшчеләргә кагылышлы кануннарны үтәмәве һәм 16 яшенә җитмәгән яшүсмерләрне яки сәламәтлеккә зарарлы җитештерү пр-тиеләренә хатын-кызны эшкә алу очракларын тыю мәсьәләләренә караган карарлар кабул ителә. Мөселманнарның Учредительләр җыенына сайлауларда катнашу мәсьәләсе аерым тикшерелә, гамәлдәге партия һәм блокларга керү-кушылу өчен аларга хезмәт таифәсе оешмасыннан артык уңга тартылмаган демократик блок төзү кирәклеге әйтелә. Шунда ук эсерлар партиясенең генә рус булмаган милләтләргә үз тормышларын үзләренчә кору хокукын яклавы әйтелә. Корылтайда *Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасын* оештыру карары кабул ителә, аның Башкарма ком-ты һәм Диния нәзарәте (мөфтият) идарәсе әгъзалары сайлана (идарә рәисе итеп Г.Баруди билгеләнә). Корылтай беркетмәләрен 1917 елда Петербургтагы «Әманәт» ширкәте бастырып чыгара.

**Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае,** 1917 елның 21 июль — 2 август көннәрендә Казанда уза. 200 ләп делегат, ш.и. Ибне Әхтәмов, М.Вахитов, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, С.Максуди, Г.Токымбәтов, Ә.Цаликов катнаша. Корылтай эшендә Төркестан, Кавказ, Кырым төбәге вәкилләре катнашмый. Көн тәртибендәге мәсьәләләр: Учредительләр җыенына сайлауларга хәзерлек; милли-мәдәни мохтарият төзелеше; җир бүленеше мәсьәләләре; хатын-кызларның ирләр б-н тигез хокуклыгына карата мөнәсәбәт һ.б. 22 июльдә Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае һәм Бөтенроссия мөселман руханилары корылтае делегатлары б-н берләштерелгән утырыш уздырыла (1000 нән артыграк кеше катнаша). Ул утырышта Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының милли-мәдәни мохтариятын төзү турында декларация кабул ителә; *Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының милли-мәдәни мохтарият нигезләрен эшләү комиссиясе* төзелә. 22 июль көне Россия мөселманнарының милли бәйрәме дип игълан ителә. Корылтайда катнашучылар мөселманнарны Россиянең революцион демократлары һәм алар төзегән дәүләт оешмалары б-н берләшергә чакыралар. Мөселман гаскәри берәмлекләрен төзергә рөхсәт алу өчен Вакытлы хөкүмәт тарафына делегатлар җибәрү карала. Учредительләр җыены чакырылганны көтеп тормыйча, шушы корылтайда ук Россия мөселманнарының милли-мәдәни мохтариятын оештыру җирлеге булырдай төп кагыйдәләрне эшләргә карар кылына. Делегатлар ш.у. түбәндәге тәкъдимнәрне хуплыйлар: Төркестан, Кырым һәм Кавказ төбәге мөселман халыкларына дәүләт төзелеше формасын сайлау хокукын үзләренә калдыру; дин, мәгариф һәм тел мәсьәләләре Эчке Россия һәм Себер мөселманнары мохтарияты карамагына тапшыру; Милли-мәдәни мохтариятның иң югары вәкаләтле канун чыгару органы — Милләт Мәҗлесен чакыру. Мөселманнар яшәгән Эчке Россия терр-се милли губерналарга бүленергә, анда иң югары вәкаләтле орган — губерна милли җыены булырга тиеш, диелә. Учредительләр җыенына хәзерлек барышында демократ-социалистлар платформасында торган гомуммөселман блогын булдыру, мөселман кандидатларның бердәм исемлеген төзү карала. Кулланылышта булган барлык җирләр шунда хезмәт итүчеләргә түләүсез бүлеп бирелергә тиешлеге; 8 сәгатьлек эш көне кертү, эшчеләрнең социаль иминиятен саклауны дәүләткә йөкләү, социалистик партияләрнең эшчеләргә мөнәсәбәтле программа минимумын хуплау кирәклеге хәл ителә. Делегатлар хатын-кызларның тигез хокуклыгы мәсьәләсендә Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче корылтаенда кабул ителгән карарны (мирас бүленеше һәм шаһитлык күрсәтмәләре бирү хокукы каралган өлештән кала) тормышка ашыру кирәклеген, Диния нәзарәтенең шул карарга таянып эш итәргә тиешлеген белдерәләр. Корылтайда кабул ителгән карарлар турында рәсми рәвештә Вакытлы хөкүмәткә хәбәр итү һәм, Учредительләр җыенын җыюны көтмәстән, аларны гамәлгә ашыру өчен рөхсәт алу бурычы Милли Шурага йөкләнә.

**Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае,** 1917 елның 17–26 июлендә Казанда уздырыла. *Бөтенроссия мөселманнарының Вакытлы Хәрби Шурасы* тәкъдиме б-н чакырыла. Хәрби министр А.Ф.Керенскийның башта корылтай уздырырга рөхсәт бирмәве сәбәпле делегатларның байтагы килә алмый кала. 200 дән артык солдат һәм офицер, ш.и. И.Алкин, Х.Әбүлханов, Г.Токымбәтов, Г.Гобәйдуллин катнаша. Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр: мөселман хәрби оешмаларын төзү эше, мөселман гаскәри берәмлекләрен туплау, Учредительләр җыенына сайлауларда катнашу, җиргә һәм хатын-кызлар хокукына караган мәсьәләләр, даими эшләүче *Бөтенроссия мөселманнары Хәрби Шурасы*н сайлау. Түбәндәге карарлар кабул ителә: тылдагы гарнизоннарда гарнизон мөселман хәрби ком-тларын, фронтларда армия һәм дивизия мөселман хәрби ком-тларын оештырырга; урыннарда армия берәмлекләрен халык милициясе дип үзгәртергә яки милли гаскәри берәмлек итәргә; кичекмәстән милли гаскәри берәмлекләрне оештыруга керешергә; Учредительләр җыенына делегатлар сайлауларда актив катнашырга, фәкать мөселман соц. оешмалары һәм төркемнәре б-н блоклар төзергә; милли-соц. блоклар оештыруга әһәмият бирергә; мөселман хатын-кызларын сәясәттә һәм тормыш-көнкүрештә ир-ат б-н тигез хокуклы санарга. Делегатлар җирдән файдалану мәсьәләсендә түбәндәге карарлар кабул итәләр: аграр секторга караган җирләр халык карамагына күмәк куллану өчен түләүсез тапшырылырга, хосусый милек булмаска, җирдән файдаланудан алынган өстәмә (югары) керем җәмәгать эшчәнлегенә һәм мәгариф-мәдәният ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә тотылырга; аграр мәсьәләләргә кагылышлы карарларны Учредительләр җыены кабул итәргә, аңа кадәр 25 майда Бөтенроссия крәстияннәре съездында кабул ителгән карарлар гамәлдә булырга тиеш. Делегатлар А.Ф.Керенский җитәкчелегендәге МКның милли сәясәтен гаепләп чыгалар, милләтпәрвәр украинлыларга карата кулланылган чараларга ризасызлык белдерәләр, мөселман халыклары өчен тулы хокуклы автономия бирелүен таләп итәләр. Корылтайда 67 кешедән торырга тиешле Хәрби Шура оештырыла, аларның 36 сы шул көнне үк сайлана. Хәрби Шура исеменнән «*Безнең тавыш*» г-тасын нәшер итү турында карар кабул ителә. 22 июльдә делегатлар Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае һәм Бөтенроссия мөселман руханилары корылтае делегатлары б-н берләштерелгән утырышта катнашалар.

**Бөтенроссия мөселман руханилары корылтае**, 1917 елның 17–21 июлендә Казанда уза. 100 гә якын делегат катнаша. Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр: 1) дини оешмалар турында; 2) хатын-кызлар хокукы мәсьәләсе һ.б. Хатын-кызлар хокукына кагылышлы мәсьәлә тикшерелгәндә зур бәхәс куба. Мөфтият тарафыннан хатын-кызларның хокукы һәм бурычлары турында әзерләнгән аңлатма ул бәхәскә сәбәп-сылтау гына була. Реакцион руханилар катгый рәвештә хатын-кызларның ирләр б-н тигез хокуклы булуына каршы чыга. Мәсьәләгә ачыклык кертү өчен мөфти Г.Баруди катнашында хатын-кызлар вәкилләре б-н киңәшмә уздырыла һәм килешүгә ирешелә. 22 июльдә корылтай делегатлары Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае һәм Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае делегатлары б-н бергәләп уздырылган утырышта катнашалар.

**Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең икенче корылтае**, 1918 елның 8(21) гыйнвар — 20 февраль (3 март) көннәрендә (бүленеп) Казанда уза. 203 делегат (күпчелеге эсерлар партиясе платформасына якын торучылар; 22 большевик б-н 13 сул эсер сул фракцияне тәшкил итәләр), ш.и. Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Г.Монасыйпов, Й.Мозаффаров катнаша. Көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләр куела: *Идел-Урал Штатын* төзү карарын гамәлгә ашыру; Совет хакимиятенә карата мөнәсәбәт белдерү; Хәрби Шура эшчәнлеге; мөселман гаскәриләренең милли хәрәкәттә катнашуы; Урта Идел һәм Көньяк Урал хәрби штабларын оештыру; милли гаскәри берәмлекләр төзү. Корылтайның төп максаты — Идел-Урал Штатын оештыру. Әмма Башкортстан авт. респ-касының Башкорт Шурасын төзү турында игълан итүе бу мәсьәләне катлауландыра. Корылтайда башкорт халкының мөстәкыйль этник берәмлек булу-булмавы хакында бәхәс җәелә. И.Алкин, башкортлар — төрки-татар халкының бер өлеше, шунлыктан алар Идел-Урал Штаты составына керергә тиеш, дип белдерә. Т.Имаков җитәкчелегендәге башкорт делегациясе вәкилләре аның фикере б-н килешми, башкортлар — үз мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре булган аерым мөстәкыйль милләт, дип чыгалар. Үзара бәхәстән һәм киңәшүләрдән соң башкортларны да үз эченә алачак автономияле Идел-Урал Совет Респ-касын оештыру кирәклеге фикеренә киленә. Корылтай булачак республиканың Кануннар чыгару җыенын булдыруны, ул оештырылганчы Вакытлы хөкүмәт төзүне хәл итәргә кирәк дип таба. Делегатлар Учредительләр җыенын таратуны хуплаган карар кабул итәләр. Ш.у. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советлары эшчәнлеген яклауларын һәм аның Совет хакимиятенең югары органы булуын тануларын белдерәләр. Мөселман гаскәри берәмлекләрен (милли армия оештырылганга кадәр) төзүне дәвам итәргә, Петроградта һәм Ставка каршында комис-т оештырырга карар кылына. Корылтай делегатларының Совет хакимиятенә карата лояль мөнәсәбәттә булуларына карамастан, Казан Советы җитәкчеләре аларга ышанмыйлар, астыртын рәвештә корылтайны тарату планын коралар. Корылтай барган көннәрдә Хәрби Шура җитәкчеләренә Казан советының үзәккә телеграмма җибәрергә әзерләнүе мәгълүм була. Казан хәрби округының идарә коллегиясе рәисе И.П.Шелымханов Хәрби эшләр комис-ты башлыгы Н.И.Подвойскийдан «өч мең гаскәридән торган Финляндия мөселман полкының Казанга килүен тоткарлау һәм коралсызландыру»ны үтенә. Корылтайда катнашучылар өчен бу көтелмәгән хәл була, алар И.П.Шелымхановны эшеннән азат итүне һәм телеграмманың җибәрелмәвен таләп иткән карар чыгаралар. Хәрби эшләр комис-тына мөселман гаскәриләренең фәкать үз хәрби-революцион оешмалары таләпләренә генә буйсынačаклары белдерелә. Урындагы хәрби оешмаларга Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советларына кичекмәстән Яңа сайлаулар уздыру тәкъдим ителә. Совет хөкүмәтен берсүзсез яклаган сул фракция корылтайны ташлап чыга. Мөселман гаскәриләре корылтае җитәкчелегенә каршы көрәшү өчен Революцион штаб оештырыла, аның составына М.Солтангалиев тә керә. Штаб утырышларында С.Сәетгалиев тә катнаша, ул «республика төзүне игълан итәргә мөмкинлек бирү ягында тора». Идел-Урал Штатын төзү карары кабул ителергә тиешле көн алдыннан, 1917 елның 28 февраль төнендә, корылтай башлыклары Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Й.Мозаффаров, Г.Токымбәтов кызылгвардиячеләр (Х.Урманов җитәкчелегендә) тарафыннан кулга алына. Корылтай утырышлары кичектерелә һәм ике көннән соң шәһәрнең Болак арты өлешендә дәвам иттерелә (к. «*Болак арты республикасы*»). Аның утырышында *Мөселман халык комиссариаты* һәм Мөселман революцион штабы оештырыла. Ш.у.к. *Идел-Урал төбәге өлкә советлары съезды*.

Чыг.: Третий Всероссийской мусульманский съезд. К., 1906; Материалы и документы по истории общественно-политического движения среди татар (1905–1917). К., 1992; Илиас Алкин — общественный деятель, военоначальник, учёный: Док. и материалы. К., 2002.

*Әд.:* Вәлиев Р. Болак арты республикасы. К., 1999; Грачев Е. Казанский Октябрь. Хроника революции 1917 г. (период март–октябрь). К., 1926; Ибрагимов Г. Татары в революции 1905 г. К., 1926; Ионенко И., Тагиров И. Октябрь в Казани. К., 1967; Давлетшин Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; Тагиров И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000; Политическая жизнь русских мусульман до февральской революции. Оксфорд, 1987; Политические деятели России. 1917: Биогр. словарь. М., 1993; Фахрутдинов Р.Р. Татарский либерализм в конце XIX – начале XX веков (очерки политической истории). К., 1998.

*Л.М.Айнетдинова, Р.Г.Хәйретдинов.*

**БӨТЕНРОССИ́Я МӨСЕЛМАННАРЫНЫ́Ң ВАКЫТЛЫ́ ХӘРБИ́ ШУРАСЫ́**, 1917 елның апрелендә *Бөтенроссия мөселман гаскәриләре киңәшмәсе* карары б-н оештырыла. Рәисе И.Алкин, әгъзалары: Җ.Алкин, И.Әхмәров, Х.Еникиев, Г.Токымбәтов, Г.Монасыйпов һ.б. (барлыгы 12 кеше). Максаты — Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 1 нче корылтаен оештыру һәм уздыру. Вакытлы Хәрби Шура урыннарда кыска вакытлы агитаторлар курсларын оештыра һәм мөселман гаскәриләренең 56 ком-тын оештыруда ярдәм итә. 1917 нең июленә кадәр эшли. Матбугат басмасы — «*Безнең тавыш*» г-тасы.

*Әд.:* Давлетшин Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; Тагиров И.Р. Революционная борьба и национально-освободительное движение в Поволжье и на Урале. К., 1977.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**БӨТЕНРОССИ́Я МӨСЕЛМАННАРЫ́Ң МИЛЛИ́ ШУРАСЫ́**, Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае карары белән 1917 елның маенда Петроградта оештырыла (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Максаты: мөселманнарның сәяси һәм иҗтимагый-мәдәни тормышына җитәкчелек итү, булачак Учредительләр җыенына мөселман вәкилләрен сайлауны оештыру, Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче корылтаен чакыруга әзерлек эшләрен башкару. Милли Шурага барлыгы 30 кеше сайлана, ш.и. Эчке Россия һәм Себер мөселманнарыннан 10 әгъза һәм 3 кандидат (Ә.Цаликов, Ф.Кәрими, Ибраһим Әхтәмов, И.Алкин, З.Шамил, М.Бигиев, М.Төмәнов, Ш.Мөхәммәдьяров, Г.Исхакый, кандидатлар Ибне Әхтәмов, С.Мәмлиев, Ф.Туктаров), Төркестан, Бохара, Хивадан 7 әгъза (Г.Ходжаев, Әхмәтзәки (Зәки) Вәлиди, К.Тугусев, И.Җайнаков, К.Абдулхаликов, К.Рахманбирдиев, С.Урынбаев), Казакъстаннан 5 кеше (К.Кушчигулов, К.Уразаев, Д.Дусмөхәммәдов, В.Таначев, Аккагыз Дусҗан кызы), Кырымнан 2 кеше (И.Леманов, Х.Баданинский), Кавказдан 5 һәм Литва татарларыннан 1 кеше (бу вәкилләр соңрак сайланырга тиеш була). Югары идарә органы — Мөселманнар башкарма ком-ты (Искомус), рәисе — Ә.Цаликов, әгъзалар И.Алкин, бертуган Әхтәмовләр, М.Бигиев, Ш.Мөхәммәдьяров, С.Максуди, Г.Исхакый, И.Леманов, З.Вәлиди, М.Төмәнов һ.б. Башкарма ком-т әгъзаларына Россиянең Вакытлы хөкүмәте утырышларында катнашу рөхсәт ителә. Милли Шура Вакытлы хөкүмәткә рус булмаган милләт вәкилен кертү тәкъдиме б-н дә чыга, әмма ул тәкъдим кире кагыла. Милли Шура Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаен әзерләү һәм Учредительләр җыенына мөселман вәкилләрен сайлау эшләрен оештыра. 1917 нең августында, генерал Л.Г.Корнилов җитәкләгән фетнә барышында, Милли Шура вәкилләреннән Ә.Цаликов, А.Намитяков, И.Кугушев җитәкчелегендәге бер төркем Кавказ халыкларыннан торган Кыргый дивизияне фетнәдә катнашмаска күндерәләр. Шул сәбәпле фетнә бастырыла. *Милләт Мәҗлесе* эшен башлап җибәргәч, Милли Шура үзенең төп вәкаләтләрен аңа тапшыра. Совет хакимиятенең 1918 елның 22 май карары нигезендә Б. м.М.Ш. эшчәнлеге тыела.

*Әд.:* Давлетшин Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX в.). К., 1999.

*И.Р.Таһиров.*

**БӨТЕНРОССИ́Я УГЛЕВОДОРО́Д ЧИМАЛЫ́ ИНСТИТУТЫ́** (ВНИИУС), фәнни-тикшеренү ин-ты. 1965 елның апрелендә СССР Госпланы каршындагы Нефть чыгару сәнәгате дәүләт ком-ты тарафыннан Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тының Казан сәнәгый нефть химиясе чималы бүлеге нигезендә Бөтенсоюз (1993 тән Бөтенроссия) углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты буларак оештырыла. Институт, 1965 нең декабреннән җиңел углеводород чималын җитештерү һәм куллану өлкәсендәге баш оешма буларак, СССР Нефтехимия сәнәгате министрлыгы карамагында. 1991 дән ТР ФАнең фәнни-методик җитәкчелегендә эшли (2005 тән Идел буе углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты — «ВНИИУС» АҖ). Ин-т составында 16 лаборатория, фәнни-техн. бүлек, ремонт-механика хезмәтләре, сынаулар өчен ярымсәнәгый тәҗрибә җайланмасы. Эшләрнең төп юнәлешләре: углеводород чималын, сыекландырылган газларны, ягулыкны һәм сәнәгатьтә кулланылган суларны күкертле кушылмалардан арындыру өчен яңа процессләр һәм катализаторлар булдыру, булганнарын камилләштерү; җиңел углеводород чималын эшкәртү технологияләрен (газ фракцияләү, чистарту, корыту һ.б.) һәм җиһазларын камилләштерү һәм аларның яңаларын булдыру; саф углеводородлар табу, метрологик тикшеренүләр өчен



Бөтенроссия углеводород чималы институты.

эталон бупырлык газ катнашмалары һәм күкертле органик кушылмалар алу һәм аларны җитештерү технологияләре эшләү; нефть эшкәртү пр-тиеләрендә күкерт һәм күкерт кислотасы җитештерү өчен күкертле водородның ресурсларны билгеләү, агымдагы һәм перспектив балансларын төзү; югары үзле нефтьләрне һәм табигый битумнарны тикшерү, аларны эшкәртү технологиясенең фәнни нигезләрен булдыру; әйләнә-тирәне саклау һәм табигый ресурсларны пр-тиеләрдә һәм аерым регионнарда рациональ куллану технологияләренең норматив документларын булдыру; җиңел углеводород чималын җитештерү һәм куллануның ресурсларын билгеләү, агымдагы һәм перспектив җыелма балансларын төзү; Россия сәнәгатенең нефть, газ, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе тармакларында углеводород чималын (этан, сыекландырылган газлар, пентаннар һ.б.) җитештерү һәм куллану торышын анализлауны үткәрү һәм алар буенча еллык отчётлар әзерләү. Ин-тның фәнни эшкәртмәләре РФнең («Татнефть» АҖ, «Түбәнкаманефтехим» АҖ, «Пермь газ эшкәртү з-ды» ААҖ, «Сибур», «Сургут-Газпром» АҖ, Ачинск, Куйбышев нефть эшкәртү з-длары, «Норси-Ойл» АҖ һ.б.), Казакъстан («Чимкентнефтеоргсинтез», Атыраус нефть эшкәртү з-дары) һәм ерак чит илләр («Шеврон» фирмасы — АКШ, «Лурги», «Линде», «БАСФ» фирмалары — Германия, «Пропак Систем ЛТД» фирмасы — Канада) нефть эшкәртү з-дларына кертелә. Ин-тта (2007 елга) 1 ТР ФА академигы, 2 фәннәр докторы, 15 фәннәр кандидаты, 9 Дәүләт бүләге лауреаты эшли; ин-т хезмәткәрләре тарафыннан уйлап табу буенча 350 авторлык таныклыгы, 13 патент, ш.и. АКШның — өч, Германиянең бер патенты алына.

**БӨТЕНРОССИ́Я ҮЗӘ́К БАШКАРМА́ КОМИТЕТЫНЫ́Ң (БҮБК) ЭКСПЕДИЦИО́Н ПАРТИЗА́Н ОТРЯДЫ́**, Гражданнар сугышы елларында кораллы оешма. 1918 елның августында большевиклар хөкүмәте акгвардияче гаскәрләр тылында партизаннар отряды төзү турында карар кабул итә. Партизаннар сугышын оештыру һәм алып бару БҮБК вәкиле И.С.*Кожевников*ка тапшырыла, отряд комиссары итеп В.Г.Кальницкий, штаб начальнигы итеп Э.К.Тиссэ билгеләнә, отрядның планы Революцион хәрби совет рәисе Л.Д.Троцкий һәм Көнчыгыш фронт баш командующие И.И.Вацетис тарафыннан тикшерелә һәм хуплана. Отряд, аклар тылында һөҗүмнәр ясап, Кызыл Армиянең хәрәкәттәге гаскәренә ярдәм итәргә тиеш була. Аңа Чаллы авылы тирәсендә Кама елгасыннан ярга чыгу, Уфа губернасының Минзәлә өязен яулап алу һәм Бөре юнәлешендә хәрәкәт итү бурычы куела. Башлыча, Курск, Түбән Новгород һәм Әстерхан почта-телеграф округларыннан җыелган отрядта барысы 500 кеше исәпләнә. Ул ике пехота ротасыннан, пулемет командасыннан (13 пулемет), артиллерия батареясыннан (3 туп) һәм элемтә командасыннан тора. Отряд, Мәскәүдән 30 сентябрьдә чыгып, 6 октябрьдә Чаллыга килеп җитә һәм шундук походка чыга: 15 октябрьдә — Матвеевка авылын, 16 октябрьдә — Минзәлә шәһәрен, 19 октябрьдә Пучы авылын сугышып ала, 5 ноябрьдә партизаннар Байсар авылына керә һәм Бөгелмә — Уфа — Минзәлә — Бөре трактлары арасындагы позицияләрне ала, нәтиҗәдә Бөрегә илтә торган юл партизаннар карамагына күчә. Ноябрьдә отрядта сугышчылар саны 12 мең кешегә җитә. Командование карары нигезендә отряд «Партизаннар Кызыл Армиясе» дип атала башлый, 9 мөстәкыйль отряд һәм 2 артиллерия дивизионы итеп үзгәртелә. Отряд командирлары итеп А.М.Козин (1 нче отряд), П.С.Полухин (2 нче отряд), И.С.Душкин (3 нче отряд), И.Ф.Рашевский һәм аның урынбасары С.С.Хәйруллин (7 нче отряд) һ.б. билгеләнә. 7 отряд Татарстан терр-ясендә хәрәкәт итә. Аларның штаблары Пучы, Ольгино, Олы Чакмак, Кече Чакмак, Рус Шуганы, Александровка һәм Чаллы авылларында урнаша. Ике отряд Башкортстан терр-ясендә (штаблары Бакалы һәм Иске Корыч авылларында) була. Отрядта даими төстә контрреволюция, саботаж һәм шпионлык б-н көрәш буенча Гадәттән тыш тикшерү комиссиясе эшли. Отряд сугышчылары көчләп продразвёрстка үткәрүгә җәлеп ителә, алар җыйган 200 мең пот ашлык илнең сәнәгать үзәкләренә җибәрелә. Яулап алынган җирләрдә отрядның сәяси хезмәткәрләре көче б-н бик зур агитация-пропаганда эшчәнлеге алып барыла: листовкалар, газеталар чыгарыла. Октябрь революциясенә бер ел тулу уңаеннан төп отрядка «Партизаннар Кызыл Армиясе, И.С.Кожевников экспедициясе» дигән мактаулы революцион байрак тапшырыла. 1918 нең декабрендә партизаннар армиясе Көньяк фронт составына кертелә, аның төп көчләре Курск губернасының Яңа Оскол шәһәре тирәсендә туплана. 1919 ның гыйнварында отрядта 30 мең кеше һәм

6 мең ат була. Купянск, Старобельск, Луганск шәһәрләре өчен барган сугышларда катнаша. Соңрак отряд базасында И.С.Кожевников җитәкчелегендәге 13 нче армия оештырыла. Армия составында Татарстан кешеләре күп була (10 меңнән артык мөселман кешесе исәпләнә).

*А.Насыйров.*

**БӨТЕНРОССИ́Я ЧЫГЫ́М ҮЛЧӘ́Ү ИНСТИТУТЫ́** (ВНИИР), фәнни-тикшеренү ин-ты, дәүләт фәнни метрология үзәге. Татарстан үлчәү техникасы буенча дәүләт күзәтү лаб. җирлегендә Бөтенсоюз физ.-техник һәм радиотехник үлчәүләр фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лы буларак 1966 елда оештырыла. 1992 дән ВНИИР, 2001 дән ВНИИР федераль дәүләт унитар пр-тиесе. Сыеклык, газ чыгымнарын төгәл үлчәү ысулларын һәм чараларын эшләү, физик-химик үлчәүләр өлкәсендә специальләшә. 1994 тә стандартлаштыру, метрология һәм үлчәү чараларын сертификацияләү буенча дәүләт фәнни метрология үзәге буларак аккредитацияләнә. Заманча тәҗрибә базасы — дәүләт метрология чыгымын үлчәү комплексында 6 дәүләт эталоны, 40 гаять төгәл үлчәү һ.б. тикшерү җайланмалары б-н җиһазланган су, газ һәм нефть үлчәү станцияләре бар. Ин-т норматив документлар б-н эш итә, халык хуҗалыгының барлык тармакларында матди һәм чимал ресурслары чыгымнарын төгәл үлчәүнең бердәм дәүләт фәнни-техник сәясәтен гамәлгә ашыру: эталоннарны камилләштерү һәм саклау, үлчәүләрнең гаять төгәл ысулларын һәм чараларын, стандарт үрнәкләрен эшләү, бердәм үлчәү берәмлекләре б-н тәэмин итү буенча норматив документлар әзерләү б-н шөгыльләнә. Метрологик аттестацияләү, дөресләү, сертификацияләү һәм үлчәү чараларын дәүләти тикшерү, үлчәү лаб-яләренә үлчәүләрне дөресләү һәм калибрын билгеләү хокукын бирү, ш.у. башка төр метрологик хезмәт күрсәтү эшләре башкара. Ин-т күп кенә илләрнең метрологик оешмалары б-н хезмәттәшлек итә. Газ, нефть, нефть продуктларын тапкан, ташыган, җитештергән һәм бүлгән вакытта үлчәү чараларын метрологик тәэмин итүдә катнаша. Ин-тта (2008 елга) 26 фәннәр канд. һәм 2 фәннәр д-ры эшли.

**БӨТЕНСОЮ́З ЛЕ́НИНЧЫЛ КОММУНИ́СТИК ЯШЬЛӘ́Р СОЮЗЫ́** (ВЛКСМ, комсомол), СССРда 1918–92 елларда яшьләрнең иҗтимагый-сәяси оешмасы. 1918 елның 29 октябрендә эшче һәм крәстиян яшьләре союзларының 1 нче Бөтенроссия съездында Россия коммунистик яшьләр союзы (РКСМ) исеме б-н оештырыла, 1924 елдан — РЛКСМ, 1926 дан — ВЛКСМ. Аның эшчәнлеге Коммунистлар партиясе программасы нигезендә алып барыла. ВЛКСМның үз уставы, үзәк һәм җирле җитәкче органнары була. Пр-тиеләрдә, колхоз-совхозларда, уку йортларында, Совет Армиясе гаскәри берәмлекләрендә башлангыч комсомол оешмалары оештырыла. Югары органы — Бөтенсоюз съезды, съездлар арасында — ҮК, аның пленумнарында ВЛКСМ ҮКнең бюросы, секретариаты сайлана. ВЛКСМ әгъзалыгына 14 яшьтән 28 яшькәчә егетләр һәм кызлар кабул ителә. Комсомол дәүләт һәм җәмгыять эшләре б-н идарә итүдә, яшьләрне тәрбияләүдә, сәяси, халык хуҗалыгына кагылышлы һәм социаль-мәдәни мәсьәләләрне хәл итүдә актив катнаша. Коммунистлар партиясе ВЛКСМны яшьләр арасында үз идеологиясен уздыручы төп оешма итеп карый. Комсомолның иң мөһим бурычы чын патриотлар, аңлы, югары белемле, хезмәт сөючән, төрле яктан хәзерлекле коммунизм төзүчеләр тәрбияләү, яшьләрне гамәли яктан коммунистик җәмгыять төзүгә җәлеп итү була. Комсомол яшь буынны пролетар интернационализм принципларына тугрылык рухында тәрбияләүгә омтыла, халыкара яшьләр хәрәкәтен җәелдерүгә ярдәм итә. ВЛКСМ әгъзалары хезмәттә үрнәк күрсәтергә, белемнәрне, мәдәниятне үзләштерергә, илнең сәяси тормышында актив катнашырга тиешләр. Комсомол В.И.Ленин исем. Бөтенсоюз пионер оешмасы б-н җитәкчелек итә.

Казанда ВЛКСМ оешмасы *Эшче яшьләр берлеге* (1917 нең июлендә нигез салына) җирлегендә оештырыла. 1919 ның 21 апрелендә *Эшче яшьләр берлегенең беренче гомумшәһәр конференциясендә* РКСМның шәһәр ком-ты сайлана. 1919 ның 25 апрелендә татар яшьләренең беренче комсомол ячейкасы оештырыла. 1919 ның 14 июлендә Казанда РКСМның 1 нче губерна конференциясе уза, Х.Гарбер, Г.Подузов, М.Федотов, Ю.Фемидин, Э.Цимхес составында беренче губерна ком-ты сайлана. Исемнәре: РКСМның Казан шәһәр оешмасы, 1919 дан — РКСМның Казан губерна оешмасы, 1920 дән — РКСМның Татарстан өлкә оешмасы, 1926 дан — ВЛКСМның Татарстан өлкә оешмасы, 1991 дән — ВЛКСМның Татарстан респ-ка оешмасы. ВЛКСМ гамәлдә чакта 2 губерна, 42 өлкә конференциясе уздырыла. 1919 ның августында губерна ком-ты каршында агитатор-инструкторлык курслары, 1920 дә шулар җирлегендә сәяси мәктәп ачыла; яшьләрнең матди мәнфәгатьләрен яклау өчен икътисад-хокук секциясе, укучылар арасында эшләү бюросы, күчмә инструкторлар коллегиясе, мобилизация секциясе оештырыла. 1919 ның июнь-июлендә өязләрдә татар яшьләренең беренче комсомол оешмалары барлыкка килә. 25 августта губерна ком-ты каршында татар бюросы (рәисе — М.Мөхәммәтов), 1919 ның 2 октябрендә чуаш бюросы (рәисе — С.Абу) булдырыла. РКСМның 3 нче съезды карары б-н 1920 нең ахырында икесе дә бетерелә. 1920 нең кышында губ. ком-ты тифка каршы көрәштә актив катнаша, дезинфекцияләү отряды һәм санитарлык комиссияләре эшли.

1920 нең 1 сентябрендә РКСМның 1 нче Татарстан өлкә конференциясе булып уза, анда Г.Кушаев, Н.Сәйфи, Л.Рубинштейн, Д.Пойгин, М.Парсин составында өлкә ком-ты сайлана. 1921 нең апрелендә өлкә ком-ты каршында гомуми, оештыру-инструкторлык, социаль-мәгариф, сәяси-агарту, икътисад-хокук, хәрби-спорт (1921 нең августында бетерелә), милләтләр бүлекләре, ярлылар арасында эшләү бюросы оештырыла. 1926 да низаг-бәхәсләрне хәл итү комиссиясе төзелә. 1950 дә өлкә ком-ты үзгәртеп корыла; финанс-хуҗалык секторы, комсомол оешмалары, пропаганда һәм агитация, студент яшьләр, хәрби-физкультура, авыл яшьләре б-н эшләү, мәктәп укучылары һәм пионерлар б-н эшләү, эшче яшьләр б-н эшләү бүлекләре оештырыла. 1964 елда һәм 1987 дә оешманың төзелешенә зур булмаган үзгәрешләр кертелә.

Комсомолның Казан губерна һәм Татарстан өлкә оешмасында әгъзалар саны

| Еллар | Әгъзалар саны | Еллар | Әгъзалар саны |
|---|---|---|---|
| 1919 ның апреле | 220 | 1941 нең гыйнвары | 92755 |
| 1920 нең феврале | 8000 | 1945 нең гыйнвары | 73094 |
| 1922 нең марты | 2078 | 1965 нең гыйнвары | 291000 |
| 1926 ның гыйнвары | 20615 | 1977 нең гыйнвары | 500000 |

Татарстан комсомолы КПСС тарафыннан уздырылган барлык чараларда актив катнаша. Меңнән артык комсомол әгъзасы Гражданнар сугышында: Көнчыгыш, Көньяк, Көнбатыш, Төркестан һ.б. фронтларда, 27 нче һәм 28 нче (Азин җитәкчелегендә) дивизияләр, Идел буе татар укчыларының 1 нче аерым бригадасы һ.б. составында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Алар халык хуҗалыгын торгызуга, Коммунистлар партиясенең индустриальләштерү һәм күмәкләштерү сәясәтен тормышка ашыруга зур өлеш кертәләр. Беренче бишьеллык чорында ТЭЦ-1, мех комб-ты, кайбер машина төзү пр-тиеләре төзелешләре респ-када комсомол-яшьләр төзелешләре дип игълан ителә. Моннан тыш Татарстан комсомоллары Днепрогэста, Березники һәм Магнитогорск комб-тлары, Донбасс шахталары, трактор һәм автомобиль з-длары төзелешләрендә эшли. Беренче бишьеллыкта яңа төзелешләргә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тыннан барлыгы 5 меңнән артык кеше җибәрелә. 1925 нең 25 гыйнварында Лаеш комсомоллары инициативасы б-н Татарстанда беренче комсомол колхозы төзелә (1930 елга аларның саны 600 гә якынлаша). Бөек Ватан сугышы елларында Казан пр-тиеләрендә 2500 комсомол-яшьләр бригадалары оештырыла, металл ватыклары җыю буенча 50 өмә, 6 ункөнлек уздырыла. Татарстан комсомоллары «Татарстан колхозчысы», «Татарстан комсомолы» танк колонналарын һәм 3 хәрби самолётлар эскадрильясе, ш.и. «Совет Татарстаны» эскадрильясен төзү өчен акча җыю турында чакыру б-н чыгалар. Сугыш елларында Татарстанның 80 меңнән артык комсомол егет-кызлары Кызыл Армия сафларына баса, алар арасыннан В.Григорьев, И.Маннанов, Ш.Рәхмәтуллин, М.Фомин, Ф.Шәрипов Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Республиканың 35 меңнән артык комсомолы сугыштан зыян күргән төбәкләрне торгызуда катнаша. 1954–58 дә Татарстанның 10 меңнән артык комсомолы чирәм җирләрне күтәрешә. КамАЗ төзелеше, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре төзелешләре һ.б. комсомол төзелешләре булып калды.

1980 еллар ахырында комсомол хәрәкәте кризис кичерә, әгъзалар саны кими. 1990 елның гыйнварында респ-ка оешмасында

375 меңнән артык әгъза исәпләнә. 1991 нең февралендә узган 41 нче өлкә конференциясендә яңа Устав кабул ителә, анда ВЛКСМ Коммунистлар партиясен яклаучы «хөкүмәтнеке булмаган яшьләр оешмасы», дип белдерелә. 1991 елда респ-ка ком-ты составында комсомолларны реабилитацияләү комиссиясе оештырыла. 1991 нең 2 сентябрендә респ-ка комсомол ком-ты аппараты бетерелә, 1992 нең гыйнварында 42 нче респ-ка конференциясендә ВЛКСМның Татарстан респ-ка оешмасы үзенең вәкаләтләрен респ-ка яшьләр оешмалары советына тапшыра.

Республика комсомол оешмасының басма органнары: «*Кызыл яшьләр*», «*Клич юного коммунара*», «*Комсомолец Татарии*», «*Татарстан яшьләре*», «*Яшь ленинчы*» г-талары, «*Ялкын*» ж-лы.

Республика комсомол оешмасының беренче секретарьлары: Х.И.Гарбер (июль 1919 — авг. 1920), Л.М.Рубинштейн (сент. 1920 — февр. 1921), М.Ф.Фёдоров (март — окт. 1921), А.М.Баландина (окт. 1921 — гыйнв. 1922), Н.И.Блудау (февр. 1922 — апр. 1923), П.Павлов (июнь 1923 — март 1925), Д.Бендюков (май 1925 — февр. 1927), С.С.Фёдоров (март 1927 — авг. 1928), Ә.З.Зарипов (авг. 1928 — дек. 1930), З.Ә.Әхмәтшин (гыйнв. 1931 — дек. 1932), В.А.Калашников (гыйнв. 1931 — дек. 1932), Г.М.Мөхәммәтҗанов (дек. 1932 — гыйнв. 1936), М.Г.Бәһаветдинов (фев. 1936 — окт. 1937), А.П.Перов (нояб. 1937 — сент. 1940), М.И.Доронин (окт. 1940 — авг. 1942), Б.М.Луцкер (авг. 1942 — окт. 1944), Ә.Ә.Милмөхәммәтов (окт. 1944 — нояб. 1949), М.Ш.Шәфиков (нояб. 1949 — июль 1950), В.Н.Макаров (авг. 1950 — окт. 1953), Д.С.Шакирҗанова (нояб. 1953 — гыйнв. 1957), В.В.Горбунов (март 1957 — гыйнв. 1958), К.Я.Җамалетдинов (гыйнв. 1958 — апр. 1961), О.И.Данилов (апр. 1961 — июль 1963), Р.К.Беляев (июнь 1963 — апр. 1969), А.П.Василец (апр. 1969 — июль 1972), И.Ш.Рахманкулов (июль 1972 — дек. 1975), В.В.Кузьмин (дек. 1975 — июль 1977), Ш.Р.Агиев (июль 1977 — февр. 1982), Б.Д.Леушин (март 1982 — авг. 1984), Д.К.Шәяхмәтов (сент. 1984 — окт. 1988), М.А.Гаделшин (дек. 1988 — авг. 1991).

*Әд.:* С м ы к о в Ю.И. Комсомол Татарии в цифрах и фактах. К., 1958; З а л я л о в А.М. Комсомол Татарии в бою и труде. К., 1968; Календарь знаменательных и памятных дат Татарии. К., 1969; Юность Татарстана: Очерки истории комсомола Татарии. К., 1978.

*Л.М.Айнетдинова.*

**БӨТЕНСОЮ́З СОЦИА́Л-ФАШИСТЛА́Р ПА́РТИЯСЕ**, к. «*Контрреволюцион фетнәчеләр оешмасы*» эше.

**БӨТЕНТАТА́Р ИҖТИМАГЫ́Й ҮЗӘГЕ́** (БТИҮ), иҗтимагый-сәяси оешма. 1989 елның февралендә Казанда татар интеллигенциясе инициативасы б-н Татар иҗтимагый үзәге буларак оештырыла (1989 ның 17 июлендә теркәлә); 1991 дән — Бөтенсоюз Татар иҗтимагый үзәге, 1992 дән хәзерге исемдә. Югары җитәкче органы — корылтай; башкарма органы — Вәкилләр советы (77 кеше, 1991 дә ТРдан читтәге җирле бүлекләр б-н җитәкчелек итү өчен Бөтенсоюз Вәкилләр советы һәм респ-кадагы бүлекләр б-н җитәкчелек итү өчен Республика Вәкилләр советы итеп үзгәртелә), идарә (21 кеше, 1991 нең февралендә бетерелә), Президиум, президент посты 1991 дә кертелә (соңыннан рәис). Җитәкчелек каршында Сәяси совет оештырыла, ул оешманың идеологиясен, тактикасын һәм стратегиясен билгели (идеологлар арасында Д.М.*Исхаков*, Р.С.*Хәкимов*, Ф.Ә.*Бәйрәмова*, Р.Ф.Мөхәммәтдинов). БТИҮнең төрле еллардагы лидерлары — М.Г.*Мөлеков*, З.Л.*Зәйнуллин*, Р.Г.Сафин, И.Г.Садыйков, Ф.Ш.Сафиуллин, И.Г.Әмирханов, Р.Ф.*Ягъфәров* һ.б. Программасы: татар халкының милли яңарышына булышлык итү, татар халкының дәүләтчелеген торгызу, РФ һ.б. дәүләтләр б-н тигез хокуклы дәүләтара мөнәсәбәтләр урнаштыру, татар милләтенең тел-мәдәни, сәяси берләшүе, милли үзаңның үсеше, дини оешмаларга исламны ныгытуга булышу, татар телен ТРның бердәнбер дәүләт теле итү өчен шартлар тудыру, ТРдан читтә яшәүче татарларның милли-мәдәни һәм терр. автономия төзүгә хокукларын тормышка ашыру өчен булышлык итү. 1989–91 елларда БТИҮ Татарстанның бәйсезлеге өчен күтәрелгән милли хәрәкәтне җитәкли, республиканың иҗтимагый-сәяси тормышында иң мөһим рольләрнең берсен уйный. 1991 дә оешманың ТРда — 25, аннан читтә 98 бүлекчәсе була. 1990 ның язында БТИҮнең радикаль фикердәге өлеше «*Иттифакъ*» татар милли бәйсезлек партиясен төзү инициативасы б-н чыга. 1992 елдан БТИҮ җитәкчелеге башка оешмалар һәм хәрәкәтләр б-н килешеп эшләү юнәлешен яклап килә, бу хәл оешманың радикаль фикерле әгъзаларында (барыннан да элек Чаллы бүлекчәсендә) ризасызлык тудыра. 3 нче корылтайда (март, 1993) оешма икегә бүленә, аның составыннан радикаль канат аерылып чыга, ул «Иттифакъ» партиясе б-н якынаюга йөз тота. 1993 нең августында М.Мөлеков җитәкчелегендәге килешеп эшләү сәясәте тарафдарлары чираттан тыш корылтай җыя, анда бүленеш тулысынча хәл ителә. Әмма 1993 нең декабрендә үк хәрәкәтне берләштерү максатында 4 нче корылтай чакырыла, анда оешманың яңа уставы һәм программасы кабул ителә, яңа җитәкчелек сайлана. 1995 нең 22 апрелендә ТИҮнең һәм БТИҮнең берләштерү пленумы була. БТИҮнең 5 нче корылтаенда барлык татар оешмаларын бердәм милли-демократик хәрәкәт кысаларында берләштерү идеясе алга куела, әмма бу хәрәкәт озак яшәми. 1999 да 6 нчы корылтайда программага беркадәр үзгәрешләр кертелә. 2002 нең 15 апрелендә 7 нче корылтай уздырыла, анда ТРның суверенлык хокукларын яклау буенча БМОга һәм Европа Советына хатлар әзерләнә. БТИҮ үзенең яшәү дәверендә даими рәвештә гомумроссия федераль хакимият органнарына сайлауларга каршы чыгып килә, ТРның дәүләт суверенлыгын яклый. Басма органнары: «*Ташкын*» (1989–90), «*Милләт*» һәм «*Известия ТОЦ*» г-талары.

БТИҮ Корылтайлары: 17–18 февр. 1989; 15–16 февр. 1991; 19–20 март 1993; 4–5 дек. 1993; 25–26 февр. 1996; 3 апр. 1999; 15 апр. 2002.

*Әд.:* Т о р о п о в Д. Татарстан: Партии и общественные организации. К., 1993; Т е р е н т ь е в а И.В., Б е л я к о в Р.Ю., С а ф а р о в М.Ф. Политические партии и движения Республики Татарстан. К., 1999; ш у л а р у к. Республика Татарстан: Политические партии, движения, лидеры. К., 2001. *Р.Ф.Ягъфәров.*

**БӨТЕНТАТА́Р КЫЗЫ́Л АЙ ҖӘМГЫЯТЕ́**, иҗтимагый хәйрия оешмасы. 1993 елның 20 мартында Казанда татар интеллигенциясе инициативасы б-н оештырыла. Җитәкче органы — Үзәк совет. Рәисе — М.Г.*Маликова*. Чаллы шәһәрендә бүлекчәсе бар (1993). Төрле оешмалар һәм аерым кешеләр иганәсе исәбенә яши. Инвалидларга, өлкән яшьтәге кешеләргә, мохтаҗларга, сугышлардан һәм табигать китергән бәла-казалардан зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтә (азык-төлек, кием-салым, дарулар һ.б. б-н). Җәмгыять Чечен Респ-касында барган сугышта бәла-каза күрүчеләргә ярдәм итү йөзеннән гуманитар колонналар оештыра (окт. 1995, апр., окт. 1996).

**БӨТЕНТАТА́Р КОЛХОЗЧЫ́-УДА́РНИКЛАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ́ СЪЕЗДЫ́**, 1933 елның 15–17 маенда уздырыла. 3 меӊ чамасы делегат катнаша. СССР ҮБК Рәисе М.И.Калинин чыгыш ясый. Докладчылар: ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты секретаре М.О.Разумов, ТАССР ХКС рәисе К.А.Абрамов, ТАССР җир эшләре халык комиссары Г.И.Искәндәров. Съездда язгы чәчүне төгәлләү нәтиҗәләренә йомгак ясала һәм СССР колхозчыларын колхозларны оештыру-хуҗалык ягыннан ныгытырга чакырган мөрәҗәгать кабул ителә.

*Әд.:* З а л я л о в А.М. Социалистическое преобразование сельского хозяйства в Татарии (1917–1937). К., 1974; Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии 1883–1985. К., 1985. Кн. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**БӨТЕРЕЛЧЕ́К СУАЛЧАННА́Р** (Rotifera), йомры суалчаннар классы. 2 меңләп төре билгеле, Татарстан терр-ясендә Keratella, Asplanchna, Polyartra, Brachionus, Syncheta һ. б. ыругныкылар очрый. Төче сулыкларда, мүктә, түшәмдә, туфракта киң таралганнар, алар арасында умырткасыз хайваннарның паразитлары очрый. Үлчәмнәре бик кечкенә (0,04 тән 3 *мм* га кадәр), ата суалчаннар ана суалчаннарга караганда шактый ваграк. Гәүдәсе баш, тән һәм аяк өлешләренә бүленә. Йөзүче төрләрә ярым үтә күренмәле капчыкны, түгәрәк пластинка яки бөтерчекне хәтерләтә; кайбер төрләре чәнечке, энә яки кабырчыклар б-н капланган; аз хәрәкәтләнүчән формалары көпшә рәвешендәге өннәрендә тереклек итә, ерткычлардан шунын эченә кереп сакланалар. Йөзүче планктон Б.с., үз күчәрләре тирәли бөтерелү аппараты ярдәмендә әйләнеп, алга таба спираль буенча хәрәкәтләнәләр. Суда йөзеп йөргән вак азык кисәкчекләрен хәрәкәт барышында эләктереп алалар. Күбесенчә субстратта яшәүче Б.с. үзенчәлекле аяклары, хортумчыгы, бөтерелү аппараты һәм кыллары ярдәмендә шуышалар яки «атлап баралар». Аз хәрәкәтләнүчән фор-

малары еш кына колонияләр хасил итә. Б.с. ның күбесе — полифаглар (төрле азык б-н туенучылар): бактерияләр, иң түбән төзелешлеләр, суүсемнәр, хайваннарның вак таркалган кисәкчекләре б-н тукланалар. Б.с. — аерым җенесле хайваннар, аларга сезонлы цикломорфоз (гәүдә формасы үзгәрү чоры), җенесле һәм җенессез циклләр чиратлашу, үсеш барышында тынлык фазалары хас. Гидробионтларның башка төрләре өчен азык булып торалар. Сулыкларның үзлегеннән чистаруы, агынты суларны биологик чистарту процессында әһәмияте бик зур. Су сыйфатын бәяләгәндә индикатор буларак кулланылалар.

*Əд.:* Кутикова Л.А. Коловратки фауны СССР. Л., 1970; Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977; Кутикова Л.А. Фауна аэротенков (Атлас). Л., 1984.

*В.А.Яковлев, М.Г.Борисович.*

**БӨТЕРКӘ́**, к. *Җепкыр.*

**БӨТНЕ́К** (Mentha), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 ләп төре билгеле, күбрәк Төньяк ярымшарның уртача поясында очрый. ТРда 4 төре бар. Кыр Б. (M. arvensis), озын яфраклы Б. (M. longifolia) барлык р-ннарда һәм урманнарда таралган. Борыч Б. (M. piperita) һәм башаклы Б. (M. spicata) эфир майлы һәм дару үләне буларак бакчаларда үстерелә. Тамыры чуксыман, өстә ята. 15–40 *см* озынлыктагы үсемлекләр. Сабаклары туры, 4 кырлы, боткаланучан. Яфраклары бөтен, тешле яки тешәүле. Чәчәкләре вак, таҗы аксыл шәмәхә-алсу яки кызыл-шәмәхә төстә, башаксыман чәчәк төркемендә, кыр Б.нең чәчәкләре куентык боҗраларында. Җимеше 4 чикләвекчектән гыйбарәт. Июнь-сентябрь айларында чәчәк ата, җимешләре июльдән алып октябрьгә кадәр өлгерә. Вегетатив юл б-н (тамырчалардан) үрчиләр. Җир өстендәге өлешләрендә флавоноидлар, каротин, органик к-талар, эфир мае бар. Бакчада үстерелә торган төрләреннән ментол алалар, ул валидол, валокордин, Зеленин тамчысы һ.б. составында бар. Халык медицинасында тынычландыру, тир, какырык чыгару өчен, ашказаны авырулары вакытында кулланыла. Барлык төрләре дә баллы үсемлекләр.



Борыч бөтнек.

**БӨЯ́** елгасы, Идел алдында. Зөянең сул кушылдыгы. Озынлыгы 40 *км*, бассейнының мәйданы 155 *км*$^2$. Апас р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Урта Биябашы авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Кабык Күпер авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 55 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 29%. Б. елгасының 0,4 тән алып 8,4 *км* га кадәр озынлыктагы 13 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,47 *км/км*$^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле үрге агымында 0,1 *л/с·км*$^2$ дан елга тамагына таба 5,1–10 *л/с·км*$^2$ га кадәр. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче көннәрендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л* га кадәр.

**БРА́ГИН** Давид Яковлевич (23.12.1905, Сембер ш. — 12.7.1982, Казан), авиация технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. кандидаты (1961), проф. (1963), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960). 1930 елда Мәскәү тау академиясен тәмамлый. 1930–60 елларда Казандагы төрле пр-тиеләрдә инженер, баш металлург. 1940–45 тә академик В.П.*Глушко* б-н эшли. 1960 тан Казан авиация ин-тында, 1963 тән материллар гыйлеме каф. мөдире. Хезмәтләре авиация техникасы эшләнмәләре җитештергәндә технологик процессларның оптималь параметрларын билгеләүгә карый. Кызуга чыдам эретмәләрнең ныклыгын арттыру ысулын, титан эретмәләреннән коелган сырлы тоташтырмаларны ныгайтуның тармак стандартын эшли һәм гамәлгә кертә. Бериллий нигезендәге югары модульле эретмәләрнең ару ныклыгын билгели, цементлап ныгытылган легирлы корычларны термик эшкәртүнең гадиләштерелгән режимнарын гамәлгә кертә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Упрощение режима термообработки цементированных сталей типа Х1Н // Металлургия. 1937. № 5 (автордаш); Диски и лопатки турбины: Учеб. пособие. К., 1965; О некоторых особенностях релаксации напряжений в жаропрочных сплавах в условиях вибраций // Термопрочность материалов и конструктивных элементов. Киев, 1969. Вып. 5.

**БРАНДТ** Яков Илларионович (фон Брандт) (1716 — 3.8.1774, Казан), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-аншеф (1773). Петербург кадетлар корпусын тәмамлый (1736). Рус-төрек (1736–39) һәм Җидееллык (1756–63) сугышларда катнаша. 1764–65 елларда Киевта Кече Россия коллегиясе әгъзасы, 1765–67 дә Новороссия (Одесса) губернаторы, 1767–70 тә Петербург кадетлар корпусы баш директоры. 1770 тән Казан губернаторы. Чума авыруы таралган 1771 дә Казан губернасы халкына мед. ярдәме оештыручыларның берсе. Ул идарә иткән чорда Казанда 1771 дә Ахун һәм Апанай мәдрәсәләре ачыла. 1773 нең гыйнварында губерна канцеляриясендә Е.И.Пугачёвтан сорау ала һәм аны Казан төрмәсенә озата. Аның төрмәдән качуына җитди игътибар бирми (1773, 29 май), бер айга соңарып кына башкалага хәбәр итә. 1773 ел урталарында губерна күләмендә һәм Казанда фетнәчеләргә каршы тору чаралары күрә башлый. 1774 тә губерна дворяннарына мөрәҗәгать итә, аларны үз крәстияннәрен коралландырырга, хөкүмәт гаскәрләренә булышлык итәргә өнди. Е.И.Пугачёвның кораллы көчләре 1774 нең 12 июнендә Казанны штурмлаганда Кремльдә була.

*Əд.:* Дубровин Н.Ф. Пугачёв и его сподвижники: Эпизод из истории царствования императрицы Екатерины II: В 3 т. СПб., 1884; Военная энциклопедия. СПб., 1911. Т. 5.

*Е.Б.Долгов.*

**«БРА́ТСТВО В НУЖДЕ́»**, к. *«Немецларның контрреволюцион-фашистик оешмасы»* эше.

**БРА́УДЕ** Вера Петровна (кыз фамилиясе Булич) (1890, Казан — 1961), сәясәт эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. 1899–01 елларда Казанда Мария исем. кыз балалар гимназиясендә укый, таләпләргә буйсынмавы сәбәпле аннан чыгарыла. Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тына кабул ителә, 1904 тә дин законнары дәресенә йөрмәгән өчен аннан куыла. 1904 нең көзендә А.И.Котованың шәхси гимназиясенә кабул ителә (Казан). 1904 тән марксистик түгәрәкләргә йөри. Гаиләдә килеп туган каршылыктан соң ата-анасы йортыннан китә. Листовкалар һәм прокламацияләр тарата, пропагандистлык эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. Казан, Уфа, Ярославльдә 1905–07 еллардагы революцион вакыйгаларда катнаша. 1905 нең октябрендә яшерен әдәбият таратканы өчен Казанда кулга алына. 1906 ның маенда атасының бертуганы, Чистай өязенең земство башлыгы А.Н.Булич кузәтүенә тапшырылып, ирекә чыгарыла. 1906 ның җәендә А.Н.Буличның утарын яндыруны оештыра. 1907 дә Ярославльдә янә полиция тарафыннан кулга алына, кыйнала. 1907 нең декабрендә авыру сәбәпле чит илгә сөрелә. 1908 дә генерал А.Г.Сандецкийга каршы һөҗүм оештыруда катнашу өчен яшерен рәвештә Россиягә кайта. 1909 ның маенда кулга алына һәм Архангельск губернасына сөргенгә озатыла, аннан чит илгә кача. 1910–15 тә Казанда һәм Петроградта революцион эшчәнлек б-н шөгыльләнә. 1915 тә кулга алына һәм Иркутск губернасына сөрелә. 1917 нең февралендә Казанга кайта, социалист-интернационалистларның һәм эсер-максималистларның Казан оешмасы секретаре булып сайлана. 1917 нең октябреннән Эшче һәм солдат депутатларының Казан губерна советы ревизия комиссиясе рәисе, Революцион трибуналның тикшерү комиссиясе рәисе урынбасары һәм Казан губурна Гадәттән тыш комиссиясе рәисе урынбасары. 1918 нең июлендә сул эсерлар партиясенең эшчәнлеген тәнкыйтьли һәм аның сафларыннан чыгуын игълан итә. 1918 нең көзеннән РКП(б) әгъзасы. 1920–35 тә СССРның ВЧК-ОГПУ-НКВД системасы үзәк аппаратында эшли; ВЧК-ОГПУның яшерен сәяси бүлеге башлыгы, ВКП(б)ның Мәскәү ком-ты каршындагы Мәскәү контроль комиссиясенең партия тикшерүчесе, ОГПУ-НКВДның өлкән оперуполномоченные була. 1935 тә репрессияләнә, запаска чыгарыла һәм Воронежга сөрелә; соңыннан аклана. Сөргеннән (1938–54) соң Мәскәүдә яши.

*Әд.:* Н а у м о в Я. Чекистка (Страницы из жизни заместителя председателя Казанского губчека В.П.Брауде). М., 1963; П а н ю к о в В., П л я ч е н к о А. Заговор. К., 1971.

*Л.М.Айнетдинова.*

**БРА́УДЕ** Самуил Максимович (20.9.1886, С.-Петербург — 1949, Мәскәү), профсоюз һәм хуҗалык эшлеклесе. Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1915). РСДРП(б)ның Казан оешмасы әгъзасы була, 1915 елда кулга алына һәм Иркутск губернасының Верхоленск өязенә сөрелә. 1917–18 тә Казан Совет Эшче-Крестьян Респ-касының профсоюзлар Советы секретаре, ХКСның хезмәт комиссары, 1918 нең языннан Казан губернасы ХКС рәисе. 1919 елдан Мәскәүдә: 1919–20 дә Баш нефть ком-ты рәисе, 1921–22 дә Профсоюзларның Мәскәү советында һәм ВЦСПСта икътисад бүлеге, 1922–23 тә Профсоюзларның Мәскәү губ. советында юридик бүлек мөдире, 1923–25 тә Мәскәү губерна суды рәисенең җинаять эшләре буенча урынбасары, 1925 тә РСФСРның Юстиция халык комис-ты прокуроры, адвокатларның Мәскәү өлкә коллегиясе әгъзасы. 1926–29 елларда Мәскәүдә губерна профсоюз мәктәбе мөдире һәм Совет сәүдәсе хезмәткәрләре Союзының губерна бүлеге инструкторы. 1929 дан СССР Центросоюзында, 1932–36 да аның Президиумы баш арбитры.

*Әд.:* М и р с и я п о в Т.А., Ф о м и н А.А. Профсоюзы Республики Татарстан: История, опыт, проблемы (1905–1995 гг.). К., 1995.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**БРА́УН** Иван Осипович (1777 — 8.01.1819), анатом, мед. д-ры (1802). 1803–06 елларда Вильно мед.-хирургия академиясендә эшли. 1807 дән Казан ун-тының анатомия, физиология һәм мәхкәмә табиблеге фәне каф. профессоры һәм мөдире; анатомия укытуны оештыручы. Казан ун-тының беренче сайланып куелган ректоры (1814–1819). Б. тырышлыгы б-н һәм аның катнашында 1807 дә Казан ун-ты терр-ясендә *Анатомия театры* бинасын төзү проекты эшләнә.

*Әд.:* Казанский университет 1804–1979. К., 1979; Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989.

**БРЕДИ́ХИН** Александр Александрович (19.10.1951, Украина ССРның Каменец-Подольск өлкәсе Изяслав ш.), химик, химия фән. д-ры (1993). Казан ун-тын (1973) тәмамлый. 1976 дан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, даруларны яңадан җитештерү лаб. мөдире (1994 тән), директор урынбасары (2003 тән). Хезмәтләре органик кушылмаларның органик синтезына, конформацион анализына, электрон төзелешенә, стереохимиясенә карый. Карбеннарның циклик винил эфирларга үзенчәлекле ялгануын сурәтли; энантиочиста β-адреноблокаторлар синтезлауга үзенчәлекле алымнар эшли. Актив гидроксил группалы хираль кушылмаларның энантиомер чисталыгын анализлау өчен яңа эффектив реагентлар тәкъдим итә. Глицидолларның актив геминаль дихлоридлар б-н яңа реакциясен ача, реакция барышының стереохимик үзлекләрен тикшерә, төрле класс циклик молекулалар табу ысулларын эшли.

Х е з м.: Взаимодействие диоксена с карбенами // Журн. органич. химии. 1976. Т. 12, № 5 (автордаш); Механизм геминального взаимодействия в хлорангидридах карбоновых кислот, хлорформиатах и фосгене // Журн. органич. химии. 1989. Т. 25, № 9 (автордаш); Конформации непредельных соединений // Конформационный анализ углеводородов и их производных. М., 1990; Cyclic (4S)-chloromethyl sulfite and sulfate derivatives of (S)-glycidol as valuable synthetic equivalentes of scalemic epichlorohydrin // Mendeleev communications. 1999. № 6 (автордаш).

**БРЕДИ́ХИНА** Земфира Әзәл кызы (8.1.1952, Чепья (хәзерге Балтач) р-ны Тлогурт а.), химик-органик, хим. фән. д-ры (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эшли. 1985 елдан РФАнең Казан фәнни үзәге Органик һәм физик химия ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2005). Хезмәтләре стерео- һәм энантиоселектив процессларга, гетероциклик кушылмалар синтезына карый. Энантиомер саф органик кушылмалар синтезлауның яңа принципларын, биш буынлы диоксакорбо- һәм гетероцикланнар табу юлларын, системалы «текто» фунгицидын синтезлау методын эшли. Йөрәк-кан тамырлары өчен дару кушылмалары табуның җиңел ярашучан схемасын, актив гидроксил төркемнәр кергән хираль кушылмаларның энантиомер сафлыгын анализлау өчен эффектив фосфорорганик регентлар тәкъдим итә. Глицеринның ике ароматик эфиры кристаллашканда конгломератлар хасил булуны ача, тиңдәшле рацематларына караганда физиологик активлыгы югарырак булган нәрацемик субстанцияләр табу юлын эшли. Фәнни эшләре органик кушылмаларны стерео үзенчәлекле синтезлау, ш.и. фармакология юнәлешендәге эксперименталь эшләрдә кулланыла.

Х е з м.: Циклические сульфаты — ключевые интермедиаты в синтезе 1-алкиламино-3-арилоксипропан-2-олов из глицидола // Журн. органич. химии. 2002. Т. 38, № 2 (автордаш); An approach to 1-Aryl-1,2,4-triazoles // Synthesis. 1993. № 1 (автордаш); Solid state properties of 1,2-epoxy-3-(2-methoxyphenyloxy) — propane — valuable intermediate in chiral drug synthesis // Tetrahedron: Asimmetry. 2005. V.16, № 20 (автордаш).

**БРЕ́ЖНЕВ**, *Чаллы* шәһәренең 1982–88 еллардагы атамасы.

**БРЕ́НИНГ** Артур Иванович (9.10.1877, — 1.07.1960, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1924), проф. (1943). 1910 елдан Казан ун-тының дәвалау клиникасында эшли. 1927–59 елларда Казан мед. ин-тында, 1927–29 һәм 1953–59 да эчке авырулар пропедевтикасы каф. мөдире. Бөер өсте бизләре физиологиясен тикшерә.

*Әд.:* Казанский медицинский институт (1814–1969). К., 1989.

**БРЕ́СЛИН ТАШБАСМАХАНӘСЕ́**, Оренбург шәһәрендә отставкадагы унтер-офицер Б.Бреслин тарафыннан 1878 елда ачылган хосусый басмаханә. 1890 елларга кадәр аерым кешеләр һәм рәсми хакимият заказы б-н татар һәм рус телләрендә төрле эш кәгазьләре, игъланнар, сирәк кенә очракларда күләмле җыентыклар (мәс., «Император Рус география җәмгыятенең Оренбург бүлеге язмалары» — «Записки Оренбургского отдела Императорского Русского географического общества» җыентыгы, 1881) басу б-н шөгыльләнә. Гарәп хәрефләрендә җыелган беренче басма — «Шәригать әл-ислам» китабы 1200 данә тираж б-н 1894 елда дөнья күрә. Оренбург уку-укыту округы заказы буенча 19 йөз ахырына кадәр рустан гайре мәктәпләр өчен татар һәм казакъ телләрендә рус хәрефләре б-н 20 китап басыла. 19 йөз азагында гарәп хәрефләре б-н дә китаплар нәшер ителә. Алар арасында — Ф.Кәриминең төрекчәдән тәрҗемә китабы «Хатыннар вазифасы», Ш.Шәһидуллинның өч чыгарылыш «Заман» календаре һ.б. 1901 елда гарәп хәрефле шрифтларны Оренбургта үз матбагасын ачкан Гыйльман Кәримов сатып ала. Бреслин матбагасында татар китапларын бастыру туктала диярлек. Матбага 1915 елга кадәр эшләсә дә, аның продукциясен кечерәк күләмле басмалар гына тәшкил итә.

*Әд.:* П о п о в А.В. Из истории типографского искусства в Оренбурге // Тр. Оренбург. уч. архивной комиссии. 1903. Вып. 12; К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

*Ә.Г.Кәримуллин, Г.Г.Габделганиева.*

**БРЕ́УС** Ирина Петровна (9.6.1953, Казан), агрохимик, биол. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1975). Казан хим.-технол. (1979–84) һәм Казан пед. (1984–85) ин-тларында эшли. 1985 елдан Казан ун-ты каршындагы Ботаника бакчасында, 1987 дән лаб., 1995 тән агроэкология бүлеге мөдире. Аның тарафыннан ТР шартларында амарантның минераль туклануын оптимальләштерүнең агрохимик һәм агроэкологик нигезләре тикшерелә, амарант һәм кукуруз үскән туфракларда авыр металлар һәм файдалы элементларның инфильтрация нәтиҗәсендә югалу үлчәмнәре билгеләнә.

Х е з м.: Влияние азота, фосфора, калия и реакции почвенной среды на рост и продуктивность амаранта // Агрохимия. 1992. № 7 (автордаш); Миграция тяжелых металлов с инфильтрационными водами в основных типах почв Среднего Поволжья // Агрохимия. 1997. № 6 (автордаш).

**БРЕ́ХМАН** Александр Иосифович (13.3.1937, Украина ССРның Винница өлкәсе Могилёв-Подольский ш.), транспорт корылмалары төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТАССРның атказ. төзүчесе (1990). 1960 елда Мәскәү автомобиль юллары ин-тын тәмамлаганнан соң, «Казанспецстрой» трестында эшли. 1974 елдан трест җитәкчесе. 1983 тән Татарстан төзелеш икътисады һәм идарәсе фәнни-тикшеренү ин-тында, 1987 дән аның директоры. Бер үк вакытта 1965 тән Казан архитектура-төзелеш ун-тында, 1994 тән автомобиль юллары һәм күперләре каф. мөдире, 2002 дән ун-тның Транспорт корылмалары ин-ты директоры. Хезмәтләре төзелеш конструкцияләрендә бетонның ныклыгын арттыруга, төзелештә җитештерү б-н идарә итү системаларын камилләштерүгә карый. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методические рекомендации по созданию автоматизированной системы оперативного управления бригадным подрядом (казанская система). К., 1986 (автордаш); Оперативное управление строительным производством. К., 1992; Систе-

мотехника строительства: Энцикл. словарь. [Б.м.], 1999 (автордаш).

**БРЕЧКЕ́ВИЧ** Митрофан Васильевич (4.6.1870, Волынь губ., Кременец өязе Бакоты а. — 23.8.1963, Киев), тарихчы, гомуми тарих магистры (1912), проф. (1940), Украина ССРның атказ. фән эшлеклесе (1948). Волынь руханилар семинариясен (1890), Юрьев ун-тын (1901) тәмамлый. Юрьев ун-ты доценты (1906–13), Казан ун-ты экстраординар проф. (1913–17), ординар проф. (1917–22), бер үк вакытта 1918–21 елларда Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография ин-ты директоры (Казан). 1922–23 тә Казан тире эшкәртү техникумы директоры. Җирле архивларны саклауга ярдәм итә һәм Идел буе халыкларының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә өлеш кертә. 1923–31 дә Днепропетровск халык мәгарифе ин-ты, 1938 дән Киев пед. ин-ты, 1940–50 дә (бүленеп) Киев ун-ты профессоры (1946 дан урта гасырлар тарихы каф. мөдире). Төп хезмәтләре урта гасырлардагы славян халыклары, 1853–56 еллардагы Кырым сугышы тарихына карый.

Х е з м.: Введение в социальную историю княжества Славии, или Западного Поморья: Исслед. по истории прибалтийских поморян за первые полтора века со времени принятия ими христианства (1128–1278). Юрьев, 1911; О славянах и их соседях в древнейшие времена. К., 1913; Полабские славяне. К., 1915; Восточно-Поморское княжество и его упадок. Начальная история Данцигского коридора (XIII–XIV вв.). Днепропетровск, 1929.

*Әд.:* М о с к а л е н к о А.Е. М.В.Бречкевич (1870–1963) и его работы по истории поморских славян // Славянский сборник. Саратов, 1972.

*Е.Б.Долгов.*

**БРЖЕЗО́ВСКИЙ** Анатолий Павлович (18.4.1879, Акмола ш. — 1942), революцион хәрәкәт эшлеклесе, журналист. 1890 елларда Себер кадет корпусында, Юрьев ун-тында, 1900–02 дә Кётен шәһәрендә (Германия) Югары техник мәктәптә укый. 1902 елдан Казанда, Алафузов з-дларында оешкан с.-д. түгәрәге җитәкчесе, РСДРПның Казан ком-тын оештыручыларның берсе һәм аның әгъзасы. 1903 тә кулга алына һәм Көнчыгыш Себергә сөрелә; 1905 тә аннан кача, «Потёмкин» броненосецында баш күтәрүдә катнаша. 1907 дә Н.Н.Накоряков б-н бергә Уфада легаль «Южный Урал» с.-д. г-тасын чыгара. Самарада, Мәскәүдә, Киевта, Одессада революцион эшчәнлек б-н шөгыльләнә. 1917 дән совет оешмаларында эшли. 1930 елларда Тверь округының Колхозлар союзы агрономы. Бөек Ватан сугышы вакытында фашистлар тарафыннан атып үтерелә.

*Әд.:* Деятели революционного движения в России: От предшественников декабристов до падения царизма: Биобиблиогр. словарь. М., 1931. Т. 5, вып. 1; Д о л г о в Е.Б. Из истории казанской социал-демократической организации в 1900–1903 гг. // Социалистический строй: Вопросы теории и исторического опыта. К., 1990.

*Е.Б.Долгов.*

**«БРИГАДИ́Р»**, газета. ВКП(б)ның Карабаш шәһәр комитеты һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның шәһәр советы органы. 1930–35 елларда Карабаш шәһәрендә (Чиләбе өлкәсе) татар телендә нәшер ителә.

**БРИОФИ́ЛЛЮМ** (Bryophyllum), кантибәрчәләр семьялыгы, каланхоесыманнар ассемьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Күпьеллык үләнчел суккулентлар. 200 ләп төре билгеле. Чыгышы — тропик Африка. Яфраклары саплы, каршыдаш, итләч, эре, тоныкуе яшел төстә, читләре тешле. Яфрак тирәли тешчекләре арасында бөреләре бар, алар үсеш дәверендә коела һәм тиз шытучан яңа үсемлек үсеп китә. Чәчәкләре вак, ак төстә, чук чәчәк төркеменә тупланган. Татарстанда декоратив бүлмә гөле итеп үстерелә. Аеруча киң таралган 2 төре билгеле: Дегремон Б.ы (B. daigremontianum) һәм көпшәчәчәкле Б. (B. tubiflorum). Касәле Б. (B. calycinum) халык медицинасында дару үләне буларак кулланыла. Б. суы ялкынсынуга каршы, тукымаларны тиз төзәтү, яра һәм җәрәхәтләрне чистартуда, пешкән, озак ятып тишелгән урыннарны һәм тукымаларның үлекләнү процессын дәвалауда файдаланыла. Ш.у. аны томау төшкәндә, стоматит, тонзиллит, күз ялкынсынуы вакытында, грипкка каршы профилактика чарасы буларак кулланалар.

**БРИ́ТВИН** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 19 *км* көньяктарак, Зөя елгасы буенда. 2002 елда 63 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, тимерчелек, 4 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1194,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 203 ир заты; 1859 да — 439, 1897 дә — 721, 1908 дә — 799, 1920 дә — 914, 1926 да — 967, 1938 дә — 969, 1949 да — 668, 1958 дә — 365, 1970 тә — 257, 1979 да — 167, 1989 да — 68 кеше.

**БРО́ЙЛЕР** (ингл. broiler, broil — утта кыздыру), ит өчен үстерелә торган гибрид чебеш, тиз үсүе, җитлегүе, итенең яхшы сыйфатлы булуы б-н аерылып тора. ТРда ит чебешләрен махсус үстерү 1960 елларда башлана. Моңа кадәр кош ите җитештерү, асылда, йомырка алу өчен үрчетелгән һәм брак дип табылган тавыклар, әтәчләрне симертү юлы б-н алып барыла. Б.ны сәнәгый җитештерү түбәндәге төп технол. принципларга нигезләнә: җитештерү процесслары тулысынча механикалаштырылган тәрәзәсез кош фермаларында алып барыла; югары дәрәҗәдә продукцияле гибрид кошлар файдаланыла, кош организмының биол. ихтыяҗына туры килә торган катнаш коры азык кулланыла; җитештерү процессы кошларны ел әйләнәсе үстерү ритмын тәэмин итә алган технол. график б-н оештырыла. Б. кошчылыгы елга 1 $м^2$ урыннан 120 *кг* (идәндә) һәм 190–250 *кг* (читлектә) ит алу мөмкинлеге бирә. Б. итенең 1 *ц* га артымына 2,0–3,5 кеше/сәг. сарыф ителә. Интенсив технологияләр куллану пр-тие эшчәнлеге нәтиҗәләренә табигый шартлар йогынтысын юкка чыгара. ТРда Б. ите Казан, Питрәч, Тукай һәм Түбән Кама кошчылык ф-каларында, Ленин һәм Юдино нәселле кошлар үрчетү репродукторларында җитештерелә. Җитештерүнең гомуми күләме 1993 елда — 37715, 1994 тә — 37198, 2000 дә — 25326, 2006 да — 55768 *т*. Кошчылык ф-калары һәм репродукторларының проект егәрлеге — 30 млн. баштан артык кош үрчетү. Казан кошчылык ф-касы ел саен 7,7–8 мең чебеш үстерә. 60 көнлек Б.ның тереләтә авырлыгы 1300–1400 *г*. 1 *кг* тере артым өчен 1997 дә — 3,54, 1998 дә 3,77 *кг* азык берәмлеге сарыф ителгән.

*Әд.:* Б о г о л ю б с к и й С.И. Селекция сельскохозяйственной птицы. М., 1991.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**БРО́НЗА ГАСЫ́Р**, энеолитны алыштырган тарихи дәвер; бу дәвердә бронза металлургиясе барлыкка килә, барлык эш һәм сугыш кораллары, бизәнү әйберләре бронзадан җитештерелә башлый. Б. г. якынча б.э.к. 4 нче меңьеллык ахыры — 1 нче меңьеллык башын үз эченә ала. Әүвәлге, урта һәм соңгы бронза дәверләргә бүленә. Евразиянең төп терр-ясендә Б. г.ның әүвәлге дәвере — б.э.к. 3 нче меңьеллыкка; урта дәвере — б.э.к. 3 нче меңьеллык ахыры — 2 нче меңьеллыкның 2 нче чирегенә; соңгы дәвере — б.э.к. 2 нче меңъеллыкның 3 нче чиреге — 1 нче меңьеллык башларына туры килә. Татарстанда Б. г. истәлекләре якынча б.э.к. 3 нче меңьеллыкның 2 нче яртысы — 2 нче меңьеллык аралыгы б-н билгеләнә. Б. г. төшенчәсен фәнни әйләнешкә беренче булып Дания тарихчысы В.Симонсен (1813) кертә, соңрак шул ук ил галимнәре К.Томсен б-н Й.-Я.Ворсо (1830–50 еллар) Б. г. төшенчәсен шактый тирәнәйтү һәм детальләштерүгә ирешәләр. 20 йөздә Б. г. истәлекләре киң планда тикшерелә, бүгенге көндә билгеле булган археол. культураларның күбесе бүлеп чыгарыла. Татарстанда мондый тикшеренүләрне О.Н.*Бадер*, В.Ф.*Генинг*, Н.Ф.*Калинин*, А.П.*Смирнов*, В.Ф.*Смолин*, А.Х.*Халиков*, Е.П.*Казаков* һ.б. башкара.

Бронза — бакырның мышьяк, аккургаш, кургаш, сөрмә б-н катнашкан эретмәсен тәшкил итә, ул тиз эрүчән металл (700–900 °С). Бронза үзенең эрү, тутыгу, механик һәм технологик үзенчәлекләре б-н саф бакырдан гаять өстен тора. Салкын килеш чүкелгән бронзаның катылыгы исә чыныктырылмаган корыч катылыгына якынлаша (200–250 *кг/мм*²). Россиядәге әүвәлге һәм урта Б. г. культурала-



Такталачык каберлегендә табылган керәч савытлар. ТР ФА Тарих ин-тының археол. эзләнүләр милли үзәге фондлары.

ры истәлекләрендә табылган беренче ясалма эретмә мышьяк катнаш бронза була. Б. г.ның соңгы дәверендә ул күпкомпонентлы һәм ике составлы бакыр-аккургаш эретмәләре б-н инде ярыша алмый. Идел-Урал төбәкләрендә бронза коюю өчен чимал булып җирле бакыр катнаш комташлар кулланыла. Б. г.да һәм аннан соңрак чорларда бакырның хәзерге Кукмара, Лениногорск һ.б. районнарда, Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы авылы янәшәсендә, Кама буеның Көңгер төбәгендә һ.б. җирләрдә чыгарылуы билгеле.

Б. г. терлекчелекнең үсүе, примитив игенчелек барлыкка килү, җәмгыятьнең социаль яктан катлаулана баруы, ыруг-кабилә инанулары булган тотемизм, кояш, ут, баба культларының таралуы, миграция процессларының көчәюе, сугыш кoралларының камилләшүе б-н үзенчәлекле. Бу дәвердә мөстәкыйль җитештерү өлкәсе буларак һөнәрчелек тармагы аерылып чыга (металлургия, савыт-сабалар җитештерү һ.б.), сугыш һәм эш кораллары эшләү технологиясе катлаулана. Б. г.на нисбәтле археол. истәлекләр Татарстанның барлык районнарында диярлек табыла. Галимнәр фикеренчә, читтән күчеп килгән терлек асраучы күчмә һәм ярымкүчмә кабиләләр күп кенә археол. культура истәлекләре калдыра, алар тарафыннан мәетләрне курганга күмү йоласы, торакларны яңача төзү, үзгә ысул б-н керамика әйберләре әзерләү, бронза, сөяк, таштан әйберләр эшкәртү һөнәрләре кертелә. Татарстан терр-ясендә соңгы Б. г. дәверендә һөнәрчелекне үстерүдә зур үсешкә ирешкән *Буралы курган культурасы* кабиләләре яшәгән. Бу кабиләләрнең металл коючылары төрле кораллар җитештерүдә җайга сала, моны Урал — Урал аръягы аккургашынлы бронзадан киң файдаланып башкаралар. *Баланово культурасы* кабиләләре дә металлургия өлкәсендә сизелерлек уңышка ирешә: оста һөнәрчеләр металл эретә, аннан балта, сөңге очлары, беләзекләр коя. Идел буе һәм Урал төбәгендәге урман-дала зонасында *Абашево культурасы* кабиләләре яшәгән. Алар да металл җитештерү осталары була, Урал-Идел буе төбәкләрендә табылган бакыр чыганакларыннан файдаланганнар. Һөнәрчеләр төрледән-төрле эш-сугыш кораллары, бизәнү, йола үткәрү әйберләре җитештерә. Урта Иделдә һәм Чулман буенда *Чиркәскүл культурасы* б-н *Казан яны культурасы* кабиләләре яшәгән, алар калдырган торулыкларда ш.у. югары үсеш алган металл эретү-кою эзләре табыла. Татарстанда *Андронов культурасы* истәлекләре дә бар. Терлекчелек һәм игенчелек б-н шөгыльләнгән бу кабиләләр Уралдан алып Енисейга, тайгадан Урта Азиягә кадәр җәелгән мәйданда яшәгән. Аларда да җирле металл эретү-кою һөнәре үсеш алган, аккургашлы бронзадан балталар, сөңге башлары, хәнҗәрләр, ураклар һ.б. кирәк-яраклар җитештерелә.

Тимер металлургиясе барлыкка килү, тимердән көнкүреш һәм сугыш кораллары җитештерү бронза әйберләрне көнкүрештән кысрыклый. Бу исә Б. г.ның тимер б-н алышынуына китерә. Әлбәттә, *тимер гасырга* күчү акрынлап бара, бу күчеш б.э.к. 2 нче меңьеллык ахыры — 1 нче меңьеллык башында тәмамлана.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; ш у л у к. Приказанская культура // Свод археол. источников. М., 1980. Вып. 1–24; Ч е р н ы х Е.Н. Древнейшая металлургия Урала и Поволжья. М., 1970; М е р п е р т Н.Я. Древнейшие скотоводы Волжско-Уральского междуречья. М., 1974; К а з а к о в Е.П. Памятники черкаскульской культуры в восточных районах Татарии // Советская археология. 1979. № 1.

*Е.П.Казаков.*



1. Бронза балталар;
2. Сөңге очлыгы. Бронза.
ТР Милли музее фондлары.

**БРОНЗАКЛА́Р** (Cetoniinae), пластинкамыеклылар семьялыгындагы коңгызлар ассемьялыгы. Дөнья фаунасында 2600 дән артык төре исәпләнә, Татарстанда 5 төре бар. Тәсе ачык, металлсыман. Канат өслекләренең яны уелган, очкан вакытта канатлары шуның эчендә була. Коңгызлары чәчәкләр, агачтан агып чыккан сыекча б-н тукланалар, яшь яфраклар һәм җимешләрне кимерәләр. Кортлары «С» сыман, аякларында тырнаклары юк, аркаларында хәрәкәтләнергә сәләтле, черек үзагачта, агач куышларында, туфракта, коелган яфрак түшәлмәсендә, кырмыска ояларында үсә. Татарстанда алтынсыман бронзак (Cetonia aurata) еш очрый. Зурлыгы 15–20 *мм.* Төсе яшелдән җирән кызылга, зәңгәргә яки карага үзгәрүчән, канат өсләрендә аркылы ак таплары бар. Йөнтәс бронзак (Epicometis hima), бакыр бронзак (Potosia metallica), сасы бронзак (Oxythyrea funesta), яшел бронзак (P. aeruginosa), төрләре очрый. Соңгы 2 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1965. Т. 2.

*С.М.Шәфигуллина.*

**БРО́ННЕР** Франц Ксавер (Ксаверий) Иванович) (23.12.1758, Бавария, Хохштадт ш. — 11.8.1850, Швейцария, Аарау ш.), педагог. Дилиннген руханилар семинариясен тәмамлый (1782). 1782–89 елларда монах, монастырь мәктәпләрендә укыта. 1789 да монахлык вазифасын үтәүдән туктый. 1793 елдан Швейцариядә: Цюрих кантоны Фәннәр министрлыгында, Аарау шәһәре мәктәбендә эшли (1803–10). 1810 нан Казанда: проф. М.Ф.Бартельс тәкъдиме б-н Казан ун-тына минералогия укытучысы буларак кабул ителә. Б. үзенең минераллар коллекциясен Казан ун-тының геология музеена тапшыра. 1812 дән Казан ун-ты каршындагы Пед. ин-ты директоры, 1815 тән казна исәбенә укучы студентлар инспекторы. 1817 дән Аарау шәһәрендә яши, кантон мәктәбендә укыта. Швейцария һәм немец вакытлы матбугатында сәясәт, тарих, әдәби тәнкыйтькә багышланган мәкаләләр бастыра. Казан ун-ты тарихы һәм пед. фикерләүләр буенча әһәмиятле чыганак булган көндәлек калдыра.

*Әд.:* Н а г у е в с к и й Д.И. Профессор Франц Ксаверий Броннер, его дневник и переписка (1758–1850 гг): В 2 ч. К., 1902.

*Р.Р.Исхакова.*

**БРОНШТЕ́ЙН** Борис Семёнович (10.12.1945, Беренче Май р-ны Чирмешән а.), журналист. Казан ун-тын тәмамлый (1970), шул ук елда «Чаян» ж-лында эшли башлый, 1981–87 елларда баш мөхәррир урынбасары. 1987–91 дә, 1991–93 тә «Советская Татария» һәм «Казанские ведомости» г-таларында эшли. Фельетоннары, юмористик хикәяләре үзәк матбугатта, «Крокодил» ж-лында, «Известия», «Труд», «Литературная газета», «Неделя» г-таларында басыла. Бөтенсоюз сатирик «Фитиль» киножурналы, Бөтенсоюз радиосының юмор-сатира бүлеге өчен сценарийлар яза. 1993 тән «Известия» г-тасының Татарстан, Мари, Удмурт Респ-калары, Киров өлкәсе буенча үз хәбәрчесе, матбугатта бу төбәкләрнең сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышларына багышланган язмалары дөнья күрә.

Ә с ә р.: Б р о н ш т е й н Б.С., Л а р и н а Ю.Б. Я вам смешу... К., 1991.

**БРУСТА́Н** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ыкның сул кушылдыгы. Озынлыгы 31 *км*, бассейнының мәйданы 161,5 *км*². Минзәлә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Чулман авылыннан 1,5 *км* көнчыгыштарак, тамагы Бикбау авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 155 *м*, тамагының — 63 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Б. елгасының 0,3 тән алып 13,2 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар, иң зурысы — Дарьянка елгасы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км*/*км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км*² га кадәр. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 46 *мм*, ташу агымы катламы 40 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м*³/*с*. Суы аз булганда елганың түбән агымы кибә. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12 *мг-экв/л* дан артыграк). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 700 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында күләме 0,96 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**БРУЦЕЛЛЁЗГА́ КАРШЫ́ ВАКЦИ́НА**, биопрепарат, штамм 82 дән ясала, мөгезле эре терлекләрдә авыруны булдырмау өчен кулланыла. 1960 елда Казан вет. ин-тында К.М.*Салмаков* тарафыннан эшләнелә. Генетик сыйфатлар (маркерлар) тупланган мутант буларак, колонияләр морфологиясен үзгәртә, вирулентлык күрсәткечләрен киметә һәм антиген үзенчәлекләрен үзгәртә. Бертөрле микроблар популяциясеннән гыйбарәт, SR-шәкелендә, антиген S- һәм R-детерминантлары бер күзәнәктә урнаша. Апатоген сыйфатлы. Диңгез дуңгызчыклары һәм мөгезле эре терлекләрдә вакцина тәэсиренә хас патоморфологик үзгәрешләр булдыра. Бруцелларның, таралып, организмда вакытлыча саклануын тәэмин итә һәм шунлыктан калдык вирулентлык үзлегенә ия. Югары дәрәҗәдә һәм озак вакытка җитәрлек иммуноген сыйфатлар (диңгез дуңгызларында 71,4–100%) туплаган. Вакцина яшь вакыттарак кертелмәгән очракта терлекләрнең бозау салу куркынычы бар. Б.к.в. мөгезле эре терлекләрдә бруцеллёз авыруына каршы гомуми көрәш чаралары үткәргәндә отышлы. Россиядә 1974 елдан кулланыла һәм бу чорда уңышсызлыкка дучар булган хуҗалыклар саны 5305 тән 169 га кадәр кими. Б.к.в. куллану ТР хуҗалыкларын 1979 елда бруцеллёз авыруыннан арындыруга китерә.

*К.М.Салмаков.*

**БРЮ́НО** Ипполит Ипполитович (18.10.1872 — 1947, Казан), инженер-архитектор. Петербург технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1900), Казан сәнәгать уч-щесендә механика һәм сызым укыта (1915 кә кадәр). 1905 елдан Казанда хосусый проектлау бюросы тота. 1909–11 дә Казан шәһәр думасы әгъзасы. 1915 тән Казан ун-ты арх. вазифаларын башкара. Б. проекты б-н Казанда Н.И.Лопатин йорты (1912) төзелә, *Психиатрия клиникасы бинасы* (1915) төзелгән дип исәпләнә.

*Әд.:* Муртазина Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999. *Л.М.Мортазина.*

**БРЮХА́НОВ** Николай Павлович (16.12.1878, Сембер ш. — 30.6.1942), сәясәт эшлеклесе. Сембер гимназиясен тәмамлый (1898), 1898–99 елларда Мәскәү ун-тында укый, студентлар чуалышында катнашкан өчен аннан куыла. 1901 дә укуын Казан ун-тында дәвам итә. С.-д. түгәрәкләр һәм Кызыл Хач җәмгыяте эшендә катнаша (1901–03). РСДРП-ның Казан ком-тын оештыручыларның һәм җитәкләүчеләрнең берсе. 1903–05 тә Көнчыгыш Себердә сөргендә була. 1905–18 дә РСДРП(б)ның Уфа оешмасы әгъзасы, «Уфимский рабочий», «Уральский рабочий» г-таларының мөхәррире, РСДРП(б)ның Уфа ком-ты рәисе, Эшче һәм солдат депутатларының Уфа советы рәисе, РСДРП(б)ның Апрель конференциясендә катнаша (1917). 1918 дән РСФСР азык-төлек халык комиссары урынбасары, 1921 дән халык комиссары; 1924 тән финанс халык комиссары урынбасары, халык комиссары, 1931 дән СССР тәэминат халык комиссары урынбасары. 1933–38 дә ашлык уңышын ачыклау буенча СССР ХКС каршындагы Үзәк комиссия рәисе урынбасары. ВКП(б)ның ҮК әгъзалыгына кандидат (1927–34). БҮБК һәм СССР ҮБК әгъзасы (1922–38). Хезмәтләре СССР-ның финанс һәм бюджет системасына карый. Репрессияләр чоры корбаны.

Х е з м.: Бюджет, финансы, хозяйство СССР в 1926/27 г. М., 1927; Нужны ли нам займы? М., 1930; Финансы 2-го года пятилетки (Бюджет 1928/29 г.). М., 1929.

*Әд.:* К и з и н Ю.П. Брюханов Н.П. (1878–1942). Уфа, 1968.

*Р.А.Циунчук.*

**БРЯ́ХИМ**, к.*Ибраһим*.

**«БТА-КАЗА́Н»**, ачык акционерлык коммерция банкы (элекке «Идел-Кама акционерлык банкы»). 1991 елда Казанда оеша. 2006 дан хәзерге исемдә. 2007 нең 1 гыйнварына устав капиталы 1001781,1 мең сум тәшкил итә, ТРның иң эре банклары бишлегенә һәм 150 иң эре Россия банкы рәтенә керә. Банкның төп акционеры — Казакъстанның иң зур банкларыннан саналучы «Туран Алем банкы», аңа акцияләрнең 47,3% ы туры килә. Акционерлары булып Голландия Үсеш банкы, Швед инвестиция төркеме, Халыкара финанс корпорациясе, Европа реконструкция һәм үсеш банкы торган «Туран Алем банкы» ААҖнең банк капиталында катнашуы аңа ТР икътисадының реаль секторын тагын да активрак кредитларга, эре инвестиция проектларын финансларга мөмкинлек бирә.

ТРда 7 өстәмә офисы эшли (Казанда, Чаллыда, Түбән Камада), алар юридик һәм физик затлар өчен һәртөрле банк хезмәте күрсәтә, пластик карталар б-н исәп-хисап алып бара, валюта исәпләүләрендә документлар б-н операцияләр үткәрә.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**БУА́** елгасы, Идел алдында. Зөянең сул кушылдыгы. Озынлыгы 31 *км* (ТР чикләрендә 19,5 *км*), бассейнының мәйданы 183,5 $км^2$. Елга башы Чуаш Респ-касы терр-ясендә, тамагы Яшел Үзән р-нының Кири авылыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 55 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 4%. Б. елгасының 0,8 дән алып 10,9 *км* га кадәр озынлыктагы 14 кушылдыгы бар, шуларның дүртесе ТР терр-ясендә. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,26 $л/с{\cdot}км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнга еллык су агымы төшүнең уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу агымы катламы 96 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,024 $м^3/с$. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында күләме 0,9 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**БУА́**, кечкенә елга, инеш, сыза, үзәндә, кайвакыт 5 *м* га кадәр тирәнлектә чокыр казып корылган ясалма *сусаклагыч*. Гадәттә, Б. — су өслегенең мәйданы 1 $км^2$ дан артмаган яки күләме 1 млн. $м^3$ дан кимрәк булган сулык, шактый текә ярлы, төбе аз авышлыклы һәм су юлы юлыуга тотрыклы. Б. язгы кар сулары яки грунт сулары хисабына тула. Артык суны агызу өчен сутөшергечләр коралар. Авыл җирлегендә Б. сугару, балык, су кошлары үрчетү, ш.у. төрле хуҗалык эшләре өчен су саклау максатында файдаланыла.

Татарстанда Б. кечкенә елгаларда, инешләрдә һәм коры сызаларда сугару, балык үрчетү, эрозиягә каршы көрәшү өчен төзелә. А.х. культураларына су сибү һәм сугарулы культуралы көтүлекләр тоту өчен Б.лар ясау 1970–80 елларда аеруча киң тарала. 1997 елның исәпкә алу нәтиҗәләре күрсәткәнчә, гомуми су күләме 353 млн. $м^3$ булган 538 Б. исәпләнә. Аеруча зур Б.лар Ык, Дала Зәе, Минзәлә, Олы һәм Кече Чирмешән, Зөя, Мишә елгалары һәм аларның кушылдыклары буйлап урнашкан. Республика мелиораторлары тарафыннан эрозиягә каршы 200 ләп Б. төзелә, аларның төп бурычы — елга һәм сусаклагычларның ләмләнүен киметү максатында эрозия продуктларын тоткарлау. Эрозиягә каршы төзелгән Б.лар ш.у. җирләрне сугару, фермаларны су б-н тәэмин итү өчен файдаланыла.

*Әд.:* Водные ресурсы и питьевая вода Республики Татарстан: Гос. доклад. К., 1997.

*Ф.Г.Борһанов.*

**БУА́**, республика карамагындагы шәһәр, Буа р-ны үзәге, ТРның көньяк-көнбатышында, Казаннан 137 *км* ераклыкта, Карлы елгасы буенда. Ульянов–Зөя тимер юлындагы Буа станциясе. Мәйданы — 8,8 $км^2$. 2006 елда 19,7 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буен-



Буа шәһәре күренеше.







Буа шәһәре. 1. Роза Люксембург урамы; 2. Автобус-тимер юл вокзалы; 3. Мәдәният сарае.

ча, татарлар — 69,2%, руслар — 20,2%, чуашлар — 9,3%) яши. Машина төзү, спирт-аракы һәм шикәр з-длары, сигарет тасмалары җитештерү, мамык ф-калары, май-сыр, азык комб-тлары, типография, көнкүреш хезмәте күрсәтү пр-тиеләре. Вет. техникумы, мед. уч-щесе, 8 гомуми белем бирү мәктәбе, авыл хуҗалыгы лицее. Төбәк тарихын өйрәнү музее, 2 балалар сәнгать мәктәбе, 5 китапханә, 2 мәдәният йорты, драма театры эшли (к. *Буа татар драма театры*). Троица соборы (18 йөз ахыры — 19 йөз башы архит-ра истәлеге), 4 мәчет. Хәзерге Б. җирендә беренче авыл 17 йөз уртасында барлыкка килә. 1780 нән Буа (Архангельский дип тә атала) авылына Сембер наместниклыгының (1796 дан — губерна) өяз шәһәре статусы бирелә. 1781 дә өяз мәхкәмәсе, хәйрия идарәсе, шәһәр башлыгы идарәсе, дворяннар опекунлыгы, Земствоның түбән мәхкәмәсе, түбән хөкем органы, өяз казначылыгы, почта экспедициясе ачыла. 1800 дән — ратуша, 1832 дән шәһәр магистраты эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, шәһәрдә 509 хуҗалык исәпләнә; чиркәү, мәчет, өяз һәм приход уч-щесе, шәһәр хастаханәсе, почта станциясе эшли. Халык төрле кәсеп — иген игү, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә, юлаучылар йортлары тота. 1913 тә Б. да 829 хуҗалык, 2 чиркәү, 2 мәчет, хатын-кызлар гимназиясе, бернечә уч-ще һәм мәктәп, 2 мәдрәсә, земство хастаханәсе, гарипләр йорты була, пәнҗешәмбе саен — базар, ел саен Крещение (6–11 гыйнв.) һәм Покрау (27 сент.-5 окт.) ярминкәләре үткәрелә. 1920 дә шәһәр өяз б-н бергә ТАССР составына керә. 1920–30 да ТАССРның Буа кантоны, 1930 ның 10 августыннан Буа р-ны үзәге. Халык саны: 1763 тә — 1273, 1782 дә — 1365, 1795 тә — 1819, 1859 да — 2949, 1897 дә — 4296, 1913 тә — 5545, 1920 дә — 5403, 1926 да — 4730 кеше, 1939 да — 5,9 мең, 1959 да — 9 мең, 1970 тә — 13,7 мең, 1979 да — 16,2 мең, 1989 да — 16,8 мең кеше.

*Әд.:* Буа ягым — Тау ягым = Буинские просторы. К., 2000.

**БУА́ ӘКӘ́М-ТӨКӘМНӘРЕ́** (Lymnaeidae), корсагаяклы моллюсклар классыннан үпкәле әкәм-төкәмнәр семьялыгы. Россиядә 20 ләп, Татарстанда 10 лап төре очрый. Б.ә.-т. төче суда яши торган корсагаяклы моллюскларның аеруча эре төрләре, барлык төр сулыкларда да, аеруча зур булмаган сусемнәр куаклыкларында яши. Гадәти төрләре: гади буа әкәм-төкәме (Lymnaea stagnalis) (кабырчыгының озынлыгы 60 *мм* га җитә); саз-буа әкәм-төкәме (L. palustris) (сузынкы конус сыман кабырчыклы); озынча түгәрәк буа әкәм-төкәме (L. ovata) (кыска бөтеркәле һәм киң авызлы); колаксыман буа әкәм-төкәме (L. auricularia) (соңгы буыны нык кабарган һәм авызы кеше колагына охшаган). Б. ә.-т. шуышу өчен җайлашкан яссы табанлы киң аяклары ярдәмендә хәрәкәтләнә. Атмосфера һавасын сулый, аның өчен аларга су өстенә күтәрелергә һәм сулыш тишеме аша һава алырга туры килә. Гермафродитлар. Йомыркаларын су үсемлекләренә — үтә күренмәле дерелдәвек сыман казылыкны хәтерләтүче ояларга сала. Б.ә.-т. сулыкларның вакытлыча кибүен һәм туңуын кичерергә сәләтле. Су үсемлекләре б-н туклана, аларның тукымаларын махсус органнары — «кыргычлары» ярдәмендә кырып ала, ш.у. үле су организмнары, вак умырткасызлар б-н туена. Үзләре, аеруча вак төрләре, балыклар өчен азык ролен үти. Кече буа әкәм-төкәме (L. truncatula) сарык һ.б. мөгезле терлектәге бавыр суыручының арадаш хуҗасы булып тора.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2.; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Р а й к о в Б.Е., Р и м с к и й - К о р с а к о в М.Н. Зоологические экскурсии. М., 1994.

*В.А.Яковлев.*

**БУА́ ВЕТЕРИНА́РИЯ ТЕ́ХНИКУМЫ**, ТР А.х. министрлыгы карамагында. 1931 елда Казан вет. техникумы буларак оештырыла. Техникум 1931 дә Буа шәһәренә күчерелә. Эшләү чорында 8 меңнән артык белгеч әзерләнгән. Техникумны тәмамлаучылар арасында — Г.Җ.*Идрисов*, И.Н.*Никитин*. 2005 тә 42 укытучы эшли, якынча 490 студент, ш.и. 155 студент читтән торып укый; белгечлекләр — ветеринария, зоотехника, хокук белеме, икътисад, бухгалтерлык исәбе һәм контроле, менеджмент.

**БУА́ КАНТОНЫ́**, 1920–30 елларда ТАССРда адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Республиканың көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Үзәге — Буа шәһәре. Элекке Сембер губернасы Буа өязенең 11, Сембер өязенең 3 волосте җирлегендә оешкан. 1927 елда Б.к.на *Тәтеш кантоны* да беркетелә. 1926 да Б.к. мәйданы 2777 $км^2$ булса, 1928 дә — 6055,1 $км^2$. Халкы 1926 да 142951 кеше, ш.и. татарлар 54,3%, чуашлар 26,8%, руслар 14,3%, мордвалар 4,6%. Шәһәрдә яшәүчеләр 4730 кеше, авылда яшәүчеләр 138221 кеше. Халкының гомуми тыгызлыгы 1 $км^2$ га 51,5 кеше, авыл җирендә 49,8 кеше. 1926 да Б.к.нда 203 авыл, 7 волостька бүленә: Буа, Борындык, Городище, Тархан, Үби, Чүпрәле, Шәйморза (1924). 1927 дә Тәтеш кантоныннан 7 волость өстәлә: Балтай, Бәки, Кама Тамагы, Килдураз, Тәтеш, Шәмәк, Шонгаты. Металл эшкәртү, азык-төлек җитештерү сәнәгате була. 1926 да вак һөнәрчелектә 1571 кеше эшли. Халыкның төп шөгыле — а.х. өлкәсендә; 1928 дә 67709 крәстиян хуҗалыгы теркәлгән, 1925 тә 24 а.х. кооперативы була. Сөрү җирләренең гомуми мәйданы 417 мең *га* тирәсе (1928), ш.и. арыш — 133097 *га*, солы — 85058, карабодай — 14425, бодай — 8936, бәрәңге — 6627, техник культуралар — 4136 *га* тәшкил иткән. 1927 елда 438006 баш мал асрала, ш.и. мөгезле эре терлек 88172, ат — 47646, сарык — 284390, дуңгыз — 9157, кәҗә 8641 баш була. 1927 дә 313 мәктәп, ш.и. 302 беренче баскыч (башлангыч) мәктәп эшли. 1930 елда ТАССРны районнарга бүлгәндә Б.к. Апас, Буа, Кама Тамагы, Тәтеш һәм Чүпрәле р-ннарына бүленә.

*Чыг.:* Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928–29. Т. 3, 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике. К., 1928–1929; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**БУА́ МЕДИЦИ́НА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, 1936 елда 2 еллык шәфкать туташлары мәктәбе буларак ачыла. 1954 елдан хәзерге исемдә.



БУА КАНТОНЫ (1921 ел)

Эшләү дәверендә 8 меңгә якын фельдшер һәм шәфкать туташлары әзерли. Шәкертләре арасында — мед. фән. д-ры М.Ф.*Мусин*. 2005 тә 47 укытучы эшли, 345 студент укый; белгечлекләр — дәвалау һәм шәфкать туташлары эше.

**БУА́ ӨЯЗЕ́**, 1780–1920 елларда Сембер губернасында адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Үзәге — Буа шәһәре. Казан губернасының элекке Сембер өязе җирлегендә оештырыла, Зөя, Бола, Карлы, Сура, Кирей, Бизнә, Якла елгалары буйларындагы җирләрне берләштерә. 1780 елга кадәр Казан губернасына керә. Төньякта Казан губернасының Зөя өязе, көнбатышта һәм көньяк-көнбатышта Сембер губернасының Алатырь, Корсунь өязләре, көньякта Сембер губернасының Сембер өязе, төньяк-көнчыгышта Казан губернасының Тәтеш өязе б-н чиктәш. 19 йөз ахырында гомуми мәйданы 4,8 мең кв. чакрым. Халкы 222,9 мең кеше, ш.и. чуашлар 44,3%, татарлар 34,6%, руслар 17,2% (1897). Б.ө. 2 станга, 21 волостька бүленә. 1 нче станга — Архангел, Борындык, Городище, Кищаков (өлешчә), Мунчалы, Иске Суыксу (өлешчә), Помаев, Үби, Чокалы, Чүпрәле, Шамкин, Шемурша (өлешчә), Яңа Кәкерле волостьлары керә. Үзәге — Үби авылы. Үзәге Олы Батыр авылында урнашкан 2 нче стан волостьлары: Батыр, Кищаков (өлешчә), Морат, Иске Суыксу (өлешчә), Тархан, Тимбай, Хомбус-Батыр, Ырынгы, Шемурша (өлешчә), Шыгырдан, Янтуган. Б.ө. халкының төп шөгыле игенчелек: арыш, солы, арпа, бодай, тары, борчак иккәннәр, ш.у. терлекчелек, умартачылык һәм һөнәрчелек б-н дә шөгыльләнгәннәр (арба-чана, ишек-тәрәзә, агач савытлар һ.б. кирәк-әйберләр ясалган, бурлак артельләре булган). Азык-төлек җитештерү, кием тегү, йон тетү, үсемлек маен сыгу, эч майларын эретү һ.б. ш. хуҗалыклар билгеле. 19 йөздә Б.ө.ндә 50 дән артыграк сәнәгать хуҗалыгы, ш.и. поставу туку ф-касы, аракы-спирт, поташ, кирпеч, такта яру з-длары, берничә тегермән эшли. Б.ө.дә җитештерелгән ашлык, агач читкә сатыла. Городище, Кыят, Промзино авылларында ярминкәләр уздырыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында өяздә берничә уч-ще (өяз уч-ще, чиркәүләр карамагында ир балалар һәм кыз балалар уч-щесе, Кошки авылында чуаш балалары уч-щесе), 43 ир балалар һәм 24 кыз балалар мәктәбе эшли. 20 йөз башында өяздә 95 мәктәп, ш.и. 56 татар мәктәбе була. Б.ө. 1920 елның май-июнь айларында бетерелә, волость биләмәләренең бер өлеше *Буа кантонына* беркетелә.

*Д.Г.Мостафина.*

**БУА́ ӨЯЗЕ́ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, 1909 елның февралендә оеша. Оештыручысы һәм идарә рәисе Г.Шәфигуллин. Максаты: ярлы-мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү, мөселман уку йортларына булышлык итү һәм мәдәният чаралары оештыру. Эшчәнлеге өяз күләмендә алып барыла. 1917 елгы вакыйгалар барышында җәмгыять тарала.


*Җ.С.Миңнуллин.*

**БУА́ РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк-көнбатышында урнашкан, Чуаш Респ-касы, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш. Идел алды икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1543,6 *км*². 31 авыл җирлеген, 97 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Буа шәһәре. Халкы — 2006 елда 26,5 мең кеше (район үзәгендәге халык санын кертмичә). 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 61,5%, чуашлар — 29,1%, руслар — 8,8%. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 17 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязенә, 1920–30 да ТАССРның Буа кантонына керә. Оештырылган вакытта Б.р. нда 1 шәһәр Советы, 78 авыл Советы, 131 торак пункт исәпләнә, аларда 89060 кеше (татарлар — 53488, руслар — 19947, башка халыклар — 15625 кеше) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә мәртәбә үзгәрә. 1940 та аның мәйданы 1138 *км*², халкы — 32 мең кеше, 21 авыл советы, 72 торак пункт исәпләнә. 1959 да Б.р. составына таркатылган Чынлы районының бер өлеше керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Б.р. на Чүпрәле, Кайбыч һәм Апас р-ннарының бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 4123 *км*², халкы 167 мең кеше тәшкил итә, ул 65 авыл Советын, 286 торак пунктны берләштерә. ТАССРда адм. бүленешнең үзгәрүе нәтиҗәсендә Б.р.ның биләмәсе 2591 *км*² га кала, халкы — 117,1 мең кеше була, аңа 44 авыл Советы, 176 торак пункт керә. 1966 да Б.р. составыннан Чүпрәле р-ны аерылып чыга. 2005 елның 26 гыйнварында муниципаль район дип үзгәртелә. Районның рельефы — калкулыклы тигезлек (биеклеге 60–226 *м*). Терр-ясеннән Зөя, аның кушылдыклары Карлы, Бола, Чынлы елгалары ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, типик һәм көлсу кара, ш.у. соры урман, аллювиаль һәм болын-кара туфраклы. Терр-ясенең 6,1% ы урманлык. Известьташ, ком, балчыксыл туфрак, кызыл балчык, фосфорит, яна торган сланец ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: Зөя елгасы, *Яңа Тинчәле сөркә (байбак) колониясе*, *Үтинкә сөркә (байбак) колониясе*, *Ивашев В.П. утар-паркы*. Район терр-ясендә бронза гасырга, Имәнкискә һәм Болгар археол. культураларына караган 130 дан артык археол. истәлек билгеле. А.х. җирләре 133,1 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр 100,9 мең *га* тәшкил итә (2005). Сабан һәм уҗым бодае, арпа, солы, карабодай, борчак игелә, шикәр чөгендере, бәрәңге үстерелә. Ит-сөт терлекчелеге, дуңгыз, сарык үрчетү алга киткән. 2006 елга районда 5 агрофирма (15 хуҗалыкны берләштерә), 12 а.х. пр-тиесе, 96 фермер хуҗалыгы, 12 агросәнәгать һәм эшкәртү комплексы пр-тиеләре исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә, электромеханика з-дында (Әхмәт а.), *Лашчы* тимер юл разъезды посёлогында тупланган. Урман хуҗалыгы. Б.р. терр-ясеннән Ульянов–Зөя (Свияжск) тимер юлы, Казан–Ульянов, Буа–Тәтеш, Буа–Яльчик автомобиль юллары уза. Районда (Буа шәһәрен дә кертеп) 71 гомуми белем бирү мәктәбе (2006/07 уку елында 6336 укучы), ш.и. 26 башлангыч, 13 тулы булмаган урта, 31 урта мәктәп; һөнәр, мед. уч-ще, 38 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе; 70 клуб, 46 китапханә, 375 урынлы 3 хастаханә эшли. Татар, рус, чуаш телләрендә «Байрак», «Знамя», «Ялав» г-талары нәшер ителә.

*Әд.*: Буа ягым — Тау ягым = Буинские просторы. К., 2000.




**БУА́ ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ**. 1942 елның октябреннән 1944 нең октябренә кадәр шушы исемдә Буа шәһәрендә Татар. акад. театры ф-лы буларак эшли. Соңыннан Респ-ка татар күчмә театры (хәзерге *Татар драма һәм комедия театры*) статусы ала. Театрның сәнгать җитәкчесе — Ә.Г.Мәҗитов, труппада артистлар — А.Әхмәтҗанова, Б.Д.*Галиуллина*, Г.М.*Гыйматов*, Х.Исмәгыйлов, З.Г.*Камалова*, С.Сәгыйтова, М.Рәхмәтуллина, С.Хөснетдинова һ.б. эшли. 1944 тә театр Казанга күчерелә. Буа муниципаль р-ны җәмәгатьчелеге һәм ТР Мәдәният министрлыгы тәкъдиме буенча ТР Президентының 2007 елгы 30 март указы нигезендә Буа дәүләт драма театры ачыла. Театрның директоры итеп А.Ж.Халитов билгеләнә, баш режиссёр — Р.И.Садриев; күп еллар буе эшләгән артист-




лар — И.Латыйпов, З.Морзаханова, А.Кәримов, Ә.Шәрифуллин һ.б.

**БУА́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Буа шәһәрендә. 1992 елның 15 июнендә оеша, ТР Дәүләт музеее ф-лы буларак 1994 нең 22 декабрендә ачыла (2001 дән ТР Милли музее), 2007 дән — муниципаль музей. Элек дәүләт учреждениесе булган ике катлы бинада урнашкан (1882 елгы архит. истәлеге). Экспозиция мәйданы — 400 *м*², музей фондында 1682 саклау берәмлеге. Экспозиция 8 залда урнаша, 3 бүлектән тора. Беренче зал Буа р-ны табигатен чагылдыра. Залдагы коллекцияләр Буа р-нында яшәүче халыкларның материаль һәм рухи культурасына багышлана, русларның милли киемнәре, көнкүреш кирәк-яраклары; татар һәм чуаш өйләре, мәдрәсә интерьеры комплекслары күрсәтелә. Экспозициянең «Төбәкнең борынгыдан алып безнең көнгәчә булган тарихы» бүлегендә археол. әйберләр, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы фронтларында һәм тылда буалыларның фидакарьлеге турында материаллар, рәссам Б.И.*Урманче*, Сов. Союзы Герое П.Г.*Шафранов*, тел галиме һәм педагог Г.Ш.*Шәрәфләрнең* шәхси әйберләре һәм документлары бар. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында: Г.Ш.Шәрәфнең чәй сервизы (4 саклау берәмлеге), Кузнецов з-ды фарфор савытлары (3 саклау берәмлеге).

Музей ел саен музей ачылу (22 дек.), Җиңү (9 май), Халыкара музейлар көннәрен (18 май) үткәрә.







1. Буа төбәк тарихы музее; 2–3. Экспозиция фрагментлары: чуаш өе (20 йөз башы), шәһәр йорты (19 йөз ахыры — 20 йөз башы) күренешләре.

**БУА́ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Апас, Буа, Чүпрәле, Тәтеш р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда оештырыла. 2006 елның 1 гыйнварына урман фондының гомуми мәйданы 17640 *га*. 3 урманчылыкны үз эченә ала: Буа — 8007 *га*, Чүпрәле — 3051 *га* һәм Төбәк Черкене — 6582 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Буа шәһәрендә. Эшләүчеләр саны 92 кеше.

Урманнарның 75% ка якыны 1 нче төркемгә карый, алар арасында: су саклагыч урманнар (7906 *га*) һәм саклаучы урманнар (4453 *га*), «Кирәмәт» (50 *га*) һәм «Гран-Тау» (69 *га*) табигать истәлекләре. 2 нче төркем (файдаланыла торган) урманнар 4431 *га*. Урман фонды мәйданының урманлы өлеше — 16734 *га*, ш.и. ылыслы агач токымнары — 3892 *га* (23,2%), каты яфраклылар — 4963 *га* (29,6%), йомшак яфраклылар — 7781 *га* (46,5%), куаксыман тал 98 *га* алып тора. Урман хасил итүче төп токымнар: имән (25,9%), нарат (23,2%), юкә (27,2%), усак (17,1%); кечкенә участокларда карама, каен, агачсыман тал, чыршы, өрәңге һ.б. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшьләре (28,5%), урта яшьтәгеләре (46,2%), өлгереп килүчеләре (12,1%), өлгергәннәре һәм картайганнары (12,7%). Урман культураларының мәйданы 5433 *га*. Б.у.х.нда агачның гомуми запасы 2854,5 мең *м*³ тәшкил итә; ылыслыларга — 883,9 мең *м*³, каты яфраклыларга — 635,3 мең *м*³, йомшак яфраклыларга 1334,3 мең *м*³ туры килә. Агачның уртача еллык артымы 65,8 мең *м*³ (ш.и. 19,4 мең *м*³ — ылыслы агач токымнары хисабына).

Төп кулланылыш өчен еллык урман кисү 16,4 мең *м*³ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан 307 *га* мәйданда чистарту эшләре башкарыла, шуның б-н бергә 8 мең *м*³ чамасы эшкә яраклы агач әзерләнә. 100 *га* лап мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла, ш.и. 15 *га* мәйданда имән агачы утыртыла. 2006 елга кадәр 200 *га* мәйданда саклагыч утыртмалар, юл буе һәм кыр ышыклау полосалары булдырылган. Урман хуҗалыгы питомникларында 10 нан артыграк төрдәге агач-куак токымнарыннан 1 млн. *га* якын үсенте һәм чәчкен үстерелә. Халык хуҗалыгы товарлары (штакетниклар, буралар, әрҗәләр, кәрзиннәр һ.б.) җитештерелә. Н.П.Белов һәм М.Ш.Мәхмүтовка ТРның атказ. урманчысы исеме бирелә.

*М.М.Гафаров.*

**БУА́ ШИКӘ́Р ЗАВОДЫ́**, азык-төлек сәнәгате предприятиесе. Буа шәһәрендә урнашкан. 1095 кеше эшли (2005). 1960 елда файдалануга тапшырыла. 1994 тән АҖ. Шикәр чөгендереннән шикәр-шикәр комы һәм чүпрә җитештерә. Шикәр эшкәртү операцияләре механикалаштырылган һәм автоматлаштырылган. Шикәр чөгендереннән шикәр җитештерү — өзлексез технологик процесс б-н башкарыла торган сезонлы эш. 1967 елда елына 7000 *т* чүпрә җитештерү цехы төзелә. 1995–2005 елларда завод үзгәртеп корыла, продукт цехлары киңәйтелә, центрифуга, вакуумлы аппаратлар, диффузион җайланмалар б-н җиһазландырыла. Чөгендер түбен киптерү һәм гранулллау, таш һәм саламны тотып калу бүлекләре бинасы, шикәр чималы складлары һ.б. төзелә. Нәтиҗәдә шикәр чөгендерен эшкәртү куәте тәүлегенә 1500 *т* дан 4500 *т* га кадәр күтәрелә. Шикәр чөгендере з-дка Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Тәтеш, Югары Ослан, Кама Тамагы р-ннарыннан китерелә. 1999 дан сезон арасында з-дта Куба, Бразилия, Гватемаладан китерелгән шикәр чималы (тәүлегенә 500–550 *т*) эшкәртелә. Завод җитәкчеләре: И.М.Ильин (1958–62), В.П.Никитин (1963–73), Н.А.Олейников (1973–79), М.И.Кепечев (1979–2000), Р.И.Яруллин (2000–04), Ф.Р.Нәбиуллин (2004–06), А.И.Ковальчук (2006 дан).

*Н.М.Ткачев.*

**«БУА́» ЭШЕ́**, 1937 елда Буа районы җитәкчеләренә карата ТАССР НКВДсы тарафыннан оештырылган гаепләү мәхкәмәсе. «Контрреволюцион эшчәнлектә» һәм «контрреволюцион уң бухаринчылык»та, Совет хакимиятенә һәм Коммунистлар партиясенә каршы эш алып баруда гаепләнгән 21 «халык дошманы» кулга алына. Буа шәһәрендә 1937 елның 21 октябреннән 4 ноябренә кадәр барган мәхкәмә утырышында А.С.Галимов, И.С.Гарин, К.Т.Гафуров, М.Х.Җәлилов, А.П.Дружинин, Ф.И.Качалин, М.Н.Попов, А.С.Сәгыйдуллин, Б.С.Садретдинов, С.Ш.Сәмирханов, А.З.Харисов, З.З.Шәрәфетдинов, С.А.Ширяев — атылуга, Я.Ш.Яушев 15 елга төрмәгә ябылуга хөкем ителәләр. РСФСР Югары суды Президиумы 1956 елның 2 апрель утырышында 1937 елгы мәхкәмә карарын юкка чыгара һәм гаепләнүчеләрне аклый.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**БУАЗКҮ́Л** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 27 *км* төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы тамагы янында. 2002 елда 359 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлауларына бүленә. Игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнәләр. Мәчет турында беренче тапкыр 1816 да искә алына, аның каршында мәктәп эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 683 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1811 дә — 42 ир заты; 1859 да — 126, 1870 тә — 137, 1897 дә — 208, 1906 да — 279, 1913 тә — 263, 1922 дә — 240, 1926 да — 234, 1938 дә — 255, 1949 да — 181, 1958 дә — 125, 1970 тә — 199, 1979 да — 252, 1989 да — 392 кеше.

**БУБЕННО́В** Михаил Семёнович (21.11.1909, хәзерге Алтай краеның Икенче Поломошново а. — 3.10.1983, Мәскәү), язучы.

Әсәрләре 1927 елда басыла башлый. 1931–41 елларда ТАССР р-ннарында, «Красная Татария» г-тасында (1935 тән) эшли. 1939 елда Ә.Вәлиев б-н берлектә «1918 елда Казанны ак интервентлардан азат итү» («Освобождение Казани от белоинтервентов в 1918 году») дигән китап, М.Савосин б-н берлектә Хәсән күле тирәсендә барган героик сугышлар турында хикәяләр («Ватан өчен» — «За Родину» җыентыгында басылган, 1939) яза. «Язгы ташу» («В половодье», 1940) җыентыгына кергән хикәяләре, «Үлемсезлек» («Бессмертие», 1940) тарихи-рев. повесте Кама буенда гражданнар сугышы вакыйгаларына нигезләнеп язылган. Б. Бөек Ватан сугышы еллары тасвирланган «Ак каен» («Белая берёза», 1 кит., 1947, СССР Дәүләт бүләге, 1948; 2 кит., 1952), чирәм җирләрне күтәрүчеләр турындагы «Бөркет даласы» («Орлиная степь», 1959), яшь төзүчеләр, Себерне үзләштерүчеләргә багышланган «Текә яр» («Стремнина», 1970) романнары б-н таныла. Ике Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Собрание сочинений: В 4 т. М., 1981–82.


*Әд.:* А ч к а с о в а Л.С. Творчество М.С.Бубеннова: Автореф. дис. ... К., 1953.

*Л.С.Ачкасова.*

**БУБИ́** (Нигъмәтуллин) Габдулла (1871, Вятка губ., Сарапул өязе Иж-Бубый а. — 7.2.1922, шунда ук), дин галиме, педагог, *җәдитчелек* хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе. Гобәйдулла *Буби* һәм Мөхлисә *Бубиның* энесе. Иж-Бубый авылында атасы Габделгалләм Нигъмәтуллин мәдрәсәсендә белем ала. Шәкертлек елларында ук атасына мәдрәсә эшләрендә ярдәм итә башлый. Шул ук чорда, искергән теоретик карашларны тәнкыйтьләп, илаһияткә багышланган классик гарәп дәреслекләренә шәрехнамә яза. Диннәрне чагыштырып өйрәнү б-н мавыга, христиан диненә тәнкыйди анализ бирелгән мәкаләләр бастыра. 1895 елда абыйсы Гобәйдулла б-н берлектә мәдрәсәне үзгәртеп кору эшенә керешә: бер шәкертен Бакчасарай шәһәренә И.Гаспринскийда җәдит ысулы б-н укырга җибәрә һәм сәүдәгәр М.Әхмәтҗанов иганәсенә башлангыч җәдит мәктәбе бинасы төзетә. 1902 дә Иж-Бубый авылында ир һәм кыз балалар өчен мәктәпләр комплексы оеша. Б. абыйсы б-н укыту программасын камилләштерү, яңа фәннәр керү, өстәмә сыйныфлар ачу эшен дәвам иттерә. 1903 тән мәдрәсәдә рус теле укытыла башлый. 1903–07 дә Б. хатын-кызлар өчен 1 сыйныфлы, ир балалар өчен 2 сыйныфлы рус-татар мәктәпләрен ачуга ирешә, аны тәмамлаучыларга башлангыч татар мәктәпләрендә укыту хокукы бирелә. Б. публицист буларак та чыгышлар ясый. Аның 1904–06 да өлешчә басылган «Хакыйкать яхуд Тугърылык» дигән фәлсәфи-полемик очерклары аеруча популярлык казана. Шул исемдәге башка очерклары (1910 га кадәр алар 20 дән артык язылы) тыела, ләкин аларның кулъязмалары яшьләр арасында киң тарала. Үз әсәрләрендә Б., әүвәлге исламга кайту, аны соңгы дәвердә үтеп кергән карашлардан арындыру татар халкының алгарышы өчен зарури дигән фикерне алга сөрә. Исламны халыклар арасында тигезлек һәм туганлык принципларын урнаштыручы, социаль гаделсезлекне инкарь итүче һәм кеше акылына таянучы дин дип исәпли. Б. фикерләрендәге рационаллек исламны урта гасырлардагыча тар рәвештә шәрехләүгә каршы юнәлтелә. Мәдрәсәнең абруе һәм Б.ның кискен публицистик чыгышлары патша хакимиятенең игътибарын җәлеп итә, һәм, нәтиҗәдә, уку йорты ябыла. 1911 дә, панисламчылыкта, рус халкына һәм хөкүмәткә каршы идеяләр таратуда гаепләнеп, Б. 6 айга төрмәгә ябыла (к. «*Бубилар эше*»). Иреккә чыккач, Голҗа шәһәренә (Кытай Төркестаны) китә һәм анда мөгаллимнәр семинариясе оештыра. Патша төшерелү хәбәрен Б. хуплап каршылый, ирекле Россиядә тамырдан үзгәрешләр булыр дип өметләнә. 1917 нең маенда Россиягә кайта. 1917–18 дә Троицк шәһәрендә (Оренбург губ.) сәүдәгәр Яушевларның мөгаллимнәр семинариясендә укыта. 1918 нең җәендә Иж-Бубый мәдрәсәсен торгызу эшенә керешә. 1919 да мөгаллимнәрнең җәйге курсларын, төбәкнең дин әһелләре һәм зыялылары корылтайларын оештыра. 2 нче баскыч мәктәп ачу эшендә актив катнаша.



Габдулла Буби.



Гобәйдулла Буби.

Б. туберкулёз б-н авырып вафат була. Күйган хезмәтен исәпкә алып, сов. хөкүмәте аның хатыны Хөснифатыймага персональ пенсия билгели. Б. исеме Казанның Черек күл тирәсендәге бер урамына бирелә, ләкин 1930 елларда, Б. панисламчылык һәм пантөркичелек хәрәкәте идеологы булып исәпләнә башлагач, бу карар юкка чыгарыла. Иж-Бубый авылында Бубилар гаиләсе музее эшли.

Х е з м.: Мөкаләмәи гарәбия. К., 1899; Фәраиз. К., 1899; Тәрәккый фөнүн вә мәгариф динсезлеке мөҗибме? К., 1902; Хакыйкать, яхуд Тугърылык: 8 кис. К., 1904–10; Татарча хотбә уку дөресме? К., 1908; Замана иҗтиһад монкарыйзмы, дәгелме? К., 1909; Гыйльме халь. К., 1909; Сарфы гарәби. К., 1910.

*Әд.:* М ә һ д и е в М. Буби мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. К., 1992; Г о с м а н о в М. Ябылмаган китап, яки чәчелгән орлыклар. К., 1996; Бертуган Бубилар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи — документаль җыентык. К., 1999; В ә л и д о в Җ. Габдулла Буби // Татарстан хәбәрләре. 1922. 20 февр.; ш у л  у к. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 года). М.-П., 1923; М а х м у т о в а А.Х. Становление светского образования у татар. К., 1982; ш у л  у к. Габдулла Буби о деспотизме // Интеллигенция Татарстана в период реформ и революций первой трети XX века. К., 1997.

*А.Х.Мәхмутова.*

**БУБИ́** (Нигъмәтуллин) Гобәйдулла (Гобәйдулла Мөхәммәтфәйзи; Фәйзи Буби) (гыйнвар, 1866, Вятка губ., Сарапул өязе Иж-Бубый а. — 1938, Ленинград), педагог. Габдулла *Буби* һәм Мөхлисә *Бубиның* абыйсы. Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем ала. Шәкертлек елларында ук мөдәррис булып торучы атасының ярдәмчесе — хәлфә итеп билгеләнә, бер үк вакытта аңа сәүдә эшләрендә дә булыша. 1890–95 елларда Төркиядәге иң абруйлы дөньяви уку йортларының берсе — Истанбулның «Мәктәбе мулкияи шахане» мәктәбендә укый, табигать фәннәрен үзләштерә. Гыйлемгә сәләтен күреп, аңа белем алуын Париж ун-тында дәвам итәргә тәкъдим ясала. Ләкин атасы Төркиядә 5 ел уку канәгатьләнерлек дип исәпли һәм Б., Иж-Бубый авылына кайтып, энесе Габдулла б-н берлектә мәдрәсәне үзгәртеп кору эшенә керешә. Табигыять фәннәрен укыта, аларның программаларын һәм дәреслекләрен төзи. Бер үк вакытта, атасы сүзен тотып, сәүдә һәм хуҗалык эшләре б-н дә шөгыльләнә. 1912 дә мәдрәсә ябылгач, 2 айга төрмәгә хөкем ителә (к. «*Бубилар эше*»). Иреккә чыгарылгач, гаиләсе б-н Уфага күченә, анда төрле уку йортларында физика, география, табигать белеме, француз теле һ.б. фәннәр укыта. 1924–26 да Казан янындагы а.х.техникумы директоры, 1927-30 да Коканд шәһәрендә (Үзбәкстан ССР) мәктәп директоры булып эшли. 1930 елларда Ленинградта яши. География, татар теле грамматикасы, физика, табигать белеме дәреслекләре авторы. Алар совет хакимияте елларында да берничә тапкыр басыла.

Х е з м.: Кавагыйде төркия. К., 1898; Мохтәсар җәгърафияи гомуми. К., 1898; Кыйраәте төрки. К., 1899. 1 җөзьә; Мохтәсар гыйльме халь. К., 1907; Кыйраәте фәнния. К., 1909; Кечек җәгърафия: Ибтидаи мәктәпләре махсус. К., 1910.

*Әд.:* М ә һ д и е в М. Буби мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. К., 1992; Бертуган Бубилар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи — документаль җыентык. К., 1999; В а л и д о в Д. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 года). М.–П., 1923; М а х м у т о в а А.Х. Становление светского образования у татар. К., 1982.

*А.Х.Мәхмутова.*

**БУБИ́** (Нигъмәтуллина) Мөхлисә (1869, Вятка губ., Сарапул өязе Иж-Бубый а. — 23.12.1937, Уфа ш.), дин эшлеклесе, педагог. Габдулла һәм Гобәйдулла *Бубиларның* кыз туганы. Башлангыч белемне әнисе Бәдрелбәнат абыстайдан ала, аннары бертуганнары Габдулла һәм Гобәйдуллада укый. Б.ны Уфа губерна, Минзәлә өязендә яшәүче өлкән яшьтәге муллага яшьли кияүгә бирәләр, ләкин никахлары озын гомерле булмый, абыйсы һәм энесе аны ике кызы б-н Иж-Бубыйга алып кайталар.

1885 елдан Габдулла б-н Гобәйдулла әтиләре мәдрәсәсен үзгәртеп коруга керешәләр. Б. бертуганнарының хатыннары Нәсимә һәм Хөснифатыйма б-н берлектә яңа типтагы хатын-кызлар мәдрәсәсен оештыруда актив катнаша. 1901 да 6 сыйныфлы татар хатын-кызлар мәктәбе ачыла, һәм Б. аның мөдире була. Анда дин гыйльме б-н беррәттән төрле дөньяви фәннәр, 1905 тән рус теле укытыла. 1907 дә Сарапул өязе земствосы акчасына 1 сыйныфлы рус-татар уч-щесе ачыла, ул хатын-кызлар мәдрәсәсенең бер бүлегенә әверелә. 1907 дә Сарапул уч-щеләр эшләре со-

ветыннан башлангыч татар уч-щесе мөгаллимәсе дәрәҗәсе өчен имтиханнар кабул итүгә, аларны уңышлы тапшыручыларга мөгаллимә таныклыгы бирергә рөхсәт алына. Иж-Бубый мәдрәсәсе мәктәп-мәдрәсәләр өчен мөгаллимәләр әзерләүдә беренче уку йорты була.



М. Буби.

Ир-балалар мәдрәсәсе таркатылып, Б.нең абыйсы һәм энесе кулга алынганнан соң (1911), хатын-кызлар уч-щесе ябыла (1912). Б. Троицк шәһәренә (Оренбург губ.) күчеп китә һәм анда 1910 да ачылган хатын-кызлар мәктәбен җитәкли. Бер үк вакытта 1913 тән хатын-кызлар гимназиясендә дин гыйльме укыта. 1914 тә сәүдәгәр Яушевларның матди ярдәме б-н хатын-кызлар мәдрәсәсе, 1915 тә мөгаллимәләр семинариясе ачуга ирешә.

Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (Мәскәү, 1–10 май, 1917) Б. Мөселманнар Диния нәзарәте әгъзасы һәм казый итеп сайлана. 1917 дән Уфада эшли, Диния нәзарәтенең гаилә эшләре бүлеге б-н җитәкчелек итә, метрика кенәгәләрен тутыру, гаилә мөнәсәбәтләрен җайга салу, ислам диненә дәгъватлау һ.б. эшләр б-н шөгыльләнә. Б. ш.у. хатын-кызлар арасында мәгърифәтчелек эшчәнлеге алып бара, «Өлфәт», «Әхбар», «Вакыт» г-таларында, «Сөембикә», «Ислам мәҗлесе» ж-лларына мәкаләләр яза, аларда хатын-кызларның вазифалары, гаиләдә һәм җәмгыятьтә тоткан урыны яктыртыла, телне, милли һәм дини традицияләрне саклау хатын-кызларның төп бурычы буларак бәяләнә. 1937 елның 20 ноябрендә Б. «Башкортстанның контрреволюцион милләтчеләр оешмасында» катнашуда гаепләнеп кулга алына һәм атылуга хөкем ителә. Вафатыннан соң аклана.

*Әд.:* Бертуган Бубилар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи-документаль җыентык. К., 1999; Махмутова А.Х. Феномен Мухлисы Буби // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. 1/2; Рахимов С. «Виновной себя не признала» // шунда ук. С.217–223.

*А.Х.Мәхмүтова.*

**БУБИ́ МӘДРӘСӘСЕ́**, Вятка губернасы Сарапул өязе, хәзер ТРның Әгерҗе р-нында, Иж-Бубый авылында, 1881 елда Габделгалләм Нигъмәтуллин тарафыннан Иж-Бубый мәчете каршында мәхәллә мәдрәсәсе буларак ачыла. 1895 тән, аның уллары Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар укыта башлагач, мәдрәсә җәдитчә белем бирү йорты һәм бөтен Россиягә мәгълүм мөселман мәгърифәт үзәге буларак танылa. Хатын-кызлар мәдрәсәсенә М.*Буби* җитәкчелек итә. Гарәп, төрек телләре һәм әдәбиятлары, француз теле, гомуми тарих, математика, физика, химия фәннәре укытыла. Рус теле сыйныфы эшли. 1910 елда химия һәм география кабинетлары ачыла. Б. м.ндә Н.Думави, З.Байчурина, Д.Гобәйди, С.Җәләл, Җ.Вәлиди һ.б. укый һәм укыта. 1911 елда бертуган Бубилар һәм барлык мөгаллимнәр пантөркичелек һәм панисламчылык идеяләрен таратуда гаепләнеп кулга алыналар. Мәдрәсә ябыла, 1912 елда хатын-кызлар мәдрәсәсе дә ябыла (к. «*Бубилар* эше»).



Иж-Бубый авылында Буби мәдрәсәсе.

*Әд.:* Бертуган Бубилар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи-документаль җыентык. К., 1999; Валидов Д. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 года). М.-П., 1923; Салихов Р.Р., Хәйретдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец 19 — нач. 20 вв.). К., 1994; Фахрутдинов Р.Р. Татарский либерализм в конце 19 — начале 20 вв.: Очерки политической истории. К., 1998; Махмутова А.Х. Лишь тебе народ служенье: История татарского просветительства в судьбах династии Нигматуллиных-Буби. К., 2003.

**«БУБИЛА́Р ЭШЕ́»**, *Буби мәдрәсәсе* җитәкчеләре бертуган Габдулла б-н Гобәйдулла Бубиларны хөкем итүгә бәйле мәхкәмә эше (1911–12). Патша хөкүмәте 1910 елда татарларның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген чикләүгә юнәлтелгән киңәшмә үткәрә (к. «*Идел буе мөселман татарларның йогынтысына каршы чаралар билгеләүче махсус киңәшмә*»). Анда татар матбугатына, мәдрәсәләргә карата күзәтүчәнлекне көчәйтергә, мәдрәсәләр санын киметергә, дигән пунктлар да бар. 1911–12 елларда Идел-Урал төбәгендә тентүләр, кулга алулар ешая. Уфада «Галия» мәдрәсәсен тотучы-иганәчеләрдән морза С.Җантурин өендә, Оренбургта Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә, иң алдынгы уку йортларының берсе саналган Буби мәдрәсәсендә тентүләр уздырыла. 1911 елның 2 февралендә бертуган Бубилар һәм мәдрәсә укытучылары кулга алына, Сарапул төрмәсенә озатыла. Алар панисламчылык тарафдары булуда, шәкертләр арасында русларга һәм патша хакимиятенә каршы коткы таратуда, панисламчылыкка кагылышлы әдәбият саклауда, яшерен рәвештә «Яшь төрекләр» хәрәкәте б-н элемтә тотуда гаепләнәләр. Кулга төшерелгән китап, кулъязма һәм хатларның эчтәлеген шәрехләп фикер әйтү өчен Казаннан Н.Ф.Катанов, Н.И.Ашмарин, П.К.Жузе кебек абруйлы галимнәр җәлеп ителә. Татар җәмәгатьчелеге исә күренекле адвокатларга мөрәҗәгать итә. Мәхкәмә утырышларында Уфадан Ибраһим Әхтәмов, С.-Петербургтан кадет, Дәүләт думасы депутаты В.А.Маклаков, Казаннан А.Г.Бать катнаша. Бер елдан соң (1912, 28 гыйн.) гаепләре расланмаган укытучылар К.Габдерахманов, Миргаяр һәм Мирзамөнәвәр Галиевләр, Ә.Габделсаттаров, Н.Думави-Туктамышев, Х.Сайманов, Г.Саматов, Ә.Сәлимов тоткынлыктан азат ителә. Хакимият карары б-н шул айда мәдрәсә ябыла. Бертуган Бубилар эше 1912 нең 28 маенда Сарапулдагы мәхкәмә утырышында карала, барлык гаепләүләр диярлек кире кагыла. Сәяси караштан чыгып, бертуган Бубилар гаепләнә: Габдулла Б. — 6 айга, Гобәйдулла Б. 2 айга хөкем ителә. Габдулла 1913 ел башында, Гобәйдулла 1912 ел ахырында төрмәдән азат ителә.

*Әд.:* Бертуган Бубилар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи-документаль җыентык. К., 1999.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**БУБЫ́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Ижның уң кушылдыгы. Озынлыгы 40,5 *км* (ТР чикләрендә 8,2 *км*), бассейнының мәйданы 279 $км^2$ (ТР чикләрендә 14 $км^2$). Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әгерҗе р-нының Иж-Бубый авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 44%. Б. елгасының ТРдан читтә агучы 11 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык сайгуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 120 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун көне эчендә башлана. Елга октябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,36 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л* га кадәр. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БУГРО́ВКА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Болгар–Базарлы Матак автомобиль юлыннан 2,5 *км* читтә. 2002 елда 174 кеше (руслар — 73%) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Памфамировка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында Александр Невский чиркәве (1895 тә алпавыт В.Т.Молоствов иганәсенә төзелә), 2 сыйныфлы башлангыч мәктәп, 3 җил һәм 1 ярма ярдыру тегермәне, кибет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 185 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Спас өязе Ширбәт волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантоны составында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935 нең 1 апреленнән — 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1859 да — 393, 1897 дә — 566, 1908 дә — 700, 1920 дә — 707, 1926 да — 669, 1938 дә — 398, 1949 да — 331, 1958 дә — 458, 1970 тә — 298, 1979 да — 224, 1989 да — 174 кеше.

**БУДА́ГОВ** Лазарь Захарович (1812, Әстерхан ш. — 1878, С.-Петербург ш.), тюрколог, тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1840), Тифлис ирләр гимназиясендә,

1845–70 елларда Петербург ун-тында укыта. 1861 елдан Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында татар һәм әрмән телләре буенча тәрҗемәче булып эшли. Б. тарафыннан төзелгән «Төрек-татар шивәләренең чагыштырма сүзлеге» («Сравнительный словарь турецко-татарских наречий», т. 1–2, СПб., 1869–71) төрки лексикография тарихында зур роль уйный.

Х е з м.: Турецко-татарский букварь, составленный учителем татарского языка в Тифлисской гимназии, кандидатом Казанского университета Лазарем Будаговым. Тифлис, 1844; Практическое руководство турецко-татарско-адербиджанского наречия. М., 1857.

*Әд.:* Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов. М., 1974.

*В.Х.Хаков.*

**БУДАРКО́В** Виктор Алексеевич (3.03.1941., Бөгелмә ш.), биол. фән. д-ры (1978), проф. (1988), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли. 1979 елдан Бөтенсоюз вирусология һәм микробиология фәнни тикшеренү ин-тында (Владимир өлкәсе, Покров ш.) радиобиология лаб. мөдире. Хезмәтләре вет. радиобиологиясе өлкәсенә карый. Чернобыль атом электростанциясе һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашканы өчен медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ветеринарная радиобиология. М., 1986; Радионуклидные методы исследований в вирусологии и микробиологии. М., 1990.

**БУ́ДДЕ** Евгений Фёдорович (13.12.1859, Херсон губ., Елизаветинский өязе Георгиевка а. — 31.7.1931, Казан), тел галиме, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1916). Новороссийск ун-тын тәмамлый (1884). Казан, Кишинев, Одесса, Скопин уку йортларында рус телен һәм әдәбиятын укыта. 1893–1922 елларда Казан ун-тында (1894 тән проф.). Тула, Калуга, Орел, Казан, Вятка, Рязань губерналарында диалектологик экспедицияләрдә катнаша. 18–19 йөз рус әдәби теле тарихына караган хезмәтләрендә: «Хәзерге рус әдәби теле тарихыннан очерк» («Очерк истории современного литературного русского языка», 1908); «А.С.Пушкин теленең грамматика тәҗрибәсе» («Опыт грамматики языка А.С.Пушкина», вып. 1–3, 1901–04) әдәби тел тарихының җәмгыять тарихы б-н тыгыз бәйләнештә булуын дәлилли. Гимназия һәм уч-щеләр өчен дәреслекләр авторы.

Х е з м.: К диалектологии великорусских наречий: Исследование особенностей рязанского говора. Варшава, 1892; К истории великорусских говоров: Опыт историко-сравнительного исследования народного говора в Касимовском уезде Рязанской губернии. К., 1896; Учебник грамматики русского языка. К., 1900; Лекции по истории русского языка. К., 1913; Основы синтаксиса русского языка. К., 1913.

*Әд.:* К а р с к и й Е.Ф. Будде Е.Ф. // Изв. отд-ния русского языка и словесности Императорской Академии наук. 1929. Т. 2, кн.2; Библиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета 1905–1963. К., 1965. Ч. 2.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**БУДЁННЫЙ РАЙОНЫ́**, к. *Чынлы районы.*

**БУ́ДНИКОВ** Герман Константинович (8.10.1936, Мәскәү), химик-аналитик, химия фән. д-ры (1976), проф. (1977), ТР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1994; 2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), СССР ФА Казан ф-лының Химия ин-тында эшли. 1966 дан Казан ун-тында, аналитик химия каф. мөдире (1986 дан). Тикшеренүләре сулы һәм аралаш эреткечләрдәге күчемле металларның органик лигандлы координацион кушылмаларының электроаналитик химиясенә, терекөмеш электродында каталитик водород бүленү процессларына һәм бушану механизмында лиганд табигатенең ролен ачуга карый. Экстракция һәм полярография (вольтамперометрия) нигезендә металларның аз микъдарларын билгеләүнең катнаш ысулларын эшли. Вольтамперометрия өчен, күмер-паста электродында органик реагентны иммобилизацияләп, электродларның химик модификацияләштерелгән яңа буынын эшли. Кулонометрия, агымлы-инжексион һәм хроматографик анализлау ысулларын үстерүгә өлеш кертә. Электрохимик активлыгы булмаган югарымолекуляр һәм түбәнмолекуляр кушылмаларны өйрәнү өчен вольтамперметриянең кулланылыш мөмкинлекләрен киңәйтә. Хезмәтләре аналитик химия тарихына һәм методологиясенә, экол.-аналитик күзәтчелек проблемаларына, ш.и., амперометрик биосенсорлар кулланып су системаларын тикшерүгә, ш.у. югары мәктәптә аналитик химия укыту мәсьәләләренә карый, («Электроаналитик химия нигезләре» («Основы электроаналитической химии») дәреслеге авторларының берсе).

Х е з м.: Промежуточные продукты в электрохимических реакциях. М., 1982 (автордаш); Вольтамперометрия на модифицированных и ультрамикроэлектродах. М., 1994 (автордаш); Экоаналитический мониторинг суперэкотоксикантов. М., 1996 (автордаш); Основы современной электроаналитической химии. М., 2003 (автордаш).

*Әд.:* Г.К.Будникову — 60 лет // Журн. аналитич. химии. 1996. Т. 51, № 10.

**БУ́ДНИКОВА** Юлия Германовна (10.10.1965, Казан), химик, химия фән. д-ры (1998). Казан ун-тын (1987) тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2000 нән). Хезмәтләре органик һәм элементорганик кушылмалар электрохимиясенә, металлокомплекслы катализ, ак фосфор химиясенә карый. Төрле дәрәҗәдә оксидлашкан металл комплекслары, галогеннар, анион-радикаллар катнашындагы эчке һәм тышкы сфера электрохимик процессларның закончалыкларын билгели; медиатор табигатенең реакция юнәлешенә тәэсирен ача. Б. эфирлар һәм фосфор кислоталары амидларын синтезлау реакцияләренә ак фосфорны катнаштыру өчен электрохим. генерирланучы нуклеофиль һәм электрофиль реагентлар кушылмасыннан файдалана. Металлокомплексларның (Ni, Ti, Zr, Cr, Mo, W) дегалогенлашу реакцияләрендә каталитик үзлекләрен билгеләү факторларын ача, аларның реакциягә керә алуын фаразлауның гомумиләштерү юлларын эшли. Ni(O) комплексларының реакциягә керә алуы галогенорганик кушылмаларның аралаштыру реакцияләрендә берничә фактор — электрохимик ярык зурлыгы, корылма күчү дәрәҗәсе, Ni-P бәйләнешенең ныклыгы, лигандларның электрон һәм стерик эффектлары, иярүчән оксидлаштыру — кайтару реакцияләренең баруы яки бармавы б-н бәйләнешен күрсәтә. Практикада киң кулланыла торган органик кушылмалар электросинтезының бер стадияле һәм аз калдыклы ысулларын эшли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007).

Х е з м.: Медиаторные системы в органической электрохимии // Журн. общей химии. 1995. Вып. 10; Электрохимия фосфорорганических соединений // Журн. общей химии. 2001. Т. 71, вып. 9; Nickel-catalysed electrochemical coupling between mono- or dichlorophenylphosphines and aryl or heteroarylhalides // J. Organometallic Chemistry. 1999. V.575 (автордаш).

**БУДРА́** (Glechoma), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләннәр ыругы. 10 лап төре билгеле, Евразиядә киң таралган. Сабаклары шуышма, озын, тамырланучан, бераз күтәренке чәчәк бәбәкле. Яфраклары йомры — бөерсыман, озын саплы. Чәчәкләре аксыл шәмәхә яки алсу аксыл шәмәхә төстә, урта һәм өске сабакларында яфрак куентыгында өчәрләп урнашкан. Май–июль айларында чәчәк ата. Җимешләре 4 чикләвеккә төрләнә. Яфраклары һәм чәчәкләре көчле сасы ис чыгара. Тамырланган бәбәкләрдән үрчи. ТРда 2 төре — плющсыман Б. (G.hederacea), 40 *см* га кадәр озынлыкта, сабагы шәрә яки сибелгән кыска төкле, киң яфраклы урманнарда, басуларда, юлларда, болыннарда үсә. Дару үләне, җир өстендәге өлеше эфир маена, сапонин, сумала, органик кислота, дуплау матдәләренә бай. Халык медицинасында порошок яки төнәтмә рәвешендә ялкынсынуга каршы, какырык куптару, бәвел кудыру, тир чыгару өчен кулланыла. Баллы. Чүп үлән. Атлар өчен агулы. Каты төкле Б. (G.hirsuta) 60 *см* га кадәр озынлыкта, сабагы төкчәле. Яфраклы һәм катнаш урманнарда, күбесенчә Көнбатыш Кама алдында үсә. Сирәк очрый торган төр.

**БУ́ДРИН** Евлампий Андреевич (1842, Пермь губ. — 1917 дән соң), дин белгече, дин гыйльме д-ры (1887). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1866). 1867–70 елларда Пермь руханилар семинариясендә укыта. 1870 елдан Казан руханилар академиясендә, 1888–1917 дә догматик дин гыйльме кафедрасында проф. Б. атаклы еретик-антитринитарийлар турындагы хезмәтләре б-н Европадагы Реформация тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә.

Х е з м.: Учение о Боге как творце мира // Православный собеседник. 1871. Ч. 3; Антитринитарии XVI века: В 3 вып. К., 1878–89; Теология социниан. О Боге и его свойствах. К., 1888.

*Әд.:* Е.А.Будрин: К 50-летию его профессорской и учебно-литературной деятельности (5 января 1867 — 5 января 1917) // Православный собеседник. 1916. № 5.

*Е.В.Липаков.*

**БУҖА́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Тойманың уң кушылдыгы. Озынлыгы 31,2 *км*, ТР чикләрендә 14 *км*. Бассейнының мәйданы 318,6 *км*². Менделеев р-нында, Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Кураково авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының

урманлылыгы күләме 23%. Б. елгасының 1,2 дән алып 22,4 *км* га кадәр озынлыктагы 11 кушылдыгы бар, иң зурысы — Ерыкса елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 141 *мм*, ташу агымы катламы 117 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче декадасында башлана. Б. елгасы ноябрьнең беренче көннәрендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,26 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БУЗА́Й** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 42 *км* көньяктарак, Зөя елгасыннан 2 *км* читтә. 2002 елда 95 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б. да мәчет була. 20 йөз башында ярма ярдыру тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 433 *дис*. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 64 ир заты; 1859 да — 265, 1897 дә — 440, 1908 дә — 858, 1920 дә — 488, 1926 да — 428, 1938 дә — 467, 1949 да — 375, 1958 дә — 232, 1970 тә — 198, 1979 да — 164, 1989 да — 110 кеше.

**БУЗУ́ЛЬНИК** (Ligularia), оешмачәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 дән артык төре билгеле, Европада һәм Азиядә үсә. ТРда бер төре — себер Б. (L.sibirica). Минзәлә р-нында үсүе билгеле. Дымлы болыннарда, куе үләнле сазлыкларда үсә. 30–125 *см* озынлыктагы үсемлек. Тамырчасы кыска, ян тамырлы. Сабагы туры, кабыргалы, кызгылт-миләүшә төсендә. Яфраклары чиратлашкан, күбесе өчпочмак рәвешендә — йөрәккә охшаган, яфрак читләре уемтыклы-тешле. Кәрзиннәре цилиндрсыман тар чукка җыелган. Июль–август айларында алтынсу-сары төстәге чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Бөрекчәле орлыклардан очып тарала. Декоратив үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БУЗЫ́КИН** Борис Иванович (7.12.1937, Свердлов өлкәсенең Түбән Салда р-ны Акинфиево а.), химик, химия фән. д-ры (1985), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), шунда ук эшли. 1968 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, гетероциклик кушылмалар лаб. мөдире (1997 дән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2002 дән). Хезмәтләре азометин кушылмалар (гидразоннар, иминнар, амидразоннар, формазаннар, оксимнар һ.б.), азотлы гетероцикллар (фталазин, хинолин, оксадиазол, триазоллар һ.б.) һәм төрле азометиннар б-н генетик бәйләнешле 1,3-диполяр реагентлар химиясенә карый. Катлаулы характерлы группалары булган гидразоннар синтезлау һәм 1,2,4-триазоль; 1,2,4-оксадиазоль һ.б. гетероциклик системалар формалаштыру ысулларын эшли. Төрле азометиннарның электрон һәм пространстводагы төзелешен, аларның төзелеше б-н спектраль характеристикалары арасындагы үзара бәйләнешне өйрәнә. Югары эффектив акарицидлар, фунгицидлар, орлык агуларын (нитроксан) синтезлый.

Х е з м.: Гидразоны. М., 1974 (автордаш); Азины, содержащие характеристические группы // Химия гидразонов. М., 1977 (автордаш); Химия формазанов. М., 1992 (автордаш).

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ — КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**БУКЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ургыдының сул кушылдыгы (Минзәлә елгасы бассейны). Озынлыгы 10,2 *км*, бассейнының мәйданы 60,2 *км*². Елга башы Тукай р-нының Князево авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Минзәлә р-ның Хуҗамәт авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 195 *м*, тамагыныкы — 85 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 21%. Б. елгасының 0,5 тән алып 9,2 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,66 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 105 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,04 $м^3/с$. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12 *мг-экв/л* һәм аннан күбрәк). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 700 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 3,1 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БУКЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Мәлләнең сул кушылдыгы (Ык елгасы бассейны). Озынлыгы 8,5 *км*, бассейнының мәйданы 34,4 *км*². Сарман һәм Азнакай р-нныры терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Ташлыяр авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Азнакай р-нының Мәндәй авылыннан көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 100 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 27%. Б. елгасының 4,2 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 89 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Б. елгасы ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр.

**БУЛА́Т** елгасы, Идел алдында. Әрәнең уң кушылдыгы (Зөя елгасы бассейны). Озынлыгы 15 *км*, бассейнының мәйданы 51 *км*². Яшел Үзән р-ны терр-ясеннән ага. Норлат авылы янында ике елга (Олы Елга һәм Кече Елга) кушылган урын Б. елгасының башлангычы булып тора, тамагы Прибой посёлогыннан 2 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 55 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 13%. Б. елгасының 1,8 дән алып 3,7 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,25 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Суы аз булганда урта һәм түбән агымда елга кибә. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Суы ел дәвамында чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 0,3 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БУЛА́Т** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 31 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2002 елда 262 кеше (татарлар — 82%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 165 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостена керә. 1920 дән ТАССР ның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир заты; 1859 да — 82, 1897 дә — 138, 1908 дә — 165, 1920 дә — 171, 1926 да — 211, 1938 дә — 236, 1949 да — 130, 1958 дә — 57, 1970 тә — 56, 1979 да — 66, 1989 да — 226 кеше.

**БУЛА́Т** (Тимербулат) Җәгъфәр Гыйззәт улы (1.12.1903, Сембер ш. — 13.10.1981, Казан), график, нәкышьче, педагог. Казандагы ирекле сәнгать остаханәләрендә (1919–20) һәм Казан сәнгать — пед. техникумында (1924–27) укый. П.П.Беньков һәм В.К.Тимофеев шәкерте. 1919 елда Казан Мөселман хәрби коллегиясе каршындагы Кызыл Армия театрында, 1920 дә Мәскәүдә Үзәк хәрби мөселман коллегиясендә, 1920–21 дә Ташкент Кызыл Армия театрында декоратор булып эшли. Төркестан укчылар дивизиясе составында сугышларда катнаша. 1923 тән Казанда. Ком-







Ж.Г.Б у л а т. 1. «Баррикадаларда (1905 елгы урам сугышлары)». Акварель. 1925; 2. «Мәңгәр авылы. Арча районы». Акварель. 1927; 3. «Ашлык сугу». Кәгазь, гуашь. 1935. Барысы да ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

мунистик клубта (1925–29), Офицерлар йортында (1929–36) рәссам булып эшли, Казан сәнгать уч-щесендә укыта (1937–39; 1949–57), «Татрәссам»да («Татхудожник», 1938–53) һәм Сәнгать фондында (1953–79) эшли. ТатАХХР (1925–32), Рәссамнар берлеге әгъзасы (1936). Б. — Татарстанда сугыш күренешләре жанрында эшләүче беренче рәссамнардан. «Төркестан сериясе» (1920 еллар), «Баррикадаларда (1905 елгы урам сугышлары)» (1925) акварельләре, фронт темасына караган станлы рәсемнәр — «Танк десанты» (1941), «Штык атакасы (Советлар Союзы Герое иптәш Батыршин подразделениесе)» (1942), «Будапешт 1945 тә» (1945), «Сугыштан соң» (1945), нәкышь әсәрләре — «Ашлык сугу» (1935), «Сабан туе» (1939), «Дус кызлар» (1947), график портретлар — «Академик А.Е.Арбузов» (1947), «ТАССР-ның атказанган сәнгать эшлеклесе Н.Җиһанов» (1947), «Ялкын» һәм «Чаян» ж-ллары өчен рәсемнәр (1950 еллар), Татарстан китап нәшриятында 1940–60 елларда басылып чыккан Г.Тукай, А.Пушкин, Д.Фурманов, М.Гафури, Н.Исәнбәт, М.Хөсәен, Ә.Ерикәй, Л.Ихсанова әсәрләренә иллюстрацияләр һәм бизәлешләр авторы. Республика (1925 тән) күргәзмәләрендә, Идел буеның 6 автономияле респ-касы күргәзмәсендә (Казан, 1947) катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм ТР Милли музеенда саклана. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М а ш к о в ц е в Н. Художественная жизнь Казани // Творчество. 1940. № 6; Художники «Чаяна». Л., 1960; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Г.А.Могильникова.*

**«БУЛА́Т БАТЫ́Р»**, татар халкы тарихына багышланган беренче нәфис фильм. 1927 елда ТАССР ХКС заказы б-н «Совкино» остаханәсендә төшерелә. Ә.Шакиров повесте буенча Н.А.Зархи сценарие, реж. Ю.В.Тарич, реж. ассистентлары В.В.Корш-Саблин, И.А.Пырьев, Каюм Поздняков, операторы Г.В.Гибер, рәссамы А.А.Уткин. Рольләрдә: Булат батыр — Ярославцев, Пугачёв — С.Борисов, Асме — А.Войцев, Елена фон Брандт — Г.С.Кравченко, эпизодларда Татар акад. һәм Казан Зур драма театрлары актёрлары, күп кешеле күренешләрдә Казан кешеләре һәм Казан гарнизоны солдатлары катнаша. Картина сюжетының нигезендә — баш күтәргән качкыннар отряды башлыгы Булат батырның фаҗигасе. Аның ике улы ике лагерьда торып сугыша: Әсфән — баш күтәрүчеләр ягында, Тимер — хөкүмәт гаскәрләре ягында. Вакыйга, көчәйгәннән-көчәя барган крәстияннәр сугышы фонында башланып, Е.И.Пугачёв һәм Булат батыр гаскәрләренең Казанга басып керүләре б-н тәмамлана. Фильм документаль-тарихи фактларга нигезләнеп эшләнә. Пугачёвның Казанга һөҗүм итү юллары (Мамадыш тракты, Арча кырындагы кир-



«Булат батыр» фильмыннан күренеш.

печ сарайлар, шәһәрнең татарлар яшәгән өлеше, Кремль һ.б.) төшерелә. Татар халкының тарихы һәм көнкүреше, нигездә, дөрес чагылдырыла, ләкин сюжетны бәян итү барышында өзеклекләр бар, кайбер урыннарда персонажларның психологик халәте озын титрлар б-н алыштырыла. Фильм беренче тапкыр Казанда 1928 нең 22 февралендә күрсәтелә, 12–18 июньдә «Электро» кинотеатрында киң экранда бара һәм тамашачы тарафыннан югары бәяләнә.

*Әд.:* А л е к с е е в И. Рубежи кинодокументалистов Татарии. К., 1974.

*Ю.А.Благов.*

**БУЛА́Т СОЛТА́Н ХАН** (Пулат бәк) (1390 тирәсе — 1409/10 тирәсе), 1407 елдан Алтын Урда ханы. Шадибәк хан (башка чыганаклар буенча Тимер Котлыгъ хан) улы. Идегәй ярдәмендә Шадибәкне хакимияттән читләштереп, тәхеткә утыра. Б.С.х. хакимияте тотрыклы булмый, ил-дәүләт сәясәтен нигездә бәкләр бәге Идегәй билгели. 1408 дә Идегәй әмир хан гаскәре б-н төньяк-көнчыгыш рус җирләренә һәм Литвага яуга чыга. Яуның сәбәп-максатлары Идегәйнең кенәзләргә җибәргән юлламасында аңлатыла: Тимер Котлыгъ хан вафатыннан бирле аралар өзелгән, ясак түләнми. Литва кенәзлеге Туктамыш улларын сыендырган. Идегәй Мәскәүне камый, ләкин яулап алырга өлгерми: Сарай аксөякләренең бер өлешенең фетнә оештыруы, Литва тарафыннан Туктамыш хан улы Җәләлетдиннең гаскәр туплап килүе ачыклана. Хан үтенече буенча Идегәй Сарай әл-Җәдидкә кайтырга тиеш була; Мәскәү кенәзе Василий I б-н килешү төзи һәм гаскәре б-н ханга ярдәмгә ашыга. 1408–10 елларда Идегәй б-н Б.С.х. Җәләлетдингә каршы орышта катнашалар. Җәләлетдингә Алтын Урда бәк-морзаларының һәм Литва аксөякләренең бер өлеше теләктәш була. Көрәш барышында Б.С.х. һәлак була. Тәхеткә вакытлыча Тимер Котлыгъ хан улы Тимер утыра һәм 1411 дә Б.С.х. исеменнән акча суктыра.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Г р е к о в И.Б. Восточная Европа и упадок Золотой Орды (на рубеже XIV–XV вв.). М., 1975.

*И.Л.Измайлов.*

**БУЛА́Т ТИМЕ́Р БӘК** (Болак Тимер) (1340 тирәсе — 1367), Алтын Урда чоры Болгар идарәчесе, әмир. Тугла би (бәк) улы дип фаразлана (Тугла би Җанибәк һәм Бирдебәк ханнар заманында бәкләр бәге була, Килдебәк хан тарафыннан җәзалана). Атасы җәзалап үтерелгәннән соң, Б.Т.б. Сарай әл-Җәдидтән Болгарга кача. 1361 елда Болгар аксөякләре ярдәмендә әмирлек тәхетен яулап ала. Алтын Урдадан бәйсез олыс оештырырга тырыша (к. *Болгар бәклеге*). 1366–67 елларда үз исеменнән акча суктыра, акчаның ал ягына: «Солтан, мәрхүм Җанибәк хан, аның патшалыгын Ходай сакласын», дип, икенче ягына «Булат Тимер Тугла би улы», дип яздыра. Элек Җанибәк исеменнән сугылган акчаларның бер өлешенә Б.Т.б.нең дә катнашы булуы ихтимал дип фараз ителә. Б.Т.б. *Мамайга* һәм *Абдуллаһ ханга* дошман була. 1367 дән Болгар аксөякләренең күпчелеге *Хәсән бәк* ягына авыша. Б.Т.б.нең шул елдагы хәрби хәрәкәтләре дә уңышсыз тәмамлана. Ул бәклек гаскәре б-н Мамай йогынтысында булган Городец кенәзлегенә һөҗүм итә, Константин кенәз уллары Дмитрий б-н Борис көчләре тарафыннан җиңелә. Калдык көчләре б-н Түбән Идел буйларына барып чыга, Газиз хан гаскәре б-н бәрелеш вакытында һәлак була.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Город Болгар. М., 1986.

*И.Л.Измайлов.*

**БУЛА́Т ХАЖИ́ ХАН** (Дәүлиллаһ Хуҗа) (? — 1364/65 тирәсе), Алтын Урда ханы (1364/65). *Алтын Урдада тәхет чуалышлары* вакытында Сарай әл-Җәдидтән Абдуллаһ хан б-н Мамайны куып җибәргәннән соң үзен хан дип игълан итә. Сарай түрәләре аның яклы була. Үз исеменнән акча суктыра. Ләкин тиздән Газиз хан тарафыннан тәхеттән төшерелә.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Куликовская битва. М., 1980; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.

*И.Л.Измайлов.*

**БУЛА́Т ШИРИ́Н** (1490 тирәсе — 1545), Казан ханлыгы дәүләт эшлеклесе, әмир, карачы бәк. *Ширин* ыругыннан. 1519 елда Мәскәүдә кенәз Василий III б-н Казан тәхетенә Шаһгалине чакыру турындагы сөйләшүдә катнашкан бәк-морзаларның берсе. Шаһгали хан булганда, Б.Ш. сарайда зур урын били. 1521 дә Шаһгали тәхеттән куылгач, дәрәҗәсен югалта. 1530 да рус гаскәре һөҗүм иткәндә Казанны саклауда катнаша. 1531 дә Сафагәрәйне тәхеттән төшерүне, хан итеп Җангалине (1531–35) чакыруны оештыра. Җангали заманында әмир итеп билгеләнә, Казан ханлыгының рәсмиләштерелмәгән идарәчесе була. Ханлыкның мөстәкыйль дәүләт булып калуы һәм затлы нәсел аксөякләренең хакимиятен ныгыту өчен көрәшә. 1535 елның сентябрендә, Мәскәү йогынтысын чикләү ниятеннән, Җангалине тәхеттән төшерә, ханлыкка Сафагәрәйне чакыра. Сафагәрәй диванында олы карачы бәк була (1536–45), ханлык түрәләре эшчәнлегенә җитәкчелек итә. 1545 тә Сафагәрәй ханның шәхси хакимияте көчәюдән шикләнеп, аңа каршы фетнә оештыра. Фетнә ачыла һәм анда катнашучылар җәзалап үтерелә.

Чыг.: Казанская история. М.–Л., 1954.

*Әд.:* Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*И.Л.Измайлов.*

**БУЛА́ТОВ** Алмас Харис улы (2.5.1931, Азнакай р-ны Түбән Сукаеш а.), Соц. Хезмәт Герое (1971). 1978 елда Чистай совхоз-техникумын тәмамлый. 1947–78 дә Азнакай р-ның «Тырыш» к-зында механизатор, звено башлыгы, комплексны бригада бригадиры. 1978–88 дә партия эшендә, 1988 дән колхозда инженер, механика остаханәләре мөдире. Герой исеме хезмәттә зур уңышларга ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Кырларымда икмәк исе. К., 1978.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**БУЛА́ТОВ** Әхмәтҗан Галимҗан улы (14.6.1937, Тәтеш ш.), партия хезмәткәре, хуҗалык эшлеклесе. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1960). 1965–67 елларда ТАССР А.х. министрлыгында өлкән зоотехник. 1967–70 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында а.х. бүлеге инструкторы. 1970–78 дә ТАССР а.х. министры урынбасары. 1978–80 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында а.х. һәм азык-төлек сәнәгате бүлеге мөдире урынбасары, 1980–85 тә мөдире, 1985–90 да өлкә ком-ты секретаре. 1990–94 тә ТР ит сәнәгате җитештерү берләшмәсенең ген. директоры, 1994–98 дә «Татарстанның ит сәнәгате» холдинг компаниясе президенты. ТР ЮС депутаты (1990–95), «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



А.Х. Булатов.



В.Г. Булатов.



Д.В. Булатов.

**БУЛА́ТОВ** Васил Галләм улы (15.9.1921. хәзерге Балтач р-ны Чутай а. — 25.6.1988, Казан), Сов. Союзы Герое (23.8.1944), майор (1946), СССР Эчке эшләр министрлыгының атказ. хезмәткәре. 1942 елга кадәр Чита өлкәсендәге руда комб-тында өлкән бухгалтер. 1942 дән Кызыл Армиядә. Байкал арты укчы-миномётчылар уч-щесен (1944) тәмамлый. 1944 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 102 нче укчы дивизия 40 нчы укчы полкның пулемёт взводы командиры. 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Белоруссияне, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда катнаша. 1944 нең 24 июнендә Друть елгасын (Белоруссия) кичкәндә батырлык күрсәтә. 1945 тә Җиңү парадында катнаша. 1946 дан запастагы майор. 1961 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1947–74 тә Татарстан Респ-касы Эчке эшләр министрлыгында эшли. Ленин, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. К., 1990; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Навечно в сердце народном. Минск, 1984.

*В.А.Шагалов.*

**БУЛА́ТОВ** Владимир Петрович (27.12.1946, Казан), балалар табибе, мед. фән. д-ры (1986), проф. (1988), РФнең атказ. табибе (1995). 1971 елда Казан мед ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1986 елдан 2 нче балалар авырулары каф. мөдире. Тикшеренүләре балаларда бавыр һәм үт юллары авыруларын булдырмау, аларга диагноз кую һәм дәвалауга; $B_1$, $B_3$ витаминнарын, ш.у. кайбер фосфорорганик кушылмаларны балаларда рахит авыруын дәвалаганда куллануны патогенетик яктан нигезләүгә, балаларда билиар системасы авыруларын дәвалауга, яңа туган балаларга ашыгыч ярдәм күрсәтү һәм реанимация үткәрү чараларын булдыруга карый.

Хезм.: Функциональные и воспалительные заболевания билиарной системы у детей. К., 1988; Учебное пособие по клинической фармакологии. М., 1990; Диагностика и лечение неотложных состояний в детском возрасте. К., 1997.

**БУЛА́ТОВ** Даян Вагыйз улы (11.2.1924, Чистай р-ны Исләй а. — 22.11.1982, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (31.5.1944, 4.8.1944, 24.3.1945), старшина. Туган авылында совхозда эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 830 нчы укчы полкның разведка взводы разведчигы (50 нче армиянең 238 нче укчы дивизиясе). 2 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Белоруссия (1944), Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1944 нең 27 мартында Смолица авылы (Могилёв өлкәсе, Быхов р-ны) янында дошман дзотын юк итә; 1944 нең 27 июнендә Могилёв шәһәре өчен барган сугышта, Днепрны беренчеләрдән булып кичеп, дошман дзотын гранаталар б-н шартлата; 1944 нең июль–сентябрендә Кнышин һәм Осовец (Польша) шәһәрләре өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Сов. Армиясендә хезмәтен дәвам иттерә (1947 гә кадәр). Үз авылындагы «Ромашкино» с-зында механизатор булып эшли. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Лобода В.Ф. Солдатская слава. М., 1963. Кн 1; Шевченко Н.Я. Звёзды Славы. К., 1969; Полные кавалеры ордена Славы Трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**БУЛА́ТОВ** Мидхәт Сәгадәтдин улы (18.4.1907, Тубыл губ., Тубыл өязе Исәнев Йорты а. дип фараз ителә — 23.7.2004), архитектор, архит-ра белгече, архит-ра д-ры (1975), Төзелеш һәм архит-ра академиясе мөхбир әгъзасы (1957–63), Үзбәкстан ССРның атказ. төзүчесе (1976). Ленинград коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлый (1934). Моссовет карамагындагы проект оешмасында эшли һәм бер үк вакытта Мәскәү архит-ра ин-тында укыта. 1937 елдан Үзбәкстанда яши. 1940–62 дә — Ташкент шәһәре архитекторы. «Пахтакор» стадионы, «Ташкент» кунакханәсе, Сәмәрканд (1937–38) һәм Ташкент (1952–54) шәһәрләренең ген. планнары, бу шәһәрләрдәге һәм Бохарадагы җәмәгать биналары проектлары һ.б. авторы. Б. юкка чыккан цивилизацияләр һәм мәдәниятләрне үзенчәлекле юл б-н өйрәнү алымын эшли, шуның нәтиҗәсендә Үзбәкстан һәм Казакъстан җирләрендә борынгы корылмалар табыла. Б. — Улугбәк обсерваториясен реконструкцияләү проекты авторы («Интерарх-85» халыкара күргәзмәсенең алтын медале, София). Хезмәтләре Урта Азия архит-расы тарихы һәм теориясенә карый.

Хезм.: Мавзолей Саманидов — жемчужина архитектуры Средней Азии. М., 1976; Геометрическая гармонизация в архитектуре Средней Азии IX–XV веков. М., 1988.

**БУЛА́ТОВ** Мөхәммәт Рәхим улы (7.10.1919, Сембер губ., Буа өязе Олы Урсак а. — 27.11.1992, Казан), тарихчы, тарих фән. канд. (1948), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәт-


кәре (1981), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1990). Казан пед. техникумын (1935), Мәскәү ун-тын (1941) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947–49 елларда Казан пед. ин-тының марксизм-ленинизм каф. мөдире. 1950–55 тә ТАССР Дәүләт музее директоры урынбасары. 1955 тән Казан а.х. ин-тында доцент, 1958–85 тә марксизм-ленинизм каф. мөдире, 1985–91 дә философия һәм фәнни коммунизм каф. профессоры. Хезмәтләре Казан губернасында Окт. рев-циясе тарихына, социализм чорында милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Об Октябрьском вооружённом восстании в Казани в 1917 г. К., 1948 (автордаш); Из истории борьбы за установление и упрочение Советской власти в Казанской губернии (ноябрь 1917 — май 1918). К., 1958; В братской семье советских народов. К., 1963; К вопросу о формировании татарской социалистической нации. Плоды великого братства. К., 1972.

**БУЛА́ТОВ** Нургали Хөсәен улы (28.7.1939, Теләче р-ны Алан а.), журналист, ТРның һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1991, 1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1964), «Яшь ленинчы» г-тасында эшли; 1979 елдан «Социалистик Татарстан» (1992 дән «Ватаным Татарстан») г-тасында: хәбәрче, 1989 дан бүлек мөдире, 1992 дән җаваплы сәркәтип, 1997 дән баш мөхәррир урынбасары; 2004 тән «Мәдәни җомга» г-тасында: бүлек мөдире, баш мөхәррир урынбасары (2005 тән). 1979–89 да балалар өчен татар телендә «Олимпия» спорт радиотапшыруларының сценарийлары авторы. Балалар һәм яшьләр өчен хикәя, очерк, репортажлары, күренекле кешеләр б-н әңгәмәләре «Казан утлары», «Мәгариф», «Татарстан», «Ялкын» ж-лларында, «Ватаным Татарстан», «Юлдаш», «Мәдәни җомга» һ.б. г-таларда басыла. Язмаларында әйләнә-тирә мохитне саклау проблемаларын, хәрби-патриотик тәрбия һ.б. мәсьәләләрне яктырта. Күпчелек мәкаләләрендә замандашларыбыз — татар генераллары, ТРның күренекле сәясәт һәм җәмәгать, мәдәният һәм фән эшлеклеләре тормышын чагылдыра. 1990 нан татарча стена календарен, «Батырлар китабы — книга Героев» (К., 2000) китабын төзүчеләрнең берсе. ТР Журналистлар берлеге бүләкләре лауреаты (1995, 1997).

Ә с ә р.: Авыл иртәсе. К., 1990; Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**БУЛА́ТОВ** Сәет Садри улы (23.5.1898, Сембер ш. — 16.7.1970, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1944). Сәхнә эшчәнлеген 1916 елда Сембер шәһәре татар театры труппасында башлый. Гражданнар сугышы елларында фронт театр труппаларында, аннан соң рус театрларында уйный. 1927–31 дә Театр сәнгате үзәк техникумының драма бүлегендә МХАТ режиссёры Б.М.Сушкевич классында укый. 1931–44 тә (өзеклекләр б-н) Татар акад. театрында актёр һәм режиссёр булып эшли. 1935–36 да Әстерхан театры баш режиссёры. Барон («Тормыш төбендә», М.Горький), Президент («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Мигуэль («Салют, Испания!», А.Н.Афиногенов), Вершинин («Бронепоезд 14–69», Вс.В.Иванов), Беркутов («Бүреләр һәм сарыклар», А.Н.Островский), Эскал («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир), Сәләхи («Шәмсекамәр», М.Әблиев) кебек рольләрне башкаруы Б.ны татар театр сәхнәсе осталары рәтенә чыгара. 1930 еллар режиссура үсешендә дә аның өлеше зур. Көнбатыш Европа классик репертуарыннан ул куйган пьесалар (Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» — «Коварство и любовь», 1932; «Юлбасарлар» — «Разбойники», Казан Зур драма театры, реж. В.А.Чиркин б-н берлектә, 1934), ш.у. хәзерге заман рус драматурглары пьесалары буенча куелган («Курку» — «Страх», А.Н.Афиногенов, 1933; «Эскадраның һәлакәте» — «Гибель эскадры», А.Е.Корнейчук, 1934) спектакльләре зур уңышка ирешә. Татар авторлары әсәрләрен куйганда, психологик реализм мәктәбе тәҗрибәсенә таянып, режиссёр идея позициясенең төгәллегенә, ачык һәм калку форма булдыруга ирешә. К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» (1931), Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1935), Т.Гыйззәтнең «Бөек борылыш» (1931) һәм «Зәңгәр болын» (1933) пьесалары буенча куелган спектакльләрдә әсәрләрнең эстетик эчтәлеге жанр һәм сәхнә үзенчәлеген төгәл тоемлау ярдәмендә ачыла. Б. спектакльләрендә зур, этаплы рольләрне М.Мутин, Ш.Шамильский, Н.Таждарова, Ф.Ильская, Г.Ибраһимова, Х.Әбҗәлилов, Х.Уразиков, Х.Сәлимҗанов кебек татар театрының танылган актёрлары уйный. 1936 да, режиссурадан нигезсез рәвештә читләштерелгәннән соң, Казан театр техникумында укыта башлый, 1940–52 дә аның директоры була. Укучылары арасында Ш.Биктимеров, В.Минкина, А.Арсланов һ.б. бар. 1954–58 елларда Әлмәт татар драма театрында баш режиссёр, анда ул А.Н.Арбузовның «Яшьлек белән очрашу» («Встреча с юностью», 1952), Р.Ишморатованың «Бай кияү», «Омтылыш» (1954), Ш.Камалның «Томан арты» (1955), Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр» (1957), яшь драматурглар Ш.Шаһгали, С.Кальметов, Х.Вахит, М.Хәсәнов, И.Абдуллин пьесаларын сәхнәләштерә.



С.С. Булатов.

*Әд.:* Р ә х и м о в Җ. Әлмәт татар дәүләт драма театры. 50 ел. Әлмәт, 1994; А р с л а н о в М.Г. Татарское режиссёрское искусство. 1941–1956. К., 1997.

*Р.М.Игъламов.*

**БУЛА́ТОВ** Фатих Гариф улы (20.3.1902, Самара губ., Бөгелмә өязе Түбән Сукаеш а. — 30.1.1986, Казан), генерал-майор (1944), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972). ТатЦИК исем. Берләшкән Татар-Башкорт хәрби мәктәбен (1923), Офицерлар белемен күтәрү курсларын (1937, Мәскәү), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясе югары академик курсларын (1948, Мәскәү) тәмамлый. 1932–37 елларда Алабуга шәһәрендә полк мәктәбе җитәкчесе, Саратов шәһәрендә батальон командиры. 1939 дан Байкал арты хәрби округының укчы полкы командиры. Бөек Ватан сугышында Брянск һәм Белоруссия фронтларында полк, дивизия б-н җитәкчелек итә. 1946 дан Идел буе хәрби округында укчы бригада командиры, 1948 дән Ерак Көнчыгыш хәрби округының укчы дивизия командиры, 1952 дән Кызыл Байраклы Аерым Ерак Көнчыгыш армиясендә дивизия командиры. 1954–56 да Белоруссия хәрби округында укчы корпус командиры урынбасары. СССР ЮС депутаты (1947–51). Ике Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Будни фронтовых лет. К., 1984.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**БУЛА́ТОВ** Эрик Владимирович (5.9.1933, Свердловск ш.), рәссам. В.И.Суриков исем. Мәскәү сынлы сәнгать ин-тын тәмамлый (1958). 1959–1989 елларда «Детгиз» нәшриятында (1963 тән — «Детская литература») рәссам. Ш.Перронның «Тылсымлы әкиятләр» («Волшебные сказки», 1973), А.Бартоның «Уенчыклар» («Игрушки», 1989), Т.М.Белозерованың «Гаҗәеп җыр; шигырьләр, табышмаклар, тизәйткечләр, уйдырмалар, әкиятләр» («Песенка — чудесенка: стихи, загадки, скороговорки, небылицы, сказки», 1984; О.В.Васильев б-н автордаш) һ.б. китапларга рәсемнәр эшли. 1989 дан — Нью-Йоркта, 1992 дән Парижда яши. Россия нонконформистлар сәнгате вәкиле, соцартка нигез салучыларның берсе. 1970 еллардагы сынлы сәнгать әсәрләренең («Офык», «КПССка дан», «Совет космосы», «Рәхим итегез», «Барам») картина фоннарында совет күргәзмә агитациясенә охшатып ясалган натуралистик хыялый рәсемнәр һәм текст язмалары берләшә. Әсәрләрнең стилистикасында фоторәсемнәргә хас образлы чараларга гына түгел, бәлки соц. реализм клишесыннан файдаланып, заманча академик сынлы сәнгать традицияләренә дә таяна. Соңгы ун елдагы әсәрләрендә («Лувр. Джоконда», 1998–2005; «Яшим дә күрәм», 1999; «Болытлар ничек ага, эшләр ничек бара», 2000; «Шул-шул менә», 2000; «Яктыда өлгереп булмады», 2003; «NEW-YORK», 2005) сатирик контекст тантаналы тыныч мәгънәви эчтәлеккә урын бирә бара; рәссам хәзерге заман сәнгать төрләре арасында беренчелекне тоткан станлы кар-



Э.В. Б у л а т о в. «Офык». 1971–72.

тинаның колачлау мөмкинлекләрен үстерүне дәвам иттерә.

«Яшь рәссамнар фестивале» (Мәскәү, 1957); «Рус авангарды, Мәскәү» (Париж, 1973); «Соцарт» (Нью-Йорк, 1984); «Рәссам һәм аның Чоры» (Мәскәү, 1987); «Башка төрле сәнгать» (Мәскәү, 1990); «XX гасырда рус авангарды» (Кёльн ш., Германия, 1993); «Гуманизм һәм технология. Кеше индустриаль җәмгыятьтә» (Сеул, Корея, 1994); «Нонконформизм. Россия, 1957–1995» (Кассель ш., Германия, 1995); «Безнең гасыр. Кеше образы — сурәтләр дөньясы» (Кёльн ш., Германия, 1995); «Коммунизм — хыяллар фабрикасы» (Франкфурт-Майнда, Германия, 2003–2004); «Мәскәү-Берлин» (Берлин, Мәскәү, 2003–2004); «Россия!» (Нью-Йорк,



Э.В. Б у л а т о в. «Томан». 1997.

2005–2006) халыкара күргәзмәләрендә катнаша. Цюрих (1988), Франкфурт-Майнда (1988), Бонн (1988), Амстердам (1988), Париж (И.Кабаков б-н берлектә, 1988; 1992), Мюнхен (1989), Лондон (1989), Нью-Йорк (1989, 1991, 1992, 1994), Мадрид (1991), Кёльн (1995), Мәскәү (В.Калинин б-н берлектә 1965 тә; Илья Кабаков б-н берлектә 1967 дә, 2003, 2006) шәһәрләрендә персональ күргәзмәләре үткәрелә. Әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясында (Мәскәү); Хәзерге заман сәнгате Милли музее (Жорж Помпиду үзәге, Париж), Майоль музее (Париж), Людвиг музее (Кёльн ш., Германия); Берн һәм Базель Сәнгать музейлары (Швейцария); Петер Стайвизантның Амстердамдагы шәхси коллекциясендә (Нидерландия); Дрезден картиналар галереясында (Германия), Циммерли музеенда (АКШ) һ.б. саклана.

*Әд.:* Д е г о т ь  Е. Русское искусство XX века. М., 2002; О б у х о в а  А.Е., О р л о в а  М.В. Живопись без границ. От поп-арта к концептуализму: Альбом. М., 2001.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**БУЛА́ТОВА** Галия Фатих кызы (24.6.1906, Казан губ. Әлки а. — 13.9.1985, Казан), драма актрисасы, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисткасы (1945, 1957). Татар театр техникумын беренче тәмамлаучылардан (1926). 1929 елдан Татар акад. театрында. Берничә ел Казан, Мәскәү, Әстерхан татар театрларында уйнап, үзен талантлы актриса итеп таныта. Уйнаган беренче рольләре б-н үк Фәтхи («Җавап», Г.Кутуй, 1929), Рәүфә («Шлем», Г.Минский, 1930), Мәфтуха («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш, 1934), Зөләйха («Яшь гомер», Г.Коләхмәтов, 1936), Маһи, Миләүшә («Чаткылар», 1936; «Кыю кызлар», 1940, Т.Гыйззәт), Рита Устинович («Корыч ничек чыныкты», Н.А.Островский әсәре буенча, 1938), Шаманова («Таня», А.Н.Арбузов, 1940) татар сәхнәсенең күренекле осталары рәтенә чыга. Б.ның иҗат эшчәнлегендә сәнгать чараларының киң диапазонын, сүз байлыгын оста файдалану, эмоциональлек һәм югары пафосны чынбарлык, үзен табигый тотуы б-н бәйләү сәләте ачык чагыла. Актриса башкарган Шәмсекамәр образы (М.Әблиевнең шул исем. әсәре, 1938) иң уңышлы рольләренең берсе санала. Бу образда Б., тыйнак һәм фидакарь хатынның байлар һәм дини фанатиклар рәхимсезлегенә каршы тора алуын күрсәтеп, кешенең җәмгыятьтәге роле темасын әчке киеренкелеге һәм поэтик көче б-н ачып сала. Б. башкарган Шәмсекамәр образы үзенең ачык, лирик нечкәлеге б-н татар халкының иң моңлы җырларының берсе «Зиләйлүк»кә авазлаш. Актриса талантына җырдагыча моңлылык, әчке темперамент, фикер киеренкелеге һәм тышкы бизәкләр б-н мавыкмау хас. Ул башкарган Инга («Профессор Мамлок», Ф.Вольф, 1935, 1941), Гаврилова («Диңгездәгеләр өчен», Б.А.Лавренёв, 1946), Зөһрә, Әминә («Мулланур Вахитов», 1948; «Муса Җәлил», 1957, Н.Исәнбәт), Грета Норман («Тормыш яңадан башлана», В.Н.Собко, 1954), Туйбикова («Ут», Ш.Камал, 1954), Нәсимә («Сәүбәновлар», К.Нәҗми, 1954) образлары шундыйлардан. Н.Исәнбәтнең «Зифа» пьесасы буенча куелган (1954) спектакльдәге баш героиняны — көчле ихтыярлы, максатчан, үз дәрәҗәсен яхшы белүче татар хатыны образын гәүдәләндерә, һәм шуның нәтиҗәсендә әлеге спектакль җәмәгатьчелектә киң яңгыраш таба. Заман чынбарлыгын чагылдырган бу образ өстендә актриса күп еллар дәвамында эшли, ул характерның яңа сыйфатларын ача, тамашачыга кеше күңеленең катып калган искелек богауларыннан арыну процессын күрсәтә. Рәйхан һәм Гүзәл (Н.Исәнбәтнең шул исем. пьесалары, 1948, 1954), Зөһрә («Таң атканда», Ш.Шәһгали, 1959), Камәрия («Бертуган Таһировлар», Ф.Хөсни, 1965) һәм бигрәк тә Миңлекамал (шул исем. пьеса, М.Әмир, 1944) образлары барыннан да элек гражданлык пафосы, татар милли драматургиясендә хатын-кызның яңа характерын тудыруы б-н кызыклы. Б. ның рус һәм дөнья классиклары репертуары спектакльләрендәге бәхәссез уңышы итеп Кручинина («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский, 1933) һәм Регана («Король Лир», У.Шекспир, 1944) образларын күрсәтергә мөмкин, алар шул заманның театр тормышында зур вакыйга булып танылалар.

Башка рольләре: Глафира, Варвара, Любовь («Бүреләр һәм сарыклар», «Яшенле яңгыр», «Кичеккән мәхәббәт», А.Н.Островский), Лидия Павловна, Люба («Варварлар», «Соңгылар», М.Горький), Лаура («Таш кунак», А.С.Пушкин), Эмилия («Отелло», У.Шекспир). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г о б ә й д у л л и н а  Ә. Галия Булатова. К., 1974; Народные артисты. К., 1980.

*Д.Ә.Гыйнмранова.*



Г.Ф. Булатова.





Г.Ф. Б у л а т о в а: 1. Миңлекамал (М.Әмирнең шул исемдәге әсәре ); 2. Рәйхан (Н.Исәнбәтнең шул исемдәге әсәре ) рольләрендә.

**БУЛА́ТОВА** (Рафигуллина) Клара Гариф кызы (18.3.1936, Сарман р-ны Татар Карамалысы а.), шагыйрә, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), авыл мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Шигырьләре 1956 елдан «Ялкын», «Азат хатын», «Казан утлары», «Чаян» ж-лларында басыла. Нефтьчеләргә, төзүчеләргә, авыл хезмәтчәннәренә багышланган «Язлар алда» дип исемләнгән беренче лирик шигырьләр җыентыгы 1967 елда дөнья күрә. «Һәрвакыт янымда» (1969), «Җәйләр җитсә» (1972), «Гел кояшка карап» (1981), «Печән өсте» (1986), «Хәтер тәрәзәләре» (1989), «Миләш кагы» (1991) китапларындагы шигырьләрдә замана кешесенең уй-хисләре, тирән кичерешләре чагыла. Б. поэзиясенең нигезендә — тормыш һәм иҗади хезмәт шатлыгы, тугрылык, дуслык һәм мәхәббәт кебек якты хисләр ташкыны. Б.ның соңрак чордагы иҗатына нечкә лиризм, уй-кичерешләрдә табигыйлек, фәлсәфи яңгыраш хас. Аны гомер узу, рухи кыйммәтләрнең югала баруы борчый. «Хәтер көзгесе» (Уфа, 1996), «Якты сагыш» (1996), «Әрнү» (2003), «Каурый канат — җил атым» (2006) исемле шигъри җыентыкларында сызлану, сыкрау кебек экзистенциаль мотивлар арта бара. Балаларга атап язылган «Марс китабы» (1982), «Курка димәгез әле» (1994), «Әллә кайсын тыңласы ...» (Уфа, 1995) китапларына кертелгән шигырьләре

күңел җылысы, җиңелчә юмор б-н аерылып тора. Хикәя-повестьлары, истәлекләре тупланган «Яшел каләм» җыентыгы (2003) автобиографик характерда.

Ә с ә р.: Шушы яктан, шушы туфрактан без. К., 2000.

*Әд.:* М а н н у р Ш. Хәерле юл телим // Казан утлары. 1971. № 2; В ә л и е в М. Мәхәббәт яшәргә тиеш // Казан утлары. 1990. № 3; З ә й н а ш е в а Г. Шатлыгымда хәсрәт орлыгы бар, хәсрәтемдә — бәхет орлыгы // Мәдәни җомга. 1996. 29 март.

*Г.М.Габделхакова.*

**БУЛА́ТОВА** (Бикбулатова) Мөнирә Закир кызы (19.5.1914, Архангельск ш.) җырчы (меццо-сопрано), педагог, театр эшлеклесе ТАССРның һәм РСФСРның халык артисткасы (1950, 1957). Казан индустриаль техникумын тәмамлый (1930). 1934–36 елларда Казан музыка уч-щесендә (К.А.Апухтина классы), 1936–38 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (М.В.Владимирова классы) укый. 1939–78 дә Татар опера һәм балет театрында әйдәп баручы солист (беренче роле — Н.Җиһановның «Качкын» операсында Бикә партиясе). 1948–53 тә Мәскәү консерваториясендә М.В.Владимирова җитәкчелегендә җырлау осталыгын камилләштерә. 1949–50 ел сезонында, стажировка үтүче буларак, П.Чайковскийның «Пики дамасы»нда Полина һәм Миловзор партияләре б-н Мәскәүнең Зур театры сәхнәсендә чыгыш ясый. Төп партияләре: Зибель («Фауст», Ш.Гуно), Кармен (шул исем. опера, Ж.Бизе), Кончаковна («Князь Игорь», А.Бородин), Марина Мнишек («Борис Годунов», М.Мусоргский), Любаша («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Ольга, Няня («Евгений Онегин», П.Чайковский), Тугзак, Хәят («Алтынчәч», «Җәлил», Н.Җиһанов), Разия («Самат», Х.Вәлиуллин), Җиһан, Мәрфуга («Башмагым», «Тапшырылмаган хатлар», Җ.Фәйзи) һ.б. Б. актив концерт эшчәнлеге алып бара. Үзен татар һәм рус композиторларының лирик романсларын оста башкаручы буларак таныта. Р.Яхин романсларының күпчелеген беренче башкаручы. Киң диапазонлы тавышы, кабатланмас үзенчәлекле тембры, күркәм төс-кыяфәте һәм актёрлык сәләте аңа опера сәхнәсендә төрле чорларда һәм стильдә иҗат ителгән әсәрләрдә онытылмас образлар тудырырга мөмкинлек бирә. Вокаль башкару культурасы, күпкырлы бай репертуары Б.ны мәшһүр опера һәм камера концерты җырчылары дәрәҗәсенә күтәрә. СССР, Болгария, Румыния, Монголия шәһәрләрендә уңышлы чыгышлар ясый. «Татарстан» ДТРК фондында татар, рус һәм Көнбатыш Европа композиторлары романсларының һәм операларыннан арияләрнең Б. башкарган 160 тан артык язмасы саклана. 1970–85 елларда Казан мәдәният ин-тында укыта. Б. киң җәмәгать эшчәнлеге алып бара: 1963–71 дә Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе рәисе; 1966–75 тә Совет-Чехословакия җәмгыятенең Казан бүлеген җитәкли; 1967–68 дә Татар опера һәм балет театры директоры була. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.



М.З.Булатова.

*Әд.:* К у т у й Г. «Ирек» операсы // Совет әдәбияты. 1940. № 5–6; Татар артистлары чит илләрдә // Азат хатын. 1958. № 1; Х ә й р у л л и н а З. Мөнирә Булатова // Азат хатын. 1961. № 1; Хуҗиәхмәтова Ф. Җыр гомере // Азат хатын. 1980. № 1; Шакиров М. Шәмдәлләрдә генә утлар яна // Казан утлары. 1984. № 6; Ә д и я т у л л и н а Ә. Күгемдә җемелди йолдызлар // Азат хатын. 1989. № 9; С а й ф у л л и н а Г. Счастье сцены: личность и судьба Муниры Булатовой. К., 1955; Т о р о п о в а В. Первая ласточка // Театральная жизнь. 1966. № 1; Народные артисты. К., 1980.

**БУЛА́ТОВА** Сәгъдия Хәсән кызы (1884, Рязань губ. Касыйм ш. — 1950), җәмәгать эшлеклесе, педагог. 1900 еллар башында Касыйм шәһәрендә беренче җәдиди кызлар мәктәбе ача, 1910–12 елларда укучы яшьләр түгәрәге оештыра һәм аның җитәкчесе була, татар телендә спектакльләр куя. 1917–21 дә авылларда татар мәктәпләре, уку йортлары оештыруда катнаша, «Чалгы» г-тасын чыгара (3 саны чыккач, газета ябыла). Революцион эшчәнлеге өчен 1917 нең җәендә Б. Пенза губернасында сөргендә була. Татар мәктәпләре буенча халык мәгарифе бүлеге инструкторы, мөселман эшләре буенча Касыйм өяз комис-тында халык мәгарифе бүлеге мөдире, татар балалар йорты мөдире булып эшли, Касыйм шәһәр музеенда татар бүлеген оештыра. 1923 тә Рязань губернасы халык мәгарифе бүлеге каршында аз санлы милләтләр Советының вәкиле булып тора. ВКП(б) ҮКнең Татар-башкорт үзәк бюросы тәкъдиме б-н 1924 нең апрелендә Мәскәүгә күчерелә, пед. эшчәнлеген анда 1934 елга кадәр дәвам итә. 1939 да репрессияләнә, үлгәннән соң аклана (1955).

*Әд.:* Х ә й р е т д и н о в Р.Г. Давыллар аша // Азат хатын. 1974. № 6; ш у л у к. С.Х.Булатова // Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1990.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**БУЛА́ТОВА** Флюра Әскәр кызы (1960), спортчы (өстәл теннисы). СССРның атказ. спорт остасы (1982). 1982, 1983 елларда — катнаш парлар арасында, 1985 тә шәхси беренчелектә СССР чемпионы. 1982 дә Европа чемпионатында (хатын-кызлар парлары арасында), 1983 тә СССР халыклары спартакиадасында (командалар беренчелегендә) көмеш медаль ала. 1984 тә дөнья чемпионатында катнаша (командалар беренчелегендә 4 нче урын). 1990 еллар башыннан Италиядә яши.

**БУЛА́ТОВА-ТЕРЕГУ́ЛОВА** Хәлимә Ибраһим кызы (26.4.1905, Казан — 13.11.2000, шунда ук), беренче татар профессиональ музыка белгече, педагог. 1938 елда Мәскәү консерваториясенең тарих-теория ф-тын (педагог — Т.И.Ливанова) тәмамлый. 1938–44 тә Казан музыка уч-щесендә һәм музыка мәктәпләрендә музыка тарихы укыта. 1944–45 тә П.И.Чайковский музей-йортында (Клин ш.) фәнни хезмәткәр. 1945–61 дә Казан консерваториясендә укыта. Хезмәтләре татар музыка культурасы тарихына һәм композитор Н.Җиһанов иҗатына карый.

Х е з м.: Н.Җиһановның «Качкын» операсы // Совет әдәбияты. 1939. № 7; Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсы // Совет әдәбияты. 1941. № 8; Новая татарская опера «Ирек» Н.Жиганова // Советское искусство. 1940. № 19; Назиб Жиганов и современная татарская музыка // Советские композиторы. М., 1945; Музыкальная культура Татарии за 25 лет // Музыка. М., 1945.

*Әд.:* Н и г м е д з я н о в М.Н. Халима Булатова-Терегулова // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Б и к ч у р и н а Ф. Халима Ибрагимовна Булатова-Терегулова // Из педагогического опыта Казан. консерватории. К., 1996; Славная жизнь // Музыкальная академия. 1996. № 3–4.

**БУЛГА́КОВ** Александр Николаевич (25.8.1911, Кырым, Феодосия ш. — 11.4.1978, Казан), язучы. Мәскәү төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1937), Ерак Төньяк һәм Ерак Көнчыгыш төзелешләрендә эшли. 1953 елдан Казанда яши, төзелеш оешмасында баш инженер була. 1957 дән башлап беренче хикәяләрен һәм очеркларын «Смена», «Огонёк», «Наш современник» ж-лларында бастыра. «Буран аша» («Сквозь пургу», 1958), «Юл тауга күтәрелә» («Трасса поднимается в горы», 1959), «Яшибез» («Будем жить», 1965), «Төньяк җиле» («Северный ветер», 1971) хикәя һәм повесть җыентыклары авторы. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

М.З.Б у л а т о в а: 1. Кончаковна (А.П.Бородинның «Князь Игорь» операсы); 2. Графиня (П.И.Чайковскийның «Пики дамасы» операсы); 3. Тугзак (Н.Г.Җиһановның «Алтынчәч» операсы) рольләрендә.







*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**БУЛГА́КОВ** Вячеслав Данилович (6.3.1941, Куйбышев ш.), дирижер-хормейстер, педагог, пед. фән. д-ры (2003). 1969 елда Казан консерваториясен (Э. Браун һәм В. Васильев классы) тәмамлый. 1971 дә — Казан сәнгать һәм мәдәният, 2003 тән Казан гуманитар-пед. ун-тларында укыта. Россиядә музыка белеме һәм хор б-н җырлау тарихы буенча хезмәтләр авторы.

Әсәр.: Русская профессиональная хоровая школа конца XIX — первой половины XX столетия. К., 2000; Русская хоровая педагогика конца XIX — первой половины XX столетия: Уч. пособие. К., 2001.

**БУЛГА́КОВ** Григорий Андреевич (? — 1589 дан соң), кенәз, бояр (1586 тирәсе), дәүләт эшлеклесе. П.А.Булгаковның энесе. Казанда 1564–66, 1571–74 елларда 2 нче, 1581–86 да 1 нче воевода. 1583–84 тә Казан төбәгендә җирле халыкның баш күтәрүен бастыру б-н җитәкчелек итә.

**БУЛГА́КОВ** (Куракин-Булгаков) Пётр Андреевич (? — 1575), кенәз, бояр (1571 тирәсе), дәүләт эшлеклесе. Г.А.Булгаковның абыйсы. 1552 елда мәскәүлеләр Казанга яу б-н килгәндә Шаһгали гаскәренең 2 нче воеводасы була, шәһәрне камауда катнаша. 1571–74 тә Казанда 1 нче (баш) воевода. 1572–73 тә Казан төбәгендә җирле халыкның баш күтәрүен бастыруга җитәкчелек итә. 1575 нең көзендә патшага каршы фетнәдә катнашуда гаепләнә һәм җәзалап үтерелә.

**БУЛГА́КОВ** Рәшит Алим (Галим) улы (2.8.1929, Хабаровск ш. — 29.1.1998, Мәскәү), авиация генерал-лейтенанты (1982). Хәрби һава көчләренең Краснодар махсус мәктәбен, Ленинград Хәрби һава инженерлары академиясен (1954) тәмамлый. 1954–59 елларда Камчаткада: авиазвено техникы, авиаполк инженеры. 1959–63 тә Белоруссия хәрби округында: техник-эксплуатация часте башлыгы, авиаполк командиры урынбасары. 1963–67 дә Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә авиация инженеры. 1967 дән Мәскәүдә: очкычларны эксплуатацияләү һәм ремонтлау буенча өлкән инженер-инспектор, баш инженер урынбасары, баш инженер, хәрби берәмлек командиры урынбасары, 1979–85 тә СССР Хәрби һава көчләре Транспорт авиациясе командующиенең авиация инженерлары хезмәте буенча урынбасары-баш инженер. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**БУЛГА́КОВ** Ришат Тимергали улы (6.6.1931, Уфа ш. — 23.2.1989, Әлмәт ш.), нефтьче, техник фән. канд. (1975), Соц. Хезмәт Герое (1976), СССРның мактаулы нефтьчесе (1977). И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), «Бөгелмәнефть» нефть чыгару идарәсендә производство бүлеге җитәкчесе булып эшли. 1963 елдан — «Әлмәтнефть» нефть промыселы идарәсендә баш инженер, 1967 дән аның җитәкчесе. 1972 дән ТатНИПИнефть директоры. 1972 дән «Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры, 1977 дән ген. директоры. 1980–83 тә нефть һәм газ сәнәгате буенча Түбән җитештерү идарәсе башлыгы. 1983 тән Мәскәүдә: СССР Госпланының нефть һәм газ сәнәгате бүлеге җитәкчесе урынбасары. «Татнефть» берләшмәсендә автоматлаштырылган идарә системасын (АСУ) һәм сәнәгый социология хезмәтен оештыру, нефть ятмаларын файдалануга тапшыруның комплекслы программасын булдыру б-н җитәкчелек итә. ТАССР (1963–80), СССР (1978–82) ЮСлары депутаты. Ленин, Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Прогнозирование и оптимизация разработки большой группы нефтяных залежей. К., 1976 (автордаш); Социальное управление нефтедобывающим предприятием. К., 1977 (автордаш).

*Р.С.Алатырева.*

**БУЛДЫ́РЬ** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2002 елда 187 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. Китапханә. 1710 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элек Демидовлар з-дларына беркетелгәннәр) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балык тоту, киез итек басу, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Рождество чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, 2 тимерчелек, 8 җил тегермәне, шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1680 *дис.* тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 313 ир заты; 1859 да — 1526, 1897 дә — 2407, 1908 дә — 2728, 1920 дә — 2579, 1926 да — 2530, 1938 дә — 1952, 1949 да — 1388, 1958 дә — 1103, 1970 тә — 832, 1979 да — 463, 1989 да — 282 кеше.

**БУ́ЛИЧ** Николай Никитич (3 яки 5.2.1824, Курган ш. — 24.5.1895, Спас өязе Урыс Йорткүл а.), әдәбият галиме, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1883). Казан ун-тын тәмамлый (1845). 1850 елдан Казан ун-тында: 1854 тән проф., 1862–64, 1875–78 һәм 1881–82 елларда тарих-филология ф-ты деканы, 1864–71 дә проректор, 1882–84 тә ректор. 1865 тән шәһәр һәм җәмгать китапханәләре б-н идарә итү к-тының мактаулы күзәтчесе, соңыннан әгъзасы. 1880–90 да земство эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, өяз һәм губерна земстволары гласные, земство мәктәбе идарәчеләре советы рәисе. 1863–95 тә «Казанские губернские ведомости», 1872–73 тә «Камско-Волжская газета», 1884–95 тә «Волжский вестник» г-таларында әдәби тәнкыйтьче буларак язмалар бастыра. 1865–68 һәм 1881–85 тә «Учёные записки Казанского университета» ж-лы мөхәррире. А.П.Сумароков турындагы монография, Г.Р.Державин, М.В.Ломоносов, Н.М.Карамзин, В.А.Жуковский, А.С.Пушкин, Ф.М.Достоевский турындагы мәкаләләр һәм чыгышлар, Казан ун-ты тарихы буенча (1887–91) беренче фәнни хезмәт авторы. 1894 елда 3000 исемдәге (7000 данә) китаптан торган китапханәсен Казан ун-тына бүләк итә.



Р.А. Булгаков.



Р.Т. Булгаков.

Әсәр.: Из первых лет Казанского университета (1805–19): В 2 ч. К., 1887–91; Очерки по истории русской литературы и просвещения с начала XIX века: В 2 т. СПб., 1902–05.

*Әд.:* Фирсов Н.А. Студенческие истории в Казанском университете. 1855–63 гг. // Русская старина. 1889. № 4; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Азбукин В.Н., Макурин В.П. К оценке литературоведческого наследия Булича // Романтизм в русской и зарубежной литературе. К., 1974.

*М.М.Сидорова.*

**БУ́ЛИЧ Н.Н. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**, Казан ун-ты профессоры Н.Н.Буличның китапханәсе. 3 меңнән артык исемдә 7 мең томга якын китап берәмлеге була, шуларның 1000 гә якыны — чит ил телләрендә. Тематика ягыннан төрлеләр: Н.В.Гоголь, А.С.Грибоедов, Ф.М.Достоевский, В.А.Жуковский, М.Ю.Лермонтов, Н.А.Некрасов, Я.П.Полонский, А.С.Пушкин, В.К.Тредиаковский, И.С.Тургенев, Ф.И.Тютчев әсәрләре; Н.И.Новиков нәширлегендә чыккан «Живописец», «Трутень», «Утренний свет» һ.б. ж-лларның төпләмнәре; Казанда чыккан фәнни һәм әдәби журналлар: «Заволжский муравей» ж-лының 1832–34 еллардагы тулы төпләме, 1856–57 елларда «Казан ун-ты профессорлары язган фәнни мәкаләләр җыентыгы» — «Сборник учёных статей, написанных профессорами Казанского университета»; «Казан университетының гыйльми язмалары» — «Учёные записки Казанского университета» басмасының 1834–95 елларда чыккан саннарының төпләмнәре; «Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» — «Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете» басмасының 1879–1902 еллардагы саннары; Казанның әдәбият һәм тел галимнәре А.С.Архангельский, В.А.Богородицкий, И.А.Бодуэн де Куртенэ, М.П.Веске, Г.Н.Городчанинов, В.И.Григорович, Н.В.Крушевский, В.И.Модестов, М.П.Петровский, И.Я.Порфирьевларның гыйльми хезмәтләре, ш.у. Казан авторлары Л.Н.Ибраһимов, А.А.Фукс һ.б.ның әдәби әсәрләре.

Мәдәни-тарихи юнәлешле гыйльми мәктәп тарафдары буларак, Н.Н.Булич үзенең китапханәсенә бик күп тарихи әсәрләр туплаган.

Алар арасында И.П.Барсуков, П.И.Бартенев, А.Г.Брикнер, С.В.Ешевский, Д.И.Иловайский, Н.М.Карамзин, Н.И.Костомаров, Н.П.Лихачёв, М.П.Погодин, Н.Г.Устрялов кебек күренекле тарихчыларның, ш.у. Казан тарихчылары Н.Я.Аристов, Н.П.Загоскин, Д.А.Корсаков, С.М.Шпилевскийларның тарихи китаплары, Халык мәгарифе министрлыгының Археография комиссиясе чыгарган басмалар, чиркәү тарихына караган хезмәтләр, истәлекләр, көндәлекләр, юлъязмалар, ш.и. И.Н.Березин, Ф.Ефремов язмалары; Н.К.Баженов, М.С.Рыбушкиннарның Казанның юл күрсәткечләре һ.б. китаплар бар. Тупланмада чех, поляк, украин язучыларының (Г.Ф.Квитка-Основьяненко, А.Мицкевич, Т.Г.Шевченко) әсәрләре булу Н.Н.Буличның кызыксыну даирәсенең киңлеге турында сөйли. Әдәбият белеме һәм фәлсәфәгә кагылышлы басмалар арасында Россиядә һәм чит илләрдә чыккан кыйммәтле китапларның байтагы була. Буличны кызыксындырган тагын бер өлкә — яшерен һәм тыелган әдәбият. А.А.Бестужевның «Ревельгә бару» («Поездка в Ревель», 1821), К.Ф.Рылеевның «Уйлар» («Думы», 1825), «Войнаровский» (1925), А.И.Герцен һәм Н.П.Огаревның Лондондагы «Полярная звезда» типографиясе басмалары (1855–68), А.Н.Радищевның «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт»е («Путешествие из Петербурга в Москву», 1858), Н.Г.Чернышевскийның 1868–70 елларда язган хезмәтләре шундыйлардан. Раритетлы басмалардан мисалга 18 йөз ахыры масон әсәрләрен, А.С.Пушкинның «Шигырьләр» җыентыгын («Стихотворения», 1826), Н.В.Гогольнең «Алов» псевд. астында чыккан һәм соңыннан үзе үк юк иткән беренче әсәре «Ганц Кюхельгартен» (1829) әсәрен А.А.Бестужев б-н К.Ф.Рылеев 1825 тә нәшер иткән «Полярная звезда» экземплярын китерергә мөмкин. Китапханәнең Казандагы һәм Булич үзенең соңгы елларында яшәгән Спас өязе Йорткүл авылындагы һәр китабына «Н.Н.Булич китапханәсе» («Библиотека Н.Н.Булича») дигән язулы экслибрис сугылган, китапны сатып алу датасы, гомуми исемлектәге тәртип саны күрсәтелгән. Тупланманың алфавит тәртибендә эшләнгән каталогы да була (соңрак ул 360 нөсхәдә басылып та чыга).

Гомеренең соңгы елларында Н.Н.Булич үз китапларын шәһәрнең җәмәгать китапханәсенә тапшырырга теләк белдерә, чөнки ачылган көненнән алып, ул бу китапханә б-н хезмәттәшлек итә. Ләкин шәһәр башлыкларының битарафлыгы, гавами китапханәнең хәерче хәле һәм анда тыелган китаплар саклау мөмкинлеге булмау Буличны бу фикереннән кире кайтырга мәҗбүр итә һәм ул тупланмасын Казан ун-ты китапханәсенә китапларны өйгә биреп җибәрелмәү шарты б-н тапшыра. Н.Н.Буличка рәхмәт-ихтирам йөзеннән, 1894 елда ун-т Гыйльми советы үзенең карары б-н китапханә һәм совет утырышлары залы стенасына Н.Н.Буличның портретларын эләргә дигән карар чыгара. 1930 елларга кадәр китаплар махсус урында тотыла, аннан соң гомуми саклау урыннарына таратып урнаштырыла.

*Әд.:* Алфавитный каталог книг, пожертвованных университету почётным членом, заслуженным ординарным профессором его Н.Н.Буличем. К., 1896; Е р м о л а е в а Н.В. Книжное собрание профессора Казанского университета Н.Н.Булича: Фонды, раритеты, история... К., 1989; О с о р г и н М.А. Заметки старого книгоеда. М., 1989.

*И.А.Новицкая.*

**БУ́ЛКИН** Вадим Александрович (12.10.1941, Приморье краеның Яковлевск р-ны Варфоломеевка а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989), проф. (1991), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2003). 1965 елда Казан хим.-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук химия производствосы машиналары һәм аппаратлары кафедрасында эшли. Хезмәтләре газ һәм сыеклыкның үзара тәэсир итешү процессларының теоретик нигезләренә карый. Газ-һава агымын чистарту процесслары, сыек катнашмалар ясаучы гидродинамик туглагычлар өчен өермә тибындагы аппаратлар эшли. Газ калдыкларын технологик чистарту өчен яңа төрдәге скруббер конструкцияләрен төзи. Уйлап табуга караган 21 авторлык таныклыгы бар. СССР ВДНХсының алтын медальләре б-н бүләкләнә (1964, 1984).

Х е з м.: Исследование особенностей течения газа в вихревых аппаратах с оросительными хими устройствами объёмного типа // Теорет. основы хим. технологии. 1986. № 4 (автордаш); Определение длины нераспавшейся части струи при ламинарном истечении жидкости из отверстий и насадков // Теорет. основы хим. технологии. 1998. № 1 (автордаш); Расчёт и проектирование целевого смесителя для гомогенизации ингибиторных растворов // Нефт. хоз-во. 1999. № 1.

**БУЛУ́ШЕВ** Зәйнулла Хөсәен улы (1886, Тамбов губ. Татарщино а. — ноябрь, 1965, Одесса ш.), сәясәт эшлеклесе. 1905–17 елларда (өзеклек б-н) Донбасс күмер бассейнындагы «Лежанская» шахтасында эшли. 1907–09 да Россия армиясендә хезмәт итә. 1917 елда Таганрог шәһәрендә Көньяк татар башкарма ком-тын оештыручыларның берсе һәм рәисе. 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары (май, июль 1917) делегаты. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армиядә хезмәт итә, Царицын шәһәре янындагы сугышларда катнаша. 1921–22 дә БУБКның һәм РСФСР Милләтләр эше буенча халык комис-тының Кырым АССРдагы вәкиле, 1923–24 тә ТАССР юстиция халык комиссарының һәм прокурорының урынбасары, ТАССР ХХС рәисе урынбасары. 1924 тән ТАССРда, Әзәрбайҗанда һәм Кыргызстанда хуҗалык эшләрендә. 1930 да кулга алына (*«солтангалиевчелек»*), атарга хөкем ителә. Аннары хөкем карары 10 елга ирегеннән мәхрүм итү б-н алыштырыла. 1933 тә азат ителә; 1956 да аклана. Ирекә чыкканнан соң ТАССР колхозларында хисапчы хезмәтен башкара. 1945 тән Кисловодск шәһәрендә яши, «Нарзан» санаториенда хезмәткәр була.

*Әд.:* В а л е е в Р.К. З.Х.Булушев // Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1990; Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2001. Т. 2.

*Р.К.Вәлиев.*

**БУЛХА́НОВ** Рафаил Усман (Госман) улы (12.1.1941, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд ш.), радиобиолог, биол. фән. д-ры (1993). Сәмәрканд а.х. ин-тының вет. ф-тын тәмамлый (1972). 1962 елдан Үзбәк вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Сәмәрканд ш.) эшли, 1991 дән радиобиология лаб. мөдире; бер үк вакытта 1979 дан Сәмәрканд а.х. ин-тында. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: радиобиология — а.х. терлекләренең инфекцион патологиясе, микробиологиясе, физиологиясендә изотоплар һәм ионлаштыручы нурланышлар; радиацион иммунология — нурлар б-н зарарланганда инфекцияләр һәм иммунитет; хайваннарны дәвалау һәм профилактика үткәрү, нурлар б-н зарарланганда саклануның гумораль һәм күзәнәк факторлары; гамәли радиобиология — а.х. терлекләренең инфекцион авыруларына каршы вакциналар эшләүнең радиацион биотехнологиясе. Б. тарафыннан мөгезле вак терлек (1997) һәм бозауларда (1998) колибактериоз һәм сальмонеллёзга каршы ассоциацияләнгән радиовакциналар булдырыла. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Үзбәкстан Респ-касының Ветеринария законнары җыелмасын төзүчеләрнең берсе (1998).

Х е з м.: К вопросу о резистентности организма животных // Незаразные болезни с.-х. животных и вопр. токсикологии: Тр. Узб. науч.-иссл. ин-та ветеринарии. Таш., 1986. Т. 40; Радиационная биотехнология в ветеринарии // Проблемы изыскания, синтеза и произ-ва препаратов для ветеринарии: Материалы 2 респ. науч.-парктической конф. Самарканд, 1999.

**БУЛЫ́ГИН** Андрей Владимирович (17.9.1935, Иваново өлкәсенең Комсомольск ш.), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1980), проф. (1981). 1959 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, «Авиация спорты» КБсында эшли. 1964 тән Казан техника ун-тында очкыч аппаратлар конструкцияләү һәм проектлаштыру кафедрасында. Хезмәтләре юка тышчалы конструкцияләрнең һәм тышчаларның ныклыгын хисаплау теориясенә, су асты тикшеренүләре өчен аппаратлар эшләүгә карый. Тор типлы тышчаларны хисаплауның геометрик теориясен эшләүдә, океанны тикшерү өчен күп кенә су асты аппаратлары төзүдә катнаша. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Концепция и выбор проектных параметров экраноплана // Изв. вузов. Авиационная техника. 1995. № 4 (автордаш); Влияние горизонтального оперения на продольную устойчивость экраноплана // Вестн. Казан. техн. ун-та. 1996. № 3.

**БУЛЫ́ГИН** Василий Фёдорович (4.1.1848, Казан губ. Царёвококшай өязе — 1919, Казан), 1 гильдия Казан сәүдәгәре (1892), нәселдән күчмә шәрәфле гражданин (1897). Казан һәм Вятка губерналарында сәүдәгәрлек һәм сәнәгатьчелек б-н шөгыльләнә. Улы б-н бергә сәүдә йорты тота («Булыгин и сын»). 10 меңнән артыграк дис. җиргә һәм 5 аракы-спирт з-дына (Казан губ. Казан өязендә — Алат, Царёвококшай өязендә — Никольский, Вятка губ. Малмыж өязендә — Александровск, Яран өязендә — Фёдоровский һәм Яранск), Яран өязендә сыра кайнату һәм май язу, Казанда такта яру з-длары хуҗасы. Казандагы Благовещение соборын төзекләндерүгә иганәлек кыла, Руханилар академия-

сенең мохтаҗ студентларына стипендия билгели (1904), Россия Кызыл Хач җәмгыятенең җирле шәфкать туташлары оешмасына бина сатып ала (1904). Казан өязе Потаниха, Царёвококшай өязе Вараксин, Малмыж өязе Бурецк авыллары земство мәктәпләренең һәм Царёвосанчурск шәһәр уч-щесенең тышкы идарәчеләр әгъзасы була. Царёвококшай өязе (1885 елдан) һәм Казан губернасы (1901 дән) земство җыеннары гласные. Казан губернасы балалар ятимханәләре идарәчелегенең шәрәфле әгъзасы (1890 дан), Царёвококшайск төрмәсе директоры (1888 дән). Царёвококшай өязенең шәрәфле мировой судьясы (1909–11). *Е.Б.Долгов.*

**БУЛЫ́ГИН** Владимир Яковлевич (1789, Пенза ш. — 4.7.1838, Казан), тарихчы, статский советник (1835). Казан ун-тын тәмамлый (1811), 1812 елдан шунда ук эшли: инспектор ярдәмчесе (1812–17), студентлар б-н эшләү инспекторы (1819–20), тарих, география һәм статистика кафедрасында экстраординар проф. (1822–23), ординар проф. (1823–37). 1837 дән Россия тарихы каф. ординар профессоры. Бер үк вакытта әхлакый-сәяси (1824–25) һәм әдәбият (1827–28) фәннәре бүлеге деканы. 1816–19 да «Казанские известия» г-тасы цензоры. Тарихи-җәмгыяви үсеш илаһи көчләр ихтыярында дигән караш тарафдары. Төп хезмәтләре урта гасырлар сәүдә тарихына, рус халкы этногенезына, Борынгы Русь сословиеләренә карый.

Х е з м.: О состоянии торговли в первой половине средних веков. К., 1825; О Туруханском крае. К., 1827; Исторические воспоминания на пути из Казани в Симбирск. К., 1834; О северо-восточных русских. К., 1836.

*Әд.:* С е л и в а н о в А.Ф. Биографии. Пенза, 1889; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**БУЛЫ́ГИН** Владимир Яковлевич (17.4.1916, Казан), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1960), проф. (1961), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991), Казан ун-тының атказ. проф. (2006). 1939 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1946–99 да шунда ук эшли, хисаплау математикасы кафедрасы мөдире һәм бер үк вакытта 1958–64 тә Хисаплау үзәгенең фәнни җитәкчесе. Хезмәтләре эластик-пластик мәсьәләләргә, нефть катламнары гидромеханикасына, нефть ятмаларын эшкәртүне имитацияләү һәм модельләштерүгә карый. Җир асты гидромеханикасында фәнни юнәлешкә нигез салучыларның берсе. Катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру, нефть чыгаргандагы чыгымнарны киметү өчен матем. модельләр, алгоритмнар һәм программалар төзи. Уйлап табуга караган 2 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гидромеханический анализ работы эксплуатируемого нефтяного месторождения. К., 1958; Гидромеханика нефтяного пласта. М., 1974; Правдоподобное моделирование. К., 1985; Имитация разработки залежей нефти. М., 1990 (автордаш).

*Әд.:* З и н о в ь е в Н.П. Штрихи к портрету // Казанский университет: Время, события, люди. К., 1994.

**БУЛЫ́ГИН** Дмитрий Владимирович (28.1.1952, Казан), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1989). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), ТатНИПИнефтьтә эшли. 1975–78 елларда Казан геол. разведка экспедициясендә. 1978–98 дә Нефть химиясе сәнәгате фәнни-тикшеренү ин-тында, 1983 тән лаб. мөдире һәм 1995 тән нефть чыганаклары геологиясе, аларны эшкәртү һәм мәгълүмат үзәге директоры. 1998 дән Казан ун-ты каршындагы Математика һәм механика ин-тында нефть ятмаларын модельләштерү һәм эшкәртү лаб. мөдире. Бер үк вакытта 1999 дан ТР Җир асты байлыклары геологиясе һәм алардан файдалану буенча фәнни-аналитик үзәк директоры. Төп хезмәтләре нефть ятмаларының геол. төзелешен, аларны эшкәртү процессын һәм матем. модельләштерү, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру ысулларын нигезләү һәм нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсенә карый. Нефть ятмаларының геологик фильтрлау модельләрен — имитацион системалар төзү концепциясен тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә Көнбатыш Себер һәм Татарстандагы чыганакларның даими модельләрен — нефть чыганакларының геол. төзелешен һәм аларны эшкәртү процессларын матем. модельләштерү буенча программа чаралары эшләнә.

Х е з м.: Имитация разработки залежей нефти. М., 1990 (автордаш); Геология и имитация разработки залежей нефти. М., 1996 (автордаш).

*Әд.:* Кто есть кто в нефтяной и газовой промышленности СНГ. М., 1992.

**БУЛЫЧЁВ** Владимир Михайлович (29.6.1942, Казан — 8.8.1995, шунда ук), тележурналист, сценарийлар авторы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан ун-тын тәмамлый (1968). «Татарстан» Дәүләт теле-радио компаниясендә эшли. 1967 елдан а.х. редакциясе хәбәрчесе, 1983 тән тапшырулар мөхәррире һәм алып баручысы; 1990 нан «Пульс» иҗат берләшмәсенең мөхәррире, 1992 дән өлкән мөхәррире, 1993 тән «Чулпан» программасының мөхәррире һәм алып баручысы. ТАССР авыл хуҗалыгының актуаль мәсьәләләренә багышланган тапшырулар циклы («Авыл: проблемалар», «Районнар конкурсы») сценарийлары авторы һәм алып баручысы. 1980–86 да Үзәк телевидение (Мәскәү) өчен ТАССРның иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышын чагылдырган еллык йомгаклау тапшыруларын әзерләүдә катнаша. Бер үк вакытта 1970 елларда Казан телестудиясенең «Зәңгәр ут» («Голубой огонёк») Яңа ел тапшыруларының сценарийларын язуда һәм алып баруда катнаша. Б. сценарийлары буенча «Җир белән сөйләшү» («Диалог с землёй», 1972), «Туган ил нәрсәдән башлана» («С чего начинается Родина», 1973), «Минем яраткан шәһәрем» («Город, который я люблю», 1976), «Текә баскычлар» («Крутые ступени» 1979), «Биш ел озынлыгындагы юл» («Дорога длиною в пять лет», 1980), «Миллионны ничек тотып бетерергә» («Как истратить миллион», 1982), «Сугыш юллары буйлап» («Дорогами войны», 1985), «Безнең игелекле җиребез», («Добрая наша земля», 1985), «Бурнашлар турында бәет» («Баит о Бурнашах», 1995) дигән документаль телевизион фильмнар төшерелә.

**БУМА́ ҮЛӘ́Н** (Pinguicula), куыгутчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 45 ләп төре билгеле, Европада, Азиядә һәм Төньяк Америкада киң таралган. ТРда бер төре — гади Б.ү. (P. vulgaris). Кама аръягында очрый. Дымлы урыннарда, чишмә янындагы сазлыкларда үсә. Бик кыска тамырчалы, чагыштырмача тәбәнәк (5–15 *см*) бөҗәк ашаучы үсемлек. Яфраклары бөтен, тамыр янындагы таралгыда урнашкан, бөҗәкләрне үзенә тартып китерү һәм ябыштыру өчен сыекча бүлеп чыгаралар. Чәчәкләре ялгыз, күксел-шәмәхә төстә, озын яфраксыз чәчәк сабында. Җимеше — күп орлыклы тартмачык. Май–июнь айларында чәчәк ата. Орлыклардан үрчи. Җир өстендәге өлешләрендә фенол-карбон кислоталары, флавоноидлар табыла. Халык медицинасында яра төзәтү, авыртуны басу өчен файдаланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БУМЫ́Н КАГА́Н** (Тумын, Илхан) (? — 552), *Төрки каганлык*ны нигезләүче, төрки *Ашина* ыругы каганнары династиясен башлап җибәрүче. «Төрки» атамасын йөрткән берничә кабиләне берләштерә. 545 елда, Көнбатыш Вей дәүләте идарәчесе Вэнь-ди ярдәменә таянып, үзе буйсынган төрки жуаньжуаньнар (аварлар) ханы Анахуаньга каршы сугыш башлый. Анахуань кул астындагы телес кабиләләре дә баш күтәрә һәм 550 дә Б.к.га буйсына. 551 дә Б.к. Авар каганлыгына каршы чыга һәм каганлык гаскәрен җиңә. 552 дә Төрки каганлыкны нигезли һәм үзен каган дип игълан итә.

Ч ы г.: Б и ч у р и н Н.Я. Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.–Л., 1950; М а л о в С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951.

*Әд.:* К л я ш т о р н ы й С.Г. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. М., 1964; Г у м и л ё в Л.Н. Древние тюрки. М.,1993; К л я ш т о р н ы й С.Г., С а в и н о в Д.Г. Степные цивилизации Евразии. СПб., 1997.

*И.Л.Измайлов.*


**БУ́НГЕ** Александр Андреевич (24.9.1803, Киев — 6.7.1890, Кильтси, хәзер Эстониянең Раквереск р-ны), флорист-систематик, Петербург ФАнең шәрәфле әгъзасы (1875). Медицина д-ры дәрәҗәсен алып, Дерпт (хәзер Тарту) ун-тын тәмамлый (1825). Казан (1833–36) һәм Дерпт (1836–67) ун-тлары профессоры. Колываново-Воскресенск тау з-дларында табиб булып эшләгәндә Алтай (1826, 1832), Монголия һәм Кытай (1830–32) буйлап сәяхәт итә, аларның флорасын өйрәнә. 1835 елда Э.А.Эверсман б-н бергә Каспий буе далаларында була. 1857–59 да Рус география җәмгыятенең Персия экспедицияләрендә катнаша. Хезмәтләре кайбер чәчәкле үсемлек ыругларының систематикасына карый. Күп кенә яңа үсемлек төрләрен билгели. Аларның кайбер төрләре (Bungea G.A.M.) ыругы аның исеме б-н атала. Үсемлекләрне системалаштыруда геогр.-морфологик ысулга нигез салучыларның берсе.

Х е з м.: Описание новых родов и видов китайских и монгольских растений // Уч. зап. Казан. ун-та. 1835. Кн. 6; Flora Altaika: В 4 т. В., 1829–33

(автордаш); Al. Lehmanni reliquiae botanicae. СПб., 1851; Species generis Oxytropis. СПб., 1874.

*Әд.:* Русские ботаники: Биобиблиогр. словарь. М., 1947. Т. 1.

**БУНЧУ́К** (буынчык), 6–17 йөзләрдә төрки-татар дәүләтләрендә ил яки гаскәр б-н идарә итүченең идарәчелек билгесе. 15–18 йөзләрдә Б.ны төрек пашалары (гаскәр башлыклары), Польша, Украина гетманнары һәм рус атлы казаклары атаманнары да куллана. Б. озын колга очына беркетелә, ул иясенең тамгасы рәвешендә ясалган металл эшләнмәдән һәм шуңа тагылган ат кылыннан гыйбарәт. Кайбер очракта ат кылы «көлтәсен» буынтыклап Б. сабына бәйләп куйганнар. Тамгалар металл очлыклар, ярымай, шар һ.б. рәвешләрдә булган.



1. «Чыңгыз хан штандарты»; 2. Җучи Олысы бунчугы.

**БУРА́-КИРТӘ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 37 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зичә елгасы буенда. 2002 елда 345 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1678 елдан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, агач эшкәртү, кышын олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Б.-К. дә мәчет һәм мәктәп була. 20 йөз башында 2 мәчет, ир балалар өчен — 2, кыз балалар өчен 1 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1695 *дис.* тәшкил итә. 1920 елларның 2 нче яртысында халыкның бер өлеше яңа җиргә күчеп килә һәм Алмалы авылына нигез сала. Күмәкләштерү елларында авылда «Кызыл Шәрекъ» к-зы оештырыла, 1958 дә ул «Якты Йолдыз» к-зы составына керә. 1991 дә Б.-К. һәм Алмалы авыллары бергә кушылып, «Таң» хуҗалыгын (1998 дән — а.х. товарлары җитештерү кооперативы) оештыралар. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1795 тә — 97 ир заты; 1859 да — 498, 1897 дә — 963, 1913 тә — 1317, 1926 да — 878, 1938 дә — 802, 1949 да — 714, 1958 дә — 683, 1970 тә — 741, 1979 да — 609, 1989 да — 415 кеше.

**БУРАКО́ВО** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 62 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Актай елгасы буенда. 2002 елда 73 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөз башында нигез салына. Революциягә кадәрге чыганакларда Богородский, Актай исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Мәрьям ана чиркәве (1839–51 дә төзелә), земство мәктәбе, 2 тимерчелек, 4 тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли; һәр елның 8 июнендә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 436,7 *дис.* тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Спас өязе Николо-Пичкас волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1859 да — 795, 1897 дә — 1135, 1908 дә — 1161, 1920 дә — 1180, 1926 да — 958, 1938 дә — 534, 1949 да — 435, 1958 дә — 398, 1970 тә — 266, 1979 да — 178, 1989 да — 116 кеше.

**БУРАКО́ВО КАБЕРЛЕГЕ́** (Коминтерн каберлеге), 7 йөзгә нисбәтле археологик истәлек. Спас р-ны Бураково авылы янында урнашкан. *Коминтерн комплексына* керә. Каманың сулъяк кушылдыгы Актай елгасының түбән агымында булганлыктан Куйбышев сусаклагычы сулары б-н юылган. 1985 елда ачыла. Яр буенда тимер кылычлар, пычаклар, ук очлыклары, авызлык, өзәңге, тимер һәм бронза аеллар, ш.у бил каешының алтыннан коелган тегелмәләре, фирүзә б-н бизәлгән тагылмалар; алтын, көмеш, бронзага асылташлар куелган каеш очлыклары табыла. Әйберләр б-н бергә кеше һәм ат сөякләре дә очрый. Е.П.*Казаков* б-н П.Н.*Старостин* фикеренчә, Б.к. комплексы әйберләре Көнчыгыштан килгән күчмә кабиләләргә карый. Аларның Көнчыгыш Европаның дала һәм урман-дала зонасына нисбәтле 7–8 йөз башы истәлекләре б-н охшашлыгы бар.

*Әд.:* М у х а м е т ш и н а А.С. Коминтерновский курган: Проблемы атрибуции и датировки // Болгар и проблемы изучения древностей Урало-Поволжья. Болгар, 1999.

*П.Н.Старостин.*

**БУРАЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәлләнең сул кушылдыгы (Ык елгасы бассейны). Озынлыгы 9,8 *км*, бассейнының мәйданы 34,1 *км*². Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Буралы авылыннан 4,4 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Чуар Абдул авылыннан көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 195 *м*, тамагыныкы — 107 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 65%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,25 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Югары агымында елга кибә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,04 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында күләме 0,7 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БУРАЛЫ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Буралы елгасы буенда. 2002 елда 380 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1680 *дис.* тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1897 дә — 857, 1926 да — 778, 1938 дә — 805, 1949 да — 716, 1958 дә — 660, 1970 тә — 729, 1979 да — 480, 1989 да — 294 кеше.

**БУРАЛЫ́ КУРГА́Н КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), бронза гасырда (якынча б.э.к. 2 нче меңьеллык уртасы) Көнчыгыш Европаның далалы һәм урман-далалы төбәкләрендә (Днепрдан Урал буйларына кадәр) яшәүчеләргә нисбәтле археол. культура. Атама җирләү йоласы үзенчәлекләре буенча, каберләрне буралы итеп ясау сәбәпле бирелә. Беренче тапкыр 20 йөз башында В.А.Городцов тарафыннан тасвирлана. Б.к.к. истәлекләре 1960–90 елларда А.Х.Халиков, Е.П.Казаков, Г.Т.Обыденнова, П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан тикшерелә.

Татарстан терр-ясендә 500 дән артык Б.к.к. истәлекләре табылган, алар, башлыча, Чулман аръягында һәм Идел алдының көньягында (ш.и. Актаныш р-ның Такталачык авылы, Чаллы шәһәре, элекке Түбән Мәрҗән авылы янындагы каберлекләр) урнашкан. Б.к.к. истәлекләре торулыклардан, каберлекләрдән һ. б. дан гыйбарәт. Б.к.к. халкы җиргә казып салынган нигезгә корылган агач йортларда яшәгән, терлекчелек, аучылык б-н шөгыльләнгән, атлар, мөгезле эре һәм вак терлек үрчеткән. Балчыктан ясалган савыт-саба өслегендәге пиктографик уелма тамгалардан күренгәнчә, Б.к.к. кабиләләренең иң гади дәрәҗәдәге язу б-н таныш булулары ихтимал. Аларда бронзадан һәм таштан төрле әйберләр ясау үсеш алган (балталар, хәнҗәр, сөңге һәм ук очлыклары, бизәнү әйберләре һ.б. табыла). Балчык савыт-саба : чүлмәкләр һәм банкалар рәвешендәге, тарак теше сыман, сызыкча һәм төрткеле бизәкләр төшерелгән, кулдан әвәләнгән яссы төпле савытлар. Каберләр өстенә курганнар өелгән. Мәетне, башын төньякка юнәлдереп, махсус бура эченә бөгәрләнгән килеш сул ягы б-н урнаштырганнар. Терсәктән бөгелгән кулларының бармаклары йөзенә каратып куелган, янында бер яки берничә савыт урын алган. Фараз ителүенчә, Б.к.к. һинд-европа (һинд-иран) кабиләләре тарафыннан калдырылган.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987; О б ы д е н н о в М.Ф., О б ы д е н н о в а Г.Т. Северо-восточная периферия срубной культурно-исторической общности. Самара, 1991; К а з а к о в Е.П. Набережно-Челнинский могильник // Отчёт Ниж-

некамской археологической экспедиции. М., 1972. Вып. 1; Очерки по археологии Татарстана. К., 2001.
*Е.П.Казаков.*

**БУРАЛЫ́ ЧИШМӘ́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 27 *км* көньяктарак, Салкынсу елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 93 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1924–26 да Күтәмәле авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Уфа губернасының Минзәлә өязе Кармалы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 елның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1926 да — 140, 1949 да — 224, 1958 дә — 211, 1970 тә — 257, 1979 да — 149, 1989 да — 86 кеше.

**БУРА́Н**, атмосфера күренеше; карның җир өстеннән җил б-н себерелүе. Җәяүле Б. вакытында яңа яуган кар бөртекләре кар капламы өстеннән 1,5–2 *м* га кадәр җиңелчә күтәрелә; астан себерә торган Б. вакытында — җил тизлеге көчле һәм кар бөртекләренең 2–3 *м* га кадәр күтәрелүе күзәтелә; гомуми Б. вакытында көчле җил исә (гадәттә, 10 *м/с* тан артыграк), кар ява һәм күрү ераклыгы начарлана (кайвакыт 100 *м* га кадәр һәм кимрәк). Һава темп-расы түбән (–15 °С тан түбән) булганда, көчле Б. кар Б. дип атыйлар. ТРда кышка хас күренеш. Октябрь аеннан апрельгә кадәрге чорда (урыны б-н сирәк кенә сентябрьдә һәм майда) күзәтелә һәм уртача 24 көннән алып (Алабуга) 58 көнгә кадәр (Бөгелмә) була. Аларның күп өлеше декабрь-март айларына туры килә — аена 6–13 көн. Бер Б.ның уртача дәвамлылыгы 7–8 сәгать, гомуми дәвамлылыгы 151 сәгатьтән (Алабуга) 345 сәгатькә кадәр (Тәтеш) тәшкил итә. Б. вакытында горизонтның көньяк чиреге җилләре өстенлек итә (70–80% очракта). 80% тан күбрәк очраклар 0 дән алып –15 °С ка кадәр темп-рада күзәтелә. Б. юлларда кар көртләре хасил итә, электр үткәргечләренең егәрлеген киметә, чыбыкларын өзә, басулардагы карны себереп чокырларга тутыра. Б. вакытында кырдан кар себертүне булдырмау өчен урман полосалары утырталар, кар өемен өстенлек иткән җилләр юнәлешенә аркылы итеп киртләү юлы б-н кар тоталар.
*М.А.Верещагин.*

**БУРА́ШЕВ** Габделгазиз (Габделгазый, Әбелгазый) Туктамыш улы (18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөзнең 1 нче яртысы), беренче татар наширләре һәм китап басу осталарыннан. Отставкадагы прапорщик. Петербург ФАнең «Азия басмаханәсе» нигезендә Казанда ачылган шул исемдәге басмаханәне җиһазлау эшләренә җитәкчелек итә, соңыннан шунда татар китапларының нашире була. Цензура рөхсәтеннән башка нәшер иткән бер китабы өчен 1805 елда наширлек эшеннән читләштерелә. Шуннан соңгы язмышы билгесез. Ш.у.к. «*Азия басмаханәсе*».

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги: От начала возникновения до 60-х годов XIX века. К., 1971; ш у л у к. Книги и люди. К., 1985.

**БУРБИЕ́Л** Густав (Burbiel Gustav) (1912, Германия), тел галиме, филол. фән. д-ры, проф. (1963). «Төрки телләр» белгечлеге буенча Берлин югары лингвистика мәктәбен тәмамлый. 1940 еллардан Канадада, аннан соң АКШта (Нью-Йорк). 1960 еллардан Колумбия ун-тында татар теле укыта. Хәзерге татар теле фонологиясенең һәм грамматикасының барлык бүлекләрен үз эченә алган, инглиз телендә язылган татар грамматикасы китабы авторы.

Х е з м.: Tatar Grammar. A Grammar of the Contemporary Tatar Literary Language by Gustav Burbiel. Stockh., 2001.

*Әд.:* Х и с а м о в а В. Инглиз телендә хәзерге татар грамматикасы // Мәгърифәт. 2001. 8 сент.
*Х.Р.Курбатов.*

**БУРГСДО́РФ** Владимир Фёдорович (17.05.1864, Түбән Новгород губ. Лысково а. — 23.04.1935, Казан), дерматовенеролог, медицина д-ры (1902). 1888 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1907–27 дә дерматовенерология каф. проф. һәм мөдире. 1900 дә яктылык б-н дәвалау буенча Россиядә икенче кабинет оештыра, беренче мәртәбә Девержи авыруы — көрпәсыман кызыл тимрәүнең клиникасын тасвирлый. Аның инициативасы б-н кафедрада бактериологик һәм гистологик тикшеренүләр үткәрү өчен клиник лаб. булдырыла. Рәссам һәм скульптор Э.Э.Спориус б-н берлектә Идел буе югары уку йортлары кафедраларын муляжлар б-н тәэмин итү остаханәсен оештыра.

Х е з м.: К вопросу об ангиопатии кожи // Врач. 1894. № 34; Болезнь Девержи. К., 1902; Целебные и вредоносные силы света. К., 1902.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989.

**БУРДО́В** Андрей Николаевич (15.06.1961, Казан), спортчы (авиамодель спорты), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1982.) Казан авиация ин-тын тәмамлый (1985). Россия (1987–89, 1991), СССР (1988), Европа (1994), дөнья (1995, 1999) чемпионы. Беренче бөтендөнья һава уеннарында көмеш медаль ала (1997), СССР, Россия кубокларына үткәрелгән ярышларда, Дөнья кубогы этапларында шәхси һәм команда беренчелегендә күп тапкырлар алдынгы урыннарны ала. 1985 елдан Казан техник ун-тында инженер. Шәкертләре арасында Европа (1992, 1994) һәм дөнья (1995, 1999) чемпионы А.Д.Хребтов бар. Дөнья кубогына ярышларда халыкара жюри составында судьялык итүдә катнаша (Бельгия, 1999). 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены б-н бүләкләнә.

**«БУРЕВЕ́СТНИК»**, югары уку йортлары укытучылары һәм студентларының ирекле спорт җәмгыяте, 1957 елда Казанда оештырыла. 1987 дә «Б.» «Зенит», «Спартак», «Труд», «Урожай», «Локомотив» ирекле спорт җәмгыятьләре б-н берләшә (к. *Профсоюзлар физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан республика советы*). «Б.» бу вакытта респ-каның 13 югары уку йортын берләштерә. Спорт базасын 23 спорт залы, 50 спорт мәйданы, 8 чаңгы базасы, 7 тир, 8 спорт-сәламәтләндерү лагере тәшкил итә. Акробатика, җиңел атлетика, баскетбол, волейбол, футбол, чаңгыда узышу, өстәл теннисы, спорт гимнастикасы, нәфис гимнастика, ориентлашу спорты, авыр атлетика, фехтование, велосипед спорты үсеш ала. «Б.»та 1 атказ. спорт остасы, 5 халыкара класслы спорт остасы, 302 СССРның спорт остасы әзерләнә. Танылган спортчылар: Н.С.Зубрилова, К.Х.Мохтаров (җиңел атлетика), Ю.Дулатов, В.Стенин (акробатика), Э.И.Гыймадетдинов (тимераякта йөгерү), А.В.Волгушев (велосипед спорты), А.П.*Курынов*, В.М.*Шадрин*, О.М.*Рукавишникова*, Р.З.*Бакыев*. Иң яхшы тренерлар: Л.Ф.*Арсланов* (баскетбол), Д.А.*Вашш* (фехтование), Ю.Ф.Золотов, С.Ә.Нәфиков (чаңгыда узышу). Ю.М.*Красильников*, Х.М.*Мортазин* (җиңел атлетика), В.А.*Павлов* (авыр атлетика), И.П.*Позняк* (баскетбол), М.Л.Шалман (фехтование), Б.И.*Якубчик* (акробатика).

**БУРЕ́ЙКИНО НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, Нурлат р-ны терр-ясендә, Нурлат шәһәреннән 7 *км* төньяк-көнчыгышта. 1969 елда ачыла, 1979 дан эшкәртелә. Тектоник яктан Мәләкәс батынкылыгының көнчыгыш кырыена туры килә. Сәнәгый нефть ятмалары урта (Башкорт ярусы, Мәскәү ярусының Кашира һәм Верея горизонтлары) һәм түбән карбон (Турне ярусы һәм Визе ярусының Бобрики горизонты) утырмаларында. Төп файдаланучы объект булып Бобрики горизонты утырмалары тора, 1982 дән контур эченә һәм контур тирәли су кудыру ысулы б-н эшкәртелә. Геологик запаслары 42,7 млн. *т*, алына торганнары — 8,7 млн. *т* (1989). Ятмалар гөмбәзсыман катлам һәм массив тибында, коллекторлары — көпшәкле типта. Катламнар 943–1377 *м* тирәнлектә, нефтькә туенган катламның калынлыгы 3,6–7,4 *м*, нефтькә туенганлык коэф-ты 0,66–0,91, үткәрүчәнлеге 0,136–0,694 *мкм*². Пластның башлангыч басымы 10,4–14,7 *МПа*. Б.н.ч. нефтьләре авыр, үзле, күп күкертле, сумалалы, парафинлы. Уртача тәүлеклек дебиты 6,3 *т*. Нефть чыгарылыш коэф-ты 0,096. Еллык иң күп нефть чыгышы 0,32 млн. *т* (1996), 1999 да — 0,26 млн. *т* чамасы. 2000 нең 1 нче гыйнварына 3,28 млн. *т* нефть алынган.
*А.Х.Хәсәншина.*

**«БУРЖУА́З МИЛЛӘТЧЕЛӘРНЕ́Ң СОВЕ́Т ХАКИМИЯТЕНӘ́ КАРШЫ́ ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́**, 1937–40 елларда РСФСР һәм ТАССР НКВДлары тарафыннан оештырылган гаепләү эше. Совет хакимиятенә каршы эш алып бару, ул урнаштырган тәртипне үзгәртү өчен буржуаз милләтчеләр оештырган төркем әгъзалары дип табылган 47 кеше җавапка тартыла. Мәскәүдә 1940 ның 28 февраль һәм 27 июлендә узган мәхкәмә утырышларында Г.Ш.Габдерәхимов, А.Г.Һадиев, А.В. һәм Ә.В.Гариповлар, Г.А.Мөхәммәтҗанов, А.Г.Мөхәммәтов, К.М.Рахманкулов, Ф.Н.Солтанбәков, Г.А.Госманов, Г.Ш.Шәрәф 8 әр елга, Г.К.Зиннуров 3 елга хезмәт б-н тәрбияләү лагерена, Ә.Р.Мостафин 5 елга Красноярск краена сөргенгә хөкем ителә. РСФСР Югары мәхкәмәсенең 1989 елгы 7 июнь утырышында 1940 та Мәскәүдә кабул

ителгән мәхкәмә карары юкка чыгарыла, гаепләнүчеләрнең күпчелеге аклана.

**БУРЖУАЗИ́Я**, капитал иялəренең иҗтимагый сыйныфы, сәүдә, сәнәгать, финанс-кредит һәм башка эшмәкәрлек эшчәнлегеннән алынган зур керемнәр хисабына яши. Россиядә башлангыч капитал туплау 18 йөз — 19 йөз башларына туры килә. Ләкин илдә яшәгән крепостнойлык тәртибе Россия Б.сенә колач җәяргә комачаулый. Россиядә Б.нең иң беренче вәкилләре 18 йөздә зур байлык тупларга өлгергән сәүдәгәрләр катлавыннан чыга. Алар керемнәренең бер өлешен көн әйберләр җитештерү, постау туку, сабын, сыра кайнату, аяк киемнәре тегү, аракы-спирт куу завод-фабрикалары ачуга тота башлыйлар. 1780 елларда Казанда шундый 87 җитештерү оешмасы теркәлгән, шуларның 45 енә татарлар, 42 сенә руслар хуҗа була. Иң эре пр-тиеләр исәбендә сәүдәгәрләр И.Кожевников, П.Шапшинский, А.Муравьёв һәм мещаннардан И.Чечулин, В.Черновларның күн эшкәртү мануфактуралары, сәүдәгәрләрдән П.Шварёв, М.Шингарёв, М.Давыдов, Л.Крупенниковның сабын кайнату з-длары була. Фәкать җитештерү өлкәсендә генә эшләүче Б. вәкилләре дә баштарак сәүдәгәрләр гильдиясендә тора, сәүдәгәр исәпләнә. 1785 елдан алар «мактаулы гражданнар» исемлегендә теркәлгән. Вак буржуазия катлавын, башлыча, мещаннар б-н һөнәрчеләр тәшкил иткән. 18 йөз ахырындагы эре Б. катлавына сәүдәгәр һәм эшмәкәрләр И.Михляев, Г.Каменев, А.Иноземцев, А.Кобелев, В.Чернов һ.б. кергән. Императрица Екатерина II фәрманы б-н бу елларда *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы* (1781) һәм *Шәһәр думасы* (1785) барлыкка китерелә. Җирле Б. көч-куәте һәм милләте ягыннан төрле була. Төбәкнең төп капиталы рус Б.се кулында булып, сәүдәдә һәм җитештерү өлкәсендә алар беренче урында тора. 19 йөз башыннан Б. арасында шәһәр мещаннары б-н крәстияннәр дә эшмәкәрлеккә актив тартыла башлый. 1819 да Казанда 232 җитештерү оешмасы эшли, шуларның 87 сенә сәүдәгәрләр, 96 сына мещаннар, 22 сенә крәстияннәр, 19 ына һөнәрчеләр һәм 8 енә башка катлау кешеләре хуҗа була. Җитештерү тармагында тора-бара сәүдәгәрләр саны кими, эшмәкәрләр саны арта. 19 йөздә эре промышленниклардан И.И.Алафузов (еллык капитал әйләнеше 0,5 млн. сум), бертуган *Крестовниковлар* (капитал әйләнеше 2 млн. сум), П.К.Ушков, А.Н.Свешников һ.б. Б. вәкилләре мәгълүм. Алар катнашында Казанда 19 йөзнең 2 нче яртысында эре җитештерү-сәүдә ширкәтләре барлыкка килә («Общество Алафузовских фабрик и заводов», «Товарищество бр.Крестовников», «Наследники Д.И.Вараксина» һ.б.). Сәүдәгәрдән һәм кулаклардан чыккан, урта сәнәгать һәм сәүдә пр-тиеләре хуҗалары булган Б. вәкилләре аерым төркемне тәшкил иткән (Журавлёвлар, Романовлар, Савиннар, Шамовлар һ.б.). Вак Б. катлавына, башлыча, крәстиян-кулаклар һәм вак һөнәрчеләр кергән. 1880 еллар башында рус авылларында андыйлар — 12%, татар авылларында 5,3% тәшкил иткән. Шәһәрләрдә татар Б.се кечерәк куәтле туку, ману, күн эшкәртү, мех әйберләр җитештерү кебек завод-фабрикаларга хуҗа була. Тулаем Россиядәге хәл б-н чагыштырганда Казан губернасында Б. үсеше әкренрәк темпта бара. Татар Б.се эшчәнлеге дәүләт тарафыннан чикләнгән булганлыктан, алар, нигездә, сату-алу эшенә күбрәк әһәмият биргәннәр. 19 йөзнең 2 нче яртысында Казанда бер-бер артлы берничә банк ачыла, финанс эшчәнлеге буенча шәһәр Россиянең көнчыгышындагы эре үзәккә әйләнә. Мәс., 1914 елның 1 гыйнварына шәһәр банклары 30 млн. сум бурычка (кредитка) акча бирәләр. Финанс-банк өлкәсендә танылган Б. вәкилләреннән А.С.Александров, М.И.Попов, Я.Д.Соколовларны билгеләп була. Б.нең төп капиталы пр-тиеләрдә эшләүчеләрнең социаль-сәяси хокуксызлыгы нәтиҗәсендә туплана. 1870 елларга кадәр кешеләрнең ничәшәр сәгать эшләргә тиешлеге дә кануни рәвештә билгеләнмәгән була; балалар һәм хатын-кызлар да ирләр б-н бер дәрәҗәдә эшли. Дөрес, Б. вәкилләре керемнәренең бераз өлешен төрле хәйрия җәмгыятьләренә, уку-укыту өлкәсенә, рухият оешмаларына иганә итеп бирәләр. Татар Б.се милли мәгарифне үстерүдә актив булса, рус Б.се һөнәри белем бирү йортларына күбрәк игътибар итә. Б. вакытлы матбугатны да финанслый (к. «*Казанский биржевой листок*» г-тасы, «*Икътисад*» ж-лы һ.б.). Б.нең үз таләп-ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында төрле җәмгыять-клублар оештырыла. Мәс., 19 йөз башыннан Казанда сәүдәгәрләр җыены, 1866 дан *Сәүдәгәрләр биржасы*, 1869 дан Рус сәнәгатенә һәм сәүдәсенә булышлык итү җәмгыяте эшли. Б.нең социаль-икътисади хәле һәм милләтләре төрле булган кебек, сәяси карашлары да бертөрле генә булмаган. Чикләнмәгән монархия тәртипләрен хуплаучылар б-н беррәттән демократик респ-ка идарәчелегенә өстенлек бирүчеләр дә булган. Милләт язмышына карата да бердәмлек булмый. «Бердәм һәм бүленмәс Россия» шигаренә турылыклылар да, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын яклаучылар да табыла. Җиргә кем хуҗа булырга тиеш дигән сорауга да җаваплар капма-каршы була: җир алпавытлар кулында булырга тиеш диючеләр дә, аны кем эшкәртә, шуның кулында булырга тиеш диючеләр дә була. 1905–07 дәге революцион хәрәкәт барышында Казанда Б. вәкилләре берничә сәяси партия төзи: «*17 октябрь берлеге*», «*Конституцион-демократлар партиясе*» (кадетлар), «*Иттифакъ әл-мөслимин*» һ.б. 17 октябрь Манифесты игълан ителгәч (1905), Б. үз вәкилләрен Дәүләт думасына сайлап, үзенә кирәкле канунннар чыгаруга ирешә. Ә 1917 елгы Февр. рев-циясе нәтиҗәсендә Б., социалистик партияләр б-н берлектә, ил б-н идарә итү вазифасын үз өстенә ала. Окт. рев-циясеннән соң Б. мәҗбүри рәвештә андый хокуклардан, мөлкәтеннән мәхрүм ителә һәм яшәүдән туктый. Халыкның көндәлек кирәк-яракка булган ихтыяҗын канәгатьләндерүне истә тотып, Совет хакимияте 1921 елның 17 маенда бик эре булмаган җитештерү пр-тиеләрен өлешчә кабат шәхси кулларга кайтарып бирү турында карар кабул итә — *Яңа икътисади сәясәт* кертелә. Ә 1921 ел 24 май декреты б-н сәүдә эшчәнлегенә дә рөхсәт бирелә. Шул рәвешле Россия Б. яңадан үз дәрәҗәсен торгызуга керешә. Әмма Б. өчен мондый иркенлек озакка бармый. Сәнәгать тармагында тизләтелгән индустриализацияләүгә һәм а.х. тармагында күмәкләштерүгә таба җитди борылыш ясала. Хөкүмәт Яңа икътисади сәясәтне тиз туктата, илдә кулакларга һәм хосусый милеккә каршы көрәш башлана. 1930 еллар урталарына СССРда Б. сыйныф буларак бөтенләй юкка чыгарыла.

**Татар буржуазиясе**, сәяси-икътисади чикләүләр булу сәбәпле, соңрак оеша, 19–20 йөзләр чигендә тәмам ныгып җитә. Идел буе Болгар дәүләте б-н Казан ханлыгы дәверләреннән башлап җирле сәүдәгәрләрнең икътисади үсешкә йогынтысы зур була. Беренче сәүдә-сәнәгать катлавы *йомышлы татарлардан* тора, 18 йөзнең 2 нче яртысында Екатерина II аларга Россия киңлегендә эш йөртергә ирек бирә (1776). Татар сәүдә капиталының активлаша баруы 19 йөз ахырларында татар Б.сен барлыкка китерә. 1782 елгы фәрман нигезендә татарларга (һ.б. милли азчылык вәкилләренә), үз капиталларын яшермичә күрсәтеп, сәүдәгәр яки *мещаннар* катлавына язылу хокукы бирелә. Үз дәүләтчелеге булмаган, элегрәк чикләнгән шартларда эшләргә мәҗбүр ителгән, төрле милли һәм дини изүне үз шәхесендә татыган татар сәүдәгәр һәм эшмәкәрләренә чынлап торып аякка басу, капитал туплау рус сәүдәгәрләре б-н чагыштырганда гаять авыр бирелә. Рус сәүдәгәр һәм эшмәкәрләренә исә патша хөкүмәте икътисади һәм сәяси җәһәттән һәрдаим булышып тора. Ә татарларга кайбер төр товар б-н сәүдә итү, металлургиягә бәйле пр-тие тоту, Россиянең үзәк өлешендә сәүдә итү тыелган була. Сәүдәне империянең читтәгерәк өлкәләрендә генә алып бару һәм күчемсез милекне Урта Азиядә генә сатып алу мөмкинлеге бирелә. 1776 дан соң ул чикләүләр бетерелә. Керәшен татарларга карата кайбер ташламалар элегрәк тә каралган була. Татарстан җирендә 17 йөздә беренче сәнәгать пр-тиесен дә керәшен татары ача — Кама елгасы буендагы Мурзиха бистәсендә 1643 тә сәүдәгәр Тумашев металлургия мануфактурасына нигез сала. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында татар Б.се вәкилләре 100 дән артык завод һәм фабрикага ия булалар. С.Борнаев, С.Назыйров, М.Таһиров, М.Үтәмишевләрнең комач мануфактуралары; М.Габбасов, И.Галиев, А.Галанскийның күн иләү; А.Гомәров, Б.Субаев, М.Хәлфиннең сабын кайнату з-длары эшли. Тимергә бәйле эш башлау яки тимерчелек б-н шөгыльләнү чукынган татарларга гына рөхсәт ителгән була. Татарларның җитештерү өлкәсендә төп эшмәкәрлек мәйданы тире иләү, күн эшкәртү, тукыма туку, сабын кайнату, бәзману, постау туку б-н билгеләнгән. 18 йөзнең урталарыннан татарларга Шәрекъ дәүләтләре б-н сәүдә итәргә рөхсәт бирелә (к. *Ташкент кәрваны*). Татар Б.се Россиянең Шәрекъ илләре б-н сәүдә багланышларын башлап җибәрүдә мөһим роль уйный. 19 йөздән башлап татар сәүдәгәрләре сафы, «*чабаталы морзалар*»дан тыш, крәстияннәр һәм һөнәрчеләр исәбенә дә тулылана. 1890 елларда Казанда 30 сабын кайнату з-дының

19 ына, 39 күн з-дының 20 сенә татарлар хуҗа була. 18 йөздә татар Б.се, башлыча, Казан губернасында гына эш йөртсә, 19 йөздә алар башка төбәкләрдә дә эшли башлый. Мәс., Самара губернасында Алиевлар, Сембер губернасында *Акчуриннар*, Саратов губернасында *Дибердиевләрнең* постау ф-калары, Вятка губернасында *Үтәмишевләрнең* туку ф-касы, Оренбург губернасында *Рәмиевләрнең* алтын чыгару прискалары. 19 йөзнең 1 нче яртысында эре сәнәгать пр-тиеләре эшендә катнашу мөмкинлеге туа башлый. Мәс., сәүдәгәрләр Х.Юнысов, Б.Якупов, Т.Якупов, Ж.Жәдгәров 500 меңнән алып 3 млн. сумга кадәр капитал б-н эш итәләр. 1860 елгы реформадан соң татарларның эшмәкәрлек эшчәнлеген киңәйтүгә яңа мөмкинлекләр туа. 1890 елда Россиянең Европа өлешендә татар Б.се исәбенә эшләүче 76 сәнәгать пр-тиесе теркәлгән, аларның еллык кереме 2 мең сумнан да ким булмаган. Бу елларда татар Б.се капиталы Казакъстан, Кытай, Төркестан җирләренә үтеп керә башлый. Гасыр ахырында Идел буенда 43, Урал төбәгендә 47, Урта Азиядә 19, Казакъстан биләмәсендә 18, Үзәк Россиядә 8, Кавказда 6 пр-тиенең хуҗасы татар була. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында эре сәүдә-сәнәгать ширкәтләре барлыкка килә: «Әхмәтҗан Сәйдәшев, уллары һәм Бакый Субаев» (1895), «Дибердиев һәм бертуганнары» (1897) ширкәтләре һ.б. 1914 тә татар Б.се карамагында шундый 154 сәүдә-сәнәгать ширкәте исәпләнә (гомуми капиталы 4 млн 925 мең сум). Шулардан иң эреләре — «Садыйк Мусин варислары» ширкәте. Татарлар эреле-ваклы 141 җитештерү хуҗалыгына ия булалар, 72 сенең еллык җитештерү куәте 10 млн 342 мең сум тәшкил итә. 19 йөз ахырында җитештерү өлкәсендә эшләүчеләрнең капиталы банк капиталы б-н кушыла. Бертуган Акчуриннар, Дибердиевләр, Рәмиевләр, Яушевлар, Хөсәеновлар, Алиевлар, Сәйдәшевләр, Арслановлар, Үтәмишевләр шул чор татар Б.сенең танылган вәкилләре була. С.М.Аитов һәм С.С.Галикәев Казан сәүдәгәрләр банкы советы әгъзалары, Х.Х.Таһиров Казандагы 2 нче үзара кредитлашу җәмгыяте әгъзасы була. 1912 дә С.-Петербургта Мөселман банкы ачыла, ул милли сәүдә-сәнәгать буржуазиясе үсешенә ярдәм итә. 1897 елгы халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре күрсәткәнчә, татарлардан 250 кеше сәнәгать пр-тиесе хуҗасы була, 5300 кеше күчемсез милек һәм акча әйләнеше кереме исәбенә яшәгән, 2100 сәүдәгәр теркәлгән. 1880 елларда авыл халкының 5,3% ын вак татар Б.се тәшкил иткән. Крәстиян катлавыннан чыккан сәүдәгәр һәм сәнәгатьчеләр арасында Борнаевлар, Маматовлар, Хуҗасәетовлар, Баязитовлар, Вәлитовлар һ.б. үз капиталлары исәбенә сәүдә йортлары, завод-фабрикалар ачканнар. Татар Б.се мәчет, мәдрәсәләр ачуга һәм тотуга, газета-журналлар, китаплар нәшер итүгә, җәмәгать китапханәләре оештыруга һәм хәйрия җәмгыятьләренә үз керемнәреннән байтак өлеш чыгарган (к. *Иганәчелек*). Окт. рев-циясеннән соң татар Б.се дә, Россия буржуазиясе кебек үк, төп милкеннән мәхрүм ителә һәм юкка чыгарыла.

*Әд.:* Хасанов Х.Х. Формирование татарской буржуазной нации. К., 1977; История Казани. К., 1988. Кн. 1; Свердлова Л.М. На перекрёстках торговых путей. К., 1995; шул ук. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; Салихов Р., Хайрутдинов Р., Хайрутдинова Л. Очерки истории Национального банка Республики Татарстан. К., 2000; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимательства Татарстана: В 2 т. К., 2001; Салихов Р.Р. Татарская буржуазия Казани и национальные реформы во второй половине XIX — начале XX вв. К., 2001.

*Л.М.Айнетдинова, Р.В.Шәйдуллин.*

**БУРИ́ЛОВ** Александр Романович (20.4.1956, Казан), химик-органик, хим. фән. д-ры (2000). 1978 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1982 дән РФАнең Казан гыйльми үзәгенең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, 2001 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре элементорганик һәм супрамолекуляр химиягә карый. Гидрофосфорил кушылмаларның тиокетоннар б-н реакцияләрен өйрәнә, α-меркаптофосфонатларны синтезлый. α-Меркаптокарбонил кушылмаларның фосфорильләнү, силильләнү, станильләнү реакцияләрен өйрәнә, сызыкча һәм циклик, туендырылган һәм чиксез кремнийлы, аккургашлы органик кушылмаларын таба. Өч валентлы фосфор к-таларының тиоаллил һәм тиобензил рәтендәге тиофосфит-фосфонатлы яңадан төркемләнүне, тиогликоль к-тасының этил эфиры һәм α-меркаптокетоннарның кремнийорганик чыгарылмалары рәтендәге яңадан төркемләнүләрне ачыклый. Алдан билгеләнгән үзенчәлекле яңа тип структуралар булдыру максатыннан каликс[4]резорцинареннарны каликсарен матрицасының югары һәм түбәнге «кайма»сын органик һәм элементорганик төркемнәр б-н модификацияләү буенча эшли. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Фосфорилирование диалкиламинометилированных каликс [4] резорцинаренов гексаалкилтриамидофосфитами и дихлорангидридами кислот четырёхкоординированного атома фосфора // Журн. общей химии. 2003. Т. 3, вып. 6 (автордаш); Одноэлектронное окисление и нуклеофильность каликс[4]резорцинаренов // Изв. РАН. Сер. хим. 2003. № 5 (автордаш); Синтез пространственно затруднённых фенольных соединений на основе 3,5-ди-трет-бутил-4-гидроксибензилацетата // Журн. органич. химии. 2004. Т. 40 (автордаш).

**БУРКО́В** Василий Герасимович (17.4.1901, Вятка губ., Алабуга өязе Кураково а. (хәзерге Менделеев р-ны) — 13.12.1957, Ленинград), танк гаскәрләре генерал-лейтенанты (1941). Гражданнар сугышында укчы полк, 5 нче бронепоезд комиссары. Бөек Ватан сугышында танк дивизиясе командиры (1941), Курск сугышында һәм Днепрны кичүдәге батырлыклары б-н дан казанган 10 нчы танк корпусы командиры (аның сафына «Татарстан колхозчысы» танк колоннасы да керә). 1949 елдан Белоруссия хәрби округында механикалаштырылган армия командующие ярдәмчесе; 1952 дән — Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә. 1954–55 тә СССР Оборона министрлыгының Баш кадрлар идарәсендә. Ленин, дүрт Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**БУРЛА́Й** Алексей Петрович (29.7.1918, Украина Респ-касы, хәзерге Днепропетровск өлкәсе Арестополь а.), нәкышьче, график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). Молотов (Пермь) шәһәрендә эшли, эшеннән аерылмыйча сәнгать уч-щесендә укый (1938–40). Бөек Ватан сугышы елларында 3 нче Украина фронтының төзекләндерү батальоны командиры; оборона заводында конструктор һәм рәссам булып эшли, «ТАСС тәрәзәләре» («Окна ТАСС») плакатларын чыгара. 1948–62 елларда Казанда яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1950). Рәссамнар берлегенең нәкышь секциясе (1951–53), нәкышь һәм рәсем студиясе б-н (1954) җитәкчелек итә, Казан сәнгать уч-щесендә укыта (1950–53). 1962 дән Волгоград шәһәрендә яши. 1950 елларда нәкышь өлкәсендә тематик картина жанрын үстерүдә зур роль уйный. Иҗаты б-н Татарстан сәнгатендә соц. реализм алымының үсешенә өлеш кертә. Төп әсәрләре: «Н.С.Хрущёв Днепрогэсны торгызучылар арасында» (1950, Мәскәүдә узган Бөтенроссия күргәзмәсенең кызыксындыру премиясе), «Коммунизм төзелешендә байрак тапшыру» (1951, Мәскәүдә узган Бөтенроссия күргәзмәсенең мактаулы дипломы), «А.М.Горький һәм В.В.Стасов И.Е.Репин остаханәсендә» (1954), «Нефть разведчиклары» (1957), «Нефть чыга башлады» (1953), «Туган җир (Сов. Союзы Герое М.П.Девятаев батырлыгы)» (1961). 1952 дә «Советская Татария» г-тасы өчен хезмәт алдынгылары портретлары сериясен яза: «Надежда Асафова — фанера фабрикасы бригадиры», «1 нче ТЭЦның данлыклы кочегары Әхмәтҗанов», «Ленин исем. күн заводы пресслаучысы С.Хәмидуллина» һ.б. «Шәһәр хезмәтчәннәренә — бәрәңге һәм яшелчәләрне күбрәк!», «Терлекчелек җитештерүчәнлеген югарырак күтәрүгә ирешик!» һ.б. плакатлар авторы. Запорожье шәһәрендә узган күргәзмәләрдә (1947 дән), бөтенсоюз, бөтенроссия («Совет Россиясе»), төбәкара («Зур Идел») һәм ТАССР рәссамнарының респ-ка күргәзмәләрендә катнаша (1950 еллар). Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1960). Әсәр-

А.П.Бурлай. «Нефть чыга башлады». 1959. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



ләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Е л ь к о в и ч Л.Я. Бурлай: Буклет. Л., 1961; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1972. Т. 2.

**БУРЛАКЛА́Р** (төрки-татарча «буйдак» сүзенә нисбәтле атама), 16–19 йөзләрдә Россиядә бау-арканнар ярдәмендә корабларны елгалар буйлап тартып йөрү өчен ялланган эшчеләр. Көймә-корабларда механик йөртү көче кулланылмаган чорга хас ысул. Корабны озата барырга ялланган Б. йөкне төяү-бушатуда, җилкәннәр тегүдә һ.б. эшләрдә катнашырга тиеш булган. Кирәк урында көймә-корабны ишкәк ишеп, яки җилкән куеп та йөртергә тиеш булганнар. Б. эшкә аерым артельләргә берләшеп ялланганнар (артельдә 4–6, кайвакыт 10 нан алып 40 ка кадәр кеше булган). Аерым вак артельләр 150 ләп кешедән торган зур артельне тәшкил иткән. Кабул ителгән йөк һәм артель өчен җавап бирүче өлкән кеше (водолив) һәм елгада юл йөрү тәртибен яхшы белүче кеше (лоцман) йөк хуҗасы тарафыннан аерым ялланган. Йөк тартучы Б. төрле вазифаларны башкару өчен үз араларыннан әйдәп баручыны һәм җыр башлаучыны, иң арткы сафта баручы, кирәккәндә бау-аркан торышын күзәтүчеләрне, азык-төлек б-н тәэмин итүче артельчене, үз унлыгына кергән кешеләргә савыт-саба әзерләүчене билгеләгәннәр. Б. эшенә, гадәттә, дәүләт һәм алпавыт крәстияннәре, солдат хезмәтеннән кайткан кешеләр ялланган. Казан губернасында Б.ның күпләп теркәлү урыннары Идел буенда — Чабаксар, Цивильск, Зөя, Лаеш, Спас, Тәтеш өязләре һәм Кама-Чулман буенда Чистай б-н Мамадыш өязләре була. Бу төбәктә эшләүче Б.ның елгада хәрәкәт барган сезон дәвамында җәйлек эш хакы 17 йөздә — 16 сумга кадәр, 18 йөздә — 40 сумга кадәр һәм 19 йөздә 80 сум чамасы булган. Б.га эш хакын көз көне, хәрәкәт туктагач кына түләгәннәр. 1851 елда Казанда — 14925 кеше, Лаешта — 5672, Чабаксарда — 5503, Мамадышта 2815 кеше Б. артелендә теркәлгән. 19 йөздә пароходлар төзелеше үсеш алу б-н Б.га ихтыяҗ калмый.

*Әд.:* Г е с с е н Ю. Бурлаки в первой половине 19 в. // Архив истории труда России. П., 1921. Кн. 2; А р х а н г е л ь с к и й С.И. Очерки по истории промышленного пролетариата Нижнего Новгорода и Нижегородской области XVII–XIX вв. Г., 1950.

*В.А.Шагалов.*

**БУРЛЮ́К** Давид Давидович (9.7.1882, Харьков губ. Семиротовщина хуторы — 15.1.1967, Лонг-Айленд, АКШ), рәссам, әдәбиятчы, нашир. Рәсем сәнгатендә беренче күнекмәләрне рәссамнар А.К.Вениг һәм А.И.Рощина — Колесовадан ала. Казан (1899–1900, 1901–02) һәм Одесса (1900–01) сәнгать мәктәпләрендә, Мюнхен Король академиясендә (1902–03), Парижда Ф.Кормон остаханәсендә (1904), Мәскәү нәкышь, сын һәм архит-ра уч-щесендә (1911–14) укый. Әдәбият-сәнгать авангарды лидерларының берсе, 20 йөз башында академик юнәлештә булмаган һәм авангард хасиятендәге күргәзмәләр оештыра һәм аларда катнаша; күпсанлы манифестлар, мәкаләләр, җыентыклар, футуристик альманахлар авторы, бизәүчесе һәм нашире («Ярсынган Парнас» («Рыкающий Парнас», 1913); «Өчәүнең догалыгы» («Требник троих», 1913); «Дөньядагы бердәнбер футуристларның җыентыгы» («Сборник единственных футуристов в мире», 1914); «Шау-шулы «бенуа»лар һәм яңа рус милли сәнгате» («Галдящие «бенуа» и новое русское национальное искусство», 1913) һ.б. 1915 елдан «Беренче футуристик журнал» («Первый футуристический журнал») мөхәррире. Күп кенә иҗади берләшмәләр («Яшьләр берлеге» — «Союз молодежи», «Буби валеты» — «Бубновый валет» һ.б.) әгъзасы, футуристларның «Будетляне» төркемен оештыручыларның берсе (1910). 1913–14 елларда, футуризмны сәнгатьнең яңа юнәлеше буларак пропагандалап, В.В.Маяковский һәм В.В.Каменский б-н Россия буйлап (Одесса, Тифлис, Симферополь, Кишинёв, Николаев, Киев, Ростов-Дон, Казан) сәяхәттә катнаша.



Д.Д. Бурлюк.



Д.Д. Б у р л ю к. «Кызыл өйлә вакыты». 1920 еллар. М.В. Нестеров исем. Башкорт дәүләт сәнгать музее.

1915–18 дә хатынының Иглино станциясе янындагы утарында (Уфа губ.) яши. Уфа сәнгать түгәрәге эшчәнлегендә актив катнаша, А.Э.Тюлькин, П.М.Лебедев, К.С.*Дәүләткилдиев* кебек рәссамнар б-н якыная. 150 гә якын әсәр авторы, алар арасында «Җиңүчеләр» (1916), «Татарлар» (1916), «Кызыл өйлә вакыты» (1917), «Татар кызчыгы» (1918), «Татар авылы» (1910 еллар) һ.б. бар. Бүздәк станциясе янындагы Каран Байраш, Түреш авылларында (Уфа губ.) эшли. 1922 дән АКШта. Актив рәвештә иҗат итә, күргәзмәләр оештыру, наширлек эшчәнлеге алып бара. «Color and Rhyme» («Төс һәм рифма»), «Рус рәссамнары Америкада» («Русские художники в Америке») ж-лларын чыгара, «Русский голос» дигән эшчеләр г-тасының баш мөхәррире була. Режиссёр Н.Евреинов, рәссамнар Н.Рерих, Н.*Фешин* (Б. аңа «Цвет и рифма» ж-лының бер санын багышлый), С.Сорин, С.Судейкин, Б.Григорьев, Б.Анисфельд, композитор һәм пианист Д.Тёмкин, сынчы А.Блазис, артист һәм режиссёр Л.Копелевич-Луга б-н якыннан аралаша. М.Горький һәм П.М.*Дульский* б-н хат алыша. Соңгысының үтенече буенча Казан рәссамы Н.Н.Ливанова, Уфа рәссамы А.Э.Тюлькин б-н берлектә үз тормышының Казан чоры турында «Сәнгать юлларында» («На путях искусства») дигән истәлекләрен яза («Голос Родины», май–июнь 1946, Нью-Йорк). 1956 да һәм 1965 тә СССРда була.

Б. әсәрләре Рус музеенда, Пермь сәнгать галереясында, Омск сынлы сәнгать музеенда, Иркутск сәнгать музеенда, Әрмәнстан картиналар галереясында, Ростов өлкә сынлы сәнгать музеенда, Куйбышев сәнгать музеенда, Уфа сәнгать музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, АКШта галереяларда һәм шәхси җыелмаларда саклана.

Х е з м.: Стихи, картины, автобиография. [Б. м.], 1924; Свирель собвея. [Б. м.], 1924; Энтелехизм. 20 лет футуризма. [Б. м.], 1930; Отец пролетарского футуризма. Поэт, художник, оратор, журналист. М., 1932; Воспоминания отца русского футуризма // Минувшее. 1991. Вып. 5.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. 1970. Т. 1; Давид Бурлюк. Фактура и цвет. Произведения Давида Бурлюка в музеях российской провинции: Каталог: В 2 кн. Уфа, 1994.

*Е.П.Ключевская.*

Д.Д. Б у р л ю к. 1. «Кичке авыл». 1917–1918. Омск сынлы сәнгать музее; 2. «Татар ишегалды». 1920 еллар. Башкорт дәүләт берләштерелгән музее.





**БУРМАМӘ́Т**, к. *Уразмөхәммәд хан.*

**БУ́РМАН** Залман Иосифович (4.3.1924, Чернигов өлкәсенең Новгород-Северский ш. — 9.10.1986, Казан), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1976), проф. (1976), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлекле-

се (1983). 1949 елда Казан авиация ин-тының самолётлар төзү ф-тын тәмамлаганнан соң, Новосибирск һәм Казандагы авиация пр-тиеләрендә махсус кулланылучы техника төзү өстендә эшли. 1963 тән Казан төзүче-инженерлар ин-тында, 1976–86 да төзелеш механикасы каф. мөдире. Бер үк вакытта 1983 тә ин-тта СССР Авиация сәнәгате министрлыгының вертолёт конструкцияләрен автоматлаштыруның хисаплау тармак фәнни-тикшеренү лабораториясен оештыра һәм җитәкли. Хезмәтләре очкыч аппаратларның аэросыгылмалылыгына, катлаулы фәзаи корылмаларның төзелеш механикасына, динамикасына һәм ныклыгына карый. Б. фюзеляж тибындагы юка стеналы авиация конструкцияләрен хисаплау ысулларын автоматлаштыру; очкыч аппаратларда флаттер күренеше һәм аны булдырмау ысулларын өйрәнү б-н шөгыльләнә. Катлаулы төзелешле очкыч аппаратларның ныклыгын һәм вибрациясен хисаплау өчен санча ысуллар, алгоритмнар, программалар эшли.

Х е з м.: Расчёт тонкостенных подкреплённых оболочек методом конечных элементов с применением ЭЦВМ. К., 1973 (автордаш); Суперэлементный расчёт подкреплённых оболочек. М., 1982 (автордаш); Программное обеспечение матричных алгоритмов и метода конечных элементов в инженерных расчётах. М., 1988 (автордаш).

**БУРМИ́СТРОВ** Вилен Иванович (1925, Бондюг заводы бистәсе, хәзерге Менделеев ш. — 24.9.1943), Сов. Союзы Герое (10.1.1944, вафатыннан соң), старшина (1943). 1943 елга кадәр Бондюг химия з-дында эшли. 1943 елның гыйнварыннан Кызыл Армиядә. Шул ук елның сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче гв. танк армиясенең 6 нчы гв. танк корпусы 22 нче гв. мотоукчылар бригадасында отделение командиры. Воронеж фронты гаскәрләре составында Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 23 сентябрендә Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Черкасск өлкәсе Канев р-ны Григоровка авылын азат итү өчен барган бәрелештә һәлак була. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. I; Шёл парнишке в ту пору... Киев, 1985.

*В.А.Шагалов.*

**БУРМИ́СТРОВ** Николай Александрович (25.12.1925, Арча кантоны Чулпан а. — 29.2.2004, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1986), проф. (1988), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1954). 1954–56 елларда Губерово урта мәктәбендә укытучы (Приморье крае). 1956 дан Казан ун-тында, 1988–91 дә гомуми тарих, 1991 дән яңа һәм иң яңа тарих каф. профессоры. Хезмәтләре тарихны укыту проблемаларына карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Образовательно-воспитательная роль системы наглядных средств в курсе новейшей истории. К., 1963; Партийность исторической науки. К., 1979; Классовая природа партийности исторической науки: Теория и практика исследования. К., 1989.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.

*А.В.Скоробогатов.*

**БУРНА́Ш** (Бурнашев) Фәтхи (Фәтхелислам) Закир улы (13.1.1898, хәзерге Чуаш Респ-касының Батыр р-ны Бикшик а. — 1.8.1942), шагыйрь, драматург, журналист, җәмәгать эшлеклесе. Мулла гаиләсендә туа. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала (1907–16). 1916 елда үзлегеннән әзерләнеп Казан татар укытучылар мәктәбе программасы нигезендә имтиханнар тапшыра. Укытучы булып эшли, бер үк вакытта «Таң» (1918–20), «Кызыл Армия» (1921), «Татарстан» (1921–24), «Безнең байрак» (1922–24) г-таларында мөхәррир вазифаларын башкара. Б. — «Чаян» ж-лын оештыручыларның берсе һәм аның беренче мөхәррире (1923–24). 1924–28 дә партия оешмаларында эшли, 1927–28 дә Татар академ. театры директоры була, 1930 елларда Татарстан Дәүләт нәшриятында һәм Татар опера һәм балет театры каршындагы опера студиясендә эшли.

Әдәби эшчәнлеге 1910 еллар уртасында башлана: «Сәйяр» труппасы өчен С.Найдёновның «Дети Ванюшина» («Ванюшин балалары», 1914) пьесасын тәрҗемә итә, үзенең беренче «Язмыш» (1914, куела 1917), «Сукбай» (1915, куела 1917), «Саташкан кыз» (1916, куела 1917) пьесаларын яза. «Аң», «Ак юл» ж-лларында беренче шигырь һәм поэмаларын, яшь авторга киң танылу китергән «Таһир-Зөһрә» (1917, куела 1918) трагедиясен, «Яшь йөрәкләр» (1917, куела 1918) комедиясен бастыра. Гражданнар сугышы елларында иске тормышны инкарь итү, социаль гаделлек өчен көрәш, җәмгыятьне революцион үзгәртү мотивлары б-н сугарылган 15 тән артык поэма, шигырь, хикәяләр, памфлетлар иҗат итә. Киләчәктә ул мотивлар «Камали карт» (1925) комедиясендә, «Адашкан кыз» (1920–26, куела 1927) драмасында, «Хөсәен мирза» (1919–26, куела 1927) трагедиясендә, «Илһам» (1928) сатирик комедиясендә үсеш ала. Бу пьесаларның геройлары гомерләрен халыкны социаль яктан азат итүгә багышлыйлар, яңа моральне яклап чыгалар. Романтик «Лачыннар» (1931, куела 1933) драмасында, тарихи-революцион «Таң» (1932) драмасында Гражданнар сугышы вакыйгалары тасвирлана; «Олы юл белән» (1929–30) драмасында, «Ялгыз Ярулла» (1940) комедиясендә крәстияннең колхоз тормышында үз урынын табуга омтылышы күрсәтелә; «Тукучы Әсма» (1931, куела 1932) драмасында производство темасы чагылдырыла; «Мин калдырдым пар казанын» (1930) поэмасында хосусый милекчелек психологиясенең яңа туып килгән социалистик коллективизм принциплары б-н каршылыгы күрсәтелә. Б. «Колхозчылар маршы»на текст (1933), хатирәләр («Мәҗит ага хатирәсе», 1934; «Горький истәлеге», 1936) һ.б. әсәрләр яза. Татар теленә А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» шигъри романын (1939), Л.Н.Толстойның «Хаджи Мурат» («Хаҗи Морат», 1935) повестен, И.С.Тургеневның «Отцы и дети»



В.И. Бурмистров.



Ф.З. Бурнаш.

(«Аталар һәм балалар», 1932), М.Горькийның «Мать» («Ана», 1933), Н.А.Островскийның «Как закалялась сталь» («Корыч ничек чыныкты», 1936–37; А.Шамов һәм Г.Хәбиб б-н берлектә) романнарын тәрҗемә итә. Б. — татар совет әдәбиятының һәм театр сәнгатенең идея-эстетик принциплары формалашуда билгеле бер роль уйнаган биш опера либреттосы (ш. и. «Таһир-Зөһрә», «Шатлык», «Яшь йөрәкләр»), хикәяләр, күпсанлы публицистик мәкаләләр, рецензияләр авторы. 1922 дә ТАССР ҮБК әгъзасы булып сайлана. Репрессияләр чоры корбаны. Милләтчелектә гаепләнеп 10 елга лагерьга сөрелә. 1942 дә атылуга хөкем ителә. Вафатыннан соң аклана.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1959; Яшь йөрәкләр: Пьесалар, шигырьләр, поэмалар. К., 1969; Әдәбият һәм сәнгать турында: Мәкаләләр, рецензияләр. К., 1978; Яшь йөрәкләр: Пьесалар, хатлар. К., 1988.

*Әд.:* Татар пьесалары: Антология. К., 1987. 1 кит.; История татарской советской литературы.М., 1965; Драматург, оставшийся поэтом // Ахмадуллин А. Горизонты татарской драмы. К., 1983.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**БУРНА́ШЕВ** Ренат Зариф улы (23.10.1940, Ташкент), машиналар гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1985), проф. (1987). 1965 елда Ташкент туку-тукыма һәм җиңел сәнәгать ин-тын тәмамлый. 1968 елдан шунда ук эшли, 1985–95 тә мамык һәм химик сүс эрләү каф. мөдире. Хезмәтләре туку-тукыма сәнәгате машиналары һәм аппаратларына, мамык б-н ефәкне беренчел эшкәртү һәм эрләүгә карый. Чимал мамыкны чистартуның фәнни нигезләрен, фрикцион эрләү теориясен һәм тукыганда артым процессы теориясен төзи. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Первичная обработка хлопка: Учеб. пособие. Таш., 1981 (автордаш); Теоретические аспекты и практические рекомендации по штапелированию и измельчению отходов натурального шёлка. Таш., 1994 (автордаш); Научные основы производства нетканых прошивных полотен с использованием волокнистых отходов. Таш., 1999 (автордаш).

**БУРНА́ШЕВА** Әлфия Вафа кызы (9.5.1942, Казан), пианист, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1990). 1965 елда Казан консерваториясен (фортепиано классы) тәмамлый, шунда ук 1969 да Э.А.Монасзон классында ассистентура-стажировка үтә. 1968 дән Казан консерваториясендә укыта (1995 тән проф., 1998 дән махсус фортепиано каф. мөдире). Актив концерт эшчәнлеге алып бара. Башкаручы буларак, борынгы кла-

вирлы (И.-С.Бах, Г.-Ф.Гендель, Д.Скарлатти) һәм хәзерге заман (С.Прокофьев, Д.Шостакович, Б.Бриттен, П.Хиндемит) музыкасына тартыла. Танылган инструментчылар (Д.Антонов, Г.Сафина һ.б.), ш.у. үзе оештырган Казан консерваториясе триосы (1979 дан), «Барокко» борынгы музыка ансамбле (1987 дән) иҗат коллективлары б-н чыгышлар ясый. Күп кенә концерт программаларын борынгы кыллы-клавишлы музыка коралы клавесинда башкара. Россиядә һәм чит илләрдә гастрольләрдә була. Б.шәкертләре арасында Мордовия Респ-касының атказ. сәнгать эшлеклесе И.Кобозева, Курган филармониясенең сәнгать җитәкчесе С.Потапов, Ижевск филармониясе солисты А.Коробов, халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреатлары Е.Михайлов, З.Мостафина, С.Малинин һ.б. бар.

*Ф.Ш.Салитова.*

**БУРНАШЕВА** Заһидә, к. *Гыйффәт туташ.*

**БУРНА́ШЕВА** Равилә Хәлил кызы (1.4.1924, Рязань өлкәсенең Ермишин р-ны Әҗи а.), аллерголог, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1978), ТАССРның атказ. табибәсе (1974). Казан клиник аллергология мәктәбенә нигез салучы. 1947 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Теләче авылында хастаханә мөдире булып эшли. 1954 тән Казан мед. ин-тында. 1970–94 тә Казан ГИДУВында, 1980 нән аллергология каф. мөдире. Бер үк вакытта Казан шәһәр аллергология үзәге җитәкчесе, 1972–97 дә ТРның штаттан тыш баш аллергологы. 1997 дән ТР Аллергология үзәгенең баш консультанты. Аллергология авыруларының килеп чыгу сәбәпләрен өйрәнә һәм аллергологик авыруларны махсус һәм махсус булмаган дәвалау ысулларын эшли. Аллергиягә каршы препаратларны: кеше иммуноглобулинын (1982), гистосероглобулинны (1990) гамәлгә кертә (бергәләп). Беренче булып гөмбәле һәм бактериаль аллергенлы аэрозоль ярдәмендә дәвалауны тормышка ашыра. Бронхиаль астма авыруын күгәрек һәм чүпрәсыман гөмбәләр б-н дәвалау схемасын эшли, бронхиаль астманың экологик факторларга бәйлелеген билгели. Б. — Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Чистай, Яшел Үзән шәһәрләрендә аллергология хезмәтен оештыручылардан.

Х е з м.: Хронический холецистит и аллергическая реактивность организма. К., 1969 (автордаш); Аллергия и заболевания желчного пузыря. К., 1982 (автордаш).

*Әд.:* П о з д н я к о в а А. Для тебя, жизнь // Советская Татария. 1972. 30 мая; П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**БУ́РОВ** Андрей Иосифович (20.9.1952, Казан), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), геол.-минер. фән. канд. (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1974–93 елларда Бөтенсоюз руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1988–92 дә табигый цеолитлар секторы мөдире. Югары Индигирка геол.-разведка, Көньяк Якутия комплекслы, Ока геол. экспедицияләрендә катнаша. 1993 тән коммерция оешмалары җитәкчесе. Б. 60 тан артык цеолит чималы чыганакларын, ш.и. Чүпрәле р-ны терр-ясендәге Татар Шатрашаны чыганакларын беренче булып ачучыларның берсе (1990). Дәүләт бүләге «Буа р-ның а.х. производствосында ТРдагы агроминераль чималны кулланып ресурс саклаучы технологияләрне гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Целитосодержащие породы Татарстана и их применение. К., 2001 (автордаш); Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их пользования. К., 2002 (автордаш).

*И.Н.Афанасьев.*

**БУ́РОВ** Борис Владимирович (4.6.1934, Казан — 7.3.2008, Казан), геолог, геол.-минерология фән. д-ры (1987), проф. (1989), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993), РФнең атказ. геологы (2000), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), шунда ук эшли (1958 дән), 1987–2002 елларда региональ геология каф. мөдире һәм 1990 нан палеомагнит лаб. җитәкчесе. Рус плитәсендәге югары Пермь утырмаларының берләштерелгән палеомагнит киселешен төзи. Пермь геомагнит инверсияләре чорында геомагнит кырының нечкә структурасы характерын тикшерә. Скважиналар кернын ориентирлауны реконструкцияләү методын (уйлап табуга авторлык таныклыгы), күл төбе утырмаларының билгеләнгән үрнәген алу җайланмасын эшли. Урта Печора, Киров өлкәсе терр-яләренең геологик карталарын, Татарстан терр-ясенең гидрогеологик карталарын төзүдә катнаша.

Х е з м.: Введение в дифференциальный термомагнитный анализ горных пород. К., 1970; Палеомагнитный анализ осадочных горных пород. К., 1985; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**БУРСЫ́К** (Meles meles), сусарлар семьялыгыннан имезүче ерткыч җәнлек. Евразиядә киң таралган. ТРның барлык терр-ясендә дә очрый. Гәүдә озынлыгы 60–90 *см*, койрыгы 25 *см* чамасы, авырлыгы 20–25 *кг*. Тәбәнәк буйлы хайван, юан гәүдәле, чөйсыман башлы, аякларында казу өчен җайлашкан озын, җиңелчә бөгелгән тырнаклары бар. Көмешсыман



төсмерле соры яки коңгырт соры төстәге озын тупас йонлы, башының ике ягына коңгырт кара яки кара сызыклар сузылган. Койрык астында, ачы ис чыгарып, исле тамгалар ясый торган махсус бизе бар. Катлаулы зур өннәрдә колония булып яшиләр. Кайвакыт берничә гаилә 50 ләп кереп чыгу юлы булган, 30–50 һәм аннан да күбрәк еллар дәвамында файдаланыла торган уртак өннәр — бурсык шәһәрчеге төзи. Вак имезүчеләр, бөҗәкләр, җир-су хайваннары, сөйрәлүчеләр, суалчаннар, җиләк-җимешләр б-н туена. Б. октябрь-ноябрьдән март-апрельгә кадәр кышкы йокыга тала. Парлашу апрельдән августка кадәр дәвам итә. Берояда 1–5 бала була. Б. 10–12 ел яши. Урманнарга һәм а.х.на зыян китерүче лайлачларны, бөҗәкләрне, тычкансыман кимерүчеләрне юкка чыгара. Промысел объекты. Б.ны фармацевтик әһәмияте зур булган Б. мае алу өчен аулыйлар. Халык медицинасында Б. мае ревматизм һәм ашказаны җәрәхәте вакытында, туберкулёзны дәвалауда кулланыла. Мехы кыйммәтле түгел. 1990 еллардан урманнарда кабан дуңгызлары саны арту сәбәпле, яшь Б.ларның кимүе күзәтелә (кабан — азык көндәше, яшь һәм зур Б.ларны юк итә, өннәрен җимерә).

*Әд.:* Г о р ш к о в П.К. Барсук в биоценозах Республики Татарстан. К., 1997.

*П.К.Горшков.*

**БУРСЫ́К** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы тамагы буенда. 2002 елда 193 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, кәрзин үрү, сатуга утын әзерләү б-н шөгыльләнә. Мәчет турында беренче тапкыр 1811 елда искә алына, аның каршында ир балалар өчен мәктәп эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 1595,8 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында авылда «Агыйдел» (соңрак Куйбышев исем.) к-зы оештырыла, 1965 тә ул «Актаныш» с-зы составына кертелә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Такталачык волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 104, 1859 да — 443, 1870 тә — 461, 1884 тә — 483, 1897 дә — 642, 1906 да — 706, 1913 тә — 654, 1920 дә — 611, 1926 да — 707, 1938 дә — 788, 1958 дә — 486, 1970 тә — 468, 1979 да — 358, 1989 да — 231 кеше.

**БУРСЫКЛЫ́ (ВО́РСКЛА) ЕЛГАСЫ́ БУЕНДАГЫ́ СУГЫ́Ш** (12 авг. 1399), Бәкләр бәге *Идегәй*, *Тимер Котлык хан* гаскәрләре һәм берләштерелгән рус-литва (кенәз Витовт җитәкчелегендә), төрки-татар (Туктамыш) гаскәре арасындагы орыш. Литваның бөек кенәзе Витовтның Туктамыш ярдәмендә Алтын Урданы бүлгәләргә, Көнчыгыш Европада Литва хакимиятен җәелдерергә омтылуына каршы Идегәй тарафыннан оештырылган сугыш. Ике гаскәр Днепр елгасының сул кушылдыгы Бурсыклы (Ворскла) буенда очраша. Витовт гаскәрендә туплар була. Идегәйнең оста манёврлары нәтиҗәсендә Витовт б-н Туктамыш гаскәре елганы кичеп чыгарга мәҗбүр ителә. Идегәй аларга ике тарафтан берьюлы һөҗүм итә, дошман якның берләштерелгән көчләре җиңелә. 70 тән артык кенәз һәм бәк, күп санда сугышчылар һәлак була. Исән калганнары чигенәләр. Идегәй гаскәре аларны Луцк шәһәренә чаклы куа килә, авыл-калаларны талый. Кенәз Витовт буйсынуындагы Киев шәһәреннән 3000 сум йолым алына. Соңыннан Литва кенәзлеге б-н ике арада солых килешүе төзелә: Литва кенәзле-

ге Алтын Урдага ясак түләп торырга, тәхетеннән куылган Туктамышка ярдәм итмәскә тиеш була. Шушы җиңү нәтиҗәсендә 1395 елгы Аксак Тимер явыннан соң көчсезләнгән Алтын Урданы кабат бергә туплау мөмкинлеге туа, дәүләтнең хәрби куәте ныгый.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Измайлов И.Л. Битва на Ворскле. 1399 // Цейхгауз. 1994. № 1 (3).

*И.Л.Измайлов.*

**БУРСЫКЪЕЛГА́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 26 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кәркәүч елгасы буенда. 2002 елда 146 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бөрсет-Елга, Бурсык-Елга исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, ярма ярдыру тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 385,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәүш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 26 ир заты; 1859 да — 209, 1897 дә — 390, 1908 дә — 439, 1920 дә — 375, 1926 да — 394, 1949 да — 266, 1958 дә — 257, 1970 тә — 238, 1979 да — 204, 1989 да — 160 кеше.

**БУСАГА́**, күп кенә халыклар (ш.и. татарлар) мифологиясе һәм фольклорында кешенең яшәгән урыны, аның өе (микрокосмос) б-н бүтән дөнья (макрокосмос) арасындагы символик чик. Кайбер халыкларда Б. исәннәр һәм үлеләр дөньясы арасындагы бер чик буларак күзаллана. Борынгыдан үлгән ата-бабаларны (ыру, гаилә башлыкларын) Б. астына яки артына күмә торган архаик йола яшәп килгән. Украинада, мәсәлән, 19 йөзгә кадәр Б. артына чукындырылмаган килеш үлгән балаларны күмгәннәр. Күп кенә халыклар арасында Б.ның сакраль үзенчәлеге б-н бәйле йолалар һәм гореф-гадәтләр яшәп килә. Татар йолалары буенча Б. аркылы исәнләшергә, аңа утырырга яки басарга ярамый. Туй б-н бәйле гадәтләр арасында: себер татарларында кәләшне туган өе Б.сы аркылы күтәреп чыгалар, чөнки аның аяклары Б.га тияргә тиеш түгел; Пенза, Түбән Новгород һәм мордва мишәрләрендә кияү өенең Б.сы аркылы беренче тапкыр атлап кергән кәләшкә сөт эчерткәннәр (сөт кебек ак булсын) һәм май ашатканнар (май кебек йомшак булсын). Темников татарларында ире йорты Б.сына килен алып килгән сыйларны куюо һәм ритуаль сөлгеләр элү йоласы бик борынгы заманнардан килә. Кыйммәтле әйберләрне урлаудан курыкмыйча яшерә торган иң ышанычлы урын — Б. дигән күзаллаулар «Тапкыр кәләш» исемле казакъ халык әкиятендә чагылыш тапкан.

*Әд.:* Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе. К., 1992; Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. К., 1999; Лавонен Н.А. Функциональная роль порога в фольклоре и верованиях карел // Фольклор и этнография: У этнографических истоков фольклорных сюжетов и образов. Л., 1984; Султангареева Р.А. Башкирский свадебно-обрядовый фольклор. Уфа, 1994; шул ук. Семейно-бытовой обрядовый фольклор башкирского народа. Уфа, 1998; Славянская мифология: Энцикл. словарь. М., 1995.

*Ф.И.Урманчеев.*

**БУСЫ́ГИН** Андрей Евгеньевич (12.12.1947, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1991), проф. (1993). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1972–87 дә шунда ук эшли, 1976–81 дә (бүленеп) Сомали милли ун-тында, Аддис-Абеба һәм Асмара (Эфиопия) ун-тларында укыта. 1987–90 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында, 1990 нан КПСС Үзәк Комитетында партия эшендә. 1991–92 дә Н.Э.Бауман исем. Мәскәү техника уч-щесендә, 1994–96 тә РФ Федераль Җыелышының Федерация Советы аппараты җитәкчесенең 1 нче урынбасары, 1996–2005 тә РФ президенты администрациясендә эшли. 2006 елдан РФ мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министры урынбасары. Хезмәтләре җитештерүнең үсешен тизләтү һәм нәтиҗәлелеген күтәрү проблемаларына, дәүләт бюджеты һәм салым системаларын камилләштерүгә карый. 1987–89 да ТАССР ЮС депутаты.

Хезм.: Диалектика становления интенсивного типа воспроизводства. К., 1985; Интенсификация и обобществление производства в экономической системе социализма. К., 1988.

**БУСЫ́ГИН** Владимир Михайлович (14.11.1949, Пермь өлкәсенең Краснокамск ш.), инженер-технолог, «Түбәнкаманефтехим» АҖ ген. директоры (1999 дан), ТР (1997) һәм РФнең (2005) атказ. химия белгече. Пермь политехника ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Березники азотлы ашламалар з-дында (Пермь өлкәсе) смена башлыгы, баш оператор, цех башлыгы урынбасары булып эшли. 1981–86 елларда Россошанск хим. з-дында (Воронеж өлкәсе) цех һәм бүлек башлыгы. 1986–88 дә «Оргминудобрения» трестының Северодонецк тармак җитештерү идарәсендә инженерлык-технология бүлеге һәм участок башлыгы (Луганск өлкәсе). 1988–92 дә «Л.Я.Карпов исем. химия заводы» АҖнең баш инженеры, 1995–99 да — ген. директоры. 1992–95 тә «Менде-Росси» уртак сов.-чех. пр-тиесе техник директоры (Менделеев ш.). Уйлап табуга 16 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. Аның җитәкчелегендә «Л.Я.Карпов исем. химия заводы» АҖдә сульфит тозлары цехы, гипосульфит цехы яңартып корыла, гранулланган углекислый барий, пропилен капчыклар эшләү һ.б. производстволар төзелә; «Түбәнкаманефтехим» АҖдә автомобиль бензины җитештерүгә ирешелә, конкуренциягә сәләтле продукция алу өчен пр-тие техник яктан яңадан җиһазландырыла. 1999 дан ТР халык депутаты. ТР Дәүләт бүләге (2001), РФ Хөкүмәте бүләге (2004) лауреаты; 2 нче дәрәҗә «Россия химия индустриясенә керткән хезмәтләре өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә (2005).

*Әд.:* По натуре я — оптимист // Химия и бизнес. 1999. № 33/34.



Е.П. Бусыгин.

**БУСЫ́ГИН** Евгений Прокопьевич (22.12.1913, Казан — 15.2.2008, Казан), этнограф, географ, тарихчы, тарих фән. д-ры (1963), проф. (1964). ТАССР һәм РФнең атказ. фән. эшлеклесе (1972, 1997), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). Россия география җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1985). Казан музыка техникумын (1935), Казан ун-тының география ф-тын (1940) тәмамлый. Н.И.Воробьев шәкерте. Ун-тта уку елларында Б. ТАССР ХКС карамагындагы Татарстан Респ-касы радиофикация һәм радиотапшырулар ком-ты оркестрында, Татар акад. театрында, Татар опера һәм балет театрында скрипкачы булып эшли. 1940 та Кызыл Армиягә алына. Бөек Ватан сугышында — политрук урынбасары, 26 нчы укчы дивизия составында сугышларда катнаша, 1942 дә яраланганнан соң фронт җыр һәм бию ансамбленә җибәрелә. 1945 тән Казан ун-тында: 1988–94 тә этнография һәм археология каф. мөдире (1960–61 елларда Вьетнамда Ханой ун-тында укыта). Хезмәтләре Урта Идел буендагы рус этнографиясенә һәм милләтара мөнәсәбәтләргә карый. Идел буе халыклары этнографиясенә нисбәтле уку әсбаплары, «Гомуми этнография» китабы (Ханой, 1961, вьетнам телендә) авторы. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Дуслык, Вьетнамның «Дуслык» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Русское население Чувашской АССР: Материальная культура. Чебоксары, 1961; Русское сельское население Среднего Поволжья. К., 1966; Среднее Поволжье и Приуралье // Крестьянская одежда Европейской России. М., 1971; Общественный и семейный быт русского сельского населения Среднего Поволжья. К., 1973; Русская сельская семья Чувашской АССР. К., 1980; Этнография народов Среднего Поволжья: Учеб. пособие. К., 1984 (автордаш); Русские в многонациональном Поволжье // Язык и национализм в постсоветских республиках. М., 1994; История географии. К., 1998; Основы этнологии: Курс лекций для студентов ист. факультетов. К., 2001.

*Әд.:* Список основных работ доктора исторических наук, профессора Е.П.Бусыгина (к 70-летию со дня рождения) // Советская этнография. 1985. № 5; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Библиогр. словарь. К., 1999.

**БУТ ТАШЫ́**, бут (итал. buttare — вату, ваклау), файдалы казылма, үлчәмнәре 150–500 *мм* га кадәр ваклаган тау токымнары: доломитлар, известьташлар, комташлар,

сирәк очракларда — гранитлар. Б.т.ның бер төре — үлчәмнәре 300 *мм* дан кимрәк йомры таш. Б.т. чыдамлыгы түбән (25–100 *МПа*), уртача (150–400 *МПа*) һәм югары (500 *МПа* дан артык) булган төрләргә бүленә; суыкка чыдамлылык коэф-ты — 0,1–2. ТР терр-ясендә югары Пермь (Казан һәм Татар ярусалары) известьташлары һәм доломитларына бәйле 50 ләп Б.т. чыганагы билгеле. Файдаланылучы чыганакларның күбесе респ-каның төньяк-көнбатышындагы Югары Казан утырмаларында. Продуктив зона Татарстанның төньягыннан һәм төньяк-көнбатышыннан Бөгелмә шәһәренә таба тараючы киң диагональ полоса булып сузыла. Иң эре чыганаклар — Әки һәм Әлдермеш (Биектау р-ны), Сугышлы (Лениногорск р-ны), *Бондюг нефть чыганагы*. Ятманың файдалы катламы 0,65–10 *м*, сирәк очракларда — 12 *м*, капкачы — берничә дистә *см* дан алып 20 *м* га кадәр калынлыкта. Известьташ һәм доломитларның төзелеш чималы итеп файдаланырлык гомуми запасы 270 млн $м^3$ чамасы (1996), 1990 елларда төзелеш ташының еллык чыгарылышы 1,5 млн $м^3$ га җитә. ТРда Б.т.ның чыдамлылыгы буенча «150» һәм «200» маркалы төрләрен (салкынга чыдамлылык коэф-ты 0,53–1,2) чыгаралар. Б.т. нигезләр, ярдәмче биналар стеналарын, канализация канаулары, гидротехнологик корылмалар салуда кулланыла.

**БУТА́ЙХА** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 44 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сәләнгеш елгасының уң кушылдыгы Бәрле суы буенда. 2002 елда 259 кеше (руслар — 82%) яши. Агач эшкәртү з-ды. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. Китапханә. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чистай кантонының Кәкре Атау волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 10, 1938 дә — 151, 1949 да — 119, 1958 дә — 69, 1970 тә — 49, 1989 да — 302 кеше. Авыл тирәсендә *Бутаиха хәзинәсе* табылган.

**БУТА́ЙХА ХӘЗИНӘСЕ́**, 11 йөз ахыры — 12 йөзгә нисбәтле болгар зәркән эшләнмәләре хәзинәсе. 1957 елда Нурлат р-ны Бутаиха посёлогы янында табыла. 1960 та А.М.Ефимова тарафыннан тикшерелә. Б.х. 46 әйбердән тора, табылдыклар арасында бизәкле көмеш аеллар, тегелмә-тәңкәләр, чигә тагылмалары, имән чикләвеге сыман чигә асылмалары да була. Б.х. әйберләренә югары һөнәри камиллек хас, күбесендә Идел буе Болгары җирендә табылган башка зәркәнчелек эшләнмәләре б-н уртаклык күзәтелә.



Бутаиха хәзинәсеннән көмеш әйберләр.
ТР Милли музее.

*Әд.:* Е ф и м о в а А.М. Бутаевский клад ювелирных изделий волжских булгар // Советская археология. 1960. № 3.

*Е.П.Казаков.*

**БУТАКО́В** Геннадий Петрович (15.6.1942, Мари АССРның Мари-Төрек р-ны Шора а. — 3.11.2001, Казан), геоморфолог, геогр. фән. д-ры (1986), проф. (1988), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005, вафатыннан соң). Казан ун-тын тәмамлый (1964). 1968–72 елларда һәм 1980 елдан шунда ук эшли, геоэкология һәм физик география каф. мөдире (1990 нан). 1972–80 дә Удмурт ун-тында, география каф. мөдире (1973 тән). Хезмәтләре Рус тигезлегенең көнчыгышында геоморфология, борынгы гидрографик челтәрне һәм дүртенчел чордагы бозлану чикләрен реконструкцияләү максатларында эре кисәкле материалларны, дүртенчел чор бозлык алды зонасының рельеф формалашу закончалыкларын, Урта Идел терр-ясендәге ерым һәм елгалар эрозиясен өйрәнүгә карый. Урта мәктәпләр өчен язылган «Татарстан географиясе» («География Татарстана», 1994) дәреслеге авторларының берсе.

Х е з м.: Аналитическое изучение крупнообломочного материала. К., 1971 (автордаш); Плейстоценовый перигляциал на востоке Русской равнины. К., 1986; Овражная эрозия востока Русской равнины. К., 1990 (автордаш).

**БУ́ТЛЕРОВ** Александр Михайлович (3.9.1828, Казан губ. Спас өязе, хәзерге Алексеев р-ны Бутлеровка а. — 5.8.1886, шунда ук), химик, Петербург ФАнең хакыйкый әгъзасы (1874). Россия органик химиклар мәктәбенә нигез салучы һәм аның башлыгы, җәмгать эшлеклесе. Н.Н.*Зининның* шәкерте. 1812 елгы Ватан сугышында катнашкан алпавыт гаиләсендә туа. 1849 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм проф. К.К.Клаус үтенече буенча профессор дәрәҗәсенә әзерлек өчен химия кафедрасына калдырыла. Физика һәм физ.географиядән, нәорганик химиядән лекцияләр укый. 1851 дә «Органик кушылмаларның оксидлашуы» дигән темага магистрлык диссертациясен яклый. К.К.Клаусның Дерпт ун-тына (1852) китүе сәбәпле, Б.ка лабораторияне җитәкләү һәм химия фәнен укыту вазифалары тапшырыла. 1854 тә Мәскәү ун-тында табигый кушылмаларны тикшерүнең башлангычы булган «Эфир майлары турында» дигән докторлык диссертациясен яклый. Бу тикшеренүләр соңыннан аның шәкертләре Ф.М.*Флавицкий*, Е.Е.*Вагнер* һ.б. тарафыннан дәвам иттерелә. 1858 дә ординар проф., 1860–63 тә ике тапкыр Казан ун-тының ректоры итеп билгеләнә. 1868 дән С.-Петербург ун-ты проф. 1885 тә отставкага китә, ләкин ун-тта химия буенча махсус курслар укуын дәвам итә.

1857 дә Германия, Австрия, Италия, Швейцария һәм Англиянең фәнни үзәкләрендә



А.М. Бутлеров.

һәм лабораторияләрендә була. Парижда химик Шарль Вюрц лабораториясендә Б. метилен катнашмалары буенча тәҗрибә эшләре циклын башлап җибәрә, йодоформга натрий этилаты тәэсирендә беренче мәртәбә йодлы метилен таба. Башланган эшләрен Б. Казанда дәвам итә. Метилен диацетатын синтезлый һәм аннан үзе диоксиметилен дип исем кушкан формальдегид полимерын таба. Шул полимер нигезендә беренче мәртәбә гексаметилентетрамин (уротропин) һәм беренче ясалма шикәрле матдә «метиленитан» синтезлый. Шәхси тикшеренү нәтиҗәләре, эксперименталь һәм теоретик органик химиянең чит илләрдә торышын өйрәнү Б.ка органик химия теориясе мәсьәләләрен тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәяләргә һәм яңа теория ачарга мөмкинлек бирә. 1861 дә Шпейер ш. (Германия) немец табигать тикшерүчеләре һәм врачлары съездында Б. «Җисемнәрнең химик төзелеше турында» чыгыш ясый, анда ул органик кушылмалар төзелеше теориясенең төп юнәлешләрен бәян итә. Б. моңарчы яшәп килгән төзелеш теорияләренең чикләнгәнлеген күрсәтә, чөнки яңа тәҗрибә фактлары бу теорияләр кысаларына сыймый. Атомнар теориясенең төп әһәмияten ассызыклый; химик төзелеш төшенчәсенә атом көчләр бүленеше, шуның нәтиҗәсендә төрле ныклыктагы химик бәйләнешләр барлыкка килү буларак билгеләмә бирә. Беренче мәртәбә төрле кушылмаларның төрле реакция үзлекләре атомнар үзара бәйләнгән «зуррак яки кечерәк энергия» (ягъни бәйләнешләр энергиясе) б-н аңлатылуына һәм, ш.у. бәйләнеш барлыкка килгәндә кушу берәмлекләренең тулы яки тулы булмаган кулланылышы б-н аңлатылуына игътибар итә. Билгеләнгән кушылманың төзелешен Б. бер генә формула б-н белдерү мөмкин дип саный. Яңа теория ярдәмендә Б. ул вакытта билгеле булмаган кушылмалар класслары барлыгын алдан әйтә. Изомерия күренешен — элементлар составы бер үк, ләкин химик төзелеше төрле булган кушылмаларның барлыгын аңлата, атомнарның молекулада үзара тәэсир итешүләренең аның үзлекләренә тәэсирен күрсәтә. Изомерлашуның кайтма булу мөмкинлеген күрсәтә, шуның б-н таутометрия турындагы тәгълиматка нигез сала. Ике изомер бутан, өч пентан һәм төрле спиртларның (амилларны да кертеп) барлыгын алдан әйтә һәм дәлилли.

Үзенең теориясен дәлилләү өчен, Б. бик күп эксперименталь тикшеренүләр үткәрә. Төзелеш теориясеннән чыгып, алдан әйтелгән өчле бутил спиртын, изобутан һәм изобутилен синтезлый һәм табигатьләрен дәлилли. Этилен рәте углеводородларының структурасын ачыклый һәм аларны полимерлаштыра. Фән тарихында химик төзелеш теориясенә нигезләнгән беренче кулланма — «Органик химияне тулысынча өйрәнүгә кереш» («Вве-

дение к полному изучению органической химии», вып. 1–3, 1864–66) хезмәтен Казанда өч тапкыр бастырып чыгара. Китапның немец телендә басылып чыгуы теориянең бөтен дөнья химиклары арасында киң танылуына, химик төзелеш теориясен эшләүдә Б.-ның өстенлегенә китерә.

Петербург ун-тында Б. чиксез углеводородлар өлкәсендәге тикшеренүләрен дәвам итә. Этилен углеводородларының гидратлашу реакциясен (химик В.Горяинов б-н берлектә) ача һәм беренче мәртәбә шушы ысул б-н этил спиртын таба. Изобутиленның тыгызлану (полимерлашу) шартларын җентекләп өйрәнә, триизобутилин таба; катализатор сыйфатында фторлы бор кулланып, пропиленны тыгызлый. Бу хезмәтләре бүгенге сәнәгый әһәмиятле химия җитештерүенә нигез була (этил спирты, бутилкаучук, югарыоктанлы ягулык). 1879 да Б. Петербург ун-тында «Соңгы кырык елда химия үсешенең тарихы» дигән махсус лекцияләр курсын укый. Актив гыйльми-җәмәгать эшчәнлеге б-н шөгыльләнә: С.-Петербург Югары хатын-кызлар курсларын оештыруда катнаша, аның тыңлаучылары өчен химия лабораториясен оештыра, түләүсез укыта, курсларга күп тапкыр акчалата ярдәм күрсәтә. Рус химия җәмгыятенең эшчәнлегендә катнаша, 1878–82 дә аның президенты була.

Б. — *Казан химия фәнни мәктәбе*нә нигез салучы һәм аның җитәкчесе. Бу мәктәпнең иң күренекле вәкилләре — Б.ның үз шәкертләре һәм аның шәкертләренең шәкертләре: В.В.*Марковников*, А.М.*Зайцев*, Ф.М.*Флавицкий*, Е.Е.*Вагнер*, С.Н.*Реформатский*, А.Н.*Попов*, А.Е.*Арбузов* һ.б.

Б. авыл хуҗалыгының гамәли мәсьәләләренә дә күп игътибар бирә. Үзенең Бутлеровкадагы утарында умартачылык, бакчачылык, чәчәк үстерү б-н шөгыльләнә; җирле крәстияннарны дәвалый. Умартачылык буенча «Умарта корты, аның тормышы һәм нәтиҗәле умартачылыкның төп кагыйдәләре» («Пчела, ее жизнь и главные правила толкового пчеловодства») дигән беренче хезмәтен 1871 елдан үзе әгъза булып торган Иректе икътисади җәмгыять басмасында чыгара. Россиядә рациональ умартачылыкны үстерүгә зур әһәмият бирә, бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмаган «Умарта кортларын карау» («Как водить пчел», 1885; 12 басма, 1929) брошюрасын яза.

Б.ның тууына 100 ел тулу уңаеннан Казан ун-ты каршында аның исеме. Химия фәнни-тикшеренү ин-ты оештырыла, Казанның бер урамы аның исемен йөртә. Галимнең тууына 150 ел тулу уңае б-н Казанның Пушкин урамындагы скверында Б.ка һәйкәл куела (скульптор Ю.Г.Орехов, арх. В.А.Петербуржцев һәм А.В.Степанов).

Х е з м.: Избранные работы по органической химии. М.,1951; Сочинения: В 3 т. М., 1953–58.

*Əд.:* Г у м и л е в с к и й Л. Александр Михайлович Бутлеров. 1828–1886. М., 1951; Б ы к о в Г.В. Александр Михайлович Бутлеров. М., 1961; Г р е ч к и н Н.П. Александр Михайлович Бутлеров (его жизнь и деятельность в Казани) // Рассказы о казанских учёных. К., 1983; П о л и щ у к В. Бутлеровский рецепт. М., 1984.

**БУ́ТЛЕРОВ А.М. ИСЕМЕНДӘГЕ́ ХИ́МИЯ ИНСТИТУТЫ́,** Казан ун-тының уку-укыту фәнни бүлекчәсе, 2003 елда химия ф-тын һәм А.М.Бутлеров исемендәге Химия фәнни-тикшеренү ин-тын бергә кушып оештырыла. Институт составында 5 уку кафедрасы (нәорганик химия, аналитик химия, органик химия, физик химия, югары молекуляр һәм элементорганик химия), 8 фәнни бүлек (5 се кафедралар карамагында), ш.и. югары басымнар химиясе, стереохимия һәм гамәли химия бүлекләре бар. Химия фәнни-тикшеренү ин-ты 1929 да Казан ун-тының физика-математика ф-ты каршында оештырыла. Аның ачылуына ун-т идарәсенең Мәгариф халык комис-тына Фәнни-тикшеренү ин-ты оештыру турындагы юлламасы (1927) сәбәп була. А.М.Бутлеров истәлегенә багышлап һәм галимнең 100 еллык юбилее уңаеннан чиста һәм гамәли химия буенча үткәрелгән 5 нче Менделеев съездында (Казан, 1928)



Бутлеров А.М. исем. Химия институты.

катнашучылар юлламаны хуплый. Химия фәнни-тикшеренү ин-ты 1837 дә ун-т ишегалдында химия һәм физика лабораторияләре өчен төзелгән классик архитектурадагы (арх. М.П.Коринфский) борынгы ике катлы бинада урнаша. Ин-тка органик химия, нәорганик химия, физик химия, аналитик химия бүлекләре керә. Органик химия бүлегендә фосфорның органик чыгарылмалары тикшерелә: фосфит к-тасының диалкил эфирлары таутомериясе һәм аларның металлы чыгарылмалары реакцияләре өйрәнелә (А.Е.Арбузов); триарилметил рәтендәге ирекле радикаллар барлыкка килү реакциясе ачыла, пирофосфор к-талары чыгарылмалары өйрәнелә, күп кенә кушылмаларның физиологик активлыгы билгеләнә, дару препаратлары, үсемлекләрне саклау чаралары алына (А.Е.Арбузов һәм Б.А.Арбузов); арил- һәм диарил арсенит к-талары эфирлары синтезлана һәм өйрәнелә (Г.Х.Камай, В.М.Зороастрова). Бүлекнең икенче фәнни юнәлеше — терпеннар өлкәсендәге эзләнүләр: скипидарның составы билгеләнә, аннан камфора алу технологиясенә үзгәреш кертелә; туендырылмаган терпеннар оксидлашу реакцияләренең юнәлеше һәм аларның оксидка әйләнү механизмнары, диен синтезы ысулын кулланып, абиетин һәм левопимар к-талары төзелеше билгеләнә; ике циклы терпеннарның алифатик терпеннарга төркемләнүе ачыла, дельта$^3$-карен химиясе буенча бик күп эзләнүләр үткәрелә (Б.А.Арбузов). Өченче юнәлеш — оксикетон ацетальләре синтезын һәм үзенчәлекләрен өйрәнү (В.В.Евлампиев). Нәорганик химия бүлегендә туендырылган тоз эремәләре барлыкка килү термохимиясе, тоз эремәләренең электр үткәрүчәнлеге һәм электролит эремәләрнең электр үткәрүчәнлегенә электролит булмаган эремәләр йогынтысы өйрәнелә (А.Я.Богородский, Г.П.Дезидерьев). Физик химия бүлеге тикшеренүләренең төп юнәлеше — металларның коллоид эремәләрен алу ысулын эшләү, гипофосфит к-тасы ярдәмендә металларны электрохимик юл б-н яңадан кайтару кинетикасын өйрәнү (А.Ф.Герасимов, Г.С.Воздвиженский). Аналитик химия бүлеге тикшеренүләрендә төп игътибар «өченче» җисем катнашындагы утырымлы реакцияләргә бирелә, микъдари анализ өчен «эрүчәнлек тапкырчыгышы» төшенчәсе кертелә (А.М.Васильев, Н.П.Смирнов).

Бөек Ватан сугышы елларында Химия фәнни-тикшеренү ин-ты бинасында СССР ФАнең Мәскәүдән эвакуацияләнгән Органик химия ин-ты һәм Радий ин-тының бер өлеше урнаша. Фәнни тикшеренүләр сугыш вакыты бурычлары б-н бәйле була: хәрби техниканы ремонтлау өчен җилемнәр, салкынга чыдам резина, самолётларда тишелгәннән соң үзеннән-үзе йомылучы сыешлык, авиация майларына һәм гидравлик сыекчаларга утырткыч кушылмалар, төнге күзәтү приборларында махсус капламнар эшләнә; тиоколларның һәм поликонденсацион мономерларның яңа типлары алына. Казан һәм Сталинград госпитальләре өчен дару препаратлары (сульфазол, стрептоцид, никотин к-тасы, сульфидин) эшләп чыгарыла. Институт хезмәткәрләре Казан з-длары һәм пр-тиеләре лабораторияләренә консультация ярдәме күрсәтәләр.

Сугыштан соңгы чорда ин-т эшчәнлегенең төп фәнни бурычы А.М.Бутлеров тәгълиматын — органик кушылмалар төзелеше теориясен тиешле дәрәҗәдә тирәнәйтү һәм киңәйтү була. Фосфит к-тасының циклик эфирлары синтезлана һәм үзлекләре өйрәнелә (А.Е.Арбузов, Б.А.Арбузов). *Абрамов реакциясе* һәм *Пудовик реакциясе* ачыла һәм җентекләп өйрәнелә. Беренче мәртәбә окись бәйралы фосфин эфирлары алына, биполяр ион һәм фосфоран катнашлыгында арадаш стадияләр тикшерелә (Б.А.Арбузов, Н.А.Полежаева, В.С.Виноградова). Циклик эфирлар б-н реакцияләр, P=C һәм As=C бәйләнешләре буенча кушылу реакцияләре (Э.Н.Дианова), фосфит к-тасының тулы һәм тулы булмаган эфирлары б-н циклоннар һәм α-еноннар арасындагы реакцияләр юнәлешләренең күптөрлелеге ачыла (А.В.Фуженкова). 1960 еллардан терпеннар өлкәсендә актив эш алып барыла. α-Пинен, камфен, 3-карен оксидларының изомер әверелешләре ачыла (Б.А.Арбузов, З.Г.Исаева), күп кенә биологик актив кушылмалар синтезлана, аларның биологик активлыгы һәм структурасы арасында бәйлелек тикшерелә. Казанда органик кушылмалар структурасын физик ысуллар б-н өйрәнүгә Б.А.Арбузов нигез сала. Органик молекулаларны структур анализлау нигезендә түбәндәге ысуллар ята: ТМР (Й.Ю.Сәмитов, А.В.Аганов), диполь моментлар (Л.К.Юлдашева, Л.М.Катаева), полярография, кулоно-

метрия, амперометрия (В.Ф.Торопова, М.К.Сайкина), электрооптик ысуллар (А.Н.Верещагин, С.Г.Вульфсон, Р.П.Аршинова). Беренче тапкыр пирролиноннар һәм пиридозиноннар чыгарылмаларының Р — нуклеофиллар б-н реакцияләре өйрәнелә (Н.А.Полежаева, А.М.Полозов, В.Г.Сәхибуллина). Стереохимия бүлегендә кушылмаларның реакциягә керү сәләте б-н аларның пространстводагы төзелеше арасындагы бәйләнеш тикшерелә. Термодинамик тикшерү шартларында күп процесслар өчен конформер реакцияләре тизлегенең парциаль константаларын билгеләргә мөмкинлек бирүче яңа ысул эшләнә. Югары басымнар химиясе бүлегендә циклик кушылулар реакциясенең тизлеген һәм тигезлеген билгеләүче факторлар өйрәнелә. Орбиталь характеристикаларны, реагентлар структураларын һәм реакция энтальпиясен исәпкә алып, процессның тизлеген микъдари тасвирлау мөмкинлеге күрсәтелә. Каталитик процессларны өйрәнү ысуллары эшләнә, реагентлар активлыгын үстерү шартлары ($10^9$ тапкырга кадәр) табыла. Югары басым астында үткәрелә торган гадәти һәм катализлы процесслар тизлеге һәм тигезлеге үзгәрүнең оптималь шартлары ачыклана, тизлек диффузия ярдәмендә тикшерелә алырлык басым чикләре билгеләнә (А.И.Коновалов, В.Д.Киселёв, Е.А.Кашаева, Г.Г.Исхакова). Гамәли химия бүлегендә нефтьне промыселга әзерләү өчен реагентлар синтезлау, яхшыртылган физик-механик күрсәткечле пенополиуретаннар һәм микроэлектроника өчен яңа материаллар алу буенча эшләр алып барыла. Яңа дару препаратлары, ш.у. биоҗиткерүчәнлеке һәм дару матдәләренең специфик активлыгын яхшыртучы полимер йөртүчеләрне эшләүгә игътибар бирелә.

Химия фәнни-тикшеренү ин-тының мөһим эшләреннән берсе — Татарстан заводларына һәм пр-тиеләренә консультация ярдәме күрсәтү: фурфурол (А.Е.Арбузов, Б.П.Луговкин), үсемлек майлары (А.И.Луньяк) алуның яңа ысуллары кертелә, Чистай акшарлау балчыклары үзенчәлекләре өйрәнелә (А.Ф.Герасимов, Г.С.Воздвиженский), камфара алу производствосы һәм канифоль-сабын з-длары калдыкларын куллану (Б.А.Арбузов) буенча зур күләмдә эш башкарыла. 1980 елларда нефтьне промыселга әзерләү эшләре башлана: су-нефть эмульсияләрен сусызландыру һәм тозсызландыру өчен реагентлар, фторкаучуклар нигезендә эшләнмәләр вулканизаторы, эмульгаторлар (Казан «Органик синтез» АҖ дә күпләп җитештерү оештырыла) эшләнә һәм патентлар б-н беркетелә. Институт тикшеренүләре буенча җитештерелгән продукцияне кулланучылар — ТР, Башкортстан Респ-касы һәм илнең башка төбәкләрендәге нефть-газ чыгару идарәләре.

Ун-тның физика-математика ф-ты составында булган һәм 1930 елда яңа оештырылган Казан хим.-технол. ин-тына күчерелгән химия кафедраларында (органик химия, нәорганик химия, физик химия, аналитик химия) үткәрелеп килгән фәнни тикшеренүләр академик һәм югары уку йорты фәненең тыгыз бәйләнешен күрсәтә. 1931 елда ун-тта яңа ф-тлар оештыру процессы башлана, ш.и. алда саналган кафедралары б-н химия ф-ты да ачыла. 1950 елларда кафедралар каршында аларның тематикасы буенча фундаменталь тикшеренүләр үткәрү өчен проблемалы (соңыннан фәнни-тикшеренү) лабораторияләр оештырыла башлый. Органик химия кафедрасы 1868 дә үк оеша, аның беренче мөдире А.М.Бутлеров була, төрле еллардагы җитәкчеләре: В.В.Марковников, А.М.Зайцев, А.Е.Арбузов, Б.А.Арбузов, Е.Г.Катаев, А.И.Коновалов, И.С.Антипин. 1957 дә Б.А.Арбузов инициативасы б-н кафедра каршында Россиядә ТМР спектроскопиясе буенча әйдәп баручы үзәкләрнең берсе — органик кушылмалар структурасын өйрәнүче фәнни-тикшеренү лабораториясе оештырыла. Эшчәнлекнең төп юнәлеше органик реакцияләрнең, реакция сәләтен һәм механизмнарын өйрәнү, супрамолекуляр химия (1987 дән фәнни җитәкче А.И.Коновалов). Казан ун-ты документларында нәорганик химия кафедрасы беренче мәртәбә 1878 дә телгә алына, мөдирләре: Г.Н.Глинский, Ф.М. Флавицкий, А.Я.Богородский, Б.Н.Воропаев, Ф.И.Богоявленский, С.Д.Громаков, В.В.Лебединский, А.А.Гринберг, А.Ф.Богоявленский, Л.Г.Берг, А.Б.Здановский, А.А.Попель, З.А.Сапрыкова, Ю.И.Сальников, Н.А.Улахович. 1970 тән координацион кушылмалар лабораториясе эшли. Фәнни тикшеренүләр максаты — 3d-күчешле һәм платиналы металларның органик һәм элементорганик лигандалы комплекслары төзелешен, составын, тотрыклылыгын, тиз алмаштыру реакцияләре кинетикасын һәм механизмнарын өйрәнүнең яңача юлларын эшләү; алдан билгеләнгән сыйфатлы кушылмалар синтезлау. Физик химия кафедрасына нигез салучы һәм аның беренче мөдире А.Ф.Герасимов (1919) була. Төрле елларда каф. б-н җитәкчелек итүчеләр: А.Ф.Капустинский, Н.А.Трифонов, Ф.Ф.Фәйзуллин, Ю.М.Каргин, Б.Н.Соломонов. Физик химия кафедрасы һәм бүлегенең төп фәнни юнәлешләре: органик һәм элементорганик кушылмалар электрохимиясе, электролит булмаган органик эремәләр термодинамикасы (СССР Дәүләт бүләге, 1987), каты аксымнар һәм органик рецепторлар — каликсареннар һәм полимерлар б-н органик кушылмаларны адсорбцияләү, ферментатив, металл-комплекслы гетероген катализ, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү процесслары өчен яңа катализаторлар эшләү һ.б. Аналитик химия кафедрасы 1919 да оештырыла, мөдирләре: А.М.Васильев, В.Ф.Торопова, Г.К.Будников. Фәнни тикшеренү юнәлешләре: электроаналитик химия, нәорганик һәм органик анализда кулонометрия, органик кушылмалар вольтамперометриясе, электрохимик сенсорлар, фосфор кушылмалары нигезендә органик реагентлар, хроматография, биосенсорлар, анализның иммунохимик ысуллары. Югары молекуляр һәм элементорганик кушылмалар кафедрасы А.Н.Пудовик тарафыннан 1948 дә синт. каучук кафедрасы буларак төзелә, мономерлар химиясенең проблемалы лабораториясе (хәзерге элементоорганик кушылмалар лабораториясе) оештырыла (1958). 1988 дән кафедра һәм бүлекне Р.А.Черкасов җитәкли. Фәнни тикшеренүләр фосфорның төрле координациядәге органик кушылмалары, ш.у. башка күчешсез элементлар чыгарылмаларының структуралары б-н реакциягә керү сәләте арасындагы бәйләнешне теоретик һәм эксперименталь өйрәнүгә, гамәли файдалы үзенчәлекләре б-н яңа матдәләр синтезлауның нәтиҗәле алымнарын эшләүгә; фосфорорганик кушылмаларның фәзаи төзелешен заманча спектраль, электрик, электрооптик алымнар ярдәмендә өйрәнүгә багышлана.

Химия ин-ты ТР, РФ фәнни оешмалары б-н иҗади бәйләнештә тора, 2 белгечлек буенча аспирантура эшли. Химия ин-тында РФАнең 1 академигы, 1 мөхбир әгъзасы, ТФАнең 1 мөхбир әгъзасы, 22 фән докторы эшли. Югары дәүләт бүләкләреннән: Ленин бүләге — 1 кешегә, Дәүләт бүләге — 3 кешегә, СССР ФАнең Д.И.Менделеев исем. бүләк — 4 кешегә, СССР ФА президиумы бүләге — 3 кешегә, Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыяте бүләге 3 кешегә бирелә. Фәнни тикшеренүләр үсешенә зур өлеш кертүчеләр: А.Е.Арбузов, Б.А.Арбузов, А.И.Коновалов. Химия фәнни-тикшеренү ин-ты бинасы фасадында Н.Н.Зинин, К.К.Клаус, А.М.Бутлеров, В.В.Марковников, А.М.Зайцев, Ф.М.Флавицкий, А.Е.Арбузов, Б.А.Арбузов истәлеген мәңгеләштергән 8 мемориаль такта һәм аларның танылган укучылары (Н.Н.Бекетов, М.Я.Киттары, А.М.Попов, Е.Е.Вагнер, С.Н.Реформатский, А.Н.Реформатский, А.Ф.Герасимов, А.Я.Богородский, А.М.Васильев, Г.Х.Камай, В.С.Абрамов) исемнәре язылган мемориаль такта бар; *Казан химия мәктәбе музее* эшли. Химия фәнни-тикшеренү ин-ты җитәкчеләре: А.Е.Арбузов (1929–60), Б.А.Арбузов (1960–88), В.Д.Киселёв (1988–2002), 2003 елдан В.И.Галкин.

*Әд.:* Сорокина Т.Д., Климовицкий Е.Н., Штырлин Ю.Г. Научно-исследовательский химический институт им. А.М.Бутлерова Казанского университета: История создания, современное состояние. К., 2004.

*В.Д.Киселёв.*

**БУ́ТЛЕРОВ А.М. ҺӘЙКӘЛЕ́,** Казанда. Галимгә 150 яшь тулу уңаеннан 1978 елда ачыла. Авторлары — скульпт. Ю.Г.Орехов, арх.



Казанда А.М. Бутлеров һәйкәле. 1978.
Скульптор Ю.Г. Орехов.
Арх. В.А. Петербуржцев, А.В. Степанов.

В.А.Петербуржцев һәм А.В.Степанов. Һәйкәл органик кушылмаларның төзелеш теориясен уйлап табучы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, Казан химик-органиклар мәктәбен оештыручы һәм аның җитәкчесе бөек рус химигының хезмәтен ихтирам итү йөзеннән куела.

Шомартылган мәрмәр нигезгә бронза постамент б-н бербөтен тәшкил итүче бронза гәүдә урнаштырылган. Бутлеров тыныч, гадәти кыяфәттә сурәтләнгән. Терсәкләренә таянган, сул кулында кысасыз күзлек. Галим фикердәшләре б-н сөйләшеп утырган кыяфәттә бирелгән. Скульптор пластик чаралар ярдәмендә дөньякүләм танылган галимнең образын ачык гәүдәләндерә алган. Киң, ачык маңгай, туры кашлар, көрәк сакал, киң күкрәкле төз гәүдә акыл иясенең физик һәм рухи көчен ассызыклый.

Бутлеровның һәйкәле Казан ун-тыннан ерак түгел, йөзе б-н шәһәр үзәгендәге Пушкин урамына каратып, Ленин бакчасында урнаштырылган. Казан шәһәренең иң яхшы монументларыннан санала.

*А.И.Новицкий.*

**БУ́ТЛЕРОВ РЕА́КЦИЯСЕ**, селтеле җир металлары, кургаш яки аккургаш гидроксидлары тәэсирендә формальдегидның үзлегеннән конденсацияләнүе:

$$CH_2O + CH_2O \xrightarrow[(H_2O)]{Ca(OH)_2,\ \sim 20\ C} CH_2OH-CHO \xrightarrow{CH_2O} \cdots \longrightarrow C_6H_{12}O_6$$

Реакция нәтиҗәсендә шикәрләр катнашмасы («формоза») хасил була. Процесс баскычлап бара һәм автокаталитик хасияткә ия. Реакция гликоль альдегиды яки диоксиацетон өстәп, ш.у. ультрашәмәхә нурланыш б-н башланып китә. 1861 елда Казан ун-тында А.М.Бутлеров тарафыннан ачыла.

*Әд.:* Вацуро К.В., Мищенко Г.Л. Именные реакции в органической химии: Справ. М., 1976.

**БУ́ТЛЕРОВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Көрнәле елгасы буенда. 2002 елда 149 кеше (руслар — 72%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, 3 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 299 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш (Спас, Чистай) өязе Алексеев волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1963 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 140 ир заты; 1859 да — 373, 1897 дә — 654, 1920 дә — 722, 1926 да — 627, 1938 дә — 515, 1949 да — 364, 1958 дә — 342, 1970 тә — 232, 1979 да — 156, 1989 да — 136 кеше.

**БУТО́МА** Борис Евстафьевич (28.4.1907, Петровск-Порт ш., хәзерге Дагстан Респ-касының Махачкала ш. — 11.7.1976, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе, техник фән. д-ры, Соц. Хезмәт Герое (1959). Ленинград кораблъләр төзү ин-тын тәмамлаганнан соң (1936), Владивосток шәһәренең суднолар ремонтлау з-дында эшли. 1944–48 елларда Яшел Үзән суднолар төзү з-дында, 1945 тән директор. Суднолар төзүнең позицияле агым ысулын эшләү б-н шөгыльләнә. 1948–57 дә СССР Суднолар төзү сәнәгате министрлыгында: баш идарә җитәкчесе, министр урынбасары, 1957–76 да министр. Б. Хәрби Диңгез Флоты (ВМФ) корабльләренең, транспорт һәм промысел судноларының яңа төрләрен төзүдә; суднолар төзелешендә атом электротехникасы җайланмаларын кертүдә катнаша. 1962–76 да СССР ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләге (1949), Ленин премиясе (1974) лауреаты. Биш Ленин, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.



Б.Е. Бутома.

**БУТУРЛИ́Н** Фёдор Васильевич (? — 4.1.1673), дәүләт һәм хәрби эшлекле, окольничий (1649). Затлы дворян Ратши нәселеннән (А.С.Пушкин да Ратшиның варисларыннан була). 1615–17 елларда К.Минин б-н Д.Пожарский ополчениесендә полякларга каршы, 1631–34 тә Смоленск өчен барган һ.б. сугыш-бәрелешләрдә катнаша. Берничә шәһәрдә, ш.и. Казанда 1639–41 дә 2 нче, 1657–59 да 1 нче воевода була. 1654–57 дә Богдан Хмельницкий радасында Россия вәкиле. Польша сугышына җибәрү өчен дворяннардан, стрелецлардан, йомышлы татарлардан гаскәри берәмлекләр туплауга җитәкчелек итә.

*Е.В.Липаков.*

**БУТЫ́РИ** авылы, Лаеш р-нында, шәһәр тибындагы Лаеш посёлогыннан 16 *км* төньяктарак, Казан–Лаеш автомобиль юлы буенда. 2002 елда 33 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 16 йөз уртасында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве (1897 дә төзелә), земство мәктәбе (1875 тә ачыла), 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 184 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 43 ир заты; 1859 да — 386, 1897 дә — 565, 1908 дә — 574, 1920 дә — 663, 1926 да — 644, 1938 дә — 438, 1949 да — 240, 1958 дә — 147, 1970 тә — 155, 1979 да — 81, 1989 да — 53 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**БУ́ХАРЕВ** Александр Матвеевич (архимандрит Феодор) (1822 яисә 1824, Тверь губ. Фёдоров а. — 2.4.1871, Переяславль-Залесский ш.), дин белгече. 1846 елда Мәскәү руханилар академиясен тәмамлый, монахлыкка керә һәм шунда ук эшли, проф. (1852). 1854 елдан Казан руханилар академиясе проф. һәм инспекторы (1855–58); студентлар арасында зур абруй казана. А.П.*Щапов*, П.В.*Знаменский* һ.б. үзләрен Б.ның шәкертләре дип исәпләгән. 1858–63 тә С.-Петербургта дини цензура ком-тында эшли. «Хисап көне»н өйрәнү» («Исследование «Апокалипсиса») трактатын бастыру тыелганнан соң (Б. аны үзенең төп хезмәте дип саный), монахлыктан ваз кичә (1863). Үз хезмәтләрендә Б. төп игътибарны Гайсәнең кешелек сыйфатларына юнәлтә, рухи һәм матди башлангычларны бер-берсенә каршы куюны инкарь итә, дини гыйлем б-н беррәттән дөньяви белем бирүне яклап чыга. Дин галимнәре арасыннан беренчеләрдән булып дөньяви мәдәниятнең күп кенә казанышларына — Н.В.Гоголь, А.С.Пушкин иҗатына, Ф.М.Достоевскийның беренче романнарына һ.б. чиркәү күзлегеннән бәя бирә. Аның күп кенә идеяләре консерватив руханилар тарафыннан кире кагыла. Б. хезмәтләре Россиядә дин гыйлеме, дини фәлсәфә үсешенә зур йогынты ясый. (В.С.Соловьев, С.Н.Трубецкой, В.И.*Несмелов*). Алар 1905 елдан соң гына киң җәмәгатьчелеккә барып ирешә.

Хезм.: О православии в отношении к современности. СПб., 1860; Три письма к Н.В.Гоголю, писанные в 1848. СПб., 1861; О современных духовных потребностях мысли и жизни, особенно русской. М., 1865; Исследование «Апокалипсиса». Сергиев Посад, 1916; О духовных потребностях жизни. М., 1991.

*Әд.:* Знаменский П.В. Богословская полемика 1860-х годов об отношении православия к современной жизни. К., 1906; Флоровский Г.В. Пути русского богословия. Париж, 1981; Розанов В.В. Около церковных стен. М., 1995; Архимандрит Феодор (А.М.Бухарев): pro et contra. Личность и творчество Феодора (Бухарева) в оценке русских мыслителей и исследователей. СПб., 1997.

**БУХА́РСКИЙ** (Галимов) Хаҗиәхмәт Гыйрфанетдин улы (1.1.1889, Казан губ., Зөя өязе Сатмыш а. — 13.5.1974, Уфа ш.), драма актёры, режиссёр, педагог, Башкортстан АССРның халык артисты (1944), РСФСРның атказ. артисты (1957). 1918 елда Кыштым реаль уч-щесен тәмамлый. Сәхнә эшчәнлеген 1918 дә Златоуст шәһәрендә һәвәскәр театрда башлый. 1923–68 дә М.Гафури исем. Башкорт акад. драма театрында: актёр, режиссёр, сәнгать җитәкчесе, театр музее мөдире. Бер үк вакытта 1926–52 дә Башкорт сәнгать техникумында укыта. 1931–33 тә Мәскәү укыту-театр комб-тының режиссёрлык — пед. ф-тында укый. Киң иҗат диапазонлы, комик һәм драматик характерларны да тирәнтен ачуга сәләтле актёр буларак, башкорт сәхнә сәнгате тарихында урын алган күп кенә рольләрне башкара. Ул иҗат иткән Мамаев («Зимагурлар», С.Мифтахов), Сафа мулла («Кара йөзләр», М.Гафури), Салих бай («Бай һәм батрак», Х.Хәмзә), Шмага («Гаепсездән гаепләләр», А.Н.Островский), Фурманов («Фет-

нә», Д.А.Фурманов), Фаюнин («Ябырылу», Л.М.Леонов), Ленин («Онытылмас 1919 ел», В.В.Вишневский), Мамлок («Профессор Мамлок», Ф.Вольф) образлары хисләрнең чынлыгы, тормышның дөрес чагылдырылуы, тышкы гадилек, характерның эчке логикасын төгәл ачу б-н аерылып тора. Режиссёр буларак, Башкорт драма театры сәхнәсендә У.Шекспирның «Отелло», Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» («Коварство и любовь»), К.А.Тренёвның «Любовь Яровая», М.А.Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» («Поднятая целина»), Х.Хәмзәнең «Бай һәм батрак», И.Абдуллинның «Тирән сулыш» әсәрләрен куя. Б. куйган спектакльләргә тирән эчтәлек, төп идеяләрнең ачыклыгы, романтик күтәренкелек хас. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1955).

*Әд.:* М ә һ ә ҙ и е в М. Театр тураһында. Өфө, 1962; Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

*И.И.Илялова.*

**БУ́ХИН** Генрих Михайлович (1.10.1910, Варшава — 9.12.1995, Казан), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1935) һәм Казан авиация җитештерү берләшмәсендә эшли (1964 елга кадәр клепкалау-җыю эшләре бүлеге башлыгы, 1964–81 дә — КБ башлыгы). Дәүләт бүләге самолётлар җитештерүдә стапель һәм универсаль җайланмалар конструкцияләрен яңа технол. процесслар кулланып җыю өчен яңа ысуллар эшләгәне һәм һәм гамәлгә кертү өчен бирелә. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**БУ́ХИНА** Валентина Петровна (25.12.1916, хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең Борский р-ны Пичугино а. — 12.7.1996, Казан), СССР Төзелеш банкының Татарстан респ-ка конторасы управляющие (1960–80). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1941), СССР Сәнәгать банкының Татарстан респ-ка конторасында өлкән кредит инспекторы, бүлек башлыгы, управляющий урынбасары. Б. сәнәгать һәм гражданлык төзелешләренең эре объектларын финанслауны оештыруга зур өлеш кертә. 1963–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Банк на все времена. Берлин, 1997.

**БУХМИ́Н** Владимир Сергеевич (24.8.1950, Үзбәкстан ССРның Термез ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли, 2000 елдан — укыту бүлеге мөдире, 2004 тән проректор — укыту-методика идарәсе башлыгы.

Хезмәтләре радиосистемаларның нәтиҗәлелеген күтәрү, мәгълүмат кабул итү һәм эшкәртү, радиодулкыннарның ионосфера аша үтүе проблемаларына карый. Казан ун-тында физика укыту системасын булдыруны һәм аның үсешен тикшерә.

Х е з м.: Система физического образования в Казанском университете (1804–1917 гг.). К., 2003; Система физического образования в Казанском университете в годы перестройки и условиях рыночного хозяйствования. К., 2005; С.А.Альтшулер — создатель Казанской школы физиков в области магнитной радиоспектроскопии // Казан. пед. журн. 2005. № 5.

*Р.Г.Усманов.*

**БУ́ХОВ** Аркадий Сергеевич (псевд. Аркадий Сергеев) (17.2.1889, Уфа ш. — 7.10.1937), журналист, язучы. Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен тәмамлаганнан соң, 1907 елда Казан ун-тының юридик ф-тына укырга керә. Шул ук елда студентлар хәрәкәтендә катнашканы өчен ун-ттан чыгарыла һәм Уралга сөрелә. Мәкаләләре гимназиядә укыганда ук, 1906 да, Казанда «Волжский курьер», «Волжский листок» г-таларында, «Метеор» ж-лында, Мәскәүдә чыгучы «Стрекоза» (1907), «Весна» (1908) ж-лларында басыла. Б.ның А.Блок, М.Кузмин, З.Гиппиус иҗатлары турындагы «Тәнкыйди штрихлар» («Критические штрихи») дигән беренче китабы 1909 да Казанда дөнья күрә. 1908 дә Б., Казан матбугаты вәкиле буларак, журналистларның 1 нче Бөтенроссия съездында (Мәскәү) катнаша. 1910 нан «Сатирикон», 1913 тә «Синий журнал» (СПб.) ж-ллары редакцияләрендә эшли. Октябрь рев-циясеннән соң Көнбатыш Белоруссиядә, аннары Литвада яши. 1920–27 дә советлар яклы «Эхо» г-тасында (Каунас ш.) мөхәррир. 1927 дә СССР ҮБК Б.ның Мәскәүгә кайтырга теләк белдергән үтенечен канәгатьләндерә. Монда ул «Бегемот», «Чудак», «Смехач» ж-лларында һәм «Труд» г-тасында мәкаләләрен бастыра. 1932 елдан «Крокодил» ж-лында эшли. Сатирик романнар һәм юмористик хикәяләр авторы. Репрессияләр корбаны.

Ә с ә р.: История трёх святых и некоторых посторонних. М., 1930; Чёрное кольцо. М.–Л., 1931; Рассказы, памфлеты, пародии. М., 1972; Ухажиратель. М., 1989.

*Әд.:* С п и р и д о н о в а - Е в с т и г н е е в а Л.А. Русская сатирическая литература начала XX века. М., 1977; Краткая литературная энциклопедия. М., 1978.

*К.Н.Куранов.*

**БУЧИРМӘ́** (Березняк) авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оштырма елгасының (Вятканың уң кушылдыгы) уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 383 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Итемган-Березник, Вощерма исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1257,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 82 ир заты; 1859 да — 496, 1897 дә — 680, 1908 дә — 698, 1920 дә — 729, 1926 да — 594, 1938 дә — 580, 1949 да — 421, 1970 тә — 425, 1979 да — 398, 1989 да — 345 кеше.

**БУШАНЧА́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 12 *км* көнчыгыштарак, Имәнле елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 118 кеше (руслар — 64%, чуашлар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — сарык, иткә терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Архистратиг Михаил чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, 2 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 738 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 440, 1897 дә — 889, 1908 дә — 962, 1920 дә — 764, 1926 да — 624, 1938 дә — 626, 1949 да — 492, 1958 дә — 437, 1970 тә — 393, 1979 да — 293, 1989 да — 216 кеше.

**БУШКА́НЕЦ** Ефим Григорьевич (12.11.1922, Пермь ш. — 16.11.1988, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1966), проф. (1967). Казан ун-тын тәмамлый (1948). 1946–63 елларда ТАССР Дәүләт музееның фән буенча директор урынбасары. Аның җитәкчелегендә музейның фәнни-тикшеренү, экспозицияләр оештыру һәм нәшрият эшчәнлеге алып барыла; «Болгар дәүләте» (1960–62), «Край территориясендә борынгы община строе», «Татарстан 1917–27 елларда» (1960) экспозицияләре оештырыла; совет чорына караган экспозицияләр үзгәртеп төзелә: беренче мәртәбә «Торгызу чорында мәдәният үсеше», «Бишьеллыклар дәверендә Татарстанда культура революциясе казанышлары» темалары эшләнә. 1963 тән Казан дәүләт пед. ин-тында, рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасын җитәкли, бер үк вакытта 1967–70 һәм 1973–76 да тарих-филология ф-ты деканы була. Төп фәнни тикшеренүләре 19 йөзнең 30–40 нчы һәм 60–80 нче елларындагы рус әдәбияты һәм җәмәгатьчелек хәрәкәте тарихына; рус әдәбиятының тарихи чыганакларын һәм җирле әдәбиятны өйрәнүгә; мемуар һәм эпистоляр әдәбиятның теоретик проблемаларына карый. Б. тарафыннан В.Г.Короленко, А.Н.Толстой, Н.А.Добролюбовның моңарчы мәгълүм булмаган кайбер әсәрләре ачыклана. Казан б-н бәйле булган язучылар иҗатына караган хезмәтләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Путеводитель по Казани. К., 1961; Мемуарные источники. К., 1975.

*Әд.:* А х м е т з я н о в М.Г. Памяти Е.Г.Бушканца // Вопр. источниковедения русской литературы. К., 1989.

*М.Г.Әхмәтҗанов.*

**БУШКО́В** Вениамин Григорьевич (27.08.1909, Вятка губ., хәзерге Киров өлкәсе Уржум өязе Туран а. — 20.04.1990, Казан), вет. хирургы, вет. фән. д-ры (1976), проф. (1977). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1932). 1932–37 елларда Минзәлә р-нында вет.табибе. Бөек Ватан сугышы елларында Ленин-

град шәһәренең гарнизон лазаретында дәвалау бүлеге башлыгы. 1946–84 тә Казан вет. ин-тында, 1971 дә гомуми һәм аерым хирургия каф. мөдире. Төп тикшеренүләре хайваннарда үтәли җәрәхәтләр, буыннар, сөяк сынулар, үзәк нерв системасының функциональ тайпылышларын дәвалауга карый. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**БУШМА́КИН** Николай Дмитриевич (24.7.1875 — 1936), анатом., медицина д-ры (1911). 1899 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Лаеш өязендә земство табибе. 1907–13 тә Казан ун-тында. 1913 тән — Варшава, 1916–19 да — Казан, 1920 дән — Иркутск ун-тлары, 1930 дан Хабаровск мед. ин-тының анатомия каф. профессоры һәм мөдире. 1932 дән Ленинград эксперименталь мед. ин-тында фәнни-тикшеренү эшендә. Хезмәтләре лимфа һәм үзәк нерв системалары анатомиясенә, антропологиягә карый.

**БУЫНТЫ́ГАЯКЛЫЛА́Р** (Arthropoda), умырткасыз хайваннар тибы. Хайваннарның барлык төркемнәре арасында төрләр саны буенча иң күп таралганнар. Дөнья фаунасында 3 млн. нан артык төр исәпләнә, чынлыкта 10 млн. тирәсе булуы да ихтимал. Б. арасында иң борынгылары — трилобитлар, алар кембрийга кадәр үк билгеле. Б. өчен хитинлы кутикула (тышча) белән капланып, сегментларга бүленгән гәүдә һәм буынтыклы очлыклар хас. Сегментлашу гетероном рәвешле, ягъни гәүдәнең төрле өлешләрендәге сегментлар төзелеше буенча төрле һәм алар бүлекчәләргә, ягъни тагмаларга бүленә. 3 тагма — баш, күкрәк, корсак аерылып өйрәнелә. Тагма эчендә сегментлар бер-берсе б-н кушылып китәргә мөмкин. Кутикула катлаулы полисахарид булып саналган хитиннан, липоидлардан, протеиннардан һ.б. матдәләрдән тора. Ул сыгылмалы һәм нык, Б.ның гәүдәсен ерткычлардан һ.б. тышкы тәэсирләрдән саклый. Кайбер төрләрнең (кысласыманнар һәм күбаяклыларның) кутикуласы, кальций, тимер, кремний тозлары сеңгәнлектән, аеруча нык була. Хитин капламында тыгызланган өлешләр — склеритлар һәм нәзек йомшак өлешләр-мембраналар аерылып тора, соңгылары сегментлар арасында була һәм гәүдәнең хәрәкәтчәнлеген тәэмин итә. Хитинлы тышча, саклау функциясеннән тыш, тышкы һәм эчке скелет ролен дә үти. Эчке яктан аңа аркылы-юллы мускуллар бәйләме беркетелгән. Б.ның үсүе вакыт-вакыт кабык салу б-н бергә бара. Гәүдәләренең куышлыгы катнаш типлы. Кан әйләнеше системасы йомык түгел, йөрәкләре бар. саңаклар, трахея яки үпкә аша сулыйлар. Нерв системасы баш миеннән һәм корсак нерв чылбырыннан тора. Күпчелек Б. аерым җенесле, еш кына җенси диморфизмлы. Тип 4 астипка бүленә: трилобитсыманнар (Trilobitomorpha), саңак б-н сулаучылар (Branchiata), хелицерлылар (Chelicerata) һәм трахея б-н сулаучылар (Tracheata).

Трилобитсыманнар — инде үлеп беткән иң гади диңгез Б.ы төркеме. Астибына берничә класс керә, алар арасында трилобитлар классы (Trilobita) иң күп өйрәнелгән һәм төрләр саны буенча иң күп таралган. Әлеге астип өчен хас билгеләр: гәүдәләре баш һәм сегментлы гәүдәгә бүленгән; бер тармаклы бер пар мыекчыклары; ике тармаклы күп функцияле очлыклары бар; саңаклар б-н сулау.

Саңак б-н сулаучылар астибына *кысласыманнар* (Crustacea) классы керә. Болар — буынтыгаяклы беренчел су хайваннары. Бу класс 5 асклasска бүленә, шулардан 4сенең вәкилләре Россиянең Европа өлешендәге һәм ш.у. Татарстандагы төче суларда яши. Болар — *саңагаяклылар* асотрядыннан саңагаяклы кысласыманнар (Branchiopoda); *яфрагаяклы кысласыманнар* отряды; максиллоподлар (Maxillopoda): *ишкәгаяклы кысласыманнар*, карп ашаучылар (Branchiura) отрядлары, кабырчыклы кыслалар (Ostracoda) һәм югары кыслалар (Malacostraca): мизидлар (Mysidacea), кумацийлар (Cumacea), *тигезаяклы кысласыманнар*, тормаяклы кысласыманнар яки *янъйөзәрләр*, *унаяклы кысласыманнар* отрядлары.

Хелицирлылар астибына дүрт пар йөрүчән аяклы Б.лар керә, аларның мыеклары булмый, шунлыктан башындагы беренче очлыклар пары ролен казналыклары — хелицерлар үти. Очлыкларның икенче пары педипальплар дип атала. Хелицерлылар — коры җиргә беренче чыккан хайваннар. Шуңа күрә аларның капламнарында дым югалудан саклый торган өске липопротеин катлам барлыкка килә. Хелицерлылар 2 класска — меростомлылар (Merostomata) һәм *үрмәкүчсыманнарга* бүленә. Хәзерге хайваннардан беренче класска кылычкойрыклар керә. Үрмәкүчсыманнар төркеме бераз киңрәк, аңа чаяннар (Scorpiones), телифоннар (Thelyphones), тартаридлар (Tartarides), пальпиградлар (Palpigradi), фриннар (Amblypygi), *ялган чаяннар*, сольпуглар (Solifugae), *печәнче үрмәкүчләр*, риценулейлар (Ricinulei), *үрмәкүчләр*, акари формалы талпаннар, паразит формалы талпаннар һәм печәнче талпаннар (к. *Талпаннар*) отрядлары керә.

Трахея б-н сулаучылар астибындагы Б.ның бер пар мыекчыгы бар. Астипка түбәндәгеләр керә: күбаяклылар (Myriapoda) (дүрт классның — иренаяклылар, ике пар аяклылар, симфиллар, пауроподларның җыелма атамасы) һәм *бөҗәкләр* классы. Күбаяклыларның гәүдәсе баштан һәм буынтыклы гәүдәдән тора. Гәүдәнең һәр буынчыгында 1–2 пар буынтыклы очлык бар. Бөҗәкләрне 35 отрядка бүлеп өйрәнәләр.

Б.ның, туклану объекты һәм чыганагы буларак (кысласыманнар, бал кортлары), паразитларның арадаш хуҗалары (кысласыманнар, бөҗәкләр), паразитлар, кеше һәм хайваннарның куркыныч авыруларын тудыручыларны күчерүчеләр (талпаннар, бөҗәкләр), куркыныч агулы төрләр (күбаяклылар, үрмәкүчләр, чаяннар, бөҗәкләр), серкәләндерүчеләр, үсемлекләрне саклауның биологик ысуллары объекты (бөҗәкләр) буларак, гамәли әһәмияте зур. Кайберләре а.х. культураларын зарарлый. Б. биосферада мөһим роль уйный. Бик күп санлы булулары аркасында, күпчелек экосистемаларда матдәләр әйләнешенә ярдәм итәләр.

*Әд.:* Жизнь животных. Т. 2. Класс Ракообразные. М., 1968; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Догель В.А. Зоология беспозвоночных. М., 1981; Общая и сельскохозяйственная энтомология. М., 1983; Жизнь животных. Т. 3. Членистоногие: трилобиты, хелицеровые, трахейнодышащие. Онихофоры. М., 1984; Определитель пресноводных беспозвоночных России. Т. 2. Ракообразные. СПб., 1995; Кадастр полезных насекомых Республики Татарстан. К., 2004.

*Р.М.Сабиров, Н.В.Шулаев.*

**БУЯ́У КУАГЫ́** (Genista), кузаклылар семьялыгыннан куак һәм ярымкуакчыклар ыругы. 100 ләп төре билгеле, Европада, Азиядә һәм Төньяк Америкада киң таралганнар. ТРда 2 төре бар. Герман Б.к. (G.germanica) — сирәк төр, Яшел Үзән р-нында очрый. Баллы Б.к. (G.tinctoria) республиканың барлык р-ннарында киң таралган. Коры ылыслы урманнарда үсәләр. Яфраклары вак, кыяк-ланцетсыман. Чәчәкләре сары, чукта, озын себеркәчле чәчәк төркеменә җыелган. Җимешләре — күп орлыклы кузаклар. Герман Б.к. 25–60 *см* озынлыкта, сабагы чәнечкеле; Баллы Б.к. 30–170 *см* озынлыкта, сабагы чәнечкесез. Май–июль айларында чәчәк ата. Орлыклардан үрчи. Б.к.ның җир өстендәге өлешендә — алкалоидлар, аскорбин к-тасы, дуплау матдәләре, чәчәкләрендә эфир мае бар. Үлән төнәтмәсе эч йомшарту, бәвел кудыру һәм тирләтү өчен файдаланыла. Декоратив, аеруча чәчәк аткан вакытта; баллы, агулы үсемлек. Комлы җирләрне ныгыта. Герман Б.к. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БУЯ́У ҮЛӘНЕ́** марена (Rubia), мареначалар семьялыгыннан күпьеллык үләннәр, ярымкуаклар һәм куаклар ыругы. 55 ләп төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясларында таралганнар. ТРда бер төре — татар Б.ү. (R. tatarica). Кама елгасының уңъяк ярларында очрый. Күпьеллык үләнчел үсемлек, озынлыгы 15–30 *см*, агачсыман күп бәбәкле тамырчалы, катлау-катлау булып кубып төшүчән кызгылт кабык б-н капланган. Сабагы туры, ботаклы, 4 кырлы. Аскы яфраклары — каршыдаш, калганнары ланцетсыман, такыяга җыелганнар. Чәчәкләре вак, саргылт-яшел төстә, ярымчатырда, себеркәч чәчәк төркеменә җыелганнар. Җимешләре — шарсыман кара сусыл төшләр. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–август айларында өлгерә. Бик сирәк, юкка чыга баручы төр, ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**«БҮЗ ЕГЕ́Т»**, лиро-эпик поэма (дастан), фарсы телендә мәхәббәткә багышлап язылган ярымфантастик хикәя сюжетына ияреп, 1842 елда *Баһави* тарафыннан Уфа шәһәрендә иҗат ителгән. Дастанның кульязмасын В.В.*Радлов* Семипалатинск өязендә таба һәм 1870 тә Петербургта үз оригинал телендә бастыра. «Б.е.»нең кульязма варианты иске татар телендә, мишәр диалектына һәм казакъ теленә хас элементлар кертеп язылган. Стиленең халык җырлары традицияләренә якын булуы әсәрнең күп кенә төрки халыклар — татарлар, казакълар, башкортлар, нугайлар, кумыклар арасында (шагыйрь *чичәннәр* башкаруында) киң таралуына сәбәп була. Дастан

Казанда беренче тапкыр 1874 тә басыла (*Ә.Кормаши* варианты). Соңрак, бераз үзгәртелеп, берничә тапкыр кабат нәшер ителә. «Б.е.»нең иң тулы варианты 1984 тә «Татар халык иҗаты» сериясенең дастаннарга багышланган томында басылып чыга. Поэмада сүз батырның Карачәчсылуга карата булган фаҗигале мәхәббәте турында бара. Урта гасырларда тудырылган башка Көнчыгыш дастаннарындагы кебек үк, геройлар бер-берсен төштә күреп гашыйк булалар. Күп кенә каршылыкларны җиңеп, дүрт ел буе эзләгәннән соң төп герой — Бүз егет сөеклесен таба. Ләкин кызның атасы шаһ аны башка хан улына кияүгә бирмәкче була. Егеттән котылу өчен аны алдау юлы б-н тотып үтерәләр. Сөйгәненең үлемен кичерә алмыйча, Карачәчсылу да үз-үзен үтерә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**БҮЗДӘ́К РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* көнбатышында. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1710 *км*². Үзәге — Бүздәк авылы (Уфадан 110 *км* көнбатыштарак). Халкы — 31178 кеше (2002). Татарлар саны: 1939 да — 32311, 1970 тә — 20644, 1979 да — 19902, 1989 да — 19756, 1999 да — 21893, 2002 дә 15833 кеше. 84 торак пункт, ш.и. 29 татар, 15 татар-башкорт, 3 татар-рус авылы. Иң зур татар авыллары (1999): Бүздәк (10538 кеше), Кәпәй-Кыбау (1001), Килем (925), Түреш (984). 2004/2005 уку елында Б.р.ның 32 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 1 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татарча «Бүздәк яңалыклары» г-тасы нәшер ителә. Б.р.нда ген.-майорлар Г.Г.Нәфыйков, *Ф.Й.Субаев*, Сов. Союзы Геройлары Ф.Г.*Габдерәшитов*, *Ә.Ә.Фәтхуллин*, Г.Х.Миңнебаев, *М.Х.Сыртланова*; Дан орденының тулы кавалерлары *Х.А.Солтанов*, Т.Җ.*Фәхретдинов*; РФАнең мөхбир әгъзасы *Р.Р.Мәүлетов*, тарих фән. д-ры *Ш.Х.Чанбарисов*, психол. фән. д-ры Ә.З.Рәхимов, пед. фән. д-ры Л.Г.Шәйхетдинов, мед. фән. д-ры Л.Д.Гатауллина, филос. фән. д-ры Р.С.Хаҗиева, химия фән. д-ры З.Я.Янбердина, актёр Н.Н.Сакаев туган.

**БҮКӘЛИ́** (Пүкәли) Фәхреддин Арслан угылы (1801, Мамадыш өязе Пүкәл а. — 1881, шунда ук), шагыйрь. Казан өязендәге Кенәр, Хәтнә авыллары мәдрәсәләрендә белем ала. Хәтнә авылы мәчетенең имам-хатибы. Күренекле замандашларына (Ш.Мәрҗани, Г.Түнтәри, Г.Курсави һ.б.), ш.у. улы Таҗетдингә багышланган мәдхия һәм мәрсияләр авторы. Гали Чокрыйның «Фәүз ән-нәҗат» («Котылу юлы») әсәрен мактап язган шигыре дә бар. 1874 елда бер төркем иске фикерле муллалар, Ш.Мәрҗанинең «*Назурат әл-хак...*» хезмәтен тәнкыйтьләп, «Мозаһәрәт әл-кәлимә әл-җәрүдә әл-ләти һыййа фи ән-Назурат» («Назуратта әйтелгән сүзләргә караш...», 1874) исемле китап бастыралар. Б., Мәрҗани фикерләрен яклап, үзенә тарафдар берничә кеше б-н берлектә, әлеге китап авторларына каршы шигъри җавабын иҗат итә. Бу шигъри җавапларны Ш.Мәрҗани үзенең «*Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар*» хезмәтенең 1 нче томы кушымтасына урнаштыра. Б.нең кульязма шигырьләр җыентыгы Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

*Әд.:* Мәрҗани мәҗмугасы. К., 1915; Ф ә т х и А. Кульязмалар тасвирламасы. К., 1968. 12 чыг.; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

*М.В.Гайнетдинов.*

**БҮКӘНЛЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Омар елгасы буенда. 2002 елда 13 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1710 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элек Кама казна з-дларына беркетелгәннәр) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, мичкә ясау, агач савыт-саба ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство уч-щесе, су тегермәне, шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1965,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Омар волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 143 ир заты; 1859 да — 592, 1897 дә — 896, 1908 дә — 959, 1920 дә — 838, 1926 да — 810, 1938 дә — 389, 1958 дә — 172, 1970 тә — 125, 1979 да — 96, 1989 да — 39 кеше.

*Әд.:* Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1904.

**БҮЛ ИЛЕ́** (Вахитов) авылы. Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2002 елда 815 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Май з-ды. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 1940 ка кадәр Бул иле дип атала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, авылда мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1561,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 141 ир заты; 1859 да — 854, 1897 дә — 1215, 1908 дә — 1380, 1926 да — 1442, 1949 да — 1044, 1958 дә — 998, 1970 тә — 642, 1979 да — 797, 1989 да — 768 кеше.

**БҮЛӘ́К** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 32 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2002 елда 260 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына, 1967 нең 30 декабренә кадәр Сасы Күл дип атала. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, дуга, тәгәрмәч тугымы бөгү, чана һәм чана табаны ясап сату б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Б. тә мәчет була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 2330 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Тымытык волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 502, 1897 дә — 969, 1920 дә — 1344, 1926 да — 602, 1949 да — 302, 1970 тә — 673, 1979 да — 363, 1989 да — 247 кеше.

**БҮЛӘ́К** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 26 *км* көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычы астында калган зона чигендә. 2002 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 1925 тә нигез салына. Күмәкләштерү елларында Б. тә «Байкал» к-зы оештырыла, 1958 дә ул «Җиңү» к-зы составына керә. Беренче көннән үк авыл ТАССРның Минзәлә кантонының Семиостров волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 391, 1949 да — 328, 1965 тә — 253, 1970 тә — 289, 1979 да — 272, 1989 да — 196 кеше.

**БҮЛӘ́К** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сикия елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 143 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 17 йөз ахырында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Б. тә мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет һәм 1 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3671,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 657, 1897 дә — 969, 1920 дә — 926, 1926 да — 810, 1938 дә — 910, 1949 да — 709, 1958 дә — 535, 1970 тә — 467, 1979 да — 354, 1989 да — 202 кеше.

**БҮЛЕНДЕ́К ПРЕДПРИЯ́ТИЕ** (җәмгыять), төп пр-тиедән бүленеп чыккан яисә төп пр-тиегә үз мөлкәтенең бер өлешен хуҗалык итүгә тапшырган һәм аның ярдәмендә оешкан, юридик яктан мөстәкыйль пр-тие. Акцияләренең контроль пакеты хуҗасы — төп фирма (компания). Б.п.ләр еш кына аларны оештырган төп пр-тиеләрнең (фирмаларның) ф-ллары буларак эш итәләр. Бүлендек фирмалар — компанияләрнең тактик һәм стратегик максатларга ирешү инстр-тларыннан бер-

се. Б.п.не оештыру тәртибе юридик затларны оештыру тәртибеннән бер ягы б-н дә аерылмый. Б.п.нең оешуы һәм эшчәнлеге юридик затлар турындагы РФ законнары б-н көйләнә. Б.п.не оештыручы аның уставын раслый, җитәкчесен билгели һәм аңа карата кайбер идарә итү, ш.и. күзәтчелек итү вазифаларын тапшыра. Төп һәм Б.п.нең оешу-хокукый төрләре: АҖләр, компанияләр, хосусый һәм дәүләт пр-тиеләре, банклар һ.б.ш. Б.п.нең тулы ширкәтләр һәм ышанычка корылган ширкәт төрләре дә бар. Алар составына физик, ш.у. юридик затларга да керү хокукы бирелгән. Эшне алып бару тәртибе оештыру шартнамәсе нигезендә төп пр-тие исеменнән билгеләнә. Б.п. төп пр-тиенең (җәмгыятьнең) бурычлары өчен җавап бирми. Б.п. акционерлары төп пр-тие гаебе б-н китерелгән зыянны кайтаруны-каплауны таләп итәргә хокуклы. ТРда Б.п.ләр 1990 еллар башында уздырылган икътисади реформалар чорында барлыкка килә. Шулар арасында: «КамАЗ» АҖнең 8 з-ды, «Транснефть» акционерлык компаниясенең Төньяк-Көнбатыш нефтьүткәргеч магистральләре, җаваплылыгы чикләнгән «Алнас» АҖнең «Әлмәт инструментлар заводы», «Ак барс» банкының Идел-Кама акционерлык банкы (2005 кә кадәр).

*Ш.М.Вәлитов.*

**БҮЛМӘ́ ЧЕБЕНЕ́** (Musca domestica), *чын чебеннәр* семьялыгына керүче бөҗәк. Синантроп төр, космополит. Гәүдәсе 7–8 *мм* озынлыкта, соры төстә, күкрәгендә 4 буй полосасы бар, түше өстән тонык кара, астан саргылт рәсемле. Уртача киңлекләрдә Б.ч. елына якынча 9 буын бирә. Яшәү циклының дәвамлылыгы, тышкы мохиттәге температура һ.б. факторларга бәйле рәвештә, 10 нан алып 45 тәүлеккә кадәр. Ана чебен үз гомеренең 2,5 ае эчендә 600 дән алып 2 меңгә кадәр йомырка сала. Бер салганда уртача 120 йомырка (озынлыгы 1–1,2 *мм*) була; алар 8–50 сәгать үсә. Б.ч. нең личинкалары (озынлыгы 13 *мм* га кадәр) ак төстә, эчәктән тыш аш кайнату үзлегенә ия. Алар азыкка аш кайнату сыекчасы бүлеп чыгаралар һәм ярым эшкәртелгән азыкны суыралар. 3–25 тәүлек үсәләр, аннан соң курчакка әйләнәләр. Курчак дәвере 3 тәүлектән берничә айга кадәр (кышлаганда) сузыла. Б.ч. личинка, курчак яки олы бөҗәк (аталандырылган ана чебеннәр) фазаларында кышлый. Б.ч. күп кенә эчәк авыруларын (корсак тифы, дизентерия, холера) тудыручыларны, гельминт йомыркаларын күчерергә мөмкин.

*А.К.Жеребцов.*

**БҮРӘНӘ́ ГӨМБӘЛӘРЕ́** (Coniophoraceae), корылмаларда агач материалы черүен китереп чыгаручы афиллофор гөмбәләр семьялыгы. 20 ләп төре билгеле, Төньяк ярымшарда очрыйлар. ТРда корылмаларда гына булган (табигатьтә очрамыйлар) гөмбәләрнең берсе — чын Б.г. (Serpula lacrymans) киң таралган. Б.г. гөмбәлеге агачка һәр юнәлештә үтеп керә һәм, аның күзәнәкләре исәбенә туенып, лингиннарны бөтен килеш калдыра. Агач көрән төскә керә, ныклыгын югалта. Черек тиз тарала, моңа агуланган агач өслегендәге гөмбә шнурлары һәм элпәләре ярдәм итә. Черек агачның түбәнге өлешендә итләч-элпәле үрчү өлешләре барлыкка килә. Чын Б.г. караңгыда яхшы үсә. Зарарланган агач ярты ел — бер ел эчендә тулысынча чери һәм таркала. Ш.у. гөмбәлеге, үрчү өлешләре һәрвакыт кардай ак булуы б-н аерылып торган күп санлы вак споралар б-н капланган ак Б.г. (Poria vaporaria) очрый. Черек бүлеп чыгару характеры б-н чын Б.г.нә охшаш, ләкин агачны акрынрак боза, аларның үсеше өчен дымлылыкның 90–95% һәм темп-раның 18–23°С тан югары булуы кирәк. Б.г. б-н көрәш максатыннан төзелештә яхшы киптерелгән урман материалы кулланалар; бинаны дымлылыктан саклыйлар, антисептиклардан файдаланалар.

**БҮРЕ́** (Canis lupus), бүресыманнар семьялыгыннан имезүче хайван. Европада, Азиядә һәм Төньяк Америкада очрый. ТР терр-ясендә зур урманнарда яши. Гәүдә озынлыгы 160 *см* га кадәр, ата бүреләр ана бүреләргә караганда зуррак. Башы һәм муены куәтле, сузынкы танаулы, казналыгы нык үскән, казык тешләре озын. Койрыгы йонтәс, озынлыгы 50 *см* га кадәр һәм, этнекеннән аермалы буларак, һәрвакыт туры. Мехы кабарынкы һәм куе, җәйге вакытта — кыска, тупас



Бүреләр.

һәм каты. Соргылт, соргылт-җирән яки кара кыллар катыш саргылт төстә. Б. — актив ерткыч, яхшы ишетә һәм күрә, көчле, җитез һәм чыдам. Су эчә торган урын тирәсендәге, аулак һәм тын җирне кулайрак күрә. Оясын табигый ышык урыннарда, уентыларда яки чокырларда, ауган агачлар арасындагы агач тамырлары яки кәүсәләре астында, чокыр битләрендә, сазлыкларда ясый. Оясында даими рәвештә бары тик язын һәм җәен, балаларын тудыру һәм тәрбияләү чорында гына яши. Күбесенчә кыргый һәм йорт хайваннары, кошлар б-н туена. Авыру һәм үлгән хайваннарны ашап, табигатьтә санитар ролен үти. Табигый биоценозларда тоязклыларның санын көйләп тора. Ач Б. кайвакыт кешеләргә дә һөҗүм итә. Б. күбесенчә төнлә ауга чыга. Терлекчелек һәм сунарчылык хуҗалыкларына зыян китерергә мөмкин. Б.ләр — моногамик хайваннар. Гомер буе парлы яшиләр. Аталану вакыты — кыш. Гадәттә, 4–6 баласы була. Гадәти шартларда 15 елга кадәр яши. Аларның санын исәпкә алу бик мөһим. Ау ел дәвамында рөхсәт ителә. Котыру авыруы вирусын йөртергә дә мөмкин. Б. йорт этенең (Canis familiaris) ыруг башлангычы булып тора.

*Әд.:* Попов В.А., Лукин А.В. Животный мир Татарии. К., 1988.

**БҮРЕ́ БИСТӘСЕ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 18 *км* көньяктарак, Устье елгасы буенда. 2002 елда 445 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1730 елларда нигез салына. Беренче булып соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелгән отставкадагы солдатлар килеп урнаша. Игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында Космодемьян чиркәве, земство мәктәбе (1866 да ачыла), 5 тегермән, шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете, сырахнә була; сишәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6032 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостена керә. 1920 дән ТАССР ның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән — Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 2166, 1897 дә — 3636, 1908 дә — 4341, 1920 дә — 4167, 1926 да — 3011, 1938 дә — 1563, 1949 да — 901, 1958 дә — 1179, 1970 тә — 984, 1979 да — 679, 1989 да — 499 кеше.

**БҮРЕ́ БӨРЕСЕ́**, карга җиләге (Actaea), казаякчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 лап төре билгеле. Төньяк ярымшарда очрый. ТРда 2 төре үсә, башаклы Б. б. (A.spicata) барлык р-ннарда да киң таралган, кызыл җиләкле Б.б. (A. erythrocarpa) Идел алды һәм Көнчыгыш Кама аръягында очрый, үз ареалының көнбатыш чигендә таралган. Ылыслы һәм катнаш урманнарда, елга буйларында үсә. 30–60 *см* озынлыктагы үсемлекләр. Тамырчасы юан. Яфраклары эре, озын сапта, икешәр-өчәрле. Чәчәкләре саргылт ак төстә, вак, кыска чуксыман чәчәк төркемена җыелган. Җимеше — кара (башаклы Б.б.) һәм кызыл (кызыл җиләкле Б.б.) төстәге күп орлыклы җиләк. Май–июнь айларында чәчәк ата. Дару үләне. Үләне һәм җимешләрендә алкалоидлар, С витамины, тамырларында сапониннар бар. Халык медицинасында башаклы Б.б. тамырларыннан ясалган төнәтмәне баш һәм йөрәк авыртканда, кызыл җиләкле Б.б. тамырлары төнәтмәсен ашказаны-эчәк авырулары вакытында файдаланалар. Агулы. Башаклы Б.б. — декоратив. Кызыл җиләкле Б.б. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**БҮРЕ́ ҖИЛӘГЕ́**, бүре юкәсе (Daphne), бүре җиләкчәләр семьялыгыннан яфрак коючан яки мәңге яшел куаклар, сирәк очракта кечкенә агачлар ыругы. 80 ләп төре билгеле, күбесенчә Европа һәм Азиянең урта поясында очрыйлар. ТРда бер төре — гади Б.җ., яки бүре юкәсе (D. mezereum). Ылыслы һәм катнаш урманнарда, күбесенчә Кама алдының төньяк р-ннарында үсә. Тәбәнәк куак (30–100 *см*). Аз ботаклы аскы ботаклары яфраксыз үсемлек; кабыгы саргылт-соры төстә, ясмыксыман коңгырт төерләр б-н капланган. Һәр ботакның очында ланцетсыман озынча яфраклы бәйләме бар. Чәчәкләре ал төстә,

хуш исле, яфрак куентыгында өчәрләп-бишәрләп урнашканнар, яфрак ярганчы барлыкка киләләр. Җимеше — кызыл, сусыл. Орлыклардан, тамыр үрентесеннән (культурада чыбыкчадан, үрентедән) үрчиләр. Кабыгы һәм агачында гликозидлар, минераль тозлар, сумала, буяу матдәләре, сагыз бар. Халык медицинасында кабыгыннан һәм җиләгеннән ясалган спиртлы төнәтмәсен ревматизм, буыннар авыртканда файдаланалар. Барлык өлеше дә (аеруча кабыгы һәм җиләге) агулы. Баллы. ТРның Кызыл китабына кертелгән.




Гадәти бүре җиләге.

**БҮРЕ́К**, җылы баш киеме, башлык. 19 йөз башына кадәр татарлар зур колакчынлы, биек очлы, маңгайлы һәм арты итәкләнгән Б. кигәннәр. Мондый башлыклар башка төрки халыклар арасында, урта гасырларда Көнчыгыш Европада киң тарала. 19 йөздә татарларда ирләрнең кышкы баш киемнәре арасында эче мех б-н сырылган, тышы тукымадан тегелгән йомры түбәле Б. («мескен» Б., тәвәккәл Б. һ.б.), мех кырпулы Б. (кырпу Б., кама Б. һ.б.) өстенлек ала. Киң мехлы, гадәттә, кондыз мехлы кырпулысын (камчат Б.) олы яшьтәге баерак татар хатын-кызлары да кигән. Алар элегрәк йомшак итеп, ефәк әчлек б-н зәңгәр, яшел, куе кызыл төстәге бәрхеттән тегелгән; Б.нең очына алтын пумалачык куелган, башы бер якка авып торырлык итеп, ялтык өстеннән киелгән. 19 йөз уртасыннан камчат Б., әчлеген сыру юлы б-н, каты итеп тегеләләр, яссы йомры башы еш кына мәрҗән, алтын яисә көмеш җеп б-н чигелә, яки зәргәр аеллар б-н бизәлә. Камчат Б. 20 йөз башында кулланыштан чыга. Кайбер авыл җирләрендә өлкән яшьтәге хатын-кызлар сарык йоныннан бәйләнгән йомры башлы кызгылт көрән төстәге Б. кигәннәр. Дин әһелләре, сәүдәгәрләр, зыялылар арасында каты кырпулы, каракүлдән (каракүл Б., мәскәүский Б.) яки соры бохар илтереннән эшләнгән яссы түбәле данадар Б. киң таралган була. Гадәттә, Б. *түбәтәй* өстеннән киелә һәм аны елның барлык фасылларында да киеп йөриләр.

Кырпу бүрек (1) һәм «мескен» бүрек (2) кигән ир-атлар. 19 йөз ахыры.





Авыл халкы өчен Б.не килеп эшләүче осталар тегә, Казан губернасы Мамадыш өязенең Шәмәрдән, Ядегәр авыллары тегүчеләре аеруча дан казана. 19 йөз урталарында кайбер төбәкләрдә (мәс., Мамадыш, Лаеш өязләре) сарык тиресе, илтер эшкәртү, алардан Б. тегү кәсепчелеге таркау мануфактура төсен ала. Б. б-н Минзәлә, Бөгелмә ярминкәләрендә сәүдә иткәннәр, аны ш.у. Түбән Новгород ярминкәсендә күпләп сатканнар. Хәзерге вакытта Б.нең традицион төрләрен өлкән яшьтәге татарлар яратып кия. Ш.у.к. *Баш киемнәре*.

*Әд.:* Воробьев Н.И. Казанские татары. К., 1953; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала. К., 1995; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

**БҮРЕСАРА́Й** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 10 *км* төньяктарак, Зәй елгасы буенда. 2002 дә 86 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Буранчай-Елга исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык, тәгәрмәч, агач савыт-саба ясау, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1037 дис. тәшкил итә. Авыл халкы 1920 елгы *«сәнәкчеләр» фетнәсендә* актив катнаша. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән — Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 261, 1884 тә — 622, 1913 тә — 592, 1926 да — 487, 1938 дә — 474, 1958 дә — 299, 1970 тә — 173, 1979 да — 211, 1989 да — 101 кеше.

**БҮРЕСЫМАННА́Р**, этсыманнар (Canidae), ерткыч хайваннар отрядыннан имезүчеләр семьялыгы. 35 ләп төре билгеле, Антарктидадан кала барлык материкларда да киң таралганнар. ТРда 4 төре бар: *бүре, төлке*, карсак (Vulpes corsac), *янутсыман эт*. Гәүдәләренең озынлыгы 40 тан алып 160 *см* га кадәр. Койрыгы кабарынкы. Тешләре яхшы үскән. Очлыклары бармакларын йөртә ала торган, алгылары — 5, арткылары 4 бармаклы. Йон капламы бик куе, озын. Тир бизләре начар үскән. Арт юлы тирәсендә еш кына исле бизләр була, бүлендекләр җәнлекләргә характерлы ис — «эт исе»н көчәйтәләр. Гадәттә утрак тормыш алып баралар яки кечкенә генә туктау урыны ясыйлар. Ел дәвамында активлар, бары тик янутсыман эт кенә кышкы йокыга тала. Күбесенчә ялгыз йөриләр, кайберләре өерләре б-н яши. Тояклылар, куяннар, вак кимерүчеләр б-н туеналар. Б. — күп төрле авыруларны (ш.и. котыру авыруы) таратучылар. «*Кощак*» с-зында, «Бөреле» агрофирмасында, «Матюшино» АҖдә һ.б. *ак төлке* (төп токымнары — көмешсыман һәм вуаль төлкеләр), төлке (кызыл һәм көмешсыман) асрыйлар.

*Әд.:* Кузнецов Б.А. Определитель позвоночных животных. М., 1975.

**БҮСЕ́Р ҮЛӘНЕ́**, касык үләне (Herniaria), канәферчәләр семьялыгыннан бер, ике һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 35 ләп төре билгеле, Европада, Азиядә, Төньяк һәм Көньяк Африкада киң таралганнар. ТРда 2 төре — яфраксыз (касык уты), яки шома Б.ү. (H. glabra) — Кама алды һәм Идел аръягы төбәкләрендә; күп җенесле Б.ү. (H. polygama) Кама алдының көнчыгышында очрый. Елга тугайларында, сөзәклекләр һәм текә яр буйларында үсәләр. 5–20 *см* озынлыктагы күпьеллык үсемлек. Үзәк тамырлы. Сабагы киң тармаклы. Яфраклары кара-каршы, вак, эллипс формасында. Чәчәкләре вак, күзгә ташланмый, яфрак куентыгына урнашкан. Җимешләре — һәрберсендә берәр орлыгы булган ачылмый торган тартмачыклар. Май–август айларында чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыклардан үрчи. Үсемлекнең җир өстендәге өлешендә сапониннар, флавоноидлар, кумарин, май бар. Халык медицинасында үләннән ясалган төнәтмәсе бөерләр һәм бәвел юллары авырулары ялкынсынган вакытта файдаланыла. Агулы үсемлекләр.

**БҮСЕРӘ́К** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Урман Зәенең сул кушылдыгы. Озынлыгы 5 *км*, бассейнының мәйданы 19,2 *км*². Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Иске Бүсерәк авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Кече Бүсерәк авылыннан 1,5 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 130 *м*, тамагыныкы — 97 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 47%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,21 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,009 *м*³/*с*.

**БҮШӘРМӘ́** елгасы, Идел алды төбәгендә. Әрә елгасының уң кушылдыгы (Зөя елгасы бассейны). Озынлыгы 8,7 *км*, ТР чикләрендә — 6 *км*. Бассейнының мәйданы 31,7 *км*². Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Чуаш Респ-касы терр-ясендә, тамагы Яшел Үзән р-нының Акъегет станциясеннән 2,2 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 3%. Б. елгасының 2,4 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 87 *мм*, ташу агымы катламы 76 *мм*. Ел дәвамында суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**БЫЗЫЛДАВЫКЛА́Р** (Carabidae), каты канатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Ерткычлар (Adephaga). 20 меңләп төрне үз

эченә алган асотрядыннан иң күп санлы семьялык. ТР терр-ясендә 64 ыругка караган 306 төре теркәлгән. Төрле формадагы, төстәге һәм зурлыктагы (1 дән алып 47 *мм* га кадәр) коңгызлар. Гәүдәләре озынча, матур, аяклары озын, йөгерүгә җайлашкан, мыеклары җепсыман яки кылсыман һәм төп буынтыклардан тыш, куе вак тоташ төкле. Барлык аяклары да 5 буынтыклы, ата коңгызларның алгы аяклары киңәйгән һәм аяк табаннары да төкле. Личинкалары камподеосыман формада. Башы яхшы аерылып тора. Мыеклары 4 буынтыклы, күзләре еш кына 6 була яки бөтенләй булмый. Аяклары 5 буынтыклы. Корсагы 10 сегменттан тора, 8 пар гади сулыш юлы бар. Тугызынчы корсак сегменты, гадәттә, церкалар, унынчысы терәк булып тора. Б. ның күпчелеге ерткычлар, бөҗәкләр, аларның личинкалары, моллюсклар, суалчаннар һ.б. умырткасызлар б-н туена (зоофаглар), кайберләре үсемлек һәм хайван азыклары б-н дә туена (пантофаглар), бик азлары — үлән б-н туенучылар (фитофаглар), алар арасында авыл хуҗалыгы һәм урман культураларын зарарлаучылар да бар, башкалары хайван һәм үсемлек калдыклары б-н туена (сапрофаглар). Б. умырткалы хайваннарның туклану чылбырында әһәмиятле урын алып тора, авыл һәм урман хуҗалыгындагы корткычлар саны динамикасын көйләү процессында зур роль уйный. Б. биоценозда антропоген һ.б. факторлар тәэсирендә үтүче процессларның һәм тереклек итү мохитенең алыштыргысыз индикаторлары булып торалар. Б. ның 16 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1965. Т. 2; Вредители сельскохозяйственных культур и лесных насаждений. Киев, 1974. Т. 2; Жеребцов А.К. Определитель жужелиц Республики Татарстан. К., 2000.

*А.К.Жеребцов.*

**БЫ́КОВ** Константин Михайлович (8.1.1886, Кострома өлкәсенең Чухлома ш. — 13.5.1959, Ленинград), физиолог, мед фән. д-ры (1946), СССР МФА (1944) һәм СССР ФА (1946) академигы, мед. хезмәте генерал-лейтенанты (1946), РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1940). 1912 елда Казан ун-тын тәмамлый. Н.А.*Миславский* һәм И.П.Павлов шәкерте. 1921 дән Ленинградта: 1921–50 дә Экспериментальь мед. ин-тында; 1950–59 да СССР ФАнең И.П.Павлов исем. Физиология ин-ты директоры. Баш мие кабыгы һәм эчке әгъзаларның үзара функциональ тәэсирен, ашкайнату физиологиясен, ярсынуларның химик юл б-н тапшырылуын өйрәнә. Баш миенең зур ярымшарлары кабыгының эчке органнарга тәэсире һәм аларның бу тәэсирне сизүе турында тәгълимат эшли (СССР Дәүләт бүләге, 1946). Эксперименталь курортологиягә нигез салучыларның берсе. 1921 елда аның тарафыннан беренче экспериментальь бальнеология лабораториясе оештырыла. 1940–50 дә Хәрби-диңгез мед. академиясендә физиология каф. башлыгы һәм СССР Хәрби-диңгез флотының баш консультанты буларак, су асты көймәсендә йөзү һәм коткару эшләре вакытында кешенең физиологиясен, электр җәрәхәтләре патологиясен өйрәнә. 1951–59 да РСФСР ЮС депутаты.

Хезм.: Лекции по физиологии пищеварения. Л., 1940; Кора головного мозга и внутренние органы. М.–Л., 1947; Кортико-висцеральная теория патогенеза язвенной болезни. Л., 1949; Избранные произведения: В 3 т. М., 1953–58; Кортико-висцеральная патология. Л., 1960.

*Әд.:* Видные ученые отечественной медицины и здравохранения — питомцы Казанского медицинского института. К., 1989.

**БЫ́КОВ** Фёдор Семёнович (1.2.1885, Сембер губ. Куаклы а. — 8.10.1966, Мәскәү өлкәсе Раменское пос.), график. Мәскәүдәге Строганов техник рәсем ясау уч-щесендә П.А.Лукин (1897–1902), И.А.Анофриевның гравирлау остаханәсендә укый. Ижевск корал ясау з-дында рәссам һәм сызымчы булып эшли (1914–17). 1922–25 елларда Дәүләт нәшриятында китаплар иллюстрацияләи һәм бизи, «Военная мысль» (1921), «Красная новь» (1922) ж-лларында эшли. Бөтенроссия пролеткультында гравюрадан дәресләр бирә (1922–24). 1925–30 да Казанда яши. ТатАХРР әгъзасы (1925 елдан). Казан рәссамнары күргәзмәләрендә катнаша. «Җеп эрләгәндә», «Инглиз доклары» ксилографияләре, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, В.И.Ленин һ.б. портретлар авторы. Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумының графика бүлегендә укыта (1928–29). Шәкертләре арасында Ш.*Мөхәммәтҗанов*, Г.*Йосыпов*, А.Хохряков һ.б. бар. Быковның иҗади һәм пед. эшчәнлеге Татарстанда 1920–30 елларда нәфис полиграфия һәм графика сәнгате үсешенә булышлык итә. 1931 дән Алатырь шәһәрендә гравирлау мәктәп-остаханәсен оештыра һәм шунда укыта (1934–39). 1939 дан Раменское посёлогында яши. Гослитиздат, Детгиз, «Советский писатель» нәшриятлары өчен китаплар иллюстрацияләи һәм бизи. ТатАХРРның 4 нче күргәзмәсендә, «Чуаш АССРның 15 еллыгына (1920–35)» республика күргәзмәләрендә (Чабаксар ш. 1935); «Республиканың 45 еллыгына Чуаш АССР рәссамнары әсәрләре күргәзмәсе»ндә (Чабаксар ш. 1966), «Гравюра һәм офорт күргәзмәсе»ндә (Мәскәү, 1953) катнаша. Б.ның әсәрләре А.С.Пушкин исем. Дәүләт сынлы сәнгать музее тупланмаларында, Чуаш сәнгать галереясында саклана.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1972. Т. 2.

**БЫ́КОВ** Юрий Владимирович (24.9.1940, Казан), инженер-электронщик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Казан авиац. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), «Элекон заводы» АҖдә эшли: инженер, радиотехника бүлегендә бюро башлыгы, сектор, бүлекчә, бүлек башлыгы, АҖнең баш конструкторы урынбасары. 13 ачышка патенты бар. Дәүләт бүләге «Конкурентлыкка сәләтле күп функцияле яңа медицина лазер техникасын уйлап табу, җитештерүне оештыру һәм Татарстан Республикасы медицина оешмаларында кулланышка кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**БЫРГЫ́**, татар халкының тынлы музыка уен коралы. Иренгә куелып уйнала торган табигый көпшә төренә карый. 0,3–0,6 *мм* калынлыктагы калайдан, бармаклар өчен тишекләр уелмыйча эшләнгән 500–600 *мм* озынлыктагы конуссыман көпшәдән гыйбарәт; киң башының диаметры — 90–110 *мм*, тар башыныкы — 12–14 *мм*. Тар башына агачтан ясалган кәтүксыман мөштек киертелә. Авазлар мөштекне кыскан ирен кырыйларының калтырануы нәтиҗәсендә хасил була. Б.да натураль авазлар рәте җиңел табыла. Оста башкаручылар исә көйне төп табигый интерваллар арасындагы арадашчы авазлар б-н дә тулыландыралар. Б. тавышының югарылыгы иреннәрнең киеренкелегенә һәм өрелгән һаваның көченә бәйле. Мөштеккә иреннәрне җиңелчә тидереп уйнаганда түбән тавыш хасил була. Иреннәр мөштекне көчле итеп кысканда урта һәм югары регистрлардагы тавышлар яңгырый. Уен коралының диапазоны бер ярым октава — $c^1$-$g^2$. Б.ның тавышы көчле, тембры яңгыравыклы, кискен. Түбән регистрның динамик мөмкинлекләре — p-mp, урта регистрныкы — f, югары регистрныкы — f-ff. Б. күп кенә башкаручылар өчен сигнал бирү коралы булып тора. Алар уйнаган сигнал төрле ритмик төзелештәге 2–3 аваздан барлыкка килә. Музыкантларның репертуарына ш.у. җыр һәм бию көйләре дә керә. 1970 елларда да Б.ны Алабуга, Әгерҗе, Кукмара р-ннары авылларында очратырга мөмкин була, көтүчеләр аны сигнал бирү өчен кулланганнар.

*Р.Ф.Халитов.*

**БЫРЫ́С** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Каманың уң кушылдыгы. Озынлыгы 32,2 *км*, бассейнының мәйданы 331,8 *км*². Елга башы Питрәч р-нының Яңа Питрәч авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, аз гына Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага, тамагы Лаеш р-ның Имән Кискә авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданы — кушылдыкларының киң үзәннәре б-н бүлгәләнгән, көньякка аз гына авышкан, гадәти эрозия тигезлеге. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 12%. Б. елгасының 2,1 дән алып 10,4 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар, иң зурысы — Сикец елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,11–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 80 *мм*, ташу агымы катламы 66 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,053 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л* га кадәр. Б. бассейнында гомуми күләме 0,7 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**БЫТБЫЛДЫ́К** (Coturnix coturnix), фазан кошлар семьялыгындагы кош. Евразиядә һәм Африкада таралган. ТР терр-ясендә барлык р-ннарда да очрый. Кырларда, су баса торган



болыннарда, урман кисентеләрендә яши. Күчмә кош. Май уртасында очып килә. Гәүдәсенең озынлыгы 20 *см* га кадәр, авырлыгы 70–100 *г*. Кара яки ачык чуар таплы кызгылт көрән, түше ачык төстә, канатлары кара, кызыл-көрән тимгелләре бар. Ата Б.ның муены көрән (көзен ак) төстә, ә ана Б.ныкы аксыл, түше чуар. Томшыгы зур түгел, җиңелчә бөгелгән. Канатлары озын һәм очлы. Койрыгы кыска. Башын әчкә тартып, койрыгын төшереп һәм һәр адымында башын селкеп тиз, әмма иләмсез йөри. Парлашмый. Үлән үскән ачык урыннарда оялый. Көрәнгә кара чуар төшкән 6–20 йомырка сала. Үсемлекләр һәм бөҗәкләр б-н туклана. Кышлау өчен сентябрьдә очып китә.

**БЫЧКО́В** Иван Дмитриевич (23.2.1873, Уфа губ. Минзәлә өязе Орловка а. — 1 яки 2.9.1937, Алабуга ш.), җәмәгать эшлеклесе. 2 сыйныфлы башлангыч уч-ще тәмамлый. 10 елдан артык Минзәлә өязенең 6 волостенда балаларга чәчәк салу үткәрә (1906 га кадәр). 1903 елдан волость старшинасына кандидат булып тора. 1905 тә Уфа губернасында Бөтенроссия крәстияннәр берлеген оештыруда катнаша. Уфа губернасы крәстияннәр куриясеннән 1 нче Дәүләт думасына депутат итеп сайлана (1906), Хезмәтчәннәр төркеме әгъзасы, «Крестьянский депутат» г-тасының редколлегия әгъзасы. Дума таратылганнан соң, хөкүмәткә каршы язылган «*Выборг өндәмәсе*»*нә* кул куйганы өчен 3 айга төрмәгә ябылуга хөкем ителә (Минзәлә төрмәсендә утыра). 1911–15 тә — урман әзерләү эшендә. 1915–22 дә Чаллы өязендә кулланучылар җәмгыятьләрен оештыру б-н шөгыльләнә. 1931–37 дә Коминтерн исем. к-зда эшли, кулга алыну алдыннан колхоздан чыгарыла, итек тегү б-н шөгыльләнә. 1937 елда, Сталинның абруен төшерүдә, Совет хакимиятенең авылда ялгыш сәясәт алып баруы турында ялган хәбәр таратуда гаепләнеп, кулга алына. Атып үтерелә. 1990 ның 3 гыйнварында аклана.

*А.Ф.Степанов.*

**«БЮЛЛЕТЕ́НЬ АСТРОНОМИ́ЧЕСКОЙ ОБСЕРВА́ТОРИИ ИМ. В.П.ЭНГЕЛЬГА́РДТА»** («В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясе бюллетене»), фәнни журнал. Казан ун-ты тарафыннан 1934–65 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. Елга 1–3 сан, барлыгы 38 саны чыга. 1934–56 да «*Учёные записки Казанского университета*» ж-лының «Астрономия» бүлегенә кушымта буларак чыгарыла. Төрле елларда баш мөхәррирләре — Астрономия обсерваториясе директорлары Д.Я.*Мартынов*, А.А.*Нефедьев*, Ш.Т.*Хәбибуллин*. Журналда астрономия өлкәсендәге актуаль тикшеренүләрнең нәтиҗәләре турында кыскача фәнни белдерүләр басыла. Күренекле астрономнар А.Д.Дубяго (кометалар хәрәкәте турында), В.А.Крат, М.И.Лавров, Д.Я.Мартынов (тотылма-үзгәрмә йолдызлар турында), А.И.Нефедьева (фундаменталь астрономия проблемалары турында), А.А.Нефедьев, Н.Г.Ризванов, Ш.Т.Хәбибуллин, А.Я.Яковкин (селенодезия, астрономик вакытның бертөрлелеге, Ай динамикасы турында) һ.б. галимнәрнең мәкаләләре дөнья күрә. Журнал обсерватория китапханәсе фондларын фәнни-астрономик басмалар б-н тулыландыру хезмәтен дә үти. Алмаштыру юлы б-н фондка «Astronomy and geophysics. The Journal of Royal Astronomical Society», «The Observatory» (Бөекбритания), «Annuaire de L'Observatoire Royal de Belgique» (Бельгия), «Annual Report European Southern Observatory», «Apparent Plases of Fundamental Stars» (Германия), «The Journal of the American Assosiation of Variable Star Observers» (АКШ), «L'Astronomie» (Франция), «Publication of the National Astronomical Observatory of Japan» (Япония) һ.б. басмалар алына.

*Н.Г.Ризванов.*

**БЮНЕМАН** (Bunemann) Генрих Людвиг (1752, Германия, Ганновер ш. — 30.7.1808, Казан), хокук белгече, хокук д-ры (1778). Гёттинген ун-тын тәмамлый. 1778 елдан Россиядә яши. 1786–1801 елларда Петербург коры җир кадет корпусының өлкән укытучысы, 1805 тән Казан ун-тында табигыять, сәясәт һәм халык хокукы каф. профессоры.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

# В


**«В МИ́РЕ МУСУЛЬМА́НСТВА»** («Мөселманнар дөньясында»), атналык газета. 1911 елның 3 апреленнән 1912 нең 20 апреленә кадәр С.-Петербургта рус телендә нәшер ителә. Барлыгы 44 саны чыга. *«Мусульманин»* («Мөселман») ж-лының (Париж) дәвамчысы. Мөхәррирләре М.Хаҗи Теләши, А.Датиев. Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан мөселман халыкларының милли хәрәкәтенең асылын бозып күрсәтү, аларны уйлап чыгарылган панисламизм һәм сепаратизмда гаепләүне аклау өчен финанслана. Укучылар, газетаның астыртын ниятен аңлап, аңа язылмый башлыйлар, «В м.м.» укучыларын югалта һәм чыгудан туктый.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Климович Л. Ислам в царской России: Очерки. М., 1936; Мусульманские депутаты Государственной думы России. Уфа, 1998; Хайрутдинов Р. «Мир ислама»: из истории создания журнала // Мир ислама. 1999. № 1.

*Р.Г.Әмирханов.*

**ВАГА́Й РАЙОНЫ́**, *Төмән өлкәсенең* көньяк-көнбатышында. 1931 елда оештырыла. Мәйданы — 18,4 мең *км*². Үзәге — Вагай авылы (Төмәннән 309 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 24256 кеше (2002). Татарлар саны — 10235. Татарлар (кургат-саргат татарлары) В.р.нда элек-электән яшиләр. Идел буе—Урал татарлары биредә 1860–70 елларда урнаша башлый. Россиянең үзәк р-ннарыннан татарлар күпләп 1900–10 һәм 1920–30 елларда күчеп утыра. Хәзерге вакытта В.р.ның 23 мәктәбендә татар теле — фән буларак, 4 мәктәптә факультатив дәресләрдә өйрәнелә. 13 мәчет һәм 1 мәдрәсә эшли, 3 яңа мәчет төзелә. Ел саен татар мәдәнияте фестивальләре үткәрелә. Районның 14 муниципаль берәмлегендә татар үзешчән иҗат коллективлары бар. 1991 дән ТИҮнең 13 башлангыч оешмасы булган район бүлеге эшли.

*Әд.:* Корусенко С.Н., Кулешова Н.В. Генеалогия и этническая история барабинских и кургатско-саргатских татар. Новосиб., 1999.



В.Л. Вагин.



Е.Е. Вагнер.

**ВА́ГИН** Владимир Львович (4.12.1907, Симферополь ш. — 4.1.1984, Казан), зоолог, биол. фән. д-ры (1950), проф. (1955). Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), Бөтенсоюз Арктика ин-тында эшли. 1935 елдан 2 нче Ленинград мед. ин-тында, 1944 тән Ленинград ун-тында. 1955–57 дә Калинин мед. ин-тында гомуми биология каф. мөдире. 1957 дән Казан ун-тында, 1977 гә кадәр умырткасызлар зоологиясе каф. мөдире. 1930–34 елларда «Русанов», «Сибиряков» һәм «Георгий Седов» бозваткычларында океанография экспедицияләрендә, 1947 дә СССР ФАнең Курил-Сахалин экспедициясендә, 1948 дә «Литке» судносында Төньяк диңгез юлы экспедициясендә («Арктика стахановчысы» мактау билгесе), 1950 дә Тын океанның төньяк өлешендә «Витязь» судносында океанография экспедициясендә катнаша. Хезмәтләре салынкы түшле кыслаларның биологиясе, тереклек циклы һәм географик таралуына карый. Салынкы түшле кыслаларның систематикасын тикшерә (1937), аларны мөстәкыйль отрядка (Ascothoracida) аера, бу төркемнең 14 яңа төрен тасвирлый. Илдә беренче мәртәбә диңгездәге паразит олигомер боҗралы суалчаннарны — мизостомидларны (Myzostomida) өйрәнә башлый, аларның яңа ыругын — астеромизостомидларны (Asteromyzostomida) билгели. Экологик эмбриология өлкәсендәге күп кенә мөһим хезмәтләр авторы. Аның җитәкчелегендә Куйбышев сусаклагычында ихтиопаразитологик тикшеренүләр үткәрелә, балыкларның 17 төрендә 85 төрле паразит булуы ачыклана. 1960–64 тә Атлантик океанның төньяк өлешенә һәм Норвег диңгезе р-ннарына «Батайск» фәнни-өйрәнү судносында Казан студентлары катнашында экспедицияләр оештыра.

Хезм.: Asteromyzostomum n.gen — новый представитель класса мизостомид (Annelides) // Тр. Ленингр. Об-ва естествоиспытателей. 1954. Т. 72, вып. 4; О влиянии паразитизма на онтогенез // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1962. Т. 65; О паразитофауне рыб в первые годы заполнения Волжского отрога Куйбышевского водохранилища // Уч. зап. Казан. ун-та. 1966. Т. 123, кн. 7 (автордаш); К вопросу о паразитохозяинных отношениях // Уч. зап. Казан. ун-та. 1968. Т. 126, кн. 3; Мешкогрудые раки — Ascothoracida. К., 1976; О положении мизостомид в системе трохофорных животных // Вопр. эволюционной морфологии животных. К., 1979.

*Әд.:* Голубев А.И., Порфирьева Н.А. Потери науки. Памяти Владимира Львовича Вагина (1907–1984) // Зоологический журн. 1984. Т. 63, вып. 10; Любарская О.Д., Голубев А.И., Порфирьева Н.А. Памяти профессора Владимира Львовича Вагина (1907–1984) // Паразитология. 1998. Т. 32, вып. 3; Grygier M.J. V.L.Wagin's collections of dendrogasteridae (Crustacea: Ascothoracida) in the USSR with designations of Lectotypes // Proc. biol. soc. Wash., 1991. 104 (4).

*Р.М.Сабиров.*

**ВА́ГНЕР** Егор Егорович (17.11.1849, Казан — 14.11.1903, Варшава), химик-органик, химия д-ры (1888), А.М.Зайцев шәкерте. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1874), шунда ук эшли. 1875 елда Петербург ун-тына А.М.Бутлеров һәм Н.А.Меншуткин лабораторияләренә җибәрелә. 1882 дән Ново Александрийск а.х. һәм урманчылык ин-ты (хәзерге Пулавы ш., Польша Респ-касы), 1886 дан Варшава ун-ты һәм Варшава политехник ин-ты профессоры. *Казан химия фәнни мәктәбе* вәкиле буларак, В. үзенең хезмәтләрендә Бутлеров карашларын дәвам итә, А.М.Зайцев б-н берлектә икенчел һәм өченчел спирт алу реакциясен ача (к. *Зайцев-Вагнер реакциясе*) һәм берничә төр спиртны синтезлый. А.Н.Попов тәгъбирләгән кетоннарның оксидлашуы кагыйдәсенә төгәллек кертә. Чиксез углеводородларны калий перманганатының сыек эремәсе б-н оксидлаштыру ысулын (Вагнерча оксидлаштыру) — кабат бәйләнешле кушылмалар төзелешен өйрәнүнең бер әһәмиятле алымын эшли (к. *Вагнер реакциясе*). Аны терпеннарны тикшерүдә кулланып, бу класс кушылмаларының тулы булмаган бәйләнешле икәнен дәлилли; лимонен, карвон, безнең илдәге нарат скипидарларының төп компоненты булган α-пинен һ.б. ның төзелешен исбатлый. Камфенлы яңадан төркемләнүнең беренче төрен борнеолның камфенга һәм киресенә күчү мисалында ача (к. *Вагнер-Меервейнның яңадан төркемләнү ысулы*).

Хезм.: К. строению терпенов и им родственных соединений // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. Часть хим. 1894. Т.26; К истории реакции окисления непредельных соединений // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. Часть хим. 1895. Т.27; О камфениловой кислоте и её производных // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. Часть хим. 1897. Т.29 (автордаш).

*Әд.:* Арбузов А.Е. Казанская школа химиков. К., 1970.

**ВА́ГНЕР** Николай Петрович (19.7.1829, Пермь губ., Верхотурск өязе Богословский з-ды пос., хәзер Свердловск өлкәсенең Карпинск ш. — 21.3.1907, Петербург), зоолог, табигыять фән. д-ры (1854), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1898), язучы. Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1899). П.И.*Вагнер*ның улы. Казан ун-тын тәмамлый (1849). 1849–51 елларда Түбән Новгород дворяннар ин-тында табигать тарихын укыта. 1851–71 дә Казан ун-тында эшли, проф. (1860). 1871 дән Петербург ун-тында. Казан ун-тында хайваннарның чагыштырма анатомиясе буенча фәнни юнәлешкә нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре энтомологиягә карый. 1862 дә педогенез — оры чебеннәре (Cecidomuiidae) семьялыгының миасторлар (Miastor) ыругыннан парканатлы бөҗәкләрнең личинкадан үрчү күренешен ача. Казан икътисад җәмгыяте эшендә катнаша, сумала, нафталин һәм парафиннан — шәм; ясалма сода, язу кәгазе, сумаладан лампа мае һ.б. җитештерү технологиясен эшли (А.М.Бут-

леров һәм М.Я.Киттары б-н берлектә). Казан ун-ты каршындагы Табигать фәннәре белгечләре җәмгыятенә нигез салучы (1869) һәм аның беренче президенты. 1881 дә Соловки биол. станциясен (1958 дән СССР ФАнең Мурманск диңгез биол. ин-ты Кола ф-лы) оештыруны башлап җибәрүче. В.ның әдәби әсәрләре арасыннан иң күренеклесе — әхлакый-психол. эчтәлектәге «Мырауҗан әкиятләре» («Сказки Кота-Мурлыки», М.–СПб., 1872, 4 басма, 1993) китабы.

Х е з м.: Самопроизвольное размножение гусениц у насекомых. К., 1862; Беспозвоночные Белого моря. СПб., 1885; Романы, повести, сказки и рассказы: В 7 т. СПб., 1902–08.


*Әд.:* Ш и м к е в и ч В.М. Н.П.Вагнер и Н.Н.Полежаев. (Из воспоминаний зоолога) // Журн. М-ва народного просвещени:. Новая сер. 1908. Т. 16. № 7, отд. 4; Л и в а н о в Н.А. Зоотомический кабинет КГУ: Из истории воспоминаний (1843–1918) // Вопр. эволюционной морфологии животных. К., 1979.

*Р.М.Сабиров.*

**ВА́ГНЕР** Пётр Иванович (1799 — 3.7.1876, Мәскәү), геолог-минералог, медицина д-ры (1831). Дерпт (1819) һәм Вильно (1826) ун-тларын тәмамлый. 1840–65 елларда Казан ун-тында минералогия һәм геогнозия кафедрасының беренче мөдире, минералогия һәм геогнозия профессоры (1840). 1841 дән геогнозия, 1843–55 тә хайваннарның чагыштырма анатомиясе һәм физиологиясе фәннәрен укыта. Саратов, Сембер һәм Оренбург губерналарында геол. тикшеренүләр үткәрә. 1843 тә Казан губернасы терр-ясендә системалы рәвештә геол. тикшеренүләр оештыра һәм аның беренче геогностик туфрак картасын бастырып чыгара. 1840 та Уралда яңа минерал таба, аны Казан ун-ты попечителе М.Н.Мусин-Пушкин хөрмәтенә «пушкинит» дип атый һәм тасвирлап бирә (эпидотның Na-Li кергән аерым төре, силикатлар классы).

Х е з м.: Геогностическая карта Казанской и Симбирской губерний. СПб., 1855–56; Общий взгляд на геогностический состав почв Казанской губернии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1859. Кн. 1.


**ВА́ГНЕР РЕА́КЦИЯСЕ**, икеләтә бәйләнешле органик кушылмаларның аз селтеле тирәлектә калий перманганаты б-н оксидлашуы (гидроксиллануы):



Еш кына реакцияне сулы органик эреткечләрдә (ацетон, этил спирты, метилциклогексан) үткәрәләр. Күп төрле этилен кушылмалар, ш.и. циклоолефиннар, шикәр, терпен, стероидлар гидроксиллана. Изоляцияләнгән икеләтә бәйләнешле диеннар оксидлашканда, дигликольләр барлыкка килә. 1887 елда Е.Е.*Вагнер* тарафыннан ачыла. Тулы булмаган бәйләнешле органик кушылмаларның төзелешен өйрәнүдә һәм гликольләрне тәҗрибә өчен синтезлауда кулланыла.

*Әд.:* В а ц у р о К.В., М и щ е н к о Г.Л. Именные реакции в органической химии: Справ. М., 1976.

**ВА́ГНЕР-МЕЕРВЕ́ЙННЫҢ ЯҢАДА́Н ТӨРКЕМЛӘ́НҮ ЫСУЛЫ́**, кушу, нуклеофиль алмашу яки элиминирлау (аеру) реакцияләрендә терпен рәте кушылмалар молекулаларында бөҗрасыман (циклик) өлешнең яңадан төзелүе. Алкил яки арил төркемнәренең күрше углерод атомына — катион үзәккә күчеше барлыкка килә (беренче төр камфенлы яңадан төркемләнү):



R=H, алкил яки арил төркеме; $Y^-$= гидроксид төркеме яки көчле кислота анионы; $Z^-$= эреткеч анионы. Углеродның ике атомы да беренчел, икенчел һәм өченчел булырга мөмкин. Процесс эремәләрдә һәм эретмәләрдә протонлы кислоталар яки Льюис кислоталары тәэсирендә җылытканда яки салкында уза; циклларның киңәюе яки тараюына китерә, эреткечнең полярлыгы арту б-н тизлек тә үсә бара. Реакция аеруча бициклик терпеннарга хас, алициклик кушылмалар рәтендә яңадан төркемләнү шул ук рәвештә уза. 1899 елда Е.Е.*Вагнер* ача һәм проф. Г.Л.Меервейн (1910–27) тарафыннан җентекләп өйрәнелә. Сәнәгатьтә камфара һ.б. хуш исле матдәләр алу өчен файдаланыла.

*Әд.:* В а ц у р о К.В., М и щ е н к о Г.Л. Именные реакции в органической химии: Справ. М., 1976.

**ВАГЫ́ЙЗОВ** Рәшит Гаяз улы (28.3.1947, Үзбәкстан ССРның Әндиҗан ш.), хокук белгече, юридик фән. канд. (1998), ТАССР һәм РФнең атказ. хокук белгече (1989, 1997). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1969–70 елларда Тәтеш р-ны прокуроры ярдәмчесе. 1972–76 да Казанның Киров р-ны прокуратурасы тикшерүчесе, прокуроры. 1976–84 тә ТАССР Прокуратурасында прокурор. ТР халык депутаты (1990–2000). 1992–95 тә ТР ЮСның закон, хокук саклау тәртибе, кеше хокукы һәм өстәмә хокук мәсьәләләре даими комиссиясе рәисе, 1995–2000 дә ТР Дәүләт Советының законнар чыгару, закон, хокукый тәртип һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе рәисе. 2000 елдан ТРда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил. Хезмәтләре халыкара һәм гуманитар хокук буенча тикшеренүләргә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татарстанда җинаятьчелеккә каршы көрәш чаралары // Казан утлары. 1996. № 7; Татарстан Республикасында кеше хокуклары һәм хокукый дәүләт төзү // Идел. 1996. № 10; Федерализм: Проблемы соблюдения прав и свобод личности // Современный федерализм: опыт и перспективы. К., 1996; Реальный федерализм как фактор стабильности российского общества // Моск. журн. международного права. 1999. № 1.

**ВАГЫ́ЙЗОВ** Сәләй Гатат улы (20.10.1908, Самара губ., Богырыслан өязе Татар Байтуганы а. — 5.10.2005, Арча), педагог, ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1968), Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, 1936–70 елларда Арча пед. уч-щесендә татар теле һәм методикасын укыта (бүленеп, 1955–60 та Арча р-н халык мәгарифе бүлеге методисты). 1960 еллар уртасыннан Р.Г.*Вәлитова* б-н берлектә милли мәктәпнең башлангыч сыйныфларында татар телен укытуны камилләштерү юнәлешендә эшли. 1965 тә аның б-н «Әлифба» яза, 1970, 1985, 2000 елларда аңа үзгәрешләр кертелә, 2006 да бу «Әлифба»ның 42 нче басмасы дөнья күрә. Болардан тыш, В. һәм Р.Г.Вәлитова 1–2 сыйныфлар өчен татар теле дәреслекләре, уку китаплары, укытучылар өчен укыту әсбабы (1975–2000 елларда үзгәрешләр б-н 5 мәртәбә басыла), пед. уч-щеләр өчен дәреслекләр авторлары. Вагыйзов һәм Вәлитованың методик системасы хәзер дә татар мәктәпләрендә мөһим урын алып тора. В. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, СССР ПФАнең К.Д.Ушинский исем. медале һ.б. медальләр б-н бүләкләнә. ТАССР Мәгариф министрлыгының К.Насыйри исем. бүләге лауреаты (1988).

Х е з м.: Рәсемле әлифба. К., 1965; Туган тел. К., 1969; Кызыклы грамматика. К., 1970; Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы. К., 1975 (Р.Г.Вәлитова б-н берлектә); Татар теле. К., 1982; Latin grafikası nigezendə əlifba. K., 2000 (автордаш).

*Әд.:* И б р а һ и м о в Ф.И. Белем әлифбадан башлана. К., 1994; Вагыйзов Сәләй Гататович. К., 1998.

**ВАЕШУ́Р** авылы, Баулы р-нында Баулы шәһәреннән 35 *км* көньяктарак, Ваешур елгасы буенда. 2002 елда 88 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Поповка волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1926 да — 38, 1938 дә — 72, 1949 да — 145, 1958 дә — 109, 1970 тә — 133, 1979 да — 146, 1989 да — 114 кеше.

**ВАЕШУ́Р** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ыкның сул кушылдыгы. Озынлыгы 10,1 *км*, бассейнының мәйданы 51,8 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Баулы р-нында ага. Елга башы Ваешур авылыннан 1 *км* көнбатыштарак, тамагы Покрау Ырыстамагы авылыннан 1 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 258 *м*, тамагыныкы — 115 *м*. Су җыелу мәйданындагы урман күләме 32%. В. елгасының 1,6 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнга еллык су агып төшүнең уртача күпьеллык катламы 93 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. В. елгасы ноябрьнең беренче ун көнендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык

чыгымы 0,05 $м^3/с$. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ВАЖАШУ́Р** (Быжа́) авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Оча елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 146 кеше (удмуртлар — 62%, татарлар — 38%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, нәселле терлек асрау. Китапханә. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1886 да ачыла), су тегермәне, 2 тимерчелек, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 836,3 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 10 ир заты; 1859 да — 225, 1897 дә — 363, 1908 дә — 420, 1920 дә — 413, 1926 да — 417, 1938 дә — 312, 1958 дә — 339, 1970 тә — 296, 1979 да — 255, 1989 да — 185 кеше.

**ВАЗА́НОВ** Андрей Юрьевич (24.7.1962, Казан), юстиция генерал-майоры (2002), ТРның атказ. хокук белгече (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1984). 1984–88 елларда Казанның Киров р-ны эчке эшләр идарәсе тикшерүчесе. 1988–94 тә ТР Эчке эшләр министрлыгының Баш тикшерүләр идарәсендә өлкән тикшерүче, җитәкче урынбасары. 1994–98 дә Яшел Үзән Эчке эшләр идарәсенең, 1998–99 да Казан шәһәре Эчке эшләр идарәсенең тикшерүләр бүлеге башлыгы. 1999 елдан ТР эчке эшләр министры урынбасары — ТР Эчке эшләр министрлыгының Баш тикшерүләр идарәсе башлыгы. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ВА́ЙДА** Александр Васильевич (15.11.1947, Ульянов өлкәсенең Иске Майна р-ны Сталино пос.), милиция генерал-майоры (1998), ТРның атказ. эчке эшләр хезмәткәре (2002). Казан төзүче-инженерлар ин-тын (1980), СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясен (1989, Мәскәү) тәмамлый. 1968–69 елларда ТАССР Җәмәгать тәртибен саклау министрлыгының Яшел Үзән р-ны буенча янгын күзәтчелеге бүлеге, 1969–70 тә хезмәт ияләре депутатларының Яшел Үзән шәһәр советы башкарма ком-тының эчке эшләр бүлеге инспекторы. 1970 елдан ТАССР Эчке эшләр министрлыгында: инспектор (1974 кә кадәр), 1978–81 дә янгын сүндерү штабы башлыгы, 1981–82 дә дәүләт янгын күзәтчелеге бүлеге башлыгы урынбасары, 1982–87 дә — янгыннан саклану идарәсенең хезмәт һәм әзерлек бүлеге, 1989–91 дә тәрбия эшләре идарәсе, 1992–93 тә — Төзәтү эшләре идарәсенең тәрбия эшләре бүлеге, «Охрана» берләшмәсе, 1993–95 тә Ведомстводан тыш саклау идарәсе башлыгы урынбасары. 1995–98 дә (бүленеп) РФ Эчке эшләр министрлыгының Ведомстводан тыш саклау эшләре баш идарәсе башлыгы урынбасары. 1998 дән ТР эчке эшләр министры урынбасары.

**ВА́ЙНЕР** Борис Гиршевич (псевд. Сулимов) (25.1.1948, Сахалин өлкәсенең Курил р-ны Буревестник пос.), язучы, тәрҗемәче. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1970). 1975–78 елларда күптиражлы «Калининец», 1978–90 да «Вечерняя Казань» г-таларында эшли, 1993–96 да — «Барабашка», 1996 елдан «Зонтик» балалар ж-ллары баш мөхәррире. Шигырьләрен «Весёлые картинки», «Крокодил», «Огонёк», «Аврора» (С.-Петербург) ж-лларында, «Литературная газета»да бастыра. Балалар өчен язылган «Нинди көн бүген!» («Что за день сегодня!», 1982), «Без Барбос белән» («Мы с Барбосом», 1987), «Бармалейны саклагыз» («Берегите Бармалея», 1998), «Тамчы да куркыныч түгел» («Ни капельки не страшно», 2001) шигырь җыентыклары, «Көзгедәгечә» («Зеркальный вариант», 1983), «Вак-төяк күңелсезлекләр» («Мелкие неприятности», 1989) «Тылсымлы көзге» («Чудесное зеркало», 2006) юмористик хикәяләр җыентыклары авторы. Инглиз теленнән Э.Блайтон, Д.Джекобс, Р.Брэдбери, Д.Раскин әсәрләрен, татар теленнән М.Җәлил, Г.Бәширов, Н.Арсланов, К.Булатова, Р.Миңнуллин әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә. Ш.Галиевнең «Куян кергән түтәлгә» («Заяц на грядке», Г.-Х.Андерсен исем. халыкара диплом, 1982) китабы тәрҗемәчеләренең берсе. Курчак театры өчен пьесалар, сценарийлар, җыр текстлары авторы. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2008).

**ВАЙС** Соломон Иосифович (1895, хәзерге Польша Респ-касының Петраков ш. — 22.04.1968, Иркутск ш.), стоматолог, мед. фән. д-ры (1946), проф. (1947). 1924 елда Харьков мед. ин-тының одонтология һәм 1932 елда дәвалау ф-тларын тәмамлый, 1937 елдан шунда ук эшли. 1938–51 елларда Казан ГИДУВында һәм Казан стомат. ин-тында стоматология терапиясе каф. мөдире. 1951 дән Иркутск мед. ин-тында шул ук исемдәге каф. мөдире. Хезмәтләре тешнең үзәк тукымасы авыртуын һәм тешнең каты тукымасының сызлавын бастыруга, теш уртларындагы һәм авыз куышлыгындагы лайлалы яры авыруларын дәвалауга карый.

Х е з м.: Анафилактическая реакция слюнных желез собаки. К., 1946; Болезни пульпы зубов. М., 1959; Терапевтическая стоматология. М., 1965.

*Әд.:* Соломон Иосифович Вайс: К 70-летию со дня рождения // Стоматология. 1966. № 3.

**ВАК БАЛЫКЛА́Р**, т ю л ь к а л а р (Clupeonella), сельд балыклар семьялыгыннан балыклар ыругы. Өч төре билгеле. Каспий (аларны килька дип атыйлар), Кара һәм Азов диңгезләрендә яшиләр. ТРда бер төре — чархаль сельде — Каспий В.б.ның Идел түбәнлекләреннән Идел һәм Кама сусаклагычларына төче сулыкларда яши торган формасы (C. cultriventris) үтеп кергән. Зур балыкларның озынлыгы 14 *см* га кадәр, авырлыгы 15 *г* чамасы. Тәңкәләре циклоидалар рәвешендә, вак, тыгыз урнашкан. Бугазыннан анальярыгына кадәр киль сузыла. Авызы кечкенә, тешсез. Арка йөзгече артында май йөзгече бар. Яшәвенең 1 нче елында җенси җитлегә. Май ахыры — июньдә су темп-расы 14–18 °С булганда уылдык чәчә. Үрчемлелеге 5–60 мең бөртек уылдык. Зоопланктон, ш.у. маймычлар б-н туена. 1–2 ел яшиләр.

**ВАК САРУ́Т**, м а м ы г у т (Puccinellia), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 120 ләп төре билгеле, Европа һәм Азиядә үсә. ТРда бер төре — сирәк кыяклы мамык үлән (P. distans). Субүләрләрнең көньяк сөзәклекләрендә, җиңелчә тозлак туфраклы уйсу болынлыклар һәм тугайларда, күбесенчә Кама аръягы төбәкләрендә үсә. 15–50 *см* озынлыктагы күпьеллык үсемлек. Көпшәк тармаклы, кайвакыт җир өстенә түшәлгән бәбәкле кыяк. Сабаклары шәрә. Яфраклары яссы, өстән кытыршы. Чәчәк төркеме — җәелеп үскән яки кысылган себеркәч. Озынча башаклы, 3–6 чәчәге бар. Җимеше — бөртекчә. Июнь-июль айларында чәчәк ата. Чәчәк атканчы — а.х. терлекләре өчен туклыклы азык.

**ВАК ҺӨНӘРЧЕ́-КӘСЕПЧЕЛӘРНЕ́Ң КАЗА́Н ҖӘМГЫЯТЕ́** (Казан шәһәре һәм бистәләренең вак кәсепчеләр һәм һөнәрчеләр комитеты), 1925 елның сентябрендә вак кәсепчелек б-н шөгыльләнүчеләрнең гомуми җыенында оештырыла (Уставы 25 ноябрьдә теркәлә). Казандагы кечерәк сәнәгать оешмаларындагы эшче һәм һөнәрчеләрне, аерым төркемнәрдә торучы йөк ташучыларны берләштерә. Максаты: җәмгыять әгъзаларының һөнәри-җәмгыяви үсешенә ярдәм итү, аларның матди хәлен кайгырту, мәдәни чаралар күрү. 1930 ның 6 февралендә эшчәнлеге туктатыла.

**ВАК ЧИКЕРТКӘЛӘ́Р**, *саранчалыларның* ялгыз тереклек итә торган төрле, күбесенчә вак төрләренең гомуми исеме. Россиядә 70 ләп төре билгеле. Киң таралганнар. Татарстан терр-ясендә а.х. үсемлекләрен һ.б. зарарлаучы себер В.ч. (Gomphocerus sibiricus), ак буйлы В.ч. (Chorthippus albomarghinatus), тәресыман В.ч. (Pararcyptera microptera) очрый.

**ВАК ЧУЕРТА́Ш**, вакланган көпшәк утырма токымнар; теге яки бу дәрәҗәдә шомартылган тау токымнары, сирәк очракларда зурлыклары 1–10 *мм* (тау эшендә 5–70 *мм*) булган минерал кисәкләр. Татарстанда В.ч. чыганакларының гранулометрик составы һәм физ.-механик үзенчәлекләре — фракцияләре 5–10 *мм* — 14,7–84,4%, уртача тыгызлыклары 1476–1740 $кг/м^3$, бушлыкларының күләме 28–37%, ләм һәм балчык катнашмасы 0,2–9%, вакланучанлыгы ДР-8-ДР-16, ышкылучанлыгы И-20-И-25, копёр сугуы күрсәткече У-75, салкынга чыдамлылыгы МРЗ-25-МРЗ-50. Петрографик составы: чакматаш һәм катнаш токымнар (30–50%), кварц, кварцит (10–30%), вулкан атып чыгарганы (30–50%), карбонатлы токымнар (4%). Барлыкка килүе буенча В.ч. елга, күл, диңгез һәм су-бозлык төрләренә бүленә.

Гадәттә, елга һәм үзән террасалары утырмаларының түбән горизонтларында ята (ш.и. Татарстан терр-ясендә дә); су-бозлык утырмаларында — кам һәм озларда (ТРдан төньяктарак), диңгез яры өемнәрендә. Цементланып каткан В.ч. гравелит дип атала. Татарстан терр-ясендә Кама буе үзәнлекләр утырмалары арасында комлы В.ч. катнашмасының 40 лап чыганагы билгеле (ш.и. *Танай ком-чуерташ чыганагы*), аларның сәнәгый запаслары 360 млн. *м*³ чамасы, 14 чыганак эшкәртелә, 3,5 млн. *м*³ чамасы чимал алына (1997). Бетонны тулыландыручы эре катнашма буларак — юл төзелешендә, сууткәргеч фильтр итеп һ.б. максатларда кулланыла. ТР чыганакларының В.ч.лары гидравлик бетон блоклар коюда, М-200, М-300 маркалы бетон эшләүдә, юл төзелеше өчен вакланган таш ясауда кулланыла.

*Г.И.Бирюлёв.*

**ВАКБА́Ш**, дәрвиш үләне (Erigeron), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер, ике һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 250 ләп төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америкада таралганнар. ТРда 4 төре бар. Зәһәр В. (E. acris), Урал В. (E. uralensis), Канада В. (E. canadensis) барлык р-ннарда да очрый; Подольск В. (E. podolicus) — сирәк очрый торган төр. Нарат урманнарында, басуларда, сөзәклекләрдә, чүпле җирләрдә үсәләр. 10–80 *см* озынлыктагы үсемлекләр. Сабагы туры, каты төкле. Яфраклары чиратлашкан, кырыйлары шома яки тешле читле. Чәчәкләре тоныкзәңгәр, аксыл шәмәхә, алсу төстә, кәрзиннәрдә, чуксыман яки себеркәчсыман чәчәк төркеменә җыелган; кырыйдагы чәчәкләре — телсыман, уртадагылары — көпшәсыман. Җимеше — орлыкча. Июнь–августта чәчәк аталар. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчиләр. Халык медицинасында Канада В.ның сабак һәм чәчәк төнәтмәсе сидек куыгы ялкынсынганда, үпкәгә, ашказаны-эчәккә кан сауганда файдаланыла. Баллы үсемлекләр.

**ВАКЛАНГА́Н ТАШ**, 1) тау токымнарының очлы-кырлы кисәкләре (100 *мм* га кадәр зурлыкта), көпшәк яки аз цементланган тупламалар рәвешендә очрый; 2) тау токымнарын яки ясалма ташны ваклау һәм вату юлы б-н җитештерелгән материал (5–150 *мм* зурлыкта). ТРда В.т. җитештерү өчен яраклы булган төзелеш ташының (известьташ, доломит) 40 чыганагы билгеле, шуларның 20 дән артыгы эшкәртелә. Чыганакларның күбесе кечкенә дип карала, аларның запасы якынча 5 млн. *м*³. Төзелеш ташының гомуми запасы якынча 60 млн. *м*³ тәшкил итә (2002). Татарстанда известьташ һәм доломитлар бик ныклы түгел, алардан алынган В.т. бары тик 200–400 һәм сирәгрәк 400–600 маркасына туры килә һәм ул эшкәртүсез чыгарыла. В.т.ның иң күбесе Биектау (якынча 200 мең *м*³), Питрәч (100 мең *м*³) һәм Югары Ослан (50 мең *м*³) р-ннары карьерларында чыгарыла. ТРда В.т. ка булган ихтыяҗ яртылаш кына үтәлә. Чыганакларда карбонат токымнарының файдалы катлам калынлыгы 3 тән алып 8 *м* га кадәр.

Бетон җитештерүдә, автомобиль юлларының нигезен салу һәм җәюдә — тутырма, тимер юллар салуда балласт катламына материал буларак, ш.у. гидротехник корылмалар төзүдә кулланыла. Кулланылышына карап, бик нык һәм тыгыз токымнарны (гранит, диабаз, кварцитлар һ.б.) яки ныклыгы зур булмаган известьташ, доломит, комташларны һ.б. файдаланалар. Җиңел бетоннар өчен күзәнәкле токымнардан һәм материаллардан торган В.т.лар: күбек ташлар, туф, шлаклар кулланыла. Татарстанда В.т. югары Пермь-Казан һәм сирәгрәк Татар ярусларының карбонат токымнарыннан (известьташ, доломитлар) алына, нык токымнардан алынган В.т. тулысынча читтән кертелә.

*Әд.:* Шишкин А.В. Карбонатное сырье для производства строительного камня // Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Шишкин А.В., Васянов Г.П. Доломито-известняковый тип // Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 2001. Ч. 3.

*А.В.Шишкин.*

**ВАКЛА́П САТУ́**, к. *Сәүдә.*

**ВА́КУУМЛЫ МАШИНАЛА́Р ТӨЗҮ́ ИНСТИТУТЫ́**, к. *ВАКУУММАШ.*

**«ВАКУУММА́Ш»**, химия һәм нефть машиналары төзү предприятиесе. Казанда урнашкан. 793 кеше эшли (2005). «В.» — РФдә вакуумлы җайланмаларны тикшерү, эшкәртү һәм сәнәгый эшләп чыгару буенча иң эре пр-тие. 1975 елда Казан механика з-дын (баш пр-тие; 1943 елда трактор моторларын ремонтлау һәм а.х. машиналарына запас частьләр эшләп чыгару з-ды буларак нигез салына), Вакуумлы машиналар төзү фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык ин-тын (1960 та нигез салына; 1986 дан фәнни-техник үзәк) һәм Вакуумлы машиналар тәҗрибә з-дын (1960 та нигез салына; 1986 дан фәнни-техник үзәк) берләштерү юлы б-н оештырыла. 1981 дән — фәнни-җитештерү берләшмәсе, 1993 тән АҖ. Казан механика з-ды составына механик җыю производствосы, эретеп ябыштыру һәм кою цехлары, штамплау, әзерләү, халык куллану товарларын эшләп чыгару участоклары, производство б-н автоматлаштырылган идарә итү системасы керә. Фәнни-техник үзәк структурасында фәнни-тикшеренү, конструкторлык бүлекчәләре, тәҗрибә производствосы бар.


Казан механика з-ды, үзгәртеп корулардан соң (1959), вакуум җайланмалары җитештерүгә керешә. Прогрессив һәм уникаль технологияләр үзләштерелә: аргон-дугалы һәм микроплазма ысулы б-н эретеп ябыштыру, ябыштыруның заманча алымнары; вакуумда пыяла һәм металл фольганы тузанландырып сиптерү юлы б-н югары сыйфатлы итеп каплау. Механик җыю производствосы санлы программалар б-н идарә ителә торган югары җитештерүчәнлекле станоклар б-н җиһазландырылган. «В.» механик насослар (су-боҗралы, пластиналы-роторлы, мембраналы, ике роторлы), агымлы (пар эжекторлы, катнаш пар-майлы), бөтен төр насослар җирлегендәге агрегатлар; вакуумлы арматура; корылай кудыру, киптерү һәм тузанландырып сиптерү өчен уникаль вакуумлы җайланмалар эшләп чыгара. Пр-тие халык кулланышы товарлары — «ВАЗ» автомобильләре өчен күзне чагылдырмый торган югары сыйфатлы көзгеләр, көнкүреш көзгеләре, тоныкландырылган пыяла, металл фольга (титан нитридыннан саклагыч һәм декоратив өслекле) җитештерә. Җитештерелгән продукциянең еллык күләме 186 млн. сум тәшкил итә (2005). Чимал б-н, башлыча, Россиянең металлургия һәм химия сәнәгате пр-тиеләре тәэмин итә. Вакуумлы техниканы төп куллануче лар: электроника, электротехника, металлургия, нефть-газ эшкәртү сәнәгате, мед. учреждениеләре, агросәнәгать комплексы пр-тиеләре. Предприятие БДБ илләренә, Германия, Иран һәм Тайваньга продукция чыгара. «В.» — «Вакуумная техника и технология» халыкара ж-лын оештыручыларның берсе (1991). Предприятие илнең икътисадын үстерүгә һәм бөтендөнья икътисадына керткән өлеше һәм конкуренциягә сәләтле югары сыйфатлы продукция җитештергәне өчен «Алтын глобус» халыкара призы б-н бүләкләнә (1993). Төрле еллардагы җитәкчеләре: Казан механика з-дында — И.М.Головицер (1943–60), А.Ф.Исаков (1960–66); Вакуумлы машиналар төзү фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык ин-тында — А.А.Абецедарский (1960–71, нигез салучы һәм баш конструктор), М.Г. Шакиров (1973–81); «Вакууммаш» АҖдә — В.В.Леонов (1981–85), Н.Ф.Капустин (1991–2006), Е.Н.Капустин (2006 дан).

*Әд.:* Соколов А.А. Казанский механический завод. К., 1969; Капустин Н.Ф. Казанскому предприятию «Вакууммаш» — 50 лет // Вакуумная техника и технология. 1994. № 3–4; шул ук. «Золотая звезда» «Вакууммаша» // Научный Татарстан. 1996. № 4.

*Г.Я.Мәүлетова, М.Ш.Галимәрдәнов, Р.М.Бакаев.*

**«ВАКЫТ»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1906 елның 21 февраленнән 1918 нең 26 гыйнва-

1. УВН-4М металлаштыручы вакуумлы җайланма; 2. DFR серияле диффузия насосларын җыю.





рына кадәр Оренбургта татар телендә нәшер ителә (1917 нең октябреннән «Яңа вакыт»). 1913 кә кадәр атнага 2–3 тапкыр, аннан соң көн саен басыла. Барлыгы 2308 саны чыга. Наширләре бертуган З. һәм Ш.Рәмиевләр, мөхәррирләре Ф.*Кәрими*, 1917 нең октябреннән Я.*Вәли*. Актив язышучылары: Һ.Атласи, З.Бәшири, М.Бигиев, Ә.Вәлиди, Җ.Вәлиди, М.Галәү, Г.Гобәйдуллин, М.Гафури, Г.Гыйсмәти, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Ш.Мөхәммәдов, С.Сүнчәләй, Р.Фәхретдин, Б.Шәрәф, З.Ярмәки. 1909 ел гыйнварына кадәр Ф.Кәрими басмаханәсендә, аннары Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә басыла. Һәр санда чит ил һәм Россия хәбәрләре, җирле яңалыклар, газетаның үз хәбәрчеләре язмалары һ.б. урын ала. Газетада сәяси мәсьәләләргә зур игътибар бирелә, Дәүләт думасындагы мөселман фракциясе депутатлары эшчәнлеге яктыртыла. Игенчелекне яхшырту ысуллары, һөнәрчелек һәм сәүдәне камилләштерү, татарларның икътисади белемен күтәрү зарурлыгы турындагы мәкаләләр басыла. «В.» битләрендә әдәбият, тел, музыка, театр, мәгариф, фән, дин, татар мөселман хатын-кызларының гаиләдәге роле мәсьәләләренә караган, мөселманнар арасында таралган хорафатларны тәнкыйтьләгән мәкаләләргә зур урын бирелә. Халыкка аң-белем таратуда татар интеллигенциясенең роле яктыртыла. Татар алфавитын камилләштерү, музейлар ачу, татар газеталарына әдәби кушымталар бирү мәсьәләләре күтәрелә. Европача белемле укытучы кадрлар әзерләүгә игътибар ителә. Үзидарә органнарында эшләү мөмкинлеге алу өчен яшьләр рус телен өйрәнергә, мәгариф мәсьәләләре турында фикер алышу өчен укытучылар съездларын үткәрергә тиешләр, диелә. Милли һәм дини мәсьәләләрне яктыртуда «В.» үз артыннан иярген барлык татар вакытлы матбугатына үрнәк булып тора; башка татар басмалары мөхәррирләре кире каккан кискен карашлы материалларны бастырып чыгара. 1906–07 дә «Әдәбият капчыгы» исемендә шигъри кушымта бастыра; 1908–18 дә кушымта рәвешендә «Шура» ж-лын нәшер итә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Самойлович А. Мусульманская периодическая печать. Печать русских мусульман // Мир ислама. 1912. Т. 1, № 2.

*А.М.Ахунов.*

**«ВАКЫ́Т» БАСМАХАНӘСЕ́**, Оренбургта шул исемдә чыккан газета басмаханәсе. 1909 елда бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр тарафыннан ачыла. Иң яхшы җиһазланган татар матбагаларының берсе. 1918 гә кадәр 222450 данә гомуми тираж б-н 125–130 лап исемдә татарча, казакъча китап бастыра. Алар арасында Риза Фәхретдиннең 39 исемдәге китабы, Фатих Кәриминең «Дөнья халыклары» сериясендәге китаплары, дәреслекләр, географик карталар, төрле белешмәлекләр, фәнни-популяр хезмәтләр, матур әдәбияттан Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Н.Думавиларның әсәрләре, Абай шигырьләре (1916), рус язучылары һәм галимнәре иҗатыннан тәрҗемәләр, казакъ авторлары әсәрләре, Шәрекъ фольклоры үрнәкләре һ.б. бар. Күпчелек китаплар «Вакыт» г-тасы редакциясе заказы б-н, аерым басмалар «Хезмәт» нәшрияты, «Хөсәен Хөсәенов һәм К°» ширкәте, Себер һәм Оренбург земство идарәләре, татар китапханәләре (Кустанай, Орск һ.б.), хосусый наширләр заказы б-н басыла. «Вакыт» г-тасы һәм «Шура» (1909–18) ж-лы, казакъ телендә «Казакъ» г-тасы (1913 — гыйн. 1918) да шушы матбагада чыга. Матбага эшләре б-н язучы Ярулла Вәли җитәкчелек итә. Совет хакимияте кулына күчкәннән соң, 1918–19 да матбагада 5 исемдә китап басылуы мәгълүм. 1920 нең апреленнән Казакъстан хөкүмәте карамагына күчә.

*Әд.:* Хәмидуллин Л. Матбагачы Рәмиевләр // Мәгариф. 2000. № 2; Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; шул ук. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932) К., 1999.

**ВАКЫТЛЫ́ РЕВОЛЮЦИО́Н КОМИТЕ́Т** (ВРК), Совет хакимиятенең Казан губернасында вакытлыча оештырылган вәкаләтле оешмасы. 1920 елның июнь-сентябрь айларында эшли. Бөтенроссия ҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 нең 27 маенда игълан ителгән «Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы» турындагы декреты нигезендә оештырыла. ВРК рәисе һәм әгъзалары исемлеге 10 июньдә РКП(б) ҮК Политбюросы утырышында карала һәм раслана. Рәисе — С.Сәетгалиев, әгъзалары — И.Казаков, К.Хәкимов, К.Мохтаров, И.Ходоровский, Б.Гольдберг, А.Бочков. Максаты — ТАССР Советларының 1 нче оештыру съездын әзерләү һәм уздыру. Съезд барышында ВРК үз вәкаләтләрен яңа сайланган ТАССР ҮБКга һәм ХКСка тапшыра. ВРК алдында торган төп бурычлар: булачак милли мохтариятның расланган проект нигезендә биләмә чикләрен, өяз, волость биләмәләрен билгеләү, яңа чик-биләмәләрдә җирле идарәләрне оештыру; Совет хакимиятенең үзәк органнары карарларын тормышка ашыру, урыннарда тәртип саклау. Казан губерна ком-ты үз вәкаләтләрен ВРКга 25 июньдә тапшыра. ВРКта 14 бүлек эшли: 1) ХХС — җитәкчесе М.Рошаль; 2) губернаны азык-төлек б-н тәэмин итүче бүлек — Барабарчук; 3) финанс бүлеге — А.Гордеев; 4) гадәттән тыш хәлләр комиссиясе — Г.Иванов; 5) хәрби комис-т — Ительсон; 6) сәламәтлек саклау — К.Мохтаров; 7) эчке эшләр — Г.Мансуров; 8) җир эшләре — Ю.Вәлидов; 9) халык мәгарифе — К.Хәкимов; 10) эшче-крәстиян инспекциясе — А.Насыйбуллин; 11) юстиция — А.Нехотяев; 12) статистика — В.Ермолаев, 13) хезмәт — А.Догадов, 14) социаль тәэминат бүлеге В.Исхаков.

Чыг.: Образование ТАССР: Сб. док. и материалов. К., 1963.

*Әд.:* Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

**«ВАКЫТЛЫ́ ТАТА́Р МАТБУГАТЫ́ (АЛЬБО́М)»**, аннотацияләнгән библиографик күрсәткеч. 1905–25 елларда Россиядә һәм чит илләрдә татар телендә нәшер ителгән газета һәм журналлар теркәлгән. Авторы һәм төзүчесе И.*Рәмиев*. 1926 да Казандагы «*Гаҗур*» басмаханәсендә татар телендә гарәп графикасында нәшер ителә. Альбом С.Атнагулов һәм И.Рәмиевнең кереш сүзе б-н ачыла. Хронологик тәртиптә төзелгән 16 бүлектән тора: газеталар (1905–17; 29 исем); журналлар (1905–17; 33 исем); Февр. рев-циясеннән соң чыга башлаган милли-буржуаз вакытлы матбугат — газеталар (1917–18; 17 исем); журналлар (1917–18; 6 исем); Февр. рев-циясеннән соң чыга башлаган социалистик вакытлы матбугат (1917–18; 13 исем); хәрби газеталар (8 исем); Мөселман эшләре халык комис-ты тарафыннан чыгарылган вакытлы матбугат (1918–19; 9 исем); баш күтәргән чех-словак корпусы, Колчак армиясе чыгарган контрреволюцион матбугат (1918–19; 12 исем); «Кызыл фронт» г-талары (1918–22; 13 исем); совет һәм партия матбугаты (1919–25; 48 исем); авылга йөз тоткан вакытлы матбугат (1920–25; 8 исем); яшьләр матбугаты (1920–25; 16 исем); Башкортстанда чыккан вакытлы матбугат (1917–25; 12 исем); Башкортстанда чыккан контрреволюцион матбугат (1917–19; 5 исем); Окт. рев-циясеннән соң чыгарылган журналлар (1918–25; 23 исем). Альбомның «Төрле мәгълүматлар» (1905–25) дигән бүлегендә кыскача хәбәрләр бирелә: 1920 елларда нәшер ителгән татар газеталарының чыгу урыны, вакыты, язылу бәяләре; цензура тарафыннан тыелган яки башка сәбәпләр аркасында чыкмый калган басмалар; 1905–25 тә нәшер ителгән яңа газеталарның саны; Кавказ, Кырым, Төркестан һ.б. төбәкләрдә казакъ, әзәрбайҗан, төрек, гарәп, кумык телләрендә басылган вакытлы матбугат; керәшен татарлар вакытлы матбугаты. И.Рәмиев 8 басманың альбомда күрсәтелмәвен искәртә. Альбомда мөхәррирләр, наширләр һәм актив авторларның фоторәсемнәре, тасвирланган басмаларда урын алган мәкаләләрдән өзекләр бирелә.

*А.М.Ахунов.*



«Вакытлы татар матбугаты» альбомы бите.

**ВАКЫ́Ф** (гарәп. وقف — тотып калу), мөселманнарда дин үсешенә ярдәм итү, иганәчелек максатларында бүләк рәвешендә тапшырылган яисә васыять ителгән күчемле һәм күчемсез милек. В. сыйфатында бирү өчен милекнең хәләл, хуҗасының аңа ия булуы, аның

табыш китерә алуы шарт. Азык-төлек, акча, кием-салым В.ка керми. 11 йөздән мәчет-мәдрәсәләр күпләп ачыла башлый һәм аларга В. рәвешендә бүләк бирү гадәте киң тарала. 12 йөздә В. дини оешмаларның төп матди чыганагына әверелә һәм мөселман руханиларының аерым бер социаль төркем булып берләшүенә этәргеч бирә.

Үзәк Россиядә милекне В. итеп тапшыру турында беренче тапкыр 1829 елда искә алына. 1889 да бу төбәктә 21 В. милке теркәлә. 1891 дә Россия Эчке эшләр министрлыгы күрсәтмәсе б-н Мөселманнарның диния нәзарәте В. б-н идарә итүне көйләүче документ проектын әзерли, ләкин ул кабул ителми. Совет хакимияте елларында В. системасы бетерелә. 1990 елларда В. тапшыру тәртибен яңарту мәсьәләсе ТРда киң җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгенә алына. 1998 дә ТР Мөселманнар диния нәзарәтендә В. бүлеге оештырыла. 1999 да ТРның «Дин иреге һәм дини берләшмәләр» турындагы Законына дини оешмаларның В. милкенә хокуклары турындагы пункт өстәп кертелә.

*Әд.:* Вакыфлар — вакуфы. К., 2001; Азаматов Д.Д. Оренбургское Магометанское Духовное собрание в конце 18–19 вв. Уфа, 1999; Вакуфная собственность. К., 2002.

**ВАЛЕРИА́НА**, маун (Valeriana), валерианачалар семьялыгыннан бер һәм күпьеллык үләнчел һәм куакчыл үсемлекләр ыругы. Төньяк ярымшарның һәм Көньяк Американың уртача һәм салкын поясларында 200 дән артык төре таралган. ТР терр-ясендә бер төре — дару В.сы (V. officinalis), урман буйларында, сазлык, елга һәм күл ярларында үсә. Кыска тамыр системасы һәм күп санлы шнурсыман иярчен тамырлары булган 50–150 *см* озынлыктагы күпьеллык үләнчел үсемлек. Сабагы нык, туры торучан, өске өлешендә тармакланган. Яфраклары каурыйсыман теленгән, кырыйлары эре тешле. Чәчәкләре — вак, хуш исле, алсу яки ак, калкансыман яки себеркәчле чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше — бүрекчәле озынча орлыкча. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив ысул б-н үрчи. Составында алкалоид, гликозид, дуплау матдәләре, шикәр, органик кислоталар, эфир майлары кергән тамырларын һәм тамыр системасын тынычландыру чәе ясауда файдаланалар. Медицинада нерв системасы бозылганда, ашказаны-эчәк куышлыгы кысылганда кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.



Валериана.

**«ВАЛКО́М»**, киез аяк киеме, киез һәм киез әйберләр эшләп чыгаручы җиңел сәнәгать пр-тиесе. Казанда урнашкан. 52,5 *га* мәйданны били. 960 кеше эшли (2000). 1932 елда М.Разумов исем. Казан киез итек-киез ф-касы буларак нигез салына, шул ук елда беренче продукция чыгарыла. 1933 тә фабрикага Галактионов исем. киез итек-киез ф-касының төп средстволары һәм җитештерү корпуслары тапшырыла. 1937 дән Казан киез итек-фетр аяк киеме ф-касы, 1946 дан киез аяк киеме һәм киез ф-касы, 1954 тән Казан киез итек-киез комб-ты. 1995 тән «В.» АҖ. 2004 тә «В.» банкротлыкка чыга, һәм мөлкәте сатыла, нәтиҗәдә пр-тие «Карамай» тышкы сәүдә җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять карамагына күчә, берләшмә җитештерү цехларын һәм җиһазларын «Татвойлок» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә арендага бирә. Илдә чыгарылган барлык киез һәм фетр аяк киемнәренең 1940 елларда 17–20%ы, 1990 елларда



Бизәкле фетр аяк киемнәре.

15–17% чамасы комб-т өлешенә туры килә. Бөек Ватан сугышы елларында фабрика фронт өчен эшли. Бу елларда 2 млн пар киез аяк киеме эшләнә, якынча 5 млн пар ремонтлана; 1000 *т* дан артык киез, 20 млн киез детальләр җитештерелә. 1950 елларда яңа җитештерү объектлары корыла башлый: модельләр ясау, металл кою, чистарту-эшкәртү цехлары (1960), җитештерү корпусы (1973), киез аяк киеме җитештерүче өч цех (1980) төзелә, пр-тие үзгәртеп корыла. Төп җитештерү процесслары механикалаштырыла һәм автоматлаштырыла. 1990 нан башлап 28 агымлы линия, 650 берәмлектән артык технол. җиһазлар, 125 автомат һәм ярымавтоматлар эшли; бутау-болгату, чистарту, формалаштыру, киез аяк киеменең төп нигезен эшләү өчен яңа машиналар куела. «В.» составында өч производство (киез аяк киеме, киез, халык кулланыу товарлары), төзелеш, ремонт-механика, металл кою, электр цехлары, пар көченә корылган хуҗалык (1999) эшли. Төп продукция: киез итекләр, киез, киез детальләр, киез ботинка һәм башмаклар, халык кулланыу товарлары. Чимал б-н төп тәэмин итүчеләр: Казан, Кукмара мех пр-тиеләре, Ставрополь һәм Краснодар крайлары күн һәм мех пр-тиеләре. Продукция Оборона һәм Эчке эшләр министрлыкларына, РФ регионнарына җибәрелә. «В.» Үзбәкстан, Төрекмәнстан б-н икътисади-сәүдә бәйләнешләрендә тора. 1960–80 елларда комб-тның продукциясе дөньяның 19 иленә чыгарыла. Җитештерү күләме 1932 дә — 250,2, 1940 та — 2707,9, 1960 та — 3000, 1970 тә — 2297, 1980 дә — 2026, 2000 дә — 360, 2005 тә — 60 мең пар аяк киеме; 1940 та — 913, 1960 та — 3610,7, 1970 тә — 3789,9, 1980 дә — 2908, 2000 дә — 568, 2005 тә 40 *т* киез тәшкил итә. «В.» эшчеләре дәүләт бүләкләре, ш.и. 3 кеше — Ленин ордены, 8 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 6 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше «Хезмәт даны» орденнары б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре: С.К.Вязовкин (1939–60), А.Ф.Калмыков (1960–71), М.Р.Архипов (1971–85), Н.Г.Хәйруллин (1985–87), Ф.З.Рәимов (1987–97), Г.К.Җәләлетдинов (1997–99), И.К.Шиһабетдинов (1999–2001), Н.К.Шакиров (2001–04), Р.Ш.Хөсәенов (2004 тән). Ш.у.к. *Киез итек-киез җитештерү.*

*Әд.:* Рабочий класс Татарии. К., 1981; Промышленность и рабочий класс Татарии (1946–80): Док. и материалы. К., 1986.

*К.Ф.Фәсхетдинов, Г.Я.Мәүлетова.*

**ВАЛЛО́ТА** (Vallota purpurea), амариллисчалар семьялыгыннан суганчалы үләнчел үсемлек. Туган ягы — Көньяк Африка (Кап провинциясе). ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Тышкы билгеләре буенча гиппеаструмны (амариллис) хәтерләтә, тик аннан кечерәк һәм кышка яфракларын коймый. Яфраклары тасмасыман туры, озынлыгы 30–40 *см*. Суганчасы эре, йомыркасыман. Чәчәк сабы куыш, яфраксыз. Чәчәкләре туры торучан, куе кызыл, ачык кызыл яки ак төстә (сирәк) чатырсыман чәчәк оешмасына тупланганнар. Яктылык яратучы үсемлек. Җәй ахырында, көзен чәчәк ата. Вак суганчалардан (2 нче елында чәчәк ата) һәм орлыктан (3 нче елында чәчәк ата) үрчетелә.

**ВАЛЮКЕ́ВИЧ** Валентина Николаевна (17.10.1958, Украинаның Донецк өлкәсе Енакиево ш.), спортчы (академик ишү), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1982). Волгоград Физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1985). Спорт б-н 1977 елда (Псков ш., «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте) шөгыльләнә башлый, 1979 дан тренер С.М.*Ульяновта* (Казан, «Динамо» спорт җәмгыяте) тәрбияләнә. РСФСР (1979–83), СССР (1986), СССР халыклары спартакиадасы (1983) чемпионы, СССР чемпионатында көмеш (1981–83), бронза (1981) медальләр ала. 1985–87 дә Казан авиация ин-тында физик тәрбия укытучысы, 1987–93 тә Үзәк СКнда инструктор, 1993 тән урта мәктәптә физик тәрбия укытучысы.

**ВАН ФЛЕК ПАРАМАГНЕТИ́ЗМЫ**, тышкы магнит кыры тәэсирендә матдәдә магнит моментлары хасил булу күренеше. В.Ф.п.ның табигате парамагнит ионның җөп санлы электроннар б-н тулмаган электрон сүрүе (мәс., $Eu^{3+}$, $Pr^{3+}$, $Tb^{3+}$, $Ho^{+3}$, $Tm^{3+}$ ионнары) кристаллның эл. кырында магнитланмаган төп халәттә була алуыннан гыйбарәт. Тышкы магнит кыры ($H_o$) төп халәтнең дулкын функцияләренә ионның өстәрәк яткан дулкын функцияләрен дә катыштыра. Нәтиҗәдә тышкы магнит кыры электрон сүрүнең магнит моментын индукцияли, анысы, үз чиратында, үз төшендә «үтә юка» магнит кыры ($H_{үю}$) хасил итә, ә соңгысы $H_o$ дән уннарча һәм йөзләрчә тапкыр зуррак булырга мөмкин. Статик магнит сизгерлеге югары темп-раларда Кюри законына буйсынган, ә түбән темп-раларда даими булган каты җисемнәргә 1932 елда беренче мәртәбә Америка физи-

гы Ван Флек игътибар итә. Соңыннан андый матдәләр (парамагнетиклар) Ван Флек исеме б-н атала.

Ван Флекның диэлектрик парамагнетикларын фәнни тикшерүдә радиоспектроскопия аеруча мәгълүматлы ысулларның берсе булып санала. Ул безнең (Мәскәү, С.-Петербург) һәм чит илләрнең (Оксфорд, Париж, Осака, Сендай һ.б.) әйдәп баручы фәнни үзәкләрендә инде 30 елдан артык киң файдаланыла. Ван Флек парамагнетикларындагы магнит резонансын фәнни тикшеренүләр Казан ун-тында М.М.Зарипов тарафыннан (1956, С.А.Альтшулер тәкъдиме б-н) башлап җибәрелә, ә беренче тәҗрибә корунд минералындагы ванадий төшендә (1964, С.А.Альтшулер, В.Н.Ястребов) һәм лантоноид ионнарының төшләрендә (1967, С.А.Альтшулер, М.А.Теплов) күзәтелә. Ван Флек парамагнетикларындагы магнит резонансының 5 төре өйрәнелгән:

– Ван Флек ионнары төшендә көчәйтелгән магнит резонансы (С.А.Альтшулер, М.М.Зарипов, М.А.Теплов, Л.К.Әминов, М.С.Таһиров һ.б.);

– парамагнит катнашмаларында электрон парамагнит резонансы (ЭПР) (А.А.Антипин, И.Н.Куркин һ.б.);

– диамагнит лигандлар төшендә магнит резонансы (М.А.Теплов, М.С.Таһиров, И.С.Конов);

– Ван Флек ионнарының дефектлы парамагнит үзәкләрендә ЭПР (М.С.Таһиров, Д.А.Таюрский һ.б.);

– электроннарның магнитсыз төп халәттән тәэсирләндерелгән магнит халәткә күчүе б-н бәйле югары ешлыклы ЭПР (М.С.Таһиров, Д.А.Таюрский, Б.З.Малкин, В.Ф.Тарасов).

Ван Флек парамагнетиклары сыек $^3$Не төше һәм аның динамик поляризациясе арасындагы магнит резонансы бәйләнешен фәнни тикшеренү һәм адиабатик магнитсызландыру ысулы б-н үтә түбән темп-ралар алу өчен (1966, С.А.Альтшулер) кулланылырга мөмкин. Интерметаллик кушылма $PrNi_5$ шундый мәгълүм парамагнетик-хладогент булып санала. Югары темп-ралы үтә үткәргечләрдә — Ван Флек парамагнетикларында — магнит резонансын күзәтү дөньяда беренче мәртәбә 1990 елда Казан ун-тында М.А.Теплов, М.С.Таһиров, А.В.Егоров, А.В.Дуглав тарафыннан башкарыла. Ван Флек парамагнетикларын оптик хәтер җайланмалары сыйфатында файдалану (1987, В.В.Самарцев, В.А.Зуйков һ.б.) гаять өметле.

*Әд.:* Аминов Л.К., Теплов М.А. Ядерный магнитный резонанс в редкоземельных ван-флековских парамагнетиках // Успехи физ. наук. 1985. Т. 147; Abragam A., Bleaney B. Enhanced nuclear magnetism: some novel features and prospective experiments // Proceedings of the Royal Society of London. 1983. A. 387; Aminov L.K., Malkin B.Z., Teplov M.A. Magnetic properties of nonmetallic lanthanide compounds // Handbook of the Physics and Ghemistry of Rare Earths 227. Amsterdam, 1996. V. 22; High frequency Electron paramagnetic resonance of $Tm^{3+}$ ions in Lanthanum and Thulium ethylsulphate single crystals // Physical Review Letters. 1996. V. 77; Submillimeter EPR spectrascopy of the Van Vlek paramagnets // Journal of Alloys and Compaunds. 1997. V. 250.

*М.С.Таһиров.*

**ВА́НДОВКА** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярындагы пристань. 2002 елда 24 кеше (руслар) яши. 18 йөз уртасында Омар авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Вандова Речка, Клочковый Враг исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, балык тоту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 139,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Омар волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 31, 1897 дә — 40, 1926 да — 62, 1938 дә — 180, 1949 да — 230, 1958 дә — 282, 1970 тә — 118, 1979 да — 75, 1989 да — 29 кеше.

**ВАНЮ́ШИН** Юрий Сергеевич (10.3.1951, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (2001). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1975). Шунда ук эшли, 1991–99 елларда физик тәрбия бирүнең медик-биологик нигезләре каф. мөдире. Хезмәтләре яшь-җенес үзенчәлекләренә, спорт төренә һәм нагрузкаларның зурлыгына бәйле рәвештә спортчыларның йөрәк-кан тамырлары һәм сулыш системаларының үзара бәйләнешен өйрәнүгә карый. Спорт нәтиҗәләрен фаразлауга һәм организмның функциональ мөмкинлекләрен камилләштерүгә ярдәм итүче әлеге системаларның адаптация типларын билгеләи.

Хезм.: Адаптация сердечной деятельности и состояние газообмена у спортсменов // Физиология человека. 1997. Т.23, № 4 (автордаш); Показатели кардиореспираторной системы у спортсменов разного возраста // Физиология человека. 1998. Т.24. № 3; Адаптация сердечной деятельности подростков // Физиология человека. 2001. Т.27, № 2 (автордаш).

**«ВА́НЯ»**, *Идел буе хәрби флотилиясенең* коралланган пароходы (1918 елның июненә кадәр буксир). «В.» пароходында 4 туп (2 се 75 *мм*, 2 се 47 *мм* көпшәле), 12 пулемёт (1918, сент.) урнаштырылган була. КОМУЧның Халык Армиясе һәм баш күтәргән Чех-словак корпусы көчләренә каршы Идел, Кама буе сугышларында катнаша. Казанны азат итү сугышында, 1918 нең 10 сентябрендә Түбән Ослан авылы янәшәсендә дошманның берьюлы 3 корабына каршы сугыша. Шул елның 1 октябрендә Камадагы Пьяный Бор пристане өчен барган сугышта батырыла. «В.» пароходы б-н бергә Идел буе хәрби флотилиясе командиры урынбасары Н.Г.*Маркин* да һәлак була. «В.» истәлегенә флотилиянең икенче бер пароходына «Ваня-коммунист» исеме бирелә.

*Әд.:* Квашинский Н.А. Гибель «Вани-коммуниста» // Вспоминая былые походы. Г., 1968; Лавренёв Б. «Ваня-коммунист» // Корабли — герои. М., 1970.

**ВАРА́КСИН В.В. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́** (типохромолитография), Казанда, 1904 елның июнендә шәһәрнең шәрәфле гражданы В.В.Вараксинның «Кокарев һәм К°» ширкәтеннән сатып алган матбагасы. Шәһәрдә эре сәүдә-сәнәгать пр-тиеләреннән саналган. Басма продукциясенең төп өлешен картографик басмалар: Казан һәм күрше губерна, өязләрнең, Борынгы Греция, Борынгы Рим (1914), Россиянең Европа һәм Азия өлеше (1914) карталары һ.б. тәшкил итә. Басылган китаплар арасында Н.Д.Колотинскийның «Рус хокукы тарихы» («История русского права»), «Рим хокукы буенча практик дәресләр» («Практические занятия по курсу римского права», 1912), «Н.К.Рерих» (1912), А.Ф.Мантельнең «Үсмерчак әкияте» («Сказка юности», 1909), «Таң вакыты» («На рассвете», 1910) әдәби альманахы, «Жизнь» ж-лы (1912 — февр. 1915) һ.б. бар. Татар наширләре һәм нәшриятлары заказы б-н 1916 елга




В.В.Вараксин ташбасмаханәсенең фирма билгесе.

кадәр 27 исемдә татарча басма дөнья күрә (гомуми тираж — 118470 данә). Алар арасында «Милләт» нәшрияты заказы б-н рәссам М.Идрисинең ташбасма гравюралары күчермәсеннән дөнья кисәкләре һәм аерым илләрнең: Европа (1909), Монголия (1912), Гарәбстан (1914) татарча карталары (барлыгы 12 карта) бар. Болардан башка шул ук ташбасма ысулы б-н татар язуы үрнәкләре (мәс., Г.Нугайбәкнең «Үрнәкләр»е), шәҗәрә, календарь, шәмаил, таблицалар басыла. Китап басуда, кагыйдә буларак, хәреф җыю ысулы кулланылмаган. Нигездә, башка типографияләрнең иллюстрацияләр әзерләүгә заказы үтәлгән. Матбага 1917 елда ябыла.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.


**ВАРА́КСИН** Дмитрий Иванович (1814, Казан — 17.12.1886, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән күчмә шәрәфле граждан (1871), җәмәгать эшлеклесе. Сәүдәгәрләр нәселеннән. Сәүдә-эшмәкәрлек эшчәнлеген Казан губернасында алып бара; Казанда аракы з-ды хуҗасы (1863 елдан эшли). 1847 елда сәүдәгәрләр старостасы, Казан шәһәре магистраты ратманы (1851–54), төрмә ком-ты директоры һәм казначее (1861–67), 1869–71 елларда Казан шәһәре башлыгы. Бер үк вакытта 1868–73 тә Казан өязе земство җыены, 1870 тән Казан шәһәр думасы гласные. Казандагы Богоявление чиркәве каршындагы ятимнәр өчен бушлай эшләүче мәктәпне тотуга, шәһәр суүткәргечен төзүгә акчалата ярдәм итә. Халык мәгарифен үстерүне һәм шәһәрдә коммерция ин-ты ачуны яклап чыга.

*Әд.:* Агафонов Н.Я. Казань и казанцы. К. 1906. Ч. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ВАРВА́РА ЧИРКӘВЕ́**, Казандагы рус дини архит-расы истәлеге. 1779–80 елларда Себер заставасы янында Казан вице-губернаторының шәһәрдән читтәге йорты урынында арх. Одинцович һәм Соколовский проекты





Варвара чиркәве. Казан. 1. 20 йөз башы фотосы; 2. Хәзерге күренеше.

буенча классицизм стилендә төзелә. «Корабль рәвешендәге» чиркәү тибына карый. Ярымшар рәвешендәге гөмбәзле төп бина, ашханә һәм дүрт катлы чаң манарасы көнчыгыштан көнбатышка таба бер-берсенә тоташып урнашкан. Интерьерларының бизәлеше 1837 дә рәссам А.Т.Бомьин тарафыннан башкарыла.1867 дә эчке бүленеше үзгәртелә, ашханәсе киңәйтелә. Тузуы сәбәпле 1901–07 дә В.ч. тулысынча диярлек сүтелә, чаң манарасының аскы 2 каты һәм притвор гына сакланып кала һәм арх. Ф.Н.Малиновский проекты буенча эклектика стиленең псевдорус юнәлешендә үзгәртеп корыла. Дүрт баганалы, өч апсидалы чиркәү, гөмбәзе тәрәзәләнгән сигез кырлы барабанга утыртылган, дүрт катлы чаң манарасы ашханәнең көнбатыш диварына тоташкан. Чиркәү б-н ашханә арасындагы кечкенә кәшәнә чатырсыман түбә һәм суганча рәвешендәге гөмбәз б-н төгәлләнә. В.ч. чаңнары сәүдәгәр И.Е.Астраханцев һәм мещан П.Н.Керюхов з-дларында коела. Благовещение соборы ябылганнан соң, 1918–19 да В.ч. кафедраль собор булып тора. 1930 да ябыла, бинасы трамвай депосы эшчеләре клубы итеп файдаланыла, соңрак биредә кинематограф, протезлар ясау остаханәсе, 1963 елдан — Казан химия-технол. ин-тының компрессорлар һәм пневматик агрегатлар кафедрасы урнаша. 1994 тә дин тотучыларга кайтарыла. 1995 тән реставрация эшләре алып барыла (чиркәү һәм кәшәнә гөмбәзләренә алтын йөгертелә, хач куела һ.б.). 1880 елларда чиркәүдә Ф.И.Шаляпин җырлый, биредә А.Н.Радищев (1790), А.И.Герцен (1835), Н.Г.Чернышевский (1864) һ.б. күренекле шәхесләр була, Н.Е.*Боратынский*, О.А.Казимбәк (1864) һ.б. никахлашалар.

*Әд.:* Православные памятники Татарстана. К., 1999.

*О.Ерёгин.*

**ВАРВАРИ́ЗМНАР** (грек. bárbaros — чит илнеке), телдә тулысынча үзләшмәгән, ят сүзләр кебек кабул ителгән чит тел сүзләре һәм гыйбарәләре. Еш кына алар телдә тәрҗемә ителмичә һәм чыганак телнең графика һәм орфографиясен саклаган хәлдә кулланыла: homo sapiens, alma mater, сэр, крона һ.б. В. беркадәр дәрәҗәдә сөйләм телендә дә очрый. Ш.у. матур әдәбиятта чит халыкларның тормыш-көнкүрешен, сөйләмдә аларның вәкилләрен тасвирлау максатында, комик эффектка һәм персонажларның сатирик бәяләмәсенә ирешү өчен кулланыла. Татар әдәбиятында әлеге алымнан Ш.Бабич, Һ.Такташ, Г.Тукай еш файдаланган.

**Самый важный генерал** да/
**Только** күрсәтте **кукиш**... (Г.Тукай)

Хәзерге татар әдәбиятында да В. киң кулланыла: Иң дөрес телдә сөйләшүче, акыллы һәм көчле **homo sapiens** бозык телдә сөйләшүче күршесен һәрвакыт тукмарга тырышкан (Н.Фәттах).

О, Кандрат, **гут ман** син, **зер гут**... (Н.Дәүли).

Батыргали агайның французларга мәхәббәте шулкадәр артты ки, үзенең Гыйсмәтулла кодасына да сәлам бирү урынына французча «**бонжур**» гына ди торган иде (Ш.Мөхәммәдев). Егет берничә **дәкыйкә** вакытка аңын югалтып торды (Т.Галиуллин).

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. М., 1966; Бабкин А.М., Шендешов В.В. Словарь иноязычных слов. М.–Л., 1966; Крысин Л.Б. Иноязычные слова в современном русском языке. М., 1968.

*Х.Р.Курбатов, М.Ә.Сәгыйтов.*

**ВАРВА́РИНО** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 45 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кыярмәт елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 134 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты. Китапханә. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кувшиновка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы Реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, Игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында башлангыч белем мәктәбе (1882 дә ачыла), су һәм 4 җил тегермәне, 4 вак-тәяклләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 909,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Тәмте волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1859 да — 509, 1897 дә — 972, 1926 да — 886, 1938 дә — 510, 1949 да — 518, 1958 дә — 446, 1970 тә — 315, 1979 да — 240, 1989 да — 156 кеше.

**ВАРКЛӘ́Д** (Әрем) посёлогы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәрклӛт елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 49 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1900 дә нигез салына. 1920 елга кадәр — Вятка губернасының Алабуга өязе Мушаков волостена, 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсенә керә. 1921 елдан — ТАССРның Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантоннарында. 1927 елның 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан — Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1926 да — 99, 1939 да — 138, 1958 дә — 105, 1970 тә — 83, 1989 да — 55 кеше.

**ВАРКЛӘ́Д-БОДЬЯ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 43 *км* көньяктарак, Бәрклӛт елгасы буенда. 2002 елда 375 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. Китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1887 елгы мәгълүматларга караганда, авылда су тегермәне була. 1920 елга кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Мушаков волостена керә. 1920–21 дә — Вотяк автономияле өлкәсендә. 1921 елдан ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 146, 1887 дә — 237, 1920 дә — 343, 1926 да — 421, 1938 дә — 484, 1958 дә — 443, 1970 тә — 494, 1989 да — 367 кеше.

**ВА́РНА РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* көньягында. 1924 елның 23 февралендә оештырыла. Үзәге — Варна авылы (Чиләбедән 280 *км* көньяктарак). Халкы — 30802 кеше, ш.и. 1987 татар (2002) исәпләнә. Татарлар, башлыча, район үзәгендә (2115 кеше) яши. 20 йөз башында Варнада 3 мәчет (1939, 1943, 1949 да ябыла) була. 1950 елларга кадәр татар мәктәбе эшли.

**ВА́РНЕКЕ** Борис Васильевич (3.6.1874, Мәскәү — 1944, Одесса ш.), филолог, латин теле-әдәбияты д-ры (1906), театр тарихчысы һәм тәнкыйтьчесе. Театр эшлеклеләре гаиләсендә туа. 1894–98 елларда Петербург тарих-филол. ин-тында күренекле филолог-классик Ф.Ф.Зелинский классында укый. 1902–04 тә Царское Село гимназиясендә борынгы телләр укыта. 1902–03 тә «Театр и искусство» ж-лында театр тәнкыйтьчесе буларак эшли, антик чор һәм рус театрлары тарихына караган кайбер мәкаләләре «Филологическое обозрение» ж-лында басыла (мәс., «Борынгы Рим театры тарихына карата» — «К истории древнеримского театра» һ.б.). 1904–10 да Казан ун-тында классик филол. профессоры, «Казанская газета»ны нәшер итүдә катнаша, 1906 да «Обновление» г-тасы мөхәррире. Рус театры тарихы өлкәсендә тикшеренүләр алып бара, халык драмасына, Д.И.Фонвизин, А.П.Сумароков, П.А.Плавильщиков, М.И.Верёвкин, А.Н.Островский иҗатларына багышланган хезмәтләр бастыра. «Рус театры тарихы» («История русского театра», 1–2 кис., 1908–10) дигән әһәмиятле хезмәте бу темага караган материалларны системага салып бастыруның беренче үрнәге булып тора. В. ның фәнни хез-

мәтләре төгәл документларга, абруйлы язма чыганакларга таянып языла.

Х е з м.: Новые комедии Менандра. К., 1909; История античного театра. М.–Л., 1940.

*Әд.:* Русские писатели 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1989. Т. 1; Театральная энциклопедия. М., 1961. Т. 1. *Ю.А.Благов.*

**ВАРСОНО́ФИЙ** (1495 тирәсе, хәзерге Мәскәү өлкәсе Серпухов ш. — 11.4.1576, Казан), дин эшлеклесе, миссионер. 1520 елда Андроник монастырендә (Мәскәү) монахлык кабул итә, 1544 тән Мәскәү янындагы Песнош монастыренда игумен, монастырь башлыгы. 1555 тән Казан Кремлендәге Спас-Преображение монастыренең беренче башлыгы. Казанның беренче архиепископы Гурийның ярдәмчесе. Татар телен белүе (ул аны Кырым татарларында 3 ел әсирлектә вакытта үзләштерә) аңа татар кешеләрен православиегә күчәргә үгетләү мөмкинлеге бирә. 1567 дән Тверь епископы, 1570 тирәсендә ялга чыга һәм Казанга килә. 1595 тә Гермоген тәкъдиме б-н изгеләштерелә. Искә алу көне — 4 (17) октябрь. В.ның җәсәде 1918 елга кадәр Благовещение кафедраль соборында була.

*Әд.:* Жития Святителей Гурия и Варсонофия. СПб., 1853; Н и к а н о р (К а м е н с к и й). Житие Святителя Варсонофия // Казан. сб. статей архиепископа Никанора. К., 1910.

**ВАРФОЛОМЕ́ЕВ** Василий Михайлович (1.1.1923, хәзерге Башкортстан Респ-касының Бакалы р-ны Карповка а. — 11.9.1988, Түбән Кама ш.), Дан орденының тулы кавалеры (29.2.1944, 29.7.1944, 24.3.1945), өлкән сержант. 1942 елның мартында Кызыл Армиягә алынганчы, туган авылында колхозда эшли. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, танкка каршы ата торган мылтык укчысы, 190 нчы запастагы укчы полк разведчигы (7 нче гв. армия). Воронеж, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Днепр елгасы янында барган бәрелешләрдә (1943), Кировоград (1944), Умань-Ботошаны (1944), Яссы-Кишинёв (1944), Дебрецен (1944), Будапешт (1944–1945) һәм Прага (1945) операцияләрендә катнаша. 1944 нең 10–20 гыйнварында Тарасовка торак пункты янында (Кировоград өлкәсе), 1944 нең июнендә Пашкани шәһәре (Румыния) янында, 1944 нең 3 ноябрендә Сольнок шәһәре янында (Венгрия) барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Совет Армиясе сафларында хезмәтен дәвам иттерә (1947 гә кадәр). Түбән Кама шәһәрендә яши, слесарь-контролёр булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Славные сыны Башкирии, Уфа, 1985. Кн. 5; Солдатская слава. К., 1985; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000. *В.А.Шагалов.*

**ВАРША́ВА МӨСЕЛМАННАРЫ́ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, Польшада яшәүче татарлар тарафыннан оештырыла, 1913–17 елларда эшли. Башлап йөрүчеләр, нигездә, Польша-Литва татарлары. 120 ләп кешене берләштергән. Рәисе К.Крычиньский, сәркәтибе Л.Крычиньский. Максаты: татар балалары өчен мәктәпләр ачу һәм аларны тоту, ярлы мөселманнарга матди ярдәм күрсәтү. Вильно (Вильнюс) шәһәрендәге Литва мөселманнары хәйрия җәмгыяте б-н хезмәттәшлек иткән. Польша татарларының иҗтимагый һәм мәдәни тормышында зур роль уйнаган. *Я.Я.Гришин.*

**ВАРША́ВСКИЙ** Владимир Валентинович (7.9.1953, Ульянов ш.), пианист, ТРның халык артисты (2003). 1977 елда Казан консерваториясен (С.Гурарий классы) тәмамлый. 1977–90 да Татар филармониясендә әдәби-муз. лекторий концертмейстеры, 1994 тән опера һәм камера музыкасы бүлеге сәнгать җитәкчесе. Күпкырлы музыка эшлеклесе (солист, ансамбльче, концертмейстер) буларак төрле оешмаларда, очрашуларда концертлар б-н чыгыш ясый. Татарстан композиторларының классик музыкасын һәм иҗатын пропагандалый.

**ВАСИЛЕ́ВСКИЙ** Николай Михайлович (19.5.1956, Биектау р-ны Яңа Горка а.), вет. эшен оештыру һәм вет. икътисады белгече, вет. фән. д-ры (1997), проф. (1998). 1979 елда Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлый, шунда ук эшли, 1997–99 да вет. медицинасы ф-ты деканы, 1999 дан вет. медицинасын һәм зоотехнияне компьютерлаштыру каф. мөдире. Хезмәтләре РФдә вет. хезмәте эшчәнлеген оештыру мәсьәләләренә: базар икътисады шартларында авыл р-ннарында вет. белгечләрен, вет. хезмәтен нормалаштыруга, вет. һәм зоотехнияне компьютерлаштыруга карый. Мөгезле эре терлекләрдә йогышлы бруцеллёз, туберкулёз һәм сальмонеллёз, трихофития, колибактериоз, диплококк инфекциясе вакытында дәвалау чараларының икътисади нәтиҗәлелеген тикшерә.

Х е з м.: Организация и экономика ветеринарного дела: Метод. указ. К., 1989 (автордаш); Рекомендации по организации ветеринарной службы в сельском районе. Красноярск, 1997 (автордаш); Организация и экономика ветеринарного дела: Учеб. М., 1998 (автордаш); Ветеринарное предпринимательство: Учеб. пособие. К., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Научная и методическая работа на кафедре организации и экономики ветеринарного дела // Казан. вет. ин-т им. Н.Э.Баумана. К., 1993; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ВАСИ́ЛИЙ I** (30.12.1371, Мәскәү — 27.2.1425, шунда ук), Мәскәү бөек кенәзе (1389 елдан). Бөек кенәз Дмитрий Донскойның улы. Алтын Урдадан рөхсәт ярлыгы бирелмәгән килеш, бөек кенәз дәрәҗәсен дәгъвалый, тәхеткә тәгаенләнүен хан илчесе Шихмәт (Шаһиәхмәт) катнашлыгында үткәрә. 1392 елда Туктамыш ханнан Түбән Новгород, Муром, Ханкирмән (соңрак *Касыйм* ш.) һ.б. шәһәр биләмәләре б-н идарә итү ярлыгын сатып ала. Урта Азия әмире Аксак Тимер Идел буена һөҗүм иткәндә, рус җирләрен саклау өчен ополчение оештыра (1395). 1396 елда Тверь кенәзе Михаил Александрович б-н тышкы сәясәт мәсьәләләренә кагылышлы килешү төзи. 14 йөз ахыры – 15 йөз башларында Двина елгасы буе биләмәләре өчен Новгород идарәчеләре б-н көрәшә, Новгородның мөстәкыйльлеген чикләргә тырыша. Литва бөек кенәзе Витовт б-н урнашкан якын мөнәсәбәтләре 14 йөз ахырында Витовтның



В.М. Варфоломеев.



В.В. Варшавский.

Туктамыш ханга ярдәмләшүе сәбәпле өзелә. 1402 елда В. I Мәскәү кенәзлеге биләмәләренә яу б-н килгән Идегәйгә 3 мең сум күләмендә йолым хакы түләргә мәҗбүр була. В. I идарә иткәндә феодалларга җир өләшү чикләнә, аларның ирегә беркадәр кысыла. Бу чорда В. I сарае даирәсенә шактый күләмдә йомышлы татарлар һәм Литва аксөякләре чакырыла.

*Әд.:* Ч е р е п н и н Л.В. Русские феодальные архивы XIV–XV вв. М., 1948. Ч. 1; 1951. Ч. 2; ш у л у к. Образование Русского централизованного государства XIV–XV вв. М., 1960. *Е.В.Липаков.*

**ВАСИ́ЛИЙ II ТЁМНЫЙ** (10.3.1415, Мәскәү — 27.3.1462, шунда ук), Мәскәү бөек кенәзе (1425 елдан). Кенәз Василий I нең улы. 1417 елда, абыйлары вафатыннан соң, Мәскәү кенәзлеге тәхетенә варис булып кала. В. II балигъ булганчы, дәүләт б-н анасы Софья, митрополит Фотий, бояр И.Д.Всеволожский һ.б. идарә итә. В. II тәхеткә утырганнан соң озак еллар дәвамында (1425–53) бөек кенәз тәхете өчен үзара көрәш бара: Галиция кенәзе Юрий Дмитриевич, аның уллары Василий Косой һәм Дмитрий Шемяка үз өстенлекләрен дәгъвалыйлар. В. II гә бер үк вакытта Литва һәм Алтын Урда басымына каршы да көрәшергә туры килә. 1437 елда Алтын Урда тәхетеннән куылган *Олуг Мөхәммәд хан* кенәзлекнең чик буендагы Биләү каласында тукталгач, В. II аңа каршы 40 меңлек гаскәр җибәрә, ул гаскәр тар-мар ителә. Олуг Мөхәммәд улы *Мәхмүд хан* көчләренә каршы тору да уңышсыз тәмамлана — *Суздаль янындагы сугышта* (1445) В. II гаскәре җиңелә, кенәз үзе яралана һәм кулга алына. Зур күләмдә йолым акчасы түләү һәм Туктамыш хан заманында атасына бирелгән Ханкирмән биләмәсен кайтару шарты б-н азат ителә. Мондый килешү боярлар арасында канәгатьсезлек тудыра. Шуннан файдаланып, кенәз Д.Шемяка 1446 елда фетнә оештыра, В. II не әсир итә һәм сукырайта (В. II нең «Тёмный» кушаматы шул вакыйгага бәйле). Шул елның декабрендә В. II, Мәскәү боярларына һәм Казан ханлыгы ярдәменә таянып, кабат үз тәхетенә утыра, Д.Шемяка яклы көчләрне тар-мар итә. Үз идарәчелеген ныгыту чараларын күрә башлый, кенәзлекнең ваграк удел биләмәләрен юкка чыгара, берләштерә. Түбән Новгород кенәзлеген һәм өлешчә Ярославль кенәзлеге биләмәсен үз кенәзлегенә кушуга ирешә. Көнчыгыштагы Вятка, Пермь һәм Төньяк-көнчыгыш Печора җир биләмәләрен яулау сугышлары алып ба-



Н. Василова.

ра. Салым түләү тәртибен барлык кенәзлек биләмәләрендә бертөрле итеп үзгәртә, салым түләүчеләрнең сан исәбен, ихтимал, җир биләмәләренең күләмен дә, санауны үткәртә. В. II идарә иткәндә феодалларга җир биләмәләре бүләк итеп бирү очраклары киметелә. Җирне беркетү, крәстияннәрнең күченеп йөрүен чикләү чаралары күрелә. Татар феодалларына рус кенәзлегендә аерым җир биләмәләр (удел җирләре) бирелә. В. II идарә иткәндә *Касыйм ханлыгы* барлыкка китерелә. В. II Новгородка берничә мәртәбә яу б-н бара (1441, 1456, 1460 һ.б.), 1458 елда *Нократ җирен*, ш.и. Нократ татарларын (*Ар ягы бәкләре* биләмәсен) Мәскәүгә буйсындыра.

*Әд.:* П р е с н я к о в А.Е. Образование Великорусского государства. П., 1918; Ч е р е п н и н Л.В. Образование Русского централизованного государства в XIV–XV вв. М., 1960; З и м и н А.А. Витязь на распутье. Феодальная война в России XV в. М., 1991.

*Е.В.Липаков.*

**ВАСИ́ЛИЙ III** (25.2.1479, Мәскәү — 4.12.1533, шунда ук), Владимир һәм Мәскәү кенәзлекләре бөек кенәзе, Русь государе (1505 елдан). Кенәз Иван III нең улы. Атасының бердәм Рус дәүләтен берләштерү сәясәтен дәвам иттерә; кайбер удел кенәзләре б-н килешүләрне яңарта. В. III заманында берничә удел кенәзлеге бетерелә. 1510 елда Псков, 1521 дә Рязань шәһәрләрен үзенә буйсындыра. Рус-Литва сугышында җиңүе нәтиҗәсендә 1514 тә В. III Смоленск кенәзлеген үз биләмәсенә кушуга ирешә. Мәскәүдән көнчыгышта һәм көньякта урнашкан җирләрне яулап алу сәясәтен дәвам иттерә, Казан ханлыгына берничә һөҗүм оештыра; 1506 елгы һөҗүме җиңелү б-н тәмамлана. Мөхәммәдәмин хан вафатыннан соң Казан тәхетенә үз кешесен — *Шаһгали*не утырта (1518). Шаһгали аннан куылгач, аны Казан тәхетенә кайтару өчен 1523, 1524 елларда яулар оештыра. 1530–31 еллардагы яу-һөҗүмнәрдән соң Казан тәхетенә В. III кешесе — Җангали утыртыла. Бер үк вакытта Казан ханлыгының көнбатыш чик буйларында үз кальга-корылмаларын төзү һәм ныгытуны дәвам иттерә. 1521 дә Олы чик буе киртәләре төзелешен башлый, 1524 тә Казан ханлыгы йогынтысында булган чуашлар җире чигендә, Сура елгасы тамагында, Васильсурск кальгасын нигезли. Шул ук елда рус сәүдәгәрләренә Казан ханлыгы ярминкәләренә баруны тыя, Түбән Новгород янәшәсендә үз ярминкәләрен ачарга әмер бирә (к. *Мәкәрҗә ярминкәсе*). Литвага каршы көрәштә үз максатында файдалану һәм үз кенәзлегенә яу-һөҗүмнәрне булдырмау ниятеннән Кырым ханлыгы б-н якын мөнәсәбәтләр урнаштыра, дипломатик килешүләр төзүгә ирешә. Кырым ханнары нәселеннән булган Сәхибгәрәй Казан тәхетенә утырганнан соң гына Кырым гаскәре 1521 елның көзендә Мәскәүгә һөҗүм оештыра, Мәскәүдә идарәче булып калган боярлардан йолым түләтә. В. III идарәсе вакытында татарларны һәм чит ил кешеләрен Мәскәү кенәзлегенә хезмәткә алу сәясәте дәвам иттерелә.

*Әд.:* П р е с н я к о в А.Е. Завещание Василия III // Сб. ст. по русской истории, посвящённых С.Ф.Платонову. П., 1922; Ш м и д т С.О. О времени составления «Выписи» о втором браке Василия III // Новое о прошлом нашей страны. М., 1967; К а ш т а н о в С.М. Социально-политическая история России конца XV – 1 й половины XVI вв. М., 1967; Повесть о болезни и смерти Василия III // Памятники литературы Древней Руси. Середина XVI в. М., 1985; З и м и н А.А. В канун грозных потрясений. М., 1986.

*Е.В.Липаков.*

**ВАСИ́ЛИЙ БЛАЖЕ́ННЫЙ ХРАМЫ́** (Я р б у е П о к р о в с о б о р ы), Мәскәүдәге, рус дини архит-расының мәшһүр истәлеге. Кызыл мәйданда урнашкан. 1555–61 елларда Казан ханлыгын яулап алу уңаеннан төзелә. Архитекторлары — Барма һәм И.Я.*Постник*. 1588 дә Покров соборына Василий Блаженный янкорма чиркәве өстәп салына, 1670 елларда чатыр рәвешендәге түбәле чаң манарасы төзелә. Храм үзәктә доминанта булып торучы чатыр түбәле Покров соборы бинасы һәм аның тирәли уртак нигезгә урнашкан, үзара эчке юллар б-н тоташкан 8 янкорма чиркәүдән гыйбарәт. Бизәкләренең купшылыгы һәм байлыгы б-н аерылып тора. Казан галимнәре С.С.Айдаров һәм Н.Х.Халитов фаразлаганча, В.б.х. Кол Шәриф мәчете үрнәгендә төзелгән. В.б.х. корылышында ш.у. чалма рәвешендәге һәм спираль кебек бөтерелеп күтәрелүче гөмбәзләр, тромплар, үзәк гөмбәздә ялтыравык кирпечтән эшләнгән төрле төстәге йолдызчыклар, чәчәк чуклары рәвешендә төгәлләнүче аркалар кебек шул чордагы ислам илләре архит-расы элементлары кулланылган. 1930 еллардан гыйбадәтханә бинасында Тарих музее ф-лы эшләп килә. 1992 дә дин тотучыларга кайтарыла.

*Әд.:* Б р у н о в Н.И. Храм Василия Блаженного в Москве. М., 1988; А й д а р о в С.С. Тезисы платформы по возраждению национальной самобытности в архитектуре малочисленных народов России // Проблемы национального в архитектуре России. К., 1990; Архитектурные ансамбли Москвы 15 — начала 20 веков. М., 1997; Х а л и т Н. Очерки по архитектуре ханской Казани: Гипотезы, факты, размышления. К., 1999.

**ВАСИ́ЛОВА** Нәфисә (Васильева Анастасия Петровна) (15.1.1943, Теләче р-ны Субаш а. — 16.7.2006), җырчы, ТАССРның халык артисткасы (1979). 1965–96 елларда ТР Җыр һәм бию ансамбле солисты. Киң диапазонлы һәм үзенә бертөрле түбән тембрлы тавышка ия, татар халык җырларын («Тәфтиләү», «Сәгать чылбыры», «Гөлҗамал», «Ак бүрек», «Карачтау авылы көе» һ.б.) һәм С.Габәшинең «Кәккүк» (Ә.Ерикәй шигыре), Ә.Бакировның «Җидегән чишмә» (Г.Бәширов шигыре) җырларын үзенчәлекле башкаручы. В. репертуарына ш.у. рус, украин, башкорт, казакъ, әзәрбайҗан җырлары керә. ТР Җыр һәм бию ансамбле солисты буларак, Япония, Италия, Франция, Финляндия, Германия, Мальта һ.б. илләрдә гастрольләрдә чыгышлар ясый. Милли җыр һәм бию ансамбльләренең 1 нче Бөтенроссия смотры лауреаты (1978).

*Әд.:* Народные артисты. К. 1980.

*В.Н.Горшков.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Александр Алексеевич (24.8.1881, Тамбов губ., Темников өязе Преображенский а. — 1918, Австро-Венгрия), Россиянең беренче очучыларыннан. 1907 елда Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлаганнан соң, 1910 елга кадәр Казан мәхкәмә палатасында хезмәт итә. Авиация б-н мавыгып, Франциягә китеп бара, анда 1910 елның августында Луи Блерионың авиация мәктәбен тәмамлый. Ике самолёт сатып ала, бер төркем очучылар туплый һәм күрсәтмә очышлар б-н Россия шәһәрләре буйлап сәяхәткә чыгып китә. 1910 да Казанга килә, Бөтенроссия һавада очу бәйрәмендә катнаша, Казан ипподромы өстендә очышлар ясый. Аңа «Беренче Казан очучысы» дигән көмеш жетон тапшырыла. Очкыч б-н идарә итүдә кыюлык һәм осталык күрсәтә, беренчеләрдән булып «Нестеров элмәге»н һ.б. югары пилотаж хәрәкәтләрен үзләштерә. 1910 елның декабрендә Елизаветполь — Тифлис (хәзер Тянджа, Тбилиси) шәһәрләре арасында беренче мәртәбә таулар өстеннән 200 *км* дан артык ара очып үтә. Саратов, Царицын, Әстерхан, Тифлис, Баку, Ашхабад, Ташкент шәһәрләрендә күрсәтмә очышлар ясый. С.-Петербург-Мәскәү (1911) һәм С.-Петербург-Мәскәү-С.-Петербург (1913) очышларында җиңүче була. 1911 нең октябрендә яңа очкыч сынаганда авариягә эләгә һәм каты яралана. 1912 нең июнендә яңадан Казанда чыгыш ясый. 1913 тән С.С.Щетининның С.-Петербургтагы авиация з-дында очучы-сынаучы булып эшли. 1914 нең язынннан Петроград-Париж-Петроград очышына әзерләнә. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, үз теләге б-н фронтка китә. Разведка очышларының берсендә 1914 нең августында Львов шәһәре тирәсендә бәреп төшерелә һәм австриялеләр тарафыннан әсир итеп алына. Әсирлектә вафат була.

Х е з м.: В борьбе с воздушной стихией. М., 1912.

*Әд.:* Авиация в России. М., 1988; Т о к а р е в С.Н. Хроника трагического перелёта. М., 1991; В е н и а м и н о в Р.Г. Запас прочности // Казань. 1993. № 3–4.

*Р.Г.Вениаминов.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Александр Васильевич (24.7.1853, Казан — 6.11.1929, Мәскәү), математик һәм математика тарихчысы, җәмәгать эшлеклесе, саф математика д-ры (1884), проф. (1887), Казан ун-тының атказ. ординар проф. (1899), Халыкара фән тарихы академиясенең мөхбир әгъзасы (1929). В.П.Васильевның улы, И.М.Симоновның оныгы. 1874 елда Петербург ун-тының физ-матем. ф-тын тәмамлый. 1874 елдан Казан ун-тында укыта. 1907 дән Петербург, 1923 тән Мәскәү ун-тларында. Хезмәтләре күплекләр һәм төркемнәр теориясенә, матем. тарихына карый. Н.И.Лобачевскийның геометрик идеяләрен пропагандалаучы (1890 еллар). 1890–1906 да Казан физ.-матем. җәмгыятен оештыручыларның берсе һәм рәисе. Н.И.Лобачевскийның геометриягә караган тулы хезмәтләре җыентыгын («Полное

собрание сочинений по геометрии», Т. 1–2, 1883–86) нәшер итүгә зур өлеш кертә. 1905 елда Дәүләт советы әгъзасы булып сайлана. I Дәүләт думасы депутаты (1906). Конституцион демократия партиясе әгъзасы.

Х е з м.: О функциях двояко-периодических. К., 1880; Систематический каталог книг по чистой математике фундаментальной библиотеки Казанского университета. К., 1880; Теория отделения корней систем алгебраических уравнений. К., 1884; Николай Иванович Лобачевский. СПб., 1914.

*Әд.:* Б а ж а н о в В.А. Николай Александрович Васильев. М., 1988.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Александр Харитонович (Вәлишин Әһлиулла Хисмәт улы) (17.4.1923, хәзерге Башкортстан Респ-касының Бәләбәй р-ны Мәтәүбаш а. — 5.5.1960, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (22.8.1944, 2.4.1945, 27.6.1945), старшина. 1934 елда Свердловск шәһәрендә 1 нче уч-щене тәмамлый. «Уралмаш» з-дында слесарь-җыючы булып эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 61 нче гв. танк бригадасының (4 нче танк армиясе 10 нчы гв. танк корпусы) автоматчылар автобатальоны пулемётчысы. 1 нче Украина фронты гаскәрләре б-н Украина, Польша, Чехословакияне азат итүдә, Берлин (1945) һәм Праганы (1945) азат итүдә катнаша. 1944 нең 27 июлендә Львов шәһәре, 1945 нең 20 гыйнварында Равич шәһәре (Польша), 1945 нең 16–17 мартында Нойштадт (Германия, хәзерге Прудник ш., Польша) шәһәре өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. Сугыштан соң туган авылында эшли. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Л о б о д а В.Ф. Солдатская слава. М., 1963. Кн. 1; Добровольцы Урала. Свердловск, 1972; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1985. Кн. 5; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Алексей Афанасьевич (17.3.1918, Уфа губ., Минзәлә өязе Поручиково а. — 3.5.1971, Одесса ш.), Дан орденының тулы кавалеры (5.6.1944, 28.8.1944, 15.5.1946), лейтенант (1955). 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. Кече авиация белгечләре мәктәбен тәмамлый (1940, Торжок ш.). 1942 елның маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 511 нче аерым разведка авиация полкының (5 нче һава армиясе) һава укчы-радисты. Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Днепр янындагы бәрелешләрдә (1943), Корсунь-Шевченко (1944), Яссы-Кишинёв (1944), Дебрецен (1944), Будапешт (1944–45), Вена (1945) һәм Прага (1945) операцияләрендә катнаша. 1943 нең 1 ноябреннән 1944 нең 30 гыйнварына кадәр Черкассы, Чигирин, Кировоград, Умань, Тальное шәһәрләре (Украина), 1944 нең 17 — 29 июнендә Валуй, Роман, Красна шәһәрләре (Румыния), 1944 нең 25 сентябреннән 26 октябренә кадәр Сольнок, Кечкемет, Цеглед, Будапешт (Венгрия) шәһәрләре янында барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Хәрби Һава Көчләрендә хезмәтен дәвам иттерә. 1955 тән запаста. «Стройснабсбыт» (Одесса ш.) базасында эшли. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



А.Х. Васильев.



Алексей А. Васильев.



А.М. Васильев.



Б.М. Васильев.

*Әд.:* Л о б о д а В.Ф. Солдатская слава. М., 1963. Кн. 1; Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Алексей Михайлович (4.4.1882, хәзерге Казакъстан Респ-касы Актүбә өлкәсенең Иргиз ш. — 10.4.1956, Казан), химик-аналитик, химия фән. д-ры (1935), проф.(1938), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1940, 1947). Ф.М.Флавицкий шәкерте. 1908 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм профессор дәрәҗәсенә әзерлек өчен калдырыла. 1918 дән проф., сыйфат һәм микъдар анализы лаб. мөдире. 1919 елда аналитик химия кафедрасын оештыра һәм аның б-н 1922–30, 1935–56 елларда мөдирлек итә, ун-тның физ.-матем. ф-ты (1926–29) деканы. Бер үк вакытта 1930 дан Казан хим.-технол. ин-тында: аналитик химия каф. мөдире (1956 га кадәр), нәорганик химия һәм технол. ф-ты деканы (1934–36), директор урынбасары (1931–32, 1936–37). Хезмәтләре нәорганик һәм аналитик химия, химик анализның классик ысулларын камилләштерүгә карый. Беренче фәнни хезмәтләре нәорганик һәм органик системаларда эвтектикалар хасил булу закончалыкларын өйрәнүгә багышлана. Калий, натрий, литий, аммоний, магний, цинк, лантан, уранил, кадмий эрүчән тозларының гидратларын; иодлы мышьяк һәм иодлы сөрмә, нафталин, паранитроанизол һәм уретанның эвтектик эретмәләрен тикшерә. Пычрануны киметү һәм үлчәү анализында төгәллекне арттыру максатыннан утырымга бергә төшү күренешен һәм аны булдырмау ысулларын өйрәнә. Микрокатышмаларның бергә утырымга төшү, уран, торий, лантан кушылмалары анализы буенча хезмәтләре илнең яңа төзелеп килгән атом сәнәгате өлкәсендә зур әһәмияткә ия була. Комплекс ясалу һәм эремәләрдә комплексның тотрыклылыгы; амперометрик титрлау ысулларын эшләү, кайбер органик реактивларны металл ионнарын амперометрик билгеләүдә куллану; ион алмашу һәм аналитик химиядә ион-алмашу бүленешләрен куллану буенча өйрәнүләрне җитәкли. Газоволюметрия, фосфоресценцияләүче матдәләр табу, химия тарихы буенча хезмәтләр авторы. Кислота-нигез индикаторлы титрлауда нейтральләшү дәрәҗәсен исәпләү формуласын тәкъдим итә. В. инглиз, француз, немец, грек, латин телләрен яхшы белә. Инглиз теленнән Д.Никольсның «Газ анализы», («Газовый анализ»), В.Рамсей, Дж.Колли, Г.Паттерсонның «Рентген көпшәләрендәге гелий турында» («О гелии из рентгеновских трубок») китапларын һ.б. тәрҗемә итә. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гидраты азотнокислых солей магния и цинка // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1909; Пирогенно-каталитический синтез аммиака // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1924; Полярографическое определение устойчивости галоидных и роданистых солей калия, натрия и аммония // Журн. аналитической химии. 1951; Т.6., № 4 (автордаш); Сборник задач по аналитической химии. М., 1951.

*Әд.:* А.М.Васильев // Журн. аналитической химии. 1956. Т. 11, № 4; В о з д в и ж е н с к и й Г.С. А.М.Васильев и его работы в области общей и неорганической химии // Страницы из истории казанской химической школы. К., 1961; Профессора, доктора наук: Политехнический институт — КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Борис Михайлович (20.11.1913, Казан губ., Ядринск өязе Лебедкино а. — 23.2.1955, Ставрополь ш.), Сов. Союзы Герое (20.11.1941), полковник (1953). Казан авиация ин-тында укый, Борисоглебск хәрби очучылар мәктәбен (1938), Качинск хәрби авиация мәктәбе каршындагы комиссар-очучылар курсларын (1941), Хәрби-һава академиясен (1951) тәмамлый. 1937 елдан Кызыл Армиядә. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, эскадрильяның хәрби комиссары ( 6 нчы армиянең 44 нче истребительләр авиация дивизиясе). Көньяк, Көньяк-Көнбатыш, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре б-н Киевны саклау (1941), Донбасс (1941), Харьков операцияләрендә (1942), Украина, Кырым, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда катнаша. 1941 елның сентябренә 35 сугышчан очыш ясый, дошманның 9 очкычын бәреп төшерә. Сугыштан соң Хәрби Һава Көчләрендә командир вазифаларын башкара. 1953 тән запаста, Ставрополь шәһәрендә яши. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; К а л и н и н В.В., М а к а р е н к о Д.Г. Герои подвигов на Харьковщине. Хар., 1970; Наши земляки — Герои Советского Союза. Чебоксары, 1970; Я к и м о в Г.В. Пике в бессмертие. А.-А., 1973; Память солдатского сердца. Чебоксары, 1979. Вып. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Валериан Михайлович (1.1.1883, Уфа губ., Бөре өязе Сусады-Ябалак а. — 3.5.1961, Йошкар-Ола ш.), мари педагог-этнографы, тел белгече, филол. фән. д-ры (1957). Казан ун-тын тәмамлый (1918). 1917–18 елларда Казан пед. ин-тында мари теле укыта, 1927–31 дә Шәрекъ пед. ин-тын-

да (Казан). Бер үк вакытта 1917–18 дә «*Ужара*» г-тасы мөхәррире. 1920–27 дә Йошкар-Ола шәһәрендә төрле оешмаларда эшли. 1931 дә буржуаз Финляндия б-н бәйләнештә торуда гаепләнә һәм Карелиягә сөргенгә җибәрелә. 1934–41 дә (өзеклек б-н) Мари пед. ин-тында укыта. 1944–58 дә Мари Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү ин-тында.

1907–14 тә «Марла календарь» исемле әдәби альманах бастыра, мари телендә беренче әлифбалар һәм уку китаплары, марилар өчен рус теле дәреслекләре, мари лингвистикасы, әдәбият белеме фольклорына караган хезмәтләр авторы. Мари фәнни-тикшеренү ин-ты һәм Йошкар-Ола шәһәренең бер урамы аның исеме б-н атала.

Х е з м.: Первоначальный учебник русского языка для восточных черемис. К., 1909; Черемисско-русский словарь. К., 1911; Элементарная грамматика марийского языка. Краснококшайск, 1927; Материалы по поэтике на марийском языке. К., 1930.

*Әд.:* В.М.Васильев: Материалы науч. конф., посвященной 100-летию со дня рождения учёного. Йошкар-Ола, 1985; И с л а м о в И.А. Янаульский учёный // Татарские края. 2003. № 6–7.

*Г.С.Сабирҗанов, В.Г.Востриков.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Валерий Архипович (18.1.1944, Калинин ш.), инженер, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), ТР һәм РФнең атказ. туку һәм җиңел сәнәгать хезмәткәре (1994, 1995). Читтән торып укып, Мәскәү туку һәм җиңел сәнәгать ин-тын тәмамлый (1984). 1962–81 елларда һәм 1988 елдан «Мелита» АҖдә эшли: баш инженер (1988–97), техник директор (1997–2002), ген. директор (2002–03), АҖнең директорлар советы рәисе (2003 тән). 1981–82 дә «Татпошивобувьбыт» берләшмәсендә баш механик, баш инженер, 1982–83 тә Модельле аяк киемнәре йорты директоры. 1983–85 тә Казан җиңел сәнәгать техникумында төзүче-инженер, укыту-җитештерү эшләре буенча директор урынбасары. 1986–87 дә «Татлесстройснаб» берләшмәсендә баш инженер, 1987–88 дә «Таттара» берләшмәсе директоры. Уйлап табу буенча авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге «Түбән температуралы плазма кулланып югары сыйфатлы мехлар һәм тунлык сарык тиресе җитештерүнең фәнни нигезләрен һәм яңа технологияләрен эшләү» дигән хезмәте өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Валерий Павлович (18.11.1947, Лаеш р-ны Лаеш а.), хакимият эшлеклесе, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1998). 1970 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1977 гә кадәр Лаеш р-ның «Волжский» с-зында инженер, баш инженер, колхоз рәисе, «Россия» с-зы директоры, 1977–85 тә КПССның Лаеш райкомы 2 нче, 1 нче секретаре. 1985–88 дә ТАССР Госагропромы рәисенең 1 нче урынбасары, 1989–95 тә ТР МС һәм МК рәисенең 1 нче урынбасары, 1995–96 да ТР Президентының Контроль идарәсе башлыгы, 1996–99 да ТРның а.х. һәм азык-төлек министры. 1999 дан ТР Дәүләт милке ком-ты рәисе. 2001 дән ТР җир һәм милек мөнәсәбәтләре министры. 1980–90 да ТАССР ЮС, 1990–93 тә РСФСР һәм РФ ЮС депутаты. «Почёт билгесе», Дуслык орденнары һәм медаль б-н бүләкләнә.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Василий Павлович (20.2.1818, Түбән Новгород ш. — 27.4.1900, С.-Петербург), шәркыятьче галим, тарих фән. д-ры (1864), Петербург ФА академигы (1886). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын монгол һәм татар телләре белгечлеге буенча тәмамлый (1837). Россиядә беренче булып монгол теле (1840) һәм соңрак татар теле магистры дәрәҗәсе ала. 1840–50 елларда Пекинга Россиянең дин эшләре буенча вәкиле итеп җибәрелә. Анда монгол, кытай, тибет телләрен үзләштерүен дәвам иттерә. 1851–55 тә — Казан, 1855 елдан Петербург ун-тларының Шәрекъ бүлекләре профессоры (1878–93 тә шул ф-тның деканы). 1852 дән — Рус геогр., 1857 дән Рус археол. җәмгыятьләре әгъзасы. 1862–68 елларда Россия Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында хезмәт итә. Хезмәтләре Кытай тарихына, географиясенә, әдәбияты һәм мәдәниятенә, ш.у. Көнчыгыш халыклары диннәренә карый. Европа фәнендә буддизм диненә караган тикшеренүләрне В. башлап җибәрә. Буддизмга багышланган күптомлы хезмәтен әзерли («Будда дине, аның кануннары, тарихы һәм әдәбияты» — «Буддизм, его догматы, история и литература»), аның 2 өлешен нәшер итә («Гомуми күзәтү» — «Общее обозрение», 1 нче кисәк, 1857; «Һиндстанда будда дине тарихы, Дараната әсәре» — «История буддизма в Индии, сочинение Даранаты». Тибет теленнән тәрҗемә. 3 нче кисәк, 1869).

Х е з м.: Россия и Средняя Азия // Биржевые ведомости. 1873. № 335; Записка о восточных книгах в Санктпетербургском университете. СПб., 1859; Китайская хрестоматия, изданная для руководства студентов: В 2 вып. 1868; Очерк истории китайской литературы. СПб., 1880; К хронологии Чингизхана и его преемников // Зап. Восточного отд-ния Рус. археол. об-ва. СПб., 1889. Т.4.

*Әд.:* И л л а р и о н о в В.Т. Русский синолог В.П.Васильев: 1818–1900 гг. Г., 1959; История и культура Китая: Сб. памяти академика В.П.Васильева. М., 1974.

*Р.М.Вәлиев.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Владимир Михайлович (27.7.1935, Вологда ш.), дирижёр, педагог, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984). Хор дирижёры (1958) һәм фортепиано (1959) белгечлекләре буенча Ленинград консерваториясен тәмамлый. 1958–74 елларда һәм 1982 дән Казан консерваториясе укытучысы. Бер үк вакытта 1970–75 тә Татар опера һәм балет театрында дирижёр, 1982–93 тә баш дирижёр, 1994 тән дирижёр. 1975–79 да Чиләбе опера һәм балет театры баш дирижёры, 1979–82 дә Одесса опера һәм балет театры дирижёры. Репертуарында: Дж.Вердиның «Риголетто», «Отелло», А.Бородинның «Князь Игорь», П.Чайковскийның «Пики дамасы» («Пиковая дама»), А.Рубинштейнның «Демон», Н.Римский-Корсаковның «Кар кызы» («Снегурочка»), Л.Хәйретдинованың «Мәкерле песи», Б.Мөлековның «Кара йөзләр» опералары; П.Чайковскийның «Щелкунчик», «Йокыга талган гүзәл» («Спящая красавица»), К.Молчановның «Макбет» балетлары, Р.Яхин музыкасына «Фидаи» И.Штрауcның «Чегән бароны» («Цыганский барон»), «Ярканат» («Летучая мышь»), Ә.Бакировның «Беренче факел» оперетталары һәм муз. комедияләре һ.б. Симф. оркестр дирижёры буларак чыгышлар ясый. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1984).

*Р.И.Такташ.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Геннадий Васильевич (11.5.1933, Яшел Үзән ш.), авиация технологиясе һәм материаллар ныклыгы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1994), проф. (1996). 1958 елда авиация ин-тын тәмамлый, ВЛКСМның Бауман райкомы беренче секретаре булып эшли. 1959–60 елларда Спорт авиациясе ОКБ бригадасы башлыгы. 1960 елдан Казан техника ун-тында конструкцияләү нигезләре кафедрасында. Хезмәтләре югары темп-рада шуучан вибрацияләүгә, виброрелаксацион һәм термовибрацион ныгытуга карый. Авиация конструкцияләре һәм оборона техникасы өчен сырлы тоташтырмаларны ныгытуның термовибрацион ысулын эшләүдә катнаша. Материалларның җәелгәндә релаксацион ныклыгын һәм шуучанлыгын билгеләү ысулын тәкъдим итә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Упрочение резьбовых соединений из титановых и жаропрочных хромоникелевых сплавов термовибрационной обработки // Проблемы прочности. 1990. № 9 (автордаш); Аналитическое описание и прогнозирование релаксации напряжений авиационных материалов в условиях вибрации // Изв. вузов. Авиац. техника. 1944. № 1 (автордаш); Расчёт термовибрационного упрочнения авиационных материалов в условиях релаксации напряжений // Изв. вузов. Авиац. техника. 1994. № 3 (автордаш).

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Иван Петрович (24.06.1879, Әстерхан ш. — 26.6.1949, Казан), патологоанатом, медицина д-ры (1913), проф. (1918), РСФСР һәм ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940, 1940). 1904 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. 1904 елдан Казан, 1911 дән Саратов ун-тларында. 1920 дән Әстерхан, 1923 тән Казан мед. ин-тларында патологик анатомия каф. мөдире. Бер үк вакытта 1930 дан Казан ГИДУВының шул ук исемдәге каф. мөдире, Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан эвакогоспитальләренең баш патологоанатомы. В. беренче мәртәбә карнифицияле пневмонияне дәвалауны тәҗрибәдә күрсәтә, авыруның морфологиясен һәм морфогенезын мәетне ярып караган материалларда җентекләп өйрәнә. Хезмәтләре үпкә ярысының башлангыч яман шеше, гемэндотелиома, спонгиобластома, ганглионеврома, аңкау дизентериясе мәсьәләләренә, сугыш җәрәхәтләрен һәм авыруларын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Облитирующая пневмония и её происхождение в связи с учением об облитирующем бронхите. Саратов, 1912; К вопросу о хоринэпителиоподобных опухолях у мужчин. Саратов, 1913; К вопросу об эпителиоме ворсистой оболочки. Саратов, 1914; Haemoendothelioma andgioplastieum // Казан. мед. журн. 1910. Т.10.

*Әд.:* Иван Петрович Васильев // Казан. мед. журн. 1959. № 6.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Константин Алексеевич (3.9.1942, Адыгея авт. өлкәсе Майкоп ш. — 29.10.1976, Яшел Үзән р-ны Васильево штп), график, нәкышьче. 1949 елдан Васильево по-

сёлогында яши. Казан сәнгать уч-щесендә укый (1957–1961). Урта мәктәптә рәсем һәм сызым укытучысы, бизәүче рәссам булып эшли. В.ның иҗади мирасы күпкырлы: картиналар, графика, этюдлар, иллюстрацияләр, Омск шәһәре чиркәвен бизәү өчен эскизлар. 1960 еллар башында иҗаты сюрреализм һәм абстракт экспрессионизм йогынтысында үсә («Кыл», 1963; «Абстракт композицияләр», 1963). 60 еллар ахырында формаль эзләнүләрдән баш тарта һәм реалистик юнәлештә эшли. В. халык иҗатына — рус җырларына, хикәятләренә һәм әкиятләренә, Скандинавия һәм Ирландия сагаларына, «эддик шигъриятькә» мөрәҗәгать итә. Мифология сюжетларын, славян һәм Скандинавия халыклары эпосларының героик темаларын чагылдырган, ш.у. Бөек Ватан сугышы турында әсәрләр тудыра («Маршал Жуков», «Һөҗүм», «Кырык беренче ел парады», «Туган илне сагыну», барысы да — 1974). Пейзаж һәм портрет жанрларында да эшли («Аккошлар» 1967; «Төньяк бөркете», 1969; «Кое янында», 1973; «Көтү», 1976; «Кеше белән байгыш», 1976). Композиторларның һәм музыкантларның график рәсем портретлары сериянләре («Шостакович», 1961; «Бетховен», 1962; «Скрябин», 1962; «Римский-Корсаков», 1962 һ.б.), Р.Вагнерның «Нибелунг бәжрасы» операсына график рәсемнәр циклы (1970 еллар) авторы.

Республиканың «Казан сатирик рәссамнары» күргәзмәсендә (Мәскәү, 1963), Яшел Үзәндә һәм Казанда узган күргәзмәләрдә (1968–76) катнаша. 1980–90 елларда В.ның берничә шәхси күргәзмәсе Россия шәһәрләрендә, ш.у. Болгария, Югославия һәм Испаниядә уза. Васильево посёлогында мемориаль музее (1996), Казанда картиналар галереясы (1996) һәм Мәскәүнең Лианозов паркында музее (1997) ачыла. Бөек Ватан сугышы турындагы картиналар циклы өчен Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләгенә лаек була (1988). Фаҗигале төстә вафат була.

*Әд.:* С о л о у х и н В.А. Письма из разных мест: Очерк о художнике // Наш современник. 1982. №1; Д о р о н и н А.И. Руси волшебная палитра. М., 1992; ш у л у к. Константин Васильев: Альбом. М., 1996; ш у л у к. Константин Васильев. М., 1999; К.Васильев: Воспоминания друзей. К., 1995; Ш о р н и к о в О. Северный символист // Актуальное национально-культурное обозрение. 2000. №1–3.

*Г.Н.Ефимова.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ КОНСТАНТИ́Н МЕМОРИА́ЛЬ МУЗЕЕ́**, Яшел Үзән р-ны шәһәр тибындагы Васильево посёлогында. 1996 елда ачыла, 1997–2006 елларда ТР Дәүләт музее (хәзерге ТР Милли музее) ф-алы, 2007 дән муниципаль музей. Музей 1949–76 елларда рәссам *К.А.Васильев* яшәгән йортның бер өлешен били; мәйданы 53,3 *м*², фондларында 555 саклау берәмлеге исәпләнә. «Гаилә һәм йорт», «Рәссам остаханәсе», «Биография һәм иҗат» экспозицияләре рәссамның бертуган сеңлесе В.А.Васильева һәм дуслары О.Е.Шорников, Г.В.Пронин тапшырган мемориаль коллекциягә нигезләнеп төзелә. Аларда йорт җиһазлары, рәссамның шәхси әйберләре (мольберт, этюдлар папкасы, палитра), документлар, фоторәсемнәр, китаплар, грампластинкалар, 1976–94 елларда К.А.Васильев иҗатына багышлап язылган мәкаләләр, ш.у. рәссамның «Л.Чугунова портреты» (1964), «Чит кеше» (1970), «С.Тарасова портреты» (1972), «Сугыш» (1974), «Дунайның яралуы» (1974), «Ярославна елавы» (1974), «Ватан» (1976) дип исемләнгән әсәрләре урын алган.



Л.Б. Васильев.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Лев Борисович (7.2.1925, Мәскәү), инженер-механик, сәнәгать җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1977). Мәскәү автомеханика ин-тын тәмамлый (1959). 1941–47 елларда СССР Елга флоты халык комис-ты автобазасында шофёр (Ульянов, Мәскәү), 1947–53 тә СССР Госснаб автобазасы шофёры, инспекторы (Мәскәү). 1953–68 һәм 1981–83 тә Ленин комсомолы исем. автомобиль з-дында (Мәскәү): 1963 елдан директор, 1981 дән ген. директор. 1968–83 тә СССРның автомобиль сәнәгате министры урынбасары һәм бер үк вакытта 1969–81 дә «КамАЗ» АҖ ген. директоры. Аның җитәкчелегендә Кама автомобиль з-дының беренче һәм икенче чираты эшли башлый, автомобильләрнең 8 моделен, ш. и. — 4 се төп һәм 3 се авыр йөк күтәрешле автомобильләрне серияләп чыгару үзләштерелә, «КамАЗ» автомобильләренә сервис хезмәте күрсәтү кертелә. 1983–85 тә СССР Госпланы рәисе урынбасары.

1985–89 да көнкүреш приборлары, җиңел һәм азык-төлек җитештерү сәнәгате өчен машиналар төзелеше министры. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Ленин, Октябрь Революциясе, өч Кызыл Байрак һ.б. орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә. 1971–80 дә ТАССР, 1979–89 да СССР ЮСлары депутаты.

Х е з м.: КамАЗ: Каким он будет? // Батыр на Каме: Год 1971–72. К., 1972; КамАЗ — главная стройка // КамАЗ: Сборник. М., 1974.


*Әд.:* Р е к м а л ь А. Сказание о КамАЗе. М., 1979; З л о б и н А. Встреча, которая не кончается. М., 1981.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Михаил Андреевич (21.1.1878, Казан губ., Чистай өязе Биләркүл а. — 13.4.1944, Казан), әдәбият белгече, фольклорчы. Казан укытучылар семинариясен тәмамлый. 1908 елда, Казандагы Өченче ир балалар гимназиясе каршында өлгергәнлек аттестатына экстерн рәвешендә имтихан тапшырып, Татар укытучылар мәктәбендә әдәбият дәресләре укыта. Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, рус әдәбияты тарихы, фольклор буенча лекцияләр укый, 1922 дән китапханә хезмәткәре. Рус телендә чыккан беренче «Татар халык авыз иҗаты ядкәрләре: Әкиятләр һәм риваятьләр» («Памятники татарской народной словесности: Сказки и легенды», 1924) җыентыгын төзүче буларак билгеле.

К.А. В а с и л ь е в. 1. «Төньяк бөркете». 1969. К.А.Васильевның картиналар галереясы, Казан; 2. «Славян хатынының хушлашуы». 1975. К.А.Васильевның иҗат музее, Мәскәү; 3. «Бетховен». Кәгазь, тушь. 1962; 4. «Скрябин». Кәгазь, тушь. 1962. Икесе дә — К.А. Васильевның картиналар галереясында, Казан.



1



3



2



4

*Әд.:* З а м а л е т д и н о в Л. Колумб татарского фольклора // Наука. 1989. 11 апр.

*Л.Ш.Җамалетдинов.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Николай Александрович (29.6.1880, Казан — 31.12.1940, шунда ук), логика белгече, философ, психолог, әдәбият галиме. А.В.*Васильевның* улы, В.П.*Васильевның* оныгы. Казан ун-тының медицина (1904) һәм тарих-филология (1906) ф-тларын тәмамлый, шунда ук эшли, 1918 елдан профессор. «Күзаллanучы» логика гыйлемен формалаштыра. Аристотельчә булмаган яңа логиканың идеясе һәм төзелеше ысуллары беренче тапкыр 1910 елның 18 маенда укылган һәм шул ук елда басылып чыккан «Шәхси фикерләүләр, капма-каршылыклар өчпочмагы, инкарь ителгән дүртенче як законы турында» («О частных суждениях, о треугольнике противоположностей, о законе исключённого четвёртого») дигән лекциясендә бәян ителә. Фикерләүнең традицион Аристотель логикасында кабул ителгән классификациясен тикшереп, В. аның төп законнарының универсаль булмавын дәлилли. «Лобачевский ысулы»н кулланып, үзенә күрә аксиома булып кабул ителгән өченче якны инкарь итү һәм каршылыксызлык (каршылык) законнарыннан баш тарта, әлеге законнарга буйсынмаган, кайбер «күзалланган» дөнья шартларында яшәргә мөмкин дип фаразланган логикалар системасын төзи. В. фикеренчә, Аристотель логикасында эмпирик, «матди» һәм теоретик, «формаль» дәрәҗәләр бербөтен булып кушылган, ә инде өченче якны инкарь итү һәм каршылыксызлык (каршылык) законнары «безнең» дөньяның корылышына, кешенең хисси танып белү табигатенә бәйләнгән эмпирик гомумиләштерү булып тора. Логикага психологик якын килеп, В. «күзаллануча» дөньяда фикер йөртү өчен иң кирәкле төп законнарны (бердәйлек һәм үз-үзен инкарь итмәү законнарын) гына үз эченә алган металогика төшенчәсен куллана. «Күзаллanучы» логикага В. яңа фикер йөртү класслары, шуңа тәңгәл рәвештә хакыйкыйлык билгеләмәсен (ш.и. каршылыклы вазгыятьләрне чагылдыручыларын да), инкарь итүнең яңа төрләрен, «n-үлчәнешле» логика өчен кирәкле махсус законнар кертә. В. — логик системаларның күп төрлелеген беренче булып әйткән һәм формаль системалар төзү юлы б-н дәлилләгән галим. Ул классик булмаган параконсистент, күп мәгънәле логика системаларына нигез салучы, интуицион һәм конструктив логика идеясенә җирлек әзерләүче булып исәпләнә. В. ш.у. психология, этика, тарих, әдәбият белеме өлкәләренә караган хезмәтләр яза. Шагыйрь буларак, ул — символизм тарафдары. Э.Верхарн, О.Суинберн шигырьләрен тәрҗемә итә, әлеге шагыйрьләр иҗатына һәм Н.В.Гоголь әсәрләренә карата әдәби тәнкыйть мәкаләләре яза.

Х е з м.: О частных суждениях, о треугольнике противоположностей, о законе исключённого четвёртого. К., 1910; Воображаемая (неаристотелева) логика // Журн. Мин-ва нар. просвещения. 1912. Ч.40; Логический и исторический методы в этике: Об этических системах Л.Н.Толстого и В.С.Соловьёва. К., [б.г.]; Лекции по психологии. К. 1914; Воображаемая логика. М., 1989.

*Әд.:* Б а ж а н о в В.А. Н.А.Васильев (1880–1940). М., 1988.

*В.А.Бажанов.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Павел Степанович (23.10.1906, Екатеринодар, хәзерге Краснодар ш. – 2000, Мәскәү), нефтьче, СССРда нефть сәнәгатен оештыручыларның берсе. Грозный нефть ин-тын тәмамлый (1932). 1927–38 елларда һәм 1946 да «Грознефть» берләшмәсендә нефть трестларын җитәкли, 1938–40 та Нефть халык комисс-тының Хуҗалык җитәкчеләре һәм инженер-техник хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү ин-тында укыта. 1952–55 тә «Бөгелмәнефть» НГДУы башлыгы, 1955–60 та «Татнефть» берләшмәсенең, 1960–63 тә Татсовнархоз нефть сәнәгате идарәсенең баш инженеры. 1965–77 дә СССР Госпланының нефть һәм газ сәнәгате бүлегендә баш белгеч, 1977–85 тә Бөтенсоюз нефть-газ сәнәгатен оештыру һәм аның икътисады фәнни-тикшеренү ин-тында. Нефть ятмаларын су кудырып эшкәртүнең яңа системасын эшләгәнө һәм аны Ромашкино нефть чыганагында кулланганы өчен Ленин бүләге бирелә (1962). Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Р.С.Алатырева.*

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Пётр Петрович (1842, Пермь ш. — 1883, Казан), китап белгече, библиограф, нашир, журналист. 1862–63 елларда Казан ун-тында ирекле тыңлаучы. 1860 елларның урталарыннан күп очракта «К. библиограф» псевдонимы б-н көндәлек матбугатта — «Казанские губернские ведомости», «Казанский биржевой листок», «Камско-Волжская газета»ларында, «Русская старина» ж-лында актив языша. Китап эшенә, әдәбият, театр сәнгате, журналистикага кагылышлы күп кенә мәкаләләр, рецензияләр авторы. 1868 дә ул шул заман өчен бердәнбер басма — рус язучыларының псевдоним-кушаматлары турында белешмәлек төзеп бастыра («Показатель псевдонимов. Список современных русских писателей, носящих псевдонимы»). В. ш.у. Казан шәһәре турында еллык календарь («Календарь-указатель города Казани на 1882 г.», 1881), И.С.Тургенев хикәяләрен, А.И.Герцен мәкаләләрен аерым китапка туплап чыгара, К.Ф.Рылеевка багышлап «Онытылган шагыйрь турында берничә сүз» («Несколько слов о забытом поэте», 1873) исемле зур мәкалә яза (мәкаләне бастыру цензура тарафыннан тыела). В.ның «Казанда китапчылык эше» («Казанское книжное дело. Вып.1», 1866) дигән җыентыгы җирле басма продукцияне теркәп бару юлында ирешелгән беренче уңышлы тәҗрибәләрдән санала. Басма алга таба дәвам иттерелмәсә дә, В.ның бу төр җыелган материаллары җирле матбугатта аннан соң да даими басылалар. В. беренчеләрдән булып җирле матбугат библиографиясенә нигез сала, «Камско-Волжская газета»ның 1873 ел 14 ноябрь санында басылган мәкаләсендә аның бурычларын билгели.

*Әд.:* В е н г е р о в С.А. Критико-биографический словарь русских писателей и учёных. СПб., 1895. Т.4, отд.1; Б а р е н б а у м И.Е., М а м о н т о в А.В. П.П.Васильев — казанский библиограф и книговед // Советская библиография. 1973. № 1; Книга: Энцикл. М., 1999.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Ремус Хөсәен улы (21.8.1931, Пенза өлкәсенең хәзерге Кузнецк р-ны Бестянка а.), хирург, мед. фән. д-ры (1973), проф. (1974). 1956 елда Волгоград мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Волгоград һәм Калининград өлкәләре мед. учреждениеләрендә эшли. 1962 дән Бөтенсоюз клиник һәм экспериментал хирургия фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). 1973 тән Мәскәү мед. стоматология ин-тында, 1976 дан гомуми хирургия каф. профессоры. Хезмәтләре корсак куышлыгы әгъзаларына диагноз кую ысулларына һәм хирургик дәвалауга, диагностик һәм хирургик лапароскопия, гастродуоденоскопиягә, криоген һәм лазер хирургиясенә, торакоскопиягә карый. Уйлап табуларга 30 лап авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Перитонеоскопия в хирургической клинике. М., 1968; Комбинированная лапароскопия. Таш., 1976; Альвеококкоз. Таш., 1978; Диагностическая и лечебная лапароскопия. Таш., 1986; Бескровные методы удаления жёлчных камней. М., 1989.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Станислав Николаевич (5.7.1946, Украинаның Чистяково ш., хәзер Торез ш.), автоматик идарә итү һәм кибернетика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1990). РФАнең мөхбир әгъзасы (1997), академигы (2006). 1970 елда Казан авиация ин-тының радиотехника ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1975–2006 да СССР ФАнең Себер бүлегендә (хәзер РФАнең Себер бүлеге): 1975–80 дә Себер энергетика ин-тында, лаб. мөдире (1978 дән); 1980 нән Иркутск исәпләү үзәгендә (хәзер Системалар динамикасы һәм идарә итү теориясе ин-ты): лаб. мөдире, бүлек мөдире (1986 дан), директор урынбасары (1989 дан), директор (1991 дән). Бер үк вакытта Иркутск ун-тының системалар теориясе (1991–96 да), идарә итү һәм информатика проблемалары (1996 дан) кафедралары мөдире. 2006 дан РФАнең Идарә итү проблемалары ин-ты директоры. Хезмәтләре динамик һәм идарә ителүчән системалар теориясенә, идарә итүнең логик ысулларына, ясалма интеллект проблемаларына карый. В. идарә итүләр теориясендә логик ысуллар фәнни мәктәбенә нигез сала. Ляпуновның векторлы функцияләр терминнары ярдәмендә нәсызыкча системаларның идарә ителүчәнлек һәм оптимальлек критерийләрен, ш.у. ясалма интеллект өлкәсендәге теоремаларны автоматик исбатлау һәм синтезлау ысулларын беренче дәрәҗә логик исәпләүләрдә эшли.

«Оптимизация, управление, интеллект» ж-лының баш мөхәррире (1994 тән). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Почёт ордены, медальләр, ш.и. РФ Космонавтика федерациясенең С.П.Королёв исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Метод сравнения в математической теории систем. Новосиб., 1980; Метод векторных функций Ляпунова в задачах быстродействия. М., 1986; Интеллектное управление динамическими системами. М., 2000 (автордаш); Моделирование и управление процессами регионального развития. М., 2001 (автордаш).

**ВАСИ́ЛЬЕВА** Галина Павловна (6.3.1932, Балык Бистәсе р-ны Югары Мәшләк а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1983). 1971 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1970–90 да «Масловский» (Балык Бистәсе р-ны) җиләк-җимеш с-зы директоры. Аның җитәкчелегендә елына 5 млн шартлы банка җимеш консервлары һәм 1,5 мең *т* алма согы җитештерелә торган җиләк-җимеш эшкәртү з-ды, 1100 баш мөгезле эре терлек өчен терлекчелек комплексы, бөтен уңайлыклары булган 248 фатирлы торак комплексы төзелә, авылга, җитештерүче объектларга газ кертелә, мәдәният йорты, урта мәктәп, 200 урынлы хезмәт һәм ял лагере һ.б. социаль-көнкүреш объектлары төзелә. Совхоз КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКнең (1986), РСФСР МС һәм ВЦСПСның (1987) күчмә Кызыл Байраклары; КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКнең Мактау грамоталары (1983, 1984) б-н бүләкләнә; Бөтенсоюз Мактау тактасына кертелә (1986); СССР ВДНХсында катнаша. В. 1982–91 дә Совет хатын-кызлары ком-ты президиумы әгъзасы. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ВАСИ́ЛЬЕВА** Любовь Николаевна (2.2.1901, Саратов ш. — 7.7.1985, Владивосток ш.), геоботаник, биол. фән. д-ры (1967). А.Я.Гордягин шәкерте. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1925), шунда ук эшли. 1944 елдан СССР ФА Ерак Көнчыгыш ф-лының Биология ин-тында (Владивосток ш.), 1949–66 да түбән төзелешле үсемлекләр лаб. мөдире. Мари АССРның үсемлекләр япмасын тикшерүләр буенча Казан ун-ты ботаника кафедрасы оештырган геоботаник экспедицияне җитәкли (1931). Нәтиҗәдә Идел-Кама өлкәсендә 100 ләп төр күп тамырлы үсемлек, 150 төр мүк һәм 119 төр лишайникны эченә алган зур гербарий материалы җыела һәм эшкәртелә. Хезмәтләре Мари һәм Чуаш АССРларның мүкле һәм торфлы сазлыкларын, ТАССРның төньяк-көнбатыш өлеше флорасын, Кавказ тыюлыгындагы түбән төзелешле үсемлекләрне, Раифа тыюлыгындагы җәймәле гөмбәләрне өйрәнүгә карый. Торфлы мүкләрнең күп төрләрен билгели һәм тәфсилләп сурәтли, аларның эчке структурасын ачыклый. В. ш. у. Ерак Көнчыгыштагы гөмбәләрне, төче суда үсә торган суүсемнәрне, мүкләр һәм лишайникларны өйрәнә.

Хезм.: О флоре сфагновых мхов северо-запада Казанского края // Уч. зап. Казан. ун-та. 1933. Т. 93, кн. 6, вып. 1; Сорные растения и меры борьбы с ними. Йошкар-Ола, 1934; К флоре мхов Марийской автономной области // Уч. зап. Казан. ун-та. 1936. Т. 96, кн. 6, вып. 3; Съедобные грибы Дальнего Востока. Владивосток, 1971; Деревообразующие грибы Дальнего Востока. Новосиб., 1975 (автордаш).

*А.П.Ситников.*

**ВАСИ́ЛЬЕВКА** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Саурыш елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 216 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1910 елларда Иске Саурыш авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәмсу волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 203, 1938 дә — 275, 1949 да — 261, 1958 дә — 312, 1970 тә — 409, 1979 да — 416, 1989 да — 246 кеше.

**ВАСИ́ЛЬЕВКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 24 *км* көньяктарак, Зәй-Каратай елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 440 кеше (мордвалар — 57%, татарлар — 39%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 18 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кузай исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, йон тетү, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү (1895–96 да төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1900 да ачыла), һөнәри уч-ще, су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва-Иваново волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан — Лениногорск, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1795 тә — 145; 1859 да — 699, 1889 да — 826, 1897 дә — 725, 1910 да — 1038, 1920 дә — 1190, 1926 да — 985, 1938 дә — 659, 1949 да — 629, 1958 дә — 565, 1970 тә — 536, 1979 да — 478, 1989 да — 319 кеше.

**ВАСИ́ЛЬЕВКА** посёлогы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2002 елда 109 кеше (татарлар — 58%, руслар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — бакчачылык. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Елховка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 196,1 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 72, 1897 һәм 1910 да — 159, 1920 дә — 243, 1926 да — 173, 1938 дә — 200, 1949 да — 149, 1958 дә — 186, 1970 тә — 182, 1979 да — 215, 1989 да — 132 кеше.

**ВАСИ́ЛЬЕВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Киртәле елгасы буенда. 2002 елда 22 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Башта — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 141, 1949 да — 288, 1958 дә — 166, 1970 тә — 140, 1979 да — 88, 1989 да — 57 кеше.

**ВАСИ́ЛЬЕВО (ӘҖМӘ́К)** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 32 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 181 кеше (руслар — 50%, татарлар — 47%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында почта станциясе, земство мәктәбе (1876 да ачыла), тимерчелек, су тегермәне, шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1465,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык-Күпер волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 47 ир заты; 1859 да — 435, 1897 дә — 846, 1908 дә — 942, 1926 да 1035, 1949 да — 566, 1958 дә — 431, 1970 тә 509, 1979 да — 375, 1989 да — 262 кеше.

**ВАСИ́ЛЬЕВО**, шәһәр тибындагы посёлок, Яшел Үзән р-нында, Идел елгасының (Куйбышев сусаклагычының) сулъяк ярында, Яшел Үзән шәһәреннән 19 *км* көнчыгыштарак. Казан — Канаш тимер юлындагы станция. 2002 елда 16,8 мең кеше (руслар — 67,8%, татарлар — 29,3%) яши. Агач эшкәртү сәнәгате пр-тиеләре, *Васильево пыяла заводы*, төзү пр-тиеләре, икмәк з-ды. 4 гомуми белем бирү мәктәбе, сәнгать һәм музыка мәктәбе. Мәдәният йорты, рәссам К.А.Васильевның музей-йорты, китапханә. Мәчет. «Васильево» санаторие. 17 йөздә нигез салына. 1693 тә Васильево авылы Раифа пустынена — вотчинага, 1764 тә Икътисади коллегиягә бирелә. Халкы, игенчелек һәм терлек үрчетүдән тыш, балта эше, көймә, кыршау ясау, кәрзин үрү, умартачылык, балык тоту б-н шөгыльләнә. 1892 дә В. аша тимер юл уза, шунлыктан халык саны шактый арта. 20 йөз башында Крестовоздвижение чиркәве (1870–71 дә Н.И.Ильминский инициативасы б-н төзелә, 1990 да яңадан эшли башлый), земство мәктәбе (1875 тә ачыла), телефон, җил тегермәне, П.И.Богдановның пыяла ф-касы, тимерче алачыгы, трактир, 2 сыраханә, 1 шәраб, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1738,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Ильинский волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1928 нең 21 маеннан шәһәр тибындагы посёлок, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 116 ир заты; 1859 да — 686, 1897 дә — 981, 1908 дә — 815, 1920 дә — 1355, 1926 да — 1591, 1940 та — 10176, 1989 да — 18,8 мең кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Приволжские города и селения Казанской губернии. К., 1892; Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1916. Вып. 3.

**«ВАСИ́ЛЬЕВО»**, санаторий. Идел елгасының сулъяк ярында, Казаннан 30 *км* көнба-



А.Г. Васильченко.

тыштарак Васильево посёлогындагы наратлыкта урнашкан. 1924 елда гомуми профильдәге санаторий буларак ачыла, 1934 тә неврология авыруларын дәвалау юнәлешендә эшли башлый, санаторий каршында пионер лагере, аналар һәм балалар өчен ял итү дачалары бар. Бөек Ватан сугышы елларында эвакуация госпиталенең хирургия бүлеге урнаштырыла. 1946 дан кардиология авыруларын дәвалау санаторие. Йөрәк-кан тамырлары, нерв системасы, кан әйләнеше системасы, гипертония, ревматик эндомиокардит, кардиосклероз, очлыклар тамырларында атеросклероз, баш мие имгәнү һ.б. авыруларны дәвалау б-н шөгыльләнә. Табигый дәвалау чаралары: «Зәңгәр күл» чыганагының аз суль



«Васильево» санаториенең кардиология корпусы.

фидлы ләме, йод, бром б-н баетылган хлоридлы натрийлы эремәләр. Санаторийда диагноз кую лабораторияләре, функциональ диагноз, электр б-н дәвалау, мануаль һәм рефлексотерапия кабинетлары, бил остеохондрозы вакытында умырткалыкны тартып турайту җайланмасы бар. Дәвалау комплексы: парафин-озокерит (аппликацияләр), гальваник ләм, ванналар (нарат, энҗе-нарат, энҗе, йод-бромлы диңгез суы, кислород, сероводород б-н баетылган, коры углекислый), дә



«Васильево» санаторие. Урман паркы.

валау душлары (Шарко, циркуляр), су астында массажлау, дәвалау физкультурасы, оксигенотерапия, аромотерапия, фитотерапия, ингаляция, диетотерапия, климатотерапия. Ял итүчеләргә сауна, бассейн, терренкурлар, чаңгыда йөрү юллары, спорт мәйданы, концерт-кино залы, китапханә хезмәт күрсәтә. Санаторий ел буе эшли. В. санаториенең ел буе эшли торган 300 урынга исәпләнгән респ-ка балалар санаторий-сәламәтләндерү лагеренда (2–8 сыйныфлар өчен) укыту эшләре оештырылган. Анда еш һәм озак авыручы балалар дәвалана. 1998 елда ачыла. Санаторийда балаларны мед.-экологик реабилитацияләү үткәрелә, алар өчен физик һәм психик савыктыру, авыруларны булдырмау (агымдагы мед. тикшеренүләре, тукландыру һәм ял режимы, физик тәрбия һәм спорт б-н шөгыльләнү һ.б.) чаралары үткәрелә.

*Ю.К.Чумаков.*

**ВАСИ́ЛЬЕВО ПЫЯЛА́ ЗАВОДЫ́**, пыяла җитештерү пр-тиесе. Яшел Үзән р-нының Васильево шәһәр тибындагы поёлогында урнашкан. 400 кеше эшли (2007). 1901 елда П.И.Богданов тарафыннан Васильево пыяла ф-касы буларак нигез салына. Беренче продукциясе (сыра, аракы шешәләре, тәрәзә пыяласы) кулдан эшләп чыгарыла. Завод эшләнмәләре киң танылa, ш.и. чит илләрдә дә; халыкара күргәзмәләрдә бүләкләргә лаек була (алтын һәм көмеш медальләр, Мәскәү, 1906; Зур алтын медаль — Париж, Бөтендөнья сәнәгать күргәзмәсенең иң югары бүләге, 1908). 1916 да завод ябыла, 1919 да дәүләт милкенә күчерелә. 1922 нең 22 июнендә «Победа труда» Васильево пыяла заводы» исеме б-н кабат эшли башлый. 1923–27 һәм 1946–60 елларда капиталь төзелеш һәм төп җитештерү көчләрен үзгәртеп корулар үткәрелә. 1941 дә Ленинград өлкәсеннән күчеп килгән «Дружная горка» з-ды б-н кушылганнан соң, Россиядә термик чыдам бромсиликат пыяла эшләү технологиясен үзләштергән бердәнбер пр-тие була. 1958 дә «Победа труда» химия лабораториясе приборлары һәм савыт-саба ясау заводы» дип үзгәртелә. 1950–80 дә СССРда химик-лаборатор җиһазлар җитештерүче төп пр-тие санала, союз күләмендә әһәмиятле заказлар үти (мәс., Мәскәү ун-ты лабораторияләре өчен). Продукциянең бер өлешен дөньяның 13 иленә, ш.и. Һиндстан, Кытай, Бирма, Польша, Югославия, Монголия, Кубага чыгара. 1995 тә «Победа» химик-лаборатор приборлар һәм савыт-саба» АҖ итеп үзгәртелә. 2004 елдан хәзерге исемдә.

Предприятие составында 3 төп цех (химия лабораториясе савытлары, пыяладан өреп төрле әйберләр ясау-аппаратура, термометр пыяласы җитештерү һәм 4 ярдәмче цех (балчыктан әйберләр ясау, җыелма, механика, ягу-транспорт) эшли. 200 дән артык төр продукция чыгарыла: лаборатория савытлары (колба, стакан, мензурка, пробирка, тоташтыргыч торбалар, дефлегматор һ.б.); югары темп-рада кайнаучы сыеклыклар, кислоталарны дистилляцияләү һәм куу аппаратлары; басым үлчәү приборлары (мановакуумметрлар); көнкүреш һәм декоратив савытлар (чәйнек, кофейник, кәстрүл, сервизлар, пыяла сувенирлар). Завод чыгарган эшләнмәләр югары температураларга (220° ка кадәр), хим. реагентларга чыдам, кристаллашу үзенчәлеге түбән, үтә күренмәле, җиңел чистартылучан, хим. реакцияләр продуктының сафлыгы югары дәрәҗәдә. В.п.з.ның продукциясе медицинада, химия, фармацевтика, азык-төлек сәнәгатендә, Россия һәм БДБ илләренең фәнни оешмаларында кулланыла.

Заводның күп кенә эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек булган, ш.и. 1 кеше Ленин ордены, 1 кеше Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кеше «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Завод җитәкчеләре: П.И.Богданов (1901–16), Одинцов (1916–18), И.Ф.Антипин (1922–23), Косьянчук (? — 1934); А.С.Демидов (1934–41), Г.Н.Зяблинцев (1941–45), В.А.Колпаков (1945–47), В.К.Ломакин (1947–50), Е.А.Шикарев (1950–56), Г.А.Пашков (1956–61), В.А.Михайлов (1961–85), А.П.Митрофанов (1985–87), В.Л.Павленко (1987–98), И.В.Латыйпов (1998–2000), В.М.Копнин (2000–2004); О.А.Антонов (2004 тән).

*Әд.:* Анисимов Н.Г. Огни на Волге. К., 1967.

*С.Г.Белов.*

**ВАСИ́ЛЬЧЕНКО** Александр Григорьевич (23.11.1911, Белгород өлкәсенең Новооскол р-ны Иске Безгинка а. — 8.11.1960, Казан), Сов. Союзы Герое (1.5.1957), полковник (1957), СССРның атказ. очучы-сынаучысы (1960). Харьков очучылар хәрби авиация мәктәбен тәмамлый (1936). 1933 елдан Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында (1939–40) катнаша. 1941 елның июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында. 1943 тән Казан авиация з-дында очучы-сынаучы. Яңа авиация техникасын сынаганда кыюлык һәм батырлык күрсәтә (1957). Хәрби бурычын үтәгәндә һәлак була. Ике Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, дүрт Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои-белгородцы. Воронеж, 1972.

*В.А.Шагалов.*

**«ВАСИТА́»**, нәшрият, Казанда 1917 елда шул исемдәге китап сату ширкәте (1910 елларда оешкан) җирлегендә ачылган нәшрият. Үз басмаханәсе булмый, заказларын «Милләт», бертуган Кәримовлар, «Өмид» басмаханәләренә биреп бастыра. 15 исемдә китап, ш.и. иҗтимагый-сәяси, педагогика, тел белеме, матур әдәбият әсәрләре нәшер итә. Алар арасында «Швейцария Федератив Республикасы», «Нәрсә ул Учредительное собрание» китаплары, Г.Камалның «Русча-татарча мөкәммәл сәяси лөгате» (барысы да 1918 дә), Г.Сәгъди һәм М.Терегуловның пед. хезмәтләре (1919) һ.б. бар. 1919 елда Ш.Әмирханов җитәкчелегендә Мөселман мәгариф халык комиссариаты бүлегенә хезмәт күрсәтә. Шул елда ябыла.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Становление и развитие татарской советской книги (1917–1932), К., 1989.

**ВАСНЕЦО́В** Николай Алексеевич (24.3.1901, Вятка губ., Малмыж өязе Әҗем а. — 7.4.1961,

Казан), вет. анатомы, биол. фән. д-ры (1940), проф (1940), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1961). 1925 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, участок табибе булып эшли, 1927–61 елларда Казан вет. ин-тында укыта, 1932 дән анатомия каф. мөдире, бер үк вакытта 1956–60 та проректор. Хезмәтләре а.х. терлекләре һәм кошларының нейроморфологиясенә карый: төрле хайваннарда нервларның таралып урнашу зоналары һәм үзара бәйләнешләре топографиясе турындагы фаразлауларга үзгәреш кертү өчен яңа биоморфологик юнәлешне эшли; сөяк, буын, эчке органнар мускуллары иннервациясе чыганакларын һәм аларның формалашу закончалыкларын өйрәнә; иннервацияләнгән әгъза тукымасына бәйле рәвештә нерв баганасының эчке төзелешен һәм җепселле составын ачыклый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы анатомии и физиологии сельскохозяйственных животных // Основы животноводства. К., 1951; Структура и функция нервной системы домашних животных. К., 1958.

*Әд.:* М и х а й л о в Н.В. Научная деятельность профессора Н.А.Васнецова и его учеников // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та. 1971. Т. 3; История Казанского государственного ветеринарного института им. Н.Э.Баумана. К., 1973; М и х а й л о в Н.В. Школа ветеринарных морфологов // Ветеринария. 1973. № 5; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ВАССА́Ф** Габдуллаһ бине Фазлуллаһ Ширази (псевдонимы Вассаф әл-Хәзрәти) (14 йөз), фарсы тарихчысы. Төп хезмәте: «Тәҗзиәт әл-әмсар вә тазҗиәт әл-асар» («Төбәкләргә һәм гасырларга бүленеш», ш.у. «Вассаф тарихы» буларак та мәгълүм). Бу хезмәттә 1257–1323 еллар арасындагы Алтын Урда б-н Иранга кагылышлы мәгълүматлар бар.

*Әд.:* Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. М.–Л., 1941. Т. 2; B r o w n e E.G. Literari history of Perca. Camb., 1956. V.3.

**ВАСЫ́ЙЛОВ** Раиф Гаян улы (4.1.1953, Мамадыш ш.), биолог, биол. фән. д-ры (1991), проф. (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1975). 1979–85 елларда СССР ФАнең Биоорганик химия ин-тында; 1986 дан «Биотехнология» фәнни-җитештерү җәмгыятендә (Мәскәү) бүлек мөдире, 1989 дан ген. директор. Хезмәтләре иммунитетның молекуляр күзәнәк механизмнарына, сәламәтлекне саклау өчен яңа диагностикумнар булдыруга, молекуляр зондлар ярдәмендә генотиплау ысулларын эшләүгә һ.б. карый. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы, патенты бар.

**ВАСЫЯТЬНАМӘ́** (гарәп. وصيت — васыять, фарсы. نامه — намә — язу, китап), язма рәвештә бирелгән: 1) хокукый документ; 2) татар әдәбиятында эпистоляр жанр төре; каләм иясенең киләчәк буыннарга, шәкертләргә теләк-үтенечләрен, үгет-нәсыйхәтләрен белдергән язма (кайбер очракларда шигъри формада). Татар әдәбиятында аеруча билгелеләре: «Галикәй Аталык васыятьнамәсе» (1639), «Кишбикә Бикәч васыятьнамәсе» (1660), «Гаделшаһ бине Габдулла васыятьнамәсе» (1788).

*Әд.:* Ш ә р и п о в Ә.М. XVIII йөз әдәбиятының кайбер жанрлары (Сәяхәтнамә һәм васыятьнамә) // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 нчы китап; Х и с а м о в а Ф.М. Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI–XVIII вв. К., 1990.

**ВА́СЬКИНО-ТУЙРАЛЫ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 3 *км* көнбатыштарак, Томбарлы елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 416 кеше (чуашлар — 60%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1809 еллар тирәсендә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 1530 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе эшли. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Баулы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 498, 1897 дә — 748, 1926 да — 889, 1938 дә — 828, 1949 да — 921, 1958 дә — 848, 1970 тә — 755, 1979 да — 566, 1989 да — 276 кеше.

**ВАСЬКО́В** Юрий Макарович (22.1.1934, Саратов өлкәсе Энгельс ш.), инженер-конструктор, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1986). 1957 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, Казан «Союз» КБнда конструкторлык бригадасы башлыгы (1960–70), бүлек башлыгы урынбасары (1974–77), тәҗрибә-тикшеренү бүлеге башлыгы (1977–92), бер үк вакытта әйдәп баручы конструктор (1969 дан). 1992–93 тә «Татэнергоремонт»ның җитештерү-ремонтлау пр-тиесендә механика-җыю цехы башлыгы. Авиация двигательләрен, аларның модельләрен һәм узелларын проектлаштырганда параметрларының туры китерелеп җиткерелүен тәҗрибәдә исәпләү-тикшеренү эшләре уздыра. Дәүләт бүләге яңа физик җайланмалар төзегән өчен бирелә.

**ВАСЯ́НОВ** Геннадий Павлович (6.7.1938, Куйбышев өлкәсе Камышлы а.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), ТРның атказ. геологы (1996). Татарстан терр-ясендә Пичкас мәрмәр ониксы чыганагын беренче ачучылардан. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1961), СССР ФА Урал ф-лының Геология ин-тында (Свердловск ш.) эшли. 1965 елдан ЦНИИгеолнерудта (өлкән фәнни хезмәткәр). Б.Ф.Горбачёв б-н берлектә элювиаль каолин һәм фарфор ташлары ятмаларының урнашу һәм формалашу закончалыкларын өйрәнә, аларны фаразлау һәм эзләүнең методик нигезләрен билгели, ТРдагы кызыл балчык чимал базасына кирпеч чималы булачак геологик-икътисади анализ ясый. А.В.Шишкин б-н берлектә ТРда мәрмәр ониксы ятмаларының геологик төзелеше закончалыкларын ачыклый. ТР Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасының утырма тышлыгында яңа һәм гадәти булмаган файдалы казылмаларны ачу» дигән хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Месторождения каолинов СССР. М., 1974 (автордаш); Минеральное сырьё. Фарфоровые камни: Справ. М., 1998.

**ВАСЯ́СИН** Георгий Иванович (4.2.1932, Горький ш.), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. канд. (1976), Казан ун-тын тәмамлый (1962). 1968–78 елларда Казан геол. экспедициясендә, 1978 дән НИИнефтепромхимда катламнарга тәэсир итүнең яңа ысулларын сынау һәм техник документлар эшләү лаб. мөдире. ТРда битум ятмалары һәм нефть табуда экологик мониторинг һәм экологик куркынычсызлык принципларын билгеләүдә катнаша. «Татарстан Республикасының нефть чыгару районнарында техногенез, мониторинг, халыкның сәламәтлеген һәм экологик хәлен яхшырту чараларын сәнәгатькә кертү» дигән хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә (1996).

Х е з м.: Техногенез и экологический мониторинг юго-востока Республики Татарстан. К., 1995 (автордаш); Геология турнейского яруса Татарстана. К., 1999 (автордаш).

**ВАТА́ГИН** Алексей Васильевич (4.8.1904, Түбән Новгород өлкәсенең хәзерге Перевозский р-ны Гредино а. — 1985), галим-агроном, а.х. фән. д-ры (1950), проф. (1951). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1930), Татарстан сәнәгать һәм а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1931 елдан Бөтенсоюз бөртекле ашлык хуҗалыгы ин-тында, 1933–34 тә Бөтенсоюз ашлама һәм агротуфрак белеме ин-тында (Мәскәү) эшли. 1934–38 дә Югары Коммунистик а.х. мәктәбендә (Горький өлкәсе), 1938–40 та Горький өлкәсе а.х. тәҗрибә станциясендә директор урынбасары. 1940–44 тә Башкортстан а.х. ин-тында. 1944–50 дә Свердловск а.х. ин-тында гомуми игенчелек каф. мөдире һәм агрономия ф-ты деканы. 1950–57 һәм 1969–78 дә Казан а.х. ин-тында гомуми игенчелек каф. мөдире. 1957 дә проректор, 1958–62 дә ректор, 1962–68 дә агрохимия һәм туфрак белеме каф. мөдире, 1978 дән Иваново а.х. ин-тында гомуми игенчелек каф. профессоры. Хезмәтләре а.х. культуралары, күпьеллык үләннәр игү технологиясенә, пар басуларында, басу һәм терлек азыгы чәчү әйләнешләрендә яшел ашламалар һәм органик-минераль катнашмаларны нәтиҗәле куллану мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Техника полеводства Мензелинского кантона Татарской республики. К., 1930; Действие минеральных удобрений на опытном поле Казанского сельскохозяйственного института. К., 1930; Действие фосфорита в Татарии. К., 1935.

*А.А.Җиһаншин.*

**ВАТАЖНИКОВ** Павел Яковлевич (7.6.1903, Вятка губ., Алабуга өязе Лекарево а. — 20.11.1967, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. 1919–24 елларда Лекарево кулланучылар җәмгыятендә, 1924–27 дә Алабуга кооперативлар берләшмәсе идарәсендә, 1929–38 дә Татпромсоветта эшли. 1938–40 та финанс бүлеге, 1940–42 дә план-финанс бүлеге башлыгы, 1942–43 тә халык комиссары урынбасары, 1943–46 да халык комиссары, 1946–51 дә ТАССР азык-төлек сәнәгате министры. 1951–57 дә ТАССРның «Заготзерно» конторасы башлыгы. 1957–61 дә ТАССР Икмәк продуктлары идарәсе башлыгының бе-

ренче урынбасары. 1959–63 тә ТАССР ЮС депутаты.

*Е.Б.Долгов.*

**«ВАТА́Н»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. Адмирал А.В.Колчакның 3 нче армиясе мәгълүмат бирү канцеляриясе органы. 1919 елда татар телендә башта Уфа шәһәрендә, аннары Себердәге төрле шәһәрләрдә нәшер ителә. Мөхәррирләре Г.Сөбханкулов, М.Нәүрузов. «Яшәсен иске режим!» шигаре астында чыга. Большевиклар диктатурасына каршы, татар милли хәрәкәтен яклап актив пропаганда алып бара.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Г а й н а н о в Р.Р., М а р д а н о в Р.Ф., Ш а к у р о в Ф.Н. Татарская периодическая печать. К., 1999.

**ВАТА́Н** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 22 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 4 *км* читтә. 2002 елда 36 кеше (татарлар) яши. 1923 тә нигез салына. ТАССРның Зөя кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 97, 1938 дә — 140, 1949 да — 190, 1958 дә — 154, 1970 тә — 111, 1979 да — 100, 1989 да — 49 кеше.

**«ВАТА́Н НАМУСЫ́ ӨЧЕ́Н»**, фронт газетасы. Воронеж фронты сәяси идарәсе, 1943 елның 20 декабреннән Украина фронты органы. 1942 нең 19 декабреннән 1946 ның 20 апреленә кадәр атнага 2 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 377 саны чыга. Мөхәррирләре: Ә.*Ерикәй*, Р.*Ишморат*. Газета редакциясендә Г.Бакиров, М.Садри, Г.Хуҗи, Г.Шәрипов, З.Шаһиморатов, Ә.Юныс, А.Ямангулов эшли. Журналистлар Ф.Галиева, Г.Иделле, М.Дибаева, солдат һәм офицерлар М.Габбасов, Г.Ибраһимов, Н.Манасыйпов, Ш.Нигъмәтҗанов, Г.Рамазанов һ.б. ның мәкаләләре басыла.

*Әд.:* А й н у т д и н о в А.К. Летопись подвига (Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984.

**«ВАТА́Н ӨЧЕ́Н»**, Бөек Ватан сугышы чорында фронтта чыккан беренче татар газетасы. Төньяк-Көнбатыш фронтның сәяси идарәсе органы. 1942 елның 10 июленнән 1944 нең апреленә кадәр татар телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә. Мөхәррире Г.Гыйльманов. Газета редакциясендә Ә.Әхмәдиев, Х.Госман, Ш.Мөдәррис, А.Салиев эшли. Язучылар М.Әмир, Г.Бәширов (псевд. Г.Разин), Ә.Ерикәй, А.Расих, ш.у. солдат һәм офицерлар Н.Гайсин, С.Минһаҗев, М.Ногманның мәкаләләре, әсәрләре басыла. Фронт таратылгач, яңа оештырылган 2 нче Белоруссия фронты карамагына тапшырыла һәм 1944 нең 24 февраленнән «*Фронт хакыйкате*» исемендә чыга башлый.

*Әд.:* А й н у т д и н о в А.К. Летопись подвига (Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984.

**«ВАТА́Н ӨЧЕ́Н СУГЫШКА́»**, фронт газетасы. Карелия фронты сәяси идарәсе органы. 1943 елның гыйнварыннан 1944 нең 12 ноябренә кадәр татар телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 89 саны чыга. 1944 нең февралендә, Карелия һәм Волхов фронтлары берләштерелгәч, «*Фронт правдасы*» г-тасы б-н кушыла. Мөхәррирләре: В.Герасимов, Б.Корбанов, Г.Хәбиб. Хәрби хәбәрчеләре: Г.Әпсәләмов, Г.Габидуллин, М.Җамалиев, К.Иманкулов, М.Савельев.

*Әд.:* А й н у т д и н о в А.К. Летопись подвига (Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984.

**ВАТА́Н СУГЫШЫ́** (1812). Россиянең Наполеон явына каршы азатлык сугышы. В.с. башлангач, император Александр I нең 1812 елның 6 июль манифесты нигезендә Казан губернасында халык ополчениесе оештырыла (к. *Казан ополчениесе*). 1812 нең 8 июле манифесты нигезендә Казан губернасы ополчениесе Нижгород, Пенза, Кострома, Сембер һәм Вятка губерналары халык ополчениеләре б-н бергә өченче округка кертелә. 1812 нең сентябрендә Казан губернасының эчке ополчениесе буенча Хәйрия ком-ты оештырыла. «Казанские ведомости» г-тасында игъланнар бастырыла, аларда: «үз хәйрияләрен китерергә яисә җибәрергә теләүчеләр иртәдән алып кичкә кадәр теләсә кайсы вакытта Комитетка килә алалар, алар һичбер тоткарлыксыз кабул ителә», — дип күрсәтелә. Татарлар хәйрияләрен җыю өчен үз җыючыларын сайлыйлар. Губерна халкы 346 мең сум (ш.и. татарлар 10 мең сум) хәйрия акчасы җыя. Моннан тыш, регуляр армиянең ике пехота полкын тоту өчен акча җыела. Зөя өязе крәстияннәре К-тка 100 пот җиз җыеп китерәләр. Чистай өязе крәстияннәреннән ополчениеләр өчен постау әзерләүгә 200 пот йон алына. Җыелган хәйрия әйберләре арасында шактый күләмдә алтын һәм көмеш әйберләр була. В.с. чорында Казан дары з-ды һәм Казан постау мануфактурасы продукция җитештерүне шактый арттыралар. Казан Кремле терр-ясендә туп з-ды урнаша, анда зарарланган туплар ремонтлана һәм яңалары коела. Казанга Мәскәүдән кайбер учреждениеләр: Сенат департаменты, Мәскәү опекуннар советы һ.б., гади халык күчерелә. Казанга барлыгы 30 мең кеше килә. Казанда яшәүчеләр аларны урнаштыруда ярдәм итә. Казан ополчениесе (татарлардан торган пехота полкы һәм атлы батальон) рус армиясенең Польша, Силезия, Богемия, Саксония терр-яләрендәге яуларында катнаша. 1913 нең октябрендә Казан ополчениесе сугышчылары Дрезден өчен сугышларда батырлык күрсәтәләр. Батырлыклары өчен Казан ополченецларының кайберләре орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә, югарырак дәрәҗәгә тәкъдим ителә. Бүләкләнүчеләр арасында татар крәстияне Агиев та була, аңа медаль һәм офицер дәрәҗәсе бирелә. 1815 нең февралендә ополчение Казанга кайта. В.с.нда Алабуга шәһәреннән Н.А.Дурова каһарманлык күрсәтә. 1812 елгы вакыйгалар әдәбиятта, халык, ш.и. татар халык авыз иҗатында («Рус-француз сугышы бәете») чагылыш таба. Ш.у.к. *Татар-башкорт атлы полклары*.

*Әд.:* А п у х т и н В.Р. Казанское дворянское ополчение 1812–1813–1814 гг. К., 1912; С л а в и н Н.Ф., Л е б е д е в а А.И., К и р с а н о в С.А. Казанцы в Отечественной войне 1812 года. К., 1942; Г а р з а в и н а А.В. «...Отчизне посвятим души прекрасные порывы!»: Декабристы и Казань. К., 1990.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**«ВАТА́Н ҺӘМ ХӨРРИЯТНЕ́ САКЛА́У БЕРЛЕГЕ́»** (1917, декабрь — 1918, август), Ак офицерларның Совет хакимиятенә каршы юнәлтелгән рәсмиләштерелмәгән оешмасы. Б.В.Савинков тарафыннан Мәскәүдә оештырыла, Казан, Ярославль һ.б. шәһәрләрдә бүлекләре була. Максаты: Совет хакимиятен бәреп төшерү, «ныклы» хакимият урнаштыру; большевикларның башлыклары В.И.Ленин б-н Л.Д.Троцкийны юк итү; Рыбинск, Ярославль, Муром шәһәрләрендә фетнә оештырып, Мәскәүне Архангельск портыннан аеру (ул портка элекке Антанта көчләре килүе көтелә). Оешманың Казан бүлеге 500 ләп әгъзаны берләштерә. КОМУЧ көчләре Казанны яулап алгач, шәһәргә Б.В.Савинков килә. Аның көрәштәшләре Кызыл Армиягә каршы сугыш-бәрелешләрдә катнаша. 1918 елның август ахырларында оешма үзлегеннән тарала.

**«ВАТАННЫ́ САКЛАУДА́»**, фронт газетасы. Ленинград фронты сәяси идарәсе органы. 1943 елның 1 гыйнварыннан 1946 ның 14 июненә кадәр татар телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 347 саны чыга. Төрле елларда мөхәррирләре: А.Мадалиев һәм З.Исхаков. Газета редакциясендә А.Айнуллин, И.Арганбаев, И.Сәйфетдинов, К.Юлдашев эшли. С.Ильясов, М.Хөсәен, Г.Шәйдуллин, К.Яһүдин һ.б.ларның мәкаләләре, шигырьләре басыла.

*Әд.:* Т е л ә ш е в Р. «Ватанны саклауда» // Татар иле. 1997. № 45; А й н у т д и н о в А.К. Летопись подвига (Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984.

**«ВАТАНЫ́М ТАТАРСТА́Н»**, атналык иҗтимагый-сәяси гомумтатар газетасы. 1918 елның 12 мартыннан Казанда татар телендә нәшер ителә. Исеме үзгәрә: 1918–20 елларда «*Эш*», 1920–22 дә «Татарстан хәбәрләре», 1922–24 тә «Татарстан», 1924–51 дә «Кызыл Татарстан», 1951–60 та «Совет Татарстаны», 1960–92 дә «Социалистик Татарстан», 1992 елның февраленнән — «В.Т.» Оештыручылары ТР Дәүләт Советы, ТР Министрлар Кабинеты, редакция коллективы. Газетада Г.Камал, Ф.Әмирхан, Ш.Усманов, К.Тинчу-



рин, Г.Нигъмәти, Г.Толымбайский, Һ.Такташ, Х.Туфан, Г.Кутуй, М.Җәлил, Г.Бәширов, М.Әмир, А.Шамов, И.Гази, Ф.Хөсни, Г.Галиев, М.Садри, Г.Минский, Ш.Мөдәррис, Н.Арсланов һ.б. күренекле татар язучылары эшли. Казан мех комб-тында (1934), Чистай (1935), Минзәлә, Әлмәт (1947), Калинин (1949) р-ннарында «В.Т.»ның күчмә редакцияләре була. Төрле елларда газета чыгарган кушымталар: «Кызыл командир» (1926, «Кызылармеец» г-тасы б-н бергә); «Сыйфат өчен» (1933), «Волга буе спартакиадасы» (1934); «Стахановчылык листовкасы» (1936); «Кызыл Татарстан» листовкасы» (1946); «Совет Татарстаны»ның махсус чыгарылышы» (1952). 1985–2003 тә «Әдәби җомга», 1999–2003 тә «Серле сандык», 2004 тән «Сәламәтлек», «Яшелчә», «Гаилә», 2005 тән «Яшел бишек», «Ышаныч һәм иминлек» даими кушымталары чыгарыла. Газета Татарстанның совет чоры тормышындагы иҗтимагый-сәяси, мәдәни, социаль һәм икътисади якларны даими яктыртып бара, укучыларга юрист киңәшләре бирә. Татар журналистларының күпчелеге өчен осталык мәктәбе булып тора. Татарстан Президенты Указларын, ТР Дәүләт Советы кабул иткән законнарны, ТР МК карарларын беренчеләрдән булып татар телендә бастыра. Республиканың әйдәп баручы газетасы буларак, «В.Т.» Татарстаннан читтә яшәүче татарлар тормышын да киң яктырта. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1968). Мөхәррирләре: Ш.Әхмәдиев (1918), Х.Урманов (1918), В.Шәфигуллин (1918–21), Ф.Бурнаш (1921–24), Ф.Сәйфи-Казанлы (1924–25), Г.Нигъмәти (1926–27), С.Борһан (1928–29), И.Еникиев (1930–31, 1937), Г.Ризванов (1932–36), А.Дәүләтъяров (1937), Х.Габдрахманов, С.Атнагулов (1938–40), И.Н.Үзбәков (1941–50), Г.Рябков (1950–60), Ш.Хамматов (1960–83), Р.Сабиров (1983–90), М.Әһлиуллин (1990–96), Г.Шәмсетдинов (1996–2003), М.Сәфәров (2003 тән).

*Әд.:* Хамматов Ш.Х., Әгъзамов Ф.И. Матбугат — дуслык байракчысы. К., 1970; Хамматов Ш.Х. Газета һәм әдәбият дуслыгы. К., 1979; Көньязмадан туа елъязмалар // Казан утлары. 1998. № 3; Насыров Т.М. Большевик Хасан Урманов. К., 1968; шул ук. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Социалистик Татарстан. 1918–1968. (Фотоальбом). К., 1968; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978; Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979; Печать, радиовещание и телевидение Татарии. 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981; Шамсутдинов Г. Газета всероссийского значения на татарском языке // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 1/2.

*Р.М.Нуруллина.*

**ВАУ́ЧЕР**, к. *Хосусыйлаштыру чегы.*


**ВАФАИ́** (15 йөз), Урта Азиядә яшәгән шагыйрь. Төрки телдә язган. Ислам дине нигезләрен шигъри юлларда аңлаткан «Рәүнәкыль-ислам» («Ислам нуры», 1464–65) исемле үгет-нәсыйхәт поэмасы авторы. Аллаһның һәм пәйгамбәрләрнең сыйфатларына дан җырлау б-н бергә, шагыйрь белемгә омтылуны, гыйлемлекне мактый. Поэма, кульъязма нөсхәләрендә киң таралып, 1850 елдан бирле Казанда күп мәртәбәләр нәшер ителгән һәм мәдрәсәләрдә дәреслек китабы буларак файдаланылган. Әсәрнең кульъязма нөсхәләре С.-Петербург, Казан, Уфа шәһәрләре китапханәләрендә саклана. Поэма татар суфи шагыйрьләрнең (Мәүла Колый, Утыз Имәни, Шәмсетдин Зәки һ.б.) иҗатларына зур йогынты ясаган. «Рәүнәкыль-ислам» поэмасының тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнгән Гали Рәхим татар халкында ислам дине, шәригать кануннарының тирән урнашуында бу әсәрнең зур тәрбияви роле булганлыгын искәртә.

*Әд.:* Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. К., 1923; Абилов Ш. Вафаи турында // Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 том; Самойлович А.Н. Очерки по истории туркменской литературы // Туркмения. Л., 1929. Т. 1; Хрестоматия по литературе народов СССР. М., 1959.

*Ш.Ш.Абилов.*

**«ВАФИ́ЙӘТ әл-ӘСЛЯ́Ф ВӘ ТӘХИЙӘ́Т әл-ӘХЛЯ́Ф»** (وفية الأسلاف وتحيات الأخلاف — «Элгәреләр һәм аларның киләсе буынга сәламнәре»), Ш.Мәрҗанинең биобиблиографик хезмәте. Гарәп тарихи әдәбиятының биографик жанры таләпләренә туры китереп, гарәп телендә язылган. Ибне Халдунның «Китаб әл-ибар вә диван әл-мобтадәә вә әл-әхбар фи әййәм әл-араб вә әл-әҗәм вә әл-барбар вә мин зави-с-солтан әл-экъбәр» («Нәсыйхәт китабы һәм гарәпләр, фарсылар, бәрбәрләр, аларга замандаш хакимнәр турында мәгълүматлар җыентыгы») китабы үрнәгендә төзелгән. Әсәр жанр традицияләренә туры китереп, Ибне Халликанның «Вафийәт әл-әйән вә әнбә әбнә әз-заман» («Атаклы шәхесләрнең вафаты көннәре һәм барлык заманнарның уллары турында хәбәрләр») китабына ияреп исемләнгән. Ике өлештән тора. 1 нче, кереш өлеше — «Мөкаддимә китаб вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» — 1883 елда нәшер ителә, икенче өлеше кульъязма хәлендә һәм аның бердәнбер күчермәсе Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар бүлегендә саклана. Әсәрнең тулы тексты 6 җилдтән (томнан) тора. «Мөкаддимә...»дә Ш.Мәрҗанинең фәннәрне, халыклар тарихын классификацияләүгә кагылышлы карашлары, исламга кадәрге пәйгамбәрләр һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлы, элгәреге ислам тарихы бәян ителә.

Әсәрнең басылмыйча калган өлешендә ислам дөньясындагы күренекле 6 мең шәхеснең биографиясе тупланган. Хронологик яктан 633–1889 елларны — Мөхәммәд пәйгамбәрнең вафаты елыннан Ш.Мәрҗанинең соңгы көннәренә кадәр дәверне колачлый. Хезмәтнең географик кысаларына ислам дөньясының үзәкләре б-н бергә Идел буеннан Йәмәнгә, Һиндстаннан Испаниягә кадәр җирләр кергән. Биографияләр, елларга бүленеп, иректә тәртиптә бирелә, томнарга бүленеш формаль характерда. Биографияләр, башлыча, 5 бүлектән тора: 1) шәхеснең тулы исеме, туган елы һәм урыны, вафат булу елы, җирләнгән урыны, шәхескә мәшһүрлек китергән вакыйга турында кыскача мәгълүмат; 2) биографик белешмәләр (галимнәрнең укыган урыннары яисә бәхәсләре, фәнни эшчәнлекләре турында бәян итү; хакимнәрнең хәрби походларын тасвирлау); 3) шәхесләрнең хезмәтләре; 4) остазлары; 5) шәкертләре. Әлеге тәртип хәлифәләр һәм госманлы солтаннар биографияләрендә генә үзгәрә: беренче бүлектән соң хакимлек итү елларының һәрберсе аерым яктыртыла.



«Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» исемлеге һәм аңа «Кереш...» («Мөкаддимә...») басмасы.

«Вафийәт...»нең төп өлеше мөселман дөньясының гомуми тарихына һәм мәдәниятенә багышлана. Әлеге әсәрен төзегәндә Мәрҗани, башлыча, гарәп-мөселман авторларының биографик хезмәтләреннән файдалана. Гарәп чыганакларында Ш.Мәрҗанигә билгеле булган Идел буе турындагы барлык мәгълүматлар (2,3 җилд), ш.у. Казан һәм Кырым ханнары турында ислам дөньясының күпчелек өлешенә мәгълүм булмаган белешмәләр (3–5 җилд), 18–19 йөзләрдә Россия, бигрәк тә Идел буе мөселманнары тормышына кагылышлы материалларның туплап бирелүе хезмәтнең аеруча әһәмиятле һәм үзенчәлекле ягы булып тора. Хезмәтнең әлеге өлешен төзегәндә Ш.Мәрҗани җирле төбәк тарихын өйрәнүгә багышланган җирле әдәбияттан да файдалана, 18–19 йөзләрдә Идел буенда ислам традицияләренең таралу һәм гореф-гадәткә әйләнү тарихын өйрәнүдә аеруча мөһим фактларны фәнни әйләнешкә кертә. Ш.Мәрҗанинең безнең көннәргә килеп җитмәгән чыганаклардан да файдалануы ихтимал дип фаразлана. Идел буе һәм Урал алды мөселманнары турындагы материалларның төп өлеше 6 нчы җилдтә бирелә (1025 биографиянең 230 дан артыгы). Ш.Мәрҗани әлеге хезмәте өстендә гомере буе эшли. Урта Азиядә яшәгәндә үк мәгълүматлар җыя башлый, Казанга кайткач, аларны эшкәртә һәм тәртипкә сала. Сакланып калган кульъязмада буш битләр очравы, йомгаклау өлешенең булмавы, кульъязмалар, сәхифәләрнең тулып җитмәве, 1883 тә басылып чыккан «Мөкаддимә...»дә вәгъдә ителүе хезмәтнең төгәлләнмәвен күрсәтә.

1879 да Ш.Мәрҗани «Мөнтәһаб мин китаб вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләсе буынга сәламнәреннән сайланмалар») дигән исем б-н «Мөкаддимә»дән һәм «Вафийәт әл-әсляф...»тан өзекләр бастырып чыгара. 1911 дә «Мөнтәһаб...» «Хазиһи әр-рисалә әл-вәҗизә мөнтәһаб вафийәт фи-т-тарих» («Вафийәт -әл-әсляфтан сайланмалар») дигән исемдә Ташкентта нәшер ителә.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөкаддимә китаб «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф». К., 1999; Гараева Н.Г. Источники «Вафийат ал-аслаф

ва тахийат ал-ахлаф» Ш.Марджани // Марджани: учёный, мыслитель, просветитель. К., 1990; Ю з е е в А.Н. «Мукаддима» Ш.Марджани и арабский философ средневековья Ибн Халдун // Марджани: учёный, мыслитель, просветитель. К., 1990.

*Н.Г.Гәрәева.*

**ВА́ФИН** Шәмсемөхәммәт Ислам улы (6.2.1929, хәзерге Теләче р-ның Күкчә а.), радиотехника системаларын проектлаштыру һәм мәгълүмат тапшыру проблемалары гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1986), проф. (1997). 1955 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1956 дан Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында эшли: лаб. (1958–64), бүлек (1965–87) һәм бүлекчә (1987–96) җитәкчесе. 1997 дән Казан энергетика ун-тында сәнәгать пр-тиеләрен электр б-н тәэмин итү каф. мөдире. Хезмәтләре радиотехника, радионавигация, радиотелеметрия һәм радиолокациягә карый. Самолёт койрыгын телевизион саклау системасын, катлаулы сигналларны синтезлау методикасын эшли һәм гамәлгә кертә, элемтә һәм телекоммуникация өчен санча яшерен махсус радиокомплекс системаларын төзи. СССРның мактаулы радисты (1983). Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**ВА́ФИНА** Альвина Әхмәт кызы (8.12.1940, Мәскәү), физик, фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), физ.-матем. фән. канд. (1972). 1963 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында эшли. 1967 дән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, 1979 дан өлкән фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре элементорганик ирекле ион-радикалларның төзелешенә һәм үзлекләренә карый. Дәүләт бүләге фосфорлы ирекле радикалларда ЭПР өлкәсендәге хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Спектры ЭПР и стереохимия фосфоросодержащих свободных радикалов. М., 1985 (автордаш).

**ВАХИДИ́** (Вахидов) Сәет Габделмәннан улы (31.5.1887, Казан губ., Спас өязе Ташбилге а. — 5.1.1938), археограф, тарихчы. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала (1911). 1911–14 елларда Казан губернасының авыл мәктәпләрендә укыта. Бер үк вакытта борынгы кульязмалар эзләү б-н шөгыльләнә. 1912 дә *Сәхибгәрәй хан ярлыгын* таба. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша (1914–17). 1918–20 дә Казанда укытучылар әзерләү курсларын оештыручыларның берсе. Бер үк вакытта 1919–21 дә Казан ун-ты рабфагында укыта. 1920 елларда төрле оешмалар б-н хезмәттәшлек итә, Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте, Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, Гыйльми үзәк һ.б.ның әгъзасы була. 1928 дән Россия археография комиссиясе б-н хезмәттәшлек итә. 1930 еллар башында Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1930 елларның 2 нче яртысында ТАССР Дәүләт музее фәнни хезмәткәре. 3 меңнән артык борынгы кульязмалар туплый. 1925 тә 200 дән артык кульязма ТАССР Дәүләт музеена, 1930 да 1127 кульязма китапны Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү ин-тына, 1934 тә 500 дән артык кульязманы СССР ФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-тына тапшыра. Төп хезмәтләре татар халкының борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнүгә карый. Репрессияләр корбаны.

Х е з м.: Мәрҗәни көтепханәсе һәм аның язмышы // Безнең юл. 1929. № 6–7; Исследование ярлыка Сахиб-Гирей хана. К., 1925; Татарские легенды о прошлом Камско-Волжского края. К., 1926.

*Әд.:* Г о с м а н о в М.Г. Сәет Вахидиның игелекле мирасы // Казан утлары. 1987. № 5; ш у л у к. Итоги и перспективы археографических работ в Казанском университете // Материалы итоговой науч. конф. Казан. гос. ун-та за 1988 год. К., 1990.

*М.Г.Госманов.*

**ВАХИДИ́ С. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́,** тарихчы, археограф Сәет Габделмәннан улы Вахидинең шәхси китаплар тупланмасы. Археографлык эшчәнлеге б-н бәйле рәвештә 1905 елдан туплана башлый. Төп өлешен төрки-татар һәм гарәп-фарсы телле кульязма китаплар тәшкил итә. 1925 тә С.Вахиди үз китапханәсендәге 200 дән артык кульязма китапны, ш.и. мәгълүм Сәхибгәрәй хан ярлыгын Татарстанның Үзәк музеена (хәзер — ТРның Милли музее) тапшыра. 1930 да 1127 берәмлек кульязма китап Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү ин-тына бирелә (исемлеге бар); 1934 тә 500 дән артык кульязма СССР ФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының Ленинград бүлегенә алына (шулардан 181 е — гарәп телендә, калганнары — төрки-татар һәм фарсы телләрендә). Алар арасында Габденнасыйр Курсави хезмәтләре: «Шәрхе кахид ән-Нәсәфийә» («ән-Нәсәфи» хөкемнәренә шәрехләр»), «Шәрхе мохтасар әл-Манари» («әл-Манар кыскартуларына шәрехләр»), «Иршад әл-Мөридин» («Мөридләргә үгет-нәсыйхәт»); Ш.Мәрҗәнинең «Мөнтәхәб мин китаб «Вафийәт әл-әсляф...» («Вафийәт әл-әсляф...» китабыннан сайланмалар») кульязма әсәре; Гобәйдулла бине Сабит әл-Болгариның «Могъҗизат ән-нәби»е («Пәйгамбәрнең могҗизалары») һ.б.

Китапханәдәге тупланманың калган өлешен 1962 дә С.Вахидиның хатыны СССР ФАнең Казан ф-лына тапшыра; соңрак аларның күбесе ф-лның Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты архивына күчерелә (140 лап кульязма); китапханәдән 2 кульязма РФАнең Казан фәнни үзәк китапханәсендә саклана; шуларның берсе — Сөләйман Бакырганиның шигырьләр җыентыгының 17 йөздә күчерелгән нөсхәсе.

ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында С.Вахиди китапханәсеннән алынган кульязма китапларның күпчелеген Якын Көнчыгыш, Урта Азия һәм Идел-Урал төбәгендә табылган ядкәрләр — гарәп, фарсы, төрек-татар телләрендә язылган хәдисләр, тәфсир җыентыклары, фикъһ, мантыйк китаплары тәшкил итә. Арада 13–14 йөзләргә караганнары да бар: Әбү әл-Ләис әс-Сәмәркандиның «Тәфсир әл-Корьән» («Корьән тәфсире») күчермәсе, ән-Нәсәфинең «Китаб әл-мостафа» («Тазарыну-сафлану китабы»), Хәсән ибне Гали әл-Кашаниның математикадан «Китаб әл-мөршид фи-л-хисаб» («Хисаплауда туры юл күрсәтү китабы») дигән миниатюралар б-н бизәүле китабы. Ш.Мәрҗәнинең күп томлы «Вафийәт әл-әсляф...» хезмәтенең матбугатта басылган кереш өлеше «Мөкаддимә...» кульязмасының цензор нөсхәсе дә игътибарга лаек.

Казан ун-ты фәнни китапханәсенә С.Вахиди тупланмасыннан кергән кульязмаларның күпчелеге татар телендә: Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» күчермәсе, Мәхмүд Гали Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис» («Оҗмахларның ачык юлы») әсәре, «Кыйсса-и ике былбыл»ның күчермә нөсхәсе. Арада Ш.Мәрҗәни, К.Насыйри һ.б. күп кенә татар дин-мәдәният эшлеклеләренең автографлары бар.

*Әд.:* Ф ә т х и А.С. Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары. К., 1960. 1 кис.; Г о с м а н о в М. Игелекле мирас (Сәид Вахидиның тууына 100 ел // Казан утлары. 1987. № 5; ш у л у к. Каурый каләм эзеннән. К., 1994.

*Н.А.Гәрәева.*

**ВАХИ́ДОВ** Равил Сәми улы (3.12.1929, Үзбәкстан ССРның Бохара өлкәсе Пешку а.), электрохимик, химия фән. д-ры (1977), проф. (1978), Башкортстан АССРның атказ. фән эшлеклесе (1979). 1952 елда Урта Азия ун-тын (Ташкент) тәмамлый. 1953–55 елларда Запорожье машина төзү ин-тында эшли. 1958–70 елларда Казакъстан хим.-технол. ин-тында (Чимкент ш.), 1963 тән электрохимик җитештерү технологиясе каф. мөдире. 1970–86 да Уфа авиация ин-тының гомуми химия кафедрасында, 1986 дан Башкортстан ун-тының физик химия каф. проф. 1993–96 да Халыкара казакъ-төрек ун-тында (Төркестан ш., Казакъстан Респ-касы) физик һәм органик химия каф. мөдире. Хезмәтләре металлар б-н нәметалл эретмәләренең электр тогы тәэсирендә төпкә утыру, нәметалл һәм металл ионнары кушылмаларының, үзенчәлекле сыйфатларга ия булган электролитик ионнар хасил итеп, бергә катодлы кайтарылу теориясенә карый. Фосфорның никель, бакыр, цинк б-н эретмәләреннән гальваник капламнар, порошоклар, башка материалларның утырымга төшү шартларын һәм технологияләрен фаразлау, сайлау һәм оптимальләштерүнең термодинамик исулын тәкъдим итә, металларны сусыз эремәләрдән электр ярдәмендә утырту вакытында электролитның фаза халәтенә һәм гальваник капламнар сыйфатына электроактив ионнар концентрациясе тәэсиренең закончалыкларын ача. Медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Новые силикатные и органические материалы. А.-А., 1967 (автордаш); Курс физической химии. Электрохимия: Учеб. пособие. Уфа, 1991. Ч. 3; Лабораторные работы по химии. Уфа, 1994 (автордаш).

*Әд.:* Вахидов Равиль Самиевич // Кто есть кто в Башкирском государственном университете. Уфа, 1997.

**ВАХИ́Т** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 22 *км* төньяктарак, Шыя елгасы буенда. 2002 елда 187 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Горелый Ельник исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тимерче алачыгы, 1 он һәм 3 ярма ярдыру тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл

җәмәгатенең имана җире 913,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 75 ир заты; 1859 да — 555, 1897 дә — 870, 1908 дә — 875, 1926 да — 1033, 1949 да — 560, 1958 дә — 450, 1970 тә — 490, 1979 да — 385, 1989 да 214 кеше.


**ВАХИ́Т** (Вахитов) Касыйм Мисбах улы (16.3.1916, хәзерге Башкортстан Респ-касының Әлшәй р-ны Нигъмәтулла а. — 4.10.1942), шагыйрь. 1935 елда Дәүләкән пед. техникумын тәмамлап, авыл мәктәбендә мөгаллимлек итә. 1941 дә Казан пед. ин-тын тәмамлый. Матбугат битләрендә («Кызыл Татарстан» г-тасы, «Совет әдәбияты», «Чаян», «Азат хатын» ж-ллары) шигырьләре 1932 елдан күренә башлый. Алар «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940), «Очкыннар» (1940), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961), «Утлы еллар поэзиясе» (1972) коллектив җыентыкларга кертелә. В. үзен поэзиянең төрле жанрларында сынап карый: «Сөйләнмәгән әкият» поэмасы, «Егет турында баллада», юмористик шигырьләр һ.б. иҗат итә. Үзе теләп Бөек Ватан сугышына китә, Сталинград тирәсендә барган сугышта һәлак була.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ВАХИ́Т** (Вахитов) Хәй (Габделхәй) Каюм улы (20.12.1918, Казан губ., Казан өязе Мәмдәл а. — 7.7.1978, Казан), драматург, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968, 1978). Бөек Ватан сугышында катнаша, хәрби разведчик була. Казан консерваториясен тәмамлый (1951). 1951–55 елларда Лаеш р-нының Татар Сараланы авылында «Яңа Алан» к-зы партия оешмасы секретаре. 1956–58 дә Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларда укый. 1937 дә «Канлы куллар», «Соры кортлар» исемле беренче пьесалары басыла, 1939 да «Дулкыннар» исемле беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә. 1960 та Татар акад. театрында куелган яшьләр турындагы «Беренче мәхәббәт» драмасы В.ка зур абруй китерә һәм ул Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә (1961) лаек була. В. үзенең пьесаларында әдәп-әхлак проблемаларын күтәрә, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне яктырта. Төп геройлары — тормышта үз көчләренә таянып, максатларына ирешергә омтылучы яшь кешеләр. «Рәхим итегез!» (1963; 1961 дә сәхнәләштерелә), «Кайда соң син?» (1964; 1963 тә сәхнәләштерелә), «Карлыгач канат кага» (1965; 1964 тә сәхнәләштерелә), «Соңгы хат» (1966; 1966 да сәхнәләштерелә), «Күк капусы ачылса» ( 1973; 1967 дә сәхнәләштерелә) пьесалары шундыйлардан. Фәлсәфи-психологик пландагы «Туй алдыннан» (1969 да сәхнәләштерелә) драмасы тамашачыларда зур кызыксыну уята. Тәрбия мәсьәләсе, яшьләрнең әхлакый йөзе, аларның өлкәннәргә мөнәсәбәте, мәхәббәт һәм тугрылык кебек проблемалар В.ның «Мәхәббәтең чын булса» (1976; русчага тәрҗемәсе «Если любовь


С.Г.Вахиди.


Х.К.Вахит.


А.Г.Вахитов.


Г.Г.Вахитов.

настоящая», М., 1979; 1972 дә сәхнәләштерелә) драмасында үзәк урынны алып тора. В. татар опера сәнгатен үстерүгә дә зур өлеш кертә. Ул «Самат» (1957; Х.Вәлиуллин муз.), «Җиһангир» (1976; Р.Гобәйдуллин муз.), «Дим буенда» (1965; Х.Вәлиуллин муз.) һәм «Мәхәббәт җыры» (1971; С.Садыйкова һәм Р.Гобәйдуллин муз.), «Кияүләр» (1972; С.Садыйкова һәм Р. Гобәйдуллин муз.) операларының, муз. комедияләрнең либреттолары авторы.

Х е з м.: Күк капусы ачылса: Пьесалар. К., 1973; Яшьлек юллары: Пьесалар. К., 1978; Пьесалар. К., 1984.

*Әд.:* Гыйззәт Б. Хәй Вахит һәм аның геройлары // Казан утлары. 1978. № 12; Әхмәдуллин А. Драматургның үсү юлы // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; шул ук. Яңалык нәрсәдә иде? // Дөреслеккә ирешү юлында. К., 1993; Кумысников Х. Он поёт молодость // Советская Татария. 1968.20 дек.

**ВАХИ́ТОВ** Акмал Гыйльфан улы (1900, Казан губ., Зөя өязе Шыгай а. — 21.11.1957, Башкортстан АССР, Ишембай ш.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1914 елда авыл мәктәбенең 4 сыйныфын тәмамлаганнан соң, Тула шәһәренә китә, корал з-дында йөк ташучы булып эшли. 1916–17 дә Кавказ арты нефть промыселларында. Гражданнар сугышында катнаша. 1923 тән «Старогрознефть» (Грозный ш.) тресты промыселларында тормозлаучы, бораулаучы ярдәмчесе, бораулаучы, тракторчы булып эшли. 1937–56 да «Ишембайнефть» тресты (Башкортстан АССР) нефть промыселларында оператор, скважиналарны җир астында ремонтлау буенча өлкән мастер. Герой исеме производство йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне өчен бирелә. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*К.А.Нәҗипова.*

**ВАХИ́ТОВ** Гадел Галәветдин улы (31.12.1928, Башкортстан АССР, Эстәрлетамак ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (1965), проф. (1967), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1999), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1965). СССРның мактаулы нефтьчесе (1978), СССРның атказ. уйлап табучысы (1984). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), «Ишембайнефть» трестында (Башкортстан АССР) тау инженеры булып эшли. 1953–56 һәм 1971–86 елларда Бөтенсоюз нефть-газ фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү), 1971 дән директоры. 1956–71 дә ТатНИПИнефтьтә, 1964 тән — директоры. 1986–90 да «Нефтеотдача» Бөтенсоюз тармакара фәнни-техник комплексның ген. директор урынбасары (Мәскәү). 1990–95 тә Нефть фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тында (Вангтау ш., Вьетнам) фәнни эшләр буенча директор урынбасары. 1995 тән «ЛУКОЙЛ» нефть компаниясенең фәнни-инженерлык үзәгендә нефть табуны технологик яктан тәэмин итү һәм ресурслар бүлеге башлыгы. Нефть-газ-сулы катламнарның бериш булмаган геологик-физик торышына карап, чыганакларны билгеләү ысулларын нигезли, нефть чыганакларын үзләштерүдәге технологик процессларга матем. модельләштерү үткәрә, нефть промыселы мәгълүматларын эшкәртүнең һәм нефть, нефть һәм газ чыганакларын проектлаштыруның автоматлаштырылган системаларын төзү өчен төп принципларны билгели. Гыйракның (Төньяк Румейла, Көнбатыш Курна), Вьетнамның (Ак Юлбарыс) һәм Алжирның (Хасси-Мессауд) зур чыганакларын, Казакъстанның (Үзән), Көнбатыш Себернең (Самотлор), Урал-Идел буеның (ш.и. ТРда Ромашкино) уникаль чыганакларын табу принципларын һәм системаларын фәнни дәлилләүдә, сәнәгый үзләштерүдә катнаша. ТРдагы табигый битум үзенчәлекләрен ачыклый, аларның хуҗалыкта үзләштерелү принципларын нигезли. 1980–89 да фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт һәм Ленин бүләкләре ком-ты әгъзасы, 1971–90 да нефть буенча СССР Милли ком-т секциясе рәисе. 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты һәм аның рәисе урынбасары. Казакъстан ССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1969, 1983). Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эффективные способы решения задач неоднородных нефтеводоносных пластов методом конечных разностей. М., 1963; Разностные методы решения задач разработки нефтяных месторождений. Л., 1970; Геотермические методы контроля за разработкой нефтяных месторождений. М., 1984 (автордаш).

*Әд.:* Кто есть кто в горно-металлургической секции: Справ. М., 1997.

**ВАХИ́ТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ́ КОЛХО́З**, Алексеев р-нында. 1929 елда Кыр Шонталысы авылында «Болгар» исемендә оештырыла (1930 дан М.Вахитов исемендә). 2005 кә 220 йорт санала. Эшләүчеләр — 157 кеше. А.х. җирләре 3439 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 3105 *га*. Хуҗалыкның төп тармаклары: игенчелек, сөт, ит җитештерү. 2005 дә мөгезле эре терлек саны — 1334, ш.и. 517 сыер. Иген культураларының уңдырышлылыгы — 35,1 *ц/га*, бер сыердан елына уртача 3635 *кг* сөт савыла. 100 *га* а.х. җирләренә 496 *ц* сөт, 74 *ц* ит туры килә. Табышлылыгы (% ларда): 2000 дә 38,6, 2001 дә 13,2, 2002 дә 10,1, 2004 тә 9%.

1960 еллардан алдынгы хуҗалык буларак билгеле, үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясе җитештерүнең заманча матди-техник базасы булдырыла, хуҗалык исәбе алып бару, коллектив һәм аренда подряды, тотылган акчаны исәпләп-теркәп бару һәм тикшерүнең чек формасы кертелә. Кыр Шонталысы авылына газ һәм телефон, үзәкләшкән су юлы үткәрелгән, асфальт юллар салынган; социаль-мәдәни оешмалар — мәктәп, мәдәният йорты, мед. пункты, кибет бар.

1979–80 дә колхоз берничә мәртәбә КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС, ВЛКСМ ҮКнең Мактау грамоталары, СССР һәм ТАССР ВДНХлары дипломнары б-н бүләкләнә. 1970 тә «Югары игенчелек культурасы хуҗалыгы» дигән исемгә лаек була. Колхозның шактый хезмәтчәннәре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 9 кеше РФ һәм ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исемнәрен алуга ирешә, 3 кеше — Ленин ордены, 1 кеше — Октябрь Революциясе, 8 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә. Колхозның беренче рәисе С.Х.Хисамиев була (1930–31). Төрле елларда колхозны С.Г.Галиев (1951–60), Н.Ә.Әхмәтов (1961–76), Н.З.Кыямов (1977–2002), 2002 елдан Р.Г.Гайсин җитәкли. 2006 да хуҗалык «Кыр Шонталысы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять итеп үзгәртелә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ВАХИ́ТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ́ СОВХО́З**, Азнакай р-ныңдагы дәүләт нәсел үрчетү з-ды. 1930 елда оештырыла. 5 торак пунктны — «Победа» пос. — үзәк, Загорье пос., Заречье пос., Константиновка, Чәкән авылларын берләштерә. 2004 кә 1490 кеше яши, ш.и. эшләүчеләр — 275 кеше. А.х. җирләре 10691 *га*, ш.и. сөрү җирләре 8935 га, печәнлек һәм көтүлекләр — 1756 *га*. Мөгезле эре терлекнең баш саны — 1262, ш.и. 590 сыер, сарыклар — 502, ш.и. үрчем бирүче сарыклар — 350. Хуҗалыкның төп юнәлеше — нәселле сарыклар үрчетү. Башта совхоз Заречье посёлогын, Эстәрлетамак авылын, төрле р-ннарга караган Чечелле, Сугышлы, элеккеге сәүдәгәр Симаков, Сафонов хуторларын да берләштергән. Хуҗалык Бөгелмә сортлы орлык җитештерүче «3 нче Интернационал» хуҗалыгына караган өч участокны: Бәйрәкә, Тымытык (соңыннан «Мөслим», «Урыссу» с-злары, Тельман исем. һәм «Коммунизмга» к-злары) һәм «Сокольский»ны (1931 дән М.Вахитов исем. участок) берләштергән. 1 июльдән шул исемдәге совхоз итеп үзгәртелә. Төрле үзгәрешләрдән соң гомуми җир мәйданы 14418 *га* тәшкил итә, ш.и. сөрү җирләре — 11784 *га*. 1933 тә совхоз җиренең бер өлеше Мичурин исем., «Алга», Тельман исем., «Коммунизмга» (хәзер Чалпы) к-зларына бүлеп бирелә. 1934 тә хуҗалык беренче тракторлар, 1935 тә «Сталинец-1» комбайны сатып ала. 1939 елга совхозның 27 тракторы, 12 ашлык җыю комбайны була. 1940 та хуҗалык дәүләткә 1120 *т* ашлык, 50,5 *т* ит, 566,5 *т* сөт, 12,9 *т* йон сата. 1957 дә совхозга Азнакай р-ныңың Ворошилов исем (Урманай а.), «Большевик» (Бүләк а.), «Шарлык» (Муратовка а.), Ютазы р-ныңың Шверник исем. (Чәкән а.) к-злары кушыла. Җир мәйданы 22940 *га* тәшкил итә. 1961 дә Ютазы р-ныңың «Ютазы» с-зы кушыла. 1964 тә хуҗалык Бөгелмә р-ны составына кертелә, 1965 тән кабат Азнакай р-ныңа кайтарыла. Совхозның бер өлеше Баулы р-ныңың «Урыссу» с-зы итеп үзгәртелә. 1970 тә хуҗалыкның ике бүлекчәсе нигезендә яңа «Урманай» с-зы оештырыла. 1975 тән В.и.с. Татарстанның «Руно» сарык үрчетү берләшмәсенең баш пр-тиесе була, ул «Урманай» с-зын, Чапаев исем., Киров, Энгельс исем. к-зларны эченә ала һәм «Овцепром РСФСР» фәнни-җитештерү берләшмәсенә керә. 1983 тә «Руно» берләшмәсе таратылганнан соң, В.и.с. Азнакай р-ны агросәнәгать берләшмәсенә кушыла. 1984 тә совхоз Татарстанның нәселле терлекләр үрчетү хуҗалыклары составына кертелә, 1986 да Вахитов исем. нәселле терлек үрчетү з-ды дип үзгәртелә. 2004 елда а.х. продукциясе җитештерү күләме (мең *т* да): ашлык 7,5, шикәр чөгендере 1,0, сөт 1,8, йон 32 *ц*, 493 баш нәселле яшь терлек сатылган. Кирәкле социаль-көнкүреш шартлары тудырылган: 247 фатир, мәктәп, 2 балалар бакчасы, мәдәният йорты, 2 китапханә, клуб, хастаханә, фельдшер-акушерлык пункты, 5 кибет, пекарня, 2 ашханә бар, торак посёлокларга газ кертелгән, ферма, ындыр табагы, остаханәләр, машиналар хуҗалыгы терр-яләре асфальт б-н капланган. 1960–80 елларда совхоз РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байраклары, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, СССР һәм ТАССР ВДНХлары дипломнары б-н бүләкләнә. Совхозның шактый эшчесе дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 15 кеше РФ, ТРның атказ. авыл хуҗалыгы хезмәткәре исеме ала, 3 кеше — Ленин, 4 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 3 кеше — Халыклар Дуслыгы, 3 кеше — «Почет билгесе», 1 кеше — 3 нче дәрәҗә Дан ордены, күпләр медальләр б-н бүләкләнә. Совхозның беренче җитәкчесе М.З.Вәлишев була. Төрле елларда хуҗалык б-н 19 кеше җитәкчелек итә, алар арасында: А.Г.Грузель (1944–49), С.В.Лавочкин (1950–55), М.Н.Нәгыймов (1957–62), С.С.*Нилов* (1962–67), М.М.Мириханов (1973–81), К.Ф.Миңнуллин (1981–85) бар. 1985–2005 тә совхоз җитәкчесе Т.М.Рахманкулов, 2005 тән И.Р.Сабирҗанов. 2000 елда хуҗалык М.Вахитов исем. җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять итеп үзгәртелә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ВАХИ́ТОВ** Марат Барый улы (26.6.1926, Минзәлә ш. — 8.7.2002, Казан) төзелеш механикасы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1966), проф. (1968), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1976, 1986). 1950 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый һәм 1953 тән шунда ук эшли: проректор (1973–78), очкыч аппаратлар төзү механикасы каф. мөдире (1983–88). Хезмәтләре очкыч аппаратлар һәм тиз йөрешле корабль конструкцияләре ныклыгын хисаплау ысулларына карый. Интеграллаучы матрицалар ысулын эшли. Россия Югары уку йортлары министрлыгының авиатөзелеш буенча Баш советы рәисе (1986–90). «Известия высших учебных заведений. Авиационная техника» ж-лының баш мөхәррире (1987–97). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Интегрирующие матрицы — аппарат численного решения дифференциальных уравнений строительной механики // Изв. вузов. Авиац. техника. 1966. № 3; Лекции по теории упругости. К., 1972; Расчёт судов на подводных крыльях. К., 1976; Теория пластин. К., 1987; Казанский авиационный институт. М., 1992 (автордаш).

**ВАХИ́ТОВ** Миңнулла (Төхфәтулла) Вәлиулла улы (1872, Казан губ., Казан өязе Наласа а. — 24.5.1927, Казан), революцион хәрәкәт эшлеклесе. 1892 елдан Алафузовларның туку ф-касы эшчесе. 1905–07 еллардагы рев-ция вакыйгаларында катнаша, 1906 дан РСДРПның Алафузов р-н ком-ты әгъзасы. 1907–13 тә Оренбург, Баку, Мәләкәс (Самара губ.), Екатеринбург, Вятка шәһәрләрендә, 1913 тән Казанда партия эшендә. 1917 дә Мөселман социалистлар ком-ты президиумы әгъзасы. 1919–20 дә Кызыл Армиядә, Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясендә агитатор. 1920–22 дә элеккеге Алафузов з-дларында РКП(б)ның 2 нче ячейкасы секретаре, туку сәнәгате эшчеләренең Татарстан өлкә союзы идарәсе рәисе. 1923 тән ТАССР Юстиция халык комис-тында, ТАССРның Баш мәхкәмәсе коллегиясе әгъзасы.

*Әд.:* Деятели революционного движения в России: От предшественников декабристов до падения царизма: Биобиблиогр. словарь. М., 1933. Т. 5, вып. 2; Х а с а н о в Х. Вахитов Минулла Валиуллович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**ВАХИ́ТОВ** Мирзаян Шәрип улы (7.9.1924, Минзәлә р-ны Тулбай а. — 2.4.2000, Арча р-ны Наласа а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1983). 1953 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1953–60 та Арча дәүләт сорт сынау участоклары мөдире. 1960–84 тә Арча р-ныңың «Октябрь» к-зы рәисе. Аның җитәкчелегендә колхоз җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешә һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены (1971), күчмә Кызыл байраклар, мактау грамоталары һәм дипломнар б-н бүләкләнә. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ВАХИ́ТОВ** Мөхәммәт Хәйретдин улы (10.11.1918, Казан губ., Лаеш өязе Яңасала а.), җәмәгать-көнкүреш гигиенасы белгече, мед. фән. д-ры (1965), проф. (1966), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). 1937 елда Чистай фельдшер-акушерлык мәктәбен, 1947 елда Казан. мед. ин-тын тәмамлый. 1942 дән Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 дан ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгында. 1951–93 тә Казан мед. ин-тында, 1966–84 тә гигиена һәм сәламәтлек саклауны оештыру каф. мөдире, 1984–91 дә проф., консультант. Фәнни тикшеренүләре мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, шәһәр һәм авыл халкының сәламәтлеге торышы һәм физик яктан үсешенә; демографик процесс һәм балалар үлеменең көнкүреш гигиенасы факторларына, гипертония авыруының көнкүреш гигиенас аспектларына багышлана. Хезмәтләре балаларга травматологик ярдәм оештыру, транспортта һәм урамда имгәнүләргә, производство гигиенасына, бил остеохондрозы

б-н интегүчеләрне диспансерлауны камилләштерүгә карый. Халыкның аерым яшьтәге төркемнәренең сәламәтлеген билгеләү, уңайсыз көнкүреш гигиенасы факторларын ачыклау һәм бетерү буенча методик кулланмалар төзи. Ленин, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Состояние здоровья населения Республики Татарстан и вопросы его охраны в 1994 году. К., 1995 (автордаш).

*Әд.:* Казанские профессора-гигиенисты: Биогр. словарь. К., 1995.

*В.Р.Матросова.*

**ВАХИ́ТОВ** Мулланур Муллаҗан улы (10.8.1885, Казан — 19.8.1918, шунда ук), сәясәт эшлеклесе. 1905–07 еллардагы рев-ция вакыйгаларында катнаша. Казан реаль уч-щесен тәмамлый (1907), Петербург политехника (1907–10), психоневрология (1911–16) ин-тларында укый. 1903 елдан татар укучы яшьләренең «Шимбә» түгәрәгендә, 1905–06 да Казандагы марксистик түгәрәкләрдә катнаша. Татар проф. театрын оештыруны яклый. 1912–14 тә «Мусульманская газета»да (С.-Петербург) фәнни алгарыш, ислам яңарышы мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре басыла. 1917 нең язында җирне крәстияннәргә, хакимиятне Советларга тапшыру мәсьәләләрендә большевиклар позициясенә баса, Беренче бөтендөнья сугышын туктату яклы була. *Мөселман социалистлар комитетлары*н оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе, «*Кызыл байрак*» г-тасы мөхәррире. 1917 нең маеннан Казан губерна земство идарәсе әгъзасы, «Игенче» г-тасы мөхәррирләренең берсе. Казанда Окт. кораллы күтәрелешендә катнаша. Казан шәһәр думасы гласные булып сайлана, Учредительләр җыенына Казан губернасыннан күрсәтелгән вәкил. Казанда Вакытлы революцион штаб әгъзасы булып тора, большевикларның бердәм соц. хөкүмәт төзүгә каршы булуына протест йөзеннән 1917 нең 28 октябрендә аның составыннан чыга, бәяләргә дәүләт контроле кертелүне якламый. 1918 дә Үзәк мөселман комис-ты комиссары, РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты коллегиясе әгъзасы, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе. 1918 нең 22 мартында И.В.Сталин б-н бергә «Татар-Башкорт Совет Республикасы турында нигезләмә»гә кул куя. «Чулпан», «Кызыл Армия», «Красное знамя» г-талары б-н хезмәттәшлек итә, төрек телендә чыгарылган «Ени дунья» г-тасының мөхәррире була. Кызыл Армиянең мөселман гаскәри берәмлекләрен оештыруга җитәкчелек итә. 1918 нең июленнән Идел буенда гадәттән тыш азык-төлек комиссары. 1918 нең августында 2 нче татар-башкорт батальонын җитәкли, Казанны саклауда катнаша. Казанны чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык Армиясе гаскәре алганнан соң, шәһәрдә яшерен эш алып бару өчен калдырыла. Хыянәтче тарафыннан фаш ителә, акгвардиячеләр кулына эләгә һәм атып үтерелә. В.ка Казанда һәйкәл куела, шәһәрнең бер р-ны һәм урамы, Казан химия комб-ты, ТРның торак пунктлары һәм а.х. пр-тиеләре аның исемен йөртә.

Х е з м.: Избранное. К., 1967.

*Әд.:* И б р а һ и м о в Г. Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы. К., 1922; Н а ф и г о в Р.И. М.Вахитов. К., 1975; Жизнь и деятельность революционера-ленинца: Сб.статей и док-тов. К., 1985; Х а б у т д и н о в А.Ю. Легенды татарской истории: Мулланур Вахитов // Идель. 1997. № 10.

*А.Ю.Хәбетдинов.*

**ВАХИ́ТОВ МУЛЛАНУ́Р ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. Тукай мәйданының көньяк өлешендәге иң югары калкулыкта урнашкан. Күренекле сәясәт эшлеклесе-революционерның тууына 100 ел тулу уңаеннан 1985 елда төзелә. Авторлары — скульпт. Ю.Г.Орехов һәм арх. В.А.Петербуржцев, А.В.Степанов, М.Х.Агишев.

Вахитовның сыны, шәһәрнең түбәндә җәелеп яткан тарихи өлешенә каратып, монолит постаментка урнаштырылган. Аның өстендә җилбәгәй җибәрелгән солдат шинеле. Һәйкәлдә Вахитов образын билгеләүче сыйфат — динамизм. Вахитов, нык дулкынланып һәм кайнарланып нотык сөйләп туктаганнан соң, тыңлаучылары янына — алга атлаган кебек сурәтләнгән. Чәчләрен җиңелчә



Мулланур Вахитов һәйкәле.

генә җил тузгыткан. Йөзе һәм гәүдәсе характерының ныклыгын һәм ихтыяр көчен, эчке җанлануын чагылдыра. Авторларның максаты — көрәшче һәм хәрби җитәкченең көчле рухын, омтылышын, игътибарлылык сыйфатын ачып бирү б-н бергә, Вахитовның сәяси трибун һәм киләчәккә омтылучан кеше икәнлеген дә күрсәтү.

Авторлар проектында Вахитов мемориалын «Көрәш» һәм «Җиңү» дип аталган ике скульптура төркеме өстәп киңәйтү күздә тотылган була. Россиядәге социаль-сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә ул проект тормышка ашмый кала.

*А.И.Новицкий.*

**ВАХИ́ТОВ** Нәбиулла Гәрәй улы (1886, Урал өлкәсе Көнгер ш. — 1940, Мәскәү), сәяси һәм хәрби эшлекле. Казан сәнгать мәктәбендә укый (1904–08), Җирле сәнәгать халык комис-ты ин-тын тәмамлый (1930 еллар, Мәскәү). 1900 еллар башында «Шимбә» театр түгәрәге эшендә катнаша. Төрек язучысы Н.Кәмалның «Кызганыч бала», «Гыйшык бәласе», Г.Ильясиның «Бичара кыз» пьесалары буенча куелган спектакльләрнең бизәлешен



М.М.Вахитов.



Н.Г.Вахитов.

эшли. 1908–10 елларда Т.Д.Шевцовның чәй фирмасы коммивояжёры, 1910–12 дә Россия-Америка «Треугольник» ширкәтенең резина мануфактурасы фирмасында сәүдә вәкиле, 1912–15 тә Ш.Әсәдуллаевның Мәскәүдәге нефть сәнәгате фирмасында хисапчы ярдәмчесе. 1915–17 дә Россия армиясендә хезмәт итә (1917 дә 95 нче укчылар запас полкының 12 нче мөселман ротасы командиры). Казанда Окт. кораллы күтәрелешендә катнаша. 1918–20 дә Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, рәис урынбасары, 1921–22 дә Кызыл Армия штабында Көнчыгыш бүлеге башлыгы, Көнчыгыш мәсьәләләре буенча консультант, оештыру идарәсе комиссары ярдәмчесе. 1922 дә ТАССР ХКСында; 1922–24 тә сәүдә оешмаларында эшли, 1924–26 да Татарстан банкы идарәсе рәисе. 1927–29 да РСФСР БҮБКнда ТАССР вәкиле. 1930 да ВКП(б)ның Төньяк-Көнчыгыш өлкәсенең Кузнецк округы Чаадаев райкомының 1 нче секретаре. Соңыннан Казанда һәм Мәскәүдә хуҗалык эшендә.

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Н а с ы р о в Т. Вахитов Н.Г. // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ВАХИ́ТОВ** Рәфыйк Кәлимулла улы (20.11.1940, Чуаш АССРның Батыр р-ны Кыр Бикшиге а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), ТАССРның атказ. механизаторы (1985). 1957 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. Апас р-нында эшли: 1970–71 дә «Сельхозтехника»ның Фёдоровский бүлегендә инженер, баш инженер, управляющий, 1971–86 да а.х. идарәсе башлыгы. 1986–2002 дә «Татрапс» АҖнең Казан ф-лы директоры. 2003 тән Казан май-экстракцион з-ды төзелеше ген. директоры консультанты. Дәүләт бүләге рапс җитештерү, эшкәртү һәм аннан файдалануның икътисади нигезләрен һәм фәнни дәлилләнгән технологиясен эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медаль, ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Масличные культуры: Производство и переработка. К., 2000 (автордаш).

**ВАХИ́ТОВ** Шамил Мөхәммәт улы (22.1.1951, Казан), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2003). 1974 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1974–77 елларда Мәскәү ГИДУВында, 1977 дән Казан ГИДУВында эшли. 1991–92 дә ТР сәламәтлек саклау министры урынбасары. «Татмединформ» фәнни-җитештерү берләшмәсен оештыручыларның берсе һәм 1992 дән аның ген. директоры. 1995 тән Казан мед. ун-тында ме-

неджмент һәм шәфкать туташлары эшен оештыру курслары мөдире, 2001 дән каф. мөдире. Хезмәтләре хәзерге шартларда РФ субъектларында сәламәтлек саклау өлкәсе б-н идарә итүнең фәнни-методик нигезен эшләүгә, югары белемле шәфкать туташларыннан сәламәтлек саклау менеджерлары әзерләүне оештыруга карый.

Хезм.: Краткий словарь-справочник современного руководителя здравоохранения. К., 1994; Специфика экономики и управления здравоохранением. К., 1998 (автордаш.); Реформирование здравоохранения и внедрение новых технологий в системе охраны здоровья населения в условиях появления специалистов с высшим сестринским образованием и квалификацией «менеджер». К., 1999 (автордаш.).

**ВАХИ́ТОВ** Шәкүр Каюм улы (10.3.1922, Арча ш.), математик, техник фән. д-ры (1972), проф. (1993). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1951 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР Хәрби-Диңгез Флотында хезмәт итә, 1973 тә 1 нче ранг капитаны. 1982 дән Оборона министрлыгының Фәнни-тикшеренү үзәгендә (Петродворец ш.) әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре сугыш хәрәкәтләре һәм сугыш өчен билгеләнгән системаларны матем. модельләштерү методологиясенә карый. Бөтен саннарда сызыкча һәм нәсызыкча программалаштыру мәсьәләләрен чишү, катлаулы объектларны сафтан чыгару нәтиҗәсен бәяләү ысулларын, хәрби көч һәм чараларны сугышчан куллануны электрон-хисаплау машинасында планлаштыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләүне исәпләү методикасын эшли. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Некоторые практические методы расчётов, связанных с оценкой эффективности обнаружения [У.к.], 1968; Новый (совершенно иной) подход к вопросу выбора показателя боевой эффективности сил и средств [У.к.], 2001.

**ВАХИ́ТОВ** Яшәр Шакир улы (4.4.1928, Свердловск ш.), акустика гыйлеме белгече, проф. (1994). 1949 елда Ленинград киноинженерлар ин-тын тәмамлый. 1949–50 дә Ленинград кинотехникумында укыта. 1953 тән Ленинград киноинженерлар ин-тында (хәзер Санкт-Петербург кино һәм телевидение ун-ты): ф-т деканы (1959–70), проректор (1970–75). Хезмәтләре архит-ра акустикасына, архит-ра акустикасында һәм электроакустикада матем. модель теориясен һәм ысулларын эшләүгә карый. Бериш булмаган кечкенә микрофоннар системасында тавыш таралу теориясен һәм ысулларын эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Вибрации и шумы киноаппаратуры. СПб., 1988; Теоретические основы электроакустики и электроакустическая аппаратура. М., 1992; Виброшумовая активность и акустическая диагностика механизмов и аппаратов. СПб., 1998; Динамические микрофоны. СПб., 2002.

**ВАҺА́ПОВ** Әбдүш (Габдулла) Әхтәм улы (1814, Казан — 1876, шунда ук), тел галиме, педагог. Казан кантонистлар батальонында, аннан соң хәрби идарә юлламасы б-н Казанның Беренче гимназиясендә укый (1835 елда тәмамлый). Казан ун-тының физ.-матем. ф-тында ирекле тыңлаучы (1860–65). 1835–68 елларда Казан гарнизонының хәрби уку йортларында (кантонистлар мәктәбе, хәрби уч-ще) укытучы. В. хезмәтләре һәм эшчәнлеге хәрби идарә мәктәпләре үсешендә, татар хәрбиләргә рус телен укыту методикасын формалаштыруда әһәмиятле роль уйный. Беренчә тапкыр басылган «Татарларга русча һәм русларга татарча үзөйрәткеч» («Самоучитель для русских по-татарски и татар по-русски», 1854, 20 изд., 1911) авторы.

Хезм.: Татарские сказания о взятии Булгара Тимуром // Казанские губернские ведомости. 1852. № 43–45; Русско-татарская азбука. К., 1854; Грамматика русского языка, составленная для татар Восточной России. К., 1873.

*Әд.:* Библиографический словарь отечественных тюркологов. М., 1974.

**ВАҺА́ПОВ** Илдар Камил улы (4.8.1949, Магадан ш.), физик, техник фән. д-ры (1992), проф. (1995). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан пед. ин-тында эшли. 1976 дан Беларусь Респ-касы ФАнең Техник акустика ин-тында (Витебск ш.), 1990 нан баш фәнни хезмәткәр, 1992 дән материалларны ультратавыш б-н эшкәртү лаб. мөдире. 1995 тән Казан техника ун-тында. Хезмәтләре магнит квант акустикасына һәм ультратавыш техникасы һәм технологиясенә карый. Парамагнит кристаллның акустик һәм электромагнитик кырлар нурланышын резонанслы йотуның нәсызыкча квант-статистик теориясен төзи. Ике дәрәҗәдә ирекле, нәсызыкча йөкләм куелган ультратавышлы технол. машиналарның резонанс сыйфатламаларын исәпләү ысулын эшли. Металларны авторезонанс режимында эшкәртү өчен үзе индукцияләнә һәм дәвам иттерелә торган схемасын тәкъдим итә. «Мединструмент» фәнни-җитештерү берләшмәсендә хирургия инстр-нтларын (скальпельләр, микроэнәләр) кайрамыйча гына үткенләүнең ультратавыш б-н вибрацияләп чүкү технологиясен гамәлгә кертә.


Хезм.: К теории нелинейных процессов в парамагнитных кристаллах // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1976. Т. 70; Нелинейные эффекты в ультразвуковой обработке. Минск, 1987; Резонансные характеристики двухстержневой колебательной системы под нагрузкой // Машиноведение. 1994. № 3.


**ВАҺА́ПОВ** Наил Гайнан улы (19.3.1956, Ташкент), график, дизайнер. Мәскәү читтән торып уку халык сәнгать ун-тын (1983), Свердловск архит-ра ин-тын тәмамлый (1991). 1976 елдан бизәүче рәссам, интерьер дизайнеры һәм Эстәрлетамак сәнгать мәктәбендә укытучы булып эшли. Савон шәһәрендәге (Италия) Бруно Чиарлионе экология музеенда сәнгать киңәшчесе (1992 дән). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1991), Пиза шәһәре (Италия) Нәфис сәнгать академиясенең (1993), Фресно шәһәре (Калифорния, АКШ) Графиклар гильдиясенең шәрәфле әгъзасы. Күбесенчә басма графика өлкәсендә эшли. «Ростов мотивлары» (1980), «Шәһәр мотивлары» (1985), «Кеше һәм экология» (1992), «Метаморфозалар», «Күңел һәм кеше» (1993) офорт серияләре, «Авыл интерьеры» (1987) триптихы, «Бөрьян», «Агыйдел буйлап» (1983) линогравюралар сериясе, «Кояш тотылуны күзәтүчеләр» акватинтлары (1989), «Утын», «Котельня» (1990) диотипияләре, агачта гравюралар, монотипияләр, «Көзге этюдлар» (1990) рәсем серияләре һ.б. авторы. В. иҗатының төп лейтмотивы — кеше яшәешенең мәгънәсен фәлсәфи яктан ачарга омтылу, җәмгыятьтәге әхлакый үзгәрешләрне, кешенең табигатькә мөнәсәбәтен чагылдыру. Графика эшләре төгәллеге, сурәтләү чараларының камиллеге, күренешләрнең капма-каршылыгы, тотрыклы ритм, чишелешнең кабатланмаслыгы б-н аерылып тора. Иҗатының нигезе образларга милли үзенчәлек бирүче тамырларны эзләүдән гыйбарәт.

Чит илләрдә узган күргәзмәләрдә («Сәнгать сугышка каршы», 1990, Хельсинки ш.; «Россия графикасы», 1993, Пиза ш., Италия; «35 нче Урта диңгез пластик сәнгать салоны», 1995, Порт-де-Бур ш., Франция; «Кече формалар», 1997 һәм 1 нче Халыкара мини-графика бьенналесе, Пиза ш., 1998; «Урал рәссамнары», 2000, Фресно ш., АКШ һ.б.), бөтенсоюз («Илнең яшьлеге», Мәскәү, 1987), бөтенроссия (4 нче эстамп күргәзмәсе, С.-Петербург, 1989) күргәзмәләрендә, төбәкара күргәзмәләрдә (2 нче Урал басма графикасы триенналесе, Уфа, 1999) һәм респ-ка күргәзмәләрендә (70 тән артык) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1988 һәм 1989 (Свердловск ш.), 1990 (Әрбет ш.), 1991 (Эстәрлетамак ш.), 1993 (Пиза ш.), 1994 (Фресно ш.) елларда үтә. Әсәрләре Әрбет сәнгать музеенда, Эстәрлетамак, Уфа, Екатеринбург шәһәрләре сәнгать галереяларында, Пиза шәһәре Сәнгать академиясендә, Фресно шәһәре көллиятләрендә саклана.

*Әд.:* Гравюры Наиля Вагапова: Каталог выставки. Ирбит, 1990; Bruono Pollacci. Nail Vagapov. Artemisia Arte Contemporanea. Pisa, 1993.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*







Н.Г. Ваһапов. 1. «Күгәрчен кетәге». Офорт. 1988; 2. «Ай тотылуны күзәтүчеләр» сериясеннән. Коры энә, акватинта, 1989; 3. «Иске шәһәрдә». Коры энә. 1990.

**ВАҺА́ПОВ** Рәшит Ваһап улы (7.5.1908, Түбән Новгород губ., Сергач өязе Актук а. — 14.12.1962, Казан), җырчы (тенор), ТАССРның халык артисты (1957). Түбән Новгород пед. техникумын (1926), Мәскәү музыка уч-щесен (1938) тәмамлый. 1941–62 елларда Татар филармониясе солисты. 1940–50 елларда татар эстрада җырчылары арасында иң актив концерт эшчәнлеге алып баручылардан санала. Халыкта зур популярлык казана. В. — татар халык җырларын һәм татар композиторлары әсәрләрен иң оста башкаручыларның берсе. Башлыча, лирик планда җырлый. Матур тембрлы көчле тавышка, милли музыка мирасының алтын фондына кергән әсәрләрне тыңлаучыга бөтен тирәнлеге б-н җиткерү сәләтенә ия була. В. башкаруында татар җырлары «Уел», «Кара урман», «Галиябану», «Зөләйха», «Нурия», «Рәйхан», «Эскадрон», «Гөлҗамал», татар композиторлары С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи җырлары популярлык казана. Милли вокаль-концерт сәнгатенә нигез салучыларның берсе булarak, В. татар музыка культурасына зур өлеш кертә. Актив концерт эшчәнлеге алып бара, СССР шәһәрләре буйлап гастрольләрдә еш була. 2004 тән башлап Казанда В. исем. татар җыры фестивале үткәрелә.



Р.В. Ваһапов.

*Әд.:* Ф ә т т а х о в Р. Рәшит Ваһапов: Тормышы һәм иҗаты. К., 2000; Х а й р у л л и н а З. Вагапов Рашит Вагапович // Народные артисты. К., 1980; Ф ә т т а х о в Р. Рашит Вагапов: Личность. Творчество. Эпоха. К., 2003.

**ВАҺА́ПОВ РӘШИ́Т ИСЕМЕНДӘГЕ́ ТАТА́Р ҖЫРЫ́ ФЕСТИВАЛЕ́**, беренче тапкыр 2004 елда Казанда уздырыла, 2005 тән (икенче) бөтенроссия, 2007 дән (өченче) халыкара статусы ала. Оештыручылары — Нижгар татарларының Казандагы «Якташлар» җәмгыяте, «Татарстан» ж-лы редакциясе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты, ТР Мәдәният министрлыгы, «Татмедия» агентлыгы, Казан шәһәр хакимияте. Фестиваль Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь р-нында 7 майда (Р.*Ваһаповның* туган көне) ачыла, концертлар Россиянең дистәләгән шәһәр һәм районнарында (Мәскәү, С.-Петербург, Архангельск, Киров, Пенза, Пермь, Самара, Свердловск, Томск, Ульянов өлкәләре, Башкортстан, Мари, Мордва, Удмурт, Чувашстан респ-калары) һәм чит илләрдә (Германия, Казакъстан, Польша, Үзбәкстан, Украина, Финляндия) куела. Декабрьдә Казанда гала-концерт б-н тәмамлана. Фестивальдә татар халык һәм эстрада җырларын башкаручы атаклы артистлар, башка милләтләрнең күренекле җырчылары, йөзләрчә һәвәскәр башкаручылар коллективлары катнаша. 2007 дән фестиваль кысаларында солистлар һәм дуэтлар номинациясендә, ш.у. профессиональ һәм һәвәскәр башкаручылар өчен аерым конкурс уздырыла. 2004 елдан фестивальнең җитәкчесе Р.Ә.*Фәттахов*.

**ВАҺҺАБЧЫЛЫ́К**, исламның сөнниләр мәзһәбендәге радикаль реформалар үткәрү хәрәкәте. 18 йөз уртасында Гарәбстанда барлыкка килә. Аңа әүвәлге ислам нормаларын кайтару максатын куйган Мөхәммәд ибне Габдел-Ваһһаб (1703–87) нигез сала. В. тәгълиматы нигезендә исламны «кабул итәргә ярамаган яңалыклардан чистарту» (*бидгать*), бер Аллаһны гына тану принцибын катгый рәвештә саклау (к.*Тәүхид*), изгеләргә (к.*Әүлия*) һәм *изге урыннар*га табынуны инкарь итү идеясе ята. Догматика һәм хокук өлкәсендә В. *Ибне Таймийә* карашларының мантыйклы дәвамы булып тора. В. барлык мөселманнарның бердәмлегенә һәм туганлыгына, социаль гаделлеккә, исламның әхлакый-этик принципларына катгый рәвештә буйсынуга чакыра. В. тәгълиматында җиһад идеясенә мөһим урын бирелә. Аны һәр мөселманның рухи камиллеккә омтылышы буларак таныган хәлдә, ваһһабчылар, эчке җиһад кече җиһадтан — кяферләргә каршы изге сугыштан аерылгысыз, дип исәплиләр.


Хәзерге Россия терр-ясендә В. Төньяк Дагстанда тарала. Ваһһабчыларның беренче легальләшмәгән төркемнәре 1970 елларда барлыкка килә, 1980–90 еллар чигендә В. бу төбәктә рәсми рәвештә һәм идея ягыннан оешып җитә: Кызылйорт шәһәрендә ваһһабчыларның беренче рәсми мәхәлләсе теркәлә. 1994–96 еллардагы чечен сугышы башлангач, ваһһабчыларның эшчәнлеге активлаша, алар арасында хәрбиләшкән төркемнәр барлыкка килә, Карамахи авылында (Дагстан) «кече җиһад»ка әзерләүче хәрби мәктәп оештырыла. Ваһһабчылар федераль гаскәрләргә каршы партизан сугышында актив катнашалар. Шул ук вакытта рәсми дин әһелләренә һәм җирле хакимият органнарына карата килешмәүчәнлек күрсәтәләр, һәм бу хәл дини, сәяси каршылык булып үсеп җитә. 1998 дә Чечня мөселманнары Диния нәзарәте, ваһһабчыларны «исламның һәм чечен халкының дошманнары» дип атап, аларның барлык җәмгыятьләрен һәм фиркаләрен тыярга чакыра. 1999 да «Дагстан республикасында В.ны һ.б. экстремистик эшчәнлекне тыю турында» закон кабул ителә. Шуңа да карамастан, В. хәрәкәте барлык Төньяк Кавказга җәелә, Нугай далаларына һәм Көньяк Идел буена үтеп керә. В.ның Карачай-Черкәс, Кабарда-Балкарда очравы турында хәбәрләр бар. В. хәрәкәтенең үзәге акрынлап Чечняга күчә.

Татарстанда В. тәгълиматы киң таралыш алмый. Ләкин төбәктәге дини оешмаларның халыкара ислам миссионерлык оешмалары б-н даими элемтәләре, 1990 еллар башында Татарстаннан 100 шәкертнең ислам илләрендә, ш.и. Согуд Гарәбстанында укуы, җирле мәдрәсәләрдә чит ил укытучыларының дәрес бирүе, халык арасында татар һәм рус телләрендәге В. әдәбиятының күпләп таратылуы озак еллар дәвамында күпгасырлык традицияләреннән аерылып торган Идел буе мөселманнары, бигрәк тә яшьләр арасында «исламны соңгы катламнардан», ш.и. татар халкының гореф-гадәтләре һәм йолаларыннан чистарту идеясенең популярлашуына китерә. Ләкин Татарстанда В. рәсми рәвештә оешуга һәм идея ягыннан берләшүгә ирешә алмый.

*Әд.:* В а с и л ь е в А. История Саудовской Аравии (1745 г. – конец XX в.). М., 1999; И д р и с А б д у л л а х. Ваххабизм: история проблемы // Мусульмане. 2000. № 1; М а к а р о в Д.В. Официальный и неофициальный ислам в Дагестане. М., 2000; М у х а м е т ш и н Р.М. Ислам в общественно-политической жизни Татарстана в конце XX века. К., 2000.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**ВА́ШУРОВ** Андрей Иванович (15.11.1925, Лаеш кантоны Караеш а. — 5.5.1995, Чаллы ш., Караеш а.), нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). Казан сәнгать уч-щесен (1952), Львов гамәли һәм декоратив сәнгать ин-тын (1958) тәмамлый. РСФСР Сәнгать фондының Бурятия (Улан-Удэ ш., 1958 елдан), Хабаровск (Комсомольск-Амур ш., 1962 дән), Магадан (Магадан ш., 1971 дән) бүлекчәләрендә эшли. 1973 тән Чаллыда сәнгать уч-щесендә укыта (1984). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1981).



А.И.В а ш у р о в. «Кама элеваторы». 1970 еллар уртасы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Байкал күле, Саян таулары, Чукотка күренешләрен сурәтләгән пейзажлар («Байкалда» 1959; «Тункин үзәне» 1959; «Себернең руда карьерлары» 1961; «Хамар-Дабан сыртлары» 1962) иҗат итә, Ерак Көнчыгыш өлкәләренең район үзәкләре мәдәният йортлары өчен пейзаж характерындагы монументаль рәсемнәр эшли. Индустриаль пейзаж жанрындагы әсәрләре рәссамның иҗади казанышы булып тора. «Кама ГЭСы казаны» (1973–74), «КамАЗ җирендә» (1975), «КамАЗның кою заводы» (1975) һ.б. картиналарында Кама буендагы сәнәгать комплекслары төзелешенең романтикасын һәм киң колачын чагылдыра, Кама төбәген индустриальләштерүнең сәнгатьчә елъязмасын тудыра.

70 еллар ахырында Байкал-Амур магистрале төзелешенә багышланган картиналар



А.И.В а ш у р о в. «КамАЗның башлангычы». 1970 еллар уртасы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

сериясен эшли. Аның нәкышь әсәрләре табигать күренешләреннән алынган ихлас хисләр, җылы кызыл-көрән, охра төсләр гаммасына баетылган буяуны кыл-каләм ярдәмендә киң итеп майлап эшләве б-н үзенчәлекле. Зона («Совет Ерак Көнчыгышы», 1964, 1967; «Зур Идел», 1974, 1980), республика («КамАЗга багышлана», 1973, «Ел йомгаклары», 1974, 1975; «Туган як», 1978 һ.б.) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1985, 1995 тә Чаллыда уза. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләренең картиналар галереяларында саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Вашуров Андрей Иванович. 1925–1995: Буклет. Сочи, 1997.

*Е.П.Ключевская.*


**ВАШШ** Дьюла Адамович (26.4.1891, Венгрия, Суботица ш. — 22.9.1967, Казан), спортчы, тренер, Татарстанда физик тәрбия һәм спорт хәрәкәтен оештыручыларның берсе, РСФСРның атказ. тренеры (1959). Укытучылар ин-тының пед. ф-тын тәмамлый (1911, Венгрия, Егер ш.). 1914 елдан Австрия-Венгрия армиясе б-н Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1915–19 да Россиядә хәрби әсир. 1919 да Красноярск шәһәрендә үз теләге б-н Интернациональ полкка керә һәм Колчак армиясенә каршы сугышларда катнаша. 1920 дә полк б-н Казанга «Алтын эшелон»ны озата бара. 2 нче Идел буе олимпиадасында (1923, Казан), Бөтенсоюз спартакиадасында (1928, Мәскәү, фехтование һәм йөзүдә 5 нче урын) катнаша. 1920–56 да урта һәм югары уку йортларында укыта. Бер үк вакытта физик культура укытучылары әзерләү курсларында укытучы, спорт секциясе җитәкчесе (җиңел атлетика, гимнастика, чаңгы, тимераяк, йөзү, көрәш, фехтование, суга сикерү, су тубы), судьялар коллегиясе җитәкчесе, йөзү һәм фехтование буенча ТАССР һәм РСФСР җыелма командаларында тренер, Казан гарнизоны курсларында һәм хәрби частьләрендә инструктор булып эшли. Шәкертләре: Н.Г.*Жеребцов*, Т.Н.*Полыгалова*, В.Я.*Базаревич* һ.б.

**ВӘДҮ́Т М.** (чын фамилиясе һәм исеме Мифтахов Вәдүт Кәшшаф улы) (20.11.1915, Уфа губ., Минзәлә өязе Яхшы Каран а. — 30.3.1942, Тула өлкәсе Рыдань а.), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1939), урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. Әсәрләре 1930 еллар уртасыннан басыла башлый. Шигырьләре «Чәчәк атабыз» (1937), «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940), «Ватан өчен» (1941) исемле коллектив җыентыкларга кертелә. 1939 елда аның «Шигырьләр» җыентыгы дөнья күрә. Аерым шигырьләре сугыштан соң басылып чыккан «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) исемле коллектив җыентыкларда урын ала. Бөек Ватан сугышында катнаша. Тула янындагы сугышта һәлак була.

*Әд.:* Давыдов Ә. Мәңге яшь // Социалистик Татарстан. 1965. 21 нояб.; Рахман Р. Очкын оча // Ватаным Татарстан. 1995. 2 дек.



Г.В. Вәзетдинов.



Б.Х. Вәисов.



Гайнанетдин Вәисов.

**ВӘЗЕТДИ́НОВ** Гыймазетдин Вәзетдин улы (1907, Уфа губ., Минзәлә өязе Исәнгол а. — 8.3.1940, Виипури ш., хәзерге Ленинград өлкәсе Выборг ш.), Сов. Союзы Герое (21.3.1940, вафатыннан соң), кече лейтенант (1938). 1929 елда Кызыл Армиягә алынганчы колхозда эшли. Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (1938). Совет-фин сугышында (1939–40) катнаша, 330 нчы укчы полкның рота командиры (7 нче армиянең 86 нчы укчы дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре составында дошманның Виипуридагы ныгытмасын штурмлауда катнаша. Виипури шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев., К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

**ВӘЗИ́ЕВА** Җамал Гали кызы (24.10.1907, Вятка губ., Алабуга өязе Салагыш а. — 17.12.1989, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1950). 1928 елда Алабуга пед. техникумын тәмамлый. 1931 дән Казан вет. ин-тында, 1935 тән Казан пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре 19–20 йөз татар әдәбияты тарихына, балалар әдәбиятына, татар әдәбиятын укыту методикасына карый. Мәктәптә әдәбият укыту программасы һәм уку ярдәмлекләре авторларының берсе.

Хезм.: Татар әдәбияты. XX йөз (1917 нче елга кадәр): Дәреслек-хрестоматия. К., 1947 (автордаш); Татар әдәбияты. XX йөз: Дәреслек-хрестоматия: 2 кис. К., 1954 (автордаш).

*Әд.:* Ибраһимова Ф. Укытучы бәхете // Азат хатын. 1987. № 10.

**ВӘЗИ́РОВ** Нәҗафбәк Фәтхгалибәк оглы (5.2.1854, Елизаветполь губ., хәзер Әзәрбайҗан Респ-касы Шуша ш. — 9.7.1926, Баку), әзәрбайҗан драматургы. Әзәрбайҗан әдәбиятында реалистик трагедия жанрын нигезләүче һәм әзәрбайҗан театрын оештыручыларның берсе. 15 драма әсәре авторы. Ялган банкрот булып кыланучы бер карт сәүдәгәр-хаҗиның уналты яшьлек кызга өйләнергә тырышып йөрүе турында язылган «Тымызык яңгыр астыннан чыгып, яшенле яңгыр астына» (1895) пьесасы татар драматургиясендә Г.Камалның «Банкрот», Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедияләрен иҗат итәргә дәртләндергәндер дип уйларга нигез бар. В.ның кан үче алу кебек иске гореф-гадәтләрне тәнкыйть иткән «Мосыйбәте Фәхреддин» («Фәхреддиннең кайгысы», 1896) трагедиясе исә 1907 елда Гыймад Нугайбәк тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, татар театр труппаларының репертуарында нык лы урын ала һәм Идел буе, Урал, Себер, Урта Азия шәһәрләрендә күп мәртәбәләр сәхнәдә уйнала. 1907–17 еллар арасында татар көндәлек матбугатында бу әсәр, аның сәхнәгә куелышы һәм авторының иҗат эшчәнлеге турында бик күп мәкаләләр басыла.

Әсәр.: Избранные произведения. Баку, 1958.

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Караев Я. Этапы азербайджанского реализма. Баку, 1983; Гаджиев А. Азербайджанский реализм. Баку, 1984.

*Р.К.Ганиева.*

**ВӘЙ́СОВ** (чын фамилиясе Хәмзин) Баһаветдин Хәмзә улы (12.9.1810, Казан губ., Зөя өязе Сатмыш а. — 1893, Казан), *вәисиләр хәрәкәтенә* нигез салучы һәм аның җитәкчесе. Казанда мәдрәсәдә укый. Төркестанда һәм Бохарада сәүдә итә. 1860 еллар башыннан В. үзен *Нәкышбәндийә* борадәрлеге суфилары шәехе дип атый башлый. Үзенең әйтүенчә, тәгълимат нигезләре аңа дәрвиш Җәгъфәр әл-Кулаткы (чыгышы б-н Саратов губ., Хвалын өязе Иске Кулаткы а.) тарафыннан җиткерелгән. Әлеге тәгълимат йогынтысында В. үзен изге Вәис дип, Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәштәше, аның эшен дәвам иттерүче дип белдерә. 1862 елда, янәсе, император Александр II биргән рөхсәткә таянып, Казанда гыйбадәт йорты ача, анда милләттәшләрен «чын дингә» өйрәтә. В. үз вәгазьләрендә мөселман дин әһелләрен тәнкыйтьли. Ул, татарлар арасында беренчеләрдән булып, халыкларның үзбилгеләнү хокукын, кешеләрнең закон алдында тигез булырга тиешлеген белдерә. Оренбург Диния нәзарәте аны рухани дәрәҗәсеннән мәхрүм итә. Моңа җавап йөзеннән ул «иске динне тотучы»ларның «автономияле» үз рухани идарәле «Вәисиләр илаһи полкы»н оештыра. В. «илаһи сугышчылар»ны гражданлык кануннарына һәм хакимияткә буйсынмаска, гамәлләрне бары тик Коръәнгә һәм шәригатькә нигезләп кылырга чакыра. «Тарикы хөҗҗәтин» («Дәлилләү ысулы», 1874) хезмәтендә үз тәгълиматының төп өлешләрен бәян итә. 1884 тә салымнар түләмәве өчен кулга алына. 1885 тә Казан мәхкәмә палатасы карары б-н В. акылга зәгыйфь дип табыла һәм Казан округы психик авырулар хастаханәсенә урнаштырыла; шунда вафат була.

*Әд.:* к. Вәисиләр хәрәкәте.

*Р.К.Вәлиев.*

**ВӘЙ́СОВ** Газизҗан Баһаветдин улы (1887, Казан губ., Тәтеш өязе Бидәңге а. — 1937), *вәисиләр хәрәкәте* җитәкчеләренең берсе. Б.Х.*Вәисовның* улы. Хәрәкәтне 1918 елдан соң җитәкли. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армиянең Төркестандагы төркемендә вәисиләрнең «илаһи полкы»н оештыра. Төркестанда сугыш хәрәкәтләре алып баруга каршы була, Совет хакимияте дошманнарына (басмачыларга) каршы сугышудан баш тарта. Аннары Үзбәкстанның Яңа Юл р-нында яши, Ниязбаш медицина пунктын-

да фельдшер булып эшли. 1940 та «милли оешмада катнашучы» буларак кулга алына, нахакка репрессияләнә (8 елга төзәтү-хезмәт лагерена җибәрүгә хөкем ителә), вафатыннан соң аклана (1989).

*Әд.:* Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2001. Т. 3.

*Р.К.Вәлиев.*

**ВӘЙСОВ** Гайнанетдин (Гайнан) Баһаветдин улы (Сәрдар) (8.11.1878, Казан губ., Зөя өязе Мулла Иле а. — 28.2.1918, Казан), *вәисиләр хәрәкәте* җитәкчеләренең берсе. Б.Х.*Вәисовның* улы. Атасы вафатыннан соң хәрәкәткә җитәкчелек итә. 1894 елда полициягә коралны каршылык күрсәтүе өчен кулга алына һәм 1895 тә Сахалин утравына сөрелә. Амнистия буенча ирекккә чыгарылганнан соң, 1906 да Казанга кайта һәм үзен чикләнмәгән хокуклы «Сәрдар» («илаһи сугышчылар» җитәкчесе) дип белдерә, тарафдарларыннан карусыз буйсынуны таләп итә. Иң тугрыларын «бөек ышанычлылар» (ярдәмчеләр) итеп билгели. Яңа бистәдә вәисиләр хәрәкәтендә катнашучыларның гыйбадәт йортын торгыза. Бу чорда В. Л.Н.Толстой б-н үзара мөнәсәбәтләр урнаштыра. 1908 дә С.-Петербургка бара, патша түрәләреннән мәхәлләне ныгыту өчен 100 мең сум акча бүлеп бирүне, Болгар шәһәре янындагы җирләргә вәисиләр хокукын тануны һәм аннан русларны чыгаруны үтенә (үтенечө җавапсыз кала). 1910 да кулга алына һәм Казан мәхкәмә палатасы карары б-н Себергә сөрелә, ул анда 1917 нең апреленә кадәр була. Казанга кайтканнан соң, Вакытлы хөкүмәткә каршы чыга, Совет хакимиятен яклый. «*Болак арты республикасы*» вакыйгалары барышында үтерелә. «Җәваһиру хикмәти дәрвишан» («Дәрвишләр фәлсәфәсенең асылы», 1907. Кайбер мәгълүматлар буенча, атасы Баһаветдин тарафыннан язылган) хезмәтендә Россиядә 19 йөзнең 70–80 нче елларында булып узган вакыйгалар тасвирлана, имансыз заман каһәрләнә, чын дингә кайтуга һәм тәүбәгә килүгә катгый чакыру яңгырый.

*Әд.:* к. *Вәисиләр хәрәкәте.*

*Р.К.Вәлиев.*

**ВӘИСИЛӘ́Р ХӘРӘКӘТЕ́**, милли һәм социаль изүгә каршы күтәрелгән көрәшнең дини-сәяси формасы. В.х.н нигезләүче — суфиларның *Нәкышбәндийә* борадәрлеге суфилары тәгълиматы дәвамчысы Б.Х.*Вәисов*. 1862 елда Казанда дини агымның үзәгенә әверелгән «Фирка-инаҗия» («Котылу партиясе») дип аталган гыйбадәт йорты ача. В.х. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөзнең 1 нче чирегендә татар крәстияннәре, һөнәрчеләр һәм вак сәүдәгәрләр арасында киң тарала. Вәисиләр үз эшчәнлекләрен «Патшаны без олылыйбыз һәм аның өчен дога кылабыз, әмма безгә дәүләт кирәкми» дигән лозунг астында алып баралар. В.х. җитәкчеләре мөселман руханиларын Коръән таләпләрен үтәмәүдә, мөселманнарга «кяферләр» армиясендә хезмәт итәргә рөхсәт бирүдә, мөселман гыйбадәтләренең вакытында үтәлүен тикшереп тормауда, Коръәндә каралмаган хокукларны үзләштерүдә, әхлакый бозыклыкта һ.б.да гаепләлиләр. Вәисиләр бары тик Аллаһы коллары гына булырга телиләр, үзләренең сәрдарыннан (Вәисовтан) кала, җир йөзендә «күкләр билгеләгән» императорны гына таныйлар, дәүләт хакимиятен инкарь итәләр. В.х.нең төп алымы буйсынмаудан гыйбарәт була: алар гражданлык законнарына һәм хакимияткә буйсынмыйлар, салымнар түләмиләр, Россия армиясендә хезмәт итүдән баш тарталар. Оренбург Диния нәзарәте аларның вәгазьчелек эшчәнлеген тыйганнан соң, Б.Вәисов «иске динне тотучы»ларның «автономияле» рухани идарәле «Вәисиләр илаһи полкы»н оештыра, үзләренең туу-үлүне теркәү кенәгәләрен гамәлгә кертә, «Мәктәбе гыйрфан» («Белемнәр мәктәбе») уку йортын, уртак касса һ.б.ны ача. В.х.нә катнашучылар, үзләренең матди хәлләреннән чыгып, билгеле бер күләмдә акча күчерергә тиеш булалар. Б.Вәисовның көрәштәшләре һәм ярдәмчеләре — Нәҗметдин Ишбаев, Габделлатыйф Халитов, Шиһабетдин Сәйфетдинов (Б.Вәисовның вафатыннан соң «сәрдар» роленә дәгъва белдерә) һ.б. 1885 нең гыйнварында Б.Вәисов һәм аның 14 тарафдары кулга алынганнан соң (Б.Вәисов психиатрия хастаханәсенә урнаштырыла, аның 6 тарафдары Себергә сөрелә), В.х. дәвамчылары яшерен эш итүгә күчәләр, үз тәгълиматларын халык арасында таратуны дәвам итәләр, шул сәбәпле полиция тарафыннан эзәрлекләнәләр. Б.Вәисов вафатыннан соң, В.х.н аның улы Г.*Вәисов* җитәкли. 1894 тә ул кулга алына һәм Сахалин утравына сөрелә. Ачыктан-ачык хакимияткә буйсынмау, 1897 елгы халык санын алуда катнашудан баш тарту В.х.ндә катнашкан 100 дән артык кешенең кулга алынуына китерә (19 йөз ахыры). 1905–07 дәге рев-ция чорында В.х. көчәя, «ислам социализмы» рухында үзенә бер яңарыш кичерә. «Болгар дәүләте» торгызылгач, «алтын дәвер»нең кире кайтуына ышаныч В.х.нең төп идеясенә әверелә. В.х. вәкилләренең күзаллавында Рус дәүләте б-н элемтә рус императоры б-н үзара уния төзү нәтиҗәсендә гамәлгә керергә тиеш була. Шул ук вакытта алар ачыктан-ачык экстремизм лозунглары («70000 указлы мулланың башын кисәргә» һ.б.) игълан итәләр, бөек җиһад сугышына өндиләр; әлеге көрәш вакытында көч куллану юлы б-н Болгар шәһәрен үз кулларына төшерүне һәм мөселман руханиларының рәсми катлавын кырып бетерүне күздә тоталар. 1906 да амнистия буенча Казанга кайткач, Г.Вәисов В.х.ен җитәкли, үзен хакимияте чикләнмәгән «сәрдар» дип игълан итә, иң тугры дәвамчыларын «бөек ышанычлылар» дип билгели. Казанда гыйбадәт йорты торгызыла. Җәмгыятьтә иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләр кискенләшкән шартларда Г.Вәисов В.х.нә сәяси төсмер бирергә омтыла. 1908 дә Казан губернасының Казан, Зөя, Арча өязләрендә, Оренбург губернасында һ.б. җирләрдә, Урта Азиядә вәисиләрнең гомуми саны 15 меңнән артып китә. В.х. вәкилләре элеккечә үк хәрби хезмәттән, салымнар түләүдән читләшәләр, Россия паспортларын танудан һ.б.дан баш тарталар. 1910 ның октябрендә В.х.нең җитәкчеләре кулга алына һәм Казан мәхкәмә палатасы чыгарган хөкем карары буенча Себергә сөрелә; алар сөргендә 1917 нең апреленә кадәр булалар. Февр. рев-циясеннән соң вәисиләр Вакытлы хөкүмәткә каршы көрәштә актив катнашалар. 1917 нең апрелендә Казанда «болгар илаһи сугышчылары»ның съезды була. Г.Вәисов съезд исеменнән Эшче һәм солдат депутатларының Петроград советына телеграмма җибәрә. Съезд делегатлары Вакытлы хөкүмәттән кичекмәстән сугышны туктатуны, аннексия һәм контрибуцияләрсез солых төзүне, барлык халыкларның вәкилләрен чакырып тынычлык конференциясе уздыруны таләп итәләр. Вәисиләр Совет хакимиятен яклауларын белдерәләр. Бу хәл башка милли төркем тарафдарлары б-н каршылыкка китерә, 1918 ел «Болак арты республикасы» вакыйгалары вакытында В.х. җитәкчесе Гайнанетдин Вәисов үтерелә. В.х.н аның энесе Газизҗан *Вәисов* җитәкли. 1919 ның гыйнварында вәисиләрнең 2 нче съезды була. Анда партиянең яңа исеме кабул ителә, ул «Революционер-коммунист вәисиләр партиясе» дип атала башлый. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армия гаскәри берәмлекләрендә Г.Вәисов инициативасы б-н вәисиләрнең «илаһи полклары» оештырыла, алар мөселманнарга каршы сугышудан баш тарталар. 1920 елларда вәисиләр Чистай кантонында Яңа Болгар авылына нигез сала, шунда яңа шартларда үз тәгълиматларын җәелдерергә омтылалар. Беркадәр вакыттан соң В.х. җәмгыяте таркала, 1930 елларда В.х.нең җитәкчеләре һәм активистлары репрессияләнә.

*Әд.:* В ә л и е в Р.К. Өзелгән дога // Мирас. 2002. № 8, 9, 11, 12; 2003. № 1; К а т а н о в Н.Ф. Новые данные о мусульманской секте ваисовцев. К., 1909; М о л о с т в о в а Е.В. Ваисов Божий полк // Мир ислама. 1912. Т. 1, ч.2; С а г и д у л л и н М.К. К истории ваисовского движения. К., 1930; К л и м о в и ч Л.И. Ислам в царской России. М., 1936; И о н е н к о И., Т а г и р о в И. Октябрь в Казани. К., 1967; В а л е е в Р.К. Революционное движение в Среднем Поволжье (июль–октябрь 1917 года). К., 1972; Д а в л е т ш и н К. Кто такие ваисовцы? // Наука и религия. 1981. № 6; Ваисовцы // Отечественная история: Энцикл. М., 1994. Т. 1; К е м п е р М., У с м а н о в а Д. Ваисовское движение в зеркале собственных прошений и поэм // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 3/4.

*Р.К.Вәлиев.*

**ВӘЛИ́** (Вәлиуллин) Зиннәт Сәгый улы (8.3.1924, Тәтеш кантоны Шәпкә а.), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1959–70 елларда Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, 1970–76 да Таткниготоргта китап таратучы булып эшли. Әдәби һәм журналистлык эшчәнлеге б-н 1943 тән шөгыльләнә. «Юл ачык» (1965) пьесасы, балалар өчен «Югалган алма» (1954), «Балан бәлеше» (1963), «Җирдәге йолдызлар» (1965), «Исәнме, кызым» (1967) исемле хикәя җыентыклары авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары б-н бүләкләнә.

**ВӘЛИ́** ( Вәлимөхәммәтев) Лотфи Вәлимөхәммәт улы (1910, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Кушнаренко р-ны Илек а. — 1943), шагыйрь. 1929 елдан Мәскәүдә яши, пролетар язучылар ассоциациясенең татар секциясе эшендә катнаша. Әсәрләре 1930 еллар башында «Эшче» г-тасында, «Октябрь баласы», «Ударниклар» ж-лларында басыла баш-

лый. «Чакыру» исемле (1932, М.Җәлил кереш сүзе б-н) беренче җыентыгына кергән шигырьләрендә хезмәткә дан җырлый. Аерым шигырьләре «Каләмле ударниклар» (1932), «Туган ил» (1938) альманахларына кертелә. 1941 нең җәендә Бөек Ватан сугышына китә. Шигырьләрен һәм очеркларын фронт газеталарында һәм «Совет әдәбияты» ж-лында бастыра. 1943 тә фронтта һәлак була.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ВӘЛИ́** (Вәлиев) Хәйретдин (1893–1969), әдәбият тәнкыйтьчесе. Г.Тукай («Поэмалар шагыйре»), Г.Кутуй («Футурист шагыйрь»), Г.Ибраһимов («Галимҗан Ибраһимовның әдәби үсүе») иҗатларына багышланган беренче мәкаләләре 1920 елларда «Кызыл Татарстан» г-тасында, «Безнең юл» ж-лында һ.б. басмаларда урын ала. Г.Нигъмәти, Ш.Саттаров хезмәтләренә рецензияләр яза, публицистик мәкаләләр бастыра. «Әдәби типлар механизмы» (1929) китабы әдәби типлар, аларның характеры һәм структура үзенчәлекләренә багышлана. «Татар шигыре төзелеше» (1929) китабында шигырь төзелешенә киң анализ бирелә.

**ВӘЛИ́** (Вәлиев) Ярулла Вәлиулла улы (1879, Сембер губ., Буа өязе Бикморза а. — 1937), язучы, драматург. Сәүдәгәр гаиләсендә тәрбияләнеп үсә. Дәрдемәнднең кияве. 1906 елдан «Вакыт» г-тасында эшли; 1909 дан Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. 1917 нең октябреннән «Вакыт» г-тасын чыгаручы мөхәррир. 20 нче еллар ахырында Оренбургтан Уфага күчеп килә, бухгалтер булып эшли. «Мәңгелек мәчет» (1901), «Әфиун» (1906), «Җанлы җеназа» (1907), «Ахырзаман бәласе» (1907), «Урман әүлийәсе» (1907) хикәяләре аерым-аерым нәшер ителә. «Оят, яки Күз яше» (1902; 1907 дә сәхнәләштерелә), «Ачлык кушты» (1908; 1911 дә сәхнәләштерелә) пьесалары авторы. Пьесалары, бигрәк тә «Ачлык кушты» драмасы үз вакытында «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» театр труппалары тарафыннан күп мәртәбә сәхнәгә куела. Репрессияләр чоры корбаны.

Әсәр.: Үзеңә кайту. Оренбург, 1913.

*Әд.:* Хәмидуллин Л. «Ачык фикерле зат...» // Ак төннәр хәтере. К., 2002; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988.

*Л.Х.Хәмидуллин.*


**ВӘЛИӘХМӘ́ТОВ** Әмир Хөснулла улы (7.1.1927, Казан), нәкышьче. Казан сәнгать уч-щесен (1944), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын (1953) тәмамлый. Г.Г.Ряжский, В.К.Цыплаков, К.М.Максимов шәкерте. Казан сәнгать уч-щесендә укыта (1953–54). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1953). 1955 елдан Мәскәүдә яши.

В. — тематик картиналар остасы, тарихи һәм көнкүреш жанрындагы әсәрләр иҗат итә, портретлар, пейзажлар, натюрмортлар авторы. Нәкышь эшләрендә Бөек Ватан сугышы темасын гәүдәләндерә («Хәтер — изге», 1979; «Партизан землянкасы хуҗабикәсе», 1970 һ.б.); аның «Герой шагыйрь Муса Җәлил Моабит төрмәсендә» исемле картинасы (1957)



Ә.Х.Вәлиәхмәтов. «Әти белән әни». 1970.

киң танылу казана. В.нең замандашлар образларын чагылдырган «Корыч ага» (1959), «Рационализаторлар» (1964), «Төнге смена» (1967), «Әти» (1967), «Әти белән әни» (1970), «Улым турында хатирәләр» (1980), «Әлфия» (1980), «Яшь рәссам кыз» (1982) һ.б. картиналары үзенчәлекле лиризм, образлар психологиясенең тирәнтен ачылуы, тормыш сө-



Ә.Х.Вәлиәхмәтов. «Хатирәләр». 1980.

юченә рухның өстенлеге б-н аерылып торалар. «Ильич сөйли» (1961), «Беренче бишьеллык төзелешенә» (1968), «Ленин янына баручылар» (1970) картиналары илнең революцион үткәне темасына багышлана. «Иосиф-Волоколамск монастыре» (1972), «Хива» (1973) дип аталган архит-ра пейзажлары — монументаль мәһабәтлекләре б-н үзенчәлекле; «Кипкән үләннәр» (1975) һ.б. натюрмортлары форманың сәнгатьчә гомумиләштерелүе б-н аерылып торалар. Бөтенсоюз («ВЛКСМга — 40 ел», Мәскәү, 1958; «Совет властена — 50 ел», Мәскәү, 1967), бөтенроссия («Совет Россиясе», 1960, 1964, 1967, 1970, 1980), респ-ка (М.Җәлилнең 70 еллыгына, Казан, 1976; «Татарстан сынлы сәнгате», Мәскәү 1970) һәм Мәскәү рәссамнары әсәрләре күргәзмәләрендә (1957–1985) катнаша. Әсәрләре Лондон, Мәскәү, Казан, Тверь, Чита һ.б. шәһәр музейларында һәм картина галереяларында саклана.

*Әд.:* Бикчәнтәев А. Якташыбыз иҗаты // Ялкын. 1968. № 9; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1972. Т. 2; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ВӘЛИӘХМӘ́ТОВ** Әхмәтмөдәррис Вәлиәхмәт улы (1.1.1894, Казан губ., Спас өязе Урта Әлки а. — 1981, Минзәлә ш.), Кызыл Армия командиры. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң полк һәм дивизия солдат ком-тлары әгъзасы, 1917 елның маенда Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 1 нче корылтаена делегат итеп сайлана. 1917 нең декабрендә демобилизацияләнә. 1918 нең сентябреннән Кызыл Армиядә. Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе 26 нчы дивизиянең 6 нчы полкы б-н Уфа шәһәрен чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык Армиясе гаскәрләреннән азат итүдә катнаша. Уфада агитатор курсларын тәмамлый. 5 нче армиянең Революцион Хәрби Советы сәяси бүлегенең крәстиян бүлекчәсе хезмәткәре. 1919 ның августында Мөселман совет укчыларының икенче мәктәбенә (курсларына) укырга җибәрелә. 1920 нең гыйнварыннан — *Икенче аерым Идел буе татар укчылары бригадасы*нда 202 нче полкның рота, сентябреннән 3 нче батальоны командиры. 1922–25 тә Әлки авыл советы рәисе һәм волость җир эшләре комиссиясе әгъзасы, волость куллланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе, Әлки волосте башкарма ком-ты һәм волость җир эшләре комиссиясе рәисе, Спас кантоны башкарма ком-ты әгъзасы. 1925 тә ТАССР ҮБК әгъзалыгына сайланганнан соң, ТАССР Халык финанс комис-тына эшкә җибәрелә. 1930–33 тә Краснобор райбашкарма ком-ты рәисе, 1933–37 дә Әлмәт, Минзәлә МТСлары директоры, 1938–42 дә Минзәлә урман хуҗалыгы директоры. 1942–44 тә ВКП(б)ның Минзәлә райкомы 2 нче секретаре. 1944–48 дә Матвеевка райбашкарма ком-ты рәисе, 1948–57 дә Минзәлә спирт з-ды директоры. 1957 дән ялда. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ерашов В. Валиахметов Ахметмударрис Валиахметович // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ВӘЛИӘХМӘ́ТОВ** Фән Гавис улы, к. 712 биттә.

**ВӘЛИӘХМӘ́ТОВ** Хөсәен Хәсән улы (22.12.1950, Әлмәт ш.), журналист, публицист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1997). Казан ун-тын (1973) һәм Ленинград политология ин-тын (1991) тәмамлый. 1973 елдан «Татарстан яшьләре» г-тасында хәбәрче, спорт һәм оборона-масса эшләре һәм пропаганда бүлекләре мөдире. 1985–86 елларда ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында радиопрограммалар, мәгълүмат һәм реклама бүлеге мөхәррире. 1986 дан «Социалистик Татарстан» г-тасында хәбәрче, пропаганда, фән һәм мәгариф бүлеге мөдире (1991). 1992–97 дә ТРның Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында әйдәп баручы белгеч. Бер үк вакытта 1993–2001 дә «Бизнес в Татарстане» ж-лының баш мөхәррире. 1998 дән «Мәгърифәт» г-тасы баш мөхәррире. Шул ук вакытта 2003 тән Казан пед. ун-тында укыта, доцент. Республиканың атаклы спортчылары һәм мәдәният эшлеклеләре турындагы очерклар циклы, «Азат хатын», «Казан утлары» ж-лларында, «Советская Татария», «Комсомолец Татарии» г-таларында басылган әдәби очерклар, юлъязмалар авторы.

Әсәр.: Бозлы чакрымнар // Яшүсмер, сиңа. К., 1979; Камышлы күл сагышы. К., 1989; Русча-татарча аңлатмалы популяр психология терминнары

сүзлеге. Аксубай (ТР), 2004; На службу призваны судьбой. К., 1997 (автордаш); Духовно-нравственное развитие личности в событийной деятельности. К., 2002 (автордаш); Учебно-событийная деятельность в духовно-нравственном развитии личности. К., 2003.

**ВӘЛИ́ДОВ** Ибраһим Гыйльман улы (29.12.1902, Вятка губ., Алабуга өязе Балтач а. — 14.7.1968, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1949), проф. (1950), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1954). Казан ун-тын тәмамлый (1931), шунда ук эшли, 1950–65 елларда кеше һәм хайваннар физиологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре нерв-мускуллар физиологиясенә карый. Беренче булып синаптик күчерү механизмында кальций ионнарының ролен күрсәтә. И.П.Павлов исем. Бөтенсоюз физиология җәмгыятенең Татарстан бүлеге рәисе (1950–57). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование феномена посттетанического усиления сокращения мышцы // Уч. зап. Казан. ун-та. 1948. Т. 158, кн.4; Кафедра физиологии человека и животных. Научная деятельность кафедр биолого-почвенного факультета // Уч. зап. Казан. ун-та. 1960. Т. 120, кн.3; Основы физиологии человека и животных: Учеб. пособие. Ч. 1. Нервно-мышечная физиология. К., 1964.

**ВӘЛИ́ДОВ** Марс Әшрәф улы (28.4.1927, Чаллы ш. — 5.10.2004, Казан), физик-оптик, техник фән. канд. (1962), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1969), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1973). 1956 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1957–70 һәм 1978–98 дә «Гамәли оптика ин-ты» (Казан) фәнни-тикшеренү берләшмәсендә: лаб., бүлек җитәкчесе. 1970–78 дә «Казан оптика-механика заводы» җитештерү берләшмәсендә: 1974 кә кадәр баш инженер, 1974 тән директор. В. җитәкчелегендә заводта оптик квант генераторлары кулланып перископлар һәм приборлар җитештерү оештырыла. 1992–96 да «Сәйяр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять директоры. Хезмәтләре юка плёнкалар физикасына карый. Уйлап табуга караган 42 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге махсус оптика приборлары төзегәне өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Инфракрасные фильтры. Минск, 1972 (автордаш).

**ВӘЛИ́ДОВ** Юныс Нуриман улы (6.4.1889, Вятка губ., Алабуга өязе Балтач а. — 1925), ТАССРның беренче җир эшләре халык комиссары (1920–23). «Буби» мәдрәсәсен тәмамлагач, шунда ук география, табигать белеме һәм физика укыта. Бертуган Бубилар кулга алынганнан соң, 1911 елда Алабуга өязе Салагыш авылындагы рус-татар мәктәбенә күчә. Полициянең яшерен күзәтүе астында була. 1917 елгы Февраль рев-циясеннән соң — Алабуга өязе земство идарәсе әгъзасы, Окт. рев-циясеннән соң Эшче һәм солдат депутатлары советы башкарма ком-ты составына керә, бер үк вакытта Алабуга өязе мөселманнар эше комиссары. 1918 дән РКП(б) әгъзасы. Гражданнар сугышында катнаша. Адмирал А.В.Колчак гаскәрләре б-н сугыш вакытында Үзәк мөселман хәрби коллегиясе сәяси бүлеге пропагандисты һәм оештыручысы була. 13 нче армиянең сәясәт бүлегендә пропагандист һәм сәяси комиссар булып эшләү өчен 1919 да Көньяк фронтка чакыртыла. Авыруы аркасында коллегиягә мәгълүмат бүлеге башлыгы, аннары сәяси бүлек башлыгы ярдәмчесе сыйфатында кире кайта. Татарстан Респ-касын төзүдә актив катнаша, Вакытлы революцион ком-т әгъзасы була. Татарстан Респ-касының автономия хокукларын ныгытуны, аны башка төрки респ-каларга мөнәсәбәттә төп милли респ-ка итеп әверелдерүне яклый. Аның инициативасы б-н а.х. техникумында җир эшләре һәм урман эшләре буенча курслар ачыла, а.х. һәм урманчылык ф-ты оештырыла. Республикада авыл хуҗалыгын тамырдан үзгәртү, җирсез һәм аз җирле татар крәстияннәрен күчереп утырту, хезмәтне фән казанышлары нигезендә оештыру яклы була. 1921–22 дәге ачлык вакытында ачлык нәтиҗәләрен киметү максатында респ-када ачыгучыларга ярдәм итү буенча махсус фонд оештыра. М.Х.Солтангалиевне барлык вазифаларыннан алгач (1923 нең июне), В. ВКП(б) ҮКгә аны яклап «*Унбиш җитәкче хаты*» белән мөрәҗәгать итүчеләр арасында була, чөнки аның күп карашларына (Татарстанга союздаш респ-ка статусы бирү, Россия составында төрки халыклар федерациясе оештыру) теләктәшлек белдерә. 1923 нең ахырында халык комиссары вазифасыннан азат ителә. РКП(б) ҮКгә «*Утыз тугыз җитәкче хаты*»на кул куючылар арасында була. ВКП(б)ның Татарстан өлкә оешмасының 8 нче өлкә партия конференциясендә (1924 нең 20–23 марты) «Утыз тугыз төркеме» әгъзалары буржуаз милләтче-солтангалиевчеләр агентлары буларак гаепләнәләр. 18 апрельдә В. ВКП(б)дан чыгарыла. 1924 тә нигезсез гаепләнә, 1925 тә амнистияләнә, үлгәннән соң аклана.

*И.Р.Таһиров.*

**ВӘЛИ́ДОВА** (Вәлидия) Мәфтуха (1894–1925), шагыйрә. «Күңел бүләкләре» (1915) исемле шигъри җыентык авторы. Җыентыкка 32 шигырь урнаштырылган, шигырьләрнең төп темасы — татар хатын-кызының гаиләдәге хокукый тигезсезлеге. В. гаилә бары мәхәббәт нигезендә генә төзелергә тиеш дип саный. Шагыйрә табигатькә дан җырлый, кешеләрдә ихласлык, киң күңеллелек сыйфатларын мактый, бер үк вакытта тормышта бу сыйфатларның сирәк очравына, яшәештә гармония юклыкка күңел сызлануларын тасвирлый.

Ә с ә р.: Гамь // Мирас. 1998. № 4.

*Әд.:* Б у р н а ш е в а З. Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан. К., 1971; Мәфтуха Вәлидия (1894–1925) // Өмет йолдызлары. К., 1988.

*З.З.Рәмиев.*



Ә.Ә. Вәлиди.

**ВӘЛИДИ́** (Вәлидов) Әхмәтзәки Әхмәтша улы (эмиграциядә: Әхмәдзәки Вәлиди Тоган) (10.12.1890, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Көзән а. — 26.7.1970, Истанбул), сәясәт эшлеклесе, шәркыятьче-тюрколог, тарихчы, публицист, филос. д-ры (1935), Манчестер ун-тының (Англия) шәрәфле д-ры (1957). Башта әнисенең бертуганы мәдрәсәсендә (Үтәк а.), аннары Казанда «Касыймия»дә (1908–12) белем ала. «Касыймия» мәдрәсәсендә төрки халыклар тарихын һәм гарәп, төрки әдәбиятларын укытырга калдырыла. Бер үк вакытта 1911–12 елларда, ирекле тыңлаучы буларак, Казан ун-ты профессорлары Н.Ф.Катанов, В.А.Богородицкий дәресләренә йөри. Эмиграциядә вакытта Вена ун-тын тәмамлый. Казанда уку елларында В. иҗади эзләнүләрен башлап җибәрә, 1909–12 дә аның төркиләр тарихына багышланган берничә мәкаләсе дөнья күрә һәм «Төрек вә татар тарихы» китабы басылып чыга (1912). 1913 тә Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә әгъза итеп сайлана. 1913–14 тә Фирганә, Бохара шәһәрләренә оештырылган археографик экспедициядә катнаша, соңрак шунда табылган «Котадгу белек» (11 йөз) кулъязмасы тасвирламасын бәян итә. 1915 тән Уфада «Госмания» мәдрәсәсендә укыта. Шул елның ахырында 4 нче Дәүләт думасына сайланган мөселман депутатларына ярдәм итү бюросы оештырылгач, шул бюро эшчәнлегендә катнашу өчен Петроградка чакыртып алына. 1917 елгы Февр. рев-циясен шунда каршылый, Россия мөселманнарының Вакытлы Мәркәз (Үзәк) бюросына әгъза итеп сайлана. Россиядә унитар дәүләт төзүгә каршы чыгучыларның берсе. 1917 нең 28 мартында Петроградтан Ташкентка Төркестан төбәге мөселманнары б-н очрашу-аралашу өчен бара. Анда мөселманнарның «Шура-и ислам» корылтаен оештыруда һәм аның эшендә катнаша (Ташкент, 16–23 апр.). Шул җыелыш исеменнән *Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаена* делегат итеп сайлана. Май аенда Мәскәүдә уздырылган шушы корылтайда В. башкорт вәкилләре җитәкчесе була. Корылтайда башкорт делегатлары Башкортстан мохтариятын (автономиясен) төзү, башкорт гаскәри берәмлекләрен туплау һәм җир мәсьәләсен хәл итү таләпләре б-н чыгалар. Шул көннәрдән соң В. башкортларның милли азатлык хәрәкәте җитәкчесе буларак таныла. 1917 дә Уфада узачак Милләт Мәҗлесенә депутат итеп сайлана. Төп игътибарын Бөтенбашкорт корылтайларын оештыруга юнәлтә: 1917 нең 20–27 июлендә һәм 8–20 декабрьдә Оренбургта, 25–29 августта Уфада корылтайлар уздыра. Башкорт федералистларының оештыру җыелышы әгъзасы. Ш.Манатов б-н берлектә Башкорт Шурасын оештыра. Үзәктә Окт. рев-циясе игълан ителгәннән соң, ноябрь урталарында Оренбургта Башкорт автономиясе төзелә, аның рәсми рәисе итеп Ю.Бикбов, хәрби һәм эчке эшләр җитәкчесе итеп В. билгеләнә; 1917–19 да мөстәкыйльлеккә омтылган бу мохтариятның фактик җитәкчесе В. була. Башкорт гаскәри берәмлекләре оештырыла, алар баштарак атаман А.И.Дутов, аннары адмирал А.В.Колчак армияләре составында совет гаскәрләренә каршы көрәшәләр.

1919 ел башында В. Совет хөкүмәте б-н сөйләшүләр алып бара. РСФСР җитәкчеләре Башкорт Автономияле Респ-касын төзү шартына килешкәч, 1919 ның февралендә В. Советлар ягына чыга. 1919 ның февраленнән 1920 нең июнь урталарына кадәр Башревком рәисе, РКП(б) әгъзасы була (өзеклекләр б-н). Үзәк хакимиятнең Башкорт Респ-касының элек килешенгән вәкаләтләрен чикләү сәясәте б-н риза булмаган башкорт хөкүмәте фетнәсеннән соң В. Төркестанга китә. Урта Азия халыкларының Совет хакимиятенә каршы алып барган көрәшендә катнаша. 1921 дән «Төркестанлылар милли берлеге» рәисе. РСФСР составында төрки халыкларның киң хокуклы милли автономияләрен төзү кирәклеге турында Совет хакимияте җитәкчеләренә берничә хат юллый (РКП(б) ҮК, В.И.Ленин һ.б. исеменә). 1923 тән эмиграциядә, анда, нигездә, укыту һәм гыйльми эш б-н генә шөгыльләнә. 1923 нең мартында Иранның Мәшһәд шәһәрендәге Рауза китапханәсендә борынгы кулъязмалар, ш.и. *Ибне Фазланның* сәяхәтнамәсе нөсхәсен таба һәм аларны тикшерә. 1925–27 елларда Төркия Респ-касы Мәгариф министрлыгында эшли (Әнкара). 1927–32, 1939–44, 1948–70 елларда Истанбул ун-ты укытучысы, профессоры. 1935–37 елларда Германиянең Бонн һәм 1938–39 да Гёттинген ун-тлары профессоры. 1944 елда, Төркиядә СССРга каршы төркичелек эшчәнлеге алып баруда гаепләнеп, Төркия хакимияте тарафыннан кулга алына, 10 елга хөкем ителә. 1,5 ел үткәч төрмәдән чыгарыла һәм аклана. 1948 дән генә укыту эшчәнлеген дәвам иттерү мөмкинлеге тудырыла. 1953 елдан Истанбул ун-ты каршында ачылган Ислам тикшеренү ин-ты җитәкчесе. Хезмәтләре, башлыча, төрки халыклар тарихына һәм мәдәниятенә карый. Истәлекләр авторы. Иран мәгариф җәмгыятенең 1 нче дәрәҗәле әгъзасы (1951), Австриянең Хаммер-Пургшталь исемендәге җәмгыяте әгъзасы.

Х е з м.: Кыскача төрек-татар тарихы. К., 1912; Воспоминания. М., 1997; 2 нче басма. К., 1917; 3 нче басма. К., 1992; On yedi kumalti sehri ve Sadri Maksudi Bey. Ist., 1934; Ibn Fadlan's Reisebericht. Leipzig, 1939; Türk Tarihine Methal. Ist., 1941; Tarihte usul. Ist., 1941; Umumi Türk tarihine giriş. Ist., 1946; Bugünkü Türkili (Türkistan) ve Jakin Tarihi. Ist., 1942–47; Hatiralar. Ist., 1969; Türklügün mukadderati uzerine. Ist., 1970; 2 нче басма. Ist., 1977; Kur'an ve Türkler. Ist., 1971; Oguz Destani: Resideddin Oguznamesi. Ist., 1972.

*Әд.:* Ахмед Заки Валиди Тоган (1890–1990): Материалы к изучению жизни и творчества. Уфа, 1990; Ахмедзаки Валиди Тоган (учёный, политик, личность) // Судьба и наследие башкирских учёных-эмигрантов. Уфа, 1995; Б а й к а р а Т у н д ж е р. Заки Валиди Тоган. Уфа. 1998; J a n s k y H. Ahmet Zeki Velidi Togan. Dogum Jili Munasebetiyle Zeki Velidi Togan Armagan. Ist., 1950–55; B e r g d o l d t F. Der geistige Hintergrund der turkischen Historikers Ahmed Zeki Velidi Togan (nach seinen Memorien). Berlin, 1981.

*И.Р.Таһиров.*

**ВӘЛИ́ДИ** Җамал (Җамалетдин) Җәләлетдин улы (13. 10.1887, Казан губ., Тәтеш өязе Апас а. — 30.11.1932), тел һәм әдәбият галиме, педагог, тарихчы, публицист, җәмәгать эшлеклесе. «Буби» мәдрәсәсендә белем ала.



Җ.Җ. Вәлиди.



А.Х. Вәлиев.



А.Ә. Вәлиев.

1911–18 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург ш.) укыта. 1918 дән Казанда: 1919–23 тә мәктәпләрдә, Татар рабфагында, укытучылар әзерләү курсларында, Шәрекъ академиясендә укыта, бер үк вакытта Җир эшләре комис-тында эшли, татар теле терминнарын эшләү комиссиясен җитәкли. 1923–31 дә Шәрекъ пед. ин-тында. Хезмәтләрендә иҗтимагый һәм милли үсеш мәсьәләләрен күтәрә, татар җәмгыятендә көнбатыш цивилизация казанышларын куллану юлларын өйрәнә, мөселман мәгарифе реформасын яклап чыга, татар әдәбияты үсешенең төп юнәлешләрен анализлый. «Татарларның укымышлылыгы һәм әдәбияты тарихыннан очерклар» («Очерки истории образованности и литературы татар». М., 1923) китабында борынгы заманнан 1917 гә кадәрге чорда татар иҗтимагый фикере үсешенең төп баскычларын тасвирлый, 19–20 йөз татар фәне һәм мәдәнияте вәкилләренең эшчәнлегенә бәя бирә. Татар тел белеменә караган хезмәтләр авторы. «Татар теленең грамматикасы» (1919) монографиясендә синтаксик категорияләрнең терминологиясен һәм системасын камилләштерә. В. нең татар теле диалектларына, башлыча, Нократ, Глазов, Карин татарлары диалектларына багышланган хезмәтләрендә татар диалектологиясенә нигез салына. «Татар теленең тулы сүзлеге»н төзи һәм басмага әзерли (1927–29; басма тәмамланмый). Әлеге хезмәттә хәзерге тюркология өчен дә әһәмиятен югалтмаган лексикографик принципларны беренче тапкыр куллана. Г.Тукай, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Ш.Камал һ.б. иҗаты турында әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы.

1931 дә репрессияләнә, Беломорканал төзелешендә вафат була; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Татар әдәбияты барышы. Оренбург, 1912; Милләт вә миллият. Оренбург, 1914; Шәрекътән Гаребкә // Аң. 1916. № 2–3; Татар теленең кагыйдәләре. К., 1918; Татар телен эшләү мәсьәләсе // Безнең юл. 1924. № 4; Очерки истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.) М.-П., 1923; О диалектах казанского татарского языка. К., 1927; Наречия каринских и глазовских татар // Тр. Об-ва изучения Татарстана. 1930. Т. 1.

*Әд.:* М ө х ә м м ә д и е в Р. Югалмас мирас эзеннән // Казан утлары. 1977. № 9; М у х а м а д и е в М.Г. Лингвистическое наследие Джамала Валиди // Татарская лексика в семантико-грамматическом аспекте. К., 1988; К а м а л о в Т. Джамал Валиди // Исторические портреты. К., 2000; Татарские интеллектуалы: исторические портреты. К., 2005.

*В.Х.Хаков.*

**ВӘЛИ́ЕВ** посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәчкәрә елгасының югары агымы буенда. 2002 елда 15 кеше (татарлар) яши. 1840 елларда нигез салына. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Каратай волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1897 дә — 56, 1920 дә — 94, 1926 да — 115, 1949 да — 108, 1958 дә — 150, 1970 тә — 121, 1979 да — 69, 1989 да — 25 кеше.

**ВӘЛИ́ЕВ** Абдулла Хәбибулла улы (1922, хәзерге Башкортстан Респ-касының Кушнаренко р-ны Бакай а. — 4.1.1944), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), рядовой. 1941 елда Кызыл Армиягә алынганчы колхозда эшли. 1942 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1031 нче укчы полк укчысы (60 нчы армиянең 280 нче укчы дивизиясе). Воронеж, Үзәк һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Харьков операциясендә (1943), Курск сугышында (1943), Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 25 сентябрендә Днепрны кичкәндә һәм сул ярда плацдарм яулау өчен барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә. Туганицы авылы янындагы (Ленинград өлкәсе Гатчина р-ны) сугышта һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. К., 1990; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1965. Кн. 1; Шел парнишке в ту пору... Киев, 1985.

**ВӘЛИ́ЕВ** Асаф Әсхәт улы (26.6.1959, Актаныш р-ны Адай а.), җырчы (баритон), ТРның халык артисты (2000). Казан пед. ин-тының музыка ф-тын (1980), Казан консерваториясенең вокал ф-тын (1986; педагоглар: И.Ишбүләкев, Э.Трескин, С.Җиһанова) тәмамлый. 1983–86 елларда Казан шәһәр киночелтәре оркестрында солист. 1986–94 тә Татар филармониясенең эстрада бүлеге солисты. 1994 тән «Асаф» җыр театры сәнгать җитәкчесе һәм солисты (Казан). Татар халык һәм эстрада җырларын популяр башкаручы. Радио, телевидениедән чыгышлар ясый, Россия, Финляндия, Төркия һ.б. илләрдә гастрольләрдә була. «Татар җыры-88» халыкара фестиваль-конкурсы лауреаты (1 нче бүләк).

*Ф.Ш.Салитова.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Әгъзам Җиһанша улы (10.4.1919, Казан губ., Чистай өязе Каргалы а. — 1986, Архангельск ш.), Сов. Союзы Герое (15.5.1946), полковник (1971). 1938 елда Кызыл Армиягә алынганчы Ташкенттагы заводта слесарь булып эшли. Оренбург хәрби авиация очучылары уч-щесен (1940), Югары офицерлар очу-тактика мәктәбен (1945), Хәрби-һава академиясен (1952) тәмамлый. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтла-

рында, 179 нчы истребительләр авиаполкының эскадрилья командиры (5 нче һава армиясе, 5 нче штурмлаучы авиация корпусы, 331 нче истребительләр авиация дивизиясе). Төньяк Кавказ, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Кавказ өчен барган сугышларда (1942–43), Харьков операциясендә (1943), Украина, Румыния, Молдавия, Венгрия, Австрия, Чехословакияне азат итүдә катнаша. 501 сугышчан очыш ясый, 25 һава сугышында катнашып, дошманның 7 самолётын бәреп төшерә. Сугыштан соң Хәрби Һава Көчләрендә югары командирлык вазифаларын башкара. 1971 дән отставкада, Архангельск шәһәрендә яши. Ленин, өч Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Д ж у р а е в Т.Д. Верные сыны Родины. Таш., 1964; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Б е р е з н я к Н.Г. Герои Советского Союза — узбекистанцы. Таш., 1984.

*В.А.Шагалов.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Әкрам Искәндәр улы (17.4.1924, Бөгелмә кантоны Илбәк а. — 10.8.1975, Азнакай р-ны Илбәк а.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), лейтенант (1946). 1941 елда Кызыл Армиягә алынганчы Бурят-Монгол АССР приискында клуб мөдире булып эшли. 1942 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 341 нче укчы полкта отделение командиры (10 нчы гв. армиянең 119 нчы гв. укчы дивизиясе). Көнбатыш, 2 нче Балтыйк буе һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре составында Смоленск операциясендә (1943), Ленинград блокадасын өзүдә, Балтыйк буен азат итүдә катнаша. 1944 нең 4 августында Айвиексте елгасын (Латвия ССР) кичкәндә батырлык күрсәтә. 1946 дан туган авылында колхозда эшли. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

**ВӘЛИ́ЕВ** Әлфир Ярулла улы (6.6.1947, Апас р-ны Зур Күккүз а. — 22.6.2000, Апас р-ны Дәүләки а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1983). 1972 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1967–74 тә Апас р-нының Горбунов исем. к-зында баш агроном, 1976–99 да рәис булып эшли. В. җитәкләгән колхоз игенчелек һәм терлекчелек өлкәсендә югары күрсәткечләргә ирешә. Бөртекләрнең уңышы 1 *га* дан 40 *ц* га, 1 сыердан савым — 4000 *кг* га, сөт җитештерү 100 *га* а.х. җирләренә 400 *ц* га җитә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ВӘЛИ́ЕВ** Габделәхәт Габделгани улы (Леонид Геонаевич), (март 1910, Казан губ., Чистай өязе Яуширмә а. — 18.4.1944, Кырым АССРның Бельбек а.), Сов. Союзы Герое (16.5.1944, вафатыннан соң), өлкән сержант (1944). Пермь шәһәре трамвай депосы эшчесе, Ленинградта йөкче булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 91 нче гв. укчы полкында отделение командиры (51 нче армиянең 33 нче гв. укчы дивизиясе). Көньяк, Кавказ арты, Кавказ, Сталинград һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Ростов (1941), Донбасс (1941), Керчь-Феодосиядә десант (1941–42), Мелитополь (1943) һәм Кырым (1944) операцияләрендә катнаша. 1944 нең 16–18 апрелендә Бельбек елгасының сул ярында (Кырым АССР) дошман оборонасын өзү сугышларында батырлык күрсәтә, атака вакытында һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои боев за Крым. Симферополь, 1972; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*



Ә.Җ. Вәлиев.



Ә.И. Вәлиев.



Г.Г. Вәлиев.

**ВӘЛИ́ЕВ** Габделфәрт Габдрахман улы (17.11.1930, хәзерге Балтач р-ны Балтач а. — 15.3.2008, Казан; Балтачта җирләнә), химик-технолог, техник фән. д-ры (1980), проф. (1982), Россия Ракета-артиллерия ФА академигы (1994), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1980), РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1988). 1953 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый. 1953–68 дә Дәүләт союз КБнда (Мәскәү өлкәсе Красноармейск ш.) производство бүлеге һәм төркем җитәкчесе. 1968 дән Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. башлыгы, директор урынбасары (1969 дан), баш фәнни хезмәткәр (1990 нан). Хезмәтләре шартлаткыч матдәләргә, эчке баллистика өлкәсенә карый. Конденсатланган системалар ныклыгының флоктуацион теориясен үстерә, шуның б-н актив реактив системаларда марш зарядының көчәнешен рөхсәт ителгәннән арттыру мөмкинлеге туа. Артиллерия ату зарядларының яңу критерийларын билгели, аларны проектлаштыру һәм эшләүне камилләштерә. Руда булмаган материалларны (гипс, вак таш һ.б.) табу өчен югары нәтиҗәле экологик чиста сәнәгый шартлаткыч матдәләр эшли. Махсус билгеләнешле техника буенча 456 хезмәт авторы (ш.и. уйлап табуга 222 авторлык таныклыгы бар). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1976). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ — КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ВӘЛИ́ЕВ** Гадел Салих улы (6.8.1933, Казан), микроэлектроника гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1986), проф. (1987). 1956 елда Казан ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң, Казандагы «Теплоконтроль» з-дында эшли. 1957 дән Казандагы 379 нчы п/я пр-тиесендә (хәзер Дәүләт гамәли оптика ин-тының Федераль фәнни-җитештерү үзәге) сектор башлыгы. 1964 тән Мәскәүдә — Молекуляр электроника фәнни-җитештерү ин-тында: бүлек башлыгы, баш фәнни хезмәткәр (1988 дән). Бер үк вакытта Мәскәү электрон техникасы ин-ты профессоры (1987 дән). Хезмәтләре гамәли оптикага һәм микроэлектроника технологиясенә карый. Күп катламлы интерференцион, кисүче һәм буйлы яктылык фильтрларын, кремнийлы интеграль микросхемаларның күп кимәлле элементара тоташмаларын әзерләү технологиясен эшли. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы бар. Таҗикстан ССРның Әбүгалисина исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1987).

Х е з м.: Планаризация многоуровневой металлизации СБИС // Электронная промышленность. 1994. № 6 (автордаш); Тонкие плёнки: применение, физическая сущность и классификация методов их формирования. М., 2000. Т. 3.


**ВӘЛИ́ЕВ** Данис Һади улы (14.4.1952, Апас р-ны Татар Пүчинкәсе а.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1991), РФнең атказ. конструкторы (1993). 1974 елда Мәскәү автомобиль юллары ин-тын тәмамлаганнан соң, «КамАЗ» АҖдә эшли: инженер-конструктор, идарә җитәкчесе һәм двигательләр проектлаштыру буенча баш конструктор (1988–95), заводның баш конструкторы (1995 тән); бер үк вакытта 1996 дан «КамАЗ» АҖнең Фәнни-тикшеренү һәм техник үсеш департаменты директорының 1 нче урынбасары, 1998 дән «КамАЗ» АҖнең Фәнни-техник үзәге директоры. В. катнашында конструкторлык эшләре башкарыла һәм 70 тән артык, ш.и. 10 база дизель двигательләренең модельләрен һәм модификацияләрен җитештерү үзләштерелә, йөк күтәрүчәнлеге яхшыртылган автомобильләр төркеме эшләнә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы, 2 патенты бар. Дәүләт бүләге транспорт машиналары төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә.

*Әд.:* Х ә с ә н о в О.В. Йөрәктә ут чаткысы // Нур. 1995, 18 май; Валеев Данис Хадиевич: биогр. справка // Вести КамАЗа. 1995. 2 марта; Б а р у н В.Н. Ступени. Записки главного конструктора. Наб.Челны, 1997. Кн. 1.

**ВӘЛИ́ЕВ** Диас Назыйх улы (1.7.1938, Арча р-ны Казанбаш а.), язучы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1981, 1983). Рус телендә яза. Казан ун-тының геол. ф-тын (1962), М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (1975, Мәскәү) тәмамлый. Геолог буларак Удмуртия, Киров өлкәсе, Көньяк Урал, Кемерово өлкәсендә эшли. 1966–72 елларда «Комсомолец Татарии» г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр. Беренче фәлсәфи-лирик хикәяләре 1959 да «Молодая гвардия», «Смена»,



Д.Н.Вәлиев.



К.Ә. Вәлиев.

«Сельская молодёжь» ж-лларында басыла. В.нең таланты бигрәк тә драматургия өлкәсендә ачыла. «Намус хөкеме» («Суд совести», икенче исеме «Охота к умножению», 1971) дип аталган беренче драмасы интеллигенция һәм хакимият арасындагы мөнәсәбәтләрнең җитди әхлакый-этик проблемаларын күтәрә. «Тормыш бүләк итәм» («Дарю тебе жизнь», 1972, ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1976) исемле фаҗигале хроникасы аеруча зур уңыш казана. Пьеса Казан Зур драма театрында, М.Н.Ермолова исем. Мәскәү драма театрында һәм тагын илнең 50 дән артык театрында уйнала. «Диалоглар» («Диалоги», 1976), «Казан Елга аръягы пәйгамбәре» («Пророк из казанского Заречья», 1977), «Казан университеты» («Казанский университет», икенче исеме «1887», 1979), «Кеше эзлим» («Ищу человека», 1985) һ.б. пьесалары Казан, Мәскәү, Ташкент, Минск һ.б. шәһәрләрнең профессиональ сәхнәләрендә уңыш б-н бара. Аерым пьесалары, татар телендә басылудан һәм куелудан тыш, белорус, украин, чех, болгар, әзәрбайҗан һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. В. 1973, 1979, 1981 елларда өч мәртәбә Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз милли драматургия конкурсларында лауреат исемен ала («Пәйгамбәр һәм шайтан» — «Пророк и чёрт», 2005, пьесалар җыентыгы). Проза әсәрләрендә В. фәлсәфи мәсьәләләргә зур игътибар бирә. «Картлар, ир-атлар, малайлар» («Старики, мужчины, мальчишки», 1975), «Әйләнә дөнья, әйләнә» («По вечному кругу», 1981), «Таш кискече тавышы» («Стук резца по камню», 1988), «Дон Жуан портреты» («Портрет Дон Жуана», 2003) китапларында автор тормышның фәлсәфи нигезләренә, әхлак мәсьәләләренә, кеше тормышының мәгънәсе проблемаларына аеруча зур игътибар бирә. «Астраль мәхәббәт» («Астральная любовь», 1999) романында реаль, романтик һәм мистик планнар тыгыз үрелеп бара. «Тәңрегә ышану» («Уверенность в Невидимом», т. 1–2, 2002) китабына кергән «Бер кеше хакыйкате, яки Өстеналлага таба юл» («Истина одного человека, или Путь к Сверхбогу», 1993) әсәрендә, «Өченче кеше, яки Фәрештә» («Третий человек, или Небожитель», 1994) дигән роман-эсседә, «Барлыгы һәм берлеге турында уйланулар» («Мысли о Едином») дигән язмаларында автор фәлсәфи яктан яңа дин, Өстеналла дине концепциясен тудыра. В. фикеренчә, төп дөньяви диннәр әкренләп саегып, бетүгә йөз тоталар, һәм алар урынына яңа, барлык расалар һәм милләтләр кешеләрен берләштергән бөтендөнья дине килергә тиеш. Соңгы елларда язылган «Дон Жуан портреты» («Портрет Дон Жуана», 2003), «Чит кеше» («Чужой», 2007) проза әсәрләренә дә фәлсәфи киеренкелек хас.

*Әд.:* Галеев Б. Неверующий Диас // Литературное обозрение. 1989. № 4; Миндубаев Ж. Один под огнём // Литературная газета. 1991. 11 дек.; Диас Валеев — анализ творчества. К., 1996.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Ибраһим (1902, Казан губ., Лаеш өязе Оет а.), корыч кайнатучы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1943). 1933–45 елларда Екатеринбург шәһәрендәге «Уралмаш» з-дында эшли. Бөек Ватан сугышы елларында хезмәт җитештерүчәнлеген гадәттән тыш арттыруга — домна миче төбенең 1 $м^2$ нан 15–17 *т* корыч агызып алуга ирешә. 1945 тән К.Е. Ворошилов исем. Машиналар төзү з-дында (Омск ш.). Дәүләт бүләге сыйфатлы корыч эреткәндә югары күрсәткечләргә ирешкән өчен бирелә.

*Әд.:* Металлургия Урала: Энцикл. Екатеринбург, 2001.

**ВӘЛИ́ЕВ** Илгиз Миргалим улы (1.6.1944, Алабуга р-ны Турай а.), физик, техн. фән. д-ры (2002), проф. (2005). ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе. 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казандагы төрле оешмаларда эшли. 2003 тән Казан энергетика ун-тында проф., электр станцияләре каф. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре электрофизик процессларны өйрәнүгә карый. Беренче булып композицион электрохимик капламалар ясау өчен электр тогы чыганакларын уйлап таба һәм эшли (1986). Тикшеренү нәтиҗәләре медицина, химия һәм машиналар төзү сәнәгатьләрендә гамәлгә кертелгән.

Хезм.: Модификация ультразвукового аппарата. М., 1976; Источник питания периодического тока с обратным импульсом для гальванических ванн // Вестн. машиностроения. 1981. № 5; Электротехнология высоких напряжений. К., 2004.

*Р.Г.Усманов.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Елгизәр (Илгизәр) Касыйм улы (19.06.1944, Яшел Үзән ш), нейрохирург, мед. фән. д-ры (1989), ТРның атказ. табибе (1994). 1966 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, ТР ФАнең «Травматология һәм ортопедия» фәнни-тикшеренү үзәгендә эшли, 1975–87 дә нейрохирургия бүлеге мөдире, 1988 елдан фәнни эшләр буенча директор урынбасары, бер үк вакытта ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм 1980 нән Казан шәһәренең баш нейрохирургы, 1998 дән Казан мед. академиясенең травматология, ортопедия һәм нейрохирургия каф. профессоры. Тикшеренүләре баш сөяге һәм минең каты имгәнүләр патогенезы һәм дәвалау проблемаларына карый. 1988 дә ТРда беренче булып сынган умырткалыкны һәм умыртка авыруын дәвалау өчен Илизаров аппаратын гамәлгә кертә.

Хезм.: Рентгенодиагностика последствий закрытой черепно-мозговой травмы. К., 1985 (автордаш); Хирургическая коррекция травматических деформаций позвоночника с учётом его анатомо-биохимических особенностей // Повреждения и заболевания позвоночника и суставов. Минск, 1998.

**ВӘЛИ́ЕВ** Инсур Габделхак улы (26.5.1949, Арча р-ны Мәмсә а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), ТАССРның атказ. механизаторы (1985), ТР һәм РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1993, 1995). 1982 елда Казан а. х. ин-тын тәмамлый. 1969–89 елларда Арча р-нының К.Якуб исем. к-зында механизатор, бригадир, баш инженер, 1989 дан «Ашытбаш» күмәк пр-тиесе рәисе. 1997 дән Арча, 1999 дан Питрәч р-нларының а.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, 2004 тән «Ясная Поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять директоры. Дәүләт бүләге фән һәм техника казанышларын гамәлгә кертү нәтиҗәсендә бөртеклеләрдән югары уңыш алуга ирешкәне өчен бирелә.

**ВӘЛИ́ЕВ** Искәндәр Габдрахман улы (24.12.1911, хәзерге Ульянов өлкәсенең Мәләкәс р-ны Мулловка штп — 13.6.2001, Казан), беренче татар профессиональ архитекторлары вәкиле, төзелеш инженеры, РСФСРның атказ. төзүчесе (1979). 1932 елда Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлый. 1933–34, 1936–39 да Казанда Оборона сәнәгате министрлыгы карамагындагы 12 нче төзелеш трестында архитектор, проектлау конторасы җитәкчесе; 1934–35, 1939–40 та Кызыл Армия сафларында, 1941–44 тә С.П.Горбунов исем. Казан авиация з-ды архитекторы. 1944–59 да ТАССР МС ның Төзелеш һәм архит-ра эшләре идарәсе башлыгы. 1959–75 тә КПСС ның Татарстан өлкә ком-тында төзелеш бүлеге мөдире, 1975–83 тә шунда ук мөдир урынбасары. В. проектлары б-н Казан вет. ин-тының уку биналары, клиникалары, тулай тораклары комплексы (1938–39), Яшел Үзән шәһәрендә тулай тораклар (1949–50), Казанда «Татэнерго» бинасы (1950), шәһәр үзәгендәге торак йортлар (1950–52), Дәрвишләр бистәсендә мәдәният сарае (1955) һ.б. төзелә. В. иҗатына хас сыйфат — корылмаларның бизәлешенә милли үзенчәлек кертү. В. фасадларда классицизм архит-расы һәм татар халкының гамәли бизәлеш сәнгате традици-

И.Г. Вәлиев. 1. Торак йорт. Казан, 1955; 2. Дәрвишләр бистәсендәге мәдәният сарае. Казан, 1957.





ясләрен оста файдалана. Аның җитәкчелегендә Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләренең, Җәлил эшчеләр бистәсенең яңа районнары ген. планы төзелә. В. — совет неоклассицизмы вәкиле. СССР Архитекторлар берлеге әгъзасы (1936), 1941–44 тә аның Татарстан оешмасы рәисе. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Т.Р.Закирова.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Камил Әхмәт улы (15.1.1931, Тәкәнеш р-ны Югары Шүләңгер а.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1964), РФА академигы (1991; 1972 дән СССР ФА мөхбир әгъзасы, 1984 тән академигы), ТР ФА академигы (1992), Казан ун-тының шәрәфле д-ры (2006). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлый. С.А.*Альтшулер* шәкерте. 1957–64 тә Казан пед. ин-тында, 1959 дан физика каф. мөдире. 1964 тән Мәскәүдә: 1965 кә кадәр Микроприборлар фәнни-тикшеренү ин-тының сектор җитәкчесе, 1965–77 дә Молекуляр электроника фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, проф. (1966), 1977–78 дә СССР ФА Космик тикшеренүләр ин-тының сектор мөдире, 1978 дән СССР ФАнең Физика ин-тында тирбәнешләр лаб. секторы мөдире, 1983 тән СССР ФАнең Гомуми физика ин-ты директоры урынбасары, 1988 дән РФАнең Физ.-техника ин-ты директоры. Бер үк вакытта 1991 дән РФАнең Информатика, хисаплау техникасы һәм автоматлаштыру бүлеге академик-секретаре урынбасары. Хисаплау техникасы һәм идарә итү системаларының фундаменталь проблемалары буенча фәнни үзәк президиумы рәисе (1989 дан), РФ бүләкләре бирү советының секция рәисе (1995 тән).

Төп хезмәтләре микроэлектрониканың физ.-технол. проблемаларына, каты җисем һәм сыеклык физикасына карый. Атомда булган электрон спины хисабына йотылу резонансының төш-спин кучешләрендә көчәйтелү эффектын фаразлый (1957), ул соңрак тәҗрибәдә табыла. Органик сыеклыкларда гы сферик булмаган молекулаларның борылмалы Броун хәрәкәтен һәм бу хәрәкәтнең сыеклыкларда йотылу спектрына тәэсир итүе (Альтшулер–Вәлиев механизмы) мәсьәләсен (С.А.Альтшулер б-н берлектә, 1958) чишә. 1968–77 дә хисаплау техникасын (өченче буын) һәм оборона системаларын (үтә югары нәтиҗәле Эльбрус-1, Эльбрус-2, Эльбрус-БЭСМ-12 хисаплау комплексларын, ЭВМ СМ системасын һ.б.) туплау өчен кремнийлы интеграль схемаларны сәнәгый җитештерү һәм оештыру б-н җитәкчелек итә. В. инициативасы б-н СССРда беренче мәртәбә 1978 дән микроэлектроникада кристалларны электрон нурланышы, рентген литографиясе һәм ион плазмасы нигезендә микротөзүнең субмикрон технологиясен эшләү буенча тикшеренү эшләре башлап җибәрелә. 1990 еллар ахырыннан эшче элементлары аерым атом төшләре булган квантлы компьютерлар физикасына караган тикшеренүләр алып бара. «Микроэлектроника» ж-лының баш мөхәррире (Мәскәү, 1987 дән). Ленин (1974), Әзәрбайҗан Дәүләт (1972), Е.К. Завойский исем. Халыкара (1997), РФ Хөкүмәте (2000), РФАнең акад. С.А.Лебедев исем. премияләре (2000) лауреаты. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, 3 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Микроэлектроника: достижения и пути развития. М., 1986; Физика субмикронной литографии. М., 1990; Квантовые компьютеры: надежды и реальность. М., 2004 (автордаш); Квантовые компьютеры и квантовые вычисления // Успехи физ. наук. 2005, вып. 1.

*Әд.:* Микрон. НИИ Микроэлектроника. 35 лет. События, люди: Сб. воспоминаний и очерков. М., 1999. *Р.Г.Усманов.*


**ВӘЛИ́ЕВ** Камил Шакир улы (20.9.1942, Башкортстан АССРның Туймазы р-ны Түбән Сәрдек а.), драма актёры, режиссёр, ТАССРның халык, РСФСРның атказ. артисты (1979, 1984). Хезмәт эшчәнлеген 1957 елда Төньяк Казакъстанда геол. разведка экспедициясендә башлый. 1963 тә Минзәлә татар драма театры труппасына кабул ителә, 1964 тә Әлмәт татар драма театры каршындагы Г.Йосыпов студиясенә укырга керә, аны тәмамлаганнан соң, шул театрда актёр, соңыннан режиссёр булып эшли, 1995–2005 елларда баш режиссёр. Күркәм тышкы сыйфатлары, тумыштан бирелгән зыялылыгы сәхнәдә фикерли, рольне төрле яклап ача белүе актёрга психол. яктан ышандырырлык, тормышчан, төрле характердагы күп образлар тудырырга мөмкинлек бирә. Иҗатының башлангыч чорында яшь геройлар рольләрен башкара: (Козы Көрпеш — «Козы Көрпеш һәм Баян Сылу», Г.Мөсрәпов; Акъегет — «Ай тотылган төндә», М.Кәрим; Гафур — «Бай һәм батрак», Х.Хәмзә), соңрак характерлы һәм социаль рольләргә алына, чикләнмәгән хакимият иясе Президентмы ул («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), сүзгә саран Юныс картмы («Шәмсекамәр», М.Әблиев), яки кешелеген югалткан Мирзанурмы («Ай булмаса, йолдыз бар», Т.Миңнуллин) — һәр геройның асылын, катлаулы эчке дөньясын тирәннән чагылдыру өчен аның төгәл тышкы сурәтен, аңа хас детальләрне, кул хәрәкәтләрен, интонациясен таба. Ул башкарган рольләр арасында — кавалер Рипафратта («Трактирщица», К.Гольдони), Шәкүр («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Креон («Антигона», Ж.Ануй), Әсфан («Әгәр бик сагынсаң», А.Гыйләҗев), Сафиулла (шул исемдәге пьеса, А.Гыйләҗев) образлары бар. 1993 тә Әлмәт театры сәхнәсендә В.нең режиссёр буларак беренче спектакле («Акбай белән сарык», Т.Миңнуллин) куела. Аннан соңгы елларда И.Абдуллинның «Айсылуның айлы кичләре», Ф.Яруллинның «Көйсез кызлар», З.Хәкимнең «Хыянәтче», Д.Салиховның «Саңгырау» әсәрләрен сәхнәләштерә.

*Әд.:* Р ә х и м о в Җ. Әлмәт татар дәүләт драма театрына 50 ел. Әлмәт, 1994; Народные артисты. К., 1980. *И.И.Илялова.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Корбан Агап улы (16.12.1906, Казан губ., Чистай өязе Иске Чаллы а. — 26.6.1980, Әлмәт ш.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1959). 1925 елдан Әзәрбайҗан нефть сәнәгате пр-тиеләрендә эшли. 1950 дән «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең «Әлмәтнефть» нефть промыселы идарәсендә мастер, бригадир. Герой исеме нефть чыгару буенча алтынчы бишьеллык йөкләмәләрен үтәүдә ирешкән зур уңышлары өчен бирелә. 1953–62 дә ТАССР ЮС, 1962–66 да РСФСР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәрендәге бер урамга В. исеме бирелә.



К.Ш. Вәлиев.



К.А. Вәлиев.

*Әд.:* Н а з и п о в а К. Валиев Курбан Агапович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ВӘЛИ́ЕВ** Леонид Геонаевич, к. *Вәлиев Габделәхәт Габделгани улы.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Мансур Хәҗи улы (1.1.1948, Әгерҗе р-ны Барҗы а.), язучы, әдәби тәнкыйтьче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1975–81 елларда «Идел» альманахы мөхәррире, 1981 дән «Казан утлары» ж-лында әдәби тәнкыйть бүлеге мөхәррире. Хәзерге әдәби процессны бәяләүгә, анализлауга багышланган тәнкыйть мәкаләләре тупланган «Яшьләр мәйданга чыга» (1978), «Табарга һәм югалтмаска» (1982), «Каһарманнар кирәк!» (1990), «Гасыр ахырында» (1993), «Тукайлар рухы» (1998), «Тормыш дулкыннары» (2005) китаплары авторы. «Үзгәң өзелгәндә» (1987), «Качу» (1993), «Мәхәббәт маҗаралары» (1997–99), «Идел яры» (2007) повестьларында бүгенге көннең рухи-әхлакый проблемаларын күтәрә.

*Әд.:* Е н и к и Ә. М.Вәлиев // Казан утлары. 1978. № 3; М а н н а п о в С. Ачкыч эзләдем // Тамыр тирәнлеген яфрак тоя. К., 1988; Г а м б ә р Н. Аккош күлендә утлар // Казан утлары. 1988. № 1.

**ВӘЛИ́ЕВ** Морзаһит Фәтхи улы (1.6.1922, хәзерге Самара өлкәсенең Похвистневск р-ны Яңа Мансур а. — 3.1.1993, Казан), партия эшлеклесе, тарих фән. канд. (1961). Казан пед. ин-тын (1952), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1961) тәмамлый. 1941–47 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1947–48 дә Ютазы р-нының «Коммунизмга» г-тасы җаваплы секретаре, 1949–51 дә ВКП(б)ның Ютазы райкомында пропагандист, сәяси мәгариф бүлеге мөдире. 1951–52 дә «Советская Татария» г-тасы хәбәрчесе. 1952–58 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында агитация бүлеге инструкторы, сектор мөдире, 1961–63 тә шунда ук лекторлар төркеме җитәкчесе. 1963–66 да Казан авиация ин-ты доценты. 1966–84 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1984–88 дә В.И.Ленин Үзәк музееның Ка-

зан ф-лы директоры. Хезмәтләре СССР халыкларының милләтара мөнәсәбәтләренә, ТАССРда мәдәният үсеше мәсьәләләренә карый. 1967–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Единой семьей к заветной цели. М., 1963; К вершинам науки. М., 1975.

**ВӘЛИ́ЕВ** Мөдәррис Харис улы (псевд. Салих Маннапов) (30.5.1953, Әлки р-ны Яңа Камка а.), әдәби тәнкыйтьче, шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989), филол. фән. канд. (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1976–79 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасында хәбәрче, бүлек мөдире. 1979–89 да «Казан утлары» ж-лында өлкән мөхәррир, җаваплы сәркәтип, баш мөхәррир урынбасары вазифаларын башкара. 1989–92 дә Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире, 1992 дән ТР «Мәгариф» милли китап нәшрияты директоры. «Сезгә ышанам» (1984), «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» (1988), «Йолдыз гомере» («Возвращение Звезды», 1992), «Гамәл дәфтәре» (2003) исемле әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыклары, татар китабын бастыру мәсьәләләренә багышланган «Китап» (2000) җыентыгы, «Яшьлектән хат» (1998) исемле шигырь китабы авторы. Чуаш язучысы М.Юхманың «Көнгыш — үлемсезлек кошы» («Кунгош — птица бессмертия», 1987), З.Фәтхетдиновның «Үлем элмәге» («Резидент — Чёрная вдова», 1991) романнарын татар теленә тәрҗемә итә.

Х е з м.: Нәшрият эше: Тарих. Теория. Гамәл. К., 2003; Китапчылык тарихы. К., 2005; Китап редакторы: Иҗади һәм оештыру эшчәнлеге. К., 2006.

*Әд.:* Н ә җ м и Н. Тирәнлекне тою // Кызыл таң. 1988. 15 дек.; Ф ә й з у л л и н Р. Кайту // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т. 4; М о с т а ф и н Р. Гомер агачы // Татарстан. 2004. № 4; Знаток книги и детской души // Книжное обозрение. 2002. 3 июль.

**ВӘЛИ́ЕВ** Мөсәлим Мөшәррәф улы (26.3.1888, Оренбург ш. — 2.1.1956, Уфа ш.), композитор, скрипкачы, дирижёр, музыка-җәмәгать эшлеклесе, Башкортстан АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1940). Хәзерге башкорт проф. музыкасына нигез салучыларның берсе. Беренче башкорт операсы, симфония һәм инструменталь әсәрләр авторы. РСФСР Композиторлар берлегенең Башкорт бүлеген оештыра һәм аның беренче рәисе була (1940–48). 1914–17 елларда Оренбург татар җәмгыятенең хәйрия музыка мәктәбендә скрипкада уйнарга өйрәнә. 1917–19 да җыр укытучысы, 1919–20 дә хәрби капельмейстер булып эшли, 1920–21 дә Оренбургта Шәрекъ музыка мәктәбендә скрипка һәм хор класслары алып бара. 1921–22 дә Эстәрлетамак һәм 1930–32 дә Казан милли драма театрлары оркестрларында скрипкачы булып эшли. 1932 дән Уфа Башкорт драма театрында музыка бүлеге мөдире һәм дирижёр. В.нең иҗатында хор әсәрләре (ш.и. башкорт халык көйләренә эшкәртмәләр), драма спектакльләренә музыка, татар һәм башкорт шагыйрьләренең шигырьләренә язылган җырлар зур урын алып тора. Популярлык алган җырлары: «Ак каен» (Ә.Ерикәй шигыре), «Матур Өфө каласы» (К.Даян шигыре), «Галимә җыры» (Г.Әмири шигыре). В. — беренче башкорт операсы «Сакмар»ның (С.Мифтаховның шул исем. әсәре нигезендә, 1940; яңа редакциясе «Айсылу», Н.И.Пейко б-н автордаш, 1943), ш.у. симф. («Башкорт увертюрасы», «Салават» сюитасы), камера-инструменталь (кыллы квартет, фортепиано, скрипка, виолончель өчен пьесалар) һ.б. әсәрләр авторы. В. иҗат иткән әсәрләргә матур аһәң, бай моң, халык җырлары б-н бәйләнеш хас. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә (1955).

*Әд.:* Композиторы Башкирии. М., 1955; Валеев Масалим Мушарапович // Музыкальная энцикл. М., 1973. Т. 1; А т а н о в а Л. Масалим Валеев. Уфа, 1979.

**ВӘЛИ́ЕВ** Наил Мансур улы (3.9.1949, Чистай ш.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1996), ТРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1997, 2003), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, хакыйкый әгъзасы (2001, 2004), гуманитар фәннәр бүлегенең академик-секретаре (2002–2007). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Чистайда урта мәктәптә укыта. 1975–77 елларда һәм 1981 дән Алабуга пед. ин-тында: рус һәм чит илләр әдәбияты каф. мөдире (1983 тән), проф. (1997), бер үк вакытта 1991 дән фәнни эшләр буенча проректор, 2000 нән — ректор, 2007 дән ТРның мәгариф һәм фән министры. Фәнни хезмәтләре рус-татар әдәби багланышларына (Ф.Әмирхан һәм рус әдәбияты), 19 йөзнең 2 нче яртысы рус әдәбияты тарихына, туган төбәкне әдәби һәм тарихи яктан өйрәнүгә, Д.И.Стахеев һәм К.И.Невоструевның тормышларын һәм иҗатларын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Әдәби Алабуга. Алабуга, 2005; Фатих Әмирханның рухи мирасы: идея-сәнгать үзенчәлекләре. К., 2005; В мире нравственных исканий. К., 1985; Дмитрий Стахеев: Судьба и творчество. Уфа, 1996; Высокое служение Отечеству: Капитон Иванович Невоструев (1815–1872). Елабуга, 1998; Гармония культур. К., 2001; Елабуга-Харбин-Сидней. К., 2007 (автордаш); Краеведы Елабуги. К., 2007 (автордаш).

*Әд.:* Академия наук Республики Татарстан. К., 2002; Наиль Мансурович Валеев: Биобиблиогр. указатель. Елабуга, 2004.

**ВӘЛИЕ́В** Наил Сабирҗан улы (19.2.1937, Дөбъяз р-ны Урта Алат а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1999), РФнең атказ. химигы (1997). Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый (1959), Полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында (Пермь ш.) эшли, ябыштыру материаллары лаб. мөдире (1983 елдан). Хезмәтләре полимерлар физик химиясенә карый. Полимер материаллар контакты чигендә диффузия процессларын, каты ягулыклы ракета двигательләренә җайлаштырып, полимерларның һәм ябыштырылган тоташтырмаларның искерүен фәнни яктан тикшерә. Ябыштырыла торган полимер материалларның химик табигатенә бәйле рәвештә, ябыштырма җөйләр ясауның үзенчәлекләрен билгели. Адгезион үзлекләрен күтәрү максатыннан материалларның өслеген модификацияләү ысулларын, ракета техникасы конструкцияләре һәм эшләнмәләрендә полимерларның һәм ябыштырылган тоташтырмаларның хезмәт итү вакытларын фаразлау ысулларын тәкъдим итә. Эпоксид, полидиенуретан эпоксид олигомерлар нигезендә югары нәтиҗәле ябыштыру материаллары, ш.у. дивинилизопрен, этиленпропилен каучуклар нигезендә җылылык үткәрми торган материаллар уйлап чыгара. Фәнни тикшеренүләре С.М.Киров исем. з-дта (Пермь ш.), «Россия» химкомбинатында (Ростов өлкәсе Каменск-Шахтинский ш.) кертелгән. 350 фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ВӘЛИ́ЕВ** Нәгыйм Бари улы (21.11.1930, Буа р-ны Иске Тинчәлә а. — 2.6.2000, Биектау р-ны Чабакса а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, а.х. фән. канд. (1971), РСФСРның атказ. зоотехнигы (1979). 1963 елда Ульяновск а.х. ин-тын тәмамлый. 1953–62 дә Әлки р-нының «Энергетик» с-зы зоотехнигы, 1962–64 тә Казан вет. ин-тының уку-укыту хуҗалыгы директоры урынбасары, 1964–67 дә Чистай р-нының а.х. идарәсе баш зоотехнигы, 1967–70 тә Чистай р-нының «Луч» җәнлек с-зы директоры, 1970–93 тә Питрәч р-нының «Кощак» җәнлек с-зы директоры. Аның җитәкчелегендә куян, ак төлке, чәшке мехы җитештерүнең күләме арта, үсеш темпы күтәрелә, нутрия һәм янут үрчетү җайга салына. Совхоз тармакта иң яхшылар рәтенә баса, РФ һәм республика җәнлек асраучыларының тәҗрибә уртаклашу базасына әверелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С о р о к и н Н.М. Колесо жизни. К., 1990.

**ВӘЛИ́ЕВ** Равил Вәли улы (20.8.1942, Арча р-ны Яңа Кенәр а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). 1969 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1970–92 дә төрле газета-журнал редакцияләрендә, Чаллы, Алабуга шәһәр радиоларында мөхәррир булып эшли. 1993 тән «Шәһри Казан» г-тасында бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, 2003 тә баш мөхәррир урынбасары. «Шәһәр булсын бүләгем» исемле беренче документаль повесте 1973 тә басыла. «Таяну ноктасы» (1978), «Көчле агым» (1984) дигән очерклар җыентыкларында, повесть һәм хикәяләре тупланган «Мәңгелек ут җылысы» (1986) китапларында төзүчеләр һәм КамАЗ эшчеләренең истә калырлык образларын тудыра, Бөек Ватан сугышы елларында халыкның тылдагы фидакарь хезмәтен чагылдыра. Геройлары ихлас күңелле, хезмәт сөючән, ярдәмчел һәм шәфкатьле, мәхәббәтләренә тугры кешеләр. В. ш. у. тарих, әдәбият һәм сәнгать өлкәсенә караган күп кенә мәкаләләр авторы. Соңгы елларда ул тарихи әсәрләр язу өлкәсендә нәтиҗәле эшли. «Җөй» (2002), «Олуг хан ярлыгы» (2005) җыентыклары шундыйлардан.

*Әд.:* Б а я н о в Ә. Безнең сафка // Казан утлары. 1980. № 1; Ә г ъ з а м о в Ф. Таяну ноктасы // Үзәктә кеше: Очеркларыбыз турында. К., 1981.

**ВӘЛИ́ЕВ** Равил Шамил улы (18.10.1956, Арча р-ны Яңа Кенәр а.), фтизиатр, пульмонолог, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2000), ТРның атказ. табибе (2000). 1979 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, ТРның мед. учреждениеләрендә эшли. 1995 елдан Туберкулёзга каршы республика клиник диспансе-

ры баш табибе, 1998 дән директоры. Хезмәтләре бронх-үпкә авыруларына дифференциаль диагноз куюга карый. Үпкәләрдәге деструктив туберкулёз авыруының төрле вариантларының көчәю үзенчәлеген һәм аны дәвалауның нәтиҗәле юлларын, үпкә туберкулёзлы авыруның шәхси үзенчәлекләрен һәм аның авыруга мөнәсәбәтен өйрәнә. Шундый авыруларны дәвалаганда җибәрелгән кимчелекләрне булдырмау өчен психотерапевтик коррекцияләү ысулын эшли һәм туберкулёзны дәвалау учреждениеләрендә гамәлгә кертә, авыруларны амбулаториядә дәвалау критерийләрен эшли.

Х е з м.: Особенности клиники, диагностики и лечения лобарной казеозной пневмонии // Казан. мед. журн. 1996. № 2; Показания к стационарному лечению больных туберкулёзом: Учебно-метод. пособие. К., 2000 (автордаш).

**ВӘЛИ́ЕВ** Радик Назыйх улы (15.9.1933, Казан — 21.3.1979, шунда ук), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1975). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1956), «Әлмәтнефть» геология идарәсендә һәм Татсовнархозда эшли (1957–59). 1959–62 елларда Казан ун-тында. 1963–79 да ВНИИгеолнерудта, 1975 тән тектоника секторы мөдире. Вятка-Кама елгаара оригиналь тектоник схеманы эшли, ярылган урын системалары, аларга бәйле структуралар формалашуның закончалыкларын нигезли, җыелмалар үсешенең янәшә торган авлакогеннар б-н синхрон бәйләнешен билгели, структураларның зурлыгы һәм тибына бәйле рәвештә Урал-Идел буе нефть чыганаклары урнашуның зона закончалыкларын күрсәтә, Рус платформасының көнчыгыш өлешендә руда булмаган файдалы казылмаларны эзләү өчен эре һәм уртача масштаблы карталар эшләүдә катнаша.

Х е з м.: Основные принципы минерагенетического анализа платформенных областей // Всесоюз. ин-т экономики минерального сырья, Экспресс-инф. 1974. Сер. 4, вып. 1; Авлакогены Восточно-Европейской платформы. М., 1976.

**ВӘЛИ́ЕВ** Разил Исмәгыйль улы (4.1.1947, Ширәмәт, хәзерге Түбән Кама р-ны Ташлык а.), язучы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, ТАССР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1990, 1997), тарих фән. канд. (2005). М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (1972, Мәскәү). 1972–76 елларда «Ялкын» ж-лында әдәби хезмәткәр, 1976–81 дә җаваплы сәркәтип. 1981–84 тә ТАССР Язучылар берлегенең Чаллы оешмасы җаваплы сәркәтибе. 1986–2000 дә ТР Милли китапханәсе директоры, бер үк вакытта 1990–95 тә ТР ЮСның Милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе рәисе. 2000 елдан ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр ком-ты рәисе, ТР Дәүләт Советы президиумы әгъзасы. Әсәрләре 1960 елларда басыла башлый. Төп жанры — шигърият. В. — гражданлык хисләрен ачык белдерүче шагыйрьләрдән. Ул «Зәңгәр кабырчыклар» (1971) дигән беренче шигырьләр китабы б-н үк үзен әхлакый проблемалар турында тирән уйланучы шагыйрь итеп таныта. «Яшен тамыры» (1977), «Ядкарь» (1987), «Кышкы учак» (1994), «Сүзләрдән дисбе» (1996) җыентыклары дөнья күрә.



Р.И. Вәлиев.

В. поэзиясенең төп тематикасы — туган җир, табигатьне саклау, Җир-Ана язмышы өчен борчылу; шигырьләре көчле идеяләргә, романтик хисләргә бай. Аның шигырьләренең аһәңлелеге танылган татар композиторларының игътибарын җәлеп итә. Ф.Әхмәтов, Р.Яхин, М.Яруллин, Р.Абдуллин, Л.Батыр-Болгари, Р.Ахиярова, Ш.Тимербулатов һ.б. композиторлар б-н берлектә иҗат ителгән ике йөзгә якын җыры «Бер алманы бишкә бүләек» (1992), «Яшьлек ядкаре» (2005), «Мәхәббәт сүрәсе» («Определение любви», 1984) җыентыкларына керә. В.нең балаларга атап язылган «Хыялый Мияубикә» (1976), «Кайтаваз кайда яши?» (1994), «Гөрләвек» (2005) шигырь китапларына балаларга хас эчкерсезлек, гади, ягымлы тел хас. В. тәрҗемәсендә дөнья халыклары әкиятләре тупланган китаплар «Тылсымлы чишмә» (1984), «Иң озын әкият» (1994), «Алтын алма» (2007). А.Конан Дойлның «Баскервильләр эте» («Собака Баскервилей»), Р.Киплингның «Маугли», А.Сент-Экзюпериның «Нәни принц» («Маленький принц») әсәрләре (2004) аерым китап булып дөнья күрә. Проза өлкәсендә В.нең яраткан жанры — документаль характердагы кыска, җыйнак повесть. «Эт кояшы» исемле повесть 1968 елда языла да, 1990 елда гына басылып чыга. Яшь солдатның батырлыгы турында «Яшисе килә!» повесте (1982; русчага тәрҗемәсе — «Жить хочется!», 1983); Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге, 1982), заман яшьләре арасындагы әхлак мәсьәләләрен үзәккә алган «Иске сәгать дөрес йөри» (2004) повесте, КамАЗ төзелеше б-н бәйле вакыйгаларга багышланган «Мирас» (1990) романы авторы. «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» (1989), «И машина, машина, җитте минем башыма» (1990) комедияләре Татар драма һәм комедия театры сәхнәсендә уйнала. В. публицист буларак та билгеле («Күкләр биек» җыентыгы, 1983). Аның әсәрләре рус, башкорт телләренә тәрҗемә ителгән. В. — Татар ПЕН-Үзәген оештыручыларның берсе һәм 1995 тән аның вице-президенты. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995 тән ТР халык депутаты. Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2007).

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 1999–2000; Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 2006–07; Зимние яблоки: Стихи. К., 1999.

*Әд.:* Разил Вәлиев: биобибл. белешмә. К.–М., 1996; Д а у т о в Р.Н. Балачак әдипләре. Кит. 1. К., 2002; З а һ и д у л л и н а Д. Мирас турында уйланулар // Мәйдан. 2005. № 6; Г а л и е в М. Язмышка рәхмәт // Вәлиев Р. Сайланма әсәрләр. 1999. Т. 1.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Рамил Миргасим улы (28.8.1955, Лениногорск р-ны Керкәле а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1999), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1981). 1984–88 елларда ТАССР Мәдәният министрлыгының сәнгать бүлеге башлыгы. 1988 дән Казан ун-тында яңа һәм иң яңа тарих кафедрасында укыта, 1997 дән ТР МКның мәгариф һәм фән бүлеге (1998 дән югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән идарәсе) башлыгы, бер үк вакытта 2003 тән Казан ун-тының Көнчыгышны өйрәнү ин-тында Көнчыгыш тарихы һәм икътисады каф. мөдире. Хезмәтләре Шәрекъны өйрәнү тарихына карый. Монголларны өйрәнүче О.М.Ковалевскийның көндәлекләрен әзерли һәм китап итеп бастыра.


Х е з м.: Из истории казанского востоковедения середины — второй половины XIX в.: Г.С.Саблуков — тюрколог и исламовед. К., 1993; Казанское востоковедение: Истоки и развитие (XIX — 20-е гг. XX вв.). К., 1998; Монголовед О.М.Ковалевский: биография и наследие (1801–1878). К., 2004 (автордаш); Александр Касимович Казем-Бек. К., 2005.

**ВӘЛИ́ЕВ** Рәмзи Кәлимулла улы (7.5.1937, хәзерге Яшел Үзән р-ны Карашәм а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1990), проф. (1992), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1994). РФнең атказанган югары мәктәп хезмәткәре (2006), КДУның атказанган профессоры (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1963). 1963–65 елларда Казан авиация ин-тында, 1968 дән Казан ун-тында, 1991 дән хәзерге заман ватан тарихы каф. профессоры, бер үк вакытта тарих ф-ты деканы (1995–2005). В. декан булган чорда тарих ф-тында бер төркем студентларны татар телендә укыта башлыйлар. Төп хезмәтләре Урта Идел буе төбәгенең 20 йөзнең 1 нче чирегендәге иҗтимагый-сәяси тарихына, татар зыялылары, ш.и. Борһанетдин, Гыйльметдин, Галимҗан һәм Шәһретдин Шәрәфләр язмышына, Татарстанда Сталин чоры репрессияләренә карый. В. беренчеләрдән булып Вәисиләр хәрәкәте тарихын, Борһанетдин һәм Гайнетдин Вәисовларның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген өйрәнә. Гайнетдиннең Л.Н.Толстой б-н дусларча мөнәсәбәтләрен бәян итә. Халыкара Кол Гали премиясе лауреаты (2002). Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фаҗига. К., 1996; Болак арты республикасы. К., 1999; Өзелгән дога. К., 2007; Революционное движение в Среднем Поволжье (июль-окт. 1917). К., 1972; Назревание общенационального кризиса и его проявление в Поволжье и на Урале в 1917. К., 1979; Признаю себя виновным. К., 2007.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999). К., 1999.

**ВӘЛИ́ЕВ** Рәфгать Әхтәм улы (18.2.1911, хәзерге Башкортстан Респ-касының Кыйгы р-ны Еланлы а. — 16.7.1993, Мәскәү), генерал-майор–инженер (1962), техник фән. канд-ты (1955). Мәскәү ун-тының механика-матем. ф-тын (1936), Ф.Э.Дзержинский исем. Артиллерия академиясенең баллистика ф-тын (1951, Мәскәү) тәмамлый. 1939–41 елларда шунда ук матем. укытучысы. 1941 нең июль аеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, Мәскәү халык ополчениесендә, аннары 11 нче гв. дивизия составында, Көнбатыш, Брянск, Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтларында сугыша. Сугышны полк командиры дәрәҗәсендә тәмамлый. 1951–56 да зенит-ракета комплекслары полигонында бүлек, фәнни-тикшеренү бүлеге җитәкчесе, җитәкче урынбасары. 1956–73 тә СССР Кораллы көчләре Ген. шта-



С.Ш. Вәлиев.



С.Г. Вәлиев.

бында. 1973–86 да Мәскәүдәге Радио төзү фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре һәм уйлап табулары самолёт һәм ракеталар һөҗүменнән саклану өлкәсенә карый. Ленин бүләге лауреаты (1965). Кызыл Йолдыз, Александр Невский, 1 нче, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Народное ополчение Москвы. М.,1961; От Москвы до Берлина. М., 1966.

**ВӘЛИ́ЕВ** Рәфгат Нури улы (5.10.1931, Түбән Кама р-ны Ташлык а.), инженер-электромеханик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1981). 1962 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, 1993 кә кадәр Уфа приборлар төзү з-дында инженер-конструктор булып эшли. Космик һәм авиация техникасын үстерүгә зур өлеш кертә. «Ритм», «Грант», «Космос» иярченнәре (1962). «Восток», «Восход» космик корабльләре борт җиһазлары комплекты (1963, 1964), «Союз» сериясе, «Салют» Ай корабле (1974), «Прогресс» йөк транспорт корабле (1977) һәм туктаусыз идарә ителүле «Мир» комплексы өчен (1985) команда-хисаплау җайланмаларын үзләштерүдә катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Инженеры Урала: Энцикл. Екатеринбург, 2001.

**ВӘЛИ́ЕВ** Револь Миргалим улы (19.8.1938, Бондюг р-ны Кураз а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2000), проф. (2001). ТАССР һәм РФнең атказ. хокук белгече (1988, 1999). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1965–76 елларда ТАССР Югары мәхкәмәсе әгъзасы. 1976–94 тә РФ Эчке эшләр министрлыгының Мәскәү читтән торып уку юридик ин-тының Казан ф-лында җинаятькә каршы хокук һәм процесс каф. башлыгы. 1994 тән Казан ун-тының халыкара хокук кафедрасында. Хезмәтләре халыкара җинаять эшләре һәм гуманитар хокукка карый.

Х е з м.: Выдача преступников в современном международном праве: Некоторые вопросы теории и практики. К., 1976; Международный контроль. К., 1998; Теоретические проблемы международного контроля. К., 1999.

**ВӘЛИ́ЕВ** Римзил Салих улы (7.3.1949, Башкортстан АССРның Бишбүләк р-ны Дүсән а.), журналист, җәмәгать эшлеклесе, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1999). Башкорт ун-тын (1972), ВЛКСМ ҮК каршындагы Югары комсомол мәктәбен (Мәскәү, 1975) тәмамлый. 1966–67, 1972–73 елларда «Светлый путь» район г-тасында (Башкортстан АССР) эшли. 1975–79 да Уфада «Ленинец» г-тасында бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип. «Комсомольская правда» (1979–83) һәм «Советская культура» (1983–85) үзәк г-таларының Идел буе респ-калары буенча үз хәбәрчесе. 1985 тән «Слово агитатора» ж-лында җаваплы сәркәтип. 1989–91 дә «Идел» ж-лының беренче баш мөхәррире. 1991–93 тә «Дөнья» г-тасын оештыручы һәм баш мөхәррире. 1992 дән Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 2002 дән Россия татарларының милли-мәдәни федераль советы рәисе. 1995–2006 да «Ватан» җәмгыяте президенты. 1995–2000 дә «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясенең чит илләр өчен тапшырулары «Дөнья» радиостудиясе мөхәррире. 2000 нән «Ирекле Европа» — «Азатлык» радиокорпорациясенең Казандагы вәкиллеге директоры. Очерк, репортажлары, аналитик мәгълүматларга бай радиопрограммалары җирле этник проблемаларга, татар халкы тарихы һәм мәдәниятенә, ТРның халыкара мөнәсәбәтләренә багышлана.

Ә с ә р.: Время, вперед! М., 1978; Радиус действия нашего радио // Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! К., 1998; Согревая Татарстан, укрепляем Россию // Солнце греет и ночью. К., 2000.

*Әд.:* Я к у п о в а В.А. 100 историй о суверенитете. К., 2000.

**ВӘЛИ́ЕВ** Рөстәм Шәвәли улы (19.10.1936, Чиләбе өлкәсе Троицк ш.), язучы. Рус телендә яза. М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый (1979, Мәскәү). Чиләбе шәһәрендә яши. «Тугрылык» («Верность», 1960) исемле беренче китабы стиленең реалистик манерасы, мәгънәви кыскалыгы б-н әдәби тәнкыйть тарафыннан уңай бәяләнде. Г.Тукайга багышланган «Дөнья гаме» («Заботы света», 1986) романында 19–20 йөзләр чигендә татар җәмгыятенең киеренке рухи тормышы чагылдырыла. «Шәһәрләр җире» («Земля городов», 1990) романында традицияләрнең тәрәккыять б-н, үткәннәрнең киләчәк б-н үзара мөнәсәбәте проблемасы куела. «Фининспектор һәм бабай» («Фининспектор и дедушка», 1970), «Күршенең ягымлы карашы» («Добрые глаза соседа», 1974), «Йөк» («Ноша», 1989), «Үкенмим, чакырмыйм...» («Не жалею, не зову...», 1990), «Хикәяләр» («Рассказы», 1996) һ.б. җыентыкларга кергән хикәяләрендә һәм повестьларында автор хәзерге заманның актуаль проблемаларына зур игътибар бирә. Рус теленә Г.Исхакый, Ә.Еники әсәрләрен тәрҗемә итә. 1992 елдан «Уральская новь» ж-лының (Чиләбе ш.) баш мөхәррире.

*Әд.:* М у с т а ф и н Р.А. Биография духа // Новый мир. 1984. № 2; Л е й д е р м а н Н. В поисках птицы самрух // Урал. 1989. № 11.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Салих Шәйбәк улы (22.10.1912, хәзерге Башкортстан Респ-касының Кушнаренко р-ны Иске Гомәр а. — 12.10.1970, Уфа ш.), Сов. Союзы Герое (23.10.1943), өлкән лейтенант (1945). 1940 елда Кызыл Армиягә алынганчы МТСта тракторчы булып эшли. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында. Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (1942). 957 нче укчы полкның взвод командиры (40 нчы армиянең 309 нчы укчы дивизиясе). Брянск, Воронеж, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Харьков операциясендә (1943), Днепрны кичүдә (1943), Молдавияне, Румыния, Венгрия һәм Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1943 нең 24 сентябрендә Балыко-Щучинка авылы янында (Киев өлкәсе, Кагарлык р-ны) Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Уфада яши. Ленин, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1965. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Солтан Галимҗан улы (19.10.1941, Приморье краеның Шкотов р-ны Шкотов пос.), астроном, физ.-матем. фән. д-ры (1991), ТР ФА академигы (2000). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1966 дан В.П.Энгельгардт исем. астр. обсерваториясендә. 1973 тән Кемерово ун-тында, 1983 тән югары математика каф. мөдире. 1987 дән Ульянов политехника ун-тында, 1992 дән гамәли математика һәм информатика каф. мөдире, проф. (1993). ТР ФАнең Ульянов төбәк бүлеген оештыручыларның һәи инициаторларының берсе (1999). Төп хезмәтләре астрометрия, планетодезия һәм күк механикасындагы астрономик күзәтүләрне һәм космик мәгълүматны матем. эшкәртү теориясе һәм практикасына карый. «Зонд-6», «Зонд-8» сериясендәге космик аппаратлардан Айның Җирдән күренми торган ягы төшереп алынган рәсемнәрне эшкәртүдә катнаша. Мәгълүмат теориясендә яңа юнәлешне — мәгълүмат эшкәртүнең математик модельләренең төзелеш-параметрларын регрессив модельләштерү юлы б-н оптимальләштерүне билгели. Бу өлкәдәге тикшеренүләрне үстерү компьютерда мәгълүмат эшкәртүнең иң кулай сценарийларын төзү мәсьәләсен чишүгә һәм интеллектуаль (эксперт) системалар булдыруга китерә.

Х е з м.: Изучение рельефа обратной стороны Луны по фотографиям КА «Зонд-8» // Космические исслед. 1976. Т. 16 (автордаш); Регрессионное моделирование при обработке наблюдений. М., 1991; Статистический анализ данных при обработке наблюдений планет // Астрон. вестн. 1991. Т. 25, № 2.

*Әд.:* Г а в р и л о в а Е.В. Математика ночного неба // Симбирский курьер. 1994. 17 нояб.

**ВӘЛИ́ЕВ** Үзбәк Салават улы (22.9.1928, Казан), физик, техник фән. д-ры (2002). 1951 елда Казан ун-тын һәм 1953 тә Ленинградтагы А.Н.Крылов исем. Хәрби-диңгез академиясен тәмамлый. 1957 дән СССР Хәрби-диңгез Флотының 14 нче ин-тында (бүленеп, 1965–69 да СССР ФА Себер бүлегенең Электрометрия ин-тында, Новосибирск ш.), 1969–86 да лаб. башлыгы, бүлек башлыгы урынбасары (С.-Петербург). Хезмәтләре үткәргеч мохиттәге электромагнит кырларына, махсус билгеләнгән радиоэлектроника һәм аппаратурага карый. 50 дән артык фәнни хезмәт, ш.и. 28 уйлап табу авторы.

Х е з м.: Электромагнитные поля, создаваемые неравномерно движущимся источником // Радиотехника и электроника. 1991. Т. 36.

*Р.Г.Усманов.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Фалес Әхәт улы (30.9.1938, Октябрь р-ны Кычытканлы а. — 8.6.2004, Зәй ш.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССР һәм РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1990, 1997). Казан ун-тын (1966) һәм Югары партия мәктәбен (1982, Саратов) тәмамлый. 1966–71 елларда Зәй р-нының Түбән Пәнәче урта мәктәбендә укытучы һәм директор, 1971 дән «Якты Йолдыз» к-зы рәисе, 1977–81 дә Зәй р-ны а.х. идарәсе башлыгы, 1983 тән халык контроле ком-ты рәисе. 1986–99 дан «Зәй» с-зы директоры (хәзерге «Заман» а.х. җитештерү кооперативы), бер үк вакытта 1990–92 дә халык депутатларының Зәй р-н советы рәисе, 1993–95 тә берләштерелгән шәһәр һәм район советы рәисе. Хуҗалыкның матди-техник базасын ныгытуга зур өлеш кертә, совхоз аның җитәкчелегендә а.х. культураларыннан тотрыклы югары уңыш алуга һәм терлекчелектә мул продуктлылыкка ирешә. 1997 гә бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 50 *ц* га җитә, ит җитештерү 2 тапкыр арта; халыкның социаль-көнкүреш шартлары яхшыртыла — юллар төзекләндерелә, мәдәният учреждениеләре, торак йортлар төзелә һәм газлаштырыла. Бетеп барган авыллар яңадан торгызыла. 1995 тән ТР халык депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ВӘЛИ́ЕВ** Фәйзи (Фәйзерахман) (1892, хәзерге Башкортстан Респ-касының Кушнаренко р-ны Шәрип а. — 1941), язучы. «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый. Озак еллар Уфа губернасы һ.б. өлкәләрнең мәгариф оешмаларында, партия һәм совет органнарында эшли. 1910–11 елларда «Шура» ж-лында, «Вакыт» г-тасында басылган шигырьләре б-н таныла. «Урал буйлары» (1914) исемле беренче проза әсәрендә Урал табигатен тасвирлый, аның җир асты байлыкларын кешеләр файдасына юнәлтергә кирәк дигән уй-хисләре б-н уртаклаша. Шул елларда иҗат ителгән «Бер тиен» (1914) һ.б. хикәяләрендә гади кешеләрнең тормышчан образларын тудыра. «Намаз» (1916), «Җырлыйлар» (1917), «Ирһан — укытель» (1918) хикәяләре Беренче бөтендөнья сугышына бәйле вакыйгаларга багышланган. «Көймәдә» (1918) хикәясендә романтик мәхәббәт темасы үзенчәлекле чагылыш таба. В.нең аерым хикәяләре 1918 дә чыккан «Идел буе әдәбияты» исемле күмәк җыентыкка кертелгән. В.нең халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю юнәлешендә дә хезмәтләре бар.

Ә с ә р.: Фәйзи хикәяләре. К., 1918; Урал буйлары. Бер тиен. Ирһан-учитель. Кәмәлә // Башкорт әдәбияты. XX быуат башы. Өфө, 1984; Өмидле күңелдән: Шигырьләр // Мирас. 1998. № 4.

*Әд.:* К у д а ш С. Сигезнең берсе // Совет Башкортстаны. 1973. 5 гыйн.


**ВӘЛИ́ЕВ** Фоат Таҗәхмәт улы (14.11.1918, хәзерге Омск өлкәсе, Большереченск р-ны Яланкүл а.), тарихчы, этнограф, тарих фән. д-ры (1988), проф. (1990), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1990). Омск пед. ин-тын тәмамлый (1948). 1936–40 елларда Яланкүл урта мәктәбе укытучысы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950–61 дә Совет Армиясендә хезмәт итә, полковник. 1961–62 дә Омск машина төзелеше ин-ты укытучысы. 1962 дән Казан архитектура-төзелеш академиясенең сәяси тарих кафедрасында. Хезмәтләре *Себер татарлары* һәм *Бохари төркиләр* тарихына, этнографиясенә һәм мәдәниятенә карый. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу об этногенетических и этнокультурных контактах сибирских татар с татарами Поволжья // Языки и топонимия. Томск, 1976; Алтайские этнические элементы у западносибирских татар // Этнография народов Алтая и Западной Сибири. Новосиб., 1978; Западносибирские татары во второй половине 19 — начале 20 вв.: Ист.-этногр. очерки. К., 1980.


*Әд.:* Т о м и л о в Н.А., Т о м и л о в а В.С. Фоат Тач-Ахметович Валеев — исследователь Сибири (К 80-летию со дня рождения) // Сибирские татары: Материалы 1-го Сибирского симпозиума «Культурное наследие народов Западной Сибири». Тобольск, 1998.

**ВӘЛИ́ЕВ** Фуад Хәсән (Хөсәен) улы (15.5.1921, Мәскәү — 11.10.1984, Казан), сәнгать белгече, архитектор, тарих фән. канд. (1966), сәнгать фән. д-ры (1984). Н.И.Воробьев, Н.Ф.Калинин һәм А.П.Смирнов шәкерте. Киев төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлый (1974). 1947–57 елларда «Татгипронефтьпроект» ин-тының архитектура-төзелеш бүлеге, 1957–59 да ТАССР МС каршындагы Махсус фәнни-реставрация остаханәсенең фәнни бүлеге җитәкчесе. 1959–69 да СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. 1971–81 дә Мари политехника ин-тында укыта (Йошкар-Ола ш.). 1981 дән ТАССРның Көнкүреш хезмәте министрлыгында баш рәссам, 1982–84 тә ТАССР Җирле сәнәгать министрлыгында киңәшче. Татар сәнгать белемен нигез салучыларның берсе; татар халкының бизәлеш сәнгатен, Казан татарларының авыл йортлары архитектура-сәнгать бизәлешен, Урта Идел буйларының борынгы чорлары, Идел буе Болгар дәүләте, Казан ханлыгы сәнгатен өйрәнә. Татарстан авылларына һәм татарлар тупланып яшәгән төбәкләргә (Әстерхан өлкәсе, Касыйм ш. һ.б.) экспедицияләр оештыра. Һөнәри-сәнгать мәдәниятенең фәнни типологиясен төзи; татар халык сәнгатенең туку, чигү, каюлы күн, зәркәнчелек сәнгате, агачка һәм ташка уеп бизәк төшерү кебек традицион төрләренең тарихи тамырларын һәм үсешен өйрәнә; татар сәнгатенең Болгар һәм Алтын Урда сәнгатьләре б-н дәвамчан бәйләнешен дәлилли. Болгар сәнгатендә Салтау-маяк культурасы элементлары булуын ачыклый, Болгар «җәнлек стиле»нә фәнни билгеләмә бирә. «*Казан бүреге*»нең һәм ш.у. Казан ханлыгы дәверенең башка сәнгать эшләнмәләренең эшләнү вакытын һәм урынын ачыклый.

Болгар тарих-архитектура саклаулыгындагы кайбер биналарның реставрацияләү һәм



Ф.Х. В ә л и е в. Болгар шәһәрендәге җамигъ мәчет. Реконструкция. 1960 нчы еллар.



Ф.Х. Вәлиев.

реконструкцияләү проектларын эшләүдә катнаша. В. — Казандагы Горький исем. ял һәм мәдәният паркы үзәк мәйданындагы Г.Тукай бюсты архитекторы (сынчысы — И.А.*Новосёлов*).

В. — 1970 елларда Казан халык һөнәрләре комб-тында, Казан нәфис эшләнмәләр ф-касында, шәһәр тибындагы Шәмәрдән поселогының зәркән остаханәсендә сувенирлар һәм халык сәнгате эшләнмәләре җитештерүне оештыручыларның берсе. Республикада музейлар эшен үстерүгә зур өлеш кертә. Экспедицияләр вакытында ул җыйган материаллар ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда татар гамәли-бизәлеш сәнгате коллекцияләренең нигезе булып тора. Аның реконструкцияләре һәм эскизлары б-н Казан арты авылларында (Әтнә, Олы Мәңгәр һ.б.) агачтан салынган йорт үрнәкләренең макетлары («Казан» милли-мәдәният



Ф.Х. В ә л и е в. Казан Кремлендәге Колшәриф мәчете.Реконструкция. Кәгазь, тушь. 1983.

үзәге экспозициясендә, «Иске Казан» музей-саклаулыгында урнаштырылган), Идел буе Болгар дәүләтенең һәм Казан ханлыгының кирәч сәнгате үрнәкләре (башкаручы — Б.А.Шубин), зәркән эшләнмәләре (Р.Әлмәнов, Л.Хисамиева һ.б.), агач сувенирлар (уеп язу һәм бизәү), металл эшләнмәләр һ.б. иҗат ителә.

Х е з м.: Народное изобразительное искусство // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Орнамент казанских татар. К., 1969; Искусство Татарской АССР // Искусство стран и народов мира: Краткая художественная энцикл. М., 1971. Т. 3; Архитектурно-декоративное искусство казанских татар (сельское жилище). Йошкар-Ола, 1975; Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Древнее искусство Татарстана. К., 2002 (автордаш); Татарский народный орнамент. К., 2004.

*Әд.:* Тематическая подборка к 75-летию со дня рождения Ф.Х.Валеева // Казань. 1995. № 5/6;

Ильина М.Е. Пионер // Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999; Фахрутдинов Р.Г. Фуад Хасанович Валеев: страницы биографии и научной деятельности // Искусство и этнос. Новые парадигмы: Материалы III Всерос. конф., посв. 80-летию Ф.Х.Валеева. К., 2002.

*М.Е.Ильина, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Шәрәф Вәли улы (4.2.1907, Сембер губ., Буа өязе Зур Күккүз а. — 19.6.1978, Казан), агроном-селекция белгече, а.х. фән. канд. (1964), РСФСРның атказ. агрономы (1961). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1934), Кузнечиха МТСында өлкән агроном булып эшли. 1936–41 һәм 1946–78 елларда Татарстан Респ-касы а.х. тәҗрибә станциясендә (1969 дан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты), 1956 дан кукуруз селекциясе һәм орлыкчылыгы бүлеге мөдире. РФнең урман-далалы Көнчыгыш Европа өлеше шартларында балавызсыман аксыл-сары һәм балавызсыман иртә өлгерешле чәкәннәр формалаштыруга сәләтле, югары уңдырышлы «Татарский 6», «Коллективный 6 ТВ», «Коллективный 10 ТВ» кукуруз гибридларының һәм 1941 дә ТАССР, Мордва АССР һәм Рязань өлкәләрендә районлаштырылган язгы арпаның «Казанский 6/4» сорты автордашы.

Хезмәтләре силос һәм ашлык өчен кукуруз игүдә агротехник алымнар куллануга карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кукуруза. К., 1954; Опыт получения высоких урожаев кукурузы. К., 1954; Возделывание кукурузы на зерно в Татарии. К., 1961.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ВӘЛИ́ЕВ** Шәүкәт Мирсәяф улы (1.10.1921, хәзерге Оренбург өлкәсенең Богорыслан ш.), журналист, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Казан юридик ин-тын (1952), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1967, Мәскәү) тәмамлый. 1943–53 елларда ТАССРның хокук саклау органнарында эшли. 1954–57, 1961–68, 1987–91 дә КПССның Татарстан өлкә, респ-ка комитетларында. 1956 дан «Советская Татария», «Социалистик Татарстан» г-таларында, «Агитатор блокноты» ж-лында мәкаләләре басыла. 1958–60 елларда «Коммунист Татарии» — «Татарстан коммунисты» ж-лында икътисад бүлеге мөдире, 1969–87 дә — баш мөхәррир. Республика матбугатында икътисад мәсьәләләре, хезмәт коллективларының уңышлы казанышлары һәм проблемалары, массакүләм мәгълүмат чараларының республика тормышында тоткан роле турында мәкаләләре басыла. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Производственная активность рабочих. К., 1975 (автордаш); Экономика, соревнование, журнал // Соревнование и печать Татарии. К., 1976; Он всегда стоял у истоков нового // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 1/2; Страницы истории татарстанской прессы // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 3/4; Старейший в республике журнал // Тонус. 2000. № 6; 2001. № 7.

*Әд.:* Г а р и ф у л л и н В. Шәүкәт Вәлиев: Укучыларыбыз алдында йөзебез ак // Татарстан. 2000. № 10; Л ю б и м о в Ю. Почерк Ш.М.Валеева // Татарстан. 2001. № 9.

**ВӘЛИ́ЕВ** Юныс Сибгатулла улы (26.6.1925, Арча кантоны Айбаш а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. ТАССРның атказ. төзүчесе (1983). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1967). 1945–60 елларда Югары Ослан, Ютазы, Бөгелмә р-ннары пр-тиеләрендә эшли. 1960–66 да СССР «Минмонтажстрой»ның 7 нче тресты монтажлау идарәсе башлыгы урынбасары, 1966–72 дә «Главтатстрой» берләшмәсе (Казан) башлыгы урынбасары. 1972–83 тә ТАССРның МС рәисе урынбасары. 1972–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ВӘЛИ́ЕВ-СУ́ЛЬВА** Сөләйман Ярулла улы (10.1.1899, Оренбург ш. — 23.4.1956, Казан), актёр, режиссёр. Сәхнә эшчәнлеген Оренбург Халык йортында реж. Н.В.Картанов җитәкчелегендә башлый. Гражданнар сугышы елларында Эстәрлетамак шәһәрендә (Башкортстан) фронт театры режиссёры. 1921 елда Оренбург Мәгариф халык комис-тының театр бүлегендә секция мөдире, 1922–23 тә Ташкентта: театр техникумы мөдире һәм татар театр труппасы режиссёры, 1923 тә Оренбургта Рабис (сәнгать хезмәткәрләре берлеге) идарәсе рәисе, Эшче-крәстиян татар театры режиссёры, 1 нче кыргыз театры труппасын оештыручы. 1924 тә ТАССР Мәгариф халык комис-тының сәнгать бүлеге мөдире, 1925–26 да Ак мәчет (Симферополь) шәһәрендә Кырым-татар театры баш режиссёры. 1926 дан В.-С. яңадан Татарстанда: халык мәгарифенең Арча кантонында Политпросвет рәисе, 1927 дән Татар акад. театры актёры һәм режиссёры; «Булат батыр» нәфис фильмын төшерүдә катнаша, «Казан өчен көрәш» исемле күмәк тамашаны (1929), «Эшче» операсын (1930) куя. 1933 тән Мәскәүдә Татар опера студиясе җитәкчесе, 1935 тән Казанда Татар эшче театры режиссёры һәм актёры, 1938–41 дә яңадан Татар акад. театрында, соңрак Республика күчмә театрында режиссёр, баш режиссёр (1949–55). Башлыча, эпизодик характердагы рольләрдә уйный (Никанор Никанорович — «Сафура», Ә.Рахманкулов; Новиков — «Рельслар гүли», В.М.Киршон; Кәбир — «Адашкан кыз», Ф.Бурнаш). Хәзерге заман татар режиссурасының формалашуына шактый зур өлеш кертә. 1920 еллар сәнгатендәге сул юнәлешләрнең (ЛЕФ, Пролеткульт) идея позицияләрен яклый. В.-С. куйган спектакльләр формалары ягыннан эксперимент рәвешен ала. Сәхнәдә күпьяруслы конструкцияләр, кинопроекцияләр, хәрәкәтләнә торган техника куллану, спектакльне эпизодлап кору, күмәк күренешләрдә күпсанлы башкаручылар кертү һәм сәхнә уены өчен тамаша залын да файдалану В.-С. куйган спектакльләргә масштаблылык, динамика, эмоциональ киеренкелек бирә. Шул ук вакытта психол. анализның булмавы, конфликтларны алдан ук агитация-пропаганда максатыннан чыгып куерту драматургик материалны гадиләштерүгә, вульгар-социологик аңлатуга китерә һәм матбугатта кискен бәхәсләр кузгата. Татар акад. театрында Т.Гыйззәтнең «Наёмщик» (1928, 1931), В.М.Киршонның «Рельслар гүли» («Рельсы гудят», 1928), Ш.Камалның «Козгыннар оясында», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (1929) һәм Г.Минскийның «Шлем» (1930) пьесаларын, үзенең «ОДВА» (1931) композициясен куя. 1930–50 елларда режиссёрлык эшендә радикаль формалардан акрынлап читләшә, актёрлар б-н эшләүгә күбрәк игътибар бирә, сәхнә хәрәкәтләрендә һәм персонажларның характерларын ачуда тормышчанлыкка ирешә. Бу елларда куйган җитди спектакльләре: Татар акад. театрында У.Шекспирның «Отелло» (1933), Г.Камалның «Банкрот» (1935), Т.Гыйззәтнең «Бишбүләк» (1938), А.Н.Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые», 1939), Республика күчмә театрында Җ.Җаббарлының «Сулган чәчәкләр» (1953), С.Кальметовның «Тын алан шаулый» (1954) әсәрләре.

*Әд.:* А р с л а н о в М.Г. Татарское режиссёрское искусство 1906–1941. К., 1992.

*Р.М.Игъламов.*

**ВӘЛИ́ЕВА** Бану Нургали кызы (14.12.1914, Казан губ., Тәтеш өязе Шәмбалыкчы а. — 24.2.2003, Уфа), җырчы (сопрано), педагог, Башкортстан АССР һәм РСФСРның халык артисткасы (1947, 1955). Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт опера студиясен тәмамлый (1938). 1938–66 елларда Башкорт опера һәм балет театры солисты. 1969 дан Уфа сәнгать ин-тында укыта, проф. (1993). В.ның вокаль осталыгы ягымлы, йомшак тембры һәм ихлас күңелдән башкаруы б-н аерыла. Төп партияләре: Каролина («Яшерен никах», Д.Чимароза), Тегермәнче кыз («Гүзәл тегермәнче кыз», Д.Паизиелло), Розина («Севилья чәчтарашы», Дж.Верди), Джульетта («Ромео һәм Джульетта», Ш.Гуно), Лакме (шул исем. опера, Л.Делиб), Антонида («Иван Сусанин», М.Глинка), Иоланта (шул исем. опера, П.Чайковский), Айсылу (шул исем. опера, М.Вәлиев һәм Н.Пейко), Таңсылу («Акбүзат», Х.Заимов һәм А.Спадавеккиа), Наза, Әминә («Кодача», «Салават Юлаев», З.Исмәгыйлев), Алтынчәч (шул исем. опера, Н.Җиһанов) һ.б. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а й р у л л и н Р. Мастера оперного искусства Башкирии. Уфа, 1963; А х м а д и е в а Р. Бану Валеева. Уфа, 1974; Валеева Бану Нургалиевна // Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

**ВӘЛИ́ЕВА** Венера Сәлах кызы (6.4.1935, Башкортстан Респ-касының Кушнаренко р-ны Кушнаренко а.), тәрҗемәче, шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлый (1957). 1969–83 елларда Мәскәү электрон техникасы ин-тында укыта. Беренче тәрҗемәләре матбугатта 1977 дә басыла башлый. Татар теленнән — Г.Тукай, Дәрдемәнд, М.Җәлил, Х.Туфан, Ф.Кәрим, С.Хәким, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим, Зөлфәт, Н.Измайлова, Г.Садә, немец теленнән — Һ.Һейне, Л.Фюрнберг, Э.Штритматтер, молдаван теленнән — П.Боцу, балкар теленнән — К.Кулиев, әрмән теленнән — Г.Эмин, башкорт теленнән Р.Бикбаев, Т.Йосыпов шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә. «Сизенү» («Предчувствие», 1989), «Саф нота» («Чистая нота», 1999), «Исәнләшү» («Перекличка», 2001) китаплары авторы.

**ВӘЛИ́ЕВА** Зилә Рәхимҗан кызы (15.10.1952, Уфа ш.) хакимият эшлеклесе, журналист. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1978). «Ленинец» (Уфа, 1970–80), «Вечерняя Казань» (1980–82), «Советская Татария» (1982–91), «Известия Татарстана» (1991–92, бүлек редакторы) г-талары редакциясе хезмәткәре. 1992–95 елларда ТР ЮС рәисенең 1 нче урынбасары. 1995–99 да ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары. 1999–2001 дә ТР Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министры. 2001 дән ТР премьер-министры урынбасары. 2005 тән ТР премьер-министры урынбасары — мәдәният министры. Бу елларда мәдәни мирасны саклау өчен «Мирас» программасы эшләнә һәм гамәлгә ашырыла; Ф.И.Шаляпин исем. опера, Р.Нуриев исем. балет сәнгате, төрки халыкларның «Нәүрүз» театр фестивальләре, Казанда «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман киносы фестивале уңышлы үткәрелә. Татар опера һәм балет, Татар драма, Яшь тамашачылар театрлары, ТРның Милли музее биналарын капиталь төзекләндерү һәм реставрацияләү буенча зур эшләр башкарыла; Казан Кремлендә «Хәзинә» милли нәфис сәнгать галереясы ачыла, Казанның 1000 еллыгы бәйрәменә багышланган мәдәни чаралар югары дәрәҗәдә үткәрелә. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. 1995–99 да ТР халык депутаты. «Татарстан хатын-кызлары» респ-ка иҗтимагый оешмасы рәисе (1996 елдан). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ВӘЛИ́ЕВА** Илдария Хәйрулла кызы, к. 712 биттә.

**ВӘЛИ́ЕВА** Майя Диас кызы (1.5.1962, Казан), язучы. Рус телендә яза. Казан ун-тының биол. ф-тын (1984), М.Горький исем. Әдәбият ин-тының югары әдәби курсларын (1992, Мәскәү) тәмамлый. В. китапларының төп проблематикасы — табигать һәм кеше дөньясы: «Кара эт турындагы хикәя» («Повесть о чёрной собаке», 1980), «Башлангыч» («Начало», 1983), «Торна тавышы» («Крик журавля», 1987), «Текә яр читендә» («На краю», 1989), «Гафу ит мине, дустым» («Прости меня, друг», 1990), «Сакчы Селәүсен тавы буенда» («У сопки Стерегущей Рыси», 1991). «Кара Дикның тормышы һәм үлеме» («Жизнь и смерть Чёрного Дика», 1993), «Торна Круның кайтуы» («Возвращение журавлёнка Кру», 1996) китапларында, «Шәһәр бүресе» («Чужая», 1998), «Кешеләр һәм бультерьерлар» («Люди и бультерьеры», 2000) повестьларында кискен экология проблемалары куела. Язучы хезмәтен В. фәнни, иҗтимагый эшчәнлек б-н бергә алып бара, вакытлы матбугатта экологиягә, әхлакка багышланган мәкаләләр бастыра. Америка турында эсселар авторы. 1990 елдан В. диварларга рәсем ясау б-н шөгыльләнә. 2000 нән АКШта яши. *Р.Ә.Мостафин.*

**ВӘЛИ́ЕВА** Надежда Геннадьевна (31.8.1956, Иваново өлкәсе Южа ш.), тарихчы, культуролог, тарих фән. д-ры (2006), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2004), РФнең атказ. югары проф. белем хезмәткәре (2007). Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1981). 1981–95 елларда Алабуга шәһәрендәге Респ-ка мәдәният уч-щесе укытучысы. Бер үк вакытта 1985 тән Алабуга пед. ин-ты укытучысы, 2003 тән Өстәмә проф. белем бирү ин-ты директоры, 2006 дан профессор. Хезмәтләре земстволарның Россия тарихындагы роленә, аларның Вятка һәм Казан губерналарында мәгарифне, мәгърифәтне һәм китапханә эшен үстерүдә катнашуына; М.И.Цветаева иҗатына карый.

Х е з м.: Елабужское земство и Россия: Гуманно-просветительская деятельность Елабужского земства. М., 2002; Библиотечно-просветительская деятельность Казанского и Вятского земств. 1865–1917 годы. М., 2005; Елабуга-Харбин-Сидней: Потомкам И.Г.Стахеева посвящается. К., 2007 (автордаш); «Я телом здесь — душа с тобою»: О судьбах русской эмиграции // Австралиада. 2007. № 52.

**ВӘЛИ́ЕВА** Наилә Шәүкәт кызы (29.5.1953, Казан), педагог, пед. фән д-ры (1999), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли. 1983–86 елларда Һөнәри-техник педагогика фәнни-тикшеренү ин-тында. 1986 дан Казан технол. ун-тында, өстәмә белем бирү ф-ты деканы (1994–97), социаль педагогика һәм психол. каф. мөдире (1998). 2002 дән социаль-икътисад ф-ты деканы. Хезмәтләре өстәмә белем бирү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Научно-педагогические основы подготовки руководителей и специалистов для малых предприятий. К., 1994 (автордаш); Дополнительная подготовка будущих инженеров по программам управленческого профиля. К., 1998; Становление и развитие дополнительного профессионального образования студентов в техническом вузе. К., 1998; Социально-психологические основы менеджмента. Наб. Челны, 2000; Научно-педагогический потенциал химической школы Г.Х.Камая. К., 2005.

**ВӘЛИ́ЕВА** (Хәлилова) Резеда Тәфкалүн кызы (1.5.1930, хәзерге Башкортстан Респ-касының Кыйгы р-ны Дүшәмбикә а.), шагыйрә, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1952). 1952–85 елларда Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөхәррире. Балалар һәм өлкәннәр өчен язылган 30 дан артык шигырь һәм поэмалар җыентыклары авторы: «Минем дусларым» (1960), «Канатлы җайдак» (1966), «Зәңгәр алан әкияте» (1971), «Әниемә бүләк» (1978), «Шиңмәс чәчәкләр» (1983), «Дәү әнигә барабыз» (1994), «Нәниләр китабы» (2000) «Кояшлы яңгыр» (2003) һ.б. В. шигырьләре тематик яктан төрле, лирик аһәңнәргә бай, алар балаларда туган як табигатенә, үз халкына мәхәббәт тәрбияли, кыю, тапкыр, хезмәт сөючән булырга өнди. Дөньяны поэтик күзаллау В.ның проза әсәрләренә дә хас. Сугыш чоры авылы балалары тормышы, аларның үзара мөнәсәбәте, гади кешеләрнең шәфкатьлелеге, кешелеклелеге чагылыш тапкан «Якты яр» повесте (1985) шундыйлардан. Аның проза әсәрләре «Якты Ярда калган балачак» (2005) җыентыгында тупланган. «Китмә, сөю» (1998), «Күңелем гөлләре» (2002) шигъри җыентыклары, «Яраттым шул, яраттым» (2001), «Татар кызы» (2002), «Оч син, җырым» (2004) җыр китаплары да укучыларга яхшы билгеле. В. әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә эшли. Ул Л.Воронованың «Старшая сестра» («Дәү апа»), 1965; Н.Верзилинның «По следам Робинзона» («Робинзон эзләреннән»), 1958; Н.Поповның «Юность Андрея» («Андрейның яшьлеге»), 1960; Л.Смилянскийның «Сашко» (1961); А.Бартоның «Наш праздник» («Безнең бәйрәм»), 1980; С.Михалковның «Мы с приятелем» («Дустым белән икебез»), 1981 хикәя һәм шигырь җыентыкларын татар теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Н и г ъ м ә т у л л и н Э. Балалар дөньясына кереп // Социалистик Татарстан. 1981. 4 июль; И х с а н о в а Л. Яңа китап — яңа сөенеч // Шәһри Казан. 1994. 30 дек.; Г а т а ш Р. Яшьлеккә тугры шагыйрә // Казан утлары. 2000. № 5.

*Г.М.Габделхакова.*

**ВӘЛИ́ЕВА** Роза Алексей кызы (19.1.1954, Балык Бистәсе р-ны Казак Чаллысы а.), педагог, пед. фән. д-ры (1997), проф (1998). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1976). 1976–78 елларда Котлы Бөкәш урта мәктәбендә укыта. 1982 дән Казан пед. ун-тында (хәзерге Татар гуманитар пед. ун-ты), 1998 дән психол. ф-ты деканы. Хезмәтләре чит илләр педагогикасы тарихына, гуманистик тәрбия бирү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Гуманистическая педагогика Януша Корчака. К., 1994; Гуманистическое воспитание: опыт реформаторских школ Европы первой половины XX века. К., 1996; Теория и практика гуманистического воспитания в европейской педагогике (первая половина XX века). К., 1997; Корчак и Сухомлинский: как любить ребенка // Педагогика. 1998. № 6; Гуманистические и воспитательные системы вчера и сегодня (в описаниях их авторов и исследователей). М., 1998 (автордаш).

**ВӘЛИ́ЕВА** Халидә Гәрәй кызы (29.12.1920, Самара ш.), анатом, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1972). 1943 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1971–89 елларда кешенең нормаль анатомиясе каф. профессоры. Хезмәтләре кеше һәм умырткалы хайваннар әгъзаларының нерв элементлары морфологиясенә, эчке әгъзалар иннервациясенә карый.

Х е з м.: Материалы к вопросу о васкуляризации щитовидной железы. К., 1951; Сравнительно-морфологическое исследование нервного аппарата почки человека и представителей различных классов позвоночных животных. К., 1969; Сравнительно-анатомическое исследование иннервации почек человека и позвоночных животных. К., 1972.

*Әд.:* Зарубежные и отечественные анатомы. К., 1977.

**ВӘЛИ́ЕВА-СӨЛӘЙМА́НОВА** Гүзәл Фуад кызы (2.1.1952, Казан), сәнгать белгече, сәнгать фән. д-ры (1998). ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2007). Казан төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң, төбәк «Союзспортпроект»ның Казан остаханәсендә өлкән архитектор булып эшли (1974–76). 1976 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 2001 дән Тарих ин-тында, бер үк вакытта 1995 тән Татар энциклопедиясе ин-тында эшли, Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты профессоры (2001). Тикшеренүләрнең төп юнәлешләре: 20 йөз Татарстан монументаль бизәлеш һәм гамәли бизәлеш сәнгате; урта гасырлар һәм 18 йөз — 20 йөз башы татар бизәлеш сәнгате тарихы; Идел һәм Урал буе татарларының зәркән сәнгате; хәзерге заман татар рәссамнары иҗатында милли традицияләрнең дәвамы; Татарстан төбәкләрендә һәм аннан читтә татар халык сәнгате. Татар сәнгате тарихы буенча чит илләрдә дөнья күргән хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Монументально-декоративное искусство Советской Татарии. К., 1984; Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990 (автордаш); Из истории изобразительного искусства // Культура и искусство родного края: В 2 кн. К., 1993–94; Декоративное искусство Татарстана (1920-е — 1990-е гг.) К., 1995; Искусство керамики Татарстана. Художник Б.Шубин. К., 1999; Древнее искусство Татарстана. К., 2002 (автордаш); The Islamic Culture of the Middle Volga region: roots and perspectives // Tatarstan: past and present. L., 1992; Tatar Art and Culture at the Cressreads of Civilization // The Turkie Speaking Peopees. 2000 years of Art and Culture from Ynner Asia to Balkans. Münich, 2006.

*Әд.:* Мәхәббәт һәм матурлык кушылмасы // Идел. 1998. № 11; Күренекле шәхесләребез // Мирас. 1999. № 3; Уметь расставить приоритеты // Идель. 1998. № 11.

*М.Е.Ильина.*

**ВӘЛИМӨХӘММӘ́ТОВА** Дания Абдулла кызы (1.6.1930, Кукмара р-ны Олыяз а.), терапевт, мед. фән. д-ры (1973), проф. (1976), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1990). 1954 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук госпиталь терапиясе кафедрасында эшли. 1974–80 елларда клиник фармакология һәм госпиталь терапиясе, 1980–95 тә клиник фармакология һәм эчке авырулар каф. мөдире. Хезмәтләре субкүзәнәкләрдә яңа биологик актив матдәләрне өйрәнүгә карый. Ике авторлык таныклыгы бар, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Диагностические возможности инструментального исследования дыхания // Казан. мед. журн. 1976. № 3; Эффективность мебикара при хронической ИБС // Казан. мед. журн. 1984. № 6; Вероятностная этиологическая диагностика острых пневмоний // Казан. мед. журн. 1994. № 6; Спектрофотометрическое определение фосфабензида в биологических жидкостях // Химфарм. хирургия. 1995. № 8.

*Әд.:* Андреев И.М., Красильников С.Н. Стоматологический факультет: История в биографиях. К., 1996.

**ВӘЛИ́ТОВ** Марсель Галиәкбәр улы (3.10.1937, Мөслим р-ны Мөслим а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1991). 1959 елда Алабуга пед. ин-тын, 1973 тә КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фән. академиясен тәмамлый. 1959–60 та «Колхоз байрагы» (Мөслим р-ны) г-тасының җаваплы сәркәтибе, 1960–61 дә ВЛКСМның Мөслим райкомы беренче секретаре. 1963–65 тә «Ленинчы» (Сарман р-ны) г-тасының мөхәррир урынбасары, 1965–67 дә «Авыл утлары» (Мөслим р-ны) г-тасы мөхәррире, 1967–70 тә КПССның Мөслим райкомы икенче секретаре. 1973–89 елларда ВЦСПСның производство-масса эшләре бүлегендә сектор мөдире, 1989–90 да «Социалистическое соревнование» ж-лының баш мөхәррире, 1990 нан «Профсоюзы и экономика» ж-лының баш мөхәррире. Фәнни тикшеренүләре җитештерү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре системасы өлкәсенә, икътисадны глобальләштерүгә, экология мәсьәләләренә карый. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Развитие соревнования и совершенствование социалистических производственных отношений. М., 1978; Социалистическое соревнование: механизм использования. М., 1989; Культура бизнеса: Справ.-самоучитель ключевых терминов. М., 1992 (автордаш).

**ВӘЛИ́ТОВ** Наил Бәкер улы (2.5.1938, Үзбәкстан ССР, Бохара ш.), геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1984), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1961), ЦНИИгеолнерудта эшли, 1986 елдан агрохимик чимал геологиясе бүлеге мөдире, 1991 дән фәнни эшләр буенча директор урынбасары, 2002 дән баш фәнни хезмәткәр. Татарстан терр-ясендәге нефть үзлекләре үзгәрүнең региональ һәм локаль закончалыкларын алар яткан урыннарның геологик шартларына бәйле рәвештә билгели; углеводородлы газларда күкертле водородның сәнәгый концентрациясе формалашуның яңа гипотезасын исбатлый. Күкертле нефть әверелешләренең табигый процессларында карбонатлы токымнарның каталитик үзенчәлекләрен билгели. Туфракның техноген күкерт б-н пычрануын бәяләү методикасын эшкәртә. Аның нефть һәм газларда күкерт запасын исәпләү методикасы РФнең файдалы казылма запаслары буенча Дәүләт комиссиясе тарафыннан кулланыла. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Атлас руд серных месторождений СССР. М., 1990; Динамическая модель экзогенного серообразования // Советская геология. 1990. № 9; Минеральное сырьё. Сера: Справ. М., 1997.

**ВӘЛИ́ТОВ** Наил Камил улы (30.5.1941, Казан), кинорежиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980). 1962 елдан Казан кинохроника студиясендә: оператор ассистенты, мультфильмнар цехында төшерүче. Бөтенсоюз кинематография ин-тының кино төшерү ф-тын тәмамлый (1973, Мәскәү). 1973–88 дә Казан кинохроника студиясендә кинорежиссёр. 1988–95 тә ТРның Кинематографистлар берлеге каршындагы киновидеоүзәктә, 1995–98 дә «Татарвидео» берлегендә сәнгать җитәкчесе, 1998 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында кино бүлеге мөдире. ТРның әйдәп баручы кинорежиссёрларыннан берсе, техник-пропаганда һәм хроника-документаль фильмнар төшерү остасы, аның күп кенә эшләре татар кинодокументалистикасында сизелерлек эз калдыра. «Җәлил. Көрәш сәхифәләре» («Джалиль. Страницы борьбы», 1975) фильмы б-н ул үзен материалны тирән аңлаучы, сюжетка үзенчә якын килә белүче җитлеккән оста итеп күрсәтә. В. төшергән фильмнар: «КамАЗ. Династия барлыкка килү» («КамАЗ. Рождение династии», 1977), «Сабан туена бару юлы» («Дорога на Сабантуй», 1980), «Владимир Кокурин мәктәбе» («Школа Владимира Кокурина», 1987) һ.б. 1980 дә «Җәлил. Көрәш сәхифәләре» һәм «Сабан туена бару юлы» фильмнары өчен Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге бирелә. 1990–93 тә ТР Кинематографистлар берлеген җитәкли.

**ВӘЛИ́ТОВ** Раил Бәкер улы (18.1.1940, Үзбәкстан ССР, Бохара ш.,), химик-технолог, техник фән. д-ры (1973), Башкортстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы (1993), Башкортстан АССРның атказ. фән эшлеклесе (1984) һәм атказ. уйлап табучысы (1981). 1963 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, Эстәрлетамак синтетик каучук з-дында эшли. 1968–74 тә Эстәрлетамак химия з-дында үзәк завод лабораториясенең җитәкче урынбасары һәм җитәкчесе. 1974 тән Уфа нефть ин-тының органик химия каф. мөдире, проф. 1981 дән Башкортстан Респ-касы ФАнең Гербицидлар һәм үсемлекләр үсешен көйләү фәнни-тикшеренү технол. ин-тында директор урынбасары, 1992 дән директор, 2007 дән фәнни консультант. Хезмәтләре хлор-органик һәм нефтехимик синтезга, үсемлекләрне химик саклауга карый. Олефин углеводородларны алу максатыннан җиңел углеводород фракцияләренең, газ конденсатлары һәм нефтьләрнең каталитик таркалуын өйрәнә. Этилендиамин, пиперазин, винилхлорид, полихлорэтиленнар җитештерү технологияләрен Эстәрлетамак «Каустик» җитештерү берләшмәсендә эшли һәм камилләштерә. Мазутны традицион ысуллар б-н алуга караганда күбрәк продукт чыгара торган каталитик эшкәртү технологиясен эшли. Биологик актив кушылмаларны булдыру, үсемлекләрне саклау өчен яңа химик чаралар һәм вет. препаратлары җитештерү б-н җитәкчелек итә.

Х е з м.: Производство хлоруглеводородов. Уфа, 1978; Производство хлоролефинов. Уфа, 1978; Справочник по пестицидам. Уфа, 1992.

**ВӘЛИ́ТОВ** Шамил Мәхмүт улы (21.12.1955, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1998), проф. (1998), ТРның атказ. икътисадчысы (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1978 елда Ленинград финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1984 елдан Казан финанс-икътисад ин-тында эшли, 1998–2004 тә җитештерү икътисады каф. мөдире, 2000 нән фәнни эшләр буенча проректор. Сәнәгатьне реформалаштыру, базар мөнәсәбәтләре шартларында оештыру формалары һәм хосусыйлаштыру проблемалары буенча тикшеренүләр авторы. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Холдинг: особенности организации и механизм функционирования. К., 1996; Индикативное планирование в экономических системах разного уровня. К., 2003.

**ВӘЛИ́ТОВА** Кояш Гыйльфан кызы (апрель 1898, Качкар приискы, хәзерге Чиләбе өлкәсе — 27.9.1985, Мәскәү), педагог. Рәмиевләрнең Балкан авылындагы кызлар мәктәбендә, Казанда кыз балалар гимназиясендә укый, Мамадыш шәһәрендә рус-татар мәктәбендә укыта. 1918 елда Казанда ике татар балалар бакчасы ача. 1927 дән — Мәскәүдә, татар балалар бакчасы мөдире, Үзәк татар эшчеләр клубында эшли. Казанда нәшер ителүче татар матбугатында, аеруча «Азат хатын» журналында көндәлек тормышка кагылышлы мәкаләләре, истәлекләре еш басыла.

Х е з м.: Мәктәпкә кадәр тәрбия // Мәгариф. 1921; Балалар бакчасында ничек эшләргә. М., 1929.

**ВӘЛИ́ТОВА** Наилә Минһаҗ кызы (15.3.1946, Кукмара штп), тәрҗемәче. Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), Әгерҗе р-ны Иж Бубый авылында урта мәктәптә укыта. 1971–2001 елларда Казанда Татарстан китап нәшриятында эшли. Татар теленә Э.Н.Успенскийның «Крокодил Гена һәм аның дуслары» (1976, «Крокодил Гена и его друзья»), В.Г.Распутинның «Онытма гомергә» («Живи и помни», 1983) повестьларын, Н.Думбадзеның «Мәңгелек канун» (1986,

«Закон вечности») романын, А.Милнның «Винни-Пух маҗаралары» (1991, «Приключения Винни-Пуха») әкият-повестен тәрҗемә итә.

**ВӘЛИ́ТОВА** Нәбилә Габделхәмит кызы (28.12.1928, хәзерге Башкортстан Респ-касының Чакмагыш р-ны Сыйрышбаш а. — 11.10.2006, Воронеж ш.), балет артисткасы, педагог, РСФСРның халык артисты (1969). А.Я.Ваганова исем. Ленинград хореография уч-щесен тәмамлый (1949). 1949–61 елларда Башкортстан, 1961–75 тә Воронеж опера һәм балет театрлары солисткасы. 1976–79 да Воронеж хореография уч-щесе сәнгать җитәкчесе, 1979–86 да баш балетмейстер, 1991 елда Воронеж опера һәм балет театрында балет сәнгате җитәкчесе. Төп хореографик партияләре: Жизель (шул исем., А.Адан), Эсмеральда (шул исем., У.Пуни), Одетта-Одиллия, Аврора («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Китри («Дон Кихот», Л.Минкус), Лауренсия (шул исем., А.Крейн), Зарема («Бакчасарай фонтаны», Б.Асафьев), Джульетта («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Сари («Яшен юлыннан», К.Кара-Караев) һ.б. В.ның иҗади йөзе — хәзерге заман һәм классик балет репертуарларындагы төрле пландагы хореографик партияләрне сәхнәдә тәэсирле чагылдыруы һәм проф. осталыгы б-н аерылып тора. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Валитова Набиля Гаптельхаметовна // Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

**ВӘЛИ́ТОВА** Рәмзия Гыйлаҗ кызы (29.3.1914, Уфа губ. Эстәрлетамак ш. — 22.10.2002, Арча), педагог. ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1961). Эстәрлетамак пед. техникумын тәмамлаганнан соң, 1931–33 елларда Башкортстан АССРда башлангыч мәктәпләрдә эшли. Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1937). 1937–69 да Арча пед. уч-щесендә татар теле һәм әдәбиятын, татар теле методикасын укыта. Шәкертләре арасында күренекле язучылар Г.А.Ахунов, М.С.Мәһдиев, С.Ф.Шакир, әдәбият тәнкыйтьчесе Ф.М.Миңнуллин һ.б. бар.

Хезмәтләре татар мәктәбенең башлангыч сыйныфларында татар теле укыту методикасына, аны камилләштерүгә карый; татар әлифбалары, ш.и. 1965–2006 да 42 тапкыр басылып чыккан «Әлифба» автордашы (С.Г.*Вагыйзов* б-н берлектә). Медальләр б-н бүләкләнә. ТАССР Мәгариф министрлыгының К.Насыйри исем. бүләге лауреаты (1988).

Хезм.: Әлифба. К., 1965; Әлифбага методик кулланма. К., 1966; Туган тел. К., 1969; Татар теле. К., 1982; Уку һәм язу китабы. К., 1986; Татар теле буенча дидактик материаллар. К., 1997.

*Әд.:* Ибраһимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана. К., 1994.

**ВӘЛИУ́ЛЛИН** Аллаһияр Гарифулла улы (5.7.1924, Мамадыш кантоны Байлар Сабасы а. — 18.9.1972, Казан), композитор. Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан музыка уч-щесен (1946), Казан консерваториясен (1952) тәмамлый. Ю.Виноградов, М.Юдин һәм А.Леман шәкерте. Иҗатында җыр жанры зур урын тота. Композиторның Н.Баян, Х.Вахит, Ә.Камал, Ф.Кәрим, З.Нури һ.б. татар шагыйрьләре шигырьләренә язылган җырларының күпчелеге шул заман вакыйгаларына багышланган (туган ил, Бөек Ватан сугышы турында әсәрләр). В. җырлары тыңлаучыны көйләренең аңлаешлы һәм тәэсирле булуы б-н җәлеп итә, халыкта популярлык казана. В. татар симфониясе үсешенә зур өлеш кертә. Аның симфоник әсәрләредә тарихи-революцион һәм заман тематикасы өстенлек итә. В.ның симф. иҗаты, башка жанрлардагы әсәрләре кебек үк, милли музыка традицияләре б-н аерылгысыз бәйләнгән, образлары күптөрле һәм тирән мәгънәле. Симфонияләренең берсе Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында (1957) башкарылган.



А.Г.Вәлиуллин.

Әсәрләре: «Язгы җилләр» операсы (К.Нәҗми романы нигезендә, Р.Хисамов либр.), Симфония (1956); «Дуслык сугышны җиңә» (1952), «Спас күтәрелеше» (1958 — 1 нче редакция, 1964 — 2 нче редакция); «Яшьлек» (1964 — 1 нче редакция, 1967 — 2 нче редакция) симф. поэмалары; камера-инструменталь әсәрләр, драма спектакльләренә музыка, җырлар, татар халык җырларына эшкәртмәләр һ.б. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Композиторы Советского Татарстана. К., 1957; Бикчурина Ф.Ш. Аллагиар Валиуллин // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

**ВӘЛИУ́ЛЛИН** Виктор Владимирович (2.7.1953, Киев), биохимик, гистолог, биол. фән. д-ры (1987), проф. (2000). 1975 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1980 елдан Казан мед. ун-тында: гистология кафедрасында укыта, 2003 тән тәрбия эшләре буенча проректор. Хезмәтләре кыскарту аксымнарының, скелетның тиз һәм салмак скелет мускулларының сыйфат составын нервлар аша көйләү механизмына карый; скелет мускулларының миозин сыйфатын саклауда тиреоид глюко-картикоид һәм җенес гормоннары ролен; скелет мускулларының миозин составына сенсибилизация тәэсирен тикшерә. Тикшерену нәтиҗәләре нигезендә скелет мускулларының сыгылмалылыгын нейротрофик күзәтүнең һәм гумораль көйләүнең төп принципларын тәгъбирли, организмның гумораль һәм нерв системаларының скелет мускуллары фенотипларын бәйсез механизмнар аша көйләвен исбатлый.

Хезм.: Влияние тироксина на фенотип интактных и денервированных скелетных мышц морской свинки // Бюллетень экспериментальной биологии и медицины. 1983. Т. 96, № 9; Нейротрофический контроль синтеза миозинов медленной мышцы морской свинки // Бюллетень экспериментальной биологии и медицины. 1991. Т. 11, № 2.

**ВӘЛИУ́ЛЛИН** Госман Хәбибулла улы (26.1.1937, Әлки р-ны Түбән Чаллы а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, а.х. фән. канд. (1981), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), РСФСРның атказ. агрономы (1980). 1965 елда Казан а. х. ин-тын тәмамлый. 1963 тән Әлки р-нының «Актай» с-зы агрономы, 1965 тән Лаеш р-нында: «Комсомольский» с-зы агрономы, 1968 дән «Атабай» с-зы директоры, 1970 тән А.х. идарәсе башлыгы һәм бер үк вакытта райбашкарма комитеты рәисе, 1976–2001 елларда «Столбище» тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы директоры. В. җитәкчелегендә элиталы орлыкчылыкның матди-техник базасы булдырыла, терлекчелек комплекслары төзелә, игенчелек һәм терлекчелекнең яңа системалары гамәлгә кертелә. 1 *га* дан 50 *ц* дан артык бөртекле уңыш, 1 сыердан 3000 *кг* сөт савып алына; тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы игенчелек һәм терлекчелектә алдынгы алымнарны һәм хезмәтне оештыруның яңа формаларын гамәлгә кертү мәктәбенә әверелә. Дәүләт бүләге уҗым бодаеның кышкы шартларга һәм корылыкка чыдам «Казан-84», «Мишә-2» сортларын чыгарган һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Ленин, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Углубление пахотного слоя // Зерновое хозяйство. 1980. № 4 (автордаш); Как повысить питательность кормов. К., 1981 (автордаш); Интенсификация возделывания зерновых культур в Татарии. К., 1987 (автордаш).

**ВӘЛИУ́ЛЛИН** Мәҗит Әгъли улы (24.7.1941, Саба р-ны Йосыф-Алан а.), журналист, ТАССР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1988, 2003). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1967). 1961 елдан Казан мәктәпләрендә укытучы. 1967 дән «Яшь ленинчы» г-тасында, 1975 тән бүлек мөдире. 1977 дән «Мәгариф» ж-лында (педагогика һәм методика бүлеге мөхәррире, 1986–87 дә җаваплы сәркәтип, 1987 дән баш мөхәррир урынбасары). В.ның очерк һәм мәкаләләре «Ватаным Татарстан», «Советская Татария» г-таларында, «Азат хатын», «Ялкын» ж-лларында басыла. Язмаларында РФ һәм ТРда мәгариф системасының үсеш юлларын, яшь буынны укыту һәм әхлак тәрбиясе бирү мәсьәләләрен яктырта.

Әсәр.: Укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү. К., 1988; Без — Ильич оныклары. К., 1990; 3 нче класста татар теле дәресләре. К., 1999 (автордаш).

**ВӘЛИУ́ЛЛИН** Нәбиулла Кәлимулла улы (март, 1911, Ростов-Дон ш., — 1943), нәкышьче, педагог. И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын тәмамлый (1937). Казан сәнгать уч-щесенең татар төркемендә укыта (1937–41). Шәкертләре: Х.*Якупов*, Л.*Фәттахов*, Г.*Рахманкулова*, Ә.*Тумашев*, К.Бикчәнтәев, У.Яруллин, Г.Маннапов, Ә.Килмәтев, Р.Пономарёв һ.б. ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1938) һәм идарәсе рәисе (1939–40). 1930–40 елларда тематик картина өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Төп әсәрләре: «Колхозчы татар хатыннары» (1936), «Авылга агитатор килде» (1937), «Татар авылында Октябрь. Агитатор» (1938–39), «Мөрәле МТСының орденлы тракторчысы Т.Әдиятуллин» (1930), «Актаныш МТСының орденлы тракторчысы Т.Вәлиев» (1930), «Колхозчы татар хатыны» (1941). Картиналары



Н.К.В ә л и у л л и н. «Татар хатыны». 1941. Шәхси җыелма.

Окт. рев-циясенең 25 еллыгына (1942), ТАССРның 25 еллыгына һәм Казан сәнгать мәктәбенең 50 еллыгына (1944) багышланган Казан рәссамнары әсәрләре күргәзмәләрендә куела. Бөек Ватан сугышында катнаша. Харьков янында һәлак була.

*Әд.:* Изобразительное искусство Советского Татарстана: Альбом. К., 1957; Искусство стран и народов мира: Краткая художественная энцикл. М., 1971. Т. 3; Я к у п о в Х. Фронтовые зарисовки: Записки художника. К., 1981; Р а х м а н к у л о в а Г. Радость творчества // Казань. 1997. № 7.

*Г.А.Могильникова.*

**ВӘЛИУ́ЛЛИН** Рәзим Нәгыйм улы (3.1.1942, Зәй р-ны Кәдек а.), шагыйрь, композитор, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1967). 1967–93 елларда Лениногорск шәһәре музыка-сәнгать пед. уч-щесе укытучысы. 1993 тән ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җаваплы сәркәтибе, бер үк вакытта 1997 дән ТР Композиторлар берлегенең Әлмәт бүлеге рәисе. Шигырьләре «Беренче карлыгачлар» исемле күмәк җыентыкта (1970), «Үз ягым» (1994), «Зирекле елга» (1994), «Уч төбендә кояш» (1995), «Ак тулпарда» (1996), «Игелек иярләре» (Әлмәт, 2001), «Сөюгә сөйкәнү» (Әлмәт, 2001), «Сүзем бар» (2003), «Иманыбыз камил» (2005) исемле шигырь китапларында дөнья күрә. В. шигъриятенә нечкә лиризм б-н сугарылган публицистик пафос хас. Ул татар халкының үзенчәлекле мәдәни мирасын саклап калу мәсьәләләрен күтәрә. С.Есенин, А.Блок, А.Ахматова шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итә. Музыка өлкәсендә В. татар җыр сәнгате традицияләренә таянып эшли. Ул — 150 дән артык җыр һәм романс (ш.и. үз шигырьләренә), 30 лап хор әсәре, симфоник сюиталар (1981; 1998), кыллы квартет, скрипка һәм фортепиано өчен пьесалар, балалар өчен җырлар җыентыгы авторы («Күңел дулкыны», 2007). Япон шагыйре Исикава Такубокуның шигырьләрен татарчага тәрҗемә итеп «Бер уч ком» (1996) исемле җыентыкка туплап бастыра.

*Әд.:* Х ә л и м А. Үз тавышым үземә ошамый... // Аргамак. 1997. № 1; Ю н ы с М. Кечкенә утрауның комлы ярында // Идел. 1998. № 8.

**ВӘЛИУ́ЛЛИН** Хөснулла Вәлиулла улы (28.2.1914, Казан губ., Мамадыш өязе Байлар Сабасы а. — 24.9.1993, Казан), композитор, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1966, 1974). Казан музыка уч-щесен (1940, В.Виноградовта), Казан консерваториясен (1950, А.Леманда) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950–51 елларда Казан музыка уч-щесе укытучысы, 1968–73 тә һәм 1978–81 дә Татарстан китап нәшриятында муз. әдәбият редакторы. В. иҗатында опера жанры үзәк урынны алып тора. Лирик-психологик рухтагы «*Самат*» операсы (Х.Вахит либр.) татар опера сәхнәсендә шул заман темаларын чагылдырган, муз. театр өчен иң уңышлы әсәрләрдән санала. *Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында* (1957) операның 1 нче редакциясе зур уңыш б-н күрсәтелә; 2 нче редакциясе муз. драматургиянең тирәнлеге һәм бөтенлеге, муз. яңгырашны симфонияләштерү тенденциясе б-н үзенчәлекле. «Самат» (2 нче редакциясе, 1977) операсында композитор талантының иң көчле яклары — тирән лиризм, музыка теленең халык җырларына нигезләнүе, көйләрнең интонацион һәм ритмик байлыгы чагылыш таба. В. татар җыр музыка үсешенә зур өлеш кертә. Аның Г.Тукай, М.Җәлил, Ә.Ерикәй, Х.Вахит, С.Хәким, Р.Фәйзуллин һ.б.ның шигырьләренә язылган җырларына һәм романсларына темалар байлыгы һәм ачык яңгырашлы көйләр хас. Төп әсәрләре — «Дим буенда» (1965) операсы, «Туган як» (1970) кантатасы, камера-инструменталь әсәрләр, җырлар һәм романслар, драма спектакльләренә музыка һ.б.; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1989).

*Әд.:* Ф ә й з у л л а е в а М. Х.Вәлиуллин иҗаты // Казан утлары. 1983. № 3; Х а й р у л л и н а З. Хуснулла Валиуллович Валиуллин // Композиторы Советского Татарстана. К., 1957; Ф а й з и Дж. Х.Валиуллин // Советская музыка. 1964. № 2; Б е р н а н д Г., Я м п о л ь с к и й И. Валиуллин Хуснулла Валиуллович // Советские композиторы и музыковеды. М., 1978. Т. 1; Б и к ч у р и н а Ф. Хуснулла Валиуллин // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

**ВӘЛИУ́ЛЛИНА** Зөһрә Мәҗит кызы (8.6.1925, Башкортстан АССРның Әлшәй р-ны Никифар а.), тел галиме, филол. фән. канд. (1954), ТАССРның атказ. укытучысы (1975). Ленинград ун-тын тәмамлый (1949). 1953–92 елларда Казан пед. ин-тында укыта. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: рус һәм татар телләрен чагыштырып өйрәнү; хәзерге татар теленең морфологиясе, синтаксисы һәм терминологиясе. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен хәзерге татар теле дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Хәзерге татар әдәби теле: Сүз ясалышы. Морфология. К., 1992; Синтаксис простого предложения // Грамматика татарского языка. Синтаксис. К., 1964; Сопоставительная грамматика русского и татарского языков. К., 1983.

**ВӘЛИХА́НОВ** Әгъзам Вәлихан улы (27.2.1927, БАССРның Мишкә р-ны Бабаев а. — 5.10.2006, Әлмәт ш.), сәнәгать җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1971), техник фән. канд. (1970), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1977). Уфа нефть ин-тын (1953) һәм Халык хуҗалыгы академиясен (1974, Мәскәү) тәмамлый. 1953–77 елларда «Татнефть» җитештерү берләшмәсендә: «Бөгелмәнефть» нефть промыселы идарәсенең бораулау мастеры, участок башлыгы, өлкән инженер, 1957–62 дә «Азнакайнефть» нефть промыселы идарәсендә баш инженер, 2 нче нефть промыселы мөдире, 1962–65 тә «Елховнефть», «Әлмәтнефть» нефть промыселы идарәләрендә башлык, 1965 тән «Татнефть» җитештерү берләшмәсе башлыгы, 1976 дан ген. директоры. В. Ромашкино (Азнакай, Зеленогорск, Павлов мәйданнары) һәм Яңа Елховой нефть чыганакларын файдалануга тапшыруда катнаша. Ул җитәкчелек иткән елларда берләшмәдә нефть чыгару иң югары күләмгә җитә (1975 елда — 103,7 млн. *т*), һәм бу күрсәткеч берничә ел буе саклана. 1977 дән Мәскәүдә: СССРның нефть сәнәгате министры урынбасары, 1985–87 дә Бөтенсоюз нефть һәм газ сәнәгатенең икътисад һәм идарә итүне оештыру фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, 1990 нан «Энергосбережение» АҖнең фәнни-техник коллективы җитәкчесе, 1992–94 тә «Норд-Вест» АҖнең директор урынбасары, вице-президенты. В. җитәкчелегендә Көнбатыш Себер, Коми АССР, Казакъстан, БАССР, Пермь һәм Оренбург өлкәләре һәм СССРның башка төбәкләрендә нефть чыганаклары үзләштерелә. Фәнни хезмәтләре нефть, газ һәм газ конденсатлары чыганакларын өйрәнү мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы бар. 1963–67 дә ТАССР ЮС, 1966–79 да СССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Х.В.Вәлиуллин.



Ә.В.Вәлиханов.

Х е з м.: Татария — крупнейший нефтегазодобывающий район Советского Союза // Нефтяное хозяйство. 1967. № 11; Очаговое заводнение — эффективный метод интенсификации разработки. К., 1968; Промышленный эксперимент по закачке воды при давлении, близком к горному // Исследователи — производству: Сборник. Альметьевск, 1969. Вып. 5; Об эффективности повышения давления нагнетания при разработке слабопроницаемых пластов // Исследователи — производству: Сборник. Альметьевск. 1970. Вып. 6; Разработка малопродуктивных коллекторов. К., 1970; Вопросы подъёма обводнённой и безводной нефти фонтанным и насосными способами. К., 1971; Оптимизация процессов сбора, транспорта и подготовки нефти. К., 1971.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2.

**ВӘЛИ́ШЕВ** Булат Мөхәммәт улы (4.2.1928, Казан), инженер-механик, СССР һәм ТР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1978, 2002),

РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1990). 1951 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, 747 нче з-дта (хәзер Казан авиация җитештерү берләшмәсе) инженер-конструктор булып эшли. 1953–55 елларда Норлат (хәзерге Яшел Үзән) р-ны Ачасыр МТСнда баш инженер. 1955–76 да Мәскәү вертолёт з-дының 1 нче филиалында (Казан) инженер-конструктор, конструкторлык бүлеге җитәкчесе урынбасары, филиал җитәкчесе урынбасары. 1976–2000 дә «Казан вертолёт заводы» АҖнең баш инженеры. В. Ми-4, Ми-8, Ми-14, Ми-17 вертолётлары төзүгә һәм сериялəп җитештерүгә, аларны модернизацияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, ш.у. производствоны яңадан җиһазландыруга зур өлеш кертә. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге машиналар төзү өлкәсендә яңа техника җитештерүне үзләштергәне өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. Авиация һәм космонавтика федерациясенең М.Л.Миль исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Обретение высоты // Казань. 1999. № 3/4.

*Әд.:* М о р о ш е к Е.М. На вертикальном взлёте. К., 1990; Казанские вертолёты: полёт продолжается. К., 2000.

**ВӘЛИ́ШИН** Мифтахетдин (1811, Казан губ., Казан өязе Кушлавыч а. — 1904, Казан), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре. Затлы мех һ.б. әйберләр б-н сәүдә иткән. Сәүдәгәр Г.Х.Абдуллин б-н бергә 1880 елда Яңа Татар бистәсендә 2 катлы мәдрәсә бинасы төзетә. Казанда Мәрҗани мәчете бинасын үзгәртеп коруга, Мәрҗән, Мулла Иле, Атабай, Аты авыллары мәчетләре төзелешенә акчалата ярдәм итә.

*Р.Р.Салихов.*

**ВӘЛИ́ШИН** Эдуард Салих улы (27.7.1936, Кабарда-Балкар АССР, Нальчик ш.), анатом, мед. фән. д-ры (1986), проф. (1987). 1960 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Дөбъяз р-нында эшли. 1962 елдан Казан мед. ун-тында, 1985 тән кешенең нормаль анатомиясе каф. мөдире. Хезмәтләре эмбриофилогенезда микроциркуляр кан әйләнеше юллары төзелешенең оешуын, ш.у. төрле тәҗрибәләр тәэсирендә, нормаль халәттә һәм патологиядә бер үк әгъзаның кан йөрешен көйләү һәм үзгәртү механизмнарын өйрәнүгә карый. Тикшеренү нәтиҗәләре ангиоархитектониканың кешеләрдә мөмкин булган вариантларын, ш.у. табибнең тәэсир итүе һәм патология вакытында кан тамырларының төрле реакцияләрен алдан аңлатырга мөмкинлек бирә.

Х е з м.: Влияние денервации почки на течение патологического процесса при нарушении нормального венозного оттока // Материалы юбилейной науч. конф., посвященной 150-летию со дня основания института. К., 1964; Т. 14; Становление мочевых структур, микроциркуляторного кровеносного русла дефинитивных почек и его потенциальных возможностей в сравнительно-анатомическом и эмбриологическом освещении. К., 1985.

**ВӘЛҮ́Л**, А к ы ш елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Чирмешәннең уң кушылдыгы. Озынлыгы 9 *км*, бассейнының мәйданы 69,3 *км*². Алексеев р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Баганалы урманчылыгы посёлогының көньяк-көнчыгыш читендә, тамагы Югары Татар Майнасы авылыннан 6,6 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 156 *м*, тамагынықы — 98 *м*. Су җыелу мәйданындагы урман күләме 37%. В. елгасының 2,1 дән алып 6,6 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнга еллык су агып төшүнең уртача күпьеллык катламы 93 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. В. елгасы ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**ВӘРӘ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ыкның уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,5 *км*, бассейнының мәйданы 49,6 *км*². Мөслим р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Вәрәшбаш авылыннан 2,5 *км* көнчыгыштарак, тамагы Иске Вәрәш авылыннан 2,2 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагынықы — 72 *м*. Су җыелу мәйданындагы урман күләме 31%. В. елгасының 0,5 тән алып 2,1 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,2–0,5 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнга еллык су агып төшүнең уртача күпьеллык катламы 120 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. В. елгасы ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–600 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. В. елгасында күләме 0,4 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**ВӘРӘШБА́Ш** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 9 *км* төньяктарак, Вәрәш елгасы буенда. 2002 елда 335 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. Китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы башкорт-вотчинниклар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, В. та мәчет, мәктәп, 3 су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ирехтин волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 440, 1897 дә — 878, 1920 дә — 1169, 1926 да — 1157, 1938 дә — 975, 1949 да — 738, 1958 дә — 630, 1970 тә — 609, 1979 да — 626, 1989 да — 374 кеше.

**ВӘРҖӘДЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Эстәрленең сул кушылдыгы (Ык елгасы бассейны). Озынлыгы 12,8 *км*, бассейнының мәйданы 69,2 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Азнакай р-нында ага. Елга башы Зирекле Елга авылыннан 1,6 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Уразай авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 240 *м*, тамагынықы — 129 *м*. Су җыелу мәйданындагы урман күләме 57%. В. елгасының 1,5 һәм 7,6 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнга еллык су агып төшүнең уртача күпьеллык катламы 83 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. В. елгасы ноябрьнең беренче ун көне эчендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* га кадәр. Елгада күләме 0,4 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла. В.нең сулъяк ярында Уразай авылыннан өстәрәк «Чатыр тау» комплекслы табигать саклаулыгы урнашкан.

**ВӘТКӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмәнең уң кушылдыгы. Озынлыгы 17,3 *км*, бассейнының мәйданы 137 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елга башы Әлмәт р-нының Дәүләт авылы (хәзер кеше яшәми) янында, Лениногорск р-ны терр-ясеннән ага, тамагы Чирмешән р-нының Софиевка авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагынықы — 84 *м*. Су җыелу мәйданындагы урман күләме 40%. В. елгасының 1,8 дән алып 8,1 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлы. Бассейнга еллык су агып төшүнең уртача күпьеллык катламы 117 *мм*, ташу агымы катламы 85 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. В. елгасы ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,149 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20 *мг-экв/л* дан күбрәк). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–7000 *мг/л*. В.бассейнында күләме 0,9 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**ВВЕДЕ́НСКИЙ БИСТӘСЕ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 25 *км* көнбатыштарак, Зөя елгасы тамагы



Введенский бистәсе. Введение чиркәве. 1782–89.

янында. 2002 елда 301 кеше (руслар — 74%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Китапханә. 1557 дән Басурман Бистәсе исеме б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чүлмәк ясау, тире эшкәртү һәм чи каеш эшләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Введение чиркәве (1782–89 да төзелә, 1990 еллар ахырында яңадан эшли башлый), земство уч-щесе, 6 кирпеч һәм 4 чи каеш з-ды, 4 чүлмәк ясау остаханәсе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатьенең имана җире 383,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1859 да — 397, 1897 дә — 354, 1908 дә — 361, 1926 да — 519, 1949 да — 572, 1958 дә — 272, 1970 тә — 268, 1979 да — 191, 1989 да — 317 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

**ВДОВИ́Н** Евгений Васильевич (1.6.1952, Орёл ш.), генерал-лейтенант (2003). Тула политехника ин-тын (1976), СССР КГБ Югары мәктәбен (1981, Мәскәү) тәмамлый. 1981–91 елларда — СССР КГБсы, 1992–93 тә — РФ Иминлек министрлыгында, 1993–95 тә РФ Федераль контрразведка хезмәтенең Орёл өлкәсе идарәсендә. РФ Федераль иминлек хезмәтенең 1995–98 дә — Магадан, 1998–2002 дә Брянск өлкәсе идарәсендә җитәкче урынбасары. РФ Федераль иминлек хезмәтенең 2002–04 елларда — Удмурт Респ-касы, 2004 тән ТР идарәсе җитәкчесе. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ВЕ́ГЕР** Евгений Ильич (21.9.1899, Кострома губ. Лисцово а. — 10.7.1938, Одесса ш.), партия эшлеклесе. Әстерхан реаль уч-щесен тәмамлый. 1917–18 елларда РКП(б)ның Казан губерна ком-ты рәисе, 1919–22 дә Көньяк-көнчыгыш фронтның сәяси бүлеге башлыгы урынбасары, Көнчыгыш фронтның 4 нче армиясендә Революцион хәрби совет әгъзасы. Мәскәү югары техник уч-щесендә укый (1922). 1923–30 да РСФСР Финанс халык комис-ты һәм ВКП(б) ҮК аппаратында эшли. 1930–33 тә ВКП(б)ның Кырым өлкә ком-ты 1 нче секретаре, Кара диңгез флотының Революцион хәрби советы әгъзасы. 1933–37 дә ВКП(б)ның Одесса өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1933–37 дә РСФСР БҮБК һәм СССР ҮБК әгъзасы. Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. Репрессияләр чоры корбаны, үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Р у м я н ц е в Е. Вегер Е.И. // Возвращённые имена. К., 1990.

**ВЕДЕ́РНИКОВ** Андрей Николаевич (12.11.1961, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (2000). 1983 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, физик химия каф. профессоры (2000–2003 тә). Хезмәтләре каталитик органик синтез өлкәсенә карый. Ионлы-парлы һәм ирекле ионлы CH-кислоталылык шкалаларын эшли, газ фазасында һәм эремәләрдә алар арасындагы бәйләнешне ача. Углеводородларның платинасыман металлар комплексларына оксидлаштырып кушылуларын термодинамик анализлауга яңа чишелеш тәкъдим итә. Комплекста координация төененең деформацияләнү энергиясен минимумлаштыру принцибын билгели, шуның нигезендә оксидлаштырып кушылу реакцияләре б-н идарә итәргә мөмкинлек бирүче полидентат fac-хелат лигандлар эшли. Пиридинофаннар рәтенең макроциклик кушылмаларын синтезлау б-н шөгыльләнә. 2003 тән АКШта яши.

Х е з м.: Теоретические исследования реакций окислительного присоединения к комплексам платиновых металлов: 2. Новый подход к анализу термодинамики реакций метана с плоскоквадратными 16 электронными комплексами родия (I), палладия (II), иридия (I) и платины (II) // Журн. общей химии. 1997. Т. 67, вып. 8 (автордаш); Пути управления активностью и селективностью комплексов платиновых металлов в реакциях окислительного присоединения алканов по данным квантово-химического моделирования // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, вып. 1 (автордаш); Cryptate Acidity Scales. Solvent Polarity Effect on Ion-Pair and Free Ion Acidity of Organic Compounds // J.Phys. Org. Chem. 1994. № 7 (автордаш).

**ВЕДЕ́РНИКОВ** Николай Михайлович (1.5.1931, Казан), инженер-урман мелиорациясе белгече, фитопатолог, а.х. фән. д-ры (1994), проф. (1998), РСФСР, ТРның атказ. урманчысы (1977, 1997). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Бөгелмә МТСында урман мелиорациясе белгече булып эшли. 1955–56 елларда Казанның инженерлык саклау корылмалары идарәсендә яшелләндерү эшләре прорабы, мастер, өлкән мастер. 1956 дан Бөтенроссия урман мелиорациясе фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан урман-тәҗрибә станциясендә, фәнни эшләр буенча директор урынбасары (1990 нан), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1993 тән). Хезмәтләре урман токымнарының утыртырга әзерләнгән үсентеләре авыруларын тикшерүгә һәм урманнарны саклауга карый. Ылыслы токымнарның чәчкеннәрен сөрлегүдән саклау ысулларын уйлап таба (1981). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Защита хвойных сеянцев от болезней. М., 1972; Наставление по защите растений от вредных насекомых и болезней в лесных питомниках. М., 1984 (автордаш); Справочник по защите леса от вредителей и болезней. М., 1988 (автордаш).

**ВЕДЕ́РНИКОВ** Николай Николаевич (14.8.1930, Ростов-Дон ш. — 1.1.2005, Казан), геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1978), проф. (1983), ТАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 1995). СССРның мактаулы җир асты эзләүчесе (1990). Новочеркасск политехника ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Казакъстан Үзәк геология идарәсе экспедицияләрендә һәм геологик эзләнүләр оешмаларында эшли. 1962 елдан Казакъстан минераль чималлар ин-тында, руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе бүлеге мөдире (1963–70, 1978–81), директор урынбасары (1970–75). 1975–78 елларда СССР ФАнең Кола ф-лы (Мурманск ш.) президиумы рәисе урынбасары. 1981–84 тә Казакъстан политехника ин-тында геология ф-ты деканы. 1984 тән ЦНИИгеолнеруд директоры, 2002 дән фәнни консультант. СССР терр-ясендә яңа генетик һәм сәнәгый типтагы берничә асбест чыганагын ачыклый. Руда булмаган файдалы казылмалар фаразы һәм минерагениясе буенча тикшеренүләрне киңәйтә һәм тирәнәйтә, бу исә республика һәм союз күләмендә руда булмаган чыганакларның чимал базаларын арттыруга китерә. Аның фәнни җитәкчелегендә Россиядәге металл булмаган файдалы казылмаларның чимал потенциалын бәяләүнең төп принциплары тикшерелә һәм камилләштерелә, федераль минераль чимал базалары, ш.у. Татарстан терр-ясендәге, Идел буе һәм Уралның башка төбәкләрендәге региональ чимал базаларын үстерү буенча төп проблемалар һәм мәсьәләләр билгеләнә. 1969–92 дә Алжирда, Эфиопия, Югославия, Чехословакия, АКШ, Италия, Испания, Кытай, Монголиядә геол. эксперт. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, «Чыганакны беренче ачучы» билгесе (1984) б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геология, методика поисков и разведки месторождений родусит-асбеста. А.-А., 1965 (автордаш); Геологические модели и парагенезис месторождений полезных ископаемых. М., 1993.

*Әд.:* Казахский институт минерального сырья: 40 лет. А.-А., 1996; Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 1996.

**ВЕДРО́В** Александр Петрович (25.8.1921, Ульянов өлкәсе, Сура р-ны Княжуха а.), техник-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). 1941 елда авиация техникумын тәмамлый. 1941–83 елларда Казан авиация җитештерү берләшмәсендә: технолог, цех технол. бюросы җитәкчесе, агрегат цехы җитәкчесе урынбасары (1965 тән). Стапель конструкцияләрен һәм универсаль җайланмаларны җыйганда принципиаль яңа технологик алымнар кулланып самолётлар җитештерү ысулын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен Дәүләт бүләге бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ВЕ́КСЛИН** Носон-Бер Залманович (11.3.1897, Витебск губ. Двинск ш. — 17.10.1942, Норильск эшчеләр пос.), географ-икътисадчы. Гражданнар сугышында катнаша, гади кызылармиячедән дивизиянең сәяси бүлек башлыгы урынбасары дәрә-

җәсенә күтәрелә. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1923), шунда ук эшли. 1926–29 һәм 1935–37 елларда ТАССРның мәгариф халык комиссары урынбасары. Германиядә командировкада вакытта аның икътисады турында хезмәт яза (1929), шуның өчен икътисади география буенча профессор дәрәҗәсе бирелә (1930). 1930–34 тә ТАССР Госпланы рәисе урынбасары һәм статистика идарәсе җитәкчесе. 1934 тән Казан ун-тында каф. мөдире, бер үк вакытта ректор (1931–35). Казан ун-тында икътисади география үсешенең башлангычы В. исеме б-н бәйле. В.В.Батыр, А.В.Ступишин, П.В.Абрамов — аның шәкертләре. В. катнашында күп кенә оештыру мәсьәләләре хәл ителә. Алар арасында — кайбер ф-тларның ин-тлар булып үзгәртелүе: мәс., аэродинамика ф-ты Казан авиация ин-ты итеп үзгәртелә, В. бер үк вакытта аның беренче ректоры була (1932). Хезмәтләре Идел-Кама краеның халык хуҗалыгын җайга салу мәсьәләләренә, икътисади географияне укыту методикасы һ.б. проблемаларга карый. В. ТАССРның адм. картасын (ун чакрымлы масштаб б-н), ТАССР һәм Чуаш АССРларның икътисади географик атласын, кечерәк масштаблы күп кенә башка карталар төзи һәм бастыра. В. Казан (ТЭЦ-1, ТЭЦ-2, С.М.Киров исем. синтетик каучук з-ды һ.б.) һәм республиканың башка шәһәрләрендә сәнәгать пр-тиеләрен төзүне планлаштыру һәм реконструкцияләүдә, Горький өлкәсе, Мари һәм Татарстан АССРларның юллар челтәрен тикшерүдә катнаша. Бөтенсоюз география җәмгыятен оештыруга зур өлеш кертә (1933). Фронт Реввоенсоветының Мактау грамотасы һәм исеме язылган корал б-н бүләкләнә. 1937 нең августында репрессияләнә. Лагерь хастаханәсендә операция вакытында вафат була. Соңрак аклана.

Х е з м.: Географические предпосылки народного хозяйства ТАССР. К., 1929; Изучение Татарстана за 10 лет. К., 1932.

*Әд.:* П и с а р е в а С.В. Векслин Носон-Бер Залманович (1897–1942) // Возвращённые имена. К., 1990; Т р о ф и м о в А.М. Кафедра экономической географии и регионального анализа: исторический ракурс и путь становления // Юбилейный сб. ф-та географии и геоэкологии КГУ. К., 1998.

*С.В.Писарева.*

**ВЕЛИКА́НОВ** Геннадий Алексеевич (18.7.1943, Карелия Респ-касы Сегежа ш.), биофизик, биол. фән. д-ры (1998). Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлый (1971), РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында эшли, 1998 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре күзәнәк биофизикасын һәм күзәнәк процессларын, электрофизиологияне өйрәнүгә карый. Күзәнәк мембраналары һәм плазмодесмаларының су үткәрүчәнлеген өйрәнүнең ЯМР импульслы ысулын куллануга нигезләнгән яңа эксперименталь алымнарын тикшерә. Плазмодесмалар буенча ионнар транспортын өйрәнүнең оригиналь электрофизиологик алымнарын тәкъдим итә һәм тормышка ашыра. Күзәнәк мембраналарының су үткәрүчәнлеген көйләү концепциясен тәкъдим итә һәм эксперименталь нигезли. Беренчеләрдән булып югары төзелешле үсемлекләрдә тамыр системасының кудыру эшчәнлегендә плазмодесмалар катнашуын күрсәтә (тамыр эксудациясе).

Х е з м.: Самодиффузия воды внутри вакуолярного и цитоплазматического симпластов // Докл. РАН. 1999. Т. 368, № 3 (автордаш); Elektric Excitation of the Vakuole Within the Protoplast Isolated from a Higher Plant Cell // Membr. and Cell Biol., Amsterdam. 1996. V. 10 (4); Intracellular transfer of Water and ions in roots of Sunflower seedling // Sov. plant Physiology. V. 39/5. Part 2 (sep.–oct. 1992).

**ВЕЛОСИПЕ́Д СПОРТЫ́**, спорт төре. Велосипедта таулы-чокырлы җирдә, шосседа, тректа узышуны, фигуралар ясап йөрүне, велоболны үз эченә ала. Татарстанда В.с. 1893 елдан һәвәскәр велосипедчылар җәмгыятендә, ш.у. «Беркут» (1908 дән), «Сила и здоровье» (1911 дән) спорт җәмгыятьләрендә фигуралар ясап йөрү, шосседа һәм ипподромда узышу буенча ярышлар уздырудан да башланып китә. Заманча спорт төре буларак, 1920 елларның 2 нче яртысында «Динамо» спорт җәмгыятендә үсеш ала. 1927 дә «Казан — Мәскәү» велоузышы оештырыла, 1928 дә велосипедта узышлар 1 нче Бөтентатарстан физик тәрбия бәйрәме программасына кертелә. Татарстан җыелма командасы 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында катнаша (Мәскәү, 1928, РСФСРда 5 нче урын). 1940–50 елларда В.с. «Труд», «Спартак», «Красное Знамя», «Динамо», «Авангард» физкультура-спорт җәмгыятьләрендә, «Прогресс» (Яшел Үзән ш.) физкультура коллективында үсеш ала. В.с. буенча Татарстан беренчелегенә ярышлар даими рәвештә 1947 дән уздырыла (оештыручылары А.С.Ломтев, А.И.Передерин). Спорт җәмгыятьләренең Үзәк һәм Россия советлары беренчелекләренә бәйгеләрдә танылган иң оста велосипедчылар, җиңүчеләр һәм бүләк алучылар: Б.Бедрин, В.Колесников, М.М.Унгвицкий («Труд», 1951), В.А.*Ребровская* («Труд», 1954), Р.Гыймадиев («Спартак», 1958), Ю.Д.Рябчиков («Спартак», 1959), А.В.Волгушев («Буревестник», 1983). 1971 дән В.с. Чаллы шәһәр хакимияте каршындагы Физик тәрбия, спорт һәм туристлык идарәсе секцияләрендә бик тиз үсеш ала. Иң яхшы велосипедчылар: дөнья чемпионы Н.А.*Кибардина*, СССР һәм Россия чемпионнары И.А.Шәрипова (1990), Е.Г.Фролова (1990), Н.В.Разенкова (1992–93), А.В.Иванова (1993), А.А.Горгос (1993–95), Ф.Закиров (1996, 2000), Е.Ю.Беляева (2000). ТРның иң яхшы тренерлары: Б.С.*Головин*, А.В.Попов.

**ВЕЛЬЯМИ́НОВ-ЗЕРНО́В** Владимир Владимирович (31.10.1830, С.-Петербург — 17.1.1904, Киев ш.; Орел губ., Малоархангельск өязе Корсунский авылында җирләнгән), шәркыятьче галим, нумизмат, археолог, төрки-татар телләре д-ры (1866), Петербург ФА академигы (1861, 1890 елдан шәрәфле әгъза). Александр исем. лицейны тәмамлый (1850, С.-Петербург). 1850–59 елларда Тышкы эшләр министрлыгында тәрҗемәче. 1851–56 да Оренбург төбәгендә фәнни командировкада була, казакъ телен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнә. 1857 дән Рус археол. җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы, 1861 дән секретаре, мөселман халыкларының теле һәм



Н.-Б.З. Векслин.

әдәбияты буенча экстраординар академик. Петербург ФАндә фәнни эшләрне оештыруга һәм Көнчыгыш кулъязмаларын җыюга зур өлеш кертә. 1861–71 дә язучылар һәм галимнәргә бирелә торган С.С.Уваров һәм П.Н.Демидов (1865 кә кадәр) премияләре комиссияләрендә эшли. Петербург ФАндәге гыйльми эшчәнлегеннән тыш, Мәскәү, Тула, Орёл, Рязань губерналарына фәнни командировкаларга бара, Италия, Франция, Бельгия, Германия һ.б. илләрдә Көнчыгыш халыклары тарихына һәм тел белемен кагылышлы төрки һәм фарсы телле чыганаклар җыя. Башкортстандагы 14 йөз татар тарихи ядкәре Хөсәен бәк төрбәсен тикшерә (кабер ташындагы татар текстын укый). 1860 елларда «Рус археология җәмгыятенең Шәркыять бүлеге хезмәтләре»н («Труды Восточного отделения Русского археологического общества») редакцияли. 1872 дән, сәламәтлеге какшау сәбәпле, фәнни эштән читләшә. 1879–88 дә Орёл губернасы Малоархангельск өязе дворяннары башлыгы. 1888–1902 дә Киев уку-укыту округы җитәкчесе, бер үк вакытта 1889 дан Киев, Подольск, Волынь губерналарының борынгы чыганакларын өйрәнү комиссиясе рәисе. 1902 дән тайный советник. Рус география, Германиянең шәркыятьчеләр, Франциянең археол. җәмгыятьләрендә һ.б. оешмаларда әгъза булып тора. Хезмәтләре Россиянең Көнчыгыш халыклары тарихы һәм мәдәниятенә карый. Татар телендә сирәк очрый торган борынгы акт үрнәген — Касыйм татары Галикәй аталык васыятьнамәсен (1639), 17–19 йөзләр тарханлык грамоталарын, 17 йөздәге билгесез авторның монгол телендәге «Алтан Тобчи» («Алтын җыентык», монгол ханнары тарихы, сакланып калмаган борынгы чыганаклардан файдаланып язылган) әсәрен таба һәм фәнни кулланылышка кертә. В.-З.ның фәнни мирасында күренекле урынны «Касыйм ханнары һәм солтаннары турында эзләнүләр» («Исследование о Касимовских царях и царевичах», СПб., ч. 1–4, 1863–87) хезмәте алып тора. Хезмәттә, күп чыганакларга нигезләнеп, Касыйм ханлыгы тарихы яктыртыла, ш.и. Алтын Урда, Идел буе, Урал, Урта Азия һәм Казакъстан халыклары тарихы киң өйрәнелә. Галим төрки-татар ханлыклары тарихын киң колачлы итеп, үзара бәйләнештә өйрәнүе б-н замандашларыннан аерылып тора. Хезмәтләре тулысынча басылып чыкмаган, кулъязмаларының язмышы билгесез. Х.Фәезханов төзегән «Кырым ханлыгы тарихына кагылышлы чыганаклар» («Материалы для истории Крымского ханства, извлечённые из Московского главного архива МИД», 1864) китабының

редакторы. Төрки телле сүзлекләр авторы. 2 нче дәрәҗә Изге Владимир орденына, Иран, Төркия, Бельгия дәүләтләренең дәрәҗәле бүләкләренә лаек була.

Х е з м.: Исторические известия о Кокандском ханстве от Мухаммеда-Али до Худояр-хана // Тр. Вост. отд.-ния Рус. археол. об-ва. 1857. Ч. 2; Монеты бухарские и хивинские // Зап. Имп. Рус. археол. об-ва. 1859. Т. 13; Памятник с арабско-татарскою надписью в Башкирии // Тр. Вост. отд-ния Рус. археол. об-ва. 1859. Ч. 4; Словарь джигатайско-турецкий. 1868.

*Әд.:* В е с е л о в с к и й Н.И. В.В.Вельяминов-Зернов (1830–1904): Некролог // Журн. Мин-ва нар. просвещения. 1904. Ч. 352; У с м а н о в М.А. Заветная мечта Х.Фаизханова. Повесть о жизни и деятельности. К.; 1980; Библиографический словарь отечественных тюркологов: Доoктябрьский период. М., 1989.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ВЕНГЕ́РОВО РАЙОНЫ́**, *Новосибирск өлкәсенең* көнбатышында урнашкан. 1925 елда оештырыла. Мәйданы — 63,8 мең *км*². Үзәге — Венгерово авылы (Новосибирскидан 450 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 22877 кеше (2002). 856 татар яши (2002). 1950 елларга кадәр 13 татар авылы исәпләнә. 2001 елдан 1 татар авылы — Улуцк (43 кеше) кала. Татарлар ш.у. Бараба (267 кеше), Сөлекле (120), Чаргар (112) авылларында яшиләр. Бараба авылы урта мәктәбендә 1994 тән татар теле факультатив дәресләрдә өйрәнелә.

**ВЕНД**, в е н д с и с т е м а с ы (ч о р ы), в е н д к о м п л е к с ы (атамасы борынгы славян кабиләләре — вендлардан алынган), *протерозойның* иң соңгы стратиграфик бүлекчәсе. Акад. Б.С.Соколов тарафыннан билгеләнә (1950). ТРда Л.Ф.Солонцов, Е.М.Аксёнов, А.И.Диденко һ.б. җентекләп өйрәнә. Моннан 570±20 – 650±20 млн. еллар элеккегә вакытка туры килә. Югарыгы һәм түбәнге (ТРда чагылмый) өлешләргә бүленә. Татарстан венды Кама-Агыйдел һәм Серноводск-Абдуллин авлакогеннарында (астан өскә) Каиры һәм Шкапово сериясенең түбәнге өлешеннән гыйбарәт. Каиры сериясенең калынлыгы 200 *м* га җитә. Аның түбән өлешендә кварц һәм кыр шпатларыннан торган эре бөртекле комсыл-гравелит токымнар катламы ята (Байкыбаш свитасы); сериянең өске өлеше, башлыча, алевролитлардан һәм аргеллитлардан торган катлам (Старопетровский свитасы), ә Шкапово сериясе — калынлыгы 150 *м* лы кызыл төстәге комлы-балчыклы утырмалардан торган Салих свитасыннан гыйбарәт. Татарстан терр-ясендә югары венд утырма токымнары диңгезнең сай сулы урыннарында һәм өлешчә яр буе лагуналарында формалашкан. В. утырмаларында нефть һәм газ булуы мөмкин.

*Әд.:* Геология и нефтегазоносность Восточно-Европейской платформы. М., 1985; Историко-геологическое и палеонтологическое обоснование // Вендская система. М., 1985. Т. 2; Геология Татарстана. Стратиграфия и техника. М., 2003.

**ВЕНЕРОЛО́ГИЯ** (лат. Venus (veneris) — Венера, борынгы Рим мифологиясендә матурлык алиһәсе һәм *...логия*), медицина өлкәсе, җенси юл б-н күчә торган венерик авырулар этиологиясен, клиникасын, дәвалау һәм авыруны булдырмау ысулларын өйрәнә. Бу авырулар хакында Борынгы Греция, Һиндстан, Кытай галимнәре хезмәтләрендә бәян ителә. «Венерик авырулар» термины 1527 елда француз галиме Ж. де Бетакур тарафыннан тәкъдим ителә. 20 йөздә бу авыруларны китереп чыгаручылар ачыла. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының Халыкара классификациясе (1988) буенча сифилис, гонорея, йомшак шанкр (шанкроид), касык лимфогранулематозы, венерик гранулёма — классик венерик авырулар рәтенә кертелә. Җенес органнарын зарарлый торган йогышлы авырулар: сидек-җенес юллары хламидиозы, трихомониазы, сидек юллары-гениталияләр кандидозы, сидек-җенес юллары микоплазмозы, гениталияләр герпесы, очлы башлы кондиломалар, гениталияләрдәге контагиоз моллюсклар, сидек юллары — гениталияләр шигелёзы, педикулёз һәм корчаңгы. Венерик авыруларның күп кенә билгеләре кешенең тән тиресендә һәм лайлалы тышчаларында барлыкка килә. Шулай итеп, В. дерматология б-н тыгыз бәйләнгән.

19 йөз башында Англия, Франция, Вена (немец), Америка (төньяк) дерматовенерологлар мәктәпләре формалаша. Россиядә дерматовенерология мәктәпләренең оешуы Мәскәү ун-тының мед. ф-тында (1869), С.-Петербургта Медицина-хирургия (соңрак Хәрби-мед.) академиясендә (1870), Казан ун-тында (1872) һ.б. шәһәрләрдә тире һәм венерик авырулар буенча беренче мөстәкыйль кафедралар ачылу б-н бәйле.

Казан ун-тында тире һәм венерик авырулар курсларын мәҗбүри предмет буларак укыту 1872 дән А.Г.*Ге* тарафыннан башлана. Әмма тире-венерология авырулары клиникасы 1900 дә генә Казан фабриканты И.И.Алафузов иганәсенә төзелә; шунда кафедра да урнаша; клиника Казан губерна халкына гына түгел, Урал, Себер, Ерак Көнчыгыш төбәкләренә дә хезмәт күрсәтә. А.Г.Ге тарафыннан оештырылган клиника базасында Казан дерматовенерология мәктәбе булдырыла һәм үстерелә. И.М.Гиммель, А.А.Хитрово, В.Ф.*Бургсдорф*, М.С.*Пильнов*, Н.Н.*Яснитский*, М.П.Батунин, А.И.Дмитриев, Г.Г.*Кондратьев*, Н.Н.Чумаков, В.П.*Сергеев* һәм Г.Г.*Нуриев*лар шул мәктәптә тәрбияләнә. Кафедра каршында В.Ф.Бургсдорф (1907–27 дә каф. мөдире) тарафыннан ачылган лаб. бактериологик һәм гистологик тикшеренүләр, ш.и. Капоша яман шеш авыруын (А.А.Хитрово, 1909) клиник-морфологик; өченчел сифилис б-н авыручыларның өченче чорында розеоланың гранулематоз төзелешен (Н.Н.Яснитский, 1924) һ.б. төрле тикшерүләр үткәрергә мөмкинлек бирә.

Икенчел сифилис б-н авыручы кешенең канындагы аксыл спирохетаның чиста культурасы: штамм Казан-IV һәм V нең бүленеп чыгуы (Г.Г.Кондратьев, З.Х.*Кәримова*, 1941) мөһим ачыш булып санала. Спирохетаның биол. үзенчәлекләре һәм аңа пенициллинның төрле препаратлары тәэсире өйрәнелә (С.М.*Вяселева*, 1943, 1955, Казан мед. ин-ты). Дөньяда беренче мәртәбә тәҗрибәдә аксыл трепонеманың L-формасының күзәнәк эчендә табигый үсеше ачыклана (Л.М.Устименко, 1964, ГИДУВ). Алопеция авыруын дәвалау өчен кремний-органик кушылмасының силокаст препараты тәкъдим ителә (В.В.Сергеев). Сифилиска диагноз кую, дәвалау камилләштерелә, яңа дәвалау алымы — өзлексез ысул б-н бергә висмут препаратын кертү (Г.Г.Нуриев, В.И.Марачковская, А.И.Бизяев һ.б., 1977, Казан мед. ин-ты); дәвамлы һәм атопик дерматитлар, псориаз, чикле склеродермияне (Р.З.Зәкиев, 1998) дәвалау камилләштерелә. Балаларда сифилисның тумыштан килә торган һәм читтән йоктыру очраклары өйрәнелә (В.Т.Куклин, В.Н.Рокицкая, К., 1996). Ш.у. к. *Диспансерлар*.

*Әд.:* В я с е л е в а С.М. Действие различных препаратов пенициллина на бледную трепонему // Журн. микробиологии, эпидемиологии, иммунобиологии. 1957. № 4; Казанский медицинский институт. 1814–1989. К., 1989; С е р г е е в В.П. Силокаст для лечения больных алопецией // Казан. мед. журн. 1982. № 6.

*Г.Г.Нуриев, В.Т.Куклин.*

**ВЕНЕТА́** авылы, Арча р-нында, р-н үзәгеннән 16 *км* көньяктарак, Норма елгасы буенда. 2002 елда 163 кеше (руслар — 76%, татарлар — 22%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий, Манята исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1838 дә төзелә), земство мәктәбе, 2 икмәк кибете, тимерчелек, су тегермәне, сыраханә, шәраб һәм 3 вак-төяклəр кибете эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 106 ир заты; 1859 да — 188, 1897 дә — 281, 1908 дә — 301, 1926 да — 445, 1938 дә — 324, 1949 да — 208, 1958 дә — 217, 1970 тә — 130, 1979 да — 149, 1989 да — 193 кеше.

**ВЕНИАМИ́Н** (Пуцек-Григорович Василий Григорьевич) (1700 тирәсе, Полтава губ. Лохвицы ш. — июнь 1785, хәзерге Биектау р-ны Семиозёрка а.). Киев руханилар академиясен тәмамлый (1732). 1732–46 елларда Казан руханилар семинариясендә укыта. 1740 тан монахлыкта. 1744 тан Спас-Преображение монастыренда префект һәм архимандрит. 1748 дән Түбән Новгород, 1758 дән Тверь, Псков епископы булып тора, 1761 дән Александр Невский лаврасы архиепископы һәм настоятеле. Пугачёв явы вакытында, император Пётр III не җирләү шаһиты буларак, Пугачёвның ялган патша булганлыгын фаш итеп, «округ хатлары» тарата. Шуңа карамастан, Пугачёв Казаннан куылгач, В. аның б-н хезмәттәшлек итүдә гаепләнә, ярты ел буе төрмәдә тотыла. 1775 тән Казан һәм Зөя митрополиты. 1782 дә ялга китә. Көчләп чукындыру чараларына каршы чыга. Беренче булып дини әдәбиятны Идел буе халыклары телләренә, ш.и. татар теленә тәрҗемә итү мәсьәләсен күтәрә.

*Әд.:* Платон (Любарский). Сборник древностей Казанской епархии. К., 1868; Гурий (Степанов). Преосвященный Вениамин (Пуцек — Григорович), митрополит Казанский и Свияжский. К., 1906.

*Е.В.Липаков.*

**«ВЕ́РА»** («Иман»), атналык мөселман газетасы. Оештыручысы Казандагы «Мөхәммәдия» югары мөселман мәдрәсәсе. 1993 елның 15 октябреннән Казанда рус телендә нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре: В.Ягъкуб, С.Попов, В.Дубинин, Н.Гарипов (2000 нән). Газета мөселман дине тәгълиматларын, ислам дине тотучы халыкларның тарихын, традицияләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, Татарстан һәм Россия мөселманнары тормышында ислам мәдәниятенең тоткан ролен яктырта.

**ВЕРГА́ЗОВ** Азат Фатыйх улы (8.3.1932, Пенза өлкәсе, хәзерге Неверкино р-ны Карновар а.), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1958). 1958–64 елларда Яшел Үзән р-нындагы Олы Җәке авылы мәктәбе директоры, 1964–70 тә Карагуҗа авылы мәктәбендә укытучы һәм соңыннан укыту бүлеге мөдире булып эшли. 1974–85 тә «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар ком-тының әдәби-драматик тапшырулар редакциясендә өлкән мөхәррир. 1991–98 дә «Аҗаган» ж-лын оештыручы һәм аның баш мөхәррире, бер үк вакытта «Аҗаган» нәшрияты директоры (1992 дән). Әсәрләре 1960 еллар урталарыннан басыла башлый. В., нигездә, яшүсмерләр, аларның эти-әниләре һәм укытучылары арасындагы мөнәсәбәтләр турында яза: «Дулкыннар ни сөйли» (1978), «Уяну» (1984), «Без — сезнең балалар» (1996), «Йөрәк жыр сорый» (1998) повестьлары шундыйлардан. «Ташу» (1979) повестенда күмәкләштерү елларының катлаулы вакыйгалары сурәтләнә. «Кайту» (1992) романы асылыбызга кайту, милли традицияләрне яңарту мәсьәләренә багышланган. 1993 тә «Кода, май кап!» дигән сатирик повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы, «Язгы сөйләшү» дип аталган шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Аларга лиризм һәм тел байлыгын нечкә тою хас.

Әсәр.: Йөрәк җыр сорый: Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т. 1.

*Әд.:* Сверигин Р. Ташу // Социалистик Татарстан. 1981. 8 февр.; Фәйзи З. Олы иҗат юлында // Шәһри Казан . 1994. 25 нояб.; Салихҗан И. Тугрылык үрнәге // Шәһри Казан. 1998. 6 нояб.

*Г.М.Габделхакова.*

**ВЕРДЕРА́МО** Эммануил Осипович (1778, Неаполь корольлегендәге Лечче ш. — ?), акушер, медицина д-ры (1815). Солерно шәһәрендә белем ала, шунда ук 1803 елдан философия һәм хирургия д-ры. 1812 дән Вена ун-тында эшли. 1815 тән Казан ун-тының акушерлык осталыгы каф. профессоры, 1817–20 елларда Казан ун-тында мед. ф-ты деканы. Хирургия, табиблек һәм фармакология, латин теле буенча лекцияләр укый. 1820 дә эшеннән азат ителә, ун-ттан киткәндә үзенең китапханәсен бүләк итеп калдыра.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**ВЕРЕЩА́ГИН** Александр Николаевич (10.11.1938, Казан — 4.2.1989, шунда ук), химик, химия фән. д-ры (1972), проф. (1979), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1988). Казан ун-тын 1960 елда тәмамлый, шунда ук органик кушылмаларның төзелешен өйрәнү лабораториясендә эшли. 1965 тән СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында: 1981 дән табигый кушылмалар химиясе лаб. мөдире, 1987 дән директор урынбасары, 1988 дән директор. Хезмәтләре органик һәм элементорганик кушылмаларның конформацион анализына, әчке молекуляр электрон тәэсирләшүенә, полярлыгына, полярлашучанлыгына бәйле. Электрик, электрһәм магнетоптик ысулларны молекулаларның төзелешен билгеләүдә комплекслы куллану буенча фәнни юнәлешне башлап җибәрә. Әчке әйләнеш көчәрләре күп булган катлаулы молекулаларны конформацион анализлау юлларын эшли, төрле класс кушылмаларның электрон һәм конформацион төзелешләре закончалыкларын билгели. Конформацион тикшеренү практикасына Рәлеевча яктылык таралу, Керр, Коттон-Мутон эффектлары ысулларын кертә; аларны комплекслы куллану органик, нәорганик, элементорганик һәм табигый кушылмаларның өйрәнелә торган классларын киңәйтергә мөмкинлек бирә, ш.у. молекулаларның әчке әйләнеше проблемалары б-н бәйле күп кенә мәсьәләләрне чишә. Күп кенә циклы кушылу реакцияләренең стереохимиясен өйрәнә. «Молекулаларның полярлашучанлыгы» («Поляризуемость молекул», М., 1980) һәм «Индуктив эффект» («Индуктивный эффект», М., 1987) монографияләрендә В. беренче тапкыр молекулаларның үзлекләрен һәм химик бәйләнешләрен — полярлылык һәм полярлашучанлыкны тикшеренүләрен гомумиләштерә һәм системалаштыра. Бу, электростатик характердагы әчке молекуляр тәэсир итешү комплексы буларак, индуктив эффект механизмы турындагы ярты гасыр дәвам иткән бәхәсләрне туктатырга мөмкинлек бирә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Характеристики анизотропии поляризуемости молекул. М., 1982; Методологические вопросы структурной химии // Химия и мировоззрение. М., 1986; Индуктивный эффект. Константы заместителей для корреляционного анализа. М., 1988.

*Әд.:* Коновалов А.И. К 60-летию со дня рождения А.Н.Верещагина // Журн. общей химии. 1988. Т. 68, вып. 11; Арбузов Б.А., Визель А.О., Бредихин А.А. Он не собирался подводить итоги (памяти А.Н.Верещагина) // Наука. 1989. 21 февр.; Валеев Д.Н. Три лика. М., 1990.

**ВЕРЕЩА́ГИН** Михаил Николаевич (1891, Вятка губ., хәзерге Киров өлкәсенең Слобода өязе Белохолуницк а. — 26.7.1970, Казан), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1940), проф. (1935), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1946, 1961). Илнең эпизоотология фәненә нигез салучыларның берсе. 1917 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1925–70 тә эпизоотология каф. мөдире. Хезмәтләре мөгезле эре терлекләрдә үпкә ялкынсынуы авыруын, йогышлы анемия, урман бете б-н зарарлану, атларда пироплазмоз, мөгезле эре терлектә һәм сарыкларда бруцеллёз, дуңгызларда чума, некробактериоз авыруларын өйрәнү, дәвалауга карый. Эпизоотия үсеше закончалыклары һәм актив юнәлештә профилактика алып бару закончалыкларын теоретик яктан гомумиләштерә. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Механизмы заражения сельскохозяйственных животных // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1961. Т. 81; Возникновение эпизоотий // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1962. Т. 87.

*Әд.:* История Казанского государственного ветеринарного института им. Н.Э.Баумана. К., 1973; Казанский ордена Ленина ветеринарный институт имени Н.Э.Баумана. К., 1993; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ВЕРЁВКИН** Михаил Иванович (1732, Мәскәү губ. Клин өязе — 21.3.1795, Мәскәү губ., Дмитров өязе Михалёво а.), драматург, тәрҗемәче, Фән һәм сәнгать академиясенең мөхбир әгъзасы (1785). 1755–57 елларда Мәскәү ун-тында укыта. 1758–61 дә Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе директоры. Аны губернаның аң-белем тарату үзәгенә әверелдерә, укучылардан һәвәскәр театр труппасы оештыра (укучылары арасында Г.Р.Державин да була). 1760 та Казан губернатор иптәше (урынбасары) итеп билгеләнә. 1761 дән Казан губерна канцеляриясендә хезмәт итә. 1763 тә үзенең нәселдән килгән утарына — Покровский авылына күчеп китә. «Шулай тиеш» («Так и должно», 1773), «Исем бәйрәмен үткәрүчеләр» («Именинники», 1774), «Төп-төгәл» («Точь-в-точь», 1774–85) комедияләре авторы. Аларда Дидроның мещан драмаларындагы үзенчәлекләр рус классицизмының сатирик комедияләре традицияләре б-н үрелеп бара. «Шулай тиеш» һәм «Төп-төгәл» комедияләрендә уңай герой ришвәтче-комсыз, куркак һәм надан кешеләр арасында яшәргә мәҗбүр. «Исем бәйрәмен үткәрүчеләр»дә, Бомарше комедияләрендәгечә, мәхәббәт низагларында хуҗаларга аларның тапкыр хезмәтчеләре ярдәм итә. Екатерина II гә панегирик рәвешендә язылган «Безнең урамнарда бәйрәм» («На наших улицах праздник») һәм «Астрея» (икесе дә 1776) пьесалары, «Уйдырма» («Небылица», 1778) повесте авторы. Коръәнне француз теленнән (Андре Рюэр де ла Гард Малезер тәрҗемәсеннән) рус теленә тәрҗемә итә (1–2 кисәк, 1790).

*Әд.:* Тупиков Н.М. М.И.Верёвкин: Историко-литературный очерк. СПб., 1895.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

**ВЕРЗУ́Б** Леонид Исаакович (22.12.1940, Украина, Днепропетровск ш.), режиссёр, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1979). Ленингр. музыка һәм кинематография ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), Казан Яшь тамашачылар театрына куючы режиссёр итеп чакырыла, 1974–87 елларда шул театрның баш режиссёры. «Тере портрет» («Живой портрет», Морето-и-Кабанья, 1970), «Кояш астындагы йорт» («Дом под солнцем», Т.Г.Ян), («Золушка», Е.Л.Шварц, 1971) кебек беренче эшләреннән үк В.ның режиссёр буларак ачык, якты театр формаларына тартылуы, иҗат ысулларының балалар театры үзен-

чәлекләренә туры килүе күренә. Аның спектакльләре динамизм, музыкальлек, мизансценаларның пластиклыгы, пьесадагы төп персонажлар образларын ачканда көтелмәгән алымнар кулланылуы б-н аерылып тора. В. тарафыннан куелган «Ә Воробьёв тәрәзә ватмады...» («А Воробьёв стёкла не выбивал...», Ю.Я.Яковлев, 1972 дә иң яхшы балалар спектакле буларак бәяләнә һәм Үзәк телевидениедән (Мәскәү) күрсәтелә) һәм «Полк улы» («Сын полка», В.П.Катаев, 1972) спектакльләрендә яшүсмерләрнең катлаулы кичерешләрен бик нечкә тоюы сиземләнә. «Пеппи-Озыноек» («Пеппи-Длинныйчулок», А.Линдгрен, 1973) спектакле театр тормышында зур вакыйга буларак кабул ителә. Эстрада-цирк спектакле жанрында куелган, бәйрәмчә театраль тамаша формасындагы бу спектакль яшүсмернең дөньяга карашын, олылар яшәешенә мөнәсәбәтен чагылдыра. В.А.Аграновский әсәре буенча куелган, балалар арасындагы җинаятьчелекнең сәбәпләре, әхлакый тәрбия бирүдә гаилә һәм мәктәпнең җаваплылыгы проблемаларын күтәргән «Малаховны туктатыгыз!» («Остановите Малахова!», 1977) спектакле җәмәгатьчелектә киң резонанс тудыра. А.В.Вампиловның «Шәһәр читендә очрашу» («Свидание в предместье», 1974), А.М.Володинның «Сөйгәннәрегез белән аерылышмагыз» («С любимыми не расставайтесь», 1980), В.Шекспирның «Җәйге төндә кергән төш» («Сон в летнюю ночь», 1982), А.А.Дударевның «Сайлау» («Выбор», 1983) әсәрләре буенча куелган спектакльләрендә сәхнәдә символик метафораны һәм тирән психол. анализны табигый рәвештә берләштереп, хәзерге заман иҗтимагый тормышы мәсьәләләрен күтәрә, шәхес һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтләре диалектикасын ача, әхлакый кыйммәтләрне саклау зарурлыгын дәлилләп күрсәтә. Театр репертуарында «Бумбараш» (Ю.Ч.Ким, В.С.Дашкевич, 1980), «Казан университеты» (Д.Вәлиев, ике редакциядә — 1980 һәм 1981), «Китәм инде» («Под знаком Марса», Р.Хәмид, 1984) спектакльләре әһәмиятле урын алып тора. Театрның сәнгать җитәкчесе буларак, В. труппаның профессиональ дәрәҗәсен күтәрүгә омтыла, актёрларның иҗади үсүен кайгырта, нәкъ менә аның спектакльләрендә З.А.Петрова, Е.С.Царьков, Н.М.Кочнева, В.А.Фейгин кебек актёрларның талантлары ачыла. В. тарафыннан куелган спектакльләр берничә тапкыр Бөтенроссия театр фестивальләрендә күрсәтелә (1970, 1972, 1982). 1988 елдан Австралиядә яши.

В. тарафыннан куелган башка спектакльләр: «Язның 30 апрель көне» («Весенний день 30 апреля», А.Г.Зак, И.К.Кузнецов, 1973), «Принц һәм теләнче» («Принц и нищий», М.Твен, 1977, Ю.А.Благов б-н берлектә), «Могҗиза тудыручы» («Сотворившая чудо», У.Гибсон, 1979), «Рядовойлар» («Рядовые», А.А.Дударев, 1985).

*Әд.:* Б л а г о в Ю. Казанский театр юного зрителя. К., 1986.

*Ю.А.Благов.*

**ВЕ́РИННАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре; 1) **Михаил Степанович** (1781–1844), 2 нче гильдия сәүдәгәр. 1818 елдан бумази, ефәк һ.б. төр товар б-н сәүдә иткән. 1832 елда Н.Д.Чижов б-н бергә кытат (тукыма) ф-касы ача. Казанда 3 кирпеч йорт тоткан. 1804–06 елларда Казан шәһәр думасы гласные һәм казначее, 1824–26 да Вөҗдан мәхкәмәсе утырышчысы. 1836–38 дә Казан шәһәре башлыгы. 1843 тә картлар йортын ачуга 7300 сум акча бирә, картлар йортын тотуны оештыручылардан була. Иганәчелек эшчәнлеге өчен алтын медаль б-н бүләкләнә; 2) **Евтихий Михайлович** (1814–76), 1 нче гильдия сәүдәгәр, ашлык б-н сәүдә итә. Нәселдән күчмә шәрәфле граждан. Ятимнәр файдасына иганәлек итә. Җәмәгать китапханәсе идарәчеләренннән.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казанский некрополь. К., [Е.к.]; ш у л у к. Казань и казанцы. К., 1906. Т. 2; ш у л у к. Из казанской истории. К., [Е.к.]; О с т р о у м о в В.П. Казань. Очерки по истории города и его архитектуре. К., 1978.

*Л.М.Свердлова.*

**ВЕРНИКО́ВСКИЙ** Лев Самойлович (5.12.1911, Харьков губ. Купянск ш. — сентябрь 1992, Казан), җырчы (баритональ бас), педагог, ТАССРның атказ. артисты (1964). Харьков физика-техника ин-тын тәмамлый (1936), уку дәверендә кичке музыка курсларында аерым җыр дәресләренә йөри. 1936–38 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (В.Туровская классы) укый. 1939–74 тә Татар опера һәм балет театрында солист, 1978–92 дә опера труппасы мөдире. Бер үк вакытта 1962–67 дә Казан консерваториясендә укытучы, 1969–87 дә Казан мед. хезмәткәрләре йортының Халык опера театры режиссёры. Тигез яңгырашлы, зур диапазонлы тавышка ия, бертигез дәрәҗәдә төрле пландагы бас һәм баритон өчен язылган опера партияләрен — Дж. Россининың «Севилья чәчтарашы» (Бартоло), Ш.Гунонның «Фауст» (Мефистофель), А.Даргомыжскийның «Су кызы» (Тегермәнче), П.Чайковскийның «Евгений Онегин», «Мазепа» (Гремин, Орлик), С.Прокофьевның «Монастырьда никахлашу» (Мендоза), Н.Җиһановның «Качкын», «Ирек», «Алтынчәч» (Аблай, Мортаза, Бураш) операларындагы һ.б. партияләрне уңышлы башкара. И.Штрауcның «Ярканат» (Прокурор), К.Милеккерның «Ярлы студент» (Олендорф), К.Листовның «Севастополь вальсы» (Боцман Кузьмич) һ.б. оперетталарда нык истә калырлык образлар тудыра.

*Әд.:* В а н с л о в В. Торжество ума и сердца // Театральная жизнь. 1963. № 13; Пробиваясь сквозь тьму // Театральная жизнь. 1965. № 11.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ВЕРТЕБРОНЕВРОЛО́ГИЯ** (лат. vertebralis — умырткалык һәм ... *логия*), мед. фәне бүлеге, умырткалык патологиясе вакытындагы нерв системасы авыруларын өйрәнә. В. 1950–70 елларда неврология һәм ортопедиянең үзара бәйләнеше рәвешендә барлыкка килә. В. мәктәбе оешуда Я.Ю.*Попелянский*, В.П.*Веселовский*, Ф.Ә.*Хәбиров*, Г.А.*Иваничев* һ.б. Казан неврологлары мөһим урын алып тора, алар универсаль диагноз кую ысулларын һәм авыруларны дәвалауның дифференциаль схемаларын эшлиләр. 1991 дә В.П.Веселовский җитәкчелегендә ГИДУВның Республика медицина клиникасы бүлеге базасында ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Вертеброневрология үзәге, 1996 елдан Республика клиник вертеброневрология үзәге ачыла, бер үк вакытта ул Казан мед. академиясенең неврология һәм вертеброневрология кафедрасының клиник базасы булып тора. 1960 еллардан вертебро-висцераль патология буенча фундаменталь тикшеренүләр үткәрелә. Вертеброневрологик билгеләр патогенетик принциплар буенча классификацияләнә (Я.Ю.Попелянский). Умырткалык остеохондрозының неврологик синдромын билгеләүне Казан вертеброневрологлары Казан мед. академиясенең нурлар б-н диагноз кую кафедрасы рентгенологлары (М.К.Михайлов һ.б., 1999) б-н берлектә башкаралар. А.Ю.Ратнер балалардагы муен умырткасы сегментларының зарарлануын тасвирлый.

Умырткалык патологиясе аркасында организмда туган үзгәрешләр өйрәнелә, организмның төп өч реакциясе: биомеханик, микроциркуляр, иммунологик һәм репаратив реакцияләр аерып күрсәтелә. Умырткада органик патологияле авыруларның хәрәкәтләнү стереотибы эволюциясе закончалыгы ачылу зарарланмаган умыртка-хәрәкәт сегментларында блоклар барлыкка килүне аңлату мөмкинлеге бирә. Умырткада органик патологияле авыруларның хәрәкәт стереотибын төзәтү барышында мануаль дәвалау өчен күрсәтмәләр эшләнә (тикшеренүләр 1997–2000 дә Казан мед. академиясенең вертеброневрология һәм мануаль дәвалау каф. б-н берлектә Ф.Ә.Хәбиров, О.С.Кочергин һ.б. тарафыннан уздырыла).

Нерв системасының вертеброген авырулар вакытында триггер феноменнарны тикшерү һәм нейротрофик контроль нәтиҗәләре триггер зоналар барлыкка килүнең авыруның көчәюю чорына һәм умырткалыкның зарарланган өлешенә иннервацион рәвештә бәйсез булуын, ш.у. тракцион дәвалауның авыртуны бетерүен аңлата (умырткаларда диск бүсере), вертеброневрологик авыруларны дәвалауның нәтиҗәле ысуллары эшләнә (Ф.Ә.Хәбиров, Г.А.Иваничев).

РФдә әйдәп баручы Казан вертеброневрологлар фәнни мәктәбе галимнәре тарафыннан 2000 нән артык мәкалә, 30 монография нәшер ителә, 130 лап фән кандидаты һәм 20 фән докторы әзерләнә. Казанда Республика клиник вертеброневрология үзәгендә Евразия мед. академиясе штаб-квартирасы урнашкан, «Вестник Европейской академии медицинской науки» һәм «*Вертеброневрология*» ж-лларының редакция коллегияләре эшли.

*Әд.:* В е с е л о в с к и й В.П. Диагностика синдромов остеохондроза позвоночника. К., 1990; ш у л у к. Практическая вертеброневрология и мануальная терапия. Рига, 1991; Х а б и р о в Ф.А. Мануальная терапия компрессионно невральных синдромов остеохондроза позвоночника. К., 1991; ш у л у к. Мышечная боль. К., 1995.

*Ф.Ә.Хәбиров.*

**«ВЕРТЕБРОНЕВРОЛО́ГИЯ»**, фәнни-гамәли медицина журналы, Россия Вертеброневрологлар ассоциациясе һәм социаль проблемалар фәнни тикшеренү ин-ты органы. 1992 елның маеннан 1995 кә кадәр Казанда рус телендә елга 2 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 4 саны чыга. Оештыручысы һәм беренче мөхәррире В.П.Веселовский. 1997 дә рәсемле басма булып 3 айга бер тапкыр яңадан чыга башлый. Оештыручысы — ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник вертеброневрология үзәге. Баш мөхәррире Ф.Ә.*Хәбиров*. Журнал вертеброневрология буенча РФдә бердәнбер басма. Аның битләрендә нерв системасының вертеброген авыруларына клиник-диагностик тикшеренүләр үткәргәндә периферик нейромотор аппарат б-н диагноз куюның яңа, заманча ысулларын куллану проблемалары карала (В.П.Веселовский, М.К.Михайлов һ.б.); дәвалау принципларының, терапевтик коррекцияләүнең яңа ысуллары яктыртыла (Г.А.Иваничев, И.Р.Шмидт, А.А.Скоромец һ.б.); авыруларны реабилитацияләү, умырткалыктагы неврологик үзгәрешләрне булдырмау чараларын күрү мәсьәләләре күтәрелә (А.А.Лиев, А.А.Кадыйрова һ.б.); нерв системасының вертеброген авырулары барлыкка килүдә нейротрофик күзәтүләр алып баруның роле турында фикер алышулар үткәрелә (Ф.Ә.Хәбиров һ.б.); умырткаара дискны хирургик юл б-н дәвалау нәтиҗәләре турында мәгълүматлар басыла. Журналда безнең ил мед. фәнендә яңа юнәлеш булган балалар вертеброневрологиясе проблемаларына зур урын бирелә.

*Ф.И.Дәүликамова.*

**ВЕРТОЛЁТ**, бер яки берничә (еш кына ике) йөртүче винт (ЙВ) хасил иткән күтәрү һәм тарту көче тәэсирендә вертикаль рәвештә очып менә һәм төшә торган очкыч аппарат. В.зур булмаган мәйданчыктан урыннан гына очып менә һәм төшә, һавада, бер урында асылынып, вертикаль күчәре тирәли борыла ала. Шунлыктан мондый очкыч аппаратлар дөньяда киң таралган. Әйләнүче винтның һавага күтәрелә алу мөмкинлеге Кытайда урта гасырларда ук мәгълүм булган. 1475 елда Леонардо да Винчи беренче булып Архимед винты ярдәмендә һавага «борылып керүче» очкыч аппарат проектын тәкъдим иткән. Ике винтлы беренче В. моделе (аэродинамик машина) 1754 тә М.В.Ломоносов җитәкчелегендә төзелә. 1912 дә Б.Н.Юрьев бер винтлы В. проекты схемасын тәкъдим итә. 1932 дә Үзәк аэродинамика ин-тында А.М.Черёмухин җитәкчелегендә төзелгән В., 605 *м* биеклеккә күтәрелеп, рекорд куя (ул вакытта чит илләрдәге рекорд биеклек — 18 *м*). 1947 дә Мәскәүдә М.Л.Миль җитәкчелегендә ОКБ-329, 1948 дә Н.И.Камов җитәкчелегендә КБ оеша. Шул ук елда МИ-1 сериясендәге беренче совет В. очыш ясый.

В.лар ЙВ санына (бер, ике һәм күп винтлы), ЙВларның үзара урнашуына (буй күчәрле, күчәрдәш, аркылы күчәрле, кисешүче күчәрле винтлар), двигательләр санына (бер, ике һәм күп двигательле), ЙВка көч күчергеч тибына (двигательдән механик күчергечле яки реактив күчергечле — калаклар очларында реактив двигательле яки фюзеляжда турбокомпрессор булган һәм калаклары очларында реактив соплолы), файдаланылуына (күп максатлы, транспорт, пассажирлар йөртү, санитар, вертолёт-кран, а.х., эзләү-коткару, хәрби һ.б.), очып менү массасына яки йөк күтәрүчәнлегенә (үтә җиңел, җиңел, уртача җиңел, авыр, үтә авыр), менү-төшү җайланмаларына (коры җир өчен һәм «амфибия») карап төркемләнә. Механик трансмиссияле һәм койрыктагы өрлеккә урнаштырылган руль винты б-н идарә ителүче бер винтлы В. схемасы (дөньядагы В.ларның 90% тан артыграгы) аеруча киң таралган. В.лар пассажирлар йөртү һәм йөк ташу, ш.у. хәрби бурычларны үтәү максатында файдаланыла. Хәзерге заманда В.ларны тагын да универсальрәк очкыч аппарат итеп төзү тенденциясе күзәтелә. В. планёрдан, — аңа фюзеляж, шасси, кайбер схемаларда канат яки канатлар керә, — ЙВ системасыннан, көч бирү җайланмасы, электр, радио һәм навигация җиһазларыннан гыйбарәт. Бер винтлы механик күчергечле В.та реактив моментны тигезләү һәм идарә итү өчен руль винты бар. Механик күчергечле ЙВлы В.ның көч бирү җайланмасында пешкәкле, соңрак газ турбиналы (турбоваль) двигательләр кулланыла. Көч бирү җайланмасы: ягулык, суыту, май, двигательләр б-н идарә итү, янгыннан саклану системаларын эченә ала.

1994 тән Казан вертолёт з-дында (КВЗ) яңа буын В.лар проектлаштырыла (җитәкчесе В.Б.Карташёв). Җиңел «Ансат» В.ы 1999 ның 17 августында беренче тапкыр очыш ясый. Җиңел В. б-н идарә итүдә дөньяда беренче мәртәбә электродистанцион идарә системасы кулланыла, механик күчергечнең кирәге бетә. Канатлары шарнирсыз беркетелгән ЙВ куллану нәтиҗәсендә В.ның манёврлыгы һәм идарә ителүчәнлеге яхшыра.

1997 дә КВЗ Волга автомобиль з-дында эшләнгән роторлы-пешкәкле двигательләр куелган үтә җиңел «Актай» В.ын җитештерә башлый. 1999 дан КВЗда М.Л.Миль исем. Мәскәү вертолёт з-ды һәм Франциянең «Еврокоптер» фирмасы б-н берлектә уртача авырлыктагы яңа буын МИ-38 транспорт В.лары төзелә. Бу — Россия-Франция мөнәсәбәтләре кысаларындагы беренче проект.

*Әд.:* Ружицкий Е.И. Вертолёты. М., 1997; Михеев В.Р. Московский вертолётный завод им. М.Л.Миля: 50 лет. М., 1998; Кузнецов Г.И. ОКБ Н.И.Камова: 50 лет М., 1999; Вертолётный мир России: Каталог. К., 2000.

*А.А.Хлебников.*

**ВЕРТОЛЁТЛА́Р ТӨЗҮ́**, авиация машиналары төзү тармагы. В.т. — техник яктан аеруча нык үсеш алган сәнәгать тармагы. В.т. өчен югары фәннилек, югары дәрәҗәдә кооперация һәм җитештерү концентрациясе хас. *Вертолёт* кебек очкыч аппарат төзү идеясе самолёт төзи башлаганга кадәр үк (19 йөз ахыры) мәгълүм булса да, шактый соңрак гамәлгә ашырыла. Вертолётларны Россиядә серияләп чыгару Казан вертолёт з-дында (КВЗ) 1950 елларда Ми-1 аппаратларыннан башлана. Ми-1 сериясендәге беренче 25 вертолёт 1952 елның җәендә Тушинода (Мәскәү) Авиация көненә багышланган парадта катнаша. Вертолётлар өчен ике төп үсеш юнәлеше билгеләнә: аларның йөк күтәрүчәнлеген арттыру һәм чагыштырма очу-техник сыйфатламаларын яхшырту. Көч бирү җайланмасын пешкәкле двигателе булган Ми-1, Ми-4, Ка-18, Ка-26 вертолётлары урынына газ турбиналы двигательләр б-н җиһазланган һәм икътисади сыйфатламалары яхшырак булган 2 нче буын — Ми-2, Ми-6, Ми-8, Ка-25 вертолётлары алмашка килә. 3 нче буын вертолётлары Ми-17, Ми-26, Ка-32 тагын да яхшырак эксплуатацион һәм икътисади сыйфатламаларга ия, аларда тавышны, вибрацияне киметә торган композит материаллар һәм камилләштерелгән җиһазлар файдаланыла. 4 нче буын Ми-28, Ми-172, Ми-38, Ка-50, Ка-60, «Ансат» вертолётларын төзегәндә фән, техника һәм технологиянең өр-яңа казанышлары кулланыла. СССРда һәм Россиядә вертолёт проектлары М.Л.Миль һәм Н.И.Камовларның махсус КБларында төзелә, Ростов (Ми-1, Ми-6, Ми-24, Ми-26), Күмертау (Ка-26, Ка-27, Ка-32), Улан-Удэ (Ка-25, Ми-8), Арсеньев (Ми-24, Ми-34, Ка-50), Оренбург (Ми-1) шәһәрләрендә серияләп җитештерелә. Казан — вертолётлар эшләп чыгаручы иң эре үзәкләрнең берсе. 1951 елда Ми-1 вертолётын җитештерү үзләштерелә. КВЗда Ми-4 вертолёты 1 ел эчендә проектлаштырыла һәм төзелә, сыйфатламалары ягыннан ул чит илләрнекеннән өстенрәк була. Ми-4 — Россиядән чит илләргә чыгарыла торган беренче вертолёт. Дөньяда иң киң таралган (70 илдә файдаланыла) Ми-8 вертолётын серияләп чыгаруны КВЗ 1965 елда үзләштерә, аерым чорларда елына 350 дән артык вертолёт җитештерә, барлыгы 4000 ләп вертолёт экспортка җибәрелә. Кайбер елларда сатудан алынган валюта кереме СССРда авиация экспортыннан кергән барлык акчаның яртысыннан күбрәген тәшкил итә. Вертолётларны серияләп җитештерүне уңышлы үзләштергән өчен КВЗ 1973 тә Октябрь Революциясе ордены б-н бүләкләнә, завод директоры Ф.С.*Аристов* Соц. Хезм. Герое дигән мактаулы исемгә лаек була. 1983 тән КВЗны А.П.*Лаврентьев* җитәкли.

1957 дә КВЗда вертолётларны серияләп җитештерүне конструкторлык күзәтчелегендә тоту өчен Казанда ОКБ-387 җирлегендә баш конструктор Г.И.Бакшаев җитәкчелегендә М.Л.Миль исем. Мәскәү вертолёт з-дының Казан ф-лы оештырыла (хәзер «Вертолёты Ми» — КНПП — Казан «Ми вертолётлары» фәнни-җитештерү пр-тиесе). Соңрак М.Л.Миль ОКБсының Казан ф-лы Улан-Удэ шәһәрендәге авиация з-дында Ми-8 вертолётларын һәм аның модификацияләрен эшләп чыгаруга да күзәтчелек итә. ОКБ-387дә Ми-8 вертолётының күпсанлы модификацияләрен проектлаштыруның төп эшләре башкарыла. 1972 дә — Ми-14 вертолёты, 1976 да — өченче буын Ми-8МТ вертолёты, 1982 дә тәҗрибә вертолёты Ми-18 төзелә. 1995 тән Казан «Ми вертолётлары» фәнни-җитештерү пр-тиесен баш конструктор А.А.Талов җитәкли. Авиация технологиясе фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лы катнашында СССРда беренче мәртәбә Ми-4, Ми-8 вертолётлары өчен винт калакларын

К В З вертолётларының төп характеристикалары

| | Ми-8 | Ми-8МТ/ Ми-17, Ми-172 | Ми-14 | Ми-38 | «Ансат» |
|---|---|---|---|---|---|
| Газ турбиналы двигатель | ТВ2-117 | ТВ3-117МТ | ТВ3-117 | ВК-3000 | PW-206K |
| Саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Егәрлеге, *а.к.* | 2x1700 | 2x1900 | 2x1900 | 2x3000 | 2x630 |
| Экипаж/Пассажирлар | 3/28 | 3/24 | 4/24 | 2/30 | 1/10 |
| Фюзеляж үлчәмнәре, *м*: озынлыгы/биеклеге/ киңлеге | 18,17/4,38/2,5 | 18,42/4,86/2,5 | 18,38/6,93/3,8 | 19,95/6,15/4,3 | 11,06/3,4/1,8 |
| Йөк/пассажир кабиналарының үлчәмнәре, *м*: озынлыгы/биеклеге/ киңлеге | 6,36/2,05/1,7 | 6,36/2,05/1,7 | 6,36/2,05/1,7 | 8,7/2,34/1,8 | 4,6/1,3/1,68 |
| Калакларның саны | 5+3 | 5+3 | 5+3 | 6+4 | 4+2 |
| Массасы һәм йөкләнеше, *кг*: | | | | | |
| иң күп, очып киткәндә | 12000 | 13000 | 14000 | 15600 | 3300 |
| нормаль, очып киткәндә | 11570 | 11100 | 13400 | 14200 | 3000 |
| буш очканда | 6800 | 7200 | 8300 | 8300 | 1850 |
| Иң зур йөкләнеш (кабинасында/тышкы асылмасында) | 4000/3000 | 4000/4000 | 3000 | 6000/6000 | 1000/1300 |
| Ягулык запасы (төп бакларда/максималь), *л* | 1890/2615 | 1890/2615 | 2615/3795 | — | 720 |
| Иң зур тизлеге, *км/сәг.* | 240 | 250 | 230 | 290 | 278 |
| Крейсер тизлек, *км/сәг.* | 225 | 230 | 210 | 275 | 250 |
| Статик түшәм, *м* | 860 | 1760 | 1760 | 2500 | 3000 |
| Динамик түшәм, *м* | 4200 | 5000 | 3500 | 5200 | 5200 |
| Практик/иң зур очыш ераклыгы, *км* | 425 | 500/950 | 660/1135 | 800 | 530 |
| Очышның иң озак дәвамлылыгы, *сәг.* | 3,5 | 3,5 | 6 | — | 4 |

тоташ металлдан сериялэп җитештерү үзләштерелә.

В.т. өчен югары квалификацияле белгечләрне Казан техника ун-ты әзерли. Ныклыкны тәэмин итү буенча тармак лабораториясендә вертолёт агрегатлары чыдамлылыкка сынала; төзелеш механикасы кафедрасында — вертолётларның аэродинамикасы, аэросыгылмалылыгы һәм ныклыгы тикшерелә. А.Ю.Лисс, В.А.Павлов, С.А.Михайлов тарафыннан В.т. гә кагылышлы докторлык диссертацияләре яклана. 1985 елдан КДТУның очкыч аппаратлар ф-тында «Вертолётлар төзү» белгечлеге бүлеге ачыла, 1999 да КВЗның баш конструктор бүлеге өчен белгечләрне максатчан әзерләү төркеме оештырыла.

1997 дә КВЗ, Россиядәге сериялэп вертолётлар төзү з-длары арасында беренче буларак, вертолёт техникасын эшләү сертификаты ала. 1990 елларда илдә урнашкан яңа икътисади мөнәсәбәтләр КВЗга «Ансат», «Актай» кебек вертолётларны мөстәкыйль проектлаштыру мөмкинлеге бирә.

Турыдан-туры КВЗ катнашында оештырылган пр-тиеләр: «Омега» (проектлаштыру эшләрен фәнни-техник оештыру), «Заречье» (җирдә хезмәт күрсәтүче заманча чаралар эшләү һәм җитештерү), «Кристалл» (КВЗ вертолётларын заказчылар таләпләренә туры китереп җиһазлау программалары), «Хелико» (вертолётларда мед. комплексларын оештыру концепциясен эшләү), «Авиаремсервис» (эчке һәм тышкы базарны запас детальләр б-н тәэмин итү), «Эрдас» (төзәтү-торгызу эшләрен оештыру) тикшеренү үзәкләре. 1998 дән Казанда, Россиядә беренче буларак, вертолётлар эшләү, җитештерү һәм файдалануга багышланган «Вертолёт» исемле махсус техник ж-л нәшер ителә (оештыручылары — КВЗ һәм КДТУ).

*Әд.:* М о р о ш е к Е.М. На вертикальном взлёте. К., 1990; М а з о С.А. От планёров-мишеней до вертолётов. К., 2000; Казанские вертолёты: полёт продолжается. К., 2000; Вертолётный мир России: Каталог. К., 2000.

*А.А.Хлебников.*

**ВЕРХНЕУРА́ЛЬСКИЙ (ЮГАРЫ́ УРА́Л) РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* көньяк-көнбатышында урнашкан. Мәйданы — 3463 *км*². Үзәге — Верхнеуральск шәһәре (Чиләбедән 360 *км* көньяктарак). Халкы — 44,2 мең кеше, ш.и. 2,4 мең татар (2000). Татарлар район үзәгендә, Яңа Ахун, Межозёрный (Күлләр), Ложкина, Петропавловский, Форштадт посёлокларында яшиләр. Татарлар В.р.на (1917 елга кадәр Оренбург губернасының Верхнеуральск өязенә керә) 18 йөз уртасында килеп урнашалар. 1754 тә Казан губернасының Зөя өязеннән күчеп утыручылар Югары Җаек кальгасыннан (хәзерге Верхнеуральск ш.) 16 *км* читтә Үҗәйле редутын төзиләр. Алар казаклар катлавына керә. Хәрби хезмәттән тыш, җир сукалау, терлекчелек, ә 19 йөз башыннан Белорецк з-дларына руда ташу б-н шөгыльләнәләр. Бераздан татарлар Үҗәйле редутыннан Верхнеуральск шәһәренә күчәләр. 20 йөз башында алтын прииcклары хуҗалары һәм җәмәгать эшлеклеләре Рәмиевләр иганәсенә төзелгән 3 мәчет (алар каршында мәктәпләр эшли), яңа ысул мәктәбе (1947 дә ябыла) була. 1918 дә Верхнеуральскида хәлле татар һәм башкорт балалары өчен гимназия ачыла. 2000 нән район үзәгендә «Мәхәллә» мөселман оешмасы эшли.

**ВЕРХОЛЁТОВ** Владимир Александрович (23.7.1932, Горький өлкәсенең Бутурлинский р-ны Борнуково а.), вет. табибе, радиобиолог, биол. фән. д-ры (1988). 1957 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, Куйбышев р-нының Куйбышев исем. һәм «Трёхозёрский» с-зларында баш. вет. табибе булып эшли. 1963 тән Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1985 тән радиобиология лаб. мөдире. Хезмәтләре хайван организмына (кан әйләнеше системасына) ионлаштыручы нурланыш тәэсирен өйрәнүгә багышланган. Көчле нурланыш авыруына диагноз кую һәм фаразлау ысулын эшли. Радиоактив элементлар б-н пычрану чыганагында терлек асрау технологиясе буенча тәкъдимнәр кертә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние малых доз ионизирующего излучения на рост и развитие цыплят // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1965. Т. 94 (автордаш); Некоторые физико-химические показатели мяса животных при инкорпорировании йода-131 // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1972. Т. 112.

*Әд.:* Казанский ордена Ленина ветеринарный институт имени Н.Э.Баумана. К., 1993.

**ВЕРШИ́НИН** Андрей Константинович (30.10.1899, Вятка губ., Уржум өязе Ялнерка а. — 8.12.1979, Казан), агроном, а.х. фән. канд. (1938), проф. (1961), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1945). Гражданнар сугышында катнаша. Шәрекъ пед. ин-тының хим.-биол. бүлеген (1929) һәм бер үк вакытта Казан а.х. ин-тын (1930) тәмамлый. Свердловск өлкәсенең Красноуфимск шәһәрендә а.х. һәм пед. техникумнарында укыта. 1931–34 елларда Казан пед. ин-тында хим.-биол. ф-ты деканы. 1934–50 дә Казан а.х. ин-тында: уку-укыту һәм фәнни эшләр буенча директор урынбасары (1941 гә кадәр), гомуми игенчелек каф. мөдире (1936 дан), директор (1941–43). Оренбург (1950 дән), Курган (1953 тән), Казан (1969 дан) а.х. ин-тларында үсемлекчелек каф. мөдире. Татарстанда шикәр чөгендере культурасын беренчеләрдән булып тикшерүче. Республиканың үз шикәр җитештерү базасын булдыру мөмкинлеген исбатлый. Хезмәтләре шикәр чөгендере, кукуруз, уҗым культуралары, сабан бодае һ.б. бөртекле культуралар үстерү алымнарына карый. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Правильные травопольные севообороты в Татарии. К., 1949; Агротехника сахарной свёклы в Татарии. К., 1950; Возделывание корнеплодов в Чкаловской области. Чкалов, 1958; Агротехника и механизация возделывания кукурузы. Челябинск, 1966.

**ВЕСЕЛО́ВСКИЙ** Виктор Петрович (21.7.1943, Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе Шемонаиха а. — 4.2.1997, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (1979), проф. (1986), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1992). Я.Ю.Попелянский шәкерте. 1966 елда Алтай мед. ин-тын (Барнаул ш.) тәмамлый. 1970 тән Казан мед. ин-тында укыта. 1980 нән Казан мед. академиясендә, 1988 дән нерв авырулары

каф. мөдире. 1994 тән В. җитәкчелегендә *Вертеброневрология* үзәге оештырыла. Хезмәтләре гамәли вертеброневрологиягә һәм мануаль терапиягә, умырткалык остеохондрозына диагноз куюга карый. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. В. Халыкара вертеброневрологлар ассоциациясен оештыручы һәм 1991–97 дә аның президенты, «*Вертеброневрология*» ж-лының баш мөхәррире.

Х е з м.: Вертеброгенная парестатическая меральгия. К., 1988 (автордаш); Диагностика синдромов остеохондроза позвоночника. К., 1990; Практическая вертеброневрология и мануальная терапия. Рига, 1991.

*Әд.:* Виктор Петрович Веселовский — клиницист, учёный, педагог // Вертеброневрология. 1998. № 1.

**«ВЕСЕ́ННИЙ»**, яшелчә үстерү буенча дәүләт унитар пр-тиесе. 1973 елда Чаллы теплица комб-ты җирлегендә оештырылган шул ук исемдәге совхоз җирлегендә 1996 да төзелә. Теплицаларның мәйданы 30 *га*, елына 8200 *т* продукция җитештерелә. А.х. җирләренең мәйданы 265 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 188 *га*, ш.и. 46 *га* ачык грунтта яшелчә үстерү өчен файдаланыла. Аерым теплицалар үсемлекләрне биол. саклау цехы һәм гөмбә җитештерү буенча уникаль комплекс итеп корылган, 1 *га* мәйданда елына 1154 *т* гөмбә җитештерелә. Хуҗалык 20 дән артык төрдә яшелчә һәм яшел үлән культуралары үстерә. Кыяр, помидор, яшел суган төп яшелчәләр булып тора. Хуҗалык ябык грунтта яшелчәдән югары уңыш ала: 1986–90 да — 35,4 *кг/м*², 1996–98 дә — 35,2 *кг/м*². Экологик чиста яшелчәләр үстерүдә яңа технологияләр үзләштерелә. Грунтның массасын киметү өчен биогумус, туфракны көпшәкләндерүчеләр куллана (салам, карабодай кибәге); субстрат сыйфатында вулканик токым цеолит файдаланыла, ул яшелчә культураларын грунтны алыштырмыйча 10–15 ел үстерергә мөмкинлек бирә, уңыш 25% ка арта; үсемлекләрне углекислый газ б-н тукландыру, тамчылап сугару, үрентеләрне кассета алымы б-н үстерү кертелгән. Производство б-н автоматлаштырылган идарә итү һәм теплицадагы микроклиматны күзәтү компьютер системасы ярдәмендә башкарыла. Пр-тиедә гомуми мәйданы 39,8 мең *м*² булган 800 фатир, балалар комб-ты, ашханә, фирма кибетләре, сәламәтләндерү үзәге, ярдәмче хуҗалык бар. 1996–98 дә производствоның табышлылык дәрәҗәсе уртача 32% тәшкил итә. 2001 дә 10188 *т* яшелчә, ш.и. ябык грунтта 9313 *т*, 1200 *т* гөмбә җитештерелә. Ябык грунтта яшелчә уңышы 34,5 *кг/м*², гөмбәнеке 120 *кг/м*² тәшкил итә. 2002 дә «В.» с-зы җирлегендә шул ук исемдә ачык АҖ оештырыла. Хуҗалыкка нигез салучы һәм 1992 елга кадәр җитәкчесе Р.М.*Низаметдинов* була. Җитештерүдә югары күрсәткечләргә һәм нәтиҗәлелеккә ирешүе өчен пр-тие коллективына бернична тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКнең (1978, 1981–82, 1987–88), РСФСР МС һәм ВЦСПСның (1979–80, 1983–85, 1989) күчмә Кызыл байраклары бирелә.

«Весенний» яшелчә җитештерү предприятиесе. 1. Яшелчә теплицасы; 2. Ачык грунтта үстерү.





**«ВЕ́СТНИК КАЗА́НСКОГО ИНСТИТУ́ТА НАУ́ЧНОЙ ОРГАНИЗА́ЦИИ ТРУДА́»** («Казан хезмәтне фәнни оештыру институты хәбәрчесе»), фәнни журнал. Шул оешма органы. 1928–31 елларда Казанда рус телендә 1930 елга кадәр ай саен, аннары 2 айга бер тапкыр нәшер ителә. 1931 дә Татарстан китап нәшрияты һәм Казан хезмәтне фәнни оештыру ин-ты органы буларак, «Казан хезмәтне фәнни оештыру институты хезмәтләре җыентыгы» («Сборник работ Казанского института научной организации труда») исемендә чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — ин-т директорлары И.М.Бурдянский, А.К.Теплов. Авторлар коллективы, башлыча, ин-т хезмәткәрләреннән тора: Ш.А.Аитова, Я.П.Красников, М.П.Марсов, В.В.Милославский, К.И.Сотонин, С.Ф.Флавицкий, М.А.Юровская. Ш.у. Казан пр-тиеләренең эшче, инженер-техник хезмәткәрләре мәкаләләре дә басыла. Редакция үзенең төп бурычын ин-тның агымдагы эшләрен, ирешкән казанышларын яктыртуда һәм аны пропагандалауда күрә. Журналда җитештерүне рационалльләштерүнең гомуми мәсьәләләре тикшерелә, хезмәт җитештерүчәнлеген һәм идарә итүне камилләштерү юлларын эзләү, ш.у. ин-т тарафыннан махсус өйрәнелә торган психофизиология, психотехника, педагогика, һөнәри гигиена, социаль яклау, физиология һәм хезмәтне нормалаштыру проблемалары яктыртыла. Җиһазларны отышлы файдалануны пропагандалауга, эшче һәм хезмәткәрләр көнкүрешен оештыруның яңа формаларын булдыруга журналда аерым игътибар бирелә. Бюрократлыкка каршы көрәш кампанияләре оештыру, ТАССРдагы фән эшлеклеләренең һөнәри һәм иҗтимагый тормышы проблемалары күтәрелә. Хезмәтне фәнни оештыру буенча язылган рус һәм чит ил әдәбиятына аннотацияләр, рецензияләр һәм рефератлар басыла.

**«ВЕ́СТНИК КАЗА́НСКОЙ МЕЖДУНАРО́ДНОЙ ВЫ́СТАВКИ»** («Казан халыкара күргәзмә хәбәрчесе»), көндәлек газета. Казан губерна земство идарәсе органы. 1909 елның 3 июненнән 31 августына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 89 саны чыга. Мөхәррире Н.А.Ильяшенко. Казанда вак һәм эре сәнәгатькә, янгынга каршы көрәш чараларына, һөнәри белем бирү һәм авыл хуҗалыгына багышланган халыкара күргәзмә ачылу уңаеннан оештырыла. Беренче (сынау өчен чыгарылган) саны 1909 ның 15 маенда басыла. Газетаның баш мәкаләләрендә сәнәгать, сәүдә һәм һөнәрчелек үсешенең актуаль проблемалары яктыртыла, Россия империясенең 1908 елгы икътисади үсешен күрсәткән статистик тикшеренүләрнең нәтиҗәләре анализлана, рус һәм чит илләр тормышы хәлләренә күзәтүләр ясала. Даими рубрикалары: «Дәүләт банкының Казан бүлеге фондлары бюллетене», «Күргәзмә хроникасы», «Бүлекләрдәге экспонатлар исемлеге», «Күргәзмә комитеты утырышларыннан». Земстволар, бигрәк тә күргәзмәдә павильоннары булган земстволар эшенә анализ ясауга зур игътибар бирелә. Материалларның күпчелеге Казан халкы һәм шәһәргә килгән кунакларга исәп тотып эшләнә: Казанның истәлекле урыннары, кибетләре, күренекле фирмалары, шәһәрнең театр, музыка һәм спортка караган яңалыклары турында хәбәрләр басыла.
*Г.Р.Заманова.*

**«ВЕ́СТНИК КАЗА́НСКОЙ ОБЛАСТНО́Й С.-Х. О́ПЫТНОЙ СТА́НЦИИ»** («Казан өлкә авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясе хәбәрчесе»), авыл хуҗалыгы журналы. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан губерна советы игенчелек бүлеге, аннан соң ТАССР Игенчелек халык комис-ты, аннары Тәҗрибә эшләре буенча Югары Идел буе өлкә идарәсе органы. 1918 елның декабреннән 1922 гә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Башта атнага 1 тапкыр, 1920 дән айга 1 тапкыр чыга (1919 ның июленнән 1920 нең августына кадәр, кәгазь булмау сәбәпле, чыгудан туктап тора). 1922 гә кадәр журнал «Казанский земледелец» («Казан игенчесе») исемендә чыга. Казан губернасы игенчеләре арасында а.х. белемнәрен тарату максатында чыгарылган беренче журнал. Оештыручысы һәм беренче мөхәррире М.А.Дернов. Ул башта «Пчеловодная жизнь» һәм «Пчеловод» ж-ллары мөхәррире була. 1920 дә мөхәррире Ф.Т.Дитякин, 1921 дән Ф.Т.Дитякин, Н.М.Фофанов, Ф.В.Чириковлар составындагы редакцион комиссия мөхәррирлегендә чыга. Профессорлар А.Я.Гордягин, В.И.Логинов, А.Н.Остряков, А.А.Юницкий, Ф.А.Александров, И.В.Благовещенский һ.б. галимнәрнең хезмәтләре басыла. Журнал республикада а.х. торышын чагылдыра, а.х. тармагына караган әдәбиятка күзәтүләр бастыра. 1921 дән Казан авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясенең басма орга-

ны буларак, аның фәнни эшләрен, гамәли эш нәтиҗәләрен яктырта. 1925–30 да тәҗрибә станциясе үз хезмәтләрен «Бюллетень Казанской областной с.-х. опытной станции» исемендәге басмаларда бастыра.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ВЕ́СТНИК НАУ́ЧНОГО О́БЩЕСТВА ТАТАРОВЕ́ДЕНИЯ»** («Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте хәбәрчесе»), рәсемле фәнни журнал. ТАССР Мәгариф халык комис-ты каршындагы *Гыйльми Үзәк*, аннан соң *Татар мәдәнияте йорты* органы. 1925–30 елларда Казанда рус телендә елга 1–3 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 10 саны чыга. Мөхәррире Н.Н.Фирсов. Журналда күренекле Казан галимнәре — *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте* әгъзалары Н.И.Воробьёв, Г.С.Гобәйдуллин, Г.Ибраһимов, М.К.Корбут, Г.Рәхим, Г.Г.Сәгъди, В.Ф.Смолин, М.Г.Худяков, Е.И.Чернышёв, Г.Ш.Шәрәф, Мәскәү һәм Ленинградның атаклы тарихчылары һәм тел галимнәре В.А.Богородицкий, Г.А.Ильинский, А.Н.Самойлович һ.б. галимнәр язышa. Журнал редакциясе вузлар, мәктәпләр, түгәрәкләр, фәнни җәмгыятьләр, хакимият-хуҗалык оешмалары һәм пр-тиеләренең төбәкне өйрәнү методологиясе һәм методикасы мәсьәләләренә караган эшләрен берләштерү бурычын куя. Хезмәтләрнең күпчелеге Урта Идел буе халыкларының матди һәм рухи мәдәниятен яктыртуга багышлана. Идел буе Болгары һәм Казан ханлыгы тарихына, Казан татарлары этногенезына аерым игътибар юнәлтелә. Татар тел белеме һәм әдәбиятына караган документларга зур урын бирелә, татар язуын латин графикасына күчерү проблемалары күтәрелә. Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыятенең гомуми җыелышларында тыңланган докладларга, «Тәнкыйть һәм библиография» бүлегендә дөнья күргән хезмәтләргә, әсәрләргә рецензияләр басыла. Журналның соңгы саны тулысынча Н.Н.Фирсовның фәнни эшчәнлегенә багышлана.

*Әд.:* Абдрашитова И.М. Вестник научного Общества татароведения // Из истории Татарии. К., 1970. Сб. 4; Фаттахова Г.А. Научное Общество татароведения (1923–1930-е годы): Возникновение и деятельность // Точка зрения. К., 1999. *Г.Р.Заманова.*

**«ВЕ́СТНИК ОБРАЗОВА́НИЯ И ВОСПИТА́НИЯ»** («Тәгълим-тәрбия хәбәрчесе»), рәсемле айлык фәнни-педагогик журнал, «*Циркуляр по Казанскому учебному округу*» ж-лына бушлай кушымта. Казан уку-укыту округы идарәсе органы. 1914 елның гыйнвар аеннан 1916 ның декабренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 36 саны чыга. Мөхәррире — Казан уку-укыту округы инспекторы В.С.Богоявленский. Хезмәттәшлек итүчеләр — күренекле галимнәр һәм педагоглар: Казан ун-ты проф. А.Н.Боголюбов, М.В.Бречкевич, Н.А.Васильев, П.М.Дульский, И.П.Забусов, Н.Ф.Катанов, К.В.Харлампович, М.М.Хвостов; Казан гимназияләре директорлары С.А.Богатырёв, В.П.Брюханов, М.М.Иванов, Н.А.Клюев; дин эшлекләре: А.И.Дружинин, С.К.Спирин, Е.Ф.Сосунцов. Журналда пед. теория һәм практиканың актуаль мәсьәләләре яктыртыла, укыту методикасына караган фәнни-популяр мәкаләләр басыла. Мәктәптә, гаиләдә балага физик һәм дини-әхлакый тәрбия бирү проблемаларына аерым игътибар бирелә. Журнал эксперименталь педагогика һәм пед. психология өлкәсендәге яңалыклар, яңа юнәлешләр б-н таныштыра. Казан уку-укыту округы һәм Кызыл Хач ком-ты эшчәнлеге даими яктыртылып килә. Бөтенроссия пед. съездлары эше турында хәбәрләр, рус һәм чит ил авторларының пед. темаларга караган китапларына һәм уку әсбапларына рецензияләр, балалар өчен чыккан китапларга күзәтүләр басыла.

**«ВЕ́СТНИК ПРОСВЕЩЕ́НИЯ ТССР»** («ТССР мәгарифе хәбәрчесе»), айлык фәнни-педагогик һәм иҗтимагый-сәяси журнал. ТАССР Мәгариф халык комис-ты органы. 1921 елның апреленнән 1924 нең март аена кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә (акча җитмәү сәбәпле, 1922 дә 2 саны гына чыга). Төрле елларда мөхәррирләре: Б.Н.Вишневский, Н.Д.Кочкарин. Журнал Татарстан Респ-касы халыклары мәгарифе һәм мәдәнияте мәсьәләләрен яктырта, мәдәни-агарту эшен алып баруның нигезләрен һәм практик юлларын күрсәтү б-н шөгыльләнә. Редакция социаль тәрбия, политехник белем бирү мәсьәләләрен, һөнәри-техник мәктәпләр һәм югары уку йортлары эшчәнлеген, ш.у. наданлыкны бетерүгә юнәлтелгән чараларны журнал битләрендә яктыртуны үзенең төп бурычларыннан саный. Журнал Татарстан Мәгариф халык комис-тының сәясәтен аңлата, пед. методология һәм практика буенча фәнни мәкаләләр, яңа уку-укыту программалары, төбәкне өйрәнү буенча материаллар, пед. журналларга күзәтүләр бастыра. Төп рубрикалары: «Мәгариф хроникасы», «Татарстан республикасында», «Фән һәм тормыш», «Яңа китаплар һәм журналлар». Журнал РКП(б) ҮКнең «Ведомстволар матбугатын кыскарту турында»гы карарын (24 март 1924 ел) үтәү йөзеннән РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты тарафыннан чыгудан туктатыла.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ВЕ́СТНИК ТАТА́РСКОГО ОБЛАСТНО́ГО КОМИТЕ́ТА РКП**(б)**»** («РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты хәбәрчесе»), журнал, к. «*Коммунист Татарии*».

**«ВЕ́СТНИК ТАТСОЮ́ЗА»** («Татсоюз хәбәрчесе»), журнал. ТАССР Кулланучылар җәмгыятьләре берлеге (Татсоюз) органы. 1924–30 елларда Казанда рус телендә, 1925–28, 1930 да татар телендә дә нәшер ителә. 1925 нең 8 нче санына кадәр «Кооперативная связь Татреспублики» («Татарстан республикасында кооперативлар бәйләнеше») исемендә чыга. Төрле елларда мөхәррирләре: И.А.Булгаков, М.Залипский. Журналга мәкаләләрне, башлыча, Татсоюзның идарә әгъзалары һәм бүлек хезмәткәрләре әзерли. «В.Т.» кооперативлар эшчәнлегенә багышланган хөкүмәт документларын һәм Татсоюзның үз карарларын бастыра. Кооперативлар хәрәкәтенең гомуми мәсьәләләрен яктырта, Татсоюз бүлекчәләре һәм конторaларының эшчәнлегенә анализ ясый, эштәге кимчелекләрен тәнкыйтьли. Кулланучылар җәмгыятьләренең эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм координацияләүне журнал үзенең төп бурычларыннан саный һәм, кооперативлар хосусый алыпсатарларны (сәүдәгәрләрне) базардан кысрыклап чыгарырга тиеш, дигән фикерне үткәрә. Укучыларны Татсоюз тарафыннан чыгарылган яңа басмалар б-н таныштыра. *Р.А.Айнетдинов.*

**ВЕТЕРАННА́Р (ПЕНСИОНЕРЛА́Р) ОЕШМАСЫНЫ́Ң РЕСПУ́БЛИКА СОВЕТЫ́**, җәмәгать оешмасы. 1987 елның мартында оештырыла. Максаты: пенсионерларның социаль-икътисади хәлен яхшырту, шәхси ирекен һәм хокукларын яклау, торак-фатир мәсьәләсен хәл итешү, мохтаҗларга матди ярдәм оештыру, көнкүреш кирәк-ярагын табышу, мед. ярдәме оештыру. 2005 ел башына ТР шәһәр һәм районнарында 60, сәнәгать, хуҗалык тармакларында 13 оешма исәпләнә. Аларга 3500 ләп беренчел оешма-советлар керә һәм алар 964 мең пенсионерны берләштерә. Рәисе Н.И.Тимашова.

**ВЕТЕРИНА́РИЯ** (лат. veterinarius — терлек караучы, терлек дәвалаучы), фәннең һәм кешеләрнең гамәли эшчәнлеге өлкәсе; терлек авыруларын булдырмауга һәм дәвалауга, кешеләргә һәм мал-туарга хас гомуми чирләрдән саклауга, терлекчелектә ветеринария таләпләренә туры килә торган сыйфатлы азык җитештерүгә, ш.у. әйләнә-тирә мохитне саклауның вет.-сан. проблемаларын хәл итүгә юнәлтелгән. Терлекләрне дәвалау турындагы борынгы мәгълүматлар Рим агроном-язучысы Колумелланың «Авыл хуҗалыгы турында» («О сельском хозяйстве», б.э.к. 1 йөз) исемле хезмәтендә очрый. Россиядә халык В. се (терлек дәвалау) кыргый хайваннарны кулга ияләштерү чорында килеп чыга; аның үсешенә көтүчелек хезмәте ярдәм итә. Көтүчеләр дәвалау өчен яраклы үләннәрне җыя, киптерә, саклый, агулы үләннәрне таный башлыйлар. Терлекләрне дәвалауда, тудыру вакытында, имгәнгәндә, ерткыч хайваннар һөҗүм иткәндә алган җәрәхәтләрен дәвалауда, печтергәндә дәвалаучы имчеләр булыша. Терлек маен, сөяк җелеген, кан, бавыр, үт, тавык йомыркасын һ.б. дәва чарасы итеп файдаланалар. Бакыр-таш культурасы чорында беренче вет. җиһазлары барлыкка килә. Күпьеллык тәҗрибә һәм белем аталардан балаларына, остазлардан шәкертләренә күчкән. 16–17 йөзләрдә Россиядә В. буенча тәрҗемә әсәрләр, ш.у. рус телендә күп кенә кулъязма һәм басма хезмәтләр кулланылышта йөргән. Казан губернасы терр-ясендә фәнни В. нең барлыкка килүенә терлекләрнең йогышлы чирләр б-н күпләп авыруы сәбәп була. Мөгезле эре терлекләрдә чума һәм үпкә куышлыгындагы әгъзаларның йогышлы ялкынсынуы, себер түләмәсе, сап һ.б. авырулар көтелмәгәндә хайваннарны күпләп юк итә. Казан ун-тында 1805 елда терлекләр табиблеге кафедрасы ачыла, 1836 да ике вет. табибе штаты (өлкән һәм кече) раслана; 1864 тә земство В.се гамәлгә кертелә, һәм ул аерым куркыныч авыруларны бетерүдә уңай нәтиҗәләр бирә. Казан губернасында В. үсешенә 1873 тә Казан вет. ин-ты ачылу да ярдәм итә (к. *Казан ветеринария медицинасы академи-*

*ясе*). Ин-тың беренче чыгарылыш шәкертләре Россиянең күп кенә көнчыгыш төбәкләренә, ш.и. Казан губернасы земстволарына җибәрелә. 19 йөз ахырында *Казан ветеринария фәнни мәктәплә*ре оеша. 1882 дә 17 вет. табиблеге участогы ачыла, һәм алар Казан губернасында дәүләт вет. хезмәтен оештыруның нигезен тәшкил итәләр. Рев-циядән соң дәүләт органнары һәм вет. хезмәте җитәкчеләре тырышлыгы б-н Татарстанда В. нык-лы үсеш ала. Татарстан Үзәк вет. идарәсенең беренче башлыгы, 1920–25 тә халык комиссары А.В.Недачин бу эштә күренекле роль уйный, ул төрле ведомство вет. табибләрен һәм фельдшерларын бердәм дәүләт вет. хезмәтенә берләштерә. Бу чорда вет. лабораторияләре ачыла, вет. табибләре корылтайлары уздырыла. 1930 еллардан Буа һәм Казан вет. техникумнарында вет. фельдшерлары әзерләнә, бу исә колхоз, совхозларда вет. хезмәтен кадрлар б-н тәэмин итүне яхшырта.

1920 еллардан Казан вет. ин-ты кафедраларында тикшеренүләрнең фәнни базасы киңәю (К.Г.Боль, А.П.Студенцов, М.П.Тушнов, Г.В.Домрачев, М.А.Сошественский, Б.М.Оливков, Л.С.Сапожников, Е.Н.Павловский, Н.П.Рухлядев, Х.Х.Абдуллин, В.В.Мосин, Х.Г.Гыйззәтуллин, А.П.Онегов), 1960 та Казан фәнни-тикшеренү вет. ин-ты (соңрак илебезнең зур фәнни үзәге) ачылу (Ф.З.Амфитеатров, Н.Җ.Хаҗипов, Г.З.Равилов, Р.Х.Йосыпов, В.А.Киршин, П.К.Сметов, К.М.Салмаков һ.б.) нәтиҗәсендә (к. *Бөтенроссия ветеринария институты*) В. фәнни нигезгә куела.

Хәзерге В. меңләгән вет. табибләре, фельдшерлар һәм төрле профессия галимнәре коллективын берләштерә. Алар а.х. һәм эшкәртү пр-тиеләренең вет. хезмәте, югары һәм урта вет. белеме бирү системасы (Казан вет. мед. академиясе, Буа һәм Минзәлә вет. техникумнары, Алабуга һөнәри техник уч-щесе), фәнни-тикшеренү оешмалары (Бөтенроссия вет. ин-ты), ТР МК каршындагы Баш ветеринария идарәсе җитәкчелегендәге дәүләт вет. хезмәте составына керәләр.

1993 тә ТРда вет. эшчәнлегенең хокукый көйләнешен тәэмин итү өчен «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Закон кабул ителә. Вет. учреждениеләрен матди-техник җиһазлауны һәм вет. өчен билгеләнгән заманча чараларны гамәлгә кертүдә Татарстан сәнәгать пр-тиеләренең (Алабуга станоклар төзү з-дында әзерләнгән дезинфекцияләү җайланмасы, Түбән Кама химия комб-тында җитештерелгән дезинфектантлар) мөмкинлекләре уңышлы файдаланыла. Татарстанда хайваннарда йогышлы һәм инвазион авыруларны булдырмау һәм бетерүгә, халыкны сыйфатлы һәм зарарсыз азык-төлек б-н тәэмин итүгә, кешеләрне кеше һәм хайваннарга хас гомуми чирләрдән саклауга гаять зур әһәмият бирелә. 1995 һәм 2000 елларда Казанда Россия вет. табибләренең 1 һәм 2 нче корылтайлары уздырыла.

*Әд.:* История Казанского государственного ветеринарного института им. Н.Э.Баумана. К., 1973; Ветеринарная служба Татарстана в борьбе с заболеваниями животных. К., 1975; Никитин И.Н., Калугин В.И. История ветеринарии. М., 1988; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*И.Н.Никитин.*

**ВЕТЕРИНА́РИЯДӘ ДИА́ГНОЗ КУЮ́ КОМПЛЕ́КТЛАРЫ**, терлекләрдә йогышлы авыруларның төрен (түләмә, бруцеллёз, туберкулёз, хламидиоз, мистериоз, сальмонеллёз, дуңгызларда классик чума, Ауески авыруы, котыру, Ку бизгәге, сап, йогышлы ринотрахлит һ.б.) ачыклау өчен кулланыла. Казан дәүләт вет. мед. академиясе һәм Бөтенроссия ветеринария ин-ты галимнәре тарафыннан (Н.Җ.Хаҗипов, Г.З.Равилов, Р.Х.Йосыпов, А.М.Климов, К.М.Салмаков, Г.Х.Фәизов, Г.Х.Ильясова, А.К.Галиуллин һ.б.) тест-системалар: молекуляр гибридлаштыру һәм полимераз чылбырлы реакция, иммунофермент һәм радиоиммун анализ, гемаглютинация реакциясе, комплемент дәвамлы бәйләнеше, иммуноссеморфез, бер һәм күп каналлы антитәнчекләр — яктылык сибүче антитәнчекләр ысулы нигезендә эшләнелә. Бөтенроссия вет. ин-тында (Казан ш.) 2000–2003 елларда РФ һәм ТР Авыл хуҗалыгы министрлыклары дәүләт заказы нигезендә РФ төбәкләрендә вет. хезмәтен алып бару өчен яктылык сибүче иммуноглобулин һәм үрнәк сыркынды (а.х. терлекләрендә хламидиозга диагноз кую өчен); антирабик яктылык сибүче иммуноглобулин, дуңгызларда махсус антитәнчекләрне РНГАда билгеләү өчен һәм дуңгызларда Ауески авыруы, чумага каршы вакцинация препаратлары; терлекләрдә хламидиоз авыруына серологик һәм Ку бизгәгенә диагноз кую өчен препаратлар (антиген һәм сыркынды); дуңгызларда чумага диагноз кую һәм әйләнә-тирә объектларда иммунофермент анализ б-н авыру китереп чыгаручыларны индикацияләү өчен препаратлар, бруцеллёз R антигены һәм бруцеллез R сыркындысы, ИФА ысулы б-н лабораториядә котыруга диагноз кую өчен җайланмалар эшләп чыгарыла. Вет. препаратларын контрольдә тоту, стандартлаштыру һәм сертификацияләү Бөтенроссия дәүләт фәнни-тикшеренү ин-ты тарафыннан 1999 һәм 2003 елда аттестацияләнә.

*Р.Х.Йосыпов.*

**«ВЕЧЕ́РНЕЕ Э́ХО»** («Кичке кайтаваз»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади, сәүдә-сәнәгый һәм әдәби газета. 1905 елның 28 декабреннән 1906 ның 10 июленә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 159 саны чыга. Рәсми нашире һәм мөхәррире П.М.Стадырнов, асылда — И.В.Мандельштам. Кадетлар партиясенең Казан ком-ты әгъзалары И.И.Бабушкин, А.В.Васильев, Н.П.Гусев, А.В.Завадский, В.Н.Ивановский, К.В.Лаврский, А.А.Симолин, М.М.Хвостов, шул партия идеологлары П.Д.Долгорукий, Г.Ф.Шершеневич, А.И.Шингарёв һ.б. авторларның мәкаләләре басыла. Газета «Барысы да халык өчен һәм халык ярдәмендә» («Все для народа и через народ») шигаре астында һәм үз алдына «тормышны мөмкин кадәр тулы һәм тиз чагылдыру» бурычын куеп эшли. Газетаның иртәнге якта чыгуы, Россия һәм Петербург телеграф агентлыгы телеграммаларын бастыруы укучыларга мәгълүматны башка газеталарга караганда алданрак җиткерергә мөмкинлек бирә. «В.э.»да, башлыча, хөкүмәт карарлары, мәхкәмә утырышлары, төрле иҗтимагый оешмаларның һәм фәнни җәмгыятьләрнең җыелышлары турында хисап материаллары, сәяси күзәтүләр басыла. Кадетлар партиясе карашларын пропагандалауга зур урын бирелә. 1 нче Дәүләт думасына сайлаулар кампаниясендә кадетлар «В.э.» ны агитация максатында файдаланалар. Газетада большевиклар партиясенең стратегиясенә һәм тактикасына анализ ясала, аларның сыйнфый килешмәүчәнлеге тәп кимчелек итеп күрсәтелә. 1906 да төрле сылтаулар б-н «В.э.» 6 тапкыр конфискацияләнә. Яшәп килүче режимны көч кулланып бәреп төшерергә өндәгән мәкалә бастырганы өчен Казан мәхкәмә палатасы газетаны чыгудан туктата. П.М.Стадырнов, суд ээзәрлекләвеннән качып, чит илгә китә. Ш.у.к. «*Казанский вечер*».

*Г.Р.Заманова.*

**«ВЕЧЕ́РНЯЯ ЖИЗНЬ»** («Кичке тормыш»), көндәлек иҗтимагый-сәяси рәсемле газета. Казанда рус телендә нәшер ителә. 1907 елның 30 сентябрендә 1 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире Е.Г.Скворцова. Иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә, ш.и. Дәүләт думасына сайлауларга багышланган мәкаләләр, фельетон, әдәби әсәрдән өзек, рус һәм чит ил матбугатына күзәтү, сәүдә-сәнәгый һ.б. белешмә материаллар басылган.

**«ВЕЧЕ́РНЯЯ КАЗА́НЬ»** («Кичке Казан»), иҗтимагый-сәяси газета. Оештыручысы КПССның Казан шәһәр ком-ты һәм халык депутатлары советы, соңрак «Вечерняя Казань» акционерлык компаниясе. 1979 елның 6 гыйнварыннан Казанда рус телендә нәшер ителә. Беренче мөхәррире А.П.*Гаврилов*. 1991 дән шеф-мөхәррире Х.Х.*Шәмсетдинов*. «В.К.» да шәһәр һәм республиканың сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышы яктыртыла. 1995 тән «Конец недели» дигән шимбә кушымтасы чыгарыла.

**«ВЕЧЕ́РНЯЯ ПО́ЧТА»** («Кичке почта»), көндәлек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. 1909 елның 1 гыйнварыннан 4 маена һәм 19 июненнән 20 октябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 204 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире В.С.Андреев. Газета башкалада нәшер ителә торган кичке газеталар үрнәгендә, шундый ук форматта көндезге сәг. 2 дә чыга, шуңа күрә «В.п.» г-тасында Балкан кризисы турындагы барлык телеграммалар, хөкүмәт карарлары һәм боерыклары, Дәүләт думасы утырышлары, Россия һәм дөнья хәлләре турындагы башка мәкаләләр Казанда нәшер ителә торган башка газеталарга караганда бер тәүлеккә алдан басыла. Вак һәм эре сәнәгатькә, янгынга каршы көрәш чараларына, һөнәри белем бирү һәм авыл хуҗалыгына багышланган халыкара күргәзмә эшен (Казан, 1909) яктыртуга, губерна земствосы утырышлары материалларына аерым игътибар бирелә. Оригиналь һәм тәрҗемә ителгән роман, повесть, хикәя, новеллалардан, бигрәк тә сентименталь һәм дини эчтәлекле әсәрләрдән өзекләр басыла. Сәүдә (коммерция) игъланнарына зур урын бирелә. Газета чыгару өзелеп торганда (5 майдан

18 июньгә кадәр) әбунәчеләргә «*Казанская вечерняя почта*» г-тасы җибәрелә. Ш.у.к. «*Волжский вечер*».

*Г.Р.Заманова.*

**ВЕЧЕСЛА́В (ВЯЧЕСЛА́В) Г.М. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́** (типолитография), 1881 елда Казанда оешкан матбага. 1882 дә ачылган хәреф коюю остаханәсендә татар шрифтлары да коела һәм татар китаплары да басыла башлый. 1888 дә матбаганың идарәчесе итеп куелган И.Н.*Харитонов* ташбасма ысулын җайга сала, гальванопластика, тиз басу машиналары булдыра. Басмалар полиграфик эшләнешләре ягыннан югары дәрәҗәгә җиткерелә, 1886 һәм 1890 еллардагы фән-сәнәгать күргәзмәләрендә бүләкләргә лаек була. Матбага татар наширләре һәм укучылары арасында зур абруй казана. Бастырып чыгарган татар китаплары саны буенча ул кайбер елларда 19 йөзнең 2 нче яртысында Казанның иң эре матбагаларыннан саналган университет һәм Чирков басмаханәләрен дә уздырып җибәрә. 1882–94 еллар арасында матбагада 225 исемдә татар китабы басыла (гомуми тиражы 1,5 млн. данә), анда иң әүвәл басылган китап — «Татарско-русская азбука», ул шуннан соң да күп мәртәбәләр дөнья күрә; икенче басма — Александр Македонский турындагы «Китаб-е Искәндәр». Матбагада татар реалистик әдәбиятының күренекле әсәрләре — З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887), «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар», 1890) романнары, Ф.Халидинең «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасы, К.Насыйри, Р.Фәхретдин әсәрләре һ.б. беренчеләр булып басыла. Ш.у. анда Шәрекъ әдәбияты әсәрләре, Һиндстан, Әфганстан турындагы тарихи китаплар, фольклор җыентыклары, татар халык җырлары, әкиятләре, мәҗмугалары, әлифбалар, сарыф-нәхү дәреслекләре, календарьлар күпләп басыла, шул җөмләдән 70 ләп басма дини китап — Коръән, Һәфтияк, догалыклар басылып чыга. Аз санда русча басмаларга да урын бирелә: дәреслекләр, сүзлекләр, реклама материаллары нәшер ителә. 1884 тә матбагада — 6 кеше, 90 нчы елларда 18 кеше эшли. Цензура эзәрлекләүләре аркасында Вечеслав матбага тоту һәм китап басу эшеннән баш тартырга мәҗбүр була, һәм 1894 тә ул үз матбагасын Б.Л.Домбровскийга сата (к. *Домбровский Б.Л. басмаханәсе*).

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1975; шул ук. Татарская книга пореформенной России. К., 1983.

**ВЕШТО́МОВ** Александр Иванович (1768, Казан губ., Соликамск провинциясе Көнгер ш. — 13.7.1831, Вятка ш.), тарихчы, төбәк тарихы белгече, титуляр советник (1807). Рухани улы. Вятка шәһәрендә руханилар семинариясен тәмамлый (1790). 1790–1800 елларда Сарапул, 1800–10 да Вятка әсасый халык уч-щеләрендә укыта. 1810–13 тә Вятка округы урман департаменты чиновнигы. Аның «Нократлыларның Нократ елгасы буена килеп урнашулары заманыннан әлеге төбәктә наместниклык оештырылуга кадәрге, яки 1181 елдан 1781 елга чаклы 600 еллык тарихы» («История вятчан со времени поселения их при реке Вятке до открытия в сей стране наместничества, или с 1181 по 1781-й год, через 600 лет»; 1807–08 дә язылa, 1907 дә басыла) дип аталган төп хезмәте — Вятка-Нократ төбәге б-н Идел буе Болгары һәм Казан ханлыгы арасындагы мөнәсәбәтләр тарихы буенча кыйммәтле чыганак. «Натурадан ясалган Нократ үсемлекләр дөньясы» («Вятская флора, рисованная с самой натуры», 1809–10) хезмәте кулъязма хәлендә саклана. Беренче булып Алабуга шәһәре һәм өязенең медик-топографик тасвирламасын төзи.

*Әд.:* Столетие Вятской губернии 1780–1880: Сб. материалов к истории Вятского края. Вятка, 1881. Т. 2; Бердинских В.А. Первый историк Вятского края // Вопр. истории. 1988. № 1; Долгов Е.Б. К биографии первых историков-вятчан // История и культура Волго-Вятского края. Киров, 1994; Энциклопедия Земли Вятской. Киров, 1996. Т. 6.

*Е.Б.Долгов.*

**ВИВИАНИ́Т**, тимерле зәңгәр балчык, (инглиз минералогы Дж. Вивиан фамилиясеннән алынган), фосфатлар классындагы минерал, $Fe_3(PO_4)_2{\cdot}8H_2O$. Составында FeO — 43,0 %, $P_2O_5$ — 28,3 %; Mn, Mg, Ca катнашмалары бар. Призма формасындагы энәсыман кристаллар; агрегатлары — бөре яки шар рәвешендә, балчыксыман. Төссез, үтә күренмәле (яңа вакытта), һавада оксидлашып, төсе сыек зәңгәрдән зәңгәрсу-карага кадәр үзгәрә. Пыяласыман ялтырый,



Бентониттагы вивианит.
Биклән бентонит балчыклар чыганагы.

перламутрлы. Катылыгы 1,5–2. Уалучан. Тыгызлыгы 2,68–2,95 *г/см³*. Тоз һәм азот кислоталарында җиңел эри. Тышкы көчләр тәэсирендә тирәлектә кайтарылу шартларында хасил була. ТРда неоген һәм дүртенчел система утырма токымнарында, сапропель, торф, урман туфракларында очрый. Зәңгәр буяу буларак кулланыла.

**ВИГДЕРГА́УЗ** Марк Соломонович (6.12.1934, Самара ш. — 20.2.1994, Израиль), химик, химия фән. д-ры (1975), проф. (1976). Куйбышев индустриаль ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Куйбышев нефть технологиясе техникумында эшли. 1959 елдан Синтетик спиртлар һәм органик продуктлар фәнни-тикшеренү ин-тының Новокуйбышев ф-лында төркем җитәкчесе, лаб. башлыгы. 1967–81 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында хроматография, нефть химиясе лаборатория мөдире, нефтехимия бүлеге мөдире. 1981 дән Самара ун-тының гомуми химия һәм хроматография каф. мөдире. Хезмәтләре газ хроматографиясе һәм нефть химиясенә карый. Хроматографиянең яңа вариантларын таба, аларны нефть эшкәртү һәм нефть химиясе продуктларын анализлауда куллана, битум нефтен өйрәнү ысулларын тәкъдим итә. 1992 дән Израильдә яши.

Хезм.: Курс газовой хроматографии. М., 1967. (автордаш); Газовая хроматография как метод исследования нефти. М., 1973; Продукты термического воздействия на битуминозный пласт. Саратов, 1986.

**ВИ́ЗЕЛЬ** Александр Андреевич (24.7.1957, Казан), фтизиатр, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. табибе (2003). 1980 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли (1994 тән Казан мед. ун-ты), 1989 дан фтизиопульмонология каф. мөдире. Бер үк вакытта 1989 дан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш пульмонологы. Тикшеренүләре сулыш алуның клиник физиологиясенә, сулыш алу әгъзаларына комачаулаучы авыруларны дәвалауга, саркоидозга диагноз кую һәм дәвалауга карый. Аның җитәкчелегендә фтизиатриядә *ксимедон*, *димефосфон* фармацевтика препаратларына клиник сынау үткәрелә, гадәти булмаган дәвамлы (хроник) авырулар һәм үпкә туберкулёзы вакытында системалы артериаль гипертензия өйрәнелә.

Хезм.: Оптимизация лекарственной коррекции функциональных нарушений кравообращения и дыхания у больных туберкулёзом лёгких. М., 1989; Хронический бронхообструктивный синдром: диагностика и опыт лечения в современных условиях. К., 1997 (автордаш); Туберкулёз. М., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Кафедре фтизиопульмонологии КГМУ 25 лет. К., 1997.

**ВИ́ЗЕЛЬ** Андрей Оскарович (19.10.1930, Ленинград), химик-органик, химия фән. канд. (1968), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1990), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), рәссам. Петербург сәнгать академиясенең мөхбир әгъзасы Э.О.Визель оныгы. 1951 елда Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый. Казан хим.-технол. ин-тын (1959) тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында (1965 кә кадәр СССР ФАнең Органик химия ин-тында), 1986 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 1992 дән яңа дару чараларын эзләп табу төркеме җитәкчесе. Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. Фосфорорганик биш буынлы чиксез гетероциклларның һәм аларның әверелеш продуктларының структурасын һәм реакциягә керү сәләтләрен, аларны табу юлларын өйрәнә. Дару чараларын нәантихолинэстераз аз токсинлы фосфорорганик кушылмалар арасыннан максатка ярашлыларын эзләү концепциясен тәкъдим итә һәм (хезмәткәрләр б-н берлектә) яңа дару препаратлары ясый. Б.А.Арбузов б-н берлектә фосфор өчгалогенидларының диеннарга цикллы кушылу реакциясен ача. Хезмәттәшләре б-н берлектә сәнәгый эремәләрдән затлы металларны аерып алу өчен яңа тип экстрагентлар, поликарбодиимид пеноматериаллар алу өчен катализатор эшли. Дәүләт бүләге үзенчәлекле дару препараты — *димефосфон* уйлап тапканы өчен бирелә. Уйлап табуга СССРның 43 авторлык таныклыгына, РФ патентына һәм 10 чит ил патентына ия.

Рәссам буларак, В. иҗатының төп төре — нәкышь, жанры — пейзаж. Зур булмаган

этюдларында Татарстан һәм Мари урманнарының, Идел киңлекләренең, көньяк дингезләрнең, тау кыяларының, Казанның матурлыгын сурәтли («Уйчан җил», «Камада таң», «Мари моңнары», «Иске Казан ишегалды» һ.б.). Шәхси күргәзмәсе Казан ун-тының тарих музеенда (1996), «Визельләрнең рәссамнар династиясе» күргәзмәсе ТР Дәүләт сәнгать музеенда (1998) уза. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мономерные тригалоидфосфораны циклического ряда и некоторые их превращения. Синтезы на основе трёхбромистого фосфора // Докл. АН СССР. 1964. Т. 158, № 5 (автордаш); Фосфорорганические соединения с низкой токсичностью // Докл. АН СССР. 1965. Т. 165, № 1 (автордаш); Новое средство метаболической терапии — димефосфон // Terra Medica nova. 1988. № 3 (автордаш).

*Әд.:* Н у г у м а н о в В. Создатели новых препаратов // Научный Татарстан. 1995. № 3; Художественная династия Визелей. Живопись, графика, декоративно-прикладное искусство: Каталог выставки. К.,1988.

**ВИ́КА**, чәчүлек вика (Vicia sativa L.), кузаклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр төре. Татарстанда язгы формасы киң таралган. Тамыр системасы үзәкле, азот туплаучы бүлбеләре бар. Ботаклары нәзек, сөрлегүчән, 1 *м* га кадәр озынлыкта, яфраклары пар каурыйсыман, 4–10 пар яфракчык һәм икегә аерылган мыекчалы. Яфрак куышлыгында чәчәкләре 1–3 әр булып утыра, үзеннән серкәләнә, таҗлары төрле төстә — аксыл шәмәхә, куе кызыл, алсу, ак. Җимеше — 4–10 яссы орлыклы кузак, 1000 орлыкның авырлыгы 50–60 *г*. Терлек азыгы үсемлеге, җиңел үзләштерелә торган яшел масса һәм 35% ка кадәр аксымлы бөртек бирә. Печән, сенаж, үлән оны буларак кулланыла; саламы һәм кибәге дә терлек азыгы итеп файдаланыла. ТР терр-ясендә озак вакытлар «Льговская — 31–292» һәм җирле вика сортлары чәчелә, «Луговская 83» (1988), ЛОС-5 (2000) сортлары районлаштырыла. В. көн яктылыгы озын вакытта үсә, туфракка һәм җылылыкка таләпчән түгел, дымны ярата. Коры елларда уңышы кими. Туфрак шартларын яхшыртканда: ашлама, известь керткәндә, туфракны тирән эшкәрткәндә, су режимын көйләгәндә яхшырак үсә. Күп очракта солы һ.б. терлек азыгы культуралары катнашында үстерелә. Ашламалар (яртылаш черегән яисә тулысынча черегән тирес, минераль ашламалар) 1 гектардан 30–35 *т* яшел масса яисә 2,5–3 *т* бөртек алу максаты куеп кертелә. В.ның 1 *т* яшел массасы туфрактан 3,5–4 *кг* азот (катнашмадагы культуралар нисбәтенә бәйле), 1–1,3 *кг* $P_2O_5$, 3–4 *кг* $K_2O$ үзләштерә, 1 *т* бөртек, тиңдәшле рәвештә, 60–65, 15–20 һәм 15–20 *кг*. Чәчүле пар басуында тоташ рәтле ысул б-н чәчү иң иртә срокларда башкарыла, бүтән очракларда чәчү вакыты яшел конвейерда массаны теләгән вакытта алу исәбеннән чыгып көйләнә. ТРда бөртек алу өчен чәчү мәйданы 1999 елда — 26,7, 2000 дә — 27,8 мең *га*, уңыш — 1 *га* дан 12,2 һәм 18,4 *ц*, 2005 тә — 24,1 *ц*.

*Әд.:* М и т р о ф а н о в А.С., Р о ж к о в М.М. Вика (яровая и озимая). М., 1961; З и г а н ш и н А.А., И с м а г и л о в Х.Х. Зернофуражное поле. К., 1985; Ч е к м а р е в П.А. Рекомендации по возделыванию вико-овсяных смесей на полях Республики Татарстан. К., 1993.

*А.А.Җиһаншин.*

**ВИКО́**, Мәгълүмат-коммерция күргәзмә берләшмәсе (1990–98), 1998 елдан «*Казан ярминкәсе*» күргәзмә үзәге.

**ВИКТО́РОВ В.Ф. БАСМАХАНӘСЕ́**, Бөгелмә шәһәрендә 1917 елга кадәр ачыла. Хосусый милек дәүләтләштерелгәннән соң, матбага гарәп шрифтлары б-н тәэмин ителә. 1918 нең җәендә матбагада Бөгелмә депутатлар советы каршындагы Мөселман бүлеге басмасы «Бөгелмә мөхбире» г-тасы, 1919 ның декабрендә «Якты юл» г-тасы басыла башлый. 1920 еллардан — Бөгелмә кантонының халык хуҗалыгы советы, 1923 тә — вак җитештерүче хуҗалыкларның берләштерелгән кантон идарәсе карамагында эшли, аннары янә Бөгелмә кантоны башкарма ком-тына тапшырыла. Соңга таба үзендә басыла торган «Сабанчы» г-тасы исеме б-н билгеле. 1930 еллар башыннан — «Колхозчы» һәм «Колхозник» г-талары басмаханәсе. 1917–32 дә 21 исемдә татар китабы бастырып чыгара. Алар арасында: «Самар вилаятендәге шураларның вакытлы уставы вә тәнзиматы» (1917), Г.Сәгъдинең «Фән һәм тәрбия дәресләре» (1918), В.Солтановның «Онытылган сүзләр» (1918) китабы, башлангыч һәм эшчеләр мәктәпләре өчен дәреслекләр, авыл хуҗалыгы артельләре уставлары, татар халык җырлары, балалар фольклоры җыентыклары һ.б.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Становление и развитие татарской советской книги (1917–1932). К., 1989.

**ВИ́КТОРОВ** Константин Рафаилович (5.9.1878, Самара ш. — 19.4.1958, Мәскәү), физиолог, проф. (1916), РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1948). Казан а.х. хайваннар физиологиясе мәктәбенә нигез салучы. 1899 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. Европаның эре лабораторияләрендә 4 ел стажировка үтә. 1910–36 да Казан вет. ин-тының физиология һәм физиологик химия каф. мөдире. 1936–40 та Мәскәү вет. ин-тында, 1940–58 дә Тимирязев исем. а.х. академиясендә укыта. В. җитәкчелегендә үзәк нерв системасы, мускуллар, ашкайнату физиологиясе, фармакология, биохимия буенча фундаменталь тикшеренүләр үткәрелә. В., югары сулыш юллары физиологиясен өйрәнеп, сулыш алу гигиенасына нигез сала, төрле әгъзалар һәм тукымаларга лизатлар, цитотоксиннар тәэсирен билгеләүгә мөһим өлеш кертә. Йорт хайваннары физиологиясе буенча югары уку йортлары өчен язылган дәреслеге кытай, румын, венгр һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Краткий курс физиологии домашних животных. Вып. 1. Пищеварение // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1911. Т. 28; Руководство к практическим занятиям по физиологии животных. М., 1953; Физиология сельскохозяйственных животных: Учеб. пособие. М., 1960.

*Әд.:* Казанский государственный ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана (1873–1953) // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1956. Т. 63; История Казанского государственного ветеринарного института им. Н.Э.Баумана. К., 1973; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ВИЛДА́НОВ** Азат Фәрит улы (16.6.1949, Мәскәү), химик-технолог, техник фән. д-ры (1998), проф. (2002). Казан хим.-технол. ин-тын (1973) тәмамлый. 1974 елдан Бөтенсоюз углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында, 1985 тән углеводород чималын күкерттән чистарту лабораториясе мөдире. Хезмәтләре нефть, газ эшкәртү, нефть продуктларын күкерттән чистартуга карый. В. җитәкчелегендә углеводород чималын меркаптаннардан чистарту катализаторлары; нефть, сыекландырылган газ, газоконденсат һ.б. нефть продуктларын, ш.у. нефть эшкәртү з-дларыннан агып чыккан суларны күкерт кушылмаларыннан чистартуның яңа технологияләре эшләнә, алар Америка-казакъ уртак «Тенгизшевройл» пр-тиесенең Тенгиз газ эшкәртү з-дында, Рязань, Куйбышев нефть эшкәртү з-дларында, Әстерхан, Пермь газ эшкәртү з-дларында, Новокуйбышевск, Салават нефтехимия комб-тларында һ.б. пр-тиеләрдә гамәлгә ашырыла. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты, ш.и. АКШның 5 патенты, ФРГның 1 патенты бар. Фән һәм техника өлкәсендә Ленин комсомолы бүләге (1981), ТР Дәүләт бүләге (1998), РФ Хөкүмәт бүләге (2005) лауреаты.

Х е з м.: Комплексная схема демеркаптанизации светлых фракций нефтей и газоконденсатов Прикаспийской низменности // Химия и технология топлив и масел. 1987. № 11 (автордаш); Современные проблемы обессеривания нефтей и нефтепродуктов // Рос. хим. журн. Всерос. хим. об-ва им. Д.И.Менделеева. 1995. Т. 39, № 5 (автордаш); Новые катализаторы и процессы для очистки нефтей и нефтепродуктов от меркаптанов // Нефтехимия. 1999. Т. 39, № 5 (автордаш).

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ-КГТУ (1930–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ВИЛДА́НОВ** Румил Җиһангир улы (24.11.1939, Фрунзе ш. — 16.3.1987, Мәскәү; Ташкентта җирләнгән), композитор, Үзбәкстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977). 1962 елда Ташкент консерваториясен (Б.Зейдман классы) тәмамлый, 1968 гә кадәр шунда ук укытучы булып эшли.

Төп әсәрләре: У.Шекспир әсәре буенча «Уникенче төн» муз. комедиясе (1969), В.В.Маяковский поэмасы буенча «Ленин» ораториясе (1964), симфонияләр, фортепиано өчен концерт (1965), скрипка һәм оркестр өчен концерт (1968); камера-инструменталь әсәрләр, хор әсәрләре, җырлар, кинофильмнарга музыка. Үзбәкстан ССРның Хәмзә исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1983).

**ВИЛДА́НОВ** Фоат Габделхак улы (8.12.1951, Чаллы (хәзерге Тукай) р-ны Сәмәкәй а.), а. х. пр-тиесе җитәкчесе, ТССРның атказ. а. х. хезмәткәре (1990). Казан а. х. ин-тын тәмамлый (1979). Хезмәт эшчәнлеген 1970 елда Түбән Кама р-нының «Ленин юлы» с-зында башлый. 1973 тән Тукай р-нында: 1979 дан «Ильбухтино» с-зында баш агроном; 1981 дән директор, 1998 дән «Камский» җитештерү кооперативы (1988 кадәр совхоз) рәисе. В. җитәкчелегендә мөгезле эре терлек өчен 1200 урынлы ферма, ашлык складлары, 10 мең *т* сыешлы ашлык чистарту-киптерү комплексы, а.х. техникасын саклау өчен 3 мең *м*² мәй-

данлы мастерской һәм ангарлар, 4,5 мең *т* сыешлы бәрәңге саклау урыны; 300 урынлы мәдәният йорты, 90 урынлы балалар бакчасы, 300 телефон номеры булган АТС, янгын сүндерү депосы, 160 фатирлы торак йортлар төзелә; хуҗалык эчендә 2,5 *км* юлга асфальт салына, торак йортлар һәм көнкүрештәге социаль-мәдәният йортлары тулысынча газлаштырыла. 2001–05 тә 1996–2000 б-н чагыштырганда хуҗалыкта ашлык җитештерү 82,4% ка, бәрәңге — 12, сөт — 8,9% ка арта. В. «Почет билгесе» ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Вильданов Фоат Габдулхакович // Кто есть кто. К., 2002; Мухаметшин Х. Заслуженные люди Тукаевского района. Наб. Челны, 2003; Шишкина И.А. Верность земле: Страницы биографии ПК «Камский». Наб. Челны, 2004.

*И.Н.Афанасьев.*

**«ВИЛЬ СИНЬ»** («Яңа караш»), атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Алабуга өязе земство идарәсе, соңрак Алабуга өязе Халык хуҗалыгы комис-ты органы. 1918 елның февраленнән сентябренә кадәр Алабуга шәһәрендә удмурт телендә нәшер ителә, барлыгы 22 саны чыга. Оештыручысы һәм беренче мөхәррире удмурт милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе К.С.Яковлев. Аннан соң газетаны большевикларга теләктәшлек иткән П.Д.Горохов һәм И.Г.Векшин җитәкли. Газета, гомумдемократик юнәлештә булса да, эсерларга да тартыла. Учредительләр җыены эшенә уңай карый, большевиклар советларын сыйнфый килешмәүчәнлекләре өчен тәнкыйтьли. Барлык катлау удмурт халкын берләшергә һәм иҗтимагый-сәяси тормышта актив катнашырга чакыра. 1918 нең июнь аенда газета удмуртларның 1 нче Бөтенроссия съездын әзерләүдә актив катнаша. РСФСРдагы фин-угыр төркеменә кергән халыклар арасында аң-белем тарату өчен көрәшә, медицина һәм а.х. белемнәрен пропагандалый. Газетада башлап язучы удмурт язучылары Михаил һәм Максим Прокопьевларның, И.Г.Векшин һәм Л.Г.Векшина (псевд. Ашальчи Оки), И.С.Михеев, Н.А.Корнилов, К.П.Чайников (псевд. Кузебай Герд) һ.б. авторларның пьесалары, шигырьләре, фольклор әсәрләре басыла, Алабуга өязе Удмурт комис-ты тарафыннан большевик Т.К.Борисов редакциясендә чыгарылган соңгы санында газета совет хакимиятенең сәяси асылын аңлата, аңа булышлык итәргә чакыра. Атаман Дутов гаскәре һөҗүме башлану һәм Көнчыгыш фронтта хәлләр катлаулану сәбәпле, газета чыгудан туктый.

*К.Н.Куликов.*

**ВИ́ЛЬКЕН А.М. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**, табигать белгече, педагог, библиофил Александр Модестович фон Вилькенның (1874 — ?) шәхси китаплар тупланмасы. 20 йөз башында Казанда иң бай коллекцияләрдән санала. 1957 елда коллекциянең төп өлеше — 9976 саклау берәмлеге — СССР ФАнең Казан ф-лы фондына алына. Шулардан 7292 се — рус телендәге китап, 445 е — чит ил телләрендә; 2289 берәмлеге — 19 йөз рус журналлары («Современник», «Отечественные записки», «Русский вестник», «Русская мысль» һ.б.), А.М. фон Вилькен архивындагы документлар. Күпчелек китаплар 19 йөзнең 2 нче яртысында һәм 20 йөз башында нәшер ителгән тарих, әдәбият белеме, фәлсәфә һәм дин тарихы, тел белеме, сәнгать һәм табигать фәннәренә карый, өчтән бер өлеше — матур әдәбият әсәрләре. Гыйльми һәм тарихи китаплардан: М.В.Ломоносовның «Россия грамматикасы» («Российская грамматика», 1755), «Борынгы Россия вивлиофикасы» («Древняя Российская вивлиофика», 1788–91) дигән хезмәт, «Патшабикә Екатерина II нең 1763–1788 елларда Вольтер б-н фәлсәфи һәм сәяси хатлар алышуы» («Философическая и политическая переписка императрицы Екатерины Второй с Вольтером, продолжавшаяся с 1763 по 1788 *г.*», 1802), Н.М.Карамзинның «Россия дәүләте тарихы» («История Государства Российского») томнары һ.б. Матбугат һәм китапчылык тарихы А.Смирдин (1840), Глазуновлар (1845–82), А.Ф.Бизунов (1879), В.К.Готьеның (1887–94) китап кибетләре каталогларында, антиквар китапларда, чиркәү-славян матбугаты басмаларында, ш.у. шәхси китапханәләрдә чагылыш таба. Тупланмада — күптомлы энциклопедик сүзлекләр, «Күренекле кешеләр тормышы» («Жизнь замечательных людей») сериясенең 1891–1918 елларда чыккан 146 томы, «Россия театры, яки Барлык рус сәхнә әсәрләренең тулы җыелмасы»ның («Российский театр, или Полное собрание всех Российских сочинений», 1787–94) 30 томлыгы, атаклы музейлар һәм картиналар галереяларында саклланган сәнгать әсәрләре репродукцияләре, карикатура, гравюра альбомнары һ.б. 1950 еллар ахырында А.М.фон Вилькенның китаплар тупланмасының тасвирланмасы СССР ФАнең Казан ф-лы хезмәткәрләре тарафыннан эшләнә, китаплар аерым фонд буларак каталогка теркәлә. Тупланманың 1000 гә якын берәмлеге (18–19 йөзләргә караган кульязма җыентыклар, Иван Фёдоровның «Төрмә Тәүрате» («Острожная Библия», 1581), 19–20 йөзләрдәге кануни актлар, революцион азатлык хәрәкәте документлары, гаилә архивы фрагментлары һ.б.) ТРның Милли музее фондларында, 15 йөзгә — 19 йөзнең 2 нче яртысына нисбәтле 13 кульязма Казан ун-ты фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә саклана.

*Әд.:* Катанов Н. Несколько слов о Казанских коллекционерах // Казан. музейный вестн. 1920. № 7–8; Музей в системе ценностей евразийской культуры: Материалы Всерос. науч.-практ. конф. 25–28 сент. 2000. К., 2000.


*Н.А.Карташёва, С.А.Лучкина, С.М.Морозкина.*

**ВИЛЬКИ́ЕВ** Җәүдәт Вәли улы (16.5.1927, Сталинград ш. — 9.11.2007, Казан), педагог, психолог, пед. фән. д-ры (1983), проф. (1985), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1990), РФнең атказ. югары мәктәп укытучысы (2002). Әстерхан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), 1950–1961 елларда Әстерхан, Татарстан укытучылар белемен күтәрү ин-тларында эшли. 1964 тән Казан пед. ин-тының педагогика кафедрасында (хәзерге Татар гуманитар-пед. ун-ты), 1968 дән, бер үк вакытта, институтның дидактика лаб. мөдире, 1983 тән психол. кафедрасында, каф. мөдире (1983–1988). Хезмәтләре логика һәм мәктәптә фәнни танып-белү алымнары проблемаларына; укучыларның фәнни фикерләү нигезләре формалашуга, педагогларның психол. әзерлеге мәсьәләләренә карый. ПФАның К.Д.Ушинский медале б-н бүләкләнә (1987).

Хезм.: Применение гипотезы в познавательной деятельности школьников. К., 1974; Методы научного познания в школьном обучении. К., 1975; Формирование педагогического мышления у студентов. К., 1992; Педагогическая психология. К., 2002.

**ВИЛЬКОВИ́СКАЯ** Вера Эммануиловна (7.2.1890, Казан — 1944, шунда ук), график, нәкышьче. Казан сәнгать мәктәбен тәмамлый (1910), СА каршындагы Югары сәнгать уч-щесендә укый (1912). Казан архитектура-сәнгать остаханәсендә укыта, анатомик рәсем һәм рәсем төшерү классларын җитәкли (1920–26). 1927–41 елларда Мәскәүдә яши, урта мәктәптә укыта.

Акварель, пастель, карандаш техникасында башкарылган пейзажлар, натюрмортлар авторы; офорт, ксилография б-н шөгыльләнә. Сәяси плакатлар (1919), экслибрислар (1920 еллар), чигү өчен эскизлар (1930 еллар) ясый. Казанның мәдәният эшлеклеләре («П.П.Беньков», «П.М.Дульский», «Ф.П.Гаврилов» һ.б.) портретлары сериясен иҗат итә (1920 еллар башы).





В.Э.Вильковиская. 1. «Әти рәсеме». Литография. 1910–20 еллар; 2. «Карчык». Линогравюра. 1920 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

*«Всадник»* берләшмәсе әгъзасы (1919–24). 1914 елдан күргәзмәләрдә, ш.и. «Җирле һәм чит өлкәләр рәссамнарының периодик күргәзмәсе»ндә (Казан, 1916), Казанда узган Беренче дәүләт фән һәм сәнгать күргәзмәсендә (1920), «Всадник» графиклар коллективының 1 нче күргәзмәсендә (1920, Казан), «Рус ксилографиясе 10 ел эчендә» күргәзмәсендә (Ленинград, 1927) һ.б. катнаша. Шәхси күргәзмәсе 1925 тә Казанда уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы музеенда саклана.

*Әд.:* Дульский П.М. Вильковиская Вера Эммануиловна: Выставка картин. 1912–1925. К., 1925; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1972. Т. 2; Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х гг. К., 1990.

*Е.П.Ключевская.*

**ВИЛЬМО́Н** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 28 *км* көнбатыштарак, Оштырма елгасы чыганагы янында. 2002 елда 30 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Мамадыш кантоны Кукмара волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан

Кукмара р-нында. Халык саны: 1926 да — 69, 1938 дә — 84, 1949 да — 72, 1958 дә — 77, 1970 тә — 102, 1979 да — 54, 1989 да — 39 кеше.

**ВИ́ЛЬЯМС** (Williams) Гарольд (1876–1928), инглиз журналисты. 1904–18 елларда Петроградта инглиз газеталары хәбәрчесе булып эшли. Г.Тукайның «Пар ат» шигырен, инглиз теленә тәрҗемә итеп, шагыйрьнең кыскача тәрҗемәи хәле һәм 20 йөз башы татар әдәбияты хакындагы мәкаләләрен «Russian Review» («Россия хәбәрләре») ж-лында (1914) бастыра.

**ВИНЕ́ЦКИЙ** Ян Борисович (10.3.1912, Александровск ш., хәзерге Запорожье ш., Украина — 1.8.1987, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967). 1932 елда Ленинград очучылар мәктәбен тәмамлый, 1936–37 дә Испания Респ-касы хәрби-һава көчләре сафында сугыша. 1941 дән Казан пр-тиеләрендә хәрби вәкил булып эшли. 1943 тә Волхов фронтында самолётларны хәрби сынауда катнаша. 1948 дә Казан Юридик мәктәбен экстерн рәвештә тәмамлап, 1956 га кадәр ТАССР Прокуратурасында эшли. 1956–72 дә «Советская Татария» г-тасы редакциясендә. Әсәрләре 1939 дан басыла башлый. «Сандугач» («Соловей», 1953) повесте, «Мадрид повесте» («Мадридская повесть», 1956) испан халкының фашистларга каршы сугышын, интернациональ бригадалар сугышчылары көрәшен тасвирлый. Хезмәт темасы «Тугрылык» («Верность», 1948) повестенда, «Үрләряулый кеше» («Человек идёт в гору», 1954), «Ышанучы» («Тот, кто верит», 1963) романнарында чагылыш таба. В. — күпсанлы хикәя, очерк һәм спектакльләргә рецензияләр авторы. Рус теленә И.Газизның «Онытылмас еллар» («Незабываемые годы», 1950), «Гади кешеләр» («За городом, за Казанью», 1957), А.Шамов, Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, М.Хәсәнов, Г.Минский һ.б. язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итә. Кызыл Байрак, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ВИНОГРА́ДОВ** Борис Сергеевич (31.1.1920, Казан — 28.10.1991, шунда ук), гамәли газ динамикасы гыйлеме белгече, техник фән. канд-ты (1950), проф. (1978), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1980). 1944 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1950 дә шунда ук эшли, газ динамикасы лабораториясенең фәнни җитәкчесе (1955–91). Хезмәтләре үзәктән кугыч компрессорлардагы процессларга, двигательләр һәм энергия җайланмаларындагы газ динамикасына карый. Үзәктән кугыч компрессорларның элементларын хисаплау, реактив двигательләрнең тарту көчен агым б-н идарә итү ысулларын эшли, агынтылы технологик лазерларның элементларын проектлаштыру методикасын төзи. Уйлап табуга 36 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Исследование рабочего процесса и характеристик центробежных компрессоров. К., 1960 (автордаш); Прикладная газовая динамика. М., 1965; Основы магнитной газодинамики. К., 1977; Газодинамический расчёт реактивных сопел воздушно-реактивных двигателей. К., 1978.

**ВИНОГРА́ДОВ** Василий Иванович (7.1.1874, Алабуга ш. — 12.11.1948, Казан), композитор, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1944). Мәскәү ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1899). Уку дәверендә Мәскәү консерваториясе проф. И.Гржималида скрипка буенча аерым дәресләр ала. 1899–1920 елларда Уфа, Златоуст, Вятка, Уржум шәһәрләрендә юрист булып эшли. Бер үк вакытта Уфада «Җыр, музыка һәм драма сәнгатен сөючеләр җәмгыяте» («Общество любителей пения, музыки и драматического искусства») хорына җитәкчелек итә, Уржумда түләүсез халык музыка мәктәбе оештыра, татар, башкорт, мари халык көйләрен язып ала, инструменталь әсәрләр иҗат итә. 1921 дән Казанда: Казан музыка уч-щесендә укыта, Татар радиосы һәм Татар акад. театры оркестрлары дирижёры, ТАССР МС каршындагы Сәнгать эшләре идарәсенең муз. фольклор кабинеты хезмәткәре. В.ның пед., иҗади һәм муз.-җәмәгать эшчәнлеге хәзерге татар музыка сәнгате үсешенә булышлык итә. В. — татар һәм башкорт музыкасы җирлегендә язылган «Татар сюитасы», «Шихан» симф. әсәрләре авторларының берсе. Зур драма һәм Татар акад. театрлары спектакльләренә музыка иҗат итә, «Сания» (1925) һәм «Эшче» (1930) дигән беренче татар опералары авторларының берсе (Г.Әлмөхәммәдов һәм С.Габәши б-н берлектә).

*Әд.:* Гиршман Я.М. Василий Иванович Виноградов // Композиторы Советского Татарстана. К., 1957.

**ВИНОГРА́ДОВ** Георгий (Юрий) Васильевич (15.2.1907, Уфа губ. Бәләбәй ш. — 4.1.1983, Казан), композитор, музыка белгече, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1954). 1926 елда Казан музыка техникумын (О.Родзевичта фортепьяно классы), Гнесиннар исем. (Мәскәү) Музыка-пед. ин-тының теория-композиция ф-тын тәмамлый (1946). Казан музыка уч-щесендә (1936–45), Казан консерваториясендә (1945–77) композиция һәм музыка теориясе фәннәрен укыта. Шәкертләре арасында: Ә.Бакиров, И.Шәмсетдинов, Х.Вәлиуллин, Х.Әбделмәнов һ.б. В.ның композиторлык иҗатында төп урынны камера-инструменталь һәм камера-вокаль әсәрләр алып тора. Алар арасында симф. оркестр өчен татар халык көе «Әпипә» темасына вариацияләр, фортепьяно өчен Балалар альбомы, ике фортепьяно өчен Татар маршы, М.Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә» балладасына кантата, А.Пушкин, С.Щипачёв шигырьләренә романслар циклы, татар шагыйрьләре шигырьләренә романслар һәм җырлар, фортепьяно өчен 12 кытай халык җыры эшкәртмәләре, вокал һәм фортепьяно өчен татар, рус, кыргыз, инглиз халык җырларының эшкәртмәләре бар.

*Әд.:* Файзи Дж. Юрий Васильевич Виноградов // Композиторы Советского Татарстана. К., 1957; Бикчурина Ф. Юрий Виноградов // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

**ВИНОГРА́ДОВ** Николай Андреевич (7.11.1831, Түбән Новгород губ., Ардатов өязе Выкса а. — 1.01.1886, Казан), терапевт, невропатолог, медицина д-ры (1858). Россия медицинасында функциональ юнәлешкә нигез салучыларның берсе. Казан терапевтлар фәнни мәктәбен нигезләүче. С.П.Боткин шәкерте. 1855 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, Мед.-хирургия академиясенең (С.Петербург) хәрби ведомствосында хезмәт итә. 1863 тән Казан ун-ты профессоры, 1870 тән ф-т терапиясе каф. мөдире. Беренче мәртәбә этиологик фактор булмаган очракта эчке әгъзалар амилоидозасының элекке хәленә кайтуын күрсәтә. В.ның күпчелек хезмәтләре йөрәк зәгыйфьлеге вакытында акустик күренешләр механизмын һәм аның урынын күрсәтүгә, мидәге, кечкенә мидәге шешнең урынын билгеләүгә, альбиминурия, зәңгелә һ.б. авыруларны өйрәнүгә карый. Россиядә невропатологлардан беренче буларак, ми авыруларының катлаулы очракларына диагноз кую үрнәкләрен тәкъдим итә, клиник лаборатория оештыра. Барлык клиник очраклар өчен мәҗбүри термометриягә һәм патолого-анатомик ярып карауга өстенлек бирә. В. медицинада авыруларны булдырмый калу юнәлеше тарафдары. Россия терапиясе тарихына В. күренекле кардиолог буларак кергән. Ул дигисталин тәэсир итү механизмын өйрәнә, югары һәм түбән темп-раның йөрәккә йогынты ясавына караган тикшеренүләре б-н таныла. В. буыннарның көчле ревматизмы вакытында арка һәм баш мие тышчаларының зарарлану мөмкинлеген беренчеләрдән булып күрсәтә. В. пед. эшчәнлеге б-н дан казана — аны «клиник укытулар реформаторы» дип атыйлар. Шәкертләре арасында: М.А.*Хомяков*, Н.И.*Котовщиков*, А.Н.*Казимбәк*, А.А.*Панормов*. В. — Казан табибләр җәмгыятенә (1868), Фәкыйрь студентларга ярдәм җәмгыятенә нигез салучы (1871), С.Петербургтагы Рус табибләре җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1883).

Хезм.: Лечение перемежающейся лихорадки холодной водой. К., 1858; О значении причинной диагностики для терапии // Мед. вестн. 1868. № 37–38.




В.И. Виноградов.



Б.А. Винокуров.

**ВИНОКУ́РОВ** Борис Алексеевич (1915, Минзәлә ш. — 11.2.1940, Карелия муентыгы, Финляндия), Сов. Союзы Герое (7.4.1940, үлгәннән соң). 1937 елдан Кызыл Армиядә. 1939 да совет сугышчыларының Көнбатыш Белоруссия походында катнаша. 1939 ның апреленнән совет-фин сугышы фронтларында, 398 нче танк батальонының танк командиры (13 нче армиянең 50 нче укчы дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш фронты гаскәрләре



В.М. Винокуров.



М.А. Винокуров.

составында 1940 ның 11 февралендә Карелия муентыгында дошман ныгытмасын өзгәндә батырлык күрсәтә, В. танкы штурм вакытында яндырыла, яна торган танктан атылып чыгып, пулёмет б-н атакага ташлана һәм шул сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Минзәләдә геройга бюст куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К. 2000; Герои Советского Союза. М., 1987. Т. 1; Золотые Звёзды Прикамья. Пермь, 1974.

**ВИНОКУ́РОВ** Владимир Михайлович (6.10.1921, Омск ш.), геолог-минералог, геол.-минералогия фән. д-ры (1966), проф. (1967), ТАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1979, 2002). М.А.*Винокуров*ның улы. Казан ун-тын тәмамлый (1950), шунда ук эшли, 1965–91 елларда минералогия һәм петрография каф. мөдире; минераллар физикасы һәм аларның синтетик аналоглары лабораториясен оештыручы (1989). Минералогиядә тау токымнары һәм *минераллар физикасы* фәнни юнәлешен нигезләүчеләрнең берсе (1964). В.ның бу өлкәдәге эзләнүләре реаль кристаллар төзелеше турында күзаллауны киңәйтергә, кристалларда гадәти булмаган валентлы халәттә кушылган ионнар булуын ачыкларга, гетеровалентлы изоморф алмаштырулар вакытында корылмалы компенсация механизмнарын ачыкларга һ.б. зур мөмкинлек бирә. ЭПР һәм ТМР кулланып минераллар өйрәнүнең спектроскопик ысулларын геол. эзләү эшләре тәҗрибәсенә кертә. Тау токымнарының физик үзенчәлекләрен әлеге алымнар б-н өйрәнү нефть һәм газ коллекторларының сыйдыру-фильтрлау үзлекләрен билгеләүнең экспресс ысулын куллануга китерә. Халыкара кристаллографик союз (1978), халыкара «Physics and Chemistry of Minerals» ж-лы редколлегиясе (1978–97) әгъзасы. Бөтенроссия минералогия җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе (1965–95), шул җәмгыятьнең шәрәфле әгъзасы (1980). Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Магнитные свойства минералов и методы их изучения // Современные методы минералогического исследования. М., 1969. Ч. 2; ЭПР — спектроскопия и изоморфизм в минералах // Проблемы изоморфных замещений атомов в кристаллах. М., 1971; Dissymmetrization of Crystals: Theory and Experiment // Physics and Chemistry of Minerals. 1980. V. 6 (автордаш).

**ВИНОКУ́РОВ** Михаил Александрович (2.10.1886, Самара губ. Сызрань ш. — 27.9.1980, Казан), туфрак белгече, а.х. фән. д-ры (1940), проф. (1931), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1950). Казан туфрак белгечлеге фәнни мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1916), шунда ук эшли. Көнбатыш Себер һәм Көньяк Урал буенча туфракны өйрәнү экспедицияләрендә катнаша. 1921–32 елларда Омск а.х. ин-тында, 1932–76 да Казан ун-тында, 1957 гә кадәр туфрак белеме каф. мөдире. Бер үк вакытта 1925–28 дә Көнбатыш Себер өлкәсе а.х. тәҗрибә станциясендә фәнни тикшеренүләрне җитәкли, 1928–32 дә Себер туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-тында, 1946–50 дә СССР ФА Биология ин-тының Казан бүлегендә. Хезмәтләре туфракның сеңдерү мөмкинлегенә, органик күкерт бүленеп чыгу методикасына, туфракның уңдырышлылыгына һәм аны культуралаштыруга карый. «Татарстан туфраклары» («Почвы Татарии», 1962) китабын төзүче һәм мөхәррире. 1950–70 тә Бөтенсоюз туфрак белгечләре җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе. Ленин, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Коллоидно-химический состав почв Предволжской части ТАССР и приёмы повышения их плодородия. К., 1952; Влияние полезащитных лесных полос на почвы. К., 1959 (автордаш); Краткая характеристика почв и агропочвенных районов Татарской АССР. К., 1963; Изменение свойств лесостепных почв под влиянием окультуривания. К., 1969; Гумус почв Волжско-Камской лесостепи и его роль в плодородии. К., 1972 (автордаш); Чернозёмы Татарии. К., 1976 (автордаш).

*Әд.:* К о л о с к о в а А.В. Михаил Александрович Винокуров (к 75-летию со дня рождения) // Почвоведение. 1962. № 4; ш у л у к. Вклад М.А.Винокурова в развитие почвоведения (к 100-летию со дня рождения) // Почвоведение. 1987. № 4.

**ВИ́НТЕР** Виктор Георгиевич (7.11.1939, Саратов өлкәсенең Духовницкий р-ны Духовницкий а. — 9.12.2005, Казан), биохимик, биол. фән. д-ры (1981), проф. (1982). Семипалатинск зоовет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), шунда ук врач-прозектор. 1962 елдан Казан ун-тында, 1969 дан фәнни-тикшеренү секторы җитәкчесе, 1975 тән ракка каршы микробиологик препаратлар синтезлау, 1987 дән нуклеин кислоталары биохимиясе лаб. мөдире, 1990 нан биохимия каф. мөдире. Хезмәтләре молекуляр биологиягә, төш аксымы һәм яман шеш үсеше биохимияләренә карый. Ул беренче тапкыр нормаль һәм шеш күзәнәкләре хроматинының негистон аксымнарында ДНКазалар булуын ачыклый; күзәнәкләр бүленүе һәм үсеше процессында ДНКазалар активлыгы көйләнеше турында принципиаль яңа мәгълүмат ала, шеш күзәнәкләренең элегрәк билгеле булмаган үзлеген — шешләрне үстерә торган РНК бүлеп чыгаруын билгели.

Х е з м.: Современные методы изучения нуклеиновых кислот и нуклеаз микроорганизмов. К., 1980; Методы генной инженерии. М., 1997 (автордаш); Электронное иммуногистохимическое изучение локализации нейтральной $Mn^{2+}$–зависимости ДНКазы // Цитология. 2000. Т. 42, № 7.

**ВИ́НТЕР** Любомир (25.6.1958, Чехословакия Халык Демократик Респ-касы Злин ш.), «Вулканпласт» АҖнең (Алабуга ш.) җитештерү буенча директоры. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). 1982 елда Техника мәктәбен тәмамлый (Злин ш.). Дәүләт бүләге автомобиль сәнәгате өчен яңа ПВХ-пластизольләр җитештерүне уйлап тапканы өчен бирелә.

**ВИО́ЛА** (Viola), е л а н к ү з е, а л а м и л ә ү ш ә, миләүшәчәләр семьялыгыннан үләнчел үсемлекләр төре. Туган ягы — Австралия, Америка, Африка. В. ыругына бер һәм күпьеллык үсемлекләрнең 400 ләп төре керә. Бакчада үсә торган эре чәчәкле В. өч төсле миләүшәдән һәм аның төрдәшләреннән башлана. ТР бакчаларында төрле төстәге формалары һәм сортлары, башка миләүшәләр б-н катнашкан гибридлары үстерелә. Читтән серкәләнүче, җыйнак, тармакланган сабаклы, 20–30 *см* биеклектәге куаксыман үсемлек. Яфраклары, сабакта урнашуына карап, рәт-рәт тезелгән, тешле-тешле, йомыркасыман, озынча түгәрәк була. Чәчәкләре эре, 4–10 *см* диаметрлы, төрле формада. Төсләре күзле-күзле ак, сары, зәңгәр, чуар; ике һәм өч төсле. Чәчәк ату вакыты, чәчү срогына карап, майда яки июньдә башлана. Җимеше өчкырлы тартмачык, орлыгы йомыркасыман түгәрәк, куе көрән төстә, ялтырап тора. Орлыктан яки сабактан үрчетелә, орлыгын башлыча июль урталарында чәчәләр. Сабактан үстерелгән үсемлекләр шул елның җәй ахырында яки көзен чәчәк аталар. В. салкынга чыдам, туфракка һәм яктылыкка таләпчән түгел. Күбесенчә бакчаларда чәчәк түтәлләре (клумба) ясау өчен, балконнарда һәм бүлмәдә үстерү өчен кулланалар. Кыргый В.ларны бакча чәчәгенә әверелдерү омтылышы 16 йөзгә карый: принц Вильгельм Гессен-Кассельский үз бакчасында үрчетә. 19 йөзнең 30 елларында, сары Европа миләүшәсен Алтай миләүшәсе б-н серкәләндереп, В.ның төрле төстәге күп төрләрен барлыкка китерәләр.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ВИРОБЯ́НЦ** Рафаэль Александрович (2.1.1898, Пятигорск ш. — 1973, Мәскәү), химик, химия фән. канд. (1960). Дон ун-тын (1924, Ростов-Дон ш.) тәмамлый. 1925–27 елларда «Красный Аксай» з-дында (Ростов-Дон ш.) лаб. мөдире. 1927–34 тә Грозный фәнни-тикшеренү ин-тының бүлек мөдире. 1934–37 дә Үзәк авиация ягулыгы һәм майлары ин-тында (Мәскәү), бер үк вакытта Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тында, 1937–48 дә Норильск тау-металлургия комб-тында, 1948–57 дә Ухта комб-тының Ижем корым з-дларында (Сосновка бистәсе, Коми АССР) эшли. 1957–66 да СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында нефть химиясе лаб. мөдире. 1966–71 дә Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тында. Хезмәтләре нефть химиясенә карый. Нефть фракцияләрен тикшерү ысулларын эшли, аларның төркемле химик составын, бу составның нефть продуктлары үзлегенә тәэсирен өйрәнә. Нефтькә һәм аның фракцияләренә, аларда метан, нафтен һәм хуш исле рәт углеводородлары булуга карап тасвирлама бирә; нефть фракцияләрен, аларның төрле технологик үзлекләрен исәпкә алып, эшкәртү мәсьәләләрен хәл итүгә фәнни караш булдыра.

Х е з м.: Термокаталитические превращения углеводородов нефтяной фракции состава $C_6$ на алюмоплатиновом катализаторе // Нефтехимия. 1961. № 4 (автордаш); Волжские нефти как сырье для получения бензола каталитическим риформингом // Химия и технология топлив и масел. 1962. № 11 (автордаш); Гидроалкилирование толуола и этилбензола на цеолите CaA, содержащем никель // Нефтехимия. 1964. № 5 (автордаш).

**ВИ́РУСЛАР** (лат. virus — агу), билгеле бер тере күзәнәкләргә үтеп, шул күзәнәкләр эчендә үрчүгә сәләтле күзәнәксез тереклек формалары. Җылы канлы умырткалыларның 500 гә якынын һәм югары төзелешле үсемлекләрнең 300 дән артыграгын зарарлаучы В. билгеле. В. 2 формада яшиләр: уянмаган хәлдә яки күзәнәктән тыш (вирус кисәкчекләре, ягъни вирионнар) һәм репродуктив хәлдә, ягъни күзәнәк эчендә. Вирионнарның формасы төрле. Күп кенә бактериофагларның формасы башчадан һәм үсентедән гыйбарәт, чәчәк авыруы В. — турыпочмаклы, герпес һәм гриппныкы — шарсыман, бәрәңге мозаик авыруы В.ның формасы — җепсыман. Вирионнарның зурлыгы 15–350 *нм* (кайбер җепсыман В.ның озынлыгы 2000 *нм* га җитә); электрон микроскопта күренәләр. Химик составы буенча В. ны гади һәм катлаулы төрләргә бүләләр. Гади В. нуклеин кислотасыннан һәм аксым сүрүе — капсидтан тора. Катлаулы В.да капсид аксымнары һәм нуклеин кислотасыннан башка липидлар һәм аксым-ферментлар бар. Нуклеин кислотасының һәрвакыт нәселдәнлек мәгълүматын таратучы бер тибы була (ДНК, яисә РНК, шуңа күрә барлык В.ны да ДНКсы яки РНКсы булганнарга бүләләр). Күзәнәкләрдә үрчиләр. Табигатьтә В. һәр җирдә очрый, йоктыручылар ярдәмендә яки механик рәвештә тарала ала. Күзәнәк эче паразитлары буларак, В. кешеләрдәге күп кенә авыруларны (чәчәк, грипп, кызамык, полиомиелит һ.б.) китереп чыгаралар. Күп кенә хайваннарны зарарлаучы полипатоген (котыру авыруы, Ауески авыруы В.) һәм монопатоген В.лар (дуңгызларда чума, тавыкларда инфекцион ларинготрахеит авыруларын китереп чыгаручы В.) бар. Үсемлек В.лары, башлыча, суыручы бөҗәкләр, талпаннар, нематодалар һәм кайбер түбән төзелешле гөмбәләр — тамыр паразитлары зооспоралары б-н, кайберләре авыру үсемлек орлыкларыннан (к. *Үсемлекләрдә вируслы авырулар*) таралалар.

*Әд.:* Общая вирусология: В 2 т. М., 1982.

**ВИ́РУСЛЫ ГЕПАТИТЛА́Р**, бавыр зарарлануга бәйле авырулар; гепатотроплы вируслар тарафыннан китереп чыгарыла һәм бавыр авыруларының 60% ын тәшкил итә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы классификациясе (1973) буенча билгеләнгән А, В, С, Д, Е (ВГА, ВГВ, ВГС, ВГД, ВГЕ) тибындагы вируслы гепатитлар күбрәк өйрәнелгән.

Сары авыруы гепатитның йогышлы табигате турындагы фараз Гиппократ дәвереннән (б.э.к. V–IV йөз) мәгълүм. 19 йөз ахырында Россия терапевты С.П.Боткин бавыр авырулары төркеменнән йогышлы-катараль сарыны («Боткин авыруы») аерып билгели. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында инъекция юлы б-н күчә торган сыркынды гепатиты ачыла. 20 йөзнең икенче яртысыннан йогышлы гепатитларның киң таралуы теркәлә, шул сәбәпле алар интенсив рәвештә өйрәнелә башлый. 1973 елда Америка галиме С.Фейнстоун А гепатитын китереп чыгаручы вирусны ача, 1975 тә В гепатитына каршы вакцина эшләнә. 1970 елларда Е, J, Т-ТҮ гепатитлары һәм аз өйрәнелгән SEH-вируслары б-н бәйле саналган вируслар ачыла. Диагноз кую өчен кыен саналган хроник Д гепатитының гадәти булмавы ачыла. ВГА һәм ВГЕ гепатитларын хроник йөртүчеләр тасвирланмаган. ВГВ һәм ВГС төрләре наркоманнар арасында күбрәк таралган (авыру инъекция һәм гемоконтакт юл б-н күчә); гемофилия б-н авыручылар, гомосексуалистлар, «гемодиализ пациентлары» югары дәрәҗәдә хәтәр төркемгә керәләр. Йогышлы авыру чыганагы: вирус йөртүчеләр (асылда, сәламәт кешеләр), персистик йогышлы авырулар, йогышлы авырулар б-н зарарланган су һәм ашамлык.

Таралу ысуллары буенча В.г. бүленеше: а) сезонлы көчәю хас булган энтераль юл б-н тарала торганнар (ВГА һәм ВГЕ); б) парентераль рәвештә, гемоконтакт, җенси, анадан балага күчү юлы б-н (вертикаль тапшырылу), ш.у. тыгыз көнкүреш элемтәсе вакытында тарала торганнарга бүленә (ВГВ, ВГД, ВГС). Парентераль юл б-н таралучы гепатит вирусларында иммунологик яктан төрле төрләр (квазивидлар) яшәешен, мутациясен, вирусның персистенция халәтенә күчешен билгеләүче гетероген геном була.

1960 елларда бер серотип, бер антигены булган, бавырда көчле ялкынсыну китереп чыгарып, балалар һәм яшьләрне зарарлый торган ВГА киң тарала. Ул җиңел һәм уртача авыр формада барып, сәламәтләнү б-н тәмамлана. Эпидемияләре һәр 5–10 ел саен кабатлана. ТРда ел саен гомерлек йогышлы авыру чыганагы булган В гепатитын йөртүче 700 авыру, С гепатитлы 700 авыру ачыкланып тора.

2004 елда ТРда 500 дән артык авыру очрагы теркәлгән һәм авыручылар санының арта баруы күзәтелә.

1990–2000 елларда Казан галимнәре — йогышлы авырулар белгечләре тарафыннан (Д.К.Бәширова һ.б.) ВГА тәэсире вакытында организмның иммунитет закончалыгы ачыклана; беренче тапкыр гепатит авыруының барышын бәяләү өчен протромбин индексы файдаланыла, индексны динамик контрольдә тоту авыруны дәваларга һәм терелтергә мөмкинлек бирә. Лазерның биоген иммунитет системасына тәэсире өйрәнелә һәм ул патогенезда организмның яраклашуын тәэмин итә. В һәм С хроник гепатитлар эпидемиологиясен аналитик тикшеренүләр ТРда фәкать 1990 елларда гына үткәрелә (беренче тапкыр тикшерелгәннәрнең 70% ында хроник гепатит булуы ачыклана). Бавыр циррозы б-н катлауланган гепатитларның 50% ы ВГС авыруына бәйле. Ашамлыкка аллергия булган балаларда ВГВ ешрак очрый. Казанда йогышлы гепатитның яшерен рәвештә баручы 8 төренең кайбер үзенчәлекләре, гепатит йөртүче аналарның аналыктагы балага авыру йоктыру мәсьәләләре өйрәнелә. Авыруның клиник һәм иммунологик үзенчәлекләре тикшерелә, вируска каршы дәвалау чаралары эшләнә (Д.Ш.Еналиева, А.И.Фазылҗанов), системалы эндотоксинемия тикшерелә һәм хроник гепатитлар вакытында антиэндотоксин саклану чарасы тәкъдим ителә (А.С.Созинов, С.В.Ткачёва), хроник гепатитлар вакытында гомеостаз тайпылышларны патогенетик көйләү ысуллары камилләштерелә (В.Х.Фазылов, Е.А.Татаринова).

*Әд.:* Б а ш и р о в а Д.К. Клиника и лечение хронических вирусных гепатитов у детей // Казан. мед. журн. 1991. № 3; З а к и р о в И.Г. Хронические вирусные гепатиты в Республике Татарстан. К., 2002. *Д.К.Бәширова.*

**ВИСУ́** (Ису), Чулманның югары агымы буендагы тарихи өлкә. Урта гасырлар Шәрекъ тарихи-географик әдәбиятында, ихтимал, Идел буе болгарларының Көнчыгыш Европаның төньяк өлкәләре турындагы мәгълүмат чыганакларыннан билгеле. Ул хәбәрләрнең бер өлеше дастан-риваять тасвирламасы буларак бик борынгыдан килә (мәңгелек төн, хәтсез суыклар). Мәгълүматларның кайберләре чынбарлык б-н бәйле. Мәс., Ибне Фазлан, «болгар сәүдәгәрләре Вису дигән илгә баралар, кеш, кара төлке тиреләре алып кайталар»; әл-Гарнати, «болгарлардан бер айлык юл чигендә Вису дип аталган өлкә бар, анда яшәүчеләр болгар иленә хәрәҗ түләп торалар», — дип хәбәр итә. В. халкының «зәңгәр күзле, җитен сүсе кебек аксыл чәчле» булуы... анда яшәүчеләрнең «җитен сүсеннән тукылган кием кию» бәян ителә. «Кайберләре кондыз тиресеннән, мехлы ягы тышка каратып тегелгән затлы тун киеп йөриләр. Арпадан әчетелгән, серкәдәй әче эчемлек эчәләр, кондыз б-н тиен ите һәм бал ашыйлар», — диелә. Затлы мехлы җәнлек тиреләренә бай бу өлкә Идел буе Болгарыннан төньяк-көнчыгыштарак урнашкан була, халкы болгарларга ярым буйсыну хәлендә яши, аларга салым түли. В. өлкәсеннән, затлы тиреләрдән тыш, бал, тимер дә китерелә һәм сәүдә юллары б-н Болгар иленнән көнбатыш җирләргә дә чыгарыла. В. өлкәсендә яшәүчеләр фин-угыр кабиләләренә кергән һәм хәзерге комиларның ерак бабалары булган дип фараз ителә (10–14 йөзләргә караган Роданов археол. культурасы вәкилләре). Бүгенге көндә борынгы В. өлкәсе биләмәсенә кергән җирләрдә болгарларга хас керамика, корал, кием-салым бизәлеше әйберләре табыла. Рус елъязмаларында В. җирләре Пермь яки Бөек Пермь атамасы б-н теркәлгән.

Чыг.: К о в а л е в с к и й А.П. Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–22 гг. Хар., 1956; Путешествие Абу Хамида аль-Гарнати в Восточную и Центральную Европу. М., 1971.

*Әд.:* Т а л и ц к и й М.В. Верхнее Прикамье в X–XIV вв. М., 1951; И в а н о в А.Г. Этнокультурные и экономические связи населения бассейна р.Чепцы в эпоху средневековья. Ижевск, 1997; Б е л а в и н А.М. Камский торговый путь. Пермь, 2000. *И.Л.Измайлов.*

**ВИ́ТЕБСК ИСЕМЕНДӘГЕ́ УКЧЫ́ ДИВИ́ЗИЯ**, 1941 елның август-октябрь айларында 334 нче укчы дивизия буларак Казанда 20 нче запас бригада җирлегендә оеша. Дивизия командиры итеп полковник

Н.М.Мищенко билгеләнә. 1941 нең ноябрендә дивизия Горький өлкәсенә күчерелә, резервтагы 60 нчы армия составында була. Соңрак 24 нче армия составына күчерелә, Пахра елгасының төньяк ярында оборона тота, Мәскәүне Нарофоминск юнәлешендә дошман һөҗүменнән саклый. Мәскәү өчен барган сугышның иң кызган чагында дивизия 27 нче армиягә (соңрак 4 нче удар армия) буйсындырыла, ул 1942 нең 9 гыйнварында Волго күле буенда сугышка керә. 1944 нең ноябрендә В.и.у.д. 2 нче гвардияче армия составына кертелә. Дивизия Калинин, Смоленск өлкәләрен, Белоруссия, Литва, Латвияне азат итүдә, Көнчыгыш Пруссиядәге сугышларда катнаша. «Багратион» операциясе вакытындагы батырлыгы өчен «Витебск исемендәге дивизия» дигән мактаулы исемгә лаек була; дивизия сугышчыларыннан 10 кешегә Сов. Союзы Герое исеме бирелә. Мазур күлләре тирәсендә һәм Кёнигсберг шәһәреннән көньяк-көнбатышта урнашкан дошман көчләрен тар-мар итүдәге уңышлары өчен дивизия 2 нче дәрәҗә Суворов ордены б-н бүләкләнә. Ш.у. дивизиянең 1124 нче полкы — Александр Невский, 1122 һәм 1126 нчы полклары 3 нче дәрәҗә Кутузов орденнары б-н бүләкләнә. *В.Ф.Телишев.*

**ВИТЕ́ВСКИЙ** Владимир Николаевич (22.7.1845, Сембер губ., Сөнгәләй өязе Подбелий а. — 3.1.1906, Казан),тарихчы, педагог. Сембер руханилар семинариясен һәм Казан ун-тын тәмамлый (1869). 1869–74 елларда Уральск шәһәрендә гаскәри казаклар гимназиясендә, 1874–1901 дә Казан укытучылар семинариясендә һәм Мария исем. гимназиядә укыта. Төп хезмәте булып «И.И.Неплюев һәм 1758 елгача булган Оренбург төбәге» («И.И.Неплюев и Оренбургский край в его прежнем составе до 1758 года», 1889–97. вып. 1–5) санала. Анда элекке Оренбург төбәге биләмәләре, ш.и. Башкортстан тарихы, башкорт-татар баш күтәрүләре турында бай мәгълүмат тупланган. Аерым шәхесләрдән В.А.Жуковский, Н.И.Ильминскийга багышланган китаплар авторы. Педагогикага караган хезмәтләре Н.И.Ильминский йогынтысында язылган (укытучылар семинариясендә эшләгәндә алар фикердәшләр була).

Х е з м.: Раскол в Уральском войске и отношение к нему духовной и военно-гражданской власти в конце XVIII в. и в XIX в. К., 1878; В.А.Жуковский в своих письмах как человек и наставник в Бозе почившего императора Александра II. К., 1883; Николай Иванович Ильминский — директор Казанской учительской семинарии. К., 1892.

*Әд.:* А л е к с а н д р о в Я.А. Владимир Николаевич Витевский: Некролог. К., 1906; Р о ж д е с т в и н А.С. Владимир Николаевич Витевский // Казанский телеграф. 1906. № 3882.

*Е.В.Липаков.*

**ВИ́ТЕР** Пётр Акимович (10.10.1923, Украина ССРның Киев өлкәсе, Миронов р-ны Мироновка а. — 4.10.2003, Самара ш.), инженер-механик, сәнәгать җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1971), техник фән. канд. (1974). Харьков авиация ин-тын тәмамлый (1951). 1951–68 елларда Куйбышев моторлар төзү з-дында мастер, цех башлыгы, производство башлыгы, баш инженер. 1968–77 дә Казан моторлар төзү берләшмәсе директоры, 1977–82 дә ген. директор. 1982–89 да Двигательләр төзү фәнни-тикшеренү ин-тының Самара ф-лы директоры. Аның җитәкчелегендә Ил-62, Ту-154, Ил-86 самолётлары өчен Нк-4, Нк-8–2, Нк-86 двигательләрен җитештерү үзләштерелә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. 1975–82 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Өч Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.



П.А. Витер.

**ВИШЛЕНКО́ВА** Елена Анатольевна (2.9.1965, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1999), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1988). 1992 елдан шунда ук эшли, 20 йөзгә кадәрге ватан тарихы каф. мөдире (1999 дан). 19 йөз Россия тарихы буенча лекцияләр курсы авторларының берсе (2003). Хезмәтләре Россия империясенең дин өлкәсендәге сәясәтен тикшерүгә карый.

Х е з м.: Религиозная политика: официальный курс и «общее мнение» России александровской эпохи. К., 1997; Духовная школа в России первой четверти XIX века. К., 1998; Заботясь о думах подданных: религиозная пошлина в России первой четверти XIX века. Саратов, 2002; Казанский университет александровской эпохи. К., 2003; Казанское житье (XIX–XX вв.). К., 2005 (автордаш); Terra Universita fis: два века университетской культуры в Казани. К., 2005 (автордаш).

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999). К., 1999.

**ВИШНЕ́ВСКАЯ** Галина Петровна (8.2.1935, Казан), физик, физ.-матем. фән д-ры (1986), проф. (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1958 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Казан физ.-техника ин-тында эшли, 1986 дан әйдәп баручы, 1997 дән баш фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта 1991 дән Казан ун-тында пед. эштә. Хезмәтләре ЭПРга, тәртипкә салынмаган һәм өлешчә тәртипкә салынган мохиттәге парамагнит ионнарның электрон релаксациясенә карый. Интеграллаучы релаксометр аппаратурасын һәм релаксация вакытларын билгеләү ысулын эшли (бергәләп), бу исә куертылган системалардагы спин-челтәр ($10^{-9}$ *с* ка кадәр) һәм спин-спин ($10^{-10}$ *с* ка кадәр) кыска вакытлы электрон релаксацияләрен аерым үлчәүне беренче мәртәбә гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә; күпчелек магнит комплексларының релаксациясе вакыты турында мәгълүмат туплый. Комплексларның микротөзелешен, молекуляр хәрәкәтчәнлеген, поликристалл эремәләрнең төрле режимда суытылу вакытындагы фаза күчешләренең үзенчәлекләрен тикшерә. Беренче мәртәбә металлы ионалмашлы полимерларның эчке төзелешен билгели (1977). 1979 да Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыяте бүләгенә лаек була. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электронная релаксация и резонанс парамагнитных ионов в растворах // Радиоспектроскопия конденцированных сред. М., 1990; ЭПР в ионитах. М., 1992 (автордаш); Структурные изменения и фазовые переходы в водных растворах нитрата гадолиния в процессе их замораживания // Физика твёрдого тела. 2003, Т. 43, № 7 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**ВИШНЕ́ВСКИЙ** Александр Александрович (11.5.1906, Казан — 19.11.1975, Мәскәү), хирург, СССР МФА академигы (1957), мед. хезмәте ген.-полковнигы (1963), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1956), Соц. Хезмәт Герое (1966). А.В.Вишневскийның улы һәм шәкерте. 1929 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1931 дән Хәрби-мед. академиясендә (Ленинград). 1940 тан Үзәк ГИДУВ (Мәскәү) профессоры, 1947 дән хәрби-кыр хирургиясе каф. мөдире. 1948–75 тә СССР МФАнең А.В.Вишневский исем. Хирургия фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Бер үк вакытта 1940–56 да Совет армиясенең төрле фронтларында һәм СССР Оборона министрлыгының Мәскәү Хәрби округында баш хирург. Беренче хезмәтләре үрмәле инфильтрат ысулы б-н дәвалау урынын анестезияләү юлын эшләүгә бәйле анатомик-гистологик тикшеренүләргә, ш.у. ярсып авыртканда организмдагы биохимик үзгәрешләрне өйрәнүгә багышлана. 1947 дән төп игътибарын күкрәк хирургиясе проблемаларына, йөрәк, үпкә һәм күкрәк читлеге урталыгы операцияләрендә дәвалау урыны анестезиясе ысулын куллануга юнәлтә. 1953 тә, дөньяда беренче булып, митраль йөрәк зәгыйфьлеге авырулы кешегә анестезия ысулы б-н уңышлы операция ясый. Нерв трофикасы мәсьәләләре, трофик язва, бик каты пешү һәм ялкынсыну вакытында йоклатып дәвалау буенча А.В.Вишневский концепциясен үстерә. В. тарафыннан хирургик операцияләр вакытында гомуми һәм катнаш анестезияне, реанимацияне өйрәнү буенча лаборатория оештырыла. Тумыштан һәм соңрак барлыкка килгән йөрәк зәгыйфьлеге авыруын операция ясап дәвалау, тамырлар хирургиясе б-н шөгыльләнә. Беренче булып илебездә төзелгән ясалма кан әйләнеше аппараты ярдәмендә гипотермия шартларында кан әйләнеше туктатылган йөрәккә уңышлы операция ясый (1957). В. илебездә беренче кибернетик лаборатория (1959), автоматлаштырылган мед. архивы оештыра, тумыштан һәм соңрак барлыкка килгән йөрәк зәгыйфьлегенә диагноз кую системаларын эшли һәм гамәлгә кертә. 1966 да беренче мәртәбә арка мие өзелеп, оча сөягендәге әгъзалар функциясе бозылган очракта, сидек куыгына радиоешлыклы стимуляцияләү ысулы кулланып, операция үткәрә. Нерв трофикасы һәм тамырлар хирургиясенә караган хезмәтләре өчен аңа Лериш исем. Халыкара бүләк (1955), Ленин бүләге (1960) бирелә. Ике Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Атлас хирургии. М., 1961; Частная хирургия: Учеб. М., 1962; Дневник хирурга: Великая Отечественная война. 1941–45. М., 1967; Избранные работы по хирургии и пограничным областям: В 2 т. М., 1970.

*Әд.:* Видные учёные отечественной медицины и здравоохранения — питомцы Казанского медицинского института. К., 1989.

**ВИШНЕ́ВСКИЙ** Александр Васильевич (23.8.1874, Дагстан, Түбән Чир-Юрт а. — 13.11.1948, Мәскәү), хирург, медицина д-ры (1905), СССР МФА академигы (1947), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1934). Казан һәм Мәскәү хирурглары фәнни мәктәпләренә нигез салучы. 1899 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый, шунда ук анатомия һәм оператив хирургия кафедрасында прозектор булып эшли, 1912 елдан гомуми хирургия каф. проф. һәм мөдире, 1914 тән госпиталь хирургиясе каф. мөдире. 1935–47 дә Бөтенсоюз экспериментал медицина ин-ты һәм Үзәк ГИДУВның (Мәскәү) хирургия клиникалары мөдире. 1947–48 дә СССР МФАнең Хирургия фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Германия, Франция клиникаларында эшли, баш мие, үт юллары, сидек-җенес системасы хирургиясен өйрәнә. Казанда Л.О.Даркшевичның нерв авырулары клиникасы, соңрак Шамов (хәзер 1 нче шәһәр) хастаханәсе каршында операция бүлмәләре оештыра. В. күкрәк куышлыгы хирургиясе, нейрохирургия,




«Александр ВасильевичВишневский» истәлек медале.

сугыш яралары, зарарлану һәм үлекләү процесслары хирургиясенә кагылышлы эксперименталь-физиологик тикшеренүләр һәм клиник эшләр алып бара, ялкынсыну процессында нерв трофикасының роле турында концепция эшли, ялкынсыну процессларын, үлекле яраларны, җәрәхәт шокларын дәвалауның яңа ысулларын (новокаин блогы, ваго-симпатик блок, майлы-бәлзәмле бәйләвеч, *Вишневский мае*) гамәлгә кертә. Операцияләр вакытында кучмә инфильтрат ысулы б-н авыртуны басу ысулын тәкъдим итә (1930), бу — фәнни клиник хирургиянең анестезиология бүлегенә зур этәргеч бирә (*Новокаин блокадасы*). В.ның майлы-бәлзәмле бәйләвеч ысулы яраларны дәвалауда уңышлы кулланыла. Новокаин б-н бәлзәмле бәйләвечне бергә кушып куллану — ялкынсыну процессларын дәвалауда яңа ысул, бу ысул Бөек Ватан сугышы елларында авыртуны басу һәм яраларны дәвалауда киң кулланыла. Авыртуны туктату ысулын эшләгән өчен СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1942). Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан мед. ун-ты клиникасына (1936) (клиника бинасы алдына А.В.Вишневскийга һәйкәл-бюст куела) һәм СССР МФАнең хирургия ин-тына (1948) аның исеме бирелә. Түбән Чир-Юрт авылында В. музей-йорты эшли.

Х е з м.: Обезболивание в хирургии. К., 1929; Местное обезболивание по методу ползучего инфильтрата. К., 1932; Новокаиновый блок нервной системы // Нервная трофика в теории и практике медицины: Сб. статей. Л., 1936; Показания к применению новокаинового блока и масляных антисептиков // Хирургия. 1946. № 6; Новокаиновый блок и масляно-бальзамические антисептики . М., 1948.

*Әд.:* А л у ф И.С. Профессор А.В.Вишневский // Казан. мед. журн. 1934. № 6; Р о з е н г а р т е н М.Ю. Александр Васильевич Вишневский // Рассказы о казанских учёных. К., 1983.

**ВИШНЕ́ВСКИЙ А.В. ҺӘЙКӘ́Л-БЮСТЫ́**, Казанда Бутлеров һәм Толстой урамнары кисешкән чатта, А.В.*Вишневский* исем. республика клиник хастаханәсе янында урнашкан. Һәйкәл 1973 елда Вишневскийның тууына 100 ел тулу уңаеннан аның истәлеген мәңгеләштерү максатында төзелә. Авторлары — скульпт. В.И.Рогожин, арх. А.А.Спориус.

Вишневский бюсты һәм турыпочмаклы постамент тоташ гранит блоктан кисеп алынган. Алар, һәйкәлгә композицион бөтенлек биреп, образның эчке һәм тышкы матурлыгын ачып тора. Сын калыбында тыныч, йомшак табигатьле галимнең эчке дөньясы һәм үзенчәлекле портреты зур төгәллек б-н сурәтләнә. Зыялы кыяфәттә интеллектуаль көч, үз-үзенә ышану, тынычлык, киң күңеллелек сыйфатлары чагыла. Скульптор хирургның һөнәри осталыгын («алтын» кулын) иң әһәмиятле пластик элемент итеп алган. Һәйкәл известьташ плитәләрдән ясалган декоратив стена фонында чәчәк түтәле б-н әйләндереп алынган. *А.И.Новицкий.*

**ВИШНЕ́ВСКИЙ** Владимир Владимирович (29.7.1929, Казан — 25.10.2007, шунда ук), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1973), проф. (1975), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1990), Казан ун-тының атказ. проф. (2007). 1950 елда Ленинградның 2 нче артил. уч-щесен, 1958 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1960 тан Казан ун-тында эшли: механика-матем. ф-ты деканы (1974–93), 1994 тән кафедра проф., гомуми математика каф. мөдире (1984–94). Хезмәтләре алгебралар төзегән фәзаларның дифференциаль геометриясенә карый. Дүрт үлчәмле Риманча фәзаларның инвариантлар системасын төзи һәм аларның үзара бәйсезлеген исбатлый. «Почёт билгесе» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Пространства над алгебрами. К., 1985 (автордаш); Многообразия над алгеброй плюральных чисел и полукасательные структуры (ВИНИТИ) // Итоги науки и техники: Проблемы геометрии. 1988. Т. 20.

*Әд.:* Н о р д е н А.П., Ш и р о к о в А.П. О научных работах В.В.Вишневского. Труды геометрического семинара. К., 1991.

**ВИШНЕ́ВСКИЙ МАЕ**, В и ш н е в с к и й б ә л з ә м л е л и н и м е н т ы, В и ш н е в с к и й б ә л з ә м е, антисептик дару. 1927 елда А.В.*Вишневский* тәкъдим итә. 3 өлеш сумала, 3 өлеш ксероформ, 100 өлеш кастор маеннан тора. В.м. тукыма рецепторларына бактерицид һәм аз ярсытулы тәэсир итә, регенерацияне (күзәнәкләр яңаруын) тизләтә. Тиредә кечле үлекләү процессларын, трофик язва, озак ятудан тишелгән урыннарны, яраларны дәвалауда (майлы бәлзәмле эмульсияле бәйләвеч ярдәмендә), ком-



А.А. Вишневский.



А.В. Вишневский.

плекслы хирургик дәвалау элементы буларак кулланыла. Дәвалау бәйләвече аз гына ярсытып, яраларда нормаль трофик процесс булдыра. А.В.Вишневский тарафыннан ш.у. тромбофлебитны дәвалау схемасы — майлы зур бәйләвечне футлярлы новокаин блогы б-н бергә куллану ысулы тәкъдим ителә. В.м. Бөек Ватан сугышы чоры хирургиясендә яраларны дәвалауда киң кулланыла.

*Әд.:* З а х а р ь я н С.Т. А.В.Вишневский. М., 1967. *В.Н.Войцехович.*

**ВИШНЕ́ВСКИЙ** Фёдор Гаврилович (23.3.1801, Казан — 23.4.1863, Мәскәү), декабрист, гвардия экипажы лейтенанты (1821). Дворян нәселеннән. Диңгез кадет корпусын тәмамлый (1816). 1815 елдан Балтыйк диңгезе буйлап йөзә. 1819 да «Гектор» фрегаты б-н Дания, Франция, Англия һәм Пруссиядә була; 1822–24 тә «Крейсер» фрегатында (капитаны М.П.Лазарев) җир шары тирәли сәяхәт кыла. Декабристларның яшерен оешмасында тормый, әмма 1825 нең 14 декабрендә С.-Петербургның Сенат мәйданындагы баш күтәрүдә катнаша, 15 декабрьдә кулга алына. 1826 ның 10 июлендә В., дворянлык титулы сакланган хәлдә, гади солдат хезмәтен үтәүгә хөкем ителә. 1826 дан Троицк гарнизоны батальонында. Рус-Иран (1826–28) һәм Рус-төрек (1828–29) сугышларында катнаша. 1828 дә унтер-офицер чины бирелә, 1829 да Апшерон укчылар полкына, 1832 дә энисе тырышлыгы б-н мичман чинында 7 нче флот экипажына күчерелә. 1833–42 елларда гражданлык хезмәтендә. Отставкага чыкканнан соң Мәскәүдә яши. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир һәм Изге Георгий Победоносец орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Декабристы: Биогр. справка. М., 1988. *С.М.Михайлова.*

**ВИШНЁВКА** авылы, 2001 елдан Казан шәһәренең Идел буе р-ны составына керә, Казан тимер юл станциясеннән 15 *км* көнчыгыштарак, Нокса елгасы буенда. 2002 елда 101 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, бакчачылык. Казан ханлыгы чорыннан Татар Кабаны, соңрак Кабачище авылы буларак мәгълүм. 1970 еллардан хәзерге атамасын йөртә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, бакчачылык б-н шөгыльләнә, Казанда кәнлекчеләр булып эшли. Ярма яру кәсепчелеге зур үсеш ала (1880 елларда В. да 21 ярма ярдыру тегермәне эшли). 20 йөз башында мәктәп була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана

җире 597,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощак волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 71 ир заты; 1859 да — 213, 1897 дә — 269, 1920 дә — 353, 1926 да — 401, 1958 дә — 370, 1970 тә — 322, 1979 да — 259, 1989 да — 134 кеше.

**ВЛАДИ́МИР** (Петров Иван Степанович) (28.5.1828, Войско-Донское өлкәсе Федосеев а. — 2.9.1897, Казан), дин эшлеклесе, тел галиме. Петербург руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1853) монахлыкта. 1851–61 елларда Орёл, Иркутск, Томск руханилар семинарияләрендә укыта. 1861 дән Петербург руханилар академиясендә инспектор һәм профессор. Православие миссионерлык җәмгыяте уставын төзүне башлап йөрүче һәм авторы. 1863–83 тә Алтай миссиясе башлыгы. 1883 тән — Томск, 1886 дан — Ставрополь һәм Түбән Новгород епископы. 1892–97 дә — Казан һәм Зөя архиепископы. Казанда руханилар академиясенең һәм семинариясенең, миссионерлык курсларының эшчәнлегенә күзәтчелек итә, Ильминский системасын гамәлгә кертүгә булышлык итә. Инҗилне һәм гыйбадәт китапларын алтай теленә тәрҗемә итә, алтай теленең грамматикасын һәм сүзлеген төзи, алтайлылар этнографиясенә багышланган мәкаләләр бастыра. В.ның нәшер ителмәгән хезмәтләре Казан руханилар академиясе галимнәре тарафыннан алтайлылар һәм калмыклар тарихын өйрәнү, миссионерлык эшчәнлеге алып бару өчен файдаланылган (хәзерге көнгә сакланмаган).

*Әд.:* А л е к с а н д р о в А.И. Высокопреосвященнейший Владимир, архиепископ Казанский и Свияжский. К., 1897; Я с т р е б о в И. (Иннокентий). Миссионер Высокопреосвященный Владимир, архиепископ Казанский и Свияжский. К., 1898.

*Е.В.Липаков.*

**ВЛАДИ́МИР** (Ужинский Владимир Кононович) (22.3.1777, Новгород губ., Валдай өязе Ужинский погосты — 16.12.1855, Казан губ. Зөя ш.), дин эшлеклесе. Новгород руханилар семинариясен тәмамлый (1803) һәм шунда укыта. 1807 елдан монахлыкта. 1808 дән Новгород руханилар уч-щесе префекты, ректоры, архимандрит (1811), 1812 дән Новгород руханилар семинариясе ректоры. 1819 дан Ревель епископы, Петербург епархиясе викарие, 1822 дән Курск, 1831 дән — Чернигов епископы, 1836 дан Казан һәм Зөя архиепископы. 1848 дән ялга китә, Зөядәге Успение монастыренда монахлыкта була.

**ВЛАДИ́МИР** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 46 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 371 кеше (татарлар — 66%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Клуб. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Бөрсет исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы (керәшен татарлар) дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1893 тә төзелә; архит-ра истәлеге), Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, ярма ярдыру тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1454,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 63 ир заты; 1859 да — 540, 1897 дә — 844, 1908 дә — 1178, 1920 дә — 1143, 1926 да — 1050, 1938 дә — 980, 1949 да — 873, 1979 да — 714, 1989 да — 478 кеше.

*Әд.:* Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1904.

**ВЛАДИ́МИР I** (чукынганнан соң Василий) (960 тирәсе — 15.7.1015), Киев кенәзлегенең бөек кенәзе (980 елдан). Бөек кенәз Святослав I нең кече улы. Атасы В. I не 970 тә Новгород шәһәре кенәзе итеп билгели. Святослав I вафатыннан соң, читтән гаскәри көчләр яллап, Киевны сугышып ала, агасы Ярополкны үтереп, атасы тәхетенә утыра (980). Бөек кенәз буларак Киев кенәзлеге биләмәләрен арттыру өчен сугышлар алып бара, 981 дә Червенск шәһәрен яулап ала, 981–82 елларда вятичларны, 983 тә ятвягларны, 984 тә радимичларны җиңә. Яңа яуланган җирләрдә кальга-калалар төзетә, идарә итү өчен үз алай-дружиналарын һәм боярларын билгели. 985 тә Идел буе Болгарына яу б-н баруы, солых килешүе төзүе мәгълүм. Болгарлар иленә тагын 994, 997 елларда һөҗүм иткән булуы ихтимал. 993, 996 да бәҗәнәкләр б-н сугыша. В.I заманында тышкы сәяси элемтәләр ныгытыла: Византия (987–89), Рим (991, 1001) һәм Германия (1006, 1013) б-н дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырыла. В. I, үз хакимиятен ныгыту максатыннан чыгып, кайсы динне кабул итү турында уйлана, төрле дин әһелләре, ш.и. болгарлар вәкилләре б-н дә очраша, киңәшә. Византия б-н илчелек мөнәсәбәтләре урнаштырылгач, 988 дә дәүләт дине буларак рәсми рәвештә христиан динен кабул итә. Шуннан соң Киев кенәзлегендә «кылыч һәм ут ярдәмендә» яңа дингә күндерү хәрәкәте колач җәя, Киев б-н Новгород шәһәрләрендә мәҗүсиләрнең табыну урыннары җимертелә, яндырыла. Яңа дин оешмалары булдыруны һәм чиркәүләр төзүне күрше төбәкләр биләмәләренә дә көчләп тага. В. I идарә иткәндә борынгы Русь дәүләтенең төп биләмәсе, идарә тәртипләре һәм яңа дине билгеләнә.

Чыг.: Д ж а к с о н Т.Н. Исландские королевские саги о Восточной Европе. М., 1993; Повесть временных лет. СПб., 1999.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д. Киевская Русь. М., 1953; Р ы б а к о в Б.А. Язычество Древней Руси. М., 1987; П а ш у т о В.Т. Внешняя политика Древней Руси. М., 1968; Введение христианства на Руси. М., 1987; Т о л о ч к о П.П. Древняя Русь. Киев, 1987; Щ а п о в Я.Н. Государство и церковь Древней Руси X–XIII вв. М., 1989; Н а з а р е н к о А.В. Древняя Русь на международных путях. М., 2001; V o d o f f V. Naiassace de la chretiente russe: La conversion du prince Vladimir de Kiev (988) et ses consequences. Paris, 1988.

*И.Л.Измайлов.*

**ВЛАДИ́МИР ТОКЫМЛЫ́ ЙӨК АТЛАРЫ́**, 1930–50 елларда Владимир һәм Иваново өлкәләре хуҗалыкларында җирле эре атларны клейдесдаль, шайр һәм суффолк атлар токымы б-н кушып чыгарыла. 1946 елда токым авыр йөк ташучы яңа токым итеп таныла. Эре, зур гәүдәле , хәрәкәтчән һәм темпераментлы токым. Хайваннарның конституциясе ныклы, күкрәк читлеге киң. Төсе кызгылт, сирәк очракта аяк һәм маңгаенда ак тамгалар була. Ял турысында биеклеге 158–161 *см*, гәүдәнең ятынкы озынлыгы 163–165 *см*, күкрәк әйләнәсе 183–196 *см*, бәкәл әйләнәсе 23–24 *см*. Атларның авырлыгы 750–800 *кг*. Югары дәрәҗәдә эшчән. 2000 *м*



Владимир токымлы ат.

арада 150 *кг* тарту көче кулланып, адымлап йөк ташу рекорды 12 *мин* 34,2 *с*. 300 *кг* тарту көче б-н йөк тарту чыдамлыгы 987 *м*, максималь тарту көче 820 *кг*, ягъни атның тере авырлыгының 94,3%. Токым атлары тиз үсә, алты айда тай 200 *кг* га җитә. Үрчеме югары (75–80% очракта сәламәт тай туа). Токым БДБ, Россия, ш.и. Татарстанда җирле атларның сыйфатын яхшырту өчен кулланыла.

*Әд.:* К а м б е г о в Б. Коневодство и коннозаводство России. М., 1988; Э р н с т Л.К., Д м и т р и е в Н.Г., П а р о н я н И.А. Генетические ресурсы сельскохозяйственных животных в России и сопредельных странах. СПб., 1994.

*Р.А.Хәертдинов.*

**ВЛАДИ́МИРОВ** Владимир Дмитриевич (1837–1903), хирург, медицина д-ры (1872). 1860 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1867–73 елларда Казан ун-тының хирургия клиникасында эшли. 1874 тән Пенза губерна хастаханәсендә. В. авыру аяк табанының алгы өлешен саклап калу өчен табанның арткы өлешен кисеп дәвалауның остеопластик ысулын тәкъдим итә. 8 елдан соң И.Микулич тарафыннан шундый ук операция тәкъдим ителә (1880). Копенгаген һәм Лондондагы Халыкара табибләр конгрессларында В. эшләренә өстенлек бирелә, шуннан соң әлеге операция *Владимиров-Микулич операциясе* исеме б-н атала.

Х е з м.: Несколько новых остеопластических операций на нижней конечности. К., 1872.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., Ч. 2.

**ВЛАДИ́МИРОВ** Владимир Петрович (16.10.1953, Чуаш АССРның Яльчик р-ны Яңа Байтирәк а.), галим-агроном, а.х. фән.

д-ры (1999), проф. (2001), ТРның атказ. агрономы (2004). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1980). 1975 елдан Казан а.х. академиясендә эшли: 1978–92 дә үсемлекчелек, 1992 дән җиләк-җимеш-яшелчәчелек кафедраларында (1997 гә кадәр каф. мөдире). Хезмәтләре ТР шартларында бәрәңге үстерү технологиясен камилләштерүгә карый. В. тарафыннан беренче тапкыр Идел буе урман-дала җирләрендә бәрәңгенең планлаштырылган уңышын арттыру теоретик яктан нигезләнә һәм технологиясе эшләнә .

Хезм.: Картофель. К., 1999; Эффективность возделывания картофеля в Поволжском регионе. К., 2003 (автордаш).

**ВЛАДИ́МИРОВ** Пётр Владимирович (19.1.1904, Казан губ., Мамадыш өязе Теплое Болото а. — ?), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Лубян урман техникумын тәмамлый (1929). 1929–30 елларда Чаллы кантоны Кармалы, 1930–31 дә Тәкәнеш р-ны Лубян урман участокларында урманчы ярдәмчесе. 1931–39 да Мамадыш урман хуҗалыгы директоры. 1939–40 та Татарстан урман хуҗалыгы идарәсе башлыгы. 1940–42 дә ТАССР урман сәнәгате халык комиссары. 1942–43 тә Яшел Үзән шәһәре эшче депутатлары советы башкарма ком-ты рәисе. 1943–47 дә ВКП(б) ның Татарстан өлкә ком-тында җирле сәнәгать буенча секретарь урынбасары, 1947–48 дә ягулык-энергетика сәнәгате буенча бүлек мөдире. 1948–55 тә ТАССР урман сәнәгате министры. 1955–56 да «Татлес» тресты башлыгы. 1956–59 да ТАССР МС каршындагы Мебель җитештерү һәм агач эшкәртү сәнәгате идарәсе башлыгы.

*Е.Б.Долгов.*

**ВЛАДИ́МИРОВ-МИКУ́ЛИЧ ОПЕРА́ЦИЯСЕ**, остеопластик операция, табан-балтыр буыны туберкулёзы һәм шешле аяк табаны очрагында табанны кисеп, табан һәм табан сөякләре б-н балтыр сөякләренең аскы өлешен алып ташлаудан гыйбарәт. Элек андый очракларда табан һәм балтыр ампутацияләнгән. В.-М.о. авыруга табанның алгы өлешен сакларга мөмкинлек бирә. В.-М.о. хирург В.Д.*Владимиров*ның докторлык диссертациясендә тасвирлана (Казан ун-ты, 1872), аның һәм И.Микулич (Германия, 1880) тарафыннан тәкъдим ителә.

*Әд.:* Большая медицинская энциклопедия. М., 1976. Т. 4.

**ВЛАДИ́МИРОВКА** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бөгелмә Зәе елгасының уң кушылдыгы Ямаш суы буенда. 2002 елда 17 кеше (руслар) яши. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек дворян Витковскийларның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 149, 1897 дә — 169, 1920 дә — 170, 1926 да — 184, 1938 дә — 216, 1958 дә — 114, 1970 тә — 98, 1979 да — 67, 1989 да 25 кеше.

**ВЛАДИ́МИРОВКА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак. 2002 елда 14 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чистай кантоны Иске Әлмәт волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 201, 1938 дә — 231, 1958 дә — 84, 1970 тә — 64, 1979 да — 72, 1989 да — 21 кеше.

**ВЛАДИ́МИРОВКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 30 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар, руслар) саны 10 нан ким. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чаллы кантоны Кузай волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 128, 1938 дә — 241, 1949 да — 151, 1958 дә — 152, 1970 тә — 77, 1989 да — 10 кеше.

**ВЛАДИ́МИРОВКА** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 18 *км* көнбатыштарак, Игәнә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2000 елда авыллар исемлегеннән сызыла. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чаллы кантоны Сарман волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Сарман р-нында. Халык саны: 1926 да — 126, 1938 дә — 98, 1949 да — 82, 1958 дә — 79, 1970 тә — 35, 1979 да — 14, 1989 да — 3 кеше.

**ВЛАДИ́МИРОВКА СӨЗӘКЛЕГЕ́**, А к т ү б ә у р м а н м а с с и в ы, табигать тыюлыгы. Азнакай р-ны терр-ясендә (Владимировка авылыннан төньяк-көнбатыштарак). 1991 елда оештырыла. Мәйданы 62 *га*. Ямаш елгасының биек уң як ярын алып тора. Болынлы ташлы даланың уникаль биоценозы



Владимировка сөзәклеге.

үрнәге. Дала үсемлекләренең 30 лап төре үсә, ш.и. тар яфраклы кылган, Альп кашкарые, кызыл гамбәрия чәчәге, иң гади оносма. Тыюлыкта ТРдагы иң зур популяцияләрдән саналган язгы адонис төре киң таралган (1 $м^2$ га 5–10 үсемлек туры килә).

**ВЛАДИ́МИРСКИЙ** Александр Павлович (1779, Новгород губ. — 28.9.1846), акушер, медицина д-ры (1816), проф. (1821). Ярославль семинариясендә укый. Рус армиясе табибе; 1807 елдан — Сембер, 1816 дан Тверь табиблек идарәләрендә эшли. 1819 да М.Л.Магницкий тәкъдиме б-н Казан ун-тына директор итеп билгеләнә, «университетка яңалыклар кертү» эшендә аның уң кулы булып санала. 1822 елда М.Л.Магницкий б-н уртак тел таба алмау аркасында директорлык вазифасыннан, проф. исеменнән мәхрүм ителә; табиб булып эшли.

Хезм.: Советы людям военным к сохранению здоровья на Кавказской линии. СПб., 1806.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**ВЛАДИ́МИРСКИЙ** Александр Поликарпович (1821, Архангельск губ. Печора өязе — 29.4.1906, Казан), дин галиме, философ, дин гыйльме магистры (1846). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1846) һәм шунда ук Библия тарихы, чиркәү хокукы укыта. 1850–71 елларда Казан ун-тында дин гыйльме профессоры, шул ук вакытта логика, психология һ.б. фәлсәфи фәннәрдән дәресләр алып бара. 1865–71 дә филол. ф-ты деканы. 1865–95 тә Казан руханилар академиясе ректоры. Хезмәтләре христиан дине тарихына карый.

Хезм.: Защита Моисеева Пятикнижия. К., 1871; Древность человека // Православный собеседник. 1872. Ч. 3; Был ли апостол Иоанн в Эфесе? К., 1873.

*Әд.:* Т е р н о в с к и й С.А. Историческая записка о состоянии Казанской духовной академии после её преобразования. 1870–1892. К., 1892; Пятидесятилетний юбилей протоиерея А.П.Владимирского. К., 1897; Александр Поликарпович Владимирский: Некролог // Православный собеседник. 1906. Ч. 2.

**ВЛА́СОВ** Валерий Александрович (20.9.1953, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, генерал-майор (1999). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1976). 1976–81 елларда КАПО инженеры. 1981–83 тә ТР Эчке эшләр министрлыгы инспекторы, 1983–89 да — өлкән инспекторы, 1989–93 тә бүлекчә башлыгы, 1993–96 да хәрби мобилизацияләү эше һәм гражданнар оборонасы бүлеге башлыгы. 1996–2007 дә ТР гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры.


**ВЛКСМ**, к. *Бөтенсоюз Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзы.*

**ВНИИГЕОЛНЕРУ́Д**, к. *Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк институты.*

**ВНИИР**, к. *Бөтенроссия чыгым үлчәү институты.*

**ВНИИУС**, к. *Бөтенроссия углеводород чималы институты.*

**ВНУ́ЧКИ** күле, Көнбатыш Кама арьягында. Актай һәм Бизнә елгалары бассейны субүләрендә, Спас р-нының Ямбакты авылы янында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,4 *га*. Су күләме 13 мең $м^3$ чамасы. Озынлыгы 220 *м*, иң зур киңлеге 95 *м*. Уртача тирәнлеге 0,95 *м*, иң зур тирәнлеге 1,52 *м*. Күл карст күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Озынча түгәрәк. Суы җиңелчә минеральләшкән, бик йомшак, болганчык, яшькелт төстә, иссез, гидрокарбонат-сульфат-натрийлы. Хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.



Г.С. Воздвиженский.

**ВОДЕВИ́ЛЬ** (фр. vaudeville, Vau de Vire — жанрга исем биргән Нормандия төбәге исеме), комедия жанрының муз. номерларны (такмаклар, романслар һәм биюләр) эченә алган бер төре. В.гә күңелле сюжет, кызыклы интрига, юмор хас. Татар драматургиясендә борынгы халык уеннары нигезендә барлыкка килә. Этнографик характердагы беренче татар В.ләре милли муз.-шигъри әсәрләрдән тора ( мәс., И.Гаспринскийның «Кыз ярәшү» В.). 20 йөз башында татар драматургиясе Көнбатыш, Шәрекъ һәм рус әдәбиятлары йогынтысында үсә. Татар сәхнәсендә А.П.Чеховның «Кыз сорау» («Предложение»), Мольерның «Саран» («Скупой»), «Ирексездән табиб» («Лекарь поневоле») пьесалары буенча куелган В. һ.б. уйнала. Рев-циядән соңгы татар драматургиясендә социаль-сәяси характердагы яңа В. барлыкка килә. Бу сыйфат бигрәк Г.Камал пьесаларына хас (мәс., «Ахырзаман»). 1930–50 елларда татар драматургиясе В. жанрына бөтенләй мөрәҗәгать итми. 1960 елларда яңадан В. жанрындагы пьесалар языла. Мәс., Г.Насрыйның «Яшел эшләпә», З.Шаһиморатның «Тугыз гашыйк», Х.Вахитның «Күк капусы ачылса», И.Юзеевнең «Бөркетләр кыяга оялый», Т.Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү», Ф.Яруллинның «Әнә килә автомобиль», Ф.Садриевның «Их сез, егетләр!..» пьесалары һ.б.

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Х а н з а ф а р о в Н.Г. Татарская комедия. К., 1996.

*Н.Г.Ханзафаров.*

**ВОЕВО́ДА ИДАРӘСЕ́**, 16 йөзнең 2 нче яртысыннан алып 1775 елга кадәр Россия дәүләтендә урыннардагы (өязләрдәге) идарә органы. Чик буе шәһәрләрендә һәм яңа яуланган Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары биләмәләрендә 16 йөзнең 2 нче яртысыннан гамәлдә була. 17 йөзнең 20 нче елларына «Болгавыр заман»нардан соң тулысынча оешып бетә. Шәһәрләрдә В.и.нә воевода һәм дьяк б-н приказ йорты (Казанда — «съезжая палата») (17 йөз ахырыннан зур шәһәрләрдә — приказ палатасы) керә. Воеводаларны Разряд приказы, ә Урта Идел буе өяз шәһәрләре Казан, Зөя, Чабаксарга — *Казан Сарай идарәханәсе* билгеләгән, алар патша һәм боярлар думасы тарафыннан расланган. Шәһәр б-н идарә итүче приказга буйсынган. Шәһәрнең хәрби һәм икътисади дәрәҗәсенә карап, зурларына В.и. башлыгы итеп боярлар, кечерәкләренә дворяннар куелган. Кайбер зур шәһәрләргә 2–3 воевода билгеләнгән (Әстерхан, Казан, Новгород, Псков һ.б.). Элекке Казан ханлыгы биләмәсендә 1660 еллар ахырларына кадәр 7–9 воевода булса, 1690 елларда аларның саны 2–3 кә калдырыла. Воеводалар 2–3 елга бер алыштырылган, чик буе төбәкләрендә һәм Себердә алар озаграк хезмәт иткән. Хезмәт хакы Мәскәүдә түләнгән. Өяз б-н шәһәрнең адм. һәм хәрби эшчәнлеге өчен В.и. җаваплы була. Өяздә мәхкәмә-тикшерү оешмасы булган очракта, мәхкәмә эшен шул оешма башкарган. Полиция вазифасын, җирне исәпкә алу һәм бүлү, хуҗалык эшләрен һәм дошман һөҗүменнән саклану чараларын воевода үтәгән. 1699 да бистә-посад халкы эшләре В.и.ннән алына, бурмистр карамагына тапшырыла. 18 йөз башында, Пётр I реформалары барышында губерналар оештырылгач, өяз В.и.нең эшчәнлеге чикләнә (1710 елдан комендант канцелярияләре дип үзгәртелә). 1711–15 елларда губерналар провинцияләргә бүленгәч, провинция воеводалары билгеләнә, шәһәр воеводалары функцияләрен оберинспектор, комиссарлар үти. 1719 да провинцияләрдә воеводалар б-н бер үк вакытта тармак идарәчеләре — камерир, рентмейстер, вальдмейстр, фискал һ.б. вазифалар кертелә. 1727 дә В.и. яңадан торгызыла, өязләрдә башка төр тармак идарәләре бетерелә. Губерналарда идарәчелекнең 2 нче, 3 нче баскычында (провинциядә һәм воевода канцеляриясендә) В.и. тора. 1728 дә «Воеводалар инструкциясе» игълан ителә. Воеводалыкка билгеләүчеләрне Сенат отставкадагы офицерлар, сарай әһелләре һәм югары чиновниклар арасыннан сайлый; аларны башта Югары яшерен совет, аннары Сенат раслый. 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышы барышында В.и.нең заман таләпләренә җавап бирмәве ачыклана. 1775 елгы фәрман б-н В.и. бетерелә.

*Әд.:* Ч и ч е р и н Б.Н. Областные учреждения в России в XVII в. М., 1856; Г р а д о в с к и й А.Д. История местного управления в России: Собр. соч. СПб., 1899. Т. 2; Г о т ь е Ю.В. История областного управления в России от Петра I до Екатерины II. М., 1941. Т. 2; Е р о ш к и н Н.П. История государственных учреждений дореволюционной России. М., 1983.

*Д.Г.Мостафина.*

**ВО́ЖИ** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 53 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Актай елгасы буенда. 2002 елда 428 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Май з-ды. Тулы булмаган урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Нелово исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), 3 он тегермәне, 3 тимерчелек, ярма ярдыру тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 368,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Николо-Пичкас волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935–91 дә — Куйбышев) р-нында. 1966 ның 26 мартыннан В. составына Пичкас авылы да керә. Халык саны: 1782 дә — 126 ир заты; 1859 да — 840, 1897 дә — 1177, 1908 дә — 1147, 1920 дә — 1186, 1926 да — 943, 1938 дә — 760, 1949 да — 568, 1970 тә — 866, 1979 да — 642, 1989 да — 486 кеше.

**ВОЗДВИ́ЖЕНКА** посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2002 елда 24 кеше (руслар) яши. 1922 дә нигез салына. Күмәкләштерү елларында В.да «Память Куйбышева» к-зы оештырыла, 1937 дә ул — «Крестьянин» к-зына, 1957 дә «Лениногорский» с-зына керә. Беренче көннән үк ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә өязенә керә. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 91, 1938 дә — 109, 1949 да — 98, 1958 дә — 95, 1970 тә — 69, 1979 да — 45, 1989 да — 32 кеше.

**ВОЗДВИ́ЖЕНСКИЙ** Геннадий Серафимович (27.8.1905, Казан губ. Царёвококшайск ш., хәзерге Йошкар-Ола ш. — 16.1.1974, Казан), электрохимик, химия фән. д-ры (1944), проф. (1945). ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1956, 1966). Казан ун-тын тәмамлый (1927). 1931–74 елларда Казан хим.-технол. ин-тында: 1941–45 тә фәнни-тикшеренү бүлеге мөдире; 1944 тән нәорганик химия каф. мөдире, 1945–51 дә директор урынбасары. Бер үк вакытта 1934–40 та Казан ун-ты каршындагы химия фәнни-тикшеренү ин-тында; 1946–71 дә СССР ФАнең Казан филиалы Органик һәм физик химия ин-тында нәорганик химия бүлеге, 1965 тән анод һәм катод процесслары лаб. мөдире. Хезмәтләре электр тогы ярдәмендә металларны утырымга төшерү һәм эретүгә карый. Беренче хезмәтләре физик һәм коллоид химиягә бәйле (кайбер коллоидларның үзлекләре һәм үз-үзен тотышы, химик реакцияләре кинетикасы). Металларның электр тогы ярдәмендә катодта утырымга төшү механизмын өйрәнә, бу процессларда коллоидларның әһәмиятен ача. Никель һәм кайбер башка металларның электр тогы ярдәмендә утырымга төшү процессы теориясен эшли, гальваностегик капламнарның яңа төрләрен тәкъдим итә: висмутлау, тимерне оксидлау, махсус өстәмәләр катнашында ялтыратып никельләү һ.б. Теоретик һәм эксперименталь материаллары «Металларның электр ярдәмендә кристаллашуы өлкәсендә тикшеренүләр» («Исследования в области электрокристаллизации металлов», 1944) дигән монографиясендә ачыклый. Металларның электр ярдәмендә кристаллары таркалуы, металларны анодлы эшкәртү, электрохимик ялтырату, электр ярдәмендә шомарту, анод — механик кисү һәм электр ярдәмендә тишү процесслары теориясен ача. Газ электрохимиясе, комплекслы кушылмалар химиясе һәм электрохимиясе, гальваник процессларны автоматлаштыру һәм оптимальләштерү буенча тикшеренүләр, металлар, капламнар һәм материалларның коррозиягә чыдамлылыгын тизләтеп сынау өчен ысуллар һәм җайланмалар табу һ.б. эшләр б-н җитәкчелек итә. В. ның теоретик тикшеренүләре нигезендә СССР ВДНХсында диплом һәм медальләр б-н бүләкләнгән бакырлау, никельләү, цинклау, кадмийлау һ.б. гальваник капламнарның

зарарсыз электролитлары сәнәгатькә кертелә. Казан химия мәктәбе тарихына, гомуми һәм неорганик химияне укыту методикасына караган хезмәтләр авторы. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Никель-водородный электрод // Докл. АН СССР. 1951. Т. 77. № 1 (автордаш); Страницы из истории Казанской химической школы. К., 1960; Электронно-микроскопическое исследование процесса анодной декристаллизации металла // Рост кристаллов. М., 1961. Т. 3. (автордаш); Исследование электродных процессов в водных растворах комплексов меди с органическими аминопроизводными методом парамагнитного резонанса // Журн. физ. химии. 1964. № 6. (автордаш).

*Әд.:* Б е р е з и н а Н.И., Г а л я в и н Р.А. Геннадий Серафимович Воздвиженский: Биобиблиография. К., 1975; Профессора, доктора наук: Политехнический институт — КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ВОЗНЕСЕ́НСКИЙ** авылы, Казан шәһәренең Совет р-нында, Нокса елгасы буенда. 2000 елда 260 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. Казан ханлыгы чорындагы авыл урынында 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек икътисади, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, яшелчәчелек, тимерчелек, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә; Казанда сөт һәм утын б-н сату итә. 20 йөз башында Тихвин-Богородица чиркәве (1740 та төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1880 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл


Вознесенский авылы. Тихвин-Богородица чиркәве манарасы. 1824.

җәмәгатенең имана җире 1205,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощак волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Биектау, 1998 нең 25 ноябреннән — Казан шәһәренең Совет р-ны карамагында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир заты; 1859 да — 392, 1897 дә — 614, 1908 дә — 796, 1920 дә — 792, 1926 да — 884, 1949 да — 438, 1958 дә — 448, 1970 тә — 402, 1989 да — 270 кеше.

*Әд.:* И з н о с к о в И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1916. Вып. 3.

**ВОЗНЕСЕ́НСКИЙ** Александр Николаевич (18.7.1888, хәзерге Мордва Респ-касы, Ардатов р-ны Чукалы а. — 16.1.1966, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1943). Варшава ун-тын тәмамлый (1913). 1921–30 елларда Белоруссия ун-тында (1926 дан проф.), 1931–34 тә кинематография, хим.-технол. һәм педагогика ин-тларында (Мәскәү) укыта. 1939 дан Казан пед. ин-тында, 1940–61 дә Казан ун-тында, 1943–48 дә тарих-филология ф-тында декан, шул ук вакытта 1946–48 дә рус әдәбияты каф. мөдире. Хезмәтләре әдәбият методологиясенең гомуми мәсьәләләренә, славян әдәбиятларын чагыштырып өйрәнүгә, М.Ю.Лермонтов, Н.В.Гоголь, И.С.Тургенев, Т.Г.Шевченко, Я.Купала, Я.Колас, М.Богданович һ.б. иҗатларына карый. Әдәбият белеменең милли үзенчәлекләре теориясен алга сөрә. А.А.Фукс, Г.П.Каменев, Г.Тукай турында басылмый калган мәкаләләр авторы.

Х е з м.: Метод преподавания литературы // Изв. Наркомата просвещения БССР. Минск, 1921; Метод изучения литературы // Тр. Белорус. ун-та. Минск, 1922. № 1; Опыт историко-литературного изучения художественных произведений в трудах профессора В.А.Богородицкого // Уч. зап. Казан. ун-та. 1961. Т. 119, кн.5.

*Әд.:* Белорусская ССР: Краткая энцикл. Минск, 1982. Т. 5.

**ВОЗОВИ́К** Игорь Семёнович (10.4.1924, Казан — 28.5.1990, шунда ук), а.х. механикалаштыру гыйлеме белгече, а.х. фән. д-ры (1988), ТАССРның атказ. механизаторы (1972). 1955 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1956–57 елларда Татарстан Респ-касының колхоз рәисләре мәктәбендә, 1957–67 дә Татарстан Респ-касының а.х. тәҗрибә станциясендә, 1960 тан механикалаштыру бүлеге мөдире. 1967 дән Казан а.х. ин-тында, машина-трактор паркыннан файдалану каф. мөдире (1968 дән). Хезмәтләре бөртекле-кузаклы үсемлекләрне урып-җыюны механикалаштыруга, егылган борчак сабагын күтәртү технологиясенә һәм урып-җыю машиналарының эш җиһазлары параметрларын нигезләүгә карый. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре борчак игүнең үрнәк технологиясенә кертелә, Бердянск махсус конструкторлык бюросында уру машиналарын проектлау өчен файдаланыла. Уйлап табуга караган 10 лап авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Операционная технология возделывания и уборки зернобобовых культур. М., 1987 (автордаш); Индустриальная технология уборки зернобобовых культур. К., 1989.

**ВО́ЙКИНО** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 46 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасы буенда. 2002 елда 223 кеше (руслар — 56%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1690 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда 3 торак пункт: Войкино № 1 (Стрижовка), Войкино № 2 (Хлуденовка) (мордвалар) һәм Войкино № 3 (руслар) булып исәпләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Войкино № 3 тә чиркәү-приход мәктәбе, земство хастаханәсе, тимерчелек, 1 ярма ярдыру һәм 4 җил тегермәне, салат ясау йорты, шәраб, 3 вак-төякләр кибете эшли. Войкино № 1 дә җил тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатьләренең имана җирләре барысы бергә 2354,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Левашево волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 103 ир заты; 1859 да — 890, 1897 дә — 1628, 1908 дә — 1950, 1920 дә — 1749, 1926 да — 1137, 1938 дә — 807, 1949 да — 675, 1958 дә — 396, 1970 тә — 463, 1979 да — 330, 1989 да — 227 кеше.

**ВОЙТО́ВИЧ** Евгений Дмитриевич (29.5.1931, Украина ССР, Запорожье өлкәсе Бердянск ш.), нефтьче-геолог, геол.-минералогия фән. канд. (1969), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1981), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Львов политехника ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), «Татнефть» АҖнең Татарстан геологик разведка идарәсендә: 1965–70 елларда геология бүлеге башлыгы, 1970–86 да баш геолог, 1993 тән әйдәп баручы геолог. Бер үк вакытта 1989 дан Һиндстанда, Төркиядә, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә геология-разведка эшләре буенча эксперт төркемен җитәкли. Татарстанда нефть ятмаларының формалашу шартларын һәм нефть структураларының урнашу закончалыкларын һәм типларын өйрәнә, девон терриген утырмаларының калынлыгын анализлау нигезендә тирәндәге күтәрелмәләрне прогнозлауның методик алымнарын эшли. 100 ләп нефть чыганагын һәм ятмаларын эзләү һәм ачу эшләрендә катнаша, 1992–94 тә Татарстанда битумнарны тематик тикшеренүләрнең фәнни җитәкчесе. Сабанчы нефть чыганагын беренче ачучы. Дәүләт бүләге «Татарстан геологиясе. Стратиграфия һәм тектоника» («Геология Татарстана. Стратиграфия и тектоника») монографиясе өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: История открытий и методика поисков и разведки нефти в Татарстане. К., 1998 (автордаш); Тектоника Татарстана. К., 1998 (автордаш).

**ВОКАЛИ́ЗМ** (лат. vocalis — сузык аваз), телдә, диалектта һәм сөйләшләрдә сузыклар системасы. В. сузык фонемалар саны, төрле фонетик позицияләрдә фонемаларның кулланылу кагыйдәләре, аларның вариантлылыгы һәм сөйләмдәге функциональ эшчәнлеге б-н характерлы. Хәзерге татар әдәби телендә В. ның ике функциональ бүленеше бар: тамыр В. һәм аффиксаль В. Тамыр В. 9 сузык фонеманы: а, ы, о, у, ә, е, и, ө, ү ләрне эченә ала. Артикуляцион яктан сузыклар рәт (телнең горизонталь хәрәкәтенә карап), күтәрелеш (телнең вертикаль хәрәкәтенә карап), иренләшү (иреннәрнең катнашу-катнашмавына карап) буенча төркемләнәләр. Рәт буенча сузыклар алгы рәт авазларына — ә, ү, е, ө, и һәм арткы рәт авазларына — а, ы, о, у бүленәләр. Күтәрелеш буенча сузыклар югары күтәрелеш — и, ү, у; урта күтәрелеш — о, ө, ы, е һәм түбән күтәрелеш — а, ә сузыкларына бүленәләр. Иреннәрнең катнашу-катнашмавына карап иренләшкән — о, ө, у, ү һәм иренләшмәгән —

а, ә, ы, е авазларына аерылалар. Тамыр сузыклар авызны ачу дәрәҗәсенә карап: тар — у, ү, и; ярымтар — о, ы, ө, е; киң — а, ә авазларына бүленәләр. Тамыр сузыкларның рәт, иренләшү һәм күтәрелеш б-н бәйле билгеләре — сүз мәгънәсен аеручы билгеләр: **ана** – **әнә**, **он** — **өн**, **ут** — **үт**. Аффиксаль сузыкларның рәт һәм иренләшү билгеләре тамырның беренче иҗегендәге сузыгына бәйле. Сингармонизм законы буенча, әгәр дә тамырдагы сузыклар алгы рәт (нечкә) сузыклары булса, аңа алгы рәт (нечкә) сузыгы кергән кушымча, тамырдагы сузыклар арткы рәт (калын) сузыклары булса, аңа арткы рәт (калын) сузыгы кергән кушымча ялгана: к**ү**лл**ә**р — к**у**лл**а**р, к**ү**лл**ә**рд**ә** — к**у**лл**а**рд**а**. Хәзерге татар әдәби телендә, башка төрки телләрдән (башлыча, алтай һәм кыргыз телләреннән) аермалы буларак, бары тик о, ө авазлары б-н генә бәйле: (колы [к**о**л**о**], көле [к**ө**л**ө**]) ирен гармониясе бар.

Иррелевант аффиксаль сузыклар, үзләренең фонетик аермаларына карамастан, ике архифонемага берләшәләр: киң — а-ә һәм тар — ы-е.

Хәзерге татар әдәби телендә аффиксаль морфемаларда тар, иренләшмәгән **и** һәм тар, иренләшкән **у**, **ү** сузыклары куллану мөмкинлеге яши. Әмма аларның мондагы урыны морфологик яктан чикле: и — бары тик фигыльнең хәзерге заман һәм юклык формасында, у,ү — исем фигыль формасында кулланыла: сөйл**и**, эшл**и**, бар**у**, кил**ү**.

*Әд.:* Исхаков Ф.Г. Общая характеристика тюркского вокализма. М., 1955; Байчура У.Ш. Звуковой строй татарского языка. К., 1959. Ч. 1; Черкасский Ч.А. Тюркский вокализм и сингармонизм. М., 1965.

*М.Ә.Сәгыйтов.*

**«ВО́ЛГА» АСТЕРО́ИДЫ**, 1149 нчы кече планета. Кырымдагы Семеиз обсерваториясендә астроном Е.Ф.Скворцов тарафыннан 1929 елда ачыла. Волга (Идел) елгасы исеме бирелә. Кояштан ераклыгы 2,6–3,2 астрон. берәмлек араларында үзгәрә. Кояш тирәли 4,9 елда әйләнә.

**«ВО́ЛГА»** фәнни-тикшерену берләшмәсе, к. *Хисаплау техникасын халык хуҗалыгында куллану* дәүләт фәнни-тикшерену һәм проектлаштыру институты.

**ВОЛГОГРА́Д ӨЛКӘСЕ́**, РФдә, Көнчыгыш Европа тигезлегенең көньяк-көнчыгышында. Мәйданы — 113,9 мең *км*². Үзәге — Волгоград шәһәре. Халкы — 2699,2 мең кеше, ш.и. 28,6 мең татар (2002). Татарлар, башлыча, Волгоград (11,5 мең кеше), Волжск (3,2 мең), Краснослободск шәһәрләрендә, Ленин (Бәхтияр һәм Маляевка а.), Палласовка (Савенково а.), Светлояр (Нариманов исем. пос., Кече Чапурин а.), Иске Полтава (Лятошинка а.) р-ннарында яшиләр. В.ө. — төрки халыклар борынгы чорлардан яши торган төбәкләрнең берсе. Аның терр-ясе Алтын Урда, Әстерхан ханлыгы, Нугай Урдасы составына керә. Урта Идел буеннан бирегә 18 йөздә күчеп утыра башлыйлар. Сембер һәм Казан губерналарыннан күчеп килүчеләр 1780 елда — Кече Чапурин, 19 йөз башында Савенково авылына нигез салалар. 1840 та Саратов губернасының Яңа Үзән (Новоузенский) өязеннән чыгучылар — Лятошинка авылына, Пенза губернасының Чембар өязе татарлары 1836 да — Бәхтияр авылына, 1874 тә Маляевка авылына нигез салалар. 1897 елгы халык исәбе буенча, татарлар Царицын өлкәсендәге барлык халыкның 1,12% тәшкил итәләр. Алар игенчелек, бакчачылык, терлекчелек б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында Царицында, Маляевкада (2), Бәхтиярдә, Кече Чапуринда мәчетләр була. Хәзерге вакытта В.ө.ндә татарларның милли-мәдәни автономиясе (1997 дән) эшли, «Халык сүзе» (1998 дән) г-тасы нәшер ителә. Татар мәдәнияте үзәге — «Старая Сарепта» тарих-этнография һәм архит-ра музей-саклаулыгы эшли. Ел саен Тукай укулары, Сабантуй бәйрәме үткәрелә. Татарлар күп яши торган урыннарда татар теленә һәм гарәп графикасына өйрәтү өчен якшәмбе мәктәпләре эшли. Татар мәдәни үзәге (Кече Чапурин а.), «Шатлык» (Лятошинка а.), «Яшьлек» һәм «Күбәләк» (Маляевка а.) фольклор ансамбльләре (Волгоград ш., Красноармейский р-ны) эшли. Краснослободск шәһәрендә мәчет бар.

**ВОЛЕЙБО́Л** (ингл. volley boll, valley — очып барганда кире сугу һәм ball — туп), 6 шар кешелек ике командалы туплы уен. 9x9 метрлы уен мәйданы 1 метр киңлектәге ятьмә б-н тигез ике өлешкә бүленә. Ятьмәнең өске чите, уенчыларның яшенә һәм җенесенә карап, 2,10 нан 2,43 *м* га кадәр биеклектә урнаштырыла. Татарстанда В. 1920 еллардан үсеш ала. 1930 еллар башыннан Казан беренчелегенә даими рәвештә ярышлар уздырыла (оештыручылары: А.С.Виноградов, Н.Царев). 1930 елларда Казан командаларының («Красное Знамя», «Динамо», «Азот») иң яхшы уенчылары: В.Година, А.Кульгин, В.Непримерова, Ю.Розмахов, Г.Трифонова. 1936 да Бөтенсоюз волейбол бәйрәме финалында Татарстанның хатын-кызлар җыелма командасы 4 нче урынны ала. Казанның «Динамо» (хатын-кызлар), «Азот» (ирләр) командалары 1938–40 та СССР чемпионатында катнаша. 1950 елларда В. Татарстан югары уку йортларында үсеш ала. Студентлар командаларының иң яхшы уенчылары: Н.Т.Колчин, Ф.А.Магарил, Ф.М.Мөлеков, Н.Л.Попов, Л.И.Ушанкина. Татарстан җыелма командалары — СССР беренчелегенә ярышларда җиңүчеләр: 1967–68 дә (кызлар), 1978, 1996 (яшүсмерләр). Россия чемпионатларында катнашучы ТР командалары: 1 нче лигада — 1999 дан «Экономист» (хатын-кызлар, Казан финанс-икътисад ин-ты), 2002 дән — «Динамо-Таттрансгаз-2» (ирләр, Казан), 2004 тән — «Казаночка-2» (хатын-кызлар, Казан); югары лигада («Б» төркеме) — 2005 тән «Динамо» (ирләр, Чаллы); суперлигада — 2003 тән «Динамо-Таттрансгаз» (ирләр, Казан), 2005 тән — «Казаночка» (хатын-кызлар, Казан). Иң яхшы уенчылар: Олимпия уеннары чемпионы Л.И.*Логинова* (1980), Олимпия уеннарының көмеш медале иясе А.Казаков (2000), дөнья чемпионнары Н.Ш.*Фәсәхов* (1960), Ю.Л.Бубнова (1990), СССР халыклары спартакиадасының көмеш медале иясе В.В.Анисович (1975). Иң яхшы тренерлар: ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре И.Б.Брен, Россиянең атказ. тренеры А.В.Воробьев, РСФСРның атказ. тренеры Э.А.*Семёнов*, ТРның атказ. тренерлары В.М.Слонин, В.Н.Соколов. 1969 дан хезмәт һәм спорт ветераннары арасында ТР беренчелегенә ярышлар уздырыла (оештыручылары — Н.Т.Колчин, Ф.А.Магарил). Халыкара категорияле судья В.И.Колупаев.

**«ВО́ЛЖСКАЯ КРАСА́ВИЦА»** («Идел чибәре»), көзге алма сорты. 1952 елда Татарстан җиләк-җимеш станциясендә «Ренет Поволжья» сортын «Боровинка» сорты б-н серкәләндереп, Г.И.Розанова тарафыннан чыгарыла. Татарстанда 1962 елда районлаштырыла. Көчле үсә торган, озын кәүсәле, киң ябалдашлы агач. Бәбәкләре туры, юан, кызыл-көрән төстә, ак ясмыкчыклары бар, төкчәсез. Яфраклары эре, түгәрәк формада, куе яшел, тонык төстә, җиңелчә сырлы, бик каты сеңерчәләнгән һәм бераз төкчәле. Яфрак сабы озын, уртача юанлыкта. Төпчек яфраклары эре, озынча. 2–3 еллык ботаклары туры кызгылт-көрән төстә, бик күп эре, ачык төстәге ясмыкчыклары бар. Күпьеллык ботаклары бик озын, юан, туры, очлары өскә таба дугаланып бөгелгән, кәүсәгә нык тоташкан. Җимешләре уртача һәм уртачадан эрерәк (100–130 *г*), йомыркасыман түгәрәк яисә түгәрәк формада, аксыл сары төстә, кабыгында ак нокталар бар һәм кояшка караган ягында ачык алсу кызыллык йөгергән була. Җимеш сабакчасы нәзек, озын. Җимеш йомшагы кардай ак төстә, вак бөртекле, уртача тыгызлыкта, сусыл, десерт тәмле. Татарстанда үстерелә торган барлык сортлар арасында иң тәмлесе. Җимешләре сентябрьнең 1 нче яртысында өлгерә, 2 айга кадәр саклана, күчереп йөртүне яхшы кичерә. Уңышы һәм кутыр авыруына чыдамлылыгы уртача. Кышкы суыкларга чыдамлылыгы, алмасының тәме һәм товарлыклы сыйфатларына карап югары бәяләнә.

*Әд.:* Определитель сортов яблони Европейской части СССР: Справ. М., 1991.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**«ВО́ЛЖСКИЕ ДА́ЛИ»** («Идел офыклары»), атналык әдәби-нәфис журнал. 1908 елның май-декабрь айларында Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 18 саны чыга. Наширләре Д.А.Венценосцев, аннан соң В.С.Андреев, мөхәррирләре М.Л.Премиров, аннары В.С.Андреев. Журналда җирле яшь язучылар А.С.Бухов, А.Ф.Ярославцев, М.Л.Премиров (аның «Немые дали» — «Серле офыклар» новелласы журналның берничә санына кушымта итеп чыгарыла) һәм башкаланың күренекле шагыйрь һәм язучылары В.Я.Брюсов, М.П.Арцыбашев, Б.К.Зайцев, С.Н.Сергеев-Ценский, Ф.Сологуб әсәрләре басыла. Журнал «Идел буе киңлекләренә, бөтен ерак провинциягә хезмәт күрсәтү»не максат итеп куя. Сәнгатькә яңа иҗади эзләнү-табышлар алып килүче кадрлар әзерләүгә йөз тота. «В.д.» декадентлык рухында була һәм «соңгы чиккә җиткән иҗат иреге» принципларын яклый, укучыларын шул чордагы әдәби агымнар б-н таныштыра. Журналда оригиналь һәм тәрҗемә романнар, по-

весть, хикәя, миниатюраларга (кечкенә күләмле әсәрләр), шигырьләргә зур урын бирелә. «Тәнкыйть һәм библиография» бүлегендә сәнгать һәм фәлсәфәгә караган төрле мәсьәләләр яктыртыла. Редакциянең бер әгъзасын плагиатлыкта (әдәби караклыкта) гаепләгән низаг чыгу сәбәпле, «В.д.» хезмәткәрләренең күбесе «*Волжское утро*» ж-лына күчә һәм нәтиҗәдә «В.д.» ябыла.

*Г.Р.Заманова.*

**«ВО́ЛЖСКИЙ ВЕ́СТНИК»** («Идел хәбәрчесе»), иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм әдәби газета. «*Волжский вестник*» ж-лының дәвамчысы. 1884 елның 1 гыйнварыннан 1904 нең 3 июненә кадәр һәм 1905 нең 8 ноябреннән 1906 ның 28 октябренә кадәр Казанда рус телендә, башта атнага 3 тапкыр, 1884 ел ахырыннан көн саен нәшер ителә. Төрле елларда наширләре: Л.П.Рейнгардт, А.Н.Каменцев, К.Х.Орлов, В.М.Боголюбов, А.А.Знаменская. Төрле елларда мөхәррирләре: Н.П.Загоскин, Л.П. һәм Н.В.Рейнгардт, В.М.Ключников, А.Н.Каменцев, В.И.Кудрявцев, А.С.Петров, В.М.Боголюбов, А.А.Знаменская, А.А.Себякина. Газета чыга башлаган беренче елларда ук журналда язышкан авторлар коллективына яңалары килеп кушыла. Сәяси күзәтүләрнең күпчелеге редакция хезмәткәрләре тарафыннан языла: Н.П.Загоскин (мөхәррир) Казан тарихына караган һәм «Фельетон» рубрикасында басылган «Якшәмбе әңгәмәләре» дигән мәкаләләр авторы (псевд: И.Миролюбов, Всё тот же); П.А.Голубев әдәбият-тәнкыйть бүлеге җитәкчесе; А.П.Подосенова-Поляк (*Федосеев түгәрәкләре* әгъзасы) соңрак ш.у. бүлекне җитәкли; А.И.Богданович, А.А.Дробыш-Дробышевский — редакция хезмәткәрләре. Газетаның тоткан юлы һәм редакция составы полиция департаментына ошамый, аның директоры «газета ялгыш юнәлештә тора һәм анда фәкать сәяси яктан ышанычсыз кешеләр генә эшли» дип саный. Газетада Казанның К.В.Лаврский, П.П.Перцов, Е.К.Чириков, Н.Ф.Юшков һ.б. танылган язучылары даими язышa. Редакция хезмәттәшлек итәргә рус фәне һәм мәдәнияте эшлеклеләрен, либераль-демократик интеллигенция вәкилләрен һ.б.ларны җәлеп итә. Газетада иҗтимагый-сәяси әһәмияткә ия булган, тирән эчтәлекле материаллар басылу нәтиҗәсендә аның эшчәнлеге 1880–90 елларда гөрләп үсеп китә һәм Россия провинциясендә чыгучы басмалар арасында иң яхшыларыннан санала. «В.в.» прогрессив позициядә тора, Россия чынбарлыгының тискәре якларын тәнкыйтьли, крәстияннәрнең икътисади хәлләрен, земство үзидарәсе эшләрен, империянең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышын игътибар үзәгендә тота. Аналитик мәкаләләрдә 1890 елларда Россиядә революцион һәм либераль агымнар арасындагы фикер каршылыклары чагыла. Башкаланың үзәк газеталарында чыккан хөкүмәт карарларын, Россиянең хуҗалык торышын, эчке һәм тышкы сәүдә эшләрен күрсәтүче атналык күзәтүләрне күчереп бастыра. «В.в.»ның даими бүлекләре: «Эчке хәбәрләр», «Корреспонденцияләр», «Чит ил хәбәрләре», «Сәүдә бүлеге», «Педагогика һәм халык мәгарифе», «Фельетоннар һәм матур әдәбият», «Мәхкәмә хроникасы», «Казан хроникасы». Идел-Кама төбәгенең төрле шәһәрләреннән алынган хәбәрләр аерым игътибар үзәгендә була. Газетада әһәмиятле урын били торган «Казан хроникасы» рубрикасында, нигездә, Казан шәһәре думасы утырышлары һәм шәһәр үзидарәсе органнарының эшләре турында материаллар басыла. Казанның фәнни, иҗтимагый һәм мәдәни тормышын яктыртуга зур урын бирелә: Казан уку-укыту округы, шәһәрнең ярлыларга ярдәм күрсәтү һәм фәнни җәмгыятьләре эшчәнлеге, театр спектакльләре, яңа чыккан китаплар турында мәкаләләр басыла. Әдәби бүлек үзенең әдәби-тәнкыйть материаллары б-н газетаның йөзен билгели һәм төбәкнең мәдәни тормышында күренекле урын алып тора. «В.в.» та күренекле рус язучылары Д.Н.Мамин-Сибиряк (повесть, хикәяләр, очерклар, «Урал артыннан Иделгә кадәр» («От Зауралья до Волги») дигән юльязмалар); В.Г.Короленко (хикәяләр һәм 1880 еллардагы сәяси реакциягә, бигрәк тә аграр һәм милли мәсьәләләрдә, мәгариф өлкәсендә хөкем сөргән реакцион фикерләргә каршы юнәлтелгән мәкаләләр); М.Горький (хикәяләр), Н.Г.Гарин-Михайловский, Г.И.Успенский һ.б. үз әсәрләрен псевдоним астында бастыралар. 1900 еллар башында редакциянең кайбер бүлекләргә караган мәкаләләрне ике телдә — рус телендә һәм, тәрҗемә итеп, татар телендә бастырырга рөхсәт сораган үтенече кире кагыла. Акча җитмәү сәбәпле Россия агентлыклары телеграммаларын, хәбәрләрен урнаштыру мөмкинлеге кими. Нәтиҗәдә «В.в.» Ерак Көнчыгыштагы хәрби хәрәкәтләрне үз вакытында оператив яктырта алмый һәм күп әбунәчеләрен югалта. 1904 елда газета чыгару хокукы башка кешеләргә сатыла, редакция составы яңартылып, газета яңадан чыга башлый. 1905 тә аның битләрендә соц.-демократик юнәлештәге мәкаләләр басыла, һәм бу хәл цензура күзәтүенең көчәюенә китерә. 1906 да хакимият тарафыннан эзәрлекләүләр башлана, газетаның кайбер саннары конфискацияләнә, соңгы 4 мөхәррире төрмәгә утыртыла. Әбунәчеләргә төрле вакытта «Волжский вестник»ның әдәби җыентыгы» («Литературный сборник «Волжского вестника») һәм «Фәнни-беллетристик эчтәлектәге җыентыклар» («Сборники научно-беллитристического содержания») җибәрелә. 1897–1903 елларда «В.в.» ка бушлай кушымта итеп «*Казанская сельскохозяйственная газета*» чыгарыла.


ВОЛЖСКІЙ ВѢСТНИКЪ

«Волжский вестник» г-тасы.

*Әд.:* Туринский М. Газеты в провинции // Ист. вестн. 1912, апр.; Волжский вестник // Русская периодическая печать (1702–1894): Справ., М., 1959; Бушканец Е.Г. Казань в жизни и творчестве русских писателей XIX века // Казань в истории русской литературы. К., 1965. Сб. 1; шулук. Цензурное дело «Волжского вестника» (обзор) // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. Русская литература и освободительное движение. К., 1974. Сб. 4; Нафигов Р.И. «Волжский вестник» как источник истории революционного движения в Поволжье и на Урале // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. Вопросы историографии и источниковедения. К., 1969. Вып. XXI; шулук. Из истории полемики марксистов с либеральными народниками (по материалам «Волжского вестника» конца 80-х — начала 90-х годов XIX века) // Революционно-освободительное движение в XIX-XX вв. в Поволжье и Приуралье. К., 1974; Колмаков Б.И. Литературная критика газеты «Волжский вестник»: Дис.... К., 1996; Литературно-критические публикации казанской газеты «Волжский вестник» (1884–1901): Библиогр. указ. К., 2000.

*Г.Р.Заманова.*

**«ВО́ЛЖСКИЙ ВЕ́СТНИК»** («Идел хәбәрчесе»), атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журнал. 1883 елның 2 гыйнварыннан 25 декабренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 52 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире Н.П.Загоскин. «В.в.» Казан ун-ты студентлары һәм профессорлары инициативасы б-н оештырыла. Н.П.Загоскин Россия Эчке эшләр министрлыгының Матбугат эшләре буенча баш идарәсе исеменә 1882 нең 15 гыйнварында язган үтенечендә басманың программасын һәм бурычларын төбәкне «тарихи, статистик-икътисади, этнографик, табигый-географик һ.б. яклардан өйрәнү» дип аңлата. «В.в.» тирәсенә Идел-Чулман төбәгенең либерал-демократлар вәкилләре Н.Я.Агафонов, И.А.Бобровников, И.М.Догель, К.В.Лаврский, Ф.М.Цомакион һ.б. туплана. Хөкүмәт карарлары һәм боерыкларыннан тыш, журналда 1880 елларда Россиянең икътисади һәм иҗтимагый-сәяси тормышының әһәмиятле якларына караган мәкаләләр басыла: авыл хуҗалыгы, сәнәгать һәм сәүдәнең торышы, крәстияннәрнең хәле, җирле үзидарә органнары эше, эшчеләрнең хезмәт һәм көнкүреш шартлары, интеллигенциянең аң-белем тарату өлкәсендәге эшчәнлеге яктыртыла. Киң тармаклы хәбәрчеләр челтәре булдырыла. «Хәбәрләр» рубрикасында Идел


№ 1. 1883. № 1.
ВОЛЖСКІЙ ВѢСТНИКЪ

«Волжский вестник» ж-лы.

буе төбәкләрендә фән, мәдәният һәм мәгърифәт үсеше турында хәбәрләр басыла. Казан шәһәр думасының хуҗалык эшчәнлеге, медицина-санитария, социаль-мәдәни чаралар турындагы язмаларга зур игътибар бирелә. «Беллетристика» рубрикасында әдәби әсәрләрдән өзекләр бастырыла. Күпкырлы мәгълүматны аңлаешлы һәм оператив рәвештә укучыга җиткерү максатыннан редакция, басманың формасын үзгәртеп, журнал урынына шул исемдә газета чыгара башлый. Журналның эчтәлеге һәм тематик күрсәткече бирелгән тулы комплекты Казанда аерым китап булып басылып чыга. Әбунәчеләргә Казандагы күренекле язучыларының әсәрләре тупланган «Волжский вестник»ның әдәби җыентыгы» («Литературный сборник «Волжского вестника») җибәрелә.

*Әд.:* Берсон М.С. Журнал «Волжский вестник» (1883 г.) как исторический источник // Вопр. историографии и источниковедения. К., 1969. Сб. 4; Волжский вестник // Русская периодическая печать (1702–1894): Справ. М., 1959.

**«ВОЛЖСКИЙ ВЕЧЕР»** («Идел киче»), көндәлек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. «Вечерняя почта» г-тасының дәвамчысы. 1909 елның 5 ноябреннән 23 декабренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 42 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире Ю.М.Швамбаум-Древницкий. Казанның күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре М.И.Ганфман, С.А.Гусев (псевд. Слово-Глагол), А.Д.Дуркин, А.Я.Журавлёв, Н.Н.Златовратский, Ф.И.Шаляпин һ.б. авторларның язмалары басыла. «В.в.» да басылган мәкалә, хәбәрләр һәм репортажларда, нигездә, Россиядә барган вакыйгалар яктыртыла. Ш.у. газета төрле рус һәм чит ил газеталарыннан да материаллар күчереп бастыра. Казанның көндәлек тормышын чагылдырган мәкаләләргә дә урын бирелә. Шәһәр үзидарәсе органнары эшчәнлеге, халык мәгарифе, театр спектакльләре, ярлыларга ярдәм күрсәтү хәрәкәтләре, һәвәскәр башкаручылар концертлары, спорт чаралары һ.б. турында мәкаләләр басыла. Әдәбият һәм библиография бүлегендә фельетоннар, матур әдәбият әсәрләре, яңа китапларга рецензияләр бирелә. «Редакциягә килгән хатлар» рубрикасын укучылар хатларына күзәтүләр һәм аларга аңлатмалар тәшкил итә. Ш.у.к. *Казанская вечерняя почта*.


**«ВОЛЖСКИЙ КУРЬЕР»** («Идел курьеры»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. 1906 елның 17 гыйнварыннан 22 октябренә кадәр, 1907 нең 11 мартыннан 24 маена кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 260 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире Г.А.Плетнёв, соңыннан — О.М.Плетнёва. 1906 ның 28 апреленнән 16 октябренә кадәр аерым бит рәвешендә «Идел курьеры» телеграммалары» исемендә кушымта чыгарыла. Газета чыкмый торган вакытта «Волжский листок» г-тасы редакциясе (авторларның күпчелеге «В.к.» да хезмәттәшлек итә) «В.к.» әбунәчеләре ихтыяҗларын канәгатьләндерүне үз өстенә ала. «В.к.» г-тасы Дәүләт Думасы һәм хөкүмәт эшчәнлеген бәяләүдә, эшчеләр хәрәкәте, халык мәгарифе, җирле үзидарә мәсьәләләрендә с.-д. юнәлештә тора. Баш мәкаләләрдә Дума утырышлары, оппозициядә торучы депу-


ВОЛЖСКІЙ КУРЬЕРЪ.

«Волжский курьер» г-тасы.

татларның чыгышлары, фракцияләр эшчәнлеге анализлана. «В.к.» П.А.Столыпинның аграр мәсьәләләр буенча карашын тискәре бәяли, җирне мәҗбүри рәвештә тартып алып, аннан тигез файдалануны яклый, профсоюз хәрәкәтенең әһәмияten аңлата, Россиянең башка шәһәрләрендәге профсоюз оешмалары эше турында хәбәрләр бастыра. Эш ташлаулар, митингларны яктыртуга зур игътибар бирә. Җирле үзидарәне демократлаштыру мәсьәләләрен күтәрә. Казан шәһәре үзидарә органнарының хуҗалык эшләре кискен тәнкыйтьләнә. «Төрмә һәм сөрген» рубрикасында басылган мәкаләләрдә сәяси тоткыннар тормышы яктыртыла, полиция әзәрлекләүләре, сәяси суд процесслары, җәзалап үтерүләр турында хәбәрләр басыла. 1906 да «В.к.» саннары 14 тапкыр конфискацияләнә. 1907 нең май аенда элекке мөхәррир Г.А.Плетнёвка каршы мәхкәмә процессы була, ул хөкүмәткә каршы мәкаләләр бастыруда гаепләнә һәм төрмәгә ябыла.

**«ВОЛЖСКИЙ ЛИСТОК»** («Идел сәхифәсе»), сәүдә-сәнәгать белешмәләре газетасы. 1903 елның 9 гыйнварыннан 1904 нең 1 гыйнварына кадәр атнага 3 тапкыр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 108 саны чыга. Наширләре һәм мөхәррирләре: Ф.А.Ярыгин (Краснораменский псевдонимы б-н казанлылар тормышыннан алынган көлкеле хикәяләр җыентыгы авторы), соңыннан аның хатыны Н.А.Ярыгина. Газетаның исеме астында «сәүдә һәм көндәлек тормышта кирәкле белешмәләр җиткерү органы», соңыннан «сәүдә, сәнәгать, һөнәрчелек, авыл хуҗалыгы һәм көндәлек тормышта кирәкле мәгълүматлар җиткерү органы» дип бирелә. Редакция фикеренчә, басманың максаты — газета битләрендә «Идел-Чулман» төбәгендә сәүдә-сәнәгатьнең торышын тулы чагылдыручы белешмәләр һәм саннар биреп бару. Шул уңайдан редакция Россиянең барлык зур авылларына һәм сәүдә-сәнәгать фирмаларына уңыш алуның һәм товар җитештерүнең төгәл күләме, бәяләр, коры җирдә, диңгез


ВОЛЖСКІЙ ЛИСТОКЪ.

«Волжский листок» г-тасы.

һәм елгаларда йөк ташу шартлары, күргәзмә һәм ярминкәләр турында мәгълүматлар тупланган анкеталар тутырып җибәрүне үтенеп мөрәҗәгать итә. Газетада Казан губернасында 1902 дә икмәкне чит илгә чыгару һәм кертү барышын күрсәтүче картограмма басыла. Фән һәм техника яңалыклары яктыртыла. Сәүдә һәм фонд биржалары килешүләре, подряд һәм дәүләт планын үтәү турындагы белешмәләр, Идел буе шәһәрләрендәге базар бәяләре турында мәгълүматлар, пассажир поездлары, Идел елгасында пароходлар йөреше расписаниеләре басыла. Әдәби бүлектә Казан язучылары әсәрләреннән кечерәк күләмле өзекләр бирелә. Күп кенә реклама белдерүләре басыла. 1904 ел башында Н.А.Ярыгина «В.л.» г-тасын чыгару хокукын И.И.Степановка тапшыра, һәм шул ук исемдә яңа газета чыгарыла башлый.

**«ВОЛЖСКИЙ ЛИСТОК»** («Идел сәхифәсе»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм икътисади газета. 1904 елның 1 октябреннән 1906 ның 14 февраленә, 1906 ның 28 октябреннән 17 ноябренә, 1909 ның 1 гыйнварыннан 4 октябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 992 саны чыга. Төрле елларда наширләре: И.И.Степанов, С.А.Ушаков, А.И.Хорош, М.З.Комлев, Г.А.Плетнёв. Төрле елларда мөхәррирләре: И.И.Степанов, С.А.Ушаков, М.З.Комлев. Башкала әдипләреннән Л.Н.Андреев, И.А.Бунин, В.Я.Брюсов, А.И.Куприн, А.С.Серафимович, Ф.К.Сологуб, К.И.Чуковский һ.б. авторларның әсәрләре басыла. Казан авторлары арасында алдынгы карашлы галим һәм шагыйрьләрдән П.Л.Драверт, А.И.Елистратов, Н.П.Загоскин, В.А.Перимов, Л.И.Пономарёв, П.И.Эмдин, Н.Н.Фирсов һ.б. була. Газетаны чыгарырга тырышып йөрүчеләр — либерал-юристлар М.Б.Зельдович, С.А.Ушаков, И.И.Степанов. Соңгысы, яңа алган наширлек хокукыннан файдаланып, газетаның тематикасын шактый киңәйтә, чыгару ешлыгын арттыра. Чыга башлавының беренче елында ук газета Россия телеграф агентлыгы хәбәрләрен даими алдыруга һәм Ерак Көнчыгыштагы сугыш хәрәкәтләре турындагы хәбәрләрне оператив рәвештә укучыларга җиткерүгә ирешә (1904 нең 1 октябреннән 1905 нең 31 августына кадәр «Волжский листок» телеграммалары» дигән кушымта чыгарыла). Укучыларның күплеге, басылган материалларның төрлелеге, авторлар коллективының җитдилеге газетага популярлык китерә. «В.л.» гомумдемократик характерда була, ләкин большевиклар аны үз идеяләрен тарату максатында файдалана башлыйлар (цензура рөхсәт иткән дәрәҗәдә). 1905 нең язына редакция хезмәткәрләре төп 2 сәяси төркемгә бүленә: адвокатлар даирәсеннән булган либераллар һәм социал-демократлар — РСДРПның Казан ком-ты әгъзалары В.В.Адоратский (псевд. Soci), Н.И.Дамперов, А.С.Кулеша (псевд. ASKA), Н.Н.Накоряков (псевд. Чарно), Б.М.Фрумкин (псевд. Ф.), М.М.Хомяков (псевд. Синьор). «В.л.» җәен Казанга килгән Я.М.Свердлов (псевд. Михайлович) мәкаләсен дә бастыра. 1906 ел башыннан газета сайлау кампанияләре һәм

Дәүләт думасы эшләрен яктырта, депутатларның, бигрәк тә с.-д. фракциясе депутатларының чыгышларын бастыра. Россиянең сәяси партияләре эшчәнлегенә зур игътибар бирелә: марксизм нигезләре, большевиклар партиясенең стратегия һәм тактикасы мәсьәләләре яктыртыла; кадетлар партиясе эшләре анализлана; уң һәм карагруһчы оешмалар эшчәнлегенә тискәре бәя бирелә. Газетада патша хөкүмәтенең милли сәясәте тәнкыйть астына алына. Киң тармаклы хәбәрчеләр челтәре Идел буе губерналары тормышын дөрес яктыртырга мөмкинлек бирә. Газета П.А.Столыпин үткәрә торган социаль-сәяси реформалар курсы җир мәсьәләсен дөрес чишә алмый, һәм аграр мөнәсәбәтләрне тамырдан үзгәртергә кирәк дип саный. «В.л.» иҗтимагый тормышны һәрьяклап демократлаштырырга, җирле үзидарә эшен реформалаштырырга чакыра. «В.л.»ның большевиклар идеяләрен үткәрергә омтылуы цензура игътибарыннан читтә калмый. Цензор М.Н.Пинегин газета «яшәп килүче хакимият режимына каршы фикердә тора, басма сүз ярдәмендә җәмгыятьтә хөкүмәт органнарына карата ышанычсызлык тудырырга омтыла» дип күрсәтә һәм газетаны аерым күзәтү астына ала. Нашир һәм мөхәррирләр еш кына җинаять җаваплылыгына тартылалар, газетага берничә мәртәбә штраф салына, саннары конфискацияләнә. 1906–07 дә, газета чыгудан туктап торган вакытларда, әбунәчеләргә «*Волжский курьер*» г-тасы җибәрелә. 1908 нең 26 маеннан 4 августына кадәр, иртәнге басмага бушлай кушымта сыйфатында, шул ук исемдә атналык кичке чыгарылыш басыла (13 сан). Ш.у.к. «*Приволжский край*».

*Әд.:* Л и в ш и ц С. Казанская социал-демократическая организация в 1905 г. // Пролетарская революция. 1923. № 2–3; М у л л и н а Л.Б. «Волжский листок» в 1905 году // Из истории местной периодической печати. К., 1960. Вып. 1; Г а в р и л о в а Н.В., Н и к о л а е в В.Н. Идея марксизма на страницах газеты «Волжский листок» в 1906–1907 гг. // Историография федосеевских марксистских кружков Поволжья. К., 1972; Э л е р т А.А. Из истории общественно-политической борьбы в Казанской губернии // Революционно-освободительное движение в XIX–XX вв. в Поволжье. К., 1974; К а р а с ё в А.М. Источники по истории профсоюзного движения в Казани в 1905–07 гг. (Обзор публикаций газеты «Волжский листок» («Волжский курьер») // Общественные отношения развитого социализма. К., 1985.


*Г.Р.Заманова.*

**«ВО́ЛЖСКОЕ»**, иртә өлгерешле кышкы алма сорты. 1952 елда Татарстан җиләк-җимеш тәҗрибә станциясендә «Боровинка» сортын «Ренет Поволжья» сорты б-н серкәләндереп, Г.И.Розанова тарафыннан чыгарыла. Татарстанда киң таралган, кышкылар төркемендә «Гади антоновка», «Алсу әнис» һәм «Ренет Поволжья» сортларыннан кала, таралу мәйданы буенча 4 нче урынны алып тора. Чуаш, Мари респ-калары, Ульянов өлкәсе бакчаларында үстерелә. Түгәрәк, куе һәм күп яфраклы ябалдашлы, уртача үсә торган агач. Бәбәкләре туры, кызгылт төсмерле кара-көрән төстә, төкчәсез, вак ясмыкчыклары бар. Яфраклары зур түгел, куе яшел төстә, түгәрәк, яссы, җиңелчә җыерчыкланган, тонык, әчке ягы азрак төкчәле. Яфрак сабы уртача озынлыкта һәм юанлыкта, сабак төбе кызгылт төстә. 2–3 еллык ботаклары көрән-кызыл төстә, яхшы күренеп тора торган аксыл сары ясмыкчыклары бар. Күпьеллык ботаклары (төп ботаклары) дугасыман бөгелгән, кәүсәгә нык тоташкан, бронза төсмерле кызыл-көрән төстә. Алмалары уртача зурлыктан кечерәк (60–70 *г*), түгәрәк-тыгыз, юан, бик матур, күп санда ачык кызгылт сары буйлары бар, җимеш сабакчасы кыска. Җимеш йомшагы ак, вак бөртекле, тыгыз, яхшы десерт тәмле. 9,5% шикәр, 23% С витамины бар. Бу сорт иртә җимеш бирә башлавы, югары уңышлы (10 еллык агачтан 80–90 *кг* кадәр), кышкы суыкларга һәм кутыр авыруына чыдамлылыгы, бик тәмле булуы б-н аерылып тора. Җимешләре сентябрь уртасында өлгерә, 4 айга кадәр саклана.

*Әд.:* Определитель сортов яблони Европейской части СССР: Справ. М., 1991.

*В.А.Наумов.*

**«ВО́ЛЖСКОЕ У́ТРО»** («Идел иртәсе»), атналык рәсемле әдәби-нәфис, фәнни-популяр, публицистик журнал. 1908 елның 10 ноябреннән 8 декабренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 5 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — китап кибете хуҗасы П.А.Бородин. Төп хезмәткәрләре — хакимият тарафыннан ябылган «Волжский листок» г-талары һәм «Волжские дали» ж-лы журналистлары. «В.у.» да басылган материалларның тематикасы гаять киң: конституция һәм реформалаштыру проблемалары, Дәүләт думасы фракцияләре эшчәнлеге, төбәк тормышы хроникасы. Россиянең уң партияләре, бигрәк тә октябрьчеләр б-н карагруһчылар тоткан юлны тәнкыйть күзлегеннән чыгып анализлауга зур игътибар бирелә. «Библиография» бүлегендә сәнгатькә багышланган китапларга күзәтүләр, «Сәнгать хроникасы» рубрикасында Казанда театрлар эшенең торышы, Император исем. рус музыка җәмгыятенең Казан бүлеге эшчәнлеге турында хәбәрләр басыла. Шигырьләр, очерклар, Казан әдәбиятчылары А.Ф.Мантель, М.Л.Премиров һ.б. авторлар әсәрләреннән өзекләр бирелә. 24 ноябрьдә 3 нче санга кушымта рәвешендә «Волжский свисток» исемле сатирик газета чыгарылган.




«Волжское утро» ж-лы.

**«ВО́ЛЖСКО-КА́МСКАЯ РЕЧЬ»** («Идел-Кама сүзе»), көндәлек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. «Казанский вечер» г-тасының дәвамчысы. 1907 елның 1 декабреннән 1908 нең 30 сентябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Нашире Н.П.Гусев, мөхәррире Н.А.Скворцов, соңрак үзе нашире дә була. Көнгә 2 чыгарылышта басыла: кичкесе — 1908 нең 31 мартына кадәр (184 сан, сәркәтибе Н.П.Гусев), иртәнгесе — 1908 нең 30 сентябренә кадәр (351 сан, сәркәтибе В.П.Кулинченко). 1907 нең 30 декабреннән (38 нче саннан) бу чыгарылышларның саннары алышынып басыла башлый. Үзен «партиясез прогрессив газета» дип белдерсә дә, гамәлдә кадетлар партиясе карашларын пропагандалый. Газетаның Казандагы хезмәткәрләре арасында кадетлар партиясе исеменнән сайланган адвокатлар һәм Казан ун-ты укытучылары И.И. һәм П.И.Александровлар — газетага акчалата ярдәм күрсәтүче завод хуҗалары, И.И.Бабушкин — газетаның гомуми юнәлешен билгеләүче, Дәүләт Советы әгъзасы проф. А.В.Васильев, адвокат Н.П.Гусев, проф. Б.К.Поленов һ.б. була. Чит шәһәрләрдә торып эшләүчеләр — кадетлар партиясенең күренекле вәкилләре А.С.Изгоев, П.Н.Милюков, А.И.Шингарёв һ.б. «В.-К.р.»нең һәр санында диярлек баш мәкалә Дума утырышларын яктыртуга багышлана. Газета фикеренчә, Дәүләт Думасы хокукларын саклау шигаре тирәсенә конституцияне яклаучылар тупланырга тиеш. Россиянең дипломатик мөнәсәбәтләре, аның Россия халыклары ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый торган колониаль сәясәте газета тарафыннан кискен тәнкыйтьләнә. Газета тирәсенә тупланган киң тармаклы хәбәрчеләр челтәре Идел-Кама төбәге җирле үзидарә органнарының эшен тулы яктыртырга мөмкинлек бирә. Идел буе төбәкләрендәге ачлык, хакимият тарафыннан аңа каршы үткәрелгән чаралар турында хәбәрләр басыла. Төбәктә яшәп килүче утар хуҗалыклары урынына крәстиян җәмәгатьләрен саклап калырга тырышкан «В.-К.р.» аграр реформа мәсьәләләрендә хөкүмәткә каршы позициядә тора. 1908 нең сентябрь аенда Н.А.Скворцов Казан губернаторы исеменә язган үтенеч хатында И.И.Бабушкинның газета чыгару хокукын үзләштерүдә гаепли, аны гражданлык судына биргүне һәм шул ук исемдә чыгарылырга әзерләнгән, тышкы күренеше б-н дә, газетага язылу шартлары, конторасы һәм редакциянең адресы да «В.-К.р.»не кабатлаган яңа газетага арест салуны таләп итә. Казан округ мәхкәмәсе И.И.Бабушкинга яңа газетаның рәсми хуҗасы булырга рөхсәт бирми, аның исемен үзгәртүне таләп итә. Ш.у.к. «*Камско-Волжская речь*».

*Г.Р.Заманова.*

**«ВО́ЛЖСКО-КА́МСКОЕ СЛО́ВО»** («Волга-Кама сүзе»), иҗтимагый-сәяси газета. Казанда 1881 елның 1 декабреннән көн саен, 1882 нең 8 августыннан атнага өч тапкыр рус телендә нәшер ителә, барлыгы 229 саны чы-


ВОЛЖСКО-КАМСКОЕ СЛОВО

ПОЛИТИЧЕСКО-ОБЩЕСТВЕННАЯ ГАЗЕТА

«Волжско-Камское слово» г-тасы.

га. Нашире һәм мөхәррире С.М.*Шпилевский*. Газетада П.А.Пономарёв, И.П.Скворцов, вет.табибе И.А.Сокольский һ.б. мәкаләләре басыла. Газетаны чыгаруда Казан губернаторы А.К.Гейнс һәм кайбер бай сәнәгатьчеләр, сәүдәгәрләр булышлык күрсәтә. Баш мәкаләләрдә хөкүмәтнең закон-боерыклары (нигездә, Казан губернасына кагылышлылары) анализлана. Идел-Кама төбәгенең иҗтимагый сәяси һәм икътисади тормышы яктыртыла. Бюрократлыкка, земство һәм шәһәр үзидарәсе органнарының мөстәкыйльлеген чикләүгә каршы фикер үткәрелә, аларның вәкаләтләрен киңәйтү кирәклеге әйтелә. Этнографик очерклар, Казан тарихы һәм археологиясенә, шәһәрнең иҗтимагый-мәдәни тормышына караган язмалар, төбәктәге фәнни, хәйрия һ.б. җәмгыятьләр эшчәнлеге турында хәбәрләр басыла. Газета земство либерализмы позицияләрендә тора, хосусый милекчелекне яклый, аны «кеше шәхесенең кирәкле атрибуты» дип саный, халыкны дини рухта тәрбияләргә чакыра, социализм һәм революцион көрәш идеяләренә каршы фикерләрне алга сөрә. Түбән катлау шәһәр халкы һәм крәстияннәрнең авыр тормышы турында мәкаләләр бастыру аркасында цензура б-н ике арада туган низаглар, ш.у. финанс кытлыгы газетаның ябылуына китерә.

*Әд.:* Волжско-Камское слово // Русская периодическая печать (1702–1894): Справ. М., 1959; Хайруллина А.Д. Казанские газеты как исторический источник для изучения благотворительности (1861–1895): Дис.... К., 1993; Галанин С.Ф. Газетная реклама как исторический источник (по материалам казанских газет второй половины XIX в.): Дис.... К., 1999.

*Г.Р.Заманова.*

**ВО́ЛКОВ** Али Харис улы (6.12.1952, Пенза өлкәсенең Городище р-ны Урта Әләзән авылы), вет. сан. экспертизасы белгече, вет. фән. д-ры (2001), проф. (2002), ТРның атказ. вет. табибе (1998). РФ югары проф. белем бирү мәктәбенең мактаулы хезмәткәре (2005). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1979), шунда ук вет.-сан. экспертизасы кафедрасында эшли, 2004 елдан каф. мөдире, 2002 дән фәнни эшләр буенча проректор. Фәнни-тикшеренү эшләрендәге төп юнәлешләр: инвазион авырулы а.х. терлекләренең табигый тотрыклылыгы үсеше һәм гельминтларны чыгарудан соң савыгу процесслары, актив азык кушылмаларын куллану, терлек продукциясенең биол. кыйммәтен билгеләү.

Хезм.: Мероприятия по борьбе с сетариозом крупного рогатого скота для разного типа хозяйств в Республике Татарстан: Рекомендации. К., 1999; Гельминтофауна Республики Татарстан // Ветеринария. 2000. № 1; Эпизоотические особенности фасциолёза крупного рогатого скота в Республике Татарстан // Ветеринарный врач. 2000. № 3.

*Әд.:* Фролов В.П. Основные этапы развития кафедры ветсанэкспертизы // Казан. ордена Ленина вет. ин-т им. Н.Э.Баумана. К., 1993; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ВО́ЛКОВ** Андрей Кононович (1844, Владимир губ. — декабрь, 1902, Казан), философ, тәрҗемәче, дин гыйльме магистры (1872). Петербург руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1867), Казан руханилар академиясендә укыта, 1873 елдан профессор. Хезмәтләре Көнбатыш Европа философиясе тарихына карый. Милль әсәрләрен, исламга багышланган инглиз һәм француз әдәбиятын тәрҗемә итә. Тәрҗемәләренең төп өлеше «Православный собеседник» ж-лында басылып чыга.

Хезм.: Библия и Коран // Православный собеседник. 1876. Ч. 3; Очерк современной пессимистической философии // шунда ук. С. 137–197; Сочинения против пессимизма // Православный собеседник. 1880. Ч. 3; К вопросу о пессимизме // Православный собеседник. 1884. Ч. 2.

*Әд.:* Андрей Кононович Волков: Некролог // Православный собеседник. К., 1903. Ч. 2.

**ВО́ЛКОВ** Борис Степанович (15.1.1921, Түбән Новгород губ., Сергач өязе Фёдоровка а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1970), проф. (1971), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1979). Казан юридик ин-тын тәмамлый (1949). 1949–52 елларда Казан юридик ин-тында. 1952 дән Казан ун-тында: 1967–82 дә җинаятькә каршы хокук каф. мөдире. 1982–86 да СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясе һәм 1986 дан Халыклар дуслыгы ун-тының (Мәскәү) җинаятькә каршы хокук һәм процесс каф. профессоры. Хезмәтләре җинаятькә каршы хокук, җинаять һәм җинаятьче шәхесенең социаль-психологик аспектларын өйрәнүгә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Ответственность за уничтожение и повреждение имущества по советскому уголовному праву. К., 1961; Проблема воли и уголовная ответственность. К., 1965; Мотив и квалификация преступлений. К., 1968; Детерминистическая природа преступного поведения. К., 1975; Мотивы преступлений: уголовно-правовое и социально-психологическое исследование. К., 1982.

**ВО́ЛКОВ** Вадим Александрович (18.3.1973, Казан), спортчы (самбо), Россиянең халыкара классды спорт остасы (1992). Профсоюзларның физкультура-спорт җәмгыятендә (Казан, тренеры З.В.Сәгъдиев) тәрбияләнә. Яшьләрнең Россия, дөнья (1992), Европа (1992–93) беренчелегендә җиңүче, дөнья беренчелегендә бронза медаль ала (1993).

**ВО́ЛКОВ** Евгений Михайлович (23.2.1952, Казан), нейробиолог, мед. фән. д-ры (1986), проф. (1988). 1975 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, 1977 дән шунда ук мед. биологиясе һәм генетика кафедрасында эшли. Хезмәтләре ярсынучан мембраналар нейрофизиологиясе һәм күзәнәк биологиясенә карый. Баканың мускул җепселләре мембраналарының тыныч халәтенә кислота-селте тәэсирен тикшерә. Мембрана формалашу мөмкинлегенә хлор ионнарының катнашуы һәм ш.у. аларның натрий-калий насосы хәрәкәтенә бәйле рәвештә мускул җепселләренә актив күчүен тәҗрибәдә исбатлый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995).

Хезм.: Факторы нейротрофического контроля ацетилхолиновой рецепции скелетных мышц // Успехи физиологических наук. 1989. Т. 20. № 2; Молекулярные механизмы нейрональной регуляции ацетилхолиновой рецепции скелетных мышц // Успехи современной биологии. 1989. Т. 108, № 4; Нейротрофический контроль проницаемости мембраны мышечного волокна // Успехи современной биологии. 1990. № 4.

**ВО́ЛКОВ** Иван Николаевич (2.12.1893, Вятка губ., Глазов өязе Яңа Волково а. — гыйнвар, 1919, шунда ук), революция вакыйгаларында катнашучы. Казан ун-тында белем ала (1913–17). 1915 елда Г.Ольkеницкий б-н бергә студентларның берләшкән комитетын оештыра. «Клич» ж-лы (гыйнв. 1917), «Рабочий» г-тасы (март — июль 1917) редколлегияләре әгъзасы, аларда крәстияннәрнең авыр тормышын тасвирлаган, патша хакимиятен тәнкыйтьләгән мәкаләләр урнаштыра. РСДРП(б)ның Казан ком-ты әгъзасы, секретаре (1917). РСДРП(б)ның апрель конференциясе делегаты (1917). Казанда Окт. короллы баш күтәрүендә катнаша, октябрь-ноябрьдә Казанда рев-ция штабы әгъзасы була (1917). 1917 нең октябрендә Кызыл Гвардия үзәк штабын җитәкли. 1918 дә контрреволюцион саботаж оештыручыларга каршы көрәш комиссиясе рәисе.

*Әд.:* Элерт А. И.Н.Волков // Борцы за счастье народное. К., 1967.

*С.И.Ионенко.*

**ВО́ЛКОВ** Михаил Никитич (8.11.1905, Казан — 1995, Мәскәү), химик, химия фән. д-ры (1957), проф. (1958), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1970). 1937 елда Химик коралдан саклану хәрби академиясен (Мәскәү) тәмамлый. 1917–37 елларда Казан химия з-дларында эшли. 1937 дән СССР ФАнең Янучан казылмалар ин-тында, 1943 тән Дәүләт Оборона Комитетында, 1945 тән РСФСР Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгында, 1960–75 елларда Югары аттестация комиссиясенең гыйльми сәркәтибе. Бер үк вакытта 1948–76 да Мәскәү физика-техника ин-тында каф.мөдире. Хезмәтләре нефть химиясенә карый. Нефть ятмаларының таралу закончалыкларын ача һәм аларны нәтиҗәле файдалану алымнарын тәкъдим итә. Кыр шартларында бензиннарның октан саннарын билгеләү ысулын һәм приборын эшли. Пешкәкле двигательләрдә мотор ягулыкларының детонациясен, ракета двигательләрендә ягулык яну шартларын тикшерә. Җирдә һәм галәмдә җанлы системаларны ионлаштыручы радиациядән саклау өчен химик кушылмалар синтезлый («Восток» һәм «Луна» космик станцияләрендә кулланыла). Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Лабораторный практикум по общей химической технологии. М., 1946; Биологическая активность некоторых аминотиолов и аминосульфидов. М., 1974.

**ВО́ЛКОВ** Николай Андреевич (9.1.1892, Саратов губ., Сердоба өязе Голицыно а. —

15.11.1980, Казан), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1971), проф. (1971). Иркутск ун-тын тәмамлый (1921). 1909–17 елларда Саратов һәм Гродно губерналары земство оешмаларында эшли. 1922–23 тә Иркутск ун-тының профессорлык стипендиаты. 1923–31 дә ОГПУның ТАССРдагы тулы вәкаләтле вәкиллеге юрисконсульты. 1931–41 дә ТАССР коммуналь хуҗалык халык комис-тында план бүлеге башлыгы, арбитр. 1943–49 да Казан юридик ин-тында, 1949–58 дә Белоруссия ун-тында укыта. 1958 дән Казан ун-тында, 1967–75 тә дәүләт хокукы һәм совет төзелеше каф. мөдире. Хезмәтләре хакимият, дәүләт хокукы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Органы советского государственного управления в современный период. К., 1962; Исполнительный аппарат местных Советов депутатов трудящихся: основные вопросы организации и деятельности. К., 1968; Высшие и центральные органы государственного управления СССР и советских республик в современный период. К., 1971.

**ВО́ЛКОВА** Ирина Николаевна (8.4.1921, Иркутск ш.), физиолог, мед. фән. д-ры (1956), проф. (1959), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1964). 1943 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук нормаль физиол. кафедрасында эшли, 1956–82 дә каф. мөдире, бер үк вакытта 1964–70 тә проректор. Хезмәтләре медиаторларның трофик функцияләренә карый. Медиаторларның эчке әгъзалар һәм тукымалар трофикасын көйләүдә, периферик (нерв-мускул) синапс функциясен көйләү механизмнарында катнашуын, үтә көчле һәм дәвамлы панкреатит, травматик шок, перитонит, ашказаны ярасы вакытында медиаторлар системасының үзгәрешен, адреналин һәм адренохолин-серотонинэргик системаларындагы үзгәрешләрне өйрәнә. Тикшеренү нәтиҗәләре медиатор тибындагы нейрогумораль чараларны физиологик функцияләр бозылуын көйләү максатында куллану мөмкинлеге бирә. 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995).

Х е з м.: Из истории казанской физиологической школы. К., 1978 (автордаш); Медиаторные механизмы регуляции и их коррекция при экстремальных состояниях. Л., 1979.

**ВО́ЛКОВА** Светлана Андреевна (3.7.1939, Пятигорск ш.), геолог-аналитик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), геол.-минералогия фән. канд. (1980). 1961 елда Төньяк Кавказ тау металлургия ин-тын (Орджоникидзе ш.) тәмамлаганнан соң, Көньяк Урал геол.-топографик төшерүләр экспедициясендә (Уфа ш.), 1961 елдан Казан ун-тында, 1964 тән Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк ин-тында эшли. Балчыклы токымнарда, кремнийлы чималда, талькларда, асбестларда, графит һәм цеолит рудаларында минераль компонентлар микъдарын билгеләү өчен рентген-фазалы тикшерү ысулын эшли, традицион булмаган исәпләү алымын тәкъдим итә, уйлап табуга патентлы бар.

«ТРда металл булмаган файдалы казылмаларны нәтиҗәле файдалануның яңа минералогик-технологик ысулларын булдыру һәм тормышка ашыру» дигән хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә.

Х е з м.: Рентгенографический количественный фазовый анализ по наложенным рефлексам на примере цеолитсодержащих пород. М., 1995; Рентгенографический количественный фазовый анализ форм кремнезёма в кремнистых породах; опоках, трепелах, диатомитах. М., 1997 (автордаш); Количественное содержание талька в талькосодержащих породах. М., 2001 (автордаш).

**ВО́ЛКОВО** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 100 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бимә елгасы буенда, Удмурт Респ-касы чигендә. 2002 елда 10 кеше (руслар) яши. 18 йөз уртасында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, бурлаклык б-н шөгыльләнә; Пермь, Самара, Саратов губерналарында эшли. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостена керә. 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1887 дә — 466, 1920 дә — 565, 1926 да — 609, 1938 дә — 480, 1949 да — 289, 1958 дә — 269, 1970 тә — 201, 1989 да — 53 кеше.

**ВОЛКОНСКОЙ́Т** (кенәз П.М.Волконский фамилиясеннән алынган), монтмориллонит төркеменнән, составында хром күп булган балчыксыл минерал. Зәңгәрсудан алып яшел төскә кадәр. Тыгыз агрегатлар һәм җирсыман массалар хасил итә. Ион алмаштыру һәм сорбция үзлекләренә ия. Татарстан терр-ясендә Пермь системасының кызыл төстәге утырмаларында очрый. Буяулар ясауда кулланыла.

**ВОЛЛАСТОНИ́Т** (инглиз табигать белгече У.Х.Волластон фамилиясеннән алынган), такта шпат, $Ca_3[Si_3O_9]$ чылбырсыман силикатлары асклассындагы минерал. CaO — 48,3%, $SiO_2$ — 51,7%. Еш кына Fe (ферроволластонитта FeO — 9,3% ка кадәр), Mn (мангаволластонитта MnO — 5,5% кадәр), өлешчә Mg (MgO — 0,6% ка кадәр) катнашмалары очрый. Тояксыман, җепселле, сирәк очракларда яссы табаклы һәм кабыксыман агрегатлар, энәсыман яки шакмаксыман формалы кристаллар хасил итә. Төсе көрән, соры, кайбер очракларда — төссез һ.б. Пыяласыман ялтырый, җепселле массаларныкы — ефәксыман яисә перламутр ялтыравыклы. Гадәттә, үтә күренмәүчән, уртача уалучан. Катылыгы 4,5–5,0. Тыгызлыгы 2,9 — 3 *г/см*³. Метаморфозаланган известьташларда, нигез, ультранигез һ.б. токымнарда очрый. Төп запаслары АКШ, Һиндстан, Казакъстан, Үзбәкстан һ.б. илләрдә. Россия терр-ясендә В.ның берничә чыганагы бар: Слюдянка, Андреевка, Дальнегорск. ТРда Татар гөмбәзе кристаллик нигезенең метаморфик комплексында чагыла. Җир шарында елга 100–130 мең *т* чыгарыла. Электро- һәм радиокерамика, буяулар, глазурь, эмальләр, ашламалар, пестицидлар, фильтрлар эшләп чыгаруда һәм төзелеш эшләрендә кулланыла.

*Әд.:* Л и с и ц ы н А.Е., О с т а н е н к о П.Е. Минеральное сырьё. Волластонит: Справ. М., 1999.

**ВОЛО́ВИЧ** Леонид Аркадьевич (9.2.1931, Украина ССР, Чернигов өлкәсе Прилуки ш.), философ, филос. фән. д-ры (1979), проф. (1986). Россия Мәгариф академиясе мөхбир әгъзасы (1989), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Мәскәү станок-инструменталь ин-тын (1953) һәм Казан консерваториясенең вокал ф-тын (1959) тәмамлый. 1953–55 елларда «Сибсельмаш» з-дында инженер-механик булып эшли (Новосибирск ш.). 1959–76 да Казан консерваториясенең ялгыз җырлау һәм марксизм-ленинизм кафедраларында укыта. 1976 дан РМАнең Урта һөнәри белем ин-тында гуманитар тәрбия лаб. мөдире. Хезмәтләре яшь буынны эстетик тәрбияләү, шәхестә культура формалаштыру, урта һөнәри белем мәктәбендә гуманитар тәрбия бирү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Система эстетического воспитания подрастающего поколения (некоторые методологические вопросы эстетического воспитания в общеобразовательной школе). К., 1976; Эстетическое воспитание трудящихся в условиях развитого социализма. София, 1977; Социокультурные основания подготовки современного специалиста в средней профессиональной школе. К., 1999.

*Әд.:* Энциклопедия профессионального образования. М., 1999. Т. 1.

**ВОЛОДА́РСКИЙ** посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 59 *км* көньяктарак, Иске елгасы буенда. 2002 елда 14 кеше (чуашлар) яши. 1910 елларда нигез салына. Башта Лихачи дип атала. Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1931 нең 5 сентябреннән — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1920 дә — 235, 1926 да — 258, 1938 дә — 248, 1949 да — 266, 1958 дә — 239, 1970 тә — 233, 1979 да — 102, 1989 да — 31 кеше.

**ВОЛО́ДИКОВ** Александр Васильевич (11.6.1965, Брянск өлкәсенең Унеча р-ны Староселье а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник училищесен (1989) тәмамлаганнан соң, «Серго исем. завод» җитештерү берләшмәсе» федераль унитар пр-тиесендә инженер-конструктор, әйдәп баручы инженер-конструктор, баш конструктор, берләшмәнең баш конструктор урынбасары. Дәүләт бүләге донор канын һәм аның компонентларын югары сыйфатлы итеп саклау һәм кулланыну тәэмин итә торган яңа буын суыту техникасын эшләгәне һәм мед. практикасына керткәне өчен бирелә.

**ВОЛО́ДИН** Игорь Николаевич (12.4.1937, Новосибирск ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1981), проф. (1990), Казан. ун-тының атказ. проф. (2007). 1960 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: 1974–85 тә математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында ихтималлык теориясе һәм матем. статистика бүлеге мөдире, 1988 дән матем. статистика каф. мөдире. Хезмәтләре ихтималлылык теориясенә, матем. статистика һәм аларны куллануга карый. Ки-

рәкле күләмне сайлап алу өчен бик төгәл асимптотик таркату таба һәм аның уртача күләме өчен универсаль түбән чикне билгеләли. Статистик нәтиҗә гарантияле булуның яңа d-апостериор теориясен төзи (автордаш).

Х е з м.: Нижние границы среднего объёма выборки и эффективность статистического вывода // Теория вероятностей и её применение. 1979. Т. 24, вып. 1; Статистические оценки с асимптотически минимальным d-риском // Теория вероятностей и её применение. 1993. Т. 38, вып. 1; Локальная асимптотическая эффективность последовательного критерия отношения вероятностей при d-гарантийном различении сложных гипотез // Теория вероятностей и её применение. 1998. Т. 43, вып. 2 (автордаш).

**ВОЛО́ДИН** Сергей Константинович (11.11.1957, Ростов-Дон ш.), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1997). 1980 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, Казан мед. академиясендә эшли. В. аналык һәм аның үсентеләренең кан б-н тәэмин ителүнең анатомик-функциональ үзенчәлекләрен өйрәнә, бала таба алмау авыруын, күкәйлек склерополикистозын, аналык һәм күкәйлеккә гади шешләрне хирургик дәвалауның яңа ысулларын эшли. Кан тамырлары анатомиясе үзенчәлекләрен һәм бу системада кан йөреше юнәлешен билгеләргә мөмкинлек биргән М.З. һәм З.М.Сигал ысулы б-н трансиллюминация һәм ангиотензометрияне беренче булып файдалана. Гинекологик операцияләр техникасына төзәтмәләр кертә, көпшә-перитонеаль сәбәпле бала таба алмаучы хатын-кызны дәвалауда микрохирургик ысулны гамәлгә кертә, җиңсә өстеннән аналыкны алып ташлаганда, аның үсентеләрен калдырып, аналык кабыргасының сероз-мускуллы ялгамасын саклап калу операциясе ысулын, дәвалауның яңа (аналык куышлыгын күзәтеп тикшерү) ысулларын эшли, күкәйлек склерокистозына гистероскопия үткәрүдә эндоскопия ысулын куллана.

Х е з м.: Ангиотензометрия и трансиллюминация при операциях на матке и придатках. К., 1986; Хирургическая профилактика нейроэндокринных нарушений после надвлагалищной ампутации матки. К., 1997 (автордаш).

**ВОЛО́ДИНА** Галина Ивановна (25.10.1927, Курск өлкәсе Ливны ш.), нурлар ярдәмендә дәвалау һәм диагноз кую белгече, мед. фән. д-ры (1968), проф. (1970), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1976). 1950 елда Ростов мед. ин-тын тәмамлый. 1960 елдан Казан мед. академиясендә, 1968 дән нурлар ярдәмендә дәвалау һәм диагноз кую каф. мөдире. Бер үк вакытта 1966 дан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш радиологы. В. М.З.Сигал б-н берлектә онкологик авыруларга нурлар ярдәмендә диагноз кую һәм дәвалауның яңа юнәлешен башлап җибәрә, тышкы яктан урнашкан яман шешләргә операция ясалган урыны, дермо-эпидермаль аутотрансплантат аша, нурлар ярдәмендә дәвалауның яңа ысулларын эшли.

Х е з м.: Реакция свободного дермо-эпидермального аутотрансплантата на действие рентгеновского и гамма-излучения. К., 1968; Рак кожи век: Клиника и лучевая терапия. К., 1972; Дифференциальная диагностика заболеваний костей и суставов позвоночника. К., 1993 (автордаш).

*Әд.:* Академия наук Татарстана. К., 1994; Лучевая диагностика и лучевая терапия, этапы становления. К., 1997.

**ВОЛО́ДИНА** Людмила Геннадьевна (16.5.1960, Тәтеш ш.), спортчы (стендта ату), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1981). «Урожай» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Тәтеш ш., тренер С.С.*Ярullин*). Дөнья (1987), СССР (1983, 1985) кубокларын ала, команда (1981, 1983, 1986) һәм шәхси беренчелектә (1986) Европа чемпионы. Европа чемпионатларында көмеш (1981), бронза (1983) медальләр ала. СССР чемпионатларында җиңүче була (1983), бронза медальләр (1981, 1984, 1986) ала. Команда зачётында дөнья, Европа, СССР (барысы да 1984 тә) рекордчысы. 1978 дән Тәтеш шәһәренең балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер. 1986 дан Одесса шәһәрендә яши.

**ВОЛОСО́ВО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), энеолит дәверенә карый (якынча б.э.к. 3 нче меңьеллык ахыры — 2 нче меңьеллыкның 1 нче яртысы), Идел-Нократ елгалары, Югары һәм Урта Идел буенда урнашкан. В.А.Городцов тарафыннан табыла, атамасы Владимир өлкәсе Волосово авылы янындагы торулыкка бәйле рәвештә бирелә. Урта Идел буенда В.к. истәлекләрен А.Х.Халиков, В.П.Третьяков, В.В.Никитин һ.б. тикшерә. А.Х.Халиков фикеренчә, Урта Идел буендагы В.к. истәлекләре б.э.к. 3 нче меңьеллыкның соңгы чиреге — 2 нче меңьеллыкның 2 нче чиреге аралыгы б-н билгеләнә. Фин-пермь кабиләләреннән калган дип фараз ителә. В.к.ның хуҗалык итү ысулы *Гарино-Бор культурасы*на якын.

В.к. халкы табигать нигъмәтләрен җыю, аучылык, балыкчылык б-н көн күргән, соңрак терлекчелек һәм игенчелек б-н шөгыльләнгән. Урта Идел буе археологик истәлекләрендә тораклар җиргә иңдереп корыла, бер-берсе б-н тоташкан дүртпочмаклар рәвешендә була, торак уртасында учаклар һәм хуҗалык базлары урнаша. Балчык савыт-саба кулдан әвәләп ясала, аңа уртача зурлыктагы һәм эре тешле тарак эзе төшерелә; чүлмәк балчыгына органик калдыклар, вакланган бака кабырчыгы кушыла. Әүвәлге чорда савыт-саба калку төпле, киң авызлы итеп ясалган, соңрак тигез төпле чүлмәкләр, банка сыман савытлар җитештерелә. Эш кораллары ясауда *Чулман буе культурасы*на хас неолитик ысуллар күзәтелә.

В.к.ның соңгы дәвере истәлекләрендә бакыр эретү-кою эзләре табыла (бакырдан эш кораллары, бизәнү әйберләре һ.б. ясала), ш.у. кеше һәм җәнлек рәвешендә чакматаштан ясалган фигураларны да очратырга мөмкин. Татарстанда В.к. истәлекләре Казанның Киров р-ны Займище авылы, Яшел Үзән р-ның Октябрьский посёлогы, Апас р-ның Кече Күккүз авылы һ.б. урыннарда очрый.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; К р а й н о в Д.А. Волосовская культура. Эпоха бронзы лесной полосы СССР. М., 1987; Т р е т ь я к о в В.П. Волосовские племена в Европейской части СССР в III–II тыс. до н. э. Л., 1990; Н и к и т и н В.В. Каменный век Марийского края. Йошкар-Ола, 1996.

*Р.С.Габәшев.*



Н.Д. Волостнов.

**ВОЛОСТНО́В** Николай Дмитриевич (1926, ТАССРның Зөя кантоны Ивановский а. — 15.4.1945, Нойкурен ш., Германия), Сов. Союзы Герое (29.6.1945, вафатыннан соң), сержант (1945). 1943 елдан Кызыл Армиядә. 1944 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 82 нче гв. укчы полкы пулемётчысы (2 нче гв. армиясенең 32 нче гв. укчы дивизиясе). 4 нче Украина, 1 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Кырым, Украина, Балтыйк буен азат итүдә, Көнчыгыш Пруссия операциясендә (1945) катнаша. Нойкурен шәһәре янында барган бәрелештә батырлык күрсәтә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Звёзды не меркнут. Калининград, 1982; Д р и г о С.В. За подвигом — подвиг. Калининград, 1984.

**ВО́ЛОСТЬ**, Россиядә 11 йөздән 20 йөзнең 30 нчы елларына кадәр гамәлдә булган адм.-терр. бүленеш берәмлеге, крәстиян җәмгате җирлегендә барлыкка килгән. Борынгы рус дәүләтендә В. сүзе кенәз биләмәләрен аңлаткан һәм «җир», «ил»,«өлкә» мәгънәсендә йөргән. 13–16 йөзләрдә В.лар бүленеше сарай, бояр, монастырьлар җирләренә хас була. Ул җирләр кенәз тарафыннан В. идарәчеләре вазифасын үтәүчеләргә идарәлеккә тапшырылган; халыктан биләмә хуҗасы (кенәз, бояр һ.б.) файдасына салым-керемнәр җыелган. 14 йөз урталарыннан В.лар воеводалар идарәлегендәге *өязләр* составына керә. 16 йөз уртасында уздырылган җир реформасы буенча, аерым хуҗа билгеләгән «волость идарәчелеге» («волостелей») тәртибе бетерелә, күпчелек өязләрдә ул земстволның сайлап куелган органнарына алыштырыла. 17 йөз — 18 йөзнең 1 нче яртысында В. «стан», «пригород» кебек вак адм. бүленеш берәмлекләре б-н янәшә яши. Император Павел I нең 1797 елның 7 август фәрманы б-н казна авылларының В.ларга бүленеш һәм идарәчелек тәртибе урнаштырыла («О разделении казённых селений на волости и о порядке их внутреннего управления»). Фәрман нигезендә төбәктә яшәүче дәүләт крәстияннәре саны 3000 чамасы булган очракта *волость идарәсе* булдырылган. Соңрак, дәүләт крәстияннәре авылларыннан тыш, патша сарае (удел) авылларында да В.лар оештырыла. Элекке Казан ханлыгы биләмәләрендә 16 йөзнең 2 нче яртысында башта сарайга караган һәм ясаклылар авылларында, 18 йөздән губернаның барлык өлешендә В.ларга бүленеш тәртибе кертелә. Дәүләт милке министры граф П.Д.Кисилёв тәкъдим иткән реформа җирлегендә урыннарда дәүләт крәстияннәре б-н идарәчелеккә, волость идарәләреннән тыш, *волость җыеннарын* җыю карала. Алар урыннардагы дәүләт милке палаталарына яки ок-

руг идарәләренә буйсынган. «1861 елның 19 февраль нигезләмәләре» таләбенчә, крепостнойлыктан азат ителгән крәстияннәр эшен карау өчен тагын бер оешма — *волость мәхкәмәсе* булдырыла. В.лар 1861 елдан — җәмәгать арадашчылары күзәтчелегендә, 1874 тән — өяз крәстиян кабулханәләре, 1889 дан земство башлыклары карамагындагы сословиеле крәстияннәр идарәсе берәмлеге була. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң волость земстволары оештырыла, В. шул төбәктә яшәүче барлык сословиеләр өчен үзидарә берәмлегенә әверелә. 1920 елда ТАССР оештырылгач, В. *кантоннарда* төп адм.-бүленеш берәмлеге була. ТАССРда районнарга бүленеш барышында В.лар бетерелә (1930).

*Әд.:* Градовский А.Д. История местного управления в России. СПб., 1868. Т. 1; Мелкая земская единица: Сб. ст. СПб., 1902. Вып. 1; Дружинин Н.М. Государственные крестьяне и реформа П.Я.Киселёва. М., 1946. Т. 1; Греков Б.Д. Крестьяне на Руси: В 2 т. М., 1952–54; Зайончковский П.А. Отмена крепостного права в России. М., 1968; Зырянов П.Н. Социальная структура местного самоуправления капиталистической России (1861–1914) // Ист. записки. М., 1982. Вып. 107.

*Е.В.Липаков.*

**ВО́ЛОСТЬ ҖЫЕНЫ́**, Россиядә крәстияннәрнең җирле җәмәгать идарәсе органы. Дәүләт милке министры граф П.Д.Киселёв тәкъдим иткән реформа барышында (1837–41) гамәлгә керә. «Крепостной бәйлелектән котылган крәстияннәр турында 1861 елның 19 февраль нигезләмәләре» нигезендә В.җ. волость старшинасы, аның ярдәмчеләре, авыл старосталары, салым җыючылар, волость идарәсе утырышчылары, волость мәхкәмәсе судьялары (үз вазифаларын үтәргә 3 елга сайланган кешеләр) һәм сайлаулы крәстиян вәкилләреннән (10 йорт-хуҗалыктан берәү) тора. Әгәр волостька 1 авыл гына керсә — авыл җәмәгате җыены җыелган. В.җ.нда волость күләмендә вазифа үтәүчеләр, ш.и. волость мәхкәмәсе әгъзалары сайланган, үтәләсе җәмәгать эшләре, җыясы салым күләме билгеләнгән, рекрутка алынучылар саны ачыкланган, волость уку йортларын, балалар ятимханәләрен, картлар, инвалидлар йортларына күзәтчелек итү мәсьәләләре хәл ителгән, сайлап куелган эш башкаручыларның эшчәнлеген тикшереп тору тәртибе билгеләнгән. В.җ. үзенә йөкләнгән йөкләмәләрдән читкә тайпылса, аның әгъзалары хөкемгә тартылган. 1905 нең 11 декабрендә кабул ителгән сайлаулар кануны һәм 1907 нең 7 июлендәге «Дәүләт думасына сайлаулар нигезләмәсе» нигезендә В.җ.нда Дәүләт думасына крәстиян депутатларын сайлаучылар билгеләнгән. 1917 елның 21 май карары б-н волость земстволары оештырылгач, В.җ. бетерелә. Ш.у.к. *Волость.*

*Әд.:* Безобразов В.П. Из деревни. Письма в редакцию журнала «Век». СПб., 1861; Михайлов С. О волостных и сельских выборах. СПб., 1883.

**ВО́ЛОСТЬ ИДАРӘСЕ́**, Россиядә җирле крәстиян җәмәгатенең башкарма идарәсе органы. Император Павел I нең 1797 елның 7 авг. фарманы нигезендә дәүләт крәстияннәре б-н идарә итү өчен кертелә. 1838 нең 30 апреленнән губерналарда дәүләт милке идарәсе оештырылгач, В.и. Дәүләт милке министрлыгы күзәтүенә күчерелә. Канун буенча волость старшиналары хакимият оешмалары күзәтчелегендә 3 елга сайланган. Волость писарен дәүләт милке палатасы билгеләгән. «Крепостной бәйлелектән котылган крәстияннәр турында 1861 елның 19 февраль нигезләмәләре» кертелгәч, В.и. алпавытлар җирләрендә дә оештырыла. В.и.нә волость старшиналары, авыл старосталары (яки В.и.билгеләгән утырышчылар) һәм салым җыючылар кергән. 1889 ның 12 июлендә земство идарәчелеге турында фәрман чыккач, В.и. аның карамагына күчә. В.и.нең бурычлары: салым җыю, элекке бурычларны түләтү, җәмәгать тәртибендә башкарыласы эшләрне бүлү һәм үтәлешен тикшерү, волость халкы җыенында расланган керем чыкләрендә акча тотуны күзәтү, казнага яки шәхси кешеләргә бурычлы крәстияннәрнең милкен сату, солдатка алынырга тиешлеләрнең һәм хезмәт тотып кайтучыларның исәбен алу, В.и.ндә эшләүчеләрне эштән чыгару яки эшкә алу. Крәстияннәр В.и.нә өстәмә салым түләгәннәр, аннары паспорт алганнар. Волость старшинасы вак гражданлык һәм адм. хокук бозуларга карата чара күрә алган. В.и. волость старшинасы карамагындагы киңәшмә органы була. Рус булмаган кешеләр күпчелекне тәшкил иткән волостьларда еш кына фактик җитәкчелекне писарь башкарган. В.и. авыл җирендә нотариаль оешма вазифасын да үтәгән — 300 сумга кадәрле булган сату-алу килешүләрен, милеккә кагылышлы һ.б. эшләрне раслаган. Волостька кергән оешмаларның архивы да В.и.ндә сакланган. 1917 нең 21 маенда волость земстволары оештырылу сәбәпле, В.и. бетерелгән. Ш.у.к. *Волость.*

*Әд.:* Бржеский Н.К. Очерки юридического быта крестьян. СПб., 1902; Дружинин Н.М. Государственные крестьяне и реформа П.Д.Киселёва. М., 1946. Т. 1; Зайончковский П.А. Отмена крепостного права в России. М., 1968; Зырянов П.Н. Социальная структура местного самоуправления капиталистической России (1861–1914) // Ист. записки. М., 1982. Вып. 107.

*Е.В.Липаков.*

**ВО́ЛОСТЬ МӘХКӘМӘСЕ́**, түбән баскычтагы сайланма крәстияннәр мәхкәмәсе органы. «Крепостной бәйлелектән котылган крәстияннәр турында 1861 елның 19 февраль нигезләмәләре» («Положения 19 февраля 1861 г. о крестьянах, вышедших из крепостной зависимости») нигезендә оеша. Казан губернасында 178 В.м. барлыкка килә. 4–12 судья (1889 елдан рәис һәм 3 судья) волость җыенында сайлана.Мөлкәт бәхәсләрен (100 сумга кадәр) һәм вак җинаять эшләрен карый. Эш ачык рәвештә алып барыла һәм карарлар шикаятькә бирелми. 1866 дан җирле җәмәгать арадашчылары җыенына апелляция б-н мөрәҗәгать итү хокукына ирешә. В.м. гадәти хокук нормаларына таянып эш итә. Түбәндәге җәзаларга тарта ала: җәмәгать эшләре б-н шөгыльләнү (6 көнгә кадәр), штрафлар (3 сумга кадәр), кулга алу (7 көнгә кадәр), тән җәзалары (тал чыбыгы б-н 20 тапкырга кадәр суктыру). 1889 ның 12 июлендә «Волость мәхкәмәсе турында вакытлы кагыйдәләр» («Временные правила о волостном суде») кабул ителү нәтиҗәсендә, В.м. земство башлыклары һәм земствоның өяз җыены контроленә тапшырыла. В.м. вәкаләтенә салым түләүче катлауга керүчеләрнең эшләрне гражданлык эшләре буенча имана мөлкәтенә кагылышлы (бәясе чикләнмәгән) бәхәсләрне һәм 300 сумга кадәрге башка эшләрне (милек мәсьәләсенә кагылмыйча) карау йөкләнә. 1912 нең 15 июнендә «Волость мәхкәмәсе турында вакытлы кагыйдәләр» («Временные правила о волостном суде») нигезендә В.м. өй хуҗалары санынан чыгып сайлана һәм аның составында рәис, 2 әгъза һәм авыл җәмәгате вәкилләреннән торган 2 махсус сайлаучылар коллегиясе кандидаты була, В.м. мировой судьялар җыенында раслана. Грамоталылык һәм яшь буенча (30 яшьтән олы) цензлар кертелә. Югары авыл мәхкәмәләре 2 нче инстанция буларак эш итә. 1917 нең 21 маенда волость земствосы барлыкка килгәннән соң бетерелә. Ш.у.к. *Волость.*

*Әд.:* Леонтьев А.Л. Волостной суд и юридические обычаи крестьян. СПб., 1895; Рудин Н.П. Новый волостной суд... 15 июня 1912 г. (Временное правило о волостном суде). СПб., 1915; Тарабанова Т.А. Состав волостных судов // Вестн. Моск. ун-та. Сер. 8. История. 1993. № 2.

*С.А.Фролов.*

**ВОЛЫ́НСКИЙ** Артемий Петрович (1689 — 27.6.1740, С.-Петербург), дәүләт эшлеклесе, дипломат, генерал-аншеф (1736). Борынгы дворяннар нәселеннән. 1704 елдан хәрби хезмәттә. 1715 ел ахыры — 1716 ел башында Казанда дипломатик хезмәткә әзерләнә. Аннары Иранга Россия илчесе итеп җибәрелә; 1717 дә Исфаганда сәүдә килешүен төзи. 1719–24 елларда Әстерхан губернаторы һәм бер үк вакытта, 1728 елга кадәр, рус-калмык мөнәсәбәтләренә бәйле эшләр идарәчесе. 1722–23 тә Пётр I нең Иранга явын оештыруда катнаша. 1725–30 да (бүленеп) Казан губернаторы. «Наказ»да каралганча (1728), губернада югары адм. вазифа б-н беррәттән мәхкәмә эшләрен һәм полиция хезмәтен дә башкара. Казанда полиция, ветеринария хезмәтен оештыра, шәһәрне төзекләндерү эшен җайга сала. Янгыннарны булдырмас өчен шактый агач корылмаларны, ш.и. шәһәр үзәген әйләндереп алган диварны сүттерә. Дәүләт ихтыяҗы өчен башкарыласы эшләрне



А.П.Волынский.

һәм бурычларны үтәү тәртибен кертә. Казан митрополиты Сильвестр һәм вице-губернатор Н.Н.Кудрявцев б-н фикер каршылыгы аркасында эшеннән азат ителә. 1731–32 дә хәрби инспектор. 1732 дән С.-Петербургта сарай ат-абзарлары хуҗалыгында, 1736 дан генерал дәрәҗәсендәге обер-егермейстер (ау хуҗалыгы генералы). 1733–35 тә Польша тәхете өчен барган сугышта катнаша. 1737 дә Немировский конгрессында Россия делегациясе вәкиле була. 1738 дән кабинет-министр вазифасын үти. «Эчке дәүләт эшләрен җайга салу генераль проект»ын эшли («Генеральный проект о поправлении внутренних государственных дел»). Дәүләттә адм. реформа үткәрү һәм сәяси, социаль-икътисади үзгәртүләр кертү кирәклеге турындагы язмалар авторы («О гражданстве» һ.б.). Э.И.Бирон, А.И.Остерман һ.б. б-н интригалар нәтиҗәсендә кулга алына, фетнә әзерләүдә һәм тәхет яуларга ниятләүдә гаепләнә, җәзалап үтерелә.

*Әд.:* Шишкин И.И. Артемий Петрович Волынский: Биогр. очерк // Отечественные записки. 1860. Т. 128–129; Корсаков Д.А. Артемий Петрович Волынский: Биогр. очерк // Древняя и новая Россия. 1876. Т. 1–2; шул ук. Из жизни русских деятелей XVIII века. К., 1891.

*Е.Б.Долгов.*

**ВОЛЫ́НСКИЙ** Михаил Петрович (? — 26.3.1683, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1683). 1642–44 елларда Терки, 1649–52 дә Томск шәһәрләре воеводасы. 1651 елда Бийск кальгасы төзелешенә җитәкчелек итә. 1662–67 дә Казанда воевода. 1663 елдан баш күтәргән башкортларга каршы яуларда һәм Кама аръягы сызыгы буендагы чикләрне саклауда катнаша. Казан төбәгендә йомышлы татарларның вотчина һәм җир биләмәләренә хокуклары турындагы мәсьәләләрне хәл итә; илчелек хезмәтләре өчен азык-төлек сатып алу б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* Корсакова В.Д. Список начальствующих лиц в городах теперешней Казанской губернии. К., 1908; Ермолаев И.П. Казанский край во второй половине XVI–XVII вв.: Хронологический перечень документов. К., 1980.

*Е.Б.Долгов.*

**ВОЛЬВО́КС** (Volvox), яшел суүсемнәр ыругы. Дөньяда 20 ләп төре очрый. ТР да 2 төре — шарсыман В. (V. globator) һәм алтынсыман В. (V. aureus). Төче сулыкларда үрчиләр. Күпләп үрчегәндә су «чәчәк ата». Шар яки эллипсоид формасында (диаметры 3 *мм* га кадәр), периферияда бер кат булып 500 дән алып 20 меңгә кадәр күзәнәк урнаша, алар, үзара протоплазма җепселләре б-н тоташып, колония хасил итәләр. Һәрбер күзәнәкнең ике камчысы була, аларның тирбәнеше В.ны хәрәкәткә китерә. Шар куышлыгы сыек лайла б-н тула. В. үрчегәндә кайбер күзәнәкләр колония тирәнлекләренә чумалар һәм анда берничә яңа колония барлыкка китереп бүленәләр. Ике төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Л.Ю.Хәлиуллина.*

**ВО́ЛЬНЫЙ СТАН** (Чатказ) авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 37 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасының уң кушылдыгы буенда. 2002 елда 498 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Мәчет. 1615 тән Чепкас авылы буларак мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт һәм удел крәстияннәре катлауларына керә, лашманлыкта хезмәт итә; игенчелек, терлек үрчетү, он тарту, олаучылык, төрле ашамлык товарлары сату б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, В.С. да мәчет була. 20 йөз башында 3 мәдрәсә, 3 мәчет, 16 сәүдә-сәнәгать бинасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2456,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Янтуган волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 974, 1897 дә — 1855, 1910 да — 1716, 1920 дә — 1783, 1926 да — 1621, 1938 дә — 1472, 1949 да — 1219, 1979 да — 988, 1989 да — 636 кеше.

**ВО́ЛЬНЫЙ ТРУД** посёлогы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 33 *км* көньяктарак, Нажар елгасыннан 2 *км* читтә. 2002 елда 29 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 елларда нигез салына. Башта Әгерҗе р-нына керә, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1926 да — 32, 1938 дә — 310, 1958 дә — 140, 1970 тә — 106, 1989 да — 48 кеше.

**ВОЛЬТЕ́Р** Борис Александрович (14.5.1887, Түбән Новгород ш. — 27.3.1968, Казан), йогышлы авырулар белгече, мед. фән. д-ры (1914), проф. (1935), РСФСРның атказ. табибе (1945). 1910 елда Хәрби-мед. академиясен тәмамлый (С.-Петербург), шунда ук эшли. 1914 тән Варшава, Мәскәү, Түбән Новгород, Сембер һәм Казандагы армия гаскәрләрендә табиб. 1920 дән Казан ун-тында, 1924 тән йогышлы авырулар каф. мөдире. 1946–50 елларда Казан ГИДУВының шул ук исемдәге каф. мөдире. В. урындагы патологияне, төрле йогышлы авырулар кизүенең кинәт башланып китүе сәбәпләрен өйрәнә, авыл шартларындагы эш урыннарында аерым йогышлы авыруларга диагноз кую һәм шул чирләрне булдырмау ысулын эшли. Кан лейкоцитларын эре тамчы буенча санау өчен гадиләштерелгән серологик реакцияләр үткәрүнең портатив җайланмасын тәкъдим итә.

Х е з м.: К вопросу об энзимах крови при туберкулёзе. К., 1914; Органные липазы Rona-Чебоксарова в клинике острых инфекций // Казан. мед. журн. 1931. Т. 27, № 1 (автордаш).

**ВОЛЬФА́РТ ЧЕБЕНЕ́** (Wohlfahrtia magnifica), саркофаидлар семьялыгыннан бөҗәк. Корсагында өч рәт кара таплы ачык соры төстәге зур чебен (озынлыгы 9–15 *мм*). Күбесенчә Россиянең далалы зонасында яши, сирәк кенә урман-дала зонасында очрый. Зур бөҗәк чатыр чәчәкләр нектары б-н туена. Тереләй тудыручы чебен, җәрәхәтле тире капламына, кеше һәм хайваннарның колак, авыз, борын һәм күзләренә 120–160 личинка сала. Личинкалары сәламәт тукымаларны ашый һәм миаз («кортлы авыру») дип аталган авыру китереп чыгара. В.ч. личинкаларының зыяны бик зур булганда, хәлсезләнгән өлкәннәр һәм балалар өчен үлем куркынычы туа. Личинкаларның тулы үсеш дәвере — 3–5 тәүлек. Җирдә курчакка әверелә. Кеше һәм хайваннарда В.ч. личинкалары тудырган миаз очраклары Татарстанда да теркәлгән: Чистай шәһәре тирәсендә (этләрдә уртлар миазы), Азнакай р-нында (бәрән тәнендә яра өслеге миазы), Әлмәт р-нында (8 яшьлек балада колак өслеге миазы). Зур В.ч. Казан шәһәре тирәсендә, Чүпрәле һәм Яшел Үзән р-ннарында күзәтелгән.

*Әд.:* Павловский Е.Н. Руководство по паразитологии человека. М.–Л., 1948. Т. 2; Степанов К.Д., Бойко В.А. Два случая паразитирования личинок Вольфартовой мухи в ТАССР // Казан. мед. журн. 1959. Вып. 3.

*В.А.Бойко.*

**ВОЛЬФСО́Н** Светослав Исаакович (16.5.1946, Мәскәү өлкәсенең Люберцы ш.), химик, техник фән. д-ры (1989), проф.(1992), ТР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (2000, 2007). Казан хим.-технол. ин-тын (1970, хәзерге Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук, синтетик каучук технологиясе кафедрасында эшли, 2005 тән эластомерлар химиясе һәм эшкәртү технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре композицион полимер материалларның молекуляр реологиясенә карый. Эшкәртү процессында молекуляр характеристикаларның бәйләнешен билгеләү һәм молекуляр параметрлар үзгәрүенең кинетик закончалыкларын исәпкә алып, полимерларны табу һәм эшкәртү процесслары б-н оптималь идарә итү ысулларын; яңа класс полимер композицион материаллар — динамик термоэластопластлар табуның фәнни принципларын эшли. Резинотехник эшләнмәләр, термопластик гидроизоляцион, түбә ябу, футеровкалау материалларын эшли һәм таба. Күп кенә фәнни эшкәртмәләре «Түбәнкаманефтьхим», «Түбәнкамашин» җитештерү берләшмәләрендә, «Кварт», «Екатеринбургрезинотехника» АҖдә гамәлгә кертелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Реологические критерии и количественные характеристики процесса механодеструкции высокомолекулярных полимеров на примере каучука СКИ-3 // Докл. АН СССР. 1982. Т. 265, № 3 (автордаш); Синтетический изопреновый каучук: молекулярная структура, переработка, свойства. М., 1984; Prediction of service properties of extruded low pressure polyethylene using rheological charcteristios // Mechanios of composite materiales. 1996. № 4. (автордаш); Динамически вулканизированные термоэластопласты: получение переработка, свойства. М., 2004; Реологические и вулканизационные свойства эластомеров. М., 2006 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ВОНЮ́ШКА** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Әнҗерә елгасының уң кушылдыгы (Нократ елгасы бассейны). Озынлыгы 12 *км*, бассейнының мәйданы 38,2 $км^2$. Можга калкулыгыннан, Алабуга р-нында ага. Елга башы Югары Шурнәк авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Яковлево авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 68 *м*. Су җыелу мәйданындагы

урман күләме 52%. В. елгасының 1,2 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнга еллык су агып төшүнең уртача күпьеллык катламы елга тамагында 148 *мм* дан үрге агымында 185 *мм* га кадәр, ташу агымы катламы 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. В. елгасы ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. В. елгасы Алабуга аучылык тыюлыгы терр-ясеннән ага.

**«ВОПРО́СЫ ТРАХО́МЫ»** («Трахома мәсьәләләре»), фәнни журнал. ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты һәм Казан трахоматоз ин-ты органы. 1933–37 елларда Казанда 3 айга бер тапкыр рус телендә нәшер ителә. Башлап җибәрүчесе һәм мөхәррире — Казан трахоматоз ин-ты директоры А.Н.*Мурзин*. «В.т.» ж-лында илнең күренекле күз авырулары табибләре һәм галимнәре В.Е.Адамюк, В.В.Чирковский, Е.Э.Трапезонцева һ.б.ның хезмәтләре басыла. Журнал Идел-Урал буе төбәкләре галимнәрен һәм табибләрен трахомага каршы көрәшкә берләштерү максатын куя; СССРның төрле регионнарында бу эшнең оештырылуы, авыруның килеп чыгу сәбәпләрен (этиологиясен) һәм трахоманы дәвалау мәсьәләләрен, авыру таралуны тамырдан бетерү өчен көнкүреш шартларын үзгәртү проблемаларын яктырта. Журналда офтальмологларның бөтенсоюз съездлары һәм киңәшмәләре материаллары, яңа китапларга һәм чит илләрдә чыккан журналларга күзәтүләр басыла. *Р.А.Айнетдинов.*

**ВОРЖЕЦО́В** Александр Григорьевич (7.5.1941, Казан), философ, филос. фән. д-ры (2000), проф. (2001). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1968), мәктәптә укыта (Түбән Кама ш.). 1971–73 елларда Казан хим.-технол. ин-тының Түбән Кама ф-лында. 1973 тән Казан технол. ун-тының идарә итү, тарих һәм социология кафедрасында. Хезмәтләре социализм теориясенә (Ф.Энгельс мирасы б-н бәйле), хәзерге заман Россиядәге җәмгыять үзгәрешләре мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Разработка Ф.Энгельсом проблем теории социализма в 80–90 годы XIX века. К., 1990; Россия перед выбором. К., 1995; Общественное согласие в России: реальность и перспективы. К., 1998; Правовое социальное государство: Запад и Россия. К., 1999.

**ВОРОБЬЁВ** Борис Андреевич (23.6.1941, Орёл ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1995), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996), СССРның шәрәфле химигы (1991). Казан хим.-технол. ин-тын (1969) тәмамлаганнан соң, Казан фотоматериаллар ин-тында эшли, 1974 тән эремә әзерләү секторы, 1981 елдан аклы-каралы кинофотоматериаллар бүлеге мөдире, 1987 дән директор урынбасары, 1991–2001 дә ген. директор. Хезмәтләре полимерлар эшкәртү, тасма ясаучы системалар, бу процессларны интенсивлаштыру һәм аппаратлар б-н җиһазлау технологияләренә, фотоэмульсион системаларда кристаллаштыруга карый. В. җитәкчелегендә целлюлоза триацетатының эреткечләр катнашмасында эрү механизмы өйрәнелә, эремәдә полимер концентрациясен бер үк вакытта реологик үзлекләрен яхшыртып арттыру юллары билгеләнә; галоидлы көмеш микрокристалларының бирелгән үзлекләренә ирешү һәм югары сизүчәнлеккә ия булган фотоматериаллар табу максатыннан фотоэмульсияләрдә кристаллаштыру процессы тикшерелә. Югары концентрацияле эремәләрдән триацетатцеллюлозалы фотонигез җитештерү буенча югары нәтиҗәле технологик линияләр; көмешкә 30% ка кадәр экономия ясарга мөмкинлек бирә торган икеагымлы эмульсификация ысулы б-н монодисперс фотоэмульсияләр җитештерү буенча исәпләү ысуллары һәм технологик линия; роторпульсация аппаратлары ярдәмендә сыеклык-сыеклык, сыеклык-каты җисем системаларында нечкә сибелү (дисперсияләү) процессын аппаратлар б-н җиһазлау булдырыла. Эшкәртмәләре «Тасма», «Свема» (Шостка ш., Украина) ҖБ, «Кубаньмаш» (Краснодар ш.) АҖдә һ.б. кертелә.


Х е з м.: Аппаратурное оформление процесса кристаллизации при синтезе монодисперсных фотографических эмульсий: Обзорная информ. М., 1984 (автордаш); Моделирование процесса двухструйной кристаллизации // Журн. науч. и прикладной фотографии и кинематографии. 1992. Т.37, № 1 (автордаш).


*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета: КХТИ — КГТУ(1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ВОРОБЬЁВ** Герман Николаевич (21.3.1908, Кострома ш. — 28.6.1991, Казан), авиаконструктор, техник фән. канд. (1951), проф. (1965), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1978). 1933 елда Новочеркасск авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында эшли: ОКБның (1938–41) һәм спорт авиациясе ОКБның (1961–67) баш конструкторы, самолёт төзү һәм проектлаштыру каф. мөдире (1944–47, 1951–78). Бер үк вакытта 1941–44 тә 22 нче авиация з-ды КБнда конструкторлык бригадасы җитәкчесе. В. җитәкчелегендә КАИ-1 пассажир самолётлары (1935) һәм өйрәнү-күнегүләр ясау өчен СССРда киң таралган КАИ-12 планёрлары (1957) төзелә (900 чамасы). Югары уку йорты студентларының СССРда беренче КБ кысаларында кадрлар әзерләү Казанда спорт авиациясе ОКБ оештырырга мөмкинлек бирә (1961). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский авиационный институт. Сб. ст. / Под ред. В.И.Локая. К., 1982; Казанский авиационный институт / Под ред. Г.Л.Дегтярёва. М., 1992.

**ВОРОБЬЁВ** Николай Иосифович (15.11.1894, Саратов губ. Хвалынск ш. — 29.9.1967, Казан), этнограф, географ, тарихчы, тарих фән. д-ры (1946), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945), проф. (1935). Бөтенсоюз география җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1964). Казан ун-тының география ф-тын


Н.И. Воробьёв.


П.Е. Воробьёв.

тәмамлый (1918). Б.Ф.Адлер шәкерте. 1918 елдан Казан ун-тында ассистент. 1918, 1920 елларда этнографик командировкаларда Көнчыгыш Себердә: Түбән Енисей р-нында яшәүче җирле халыкларның мәдәниятен, шөгыльләрен һәм тормыш-көнкүрешен өйрәнә. 1922 дән ТАССР дәүләт музееның этнография һәм табигать-тарих бүлекләре мөдире, 1923 тән — музейның директоры. 1923 тән Көнчыгыш пед. ин-тының география каф.сы доценты, шул ук елдан каф. мөдире һәм геогр. бүлеге җитәкчесе. 1934–44 елларда Казан пед. ин-тының география ф-ты деканы, бер үк вакытта Казан ун-ты профессоры. 1944 тән СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында директор урынбасары, археол. һәм этнография секторы мөдире. Хезмәтләре татар һәм чуашларның мәдәниятенә, тормыш-көнкүрешенә, Идел буе географиясенә карый. Музей оештыру, фәнни белгечләр әзерләү (шәкертләре: Е.П.Бусыгин, Н.В.Зорин, Р.Г.Мөхәммәдова), фәнни белемнәрне пропагандалау эшенә зур өлеш кертә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Материальная культура Казанских татар. К., 1930; Основы физической географии Татарской АССР. К., 1933; Физико-географические экскурсии в окрестностях Казани. К., 1940 (автордаш); Казанские татары. К., 1953; Чуваши. Чебоксары, 1956. Ч. 1; 1970. Ч. 2 (автордаш); Поволжские татары // Народы мира. М., 1964; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967 (автордаш).

*Әд.:* Б у с ы г и н Е.П., З о р и н Н.В. Николай Иосифович Воробьёв. 1894–1964. К., 2002.

**ВОРОБЬЁВ** Пётр Егорович (8.7.1908, Казан губ., хәзерге Кукмара р-ны Танькино а. — 25.9.1984, шунда ук), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), сержант (1941). 1930–41 елларда Кукмара р-ның «Кызыл крестьян» к-зы рәисе. 1941 нең июленнән Кызыл Армиядә. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 718 нче укчы полкта отделение командиры (50 нче армиянең 139 нчы укчы дивизиясе). Брянск, Көнбатыш, Үзәк, Белоруссия, 2 нче һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәүне саклауда (1941–42), Ржев-Вязьма (1943), Орел, Смоленск, Брянск (1943), Белоруссия (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия операцияләрендә (1945) катнаша. 1944 нең 24 июлендә Чаусы шәһәре янында Проня, Баля елгаларын кичкәндә (Могилёв өлкәсе), ш. у. Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң туган авылында колхоз рәисе булып эшли. Ленин, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — Наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Навечно в сердце народном. Минск, 1984.

**ВОРОБЬЁВКА** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 8 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 3,5 *км* читтә. 2002 елда 24 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1646 дан Воробьёв Пүчинкәсе буларак мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — икътисади, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 931 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Югары Ослан волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 61 ир заты; 1859 да — 300, 1897 дә — 398, 1908 дә — 477, 1926 да — 554, 1938 дә — 628, 1949 да — 438, 1958 дә — 337, 1970 тә — 175, 1989 да — 51 кеше.

**ВОРО́ВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ́ СОВХО́З** посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2002 елда 651 кеше (татарлар — 68%, руслар — 30%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Преображенье чиркәве — 19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге. 1919 да Минзәлә Покрау хатын-кызлар монастыреның шәһәр читендәге дачасы урынында «Никольский» (1924 тән — В.В.Воровский исем.) с-зы үзәге буларак нигез салына. 1930 га кадәр — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 дан — Минзәлә р-нында. Халык саны: 1957 дә — 837, 1959 да — 1036, 1979 да — 1052, 1989 да — 802 кеше.

**ВОРОЖЕ́ЙКИН** Алексей Павлович (16.5.1938, Куйбышев өлкәсенең Пестравский р-ны Красный Яр пос.), химик-технолог, техник фән. канд. (1994), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989), ТАССРның атказ. химигы (1983). 1968 елда Куйбышев политехника ин-тын тәмамлый. 1961–66 да Куйбышев спирт синтезы з-дының полиэтилен бүлеп чыгару цехы аппаратчысы. 1966–68 дә Яңа Куйбышев нефть химиясе комб-тының (Куйбышев өлкәсе) бүлек җитәкчесе. 1968–97 дә «Түбәнкаманефтьхим» АҖдә: цех җитәкчесе, баш инженер урынбасары, 2 нче санлы ясалма изопрен каучук җитештерү з-ды директоры; 1977 дән 1 нче санлы изопрен мономер җитештерү з-ды директоры; АҖнең баш технологы, 1993 тән баш инженеры, вице-президенты, баш инженер урынбасары. В. җитәкчелегендә изопрен-мономер җитештерү з-ды төзелә, гади полиэфир һәм стирольдан өстәмә пропилен окисе алу производстволарында проектта каралган куәткә җибәрү-көйләү эшләре башкарыла. Уйлап табуга 75 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге ясалма каучук мономерлары җитештерүне арттыруның яңа ысулларын эшләгән һәм гамәлгә керткән өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Изучение распределения катализатора ИМ-2201 в реакторах дегидрирования // Пром-сть синтетического каучука, шин и резино-технических изделий. 1986. № 12 (автордаш); Условия работы электрофильтров ОГП-4–16 на блоках дегидрирования углеводородов // Пром-сть синтетического каучука, шин и резино-технических изделий. 1987. № 4 (автордаш); Природоохранные мероприятия в ПО «Нижнекамскнефтехим» // Нефтепереработка и нефтехимия. 1990. № 11 (автордаш).

**ВОРО́НИН** Корнелий Валентинович (2.8.1937, Горький ш.), акушер-гинеколог, мед. фән д-ры (1976). 1960 елда Горький мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Горький өлкәсе Воскресенский р-ны хастаханәсендә эшли. 1962 дән Казан мед. ин-тында, 1965 тән гыйльми сәркәтип, 1968 дән 1 нче акушерлык һәм гинекология каф. доценты. 1978 дән Осетия мед. ин-ты профессоры. Бала тудыру бүлекләрендә диагноз кую ысулларын реоэнцефалография, ана һәм яралгының фоноэлектрокардиографиясе, тудыру вакытында балага электрокардиография, аналык реоплетизмографиясе, күзгә кан төшү авыруына бинокуляр микроскопия, канның кислоталы балансын тикшерү, амнеоскопия һәм биохимик тестларны гамәлгә кертә. Бу ысулларны куллану бала тудыру вакытын 2 — 2,5 тапкыр кыскарта, балалар үлеме очракларын киметә.

Х е з м.: Вызывание родов внутривенным введением окситоцина // Казан. мед. журн. 1966. № 1; Микроциркуляция и метаболические нарушения при осложнении беременности резус-изоиммунизацией и поздним токсикозом // Казан. мед. журн. 1976. № 4 (автордаш); Радиоизотопная ренография в акушерско-гинекологической клинике // Казан. мед. журн. 1978. № 4 (автордаш).

**ВОРО́НИН** Юрий Михайлович (26.2.1939, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1989). 1962 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1962–68 дә Казан пр-тиеләрендә инженер булып эшли, 1968–88 дә КПССның Ленин р-ны һәм Татарстан өлкә ком-тларында, «Радиоприбор» җитештерү берләшмәсендә партия эшендә. 1988–90 да ТАССР МС рәисе урынбасары — План дәүләт ком-ты рәисе. 1990–93 тә Бюджет, план, салым һәм бәяләр буенча Республика Советы комиссиясе рәисе, РСФСР ЮС рәисе урынбасары. Фәнни хезмәтләрендә фәнни-техник прогрессның төбәк факторларын ачыклый, региональ максатчан фәнни-техник программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыруның фәнни нигезләрен тәгъбирли. 1980–90 да ТАССР ЮС, 1990–93 тә РСФСР ЮС депутаты. 1995–99 да РФ Дәүләт Думасы депутаты. Халыклар Дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Курсом научно-технического прогресса. К., 1980; Единый народнохозяйственный комплекс. К., 1983; Новые методы хозяйствования в промышленности. К., 1986; Налоги, пошлины, сборы России. М., 1992.

**ВОРО́НИНО** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 31 *км* көнчыгыштарак, Казан–Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2002 елда 115 кеше (татарлар — 38%, руслар — 34%, чуашлар — 28%) яши. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Ильинка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 69, 1926 да — 76, 1938 дә — 104, 1949 да — 150, 1970 тә — 137, 1979 да — 116, 1989 да — 91 кеше.

**ВО́РОНОВ** Виктор Иванович (16.12.1944, Мәскәү), лазер техникасы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1998), проф. (2000). 1968 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый, 1975 тән шунда ук радиоэлектрон һәм квант җайланмалары кафедрасында эшли. Хезмәтләре лазер спектроскопиясенә, оптикасын һәм лазер системаларын компьютерда модельләштерүгә карый. Лазер гирометрларында каршы таралучы яктылык һәм миллиметрлы дулкыннарның тәэсир итешүен фәнни тикшерә. Ешлыгы модуляцияләнгән дулкыннарның өстенлеген бетерү эффектын теоретик билгели һәм тәҗрибәдә раслый. Катлаулы лазер резонаторларының һәм нурланыш бирү системаларының формалашу структурасын анализлау мөмкинлеге бирә торган ысуллар һәм санча модельләр эшли. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: $CO_2$ — лазер с активным объёмом кольцевого сечения // Приборы и техника эксперимента. 1983, № 3; Пространственные характеристики многоходовых мод в лазерах с активным объёмом кольцевого сечения // Журн. техн. физики. 1995. Т. 65, вып. 7; Численный анализ лучевых трасс разъюстированных резонаторов. Оптика и спектроскопия. 1996. Т. 81, вып. 2; Способ стабилизации частоты излучения лазера. Пат. № 2086060 (РФ). 1997.

**ВО́РОНОВ** Владимир Александрович (29.8.1927, Омск өлкәсенең Ишим ш. — 13.10.1998, Казан), җырчы (лирик-драматик тенор), педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978, 1986). Казан финанс-икътисад ин-тын (1951), Казан консерваториясен (А.Шиканян классы) тәмамлый (1957). 1957 елдан Казан консерваториясендә укыта: 1967–80 дә башкаручылар ф-ты деканы, 1981–90 да укыту эшләре буенча проректор, бер үк вакытта 1982 дән ялгыз җырлау (вокал), 1990 нан ялгыз һәм опера-да җырларга әзерләү каф. мөдире, проф. (1987). 1960–80 дә концертлар б-н Татарстан һәм Россия шәһәрләрендә чыгышлар ясый. В. репертуарының төп өлешен Көнбатыш-Европа, рус классиклары һәм татар композиторлары әсәрләре тәшкил итә. В. шәкертләре арасында Х.Бигичев, В.Васильев, Р.Гобәйдуллин, Э.Җәләлетдинов, М.Имашев, Чуаш Респ-касы халык артисты В.Гордеев, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре С.Кондратьев бар. Вокаль әзерлек проблемаларына караган хезмәтләр (ш.и. татар җырчылары б-н эшләү методикасы) авторы.

Х е з м.: Мәңгелек яшьлек: (З.Байрашеваның иҗат портреты) // Казан утлары. 1967. № 6. Из опыта работы с татарскими певцами. Некоторые методические принципы ведущих педагогов — во-

калистов Татарии // Уч. зап. Казан. консерватории. К., 1970; Особенности обучения татарских певцов в консерватории // Музыкальная культура народов Поволжья. М., 1978; Народные артисты. К. 1980.

*Т.А.Алмазова.*

**ВОРОНО́ВИЧ** Али (1902, Литва, Лаховичи а. — 1940 яки 1941), тарихчы, дин эшлеклесе, Шәрекъ белгечлеге магистры (1932). Польша-Литва татарларыннан. Львов һәм 1933–36 елларда Мисырда әл-Әзһар ун-тларында укый. 1937–39 да Варшава шәһәрендә мөселман гминасы имамы һәм бер үк вакытта 13 нче Вильно улан полкының 1 нче татар эскадроны капелланы. 1938 елдан Югары мөселман коллегиясе әгъзасы. Речь Посполита (Польша) татарлары тарихына һәм ислам диненә караган хезмәтләр авторы. Икенче бөтендөнья сугышында һәлак була.

*Я.Я.Гришин.*

**ВО́РОНОВКА** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 18 *км* көньяктарак, Казан–Боровое Матюшино автомобиль юлы буенда. 2002 елда 76 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1920 елларда нигез салына. Башта Воронцовка дип атала. ТАССРның Арча кантоны Столбище волостена керә. 1927 нең 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1926 да — 7, 1958 дә — 102, 1970 тә — 177, 1979 да — 157, 1989 да — 84 кеше.

**ВОРОНЦО́В** Даниил Семёнович (12.12.1886, Могилёв губ., Быхов өязе Рогожный утары — 12.7.1965, Киев), физиолог, мед. фән. д-ры (1934), УССР ФА академигы (1957). Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1912), шунда ук эшли. 1913 елдан Петербург хатын-кызлар югары (Бестужевлар) курсларында. 1916–19 да Новороссийск ун-тында (Одесса ш.), Чериков а.х. техникумын (Могилёв губ.) оештыручы һәм 1919 дан мөдире. Смоленск (1922–30), Казан (1930–35) ун-тларында физиология каф. мөдире. 1935–41 дә Киев мед. ин-тында, 1945 тән Украина ССР ФАнең физиология ин-тында. Хезмәтләре нерв тукымаларын ярсыту һәм тоткарлауның электрофизиологик процессларына карый. Нерв җепселләрендә тәэсир итү потенциалы б-н туа торган биоэлектрик потенциалларның тирбәнү күренешен ача (1932). Бервалентлы нерв тукымасының катионнар тәэсирендә югалган ярсынучанлыгын даими ток аноды тәэсирендә бик тиз торгызу мөмкинлеген; икевалентлы катионнар китереп чыгарган үзгәрешләрнең даими ток катоды тәэсирендә торгызылуын билгели. Пессималь тоткарлануның нерв очлары өлкәсендә эзлекле импульсларның үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә килеп чыгуын исбатлый.

Х е з м.: Об электрической реакции нервного процесса // Уч. зап. Казан. ун-та. 1932. Кн. 2–3, вып. 1–2 (автордаш); К анализу электрической реакции нерва // Сб. работ Казан мед. ин-та. 1933. № 3–4 (автордаш); Физиология животных и человека. К., 1952 (автордаш); Выдающийся русский физиолог Н.Е.Введенский. Киев, 1953; Общая электрофизиология. М., 1961; Электричество в живом организме. М., 1961; Физический электротон нервов и мышц. Киев, 1966 (автордаш).

*Әд.:* С е р к о в Ф.Н. Даниил Семёнович Воронцов. Киев, 1986.

**ВОРО́НЧИХИН** Владимир Ярополович (20.10.1948, Казан), радиофизик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), «Элекон заводы» АҖдә эшли: инженер, сектор, лаб. башлыгы. Уйлап табу буенча 5 патенты бар. Дәүләт бүләге «Камил һәм күп функцияле яңа мед. лазер техникасын эшләү, җитештерүне оештыру һәм Татарстан Республикасы мед. оешмаларында кулланышка кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ВОРОТЫ́НСКИЙ** Иван Михайлович (? — 1627, Мәскәү), кенәз, дәүләт һәм хәрби эшлеклe, бояр (1605). Күренекле гаскәр башлыгы М.И.Воротынскийның улы. 1582–83 елларда В. Казан төбәгендә татарлар һәм чирмешләр баш күтәрүен бастыруда катнашкан воеводаларның берсе. 1583 тә Түбән Новгород шәһәре воеводасы. 1586–87 дә патша сараенда Борис Годуновка каршы көрәшүчеләр яклы була. 1593–97 дә Казанның беренче воеводасы. «Болгавыр заман» вакыйгаларында: Ялган Дмитрий I не Мәскәүдән куып җибәрүдә, И.Болотников фетнәсен бастыруда (1606–07), Василий Шуйскийны тәхеттән төшерүдә (1610) катнаша. «Җиде бояр» хөкүмәте әгъзасы. Полякларга каршы фетнәдә катнашуда гаепләнә, 1610 да кулга алына, 1612 дә азат ителә. 1613 тә Земство соборы эшендә катнаша. Кайбер мәгълүматларга караганда, В. Россия тәхетен биләргә тиешле кандидатлар исемлегендә була.

*Әд.:* Н а з а р о в В.Д. Тайна челобитной Ивана Воротынского // Вопр. истории. 1969. № 1; З и м и н А.А. Формирование боярской аристократии в России во 2-й половине XV – 1-й трети XVI вв. М., 1988.

*Е.В.Липаков.*

**ВОРОШИ́ЛОВ** Константин Васильевич (1.2.1842, Түбән Новгород губ. Рождествено а. — 3.12.1899, Казан), физиолог, медицина д-ры (1871). И.М.Сеченов шәкерте. Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлаганнан соң (1868), шунда ук клиник госпитальнең ординаторы. 1876 елдан Казан ун-тында профессор, физиология каф. мөдире, 1889 дан ректор. Арка миенең муен өлешендәге тою һәм хәрәкәт нервлары эшчәнлеген өйрәнә. В. билгеләгәнчә, авыртуны тою нервлары арка миенең ян-яктагы баганаларыннан үтә. Төрле әгъзаларда гликоген булуын, йөрәк-мускул җепселләренең беркетелү урынын һәм алымнарын өйрәнә. Казан невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыятен оештыручыларның берсе. 3 нче дәрәҗә Изге кенәз Владимир һәм Черногориянең 1 нче дәрәҗә кенәз Даниил орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследования о питательных свойствах мяса и гороха. СПб., 1871; Der Verlauf den motorishen und sensibleh Bahnen durch das Kaninchen. [S.I.], 1874.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Деятели Императорского Казанского университета 1805–1900 г. К., 1900; Л е б е д е в К.В., В о л к о в а И.Н., З е ф и р о в Л.Н. Из истории Казанской физиологической школы. К., 1978; Г а м б а р о г л у К., Л я т и ф о в Д.Х. Константин Васильевич Ворошилов — видный русский физиолог XIX века (к 125-летию со дня рождения) // Физиологический журн. СССР. 1967. Т. 53, № 12.



Д.С. Воронцов.



К.В. Ворошилов.

**ВОРОШИЛОВ РАЙОНЫ**, к. *Яңа Юл районы.*

**«ВОРОШИ́ЛОВСКИЙ»** совхозы, Тукай р-нында. 1970 елда «Путь Ильича» к-зы җирлегендә оештырыла (К.Е.Ворошилов исемендә). Үзәк утары — Бәтке авылы, 1138 йорт исәпләнә, совхозда 740 кеше эшли (1995). А.х. җирләренең мәйданы 5866 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 4772 *га*, ш.и. а.х. җитештерүендә 548,95 *га* печәнлек, 996 *га* көтүлекләр файдаланудa. Сугарулы җирләр — 2309 *га*. «Татплодоовощпром» концерны составындагы эре яшелчәчелек хуҗалыгы. Төп җитештерү тармагы — ачык грунтта яшелчә үстерү. Өстәмә тармаклар — бөртекле ашлык һәм сөт җитештерү. 1995 елда яшелчә культуралары 640 *га* мәйданда үстерелә. Яшелчәнең уртача уңышы 1 гектардан 297 *ц* тәшкил итә, уртача еллык тулай җыемы — 190 мең *ц* дан артык. Мөгезле эре терлек 1982 баш, ш.и. 450 баш сыер. 1 савым сыердан 3870 *кг* сөт алына, а.х. җирләренең 100 *га* исәбенә 207 *ц* сөт җитештерелә. А.х. продукциясен җитештерүдәге уңышлары өчен берничә тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКнең (1980, 1987), РСФСР МСның (1976) күчмә Кызыл Байраклары, Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. Коллективның 9 кешесенә ТРның мактаулы исеме бирелгән. 1996 да «В.» с-зы җирлегендә дәүләт унитар пр-тиесе оештырыла, 2000 нән ААҖ.

**ВОСКОБО́ЙНИКОВ К.П. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́** (типохромолитография), Казанда 1870 ел башында вакытлыча ялдагы унтер-офицер К.П.Воскобойников (1880 елларда — Казан сәүдәгәре) тарафыннан хатынының милке буларак ачыла. 1877 елда *Тилли К.А. басмаханәсе* ябылганнан соң, монда аның «Листок объявлений» г-тасы басыла. 1872 дән Воскобойников матбагасы һәм ташбасмаханәсе буларак билгеле. 1886 дан — типохромолитография. Матбагада төрле елларда 9 дан 14 кә кадәр кеше эшли, еллык җитештерү куәте 2 меңнән 3,5 мең сумга кадәр җитә. 20 йөз башында матбага аның улы В.К.Воскобойниковка күчә, 1883 тә ул Чистай шәһәрендә басмаханә ача.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

*Р.Р.Исмәгыйлев.*

**ВОСКРЕСЕ́НИЕ МОНАСТЫРЕ́** («Яңа Иерусалим»), Казандагы 17–20 йөзләргә караган рус дини архит-расы истәлеге. Урта Кабан күленең көнчыгыш ярына урнашкан. Фаразланганча, 1665 елда митрополитлар утары урынында митрополит Лаврентий II тарафыннан нигез салына. Патриарх Никон фәрманы б-н Мәскәү янындагы Яңа Иерусалим монастыре үрнәгендә агачтан ирләр монастыре төзелә башлый. В.м.ның икенче атамасы шуңа бәйле. 17–18 йөзләр чигендә монастырьда таш корылмалар — чаң манарасы б-н Воскресение соборы барлыкка килә, Тихон Амафунтский чиркәве, монастырь хөҗрәләре һәм хуҗалык максатындагы биналар төзелә, биләмәсе сыргавыллар куелган кирпеч коймa б-н уратып алына. Шул вакыттан В.м. Казан митрополитларының яшәү урынына әверелә. Монастырьның ындыр табагы, әвеннәр, ашлык суктыру сарайлары, амбарлар, май язу урыны, мал-туар абзарлары һ.б. хуҗалык корылмалары, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчалары, теплицалардан торган зур хуҗалыгы була. 1764 тә В.м. штаттан тыш булып кала. 1781 дә Екатерина II фәрманы б-н монастырьда митрополит Вениамин (Пуцек-Григорович) өчен дача йорты төзелә (к. *Архиерей дачасы*), монастырьның тагын бер исеме шуның б-н бәйле. Шул ук вакытта өстенә чиркәү урнашкан үзәк капкага каршы якта хуҗалык утары барлыкка килә һәм ул барокко стилендәге капкалары булган кирпеч койма б-н уратып алына. 19 йөзнең 1 нче яртысында монастырь биләмәсенең үзәк өлешендә агач кәшәнә салына. Воскресение соборының көньягында зират була. 1919 да В.м. ябыла, 1929 да аның биналары Казан Авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясе (хәзер «Татарстан кыры» фәнни-җитештерү берләшмәсе) карамагына тапшырыла. Безнең көннәргә В.м. комплексы кайбер югалтулар б-н килеп җитә: Совет хакимияте елларында Воскресение соборы үзгәртеп корыла, аның чаң манарасы сүтелә, коймасы җимерелә, зират юкка чыгарыла, терр-ясендә яңа административ биналар төзелә.



Воскресение монастыре. Казан. Воскресение соборы. 1698. А.И.Бренинг фотосы. 1935.

Монастырьның сыргавыллары һәм капкалы манарасы булган коймасы — 17 йөз ахыры — 18 йөз кальга архит-расы истәлеге. Ярымтүгәрәк а́ркалы, турыпочмаклы тәбәнәк манара рәвешендәге үзәк капка монастырьның көньяк диварында урнашкан. 1706 да, Митрополит Тихон заманында, манараның 2 нче катында Тихон Амафунтский чиркәве — чатыр рәвешендәге түбәле һәм барабан өстенә утыртылган гөмбәз б-н төгәлләнгән гыйбадәтханә төзелә. Аның бизәлеше рус бароккосы стиленә хас формаларда башкарылган: ярымколонналар һәм ярымбаганалар б-н ныгытылган фасадлары баскычсыман кәрнизләр б-н төгәлләнә, барокко стилендәге ярымколонналы тәрәзә йөзлекләренең өске ягы «әтәч кикриге» рәвешендә эшләнгән.

Воскресение соборы һәм аның ашханәсе — рус бароккосы истәлеге. Аны 1698 дә митрополит Маркел төзетә. Ашханә һәм биш катлы чаң манарасы б-н тоташкан гыйбадәтханә башта аслы-өсле тәрәзәле, өч а́ркалы, бер гөмбәзле, баганасыз корылма була. Монастырьның үзәк өлешендә урнашкан. Фасадлары тәрәзә араларында — икешәр, ә почмакларында өчәр колонна б-н ныгытылган. Гыйбадәтханә һәм ашханә тәрәзәләре «әтәч кикриге» рәвешендә төгәлләнгән ярымколонналы йөзлекләр б-н каймаланган, эргә кат тәрәзәләренең өске ягы кашагаланган. 1949 да торак йорт итеп үзгәртеп корыла, ашханә өлеше гыйбадәтханә биеклегенә кадәр өстәп салына, түбәсе үзгәртелә, чаң манарасы сүтелә. Фасадының 17 йөз ахырына караган бизәлеше юкка чыга, аның аерым өлешләре — бизәк пояслары, эргә кат пилястралары һәм а́ркалар арасындагы колонналар гына сакланып кала.

Ашханә урнашкан 1 катлы бина 17–18 йөзләр чигендә төзелә, аның төньяк дивары монастырь коймасының бер өлеше булып тора. Фасадлары бизәлмәгән, фәкать ярым баганалар б-н аерымланган.

17–18 йөзләр чигендә рус бароккосы стилендә төзелгән хөҗрәләр бинасы Г рәвешендәге нигездә утыра, ике катлы канаты кыска, бер катлысы — озынрак һәм алар көймәсыман түбә б-н ябылган. Тәрәзә йөзлекләре, Тихон Амафунтский чиркәвенеке кебек үк, барокко стилендә башкарылган. 1949 дан торак йорт итеп файдаланыла, эчке бүленеше, түбәсе үзгәртелә, бизәлешенең кайбер элементлары юкка чыгарыла.

Архиерей дачасы парк эчендә урнашкан, шәһәр яны сарайлары үрнәгендә төзелгән. В.м. паркы — бакча-парк сәнгате һәм ландшафт архит-расы истәлеге, ул 1780 елларда утыртыла. Юкә һәм өрәңге аллеялары, үзәк өлештән нурлар рәвешендә таралып, парк артындагы агачлыкка тоташа. Үзәк аллея архиерей йортының фасады уртасындагы үзәк ризалитка юнәлдерелгән. Монастырьның үзәк мәйданын парктан тимер койма аерып тора.

Кәшәнә — рус классицизмы стилендәге гыйбадәтханә. Ул 19 йөзнең 1 нче яртысында В.м.нең үзәк өлешендә, Воскресение соборының көньяк тарафында төзелә. Элек кәшәнә тирәли монастырь зираты урнашкан була.

В.м.нең хуҗалык утары соңгы дәвер барокко стилендәге капкалары булган кирпеч койма б-н уратылган, турыпочмаклы мәйдан били. 18 йөз ахырында төзелә. Капка элеккеге ат абзарының 1 катлы бинасы б-н тоташа, аның үзәк фасадындагы бизәлеш элементлары үзгәрешсез сакланган.

*Әд.:* Покровский И.М. Казанский архиерийский дом. К., 1906; Справочная книга Казанской епархии. К., 1909; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Республика Татарстан: Православные памятники. К., 1998.

*С.Г.Персова.*

**ВОСКРЕСЕ́НСКИЙ** посёлогы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 15 *км* көнбатыштарак, Бәрле елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 43 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Башта Кайбыч р-ны составына керә. 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1938 дә — 54, 1970 тә — 93, 1979 да — 59, 1989 да — 42 кеше.

**ВОСКРЕСЕ́НСКИЙ** Алексей Андреевич (1856, Кострома губ. Буткево а. — 23.2.1921, Запорожье өлкәсенең Преслав а., шул ук өлкәнең Ногайск пос. җирләнгән), лексикограф, дин белгече. Казан руханилар академиясен тәмамлый (1883). 1883–94 елларда Казан керәшен татар мәктәбендә дин укытучысы. 1895 тән Әстерхан губернасының Букәй урдасы казакъ мәктәпләре инспекторы. 1906–13 тә — Казан, 1914 тән Преслав укытучылар семинарияләре директоры. Г.С.Саблуков хезмәтләрен нәшер итүдә актив катнаша. Аның катнашы һәм төзәтмәләре б-н Казанда Н.П.Остроумовның татарча-русча сүзлегенең 2 нче басмасы дөнья күрә.

Хезм.: Русско-татарский словарь с предисловиями о произношении и этимологических изменениях татарских слов А.Воскресенского. К., 1894; 1613–1913. Трёхсотлетие царствования августейшего дома Романовых. К., 1913.

*Әд.:* Баскаков Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1960; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1974.

*В.Х.Хаков.*

**ВОСКРЕСЕ́НСКИЙ** Василий Николаевич, к. *Гавриил*.

**ВОСКРЕСЕ́НСКИЙ** Владимир Александрович (21.5.1914, Түбән Тагил ш. — 13.2.1986, Казан), химик, химия фән. д-ры (1967), проф. (1968), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе(1969, 1974). Мәскәү хим.-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1939), Мәскәү өлкәсенең химия з-дларында эшли. 1947–54 елларда Казанның химия һәм авиация сәнәгате пр-тиеләрендә. 1954–86 да Казан төзүче-инженерлар ин-тында: гомуми химия каф. мөдире, бер үк вакытта 1957 дән проректор, 1964–68 дә ректор. Хезмәтләре полимерларны физик-химик модификацияләүгә карый. Төзелештә куллану максатыннан полимерларны пластификацияләүне тикшерә. Күпсанлы полимерларның төрле төр модификацияләр вакытында структурасы һәм

үзлекләре үзгәрү закончалыкларын ача. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Закономерности старения некоторых образцов пластифицированного поливинилхлорида // Журн. прикладной химии. 1958. т. 31, № 1; Современные представления о пластификации полимеров // Успехи химии. 1964. Т. 33, вып. 3 (автордаш); О свойствах некоторых совмещённых полимерных систем // Журн. прикладной химии. 1965. Т. 38, № 7.

*Әд.:* Воскресенский В.А. (К 85-летию со дня рождения) // Полимеры в строительстве: Сб. науч. трудов первых воскресенских чтений. К., 1999.

**ВОСКРЕСЕ́НСКИЙ РАЙОНЫ́**, к. *Казан авыл районы.*

**«ВОСТОККИНО»** («Шәрекъ киносы»), акционерлык җәмгыяте. 1928–32 елларда, Үзәк милли кинематографчылар оешмасы (трест) буларак, Идел буе һәм Урал автономияле респ-калары һәм өлкәләре өчен кинофильмнар төшерү һәм күрсәтү б-н шөгыльләнә. ТАССР да акционерлар исәбенә керә. Җәмгыятьнең максаты: Шәрекъ халыклары тормышын өйрәнү һәм кино сәнгатендә чагылдыру, алар арасында совет идеологиясен пропагандалау, аларның гомуми культура дәрәҗәсен күтәрү, милли кинематография кадрлары әзерләү. Татарстан ХКС заказы б-н «В.» 1929 да Татарстан турында беренче тулы метражлы документаль фильм төшерә: «Татарстан (Дүрт елга иле)» — «Татарстан (Страна четырех рек)», реж. А.И.Дубровский, реж. ассистенты К.Х.Поздняков, композиторы С.Сәйдәшев, операторлары Н.Анощенко, К.Венц, В.Франциссон. Фильмны «Электро», «Чаткы» кинотеатрларында, Кызыл Армия йортында, Вахитов исем. з-дта күрсәтәләр. 1930 да «Койрыклы йолдыз» («Комета») дигән нәфис фильм төшерелә. Ә.-Т.Рахманкуловның «Упкын» исемле пьесасы буенча В.К.Туркин сценарие, реж. В.Инкижинов, үзәк рольләрнең берсендә М.М.Яншин уйный. Ике фильм да республика җәмәгатьчелеге тәнкыйтенә дучар була. ТАССР ХКСның 1930 ел 5 март карары нигезендә кино һәм театрларның шәһәр берләшмәсе «В.»ның Татарстан бүлеге дип үзгәртелә, аңа операторлар К.Ф.Мотков, К.Х.Поздняков һәм башкалардан торган кино төркеме керә, сценаристлар курслары оештырыла. Курсларда Г.Минский, Р.Ишморат, Һ.Такташ, И.Кудашев-Ашказарский, М.Әмирләр укый. 1930 елның июлендә Бөтенсоюз экраннарына «Татарстанның 10 еллыгы» («10-летие Татарстана») дигән хроникаль-документаль фильм чыгарыла, 1930–31 дә социалистик ярыш җәелдерү турында «Өндәү» («Вызов»), Советларның Бөтентатарстан съездына багышланган «Тугызынчы» («Девятый»), «Казан укчылар дивизиясе» («1-я Казанская»), «В.И.Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты-на 125 ел» («125 лет Казанского государственного университета имени В.И.Ленина»), «Икмәк өчен көрәш» («Борьба за хлеб»), Удмуртия турында документаль очерклар («Дассар») һәм Мари автономияле өлкәсе турында «Яңа тормыш» («Новая жизнь»), «МАО» дигән документаль фильмнар иҗат ителә. 1932 елның 1 апреленнән «В.» ның Татарстан бүлеге барлык прокат пунктлары б-н «Роскино» карамагына тапшырыла, житештерү остаханәсе базасында «Союзкинохроника»ның Татарстан бүлеге оештырыла (к. *Казан кинохроника студиясе*).

*Әд.:* А л е к с е е в И. Рубежи кинодокументалистов Татарии. К., 1974.

*Ю.А.Благов.*

**ВОСТО́ЧНАЯ ЗВЕЗДА́** (Шәрекъ Йолдызы) посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* читтә. 2002 елда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким. 1920 дә нигез салына. Башта ТАССР ның Зөя кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 53, 1938 дә — 70, 1958 дә — 34, 1970 тә — 40, 1979 да — 26, 1989 да — 15 кеше.

**ВОСТО́ЧНЫЙ** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 12 *км* көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2002 елда 770 кеше (татарлар — 60%) яши. Халкының төп шөгыле — җәнлек үрчетү, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1970 елларда нигез салына. Халык саны: 1979 да — 428, 1989 да — 812 кеше.

**«ВОСТО́ЧНЫЙ КУРЬЕ́Р»** («Шәрекъ курьеры»), атналык газета. 1908 елның 17 ноябреннән 15 декабренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 5 саны чыга. Наширe һәм мөхәррире В.С.Андреев. «В.к.» «Волжский листок» г-тасын вакытлыча туктатып торганда барлыкка килә, аның хезмәткәрләре «В.к.» редакциясендә эшли башлый. Үзен иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета дип игълан итсә дә, аның эчтәлеге бу билгеләмәгә туры килми. Россия газеталарыннан күчереп басылган, обывательләр, мещаннар зәвыгын гына канәгатьләндерерлек материалларга зур урын бирелә. Эчтәлекләре җәнҗалга, шаккатыруга корылган хәбәрләр, көн яңалыклары, репортажлар, Казанны төзекләндерү турында мәгълүматлар, банклар эшчәнлеге хакында кыскача хисаплар һ.б. басыла. «Театр һәм музыка» рубрикасында (аны Казанның танылган әдәбиятчысы Н.Ф.Юшков алып бара) спектакльләр турында белешмәләр, рецензияләр, булачак гастрольләр һәм муз. кичәләр хакында белдерүләр бирелә. Ш.у.к. «*Курьер*».


*Г.Р.Заманова.*

**«ВОСТО́ЧНЫЙ ЭКСПРЕ́СС»** («Шәрекъ экспрессы»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. 2000 елның ноябреннән Казанда рус телендә нәшер ителә. Оештыручысы — җаваплылыгы чикләнгән «Евразия-Медиа» җәмгыяте. Мөхәррирләре: Р.З.Галләмов, Р.В.Билалов, Т.Н.Вафина. Төп рубрикалары: «Жиде көн», «Мәдәният паркы», «Көзге», «Яшерен материаллар». Казанның һәм ТРның сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышын яктырта. Милли мәсьәләләргә зур игътибар бирелә: «Татар гасыры» рубрикасында ТР һәм аннан читтә яшәүче татарлар тормышына багышланган материаллар, татар интеллигенциясенең күренекле вәкилләре б-н интервью-әңгәмәләр басыла.

**ВОСХО́Д** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 6 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы буенда. 2002 елда 13 кеше (руслар) яши. 1922–23 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 189, 1938 дә — 220, 1949 да — 169, 1958 дә — 160, 1970 тә — 87, 1979 да — 90, 1989 да — 22 кеше.

**ВО́ТКИН** посёлогы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 11 *км* көньяктарак, Томбарлы елгасы буенда. 2002 елда 19 кеше (удмуртлар, руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Башта Вотский дип атала. Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 62, 1949 да — 60, 1958 дә — 48, 1970 тә — 86, 1979 да — 62, 1989 да — 9 кеше.

**ВО́ТКИНСК ШӘҺӘРЕ́**, *Удмурт Республикасында*, Воткинск р-ны үзәге, Ижевск шәһәреннән 62 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Вотка елгасы (Кама бассейны) буенда. Халкы — 99441 кеше (2006). Татарлар саны: 1959 елда — 4 мең, 1970 тә — 4,04 мең, 1979 һәм 1989 да 3,9 мең, 2002 дә — 3683, 2006 да — 3184 кеше. Татарлар В. ш.ндә 1750–60 елларда яши башлыйлар. Башлыча, алар Казан һәм Оренбург губерналарыннан (хәзерге ТРның Әлмәт, Зәй, Алабуга, Түбән Кама, Тукай р-ннары терр-ясе) чыккан, Воткинск тимер кою з-дына беркетелгән крәстияннәр була. Шәһәрдә «Дуслык» татар мәдәни җәмгыяте (1989 дан), Удмуртия ТИҮнең Воткинск бүлеге (1993 тән) эшли. Сабантуй бәйрәме, татар җырлары һәм биюләре фестивальләре үткәрелә. «Тургай» ансамбле оештырылган. 1993 тә 12 нче мәктәп каршында татар телен өйрәнү сыйныфы ачыла. 2004 тә 42 нче балалар бакчасында татар телен һәм мәдәниятен өйрәнү төркеме ачыла. Шәһәр мәчете (1794 тә төзелә, архит-ра истәлеге) каршында ислам нигезләрен, гарәп графикасын өйрәтү якшәмбе мәктәбе эшли.



Воткинск шәһәре. Мәчет. 1794 (1997 елда яңартылганнан соң).

**ВО́ТЧИНАЛЫ БАШКОРТЛА́Р**, к. *Асаба башкортлар.*

**ВОТЯКО́В** Михаил Тимофеевич (5.11.1881, Казан губ., Чистай өязе Үтәк а. — 18.6.1931,



А.Н. Вощинин.

Казан), дин эшлеклесе. Саурыш авылында икенче класслы укытучылар мәктәбен тәмамлый. 1899–1903 елларда Чистай өязендәге чиркәү-приход мәктәпләрендә укытучы. 1903–06 да шул ук өязнең Җүкәтау авылында псаломчы һәм укытучы, 1906 дан Царёвококшайск Богородица хатын-кызлар монастыре дьяконы. 1914–19 да Козьмодемьян өязе Кумья авылында, 1919 дан Кулаково авылында, 1923–30 да Чистай өязенең Рус Сарсазында (1926 дан — протоиерей) эшли. 1930 да шул ук өязнең Чистай Выселкасы авылында рухани. 1920 елларда чиркәүдә яңалык кертүгә каршы көрәшә; 1930 да Чистай Выселкасындагы гыйбадәтханәне яптырмый саклап кала һәм ул храм, Чистай шәһәрендәге барлык чиркәүләрдә гыйбадәт кылу тыелганлыктан, эшли торган бердәнбер чиркәү булып кала. 1931 дә В. кулга алына һәм атып үтерелә. Вафатыннан соң аклана. 2006 ның 8 июлендә, җәфа чигүче рухи зат буларак, Рус Православие чиркәве тарафыннан изгеләр рәтенә кертелә.

*Әд.:* Священномученик Михаил Вотяков. К., 2006. *Е.В.Липаков.*

**ВОШЕ́РИЯ** (Vaucheria), саргылт-яшел суүсемнәр ыругы. ТРда сулыклар төбендә һәм иркен йөзүче җеп төркемнәре рәвешендә — су өстендә, ш.у. дымлы туфракларда яшел хәтфә кебек барлыкка китереп үсәләр. В. — яшел, ботакланган җеп, бүленгесез көпшәсыман куышлык, целлюлозалы тышча б-н уратып алынган һәм бик күп хлорофилл бөртекләре һәм күзәнәк төше протоплазмасы булган бер гигант күптөшле күзәнәк. Вегетатив үрчү җепләр өзелү юлы б-н бара, җенессез юл б-н күп төшле күп камчылы зооспоралардан үрчи.

*Л.Ю.Хәлиуллина.*

**ВОЩА́КИНА** Ольга Борисовна (27.1.1961, Новосибирск ш.), спортчы (фехтование), СССРның халыкара классы спорт остасы (1983). Тренер В.В.*Житловта* шөгыльләнә («Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте, Казан). Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1990). Шәхси һәм команда ярышларында СССР чемпионы (1984–89), СССР кубогы иясе (1985), «Дружба-84» халыкара ярышларында, Бөтендөнья универсиадасында (1986) көмеш медальгә лаек була. Команда беренчелегендә дөнья чемпионы, шәхси беренчелектә бронза медаль (1986), дөнья чемпионатларында (1983 — бронза, 1989 — көмеш) медальләр ала. Олимпия уеннарында (1988, 1992) катнаша. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ВОЩИ́НИН** Александр Николаевич (1914, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Троицк а. — 1986, Мәскәү), вице-адмирал (1984). Татар милләтеннән. М.В.Фрунзе исем. Ленинград югары командалык хәрби-диңгез уч-щесенең артиллерия ф-тын (1937) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1937 елдан хәрби заводта (Сумы өлкәсе, Шостка ш.): өлкән техник, Хәрби диңгез флоты вәкиле урынбасары, директор. 1941–43 тә Хәрби диңгез флотының артиллерия идарәсендә (Мәскәү) өлкән офицер. Отставкага кадәр (1975) СССР Оборона министрлыгында һәм Хәрби диңгез флоты аппаратында югары җаваплы вазифалар башкара. Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы көчләрендә Ватанга хезмәт өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ВРА́НГЕЛЬ** Георг-Густав (Егор Васильевич) (9.10.1784, Лифляндия губ. Мейдель ш. — 15.6.1841, С.-Петербург), барон, хокук белгече, хакыйкый статский советник (1840). Германиядә Вюрцбург ун-тын тәмамлый (1804). 1806 елдан Сенатның Кануннар чыгару комиссиясендә эшли, М.М.Сперанскийның хезмәттәше (С.-Петербург). 1809 дан Казан ун-тында: хокук белгечлеге фәне адъюнкты (1809–11), экстраординар проф. (1811–15), ординар проф. (1815–19). 1820 дән Петербург ун-ты профессоры, бер үк вакытта 1835 тән Хокук белгечлеге уч-щесе класслары инспекторы. Хезмәтләре җинаять хокукы мәсьәләләренә, Россиядә мәхкәмә эше тарихы һәм теориясенә карый.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**«ВРЕ́МЯ И ДЕ́НЬГИ»** («Вакыт һәм акча»), иҗтимагый-сәяси газета. 1996 елда Казанда «*Известия Татарстана*» г-тасы җирлегендә оештырыла. Оештыручылары: ТРның Дәүләт мөлкәте б-н идарә итү дәүләт ком-ты, газета редакциясе коллективы. Мөхәррире — Ю.П.Алаев. Атнага 3 тапкыр рус телендә нәшер ителә. Иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади мәсьәләләрне яктырта, республикада һәм аннан читтә булган мөһим вакыйгалар турында оператив хәбәрләр бастыра, ТР һәм РФдә икътисадны реформалаштыруның барышына анализ ясый.

**«ВСА́ДНИК»** («Җайдак»), Казан график-рәссамнарның иҗат берләшмәсе. 1919 елда И.Н.*Плещинский* (рәисе) һәм Н.С.*Шикалов* (рәистәш) инициативасы б-н Казан дәүләт ирекле сәнгать остаханәләренең графика бүлеге нигезендә оеша. Аның әгъзалары — остаханәләрдәге укытучылар һәм укучылар: Д.М.Фёдоров (сәркәтип), М.Г.Андреевская, М.Меркушев, А.Бутин, В.Э.*Вильковиская*, С.С.Федотов, И.Стаднюк, А.Г.*Платунова*, К.*Чеботарёв* (1922 дән — рәис).

Берләшмә исеменең килеп чыгышы турында төгәл мәгълүмат юк. Мюнхендагы «Der Blaue Reiter»га («Зәңгәр җайдак») бәйләнешле булуы ихтимал (Беренче бөтендөнья сугышы елларында И.Плещинский әсирлектә чагында Мюнхенда графика сәнгатен өйрәнә).

Берләшмәнең «Гадәти көннәрдә батырлык» дип исемләнгән иҗат декларациясе (авторы Н.Шикалов) «Всадник» график альманахының 1 нче санында басылып чыга (1920). Анда житештерү сәнгатенең пролеткульт идеяләре алга сөрелә, басма графика сәнгатен яңарту, китапны яңадан сәнгать әсәре югарылыгына күтәрү, ш.у. яңа типтагы «рәссам — җитештерүче» тәрбияләү төп бурыч итеп куела. «В.» әгъзалары үз иҗатларында графиканың элек Казанда киң таралмаган алымнарын (офорт, литография, линогравюра, ксилография, монотипия) үзләштерәләр, яңа ысулларны (фанераны көйдереп гравирлау) гамәлгә кертәләр, Казан рәссамнарының графика сәнгатенең төр һәм жанрлар колачын шактый киңәйтәләр (эстамп, плакат, экслибрис, китап графикасы, нәшрият эмблематикасы һәм дизайны). «В.»ның җитештерү-нәшрият бүлеге тарафыннан 20 дән артык китап, ш.и. 4 график альманах, эстамп альбомнары, «Казан китабы билгесе» («Казанский книжный знак») җыентыгы бастырып чыгарыла, «Шагыйрьләр витринасы» нәшриятында литографияләнгән аз тиражлы китаплар һ.б. дөнья күрә. Барлык басмалар 5–100 данәдә кулдан басыла. «В.»ка кергән һәр рәссам үзенә генә хас иҗат рәвеше, стиле, образлар һәм темалар даирәсе б-н аерылып тора. Мәс., Н.Шикалов һәм М.Андреевская төсле линогравюраның Мәскәү мәктәбе традицияләрен дәвам итә. Н.Плещинский иҗатына югары графика культурасы һәм немец экспрессионизмы стильләрен үзенчәлекле куллану хас. К.Чеботарёв графикасында линогравюраның сурәтләү чараларын яңарту юнәлешендәге тынгысыз эзләнүләр һәм агитация-массачыл сәнгать стильләре чагылыш таба. А.Платунова иҗаты якты хисләр, фантазия байлыгы, образларны гәүдәләндерүдә иҗат теленең нәфислеге, нәзакәтлелеге б-н үзенчәлекле. «В.» берләшмәсе әсәрләре һәм басмалары Татарстан Респ-касы Үзәк музее (хәзерге ТР Милли музее) гравюралар кабинеты, Казан ирекле сәнгать остаханәләре тупламаларында һәм шәхси коллекцияләрдә саклана (Н.Н.Андреев, Б.П.*Денике*, П.Е.*Корнилов* һ.б. җыелмалары). Берләшмәнең беренче һәм бердәнбер күргәзмәсе 1920 елда оештырыла. 1924 тә «В.» таркала.

«В.» һәм «Всадник» графика остаханәсе басмалары: Графический альманах (№ 1. К., 1920; № 2. К., 1921; № 3. К., 1922; № 4. К., 1923); Плещинский И.Н. Литографии (К., 1920); Плещинский И.Н. Офорты. (К., 1920); Первая выставка графического коллектива «Всадник» (К., 1920); Восточный орнамент (Н.С.Шикалов, И.Н.Плещинский, М.Г.Андреевская, В.Э.Вильковиская (К., 1920); Корнилов П.Е. Каталог выставки Н.Шикалова и М.Андреевской (К., 1921); И.Н.Плещинский. 18 автолитографий (К., 1921); А.Г.Платунова. Графика (К., 1921); К.К.Чеботарёв. Революция. Автогравюра. (К., 1921); А.Г.Платунова. Виньетка. (К., 1921); Тукаев Г. Шурале. Илл. и обложка И.Плещинского. (К., 1921); Радимов П.А. Старик и липа. Илл. и обложка Д.М.Фёдорова (К., 1922); К.К.Чеботарёв.



1



2


3


4

1. «Всадник». Беренче күргәзмә каталогы тышлыгы. Авторы И.Н.Плещинский. 1920; 2. «Всадник». Беренче күргәзмә каталогының титул бите. Авторы Д.М.Фёдоров. 1920; 3. Д.М.Фёдоров. Линогравюра. 1910–20 еллар; 4. И.Н.Плещинский. «Сугыш». Линогравюра. 1910–20 еллар.

Эскизы. (К., 1922); А.Г.Платунова. Сказки. (К., 1922); А.Платунова. Линогравюра (К., 1922); Автографы (К., 1922); В.В.Кудряшов. Казанский кремль. Офорты. (К., 1922); Книжные знаки. (Вып. 1, А.Платунова, К.Чеботарёв. К., 1922); Н.М.Сокольский. Казань. Гравюры на линолеуме (К., 1923); Казанские книжные знаки (К., 1923); Мастфор К., 1923; Сотонин К. Творчество А.Г.Платуновой. (К., 1924).

*Әд.:* Сидоров А.А. Графика и искусство книги // Печать и революция. 1927. Кн. 7; Аристов В., Ермолаева Н. Всё началось с путеводителя... Поиски литературные и исторические. К., 1975; Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х годов. К., 1990.

*Е.П.Ключевская.*

**ВСЕ́ВОЛОД III БОЛЬШО́Е ГНЕЗДО́** (1154 — 13.4.1212), Владимир кенәзлегенең бөек кенәзе (1177 елдан). Кенәз Юрий Долгорукийның улы. Күп балалы булганлыктан, «Зур оя» («Большое гнездо») кушаматы ала (8 улы һәм 4 кызы була). Башта атасы аны Ростов Великий шәһәре кенәзе итеп билгели. Атасы вафатыннан соң бертуганы Андрей Боголюбский аны тәхеттән мәхрүм итә. 1162 елда В. III анасы һәм бертуганы Михаил б-н иленнән куыла, Константинопольдә император Мануил сараенда тәрбияләнә. Иленә кайткач, 1174 кә кадәр, Андрей Боголюбскийга хезмәт итә. Ул үтерелгәч, үзара көрәш барышында Владимир тәхетенә агасы Михаилны утыртуда катнаша (1176). Аның вафатыннан соң бөек кенәз вазифасы В. III кә йөкләнә. Тышкы сәясәттә В. III үз дружинасына һәм Владимир боярларына таяна, Андрей Боголюбский кебек үк, башка кенәзлекләрдән өстен булу, үз биләмәләрен киңәйтү өчен көрәшә. Новгород феодал респ-касына басым ясап, анда үз кешеләренең идарәлеккә үтүенә ирешә. Муром һәм Рязань кенәзлекләре эшенә тыкшына, үз туганнары — Смоленск һәм Переяславль кенәзләре ягында Чернигов кенәзлегенә каршы сугыша. Кенәзләр төркемнәре арасында барган каршылыкларны оста файдалана, рус сәяси дөньясында үз йогынтысын булдыруга ирешә. Аның көч-куәтен һәм абруен «Игорь полкы турында җыр» («Слово о полку Игореве») поэмасы авторы да билгеләп үтә. В. III идарә иткәндә Владимир-Суздаль кенәзлеге чикләре көнчыгышка таба шактый киңәя. В. III берничә мәртәбә Идел буе Болгарына яу б-н бара (1183, 1185, 1205). Берничә кенәзлек көчен берләштереп Биләр шәһәренә оештырылган 1183 елгы һөҗүме җиңелү б-н тәмамлана. В. III идарә иткән еллар Владимир-Суздаль кенәзлегенең иң югары куәткә ирешкән еллары була: шәһәрләр төзелә, һөнәрчелек һәм мәдәният үсеш ала (чиркәүләр төзелә, әдәби әсәрләр иҗат ителә, 1187, 1193 елларда елъязмалар тупламасы әзерләнә). В. III вафатыннан соң кенәзлек берничә өлешкә таркала, алар б-н аның уллары идарә итә.

Чыг.: Приселков М.Д. Троицкая летопись. М.–Л., 1950; Полное собрание русских летописей. М., 1965. Т. 15; Л., 1989. Т. 38; М., 1997. Т. 1; М., 1998. Т. 2.

*Әд.:* Ключевский В.О. Древнерусские жития святых как исторический источник. М., 1871; Воронин Н.Н. Зодчество Северо-Восточной Руси XII–XV вв. М., 1961. Т. 1; Пашуто В.Т. Внешняя политика Древней Руси. М., 1968; Кучкин В.А. Формирование государственной территории Северо-Восточной Руси в X–XIV вв. М., 1984; Лимонов Ю.А. Владимиро-Суздальская Русь. Л., 1987; Соловьёв С.М. Сочинения. М., 1988. Кн. 1; Измайлов И.Л. 1183 г. Крестовый поход на Волге // Родина. 2000. № 3.

*И.Л.Измайлов.*

**«ВТОРА́Я ОТЕ́ЧЕСТВЕННАЯ ВОЙНА́»** («Икенче Ватан сугышы»), Беренче бөтендөнья сугышы башлануга багышлап чыгарылган газета. 1914 елда Казан губерна земствосы тарафыннан Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 8 саны чыга. Максаты — губернада яшәүче халыкларда патриотизм хисләре тәрбияләү. Россия һәм халыкара телеграф агентлыкларыннан алынган рус армиясе баш командующие штабы боерыклары, сугыш хәрәкәтләре, рус гаскәрләренең уңышлары, Австрия һәм Германия армияләренең җиңелүе турында хәбәр иткән телеграммалар басыла.

**«ВТОРМЕ́Т»**, кара металлургия пр-тиесе. Казанда урнашкан. 500 кеше эшли (2005). 1929 елда «Главвтормет» республика конторасы буларак нигез салына. Күп үзгәртүләрдән соң, 1995 тән «Втормет» АҖ. Икенчел чимал — кара һәм төсле металл ватыкларын җыю, әзерләү, сортларга аеру, эшкәртү, төргәкләү б-н шөгыльләнә. Аннан соң эшкәртү өчен икенчел чимал РФ металлургия комб-тларына һәм экспортка җибәрелә. 1960 елларда металл ватыкларын әзерләү һәм төяп җибәрү күләме арту сәбәпле, пр-тие киңәйтелә һәм җитештерү куәтен үстерә. Җитештерү процессларын механикалаштыру һәм автоматлаштыруга игътибар бирелә. «В.»ның республика районнарында үз бүлекчәләре бар. Пр-тие җитәкчеләре: И.Н.Парахин (1955–60), И.Г.Злыдень (1960–74), В.Г.Никитенко (1974–85), Р.А.Галиәкбәров (1985–98). В.А.Новиков (1998–2002), Э.К.Аристархов (2005 тән).

*В.А.Нагорская.*

**ВТО́РОВ** Иван Алексеевич (1.6.1772, Оренбург губ., Бозаулык өязе Ласкарёвка а. — 14.2.1844, Казан), библиофил. 1805–15 елларда Самара шәһәрендә судья булып сайлана, бер үк вакытта 1812–14 тә городничий булып тора. 1790 еллар башында шигырьләр яза башлый, ләкин 1800 дән соң матбугатта әсәрләре басылмый. 1835 тә Казанга килеп урнаша. В. истәлекләрендә 19 йөз башы Мәскәү һәм Казан тормышына караган әһәмиятле мәгълүматлар тупланган. Атаклы рус әдипләренең тәрҗемәи хәлләрен өйрәнгәндә алар чыганак ролен үти, мәс., аларда А.С.Пушкинның Казанда булуы турында хәбәрләр, В.А.Жуковский, Н.М.Карамзинның һәм 18 йөзнең күренекле рус «вольтерчы»сы В.И.Полянскийның әдәби портретлары бар. В. ның 903 исемдәге 1908 томнан торган китапханәсен аның вафатыннан соң улы Казан шәһәренә тапшыра, ул Казан шәһәр китапханәсенең (1991 дән ТРның Милли китапханәсе) нигезен тәшкил итә.

Хезм.: Москва и Казань в начале XIX в. // Русская старина. 1891. № 4.

*Әд.:* Бобров Е.А. А.А.Фукс и казанские литераторы в 30–40-х гг. // Русская старина. 1904. № 7; Русские писатели. 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1989. Т. 1.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

**ВУЛЬГАРИ́ЗМНАР** (лат. vulgaris — гади, гадәти), әдәби лексикада кулланылмый торган сүзләр һәм гыйбарәләр. Кайвакыт В. көнкүреш колориты өстәү, уйлаган предметка карата тискәре мөнәсәбәт белдерү өчен, стилистик элемент буларак, персонажлар сөйләменә яки әдәби әсәрнең текстына кертеләләр.

Аристократ — **сорыкортлар**, **калын корсак**, **кечек башлар**;
Ашыйлар соң **бирән булган кешеләр**, ну гаҗәп, ай-яй!
Вә һәрберсе — губернатор, **кикерәләр дөбер-шатыр**;
Тамак туйгач, **төкер-какыр**, бөтен эч май гына, май-май!
(Г.Тукай, «Сорыкортларга»).

Ишектәге «**күз**» ачылды. Бүренекедәй кан баскан бер яман **бәбәк** карады (И.Салахов).

Ләкин егет **дөмекмәде**, алты айдан кире кайтты (Г.Ибраһимов).

*Әд.:* Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. М., 1966; Городское просторечие: Проблемы изучения. М., 1984; Розенталь Д.Е., Теленкова М.А. Словарь-справочник лингвистических терминов. М., 1985.

*Х.Р.Курбатов, М.Ә.Сәгыйтов.*

**ВУЛЬФ** Георгий (Юрий) Викторович (10.6.1863, Чернигов губ. Нежин ш. — 25.12.1925, Мәскәү), кристаллограф, минералогия һәм геогнозия докторы (1896), Россия ФАнең мөхбир әгъзасы (1921). Россиядә кристаллар физикасына һәм рентгеноструктур анализга нигез салучы. Варшава ун-тын тәмамлый (1885). Казан (1897–98) һәм Варшава (1898–1906) ун-тларында минералогия профессоры. 1908–11, 1918–25 елларда Мәскәү ун-тында эшли. Кристалл структураларын тикшерү буенча Россиядә беренче рентген кабинетын оештыра. 1911–17 дә — Мәскәү хатын-кызлар югары курсларында кристаллография һәм минералогия каф. мөдире. 1897 дә Казанда пространстволы проектлаштыру өчен стереографик челтәр ярдәмендә кристалларның гониометрик үлчәү нәтиҗәләрен эшкәртүнең график ысулын өйрәнә. В. челтәре бөтен дөньяга танылa һәм әлегә кадәр кристаллографиянең, физика, химия, геодезиянең төрле тармакларында киң кулланыла. 1913 тә (инглиз физиклары У.Л. һәм У.Г.Брэгглардан бәйсез рәвештә) кристаллик рәшәткәдә рентген нурлары дифракциясе шартларын билгели һәм рентгеноструктур анализның төп формуласын чыгара (Вульф-Брэгг формуласы). Кристалл кырларының үсү тизлеге турындагы законны тасвирлый (П.Кюри—Вульф принцибы, 1895).

Х е з м.: Руководство по кристаллографии. Варшава, 1904; Симметрия и её проявления в природе. М., 1915; Избранные работы по кристаллофизике и кристаллографии. М.–Л., 1952.

*Әд.:* Чернов В.Г. Геологи Московского университета. М., 1989.

**ВУЛЬФСО́Н** Григорий Наумович (22.4.1920, Новосибирск ш. — 4.11.2002, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1973), проф. (1975), ТАССРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1988, 1997). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1945), шунда ук 20 йөзгә кадәрге ватан тарихы кафедрасында эшли. Россиянең 19 йөздәге сәяси тарихына, иҗтимагый хәрәкәткә, Идел буе һәм Урал яны мәдәни тормышына, Казан ун-ты тарихына, ш.у. тарих фәненең үсеше, чыганакларны өйрәнү фәне мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр авторы. «1861 елгы Бизнә крәстияннәре кузгалышы» документлары җыентыгын («Бездненское восстание», 1948), «Татарстан тарихыннан хрестоматия (XIX йөзнең 2 нче яртысы — XX йөз башы)» («Хрестоматия по истории Татарии (2 половина XIX — нач. XX вв.», 1979) басмаларын төзүчеләрнең берсе. Музейлар оештыру мәсьәләләре б-н шөгыльләнә; Казан ун-ты мемориаль зонасы, И.И.Шишкинның Алабуга шәһәрендәге мемориаль музее, В.И.Ленинның Ленино-Кокушкино авылындагы һәм Казандагы мемориаль музейлары экспозицияләренең концепцияләре авторларының берсе. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Общественно-политическая борьба в Казанском университете в 1859–1861 гг. К., 1955 (автордаш); Из истории разночинно-демократического движения в Поволжье и на Урале. К., 1963; Разночинно-демократическое движение в Поволжье и на Урале в годы первой революционной ситуации. К., 1974; Глашатай свободы: Страницы из жизни А.П.Щапова. К., 1984; Жаждали воли: (К 125-летию Бездненского восстания). К., 1986; Братья по духу: Питомцы Казанского университета в освободительном движении 1840–1870 гг. К., 1989 (автордаш).

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999). К., 1999.

**ВУЛЬФСО́Н** Сергей Григорьевич (4.8.1945, Казан), химик, химия фән. д-ры (1979), проф. (1991). 1967 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1969–93 елларда РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, 1989 дан комплекслы кушылмалар һәм лигандлар структурасы лаб. мөдире. Хезмәтләре бициклик терпеннарда икеле бәйләнеш буенча нуклеофиль кушылу реакцияләре стереохимиясе, электрик һәм оптик ысулларның җыелма мәгълүматлары нигезендә молекулаларга конформацион анализ, молекуляр магнетохимия, цианофосфатларның синтезы һәм структура үзлекләре, молибденның координацион кушылмалары синтезы һәм структурасына карый. В. диполь моментлар, Керр эффекты, Рәлеевча яктылык таралу ысуллары нигезендә эремәдә катлаулы конформацион катнашмаларны анализлауның комплекслы ысулын ача. Б.А.Арбузов, А.Н.Верещагин, В.Ф.Николаев, Н.В.Үтәгәнов б-н берлектә парамагнитик ионнар һәм орбиталь магнитик моментлы комплекслары булган эремәләрдә парамагнитик икеле нур сыну күренешен ача. Эремәләрдә металлокомплексларның структураларын билгеләүнең уникаль эксперименталь ысулын эшли. В. АКШта, Европа Берлеге һәм БДБ илләрендә патентланган, көчле электроакцепторлар группасы булган пирофосфат, фосфорлы ангидрид һәм фосфатлардагы Р-О бәйләнешләре һәм цианид ионнары арасындагы реакцияне ача. 1993 елдан АКШта.

Х е з м.: Молекулярная магнетохимия. М., 1989; Парамагнитные эффекты линейного двулучепреломления в магнитном поле // Журн. неорганич. химии. 1990. 35(2); Molecular Magnetochemistry. N.Y.–London–Amsterdam, 1999.

**ВУ́РГАФТ** Моисей Бенционович (21.2.1913, Винница губ. Гайсин ш. — 8.6.1994, Казан), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1970). 1939 елда Одесса мед. ин-тын тәмамлый. 1941–45 тә Армиядә күз авырулары хирурглары төркеме башлыгы. 1945–51 дә В.П.Филатов исем. Күз авырулары ин-тында эшли (Одесса ш.). 1959–62 дә — Трахоматоз ин-тында (Уфа ш.). 1962–69 да Одесса-Кишинёв тимер юлы күз авырулары табибе. 1967–86 да — Казан ГИДУВында офтальмология каф. мөдире. В. глаукомага диагноз кую һәм дәвалау проблемасын өйрәнә, сәламәт күздән яшь акканда һәм глаукома вакытында яшь бүлеп чыгару бизләрен компрессорлы-тонометрик тикшерүгә нигез сала (1966). Глаукомага һәм кылый күзгә микрохирургик операция ясау ысулын эшли һәм гамәлгә кертә (1970–71). Аның тарафыннан «*Вургафт сынау ысулы*» (1950) эшләнә, аппланацион фотоэлектромонограф (автордаш, 1959) тәкъдим ителә. ТАССР офтальмологлары фәнни җәмгыяте рәисе (1973–86). Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: «Вургафта проба» // Офтальмология. 1950. № 2; Актуальные и спорные вопросы диагностики и лечения глаукомы. Л., 1986.

*Әд.:* Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина (1920–1990). К., 1990; Вургафт Моисей Бенционович: Некролог // Офтальмологический журн. 1995. № 1.

**ВУРГА́ФТ СЫНА́У ЫСУЛЫ́**, күзнең гидродинамик басым күрсәткечләрен тикшерү. Сынау ысулы беренче тапкыр 1950 елда М.Б.Вургафт тарафыннан эшләнә һәм 1966 да гамәлгә кертелә. Глаукомага диагноз кую өчен кулланыла. Физик тәэсирдән соң һәм тәэсир итүгә кадәр өч тапкыр күзнең эчке басымы, күз яше бүленеп чыгару бизләренең күләме һәм тизлеге үлчәнә. Гамәли медицинада гади һәм файдалы ысул булып танылa.

**«ВЫ́БОР»**, атналык газета. Оештыручылары: ТР Инвалидларының иҗтимагый-социаль оешмалары ассоциациясе, РФ Пенсия фондының ТР бүлеге, Республика адреслы социаль яклау фонды, ТРның Социаль тәэминат министрлыгы органы. 1993 елдан Казанда — рус телендә, 1998 дән «Өмет» исемендә татар телендә дә нәшер ителә. Мөхәррире — Г.И.Нуруллина. Газетада халыкны социаль яклау турындагы законнар, норматив актлар һәм аларга аңлатмалар басыла, инвалидлар, пенсионерлар, сугыш һәм хезмәт ветераннарының проблемалары яктыртыла. «В.» редакциясе аларга ярдәм итү йөзеннән хәйрия акцияләрен оештыруда актив катнаша.

**ВЫ́БОРГ ӨНДӘМӘСЕ́** («Халыкка — халык вәкилләреннән»), 1 нче Дәүләт думасы таратылу б-н риза булмаган депутатларның Россия халкына мөрәҗәгате. Ул 1906 елның 10 июлендә Выборг шәһәрендә кабул ителә. Мөрәҗәгатьнең беренче текстын П.Н.Милюков әзерли, соңгы вариантын 6 кешедән торган комиссия эшләп бетерә (кадетлардан М.М.Винавер, Ф.Ф.Кокошкин, трудовиклардан И.В.Жилкин һәм С.И.Бондарёв, с.-д.лардан — меньшевиклар Н.Н.Жордания һәм С.Д.Джапаридзе). Мөрәҗәгатьтә, Бөтенроссия халкы яңа Дәүләт думасы эшли башлаганчыга кадәр «казнага бер тиен акча түләмәскә, армиягә бер солдат җибәрмәскә тиеш», диелә. Хөкүмәтнең Дума б-н килешмичә алган акчалата бурычлары расланмаячак, дип белдерелә. Мөрәҗәгатькә 180 ләп депутат кул куя, ш.и. С.Алкин, Ә.Әхтәмов, А.Букейханов, С.Җантурин, И.Зиадханов, Г.Туп-

чыбашев. 1906 ның 16 июлендә мөрәҗәгатькә кул куючыларга карата мәхкәмә эше кузгатыла, 1907 елның 12–18 декабрендә Петербург мәхкәмә палатасының махсус утырышларында 169 элекке депутат эше карала, шуларның 167 се 129 нчы статья нигезендә 3 айга төрмәгә ябылуга хөкем ителә. Шул рәвешле алар чираттагы Дәүләт думасына сайлану һәм берникадәр вакыт җәмәгать эшчәнлеге алып бару хокукыннан мәхрүм ителәләр. Кул куйган 6 мөселман депутаттан фәкать Ә.Әхтәмов кына хөкем ителмичә кала.

*Әд.:* Винавер М.М. История Выборгского воззвания: Воспоминания. П., 1917; Черменский Е.Д. Буржуазия и царизм в революции 1905–07 гг. М.–Л., 1939.

*Д.М.Усманова.*

**ВЫ́ГОРОЖЕННЫЙ КЛЮЧ** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 58 *км* көньяк-көнбатыштарак, Түбән Кама–Кама Аланы автомобиль юлы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 1920 елларда Сухарево авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. ТАССРның Чаллы кантоны Шәңгәлче волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 99, 1949 да — 130, 1958 дә — 106, 1970 тә — 56, 1979 да — 27, 1989 да — 4 кеше.

**ВЫ́РИН** Василий Филиппович (22.4.1913, Мәскәү — 7.10.1990, Казан), тепловоз машинисты, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1935 елда машинистлар курсын (Юдино ст.) тәмамлый. 1935–69 да Горький тимер юлының Казан бүлеге Юдино станциясенең локомотивлар депосында — паровоз, аннан соң тепловоз машинисты булып эшли. Товар поездларын уртача күрсәткечләргә караганда ике тапкыр артыграк тизлектә йөртә. Герой исеме йөк ташуның җидееллык план йөкләмәләрен үтәүдә ирешкән уңышлары һәм тимер юлда техник реконструкцияләр ясаганы өчен бирелә. 1967–71 дә — ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Горник Г. Вырин Василий Филиппович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ВЫ́РОДКОВ** Иван Григорьевич (? — 1564), хәрби инженер, дипломат. 1535 елдан разрядлы приказда кече дьяк, дьяк булып хезмәт итә. 1538–39 да Нугай Урдасына җибәрелгән илчелек башлыгы. 1545, 1550 елларда Мәскәү патшалыгы гаскәрләренең Казанга каршы яуларында катнаша, тупчылар төркемендә дьяк була. 1550–51 елларда Зөя кальгасын төзү эшләренә җитәкчелек итүчеләрнең берсе: Углич шәһәре тирәсендә буралык агачлар кистерү, Идел буйлап аларны Зөягә китерү һәм 20 көндә ныгытмалы шәһәрчек төзү эшләре б-н шөгыльләнә. 1551 дә Мәскәү патшалыгы б-н Казан ханлыгы вәкилләре арасындагы сөйләшүләрдә катнаша. Шул сөйләшүләрдән соң Казан тәхетенә Шаһгали утыртыла. И.И.Хабаров б-н бергә Шаһгалине Зөя кальгасына, соңыннан Казанга озатып килүчеләрдән була. 1552 дә Казанны камауда катнаша, Кремль диварларын тупка тоту өчен махсус корылма-каланчалар төзүгә җитәкчелек итә. 1557 дән Патша сарае хезмәткәре. 1557–58 дә яңарак яуланган Әстерхан шәһәре воеводасы. Ливон сугышы (1558–83) барышында Полоцк шәһәрен камау өчен махсус хәрби корылмалар төзүгә, шәһәр яуланып алынгач, аның ныгытмаларын яңарту һәм төзү эшләренә җитәкчелек итә. Опричнина чорында җәзалап үтерелә.

*Әд.:* Кирюхин А.В. Дьяк Разрядного приказа: Документальное повествование о жизни и деяниях первого русского военного инженера дьяка И.Выродкова. М., 1991.


*Е.В.Липаков.*

**ВЫ́РУБОВ** Николай Алексеевич (13.1.1869 — 1919), психиатр, җәмәгать эшлеклесе, медицина д-ры (1899). 1894–95, 1899–1901 елларда Хәрби-мед. академиясендә, 1896–99 да С.-Петербург хастаханәләрендә эшли. 1901–07 дә Воронеж губернасының земство психиатрия хастаханәсе директоры. 1907–19 да Казан ун-ты психиатрия каф. профессоры һәм мөдире. Баш мие анатомиясе һәм физиологиясенә, психиатрия һәм хәрби психоневрологиягә, Россиядә авыруларга психотерапия ярдәме оештыруга, эчкечелекне дәвалауга караган хезмәтләр авторы. 1917–18 дә Казан губернасының сәламәтлек саклау бүлеге каршындагы совет әгъзасы була.

Х е з м.: Земельный фактор в этиологии душевных заболеваний. К., 1914.

*Әд.:* Болотовский И.С. Развитие научной и практической психиатрии в Казани в советский период // Тр. Казан. мед. ин-та. К., 1964. Т. 12.

**ВЫСО́ЦКИЙ** Николай Фёдорович (9.11.1843, Түбән Новгород ш. — 12.2.1922, Казан), хирург, җәмәгать эшлеклесе, мед. д-ры (1872), Казан ун-тының атказ. профессоры (1893). 1863 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1881 дән — теоретик хирургия каф., 1885–1905 тә хирургик патология каф. профессоры. 1907 дә мед. ф-ты деканы. 1900 елда Бактериология һәм 1917–19 елларда хатын-кызлар мед. ин-тларын оештыручы һәм аларның беренче директоры. 1968 дән Казан табибләре җәмгыяте әгъзасы, 1870 тән — сәркәтибе. Чәчәк һәм башка йогышлы авыруларга каршы прививка ясату турында стат. язмалар чыгаруны оештыручыларның берсе («Дневник общества врачей» —«Табибләр җәмгыяте көндәлеге»). Дифтерия эпидемиясенә каршы көрәштә земство эшчәнлегендә актив катнаша, 1896 да үткәрелгән 1 нче өлкә корылтаенда шул проблема буенча рәис итеп сайлана. 1870 тә Яралы һәм авыру хәрбиләр турында кайгырту җәмгыяте оештыра һәм җитәкли, бу җәмгыять 1876 дан Кызыл Хач җәмгыятенең Казан идарәсе дип атала башлый; 1904 тә Кызыл Хачның ун-т комитетын оештыра һәм җитәкли. Казан ун-тының Фәкыйрь студентларга ярдәм итү җәмгыяте (1871, шәрәфле әгъзасы), Табигыятьчеләр җәмгыяте һ.б. эшләрендә актив катнаша. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы. Казан, Лаеш, Спас, Тәтеш өязләрендә археологик эзләнүләр үткәрә; Муром шәһәре тирәсендә Ока елгасы экспедициясендә катнаша. 1910–14 тә Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография музее директоры. В. күп еллар буе антик чорга караган археологик казу эшләре вакытында табылган иконалар, бакыр савыт-саба кебек (коллекциясенең бер өлеше ТР Милли музее һәм Казан ун-тының археология музее фондларында саклана) борынгы әйберләр коллекциясен җыя. 1907 нең май аеннан ун-тның Крестовоздвиженск чиркәве ктиторы (старостасы). 1905 елда «Казан шәһәренең пастырьлар һәм чиркәү старосталары берлеге» җәмгыятен оештыручы һәм аның рәисе. 1906 дан октябристлар партиясенең Казан бүлеге әгъзасы, аның җитәкчеләреннән берсе: 1907–12 дә партиянең Казан шәһәр сайлау комитетын җитәкли. Окт. рев-циясеннән соң Казан ун-тында фәнни һәм укыту эшчәнлеген дәвам иттерә. Бер үк вакытта Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография ин-тында археология укытучысы. Хезмәтләре йогышлы авыруларның (чума, тимгелле тиф, холера, дифтерия) килеп чыгу сәбәпләренә, аларга диагноз кую, дәвалау һәм булдырмау ысулларына, дәвалау-профилактика препаратларын эшләү һәм камилләштерүгә карый.



В.Ф. Вырин.


Х е з м.: Материалы к учению о происхождении и развитии рака нижней губы. К., 1872; Чума при Алексее Михайловиче 1654–1655 гг. // Сб. статей о чуме. К., 1879; Общая хирургическая патология и терапия. К., 1885; Новая антропологическая находка в с. Болгары // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1889. Т. 7; Несколько слов о древностях Российской Булгарии // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1908. Т. 24; Следы каменного века в Казанской губернии // Изв. Сев.-Вост. этногр. и археол. ин-та. 1920. Т. 1; Несколько слов о болгарах и болгарской культуре // Казан. музейный вестн. К., 1921. № 1–2.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Казанского Императорского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Александров А.И. О трудах и занятиях по археологии и этнографии заслуженного ординарного профессора Императорского Казанского университета Н.Ф.Высоцкого // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1907. Т. 23, вып. 1; Деканы Казанского медицинского университета: Биогр. словарь. К., 1997.

*Л.М.Айнетдинова, Е.П.Казаков.*

**ВЮНСДО́РФ ЛА́ГЕРЕ**, Германиядә Вюнсдорф станциясе янында, Берлиннан 40 *км* көньяктарак урнашкан. 1915 ел башында Россия, Бөекбритания, Франция һ.б. илләрдән әсирлеккә төшкән мөселман гаскәриләре өчен оештырыла. Башлыча, мөселман хәрби әсирләре тотылган Йөземтау лагерена (Weinberg-







Вюнсдорф лагере.
1. Йөземтау лагере;
2. Ярымай лагере;
3. Ярымай лагере мәчете.

lager) һәм Ярымай лагерена (Halbmondlager) бүленгән була. В.л.нда 15 мең хәрби әсир тупланып, алар арасында татарлар, Кавказ халыклары вәкилләре, гарәпләр, һиндлар була. Алар өчен мәчет, китапханә эшли, халык уен кораллары оркестры оештырыла, немец һәм кайбер Кавказ халыклары телләрендә «Кавказ», татар һәм рус телләрендә «әл-Җиһад», татарча «Татар иле» г-талары чыгарыла. 1916 дан В.л.ның рәсмиләштерелмәгән җитәкчесе булып лагерь мәчете имамы Г.*Идриси* тора. Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланганнан соң, В.л. беркадәр вакыт Германиядә, башлыча, элеккеге хәрби әсирләрдән торган татар мөһаҗирлеге үзәкләренең берсе булып кала. Рәсми рәвештә 1922 нең маенда ябыла, мәчет 1928 нең августына кадәр эшли.

*Әд.:* A b d u l l a M u h a m m a d S. Geschichte des Islams in Deutschland. Graz-Wien, Këln, 1981; H ё p p G. Muslime in Markischer Heide: die Wunsdorfer Moschee — 1915 bis 1924 // Moslemische Revue. 1989. № 9; S e i l e r - C h a n A l b e r t - C h a l i d. Der Islam in Berlin und anderwarts im Deutschen Reiche // Moslemishce Revue. 1934. № 10 (4).

*И.А.Гыйләҗев.*

**ВЯ́ЗЕМСКИЙ** Павел Петрович (2.6.1820, Санкт-Петербург — 29.6.1888, шунда ук), кенәз, халык мәгарифе эшлеклесе, әдәбият тарихчысы. Шагыйрь кенәз П.А.Вяземскийның улы. Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1840), Тышкы эшләр министрлыгында эшли, 1856 дан Петербург уку-укыту округында попечитель ярдәмчесе, 1859 ның 4 ноябреннән 1862 нең 12 июненә кадәр *Казан уку-укыту округы* попечителе. В.ның идарә итүе мәгариф системасына император Николай I керткән катгый кысаларның бетерелгән, ләкин реформалар уздырылмаган һәм элекке закон һәм күрсәтмәләр формаль дәвам иткән вакытка туры килә. Бу шартларда җитәкчеләрнең роле аеруча зур була. В. үзен уртача либераль курс яклы итеп күрсәтә, университет өстеннән административ күзәтүне йомшарта. Аның ризалыгы б-н студентлар һәм алдынгы профессорлар басымы астында, ул вакыттагы фән дәрәҗәсенә туры килмәгән профессорлар эштән җибәрелә, студентлар үзидарәсе нигезләре — студентлар суды һәм җәмәгать китапханәсе кертелә, форма кием бетерелә, студентлар саны ике тапкырдан күбрәккә арта. В. Казан ун-тына А.П.*Шаповның* билгеләнүенә булышлык итә, аны Куртина чиркәвендәге вакыйгалардан соң репрессиядән саклап калырга тырыша. Икенче яктан, студентлар кузгалышыннан соң В. инициативасы б-н 1861 елның октябрендә студентлар күпләп укудан чыгарыла.

1862 дән Эчке эшләр министрлыгының цензура ком-ты рәисе, 1881 дән Матбугат эшләре буенча баш идарә башлыгы, 1883 тән сенатор.

«Игорь полкы турында җыр» («Слово о Полку Игореве») турындагы хезмәтләр һәм үзе дә шәхсән белгән А.С.Пушкин турында биографик тикшеренүләр авторы. 1877 дә Россия филология үсешендә мөһим роль уйнаган Борынгы язма әдәбият сөючеләр җәмгыятен оештыра һәм вафатына кадәр җитәкли.

*Әд.:* О п о ч и н и н Е. Памяти князя Павла Петровича Вяземского. СПб., 1888; К о р б у т М.К. Казанский государственный университет им. В.И.Ульянова-Ленина за 125 лет, 1804/05–1929/30. К., 1930. Т. 1.

**ВЯ́ЗОВКА** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Минзәләнең уң кушылдыгы. Озынлыгы 8 *км*, Минзәлә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Чулпан авылыннан 5 *км* көнбатыштарак, тамагы Җәмәк авылыннан 2,5 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 74 *м*. Су җыелу мәйданындагы урман күләме 22%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,47 *км/км²*. Тукланушы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. В. елгасы ноябрь башында туңа. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12 *мг-экв/л* дан күбрәк). Гомуми минерализашүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 700 *мг/л*, га кадәр. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**ВЯ́ЗОВКА** елгасы, к. *Кислинка*.

**ВЯ́ЗОВКА** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 10 *км* көнбатыштарак, Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы янында. 2002 елда 670 кеше (руслар — 44%, татарлар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 19 йөз ахырында сәүдәгәр Санин утарлары нигезендә барлыкка килә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Санин-Ключевский посёлогы буларак билгеле, Совет чорында авылның бер үк вакытта 2 исеме — В. һәм Югары Санин Чишмәсе була. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1920 дә — 365, 1926 да — 398, 1970 тә — 219, 1979 да — 154, 1989 да — 517 кеше.

**ВЯЛКО́В** Сергей Григорьевич (11.10.1927, Иваново өлкәсенең Кохомск р-ны Родионцево а.), инженер-электрик, Ленин бүләге лауреаты (1965). 1950 елда Иваново энергетика ин-тын тәмамлый. Яшел Үзән проект КБсында эшли, әйдәп баручы конструктор (1962–70), бүлек башлыгы (1960–62, 1970–75), баш конструктор урынбасары (1962–70), электр һәм радиотехника чаралары б-н җиһазлау буенча баш инженер урынбасары (1975–77). 1977 дән «Атолл» фәнни-тикшеренү ин-тында (Дубна ш., Мәскәү өлкәсе): фәнни-тикшеренү бүлеге башлыгы (1977–79), баш инженер урынбасары (1979–99), фән-техника бүлеге башлыгы (1999–2000). Корабльләрдәге радиоэлектроника һәм корал комплексларын проектлаштыруда, эшләтеп карауда катнаша. Корабльләрдә сынаулар уздыра һәм аларны Хәрби-Диңгез Флотына, ш.у. КХР һәм ГДР флотларына тапшыра. Ленин бүләге махсус машиналар төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ВЯ́СЕЛЕВ** Морат Рөстәм улы (25.2.1934, Казан), электроника гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1985), проф. (1987), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1999). 1958 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан дәүләт техника ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: радиотехника ф-ты деканы (1970–73), радиоэлектрон җайланмалар һәм үлчәүләр (1985 тән), теоретик радиотехника һәм электроника (хәзер радиоэлектроника һәм информацион-үлчәү техникасы) кафедралары мөдире (1988 дән), каф. профессоры (1998 дән). Бер үк вакытта 1989 дан мәгълүматны электрохимик әверелдерүләр лабораториясенең фәнни җитәкчесе. Хезмәтләре электрохимик мәгълүмат әверелдергечләр нигезендә эшләүче мәгълүмат-үлчәү техникасына карый. Вольтамперметриянең гомумиләштерелгән теориясен төзи, электр датчиклары мо-

дельләре, аппаратура методларының яңа төрләрен — баскычлап җәелүче хроновольтамперметрия, реверсив циклик вольтамметрия, параметрик полярография һәм импедансометрия ысулларын эшли. Электр диффузияле әверерелдергечләр теориясен үстерә. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Общие уравнения и электронная модель электроаналитического датчика // Докл. АН СССР. 1981. Т. 260, № 5; Теория аппаратных методов вольтамметрии. К., 2000; Основы современного электрохимического анализа. М., 2003 (автордаш).

**ВЯ́СЕЛЕВ** Рөстәм Галләм улы (4.5.1900, хәзерге Саратов өлкәсе Түбән Юләзән а. — 22.6.1967, Казан), хирург, проф. (1965), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1963). 1926 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук хирургия клиникасында эшли. 1932 дән Казан ГИДУВында. 1933 тән Казан мед. ин-тында, 1947–63 тә ректор, 1963 тән каф. мөдире. Хезмәтләре эчәкләрдә көчле үткәрмәүчәнлек вакытында ашказаны-эчәк юлы кинетикасы бозылуын өйрәнүгә, сәнәгый җәрәхәтләрне һәм пешүләрне ревоноль б-н дәвалауга, йогышлы тире авыруын дәвалаганда новокаин блокадасын куллануга багышланган. В. тырышлыгы б-н стоматология ф-ты оештырыла, яңа уку бинасы, тулай торак төзелә һәм файдалануга тапшырыла. Бөек Ватан сугышында катнаша, фронт госпитальләрендә әйдәп баручы хирург була. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Консервирование крови концентрированными растворами цитрата натрия. К., 1939.

*Әд.:* С а л и х о в И.А. Выдающийся организатор, учёный, хирург Рустам Аллямович Вяселев // Казан. мед. журн. 2000. № 3.

**ВЯ́СЕЛЕВА** Сара Мөхәммәтҗан кызы (20.1.1909, Пенза ш. — 28.12.1974, Казан), микробиолог, спирохетолог, мед. фән. д-ры (1955), проф. (1956). 1932 елда Мәскәү 1 нче мед. ин-тын тәмамлый. 1934 тән Казан мед. ин-тында. 1945–50 дә Казан стоматология ин-тында микробиология каф. мөдире. 1950–74 тә Казан ГИДУВында, 1956 дан шул исемдәге каф. мөдире. Сифилис микробиологиясе буенча тикшеренүләр алып бара. В. трепонемаларны анаэроб шартларда тыгыз туклану мохитендә үстерү ысулларын эшли, аерым штаммнарның ферментатив үзлекләрен, физик-химик факторларга тотрыклылыгын өйрәнә һәм антиген төрдәшлекләрен ачыклый, тәҗрибә һәм клиника шартларында тукымадагы аксыл трепонемага антибиотикларның тәэсирен ачыклый. В., илебездә беренче булып, сифилис чыганагына, эренле микроорганизмнарга, дифтерия таякчыкларына пенициллин, новоцеллин, экмоновоциллиннарның бактерицидлы тәэсирен өйрәнә. Пенициллинга озак вакытлар күнеккәндә морфологик, культураль һәм биохим. яктан үзгәргән трепонема штаммнары барлыкка килүен, трепонема штаммнарының пенициллинга сизгерлеге үзгәрмәвен ачыклый. Югары концентрацияле пенициллин тукымадагы аксыл трепонема үзенең патоген үзенчәлеген югалта, пенициллин һәм аннан хасил булган төрләр аксыл трепонеманың вирулентлыгына һәм юкка чыгу тизлегенә тәэсир итә. Алынган нәтиҗәләр сифилисны амбулатор һәм клиник шартларда пенициллин препаратларын кулланып дәвалауның нигезен тәшкил итә. В., СССР МФА мөхбир әгъзасы З.В.Ермольева б-н берлектә микроорганизмнарны фаголизабель халәткә китерә торган лицетин антибиотигы уйлап таба. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Действие различных препаратов пенициллина на бледную трепонему // Микробиология, эпидемиология, иммунология. 1957. № 4, 7; Этиология и основы лабораторной диагностики гриппа // Казан. мед. журн. 1957. № 2, 3; Сравнительная характеристика антибактериальных свойств органических соединений фосфора // Тр. Казан. ГИДУВа. 1960. Т. 14.

**ВЯ́ТКА** (Нократ) елгасы, Каманың уң кушылдыгы. Югары Кама калкулыгыннан (Удмурт Респ-касының төньягы) башлана. Бассейнының төп өлеше Киров өлкәсе терр-ясендә, түбән агымы Татарстанда. Озынлыгы 1314 *км* (ТР чикләрендә — 67 *км*), бассейнының мәйданы — 129 мең *км*$^2$ (ТР чикләрендә — 4,1 мең *км*$^2$). Иң түбән өлешләре Куйбышев сусаклагычының су күтәрелеше йогынтысын кичерә. Урман зонасындагы гадәти тигезлекле елга. Киң тугае б-н аерыла (бигрәк тә сул як яр буенча һәм Шыя елгасы тамагы б-н Мамадыш шәһәре арасында уң яр буенча) елга юлы нык бормалы, аның киңлеге, гадәттә, 250–300 *м* (киңәйгән урыннарда 500 *м* га кадәр), сай урыннарда тирәнлеге 1,5–2 *м*, киң урыннарда 10 *м* га кадәр. ТР терр-ясендә елганың 23 бормасы бар; иң зур кушылдыклары — Шушма, Бора, Оштырма, Шыя (уң), Лубян, Үмәк, Әнҗерә (сул).

В.ның гидрологик режимы Мамадыш, Вятские Поляны (Киров өлк.) шәһәрләре, һәм Берёзовые Поляны (Мамадыш р-ны) сүлчәү постларында яхшы өйрәнелгән. Постларда беренче күзәтүләр 1881 елда башлана. Елга тамагында суның уртача еллык чыгымы 860 *м*$^3$/*с*, иң югары уртача тәүлеклек чыгымы 8300 *м*$^3$/*с* чамасы. Бер ел эчендәге агып төшкән су микъдары (уртача еллык күләмнән чыгып % ларда) түбәндәгедән гыйбарәт: гыйн. 2,4, февр. 2,2, март 2,1, апр. 17,3, май 38,2, июнь 13,3, июль 4,1, авг. 3,2, сент. 4,8, окт. 4,7, нояб. 4,6, дек. 3,1.

Күбесенчә кар сулары исәбенә туена (еллык агымның 60–70%). Елганың боздан арчылуы һәм ташу башлану вакыты якынча апрель аеның 20 ләренә, иң югары күтәрелеше май урталарына туры килә, июньнең икенче яртысында башланган җәйге саегу биеклеге яңгыр сулары б-н үзгәреп тора. Су тигезлеге үзгәрешенең уртача еллык амплитудасы 6,5–7,5 *м* (иң зуры — 9 *м* дан артык). Җәйге һәм кышкы саегу вакытында су чыгымы, гадәттә, 200–500 *м*$^3$/*с* тәшкил итә һәм елга сай сулы булып кала.


Вятка елгасы (Кукмара р-ны).

Боз күренешләре уртача ноябрь ае башларында күзәтелә, тоташ боз кату ноябрьнең 2 нче яртысында формалашып җитә һәм якынча 170 көн дәвам итә (гадәттә, апрельнең 3 нче декадасы башларына кадәр). Бозның иң зур калынлыгы (60–70 *см*, кайвакыт 1 *м* га кадәр) март урталарына туры килә. Боз китү бер атна чамасы дәвам итә (иң күбе өч атнага кадәр). Боз киткәннән соң су бик тиз җылына башлый (июль уртасында 21–24 °С ка кадәр).

Ел саен елга тамагына 3 млн. *т* йөзмә китерелмә чыгарыла (уртача еллык болганчыклыгы 105 *мг/л*). Ел дәвамында минеральләшүе зур түгел: саегу вакытында 320–380 *мг/л*, ташу вакытында 80–100 *мг/л*. В. Камага ел саен 4,3 млн. *т* чамасы эрегән матдәләр чыгара (уртача еллык минеральләшүе 160 *мг/л*). Алар составында күпчелекне гидрокарбонат ионнар, кальций, азрак күләмдә магний ионнары тәшкил итә.

ТР терр-ясендә ага торган зур елгалар арасында В. — иң чиста сулы. Балыкка бай (корбан балык, судак, чуртан, кәлчәк, чабак, алабуга һ.б.). Сал агыза торган елга. Киров шәһәренә кадәр (688 *км*), язын Кирс шәһәренә кадәр (1068 *км*) суднолар йөри, ләкин күп кенә сайлыкларда су төбен тирәнәйтү эшләре башкару таләп ителә.

*Әд.:* Ресурсы поверхностных вод СССР. Л., 1973. Т. 11; Русловой режим рек Северной Евразии (в пределах бывшего СССР). М., 1994.

*В.И.Мозжерин.*

**ВЯ́ТКА АЛАНЫ́ РАЙОНЫ́**, *Киров өлкәсенең* көньяк-көнчыгышында. Мәйданы — 907 *км*$^2$. Үзәге — Вятские Поляны шәһәре (Кировтан 350 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 74326 кеше (2002 ел). Татарлар саны: 18906 кеше. 7 татар авылы: Иске Пенәгәр (1194 кеше), Урта Шөн (1016), Яңа Пенәгәр (100), Түбән Шөн (796), Сасмак (523), Ямул (310), Чумачар (75) исәпләнә. Татарлар шулай ук район үзәгендә (7,2 меңгә якын кеше), Сосновка шәһәрендә, шәһәр тибындагы Красная Поляна посёлогында (2,7 меңләп) яшиләр. В.А.р.нда татарлар 17 йөз ахыры — 18 йөз башында даими яши башлыйлар, Урта Шөн, Түбән Шөн, Сасмак авылларына нигез салалар. Иске Пенәгәр авылы 1726 дан мәгълүм. 1846 да Сасмак авылыннан күчеп утыручылар — Ямул, 1860 та Иске Пенәгәр авылыннан күчеп утыручылар Яңа Пенәгәр авылларына нигез сала. В.А.р. терр-ясендә 10 мәчет, 5 татар мәктәбе, Милли мәдәни үзәк (Вятские Поляны ш.) каршында татар мәдәнияте бүлеге эшли. Сосновка шәһәрендә «Идел» татар җыр ансамбле бар. В.А.р.нда Советлар Союзы Герое Ф.Ә.*Сабиров*, Дан орденының тулы кавалеры Х.М.*Миңнекәев*, Соц. Хезмәт Герое Г.Х.*Галиәхмәтов*, язучы Л.Ф.*Ихсанова* туган.

**ВЯ́ТКА ӨЕЛМӘСЕ́** (Вятка валы), ТРның көнбатыш өлешен һәм Киров өлкәсен биләүче эре тектоник структура. Идел-Урал ан-

теклизы составына керә. Генетик яктан, борынгы рифей чокыры (грабены) — Казан-Кажым авлакогенын (к. *Казан-Киров бөгелеше*), девон бөгелешен (урта франк дәверенә кадәр) һәм югары девон-ташкүмер, Пермь-аскы триас һәм юра утырмаларының өелмәсыман күтәренке катлаулы системаларын берләштерелә. В.ө. меридиан юнәлешендә 800 *км* дан артык озынлыкка сузыла, киңлеге 150 *км* га кадәр, биеклеге 300 *м* га җитә. Инверсия (бөгелешнең өелмәгә әверелүе), Рус платформасының тектоник формалашуы, альп этабына бәйле буларак, моннан 200 млн. ел элек башлана һәм хәзерге дәвердә дә күзәтелә (к. *Вятка увалы*). ТР терр-ясендә В.ө.нең түбәнәеп баручы көньяк өлеше ята, түбән Казан утырмаларының 150 *м* калынлыктагы өске катламы буйлый үтә. Бирёдә Казаклар, Сумка, Столбище, Үләмә һ.б. күтәрелмәләр билгеле. В.ө. чикләрендә файдалы казылмалардан кирпеч һәм керамзит балчыклары, төзелеш ташы, ком, җир асты минераль сулары, карбонатлы токымнар ачылган.

*Әд.:* Войтович Е.Д., Гатиятуллин Н.С. Тектоника Татарстана. К., 1998. Геология Татарстана. Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

*Б.В.Буров.*



Вятка увалы. Көньяк чите.

**ВЯ́ТКА УВАЛЫ́**, биеклеге 284 *м* га кадәр булган, меридиан юнәлешендәге диярлек, Казаннан Киров шәһәренә кадәр сузылган калкулык. Пермь системасы известьташлары, доломитлары, балчыклары, мергельләре, шулай ук төньякта Юра системасы балчыклары катлаулы төзелешләр антиклиналь катламнар зонасын (*Вятка өелмәсе*) хасил итә. В.у. урта өлешендә Вятка елгасы кисеп үтә. Карст киң таралган. Урманнар зонасының көньягында урнашкан, игенчелек уртача дәрәҗәдә үскән. Беренче булып 19 йөз ахырында Казан ун-ты профессоры П.И.Кротов тарафыннан билгеләнә һәм тикшерелә. ТР терр-ясенә В.у.ның көнчыгыш өлеше туры килә. Монда Илләт, Ашыт һәм Петьялка елгаларының сул кушылдыклары бассейнында зур булмаган 2 субүләр калкулык бар (биеклеге 220 *м* га кадәр), аларны, нигездә, югары Пермь — Казан ярусы һәм Вятка өелмәсенең Казаклар һәм Яңаул брахиантиклиналь катламнарына туры килгән известьташлар тәшкил итә.

*Әд.:* Кротов П.И. Вятский Увал // Землеведение. М., 1984. Кн. 3; Бутаков Г.П., Дедков А.П. Вятский Увал: основные черты геоморфологии и неотектоники // Геодинамика равнинного рельефа. К., 1992.

*А.П.Дедков.*

## ӨСТӘМӘЛӘР

**ВӘЛИӘХМӘ́ТОВ** Фән Гавис улы (18.1.1951, БАССРның Шаран р-ны Хафиз а.), җырчы, БАССРның атказ. (1989), ТРның халык (2007) артисты. 1974–79 елларда Уфа сәнгать уч-щесендә укый, Башкорт ун-тын тәмамлый (1993). 1979 дан Башкорт филармониясендә эшли. БАССРда татар башкаручыларының беренче концерт бригадасын оештыра. Татар халкының сирәк башкарыла торган җырларын яңа интерпретация б-н халыкка кайтаруга зур өлеш кертә («Урам көе», «Рамай», «Герман җыры» һ.б.). 1995 тә Татарстанга күчеп килә, төрле иҗат берләшмәләрендә, концерт бригадаларында җырчы һәм гармунчы буларак чыгышлар ясый. В. моңлы тавышка, үзенчәлекле башкару осталыгына ия. Аның репертуарын татар һәм башкорт композиторлары әсәрләре, халык җырлары тәшкил итә. «Казан–Уфа юллары» (Р.Миңнуллин шигыре), «Нәрсә ул бәхет?» (Р.Чурагулов шигыре) һ.б. җырлар авторы.



Ф.Г. Вәлиәхмәтов.

Хезм.: Яшәүләрем — җыр минем! К., 2006.

**ВӘЛИ́ЕВА** Илдария Хәйрулла кызы, (31.1.1950, хәзерге Менделеев р-ны Тукай а.), биохимик, биол. фән д-ры (2004). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1977). 1968–70 елларда Кайбыч туберкулёзга каршы көрәш диспансерында шәфкать туташы, 1970–74 тә Казан шәһәренең 6 нчы хастаханәсендә. 1974 тән Казан мед. ун-тында: госпиталь терапиясе кафедрасында (1977 гә кадәр), үзәк фәнни-тикшеренү лабораториясендә (1987 дән өлкән фәнни хезмәткәр). Хезмәтләре аз токсинлы фосфорорганик кушылмаларның субкүзәнәк һәм күзәнәк дәрәҗәсендә тәэсир итү механизмын ачыклауга карый. В. төрле патологик халәттә (остеопороз, ашказаны җәрәхәте, гепатит һ.б.) *димефосфон* препаратының антиоксидант тәэсирен ачыклый.

Хезм.: Лечебная эффективность димефосфона и ксидифона на экспериментальной модели «пульс-терапии» преднизолоном // Бюллетень экспериментальной биологии и медицины. М., 2003. № 7 (автордаш); К механизму действия отечественного препарата димефосфона // Казан. мед. журнал. 2005. Т. 86. № 2 (автордаш).

## ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ТӨП КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
абс. — абсолют
авг. — август
адм. — администрация, административ
адм.-терр. — административ-территориаль
акад. — академик, академия
акц. — акционерлык
апр. — апрель
арх. — архитектор
архит-ра — архитектура
атказ. — атказанган
атм. — атмосфера
а.м. — атом массасы
а.х. — авыл хуҗалыгы
әзәрб. — әзәрбайҗан
башк. — башкорт
балетм. — балетмейстер
биол. — биология
вет. — ветеринария
б.к. — баш килеш
г-та — газета
б.э. — безнең эра
б.э.к. — безнең эрага кадәр
гарәп. — гарәпчә (гарәп теленнән)
гв. — гвардия, гвардияче
ген. — генераль, генерал
геогр. — география
геол. — геология, геологик
геом. — геометрия, геометрик
гинекол. — гинекология
геоморфол. — геоморфология
гистол. — гистология
гыйн. — гыйнвар
грек. — грекча (грек теленнән)
губ. — губерна
дек. — декабрь
дис. — дисәтинә
д-р — доктор
ж-л — журнал
з-д — завод
зоол. — зоология
инстр-т — инструмент
илл. — иллюстрация
ин-т — институт
ингл. — инглизчә (инглиз теленнән)
исем. — исемендәге
ит. — итальянча (итальян теленнән)
к. — кара(гыз)
канд. — кандидат(ы)
к-та — кислота (исем янында)
К° — компания
кап. — капиталь (төзелеш)
каф. — кафедра
кв. — квадрат
к-з — колхоз
ком. — командир
ком-т — комитет
комис-т — комиссариат
комп. — композитор
комб-т — комбинат
конф. — конференция
коэф. — коэффициент
крист. — кристаллик
к/т — кинотеатр
күпл. — күплек (саны)
лаб. — лаборатория
лат. — латинча (латин теленнән)
лингв. — лингвистика
макс. — максималь
матем. — математика, математик
мәс. — мәсәлән
мед. — медицина
метеорол. — метеорология
минерал. — минералогия
миним. — минималь
мифол. — мифология
млн. — миллион
млрд. — миллиард
монгол. — монголча (монгол теленнән)
морфол. — морфология, морфологик
муз. — музыкаль
нем. — немецчә (немец теленнән)
неол. — неологизм
норм. — нормаль
нояб. — ноябрь
окт. — октябрь
Окт. рев-циясе — Октябрь революциясе (1917)
пасс. — пассажир
пед. — педагогика, педагогия, педагогик
пос.- посёлок
пр-тие — предприятие
проф. — профессор, профессиональ
псевд. — псевдоним
психол. — психология
публ. — публикация
райком — район комитеты
райсовет — район советы
ревком — революцион комитет
рев-ция — революция
реж. — режиссёр
рентгенол. — рентгенология
респ-ка — республика
р-н — район
сан.-эпид. — санитария-эпидемиология
сент. — сентябрь
с.-д. — социал-демократлар
симф. — симфоник, симфония
скульп. — скульптор
сов. — совет(лар)
с-з — совхоз
соц. — социалистик
социол. — социология, социологик
стат. — статистика, статистик
стомат. — стоматология
т. — том
темп-ра — температура
терр. — территориаль
терр-я — территория
технол. — технология, технологик
төрки. — төркичә (төрки телләрдән)
ун-т — университет
уч-ще — училище
фарм. — фармацевтика, фармацевтик
фармакол. — фармакология
фарсы. — фарсыча (фарсы теленнән)
фән. — фәннәр
февр. — февраль
физ. — физика, физик
физиол. — физиология, физиологик
филол. — филология
филос. — философия
ф-ка — фабрика
ф-л — филиал
ф-ла — формула
ф-т — факультет
фр. — французча (француз теленнән)
һ.б. — һәм башкалар
һ.б.ш. — һәм башка шундый
ш. — шәһәр
штп — шәһәр тибындагы посёлок
ш.и. — шул исәптән
ш.у. — шулай ук
ш.у.к. — шулай ук кара
экз. — экземпляр
эл. — электр; электро-...

## ШӘҺӘР ИСЕМНӘРЕНДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР
(библиографиядә)

### Татар/рус телләрендә

А.-А. — Алма-Ата
Аш. — Ашхабад
Г. — Горький
Дүш./Душ. — Дүшәнбе/Душанбе
Ер. — Ереван
К. — Казан/Казань
Киш. — Кишинёв
Л. — Ленинград
М. — Мәскәү/Москва
М.–Л. — Мәскәү–Ленинград/Москва–Ленинград
Н. Новгород — Нижний Новгород
Наб. Челны — Набережные Челны
Новосиб. — Новосибирск
Од. — Одесса
П. — Петроград (Петербург)
Ростов н/Д. — Ростов-на-Дону
СПб. — Санкт-Петербург
Тал. — Таллин
Таш. — Ташкент
Тб. — Тбилиси
Фр. — Фрунзе
Хар. — Харьков

### Чит ил телләрендә

Amst. — Amsterdam
Antw. — Antwerpen
B. — Berlin
Balt. — Baltimore
Bdpst. — Budapest
Brat. — Bratislava
Brux. — Bruxelles
Buc. — Bucuresti
Camb. — Cambridge
Chi. — Chicago
Cph. — Copenhagen, Copenhague
Fr./M. — Frankfurt am Main
Gen. — Geneve
Hamb. — Hamburg
Hdlb. — Heidelberg
Hels. — Helsingfors, Helsinki
Ist. — Istanbul
L. — London
Los Ang. — Los Angeles
Lpz. — Leipzig
Mass. — Massachusetts
Melb. — Melbourne
Mex. — Méxiсo
Mil. — Milano
Münch. — München
N.Y. — New York
Oxf. — Oxford
P. — Paris
Phil. — Philadelphia
Rio de J. — Rio de Janeiro
S.F. — San Francisco
Stockh. — Stockholm
Stuttg. — Stuttgart
W. — Wien
Warsz. — Warszawa
Wash. — Washington
Z. — Zürich

Башка шәһәрләрнең исемнәре кыскартылмыйча бирелә.

## БИБЛИОГРАФИЯДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР

әд. — әдәбият
әсәр. — әсәрләр(е)
библиогр. — библиография
бюл. — бюллетень
вестн. — вестник
дис. — диссертация
докл. — доклад(лар)
журн. — журнал
зап. — записки
кис. — кисәк
конгр. — конгресс
конф. — конференция
реф. — реферат
рец. — рецензия
тәрҗ. — тәрҗемәче
төз. — төзүче(се)
у. һәм е.к. — урыны һәм елы күрсәтелмәгән
хезм. — хезмәт(ләре)
чыг. — чыганак
экз. — экземпляр
энцикл. — энциклопедия

## АББРЕВИАТУРАЛАР

АЖ — акционерлык җәмгыяте
ААЖ — ачык акционерлык җәмгыяте
АКШ — Америка Кушма Штатлары
АТС — автоматлаштырылган телефон станциясе
БАССР — Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
БДБ — Берләшкән Дәүләтләр Берлеге
БҮБК — Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты
ВАСХНИЛ — Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе (Всесоюзная академия сельскохозяйственных наук имени Ленина)
ВДНХ — Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе (Выставка достижений народного хозяйства)
ВКП(б) — Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе (Всесоюзная коммунистическая партия (большевиков))
ВЛКСМ — Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзы (Всесоюзный ленинский коммунистический союз молодёжи)
ВНИВИ — Бөтенсоюз ветеринария фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский ветеринарный институт)
ВНИИгеолнеруд — Бөтенсоюз руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский институт геологии полезных ископаемых)
ВРК — Вакытлы революцион комитет (Временный революционный комитет)
ВЧК — Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (Всероссийская чрезвычайная комиссия)
ВЦСПС — Профсоюзларның бөтенсоюз үзәк советы (Всесоюзный центральный совет профессиональных союзов)
ГИДУВ — Табибләрнең белемен күтәрү дәүләт институты (Государственный институт для усовершенствования врачей)
ГЭС — гидроэлектростанция
ДОСААФ — Армия, авиация һәм флотка булышлык итү ирекле җәмгыяте (Добровольное общество содействия армии, авиации и флоту)
ЖБ — җитештерү берләшмәсе
ЖЧЖ — җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять
КамАЗ — Кама автомобиль заводы
КБ — конструкторлык бюросы
КГБ — Дәүләт иминлеге комитеты (Комитет государственной безопасности)
КГҮ — Казан гыйльми үзәге
КОМУЧ — Учредительләр җыены әгъзалары комитеты (Комитет членов учредительного собрания)
КОМЗ — Казан оптик механика заводы
КП — Коммунистлар партиясе
КПО ВС — Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе (Казанское производственное объединение вычислительных систем)
КПСС — Советлар Союзы коммунистлар партиясе (Коммунистическая партия Советского Союза)
КЭМСТ — Хәзерге заман театрының конструктив тәҗрибә остаханәсе (Конструктивно-экспериментальная мастерская современного театра)
МК — Министрлар Кабинеты
МС — Министрлар Советы
МТС — машина-трактор станциясе
НГДУ — нефть һәм газ чыгару идарәсе (нефтегазодобывающее управление)
НКВД — Эчке эшләр халык комиссариаты (Народный комиссариат внутренних дел)
нэп — яңа икътисади сәясәт (новая экономическая политика)
ОГПУ — Дәүләтнең берләштерелгән сәяси идарәсе (Объединенное государственное политическое управление)
ОСОАВИАХИМ — Авиация һәм химия төзелешенә булышлык итү җәмгыяте (Общество содействия авиационному и химическому строительству)
ПТУ — профессиональ-техник училище
ПФА — Педагогия фәннәре академиясе
РАХФА — Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе
РВС — Революцион хәрби совет (Революционный военный совет)
РМА — Россия мәгариф академиясе
РМФА — Россия медицина фәннәре академиясе
РОСТО — Россия оборона-спорт техник оешмасы (Российская оборонно-спортивная техническая организация)
РСДРП — Россия социал-демократик эшчеләр партиясе (Российская социал-демократическая рабочая партия)
РСФСР — Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы
РФ — Россия Федерациясе
РФА — Россия Фәннәр академиясе
СА — Сәнгать академиясе
СК — спорт клубы
СССР — Совет Социалистик Республикалар Союзы
ТАССР — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
ТМР — төш магнит резонансы
ТР — Татарстан Республикасы
ТССР — Татарстан Совет Социалистик Республикасы
ТЭЦ — электр энергиясе-җылылык җитештерү үзәге (теплоэлектроцентраль)
ФА — Фәннәр академиясе
ФҖБ — фәнни-җитештерү берләшмәсе
ХКС — Халык комиссарлары советы
ХХС — Халык хуҗалыгы советы
ЦНИИгеолнеруд — Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (Центральный научно-исследовательский институт геологии нерудных полезных ископаемых)
ЧК — Гадәттән тыш комиссия (Чрезвычайная комиссия)
ҮК — Үзәк Комитет
ҮБК — Үзәк Башкарма Комитеты
ЭПР — электрон парамагнит резонансы
ЮС — Югары Совет
ЯАЖ — ябык акционерлык җәмгыяте

## ЗУРЛЫК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ КЫСКАРТУЛАРЫ

*А* — ампер
*а.б.* — астрономик берәмлек
*а.к.* — ат көче
*В* — вольт
*Вб* — вебер
*В·А* — вольт-ампер
*Вт* — ватт
*Гн* — генри
*Гц* — герц
*Гпа* — гектопаскаль
*Гс* — гаусс
*г* — грамм
*га* — гектар
*град* — почмакча градус
*Дж* — джоуль
*дБ* — децибел
*дал* — декалитр
*дптр* — диоптрия
*К* — кельвин
*кВт·сәг.* — киловатт-сәгать
*кал* — калория
*кар* — карат
*кг* — килограмм
*кл* — кулон
*км* — километр
*л* — литр
*лк* — люкс
*лм* — люмен
*м.а.б.* — массаның атом берәмлеге
*м* — метр
*мг* — миллиграмм
*мин.* — минут
*мкм* — микрометр
*мм* — миллиметр
*н* — ньютон
*окт* — октава
*Па* — паскаль
*рад* — радиан
*°С* — Цельсий градусы
*с* — секунд
*сәг.* — сәгать
*см* — сантиметр
*т* — тонна
*Ф* — фарад
*Э* — эрстед
*эВ* — электронвольт
‰ — промилле

## КАРТАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

(җәя эчендә бит саны күрсәтелә)

Географик тематик карталар.
Татарстан Республикасының агроклиматик зоналары (47), Атмосферадагы явым-төшемнәр, парга әйләнү, җил (236).

Тарихи карталар.
Алабуга кантоны (112), Алабуга өязе (113), Арча кантоны (219), Әгерҗе кантоны (268), Әкрам авылы кузгалышы, 1842 ел (283), Әстерхан ханлыгы (312), Бөгелмә кантоны (464), Бөгелмә өязе (565), Бөек Болгар дәүләте (569), Буа кантоны (593), Буа өязе (594).

Районнарның административ карталары.
Азнакай районы (63), Аксубай районы (91), Актаныш районы (94), Алабуга районы (114), Алексеев районы (127), Апас районы (183), Арча районы (220), Әгерҗе районы (269), Әлки районы (287), Әлмәт районы (290), Әтнә районы (315), Балтач районы (379), Балык Бистәсе районы (381), Баулы районы (409), Биектау районы (476), Бөгелмә районы (566), Буа районы (594).

## КАРТАЛАРДА КАБУЛ ИТЕЛГӘН КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
исем. — исемендәге
пос. — посёлок
р-н. — район
с-з. — совхоз
ш. — шәһәр
штп. — шәһәр тибындагы посёлок

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАЙОННАРЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ КАРТАЛАРЫНДА

**Торак пунктлар**

Татарстан Республикасы башкаласы - Казан шәһәре
Район үзәкләре

Төре буенча

ӘГЕРҖЕ — Шәһәрләр
ЛАЕШ — Шәһәр тибындагы посёлоклар
*Чирмешән* — Авыл тибындагы торак пунктлар

Яшәүчеләр саны буенча

10 000 һәм аннан артыграк
1000 нән 10 000 гәчә
500 дән 1000 гәчә
500 дән кимрәк

**Чик билгеләре**

Республика һәм өлкәләр арасында
Районнар арасында

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
1Р 241 — Төп автомобиль юллары һәм аларның номерлары
Башка төр автомобиль юллары:
а) түшәүле юллар
б) түшәүсез юллар

Елгалар
Сусаклагычлар

### ТАССР КАНТОННАРЫ КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Татарстан АССР 1921 елда
Татарстан Республикасы 2008 елда
Татарстан АССР кантоннары 1921 елда

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

### ӨЯЗЛӘР КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Россия империясенең 1890 нчы еллардагы губерналары арасында
Өязләр

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

# Татар энциклопедиясенең фәнни мөхәрририяте

**Археология.** Ф.Ш.Хуҗин (рәис), А.Ә.Борһанов, Е.П.Казаков, А.Г.Ситдыйков.
**Архитектура.** С.С.Айдаров (рәис), Г.Н.Айдарова, Х.Г.Надыйрова, С.П.Саначин, Н.Х.Халитов.
**Астрономия.** Н.А.Сәхибуллин (рәис), Е.Е.Беляева, И.Ф.Бикмаев, Р.В.Заһретдинов, Н.Г.Ризванов.
**Биология.** А.А.Җәләлов (рәис), В.А.Бойко, В.И.Гаранин, Р.Я.Гыйльметдинов.
**География.** А.П.Дедков (рәис), А.Х.Газизуллин, В.И.Мозжерин, М.Р.Мостафин, Ю.П.Переведенцев, Ә.С.Тайсин.
**Геология.** Б.В.Буров (рәис), В.М.Винокуров, У.Г.Дистанов, Д.К.Нургалиев, В.М.Смелков.
**Дәүләт һәм хокук.** В.П.Малков (рәис), Н.В.Бахарев, Е.Б.Долгов, Б.Л.Железнов, Г.И.Курдюков, И.Г.Тарханов, Р.Ш.Хафизов.
**20 йөзгә кадәрге Татарстан һәм татар халкы тарихы.** М.Г.Госманов (рәис), С.Х.Алишев, И.А.Гыйләҗев, И.П.Ермолаев, И.Л.Измайлов, Д.Г.Мостафина.
**20-21 йөзләр Татарстан һәм татар халкы тарихы.** И.Р.Таһиров (рәис), Р.У.Әмирханов, Р.К.Вәлиев, Р.Р.Салихов, О.В.Синицын, Р.В.Шәйдуллин.
**20 йөзгә кадәрге татар әдәбияты.** Х.Й.Миңнегулов (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Р.К.Ганиева, Н.Ш.Хисамов.
**20 йөз татар әдәбияты.** Ф.М.Мусин (рәис), А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н.Галиуллин, Р.Н.Даутов, Д.Ф.Заһидуллина, З.З.Рәмиев, Р.М.Харисов.
**Икътисад.** Ф.Г.Газизуллин (рәис), С.Н.Абдуллина, В.П.Захаров, Ф.С.Зыятдинов, В.А.Мальгин.
**Массакүләм мәгълүмат чаралары.** В.З.Гарифуллин (рәис), Ф.И.Әгъзамов, Е.С.Дорощук, Р.М.Нуруллина, Р.А.Ратникова.
**Математика.** Р.Г.Бохараев (рәис), М.М.Арсланов, А.М.Елизаров, Д.Х.Мөштәри, Э.В.Скворцов, Б.Н.Шапуков.
**Медицина. Сәламәтлек саклау.** М.К.Михайлов (рәис), Н.Х.Әмиров, В.Ф.Богоявленский, Х.З.Гафаров, Я.Г.Павлухин, В.Х.Фазылов.
**Музейлар.** Г.Р.Нәҗипова (рәис), С.Ю.Измайлова, Е.И.Карташова, О.Е.Шелковская.
**Музыка.** Р.К.Абдуллин (рәис), В.Н.Горшков, В.Р.Дулат-Алиев, А.Л.Маклыгин, Ш.Х.Монасыйпов, З.Н.Сәйдәшева, В.М.Спиридонова.
**Педагогика, халык мәгарифе.** Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, С.М.Михайлова, Ф.Ә.Шәрифуллин.
**Рус әдәбияты.** А.М.Сәяпова (рәис), Л.С.Ачкасова, Р.Ә.Мостафин, В.И.Шишкин.
**Сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә.** Ш.М.Вәлитов (рәис), К.А.Нәҗипова, Р.С.Рәхимова, И.Ш.Рахманкулов, К.Ф.Фәсхетдинов.
**Сынлы сәнгать.** Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова (рәис), А.Ә.Абызгилдин, Е.П.Ключевская, Х.Г.Якупов.
**Театр сәнгате.** А.Г.Әхмәдуллин (рәис), М.Г.Арсланов, Ю.А.Благов, Д.Ә.Гыймранова, И.И.Илялова.
**Тел белеме.** М.З.Зәкиев (рәис), Л.К.Бәйрәмова, Ф.Ә.Ганиев, Д.Б.Рамазанова, А.Г.Яруллина.
**Терлекчелек. Ветеринария.** Н.Җ.Хаҗипов (рәис), Р.Г.Госманов, Р.Х.Йосыпов, М.Ш.Шәкүров.
**Техника.** Ш.М.Чабдаров (рәис), Р.И.Әдһәмов, М.Р.Вяселев, Г.Ю.Даутов, И.М.Закиров, Р.Р.Җиһаншин, С.О.Мирумянц, Б.А.Тимеркәев.
**Торак пунктлар тарихы.** М.И.Әхмәтҗанов (рәис), Р.Ф.Галләмов, Е.В.Липаков, Д.Г.Мостафина, Р.Р.Хәйретдинов.
**Үсемлекчелек.** Г.Г.Җиһаншин (рәис), И.А.Гайсин, Е.И.Захарова, Ф.З.Кадыйрова, М.Л.Пономарёва, Ә.С.Салихов.
**Фәлсәфә һәм дин.** Р.М.Мөхәммәтшин (рәис), Н.М.Мөхәррәмов, Ф.М.Солтанов, М.Д.Щелкунов.
**Физик культура һәм спорт.** И.Г.Илдарханов (рәис), Р.А.Абзалов, А.Ш.Баһаветдинов, Н.Д.Бобырев, З.Н.Пантелеева, Д.Р.Шәрәфетдинов.
**Физика.** К.М.Салихов (рәис), А.В.Аганов, Л.К.Әминов, В.А.Голенищев-Кутузов, А.В.Ильясов, И.В.Овчинников, В.В.Самарцев, Р.Г.Усманов.
**Фольклор.** Ф.И.Урманчеев (рәис), Ф.В.Әхмәтова, Л.Ш.Җамалетдинов, Х.Ш.Мәхмүтов, И.Н.Надыйров.
**Хәрби эшлекләр, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары.** А.А.Иванов (рәис), Н.Х.Булатов, И.И.Мостюков, В.Ф.Телишев.
**Химия һәм химия технологиясе.** В.П.Барабанов (рәис), Г.К.Будников, А.О.Визель, В.И.Галкин, Ф.П.Мадякин.
**Этнография.** Д.М.Исхаков (рәис), Р.Н.Мусина, Р.К.Уразманова.

## Татар энциклопедиясе институты

Директоры – филол. фән. д-ры, ТР ФАнең хакыйкый әгъзасы М.Х.ХӘСӘНОВ
Директор урынбасары – тарих фән. канд-ты Г.С.САБИРҖАНОВ
Гыйльми секретарь – пед. фән. канд-ты Н.Д.БОБЫРЕВ

### Бүлекләр

**Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү бүлеге**. Мөдире – филол. фән. канд. А.Г.Яруллина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: В.А.Габдрахманова, Л.К.Галиева, Р.Г.Зәкиева, В.К.Зыятдинов, И.Г.Нигъмәтҗанов, М.Х.Харисов, Ә.М.Хисамова; әдәби мөхәррирләр төркеме: җитәкчесе Ф.Ә.Шәрифуллин (2006 елга кадәр С.С.Шәмсетдинов); мөхәррирләр: Р.С.Вафина, Ф.Г.Камалетдинова, Г.Х.Нургалиева, И.Х.Хәлиуллин, Л.Х.Хәмидуллин; корректор Ф.Г.Макарова.

**Биология, география һәм геология бүлеге**. Мөдире – а.х. фән. канд. Ф.Г.Борһанов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: биол. фән. канд-тлары В.Г.Бакирова, С.И.Кадошников, геол.-минерал. фән. канд. Э.Х.Рәхмәтуллин, Л.Р.Камалиева; фәнни хезмәткәрләр: О.В.Ерёгин, Р.Э.Рәхмәтуллин.

**Икътисад һәм халык хуҗалыгы тарихы бүлеге**. Мөдире – Г.Я.Мәүлетова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: икътисад фән. д-ры Ф.С.Зыятдинов, а.х. фән. д-ры Ә.Х.Фазылҗанов, икътисад фән. канд. М.Җ.Гаитов, И.Н.Афанасьев; фәнни хезмәткәрләр: С.Г.Белов, Л.Д.Полякова.

**Иллюстрацияләр һәм картография бүлеге**. Мөдире – Ф.Ә.Ибраһимова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: геогр. фән. канд. Г.Н.Булатова, Г.Р.Дәүләтьянова, Р.Г.Нурмөхәммәтов; фотограф Р.Н.Шакиров.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм мәдәният учреждениеләре бүлеге**. Мөдире – тарих фән. канд. Р.А.Айнетдинов; өлкән фәнни хезмәткәр – филол. фән. канд. А.Ә.Хәсәвнех.

**Медицина, сәламәтлек саклау һәм спорт бүлеге**. Мөдире – биол. фән. канд. Р.Г.Исхакова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: пед. фән. канд. Н.Д.Бобырев, Л.Ф.Ильина, Ф.Ф.Нуриева.

**Рус телендәге текстларны редакцияләү бүлеге**. Мөдире – пед. фән. канд. И.И.Барабанова; редакторлар: Р.Х.Нуриев, С.А.Ярмөхәммәтова; корректорлар: Ф.Ш.Әхмәтҗанова, В.П.Лащёнова.

**Табигать һәм техник фәннәр бүлеге**. Мөдире – биол. фән. канд. Г.Г.Осокина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: физ.-матем. фән. д-ры Р.Г.Усманов, В.Г.Абзалова, фәнни хезмәткәр Л.Р.Хәлилова.

**Тарих һәм иҗтимагый фикер бүлеге**. Мөдире – тарих фән. д-ры Р.В.Шәйдуллин; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. д-ры Е.П.Казаков, тарих фән. канд-тлары: Л.М.Айнетдинова, Е.Б.Долгов, И.Р.Вәлиуллин, Ф.Г.Кәлимуллина, М.З.Хәбибуллин; фәнни хезмәткәр А.В.Климин.

**Тел белеме һәм әдәбият бүлеге**. Мөдире – филол. фән. канд. Р.Р.Мусабәкова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: филол. фән. д-рлары Ф.И.Урманчеев, В.Х.Хаков; филол. фән. канд. А.М.Ахунов, Л.Р.Аскарова, Г.М.Габделхакова; фәнни хезмәткәр Л.Т.Нигъмәтҗанова.

**Торак пунктлар тарихы бүлеге**. Мөдире – тарих фән. канд. А.И.Ногманов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Р.Р.Ибраһимов, Х.Ә.Абдулкаюмов; фәнни хезмәткәрләр: Д.М.Васильев, С.А.Фәйзуллин.

**Фән, мәгариф һәм мәдәният бүлеге**. Мөдире – тарих фән. канд. Е.П.Липаков (2007 елга кадәр сәнгать фән. канд. Е.П.Ключевская); өлкән фәнни хезмәткәрләр: сәнгать фән. д-ры Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, архит. фән. канд. Х.Г.Надыйрова, сәнгать фән. д-ры Ф.Ш.Салитова, Ю.А.Благов, И.А.Новицкая, фәнни хезмәткәр Ф.Ә.Әхмәтшина.

**Фәнни мәгълүмат хезмәте һәм библиография бүлеге**. Мөдире – Р.Ф.Шәрәпова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: Г.Р.Садриева, Э.Г.Сәйфетдинова; әйдәп баручы библиограф Р.М.Вовченко; программист Н.Ф.Мироновская; архив хезмәткәре Л.М.Сәхапова.

**Фәнни методика һәм контроль бүлеге**. Мөдире – биол. фән. канд. И.Г.Кадошникова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: А.В.Гарзавина, Р.И.Гурьянова, Т.П.Жучкова, И.В.Патина.

**Фәнни нәшрият бүлеге**. Мөдире – техн. фән. канд. Р.Р.Сәләхиев, программист Г.Х.Галимуллина; компьютерда җыючылар: Л.С.Касыймова, Г.Н.Харисова, Л.Р.Хисамиева.

* * *

**Бухгалтерия**. Баш бухгалтер – Н.Г.Локманова, бухгалтер-экономист Ә.Н.Вәлиева.

**Канцелярия мөдире** Г.Р.Вәлиуллина.

**Кадрлар буенча белгеч** Ә.Р.Мөхәммәтҗанова.

**Маркетинг һәм хуҗалык эшләре бүлеге**. Мөдире – Э.А.Гобәев; хуҗалык бүлеге башлыгы Е.Н.Алькова, күчермәләр бүлеге хезмәткәре З.Н.Таҗиева, машина йөртүче Р.В.Әминов.

# ТЭ 1нче томының авторлар исемлеге

Р.А.Абдрахманов, С.Н.Абдуллина, В.Г.Абзалова, Ф.М.Абилов, Ш.Ш.Абилов, О.Н.Авксентьева, С.С.Айдаров, Г.Н.Айдарова, Р.А.Айнетдинов, Л.М.Айнетдинова, Р.С.Алатырева, Е.П.Алексеева, А.М.Алимов, С.Х.Алишев, Т.А.Алмазова, В.Ю.Альбицкий, М.Д.Анисимова, О.В.Андреева, М.М.Арсланов, А.В.Артамонов, И.Н.Афанасьев, А.М.Ахунов, Л.С.Ачкасова, В.Р.Әминова, Р.К.Әмиров, Р.Г.Әмирханов, Р.Х.Әмирханов, Л.Р.Әскәрова, А.Г.Әхмәдуллин, Ү.Ш.Әхмәров, М.Г.Әхмәтҗанов, М.И.Әхмәтҗанов, Н.Ш.Әхмәтҗанова, Э.И.Әхмәтҗанова, Н.Г.Әхмәтов, Р.Ә.Әхмәтов, Р.К.Әхмәтова, А.С.Әюпов, Э.З.Бадамшин, В.А.Бажанов, Р.М.Бакаев, Ю.А.Бакиров, В.Г.Бакирова, О.И.Балахович, Е.А.Баранова, А.А.Барсков, Д.А.Барсков, Ю.В.Баталин, Р.М.Батулла, Л.К.Бәйрәмова, Д.К.Бәширова, С.Г.Белов, О.И.Белькович, Е.Е.Беляева, Р.Х.Бикбулатов, И.Ф.Бикмаев, А.Н.Бикташева, Ю.А.Благов, Н.Д.Бобырев, В.А.Бойко, Н.Р.Болгар, М.Г.Борисович, А.Ә.Борһанов, Ф.Г.Борһанов, Р.А.Борһанова, Р.Г.Бохараев, Э.А.Браун, Г.К.Будников, Г.Н.Булатова, Б.В.Буров, Л.Е.Бушканец, Г.А.Вайсов, М.А.Вайсов, А.А.Вакатов, Л.Н.Вальникова, Ш.М.Вахитов, Р.К.Вәлиев, Р.М.Вәлиев, Ф.Т.Вәлиев, Э.Н.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Ш.М.Вәлитов, И.Р.Вәлиуллин, С.И.Вәлиуллина, Э.С.Вәлишин, А.А.Вениаминов, Р.Г.Вениаминов, М.А.Верещагин, Л.В.Веткасова, В.М.Викторин, А.К.Вишняков, В.Н.Войцехович, Л.Я.Воронова, В.Г.Востриков, Р.С.Габәшев, Г.Р.Габделганиева, Х.Ә.Габделкаюмов, Г.С.Габделмәҗитова, Г.М.Габделхакова, А.А.Габдрахманов, И.Р.Габдуллин, Я.Т.Газизов, М.Җ.Гаитов, Н.М.Гайдукова, М.В.Гайнетдинов, Н.Г.Гайнетдинов, И.А.Гайсин, Н.Э.Галиев, Ф.Г.Галимуллин, М.Ш.Галимәрдәнов, Т.Н.Галиуллин, Ә.Г.Галләмова, А.А.Гамзов, В.Г.Ганиев, В.Х.Ганиев, Ф.Ә.Ганиев, Р.К.Ганиева, В.И.Гаранин, И.И.Гаранина, А.В.Гарзавина, Х.Х.Гатина, М.М.Гафаров, Ф.М.Гәрәев, Н.Г.Гәрәева, В.А.Голенищев-Кутузов, Т.В.Голубцова, А.И.Голубев, С.Г.Гордиенко, В.Н.Горшков, П.К.Горшков, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, Д.М.Госманова, Н.Д.Григорьев, Я.Я.Гришин, Ф.Ф.Гулова, В.И.Гуськов, Е.А.Гуськов, М.З.Гыйбадуллин, И.Г.Гыйзәтуллин, Н.Г.Гыйзәтуллин, З.А.Гыйззәтуллина, И.А.Гыйләҗев, Т.Ш.Гыйләҗев, О.Н.Гыйлметдинова, М.М.Гыймадиев, Д.Ә.Гыймранова, Р.Н.Даутов, Г.М.Дәүләтшин, Ф.И.Дәүликамова, А.П.Дедков, В.Л.Дёмин, Т.А.Денисенко, Е.Б.Долгов, И.В.Дьячков, Г.Г.Емельянова, О.В.Ерёгин, Н.М.Ершова, Г.Н.Ефимова, Е.А.Ефремов, А.К.Жеребцов, Т.П.Жучкова, Л.Ш.Җамалетдинов, Ф.Ф.Җамалиева, А.А.Җәләлов, А.М.Җәләлов, Г.Г.Җиһаншин, И.В.Завьялова, З.Г.Закиров, Р.А.Закиров, Т.Р.Закирова, Г.Р.Заманова, И.Н.Зарипов, И.К.Заһидуллин, Д.Ф.Заһидуллина, Н.В.Звёздочкина, Н.В.Зорин, С.О.Зорина, Д.М.Зөбәеров, Ф.С.Зыятдинов, М.Х.Ибраһимов, Р.Р.Ибраһимов, Ф.И.Ибраһимов, Ф.И.Ибраһимова, Р.М.Игъламов, И.Л.Измайлов, М.Е.Ильина, И.И.Илялова, С.И.Ионенко, Р.Ф.Исламов, Р.Р.Исмәгыйлев, Д.М.Исхаков, Р.Г.Исхакова, Р.Р.Исхакова, Р.Х.Йосыпов, Ә.Ф.Йосыпова, Г.И.Йосыпова, Н.М.Йосыпова, С.И.Кадошников, Е.П.Казаков, Л.Р.Камалиева, Б.А.Канеев, Н.П.Капитонова, Н.А.Карташева, Н.З.Капкаева, Р.А.Кашапов, А.Р.Каюмов, Ф.Г.Кәлимуллина, Ф.Г.Кәримова, Ә.Г.Кәримуллин, В.Д.Киселёв, А.В.Климин, Е.П.Ключевская, Л.А.Козлов, Т.А.Кондратьева, Б.Л.Кузнецов, В.Т.Куклин, К.Н.Куликов, Х.Л.Кумысников, К.Н.Куранов, Х.Р.Курбатов, И.Б.Лещинская, Е.В.Липаков, А.Л.Литвин, С.А.Лучкина, О.Д.Любарская, Е.Л.Любарский, А.А.Маликов, Н.А.Мамакова, В.Н.Марков, Т.В.Мартынова, В.В.Мастриков, В.Р.Матросова, Л.И.Машонкина, З.М.Мәҗитов, М.М.Мәүләтшин, Г.Я.Мәүлетова, Х.Ш.Мәхмүтов, Һ.К.Мәхмүтов, А.Х.Мәхмүтова, М.С.Мәһдиев, Н.В.Мезина, Д.М.Менделевич, Г.А.Милашевский, И.З.Миңһаҗева, Н.М.Миңһаҗева, К.С.Миңлебаев, Х.Й.Миңнегулов, Ж.С.Миңнуллин, С.М.Михайлова, Г.А.Могильникова, В.И.Мозжерин, Ш.Х.Монасыйпов, С.М.Морозкина, В.И.Морозов, Л.М.Мортазина, М.Р.Мостафин, Р.Ә.Мостафин, Д.Г.Мостафина, Л.В.Мошкова, И.Х.Мөдәррисов, Р.Х.Мөслимов, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Н.Н.Мөхәммәтгалиев, Ф.Н.Мөхәммәтгалиев, Н.Р.Мөхәммәтҗанова, Р.М.Мөхәммәтшин, Р.Р.Мусабәкова, Ф.М.Мусин, В.А.Нагорская, И.Н.Надыйров, Х.Г.Надыйрова, А.Т.Насыйров, Т.М.Насыйров, В.А.Наумов, Э.П.Наумов, Р.Э.Нәбиев, К.А.Нәҗипова, Р.И.Нәфыйгов, И.М.Нестеренко, А.З.Нигамаев, Э.Г.Нигъмәтуллин, И.Н.Никитин, А.Е.Никифоров, Г.А.Николаев, К.В.Николаев, Л.А.Никольская, К.Ноак, И.А.Новицкая, А.И.Новицкий, А.И.Ногманов, Г.Г.Ногманова, Д.Р.Нуретдинова, Г.Г.Нуриев, Р.М.Нуруллина, В.Н.Овечкин, Я.Г.Павлухин, Т.В.Пашагина, Ю.П.Переведенцев, С.Г.Персова, Н.Г.Петров, Р.С.Петрова, С.В.Писарева, Л.Д.Полякова, С.Н.Пономарёв, М.Л.Пономарёва, Н.Б.Прохоренко, Т.Г.Прохорова, А.П.Пухачёв, А.З.Равилов, Д.Б.Рамазанова, А.Р.Рахмани, С.И.Рәимова, З.З.Рәмиев, Р.Э.Рәхмәтуллин, Э.Х.Рәхмәтуллин, Н.Г.Ризванов, Г.С.Сабирҗанов, Р.М.Сабиров, А.А.Сабитов, Б.Г.Садыйков, Ф.Ш.Салитова, Р.Р.Салихов, Ф.В.Салихова, К.М.Салмаков, А.А.Сальникова, Е.А.Сапаев, Г.Ф.Саттаров, С.Г.Сафуанов, М.Ә.Сәгыйтов, З.Н.Сәйдәшева, Х.Х.Сәлимов, Л.М.Свердлова, Р.Х.Сверигин, И.Б.Сидорова, М.М.Сидорова, Т.К.Сиражетдинов, А.П.Ситников, А.Э.Скворцов, А.В.Скоробогатов, Р.Р.Солтанова, В.Г.Софронов, В.М.Спиридонова, В.П.Станьял, П.Н.Старостин, Е.А.Стахов, А.Ф.Степанов, И.А.Студенцова, А.И.Сурская, Ш.Л.Таипов, Н.И.Таиров, А.С.Тайбинский, Ә.С.Тайсин, Р.Һ.Такташ, И.Р.Таһиров, М.С.Таһиров, В.Ф.Телишев, Е.С.Тимофеева, Н.М.Ткачев, А.Х.Төхфәтуллин, А.Я.Третьякова, Р.Х.Тукшаитов, К.П.Тулузакова, Л.А.Ульянова, Ф.Я.Уразаев, О.Н.Урбанова, Ф.И.Урманчеев, Р.Г.Усеинова, Р.Г.Усманов, Б.В.Успенский, Ә.Х.Фазылҗанов, В.Х.Фазылов, Г.Р.Фәйзрахманова, Р.И.Фәйзуллин, Р.С.Фәссахов, К.Ф.Фәсхетдинов, Р.А.Фәттахов, В.Д.Федотов, Н.Л.Фомичёва, С.А.Фролов, Н.Ж.Хаҗиева, Н.Ж.Хаҗипов, В.Х.Хаков, Н.А.Халиков, Н.Х.Халитов, Р.Ф.Халитов, Н.Г.Ханзафаров, К.Т.Харисов, Н.Г.Харисов, Ф.И.Харисова, А.Ю.Хәбетдинов, Г.Х.Хәбибрахманов, М.З.Хәбибуллин, Ш.Т.Хәбибуллин, Ф.Ә.Хәбиров, Р.А.Хәертдинов, Р.А.Хәйдәров, А.Г.Хәйретдинов, Р.А.Хәйретдинов, Р.Г.Хәйретдинов, Р.Р.Хәйретдинов, З.Ш.Хәйруллина, Ж.Ф.Хәкимова, А.Н.Хәлим, И.Х.Хәлиуллин, Л.Ю.Хәлиуллина, Л.Х.Хәмидуллин, Р.Х.Хәмидуллин, Ф.Т.Хәмитова, Г.Г.Хәсәнова, А.Х.Хәсәншина, Н.Ш.Хисамов, А.А.Хлебников, Л.П.Хохлова, В.М.Хөсәенов, Ф.Ш.Хуҗин, Р.А.Циунчук, В.Г.Чайкин, Т.Г.Чекменёва, Ю.К.Чумаков, В.А.Шагалов, О.Л.Шайтанов, Р.Г.Шаһиева, Р.В.Шәйдуллин, Г.Г.Шәйдуллина-Хәсәнова, З.Р.Шәйхелисламов, Р.Г.Шәмсетдинова, Д.Р.Шәрәфетдинов, Ә.М.Шәрипов, С.М.Шәфигуллина, О.Е.Шелковская, А.И.Шипилов, А.В.Шишкин, В.И.Шишкин, Н.В.Шулаев, Г.И.Щербаков, Р.Ф.Ягъфәров, В.А.Яковлев, В.Я.Яковлев, А.Х.Яруллин.

Тышлыкның макеты, «Биология», «Үсемлекчелек» бүлекләрендәге төсле иллюстрацияләр һәм таблицалар рәссам В.Е.Булатов тарафыннан эшләнде.
Махсус фотолар З.Г.Бәширов, О.В.Ерёгин, И.М.Йосыпов, Р.Н.Шакировлар тарафыннан әзерләнде.
Томда шулай ук Г.П.Бутаков, А.И.Галиев, М.Г.Гафуров, А.Г.Гаянов, В.А.Голенищев-Кутузов, Ф.С.Гобәев, Ш.Ф.Дәүләтшин, Д.Р.Йосыпов, Е.Ю.Логвинцев, В.Г.Марфин, М.М.Медведев, В.Ю.Соломахин, А.Л.Яскович, И.В.Яценколарның архивларыннан һәм М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры музее (Р.И.Такташ) фондларыннан алынган фотография һәм слайдлар файдаланылды.
Иске Казан фотографияләре — Г.В.Фролов коллекциясеннән.
Сәнгать бизәлеше консультантлары: Г.Е.Трифонов, Р.Г.Шәмсетдинов.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты бу томны әзерләүдә зур ярдәм күрсәткәннәре өчен ТР ФА Президиумы аппаратына, ТР буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәт территориаль оешмасына, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә, ТРның икътисад, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек, мәгариф һәм фән, мәдәният, сәламәтлек саклау министрлыкларына; Казан дәүләт университеты, Казан дәүләт консерваториясе, Казан дәүләт медицина академиясе, Казан медицина университеты, Казан техника университеты, Казан дәүләт технология университеты, Казан дәүләт аграр университеты; ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Тарих институты, Табигыять системалары экологиясе институты, «Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты» (ТатНИИСХ) галимнәренә һәм белгечләренә, ТР муниципаль берәмлекләре хакимиятләре аппаратларының җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә зур рәхмәтен белдерә.

Төрле вакытта Татар энциклопедиясенең 1 нче томын әзерләүдә катнашучылар: Ф.Т.Арсланова, Ф.З.Вәлиев, Ф.Г.Гайнанова, Р.Ф.Галләмов, Ф.Г.Гарипова, Д.Ә.Гыймранова, Р.Н.Даутов, М.Н.Исламова, А.Х.Мәхмүтова, К.С.Миңлебаев, Г.С.Нуретдинова, Р.Х.Фәйзрахманова, Р.Ф.Халитов, А.И.Хәбибуллина, Р.Ә.Шакирҗанов, М.З.Яруллин.

Текстларны компьютерда җыю һәм макетка салуда «Jahat Lab., KAI» лабораториясенең (җитәкчесе Р.Р.Имамов) Jahat™ программалар пакеты кулланылды.

**Татар энциклопедиясе:** 6 томда / Баш мөхәррир М.Х.Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов. — Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2008. — **1 т.**: А–В. — 720 бит, илл., карталар.
ISBN 978-5-902375-04-5

Татар энциклопедиясе — татар халкы һәм Татарстанның борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын һәм яшәешен яктырткан татар телендәге беренче фәнни универсаль басма. Китапта 3860 мәкалә (1620 се биографик), 1200 иллюстрация (655 е төсле) урын алды.

**Tatar ensiklopediəse:** 6 tomda / Baş məxərrir M.X.Xəsənov, cavaplı məxərrir Ğ.S.Sabircanov. — Qazan: TR FAneꞑ Tatar ensiklopediəse institutı, 2008. — **1 т.**: A–B. — 720 b., ill., kartalar.
Tatar ensiklopediəse — tatar xalqı həm Tatarstannıꞑ borıngı zamannardan alıp bezneꞑ kənnərgə qadərge tarixın həm yəşəyeşen yaqtırtqan tatar telendəge berençe universal’ basma. Tomda 3860 məqalə (1620 se şəxeslərgə qarıy), 1200 illustratsiə (655 e təsle).

**Татар энциклопедиясе**

1 нче том

Китапны компьютерда җыю һәм макетка салу Татар энциклопедиясе институтының фәнни нәшрият бүлегендә башкарылды.

Басарга кул куелды 15.5.2008. Махсус кагазьдә. Форматы 84×108/16.
«Петербург» гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды.
Шартлы басма табагы 75,6. Нәшер-хисап табагы 129,9.
Заказ Т-440.

«ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе.
420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 56.
e-mail: info-ite@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфик нәшрият комплексы.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.